ТАТАР
ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ



ТАТАР ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ

БАШ МӨХӘРРИР М.Х.СӘЛАХОВ

6

Тә–Ч

КАЗАН
ТАТАР ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕ ҺӘМ ТӨБӘКНЕ ӨЙРӘНҮ ИНСТИТУТЫ
2019

УДК 94(470.41):031
ББК 63.3(2Рос=Тат)2-64 я2
Т 23

ҖАВАПЛЫ МӨХӘРРИР
Г.С.САБИРҖАНОВ

Баш гыйльми мөхәрририят

М.Х.Сәлахов (рәис), И.А.Гыйләҗев (рәис урынбасары), Р.К.Абдуллин, А.Г.Әхмәдуллин, Н.М.Вәлиев, Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова, В.З.Гарифуллин, М.Г.Госманов, Р.Г.Госманов, М.З.Зәкиев, Г.Г.Җиһаншин, А.А.Җәләлов, Д.М.Исхаков, Е.П.Казаков, В.П.Кандилов, А.Н.Латышев, Х.Й.Миңнегулов, М.К.Михайлов, К.М.Салихов, М.М.Сәфәров, Н.А.Сәхибуллин, И.Р.Таһиров, Ж.И.Фәйзрахманов, Р.М.Харисов, Р.С.Хәкимов.

© ТР ФАнең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты, 2019.
РФнең «Авторлык хокукы һәм эргәдәш хокуклар турында» Законы нигезендә саклана.
Китап материалларын ТР ФАнең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтының язма рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.

ISBN 978-5-902375-31-9

Т

ТӘБӘРДӘ́ ШӘҺӘРЛЕГӘ́, к. *Чаллы шәһәрлеге*.

ТӘБЕРДӘ́ ЧАЛЛЫСЫ́ авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 44 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Кече Шомбыт елгасы буенда. 2010 елда 589 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1680 нән Чаллы елгасы буендагы Пүчинкә исеме б-н билгеле. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Тәберде буларак та мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәдрәсә, су тегермәне, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1077,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Шомбыт волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августын нан — Балык Бистәсе, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Мамадыш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 121 ир-ат; 1859 да — 628, 1897 дә — 1023, 1908 дә — 1223, 1920 дә — 1249, 1926 да — 1038, 1938 дә — 1077, 1949 да — 1013, 1958 дә — 909, 1970 тә — 884, 1989 да — 599, 2002 дә — 580 кеше. Т.Ч. янында *Чаллы шәһәрлеге* урыны саклана.

ТӘБӘРЛӘ́ авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 44 *км* көньяк-көнбатыштарак, Чаж елгасы буенда. 2010 елда 262 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 16 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Ишкильдино, Шеколдино исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау, сумала кайнату, чыпта-кап сугу, сәүдә б-н шөгыльләнә. 1773 тә Т. аша — П.С.Паллас җитәкчелегендәге акад. экспедиция, 1774 тә Е.И.Пугачёв отрядлары уза. 19 йөзнең 2 нче яртысында авыл янында поташ з-ды эшли. 20 йөз башында 2 мәчет, мәктәп, тегермән була; 1910 да рус-татар земство мәктәбе ачыла. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1694,2 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Зур Кибә волостенда, 1921 дән ТАССРның — Әгерҗе, 1924 тән Алабуга кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1744 тә — 59 ир-ат; 1859 да — 324, 1887 дә — 560, 1905 тә — 682, 1914 тә — 898, 1920 дә — 883, 1926 да — 869, 1938 дә — 1056, 1958 дә — 544, 1970 тә — 498, 1989 да — 357, 2002 дә — 282 кеше.

Әд.: Мәрданов Р.Ф., Һадиев И.Г. Әгерҗе төбәге тарихы. К., 2003.

ТӘВАРИ́Х (гарәп. تواريخ — тарих), урта гасырлардагы тарихи әдәбият жанры. *Ягъкуб бине Ногман, Ялчыгол, Шәрәфетдин бине Хисаметдин* әл-Мөслими әл-Болгари һ.б.ның Идел буе Болгар дәүләте турындагы тарихи хикәя җыентыкларында, *Рәшидетдин, Кадыйргали бәк* һ.б. кулъязмаларында урын алган. Алар татар халкы тарихы һәм мәдәния - те буенча мәгълүмат чыганагы булып торалар. Ул җыентыкларда геогр., астрономия, фәлсәфә, дин гыйлеме буенча мәгълүматлар бар. Татар әдбиятында Т. төзү традициясе 20 йөз башына кадәр дәвам итә (Х.Әмирханның «Тәварихы Болгарийә» б-н «Нөҗүм әт-тәварих»ы, К.Халидинең «Тәварихы хәмсәи шәркыйә»се һ.б.).

«ТӘВАРИХЫ́ БОЛГАРИЙӘ́» («Болгар иле тарихы»), тарихи әдәбият әсәре. 18 йөз ахырында — 19 йөз башында иҗат ителгән дип фаразлана. Кулъязмаларда киң таралган була (50 дән артык нөсхәсе билгеле). Казанда берничә тапкыр басыла (1870, 1887, 1907 һ.б.). Авторы булып *Шәрәфетдин бине Хисаметдин* әл-Мөслими әл-Болгари исәпләнә. Текст 1551–84 елларда Ташбилге авылында (Болгар шәһәре тирәсендә) язылган дип күрсәтелә. Әсәр кереш өлештән, 2 кисәктән (мәкаләләрдән) һәм йомгак өлешеннән (хатимә) тора. Беренче кисәгендә — «Гажәп нәрсәләр барлыкка килү» — атнадагы көннәр (теге яки бу пәйгамбәр атнаның кайсы көнендә туган яки үлгән, бу көнне нәрсә эшләргә ярый һәм нәрсә эшләргә ярамый һ.б.), айлар (һәр айның теге яки бу числосында булган вакыйгалар һ.б.), дөньядагы, күк йөзенең теге яки бу өлешендәге, диңгезләрдәге, елгалардагы һ.б. сәер хәлләр турында сөйләнә; икенче кисәге «Болгарда яшәгән һәм пәйгамбәрнең эшен дәвам итүчеләр (Мөхәммәднең көрәштәшләре) турында» дип атала. Йомгак өлешендә Урта Азия идарәчесе Аксак Тимернең сугыш хәрәкәтләре һәм аның Болгар шәһәрен «җимерүе» турында бәян ителә. «Т.Б.»дә каршылыклы фактлар һәм анахронизмнар бар, шунлыктан әлеге әсәрне 16 йөз ядкәрләре исәбенә кертү мөмкин түгел. Авторның исеме һәм әсәрнең язылу вакыты төрле эпитафия истәлекләреннән алынган (археограф С.Г.Вахиди мәгълүматлары буенча, 19 йөз уртасында охшаш мәгълүматлар тәркәлгән кабер ташы була). Анда тулысынча чынлыкка туры килгән материаллар (кайбер риваятьләр, шәҗәрә мәгълүматлары, тапонимнар) бар. Тикшерүчеләр арасында «Т.Б.»гә карата төрле караш формалаша: кайберәүләр ул 16 йөздә язылган дип исәпли (К.Фукс, В.В.Вельяминов-Зернов, П.А.Пономарёв, Х.Х.Хисмәтуллин һ.б.), башкалар (Ш.Мәржани, Р.Фәхретдин һ.б.) аның тарихилыгын кире кага. «Т.Б.» тексты урта гасырларның соңгы чорында татарларның тарихи фикер үсеше үзенчәлекләрен өйрәнүче галимнәрдә кызыксыну уята.

Әд.: Усманов М.А. Татарские исторические источники XVII–XVIII вв. К., 1972.

ТӘВӘ́ КАУРЫЙ́ (Matteuccia), оноклиячәләр семьялыгыннан күпьеллык абагалар ыругы. 3 төре билгеле, Төньяк ярымшарның уртача поясында таралган. Россиядә бер төре — гади Т.к. (M. struthiopteris) бар. Татарстан терр-ясендә ара-тирә барлык районнарда очрый. Дымлы күләгәле урманнарда, урман елгалары һәм инешләре буенда үсә. Тамырчасы калын, кыска, яфрак сабының калдыклары бар. Яфраклары бик күп, бәйләмгә җыйналган, бер- яки икешәр каурыйсыман, формасы тәвә кошы каурыен хәтерләтә. Споралы яфраклары коңгырт төстә, каурыйсыман; споралы соруслар сеңерчә очында урнашканнар. Июль–сентябрьдә споларын коя. Вегетатив юл б-н һәм споралар ярдәмендә үрчи. Декоратив үсемлек.

«ТӘГАРИФӘ́ МӨСЛИМИ́Н» («Мөселман белән танышу»), атналык әдәби журнал. 1910 елда Истанбулда (Төркия) төрек телендә нәшер ителә. Мөхәррирләре — Р.*Ибраһимов*, Ә.Тәҗетдинов. Россия империясенең хөкүмәт сәясәтенә багышланган тәнкыйди юнәлештәге (исламны кысыклауда, мөселманнарны җәберләүдә, Россия мөселманнарының белемен үстерүгә каршылык тудыруда гаепләнгән) мәкаләләр басыла.

ТӘГЕЛӘ́Й, сугышчы киеме. Эченә мамык яки сүс катламы куеп сырылган билле озын кафтан. Кайвакыт ныклык өчен аңа тыштан калай кисәкчекләреннән кабырчыклар тегелә. 16–17 йөзләрдә татар ханлыкларында һәм рус кенәзлекләрендә гади сугышчылар арасында киң кулланылышта була.

И.Л.Измайлов.

ТӘГИ́Н, борынгы төрки титул. Төрки каганлыкларда каган уллары титулы. Еш кына исемгә кушыла (Алыптәгин, Күлтәгин һ.б.). 8–12 йөзләрдә Хәзәр каганлыгында, угызлар, сәлҗүкләр, караханилар дәүләтләрендә аксояк һәм хан нәселеннән булган ир заты титулы. 13 йөздән башлап угълан атамасына алыштырыла, кулланылыштан чыга.

Әд.: Малов С.Е. Памятники древнетюркской письменности. М.–Л., 1951; Гумилёв Л.Н. Древние тюрки. М., 1967.

И.Л.Измайлов.

ТӘКӘНӘ́Ш РАЙОНЫ́, ТАССРда. 1930 елның 10 августында оештырыла. Үзәге — Түбән Тәкәнеш авылы. 1920 гә кадәр район

терр-ясе Казан губернасының Мамадыш өязендә, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. Оешкан вакытында Т.р. 38 авыл советый, 67 торак пунктны берләштерә, аларда 41552 кеше (татарлар — 29372, руслар — 9024, башка халыклар — 3156) яши. 1932 нең 1 гыйнварында район таркатыла, терр-ясе Мамадыш һәм Кукмара р-ннарына бирелә. Район торгызылганнан соң (10.2.1935), адм. бүленеш берничә тапкыр үзгәрә. 1940 та Т.р.ның мәйданы — 1280 *км*^{2}, халкы — 47,8 мең кеше; 1 посёлок һәм 33 авыл советы, 88 торак пункт исәпләнә. 1960 та районның мәйданы — 1340,8 *км*^{2}, 1 посёлок һәм 13 авыл советы, 94 торак пункт була. 1963 нең 1 февраледә Т.р. таркатыла, терр-ясе Мамадыш һәм Саба р-ннарына бирелә.

ТӘКӘРЛЕ́К (Vanellus vanellus), шөлдиләр семьялыгындагы кош. Евразиядә, Төньяк-Көнбатыш Африкада таралган. Татарстан терр-ясендә бөтен районнарда очрый. Елга тугайларында, болыннарда, кырларда яши. Оя коручы күчмә төр. Апрельнең 1 нче яртысында очып киләләр. Гәүдә озынлыгы 30 *см* га якын, авырлыгы 190–230 *г*. Аркасы металл - сыман ялтыравыклы кара яшел, корсагы ак



Тәкәрлек.

төстә. Башында озын тар кара бүреге бар. Койрыгы ак, киң кара сызыклы. Канатлары киң һәм түгәрәкләнгән. Томшыгы кыска, туры. Тиз, текә борылышлар ясап оча. Куркыныч янаганда, тиз генә һавага күтәрелә. Үлән чел саз - лыкларда, көтүлекләрдә, кырларда кечерәк төркемнәр ясап оялый. Оясы — чокырчык. Моногамнар. Кара-көрән тимгелле 3–4 коңгырт-сары грушасыман йомырка сала. Бөҗәк - ләр, аларның личинкалары, ш.у. моллюсклар, яңгыр суалчаннары, күбәяклылар б-н туклана. Кышларга сентябрьдә очып китә.

ТӘКӘРЛЕ́К авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 32 *км* төньяктарак, Юкәче елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 1 кеше (татар) яши. 1920 елларда нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Мамадыш кантоны Вахитов волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән Мамадыш р-нында. Халык саны: 1949 да — 57, 1958 дә — 51, 1970 тә — 30, 1979 да — 19, 1989 да — 5, 2002 дә — 2 кеше.

ТӘКБИ́Р (гарәп. تكبير — зурлау), гарәпчә «Аллаһу әкбәр» — «Аллаһ — иң бөек» дигәнне аңлатучы сүзтезмә. *Корьән*дә расланган һәм әүвәлге мөселман риваятьләрендә сакланган йолалар башкаруга бәйле дога. Күп кабатлы Т. — мөселман гыйбадәтенә хас үзенчәлекләрнең берсе. Шулай ук мәчеттә намазга чакыручы *азан* догасының бер өлеше булып тора. Көн дәвамында 5, өстәмә намазлар вакытында күп тапкырлар кабатлана. Т. ш.у. мөселман хәрбиләрендә сугышка өндәү хәбәре булып та санала. Ул тылсымлы мәгънәгә дә ия: «Аллаһу әкбәр» догасының язылышы бизәлеш сәнгатендә, дини биналар декорында, каллиграфиядә һәм гамәли-бизәлеш сәнгатенең башка төрләрендә дә еш кулланыла; Иран һәм Гыйрак илләренең дәүләт байракларына да язылган.

Әд.: Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

ТӘКИ́Я, мавзолей, кабер өстенә корылган төрбә. Планда бүлмәләре гөмбәзсыман түшәмәләр б-н ябылган турыпочмаклы бина, кайвакыт табут кую өчен җирне казып ясалган махсус бүлмәсе дә була. Рязань өлкәсендәге Касыйм шәһәрендә ак таштан төзелгән Шаһгали хан тәкиясе (1556) һәм кирпечтән салынган Әфган-Мөхәммәд Солтан тәкиясе (1649) сакланып калган.

ТӘКМӘ́К авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 42 *км* көньяк-көнбатыштарак, Сикия елгасы буенда. 2010 елда 107 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек, балта эше, такта яру б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.тә мәчет (иске мәчет урынында 1893 тә төзелә), мәктәп (1831 дә ачыла), бакалея кибете, ашлык саклау-сату кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1123 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Байсар волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1816 да — 99 ир-ат; 1859 да — 356, 1870 тә — 414, 1884 тә — 544, 1897 дә — 471, 1906 да — 707, 1913 тә — 548, 1920 дә — 522, 1926 да — 298, 1938 дә — 330, 1949 да — 129, 1958 дә — 315, 1970 тә — 286, 1979 да — 221, 1989 да — 153, 2002 дә — 112 кеше.

ТӘКЪЛИ́Д (гарәп. تقليد — иярү), мөселман хокукы — *фикъһ* белемендәге аерым мәсьәләләрне хәл итүдә нинди дә булса дини-хокукый мәктәпнең (*мәзһәб*) абруена иярү. Т. төшенчәсе 7 йөздә барлыкка килә. Элегрәк Мөхәммәд пәйгамбәр сәхабәләреннән берсенең, соңрак аларның фикердәшләренең нинди дә булса берлеккә катнашы булуын аңлаткан. 10 йөз уртасыннан мөселман хокукына яңача аңлатма бирү тыела, *иҗтиһад* «ишекләре ябыла». Тәкълид мәсьәләләре 19 йөзнең 2 нче яртысында — 20 йөз башында «ачык ишекләр» идеясен алга сөргән ислахчылар хәрәкәте идеологларының хезмәтләрендә аеруча әһәмият казана (к. *Мөселман ислахчылыгы*). Беренче татар ислахчылары Г.*Курсави*, Ш.*Мәр җани* дә әлеге карашлар юнәлешендә чыгыш ясыйлар. Үзләренең хезмәтләрендә алар шул чорда мөселманнар арасындагы турыдан-туры Коръәнгә һәм Сөннәгә мөрәҗәгать итү урынына мөселман вәгазьчеләренең киңәшләрен тоту гамәлләрен тәнкыйтьләп чыгалар. Ш.Мәрҗанинең иҗтиһад, Т., мәзһәбләрне катнаштыру һ.б. мәсьәләләренә караган фикер һәм идеяләре *кадимчеләрдә* — иске карашлы мөселман вәкилләрендә ачу уята. Татар дини ислахчылары М.Бигиев, Г.Буби, К.Тәр җемани, Р.Фәхретдин ислам өммәтендә, башлыча, татар җәмгыятендә күп кенә тискәре күренешләр (схоластика, догматчылык) тудырган Т.не Коръәннән тайпылу дип бәялиләр. Хәзерге шәркый ислам белемендә һәм социаль-сәяси әдәбиятында «Т.» төшенчәсе «консерватизм», «катып калганлык» мәгънәсендә кулланыла.

Әд.: Тухватуллина Л.И. Проблема человека в трудах татарских богословов: конец XIX — начало XX вв. К., 2003; Таклид. К., 2004; Мухаметшин Р.М. Татарский традиционализм: особенности и формы проявления. К., 2005; Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

ТӘКЪЛИ́Д, борынгы әсәргә ияреп язу. Бигрәк тә Шәрекъ әдәбиятларында, ш.и. татар әдәбиятында да урын алган. Г.Тукайның аерым шигырьләре борынгы төрки әсәрләргә (Бакыргани), рус (А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов), Көнбатыш Европа авторлары (У.Шекспир, Гёте) шигырьләренә Т. буларак язылган. Аерым Т.ләр теге яки бу язучының идеяләренә җавап нәтиҗәсендә барлыкка килгән; мәс., Г.Коләхмәтовның «Яшь гомер» драмасы (М.Горькийның «Дошманнар» («Враги»), «Тормыш төбендә» («На дне») пьесалары йогынтысында язылган дип санала) башында мондый юллама урнаштырылган: «Бу әсәр мәшһүр рус мөхәррирләреннән Максим Горькийга тәкълиддән язылмыштыр».

Әд.: Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990.

ТӘЛЛӘТӘВЕ́Ч, урман шөлдие (Scolopax rusticola), чуллыклар семьялыгындагы кош. Европа һәм Азиядә таралган. ТР терр-ясенә апрель уртасында очып килә. Күләгәле киң яфраклы урманнарда яши. Каурый катламы тыгыз, түгәрәк, озынлыгы 35 *см* га кадәр. Авырлыгы якынча 400 *г*. Канатлары киң, кыска. Томшыгы озын, туры. Аркасы чуар җирән-коңгырт, корсагы аркылы сызыклы ачыграк төстә. Күчмә кош. Яшәү рәвеше төнлә һәм караңгылы-яктылыда. Ана зат оясын урманның караңгы почмагында җирдә ясый. Кара тимгелле 4 тонык кызыл йомырка сала. Яңгыр суалчаннары, бөҗәкләр һәм аларның личинкалары б-н туклана. Спорт аучылыгы объекты.

ТӘМӘ́Й авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 27 *км* төньяктарак, Бөре елгасы буенда. 2010 елда 72 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Тайман, Ерболдино (соңгысы 1940 елларга кадәр кулланыла) исемнәре б-н билгеле. 18 йөздә – 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында

авыл җәмәгатенең имана җире 361,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Кошки волостенда, 1920 дән ТАССРның — Арча, 1928 дән Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1905 тә — 280, 1920 дә — 345, 1926 да — 325, 1938 дә — 387, 1949 да — 318, 1958 дә — 220, 1970 тә — 128, 1979 да — 116, 1989 да — 82, 2002 дә — 84 кеше.

ТӘМӘКЕ́ СӘНӘГАТЕ́, к. *Азык-төлек җитештерү сәнәгате*.

ТӘМИНДА́РОВА Миләүшә Әмир кызы (13.5.1960, Казан), хор дирижёры, педагог, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2007). 1986 елда Казан консерваториясен (С.Казачков, В.Лукьянов классы) тәмамлый. 1986–88 дә Казан пед. ин-тында эшли. 1991–2000 дә Казан консерваториясендәге опера студиясенең хормейстеры һәм укытучысы. 2000–07 дә Горький А.М. әдәби-мемориаль музее мөдире. 2007 дән яңадан оешкан ТР Дәүләт камера хорының сәнгать җитәкчесе. Казан консерваториясенең опера студиясендә эшләгән елларында әзерләгән спектакльләре арасында «Дидона һәм Эней» («Дидона и Эней», Г.Пёрселл), «Мәхәббәт шәрабы» («Любовный напиток», Г.Доницетти), «Фауст» (Ш.Гуно), «Кар кызы» («Снегурочка», Н.А.Римский-Корсаков), «Сатып җибәрелгән кәләш» («Проданная невеста», Б.Сметана) һ.б. бар. ТР Дәүләт камера хорының хор программалары һәм муз. әсәрләре: «Раштуа бәйрәменә романс» («Романс к Рождеству»), «Эльбада очрашу» («Встреча на Эльбе», Бөек Ватан сугышында җиңүнең 65 еллыгына багышлана); «Stabat Mater» (Д.Б.Перголези), «Зур булмаган тантаналы месса» («Маленькая торжественная месса», Дж. Россини), «Дөнья яралу» («Сотворение мира», Ф.Й.Гайдн), «Всенощная» (С.Рахманинов) һ.б. Бу программаларда Т. солист буларак та чыгыш ясый.

ТӘММИНДА́Р Мохит (15.5.1919, Вятка губ. Алабуга өязе, хәзер Әгерҗе р-ны Салагыш а. — 30.3.2009, Токио, Япония), эшмәкәр, җәмәгать эшлеклесе. 1919 елда әти-әнисе б-н бергә Харбинга (Кытай) күчеп китә, рус гимназиясендә укый. 1932 дән Токиода яши. 1946 да Токиодагы Чуо (Chuo) ун-тының икътисад ф-тын тәмамлый. «Роса Треген» сәүдә компаниясенә нигез салучы, 1949 дан «Марую» компаниясенең ген. менеджеры. 1964 тән «Миханг Трайдинг» компаниясе президенты (Япония). Төрле елларда «Ислам ия» җәмгыятенең идарә әгъзасы, секретаре, җәмгыять рәисе, Япония мөселманнарының Диния нәзарәте рәисе, Япониянең Ислам үзәге рәисе. Токионың төрки-мөселман җәмәгате башлыгы. Төркия, Якын Көнчыгыш, Урта һәм Үзәк Азиядәге ислам илләре җәмәгатьчелеге вәкилләре б-н шәхси элемтәдә тора; күпсанлы ислам диненә багышланган һәм фәнни форумнарда катнаша. 1990 елларда туган авылы Салагышта мәчет салдыра.

Әд.: А д у т о в Р.М. Татаро-башкирская эмиграция в Японии. Наб.Челны, 1997.

ТӘМТЕ́ (Тәмтебаш) елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Мишә елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 24,6 *км*. Бассейнының мәйданы 157,8 *км*^{2}. Теләче р-ны терр-ясеннән ага. Ел га башы Төрек-Тәмте авылыннан 7 *км* төньяк-көнбатыштарак, тамагы Сауш авылыннан көньяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 170 *м*, тамагыныкы — 73 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 0,42 *км/км*^{2}. Туенуы катнаш, өчтән ике өлеше кар сулары исәбенә туры килә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км*^{2}. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 156 *мм*, ташу агымы катламы 100 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,3 *м*^{3}*/с*. Язын суы йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минераль-ләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. Т. бассейнында суының гомуми күләме 1,4 млн. *м*^{3} булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

ТӘМТЕ́ авылы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 45 *км* төньяк-көнбатыштарак, Куйбышев сусаклагычы ярында урнашкан. 2010 елда 1426 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. А.х. техникасы пр-тиесе, известь карьеры. Урта мәктәп, һөнәр уч-щесе, мәдәният йорты, китапханә. Чиркәү, мәчет. 1565–68 дән рус авылы буларак билгеле. Башта сарай ведомствосы, 1680 еллар ахырында — кенәз Нарышкиннар, 19 йөздә Гагариннар нәселе карамагына күчерелә. Халкы игенчелек, терлекчелек, бакчачылык, тегермән тарту, тимерчелек, штукатурлау, балта эше, мичкә ясау, йон-тукыма ману, тегү, кирпеч сугу, икмәк һ.б. а.х. товарлары сату б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.дә волость идарәсе урнаша; Троица чиркәве (1791–96 да алпавыт К.С.Нарышкин иганәсенә төзелә; архит-ра истәлеге), иске дин тарафдарлары чиркәве (1909 да төзелә), земство (1877 дә ачыла), чиркәү-приход (1883) һәм 2 класслы (1896) мәктәпләр, земство хастаханәсе, даруханә, тимерче алачыгы, 11 су тегермәне, 3 мануфактура кибете, 12 юлаучылар йорты, 3 чәйханә, 1 казна шәраб һәм 25 вак-төякләр кибете, пароход һәм агач материаллары пристаньнары була; шимбә базары эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3148 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Тәмте волосте үзәге, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән Тәмте р-ны үзәге, 1931 нең 20 октябреннән Кама Тамагы р-нында, 1935 нең 10 февраленнән Тәмте р-ны үзәге, 1958 нең 16 июленнән — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1646 да — 592, 1782 дә — 1702 ир-ат; 1834 тә — 2569, 1859 да — 2634, 1897 дә — 2677, 1908 дә — 2854, 1920 дә — 3299, 1926 да — 3078, 1938 дә — 3373, 1949 да — 2741, 1958 дә — 2765, 1970 тә — 2331, 1979 да — 2212, 1989 да — 1741, 2002 дә — 1545 кеше.

ТӘМТЕ́ авылы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 30 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Нырсы елгасы буенда. 2010 елда 35 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп. 1680 нән рус чыганакларында Починок на пустоши Бахты Враг исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.дә су тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 738 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Шомырбаш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Балык Бистәсе, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1782 дә — 57 ир-ат; 1859 да — 307, 1897 дә — 476, 1908 дә — 563, 1920 дә — 557, 1926 да — 555, 1938 дә — 543, 1949 да — 539, 1970 тә — 263, 1979 да — 200, 1989 да — 102, 2002 дә — 46 кеше.

ТӘМТЕ́ АУЧЫЛЫ́К ТЫЮЛЫГЫ́, Юга ры Ослан һәм Кама Тамагы р-ннары терр-ясендә, Идел елгасының уңъяк яры буенда урнашкан. Мәйданы — 53,8 *га*, ш.и. урманнар — 9,3 мең *га*, сулы-сазлыклы җирләр — 60 *га*. Елга кондызын һәм тояклы хайваннарны саклау максаты б-н 1976 елда оештырыла. Фауна составында — поши, кабан дуңгызы, кәҗәболан, янутсыман эт, бурсык, сусар, сасы көзән, Америка чәшкесе, ондатра, ак куян, үр куяны, көртлек, соры көртлек; ТРның Кызыл китабына кертелгәннәрдән — елга каракошы.

Р.Э.Чиспияков.

ТӘМТЕ́ КЫЛГА́Н ДАЛАСЫ́, ландшафтлы табигать истәлеге. Кама Тамагы р-ны терр-ясендә, Тәмте авылыннан көньяктарак



Тәмте кылган даласы.

урнашкан. 1991 елда билгеләнә. Мәйданы 41,1 *га*. Идел елгасының уңъяк ярындагы коры үзәнле болыннар. Дала үсемлекләренең 30 га якын төре, ш.и. дала кылганы (ТРның Кызыл китабына кертелгән) үсә.

ТӘМТЕ́ РАЙОНЫ́, ТАССРда. 1927 елның 14 февраленда оештырыла. Үзәге — Тәмте авылы. 1920 гә кадәр район терр-ясе Казан губернасының Зөя һәм Тәтеш өязләрендә, 1920 дән ТАССРның Зөя һәм Тәтеш кантонларында. 1930 да Т.р. 29 авыл советын, 76 торак пунктны берләштерә, аларда 26375 кеше (руслар — 23529, татарлар — 2202) яши. 1931 нең 20 октябрендә район таркатыла, терр-ясе Югары Ослан, Кама Тамагы һәм Апас р-ннарына бирелә. 1935 нең 10 февралендә кире кайтарыла. 1940 та Т.р. мәйданы — 806 *км*^{2}, халкы — 27,2 мең кеше, 20 авыл советы, 60 торак пункт исәпләнә. 1956 да районга 13 авыл советы, 60 торак пункт керә. 1958 нең 16 июлендә таркатыла, терр-ясе Кама Тамагы һәм Югары Ослан р-ннарына бирелә.

«ТӘМТЕ́ РЕНКЛОДЫ́», слива сорты. 1965 елда Татарстан а.х. тәҗрибә станциясендә Л.А.*Севастьянова* тарафыннан чыгарыла. Өлгереш вакыты, салкынга, корылыкка һәм клястероспориозга чыдамлыгы уртача. Уртача биеклектә. Ябалдашы күтәренке-җәенке, уртача куелыкта. Җимешенең авырлыгы 18 *г*, озынча-түгәрәк формада, куе кызыл төстә, көчле балавыз куныклы; җимешәне сары, тәме әчкелтем-баллы; яңа өлгергән һәм эшкәртелгән килеш кулланыла. 3–4 елдан җимеш бирә башлый. Уңышы 1 агачтан 15 *кг* нан артыграк. Бу сорт Татарстанда 1984 тән районлаштырылган.

Әд.: Фруктовый сад Татарстана. К., 2005.

ТӘМТЕ́ УРМАНЧЫЛЫГЫ́ посёлогы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 50 *км* көньяктарак, Кыярмәт елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 61 кеше (руслар, татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — урманчылык. Башлангыч мәктәп, клуб. 1930 елларда нигез салына. Оешкан көненнән Тәмте р-нында. 1958 нең 16 июленнән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1949 да — 147, 1958 дә — 133, 1970 тә — 122, 1979 да — 79, 1989 да — 54, 2002 дә — 84 кеше.

ТӘМТЕ́-МӘТӘСКӘ́ авылы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 6 *км* көнбатыштарак, Тәмте елгасы буенда. 2010 елда 96 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. Башлангыч мәктәп. 1565–67 еллардан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, өс-баш киемнәре тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.-М.дә мәчет, мәдрәсә, су тегермәне, ярма яргыч, 2 вак-төяклар кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 686 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Панова волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1782 дә — 62 ир-ат; 1859 да — 325, 1897 дә — 456, 1908 дә — 509, 1920 дә — 536, 1926 да — 462, 1938 дә — 377, 1949 да — 368, 1958 дә — 265, 1970 тә — 168, 1979 да — 175, 1989 да — 115, 2002 дә — 98 кеше.

ТӘМТҮ́З, урта гасырлар Идел буе Болгары шәһәре. Түбән Кама алдында яки Көнбатыш Кама аръягында булган дип фаразлана. Феодаль округ үзәге булган. Рус елъязмаларында рус гаскәрләренең Биләр шәһәренә 1183 елдагы яулары б-н бәйле рәвештә телгә алына.

Чыг.: Полное собрание русских летописей. М., 1962. Т. 2. *И.Л.Измайлов.*

ТӘМЬЯ́Н авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 14 *км* төньяк-көнбатыштарак, Ык елгасы буенда. 2010 елда 88 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1735 кә кадәр нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы асабалар, типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.да мәчет, мәктәп, ашлык саклау-сату кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 957 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Иректе волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1816 да — 73 ир-ат; 1858 дә — 221, 1870 тә — 275, 1913 тә — 397, 1920 дә — 388, 1926 да — 257, 1938 дә — 284, 1949 да — 213, 1958 дә — 166, 1970 тә — 211, 1979 да — 152, 1989 да — 100, 2002 дә — 101 кеше.

ТӘНИБӘ́К ХАН (14 йөз башы — 1342), Алтын Урда ханы (1342). *Үзбәк ханның* олы улы. Атасының Кавказ артына яуларында катнаша. Үзбәк хан үләр алдыннан аны үзенең варисы дип белдерә. Бик аз вакыт идарә итә. Бертуганы *Җанибәк хан* оештырган фетнә вакытында Т.х. һәм бертуганы Хозыр үтерелә.

Әд.: Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; Федоров-Давыдов Г.А. Общественный строй Золотой Орды. М., 1973. *И.Л.Измайлов.*

ТӘНКИСӘ́Р, кискеч кыяк (Stratiotes), субуярчалар семьялыгыннан күпъеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Бер төре — гади яки алоэсыман Т. (S. aloides) билгеле, Евразиядә таралган. Татарстан терр-ясендә барлык районнарда да очрый. Агымсыз яки әкрен агымлы сулыкларда үсә. 15–45 *см* биеклектәге үсемлек. Тамырчасы калын, кыска. Яфраклары ачык яшел, сусыл, кыяк-ланцетсыман, очлы пычкы читле, зур таралгы хасил итә (алоэ яфракларына ошаш). Чәчәкләре бер җенесле, кечкенә, өч ак таҗ яфракчыклы. Җимеше — җиләксыман. Июльдә чәчәк ата. Җимешләре августта өлгерә. Вегетатив юл, күбесенчә яннан үскән үргеннәр ярдәмендә үрчи; күпләп үсеп, зур мәйданнарны каплый, бу исә сулыкларның саегуына китерә. Тулаем сулык төбенә төшеп һәм тамырчыгы б-н ләмгә берегеп кышлый. Язын тамырчык коры, һәм үсемлек яңадан су өстенә күтәрелә, биредә исә сабактан йөзүче тамырлар үсеп чыга. Терлек азыгы.



Алоэсыман тәнкисәр.

ТӘҢКӘ́, Алтын Урдада һәм татар ханлыкларында 1/6 мыскалга тигез һәм 16 *пулдан* торган акча һәм акча-авырлык берәмлеге. Бер Т.нең авырлык нормасы — 0,76 *г*, ике Т.неке — 1,52 *г* (көмеш дирһәм авырлыгына тигез). Т. атамасы «danaka» дигән фарсы сүзеннән килә, ул эллинистик Шәрекътәге грек оболасына тиңдәш вак көмеш акчаны белдерә. Алтын Урдада акчалардагы «Т.» язмасы 1314 елда, Үзбәк хан идарә иткән чорда, барлыкка килә. Русьта Т. татар акчасы буларак таралыш ала, Дмитрий Донской вакытыннан алып, аның өслеге Мәскәү бөек кенәзләре исемнәрен өстәп бизәлә. 2,04 *г* лы Т.ләр 15 йөз башында Мәскәү һ.б. кайбер рус кенәзлекләрендә сугыла. 1534 елгы акча-авырлык реформасыннан соң акчада Георгий Победоносец рәсеме төшерелгән Мәскәү гербы сурәте барлыкка килә, ул «тиен» («копейка») (сөңгеле җайдак сурәтеннән) дип йөртелә башлый һәм Россия акча системасының төп унарлыгы булып китә. 18 йөз башыннан Т. (акча) дип ярты тиенлек акчалар атала.

Әд.: Спасский И.Г. Русская монетная система. Л., 1962; Фёдоров-Давыдов Г.А. Монеты Московской Руси. М., 1981; Мухамадиев А.Г. Булгаро-татарская монетная система XII–XV вв. М., 1983; шул ук. Древние монеты Поволжья. К., 1990. *И.Л.Измайлов.*

ТӘҢКӘ́ КАНАТЛЫЛА́Р, к. *Күбәләкләр*.

ТӘҢКӘЯФРА́К (Hedysarum), кузаклылар семьялыгыннан күпъеллык, сирәк кенә берьеллык үләннәр һәм ярымкуакчыклар ыругы. 150 гә якын төре билгеле, Төньяк ярымшарда, башлыча, Урта диңгез буенда таралган. ТР терр-ясендә 4 төре бар. Гмелин Т.ы (H. gmelinii) һәм эре чәчәкле Т. (H. grandiflorum) — Кама аръягында; Альп Т.ы (H. alpinum) һәм Разумовский Т.ы (H. razoumovianum) — респ-ка өчен сирәк төрләр.

Нигездә, известь ташлы тау битләрендә үсәләр. 10 нан 120 *см* га кадәр биеклектәге күпъеллык үләнчел үсемлекләр. Тамыры үзәк. Яфраклары парсыз каурыйсыман, төпчек яфраклы. Күпчелек чәчәкләре алсу, җете кызыл яки шәмәхә, сары төстә, чук чәчәк төркеменә җыйналган. Җимеше — тәңкәгә охшаган (исеме шуннан) бер яки ике — алты яссы яки аз гына кабарынкы өлешле кузак. Май–июльдә чәчәк ата. Җимешләре августта өлгерә. Орлыктан үрчиләр. Декоратив, баллы үсемлекләр. Терлек азыгы. Гмелин Т.ы, Альп Т.ы, эре чәчәкле Т. ТРның Кызыл китабына кертелгәннәр.

ТӘҢРЕ́, борынгы төрки мифологиядә — күк Алласы, «Күк Рухы», галәмне яратучы илаһи зат һәм аның хакиме. Т.нең яшәү урыны

күк дип санала. «Т.» атамасы Урта Азия халыкларының борынгы мифологик фондына карый, мөгаен, әле *хунну* телендә дә яшәгәндер; байтак тәңгәллекләргә ия: монгол телендә тәнгери, төрекләрдә — танри, хакасларда — тигир, чуашларда — тура, якутларда — тангара. Дәүләтләр, халыклар, кеше язмышлары б-н идарә итүче, аерым зат итеп каралмаган, ирләр башлангычыннан булган илаһ, тәңре. *Каһанның* яклаучысы була; аны зираклек һәм хакимлек сәләте б-н бүләкли. Т. хөрмәтенә яз ахырында махсус урыннарда (кагыйдә буларак, тау башындагы изге каен янында) сарык, тай чалына. Корбан чалу йоласы вакытында мул уңыш, сәламәтлек, бәхет сорап ялварганнар. Исламга кадәрге чор болгарларында утка, кояшка, суга, борынгы бабалар рухына һ.б. табынганнар, Т. аллалар пантеонының тажы булган. Болгарлар 922 елда ислам дине кабул иткәннән соң да, мәҗүси ышанулар юкка чыкмый. Алар яңабаштан карала, яңа дини системага кереп, халыкның рухи мәдәниятен формалаштыруга йогынты ясыйлар. Т. культының эзләре *халык йолаларында* хәзер дә саклана. «Т.» сүзе татарларда Аллага мөрәҗәгать итүнең бер формасы буларак яшәп килә («Аллаһ» сүзенең синонимы). Ш.у.к. *Мәҗүсилек.*

Әд.: Малов С.Е. Памятники древнетюркской письменности. М.–Л., 1951; Алексеев Н.А. Ранние формы религии тюркоязычных народов Сибири. Новосиб., 1980; Традиционное мировоззрение тюрков Южной Сибири. Новосиб., 1988; Безертинов Р.Н. Тэнгрианство — религия тюрков и монголов. Наб. Челны, 2000; Татары. К., 2001.

ТӘПИЧӘ, бәпкә үләне, каз үләне (Potentilla), роза чәчәкләр семьялыгыннан бер-, ике- һәм күпьеллык үләннәр һәм ярымкуаклар ыругы. 500 гә якын төре билгеле, барлык җирдә, башлыча, Евразия һәм Төньяк Америкада очрыйлар. ТР терр-ясендә 19 төре бар, каз тәпие (P. anserina), көмешсыман Т. (P. argentea), кыска каз үләне (P. intermedia) киң таралган. Урманнарда, далаланган болыннарда, юл, сулык ярларында үсәләр. 5 тән (яткын үсентеле төрләре) 70 *см* га кадәр биеклектәге үләнчел үсемлекләр. Яфраклары өчәрле, бармак- яки каурыйсыман теленмә. Чәчәкләре сары, ак, кызыл, берле яки калкан-себеркәч чәчәк төркемендә. Җимеше — күпчикләвекчек, 5–12 орлыктан тора. Орлыклары йомыркасыман, шома, сирәк кенә җи нәлчә җыерчыклы. Май–сентябрьдә чәчәк ата, җимешләре июль–октябрьдә өлгерә. Орлыктан үрчи. Барлык төрләре дә дияреклек халык медицинасында кулланыла. Тамырчасында дуплау матдәләре, флавоноид, органик к-та, эфир мае, сумала, лайлалы матдәләр, таниннар бар. Тамырчасыннан ясалган төнәтмә бөрешергеч буларак тамак һәм авыз куышлыгы авыруларына каршы, ашказаны-эчәк тракты ялкынсынганда кулланыла. Каз тәпие, көмешсыман Т. — терлек азыгы, туры Т. (P. recta) — декоратив үсемлек. Кайбер төрләре баллы. Ак Т. (P. alba), озын сабаклы Т. (P. longipes), төз Т. (P. erecta) ТРның Кызыл китабына кертелгән.

«ТӘРӘКЪКЫЙ» («ترق» — «Алгарыш»), яшерен әдәби-сәяси түгәрәк. *Казан татар укытучылар мәктәбе* укучылары тарафыннан 1895–1900 елларда оештырыла. Башлап йөрүчеләре — Г.*Исхакый*, С.*Максуди*, Г.*Терегулов*, Х.*Ямашев*. Түгәрәккә йөрүчеләр фарсы, рус, төрек телендәге әдәбиятны өйрәнәләр, шәкертләр арасында милли азатлык идеяләрен тараталар, рәсми булмаган гектографта «Тәрәкъкый» г-тасын чыгаралар. Түгәрәкнең актив әгъзалары Ә.Максуди, Г.*Камал* мәдрәсә мөгаллимнәре һәм шәкертләре арасында татар милли үзаң үсешенә ярдәм итүче алдынгы идеяләрне тараталар. Түгәрәк әъзалары б-н Ф.*Туктаров*, Ш.*Мөхәммәдъяров* һ.б. хезмәттәшлек итәләр.

Әд.: Амирханов Р.У. Татарский народ и Татарстан в начале XX в. К., 2005.

ТӘРБИ́ РАЙОНЫ́, *Мордва Республикасының* көньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. Мәйданы — 1141,6 *км*². Үзәге — шәһәр тибындагы Тәрби (Торбеево) посёлогы (Саранскидан 168 *км* көнбатыштарак). Халкы — 18973 кеше (1.1.2017), татарлар — 724 кеше (2010). Татарлар, тупланып, Йенә (Татарские Юнки), Сыркыды (Сургодь) авылларында яшиләр. Т.р. терр-ясенә татарлар 14 йөз башында урнаша башлый. Аларның төп шөгыле игенчелек, терлекчелек, сәүдә була. 19 йөздә — 20 йөз башында җирле сәүдәгәрләр, дөя йоны һәм тукыма сатып алу өчен, Казакъстанга һәм Урта Азиягә баралар. 1885 елда Йенә авылы сәүдәгәрләре сәүдә эшләре б-н Маньчжурия, Харбин, Япониягә йөриләр, Россиянең төрле шәһәрләрендә кибетләр тоталар. 1913 тә Йенә авылында 408 хуҗалык була, 2659 кеше яши, 4 мәчет, 4 мәктәп, хатын-кызлар һәм ирләр өчен мәдрәсәләр эшли, аларда 332 кеше укый; Сыркыды авылында 3 мәчет һәм 1 мәдрәсә була. Хәзерге вакытта Йенә авылында мәчет эшли, җирле мәктәптә татар теле фән буларак укытыла. Язучы Г.Ю.*Коләхмәтов*, шагыйрь Һ.Х.*Такташының* тормышлары һәм хезмәт эшчәнлекләре Т.р. б-н бәйле.

Әд.: Мордовия: Энцикл. Саранск, 2004. Т. 2.

«ТӘРБИЯ́», рәсемле пед. журнал. 1908 елның февраленнән апреленә кадәр Казанда татар телендә аена 2 тапкыр нәшер ителә, барысы 4 саны чыга. Нашире — Ф.Казакова, мөхәррире — М.Саинов, фактик мөхәррире — Х.Зәбири. Казан уку-укыту округының мөселман һәм дәүләт уку йортларына караган карарлары һәм күрсәтмәләре басыла, пед. теория һәм практика, татар теле белеме, табигать белеме буенча әһәмиятле сораулар яктыртыла, тәрбия һ.б. буенча гамәли киңәшләр бирелә. «Мөгаллим һәм мөгаллимәләргә», «Әниләргә һәм булачак әниләргә киңәшләр», «Сәламәтлекне саклау» бүлекләрендә мәдрәсәләрне үзгәртеп кору турында мәкаләләр, дидактик материаллар, мед. темасына фәнни-популяр очерклар, уку китапларына рецензияләр басыла. Г.Тукай, Г.Ибраһимов, Н.Думави, Г.Гыйсмәти, С.Рахманколый һ.б.ның әдәби әсәрләре, И.С.Тургенев, Л.Н.Толстой турындагы материаллар дөнья күрә. Г.Шәрәфнең басмаханәсе ябылгач, чыгудан туктый.

Әд.: Мәрдиева М. XX йөз башы татар тәгълим-тәрбия журналларының библиографик күрсәткече. К., 1997; Понятие «тип издания» и его значение в журналистике // Тонус. 2006. № 15.

«ТӘРБИЯЙ ӘТФА́ЛЬ» («تربية الاطفال» — «Балалар тәрбиясе»), фәнни-агарту юнәлешендәге рәсемле әдәби журнал. 1907 елның гыйнварыннан мартына кадәр Мәскәүдә татар телендә аена 2 тапкыр нәшер ителә, барысы 5 саны чыга. Наширләре һәм мөхәррирләре — З.Шамил, Х.Байбетов, сәркатибе — Ф.*Әмирхан*. Мәктәп укучылары өчен татар телендә булган беренче журнал. Үсеп килүче буынның акыл дәрәҗәсен үстерүне, милли гореф-гадәтләр б-н тәрбияләүне үзалдына максат итеп куя. Төрле фәннәрнең нигезләре турындагы; тарих, география буенча; Россиянең сәяси һәм икътисади хәле, Истанбул, Мәккә, Мәдинә һ.б. шәһәрләр тасвирланган мәкаләләр басыла (төсле рәсемнәр б-н бирелә). Күп кенә мәкаләләр ислам дөньясының күренекле вәкилләре — төрек солтаны Госман хан, Иран шаһы Мозафаретдин, имам Шамил, мәгърифәтчеләр И.Гаспринский, Г.Баруди, Г.Исхакый һ.б.га багышлана. Журнал укучыларны Европа һәм мөселман мәдәнияте, әдәбияты, тарихы б-н таныштыра. Х.К.Андерсен әкиятләре, Н.Думави, З.Ярмәкинең балалар өчен шигырьләре, Ф.Әмирханның әсәрләре һәм тәр җәмәләре басыла. Үз вакытының иң бай рәсемле татар басмасы булып тора; аның битләрендә 50 гә якын фоторәсем һәм рәсем урын ала.

Әд.: Мәрданов Р. «Тәрбияи әтфаль» журналына йөз ел // Казан утлары. 2007. № 2.

«ТӘРҖЕМА́Н», иҗтимагый-сәяси, әдәби һәм фәнни газета. 1885–1918 елларда Бакчасарай шәһәрендә (Кырым) нәшер ителә. Башта — атнага бер, 1903 тән 2–3 тапкыр чыга, 1912 дән — көндәлек газета. Рус телендә, 1905 тән — төрки-татар телендә басыла. 1909–10 да Казанда балалар өчен «Галәмә сыйбъян» кушымтасы дөнья күрә. «Телдә, фикердә һәм эштә берлек!» лозунгы б-н чыга. Нигезләүчесе, нашире һәм мөхәррире — И.*Гаспринский*, 1914 тән мөхәррире — Х.С.Ай-





«Тәрҗеман» газетасы.

вазов, нашире — Р.Гаспринский (И.Гаспринскийның улы). 1887–88 дә редакциядә журналист һәм икътисадчы галим М.*Акъегетзадә* эшли. Мисыр, Иран, Кытай, Төркиядә дә тарала. 1905 кә кадәр Россиядә бердән-бер мөселман газетасы була. Илдәге иҗтимагый-сәяси вазгыятьне яктырта һәм аңлата. Редакция төп бурычы итеп мөселман халыкларын агартуны куя, аның мөһим шартларын рус һәм Европа телләрен өйрәнүдә, заманча Европа мәдәнияте б-н таныштыруда күрә (И.Гаспринскийның «Европа хатлары», «Хозурлык иле» мәкаләләре һ.б.). Укырга өйрәнүнең әлифба-аваз алымын, мәктәп-мәдрәсәләр программасына дөньяви тәртипләрне кертүне, яңа ысуллы уку йортлары барлыкка китерүне пропагандалый. 1915 тә Бакчасарай мәдрәсәсе укучыларының күп кенә татар газеталары тарафыннан күчереп бастырылган һәм көчле бәхәс тудырган, укытучылар һәм укучылар өчен армиягә чакырылуны кичектереп торуның мөһимлеге турындагы хаты басыла. Шулай ук хатын-кызларга белем бирүнең милли системасын үстерү турындагы мәсьәлә куела. Төрки-татар тарихи-мәдәни мирасын пропагандалауга зур урын бирелә. Газета рус халкын мөселман халыкларының тарихы һәм мәдәнияте б-н таныштыруны, мөселманнарның иҗтимагый омтылышының асылын гаделлек һәм тигез хокуклылыкка хәрәкәт буларак аңлатуны үз бурычы итеп куя. Европа илләренең фәнни-техник казанышлары яктыртыла. 1904–05 тә, Көнбатыш технологияләрен үзләштереп, шул ук вакытта милли һәм мәдәни үзенчәлеген саклап калган ил буларак, Япония турында күп мәкаләләр басыла. «Т.» мөселман халыкларына гаять зур йогынты ясый һәм эшчәлегендә татар зыялыларының (Й.Акчура, Г.Исхакый, С.Максуди, Ә.Максуди, Гани бай Хөсәенов һ.б.) булышлыгына таяна. 1905–07 еллардагы рев-циядән соң татар басмаларының саны арту б-н, басманың роле кими.

Әд.: Хамитбаева Н.С. Вопросы образования у татар на страницах газеты «Тарджеман» (1889–1894) // Народное просвещение у татар в дооктябрьский период. К., 1992; Ислам в Евразии: Современные этические и эстетические концепции суннитского Ислама. М., 2001.

ТӘР ҖЕМАНИ́ Кәшшаф Кыям улы (1877, Казан губ., Спас өязе Ямкино а. — 1943), дин һәм җәмәгать эшлеклесе, илаһият галиме. Руханилар нәселеннән. «Мәр җәния» мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң (Казан, 1904), Казандагы 11 нче мәхәллә имам-хатибы, бер үк вакытта «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыта. Мөселманнар хәрәкәтендә актив катнаша: Түбән Новгород шәһәрендә узган 3 нче Бөтенроссия мөселманнар корылтаеның дини комиссиясе әгъзасы (1906), С.-Петербургта узган 4 нче Бөтенроссия мөселманнар корылтаенда Казаннан делегат була (1914). 1917 елдан Эчке Россия һәм Себер мөселманнары Үзәк Диния нәзарәте казые, бер үк вакытта, 1921 дә, Ачларга ярдәм комиссиясе башлыгы, үзәк хакимият органнарында Мөселман Диния нәзарәте вәкиле. 1924–28 дә «Ислам» (1926 га кадәр «*Ислам мәхәлләсе*») ж-лы мөхәррире. 1926 да яңадан казый булып сайлана, Үзәк Мөселман Диния нәзарәте (ҮМДН) Голямалар шурасы составына керә. 1926 да мөфти Р.Фәхретдин б-н бергә Согуд Гарәбстанында мөселманнарның 1 нче Бөтендөнья конгрессы эшендә катнаша. Р.Фәхретдиннең вафатыннан соң (1936), мөфти урынбасары буларак, мөфти вазифаларын башкара, чираттагы мөфти сайлауларын совет хакимияте тыя. 1936 да Т. «ҮМДН җитәкчеләре фетнәсе турындагы эш» буенча кулга алына; 1937 дә 10 елга ябылуга хөкем ителә; төрмәдә вафат була. Аклана.

Әд.: Хабутдинов А.Ю. Российские муфтии от екатерининских орлов до ядерной эпохи (1788–1950). Н.Новгород, 2006; Ислам на европейском Востоке: Энцикл. словарь. К., 2004.

ТӘРҖЕМА́НОВ Әмин Әфтах улы (4.1.1924, Казан – 26.5.2010, шунда ук), термофизик, техник фән. д-ры (1972), проф. (1974), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлекләсе (1979), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2006). 1943 елда 3 нче Ленинград арт. уч-щесен (Кострома ш.) тәмамлый, 1950 дә Казан химия-технол. ин-тында. 1950–56 да — Казан компрессорлар з-дында, 1957–62 дә Бөтенсоюз җылылык техникасы ин-тында (Мәскәү) эшли. 1962 дән Казан технол. ун-тында, гидравлика каф. мөдире (1978–88), шул ук каф. профессоры (1989 дан). Хезмәтләре матдәләрнең термофизик үзлекләренә, югары басымнар техникасына карый. Т. югары басым һәм темп-ра астында сыеклык һәм газларның үзлекләренә (тыгызлык, тавыш тизлеге, үзлелеге, җылы үткәрүчәнлеге һ.б.) теоретик һәм эксперименталь тикшеренүләр уздыра; җиһазларның импульслы техника, ш.у. ЭВМнар ярдәмендә информацион-үлчәү системалары кулланылган конструкцияләрен тәкъдим итә; матдә үзлекләренең стандарт белешмәлек таблицаларын эшли. Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы бар. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Казан технол. ун-тының атказ. профессоры.

Хезм.: Теплопроводность жидкостей и газов. М., 1978 (автордаш); Справочник по теплопроводности жидкостей и газов. М., 1990 (автордаш).

ТӘР ҖЕМА́НОВ Җәвад Әфтахетдин улы (8.7.1920, Казан — 9.3.1995, шунда ук), язучы, механик, техник фән. канд. (1950), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлекләсе (1981). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый (1944). 1950 елдан шунда ук, металлар технологиясе кафедрасында эшли, бер үк вакытта — «С.М.Киров исем. КХТИның фәнни хезмәтләре» («Научные труды КХТИ им. С.М.Кирова») җыентыгының җаваплы сәркәтибе. Танылган балалар язучысы. «Галстук» исемле беренче шигъри җыентыгы 1938 дә дөнья күрә. Т.ка танылуны «Тукран малае Шуктуган» (1962, рус теленә тәрҗемәсе — «Шуктуган», М., 1970), «Шаян белән Наян» (1966), «Көмешкойрык маҗаралары» (1979, рус теленә тәрҗемәсе — «Приключения Серебряного Хвостика», 1978) әкиятләре китерә. «Тургай» (комп. Л.Хәмиди) муз. комедия либреттосы, «Лобачевскийның яшьлеге» документаль романы авторы. Соңрак бу роман яңадан эшләнеп «Көмеш дага» (1971, рус. теленә тәрҗемәсе — «Серебряная подкова», М., 1979) исеме б-н чыга. Т. ш.у. интермедияләр, «Без театр уйныйбыз» пьесасын (1963), балалар әдәбиятына багышланган мәкаләләр, танылган язучылар турында очерклар яза («Ян, йолдызым, ян!», 1966; «Очрашулар, очрашулар...», 1990).

Әсәр.: Сайланма әсәрләр. К., 1969; Ачкыч һәм баскыч. К., 1980.

Әд.: Ихсанова Л. Зур бакчаның бер гөле // Казан утлары. 1980. № 6; Кукушкин Р. Канатлы дөнья. К., 1984.

Г.М.Габделхакова.

ТӘРИКА́ТЬ, к. *Суфичылык.*

ТӘСИ́МОВ Измаил (18 йөз), сәнәгатьче, иганәче, Усы даругасының Гайнә волосте Куян авылында туган (хәзер Пермь крае). Уралда тау сәнәгатен оештыручы. Рудалар эзләү б-н шөгыльләнә; аларны Пермьнең Егошихинск һәм Юговск заводларына җибәрә. 1750 елларда Яңа кануннар эшләү комиссиясенең чираттагы чакырылышын әзерләгәндә Пермь заводчылары һәм руда сәнәгатьчеләре наказлары проектларын эшләүдә катнаша. Россиядә беренче югары техник мәктәп — Тау уч-щесен (1773; хәзерге Петербург Тау ин-ты) оештыруда башлап йөрүче. Император Екатерина II гә Сенат докладында (1773 ел 21 окт.), Тау уч-щесе укучыларын тоту өчен, Т. «иптәшләре» ...руданың һәр потыннан алына торган бәядән чирек тиен» бирергә вәгъдә итә, дип әйтелә (Т. бүлеп биргән акчадан уч-щенең беренчел бюджеты оеша).


Р.Н.Апкин.

ТӘТЕ́Ш, район карамагындагы шәһәр, Тәтеш р-ны үзәге. ТРның көньяк-көнбатыш өлешендә, Буа тимер юл станциясеннән



Тәтеш шәһәре. Яңа микрорайон.

(Ульянов–Зөя юнәлеше) 45 *км* көнчыгыштарак, Казаннан 180 *км* ераклыкта урнашкан. Идел елгасының уң ярындагы пристань. Мәйданы — 7,3 *км*². Халкы — 11250 кеше (2018). 2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 54,3%, татарлар — 25,7%, чуашлар — 13,2%, мордвалар — 5,5%. Шәһәрдә «Тәтеш-Водоканал» АҖ, «ПМК Стройинвест» ҖЧҖ, «Газтехмонтаж» ҖЧҖ, «Тәтеш җылылык челтәре предприятиесе» АҖ, «Балык промыселы» ҖЧҖ, «Иделстрой» ҖЧҖ, механика з-ды, типография, автотранспорт пр-тиесе, тегү ф-касы, май-сыр комб-ты, район кулланучылар җәмгыяте, ашлык кабул итү пр-тиесе эшли. Социаль мәгариф академиясе (КСЮИ) ф-лы, пед. көллияте, а.х. техникумы, 3 урта мәктәп, кадет мәктәп-интернаты, балалар сәнгать мәктәбе, 2 балалар-үсмерләр спорт мәктәбе (ш.и. стендка ату буенча олимпия резервы мәктәбе). Район мәдәният йорты, төбәк тарихы музее, 2 китапханә. Район үзәк хастаханәсе. Троица чиркәве (1777 дә



Тәтеш шәһәре. Троица чиркәве. 1777.

төзелә; архит-ра истәлеге), мәчет. Т. терр-ясенә халык борынгыдан килеп урнаша. Монда каберлекләр һәм Казан яны (б.э.к. 16–19 йөзләр), Ананьино (б.э.к. 8–3 йөзләр), Азелино (3–7 йөзләр) һәм Имәнкискә (5–7 йөзләр) археол. культуралары истәлекләре табыла. Болгар чорында Т. урынында Иделнең уң ярыннан Болгарга чыгу юлын күзәтү посты урнаша. 1571 ел тирәсендә (башка мәгълүматлар буенча, 1555–57 дә) бу пост урынында Идел алдын колонияләштерүнең терәк пункты булып киткән рус күзәтү кальгасе төзелә. Немец галиме һәм дипломаты А.*Олеарий* 1636 да су юлы б-н Т. яныннан уза һәм аны сурәтләп калдыра. 1646 да анда 257 ху җәлык, 922 ир-ат исәпләнә, аларның күпчелеге йомышлы кешеләр була. 17 йөз уртасында Сембер чик буе киртәсе төзелгәннән соң, Т. хәрби әһәмиятен югалта. 1708 дә — Казан губернасы бистәсе, 1781 дә — Казан намест-никлыгының өяз шәһәре, 1797 дә — штаттан тыш шәһәр, 1802 дә Казан губернасының өяз шәһәре итеп билгеләнә. 18 йөз ахырында Т.тә таш чиркәү, сәүдә йорты, 10 кибет һәм 2 тимерче алачыгы була. 20 йөз башында 4 таш чиркәү, 1 агач мәчет, 33 таш һәм 585 агач торак бина, торак буларак файдаланылмаган



Тәтеш шәһәренең үзәк өлеше күренеше.

20 таш һәм 512 агач бина, шәһәр уч-щесе (1818 дә ачыла; 1902 гә кадәр — өяз уч-щесе), хатын-кызлар прогимназиясе (1906 да ачыла, 1910 нан — гимназия), 3 чиркәү-приход мәктәбе, рус-татар уч-щесе (1900 дә ачыла), мәдрәсә, земство һәм төрмә хастаханәсе, земство даруханәсе, почта бүлекчәсе, телеграф, телефон, гарипләр йорты, 2 ятим балалар йорты, кием кисү һәм тегү мәктәбе, земство слесарьлык бинасы, 1 ярма яргыч, 6 тимерче алачыгы, 5 сыраханә, 2 казна шәраб, 5 зур һәм 32 вак кибет була; дүшәмбе базары эшли. Халкының төп шөгыле ашлык сату, балыкчылык, җирле пристаньда һәм пароходларда эшләү була. Ел саен 2 зур ярминкә — Казан (июньдә) һәм Воздвиженка (сентябрьдә) ярминкәләре уздырыла, анда 70 мең сумлык төрле товар (мануфактура, бакалея, мех, күн, аяк киеме һ.б.) китерелә. Т.нең гомуми йөк әйләнеше 109570 *т* га җитә. Төп товар бөртекле ашлык була. Уңыш мул булган елларда Т. пристаненнан 115 мең *т* га кадәр ашлык озатыла, аның күбесе Рыбинск (85% ка кадәр) һәм соңрак С.-Петербург шәһәрләренә җибәрелә. 1920 дә ТАССР оештырылу б-н, Т. шулук исемдәге кантон үзәге булып китә. 1927–30 елларда ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәтеш р-ны үзәге. Халык саны: 1859 да — 2553, 1897 дә — 4574, 1908 дә — 5559 кеше, 1917 дә — 5,4 мең, 1920 дә — 5,7 мең, 1926 да — 4,8 мең, 1939 да — 8,6 мең, 1959 да — 5,9 мең, 1979 да — 10,5 мең, 1989 да — 10,5 мең, 2002 дә — 11,9 мең кеше. Сов. Союзы Герое П.С.*Ханжин*, СССР ФА академигы М.А.*Лаврентьев*, химик Г.Х.*Камай*, авыр атлетика буенча ике тапкыр Олимпия чемпионы А.Н.Воробьёв, стендка ату буенча күп тапкыр дөнья һәм Европа чемпионы С.А.*Дёминаның* тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге Т. б-н бәйле.


Әд.: Приволжские города и селения в Казанской губернии. К., 1892; Есть на Волге городок... К., 2004.

ТӘТЕ́Ш АВЫ́Л ХУҖАЛЫГЫ́ ТЕ́ХНИКУМЫ, ТР А.х. һәм азык-төлек министрлыгының урта һөнәри уку йорты. 1921 елда ачыла, 2001 гә кадәр совхоз-техникум, 2001 дән хәзерге исемдә. Укыту урта һөнәри белгечлекләр (агрономия, а.х.н механикалаштыру, фермер хуҗалыкларын оештыру, файдалы казылмалар чыганакларын эзләүнең геофизик алымнары, икътисад, бухгалтерлык исәп-хисабы) һәм башлангыч һөнәри белгечлекләр (автомеханик, тракторчы-машинист) буенча алып барыла. 2015 кә көндезге бүлектә 450, читтән торып уку бүлегендә 250 студент укый; укытучылар коллективын 34 кеше тәшкил итә. 25 меңнән артык белгеч әзерләнә.

ТӘТЕ́Ш АУЧЫЛЫ́К ТЫЮЛЫГЫ́, Тәтеш р-ны терр-ясендә урнашкан. Мәйданы — 30 мең *га*, ш.и. урманнар — 7,5 *га*, сулы-сазлыклы җирләр — 600 *га*. 1978 елда кәҗәболан, суер, соры көртлекне саклау максаты б-н оештырыла. Тыюлыкта ш.у. поши, кабан дуңгызы, төлке, бурсык, сусар, сасы көзән, Америка чәшкесе, ондатра, ак куян, үр куяны, көртлек яши; ТРның Кызыл китабына кергән төрләрдән — елга каракошы, колаклы ябалак, гади бакыр елан.

Р.Э.Чиспияков.

ТӘТЕ́Ш КАНТОНЫ́, 1920–27 елларда ТАССРда адм.-терр. бүленеш берәмлеге. Респ-каның көньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. Үзәк адм. берәмлек комиссиясенең 1920 ел 8 сентябрь карары нигезендә ТАССР *Тәтеш өязенең* 23 волосте җирлегендә оештырыла. Үзәге — *Тәтеш* шәһәре. Т.к. чикләре һәм адм. бүленеше берничә тапкыр үзгәрә. 1924 тә ТАССРдагы адм.-терр. реформа нәтиҗәсендә Т.к.нда волостьлар саны 17 дән 7 гә калдырыла. 1921 дә Т.к. мәйданы 3878 *км*² булса, 1926 да — 3292 *км*². 1921 дә 23 волость-ны һәм 249 авыл торак пунктын, 1927 дә 7 волостьны (Балтай, Бәки, Кама Тамагы, Килдураз, Тәтеш, Шәмәк, Шонгаты) һәм 222 авыл торак пунктын берләштерә. Халкы 1920 дә — 225296 кеше, ш.и. татарлар — 52,3%, руслар — 30%, чуашлар — 16,3% (1917 елгы халык санын исәпкә алу мәгълүматлары буенча). Шәһәрдә яшәүчеләр — 5689 кеше, авылда яшәүчеләр — 219607 кеше. 1926 да — 146200 кеше, ш.и. татарлар — 53,4%, руслар — 37,3%, чуашлар — 5,9%, шәһәрдә яшәүчеләр — 4803 кеше, авылда яшәүчеләр 141397 кеше исәпләнә. Халкының гомуми тыгызлыгы 1 *км*² *га* 44,4 кеше. Металл эшкәртү һәм азык-төлек сәнәгате пр-тиеләре була; һөнәрчелек остаханәләрендә якынча 1,9 мең кеше хезмәт итә (1926). 1920 дә 268 мәктәп (ш.и. 6 сы — икенче баскыч (урта мәктәп), 1924 тә 133 мәктәп (2 се — икенче баскыч), 20 китапханә эшли. 1920 дә сөрү җирләренең гомуми мәйданы 117228 *га*, 1925 тә — 121403 *га*, ш.и. арыш — 60409, бодай — 5693, солы — 21148, ясмык —



6397, карабодай — 4407, борай — 3362, бәрәңге 4176 *га* тәшкил иткән.

1920 дә — 38134 крәстиян хуҗалыгы, 1925 тә 34673 крәстиян хуҗалыгы һәм 22 а.х. кооперативы исәпләнә; 179825 баш терлек, ш.и. 21692 ат, 39079 мөгезле эре терлек (ш.и. 20249 сыер), 84581 сарык, 25187 кәҗә, 9286 дуңгыз асрала. 1927 нең 14 февраленнән Бөтенроссия ҮБК Президиумы карары б-н Т.к. *Буа кантоны* составына кертелә.

Чыг.: Предварительные итоги переписи населения 28 августа 1920 г. Население 25 губерний Европейской и Азиатской России. М., 1921. Т. 1, вып. 2; Народное образование по основному обследованию 1920 года (1920–21 учеб. год). Поуездные итоги предварительного подсчёта. М., 1922. Т. 12, вып. 1; Статистический справочник по промышленности ТССР. К., 1924; Статистический справочник по сельскому хозяйству. К., 1925; Всесоюзная перепись населения 1926 года. М., 1928. Т. 3; 1929. Т. 9.

ТӘТЕ́Ш КЕНӘГӘЛӘРЕ́, писцовый кенәгәләр. 1571 елда нигезләнгән Тәтеш кальгасын да яшәгән рус йомышлыларының җир биләмәләре тасвирлана. 1573–74 тә чиновник В.Соколов тарафыннан төзелә. Сакланмаганнар, Т.к. турында төрле документларда искәртелә. *Д.Г.Мостафина.*

ТӘТЕ́Ш ӨЯЗЕ́, 1802–1920 елларда Казан губернасында адм.-терр. бүленеш берәмлеге. Үзәге — *Тәтеш* шәһәре. Баштарак *Казан өязе* составындагы «эчке» өяз саналган. 1781 дән Казан наместниклыгы эчендәге мөстәкыйль өяз. 1796 да Т.ө. бетерелә, аның терр-ясе Казан өязе составына бирелә, 1802 дә Казан губернасы составында яңадан торгызыла. Көнбатышта Цивильск, төньякта Зөя, төньяк-көнчыгышта Лаеш, көнчыгышта Спас өязләре, көньякта Сембер губернасының Буа өязе б-н чиктәш булган. Идел, Зөя, Чирмешән, Кылна, Киртәле, Карлы, Үләмә, Бола, Грязнуха, Тояба һ.б. елгалар кергән мәйданда урнашкан. Гомуми мәйданы якынча 3,5 мең кв. чакрым. Халкы 195,6 мең кеше, ш.и. татарлар — 51,1%, руслар — 28,9%, чуашлар — 16,5%, мордвалар — 3,5% (1900). 17 волостька бүленгән. Халкы игенчелек, умартачылык, бакчачылык, балыкчылык б-н шөгыльләнгән. Өяздә 216 мәктәп, шулардан 103 е татар мәктәбе була. Бүленгәндә биләмәсенең зур өлеше *Тәтеш кантонына* бирелә.

Чыг.: Материалы для географии и статистики России, собранные офицерами Генерального штаба: Казанская губерния. СПб., 1861; Опись городских поселений Казанской губернии. К., 1885.

Әд.: Спасский Н.А. Очерки по родиноведению: Казанская губерния. К., 1912.


Д.Г.Мостафина.

ТӘТЕ́Ш ПЕДАГО́ГИКА КӨЛЛИЯТЕ́, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының урта һөнәри уку йорты. 1917 елда укытучылар семинариясе буларак ачыла, 1919 дан пед. курслар, 1921 дән пед. техникумы; 1937 дән пед. уч-ще се, 2009 дан хәзерге исемдә. Башлангыч сыйныфларда укыту, физкультура (1966 дан), муз. белем бирү (1993 тән), гамәли информатика (2010), гадәттән тыш хәлләрдә саклану (2014), янгын куркынычсызлыгы (2014) белгечләрен әзерли. 330 укучы укый (2015), барысы да көндезге (бюджет) бүлектә. Пед. коллективта 36 кеше эшли, ш.и. ТРның атказ. укытучысы — 1, Мордва Респ-касының атказ. мәдәният хезмәткәре — 1, Чуаш Респ-касының атказ. укытучысы — 1, фән. канд. — 1 кеше. Бу чорда якынча 10 мең белгеч әзерләнә. 1989 дан уч-ще тарихы музее эшли. Уч-щене тәмамлаучылар арасында — чуаш шагыйре, дәүләт эшлеклесе М.*Сеспель*, дәүләт эшлеклесе Г.Г.*Галиев*. Уч-щенең бинасы (элеккеге ир балалар гимназиясе бинасы) архит-ра истәлеге (1914, арх. С.В.Бечко-Друзин).

ТӘТЕ́Ш РАЙОНЫ́, ТРның көньяк-көнбатыш өлешендә, Ульянов өлкәсе б-н чиктәш урнашкан. Мәйданы — 1632,2 *км*². 1 шәһәр һәм 20 авыл җирлеген, 75 торак пунктны берләштерә. Үзәге — *Тәтеш* шәһәре. 2018 елда 22425 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 34,7%, татарлар — 32,7%, чуашлар — 21,7%, мордвалар — 9,9%) яши. Шәһәр халкы — 11250, авыл халкы — 11175 кеше. Халыкның уртача урнашу тыгызлыгы — 1 *км*² *га* 14,2 кеше. 1930 ның 10 августында оештырыла. 1920 гә кадәр район терр-ясе Казан губернасының Тәтеш өязенә керә, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. Оешкан вакытында Т.р. составында 1 шәһәр һәм 46 авыл советы, 85 торак пункт була, аларда 61883 кеше (руслар — 34810, татарлар — 8243, башка милләтләр — 18830) яши. Т.р.ның чикләре һәм адм. бүленеше берничә тапкыр үзгәрә. 1938 нең 4 августыннан терр-ясенең бер өлеше кабат оештырылган *Олы Тархан районына* бирелә (1959 ның 12 октябрендә кире кайтарыла). 1940 та районның мәйданы — 905 *км*², халык саны — 38,1 мең кеше, 1 шәһәр советы, 25 авыл советы, 48 торак пункт була. 1960 та район 1507,1 *км*² мәйдан били, аңа 1 шәһәр һәм 19 авыл советы, 82 торак пункт керә. 1963 нең 1 февралендә ТАССРда адм. берәмлекләр эреләндерелү сәбәпле, Т.р.на Кама Тамагы һәм Апас р-ныың бер өлеше кушыла. Районның мәйданы — 3334 *км*², халкы — 93,8 мең кеше, 1 шәһәр советы, 2 посёлок советы, 46 авыл советы була, торак пунктлар саны 135 кә җитә. 1964 нең 4 мартыннан Т.р. биләмәсенең бер өлеше яңа торгызылган Апас р-нына күчә, 1965 нең 12 гыйнварында Т.р.ннан Кама Тамагы р-ны бүленеп чыга. Районның терр-ясе кечерәя: мәйданы — 1618 *км*², халык саны — 45,2 мең кеше, 1 шәһәр советы, 22 авыл советы, 88 торак пункт кала.



Т.р.ның рельефы — елга үзәннәре, ерымнар, сызалар б-н бүлгәләнгән калку тигезлек (биеклеге 180–220 *м*). Идел (Куйбышев сусаклагычы), Зөя һәм аның кушылдыклары — Кылна, Үләмә елгалары ага. Җирләре күбесенчә селтесез көлсу кара, соры һәм кара-соры урман туфраклы. Терр-ясенең урманлылыгы — 16,1%. Кызыл балчык, фосфорит ятмалары бар. Саклаулы табигать истәлекләре: *Зөя* һәм *Үләмә* елгалары, *Тәтеш аучылык тыюлыгы, Тархан имәнлекләре*, *«Таштау»* ерым-сызалар системасы, *Озын Алан* комплексы табигать һәм тарих-архит-ра истәлеге. Район терр-ясендә күбесе



Болгар һәм Алтын Урда чорына караган 120 дән артык археол. истәлек табыла. Сәнәгать пр-тиеләре Тәтеш шәһәрендә тупланган. Районда «Тәтеш урманчылыгы», «Тәтешурман» дәүләт бюджет учреждениеләре урнашкан. Мөгезле эре терлек, дуңгыз, сарык үрчетү тармаклары алга киткән. А.х. җирләре 96,8 мең *га* били, ш.и. 83 мең га — сөрүлек җир (2016). Сабан бодае, көзге арыш, арпа, солы, карабодай, борчак игелә; шикәр чөгендере үстерелә. 2016 да Т.р.нда төрле милектәге 48 а.х. пр-тиесе исәпләнә. Т.р. җиреннән Буа–Тәтеш, Тәтеш–Апас, Тәтеш–Ульянов автомобиль юллары уза. Идел ярында Тәтеш пристане урнашкан. Районда 29 гомуми белем бирү мәктәбе, ш.и. 13 башлангыч, 4 тулы булмаган урта, 12 урта мәктәп; сәнгать мәктәбе, 1 кадет мәктәп-интернаты, 2 балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе, а.х. техникумы, гражданнарны яклау көллияте, 19 мәктәпкәчә тәрбия учреждениесе, 36 китапханә, 52 клуб, район үзәк хастаханәсе, участок хастаханәсе (Олы Тархан) һәм дәвалау амбулаториясе (Олы Шәмәк) эшли. Тәтеш төбәк тарихы, И.Яковлев исем. (Кошки-Яңа Тимбай а.) музейлар эшли. Татар һәм рус телләрендә «Авангард» район г-тасы нәшер ителә.

ТӘТЕ́Ш ТӨБӘ́К ТАРИХЫ́ МУЗЕЕ́, ТР-ның Милли музее ф-лы. 1920 елда җәмәгать-челек башлангычы б-н ачыла, 1928 дән дәүләт музее. 1 нче гильдия сәүдәгәр, Тәтешнең нәселдән килгән мактаулы гражданы П.В.Серебряков йортында (1870, архит-ра истәлеге) урнашкан. Экспозиция мәйданы 274 *м*², музей коллекцияләрен 12 меңгә якын саклау берәмлеге тәшкил итә. Экспозиция шәһәр һәм район тарихына багышлана. Төбәк табигатен чагылдырган палеонтология һәм археол. коллекцияләре, предметлары зур урын били. Этнография бүлегендә район терр-ясендә яшәүче халыкларның: руслар, татарлар, чуашлар, мордваларның көнкүреш әйберләре һәм киемнәре куелган. Шәһәр тарихы 18–19 йөзләр документларында һәм фоторәсемнәрендә чагылган; экспонатлар арасында — Е.И.Пугачёв заманындагы туплар, 19 йөзнең 1 нче яртысы көбәләре, биш көпшәле капсуллы пистолет, 19 йөз башы җәмәгать судьясының һәм шәһәр башлыгының күкрәк билгеләре, Троица чиркәве дини предметлары (1777) һ.б. Экспозициянең аерым өлешен *Долгая Поляна — Молоствовлар* нәселе утары турындагы материаллар (нәсел туграсы күчермәләре, 18–19 йөзләр документларының ксерокопияләре һ.б.) тәшкил итә. Экспозициянең 20 йөз тарихына багышланган өлешендә районда туган танылган шәхесләр: сигез Советлар Союзы Герое, стендка ату буенча Олимпия резервы мәктәбен оештыручы С.С.Яруллин, стендтка ату буенча 13 тапкыр — Европа, 8 тапкыр дөнья чемпионы һәм Олимпиада-2000 көмеш призёры С.А.*Дёмина* һ.б. турында материаллар урнаштырылган.

Музейның аеруча мөһим экспонатлары арасында 19 йөз Россия һәм Саксония заводларының (Гарднер, Насонов, Кузнецов һ.б.) фарфор һәм яктырту приборлары коллекцияләре; 19 йөз ахыры — 20 йөз башы «Польша көмеше» әйберләре коллекциясе; шагыйрь М.*Сеспель* өеннән мемориаль әйберләр һәм гаилә архивы; революцион хәрәкәт эшлеклесе В.Н.*Фигнерның* туганнары йортыннан өй җиһазы; 17–19 йөзләргә караган кулъязмалар һәм иске басма китаплар коллекцияләре; А.Ф.*Мантель* тупланмасыннан 19 йөз ахыры — 20 йөз башы рус графикасы әсәрләре бар. Ел саен Халыкара музейлар көне (18 май), Бүләкләр кабул итү атнасы (11–17 июль), Белем көне (1 сентябрь) билгеләп үтелә. Музей тарафыннан «Тәтеш музее язмалары» («Записки Тетюшеского музея») ж-лы нәшер ителгән.

Әд.: Исторические и краеведческие музеи в СССР: Каталог. М., 1988; Российская музейная энциклопедия. М., 2001. Т. 2.

ТӘТЕ́Ш УРМАНЧЫЛЫГЫ́, Тәтеш, Кама Тамагы, Буа һәм Апас р-ннары терр-яләрендә урманнардан файдалану, аларны саклау, яңадан утырту өлкәсендә идарә эшләрен алып бара. 1936 елда Тәтеш урман хуҗалыгы буларак оештырыла. 1962–92 дә механикалаштырылган урман хуҗалыгы, 2007 дән хәзергә исемдә. 2008 ел башына Т.у.ның гомуми мәйданы 37610 *га*. 4 урманчылык — Келәр (10326 *га*), Тәтеш (10656 *га*), Тархан (6806 *га*), Урюм (9822 *га*) участокларыннан тора. Сакланучы урманнар — 27774 *га*, кулланылучы урманнар 9836 *га* били. Урман культуралары мәйданы 8862 *га*. Урман б-н капланган мәйдан 35512 *га*, ш.и. ылыслылар — 1330 *га*, каты яфраклылар — 14614 *га*, йомшак яфраклылар — 19527 *га*, куаклыклар 41 *га* тәшкил итә. Урман барлыкка китерүче төп токымнар: юкә (46%), имән (40%), усак (6%), нарат (3%); каен, чыршы, карагай, корычагач, өрәңге, сары һәм кара зирек, тополь зур булмаган участокларны билиләр. Урманнарның яшь ягыннан структурасы: яшь урманнар — 19%, урта яшьтәгеләр — 46%, өлгереп килүчеләре — 16%, өлгергәннәре — 14%, картайганнары — 5%. Агачның уртача еллык үсеше 115,3 мең *м*³ (ш.и. йомшак яфраклы токымнар — 78,6, каты яфраклылар — 32,6, ылыслылар — 4,1 мең *м*³) күләмдә билгеләнә. Төп кулланылыш өчен урман кисү күләме 11,2 мең *м*³ тәшкил итә. Урман торгызу эшләре ел саен 90 *га* мәйданда алып барыла (имән, нарат, чыршы утыртыла), 70 *га* дан артык мәйданда саклаучы утыртмалар, юл буйларын һәм кырларны ышыклау полосалары булдырыла. 6 урман питомнигында (гомуми мәйданы 19,6 *га*) 10 нан артык исемдәге агач-куак токымнарының 1 млн. га кадәр үсентесе үстерелә. Т.у. терр-ясендә табигать истәлекләре: *Тархан имәнлекләре, «Таштау»* ерым-сызалар системасы, *Антоновка чокыр-лары*, табигать тыюлыклары: *Озын Алан, Лобач тавы, Лабыш таулары* урнашкан. А.М.Ваватов, И.И.Халитов, К.К.Ситров ТРның аткаранган урманчысы исеменә лаек булалар.

И.И.Халитов, Л.С.Панягина.

ТӘТЕШЛЕ́ РАЙОНЫ́, *Башкортстан Республикасының* төньягында урнашкан. 1935 елның 31 гыйнварында оештырыла. Мәйданы — 1376 *км*². Үзәге — Үрге Тәтешле авылы (Уфадан 250 *км* төньяктарак). Халкы — 22918 (1.1.2017), татарлар — 3754 (2010) кеше. Районда 75 торак пункт, ш.и. 3 татар, 20 башкорт-татар, 1 татар-удмурт, 1 рус-татар һәм 1 башкорт-татар-удмурт торак пункты исәпләнә. Татар халык коллективлары: «Нәүрүз» фольклор ансамбле, «Җидегән чишмә» татар җыры вокаль ансамбле, «Таң» тальянчылар ансамбле һәм ш.у. «Яңкәр» инструменталь фольклор коллективы, «Алсу» үрнәк хореография ансамбле эшли. 2014/15 уку елында Т.р.ның 15 мәктәбендә татар теле фән буларак өйрәнелә. «Җитәкче» г-тасы нәшер ителә. Шагыйрь Ә.К.*Атнабаев*-ның, Сов. Союзы Геройлары М.Б.*Бәдретдинов* һәм Г.С.*Сәетов*, ботаник, эколог Р.Г.*Мицлебаев*, геофизик Д.К.*Нургалиев*, җырчылар Х.Ф.*Фәрхи*, С.З.*Фәтхетдинов* һәм мед. фән. д-ры Х.С.Халитовның тормышлары Т.р. б-н бәйле.

«ТӘҮБӘ» мәчете, Чаллы шәһәрендә. 1989–92 елларда арх. М.М.Басыйров проекты буенча шәһәрнең тарихи урынында — Кама ярында төзелә. Ирләр (көнбатыштан) һәм хатын-кызлар (көнчыгыштан) өчен аерым ишек һәм заллары, төньягында 52 *м* биеклектәге манарасы булган катлаулы конфигурацияле бина. Мәчетнең гомуми композициясе төньяктан манара кисеп кергән күпкыеклы түбә астындагы ике рәт тәрәзәле биек күләм б-н формалаша. Төп күләмгә төнъяктан бер катлы корпус тоташкан. Аның өстенә түбә урынына терраса түшәлгән, аннан тамбур аша намаз залына керү өчен манара нигезендә ишек куелган. Мәчетне төнъяк-көнбатыштан дүрт биеклектә мәйданчыклар һәм баскычлар әйләнеп үтә. Вестибюльнең тоташ фәсәсы ир-атлар һәм хатын-кызлар ягына бүленгән. Тәһарәт алу һәм юыну бүлмәләре — вестибюльнең төньягында, баскычлар һәм гардероб көньягында урнашкан. Биредән фойега һәм 130 урынлы тамаша залына үтәргә мөмкин. Төньяк-көнбатыш һәм









1. Тәтеш төбәк тарихы музее;
2. Экспозиция фрагменты;
3. Татар һәм чуаш милли киемнәре. 19 йөз;
4. Кораллар. 19 йөз.

төньяк-көнчыгыш почмакларында баскычлар һәм ир-атлар гыйбадәтханәсе урнашкан төп күләм (18×18 *м*) ике кыеклы түбә б-н ябылган. Төньяк фасадтагы түбә кыеклары арасында коелма пыяладан төсле витражлы вертикаль яктылык уемнары бар. Залның төньяк өлешендә хатын-кызлар өчен балкон урнаштырылган. Сигез кырлы манара чатыр б-н тәгәлләнгән. Мәчет силикат кирпечтән төзелгән. Фасадлар ак таш плитәләр б-н тышланган, көньяк өлеше Коръән текстлары б-н бизәлгән. Эргә шомартылган кара гранит б-н капланган. Зал диварлары медальоннар, ак мәрмәр, уеп ясалган үсемлек нәкыше б-н бизәлгән. Михраб куышы Коръән аятьләре уелган кара мәрмәр б-н каймаланган.

Әд.: Мечети Татарстана / Сост. Х.Г.Надырова, Р.Р.Салихов, Р.Р.Хайрутдинов. К., 2000.

Х.Г.Надыйрова.

ТӘҮГЕЛДЕ́, к. *Кыр Тәүгелдесе*, Буа р-ны.

ТӘҮГЕЛДЕ́ авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 28 *км* көнбатыштарак, Чирмешән елгасы буенда. 2010 елда 229 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — сарык асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, өс-баш киемнәре тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.дә мәчет, мәдрәсә, су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 804 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Урта Балтай волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1935 нең 25 гыйнварыннан — Кайбыч, 1944 нең 19 февраленнән — Подберезье, 1956 ның 17 маеннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 80 ир-ат; 1859 да — 472, 1897 дә — 808, 1908 дә — 928, 1920 дә — 887, 1926 да — 617, 1938 дә — 703, 1949 да — 546, 1958 дә — 447, 1970 тә — 334, 1979 да — 283, 1989 да — 334, 2002 дә — 285 кеше.

ТӘҮДЕ́ шәһәре, *Свердловск өлкәсенең* көнчыгыш өлешендә, *Екатеринбург* шәһәреннән 360 *км* көнчыгыштарак урнашкан. Халкы — 33356 кеше (1.1.2018). Татарлар саны: 1920 дә — 4, 1939 да — 356, 1959 да — 718, 1970 тә — 749, 1979 да — 686, 1989 да — 654, 2002 дә — 491, 2010 да — 472 кеше. 1910 да урман бүлемтеге оештырганда посёлок буларак барлыкка килә, 1937 дән шәһәр. Татарларның Т.гә актив күченүләре 1920 еллар ахыры — 1930 еллар башында агач эшкәртү пр-тиеләре төзелгәч башлана. Бөек Ватан сугышы елларында шәһәрдә татарлар саны монда дәваланганнан соң даими яшәп калучы кызылармиячеләр исәбенә арта. Т.дә мәчет эшли (2000 нән). Ел саен *Ураза бәйрәме*, *Корбан бәйрәме*, *Сабан туе* уздырыла. Шәһәрдә Россия Герое Р.Н.Гайнетдинов туган.

ТӘҮРИ́З РАЙОНЫ́, *Омск өлкәсенең* төньягында урнашкан. Мәйданы — 9,8 мең *км*^{2}. Үзәге — шәһәр тибындагы Тәүриз посёлогы (Омскидан 453 *км* төньяктарак). Халкы — 14335 (1.1.2017), татарлар — 3319 (2010) кеше. Татарлар, тупланып, район үзәгендә, Туйчы, Югары Ай (Нагорно-Аевск), Ташаткан, Байбы, Отыз, Кышлау (Малые Кулары), Кипкуллар, Азы, Тау (Тавинск), Козгын авылларында яшиләр. Район терр-ясендә Татар милли-мәдәни үзәге (Тәүриз), «Дуслык» (Ташаткан, 1980 нән), «Алмаз» (Туйчы, 1988 дән), «Дуслык» (Отыз, 1989 дан), «Нәфис» (Тау, 1992 дән), «Шатлык» (Тәүриз, 2005 тән), «Яшьлек» (Кипкуллар) ансамбльләре эшли. Туйчы, Ташаткан, Байбы, Отыз, Тау мәктәпләрендә татар теле факультатив рәвештә өйрәнелә. Бу торак пунктларда мәчетләр эшли.

ТӘҮХИ́Д (гарәп. توحيد — бер Аллаһка инану), ислам диненең нигезен тәшкил итүче бераллаһлык доктринасы. Аллаһы Тәгаләнең бердәнбер илаһ (гыйбадәткә лаеклы зат, Аллаһ) икәнлегенә ышану. Т.нең капма-каршысы, аны боза торган нәрсә — ширек.

ТӘФКИ́ЛЕВ Котлыгъмөхәммәд Батыргәрәй улы (4.8.1850 — 1917 елдан соң), җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе. *Тәфкилевләр* нәселеннән, морза. Уфа губернасы Бәләбәй өязе дворяны. Пажлар корпусын тәмамлаганнан соң (1870), казаклар полкының лейб-гвардия офицеры. 1877–78 еллардагы рус-төрек сугышында катнаша. 1885 тә полковник дәрәҗәсендә отставкага чыканнан соң, Бәләбәй шәһәрендә яши. 1–4 нче Дәүләт Думалары депутаты (1906–17), 3 нче һәм 4 нче Думада *мөселманнар фракциясе* рәисе. 2 нче Дәүләт Думасында — азык-төлек, сәүдә һәм һөнәрчелек йортларында хезмәткәрләрнең ял итү вакытларын билгеләү; 3 нче Думада — финанс, читтән килеп урнашучылар эше, дәүләт оборонасы, шәхси иминлек турында; 4 нче Думада җирле үзидарә, хәрби һәм диңгез эшләре, азык-төлек комиссияләренә керә. 1916 ның җәендә, казакъларның, кыргызларның һәм Төркестандагы башка Урта Азия халыкларының фетнәләре вакытында, Т. А.Ф.Керенский б-н бергә, халык чуалышларының сәбәбен ачыклау өчен, Думаның махсус комиссиясен җитәкли. 1905 тән кадетларның Уфа оешмасы һәм «Иттифакъ әл-мөслимин» партиясе әгъзасы. Мөселман дини оешмаларын яңартыр коруга багышланган Бөтенроссия мөселман-нарының дүртенче корылтаен оештыруда катнаша (Петроград, 1914; к. *Бөтенроссия мөселманнары корылтайлары*). Бөтенроссия мөселман җәмәгать оешмалары вәкилләре корылтае делегаты (Петроград, 1914 нең дек.), хәйрия учреждениеләренең эшчәнлеген килештерү б-н шөгыльләнүче Россия мөселман җәмәгать оешмаларының ҮКна сайлана. Россия халыклары Конгрессында катнаша (Лозанна, Швейцария, 1916). 1889 дан Бәләбәй өязенең земство яшены гласные, шәрәфле җәмәгать судьясы, Уфа губернасының земство җыены гласные, Уфа шәһәр думасы гласные. Бәләбәй өязе дворяннары башлыгы (1905–10, 1914–17). Дворяннар җир банкының Самара бүлекчәсе әгъзасы (Уфа губернасы дворяннарыннан). Уфа үзара кредитлашу җәмгыяте советы, өлкән яшьтәге



К.Б.Тәфкилев.

мөселман ир-атлар һәм ир балалар ком-ты рәисе. 1917 нең мартында Петроградта Россия мөселманнарының Вакытлы үзәк бюросы әгъзасы. Аннан соңгы язмышы билгесез.

Әд.: Мусульманские депутаты Государственной Думы. 1906–1917 гг. Сб. док. и материалов. Уфа, 1998.

Р.А.Айнетдинов.

ТӘФКИ́ЛЕВ Котлыгъмөхәммәд Мәмеш улы (1674 — 13.4.1766, Вятка губ. Алабуга өязе, хәзер Әгерҗе р-ны Мордыбай а.), Россия дипломаты, генерал-майор (1755), *Тәфкилевләр* нәселеннән, бәк. Хезмәтен император Пётр I вакытында башлый (Прут (1711) һәм Персия (1722–23) яуларында тылмач). 1716 елда кенәз А.Бекович-Черкасскийның Урта Азиягә экспедициясендә катнаша. Шул ук елда Пётр I күрсәтмәсе буенча Астрабад шәһәренә (Персия) җибәрелә, әсирлеккә эләгә; 1718 дә Россиянең Персиядәге илчесе А.П.Волынский катнашы нәтиҗәсендә азат ителә. 1730 да илчелек б-н Кыргыз-Кайсак урдасының Кече җуз ыруы биләмәсенә җибәрелә, казакъ ханы Әбелхәер һәм башка ыру башлыклары б-н җузның Россия империясенә кушылуы, казакъларның Россия гражданлыгын кабул итүләре турында уңышлы сөйләшүләр алып бара, моның өчен аңа полковник дәрәҗәсе бирелә. 1731 дән Оренбург өлкәсендә хәрби-адм. хезмәттә, Оренбург экспедициясе башлыгы И.К.Кирилловның ярдәмчесе (1734), 1735–36 һәм 1755 тә татар-башкорт чуалышларын бастыруда катнаша. Т. тыныч татар-башкорт халкына карата аеруча рәхимсезлеге б-н таныла. 1736 да аның җәза отряды 51 авылны яндыра, Балыкчы волостендагы Сөянтәз авылының барлык кешеләрен кырып бетерә. «Тәфтиләү» тарихи халык җырында Т. исеменә, палач буларак, хурлык тамгасы салына. 1742 дә, татар-башкорт чуалышларын бастыруда катнашканы өчен, офицер дәрәҗәсендәге бригадир чины бирелә. 1739 дан әҗнәбиләр һәм чик буе эшләре комиссиясе башлыгы, Оренбург губернаторы И.И.Неплюевның ярдәмчесе. Кыргыз-кайсакларның, татарларның һәм башкортларның телләрен һәм гореф-гадәтләрен белүен үткен акылы б-н бер-берсенә бәйли алуы нәтиҗәсендә Т. Оренбург өлкәсендә эшләү өчен алыштырғысыз чиновникка әверелә. Яңа җирләрне үзләштерүдәге хезмәтләрен бәяләп, император Анна Иоанновна аңа Иске Балтач авылында (хәзерге Актаныш р-нына керә) 1 мең крепостной татары булган утар бүләк итә. 1742–44 тә аның татар крәстиян-нәреннән торган Тирсә волостендагы биләмәләрендә крепостной тәртипләргә каршы чуалышлар була (*Тирсә крәстияннәре кузгалышы*). Т. 20 гә якын кальгага, ш.и. Оренбург (1735), Орск (1735), Чиләбегә (1736) нигез сала. 1763 тә отставкага чыккач, Барҗы-Алексеевский бакыр эретү з-ды төзи (Тирсә волосте). Т.нең улы Осип (Йосыф) әтисеннән Уфа

наместниклыгында 897, Вяткада 1130, Рязаньда 83 крепостной крәстиянне мирас итеп ала.

Әд.: Х а н ы к о в Я.В. Сведения о роде Тевкилевых и о службе генерал-майора Алексея Ивановича Тевкелева // Временник Имп. Моск. об-ва истории и древностей российских. 1852. Кн. 13; Р ы ч к о в П.И. История Оренбургская. Оренбург, 1896; Башкортостан: Краткая энцикл. Уфа, 1996; Челябинск: Энцикл. Челябинск, 2001.

М.З.Хәбибуллин.

ТӘФКИ́ЛЕВ Сәлимгәрәй Шәрифгәрәй улы (1805, Вятка губ., Алабуга өязе Килем а. — 2.1.1885, Уфа ш.), дин эшлеклесе, *Тәфкилев - ләр* нәселеннән, морза. 1826–33 елларда Павлоградта гусар полкында хезмәт итә. 1828–29 елларда рус-төрек сугышында, 1830–31 елларда поляк баш күтәрүчеләрен бастыруда катнаша. Армия хезмәтеннән киткәннән соң, үз утарында яши. 1848–51 дә Оренбург губернасы Бөгелмә өязендәге татар морзаларының сайлап куелган җитәкчесе. 1852 дә хаҗ кыла. 1865 тән Оренбург Мөселман Диния нәзарәтендә мөфти. Т. Диния нәзарәтен реформалау, мәхәллә руханилары эшчәнлеген җайга салу буенча берничә проект тәкъдим итә (кайберләре аның вафатыннан соң тормышка ашырыла). Татар зыялыларының кайбер вәкилләре Т. эшчәнлегеннән риза булмый. Әйтик, Ш.Мәр җәни аны тормышка ашмас проектлар б-н мавыгуда, күп сөйләргә яратуда гаепли. Т. юмарт хәйрияче буларак шөһрәт казана, Уфада мөселман ятим балалар һәм картлар йортлары ача, байлыгын мәчетләр һәм мәктәпләр төзелешенә васыять итеп калдыра. 1–4 нче дәрәҗә Изге Анна орденнары, Польша орденнары һәм медальләре б-н бүләкләнә.

Әд.: В память столетия Оренбургского магометанского духовного собрания, учреждённого в городе Уфе. СПб., 1892; А з а м а т о в Д.Д. Оренбургское магометанское духовное собрание в конце XVIII — XIX вв. Уфа, 1999.

ТӘФКИ́ЛЕВЛӘР, татар бәкләре нәселе. Чыганакларда 1610 елда Уразлы Тәфкилев «Бежица ягы татары Уразлай Тәфкилев» дип искә алына. Дәүләтмәмәт һәм Габдрахман исемле оныклары була. Уразмәмәт улы Дәүләтмәмәт Владимир губернасының Владимир өязендә җир биләүче, 1669 да Керенск өязенең Шелдаис авылында яшәүчеләр арасында искә алына. Аның улы, Касыйм шәһәре морзасы Мәмеш Касыйм, Владимир, Темников (Тамбов губ.), Керенск өязләрендә җир биләүче дип күрсәтелә. Габдрахман улы Рамазан — йортында тылмач. 1719 ел мәгълүматлары буенча, Касыйм өязе Подлипки авылында утар крәстиянне хуҗасы. Улы Мортаза — Чит илләр коллегиясендә тылмач, коллегия утырышчысы. Әбелгазый Баһадур ханның «Төркиләр шәҗәрәсе» («Шәҗәрәи тюрк») дигән мәгълүм хезмәтенә шәрехләүләр төзи. Рамазанның бер оныгы — Әхмәт Мортаза улы (Михаил Александрович) Бутыр полкында прапорщик булып хезмәт итә.

Т. нәселенең аеруча танылган вәкиле — генерал-майор Котлыгъмөхәммәд Мәмеш улы *Тәфкилев* (Алексей Иванович).

Т. нәселенең күпчелек вәкилләре хәрби - ләр. Котлыгъмөхәммәднең улы Йосыф (Осип Алексеевич) — секунд-майор, 1773 тә Е.И.Пугачёв җитәкчелегендәге крәстияннәр кузгалышын бастырганда һәлак була; оныгы Шаһингәрәй (Пётр Осипович) лейб-гвардиянең атлы полкында ефрейт-капрал булып хезмәт итә. Шаһингәрәйнең ике улы була: танылган дин галиме Сәлимгәрәй *Тәфкилев* һәм майор Батыргәрәй. Батыргәрәйнең улы Котлыгъмөхәммәд Тәфкилев — танылган татар җәмәгать эшлеклесе, 1–4 нче Дәүләт Думала - ры депутаты (1906–17).

Т. эре җир биләүчеләрдән саналалар: Шаһингәрәй Йосыф улының Уфа, Вятка, Рязань наместниклыкларында 2110 крәстияне була. 1773 тә Котлыгъмөхәммәд Мәмеш улы Казан губернасының Тирсә волосте морзалары Яушевлардан крәстияннәре б-н бергә җир сатып ала (Биектау, Мордыбай, Наҗар, Тирсә авыллары). 18 йөзнең 2 нче яртысында Т. Оренбург губернасының Канлы һәм Кыр Елан волосте башкортларыннан күп кенә күләмдә җир сатып алалар һәм Минзәлә өязенең Кәзкәй, Сарапул өязенең Иске Балтач авылларындагы үз крепостной крәстияннәрен урнаштыралар. 19 йөз уртасында Т. Уфа губернасы Бәләбәй өязенең Ахун, Каръяуды, Килем, Яңа Балтач, Яңа Каръяуды, Яңа Килем, Минзәлә өязенең Кәзкәй авыллары һәм Уфа губернасының Оренбург өязе Тәфкил хуторы крепостной крәстияннәренә хуҗа булалар. Т. утары Килем авылында урнаша. Ш.у.к. *Тәфкилевләр йорт-утары, Тирсә крәстияннәре кузгалышы.*

Әд.: Х а н ы к о в Я.В. Сведения о роде Тевкелевых и о службе генерал-майора Алексея Ивановича Тевкелева // Временник Имп. Моск. об-ва истории и древностей российских. 1852. Кн. 13; Г и л я з о в И.А. Помещики Тевкелевы в XVIII — начале XIX вв. // Классы и сословия России в период абсолютизма. Куйбышев, 1989; Г а б д у л л и н И.Р. От служилых татар к татарскому дворянству. М., 2006.

Р.А.Айнетдинов.

ТӘФКИ́ЛЕВЛӘР ЙОРТ-УТАРЫ́, татар архит-расы истәлеге. Башкортстан Респ-ка - сы Бүздәк р-ны Килем авылында. 1848–52 елларда татар бәге К.М.*Тәфкилев* нәселе вәкилләре утарында корыла. Император Екатерина II аңа Сәрмәсән елгасының сулъяк ярыннарын, ш.и. Килем авылын бүләк итә. Архитекторы билгесез. 3 *га* мәйдандагы утар ике парктан: Идәш елгасы тугаендагы — түбәнге һәм тугайдан 15 *м* биеклектәге үрге парклардан тора. Утар үрге паркның түрендә, яр буендагы тау битендә урнашкан. Дүрт кыеклы түбә б-н ябылган, романтик юнәлештәге эклектика стилендә үзәктән симметрияле итеп корылган ике катлы кирпеч бина. Киль рәвешендәге аттиклар һәм фланглаштырылган алты кырлы колонна б-н төгәлләнгән ризалитлар Т.й.-у.ның буй фасадларындагы симметрия үзәген ачып тора. Колонналар ризалитлар б-н бертигез биеклектә һәм кирпеч дивардан яртылаш чыгып торалар. Манараларга охшаш цилиндрик почмак башнялары б-н бина өстеннән калкып торган вертикальләрнең уртаклыклары бар. Алты кырлы калын терәкләр (һәр яктан өчәр) икенче катның террасасын күтәреп тора. Терәкнең таш шарлар б-н төгәлләнгән өске өлеше балюстрада б-н бергә террасаны киртәли. Әлеге монументаль портик йортның ел - гага һәм түбәнге паркка алып чыгучы көньяк фасадындагы ишеген аерып күрсәтә. Аның б-н бер күчәрдә, ләкин элек үрге паркка караган төньяк фасадта төп ишек урнашкан. Т.й.-у. биналары биек, уксыман тәрәзәләр б-н яктыртылган, аларның өске өлешләре шәкелле йөзлекләр б-н каймаланган. Бина штукатурлап агартылган. Кәрнизләрдәге һәм манараладагы декор элементлары, аркатуралы аттик Т.й.-у.на шәрекъ колориты бирә. Ян фасадка сул яктан йорт-утарның симметрик чишелешен бозучы бер катлы кирпеч бина кушып салынган. Ул совет чорында, йорт-утар мәктәп итеп файдаланылганда барлыкка килә. Т.й.-у.нда 2002 дән реставрация алып барыла, анда музей һәм мәдрәсә ачыла.

1821 дә төзелеп 1856 да реконструкцияләнгән ике катлы кирпеч мәчет Т.й.-у. б-н бердәм комплекс хасил итә. Манарасы түбә үзәгеннән күтәрелгән традицион татар мәчетләре төренә керә. 1825 тән мәчет бинасында мәдрәсә эшли. 1930 еллар башыннан ул ашлык амбары һәм товар склады итеп файдаланыла. 1997 дә мәчет диндарлар җәмгыятенә тапшырыла. 2002 дә реставрация эшләре тәмамлана.

Әд.: Х у с а и н о в А. Судьба Килимовского дворца // Татар дөньясы — Татарский мир. 2007. № 3.

Х.Г.Надыйрова.

ТӘФСИ́Р (гарәп. تفسير — аңлату, төшендерү, шәрехләү), *Коръәннең* фәлсәфи аңлатма-шәрехләмәсе; ила һият белемендә аерым жанр. Элек Т. сөйләм формасында яшәгән. Мөселман традициясе *Мөхәммәд* пәйгамбәрнең туганнан туган энесе Гали ибне Габбасны (686 да вафат) Т. жанры юнәлешенә нигез салучы итеп таный. Урта гасырда яшәгән гарәп, һинд, фарсы илаһиятчеләре М.Айнтаби, әл-Бәлхи, әл-Бәйдавый, әл-Бохари, әл-Җуфи, әз-Зәмәхшәри, Ибне Кәссир, әл-Күртүби, әр-Рази, әс-Суюти (әл-Мәхәлли б-н бергә иҗат итә), әс-Сүдди, әс-Сәгалиби, әт-Табари, әт-Тустари арада иң абруйлы Т. авторларыннан. 19–20 йөзләр чигендә мөселман ила һиятчеләрен Европа фәнни фикере б-н таныштыручы Т.ләр (М.*Габдөһү* һәм Р.Рида), социаль аңлатма бирү юнәлешендәге Т.ләр (С.Котб) барлыкка килә. Коръәнне гарәп теленнән башка телләргә тәрҗемә итү бик күп еллар тыелу сәбәпле, гарәп телен белмәгән мөселманнарны Коръән б-н таныштыруда Т. һәм шәрехләмәләр мөһим роль уйный. 12–13 йөзләрдә Каршы (Үзбәкстан) шәһәрендә табылган Т. төрки телдәге тәүге Т.ләрнең берсе дип фаразлана. Коръәндәге аерым сүрәләрнең татар телендәге Т.е 16 йөздән мәгълүм (1507, 1653, 1663 елларга караган Т.ләр табыла). Кулъязма хәлендә сакланган Т.дән Г.*Курсавиның* «Һәфтияк тәфсире» («Коръәннең 1/7 өлешенә аңлатма») аерым игътибарга лаек. ТР терр-ясендә татарлар арасында да популяр булган төрек телендәге күпсанлы кулъязма Т.ләр сакланган (мәс., М.Айнтабиның «Тәфсирү Тибйән» («Коръән тәфсире» китабы). Т.нең татар телендә

дөнья күргән 20 гә якын басмасы булуы мәгълүм, шулардан Х.Әмирханның «Әл-Фәваид» («Файдалы китап», 1870–80), Ш.Хәмидинең «Әл-Иткань фи-тәрҗимәтил-Коръән» («Коръәннең камил тәрҗемәсе», 1907; 2 басма, 1911), Ногманиның «Тәфсире-Ногмани» («Ногмани тәфсире», Оренбург, 1907; 2 басма, 1911), М.Иманколыйның «Тәс Ыйүл-бәйан фи тәфсирил-Коръән» («Коръән шәрехләмәсенә җиңелчә аңлатма», 1–2 т., 1910–11), К.*Мотыйгыйның* «Татарча Коръән тәфсире» (1914) китаплары аеруча популяр була. 1990 нан соң Россиядә басылган Коръән шәрехләмәләре арасында ила Ыият галимнәре Абдулла Йосыф Али («Изге Коръән», Түбән Новгород, 2007) һәм Габдрахман бине Насыйр әс-Сәгъди («Изге Коръәнне шәрехләү», 1–3 т., М., 2007–08) Т.ләре аеруча киң тарала.

Әд.: Ф ә х р е т д и н о в Р. Коръән вә табигать. К., 1900; ш у л у к. Дини вә иҗтимагый мәсьәләләр. Оренбург, 1914; Б и г и е в М. Тәзриҳүл-Коръән вәл-Масахиф. СПб., 1905; Б о р о в к о в А.К. Лексика среднеазиатского тафсира XII–XIII вв. М., 1963; Зайнуллин Дж. Г. Во имя Аллаха. К., 1999.

ТӘХӘВЕТДИ́НОВ Рөстәм Гомәр улы (16.4.1964, Мамадыш р-ны Түбән Тәкәнеш а. — 7.6.2008, Казан), химик технол. процесслары һәм аппаратлары өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2000), проф. (2005). 1986 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казан технол. ун-тында эшли. 2002–08 дә Казан энергетика ун-тының информатика һәм информацион-идарә системалары каф. профессоры. Хезмәтләре химик технол. аппаратларында үзара бәйләнешле күчеш һәм химик әверелеш күренешләрен тикшерүгә, гидродинамика һәм җылылык-масса алмашу процессларын компьютерда модельләштерүгә карый. Т. сәнәгать полимерлагычларын табу алымнарын, аппаратларын (кече габаритлы көпшәсыман турбулент реактор-катнаштыргычлар, реакция катнашмасы кайный торган реакторлар), ш.у. аларның тәэсир көчен арттыруның югары нәтиҗәле ысулларын эшли. Уйлап табуга 4 патенты бар.

Х е з м.: Автомодельный режим течения потоков в трубчатых турбулентных аппаратах струйного типа // Докл. РАН. 2000. Т. 372, № 3 (автордаш); Влияние диффузионных сопротивлений на перенос мономеров у межфазной поверхности // Теорет. основы хим. технологии. 2000. Т. 34, № 1 (автордаш); Информационно-измерительная система оценки потерь тепловой энергии // Изв. вузов. Проблемы энергетики. 2004. № 11/12 (автордаш).

ТӘХӘВЕТДИ́НОВ Шәфәгать Фәхрази улы (23.4.1946, Әлмәт р-ны Габдрахман а.), хуҗалык эшлеклесе, нефтьче, икътисад фән. д-ры (2006), РФнең атказ. нефть һәм газ сәнәгате хезмәткәре (1993), ТРның атказ. нефтьчесе (1996), ТР ФАнең шәрәфле академигы (2008). Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тын тәмамлый (1971). 1965 елдан «Татнефть» АҖдә (бүленеп: 1985–90 да КПССның Лениногорск шәһәр ком-тының 1 нче секретаре): Әлмәт бораулау эшләре идарәсендә, 1978 дә «Җәлилнефть» НГДУы башлыгы, 1983–85 тә — «Әлмәтнефть»тә, 1990 нан баш инженер — ген. директорның беренче урынбасары; 1996 да «Татарстан Респ-касының нефть чыгару район - нарында техногенез, мониторинг, халык сәламәтлеге һәм экологик халәтне яхшырту чараларын сәнәгый кулланышка кертү» дигән уртак хезмәт өчен фән һәм техника өлкәсендә ТР Дәүләт бүләгенә лаек була. 1999 дан «Татнефть» АҖ ген. директоры, бер үк вакытта «Түбән Кама нефть эшкәртү заводы» һәм «Түбәнкамашин» (2000 нән) АҖләренең директорлар советы рәисе, 2013 тән нефть сәнәгате буенча ТР Президенты киңәшчесе. Т. җитәкчелегендә «Татнефть» берләшмәсендә нефть чыгару күләмен арттыру, икътисади кризис елларында компаниянең финанс хәлен тотрыклыландыру, респ-када нефтьне тирәнтен эшкәртүне оештыру буенча зур чаралар комплексы үткәрелә. «Татнефть» Түбән Кама шәһәрендә РФдә иң зурлардан булган нефть эшкәртү з-дын төзүдә төп инвестор булып тора, аның база комплексы исә 2010 да төзелә башлый. «Татнефть» АҖ 2000 елларда РФнең төрле төбәкләрендә: Самара, Ульянов, Оренбург өлкәләре, Калмык Респ-касы, Ненец автономияле округында һәм күп кенә чит илләрдә: Гыйрак, Иран һ.б.да нефть чыганакларын эшкәртү буенча эшчәнлеген шактый киңәйтә. Берләшмә читкә товар чыгара һәм заманча технол. проектларны тормышка ашыра. Т. респ-каның нефть район - нарында зур социаль проблемаларны хәл итүдә, мөһим экологик чаралар үткәрүдә, Әлмәт шәһәренең инфраструктурасын үзгәртеп коруда, Казан һәм ТРның башка шәһәрләрендәге мөһим тарихи һәм архит-ра һәйкәлләрен реставрацияләүне финанслауда актив катнаша. «Татнефть» АҖнең актив катнашы нәтиҗәсендә тузган торакны бетерү программасы тормышка ашырыла, Казанда Колшәриф мәчете, «Татнефть Арена» боз сарае төзелә, Казан Кремленең архит-ра ансамбле реставрацияләнә, Казан ун-тының уку корпусы җи Ыазлана. Т. — «Ак Барс» хоккей СК һәм ТР Хоккей Федерациясе президенты (2004 тән). Ул чорда «Ак Барс» 3 тапкыр РФ чемпионы (2006, 2009, 2010), 2 тапкыр Континенталь хоккей лигасы (КХЛ) чемпионы, Гагарин Кубогы иясе (2009, 2010) була. Хезмәтләре нефть-газ комплексы б-н нәтиҗәле идарә итү, әйләнә-тирә мохитне яхшырту проблемаларына карый. 1995–2014 тә ТР Дәүләт Советы депутаты. Уйлап табуга күп кенә авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Зур чыганаклары эшкәртүнең соңгы стадияләрендә нефть чыгаруны тотрыклыландыру буенча технологияләр комплексын фәнни нигезләве һәм сәнәгатькә кертүе өчен РФ Хөкүмәте бүләгенә лаек була. Хезмәт Кызыл Байрагы, Дуслык, 3 нче һәм 4 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Әлмәт р-нының (2001), Әлмәт (2001) һәм Казан (2008) шәһәрләренең Мактаулы гражданы.



Ш.Ф. Тәхәветдинов.

Х е з м.: Технологические проблемы эксплуатации нефтяных месторождений // Нефть и наука. К., 1993; Мониторинг природной среды при разработке битумных залежей. К., 1996 (автордаш).

Әд.: М е л у а А.И. Геологи и горные инженеры России: Энцикл. М.–СПб., 2003. Т. 1; Әлмәт — Альметьевск. К., 2003.

ТӘХӘВИ́ЕВА Диләрә Гобәй кызы (20.12.1924, Казан — 26.6.2013, шунда ук), травматолог-ортопед, мед. фән. д-ры (1973), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1981). Проф. Л.И.Шулутко шәкерте. Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1949), Казан Травматология һәм ортопедия фәнни-тикшеренү ин-тында эшли, 1962 елдан директор урынбасары, 1988 дән фәнни консультант. 1989–94 тә ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының Респ-ка диагностика үзәге консультанты. Хезмәтләре сөяк тукымасы трансплантациясенә карый. «Почёт билгесе» ордены, медальләр, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Экспериментальное обоснование применения остеопериостальной декортикации при костной гомопластике // Ортопедия, травматология и протезирование. 1971. № 8; Определение механических характеристик костной ткани методом голографической интерферометрии // Ортопедия, травматология и протезирование. 1980. № 7 (автордаш).

Әд.: К а м а л о в И.Н. Доктор медицинских наук Диляра Губаевна Тахавиева // Казан. мед. журн. 1985. № 1.

ТӘХӘВИ́ЕВА Фәридә Вазыйх кызы (27.9.1959, Казан), дәвалау физкультурасы һәм спорт медицинасы табибе, мед. фән. д-ры (2005). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1982), Казан ГИДУВының дәвалау физкультурасы кафедрасында эшли. 1985 елдан Мәскәү мед. стомат. ин-тының дәвалау физкультурасы һәм спорт медицинасы кафедрасында. 1989 дан Казан мед. ин-тының (хәзер Казан мед. ун-ты) неврология һәм реабилитация кафедрасында. Хезмәтләре нейро - реабилитациягә, травматология һәм ортопедия реабилитациясенә карый.

Х е з м.: Лечение больных гипертонической болезнью с помощью дозированных физических тренировок в условиях стационара // Вопр. курорто - логии, физиотерапии и лечебной физкультуры. 1989. № 6 (автордаш); Прогноз восстановления двигательных функций у больных с острым нарушением мозгового кровообращения // Казан. мед. журн. 2004. № 2; Физиотерапия. К., 2006 (автордаш).

ТӘХМИ́С (гарәп. تحميس — бишьюллык), башка авторларның әсәрләрендәге һәр бәеткә өчәр мисрагъ өстәп иҗат ителгән лирик җанр. Т.нең төп үзенчәлеге: тышкы формадан тыш башкаларның шигъри юлларын файдалану. Мәс., Ш.Бабичнең «Әсма» китабындагы шигырьләргә тәхмис» шигыре Дәрдемәндның «Үткән көннәр» газәленә Т.

Әд.: Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990.

ТӘХСИ́Н ҖӘМИ́Л (21.9.1943, Румыниянең Меджидия ш.), тарихчы, тарих фән. д-ры (1976), дипломат, җәмәгать эшлеклесе. А.Кузы исем. ун-тны (Яссы ш.) тәмамлый. 1966 елдан А.Ксенопол исем. тарих һәм археол. фән - ни-тикшеренү ин-ты хезмәткәре, 1977 дән Милли архивлар ин-ты баш архивчысы. 1984–98 дә Тарих фәнни-тикшеренү ин-ты

(Бухарест) хезмәткәре. Бер үк вакытта, 1991 дән, Овидий исем. ун-т (Констанца ш.) профессоры, 1996 дан Халыкара мөнәсәбәт - ләр ин-ты хезмәткәре. 1998 дән Румыниянең Әзәрбай җан Респ-касындагы илчесе. Румыния төрки-мөселман татарларыннан Румыния парламенты депутаты (1996 дан). «Румыния төрки-мөселман татарларының демократик берлеге»н оештыручыларның берсе һәм аның беренче президенты. Төрки тарих җәмгыяте (академиясе) әгъзасы. Хезмәтләре Румыниянең урта гасырлар тарихына карый.

Хезм.: The Romanian Countries in the International Political Context, 1921–1972. Bucharest, 1972; The Romanian Countries in Turkish Documents, 1601–1712. Bucharest, 1984; The Romanian and the Turks in the XIV–XVI Centuries. Bucharest, 1991.

ТӘҺАРӘ́Т (гарәп. طهارة — чисталык, чистарыну), юыну йоласы, *ислам* дине кагыйдәләренең берсе. Намазга әзерләнгәндә мәҗбүри шарт булып тора. Т. эчке (гөнаһ яки начар гамәл кылганнан соң иман яңарту) һәм тышкы (тәнне, өс-баш, аяк киемнәрен, йорт кирәк-ярагын һ.б.ны чистарту) төрләргә бүленә. Эчке Т.кә тормышта тәкъвалык, тәүбә итү, изге эшләр һ.б. б-н ирешелә. Тышкы Т.кә табигый арулануның барлык төрләре: намаз алдыннан өлешчә юыну яки бөтен тәнне юу (госел), якын-тирәдә су булмаса, ком, балчык б-н тәһарәт алу да рөхсәт ителә, бу тәям - мем дип атала), теш чистарту, табигый ихтыяҗларны үтәгәннән соң юыну, чиста өс-баш, аяк киемнәре кию һ.б. керә. Т. алганда яки аннан соң табигый ихтыяҗларны башкару, канау, үлекләү, косу, аң югалту, ятып йоклау, исерткеч әчемлекләр эчү, кычкырып көлү очракларында Т. бозылган дип санала. Т. ш.у. йорт-җирне чиста, ару тотуны таләп итә. Пычранган урыннарны су б-н чистарту, мәет юу да тәһарәт йолаларына карый. Дин-этика, гыйбадәт мәгънәсендәге Т. — барлык әшәкелекләрдән арындыручы йола. Ул мөселман халыкларының көнкүрешендә санитария культурасын югары дәрәҗәдә тотуда йөзләрчә еллар дәвамында гаять зур роль уй - ный.

Әд.: Шейх Баянуни. Тахарат и Намаз по ханафитскому фикху. К., 1998; Аль-Кок-Кози М. Мухтасар Ильмихал. СПб., 2002; Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

«ТВЕРИТИ́НОВСКАЯ», чия сорты, 1964 елда Татарстан респ-ка тәжрибә станциясен - дә А.М.Тверитинов, А.С.Вологдина һәм Л.А.*Севастьянова* тарафыннан чыгарыла. Уртача өлгерешле сорт, салкынга чыдамлы - гы уртача, авыруларга чагыштырмача чыдам, үзеннән-үзе серкәләнми. Уртача биеклектә. Ябалдашы җәенке, уртача куелыкта. Җимеш - ләре уртача зурлыкта (3,8 *г*), озынча, куе кы - зыл төстә, яңа өлгергән һәм эшкәртелгән ки - леш кулланыла. 3–4 елдан җимеш бирә баш - лый, уңышы — бер куактан 20–25 *кг*. Иң ях - шы серкәләндерүчеләре — «Владимирская», «Заря Татарии», «Краса Татарии» сортла - ры. 1993 тән Татарстан һәм Мордва Респ-ка - ларында районлаштырылган. Коллектив һәм йорт яны бакчаларында үстерелә.

Әд.: Фруктовый сад Татарстана. К., 2005.

Л.А.Севастьянова, В.А.Наумов.

«ТВЕРЬ», галера. 1767 елның май–июнь айларында император *Екатерина II* нең Идел буйлап сәяхәте өчен махсус төзелә. 1767 дә Тверьда суга төшерелә. Озынлыгы 154 фут һәм 6 карыш (47,2 *м*), киңлеге 27 фут (8,2 *м*). Корпусы яшел төстә; диңгез мифологик фигуралары б-н, арткы өлеше император гербы һәм Екатерина II нең вензеле б-н бизәлә.



«Тверь» галерасы. 20 йөз башы фоторәсеме.

«Т.»ның арткы өлешендә император һәм аның яранарының бүлмәләре урнашкан. 1767 нең маенда Екатерина II шу ң утырып Казанга килә. Сәяхәт тәмамланганнан соң, галера Казанда саклана. 1956 да янгын вакытында юкка чыга.

Әд.: Корнилов П.Е. Памятник Волжского судоходства галера «Тверь» XVIII в. К., 1927.

ТВЕРЬ ҖАМИ́ГЪ МӘЧЕТЕ́, дини архит-ра истәлеге. Тверьда мөселман мәхәлләсе 19 йөз ахырында, Тверь гарнизонына хәрби мулла билгеләнгәннән соң барлыкка килә. 1906 елда мөселман гражданнар җәмгыяте оештырыла. Мәчет 1906 да арх. Б.Г.Поляк проекты буенча татар сәүдәгәре Ф.И.Алышев һәм хәрби мулла Х.Сәетбор һанов акчасына төзелә. 1935 тә ябыла, кибет һәм кафе буларак файдаланыла. 1992 дә диндарлар җәмгыятенә кайтарыла.

Ике рәт тәрәзәле, турыпочмаклы мәчетнең өч яруслы манарасы — бинаның төньягында, ишек челтәрләп бизәлгән түгәрәк балконлы һәм уксыман гөмбәзле, цилиндр кәүсәле манараның турыпочмаклы аскы катында урнашкан. 16,5 *м* биеклектәге манара бина үзәгенең сул ягында күтәрелгән, уң ягында исә төп бинага бер катлы вестибюль кушылып киткән. Ике рәт тәрәзәле намаз уку залы биек әркалы тәрәзәләр һәм икенче каттагы түгәрәк уентыларга урнаштырылган сигезпоч - маклы йолдызсыман тәрәзәләр б-н яктыр -



Тверь җамигъ мәчете.
Архитекторы Б.Г.Поляк. 1906.

тылган. Өчкырлы михраб бинаның көньяк өлешендәге тәрәзәсез фасадында корылган. Түбәнең зал күләме өслеге үзәгендә һәм поч - макларында гөмбәзләр калыккан. Мәчет романтик юнәлештәге модерн стилендә, мавритан чалымнары кертеп бизәлгән (дивар - ларның «тешле» очлары, дагасыман әркалар, ак һәм кызыл төсләрнең аралашып килүе һ.б.). 1950 елларда төп гөмбәз һәм почмаклардагы гөмбәзләр сүтелә. 2000 елларда реконструкцияләнә.

Әд.: Батыргарей Ф. Татары в Тверском крае: Ист.-этногр. очерк. Тверь, 2004.


Е.В.Липаков, Х.Г.Надыйрова.

ТЕА́ТР, халык алдында тамашалар б-н чыгыш ясап, актёрлар башкарган сәхнә күре - неше аркылы чынбарлыкны гәүдәләндерүче сәнгать төре. Казанда халык алдында башкарыла торган беренче театраль тамашалар 1723–26 елларда оештырыла: славян-латин руханилар мәктәбендә (алга таба — семина - рия) укытучы В.Я.Свентицкий (Свенциц - кий) җитәкчелегендә зур христиан бәйрәмнәренә туры китереп «комедия акцияләре» уздырыла. 1758/59 уку елында Казан гимназиясендә аның директоры драматург М.И.Верёвкин җитәкчелегендә гимназия укучылары һәм укытучылары катнашында спектакльләр, ш.у. күренекле дворян гаиләләреннән чыккан һәвәскәрләр катнашында «затлы спектакльләр» куела башлый. Гимназия театры сәхнәсендә А.П.Сумароковның «Синав һәм Трувор», «Семира», «Ялган бирнә» («Приданое обманом»), М.И.Верёвкинның «Төп-төгәл» («Точь-в-точь»), «Шулай тиеш» («Так и должно»), Ж.Б.Мольерның «Ир - ләр мәктәбе» («Школа мужей»), ш.у. гимназия укытучылары тарафыннан иҗат ителгән, аллегорик формада Екатерина II не данлаган «Прологлар» буенча спектакльләр күрсәтелә. 1791 дә Казан наместниклыгы идарәчесе кенәз С.М.Баратаев юллавы б-н Казанда халык Т.ы ачыла. С.-Петербургтан килгән актёр В.Р.Бобровский гимназия тәмамлаучылардан һәм халык уч-щесе укыту - чыларыннан труппа оештыра. Беренче спектакльләр, шушы максатларны күздә тотып, Воскресенский (хәзер Кремль) урамында арендага алынган И.И.Мергасов йортында уза. Драма әсәрләре б-н бергә муз. әсәрләр дә сәхнәләштерелә; аларның кайберләренең авторы Казан руханилар семинариясен тәмамлаган комп. П.И.Протопопов була. Бобровский Т.ы 1796 га кадәр эшли һәм 1800 дә кыска гына вакытка эшчәнлеген яңадан башлап җибәрә. Бер үк вакытта алпавыт утарларында (мәс., Зөя өязенең Юмат авылында) крепостной театрлар барлыкка килә, аларда «йорт» спектакльләре оештырыла. Танылган нәкышьчеләрнең сынлы сәнгать әсәрләре, мәсәл, мәзәк һәм кыска хикәя сюжетларына эшләнгән «тере картиналар» (мимика күренешләре) популярлык казана. Башкару сәнгате Көнбатыш Европа үрнәкләренә иярү һәм халык Т.ы алымнарын файдалану нигезендә формалаша. 19 йөз дәвамында Казанда Т. хосусый антреприза сыйфатында эшли, труппалар һәвәскәрләрдән һәм башкала театр мәктәпләрен тәмамлаучылардан оеша. 19 йөз

башыннан Казан Т.ында П.А.Плавильщиков б-н М.С.Щепкинның турыдан-туры йогынтысында реалистик сәхнә уены раслана, актёрлык сәнгате хис-кичерешләр хаклыгына һәм тормыш хакыйкатенә нигезләнә. Казан шәһәр Т.ы мәшһүр антрепренёрлар Н.К.Милославский, П.М.Медведев, М.М.Бородай, Н.И.Собольщиков-Самарин җитәкчелегендә Россия провинциясенең әйдәп баручы Т.ларыннан берсе буларак таныла. Анда иҗатлары рус Т.ы тарихына кереп калган күп кенә актёрлар эшли. 1874 тән даими рәвештә *Казанда опера сезоннары* уздырыла башлый. 1919 га кадәр эшләп килгән хосусый антреприза 1919 дан соң дәүләт статусы ала, 1996 да театр сәнгате өлкәсендәге казанышлары өчен акад. дәрәҗәсенә лаек була (к. *Казан Зур драма театры*).

Шәһәр думасына караган Т. бинасын арендага алган труппа б-н берраттан шәһәрдә һәм Казан губернасы терр-ясендә Казандагы Яңа, Шәрекъ, Сәүдәгәрләр, приказчиклар корпоратив һәм җәмәгать клублары, Алафузов Т.ы, Н.В.Гоголь исем. Т., ш.у. Чистай, Алабуга шәһәрләрендәге клублар, Т.лар биналарында хосусый Т. антрепризалары эшли. 20 йөз башына кадәр шәһәр һәм авыл дворяннары утарларында «йорт спектакльләре» оештыру дәвам итә, анда катнашу өчен якын-тирәдәге авыллардан асраулар һәм крәстияннәр җәлеп ителә. 20 йөздә, аеруча Гражданнар сугышы елларында, һәвәскәр театр сәнгате киң җәелә, Т. төркемнәре хәрби частьларда, дәүләт учреждениеләрендә, югары һәм урта уку йортларында, сәнәгать пр-тиеләрендә оеша (алга таба югары осталыкка ирешкән үзешчән Т. коллективлары мактаулы «халык Т.ы» исемен ала). 1932 дә балалар һәм яшүсмерләр өчен үзенчәлекле репертуарга ия Т. (ТЮЗ) оештырыла. Ул актёрларның теге яки бу рольне башкару үзенчәлекләре ягыннан аерылып тора, спектакльләр кую б-н берраттан тамашачылар арасында агарту һәм пед. эш-чәнлек алып бара. Бер үк вакытта Петрушка халык Т.ы, рев-ция чорындагы агиттеатр тәҗрибәләрен үзләштергән курчак Т.ы барлыкка килә.

Татар Т. сәнгате, аның заманча сәхнә формалары 19 йөз ахырында формалаша башлый. 1898 дән Казан татар укытучылар мәктәбендә иң элек рус телендә спектакльләр куела башлый (катнашучылар арасында — Әхмәтвәлиев, С.Искәндәров, Мөлеков, Ханбәков, Хәсәнов, Чанбарисов). Югары татар мәктәпләре (мәдрәсәләре) укучылары (шәкертләре) тарафыннан тормышчан күзәтүләргә нигезләнгән комедия һәм сатирик характердагы кыска спектакльләр куела. Шәкертләрнең Т. сәнгате билгеле бер дәрәҗәдә рус Т.ына иярү нигезендә барлыкка килә. Шәкертләр шамакайларның, *чичәннәрнең* Идел буе Болгар дәүләте чорларыннан укбилгеле халык мәзәкчеләре, тапкыр сүз остала-лары, әкиятчеләре алымнарына охшаш, халык арасында киң кулланылышта булган уен ысулларыннан, ш.у. Шәрекъ илләрендә танылган кызыкчылар, мәсхәрәчеләр чыгыш ясаган мәйдан Т.ы традицияләреннән активфайдаланалар. Бер үк вакытта алдынгы карашлы татар зыялылары мохитендә «йорт» спектакльләре күрсәтү традициясе генә гадәткә кереп калмый, түгәрәкләр дә оеша, аларда татар телендә язылган беренче тәр җәмә һәм оригиналь драма әсәрләре укыла, фикер алышулар була, соңыннан әсәрләр сәхнәләштерелә. Мондый түгәрәкләр һәм спектакльләр Уфа, Чиләбе, Әстерхан, Оренбург, Троицк, Орск, Павлодар, Кустанай, Ташкент, Төмән шәһәрләрендә дә танылу ала. Казанда 1903 тә бертуган И. һәм Г.Габитовлар башлангычында барлыкка килгән «Шимбәчеләр» түгәрәге аеруча популяр була (аның әгъзалары, нигездә, студентлар, гимназия укучылары, шәкертләр). Түгәрәк утырышларына соңыннан сәясәт эшлеклеләре, язучылар, драматурглар булып танылган М.Вахитов, Х.Ямашев, Ф.Әмирхан, Г.Коләхмәтов һ.б. йөри. Башта әлеге спектакльләрнең тамашачылары, нигездә, дус-ишләр һәм якын танышлар була, әмма 1905–06 да халык алдында спектакльләр оештыру омтылышы күзәтелә. 1906 ның 22 декабрендә түгәрәк әгъзалары тарафыннан



1906 елның 22 декабрендә Казанда Яңа клуб сәхнәсендә тәкъдим ителгән «Кызганыч бала» (Н.Кәмал) спектакленең афишасы.

Яңа клуб сәхнәсендә төрек драматургы Н.Кәмалның «Кызганыч бала» пьесасы буенча спектакль куела. Бу көн татар халык Т.ының рәсми туган көне санала (спектакльдә катнашучылар арасында — Әминә, Зәйнәп һәм Әбүбәкер Терегуловлар, Р.Габитова, Ш.Мөхәммәдъяров, Ш.Сүнчәләй, Г.Сәйфелмөлеков). 1905 тә Казан татар укытучылар мәктәбен тәмамлаган И.Кудашев-Ашказарский даими проф. нигездә эшләү нияте б-н Оренбургта татар Т. труппасы оештырырга омтылыш ясый. Иске карашлы мөселман рухани-лары һәм сәүдәгәрләр катлавы басымы б-н шәһәр хакимияте труппа әзерләгән спектакльне күрсәтүне тыя, шулай да И.Кудашев-Ашказарский җитәкчелегендә төзелгән *Россиядә беренче күчмә мөселман драма артистлары труппасы* 1907 дә Оренбург, соңрак Самара, Сембер, Казан, Чистай, Түбән Новгород, Касыйм, Рязань һәм Мәскәүдә чыгышлар ясый. Бер үк вакытта, 1907 дә, татар Т. труппасы Әстерханда оеша, 1907 дә — Г.Камиев җитәкчелегендә «Сәйяр» (Оренбург ш.), 1912 дә — С.Гыйззәтуллина-Волжская җитәкчелегендә «Нур» (Уфа ш.), 1915 тә В.Мортазин-Иманский җитәкчелегендә «Ширкәт» (Оренбург ш.) труппалары барлыкка килә. Аларның уңышлы эшләвенә татар драматургиясенә нигез салыну зур йогынты ясый. 1920 еллар ахырына татар Т.ы репертуарын, нигездә, Г.Камал, Г.Исхакый, Ф.Бурнаш, Г.Коләхмәтов, М.Фәйзи, И.Богданов, С.Рәмиев, Ф.Сәйфи-Казанлы, Ф.Әмирхан, К.Тинчурин, Ш.Камал, Г.Ибраһимов, Т.Гыйззәт, Н.Исәнбәт кебек татар авторларының пьесалары тәшкил итә. Рус Т.ы тәжрибәсен иҗади үзләштерү б-н бергә халыкчан тамашаларның традицион формаларын файдалану үзенчәлеклелеге б-н аерылып торган милли Т. мәктәбе тууга этәргеч бирә. 1919, 1920, 1922 дә татар Т.ы өчен актёрлар һәм режиссёрлар әзерләүче махсус уку йортлары ачылу профессиональләшү юлыннан алга таба үсеш юнәлешләрен билгели. 1920–22 дә аңа кадәр эшләгән «Сәйяр», «Нур», «Аң» татар күчмә Т. труппалары нигезендә Беренче татар дәүләт Т.ы (хәзер *Татар академия театры*) оеша. Ул 20 йөз ахырына Россиянең әйдәп баручы милли коллективларының берсенә әверелә. 1933–34 тә — Күчмә колхоз-совхоз Т.лары, соңрак алар нигезендә Әлмәт һәм Минзәлә шәһәрләрендә Татар дәүләт Т.лары төзелә, 1990 елларда — Чаллы, Түбән Кама шәһәрләрендә яңа татар Т.лары, Казанда Яшь тамашачылар театры (ТЮЗ), 2007 дә Буада — Татар сатира Т.ы, 2011 дә Әтнәдә драма Т.ы ачыла; Уфа («Нур»), Оренбург, Туймазы шәһәрләрендә дә татар театрлары торгызыла. Ш.у.к. *Актёрлык сәнгате, Режиссёрлык сәнгате*.

Әд.: Татар театры (1906–1926). К., 2003; Крути И. Русский театр в Казани. М., 1958; Илялова И. Театр имени Камала. К., 1986.

Ю.А.Благов, И.И.Илялова.

ТЕА́ТР БИЗӘЛЕШЕ́ СӘНГАТЕ́, сәхнәне бизәү, костюмнар, яктырту һәм сәхнәгә куюның техник алымнары ярдәмендә спектакльнең тышкы образын тудыру сәнгате. 18 йөз уртасында Казан гимназиясендә куелган беренче тамашаларга багышланган язмалар спектакльләрне («Кереш», «Синав һәм Труворы») бизәгәндә классицизмның архит-ра формалары һәм аллегорик символлар актив кулланылу турында сөйли. Сәхнә бизәлешендә зиннәтлелеккә ирешү өчен, рәссам И.И.Протопопов, италияле нәкышьче Дельмедико күптөрле декоратив чаралар – аппликация, сусаль алтын һ.б.ны кулланалар. 19 йөз уртасында пратикабльләр — «кыялар», «калкулыклар», «баскычлар»ны сурәтләүче күләмле формалар, ш.у. төрле сәхнә эффектлары тудыручы машина һәм механизмнар киң кулланыла («корабның һәлакәткә очравы», «яшен яшьнәве», «поезд чабуы» һ.б.). Сәхнә бизәлеше аерым спектакльләргә бәйле булмаган«дежур» декорацияләр б-н тормышка ашырыла («бүлмә», «сарай тынлыгы», «бакча» һ.б.).

Казанда шәһәр театрының таш бинасы төзелеше тәмамланганда, М.И.Живокини тарафыннан үрнәк декорацияләр һәм станлы-пратикабльләр комплекты әзерләп куела. Әмма үрнәк декорацияләр б-н бергә ае-



«Театр бизәлеше сәнгате» мәкаләсенә. 1. М.М.Фәйзинең «Галиябану» әсәре буенча куелган спектаклгә декорация эскизы. Татар академия театры. Рәссам М.Г.Сутюшев, 1952; 2. Р.Г.Гобәйдуллинның «Кисекбаш» балетына декорация эскизы. Татар опера һәм балет театры. Рәссам П.Т.Сперанский, 1959; 3. Р.Г.Гобәйдуллинның «Кисекбаш» балетына костюмнар эскизы. Татар опера һәм балет театры. Рәссам Л.Л.Сперанская. 1959; 4. Ж.Фәйзинең «Башмагым» комедиясенә декорация эскизы. Татар опера һәм балет театры. Рәссам Э.Б.Гельмс, 1965; 5. М.И.Носырева. «Тантана итүче мәхәббәт җыры» балетына декорация эскизы. Кәгазь. Катнаш техника. 1970; 6. Н.Г.Җиһановның «Алтынчәч» операсына декорация эскизы. Татар опера һәм балет театры. Рәссам А.Г.Нагаев. 1978; 7. Н.Фәттахның «Сармат кызы Сәринә» әсәре буенча куелган спектаклгә костюмнар эскизы. Рәссам К.А.Нәфыйков. 1985. Әлмәт театры; 8. С.Прокофьевның «Өч эфлисунга мәхәббәт» операсына декорация эскизы. Рәссам Н.Х.Кумысникова. 1983; 9. К.Г.Тинчуринның «Зәңгәр шәл» әсәре буенча куелган спектаклгә декорация эскизы. Рәссам Р.Х.Газиев. Татар академия театры. 1986; 10. Л.Кронфельд, Л.Компанейцның «Лейпциг, 1933» әсәре буенча куелган спектаклгә декорация эскизы. Рәссам В.С.Никитин. Кәгазь. Гуашь. Казан Зур драма театры; 11. М.А.Гыйләҗевнең «Падишаһ кәләше» әсәре буенча куелган спектаклгә декорация. Рәссам А.А.Губский. Татар «Әкият» курчак театры. 1990; 12. Ф.Бурнашның «Таһир–Зөһрә» әсәре буенча куелган спектаклгә костюм эскизы. Рәссам Ә.Ә.Җәмилова. 1987; 13. «Сабантуй» кинофильмына эскиз. Рәссам У.Н.Абдуллов. Кәгазь. Гуашь. 1997; 14. М.А.Гыйләҗевнең «Баскетболист» әсәре буенча куелган спектаклгә декорация эскизы. Рәссам С.Г.Скоморохов. Татар академия театры. 2002.

рым спектакльләрне аерым сәнгатьчә бизәү практикасы да була, бу хакта театр афишаларында алдан белдерелә; мәс., мондый бизәлеш А.К.Толстойның Казанда беренче тапкыр 1868 дә куелган «Иоанн Грозный»ның үлеме» спектакленә рәссам Г.Я.Паулино тарафыннан әзерләнә. Аның декорацияләрендә вакыйга барган урыннарны тормыштагыча күрергә теләү сизелә, көнкүреш үзенчәлекләренә игътибар бирелә, бутафор һәм чын җиһазлар, тарихи костюмнар файдаланыла. Н.И.Соболь щиков-Самарин антрепризалары вакытында спектакльләрне бизәүдә еш кына Мәскәүдән чакырылган рус һәм Европа рәссамнары катнаша. О.Н.Егоровның опера спектакльләренә әзерләнгән декорацияләре сәнгатьлелеге б-н аерылып тора.

Казанда сәнгать мәктәбе ачылганнан соң, театр эскизларын иҗат итүгә аның педагог - лары һәм укучылары, аерым алганда, П.П.Беньков, Н.И.Фешин, В.С.Щербаков, П.Т.Сперанский җәлеп ителә. 1920 елларда Казанда барлыкка килгән футуризм, конструктивизм һ.б. авангард сәнгате агымнары Т.б.с. үсешенә сизелерлек йогынты ясый. Бизәүче рәссам иҗатын икенчел дәрәҗәдә караган узган чорлардан аермалы буларак, авангард театры аны режиссёр иҗаты б-н бер рәткә куя. Сәхнә бизәлешенең *КЭМСТ* театры спектакльләренә хас (рәссамнар М.В.Барашов, К.К.Чеботарёв) шартлылыгы, бута - фориядән баш тарту, пәрдә юклыгы театраль-лек турында принципиаль яңа төшенчә бар - лыкка килүгә сәбәп була. Әлеге агымнар 1920–30 еллар чигендә В.Э.Мейерхольд б-н бергә эшләгән һәм Казан Зур драма театрында күп кенә спектакльләр бизәгән рәссамнар В.Д.Шестаков, Г.Л.Миллер, Р.В.Распопов, ш.у. театр рәссамнары Е.К.Щаблиовский, Н.Н.Медовщиков, Г.А.Белоуско, И.Ю.Шлепянов, А.Ф.Холодков, А.В.Кукин, С.С.Серёжкин иҗатында үсеш ала. Гомуми чишелешнең шартлылыгы б-н бергә төрле биеклектәге сәхнә мәйданнарыннан файдалану, архит-ра детальләре һәм көнкүреш әйберләре куллану спектакльләргә (А.В.Луначарскийның «Агу», А.М.Файконың «Портфельле кеше», А.Н.Островскийның «Яшенле яңгыр», Л.Н.Толстойның «Мәгърифәт җимешләре», О. де Бальзакның «Давыллар культыгы», Л.И.Славинның «Интервенция» әсәрләре буенча) динамика һәм тирән мәгънә бирә.

1920 еллар башында яралган татар Т.б.с., проф. рәссамнар булмау сәбәпле, үзенчәлек - ле үсеш юлы үтә. Татар өенең эчке бизәү әй - берләре – чигелгән сөлгеләр, чаршаулар, кашагалар, намазлыклар һ.б. сәхнә бизәлешенә башлангыч нигез булып тора. Беренче татар театры спектакльләре рәссам С.Г.Яхшыбаев тарафыннан «интерьер» принцибы буенча бизәләләр. Ләкин Ф.Әмирханның «Тигез - сезләр» әсәре буенча куелган спектакльне бизәгәндә үк (1915), Яхшыбаев нәкышьле декорацияләрдән файдалана. 1926–27 дә К.Тинчуринның «Җилкәнсезләр», Г.Кутуй - ның «Балдызкай», Ф.Бурнашның «Хөсәен мирза», Ә.Хәмиднең «Һинд кызы» әсәрләре буенча куелган спектакльләрне бизәгән П.П.Беньков татар сценографиясенең бизәү культурасы үсешенә зур йогынты ясый. Шул ук вакытта К.К.Чеботарёв Е.П.Карповның «Эшчеләр бистәсе», В.В.Каменскийның «Степан Разин», В.Андреенконың «Хезмәткә гимн» әсәрләре буенча куелган спектакльләрнең сәхнә фәсәсы чишелешендә конструктив алымнар кертә.

1930–40 елларда Т.б.с.ндә спектакльләрне зур формалар файдаланылган сәнгатьле-күләмле бизәү принцибы урнаша. Рәссамнар П.Т.Сперанский, М.Г.Сутюшев, М.М.Абдуллин, Р.М.Һибәтуллин (Татар акад. театрын - да), Е.К.Щаблиовский, Н.Н.Медовщиков, Г.Л.Миллер, Г.А.Белоуско, С.С.Серёжкин, Н.С.Маткович (Казан Зур драма театрында) чын тормышчан бизәлеш иҗат итәләр. 1950–60 елларда Татар акад. театрында — Ә.И.Тумашев, Казан Зур драма театрында В.С.Никитин төсле чишелешләргә зур игътибар бирәләр, куелышлардагы хисләр яңгырашын көчәйтеп, декорацияләрдәге сәнгать башлангычын активлаштыралар. Н.Исәнбәтнең «Миркәй б-н Айсылу», Т.Гыйззәтнең «Ташкыннар», Н.Фәттахның «Кол Гали» (рәссам Ә.И.Тумашев), Я.Райнисның «Ис, җилкәй», А.П.Чеховның «Чия бакчасы» (рәс - сам В.С.Никитин) әсәрләре буенча куелган спектакльләрнең бизәлеше «шигъри чынбарлык»ның ачык чагылышы була.

1970–90 елларда Т.б.с. Э.Б.Гельмс, А.Б.Кноблок, С.Г.Скоморохов, Т.Г.Еникиев, Ә.Ә.Җәмилова, Р.Х.Газиев, курчак театрында — А.А. һәм В.Е.Губскийларның иҗади эзләнүләре б-н байый. Сценографиянең бурычын спектакльләрнең тышкы бизәлеше итеп аңлаудан баш тартып, әлеге рәссамнар режиссёр б-н бертигез дәрәҗәдә спектакльне куючылар булып алга чыгалар, аның визуаль концепциясен иҗат итәләр. Сәхнә фәсәсы чишелеше формаларының һәм алымнарының күптөрлелегендә вакыйгалар үсеше динамикасын ачыкларга, идея-фикер басымнарын билгеләргә мөмкинлек бирүче якты - лык бизәлеше әйдәп баручы әһәмиятен ала. Бизәгәндә файдаланылган табигый матери - алларның (металл, агач, күн) фактурасына зур әһәмият бирелә.

20–21 йөзләр чигендә сценография мохи - ты яңа исемнәр б-н тулылана. Әлмәт татар (К.Тинчуринның «Җилкәнсезләр»е, рәссам Н.Х.Кумысникова; Г.Каюмовның «Ахырза - ман»ы, рәссам Б.В.Нәсыйхов; Д.Р.Кинҗәбаевның «Онытылган серләр»е, рәссам Б.Ф.Ибра һимов), Бөгелмә рус (К.Гоццинның «Коз - гын»ы; Ф.Бүләковның «Әбиләргә ни җит - ми» әсәре; А.Гернинның «Сильвия»се — бары - сы да Т.Ю.Виданова бизәлешендә), Минзәлә татар (Н.В.Гогольнең «Өйләнү»е, рәссам Н.Х.Кумысникова), Чаллы татар (М.Фәйзинең «Галиябану»ы, рәссам Е.А.Сорочайкина; К.Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар»ы, рәссам Б.А.Гыйльфанов; Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ы, рәссам Р.Хәйруллина) драма театрлары, Чаллы курчак театры (Т.Миңнуллинның «Авыл эте Акбай» әсәре; В.Ткаченконың «Төсле кар бөртекләре», икесе дә рәссам Б.В.Нәсыйхов бизәлешендә) сәхнәләрендә кызыклы бизәлеш тәкъдим ителә. Казан Зур драма театрында – А.М.Патраков (театрның барлык спектакльләре диярлек аның бизәлешендә куела), татар һәм рус яшь тамашачылар театрларында Л.Р.Гыйльметдинов, Н.Е.Пачкова актив эшлиләр.

Әд.: Выставка работ театральных художников Казани: Каталог. К., 1964; Червонная С.М. Искусство Советской Татарии. Живопись, скульптура, графика. М., 1978; Современная сценография Татарстана: Каталог. К., 2002.

Ю.А.Благов, Р.Р.Солтанова.

ТЕА́ТР БИНАЛАРЫ́, Казанда. Беренче махсус төзелгән агач бина (таш нигезгә утыртылган) Казанда 1802–03 елларда хәзерге Татар опера һәм балет театры урынында барлыкка килә (к. *Есипов театры*); ул 1815 кә кадәр эшли. 1833–34 тә яңадан шунда ук П.А.Соколов труппасы уйнаган агач бина төзелә; 1842 дә яна. 1845–49 да Ирек мәйданында хәзерге сквер урынында таштан шәһәр театры бинасы төзелә. Эшне оештыручы — И.В.Доленге-Грабовский, губерна архитекторы — И.П.Безсонов, декоратор һәм машинист — М.Г.Живокини. Бина шәһәрнеке санала һәм шәһәр хакимиятләре карамагында була. Анда һәм драма, һәм опера спектакльләре (1918 дән бары тик опера спектакльләре) куела. Бина берничә тапкыр үзгәртеп корыла (1874 тән соңгы янгыннан соң, 1902–04 тә), 1919 да яна, 1925 нең көзендә сүтелә. 1900 дә фабрикант Н.И.Алафузов үз фабрикаларының эшчеләре өчен театр залы булган Халык йорты (арх. Л.Х.Хрщонович) төзи. Ул Алафузов театры исемен ала. 1918 дән анда Елга аръягы эшчеләр театры, соңрак Казан җитен комб-ты клубы, аннары Казан татар яшь тамашачылар театры урнашкан була. Соңгысы хәзерге вакытта Петербург урамында. 1908 еллар тирәсендә Өченче тау урамында (хәзер Калинин ур.) Казан Ирекле янгын сүндерүчеләр җәмгыяте йортында «Гоголь» театры (Н.В.Гоголь исем. театр) урнашкан була. Анда драма труппасы спектакльләре куела. 1909 да, ин-







1. Яңа театр (Яңа клуб). 20 йөз башы фоторәсеме; 2. Шәһәр театры. 1904 ел фоторәсеме; 3. Сәүдәгәрләр җыены театры бинасы. 1908 елгы фоторәсем.

терьерлары үзгәртеп корылганнан соң, Вознесенский урамындагы (хәзер Островский ур.) Журавлёв варислары йортында Сәүдәгәрләр җыены театры ачыла. 1909 да М.П.Ромаскевичның Интим театры эшли. Бинаны, спектакльләр кую һәм кичәләр оештыру өчен, еш кына Шәрекъ клубы арендага ала. 1923–24 тә бина, фасадына шактый үзгәрешләр кертелеп, Татар дәүләт театры өчен үзгәртеп корыла, 1927–30 да анда — Татар мәдәнияте йорты, соңрак — Укытучылар йорты, 1935 тән Казан яшь тамашачылар йорты урнаша. 1995 тә бина яна, 2001 дә, элекке фасадлары торгызылып, тулысынча үзгәртеп корыла. 1911 дә театр залы Евангелистлар урамындагы (хәзер Татарстан ур.) Шәрекъ клубы тарафыннан арендага алынган М.М.Апанаев йортында төзелә; анда драма труппалары, ш.и. «Сәйяр» труппасы тамашалар оештыра. 1912 дә хөкүмәт һәм җәмәгать оешмалары хезмәткәрләре өчен Зур Лядской (хәзер Горький) урамында театр залы булган Яңа клуб төзелә (арх. Ф.Р.Амлонг), ул ш.у. Яңа театр дип тә аталып йөртелә (1918 дән — Кызыл Армия сарае яки Кызыл сарай). 1914 тән анда — икенче шәһәр драма труппасы, 1919 дан опера труппасы уйный, 1928 дән Татар акад. театры урнаша, ул 1939 дан бинаны кабат оешкан Татар опера һәм балет театры б-н бүлешә; 1989 дан анда Татар драма һәм комедия театры эшли. 1913 тә арх. Амлонг Зур Проломный (хәзер Бауман) урамында антрепренёр В.В.Образцов өчен Миниатюралар театры төзи, 1918 дән анда — «Яңа тормыш» («Новая жизнь») эшчеләр клубы, 1940 еллардан М.Горький исем. клуб эшли. 1914 тә Казан кинотеатрларының хуҗасы Г.А.Розенберг сәүдәгәр А.С.Меркуловның Зур Проломный урамындагы элекке йортын 1500 урынлы тамаша залы булган Зур театрга үзгәртеп төзетә. 1919 га кадәр анда фильмнар күрсәтелә, оперетта (кайвакыт драма) труппалары уйный, 1919 дан рус драма труппасы (к. *Казан Зур драма театры*) урнаша. 1956 да — Татар опера һәм балет театры (арх. И.Г.Гайнетдинов), 1986 да Татар акад. театры (арх. М.Х.Агишев, М.Н.Горлышев) биналары төзелә. Татар «Әкият» курчак театры озак еллар дәвамында элекке Изге Рухның җиргә төшүе чиркәве бинасында эшли. 2012 дә Петербург урамында яңа бина төзелә (арх. С.Ә.Мамлиева). Из - носков («Эрмитаж» — хәзерге Некрасов һәм Щапов урамнары арасында), Панаев (хәзерге «Динамо» стадионы урынында), «Аркадия» (Кабан күле буенда) бакчаларында, Үзәк мәдәният һәм ял паркында ш.у. җәйге Т.б. да була.

Әд.: К р у т и И. Русский театр в Казани. М., 1958; Б л а г о в Ю. Казань театральная. К., 1998.

Ю.А.Благов.

«ТЕА́ТР И ЭКРА́Н» («Театр һәм экран»), журнал. 1915 елда Казанда рус телендә нәшер ителә, барысы 6 саны чыга. Беренче саны 1915 нең 15 сентябрендә басыла; башта журналны атнага 4 тапкыр чыгарырга ниятлиләр. «Театр, сәнгать һәм кинематограф сорауларына багышланган журнал, Казан театрлары программасы кушымтасы» дигән баш исем б-н дөнья күрә. Нашире — Ю.А.Еленёв, мөхәррире — В.С.Андреев. Редакция заман - ча сәнгатькә тартучы, 20 йөз башында масса - күләм тамашага әверелгән театр һәм киноны популярлаштыручы, һәркем укый алырлык басма чыгаруны максат итеп куя. Театр сән - гатенең роле ассызыклана, әлеге эстетик хозурлык заманча шәһәр кешесенең мөһим ихтыяҗы була бара. Казанның әйдәп баручы кинотеатрларының (Г.Розенбергның «Электра», «Зур театр» кинотеатрлары, «Пассаж» һ.б.) анонслары, кинорецензияләр, шигырьләр, фельетоннар, шаржлар һ.б. басыла. Кино һәм театр тормышы (мәс., Л.Андреевның «Екатерина Ивановна» пьесасы буенча кинокартина Казанда Мәскәүгә караганда иртәрәк



«Театр и экран» журналы тышлыгы.

күрсәтелә дип билгеләп үтелә) тәфсилләп яктыртыла. «Т.и э.» театр премьералары турында хәбәр итә; 1 нче саннан башлап режиссёрлар б-н (Шәһәр театрының — А.Двинский, Зур театрның — Д.Гутман, Яңа театрның — Е.Мещерский) яңа сезондагы репертуар планнар турында интервьюлар басыла. Редакция В.М.Дементьевның кинематографны дәүләтләштерү (Дәүләт Думасы депутаты В.М.Пуришкевич идеясе) һәм аны «казна шәрабын сату» үрнәге буенча файдалану зарурлыгы дәлилләнгән «Хөкүмәт регалиясе буларак кинематограф» («Кинема - тограф как правительственная регалия») дигән брошюрасы чыгу уңаеннан үз фикерен белдерә. Журнал проектны — «көлке», ә авто - рын — «субсидияләнгән патриот» (№ 1) дип атый, кинематографны монополизацияләү идеясендә байтак куркыныч күргән Мәскәү кино эшмәкәрләренең җавабын китерә (№ 5).

Р.А.Айнетдинов.

ТЕА́ТР СӘНГАТЕ́ ГЫЙЛЕМЕ́, *театр* та - рихын, теориясен һәм практикасын өйрәнүче фән тармагы. Мөстәкыйль фән буларак Т.с.г., башлыча, 20 йөздә формалаша, әмма Казанда аның үсеше өчен алшартлар 19 йөз уртасында ук барлыкка килә. 1840 елда «Пан - теон русских и всех европейских театров» ж-лындагы, «Москвитянин» г-тасындагы К.Д.Данненберг мәкаләләрендә һәм А.И.Ар - темьев язмаларында тормыш хакыйкатенә тугрылык принципларына нигезләнгән театр сәнгатенең билгеле бер эстетик таләпләре формалаша. А.В.Попов, И.Н.Березин мәкаләләрендә («Казанские губернские ведомости», 1852–53) театр тамашачыга этик һәм эстетик тәрбия бирү чарасы буларак карала. Казан труппасы актёры Н.С.Стружкин һәм «Справочный листок города Казани» (1867) г-тасында театр турында мәкаләләр бастырган автор арасындагы бәхәс театр сәнгатендәге «чын мәктәп»нең берничә принципиаль нигезләмәсен дә үз эченә ала. А.И.Артемьевның «Казан буйлап йөрү» («Прогулки по Казани» // «Казанские губернские ведомости», 1849–50) мәкаләләр циклында Казан театрының тарихи үткәненә, тәүге чыганакларга мөрәҗәгать итү омтылышы күзәтелә. Бу омтылышлар С.М.Шпилевский («Справочный листок города Казани», 1867) һәм Н.П.Загоскин («Волжский вестник», 1892; «Казанские вести», 1891–92) мәкаләләрендә дә дәвам ителә, алар җитди документаль һәм мемуар материал тикшеренүләренә, шаһитләрнең дәлилләренә нигезләнә. Казан һәм Россия Т.с.г. формалашуда «Рус сәхнәсе тарихына карата. Е.Б.Пиунова-Шмидгоф үзенең һәм башкаларның хатирәләрендә» («К истории русской сцены. Е.Б.Пиунова-Шмидгоф в своих и чужих воспоминаниях», 1889; Н.Ф.Юшков), «Рус театры тарихы» («История русского театра», ч. 1–2. 1908–10; Б.В.Варнеке) китапларының өлеше зур була. 20 йөз башында, татар проф. театры туу б-н бәйле рәвештә, «Казан мөхбире», «Фикер», «Кояш», «Йолдыз» г-таларында Т.с.г.нә караган беренче мәкаләләр күренә башлый. Аларның авторлары Г.Тукай, Г.Камал, Ф.Әмирхан, Ф.Бурнаш, М.Вахитов, Ш.Усманов пьеса һәм спектакльләрнең эчтәлекләрен анализлау б-н берраттан татар милли театр сәнгатенең төп принципларын да формалаштыралар. Татар Т.с.г. тууда Г.Кәрам эшчәнлеге аеруча зур роль уйный; аның мәкаләләрендә татар театры иҗатына тирән бәя бирелә, театрның иҗтимагый бурычлары, киләчәктә үсеш перспективасы билгеләнә. Татар театрының 10 еллыгы уңаеннан Ф.Әмирханның «Аң» (1916, № 16–17) ж-лында басылган мәкаләсе аналитик характерга ия була. 1920 еллар башында театр сәнгатенең алга таба үсеш юллары, аның җәмгыятьнең социаль төзелешендә күзәтелгән тамырдан үзгәртеп коруларга ярашлылыгы хакында көчәеп киткән бәхәсләр, яңа сәнгатьчә сурәтләү чаралары һәм драматургия материалын сәхнәдә яңача гәүдәләндерү ысулларын эзләү юллары З.М.Славянованың «Ял» («Отдых», 1919), «Эшче-крәстиян театры» («Рабоче-крестьянский театр», 1921), М.Мәһдиевнең «Уен һәм сүз техникасы» (1928), «Театр эше» (1929), «Театр» (1932), Г.Айдарскийның «Театр сәнгате» (1931) хезмәтләрендә ачык чагылыш таба. 1926 да татар театрының 20 еллыгы зурлап билгеләп үтелә. «Татар театры (1906–1926)» җыентыгында Г.Ибраһимов, Г.Сәгъди, Г.Рәхим, М.Парсин, С.Гыйззәтуллина-Волжская, К.Тинчурин, З.Солтанов, К.Шамил, С.Габәши мәкаләләре урын ала. Алар, татар театры тарихына һәм тәүге чыганакларга мөрәҗә-

гать итеп, документаль материалны, төгәл вакыйгалар хронологиясен бәян итү б-н берәттән театрның эстетик һәм социаль-мәдәни асылын үзләштерергә, милли сәнгатьнең үзенчәлекләрен, алга таба үсеш юлларын ачарга тырышалар. Татар театры тарихын дөньяви сәхнә сәнгате кысаларында кыска очеркта бәян итеп, «Татар театры тарихыннан» (М., 1926) китабы авторлары В.Мортазин һәм Т.Ченәкәй татар театры тарихын дөньяви театраль процесс контекстында өйрәнү омтылышы ясыйлар. Казанда рус театрының 150 еллыгын (1954) һәм татар театрының 50 еллыгын (1956) уздыру Г.Кариев, Г.Болгарская, С.Гыйззәтуллина-Волжская, Н.Таҗдарова, Х.Әбҗәлилов, З.Солтанов, Е.Е.Жилина, Н.И.Якушенко кебек аерым актёрлар иҗатына багышланган монография характерындагы күп кенә фәнни хезмәтләр нәшер ителүгә сәбәп була; авторлар (Ш.Сарымсаков, Ф.Шәрәфиев, Г.Кашшаф, Ә.Еники, Х.Кумысников, Ш.Рахманкулов, А.П.Авдеев, Е.Г.Зильберман) актёрларның иҗатын театрның гомуми үсеше һәм аерым шәхесләрнең театр тормышындагы роле контекстында өйрәнәләр. Аннан соңгы елларда татар театры актёрлары һәм режиссёрлары Ф.Камалова, Г.Булатова, М.Мутин, Г.Шамуков, К.Шамил, М.Сәлим җанов, Ш.Биктимеров, Ә.Шакиров, Н.Ихсанова иҗатларына багышланган китаплар, «Халык артистлары» («Народные артисты», 1980) очерклар җыентыгы, истәлекләр һәм документаль материаллар җыентыгы дөнья күрә.

1958 дә Мәскәүдә И.А.Крутиның Казанның театр сәнгате тарихына багышланган (башлангыч чорыннан алып 19 йөз ахырына кадәр) «Казанда рус театры» («Русский театр в Казани») китабы чыга, ул провинция театры тарихын фундаменталь тикшеренүләр нең тәүге тәжрибәләреннән берсе була. 1966–71 дә Мәскәүдә 6 томда «Совет драма театры тарихы» («История советского драматического театра») фәнни хезмәте нәшер ителә. Анда Б.Гыйззәтнең татар театры тарихын беренче булып эзлекле яктырткан очерклары басыла. 1975 тә Казандагы татар театры тарихына һәм аның хәзерге торышына, ш.у. Әстерхан, Оренбург, Әлмәт, Минзәлә, Мәскәү эше һәм респ-ка күчмә театрларына багышланган «Татар совет театры» китабы басылып чыга. Әлеге җыентыкның тарихи өлеше Б.Гыйззәт, И.Илялова һәм Һ.Мәхмүтовның бергә иҗат иткән «Октябрьгә кадәрге татар театры» китабында дәвам ителә. Анда рев-циягә кадәрге театрның бай фактик материалга нигезләнеп өйрәнелгән үсеш юлы бирелә, аның формалашуы һәм үсешенең төп этаплары аеруча җентекле тикшерелә. Казан Т.с.г.ндә тарихи юнәлеш аерым театрларга багышланган «Камал исемендәге театр» («Театр имени Камала», 1986, И.Илялова), «Казан яшь тамашачылар театры» («Казанский театр юного зрителя», 1986, Ю.Благов), «Казанда рус театры (совет чоры)» («Русский театр в Казани (советский период)», 1991, И.Ингвар, И.Илялова), «Тинчурин исемендәге театр» («Театр имени Тинчурина», 2002, И.Илялова), «Уйнаучы курчаклар сәнгате» («Искусство играющих кукол», 2004, Р.Игъламов), «КЭМСТ һәм 1920 елларда Казанда театраль тормыш» («КЭМСТ и театральная жизнь Казани 1920-х гг.», 2005, Ю.Благов), «Сабир Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт драма театры» (2007, Д.Гыймранова) хезмәтләрендә дә дәвам ителә. Казан рус театрының тарихи үткәненә Ю.А.Благовның 2001–06 да чыккан «...Казанский кушаматын алды» («...получил прозвище Казанский», П.М.Медведев турында), «Собольщиков-Самаринның Казан антрепризасы» («Казанская антреприза Собольщикова-Самарина»), «Казан алпавыты Александр Каширин» («Казанский помещик Александр Каширин») хезмәтләре дә багышлана.

Бер үк вакытта театр белгечләре театр сәнгатенең аерым якларын (актёр, режиссёр, драматург осталыгы) өйрәнүгә керешәләр, иҗатның мөстәкыйль төрләре буларак аларның үсеш закончалыкларын һәм үзенчәлекләрен ачалар: «Хәзерге татар театрында актёрлык осталыгы» («Актёрское искусство современного татарского театра», 1978, И.И.Илялова), «Татар театрының милләтара бәйланышлары» («Межнациональные связи татарского театра», 1985, И.И.Илялова), «Казан театр ленинианасы» («Казанская театральная лениниана», 1989, И.Г.Ингвар), 1906–90 елларны үз эченә алган «Татар режиссёрлык сәнгате» («Татарское режиссёрское искусство», кн. 1–3, 1992–2002, М.Г.Арсланов) китаплары нәшер ителә. А.Г.Әхмәдуллинның «Сәхнә әдәбияты һәм тормыш» (1980), «Офыклар киңәйгәндә» (2002), «Күңелләрне уятыр: Хәзерге татар драматургиясе» (2007), «Татар драмасы офыклары» («Горизонты татарской драмы», 1983), «Татар драматургиясе» («Татарская драматургия», 1983), Р.М.Игъламовның К.Тинчурин турында «Мәшһүр драматург» («Выдающийся драматург», 1987), М.Х.Гайнуллинның «Татар әдәбияты һәм XX йөз башы публицистикасы» («Татарская литература и публицистика начала XX века», 1966), А.Р.Салиховның «Габдрахман Кәрамның әдәби-тәнкыйди мирасында татар театры» («Татарский театр в литературно-критическом наследии Габдрахмана Карама», 2003) хезмәтләре татар драматургиясен һәм театр тәнкыйтен өйрәнүгә багышлана.

Әд.: Татар совет театры. К., 1975; Махмутов Х.И. Развитие татарской театральной критики и театроведения // Татарский театр (новаторские искания татарского советского театра). К., 1981; Театральная энциклопедия. М., 1967. Т. 5; Народные артисты: Очерки. К., 2011.

Ю.А.Благов, А.Габәши.

ТЕА́ТР СТУ́ДИЯЛӘРЕ, театрлар каршында яисә аларга бәйсез рәвештә оешкан, яңа сәнгатьчә чаралар, методик эш алымнары эзләү һәм сәхнә телен яңартырга сәләтле театр кадрлары тәрбияләү б-н бәйле белем бирү һәм тәжрибә туплау бурычларын алга куйган театр-сәнгать коллективлары. Махсус театр белеме бирүче уку йортлары булмаган очракта, нигездә, актёрлар әзерләү б-н шөгыльләнәләр. Татар проф. театры формалашуда мөһим роль уйныйлар. 1918 елда Казанда Грузинский урамында Соболевлар йортында драма курслары алып барылган ирекле сәнгатьләр студиясе, Зур Лядской урамында Кызыл армия сараенда «өлкәннәр һәм кызылармиячеләрнең балалары өчен» муз.-драма студиясе ачыла. Татар театры өчен актёрлар әзерләүче беренче театр студиясе 1919 да З.Солтанов тарафыннан оештырыла һәм *Әстерхан татар театр студиясе* дип атала; 1919 ның 24 декабрендә Казан Зур драма театрында актриса һәм реж. З.М.Славянова җитәкчелегендә драма студиясе эшли башлый («Казан губернасының эшче-крәстиян театрлары өчен артистлар, инструкторлар һәм режиссёрлар әзерләүче губерна драма курслары»), бүленеп, 1961 гә кадәр эшли. Ул берничә буын актёрлар әзерләп чыгара. Алар арасында СССРның халык артистлары В.В.Белокуров, Е.Е.Жилина, РСФСРның халык артистлары В.З.Гатаев, И.П.Зарубина, В.В.Кешнер, М.Л.Кондратьев, Ю.С.Федотов, Украина ССРның халык артистлары М.М.Белоусов, А.М.Таршин, ТАССРның халык артистлары И.В.Баһманов, Н.Х.Гәрәева, Е.А.Кузин, Л.В.Маклакова, Ю.А.Максимов була. Төрле елларда студиядә В.С.Зотов, П.Л.Вульф, А.М.Кречетов, А.М.Миронов, Ю.А.Муко, Ю.В.Соболев, Д.П.Шестаков, Л.Ф.Лазарев, Е.Г.Гаккель, Е.А.Простов, Ф.Ф.Витт, Ф.В.Ваш, Я.Б.Мацкевич, М.В.Шейнин, Н.И.Якушенко кебек педагоглар хезмәт куя. 1919–24 тә сәхнә хәрәкәтләре, актёрларда сыгылмалылык тәрбияләү, пантомима, хор декламациясе буенча дәресләр укытуга шактый игътибар бирелә. Аннан соңгы елларда Казан Зур драма театры, башлыча, актёрлар әзерләү б-н шөгыльләнә. 1920–21 дә Самара шәһәрендә З.Солтанов, К.Тинчурин, И.Рәмиев тарафыннан *Самара татар драма һәм музыка студиясе* төзелә, аны тәмамлаучылар «Г.Кариев истәлегенә» театры, аннары Оренбург татар драма театры труппасын оештыралар. Казанда 1923 тә Б.Н.Симолин җитәкчелегендә оешкан «КЭМСТ театр тамаша лары остаханәсе» дә студия булып китә, анда спектакльләр кую б-н берәттән даими рәвештә дәресләр алып барыла, тәжрибә формалары һәм сәнгатьчә чаралар эшләнә, В.Э.Мейерхольд һәм Н.М.Форегтерның иҗади эзләнүләре нәтиҗәләре файдаланыла. 1934 тә Мәскәүдә *Татар опера студиясе* төзелә, ул Казанда кабат ачылган дәүләт опера театры өчен труппа әзерли. 1944 тә Мәскәүдәге Дәүләт театр сәнгате ин-ты (ГИТИС) каршында Татар драма студиясе оеша, аны тәмамлап чыгучылар Казан яшь тамашачылар театрының (ТЮЗ) башлангыч татар төркемен булдыралар, соңрак аларның бер өлеше Татар акад. театрына кабул ителә. Казан ТЮЗында укыту максаты б-н 1945–47, 1958–61, 1976–80 елларда студияләр ачыла.

Әд.: Благов Ю. КЭМСТ и театральная жизнь Казани в 1920-х гг. К., 2005; Театральная энциклопедия. М., 1965. Т. 4.

Ю.А.Благов.

ТЕА́ТР ТӘНКЫЙТЕ́, әдәбиятның бер төре; театрның агымдагы эшчәнлеген чагылдыра, аерым спектакльләрне, гомумән, театрны, аның репертуарын, идея-сәнгати юнәлешен, ш.у. аерым актёрлар һәм режиссёрларның иҗатларын анализлау һәм тикшерү-

не үз эченә ала; нигездә, вакытлы матбугатны файдалана. Казанда 19 йөз уртасында күзәтелә башлый. Казан ун-ты профессорлары һәм укытучылары А.В.Попов, И.Н.Березин, Н.А.Фирсов, А.К.Чугунов, С.М.Шпилевский «Казанские губернские ведомости», «Справочный листок города Казани» г-таларындагы мәкаләләрендә Россиядәге тормышчан вакыйгалар һәм проблемаларны гәүдәләндерү мөмкинлегенә ия реализм юнәлешендәге драматургиягә нигезләнгән репертуарның формалашу бурычларын алга куялар; актёрлардан тиешенчә башкаруны таләп итәләр, шул рәвешчә Казанда Т.т.нә нигез салалар һәм югары театр культурасы тууга булышлык итәләр. 19 йөзнең 2 нче яртысында Н.П.*Загоскин* һәм Н.Ф.*Юшковның* Казан драма һәм опера театрлары труппалары иҗатын анализлауга багышланган мәкаләләре Казан Т.т.ндә зур бер вакыйга буларак кабул ителә. Е.Ю.Геркен, Н.Н.Урванцов, П.П.Перцов, П.А.Пономарёв, В.П.Первушин, В.Н.Соловьёв, И.П.Котелов, А.Н.Кремлёв, В.А.Радин, М.Зельдович, В.Вальцның «Волжский вестник», «Казанский телеграф», «Камско-Волжская газета» г-таларында басылган рецензияләре Казан театрының иҗади хәлен генә яктыртып калмый, мәкалә авторлары Казан сәхнәсендә тирән эчтәлекле, иҗтимагый әһәмияткә ия заманча репертуарны раслау юнәлешендә дә максатчан эш алып баралар. П.А.Стрепетова, В.Ф.Комиссаржевская, И.М.Шувалов, П.В.Самойлов, А.И.Каширин, В.И.Качалов, Е.Б.Пиунова-Шмидгоф, Е.П.Шебуева, М.И.Свободина-Барышева кебек актёрларның иҗатларын анализлап, рецензентлар теге яки бу актёрның башкару үзенчәлеген күрсәтүче аеруча әһәмиятле сыйфатлар буларак аларның үзләре гәүдәләндергән персонажларның эчке дөньяларын тирәнтен ачу, берөзлексез сәхнә тормышы б-н яшәү, тамашачыга эмоциональ һәм рухи яктан тәэсир итү осталыкларын билгеләп үтәләр. 1900–10 елларда, Казан театры сәхнәсендә М.Горький, Е.Н.Чириков, С.А.Найдёнов пьесаларын сәхнәләштерү б-н бәйле рәвештә, Т.т.ндә демократик ирекләр өчен идея-сәяси көрәш чагылыш таба.

20 йөз башында, татар театры туу б-н бергә, татар Т.т. формалаша башлый. Аның үзенчәлеген татар театры үсеш алу процессында язучыларның, драматургларның «Сәйяр» труппасы спектакльләренә һәм театрның демократик юнәлешенә мөнәсәбәтле театр тәнкыйтьчеләре һәм рецензентлары сыйфатында актив катнашулары билгели. Казан, Оренбург, Әстерхан, Уфа шәһәрләрендә нәшер ителгән *«Казан мөхбире», «әл-Ислах», «*Йолдыз», «Кояш», «Вакыт», *«Идел», «Тормыш»*, «Фикер» г-талары һәм «Аң» ж-лында аналитик мәкаләләр б-н Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Камал, Г.Ибра һимов, С.Рәмиев, М.Вахитов, Ш.Усманов, журналистлардан Казанда Ш.Әхмәдиев, Г.Нугайбәк, З.Нуркин, И.Бикколов, Оренбургта К.Бәкер, Уфада С.Шәрәфетдинов чыгышлар ясыйлар. Татар Т.т. формалашуда мәгърифәтче, журналист, әдәбият һәм сәнгать белгече Г.Кәрамның эшчәнлеге аеруча зур роль уйный. Ул сәхнәдә куелган һәр спектаклгә төгәл анализ бирә, спектакльнең тышкы күренешенә, ш.у. актёрлар уенына, сәхнәдә үз-үзләрен тоту рәвешләренә, сөйләмнәренә, костюмнарына зур игътибар бирә, шул рәвешчә аларда да, тамашачыда да югары зәвык тәрбияләргә омтыла. 1920 елларда, вакытлы матбугат кимү сәбәпле, театр турында язучы авторлар даирәсе тарая. Рәсми басма органнарда чыгыш ясаганда, тәнкыйтьчеләр сәнгать өлкәсендә партия карашларына таянырга мәҗбүр булалар. Шулай да Г.Кутуй, Ф.Саллави, М.Парсин, А.Гомәров, Ә.Мәҗитов, З.Гали, Г.Минский, Ф.Мөсәгыйть, Е.С.Гинзбург мәкаләләрендә театр сәнгатендә күзәтелгән реалистик һәм формализм агымнары арасындагы көрәш чалымнары табыла, театрның сәнгати торышында тәэсирлелек һәм гражданлык таләпләре әзлекле чагыла. Бу чорда язучы Г.Кутуйның публицистик эшчәнлеге татар Т.т.ндә аеруча әһәмиятле күренеш була; аның ялкынлы, сугышчан рухлы һәм үткен нәтиҗәләр ясалган мәкаләләре 1920–30 елларда татар театры үсешен билгели. Татар Т.т.ндә М.Җәлил, Ә.Фәйзи, Н.Исәнбәт, Г.Кашшаф, М.Гайнуллин мәкаләләре дә әһәмиятле эз калдыра. 1930 елларда барлык әдәби иҗат кебек үк Т.т. дә акрынлап партия аппараты һәм дәүләт контроленә алына. Театр рецензияләрендә игътибар беренче чиратта әсәрләрнең идея эчтәлегенә, аларның партиянең идеология сәясәтенә ярашлы булуына юнәлдерелә; чынбарлыктан аз гына читкә тайпылу очрагы да, форма туды ру, сәхнәдә гәүдәләндерелгән театраль шартлылык б-н мавыгу катгый тәнкыйтькә дучар ителә. Театр рецензиясенең билгеле бер схемасы булдырыла: пьесаның эчтәлеген, һичшиксез, бәян итү, аның мәгънәви әһәмиятен бәяләү һәм режиссёр б-н актёр шәрехләмәсен автор фикеренә ярашлылыгы ноктасыннан чыгып анализлау күздә тотыла. Театр сәнгате әсәрләрен шушы чорда билгеләнгән бәяләү рәвеше 1940–50 елларда да Н.А.Козлова, В.Я.Гудкова, Я.Б.Винецкий, А.П.Авдеев, В.В.Королёва, Б.Гыйззәт, Ф.Хөсни мәкаләләрендә дәвам итә. 1950 еллар ахыры — 1960 еллар башында, яңа тәнкыйтьчеләр — Казан ун-ты укытучылары Е.А.Слободская, Е.А.Колесникова, Е.К.Бахмутова, Казан пед. ин-ты укытучылары И.А.Рахлин, Б.Г.Зильберман, Р.Ф.Усманова, Т.А.Геллер килү б-н, театр рецензиясе тагын да эчтәлеклерәк (әсәрдәге фәлсәфи карашлар да исәпкә алына), пьеса һәм спектаклгә анализ тагын да тирәнрәк һәм төгәлрәк була бара. 1970–90 елларда Казанда Т.т. үсеше И.И.Илялова, Д.Ә.Гыймранова, Р.М.Игъламов, Ю.А.Благов, Л.В.Агеева, А.М.Миллер, А.Н.Богданов, О.Д.Стрельникова, Р.И.Копосов, Т.В.Мамаева, Н.А.Салтина исемнәре б-н бәйле. Театр рецензиясе гадәти схемасыннан читләшә, теге яки бу спектаклне иҗат итүчеләргә автор фикерен иреклерәк җиткерү мөмкинлеге бирелә һәм аларның эшләрен бәяләгәндә исәпкә алына, бу күп очракта иҗтимагый проблемалар турында җитди сөйләшү алып бару өчен сәбәп булып тора. 20 йөз дәвамында Т.т.ндә яшәп килгән катгый идеологик чикләүләргә карамастан, ул Казанда театр сәнгате алга китүдә әһәмиятле роль уйный, рус һәм татар сәхнәсендә югары сәнгатьчән репертуарны раслауга булышлык итә, башкару осталыгы артуга йогынты ясый, тамашачыда югары зәвык тәрбияләүгә булыша, *театр сәнгате гыйлеме* үсешенә нигез сала.

Әд.: Махмутов Х.К. Развитие татарской театральной критики и театроведения // Татарский театр (Новаторские искания татарского советского театра). К., 1981; Бурмистрова Л.П. Искусство актёра глазами современников середины прошлого века // Казань. 2002. № 3/4; Салихова А.Р. Татарский театр в литературно-критическом наследии Габдрахмана Карама. К., 2003; Театральная энциклопедия. М., 1967. Т. 5.

Ю.А.Благов, А.Габәши.

ТЕА́ТР ФЕСТИВАЛЬЛӘРЕ́, театр сәнгате казанышлары смотрлары; иң яхшы башкаручыларны (режиссёрлар, актёрлар) билгеләп үтү һәм театр сәнгатен пропагандалау максатыннан истәлекле даталар, иҗтимагый вакыйгалар хөрмәтенә уздырылган тантаналы бәйрәмнәр. ТРда Мәдәният министрлыгы, Театр эшлеклеләре берлеге, аерым театр коллективлары (Әлмәт, Минзәлә татар драма театрлары уздырган Т.ф., 1967) тарафыннан уздырыла. 1983 тә — «Авылга театр» («Театр — селу») дип аталган Респ-ка театр фестивале, 1984–85 тә — балалар һәм яшүсмерләр өчен иң яхшы спектакльгә Респ-ка смотр-конкурсы, 1991 дә театр-студияләрнең Респ-ка Т.ф. була. Кама аръягы театрлары фестивале (Әлмәт, 2003, 2004), яшь режиссёрларның Т.ф. (Казан, 2009), *Тинчурин К. исемендәге театр фестивале, «Нәүруз» театр фестивале* үткәрелә.

ТЕГЕРМӘ́Н, к. *Мельничный*, Балтач р-ны.

ТЕГЕРМӘ́Н ПҮЧИНКӘСЕ́ авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 25 *км* көнчыгыштарак, Суша елгасы буенда. 2010 елда 176 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 59%, татарлар — 39%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1646 дан мәгълүм. 1861 гә кадәр халкы алпавыт крәстиннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.П.ндә иске дин тарафдарлары гыйбадәтханәсе, чиркәү-приход мәктәбе (1891 дә ачыла), 2 тегермән, ярма яргыч, 4 вак-төяклөр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1149 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Уракчы волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 120 ир-ат; 1859 да — 690, 1897 дә — 1291, 1908 дә — 1321, 1920 дә — 1165, 1926 да — 1099, 1938 дә — 978, 1949 да — 690, 1958 дә — 533, 1970 тә — 419, 1989 да — 224, 2002 дә — 267 кеше.

ТЕГЕРМӘ́Н ТАВЫ́ авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 37 *км* көнчыгыштарак, Нырсы елгасы буенда. 2010 елда 7 кеше (татарлар, руслар) яши. Халкының төп шөгы-

ле — кырчылык. 1680 нән Тегермән Пүчин - кәсе исеме б-н билгеле. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Таутимерчан, Таутерлан, Таукирмән буларак та мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тимерчелек, йон-тукыма ману б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү-приход мәктәбе (1900 дә ачыла), су тегермәне, 4 тимерче алачыгы, 2 йон-тукыма ману йорты, 2 вак-төяклəр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 988 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Питрәч, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән Питрәч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 28 ир-ат; 1859 да — 418, 1897 дә — 652, 1908 дә — 785, 1920 дә — 740, 1926 да — 177, 1938 дә — 509, 1949 да — 442, 1958 дә — 276, 1970 тә — 174, 1979 да — 116, 1989 да — 53, 2002 дә — 32 кеше.

ТЕГЕРМӘНЛЕ́К авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 17 *км* төньяк-көнбатыштарак, Ык елгасыннан 2 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 110 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1735 кә кадәр нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Тегермәннек исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы типтәрләр, дәүләт крәстияннәре һәм асабалар катлаулары - на бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп, ашлык саклау-сату һәм бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1037,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Иректе волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1816 да — 103, 1834 тә — 117 ир-ат; 1870 тә — 382, 1897 дә — 506, 1906 да — 601, 1913 тә — 611, 1920 дә — 561, 1926 да — 384, 1938 дә — 355, 1949 да — 261, 1958 дә — 210, 1970 тә — 208, 1979 да — 167, 1989 да — 123, 2002 дә — 96 кеше.

ТЕГЕРМӘНЧЕ́ авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 32 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Мөшеге елгасы буенда. 2010 елда 91 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Чуплюк исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы типтәрләр катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, он тарту б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, су тегермәне була. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 195 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Пучы волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1944 нең 19 февраленнән — Матвеевка, 1954 нең 19 ноябреннән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән Минзәлә р-нында. Халык саны: 1795 тә — 40, 1859 да — 81, 1870 тә — 92, 1884 тә — 99, 1906 да — 193, 1913 тә — 153, 1920 дә — 126, 1926 да — 127, 1938 дә — 132, 1949 да — 123, 1958 дә — 118, 1970 тә — 141, 1979 да — 121, 1989 да — 93, 2002 дә — 101 кеше.

Әд.: Мензелинский край: История и современность. Мензелинск, 2006.

ТЕГҮ́ СӘНӘГАТЕ́, җи ңел сәнәгатьнең көнкүреш ихтыяҗлары өчен һәм техник максатларда тукымалардан, трикотаж, ясалма һәм табигый күн, мех һ.б.дан кием-салым һ.б. эшләнмәләр җитештерү тармагы. ТРда 217 пр-тиене үз эченә ала, эшләүчеләрнең гомуми саны — 5 меңгә якын кеше; җи ңел сәнәгатьнең тулай продукциясендә чагыштырмача өлеше — 23,8% (2011). Эре һәм уртача зурлыктагы пр-тиеләрнең саны — 69, алар арасында — «Адонис», «КазХимНИИ» (икесе дә — Казанда), «Азнакай киемнәре», *«Алсу» Әлмәт оек-оекбаш фабрикасы»* акц. җәмгыятьләре, «Татмехторгпром», «Мелита», «Бамбл-Би» (Казан), «Мерлин», «Петро-Плюс» (Яшел Үзән ш.), «Карлен» (Лениногорск ш.) «Алексеев нәфис туку фабрикасы», «Мамадыш сәнәгать комбинаты», «Чистай «Реглан» УПП», «ТАТТекс» (Алабуга ш.) ҖЧҖләре һ.б. Кайбер шәһәрләрдә (Чаллы, Лениногорск һ.б.), шәһәр тибында - гы посёлокларда, авылларда кече тегү пр-тиеләре эшли.

Казан губернасында *тегүчелек кәсепчелеге* 19 йөзнең 2 нче яртысында таралыш ала, һөнәрчеләр шәһәр байларына хезмәт күрсәтәләр. 1880 елга 4 меңгә кадәр өйдә тегүче (башлыча татарлар) исәпләнә. Баш киемнәрен өйдә эшләүче 170 тегүче тегә (башлыча Казан, Мамадыш һәм Тәтеш өязләрендә). Техник җиһазлану дәрәҗәсе түбән була.

19 йөз ахырында — 20 йөз башында остаханәләр оештырыла башлый. Казанда 11 өс киемнәре тегү остаханәсе эшли, аларның иң әресе Алафузовларның хәрби кием тегүче пр-тиеләре була (1860 та нигезләнәләр, 1905 тә эшләүчеләр саны 2 мең кешегә җитә). «Шмулевич һәм К°» сәүдә йорты» остаханәсендә (1905 тә нигезләнә, 200 гә кадәр кеше эшли) — күлмәк, 4 остаханәдә, ш.и. «В.Д.Петрова һәм К°» ширкәтендә — баш киемнәре, Гликин һәм Шабанов пр-тиеләрендә сарык тиресеннән туннар тегәләр. Шәһәрдә тегүчелектә мәшгульләр саны 3 мең кешедән арта. Губернаның башка шәһәрләрендә һәм авылларында да тегү остаханәләре була. 1913 тә җитештерелгән продукциянең бәясе 7 млн. сум тәшкил итә.

1920 елларда Т.с. яңа пр-тиеләр төзү һәм булган пр-тиеләрне техник яктан яңартып коралландыру хисабына үсеш кичерә. Казанда 3 нче Интернационал исем. тегү ф-касы яңадан эшли башлый, 1 нче тегү ф-касы, 1 нче Казан мех ф-касы (к. «*Мелита*») файдалануга тапшырыла. 1930 елларда 13 тегү ф-касы, ш.и. 6 мех пр-тиесе эшли, аларда эшләүчеләр саны 7,4 мең кеше тәшкил итә. Барлык ф-калар да «Татшвейтрест» (1930–75) карамагында була.

Бөек Ватан сугышы елларында респ-кага Киев һәм Харьковтан берничә фабрика эвакуацияләнә; тармак пр-тиеләре хәрби киемнәр һәм кирәк-яраклар эшләп чыгара. Соңрак фабрикалар көндәлек кием-салым җитештерүгә күчә.

1950–60 елларда пр-тиеләрнең техник җиһазлануы сыйфат ягыннан үзгәрешләр кичерә. Аларның күбесе эреләндерелә һәм махсуслаштырыла. 1940 ел б-н чагыштырганда, 1950–55 тә җитештерү күләме 1,7 тапкыр, 1960 та 3 тапкыр диярлек арта. Тармакны техник яктан яңартып коралландыру махсус машиналар, ярымавтоматлар, тегү эшләнмәләрен дымлы һәм җылы ысул б-н эшкәртү өчен пресслар кулланышка кертелү хисабына 1960–70 елларда аеруча интенсив бара. Тегү ҖБләре ачыла («Волга», «Татарстан», «Татшвейбыт» һ.б. — составларына 3 тән 17 гә кадәр фабрика керә; эшләнмәләрнең 600 яңа фасоны һәм моделе үзләштерелә). 1975 тә костюмнар, өске киемнәр, күлмәкләр һәм эчке киемнәр чыгаручы 3 Татарстан тегү берләшмәсе оештырыла, 1988 дә алар Татарстан «Киемнәр» сәнәгать-сәүдә тегү берләшмәсе составына керәләр; фабрикалар Казанда һәм ТАССРның 9 шәһәрендә урнаша, эшләүчеләр саны 8 меңгә якын була. Мехтан кышкы өс-баш киемнәре составына 6 фабрика (ш.и. кайры туннар чыгаручы «Золотое руно»), респ-каның 5 шәһәрендәге 66 ателье һәм остаханә, «Люкс» модалар йорты кергән «Зима» берләшмәсе (1980–2005) пр-тиеләрендә тегелә. 1980 дә, 1970 ел б-н чагыштырганда, 34% ка күбрәк продукция җитештерелә. 1980 елларда сыйфаты һәм ассортименты яхшыртылган эшләнмәләр «Н.» («Новинка») билгесе б-н чыгарыла. 1981–85 тә, алдагы бишьеллык б-н чагыштырганда, продукция җитештерү 13% ка арта.

Базар икътисады мөнәсәбәтләренә күчү чорында (1990 еллар) тармак пр-тиеләре хосусыйлаштырыла, АҖ һәм ҖЧҖләр итеп үзгәртелә. Чималга бәяләр кискен үсү, халыкның сатып алу сәләте кимү, әйләнештәге акчалар җитмәү, кием-салымны күпләп читтән кертү нәтиҗәсендә пр-тиеләр кризис хәленә төшә, аларның кайберләре бөлгенлеккә төшә («Диона», «Илдан», «Киемнәр», «Динамо» акц. җәмгыятьләре һ.б.). 1990 ел б-н чагыштырганда, 1998 дә тармак продукциясен җитештерү 5 тапкыр кими (тиңдәшле бәяләрдә).

2000 елларда күп кенә пр-тиеләр техник яктан яңартып җиһазлана һәм җитештерү модернизацияләнә, киемнәрнең яңа модельләре чыгарыла башлый, хезмәт җитештерүчәлеге арта. 2011 дә Т.с.нең тулай продукциясе күпкә арта, аның бәясе 1,3 млрд. сум тәшкил итә (шуның 22% ы — мехлар, мех эшләнмәләр); 25,5 мең данә күлмәк, 6,1 мең пальто һәм кыска пальто, 32,2 мең куртка, 6,7 мең плащ, 119 мең костюм, 255,9 мең чалбар, 62,5 мең блузка, натураль мехтан 12,2 мең пальто һәм кыска пальто, 41,5 мең баш киеме җитештерелә.

Әд.: Борисов И. Казанские швейники до и после октября 1917 г. К., 1927. Кн. 1; Рабочий класс Татарии (1861–1980). К., 1981; Шакиров Н.К. У подножия Синей горы // Идель. 2002. № 12; История Казани в документах и материалах. XX век. К., 2004; История Казани в документах и матери -

алах. XIX век: Промышленность, торговля, финансы. К., 2005.

М.Ж.Гаитов, М.Х.Ибраһимов.

«ТЕГҮЧЕ́», газета; к. «*Большевичка*».

ТЕГҮЧЕЛЕ́К КӘСЕПЧЕЛЕГЕ́, Казан губернасының Лаеш б-н Мамадыш өязләрендә аеруча киң тарала. Тарихи чыганакларда бу өязләрдә «...тулаем алганда, тегүчелек б-н шөгыльләнүче татар халкы яши торган бик күп волостьлар бар» диелә. 1880 еллар ахырында Лаеш, Мамадыш һәм Казан өязләрендә Т.к. б-н шөгыльләнгән 4 меңнән артык кеше исәпләнә, аларның күбесе татарлар була. Тегүчеләрнең бер өлеше өйдә эшли, калганнары эш эзләп якын-тирәдәге авылларга һәм күрше Вятка, Пермь, Уфа губерналарына юнәлә. Кайбер тегүчеләр Оренбург, Троицк, Ташкент шәһәрләренә китәләр. Тегүчеләрнең эш сезоны а.х. эшләре тәмамлангач башлана һәм көзге-кышкы чорда берничә ай дәвам итә. Заказ буенча туннар, кафтаннар, бишмәтләр һ.б. тегәләр. Тегүченең хезмәт хакы бер елга 80 сумнан алып 120 сумга кадәр тәшкил иткән.

Әд.: Материалы для исследования промыслов населения Казанской губернии. к., 1887.

И.Р.Вәлиуллин.

ТЕЗМӘ, татар хатын-кызларының чәч толымы бизәге төре. Кызларның классик төрдәге бизәнү әйбере, зур булмаган кабарынкы аеллар (еш кына гарәп язулары б-н тулыландырылган үсемлек бизәкләре төшерелә) яки көмеш акчалар тагылган 2 тукыма тасмадан тора (киңлеге 2–3 *см*, озынлыгы 80 *см* га кадәр). Тасмалар бер-берсенә тар тасмалар б-н беркетелә. Т.нең өске өлешендә, гадәттә, зур аел яки *Коръән тартмачыгы* беркетелә, аскы өлеше көмеш, алтын җепле чуклар яки розеткалы вазон рәвешендәге асылмалы бизәкләр, сузынкы формалы аеллар б-н тәмамлана. Тасмаларның очына еш кына *чулпы* беркетелә. Кыйммәтле Т.ләрдә тукыма нигез урынына ике яктан аеллар яки көмеш акчалар, өске өлешенә — Коръән тартмачыгы беркетелгән озын көмеш чылбыр файдаланыла. Мондый Т.ләрне Казан (Казан арты төбәкләре) һәм Касыйм татарлары еш кулланган. Аның төрдәшләрен төрекмән, казакъ, тажик хатын-кызларының чулпыларында күрергә мөмкин.

Этнограф Н.И.Воробьёв фикеренчә, Т.нең барлыкка килүе каты нигездәге биек формалы хатын-кызлар баш киеме комплексының үзгәргән, «канат-көйрык» дип йөртелгән өлеше б-н бәйле («көйрык» чәчләрне арка ягыннан каплаган). *Калфаклар* барлыкка килгәч, ул мөстәкыйль бизәнү әйбере — Т.гә әйләнә. Ф.Х.Вәлиев мәгълүматы буенча, Казан татарларында Т. болгар гореф-гадәтләренә барып тоташа (8–9 йөзләргә караган Югары Салтау каберлегенә нисбәтле чәч толымы бизәкләре аның үрнәге санала). Алар аскы өлеше фигуралы божралар, өсте бөти-тартма б-н тәмамланган дүрт озын чылбырдан торган.

Бер яки ике-өч рәт акчалар б-н тегелгән бер киң яки өч тар тасма рәвешендәге Т. үрнәкләре татарларның төрле этник төркемнәренә, башлыча, авыл хатын-кызларына нисбәтле (керәшен татарларда, татар-мишәрләрнең аерым төркемнәрендә). Шундый Т.нең аскы өлеше — койрык — эре көмеш акчалар, кайвакыт кечкенә кыңгыраулар, чуклар һәм чулпылар б-н бизәлгән. Буй-буй киң тасмалы Т.ләр ш.у. башкортларда, удмуртларда, мордва, мариларда очрый. Т.гә толымнарга ябыла торган, тукымадан теккән чәчкап якын тора.



Тезмә. Тукыма, көмеш тәңкә, вак акча. Коелма, чүкеп ясалган бизәк, асылташлар б-н корлау. 19 йөз. Икесе дә – ТР Милли музеенда.

Челтәр уеллы Т. зәркән бизәкләрнең башка бер төренә керә. Гадәттә, алар түгәрәк формасында уеплау, чүкеп бизәк төшерү, сирәк кенә каралту техникаларында башкарылган, чәчәк розеткалары, букетлары, яшь ботак, бау үрнәкләрендә, канатларын җәйгән бер яки ике башлы кошлар рәвешендә бизәлгән нәр. Мондый уеллар ш.у. *хәситә* һәм *изүдә* кулланыла. Т.дәге борынгы уелларның кайбер бизәкләре болгар металл сәнгате әйберләрендәге уел бизәкләренә якын тора.

Әд.: Воробьёв Н.И. Казанские татары. К., 1953; Суслова С.В. Женские украшения Казанских татар середины XIX — начала XX вв.: Ист.-этногр. исслед. М., 1980; Валеев Ф.Х. Народное декоративное искусство Татарстана. К., 1984; Валеев Ф.Х., Валеева-Сулейманова Г.Ф. Древнее искусство Татарии. К., 1987.

Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.

ТЕЙТЕЛЬБА́УМ Бенцион Яковлевич (22.2.1918, Царицын ш. — 3.4.1999, Казан), физик-химик, химия фән. д-ры (1972), проф. (1977). 1940 елда Ростов ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. 1947–92 дә РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында эшли, физик-химик тикшеренүләр лаб-ясе мөдире (1956–86). Хезмәтләре физик химиягә, югары молекуляр кушылмаларга һәм күп компонентлы системаларга карый. Т. югары молекуляр кушылмаларны физик-химик һәм термомеханик алымнар ярдәмендә тикшерә, полимерларның темп-раны өзлексез үзгәртү режимында халәте закончалыкларын ачыклый. Төрле полимер системаларның фаза-агрегат халәте турында яңа мәгълүмат ала, үзлекләрнең молекуляр төзелешкә һәм физик структурага бәйлелеген өйрәнә. Химия фәненең төрле өлкәләрендә куллану тапкан күпкенә приборлар, ш.и. автомат газ бюреткасын (СССР ФА Президиумы бүләге, 1958), полимерларның термомеханик кәкреләрен автомат рәвештә теркәү җайланмасын (СССР ВДНХсының көмеш медале, 1975), җир асты токымнары һәм грунтларның микъдари-фаза анализлары өчен автомат зур тизлекле прибор (Л.Г.Берг б-н бергә) һ.б.ны эшли. Үйлап табуга 5 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр; ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Термомеханический анализ полимеров. М., 1979; Исследование молекулярновесового распределения олигомерных полиэтиленгликолей // Высокомолекулярные соединения. Сер. А. 1975. Т. 17, № 1 (автордаш); Влияние состава на фазовые состояния уретановых термоэластопластов на основе 4,4-дифенилметандиизоцианата // Высокомолекулярные соединения. Сер. А. 1977. Т. 19, № 6 (автордаш).

ТЕЙТЕЛЬБА́УМ Григорий Бенционович (10.6.1946, Ростов-Дон ш.), физик, физика-матем. фән. д-ры (1986), проф. (2000), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2002). 1968 елда Казан ун-тын тәмамлый һәм РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында эшли, перспектив материаллар физикасы лаб-ясе мөдире (1987 дән). Хезмәтләре магнит күренешләре физикасына һәм югары темп-ралы үтә үткәрүчәнлеккә карый. Т. үткәрүчәнлек электрон-нарына доплерча авыш спин резонансын фаразлый, соңрак ул тәжрибәләрдә раслана. ТМР алымнары ярдәмендә беренче булып металл-оксидлар страйп-фазасының локаль үзлекләрен билгели. Төш-спин релаксациясе анализы нигезендә үтә үткәрүчән купратлардагы ялган ярыкларның микромасштаблы металл һәм магнит өлкәләргә фазалы динамик катламлану нәтиҗәсе икәнен аңлата. Үтә үткәрүчән металл-оксидларның стандарт булмаган күчерү үзлекләре тышкы допирлану һәм термоактивлану аркасында туган ике төрле корылма йөрткечләр булуга бәйле икәнен һәм алар арасындагы балансның ялган ярыклар фазасына күчүне билгеләвен ачыклый. Үтә үткәргечләрнең нано үлчәнешле үзлекләре табигатен магнит резонансы алымнары ярдәмендә тикшеренүләр циклы өчен ТР Дәүләт бүләгенә лаек була (2007). Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Допплеровски сдвинутый спиновый резонанс в электронной жидкости металлов // Журн. эксперим. и теорет. физики. 1972. Т. 63, вып. 1; Динамика намагниченности в дипольной критической области // Письма в журн. эксперим. и теорет. физики. 1975. Т. 21, вып. 6; Interplay of externally doped and thermally activated holes in LSCO and its impact on the pseudogap crossover // Phys. Rev. Lett. 2006. V. 97 (автордаш).

ТЕКӘ́ КҮЛ, Көнбатыш Кама алдында. Сумка елгасы бассейнында урнашкан, Яшел Үзән р-ны Белобезводный авылыннан 2 *км* көнчыгыштарак, Идел-Кама саклаулыгының саклау зонасы янында. Көнбатыштан күлгә урман массивы тоташа. Су өслегенең мәйданы якынча 2 *га*. Су күләме 20 мең $м^3$. Озынлыгы 220 *м*, иң зур киңлеге 140 *м*. Уртача тирәнлеге якынча 1 *м*, иң зур тирәнлеге 3 *м*. Күл карст-суффозия процессы нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Формасы буенча катлаулы, озынча, трапециясыман. Суы җи ңелчә ми-



Текә күл.

нераль ләшкән (100 *мг/л* га кадәр), гидрокарбонат-сульфат-хлорид-кальцийлы типта. Җәйге чорда үтә күренмәлелеге 0,5 *м*. Ял итү урыны.

ТЕКСТИ́ЛЬ СӘНӘГАТЕ́, *җи ңел сәнәгать* нең иң борынгы һәм иң эре тармакларыннан берсе, үсемлекләрдән (җитен, мамык, киндер), хайваннардан (йон) алынган һәм ясалма сүсләрдән эрләнгән яки башка төр җепләр, тукыма, трикотаж һәм тукылмаган материаллар эшләп чыгара. Татарстанда Т.с.нә йон ны беренчел эшкәртү пр-тиеләрен, җитен эшкәртү, текстиль галантерея, *трикотаж сәнәгате*, киез һәм киез итек җитештерү пр-тие ләрен кертәләр. 18–19 йөзләрдә Казан губернасы икътисадында *постау сәнәгате*, ш.у. *чыпта-кап сугу* һәм *бау-аркан ишү сәнәгате* зур роль уйный. 18 йөз уртасында *комач ма нуфактуралары* оеша башлый, соңрак *киҗе-мамык җитештерү сәнәгате* шактый үсеш ала (пр-тиеләрнең күпчелеге 1990–2000 елларда ябыла). Т.с.нең әйдәп баручы пр-тие ләре булып *«Алсу» Әлмәт оек-оекбаш фабрикасы*, «*Казан җитене*», «*Казан текстиле*», «Казан трикотажы», «*Кукмара киез итек-киез комбинаты*» акц. җәмгыятьләре, «Алабуга армирлау тукымалары з-ды «Крёз» ҖЧҖ санала (Т.с.нең төп продукцияләрен җитештерү күләме таблицада китерелә).

ТЕКСТОЛО́ГИЯ (лат. textus — элемтә, күшылма һәм *...логия*), филол. фәне өлкәсе. Төп (каноник) текстларны ачыклау йөзеннән әдәби, фәнни-тәнкыйди, фәлсәфи, публицистик әсәрләрне, фольклор текстларын, тарихи документларны өйрәнә. Мо ңа барлык күлъяз ма һәм басма чыганакларны анализлау, ш.у. аноним яки псевдоним б-н билгеле булган әдәби әсәрләрнең авторларын, язылу уры нын һәм вакытын ачыклау — *атрибуция* аша ирешеп була. Т. әдәбият теориясе, тарихы, тәнкыйте һәм җәмгыять тарихы б-н бәйле. Т.нең максаты — текстны (автор ихтиярына мөмкин кадәр туры китереп) тирәнтен аңлау өчен шартлар тудыра торган, гыйльми эзләнүләргә, алга таба тикшерү һәм интерпретацияләүгә хезмәт итәрдәй шәрехләүләр төзеп бастыруга әзерләү. Бу вакытта алар идеологик сәбәпләргә бәйле рәвештә, теге яки бу дәрәҗәдә үзгәрергә мөмкин. Шәрехләүләрдә текстологның субъектив фикри нәтиҗәләре дә чагылуы ихтимал.

Татар әдәбияты һәм фольклоры Т.се мәсел ман Көнчыгышында киң таралган дини, фәл сәфи һәм филол. эчтәлекле әсәрләргә, ш.у. Урта гасыр гомумтөркиләзма ядкәрләренә шәрехләмә бирү традициясенә барып тоташа. 19 йөз татар әдәбиятында күренекле тексто логларның берсе шагыйрь һәм фикер иясе Г.Утыз Имәни була. Ул 1839 елда, күлъязмаларга таянып, Кол Галинең «Кыйссаи Йо сыф» поэмасының тәнкыйди текстын басмага әзерли. Татар Т.сенә Ш.Мәр җани, К.Насыйри, Г.Баһапов, Т.Яхин, Г.Фәезханов, С.Кукляшев, Р.Фәхретдинов зур өлеш кертә. Аларга төркитатар язма ядкәрләрен бастырганда күп кенә текстологик мәсьәләләрне (мәс., күлъязма-автографларның булмавы) хәл итәргә туры килә. Татар Т.сенең теоретик һәм әдицион-текстологик өлкәләре үсешенә В.В.Радлов, М.И.Иванов, К.Ф.Фукс, Н.Ф.Катанов, С.Рыбаков, Е.Э.Бертельс, А.Н.Самойлович, В.В.Вельяминов-Зернов, Х.Д.Френ, И.Н.Березин һ.б. рус шәркыятьче галимнәре, Г.Вамбери, Г.Балинт, А.Зайончковский, Ф.Күпрелезадә кебек чит ил галимнәре зур йогынты ясый. 1910–1930 елларда текстологик эзләнүләрдә Г.Ибра һимов, Гали Рәхим, Җ.Вәлиди, Ф.Туйкин, Ф.Сәйфи-Казанлы, Г.Газиз, Г.Сәгъди катнаша. 1940–50 елларда әдәби мирасны җыю һәм бастыруга әзерләү эшен ТАССР ХКС каршында оешкан Татар теле һәм әдәбияты фәнни-тикшеренү ин-ты (хәзер ТР ФАнең *Тел, әдәбият һәм сәнгать институты*) галимнәре Я.Х.Агишев, Х.Х.Хисмәтуллин, М.Х.Гайнуллин, М.В.Гали, Х.Х.Ярми, язучы А.Ш.Шамов дәвам итә. Т. үсешендә 1976 дан ин-тның татар әдәбия ты секторында, 1987 дән яңадан ачылган күлъязмалар һәм Т. бүлегендә татар әдәбия ты классиклары әсәрләрен бастыруга әзерләү буенча текстологик төркем оештырылу мө һим роль уйный (җитәкчесе З.З.Рәмиев). Төркемнең фәнни хезмәткәрләре (Р.Р.Гайнанов, М.И.Әхмәт җанов, Ф.И.Ибра һимова, Н.Г.Ханзафаров, Л.Р.Гайнанова, Ә.Х.Алие ва, Н.И.Садыйкова һ.б.) тарафыннан 1970–80 елларда Г.Тукай, Ф.Әмирхан, М.Гафури, Г.Ибраһимов, Г.Камал, Һ.Такташның күп томлы әсәрләре басмага әзерләнә. 2007 дә ин-тта Т. төркеме нигезендә Р.Кадыйров, З.Мөхәммәтшин, З.Шәйхисламов, Э.Галимҗанова, Г.Хөснетдинова, Ф.Фәйзуллина һ.б. катнашында махсус Т. бүлеге төзелә. 2012 гә кадәр аның фәнни тикшеренүләрендә төп юнәлеш Г.Исхакыйның унбиш томлы «Әсәрләр»ен басмага әзерләү була. Совет чорында татар халкының классик әдәби мирасын өйрәнү цензура басымы б-н шактый чикләнә (басмаларга әсәрләрне сайлап яисә купюралар белән кертү, шәрехләүләрне марксистик-ленинчыл идеология принциплары позициясеннән бирү, текстларның дини мотивларны чагылдырган аерым шәхесләр телгә алынган өлешләрен төшереп калдыру һ.б.). Идеологик басым бетерелү, тарихи-әдәби текстларны, ш.и. элек тыелган эмигрант язучылар иҗатын объектив өйрәнү мөмкинлеге бирә. Татар әдәбияты Т.сенең теоретик мәсьәләләре Н.Г.Юзиев, З.З.Рәмиев, Х.Й.Миңнегулов, Ж.С.Миңнуллин, Р.Ф.Мәрданов хезмәтләрендә чагылыш таба. Ф.С.Фәсиев, Ш.Ш.Абилов, И.Абдуллин, Ә.Ш.Шәрипов, Х.Госман, М.Г.Госманов, Х.Й.Миңнегулов, Ш.А.Садретдинов, Р.Ф.Исламов тарафын нан зур күләмле текстологик гамәли эшләр башкарыла. *З.З.Рәмиев.*

ТЕКТО́НИКА (грек. tektonikós — төзелешкә нисбәтле), геол. бүлеге; Җир кабыгының төзелешен, хәрәкәтен, үзгәрүләрен һәм үсешен өйрәнүче фән. Т. тикшеренүләре нигезендә тектоник карталар төзелә (к. *Структур карта*), алары исә файдалы казылмалар эзләүдә, җир тетрәүләрне прогнозлауда, төзелештә һ.б. максатларда файдаланыла. Т.ның нигезе 17 йөздә Дания галиме Н.Стено тарафыннан салына. 18 йөздә М.В.Ломоносов һәм Шотландия галиме Дж.Геттон Җир кабыгы үсешенең беренче фәнни гипотезасын эшлиләр. 19 йөздә Америка геологлары тарафыннан — геосинклиниаль, рус галимнәре Н.А.*Головкинский*, А.П.Карпинский һ.б. тарафыннан — платформалар, 19 йөз ахыры — 20 йөзләр башында континентлар хәрәкәте (плитәләр Т.сы дип аталучы) турындагы тәгълиматларга башлангыч салына. Татарстанда Т. өлкәсендә тикшеренүләр Казан ун-тын да, ЦНИИгеолнеруд, «Татнефть» АҖ, «ТНГ-Групп» һ.б. оешмаларда алып барыла. А.П.Боронин, Г.Е.Кузнецов, А.Г.Салихов, В.П.Степанов, И.М.Уразаев һ.б. тарафыннан җир кабыгының тирәнтен төзелеше билгеләнә. ТР терр-ясендә Җир кабыгының табаны 35–43,5 *км* тирәнлектә ята һәм тирәнтен җимерелүләр б-н бүленгән 12 калку, 8 иңкү зона хасил итә. Җимерелүләр кристаллик нигезне — блокларга, ә утырма тышлык калку (гөмбәзләр, чокырлар) һәм иңкү (батын кылык һәм бөгелешләр) участокларга бүлә. 1 нче рәт структуралары: *Югары Кама иңкүлеге, Казан-Киров бөгелеше, Кама-Кинель бөгелешләр системасы, Мәләкәс батынкылыгы, Төньяк Татар гөмбәзе*, Көньяк Татар гөмбәзе, *Токмово гөмбәзе* (мегаблок) һәм аларны катлауландыручы 2 нче һәм 3 нче рәт струк-

Татарстанда 1940–2013 елларда текстиль сәнәгатенең төп продукция төрләрен җитештерү

	1940	1950	1960	1970	1980	1990	2000	2013
Ки же-мамык җеп, *т*	28,0	70,0	1770,0	2604,0	1676,0	1511,0	–	–
Ки же-мамык тукыма, млн. *м*	0,1	6,1	3,6	8,9	5,5	3,0	–	–
Ки же-мамык, *т*	2100,0	2079,0	4758,0	2911,0	4109,0	811,0	–	–
Җитен җебе, *т*	2924,0	4696,0	9059,0	8986,0	5182,0	3143,0	212,0	–
Җитен тукыма, млн. *м*	5,5	8,8	16,3	12,9	9,9	6,9	1,3	–
Трикотаж өс киеме, мең данә	160,0	453,0	1095,0	2880,0	3082,0	2629,0	46,9	211,3
Юылган йон, мең *т*	2,9	4,5	10,9	11,7	10,9	6,1	1,1	–
Тукылмаган материал, мең *м*	–	–	–	1044,0	2741,0	3061,0	558,0	257,8

туралар билгеләнгән, алар б-н исә нефть чыганаклары бәйле. Ш.у.к. *Неотектоник хәрәкәтләр*.

Хезм.: Юсупов Б.М. Тектоника Татарии // Тр. КФАН СССР. Сер. геол. наук. 1960. Вып. 6; Войтович Е.Д., Гатиятуллин Н.С. Тектоника Татарстана. К., 1998; Геология Татарстана: Стратиграфия и тектоника. М., 2003; Нефтегазоносность Республики Татарстан. К., 2007. Т. 1; Ларочкина И.А. Новая модель тектонического строения структуры кристаллического фундамента Татарстана // Георесурсы. 2008. № 4.

ТЕЛ, ӘДӘБИЯ́Т ҺӘМ СӘНГА́ТЬ ИНСТИТУТЫ́, Г. Ибраһимов исемендә, ТР ФАнең фәнни-тикшеренү ин-ты. *Тел, әдәбият һәм тарих институты* составыннан 1997 елда (ТР МКның 1997 ел 17 февр. карары нигезендә) *Тарих институты* аерылып чыкканнан соңгы исеме. Институтта (2016) 10 бүлек: гомуми лингвистика, лексикология һәм диалектология, лексикография, әдәбият белеме, текстология, халык иҗаты, театр һәм музыка, тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать белеме, фәнни-нәшрият бүлеге, Язма һәм музыкаль мирас үзәге эшли. Институтта 4 юнәлеш буенча аспирантура бар. Эшчәнлегенең өстенлекле юнәлешләре: татар теленең функциональ һәм структур үсеше мәсьәләләре; татар әдәбияты тарихы һәм теориясе; татар халык иҗаты тарихы һәм теориясе; татар әдәбияты өлкәсендә текстологик эзләнүләр һәм чыганакларны барлау; мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә дәвамлылык һәм үсеш мәсьәләләре. Чит илләргә, Россия төбәкләренә һәм Татарстан районнарына археографик, диалектологик, фольклор, сәнгать буенча комплексны экспедицияләр оештырыла. Экспедицияләр нәтиҗәсендә «Милли-мәдәни мирасыбыз» сериясенән җыентыклар дөнья күрә. 2014 тән ин-т татар телендә «Фән-ни Татарстан» ж-лы чыгара. Коллективта 111 кеше эшли, шуларның 91е — фәнни хезмәткәр, ш.и. 23 — фән д-ры һәм 51 — фән канд. Институт акад. оешмалар һәм югары уку йортлары, музейлар, иҗади берләшмәләр, ТР һәм РФ китапханәләре, якын һәм ерак чит илләр фәнни үзәкләре б-н әлемтәдә тора. Төп хезмәтләре: «VIII–XVIII гасырлар татар әдәбияты» (1999), «Татар грамматикасы» (1–3 т., 1998–2002), «Яңа дәвер татар әдәбияты тарихы (XIX — XX гасыр башы)» (2003), «Татар әдәби теле тарихы (XIII–XX гасырның беренче чиреге)» (2003), «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» (2005), 2 томлык «Татарча-русча сүзлек» (2007), «Диалектологик сүзлек» (2009), 2 томлык «Татар теленең этимологик сүзлеге» (2015), Гаяз Исхакыйның 15 томлык «Әсәрләр»е (1998–2014), Габдулла Тукай әсәрләренең 6 томлык акад. басмасы (2011–2016), 1 томлык «Габдулла Тукай энциклопедиясе» (2016).

Өч томлык «Академик лексикология»нең, 3 томлык «Академик грамматика»ның, 6 томлык «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»нең, 3 томлык «Татар әдәби теле тарихы»ның беренче томнары дөнья күрә, 8 томлык «Татар әдәбияты тарихы»ның 3 томы, 15 томлык (рус телендә) «Татар халык иҗаты» җыелмасының биш томы басылып чыга. Институт галимнәре 3 томлык «Татар театры тарихы»н, 3 томлык «XX гасыр Татарстан рәссамнары» антологиясен, 2 томлык «Татарстанда китап сәнгате»н, 25 томлык (татар телендә) «Татар халык иҗаты» җыелмасын, «Татарстан Республикасы топонимнарының электрон картотекасын һәм географик объект исемнәренең дәүләт каталогы»н әзерли.

Фәнни эзләнүләргә зур өлеш керткән галимнәр — М.Г.Арсланов, М.И.Әхмәт җанов, Ф.С.Баязитова, И.Б.Бәширова, М.В.Гайнетдинов, Ф.Ә.Ганиев, Ф.Г.Гарипова, М.З.Зәкиев, Х.Р.Курбатов, Х.Ш.Мәхмүтов, Ф.М.Мусин, Д.Б.Рамазанова, З.З.Рәмиев, Ф.И.Урманчеев, М.Б.Хәйруллин, Н.Ш.Хисамов һ.б. Ин-т директорлары: М.З.Зәкиев (1997–2000), Н.Ш.Хисамов (2001–2006), К.М.Миңнуллин (2006 дан).

ТЕЛ, ӘДӘБИЯ́Т ҺӘМ ТАРИ́Х ИНСТИТУТЫ́ (ТӘТИ), Г. Ибраһимов исемендә, ТР ФАнең Татарстан һәм татар халкы тарихы һәм мәдәнияте өлкәсендә фәнни-фундаменталь тикшеренүләр үзәге. 1939 елда ТАССР ХКС каршында Татар теле һәм әдәбияты фәнни-тикшеренү ин-ты буларак оештырыла, 1941 дә Татар теле, әдәбияты һәм тарих фәнни-тикшеренү ин-ты дип үзгәртелә, 1945 тән – СССР ФАнең Казан ф-лы составында, 1973 тән — Тел, әдәбият һәм тарих ин-тына, 1991 дән — РФАнең КГҮнә, 1993 тән ТР ФАнә керә, 1967 дән Г.Ибраһимов исемендә.

Башта ин-тта әдәбият, тарих, татар теле, фольклор, рус теле бүлекләре булдырыла; 1991 дә археол., тарих, этнография, тел белеме, әдәбият белеме, лексикология һәм лексикография, күлъязмалар һәм текстология, халык иҗаты, иҗтимагый фикер, сәнгать, Татар энциклопедиясе, икътисад, тарихи һәм мәдәни ядкәрләр җыелмасы бүлекләре эшли. Хезмәткәрләрнең саны 19 дан (1939) 215 кә (1993) җитә. 1997 дә тарих бүлеге нигезендә *Тарих институты* оеша, ТӘТИ *Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты* итеп үзгәртелә (директоры К.М.Миңнуллин).

Ин-тта иң мөһим юнәлешләрнең берсе — борынгы заманнардан алып төбәк тарихын, татар халкы һәм Татарстан чыганакларын, историографиясен, Казан тарихын өйрәнү. «Татарстан АССР тарихы» («История Татарской АССР», т.1–2, 1955–60), «ТАССР тарихы» («История ТАССР», 1968), «Татарстан АССР тарихы» (1970), «Казан тарихы» («История Казани», т. 1–2, 1988–91) әлеге өлкәдә мөһим хезмәтләрдән саналалар. Идел буе Болгар дәүләте тарихы (Н.Ф.Калинин, Х.Г.Гыйматди, Р.Г.Фәхретдинов, А.Х.Халиков), Казан ханлыгы тарихы (Ш.Ф.Мөхәммәдъяров, Е.И.Чернышов, С.Х.Алишев), төбәктә капитализм үсеше тарихы (Е.И.Чернышов, Е.И.Устюжанин, Х.Х.Хәсәнов, Ю.И.Смыков) буенча җитди эзләнүләр алып барыла. 20 йөз рев-цияләре, Гражданнар сугышы (Е.И.Медведев, А.А.Тарасов, И.Г.Гыйззәтуллин), милли дәүләт төзелеше (М.К.Мөхәррәмов, М.А.Сәйдәшева), ТАССР икътисады һәм мәдәнияте үсеше (Ж.И.Гыйльманов, З.Г.Гарипова, Т.И.Славко, К.Г.Нәҗипова, А.М.Җәләлов) тарихларын өйрәнүгә зур игътибар бирелә.

Археол. эзләнүләр төрле археол. чорлар (палеолит, мезолит, неолит, энеолит) истәлекләрен, бронза һәм элгәреге тимер дәверләрен, Идел буе Болгар дәүләте һәм Алтын Урда, Казан ханлыгы мәдәниятләрен өйрәнү өлкәсендә бара. Археол. эзләнүләрдән тыш палеозоологик һәм палеоантропологик эзләнүләр дә алып барыла (А.Г.Петренко). 1994 тән актив археол. эзләнүләр Казанның тарихи өлешендә җәелдерелә (Ф.Ш.Хуҗин).

Планга кергән казу эшләре һәм фәнни эзләнүләр нәтиҗәләре буенча 6 томлык «*Татарстан Республикасының археологик картасы*» төзелә. 1940–60 елларда Куйбышев ГЭСы сусаклагычы астында калган зонаны (Н.Ф.Калинин, А.Х.Халиков, Е.П.Казаков, П.Н.Старостин, Р.С.Габәшев), Биләр (А.Х.Халиков, Ф.Ш.Хуҗин) һәм Болгар (А.П.Смирнов, Т.А.Хлебникова) шәһәрләкләрен өйрәнү буенча масштаблы эзләнүләр алып барыла.

Ин-ттагы этнографик эзләнүләр татарлар күпләп яшәгән төбәкләрне планлы рәвештә тикшерүгә нигезләнеп оештырыла. Бу эшләрнең нәтиҗәләре татар халкының традицион мәдәнияте формалашу һәм үсешенең төрле аспектларын өйрәнүгә (Н.И.Воробьёв, Р.Г.Мөхәммәдова, Р.К.Уразманова, Й.Г.Мөхәммәтшин, Д.М.Исхаков, С.В.Суслова, Н.А.Халиков, Г.В.Йосыпов), «Урта Идел һәм Урал буе татарлары» («Татары Среднего Поволжья и Приуралья», М., 1967) фундаменталь хезмәте, «Татар халкының тарихи-этнографик атласы» («Историко-этнографический атлас татарского народа») сериясе кебек хезмәтләр язылуга нигез була.

Тел белеменә караган эзләнүләр татар теленең тарихын, фонетикасын, морфология, синтаксис, лексикология һәм лексикографиясен, диалектларын һәм сөйләшләрен өйрәнүгә карый. Күпьеллык фәнни тикшеренүләрнең нәтиҗәсе буларак «Русча-татарча сүзлек» («Русско-татарский словарь», т. 1–4, 1955–59), «Татарча-русча сүзлек» («Татарско-русский словарь», М., 1966), «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» (т. 1–3, 1977–81), «Хәзерге татар әдәби теле» («Современный татарский литературный язык», т. 1–2, М., 1969–71), «Урта Идел һәм Урал буе татар халкы сөйләшләре атласы» (1–2 т., 1989), «Татар грамматикасы» (1–3 т., 1989–2002) («Татарская грамматика», т. 1–3, 1992–93) кебек хезмәтләр нәшер ителә.

Тел галимнәренең фәнни эзләнү юнәлешләре: татар теленең грамматик төзелешен өйрәнү (В.Н.Хангилдин, К.С.Сабиров, Р.Ф.Шакирова, М.З.Зәкиев), татар әдәби теленең үсеш тарихы (И.Г.Абдуллин, Я.С.Әхмәтгалиева, Ф.М.Газизова, М.Г.Мөхәммәдиев, Ф.С.Фасиев, Ф.С.Хәким җанов), лексикография (Г.Х.Ахунҗанов, С.Б.Вахитова, Ш.С.Ханбикова, Ф.Ә.Ганиев), татар диалектологиясе (С.Х.Әмиров, Л.Ж.Җәләй, Н.Б.Борһанова, Л.Т.Мәхмүтова, Ф.С.Баязитова, Д.Б.Рамазанова, Т.Х.Хәйретдинова), рус һәм татар телләренең үзара багланышлары (Ә.М.Ахунҗанов, Н.Х.Шәрыпова, Л.П.Смолякова).

Ин-т галимнәре тарафыннан татар әдәбия - тының күпгасырлык тарихына, милли әдәби - ятның жанр үзенчәлекләренә караган хез - мәтләр языла, татар әдәбиятының классик мирасы әзерләнеп, дөньяга чыгарыла: «Та - тар әдәбияты тарихы» (1–6 т., 1984–2001), Г.Камал (1–3 т., 1978–82), М.Гафури (1–4 т., 1980–86), Ф.Әмирхан (1–4 т., 1984–89), Г.Ту - кай (1–5 т., 1985–86), Г.Ибраһимов (1–9 т., 1974–2000), М.Жәлил (1–4 т., 1975–76).

Ин-ттагы әдәбият галимнәренең фәнни эз - ләнүләре, нигездә, урта гасыр татар әдәбия - ты тарихын (Б.Г.Яфаров, Ш.Ш.Абилов, М.В.Гайнетдинов, Н.Ш.Хисамов), 20 йөз ба - шы татар әдәбияты тарихын (Г.М.Халит, Х.Х.Хисмәтуллин, М.Х.Гайнуллин), совет әдәбиятын (Н.Г.Гыйззәтуллин, Б.Т.Гыйззәт, Х.Ф.Хәйри, А.Г.Әхмәдуллин, Н.Г.Ханзафа - ров, Н.Г.Юзиев, Ф.М.Мусин), текстология - не (Я.Х.Агишев, Х.Хисмәтуллин, М.В.Гали, Р.Р.Гайнанов, Л.Р.Гайнанова, Ф.И.Ибраһи - мова, Н.И.Садыйкова, З.З.Рәмиев) өйрәнүгә юнәлдерелгән. Фольклористикада эш 2 юнә - лештә алып барыла: фольклор-этнография материаллары җыю һәм халык авыз-поэтик иҗаты мәсьәләләрен теоретик өйрәнү өчен татарлар тупланып яшәгән төбәкләргә фольк - лор экспедицияләре оештыру. 1976–93 тә татар фольклорының «Татар халык иҗаты» (1–13 т.) күптомлы басмасы чыгарыла, анда татар фольклорының барлык жанрлары ки - терелгән.

Сәнгать бүлегендә татар театр тарихы (Х.Х.Гобәйдуллин, И.И.Илялова, Б.Н.Гыйз - зәт, Һ.К.Мәхмүтов, М.Г.Арсланов), татар халык һәм проф. музыкасы (М.Н.Нигъмәтҗа - нов, З.Н.Сәйдәшева, А.Г.Алмазова, Г.Б.Го - бәйдуллина), татар халык гамәли-бизәлеш сәнгате һәм архит-расы (Ф.Х.Вәлиев, Г.Ф.Вә - лиева-Сөләйманова, Н.Х.Халитов, Д.К.Вә - лиева) өйрәнелә. Ин-т директорлары: М.А.Нигъмәтуллин (1939), Х.А.Шабанов (1939–42), Х.Х.Ярмөхәммәтов (1942–44), М.Х.Гайнуллин (1944–53, 1959–61), Х.Ф.Хәйруллин (1953–59), К.Ф.Фасиев (1961–63), М.К.Мөхәррәмов (1963–82), Я.Г.Абдуллин (1982–86), М.З.Зәкиев (1986–96).

Әд.: 50 лет поисков и открытий. К., 1989; 60 лет Институту языка, литературы и искусства имени Г.Ибраһимова. 1939–1999. К., 1999; Институт языка, литературы и искусства имени Г.Ибрагимова в документах и материалах. 1986–2000. К., 2001.

ТЕЛ БАГЛАНЫШЛАРЫ́ (лат. contactus — кагылу, орыну), бер-берсенең төзелешенә һәм лексик фондына йогынты ясаучы ике яки берничә телнең үзара тәэсир итешүе. Т.б. үзара бәйләнешле телләрдә сөйләшүчеләр - нең бер-берләре б-н аралашуы нәтиҗәсендә барлыкка килә. Халыклар арасында даими сәяси, икътисади һәм мәдәни багланышлар *икетеллелек* һәм күптеллелекне тудыра, бу үз чиратында турыдан-туры лексик *алынма - лар* булдыруга, калькалаштыру (к. *Калька*) һәм ярымкалькалаштыруга китерә. Т.б. ике - яклы (паритетлы) икетеллелек өстенлек ит - кәндә — телләрнең үзара йогынтысына, бер - тигез дәрәҗәдә кулланылышына, ә берьяклы икетеллелек (диглоссия) очрагында, ягъни бер телнең кулланылыш дәрәҗәсе — соци - аль статусы югарырак булганда, икенче тел - нең йотылуына китерә. Идиолект күренеше күзәтелгәндә, ягъни аерым бер кеше тара - фыннан гына кулланыла торган индивидуаль тел өстенлек иткәндә, Т.б.ның нәтиҗәсе — *интерференция*, телләрне гомумән алганда, төрле телләрнең яки тел күренешләренең якынлыгын, охшашлыгын билгеләүче кон - вергенция б-н аңлатыла.

Урта Идел һәм Урал буенда төрки һәм фин-угор телләре элек-электән үзара багла - нышта була, алар 11–13 йөзләрдә Идел-Ка - ма буе Болгары терр-ясендә Идел-Кама тел - ләр союзын барлыкка китерә. Төрки бергә - лекнең үз эчендә дә Т.б. нык була. Төркиләр зур киңлекләрдә таралып урнашкан булула - рына карамастан, һәр төрки халыкның диа - лектында башка төрки телләргә хас барлык үзенчәлекләр дә чагылыш таба.

9 йөздә ислам динен кабул итү болгар-та - тар телендә күпләп гарәп (к. *Гарәп алынма - лары*) һәм фарсы (к. *Фарсы алынмалары*) алынмалары барлыкка килүгә сәбәпче була. Озакка сузылган татар-рус Т.б. нәтиҗәсендә рус теле лексикасы — төрки алынмалар, та - тар теле лексикасы рус алынмалары б-н ту - лылана. 1917 елгы рев-циядән соң дәүләт - нең тел сәясәте берьяклы татар-рус икетелле - легенә китерә. «Татарстан Республикасы ха - лыклары телләре турында» ТР Законын ка - бул итү (1992) икеяклы (паритетлы) икетел - лелеккә ирешүгә юнәлдерелә. ТРда тыгыз урнашып яшәүче башкорт, мари, удмурт, чу - аш һ.б. халыклар арасында Т.б., нигездә, өч - теллелек б-н характерлана. Руслар һәм та - тарлар б-н Т.б. аларның телләренә йогынты ясамый диярлек, бары җирле диалектлар һәм сөйләшләр дәрәҗәсендә генә эз сала.

Әд.: Большой энциклопедический словарь. Язы - кознание. М., 1998; Байрамова Л.К. Татар - стан: языковая симметрия и асимметрия. К., 2001.

М.З.Зәкиев, Л.К.Бәйрәмова.

ТЕЛ БЕЛЕМЕ́, лингвистика, кешеләр - нең аралашу чарасы булган табигый тел һәм дөньядагы барлык телләр турындагы фән. Ул тел күренешләрен, аның төзелеш закон - чалыкларын һәм функцияләрен өйрәнә. Өй - рәнү аспектларыннан чыгып, шартлы рәвеш - тә эчке һәм тышкы лингвистиканы аерып ка - рыйлар. Эчке лингвистикага гомуми Т.б. (го - мумтел категорияләрен өйрәнә), чагыштыр - ма һәм чагыштырма-тарихи Т.б. (төрле тел - ләр арасындагы генетик һәм типологик мөнә - сәбәтләрне өйрәнә), тел системасын төрле юнәлештә өйрәнүче Т.б. тармаклары — *фоне - тика*, фонология, *грамматика* (*морфология, сүз ясалышы, синтаксис*), *морфонология, лек - сикология*, *фразеология* керә. Тел системасы - ның үсеш этапларын — тел тарихы (тарихи фонетика, фонология һ.б.) һәм этимология, ялгызлык исемнәрне *ономастика*, ш.и. *то - понимика* һәм *антропонимика* өйрәнә. Тыш - кы лингвистика (паралингвистика, этнолин - гвистика, психолингвистика, социолингвис - тика һ.б.) җәмгыятьтә сөйләүче кеше функ - цияләре б-н бәйле тел аспектларын тикшерә. Аңа ш.у. *диалектология* һәм *лингвистик гео - графия* дә керә. Т.б.нең махсус тармагын ин - терлингвистика тәшкил итә. Ул халыкара аралашуның төрле аспектлары, аның опти - мальләшү мөмкинлекләре, халыкара ясалма телләр б-н шөгыльләнә.

Татар Т.б. 10–11 йөзләрдә гарәп филоло - гиясе («Төрки шивәләр җыелмасы», Мәх - мүд Кашгари, 1072–74) йогынтысында нигез салынган *тюркологиянең* бер өлеше буларак гомуми Т.б. чикләрендә үсеш ала. 17–18 йөз - ләрдә гимназияләрдә, руханилар уч-щеләре һәм семинарияләрендә «татар теле» предме - ты кертелә һәм системалы рәвештә фәнни нигездә өйрәнелә башлый. Татар Т.б. фән бу - ларак 18 йөзнең 2 нче яртысыннан С.Х.Хәл - фин, И.И.Гиганов, А.А.Троянский һ.б.ның хезмәтләрендә формалаша башлый. Алга та - ба ул Казан ун-тының *Шәрекъ булеге* галим - нәре М.К.Казимбәк, И.Н.Березин, И.И.Хәл - фин, М.-Г.Мәхмүдов һ.б.ның хезмәтләрендә үсеш ала. Казан ун-тының төрек-татар теле кафедрасында Россия тюркологиясенә ни - гез салына (19 йөз башы). 19 йөзнең 2 нче яр - тысында К.Г.Насыйри, В.А.Богородицкий, Х.Ф.Фәезханов, Н.Ф.Катанов һ.б.ның Т.б.нә караган хезмәтләре нәшер ителә. 19 йөзнең соңгы чирегендә *Казан лингвистика фәнни мәктәбе* (нигез салучы — И.А.*Бодуэн де Кур - тенэ*) барлыкка килә, шул юнәлештә Г.Г.Иб - ра һимов, Г.Ш.Нугайбәк, Ә.Н.Максуди, Ж.Ж.Вәлиди, Г.Х.Алпаров, Г.Ш.Шәрәф, М.Х.Корбангалиев нәтиҗәле эшләр. 1940–50 елларда татар Т.б.нең фонетика, грамматика, сүз ясалышы (М.З.Зәкиев, Д.Г.Тумашева, Ү.Ш.Байчура, Ф.Ә.Ганиев, Р.Г.Сибәгатов, К.З.Зиннәтуллина), диалектол - огия (Г.Х.Ахунҗанов, Л.Т.Мәхмүтова, Ф.Й.Йосыпов, Л.Ш.Арсланов, Д.Б.Рамаза - нова, Ф.С.Баязитова), тел тарихы һәм стилис - тика (Ә.Р.Тенишев, В.Х.Хаков, Ф.С.Фаси - ев, Х.Р.Курбатов, Ф.М.Хисамова, И.Б.Бәши - рова), ономастика (Г.Ф.Саттаров, Ф.Г.Гари - пова), чагыштырма һәм контрастив лингвис - тика (Р.Г.Юсупов, Ә.М.Ахунҗанов, Л.К.Бәй - рәмова, Ф.С.Сафиуллина), этимология (Р.Г.Әхмәтьянов), этно- һәм социолингвис - тика кебек төрле тармаклары формалаша. 1950 елларда СССР ФАнең Казан ф-лы тел, әдәбият һәм тарих секторында (1997 дән — ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты) татар теленең 3 томлык аңлатмалы сүзлеге («Татар теленең аңлатмалы сүзлеге», 1977–81) төзелә башлый. 1990 елларда Татар Т.б.нең чираттагы үсеш чоры башлана. Акад. «Татар грамматикасы» (1–3 т., 1998–2002; «Татарская грамматика», т. 1–3, 1992–93; Дәүләт бүләге, 1994) басылып чыга. 2002 дә — Ф.С.Сафиуллина һәм М.З.Зәкиевнең юга - ры уку йортлары өчен «Хәзерге татар әдәби теле» дәреслеге, 2003 тә Х.Р.Курбатов редак - циясендә «Татар әдәби теле тарихы» дөнья күрә. 2009 да «Татар халык сөйләшләре атла - сы» (Д.Б.Рамазанова, Ф.С.Баязитова, Т.Х.Хәйретдинова, З.Р.Садыйкова, Р.С.Бар - сукова һ.б.) эшләнеп бетә. Татар һәм рус тел - ләрен чагыштырып өйрәнү б-н — Р.Г.Вафи - ев, К.Р.Галиуллин, Р.А.Юналиева, Ә.Ә.Әми - нова, Л.К.Бәйрәмова, Д.Ә.Сәлимова, татар һәм чит телләрне чагыштырып өйрәнү б-н А.Г.Садыйкова, А.Ә.Билалова, М.Н.Закамул - лина, В.Н.Хисамова, Г.Г.Зәйнуллин һ.б. шө - гыльләнә. Татар Т.б.ндә лингвокультуроло -

гия (Р.Р.Җамалетдинов), татар компьютер лингвистикасы (Ж.Ш.Сөләйманов) юнәлешләре дә барлыкка килә. Татар кулъязма сүзлекләре — М.Н.Ногманов, Ә.Ш.Йосыпова, эпиграфик ядкәрләр Ф.С.Хәкимҗанов, Ж.Г.Мөхәммәтшин, М.З.Зәкиев тарафыннан өйрәнелә. ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында, Казан ун-тында, аның Чаллы, Алабуга һ.б. шәһәрләрдәге ф-лларында эшләүче галимнәр тарафыннан төрле сүзлекләр, югары уку йортлары һәм урта мәктәпләр өчен татар теле буенча дәреслекләр, уку ярдәмлекләре нәшер ителә, татар телен укыту методикалары эшләнә.

Әд.: Валеев Р.М. Казанское востоковедение: истоки и развитие (XIX — 20-е гг. XX в.). К., 1998; Языкознание: Большой энцикл. словарь. М., 1998; Юдакин А.П. Урало-Алтайское (тюрко-монгольское) языкознание: Энцикл. М., 2001; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь: В 3 т. К., 2002–04; История Казанского университета, 1804–2004. К., 2004; Казанская лингвистическая школа. К., 2008.

М.З.Зәкиев.

ТЕЛ НОРМАЛАРЫ, билгеле бер тарихи чорда гамәлдәге тел коллективы тарафыннан аеруча дөрес дип табылган гомумкулланылыштагы тел чаралары җыелмасы, аларны сайлап алу һәм файдалану кагыйдәләре. Т.н. *әдәби телнең* үзенчәлекле билгеләре булып тора. Әдәби Т.н.ның формалашуы — катлаулы процесс, телнең тарихи үсешен тикшерү, өйрәнүне таләп итә. Нинди дә булса милләт барлыкка килгәнче, аның Т.н. тотрыксыз була, әдәби телнең сөйләм һәм язма формалары арасында шактый аерма күзәтелә. Татар теленең төп нормалары *борынгы төрки телләргә* (6–9 йөзләр) барып тоташа. Идел буе төрки-татар теленә хас локаль нормалар формалаша башлау Болгар (9 йөз — 13 йөзнең 1 нче яртысы) һәм Алтын Урда (13 йөзнең 2 нче яртысы — 14 йөз) дәүләтләре төзелү чорларына туры килә. Казан ханлыгы чорында (14–16 йөзләр) иске татар әдәби теленең лексик, фонетик һәм грамматик нормалары формалаша, алар 17–18 йөзләрдә алга таба үсеш ала. Татар милләте формалашу чорында (19 йөз — 20 йөз башы) татар теле үсешендә яңа этап башлана: фонетик, лексик һәм грамматик нормалар җанлы халык сөйләменә якыная. Татар әдәби теленең хәзерге нормалары Г.Тукай, Г.Исхакый, Г.Ибраһимов, Г.Камал, Ф.Әмирхан һ.б. язучыларның әсәрләрендә, К.Насыйри, Г.Нугайбәк, Ә.Мактуси һ.б.ның дәреслекләрендә һәм грамматикаларында формалаша башлый. Хәзерге татар теленең төп нормалары 20 йөзнең 1 нче яртысында тулысынча урнаша. Тулаем алганда, кабул ителгән әдәби норма аерым тел чараларының төрле стилистик функцияләр башкарганда килеп чыккан башка төрләрен дә кире какмый. Әдәби норма б-н телнең реаль кулланылышы арасында аермалар булмый калмый. Алар җәмгыять үсешенең тарихи этабы, аның социаль төзелеше, ш.у. тел мохите үзенчәлекләре б-н билгеләнә. Әдәби телнең орфографик һәм грамматик нормалары — шактый тотрыклы булулары б-н, лексик нормалары ирекле кулланылышка ия булулары б-н аерылып торалар. Әдәби нормаларны яңартучы чыганаклар күптөрле. Беренче чиратта бу — җанлы сөйләм. Яңа сүзләр, күпчелек кешеләр телендә еш кабатлану сәбәпле, әдәби кулланылышка кереп китәргә һәм норматив сүзләр буларак кабул ителергә мөмкин. Төрле үзгәрешләр чыганагы булып *диалектлар* хезмәт итә; мәс., татар әдәби теленә күлдәвек, җайдак, тоҗым (көзге пәрәвез) кебек диалекталь сүзләр керә. Әдәби норма башка телләрдән *алынмалар* ала. Күпчелек *гарәп алынмалары* (китап, мәхәббәт, хәрби, хат), *рус алынмалары* (арыш, мич, чиркәү), *фарсы алынмалары* (тәрәзә, чалбар, дару), кытай (бакыр, эн же), монгол (карагай, ясаул) алынмалары татар теленең фонетик һәм грамматик йогынтысы нәтиҗәсендә анда ныклап урнашалар һәм алынма сүзләр булып кабул ителми башлыйлар. 20 йөз ахыры — 21 йөз башында татар телендә (нигездә, рус теле аркылы) инглиз һәм башка Көнбатыш Европа телләреннән кергән алынма сүзләр (спикер, бизнес-план, менеджер) барлыкка килә. Әдәби нормаларның формалашуы, саклануы һәм таралыш алуында матур әдәбиятның, мәктәп, театр, телевидение, радио тапшырулары һ.б. массакүләм мәгълүмат чараларының роле зур. Әдәби нормалар телнең үзендә күзәтелгән үзгәрешләргә бәйле рәвештә яңарыш кичерүче грамматика дәреслекләрендә һәм сүзлекләрдә теркәлә.

Әд.: Хаков В.Х. Тел — тарих көзгесе. К., 2003; Ицкович В.А. Языковая норма. М., 1968; Языкознание: Большой энцикл. словарь. М., 1998.

Ф.Ә.Ганиев, В.Х.Хаков.

ТЕЛӘБУГА́ ХАН (?–1291), Алтын Урда хәне (1287 елдан). Тарбу бәкнең улы, *Батый хан* оныгы. *Туда Мәнгү хан* идарә иткән чорда сарай аксөякләре арасында йогынтысы зур була. 1285–86 елларда Нугай әмир б-н бергә Венгрия һәм Польша җирләренә яулар оештыра. Туда Мәнгү үтерелгәннән соң, Алтын Урда тәхетенә утыра. 1288 дә Рязань һәм Муром җирләренә яу чаба. Хан тәхетенә Тукта ханны тәкъдим иткән Нугай әмир б-н үзара көрәш барышында һәлак була.

Әд.: Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960.

ТЕЛӘНЧЕ́ ТАМА́К авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 35 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Игәнә елгасы буенда. 2010 елда 1242 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, яшелчәчелек. А.х. химиясе пр-тиесе, азык-төлек комб-ты. Урта мәктәп, мәдәният йорты, өлкәннәр һәм балалар китапханәсе. 2 мәчет. Мәдрәсә биналары комплексы — 19 йөз ахыры архит-ра истәлеге. 1721–22 еллардан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Кламчитамак исеме б-н дә билгеле. 18 йөз — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы асабалар, типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек, он тарту һәм тимерчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 мәчет, мәктәп, мәдрәсә, 3 су тегермәне, 2 тимерче алачыгы, 2 ашлык саклау-сату һәм 8 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3506 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Нөркәй волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1935 нең 10 февраленнән — Ворошилов р-ны үзәге, 1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл, 1959 ның 12 октябреннән — Сарман, 1984 нең 4 июненнән Тукай р-нында. Халык саны: 1859 да — 623, 1870 тә — 962, 1897 дә — 1820, 1906 да — 1665, 1920 дә — 2253, 1926 да — 1685, 1938 дә — 1767, 1949 да — 1503, 1958 дә — 2047, 1970 тә — 1677, 1979 да — 1505, 1989 да — 1236, 2002 дә — 1202 кеше.

ТЕЛӘЧЕ́ авылы, *Теләче районы* үзәге. ТР-ның төньяк-көнбатыш өлешендә, Арча тимер юлы (Казан–Әгер же юнәлеше) станциясеннән 32 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кече Мишә елгасының Мишәгә койган җирендә урнашкан. 2018 елда 4245 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 87%) яши. «Татавтодор» АҖ, «Просто молоко» ҖЧҖ (сөт-май язу з-ды) ф-ллары; кирпеч з-ды, балалар музыка һәм балалар-үсмерләр спорт мәктәпләре, төбәк тарихын өйрәнү музее, мәдәният йорты, китапханә, район үзәк хастаханәсе. Мәчет, чиркәү. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 1560 елларда рус крәстияннәре килеп урнаша. Тарихи чыганакларда Теләзе, Теләнче, Покровский исемнәре б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, арба һәм кисмәк ясау, сәүдә б-н шөгыльләнә. 19 йөз уртасыннан 20 йөз башына кадәр Покровка (1–8 окт.) һәм Богоявление (6–12 гыйн.) ярминкәлә-



Теләче авылы. Гомуми күренеше.





Теләче авылы. 1. Район хакимияте бинасы; 2. Мәчет.

ре уздырыла. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша, Покров чиркәве (1771 дә төзелә), земство мәктәбе (1875 тән), тире эшкәртү һәм май язу з-длары, 4 тимерче алачыгы, телефон, 2 — зур, 1 казна шәраб һәм 9 вак-төяклəр кибете, трактир, 3 сыраханә, 1 йөзем шәрабы базы була; пәнҗешәмбе базары эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1614,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Олы Кибәхуҗа волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 дан Саба р-нында, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче р-ны үзәге, 1959 ның 12 октябреннән — Саба р-нында, 1991 нең 4 октябреннән — Теләче р-ны үзәге. Халык саны: 1782 дә — 147 ир-ат; 1859 да — 941, 1897 дә — 1319, 1908 дә — 1276, 1920 дә — 1353, 1926 да — 1298, 1938 дә — 1567, 1949 да — 1404, 1958 дә — 1509, 1971 дә — 1074, 1979 да — 1166, 1989 да — 1318, 2002 дә — 2943 кеше.

Әд.: Туган ягым — Теләче. К., 2003.

ТЕЛӘЧЕ́ РАЙОНЫ́, ТРның төньягында урнашкан. Мәйданы — 1160 *км*². 13 авыл җирлеген, 53 торак пунктны берләштерә. Үзәге — *Теләче* авылы. 2018 елда 13902 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 89,4%, руслар — 10%) яши. Халыкның урта-ча урнашу тыгызлыгы — 1 *км*² га 12,1 кеше. 1935 нең 25 гыйнварында оештырыла. 1920 гә кадәр район терр-ясе Казан губернасының Лаеш өязенә, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонына һәм Балык Бистәсе р-нына, 1930 дан Арча, Питрәч, Балык Бистәсе һәм Саба р-ннарына керә. 1940 та мәйданы — 853 *км*², халык саны — 33,5 мең кеше, 25 авыл советы, 67 торак пункт була. 1956 да 20 авыл советы, 69 торак пункт исәпләнә. 1959 ның 12 октябрендә Т.р. таркатыла, биләмәсе Саба р-нына бирелә. 1991 нең 4 октябрендә район кабат торгызыла.



Т.р. рельефы — елга үзәннәре б-н бүлгәләнгән калку тигезлек (биеклеге 150–180 *м*). Мишә елгасы һәм кушылдыклары Кече Мишә, Нырсы елгалары ага. Җирләре күбесенчә аксыл соры, көрән соры, кәсле көлсу, соры урман туфраклы. Саклаулы табигать истәлекләре: Мишә елгасы, *Мишә аучылык тыюлыгы*. Район терр-ясендә бронза, башлангыч тимер гасырларга, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорларына караган 40 ка якын археол. истәлекләр табыла. Терр-ясенең 14,8% ы — урманлык. Бут ташы, известь, балчык, ком, торф ятмалары бар. Т.р.нда а.х. тармагы алга киткән. Мөгезле эре терлек, сарык үрчетү нык үскән. А.х. җирләре — 58,2 мең *га*, ш.и. 48,7 мең *га* сөрүлек җир (2016). Сабан бодае, арыш, арпа, солы, борчак игелә; бәрәңге үстерелә. 2016 елда Т.р.нда төрле милектәге 49 а.х. пр-тиесе эшли. Сәнәгать пр-тиеләре район үзәгендә урнашкан. Т.р. җиреннән Казан–Уфа, Казан–Шәмәрдән автомобиль юллары уза. Районда 11 гомуми белем бирү мәктәбе, ш.и. 1 тулы булмаган урта, 9 урта, балалар сәнгать мәктәбе, балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе, 17 мәктәпкәчә яшьтәгеләр учреждениесе, балалар иҗат үзәге, 24 китапханә, ш.и. балалар өчен, 30 клуб, район үзәк хастаханәсе эшли. Төбәк тарихы музее. Татар телендә «Теләче хәбәрләре» район г-тасы нәшер ителә.

ТЕЛӘЧЕ́ ТӨБӘ́К ТАРИХЫ́ МУЗЕЕ́, муниципаль музей. 1997 елның 1 гыйнварында нигез салына, 2006 ның 24 ноябрендә ачыла. Аерым бер катлы агач бинада урнашкан. Экспозиция мәйданы 166 *м*², музей фондларында 4 меңнән артык саклау берәмлеге исәпләнә. Экспозиция 2 залда урнашкан. Беренче залда – археол. һәм палеонтология коллекцияләре, 19 йөз ахыры — 20 йөз башы татар милли костюмы, татар гамәли бизәлеш сәнгате һәм сәнгать һөнәрләре әсәрләре, 1930 һәм 1950 елларгадагы татар өе күренешләре. Икенче залда – Теләче р-ны оешу турында материаллар, язучылар М.М.*Хәсәнов*, Ф.Х.*Хөсни*, җырчы Т.Г.Якупов, комп. Ф.Х.Хатыйповның шәхси әйберләре. Иң кыйммәтле экспонатлар арасында — татарларның 19 йөз ахыры — 20 йөз башы зәркән бизәнү әйберләре. Музей ел саен Шигърият көнен (26 апрель), Халыкара музейлар көнен (18 май) билгеләп үтә.



Г.Г.Теләшев.

ТЕЛӘ́ШЕВ Гомәр Гариф улы (13.12.1931, БАССРның Дәүләкән р-ны Имай Карамалысы а.), нефтехимик, техник фән. д-ры (1993), проф. (1994), Соц. Хезмәт Герое (1960), СССРның атказ. рационализаторы (1978), БРның атказ. химигы (1991). 1961 елда Уфа нефть ин-тын тәмамлаганнан соң, Яңа Уфа нефть эшкәртү з-дында эшли, ректификация-тикшереңү лаб-ясе (1964 тән), тәҗрибә-тикшереңү цехы (1967 дән) башлыгы, фәнни-техник үзәк директоры (1989 дан). 1994 тән Уфа нефть-техник ун-тының нефть һәм газ эшкәртү технологиясе кафедрасында. Хезмәтләре нефть химиясе процессларына һәм аппаратларына карый. Т. җитәкчелегендә югары нәтиҗәле масса алмашу конструкцияләре һәм аппаратлары эшләнә, экологик чиста мотор ягулыклары технологиясе гамәлгә кертелә, илдә беренче булып югары сыйфатлы легирланган корыч эретүдә электрод сыйфатында кулланыла торган энәсыман коксны күп тонналап сәнәгый җитештерү оештырыла. Уйлап табуга 100 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Россия хөкүмәтенең фән һәм техника өлкәсендәге премиясе, Ленин ордены, медальләр, ш.и. «Урак һәм Чүкеч» медале; СССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Некоторые особенности исследования работы промышленных ректификационных колонн // Технология нефти и газа. Вопросы фракционирования. М., 1967 (автордаш).

Әд.: Х а к и м о в М.С. Татары: Воины, труженики, патриоты: Биогр. справ. К., 2006.





Теләче төбәк тарихы музее. 1. Музей бинасы; 2. Экспозиция фрагменты: татар өе интерьеры. 20 йөз башы.

ТЕЛЕГРА́Ф (грек. tḗle — ерак, ерак һәм gráphō — язам, сызам, рәсем ясыйм), 1) телеграф элемтәсенең гомуми кабул ителгән атамасы; 2) телеграммалар тапшыру, кабул итү һәм илтеп җиткерүне гамәлгә ашыра торган элемтә пр-тиесе. Казанда беренче Т. станциясе 1859 елда ачыла, ул илнең үзәге б-н Урал һәм Себер элемтә линияләрен төйнәүче ролен үти. 1850 еллар ахырында — 1860 еллар башында Казан–Екатеринбург һәм Казан–Оренбург Т. линияләре салына. Казан ш.у. Сембер, аннан соң Сызрань һәм Самара шәһәрләре б-н дә Т. линиясе аша тоташа. Казан Т.ы С.-Петербург һәм Пекин шәһәрләре элемтәсе арасында арадаш пункт булып тора һәм шуның аркасында халыкара әһәмият казана. 1862 дә Казанда 5 Т. аппараты эшли: 2 се — Малмыж шәһәре юнәлешендә, 2 се Чабаксар шәһәре б-н хәбәрләр алмашу буенча эшли һәм 1 се Сембер б-н элемтә тота. Сәүдә мөнәсәбәтләренең үсеше Казан губернасы эчендә Т. элемтәсе таралуга этәргеч була. Чистай, Лаеш, Тәтеш сәүдәгәрләре соравы буенча яңа Т. станцияләре ачыла. Чистай линиясендә кабель Чулман елгасы аша салына, Мурзиха авылында (хәзер Алексеев р-ны терр-ясе) Т. станциясе төзелә.

1870 тә судно тотучылар тырышлыгы б-н һәм алар хисабына Яр бие Т. станциясе төзелә, 1874 тә завод һәм фабрика хуҗалары соравы буенча Казанның төрле почмакларында 5 станция ачыла. 1871 дә Т. линиясен Козьмодемьянск һәм Чабаксар арасында үткәрәләр. 1876 да Т. департаменты, кече торак пунктларның Т. элемтәсенә ихтыяҗын канәгатьләндерү өчен, ярдәмче станцияләр төзергә рөхсәт бирә. 1881 дә Яр Чаллы авылында Алабуга шәһәренә кадәр линиясе сузылган Т. станциясе эшли башлый. Шул ук елда Цивильск, Ядрин, Царёвококшайск (хәзер Йошкар-Ола) шәһәрләре, Олы Килмез, Вятка Аланы һ.б. торак пунктлар Т. челтәренә кертелә. 1899 да Казан губернасы терр-ясендә Т. үткәргечләренең гомуми озынлыгы 818 *км* була. Барлык Т. элемтәләре бер үткәргечле корыч линияләр буенча гамәлгә ашырыла һәм баштарак — бары тик Морзе аппаратлары (тапшыру тизлеге сәгатькә 500–550 сүз), соңга таба Юз (1 мең сүзгә кадәр) һәм Уинстон (3 мең сүзгә кадәр) системалары ярдәмендә эшли. 1905 тән Казанда тагын да камилләштерелгән һәм хәреф баса торган Бодо аппаратлары (сәгатькә 2,5 тән 4,5 меңгә кадәр сүз) кулланыла башлый, алар ярдәмендә бер Т. үткәргече аша бер үк вакытта 2 яки 4 телеграмма тапшыру мөмкин була. Дифференциаль схема буенча дуплекслы телеграф та кулланыла башлый. Т. станцияләрендә электр тогы химик чыганаклардан алына, 1901 дән электр кертелә. 1916 да Казан Т. конторасында эшләп торучы 48 Т. аппараты исәпләнә. 1894 тә кабул ителгән, тапшырылган һәм транзит телеграммаларның гомуми саны 206 мең, ә 1916 да 6 млн. нан артык була. Т. линияләрен урнаштыру һәм төзәтү б-н башта чит ил белгечләре шөгыльләнә, төзелешне күзәтү эше тимер юл инженерларына йөкләтелә. Соңга таба линияләр төзү эше рус техникларына күчә; 1871 дә Казанда механиклар, телеграфчылар һәм күзәтчелек итүчеләр мәктәбе ачыла. 1878 дә Т. линияләре төзү буенча Россиядә беренче кулланма чыгарыла. Т. аппаратлары чит илләрдән сатып алына, Россиядә өлешчә генә чит ил фирмаларының ф-ллары нда җитештерелә. 1885 тән Казан Т.ы Казан почта-телеграф округы карамагында була. 1916 да Казан губернасында Т. элемтәсенең 48 учреждениесе: 1 Т. конторасы, 14 почта-телеграф конторасы, 33 бүлекчә (16 сы — телеграф, 17 се — почта-телеграф) эшли.

Казан Т.ы тарихында иң катлаулы чорларның берсе Гражданнар сугышы еллары була, бу елларда элемтә линияләре җимерелә, Т. ба ганалары киселә, станцияләрнең милке талап юкка чыгарыла. Нәтиҗәдә, барлык Т. линияләренең 90% ын төзәтергә туры килә. 1924 кә респ-када Т. элемтәсе пр-тиеләре челтәре яңадан торгызыла. 1930 елларда Казан инде Мәскәү, Ульянов, Уфа, Пермь, ш.у. Украина шәһәрләре б-н турыдан-туры Т. элемтәсенә ия була. 1933 тә телеграмма җибәрүчедән алып адресатка кадәр — Мәскәү б-н Казан арасында 2 сәг., ә Казан б-н район үзәкләре арасында 3 сәг. эчендә барып җитә. 1930 елларның 2 нче яртысында телеграф-телефон үткәргечләре шактый ук озынайтыла. Казан аша үтә торган магистраль элемтә челтәрләре тыгызлагыч аппаратлар б-н җиһазландырыла башлый, шуның аркасында элемтәнең манёврлыгы да, ышанычлылыгы да арта. Үзебезнең илдә җитештерелгән «Шорин һәм Тремель» хәреф басу аппаратлары кулланыла башлый. Бөек Ватан сугышы елларында Т. хәрби режимда эшли. 102 кеше (ш.и. 60 хатын-кыз) фронтка китә. Телеграфчыларның бер өлеше хәрби заводларга алына. Сугыштан соңгы елларда Т. аппаратлары техник яктан унификацияләнә. СТ-35 аппаратларының тизлеге минутына 380 тамга була. 1947 дә Казан телеграфына Мәскәү б-н аралашу өчен беренче тональ Т. аппаратлары куела. 1959 да абонент Т.ы — телетайплар челтәре урнаштырыла башлый. 1960–75 тә турыдан-туры тоташуларның автоматлаштырылган системалары һәм телеграммаларны фототелеграф алымы б-н эшкәртү гамәлгә кертелә, нәтиҗәдә, 1971 дә Мәскәүдән газета һәм журналлар шушы алым б-н кабул ителә. Казан һәм Чаллыда Югославия нең «Никола Тесла» фирмасы җитештергән Т. станцияләре монтажлана. 1988 дә абонент Т.ы һәм халыкара ТЕЛЕКС челтәре станциясе файдалануга тапшырыла. 1993 тә РОСНЕТ телекоммуникация төйнәлеше төзелә. Татарстанның гомуми кулланыштагы хәзерге Т. челтәре «СТИН-Э» интеграль электрон станциясенә һәм «ЭТК-КС» станцияләренә нигезләнә. 200 дән артык юнәлештә элемтә урнаштырыла ш.и. Мәскәү, Екатеринбург, Түбән Новгород, Самара, Чиләбе — магистраль юнәлешләр. Респ-када күп функцияле REX-400 төйнәлеше эшли, аның ярдәмендә кулланучы заманча элемтә чаралары (факс, Интернет һ.б.) б-н файдалана ала. Ш.у.к. *Шәһәрара телефон челтәре*.

Әд.: О р л о в а А.Ф. Время и связь: Очерки по истории связи в ТАССР. К., 1988; Людей связующая нить. К., 2003.

Г.Я.Мәүлетова, Е.А.Стахов.

ТЕЛЕФО́Н ЧЕЛТӘРЕ́, телефон элемтәсен гамәлгә ашыручы техник корылмалар һәм җиһазлар комплексы. Т.ч.нең төрләре: җирле (шәһәр яки район эчендәге коммутация станцияләре һәм узеллары, линияләре, абонентларга куелган җиһазлар), зона челтәре (бер зона эчендә нумерациясе шул ук булган җирле челтәрләрнең үзара элемтәсен, аларның шәһәрара һәм халыкара челтәрләргә чыгуын тәэмин итүче техник җиһазлар), шәһәрара (төрле нумерацияле зоналарда урнашкан станцияләр, аларны үзара бәйли торган автомат коммутация узеллары һәм электр элемтәсе каналлары), халыкара (төрле илләрнең соңгы һәм соңгы-транзит станцияләре, аларны үзара бәйли торган каналлар), ведомство челтәрләре (җитештерүдәге һәм махсус ихтыяҗларны канәгатьләндерү һәм гомуми куллану челтәренә чыгу өчен мини-АТСлар һ.б. җайланмалар; халыкка һ.б. кулланучыларга элемтә челтәреннән файдалану мөмкинлеге дә бирәләр), кәрәзле (хәрәкәтчән радиоэлемтә б-н тәэмин итүче техник җайланмалар). Һәр пр-тиенең — элемтә операторының челтәре гомуми кулланыштагы Т.ч.нең бер өлеше булып тора. Үз клиентларына хезмәт күрсәтү барышында операторлар үзара бәйләнештә тора һәм элемтә төзелешенең бердәм кагыйдәләренә буйсына. Татарстан Респ-касының Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы, дәүләт идарәсе буларак, операторларның үзара бәйләнешен координацияли, бердәм техник сәясәтнең, норматив һәм закончалык документларын үтәтүнең гаранты булып тора.

Казан губернасында Т.ч. үсешенә 1880 елларда нигез салына (к. *Земство телефон челтәре, Казан шәһәр телефон челтәре, Халыкара телефон элемтәсе*). 1945–90 елларда Татарстанда Т.ч. сыйдырышлыгы 50 тапкыр арта. 1970 елларга барлык пр-тиеләр һәм авыл советлары б-н район үзәкләре арасында телефон элемтәсе урнаштырыла. 1960 та респ-када телефон аппаратларының гомуми саны 27,5 мең булса, 1990 га ул 325,5 меңгә җитә. Әмма шәһәр гаиләләреңенең 22,5% ында һәм авыл җирлеге гаиләләреңенең 8,2% ында гына телефон була. Т.ч. үсеше буенча респ-ка илнең башка төбәкләреннән шактый артта кала, цифрлы элемтә челтәре булмый диярлек (10% тан ким). Т.ч.нең төп җитештерү фондлары шактый ук дәрәҗәдә тузган була. 1990 елларда Т.ч. үсешенең яңа этабы башлана.

2009 га, гамәлгә заманча технологияләр һәм хезмәт күрсәтүләр кертү нәтиҗәсендә, 3,9 млн. нан артык номерга үткәргечле һәм кәрәзле элемтә объектлары төзелә һәм файдалануга тапшырыла; респ-када монтажланган телекоммуникация челтәрләренең гомуми күләме 7,79 млн. номерга җитә (ш.и. үткәргечле җирле телефон элемтәсе — 1,36 млн. га); үткәргечле һәм кәрәзле телефон элемтәсе хезмәтеннән файдаланучылар саны 6,69 млн. га җитә (үткәргечле элемтә хезмәтеннән шәһәр халкының 35,9% ы, авыл халкының 17,9% ы файдалана; халыкның кәрәзле элемтә б-н тәэмин ителеше 148% ка җитә. Үткәргечле элемтә челтәрләрендә дөнья стандартларына туры килгән цифрлы коммута-

ция җиһазлары өлеше 100% ка кадәр үсә. Респ-када 12 мең *км* дан артык авыл һава линияләре кабельлегә алыштырыла һәм шуның б-н авыл Т.ч. хезмәтенең ышанычлылыгы һәм сыйфаты күтәрелә. Авыл торак пунктларын телефонлаштыру күрсәткече 98,5% ка җитә. Авыл АТСларында станцияара элемтәнең аналоглы тапшыру системалары цифрлыга алыштырылып бетә. Респ-ка җирле Т.ч.ләренең җепселле-оптик линияләре озынлыгы 7147,8 *км* тәшкил итә.

1997 дән коммуникация челтәрләре мультисервислы мәгълүмат-транспорт челтәрләрен төзү юнәлешендә үстерелә. Казанда һәм Чаллыда мәгълүматны 2,5 Гбит/с тизлеге б-н тапшыра торган цифрлы синхрон иерархияләр төзелгән, алар күп төрле хезмәт күрсәтүгә — электрон почта, мәгълүмат базалары ресурслары, хәбәрләрне язма һәм тавыш аша тапшыру, телеконференцияләр, аудио- һәм видеоконференция элемтәсе һ.б.га сәләтле.

2000 дә таксофон челтәре яңартып корыла: респ-када барлык жетонлы таксофоннар махсус карта яки PIN-код куллануга күчерелә, алар ярдәмендә җирле генә түгел, шәһәрара һәм халыкара элемтә хезмәтеннән дә файдалану мөмкинлеге туа.

ТРда беркетелгән җирле үткәргечле элемтә хезмәтен 48 оператор күрсәтә. Иң зур операторлар: «Таттелеком» (чыбыклы телефония базарындагы өлеше — 76%), «Ростелесеет» (9%), «МТС» (5%), «Эр-телеком Холдинг» (5%) АҖләре, ТатАИСнефть (4%) ҖЧҖ һ.б. (3%).

Телекоммуникацияләр базарының аеруча динамик үсештәге сегменты — хәрәкәтчән кәрәзле элемтә. Респ-када кәрәзле элемтәнең 2G, 3G, 4G стандартлары буенча операторлар — «МТС», «Вымпелком», «Мегафон» АҖләре, «Т2 Мобайл» ҖЧҖ (2G, 3G стандартлары буенча), «ТМТ» һәм бер виртуаль оператор («Скартел» ҖЧҖ, «Мегафон» челтәре инфраструктурасы файдаланыла) хезмәт күрсәтә. Активлаштырылган сим-карталардан файдаланучылар 6,52 млн. кеше тәшкил итә.

ТРда югары тизлекле телекоммуникацион элемтә транспорт челтәре халыкара, шәһәрара һәм зона эчендәге телефон элемтәсенә сыйфатлы хезмәт күрсәтүгә сәләтле. Зона эчендәге элемтә җепселле-оптик линияләргә (1993–2008 дә 3913,2 *км* үткәрелә) һәм цифрлы тапшыру системаларына нигезләнә; ул синхрон бөжра принцибы буенча төзелгән һәм STM-16 дәрәҗәсендәге SDH җи һазлары һәм DWDM дулкынлы тыгызлау җи һазларына нигезләнгән зур синхрон бөжрадан, ш.у. STM-4 һәм STM-1 дәрәҗәләрендәге SDH җи һазларына нигезләнгән 3 кече синхрон бөжрадан тора (бөжраларга респ-каның шәһәрләре һәм район үзәкләре керә). ТР Россиядә беренче булып телекоммуникацияләрнең 100% лы цифрлы инфраструктурасына күчә, чираттагы NGN буыны челтәре, Jp/MPLS технологиясе буенча Gigabit Ethemet (GE) интеффейслы мәгълүматлар тапшыруның куәтле, югары тизлекле респ-ка магистраль челтәре төзелә. Нәтиҗәдә, респ-каның һәр торак пунктында телефон элемтәсендә универсаль хезмәт күрсәтү б-н тәэмин ителешкә ирешелә. Гомуми кулланылыштагы зона эче автомат телефон элемтәсе хезмәтен «Таттелеком», «Телесет», «Татнефть» операторлары күрсәтә. Гомуми кулланылыштагы шәһәрара һәм халыкара Т.ч. хезмәте «Ростелеком», «Межрегиональный Транзиттелеком», «Синтерра», «СЦС Совинтел», «Компания Транстелеком», «Эквант» тарафыннан гамәлгә ашырыла. Дөньяның 214 тән артык иле, ш.и. Европаның — 45, Төнъяк һәм Көньяк Американың — 50, Азиянең — 40, Африканың — 54, Австралия һәм Океаниянең — 14, БДБнең 11 иле б-н элемтә урнаштырылган. Емсат, Турай, Инмарсат спутник челтәрләре абонентлары б-н элемтәгә чыгыш оештырылган.

Әд.: Орлова А.Ф. Время и связь: Очерки по истории связи в ТАССР. К., 1988; Людей связующая нить. К., 2003.

Г.Я.Мәүлетова, Л.В.Луконина.

«ТЕЛЕФО́Т», төсле рәсемне ераклыкка тапшыру аппараты. Казанда 19 йөз ахырында А.А.*Полумордвинов* эшли һәм конструкцияли. Уйлап табу оптик-механик система ярдәмендә өч компонентлы төсле күрүчәнлек теориясенә нигезләнә. Конструктив төзелешендә параллель күчәрләрдә төрле тизлек б-н әйләнә торган ике диск кулланыла. Беренче дискта — радиаль ярыклар, икенчесендә архимед спирале буйлап ярыклар ясала. Дискларның берсендәге ярыклар бер-бер артлы кызыл, яшел, шәмәхә төс фильтрлары б-н каплана; дискларда ярыклар саны өчкә кабатлы (төп төсләр санына) итеп алына. Дисклар үзара икеле тешле тапшыргыч б-н тоташалар һәм бер үк якка төрле тизлекләр б-н әйләнәләр; һәр ярык сурәтнең бер юлын истә калдыра (үзенә күчерә) дип фаразлана. Беренче ярык беренче юлны әйләнеп узган мизгелдә икенче ярык икенче юлны укый башлый һәм шулай дәвам итә. Әйләнү барышында ярыкларның кисешүе ромб рәвешендәге үтәли тишек барлыкка китерә, аның аша үтүче яктылык, электр сигналына әверелдерелеп, кабул итү пунктына тапшырыла һәм шундый «җәелдергеч» җайланмада яктылыкның ачыклыгы б-н идарә итү өчен кулланыла. «Яктылык бүлгечнең» башка вариантларында дисклар урынына бер үк күчәрдә әйләнә торган 2 концентрик цилиндр яки үзара перпендикуляр күчәрләрдә әйләнүче бер үк сандагы көзгедәй кырлары булган 2 призма кулланы күздә тотыла. Әйләнү тизлекләре аермасы хисабына кабул итү станциясе экраны үлчәмнәрен шактый зурайтырга мөмкин. «Сурәтне ераклыкка тапшыруда кулланыла торган аппарат өчен яктылык бүлгеч»кә автор-лык хокукына гариза 1899 елның 23 декабрендә бирелә. Уйлап табуга 10738 нче патент 1906 ның 27 февралендә тапшырыла. Әмма 20 йөз башында Россиядә техника үсешенең дәрәҗәсе түбән булу сәбәпле, «Т.» идеясе матди ярдәм тапмый. Төсләрнең өч компонентлы теориясе принциплары төсле телевидениенең барлык заманча системаларында да кулланыла.

Әд.: Орлова А.Ф. Время и связь: Очерки по истории связи в ТАССР. К., 1988; Григорьев Е.И. Преподаватель Казанского соединённого промышленного училища А.А.Полумордвинов (1874–1942 гг.) // К 100-летию изобретения цветного телевидения: Материалы науч.-практ. конф. К., 1999; Казанское промышленное училище (1890–1917 гг.). К., 2006.

Б.Р.Милицын.

ТЕЛЖА́НОВ Канәфия Тимербулат улы (1.5.1927, хәзер Омск өлкәсенең Байтояк а.–30.9.2013, Казакъстан Респ-касы, Алма-Ата ш.), рәссам, Казакъстан ССРның, СССРның халык рәссамы (1963, 1978), Казакъстан ССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1961), СССР Сәнгать академиясенең мөхбир әгъзасы (1967), Казакъстан Респ-касы Милли ФА академигы (2003). 1937 елда СССР Сәнгать академиясе каршындагы сәләтле балалар сәнгать мәктәбенә кабул ителә. Алма-Ата сынлы сәнгать уч-щесен (1947), Ленинград нәкышь, скульптура һәм архит-ра ин-тын (1953) тәмамлый. 1965–68 дә Казакъстан ССР Рәссамнар берлеге идарәсе рәисе. 1973–86 да А.Кастиев исем. Дәүләт сынлы сәнгать музее директоры. 1978 дән Алма-Ата театр-сәнгать ин-тында эшли (каф. мөдире, 1981 дән проф.). 1993 тән Казакъстан Сәнгать академиясендә, 2000 нән Казакъстанның Т.К.Жургенов исем. милли сәнгать академиясендә. 1963–70 тә Казакъстан ССР ЮС депутаты. Т.ның иҗаты кечерәк поэтик картиналардан үсә барып, тарихи һәм заманча темаларны колачлаган монументаль әсәрләрдә чагылыш таба: «Җамал» (1955), «Думбыра аһаңнәре» (1958), «Ата-бабалар җирендә» (1958), «Көкпар» (1960), «Тыныч утлар» (1961), «Тынлык» (1964) һ.б. Казакъстан ССР Дәүләт бүләгә лауреаты (1967), Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе», «Отан» («Ватан»), «Парасат» («Зыялылык») орденнары (соңгы икесе — Казакъстан), медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: Вандровская Е.Б. Канафия Тимер-Булатович Тельжанов. М., 1970.

И.Р.Вәлиуллин.

ТЕ́ЛИШЕВ Валерий Фёдорович (1.3.1947, Приморье краеның Покровка р-ны Чернятино а.), тарихчы, тарих фән. канд. (1988), РФнең атказ. югары уку йорты хезмәткәре (2003). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1975), шунда ук 20 йөз Россия тарихы кафедрасында, 2013 елдан Россия һәм якын чит илләр тарихы кафедрасында эшли, бер үк вакытта, 1984–2009 да, әзерлек бүлеге мөдире. 1970–80 елларда яшьләрнең «Кар десанты» хәрби-патриотик хәрәкәтен оештыручыларының һәм җитәкчеләренең берсе. Хезмәт-ләре мед.-социаль иминият, Казан губернасында хезмәтне саклау мәсьәләләренә, Бөек Ватан сугышы тарихына карый. «Һәлак булганнар һәм исәннәр хакына...»: Казан университетының хәтер китабы» («Во имя павших и живых во имя...»: Книга памяти Казанского университета», 2010); «Тере хатирә: сугыш чоры балалары истәлекләре» («Живая память: воспоминания детей войны», 2013) һ.б. тарихи-мемориаль хезмәтләрнең автор-төзүчесе. Медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: Валерий Фёдорович Телишев: педагог, учёный и общественный деятель. К 70-летию со дня рождения историка. Сборник статей. К., 2017.

ТЕЛМӘКАНАТЛЫЛА́Р (Pterophoridae), төрле мыеклы күбәләкләр семьялыгы. 600 дән артык төре билгеле, киң таралганнар; Рос-

сиядә 100 дән артык төре очрый. Канат җәй - ме 20–30 *мм*, коңгырт, сары, соры, сирәк ке - нә ак төстә; кагыйдә буларак, тармакларга телгәләнгән: алгылары — 2 гә, арткылары — 3 кә. Канат пластинкалары телгәләнмәгән оч - ракта, арткы канатларының түбәнге өлешендә озын төкчәләр бәйләме барлыкка килә. Гәүдәсе юка, аяклары озын. Гусеницалары вак, кыска, чагыштырмача калын; үлән чел үсемлекләрнең төрелгән яфракларында, кайвакыт сабак эчендә яшиләр. Татарстан терр-ясендә җәтә ак Т. (Alucita pentadactila), кыскычсыман Т. (Pselnophorus brachydac - tylus) һәм бер бармаклы Т. (Emmelina monodactila) еш очрый.

С.Г.Гордиенко.

ТЕ́ЛЬМАН РАЙОНЫ́, ТАССРда. 1935 елның 10 февралендә оештырыла. Үзәге — Мамык авылы. 1920 гә кадәр терр-ясе Казан губернасының Спас һәм Чистай өязләрендә, 1920 дән ТАССРның Спас һәм Чистай кантоннарында, 1930 дан Аксубай, Биләр һәм Октябрь р-ннарында. 1940 та районның мәйданы — 1073 *км*², халкы — 29,4 мең кеше бу - ла; 21 авыл советын, 66 торак пунктны берләштерә. 1956 да 17 авыл советы, 78 торак пункт исәпләнә. 1958 нең 16 июлендә Т.р. таркатыла, терр-ясе Аксубай, Биләр һәм Октябрь р-ннарына бирелә.

ТЕЛЯКО́В Эдуард Шәрхиевич (4.1.1939, Сызрань ш.), химик-технолог, техник фән. д-ры (1983), проф. (1984), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1999). 1961 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый. 1961–65 тә Казан компрессорлар з-дында конструктор булып эшли. 1965 тән Казан технол. ун-тының химия производствосы машиналары һәм аппа - ратлары кафедрасында (бүленеп: 1972–78 дә Бөтенсоюз углерод чималы фәнни-тикшеренү ин-тының масса алмашу процессларын тикшерү һәм модельләштерү лаб-ясе мөдире; 1984–86 да Казан химия-технол. ин-тының Түбән Кама ф-лында гомуми инженерлык фән. каф. мөдире), проф. (1986 дан). Хезмәт - ләре газ-нефть эшкәртүдә һәм нефть химиясендә углеводород чималын таркату процессларын модельләү һәм оптимальләштерүгә карый. Т. газ эшкәртү з-дында (Оренбург ш.) һәм нефть химиясе комб-тында (Салават ш.) үтә күкертле углеводород чималын бүлү; нефтьне тотрыклыландыру («Татнефть» һәм «Башнефть» АҖ) технологияләрен эшли. Катлаулы химик-технологик системаларның Т. төзегән динамик схемалары технологик җайланмаларның арадаш режимнарын модельләү мөмкинлеген бирә. Үйлап табуга 18 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Х е з м.: Очистка широкой фракции лёгких углеводородов газового конденсата Оренбургского месторождения от сернистых соединений // Химия и технология топлив и масел. 1976. № 12 (автордаш); Совместное проектирование ректификационного объекта и системы управления // Теорет. основы хим. технологии. 1992. Т. 26, № 2 (автордаш); Математическое моделирование динамики многокомпонентной ректификации в сложных агрегатах // Вестн. Междунар. академии системных исслед. «Информатика, экология, экономика». 1999. Т. 3 (автордаш).

ТЕМБӘ́КОВЛАР, татар морзалары нәселе. Т. турында беренче искәрмәләр 1616 елга кары: Тамбов губернасы Темников өязенең Аксал авылын биләүчеләр арасында морза Янбулат була. Кадомның 1625 елгы писцовый кенәгәсендә кенәз Колубай Тембәковның урман биләмәләре турында мәгълүматлар бар. Темников морзалары арасында ш.у. Евгости һәм Позняк Т. искә алына. 1627 дә Темников өязенең Саров авылын биләүчеләр даирәсендә Иванай Тембәков та исәпләнә; 1697–98 еллар грамоталары буенча, аңа башка йомышлы татарлар б-н бергә Кичү, Чиш - мә һәм Мишә елгалары буендагы җирләр би - релә. 18 йөзнең 1 нче чиректә Т. Рязань губернасы Касыйм өязенең Собакино, Казаново, Савоново авыллары халкы арасында күрсәтелә. Т. патша Алексей Михайлович вакытында Эстәрле елгасы буеннан бирелгән җирләрне билиләр (17 йөз уртасы). 1794 тә Уфа казна палатасы фәрманы буенча Т.ның Усман авылында яшәгән балалары — йомышлы татарлар Кәрим Ходайбирдин, Усман Мәхмүтов, Йосыф Мансуров, Шәрип Якупов гаиләләре кенәзләр дәрәҗәсендә танылалар. Сенат әлеге фәрманны расламый һәм гаиләләр дәүләт крәстияннәре катлавында кала. 19 йөздә Т. Самара губернасы Бөгелмә өязенең Эстәрлетамак һәм Усман авылларында яшиләр.

Әд.: Г а б д у л л и н И.Р. От служилых татар к татарскому дворянству. М., 2006.

ТЕ́МНИКОВ РАЙОНЫ́, *Мордва Республикасының* төньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. 1928 елның 16 июлендә оештырыла. Мәйданы — 1936,8 *км*². Үзәге — Темников шәһәре (Саранскидан 158 *км* төньяк-көнбатыштарак). Халкы — 14304 (1.1.2017), татарлар — 1326 (2010) кеше. Татарларның таралып урнашу урыннары (2007): Рус Карае (260 кеше), Тархан (247), Митрәле (224), Ишейки (91) авыл җирлекләре. Т.р. терр-ясендә татарлар электән яшиләр. Монда 16–18 йөзләрдә күп кенә татар бәкләре һәм морзалары вәкилләренең (*Акчуриннар*, Бигловлар, Бибарсовлар, *Дашкиннар*, Дәүләткилдиевлар, *Дивеевлар*, *Енгалычевлар*, *Еникиевләр*, *Кудашевлар*, Колынчаковлар, *Мам - лиевлар*, Сакаевлар, *Тенишевләр*, Терегулов - лар, Яушевлар) нәселдән күчмә вотчиналары һәм җирләре була. Район терр-ясендә 5 мәчет эшли. Тархан авылы урта мәктәбендә укыту рус, татар, мордва телләрендә алып барыла; татар мәдәнияте музее, «Матур кызлар» во - каль төркеме эшли. Т.р.нда татар теле һәм әдәбияты буенча респ-ка олимпиадалары, татар мәдәнияте фестивале, *Корбан* бәйрәме үткәрелә. Район төбәк тарихы музеенда бу як татарлары тарихына караган мәгълүматлар саклана.

Әд.: Е н и к е е в С. Очерк истории татарского дворянства. Уфа, 1999; Г а б д у л л и н И.Р. От служилых татар к татарскому дворянству. М., 2006.

ТЕНЕКИ́ авылы, Саба р-нында, шәһәр ти - бындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 5 *км* көньяктарак, Казкаш елгасы буенда. 2010 елда 180 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 17 йөз - нең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-цияго кадәрге рус чыганакларында По речке Уре, Чёлка исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп, тегермән, тимерчелек, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1530,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Сатыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 101 ир-ат; 1859 да — 589, 1897 дә — 742, 1908 дә — 894, 1920 дә — 873, 1926 да — 665, 1938 дә — 525, 1949 да — 414, 1970 тә — 241, 1979 да — 422, 1989 да — 191, 2002 дә — 183 кеше.

ТЕНЕ́Ш, шәһәр тибындагы посёлок, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 8 *км* төньяк-көнбатыш - тарак, Куйбышев сусаклагычы ярында урнашкан. 2010 елда 809 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 53,1%, татарлар — 44,6%) яши. «Кама Тамагы гипс руднигы» АҖ, пристань. Урта мәктәп. 1930 елларда Тугызынчы гыйнвар исем. завод посёлогы буларак нигез салына, 1959 ның 14 мартында Тугызынчы гыйнвар посёлогы итеп үзгәртелә, 1980 елларда шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогы составына керә, 1997 нең 20 ноябрендә Тугызынчы гыйнвар исеме б-н аерым торак пункт буларак теркәлә, 1999 ның 16 июненнән хәзерге исемен йөртә. Оеш - кан көненнән Кама Тамагы р-нында. 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны 2002 дә — 866 кеше.

ТЕ́НИШЕВ Әдһәм Рәхим улы (25.4.1921, Пенза ш. — 11.7.2004, Мәскәү), тел галиме, филол. фән. д-ры (1969), СССР ФАнең мөх - бир әгъзасы (1984), ТРның атказ. фән эш - леклесе (1997), Башкортстан Респ-касы ФАнең шәрәфле академигы (2001). *Тенишевләр* нәселеннән, морза. Ленинград ун-тын тәмамлаганнан соң (1949), шунда ук эшли. 1954 елдан СССР ФАнең Тел белеме ин-тында, 1963 тән төрки һәм монгол телләре бүлеге мөдире, проф. (1971). Т. җитәкчелегендә «Төрки телләрнең чагыштырма-тарихи грамматикасы» («Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков», 1–5 т., М., 1984–2005) коллектив хезмәте бастыруга әзерләнә. Т. — «Төрки телләр» («Тюркские языки») коллектив хезмәтендә («Дөнья телләре» («Языки мира») сериясе, Бишкәк, 1997) тупланган күп кенә мәкаләләр авторы һәм җаваплы мөхәррире. 1956–58 дә, төрки телләрне өйрәнүдә ярдәм күрсәтү максаты б-н, Кытай Халык Респ-касы ФАнә командировкага җибәрелә, төрки телләр буенча курс - лар укый, кытай телендә ике монография чыгара: «Төрки телләрне өйрәнүгә кереш» («Введение в изучение тюркских языков», Пекин, 1958) һәм «Төрек теле грамматикасы» («Грамматика турецкого языка», Пекин, 1959). Уйгыр һәм салар телләре диалектла - рын өйрәнү, ш.у. лингвистик, фольклор, эт - нографик һәм тарихи материаллар җыю һәм

туплау максаты б-н Көнбатыш Кытай районнары буйлап 3 экспедиция үткәрә (1956 да — Шөнҗан автономияле р-нына, 1957 дә — Цинхай провинциясенә, 1958 дә — Ганьсу провинциясенә). Мәскәүгә кайткач, «Салар теле төзелеше» («Строй саларского языка», М., 1976) һәм «Сарыг-уйгыр теле төзелеше» («Строй сарыг-уйгурского языка», М., 1976) монографияләрен бастырып чыгара. Т. борынгы төрки телләрнең Үзәк Азия халыклары телләре берлегенә караулары б-н бәйле үзенчәлекләрен тикшерүгә зур өлеш кертә. Төрки әдәби телләрнең Орхон-Енисей язма истәлекләреннән алып эзлекле үсеше схемасын төзи. Т.нең теоретик нигезләмәләре тюркологиядәге яңа юнәлешкә — төрки әдәби телләрнең тарихи грамматикалары эшкәртмәләренә нигез була. «Борынгы төрки сүзлек»не («Древнетюркский словарь», Л., 1969; автордаш), «Уйгыр диалектик сүзлеге»н («Уйгурский диалектический словарь», М., 1990) төзүче. Төрек лингвистика җәмгыятенең шәрәфле әгъзасы (1972); Фин-угор җәмгыятенең мөхбир әгъзасы (1982).



Ә.Р.Тенишев.

Х е з м.: Уйгурские тексты. М., 1984; У тюркских народов Китая. М., 1995; Древнекыргызский язык. Бишкек, 1997; Избр. труды: В 2 кн. Уфа, 2006.

Әд.: А ш н и н Ф.Д. Эдхям Рахимович Тенишев (в связи с 70-летием со дня рождения) // Исследование языковых систем в синхронии и диахронии. М., 1991; Ю д а к и н А.П. Урало-Алтайское (тюрко-монгольское) языкознание: Энцикл. М., 2001; Казанская лингвистическая школа. К., 2008. Кн. 1.

Ф.Ш.Нуриева.

ТЕ́НИШЕВ Василий Борисович (1709–1789 тирәсе), кенәз, дәүләт эшлеклесе, яшерен советник (1764). Дворяннар нәселеннән. 1722 елдан хәрби хезмәттә. 1726–35 тә рус гаскәрләре составында Пётр I нең Иранга яулары (1722–23) нәтиҗәсендә басып алынган Каспий буе өлкәләрендә була. Рус-төрек (1735–39) һәм рус-швед (1741–43) сугышларында катнаша. 1744 тән Мәскәү башкоманду ющие штабы карамагында. 1755–60 та Казан вице-губернаторы, 1760–64 тә Казан губернаторы. *Казандагы Беренче ир балалар гимназиясе* (1759), шәһәр гарипләр йорты (1760) ачуга булышлык итә. Т. эшләгән вакытта 3 нче «җан башы ревизиясе» — губерна халкы исәбен алу үткәрелә (1761 дән). Казанда беренче театраль тамаша куела (1760); ирекле татарларга да шәһәрнең татар бистәләрендә урнашырга рөхсәт ителә, тоткарлыксыз сәүдә итү, земство салымнарыннан һәм йөкләмәләреннән азат ителү хокуклары раслана (1763); Яңа чукындырылганнар конторасы бетерелә (1764). 1764 тән отставкада, Казанда һәм Казан өязендәге утарларында яши.

Әд.: Дворянские роды Российской империи. М., 1966. Т. 3.

Е.Б.Долгов.

ТЕ́НИШЕВЛӘР, татар бәкләре нәселе. Темников бәге Тениш Кугушевтан башлана. 1298 елда аның ерак бабасы Алтын Урда бәге Сәетәхмәт ясак җыю максаты б-н мордва җирләренә килеп урнаша. 14 йөз ахырында Сәетәхмәтнең варисы Бәкхан (Бихан) бәк Сараклыч (хәзер Саров) шәһәрен били, аңардан татар бәкләре *Акчуриннар, Еникиевләр*, Ишәевләр, *Кугушевлар*, Колынчаковлар нәселләре башланып китә. 1528 дә Мәскәүнең бөек кенәзе Василий II Рус дәүләтенә хезмәткә күчкән Тениш Кугушевка Темников шәһәрен бүләк итә. Тениш бәкнең (1539 да үлгән) өч улы була: Еники (бәк Еникиевләрнең ерак бабасы), Ямаш һәм Исәш (Т.нең ерак бабалары). Иван IV нең 1554 елгы ярлыкаш грамотасы нигезендә хезмәтләре өчен Исәш (уллары: Уразбакты, Уразкилде, Исәкәй, Үтәш) һәм Ямаш Т.гә (уллары: Безсон, Җангали, Җанбарс, Җанъегет) ясак җыю хокукы бирелә («Сыхретинские мордвы Кучукова беляка»). Т.нең җирләре бөтен Мещера төбәген били. Т.дән Тимергали (Исәкәй улы) Речь Посполита б-н сугышта (1654–67) һәм С.Разин фетнәсен (1670–71) бастыруда катнаша. Т.нең император Пётр I дәверендә православие динен кабул итмәгән варисларына җан башыннан салым түләтәләр. Чукынмаган Арыслан (Мәрдәш улы), Сөләйман (Арыслан улы) һәм Шибанның (Тимергали Т. улы) крепостной крәстияннәре 1713 тә казна файдасына тартып алына.

Православие кабул иткән Т.гә рәсми рәвештә кенәз титулын йөртү хокукы бирелә. Россия дворяннары арасында алар күренекле урын билиләр. Кенәз **Родион Мәрдәш улы** (Мәрдәш Мәмәт улының улы), ш.у. кенәз **Василий (Ибраһим) Сәфәр улы** (Сәфәр Мәмәт улының улы) стольниклар булып хезмәт итәләр. Василий (Ибраһим) Сәфәр улының Темников, Шацк, Кадом, Саранск, Инзар өязләрендә зур җир биләмәләре була. Ул воевода Б.П.Шереметев полкы составында Пётр I нең Азов явында катнаша, сугышта үтерелә. Аның улы, **Борис Васильевич** — стольник; оныгы, **Василий Борисович** *Тенишев* — Казан губернаторы.

Василий Борисовичның улы **Дмитрий Васильевич** (1766, башка мәгълүматлар буенча, 1769–1829), Преображенский полкының лейб-гвардиясендә хезмәт итә (1780 нән), ротмистр (1793), полк командиры була, бригадир чинында отставкага чыга (1794). 1797 нең гыйнварында Казан губернасының вице-губернаторы итеп билгеләнә. 1803–08 дә Әстерхан гражданнар губернаторы, бер үк вакытта Әстерхан тоз запаслары экспедициясе идарәчесе. 1820–22 дә исемле фәрман нигезендә оештырылган Казан губернасында закон бозу очракларын ачыклау Вакытлы тикшерү комиссиясен җитәкли. Казан, Сембер, Пенза губерналарында крәстияннәр били. Казан губернасының Казан өязе Пановка авылында Никола чиркәвен төзи (1824), анда Алатырь сәүдәгәре кызы Анна Савинкова б-н никахлаша (1824, икенче тапкыр өйләнүе). 1798 дә Дмитрий Васильевич Т.нең Казанда Воскресенский урамындагы (хәзер Кремль урамы) ике катлы таш йорты *Казандагы Беренче ир балалар гимназиясе* өчен сатып алына; соңрак әлеге йортта Казан ун-ты урнаша.

1812 елгы Ватан сугышында катнашучылар арасында кенәз **Иван Григорьевич** Т. искә алына. 1815 тә А.Фёдоров наширлегендә чыккан «Кенәз И.Г.Тенишевның патриотик һәм героик батырлыклары» («Патриотические и героические подвиги князя И.Г.Тенишева») китабында аның ка һарманлыгы турында җентекләп хикәяләнә. Рус гаскәрләре чигенгәндә ул урманнарга «китә», Смоленск губернасында лагерь һәм оборона оештыра, берничә тапкыр французлар б-н бәрелешләрдә катнаша, камалышта була, кыюлыгы һәм җитезлеге аркасында әсирлеккә эләкми кала. Смоленск губернасының Рославль һәм Ельня өязләрендә кардон башлыгы буларак якындагы юлларда заставалар төзи һәм чигенүче француз частьларына Брянск арсеналына үтеп чыгара ирек бирми; 400 мародёрны тота. М.И.Кутузов тәкъдиме нигезендә бантлы 4 нче дәрәҗә Изге Владимир ордены б-н бүләкләнә.

Кенәз Т.дән ш.у. **Николай Иванович** та (1798–1862) билгеле. Атасы Иван Иванович кебек ул да хәрби (генерал-майор) була. Инженер белгечлеге ала, Польша патшалыгында аралашу юллары идарәчесе вазифасын башкара. Хәрби һәм хезмәттәге казанышлары өчен 2 нче дәрәҗә Изге Анна, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Изге Станислав, 3 нче һәм 4 нче дәрәҗә Изге Владимир, 4 нче дәрәҗә Изге Георгий орденнары, «Батырлык өчен» язулы алтын кылыч, 20 еллык намуслы хезмәте өчен аерымлык билгесе б-н бүләкләнә.

Аның улы **Вячеслав Николаевич** (1843–1903) сәнәгатьче, социолог, этнограф була. Петербург ун-тында, Карлсруэ шәһәрендә (Германия, 1861–64) Политехникумда укый. Укуын тәмамлагач, хәрби хезмәттә була (император флигель-адъютанты, кавалергард полкы полковнигы). 1873 тә «Брянск рельслар эшләү, тимер рудасы эшкәртү һәм механик заводы акционерлык җәмгыяте» әгъзасы, 1880 елларда — җәмгыятьнең идарә рәисе, заводта инженер-техник эшләр б-н җитәкчелек итә. Ул эшләгән вакытта завод корыч җитештерү буенча Россиядә 2 нче урынны били. С.-Петербургта Электромеханика з-ды ху җаларыннан, Россиядә автомобильләр җитештерүне оештыручыларның һәм Россия автомобильләр җитештерү җәмгыятенә нигез салучыларның берсе, Сәүдә һәм мануфактуралар советы әгъзасы, Сәнәгать һәм сәүдәгә булышлык итү җәмгыяте әгъзасы. 1896 да эшмәкәрлек эшчәнлеген туктата, фән, пед. б-н мавыга башлый. Т.нең фәнни шөгыльләре нигезендә ижтимагый тормышның төп «пружиналарын» тикшерү омтылышы ята; функционализм тарафдары, позитивистик, социал-дарвинистик карашларны яклый. Аның беренче хезмәтен математиканы гамәли үзләштерүгә багышланган «Математик белем алу һәм аның әһәмияте» («Математическое образование и его значение», СПб., 1886) китабы тәшкил итә. 1889 да кешенең ижтимагый эшчәнлеге турындагы хезмәтенең 1 нче өлешен — «Хайваннар эшчәнлеге»н («Деятельность животных», СПб.)

китабын нәшер итә. Ч.Дарвин тәгълиматына ияреп, ул кеше яшәешенең аны хайваннар б-н якынайткан якларын (ашау, балаларын кайгырту, кабиләдәшләре арасында тоткан урыны, куркыныч хәлдән читләшү, ирешкән яшәү дәрәҗәсен саклау) аерырга омтыла. «Кеше эшчәнлеге» («Деятельность человека», СПб., 1897) дип аталган 3 нче китабының максаты — төрле иҗтимагый төркемнәрнең социумда үз-үзләрен тотышы классификациясен булдыру. 1898 дә Т. С.-Петербургта Этнография бюросы оештыра, бюро, аның идеяләренә нигезләнеп, Россиядә крәстиннәрнең фикер-халәтен тикшерү проектын эшли. Т. тарафыннан ш.у. шәһәрнең социаль катлауларын өйрәнү программасы да уйланыла. 1899 дан Интернациональ социол. ин-тының, Париж социол. җәмгыятенең шәрәфле әгъзасы. Гамәлдә үзенең пед. күзаллауларын тормышка ашырырга омтыла, С.-Петербургта Тенишев реаль уч-щегә нигез сала (1898).



Кенәз В.Н.Тенишев портреты. Рәссам Л.Бонна. 1896. Дәүләт Эрмитажы. Санкт-Петербург.

Париждагы Бөтендөнья күргәзмәсендә Россиядән килгән ген. комиссар була (1900); Россия бүлеге зур уңышка ирешә һәм Т. Император сарае камергеры дәрәҗәсе ала, Франциянең Почётлы легион ордены б-н бүләкләнә. Муз. белемгә ия (виолончель классы буенча); 1883–87 дә Рус музыка җәмгыятенең Петербург бүлеге рәисе. Т. йортында муз. кичәләр оештырыла, кичәләрдә танылган музыкантлар һәм композиторлар: А.С.Аренский, Л.С.Ауэр, А.А.Брандуков, А.В.Вержбилович, С.О.Метнер, А.Н.Скрябин катнашалар; П.И.Чайковский да кунакта була. Хатыны **Мария Клавдиевна** (1861–1929) тырышлыгы б-н Т.нең Смоленск губернасы Талашкино авылындагы утары Россиянең сәнгать тормышы үзәкләренең берсенә әверелә.

Аның улы **Вячеслав Вячеславович** (1878–1959) җәмәгать эшлеклесе, юрист була. Петербург ун-тының юридик ф-тында укый. Орёл губернасында 5 мең дисәтинәдән артык җире була. Университетны тәмамлаганнан соң, Брянск шәһәренә китә, хәрби бурычны үтәү буенча өяз кабулханәсен җитәкли. Орёл губернасының Брянск өязе дворяннары башлыгы, 3 нче Дәүләт Думасында Орёл губернасыннан депутат, октябристлар фракциясе әгъзасы; Беренче бөтендөнья сугышы вакытында яралы сугышчыларның Брянск округ эвакуация пунктында Кызыл Хач җәмгыяте вәкиле, Брянск земствосы б-н бергә 600 урынлык 6 лазарет оештыра. Әтисе башлаган эшне тәмамлый һәм «Крәстияннәр көнкүрешендә хөкем эшләре» («Правосудие в крестьянском быту», Брянск, 1907), «Рус крәстияненең административ хәле. Мәрхүм кенәз В.Н.Тенишевның этнографик материаллары аша табылган мәгълүматлар җыелмасы» («Административное положение русского крестьянина. Своды данных, добытых этнографическими материалами покойного князя В.Н.Тенишева», СПб, 1908); юриспруденциядән берничә хезмәт, ш.и. «Вәкиллекле учреждениеләр нигезендә сайлау хокукы» («Избирательное право на основе представительных учреждений», Брянск, 1906) хезмәте авторы. «Мәңгелек тынычлык һәм өчлек суды» («Вечный мир и международный третейский суд», СПб., 1909) хезмәтендә гомуми коралсызлану идеяләрен яклый. Окт. рев-циясеннән соң Франциягә күчеп китә.

19–20 йөзләрдә Т.нең татар тармагы вәкилләре Тамбов һәм Пенза губерналары авылларында яшиләр. Т. фамилиясеннән килеп чыккан берничә авыл бар: Пенза губернасының Краснослободск өязе Татар Тенеше а. (хәзер Пенза өлкәсенең Атюрьев р-ны) 1675 тә Т.нең улы Нурай Креев милке санала; Краснослободск өязенең Тенеш авылы (хәзер Мордва Респ-касының Краснослободск р-ны). Т. нәселенең Пенза шәһәрендәге вәкилләре арасында — шәркыятче галим Әдһәм Рәхим улы *Тенишев* туганнары. 1893–94 тә Хәбиб җамал Хәбибулла кызы Тенишева (Мөхәммәд җан Мөхәммәдшәриф улы Тенишевнең хатыны, Пенза җамигъ мәчете имамы Ш.Х.Потиевнең бертуганы) Пенза шәһәрендә үзе сатып алган утарның таш флигельләренең берсен үзгәртеп, үз хисабына мәчет салдыра; 1918 дә Т. гаиләсе ярдәме б-н утар комплексында балалар бакчасы, мәктәп, китапханә, татар хатын-кызлары өчен тәрбиячеләр һәм шәфкать туташлары курслары ачыла.

Әд.: Вахитова Т. «Русский американец» в Петербурге // Новый журн. 1994. № 2/3; Дворянские роды российской империи. М., 1996. Т. 3; Еникеев С. Очерк истории татарского дворянства. Уфа, 1999; Габдуллин И.Р. От служилых татар к татарскому дворянству. М., 2006; Беляев А.Б. Историческая генеалогия татарского народа. К., 2014.

Р.А.Айнетдинов.

«ТЕНЬКО́ВСКАЯ РА́ННЯЯ», кура җиләге сорты. 1964 елда Татарстан респ-ка тәҗрибә станциясендә Н.И.Вакуленко һәм А.А.*Надысева* тарафыннан чыгарыла. Иртә өлгерешле сорт (июль башында), салкынга чыдам. Куагы биек, көчле, туры үскән. Аз тәнечкеле, яфраклары эре, куе яшел төстә, уртача сырлы. Җиләкләре эре (3,2 *г*), кызыл, тупа конус сыман формада, тәме әчкелтем-баллы; яңа өзелгән һәм эшкәртелгән килеш кулланыла. Уңышы — бер куактан 1,5–2 *кг*. Вируслы авырулар б-н зарарлануы уртача дәрәҗәдә. Татарстанда 1974 тән районлаштырылган. Коллектив һәм йорт яны бакчаларында үстерәләр.

«ТЕНЬКО́ВСКАЯ СИ́НЯЯ», слива сорты. 1946 елда Татарстан респ-ка тәҗрибә станциясендә А.М.Тверитинов һәм Л.А.*Севастьянова* тарафыннан чыгарыла. Соң өлгерешле сорт (сентябрьнең беренче яртысында), кырауга, корылыкка чыдамлыгы уртача, ябалдашы уртача куелыкта һәм яфраклы, шарсыман. Җимешләре вак (13,5 *г*), киңчә-озынча, куе зәңгәр яисә шәмәхә төстә, күп балавыз куныклы. Җимеш йомшагы саргылт-яшел, сусыл, баллы-әчкелтем. Җимешләре яңа өлгергән һәм эшкәртелгән килеш кулланыла. Утыртканнан соң 2–3 елда җимеш бирә башлый. Авырулар һәм вируслар б-н уртача дәрәҗәдә зарарлана, үзеннән-үзе серкәләнә. Татарстанда 1988 дән районлаштырыла. Коллектив һәм йорт яны бакчаларында үстерелә.

ТЕҢКӘ́Ш авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 7 *км* көньяк-көнбатыштарак, Карлы елгасы буенда. 2010 елда 430 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, чуашлар — 59%, татарлар — 40%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 1669 дан мәгълүм. 1720 еллардан халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, 1835–1860 елларда Удел ведомствосы карамагында; игенчелек, терлекчелек, такта яру б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.тә мәчет, мәдрәсә, чиркәү-приход мәктәбе, 8 сәүдә-сәнәгать йорты эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 849,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Ырынгы волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Буа р-нында. Халык саны: 1859 да — 53, 1897 дә — 776, 1913 тә — 774, 1920 дә — 1108, 1926 да — 483, 1938 дә — 927, 1949 да — 798, 1958 дә — 759, 1970 тә — 734, 1979 да — 688, 1989 да — 511, 2002 дә — 422 кеше.

ТЕПЛИ́ЦА ХУ ҖАЛЫГЫ́, яшелчә, чәчәк һәм аларның рассадаларын үстерә торган пр-тие. Татарстанда беренче зур Т.х. — Казанның 7 нче теплица комб-ты, 1956 елда эшли башлый. 1970–80 елларда башка зур Т.х. барлыкка килә. «*Весенний*» (Тукай р-ны), «Түбән Кама», «*Майский*», «Овощевод» (Яшел Үзән р-ны), «Мактама» (Әлмәт р-ны) с-зларында шактый мәйданда теплицалар бар. 1970–90 елларда Т.х.нда блоклы һәм пыялалы туфраклы зур теплицалар төзелә, аларда биек сабаклы культуралар үстерү, җитештерүне механикалаштыру һәм автоматлашты -



«Майский» теплица хуҗалыгының яшелчә цехы.

ру, үсемлекләр өчен кирәкле шартлар тудыру (сугару, тукландыру, яктылык, газ режимы), ел дәвамында берничә тапкыр продукция алу мөмкинлеге туа. Бу теплицалар темп-раны көйләү, су сиптерү һәм һаваны дымландыру, яктырту автоматикасы б-н җиһазланган. Т.х.да ш.у. продукция сату цехлары (суыткычлар б-н), утырту материалларын саклау биналары, минераль ашламалар, инвентарь складлары бар. Татарстанның Т.х.нда кыяр, томат, борыч, баклажан, яшел суган, яшел тәмләткечләр һәм чәчәк культуралары үстерелә. Т.х.нда 1980 дә — 22,7 мең *т*, 1990 да — 23,7, 2000 дә — 26,9, 2007 дә — 31,7, 2014 тә 30,4 мең *т* яшелчә җитештерелгән.

Әд.: Овощеводство защищённого грунта. М., 1974.

И.Н.Афанасьев.

ТЕПЛО́В Михаил Александрович (3.3.1939, Казан — 13.6.1998, Италия, Казанда җирләнә), физик, физика-матем. фән. д-ры (1981), проф. (1984), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1991). 1961 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1961–64 тә СССР ФА Сибер бүлегенең Радиофизика һәм электроника ин-тында (Новосибирск ш.). 1967 дән Казан. ун-тында, проф. (1982 дән), квант электроникасы һәм спектроскопия каф. мөдире (1983–98), магнит радиоспектроскопиясе һәм квант электроникасы проблемалы лаб-ляренең фәнни җитәкчесе (1985–98), проректор (1985–89).

Хезмәтләре парамагнит кристаллардагы магнит резонансына карый.

Т. кристаллик электр кырында бозылмаган төп халәттәге сирәк мәгъдән ионнары төшләрендә магнит резонансы күренешен ачыклый һәм өйрәнә.

Беренче булып V-Ba-Cu-O кушылмаларында тулий һәм празеодим төшләренең көчле ТМРн тикшерә. Ван-Флек парамагнитларыфизикасына караган хезмәтләр циклы өчен ТР Дәүләт бүләгенә лаек була (2006, үлгәннән соң). БДБ илләренең яшь галимнәре өчен Этторио Майоран үзәге (Италия,1998) һәм Казан ун-ты студентлары өчен физика ф-тының гыйльми советы (2000) Т. исем. стипендияләрне гамәлгә кертә.

Х е з м.: Магнитный резонанс в ван-флековских парамагнетиках // Проблемы магнитного резонанса. М., 1978 (автордаш); Ядерный магнитный резонанс в редкоземельных ван-флековских парамагнетиках // Успехи физ. наук. 1985. Т. 147, вып. 1 (автордаш); Magnetic properties of nonmetallic lanthanide compounds // Handbook on the Physics and Chemistry of Rare Earths. 1996. V.22 (автордаш).

«ТЕПЛОКОНТРО́ЛЬ», приборлар төзү пр-тиесе; сыек һәм газсыман матдәләрнең басымын, темп-расын, чыгымын үлчәү, тикшерүдә тоту һәм көйләү аппаратлары җитештерү буенча РФдә иң зур пр-тие. Казанда урнашкан. «Т.» з-ды 1948 елда төзелә башлый, 1952 дә файдалануга тапшырыла. 1973 тә аның җирлегендә Казан «Т.» ҖБ оештыра, берләшмәгә 1959 да төзелгән «Теплоприбор» үзәк проектлау-конструкторлык бюросы да кертелә. 1999 дан дәүләт унитар пр-тиесе, 2004 тән «Т.» АҖ. Беренче продукция 1953 тә алына. Эшчәнлеге чорында завод җитештерүнең төрле климат зоналарында, катлаулы техник шартларда куллану өчен төрле модельдәге күрсәткеч, сигнал биргеч һәм үзьязгыч приборларны күпләп чыгаруга ирешә, болар — техник манометрлар, термометрлар, басым һәм тигезлек күрсәткечләре һәм датчиклары, дифманометрлар (кыйммәтләрнең кискен үзгәрешен үлчәү һәм теркәү өчен), турыдан-туры көйләгечләр, үлчәнә торган кыйммәтләрне ток һәм пневматика сигналына әверелдергечләр, релелар. Продукциянең төп кулланучылары — атом һәм җылылык энергетикасы, нефть-газ-химия, агросәнәгать, хәрби сәнәгать комплекслары, металлургия, торба үткәргеч транспорты пр-тиеләре һ.б. Халык кулланыу өчен төрле елларда кече габаритлы газ плитәләре, баллоннар, җылылыкка чыдам пыяладан савыт-саба, үенчыклар эшләп чыгарыла.

1950 елларда пр-тиедә пластмасса пресслау, прибор циферблатларын штамплау, басу технологияләре, эретеп ябыштыру һәм басым астында коюның алдынгы ысуллары гамәлгә кертелә. 1960–70 елларда завод авырлыгы һәм үлчәмнәре азрак, үлчәү төгәллеге һәм ышанычлылыгы күпкә югарырак приборлар җитештерә башлый. 1980 елларда төп игътибар приборларны төргәкләү һәм тикшерү максатындагы ярымавтомат җиһазлар урнаштыруга, санлы программалар б-н идарә ителүле агрегат станоклар санын арттыруга юнәлтелә; елына 5–7 млн. техник манометр эшләп чыгаруга сәләтле көйләнешле җитештерү системасының уникаль линияләре гамәлгә кертелә, сыйфат параметрларын яхшырту һәм составында металл кулланышын киметү максатында пр-тиенең төп үлчәү чараларыяңартыла.

1958–82 дә товар продукциясен чыгару 34 тапкыр арта. Эшләүчеләр саны 6 меңнән артып китә. 1980 еллар ахырына ҖБ Европаның әйдәп баручы приборлар төзү пр-тиесенә әверелә. Аның эшләнмәләре техник һәм файдалану характеристикалары буенча күпкенә чит илләрнекеннән өстенрәк була, эчке һәм тышкы базарларда югары бәяләнә, СССРның һәм 50 дән артык чит илнең 18 меңнән артык пр-тиесенә җибәрелә (1955 тән башлап читкә чыгарыла).

1990 еллардагы икътисади кризис шартларында пр-тиенең җитештерү һәм идарә системалары реконструкцияләнә, бүлекчәләр заводларга: техник манометрлар, термометрлар, дифманометрлар, инструментлар һәм нәстандарт җиһазлар, тимерчелек-кою заводларына берләштерелә, сәүдә йорты оештырыла һ.б. Элегрәк арадаш пр-тиеләрдән китерелә торган комплект эшләнмәләрнең күпчелек өлешен, халык кулланыу товарларының яңа төр эшләнмәләрен (автомобиль, плитә, суыткыч датчиклары, термокөйләгечләр, мед. манометрлары, су һәм газ үлчәгечләр) җитештерү үзләштерелә. «Т.»нең төбәк-ләр һәм БДБ илләрендә вәкиллекләре бар.

Эшләү чорында «Т.» 150 млн. прибор чыгара. Иң зур заказчылары — «Татнефть» һәм «Татэнерго» АҖләре. Продукциянең бер өлеше якын чит илләргә чыгарыла. Җылылык энергиясен, су һәм газны сакчыл тоту эшләнмәләрен булдыру һәм үзләштерү, тикшерү-үлчәү приборларын яңарту һәм микропроцессорлар нигезендәге өр-яңа типларын булдыру буенча эшләр җәелдерелә.

Пр-тие тарафыннан күпкатлы торак йортлар, 270 коттеджлы посёлок, поликлиника, профилакторий, бассейн, 5 мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениесе, ял базасы һәм балалар лагерьлары, чиркәү төзелә. Җитештерүдәге казанышлары өчен пр-тие Хезмәт Кызыл Байрагы ордены (1971), «Европаның Алтын Йолдыз áркасы» халыкара премиясе (1993) б-н бүләкләнә. Күп кенә хезмәткәрләр дәүләт бүләкләренә, ш.и. 1 кеше — Соц. Хезмәт Герое, 1 кеше — ТССРның, 6 кеше ТРның атказ. машина төзүчесе исеменә лаек була; 2 кеше — Ленин ордены, 11 кеше — Хезмәт Кызыл Байрагы, 1 кеше — Халыклар дуслыгы, 13 кеше — «Почёт билгесе», 8 кеше 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә Хезмәт Даны орденнары б-н бүләкләнә.

Завод директорлары: Ф.Г.Карчевский (1948–55), В.Д.Жуков (1955–57), Г.И.Соловьев (1957–63), Н.С.Иваньшин (1963–81), В.К.*Кулагин* (1981–2004), А.Г.Абдуллин (2004–2018), И.Х.Шәмсиев (2018 дән).

С.Г.Белов.

ТЕ́ПТИН Герман Михайлович (19.6.1937, Казан), физик, физика-матем. фән. д-ры (1986), проф. (1989). ТРның атказ. фән эшлеклесе (1996). 1959 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, радиоастрономия каф. мөдире (1987 дән), бер үк вакытта «Гамәли радиофизика» фәнни-тикшеренү секторының фәнни җитәкчесе (1995 тән). Хезмәтләре электромагнит дулкыннарның очраклы беришсезлекләр булган тирәлекләрдә таралуына карый. Т. турбулент атм. динамикасын 80–100 *км* биеклектә радиометеор тикшерүләр өчен яңа алымнар эшли. Атм. һәм геомагнит кыр динамикасына бәйле рәвештә, түбәнге ионосферада электрон концентрациясе беришсезлекләре спектрының микъдари төзелеше турында фундаменталь нәтиҗәләр ала. Атм. һәм аның пычрануларыпараметрлары беришсезлекләренең макротурбулент (1–6 *км*) һәм мезомасштаблы (300 *км* га кадәр) характеристикаларын синхрон тикшерә. Халыкара фәнни-техник «Environmental radioecology and Applied Ecology» ж-лының баш мөхәррире (1995 тән). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Структура нижней термосферы. К., 1976; Временные вариации аэрозоля и малых примесей в приземном городском воздухе // Изв. РАН. Физика атмосферы и океана. 2003. Т. 39, № 6 (автордаш); Макротурбулентные характеристики средней и нижней атмосферы и рассеяние радиоволн. К., 2004.

ТЕРАПИ́Я (грек. therapéia — дәвалау), теоретик һәм гамәли мед. өлкәсе, кешенең төп (эчке) авыруларын: аларның клиник билгеләрен, барлыкка килү сәбәпләрен, авыру барышының закончалыкларын һәм механизмнарын; авыруларны кисәтү һәм дәвалау ысулларын өйрәнә. 19 йөзгә кадәр Т. клиник дисциплиналарның күпчелеген үз эченә ала. Мед. белемнәре үскән саен, педиатрия, невропатология, психиатрия, дерматология, йогышлы авырулар, фтизиатрия, оториноларингология, эндокринология һ.б. аерым дисциплина сыйфатында аерылып чыга. Т. үсе-

ше тарихында биол., химия, физика һ.б. фәннәр өлкәсендәге ачышлар әһәмиятле роль уйный. 1840 елларга кадәр Т.дә эмпирик («Гиппократча») юнәлеш өстенлек итә, 16–18 йөзләрдә анатомик, соңрак физиол. һәм микроскопик юнәлешләр барлыкка килә. Рус Т. мәктәбенә Мәскәү ун-ты профессоры М.Я.Мудров нигез сала, ул дәвалау барышында авыру кешене төрле яклап тикшерү һәм системалы рәвештә авыру тарихын алып баруны гамәлгә кертә. Эчке авыруларны дәвалау өлкәсендәге үсешнең табигый-гыйльми («Боткинча») юнәлешен С.П.Боткин, Г.А.Захарьин, А.А.Остроумов, В.Н.Сиротkин, И.Я.Чистович, М.В.Яновский һ.б. әйдәп бара. 19 йөздә перкуссия һәм аускульта ция методикасы эшләнә һәм гамәлгә кертелә (М.Я.Мудров, Г.И.Сокольский), гистоморфологик һәм лаборатор тикшерүысуллары кулланыла башлый. Шуларга бәйле рәвештә Т.дә әгъзалардагы патологияләрне өйрәнү юнәлеше өстенлек ала, аны эчке авыруларны дәвалаудагы физиол. юнәлеш алыштыра. 20 йөз башы Франциядә — Л.Пастер, Россиядә — И.И.Мечников, Германиядә Р.Кох хезмәтләре б-н алгарыш алган бактериология чоры буларак билгеләнә. Шушы ук дәвердә бактериология, йогышлы авырулар кебек яңа мед. дисциплиналарына нигез салына; медицинада физиол.-функциональ юнәлеш үсеш ала (Н.А.*Виноградов*, С.С.*Зимницкий*); «нервизм» (кеше организмындагы кортик-висцераль бәйләнешләр) турындагы тәгълимат формалаша. Хәзерге вакытта Т.дә тикшеренүнең морфологик исуллары: кан, сыеклыклар, сөяк җелеге пунктаты анализы, лимфа төеннәре һәм төрле әгъзалар пунктатларын тикшерүләр өстенлекле урын били.

Татарстанда Т. фәне үсеше Казан ун-тының мед. ф-ты (1814 елда оештырыла) эшчәнлеге б-н бәйле. «Төбәк патологиясен» (ваба һ.б. эпидемик авырулар) өйрәнүгә Казан ун-ты профессорлары Ф.Х.*Эрдман* һәм К.Ф.*Фукс* зур өлеш кертә; Казан Т. мәктәбенә Казан ун-ты профессоры Н.А.*Скандовский* нигез сала. Т.нең алга таба үсеше проф. Н.А.Виноградов (С.П.Боткин шәкерте) тарафыннан 1868 дә Казан ун-ты каршында Табиблар җәмгыяте оештырылу б-н бәйле. Т.дә морфологик-лаборатор юнәлешне И.И.*Зедерштедт* һәм М.Ф.*Субботин* (1877 дән башлап, М.Ф.Субботин үлгән па циентларга мәҗбүри патологоанатомик тик шерү уздыру тәртибен кертә) үстерә. Проф. Н.И.*Котовщиков* диагноз кую процессының алгоритмнарын төзүгә нигез сала. 1880 дә Россиядә беренче буларак кушымтасы б-н «Эчке авыруларны өйрәнүнең клиник исыл лары буенча кулланма» («Руководство к клиническим методам исследования внутренних болезней») ярдәмлеге басылып чыга. Па циентларга диагноз кую һәм авыруларны дәвалауда индивидуаль караш традицияләрен Н.А.*Засецкий* һәм А.Н.*Казимбәк* дәвам итә. Казанда рентген ярдәмендә диагноз кую хезмәтен нигезләүчеләрнең берсе Ә.Б.*Терегулов* була. Эчке авыруларны дәвалау юлларын өйрәнүгә В.Ф.*Орловский* (бөер һәм ашкайнату системасы әгъзалары физиологиясе һәм бу әгъзалардагы авыруларга лаборатор ысул б-н диагноз куюга багышланган хезмәтләр авторы) зур өлеш кертә.

20 йөзнең беренче яртысында Казан Т. мәктәбе диагност С.С.Зимницкий, кардиолог П.Н.Николаев («Йөрәгалды колакчыннарының лепердәве һәм тибрәнүе турында» («О порхании и мерцании предсердий», 1923) монографиясе авторы, гематолог Н.К.*Горяев* (канның гомуми анализы исулын кертә, канның формалы аерым элементларының исәбен алу өчен «*Горяев санау камерасы*» конструкциясен эшли) хезмәтләре б-н таныла. 20 йөзнең икенче яртысыннан Т. фәне гамәли хезмәттәге табибләр б-н тыгыз элемтәдә торучы Казан мед. ин-ты, ГИДУВ, Казан эпидемиология һәм микробиол. ин-ты галимнәренең эзләнүләре нәтиҗәсендә уңышлы үсешен дәвам итә. Кардиология мәсьәләләрен өйрәнүдә галимнәр Л.М.*Рахлин*, Л.А.Лушников, И.П.*Арлеевский* зур хезмәт куя. Атеросклероз, гипертония һәм ишемиягә диагноз кую һәм авыруларны дәвалау юллары В.Е.*Анисимов*, Ә.Б.Терегулов, В.Ф.*Богоявленский*, И.Г.*Салихов*, И.Ә.*Лотфуллин* һ.б. тарафыннан төрле яклап тикшерелә. З.И.*Малкин* һәм аның шәкертләре — Р.Ш.*Абдрахманова*, Р.Ә.*Хәбиров*, С.И.*Щербатенко*, Р.М.Газизов тарафыннан ревматология буенча аерым фәнни юнәлеш оештырыла. Гастроэнтерология өлкәсендә О.С.*Радбиль*, И.Л.*Билич*, А.Г.Опарин, К.А.*Маянская*, Р.Х.*Борнашева*, Р.А.*Абделхаков*, Р.И.*Хәмидуллин* зур уңышларга ирешәләр. Микрогемоциркуляция һәм аны дәвалау б-н бәйле мәсьәләләр В.Ф.Богоявленский, Л.В.*Никонова*, Б.Г.*Садыйков*, Н.Б.*Әмиров*, Р.Г.*Биктимерова* һ.б. тарафыннан өйрәнелә. Эндокринология буенча фәнни юнәлеш булдырыла (В.В.*Талантов*, Л.И.*Анчикова*). Пульмонологиядә (Р.Ш.Абдрахманова, Д.А.*Вәлимөхәммәтова* һ.б.) һәм медицинаның башка өлкәләрендә инструменталь диагностика уңышлы үстерелә. Ш.у.к. *Казанда фәнни медицина җәмгыятьләре*.

Әд.: Казанский ГИДУВ им. В.И.Ленина. 1920–1990. К., 1990; Арлеевский И.П. История кафедры терапии. К., 2001; Салихов И.Г., Якупова С.П., Лапшина С.А. Кафедра госпитальной терапии Казанского государственного медицинского университета (1814–2004 гг.). К., 2004.

В.Ф.Богоявленский.

ТЕРЕГУ́ЛОВ Айрат Рәүф улы (30.10.1957, Уфа ш.), график, нәкышьче, дизайнер, БР нның, РФнең атказ. рәссамы (2004, 2014). М.В.Нестеров исем. БР Дәүләт сынлы сәнгать музее директоры (2015 елдан). Башкорт пед. ин-тының сәнгать-графика ф-тын тәмамлый (1985). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1990), бүгенге Россия графикасының әйдәп баручы осталарыннан, офортның төсле (катнаш техника) һәм аклы-каралы (кислота б-н уйдырылган штрих, коры энә, акватинта, меццо-тинто), югары басмалы (линогравюра, ксилография), цинк табакларда эшләнгән эре форматлы монотип техникаларда башкарылган эстамплар һәм уникаль станлы әсәрләр авторы. Абстракт һәм фигуратив композицияләрдәге сызыклар һәм таплар нның экспрессив хәрәкәтчәнлеге персонаж ларның гротеск һәм комик образлары б-н үрелеп бара («Ир-ат уеннары»; 200 табактан артык, 1988–2009; «Соңгы солдат», 1989–2000 офортлар сериясе). Т. «Шәһәр» (1985–88), «Сугышлар тарихы», «Онытылган йөзләр», «Көй» (барысы да — 2002), «Дала» (2003), «Габитус» (2006) кебек тематик циклларда персонажларын силуэт ясаучы бер сызык (офортта) яки кискеченең берничә хәрәкәте б-н сурәтли (линогравюрада). Тәэсирле образлары кабатланмас график композицияләрдә иҗат ителгән («Nu», 1988–2009; «Портретлар», 30 табак, 1990–2000; «Сөңге», 1999; «Көймә», 2000; «Син минем исемемдә», 2002). Күпчелек әсәрләре постмодерн стилендә башкарылган. Шуның б-н бергә, рәссам әүвәлге хезмәтләренең фрагментларын типографик ысул б-н җыю принцибы буенча композициягә туплап, әсәрләренең вариацияләрен эшли («Минем исемем» триптихы, 2003 һ.б.). Т.ның сәнгать алымнарының ачык аңлаешлылыгы, форма һәм фәзаны шәрехләүдә кинаяле, ирекле булуы б-н аерылып тора.



А.Р.Терегулов. «Габитус». Кәгазь. Линогравюра. 2006.

Т.ның нәкышь иҗаты күпкырлы: портрет, пейзаж һәм натюрморт жанрларыннан алып, абстракт композицияләргә кадәрге төрләрне колачлый: «Брудершафт» (1990), «Шыгырдавык сын», «Борычлы натюрморт» (икесе дә — 1999), «Штопорлы натюрморт», «Көтүче Мәхмүт» (икесе дә — 2000), «Эңгер-меңгер» (2003), «Бизмән», «Сарылык саркылган басу пейзажы», «Эчкерсез сафлык» (барысы да — 2009). Уфа нәшриятында үзен китап дизайнеры буларак таныта («Башкортстан — туган йортым» фотоальбомы, 2007; С.Синенконың «Рудольф Нуриев. Иҗат чишмәләре, язмыш шаяруы», 2008; Ә.Вәлиевнең «Якты эз. Хөсәен Мәҗитов сәхнәдә һәм тормышта», «Николай Калинушкин» (икесе дә — 2009) китаплары һ.б.) 1981 дән Урал зона — 1 нче (1995), 2 нче (1998, 3 нче бүләк һәм бронза медаль), 5 нче (2007, 1 нче бүләк һәм алтын медаль); бөтенсоюз — 1 нче станлы графика (Мәскәү, 1987), 7 нче эстамп (Мәскәү, Тбилиси, 1989); халыкара — Миниатюр сәнгать (Торонто ш., Канада, 1989, 1990), Басма миниатюра (Сеул ш., Көньяк Корея, 1996, «Югары профессиональлек» номина-



Г.Х.Терегулов.



И.В.Терегулов.



И.Г.Терегулов.

циясендәге бүләк) һ.б. күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре Уфада (1990, 1995, 2003, 2008, 2009), Копенгагенда (Дания, 1995, 1996), Мәскәүдә (2001), Казанда (2002, 2008), С.-Петербургта (2005), Бая-Мареда (Румыния, 2005) уздырыла. Әсәрләре «Казан» милли мәдәният үзәгендә, М.В.Нестеров исем. Башкорт дәүләт сәнгать музее, Мәскәү хәзерге заман сәнгать музее, Хәзерге заман сәнгать музее (Париж, Франция), Хәзерге заман сәнгать музее (Хельсинки, Финляндия), Копенгагенның Милли Король китапханәсе (Дания), Истанбул графика сәнгате музеенда (Төркия), Россия һәм чит илләрдәге күп кенә музей һәм шәхси тупланмаларда саклана.

Х е з м.: Постскриптум // «ВХ». 2006. № 4.

Әд.: Ф е н и н а Э.П. Художники Башкортостана. XX век. Уфа, 2002; Айрат Терегулов: Каталог выставки. Уфа, 2008.

Г.Р.Фәйзрахманова.

ТЕРЕГУ́ЛОВ Әбүбәкер Батыргәрәй улы (1.2.1885, Уфа — 18.12.1966, Казан), терапевт, мед. фән. д-ры (1927), проф. (1929), ТАССР һәм РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1940). Профессорлар Н.А.Мирославский һәм А.Н.*Казимбәк* шәкерте. Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1911), Уфа губернасы Бәләбәй өязенең Чишмә тимер юл станциясендә земство табибе булып эшли. 1912 елда Уфа губернасындагы ачлыкка каршы көрәш чараларында катнаша. 1913 тән Казан ун-тының факультет терапиясе кафедрасында (бүленеп: 1918–21 дә Томск ун-тында; 1919–20 дә Иркутск ун-тында, эчке авыруларга диагноз кую кафедрасында, бер үк вакытта 452 нче запас госпитальдә терапия бүлеге мөдире). 1920–63 тә Казан мед. ин-тында, эчке авырулар пропедевтикасы (1929–44), 1 нче госпиталь терапиясе (1944–63) кафедралары мөдире. СССР ФА академигы Б.Е.Вотчал б-н берлектә Казанда «Медфизприбор» махсус конструкторлык-технол. бюросы төзүдә катнаша (1958). Хезмәтләре клиник физиологиягә: Чейн-Стокча сулыш алу патологиясе барлыкка килү сәбәпләрен, аш-кайнату әгъзалары патологияләрен өйрәнүгә карый. Татарлардан клиник мед. өлкәсендә хезмәт куйган беренче проф., «Казанский медицинский журнал»ны кабат чыгаруда башлап йөрүчеләрнең берсе һәм басманың мөхәррире (1957). 1969 да Казан шәһәре 1 нче клиник хастаханәсенә Т. исеме бирелә. Ленин ордены, 2 Кызыл Байрак ордены, медальләр б-н бүләкләнә. ТР ФА Президиумы тарафыннан клиник мед. мәсь әләләренә багышланган хезмәтләр өчен ТР ФАнең Э.Б.Терегулов исем. бүләге булдырыла (2000).

Х е з м.: Болезни органов кровообращения // Справочник начинающего советского врача. К., 1933; Клинико-лабораторное исследование и курация больного с заболеванием внутренних органов. К., 1959.

Әд.: А б д р а х м а н о в а Р.Ш., М а я н с к а я К.А. Профессор Абубекир Гиреевич Терегулов // Казан. мед. журн. 1985. № 2.

В.Ф.Богоявленский.

ТЕРЕГУ́ЛОВ Гомәр Хәбибрахман улы (9.4.1883, Уфа губ., Бәләбәй өязе Яңа Каргалы а. — 29.8.1938, Әнкара ш., Төркия), сәясәт эшлеклесе. Уфа губернасының нәселдән күчмә дворяннар нәселеннән. Казан татар укытучылар мәктәбен тәмамлый (1902). Уфа (1900–06), Спас (1910–11) шәһәрләрендә укытучы булып эшли. Казанда укыган дәвердә Г.Исхакый, Ф.Туктаров, Х.Ямашев б-н таныша. Соц. идеяләр б-н кызыксынып китеп, 1905 елда РСДРПга керә (со ңыннан меньшевикларга кушыла). 1907 дә с.-д.ның «Урал» г-тасын нәшер итүдә катнаша (Оренбург ш.). Ул ябылганнан соң, Казан ун-тының юридик ф-тына ирекле тыңлаучы булып керә. 1908–10 да С.-Петербургта яши. 1911–17 дә Уфа земствосында хезмәт итә. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң актив иҗтимагый-сәяси эшчәнлек алып бара: Уфада «Мәселманнар арасында гражданлык идеясен тарату ком-ты» әгъзасы; Мәскәүдә һәм Казанда 1 нче һәм 2 нче Бөтенроссия мөселманнары корылтайларында катнаша (1917). 1 нче корылтайда мәдәният һәм мәгариф мәсьәләләре буенча доклад б-н, икенчесендә — милли-мәдәни мохтариятне яклап чыгыш ясый. Уфа губернасы Милли Шурасы башкарма ком-ты әгъзасы. 1917–18 дә Милләт Мәҗлесе депутаты; регламент һәм мәгариф мәсьәләләре буенча комиссияләр эшендә катнаша, төркичеләр (Эчке Россия һәм Себер төркиләренең милли-мәдәни мохтарияте тарафдарлары) фракциясенә керә. *Милли Идарә* оештырылганнан соң (1918 нең гыйн.), Мәгариф нәзарәте (Мәгариф министрлыгы) составына сайлана. Уфа губернасыннан Оештыру җыелышы делегаты (1918), 1918 нең гыйнварында ул таратылганнан соң, Оештыру җыелышы ком-ты (КОМУЧ) составына керә. Петропавловск шәһәрендә «*Маяк*» татар г-тасын нәшер итүдә катнаша. 1919 да чит илгә күчеп китә. Японияда, аннан соң Харбин шәһәрендә (Кытай) яши. 1924 тә Европага күченә, 1920 елларның 2 нче ярты сында Төркиядә төпләнә.

Әд.: У с м а н о в а Д.М. Разлучённый с Родиной (Жизнь и судьба Гумера Терегулова) // Татарстан. 1997. № 11.

Д.М.Госманова.

ТЕРЕГУ́ЛОВ Гыйниятулла Нигъмәтулла улы (31.5.1891, Уфа губ. Каргалы а. — 4.3.1984, БАССР), терапевт, мед. фән. д-ры (1940), проф. (1940), БАССРның атказ. фән эшлеклесе (1944). Мәскәү ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1927), Башкорт мед. ин-тында эшли, 1936–78 елларда пропедевтика каф. мөдире. 1943–45 тә эвакогоспитальләрнең баш терапевты, БАССР Сәламәтлек саклау министрлыгының баш терапевты (1950 гә кадәр). Хезмәтләре проф. авырулары кисәтүгә һәм курортологиягә карый. БАССРның Респ-ка терапевтлар җәмгыяте рәисе (1951–80). 1956–60 та БАССР ЮС депутаты. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы һәм «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Тёплая гора Янган-тау. Уфа, 1939; Курорты Башкирии. Уфа, 1968 (автордаш).

ТЕРЕГУ́ЛОВ Ибраһим Вәлиулла улы (29.5.1852, Уфа — 22.11.1921, Төркестан АССРның Сәмәрканд ш.), педагог. 1874 елда Казан вет. ин-тына укырга керә, уку дәверендә «Касыймия» мәдрәсәсендә рус теле укыта. Институтны тәмамлаганнан соң, Казан татар укытучылар мәктәбендә табигать белемен укыта (1878–1912) (бүленеп: 1906–08 дә Казан ун-ты студентлары инспекторының ярдәмчесе булып эшли). 1915 тән — Мәскәү, 1916 дан Оренбург уку-укыту округларының татар мәктәпләрендә инспектор, 1918 дән Оренбург губерна башкарма ком-тында халык мәгарифенең мөселман бүлеге мөдире, бер үк вакытта, 1918–20 дә, өчъеллык пед. курсларда укыта. 1921 дән Сәмәрканд пед. ин-тында. Т. тырышлыгы б-н Казан татар укытучылар мәктәбендә табигать фәннәрен укыту югары дәрәҗәдә оештырыла; укыту гимназияләр өчен Т. татарчага тәрҗемә иткән уку ярдәмлекләре буенча алып барыла. Татар телендә мед., гигиена, а.х.на караган фәнни-популяр басмалар, Т.ның үз хезмәтләре һәм тәрҗемәләре басылып чыга (алар табигать фәннәренә караган татар лексикасын формалаштыруда мөһим роль уйныйлар). *Шәрекъ клубы*н оештыру инициаторларыннан берсе һәм идарәсенең 1 нче рәисе. А.Н.Островский һәм А.К.Толстой пьесаларын татар теленә тәр җемә итүне һәм басты руны оештыра (тәр җемәчеләрнең берсе үзе дип фаразлана).

Х е з м.: Су. Кыйрает китабы. СПб., 1897; Татар нәхүсенең мохтасары. К., 1901; Бәрәңге, аның нәүгылары (сортлары) һәм аны үстерү. К., 1913; Кычу тугрысында. К., 1913.

Әд.: Терегулов Ибраһимның 30 сәнәлек гыйльмиясенә ядкарь. Оренбург, 1908; Ә х м ә т җ а н о в М. Галим-педагог Ибраһим Терегулов // Мирас. 1994. № 2.

ТЕРЕГУ́ЛОВ Илтөзәр Гыйззәт улы (14.6.1930, Арча кантоны Кышкар а. — 11.11.2005, Казан), механика өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (1968), ТР ФАнең хакыйкый әгъзасы (1992), ТАССРның, РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1980, 1990). 1954 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, Казан химия-технол. ин-тында эшли. 1960 тан СССР ФА Казан ф-лының Физика-техника ин-тында, бер үк вакытта Казан югары хәрби командир-инженерлар уч-ще сендә теоретик механика каф. мөдире (1963–71), проф. (1969). 1971 дән Казан архит.-төзелеш ун-тында, материаллар каршылыгы һәм эластиклык-пластиклык теориясе

нигезләре каф. мөдире. Хезмәтләре дефор мацияләнә торган каты җисем механикасына, сүрүләр теориясенә, композитлар механикасына карый. Т. деформацияләнә торган каты җисемнең нәсызыкча механикасында вариатив принципларны формалаштыра, сүрүләрнең нәсызыкча төгәл теориясенең төрле вариантларын төзи, композит сүрүләр өчен билгеләгеч нисбәтләр теориясен эшли.

Х е з м.: Изгиб и устойчивость пластин и оболочек при ползучести. М., 1970; Сопротивление материалов и основы теории упругости и пластичности. М., 1984; Нелинейные задачи теории оболочек и определяющие соотношения. К., 2000; Расчёт конструкций по теории предельного равновесия. К., 2003 (автордаш).

ТЕРЕГУ́ЛОВ Рал Гыйниятулла улы (28.2.1922, хәзер БРның Благовар р-ны Каргалы а. — 11.9.1998, Уфа), патофизиолог, мед. фән. д-ры (1969), проф. (1970), БАССРның атказ. фән эшлеклесе (1989). БР ФАнең мактаулы академигы (1995). Терегуловлар нәселеннән, Г.Н.*Терегуловның* улы. Башкорт мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1948), шунда ук, патофизиол. кафедрасында эшли. 1971–87 елларда каф. мөдире, 1987 дән проф.-консультант. 1956–60 та Алтай мед. ин-тының (Барнаул ш.) патофизиол. каф. мөдире. Хезмәтләре организмның реактивлык механизмнарын, иммунитет халәтләрен (фагоцитозның ролен) өйрәнүгә карый. 2 уйлап табу авторы. Башкортстан патофизиологлар җәмгыяте рәисе (1971–87).

Х е з м.: Патофизиология Урала. Уфа, 1985.

ТЕРЕГУ́ЛОВА Бибигайшә Мөхәммәдгали кызы (30.3.1868, Казан — 1940, шунда ук), язучы, тәрҗемәче. М.*Мәхмүдов* кызы. 1916–24 елларда Оренбургта яши. 1924 нең гыйнварында Казанга кайта. «Йолдыз» г-тасы өчен а.х. темасына бәйле фәнни-популяр мәкаләләр тәрҗемә итә. «Солдат хикәясе» (1897), «Хикаятләр. Балаларга һәдия» (1904) дидактик хикәяләре авторы; В.Слепцовның «Җефәк күлмәк» («И в черве толк, и в черве шёлк», 1904) китабын, А.Н.Островскийның «Без вины виноватые» («Гөнаһсыз гаеплеләр») драмасын татар теленә тәрҗемә итә. Соңгысы 1916 да Казанда Зур драма театры сәхнәсендә куела.

Әд.: М ә х м ү т о в Һ., И л я л о в а И., Г ы й з з ә т Б. Октябрьгә кадәрге татар театры. К., 1988; Татар әдипләре, мәгърифәтчеләре (XX йөз башы): Биобиблиогр. сүзлек. К., 2005.

ТЕРЕГУ́ЛОВЛАР, татар морзалары нәселе. Чыгышы б-н Нугай Урдасыннан булган, 16 йөз ахырында русларга хезмәткә күчкән һәм Темников шәһәрендә хезмәт иткән Ени-ки Кулдашевның варислары. Еникинең өлкән улы Терегул — Терегуловлар нәселен башлаучы (башкалар *Еникиевләр* фамилиясен йөртәләр), хезмәте өчен аңа Саранск өязенең Ирсит авылы һәм Темников өязенең Идей авылы крәстияннәре тапшырыла. Терегулның 4 улы була: Теребирде, Уразай, Теләш һәм Кечекәй. Терегул Еникиевнең күпсанлы варислары Тамбов, Саратов, Уфа губерналарында таралып урнашалар. 18 йөз башына Т. улы Ибраһим Сәфәровның Пенза өязенең Урта Әләзән авылында крәстияннәре булуы мәгълүм. 1770 елларда морза Т. тугандаш Ени-киевләр б-н Каргалы авылы янында җирләр сатып алалар, 1836 да Каргалы авылында морза Т. милкендә 74 ир-ат исәпләнә. 1796 да Павел I Фәрманы б-н Т. Еникиевләр б-н бергә дворянлыкка кабул ителәләр. Т. нәселе вәкилләре Тамбов губернасының Идей авылында, Саратов губернасының Терегул авылында, Уфа губернасының Каргалы авылында яшиләр. Т. улы Кәлимулла Бәшировның Оренбург межа конторасына канцелярия хезмәткәре булып урнашуы, 1820 дә коллегия теркәүчесе, 1824 тә губерна секретаре чинын алуы мәгълүм. Т.ның Уфадагы тармагы вәкилләре Оренбург мөселман Диния нәзарәте б-н бәйле булган. Окт. рев-циясенә кадәр анда Идиятулла Гайфулла улы һәм Госман Сафиулла улы Т. хезмәт итәләр; титуляр советник Миңлешәрәфетдин Нәҗметдин улы Т. Нәзарәтнең теркәүчесе һәм архивариусы була. Нәселнең Уфадагы вәкилләре арасында Әхмәтсолтан Гали улы (1880–1952) аеруча мәгълүм. Ул Уфада шәһәр уч-щесе һәм гимназия тәмамлый, Уфа шәһәр һәм земство кабулханәләрендә эшли, вак кредит буенча губерна ком-ты эшләре б-н идарә итә. 1905 тән Уфа губернаторы канцеляриясендә хезмәттә, 1915 тән — губернатор каршында махсус йөкләмәләр башкаручы өлкән чиновник. Уфа губернасы дворяннар җыены депутаты, 1915–17 дә Уфа шәһәр думасы гласные. 1917 дә Вакытлы хөкүмәтнең губерна комис-тында хезмәт итә. 1917 дән соң Уфаның төрле оешмаларында бухгалтер булып эшли. Т. нәселе вәкилләре арасында — табиблар Әбүбәкер Батыргәрәй улы *Терегулов*, Гыйниятулла Нигъмәтулла улы *Терегулов*, Рал Гыйниятулла улы *Терегулов*, сәясәт эшлеклесе Гомәр Хәбибрахман улы *Терегулов*, галим Роберт Искәндәр улы *Нигъмәтуллин* бар.

Әд.: Е н и к е е в С. Очерк истории татарского дворянства. Уфа, 1999; Г а б д у л л и н И.Р. От служилых татар к татарскому дворянству. М., 2006.

ТЕ́РЕК ЕЛГАСЫ́ БУЕНДАГЫ́ СУГЫ́Ш (1935 елның 15 апр.) Аксак Тимернең Туктамышка каршы оештырган икенче зур сугышы (к. *Кондырча елгасы буендагы сугыш*). 1394 елның язында Алтын Урда гаскәрләре, Туктамыш ханның төрек солтаны Йылдырым һәм мәмлүкләр Мисыры идарәчесе солтан Баркук арасындагы килешү шартларын үтәү йөзеннән, Кавказ артына бәреп керәләр, әмма Аксак Тимер гаскәрләре тарафыннан кысрыклап чыгарылалар. 1395 нең февралендә Аксак Тимер, 100 меңгә кадәр кешелек гаскәр җыеп, Дагстанның диңгез буендагы җирләренә үтеп керә. Каршы яклар Терек елгасы буйларында очрашалар. Туктамыш атлылары Аксак Тимер гаскәрләренең уң канатына һөҗүм итәләр, дошман көчләренең үзәк өлешен кысрыклауга ирешәләр. 3 көн дәвам иткән сугыш барышында Аксак Тимер, Алтын Урда гаскәрләренең сул канатындагы кайбер бәкләрнең үз ягына күчүеннән файдаланып, башта Туктамышның сул флангын, аннан соң төп көчләрен тар-мар итә, Туктамыш сугышып төньякка таба чигенә. Аксак Тимер гаскәрләре, аны эзәрлекләп барып, Алтын Урданың *Азак, Маҗар, Укәк, Ха җитархан* һ.б. шәһәрләрен талый һәм яндыра.

Әд.: Г р е к о в Б.Д., Я к у б о в с к и й А.Ю. Золотая Орда и её падение. М.–Л., 1950; С а ф а р г а л и е в М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; Х и з р и е в Х.А. Нашествие Тимура на Северный Кавказ и сражение на Тереке // Вопр. истории. 1982. № 4; Б е л я е в А.Б. Историческая генеалогия татарского народа. К., 2014.

И.Л.Измайлов.

ТЕРЕЛӘ́Й ТУДЫРУЧЫ́ МОЛЛЮ́СКЛАР (Viviparidae), *корсагаяклы моллюсклар* семьялыгы. Көньяк Америкадан кала бөтен Җир шарында таралганнар. Европа фаунасында 5, Татарстан терр-ясендә 2 төре билгеле: барлык төр сулыкларда (сазлык, күл һ.б.) очраучы саз Т.т.м.ы (Viviparus contectus), Кубышев сусаклагычы һәм зур елгаларда яшәүче чын Т.т.м. (V. viviparus). Кабырчыгы спиральсыман бөтерелгән, кара көрән төстә, кайвакыт яшькелт төсмерле, куркыныч тугында моллюскның аягында урнашкан тыгыз мөгезсыман капкач б-н ябылучы авызчык б-н тәмамлана. Мантиянең аскы ягында урнашкан саңаклар ярдәмендә сулыйлар. Т.т.м. — аерым җенеслеләр, бөтен җәй дәвамында диярлек үрчиләр. Аталанган күкәйләр ана затның гәүдәсендә җитлегә. Олы затлардан аермалы буларак, яшьләрнең кабырчык борылмаларында берничә рәт булып спиральсыман чачаклы орылар урнашкан. Капкаччык б-н кабырчыкны тыгыз ябып һәм катып калу халәтендә Т.т.м. суның катуын да җи ңел кичерергә сәләтле. Күп кенә бентос балыклары өчен азык булып торалар.

Әд.: Жизнь животных. М., 1968. Т. 2; Краткий определитель водных беспозвоночных Среднего Поволжья. К., 1977. *В.А.Яковлев.*

ТЕРЕ́НИН Дмитрий Степанович (27.9.1873, Амстердам, Голландия — 1916 елның июленнән соң), җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе. Генерал-майор, Казан губернасы дворяннары башлыгы С.Н.Терениннның улы. Беренче ир-балалар гимназиясен (1891), Казан ун-ты-ның юридик ф-тын (1895) тәмамлый. 1895 елдан Казан округ мәхкәмәсендә, 1897 дә — Казан дворян депутатлары җыены канцеляриясендә, 1898 дә Дворяннар җир банкының Казан бүлегендә хезмәт итә. Казан губернасының Спас өязендә земство идарәсе башлыгы (1898–1906). Спас өяз һәм Казан губерна земствосы җыеннары гласные. Казан губерна земствосының Крәстияннәр җир банкы идарәсе әгъзасы, соңрак Сембер шәһәрендә Крәстияннәр банкының тәгаен әгъзасы һәм баш бухгалтеры. 1904–05 тәге рус-япон сугышында катнаша. Спас өязенең Салман авылында нәселдән килгән 440 дис. җире була. 1912 дә Казан губернасыннан 4 нче Дәүләт Думасы депутаты итеп сайлана, октябристлар партиясе фракциясе әгъзасы, финанс, керемнәр һәм чыгымнар дәүләт исемлеген гамәлгә ашыру комиссияләре составына керә. Беренче бөтендөнья сугышы башында хәрби хезмәткә алына; хәрби-санитария частенда хуҗалык мөдире (1915), аннан соң үз теләге б-н хәрәкәттәге армиягә (161 нче Александрополь пехота полкы) күчерелә. Алдагы язмышы билгесез.

Әд.: У с м а н о в а Д.М. Депутаты от Казанской губернии в Государственной думе. 1906–1917. К., 2006; Казанское дворянство. 1785–1917 гг. Генеал. словарь. К., 2001.



Н.Г.Теркулова.

ТЕ́РЕХОВ Павел Петрович (20.8.1950, Орёл өлкәсенең Глазунов р-ны Сеньково а.), баянчы, дирижёр, пед. фән. д-ры (2004), ТРның атказ. мәктәп укытучысы (1994), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2007). 1974 елда — В.Яковлевта Казан консерваториясенең баян классын, 1980 дә Ленинград мәдәният ин-тының оркестр дирижёрлыгы классы буенча ассистентура тәмамлый. 1975–77 дә һәм 1980 нән Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тында эшли, 1990–99 да социаль-мәдәни эшчәнлек ф-ты деканы, 1999–2015 тә ун-тның 1 нче проректоры, 2015 тән социаль-мәдәни эшчәнлек каф. мөдире. Хезмәтләре мәдәният хезмәткәрләре әзерләү мәсь әләләренә карый.

Х е з м.: Специалист социально-культурной сферы: педагогическая компетентность. К., 2002; Формирование педагогической компетентности специалиста в условиях модернизации непрерывного профессионального социо-культурного образования. К., 2003.

ТЕРЕ́ЩЕНКО Владислав Юрьевич (27.3.1947, Оренбург ш. — 7.1.2006, Казан), хирург, мед. фән. д-ры (2001). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1971), 2 нче Респ-ка клиник хастаханәсендә (РКБ № 2) хирург булып эшли. 1978 елдан Казан мед. ин-тында: 1990–2001 дә гомуми хирургия каф. мөдире. 1984–85 тә Замбия Респ-касында командировкада. 2000–06 да Казан сәламәтлек саклау идарәсендә үлекле-септик хирургия буенча белгеч. Хезмәтләре хроник остеомиелитны, кискен панкреатитны, маститларны дәвалауга карый. Үйлап табуга патенты бар.

Х е з м.: Роль медиаторных систем в экспериментальной терапии острых панкреатитов // Казан. мед. журн. 1976. № 2 (автордаш); Использование ксимедона в сочетании с лазерной терапией в комплексном лечении хронического остеомиелита // Новые методы диагностики и лечения. К., 1996; Маститы: Учеб.-метод. пособие. К., 2005 (автордаш).

ТЕРЕЩУ́К Валерий Степанович (13.1.1940, Украина ССРның Донецк өлкәсе Троицко-Харцызск пос.), очкыч аппаратларның электр җи һазлары өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1988), проф. (1991), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (2000). В 1963 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, проф. (1989–93), очкыч аппаратларның электр җи һазлары каф. мөдире (1993 тән). Хезмәтләре автомат транспорт чараларының һәм энергетик җайланмаларның электр җи һазлары системаларын автоматлаштырыл-ган проектлау барышында синтезлауга карый. Электр энергиясен бүлү системаларын һәм борттагы электр җиһазлары комплексының башка системаларын топологик һәм параметрларда синтезлау алымнарын һәм алгоритмнарын эшли (хезмәтләре А.Н.Туполев исем. Авиация фәнни-техник комплексында (АНТК), АНТКның Казан КБсында, С.П.Горбунов исем. Казан авиация ҖБдә, «КамАЗ» АҖдә гамәлгә кертелгән).

Х е з м.: Синтез оптимальной самолётной системы распределения электроэнергии при автоматизированном проектировании // Изв. вузов. Авиац. техника. 1984. № 1; Синтез систем распределения электрической энергии автономных объектов // Электричество. 1984. № 11; Системная модель, логическая схема проектирования и общий алгоритм синтеза оптимальных систем бортового комплекса электрооборудования в САПР // Изв. вузов. Авиац. техника. 1986. № 2.

ТЕРКӘГЕ́Ч, гади җөмләдә сүзләрне һәм куш-ма җөмләдә гади җөмләләрне үзара бәйли торган ярдәмлек сүз төркеме. Татар телендә, нинди синтаксик бәйләнеш барлыкка китерүләренә карап, барлык Т.ләрне дә тезүче һәм ияртүче Т.ләргә бүлеп өйрәнәләр. Тезүче Т.ләр синтаксик төзелмәләрнең үзара тигез хокуклы кисәкләрен бәйләүдә катнашалар. Төзелмәләрнең кисәкләре арасындагы мәгънә мөнәсәбәтләренә бәйле рәвештә тезүче Т.ләр 3 төркемчәгә бүленәләр: җыючы (һәм, вә; тагын, янә; ни... ни, да-дә / та-тә), каршы куючы (ә, әмма, ләкин; тик, бары, фәкать, исә; бәлки, мәгәр), бүлүче (я, яки, яисә, әле, бер-бер, әллә) Т.ләр. Ияртүче теркәгечләр иярчен кисәкне баш кисәккә, иярчен җөмләне баш җөмләгә бәйлиләр; шарт (әгәр; гәрчә), сәбәп-нәтиҗә (чөнки, ник дисәң), чагыштыру (әйтерсең) һ.б. ияртүле мөнәсәбәтләрне оештыруда катнашалар. Т. җөмлә кисәге булып килә алмый, шул ягы б-н ул теркәгеч сүздән (кайда; кем, нәрсә, ни; никадәр, ничаклы, нинди) аерыла. Теркәгеч сүзләр 2 төрле вазифа башкаралар: алар, сүзләрне һәм җөмләләрне үзара бәйләүдән (ягъни ярдәмлек сүз вазифасын башкарудан) тыш, иярчен җөмлә составына керәләр һәм җөмлә кисәге булып киләләр, мәс., Җирең **нинди** булса, икмәгең дә шундый була (мәкаль).

Әд.: Татар грамматикасы. Морфология. М.–К., 2002. Т. 2; Хисамова Ф.М. Татар теле морфологиясе. К., 2006.

ТЕРКУ́ЛОВА Нәҗия Габдерахман кызы (25.7.1929, Әстерхан ш. — 14.10.2016, Казан), җырчы (лирик-колоратуралы сопрано), ТАССРның халык артисты (1982). 1957 елда Казан консерваториясен (Е.А.Абросимова классы) тәмамлый. 1957–58 дә — ТАССРның Дәүләт җыр һәм бию ансамбле, 1959–62 дә — Абай исем. Казакъ опера һәм балет театры, 1962–64 тә Үзбәк филармониясе, 1964–66 да Москонцерт солисты. 1958–59 һәм 1966–91 дә Татар филармониясе солисты. Актив концерт эшчәнлеге алып бара, репертуарын халык җырлары («Ал Зәйнәбем», «Тәфтиләү» һ.б.), С.Сәйдәшев, Р.Яхин, Р.Еникиев һ.б. татар композиторларының муз. әсәрләре, ш.у. классик әсәрләр: опера арияләре, Көнбатыш Европа һәм рус композиторлары романслары тәшкил итә. Медальләр б-н бүләкләнә.

ТЕРЛЕ́К АЗЫГЫ́, а.х. терлекләрен туклан-дыру өчен кулланыла торган үсемлек, терлек, микробиологик һәм химик чыгышлы продуктлар. Үзләштерелә торган формада туклыклы матдәләре бар. Т.а. берничә төркемгә бүленә: яшел (чәчеп үстерелгән яшел *терлек азыгы культуралары*, табигый болын печәннәре, сабак-яфрак һ.б.), консервланган яшел (чәчеп үстерелгән терлек азыгы культуралары һәм үләннәрдән *силос, сенаж*, химик юл б-н консервланган яшел терлек азыгы); табигый кипкән үләннәр (печән, печән оны), ясалма киптерелгән үләнчел үсемлекләр (үлән оны, үлән гранулалары һәм брикетлар); тамыразыклар, сусыл җиләк-җимешләр һәм аларны эшкәртеп ясалган продуктлар; шикәр чөгендере, крахмал-патока, спирт, сыра, кондитер, май экстракцияләү производстволарының калдык продуктлары (жом, меласса, барда, мезга, салат үрентеләре, шрот, мальтоза түбе, җиләк-җимеш сыгынтылары); бөртекле ашлык һәм аны эшкәртеп ясалган продуктлар, он тарту, крахмал-патока, спирт, май экстракцияләү производствосының калдык продуктлары (көрпә, вакланган бөртек), үсемлекчелек һәм урман хуҗалыгының калдык продуктлары, кырчылык калдыклары (салам, кибәк, чәкән үзәге, көнбагыш башлары), агачлар (ботаклар, яфраклар, яфрак оны, терлек азыгы целлюлозасы); терлекчелектән алынган азык — сөт һәм аны эшкәртүнең (эремчек суы, әйрән, казеин), ит сәнәгатенең (ит, кан, сөяк оны) һәм балык сәнәгатенең (балык, краб, криль оны) калдык продуктлары; микробиол. һәм химик синтез ысулы б-н әзерләнгән азыклар (азык чүпрәсе, икмәк пешерү чүпрәсе); *катнаш азык* — тулы рационлы һәм концентратлар; хайваннар өчен өстәмә азыклар, биол. актив матдәләр һәм өстәмәләр, синтетик азот кушылмалары (аминок-талар, карбамид, аммоний тозлары һ.б.); *минераль азыклар* — өстәмәләр, витаминлы һәм ферментлы препаратлар, азык антибиотиклары, дару матдәләре. Шәһәр тирәсендәге хуҗалыкларда Т.а. сыйфатында шәһәр халкының һәм җәмәгать тукланыу пр-тиеләренең азык калдыклары файдаланыла. Т.а.ның хуҗалык кыйммәте аның туклыклылыгы, диетик үзенчәлекләре, бер азык берәмлеге җитештерүнең уртача бәясенә карап билгеләнә. Т.а.ның туклыклылыгы химик составына — протеин, азотсыз экстрактив матдәләр (башлыча крахмал һәм шикәр), майлар, минераль матдәләр һәм витаминнарга, ш.у. туклыклы матдәләрнең үзләштерелүенә бәйле. Протеинга бөртекле-кузаклы культуралар (20–30%), түп (30–40 %), яшел азык, кузаклы үләннәр, тереклек калдыклары бай. Май иң күп күләмдә май культуралары орлыкларында була (30–40 % ка кадәр). Углеводларга бөртеклеләр һәм бүлбеле тамыразыклар (башлыча крахмалга), кабак, тамыразыклар, яшел азык (башлыча шикәргә) бай. Клетчатка саламда (30–40 %) һәм печәндә (25–30 %) күп. Т.а.ндагы төп витаминнар: каротин (яшь үләндә, печәндә, кызыл кишердә), В группасы витаминнары (кузаклылар сабагында, бөртекле ашлыкта), Д витамины (нурландырылган терлек азыгы чүп-

рәсендә). Т.а.ның составына һәм туклыклылыгына таләпләр ГОСТ тарафыннан билгеләнә. Гамәли кулланыш өчен Т.а.ның туклыклылык таблицалары эшләнгән. Т.а.ның сыйфатын химик анализ нәтиҗәләре һәм тышкы билгеләре (төсе, исе, формасы) буенча бәялиләр. Гөмбәчекләр б-н зарарланган, механик кушылмалар яисә агулы матдәләр, амбар корткычлары калдыклары б-н чүпләнгән, ш.у. составында терлекләр сәламәтлеге өчен зарарлы үсемлекләр, микроорганизмнар һ.б. булган Т.а. сыйфатсыз дип санала. Тикшерү һәм Т.а.ның сыйфатын күтәрү максатында токсикологик анализ ясыйлар, аларны зарарсызландыру ысулларын (консервлау) кулланалар. Т.а. консервлауның барлык ысуллары да азык сыйфатын түбәнәйтүгә яисә бозуга, ферментларны бетерүгә яисә аларның яшәве өчен начар шартлар булдыруга сәләтле микроорганизмнарны бетерүгә китерә. Т.а. консервлауның төп алымнары — киптерү, силослау, стерильләштерү, химик чаралар-консервантлар (пропилен, уксус, бензой к-талары һәм аларның катнашмалары, пиросульфат натрий) б-н эшкәртү. Силослаганда «Татарстан кыры» ФҖБ һәм Казан технология ун-ты галимнәре эшләгән консервант кулланыла. Заманча Т.а. җитештерү азык культураларын үстерү, әзерләү һәм саклауның интенсив технологияләрен куллану нигезендә алып барыла, бу җитештерүне арттырырга һәм сыйфатны күтәрергә мөмкинлек бирә.

Т.а. җитештерүне яхшырту өчен респ-када махсус азык чәчү әйләнеше: *яшел конвейер*, сугару, терлек азыгы культураларын үстерүнең интенсив технологияләре, актив җилләтү, яшел азыкларны ясалма киптерү, аларны грануллаштыру, брикетлау, химик консервлау, сенаж һәм силос ясау кебек печән әзерләү алымнары эшләнеп гамәлгә кертелә.

Чыг.: Республика Татарстан. 1920–2000: Стат. сб. К., 2015; Сельское хозяйство Республики Татарстан в цифрах: Стат. сб. К., 2015.

Әд.: Томме М.Ф. Корма и рационы кормления сельскохозяйственных животных. М., 1969; Григорьев Н.В. Справочник по заготовке и приготовлению кормов. К., 1980; Маликов М.М. Система кормопроизводства в Республике Татарстан. К., 2002.

И.Н.Афанасьев.

«ТЕРЛЕ́К ТАУЛАРЫ́» («Швейцария»), ландшафтлы табигать истәлеге. Казан эченда, Казансу елгасының сулъяк ярында урнашкан. 1989 елда билгеләнә. Мәйданы 30 *га*. Идел буе террасасы биеклегендәге калдык калкулыклар, елгага төшүче тирән ерымнар б-н бүлгәләнгән. Болынлы дала участогы (чәчсыман кылган, типчак, Австрия һәм тигезлек әреме, яшел шартлавык чәчәк, дарулы әспе, аралаш яфраклы гентиана, төньяк тишмәнуты, арадаш кисәр үлән, ябышкак төнчәчәк һ.б.). ТРда күләгә сыражының бердәнбер популяция урыны. Фаунада — үр куяны, Европа керпесе, урман сусары, кошларның 26 дан артык төре, гади тузбаш, җитез кәлтә, яшел гөберле бака, очлы башлы бака.

ТЕРЛЕКЛӘРНЕ́ ДИСПАНСЕРИЗА́ЦИЯЛӘҮ, терлекләрнең сәламәтлеген саклау, продуктлылыгын күтәрү һәм югары продуктлы сәламәт көтүлекләр булдыруга юнәлдерелгән планлы вет. чаралары системасы. Т.д. елга ике тапкыр — язын һәм көзен үткәрелә. Бу эштә баш вет. табибе, адм. һәм зоотехник хезмәтләр вәкилләре катнаша. Терлекләрне аерым схема: гомуми габитус, темп-ра, пульс, сулыш алу, өске лимфа төеннәре халәте (тире, лайлалы тышчалар) буенча карап тикшерәләр. Кайбер очракларда махсус тикшерүләр (кан, бәвел, тәрәт анализы, электрокардиография һ.б.) кирәк була. Алынган мәгълүматларны анализлап, гомумиләштереп, а.х. терлекләре авыруларын кисәтү буенча күрсәтмәләр бирелә. Диспансеризация уздыру һәр ферма, терлекчелек комплексы, ясалма орлыкландыру станциясе һәм вет. авыруларын кисәтү учреждениесе өчен мәҗбүри итеп кулела. Районнарда Т.д.нең чиратын һәм вакытын районның баш вет. табибе билгели. Т.д. нигезләре 1960 елларда Казан вет. ин-тында эпизоотолог Х.Г.Гыйззәтуллин тарафыннан эшләнә.

М.Г.Сафин.

ТЕРЛЕКЧЕЛЕ́К, терлекчелек продукциясе: азык-төлек (сөт, ит, май, йомырка һ.б.), җиңел сәнәгать өчен чимал (йон, тире һ.б.) җитештерү өчен а.х. терлекләре үрчетү б-н шөгыльләнүче а.х. тармагы. Т. шулай ук халыкның, а.х. һәм сәнәгатнең җигүле көчкә (ат, мул, ишәк, як, дөя, болан һ.б.) булган ихтыяҗын да канәгатьләндерә. Татарстанда Т. *мөгезле эре терлек* (сөт, сөт-ит, ит юнәлеше) асрау, *дуңгыз асраучылык, сарык асраучылык,* кәҗә асраучылык, *ат асраучылык, кошчылык, балыкчылык, умартачылык,* куян асраучылык, *җәнлекчелек* тармакларын үз эченә ала.

1916 елга Казан губернасында терлекләрдән: атлар — 485,8 мең, мөгезле эре терлек — 609 мең, дуңгызлар — 373,2 мең, сарыклар һәм кәҗәләр 2418,9 мең баш исәпләнә. Бер кәстиян хуҗалыгына уртача 1,1 баш ат, 1,6 баш мөгезле эре терлек, 6,2 баш вак терлек туры килә. 1913–14 тә хуҗалыкларның үз терлек азыгы б-н тәэмин ителеш ихтыяҗы 26% ында — яртысыннан кимрәк, 40% ында яртысыннан аз гына күбрәк өлешен тәшкил итә. 1913 тә Казан губернасында 74 вет. табибе һәм 86 вет. фельдшеры исәпләнә. Терлек азыгы җитешмәү, вет. күзәтүе булмау, авыруларны кисәтү һәм үтә куркыныч йогышлы авыруларга каршы көрәш алып барылмау сәбәпле, терлекләрнең 13–25% ы төрле авыруларга дучар була. Түләмә, чума, котыру һәм атларда маңка авыруы аеруча еш очрый. Мал һәм кош-корт үләте ел саен меңнәр б-н исәпләнә.

Күмәкләшү елларында колхозларда яңа Т. фермалары төзелә. 1931 дә 7,8 мең башка исәпләнгән 93 товарлыклы-сөтчелек фермасы, 3 мең башка исәпләнгән 55 дуңгызчылык фермасы сафка баса. 1932 гә товарлыклы-сөтчелек фермалары саны 704 кә (баш саны — 64 меңгә), дуңгызчылык фермалары 329 га (баш саны — 24,4 меңгә) җитә. 1935 тә колхозларда 1052 товарлыклы-сөтчелек (терлекләр саны — 78,9 мең баш), 767 дуңгыз (63,4 мең баш), 904 сарык (144,9 мең баш) фермасы була. Совхозларда мөгезле эре терлек саны — 25,5 мең, дуңгызлар — 34,3 мең, сарыклар 19,5 мең башка җитә. 1920–30 елларда нәселле терлек совхозлары һәм фермалары, дәүләт нәселле терлек үрчетү хуҗалыклары барлыкка килә. 1932 гә мөгезле эре терлек, дуңгыз, сарык, ат асраучылык һәм кошчылык тармакларында төп максатлары аерым токымнарны камилләштерү һәм үрчетү булган 42 совхоз исәпләнә. Иң сыйфатлы терлекләр дәүләт нәсел китабына теркәлә. 1935 тә мөгезле эре терлекләрнең — 6, дуңгызларның — 9,2, сарыкларның 7% ы чиста токымлы була.

Сугыштан соң иҗтимагый секторда терлекләр саны кызу темплар б-н арта. 1950 дә барлык категорияләргә караган хуҗалыкларда 714,8 мең баш мөгезле эре терлек (ш.и. 331,7 мең баш сыер), 239,6 мең баш дуңгыз, 1 млн. 304,4 мең баш сарык һәм кәҗә исәпләнә. 1960–70 елларда Т.тә үсеш югары темплар б-н бара: 1966–70 тә (1960–65 б-н чагыштырганда) еллык уртача җитештерү ит буенча — 37, сөт буенча — 40, йомырка буенча — 54, йон буенча 8% ка арта. Т.тә җитештерү һәм продукция әзерләп чыгару күләме үсүгә терлекләрнең продуктлылыгын күтәрү һәм баш санын арттыру аркылы ирешелә.

1960–80 елларда нәсел үрчетү эшен камилләштерү һәм көтүне яңарту юнәлешендә чаралар күрелә: 1 респ-ка һәм 10 районара нәсел үрчетү берләшмәсе оештырыла. 120 нәсел үрчетү фермасы һәм хуҗалыгы булдырыла, селекция-нәсел үрчетү эше яхшыртыла. 1969 да барлык категория хуҗалыкларындагы (шәхси хуҗалыклардан кала) барлык терлекне токымлы терлекләр тәшкил итә (1954 тә токымлы терлекләр 76% була).

2017 ел башына барлык сыерларның 32,2% ы — Татарстан, 61,8% ы — кара-чуар, 5,8% ы — кызыл-чуар голштин, 0,2% ы — симменталь токымлы була.

Респ-када асрала торган дуңгызлар тулаем чиста токымлы, ш.и. элита — 36%, 1 нче класслы дуңгызлар — 47%, 2 нче класслылар 17% тәшкил итә. Ана дуңгызларның үрчемлелеге — бер ояга 10 баш. Бер ояның 2 айдагы



«Терлек таулары» ландшафтлы табигать истәлеге.

авырлыгы — 163 *кг*. Бонитировкаланган дуңгызларның чагыштырма өлеше: эре ак токым — 49,93%, эре ак (чит ил) токым — 50,06%, ландрас токымы — 0,01%.

Сарыклар шулай ук чиста токымлы. Көтүлекнең 68% ы — прекос, 6,2% ы — эдильбай, 3,4% ы — романов, 10,8% ы — алтай мериносы токымлы сарыклардан тора. Бер баш сарыктан уртача 2,6 *кг* йон кырыкып алына. Көтүлектәге сарыкларның 20% ы – элита, 42% ы — 1 нче класслы, 30% ы — 2 нче класслы.

1980 еллар башында респ-када Т. буенча иң югары күрсәткечләргә ирешелә: колхозлар, совхозлар, хуҗалыкара пр-тиеләрдә 1314 мең баш мөгезле эре терлек (ш.и. 409 мең баш сыер), 1 млн. баштан артык дуңгыз, 839 мең баш сарык, 82 мең баш ат, 86 мең баш куян, 6 млн.нан артык төрле кош-корт исәпләнә. 194 мең *т* ит (терлек һәм кошларның тереләй авырлыгы б-н), 932 мең *т* сөт, 515 млн. данә йомырка, 2 мең *т* йон җитештерелә һәм сатыла. 1 сыердан савылган сөт 2364 *кг*, 1 сарыктан кыркылган йон 2,7 *кг* тәшкил итә, 1 йомырка тавыгына 218 данә йомырка туры килә. Т.не индустриаль нигезгә күчерү буенча зур эш алып барыла: 90 эре Т. комплексы һәм механикалаштырылган ферма сафка баса, ш.и. 11 эре кошчылык, 30 сөтчелек ф-касы, 7 сарык асраучылык һәм 30 дуңгыз симертү комплексы һ.б.

2004 ел башына ТРда барлык категория хуҗалыкларында 1174,7 мең баш мөгезле эре терлек (ш.и. 469,3 мең баш сыер), 757,1 мең баш дуңгыз, 417,8 мең баш сарык һәм кәҗә, 56,4 мең баш ат, 6930 мең кош-корт исәпләнә.

2017 дә тереләй авырлыкта 378 мең *т* ит (ш.и. 98,1 мең *т* — сыер, 84,0 мең *т* — дуңгыз, 193,6 мең *т* кош ите), 1402,0 мең *т* сөт җитештерелә.

2017 дә ху җалык итүнең төрле формалары на караган коллектив пр-тиеләрдә (шәхси ху җалыклардан башка) 1 сыердан савылган сөт — 5446 *кг* тәшкил итә.

Әд.: Григорьев Н.З. Животноводство Татарии: опыт, проблемы, перспективы. К., 1976; Палкин Г.А., Герасимов И.С., Черношёв Н.Р. Достижения науки — в практику животноводства. К., 1982; Итоги селекционно-племенной работы хозяйств Республики Татарстан за 2001 год (итоги бонитировки). К., 2002; Ахметов И.В. и др. Современное состояние селекционно-племенной работы в хозяйствах Республики Татарстан и пути её улучшения (итоги бонитировки за 2015, 2016, 2017 годы). К., 2016; 2017; 2018.

Ә.Х.Фазылҗанов.

ТЕРЛЕКЧЕЛЕКТӘ ДЕЗИНФЕКТАНТЛА́Р, кешеләр һәм хайваннарда йогышлы авырулар китереп чыгаручыларга каршы кулланылучы физик һәм химик дезинфекция чаралары. Физик чараларны — ультрашәмәхә нурлар, объектка термик юл б-н тәэсир итү (кайнату, киптерү, коры кайнар һава, су пары б-н эшкәртү, кыздыру, яндыру һ.б.), химик чараларны — киң тәэсир итү спектрына ия, аз гына микъдарда да актив, суда яхшы эрүчән, микроб күзәнәгенә тиз үтеп керә һәм ныклап берегә торган төрле химик матдәләр (оксидлаштыручылар, кислота, селте, фенол, формальдегидлар) тәшкил итә. Ветеринариядә дезинфекция өчен күбрәк селтеләр: зәһәр натр (каустик сода), зәһәр калий, яндырылмаган известь, поташ, көл, каспос, «Демп», ш.у. хлорлы-водородлы к-та, хлорлы известь, кальций гипохлориды, гипохлор, бер хлорлы йод, хлорамин һ.б. кулланыла.

Феноллы препаратларга кристаллик карбол к-тасы, юеш крезол, нафтализол, ксилонафт-5, креолин, күкерт-карбол катнашмасы, дегет һ.б. керә, ләкин көчле исле булулары һәм әз калдырулары сәбәпле, аларның кулланылышы шактый чикләнә. Эремә (формалин) һәм парсыман халәттәге формальдегид күп төрле авырулар вакытында бүлмәләрне, әйберләрне дезинфекцияләү өчен һәм дезинфекция камераларында кулланыла.

1969–2000 елларда Бөтенроссия фән-ни-тикшеренү вет. ин-тында натрий фенолятлары, феносмолин, сульфат-формиат эремәсе, техник натрий гипохлориды, йодохлорин дезинфектантлары эшләнә (Х.Х.Абдуллин, Г.З.Равилов, А.С.Селиванова, В.С.Угрюмова, Г.Р.Йосыпова).

Р.Х.Йосыпов.

«ТЕРМИНА́Л», радиоэлектроника сәнәгате пр-тиесе. 1924 елның декабрендә Казан язу машиналары механик остаханәсе «Татязмаш» буларак нигезләнә (5 тән алып 14 кә кадәр кеше эшли). Баштарак анда язу һәм санау машиналары, касса аппаратлары төзәтү б-н шөгыльләнәләр; 1926 да шрифтлар штамплау һәм махсус хәрәкәтләндерү механизмнарын әзерләү җайга салынып, чит илдә җитештерелгән *язу машиналары* җирлегендә гарәп графикасындагы татар шрифтлары куелган машиналар чыгарыла башлый (1929 га 150 ләп машина эшләнә). 1929 да остаханәдә, СССРда беренче тапкыр, барлык деталь һәм конструкцияләре үзенеке булган һәм латин графикасы нигезендәге татар шрифты куелган «Яңалиф» язу машиналары эшләнә. 1930 ның декабрендә остаханә җирлегендә аларны сериялә чыгару максатында Казан язу машиналары ф-касы (1931 дән — з-д) оештырыла. 1931–39 да җитештерүнең еллык күләме 139 дан 5750 данәгә җиткерелә, барысы 30 мең тирәсе язу машинасы эшләп чыгарыла (СССРда җитештерелгән шундый продукциянең 40% ы). Машиналар СССР халыкларының 44 теле шрифтлары б-н җитештерелә, 1935 тән Төркия, Монголия, Кытай һ.б. илләр өчен әзерләнә. 1940 та завод кириллица шрифты куелган «Прогресс» язу машиналарын чыгаруга күчә (1950 гә 100 мең машина чыгарыла). 1950 елларда «Волга», «Казан» маркалы яңа машиналар үзләштерелә. 1959 да заводка Казан язу җайланмалары з-ды исеме бирелә. 1960 елларда мәгълүматларны эшкәртү нәтиҗәләрен график рәвештә язу өчен ике координаталы теркәү приборларын (СССРда беренче тапкыр), тиз баса торган ТБПМ 16/1200 типлаштырылган машинасы, КУ-1М клавишлар җайланмасын чыгару җайга салына. 1963 тә пр-тие Казан ЭВМ язу җайланмалары з-ды дип атала башлый, 1968 дән тулысынча хисаплау техникасы өчен периферик җайланмалар эшләүгә күчә. 1970 елларда кече габаритлы язу җайланмалары, планшет тибындагы график төзегечләр үзләштерелә. Продукция Һиндстанга, Голландия, Бөекбритания, Норвегиягә, Көнчыгыш Европа илләренә чыгарыла. 1981 дә яңа техника төзүдә махсус йөкләмәләрне уңышлы үтәгәне өчен Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә. 1989 да аның җирлегендә Казан «Т.» ҖБ оештырыла, берләшмәгә Казан хисаплау техникасы чаралары з-ды да (1978 дә нигез салынган) кертелә; эшләүчеләр саны 3 меңнән артып китә. 1980 елларда — 1990 еллар башында төрле класслы ЭВМнар өчен яңа терминал җайланмаларын, прецензион механикага һәм электроникага нигезләнгән көчәйтү-акустика җайланмаларын, рулонлы график төзегечләр (плоттерлар), киң басу (язу) җайланмаларын булдыру һәм сериялә җитештерүгә кертү эшләре алып барыла. Конверсия кысаларында банк техникасы, стоматология җиһазлары, транспорт чараларын оператив эзләү һәм тоткарлау өчен радиокомплекслар, ш.у. халык кулланулы товарлары сериялә җитештерүгә әзерләп кертелә. 1994 тә «Т.» ҖБ *Казан хисаплау системалары җитештерү берләшмәсе* б-н берлектә Казан «Т.» хисаплау техникасы чаралары ҖБ итеп берләштерелә (2001 дә банкрот дип таныла һәм ябыла).

Күп кенә хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә лаек була, ш.и. 1 кешегә — Соц. Хезмәт Герое, 5 кешегә — ТССР, РФнең төрле халык ху җалыгы тармакларының атказ. хезмәткәре исеме, 3 кешегә СССР Дәүләт бүләге бирелә.

Җитәкчеләр: Г.Д.*Шәехгали* (1924–30), И.А.Жирнов (1930–32), Ф.Н.Меркулов (1932–35), А.Н.Кулалаев (1935–36, 1947–50), Усманов (1936–37), Г.А.*Елизаров* (1938–41, 1944–46), Х.Х.Искәндәров (1941–42), А.Таҗетдинов (1943–44), Г.А.Батыршин (1944), А.П.Шерстобитов (1946–47), В.А.Кондратьев (1950–51), А.П.Павлов (1951–59), Б.Е.Кустовский (1959–60), Н.П.Шевченко (1960–62), Н.С.*Якубов* (1962–87), М.А.Рәимов (1987–94).

Әд.: Кушаев Г.А., Урманчеев А.А. Краткая история Казанского завода пишущих устройств. 1928–39 гг. К., 1940; Уткин М. Люди одной судьбы. Очерки истории Казанского ордена Трудового Красного Знамени завода пишущих устройств и о его людях. К., 1991.

М.Ш.Бәдретдинова, С.Г.Белов.

ТЕРМИНОЛО́ГИК СҮЗЛЕКЛӘ́Р, фән, техника, сәнгать һ.б. өлкәләрдә терминнарны тәртипкә салу, унификацияләү максатыннан чыгып төзелгән сүзлекләр төре. Татар тел белемендә Т.с. төзүгә К.Насыйри нигез сала, аның тарафыннан математикадан («Хисаплык», 1873), географиядән («Истилях әт-җәгърафия», 1890), ботаникадан («Гөлзар вә чәмәнзар, ягъни үләнлек вә чәчәклек», 1894) һ.б. сүзлекләр төзелә. Татар телендә Т.с. төзү 20 йөздә аеруча активлаша. Аерым фәннәр буенча Т.с. басылып чыга: сәясәт (1918; 7 басма, 1995; 8 басма, 1997), хокук (1927; 3 басма, 1996), физика (1927; 4 басма, 1972; 5 басма, 1994), физика-техника (2014), мед. (1929, 1994, 2004, 2009, 2011), химия (1931; 3 басма, 1978, 2002), матем. (1935, 1972, 1997), а.х. (1939, 1950; 3 басма, 1971), пед. (1950), психол. (1985), геогр. (1953, 1977, 2010), тел белеме (1953, 1998, 2016), әдәбият белеме (1958, 1990, 2007), икътисад (1972, 1996, 1999), биол. һәм табигать белеме (1935,

1966, 1972, 1997), астрономия (1974), төзелеш (1992), гигиена (1999), агрохимия һәм туфрак белеме (2003), агроэкология (2008), вет. медицинасы (2004), нефть сәнәгате (2004), компьютер (2015), политехника (2016) б-н бәйле терминология һ.б. Ш.у.к. *Терминология.*

Әд.: Татар терминнарын төзү, камилләштерү һәм куллану кагыйдәләре. К., 1995; Миңнуллин К.М., Вәлиуллин Р.Н. Татар теле — сүзлекләрдә (1992–2005 еллар): Библиогр. күрсәткеч. К., 2005. *Д.Б.Рамазанова.*

ТЕРМИНОЛО́ГИЯ (лат. terminus — чик һәм *...логия*), 1) тел белемендә фән, техника, җитештерү, сәнгать төрләре, иҗтимагый эшчәнлек һ.б. өлкәләргә караган терминнар җыелмасы; 2) тел белеменең терминнарны өйрәнә торган тармагы. Тел белеме һәм географиягә караган терминнар системасын тәкъдим иткән беренче татар галиме — Х.Фәезханов. Татар Т.сенең фән буларак формалашуы К.Насыйри хезмәтләре б-н бәйле. Ул татар терминнары ясалышының төп принципларын һәм чыганакларын билгели, матем., геогр., ботаника һ.б. фәннәр буенча фәнни терминнар эшли. К.Насыйри үзенең «Рус хоруфы һи җәсы үзрә мөрәттәб лөгать китабы» («Рус телендә фәнни термин буларак кулланылучы чит телдән кергән сүзләр өстәлеп эшләнгән русча-татарча тулы сүзлек», 1904) хезмәтендә гарәп-фарсы чыгышлы терминнарны татар терминнары б-н алыштыру мәсьәләсен күтәрә. 1920 елларда ТАССР Мәгариф халык комис-ты каршында фәнни үзәк оеша, анда Терминология комиссиясе эшли. Комиссия җитәкчелегендә авыл хуҗалыгы, физика, медицина, хәрби, сәясәт һ.б. фән тармаклары буенча сүзлекләр (тармак сүзлекләре) төзелә. Татар телендә «термин» сүзе 1930 елларда кулланыла башлый (аңарчы «истилях» һәм «атама» төшенчәләре кулланылышта була). Татар терминнарын төзү тарихы һәм татар Т.сенең теоретик нигезләре Г.Г.Ибраһимов, Ш.Г.Рамазанов, Ф.С.Фасиев, М.Ә.Сәгыйтов һ.б.ның хезмәтләрендә яктыртыла. Сүзләрнең тематик төркемнәргә бүленеше һәм төрле тармакларга караган терминнар М.З.Зәкиев, И.М.Низамов, Р.Г.Юсупов, Ф.Ә.Ганиев, Р.К.Рәхимова, Р.Г.Әхмәтьянов, Ф.Ф.Гаффарова, Ф.С.Баязитова, Д.Б.Рамазанова, Т.К.Хәйретдинова, З.Р.Садыйкова, Г.Г.Саберова һ.б.ның хезмәтләрендә өйрәнелә. 1994 тә ТР МК каршында «*Татарстан Республикасы халыклары телләре турында*» *ТР Законын гамәлгә ашыру комитеты* тарафыннан Терминология комиссиясе төзелә. Ул дәреслекләр, ярдәмлекләр, сүзлекләр төзү, терминнарны унификацияләү һ.б. мәсьәләләр б-н шөгыльләнә. 2008 дән бу эшне ТР телләре турындагы законнарны гамәлгә ашыру советы дәвам итә. Фәннең төрле тармакларына караган татар терминнары *терминологик сүзлекләрдә* чагылыш таба.

Әд.: Фасеев Ф.С. Татар телендә терминология нигезләре. К., 1969; Зәкиев М.З., Низамов И.М. Терминология комиссиясе: Кичә һәм бүген // Проблемы лексикологии и терминологии. К., 1994; Әхмәтьянов Р.Г. Татар терминологиясенең тарихи чыганаклары. К., 2003; Зәкиев М.З. Татар терминнары ясалу һәм аларны төркемләү // Фәнни Татарстан. К., 2015, № 2; Рамазанова Д.Б. О терминологической работе в Республике Татарстан в 90-х годах // Проблемы совершенствования терминологии татарского языка: Материалы науч.-практ. конф. К., 2006. *Д.Б.Рамазанова.*

ТЕРНО́ВСКИЙ Василий Николаевич (25.7.1888, Ташкент — 15.9.1976, Мәскәү), анатом, мед. фән. д-ры (1922), СССР МФА академигы (1944), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1958). Мәскәү ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1915), шунда ук, госпиталь хирургиясе клиникасында проф. А.В.Мартынов кул астында эшли; 1920–24 елларда 1 нче Мәскәү ун-тының анатомия кафедрасында. Беренче бөтендөнья сугышы елларында (1915–17) Көнбатыш фронтта Кызыл Хачның 38 нче алгы позиция хирургия отряды кече табиб-хирургы. 1924–44 тә Казан ун-тының (1930 дан Казан мед. ин-ты-ның) нормаль анатомия каф. мөдире, проф. (1935). 1945 тән 2 нче Мәскәү мед. ин-тының нормаль анатомия каф. мөдире, бер үк вакытта (1950 гә кадәр), СССР МФАнең Нормаль һәм патологик морфология ин-тының анатомия бүлеген җитәкли. Хезмәтләре вегетатив нерв системасы морфологиясенә, анатомия тарихына карый. Типлаштырылган анатомия тәгълиматына нигез салучы. Әбүгалисина, А.Везалийның рус телендәге беренче басмалары мөхәррире. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Лечение диатермией хирургических заболеваний // Клиническая медицина. 1924. № 8; Вегетативная нервная система и её патология. М.–Л., 1925 (автордаш); Руководство к практическим занятиям по анатомии (мышцы, связки и внутренности). М., 1948.

Әд.: Профессор Василий Николаевич Терновский (к 80-летию со дня рождения) // Казан. мед. журн. 1968. № 4; Валишин Э.С. Василий Николаевич Терновский. К., 1989.

ТЕРНО́ВСКИЙ Сергей Алексеевич (8.8.1847, Мәскәү — 4.2.1916, Казан), язучы, православие теологы, чиркәү тарихы д-ры (1899), проф. (1899). Руханилар гаиләсеннән. Киев руханилар семинариясен (1867), Киев руханилар академиясен (1871) тәмамлый. 1871–73 елларда руханилар карамагындагы Киев кызлар уч-щесендә — география, бер үк вакытта Киев руханилар семинариясендә дөньяви тарих укыта. 1873–1911 дә Казан руханилар академиясендә: чиркәү-тарих бүлегенең борынгы чиркәү тарихы каф. приват-доценты, доценты (1884 кә кадәр), яһүд теле һәм Библия археологиясе каф. доценты, профессоры (1884–1911). 1872 дә зур күләмле кереш б-н Киев митрополиясенең Мәскәү патриархатына буйсынуы турындагы тикшеренүләрдән торган 17 йөз истәлеге — «Икона»ны бастырып чыгара («Архив Юго-Западной России», Киев, 1872, 1 кис., 5 т.), шуның өчен 1873 тә православие теологиясе магистры дәрәҗәсен алуга ирешә. Абыйсы Филипп Алексеевич б-н берлектә язылган «Христианлыкның беренче өч гасырлары» («Три первые века христианства», Киев, 1878) хезмәте өчен сафсата таратуда гаепләнә һәм, протестантлыкка теләктәшлектә шикләнелеп, яшерен күзәтү астына алына; абыйсы Киев руханилар академиясеннән һәм Киев ун-тыннан куыла (тиздән вафат була). Т.ны Казан архиепископы *Палладий* яклап чыга. Т. 1885–89 да, 1897–1904 тә һәм 1907–13 тә *«Православный собеседник»* акад. ж-лында редакция эшләре бүлеге мөдире, мөхәррир булып эшли. 1893–94 тә Иерусалимда фәнни командировкада була, «Библия археологиясенең кыскача очеркы» («Краткий очерк библийской археологии», М., 1896) хезмәте — шуның нәтиҗәсе. Хезмәтләре чиркәү тарихына һәм Библия археологиясенә карый. Киев Елъязмачы Нестор тарих җәмгыятенең һәм Киев археография комиссиясенең хакыйкый әгъзасы (1872), Казан (1911) һәм Киев (1915) руханилар академияләренең шәрәфле әгъзасы. Палестина җәмгыятенең гомерлек хакыйкый әгъзасы (1902). 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә Изге Анна, 4 нче дәрәҗә Изге Владимир, 1, 2, 3 нче дәрәҗә Изге Станислав орденнары б-н бүләкләнә.

Хезм.: Русская и иностранная библиография по истории Византийской церкви IV–IX вв. Киев, 1885; Праздник кущей у евреев. К., 1890; Историческая записка о состоянии Казанской духовной академии после её преобразования. 1870–1892. К., 1892.

Әд.: Полянский Е.Я. Профессор Сергей Алексеевич Терновский. К., 1916.

М.З.Хәбибуллин.

ТЕРПЕЛЕ́ елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Сөн (Агыйдел елгасы бассейны) елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 23,8 *км*. Бассейнының мәйданы 156 *км*². Актаныш р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Киров авылыннан 5 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы Ахун авылыннан төньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 140 *м*, тамагыныкы — 71 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 15%. Т.нең 1,5 *км* дан 2 *км* га кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,17 *км/км*². Туеную катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Коры елларда елганың аерым урыннары кибә. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 52 *мм*, ташу агымы катламы 50 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче көннәрендә башлана. Елга октябрь ахыры — ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,01 *м*³/с. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 500–700 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. Т. бассейнында суының гомуми күләме 1,1 млн. *м*³ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

ТЕРПЕЛЕ́ посёлогы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 27 *км* көньяк-көнбатыш-тарак, Терпеле елгасы буенда. 2010 елда 39 кеше (марилар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Башта асабалар яши, 1750 дә бу җирләр мари-тип тәрләргә арендага бирелә. Халкы игенчелек, терлекчелек, умартачылык, чабата үрү б-н шөгыльләнә. 1773–75 еллардагы Крәстиян-нәр кузгалышында Е.И.Пугачёв ягында сугышалар. 20 йөз башында Т.дә бакалея һәм шә-

раб кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 830 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Байсар волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 69 кеше; 1816 да — 46, 1834 тә — 88 ир-ат; 1859 да — 203, 1870 тә — 231, 1884 тә — 318, 1906 да — 308, 1913 тә — 314, 1920 дә — 321, 1926 да — 117, 1938 дә — 191, 1949 да — 120, 1958 дә — 128, 1970 тә — 131, 1979 да — 114, 1989 да — 50, 2002 дә — 51 кеше.

ТЕРРА́САЛАР (лат. terra — җир), рельеф формалары, елга үзәннәре сөзәкләкләрендә, күл һәм диңгез ярларында аз гына авыш яткан мәйданчыклар. Т. составында ш.у. Т. киртләчен — су агымы ягына таба бернидәр текә яр (аның бөгелешен яр кашы дип йөртәләр) һәм эчке җөй — Т.ның рельефның югарыдарак урнашкан башка элементлары б-н тоташу урыннарын билгелиләр. Татарстан терр-ясендә елга (эрозияле-аккумулятив) һәм структур Т. киң үсеш алган, ара-тирә күл Т.ы очрый. Елга Т.ы барлык елга үзәннәрендә дә бар; аларның саны 1–2 дән 5–6 га кадәр җитә, ТР терр-ясенең 19–20% ын тәшкил итә. Елга Т.ы аеруча Идел, Кама, Ык, Зәй, Чишмә, Зөя елгалары үзәннәрендә үсеш алган. Тугайга нисбәттә нинди биеклектә урнашуына карап, түбән (1 нче, 2 нче) һәм югары (калганнары) тугай өсте Т.ына аералар, болары — элеккеге тугайлар. Эрозия базисы түбәнәйгәндә һәм елга тарафыннан тигезлекнең яңа профиле ясалганда елга юлы җир кабыгын ерып керә һәм, нәтиҗәдә, тугайлар үзгәреп, Т. хасил була. Экстремаль көчле су ташулар вакытында түбән тугай өсте Т.ы кыска вакытка су астында калырга мөмкин. Иң борынгы һәм югары елга Т.ы 1 млн. ел чамасы элек формалашкан. Кагыйдә буларак, аларның морфологик чагылышы сизелер-сизелмәс кенә, Т. бары тик елга утырмалары буенча гына билгеләнә. Сусаклагыч сулары астында калганга кадәр, зур елгалардагы иң борынгы Т.ның биеклеге суның иң аз вакытындагы биеклеге б-н чагыштырганда 75–95 *м* га җитә. Елга Т.ының киңлеге — кече елгаларда берничә дистә метрдан Идел һәм Кама елгаларында 20–40 *км* га кадәр. Югары Т.ның өслеге, гадәттә, төрле процесслар: ерым эрозиясе, карст, эол б-н бүлгәләнгән. Елга Т.ы мөстәкыйль аллювиаль свита төзүче елга юлы, тугай һәм елганың элекке юлы фацияләре утырмаларының законча-лыклы тезмәсен тудыручы аллювийдан тора. Кайвакыт Т. 3 нче һәм 4 нче тугай өсте Т.ына аеруча хас булган бер-берсенә ятучы ике свитадан тора. Кайбер аллювиаль свиталар төрле чыгышлы (делювиаль, пролювиаль һ.б.) яшьрәк утырмалар б-н капланган. Елга юлы утырмалары — чуерташ-вакташ, вакташ-ком-су материалдан, тугай һәм елганың элекке юлы утырмалары комсыл балчык һәм балчыктан тора. Структур Т. денудация процессларына тотрыклы известьташ һәм доломит пластлары чыгышларыннан барлыкка килгән һәм *Бөгелмә яссы калкулыгында* киң таралган. Күл Т. аз үсеш алган, аларның биеклеге 0,5–1 *м* дан артмый, бу күл казанлыкларының яшь булуы б-н аңлатыла (күлләрнең күбесе тугайда урнашкан). Идел һәм Кама елгаларының Т.ында Татарстанның зур шәһәрләре — Казан, Чаллы, Түбән Кама, Яшел Үзән урнашкан, комсу утырмаларда югары продукцияле нарат урманнары сакланган.

Әд.: Дедков А.П. Экзогенное рельефообразование в Казанско-Ульяновском Поволжье. К., 1970; Озёра Среднего Поволжья. М., 1976; Бутаков Г.П. Плейстоценовый перигляциал на востоке Русской равнины. К., 1986; Ландшафты Республики Татарстан: Регион. ланшафтно-экол. анализ. К., 2007. *В.И.Мозжерин.*

ТЕТВЕ́ЛЬ елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Кичү елгасының (Чишмә елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 16,3 *км*. Бассейнының мәйданы 81,1 *км*^{2}. Түбән Кама терр-ясеннән ага. Елга башы Тетвель авылыннан 8 *км* төньяк-көнчыгыштарак, тамагы Благодатский авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 165 *м*, тамагыныкы — 72 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 45%. Т.нең 1 дән 10,8 *км* га кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар, иң зурысы — Иске елгасы. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,36 *км*/*км*^{2}. Туенуы катнаш, өчтән ике өлеше кар сулары исәбенә туры килә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1–3 *л*/*с*·*км*^{2}. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 110 *мм*, ташу агымы катламы 69 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,115 *м*^{3}/*с*. Язын суы каты (3–6 *мг-экв*/*л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв*/*л*). Гомуми минеральләшүе язын 300–400 *мг*/*л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг*/*л*.

ТЕТВЕ́ЛЬ авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 26 *км* көньяк-көнбатыштарак, Лениногорск–Азнакай автомобиль юлы буенда. 2010 елда 30 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — нефть-газ чыгару. 19 йөз башында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 1777 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Микулин волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1889 да — 207, 1897 дә — 447, 1910 да — 557, 1920 дә — 682, 1926 да — 292, 1938 дә — 487, 1949 да — 365, 1958 дә — 302, 1970 тә — 183, 1979 да — 175, 1989 да — 63, 2002 дә — 36 кеше.

ТЕТВЕ́ЛЬ авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 73 *км* көньяктарак, Тетвель елгасы буенда. 2010 елда 87 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кыр-чылык, сарык һәм иткә терлек асрау. 18 йөз уртасына кадәр нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.дә Александр Невский чиркәве, земство мәктәбе (1887 дә ачыла), тегермән, 1 казна шәраб һәм 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1280 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Зирекле волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Яңа Чишмә, 1944 нең 19 февраленнән — Ямаш, 1956 ның 7 декабреннән — Яңа Чишмә, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1983 нең 26 апреленнән Яңа Чишмә, 1984 нең 3 июленнән — Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1859 да — 639, 1897 дә — 1087, 1908 дә — 1105, 1920 дә — 1172, 1926 да — 822, 1938 дә — 773, 1949 да — 636, 1958 дә — 511, 1970 тә — 405, 1979 да — 248, 1989 да — 150, 2002 дә — 111 кеше.

ТЕТЕ́ЕВО (Тәти) авылы, Лаеш р-нында, Казан тимер юл станциясеннән 49 *км* көньяктарак, Куйбышев сусаклагычы ярында урнашкан. 2010 елда 113 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Клуб. 1646 дан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Ильинка исеме б-н дә билгеле. Халкы башта Казан Спас-Преображение монастырена карый, 1764 тә — экономик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә; игенчелек, терлекчелек, бакчачылык, балык тоту, тимерчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Илия чиркәве (1764 тә төзелә), чиркәү-приход мәктәбе (1885 тә ачыла), Халыкта аек яшәү рәвеше тәрбияләүче уку өе, су һәм җил тегермәне, тимерче алачыгы, 1 мануфактура һәм 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1955 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Әстерхан волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 107, 1859 да — 312 ир-ат; 1897 дә — 985, 1908 дә — 1179, 1920 дә — 1195, 1926 да — 1405, 1938 дә — 934, 1949 да — 734, 1958 дә — 643, 1970 тә — 352, 1979 да — 259, 1989 да — 201, 2002 дә — 136 кеше.

ТЕТЁРКИН Николай Степанович (28.7.1924, Ленинград өлкәсенең Череповец р-ны Кече Липенка а. — 9.2.2003, Казан), спортчы, тренер (байдаркада һәм каноэда ишү), СССРның спорт остасы (1951), РСФСРның атказ. тренеры (1960). 1947–48 елларда киез итек басу-фетр ф-касында мастер-комплектлаучы (Казан), 1948–57 дә ТАССР Эчке эшләр министрлыгының Янгыннан саклау идарәсе хезмәткәре. Спорт б-н 1948 дә шөгыльләнә башлый, «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятенең Татарстан респ-ка советында тәрбияләнә, тренеры — А.Ф.Вялимаа. РСФСР (1948–58), СССР (1953), РСФСР халыклары спартакиадасы (1956), СССР (1956) чемпионы; 5 нче Халыкара яшьләр фестивалендә (1952), СССР чемпионатларында (1950–52, 1954–55) көмеш медаль, Европа (1957), СССР (1951), РСФСР (1954) чемпи-

онатларында бронза медаль ала. Олимпия уеннарында катнаша (1952, 10 мең *м*). Бер үк вакытта, 1954–57 дә, ТАССР МСның Физик культура һәм спорт ком-ты тренеры. 1957–62 дә СССР җыелма командасында тренер; 1962–94 тә Респ-ка югары спорт осталыгы мәктәбендә өлкән тренер (Казан), 1994 тән ТРның Физик культура, спорт һәм туризм дәүләт ком-тының спортның су төрләре буенча Үзәк спорт клубында баш белгеч. 30 СССР спорт остасын, 5 халыкара класслы спорт остасын, шулай ук РСФСР, «Динамо» үзәк советы, СССР чемпионатларының, РСФСР, СССР халыклары спартакиадаларының, халыкара регаталарының чемпионнары һәм призёрлары М.К.Герасимов, А.А.Захаров, Ю.П.Корнилов, А.П.Лукоянов, Ф.Г.Сәләховны әзерли. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

ТЕ́ХНИК КИБЕРНЕ́ТИКА, фән тармагы; кибернетика (грекча kybernētiké — идарә итү сәнгате) идеяләре һәм алымнары нигезендә техник идарә системаларын комплексы автоматлаштыруның фәнни нигезен тәшкил итә. Т.к.ның төп бурычы — нәтиҗәле эшләвен һәм сыйфат күрсәткечләрен тулысынча тәэмин итү максатында катлаулы фәнни объектларны идарә итү системаларының техник һәм технологик характеристикаларын оптимальләштерү. Т.к. тикшеренүләренең төп юнәлешләре катлаулы объектлар б-н идарә итүнең автомат һәм автоматлаштырылган системаларын булдыра торган; мәгълүмат тапшыру, аны эшкәртү һәм саклау өчен автомат җайланмалар һәм комплексларның төгәл эшләвен, катлаулы техник системаларның ышанычлылыгын һәм аларга даими тикшерү уздыруны тәэмин итә торган теория һәм алымнарны үстерүдән гыйбарәт. Т.к.да кулланыла торган төп математик төшенчәләр аппараты — дифференциаль тигезләмәләр теориясе, функциональ анализ, үзгәрешле исәпләү, матем. программалаштыру, графлар теориясе, матем. логика, ихтималлык теориясе, оптимальләштерү теориясе. Т.к. тикшеренүләре нәтиҗәләре аэро һәм ракеталар динамикасы мәсь әләләрендә, очкыч аппаратлар б-н идарә итү системаларын проектлаштыру, төрле өлкәләргә караган катлаулы техн нол. процесслар б-н автоматлаштырылган комплексы идарә итү системаларын төзүдә, җитештерү һәм икътисад системаларын модельләштерүдә, җитештерүне комплексы автоматлаштыруда кулланыла.

Татарстан галимнәре Т.к. теориясен һәм практикасын үстерүгә зур өлеш кертәләр. 1940 елларда Казан ун-тында һәм Казан авиация ин-тында (хәзер Казан техник ун-ты) бу фәннең төрле өлкәләрендә тикшеренүләр башлана. Н.Г.Четаевның аналитик механика һәм хәрәкәтнең тотрыклылыгы теориясе буенча фундаменталь хезмәтләре Т.к.ның төрле гамәли мәсь әләләрендә кулланыла. Аның механиканың вариатив принципларын үстерүгә һәм берләштерүгә, төркемле үзгәрешләләр б-н бирелгән системалар динамикасына караган классик тикшеренүләре катлаулы техник системалар төзүдә кулланылыш таба (Ленин бүләге, 1960). Г.С.Галиуллин программалаштырылган хәрәкәт системаларын аналитик төзү нигезләрен эшли, Ляпунов функцияләре алымын кулланып, дифференциаль тигезләмәләр теориясенең кире мәсь әләләрен чишә һәм идарә ителүле объектлар хәрәкәтенең тотрыклылыгын тикшерә.

1960 елларда Казан авиация ин-тының аэродинамика кафедрасында Н.В.Куршев җитәкчелегендә оптималь процесслар теориясе, катлаулы техник системаларны аналитик проектлаштыру буенча тикшеренүләр башлана, алар Ю.В.Кожевников, В.Г.Павлов, Т.К.Сира җитдинов хезмәтләрендә тагын да үстерелә. Автоматлаштырылган идарәнең нәсызыкча системалары тотрыклылыгын һәм аларны синтезлауны тикшерү барышында И.И.Әхмәтгалиев асимметрик төрле яклы бәйләнешләре булган ике каналлы системалар теориясен эшли. В.М.Матросов җитәкчелегендә векторлы функцияләрнең матем. аппараты эшләнә, процесслар һәм системаларның динамик үзлекләре тотрыклылыгын тикшерү өчен чагыштыру принцибы тәкъдим ителә. Әлеге алымнар стратосфера астрономия обсерваторияләренең һәм күп кенә башка космик системаларның тотрыклылыгын өйрәнүдә һәм аны тәэмин итүдә (СССР Дәүләт бүләге, 1984), конкрет космик системалар б-н идарә итү буенча илнең әйдәп баручы КБ һәм ФҖБдә гамәлгә кертелгән алгоритмнар төзүдә кулланыла.

Т.К.Сиражетдинов җитәкчелегендә бүленгән параметрлы системаларны оптимальләштерү теориясенә һәм аны төрле процесслар б-н идарә итүдә куллануга караган тикшеренүләр үткәрелә; катлаулы техник системаларны аналитик проектлаштыру тикшерелә. Алынган нәтиҗәләр космик аппаратлар б-н идарә итү алгоритмнарын төзүдә, космос өчен адаптив оптик-электрон приборлар һәм системалар җитештерүдә кулланыла (А.А.Балоев, А.И.Богомолов, Г.Л.Дегтярёв, В.Н.Куршев).

Ю.В.Кожевников очраклы үзлекләргә ия булган процесс һәм системаларны оптимальләштерү буенча фәнни юнәлешләргә нигез сала; күп режимлы һәм күп максатлы катлаулы идарә системаларын проектлаштыру һәм карарлар кабул итүне автоматлаштыру алымнарын эшли; очкыч аппаратларны статистик оптимальләштерүгә караган тикшеренүләр үткәрә. Аның шәкертләре тарафыннан: объектларны сынауның автоматлаштырылган системалары теориясе нигезләре; авиация җитештерүенең автоматлаштырылган идарә системасы (АСУ) шартларында оптималь карарлар кабул итү алымнары; авиация двигательләрен автоматлаштырылган комплексы тикшерү системалары (КАСКАД) эшләнә һәм авиация сәнәгате пр-тиеләрендә гамәлгә кертелә (Р.И.Әдһәмов, С.В.Дмитриев, В.С.Моисеев, Н.Е.Роднищев, Ә.Х.Хәйруллин). Хезмәт процесслары на техник диагностика һәм ракета двигательләрен эксплуатацияләгәндә авария очрагын алдан ачыклау системасын булдыру өлкәсендә тикшеренүләр үткәрелә (Р.Г.Гафуров). НК-8–2У авиация двигательләренең ышанычлылыгын җитештерү барышында ук тәэмин итүнең теоретик һәм конструктив нигезләре һәм концепциясе эшләнә (М.Г.Хәбибуллин).

Казан ун-ты каршындагы Н.Г.Чеботарёв исем. Математика һәм механика ин-тында тотрыклылык теориясенең (К.П.Персидский, И.Г.Малкин), вибрация теориясенең (Н.Н.Парфентьев) гомуми проблемалары тикшерелә; агым б-н идарә итү җайланмалары булган аэродинамик профильләр төзү һәм аларның формаларын оптимальләштерү мәсь әләләре хәл ителә (Н.Б.Ильинский).

Очкыч аппаратларның катлаулы техник системаларындагы, оптик-механик конструкцияләрдәге сүрүләр һәм пластиналарның ныклыгы, тотрыклылыгы һәм тирбәнешләрнә караган гамәли мәсь әләләрне чишү юллары эшләнә (Ю.Г.Коноплёв). Матем. сызыкча, квазикабарынкы программалаштыру буенча тикшеренүләргә нигезләп, автоматлаштырылган идарәдә матем. алымнар тәкъдим ителә (Я.И.Заботин). Ихтималлык теориясе һәм матем. статистика теориясенә караган тикшеренүләр катлаулы техник системалар төзегәндә кулланылыш таба (И.Н.Володин). Т.к.да информатика куллану б-н бәйле мәсь әләләр Р.Г.Бохараев тарафыннан үстерелә. Ул ихтималый процесслар — ихтималый машиналар сериясенең прототибын эшли, СССРда беренче булып ихтималый автомат төшенчәсен кертә, аның анализы һәм синтезының төп теоретик мәсь әләләрен тикшерә, компьютер лингвистикасы һәм ясалма интеллектны үстерү проблемаларын өйрәнә.

РФА КГҮнең Механика һәм машиналар төзү ин-тында юка стеналы конструкцияләрнең нәсызыкча механикасы теориясе (Х.М.Мөштәри), гидроаэросыгылма һәм дулкынлы система теориясе буенча фундаменталь тикшеренүләр үткәрелә һәм алар очкыч аппаратлар, көч бирү җайланмалары, парашют системалары һ.б. б-н идарә итүче катлаулы техник системаларны модельләштерүдә һәм төзүдә кулланылыш таба (М.Ә.Ил һамов, Ә.Н.Гыйльманов, Ж.Н.Сәхәбетдинов һ.б.). Очраклы структур үзгәрешләр б-н нәсызыкча идарә итү системаларының тотрыклылыгын тикшерү өчен А.М.Ляпуновның векторлы функцияләр алымы тагын да үстерелә (А.И.Маликов). ТР ФАнең Информатика проблемалары ин-тында нәклассик логика алгебрасы нигезендә интеллектуаль мәгълүмат системалары төзүнең теоретик нигезләре эшләнә, һәм алар Т.к.ның гамәли мәсь әләләрендә кулланыш таба. Хисаплау техникасын халык хуҗалыгында гамәлгә кертү ин-ты коллективы тарафыннан сәнәгать пр-тиеләрендә автоматлаштырылган идарә системалары (АСУ) өчен программа һәм техника комплекслары, аерым алганда, сериялап җитештерү пр-тиеләрендәге АСУлар өчен «Җитештерү белән идарә итүнең мәгълүмати системасы» (ИСУП) дип аталган гамәли программалар пакеты эшләнә.

Әд.: Кожевников Ю.В. Статистическая оптимизация летательных аппаратов. М., 1978; Сиразетдинов Т.К., Дегтярёв Г.Л. Теоретические основы оптимального управления кос-

мическими аппаратами. М., 1986; Автоматизированные испытания в авиастроении. М., 1989; Политехнический словарь. М., 1977.

Р.И.Әдһәмов.

«ТЕ́ХНИКА», рәсемле фәнни-популяр, иҗтимагый-сәяси журнал. Казанда 1932 елның декабреннән 1936 га кадәр нәшер ителә, баш та ай саен, аннары атнага 2 тапкыр татар телендә басыла. Төрле елларда ТАССР Җи нел сәнәгать халык комис-ты, ТАССР Авыр сәнәгать халык комис-ты, Татарстан ЮС һәм ВЛКСМ өлкә ком-ты органы, 1933 тән «Тех никаны үзләштерү өчен» җәмгыяте органы. «Барысын да кадрлар хәл итә!» лозунгы б-н чыга. Мөхәррире — Г.Әлмиев, җаваплы сәркәтибе — А.*Алиш*. «Т.»ның максаты булып техник белемнәрне пропагандалау, укучыларны алдынгы пр-тиеләр казанышлары һәм



«Техника» журналы.

заманча техник терминология б-н таныштыру, техник әдәбиятны татар телендә тарату тора. Актив авторлары арасында — проф. Г.Камай, Казан пр-тиеләренең эшчеләре һәм инженер-техник хезмәткәрләре Г.Вәлидов, В.Ибраһимов, Д.Локман, Х.Вәлиев, З.Мохсинов, Г.Хәкимов. Җитәкче органнарның күрсәтмәләре басыла, югары квалификацияле милли кадрлар әзерләү мәсьәләләре яктыртыла, стахановчылар һәм җитештерү отличниклары пропагандалана, проектлар буенча техник консультацияләр гамәлгә ашырыла. Журнал укучыларны күренекле галимнәр: Архимед, Ампер, Леонардо да Винчи, Дж. Далтонның тормышы һәм эшчәнлеге б-н таныштыра. Алдынгыларның биографияләре һәм портретлары, уйлап чыгаручылар һәм оста кулларга булышлык итә торган материаллар басыла (1934 тә тегү машинасын төзәтүгә багышланган мәкаләләр циклы чыга). Җитештерү процессларын механикалаштыру, Казан һәм респ-ка пр-тиеләрендә рационализаторлык тәкъдимнәре кертү мәсь әләләре турында фикер алышына. Даими рубрикалары: «Уйлап табарга өйрән», «Радио сөюче», «Сызымнар сызарга өйрәтү», «Балалар поч магы», «Т.» редакциясе тарафыннан техник конкурслар һәм викториналар уздырыла. 1936 да басманың 3 еллыгы билгеләп үтелә; әлеге вакыйгага багышланган санда дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләренең, стахановчыларның, уйлап табучыларның һәм рационализаторларның чыгышлары басыла.

З.З.Гыйләҗев.

ТЕХНОГЕ́Н КАЛДЫКЛА́Р, кеше эшчәнлегенең сәнәгать, а.х., көнкүреш һ.б. эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килгән чимал һәм материал калдыклары. Саны һәм сыйфаты буенча сәнәгый кулланышка яраклы Т.к. техноген чимал дип атала. Т.к. составында табигый, ш.у. ясалма минераллар да бар. Соңгы лары чималны тирән эшкәртүдә шламда, шлак һәм көлдә барлыкка киләләр. Силикатларның каты эремәләре һәм төрле составлы пыялалар ясалма минералларга керә. Т.к. 600 гә якын төрдәге калдыкны берләштерә: ташландык тау тоқымнары, эшкәртү һәм бәету өемнәре. ТР терр-ясендә аларга Вятка елгасы р-нында бакыр рудаларының иске тау чыганаклары өемнәре, карьерларның ачылма тоқымнары, Кама елгасында комсу-вак чүерташлы чималны эшкәртүдә хасил булган иләк асты комнары, карбонатлы тоқымнардан вакланган таш алу вакытында иләнгән калдыклар, КАМАЗда форма комнарын юдыртканда калган балчыксыл шламнар; химия һәм металлургия җитештерүе калдыклары («Оргсинтез», «Түбәнкамнефтехим», КАМАЗ һ.б.); җылылык-энергетика (җылылык электростанцияләре шлагы һәм көле), нефть (нефть шламнары, нефть продуктлары калдыклары), азык-төлек (яшелчә һәм җиләк-җимеш эшкәртү калдыклары), урман, төзелеш һәм мед. сәнәгате (бер тапкыр кулланыла торган шприцлар һәм системалар); терлекчелек (тирес, кош тизәге), көнкүреш пр-тиеләре, торак-коммуналь хуҗалык, агымсулар утырымнары, стационар һәм хәрәкәтчән чыганаклардан атмосфераны пычратучы матдәләр чыгарылу; нигез асларына, ерым һәм иңкүлекләргә салу өчен грунт, асфальт һәм тимер юллар астындагы өем һәм дамбалар, буа плотиналары, «культуралы катлам» (Казанда 9 *м* га кадәр) һ.б. керә. ТРда ел саен 1300 пр-тиедә гомуми күләме (млн. *т*) 10–13 булган 580 төргә якын Т.к. барлыкка килә, ш.и. терлекчелектә 8–10, сәнәгатьтә 1,5–2,1, көнкүрештә 0,8–0,9, агымсулар утырымнарында 0,15. Т.к.ның күләме ел саен 0,1–0,4 млн. *т* га арта. Якынча 1,5 млрд. $м^3$ тупланган, аларның 1 млрд. $м^3$ ын иләнгән ком тәшкил итә. 35–40 мең стационар һәм 700 мең хәрәкәтчән чыганаклардан атмосферага 0,5 млн. *т* дан артык пычратучы матдәләр, ш.у. парник тәэсире хасил итүче 130 млн. *т* (CO_2 — эквивалент) газлар чыга. ТРда каты көнкүреш калдыкларының 50 гә якын типлаштырылган полигоны бар, аларга ел саен 700–800 мең *т* калдык чыгарыла; шуларның яртысы эшкәртелә. 90 нан артык махсус пр-тие җыю һәм эшкәртү эшләрен башкара. Т.к.дан (мең *т*): 2,8–3 макулатура, 0,15 тән артык полимер, 9–10 металл, 0,4 пыяла ватыгы, 0,2–0,3 тукыма, 1,5–2 нефть продуктлары алалар. Т.к. бетон, цемент, флюс, асфальт, абразивлар, пластмасса, көл һәм шлак-мелиорантлар; көйгән җирләрдән (металл кою калдыклары) — кирпеч, сары шәм калдыкларыннан — пигментлар; иләнгән известьташ калдыклары — известь оны, иләнгән ком — төзелеш материалы, азык-төлек калдыклары — биоҗылылык; агымсулар, иске тау чыганаклары өемнәре, атм.га чыгарылган матдәләр — металлар, нефть шламнары һәм агымсулар — нефть продуктлары җитештерүдә кулланылалар. РФнең «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» Законы нигезендә ТРда Т.к.ны паспортлаштыру системасы, ш.у. үләт базлары өчен вет.-сан. карточкалары кертелгән. Т.к. хакында мәгълүмат табигый байлыкларның торышы турындагы еллык Дәүләт докладларында басыла.

Әд.: Туманова Е.С., Туманов Р.Р. Минеральное сырьё. Сырьё техногенное. Справ. М., 1998.

ТЕХНОПА́РК, эшчәнлек профиле уртак булган фәнни-тикшеренү учреждениеләрен, җитештерү куәтләрен, эшлекле үзәкләрне, күргәзмә мәйданнарын, уку йортларын, шулай ук инфраструктура объектларын (транспорт, телекоммуникацияләр, торак йортлар, саклау чаралары һ.б.) бер терр-ядә берләштерүче оешма. Максаты — фәнни-техник алгарышка ярдәм итү һәм икътисади үсешнең инновацион моделен фәнни идея туу мизгеленнән алып аны коммерциячел файдалануга җиткергәнче фәнни инновацион проектларны туплау юлы б-н гамәлгә ашыру. Беренче Т. 1950 еллар башында АКШта, Стэнфорд ун-ты каршында («Силикон үзәне») оештырыла. 1970 еллар башында Т.лар — Бөекбританиядә, Бельгия, Франциядә, 1980 елларда Канада, Сингапур, Австралия, Бразилия, Һиндстан, Малайзия, Кытай, Япониядә төзелә. Илебездә беренче Т. — 1990 да төзелгән Томск фәнни-технол. паркы. 2015 кә ТРда 14 Т. эшли.

Татарстанда 2004 тә Казанда оештырылган «Идея» инновацион-җитештерү Т.ы (гомуми мәйданы 2 *га*, офис һәм җитештерү корылмалары мәйданы 29,6 мең $м^2$) әйдәп баручылардан санала. Аңа иҗат коллективларын һәм компанияләрен (конкурс нигезендә сайлап алыналар) урнаштыру өчен «Свияга» (мәйданы 8 мең $м^2$) бизнес-инкубаторы (проектны гамәлгә ашыруның башлангыч этапларында зарури булган мәгълүмат, маркетинг, консалтинг, хокукый, бухгалтерия һ.б. төрле хезмәтләр бу оешмаларга беренче эшләү елында бушлай күрсәтелә); компанияләрне өч ел дәвамында өстенлекле аренда шартларында урнаштыру өчен инновацион-технол. үзәк; технол. юнәлешне һәм Т. инфраструктурасына хосусый инвестицияләр кертүне тәэмин итүче эре резидентлар урнашкан бизнес-парк (алар түләүле аренда шартларында эшли) керә. 2017 дә «Идея» Т.ында 8000 хезмәткәрне берләштергән 500 дән артык компания (ш.и. «Панасоник Рус», «Honeywell», «Bosch», «Йокогава Электрик СНГ» һ.б. зур халыкара корпорацияләр) эшли. Бу компанияләр нефть-газ комплексы өчен инновацион инжиниринг эшләрен алып бара, компьютер программалары төзи, заманча лазер технологияләрен гамәлгә кертә, төбәк пр-тиеләре өчен махсус җитештерү җиһазлары һ.б. эшли. «Идея» Т.ында ТР югары уку йортлары һәм урта белем бирү учреждениеләре студентларын инновацион һәм проект эшчәнлегенә җә-

леп итү юлы б-н кадрлар әзерләү юнәлешендә дә зур проектлар тормышка ашырыла.

2004 тә Чаллы шәһәрендә машина төзелеше тармагына йөз тоткан «Мастер» Кама индустриаль паркы» (башта — «Ремдизель» з-ды мәйданнарында, 2015 кә — 600 мең $м^2$ тирәсе), Лениногорск шәһәрендә «Идея-Юго-Восток» Т.ы (мәйданы 38 мең $м^2$, 40 лап резидент компания) төзелә.

Нефть химиясе комплексында кече эшмәкәрлекне үстерү максатында 2006 да «Химград» Т.ы («Тасма» пр-тиесе мәйданнарында, гомуми мәйданы 181 *га*, Химия һәм полимерлар эшкәртү өлкәсендәге 200 кече һәм урта инновацион югары технологияле резидент компания булдырыла. 2009 да Казанда (мәйданы 32 мең $м^2$), 2012 дә Чаллы шәһәрендә (мәйданы 12 мең $м^2$) югары технологияле тармакларны үстерү һәм фәнсыйдырышлы яңа продукция төрләрен җитештерү максатында «IT-парк» Т.ы төзелә. Казан авиация технологиясе фәнни-тикшеренү ин-тының Инновацион-технол. үзәге (мәйданы 9,5 мең $м^2$), Казан ун-тының (Казан ун-тының Инновацион эшчәнлек үзәге) һәм Казан техник ун-тының (А.Н.Туполев исем. КДТУ бизнес-инкубаторы, мәйданы 1460 $м^2$) фәнни-технол. парклары, Чаллы шәһәрендә «Кама алды технопаркы» фәнни-җитештерү партнёрлыгы (мәйданы 279 $м^2$), Чистай шәһәрендә «Чистай» индустриаль паркы (мәйданы 3393,78 $м^2$), Чаллы, Алабуга, Әлмәт, Чистай шәһәрләрендә бизнес-инкубаторлар (мәйданнары тиңдәшле рәвештә 2651 $м^2$, 991 $м^2$, 1643,7 $м^2$, 2140 $м^2$) эшләп килә. Директоры: О.Е.Ибрагимов (2018 дән).

ТЕШСЕ́З ӘКӘ́М-ТӨКӘМНӘ́Р (Anadonta һәм Pseudoanadonta), перловицалар семьялыгыннан төче суларда яши торган ике кабырчыклы моллюскларның ике ыругы. Дөнья фаунасында 50 гә якын, Татарстан терр-ясендә 6 төре билгеле. Идел, Кама, Мишә, Казансу, Зөя, Зәй һ.б. елгаларда гади Т.ә.-т. (Anadonta cygnea) киң таралган. Т.ә.-т.нең башка төрләре (A. pescinalis, A. subcircularis, P. complanata) сирәгрәк очрый, нигездә, Куйбышев сусаклагычында яшиләр. Кабырчыклары яшькелт-көрән яки коңгырт төстә, канат җәеме 20 *см* га кадәр, озынча-түгәрәк формадагы 2 шома кабырчыктан тора, аларда исә үсү сызыклары күренеп тора. Кабырчыклары юка яки калын, эчке өслеге сәдәф катлау б-н капланган, үзара сырт ягындагы сыгылмалы сеңер б-н тоташкан. Бикләгеч тешләре юк (исеме шуннан). Күбесенчә әкрен агымлы яки торгын суларда, ләмле йомшак грунтларда яши, алгы тар башы б-н грунтка ятрылаш яки гәүдәсенең өчтән ике өлеше күмелә. Судагы йөзмә бактерияләр, су үсемнәр һәм таркала баручы органик калдыклар б-н туена, кабырчыклар аша су фильтрлана. Аяк мускулларының кыскаруы исәбенә хәрәкәтләнә. Эмбрионнары көздән мантия куышлыгында йөри, язын ыргаклы личинкалар (глохидияләр) тышка чыга, балыкларның сабагына, тәненә берегәләр һәм, шунда паразитлык итеп, акваториядә таралалар. Т.ә.-т., зур күләмдәге суларны чистартып, сулыкларның үз-үзләрен чистартуында зур роль уйныйлар. 10–15 ел (күбрәк тә булырга мөмкин) яшиләр. Т.ә.-т. йорт хайваннары азыгында файдаланыла. Кабырчыклары төймә ясауда чимал буларак хезмәт итә.

Әд.: Жизнь животных. М., 1968. Т. 2; Краткий определитель водных беспозвоночных Среднего Поволжья. К., 1977.

В.А.Яковлев, Т.А.Кондратьева.

ТЁМКИН-РОСТО́ВСКИЙ Юрий Иванович (?–1561, Казан), кенәз, хәрби эшлекле, бояр (1549). 1530–31 елларда Казанга каршы оештырылган яуда, 1531–35 тә Бөек Литва кенәзлеге б-н сугышта катнаша. 1536–37 дә Түбән Новгород шәһәрендә 1 нче воевода. 1541 дә Казанга каршы оештырылган яуда сак полкында 1 нче воевода (хәрби хәрәкәтләр булмый кала). 1541–43 тә Серпухов шәһәрендә воевода (1543 тә Кырым татарларының һөҗүмен кире кагуны оештыра). 1544–45 тә Казанга каршы оештырылган яуда ертаул полкының 1 нче воеводасы. 1547 дә тәхет түнтәрелешендә актив катнаша, нәтиҗәдә кенәз Глинскийлар хакимияте бәреп төшерелә; шул ук елда сөргенгә җибәрелә, 1549 да кичерелә. 1550 дә Казанга каршы яуда Уң кул полкында 1 нче воевода. 1552 дә Казанны алуда катнашмый (Смоленск шәһәре воеводасы була), 1553 тә Казан воеводаларының берсе. 1557 дә Казанда 4 нче воевода. 1557–60 та Смоленск наместнигы. 1560–61 дә Казанда 1 нче воевода.

Е.В.Липаков.

ТЁПЛЫЙ КЛЮЧ (Аты Шыв) авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 16 *км* төньяк-көнбатыштарак, Сола елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 1 кеше яши. 1910 елларда нигез салына. Оешкан көненнән Казан губернасының Казан өязе Кавал волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Воскресенский, 1927 нең 1 августыннан Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1958 нең 16 июленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1920 дә — 84, 1926 да — 101, 1938 дә — 135, 1949 да — 189, 1958 дә — 148, 1970 тә — 131, 1989 да — 8, 2002 дә — 4 кеше.

ТИГӘ́Н-БУЛӘ́К авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 24 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Шонталы елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 175 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. 1710 нан Тигәнәле елгасы буендагы авыл исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстиннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.-Б.тә 3 җил тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 679,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Полянка волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1782 дә — 66 ир-ат; 1859 да — 191, 1897 дә — 334, 1908 дә — 360, 1920 дә — 398, 1926 да — 321, 1938 дә — 256, 1949 да — 205, 1958 дә — 186, 1970 тә — 257, 1979 да — 251, 1989 да — 207, 2002 дә — 229 кеше.

ТИГӘНӘ́К, к. *Әрекмән*.

ТИГӘНӘКЧЕ́К (Agrimonia), роза чәчәкле семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 23 төре билгеле, күбесенчә Төньяк ярымшарның уртача поясында таралганнар. Татарстан терр-ясендә 3 төре бар. Гади Т. (A. eupatoria) һәм төкле Т. (A. pilosa) ара-тирә барлык районнарда да, Азия Т.е (A. asiatica) Көнчыгыш Кама алдында очрый. Болыннарда, тау битләрендә, урман, юл буйларында үсәләр. 30–150 *см* биеклектәге үсемлек. Сабагы бизле-төкчәле. Яфраклары парсыз каурыйсыман. Чәчәкләре вак, сары төстә, хуш исле, озын башак чәчәк төркеменә җыйналган. Җимеше — чикләвекчек, ыргаксыман төкчәләр б-н капланган; өлгергәч хайваннар йонына һәм киемгә ябыша. Июнь–июльдә чәчәк ата. Җимешләре август–сентябрьдә өлгерә. Гади Т.нең җир өсте өлешләрендә дуплау матдәләре бар; төнәтмәсе бавыр һәм үт куыгы авыруларын, авыз куышлыгында ялкынсыну процессларын, чуан, җәрәхәтләрне дәвалау өчен кулланыла.

ТИГӘНӘЛЕ́ елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Шонталы елгасының (Кама елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 16,6 *км*. Бассейнының мәйданы 70,7 $км^2$. Идел аръягы калкулыгыннан, Алексеев р-нында ага. Елга башы Әшнәк авылыннан 1,3 *км* көньяк-көнчыгыштарак, тамагы Зур Кызылъяр авылының көньяк читендә. Елга башының абс. биеклеге 150 *м*, тамагыныкы — 69 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 10%. Т.ның 2,6 *км* озынлыктагы уң кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,27 $км/км^2$. Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 1–3 $л/с{\cdot}км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 87 *мм*, ташу агымы катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрь ахырында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,017 $м^3/с$. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. Елгада суының гомуми күләме 1 млн. $м^3$ булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

ТИГЕЗАЯКЛЫ́ КЫСЛАСЫМАННА́Р (Isopoda), югары төзелешле кысласыманнар отряды. Якынча 4,5 мең төре билгеле, күбесенчә диңгездә, төче суларда һәм коры җирдә яшиләр. Россиядә 40 тан артык төре бар. Гәүдәсе яссы, тыгыз хитин катламлы, 1 дән 5 *см* га кадәр озынлыкта. Күкрәк өлешендәге 7 калканчыкта бертигез зурлыкта һәм формадагы берәр пар күкрәк аяклары (исеме шуннан) урнашкан. Сулыш органнары — рәвешен үзгәрткән арткы пар корсак аякларыннан торучы саңаклар. Татарстан терр-ясендә күбесенчә кечерәк кенә төче сулыкларда яшәүче *су ишәкчеге* таралган. Ара-тирә Урта

Иделдә тозлырак су төре Jaera sarsi очрый (Иделнең түбән агымында; су ишәкчегеннән озынча түгәрәк гәүдәле булуы б-н аерыла). Агач кайрысы, түмгәкләр астында, мүктә *кыргаяклар*: стена кыргаягы (Oniscus murarius) һәм Porcellio scaber (ш.у. юеш корылмаларда һәм базларда очрый) кыргаягы яши. Су ишәкчеге һәм кыргаяклар таркала баручы үсемлек калдыклары, яшь үсемлекләр б-н тукланалар. Су ишәкчеген балыклар ашый; куркыныч янганда ишәкчекләр очлыкларын ян-якка җәеп үзләрен саклыйлар. Елның җылы вакытында үрчиләр. Аталанганнан соң ана затның корсагында күкәй сумкасы барлыкка килә. Черегән үсемлекләр б-н туенып, су ишәкчекләре сулыкларны чистарталар; кыргаяклар туфракның уңдырышлылыгын арттыруга булышалар. Кайбер төрләре а.х. культураларын, аеруча парник үсемлекләрен зарарлыйлар.

Әд.: к. *Кысласыманнар* мәк.

В.А.Яковлев.

ТИГЕЗКАНАТЛЫЛА́Р (Homoptera), бөҗәкләр отряды. Иртә карбон чорыннан билгеле. Дөнья фаунасында 30 меңнән артык, Татарстан терр-ясендә 50 гә якын төре билгеләнгән. Озынлыгы берничә мм дан 15 *см* га кадәр. Башы аз хәрәкәтләнә. Авыз аппараты чәнчеп суыруга җайлашкан. Үсемлек согы б-н генә тукланалар. Хортумчыгы улаксыман көпшәчек рәвешендәге буынтыклы аскы иреннән тора, анда үсемлек тукымасын тишүгә хезмәт итүче 4 озын нәзек төкчек урнашкан. 2 пар канатлы, күп кенә төрләрендә ул үсеш алмаган. Эчке аталану, аерым төрләренә партеногенез хас.

Отряд үз эченә 5 асотрядны ала: *цикадасыманнар*, яфрак борчалары (Psylloidea), акканатлылар (Aleurodoidea), гөбләсыманнар яки *гөбләләр*, *кортчалар*. Татарстан терр-ясендә барлык асотряд вәкилләре дә очрый.

Цикадасыманнар — отрядтагы иң зур бөҗәкләр. Аларга көчле аваз чыгаручы тавыш аппараты булган сайрак цикадалар керә. Төрле, ш.и. культуралы үсемлекләрнең вируслы авыруларын йоктыручылар. Яфрак борчалары — вак бөҗәкләр (6 *мм* дан зур түгел), гөбләләрне хәтерләтәләр. Кайбер төрләре бакча культураларына зыян сала. Акканатлыларның озынлыгы 3 *мм* га кадәр; канатлары ончыл порошоксыман балавызлы кунык б-н капланган. Личинкалары үсемлекләргә бер ерегә, хәрәкәтсез яшәү рәвеше алып баралар. Гөбләләрнең озынлыгы 0,5–6 *мм*; нәфис капламлы, алар дымны парга әйләндән сакълый алмый. Кибеп үлмәс өчен, бөҗәкләр үсемлек согын күплән суырып, яфрак, ботак деформациясен һәм орылар китереп чыгаралар. Кортчалар — Т. арасында иң кечкенәләре, бик күренмиләр; җир өсте умырткасызлары арасында хәрәкәтсез яшәү рәвеше алып баручы бердәнбер бөҗәкләр. Ана затлар хортумчыклары ярдәмендә үсемлек сабакларына һәм яфракларына берегәләр; аяк-мыекларны үсеш алмаган; гәүдәләре балавызсыман төкчәләр б-н капланган. Ата затлар хәрәкәтчән, канатлы. Кайбер төрләренең ата затлары юк, партеногенез юлы б-н үрчү хас. Җимеш, декоратив һәм оранжерея үсемлекләре кортканычлары.

Әд.: Общая и сельскохозяйственная энтомология. М., 1983; Жизнь животных. Т. 3. Членистоногие: трилобиты, хелицеровые, трахейнодышащие. Онихоформы. М., 1984.

ТИДЕ́Я, к. *Колерия*.

ТИЕНСЫМАННА́Р (Sciuridae), кимерүчеләр отрядыннан имезүчеләр семьялыгы. 250 гә якын төре билгеле, Евразия, Африка һәм Америкада таралганнар. ТР терр-ясендә 5 төре бар: *гади тиен*, *борындык*, *сөркә*, җирән һәм тимгелле *йомраннар*. Төрле ачык һәм урман ландшафтларында яшиләр. Гәүдә озынлыгы 60 *см* га кадәр. Күзләре зур, колаклары кыска, аяклары яхшы үскән, арткылары, гадәттә, алгыларыннан 1,5 тапкыр озынрак. Мехы куе, йомшак. Аркасы җирән-коңгырт, сирәк кенә буй сызыклы кара төстә, корсагы ачыграк. Яшәү рәвешләре төрлечә: агачта (гади тиен), җирдә-агачта (борындык), җирдә (йомраннар, сөркәләр). Аерым (агачта яшәүчеләр) яки колония булып (җирдә яшәүчеләр) өннәрдә яшиләр. Күбесенчә орлыклар, үсемлекләрнең вегетатив өлешләре, бөҗәкләр, моллюскларб-н тукланалар. Кайберләре кышка запас туплый. Елның җылы вакытында үрчиләр (1 дән 15 кә кадәр бала). Гади тиен — кәсәбәчелек объекты. Йомран а.х. культураларына зыян китерә. Борындык, сөркә, йомран — табигый тупланыш авыруларын (түләрәмә, энцефалит, бруцеллёз һ.б.) таратучылар. Борындык, сөркә, тимгелле йомран ТРның Кызыл китабына кертелгән.

ТИЗӘЙТКЕ́Ч, балалар фольклоры жанры, тотлыкмыйча тиз-тиз һәм ачык, аңлаешлы итеп әйтелергә тиешле катлаулы, җайсыз-уңайсыз сүзләрдән төзелгән шигъри һәм чәчмә әсәр. Т.ләр бер үк төрле авазларны һәм аларның күшылмаларын берничә тапкыр кабатлауга таянып төзелә («Абагага бага-бага башым бәрдем баганага»; «Үгезегезнең мөгезен үзегез сындыргач, үгезегездән күрмәгез, үзегездән күрегез!»). Кайбер Т.ләрдә барлык сүзләр дә бер аваздан башлана («Кара, кара, кара карга карга карый», «Сәлимә сигез сыерның сауган сөтен сандыктагы сары сай савытка салып саткан»). Т.ләр рифмалашкан булырга мөмкин («Мич башында биш мәче, биш мәченең биш башы. Биш мәченең биш башына ишелмәсен мич ташы»).

Татар Т.ләрен җыю һәм өйрәнү б-н Х.Ш.Мәхмүтов, Р.Ф.Ягъфәров шөгыльләнә. Татар Т.ләренең иң тулы җыентыгы — «Татар халык иҗаты: Балалар фольклоры» (1993). Татарстан, Башкортстан, Мари респ-калары районнарында язып алынган Т.ләрнең күпчелеге ТР ФА Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тының кулъязмалар мирасханәсендә һәм фольклор фондында саклана.

Әд.: Мәхмүтов Х.Ш. Тизәйткечләр // Татар халык иҗаты: Мәкальләр һәм әйтемнәр. К., 1987; Ягъфәров Р.Ф. Тел көрмәкләндергечләр // Татар халык иҗаты: Балалар фольклоры. К., 1993; Урманче Ф. Татар халык иҗаты. К., 2005.

Ф.И.Урманчеев.

ТИЗЕНГА́УЗЕН Владимир (Эрнест-Вальдемар) Густавович (1825, Нарва ш. — 2.2.1902, С.Петербург), шәркыятьче галим, археолог, нумизмат, Петербург ФАнең мөхбир әгъзасы. Петербург ун-тын тәмамлый (1848). 1849 елдан диңгез һәм мед. оешмаларында язу эшләрен башкаручы булып хезмәт итә. 1857 дә Император сарае министрлыгына хезмәткә күчә: өстәл башлыгы; 1861 дән Археол. комиссиясендә: эшләр башкаручы, комиссиянең кече, өлкән әгъзасы, 1894–1900 дә комиссия рәисе урынбасары. 1900 дә отставкага чыга. Скифларның Чертомлык (1863), «Җиде туган» (1875–76) курганнарын археол. казып тикшерү эшләрендә катнаша. 1864 тә — Болгар шәһәрендәге («Бабий бугор» дип исемләнгән урында борынгы болгар каберлеген ача), 1868–84 тә Төньяк Кавказдагы (антик истәлекләрне өйрәнү) казу эшләренә җитәкчелек итә. Рус археол. (1854 тән), Казан ун-ты каршындагы Археол., тарих һәм этнография (1891 дән) җәмгыятьләренең шәрәфле әгъзасы. 17 археология, нумизматика һәм Шәрекъне өйрәнү, ш.и. Мәскәү, Вена, Лондон, Берлин җәмгыятьләре әгъзасы. Хезмәтләре Шәрекъ нумизматикасына һәм археологиясенә, Идел буе Болгары һәм Алтын Урда тарихына карый. Шәрекъ нумизматикасына багышланган хезмәтләре өчен Рус археол. җәмгыятенең бүләгенә (1852, 1861) һәм Зур көмеш медаленә (1874), Алтын Урда тарихы чыганакларын нәшер иткәне өчен Зур алтын медаленә (1884) лаек була. Соңгы елларда «Мөселман Шәрегы-нең X–XV йөзләр зиннәтле әйберләре тарихы» («История предметов роскоши мусульманского Востока X–XV вв.», басылмаган) китабы өстендә эшли. Т. тарафыннан гарәп һәм фарсы авторларының Алтын Урда тарихына нисбәтле хезмәтләреннән алынган өземтәләр һәм эшләнгән тәрҗемәләр хәзерге вакытта да әһәмиятен югалтмый.



В.Г.Тизенгаузен.

Х е з м.: О саманидских монетах // Зап. Имп. Рус. археол. об-ва. 1853. Т. 6; Собрание булгарских древностей // Изв. имп. Рус археол. об-ва. 1868. Т. 6; Древности, найденные близ г.Спасска Казанской губернии // Тр. Моск. археол. об-ва. 1873. Т. 3; Монеты Восточного халифата. СПб., 1873; Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды. СПб., 1884. Т. 1; М.–Л., 1941. Т. 2; В защиту Ибн-Фадлана. СПб., 1900.

Әд.: Розен В.Р. Памяти барона В.Г.Тизенгаузена // Зап. Вост. отд-ния Рус. археол. об-ва. 1905. Т. 16, вып. 2/3; Бойко К.А. Из рукописного наследия В.Г.Тизенгаузена // Краткие сообщ. Ин-та народов Азии АН СССР. 1961. № 47.

И.Л.Измайлов, Л.Ф.Недашковский.

ТИЗЯКО́В Александр Иванович (10.12.1926, Чистай кантоны Яңа Иванаево а.), инженер-металлург, сәнәгать җитештерүен оештыручы, икътисад фән. канд-ты (1984), РСФСРның атказ. авиация төзүчесе (1978), атказ. машина төзүчесе (1985). Бөек Ватан сугышында катнаша. Урал политехник ин-тын тәмамлый (Свердловск ш., 1958), 1950–53 елларда «Уралхиммаш» з-дында слесарь, мастер булып эшли. 1953–56 да комсомол эшендә. 1956–91 дә «М.И.Калинин исемендәге машиналар төзү з-ды» ФҖБдә (Сверд-

ловск ш.): корыч фасон цехы технологы, цех башлыгы урынбасары, партком секретаре (1962 дән), баш инженер урынбасары (1964 тән), ген. директор (1977 дән), бер үк вакытта, 1988 дән, ФҖБнең фәнни җитәкчесе. 1989–91 дә СССР Дәүләт пр-тиеләре һәм берләшмәләре ассоциациясе президенты. Т. җитәкчелегендә 20 дән артык зенит-ракета (С-300 В ракеталар системасында) һәм көймәгә каршы ракета системаларын җитештерү оештырыла, аларның күпчелеге тактик-техник характеристикалары буенча 20 йөзнең берничә дистә елы дәвамында дөньяда иң яхшылардан санала. Яңа төзелергә тиешле эшләнмәләрнең конструкциясен һәм технологиясен эшкәртүдә, заманча алдынгы җиһазлар һәм автомат линияләрне гамәлгә куюда катнаша. Энергия саклау мәсьәләләренә (төрле углеводород ягулыгының януын оптимальләштерү) һәм өр-яңа җылылык энергиясен табу юлларын эзләүгә караган басма хезмәтләр авторы. СССР Дәүләт бүләге иясе (1981). Уйлап табуга 30 дан артык авторлык таныклыгы бар. СССР Дәүләт Гадәттән тыш хәлләр ком-ты әгъзасы (1991). Дәүләткә каршы эшчәнлектә гаепләнеп кулга алына; 1994 нең февралендә Дәүләт Думасы карары б-н амнистияләнә. Октябрь Революциясе, 2 нче дәрәҗә Бөек Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: Инженеры Урала: Энцикл. Екатеринбург, 2001; Металлурги Урала: Энцикл. Екатеринбург, 2001.

ТИЛЕ́ ТОРМА́ (Erysimum), әвернә чәчәкләләр семьялыгыннан бер-, ике- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 100 дән артык төре билгеле, Европа, Азия һәм Төнья Африкада таралганнар. ТРда 4 төре билгеле. Шөббуйсыман Т.т. (E. cheiranthoides), карчыга үләне яфраклы Т.т. (E. hieracifolium) респ-каның бөтен җирендә, соры Т.т. (E. canescens) Кама аръягында очрый. Үләнле тау битләрендә, ерым, елга үзәннәрендә, юл буйларында үсәләр. Тешәүле Т.т. (E. repandum) Идел алдында, тимер юл кырыйларында үсә. 15–90 *см* биеклектәге үсемлек. Сабагы туры. Яфраклары чиратлашкан, тар, ланцетсыман. Үсемлек өслеккә береккән йолдызчыксыман төкчәләр б-н капланган. Чәчәкләре сары, чукка җыйналган. Җимеше — ике капкачлы ачылучан кузакчык. Орлыклары һәрбер ояда бер рәткә урнашкан. Шөббуйсыман Т.т. киңрәк яфраклары, кузакчыкларның сабакта үзенчәлекле урнашуы б-н аерыла: җимеш сабакчасы почмак ясап берегә. Төз Т.т.ның кузакчыклары сабакка сыенган. Май–августта чәчәк аталар. Орлыктан үрчиләр. Җир өсте өлешләрендә гликозидлар, сапониннар бар. Халык медицинасында йөрәк-кан тамырлары авырулары вакытында, ш.у. бәвел куду чарасы буларак кулланыла. Декоратив, баллы үсемлекләр. Шөббуйсыман Т.т. — чүп үләне.

ТИЛЕБӘРӨ́Н ҮЛӘНЕ́ (Hyoscyamus), паслёнчалар семьялыгыннан бер-, ике- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Якынча 20 төре билгеле, Европа, Азия, Африкада очрыйлар. ТР терр-ясендә икееллык төре — кара Т.ү. (H. niger) таралган. Бөтен респ-када буш җирләрдә, йорт яннарында, юл буйларында, яшелчә һәм җиләк-җимеш бакчаларында чүп үләне буларак үсә. Тәмсез исле йомшак төкчәле үсемлек. Тамыры үзәк, тармаклы, йомшак, калын тамыр муенлы. Тармаклы итчел сабагы 30–60 *см* биеклектә, бизле ябышкак төкчәле, алар үсемлекне хайваннардан саклый. Яфраклары соргылт яшел төстә, чиратлашкан, зур, уемтыклы-каурыйсыман киселмә. Чәчәкләре эре, куентылы, шәмәхә сеңерле соргылт сары төстә, бөтеркәгә җыйналган. Җимеше — йомыркасыман, ачылучан капкачлы күп орлыклы тартмачык. Май–июньдә чәчәк ата. Җимешләре август–сентябрьдә өлгерә. Орлыктан үрчи. Үсемлек составында алкалоид һәм гликозидлар бар. Медицинада яфракларыннан ясалган экстрактны кайбер ашкайнату тракты һәм сулыш юллары авыруларында спазмга каршы һәм авыртуны басу чарасы буларак куллана лар. Вакланган яфрагы бронхиаль астманы дәвалау препараты «Астматол» составына керә. Агулы үсемлек. Агулану симптомнары: көчле



Кара тилебәрән үләне.

ярсыну, күз бәбәкләре зураю, галлюцинацияләр, саташу; үлемгә дә китерергә мөмкин. Агуланган очракта беренче ярдәм: калий перманганаты эремәсе һәм активлашкан күмер б-н ашказанын юдыру, аннары тозлы эч йомшарткычлар, каты чәй, кофе эчү.

ТИЛЕРТКЕ́Ч (Datura), паслёнчалар семьялыгыннан үләннәр, сирәк кенә куаклар һәм агачлар ыругы. 25 кә якын төре билгеле, күбесенчә тропикларда, субтропик һәм уртача поясларда таралганнар. ТР терр-ясендә бер төре — сасы, яки гади Т. (D. stramonium) очрый. Елга һәм инеш ярларында, кырларда, бакчаларда чүп үләне буларак үсә. 15–80 *см* биеклектәге берьеллык үләнчел үсемлек. Тамыры орчыксыман, ак төстә. Сабагы туры, шома, ботаклы. Яфраклары саплы, очлы, яфрак пластинкасы уемтылы-тешле читле. Чәчәкләре берле, эре, ак, тәмсез тилерткеч исле (исеме шуннан), яфрак куентыгында урнашканнар. Җимеше — озынча түгәрәк тартмачык, яшел чәнечкеләр б-н капланган. Июнь аеннан көзгә кадәр чәчәк ата. Җимешләре июльдә өлгерә башлый. Орлыктан һәм ботактан үрчи. Барлык органнарында — алкалоидлар, яфракларында — эфир мае, каротин, дуплау матдәләре бар. Яфраклары бронхиаль астма авыруына каршы җыелмалар составына керә. Орлыкларыннан күз авыруларыннан файдаланылучы атропин алкалоидын алалар. Төнәтмәсе — гөбләләр, үсемлек кандалалары һ.б. өчен инсектицид. Агулы үсемлек.

ТИ́ЛЛИ К.А. БАСМАХАНӘСЕ́, Казанда 1866 елда элегрәк Тилли управляющий булып эшләгән П.И.Фан-дер-Флита– И.А.Фон-Глен басмаханәсе җирлегендә ачыла. Техник җиһазланышы һәм эшләнгән эшләрнең сыйфаты буенча шәһәрдә иң яхшысы санала. Басмаханәдә бланк, афиша, китап басу өчен махсус шрифтлар, ш.и. гарәп шрифтлары күп була. Җиһазлар Берлин, Ганновер, Франкфурттан (Германия) кайтарыла. 1872 гә кадәр «басмаханә, ташбасмаханә һәм хәреф кою ширкәте» буларак, соңрак — «басмаханә, ташбасмаханә, хәреф кою ширкәте һәм басма бизәк төшерү кирәк-яракларын җитештерүче оешма» буларак билгеле. Төп продукцияне бланклар, реклама игъланнары, чакыру кәгазьләре тәшкил итә (рус телендә бары берничә китап, татар телендә бер китап басыла). 1875 тә монда «*Листок объявлений*» г-тасы нәшер ителә. Хакимиятләрнең гел тыкшынып торуы басмаханәгә бөтен мөмкинлекләрен дә кулланырга комачаулый. 1877 дә басмаханә сатыла. Җиһазларның бер өлешен А.Д.Линимайер ала, аннары ул аларны М.А.Гладышевага сата (к. *М.А.Гладышева ташбасмаханәсе*).

Әд.: Карамуллин А.Г. Татарская книга пореформенной России. К., 1983; Габдельганеева Г.Г. Полиграфия и печать в Казанской губернии, 1800–1917 гг. К., 2005.

Г.Г.Габделганиева.

«ӘТ-ТИЛМИ́З» (التلميذ — «Укучы»), иҗтимагый-пед., фәнни, әдәби атналык газета. 1906–07 елларда С.-Петербургта гарәп телендә нәшер ителә, барысы 30 саны чыга. Нашире һәм мөхәррире — Р.*Ибраһимов*. «Бөтен дөнья мөселманнары, берләшегез!» лозунгы б-н басыла. Газетада зур игътибар халык мәгарифе мәсьәләләренә бирелә, мөселман уку йортларындагы уку процессын оештыру тәнкыйткә дучар ителә.

ТИМА́ШЕВ Александр Егорович (3.4.1818, С.-Петербург — 20.1.1893, шунда ук), хәрби һәм дәүләт эшлеклесе, кавалерия генералы (1872), САнең хакыйкый әгъзасы (1889). Дворяннар нәселеннән. Мәскәү ун-ты каршындагы затлы нәсел ир балалар пансионын, гвардия подпрапорщиклары һәм кавалерия юнкерлары мәктәбен тәмамлый (1835). 1835 елдан хәрби хезмәттә. Кавказдагы хәрби операцияләрдә (1844), Венгриядәге рев-цияне бастыруда (1849), Кырым сугышында (1854–56) катнаша. 1856–61 дә Жандармнар корпусы штабы башлыгы һәм Император канцеляриясенең III бүлеге идарәчесе. Консерватив карашларны яклый. 1861 елгы Крәстияннәр реформасын тәнкыйтьләп чыга. 1863–64 тә Казан, Пермь, Вятка генерал-губернаторы. Сәнәгать һәм сәүдә үсешенә, Казанны төзекләндерүгә булышлык күрсәтә. 1863 елгы *Казан фетнәсе* эшен тикшерү б-н җитәкчелек итә; фетнәне оештыручыларга карата үлем җәзасын раслый (июнь 1864). 1867–68 дә почта һәм телеграфлар министры, 1868–78 дә эчке эшләр министры, 1878 дән Россия Дәүләт Советы әгъзасы. Россиядә 1870 тәге Шәһәр һәм 1874 тәге Хәрби реформаларны уздыруга булышлык итә. Скульптура һәм нәкышь сәнгате әсәрләре, хатирәләр авторы. Казанның мактаулы гражданы (1864). Изге Андрей Первозванный, Изге Александр Невский орденнары б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Из истории раскрепощения помещичьих крестьян // Рус. архив. 1887. Кн. 2.

Е.Б.Долгов.

ТИМА́ШЕВ Хафиз Шәйхулла улы (1.8.1947, Севастополь ш.), спортчы, тренер (грек-рим көрәше), СССРның халыкара спорт остасы (1970), РСФСРның атказ. тренеры (1992). Омск физкультура ин-тын тәмамлый (1970). СССР чемпионы (1970), И.Поддубный призына халыкара турнирда бронза приз ала (1970). 1972–76 елларда Әлмәт физкультура техникумында укыта, 1976–83 тә Волгоград физкультура ин-тының Казан ф-лында укытучы, 1983–84 тә Респ-ка югары спорт остаханы мәктәбе директоры (Казан). 1984–85 тә грек-рим көрәше буенча ТРның өлкән тренеры, 1991–2005 тә «Батыр» респ-ка махсуслаштырылган балалар-яшүсмерләр олимпия резервы спорт мәктәбендә, 2005 тән «Казан Олимпия резервы уч-щесе» урта һөнәри белем бирү дәүләт учреждениесендә тренер-укытучы. Бер үк вакытта, 1984–93 тә, ТРның Грек-рим көрәше федерациясе рәисе. СССР халыклары спартакиадаларына (1980, 1984) РСФСР җыелма командаларын җитәкләгән. Т. 20 дән артык СССР, Россия спорт осталарын әзерли. Шәкертләр арасында Ю.А.Гоц — яшүсмерләр арасында СССР беренчелегендә көмеш медаль алучы (1978), Т.Х.Кәримов — яшьләр арасында СССР беренчелегендә җиңүче (1980), көмеш медаль алучы (1981), Э.Д.Хәсәнов — Россия беренчелегендә көмеш медаль алучы (1992–93, яшүсмерләр арасында, 1994–95, яшүсмерләр арасында). Медаль б-н бүләкләнә.

ТИМАШЁВ Геннадий Александрович (22.9.1946, Куйбышев өлкәсе Шигоны р-ны Кяхта а. – 11.5.2012, Казан), генерал-майор (1990). Ульянов гв. командирлар танк уч-щесен (1967), Сов. Союзы Маршалы Р.Я.Малиновский исем. Бронетанк гаскәрләре хәрби академиясен (Мәскәү, 1973) тәмамлый. 1967–70 тә Белоруссия хәрби округында: танк взводы командиры, уку-өйрәнү взводы командиры, танк ротасы командиры. 1973–74 тә 1 нче Мәскәү мотоукчылар дивизиясенең (Калининград ш.) танк батальоны командиры. 1974–75 тә 250 нче мотоукчылар дивизиясендә (Калининград өлкәсе Гусев ш.) полк штабы башлыгы. 1975–77 дә 1 нче танк дивизиясендә (Калининград өлкәсе Мамонтов ш.) полк штабы башлыгы. 1977–80 дә Сүрия Гарәп Респ-касында (Димәшкъ) механикалаштырылган бригада штабы башлыгы киңәшчесе. 1980–85 тә танк полкы командиры, Германиядәге Совет гаскәрләре төркемендә 41 нче мотоукчылар дивизиясе берләшмәсенең штаб башлыгы. 1987–95 тә Казан югары хәрби командирлар танк уч-щесе башлыгы. 1995 тән — запаста. Сүрия Гарәп Респ-касының 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә «Сугышчан әзерлек өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

ТИМАШО́ВА Надежда Ивановна (21.6.1928, Калуга өлкәсенең Песочня пос., хәзер Киров ш. — 7.10.2008, Казан), икътисадчы, хуҗалык хезмәткәре. Севастополь тимер юл-төзелеш техникумын (1952), Профсоюзлар югары мәктәбен (Мәскәү, 1962) тәмамлый. 1952–55 елларда Ленинград метросы төзелешендә мастер, өлкән мастер булып эшли. 1955–68 дә «Казантрансстрой» трестында: колонна башлыгы, прораб, планлаштыру-икътисад бүлеге башлыгы, ген. директор урынбасары (1966 дан). 1968–87 дә «Татмебель» ҖБ ген. директоры. «Татмебель» ҖБдә Т. җитәкчелегендә пр-тиегә реконструкция үткәрелә, яңа җитештерү корпуслары төзелә; илдә беренче булып агачны һәртөрле эшкәртү буенча автомат линия куела, мебель җитештерүнең яңа технологияләре гамәлгә кертелә. 1987 дән ТР ветераннар оешмасы советы рәисе. СССР ЮС депутаты (1989–91). Ике Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы орденнары, медальләр; ТАССР ЮСның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

ТИМӘ́Ш авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 9 *км* көньяк-көнбатыштарак, Урман Чишмәсе елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 2634 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 72%) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау, кошчылык. А.х. химиясе пр-тие се. Урта мәктәп, китапханә. Мәчет. 1762 гә кадәр Иске Шәйморза авылы кешеләре нигез сала. Рус чыганакларындагы беренче исеме — Новопоселённая Темешева, рев-циягә кадәрге чыганакларда Ромашкино атамасы б-н дә билгеле. 1860 ларга кадәр халкы дәүләт крәстиәннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, курыс-мунчала төшерү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп була; якшәмбе базары эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2242 дис. тәшкил итә. 1948 дә Т. янындагы *Ромашкино нефть чыганагының* 3 нче скважинасыннан беренче нефть чыгарыла. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Яңа Писмән волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Шөгер, 1935 нең 10 февраленнән — Яңа Писмән, 1955 нең 18 августыннан Лениногорск р-нында. Халык саны: 1785 тә — 132 ир-ат; 1859 да — 651, 1889 да — 1246, 1897 дә — 1202, 1910 да — 1284, 1920 дә — 1413, 1926 да — 1006, 1938 дә — 690, 1949 да — 585, 1958 дә — 2202, 1970 тә — 2117, 1979 да — 1817, 1989 да — 1834, 2002 дә — 2680 кеше. Т.тә шагыйрь Г.*Утыз Имәни* җирләнгән.

ТИМБА́Й авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 27 *км* көнбатыштарак, Чуаш Респ-касы б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 76 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кыр-чылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 1593–94 тә чуаш авылы буларак нигез салына, 1695 тән рус авылы. 1720 еллардан халкы дәүләт крәстиәннәре катлавына керә, 1835–1860 та Удел ведомствосы карамагында; игенчелек, терлекчелек, тегү, тимерчелек, киез итек-киез җитештерү, итек тегү, арба ясау, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.да волость идарәсе урнаша, кәшәнә, почта бүлеге, һөнәр уч-щесе, 26 сәүдә-сәнәгать йорты эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2086,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Тимбай волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Буа, 1935 нең 10 февраленнән — Будённый, 1957 нең 29 ноябрен-нән — Чынлы, 1959 ның 12 октябреннән Буа р-нында. Халык саны: 1859 да — 928, 1897 дә — 1375, 1913 тә — 1850, 1920 дә — 1647, 1926 да — 1131, 1938 дә — 1073, 1949 да — 742, 1958 дә — 597, 1970 тә — 309, 1979 да — 215, 1989 да — 121, 2002 дә — 93 кеше.

ТИМБИ́КОВ Әкрам Хәлим улы (14.3.1923, Чистай кантоны Яңа Әмзә а.), химия фән. д-ры (1987), проф. (1990). 1948 елда Урта Азия ун-тын (Ташкент ш.) тәмамлый. 1951 дән Ташкент текстиль һәм җи ңел сәнәгать ин-тында эшли. Хезмәтләре физиологик актив кушылмалар химиясенә карый. Т. 2,3'-дипиридил рәте алкалоидлары, хинолизидин, тетрагидроизохинолин һәм алар нигезендә табылган продуктлар химиясенә зур өлеш кертә. Аминнар һәм спиртларны цианэтилирлау реакциясе механизмнарын эшләүчеләрнең берсе. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

ТИМБИ́КОВА Кояш Закир кызы (16.11.1937, Чистай р-ны Наратъелга а. — 7.1.2004, Казан, туган авылында җирләнә), язучы, ТАССРның, РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1976, 1989). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1959), «Азат хатын» ж-лы редакциясендә әдәби хезмәткәр, бүлек мөдире, җаваплы сәркәтип булып эшли. 1979–97 елларда — «Казан утлары» ж-лында җаваплы сәркәтип, бүлек мөхәррире. Беренче очерклары «Кояш безгә елмая» (1962), «Тылсымлы таяк» (1964) күмәк җыентыкларында дөнья күрә. «Күңелләргә күләгә төшмәсен» (1969), «Зәңгәр күлмәк» (1969), «Кайгы белән шатлык янәшә» (1979), «Бәхет хакына» (1981) җыентыклары, «Тәңкәле тау» (1982), «Ярлар биек» (1985), «Тын бакчада» (1990) повестьлары авторы. Т. әсәрләренә образларның психол. эшләнеше, бүгенге көн хатын-кызының эчке дөньясы нечкәлекләрен, гаилә-көнкүреш мәсьәләләрен тирән аңлау хас.

Әс ә р.: Дулкын баласы. К., 1997.

Әд.: Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

ТИМЕ́Р (псевд., чын фамилиясе Яруллин) Әхмәт Рәшит улы (14.11.1912, Самара губ., Бөгелмә өязе Әлмәт а. — 19.4.2003, Әнкара), төрки һәм монгол телләре галиме, филол. фән. д-ры (1941), проф. (1962). 1929–36 елларда Төркиядә: Трабзон шәһәрендәге укытучылар мәктәбендә, Истанбул шәһәрендәге Хәйдәр паша лицеенда һәм Әнкара ун-тында белем ала. 1936–43 һәм 1952–54 тә Германиядә яши. 1936 дан проф. Г. фон *Менде* чакыруы буенча Россияне өйрәнү ин-ты каршындагы татар китапханәсендә (Берлин) эшли. Берлин ун-тын тәмамлый (1941), Гамбург ун-тында татар теле укыта. 1941–43 тә — Оккупацияләнгән шәрекъ терр-яләре эшләре министрлыгында, ш.у. хәрби төткынлыктагы кызыл армиячеләр лагерьларында һәм татар эмигрантларының сәяси хәрәкәте оешмасында Министрлык комиссияләре эшендә катнаша. 1943 тән яңадан Төркиядә. 1946–51 дә Милли мәгариф министрлыгы каршындагы Музейлар идарәсендә эшли. 1955–82 дә Әнкара ун-тында төрек теле укы-

та, бер үк вакытта, 1961 дән — Төрки мәдәни - ятләрне тикшерү-өйрәнү ин-тында (1975 кә кадәр директоры). Хезмәтләре татар һәм монгол телләре грамматикасына, алтай теленә карый. «Монголларның яшерен тарихы» («Тайная история монголов», Әнкара, 1948) китабын — монгол теленнән төрекчәгә, В.Радловның Алтай һәм Көнбатыш Себер буйлап сәяхәте вакытында җыйган этнографик һәм фольклор материалына нигезләнеп язган «Себердән» («Из Сибири», 1–4 т., Әнкара, 1954–57) хезмәтен рус теленнән төрекчәгә тәр җемә итә. 1970–80 дә Ә.*Мәңгәр* б-н берлектә Истанбулда «Казан» ж-лын чыгара.

Х е з м.: Yusuf Akçura. Ankara, 1987; Moğolların Gizli Tarihine Göre Cendiz Han. Ankara, 1989; Türkoloji tarihinde W.Radloff devri. Hayatı–ilmî kişiliği–eserleri. Ankara, 1991.

Әд.: Г а ф ф а р о в а Ф.Ю. Татар мөһаҗирләре. К., 2004; А х у н о в А.М. Ахмет Тимер // Әл - мәт–Альметьевск. К., 2003.

ТИМЕ́Р ГАСЫ́Р, кешелек тарихының ти - мер металлургиясен беренчел үзләштерүгә бәйле этабы. *Таш гасырга* һәм *бронза гасыр - га* алмашка килә. «Т.г» атамасын фәнни әй - ләнешкә 1830–50 елларда археолог К.Ю.Томсен кертә. Т.г. истәлекләренә караган иң әһә - миятле тикшеренүләр, аларны төркемләү һәм вакытын билгеләү Россиядә күренекле ар - хеологлар Д.Я.Самоквасов, А.А.*Спицын*, В.А.Городцов, А.Х.*Халиков* һ.б. тарафыннан башкарыла. Бер төркем галимнәр Т.г. башла - нуны теге яки бу төбәктә беренче тимер эш - ләнмәләр барлыкка килү б-н, икенчеләре — даими рәвештә тимер җитештерелә башлау б-н, өченчеләре — бронза хезмәт һәм сугыш коралларының тимердән эшләнгәннәре б-н кысрыклап чыгарылуына бәйләп карыйлар. Т.г. ахырын археологларның күпчелеге *Ха - лыкларның бөек күчеше* чорына (2–6 йөзләр) нисбәт итә.

Борынгы кеше башта саф килеш табыл - ган металл һәм метеорит тимер б-н таныш була. Соңрак тимер алу өчен төп материал бу - лып тимер рудалары: карбонатлы (тимер шпаты), гематитлы (кызыл тимер рудасы), магнетитлы (магнитлы тимер рудасы), ли - монитлы (көрән тимер рудасы) яисә башка металлурглар тарафыннан барысыннан да ешрак кулланылган сазлык рудалары хезмәт итә башлый. Борынгы заманнарда билгеле башка металлар б-н чагыштырганда, тимер иң югары эрү температурасына ия (1539°С), бу «дымлы өрдерү алымы»н беренчел үзләш - терүгә нигез була, бу очракта тимер эреми, ә 800–900 °С температурада окисьтан яңа - дан кайтарыла; әлеге алым төсле металларны эретү технологиясенә караганда катлаулы - рак, дип исәпләнә.

Баштарак тимер сугыш һәм хезмәт корал - лары бронзадан эшләнгәннәреннән кайтыш - рак була, шу ңа күрә тимер эшләнмәләрнең сыйфатын яхшырту максатында махсус алымнар кулланыла башлый: цементлау (уг - лерод б-н туендыру), пакетлау (тимер калай кисәкләрен беркетү, эретеп ябыштыру) һ.б. Эретелгән тимер өреме (крица) яңадан үкеп ясау юлы б-н күчереп йөртү, алмашу, сату өчен уңайлы (очлы башлы дүрт кырлы кисәк - ле һ.б.) бер формага китерелә. Бронза гасы - рында башланган тимер үзләштерү процессы шактый озакка сузыла. Металлургиянең иң борынгы чыганаклары Шәрекъ илләрендә урнашкан була. Урта Идел буенда Т.г. куль - турасы фин-угор кабиләләренә бәйләп кара - ла. Аның үсешенең беренче этабына нисбәт - ле археол. катламнарга аз санлы металл эш - ләнмәләр табылу, сөяктән ясалган сугыш һәм хезмәт кораллары өстенлек итү хас. Ихти - мал, тимер б-н таныш булу сөяктән әйберләр эшләү һөнәрчелегенең үсешенә этәргеч яса - гандыр да. Б.э.к. 1 нче меңьеллыкның 2 нче ярты сы ахырыннан башка фин-угор кабиле - ләре яшәгән урыннарда да Т.г. урнаша. Тимер үзләштерү төсле металлар эшкәртү б-н тыгыз бәйләнештә була; сөяк эшләнмәләрнең саны әкренләп кими. Тимер ясаучылык һәм ти - мерчелек производстволары халыкның ху - җалык эшчәнлегендә игенчелек һәм терлек - челекнең роле күтәрелүгә булышлык итәләр. Шуның б-н бергә, ит ризыклары җитештерү чыганагы буларак, аучылыкның роле кими, тик урман зонасына кергән кайбер урыннар - да кыйммәтле мех бирә торган җәнлекләрне промысел өчен аулау үсеш ала. Урта Идел нең сул ярын һәм Кама буен алып торган *Анань - ино культурасы* (б.э.к. 8–3 йөзләр) вәкилләрендә тимер үзләштерү процессы башкача була. Барлыкка килгән вакытыннан ук аңа бронза һәм тимер хезмәт кораллары ның янә - шә кулланылуы һәм күпсанлы бронза бизә - нү әйберләре булу хас. Тимер үзләштерү про - цессы бронза кою эшенең көчле үсеше б-н бер үк вакытта бара. Ананьино осталары ти - мерне чыныктыруны кулланалар, ләкин Т.г.ның башлангыч чорында аларда сөяктән ясау эше киң үсеш ала: сөяктән хезмәт һәм су - гыш кораллары, бизәнү әйберләре җитеште - релә. Тимерне эшкәртүне яңа технология - ләр куллану юлы б-н камилләштергән (це - ментлау, ционирлау һ.б.), ныклы тимер су - гыш кораллары (ук очлыклары, сөңгеләр, кылычлар һ.б.), игенчелектә кулланыла тор - ган хезмәт кораллары ның (урак, чалгы һәм сука очлыклары һ.б.) эшләргә өйрәнгән *Горо - дец культурасы* (б.э.к. 7 йөз — б.э.ның 5 йө - зе), *Пьянобор культурасы* (б.э.к. 3 йөз — б.э.ның 3 йөзе), *Мазунино культурасы* (3–5 йөзләр), *Азелино культурасы* (3–7 йөз - ләр), *Имәнкискә культурасы* (5–7 йөзләр), *Ломоватово культурасы* (5–10 йөзләр), *Куш - наренко культурасы* (6–10 йөзләрнең 2 нче ярты сы) кабиләләрендә тимерне үзләштерү аерым шартларда бара. Б.э.ның 1 нче меңьел - лыгында тимер һәм корычның Урта Идел буенда киң таралыш алуы кискен техник үз - гәрешләргә китерә: шактый зур урман мәй - даннарын чәчүлек җирләр өчен әзерләүгә, туфрак эшкәртүне яхшыртуга мөмкинлек - ләр ачыла; һөнәрчелек үсеше, аерым алганда тимерчелек һәм кораллар җитештерү, тиз - ләнә төшә. Торак төзелеше, транспорт чара - лары (суднолар, зур экипаж һ.б.) җитештерү, төрле кирәк-яраклар ясау өчен агач эшкәртү камилләшә. Юллар төзү активлаша, сугыш сәнгате үсеш кичерә, товар алмашу киңәя.

Әд.: З б р у е в а А.В. История населения При - камья в ананьинскую эпоху // Материалы и исслед. по археологии СССР. 1952. № 30; Х а л и к о в А.Х. Волго-Камье в начале эпохи раннего железа (VIII — VI вв. до н. э.). М., 1977; Очерки по археологии Татарстана. К., 2001.

Е.П.Казаков.

ТИМЕ́Р КОТЛЫ́ГЪ ХАН (1370 тирәсе — 1399), Алтын Урда ханы (1397 елдан). *Ти - мер Малик бәк* улы. Атасы вафатыннан соң (1379), Идегәй әмир тарафыннан Туктамыш хан сараенда тәрбияләнә. 1388 дә Туктамыш - ка каршы оештырылган уңышсыз фетнәдән соң, Идегәй б-н бергә Урта Азия идарәчесе Аксак Тимер янына кача. Со ңыннан Аксак Тимернең Туктамышка каршы явында катна - шалар (1391), аны тар-мар иткәннән соң Иделнең түбән агымында, үзәге Сарайчык шәһәре булган мөстәкыйль олыс төзиләр (1391–95). Идегәй ярдәме б-н Алтын Урда тә - хетенә утыра. 1398 дә үз исеменнән акча сук - тыра. 1399 да Т.К.х. Идегәй б-н бергә *Бурсык - лы (Ворскла) елгасы буендагы сугышта* Тук - тамыш гаскәрен тар-мар итә. Соңрак тәхет өчен Туктамыш хан улына каршы алып ба - рылган көрәштә һәлак була.

Әд.: Г р е к о в Б.Д., Я к у б о в с к и й А.Ю. Зо - лотая Орда и её падение. М.–Л., 1950; С а ф а р г а - л и е в М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960.

И.Л.Измайлов.

ТИМЕ́Р МАЛИ́К БӘК (Тимер бәк, Нумукан, Тумукан) (?–1379), Күк Урда идарәчесе (1376/77 дән). *Ырыс Мөхәммәд хан* улы. Бертуганы *Туктакыя бәк* үлеменнән соң тә - хеткә утыра. Урта Азия идарәчесе Аксак Ти - мер гаскәрләре ярдәмендә Күк Урданы яула - ган Туктамыш хан б-н сугыш алып бара. Су - гыш барышында Т.М.б. Күк Урдадан Туктамышны куып җибәрә. Үз хакимиятен нығы - та алмый һәм аксөякләргә таянычын югалта. Т.М.б.кә, башлыча, Ырыс Мөхәммәд вакы - тында күтәрелгән, нәселдән килмәгән әмир - ләр ярдәм итә. 1379 елда Туктамыш Аксак Тимер гаскәрләре һәм аның ягына күчкән Күк Урда әмирләре б-н Т.М.б.не тар-мар итә. Үзенә тугры әмирләре б-н җәзалап үтерелә.

Әд.: Г р е к о в Б.Д., Я к у б о в с к и й А.Ю. Зо - лотая Орда и её падение. М.–Л., 1950; С а ф а р г а - л и е в М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960.

И.Л.Измайлов.

ТИМЕ́Р ХАН (1390 ел тирәсе — 1411), Ал - тын Урда ханы (1411), *Тимер Котлыгъ ханның* улы. *Булат Солтан хан* вафатыннан соң Иде - гәй ярдәмендә Алтын Урда тәхетенә утыра. Идегәй хакимиятенең көчәюе б-н риза булма - ган аксөякләр фетнә күтәрәләр, анда Т.х. да катнаша (аксөякләр Т.х. хакимиятен кайта - руны сылтау итәләр). Кораллы бәрелешләр - дән соң Идегәй Харәзем тарафына куыла. Т.х. һәм Идегәйнең бер-берсенә каршы көрә - ше вакытында Алтын Урдада хакимиятне Туктамыш ханның улы *Җәләлетдин хан* үз кулына ала. Аксөякләр фетнәсе нәтиҗәсендә һәлак була.

Әд.: Г р е к о в Б.Д., Я к у б о в с к и й А.Ю. Зо - лотая Орда и её падение. М.–Л., 1950; С а ф а р г а - л и е в М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960.

И.Л.Измайлов.

ТИМЕ́Р ХУҖА́ ХАН (?–1361), Алтын Ур - да ханы (1361). Сарай әл-Җәдид шәһәрендә фетнә оештыра һәм *Хызыр* ханны бәреп төше - рә. Алтын Урда аксөякләре арасында абруе булмый, Т.Х.х. хакимлеге башкалада гына

таныла. Әмир Мамай аңа каршы чыга. Т.Х.х. Идел арьягына кача, үтертелә.

Әд.: Куликовская битва. М., 1980; М у х а м а д и е в А.Г. Булгаро-татарская монетная система XII–XV вв. М., 1983.

И.Л.Измайлов.

ТИМЕ́Р ЮЛ ВОКЗАЛЫ́, Казан тимер юл станциясендәге пассажирларга хезмәт күрсәтү бинасы, 1895–96 елларда арх. Г.Б.Руш проекты буенча эклектика формаларында, традицион рус кирпеч бизәге ысулы кулланып төзелә. Вокзалның төп бинасы тимер юлның бер ягында урнашкан, вестибюль, көтү заллары, ресторан һәм хезмәт күрсәтү бүлмәләре бар. Таррак һәм түбәнрәк аралыклар б-н тоташтырылган һәм чатыр түбә ябылган,





Казандагы тимер юл вокзалы.
Фоторәсемнәр: 1. 20 йөз башы; 2. 2018.

куб рәвешендәге 3 күләмнән формалашкан үзәкләштерелгән композицияле бина. Үзәк күләм ике 4 кырлы гөмбәз б-н төгәлләнгән. 1992 елгы янгыннан соң, бинаның барлык фасадлары һәм интерьерлары әүвәлге һәм Мәскәү–Казан тимер юлы узган Россия губерналарының гербларын б-н бизәлгән.

Әд.: Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982.

ТИМЕ́Р ЮЛ ТРА́НСПОРТЫ, локомотив көче б-н йөкләрне һәм пассажирларны рельслы юллар буйлап вагоннарда, башлыча урта һәм ерак араларга ташуны гамәлгә ашыручы транспорт төре. Хәзерге Т.ю.т. — тимер юллар челтәренең озакка сузылган үсеше һәм аның аерым элементларының — юлларның, станцияләрнең, вагоннарның, тарту чараларының, сигнализациянең, элемтәнең һ.б.ның камилләшүе нәтиҗәсе. Татарстанда Т.ю.т. 19 йөз ахырыннан үсеш ала. 1860 елларда, көньяк-көнчыгыш тарафка Казан аша тимер юл төзү хокукына ирешү өчен озак дәвам иткән көрәштән соң, Мәскәү–Рязань тимер юлы җәмгыяте Казаннан Рязань, Рузаевка һәм Алатырь аша Мәскәүгә тимер юл линиясе проектын эшли башлый. Линия төзелеше 1891–93 тә алып барыла, соңрак (1895–96 да) Казанда *тимер юл вокзалы* төзелә. 1896 ның 22 декабрендә даими пассажирлар һәм йөкләр хәрәкәте өчен Мәскәү–Рязань тимер юлының Сасово станциясеннән Зөя станциясенә кадәрге участок, 1894 тә Казаннан Зеленодольскига (хәзер Яшел Үзән) кадәрге участок ачыла; ул вакытта әле Идел аша күпер булмый, пассажирлар һәм йөкләр станцияләргә кадәр пароходлар б-н, кыш кы чорда чаналарда китерелә. Казан–Яшел Үзән участокларында Дары з-ды (хәзер Лагерьная), Аракчино, Красная Горка (Юдино), Торки (Васильево) тукталыш пунктлары ачыла. 1913 тә Зөя станциясе янында Идел аша бер тимер юллы күпер эшли башлый. Романовлар нәселенең 300 еллыгы хөрмәтенә ул Романовлар күпере дип атала (инженер-арх. Н.А.Белелюбский проекты). 1957 дә шунда ук икенче күпер төзелү б-н (Романовлар күпере реконструкцияләнә), поездлар ике яклап хәрәкәт итә башлый. 1911–13 тә Кама-Идел коммерция банкы хисабына хәзерге Татарстан терр-ясендә икенче тимер юл — Идел-Бөгелмә тимер юлы сузыла. 1913 тә Казан губернасы терр-ясендә барлык тимер юлларның озынлыгы 249 *км* тәшкил итә, Т.ю.т. б-н 140 мең *т* йөк озатыла. 1918–19 да, 1912 дән төзелә башлаган Арзамас-Шихран (Канаш) юлы һәм Әгерҗе-Воткинск тармагы б-н Юдино-Дружинино участогы файдалануга тапшырылу нәтиҗәсендә Казан–Екатеринбург тимер юл линиясен (ул вакытта Казанбург линиясе) төзү төгәлләнә.

Окт. рев-циясеннән соң Мәскәү–Казан тимер юлында эшчеләр контроле урнаштырыла, 1918 нең июнендә юл национализацияләнә. Гражданнар сугышы чорында җирле тимер юллар сугыш хәрәкәтләре зонасына әләгә һәм хәрби частьлар хәрәкәт итүендә һәм фронт яны терр-яләрен тәэмин итүдә аеруча мөһим роль уйный. Сугыш хәрәкәтләре нәтиҗәсендә линиянең Зөядән Дружининога кадәрге участогы яраксыз хәлгә килә, күперләр, ш.и. Зөя янындагы күпер зарарлана. Сугыш тәмамлангач, торгызу эшләре башкарыла. 1924 тә Казан–Свердловск тимер юл линиясе кабат сафка баса, 1927 дә Яшел Үзән–Йошкар-Ола линиясе файдалануга тапшырыла. Юл, башлыча, транзит бурычларын үти. 1920–30 елларда тимер юлларның йөкләр ташу һәм үткәрү мөкинлекләре арттырыла, Юдино, Әгерҗе, Канаш станцияләренең техник җиһазландырылуы көчәйтелә. Юдино станциясендә сортировка үзәге корыла (1926), паровозлар депосының таш бинасы (1926), яңа вокзал (1930) файдалануга тапшырыла; Бөгелмә станциясендә вокзал, паровозлар һәм вагоннар ремонтлау депосы төзелә (1926). 1928 дә Казан янында көньяктан узу юлы (Казан–Дербышки линиясе) төзелә, нәтиҗәдә элек тупикта калган Казан станциясеннән турыдан-туры көнчыгыш юнәлештә төп магистральгә чыгу мөмкинлеге ирешелә. Бу вакытта респ-ка терр-ясендә файдаланулы тимер юлларның озынлыгы 346 *км* (елга 703 мең *т* йөкләр ташыла), 1939 да 392 *км* (1469 мең *т*) тәшкил итә. 1940 та Канаш–Чабаксар линиясе файдаланугa тапшырыла. Бөек Ватан сугышы елларында тимер юллар үсеше дәвам итә. Бу чорда 19 кисешү урыны (разъезд), Юдино–Бөреле участогында 40 *км* лык арада автоблокировка төзелә һәм файдалануга тапшырыла, 69 аеру пунктында станция юллары озайтыла, иң мөһим участоклардагы юлларда капиталь ремонт уздырыла, су б-н тәэмин ителәш яхшыртыла, паровоз хуҗалыгының ремонт һәм экипировка базалары киңәйтелә. 1943 тә Зөя–Сельд юлы участогы (яңа Сталинград–Саратов–Ульянов–Зөя линиясенең бер өлеше) төзелә. Линияләрнең тотрыклырак эшен тәэмин итү, үткәрү мөмкинлекләрен макс. файдалану өчен, сугыш башлангач поездлар хәрәкәтенең хәрби графигы гамәлгә кертелә, тимер юллар сугыш чоры хәленә күчерелә. Т.ю.т. ягулык һәм чимал ташуны, көнбатыштан көнчыгышка эвакуацияләү, мобилизацияләнгән контингентларны, сугыш техникасын, фронт ихтыяҗларын тәэмин итү өчен кирәк-яракларны күчерү эшләрен башкара. 1942 нең апрелендә Юдино станциясе тимер юлчылары тарафыннан Сталинград янындагы сугышларда, Польшаны азат итүдә һ.б. катнашкан «Кызыл Татарстан» бронепоезды төзелә һәм шәхси состав б-н комплектацияләнә. Сугыштан соңгы чорда (1946–50) Дружинино–Муром линиясе (1046 *км*) автоблокировка б-н, 11 станция радио элемтәсе б-н җиһазландырыла, станцияләрдә пассажирлар биналары төзелә, диспетчерлык үзәкләштерү системасы корыла башлый. 1950 елларга кадәр паровозлар файдаланыла, шуннан соң тепловозлар, 1970 ел-лар башыннан электровозлар куәтеннән файдалануга күчелә. 1971 дә Бөгелмә–Круглое Поле тармагында поездлар хәрәкәте ачыла, соңрак тармак Әгерҗе станциясенә кадәр озайтыла. Яңа линияләр төзү б-н бер үк вакытта элеккеләре техник яктан реконструкцияләнә: районара төп магистральләр ике юллы итеп корыла, электрлаштырыла (төп Канаш–Юдино–Кизнер юлы участоклары, 351 *км*), сигналлар бирү һәм блокировкалау чаралары б-н җиһазландырыла; төп юллар озынлыгының өчтән бер өлешендә хәрәкәт б-н үзәкләштерелгән диспетчерлык хезмәте идарә итә. Ике күчәрле вагоннар 60–125 *т* йөк күтәрүле 4,6 һәм 8 күчәрле, зур күләмдә йөк ташуга сәләтле вагоннар б-н алмаштырыла. Барлык вагоннар автомат тагылыш системасы һәм автотормозлар б-н җиһазландырыла. Тимер юлларның локомотивлар паркы ку әгле электровозлар б-н яңартыла. Пассажирлар поездларының тизлеге, ш.у. берничә тапкыр йөк ташучы составларның авырлыгы арта. Пассажирларны ташу кондиционерлар б-н җиһазландырылган уңайлы металл вагоннарда башкарыла. Тимер юллар магистральләре респ-каның 19 районы терр-ясеннән уза. Татарстанның төньяк өлешендә тимер юллар Түбән Вязовой (Карамалы Тау), Яшел Үзән, Казан, Кукмара һәм Әгерҗе (Мәскәү–Екатеринбург тимер юллар магистрале участогы), көньяк өлешендә Нурлат, Бөгелмә һәм Урыссу (Мәскәү–Чиләбе тимер юллар магистрале участогы) аша үтә. Әлеге ике юл респ-каның көнбатышында

Зөя–Буа–Ульянов, көнчыгышында Әгерҗе–Акбаш тимер юллар линияләре б-н тоташтырылган. Татарстанның төп тимер юл төйнәлешләре — Юдино, Яшел Үзән, Әгерҗе, Круглое Поле (Чаллы янында). ТР терр-ясендә тимер юл буйлап пассажирлар һәм йөк ташу Горький (төбәк буенча үзәге Казан шәһәрендә) һәм Куйбышев тимер юллар «РЖД» АҖ, «Содружество» АҖ (шәһәр яны хәрәкәте), сәнәгать Т.ю.т. пр-тиеләре тарафыннан тормышка ашырыла. Респ-кадагы тимер юлларның тулай озынлыгы 1494,4 *км*, ш.и. гомуми кулланылыштагы тимер юллар — 876,8 *км*; ерак араларга һәм шәһәр янында пассажирлар ташу күләме — 7,9 млн. кеше, йөк ташу 15,2 млн. *т* тәшкил итә (2016). Ш.у.к. *Горький тимер юлының Казан бүлеге*.

Әд.: Карягин Д. По городам Советской Татарии. Бугульма. К., 1963; Город счастливой судьбы: Ист. очерк. К., 1981; 100-летний юбилей Казанской железной дороги. К., 1993; Свод памятников истории и культуры Республики Татарстан. Т. 1. Административные районы. К., 1999; Город мой любимый: 70-летию Зеленодольска посвящается. Зеленодольск, 2002.

А.А.Турцева, Г.Я.Мәүлетова.

ТИМЕ́Р-БЕТО́Н, корыч арматура һәм бетон б-н ныгытылган композицион төзелеш материалы. Т.-б.да арматура, башлыча, сузу, ә бетон — кысу көченә ия һәм арматураны тутыгыдудан саклый. Т.-б. корылмалар нык, утка чыдам, атм. йогынтысына бирешми, тотрыклы. Т.-б.га беренче патент 1867 елда Франциядә бирелә. Т.-б. Россиядә 1886 дан кулланыла. Казан губернасында күперләр, коллекторлар һ.б. корылмалар төзегәндә файдаланыла. 20 йөзнең 2 нче яртысыннан гражданлык һәм сәнәгать төзелешендә төп материалларның берсе. ТРда Т.-б. авыр, җи ңел, күзәнәкле, көчәйтелгән ныклыктагы, кызуга чыдам бетоннардан җитештерелә. Алдан арматура механик яки электромеханик сузу юлы б-н ныгытыла. ТРдагы пр-тиеләрнең егәрлеге елына 2 млн. $м^3$ тан артык Т.-б. җитештерергә мөмкинлек бирә. Бу респ-када җитештерелгән барлык төзелеш материаллары күләменең якынча 75% ын тәшкил итә.

ТИМЕ́Р-БЕТО́Н КОНСТРУ́КЦИЯЛӘР, хәзерге төзелештә кулланыла торган конструкцияләрнең төп төрләреннән берсе. Монолит (төзелеш мәйданында әзерләнә), җыелма (заводта эшләнә), җыелма-монолит төрләргә бүленә. Монолит Т.-б.к., гадәттә, аерым кисәкләргә бүлү кыенга туры килгән биналарда һәм корылмаларда, бер үк төрдән һәм кабатлануы ихтимал булмаган конструкцияләрдә кулланыла. Төрле максатлардагы җыелма Т.-б.к. — нигезләр (субайлар, блоклар, подвал диварлары панельләре), каркаслар (колонналар, өрлекләр, кизәлекләр, мачалар, фермалар), диварлар (дивар панельләре, бүлү диварлары), биналарның катара түшәмнәре һәм түбәлекләре (панельләр, плитәләр һәм түшәмнәр), баскычлар (баскыч басмалары һәм мәйданчыклары), инженерлык корылмалары (күпер терәкләре һәм торакларының, су үткәрү торбалары, туннельләр кору өчен өрлекләр һәм тюбинглар, юллар һәм аэродромнар җәю плитәләре, шпаллар, электр баганалары һ.б.ш.) аеруча киң файдаланыла. Монтажлау вакытында конструкция элементлары монолитлаштыру яки эретеп ябыштыру юлы б-н беркетелә. Т.-б.к. кулланыу зур конструктив мөмкинлекләр ача, башкарылган эшләрнең төп өлешен махсус җиһазландырылган заводка күчерергә мөмкинлек бирә, төзелешне монтажлауга һәм җыюга китерә. Т.-б.к.нең технологик процессы өч төпысул — урыныннан күчми торган җиһазда күчеп йөрүче агрегат-конвейр, күчеп йөрүче җиһазда үзгәрешсез эшләүче конвейр һәм стенд ысуллары б-н оештырыла.

ТРда Т.-б.к. һәм эре панельле йортлар төзелешенең 50 дән артык заводы, цехы, полигоннары, комб-тлары бар (Казанда, Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт, Бөгелмә, Алабуга, Зәй, Чистай, Азнакайда). Ш.у.к. *Тимер-бетон*.

ТИМЕРАЯКТА́ ФИГУ́РАЛЫ ШУУ́, тимераякта шуу спорты төре. Ялгыз (ирләр һәм хатын-кызлар), парлы шуу, спорт биюләрен, төркемләп синхрон фигуралы шууны (рәсми төстә 1994 елда таныла) үз эченә ала. Т.ф.ш. буенча Казан беренчелегенә беренче ярыш 1913 тә уза (оештыручысы — «Көч һәм сәламәтлек» спорт җәмгыяте). Татарстанда ялгыз һәм парлы шуу, спорт биюләре Т.ф.ш. дисциплинасы буларак 1940 еллардан үсеш ала (башлап җибәрүчеләре — Ф.Ю.*Йосыпов*, В.А.Козлов), синхрон шуу — 1992 дән. 1950–80 елларда Т.ф.ш. «Медик», «Фән», «Спартак», «Труд», «Буревестник» ирекле спорт җәмгыятьләре тарафыннан җәелдерелә. Татарстанда Т.ф.ш.ның үсешенә 1967 дә нигезләнгән (1980 нән махсуслаштырылган) «Труд» ирекле спорт җәмгыяте каршындагы (директоры И.А.Андрушко) Т.ф.ш. буенча олимпия резервындагы Респ-ка Балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе коллективы шактый өлеш кертә (2018 дән ТР Спорт министрлыгы карамагындагы «Республика олимпия резервындагы тимераякта фигуралы шуу һәм шорт-трек буенча спорт мәктәбе» дәүләт бюджет учреждениесе). Мәктәп каршында тимераякта синхрон шуу командалары эшли: «Татарстан» — 1992 дә (спорт мастерлары категориясе), «Идел» — 1994 тә (спорт мастерлыгына канд. категориясе), «Казаночка» — 2010 да (1 разряд категориясе); алар берничә тапкыр Россия, Европа, дөнья чемпионатлары һәм беренчелекләрендә, Идел буе, дөнья кубоклары һәм төрле халыкара турнирларда катнашалар, җиңүчеләр һәм призёрлар булалар. ТРның иң яхшы спортчылары — чемпионатларда (ш.и. яшүсмерләр), Профсоюзларның ирекле спорт җәмгыятьләренең үзәк советларында, РСФСР, СССР, Европа, дөнья халыклары спартакиадаларында, олимпия уеннарында җиңүчеләр һәм медаль алучылар — И.А.*Андрушко*, Е.А.Безменов, В.И.Галимбәков, Ю.В.*Голунков*, Е.С.Горбунова, Б.Л.Еляшевич, Г.Г.Зайцев, И.Г.Извеков, Д.Н.Рәшитов, Е.М.Тарасова, А.В.*Фадеев*, Р.Г.Хәйруллин, Ф.С.Юсупов. Иң яхшы тренерлар — Т.Е.Александрова, Ю.А.Баландин, М.В.*Галиев*, В.Д.Головлёв, Д.В.Гурикова, И.П.Добрынина, Г.И.Зайцев, Э.Ф.Мәҗитов, В.Н.Павлов, М.П.Павлова, Д.М.Пичугина, Е.А.Полысалова, Р.В.Семёнова, Г.С.*Тарасов*, Е.Н.Тарасова, М.Л.Тарасова, Н.Н.Шанталинская; хореографлар — Е.М.Антонова, А.К.Багавова, А.Р.Канәфиева, А.Н.Шәрифуллина.

1970 тән Казанда «Идел» турниры уздырыла (2006 дан — Бөтенроссия турниры, Г.С.Тарасов истәлегенә).

2018 елга Татарстанда Т.ф.ш. 20 Балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә (Әлмәт, Әгер жө, Буа, Алабуга, Зәй, Яшел Үзән, Казан, Мамадыш, Минзәлә, Чаллы, Чистай, Кукмара штп, Актаныш), «Баско» боз аренасында, «Ватан» спорт-сәламәтләндерү комплексы секциясендә, Спорт сараенда (барысы да — Казан), «Нарат» СКда (Саба р-ны) җәелдерелә. Шөгыльләнүчеләрнең гомуми саны 3 меңнән артык кеше. 2009 да ТР Т.ф.ш. федерациясе оештырыла (президенты И.Г.Измайлов, 2016 дан Э.А.Быстрицкая).

Н.Д.Бобырев.

ТИМЕРАЯКТА́ ШУУ́ СПОРТЫ́, бозда тимераякта шуу. 3 төргә бүленә: тиз шуу, *тимераякта фигуралы шуу*, шор-трек. Ярышларның уздырылышы: тиз шуу буенча — ирләр өчен 100, 500, 1000, 1500, 5000, 10000 *м* лы дистанцияләрдә, команда узышында (4 катнашучы — 3200 *м*), хатын-кызлар өчен 500, 1000, 1500, 3000, 5000 *м* лы дистанцияләрдә, команда узышуында (4 катнашучы — 2400 *м*); шор-трек буенча — 500, 1000, 1500, 3000 *м* лы дистанцияләрдә, 4×3000 *м* лы эстафетада (ирләр һәм хатын-кызлар өчен). Күп төр ярышларда җиңүче барлык дистанцияләрдә җыелган очколар суммасы буенча билгеләнә. Казанда тимераякта шуу 1910 нан урта уку йортлары, Казан ун-ты, «Яхт-клуб» спорт җәмгыяте тарафыннан җәелдерелә башлый. Тиз шуу буенча беренче чемпионат Казанда 1912 дә уза (чемпион — В.Ананьев). Тиз шуу буенча ТАССР җыелма командасы Идел буендагы биш респ-ка (3 урын, 1937), тугыз милли респ-ка (2 нче урын, 1939; 1 нче — 1940; 3 нче — 1946), РСФСР халыклары (3 нче урын, 1957) спартакиадаларында; кышкы студентлар уеннарында (3 нче урын, 1959; 1 нче — 1960); РСФСРның сигез шәһәре матчында (3 нче урын, 1952); «Труд» ирекле спорт җәмгыяте үзәк советы беренчелекләрендә (3 нче урын, 1965); Идел буе автономияле респ-каларының матч очрашуларында (2 нче урын, 1961–64; 1 нче — 1965–69) медальләр ала. Тиз шууны җәелдерүчеләр: Респ-ка советлары — «Динамо» физкультура спорт җәмгыяте, «Зенит», «Труд», «Спартак», «Буревестник», «Трудовые резервы» ирекле спорт җәмгыятьләре; Казан, Чаллы, Азнакай, Яшел Үзән, Түбән Кама, Чистай шәһәрләрендә Профсоюзларның физкультура-спорт җәмгыяте Татарстан Респ-ка советы. Иң яхшы спортчылар, дөнья, Европа, СССР, РФ, ТР, Профсозларның ирекле спорт җәмгыяте Респ-ка советлары һәм үзәкләре беренчелекләрендә (ш.и. яшүсмерләр һәм яшьләр) катнашучылар һәм медаль алучылар — М.А.Абрашина, Э.И.Гыймадетдинов, А.П.Гомәрова, И.Ю.Гусев, М.М.Домрачёва, Р.Р.*Зәһидуллин*, О.Н.Зубаков, А.С.Ломтев, Л.В.Ляпунова, Е.Д.Масленникова, И.Михайлова, Г.Г.Мортазина, Д.Плешаков, И.Пронин, Р.Н.Раузетдинова, В.И.Рысьев, Р.Ф.Сад -

ретдинов, В.А.Тихонов, М.М.Унгвицкий, Н.С.Чиков. Иң яхшы тренерлар: М.М.Домрачева, Е.А.Җарков, О.Н.Зубаков, В.А.Кирьянов, В.В.Кирьянов, В.А.Корсаков, И.Ю.Латинский, А.С.Ломтев, Т.И.Нәбиева, Н.Н.Николаев, Л.А.Рубцова, В.И.Рысьев, М.М.Унгвицкий, А.Е.Чемоданов, Н.С.Чиков. Шор-трек ТРда 1981 дән җәелдерелә, чемпионатлар 2003 тән уздырыла. Иң яхшы спортчылар — Н.Мутовкина, Е.Д.Нәбиева. Халыкара категорияле судья — З.Н.*Усманов*.

ТИМЕРБА́ЕВ Владимир Нури улы (8.12.1941, Ташкент), биохимик, мед. фән. д-ры (1997), проф. (2000). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1965), шунда ук, биохимия кафедрасында эшли, 2003–04 елларда гомуми һәм органик химия каф. мөдире, каф. профессоры (2004–13). Проф. Д.М.*Зөбәеров* шәкерте. Хезмәтләре кан оешу биохимиясенә карый. Т. кан оешу биохимик реакцияләре каскадын күзәнәкләрнең мембраналарының фаза структурасын күзәнәкләрнең Ca^{2+}- мобилизацияләүче сигнал механизмнары аша этелеш биреп үзгәртү юлы б-н кузгату концепциясен эшли (төрле авырулар вакытында кан оешу-бозылу механизмнарын аңлата).

Х е з м.: Функциональная концепция инициирования свёртывания крови клеточными мембранами // Гематология и трансфузиология. 1991. Т. 36, № 4 (автордаш); Медицинская биохимия: Практикум. К., 2001 (автордаш); Основы биофизической химии: Избр. лекции. К., 2005.

Әд.: Профессор Владимир Нуреевич Тимербаев // Казан. мед. журн. 2006. № 6.

ТИМЕРБА́ЕВ Марат Равил улы (4.11.1961, Казан), математик, физика-матем. фән. д-ры (2008). 1984 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук, хисаплау математикасы кафедрасында эшли. Хезмәтләре функциональ фәзаларга, матем. физиканың чик мәсьәләләренә һәм аларны санлы чишү алымнарына карый. Т. үлчәнешле Соболев фәзаларын тикшерә: шома булмаган чикле өлкәләр өчен кертелмәләр теоремаларын исбатлый; аларда кулланылган үлчәү системалы шома функцияләрнең тыгызлыгын билгели; Дирихле һәм Нейман кырый мәсь әләләре өчен элеккеге рәвешен үзгәртә торган эллиптик тигезләмәләр чишелешен бәяли. Коэффициентлары беренчел кыйммәтен югалта торган кырый эллиптик мәсь әләләр (җыелучанлык тизлеген бәяли) һәм элеккеге рәвешен үзгәртә торган мәсь әләләр (үзенчәлекне мультипликатив аерып алу нигезендә) өчен ахыргы элементлар алымын төзи; эллиптик мәсь әләләр өчен өлкәне декомпозицияләү алымын тикшерә (өлкә эчендә элеккеге рәвешне үзгәртеп).

Х е з м.: Теоремы вложения весовых пространств Соболева // Изв. вузов. Математика. 1991. № 9; Мультипликативное выделение особенности в схемах МКЭ для эллиптических вырождающихся уравнений // Дифференциальные уравнения. 2000. Т. 52, № 7; Весовые оценки решения задачи Дирихле с анизотропным вырождением на части границы // Изв. вузов. Математика. 2003. № 1.

ТИМЕРБУЛА́ТОВ Шамил Харис улы (25.9.1950, Казан — 30.5.2013, шунда ук), композитор, педагог, ТР һәм РФнең атказ. сәнгать эшлеклесе (1995, 2005). Композиторлар берлеге әгъзасы (1980). 1978 елда Казан консерваториясен (А.Б.Луповта композиция классы) тәмамлый. 1976–78 дә — Казан музыка уч-ще сендә, 1978–80 дә — Казан консерваториясендә, 1980 нән 1 нче балалар музыка мәктәбендә укыта. Композитор буларак Т. масштаблы әсәрләр иҗат итәргә омтылуы б-н аерылып тора. Аның иҗатында яшәешнең катлаулы проблемалары, татар халкы тарихы чагылыш таба. Т.ның гражданлык позициясе программ симфонияләрдә гәүдәләнә: тенор, камера оркестры һәм бәрмә уен кораллары өчен 1 нче — «Бомбаны яшерегез!» («Спрячьте бомбу!»), 2 нче — «Җир сулышы» («Дыхание земли»), 3 нче — «Гасырлар чоры» («Время столетий») симфонияләре, солист, хор һәм оркестр өчен Г.Тукай һәм Р.Фәйзуллин шигырьләренә 4 нче «Ышаныч» («Доверие») симф.-ораториясе, 5 нче «Сугыш һәм хатын-кыз язмышы» («Женский лик Победы») симфониясе. 6 нчы «Сак-Сок» симфониясенең идеясе шул ук исем. татар бәетенең сюжеты б-н бәйле. Сөембикә ханбикәнең трагик образы (Р.Батулла романы буенча) гәүдәләнеш тапкан симф. картиналарда татар халкының тарихы җанлана. Т. — татар музыкасында оркестр б-н баян өчен беренче концерт авторы. Композитор иҗатының үз стилен барлыкка китерүче әһәмиятле өлеше — концептуаль һәм драматургик аспектлар ягыннан аның симф. әсәрләренә якын торган камера-инструменталь музыкасы. Т.ның «Дусларым» (Э.Шәрифуллина шигырьләре), «Урман чишмәсе» (Г.Зәйнашева шигырьләре), «Күңелем яшәргә ашкына» (Р.Фәйзуллин шигырьләре), «Әлли-бәлли» (Р.Вәлиев шигырьләре) һ.б. вокаль әсәрләре; балалар өчен «Яланда» (Р.Фәйзуллин шигырьләре), «Табигать кочагында» (Р.Корбанов шигырьләре), «Каурыйлар» (Г.Зәйнашева шигырьләре) җырлары һәм вокаль цикллары популярлык казана. Т. иҗатында индивидуальлек, интонацион эчтәлек, татар-мишәрләр фольклорының мәгънәле, тәэсирле зур потенциалын ачып, үзлегеннән үстергән халык көйләре традицияләренә нык таяну күзәтелә. Т. композитор каләменә хас төрле стиль элементларын һәм принципларын табигый яраштыра белә. Аның әсәрләре кискен каршылыклы образларны чагыштырып бирүгә нигезләнгән киеренке, драматик үсешкә ия булулары б-н аерылып тора. Аларда эпос һәм лирика, драматизм һәм хыял, медитация һәм ихтыяр көче, эчкерсезлек һәм гротеск бер сәнгати киңлектә бирелә. Т. әсәрләре киң танылу ала, уку-укыту һәм концерт репертуарына кертелә, Россия һәм чит илләрдә яңгырый.



Ш.Х.Тимербулатов.

Төп әсәрләре: симф. әсәрләр — 6 симф. (1978, 1994, 2000, 2006, 2007, 2008), оркестр б-н фортепиано өчен 2 концерт (№ 1, 2; 2000, 2008), Оркестр б-н скрипка өчен концерт (2009), Р.Батулла романнары буенча «Сөембикә — Казан ханбикәсе», «Гашыйклар бакчасы» (2001, 2002) симф. картиналары; халык музыка уен кораллары оркестры (2007), баян б-н оркестр (1978), думбра б-н оркестр (2005) һ.б. өчен концертлар, концерт пьесалары һәм фантазияләре; камера-инструменталь әсәрләр — Ике рояль өчен концертино (1972); виолончель һәм фортепиано (1973), скрипка һәм фортепиано (1985) өчен сонаталар; Тынлы агач музыка уен кораллары өчен квартет (1974), Кыллы квартет (1975), фортепиано өчен «Урман багулары» («Лесные гадания») пьесалар циклы (1977); инструменталь пьесалар, җырлар, романслар, татар халык җырлары эшкәртмәләре, драматик спектакльләргә музыка һ.б.

Әд.: С ә й д ә ш е в а З.Н. Чын татарча милли көй... // Казан утлары. 2006. № 10; Л у п п о в А.Б. Шамиль Тимербулатов // Композиторы и музыковеды Советского Татарстана. К., 1986; Ф а й з у л а е в а М. Дорогой поиска // Советская музыка. 1987. № 3; А л м а з о в а Т.А. Шамиль Тимербулатов // Композиторы Татарстана. М., 2009.

Т.А.Алмазова.

ТИМЕРГАЗИ́ЕВ Минсәлим Вәли әхмәт улы (28.1.1950, Төмән өлкәсе, Ялутор р-ны Кызылтъяр а.), гамәли-бизәлеш сәнгате рәссамы, сөяккә уеп бизәк ясаучы оста. 1967–69 да Тубыл сәнгати уеп бизәлгән сөяк әйберләр ф-касы каршындагы сәнгать студиясендә А.И.Метелевта шөгыльләнә, 1985 кә кадәр шул ук фабрикада уеп бизәк төшерүче булып эшли. 1977 дә Абрамцево сәнгать-сәнәгать уч-щесенең квалификация күтәрү курсларында А.М.Ферапонтовада укый (Мәскәү өлкәсенең Хотьково ш.). 1980–89 да Тубыл шәһәрендә балалар сәнгать мәктәбендә укыта. 1991 дә уллары б-н берлектә «Минсәлим» сөяккә уеп бизәк ясау артелен оештыра. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1983).

Т. иҗаты Тубыл сөяккә уеп бизәк ясау һөнәренең үзенчәлекле традицияләре нигезендә үсеш ала. Россиядә һәм чит илләрдә сөяктән уникаль кечкенә, нәфис сыннар ясау остасы буларак таныла. Хезмәтләрендә автор-лык башлангычы, шәрекъ стиле һәм милли образлылык өстенлек итә. Эшләнмәләрне



М.В.Тимергазиев. «Кошлар очыручылар». Поши мөгезе, сөяк, агач. Кыру станогында агачка һәм сөяккә уеп ясалган күләмле бизәк, уеплау. 1996.

тоташ сөякләрдән (мамонтның казык тешләре һәм скелеты, казылмаларда табыла торган хайван сөякләре, поши һәм болан мөгезе, кошларның шүре сөяге һәм кашалот тешләре һ.б.) кисеп ала һәм кыру станогында уеплангән зур күләмле, рельефлы бизәкләр төшерә; сөякне агач, ат кылы, сәйләп, металл б-н аралаштырып, кайвакыт төсләрдән файдаланып, композицияләр төзи. Көнбатыш Себердәге җирле халыкның (хант, манси, себер татарлары) риваятьләренә, хикәятләренә нигезләнгән жанрлы, күпфигуралы композицияләр, дини сюжетлар, татар фольклоры образлары авторы: «Шүрәле» (вариантлар, 1970–85), «Татар кызы» (1973), «Шук», «Бию», «Болан булып уйнау» (барысы да — 1974), «Болан өстендә» (1982), «Кошлар очыручылар», «Көймә», «Вулкан» (барысы да — 1996), «Көй» (1998), «Намаз», «Күчем» (икесе дә — 2005), «Югорлар җире» сериялә-ре (1993) һ.б. Сургут шәһәрендәге Кара төлке һәйкәле (шәһәр гербында сурәтләнгән) авторы (2007, бронза).

Дижон шәһәрендә ел саен уздырылучы халыкара ярминкә (Франция, 2002), 5 нче Бөтенсебер нәфис сәнгать (Новосибирск ш., 2003), 4 нче Халыкара агач скульптура симпозиумы (Бриенц ш., Швейцария, 2006), 2 нче «Традицияләр һәм заман» Мәскәү халыкара фестивале (2008) һ.б. күргәзмәләрдә катнаша. Шәхси күргәзмәләре Сургут (1995), Тубыл (2001), Төмән (2009) һ.б. шәһәрләрдә уздырыла.

Әсәрләре Рус музеенда (С.-Петербург), Дәүләт Тарих музеенда (Мәскәү), «Казан» милли мәдәният үзәгендә, Тубыл тарих-архит-ра музеенда, Екатеринбург һәм Төмән сынлы сәнгать музейларында саклана. Т.нең иҗаты турында «Елмаю бүләк итәм» (1984, реж. Ю.Н.Малашин, «Новосибирсктелефильм»), «Себер әкиятчесе» (2006, реж. К.Артюхов, «Лентелефильм») документаль фильмнары төшерелә. СССР ВДНХсының көмеш һәм бронза медальләре б-н бүләкләнә.

Әд.: Валов А.А. Тобольская резная кость. Свердловск, 1987; Быкова А.Г., Рыженко В.Г. Тобольский косторез Минсалим Тимергазеев // Культура Западной Сибири: История и современность: Курс лекций. Омск, 2002. Гл. 27; Тобольский косторез Мирсалим Тимергазеев. Тобольск, 2004.

Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.

ТИМЕРГА́ЗИН Кадыйр Рәхим улы (5.2.1913, Пермь губ., Шадринск өязе Сабактыкүл а. — 4.4.1963, Мәскәү, Уфа ш. җирләнә), геолог-нефтьче, минерал. фән. д-ры (1958), проф. (1959), РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1957). Казан ун-тын тәмамлый (1935), Башкорт нефть комб-тын да эшли (1935–46). Уфа нефть фәнни-тикшеренү ин-тын (хәзер Баш НИПИнефть) нигезләүчеләрнең берсе һәм аның директоры (1947), литология һәм геохимия лаб-ясе мөдире (1947–50), геол. бүлеге башлыгы (1950–51). 1951 елда СССР ФА Башкорт ф-лын һәм Тау геологиясе ин-тын оештыручыларның берсе. Хезмәтләре палеозой һәм кембрийгача чор стратиграфиясенә, нефть геологиясенә карый. Т. палеозой һәм кембрийгача чор утырмаларының беренче стратиграфик схемасын һәм БАССРның көнбатыш һәм ТАССРның көнчыгыш өлешләре терр-ляре кристаллик нигезе картасын төзи; биредә нефть чыганакларын ачу мөмкинлеген нигезли. Баулы, Туймазы һ.б. нефть чыганакларын беренче ачучылардан. 1959–63 тә РСФСР ЮС һәм БАССР ЮС депутаты. Бөек Ватан сугышында катнаша. Кызыл Йолдыз, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Верхний докембрий Урало-Поволжской области // Стратиграфия СССР: Верхний докембрий. М., 1963. Т. 2 (автордаш).

Әд.: Профессор К.Р.Тимергазин в воспоминаниях современников. Уфа, 1984.

ТИМЕРГАЛИ́ЕВ Корбан Тимергали улы (19.9.1924, Мамадыш кантоны, хәзер Саба р-ны Килдебәк а. — 19.2.1982, Әлмәт ш.), Дан орденының тулы кавалеры (27.7.1944, 10.2.1945, 15.5.1946), кече сержант. Туган авылында колхозда эшли. 1942 елның августыннан Кызыл Армия сафларында. 1943 нең маеннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, пулемётчы, 504 нче аерым пулемёт-артиллерия батальонының (48 нче һәм 33 нче армияләрнең 115 нче ныгытылган р-ны) расчёт командиры. Үзәк һәм 1 нче Белоруссия фронты гаскәрләре составында Чернигов-Припять, Гомель-Речица (икесе дә 1943 тә) һәм Берлин (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 24 июнендә Жлобин шәһәреннән (Белоруссия ССРның Гомель өлкәсе) төньяк-көнбатыштарак барган сугышларда (дошман уты астында сугыш кырыннан каты яраланган рота командирын һәм 10 яраланган кораллы сугышчыны алып чыга); 1945 нең 14–15 гыйнварында Гурна торак пункты (Солец шәһәреннән төньяктарак, Польша) өчен барган сугышларда (пулемёттан атып, дошманның 2 пулемёт ноктасын сафтан чыгара, моның б-н ул үзенең ротасына алга таба юл ача; дошман траншеясына бәреп кереп, берничә немец солдатын юк итә, танкка каршы граната б-н дзотны җимерә); 1945 нең 22–24 апрелендә Будерозе торак пункты (Губен шәһәреннән төньяктарак, Германия) тирәсендәге Нейсе елгасы аша чыкканда, разведчиклар төркеменнән беренче булып елганы йөзеп чыга, дошман урнашкан җиргә бәреп кереп, граната б-н һәм автоматтан 10 немец солдатын юк итә. Демобилизацияләнгәннән соң (1947), Әлмәттә яши, 1948–81 дә төзелештә прораб булып эшли. Октябрь Революциясе ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Т. туган авылдагы урта мәктәп аның исемен йөртә.

Әд.: Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

М.З.Хәбибуллин.

ТИМЕРГАЛИ́ЕВ Самат Низаметдин улы (24.3.1959, Саба р-ны Югары Шытсу а.), математик һәм механик, физика-матем. фән. д-ры (2003), проф.(2005). 1981 елда Казан. ун-тын тәмамлый. 1983 тән Кама политехник ин-тында (хәзер Кама инженерлар-икътисад академиясе, Чаллы ш.), гамәли математика каф. мөдире (2004–07), проректор (2007 дән). Хезмәтләре матем. физика тигезләмәләре өчен кырый мәсь әләләргә, сыгылмалы юка сүрүләрнең нәсызыкча теориясендәге матем. проблемаларга карый. Т. күп гөмбәзле өлкәләрдә катнаш типтагы аерым чыгарылмаларда бирелгән дифференциаль тигезләмәләр өчен кырый мәсьәләләрнең чишелүчәнлеген тикшерә, сыгылмалы юка анизотроп сүрүләр өчен нәсызыкча кырый мәсьәләләрнең чишелеше барлыгын исбатлый.



К.Т. Тимергалиев.



Х.С. Тимергалиева.

Хезм.: О существовании решения одной задачи нелинейной теории пологих оболочек // Изв. РАН. Механика твёрдого тела. 1998. № 3 (автордаш); Вариационный метод в проблеме разрешимости краевых задач геометрически нелинейной теории тонких оболочек // Дифференциальные уравнения. 2002. Т. 38, № 4; О существовании решений нелинейных краевых задач для тонких упругих нерегулярных оболочек // Изв. РАН. Механика твёрдого тела. 2007. № 2 (автордаш).

ТИМЕРГАЛИ́ЕВА Хәмдүнә Сәетгали кызы (24.5.1949, БАССРның Борай р-ны Котлыяр а.), җырчы, ТССРның халык артисты (1991). Эстәрлетамак мәдәни-агарту уч-щесен тәмамлый (1971). 1972–76 елларда Яңавыл шәһәрендә Мәдәният йорты хоры җитәкчесе, 1976–98 дә Татар филармониясе солисты. Татар вокаль сәнгатенең күренекле вәкилләреннән берсе. Аның иҗаты эстрада сәхнәсендә татар халык җырлары традицияләрен дәвам итә. Җырчының күпкырлы репертуарында эстрада сәхнәсендә башкару өчен язылган төрле характердагы халык җырлары (лирик җырлардан алып шаян җырларга кадәр) эшкәртмәләре аерым урын алып тора: «Җомга», «Ялгыз каен», «Mahисәрвәр», «Кәләй урамнары», «Эскадрон» һ.б., Р.Яхин, Ф.Әхмәтов, З.Исмәгыйлев, Р.Сәхәүтдинова, Р.Хәсәнов, Р.Тимербаев һ.б. татар һәм башкорт композиторларының вокаль әсәрләре Т. иҗатын яратып тыңлаучылар арасында зур популярлык казана. «Бәллүр былбыл» (Уфа ш., 2008) фестивале лауреаты. Татарстан һәм Россия шәһәрләре буйлап гастрольләрдә йөри.

Ф.Ш.Салитова.

ТИМЕРГА́ЛИН Адлер Камил улы (1.1.1931, Сарман р-ны Иске Минзәләбаш а. — 16.1.2013, Казан, туган авылында җирләнә), язучы, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1981). 1950 елда, Казан ун-тында укыган чагында, советларга каршы пропагандада гаепләнеп кулга алына, ел ярымга психиатрия хастаханәсенә ябыла. 1952 дә Т. Ташкентка китә. Ташкент укытучылар ин-тының физ.-матем. ф-тын тәмамлаганнан соң (1954), туган авылы мәктәбендә укыта. 1956 дан Казанда яши. 1957–69, 1979–91 дә Татарстан китап нәшриятында фәнни-техник әдәбият



А.К.Тимергалин.



З.Т.Тимержанов.

мөхәррире. Әсәрләре 1959 дан басылып килә. Күбесенчә фәнни фантастика һәм ма жара жанрында яза. «Пәһлеван кабере» (1960), «Ике хикәя, бер хыял» (1965), «Ерак планетада» (1967), «Мәңгелек хатирәләр» (1969), «Коҳау ронго-ронго» (1972), «Космостан кунаклар» (1974), «Адашкан йолдыз» (1978), «Таш алиһә» (1980) җыентыклары, юмористик миниатюралар авторы. Татар теленә И.А.Ефремовның «Сердце змеи» («Елан йөрәге», 1969) фантастик повестен, рус фантаст-язучыларының аерым хикәяләрен («Тау күленең серләре» — «Тайны горного озера» җыентыгы, 1969), А.П.Романовның «Конструктор космических кораблей» («Космик корабльләр конструкторы», 1983) документаль повестен, балалар өчен фәнни-популяр басмаларны, урта мәктәпләр өчен физика дәреслекләрен тәр жәмә итә. Техника, астрономия, физика һ.б. буенча рус-татар терминологик сүзлекләрен төзүче, «Миллият сүзлеге: Аңлатмалы сүзлек» (2007), 3 томлы «Миллият сүзлеге» (2017–2018) авторы. Сүзлек татар этномәдәни лексикасын, тарихи үсешенең төрле дәверләрендә халыкның милли һәм универсаль тормыш чынбарлыгын лексикографик тасвирлау нигезендә ижат ителә. [Анда татар теленең фольклор әсәрләрендә, дини-фәлсәфи трактатларда һәм таралышы чикләнгән башка чыганакларда очрый торган, әмма теге яки бу сәбәпләр арка сында элек басылган аңлатмалы сүзлекләргә керми калган тарихи һәм архаик лексикасы теркәлгән.]

Әсәр.: Кайтыр юллар. К., 1981; Кабул булсын теләгең. К., 1990.

Әд.: Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. 2 т.

ТИМЕРГА́ЛИН Рафак Шәех улы (10.10.1928, Минзәлә кантоны Иске Байсар а. — 21.2.1999, Казан), журналист, тәрҗемәче, ТАССР һәм РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1958, 1968). Казан ун-тын (1951), КПСС ҮК каршындагы Югары партия мәктәбен (Мәскәү, 1960) тәмамлый. 1951–54 елларда «Яшь сталинчы» г-тасында мөхәррир урынбасары, 1954–58 дә «*Татарстан яшьләре*» г-тасы мөхәррире, 1960–90 да «Социалистик Татарстан» г-тасында мөхәррир урынбасары, 1991–93 тә Татарстан хәбәрләр агентлыгы баш мөхәррире. Мәкаләләре нең тематикасы: икътисад, а.х., сәнәгать. Татар теленә сәяси әдәбият, публицистика тәрҗемә итә. Медальләр, РСФСР ЮС Президиумының Мактау грамотасы (1988) б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Безнең таңнар. К., 1953; Ил өстендә саф жилләр. К., 1988.

ТИМЕРЖА́НОВ Ефрат Әхмәди улы (20.12.1931, Бөгелмә р-нының Татар Димәкәе а. — 1993, Бөгелмә ш.), тренер (авыр атлетика), РСФСР, СССРның атказ. тренеры (1976, 1989), ТАССРның атказ. физик культура хезмәткәре (1989), Бөтенсоюз категорияле судья (1977). Дәүләт үзәк физик культура ин-тын тәмамлый (Мәскәү, 1965). 1955–63 елларда «Нефтьче» ирекле спорт жәмгыятенең Татарстан советында тренер-инструктор, 1963–77 дә «Труд» ирекле спорт жәмгыятенең районара советы рәисе, 1979 дан «Динамо» физкультура-спорт жәмгыятендә тренер (Бөгелмә). Шәкертләре арасында — Татарстан, СССР, Россиянең берничә тапкыр чемпионнары — И.Зыятдинов, Н.В.Капитонов, Н.А.*Колесников*, Д.Прусов. 2001 дән Бөгелмәдә Т. призына яшүсмерләр арасында респ-ка ярышлары уздырыла.

ТИМЕРЖА́НОВ Зәки Тимержан улы (20.1.1926, Бөгелмә кантоны Акбаш а. — 31.03.2013, Нурлат ш.), нефтьче, Соц. Хезмәт Герое (1971). Хезмәт эшчәнлеген 1940 елда үзенең туган авылында башлап жибәрә. 1948–88 дә «Татнефтегазразведка» трестында: Кырымсарай, Урал, Мөслим нефть эзләү оешмаларында бораулаучы, Норлат нефть эзләү-бораулау идарәсендә торбаларны пресслау операторы, бораулау жи һазларын ремонтлау слесаре. Ульянов, Степно-Озёрск, Нурлат нефть чыганакларын ачуда катнаша. Герой исеме нефть чыгаруның бишьеллык план (1966–70) йөкләмәләрен үтәүдәге югары казанышлары һәм югары техник-икътисади күрсәткечләргә ирешкәне өчен бирелә. Ленин ордены, «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Лениногорск шәһәренең Геройлар аллеясында Т.ның бюсты куелган.

Әд.: Румянцев Е. Тимерзянов Закий Тимерзянович // Герои Социалистического Труда Татарии: Док. очерки. К., 1984. Кн. 2; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003; Гордость земли Нурлатской: Вспомним годы фронтовые. Самара, 2005. Кн. 1; Хакимов М.С., Сафаров М.А. Татары: Воины, труженики, патриоты: Биогр. справ. М., 2006.

ТИМЕР ЖА́НОВ Ринат Зәки улы (5.1.1955, Сарман р-ны Татар Карамалысы а.), милиция генерал-майоры (1999), ТРның, РФнең атказ. эчке эшләр органнары хезмәткәре (2001, 2007). СССР Эчке эшләр министрлыгы академиясен тәмамлый (Мәскәү, 1990). 1978–83 елларда ТАССРның Октябрь р-ны эчке эшләр бүлегенең балигъ булмаганнар б-н эшләү инспекциясе башлыгы, 1983–88 дә районның эчке эшләр бүлеге башлыгы. 1990 нан ТССР, ТР Эчке эшләр министрлыгында: 1991–94 тә жәмәгать куркынычсызлыгы хезмәте бүлеге башлыгы, 1994–95 тә Милициянең махсус хезмәтләр идарәсе башлыгы урынбасары, 1995–97 дә башлыгы, 1997–98 дә ТР хакимият органнары объектларын саклау идарәсе башлыгы. 1998 дән ТР эчке эшләр министрының 1 нче урынбасары — ТР Эчке эшләр министрлыгының криминаль милиция башлыгы. Батырлык, «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Е.Б.Долгов.

ТИМЕРКӘ́ЕВ Борис Ахун улы (21.2.1950, Мөслим р-ны Уразмәт а.), физик, физика-матем. фән. д-ры (1993), проф. (1997), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (2000). 1973 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1973 тән Казан техник ун-тында, гомуми физика каф. профессоры (1993), шул ук каф. мөдире (1995 тән). Хезмәтләре тигезләнеш халәтеннән ерак торучы газ бушану плазмасы өлкәсенә карый. Т. фононнар кыры аша туры дан-туры булмаган спин-спин тәэсире күренешен фаразлый (1977). Газ агымында пыскулы бушану плазмасы моделен эшли. Тавыш тизлегеннән зуррак тизлекле соплолардагы бушануны өйрәнә һәм лазерларда кулла на.

Х е з м.: Физика: Югары техник уку йортлары өчен дәреслек: 3 кисәктә. К., 1999–2002 (автордаш); Парамагнитная релаксация электронов проводимости, обусловленная косвенным спин-спиновым взаимодействием через поле фононов // Журн. эксперим. и теорет. физики. 1977. Т. 73, № 9 (автордаш); Генераторы сильнонеравновесной газоразрядной плазмы. К., 1996 (автордаш).

ТИМЕРЛЕ́К елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Олы Чирмешән елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 33,1 *км*. Бассейнының мәйданы 267,3 *км*^{2}. Нурлат р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Рус Тимерлеге авылыннан 6 *км* төньяктарак, тамагы Заречный посёлогы янында. Елга башының абс. биеклеге 150 *м*, тамагыныкы — 67 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 75%. Т.нең 0,8 дән 10,8 *км* га кадәр озынлыктагы 12 кушылдыгы бар, иң зурысы — Сирма елгасы (уң кушылдык). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,3 *км/км*^{2}. Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,25–0,5 *л/с·км*^{2}. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 75 *мм*, ташу агымы катламы 60 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрьнең беренче ункөнлегендә ту ңа. Тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,14 *м*^{3}*/с*. Суы бик каты: язын 9–12 *мг-экв/л*, кышын һәм җәен 20–40 *мг-экв/л*. Гомуми минераль әшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

«ТИМЕРХА́Н», язгы арпа сорты. 2005 елда Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында Э.Д.*Нettevич*, В.П.Смолин, Л.М.Ерошенко, В.И.Блохин тарафыннан чыгарыла. Уртача өлгерешле сорт (вегетация чоры 76–87 көн), бер вакытта өлгерүе б-н аерылып тора. Үсемлекнең биеклеге 74–80 *см*. Бөртеге эре, 1000 орлыкның авырлыгы 52,1 *г*; аксым 14%. Кисәү гөмбәсе авыруына чыдам. Яфрак авырулары б-н аз зарарлана. «Т.» сорты яхшы куаклана, уңышы югары һәм тотрыклы (1 *га* дан 57,5 *ц*). РФнең селекция казанышлары реестрына кертелгән һәм 2007 дә Идел буе (ш.и. ТРда) һәм Идел-Вятка регионнарында чәчәргә рөкъсәт ителгән. Уңышы 1 *га* дан 34,4 *ц*.

ТИМЕРХА́НОВ Айнур Әхәт улы (26.3.1974, Саба р-ны Иске Икшермә а.), тел галиме, филол. фән. д-ры (2007). 1996 елда Казан пед. ун-тын (2005 тән Татар гуманитар-пед. ун-ты) тәмамлый; шунда ук эшли (1995–2007). Бер үк вакытта, 2003 тән, ТР ФА Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында, 2007 дән лексикография бүлеге мөдире. Бер үк вакытта, 2005 тән, Россия гадел хөкем академиясенең Казан ф-лында, 2007 дән тел белеме һәм чит телләр каф. профессоры. Хезмәтләре татар теленең функциональ стилистикасы, лексикографиясе, контрастив лингвистикага карый. «Русча-татарча эш кәгазьләре лексикасы сүзлекчәсе»н («Краткий русско-татарский словарь деловой лексики», 2002) төзүче. Югары уку йортлары өчен татар теле буенча уку ярдәмлекләре авторы.

Х е з м.: Язык деловых бумаг в современном татарском языке. К., 2002; Язык и стиль татарского документа. К., 2005; Двуязычие и перевод: теория и опыт исследования. М., 2012 (автордаш).

Әд.: Казанская лингвистическая школа. К., 2008. Кн. 1.

ТИМЕРХА́НОВ Дамир Вәкил улы (25.6.1935, Сарман р-ны Сарман а.), генерал-майор (1981). В.И.Ленин исем. Ульянов танк уч-щесен (1957), Казан ун-тын (1966), В.И.Ленин исем. Хәрби-сәяси академияне (Мәскәү, 1969) һәм аның сәяси составының белемен күтәрү акад. курсларын (1974) тәмамлый. 1954 елдан Совет Армиясендә, 1957–63 тә һәм 1970 тә Германиядәге Совет гаскәрләре төркемендә 1 нче гв. танк армиясенең гв. авыр танк полкында: 9 нчы танк дивизиясенең танк взводы командиры, батальонның ВЛКСМ бюросы секретаре һәм 13 нче авыр танк дивизиясенең комсомол эше буенча сәяси бүлек башлыгы ярдәмчесе. 1963–65 тә Төркестан хәрби округында: 17 нче армия корпусының 102 нче һәм 203 нче мотоукчылар дивизиясендә комсомол эше буенча сәяси бүлек башлыгы ярдәмчесе. 1970–77 дә Төньяк Кавказ хәрби округында: сәяси идарәнең пропаганда һәм агитация бүлегендә өлкән инструктор, 42 нче гв. уку-өйрәнү мотоукчылар дивизиясенең 143 нче гв. артиллерия бригадасында сәяси бүлек башлыгы — сәяси бүлек командиры урынбасары. 1977–82 дә Кавказ арты Хәрби округы сәяси идарәсендә: партия-оештыру эше бүлеге башлыгы, идарә башлыгы урынбасары. 1982–84 тә СССР Совет Армиясе һәм Хәрби Диңгез флотының Баш сәяси идарәсендә Партия-оештыру эшләре идарәсенең коры җир гаскәрләре буенча өлкән инспекторы. 1984–88 дә инспекторлар төркемененң өлкән инспекторы (СССР Гражданнар оборонасының сәясәт буенча башлык урынбасары каршында). 1988 дән — запаста, Мәскәүдә яши. 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

ТИМЕРХА́НОВА (Мөхәммәт җанова) Разия Дәүләтша кызы (18.6.1918, Казан, башка чыганаклар буенча Тәтеш өязе Олы Карамалы а. — 22.11.1997, Казан), җырчы (лирик сопрано), ТАССРның атказ. артисты (1950). 1937 елда Казан музыка уч-щесен (Е.Ковель кова классы) тәмамлый. 1937–62 дә ТАССР Дәүләт җыр һәм бию ансамбленең әйдәп баручы солисты, радиодан чыгышлар ясый, ялгыз җырлау буенча концерт эшчәнлеге алып бара. Татар халык җырларын, аеруча борынгы озын көйләрне оста интерпретацияләүче буларак популярлык казана. Халык иҗаты б-н яхшы таныш буларак, Җыр һәм бию ансамбле репертуарын баетуга зур өлеш кертә, танылган милли муз. фольклор үрнәкләренең хор эшкәртмәләрен булдыруга, С.Сәйдәшев, С.Садыйкова, А.Ключарёв, Ә.Бакиров һ.б. татар композиторларының яңа вокаль әсәрләрен популярлаштыруга булышлык итә. 2004 тә Т. башкаруында радиодан яңгыраган муз. әсәрләрнең язма компакт-дисклар сериясе чыга. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

Әд.: С ә й ф у л л и н Р. Ансамбльнең беренче сандугачы // Халыкка багышланган тормыш. К., 2012; А р с л а н о в а Ф.Т. Государственный ансамбль песни и танца Республики Татарстан. К., 2007. *Ф.Ш.Салитова.*

ТИМЕРЧЕ́ авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 32 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Казансу елгасы буенда. 2010 елда 76 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.дә мәчет, мәктәп, вак-төяклөр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 551,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Мүлмә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Арча, 1935 нең 10 февраленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 57 ир-ат; 1859 да — 299, 1897 дә — 394, 1908 дә — 399, 1920 дә — 347, 1926 да — 387, 1938 дә — 400, 1949 да — 386, 1958 дә — 223, 1970 тә — 270, 1989 да — 152, 2002 дә — 97 кеше.

ТИМЕРЧЕЛЕ́К КӘСЕБЕ́, Казан төбәгендә Идел буе Болгары һәм Казан ханлыгы заманнарыннан билгеле. 18–19 йөзләрдә Казан, Лаеш, Спас, Зөя һәм Чистай өязләрендә киң тарала. Т.к. үзәкләре — Казан губернасының Казан өязендәге Чабакса, Олы Дәрвишләр, Биектау, Киндерле, Самосырово авыллары. Гадәттә, аерым гаиләләр шөгыльләнгән. Россия хакимияте Урта Идел буендагы рус булмаган халыкларга тимер эшкәртүне һәм металлдан эшләнгән әйберләр б-н сәүдә итүне тыю сәбәпле (к. *Тыелган товарлар*), Т.к. татарларда артык зур урын биләми, көнкүреш ихтыяҗларына (комганнар, самоварлар, савыт-саба) һәм җирле базарга юнәлдерелгән була. 19 йөз ахырында тимерчелек эшендә 12608 кеше теркәлгән, шулардан 12112 се руслар. НЭП елларында Т.к. татарлар арасында тиз үсә башлый, мәс., 1928–29 да Мин зәлә кантонында 231 тимерченең 136 сы татар була. Фабрика-заводлар җитештергән әйберләр киң таралу һәм кәсепчелек артельләре таратылу сәбәпле, 1930–50 елларда юкка чыга.

Әд.: Кустарные и отхожие промыслы в Казанской губернии // Изв. Имп. русского геогр. об-ва. СПб., 1875, Т. 11; П о б е д о н о с ц е в И.Ф. Мелкая промышленность Мензелинского кантона // Тр. об-ва по изучению Татарстана. К., 1930, Т. 2; Д и м и т р и е в В.Д. Заповедные товары и запрет кузнечного и серебряного дела в национальных районах среднего Поволжья в XVII в. // Вопр. истории Чувашии. Чебоксары, 1977. Чыг. 73; Х а л и к о в Н.А. Хозяйство татар Поволжья и Урала (сер. XIX — нач. XX в.). К., 1995; ш у л у к. Промыслы и ремёсла татар Поволжья и Урала (сер. XIX — нач. XX в.). К., 1998.

ТИМЕРШЫ́К авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 8 *км* төньяк-көнбатыштарак, Мишә елгасы буенда. 2010 елда 743 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1678 дән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, киез итек-киез җитештерү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.та 3 мәчет, 3 мәктәп, тегермән, тимерче алачыгы, 4 вак-төяклөр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2857 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Бөкмеш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 268 ир-ат; 1859 да — 850, 1897 дә — 1186, 1908 дә — 1759, 1920 дә — 1841, 1926 да — 1694, 1938 дә — 1506, 1949 да — 1015, 1970 тә — 1102, 1979 да — 441, 1989 да — 816, 2002 дә — 782 кеше.

ТИМИРЯ́СОВ Виталий Гайнулла улы (6.9.1937, Аксубай р-ны Барское Енорускино а. — 20.5.2013, Казан), икътисадчы, хокук белгече, хокук фән. д-ры (1998), проф. (1996). Казан ун-тының юридик ф-тын (1959), Мәскәү ун-тын (1964) тәмамлый. 1959–72 елларда Казан ун-тының сәяси икътисад кафедрасында. 1972 дән Мәскәү ун-ты гуманитар ф-тларының сәяси икътисад кафедрасында. 1988 дән СССР Химия сәнәгате министрлыгының Квалификация күтәрү ин-тында икътисад каф. мөдире (Мәскәү). 1990 нан Татарстан Мәгариф хезмәткәрләренең белемен күтәрү ин-тының икътисад каф. мөдире. Икътисад, идарә һәм хокук ин-тын (Казан) оештыручылардан берсе һәм аның ректоры (1994 тән). Хезмәтләре икътисад теориясе, тармаклар һәм тармак аскомплексларының икътисадының актуаль мәсь әләләренә карый. Медальләр, ш.и. «Намуслы хезмәт өчен» медале, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Экономические интересы в механизме соревнования. М., 1976; Экономическая эффективность общественного производства и пути её повышения. К., 1984; Лизинг: зарубежный опыт и российская практика. К., 2000 (автордаш); Факторы корпоративной устойчивости. К., 2007 (автордаш); Нанотехнология: новый этап в развитии человечества. К., 2009.

Әд.: Кто есть Кто в Республике Татарстан: Справ. К., 2000. Вып. 3; Н у р и с л а м о в а А. Щедро дарите миру энергию добра и созидания // Татарстан. 2005. № 9. *Ф.С.Зыятдинов.*

ТИММЕРМА́НС (Timmermans) Андре (5.12.1917, Франция — 1978), Каршылык хәрәкәтендә катнашучы. Икенче бөтендөнья сугышы вакытында Тирлемон шәһәрендә (Бельгия) фашистларга каршы хәрәкәттә катнаша: хыянәтчеләр исемлеген төзи, яшерен газета тарату б-н шөгыльләнә. 1942 елда гестапо тарафыннан кулга алына. Төрмәгә ябыла. Берлиндагы Моабит төрмәсендә татар хәрби тоткыннарының яшерен төркеме активисты М.*Җәлил* б-н бер камерада утыра (ш.у.к. «*Җәлилчеләр төркеме*»). 1944 тә М.Җәлил үтенече б-н шагыйрьнең тоткынлыкта иҗат иткән шигырьләренең кулъязма тупланмасын («*Моабит дәфтәре*») саклап кала. М.Җәлилнең «Яңа ел теләкләре» шигыре Тиммерманска багышланган:

Бу яңа ел безгә татлы ирек
Һәм бәхетле яшәү китерсен!
Ул салдырсын кулдан богауларны!
Һәм күзләрдән яшьне киптерсен!

Мәхкәмә карары б-н Т. 5 елга каторгага хөкем ителә. М.Җәлилнең дәфтәрен ул өенә җибәреп өлгерә; сугыштан соң аны Брюссельдәге совет дипломатларына тапшыра. 1956 да язучы К.Симонов б-н очраша. 1956 ның 13 октябрендә «Литературная газета» битләрендә басылган әлеге әңгәмәнең язмасы М.Җәлилнең гестапо төрмәсендәге тормышы турында кыйммәтле мәгълүмат чыганагы булып тора. 1957 дә һәм 1966 да Т. Советлар Союзында булып китә. Совет хөкүмәте тарафыннан «Батырлык өчен» медале б-н бүләкләнә.

Әд.: С и м о н о в К. Сосед по камере // Воспоминания о Мусе Джалиле. К., 1966; М у с т а ф и н Р.А. По следам оборванной песни. К., 2004.

И.Р.Вәлиуллин.

ТИМОНО́В Кир Вениаминович (5.6.1937, Зәй р-ны Зәй а.), генерал-майор (1988). 1958 елда Киев Һава һөҗүменнән саклану югары инженерлар радиотехника уч-щесен, Сов. Союзы Маршалы Г.К.Жуков исем. Һава һөҗүменнән саклану хәрби командирлар академиясен (Тверь ш., 1980) тәмамлый. 1958 дән Совет Армиясендә. 1958–67 дә Карпат буе авиация-зенит укыту-өйрәтү базасында: хәрәкәтләнүче цель селекциясе һәм тану аппаратлары инструкторы, инструкторлар төркеме башлыгы урынбасары, зенит-ракета гаскәрләрендә кулланылучы 42 нче укыту-өйрәтү үзәгенең сугышчан атышлар бүлегендә төркем башлыгы. 1967–80 дә Баку һава һөҗүменнән саклану округының 12 нче корпусында: Зенит-ракета гаскәрләре командующийлары идарәсенең хәрби әзерлек һәм сугышчан кулланылыш бүлегендә ракета подразделениеләренең хәрби әзерлек офицеры, 11287 нче хәрби часть командиры урынбасары, 73 нче һава һөҗүменнән саклану зенит-ракета бригадасы командиры урынбасары, 903 нче зенит-ракета полкы командиры, 48 нче авиация-зенит укыту-өйрәтү базасының һава һөҗүменнән саклану зенит-ракета гаскәрләрен өйрәтүче 42 нче укыту-өйрәтү үзәге башлыгы. 1980–92 дә Кавказ арты хәрби округының Һава һөҗүменнән саклану идарәсендә: зенит-ракета гаскәрләре бүлеге башлыгы, 37 нче корпус командиры урынбасары, 8 нче аерым армиянең зенит-ракета гаскәрләре башлыгы. 1992 дән — запаста, Киевта яши. «Кызыл Йолдыз», 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» орденнары б-н бүләкләнә.

М.З.Хәбибуллин.

ТИМОФЕ́ЕВ Александр Игнатьевич (12.3.1881, Казан — 28.8.1929, шунда ук), акушер-гинеколог, медицина д-ры (1913). В.С.Груздев шәкерте. Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1904), Пермь губернасында земство табибе булып эшли. 1909 елдан Казан ун-тының акушерлык-гинекология клиникасында, 1910 нан клиникада лаб. мөдире. 1918 дән Томск ун-тының акушерлык-гинекология клиникасында. 1920 дән Казан ГИДУВының акушерлык һәм гинекология каф. һәм клиникасы мөдире, проф. (1920). Хезмәтләре анатомиягә, физиологиягә, патологик гистологиягә, бактериологиягә һәм хатын-кызларның җенес әгъзалары авыруларын дәвалауга карый. Т. беренче булып кеше күкәйлегендәге сары тәнчекнең эпителийдан килеп чыгуын исбатлый (1913). СССРда беренче булып акушерлык-гинекология операцияләре вакытында А.В.Вишневскийның аерым урында авыртуны басу ысулын куллана (1925).

Х е з м.: О развитии жёлтого тела (corpus luteum) яичника человека. К., 1913; Руководство по женским болезням. Л., 1927 (автордаш); Опыт применения местной инфильтрационной анестезии при гинекологических операциях // Казан. мед. журн. 1928. № 10.

Әд.: М а н е н к о в П.В. Профессор Александр Игнатьевич Тимофеев (1881–1929) // Акушерство и гинекология. 1958. № 2.

В.Ф.Богоявленский.

ТИМОФЕ́ЕВ Валерий Фёдорович (22.2.1962, Кукмара р-ны Үрәсбаш а.), инженер-механик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2005), ТРның атказ. а.х. хезмәткәре (2004), а.х. фән. канд. (2009). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1984). Кукмара р-нында эшли: 1986–89 елларда Түбән Үрәс авыл советы рәисе, район башкарма ком-тының эшләр идарәчесе (1990 елга кадәр), Кукмара р-нының а.х. һәм азык-төлек идарәсендә инженер (1998 гә кадәр), «Кукмараагрохимсервис» АҖ директоры (1999 дан). Дәүләт бүләге ТРда сәламәт ләндерелгән нигездә бәрәңге орлыкчылыгы системасын эшләгәне һәм гамәлгә керткәне өчен бирелә.

ТИМОФЕ́ЕВ Василий Кириллович (1.1.1891, Владимир губ., Вязники өязе Осинки а. — 29.6.1968, Казан), нәкышьче, график, педагог, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1940, бу мактаулы исемгә беренчеләрдән лаек була). 1900–04 тә — чиркәү-приход мәктәбендә, 1904–08 дә Владимир губернасы Мстёра авылының икона ясау остаханәсендә (П.Ф.Бессонов һәм М.К.Евлампиевта) укый. 1913–14 тә Беренче бөтендөнья сугышында катнаша, Казан сәнгать мәктәбен тәмамлый (1915, Т.ның укытучылары — Н.И.Фешин, П.П.Беньков, Г.А.Медведев, И.А.Денисов). Казан сәнгать мәктәбендә, Казан сәнгать уч-щесендә (1915–61, бүленеп), Ташкент сәнгать техникумында (1921) укыта. Респ-ка нәкышьчеләренең асылын тәшкил итүче күп кенә шәкертләр тәрбияли, алар арасында В.А.Бадюль, Н.Г.Бикташев, К.К.Васильев, Р.Ә.Килдебәков, С.О.Лывин, Ю.Б.Лысогорский, Ә.Н.Мәҗитов, Е.А.Симбирин, Э.Г.Ситдыйков һ.б. бар. «Кызыл Татарстан», «Яңа авыл», «Ильич юлы» г-таларында рәссам булып эшли. Мәскәүдәге Бөтенсоюз а.х. күргәзмәсенең ТАССР павильонын бизәүдә катнаша (1936). ТатАХРР әгъзасы (1923–30) һәм рәисе (1924–25). ТАССР Рәссамнар берлеген (1936) оештыручыларның берсе, берлек әгъзасы, идарә рәисе (1938), идарә рәисе урынбасары (1941–51). «Татхудожник» берлеген оештыруда катнаша (1935, к. *Татарстан Республикасы Сәнгать фонды*), аның идарә әгъзасы (1937 дән).

Т. — Казан сәнгать мәктәбе традицияләрен үстерүче реалистик юнәлеш вәкилләренең берсе. Үзенең иҗади, иҗтимагый һәм пед. эшчәнлеге б-н Татарстанда проф. нәкышьне аякка бастыруда хәлиткеч роль уйный. Иҗатының башлангыч чорында пленәрда эшли, натурадан этюдлар, пейзажлар, жанрлы композицияләр иҗат итә: «Татар карты портреты», якынча 1915 еллар; «Кисмәк янында», 1915–17; «Казансу», 1917; «Яфраклы урман», 1920; «Кер юганнан соң», 1920 һ.б. 1926–29 да чакыру буенча Мари автономияле өлкәсендә эшли, марилар тормышы турында 100 гә якын картина, этюд һәм эскиз эшли: «Мари авылы», «Богыл салу», «Мари хатын-кызы», «Болдырлы мари өе күренеше», «Мари туе», «Шагыйрь С.Г.Чавайн портреты», «Гөсләче П.Терентьев» һ.б.



В.К.Т и м о ф е е в. «Кечкенә ишегалды. Казан» Этюд. 1930. Алатырь сәнгать музее.

1920 еллар ахырында Т. иҗатында Казан заводларындагы хезмәт темасы: «В.И.Ленин исемендәге күн заводы», «Спартак» аяк киемнәре фабрикасы», ш.у. Казан мех ф-касы цехларында язылган этюдлар циклы (1929–31) барлыкка килә. 1930 еллар башыннан ул революцион, тарихи һәм хәрби темаларга багышланган сюжетларга һәм күпфигуралы композицияләргә бай, масштаблы картиналарга («ТАССР колхозында җирне мәңгегә файдалану актын тапшыру уңаеннан митинг», 1937–38; «В.И.Ленинның ТАССР төзелү турындагы Декретка кул куюы», 1941, картина тәмамланмый кала; «М.И.Калинин колхозчылар арасында», 1941; «Совинформбюро хәбәрләрен тыңлыйлар», 1942; «1920 елда ТАССРны тантаналы төстә

игълан итү», 1943; «Казанда Җиңү көне», 1945; «1887 елда Казан университетында студентлар кузгалышы», 1950), Идел буе халыкларының индустриаль һәм колхоздагы хезмәтенә, көндәлек тормышына («Күпер төзелешендә», 1934; «Бригадаларның социалистик ярышы», «Чуашиядә юллар төзелеше», икесе дә — 1935; «М.Вахитов исемендәге колхозда», 1956 һ.б.) мөрәҗәгать итә. Т.ның ижади мирасы дәүләт эшлеклеләре һәм тарихи шәхесләр, мәдәният вәкилләре портретлары галереясын, ш.у. жанрлы портретларны («Татар карты портреты», якынча 1915; «Автопортрет», 1920 еллар; «ТАССР халык комиссарлары советы рәисе иптәш Мохтаров», 1923; рәссамнар: М.М.Васильева, 1925; Е.К.Частихин, 1926; В.А.Бадюль, 1945;



В.К.Тимофеев. «Вятка кичүе». 1961. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

Н.И.Фешин, 1960; сәнгать белгечләре: П.М.Дульский, П.Е.Корнилов, икесе дә — 1945, комп. Н.Г.Җиһанов, 1944; 1 нче Татар укчы дивизиясе командирлары һәм сугышчыларының портретлары, ш.и. график портретлар циклы, 1933–38) үз эченә ала. Ул Идел буе респ-каларының табигатен, тарихи урынларын һәм истәлекләрен сурәтләгән пейзажлар («Казансу», 1917; «Алатырь», 1935; «Куженер авылы», 1940; «Васильево янындагы Идел», 1945; «В.И.Ленинның Кокушкино авылындагы музей-йорты», 1956; «Подлужный урамы. Казан», 1964), Төркестанга багышланган этюдлар циклы («Сәмәрканд», «Борынгы шәһәрнең ямьле җире», «Төркестан базары» һәм Урта Азия сәфәреннән алган тәэсирләре буенча иҗат иткән башка әсәрләре) авторы. Т. заманның актуаль вакыйгаларын һәм революцион үткәннәрне документаль нигездә, кайвакыт хыялга корылган күтәренке рухта сурәтли, әүвәлге картиналарында этнографик һәм көнкүреш вак-тояганә зур игътибар бирә. Т.ның график мирасы башлыча 1930 елларда карандаш һәм сангина б-н башкарылган портретлардан тора («Хатын-кыз портреты», «Һади Такташ», икесе дә — 1930; «Комиссар иптәш Маликов», 1932; «Парашютчы кыз», 1937; «Сынбагар», 1940 һ.б.).

1 нче һәм 2 нче дәүләт күргәзмәләрендә (Казан, 1920, 1921), 1 нче картиналар күргәзмәсендә (Козьмодемьянск ш., 1920), ТатАХРР (Казан, 1923, 1925), АХРР (Мәскәү, 1926, 1929), «РККАга 15 ел» (Мәскәү, 1933), Мәскәү һәм Татарстан рәссамнары хезмәтләре (Казан, 1937), «РККАга һәм Хәрби Диңгез флотына — 20 ел» (Мәскәү, 1938–39), алты автономияле респ-ка рәссамнары (Казан, 1947), Мәскәүдә Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы көннәре (Мәскәү, 1957), 1 нче һәм 2 нче «Зур Идел» зона (Куйбышев ш., 1964; Волгоград ш., 1967), 16 автономияле респ-ка рәссамнары (Мәскәү, 1971) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре Казанда (1928, 1940, 1945, 1951, 1961, 1965, Н.М.Сокольский б-н берлектә; 1970, вафатыннан соң), Мәскәүдә (1973) була; тууына 115 ел тулуга багышлап, Казанда ретроспектив күргәзмәсе уздырыла (2006). Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда (шунда Т.ның шәхси архивы да тапшырыла), ТР Милли музеенда, А.М.Горькийның Казандагы әдәби-мемор. музеенда, Әлмәт, Козьмодемьянск шәһәрләренең картиналар галереяларында, Мари респ-ка төбәк тарихы музеенда (Йошкар-Ола), Хельсинкидагы Милли музейда (Финляндия) саклана. Медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: 30 лет творческой и педагогической деятельности заслуженного деятеля искусств ТАССР Василия Кирилловича Тимофеева (1915–1945): Каталог выставки. К., 1945; Выставка произведений заслуженного деятеля искусств ТАССР Василия Кирилловича Тимофеева (1891–1968): Каталог. К., 1970; Червонная С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984.

ТИМОФЕ́ЕВ Василий Тимофеевич (1836, Казан губ., Мамадыш өязе Никифорово а. — 2.12.1895, Казан), дин эшлеклесе, мәгърифәтче миссионер, тәрҗемәче. Элеккеге чукындырылган керәшен татарлардан. Башлангыч мәктәптә русча укырга-язарга өйрәнә. Шунда ук православие дине һәм христиан әдәбияты б-н мавыга, бу исә гаиләдә ызгыш-гауга чыгуга китерә. 1856 елда Казан Иоанн-Предтеча монастырена китеп монах булырга әзерләнә. Әмма, авыл җәмәгатеннән рөхсәт ала алмау сәбәпле, 1858 дә туган авылына кайтырга мәҗбүр була, анда аны мәҗбүри өйләндерәләр. Башта Т. Н.И.*Ильминский* ярдәмендә авыл җәмәгатеннән китә һәм Казан Богородица хатын-кызлар монастырена мич ягучы һәм су ташучы булып урнаша, 1863 тә Ильминский тәкъдиме б-н татар теле укытучысы-практикант сыйфатында Казан руханилар академиясенә кабул ителә (1893 кә кадәр эшли). 1864 тә Ильминский кушуы буенча Т., керәшен татарлар арасында рус телен белү дәрәҗәсен тикшерү өчен, Мамадыш өязенең берничә авылында була. Әлеге сәфәр нәтиҗәсендә 1864 тә *Казан үзәк керәшен татар мәктәбе* ачыла (православие догалыкларын мөстәкыйль укысыннар өчен керәшен татарларны укырга-язарга өйрәтү күздә тотыла). Т. әлеге мәктәпкә мөдир һәм укытучы итеп билгеләнә. 1864–67 елларда керәшен татар авылларында йөргәндә, ул Мамадыш өязенең Никифорово һәм Әрнәш, Казан өязенең Апаз авылларында мәктәпләр ача, дини-әхлакый укулар һәм аңгәмәләр үткәрә. 1869 да руханилык дәрәҗәсен кабул итә. 1873 тән Казан, Вятка һәм Уфа архиерей-лары тарафыннан аңа шул епархияләргә караган керәшен татар авылларында булганда татар телендә гыйбадәт алып бару йөкләнә. Мәктәптә эшләгән елларында Т. Идел-Чулман төбәге терр-ясенең керәшен татарлар яшәгән барлык авылларында диярлек булып чыга. 1890–95 тә *Изге Гурий борадәрлеге* каршындагы Тәрҗемә комиссиясе әгъзасы була.

19 йөзнең 2 нче яртысында керәшен татарларның мәгариф системасын формалаштыруга зур өлеш кертә. Керәшеннәргә *кириллицаны* эшләүдә (к. *Ильминский алфавиты*), православие тәгълиматларын, дини әдәбиятны татар теленә тәрҗемә итүдә һәм басты-руда актив катнаша. 3 нче дәрәҗә Изге Анна ордены б-н бүләкләнә.

Хезм.: Дневник старокрещёного татарина 1865 года // Казанская центральная крещёно-татарская школа: Материалы для истории христианского просвещения крещёных татар. К., 1887.

Әд.: Знаменский П.В. История Казанской духовной академии за первый (дореформенный) период её существования (1842–1870 годы). К., 1892. Вып. 2; шул ук. В.Т.Тимофеев: Некролог // Православный собеседник. 1896. Ч. 1; Карпов Ю.П. Просветитель татар-кряшен о.Василий Тимофеев (1836–1895) // Православный собеседник. 2003. № 2; Хабибуллин М.З. Михаил Александрович Машанов — профессор Казанской духовной академии, миссионер и исламовед. К., 2006.

ТИМОФЕ́ЕВ Дмитрий Александрович (1859, Пенза ш. — 21.2.1921, Казан), гистолог, медицина д-ры (1896). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1883), Уфа губернасында земство табибе булып эшли. 1892 елдан Казан ун-тында: гистология кафедрасында, 1887 дән госпиталь хирургиясе клиникасында ординатор, 1903 тән проф., гистология һәм эмбриология каф. мөдире. 1897 дә Германиядә (Бонн һәм Тюбинген ун-тларында) командировкада була. Хезмәтләре сизгер нерв очлыклары морфологиясенә карый. Беренче булып яры куык составындагы механорецепторларның өстәмә нерв җепселләрен тасвирлый (Тимофеев аппараты).

Хезм.: О нервных окончаниях мужских половых органов млекопитающих и человека. К., 1896; О некоторых особенностях строения спинных и симпатических узлов у птиц // Неврол. вестн. 1899. Т. 7, вып. 2.

Әд.: Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1814–1904). К., 1904. Ч. 2.

В.Ф.Богоявленский.

ТИМОФЕ́ЕВ Николай Егорович (1.11.1939, БАССРның Бакалы р-ны Иске Шәрәшле а.), химик-технолог, техник фән. д-ры (1994), проф. (1996), ТРның атказ. фән. эшлеклесе (2003). 1962 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. Хезмәтләре техник химиягә карый. Т. аеруча энергетикалы системаларның кабынып китүен һәм яныуын тикшерә. Боз явуга каршы ракеталар өчен боз ясагыч композицияләр алуның фәнни нигезләрен эшли; боз ясагыч пиротехник составлар һәм каты ягулыклар, актив аэрозоль генераторлары тәкъдим итә. Генератор һәм заряд-ларның боз ясау активлыгын (ш.и. югары тизлекле һава агышы өрдергәндә) билгелә-ү җайланмаларын гамәлгә кертә.

Хезм.: Влияние особенностей генератора на эффективность льдообразующих составов с полиакрилонитрилом. М., 1991 (автордаш); Льдообразующие составы с ультрамалым содержанием иодида серебра. М., 1991 (автордаш). Льдообразующие пиротехнические составы и средства. К., 1995.

ТИМОФЕ́ЕВ Сергей Фёдорович (19.3.1950, Казан), спортчы (ирекле көрәш), СССРның халыкара класслы спорт остасы (1976), ТРның атказ. физкультура хезмәткәре (2002). Казан пед. ин-тының физик культура ф-тын тәмамлый (1978). Спорт б-н 1961 елда «Ракета» СКда шөгыльләнә башлый (Казан), тренеры — Ж.Б.*Гафиятуллин*. РСФСР (1974), Европа (1976) чемпионатларында, РСФСР халыкларының 6 нчы спартакиадасында (1975), халыкара турнирларда (1975, Япония, ГДР) җиңүче, СССР Кубогы иясе (1975); РСФСР беренчелекләрендә (1965, яшүсмерләр арасында), Халыкара турнирларда (1975, Минск, Тбилиси, Төркия) көмеш медаль ала; РСФСР чемпионатында, РСФСР халыкларының 7 нче спартакиадасында (1979) бронза приз ала; Олимпия уеннарында катнаша (1976). 1976–97 дә тренер-укытучылык эшендә, 1997–2006 да «Ракета» спорт-сәламәтләндерү комплексы» муниципаль учреждениесендә директор, 2007 дән «Ш.Тарпищевның теннис академиясе» ҖЧЖдә тренер.

ТИМОФЕ́ЕВА Ольга Арнольдовна (6.7.1962, Чистай ш.), үсемлекләр физиологы, биол. фән. д-ры (2010). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1985), СССР ФА Казан ф-лының Биология ин-тында эшли. 1991 елдан Казан ун-тында, үсемлекләр физиологиясе һәм биохимиясе каф. профессоры (2010 нан), укыту-методика идарәсе башлыгы (2011 дән). Хезмәтләре үсемлекләрнең экологик физиологиясенә карый. Мохитнең тискәре факторларына үсемлекләрнең җайлашуы һәм чыдамлыгының үсемлекләрнең яңа сортларын һәм формаларын булдыру һәм скринингы өчен файдаланырга мөмкинлек бирә торган субкүзәнәк һәм молекуляр механизмнарын ачыклый. ТР ФАнең В.А.Энгельгардт исем. бүләге лауреаты.

Х е з м.: Влияние инфицирования растений на активность лектинов. Воронеж, 2011 (автордаш); Культура клеток и тканей растений. К., 2012 (автордаш); Об организации академической мобильности в Казанском (Приволжском) федеральном университете. Саратов, 2012 (автордаш); Динамика активности лектинов в проростках пшеницы при инфицировании и действии дитерпенового гликозида // Физиология растений — теоретическая основа инновационных агро- и фитобиотехнологии: Материалы Междунар. науч. конф. Калининград, 2014. Ч. 2 С. 477–479 (автордаш).

ТИМОФЕ́ЕВКА авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 12 *км* төньяктарак, Сола елгасы (Казансуның уң кушылдыгы) буенда. 2010 елда 9 кеше (руслар) яши. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Мәмәт, Янгелде Пүчинкәсе исемнәре б-н дә билгеле, 1940 еллардан хәзерге исемен йөртә. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында су тегермәне, 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгате нең имана җире 193,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Собакино волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 49 ир-ат; 1859 да — 190, 1897 дә — 201, 1908 дә — 184, 1920 дә — 194, 1926 да — 776 (Толмач, Мишавки авыллары халкын да кертеп), 1958 дә — 106, 1970 тә — 60, 1989 да — 25, 2002 дә — 15 кеше.

ТИМОФЕ́ЕВКА авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 7 *км* төньяктарак, Сола елгасының Казансуга койган җирендә урнашкан. 2010 елда 397 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 51%, татарлар — 49%) яши. 1920 елларда нигез салына. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Спирт з-ды. Оешкан көненнән ТАССРның Арча кантоны Калинин волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1935 нең 10 февраленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1926 да — 33, 1970 тә — 527, 1989 да — 438, 2002 дә — 382 кеше.

ТИМОФЕ́ЕВКА (Phleum), кыяклылар семьялыгыннан бер- яки күпьеллык үсемлекләр ыругы; терлек азыгы үсемлеге. Ике ярымшарның да тропиктан тыш поясларында — якынча 20 төре, Россиядә — 9, Татарстанда 3 төре билгеле. Болын Т.сы (P. pratense) әһәмияткә ия. Башлыча, Россиянең, Көнбатыш һәм Көнчыгыш Себернең Европа өлешендә урман зоналары болыннарында, бигрәк тә тугай болыннарында очрый. Тамыры кыска, үсемлек көпшәк кәсләр хасил итә. Сабаклары туры, сирәгрәк күтәренке, гадәттә, сабак төбе суганчасыман юанайган була. Яфраклары яссы, кытыршы, 3–10 *мм* киңлектә. Чәчәк төркеме — тыгыз, цилиндр рәвешендәге башаксыман себеркәч (солтан), җәйнең беренче яртысында чәчәк ата. Россиядә 18 йөздә культуралаштырыла. Яшел азык өчен — башаклану алдыннан, печән өчен чәчәк ату алдыннан җыела. 100 *кг* яшел масса сында — 20–25 терлек азыгы берәмлеге һәм 1,5–1,7 *кг* үзләштерелә торган протеин, печәнендә 50 терлек азыгы берәмлеге һәм 5 *кг* үзләштерелә торган протеин бар. Салкынга чыдам, иртә язда үсә башлый, ләкин үсүе акрын. Печәнлекләр һәм көтүлекләрнең үлән катнашмасында мөһим компонент булып тора. Кыр һәм болын-көтүлек чәчү әйләнешендә кызыл клевер б-н чәчелә, чәчү нормасы 1 *га* га чиста килеш 12 *кг*, 2–3 *см* тирәнлектә. 2–3 елда тулысынча өлгерә. Коры үзәнлекләрдә уңышы (1 *га* дан 30–65 *ц* печән) — 4–5 ел дәвамында, түбән җирлә рдәге һәм тугай болыннарында 10–15 ел дәвамында. Татарстанда чәчүгә «Казан» сорты (1956 дан) рөкәт ителгән, катнаш чәчүлекләрдә үстерелә.

Әд.: Бакин О.В., Рогова Т.В., Ситников А.П. Сосудистые растения Татарстана. К., 2000.

ТИМО́ШЕВ Рафаэль Миргали улы (25.11.1954, Дрезден ш., Германия), философ, филос. фән. д-ры (1997), проф. (1998), генерал-лейтенант (2007). Ростов югары хәрби командирлар уч-щесен (1976), В.И.Ленин исем. Хәрби-сәяси академияне (1994 елдан РФ Оборона министрлыгы хәрби ун-ты; Мәскәү, 1986) тәмамлый. 1976–84 тә «Байконур космодромы» сынау полигонында. 1987 дән Хәрби ун-тта; укытучы, 2003–08 дә уку-укыту һәм фәнни эшләр буенча башлык урынбасары. 2008 дән «Фән XXI» Иминлек проблемаларын фәнни өйрәнүгә ярдәм фонды президенты. Хәрби ФАнең хакыйкый әгъзасы (1998). Хезмәтләре хәрби эшчәнлек өлкәсендә идарә итү методологиясе, Көнчыгыш фәлсәфә куль турасы тарихы мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Восточная философская культура XX века. М., 1994; Методологическая культура военно-управленческой деятельности. М., 1996; Освобождение как условие и функция победы в войне // Философия освобождения. М., 2005.

ТИМО́ШКИНО авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 12 *км* көнчыгыштарак урнашкан. 2010 елда 22 кеше (руслар) яши. 1646 дан Кече Шәпше авылы буларак билгеле. 19 йөз башында алпавыт И.Депрейс (авылның 19 йөздәге Депрейсовка атамасы шуннан алынган) Сембер губернасының Сөнчеле өязе Т. авылы крәстияннәрен монда урнаштыра. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында земство мәктәбе (1901 дә ачыла), 2 вак-төяк ләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 362,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Собакино волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Казан авыл р-нында, 1935 нең 10 февраленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1646 да — 37 ир-ат; 1859 да — 194, 1897 дә — 202, 1908 дә — 185, 1920 дә — 263, 1926 да — 290, 1938 дә — 317, 1949 да — 344, 1958 дә — 273, 1970 тә — 200, 1989 да — 25, 2002 дә — 20 кеше.

Әд.: Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

ТИ́МЧЕНКО Александр Григорьевич (25.3.1927, Краснодар краеның Северский р-ны Ильская станицасы — 27.4.1984, Лениногорск ш., 2006 да Төмән өлкәсенең Сургут шәһәренә күчереп җирләнә), нефтьче-вышка монтажлаучы, Соц. Хезмәт Герое (1959). Хезмәт эшчәнлеген 1944 елда «Грознефтеразведка» трестында башлый. 1950 дән «Татбурнефть» трестының вышка монтажлаучылар бригадиры, 1959 дан «Татнефтегазразведка» трестының 4 нче бораулау конторасында (икесе дә Лениногорскида). 1965 тән «Төмәннефтегаз» ҖБ «Төмәннефтгазразведка» трестының Сургут һәм Усть-Балык бораулау конторалары рында эшли, 1974 тән «Запсиббурнефть» берләшмәсенең 2 нче Нефтеюганск вышка монтажлау идарәсендә, 1975–84 тә «Сургутнефтегаз» берләшмәсенең 4 нче Сургут вышка монтажлау идарәсендә.

Т. бригадасы тармакта беренчеләрдән булып нефть вышкаларын төзүнең «Татнефть» белгечләре эшләгән яңа индустриаль алымын кертә, шуның нәтиҗәсендә бораулау җайланмалары, өлешчә блоклап сүтелеп, тракторлар ярдәмендә яңа мәйданчыкларга күчерелә. Бу бораулау җайланмаларын күчерүнең вакытын 70 тапкырга кыскартырга,

хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрергә, нефть чыганакларын эшкәртү темпларын тизләтергә мөмкинлек бирә (1960 та — 82, 1963 тә — 102, 1964 тә 114 вышка монтажлана). Т. башлангычында бораулау җайланмаларының детальләре һәм төеннәре, ярдәмче механизмнары яңартыла; монтажлау эшләрен сизелерлек җиңеләйтә торган тиз сүтелүче механизмнар һәм башка күп кенә камилләштерүләр эшләнә һәм гамәлгә кертелә. Герой исеме нефть-газ сәнәгате үсешенә аеруча зур өлеш керткән өчен бирелә. «СССР нефть чыгару сәнәгате отличнигы» исеменә лаек була (1968). КПССның 22 нче съезды делегаты (1961), СССР Нефть-газ-химия сәнәгате эшчеләре профсоюзларының ҮК әгъзасы. 1963–67 дә ТАССР ЮС депутаты. Ике Ленин ордены, Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш, бронза медальләре б-н бүләкләнә. Лениногорск шәһәрендә Геройлар аллеясында барельеф, Сургутта Т. яшәгән йортка мемориаль такта куелган.

Әд.: Профессионалы нефтегазовой отрасли. М., 1966; Долгая дорога к нефти. Сургут, 1997; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003; Зубарев А. Тот самый Тимченко // Югра. 2007. № 11; Югория: Энцикл. Ханты-Мансийского автономного округа. Екатеринбург, 2000. Т. 3.

ТИМЬЯ́НСКИЙ Василий Ильич (1791–1840 тан соң), табигать белеме белгече, геолог-минералог. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1809), шунда укыта, Минерал. кабинеты саклаучысы (1823 елга кадәр), экстраординар (1820 дән), ординар проф. (1823 тән), бер үк вакытта *Казандагы Беренче ир балалар гимназиясендә* (1809 дан). Казан ун-тының табигать тарихы һәм ботаника кафедрасында К.Ф.*Фукс* эшен дәвам иттерә. 1824 тә экспедиция б-н Аляска һәм Алеут утрауларына җибәрелә. Экспедициягә Норвегиядә туктальга туры килә, биредә Т. минераллар коллекциясе туплый, аны, Казанга кайту б-н, ун-тның Минерал. җәмгыятенә тапшыра. 1825 тән директор ярдәмчесе, 1840 елларда Диңгез министрлыгының Төзелеш департаменты гомуми канцелярия бүлекләренең берсендә башлык (С.-Петербург). Минерал., зоология, ботаника буенча лекцияләр курсы төзи. Казан губернасы буенча экскурсияләр оештыра, үсемлекләр, хайваннар һәм минераллар коллекциясе җыя. Хезмәтләре минерал. һәм зоологиягә карый.

Әд.: Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 1.

ТИНЧУ́РИН Кәрим Гали улы (15.9.1887, Тамбов губ., Спас өязе Таракановка а., хәзер Пенза өлкәсенең Спас р-ны Аккүл-Тараклы а. — 15.11.1938, Казан), драматург, актёр, режиссёр, педагог, ТАССРның атказ. артисты (1926). Крәстиян гаиләсендә туа. Башлангыч белемне авыл мәдрәсәсендә ала, 1900–06 елларда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә (Казан) укый. 1910 да «Сәйяр» труппасына актёр булып урнаша. Казанда узган кышкы гастрольләрдән соң шунда калган «Сәйяр» труппасы артистлары б-н 1918 дә Татар драма артистлары труппасын оештыра һәм аның б-н җитәкчелек итә (1919 да бу труппа Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең Сәяси бүлеге каршындагы 13 нче Күчмә татар драма труппасы итеп үзгәртелә). 1920 дә З.Солтанов б-н берлектә Самара шәһәрендә татар актёрлары әзерләү өчен студия ача, 1921 дә студияне тәмамлаучылар б-н бергә Оренбургта Г.Кариев исем. театр оештыра. 1922 дә аз гына вакыт Ташкентта эшли, 1922 нең көзендә Казандагы Беренче татар дәүләт театрының баш режиссёры итеп билгеләнә, 1928–29 да Әстерхан татар театры б-н җитәкчелек итә. 1929 дан Татар акад. театрының сәнгать җитәкчесе һәм баш режиссёры. Актёр буларак Г.Кариев традицияләрен дәвам итә, образга керә белү мәктәбе тарафдары була. Т. гәүдәләндергән күпчелек образлар арасында аеруча истә кала торганнары — сизгер, күтәренке рухлы Незнамов, елгыр, җитез Кудряш («Гаепсездән гаеплеләр», «Яшенле яңгыр», А.Н.Островский), зыялы язучы Сөләйман («Тигезсезләр», Ф.Әмирхан), гротеск дәрәҗәсендә бирелгән Вурм («Мәкер вә мәхәббәт», Ф.Шиллер) һәм Хлестаков («Ревизор», Н.В.Гоголь), трагик Борис Годунов («Иоанн Грозныйның үлеме», А.К.Толстой) һ.б. Үзенең пьесалары буенча куелган спектакльләрдә Кыям («Беренче чәчәкләр»), Батырхан («Җилкәнсезләр»), Булат («Зәңгәр шәл»), Мәхдүм («Сүнгән йолдызлар»), Искәндәр («Американ»), Җантимер («Ил») һ.б. төп рольләрне башкара. 1918 дән режиссура б-н шөгыльләнә башлый, үзе куйган спектакльләрдә реализм принцибын, ягъни спектакльнең тышкы күренешендә дә, характерлар үсешендә дә тормыш чынбарлыгына тугрылыкны эзлекле гәүдәләндерә. Үзе язган пьесаларның барысын да беренче булып сәхнәләштерә, ш.у. «Яңа кешеләр» (Г.Ибраһимов, 1920), «Таһир-Зөһрә», «Яшь йөрәкләр» (Ф.Бурнаш, 1920), «Җир уллары» («Җир уллары трагедиясе» буенча, Һ.Такташ, 1922), «Бай кызы» (Ш.Усманов, 1922), «Упкын» (Ә.Т.Рахманкулов, 1925), «Тормыш төбендә» («На дне», М.Горький, 1932), «Ревизор» (Н.В.Гоголь, 1929, 1932) спектакльләрен куя. Т. комп. С.Сәйдәшев б-н бергә иҗат итә. Аның «Сүнгән йолдызлар» (1924), «Казан сөлгесе» (1924), «Зәңгәр шәл» (1926), «Ил» (1929), «Кандыр буе» (1932) пьесаларына С.Сәйдәшев язган көйләр алар буенча куелган спектакльләрнең табигый һәм аерылмас өлешенә әверелә.



К.Тинчурин (сулда), Ф.Бурнаш Татар дәүләт театры актрисалары б-н (сулдан уңга утырып торалар — Н.Таждарова, Н.Арапова, Г.Болгарская; басып торалар — Ф.Кудашева-Арская, Р.Кушловская, С.Мирсәлимбәкова, Б.Баязитская, М.Сульва). 1925/26 сезон.



К.Г.Тинчурин Калаф ролендә («Турандот», К.Гоцци).



А.Г.Тимченко.



К.Г.Тинчурин.

Актёрлык эшчәнлеген башлаганчы ук, Т. үзен драматург буларак таныта, 1906 да мәдрәсәдәге тәртипләрдән көлгән «Моназа-ра» («Бәхәс») сатирик комедиясен яза. «Сәйяр» труппасында эшләгән елларда, нигездә, комедияләр иҗат итә: «Хәләл кәсеп» (1910), «Шомлы адым» (1912), «Ач гашыйк» (1915), «Назлы кияү» (1916). Аларда көчле гротеска корылган төрле хәлләр һәм характерлар аркылы татар зыялыларының милләтне социаль үзгәртеп коруга һәм аның алдынгы үсешенә омтылышлары гәүдәләнә. «Йосыф белән Зөләйха» (1919), «Зар» (1922), «Сакла, шартламасын!» (1923), «Тутый кош» (1924), «Американ» (1924), «Нәни абый» (1925), «Җилкәнсезләр» (1926) пьесаларында драматург сатирасы тирән социаль мәгънә һәм масштаблык ала. Бу чорда Т. милли фольклор күренешләренә мөрәҗәгать итә, комп. С.Сәйдәшев б-н иҗади берлектә зур популярлык казанган «Сүнгән йолдызлар», «Казан сөлгесе», «Зәңгәр шәл» муз. драмаларын иҗат итә. 1930 елларда драматург иҗатында уңай герой эзләү күренешләре күзгә ташлана. Т.ның «Корыч орчык» (1930), «Тургай» (1932, Р.Ишморат б-н берлектә), «Ударниклар бәйрәме» (1933), «Булат бабай семьясы» (1933, К.Нәҗми б-н берлектә), «Алар өчәү иде» (1935) пьесалары соц. төзелеш, тормышны тамырдан яңарту рухын бирү омтылышы б-н сугарылган. Татар драматургиясе

һәм театры үсешенә мөнәсәбәтле үз карашларын дәлилләргә омтылып, ш.у., бер яктан караганда, яңа театрның реализм юлыннан барырга тиешлеген, икенче яктан, театр телен, сәхнә күренешләре динамикасын яңарту зарурлыгын раслап, публицистик мәкаләләр б-н чыгышлар ясый.

1938 дә Т. репрессияләнә, аның пьесалары озак еллар дәвамында тыела. Үлгәннән соң аклана. 1988 дә Т. исеме Татар драма һәм комедия театрына бирелә, Казандагы бер урам аның исемен йөртә.

Әсәр.: Сайланма хикәяләр. К., 1967; Сайланма драмалар һәм комедияләр: 2 томда. К., 1969.

Әд.: Татар театры (1906–1926). К., 2003; Кәрим Тинчурин: Истәлекләр, шигырьләр. К., 2003; Кәрим Тинчурин: тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык. К., 2011; Гимранова Д. Современное прочтение классики // Сцена и время. К., 1982; Ахмадуллин А. Многогранный художник // Горизонты татарской драматургии. К., 1983; Карим Тинчурин и татарское искусство: Материалы Всерос. науч.-практ. конф. К., 2007.

И.И.Илялова, Р.Р.Мусабәкова.

ТИНЧУ́РИН К. ИСЕМЕНДӘГЕ́ ТЕА́ТР ФЕСТИВАЛЕ́, 1992 елда ТР Мәдәният министрлыгы һәм Театр эшлеклеләре берлеге карары б-н татар театр мәдәниятенең күренекле эшлеклесе К.*Тинчурин* хөрмәтенә оештырыла. Ул респ-каның театр сәнгате казанышларын ачыклау максатыннан ел саен уздырыла. Анда иң яхшы спектакль, иң яхшы хатын-кыз һәм ир-ат рольләре, иң яхшы режиссура өчен призлар бирелә. Фестивальдә катнашу өчен, респ-каның барлык проф. театр коллективлары, ш.у. РФнең башка төбәкләреннән дә кунаклар чакырыла. Барлыгы 9 фестиваль булып узган (1991, 1992, 1993, 1994, 1996, 2012, 2014, 2016, 2018). Төрле елларда гы лауреатлар — режиссёрлар М.Х.Сәлимҗанов, Ф.Р.Бикчәнтәев, Р.М.Заһидуллин, А.Я.Славутский; актёрлар Ш.Биктимеров, А.Гайнуллина, Ф.Бәдриев, И.Фәизов, Г.Ишкова, А.Калаганов, Р.Хәйруллина, В.Ганиева, Е.Щеглова һ.б. 2014 тә фестивальнең чикләре киңәя, ул Халыкара фестиваль статусы ала.

ТИНЧУ́РИН Форель Закир улы (12.12.1926, Казан — 30.9.2002, шунда ук), инженер-механик, техник фән. канд. (1963), проф. (1989), ТАССРның атказ. энергетигы (1986), ТР-ның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1993), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (1998). 1950 елда Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң, Казан авиация техникумында эшли. 1952–76 да Казан авиация ин-тында: металлар технологиясе кафедрасында, профсоюз ком-ты рәисе (1959–63), партия ком-ты секретаре (1964–76). 1976 дан Мәскәү энергетика ин-тының Казан ф-лында: директор (1994 кә кадәр), гомуми техник дисциплиналар каф. мөдире (1980–96), проф. (1996 дан), директор киңәшчесе (1994 тән).

Хезмәтләре металларны химик-термик эшкәртү процессларын оптимальләштерүгә карый. Т. Татарстан нефть чыганакларында корычның иярчен газлар тарафыннан цементлануы мәсьәләләрен өйрәнә. Институтны җитәкләгән елларында аны аякка бастыруга һәм үстерүгә, фәнни-пед. эшне оештыруга, әлеге югары уку йортының кадрлар һәм социаль сәясәтенә зур өлеш кертә. Уйлап табуга 30 авторлык таныклыгы бар. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр; ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре.

Хез м.: Цементирование стали попутным газом нефтяных месторождений Татарстана // Бюл. Татсовнархоза. 1960. № 7; У истоков авиационного образования в Казани // Изв. вузов. Авиац. техника. 1982. № 4.

Әд.: Форель Закирович Тинчурин (к 80-летию со дня рождения). К., 2006.

ТИНЧУ́РИНА Сәйдә Галимҗан кызы (25.5.1926, Самара ш. — 28.4.2002, Казан), травматолог-ортопед, мед. фән. д-ры (1979), ТАССР һәм РСФСРның атказ. табибе (1967, 1983). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1950), Казан травматология һәм ортопедия фәнни-тикшеренү ин-тында эшли, 1965 елдан травматология һәм ортопедия бүлеге җитәкчесе, 1979 дан балалар травматологиясе һәм ортопедиясе бүлеге мөдире, 1985–92 дә һәм 1994–96 да шул ук бүлекнең консультация поликлиникасы табиб-ортопед-травматологы. Хезмәтләре түбән очлыкларның зарарланган эре буыннарын дәвалауга карый. Казан шәһәренең баш травматологы (1966 дан), ТАССРның баш балалар ортопед-травматологы (1983–87). «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хез м.: Влияние кортизона и ДОКа на заживление экспериментальных переломов // Ортопедия, травматология и протезирование. 1964. № 5; Применение кожной пластики у детей // Вестн. хирургии. 1966. № 2 (автордаш); Способ костной трансплантации и устройство для его осуществления // Казан. мед. журн. 1983. № 6 (автордаш).

В.Ф.Богоявленский.

ТИПТӘРЛӘ́Р, Идел буе һәм Урал алды татарларының субэтник төркеме. 1926 елда халык санын исәпкә алганда 27,4 мең кеше теркәлгән (башка елларда аерып алып исәпләнелмәгән), Татарстан һәм Башкортстан респ-каларында, Пермь, Оренбург, Свердловск өлкәләрендә яшиләр. Т.нең күпчелеге татар теле урта диалектының минзәлә һәм аңа якын бөре сөйләшләрен кулланалар. Мөселман-сөнниләр. Халыкның әлеге төркеме 16 йөзнең 2 нче яртысында оеша башлый. Башта «Т.» атамасы билгеле социаль-икътисади мәгънәгә ия була, төрле шартларда башкорт җирләренә килеп урнашкан кешеләргә карата кулланыла. Алар арасында татарлар, башкортлар, бисермәннәр, марилар, мордвалар, удмуртлар һәм чуашлар була. «Т.» термины этимологиясе «исемлек», «салым түләүче халыкны һәм мәхкәмә карарларын теркәү дәфтәре» мәгънәсендә кулланылган һәм гарәпләргә үтеп кергән фарсы телендәге «дәфтәр» сүзенә барып тоташа. Рев-циягә кадәрге тарихчылар (Г.Н.Әхмәров һ.б.) вотчина хуҗалары аренда түләүчеләрне нәкъ шундый дәфтәрләрдә теркәп барганнар дип билгелиләр.

18 йөз башында башкорт җирләренә килеп урнашкан кешеләр (припущенниклар) Т. һәм *бобыльләргә* бүленгәннәр. Т. дип — төркителле халыклар (татарлар, чуашлар, башкортлар), бобыльләр дип фин телле халыклар (марилар, удмуртлар, мордвалар) аңлашылган. 18 йөз уртасына Т.нең төркителе өлеше мөстәкыйль этник төркем булып аерыла. Т.нең нигезен татарлар, башкортлар, ассимиляцияләнгән чуашлар, ш.у. өлешчә бисермәннәр һәм марилар тәшкил итә. 1780 елларда Т. Уфа казна палатасы, 1798 дән Оренбург хәрби губернаторы карамагында булалар. Йөкләмәләр һәм салым төрләре буенча алар хәрби-йомышлы (башкортлар, мишәрләр, казакълар) һәм дәүләт крәстияннәре катлаулары арасындагы урынны билиләр. 1790 елларда хәрби-йомышлы халык разрядына күчерелеләр (хакимият тарафыннан 2 типтәр полкы оештырыла, алар 1835 кә кадәр гамәлдә була). 1830 елларның 2 нче яртысыннан Т. җирле гражданнар башлыклары карамагында булалар, әмма рекрутлар б-н тәэмин итүне һәм Оренбург (аннан соң Уфа) казаклар полкын тоту өчен салым түләүне дәвам итәләр. 1855–65 тә *башкорт-мишәр гаскәре* составында булалар.

19 йөзнең 1 нче яртысында Т., башлыча, Башкортстанның төньяк һәм көнбатыш районнарына (Агыйдел елгасының түбән агымы буенда, Ык елгасы бассейнының көнбатыш өлешендә) башкорт-вотчинниклар арасына килеп урнашалар, башкортларның тел һәм мәдәният үзенчәлекләрен үзләштерәләр. Мо ңа аларның аерым яшәүләре генә түгел, ә башкорт авылларында җирлекләр («очлар») оештырулары да сәбәпче була. 18–19 йөзләрдә Т. этник катлавы күпләп яшәгән урыннарда татарлар саны арткан саен, Т.нең этномәдәни охшашлыгы формалашу процессына татар мәдәнияте һәм теленең тәэсире көчәя. 1970 елгы Бөтенсоюз халык санын исәпкә алу материалларында (Башкортстан АССР буенча) Т. күп очракта үзләрен татарлар дип күрсәтәләр. Күпчелек этномәдәни сыйфатлар Т.не Урта Идел һәм Урал алды татарларының үзенчәлекле этнографик төркеме дип санарга мөмкинлек бирә. Т. иген-челек һәм терлекчелек (1930 елларга кадәр) б-н шөгыльләнәләр. Солы, тары, арыш, бодай үстерәләр. Т. күпләп яшәгән кайбер район-



«Типтәрләр полкы рядовое». 19 йөз башы гравюрасы. А.В.Висковатовның «Россия гаскәриләренең киемнәрен һәм коралларын тарихи тасвирлау» китабыннан. Санкт-Петербург. 1860

нарда (Учалы Т.е) терлекчелек өстенлек итә. Сунарчылык, умартачылык, балыкчылык, урманчылык һ.б. кәсепләр б-н шөгыльләнәләр. Т.ларнең традицион мәдәнияте үзенчәлекләргә бай булса да, ул Идел-Урал төбәге татарлары мәдәниятеннән аз аерыла. Т.нең йортларында стиль ягыннан Кама һәм Идел алды Казан татарлары өйләренә хас әйберләргә якын элементлар өстенлек итә. Т. киеменең үзенчәлеген хатын-кыз костюмы ачык күрсәтә. 19 йөздә — 20 йөз башында хатын-кыз



Типтәр хатын-кызлары традицион киемнәрдә. Башкортстан Республикасы Учалы районы Илче авылы.

костюмы ансамбленә зур калфак, япма рәвешендәге үзенчәлекле баш киемнәре (баулы яулык, өрпәк), билле эчке һәм тышкы киемнәр (өч билле, биш билле, күлмәк, ыштан һ.б.), бизәкле күн аяк киемнәре, бизәкләп тукылган киемнәр, мәс., тамбурлап чигелгән күкрәкчә керә. Т. яз-көз бишмәт, *казаки* (татар-мишәрләр б-н бергә яшәгән урыннарда), чикмән, кыш сарык тиресеннән тегелгән кайры тун кигәннәр. Казан татарларына хас ювелир бизәнү әйберләре (изү, яка чылбыры, сырга) кулланганнар. Йола һәм бәйрәмнәрдән *ташу карау, Җыен*, ш.у. төрле ярышларны һәм уеннарны (*карга боткасы, сөрән салу*, орлык чыгару) эченә алган *Сабан туе* бәйрәмнәре уздырылган, *Корбан* һәм *Ураза* гаете бәйрәм ителгән, ш.у. җәй көне мул тормыш теләү (корбан китерү, салкын су кою) йоласы үткәрелгән.

Әд.: Ахмаров Г.Н. Тептяри и их происхождение. К., 1907; Исхаков Д.М. Тептяри: Опыт этностатистического изучения // Советская этнография. 1979. № 4; шул ук. Этнографические группы татар Волго-Уральского региона. К., 1993; Давлетшина З.М. Татарское население Башкортостана: Этнодемогр. исслед. Уфа, 2001; Якупов Р.И. Тептяри: Ист.-этнол. очерки (к проблеме генезиса этничности). М., 2001.

Р.Р.Батыршин.

ТИПТӘРЛӘ́Р ҺӘМ БОБЫЛЬЛӘ́Р КУЗГАЛЫШЫ́, 1747 елның июль–август айларында җан башыннан салым кертүгә каршы Усы һәм Себер даругалары типтәрләренең һәм бобыльләренең кузгалышы. Оештыручылары — Б.Азаматов, Ә.Асанов, Н.Борисов, М.Лурмешев, Г.Мәмәтов, С.Семёнов, Г.Сулеев, С.Ураев һ.б. 1747 нең маенда Россия империясе Сенаты типтәрләр һәм бобыльләр өчен җан башыннан салым түләүне кертергә күрсәтмә бирә (ир-ат җаны башыннан 80 тиен); салым җыючылар хөкүмәт әмере б-н түгел, ә җирле хакимият әмере б-н килгәннәр дип, халык салым түләүдән баш тарта. 1747 нең июлендә Себер даругасының Мәләкәс авылында кузгалыш була, анда татар, мари, чуаш авылларында яшәүчеләр салым түләүдән баш тартуларын белдерәләр; салым кертү турындагы Фәрман игълан иткән вахмистр И.Моисеев куыла, җирле хакимият вәкилләре кыйнала һәм кулга алына. Усы даругасының берничә авылы татарлары һәм мари лары, Тагай авылында җыелып, ш.у. салым түләүдән баш тартулары турында игълан итәләр. Типтәрләр һәм бобыльләр сайлап алынган вәкилләрен шикаять б-н С.-Петербургка җибәрергә дигән карарга киләләр. Хәрәкәткә мишәрләрнең бер өлеше кушыла. Кузгалышны бастырырга майор Кублицкий (550 кеше) һәм генерал-майор Штокман (1750 кеше) җитәкчелегендәге җәза командалары җибәрелә. Типтәрләрнең һәм бобыльләрнең бер өлеше яңа салым түләргә ризалаша, икенче өлеше көрәшне дәвам итә һәм Танып елгасы буендагы сугышта җиңелә. 1748 нең маенда хәрәкәтнең төп оештыручылары камчы б-н суктырылалар һәм Рогервик шәһәренә мәңге лек каторгага җибәреләләр. Хәрәкәттә катнашучыларның күбесе каторга хезмәтенә озатыла, башкалары, камчы б-н суктырылганнан соң, старшиналар җаваплылыгына тапшырыла.

Әд.: Акманов И.Г. Башкирские восстания в XVIII в. Уфа, 1987.

И.Р.Вәлиуллин.

ТИРӘ́Н КҮЛ, Көнбатыш Кама алдында. Идел елгасының югары террасасында, «Аккош күле» урман-паркы терр-ясендә, Казанның Киров р-нында. 1960 елларга кадәр су өслегенең мәйданы 17,5 *га*, су күләме 1386 мең $м^3$, озынлыгы 1100 *м*, уртача киңлеге 160–170 *м*, уртача тирәнлеге 7,6 *м*, иң зур тирәнлеге 18,2 *м*. Соңгы берничә дистә елларда күлнең көньяк-көнчыгыш һәм төньяк-көнбатыш өлешендә йозмә «үлән-утраулар» барлыкка килә, со ңыннан алар яр б-н тоташалар һәм агачлар, куаклар б-н капланалар. Шундый бер йозмә «үлән-утрау» б-н Т.к.дән *Кече Тирән күл* аерылган. 1990 елларда Т.к. өслегенең мәйданы 10,4 *га*, су күләме 785 мең $м^3$, озынлыгы 760 *м*, уртача киңлеге 140 *м*, уртача тирәнлеге 6,5 *м*, иң зур тирәнлеге 13,6 *м*. Күл төбендә карст бүрәнкәләре бар. Күл карст-суффозия процессы нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Формасы озынча түгәрәк, сузынкы. Ярлары биек. Төньяк-көнбатыш өлешендә комлы пляж бар. Атм. явым-төшемнәре һәм, өлешчә, грунт сулары исәбенә туена; күлгә җир өсте суларының шактый өлеше төньяк-көнбатыштан килүче эрозияле уйсулыктан керә. Көзге-кышкы чорда күл суының үтә күренмәлелеге (2,7 *м* га кадәр) югары. Суы җи нәлчә минераль ләшкән (80–160 *мг/л*), бик йомшак (1 *мг-экв/л*), гидрокарбонат-калий-натрийлы типта. Җәен суының өске катламының темп-расы 20 °С ка җитә, төптә 6–9 °С тан артмый. Т.к. һәм аның тирә-юне ял итү максатларында файдаланыла.

Тирән күл.



Н.М.Минһаҗева.

ТИРӘНДӘГЕ́ СЫНДЫРМАЛА́Р, линеаментлар, җир кабыгының хәрәкәтчән блоклары һәм өске мантиянең түшәлмә өлеше арасындагы зона. Т.с. мөмкин булган барлык ярыклар, ваклану һәм шуңа охшаш башка зоналардан гыйбарәт. Еш кына эффузив, интрузив һәм нык кына үзгәргән токымнардан тора. Озынлыкка йөзләрчә һәм меңнәрчә *км* га, киңлеккә берничә дистә *км* га, тирәнлеккә 700 *км* га кадәр җитә. Т.с. аэротөшерү, геол. һәм геофиз. алымнар (сейсмик, магнит һ.б.) б-н ачыклана. ТР терр-ясендә кристаллик нигез күбесенчә төньяк-көнбатыш (50–60%) һәм төньяк-көнчыгыш (32–33%) җәелү системалары барлыкка китерүче күпсанлы Т.с. б-н бүлгәләнгән. Беренчеләре гранулитлы (к. *Гранулит*), икенчеләре гранитлы (к. *Гранит*) комплексларның сызыксыман җыерчыклы структуралар юнәлешенә туры килә. Киңлек яны һәм субмеридиональ җәелүнең Т.с.ы шактый кечкенә, үзәктәш һәм дугалы. Рельефта алар еш кына елга үзәннәренең тигез участоклары б-н туры килә. Мәсәлән, ТРда төньякта Идел елгасы киңлек юнәлешле агымга ия, ә Югары Ослан авылы янында зур Т.с. юнәлешенә ярашлы рәвештә кисәк кенә көньякка борыла. Геопатоген зоналар, Җирдән чыгучы югары темп-ралы җылылык агымы һәм көчле җир тетрәүләр Т.с. б-н бәйле. Т.с. буйлап җир кабыгы кантарларының күчүе вертикаль буенча — 10–15 *км* га (убылма, күтәрелмә) (к. *Авлакоген, Татар гөмбәзе, Токмово гөмбәзе*), горизонталь буенча 100 һәм артыграк *км* га җитә (күчү, шуышу). Т.с.ның үсеше — озак процесс (хәзерге көннәргә кадәр бара), алар утырма һәм магматик токымнар тупланышын контрольдә тоталар. Т.с. күп кенә файдалы казылма төрләренең (ТРда, аерым алганда, нефтьнең) тупланышында мөһим роль уйныйлар, өстәрәк ятучы токымнарга нефть үтеп керү юллары булып хезмәт итәләр, коллекторлык үзлекләренә йогынты ясыйлар. Т.с. өзелмәләре тектоник структуралар формалашуга китерә, аларда нефть, газ һәм су ятмалары барлыкка килә. Т.с. киселешендәге урыннар файдалы казылмалар эзләү өчен аеруча уңайлы.

Әд.: Кристаллический фундамент Татарстана и проблемы его нефтегазоности. К., 1996.

ТИРГӘВЕ́Ш елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Ык елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 17,6 *км*. Бассейнының мәйданы 120 $км^2$. Елга башы Тукай р-ны Югары Байлар авылыннан 2 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы Минзәлә р-ны Гөлек авылыннан 2 *км* төньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 210 *м*, тамагыныкы — 62 *м*. Су җыелу

мәйданының урманлылыгы 10%. 1 дән 10,1 *км* га кадәр озынлыктагы 7 кушылдыгы бар, иң зурысы — Сөрмәт елгасы (уң кушылдык). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,45 *км/км*^{2}. Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,25–0,5 *л/с·км*^{2}. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда елдык су агымының уртача күпьеллык катламы 92 *мм*, ташу агымы катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ункөнлегендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,05 *м*^{3}*/с*. Суы язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минераль-ләшүе язын 300–400 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*. Т. бассейнында суының күләме 0,5 млн. *м*^{3}лы буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

ТИРЕ́-ВЕНЕРОЛО́ГИЯ ДИСПАНСЕРЫ́, к. *Диспансерлар*.

ТИРЕ́-ЙОН КОҢГЫЗЛАРЫ́ (Dermestidae), төрле азык б-н тукланучылар асотрядыннан коңгызлар семьялыгы. Озынлыгы 1,5 тән 12,5 *мм* га кадәр; кабарынкы, озынча түгәрәк, бераз яссы, кинәт озынаеп киткән яки түгәрәк диярлек формада; куе төкчәле яки тәңкәле. Төсе кара-көрән, кара, еш кына чуар рәсемле. Мыекчыклары 3–11 буынлы, чукмарсыман. Тәпиләре 5 буынлы. Личинкалары каты, хәрәкәтчел, 3 пар күкрәк аяклы, озын төкле. Курчакланганда личинкаларның тиресе аркасында гына ертыла, салдырылмый, һәм ул курчак өчен саклагыч тышча буларак хезмәт итә. Үсеше кош, бал корты, шөпшә, үрмәкүч ояларында, үләксәләрдә, имезүчеләр өннәрендә бара. Олы затлар личинкалары чыккан урыннарда яки чәчәкләрдә очрый. Хайваннар (сирәк кенә үсемлекләр) чыгышыннан булган коры матдәләр б-н тукланалар, мех, тире, мамык, каурый, хайван һәм кош карачкыларына, бөҗәкләр коллекциясенә зыян салалар.

Якынча 900 төре билгеле, Россиянең Европа өлешендә 11 ыругтан 48 төре, Татарстан терр-ясендә 4 ыругтан 15 төре билгеләнгән. Attagenus ыругы вәкилләре: келәм Т.-й.к. (A. megatoma F.), тимгелле мех Т.-й.к. (A. pellio) — йон һәм мех әйберләренә, Dermestes ыругы вәкилләре: ветчина Т.-й.к. (D. lardarius), Фриш Т.-й.к. (D. frishi Kug) тире, мех, ит һәм балык продуктларына зарар китерәләр, личинкалары йорт кошларының чебиләренә нөҗүм итәләр, Anthrenus ыругы вәкилләре — музей Т.-й.к. (A. museorum) — зоол. һәм энтомологик коллекцияләрне, мехларны зарарлый.

Әд.: Определитель насекомых Европейской части СССР. М.–Л., 1965; Насекомые и клещи — вредители сельскохозяйственных культур. Т. 2. Жесткокрылые. Л., 1974; Вредители сельскохозяйственных культур и лесных насаждений. Киев, 1975. Т. 1.

А.К.Жеребцов.

ТИРЕ́С ГӨМБӘЛӘРЕ́ (Coprinus), тирес гөмбәләре семьялыгыннан эшләпәле бази-диаль гөмбәләр ыругы. Якынча 200 төре билгеле, бөтен Җир шарында таралганнар. ТР терр-ясендә 3 төре бар: ак Т.г. (C. comatus), соры Т.г. (C. atramentarius), җемелдәвек Т.г. (C. micaceus) бар. Черемәле туфракта һәм тирестә, чери торган түмгәкләрдә һәм үсемлек калдыкларында төркемләп үсәләр. Майдан октябрьгә кадәр очрыйлар. Ак, соры, сары-лт-коңгырт төстә. Эшләпәсенең диаметры 10 *см* га кадәр, еш кына кыңгыраусыман, карт гөмбәләрнең җәенке вак тәңкәчекләре бар; җемелдәвек Т.г.нең тәңкәчекләре ялтырыйлар да, соңыннан юкка чыгалар (исеме шуннан). Тулаем алганда, үрчү өлеше юка итчел. Пластинкалары иркен, башта ак, споралары өлгереп килгәндә карала. Сабы цилиндрсыман, биеклеге 20 *см* га кадәр, диаметры 1,5–2,5 *см*. Ак Т.г. сабының өске өлешендә хәрәкәтчел ак божра бар, төбендә — капчыксыман ак җиңсә. Споралары өлгергәндә эшләпә йомшагы кара сыеклык булып җәелеп китә. Чиста ак пластинкалы яшь гөмбәләр генә ашарга яраклы.

ТИРЕ́С КОҢГЫЗЛАРЫ́, пластинкамыекчылар семьялыгыннан коңгызлар төркеме; тирес коңгызчыклары (Aphodiinae), җир казучылар (Geotrupinae), скарабей (Scarabaeinae), тирес коңгызлары (Coprinae) һ.б. ас-семьялыкларны үз эченә ала. Озынлыгы 3 тән 70 *мм* га кадәр, көрән яки кара төстә, кайвакыт металлсыман ялтыравыклы. 6 меңнән, Россиядә 400 дән, Татарстанда 200 дән артык төре билгеле. Аеруча гади Т.к. (Geotrupes stercorarius), гади тирес коңгызчыгы (Aphodius fimetarius), казучы тирес коңгызчыгы (A. fossor) киң таралган. Күпчелек төрләре, җирдә өн казып, анда тирес (яки үсемлек сабаклары һәм яфраклары) туплый, аларның личинкалары шуның б-н туклана (исеме шуннан). Кайбер Т.к.на азык булып үсемлек калдыклары, сирәк кенә гөмбәләр һәм үсемлекләрнең яшел өлешләре хезмәт итә. Ассениаторлар буларак файдалы (экскрементларны ташып күмәләр); күп кенә төрләре (гади тирес коңгызчыгы һ.б.) кыр, җиләк-җимеш, яшелчә культуралары үсентеләренә зыян китерә, кайберләре — паразит суалчаннарның арадаш хуҗалары. Язгы Т.к. (Geotrupes vernalis), *төнге копр, мөгезборын коңгыз* ТР-ның Кызыл китабына кертелгән.

ТИРСӘ авылы, Әгер җ. р-нында, Әгер җ. шәһәреннән 25 *км* көньяктарак, Әгер җ. — Акбаш юнәлешендәге тимер юл станциясе. 2010 елда 1765 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 1560 еллардан татар морзалары Яушевларныкы булып исәпләнә, 1733 тә, Т. волостеның башка авыллары б-н бергә, генерал-майор К.М.*Тәфкилев* (1756 да Т.дә җирләнә) сатып ала. Җирле крәстияннәр берничә тапкыр (1742–44 һәм 1764–67) крепостной бәйлелеккә каршы баш күтәрәләр (к. *Тирсә крәстияннәре кузгалышы*), 1773–75 еллардагы Крәстияннәр кузгалышында Е.И.Пугачёв ягында сугышучы зур отряд оештыралар. Игенчелек, терлекчелек, сумала кайнату, тире эшкәртү, капчык-чыпта сугу, итек тегү һәм арба ясау б-н шөгыльләнәләр. 19 йөз башыннан Т.дә пыяла, кирпеч, поташ һәм шырпы з-ды эшли. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша, мәчет, мәдрәсә (1815 тә ачыла), мәктәп, земство мәктәбе (1882 дә ачыла), мед. участогы була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1241 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Зур Кибә волостенда, 1921 дән ТАССРның — Әгерҗе, 1924 тән Алабуга кантонында, 1927 нең 14 февраленнән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1859 да — 883, 1887 дә — 915, 1905 тә — 1047, 1920 дә — 1177, 1926 да — 1192, 1938 дә — 1152, 1958 дә — 758, 1970 тә — 815, 1989 да — 1351, 2002 дә — 1678 кеше.

Әд.: Мәрданов Р.Ф., Һадиев И.Г. Әгерҗе төбәге тарихы. К., 2003.

ТИРСӘ КРӘСТИЯННӘРЕ́ КУЗГАЛЫШЛАРЫ́, Казан губернасы Тирсә волосте крәстияннәренең алпавыт *Тәфкилевләргә* каршы баш күтәрүләре (18 йөз). 1 нче кузгалыш 1742 елда була. Сәбәбе — әлекке дәүләт крәстияннәрен алпавыт Котлыгъмөхәммәд Тәфкилевкә крепостнойлыкка бирү. Башта крәстияннәр хакимиятләргә үтенеч хаты тапшыралар. Анда алар, «бабалар һәм аталар салым түләмәгәннәр» дип, «үзләрен крәстиянлектә мәҗбүри тотмауларын» үтенәләр. 1742 дә үтенеч хатларының берсенә кул куйган 8 крәстиян кулга алына. Җавап итеп Чишмә, На җар, Тирсә, Балтач, Мордвинкино, Кибәкшур авыллары крәстияннәре «бердәм булырга һәм Тәфкилевтән котылырга» дип карар кылалар; алпавытка һәм хакимияткә буйсынудан, салым түләүдән баш тарталар. Крәстияннәрнең кузгалышларын бертуганнар К., М. һәм И.Заһитовлар, Хәбибулла һ.б. җитәкчиләр. Шул ук елның октябрь аенда, крәстияннәрне тынычландыру максаты б-н, Чишмә һәм Наҗар авылларына гаскәр җибәрелә; На җар авылында солдатларны «кыйныйлар һәм куалар». Ноябрь аенда, кузгалышны бастыру максаты б-н, кабат 500 кешедән торган гаскәр килә. Хакимиятләр крәстияннәр буйсынмаган очракта, аларның һәр унынчысын җәзалап үтерергә дип күрсәтмә бирәләр. Чишмә, Наҗар, Мордвинкино, Балтач авылларында каты сугышлар була. Хакимиятләр крәстияннәрне бастыруда зур уңышларга ирешә алмый. 1743 нең гыйнварында Тирсә волостена гаскәр килә, фетнә бастырыла, крәстияннәр җәзага тартыла. 1764–67 дә Тирсә волостенда кабат крәстияннәр кузгалышы башлана. Сәбәбе — крепостнойлыктан азат итү фәрманы чыккан дигән хәбәр таралу. Җитәкчеләре — Г.Әмиров, Я.Ермаков, И.Исәнәев, Г.Минкин һ.б. Крәстияннәр салым түләүдән туктыйлар, «алпавытны һәм аның приказчикларын куркыта» башлыйлар һ.б. 1767 дә Тирсә волостена секунд-майор Г.Широков җитәкчелегендә бер батальон солдат җибәрелә. Крәстияннәрдән җан башыннан акча җыеп алалар һәм алпавытка буйсыну турында йөкләмәгә кул куйдыралар; фетнәнең кайбер җитәкчеләре кулга алына һәм Казанга җибәрелә. Тирсә волосте халкы 1773–75 еллардагы *Крәстияннәр кузгалышында* актив катнаша.

Әд.: Алишев С.Х. Татары Среднего Поволжья в пугачёвском восстании. К., 1973; шул

у к. Тернистый путь борьбы за свободу (социальная и национально-освободительная борьба татарского народа. 2-я половина XVI–XIX вв.). К., 1999.

«әт-ТИРЪЯ́КЪ әл-КӘБИ́Р» («Зур тиръякъ», «Агуланулардан көчле дәва»), дару әзерләүгә багышланган (фармакогнозия) гыйльми хезмәт. 13 йөзнең 1 нче яртысында гарәп телендә языла. Авторы — болгар галиме Таҗетдин бине Юныс әл-Болгари. 1220–21 елларда аның тарафыннан Мосул шәһәренә (хәзерге Гыйрак терр-ясе) Мәхмүт бине Госман бине Әхмәт әт-Тифлисигә әйтеп торып яздырыла. Анда тиръякъ — составы катлаулы һәм универсаль дару рецепты бар, ул, башлыча, каты авырулардан һәм агуланганда кулланыла. Хезмәттә аның составына керүче, 7 «разряд»ка бүленгән дару ясый торган материаллар исемлеге китерелә: беренчесе — 2, икенчесе — 9, өченчесе 20 төрле ингредиентны һ.б.ны үз эченә ала. Аларның күләме, дару әзерләүнең төрле этапларында эшкәртү алымнары аңлатыла. Йомшак өлешендә тиръякъны куллану буенча киңәшләр тәкъдим ителә. 17 йөз күчермәсе Тәһран шәһәрендәге Иран Мәҗлесе китапханәсендә саклана. Кулъязма турында 1970 еллар ахырында проф. Г.Т.*Тәһир җанов* язып чыга. Профессорлар М.Г.*Госманов* һәм Ә.Б.*Халидовлар* тарафыннан фәнни әйләнешкә кертелә. 1997 дә Казанда рус телендә Ә.Б.Халидов тәр җәмәсендә һәм аның шәрехләмәләре б-н «Большой тирйак» («Большое противоядие») исемендә нәшер ителә.

Әд.: Таһиржанов Г.Т. Тарихтан — әдәбиятка. К., 1979; Давлетшин Г.М. Очерки по истории духовной культуры предков татарского народа (истоки, становление и развитие). К., 2004.

«ТИ́СБИ» ИДАРӘ́ УНИВЕРСИТЕТЫ́, дәүләт карамагында булмаган югары уку йорты. 1992 елда «Татарстан-Бавария» эшмәкәрлеккә ярдәм академиясе буларак ачыла, 1994 тә Татарстан эшмәкәрлеккә ярдәм ин-ты исемен ала, 2003 тән «ТИСБИ» идарә академиясе, 2011 дән хәзерге исемдә. Оештыручылары: «Акционерлык инвестиция коммерция банкы» ААҖ, «Татфондбанк», «Дайна» ҖЧҖ, «Интер» ҖЧҖ. Академия 2003 тә дәүләт карамагында булмаган башка югары уку йортлары: Казан эшмәкәрлек һәм идарә итү, ш.у. Идел буе халыкара мөнәсәбәтләр региональ ин-ты б-н берләштерелә. 2015 кә ун-т составында икътисад, идарә итү, юридик, мәгълүмат технологияләре, салым эше, гуманитар, читтән торып-дистанцион уку, югары уку йортына кадәрге белем бирү, урта һөнәри белем бирү ф-тлары, өзлексез белем бирү ин-ты, яшьләр ин-ты (2003 тән) эшли. Чаллы һәм Әлмәттә 2 ф-лы бар. Укыту юриспруденция, халыкара мөнәсәбәтләр, яшьләр б-н эшләү; персонал б-н идарә итү; оешма менеджменты; гамәли информатика; соц.-мәдәни сервис һәм туризм; исәпләү техникасын программа б-н тәэмин итү белгечлекләре буенча алып барыла. Көндезге бүлектә — 1000, читтән торып уку бүлегендә 6000 студент укый (барысы да бюджеттан тыш нигездә). Урта һөнәри белем бирү ф-тында укыту хокук һәм социаль тәэминатны оештыру, икътисад һәм бухгалтерлык исәбе, логистикада операцион эшчәнлек, финанслар, кунакханә сервисы, компьютер системаларында программалаштыру, дизайн (тармаклар буенча), сурдокоммуникацияләрне оештыру белгечлекләре буенча бара. Факультетта 1500 студент укый. Өзлексез белем бирү ф-тында югары белеме булганнар өчен икътисад һәм идарә итү белгечлекләре буенча укыту һәм яңадан укыту алып барыла; моннан тыш икътисади һәм юридик белгечлек буенча 120 аспирант укый. Укытучылар коллективында 300 кеше, ш.и. 30 фән. д-ры, 210 фән. кандидаты эшли. 1999 дан «Вестник ТИСБИ», «Казанский журнал международного права и международных отношений», «Сборник трудов молодых учёных НОУ ВПО Университет управления «ТИСБИ» фәнни-мәгълүмати ж-ллары басыла. Ректоры — Н.М.Прусс (1992 дән).

ТИСМӘННӘ́Р (Anobiidae), төрле азык б-н тукланучылар асотрядыннан коңгызлар семьялыгы. 1700 гә якын төре билгеле, киң таралганнар. Россиядә 100 дән артык төре бар. Гәүдәсе сузынкы, цилиндрсыман, сирәк кенә озынча түгәрәк, өске өлеше кысылган. Кара көрән яки кызыл төстә. Күпчелеге үсемлек, агач (корыган яки корый башлаган) б-н туена. Кайберләре гөмбәдә, ылыслы агач күркәләрендә, ара-тирә үсемлек сабакларында яши. Т., куркыныч янаганда, аякларын җыеп кысалар һәм үлгәнгә салышалар. Күп кенә төрләре агачта үзләре ясаган юлларның стеналарына башлары б-н бәреп аваз чыгара, бу исә ата һәм ана затларның бер-берсен табуына ярдәм итә. Сәгать текелдәвенә охшаган бу ритмик тавышны хорафатка ышанучан кешеләр элегрәк «үлем сәгате» дип атаганнар, һәм бу яман билге булып исәпләнгән. Кайбер төрләре агач йортларга, җиһаз, китапларга зыян китерә, азык продуктларын бозалар. Татарстан терр-ясендә 4 төре теркәлгән: йорт тисмәне (Anobium pertinax) һәм төньяк тисмәне (A. confusum) агач торакларда очрый, җиһаз тисмәне (A. punctatum) һәм ашлык тисмәне (Stegobium panicaum) Идел-Кама саклаулыгында билгеләнгән.

ТИ́ССЕН Юлиан Иванович (1863, Киев губ. Белая Церковь ш. — 1939, Ленинград), уеп бизәкләүче, педагог. Зәргәрче гаиләсендә туган. Петербург САнең уеп бизәк төшерү бүлегендә (ирекле тыңлаучы булып) И.П.Пожалостинда укый (1887–95). Йке көмеш медаль гә лаек була (И.-Г.Вилле нөсхәсеннән «Карчык» гравюрасы һәм натурадан төшерелгән рәсем өчен). Акад. курс тәмамлаганнан соң, 3 нче дәрәҗә класслы рәссам исеме бирелә.

Т. — Казан сәнгать мәктәбен оештыручыларның берсе; гравюра сәнгатен оештыруга зур өлеш кертә; 20 йөз Казан графика мәктәбенә нигез сала. 1896–1908 елларда Казан сәнгать мәктәбенең гравюра бүлеген җитәкли, рәсем, 1897 дән уеплаулы гравюра һәм офорт дәресләрен укыта, 1904–06 да мәктәп мөдире була. Мәктәпнең графика остаханәсе эшен оештыруда күп көч куя, аның үтенече һәм В.В.Матэ булышлыгы б-н китап басу станогы алына. Т. 18 йөздә САндә барлыкка килгән, төп нөсхәләрнең күчермәсен алуга нигезләнгән традицион алымнар б-н укытуга йөз тота, натурага карап эшләү 4 ел укыганнан соң рөхсәт ителә (күпләр тарафыннан искергән ысул дип санала). Полиграфия өлкәсе белгечләре әзерләү өчен, Т. 1907 дә укыту процессын үзгәртеп корырга һәм өстәмә дисциплиналар: ксилография һәм литография кертергә тәкъдим итә. 1908 дә укытучылар б-н низагка кереп, мәктәптән китәргә мәҗбүр була. Казан коммерция уч-щесендә рәсем һәм гравюра дәресләрен укыта. 1917 дән соң — Сочида, 1925 тән Ленинградта яши. Т.ның танылган шәкертләре арасында Л.Ф.Овсянников, П.М.Дульский бар.



Ю.И.Тиссен. «Карт портреты». 1863. Кәгазь. Офорт. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

1890 елларның 1 нче яртысында — Т.ның САндә укыган вакытта репродукцияләгән гравюралары сакланган (Р.Моргенның «Оекбашлар һәм куллар», А.Олещинскийның «Такта яручы» эшләреннән). ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда Т.ның кырыс акад. стильдә башкарылган «Натурщик карт портреты» офорты саклана (1890 еллар ахыры — 1900 еллар башы).

Әд.: Ровинский Д.А. Подробный словарь русских гравёров XVI–XIX вв. СПб., 1895; Ключевская Е.П. Казанская художественная школа. 1895–1917. СПб., 2009.

О.Л.Улемнова.

ТИТО́В Сергей Павлович (23.9.1932, Тула өлкәсенең хәзерге Одоев р-ны Левенское а. – 13.9.2011, Чаллы ш.), инженер-технолог, «Чаллы кәгазь-картон комбинаты» халык предприятиесе» АҖнең ген. директоры (1991 елдан). Ленинград урман техникасы академиясен тәмамлый (1963). Хезмәт юлын 1951 елда «Леспроект» берләшмәсенең 3 нче Мәскәү аэрофото-урман төзелеше экспедициясендә таксатор буларак башлый. 1957–58 дә «Костромалес» берләшмәсенең Нейск урман хуҗалыгында инженер-технолог (Кострома өлкәсе). 1963–76 да Кондопога целлюлоза-кәгазь комб-тында (Карелия АССР): мастер, целлюлоза з-ды башлыгы урынбасары, башлыгы, 3 нче кәгазь ф-касы башлыгы, баш инженер урынбасары, баш инженер. 1976–80 дә Кама целлюлоза-кәгазь комб-ты баш инженеры (Пермь өлкәсе Краснокамск ш.). 1980–81 дә «Камснаб» идарәсе башлыгы урынбасары (Чаллы ш.). 1981–91 дә Чаллы кәгазь-картон комб-ты директоры. Т.ның ту-



А.И. Тиханкова.

рыдан-туры җитәкчелегендә комб-т (3 чират), 170 мең *м*² торак, 20 дән артык социаль-көнкүреш объекты төзелә. Бөек Пётр исем. бүләк лауреаты. ТССР ЮС (1990–92), ТР ЮС (1992–95) депутаты, 1999–2009 да ТР Халык депутаты. Почёт, «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» орденнары, медальләр; Карелия АССР, ТР ЮС Президиумнарының Мактау грамоталары б-н бүләкләнә.

Әд.: Набережночелнинский картонно-бумажный комбинат. М., 1994.


ТИТО́ВА Татьяна Алексеевна (19.9.1967, Казан), этнограф, тарих фән. д-ры (2008). Казан ун-тын тәмамлый (1990), шунда ук этнография һәм археол. кафедрасында эшли. Хезмәтләре этнографиягә, этносоциологиягә һәм Урта Идел буендагы этносара мөнәсәбәтләргә карый. Россия этнографлары һәм антропологлары ассоциациясе әгъзасы.

Х е з м.: Лезгинская семья. К., 1999; Этническое самосознание в национально-смешанных семьях. К., 1999; Этнические меньшинства в Татарстане: статус, идентичность, культура. К., 2007; Этнические меньшинства в Татарстане: теории, стратегии и практики межэтнического взаимодействия. К., 2011 (автордаш); Диаспоры и сообщества мигрантов в Республике Татарстан: этносоциологические очерки. К., 2013 (автордаш); Диаспоры и сообщества мигрантов в Республике Татарстан: Женская трудовая миграция. Этносоциологические очерки. К., 2014. Ч. 2 (автордаш).

ТИХАНКО́ВА Анастасия Ивановна (7.9.1931, Акташ р-ны Төги а. — 18.5.1999, Алабуга ш.), сыер савучы, Соц. Хезмәт Герое (1971). 1945–86 елларда Әлмәт р-ныңң «Победа» к-зында эшли. Эшнең алдынгы алымнарын, фән һәм алдынгы тәҗрибә казанышларын куллану Т.га һәр сыердан уртача еллык савымны 1000 *кг* нан (1951) 4000 *кг* га (1970) җиткерергә мөмкинлек бирә. Бернидән тапкыр «Районның иң яхшы сыер савучысы» исеменә лаек була. Җидееллык планны (1959–65) үтәү нәтиҗәләре буенча респ-ка-ның алдынгы сыер савучылары рәтенә баса. Герой исеме җитештерүдә аеруча югары казанышларга ирешкән өчен бирелә. 1967–71 дә ТАССР ЮС депутаты. Ике Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Әлмәт шәһәренең Геройлар аллеясында Т.ның бюсты куелган.

Әд.: Р у м я н ц е в Е. Тиханкова Анастасия Ивановна // Герои Социалистического Труда Татарии (1938–1978 гг.): Док. очерки. К., 1980; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

ТИ́ХВИН ЧИРКӘВЕ́, Казанда архит-ра истәлеге. Барокко стилендә, соңгы янкормалары неоклассицизм, эклектика стильләрендә төзелә. Бер престоллы Тихвин Мәрьям Ана чиркәве Болак артында 1646–1685 еллар арасында төзелә. Кайбер чыганакларга караганда, храм 18 йөздә реставрацияләнә һәм үзгәртеп корыла, икенче бер мәгълүматлар буенча, 17 йөздә сүтелә һәм аның урынына яңасы төзелә. Риваятьләргә караганда, 1859 да янгын вакытында храм өстендә Мәрьям Ана образы күренә һәм янгын сүнә. Бу вакыйга Казан халкын бик тәэсирләндерә. Шуннан соң Тихвин храмы иконасы — шәһәрнең иң изге әйберләренең берсенә, ә храм шул иконага табыну урынына әйләнә (хәзер икона Казандагы Никола кафедраль соборына куелган). 1898–1900 елларда гыйбадәт кылучыларның хәйрия акчасына чиркәү капиталь төзекләндерелә һәм киңәйтелә, Сретение Господня һәм Сошествие Святого Духа храмнары хөрмәтенә 2 янкорма төзелә. 1938 дә чиркәү ябыла, бина хуҗалык максатларында файдаланыла, 1997 дә диндарлар җәмгыятенә кайтарып бирелә. Биредә керәшен татарларның приходы урнашкан, дини хезмәтләр татар телендә үткәрелә. Чиркәү хәзер Тукай тыкрыгы дип аталган кечерәк мәйданның үзәгендә урнашкан. Үзәкләштерелгән симметрик композицияле гыйбадәт корылмасы төренә карый. 18 йөз ахырында чиркәүнең



Казандагы Тихвин чиркәве. Хәзерге күренеше.

беренче күләме дүрткырлыкка сигезкырлык утыртылган, барабаннары яссы, сигезкырлы гөмбәз б-н очланган була. Араларында ике кыеклы түбә астында бер рәт тәрәзәле ашхана урнаша. Храмның ике рәт тәрәзәле дүрткырлыкларында һәм чаң манараларында тешсыман бизәкле кәрнизләр сакланып калган. Ярымколонналы барокко стилендәге йөзлекләр сигезкырлы биек храмның әркалы 4 тәрәзәсен каймалый. Чаң манарасы ярусындагы әркалы уемнарда каймалар юк. Чиркәүнең өске ярусы шәкелле кәрнизләр, горизонталь чыгынтылар, яссы пилястрлар һәм ярымколонналар кебек гади генә бизәкләрдән тора (соңгы яңартулар чорында да барлыкка килгән булуы мөмкин). Көнчыгыш фасадта 3 ярымтүгәрәк апсида чыгып тора, аларның икесе соңрак төзелгән янкормаларга карый. Янкормаларның биек әркалы тәрәзәләр урнашкан ян фасадлары өчпочмаклы фронтоннар б-н төгәлләнгән, тоскан ордерындагы икепортик б-н бүленгән. Уң янкормадагы көнбатыш фасадның чишелеше 2 катны да исәпкә ала. Янкормалар б-н бер үк вакытта һәр фасадта өчәр әркалы уемнары булган чиркәү алды баскычы төзелгән дип фаразлана. Реконструкцияләр нәтиҗәсендә неоклассицизм төсмерләре булган барокко формалары урнаша. Чиркәү алды баскычы чишелешендә эклектик төсмерләр күзәтелә.

Е.В.Липаков, Х.Г.Надыйрова.

ТИ́ХВИНСКАЯ Евгения Ивановна (6.5.1901, Смоленск губ. Вязьма ш. — 30.10.1976, Казан), геолог, геол.-минерал. фән. д-ры (1943), проф. (1944), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1954), СССРның мактаулы нефтьчесе (1961). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1924), шунда үк эшли, СССР геологиясе каф. мөдире (1943 тән), бер үк вакытта геол. ф-ты деканы (1949–53). Хезмәтләре геология, стратиграфия, тектоника, геоморфология, палеонтологиягә карый. Т. Ромашкино, Баулы һәм Туймазы мәйданнарында структур-геол. рәсемгә төшерүләрне җитәкли, соңыннан биредә шул мәйданнар исемендәге бик зур нефть чыганаклары ачыла. Шулай ук Куйбышев гидроузелының инженерлык-геол. партиясендә геол. эшләрне җитәкли. Геофизик карталарга аңлатмалар эшләүдә катнаша, шулар нигезендә Татарстан терр-ясенең беренче тектоник схемалары төзелә. Беренче тапкыр, утырымнар туплану мохитенең цикллы үзгәрешләре принцибына бәйләп, Пермь системасының кызыл төстәге катламнары өчен биостратиграфик алымны киң куллана. Казан ун-тының геол. ф-тында геофиз., нефть һәм газ геологиясе кафедралары, палеомагнит лаб-ясе булдыру инициаторы. СССР Палеонтология җәмгыятенең шәрәфле әгъзасы (1941 дән). 1946–58 елларда ТАССР ЮС депутаты. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Основы палеогеографии востока Русской платформы в верхнепермское время // Докл. АН СССР. 1949. Т. 64, № 2; Тектоника и размещение нефтегазовых месторождений востока Русской платформы. М., 1968 (автордаш); Палеонтологическая школа Казанского университета // Отечественная палеонтология за 100 лет, 1870–1970. Л., 1977 (автордаш).

Әд.: Б у р о в Б.В. Е.И.Тихвинская. К., 2004.

ТИ́ХВИНСКИЙ Индрик Николаевич (27.1.1931, Түбән Новгород ш. — 29.10.2006, Казан), геолог, геол.-минерал. фән. д-ры (1972). 1953 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, «Татнефтегазразведка» трестында эшли. 1960 тан Казан геол. экспедициясендә. 1962 дән ЦНИИгеолнерудта, тау-химия чималы геол. бүлеге мөдире (1985 тән), әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1991–95). Хезмәтләре стратиграфия, палеонтология, руда булмаган файдалы казылмалар геологиясенә карый. Т. Рус платформасы түбән Пермь утырмаларының стратиграфик шкаласын камилләштерә, тозлы бассейннар системасы теориясен эшли, СССР терр-ясендә калийлы тозларның чимал базасы һәм калийлылыгы перспективаларын ачыклый, Татарстанда төзелеш материалларының минераль-җитештерү комплексы үсешен нигезли (ТР Дәүләт

бүләге, 1995). Медальләр, СССРның «Мактаулы җир асты байлыкларын тикшерүче» билгесе б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Пермская система. Нижний отдел // Геология СССР. М., 1967. Т. 11, ч. 1; Геология Татарстана: Неметаллические полезные ископаемые. М., 1982; Геология Татарстана: Стратиграфия и тектоника. М., 2003 (автордаш).

Әд.: Геологи и горные инженеры России. СПб., 2003. Т. 2.

ТИ́ХИЙ ПЛЁС авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 37 *км* көнбатыштарак, Зөя елгасыннан 1 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 5 кеше (руслар) яши. 1565–67 еллардан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Ягодный, Ягодный бистәсе исемнәре б-н дә билгеле. Халкы башта Зөя Успение Богородица монастырена карый, 1764 тә — экономик, соңрак дәүләт крәс тияннәре катлавына күчерелә; игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә, төзү эшенә китә торган агач б-н сәүдә итә. 20 йоз башында Ризоположения Господня чиркәве (1877–82 дә төзелә; архит-ра истәлеге), чиркәү-приход мәктәбе (1884 тә ачыла), су тегермәне, 3 вак-тояклар кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 560 дис. тәш кил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Юмат волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Зөя, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1782 дә — 119 ир-ат; 1859 да — 291, 1908 дә — 373, 1920 дә — 450, 1926 да — 402, 1938 дә — 300, 1949 да — 198, 1958 дә — 129, 1970 тә — 17, 1979 да — 13, 1989 да даими яшәүчеләр юк, 2002 дә — 1 кеше.

ТИХОМИ́РНОВ Виктор Александрович (партиядәге тәхәллүсләре Владимир Михайлович, В.Терентьев, Д.Ветов һ.б.) (24.11.1889, Казан — 31.3.1919, шунда ук), Россиядә революцион хәрәкәттә катнашучы, РСДРП(б) әгъзасы (1905 елдан). Сәүдәгәр *Тихомирновлар* нәселеннән. Казандагы 1 нче реаль уч-ще дә укый (1900–08). Укучы яшьләрнең иҗтимагый-сәяси «Казан урта мәктәпләрендә уку чыларның берләштерелгән төркеме»н оештыручыларның һәм җитәкчеләренең берсе (1904–07). 1909 елда революцион эшчәнлеге өчен кулга алына һәм төрмәгә ябыла, аннан соң 2 елга Архангельск өлкәсенә сөрелә, шуннан чит илгә чыга. 1911 дә Мәскәү коммерция ин-тына укырга керә, эшчеләр арасында революцион пропаганда эшен дәвам итә. 1912 дә «Правда» г-тасын оештыручыларның һәм аның хезмәткәрләренең берсе. Берничә мәртәбә кулга алына, сөргендә, эмиграциядә (Австрия, Швейцария, Финляндия) була, анда В.И.Ленин б-н очраша. Россиягә кайткач, партия эшен дәвам итә. Петроградта 1917 елгы Февр. рев-циясендә катнаша. Март аенда РСДРП(б) УК тарафыннан, партия оешмасын торгызу өчен, Казанга җибәрелә, 26 мартта Казан шәһәр ком-ты рәисе булып сайлана, «Рабочий» г-тасын торгызуда катнаша. Казан сәяси оешмасыннан РСДРП(б)ның 6 нчы съезды делегаты. 1917 нең октябрендә РСДРП(б)ның Мәскәү ком-ты Хәрби бюросында эшли, аннан соң — Мәскәү советында большевиклар фракциясе секретаре. 1918 дә НКВД коллегиясе әгъзасы, совет милициясен оештыручыларның берсе. 1919 ның гыйнварында Казанга сәяси эшкә җибәрелә, шәһәрне адмирал А.В.Колчак армиясеннән саклау чараларын оештыруда катнаша.

Әд.: Герои Октября. М., 1967; Тарасов А. Тихомирнов Виктор Александрович // Борцы за счастье народное. К., 1967.

ТИХОМИ́РНОВЛАР, Казан сәүдәгәрләре, сәнәгатьчеләр, җәмәгать эшлеклеләре, игенчеләр. Т. династиясен нигезләүче — 3 нче гильдия Казан сәүдәгәре **Осип Терентьевич** (6.3.1797 — 26.8.1864). Чыгышы б-н мещаннардан. Ваклап, төрле товарлар б-н сату итә. Арткы Ям урамындагы таш йорт хуҗасы. Осип Терентьевич вафат булганнан соң, аның эшен хатыны Матрёна Матвеевна һәм уллары Василий, Иван, Тимофей, Александр дәвам итә. **Василий Осипович** (1820–?) — 2 нче гильдия Казан сәүдәгәре, гаиләдән аерылып, мөстәкыйль эш алып бара. Матрёна Матвеевна өч улы һәм шуларның гаиләләре б-н 2 нче гильдиягә керә. 1881 елда алар, икмәк һәм курыстан эшләнгән әйберләр сату өчен, «М.М.Тихомирнова уллары белән Казанда» сәүдә фирмасы (устав капиталы — 450 мең сум) оештыралар. Икмәк базарында сату итәләр. Мәскәү урамында амбарлары, Мунчала мәйданы б-н янәшә кап һәм чыпта сугу пр-тиеләре була. Т. җитештергән чыпталар 1878 дә Парижда узган Бөтендөнья күргәзмәсендә көмеш медаль, юкә курысыннан үрелгән эшләнмәләр 1893 тә Чикагода узган күргәзмәдә алтын медаль б-н бүләкләнә. Казан шәһәренең нәселдән күчмә мактаулы граждане исеменә лаек булалар. 1895 тә гарипләр йортында бер урынны тәэмин итү өчен акча бирәләр. 1906 да фирма таркала, «Тихомирнов Т.О. уллары белән», «Тихомирнов А.О. варислары» яңа ширкәтләре барлыкка килә. **Иван Осипович** (1835–?) әтисе йортында яши. Җәмәгать эшендә актив катнаша. 1870–90 елларда Казан шәһәр Думасы гласные, Казан шәһәре җәмәгать банкы исәпкә алу ком-ты составына керә. Шәһәр кредитлашу җәмгыятен оештыру комиссиясе әгъзасы, Казан сәүдәгәрләренең үзара кредитлашу җәмгыятендә идарә әгъзасы. **Тимофей Осипович** (1840–?) Вознесенская урамында яши. 1 нче шәһәр уч-щесенең җәмәгать идарәчесе, Казан шәһәр Думасы гласные, Казан шәһәре җәмәгать банкы исәпкә алу ком-ты әгъзасы. **Александр Осипович** (1850–1901) скипидар з-ды һәм «Тихомирнов А.О. уллары белән» сәүдә йорты хуҗасы; революцион хәрәкәттә катнашучы В.А.Тихомирновның әтисе. Казан шәһәр Думасы гласные, Георгий чиркәве каршындагы приход мәктәбенең җәмәгать идарәчеләре рәисе (1896 да Пески урамында бина төзи). Епархия училищеләре советының Казан өязе бүлеге әгъзасы, чиркәү каршындагы приход мәктәбе укучыларына зур күләмдә акча иганә кыла.

Л.М.Свердлова.

ТИХОМИ́РОВ Борис Иванович (8.5.1946, Коми АССРның Кожва р-ны Абезь а.), инженер, ТАССРның атказ. машина төзүчесе (1991), ТРның атказ. төзүчесе (1996). 1970 елдан, Мәскәү энергетика ин-тын тәмамлаганнан соң, «Гипрониавиапром» ин-тының Казан ф-лында эшли (1992 дән — «*Казан Гипрониавиапром*»), 1988 дән — башлык, 1992 дән — директор, 1994 тән — ген. директор. «Торак, җәмәгать, сәнәгать биналарының һәм корылмаларының көчле терәк системаларын булдыру һәм тормышка ашыру» хезмәте өчен фән һәм техника өлкәсендә ТР Дәүләт бүләгенә (2000) лаек була. 2 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» ордены медале (2007) һәм башка медальләр б-н бүләкләнә.

ТИХОМИ́РОВ Михаил Николаевич (19.5.1893, Мәскәү — 2.9.1965, шунда ук), тарихчы, археограф, чыганакларны өйрәнү белгече, историограф, тарих фән. д-ры (1939), СССР ФАнең хакыйкый әгъзасы (1953; 1946 елдан мөхбир әгъза). Мәскәү ун-тын тәмамлый (1917). 1917 дән Дмитров, Богородск, Самара шәһәрләрендә музей, китапханә, укыту эшендә. 1919 да Кызыл Армия сафларында хезмәт итә, Гражданнар сугышында катнаша. 1919–23 тә Самара ун-тында. 1923 тән Мәскәүдә. 1934 тән Мәскәү ун-тында: тарих ф-ты деканы (1946–48), язма чыганакларны өйрәнү каф. мөдире (1952 дән), проф. (1940). Бер үк вакытта, 1935–53 тә, СССР ФАнең Тарих ин-тында, 1958 дән Славяннарны өйрәнү ин-тында. 1953–57 дә СССР ФАнең Тарих фәннәре бүлеге акад.-секретаре. 1956 дан Археография комиссиясе рәисе. Хезмәтләре Россия һәм СССР халыклары тарихына, гомумславян мәсьәләләренә, язма чыганакларны өйрәнү, археография, тарихи география, палеография, дипломатика, историографиягә карый. Татарларның болгарлардан килеп чыгышы теориясе тарафдары. Алтын Урда тарихын, Идел буе һәм Урал алды халыкларын формалашуда аның ролен өйрәнүне яклап чыга (к. *СССР ФА фәнни сессиясе*). «Борынгы Мәскәү» («Древняя Москва», М., 1947), «XIV–XV йөзләрдә урта гасырлар Мәскәве» («Средневековая Москва в XIV–XV веках», М., 1957), «Россия XVI йөздә» («Россия в XVI столетии», М., 1962), «Урта гасырлар Россиясе XIV–XV йөзләрдәге халыкара юлларда» («Средневековая Россия на международных путях XIV–XV вв.», М., 1966), «Россия дәүләте XV–XVII йөзләрдә» («Российское государство в XV–XVII вв.», М., 1973), «Борынгы Русь» («Древняя Русь», М., 1975) монографияләрендә Россия составындагы Идел буе ханлыкларының икътисади, сәяси һәм мәдәни багланышларын өйрәнә; татар халкы формалашуда Идел буе болгарларының һәм болгарлар мәдәни мирасының әһәмиятен күрсәтә; татар халкының урнашу урыннарын ачыклый; Казан ханлыгының тарихи географиясе һәм аны Рус дәүләтенә кушу б-н бәйле мәсьәләләрне өйрәнә. Күп кенә язма чыганакларны (ш.и. 1549 елгы Казан ярлыгын) бастыручы, «Куликово сугышы турында хикәятләр»не («Повести о Куликовской битве», М., 1959), «Мамай явы турында риваять»не («Сказание о Мамаевом побоище», М., 1959) нәшер итә. Ленин ор -



К.К. Тихонов.

дены, ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Исследование о «Русской Правде». М.–Л., 1941; Древнерусские города. М., 1946; Источниковедение истории СССР. М., 1962; Русская культура X–XVIII вв. М., 1968; Классовая борьба в России XVII в. М., 1969.

Әд.: М.Н.Тихомиров // Материалы к биобиблиографии учёных СССР. Сер. истории. М., 1963. Вып. 6; С т а р о в е р о в а И.П. Рукописное наследие академика М.Н.Тихомирова в Архиве Академии наук СССР. М., 1974; М у х а м е д ь я р о в Ш.Ф. Вопросы истории народов Поволжья в трудах М.Н.Тихомирова // Археогр. ежегодник за 1976 г. М., 1977; Ч и с т я к о в а Е.В. Михаил Николаевич Тихомиров (1893–1965). М., 1987.

Е.Б.Долгов.

ТИХОМИ́РОВ Пётр Валерианович (1829, Казан — 1889, шунда ук), архитектор. Иреккә җибәрелгән крепостной крәстиян улы. Казан өяз уч-щесен тәмамлый, 1855 тә (башка мәгълүматлар буенча, 1861 дә), ирекле рәссам дәрәҗәсен алу өчен, САнә экстерн рәвештә имтихан бирә. 1850 еллар башыннан Казан



П.В.Т и х о м и р о в. Казан Богордица монастыреның Крестовоздвижение чиркәве. Хәзерге күренеше.

губернасының төзелеш һәм юл комиссиясендә — сызымчы, 1863 тән архитектор ярдәмчесе булып хезмәт итә. 1865–70 тә Казан губерна идарәсенең төзелеш бүлеге технигы, отставкага чыккач, шәхси заказлар үти. Үзеннән өйрәнгән архитектор, Т. югары техник һәм сәнгать дәрәҗәсендә төрле стильдәге күп кенә биналар проектлаштыра. Аның проекты буенча төзелгән корылмаларның күпчелеге совет чорында һәм советтан соңгы чорда әһәмиятен югалта (ш.и. Балык базары мәйданы, хәзерге Тукай исем. мәйдан). Казандагы И.М.Кузнецов (1863), И.П.Оконишников (1873), А.С.Меркулов (1874), Н.А.Колобов (1877) йортлары, М.М.Данилов мунчалары (1874); Чистайдагы К.Ф.Розентрейтер йорты (1863), Алексеев р-нының Приозёрный, Мамадыш р-нының Дегетле, Покровка, Спас р-нының Бураково, Тәтеш р-нының Никифоровка авылларындагы чиркәүләр сакланып кала. Т.ның аеруча мәгълүм корылмасы — Крестовоздвижение чиркәве булган Казан Богородица хатын-кызлар монастыре корпусы (1866 елгы проект, 1887 елгы бина).

Әд.: О с т р о у м о в В.П. Казань: Очерки по истории города и его архитектуры. К., 1978; М о р т а з и н а Л.М. Казанские архитекторы конца XVIII – начала XX века: биогр. справ. к., 1999.

Е.В.Липаков, Л.М.Мортазина.

ТИ́ХОН (Воинов Тимофей Васильевич) (21.2.1655, Түбән Новгород ш. — 24.3.1724, Казан), дин эшлеклесе. Т. атакай рус сәүдәгәрләренең өстен хокуклы корпорациясе — Сәүдә йөзлегенә карый. Яшьли ятим кала (1659), апасында тәрбияләнә. Бик диндар була. 1672 елда монастырьга китә, әмма өенә кайтарып җибәрелә. 1677 дә, милкен өләшеп бетереп (соңрак храмнар һәм монастырьлар ихтыяҗына иганә иткән акчасыннан кала), монахлык кабул итә һәм Түбән Новгородтагы Благовещение монастыренда монах була. 1678–92 дә Мәскәүдә патриарх йорты карашында хезмәт итә. 1692–95 тә Мәскәү Новоспас монастыре архимандриты. 1695–99 да — Сарск һәм Полонск, 1699 дан Казан һәм Зөя митрополиты. Сәяси һәм дини әлемтәләре зур була, император Пётр I, А.Д.Меншиков һ.б. б-н хат алыша. Т. башлангычы б-н, Идел буенда берничә дистә ел тынлыктан соң, башарак актив агитация формасында, миссионерлык эшчәнлеге яңартыла (к. *Православие миссионерлыгы*). Рус булмаган балалар өчен руханилар православие мәктәбе (1707–09 да Казанда эшли), 1718 дә — цифирь мәктәбе, 1723 тә Казан славян-латин мәктәбе (соңрак руханилар семинариясе итеп үзгәртелә) ача. Т. вакытында һәм өлешчә аның акчасына *Богородица пустыненың* күпчелек өлеше төзелә. 1722 дә, Пётр I Казанга килгәндә, Т. императорны каршы ала, Болгар шәһәре хәрабәләренә сәфәре вакытында аны озата бара. Пётр I үзенең фәрманы б-н Т.га Болгар истәлекләрен саклауны йөкли, кабер ташларындагы язуларны күчереп алып, мәгънәсен белергә куша.

Х е з м.: Тихон (Воинов), митрополит Казанский и Свияжский по переписке с Петром Великим // Странник. СПб., 1905. Ч. 1.

Әд.: С в е т л а к о в А. Митрополит Тихон (Воинов): его жизнь и просветительско-административная деятельность. К., 1908; Л и п а к о в Е.В. Архипастыри Казанские. 1555–2007. К., 2007.

ТИ́ХОНОВ Георгий Фёдорович (16.11.1905, Түбән Новгород губ. Васильсурск эшчеләр пос. — 24.12.1992, Казан), хирург, мед. фән. д-ры (1964). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1936), шунда ук хирургия кафедрасында эшли. 1938–42, 1944–50 елларда Казан стомат. ин-ты, 1942–44 тә Казан мед. ин-ты директоры, 1950 дән гомуми хирургия кафедрасында; бер үк вакытта, 1956 дан, Казан мед. ин-тының стомат. ф-ты деканы. 1952–54 тә ТАССР сәламәтлек саклау министры. Хезмәтләре ашказаны-эчәк тракты авыруларын хирургик дәвалауга карый. Кызыл Йолдыз ордены, медальләр, ТАССР ЮСның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Варианты щадящих операций на стремени и их функциональные результаты // Тр. Казан. мед. ин-та. 1985. Т. 63.

Әд.: Доцент Георгий Фёдорович Тихонов (к 85-летию со дня рождения) // Казан. мед. журн. 1990. № 6.

ТИ́ХОНОВ Кирилл Клементьевич (26.4.1921, Мәскәү — 28.12.1998, шунда ук), дирижёр, педагог, ТАССР, РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1957, 1962), РФнең халык артисты (1997). 1947 елда — Мәскәү консерваториясенең оркестрлык ф-тын, 1952 дә Ленинград консерваториясенең симф. дирижёрлык бүлеген тәмамлый. 1945 тән — Н.П.Охлопков исем. Мәскәү драма театры, 1947 дән — Ленинград комедия театры, 1954 тән П.И.Чайковский исем. Пермь опера һәм балет театры оркестры дирижёры. 1956–60 та Татар опера һәм балет театрының баш дирижёры, бер үк вакытта Казан консерваториясендә укыта. 1960–68, 1972–77 дә — Свердловск, 1968–72 дә Белорус опера һәм балет театрларының баш дирижёры. 1977 дән Мәскәү мәдәният ин-ты профессоры, бер үк вакытта Зур һәм Мария театрларында куелган спектакльләрнең муз. җитәкчесе. 1990 нан Мәскәү «Геликон-опера» театрының баш дирижёры һәм муз. җитәкчесе. Казанда Н.Җиһановның «Җәлил», Ж.Фәйзинең «Тапшырылмаган хатлар», Ш.Гуноның «Ромео һәм Джульетта» һ.б. операларны сәхнәләштерә.

Ф.Ш.Салитова.

ТИ́ХОНОВ Павел Михайлович (1892, Түбән Новгород өлкәсе — 2.5.1954, Казан), агроном-селекционер, а.х. фән. д-ры (1943), ТАССР, РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1944, 1950). Казан урта а.х. уч-щесен (1913), Мәскәү а.х. ин-тын (1918) тәмамлый. 1919 елда Түбән Новгород өлкәсендә агроном, 1919–20 дә Казан губернасы җир бүлегенең губерна агрономы ярдәмчесе. 1920–21 дә Казан политехника ин-тында. 1921–54 тә Казан а.х. ин-тының селекция каф. мөдире, проф. (1935 тән). 1932 дә Т. респ-када беренчеләрдән булып язгы бодай селекциясе буенча эш башлый. Хезмәтләре үсемлекләр үсешенә тышкы шартларның тәэсирен өйрәнүгә карый. Ленин ордены б-н бүләкләнә (1952).

Х е з м.: Семеноводство и сорта культурных растений. К., 1933; Яровая пшеница в Татарии. К., 1949; Основы агротехники. К., 1953.

ТИ́ХОНОВА Валентина Петровна (15.2.1948, Казан), технолог, ТР Дәүләт бүләгеләре лауреаты (2003), техник фән. канд. (1982). Казан җиңел сәнәгать техникумын (1963), Бөтенсоюз текстиль һәм җ. ң. сәнәгать читтән торып уку ин-тын (1972) тәмамлый. 1969 елдан В.И.Ленин исем. Казан күн җитештерү берләшмәсендә эшли. 1976 дан Бөтенсоюз текстиль һәм җ. ң. сәнәгать читтән торып уку ин-тында, 1990 нан Казан химия-технол. ин-тында, 1992–98 дә «Сафьян» АҖдә (каты күннәр җитештерү башлыгы). 1998 дән Казан технол. ун-тында. Т. тигезсез түбән темп-ралы плазманың коллаген һәм кератин катыш

материалларга тәэсирен тикшерә. Дәүләт бүләге югары сыйфатлы мех һәм туннар өчен сарык тиресе җитештерүдә түбән темп-ралы плазма куллануның фәнни нигезләрен һәм яңа технологияләрен эшләүдә катнашканы өчен бирелә.

Х е з м.: Влияние плазменной обработки на основные свойства кож для низа обуви // Кожевенно-обувная пром-сть. 2003. № 6 (автордаш); Применение низкотемпературной плазмы пониженного давления на стадии выделки шкуры северного оленя // Кожевенно-обувная пром-сть. 2004. № 5 (автордаш).

ТИ́ХОНОВКА авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 4 *км* көньяк-көнчыгыштарак урнашкан. 2010 елда 1660 кеше яши. Урта мәктәп. Чиркәү. 1780–90 елларда нигез салына. Беренче исеме — Тихая Ерыкла, хәзерге исеме 1830–40 елларда беркетелә. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Тихая Ерыкла буларак та билгеле. 20 йөз башында Т.да Михаил-Архангел чиркәве (1869 да төзелә), чиркәү-приход мәктәбе, су тегермәне, кредит ширкәте эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1191 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Урсалы волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Әлмәт р-нында, 1966 ның 24 мартыннан шәһәр тибындагы Түбән Мактама посёлогы составына керә, 1996 ның 2 октябреннән — яңадан мөстәкыйль торак пункт. Халык саны: 1795 тә — 109, 1859 да — 417, 1897 дә — 681, 1910 да — 973, 1920 дә — 845, 1926 да — 719, 1938 дә — 737, 1949 да — 664, 1958 дә — 724, 1970 тә — 1111, 1979 да — 988 кеше, 1989 һәм 2002 дә халык саны шәһәр тибындагы Түбән Мактама посёлогын да кертеп исәпләнә.

ТИ́ХОНОВО авылы, Менделеев р-нында, Менделеев шәһәреннән 10 *км* көньяктарак, Туйма елгасы буенда. 2010 елда 814 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 59%, татарлар — 28%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, җәнлек үрчетү. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1760 елларда Трёхсвятское (к. *Алабуга*) авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала, 1866 га кадәр Пустобаево исемен йөртә. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы удел крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Тихон Амафунтский чиркәве (1866–72 дә төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1863 тән), китапханә, су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1352,4 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Трёхсвятское волостенда, 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Бондюг, 1931 нең 20 гыйнварыннан — Алабуга, 1935 нең 10 февраленнән — Бондюг, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1985 нең 15 августыннан Менделеев р-нында. Халык саны: 1836 да — 617, 1859 да — 813, 1887 дә — 1052, 1905 тә — 1215, 1920 дә — 1308, 1926 да — 1268, 1938 дә — 833, 1949 да — 668, 1958 дә — 452, 1970 тә — 269, 1979 да — 431, 1989 да — 749, 2002 дә — 758 кеше.

ТИШМӘНУ́Т (Androsace), нәүрүзгөлчәләр семьялыгыннан бер- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 100 гә якын төре билгеле, күбесенчә Евразиядә, берничә төре Америкада таралган. Татарстан терр-ясендә 4 төре бар: озынча Т. (A. elongata), җепсыман Т. (A. filiformis), әре касәле Т. (A. maxima) һәм төньяк Т.ы (A. septentrionalis). Барлык районнарда да очрыйлар. Су буйларында, далаланган тау битләрендә, куаклыкларда, болыннарда үсәләр. 2–20 *см* биеклектәге берьеллык үсемлекләр. Яфраклары ланцетсыман яки озынча, таралгыда урнашкан. Чәчәкләре вак, алсу, ак, берле яки чатыр чәчәк төркемендә. Җимеше — вак кара көрән орлыклы шарсыман тартмачык. Апрель–августта чәчәк аталар. Җимешләре июнь аеннан өлгерә башлый. Орлыктан һәм вегетатив юл б-н (тамыр үсентеләреннән) үрчи. Халык медицинасында җепсыман Т. һәм төньяк Т.ы үләне төнәтмәләре йөрәк, нерв авырулары вакытында, бәвел юлларында таш утырганда кулланыла; декоратив үсемлек.

«ТКУ СТУДЕНТЫ́», журнал; к. *«Комвуз студенты»*.

«ТНГ-ГРУПП», нефть сервисы компаниясе. 1953 елда Бөгелмә шәһәрендә Союз Дәүләт Татарстан геофизика тресты буларак оештырыла, 1987 дән ҖБ, 1996 дан АҖ, 2006 дан «ТНГ-Групп» ААҖ. 20 дән артык промысел, геол.-разведкалау, бораулау һәм фәнни-җитештерү бүлекчәләрен берләштерә, РФнең барлык нефть-газ чыгаручы төбәкләрендә, ш.у. чит илләрдә эш алып бара. Казакъстан, Үзбәкстан, Ливия, Гыйрак, Анголада уртак пр-тиеләре, филиаллары һәм вәкилләкләре бар. Төп эшчәнлеге: нефть һәм газ чыганакларын разведкалау һәм эшкәртү өчен геол.-геофизик эшләр; нефть һәм газ скважиналарында геофизик хезмәтләрнең тулы спектры; чыганакларны эшкәртү мониторингы; электро-, грави-, магнито- һәм сейсморазведкалау, аэрокосмик дешифрлау, геол.-геофизик мәгълүматны эшкәртү, скважиналар бораулау, фондтагы иске скважиналарны ремонтлау. «Т.-Г.»ның геофизик эшләреңең нәтиҗәсе буенча 100 дән артык углеводород чыганагы ачыла, углеводород перспективалы 800 дән артык геол. структура тирәнтен бораулап разведкалау өчен әзерләнә. 220 дән артыграк ачыш ясала, 42 хезмәт СССРның һәм Татарстанның Дәүләт бүләкләренә, СССР ВДНХсы, Бөтенсоюз күргәзмәләреңең медальләренә лаек була. Хезмәткәрләр саны 9 мең кеше, ш.и. 6 фән канд. (2016).

Җитәкчеләре: М.Б.Кадисов (1953–66), Э.П.Халабуда (1966–95), Р.Г.*Харисов* (1995 тән).

ТОБА́ авылы, Әгерҗе р-нында, Әгер җе шәһәреннән 30 *км* көньяктарак, Иж елгасы буенда. 2010 елда 83 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Клуб. Мәчет. 1640 тан мәгълүм. 1730 еллар-да Тирсә волостеның башка авыллары б-н бергә генерал-майор К.М.*Тәфкилев* сатып ала, һәм 1861 елгы реформага кадәр авыл аның нәселенеке булып санала. Җирле крәстияннәр берничә тапкыр (1742–44 һәм 1762–64 ләрдә) крепостной бәйлелеккә каршы баш күтәрәләр (к. *Тирсә крәстияннәре кузгалышы*). 1773–75 ләрдәге Крәстияннәр кузгалышы чорында Е.И.Пугачёв ягында сугышалар. Игенчелек, терлекчелек, балык тоту, агачтан өй җиһазы ясау б-н шөгыльләнәләр. 20 йөз башында Т.да мәчет, мәктәп эшли, 1914 тә земство мәктәбе ачыла. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 468 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Сарсак-Умга волостенда, 1921 дән ТАССРның — Әгерҗе, 1924 тән Алабуга кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1859 да — 257, 1887 дә — 313, 1920 дә — 415, 1926 да — 413, 1938 дә — 414, 1958 дә — 195, 1970 тә — 182, 1989 да — 104, 2002 дә — 61 кеше.

ТОБА́ авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 21 *км* көньяктарак, Зәй елгасы буенда. 2010 елда 245 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1678 дән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.да мәчет, мәктәп, су тегермәне, ашлык саклау-сату кибете, 4 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1182 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Сухарево волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1859 да — 333, 1870 тә — 377, 1897 дә — 669, 1920 дә — 875, 1926 да — 494, 1949 да — 714, 1958 дә — 626, 1970 тә — 623, 1979 да — 504, 1989 да — 281, 2002 дә — 256 кеше.

ТОВСТЫ́Х Евгений Васильевич (29.4.1905, хәзерге Молдавия Респ-касының Рышковка а. — 1976, Ленинград), корабльләр төзүче, югары белем бирүне оештыручы, техник фән. канд. (1959), Дагстан АССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1965). 1933 елда Николаев корабль төзүчеләр ин-тын тәмамлый. 1920–30 елларда — Одесса өлкәсенең төрле пр-тиеләрендә, 1926–33 тә Николаев судно-лар төзү з-дында эшли. 1933 тән — Балтыйк суднолар төзү з-дында (Ленинград), 1939–41 дә заводның директоры. Т. «Сталин», «Молотов» бозваткычлары, «Киров», «Максим Горький» крейсерлары төзелеше б-н җитәкчелек итә. «Ермак» бозваткычын (И.Д.Папанин җитәкләгән поляр экспедицияне коткаруда катнаша, 1938) уңышлы ремонтлау уңаеннан «Хезмәттәге батырлык өчен» медале б-н бүләкләнә. 1941–45 тә 340 нчы з-д директоры (к. *Яшел Үзән судно-лар төзү заводы*). Т. җитәкчелегендә з-дта илнең Хәрби-диңгез флоты өчен бронекатерлар һәм буксирлар чыгарыла, корал һәм сугыш кирәк-яракларын сериялә җитештерү оештырыла. 1945–76 да Ленинград ко-

рабль төзүчеләр ин-тының ректоры, суднолар төзү каф. профессоры була. Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: Судостроение России: Биогр. энцикл. М., 2008.

ТОГА́ЕВО авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 15 *км* көнчыгыштарак, Казан–Уфа автомобиль юлы буенда. 2010 елда 44 кеше (руслар) яши. 1731 гә кадәр нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Ильинский исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы удел (1790 елларга кадәр — сарай) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү-приход мәктәбе, тимерче алачыгы, ашлык саклау-сату һәм 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 454 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Яр Чаллы волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Чаллы, 1976 ның 20 апреленнән Тукай р-нында. Халык саны: 1859 да — 248, 1870 тә — 476, 1906 да — 513, 1920 дә — 437, 1926 да — 351, 1938 дә — 517, 1949 да — 246, 1958 дә һәм 1970 тә — 136 шар, 1979 да — 109, 1989 да — 48, 2002 дә — 31 кеше.

ТОГА́ШЕВО (Тугаш) авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 17 *км* көньяк-көнбатыштарак, Мишә елгасы буенда. 2010 елда 103 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Тулы булмаган урта мәктәп, китапханә. 16 йөз ахырына кадәр нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Тагашево, Покровский исемнәре б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тимерчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Покров чиркәве (1787 дә төзелә), земство мәктәбе (1868 дә ачыла), 2 тегермән, 4 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1444,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Колай волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Питрәч, 1938 нең 4 августыннан — Столбище, 1959 ның 26 мартыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 203 ир-ат; 1859 да — 781, 1897 дә — 1102, 1908 дә — 1306, 1920 дә — 1419, 1926 да — 1585, 1949 да — 911, 1958 дә — 658, 1970 тә — 367, 1979 да — 295, 1989 да — 192, 2002 дә — 135 кеше. Т.ның истәлекле уры-ны — төрле елларда алпавытлар И.Д.Макаров, В.Ф.Желтухин, Могилатовлар яшәгән йорт (18 йөз архит-ра истәлеге).

ТОДУ́Н, Хәзәр каганлыгында каганның идарәчесе. Т.нар — дәүләтнең адм. үзәкләренә, кайбер очракларда аның чигенең тышында-гы шәһәрләргә (мәс., 8 йөз башында Т. элек-рәк хәзәрләр протекторатына күчкән Херсон шәһәрендә була) җибәрелә. Урыннарда идарә эшләрен, салымнар җыюны контрольдә тота һ.б.

Әд.: Артамонов М.И. История хазар. Л., 1962.

ТОЖ елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Шәмәк елгасының (Казансу елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 10,3 *км*. Бассейны-ның мәйданы 28,6 *км*^{2}. Биектау р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Олы Пүчинкә авылыннан төньяктарак, тамагы Ташлы Кавал авылында. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 82 *м*. Т.ның су җыелу мәйданында урман үсемлекләре юк. Елганың 0,5 *км* дан 1,8 *км* га кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,47 *км/км*^{2}. Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,25–0,5 *л/с·км*^{2}. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Корылык булган елларда елга урыны-урыны б-н кибә. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 114 *мм*, ташу агымы катламы 110 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ункөнлегендә башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,02 *м*^{3}*/с*. Суы язын чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минераль-ләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*.

ТОЗЛА́К (Salsola), алабутачалар семьялыгыннан берьеллык үләнчел үсемлекләр, ярымкуак һәм куаклар ыругы. 200 дән артык төре билгеле. Евразия, Африка чүлләре һәм ярымчүлләрендә таралган, Америка һәм Австралиягә читтән кергән үсемлек. Татарстан терр-ясендә 2 төре бар: калкулык Т.ы (S. collina) һәм күрай Т.ы (S. tragus) — ара-тирә барлык районнарда да очрыйлар. Даланган тау битләрендә, көтүлекләрдә, чүпле урыннарда, юл буйларында үсә. 10–100 *см* биеклектәге үсемлек. Сабагы ботаклы. Яфраклары тар, чиратлашкан. Чәчәкләре ике җенесле, куентылы башак чәчәк төркемендә. Җимеше — канатча. Июль–сентябрьдә чәчәк ата. Җимешләре август–октябрьдә өлгерә. Орлыктан үрчиләр. Калкулык Т.ының җир өсте өлешендә сапонин, алкалоид, калий тозлары, натрий бар. Халык медицинасында үләнтөнәтмәсе бөер, бавыр һәм йөрәк авыруларын дәвалауда кулланыла. Курай Т.ы — терлек азыгы.

ТОЗЛАКЛА́Р, тозланган туфраклар тибы, тозланган ана токымнарда (автоморф Т.) яки минерализацияланган грунт сулары якын булган һәм өскә күтәрелеп чыккан шартларда (гидроморф Т.) формалашалар. Т.га хас үзенчәлек — зур күләмдә җи ңел эрүчән тозлар, алар җир өслегендә — аксыл-соры кабык, туфрак эчендә тамыр, нокта һәм конкрецияләр барлыкка китерә. Тозның составы буенча сульфат-содалы, сульфат-хлоридлы һәм хлоридлы Т.ны билгелиләр. Т.ны үзләштергәндә, туфрактан җи ңел эрүчән тозларны бетерү өчен, төче су б-н юдыру алымы кулланалар. Гидроморф Т.да грунт сулары биеклеген түбәнәйтү өчен, башта дренаж үткәрәләр. Т.ны эшкәртү ш.у. системалы рәвештә органик һәм минераль ашламалар кертүне, селтеле реакция вакытында гипслау үткәрүне үз эченә ала. Т. ТР терр-ясендә Кама аръягының көньяк-көнбатыш өлешендә һәм Идел алдында кара һәм болын-кара туфраклар б-н комплекста очрыйлар. Аларның гомуми мәйданы 4,8 мең *га* тәшкил итә. Печәнлек һәм көтүлек җирләр буларак файдаланыла.

ТОЙГЕЛДЕ́ авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 14 *км* көнбатыштарак урнашкан. 2010 елда 768 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1737 дән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп, су тегермәне, тимерчелек, ашлык саклау-сату кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1792 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Иректе волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1798 дә — 206 кеше, 1816 да — 137 ир-ат; 1870 тә — 846, 1897 дә — 1186, 1906 да — 1253, 1920 дә — 1449, 1926 да — 1174, 1938 дә — 1040, 1949 да — 663, 1958 дә — 511, 1970 тә — 702, 1979 да — 623, 1989 да — 688, 2002 дә — 733 кеше.

ТО́КАРЕВ Александр Михайлович (30.4.1956, Саратов өлкәсе Яңа Бурасы р-ны Кутьино а.), инженер-механик, «Әлмәт торба заводы» АҖнең ген. директоры (1989 елдан), икътисад фән. канд-ты (2004), ТРның атказ. машина төзүчесе (1996). 1978 дә Саратов политехника ин-тын тәмамлаганнан соң, Горький автомобиль з-дында мастер булып эшли. 1979–89 да Әлмәт батырылма электр насослары з-дында инженер, бюро, цех башлыгы, җитештерү башлыгы, директор урынбасары. Т. җитәкчелегендә пр-тие техник яктан үзгәртеп корыла, туры җәйле торбалар җитештерү өчен заманча торба станнары сафка кертелә, рулонлы корычны буйга кисү, торба үткәргечләрнең тоташтыру детальләрен әзерләү, торба эчен эпоксид материаллар б-н каплау производствolары оештырыла. РФ Хөкүмәте бүләге лауреаты (2003). Медальләр б-н бүләкләнә.

ТО́КАРЕВ Виктор Борисович (8.2.1924, Казан — 26.10.1979, шунда ук), тарихчы, тарих фән. д-ры (1977), проф. (1979). Бөек Ватан сугышында катнаша. Казан юридик ин-тын тәмамлаганнан соң (1951), Алтай крае прокуратурасында өлкән тикшерүче булып эшли. 1953–59 елларда Казан мед. уч-щесендә укыта, 1959–69 да Казан ун-тының КПСС тарихы кафедрасында эшли. 1969–79 да Казан төзүче инженерлар ин-тында КПСС тарихы каф. мөдире. «Белем» җәмгыятенең фәнни-методик советы әгъзасы. Хезмәтләре Урта Идел буе респ-калары сәнәгате һәм Татарстан эшчеләр сыйныфы тарихына карый. Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Партийное руководство развитием промышленности автономных республик Среднего Поволжья (1946–1958 гг.). К., 1976; Рабочий класс Татарии (1961–1980). К., 1981.

ТО́КАРЕВ Дмитрий Степанович (1.10.1902, Оренбург губ., Оренбург өязе Исаево-Дедово а. — 1993, Мәскәү), генерал-майор (1945).

1917–24 елларда Исаево-Дедово волость идарәсендә, өяз профсоюз бюросында, өяз башкарма ком-тында эшли. 1924–37 дә (бүленеп) Казакъстанда чик буе гаскәрләрендә. 1938–43 тә — СССР Эчке эшләр халык комис-тының Калинин өлкәсе буенча идарәсе, 1943–45 тә СССР Дәүләт куркынычсызлыгы халык комис-тының Калинин өлкәсе буенча идарә башлыгы. 1945–46 да — Таҗикстан ССРның халык комиссары, 1946–48 дә — дәүләт куркынычсызлыгы министры. 1948–53 тә ТАССР дәүләт куркынычсызлыгы министры. М.*Җәлилне* һәм аның «*Җәлилчеләр төркеме*»ндәге көрәштәшләрен аклау эшенә зур өлеш кертә. СССР Эчке эшләр министрлыгының Владимир өлкәсе буенча идарәсе бүлеге җитәкчесе. 1954 тән отставкада. 1940–54 тә — СССР ЮС, 1947–51 дә Таҗикстан ССР ЮС депутаты. Ленин ордены, ике Кызыл Байрак, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт Билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Р.Ә.Кашапов.

ТОКА́РЛИКОВ Никита Евдокимович (1918, Уфа губ. Минзәлә өязе, хәзер Әлмәт р-ны Кәләй а. — 18.8.1944, Жагар ш., Литва), Сов. Союзы Герое (24.3.1945, үлгәннән соң), сержант. Туган авылында хисапчы булып эшли. 1939 елдан Кызыл Армиядә. 1944 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 1971 нче истребительләр-танкка каршы артиллерия полкында орудие командиры (55 нче армиянең 45 нче истребитель-танкка каршы артиллерия бригадасы). 1 нче Балтыйк буе фронты гаскәрләре составында Тарту һөҗүм операциясендә катнаша (1944). Литваның Шауляй шәһәре тирәсендә дошманның танк атакаларын кире кайтарганда батырлык күрсәтә: 1944 нең 18 августында орудие уты б-н дошманның 6 хәрби машинасын һәм гаять күп тере көчләрен юк итә; сугышта һәлак була. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Кәләй авылында Геройга обелиск куелган. Әлмәт шәһәрендәге бер урам Т. исемен йөртә.

Әд.: Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

ТОКМА́Ч, традицион татар милли ризыгы; камыр ашы. Т. атамасын киң мәгънәсендә токмачлы ашны белдерү өчен кулланалар. Өйдә нәзек итеп токмач кисү татар халкында зур осталык санала. Т.ны, гадәттә, бодай оныннан әзерлиләр. Камырны йомыркага басалар, уклау б-н 1–1,5 *мм* калынлыкта зур җәем итеп җәяләр, чыбык токмач яки шакмак токмач рәвешендә кисәләр. Мишәрләрдә шундый камыр ризыкларын салма, ләкшә, Әстерхан татарларында ләкшә дип атыйлар.

Әд.: Әхмәтжанов Ю.Ә. Татар халык ашлары. К., 1999; Татарская кухня. К., 1985; Мухамедова Р.Г. Пища и домашняя утварь // Татары. М., 2001. *Р.Р.Батыршин.*

ТОКМА́Ш авылы, Алабуга р-нында, Алабугага шәһәреннән 29 *км* көнбатыштарак, Вонюшка елгасы буенда. 2010 елда 41 кеше (рус-лар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. Рус чыганакларында 1680 нән Деревня по речке Воне Сухие Врашки буларак билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 380 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Казиле волостенда, 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга, 1944 нең 19 февраленнән — Костенеево, 1944 нең 8 июненнән — Морт, 1954 нең 19 ноябреннән Алабуга р-нында. Халык саны: 1859 да — 299, 1887 дә — 380, 1905 тә — 370, 1920 дә — 381, 1926 да — 283, 1938 дә — 369, 1949 да — 250, 1958 дә — 205, 1970 тә — 154, 1979 да — 92, 1989 да — 52, 2002 дә — 47 кеше.

ТӨ́КМОВО ГӨМБӘЗӘ́, Токмово мегаблогы, утырма тышлык буенча гөмбәзсыман күтәренке һәм кристаллик нигез рельефында блок рәвешендәге тектоник структура. Т.г. ТР терр-ясенә субмеридиан авышлыктагы Чуаш макроблогының көнчыгыш өлешеннән (Ульянов, Канаш) керә, ул исә абс. билгесе 1510 нан 1834 *м* га кадәр булган Казан битләве ягына таба көнчыгышта кристаллик нигез буенча баскычсыман күмелә. Чуаш макроблогының утырма тышлык токымнары буенча Токмово күтәрелмәләре системасының шул ук исемдәге гөмбәзе һәм Кама-Кинель бөгелешләр системасының Буа тармагы туры килә. Буа шәһәреннән көньяк-көнбатыштарак яшьрәк утырмаларда якынча 5 млн. ел элек барлыкка килгән Карлы вулканоген структурасы ачыкланган. Алмаз чыккан районнарга хас көпшә тибындагы 2 аэромагнит аномалия билгеләнгән. ТР терр-ясендә Т.г. чикләрендә күп санлы казылмалар: минераль буяулар, янучан сланецлар, фосфорит, цеолитлы токымнар, алмаз иярченнәре ачыкланган. 1986 елда Буа шәһәреннән көнбатыштарак Карлы елгасында 0,25 *мм* га кадәрге зурлыктагы, яссы формалы, сары төстәге алмаз кисәкләре табыла.

Әд.: Карлинский потенциально алмазоносный район Республики Татарстан // Георесурсы. 2000. № 26; Геология Татарстана: Стратиграфия и тектоника. М., 2003.

ТОКСИКОЛО́ГИЯ (грек. toxikо́n — агу һәм *...логия*), агуларны, аларның физик һәм химик үзлекләрен, тере организмнар б-н үзара тәэсир итешү закончалыкларын, кешеләр, хайваннар һәм үсемлекләрнең агулану очракларын кисәтү һәм агулану нәтиҗәсендәге авыруларны дәвалау турындагы фән. Яшәгән тирәлек: хезмәт урыннары, көнкүреш, табигать объектларындагы агулы химик кушылмалар кеше организмына һава, туфрак, азык-төлек аркылы үтеп керә. Т. клиник, профилактик, экологик, хәрби Т., дару, вет., мәхкәмә Т.се төрләренә бүленә.

Казан ун-ты Россиянең Т. фән буларак укытыла торган беренче уку йорты була (1842); Россиядә шул юнәлештәге беренче кулланма — Г.И.*Блосфельдның* «Мәхкәмә токсикологиясе» («Судебная токсикология», 1856) ярдәмлеге ш.у. биредә языла һәм нәшер ителә. Казан гистологы И.М.*Догель* Россия эксперименталь Т.сенә башлангыч бирүче санала. С.В.Аничков үзәк холинолитик матдәләр синтезлый һәм сынау уздыра, В.М.Карасик агулар тәэсире һәм кешенең яше арасындагы бәйлелекне өйрәнә. Гигиена белгече Н.С.Правдин беренче булып «токсикометрия» терминын тәкъдим итә («Сәнәгать-тәге агуларның аз зыянлылыгы методикасы» — «Методика малой токсикологии промышленных ядов», 1947). Биолог Н.В.Лазарев химик матдәләрнең нәэлектролит тәэсире теориясен төзи һәм органик кушылмаларның биол.-физик-химик классификациясен тәкъдим итә («Сәнәгатьтә зарарлы матдәләр» — «Вредные вещества в промышленности», 1951).



Н.Е. Токарликов.

20 йөзнең икенче яртысыннан Т. буенча әйләнә-тирәнең аерым объектлары өчен сан. стандартлары булдыруга юнәлдерелгән гамәли тикшеренүләр үсеш ала. Составта агулы матдәләр булган очраклар өчен аларның нормативлары эшләнә һәм раслана. 1960–70 елларда И.С.Бадюгин — синтетик агулар Т.сен, В.Д.Белогорский — дифосген б-н агулану очрагында кислород кытлыгы билгеләрен һәм кислород терапиясенең нәтиҗәлелеген, А.В.Тонких токсиннар б-н бәйле үпкә шешенең нерв-рефлектор һәм гормональ механизмнарын өйрәнә. 2000 елларда кешеләр арасында кискен агулану очракларының этиологик факторлары билгеләнә: дару матдәләре (40–60%), көндәлектә кулланылучы химик матдәләр, пестицидлар (15–30%), алкоголь һәм аның суррогатлары (10%). Казан галимнәренең Т. өлкәсендәге алга таба эзләнүләре химик матдәләрнең (ш.и. пестицидларның) гомуми агулану механизмнарын өйрәнүгә, детоксикация ысулларын, экстремаль (һәлакәт) очракларда ашыгыч ярдәм күрсәтү юлларын ачыклауга карый. Т. буенча фәнни тикшеренүләр Казан мед. ин-тында, Бөтенроссия вет. фәнни-тикшеренү ин-тында, А.Е.Арбузов исем. Органик һәм физик химия ин-тында алып барыла.

Әд.: Белогорский В.Д. Развитие токсикологических исследований в Казани // Изучение экстремальных состояний. К., 1976; Токсикометрия химических веществ, загрязняющих окружающую среду. М., 1986. *Р.Я.Хәмитова.*

ТОЛМА́Ч авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 13 *км* төньяктарак, Сола елгасы (Казансуның уң кушылдыгы) буенда. 2010 елда 148 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. 1565–67 еллардагы чыганакларда Сәетләр авылы буларак билгеле. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Зур Ситляры исеме б-н дә мәгълүм. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында земство мәктәбе (1901 дә ачыла), бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 379,7



Е.П. Толстой.



И.А. Толстой.

дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Собакино волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1935 нең 10 февраленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1646 да — 104, 1782 дә — 74 ир-ат; 1859 да — 291, 1897 дә — 288, 1908 дә — 295, 1920 дә — 286, 1926 да — 776 (Мәмәт, Мишавки авыллары халкын да кертеп), 1938 дә — 363, 1949 да — 291, 1958 дә — 174, 1970 тә — 168, 1989 да — 117, 2002 дә — 154 кеше.

Әд.: Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

ТОЛМАЧЁВ Николай Александрович (19.11.1823, Пермь губ. Көнгер ш. — 21.1.1901, Казан), педиатр, медицина д-ры (1875). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1845), Козьмодемьянск (1846 елдан) һәм Мамадыш (1848 дән) шәһәрләрендә өяз табибе булып эшли, ваба эпидемиясен бетерүдә катнаша (1847–48 дә). 1849 дан Казанда шәһәр табибе, бер үк вакытта Казан Җәмәгать тәрбиясе приказында кече табиб. 1865–69 да Германиянең Тюбенген шәһәрендә фәнни командировкада. 1870–74 тә Казан ун-тының акушерлык клиникасы гинекология бүлеген дә, ун-тның балалар авырулары кафедрасын оештыручы һәм аның мөдире (1875–93), проф. (1881). Хезмәтләре төбәккә хас зоб патологиясенә, имчәк балаларны табигый һәм ясалма ашатуны чагыштырма өйрәнүгә, балаларда сидек бүленеп чыгу б-н бәйле авыруларны кисәтү һәм дәвалауга, рахитны дельфин мае б-н дәвалауга карый. Т. ана сөтендә холестерин табу ысулын тәкъдим итә; кече яштәге балаларны перкуссия һәм аускультация ысулы б-н тикшерүне гамәлгә кертә.

Хезм.: О демонстрации способа осаждения сернокислой магнезией белков женского молока. К., 1890; К вопросу о дезинфекции при заразных болезнях. СПб., 1892.

Әд.: Абрамова Т.В. Первый профессор педиатрии в Казани Н.А.Толмачёв (1823–1901) // Педиатрия. 1965. № 1.

В.Ф.Богоявленский.

ТОЛПЕ́ГИНА Татьяна Борисовна (25.12.1924, Казан — 21.7.2008, шунда ук), патофизиолог, мед. фән. д-ры (1967), проф. (1969), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1975). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1947), шунда ук, патофизиол. кафедрасында эшли. 1967 елдан Казан ГИДУВында: функциональ диагностика каф. мөдире, 1968–83 тә проректор, бер үк вакытта, 1970–79 да, аллергология кафедрасын оештыручы һәм аның мөдире, 1979–89 да гомуми клиник патология каф. мөдире, 1990 нан клиник лаборатор диагностика каф. профессоры. 1954–56 елларда Монголия Халык Респ-касында (Улан-Батор) командировкада. Хезмәтләре иммунологик реактивлыкны өйрәнүгә, бронхиаль астма һәм астма алды халәте патогенезына, поллинозларга, холециститка, ашамлыклар аллергиясенә һәм анафилактик шок-ка карый. СССР ВДНХсының бронза медале, ТАССР ЮСның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Хезм.: Хронический холецистит и аллергия. К., 1969 (автордаш); Аллергия и заболевания желчного пузыря. К., 1982 (автордаш).

Әд.: Рахматуллин И.М., Цибулькин А.П., Нефёдов В.П. Профессор Татьяна Борисовна Толпегина // Казан. мед. журн. 1995. № 2.

В.Ф.Богоявленский.

ТОЛСТО́Й Алексей Николаевич (29.12.1882, Самара губ. Николаевск ш. — 23.2.1945, Мәскәү), язучы, җәмәгать эшлеклесе, СССР ФА акад. (1939). «Михнәтле заман» («Хождение по мукам», 1941) трилогиясе, «Аэлита» (1923), «Инженер Гариннның гиперболоиды» («Гиперболоид инженера Гарина», 1927), «Пётр I» (1–3 кит., 1929–45, төгәлләнмәгән) романнары, «Иван Грозный» (1943) дилогиясе, балалар өчен әсәрләр, антифашистик публицистика авторы. Беренче тапкыр Казанда 1901 елның җәендә була. Алган тәэсирләре турында: «... һәр нәрсәдә аристократия тамгасы бар, ни дисәң дә — университетлы шәһәр», — дип яза. 1902 дә Алабуга өязенең Сюгинск пыяла з-дында практикада була. 1905 нең җәеннән 1906 ның февраленә кадәр гаиләсе б-н Казанда яши. «Волжский листок» г-тасында эшчеләр хәрәкәтенә багышланган шигырьләрен, «Редакциягә хат» («Письмо в редакцию») мәкаләсен бастыра. «Аксак барин» («Хромой барин», 1911) романында, «Күңелсез хәлләр» («Большие неприятности», 1914), «Кара елан» («Гадюка», 1928) повестьларында Казан тәэсирләре чагылдырылган. «Кара елан» повестеның геройнясы — Казан сәүдәгәре кызы; вакыйгалар Гражданнар сугышы елларында, ш.и. Казанда да бара. «Михнәтле заман» трилогиясе герое И.И.Телегин Казан реаль уч-щесендә укыган елларын искә ала; Казан Гражданнар сугышы б-н бәйле рәвештә дә искә алына. 1941 дә Т. юл уңаеннан янә Казанда була, Матбугат йортында «Кем ул герой, нәрсә ул героизм» дигән темага доклад укый. Казан Зур драма театрында «Иван Грозный» пьесасы (1945), «Михнәтле заман» әсәреннән (1947) аерым күренешләр сәхнәләштерелә. 1937–45 тә СССР ЮС депутаты, СССР Дәүләт бүләкләре лауреаты (1941, 1943, 1946, үлгәннән соң).

Әд.: Порман Р.Н. Советские писатели в Татарии в годы Великой Отечественной войны. К., 1958; Крестинский Ю.А. А.Н.Толстой: Жизнь и творчество. М., 1960.

Л.Е.Бушканец.

ТОЛСТО́Й Егор Петрович (9.7.1802, С.-Петербург — 12.3.1874, Мәскәү), граф, хәрби һәм дәүләт эшлеклесе, генерал-лейтенант (1859), сенатор (1861). Дворяннар нәселеннән. 1819 елдан — хәрби, 1835 тән дәүләт хезмәтендә. Россия–Иран (1826–28), рус-төрек (1828–29), Кырым (1855–56) сугышларында, Польшадагы кузгалышны бастыруда (1831) катнаша. 1847–50 дә Мәскәү вөждан мәхкәмәсе судьясы. 1850 дә гражданнар б-н идарә итүче Казан хәрби губернаторы. Казан губернасында ваба кизүенә каршы көрәш б-н җитәкчелек итә (1850). Т. заманында Казанда кыз балалар уч-щесе ачыла. 1851–54 тә — гражданнар б-н идарә итүче Калуга, 1854–56 да — Таганрог, 1859–61 дә Пенза хәрби губернаторы. 1861 дә Пенза һәм Тамбов губерналарында крәстияннәр чыгышларын бастыруда катнаша. 1861 дән Сенатның Мәскәү департаментларында. Изге Александр Невский ордены б-н бүләкләнә.

Әд.: Долгов Е.Б. Казанский военный губернатор Е.П.Толстой // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2004. № 1.

Е.Б.Долгов.

ТОЛСТО́Й Илья Андреевич (20.7.1757 — 21.3.1820, Казан), граф, дәүләт эшлеклесе, статский советник (1815). Дворяннар нәселеннән. Л.Н.*Толстойның* бабасы. Диңгез кадетлар корпусын тәмамлый (С.-Петербург). 1770 елларда һәм 1793 кә кадәр хәрби хезмәттә. 1793–1815 тә отставкада, Мәскәүдә яши. 1815 тән Казан гражданнар губернаторы. Казанда чыккан көчле янгынны сүндерүдә катнаша (1815 нең сент.), шәһәрне торгызу һәм төзекләндерү эшләре б-н җитәкчелек итә. Казан ярлыларга ярдәм ком-тын төзүгә булышлык итә (1816), җирле полициянең штатын арттыру, шәһәр йөкләмәләрен тәртипкә салу һәм азык-төлек бәяләрен контрольдә тотуны яклый. Т. заманында 7 нче «җан башыннан ревизия» — губернаның халык санын исәпкә алу уздырыла (1815–17), Казан руханилар академиясе руханилар семинариясе итеп үзгәртелә (1818). Россия Библия җәмгыятенең Казан ком-ты вице-президенты була (1818 дән). Т. б-н җирле дворяннар арасындагы каршылыклар губернада 1819–20 елларда Сенатор ревизиясе уздыруга китерә, нәтиҗәдә, хакимияттән законсыз файдаланганы өчен, вазифасыннан азат ителә; тикшерү барышында вафат була.

Әд.: Загоскин Н.П. Казанский разгром 1819–1820 гг. // Волжский вестн. 1892. 24, 28 июня; Толстой С.М. Толстой и Толстые: Очерки по истории рода. М., 1990.

Е.Б.Долгов.

ТОЛСТО́Й Лев Николаевич (28.8.1828, Ясная Поляна, хәзер Тула өлкәсенең Щёкино р-ны — 7.11.1910, Рязань-Урал тимер юлының Астапово станциясе, хәзер Липецк өлкәсенең Лев Толстой станциясе; Ясная Полянада җирләнә), граф, язучы, Петербург ФАнең мөхбир әгъзасы (1873), шәрәфле академигы (1900). «Сугыш һәм тынычлык» («Война и мир», т.1–4, 1867–69), «Анна Каренина» (1878), «Яңадан туу» («Воскресение», 1899) романнары, «Балачак» («Детство», 1852), «Үсмерчак» («Отрочество», 1854), «Егетчак» («Юность», 1857), «Алпавыт иртәсе» («Утро помещика», 1856), «Казаклар» («Казаки», 1863), «Иван Ильичның үлеме» («Смерть Ивана Ильича», 1886), «Крейцер сонатасы» («Крейцерова соната», 1891), «Сергий атакай» («Отец Сергий», 1912), «Хаҗиморат» («Хаджи-Мурат», 1912) повестьлары, хикәяләр, пьесалар, публицистик әсәрләр, балалар

өчен хикәяләр һәм әкиятләр һ.б. авторы. Толстойлар нәселе Казан б-н тыгыз бәйләнештә була. Язучының бабасының әтисе А.И.*Толстой* — Казан гарнизонының секунд-майоры, соңрак — Зөя шәһәрендә воевода, бабасы И.А.Толстой — Казан губернаторы (1815–20), әтисенең апасы Пелагея Ильинична — Казан дворяны В.И.Юшков хатыны. Толстойлар гаиләсе (бертуган дүрт егет һәм бер кыз) әниләрен иртә югалталар, балаларны кайгыртуны үз өстенә П.И.Юшкова ала. 1841 елда ул аларны Казанга алып килә. Балаларны Казан ун-тына әзерләү б-н университет профессоры А.К.*Казимбәк* шөгыльләнә. 1844 нең октябрендә Т. фәлсәфә ф-тының шәрекъ бүлегенә укырга керә (төрек-гарәп филологиясе разряды). 1845 нең апрелендә, дәрес калдырганы өчен, Т. имтиханнарга кертелми; ул юридик ф-тка күчә. Граждannар хокукы профессоры Д.И.Мейер җитәкчелегендә Екатерина II идарә иткән дәвер законнарын өйрәнә. Буш вакытының күп өлешен күңел ачуга сарыф итә. Соңрак ул



Л.Н.Толстой Казанда. 1840 еллар.

болай дип искә ала: «... беренче елны Казан университетында мин, чыннан да, берни дә эшләмәдем. Икенче елны ныклап укый башладым. Ул вакытта анда проф. Мейер бар иде. Ул минем б-н кызыксынуын белдерде һәм ми ңа эш бирде — Екатерина «Наказ»ын Монтескьёның «Esprit des lois» («Законнар рухы») б-н чагыштырырга кушты. Хәтерлим: бу эш мине мавыктырды; мин авылга кайтып киттем, Монтескьёны укый башладым, бу уку ми ңа киң офыклар ачты; Руссоны укый башладым һәм университетны нәкъ ныклап шөгыльләнәсе килүем аркасында ташладым». 1847 нең мартында көндәлек яза башлый (гомеренең соңгы көннәренә кадәр алып бара). Шул ук елның апрелендә университеттан китүе турында гариза яза, Ясная Полянага кайтып китә. Казан ун-тыннан китүенең сәбәпләре турында ул болай ди: «Казанда укытучылар укыткан нәрсәләр мине аз кызыксындыра иде. Башта мин бер ел чамасы шәрекъ телләре б-н шөгыльләндем, әмма аз өйрәндем. Мин, бик нык мавыгып, чиксез күп китап укыдым, ләкин һаман шул бер юнәлештә». Казанда ул кабат 1852 дә Кавказга барышлый туктала.

Татар мотивлары Т.ның күп кенә әсәрләрендә чагылыш таба. «Сугыш һәм тынычлык» («Война и мир») романында исемсез татар казагы курку белмәс ватан сакчысы буларак гәүдәләнә, «Хаҗиморат» повестенда тау халыклары татарча сөйләшә. «Тәрәккият һәм белем алу мәсьәләләре» («Прогресс и определение образования») мәкаләсендә 1862 дә Ошковлар биләмәсенә кергән Панау авылы крәстияннәре хәле б-н танышу тасвирлана. Т. гомеренең Казан чоры аның берничә әсәрендә, аерым алганда, «Үсмерчак» («Отрочество») һәм «Егет чак» («Юность») повестьларында күзәтелә. Аларда аның якыннары, аерым вакыйгалар (мәс., университетка керү), күңел кичерешләре (яшүсмерләр дуслыгы, югары катлау затларның дөньяви идеалы, китап уку, «Яшәеш кагыйдәләре»н төзү һ.б.) чагылыш таба. «Балдан соң» («После бала», 1903) хикәясендә тормышта булган вакыйгалар тасвирлана. Татар зыялылары Т.ның иҗтимагый эшчәнлеген зур игътибар б-н күзәтәләр, татар укучысын аның иҗатына якынайтырга тырышалар. Т. б-н С.Максуди, Ф.Кәрими очрашалар. 1906 да Тукай аның «Ильяс» һәм «Бик кыйбат» («Дорого стоит») хикәяләрен татар теленә тәржемә итә. 20 йөз башында Т. әсәрләрен ш.у. С.Рәмиев, С.Сүнчәләй, Д.Гобәйди, М.Галәү, И.Богданов һ.б.; совет чорында М.Солтангалиев, А.Шамов, М.Максуд, К.Миңлебаев тәр җемә итәләр. Татар җәмәгатьчелегенең кайбер вәкилләре б-н Т. хат алыша. Аның дини һәм иҗтимагый-сәяси хәрәкәт җитәкчесе Г.Б.*Вәисов* б-н язышкан хатлары аеруча кызыксыну уята. Т. аның карашларын таный, хатларында аңа «Сөекле туганым Хуҗа Мөхәммәт Гайнетдин улы Вәисов» дип мөрәҗәгать итә, хат ахырында исә «Сине яратучы туганың» дип яза. Рәсми рәвештә чиркәүдән читләштерелгән (1901) язучыга Әсфәндияр Воинов теләктәшлек күрсәтә. Үзенең дини карашларын Т. Е.Е.Вәкилевага язган хатында белдерә: «... минем тарафтан — христиан идеалларын һәм христиан тәгълиматын аның асыл мәгънәсендә барыннан да өстен куйган кеше тарафыннан — тышкы формасы б-н Мөхәммәд диненең чиркәү православиесеннән чагыштыргысыз дәрәҗәдә өстен торуы берничек тә шик астына куела алмый. Шулай итеп, әгәр кеше алдында чиркәү православиесен яки Мөхәммәд динен сайлау мәсьәлә се тора икән, акылы камил кешедә аны сайлауда бернинди икеләнү булырга тиеш түгел, һәм ул катлаулы һәм аңлаешсыз троица, гафу ителү, серле йола, Мәрьям Ана, изгеләр һәм аларның сурәтләре, катлаулы гыйбадәтләр б-н бәйле дини тәгълимат урынына бер Аллаһны һәм аның пәйгамбәрен таныган Мөхәммәд диненә өстенлек бирергә тиеш». 20 йөз башында татар дөньясында башка бер генә рус язучысы да Т. дәрәҗәсендә популяр булмый. Аның 80 еллык юбилеена татар җәмәгатьчелегенең барлык катлаулары да үз мөнәсәбәтен белдерә. Т.ның үлеме зур кайгы булып кабул ителә. Тукай аны «дөнья халкы күңеленә кодсият нуры чәчүче» дип атый.

Әсәр.: Собр. соч.: В 12 т. М., 1972–76.

Әд.: Гарзавина А.В. Лев Толстой в Казани. К., 1983; Ахунов А. Лев Толстой и татары // Татарский мир. 2003. № 15; Кадыров О.Х. Толстой в татарских переводах советской эпохи. К., 2005; Бушканец Е.Т. Юность гения // Нева. 2008. № 8.

О.Х.Кадыйров.

ТОЛСТО́Й Л.Н. МУЗЕ́Е, Казанда. ТР МКның 2000 ел 27 сентябрь карары нигезендә ТР Дәүләт музееның бүлеге буларак оештырыла (хәзер — ТРның Милли музее). 2001 дә музейга Япеев урамындагы 1841–45 елларда Л.Н.*Толстой* яшәгән элеккеге Горталов йорты тапшырыла. Йортта реставрация эшләре алып барыла. 2015 тә бина торгызылып, Л.Н.Толстой исем. музей-мәгариф үзәге составына кертелә. Төп йортта бертуган Толстойлар һәм П.И.Юшкованың бүлмә күренешләре торгызыла. Алар 19 йөзнең 1 яртысында Казанда дворяннарның утар культурасының көнкүреш тормышы б-н таныштыра.

ТОЛЫМБА́Й (ТОЛЫМБА́ЙСКИЙ) ГОМӘ́Р (псевд., чын исем-фамилиясе Шаһи әхмәтов Габделхак Җәләлетдин улы) (14.4.1900, Сембер губ., Буа өязе Адав-Толымбай а. — 8.5.1938, Казан), язучы, әдәбият галиме. Авыл мәдрәсәсендә белем ала. 1916 елда Петроградка китә, Февр. рев-циясе шаһите була. 1917 дә туган авылына кайткач, крәстияннәр чуалышында катнаша. 1918 дән күрше Бикмураз авылында укыта. Гражданнар сугышында катнаша. Яраланганнан соң Казанга кайта. 1920 еллар башында вакытлы матбугатта күп кенә мәкаләләр, сугыш рухы б-н сугарылган агитация характерындагы әдәби әсәрләр бастыра; «Бажайлар» (1925 тә Татар акад. театрында куела) пьесасын яза. 1924 тә Г.Кутуй б-н бергә *СУЛФ* иҗади берләшмәсен төзи (шул ук елда таркала). 1924–27 елларда Казанда Татар коммунистлар ун-тында укый, 1926 дан *Академүзәктә* эшли, 1927 дән — «Гажур» нәшриятында баш мөхәррир урынбасары, «Колхоз газетасы» мөхәррире, 1929–31 дә Шәрекъ пед. ин-тында эшли. 1931–34 тә Мәскәүдә Кызыл профессорлар ин-тында укый, аны тәмамлаганнан соң, Казан пед. ин-тында укыта, проф. (1934), Татарстан дәүләт нәшриятында матур әдәбият секциясен җитәкли. Т. татар әдәбиятына психол. («Нигә кыр үрдәге булмаганнар?», 1927; «Читән буе», 1928; «Кара такта алдында», 1930) һәм сатирик («Фамилия ясаучылар», 1926; «Әтәчләр сугышы», 1928) хикәяләр остасы буларак килеп керә. Бу әсәрләрдә авылда барган тирән социаль үзгәрешләр һәм аларның кеше психикасына ясаган йогынтысы чагылыш таба; хикәяләр оста сурәтләнгән геройлар характерлары, күпләгән мәкальләр, әйтемнәр, инверсияләр, бай теле б-н аерылып торалар. 1930 да Т. иҗаты сыйнфый көрәшне тулы чагылдырмаган өчен бик катты тәнкыйтьләнә. 1930 елларда язылган «Түбән елгада» (1932), «Куян солдат» (1933) повестьлары идеологик күрсәтмәләргә ярашлаштырылып языла. «Тар буржуа теле — безнең тел түгел» (1931) һ.б. мәкаләләрдә, «Фатих Әмирхан» (1936) китабында 1930 елларда хөкем сөргән вульгар социологизм йогынтысы сизелә. Т. татар фольклор әсәрләрен җыя (51 әкият язып ала), өйрәнә, системага сала һәм аларны (күбесенчә әкият һәм

бәетләрне) фәнни яктан эшкәртә; аның татар халык иҗатына карата фикерләре «Тукай һәм халык әдәбияты» китабында (1930) чагылыш таба. «*Троцкийчы милләтчеләрнең контрреволюцион-террористик оешмасы*» *эше* буенча репрессияләнә, атарга хөкем ителә; үлгәннән соң аклана.

Әсәр.: Толымбай әсәрләре: 2 китапта. К., 1929–30; Сайланма әсәрләр. К., 2000.

Әд.: Рахмани Р. Җитмеш елдан соң очрашу // Казан утлары. 2000. № 11; Галиева Э.Р. Татар әдәбият белемендә культура-тарих мәктәбе. К., 2002. *Р.Ф.Рахмани.*

ТО́ЛЬСКИЙ Андрей Петрович (1.8.1874, С.-Петербург — 9.1.1942, Ленинград), урман белгече, а.х. фән д-ры (1940), проф. (1938), Мари АССРның атказ. фән. эшлеклесе (1941). Петербург урман ин-тын тәмамлый (1897). 1903–17 елларда Бозаулык наратлыгында Боровой тәжрибә урманчылыгын җитәкли. 1917–20 дә Ново-Александрийск а.х. һәм урманчылык ин-ты (Харьков ш.) профессоры. 1920–22 дә А.х. һәм урманчылык буенча югары курслар (Мәскәү) профессоры. 1922–25 тә Баш геофизика обсерваториясендә (Ленинград). 1925–31 дә Казан а.х. һәм урманчылык ин-ты профессоры, урман культуралары каф. мөдире. 1931 дән Агрогидрометеорология ин-тында (Ленинград). 1937 дән Идел буе урман-техника ин-тында (Йошкар-Ола ш.) урман культуралары каф. мөдире. Хезмәтләре урман культуралары үстерү эшенә, агач токымнарының физиологиясе һәм экологиясенә, урманнарның су лыкларны саклау үзлекләре мәсьәләләренә, урман метеорологиясенә карый. Т. тарафыннан Бозаулык наратлыгында нарат утыртмаларын ясалма үстерү шартларын өйрәнү өчен 16 тәжрибә объекты булдырыла, биредә утырту тыгызлыгы, урман культураларының типлары, аларны төрле геогр. җирлектән алынган орлыклардан үстерү буенча эш алып барыла. Бозаулык наратлыгында, Раифа һ.б. урманчылыкларда аның җитәкчелегендә оештырылган урман культуралары тәжрибә-җитештерү мәйданнары 500 *га* тәшкил итә. Т. урман-орлыкчылык хуҗалыгы һәм нарат, Себер карагае кебек урман культуралары өчен климатик күрсәткечләр эшли. Аның «Хосусый урманчылык» («Частное лесоводство», т. 1–4, Л., 1927–31) монографиясе киң таныла ала, биредә урман орлыкчылыгы, туфракны эшкәртү, урман культураларын үстерү һәм урман питомниклары мәсь әләләре карала. Урман сәнәгатенең мактаулы хезмәткәре (1939).

Хезм.: Разработка почвы в лесном хозяйстве. М., 1921; Лесные культуры. Л., 1930; Лесная метеорология и её задачи // Климат и погода. 1935. № 1.

«ТОМ СҮЗЕ́», иҗтимагый-сәяси газета. Бөтенроссия мөселманнар Милли Шурасы органы. 1919 елда Томск шәһәрендә татар телендә нәшер ителә. Атнага 1–2 тапкыр чыга. Нашире — Н.Карпов, мөхәррире — З.Аюхан.

Әд.: Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926.

ТОМА́ БАЛАВЫ́З (прополис; грек. pro — ал, алда, pólis — ныгытма), бал кортлары җилеме, бал кортларының үсемлекләрдән җыеп, үз селәгәй бизләре ферментлары б-н эшкәртүеннән барлыкка килгән катлаулы матдәләр комплексы. Бал кортлары Т.б.ны ана кортка йомырка салу өчен кәрәз ясаганда, умарта оясындагы ярыкларны сылаганда, умарта оясы авызын кечерәйткәндә, умарта оясына эләккән ят предметларны, бөҗәк, кәлтә елан, тычкан һ.б.ны томалаганда кулланалар. Т.б. умарта оясын һәм бал кортларын бактериаль, вируслы һәм гөмбәле инфекцияләрдән саклый.

Т.б.ның химик составы катлаулы һәм даими түгел (үсемлек төрләренә, алардагы сумаласыман матдәләр микъдарына, үсемлекнең үскән урынына, җыю вакытына бәйле). Люминесценциясе көрән-яшел. Көленең спектраль анализы Т.б.да күптөрле макро- һәм микроэлементлар (тимер, кальций, алюминий, магний, кремний, бакыр, кобальт, фосфор, цинк, марганец һ.б.) булуын күрсәтә. Анда ш.у. балавыз, серкә, эфир майлары, сумалалар һ.б.; ароматик, бәлзәмле, буягыч, сумалалы, дуплаучы матдәләр бар (микъдарлары даими түгел). Т.б.да ванилин, дарчин (корица) спирты, дарчин к-тасы, хризин, 1–3-диоксифлавон, флавонол, галангин, альпенин, пиноцембрин һ.б. кушылмалар барлыгы билгеле. Флавоноидлы фракциянең — Р-витамин активлыгын тәэмин итүе һәм бактерияләргә каршы көрәшү үзлеге, терпенлы фракциянең анестезия үзлеге бирүе ачыкланган (Казан мед. ин-ты, 1971–75). Т.б.дан химик актив матдәләр: 4,7-диметокси-5-оксифлаванон һәм сакуранетин (С.А.Поправко, Р.Г.Исхакова, 1972), ферул һәм бензой к-талары аерып алынган (И.Чижмарик, И.Мател һ.б., Чехословакия, 1981).

Кушылмаларның күпчелек өлешен флавоннар, флавоноллар, флавононнар (хризин, тестохризин, галангин, альпенин, зальпенин, рамноцитрин, кемпферид, пиноцембрин, пиностромбин, ацетокси-бетуленол, ферул к-тасы, изованилин һ.б.) тәшкил итә. Апигенин чыгарылмалары төркеме, кемпферолның метил эфирлары, кверцетин һәм оксифлаванон чыгарылмалары аерып карала. Флавоноид спектрында кемпферол, кверцетин, нафингенин апигенины чыгарылмалары киң чагылыш таба (С.А.Поправко, 1973). Т.б. составындагы флавоноидларның капиллярларны ныгытуы исбатланган (А.Деревич, Румыния, 1985).

РФ терр-ясендә Т.б.ның 3 тибы: каен (65%), тополь (15%), катнаш (15%) типлар таралыш алган; Кавказ, Ерак Көнчыгыш Т.б.ы сирәк типлардан санала (5%). ТР терр-ясендә җыелган Т.б. үрнәкләрендә каен тибы өстенлек итә.

Татарстанда Т.б. препаратлары беренче булып Казан мед. һәм вет. ин-тларында өйрәнелә башлый. Аларның бактериостатик, бактерицид һәм анестезия (новокаинның авыртуны басу дәрәҗәсеннән күп тапкырлар өстен) үзлекләренә, антиоксидант активлыкка ия булулары; шешләр очрагында микрофлорага көчле тәэсир итүләре, тукымалар регенерациясен тизләтүләре ачыклана. Казан галимнәре хезмәтләре б-н Т.б.ның микробларга каршы көрәш үзлекләрен җитди өйрәнүгә нигез салына (В.П.*Кивалкина*, З.Х.*Кәримова*, Е.К.Наумова, А.А.Барсков, М.Н.Нәҗипов, К.М.Салмаков, Ю.С.Александров, Ю.С.Нәҗипов һ.б., 1950–70). Т.б.ның агулау үзлеге булмау З.Х.Кәримова, Л.С.Афонская, Д.М.*Зөбәеров*, Г.Ф.Ржевская, И.А.*Студенцова* (1963), зыянсызлыгы һәм иммун системасына уңай тәэсире В.П.Кивалкина (1969) хезмәтләрендә билгеләп үтелә. Т.б.ның туберкулёз, гөмбәле һәм стафилококклы үлекле инфекцияләр, дифтерия, сифилис, лептоспироз китереп чыгаручыларга һ.б. патоген микроорганизмнарга карата бактерицид үзлекләре (З.Х.Кәримова, Р.Г.Исхакова, К.Б.Брудная, К.М.Салмаков, Е.К.Наумова, Т.А.Кәримова, А.М.Орешникова һ.б., 1960–75); Т.б. препаратлары б-н бергә кулланганда антибиотиклар тәэсире көчәю (В.П.Кивалкина, В.Г.Горшунова, Ә.И.Ибраһимова, Э.Л.Бударкова, 1963–73); Т.б.ны паратифка каршы вакцина адъюванты сыйфатында (И.И.Тетерев), хәлсез авыруларга биостимулятор буларак куллану (Е.И.Родионова, З.Х.Кәримова, 1971–74) һ.б. өйрәнелә.

Медицинада һәм ветеринариядә Т.б.ның бактерицид, бактериостатик, аерым урында авыртуны басу, фунгистатик, фунгицид, антифлогистик, дермапластик, агуларга һәм вирусларга каршы көрәшү үзлекләре кулланылыш таба. Т.б.дан дару матдәләре уйлап тапкан һәм аларны ветеринариядә сыерларның сулыш юлларын, ашкайнату трактын авыруларын һ.б.ны дәвалауда гамәлгә керткән өчен Р.Г.*Госманов*, А.М.*Барсков*, Э.И.Ибраһимова ТР ФАнең К.Г.Боль исем. бүләгенә лаек була (2007). Мед. һәм вет. өлкәсендә Т.б. спиртлы һәм сулы эремәләр, спрей, мазь, гранула, паста, эмульсия, аэрозоль, таблетка, порошок, суппозиторий (шәм), капсула, сагыз кебек төрле дару формаларында кулланыла. Препаратларның күпкомпонентлы булуы микроорганизмнарда аларга карата бирешмәүчәнлек барлыкка килүгә ирек бирми. Т.б.ны сәнәгатьтә югары сыйфатлы лак ясау өчен (музыка уен кораллары, зиннәтле йорт җиһазлары, картиналар, Хохлома бизәге һ.б. өслеге ялтыратыла) һ.б. максатларда файдаланалар.

Әд.: Каримова З.Х. Использование прополиса в медицине // Пчеловодство. 1960. № 86; Госманов Р.Г. Итоги изучения прополиса // Ветеринарный врач. 2004. № 4.

Р.Г.Госманов, Д.Р.Нуретдинова, А.И.Ибраһимова.

ТОМАЛАННА́Р, томаланчалар рәтендәге гөмбәләр. Якынча 100 төре билгеле, ике ярымшарның да уртача поясында таралганнар. Татарстан терр-ясендә бер төре — ак Т. (Choiromyces meandriformis) Идел алдында һәм Көнбатыш Кама алдында, берәрләп яки төркемләп очрый. Имән, юкә, каен, чикләвек, миләш һ.б. катнаш яфраклы урманнарда үсә. Үрчү өлеше бүлбесыман, массасы 500 *г* га кадәр һәм артыграк та, диаметры 5–15 *см* га кадәр. Үрчү өлешенең өслеге төерчекле-җыерчыклы, саргылт-ак, соңрак коңгырт төскә керә, шома, урыны б-н ярганган. Йомшагы корырак, киселгән урынында башта ак, аннары бормалы саргылт-коңгырт сеңерле соргылт-ак төскә керә; хуш исле. Микориза тудыручы. Җир астында 8–10 *см* тирәнлектә үсә. Җир өслегенә бик сирәк чыга. Споралары үрчү өлешенең эчендә барлыкка

килә, туфрак һәм җир казучы хайваннар б-н күчә. Ашарга яраклы гөмбә. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

ТОМА́Н, атм. күренеше; су парының конденсация һәм сублимация продуктлары җыелмасы — атм.ның җиргә якын өлешендә вак су тамчылары һәм боз кристаллары, бу вакыт-та күрү ераклыгы 1 *км* дан кимрәк (күрү ераклыгы 1 дән 10 *км* га кадәр булганда төтенсыман томан дип атала). Т. һава чык ноктасыннан түбәнрәк суынганда (радиацион һәм адвектив Т.) яки суык һавага җылы сулык өсләреннән, дымсу туфрактан пар күтәрелгәндә (парга әйләнү Т.ы) барлыкка килә. Радиацион Т. файдалы нурланыштан җир өслегенең төнлә суынуы нәтиҗәсендә барлыкка килә. Адвектив Т. елның суык вакытында дымлы һәм чагыштырмача җылы һаваның суык өслектән күчеше вакытында туа; бик көчле булырга, бик биеккә күтәрелергә, берничә тәүлеккә сузылырга мөмкин. Парга әйләнү Т.ы еш кына җәен һәм көзен елгалар, күлләр һәм сазлыклар өстендә күзәтелә. ТРда томанлы көннәр 16 дан (Акташ, Мөслим) 46 көнгә кадәр (Бөгелмә), иң күбе — 30 көннән (Минзәлә, Мамадыш) 52 көнгә кадәр (Бөгелмә) күзәтелә. Аларның 60–70% ы октябрьдән мартка кадәрге чорга туры килә. Кайбер елларда язгы-көзге айларда Т. күзәтелми. Т.ның уртача дәвамлылыгы салкын вакытта 4,5–6,5 сәг., җылы вакытта 2,5–4 сәг. Якынча 70% очракта 4 сәг.тән артыкка сузылмый. Т.ның өзлексез дәвамлылыгы урыны-урыны б-н 2–3, Куйбышев сусаклагычында 7 тәүлек (5–12 нояб. 1967). Төтенсыман Т. 2 тапкыр күрәк күзәтелә. Барлык төр транспорт эшенә каршылык тудыра.

Э.П.Наумов, Ф.Г.Борһанов.

ТО́МАС Иоһанн Михель (Иван Григорьевич) (1770, Саксония, Кобург ш. — 1844 тән соң, Франция), тарихчы. 1780 еллар ахырында — 1790 да Галле, Иена ун-тлары (Германия) студенты. 1792 дән өйдә укыта, 1800–01 дә Дерпт шәһәрендә пастор. 1801 дән Казан алпавытлары гаиләләренең өйләрендә укыта. 1810–19 да Казан ун-тында бөтендөнья тарихы, статистика һәм геогр. кафедрасының ординар профессоры, бер үк вакыт-та, 1816–22 дә , Казан евангелист-лютераннар җәмгыяте пасторы. Казан уку-укыту округы попечителе М.Л.Магницкий әмере б-н ун-ттан куыла; Мәскәүгә, аннары Франциягә китә. 1842 дә Казанга килә һәм университет профессоры К.Ф.Фукс б-н очраша. Идел буеның Казан төбәгендә яшәүче халыклар-ның тарихы һәм көнкүреше б-н кызыксына. «Россия турында хатирәләр» («Souvenirs de Russie», Франция, 1844) китабында Т. самодержавиене һәм крепостнойлыкны тәнкыйтләп яза; 19 йөзнең 1 нче яртысындагы Казан тормышын, түрәләрнең башбаштаклыгын, халыкның авыр хәлен тасвирлый. Гомуми тарихны укыту турында кулъязма авторы (1810).

Әд.: Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 1; Знаменитые люди о Казани и Казанском крае. К., 2005.

Е.Б.Долгов.

ТОМА́Т, помидор (Lycopersicon), паслёнчалар семьялыгыннан күпьеллык (культурада берьеллык) яшелчә үсемлекләре яругы. Чыгышы б-н Көньяк Америкадан. Европага 16 йөз уртасында китерелә. Россия терр-ясендә Т. 18 йөздән үстерелә. Тамыр системасы көчле үскән, үзәк типта, тармакланган, бик тирәнгә китә (1 *м* га кадәр һәм аннан да тирәнгә). Дым һәм туклану җитәрлек булганда, сабагының теләсә кайсы урынында өстәмә тамыр барлыкка килә, шу ңа Т.ны ян-як үренителәреннән дә үрчетергә мөмкин. Сабаклары туры һәм түшәлмә, төкчәле, ботаклануы, 20–300 *см* биеклектә. Яфраклары парсыз каурыйсыман, эре өлешләргә телгәләнгән. Чәчәкләре яшькелт-сары, чукка җыелган. Җимеше — сусыл, ике- яки күп оялы, формасы, зурлыгы һәм төсе буенча төрле. Орлыклары саргылт-аксыл, вак, яссы, төбе очланган, гадәттә, төкчәле, яшел, формалашкан җимешләре физиол. өлгергән санала, тишелеше 8 елга кадәр саклана. Т.ны ачык (рассада культурасы буларак) һәм ябык грунтта үстерәләр.



Т. җылы, якты ярата, корылыкка чыдам. Төрле туфракларда үсә, минераль (аеруча фосфорлы һәм калийлы) ашламаларны ярата. Үсемлекләрнең үсеше өчен иң яхшы темп-ра — 22–24 °С. Уңышын чәчәк ата башлагач 30–40 көннән соң җыялар. Җимешләрендә 4,5–8,1% коры матдә, 3,5–8,5% органик кислоталар, 0,13–0,23% пектин матдәләр, ш.у. минераль тозлар, С витамины, В, РР витаминнары, каротин бар. Җимешләре яңа өлгергән килеш, тозлаган, маринадлаган, киптерелгән килеш, соклар һәм тәмләткечләр әзерләү өчен кулланыла. Т.ның киң сорт-менты нигезен индетерминант (яңару бөреләре һәм чиксез үсеше булган), детерминант (аз тармаклы һәм үсеше чикле) һәм ярымдетерминант сортлар һәм гибридлар тәшкил итә. ТРда «Дана», «Агата», «Никола», «Роткенхен», «Ляна», «Юлиана», гибрид «Андромеда» сортлары, ачык грунт өчен — «Верлиока», консервлау сәнәгате өчен «Новинка Приднестровья», «Стрелка» сортлары районлаштырылган. Йорт яны һәм коллектив бакчаларда төп яшелчә культурасы. ТРда ябык грунтта Т. үстерү б-н «Майский» теплица комб-ты шөгыльләнә.

Әд.: Справочник по овощеводству. Л., 1982.

ТОМБА́ елгасы, Идел алдында, Чирмешән елгасы (Бола, Зөя елгалары бассейны) кушылдыгы. Озынлыгы 10,1 *км*. Бассейнының мәйданы 42,3 *км*^{2}. Идел буе калкулыгыннан ага. Елга башы һәм югары агымы Чуаш Респ-касы терр-ясендә, тамагы Кайбыч р-ны Чирмешән авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 170 *м*, тамагыныкы — 110 *м*. Т.ның су җыелу мәйданында урман үсемлекләре үсми диярлек. Т.ның 0,4 тән 5,2 *км* га кадәр озынлыктагы 7 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,57 *км/км*^{2}. Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км*^{2}. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 107 *мм*, ташу агымы катламы 100 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,01 *м*^{3}*/с*. Суы ел дәвамында уртача каты (3–6 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–700 *мг/л*.

ТОМБАРЛЫ́ елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Ык елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 34 *км*. Бассейнының мәйданы 185,6 *км*^{2}. Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгыннан ага. Елга башы Оренбург өлкәсендә, югары агымының берникадәр өлеше — Бөгелмә р-нында, уртача һәм түбән агымы — Баулы р-ны терр-ясендә, тамагы Исергәп авылыннан 1 *км* төньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 330 *м*, тамагыныкы — 110 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 35%. Т.ның 0,7 дән 6,9 *км* га кадәр озынлыктагы 11 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,34 *км/км*^{2}. Туенуы катнаш, яртысыннан күбрәге кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1–3 *л/с·км*^{2}. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 122 *мм*, ташу агымы катламы 70 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы — 0,33 *м*^{3}*/с*. Суы язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 500–1000 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк. Елгада суының гомуми күләме 0,5 млн. *м*^{3}лы буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

ТОМИ́ЛОВ Николай Аркадьевич (14.9.1941, Красноярск крае Енисейск ш.), тарихчы, тарих фән. д-ры (1983), проф. (1985). Томск ун-тын тәмамлый (1967). 1969 елдан Томск (Себер тарих, археол. һәм этнография лаб-ясенең фәнни хезмәткәре), 1974–91 дә Омск (1985 тән СССР тарихы чыганаклары, историографиясе һәм этнографиясе каф. мөдире) ун-тларында. 1991 дән РФАнең Себер бүлегендә Тарих, филол. һәм филос. ин-тының Омск ф-лы директоры. 1993 тән Россия культурология ин-тының Омск ф-лы директоры. 1969–74 тә Томск ун-тының Көнбатыш Себердә яшәүче татар, рус һ.б. халыклар этнографиясен өйрәнү буенча экспедицияләре башлыгы. Омск ун-тының этнография кафедрасына, археол. һәм этнография музеена нигез салучыларның берсе. Төп фәнни

тикшеренүләре өлкәсе — Россия, Үзәк һәм Көнчыгыш Азиянең аның б-н чиктәш рай - оннарында яшәүче халыкларны өйрәнү методологиясе, теориясе, методикасы мәсь әләләре; Көнбатыш Себер халыклары антропологиясе. Яңа юнәлеш — этноархеологиягә баш - лангыч бирүчеләрнең берсе, этнология һәм археол. интеграциясенең күп кенә теоретик нигезләмәләрен эшли, Омск ун-тында этно - археология мәктәбенә нигез сала. Хезмәтләре *Себер татарлары* һәм шул төбәкнең башка төрки телле халыклары тарихына карый. Себер татарларының этник тарихын: урнашу тәртипләрен, халык санын, хуҗалыкларын, матди мәдәниятләрен, гаилә һәм иҗтимагый көнкүрешләрен, гореф-гадәтләрен, рухи мәдәниятләренең аерым якларын (мәгариф, фольклор, дини карашлар, ышанулар) өйрәнүгә өлеш кертә, татарларның күрше халыклар (теут, казакъ, селькуп, Себер бохарилары), ш.у. башка төрки, самодий, угор халыклары б-н багланышларын ачыклый. «Вестник Омского отделения Академии гуманитарных наук» ж-лының, күптомлы «Россия музейларының этнографик тупланмаларында дөнья халыкла - ры мәдәнияте» («Культура народов мира в этнографических собраниях российских музеев»), «Россия халыклары мәдәнияте» («Культура народов России»), «Этнография-археология комплекслары: мәдәният һәм социум проблемалары» («Этнографо-археологические комплексы: проблемы культуры и социума») сериялəренең баш мөхәррире.

Х е з м.: Современные этнические процессы среди сибирских татар. Томск, 1978; Этнография тюркоязычного населения Томского Приобья. Томск, 1980; Тюркоязычное население Западно-Си - бирской равнины в конце XVI — первой половине XIX вв. Томск, 1981; Очерки этнографии тюркского населения Томского Приобья. Томск, 1983; Проблемы этнической истории. Томск, 1993.

ТОМО́ГРАФ (грек. tómos — кисәк, катлам һәм *...графия*), кеше әгъзаларының эчке структураларын катламлап тикшерү мөмкинлеге бирүче диагноз аппараты. Организм - дагы патологик процессларның үзенчәлеген белү максатыннан файдаланыла. Ротацион рентген диагностикасы ысулын беренче булып Казан профессоры Р.Я.Гасуль тәкъдим итә. Ул 1936 елда В.А.*Новиков* б-н бергә Ка - зан ГИДУВында Сименс интроскобына төр - дәш беренче совет Т.ын конструкцияли; шул ук елда Казанда беренче үпкә томограммасы төшерелә. 1951 дә В.А.Новиков Т.ның моди - фикациясен — вертикаль томофлюорограф тәкъдим итә. 2005 тә М.К.Михайлов Казан физика-техника ин-ты хезмәткәрләре Я.В.Фәттахов, Ә.Ә.Гыйльманов, К.Л.Эминов, В.Н.Анашкин, А.Р.Фәхретдинов, В.А.Шагалов һәм «Радиоприбор» АҖ ген. директоры Р.У.Апаков б-н берлектә магнит-резонанс Т.ы (ТМР-0,06 — КФТИ; ТР Дәүләт бүләге, 2005) төзи. Медицинада 2 төр Т. киң кулланыла: магнит-резонанс Т.ы (МР — мәгълүматлы - лыгы киң, сәламәтлек өчен зарарсыз; баш мие, умыртка сөяге, буыннар, эчке әгъзалар авыру - ларына диагноз кую өчен кулланыла) һәм рентген-компьютер Т.ы (КТ-спиральле, муль - тиспиральле; бу төр Т.ның өстенлекләре: тик - шерү тизлеге, кискен кан тамырлары авыру - лары диагностикасы очрагында югары нәти - җәлелек; кимчелеге — пациент өчен нурла - ныш дозасының югары булуы).

Әд.: Н о в и к о в В.А. Первый советский томограф // Казан. мед. журн. 1937. № 1.

Р.Г.Исхакова, Я.В.Фәттахов.

ТОМСК МӨСЕЛМАННАРЫ ХӘЙРИЯ ҖӘМГЫЯТЕ́, 1916 елның августында оеш - тырыла. Башлап йөрүчеләре: Г.С.Гобәйдул - лин, С.И.Измайлов, И.М.Карпов, Ф.С.Сәй - дәшев, С.Юнысов. Төп максатлары — мөсел - ман мәдәнияте һәм дини учреждениеләре үсешенә булышлык итү, ярлыларга матди ярдәм күрсәтү. Томск шәһәрендә эшчәнлек алып бара. 1917 дән соң гамәлдән чыгарыла.

Ж.С.Миңнуллин.

ТОМСК ӨЛКӘСЕ́, РФдә, Көнбатыш Себернең көньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан. 1944 елның 13 августында оештырыла. Мәйданы — 316,9 мең *км*². Үзәге — Томск шәһәре. Халкы — 1078280 кеше (1.1.2018). 2010 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 17029 (1970 тә — 15286, 1979 да — 17629, 1989 да — 20812, 2002 дә — 20145) кеше. Татарлар, тупланып, Томскида һәм шәһәр яны авылларында (Абытай (Чёрная Речка), Әүш - тә (Эушта), Ум-Авыл (Барабинка), Казан - йорт (Казанка), Кафтанчиково, Курлек, Так - тамыш, Калтай, Воронино, Исламбул (Ново - исламбуль)); Стрежевой шәһәрендә; Колпа - шево, Кривошеин, Зырянка, Югары Кеть, Кожевниково һәм Бакчар р-ннарында яши - ләр. *Себер татарлары* Т.ө. терр-ясендә элек-электән яшәгәннәр. Аларның формала - шуында төрки халыкларның төп (чатлар, әүштәләләр, калмаклар) һәм читтән килгән (*бохари төркиләр*) төркемнәре катнаша. Идел-Урал буе татарлары анда 19 йөздә, төбәкне үзләштерү чорында, урнаша башлый. 20 йөз башында, Столыпинның аграр рефор - масы б-н бәйле рәвештә, аларның саны тагын да арта. 1897 елгы халык санын алу мәгъ - лүматларына караганда, Томскида татарлар 1322 кеше исәпләнә, алар, тупланып, Татар бистәсендә (җирле атамасы — Заисток) яши - ләр, анда Татар урамы да була. 20 йөз ба - шында татарлар Томск губернасының, гу - берна үзәгеннән тыш, 30 дан артык торак пунктында яшиләр. Алар утырган җирләрдә мәчетләр, мөселман уку йортлары эшли. 19 йөз ахырында Томскида 3 мәчет (ш.и. Бо - хара диния нәзарәте карамагындагы Ак мәчет һәм Казан диния нәзарәтенеке — Кызыл мә - чет) эшли. 1876 да шәһәрдә — беренче, 1897 дә — икенче (сәүдәгәр Ш.М.Сәйдәшев иганәсенә), 1905 тә өченче (сәүдәгәр К.М.Хә - митов иганәсенә төзелә) мәдрәсә ачыла. Кыз балалар Ф.М.Нәүрүзованың шәхси мәктә - бендә белем ала. 1908 дә Томск губернасын - да 615 укучысы булган 6 татар мәктәбе исәп - ләнә. 1912–13 елларда Томскида татар те - лендә «*Сибирия*» г-тасы нәшер ителә, 1916–17 дә *Томск мөселманнары хәйрия җәмгыяте* эшли. 1917 дән соң татар халкының милли яшәешен үстерү өчен мөмкинлекләр киңәя. 1918 дә Томскида Мөселман социа - листлар ком-ты (к. *Мөселман социалистлар комитетлары*) эшчәнлек алып бара, татар телендә «*Чулпан*» (1918), «*Себер юксылла - ры*» (1919–21), «*Том сүзе*» (1919) г-талары нә - шер ителә, 1920 елларда татар китапханәсе (хәзер — «Истоки» китапханәсе), «Нацмен» клубы эшли. Татар уку йортларының саны арта: 1919 да өлкәдә — 13 татар мәктәбе (15 укытучы, 556 укучы), 1927–28 дә 31 мәк - тәп (51 укытучы, 2 мең укучы) исәпләнә. 1917–19 да Томскида — мөселман укытучы - лар семинариясе, 1924–56 да Себер төрки-та - тар пед. техникумы (милли мәктәпләр өчен 2 меңгә якын башлангыч сыйныф укытучы - лары әзерли) эшли. Хәзерге вакытта Т.ө.ндә Татар мәдәни үзәге (1993–2007 дә — Татар өл - кә мәдәни үзәге, җитәкчесе Ф.Г.Сабирова), Томск төбәк «Татар яшьләре берлеге» иҗ - тимагый хәрәкәте, мәдәни-мәгариф үзәге (2001 дән), Милли көрәш федерациясе (2003) бар. Татар мәдәни үзәге каршында клуб һәм 21 үзешчән коллектив: «Халык моңнары» (1960 еллардан), «Нур», «Гүзәл» (2001 дә ха - лык ансамбле исеме бирелә) вокаль ан - самбльләре, «Шаян кызлар» хореографик ансамбле, «Күбәләк» балалар вокаль ансамб - ле, «Чулпан» балалар вокаль-хореографик ансамбле, «Сандугач» инструменталь музы - ка коллективы, «Тоян» театр төркеме һ.б. халыккка хезмәт күрсәтә. «Музыкальная гостиная» («Музыка кунакханәсе») классик музы - ка яратучылар клубы, «Ак калфак» ха - тын-кызлар клубы (2002 дән), «Родник» («Чишмә») мәктәпкәчә яшьтәгеләр клубы, «Туган тел» туган телне һәм гореф-гадәтләр - не өйрәнү түгәрәге эшли. Татар мәдәни үзә - генең иҗат коллективлары Т.ө.нең Томск,



Томск шәһәренең «Нур» вокаль ансамбле.

Зырянка, Кожевниково һ.б. р-ннарындагы татар авылларына гастрольләр оештыра. Ел саен Татар мәдәнияте көннәре, милли көрәш ярышлары (Томск ш.) уздырыла, *Ураза бәй - рәме, Корбан бәйрәме, Сабан туе* бәйрәм ите - лә, аларда ТРдан чакырылган артистлар кат - наша. 2002 дә 1 нче төбәкара «Салават күпе - ре» балалар иҗаты, 1 нче өлкә «Татар җыры» конкурслары үткәрелә. Татар телен яхшы бе - лүчеләр өлкә конкурсы (2000 нән), «Бала - лар чишмәсе» татар җырын яшь башкаручы - лар конкурсы (2005 тән), «Радуга» («Салават күпере») милли җыр һәм бию конкурсы уз - дырыла. Татар теле Тактамыш, Әүштә, Ис - ламбул, Абытай авыл мәктәпләрендә факуль - татив дәресләрдә укытыла. Т.ө. Мәгариф де - партаменты б-н ТР Мәгариф һәм фән ми - нистрлыгы арасында килешү төзелә, ул Т.ө.ндә милли мәгарифне үстерү, ТРда мәдә - ният, тарих һәм татар теле укытучыларын

әзерләүне күздә тота. Татар балалары һәм яшьләре ел саен Казан янындагы халыкара «Идел» лагеренда ял итә. Татар мәдәни үзәге Бөтендөнья татар конгрессы башкарма ком-ты, ТРның Мәдәният, Мәгариф һәм фән министрлыклары, ТР Милли китапханәсе б-н элемтәдә тора, алардан татарча фәнни-мәгъ - рифәтчелек һәм укыту-методик әдәбият, вакытлы матбугат ала. Т.ө. терр-ясендә татар тормышы б-н бәйле мәдәни истәлекләр: Ак һәм Кызыл җамигъ мәчетләр, К.М.Хәмитов утары (Кәрим бай йорты, 1996 дан Татар



Томск шәһәре. Сәүдәгәр К.М.Хәмитов утары (Кәрим бай йорты).

мәдәни үзәге) урнашкан. Сов. Союзы Герой-лары Х.Н.*Мөхәммәдиев*, Ш.С.*Рәхмәтуллин*, Ф.Г.*Камалетдинов*, тарихчылар Н.А.*Томилов*, И.И.*Шәрифҗанов*, СССРның халык артисты Г.Б.*Измайлова*, җәмәгать эшлеклесе И.Ж.*Бик - колов*, физик М.И.*Бичурин*, гамәли-бизәлеш сәнгате рәссамы Ф.Ш.*Яхинның* тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге Т.ө. б-н бәйле.

Әд.: Иванов П.Г. Томские татары. Томск, 1927; Томские татары в прошлом и настоящем: Сб. док. и материалов. Томск, 2000; Муравьёва Л.В., Савельева Н.Г. Моя Малая Родина (Из истории Заистока). Томск, 2002; Тюркоязычное население Томского края: Этнография и фольклор. Томск, 2002.

Л.В.Муравьёва, Н.Г.Савельева.

ТӨМСКИДА ТАТА́Р БИСТӘСЕ́ (Елга аръягы), 17 йөз башында оешкан татар авы - лы. «Елга аръягы» атамасы Том елгасының хәзер юкка чыккан зур булмаган уң тармагыннан барлыкка килә. Бистә Себер бохарилары сәүдә иткән шәһәрчек урынында төзелә (16 йөздә нигез салына). Аның тышкы кыя - фәтен, башлыча, хасил итә. 1882 һәм 1915 еллардагы янгыннар нәтиҗәсендә Т.т.б.нә зур зыян килә. 1882 елгы янгыннан соң, урам - нарга кабат планлаштыру үткәрелә. Бистә төзелешендә 20 йөз башында салынган сәүдә-гәр К.Хәмитов йорты, Кызыл һәм Ак мәчет - ләр аерылып тора. Бистәдә беренче булып яшәүчеләрнең бер өлеше Юрта тавыннан (Томскидагы тарихи р-ннарның берсе) күченеп килгән татарлар була. 20 йөз башында Томскида 2,5 меңгә якын мөселман исәпләнә, аларның күпчелеге Т.т.б.ндә яши. Хал - кының баштагы ху җалык эшчәнлеге шәһәр аша үтүче Себер трактына хезмәт күрсәтү б-н бәйле. Т.т.б.ндә юлаучылар йортлары, трактирлар урнаша, тимерче алачыклары, җи цел арба ясау, тире илләү остаханәләре һ.б. эшли. Пароходчылык һәм тимер юллар үсе - ше башлану б-н (20 йөз башыннан), Себер тракты бистә халкының ху җалык тормышын - да әһәмиятен югалта, халык, башлыча, сәүдә һәм кәсепчелек һ.б. б-н шөгыльләнә башлый (тегүчелек, утынга урман кисү һ.б.). Бистә-дә ш.у. сыра кайнату з-ды, кондитер ф-касы һ.б. пр-тиеләр урнаша. Кызыл мәчет каршын - да, Сәйдәшев, Хәмитов мөселман уку йортлары эшли. Бистә Себердәге татар мәдәнияте үзәкләренең берсе булып тора, биредә мө-селман-тәрәкъкыятьчеләре җәмгыяте эшчән-лек алып бара, «Сибирия» г-тасы нәшер ите-лә. Хәзерге вакытта Горький, Мәскәү тракты, М.Җәлил, Татар, Трифонов һ.б. урамнар урнашкан терр-яне үз эченә алган булган.

Әд.: Караваева А.Г. Татарская слобода: прошлое в будущем // Томск magazine. 2006. № 6 (19); Томская область: Народы, культуры, конфессии: Энцикл. Томск, 2007.

В.А.Шагалов.

ТӨ́МСКИДАГЫ ҖАМИ́ГЪ МӘЧЕ́Т (Ак җамигъ мәчет). Томскидагы агач мәчет 19 йөзнең уртасына кадәр эшли, 1900 елда яна. 1904 тә аның урынына таш (Кызыл) мә-чет төзелә. Соңгы елларда реставрацияләнеп, диндарларга кайтарыл а Ак җамигъ мә-чет 1913 елда Томск шәһәре ахуны Хәмзә Хәмитов һәм мәхәллә халкы акчасына салы-на. 1930 еллар башында ябыла, бина хуҗалык максатларында файдаланыла, манарасы һәм гөмбәзе сүтелә. 1990 да мөселманнарга тап-шырыла, 1999 елга әүвәлге рәвешендә торгы-зыла.

Гөмбәзе үзәкләшкән композициягә корыл-ган ике катлы таш бина урам чатында, әй-ләндереп алынган аерым терр-ядә урнашкан. Уксыман гөмбәзләр б-н төгәлләнгән төп на-маз залының куб рәвешендәге күләме һәм дүрт яруслы манара композициянең нигезен тәшкил итә. Бинаның ике ишеге бар. Беренче катта (ишек — көнбатыш фасад ягында) ха-тын-кызлар залы һәм хезмәткәрләр бүлмәлә-ре, икенче катта вестибюль һәм ир-атлар за - лы урнашкан. Көньяк фасадта биш почмак-лы михраб чыгып тора. Төньяк фасадның икенче катында урнашкан төп ишеккә ике яклы тимер баскыч илтә. Әүвәл (проект бу-енча) таштан һәм өч як басмалы була. Куб рә-вешендәге күләм уксыман гөмбәз б-н ябы - ла. Катлар бүленешен фасадлардагы кәрниз-ләр һәм төрле зурлыктагы тәрәзәләр аерып тора. Беренче каттагы бүлмәләрне тәбәнәк җәясыман, икенче катны ике кыеклап төгәл - ләнгән зур йөзлекле һәм як-якта яңгыр суы төшә торган ярымклонналар урнашкан биек аркалы тәрәзәләр яктырта. Почмакта һәм тә-



Томскидагы җамигъ мәчет (Ак җамигъ мәчет).

рәзә араларында чыгып торган киң лопатка-лар, кәүсәсенә тар куышлар уелган югарыга таба нечкәрә төшкән сигез кырлы мәһабәт манара бинага монументаль кыяфәт, ә куб рәвешендәге күләм һәм манара өстендәге сырлап эшләнгән уксыман гөмбәзләр, кәр - низ асты аркатур билдәүләре һәм уксыман уемнары шәрекъ колориты бирепторалар. Гомумән, бина фасадларга үзендә милли-ро-мантик юнәлештәге модерн стилен туплаган.

Әд.: Томские татары в прошлом и настоящем. Томск, 2000.

Х.Г.Надыйрова.

ТОМСЫ́К ГӨМБӘ́ (Amanita phallodes), җәймәле гөмбәләр рәтендәге аманитчалар семьялыгыннан гөмбә ыругы. Евразия, Төнь-як Америкада таралган. ТР терр-ясендә кат - наш һәм яфраклы (каенлык, имәнлек) ур-маннарда ялгыз яки төркемләп үсә. Дым яра-тучы үсемлек. Яфраклы токымнар б-н ми-кориза тудыручы. Яшь гөмбәләрнең эшлә-пәсе ярымшарсыман, өлгергәннәрендә — ка-барынкы-җәенке, диаметры 5–10 *см*, ак, ачык яшел, зәйтүнсыман — яшел; дымсу һавада — лайлалы, кайвакыт өслеге ак куныклы. Саба-гы 8–12 *см* биеклектә, 1,5–2 *см* юанлыкта, ак, сиреграк зәйтүнсыман яки саргылт төсмерле, төбендә бүлбесыман юанайган, ак касәсыман җиңсә-бөҗра (Т.г.гә хас билге) әйләндереп алган. Яшь гөмбәләрнең йомшагы ак, исе һәм тәме юк. Карт гөмбәләр тәмсез исле. Т.г. тышкы кыяфәте б-н шампиньоннарга охшаш; алар-дан пластинкаларының ак төстә булуы һәм бөҗрасы б-н аерыла. Үрчү өлеше июнь–но-ябрьдә күренә. Агулы гөмбә: составында эш-кәртү вакытында да таркалмый торган ток-синнар бар. Агулану билгеләре (кинәт эч авыр - ту, косу, эч китү, гомуми хәлсезлек) 8–12 сә-гатьтән һәм соңрак та күзәтелә.

ТОН Константин Андреевич (26.10.1794, С.-Петербург — 25.1.1881, шунда ук), архитек-тор, педагог, СА академигы (1830), проф. (1830). 1815 елда Петербург САн тәмамлый (А.Н.Воронихин классы), шунда ук укыта. 1817 дән Төзелешләр һәм гидравлика эшлә-ре ком-тында (С.-Петербург). 1819 дан Ита-лиядә СА стажёры, антик архит-ра истәлек - ләрен өйрәнә, бер үк вакытта Рим һәм Фло-ренция гыйлем йортларында укыта. 1828 дән яңадан сәнгать академиясендә, 1854–81 дә ректор. Бер үк вакытта, 1830 еллар башыннан, Россиянең әйдәп баручы архитекторы, мө-һим дәүләт заказларын башкара. Византия һәм Русь урта гасырлар архит-расын өйрән - гәч, неорус стилен (рус модернының мил - ли-романтик тармагы) эшли. 19 йөзнең архи-тектур фикерен формалаштыруда эклектика чоры архит-расындагы «милли» юнәлеш зур йогынты ясый. Т. проектлары буенча күп ке - нә биналар, ш.и. Коткаручы Гайса, Кремльнең Зур сарае, Кораллар палатасы, Мәскәүдәге Петербург вокзалы; С.-Петербургтагы Мәс-кәү вокзалы; Казан Кремлендәге *Губернатор сарае* төзелә. Казандагы *Г.Р.Державин һәйкә-ле* архитекторы. 1840–60 елларда төрле губер-наларда гы, ш.и. Казан губернасындагы йөз - ләрчә храмнар аның авторлыгында дөнья күргән үрнәк чиркәү проектлары (1839 да расланган) альбомы буенча төзелә.

Әд.: История русской архитектуры. СПб., 1990.

ТОНКО́В Владимир Николаевич (2.1.1872, Пермь губ., Чердынь өязе Коса а. — 6.10.1954, Ленинград), анатом, медицина д-ры (1900), СССР МФА академигы (1944), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1934), мед. хезмәте генерал-лейтенанты (1943). Хәрби-мед. академиясен тәмамлаганнан соң (1895, С.-Петербург), анатомия кафедрасында калдырыла. 1898 елда Германиядә (Берлин, Фрейбург) командировкада була. 1900 дән Петербург хатын-кызлар мед. ун-тында анатомия каф. мөдире булып эшли, анатомия музеен оештыра. 1905 тән Казан ун-тының анатомия каф. мөдире, бер үк вакытта мед. ф-ты деканы; анатомия музеена нигез салучы. 1915 тән Хәрби-мед. академиясенең (Петроград) анатомия каф. мөдире, 1917–25 тә академия башлыгы. Бөек Ватан сугышы елларында Хәрби-мед. академиясенең 3 нче ф-ты башлыгы вазифаларын башкара, 1950 дән проф.-консультант. Хезмәтләре кан тамырлары системасы морфологиясенә, коллатераль кан әйләнешенә карый. «Кешенең нормаль анатомиясе дәреслеге» («Учебник нормальной анатомии человека», т. 1–2, Л., 1953) авторы. Т. яңа коллатераль артерия юлларын ача, беренче булып умыртка арасы төеннәре, нервлары һәм лимфа төеннәренең кан б-н тәэмин итеше закончалыкларын ачыклый, талакның мезенхимадан барлыкка килүен исбатлый, мезотелийның күптөшле күзәнәкләрен тасвирлый, анатомик тикшеренүләр вакытында рентген нысулын куллануны гамәлгә кертә. Халык ун-тлары җәмгыятен оештыра һәм аңа җитәкчелек итә (Казан, 1907). Бөтенсоюз анатомнар, гистологлар һәм эмбриологлар фәнни җәмгыяте рәисе (1952–54). 2 Ленин ордены, 2 Кызыл Байрак ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы һәм Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.



В.Н. Тонков.

Х е з м.: Об артериях, питающих нервы и нервные сплетения человека // Врач. 1897. Т. 18, № 1; Кровеносные сосуды лимфатических узлов // Врач. 1898. Т. 19, № 34; Руководство к практическому изучению сосудов и нервов человека. Л.–М., 1930; Избр. труды. Л., 1959.

Әд.: Профессор Владимир Николаевич Тонков (1872–1954) // Архив анатомии, гистологии и эмбриологии. 1955. № 3; Гинсбург В.В., Михайлова Л.В. Путь советского анатома. Л., 1965.

Э.С.Вәлишин.

«ТО́НУС», Казан ун-ты журналистика һәм социол. ф-тының фәнни-публицистик альманахы. Басманы башлап җибәрүче һәм баш мөхәррире — проф. А.А.*Роот*. 1996 елдан Казанда елга 1–3 тапкыр нәшер ителә, текстлар рус һәм татар телләрендә басыла. Төп бүлекләре: «Журналистика», «Татар журналистикасы», «Социология», «Психология». Бүлек мөхәррирләре һәм аеруча актив авторлары арасында факультет хезмәткәрләре Ф.И.Әгъзәмов, В.З.Гарифуллин, Е.С.Дорощук, Л.П.Попов, Э.С.Рәхмәтуллин, Д.В.Туманов, С.К.Шәйхетдинова һ.б. була. Материалларның күп өлеше «Журналистика тарихы һәм теориясе» («Теория и история журналистики»), «Рус эмигрант басмасы тарихы» («История русской эмигрантской прессы»), «Татарстан журналистикасы тарихы» («История журналистики Татарстана»), «Фән — практикада» («Наука — в практике»), «Эш өстәленнән» («С рабочего стола») һ.б. сәхифәләрендә бирелә.

Әд.: Роот А.А., Баканов Р.П. Тонус: Классификация издания. К., 2006.

ТОНШЕРМА́ (Чирмеш) авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 25 *км* көнбатыштарак, Тоша елгасы буенда. 2010 елда 457 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Чиркәү. 1716 дан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү-приход мәктәбе (1891 дә ачыла), 3 җил тегермәне, 3 вак-төяклөр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1573,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Олы Шәмәк волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 елның 10 августыннан Тәтеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 118 ир-ат; 1859 да — 500, 1897 дә — 882, 1908 дә — 964, 1920 дә — 1111, 1926 да — 864, 1938 дә — 846, 1949 да — 742, 1958 дә — 867, 1970 тә — 925, 1979 да — 718, 1989 да — 485, 2002 дә — 498 кеше.

ТОПИНА́МБУР, җир грушасы (Helianthus tuberosus), катлаулы чәчәкләләр семьялыгыннан күпьеллык бүлбеле үсемлек; терлек азыгы культурасы. Чыгышы б-н Төньяк Америкадан. Европага 17 йөз башында кертелә. Барлык җирдә дә үстерелә. Т.ның бүлбеләре 100–150 *г* авырлыкта (бер үсемлеккә 10–30 данә), 15–25 *см* тирәнлектә булалар. Сабагы туры, цилиндрик формада, өске ягы тармаклы, биеклеге 3,5 *м* га кадәр. Т.ның җир өстендәге өлеше көнбагышка охшаган. Яфраклары зур йомыркасыман очлы формада һәм читләре теш-тешле. Чәчәк оешмасы сары чәчәкчекләрдән тора. Читтән серкәләнә. Җимеше — орлыкча. Орлыктан һәм бүлбеләрдән, ТР шартларында — бүлбеләрдән генә үрчи. Төрле типтагы туфракта үсә. Корылыкка, салкынга чыдам. Җир өстендәге өлеше — 6°С ка кадәр, бүлбеләре –30 °С ка кадәр салкынга чыдый. Татарстан терр-ясендә Т.ның беренче тәжрибә плантацияләре 1950–60 елларда а.х. һәм вет. ин-тларының укыту хуҗалыкларында барлыкка килә. Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тының тәжрибә кырларында 1980 елларда яшел массаның уңышы 1 *га* дан — 500–900 *ц* га, бүлбе уңышы 300–600 *ц* га җитә. Татарстанда зур булмаган мәйданнарда үстерелә. Терлек азыгы өчен бүлбеләре һәм сабаклары (яңа өлгергән килеш һәм силосланган хәлдә) кулланыла. Бүлбеләре азык буларак кулланыла (кыздырып, пешереп), спирт һәм фруктозага эшкәртелә; аларда B_1 һәм С витаминнары, фосфор һәм тимер бар. 100 *кг* бүлбедә 25–27 азык берәмлеге һәм 1,5 *кг* үзләштерелә торган протеин бар, сабагында 22,5 азык берәмлеге һәм 1,8 *кг* протеин бар. Шикәр авыруы булганда азык буларак кулланыла. Терлек азыгы чәчү әйләнешендә үстерелә. Яз һәм көз көннәрендә бәрәңге утырта торган машина б-н утыртыла. Рәт аралары көпшәкләндерелә, ашлама-лар б-н тукландырыла. Сабакларын — силос комбайны б-н, бүлбеләрен бәрәңге комбайны белән җыялар. Бүлбеләре җирдә яхшы саклана, шуңа аны кирәк кадәр генә казып алалар.

Әд.: Справочник по овощеводству. Л., 1982.


ТОПОГРА́ФИК АНАТО́МИЯ, анатомиянең әгъзалар һәм тукымалар төзелешен, рәвешен, урнашуын, анатомик яра-җәрәхәтләрне, оператив хирургияне өйрәнүче бүлеге. Хирургия операцияләренең рациональ ысулларын билгеләү һәм топик диагностика (авыру урынын ачыклау) өчен нигез булып тора. Россиядә Т.а. югары мед. мәктәбе барлыкка килгәннән һәм предметның махсус курсы аерылып чыкканнан соң үсеш ала. Мәскәү һәм С.-Петербург ун-тларында мөстәкыйль кафедралар барлыкка килү 18 йөзгә карый, соңрак Т.а. һәм оператив хирургияне берләштергән «парлы дисциплина» оеша. Рус анатомы И.В.Буяльский хирургиядә анатомик юнәлешнең мөһимлеген нигезли, гәүдәне бәлзәмләү ысулын эшли, «Анатомия-хирургия таблицалары» («Анатомохирургические таблицы», 1828) төзи. С.-Петербургта Т.а. фәнни юнәлеш буларак Мед.-хирургия академиясендә (соңрак Хәрби-мед. академиясе) формалаша. Россиядә Т.а. һәм оператив хәрби-кыр хирургиясенең үсеше Н.И.Пирогов хезмәтләре б-н билгеләнә. Аның «Артерия кәүсәләре һәм фасцияләренең хирургик анатомиясе» («Хирургическая анатомия артериальных стволов и фасций», 1880) китабы күпсанлы тикшеренүләргә башлангыч бирә. Ортопедия буенча Россиядә беренче дәреслек (1887) авторы Казан топограф-анатомы Н.И.*Студенский* була, ул рус-төрек сугышы вакытында (1877–78) Н.И.Пирогов кул астында эшли. Т.а. фән буларак Казан ун-тында 1815 тән үсеш ала (каф. мөдире Э.О.Вердерамо). П.Ф.Лесгафтның Т.а., сөякләр архитектурасы, буыннар һәм тукымалар төзелеше һәм функцияләренә багышланган хезмәтләре дөнья күләмендә таныла (1860–70 еллар). Имезүче хайваннар һәм кешенең кан тамырлары һәм бөерләрен Россиядә беренчеләрдән булып В.Э.Голубев өйрәнә (1894). Н.Н.*Боголюбов* күкрәк бизе рагы, бөер эхинококкозы очракларында операция ясауның яңа ысулларын тәкъдим итә (1917). Н.В.*Соколовның* фәнни тикшеренүләре нәтиҗәсе — «Калкансыман биз яны анатомиясенә карата» («К анатомии околощитовидной железы», 1926) китабы хәзергәчә әлеге өлкәдә бердәнбер хезмәт булып кала. А.Н.Сызганов «Бөерләрнең лимфа системасы топографиясе» («Топография лимфатической системы почек», 1924–27) хезмәтен яза. П.М.*Красинның* — периферик нервлар (1927), А.И.*Лаббокның* кан һәм лимфа тамырлары (1948) регенерациясен өйрәнүгә багышланган хезмәт -

ләре морфологларның югары бәясен ала. Н.Н.Бурденко (Мәскәү) тарафыннан фасция һәм күзәнәкара фәза өйрәнелү А.В.*Вишневскийның* уникаль анестезия ысуллары (1926) өчен алшартлар тудыра. В.Н.Шевкуненко, А.Н.Максимов, А.В.Вишневский төзегән «Периферик нерв һәм вена системалары атласы» («Атлас периферической нервной и венозной систем») СССРның Дәүләт бүләгенә лаек була (1954). В.Х.*Фраучи* лимфа-вена анастомозларын һәм ашказаны-ашказаны асты бизе бәйләнешен өйрәнү буенча җитди тикшеренүләр алып бара. Лимфология турындагы тәгълиматка нигез салучыларның берсе Ф.Ш.*Шәрәфисламов* Мәскәү лимфәре б-н автордашлыкта беренче булып лимфа һәм вена тамырларына операция ясау ысулын эшли (1971), күкрәк өлешендәге лимфа агымын дренажлау, вена анастомозы салу хәзер «Шәрәфисламов операциясе» дип атала. А.А.*Агафонов* җитәкчелегендә (1970–90 еллар) дигисталь тракт әгъзалары тышчаларына операция ясауның өр-яңа ысуллары гамәлгә кертелә (уйлап табуга патентлар алына), операция аның исемен йөртә; ш.у. аның тарафыннан микроциркулятор юнәлешне һәм лимфа циркуляциясен экспериментларда һәм дәвалау барышында өйрәнү өчен оригиналь приборлар уйлап табыла. РФдә беренче буларак, Ә.Х.*Дәүләтшин* тарафыннан корсакта кан китү чыганаклары тасвирлана, кан таралу юлларына топографик-анатомик нигезләмә бирелә, корсакның эчке җәрәхәтләре вакытында диагноз куюның комплекслы нәинвазив ысуллары күрсәтелә (1990). Беренче галим-анатомнарның фәнни эзләнүләрендәге төп юнәлешләрне кешенең кан һәм лимфа системаларын өйрәнү тәшкил итә. Казан анатомия мәктәбе вәкилләре — экспериментатор-клиницист Ф.С.Бәширов, С.В.*Доброквашин*, Ф.Г.Биккенәев, И.Х.Зарипов, М.Ю.Кедрин, А.И.Кормилин, А.В.Ивановлар нәтиҗәле эшли. Ш.у.к. *Хирургия.*

Әд.: А г а ф о н о в А.А. Кафедра оперативной хирургии с топографической анатомией // Казанский медицинский институт. 1814–1989. К., 1989. Ч. 1.

А.А.Агафонов, Ә.Х.Дәүләтшин.

ТО́ПОЛЬ, т у п ы л, т и р ә к (Populus), талчалар семьялыгыннан яфрак коючан агачлар ыругы. Якынча 110 төре билгеле, Евразия, Төньяк Америка һәм Төньяк Африкада таралганнар. Татарстан терр-ясендә 4 төре үсә. Ак Т. (P. alba) зур елга үзәннәрендә очрый. 30 *м* га кадәр биеклектәге агач. Тамыр системасы тирәндә. Ябалдашы җәенке, зур ботаклы. Кайрысы соры-яшел, шома, карт агачлар ярыклы, тупас кара кабыклы. Яшь ботаклары ак киезсыман. Яфраклары тыгыз, озынча — түгәрәктән бармак-калаксыманга кадәр, чит-читләре киртләч, өсте куе яшел, ялтырап тора, аскы ягы төкчәле, ак киезсыман, калын. Көзен яфраклар ачык сары төскә керә. Ике өйле үсемлек. Ата алкалары кызыл, аксыл, кызгылт-көрән серкәлекле, аналар — яшькелт-сары, күрексез. Апрельдә чәчәк ата, июньдә җимеш бирә. Кара Т. (P. nigra) елга һәм урман инешләре буенда үсә, кайвакыт аерым агачлыклар хасил итә; культуралы үсемлек буларак үстерелә, яңадан кыргыйланна. Биеклеге — 8–20 *м*. Ябалдашы тармаклы. Көүсәсе цилиндрсыман. Кайрысы тирән ярыклы, кара соргылт төстә. Яфраклары ромбсыман яки өчпочмаклы, очлы, өсте куе яшел, аскы ягы ачыграк төстә. Яфрак ярганчы чәчәк ата. Җимеше июнь–июльдә өлгерә. Калтыравык Т. яки *усак* (P. tremula) кисенделәр, ш.у. ачыклык һәм урман буйларында икенчел вак яфраклы урманнар хасил итә. Симон Т.е (P. simoni) Куйбышев сусаклагычы ярлары буенда кыргыйланган төр буларак очрый. 25 *м* биеклектәге декоратив агач. Ябалдашы җәенке. Яфраклар эллипс яки йомыркасыман, ялтыравык, өсте кара яшел, аскы ягы аксыл, яшьләре — ябышкак; ачылганда хуш исле. Яфрак ярганчы чәчәк ата.



Кара тополь: 1 – гомуми күренеше; 2 – ана алкалы бәбәк; 3 – ата алкалы бәбәк; 4 – яфрак.

Бәлзәмле Т. (P. balsamifera), берлин Т.е (P. berolinensis) һәм дельтасыман Т. (P. deltoides) торак пунктларны яшелләндерү, юл буйларын һәм кырларны ышыклау, урман полосалары булдыру өчен үстерелә. Шәһәрләрдә ак Т., башлыча аның ата затлары утыртыла, чөнки ана үсемлекләрнең «мамыгы» аллергия бирә. Җимеше — тартмачык. Орлыктан һәм чыбыкчадан үрчи. Кортлар, ш.у. ракның төрле формаларын китереп чыгаручы гөмбә һәм бактерияләр б-н зарарлана. Кортлар аеруча яфраклар-га зыян салучы тополь яфрагашары, парсыз ефәк күбәләге, көмешсыман айкүбәләк, үзагачка зыян салучы тал агачтишәре, шыгырдавык һ.б. билгеле. Шәһәрдә Т. еш кына тополь көясе б-н зарарлана. Т.нең үзагачы тартмалар, төрле эшләнмәләр ясауда файдаланыла. Халык медицинасында кайры һәм бөре төнәтмәләре бизгәктән, пешкән урыннарны дәвалау өчен кулланыла. Хуш исле ябышкак сумаласыннан бал кортлары прополис ясыйлар.

ТОПОНИ́МИКА (грек. tópos — урын һәм ónyma — исем, атама), *ономастиканың* бер тармагы; геогр. атамаларны (топонимнар), аларның функцияләрен, мәгънәләрен, килеп чыгышларын, төзелешләрен, таралу ареалын, билгеле бер вакыт эчендә үсеш һәм үзгәреш кичерүләрен өйрәнә. Нинди дә булса терр-янең топонимнары җыелмасы аның топонимиясен тәшкил итә. Татар телендә, объектлар характерыннан чыгып, топонимиянең түбәндәге төп төрләре аерып карала: ойконимия (грек. oikos — йорт, торак) — торак пунктларның атамалары: Бөгелмә ш., Аксу а.; гидронимия (к. *Гидронимика*) — су чыганакларының атамалары: Ык елгасы, Кабан күле; оронимия (грек. óros — тау) — рельеф үзенчәлекләренең атамалары: Чатыр Тау калкулыгы; космонимия — күк җисемнәренең атамалары: Чулпан йолдыз (Венера планетасы) һ.б. Т. геогр., тарих, этнография б-н үзара тыгыз бәйләнештә үсеш ала. Топонимия — тел тарихын тикшерү өчен мөһим чыганак, чөнки кайбер топонимнар (аеруча гидронимнар) архаизм һәм диалектизмнарны тотрыклы саклый, халыкларның тарихи үткәнен тергезү, аларның урнашу урыннарының чикләрен билгеләү, телләрнең үткәндәге таралыш өлкәләрен, мәдәни һәм икътисади үзәкләр, сәүдә юллары географиясен һ.б.ны ачыклау мөмкинлеге бирә. Татар топонимнарын өйрәнүгә Г.Ф.Саттаров, Ф.Г.Гарипова, Л.Ш.Арсланов һ.б.ның хезмәтләре багышлана.

Әд.: С а т т а р о в Г.Ф. Татар топонимиясе. К., 1998; Г а р и п о в а Ф.Г. Авыллар һәм калалар тарихыннан: 2 томда. К., 2001–03; П о д о л ь с к а я Н.В. Словарь русской ономастической терминологии. М., 1978; Языкознание: Большой энцикл. словарь. М., 1998; Г а р и п о в а Ф.Г. Татарская гидронимия. К., 1998.

Ф.Г.Гарипова.

ТО́ПЧИЙ Леонид Иванович (23.3.1913, Харьков ш. — 24.9.1974, Казан), шагыйрь. 1954 елдан Казанда яши, «Советская Татария» г-тасында, «Чаян» ж-лында хезмәттәшлек итә. «Зәңгәр диңгез буенда» («У синего моря», Харьков, 1939), «Сугыш вакыты» («Военное время», Харьков, 1943), «Россия күге астында» («Под Российским небом», М., 1963), «Бәхетем минем» («Счастье моё», 1964), «Киләчәк көн» («Грядущий день», М., 1965), «Үзем өчен яшәмим» («Живу не для себя», 1970), «Минем алтын көзем» («Моя золотая осень», 1983), «Яңадан терелү» («Воскрешение», 2003) шигъри җыентыклар авторы. Т. шигырь һәм поэмаларының герое — гади кеше: Бөек Ватан сугышы солдаты, сугыштан соңгы еллардагы хезмәт кешесе. Лирикасында табигать зур урын тота. Т. поэзиясенә интонация гадилеге хас. Репрессияләнә (1944), үлгәннән соң аклана (1993).

Әд.: Б а л а ш о в Ю. Доброе сердце поэта // Казань. 2003. № 12.

«ТОР» («Хаклык»), иҗтимагый-сәяси газета. Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатларның Казан Советы мари бүлекчәсе органы. 1919 елның 17 гыйнварыннан 1920 нең маена кадәр Казанда мари телендә тау марилары диалектында басыла. 1919 ның сентябренә кадәр «Незерын шамакшы» исемендә чыга. Мөхәррире — Н.В.Игнатьев, фактик мөхәррире — В.А.Мухин. РКП(б) сәясәтен пропагандалый, кулакларны юкка чыгарырга чакыра. 1920 нең язында «Т.» редакциясе Козьмодемьянск шәһәренә күчерелә. 1922 нең 15 гыйнварында РКП(б) ҮК вәкиле Н.Кубяк карары б-н газета чыгудан туктый.

Әд.: С е р г е е в М.Т. Возникновение и развитие печати Марийской АССР. Йошкар-Ола. 1971.

ТОРА́К. Идел һәм Урал буе татарларының утрак тормышка күчеп, авыл һәм шәһәрләр корып яшәү шартларында халык архит-расы һәм төзелеш мәдәнияте күпгасырлык үсеш юлы үтә, йорт салуның тотрыклы традицияләрен булдыра. Кайбер терр. һәм субэтник аермалар булуга карамастан, 20 йөз башына татар Т.ының нык үскән һәм бердәм комплексы барлыкка килә. Ул Идел буе һәм Урал халыклары Т.ы б-н күп якстан охшаш, ләкин аның төрки ярымкүчмә тормышка, ш.у. Урта Азия һәм Шәрекъ илләре мәдәнияте б-н тыгыз бәйләнгән болгар-татар шәһәр мәдәниятенә килеп тоташучы үз йөзе бар. 19–20 йөзләр чигендә традицион Т. күбесенчә авыл җирләренә хас була, чөнки шәһәрдә яшәүче татарлар нибары 5% тәшкил итә (1897). Татарларда утар Т.ның ху җәлык корылмаларыннан аерым торуы б-н үзенчәлек-ле. Йортның, бигрәк тә Казан артына хас булганча, койма артында, урам сызыгыннан эчкәре урнаштырылуы этник үзгәлек булып тора. Монда, ихтимал, мөселманнарның аерымлану традицияләре генә түгел, тагын да борынгырак, ислам диненә кадәрге — күчмә тормыш б-н яшәүдән утрак тормышка күчү һәм даими торулыклар барлыкка килү б-н бәйле традицияләре дә чагыла. Агач иң киң таралган төзелеш материалы була һәм хәзер дә шулай булып кала. Өйләрне буралап, көнь-як районнарда — каркас-багана файдаланып салалар. Идел буеның көньяк һәм көнь-як-көнчыгыш р-ннарында — саман (салам катыштырып ясалган кирпеч), ә Урал алдында таш киң кулланыла. 19–20 йөзләр чигендә кирпеч йортлар сирәк, башлыча, Рязань губернасы Касыйм өязе һәм Казан артының сәүдәгәр-эшмәкәрләре арасында очрый. Хәзерге вакытта төзелештәге әлеге терр. үзенчәлекләр, гомумән, саклана, әмма кирпеч һәм заманча материаллар куллану шактый арта. Буралап салынган Т. нигезгә утыртыла (почмаклардагы бүрәнә «урындыклар» яки буйга сузып салынган бүрәнә рәвешендә), төнь-як төбәкләрдә бураның аскы өлеше идән асты (аскы келәт) яки түбән өй хасил итә. Бүрәнәнең юанлыгына бәйле рәвештә, бура 10 нан алып 18 гә кадәр ниргәдән корыла, рус булмаган күрше халыклар б-н чагыш-тырганда, татар өйләре биеклекләре б-н аерылып тора. Идән һәм түшәм тактадан эшләнә, 2–3 тәрәзә өйнең ал ягында һәм 1–3 тәрәзә ян ягында уела. Түбәләрне, гадәттә, ике яки дүрт кыеклы итеп ясыйлар, такта, салам б-н яба-лар; 19–20 йөзләр чигендә калай б-н дә яба башлыйлар, ул, шифер б-н беррәттән, төп түбә ябу материалы булып тора. Элек ачык яки ярылаш ачык булган өйалды 20 йөз дәвамында ябык өйалдыга һәм верандага әверелә. Т. үзе ике яклы корылма рәвешендә була (ягыла торган өй + салкын өйалды). Төньяк-тагы урманлы төбәкләргә берләштерелгән — йорт + өйалды + келәт рәвешендәге Т. хас. Ишле гаиләләр Т.ны йорт + өйалды + йорт тибында төзиләр. 19 йөзнең 2 нче яртысында алты почмаклы һәм бер ягына өстәп салынган өйләр барлыкка килә, хәзерге вакытта алар аеруча киң таралыш ала. Казан артында һәм Касыйм өязендә бай тормышлы ху җәлар йортларын 2–3 катлы, күп бүлмәле итеп төзиләр (аскы катта кибет, склад һ.б. урнаша). Соңгы чорда авылларда, традицион йортлар б-н бергә, күп бүлмәле йортлар, коттеджлар салалар. Татарларда, аеруча Казан артында һәм Касыйм татарларында, Т. нык үскән архит-ра һәм гамәли бизәлеш ягыннан аерылып тора. Капкаларны, өйнең алдын, фронтонны, йөзлекләрне бизәү өчен өслеккә бер-кетелгән һәм кисеп ясалган бизәкләр киң кулланыла. Орнаментта үрелгән бау, дулкын, ромб, чәчәк, балкыш, кояш сурәте һ.б. кебек элементлар өстенлек итә. Т. төрле төсләргә, башлыча, зәңгәрсу, яшел, көрән, сары, ак буяуларга буяла. Болгар һәм Казан татарларының шәһәр төзелеше һәм архит-расы традицияләре үзенчәлеген тәшкил иткән әлеге сыйфатлар авыл җирләренә 16 йөзнең 2 нче



Татар торагы интерьеры. 1862.
К.Гун аквареленнән М.Рашевский гравюрасы.

яртысында — 17 йөздә Казаннан татарлар б-н килгән дип санала. Ука-Сура елгалары арасында яшәгән мишәр татарларда мондый традиция юк. Көньякътагы далалы р-ннарда диварларны агарту киң таралган. Торак йортның (кара өйнең) эчке төзелеше, кайбер үзенчәлекләрне исәпләмәгәндә, бертөрле була. Ишектән керү б-н авызы алгы диварга караган зур, ипи миче тора. Мич почмагыннан алгы диварга таба сузылган бүлмә тактасы яки чаршау өйне түр як һәм аш-су ягына бүлә. Алгы дивар буйлап киң һәм тәбәнәк *сәке* урнаштырыла, аның мич каршындагы почмагы иң кадерле урын булып исәпләнә. Мишәрләр һәм керәшен татарларда — сәкедән тыш, өйдә киң эскәмияләр һәм өстәл, Чыпса һәм Пермь татарларында ишек өстендә сәнderәләр дә була. Кузгатылмый торган башка әйберләрдән түшәмнән түбән — кием-салым элү өчен колгалар, дивар буйлап — урын-җир әйберләре, савыт-саба, китаплар өчен киштәләр, ш.у. аш-су ягы (кече як) диварында савыт-саба өчен ачык шкаф куела. Күп бүлмәле өйләр (өй + өйалды + өй, алты почмаклы өй һ.б.) икегә бүленә: аш-су ягы (кара өй), кунак бүлмәсе (ак өй). Элеккеге өйләрнең эчке төзелеше һәм интерьеры бер-берсеннән бик аз аерыла; соңрак ак як (ак өй) шәһәрчә җиһазландырыла башлый. Ипи миче голландка яки учак миче б-н алыштырыла. Казан татарларында ипи миченең тәбәнәк мич алды һәм батырып эшләнгән, астына аерым ягыла торган казаны була. Элеккеге «кара» мич урынына 19 йөз ахырыннан һәр җирдә диярлек мор җәлы «ак» мич чыгара башлыйлар. Өй эчен бизәүдә чигүле һәм бизәкле тукымалар — дивар һәм матча *кашагалары*, *чаршау*, *чыбылдык*, сөлге, тастымал, *намазлык*, тәрәзә пәрдәләре зур роль уйный. Идәнгә — өйдә тукылган тар озын палас, бай йортларда келәм җәелә. Татар өенең тагын бер үзенчәлеге — урын-җир әйберләренең: түшәк, ястык, мендәр һ.б.ның күплеге, аларны көндез биек итеп матурлап өеп куялар. Урта хәллеләрнең йортларында бер яки берничә сандык, буфет, самаварлы һәм савыт-сабалы өстәл, көзгеләр, суга торган сәгать, *шәмаиллар* була, тәрәзә төбендә гөлләр үсә. Бай йортларының бер бүлмәсен булса да шәһәрчә (өстәлләр, урындыклар, диваннар һ.б. б-н) җиһазландыралар. Татарлар аерымланып яшәгән шәһәр бистәләрендәге бай булмаган йортларның тышкы бизәлеше эчке төзелеше, интерьеры авыл Т. төзелеше б-н бик охшаш була. Таза тормышлы шәһәр татарлары мул җиһазландырылган, эчке төзелеше катлаулы булган 1–3 катлы, башлыча кирпеч йортларда яшиләр. Мондый Т. интерьеры, традицион нигезен саклаган хәлдә (ирләр һәм хатын-кызлар өчен аерым бүлмәләр, тукыма әйберләрнең күп булуы һ.б.), 19 йөзнең 2 нче яртысыннан гомумевропа үзенчәлекләрен ала. 20 йөз ахырыннан халыкның, аеруча шәһәр халкының тормыш итүдә Европа стандартларына юнәлеш алуы сизелерлек үсә, бу шәхси йортлар төзүдә һәм муниципаль Т. төзелешендә чагыла (уңайлы Т. проектлары, яңа төзелеш технологияләре, материаллары, интерьерның заманча дизайны, яхшы сыйфатлы көнкүреш техникасы).

Әд.: Воробьёв Н.И. Казанские татары. К., 1953; Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967; Мухамедова Р.Г. Татары-мишары. М., 1972; Мухаметшин Ю.Г. Татары-кряшены. М., 1977; Шарифуллина Ф.Л. Касимовские татары. К., 1999; Татары. М., 2001.

Н.А.Халиков.

ТОРА́К ПУНКТ, кешеләрнең даими һәм вакытлыча яшәү урыннарының гомуми исеме. Зурлыгы, адм. статусы, яшәүчеләрнең эш төрләре һ.б. б-н аерылалар. Т.п.ларның төп 2 төре — функциональ төзелеше һәм кеше саны буенча нык аерылучы авыл һәм шәһәр җирлекләре бар. Шәһәр җирлекләре 2 категориягә — шәһәр һәм шәһәр тибындагы посёлокларга (ш.у. эшчеләр посёлогы дип тә йөртеләләр) бүленә. Кагыйдә буларак, шәһәрләрдә халык саны шактый күбрәк, алар, а.х.ннан тыш сәнәгать, сәүдә, хезмәт күрсәтү, фән, мәдәният өлкәсендә эшлиләр. Шәһәр тибындагы посёлоклар сәнәгать, транспорт, курорт, адм. һ.б. функцияләрне башкаралар, әмма шәһәр статусы дәрәҗәсенә җитәрлек үсеш алмаганнар. Авыл җирлекләренә посёлоклар яки аерым ферма хуҗалыклары — җир милекчеләре яки арендаторлар; яшәүчеләре сәнәгатьтә, транспорт, урман ху җәлыгында һ.б.да эшләүче авыл җирлекләре; җирле адм. һәм мәдәни көнкүреш үзәкләре функцияләре булган катнаш, ш.и. аграр-индустриаль җирлекләр; яшәүчеләре шәһәргә эшкә йөрүче шәһәр яны җирлекләре керә. Крәстиян авыл җирлекләренең тарихи тибы булып авыллар тора. ТРда хәзерге вакытта 21 шәһәр, 19 шәһәр тибындагы посёлок,

3082, ш.и. даими яшәүчеләре булмаган 51 авыл торак пункты исәпләнә. Шәһәрләрдә яшәүчеләр саны — 2625,8 мең (барлык яшәүчеләрнең 69,8% ы), шәһәр тибындагы посёлокларда — 178,1 мең (4,7%). Шәһәр халкының 75% тан артыгы Татарстанның аеруча зур 4 шәһәрендә — Казан, Чаллы, Түбән Кама, Әлмәттә яши. 2 шәһәрдә — Болгар һәм Лаешта — яшәүчеләр саны 10 меңнән азрак. Авыл Т.п.ларында 973,1 мең кеше (барлык яшәүчеләрнең 25,5% ы) яши. Ш.у.к. *Шәһәр агломерациясе.*

ТОРА́К РЕФО́РМАСЫ, милек формаларына, торакка хуҗа булу һәм файдалану, ш.у. торак фондын тоту, хезмәт күрсәтү формаларына яңалыклар кертү. 1990 елларга кадәр торак-коммуналь хуҗалык икътисад өлкәсенә түгел, социаль секторга карый, тулысынча дәүләт контролендә була һәм нәтиҗәлелеге түбән булу б-н аерылып тора. Торак өлкәсендәге кризис зур масштабта реформа үткәрү кирәклеген күрсәтә. 1990 еллар ахырына Т.р. Россиядә дәүләтнең социаль һәм икътисади сәясәтенең өстенлекле юнәлешләренә берсенә әверелә. Респ-када аңа ТРның дәүләт һәм муниципаль торак фондын хосусыйлаштыру принципларын билгеләгән «Татарстан Республикасында торак фондын хосусыйлаштыру турында»гы 1993 ел 15 июль Законы нигез була. 1990 елларга кадәр ТРдагы торак фондының 66,4%ы (шәһәрләрдә 83,7%, авыл җирләрендә 25,3%) дәүләт һәм муниципалитетлар карамагында була. Торак төзелешендә бюджет өлеше 80% чамасы тәшкил итә. Т.р. нәтиҗәсендә 2001 ел башына торак фондының 70% ы гражданнарның шәхси милке булып санала. Торак төзелешен финанслауда тамырдан үзгәрешләр була: бюджет өлеше 12% ка кадәр кыскара. Төзелешне стимуллаштыру һәм халыкка хосусый торак алуда ярдәм итү өчен хәзер төрле чаралар кулланыла: а.х. продуктлары б-н түләү аркылы авылда торак төзелешенә озак сроклы кредит бирү фондын булдыру; аерым категория гражданнарга торак төзү һәм торак алу өчен түләүсез субсидияләр бирү; торак сертификатлары, заёмнар чыгару; озак сроклы ипотека һ.б. чаралар күрелә. Торак базары барлыкка килә. Т.р. барышында торак фонды структурасындагы үзгәрешләр һәм шуңа бәйле рәвештә җәмәгатьчелек аңының үзгәрүе икенчел торак базарындагы сату-алулар күләменең артуына китерә. Хокукый базасын камилләштерү, торак фондын идарә итү һәм аңа хезмәт күрсәтүне конкурс нигезенә күчерү Т.р.ның иң мөһим мәсь әләлфе булып тора. Ш.у.к. *Шәһәр төзелеше. Торак хуҗалыгы.*

Чыг.: Закон РТ «О приватизации жилищного фонда в Республике Татарстан» от 15.07.1993. № 1936-XII // Советская Татария. 1993. 7 авг.; Республика Татарстан 1920–2000: Стат. сб. К., 2001.

А.М.Туфитуллов.

ТОРА́К ХУҖАЛЫГЫ́, халык ху җалыгы тармагы, төп бурычы — халыкның торак-көнкүреш ихтыяҗларын канәгатьләндерү. Т.х.на үз тирәсендәге җир участоклары һәм социаль инфраструктура объектлары, кешенең яшәве өчен тиешле дәрәҗәдәге уңайлыклар тәэмин итә торган инженерлык корылмалары б-н бергә торак фонды һәм бу фондка хезмәт күрсәтүче структуралар керә. Икътисадны реформалаштыру елларында Татарстанда торак фондының структурасы нык үзгәрә. 2014 елның 1 гыйнварына торак фондының гомуми мәйданы 92826,0 мең $м^2$, биредә муниципаль милекне һәм ведомстволарга караган тораклы да кертеп, дәүләт милке мәйданы — 9%, шәхси торак йортлар һәм хосусыйлаштырылган фатирларны кертеп, гражданнарның хосусый милке мәйданы — 91,0%, башка төр милек мәйданы — 1,0%. 2014 нең 1 гыйнварына респ-када яшәүче бер кешегә 24,4 $м^2$ торак мәйданы туры килә, ш.и. авылларда — 27,6 $м^2$, шәһәрләрдә — 23,1 $м^2$. ТРда ел саен кеше башына 0,62 $м^2$ яңа торак сафка кертелә. 1995 тә ТР Президентының «Тузган торак фондында яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту чаралары һәм тузган торак кварталларына реконструкция турында» Указы кабул ителә. Аның нигезендә 4,9 мең (ш.и. Казанда 3519) гаилә өчен барлык уңайлыклары булган 1763 торак йорт төзелә. Әлеге дәүләт программасын гамәлгә ашыру барышында Татарстанда беренче тапкыр аны финанслау өчен бюджеттан тыш чыганаклар файдаланыла. ТРда тузган тораклы бетерү программасын тормышка ашыруда тупланган тәжрибә һәм уңышлы нәтиҗәсендә респ-када социаль ипотеканы кредитлау программасын гамәлгә кертү һәм торак төзелешен алга таба үстерү өчен кирәкле нигез булдырыла. Барлык торак фондының төрле уңайлыклар б-н тәэмин ителеше: электр б-н — 100%, газ челтәреннән бирелә торган газ — 90,5%, электр плитәләре — 8,2%, үзәкләштерелгән җылылык — 68,7%, сууткәргечләр — 87,7% (шәһәрләрдә — 96,3%, авылларда — 64,8%), җылы су — 73,7% (ш.и. үзәкләштерелгән тәэмин ителеш — 52,1%), ванналар (душ) б-н — 71,7% (шәһәрләрдә — 88,9%, авылларда — 25,7%). Респ-ка буенча комплекслы уңайлыклар тудырылган тораклар ның өлеше — 73,7%, тузган һәм авария хәлендәге торак фонды 1223,69 мең $м^2$ (10595 йорт) тәшкил итә (2013). Индивидуаль торак фондыннан файдалану тулысынча диярлек (янәшә терр-яләрне төзекләндерүдән тыш) гомумиләштерелгән торак фонды ху җалары — фатир ху җалары һәм аны вакытлыча файдалануга алучылар исәбенә һәм ТР бюджетыннан финанслана. Гомумиләштерелгән торак фонд өчен торак-коммуналь хезмәт күрсәтүгә дотацияләр бу хезмәтнең төрләре һәм аның уңайлылык дәрәҗәсенә карап бүленә. Хосусый торак фондын файдалануны милек ху җалары идарә итә. 2003 ел башыннан күп фатирлы торак йортлар б-н идарә итү һәм аларга хезмәт күрсәтү вазифалары бүленә. Барлык юнәлешләр буенча муниципаль һәм хосусый оешмалар эшчәнлек алып бара. Капиталь ремонт конкурс нигезендә башкарыла. Т.х. б-н гомуми идарә эшен ТР ның Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы алып бара. Ш.у.к. *Шәһәр төзелеше, Торак реформасы.*

Л.С.Вәлиев, Р.И.Хөсәенов.

ТОРА́К ҺӘМ ҖӘМӘГА́ТЬ БИНАЛАРЫ́ ТӨЗЕЛЕШЕ́, к. *Татарстан Республикасы, Торак реформасы, Торак хуҗалыгы, Шәһәр төзелеше.*

ТО́РГОВ Игорь Владимирович (2.2.1912, Казан — 15.6.2007, Мәскәү), химик, химия фән. д-ры (1953), РФА мөхбир әгъзасы (1991; 1972 елдан СССР ФА мөхбир әгъзасы). 1937 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, Казан мех ф-касында эшли. 1939–59 да СССР ФАнең Органик химия ин-тында, 1959–87 дә — Биоорганик химия ин-тының стероидлар химиясе лаб-ясе мөдире (Мәскәү). Хезмәтләре стероидлар химиясенә карый. Стероидларны сәнәгыйысул б-н табуның нигезен тәшкил иткән реакцияне — α-окси-α-винилтетралиннарның селтеләр катнашында циклик 1,3-дикетоннар б-н куерусын ача (Торгов реакциясе). Т. стероидларның микробиологик трансформациясен тикшерә, нәтиҗәдә, табигый һәм модификацияләнгән стероидларның оптик изомерларын алу мәсьәләсен хәл итә. Эстронның гади һәм кыска синтезын эшли. Стероидларның энзиматик әверелешләрен өйрәнгәндә изомераза — стероидлы метаболизмның төп реакциясе ферменты тәэсирендә водород күчү механизмын ачыклый. Т. җитәкчелегендә пестицидлар һәм үсемлекләрнең үсешен көйләгечләр химиясенә караган күпсанлы тикшеренүләр башкарыла. Табигый кушылмалар химиясе буенча илдә беренче дәреслек авторы. Бөек Ватан сугышында катнаша. Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Химия природных соединений. М., 1961 (автордаш).

Әд.: В о л к о в Р.А., В о н с к и й Е.В., К у з н е ц о в а Г.И. Выдающиеся химики мира: Биогр. справ. М., 1991.

ТОРМА́ (Raphanus), әвернә чәчәкләләр семьялыгыннан икееллык яисә берьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 8 төре бар (Европада, ш.у. Европаның Урта диңгез буе илләрендә). БДБда 3–4 төре, нигездә, Кара диңгез һәм Каспий диңгезе буйларында үстерелә. Кыр тормасы яисә Кыргый Т. (R. raphnistrum) — берьеллык чүп үлән, язгы чәчүлекләрдә һәм яткын җирләрдә таралган. Сабагы тармаклы, 60 *см* биеклектә. Үзәк тамырлы. Касәсыман яфраклары туры, таҗ яфракчыклары сары, ак, алсу, шәмәхә яисә сыек шәмәхә. Җимешләре өлгергәннән соң үсемлек а.х. терлекләре өчен зарарлы була (горчица мае булган орлыклары аркасында). Чәчүлек Т. яисә бакча Т.сы (R. sativus) киң таралган, бакчаларда үстерелә торган гади Т. һәм *редис* — шуның төрчәсе. Гади Т. (R.s.var. sativus) — икееллык яшелчә үсемлеге. Беренче елда — телгәләнгән яфрак таралгысы б-н тамыразык, икенче елда чәчәк үрентеләре һәм орлыклар барлыкка китерә. Чәчәк оешмасы — чук. Чәчәк таҗлары алсу, шәмәхә, кызыл, шәмәхә-кызыл, сирәгрәк аксыл-сары төстә. Баллы үсемлек. Җимеше — ачылмый торган кузак. Читтән серкәләнә. Тамыразыгының формасы түгәрәк, озынча конуссыман, төрле төстә (ак, кара, соры, сары, шәмәхә, ачык-кызыл). Т. — салкынга чыдам, дым яратучы үсемлек, үсеше өчен иң яхшы шартлар — салкынча дымлы һава, балчыксыл һәм

комсу туфраклар, органик ашламалар кертканнән соң, 2–3 нче елда чәчелә. Орлыклары чәчү нормасы 1 *м*² га 0,4–0,6 *г* (1 *га* га 4–6 *кг*). Уңышы 1 *га* дан 30–50 *т* һәм аннан да күбрәк. Тишемнәре –3 °С темп-рага, зур үсемлекләре -6 °С темп-рага чыдам. Үсемлекнең үсеше өчен иң яхшы темп-ра 18–20 °С. Тамыразыгында 1,58% шикәр, 1,92% аксым, С витамины (20–25 *мг* %), минераль тозлар, ферментлар бар. Азык буларак яңа өлгергән килеш (чи килеш) кенә кулланыла. Татарстанда кулланыла тәкъдим ителгән сортлары: «Зимняя круглая чёрная» (1975), «Зимняя круглая белая» (1983).

Әд.: Сазонова Л.В., Пивоварова Н.С., Мантрова Э.Г. Редис, редька, репа, брюква. Л., 1986. *И.Н.Афанасьев.*

ТОРМЫ́ елгасы, Идел алдында. Үләмә елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 19,8 *км*. Бассейнының мәйданы 105,8 *км*². Идел буе калкулыгыннан ага. Елганың югары агымы Буа р-нында, урта һәм түбән агымы — Тәтеш р-нында. Елга башы Кече Фролово авылыннан 4 *км* төньяк-көнчыгыштарак, тамагы Олы Тормы авылыннан 2 *км* көньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 80 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 10%. Т.ның 2 дән 9,1 *км* га кадәр озынлыктагы 6 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,43 *км/км*². Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен ныкаегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 144 *мм*, ташу агымы катламы 130 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры – апрель башында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,05 *м*³/*с*. Суы язын чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

«ТОРМЫ́Ш», иҗтимагый-сәяси һәм икътисади газета. 1913 елның 18 октябреннән 1918 нең 29 апреленә кадәр Уфа шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, баштарак атнага 3 тапкыр, аннан соң көн саен чыга, 800 гә якын саны дөнья күрә. *«Сибирия»* г-тасының дәвамчысы. Мөхәррирләре — М.Нәүрүзов, З.Кадыйри (1914 тән), нашире — Г.Усманов. Мәгариф, дин, татар теле, әшмәкәрлекне үстерү мәсьәләләренә, хатын-кызларның җәмгыятьтәге урыны, авыл тормышы мәсьәләләренә багышланган мәкаләләр дөнья күрә. Аеруча актив авторлары — С.Шәрәфетдинов, С.Хәбиров, Н.Кадыйри һ.б. Ш.Бабич, З.Бәшири, М.Гафури, Г.Ибраһимов, А.Тангатаров, З.Ярмәки һ.б. әсәрләре, Иркутск, Омск, Оренбург, С.-Петербург, Петропавловск, Төмәндәге татар театрлары спектакльләренә рецензияләр басыла. Газета битләрендә татар матбугатының 10 еллыгы билгеләп үтелә (Ә.Вәлидинең «Иске газеталарыбыз турындагы хәбәрләргә кушымта», «Безнең журналлар» һ.б. мәкаләләр). Уфа мөселман комис-ты тарафыннан «пролетар революциягә каршы чыгыш ясаганы» өчен тыела.

«ТОРМЫ́Ш», Уфа шәһәрендәге басмаханә. Шәһәрдәге икенче хосусый басмаханә, анда китаплар татар һәм башкорт телләрендә басыла. 1914–16 елларда эшли. «*Иршад*» китап нәшрияты, «Хөсәенов варислары» нәшрият һәм китап сәүдәсе фирмасы (Уфа), җыентык авторлары заказлары буенча, 42 меңнән артык тираж б-н 11 исемдәге китап чыгара (нигездә, матур әдәбият һәм фольклор әсәрләре: Ш.*Бабич*, башкорт язучылары С.Яхшыгулов, З.Мостафин, Г.Мәсрур, Н.Ягъфәров һ.б.). Басмаханәдә ш.у. «*Тормыш*» г-тасы нәшер ителә.

Әд.: Каримуллин А.Г. Татарская книга начала XX века. К., 1974.

«ТОРНА́ БЕЛӘН ТӨЛКЕ́», хайваннар турында татар халык әкияте. Эчтәлеге б-н мәсәлгә якын. Сюжеты күп халыкларның фольклорында киң таралган. Торна б-н Төлке дуслашалар. Төлке Торнаны кунакка чакыра, алдына, тәлинкәгә салып, тары боткасы куя. Торна озын томшыгы б-н ботканы ашый алмый. Икенче вакыт Торна сөтле умач пешерә һәм аны озын муенлы кувшинга сала. Төлкене кунакка чакыра. Аның борыны кувшинның тар муенына сыймый, ул да ач килеш кайтып китә. Шулай итеп, «дуслар» аерылышалар. Әкиятнең берничә варианты бар. 1936 елда Апас р-нының Танай Турай авылында Г.Толымбайский тарафыннан К.Әхмәдишин сүзләреннән язып алына. Беренче тапкыр «Татар халык әкиятләре» (1956) җыентыгында нәшер ителә. Кулъязмасы ТР ФА Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тының фольклор фондында саклана.

Әд.: Татар халык иҗаты: Әкиятләр. К., 1977. 1 кит.; Урманчеев Ф. Хайваннар турындагы әкиятләр // Татар халык иҗаты: Дәреслек. К., 2005. *Ф.И.Урманчеев.*

ТОРНА́ БОРЧАГЫ́ (Orobus), кузаклылар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Якынча 30 төре билгеле, Төньяк ярымшарның уртача поясында таралганнар. Татарстан терр-ясендә 2 төре бар. Язгы Т.б. (O. vernus) — барлык районнарда, күгелҗем Т.б. (O. canescens) Кама аръягында очрый. Урманнарда, куаклыкларда үсәләр. 15–40 *см* биеклектәге үсемлек. Тамырчасы озын, шуышма. Сабагы туры. Яфраклары парлы каурыйсыман, очлы. Язгы Т.б.ның чәчәкләре зәңгәрсу-шәмәхә, чәчәк атып бетергәч, зәңгәр төскә керәләр, күгел җем Т.б.ныкы — ак яки саргылт. Җимеше — озынча күп орлыклы кузак. Язгы Т.б.ның җир өсте өлешләрендә алкалоид, флавоноид, аскорбин к-тасы бар; үлән тәнәтмәсе йөрәк авыруларыннан кулланыла. Вакланган яфраклары яраларны төзәтүдә файдаланыла. Терлек азыгы, баллы үсемлек.

ТОРНА́ КУЗГАЛАГЫ́ (Descurainia), әверенә чәчәкләләр семьялыгыннан бер-, сирәк кенә икееллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 50 гә якын төре билгеле; нигездә, Төньяк Америкада, берничә төре Европа, Азия һәм Африкада таралган. ТР терр-ясендә бер төре — София Т.к. (D. sophia) бар, респ-каның бөтен терр-ясендә очрый. Буш, яткын җирләрдә, чүплекләрдә, юл буйларында үсә. 25–100 *см* биеклектәге берьеллык үсемлек. Тамыры нәзек, орчыксыман. Сабагы туры, нык төкчәле. Яфраклары чиратлашкан, икешәр, өчәр каурыйсыман. Үсемлек соры-яшел төстә, тармаклы төкчәләр б-н капланган. Чәчәкләре вак, аксыл-сары. Җимеше — көрән төстәге бик күп вак орлыклы кузакчык. Май–августта чәчәк ата. Җимешләре июнь–сентябрьдә өлгерә. Орлыктан үрчи (бер үсемлек 800 меңгә кадәр орлык бирә), орлыклары туфракта 4–5 ел шыту сәләтен югалтмый. Орлыкларында гликозид, май бар. Халык медицинасында үлән тәнәтмәсен эч йомшарту һәм бәвел кудыру чарасы буларак кулланалар. Т.к. орлыклары тәмләткеч сыйфатында файдаланыла.

ТОРНАБА́Ш (Erodium), яранчалар семьялыгыннан бер- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 50 гә якын төре билгеле, Төньяк ярымшарның уртача поясында таралган. ТР терр-ясендә бер төре — гади Т. (E. cicutarium) бар, 10–45 *см* биеклектәге берьеллык үсемлек. Республиканың барлык терр-ясендә очрый; бакчаларда чүп үләне буларак үсә. Сабагы куе кара төкчәле. Яфраклары озынча, каурыйсыман теленмә. Чәчәкләре кара сере һәрле кызыл, аксыл кызыл яки алсу төстә, чатыр чәчәк төркемендә. Июль–августта чәчәк ата. Җимеше — тартмачык, формасы буенча торна башын һәм томшыгын хәтерләтә (исеме шуннан). Өлгергән җимеш кылчыклы 5 орлыкка таркала; дым сеңдергәндә, кылчыклар үзелә һәм орлыклар җиргә күмелә. Дару үсемлеге. Җир өсте органнарында сапониннар, эфир мае, дуплау матдәләре, С витамины бар. Халык медицинасында төнәтмәсе бөрешергеч, кан туктату һәм көзән җыеруга каршы чара буларак кулланыла.

ТОРНАЛА́Р (Grus), торна кошлар семьялыгыннан чын торналар ыругы. 10 төрне үз эченә ала. Европа, Азия, Төньяк Америка, Австралия, Яңа Гвинеядә таралганнар. Татарстан терр-ясендә 1 төре — соры торна (G. grus) бар. Озын муенлы, озын аяклы кош. Басып торучы кошның биеклеге 115–125 *см*, канат җәеме 2 *м* га, авырлыгы 7 *кг* га кадәр. Каурый капламы соры төстә, канат очлары кара диярлек, муенының як-яклары аксыл буй-буй сызыклы. Ботының түбәнге өлеше каурыйсыз. Алгы бармаклары төбеннән үк кыска элпә б-н тоташкан, арткы бармагы башкаларына караганда биектәрәк. Койрыгы кыска. Т. муен һәм аякларын сузып очалар. Көчле быргы тавышы (озынча трахея резонатор булып хезмәт итә) чыгаралар. Күчмә кошлар. Кышларга киткән җирләреннән ТР



Соры торна.

терр-ясенә апрельнең икенче ункөнлегендә кайталар. Очып килгәннән соң, гөрләп чакыру чоры башлана. Аулак урыннарда (урман сазлыклары, сазлыклы зыреклекләрдә, елга тугайларында, күл буендагы биек үләнле болыннарда) оялыйлар. 2 йомырка сала, ата кош б-н ана кош чиратлашып утыралар. Августта оялардагы кошлар 10–20 шәр булып төркемнәргә берләшәләр һәм азык эзләп кырларга очып китәләр, шунда арыш, бодай, бор - чак һ.б. культураларның коелган бөртекләрен чүплиләр. Олы кошларның рационына бөжәкләр, моллюсклар, вак умырткалылар да керә. Кышлар өчен (Көньяк Европага һәм Төньяк Африкага), гадәттә, сентябрьдә очып китәләр. Почмак ясап тезелеп, каңгылдап бик биектә һәм фәкать көндез генә очалар. ТРның Кызыл китабына кертелгәннәр.

ТОРНАТА́Ш авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 38 *км* көньяк-көнчыгышта - рак, Иганә елгасы буенда. 2010 елда 51 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. Клуб. 1748 дән мәгъ - лүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 524 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Бишенде-Останково волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1935 нең 10 февраленнән — Ворошилов, 1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл, 1984 нең 4 июненнән Тукай р-нында. Халык саны: 1795 тә — 79 кеше, 1816 да — 42 ир-ат; 1834 тә — 101, 1870 тә — 223, 1906 да — 434, 1913 тә — 391, 1920 дә — 411, 1926 да — 203, 1938 дә — 312, 1949 да — 217, 1958 дә — 189, 1970 тә — 182, 1979 да — 130, 1989 да — 69, 2002 дә — 51 кеше.

ТОРНАЯ́З авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 26 *км* төньяктарак, Касыйм елгасы буенда. 2010 елда 69 ке - ше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау, кошчылык. Клуб. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенче - лек, терлекчелек, он тарту, чыпта һәм киндер сугу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп, 2 җил тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 428,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр ТАССРның Арча кантоны Алат волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Зелено - дольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 187 ир-ат; 1859 да — 216, 1897 дә — 307, 1908 дә — 501, 1920 дә — 397, 1926 да — 418, 1938 дә — 385, 1949 да — 283, 1958 дә — 135, 1970 тә — 115, 1989 да — 77, 2002 дә — 73 кеше.

Әд.: Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

ТОРНАЯ́З авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 40 *км* көнбатыштарак, Самара өлкәсе б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 299 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шө - гыле — кырчылык, терлекчелек. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.да 2 вак-төякләр кибете була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 316,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Юхмачы волостенда, 1920 дән ТАССРның — Спас, 1924 тән Чис - тай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Октябрь, 1935 нең 10 февраленнән — Тельман, 1958 нең 16 июленнән — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән — Нурлат р-нында. Халык саны: 1859 да — 240, 1897 дә — 424, 1908 дә — 453, 1920 дә — 505, 1926 да — 461, 1938 дә — 458, 1949 да — 395, 1958 дә — 481, 1970 тә — 534, 1979 да — 377, 1989 да — 267, 2002 дә — 347 кеше.

ТОРНО́В (Персианинов) Василий Иванович (1737, Мәшһәд ш., хәзерге Иран — 10.1.1775, Мәскәү), Е.И.*Пугачёвның* көрәштәше. Чыгышы б-н Персиядән. 1750 елдан Россиядә, православие кабул итә, Оренбург гу - бернасының Ставрополь өязендә яши. 1773–75 еллардагы *Крәстияннәр кузгалышында* Е.И.Пугачёвка кушыла, 1773 нең декабрендә Пугачёв фәрманы б-н Нагайбәк кальгасенә атаман итеп җибәрелә. Кама аръягында баш күтәрүчеләр отрядлары б-н җитәк - челек итә. 1774 нең апрелендә әсирлеккә төшә; Казанда тоткынлыкта була; 1774 нең июлендә, *Казан өчен сугыш* барышында, баш күтәрүчеләр тарафыннан азат ителә. Баш күтәрүчеләр гаскәренең Идел буендагы явында катнаша. Е.И.Пугачёв тәмам җиңелгәннән соң (1774 нең августы ахыры), гаебен танып, хакимиятләргә бирелә. 1775 нең 10 гыйнварында Мәскәүдә җәзалап үтерелә.

Чыг.: Пугачёвщина. М.–Л., 1929. Т. 2.

Әд.: О в ч и н н и к о в Р.В. Следствие и суд над Е.И.Пугачёвым и его сподвижниками: Источниковед. исслед. М., 1995.

ТО́РОПОВА Вера Фёдоровна (20.11.1915, Ярославль өлкәсе Молога ш. — 31.12.2008, Казан), химик-аналитик, химия фән. д-ры (1959), проф. (1960), ТАССР, РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1970, 1980), Казан ун-тының атказ. профессоры (2004). 1938 елда Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шун - да ук эшли. 1941–43 тә оборона з-дының үзәк лаб-ясендә. 1943 тән Казан ун-тының анали - тик химия кафедрасында, каф. мөдире (1957–86), химия ф-ты деканы (1961–64), профессор-киңәшче (1986 дан). Хезмәтләре электроаналитик химиягә карый. Т. эремәләрдә комплекслар хасил булуны электрохимик алымнар (полярография, потенцио - метрия, вольтамперометрия, кулонометрия, осциллополярография) б-н тикшерә. Аның җитәкчелегендә югары коэрцитив эретмәләрне анализлауның амперометрик ысулы, биол. материалларда иодид һәм бромидның микромикъдарларын билгеләү ысулы эшләнә. Кинофотоматериаллардагы органик ку - шылмаларны өйрәнү һәм анализлау өчен по - лярография мөмкинлекләре карала, нефть промыселы суларында селтеле-җир метал - ларын аеру һәм билгеләү мәсь әләсе тикшере - лә. Органик пероксид реакцияләре өйрәнелә, кино-фото сәнәгатендә файдаланыла торган органик кушылмаларны билгеләү өчен ике фазалы титрлау алымы кулланышка кертелә. Азот катнашкан гетероциклик кушылмалар б-н көмеш ионнары комплексларын аларны химия-фотография җитештерүендә аналитик тикшерү сыйфатында куллану макса - тыннан чыгып бәяләнә. Терекөмештә водо - родны каталитик бүлеп чыгара торган комплекслар полярографиясенә, анализның ки - нетик ысулларына караган хезмәтләр авторы. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Исследование устойчивости комплексных соединений с аддендами, содержащими селен // Журн. неорган. химии. 1957. Т. 26, № 3 (автордаш); Комплексы никеля(II) и кобальта(II) циклическими и ациклическими производными дитиокислот фосфора. Взаимосвязь устойчивости и строения // Журн. общей химии. 1985. Т. 55, № 2 (автордаш); Новые индикаторные реакции с участием серосодержащих органических соединений при определении селена кинетическим методом // Журн. аналит. химии. 2001. Т. 56, № 5 (автордаш).

Әд.: А н и с и м о в а Л.А., Б у д н и к о в Г.К. Вера Фёдоровна Торопова. К., 2004.

ТОРСУ́ЕВ Николай Павлович (31.10.1932, Казан), географ, карст белгече, геогр. фән. д-ры (1988), проф. (1990), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2002). Казан пед. ин-тын тәмам - лаганнан соң (1954), Ленинград пед. ин-тында эшли. 1962 елдан Казан ун-тында, ланд - шафт экологиясе каф. мөдире (1989–99). Хезмәтләре Рус тигезлегенең төньяк өлешендәге тигезлек карсты географиясенә, атм. явым-төшемнәре һәм җир өсте суларының химик составын өйрәнүгә, әйләнә-тирә мохитне саклауга һәм табигатьтән файдалану мәсь - әләләренә карый. Т. Россиядә беренчеләр - дән булып РФнең төньяк Европа өлешендә карстны тикшерә, карстның яшь буенча гене - рацияләрен ачыклый. Антропоген эшчәнлек нәтиҗәсендә 20 йөзнең 2 нче яртысында атм. явым төшемнәренең сәбәпләрен һәм үзгәрү - чәнлеген күрсәтә. ТР Дәүләт бүләге Татарстан Респ-касының көньяк-көнчыгышында табигатьне саклау чараларын планлаштыру һәм тормышка ашыру максаты б-н геоинформация системаларын эшләгәне һәм гамәлгә керткәне өчен бирелә (2004). «Табигатьтән файдалану нигезләре» («Основы природопользования», 2008), «Табигый ресурслар белеме» («Ресурсоведение», 2008) дәреслекләре авторы. Халыкара пед. академиясе мөхбир әгъзасы (1997 дән); Казан ун-тының атказ. профессоры (2008 дән).

Х е з м.: Карст Онего-Северодвинского междуречья. К., 1964; Географические аспекты изучения равнинного карста. К., 1980 (автордаш); Пространственно-временная организация карстовых систем. К., 2007.

ТОРФ (нем. Torf), янучан файдалы казылма, сазлык шартларында җыелган һәм тулысынча таркалып бетмәгән үсемлек калдыкларын - нан барлыкка килә. Төсе сары-көрәннән кара-сорыга кадәр. Структурасы җепселсыман яки аморф халәтендә. Дымлылыгы 75–95 %. Күзәнәклелеге 70–80 % ка кадәр. Составында: минераль кушылмалар (балчык, кварц, гипс һ.б.) 18% ка, углерод — 60%, А битумы — 14%, гумин к-талар — 47%, лигнин

30% ка кадәр, pH 2–7, көллелеге 11–15%. Т. көрән күмерләрдән дымлылыгының юга - ры һәм үсемлек өлешләренең күбрәк булуы б-н аерыла. Югары (калкулыклы урыннарда), түбәнге (елга һәм болын үзәннәрендә) һәм күчмә типларга; урман, урман-баткаклык һәм баткаклык астипларына; агачлы, күрәнле, мүкле һ.б. төрләргә аерылалар. Татарстан терр-ясендә сазлыклана башлаганнан алып тулысынча калын келәм б-н капланган күл-сазлыклар киң таралган. Т. чыганаклары елга тугайларына һәм террасаларына туры килә. Түбәнге типтагы чыганаклар (ресурс - ларның 95%ы), агачлы-үләнле һәм үләнле төрләр өстенлек итә. Файдалы горизонтлар- ның калынлыгы 6,3 *м* га, озынлыгы 12 *км* га кадәр җитә. Т. составында югары концентра - цияле Mn (1%), Cu (0,05% ка кадәр) һ.б. микроэлементлар бар. Якынча 900 чыганак ачыкланган, шуларның 201 е эшкәртелә, 685 чы - ганактагы запаслар 62 млн. *т* тәшкил итә. 1989 елда якынча 50 чыганак (Т. чыгару 2 млн. *т* га җитә), 2009 да «Аккүл» (Тукай р-ны, 0,8 млн. *т*) чыганагы гына эшкәртелә. 10 ел эчендә 19 млн. *т* чыгарыла. ТРда Т., башлыча, эшкәртелмәгән килеш ашлама сый- фатында, туфрак мүлчәләү, теплица һәм пар- никлар өчен грунт һәм субстрат җитештерү- дә, торф-кәсле келәмнәр, хайван һәм кошлар астына түшәмә буларак, җиләк-җимеш һәм яшелчәләр саклауда файдаланыла.

Әд.: Агроминеральные ресурсы Татарстана и перспективы их использования. К., 2002; Минерально-сырьевая база Республики Татарстан. К., 2006; Государственный доклад о состоянии природных ресурсов и об охране окружающей среды Республики Татарстан в 2006 г. К., 2007.

ТО́РФЛЫ ТУФ, *торфның* известьле бер төре, карбонатлы җир асты сулары җир өстенә чыккан урыннарда барлыкка килә. Якын- ча 40 микроэлементны (Mn, Cu, Ni һ.б.) үз эченә ала. ТРда Т.т. чыганаклары Сөйки авы- лы һәм Идел елгасындагы Красный Ключ пристане янында (Кама Тамагы р-ны) табы- ла. Төзелештә туфракны известьләү өчен кулланыла.

ТО́РФЛЫ УЙСУ́ САЗЛЫ́К ТУФРАК- ЛА́Р, туфрак тибы, минераль әшкән грунт сулары, җыелып торган яки агымсулар тәэси- рендә формалаша. Профильнең өске өлеше торфлы (20–100 *см* һәм артыграк), асты глей- ланган гумуслы һәм минераллы горизонт- лардан тора. Торфның көллелеге 100% тан ар - тык, тирәлек реакциясе аз ачылыклы яки нейтраль. ТРда 2 астибы бар: торфлы глей (50 *см* дан кимрәк калынлыктагы торфлы-че - ремәле горизонт) һәм торфлы (50 *см* дан ар - тык) туфраклар. Гомуми мәйданы 19,1 мең *га*. Урманлы, сазлыклы җирләрне билиләр, пе - чәнен чабып алу, көтү йөртү өчен файдалану- лалар. Мелиорация үткәрелгән очракта, а.х. культураларын үстерергә яраклы.

ТОРЦК (Торьцк, Торцьск), Идел буе Болгар дәүләтендәге урта гасырлар шәһәре. Кама аръягының көнбатышында урнаша. Феодаль округ үзәге. Рус елъязмаларында рус гаскәр - ләренең Биләр шәһәренә яу б-н баруына бәй - ле искә алына (1183). Т. болгарларның сак - лану үзәге була; биредә Биләр янындагы рус чирүенең чигенү юлларын кисүче атлы гас- кәр торган.

Чыганак: Полное собрание русских лето- писей. М., 1962. Т. 1–2.

И.Л.Измайлов.

ТОРЫ́Ш авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 18 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Мөшеге елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 191 кеше (татарлар) яши. Халкы- ның төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 20 йөз башында нигез салына. 1913 елгы мәгълүматларга ка - раганда, Т.та мәчет һәм мәктәп була. Оешкан көненнән Уфа губернасының Минзәлә өязе Пучы волостенда, 1920 дән ТАССРның Мин- зәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1913 тә — 355, 1920 һәм 1926 да — 412 шәр, 1938 дә — 506, 1949 да — 446, 1958 дә — 428, 1970 тә — 437, 1979 да — 370, 1989 да — 260, 2002 дә — 215 кеше.

ТО́ЦКИЙ РАЙОНЫ́, *Оренбург өлкәсенең* көнбатыш өлешендә урнашкан. Хәзерге чик- ләре 1965 елдан бирле саклана. Мәйданы — 3113 *км*². Үзәге — Тоцкое авылы (Оренбург- тан 200 *км* көнбатыштарак). Халкы — 31802 кеше (1.1.2017). Татарлар саны: 1970 тә — 3489, 1979 да — 3015, 1989 да — 3230, 2002 дә — 3883, 2010 да — 2953 кеше. Татар - лар, тупланып, Мөлек, Әмирхан, Хөсәен (Са- иновка) (272 кеше, 2002), Сәйфетдин, Кызыл Мәчет (252 кеше, 2002), Кондызлытамак (9 кеше, 2002) авылларында яшиләр. Район терр-ясенә татарлар 18 йөздә килеп урнаша. 1787 дә Казан губернасыннан күченүчеләр Хөсәен авылына нигез сала. 1910 да монда мәдрәсә төзелә, 1918 дә татар башлангыч мәк- тәбе (1932 дән — бишьеллык, 2007 дән — ту - гызъеллык) эшли башлый. Кызыл Мәчет авылында 1933 кә кадәр — мәчет, 1957 гә ка - дәр татар мәктәбе эшли. Кондызлытамак мәк - тәбендә 1987 гә кадәр татар теле фән буларак укытыла. Кызыл Мәчет авылында «Туган тел» татар үзешчән коллективы эшли, авыл китапханәсендә татар китаплары фонды сак- лана, татар вакытлы матбугаты килә.

Әд.: Бирюков В., Богатов А. Тоцкая земля: люди и события. Оренбург, 2005.

Э.Г.Әлмәнова.

ТО́ША елгасы, Идел алдында, Зоя елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 17,3 *км*. Бассей - нының мәйданы 112,2 *км*². Идел буе калкулы- гыннан ага. Елга башы Тәтеш р-ны Келәш авылыннан 5 *км* төньяктарак, тамагы Буа р-ны Степановка авылы янында. Елга башы- ның абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 65 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 25%. Т.ның 0,3 тән 5,6 *км* га кадәр озынлыктагы 9 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлы- гы 0,29 *км/км*². Туенуы катнаш, күбрәк кар су- лары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1–3 *л/с·км*². Гидрологик режимы та - шу вакытында су муллыгы һәм җәен нык са - егуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 118 *мм*, ташу агымы катламы 100 *мм*. Язгы та - шу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы урта- ча күпьеллык чыгымы 0,07 *м*³/*с*. Суы язын ур- тача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен ка - ты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минераль әшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. Т. бассейнында суының гому- ми күләме 2,02 млн. *м*³ булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

ТӨБӘ́К авылы, Саба р-нында, шәһәр тибын- дагы Байлар Сабасы посёлогыннан 33 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Нысы елгасы буен- да. 2010 елда 290 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Башлан- гыч мәктәп, клуб. Мәчет. 1680 нән рус чыга- накларында Починок по речке Чичерме исе- ме б-н мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре кат - лавына керә, игенчелек, терлек асрау, өс-баш киемнәре тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башын- да мәчет, мәктәп, су тегермәне, 2 вак-тояклар кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең има- на җире 931,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Елыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 76 ир-ат; 1859 да — 420, 1897 дә — 773, 1938 дә — 755, 1949 да — 567, 1970 тә — 541, 1979 да — 472, 1989 да — 327, 2002 дә — 319 кеше.

ТӨБӘ́К ЧЕРКЕНЕ́ авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 13 *км* көньяк-көнбатыштарак, Казан–Ульянов авто- мобиль юлы буенда. 2010 елда 148 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1721 гә кадәр нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, тер- лекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.Ч.ндә Петропавел чиркәве, земство мәктә- бе (1886 да ачыла), 5 җил тегермәне, ярма яргыч, тимерче алачыгы, май язу йорты, 7 вак-тояклар кибете эшли. Бу чорда авыл җә- мәгатенең имана җире 1864 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өя - зе Зур Фролово волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа канто- нында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 73 ир-ат; 1859 да — 686, 1908 дә — 1474, 1920 дә — 1300, 1926 да — 1099, 1938 дә — 958, 1949 да — 658, 1958 дә — 529, 1970 тә — 310, 1979 да — 269, 1989 да — 164, 2002 дә — 128 кеше.

ТӨБӘ́К-ЧОКЫРЧА́ авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 3 *км* көньяк-көнчыгышта- рак урнашкан. 2010 елда 677 кеше (2002 ел- гы халык исәбе буенча, руслар — 50%, татар- лар — 49%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Урта мәктәп, клуб, китапханә. 1940 елларга кадәрге рәсми чыганакларда 2 торак пункт: Чокырча (1646 дан мәгълүм) һәм Төбәк (1664 тән мәгълүм) буларак исәп - ләнә. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, киез итек-киез җи -ештерү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында

Чокырчада Преподобный Герман чиркәве, земство мәктәбе, кредит ширкәте, 3 тимерче алачыгы, 3 бакалея кибете һәм Төбәктә 3 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгать-ләренең имана җирләре 2617,1 һәм 2126,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр бу торак пунктлар Казан губернасының Казан өязе Арча волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында, 2010 ның 16 маеннан Арча шәһәре составында. Халык саны (2 авыл халкын да кертеп): 1782 дә — 379 ир-ат; 1859 да — 1591, 1897 дә — 1787, 1908 дә — 1991, 1920 дә — 2055, 1926 да — 2911, 1938 дә — 2205, 1949 да — 1415, 1958 дә — 1442, 1970 тә — 1033, 1979 да — 890, 1989 да — 775, 2002 дә — 697 кеше.

ТӨБӘ́КАРА КЛИ́НИК ДИАГНО́СТИКА ҮЗӘГЕ́, ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагында; күппрофильле мед. үзәге. Казанда 1999 елда оештырыла; диагностика корпусы — 1999 да, терапия комплексы — 2004 тә, хирургия комплексы 2006 да сафка баса. ТР һәм Урта Идел төбәкләре халкына стационар һәм поликлиника хезмәте күрсәтә. Үзәкнең төп бурычлары — хезмәткә сәләтне югалту, үлем очраклары сәбәпләре структурасында күпчелекне тәшкил иткән һәм заманча мед. технология-ләре куллану таләп ителгән авыруларны



Төбәкара клиник диагностика үзәге. Казан.

ачыклау һәм дәвалау; фәнни-тикшеренү эшчәнлеге алып бару, тоташтыргыч тукыма авыруларын һәм атеросклероз барышын өйрәнү проектларын тормышка ашыру, ишемик һәм геморрагик зыян күрүләрдән соң әгъзалар һәм тукымалар функциясен тергезү; хирургиядә: минимизация һәм лапароскопия ысулларына өстенлек бирү, робот техникасы ысуллары кертү. Т.к.д.ү. йөрәк-кан тамырлары һәм неврологик авырулар, кан авырулары, репродукция мәсь әләләре буенча специальләшә. Т.к.д.ү. үзәк структурасына диагностика, неврология, нейрохирургия, кардиохирургия, кардиология, кискен инфаркт, реанимация һәм кан тамырлары, торакаль, гепатобилиар зоналар хирургиясе клиник бүлекләре керә. Аның җирлегендә телемедицина, консультация-диагностика, йөрәк-кан тамырлары авырулары респ-ка үзәкләре эшчәнлек алып бара; ул ш.у. Казан мед. ун-ты һәм Казан мед. академиясе өчен уку-укыту базасы булып тора. Консультация-диагностика бүлеге составында 5 бүлек эшли: функциональ диагностика (йөрәк, сулыш органнары h.б. әгъзаларның халәтен тикшерү; магнит резонанслы һәм компьютер томографы, гамма-камера, электрокардиограф, эхокардиограф, стресс-эхокардиограф h.б. бар); нур яр-дәмендә диагноз кую (күкрәк читлеге, корсак куышлыгы, кече оча сөяге әгъзаларының, умыртка баганасы, сөякләр, буыннарның халәтен тикшерү); нейродиагностика (нерв системасының барлык бүлекләре һәм баш миендәге кан тамырларының функциональ халәтен комплексы тикшерү), артерия һәм веналарга ультратавыш допплерографиясе, электроэнцефалография. Т.к.д.ү. дөньякүләм алдынгы операция һәм реабилитация җиһазлары б-н тәэмин ителгән (ясалма кан әйләнеше, гемодиализ, аутогемотрансфузия аппаратуралары, баш миенең тирәндәге структураларына үтеп операция ясау өчен стереотоксик системалар, ламинар һава стерилизаторлары h.б.). Үзәктә ел саен 150 мең пациент тикшеренү уза. Ятак-урыннар саны — 382 (терапия, неврология, кардиология бүлекләре); 450 хезмәткәр, ш.и. 16 мед. фән. д-ры, 58 мед. фән. канд. эшли. Стационарда ел саен 12 мең пациент дәвалана. Баш табиблар — Р.И.Туишев (1999–2004), Р.Н.Хәйруллин (2004 тән).

Р.Н.Хәйруллин, Р.Г.Исхакова.

ТӨБӘКЧЕЛЕ́К БЕЛЕМЕ́, билгеле бер терр-янең (төбәк, шәһәр, авыл) тарихын, мәдәниятен, этнографиясен, икътисадын һәм табигатен өйрәнүгә нигезләнгән белемнәр җыелмасы. Т.б. оештыру формалары буенча дәүләт (фәнни), җәмгать һәм мәктәп төркемнәренә бүленә. Тарих, геогр., әдәбият h.б. белем тармакларын эченә ала. Туган як, аның тарихы һәм күренекле кешеләре турындагы белемнәрне хезмәтнең музей формалары аша, гаммәви мәгълүмат чараларында h.б.да тарату Т.б.ндә мөһим юнәлеш булып тора. Россиядә төбәкчелек эшчәнлеге күптәннән алып барыла, ләкин «Т.б.» атамасы бары тик 20 йөзнең 1 нче утызъеллыгында гына киң кулланыла башлый; совет чорында, башлыча, төбәк җирле халык көче б-н өйрәнелә дип кабул ителә.

Иң элек геогр. һәм тарихи Т.б. формалаша башлый. Урта Идел буе җирләре беренче тапкыр урта гасырлар гарәп сәяхәтчеләре *Ибне Фазлан*, *Ибне Рустә* h.б. тарафыннан тасвирлана. 1135–36 елларда һәм 1150 дә Идел буе Болгар дәүләтендә булып киткән гарәп географы *әл-Гарнати* җирле казый *Якуб ибне Ногман* язган «Болгар тарихы»н укуын искә ала. Идел буе Болгарында, Алтын Урда-да, Казан ханлыгында гаять зур мәдрәсәләр һәм мәктәпләр челтәре була. Мөгаллимнәр һәм шәкертләр үз төбәкләренең тарихы б-н тирән кызыксыналар (мәктәп-мәдрәсәләрдә тупланган кулъязма китаплар китапханәләре һәм шул чорларның төбәк тарихы буенча күп кенә башка чыганаклары безнең көннәргә кадәр сакланмаган). Үз халкыңның үткәне турындагы белемнәрне теркәү юлы б-н таралган формаларыннан берсе — нәсел *шәҗәрәсе*. Татар халкы, Казан ханлыгы яулап алынганнан соң (1552), үткәндәге вакыйгаларны үзе иҗат иткән *бәетләр* һәм тарихи җырлар («Казан бәете», *Сөембикә* турындагы җырлар, «Болгар иле кызлары» h.б.), соңрак, 17 йөздән, тарихи һәм әдәби хезмәтләр (Кадыйргали бәкнең «Җами әт-тәварих», Шәрәфетдин бине Хисаметдиннең «Тәварихы Болгария»се) h.б. аша күзаллый. М.Г.Худяков язып үткәнчә, «Тәварихы Болгария» хезмәтендә «Казан ханлыгы авылларының атаклы мәктәпләре, мәшһүр мөгаллимнәре һәм имамнары, күренекле галимнәренең каберләре искә алынган озын исемлеге китерелгән».

16 йөздән башлап, Т.б.нең кыйммәтле мәгълүматларын туплауда «җир язулары» — җан башына төшкән салымны исәпләп чыгару өчен шәһәр һәм авыллар тасвирламалары җыелмасы, ш.у. Казан, Зоя, Лаеш шәһәрләренең писцовый кенәгәләре мөһим роль уйный.

Билгесез авторның уйдырма сюжетлары б-н бергә Казан ханлыгы һәм аның башкаласының халкы тормышы турында кызыклы күзәтүләрдән торган «Казан патшалыгы тарихы» (к. «*Казан елъязмасы*») — төбәк тарихына багышланган тәүге хезмәтләрнең берсе.

18 йөздән башлап Петербург ФА үткәргән *академия экспедицияләре* Т.б. үсешендә фәнни белемнәр буларак мөһим этап булып тора. 1768–74 тә алар тарафыннан Россия империясе төбәкләрен, шуларда яшәүче халыкларның хуҗалыгын, көнкүрешен, этнографиясен комплексы өйрәнү үткәрелә. Академиклар П.С.*Паллас* һәм Н.П.*Рычков* Бөгелмә-Бәләбәй һәм Югары Кама калкулыкларын, әлеге урыннардагы торак пунктларны, татар, башкорт, чуаш, мордваларның тормыш һәм гореф-гадәтләрен тасвирлыйлар. 1767 дә П.И.*Рычков* (Бөгелмә өязе Спас авылы алпавыты) тарафыннан С.-Петербургта «Борынгы һәм урта заманнарда Казан тарихы тәжрибәсе» («Опыт Казанской истории древних и средних времён») китабы нәшер ителә. Төбәк тарихы турында кыйммәтле мәгълүматлар ш.у. В.Н.Татищев хезмәтләрендә дә китерелә. Козьмодемьянск, Чабаксар һәм Казан шәһәрләренең тасвирламасы акад. И.Г.*Гмелин* тарафыннан төзелә.

1758 дә Казандагы Беренче ир балалар гимназиясенә нигез салынганнан соң, 1804 тә Казан ун-тында Казан төбәген эзлекле рәвештә фәнни өйрәнүләр башланып китә. Университет галимнәре, Болгар шәһәре харәбәләренә барып, борынгы истәлекләрдә археол. тикшеренүләр үткәрәләр, җирле газета-журналларда төбәк турында мәкаләләр бастыралар.

19 йөзнең 1 нче яртысында Казан төбәген иң актив өйрәнүчеләрнең берсе медицина д-ры К.Ф.*Фукс* була. 1815 тә ул «*Казан шәһәренең кыскача тарихы*» («*Краткая история города Казани*») хезмәтен, 1840 елларда «Казан губерна хәбәрләре» («Казанские губернские ведомости») г-тасында төбәк халыклары турында мәкаләләр сериясен, 1844 тә «Статистик һәм этнографик җәһәттә Казан татарлары» («Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях») китабын бастыра. Университет укытучылары А.И.*Артемьев*, Ф.Х.*Эрдман*, Д.А.*Корсаков* h.б. төбәктәге рус булмаган халыкларның үткәне һәм көнкүреше турында язып чыгалар.

«*Заволжский Муравей*» ж-лы (1832–34 тә басыла), аның нашире һәм мөхәррире, төбәк тарихы һәм истәлекле урыннары буенча күп кенә хезмәтләр авторы М.С.*Рыбушкин* Т.б.

үсешенә җитди өлеш кертәләр. И.А.*Износков* һәм С.М.*Шпилевский* зур тарихи-төбәкчелек хезмәтен башкаралар. Износков — Казан һәм Лаеш өязләрендәге торак пунктлар тарихы, Казан губернасындагы мәктәпләр эше үсеше буенча байтак мөһим мәкаләләр авторы. 1878 дә ул «Казан губернасында урнашкан шәһәрләр, курганнар, борынгы торак урыннар һәм аларда очраган табылдыклар турында язмалар»ны («Заметки о городах, курганах и древних жилищах, находящихся в Казанской губернии, и о встречающихся в них находках»), 1885–95 тә «Казан губернасындагы торак урыннарның кыскача тасвирламалы исемлеге»н («Список населённых мест Казанской губернии с кратким их описанием») бастыра. 1884 тә Шпилевскийның күләмле «Казан губернасындагы борынгы шәһәрләр һәм башка болгар-татар истәлекләре» («Древние города и другие булгаро-татарские памятники в Казанской губернии») хезмәте ике чыгарылышта нәшер ителә. Казан губернасы учреждениеләре, халыкның шөгыльләре турында кыйммәтле хәбәрләр, кайбер тарихи мәгълүматлар белешмә басмаларда — *Адрес-календарьларда*, Казан губернасының Истәлекле китапларында саклана (1840 тан 1920 гә кадәр басыла).

1870–80 елларда Т.б. эшенә земство хезмәткәрләре, укытучылар һәм табиблар кушыла. 1884 тә «1883 елда Казан губерна земствосы әзерләгән статистик экспедиция хезмәтләре» («Труды статистической экспедиции, снаряжённой в 1883 году Казанским губернским земством») нәшер ителә, аларда Казан губернасындагы Мамадыш, Лаеш, Тәтеш һәм Чистай өязләренең торак пунктлары турында тулы мәгълүматлар урын ала. Укытучы А.Боголюбов 1902 дә Ключище авылы тарихын бастырып чыгара.

19 йөзнең 2 нче яртысыннан башлап, Т.б. буенча тикшеренүләр б-н татар зыялылары актив шөгыльләнә башлый. Ш.*Мәр җәни* хезмәтләре Россиядә генә түгел, хәтта чит илләрдә дә танылу ала. 19 йөз ахырында Т.б. үсешендә Казан ун-ты каршындагы *Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте* һ.б. фәнни җәмгыятьләрнең эшчәнлеге гаять зур роль уйный. «Казан тарихыннан» («Из Казанской истории», 1906), «Казан һәм казанлылар» («Казань и казанцы», вып. 1–2, 1906–07) хезмәтләренең авторы Н.Я.*Агафонов* һәм «Казан буенча сәфәрдәш» («Служник по Казани», 1895) юлкүрсәткеч ярдәмлеген язган Н.П.*Загоскин* шул чорның күренекле төбәкне өйрәнүчеләре булалар.


19 йөз ахырында — 20 йөзнең башында Б.П.Денике, П.М.Дульский, К.В.Харлампович ның төбәк архит-расына һәм сәнгатенә багышланган хезмәтләре басылып чыга. Дульскийның «Иске Казан истәлекләре» («Памятники Казанской старины», 1914) китабы җәмәгатьчелектә Т.б.нә карата кызыксынуны шактый көчәйтә. П.П.Семёнов-Тян-Шанский редакциясендә «Россия нең тулы географик тасвирламасы»ның («Полное географическое описание России») Идел буе тарихы, мәдәнияте, икътисады һәм табигатенә багышланган 6 нчы томы дөнья күрүе Т.б. үсешендә зур вакыйга була. Т.б. буенча тупланган мәгълүматлар гимназияләр нең уку программасына кертелә. 19 йөз ахырында — 20 йөз башында «туган ил белеме» атамасы киң кулланыла башлый. 1910 да Г.И.Спасскийның «Туган ил белеме буенча очерклар. Казан губернасы» («Очерки по родиноведению. Казанская губерния», 1913 тә кабаттан басыла) хезмәте нәшер ителә, анда төбәк турында киң колачлы тарихи геогр. очерк тәкъдим ителә, өяз һәм шәһәрләрнең кыскача үзенчәлекле сыйфатлары, адм.-терр. бүленеше тасвирлана, күренекле эшлеклеләр, истәлекле урыннар турында мәгълүматлар бирелә.

19 йөздә — 20 йөз башында тарих фәне үсеше йогынтысында татар халык Т.б.нең формалашуы күзәтелә. Татар мәгърифәтчеленең иң талантлы вәкилләреннән берсе И.Хәлфин ватандашларында төбәктә яшәүчеләрнең үткәннәрен яктыртучы тарихи истәлекләрне җыюга һәм саклауга кызыксыну уятырга омтыла. «Әхвале Чыңгызхан вә Аксак Тимер» хрестоматиясенең (1819) кереш өлешендә ул: «Әлеге өзекләрне бастырганда... мин аларны югалтудан һәм күчереп язганда тәмам бозып күрсәтүдән саклаудан бигрәк, шушы юл б-н үзебезнең галимнәребез-диндәшләребезнең игътибарын моңа кадәр татар милләте тарихындагы алар тарафыннан бөтенләй сакланмаган истәлекле вакыйгалар эзләп табуга һәм танып белүгә юнәлтүне күз алдында тоттым», — дип яза. Беренче хезмәтләр, башлыча, теге яки бу җирлекнең үсешенә бәйле шәҗәрәләр, мәдрәсәләр һәм мөселман мәхәлләләре тарихын, аерым шәхесләрнең биографияләрен төзегән, халык телендә сакланган риваятьләрне язып калдырган һәвәскәр тарихчыларга карый. «Ильяс мулла атасыннан ишеткәне» дигән әсәр — шуларның берсе, аны В.В.Радлов «Төрки кабиләләрнең халык әдәбияты үрнәкләре» («Образцы народной литературы тюркских племён», ч. 4, СПб., 1872) хезмәтенә дә кертә. Радлов ш.у. күп кенә башка төбәкчелек хезмәтләрен бастырып чыгара. Алга таба күп кенә хезмәтләрдә авыллар һәм җирлекләр тарихын төзегәндә шәҗәрәләр төп чыганак булып тора. Ш.Мәр җәни үзенең хезмәтләрендә ш.у. тупланган бик күп төбәкчелек мәгълүматларыннан, Тенеки авылыннан Габделкәрим улы Зәйнетдин, Олы Кавалдан Дусмөхәммәт улы Сәлим җән һ.б. хезмәтләреннән (безнең көннәргә кадәр килеп җитмәгән) файдалана. Татар галиме К.Насыйри беренчеләрдән булып Казан губернасындагы 20 авылның тарихы буенча фәнни-төбәкчелек әсәрен яза (1926 да басылып чыга). Аның шәкерте Габдрахман Күки шул ук өязләге Мулла иле авылының бай тарихын төзи. Риза *Фәхретдин* «Шура» ж-лында туган як тарихын тасвирларга өнди. Аның архивында шул чорның Т.б. өлкәсендәге иң әһәмиятле









1. М.Р ы б у ш к и н. Казан шәһәренең кыскача тарихы. Титул бите. Казан. 1834; 2. А.Ф у к с. Казан шәһәренең нигезләнүе. Татар риваятьләреннән алынган шигъри хикәйәт. Титул бите. Казан. 1836; 3. Н.Б а ж е н о в. Казан тарихы. Тышлык. Казан. 1847; 4. Н.Баженов. Казан тарихы. Титул бите. Казан. 1847.

хезмәтләрнең берсе — М.Шәмсетдиновның «Түнтәр авылы тарихы» сакланган. 19 йөздә шигъри калыпта иҗат ителгән тарихи әсәрләр, ш.и. 1823 тә Каргалы авылында чыккан янгын тасвирланган «Тарихи рисалә» (авторы билгесез), 1778–79 еллардагы крәстиннәр хәрәкәте вакыйгалары теркәлгән «Романовтан бабайлар ниләр күргән?» (авторы — Олы Мәңгәр авылыннан Мәймүнә Шаһиәхмәтова) киң тарала. Татар телендә төбәк тарихы турында беренче тапкыр басылган хезмәт — М.М.*Тукаевның* «Эстәрлебаш тарихы». Аерым торак пунктлар турындагы әсәрләр арасыннан Ә.Бәрәңгәвинең «Бәрәңге тарихы», М.Сүнчәләйнең «Иске Кышкы тарих»ы (Оренбург, 1911), М.Түнтәринең «Түнтәр авылы тарихы»; И.Динмөхәммәтовның «Әмин авылы тарихы» аеруча кызыксыну уята. Үз хезмәтләрен язганда төбәк белгечләре эпиграфик чыганаклардан, акт документларыннан, кулъязмалардан, халык авыз иҗаты әсәрләреннән файдаланганнар. Туган як тарихы турында язу традициясен хәзерге заман татар төбәкчеләре дә уңышлы дәвам итәләр. А.Ганиевнең «Ык, Шушма, Чирмешән, Сок һәм Кинел елгалары буенда яшәүче халыкларның тарихы турында очерклар» (1967–70 тә язылган), Н.Садыйковның «Янбай авылы тарихы» (1968–69) һ.б. моңа ачык мисал булып тора.

Окт. рев-циясеннән соңгы беренче унъеллыкта Т.б. көчле күтәрелеш кичерә. 1921 нең декабрендә Мәскәүдә РСФСР Халык мәгарифе комис-тының Академүзәге чакырган җирле төбәкләрне өйрәнүче фәнни җәмгыятьләрнең 1 нче конференциясе була. Анда төбәкчелек җәмгыятьләренең типлаштырылган Уставы кабул ителә, Т.б. бюросы сайлана, Т.б.н ун-тларда һәм пед. ин-тларда укыту зарурлыгы турында мәсьәлә куела; ш.у. Т.б.н оештыру буенча бердәм җитәкчелек үзәге төзү теләге әйтелә. 1922 нең гыйнварында Россия ФА карары б-н Т.б. Үзәк бюросы оештырыла. Аның составына — ТАССРдан профессорлар М.Э.*Нөшнский* һәм К.В.Харлампович, 1924 тә Н.И.*Воробьёв* кертелә. 1920 еллар уртасында респ-када 20 дән артык төбәкне өйрәнү җәмгыяте эшли. Аларның эшчәнлеген координацияләүдә *Академик үзәк, Татар халкын өйрәнү гыйлеме фәнни җәмгыяте, Татарстан төбәкләрен өйрәнү бюросы* мөһим роль уйный. Төбәкчелек хәрәкәте б-н Н.И.Воробьёв, Г.Г.*Ибраһимов*, М.Кор бангалиев, В.М.*Смолин*, Н.Н.*Фирсов*, М.Г.*Худяков*, Е.И.*Чернышёв* һ.б. җитәкчелек итә. 1925 нең май–июнендә 1 нче респ-ка төбәкчелек конференциясе үткәрелә. Төбәкчелек ячейкалары һәм бюролары ш.у. Зоя, Тәтеш, Чистай һ.б. шәһәрләрдә эшли. 1927 нең февраленда ТАССР Халык мәгарифе комис-ты коллегиясе «Татар Халык мәгарифе комиссариаты Академүзәге каршындагы төбәкчелек бюросының кантоннардагы һәм волостьлардагы төбәкчелек ячейкалары һәм бюролары турындагы төп кагыйдәләр»не раслый. Төбәкчеләр алдына архит-ра истәлекләрен һәм тарихи ядкәрләрне ачыклау һәм саклау, авыллар һәм шәһәрләр тарихын өйрәнү бурычы куела. Төбәкне өйрәнүчеләр еш кына район музейлары тирәсендә берләшәләр яки аларның оештырылуына ярдәм итәләр. 1920 дә укытучы Н.К.Енгурин башлангычында Тәтеш музее төзелә (1927–30 да музей тарафыннан «Тәтеш музее язмалары» («Записки Тетюшского музея») ж-лы чыгарыла; Чистай музее 1921 дә, ш.у. төбәк белгечләренең актив катнашуы нәтиҗәсендә барлыкка килә, аның оештырылуында а.х. техникумы укытучысы А.К.Буличның роле зур. Төбәкне өйрәнүчеләр Алабуга (1920), Зоя (1921) һ.б. шәһәрләрдә музейлар оештыралар. 1928 дә, ТАССР ХКС карарына туры китереп, респ-када Т.б. бюросы урынына төбәкчелек хәрәкәте үзәге буларак *Татарстанны өйрәнү җәмгыяте* төзелә. Җәмгыять эшчәнлеге б-н төрле секцияләрдән торган Үзәк совет җитәкчелек итә. Төбәк тарихын өйрәнү мәдәният һәм көнкүреш секциясе колачлаган мәсьәләләр эченә кертелә. Җәмгыять әгъзалары Т.б. буенча библиография эшләрен алып баралар, күргәзмәләр оештыруда катнашалар. Җәмгыять төбәкне өйрәнү эшенә ш.у. укучы яшьләрне җәлеп итүгә зур әһәмият бирә. Җәмгыять составында Н.С.*Надиев* һәм Н.Ф.*Калинин* җитәкчелегендә студентлар бюросы һәм мәктәпләр Т.б. секциясе оештырыла. Мәктәп секциясе алдына укытучыга ярдәмгә материаллар җыю, методик хатлар, кулланмалар бастыру, мәктәпләрдә төбәкне өйрәнү музейлары яки кабинетлары, төбәкне өйрәнү түгәрәкләре оештыру, төбәкчелек эшчәнлегенә халык мәгарифе хезмәткәрләрен җәлеп итү бурычы куела. Секция ш.у. респ-када мәктәпләрдәге төбәкне өйрәнү түгәрәкләрен һәм оешмаларын барлау эшен алып бара. Акад. үзәкләр бетерелгәннән һәм РСФСР Халык мәгарифе комис-ты структуралары үзгәртеп корылганнан соң, төбәкне өйрәнү функцияләре баш музейларга тапшырыла. ТАССРда алар ТАССРның Үзәк музеена (хәзер ТР Милли музее) йөкләнә. 1930 елларда төбәкчелек хәрәкәте сүрелә башлый. Тарихи чынбарлыктан аерылмаган революцион хәрәкәт б-н тыгыз бәйләнгән конкрет вакыйгаларны өйрәнү зарурлыгы турындагы фикер өстенлек итә. 1928 нең мартында 1 нче Бөтенсоюз марксистик-ленинчыл фәнни-тикшеренү учреждениеләре конференциясендә төбәкчеләрнең игътибарын хәзерге заман тарихы проблемаларына юнәлтү теләге әйтелә. 1930 нның февраленда Коммунистик академия Президиумы П.Г.Смидович җитәкчелегендәге төбәкчеләр секциясе бюросын раслый. Шул ук елдан «Советское краеведение» ж-лы чыга башлый. 1931 дә Коммунистик академиянең төбәкчеләр секциясе җирлегендә Төбәкче-марксистлар җәмгыяте оештырыла. 4 нче Бөтенроссия төбәкчеләр конференциясендә төбәкче оешмалар челтәрен үзгәртеп кору турында карар кабул ителә. РСФСР ХКСның 1937 дә кабул ителгән «Төбәкчелек эшләрен үзәктә һәм урыннарда үзгәртеп кору турында» карарында «төбәкчеләрнең Үзәк һәм җирле бюроларының алга таба яшәүләре максатка яраксыз» дип табыла һәм Халык мәгарифе комис-тына әлеге оешмаларны ябарга күрсәтмә бирелә. Шуның б-н бәйле барлык өлкә җәмгыятьләре ябыла; Татарстанны өйрәнү җәмгыяте, Археол., тарих һәм этнография җәмгыяте эшчәнлеге туктатыла. Күп кенә танылган төбәкчеләр репрессияләнә. Алмашка заводларда, фабрикаларда, колхозларда, учреждениеләрдә, мәктәпләрдә төбәкчелек ячейкалары челтәре оештырыла; алар б-н район һәм респ-ка бюролары җитәкчелек итә. Ул елларда Т.б. алдына аны *культура революциясе* коралына әйләндерү бурычы куела. Төбәкчелек эше б-н җитәкчелек итү Халык мәгарифе комис-тына тапшырыла. Бу, башлыча, мәктәп Т.б.нең алга таба үсешенә шартлар тудыра.

Бөек Ватан сугышыннан соң Т.б.н җанландырырга тырышу күзәтелә. 1946 нең октябрендә, ТАССР МС карарына туры китереп, ТАССР Дәүләт музее каршында Татарстанның Т.б. җәмгыяте төзелә. 1946–47 дә респ-каның 10 районында җәмгыятьнең филиаллары ачыла һәм мөхбир әгъзалар челтәре оештырыла. 1947 нең октябрендә Окт. рев-циясенең 30-еллыгына багышланган фәнни-төбәкчелек конференциясе үткәрелә; ш.у. конференцияләр Бөгелмә һәм Чистай шәһәрләрендә уздырыла. Җәмгыять эшендә В.И.Баранов, Н.И.Воробьёв, В.М.*Горохов*, Г.Х.*Гыймади*, комп. Н.Г.*Жи һанов* һ.б. катнаша. Бер үк вакытта Т.б.н мәктәп укучылары арасында популярлаштыруга йөз тоткан яшь төбәкчеләрнең «Идел» («Волга») җәмгыяте төзелә. КПССның 20 нче съездыннан соң (1956) җәмәгатьчелекнең Т.б.нә карата кызыксынуы арта. Илдә төрле төбәкчелек оешмалары һәм берләшмәләре: төбәкчеләр, «кызыл эзтабарлар» клублары, рев-ция, Гражданнар һәм Бөек Ватан сугышлары ветераннары секцияләре төзелә башлый; мәс., укытучы С.Х.Әхмәтшин башлангычы б-н *Елхово авылы тарихы музее* ачыла. 1966 да төп бурычы барлык төр ядкәрләрне өйрәнү, саклау һәм пропагандалауда дәүләткә ярдәм күрсәтүдән гыйбарәт булган Бөтенроссия тарихи һәм мәдәни ядкәрләрне саклау җәмгыяте оештырыла. Җәмгыятьнең ф-лы ТАССРда да эшли. Бу елларда Т.б. проблемаларын Казан пед. ин-ты укытучылары Е.Г.*Бушканец*, К.Р.Синицына һ.б., КДУның Фәнни китапханә хезмәткәрләре В.В.*Аристов*, Н.В.Ермолаева актив һәм тирәнтен өйрәнәләр. 1986 да Чаллы, Алабуга, Менделеев, Түбән Кама шәһәрләре төбәкчеләре төркеме башлангычы б-н Чаллы шәһәре һәм Түбән Кама буе тарихы, географиясе, икътисады, мәдәнияте буенча күпсанлы мәкаләләр авторы А.Г.Дубровский җитәкчелегендәге «Түбән Кама» төбәкчелек җәмгыяте оештырыла. КамАЗ, күрсәтелгән шәһәрләр һ.б. тарихы буенча китаплар, брошюралар һ.б. язмалар сериясе: Чаллы тарихы буенча В.В.Николаевның «Башлангыч чорга мөрәҗәгать» («Обращение к истокам»), А.Г.Дубровский һәм Б.А.Канеевның «КамАЗ эпохасы» («Эпоха КамАЗа») (Чаллы, 2005) һ.б. хезмәтләр басылып чыга. Даими рәвештә фәнни-гамәли конференцияләр үткәрелә, аларның материаллары басыла (мәс., «Төбәкчеләр таләп ителә...», Чаллы, 2004). Җәмгыять Т.б. буенча ел саен уздырыла торган мәктәп укытучылары олимпиадаларын үткәрүдә катнаша. Хәзерге төбәкче-

лек тикшеренүләрендә тарихи һәм мәдәни ядкәрләрне, торак пунктларны, туган як тарихын өйрәнү һәм саклау мөһим урын алып тора. Энтузиаст-укытучы В.С.Малахов озак еллар Зәй төбәге тарихын өйрәнү б-н шөгыльләнә; 1994 тә «Зәй энциклопедиясе»н бастырып чыгара. Алабуга пед. ин-ты укытучысы В.А.Ендиряков Казан губернасының Чистай өязе Егорка волосте тарихын (XVII йөз уртасыннан алып, 1930 елга кадәр) өйрәнә һәм 1994 тә шул исемдәге кулланма әсбап бастырып чыгара. Педагог, халык сәнгате һәм фольклор әсәрләрен туплаучы М.Г.*Газыймов* Яңа Чишмә р-нының Зирекле авылында халык иҗаты һәм көнкүреше музеена нигез сала (1992). ТРның күп кенә район җитәкчеләре башлангычы б-н, үз р-ннарының тарихын язу өчен, җирле төбәкчеләрдән, фән-ни-тикшеренү ин-тлары һәм югары уку йортларыннан чакырылган белгечләрдән иҗат төркемнәре оештырыла. «Арча төбәге тарихы = История Арского края» (1996), «Лаеш төбәге тарихы» («История Лаишевского края», 1997), «Әлмәт төбәге тарихыннан» («Из истории Альметьевского региона», 1999), «Татарстан Республикасының Биектау районы тарихы турында очерклар» («Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан», 1999), «Азнакай тамчылары» (2000), «Алексеев районы: тарих һәм хәзерге заман» («Алексеевский район: история и современность», 2000), «Саба районы. Рәхим итегез! Сабинский район. Добро пожаловать!», «Саба районы — 70 ел», «Сарман районы энциклопедиясе» (2000), «Әгерҗе районы торак пунктлары тарихы» («История населённых пунктов Агрызского района», 2003), «Идел буенда бер шәһәр бар... (Татарстанның Тәтеш шәһәре һәм Тәтеш районының үткәне һәм хәзергесеннән)» («Есть на Волге городок... (Из прошлого и настоящего города Тетюши и Тетюшского района Татарстана), 2004), «Без — иделләләр! Татарстан Республикасының Яшел Үзән шәһәре һәм Яшел Үзән районының үткәне һәм хәзерге-сеннән» («Мы — волжане! Из прошлого и настоящего города Зеленодольска и Зеленодольского района Республики Татарстан», 2005), «Балтач энциклопедиясе» (2006), «Чаллы шәһәре энциклопедиясе» («Энциклопедия города Набережные Челны», 2007), «Апас тарихи-төбәкчелек энциклопедиясе» («Апастовская историко-краеведческая энциклопедия», 1–3 т., 2013), «Болгар шәһәре һәм Спас районы энциклопедиясе» («Энциклопедия города Булгар и Спасского района», 2014; 2 нче басма, 2016), «Актанышым — ак илем» (2010) һ.б. хезмәтләр басыла. Аерым торак пунктлар тарихы буенча байтак хезмәтләр языла. К.Ш.Сиражетдиновның «Яңа Болгар авылы тарихы» (2001), К.С.Миңнебаев һәм З.З.Алимовның Чүпрәле р-ны Кече Чынлы авылы тарихына багышланган «Чынлы чишмәләре» (2002), төбәк тарихчысы Й.Й.Йосыпов Актаныш, Минзәлә һәм Тукай р-ннары торак пунктлары тарихы буенча күп кенә хезмәтләр бастырып чыгара: «Бикбау авылы (авыл тарихына бер караш)» (2001), «Дәвегем — дәү илем» (2002), «Колморза — морзалар ягы» (2003); Ж.Г.*Рәхимовның* Лениногрск р-ны торак пунктлары турында «Шугур — край сокровищ — Шөгер төбәге — хәзинәләр чишмәсе» (1997), В.А.Архиповның Яшел Үзән р-нының Осиново авылы тарихы буенча «Осиново сәхифәләре» (2002), Н.С.Фроловның «Чирмешән Кирмәне авылы (XVII–XIX гасырлар). Тарихи очерклар» («Село Черемшанская Крепость (XVII–XIX века). Исторические очерки», 2002), Б.Ш.*Зыятдиновның* — «Мәгърифәтле Таузар иле» (2004), «Рәхмәт сиңа, Хәсәншәех!» (2006), «Себер юлы буйлап: Карадуган, Арбаш авыллары тарихыннан» (2010), И.Х.*Хәлиуллинның* «Яңа Тинчәле таңы» (2006), «Килдураз: заман һәм кеше» (2018), И.Ә.Кыямовның «Кара Чишмә карьясе» (2017) хезмәтләре дөнья күрә. Түбән Камадан укытучы Г.Ш.Вәлиев Тукай р-ны Күзкәй авылы һәм мәктәбе тарихы буенча берничә китап: «Авылым адымнары» (Түбән Кама, 1996), «Яшьлегем сәхифәләре» (Түбән Кама, 1998), «Күзкәй мәктәбе (1946–2000 еллар)» (Түбән Кама, 2004) һ.б. әсәрләр бастыра. Казандагы ТРның Милли музее, А.М.Горький әдәби-мемориаль музее, Е.А.Боратынский әдәби музее, респ-ка шәһәрләре һәм авылларында төзелгән төбәкчелек музейлары зур эш алып баралар. Алар төбәкчелек укулары, «түгәрәк өстәлләр», күргәзмәләр үткәрәләр, фәнни-методик әсбаплар, төбәкчелек материаллары җыентыклары, «Татарстан Республикасының Милли музее». Еллык басма («Национальный музей Республики Татарстан». Ежегодник, 1995 тән), «Менделеев музее хәбәре» («Менделеевский музейный вестник») (Менделеев шәһәренең төбәкчелек музее, 2000 нән) ж-лларын, һ.б.ны бастыралар. Респ-када төбәкчелек үсешенә Казанның һәм Алабуга шәһәренә нигез салынуның мең еллыгын бәйрәм итүгә әзерләнү этәргеч бирә. Казанда төбәкчелек эше б-н Р.Х.Бикбулатов, Л.И.Девятых, Б.Г.Ерунов, Л.М.Жаржевский һ.б. нәтиҗәле шөгыльләнәләр. Соңгы унъеллыкта ш.у. фәнни Т.б. киң үсеш ала. 1989 да ТАССР Мәдәният министрлыгы һәм Тел, әдәбият һәм тарих ин-ты б-н төзелгән «Ядкәрләр җыенты-гы» бүлеге галимнәре коллективы б-н Татарстан тарихы һәм мәдәнияте ядкәрләрен ачыклау һәм өйрәнү буенча зур тикшеренү эшләре үткәрелә, «Татарстан Республикасы: тарих һәм мәдәният ядкәрләре. Каталог-белешмә» («Республика Татарстан: памятники истории и культуры. Каталог — справочник», 1993), «Татарстан республикасы: Татар халкының тарихы һәм мәдәнияте ядкәрләре (XVIII йөз ахыры — XX йөз башы)» («Республика Татарстан: Памятники истории и культуры татарского народа (конец XVIII – начало XX веков)», 1995), «Татарстан Республикасы: Православие ядкәрләре (XVI йөз уртасы — XX йөз башы)» («Республика Татарстан: Православные памятники (середина XVI — начало XX веков)», 1998), «Татарстан Республикасының тарихы һәм мәдәнияте ядкәрләре җыентыгы, 1 том. Административ районнар» («Свод памятников истории и культуры Республики Татарстан, Т.1. Административные районы»), 1999) китаплары һ.б. басылып чыга. Татарстанның көньяк-көнчыгыш р-ннары тарихы буенча тикшеренү эшләренең шактый зур күләмен «Әлмәт-нефть» НГДУы каршында төзелгән «Әлмәт энциклопедиясе» галимнәре коллективы башкара (1995–2006). «Әлмәт төбәге тарихыннан» («Из истории Альметьевского региона») махсус сериясе, «Әлмәт-Альметьевск» хезмәте (2003) һ.б. алар тарафыннан нәшер ителә. ТР ФАнең Татар энциклопедиясе ин-ты авторлары коллективы 1997 дә геогр. халәт, адм. урнашу, барлыкка килү вакыты, халык исәбе һәм милли состав, мәдәният учреждениеләре һ.б. турында белешмәләр бирелгән «Татарстан Республикасының торак пунктлары» (Населённые пункты Республики Татарстан») китабын бастыра; ш.у. Р.В.*Шәйдуллин*, Б.И.Сибгатов, Л.М.Сахавованың «Татарстан Республикасының юкка чыккан авыллары» («Исчезнувшие населенные пункты Республики Татарстан», 2016) китабы нәшер ителә. Хәзерге заман шартларында, халыкның милли үзаңын формалаштыруда мөһим фактор буларак, Т.б.нең өлеше даими рәвештә арта, мәктәп программасына кертелә, бик күп урта махсус һәм югары уку йортларында укытыла (Казан федераль ун-ты, Казан мәдәният ин-ты һ.б.). Ш.у.к. «*Кар десанты*».

Әд.: Синицына К.Р. Историческое краеведение. К., 1983; Милонов Н.А. Литературное краеведение. М., 1985; Филимонов С.Б. Краеведение и документальные памятники (1917–1929 гг.). М., 1989; Шайхиев Р.А. Татарская народно-краеведческая литература XIX — XX вв. К., 1990; Шмидт С.О. Краеведение и документальные памятники. Тверь, 1992; Галлямов Р.Ф. История села Параньга Ахмеда Бараньгави как оригинальный образец татарской народно-краеведческой литературы нач. XX в. // Источники и проблемы источниковедения истории Марий Эл: Сб. статей. Йошкар-Ола, 1997; История Казанского университета. К., 2004; Сабирзянов Г.С. Историческое краеведение и региональная энциклопедистика в Татарстане // Краеведение в России: История. Современное состояние. Перспективы развития: Сб. статей. М., 2004.

Г.С.Сабиржанов, А.В.Гарзавина, Л.М.Айнетдинова.

ТӨГӘ́Л КУЕ́ЛМАГАН МӘСЬӘЛӘЛӘ́Р, математик физика мәсьәләләре, аларда француз математигы Ж.Адамар керткән шартларның (мәсьәләнең чишелеше булу, чишелешнең бер мәгънәле булуы, башлангыч бирелгәннәрнең аз үзгәрешлеләрендә мәсьәләнең тотрыклы булуы) берсе генә булса да үтәлми. Адамар нинди дә булса физик яки техник мәсьәлә төгәл куелган булырга тиеш дип исәпли, чөнки башта бирелгәннәрнең иң кечкенә үзгәрешләренә чишелешнең зур үзгәрешләре туры килә, бу чишелешнең физик аңлатмасын күз алдына китереп булмый, ди ул. Әлеге фикер төгәл куелмаган мәсьәләләрне өйрәнү кирәклеген шик астына куя (мисалларны Адамар үзе китерә). Соңрак шактый киң таралган матем. мәсьәләләрнең аерым бер үлчәнешләрдә (метрикаларда) тотрыксыз булуы ачыкланган, болар — 1 нче төр интеграль тигезләмәләрне чишү; якынча билгеле булган функцияләрне дифференцияләү; коэффициентлары якынча билгеле булган

Фурье рәтләрен санча кушу; система билгеләгечә нульгә якын булганда, алгебраик сызыкча тигезләмәләр системаларын чишү; Лаплас тигезләмәсе өчен Коши мәсьәләсе; функцияләрне аналитик дәвам итү; гравиметриянең кире мәсь әләлфе; функционал ларны минимальләштерү; сызыкча программалаштыру һәм идарә итүне оптимальләштерү, ш.у. оптималь проектлаштыру (антенналар һ.б. физик системалар синтезы) буенча кайбер мәсьәләләр; дифференциаль тигезләмәләр ярдәмендә сурәтләнә торган объектлар б-н идарә итү. Алда санап үтелгән мәсь әләләр төрле физик һәм техник проблемаларны, ш.и. физика, техника һ.б. фән тармакларында кире мәсьәләләр дип йөртелә торганнарның киң классын сурәтләү барышында туа. Т.к.м. теориясендә хәлиткеч рольне акад. А.Н.Тихоновның Казанда шартлы-төгәл мәсь әләләр теориясе буенча башкарган хезмәте (1943) уйный. 1970 еллар уртасыннан Казан математиклары аналитик функцияләр теориясендә кайтма кырый мәсьәләләр (ККМ) куелышының төгәллеген тикшерәләр (Л.А.*Аксентьев*, Л.Н.Журбенко, Ф.Г.*Әхәдиев*, А.М.*Елизаров*), аэрогидродинамика ККМнә карата квазичишелешләр алымын эшлиләр (А.М.Елизаров, Н.Б.*Ильинский*, А.В.*Поташёв*), параболитик типтагы тигезләмәләр өчен коэффициентлы кире мәсь әләләрне тикшерәләр (П.Г.*Данилаев*), төгәл куел маган вариатив тигезсезлекләр чишүнең төрле кушылма алымнарын, ш.и. модификацияләнгән Лагранж функциясе алымнарын һәм интеграль функция буйлап төшү алымнарын тәкъдим итәләр (И.В.Коннов). Байес теоремасы нигезендә нәстационар сигналларның төрле бәяләмәләрен табарга мөмкинлек бирүче статистик көйләнеш алгоритмнары эшләнә; күп үлчәнешле мәсь әләләр өчен кайтма мәсь әләне статистик көйләнеш алымы нигезендә чишүнең икътисади алгоритмы гамәлгә кертелә (И.Д.Грачёв, М.Х.*Сәлахов*, И.С.Фишман). Эксперименталь үзенчәлекле мәгълүматны эшкәртүче (кайбер мәгълүматның төшеп калуы, фракталь тавыш, синрегулярлык, нәстационарлык, вакланма дәрәҗәле тренд һ.б.) төгәл куелмаган кайтма мәсьәләләр чишү алымнарының кимчелекләре тикшерелә һәм аларны төзәтү юллары тәкъдим ителә (М.Х.Сәлахов, С.С.Харинцев). Хисаплаулардагы тотрыксызлыкны төзәтү өчен вейвлет рәвешүзгәртүләр куллану идеяләре үстерелә, аерым алганда, нәсызыкча динамик системаларда, катлаулы сигналлар редукциясендә, томографиядәге тиз үтүчән процесслар очрагында адаптив вейвлетлар базисын куллану тәкъдим ителә. Көйләнешле нейрочелтәр модельләре системаның тышкы тәэсиргә җавабын модельләштерүдә, эчке халәтләрне классификацияләүдә, үзгәрешләр динамикасын фаразлауда һәм система б-н адаптив идарә итүдә куллану мөмкинлеге күрсәтелә (С.С.Харинцев, А.А.Севастьянов, М.Х.Сәлахов). Көйләнеш алымнары ш.у. металлларны үлчәмнәре буенча электрохимик эшкәртү мәсь әләләренә карата кулланыла (А.Х.Кәримов, В.В.Клоков, Е.И.Филатов).

Әд.: Тихонов А.Н., Арсенин В.Я. Методы решения некорректных задач. М., 1979; Грачёв И.Д., Салахов М.Х., Фишман И.С. Статистическая регуляризация при обработке эксперимента к прикладной спектроскопии. К., 1986; Каримов А.Х., Клоков В.В., Филатов Е.И. Методы расчёта электрохимического формообразования. К., 1990; Елизаров А.М., Ильинский Н.Б., Поташёв А.В. Обратные краевые задачи аэрогидродинамики: Теория и методы проектирования и оптимизации формы крыловых профилей. М., 1994; Салахов М.Х., Харинцев С.С. Математическая обработка и интерпретация спектроскопической информации. К., 2001.

А.М.Елизаров.

ТӨГӘЛБА́Й Галәветдин (19 йөзнең 1 нче яртысы), шагыйрь. «Мәгъшукнамә» (1880) җыентыгына кергән лирик шигырьләр авторы. Китап татар яшьләре арасында зур популярлык казана.

Әд.: Татар әдәбияты тарихы. К., 1985. 2 т.

ТӨГИ́ авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 30 *км* көньяк-көнбатыштарак, Батрас елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 261 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 62%, руслар — 32%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, иткә терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-цияга кадәрге чыганакларда Иске Батрас, Тюкай исемнәре б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, арба һәм мичкә ясау, олаучылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү-приход мәктәбе, тегермән, ашлык саклау-сату һәм 2 бакалея кибете эшли; 1912 дә земство мәктәбе ачыла. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1147 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр авыл Уфа губернасының Минзәлә өязе Троицк-Йосып волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1944 нең 19 февраленнән — Ямаш, 1956 ның 7 декабреннән — Акташ, 1959 ның 26 мартыннан — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1859 да — 301, 1897 дә — 594, 1913 тә — 789, 1920 дә — 810, 1926 да — 713, 1938 дә — 586, 1949 да — 482, 1958 дә — 449, 1970 тә — 461, 1979 да — 382, 1989 да — 253, 2002 дә — 248 кеше.

Әд.: Заинская энциклопедия. К., 1994.

ТӨЕРТАМЫ́Р, күке яше, сәхләб (Orchis), сәхләбчәләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 100 гә якын төре билгеле. Татарстан терр-ясендә 2 төре: башлыксыман Т. (O. militaris) һәм көйгән Т. (O. ustulata) бар. 10–50 *см* биеклектәге үсемлек. Тамыры, гадәттә, йомыркасыман 2 бүлбеле. Сабагы туры, яфраклы. Яфраклары күбесенчә тамыр яны таралгысында, йомыркасыман яки ланцетсыман. Чәчәкләре вак, алсу, аксыл шәмәхә төстә, башак чәчәк төркемендә, бал исе килә. Җимеше — тартмачык. Май–июньдә чәчәк аталар. Җимешләре августта өлгерә. Орлыктан үрчиләр. Киптерелгән бүлбеләреннән (салеп) тонусны күтәрү өчен һәм көзән җыеруга карашы төнәтмә әзерлиләр. Декоратив үсемлек. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

ТӨЗӘТҮ ОЕШМАЛАРЫ́, иректән мәхрүм итү рәвешендәге җәза срогын тутыру урыны. Казан краенда андый урыннарны, бөтен Россиядәге кебек, 16 йөзнең 2 нче яртысыннан 19 йөз башына кадәр — монастырьлар, төрмә сарайлары (Казанда мондый сарайда Е.И.Пугачёв тоткынлыкта була), соңрак төрмә кальгалары тәшкил итә. Баштарак иректән мәхрүм итү җәза рәвешендә була һәм рәсми рәвештә җиназтьчене төзәтү максаты куелмый. Татарстан терр-ясендәге хәзергәчә сакланган Т.о. арасыннан иң борынгылары — Минзәлә өязендәге (1806) һәм Казан губернасындагы (1807) төрмә кальгалары. 18 йөз ахырында сәүдәгәр И.А.Михляевның постау пр-тиесе бинасы озату төрмәсе итеп яраклаштырыла. Төрмәләрдән тыш Т.о.на арестант йортлары, арестант роталары, буйсындыру һәм хезмәт йортлары, полиция бүлекләре каршындагы арестант биналары һәм бүлмәләре керә. 1845 елдан иректән мәхрүм итү б-н бәйле түбәндәге төзәтү җәзалары кулланыла: «кайбер аерым хокук һәм өстенлекләр чикләнгән хәлдә, яки чикләүләрсез, буйсындыру йортында вакытлыча ябылуда тоту; кыска вакытка кулга алу; вакытлыча төрмәгә ябып тоту». 1879 елгы төрмә реформасына кадәр ябылуда тоту урыннары б-н үзәкләштерелгән идарә булмый һәм җәза башкаруда катлауларга бүленеш катгый исәпкә алына. 1879 дан бердәм гомумдәүләт төрмә системасы оештырыла башлый, аның б-н җитәкчелек итү өчен 1879 да Баш төрмәләр идарәсе (элек — Эчке эшләр министрлыгы, 1895 тән Юстиция министрлыгы составында) булдырыла. Төрле буйсындыру һәм хезмәт йортлары, арестант роталары, бурыч төрмәләре һ.б. бетерелә. Алар урынына төп өч төрдәге төрмәләр булдырыла: 1) эре төрмәләр («централлар») — турыдан-туры Баш төрмә идарәсенә буйсыналар; 2) гомуми типтагы төрмәләр — губерна төрмә инспекцияләренә буйсыналар; 3) каторга төрмәләре. 1917 елда Казан губернасында, Казан губернасы төрмәсе һәм озату төрмәләреннән тыш, барлык өязләрдә дә диярлек — өяз төрмәләре һәм земство карамагындагы арест йортлары (Царёвококшайск өязендә 2 арест йорты — Царёвококшайск шәһәрендә һәм Морки авылында), ә Казанда хезмәт б-н төзәтә торган арест бүлекләре дә була. Губерна идарәсе составына Казандагы һәм Чистай өязендәге төрмә инспекцияләре керә. Җәмгатьчелекне тоткыннарны төрмәдә тоту һәм тәрбияләү мәсь әләләренә җәлеп итү өчен, «Төрмәләрне кайгырту җәмгыяте» Уставы нигезендә дәүләтнең адм., әхлакый һәм финанс ярдәменнән файдаланучы төрмә җәмгать ком-тлары оештырыла. Попечительләр төрмәләр өчен иганә акчасы җыю, төрмә җитәкчелеген контрольдә тоту (дәүләт милкен үзләштерүне һәм ришвәтчелекне ачу максатыннан) б-н шөгыльләнәләр, тоткыннарны укытуда, аларны төрле һөнәрләргә, кустарчылыкка тартуда ярдәм итәләр. Казан губернасы «Төрмәләрне кайгырту җәмгыяте» ком-тына губернатор һәм идарәче архиерейдан тыш, губерна вице-губернаторы, дворяннар башлыгы, округ мәхкәмәсе рәисе һ.б. югары дәрәҗәле түрәләр

кертелә. Абруйлы Казан эшмәкәрләре ком-т әгъзалары булып тора. Җәмгыятьнең бүлекләре Казан губернасының һәр өязендә дияр-лек була. Окт. рев-циясеннән соң совет хакимияте элекке төрмә инспекциясен һәм адми-нистрациясен саклап калу чараларын күрә. 1918 нең июлендә РСФСР Юстиция халык комис-ты «Җәза чарасы буларак иректән мәхрүм итү һәм җәза башкару тәртибе турында» вакытлы инструкцияне раслый, анда түбәндәгеләр билгеләнә: 1) иректән мәхрүм ителүгә хөкем ителгән затлар, сак астындагы затлар, хөкем ителүче затлар һәм озатылучы затлар өчен гомуми иректән мәхрүм итү урыннары (төрмәләр); 2) психик тайпылышлары шиксез булган арестантлар, дегенератлар һ.б.ш. өчен җәза-дәвалау оешмалары; 3) акылга зәгыйфь хроник авырулар өчен төрмә хастаханәләре; 4) йомшаграк режимга һәм вакытыннан алда иреккә чыгарылуга нигезләре булган затлар өчен сынау оешмалары; 5) яшь җинаятьчеләр өчен тәрбияләү-җәза оешмалары (реформаториләр һәм игенчелек колонияләре); 6) милиция тарафыннан тот-карланган һәм җирле халык мәхкәмәсендә исәпләнгән затларны, ш.у. озатылырга тиешле арестантларны вакытлыча тоту биналары. БҮБКның 1919 ел 21 март Декреты һәм БҮБКның 17 май карары нигезендә Бөтенроссия гадәттән тыш комиссиясе карамагындагы концентрацион лагерьлар оештырыла башлый. РСФСР БҮБК «Мәҗбүри хезмәт лагерьлары турында» Декрет кабул итә. Алар алдына күптөрле «дошмани көчләрне» изоляцияләү һәм изүче сыйныф вәкилләрен «үзгәртеп кору» бурычы куела. Мондый лагерьлар оештыру губерна гадәттән тыш хәлләр комиссияләренә йөкләнә, алар соңыннан составында Мәҗбүри эшләр бүлеге булган Эчке эшләр халык комис-ты карамагына тапшырыла. Мәҗбүри хезмәт лагере дип тә йөртелгән концентрацион лагерь Казанның Троицк урманында, элек яшь җинаятьчеләр колониясе булган урынында урнаша. 1918–40 елларда Т.о. күп үзгәртүләр кичерә, аларның исемнәре һәм җитәкче ведомстволары алышынып тора. Төрмәләр төзәтү оешмалары дип атала башлыйлар, алар Казанда (2), Алабугада, Мамадышта, Минзәләдә, Зөядә һәм Чистайда була. 1940 та ТАССРдагы 9 төрмәдә 6074 тоткын исәпләнә (ш.и. Казанда — 2462, Бөгелмәдә — 971, Чистайда — 806, Алабугада — 816, Минзәләдә — 497, Куйбышевта (хәзер Болгар ш.) — 522 кеше). Сәяси репрессияләр чорында төрмәләр күпләп юк итү урыннарына әвереләләр (җәзалар Казанда, Бөгелмәдә, Алабугада, Куйбышевта, Минзәләдә, Чистайда башкарыла). Күпләп юк итүнең иң дәһшәтлесе Окт. рев-циясенең 20 еллыгы алдыннан Чистайда була: 1937 нең 4 ноябрендә анда 88 кеше атып үтерелә. СССР Югары мәхкәмәсе Хәрби коллегиясенең күчмә сессиясе карары нигезендә 9 майдан 12 сенә кадәр Казанда 185 кеше, ш.и. ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты һәм ХКС җитәкчеләре, язучылар, педагоглар, студентлар атып үтерелә. 1930–50 елларда төрмәләр һәм хезмәт б-н төзәтү лагерьлары (ИТЛ) б-н беррәттән ш.у. лагерь пунктлары да (Казанда — 7, шәһәр тибындагы Бондюг посёлогында — 2, Минзәлә, Чистай, Бөгелмә һәм Питрәч р-нының Пановка авылында 1әр) эшли. 1942 нең февраленнән 1943 нең апреленә кадәр Волжск тимер юл хезмәт б-н төзәтү лагере эшли (идарәсе Казанда була), тоткыннар саны — 5,4 мең кеше (Зөя–Ульянов тимер юлы төзиләр, а.х. тармагында эшлиләр). 1947 нең июнендә Зөя станциясендә Тимер юл төзелеше лагерьлары Баш идарәсенең (ГУЛЖДС) 1 нче Зөя з-ды каршында Зөя лагерь бүлеге оештырыла (1948 нең октябренә ябыла). Тимер юл төзелеше лагерьлары Баш идарәсенең (ГУЛЖДС) 1 нче Зөя з-дында эшләүче тоткыннар саны 72 дән 486 га кадәр җитә. 1952 нең августыннан 1953 нең апреленә кадәр Казан нефть эшкәртү з-дының хезмәт б-н төзәтү лагере эшли (лагерьның идарәсе Казанда була), 500 ләп тоткын әлеге завод төзелешендә катнаша. 1952 нең августында 1 нче «Татспецнефтестрой» төзелеше хезмәт б-н төзәтү лагере оештырыла (идарәсе Әлмәт шәһәрендә була), андагы 2,3 тоткын нефть эшкәртү сәнәгате пр-тиесен төзүдә эшли (1953 нең апрелендә ябыла). 1952 нең августыннан 1953 нең апреленә кадәр 2 нче «Татспецнефтестрой» төзелеше хезмәт б-н төзәтү лагере оештырыла (идарәсе Яңа Писмән авылында, хәзерге Лениногорск шәһәрендә була), тоткыннар саны 1,3 мең кеше тәшкил итә. Хәзергә вакытта ТР терр-ясендә Т.о.ның төзәтү колонияләре (ТК), төзәтү-тәрбия колонияләре (ТТК), тикшерү изоляторлары (СИЗО) дип аталганнары бар: ТК-1 (1961 дә оештырыла, Түбән Камада урнашкан), ТК-2 (1932, Казан; 1875 тән земство арест йорты буларак эшли), ТК-3 (1935, Пановка а.), ТК-4 (1961, Түбән Кама), ТК-5 (1960, Карамалы Тау штп.), ТК-8 (1968, Әлмәт), ТК-18 (1989, Казан), ТК-19 (1993, Казан), ТТК (1972, Казан; ТК-9 җирлегендә оештырыла, 1963 тән эшли), СИЗО-1 (1807, Казан; элеккеге губерна төрмәсе), СИЗО-2 (1939, Казан), СИЗО-3 (1937, Бөгелмә), СИЗО-4 (1806, Минзәлә), 4 нче төрмә (1857, Чистай). 1939 да катгый күзәтчелек тәртибендәге Казан психиатрия хастаханәсе оештырыла (Махсус психик авырулар хастаханәсе; берничә тапкыр исемен алыштыра; хәзер РФ Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагында). Округ, психиатрия дәваханәсе буларак, 1870 еллардан психик авырулы җинаятьчеләр өчен ябылуда тоту урыны булып тора. Анда Б.Вәисов, М.Бейдеман (О.Форшның «Ташлан киенгәннәр» («Одетые камнем») романы героеның прототибы), совет адмиралы Л.М.Галлер һ.б. ябып тотыла һәм вафат була. Шулай ук монда танылган җәмәгать эшлеклесе В.И.Новодворская да ябылуда була.

Әд.: Система исправительно-трудовых лагерей в СССР. М., 1998; Тимофеев В.Г. Уголовно-исполнительная система России: Цифры, факты и события. Чебоксары, 1999.

Л.М.Жаржевский.

ТӨЗЕЛЕ́Ш, төрле максатларда биналар һәм корылмаларны төзү, реконструкцияләү б-н шөгыльләнүче икътисад тармагы. Т. продукциясе: эшләнеп беткән һәм кулланышка әзер җитештерү объектлары, предприятиеләр, торак йортлар, җәмәгать биналары, корылмалар һ.б. объектлар. (к. *Татарстан архитектурасы, Шәһәр төзелеше, Торак һәм җәмәгать биналары төзелеше, Юл-транспорт төзелеше, Сәнәгый төзелеш, Төзелеш материаллары сәнәгате, Татарстан Республикасы*).

ТӨЗЕЛЕ́Ш МАТЕРИАЛЛАРЫ́ СӘНӘГАТЕ́, торак төзелеше, сәнәгать төзелеше, а.х. төзелеше һ.б. *төзелеш* тармаклары өчен материаллар һәм эшләнмәләр җитештерүче пр-тиеләр тупланмасы, төзелеш өлкәсе матди-техник базасының мөһим өлеше.

Татарстан Респ-касы Т.м.с. РФ субъектлары арасында иң эре төзелеш индустриясе базаларының берсенә ия; ул үз эченә җыелма тимер-бетон конструкцияләр һәм детальләр, дивар, җылылык үткәрмәүчән, руда булмаган төзелеш материаллары, түбә япмалары, линолеум һ.б.ны җитештерүне ала. Респ-ка-да сәнәгатьнең бу тармагына караган 500 гә якын пр-тие, ш.и. тимер-бетон, товар бетоны һәм измә җитештерүче 60 завод (тулай проект куәте елга 3,5 млн. $м^3$), силикат кирпеч һәм керәч кирпече җитештерүче 8 завод һәм цех (тулай проект куәте елга 710 млн. данә шартлы кирпеч), җылылык үткәрмәүчән материаллар җитештерүче 8 пр-тие (тулай проект куәте елга 1500 $м^3$ дан артык) һәм күпсанлы кече пр-тиеләр эшли, Эре панельле йортлар төзү заводлары елга 1238 мең $м^2$ торак төзерлек тулай җитештерү куәтенә ия. Респ-ка төзелеш комплексының гомуми индустрия базасы елга 2 млн. $м^2$ дан артыграк торак төзәп тапшырырга мөмкинлек бирә (таблицаны к.). Төп төзелеш материаллары җитештерү күләмнәре Татарстанның Башкала, Кама һәм Нефть икътисади районнарында тупланган (җыелма бетон һәм тимер-бетон эшләнмәләр, кирпеч җитештерүнең тулай куәте күләменең 90% ы тирәсе, тәрәзә һәм ишек блоклары җитештерү буенча — 90% ы). Т.м.с.нең минерал-чимал базасы ком-гравий катнашмасына, төзелеш һәм силикат комына, гипс ташына (сәнәгый әһәмияткә ия 40 чыганак ачыкланган), кирпеч һәм керамзит балчыкларына булган ихтыяҗны тулысынча тәэмин итәргә сәләтле.

Татарстан терр-ясендә төзелеш материаллары җитештерелә башлауның ерак тарихы бар. Археол. тикшеренүләр Идел буе Болгар дәүләте шәһәрләре биналарын төзегәндә агач һәм табигый таш б-н беррәттән конструкцияләр өчен — кирпеч һәм уңайлыклар өчен керәч торбалар кулланылуын раслый. Казан губернасында беренче эре кирпеч заводлары Поповка, Воскресенское (1860, хуҗасы П.А.Смолин), Клыки (1860, 1892, И.Д.Иванов), Әмәт (1899, Л.В.Кекин) һ.б. авылларда барлыкка килә. 1900 елга эшләүчеләр саны 101 кеше булган 10 кирпеч заводы исәпләнә. 1903 тә известь заводларына да нигез салына (хуҗалары — И.А.Игошин, В.Г.Шабанов). 762 кеше — кирпеч сугу, 290 кеше таш вату, алебастр һәм известь табу б-н кәсеп итә (1878). Тәрәзә пыяласы (1900 дә — 5 пр-тие; 193 эшче), паркет (5 фабрика; 115 эшче), мозаика-цемент (1 пр-тие; 13 эшче) җитештерү үсә. 1918–22 дә тармак пр-тиеләре национализацияләнә, 1920–30 елларда алар төзелеш материаллары тресты (Силикаттрест), Ур-

1940–2013 елларда Татарстанда төзелеш материаллары җитештерү

	1940	1950	1965	1970	1980	1990	2000	2016
Төзелеш известе, мең *т*	23,1	16,9	35,8	56,9	36,1	44,8	11,0	3,9
Гипс, мең *т*	15,5	27,5	127,0	137,0	117,0	98,0	26,0	52,8
Төзелеш кирпече, млн. шартлы данә кирпеч, ш.и. силикат кирпеч һәм шлак кирпече	73,3 / 26,4	90,4 / 24,1	444,1 / 104,1	503,7 / 123,6	688,0 / 259,0	762,0 / 322,0	487,0 / 94,0	340,5 / 129,3
Җыелма тимер-бетон конструкцияләр, детальләр, мең *м*³	—	—	610,0	1151,0	2110,0	2547,0	688,0	749,0
Дивар панельләре, мең *м*³	—	—	—	—	—	647,0	122,0	...
Вакташ , мең *м*³	—	—	658,0	1459,0	1323,0	2030,0	641,0	563,2
Гипс ташы, мең *т*	—	—	579,0	777,0	714,0	—	—	...
Төзелеш комы, мең *м*³	—	—	1055,0	1676,0	3203,0	6006,0	—	2458,8
Керамзит, мең *м*³	—	—	137,0	193,0	688,0	776,0	—	89,8
Бетон катнашмасы, мең *м*³	—	—	—	—	—	—	151,5	1321,6

ман-силикат тресты, «Татарстан төзелеш берләшмәсе» составында була.

Т.м.с. 1930 елларда — *индустрияләштерү* һәм шу нә бәйле рәвештә шәһәрләрнең кызу темпта үсүе, торак һәм социаль объектлар күпләп төзелү чорында аерым үсешкә ирешә. Хәзерге вакытта да эшләп килүче пр-тиеләрнең иң беренчеләре 1 нче бишъеллыкта төзелә (1930 да — 1 нче Май исем. Казан силикат кирпеч з-ды, 1931 дә — керәч кирпеч җитештерүче К-28 з-ды). 1931 дә силикат з-ды — 10 млн. данә, 1940 та 21 млн. данә кирпеч эшләп чыгара. Заводта ш.у. 50 млн. данә кирпеч эквивалентында фибролет эшләп чыгару куәтләре дә сафка баса. Бөек Ватан сугышы елларында кирпеч сугу 2 тапкыр кими, сыек пыяла эшләү оештырыла (елга 86 *т* га кадәр). 1946 да япсарлар һәм тоташтырмалар өчен арматуралы силикат плитәләр, бетон блок, торба һәм ярымбожралар, мозаика путалар, баскыч һәм баскыч маршлары, фасадлар өчен күпертмә орнаментлы эшләнмәләр ясау үзләштерелә.

Төзелешне индустрияләштерүдә Т.м.с.нең җыелма тимер-бетон конструкцияләр һәм детальләр җитештерү кебек яңа юнәлеше барлыкка килү зур роль уйный. 1947 дә 40 нчы трест базасында Казандагы тимер-бетон эшләнмәләр з-дының (ЖБИ) иң беренчесе сафка баса. 1950 елларда Чаллы шәһәрендә төзелеш индустриясе базасына нигез салына. 1959–62 дә газ-бетон һәм тимер-бетон эшләнмәләр з-ды төзелә (хәзер Чаллы кәрәзле бетон з-ды). 1960 ка респ-каның җыелма тимер-бетон конструкцияләр һәм детальләр эшләп чыгаручы заводларының хезмәт җитештерүчәнлеге елга 400 мең *м*³ тәшкил итә. 1959–1960 еллар башында Казанда 2 эре панельле йортлар салу з-ды (гомуми җитештерүчәнлекләре — елга 25 һәм 85 мең *м*² торак мәйданы) һәм Әлмәттә 1 завод (85 мең *м*² торак мәйданы) төзелә. 1976–80 елларда Казанда, Чаллыда, Түбән Камада



«КамАЗстройиндустрия» ҖЧҖнең әзер продукция мәйданчыгы.

тагын берничә эре панельле йортлар салу з-ды һәм ЖБИ эшли башлый. Бу пр-тиеләр эре панельле йортларның 9 сериясен эшләп чыгара. 1988–93 тә «КамАЗстройиндустрия» төзелеш-җитештерү фирмасы составында ЖБИ һәм керәч дивар материаллары з-длары салына.

1950 елларның 2 нче яртысында Казан механика з-дында (хәзер «Сантехприбор») сан.-техник арматура эшләү үзләштерелә.

1957 дә шәһәр тибындагы Арча, Аксубай, Зеленодольск районының Васильево посёлокларында, Азнакай районының Тымытык авылында арболит (җи нел бетон төре) җитештерү җайга салына. 1960 еллар ахырында Казанда ком-гравий катнашмасын фракцияләргә аеру мөмкинлеге бирүче ике продуктлы классификаторга ия гравий з-ды сафка баса.



Казан тимер-бетон конструкцияләр заводы. Төп җитештерү мәйданы.

Шушы чорда кирпеч заводларының эшчәнлеген көйләү һәм үсешен тәэмин итү максатыннан «Татарстан төзелеш материаллары» (*«Татарстройматериалы»*) идарәсе оештырыла. Респ-када нефть чыгару сәнәгате үсеше Т.м.с. үсешенә дә уңай йогынты ясый. «Татарстан нефть төзелеш материаллары» («Татнефтестройматериалы») тресты составына кирпеч заводлары, руда булмаган материаллар комб-тлары, ЖБИ заводлары, карьерлар, коры гипс штукатуркасы һәм товар гипсы җитештерү з-ды, Чупай чыганагы ташыннан бизәү һәм тышлау материаллары җитештерү кертелә. 1970 елларда Урыссу бемит з-ды төзелә.

1960 елларда, а.х. үсешенә бәйле рәвештә, ху жалыкара төзелеш оешмаларының матди-техник базасы ныгый һәм респ-ка дәрәҗәсендәге төзелеш индустриясе пр-тиеләре оештырыла башлый, а.х. җитештерүе объектлары төзү интенсив төс ала. 1960–65 тә «Татколхозстрой» берләшмәсе составында 24 сезонлы кирпеч з-ды була. 1962 дә Казан ЖБИ з-ды төзелә. Кыска гына вакыт эчендә Чаллы «Стройдеталь» з-ды, Коркачык (1969) һәм Зәй (1971) сәнәгать-төзелеш комб-тлары, Чистай ЖБИ з-ды (1971), руда булмаган материаллар комб-ты (1978), карьерлар идарәсе (1971) сафка баса. 1980–1990 елларда *«Татагропромстрой»ның* төзелеш индустрия базасы үсеш ала; Зәй җиңел металл конструкцияләр з-ды төзелә. 1992 дә ТР хөкүмәте тарафыннан Авыл җирләрендә кирпеч заводлары төзү программасы кабул ителә, Азнакай, Алексеев, Арча, Балтач, Зәй, Минзәлә, Түбән Кама һәм Чирмешән р-ннарында заводлар эшли башлый.

1980 еллар ахырында респ-када төзелеш материаллары җитештерү, башлыча, «Татарстройматериалы», «Татагропромстрой», «Татнефтегазстрой», «Татстрой», «Камгэсэнергострой», *«Камэнергостройпром»* берләшмәләре составындагы пр-тиеләр тарафыннан гамәлгә ашырыла. Т.м.с.ндә хезмәт куючылар саны якынча 40 мең кеше тәшкил итә.

1980 елларда төзелеш индустриясе һәм төзелеш материаллары пр-тиеләре тарафыннан якынча 2,5 млн. *м*³ җыелма тимер-бетон, 700 млн. данә шартлы кирпеч, 700 мең *м*³ дан артык керамзит һ.б. эшләп чыгарыла.

Бу елларда, гомумән, Татарстанда да бөтен Россиядәгечә, башка төбәкләрдән китерелгән бер катлы тимер-бетон дивар конструкцияләре кулланып, эре панельле йортлар салу киң таралыш ала.

1990 елларда, икътисади кризис чорында, төзелеш күләмнәре кискен рәвештә кыскара, төзелеш материаллары һәм төзелеш индустриясе пр-тиеләре эшләп чыгарган продукциягә ихтыяҗ кими һәм аларның кайберләре (төп фондларының кыйммәте зур булган, җи һазлары тузган, күп энергия таләп итүче технологияләргә корылган, көндәшлеккә дәгъва кылучы сыйфатлы продукция җитештерү мөкинлеге булмаган пр-тиеләр) үз эшчәнлекләрен туктата.

1990 еллар уртасына күп кенә яңа оешкан төзелеш фирмалары («ТАИФ» пр-тиеләре

төркеме, «ПСО Казань», «Кулонстрой», «Унистрой», «Фон» һ.б.) хосусый җитештерү базаларын җәелдерә башлыйлар, төзелеш материаллары һәм конструкцияләре эшләп чыгару өлкәсендә эре җитештерүчеләр сафына басалар; руда булмаган материалларны чыгару, эшкәртү, күчерү һәм реализацияләүне гамәлгә ашыралар. Бу пр-тиеләрдә прогрессив технологияләр һәм заманча җиһазлар киң кулланыла; эшләнмәләрне җылылык ярдәмендә эшкәртү процессларын автоматлаштыру, бушлыклы плитәләрне экструзия ысулы б-н кысасыз формалаштыру,



Куыш түшәмә җитештерү. «Кулонстрой» АҖ.

бетонны әзерләү һәм ташшыру һ.б. буенча эш алып барыла; автомобиль базасындагы бетон насослары, миксерлар һәм башка техника кулланыла. Респ-када Т.м.с. өлкәсендә җитештерүне модернизацияләү һәм җитештерүнең яңа төрләрен кертү буенча проектлар тормышка ашырыла. Дивар кирпече һәм керәч өслек кирпече, буялган һәм рельефлы силикат кирпече эшләп чыгаруга көйләнгән яңа ку аглар сафка кертелә (Алабуга кирпеч з-дының 1 нче чираты, Чаллы шәһәрендәге төзелеш материаллары комб-тында, Казан силикат төзелеш материаллары з-дында, «Алексеев керәче» АҖдә, «Питрәч керәче» ҖЧҖдә һ.б.). 2000 дә респ-када бетон һәм тимер-бетон эшләнмәләр һәм товар бетоны җитештерү буенча тулай куәте елга 5 мең $м^3$ дан артык булган 100 дән артык пр-тие исәпләнә. 1995 тә пластик тәрәзә блоклары җитештерү өлкәсендә Россия күләмендә иң эреләрдән саналучы «Стройпласт» з-ды (Казан) үзенең беренче продукциясен бирә. Пр-тиедә, тәрәзә ясау өчен чимал булган пластик профильләр әзерләүдән башлап, әзер эшләнмәләрне, ш.и. ишек һәм балкон блокларын да кертеп, җыюга кадәрге тулы технол. цикл башкарыла. Җитештерүнең экструзион ку аглә ре төрле системалы һәм кулланыштагы пластик профильләр: панельләр, тәрәзә төпләре, плинтуслар, почмак ялганмалары һ.б.ны эшләп чыгарырга мөмкинлек бирә. 2007 елга тулай ку аге 22 млн. $м^2$ булган 17 пр-тие төзелә, 12 млн. $м^2$ дан артыграк түбә ябу материаллары җитештерелә. 2007 елда ку аге елга 30 мең *т* тәшкил итүче Казан модификацияләнгән коры катнашмалар з-ды эшли башлый.

1990 елда ТРда түбә ябу материаллары җитештерүче пр-тиеләр барлыкка килә. Пыялалы-җепсел аслыктагы рулонлы битум полимер түбә ябу материаллары һәм битум-полимер мастикалар — «Нижнекамсккровля» АҖдә, «Алтея» ҖЧҖдә (Казан), рулонлы полимерлар һәм полимерлы мастикалар — «Кварт», «Казан синтетик каучук заводы» акц. җәмгыятьләрендә, табаклы яссы һәм профильле корыч һәм металл б-н тышланган өч катлы түбә ябу материаллары — «Тимер» АҖдә (Казан) һ.б.да җитештерелә. Төзелеш өчен металл конструкцияләр һәм эшләнмәләрне тулай куәтләре 190 мең *т* металл конструкция һәм 1,4 млн. $м^3$ дивар япма панеле тәшкил иткән 50 пр-тие эшләп чыгара (Чаллы шәһәрендәге «ТЭМ-ПО» металл конструкцияләр з-ды, Кама вагон төзү з-ды «Технопарк»ы, «Кулонстрой» АҖ һ.б.). 2000 нән фасад системалары элементлары эшләү, тиз җыела торган тулы комплектацияле агач торак йортлар төзү үсеш ала (Казандагы «Эстель» ҖЧ Җ, Чаллы металл конструкцияләр з-ды, Алабуга җилемләнгән модульле конструкцияләр нигезендә йортлар төзү комб-ты һ.б.). Шул ук вакытта читтән кертелүче төзелеш материалларына, ш.и. кирпеч, цемент, гипс бизәү материаллары, тимер-бетон эшләнмәләр өчен корыч арматура, төзелеш пыяласы, утка һәм кислотага чыдам материалларга зур ихтыяҗ саклана. 2001 дә Т.м.с.нә инвестицияләр күләме 51,86 млн. сум (бюджетның 28% ы) тәшкил итә; 2006 да бу күрсәткеч, 2001 ел б-н чагыштырганда 20 тапкыр арта (бюджет финансларыннан башка).

2006 да Т.м.с.нә кагылышлы өстәмә программасы булган «2005–10 елларга Татарстан Республикасы төзелеш комплексының тотрыклы үсеше» программасы раслана. 2007 дә үз эченә «Төзелеш материаллары сәнәгате» блогын алган «2020 елга кадәр һәм 2030 елга кадәрге чор өчен җитештерү көчләрен кластерлы караш нигезендә үстерү һәм урнаштыру» программасы эшләнә. Программа төзелеш индустриясе базасын оптимизацияләү һәм структура ягыннан үзгәртеп коруны, эре панельле йортлар төзү з-дларының яңа куәтләре һәм яңа кирпеч заводлары үсешен туктатуны; эшләп килүче пр-тиеләрне төрле катлылыктагы йортларның комбинацияле системаларын төзү өчен эшләнмәләр комплектлары җитештерүгә, блоклы, утар тибындагы, аерым йортлар, ш.у. коттеджлар төзүгә юнәлдерүне; эшләп килүче заводларны күбесенчә эче куыш керәч кирпеч һәм таш, тышлык кирпече һәм архитектур кирпеч җитештерү максатыннан үзгәртеп җиһазлау һәм реконструкцияләүне; бетон ташлар, блоклар, җылылык үткәрмәүчән плитәләр, бүлем плитәләре, кәрәзле бетон, орогипс, пенопластлар, җирле чимал нигезендәге материаллар һәм сәнәгать калдыклары, цемент-ком чирәп, коры бетон һәм измә катнашмалары җитештерүне җайга салуны күздә тота.

Респ-кадан зур күләмдә гади керәч кирпеч, эре форматлы керәч блоклар, монолит һәм кәрәзле поликарбонат, минерал-мамык җылылык үткәрмәүчән материаллар эшләнгән торбалар чыгарыла.

Әд.: Анализ и основные направления развития и размещения производительных сил Республики Татарстан. К., 1996; Минерально-промышленный комплекс твёрдых полезных ископаемых Республики Татарстан. К., 1996; Архитектурно-строительный комплекс Республики Татарстан: История, биографии, свершения, надежды. К., 2005; Татагропромстрой: события, люди: 45-летию Татагропромстроя посвящается. К., 2005; Рахимов Р.З. Состояние и развитие промышленности строительных материалов Республики Татарстан // Строительные материалы. 2008. № 4.

Г.Я.Мәүлетова.

«ТӨЗҮ́ УДА́РНИГЫ», газета; к. «*Коммунист*».

ТӨЙМӘЧӘЧӨ́К (Cicerbita), чатыр чәчәкләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 20–25 төре билгеле, Евразия, Төньяк Африка һәм Төньяк Америкада таралганнар. Татарстан терр-ясендә бер төре — Урал Т.ге (C. uralensis) Идел алдында һәм Кама аръягында очрый. Киң яфраклы һәм ылыслы-киң яфраклы урманнарда үсә. 80–200 *см* биеклектәге үсемлек. Тамырчасы кыска. Сабагы куыш, буразналы. Аскы яфраклары зур, сөңге-йөрәксыман, озын сапларда, өскеләре — утырма, ланцетсыман. Чәчәкләре телчекле, зәңгәр-шәмәхә төстә, калкан-себеркәч чәчәк төркемендә. Җимеше — орлыкча. Июльдә чәчәк ата. Җимешләре сентябрьдә өлгерә. Орлыктан һәм вегетатив юл б-н үрчи. Декоратив, баллы үсемлек.

ТӨКӘ́Ш посёлогы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 39 *км* көньяк-көнбатыштарак, Куйбышев сусаклагычыннан 2 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда даими яшәүчеләр юк. 1930 елларда нигез салына. Беренче исеме — Кызыл Йолдыз. Оешкан көненнән Тәтеш р-нында. 1938 нең 4 августыннан — Олы Тархан, 1959 ның 12 октябреннән Тәтеш р-нында. Халык саны: 1949 да — 167, 1958 дә — 113, 1989 да — 10 кеше, 2002 дә даими яшәүчеләр юк.

ТӨКЛЕ́ СУАЛЧАННА́Р, турбеллярияләр (Turbellaria), яссы суалчаннар классы. Ике яклы симметрияле хайваннарның гади төркеме. Күбесенчә төче су һәм диңгез суалчаннары, ара-тирә коры җирдә яшәүчеләре дә очрый. Гәүдәсе төкчәле эпителий (исеме шуннан) б-н капланган, еш кына ачык төстә, озынлыгы мм өлешләреннән алып 60 *см* га кадәр. Эпителий астында сыгылмалы базаль мембрана бар, аңа тире-мускул капчыгы хасил итеп мускуллар берегә. Органнар арасы тоташтыргыч тукыма — паренхима б-н тулы. Ашкайнату системасы йомык эчәк б-н тоташучы алгы һәм урта эчәкләр - дән тора. Авыз туклану өчен генә түгел, ә аналь тишем булып та тора. Нерв системасы ми ганглиеннан һәм аннан китүче нерв кәүсәләреннән тора. Күрү сәләте яхшы үскән, сулыш органнары юк, бүлеп чыгару системасы ике яки берничә көпшәчектән тора, аларның һәрберсе берәр очы б-н тышкы якка ачыла. Гермафродитлар. Күбесенчә женси юл б-н үрчү хас. 11 отрядка берләшүче 3 меңнән артык төре билгеле. Татарстан терр-ясендә төгәл саны билгеләнмәгән. Т.с. барлык сулыкларда яшиләр, күпчелеге ерткычлар, аерым төрләре — кысласыманнарның паразиты. Аеруча планарияләр асотряды төрләре күп очрый.

О.Д.Любарская.

ТӨКЛЕ́ ТАЛПАННА́Р (Listrophoroidea), акариформчалар отрядыннан талпаннар семьялыгы. Имезүчеләр: кондыз, ондатра, куян, гади тиен, гади кыр тычканы, йорт тычканы йонының специфик паразитлары. Якынча 300, БДБдә 50 гә якын төре билгеле, Татарстанда төрләренең саны билгеләнмәгән. Т.т.ның гәүдәсе (озынлыгы 0,2 дән 0,7 *мм* га һәм киңлеге 0,13 тән 0,25 *мм* га кадәр) уклаусыман (киңлеге б-н биеклеге бертигез) һәм ике өлешкә бүленә. Баш өлеше склетлашкан калкан, ә гәүдәсе күпсанлы бөжрасыман җыерчыклы йомшак тире б-н капланган. Авыз аппараты кимерүче типта. 5 буынлы 4 пар аягы бар. Ике пар арткы очлыклар төк капламына берегү органнарына үзгәргән. Төк фолликуллы, лимфа һәм кан плазмасы б-н туклана. Үсеш циклы: күкәй-личинка-бер-ике нимфа чоры-олы талпан. Тиредә (кешедә) кычыттыргыч ялкынсыну тудыра.

Әд.: Дубинин В.Б. Волосяные клещи // Клещи грызунов фауны СССР. М.–Л., 1955.

В.А.Бойко.

ТӨКЛЕ́ ЧӘЧӘ́К, тәңкәяфрак (Alchemilla), роза чәчәкләр семьялыгыннан күпьеллык, сирәк кенә берьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 300 гә якын төре билгеле, башлыча Европада, ш.у. Азиядә, Америка һәм Африкада таралганнар. ТР терр-ясендә 24 төре бар: караңгы яфраклы Т.ч. (A. atrifolia), Балтыйк Т.ч.е (A. baltica), матур Т.ч. (A. gracilis), Сармат Т.ч.е (A. sarmatica) һ.б. Нигездә, Кама алдында һәм Идел алдында очрыйлар. Болыннарда, урман буйларында, куаклыкларда үсәләр. 5 тән 70 *см* га кадәр биеклектәге үсемлек. Яфраклары гади, бармак-калаксыман, тамыр янындагылар озын сабакта, кырыйлары бөрмәле, челтәрле манжетны хәтерләтә. Чәчәкләре вак, яшькелт-сары, таҗ яфракчыклары юк, йомгакларда, калкан-себеркәч чәчәк төркеменә җыйналган. Җимеше — чикләвекчек. Май ахыры — июльдә чәчәк аталар. Җимешләре сентябрьдә өлгерә. Орлыктан һәм вегетатив юл б-н үрчиләр. Үсемлек дуплау матдәләренә бай. Т.ч.нең күп кенә төрләре халык медицинасында бөрешергеч, какырык куптару, матдәләр алмашын яхшырту чарасы буларак кулланыла. Очлы калаклы Т.ч. (A. acutiloba), ачык яшел Т.ч. (A. cheirochlora), күгел җем Т.ч. (A. glaucescens) һ.б. — терлек азыгы.

ТӨКЛЕТУРАЛА́Р (Bombus), чын умарта кортлары семьялыгыннан элпәканатлылар ыругы. Күч булып яшиләр. Озынлыгы 3,5 *см* га кадәр, еш кына кара, кызгылт-сары, ак һәм сары буйлар барлыкка китерүче куе озын төкчәләр б-н капланган. 300 гә якын төре билгеле, Африкадан кала бөтен Җир шарында таралганнар. РФдә якынча 70, Татарстан терр-ясендә 31 төре билгеләнгән. Башлыча урманнарда, ш.у. далаларда, болын, күпьеллык үләнчәчәкләрендә, торак пунктларда яшиләр. ТРда иң күп таралган төр — кечкенә җир Т.ы (B. lucorum), ш.у. урман Т.ы (B. silvarum) һәм кыр Т.ы (B. agrorum) да очрый. Күкрәк мускулларын кыскартып (каты чәрелдәү тавышы чыгара) тәннәрен җылытырга һәм ояларындагы темп-раны 30–35 °С ка кадәр күтәрергә сәләтлеләр. Шул сәбәпле суыкта да (0 °С ка кадәр) үсемлекләрне серкәләндерә алалар, бу вакытта исә башка серкәләндерүче бөҗәкләр очмый. Аталанган ана затлар иртә язда күренәләр, җир өстә (мәс., куыш Т.ы — B. hypnorum, мүк Т.ы — B. muscorum) һәм җир асты (таш Т.ы — B. lapidarius, бакча Т.ы — B. hortorum) оялары кору өчен урын эзли башлыйлар. Кайбер төрләре кимерүчеләрнең өннәрендә, туфрак бушлыкларында, агач корылмаларда оялый. Балавыз һәм серкә катнашмасыннан ана зат берничә көрәз күзәнәге ясый: берсенә күкәй, башкаларына бал һәм серкә запасы тутыра. Беренче личинкалары эшче затлар булып җитлегә һәм ояны төзелеш материалы һәм азык б-н тәэмин итә. Җитлеккән ата һәм ана затлар сезон ахырында гына күренәләр. Оядагы затларның саны берничә дистәдән 1 меңгә кадәр җитә. Аталанган аналар кышларга кала, ата һәм эшче затлар үләләр. Т. урман, болын һәм кыр үсемлекләрен, ш.и. күп кенә а.х. культураларын (аеруча кызыл клевер чәчүлекләрен) серкәләндерүчеләр буларак файда китерәләр. Т. һәм аларның оялары саклауга мохтаж, Т.ның 15 төре: әрмән Т. (B. armeniacus), поморум Т.ы (B. pomorum), Себер Т.ы (B. consobrinus), мүк Т.ы һ.б. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

Е.А.Сапаев.

ТӨКЧӘЛЕЛӘ́Р (Dipsacaceae), ике өлешле үсемлекләр семьялыгы. Европа, Азия һәм Африкада үсүче 10 ыругы, якынча 300 төре билгеле. Бер-, ике- һәм күпьеллык үләнчәчәкләре ике җенесле, дөрес булмаган формада, тыгыз башча чәчәк төркемендә. Күп яфраклы тышча б-н әйләндереп алынган. Таҗы бүрәнкәсыман, тоташып үскән 5 таҗ яфракчыклы. Җимеше — тыгыз сыланган тышлыклы орлыкча, бер орлыклы зәңгәр тупыйбаш — дару, кыр тупыйбашы, татар тупыйбашы, сары ялмача, исет ялмачасы — декоратив үсемлекләр. Кайберләре (болын зәңгәр тупыйбашы, татар тупыйбашы) — баллы үсемлекләр. Кыр тупыйбашы — чүп үләне. Татар тупыйбашы, зәңгәр тупыйбаш, сары ялмача ТРның Кызыл китабына кертелгән.

ТӨЛКЕ́, бүреләр семьялыгындагы имезүче ерткычлар ыругыннан. ТРда гади төлке таралыш алган. Мехы кызгылт-җирән, соргылт-сары төстә. Вак кимерүчеләр, куяннар, кошлар, ш.у. үләксә б-н туклана. Өндә яши. Елга 3–12 бала китерә. Гади Т. читлектә аерала торган кыйммәтле мехлы җәнлек төрләре чыгару өчен нигез булып тора. Татарстанда 1931 елдан асрала. Бөгелмә р-нының «Восточный» җәнлек с-зында, Мамадыш р-ның «Бөрсет» агрофирмасында, Биектау р-ның «Бөреле» нәсел з-дында, Лаеш р-ның «Матюшино» һәм Чистай р-ның «Тандем» хуҗалыкларында үрчетелә. Ана затлар 5310 баш (кызыл токым — 180, көмешсу-кара токым — 5130 баш), яшь җәнлекләр 22,6 мең баш тәшкил итә (2005).

Ә.Х.Фазылҗанов, Г.Б.Вәлиев.



Гади төлке.

ТӨЛКЕКОЙРЫ́К (Alopecuzus), кыяклылар семьялыгыннан күпьеллык, сирәгрәк берьеллык терлек азыгы үсемлеге. СССР терр-ясендә 29 төре билгеле. Татарстанда 5 төре бар: болын Т.ы, тигез Т., камышсыман Т., буынтыклы Т., кылчыклы Т. Барлык Т.лар да — гидрофитлар, табигый шартларда су баса торган болыннарда, сазлыклы үзәнлекләрдә, сулык ярларында, чокыр буйларында үсә. Болын Т.ы терлек азыгы буларак кулланыла, көзге-язгы үсеш тибындагы тамырчалы-көпшәк куаклы иртә өлгерешле кыяклы үсемлек. Киска тамырчалар б-н бәйләнгән, биеклеге 120 *см* га җиткән яхшы яфракланган йомшак сабаклы һәм күп санда озын тамыр яны яфраклары булган куаклыклар барлыкка китерә. Печән буларак файдаланылган үлән капламында җи нәл коела торган орлыкларының тиз өлгерүе һәм тамырчалар б-н вегетатив үрчүе сәбәпле, 50 елга кадәр саклана. Чәчәк оешмасы — тыгыз көмешсыман солтан. 1970 елларда респ-каның а.х.нда Болын Т.ы сугарулы печәнлекләр һәм көтүлекләр булдырганда үлән капламы составына кертелгән (аның орлыгы башка төбәкләрдән кайтарылган). Туфракның уңдырышлылыгына һәм әчелегенә талымсыз, сугарганда һәм ашламалар керткәндә, яхшы үсә. Салкынга, 45 көнгә кадәр язгы су басуга чыдам, ләкин корылыкка бирешә. Беренче елда акрын үсә, 3–4 елдан тулай продукция бирә башлый. Югары туклыклылык кыйммәте б-н аерылып тора. Көтүлек буларак файдалануны яхшы кичерә, ләкин артык һәм системасыз файдаланганда үлән капламыннан югалырга мөмкин. Су баса торган җирләрдә 2 тапкыр чабып алганда, 1 *га* дан 6 *т* печән бирә, 100 *кг* печәндә 47,7 азык берәмлеге, 5,1 *кг* үзләштерелә торган протеин, 10 *г* каротин бар. Орлык бирүчәнлеге 1 *га* дан 2–4 *ц* тәшкил итә. Орлыклары яссы, якынча 4 *мм* озынлыкта, кылчыклы, җиңелчә төкле. 1000 орлыкның авырлыгы 0,7–0,8 *г*. Чәчкеч б-н чәчү өчен аларга яхшы сибелә торган балласт катнаштыралар. Орлыкның чәчү нормасы 1 *га* га үлән катнашмаларында — 4–6 *ц*, чиста килеш — 6 *ц* (киң рәтле ысул б-н), 12 *ц* (рәтләп). Орлыкны күмү тирәнлеге 1–1,5 *см*. Орлыгы сирәк булу сәбәпле, Т. Татарстан а.х.нда киң таралмый.

Әд.: Материалы по отбору луговых дикорастущих трав // Казанское губернское земство. Отчёт за 1913–1914 гг. К., 1915. Вып. 1; Справочник по кормопроизводству. М., 1993; Шайтанов О.Л. Подбор многолетних трав и травосмесей для организации зелёных и сырьевых конвейеров на орошаемых землях Среднего Поволжья: Дис. ... М., 1995; Бакин О.В., Рогова Т.В., Ситников А.П. Сосудистые растения Татарстана. К., 2000.

О.Л.Шайтанов.

ТӨМӘН, (төркн), Чыңгызыйлар дәүләтләрендә 10 мең гаскәридән торган хәрби берәмлек. Унлык, йөзлек һәм меңлекләргә бүленгән. Яуга 10 меңлек гаскәри берләшмә куяргa тиешле эре феодаль биләмәне ш.у. Т. дип йөрткәннәр. Аның башында *төмәнбашы* торган.

ТӨМӘН ӨЛКӘСЕ́, РФдә, Көнбатыш Себернең төньякында, төньяктан Карск диңгезе юа. 1944 елның 14 августында оештырыла. Т.ө. составына РФнең 2 субъекты: Ямал-Ненец һәм Ханты-Манси автономияле округлары керә. 1918 гә кадәр терр-я, башлыча, — Тубыл, 1918–23 тә — Төмән губерналары, 1924–32 дә — Урал, 1932–44 тә Омск өлкәләре составында. Мәйданы — 1435,2 мең *км*^{2}. Үзәге — Төмән шәһәре (Мәскәүдән 2144 *км* көнчыгыштарак). Халкы — 3692400 кеше (1.1.2018). 2010 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 239995 (1816 да — 25 меңләп, 1897 дә — 57 меңләп, 1920 дә — 62 мең, 1926 да — 70 мең, 1959 да — 72,3 мең, 1970 тә — 102,8 мең, 1979 да — 136,7 мең, 1989 да — 227,4 мең, 2002 дә — 242,3 мең) кеше. Алар, тупланып, Төмән (33984 кеше), Тубыл (16643), Ялутор (2255) шәһәрләрендә; *Аромашев* (1143), *Вагай* (8949), *Заводоуковск* (589), Исәт (880), *Түбән Тәүде* (3151), *Тубыл* (7627), *Төмән* (14099), *Уват* (964), *Ялутор* (3492), *Яркәү* (7538) р-ннарында яшиләр. Т.ө. терр-ясе — элек-электән төрки телле кабиләләрнең (кара кыпчаклар, хатаннар һ.б.) яшәү урыны була, алар бохари төркиләр, нугайлар, башкортлар б-н бергә *Себер татарлары* этногенезында катнаша. 14–15 йөзләрдә бу җирләр — Төмән ханлыгына, 16 йөздә Себер ханлыгына керә. Идел-Урал буе татарлары (җирле атамалары — чуалчылар) монда 18 йөздә урнаша башлый. Җирле халыкның төп шөгыле аучылык, балык тоту, азык туплау була; килгән халык үзе б-н терлекчелек (ат, сыер, сарык үрчетү) һәм утрак игенчелек (арпа, солы, борай һ.б. а.х. культуралары үстерү) традицияләрен алып килә. Себер Рус дәүләтенә кушылганнан соң, татарларны казакъ һәм ямчылык хезмәтендә файдаланалар. Дин татарлар тормышында мөһим урын тота. 18 йөздә берничә тапкыр *христианлаштыру сәясәтен* үткәрергә тырышып карыйлар. 1858 дә Тубыл губернасында 154 (ш.и. 6 сы — таш) мәчет исәпләнә, 20 йөз башында губернадагы 275 татар авылының барысында да диярлек мәсьеләман гыйбадәтханәсе була. 63 авылда мәдрәсә (иң элек — 17 йөз ахырында Тубыл шәһәрендә барлыкка килә) һәм мәктәп эшли. Мөселман уку йортлары арасында иң танылганы Төмән өязенең Ямбай авылы мәдрәсәсе (1841 дә ачыла) исәпләнә. Совет хакимияте чорында мәчетләр ябыла, дини оешмалар бетерелә, мәктәп һәм мәдрәсәләр дөньяви белем мәктәпләре итеп үзгәртелә. Яңа милли кадрлар әзерләү максатыннан 1920 дә Төмәндә татар мәктәпләре өчен укытучылар әзерләү пед. курслары (1922 дән — Төмән пед. техникумының төрки-татар бүлеге) оештырыла; 1930 да татар пед. уч-щесе (1934 тә Тубыл шәһәренә күчерелә) ачыла, 1955 кә кадәр Төмән, Омск һ.б. өлкәләрдәге татар мәктәпләре өчен 1,5 меңләп укытучы чыгара. 1950 дә Төмән пед. ин-тында татар теле һәм әдәбияты ф-ты (1953 тә Тубыл пед. ин-тына күчерелә) оештырыла. 1923 кә кадәр Төмән губернасы терр-ясендә татар волостьлары эшли, районлаштыру барышында алар бетерелә. Төмәндә «*Коммунизм байрагы*» (1919 да), «*Юксыллар чаткысы*» (1922–23), «*Коммунизмга*» (1931–36); Тубылда «*Колхоз юлы*» (1930–36), «*Ленин юлы*» (1957–63); Ялуторда «Коллектив ху җәлык» (1930 елларда) татар г-талары нәшер ителә. «Красное знамя» Төмән өлкә г-тасында даими рәвештә татарларның тормышын һәм эшчәнлеген яктырткантатарча кушымта чыга. 1920–30 елларда өлкә татарлары арасында Свердловск һәм Омск шәһәрләрендә чыга торган «Коммунист» (1925 тән — «Сабан һәм Чүкеч», 1930 дан — «Социализм юлы»), «Сталин юлы» г-талары тарала. 1959 елгы мәгълүматларга караганда, Т.ө. татарларының 90% тан артыгы көньяк авыл р-ннарында яши. 1960–70 елларда өлкәнең төньягында нефть һәм газ ятмалары табылу хезмәт ресурсларын яңача бүлүгә сәбәпче була; татарларның (10 меңләп кеше) нефть-газ чыгару төбәкләренә агылуы Т.ө.нең көньягында 20 ләп татар авылы югалуга китерә. Татарларның күпчелеге илнең башка төбәкләреннән килә. Алары, башлыча, (54,6%) Ямал-Ненец һәм Ханты-Манси автономияле округларында яши. 1980 еллар ахырында татарларның милли-мәдәни тормышы күтәрелеш кичерә. Татар телендә «Яңарыш» өлкә г-тасы, «Себер мөселманнары», «Хакыйкать», «Мөслим», «Себер иле», «Ак калфак» басмалары дөнья күрә. 1988 дә Себер татарлары яңарышы ком-ты оештырыла. 1990 еллар башыннан Тубыл, Төмән, Ялутор шәһәрләрендә, ш.у. Вагай, Түбән Тәүде, Төмән, Ялутор, Яркәү р-ннарында, Ханты-Манси һәм Ямал-Ненец (Салехард ш.) автономияле округларында милли-мәдәни автономияләр; Тубыл татар мәдәни үзәге, Нефтеюганск шәһәрендә «Тальян» мәдәни үзәге, Төмән «Ак калфак» өлкә иҗтимагый оешмасы (1994 тән), Төмән «Мирас» өлкә хәйрия фонды (2003 тән) эшчәнлек алып бара. 1990–94 тә Төмәндә «Строитель» мәдәният йорты каршында Өлкә татар мәдәнияте үзәге эшли, аның каршында «Төмән нурлары» татар хоры, бию коллективы, фольклор һәм эстрада ансамбльләре, татар халык музыка уен кораллары оркестры, үзешчән театр труппасы, әдәби түгәрәк эшли. Үзәк инициативасы б-н гармунчылар, гаилә ансамбльләре, татар җырлары һәм биюләре, балалар иҗаты конкурслары, фольклор кичәләре, *Рамазан, Сабан туе* бәйрәмнәре уздырыла. Үзәк хезмәткәрләре татар авылларында мәдәни-агарту эшчәнлеге б-н шөгыльләнүчеләргә методик ярдәм күрсәтәләр, алар б-н семинарлар үткәрәләр, методик ярдәмлекләр, сценарийлар, репертуар планнары, аудио-, видеокассеталар җибәрәләр. 1994 нең ахырында Үзәкнең иҗат коллективлары бетерелә. Хәзерге вакытта Төмәндә «Дуслык» җыр һәм бию ансамбле (1988 дән), Тубылда Арангуловларның «Ләйлә» гаилә ансамбле, Төмән р-нының Ямбай авылында татар мәдәнияте музее эшли. 2014–15 тә Т.ө.ндә Татар мәдәнияте көннәре үткәрелә. 1990 еллардан мөселман җәмгыятьләренең эшчәнлеге яңара. 2010 да Т.ө. терр-ясендә 46 мөселман җәмгыяте теркәлә, 76 мәчет эшли. Вагай, Тубыл, Уват, Яркәү, өлешчә Аромашев һәм Төмән р-ннарында Себер татарларының дини культура истәлекләре — «астаналар» («изгеләр каберлеге»), ш.и. төньяктагы Цингалы астанасы (Ханты-Манси р-нындагы Цингалы а. янында) саклана. Дан орденының тулы кавалеры Х.Х.*Якинның* тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге Т.ө. б-н бәйле.

Әд.: Ю ш к о в И. Сибирские татары. Тобольск, 1861; Т о м и л о в Н.А. Современные этнические процессы среди сибирских татар. Томск, 1978; ш у л у к. Сибирские татары — семейная обрядность народов Сибири: Опыт сравнительного изучения. М., 1980; В а л е е в Ф.Т. Западносибирские татары во второй половине XIX — начале XX в. К., 1980; ш у л у к. Сибирские татары: Культура и быт. К., 1992; В а л е е в Ф.Т., Т о м и л о в Н.А. Татары Западной Сибири: История и культура. Новосиб., 1996; Г а р и ф у л л и н И.Б. Татарская школа Тюменской области: прошлое и настоящее (в документах). Тюмень, 1998; ш у л у к. Очерки истории татарского населения Тюменской области. Тюмень, 2000; Ф а й з р а х м а н о в Г.Л. История сибирских татар (с древнейших времён до начала XX в.). К., 2002; С о к о в а З.Н. Ислам и сибирские татары на современном этапе // Сулеймановские чтения: материалы регион. науч.-практ. конф. Тюмень, 2004.

ТӨМӘН РАЙОНЫ́, *Төмән өлкәсенең* көньяк-көнбатышында урнашкан. 1923 елның 12 ноябрендә оештырыла. Мәйданы — 4,3 мең *км*^{2}. Үзәге — Төмән шәһәре. Халкы — 118123 (1.1.2017), татарлар — 14099 (2010) кеше. Татарлар, тупланып, Ямбай (элеккеге исемнәре — Ямбай Йорты, Олуг-Манчыл), Каскара (Олы Каскара Йорты һәм Кече Каскара Йорты), Муллаш, Нариман, Салаер, Успенка, Шыкча (Шыкча Йорты), Манат, Олы Акъяр (Олы Акъяр Йорты), Талмы, Турай (Турай Йорты, Кече Манчыл), Чаплык, Явызбы (русча Якуши), Янтык (Янтык Йорты) авылларында; Индерәй (Индерәй Йорты), Богандинский, Боровский, Винзили посёлокларында яшиләр. Районның хәзерге күпкенә авыллары борынгы татар авыллары урынына урнашкан, һәм аларның атамаларының тарихы Себер ханлыгы чорына барып тоташа. Иң борынгы авыллар — 13–14 йөзләрдә барлыкка килгән Ямбай, Каскара, Индерәй Йорты, Талмы (Есаулово). Хәзерге татар торак пунктларын нигезләүчеләрнең күбесе *бохари төркиләр* була. Идел буе татарлары Т.р. терр-ясенә 19 йөзнең 1 нче чиregеннән урнаша башлый. Аларның төп шөгыле игенчелек, терлекчелек (ат, сыер, сарык үрчетү), кошчылык, балык тоту, аучылык, киез һәм күннән кием тегү, сәүдә була. Шыкча авылында чүлмәк ясау, тире иләү, йон эрләү, киндер сугу зур үсеш ала. 1841 дә Ямбай Йортында Бохара татары Габделниязов тырышлыгы б-н мәдрәсә ачыла, анда 1870–80 елларда мәшһүр шагыйрь-мәгърифәтче М.*Юмачиков* укыта. 1890 да мәдрәсә яңа ысул б-н укытуга керешә һәм 20 йөз башында Көнбатыш Себердәге абруйлы уку йортларының берсенә әверелә. Мәдрәсәнең зур китапханәсе (1913 тә гарәп, фарсы, татар һәм рус телләрендә 2,2 мең-

ләп том һәм кулъязма исәпләнә), кунакханә, ашханә, медпункт, мунчасы була. Аны иганәчеләр, аеруча Себер татарларының мәдәниятен һәм мәгарифен үстерүдә мөһим роль уйнаган сәүдәгәр һәм меценат *Сәйдуков* Нигъмәтулла (1829–1901) үз хисабына тота. 1914 тә аның акчасына Ямбай Йортында укытучылар семинариясе (укучылары арасында атаклы фольклорчы Х.Х.*Ярми* була) ачыла, 1919 да татар башлангыч мәктәбе (1928 дә — җидееллык, 1952–53 тә урта мәктәп итеп үзгәртелә) эшли башлый. Совет чорында Ямбай, Турай, Олы Акъяр авыллары халык йортларында муз., сәяси, әдәби секцияләр, һәвәскәр театр труппалары эшли. Ямбай һәм Акъяр мәктәпләре пед. коллективлары көче б-н өлкә филармониясе һәм драма театры сәхнәләрендә татар драматургларының әсәрләре сәхнәләштерелә. Т.р. б-н ТР арасында күптәннән мәдәни элемтәләр урнашкан. 1950 елларда татар язучылары, шагыйрь, драматурглары әсәрләрен пропагандалауда А.Г.*Әхмәдуллин*, Ф.М.*Хатипов*, Г.Ф.*Саттаров*, Г.Х.*Әхәтов* зур эш алып бараlар. 1960–80 елларда Төмәндә һәм татар авылларында китап сөючеләр б-н З.*Нури*, Ф.*Хөсни*, А.*Гыйләҗев*, Ш.*Галиев*, Т.*Әйди*, Р.*Фәйзуллин*, Т.*Миңнуллин*, М.*Хөсәен* һ.б. татар язучылары, шагыйрь, драматурглар очрашулары үткәрелә. 1950 еллар башыннан анда татар мәдәниятенең күренекле эшлеклеләре (Ә.Авзалова, И.Шакиров, И.Бикта һиров, З.Билалов, З.Фәрхетдинова, С.Фәтхетдинов, Р.Закиров, З.Хәйретдинов, Илсаф, З.Шәрифуллина һ.б.), Казан, Башкортстан, Мәскәү, Әлмәт, Чаллы, Минзәлә музыка һәм театр коллективлары чыгыш ясый. Казан галимнәре Ф.Т.*Вәлиев*, Д.Г.*Тумашева*, Д.М.*Исхаков*, Г.Л.*Фәйзрахманов* һ.б. Себер татарлары тарихы һәм мәдәниятенә багышланган фәнни докладлар б-н чыга. 1992 дә Т.р.нда Себер татарлары ассоциациясе, 1998 дән Т.р. татарлары милли-мәдәни автономиясе (рәисе Х.К.Биктимеров) оештырыла. Аның тырышлыгы б-н *Сабан туе, Корбан бәйрәме, Ураза бәйрәме*, «Утренняя звезда» («Иртәнге йолдыз») төрки телле балалар иҗат конкурсы үткәрелә; Себер татарларының традицион уеннарын («йөзек салыш», «биш пар», «каптырмак», «каеш», «номер уйнау» һ.б.) яңадан кайтару һәм саклау максатында авылларда «Кичке уеннар» уза. Ямбайда 1994 тән Т.р. тарихы һәм татар мәдәнияте музее, Шыкчада (2000 нән) һәм Индерәйдә (2002 дән) Себер татарларының 19 йөз башыннан бүгенге көнгәчә кадәрге тарихын, мәдәниятен, көнкүрешен чагылдырган авыл музейлары эшли. Ямбайда 2 мәчет — 18 йөз архит-расы истәлекләре сакланган. 2014–15 уку елында Т.р.ның 7 мәктәбендә (Акъяр, Ямбай, Каскара, Индерәй, Янтык, Шыкча, Муллаш) татар теле фән буларак укытыла. Бу мәктәпләрдә укучылар Казанда уздырыла торган татар теле һәм әдәбияты буенча респ-ка олимпиадаларында катнаша, укуны тәмамлагач, ТРның югары һәм махсус урта уку йортларында белем ала. Т.р.нда Ямбай музее каршында «Милли моңнар» татар җыры фольклор ансамбле (1996 да оештырыла), «Ләйсән» балалар вокаль ансамбле (1996), «Күңелле Янтык» бию төркеме (2003), «Энҗе» вокаль ансамбле (2004), Янтык мәдәният йорты каршында «Барбарис» халык музыка уен кораллары ансамбле (2006), Шыкча мәдәният һәм ял үзәге каршында «Шытыр-шытыр» балалар фольклор ансамбле (2007), Каскарада «Юность» мәдәният һәм ял үзәге каршындагы «Синтез» үзешчән бию коллективы (1995), Индерәй посёлогында сәнгать мәктәбе хоры (2000) эшли. Т.р. вәкилләре Татарстанда уза торган конкурс һәм фестивальләрдә («Радуга Сабантуя», «Уйнагыз, гармуннар» һ.б.) катнаша. Сов. Союзы Герое Ә.Р.*Аширбәков*, Дан ордены тулы кавалеры Х.Х.*Якин*, Соц. Хезмәт Герое (1970) Ф.Н.*Ибраһимованың* тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге Т.р. б-н бәйле.

Әд.: Хәбибуллина Л.Б. Себердә татар мәгарифе (XX гасыр). Төмән, 2008; Тюменский район вчера и сегодня: Сб. материалов. Тюмень, 1993; Гарифуллин И.Б. Социально-демографическое развитие татарского населения Тюменской области в годы освоения Севера (1960–1996 гг.). Тюмень, 1997; шул ук. Татарская школа Тюменской области: прошлое и настоящее. Тюмень, 1998; шул ук. Очерки истории татарского населения Тюменской области. Тюмень, 2001.

Л.Р.Сөрмәтова.

ТӨМӘНБАШЫ́, төрки-татар һәм монгол гаскәрендә хәрби җитәкче. *Төмән* б-н җитәкчелек итә; җир биләмәсенә ия, 10 меңлек гаскәрне тупларга һәм походка җибәрергә тиеш була. Сугыш вакытында үз төмәненең гаскәр башы була. Т. вазифаларына үзенә буйсынган терр-я өстеннән күзәтчелек башкару, салым, пошлина җыюны тәэмин итү һ.б. керә. Т. нәселдән күчмә вазифа була.

ТӨМӘ́НОВ (Туминов) Мостафа (Мөхәммәдмостафа) Хәсән улы (4.12.1892, Акмулла өлкәсенең Петропавловск ш. — ?), җәмәгать эшлеклесе. Петропавловск шәһәрендә мәдрәсә (1904) һәм реаль уч-ще (1912) тәмамлый. 1915–17 елларда Мәскәү коммерция ин-тын да укый. 1 нче һәм 2 нче Бөтенроссия мөселманнары корылтайлары делегаты (1917). 1917–18 дә Милли Шура әгъзасы, Мәскәү губернасы Милли Шурасы рәисе. Репрессияләр чоры корбаны: 1938 дә кулга алына, 1940 та 8 елга хезмәт б-н төзәтү лагерьларына ябылуга хөкем ителә (к. *«Милләтчеләрнең Совет хакимиятенә каршы оешмасы» эше*). Сөргендә вафат була. 1955 тә аклана.

Д.М.Госманова.

ТӨН КҮГӘРЧЕННӘРЕ́ (Caprimulgus), төн күгәрченнәре семьялыгыннан эңгер-меңгер һәм төнге кошлар ыругы. 46 төре билгеле, Евразия һәм Төньяк-Көнбатыш Африкада таралганнар. ТР терр-ясендә бер төре — гади Т.к. (C. europaeus) бар. Татарстанның бөтен терр-ясендә очрый. Урманнарда, урман буйларында, кисенделәрдә һәм аланнарда яши. Оя коручы күчмә кош. Майда очып килә. Респ-ка урманнарында рекреацион йөкләнеш һәм көтү йөрү сәбәпле, саны кими бара. Гәүдә озынлыгы 25–30 *см*, авырлыгы 70–80 *г*. Каурыйлары йомшак, аркасы кара һәм аксыл буй сызыклы соргылт-көрән төстә, корсагы кара тимгелле җирән-көрән. Канаты һәм койрыгы озын, ата затларның каурый капламы төнлә дә күренә торган зур ак таплы. Томшыгы кечкенә, очы бөгелгән, авыз кырыенда кыллар бар. Кош көндез көчсез. Берни дә түшәлмәгән оя-чокырчыгы җирдә. Кара тимгелле ике соры йомырка сала. Балалары июнь ахыры — июль башында чыга. Т.к. төнлә яки эңгер-меңгердә очучы бөҗәкләр б-н тукланалар, ятьмә кебек авызлары ярдәмендә аларны җиңел аулыйлар. Зарарлы бөҗәкләрне юк итәләр. Август ахырында кышларга очып китәләр. Гади Т.к. ТРның Кызыл китабына кертелгән.


ТӨН МИЛӘҮШӘСЕ́ (Platanthera), сәхләбчәләр семьялыгыннан бер- яки күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 50 дән артык (башка мәгълүматлар буенча якынча 200) төре билгеле, Төньяк ярымшарда таралганнар. ТР терр-ясендә бер төре — ике яфраклы Т.м. (P. bifolia) үсә; барлык (ешрак — көньяк) районнарда зур булмаган төркемнәрдә очрый. Урман аланнарында, куаклыкларда үсә. 25–40 *см* биеклектәге күпьеллык үсемлек. Тамыры бүлбесыман. Сабагы киң эллипс формасында яхшы үскән 2 яфраклы. Чәчәкләре ак, вак, цилиндрсыман чүк чәчәк төркемендә, төнгә һәм яңгыр алдыннан көчәюче хуш исле. Җимеше — бик күп вак орлыклы тартмачык. 6–8 ел үскәннән соң гына, май ахыры — июньдә чәчәк ата. Орлыклары июнь–августта өлгерә. Орлыктан һәм вегетатив юл б-н үрчи. Медицинада «салеп» дип йөртелүче киптерелгән яшь тамыр-бүлбеләрен кулланалар. Составында лайла, крахмал, шикәр, аксым һ.б. матдәләр бар. Тамыр-бүлбеләрдән ясалган дарулар агуланганда, хроник гастрит, ашказаны һәм уникеилле эчәк җәрәхәте авыруларын дәвалау чарасы буларак кулланыла. Декоратив, баллы үсемлек. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

ТӨН ЯРКАНАТЛАРЫ́, күбәләкләр семьялыгы; к. *Ябалакчыклар*.

ТӨН ЯРКАНАТЛАРЫ́ (Myotis), шомаборынлы ярканатлар семьялыгыннан имезүчеләр ыругы. 60 тан артык төре билгеле, Евразиядә таралганнар. ТР терр-ясендә 5 төре бар: гади яки Брандт Т.я. (M. brandti), су Т.я. (M. daubentoni), Наттерер Т.я. (M. nattereri), мыеклач Т.я. (M. mystacinus), буа Т.я. (M. dasycneme). Фауна өчен сирәк төрләр. Сулыклар янында, елга тугайларында, ш.у. урманнарда, урман ерымнарында, агач куышларында, корылмаларда колония булып һәм аерым да яшиләр. Мыеклач Т.я.ның (Татарстанда очрый торган Т.я. арасында иң кечкенәсе) озынлыгы 39–46 *мм*, канатлары 35–37 *мм*; буа Т.я.нының (иң зурысы) — яшлы рәвештә 62 *мм* га кадәр һәм 49 *мм*. Канатлары киң, кыска, җәенке. Колаклары чагыштырмача озын. Төрле-төрле төсмерле коңгырт: тонык-коңгырттан зәйтүнсыман-көрәнгә кадәр төстә. Эңгер-меңгердә ауга чыга. Кискен борылышлар ясап, тиз оча. Парканатлылар, челтәрканатлылар, көнлекчеләр, вак коңгызлар б-н туклана. Ана затлар җәен 1–2 бала тудыра. Барлык төрләре дә ТРның Кызыл китабына кертелгән.

ТӨНБОЕ́К, суаләсе (Nymphaea), төнбоекчалар семьялыгыннан күпьеллык су үсемлекләре ыругы. 50 дән артык төре бил-

геле, бөтен Җир шарында таралганнар. ТР терр-ясендә 2 төре бар. Ап-ак Т (N. candida) — бөтен респ-када агымсыз һәм әкрен агымлы сулыкларда, ак Т. (N. alba) Зөя һәм Чишмә елгаларында очрый. Сабаксыз үсемлек, сулык төбендә ку ағле горизонталь тамырчалы һәм су өслегендә йөзеп йөрүче цилиндрсыман озын сапларда урнашкан ялтыравык йөрәксыман озынча-түгәрәк зур яфраклы. Чәчәк бөреләре ачылганнан соң, озын чәчәк сапларында күп таҗ яфракчыклы йөзеп йөрүче берәр-берәр ак чәчәкләр



Төнбоек.

күренә башлый, алар кичен йомылып суга күмеләләр, иртән яңадан калкып чыгып ачылалар (яңгырлы көннәрдә көндез дә ачылмыйлар). Ак Т.ның касәсе түгәрәк нигезле, ап-ак Т.ныкы — 4 кырлы. Июнь–августта чәчәк аталар. Чәчәк атып бетергәннән соң, чәчәк сабы бөтерелә, җимеше суда үсә. Җимешләре — аркылы җөйле күп орлыклы зур тартмачык. Август–октябрьдә өлгерәләр. Үсемлек составында эфир мае, гликозид, алкалоид, дуплау матдәләре, крахмал, глюкоза бар. Халык медицинасында тынычландыру, йоклату, авыртуны басу чарасы, тән кызышканда, ш.у. тире ялкынсынуын дәвалауда кулланыла. Тамырчасы һәм орлыклары су кошлары, кондыз, ондатра һ.б. терлек ияләре өчен азык булып тора. Декоратив үсемлекләр. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

ТӨНГӘ КОПР (Copris lunnaris), пластинкамыеклылар семьялыгыннан тирес коңгызлары өссемьялыгындагы коңгыз. Россиянең урта полосасында һәм аеруча Көньяк Европа өлешендә шактый еш, Татарстан терр-ясендә сирәк очрый. Аерым затлары Кама алды, Идел буе калкулыгы һәм Кама аръягы уйсулыкларының урман-дала зонасында, Идел-Кама саклаулыгының Саралан һәм Раифа участокларында билгеләнә. Гәүдәсенең озынлыгы 15–25 *мм*, ялтыравыклы кара яки коңгырт-кызыл төстә. Ата затның башында — мөгез, алгы сыртында — икегә бүленгән төер, аның ян-якларында зур 2 чыгынты урнашкан. Ана затларның мөгезе кыска тупыйк башлы. Ана һәм ата зат тирес астында җирдә куышчык казыйлар, анда тирес кертәләр, аннан исә озынча-түгәрәк 5–8 зур «груша» ясыйлар, ана зат аларның тар башына берәр күкәй сала. Личинкалары «груша» эчендә туклана һәм үсәләр, олы затлар токымны саклап һәм яшь коңгызларның чыгуын көтеп куышчыкта калалар. ТРның Кызыл китабына кертелгәннәр.

ТӨНЛӘ КҮРҮ́ ПРИБОРЛАРЫ́, түбән яктыртылу шартларында күзәтү өчен оптик-электрон җайланмалар, Т.к.п.ның төп элементлары — объектив, югары вольтлы ток чыганагы блогы булган электрон-оптик үзгәрткеч (ЭОҮ), окуляр. Күзәтелә торган объекттан кайтарылган яктылык объектив аша ЭО Үнең фотокатодына тапшырыла. Фотокатод чыгарган электроннар электр кырында тизләнүләре хисабына зур кинетик энергия алалар һәм, люминофор б-н капланган экранга әләгеп, люминесценция китереп чыгаралар; бу вакытта экраннан нурланган фотоннар саны фотокатодка эләккәннәре саныннан күп тапкырлар арта (ЭО Үнең көчәйтү коэффициенты).

Гамәлдәге классификация буенча 1 нче буын (яки 0 нче буын), 2 нче, 2 нче$^+$, 3 нче, 3 нче$^+$ буын ЭОҮ аерылып күрсәтелә. 1 нче буын ЭОҮтә (көчәйтү коэффициенты 200 тәртибендә) электрон бәйләмен тизләтү һәм люминесцент экранга фокуслау өчен электрод кулланыла. 2 нче буын ЭОҮтә аның урынына күпсанлы микроканаллары булган ток үткәрүчән пластина кулланалар, микроканалларда зуррак электр кыры көчәнешлелеге хасил була һәм ул көчәйтү коэффициентын арттыра. Интеграль (пакетлы) төзелешле 2 нче$^+$ буын модельләрендә фотокатод, микроканаллы пластик һәм экран аралары кимителә, шунлыктан электр кырының тыгызлыгы һәм тиңдәшле рәвештә көчәйтү коэффициенты зурая. 3 нче буын ЭОҮтә фотокатод аның спектраль сизгерлеген артты ра торган материаллардан эшләнә. 1 нче буын ЭОҮ нигезендә эшләнгән Т.к.п. — йолдызлар һәм сурән ай яктысында, ә хәзергеләре болытлар булганда да күзәтүләр алып барырга мөмкинлек бирә.

1950 еллар ахырында Т.к.п.н әзерләү эшләре *Казан оптика-механика заводы* тәҗрибә КБда (хәзер Федераль «ЦКБ «Фотон» ДУП) башлана. Пр-тиедә 1 нче буын ЭОҮ нигезендә — «Дуэт» күчмә күзәтү приборы (разведка өчен), БН-1 бинокле (1960 еллар); 2 нче буын ЭОП нигезендә — үтә җиңел ПВН-1 күзлекләре, БН-2 бинокле, автомат корал өчен 1ПН 83 төзәгечләре (1970–90 еллар); 2 нче$^+$ һәм 3 нче буын ЭОҮ нигезендә БН-3 бинокле; диңгез һәм яр буе объектларына караган катлаулы оптик-электрон күзәтү комплексы модульләре, гражданнар бинокльләре һәм «Байгыш» аучылык төзәгечләре нең 12 нче моделе (1990 еллар уртасы) җитештерелә. Т.к.п.ның яңа үрнәкләрен булдыру эше микроэлектроника, 3 нче буын ЭОҮ һәм зарядлы бәйләнеш приборларын кулланы б-н бәйле. Т.к.п.н төзүдә уникаль функциональ модульләр нигезендә модульле конструкцияләүгә күчү бара. Т.к.п.н эшләүгә пр-тие хезмәткәрләре А.В.Краснов, А.А.Гәрәев, В.И.Костюкевич, Л.В.Чернов, Б.И.Кондратьев, Р.К.Сафин, А.Т.Троценко, И.Х.Галиева, Д.Б.Равдель һ.б. зур өлеш кертә. Үзәк «Фотон» КБнда эшләнгән һәм Казан оптика-механика з-дында сериялэп җитештерелгән Т.к.п. РФ армиясен һәм флотын коралландыруга кабул ителгән, чит илләргә чыгарыла.

Әд.: Казанский оптико-механический завод. 1940–2000. К., 2000.

ТӨНЬЯК БА́НКЫНЫҢ КАЗА́Н БҮЛЕГЕ́. 1901 елның гыйнварында финанс базарындагы эшчәнлек өлкәсен киңәйтү һәм клиентларга хезмәт күрсәтүне тизләтү максатыннан ачыла. Сәнәгать һәм сәүдә пр-тиеләре, шәхси затларга кредит бирү, акча туплау һәм финанс базарында операцияләр башкару б-н шөгыльләнә. 1909 да Казан бүлегенең кереме 113 мең сумга якын була. 1911 нең гыйнварында ябыла.

ТӨНЬЯК КАВКА́З АСТРОНО́МИЯ СТА́НЦИЯСЕ, Казан ун-тының системалы рәвештә астрономик күзәтүләр һәм тикшеренүләр алып баручы фәнни-укыту бүлекчәсе. 1975 елда Зеленчук станциясеннән (Карачай-Чиркәс Респ-касы) 40 *км* дагы А.В.Пастухов тавында — диңгез өсте тигезлегеннән 2000 *м* биеклектә урнашкан. Астрономик климат елның 150–200 төнендә, бигрәк тә көзге-кышкы чорда, аеруча аяз атмосфера шартларында күзәтүләр алып бару мөмкин леге бирә. Станция астрономик күзәтүләр үткәрү, ш.у. студентлар һәм аспирантларны астрономик җиһазлар б-н эшләргә өйрәтү максатында төзелә; «Цейс-400», АЦУ-26 телескоплары, автомат телескоплар б-н җиһазландырылган. Фотога төшерү һәм фотоэлектрик алымнар ярдәмендә станциядә күп кенә күк җисемнәренең төгәл урыннары һәм яктылыклары билгеләнә. Галлей кометасы, зур һәм кече планеталар, Марс, Юпитер, Сатурн иярченнәре, үзгәрүчән йолдызлар тикшерелә. Станция хезмәткәрләре көньяк һәм төньяк күкнең координат системаларын төзү б-н бәйләнгән халыкара ФОКАТ һәм ФОН проектларында (1982–88); Галлей кометасына (1985–86) һәм Марс иярченнәренә (1986–87) очучы космик аппаратларның координатларын тәэмин итү буенча ВЕГА һәм ФОБОС проектларында катнашалар. Казан ун-тының астрономия станциясе — РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы системасының Россия терр-ясендә тау обсерваториясе булган бердәнбер фәнни-укыту бүлекчәсе; биредә студентлар һәм мәктәп укучылары өчен җәйге лагерьлар оештырыла; слётлар һәм олимпиадалар (халыкараларын да кертеп) үткәрелә. СССР Космонавтика федерациясенең махсус дипломы б-н бүләкләнә (1986).

М.И.Шпекин, В.Я.Соловьёв.

ТӨНЬЯК ТАТА́Р ГӨМБӘЗЕ́, Көньяк Татар гөмбәзе б-н берәттән Көнчыгыш Европа платформасының иң зур структур формасы булып тора. Төзелешләре буенча Төньяк Татар һәм Көньяк Татар гөмбәзләре күп кенә уртак һәм үзләренә генә хас аерым билгеләргә ия. Уртак билгеләре: рифей-венд утырмаларының булмавы; кристаллик нигезнең һәм өстәрәк ятучы структураларның күтәренке торышы. Аерым билгеләре: Көньяк Татар гөмбәзе б-н чагыштырганда, Т.Т.г.нең девон терриген утырмалары юка катламлы; Т.Т.г. субмеридиональ һәм төньяк-көнчыгыш юнәлешле блокларга ергаланган, ә Көньяк Татар гөмбәзе кристаллик нигезнең субмеридиональ юнәлешле блоклар комбинациясеннән гыйбарәт. Көньяк Татар гөмбәзенең

утырма тышлыгындагы углеводородлар тупланышы Т.Т.г.нең нефть-газ потенциалынан шактый югары. Көньяк Татар гөмбәзенең терриген девон структурасында эре Ромашкино гөмбәзе аерылып тора, аңа уникаль Ромашкино нефть чыганагы туры килә.

ТӨНЬЯК ТӨРБӘ, Болгар шәһәрендәге Алтын Урда дәвере болгар архит-расы истәлеге. Борынгы төрбә 1330 елларда *Болгар җәмигъ мәчетенең* төньягында төзелә. Сәлҗүк архит-расы стиле сыйфатларын саклый. Формасы буенча Алтын Урда дәверенең башка



Төньяк төрбә. 1330 еллар. Болгар тарих-архитектура музей-саклаулыгы. Хәзерге күренеше.

төрбәләренә якын тора. Пландагы турыпоч-маклы таш дурткырлык авыш почмаклар аша сигез кырлы түбәле сигезкырлыкка күчә. Эчке квадрат бина (9,5×9,5 *м*) почмак тромплары аша гөмбәзсыман түбә б-н ябылган. Элек аның өстендә пирамидаль таш түбә калкып торган. Төрбәнең уксыман ишек уемы көньяк фасадта урнашкан (элек 6,5 *м* киңлектә һәм 4,5 *м* тирәнлектәге чыгынтылы төп ишек булган). Калган өч диварны зур булмаган уксыман-а́ркалы тәрәзәләр бизәгән (соңрак ташлар б-н томалап куелган). 1,7 *м* калынлыктагы диварлар эчтән тупас эшкәртелгән известь һәм туф ташлары б-н ныгытылган (вак таш кушылган известьле измә), эчтән — туф, тыштан известь тышлык б-н капланган. Портал җентекләп шомартылган блоклар б-н тышланган, аның вертикаль кисемнәре һәм орнаментлы бизәкләре булуы да ихтимал. Бинаның пирамидаль түбәсе, тышлыгы һәм порталы сакланмаган. Хәрабәләре 18 йөздә Успение монастыре өчен файдаланылган, Т.т.нең «Монастырь базы» дигән башка исеме дә булган. 1968–69 елларда С.С.Айдаров җитәкчелегендә консервация һәм фрагментар реставрация үткәрелә.


Әд.: Город Болгар: Монументальное строительство, архитектура, благоустройство. М., 2001.

Х.Г.Надыйрова.

ТӨ́НЬЯК-КӨ́НБАТЫШ МАГИСТРА́ЛЬ НЕФТЬ ҮТКӘРГЕЧЛӘРЕ́ (ТКМНҮ), нефтьне транспортлау һәм саклауны, магистраль үткәргеч торбалардан һәм технологик объектлардан файдалану һәм аларны капиталь ремонтлауны гамәлгә ашыручы пр-тие; РФнең «Транснефть» нефть транспортлау акц. компаниясенең иң зур бүлендек пр-тиеләреннән берсе. 1949 елда Куйбышев тимер юллары Келәүле станциясендә Татар-стан нефть үткәргечләр конторасы буларак нигезләнә. 1951 дән Татарстан товар-транспорт идарәсе (Бөгелмә ш.), 1955 тән Татар-стан, 1963 тән Төньяк-көнбатыш нефть үткәргечләр идарәсе, аңа 1953 тә оешкан Төзелүче нефть үткәргечләр дирекциясе кушыла. 1970 тән — Төньяк-көнбатыш магистраль нефть үткәргечләр идарәсе, 1991 дән Төньяк-көнбатыш магистраль нефть үткәргечләр ҖБ дип үзгәртелә. 1994 тән хәзерге исемдәге АҖ (2001 дән үзәк офисы Казанда).

Баштагы чорда пр-тие Шөгер–Келәүле һәм Байтуган–Келәүле нефть үткәргечләре (озынлыгы 66,5 *км*, диаметры 200–250 *мм*), насослар бүлеге, Келәүле станциясендәге нефть салу эстакадасы, Ульянов нефть базасы составында нефтьне тимер юл транспортына тутыру, аннары Ульянов шәһәрендә тимер юл транспортыннан елга транспортына күчерү б-н шөгыльләнә. Яңа нефть чыганакларын үзләштерү һәм нефть чыгару күләмен арта бару нәтиҗәсендә магистраль нефть үткәргечләр, нефть кудыру станцияләре, резервуарлар төзү киң колач ала. 1950 елларда Әлмәт–Горький-1, Ромашкино–Куйбышев, Әлмәт–Миңлебай–Ромашкино, Сөбханкул–Азнакай, Әлмәт–Пермь нефть үткәргечләре төзелә (торбаларның диаметры 350–500 *мм*). 1960 елларда 800–1000 *мм* диаметрлы магистраль нефть үткәргечләр файдалануга тапшырыла: Әлмәт–Горький-2, 3, Әлмәт–Куйбышев-1, 2, Горький–Ярославль, Ярославль–Кириши, Горький–Рязань-1,2, Рязань–Мәскәү, Чаллы–Әлмәт, Азнакай–Әлмәт, Чакмагыш–Азнакай, Оса–Пермь. 1964 тә Татарстан нефте «*Дуслык*» нефть үткәргече буенча озатыла башлый. Безнең илнең үткәргеч торбалар транспортында беренче тапкыр 820 һәм 1020 *мм* диаметрлы торбалар кулланыла, 10 мең *м*³ күләмле җир астына күмдерелгән тимер-бетон резервуарлар төзелә, нефть кудыру станцияләрендә пар һәм дизель двигательләре, пешкәкле насослар урынына үзәктән куулы насослар, электр двигательләре кулланыла башлый. Шул ук вакытта нефть үткәргечләрне һәм нефть чыгару станцияләрен автоматлаштыру, күп хезмәт таләп ителә торган эшләрне механикалаштыру зур үсеш ала; телемеханиканың тәҗрибә системаларын кертү, басымны көйләү, резервуарлар паркын автоматлаштыру эшләре башлана. 1970 елларда Усть-Балык–Курган–Уфа–Әлмәт трансконтиненталь нефть үткәргече (1973, торбалар диаметры 1200 *мм*; нәтиҗәдә, нефть Көнбатыш Себердән илнең үзәк районнарына һәм чит илләргә җибәрелә башлый), илнең иң төньяк нефть үткәргече Уса–Ухта–Ярославль һәм Сургут–Полоцк нефть үткәргече сафка кертелә. Экспорт өчен Көнбатыш Себер һәм Татарстанның эшкәртелмәгән нефтьләрен кушу технологиясе эшләнә һәм гамәлгә кертелә, җитештерү процессларын автоматлаштыру һәм телемеханикалаштыру эшләре зур масштабта үткәрелә, 20 мең *м*³ сыйдырышлы корыч резервуарлар төзелә, торба үткәргечләр торышына иртә диагностика ясау өчен яңа технологик чаралар кертелә. 1980 елларда Холмогор–Клин нефть үткәргече файдалануга тапшырыла; йөзмә капкачлы һәм 50 мең *м*³ сыйдырышлы корыч резервуарлар, нефть үткәргечләрне һәм җиһазларны ремонтлау өчен яңа технологияләр һәм җайланмалар, коррозиядән электрохимик саклау алымнары гамәлгә кертелә. Тармакта бе-

«ТӨНЬЯК-КӨНБАТЫШ МАГИСТРАЛЬ НЕФТЬ ҮТКӘРГЕЧЛӘРЕ» АҖнең НЕФТЬ ҮТКӘРГЕЧЛӘРЕ СХЕМАСЫ



ренче тапкыр нефтьнең җи ңел фракцияләрен тотып калу технологиясе эшләнә һәм кулланыла, шуның нәтиҗәсендә аның резервуарлардан югалуы 90–95% ка кими. Пр-тие нефть үткәргечләренең озынлыгы (*км*): 1951 дә — 209, 1955 тә — 689,5, 1960 та — 1893,9, 1970 тә — 6100, 1976 да — 7000, 1985 тә — 7122,8; барлыгы 10 мең *км* дан артык нефть үткәргеч төзелә, аларның бер өлеше төрле елларда башка оешмаларга (Главтранснефть системасында һәм нефть чыгаручыларга) бирелә, 1955–90 елларда резервуарлар паркы 66,4 мең $м^3$ дан 2,08 млн. $м^3$ га кадәр арта. 1951–88 елларда нефтьне еллык кудыру күләме 860 мең *т* дан 267,7 млн. *т* га җитә.

1997 дә кулланучыларга 132,6 млн. *т* нефть тапшырыла. 1990 еллар ахырыннан, нефть чыгару күләме үсә бару сәбәпле, ТКМНҮн дә нефть үткәргечләр транспорты объектларын реконструкцияләү, техник үзгәртеп кору һәм капиталь ремонтлауның комплекслы программалары гамәлгә ашырыла; алар икътисади нәтиҗәле, хәвеф-хәтәрсез эшләүне һәм экологик куркынычсызлыкны тәэмин итүгә юнәлдерелгән. Нефтьне күчерү һәм саклауның барлык процесслары б-н идарә итү һәм тикшерүнең коммуникатив технологияләре үсеш ала. Су асты күчешләрен реконструкцияләгәндә, үткәргечләрне авыш юнәлешле бораулау алымы б-н траншеяларсыз салу кулланыла, сазлыклы урыннарда торбалар аеруча нык изоляцияләнә. Су асты күчешләрендәге авария нәтиҗәләрен бетерү өчен, махсус чаралар һәм технологияләр (бон киртәләре, нефть җыйгычлар һ.б.) эшләнә һәм сериялап җитештерүгә кертелә. Резервуарларны реконструкцияләгәндә үтә нык изоляция материаллары, камиллэштерелгән сулагыч клапаннар, кайтаргыч дисклар, зарарлы матдәләр чыгаруны булдырмау өчен газ тигезләү системалары, катлам асты янгын сүндерү һәм сугару системалары кулланыла.

2010 га ТКМНҮнә 6 мең *км* тирәсе озынлыктагы (ш.и. 235 *км* су асты күчеше) магистраль нефть үткәргечләр челтәре (шуларның 1/3 е ТР терр-ясе буйлап үтә, картаны к.), 50 нефть кудыру станциясе, гомуми сыйдырышлыгы 1,56 млн $м^3$ булган резервуарлар паркы керә. Кудырыла торган нефтьнең еллык күләме 277 млн. *т* (2010). ТКМНҮ нефтьне турыдан-туры аны чыгаручылардан — «Татнефть», «Удмуртнефть» АҖләрдән, «Лукойл-Пермь» ҖЧҖтән һ.б.дан ала, Башкортстанда, Көнбатыш Себердә табылган нефтьне күчерә, аны нефть эшкәртү һәм нефть химиясе пр-тиеләре: «ТАИФ-НК» (Түбән Кама ш.), «ЛУКойл-Пермьнефтеоргсинтез» ҖЧҖ һ.б.га тапшыра. Эшчәнлек чорында пр-тие тарафыннан 6 млрд. *т* нефть кудырыла.

ТКМНҮнең төп структур бүлекчәләре — Казан, Әлмәт, Удмурт (Ижевск ш.), Ромашкино (Лениногорск ш.) район нефть үткәргеч идарәләре, куркынычсызлык хезмәте. Пр-тие ТР торак пунктларын социаль үстерүгә зур өлеш кертә: 300 мең $м^2$ тирәсе торак, 1375 урынлык 19 мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениесе, 8 гомуми белем бирү, музыка һәм спорт мәктәбе, поликлиника һ.б. объектлар төзелә.

2015 тә пр-тие «Транснефть-Кама алды» («Транснефть-Прикамье») итеп үзгәртелә. «Почёт билгесе» ордены (1976), СССР ВДНХсы медальләре б-н, күп тапкырлар СССР Нефть сәнәгате министрлыгы һәм тармак профсоюзлары ҮКның күчмә Кызыл байрагы б-н бүләкләнә. Күп кенә хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә лаек була.

Җитәкчеләре — Б.П.Павлов (1949–51), А.Ф.Шестаков (1951–55), З.Л.Конторович (1955–58), В.П.Стрижков (1958–63, 1969–79), И.Т.Зоненко (1963–69), Ә.К.Мөхәммәтҗанов (1979–80), С.П.Лебедич (1980–2001), Ф.Р.Хәйдәров (2001–05), Р.Н.Хисаев (2005–06), А.А.Усманов (2006–07), Р.Н.Хәкимов (2007–16); Р.А.Галиев (2016 дан).

Әд.: Корчагин В.В. Хозяева подземных магистралей. К., 1999.

А.А.Бус, Н.М.Баянова.

ТӨНЬЯК-КӨНЧЫГЫШ АРХЕОЛОГИЯ ҺӘМ ЭТНОГРАФИЯ ИНСТИТУТЫ, Казандагы югары уку йорты. Археол., археография һәм этнография бүлекләре составында фәнни кадрлар әзерләү һәм фәнни тикшеренүләр оештыру өчен, Халык мәгарифе министрлыгының 1916 ел 30 ноябрь нигезләмәсе б-н 1917 елның 4 октябрендә ачыла, 1919 да Көнчыгыш филологиясе бүлеге өстәлә. Укытучылар арасында — Н.Ф.Катанов, С.Е.Малов, Н.В.Никольский, Казан ун-ты һәм Казан руханилар академиясе профессорлары. Студентлар саны — 100 дән 200 гә кадәр, ш.и. якынча 20 се — татар һәм 30 ы — Идел буендагы башка халыклар вәкилләре. Гражданнар сугышы шартларында да ин-т этнографик һәм археографик тикшеренүләрен дәвам итә. 1919 да аңа Казан губернасындагы архив эше б-н җитәкчелек итү тапшырыла; ин-т профессорлары һәм студентларының, беренче чиратта И.А.*Стратонов* һәм К.В.*Харламповичның* тырышлыгы б-н рев-циягә кадәрге губерна һәм шәһәр учреждениеләренең, Казан руханилар академиясенең һ.б.ның архивлары саклана. 1921 нең июлендә ин-т *Шәрекъ академиясе* итеп үзгәртелә. Директорлары — С.П.Покровский (1917–18), М.В.Бречкевич (1919–21).

Әд.: Известия Северо-восточного археологического и этнографического института в Казани: В 2 т. К., 1920–21; Зайцев А.В. Исторические учреждения Республики Татарстан в 20–30-е годы XX века. К., 1998.

ТӨПЛӘНДЕРҮ (коренизация), 1920–30 елларда Коммунистлар партиясе һәм Совет дәүләтенең СССР милли респ-каларындагы милли сәясәтенең совет, мәхкәмә, җәмәгать һәм ху җалык органнарында җаваплы һ.б. хезмәткәрләр вазифаларын төп халыклар вәкилләре биләүдә, ш.у. эш кәгазьләрен рус телен б-н берәттән әлеге халыкларның туган телләрендә алып баруны оештыруда махсус чаралар башкаруны күздә тоткан юнәлеше.

Үзәктә һәм урыннарда бу программаны гамәлгә ашыруга киң халык массаларын җәлеп итү өчен, төп халыкларның телен, гореф-гадәтләрен, традицияләрен һәм психологиясен белгән кадрлар кирәклегеннән чыгып эш йөртәләр.

Татар телен эш кәгазьләре өлкәсенә кертү буенча кампания Гражданнар сугышы тәмамлангач ук башлана. Беренче тапкыр бу мәсь әлә 1921 нең 14 февралендә ТАССР ҮБК Президиумы утырышында карала, анда респ-каның барлык партия һәм дәүләт органнарында эш кәгазьләрен алып баруга татар телен мәҗбүри кертү турында карар кабул итәләр. 1921 нең 25 июнендә татар телен респ-каның совет учреждениеләрендә эш кәгазьләрен алып баруга кертү турында Декрет кабул ителә, ул ҮБК Президиумы рәисе Б.Х.Мансуров һәм ТАССР ХКС рәисе С.С.Сәетгалиев тарафыннан имзалана. Бу эшне оештыру өчен ТАССР ҮБК каршында махсус *Татар телен гамәлгә кертү комиссиясе* төзелә, аңа «барлык татар мәдәни көчләрен» үстерү һәм файдалану, ш.у. ТАССР Мәгариф халык комис-ты б-н берлектә «татар мәдәният хезмәткәрләренең татар телен һәм хезмәт ияләренең милли көнкүрешен белгән яңа кадрларын» әзерләүне тәэмин итү йөкләнә. ТАССР ҮБКның 1922 ел 13 май карары нигезендә ш.у. кантоннарда да шундый комиссияләр оештырыла.

Татарлардан җитәкче хезмәткәрләр әзерләү өчен, 1921 нең гыйнварында РКП(б) өлкә ком-ты каршында өч айлык партия мәктәбе, февральдә татар, мари һәм чуаш секцияләре булган Шәрекъ халыкларының Югары партия өлкә мәктәбе ачыла. 1922 дә Казанда Татар коммунистлар ун-ты оештырыла (1932 дә Татар югары коммунистлар а.х. мәктәбе итеп үзгәртелә).

1921–22 дәге ачлык Т. буенча эшләрне җәелдерүгә комачаулый, ләкин 1922 нең ахырыннан ук алар зур колач ала башлыйлар. 1923 нең августында РКП(б) ҮКның оештыру бюросы РКП(б) Татарстан өлкә ком-ты секретареның Татарстанда партиянең милли сәясәтен гамәлгә ашыруның барышы турындагы хисабын тыңлый һәм җирле халыкны җитәкче совет органнарына җәлеп итү, «соңгыларын татар телен дәүләтләштерү юлы белән татар халкына якынайту эше канәгатьләнерлек» дип таный. Бу эшнең уңай нәтиҗәләре конкрет фактларда күренә (к. табл.).

Җирле советларның башкарма комитетлары хезмәткәрләре арасында татарлар, %

	1922	1923	1924	1925
Волость башкарма ком-тларында	40,4	46,3	51,4	52,0
Кантон башкарма ком-тларында	34,4	41,4	51,7	52,0

Респ-ка учреждениеләрендә дә татарларның саны арта: 1921 дә алар өлешенә 7,8% туры килсә, 1925 тә бу күрсәткеч 15,5% тәшкил итә. ТАССР ҮБКның һәм ХКСның 1923–24 еллардагы эшчәнлеге турындагы хисапта 1924 тә татар авыл советларының инде 80% ы эш кәгазьләрен туган телдә алып баруы, татарлар сан ягыннан өстенлек иткән волостьларның күпчелегендә дә эш кәгазьләренең татар теленә күчүе билгеләп үтелә.

1924 нең ноябрендә ТАССР Мәгариф халык комис-тының *Академүзәге* барлык совет

учреждениеләрендә, мәктәпләрдә һәм татар матбугатында реформалаштырылган *гарәп язуы* — «Яңа имля» кулланылырга тиешлеге турында карар бастырып чыгара. Шул елларда ТАССР да, илнең төрки телле респ-калары арасында беренче тапкыр яңа орфографиягә нигезләнгән язу машиналары җитештерү җайга салына, ә 1929 дан, латин язуына күчү сәбәпле, «Яңалиф» язу машиналары чыгарыла башлый.

Милли кадрлар әзерләү өчен, эшче ф-тлар, совет һәм партия мәктәпләре файдаланыла, эшче һәм крәстиян яшьләр респ-кадагы һәм илебезнең башка өлкәләрендәге югары уку йортларына җибәрелә. 1924/25 уку елында респ-ка югары уку йортларын 680 кеше тәмамлый, шулар арасында нибары 8 татар була; 1925/26 да — шул ук нисбәттә 886 һәм 37, 1926/27 дә — 548 һәм 35 кеше. Махсус урта уку йортларын тәмамлаучылар арасында татар яшьләре күбрәк була: 1924/25 уку елында аларны барлыгы 403 кеше тәмамлый, шуларның 127 се татар була; 1925/26 да — шул ук нисбәттә 525 һәм 119, ә 1926/27 дә — 453 һәм 113 кеше. ТАССР Мәгариф халык комис-ты мәгълүматлары буенча, 1927 дә татарларны һәм респ-кадагы башка милләт вәкилләрен укыту өчен, Мәскәү, Ленинград, Түбән Новгород, Томск, Свердловск, Самара, Саратов югары уку йортларында индустриаль-техник белгечлекләр буенча 17 урын (аларда 13 татар һәм 3 башка милләт вәкилләре укый), а.х. белгечлекләре буенча 30 урын (шул ук нисбәттә 7 һәм 7), пед. белгечлекләр буенча 25 урын (5 һәм 8), мед. белгечлекләре буенча 30 урын (2 һәм 9) билгеләнә.

1928 нең октябрендә ТАССР ҮБК Президиумы Казан ун-тында совет төзелеше һәм хокукы ф-тын, 1931 нең маенда респ-калар, крайлар, өлкәләр, районнар һәм шәһәрләр советлары җитәкче хезмәткәрләрен һәм инструкторларын әзерләү өчен аның җирлегендә Совет төзелеше ин-тын (1936 ның июнендә ябыла) ачу турында карар кабул итә. Шул ук елда Казан совет хокукы ин-ты (1936–52 дә Казан юридик ин-ты) оештырыла.

Т. сәясәтен гамәлгә ашыру татар булмаган халыкның бер өлеше тарафыннан сагаеп кабул ителә, ул төрле милләт вәкилләренә тигез карамау һәм рус кадрларын кысыклап чыгару, татарларга чиктән тыш өстенлекләр бирү буларак аңлана. Асылда исә, квалификацияле татар кадрлары җитенкерәмәү сәбәпле, 1920 елларда да, 1930 елларда да респ-када партия һәм совет органнары аппаратларында тирән Т. уздырылмый. 1930 елларның 2 нче яртысыннан Сталин репрессияләре башлану б-н, Т. эше тагын да катлаулана, чөнки алар иң элек нәкъ менә татар милли интеллегенциясенә кагыла (к. «*Сәлтангалиевчелек», «Атласов» эше, «Троцкийчы милләтчеләрең контрреволюцион-террорчылык оешмасы» эше*). Бөек Ватан сугышы елларында респ-ка халкы гаять зур югалтулар кичерә, нәтиҗәдә, ТАССРда 1948 дә эшләгән югары белемле 12403 белгечнең нибары 2141е (17%), югары урта белемле 31870 белгечнең 9935 е (31%) татар була; башлыча авылларда татар халкы массалары б-н эшләгән агрономнар арасында татарлар 38,3% тәшкил итә. Шулай да җитәкче карата Т. уздырылу беркадәр уңышка ирешә: 1949 ел башына татарлар колхоз рәисләре арасында — 51,4%, авыл советлары рәисләре арасында — 55,4%, район башкарма ком-тлары рәисләре арасында 46 кеше (57%) була.

КПССның шәһәр һәм район ком-тлары секретарьлары составында 125 татар (52%), 97 рус (40,4%), 17 башка милләт вәкилләре (7,6%), партиянең өлкә ком-ты аппаратында шул ук нисбәттә 61 (43,6%), 64 (45,6%) һәм 15 кеше (10,7%) исәпләнә.

Чыг.: Культурное строительство в Татарии. 1917–1941: Сб. док. и материалов. К., 1971; Осуществление политики коренизации в Татарстане в документах. 1920–1930-е гг. К., 2009.

Әд.: История Татарской АССР. К., 1956. Т. 2; Очерки истории партийной организации Татарии. К., 1962; Климов И.М., Сафин В.Г. Татарская партийная организация в востановительный период (1921–1925 гг.). К., 1962; Алёкминская Г.М. Трудности коренизации на промышленных предприятиях ТАССР в годы предвоенных пятилеток (1928–1941 гг.). К., 1966; Каримов А.И. Съезды Советов Татарии. 1920–1937. К., 1967; Культурная революция в Татарии (1917–1939 гг.) К., 1986; Тагиров И.Р. Очерки истории Татарстана и татарского народа (XX век). К., 1999; шул ук. История национальной государственности татарского народа и Татарстана. К., 2000.

Г.С.Сабирҗанов.

ТӨПСЕ́З КҮЛ, Көнчыгыш Кама аръягында, элекке елга юлында сакланып калган күл. Ык елгасының сулъяк яры тугаенда, Азнакай р-ны Чәкән авылыннан 1,1 *км* көньяк-көнчыгыштарак. Су өслегенең мәйданы 0,18 *га*. Су күләме 1,5 мең $м^3$. Озынлыгы 50 *м*, иң зур киңлеге 40 *м*, уртача тирәнлеге 0,84 *м*, иң зур тирәнлеге 1,66 *м*. Күл карст-суффозия процессы нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Суы җи җәлчә минераль(әшкән, бик йомшак (катылыгы 1,2 *мг-экв/л*), сары төстә, иссез, гидрокарбонат-хлорид-кальцийлы типта, үтә күренмәлелеге 55 *см*. Суы ху җалык-көнкүреш максатларында файдаланыла.

ТӨР (фигыль төрләре), фигыльнең эш-хәрәкәт чигенә ирешү яки ирешмәүне билгеләүче грамматик категориясе. Рус телендә, ш.у. башка славян телләрендә ике Т. — тәмамланган (совершенный) һәм тәмамланмаган (несовершенный) Т.ләр бер-берсенә капма-каршы куела. Татар телендә рус телендәге кебек мөстәкыйль Т. категориясе юк. Татар фигыленең Т. мәгънәләре, ягъни эш-хәрәкәтнең тәмамланганлыгын яки тәмамланмаганлыгын белдерүче мәгънәләр фигыльләрнең чиклелек-чиксезлекләренә нисбәтле рәвештә заман формалары б-н бәйле. Чикле фигыльләр (чыгу) үткән заман формаларында (чыкты, чыккан, чыккан иде) һәм киләчәк заман формаларында (чыгар, чыгачак) һәрвакытта да рус фигыленең тәмамланган Т.ен белдерәләр. Чиксез фигыльләр барлык башка заманнарда тәмамланмаган Т. (йөрде, йөргән, йөргән иде; йөрер, йөриячәк) мәгънәсенә ия булалар. Ике төрле фигыльләрнең нинди Т.дә булулары аларның теге яки бу контекстта нинди мәгънәдә килүләренә бәйле. Чикле мәгънәдә ике төрле фигыльләр чикле фигыльләр өчен билгеләнгән формаларда тәмамланган Т. (Марат урындыкка утырды) мәгънәсен белдерәләр. Чиксез мәгънәдә ике төрле фигыльләр тәмамланмаган Т. (Марат урындыкта утырды) мәгънәсен бирәләр.

Әд.: Вопросы глагольного вида. М., 1962; Ганиев Ф.А. Видовая характеристика глаголов татарского языка. К., 1963.

Ф.Ә.Ганиев.

ТӨРБӘ́, үзәкләштерелгән композицияле, сигез кырлы, кайвакыт чатыр яки гөмбәз б-н ябылган кв. формасындагы мөселман каберлеге. Татарстан терр-ясендә 14–16 йөзләр уртасында таралыш ала: Болгар шәһәрендәге *Төньяк төрбә*, *Көнчыгыш төрбә* һәм *Хан төрбәсе*, Казандагы Хан төрбәләре һ.б. билгеле.

ТӨРЕ́К-ТӘМТЕ́ авылы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 11 *км* төньяк-көнбатыштарак, Тәмте елгасы буенда. 2010 елда 113 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Тулы булмаган урта мәктәп, китапханә. Казан ханлыгы чорында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Иске Йорт Пучинкәсе, Төрек исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау, тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 мәчет, 2 мәдрәсә, су тегермәне, 2 вак-төяклар кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 925 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Пановка волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1782 дә — 123 ир-ат; 1859 да — 718, 1897 дә — 930, 1908 дә — 1040, 1920 дә — 1009, 1926 да — 772, 1938 дә — 624, 1949 да — 539, 1958 дә — 454, 1970 тә — 392, 1979 да — 315, 1989 да — 196, 2002 дә — 145 кеше.

ТӨРЕКЛӘ́Р авылы, Әтнә р-нында, Олы Әтнә авылыннан 14 *км* көньяктарак, Шәмәк елгасы буенда. 2010 елда 108 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 1646 дан рус чыганакларында Тлюхляр исеме б-н билгеле. Рев-циягә кадәрге чыганакларда — Клевляр, Трухляр буларак та мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тимерчелек һәм он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, 3 җил тегермәне, тимерче алачыгы, 2 вак-төяклар кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1046,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Олы Әтнә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1938 нең 25 мартыннан — Әтнә, 1959 ның 12 октябреннән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1990 ның 25 октябреннән Әтнә р-нында. Халык саны: 1782 дә — 122 ир-ат; 1859 да — 513, 1897 дә — 642, 1908 дә — 725, 1920 дә — 634, 1926 да — 680, 1938 дә — 678, 1949 да — 435, 1958 дә — 339, 1970 тә — 227, 1979 да — 162, 1989 да — 120, 2002 дә — 101 кеше.

ТӨРЕКУГЛЫ́ Исмаил (10.9.1966, Бай - бурт ш., Төркия), төрек тарихчысы, тарих фән. д-ры (2000). Мәрмәрә ун-тын тәмамлый (Истанбул ш., 1989), 1992 елдан шунда ук эшли. Хезмәтләре татар халкы һәм Татарстан тарихына, ш.и. Р.Ибра һимовка, Р.Фәхретдингә, хәзерге Татарстанның социаль һәм мәдәни структурасы мәсь әләренә карый.

Х е з м.: Sibiryalı Meşhur Seyyah Abdürreşid İbrahim. Ankara, 1997; Rusya Türkleri Arasındaki Yenileşme Hareketinin Öncülerinden Rızaeddin Fahreddin. Ist., 2000.

ТӨРКӘ́Ш авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 29 *км* көньяктарак, Баш-Арбаш елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 270 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. 1680 нән мәгълүм. Рев-цияга кадәрге рус чыганакларында Туркач, Тукаш, Туркашева исемнәре б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстиянн әре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында почта станциясе урнаша; мәчет, су тегермәне, ярма яргыч, йон-тукыма ману һәм токарьлык йортлары эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 978,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Петропавел волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Кукмара, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварынан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 24 ир-ат; 1834 тә — 179, 1859 да — 336, 1877 дә — 439, 1897 дә — 750, 1908 дә — 830, 1914 тә — 989, 1920 дә — 866, 1926 да — 1000, 1938 дә — 922, 1949 да — 573, 1958 дә — 641, 1970 тә — 625, 1979 да — 551, 1989 да — 372, 2002 дә — 265 кеше.

Б.Ф.Шәкуров.

ТӨРКЕМНӘ́Р ТЕО́РИЯСЕ, математиканың бер бүлеге, математикада һәм аның кушымталарында иң еш очрый торган операцияләрне гомуми формада өйрәнә. 1771 елда француз математигы Ж.-Л.Ланграж радикаллардагы алгебраик тигезләмәләрне чишү өчен беренче тапкыр алыштыргычлар төркемен кулланa. 19 йөздә Норвегия математигы Н.Г.Абель һәм француз математигы Э.Галуа («төркем» атамасын катгый билгеләмәсез кертә) алыштыргыч төркемнәр үзлекләре б-н тигезләмәләрнең үзлекләре арасындагы бәйләнешләрне ачыклыйлар. Т.т.н системага салуда һәм үстерүдә француз математигы К.Жорданның, немец галимнәре Ф.Клейн һәм Л.Кронекерның, Россия математигы О.Ю.Шмидтның хезмәтләре зур роль уйный.

G төркеме түбәндәге төркем аксиомаларын канәгатьләндерүче ике урынлы бер ∘ операциясе б-н бирелә торган элементлар күплеге буларак билгеләнә:

ассоциативлык: *G* төркеменең барлык *a, b* һәм *c* элементлары өчен $a\circ(b\circ c)=(a\circ b)\circ c$;

нейтраль элемент (төркем берәмлеге) булу: *G* төркеменең барлык *a* элементлары өчен $a\circ e=e\circ a=a$ үтәлә торган *e* элементы бар;

төркем берәмлегенә карата кире элемент булу: төркемнең һәр *a* элементы өчен $a\circ a^{-1}=a^{-1}\circ a=e$ үтәлә торган a^{-1} кире элементы бар.

Болардан тыш әгәр төркемнең ∘ операциясе коммутативлык үзлегенә ия булса (*G* төркеменең теләсә нинди *a* һәм *b* элементлары өчен $a\circ b=b\circ a$ үтәлә), бу төркем Абель төркеме дип атала.

Математикада һәм аның кушымталарында Галуа төркеме, санлы һәм гомологик төркемнәр, симметрияләр төркемнәре һәм Ли төркемнәре еш кулланыла.

Э.Галуа һәрбер алгебраик тигезләмәгә билгеле бер алыштыргычлар төркемен тиңдәш итеп куя, шуның ярдәмендә радикалларда бирелгән алгебраик тигезләмәнең чишелеше булу-булмавын әлеге төркемнең үзлекләре б-н бәйләүче критерийны формалаштыра. Мондый төркемнәр табигать фәннәрендә күпсанлы кулланылыш тапкан Галуа теориясенең нигезен тәшкил итәләр.

Барлык бөтен саннар күплеге нейтраль элемент сыйфатындагы нуль б-н кушу операциясенә карата аддитив төркем төзи. Нульгә тигез булмаган барлык рациональ саннар күплеге нейтраль элемент сыйфатында бер берәмлек б-н тапкырлау операциясенә карата мультипликатив төркем хасил итә. Әлеге һәм башка санлы төркемнәр математиканың күп кенә бүлекләрендә киң кулланыла.

Гомологик төркемнәрдә һәрбер топологик фәзага Абель төркемнәре семьялыгы тиңдәш итеп куела, һәм бу әлеге фәзаның кайбер үзлекләрен сурәтләргә мөмкинлек бирә.

Симметрияләр төркемнәре фигураның (мәс., квадрат, төзек өчпочмак яки әйләнә) үз-үзенә салынуын китереп чыгара торган хәрәкәтләре күплеген сурәтли. Квадратның — шундый 8 хәрәкәте (бердәйләрен дә кертеп), төзек өчпочмакның — 6, әйләнәнең чиксез күп хәрәкәте бар (биредә рәттән килүче ике хәрәкәтнең үтәлеше операция дип атала). Бу күплекләрнең һәркайсы берәмлек сыйфатында бердәй хәрәкәт алынган төркем хасил итә. Фигураның торышын сакларга калучы бер генә бердәй хәрәкәте булган фигуралар булырга мөмкин (мәс., У хәрефе). Әгәр фәзаи фигураны, мәс., кубны алсак, аның тиешле хәрәкәтләр күплеге, кагыйдә буларак, коммутатив булмаска мөмкин.

Ли төркемнәре (өзлексез төркемнәр) — үзара бәйләнгән 2 структура (төркем һәм топологик фәза структуралары) билгеләнгән күплекләр. Аларны Галуа теориясен квадратураларда бирелгән дифференциаль тигезләмәләрнең чишелешләрен ачыклауда кулланган вакытта норвег математигы С.Ли аерып күрсәтә. Ли төркемнәре — Ли алгебралары төшенчәсенә, ә бу төшенчә аерым зур теориягә әверелә.

Казан ун-тында Т.т. буенча тикшеренүләр 19 йөз ахырында башланып китә. Профес сор П.С.Назимов Т.т. алымнарын саннар теориясе һәм алгебраик тигезләмәләр чишү проблемаларын өйрәнгәндә куллана. Н.Г.Чеботарёв Галуа теориясендә класслар кырының абсолют Галуа төркеме структурасын билгели һәм класслар санының гади бүлүчеләренә куелган чикләмәләрне ачыклый. Ул Ли төркемнәре теориясендә француз математигы А.П.Картан фаразларын (1894) — максималь тәртиптәге гади төркемнәр астөркемнәренең регуляр булуын раслый һәм шул рәвештә бирелгән Ли төркемендә үлчәнеш булу-булмауның аналитик билгесен таба. И.Д.Адо үлчәнешле теләсә нинди Ли алгебрасының чикләнгән үлчәнешле төгәл рәвеше барлыгын исбатлый. В.В.Морозов (Е.Б.Дынкин б-н бергә) гади Ли төркемнәренең иң гади рәвешләрен һәм ярым гади максималь астөркемнәрен санап чыга, шуның нәтиҗәсендә Ли төркемнәренең барлык примитив рәвешләрен классификацияләү мәсьәләсен хәл итә.

Казан математиклары Т.т.н дифференциаль геометриягә, гравитация теориясенә караган хезмәтләрендә, нәевклид фәзаларның рәвешүзгәртү төркемнәрендә (П.А.Широков, А.З.Петров, А.П.Норден, А.В.Әминова), аналитик механикада (Н.Г.Четаев, Г.Ш.Әминов), идарә итү теориясендә (В.Г.Павлов, К.Г.Гәрәев) кулланалар.

Әд.: Чеботарёв Н.Г. Теория групп Ли. М.–Л., 1940; Каргополов М.И., Мерзляков Ю.И. Основы теории групп. М., 1972.

М.М.Арсланов.

ТӨРКИ́ АЛЫНМАЛА́Р, *төрки телләрдән* алынган сүзләр һәм сүзтезмәләр. Дөньяның күпчелек телләрендә теге яки бу күләмдә күзәтелә. Хәзерге рус әдәби теле лексикасында һәм диалектларында (800 берәмлектән күбрәк), ш.у. рус язма ядкәрләренең сүзлек составында сизелерлек урын билиләр. Хәзерге рус әдәби телендә Т.а. түбәндәге тематик төркемнәргә бүлеп өйрәнеләләр: торак, төзелеш лексикасы (амбар, сарай, шалаш, чулан (чолан), чердак (чардак)); көнкүреш лексикасы (очаг (учак), сундук (сандык), топчан (тапчан), утюг (үтүк), фитиль (филтә)); ризыклар (лапша (ләкшә), плов (пылау), шашлык), эчемлекләр (чай (чәй), кумыс (кымыз)), кием-салым (кафтан, сарафан, халат, шаровары (чалбар); аяк киемнәре (башмак, каблук, чулок (чолгау)); баш киемнәре (башлык, колпак (калпак), фата, шаль (шәл)); асылташлар (алмаз, бирюза (фирәзә), жемчуг (эн же), изумруд (зөбәрҗәт); савыт-сабалар (бадья, стакан, таз); тукымалар (атлас, бязь (бәз), парча); эш кораллары (бурав (борау), кирка (киркә), наждак); музыка уен кораллары (барабан, домра (думбра)); үсемлекләр (арбуз (карбыз), баклажан, камыш, ревень (рәваҗ)); хайваннар (барсук (бурсык), кабан, лошадь (алаша), сурок (сөркә), шакал); кошлар (баклан, беркут (бөркет), чомга); сәүдә (базар, деньги (тәңкә), магарыч (мәгәрич), пай, товар); төсләр (алый (ал), бурый (бурлы), карий (кара)); кеше атамалары (атаман, есаул, казначей (казначы), палач, товарищ (товар ише — иптәш), хозяин (хуҗа)); дин (медресе (мәдрәсә), минарет (манара), мулла, намаз) һ.б. Рус телендәге Т.а. арасында төрки телләргә башка шәрекъ телләреннән (гарәп, фарсы, монгол, кытай, һинд) кергән алынмалар да, ш.у. төрки чыгышлы сүзләр дә бар. Соңгылары татар алынмаларына (татар теленнән кергән сүзләр), казакъ алынмаларына (казакъ теленнән кергән сүзләр), төрек

алынмаларына (төрек теленнән кергән сүзләр) һ.б.га бүленә. ТР терр-ясендә яшәүче рус, чуаш, мари, мордва, удмурт халыкларының сөйләм һәм язма телләрендә татар алынмалары аеруча күп очрый. Алар — ризык (бавырсак, гөбәдия, катык, пәрәмәч, чәк-чәк), кием-салым (калфак, кәләпүш, чүәк), рухи мәдәният (бәет, дастан, кубыз, сорнай), дин (Корбан бәйрәме, Ураза), кешеләр (абый, апа, бабай, малай) һ.б. атамалар б-н бәйле сүзләр. Рус телендәге Т.а. Х.Д.Френ, Ф.И.Эрдман, И.Н.Березин, М.К.Казимбәк тарафыннан өйрәнелә башлый. 20 йөздә бу өлкәдә тикшеренү эшләрен Е.К.Бахмутова, Н.Н.Назаров, Р.А.Юналиева, К.Р.Галиуллин, Л.К.Бәйрәмова, Л.С.Борһанова, Р.Г.Гатауллина, Г.Х.Гыйләҗетдинова, Г.Н.Кәримуллина, А.Г.Сәгыйтова, А.Г.Яруллина дәвам итә.

Әд.: Дмитриев Н.К. О тюркских элементах русского словаря. М., 1958. Вып. 3; Шипова Е.Н. Словарь тюркизмов в русском языке. А.-А., 1976; Юналеева Р.А. Тюркизмы русского языка. К., 2000; шул ук. Тюркизмы в русской классике. К., 2005.

К.Р.Галиуллин.

ТӨРКИ́ КАГАНЛЫ́К, 552–745 елларда Үзәк Азиядәге борынгы төркиләрнең феодаль дәүләте. 5 йөздә Алтайда төрки кабиләләр берлеге оеша. 545 тә төркиләр уйгыр кабиләләрен, 551 дә жужаннарны тар-мар итә. 552 дә Бумын каган җитәкчелегендә Т.к. оеша. 555 тә бөтен Үзәк Азия Т.к. хакимлегендә була; 560 та Урта Азиядә эфталитлар дәүләте юк ителә; Т.к.ка Төньяк Кытай дәүләтләре Чжоу һәм Ци (6 йөзнең 3 нче чиреге) бәйлелеккә эләгә; Бөек ефәк юлын контрольдә тоту өчен Иран б-н сугыш бара; Боспор яулана (576), Херсонес камап алына (581). Үзара сугыш һәм сәяси кризис (582–603) Т.к.ның Көнбатыш һәм Көнчыгыш Каганлыкларга бүленүенә китерә. Ишби (609–19) һәм Хели (620–30) каганнар вакытында Көнчыгыш Т.к. Үзәк Азиягә йогынтысын торгыза. 630 да Кытайның Тан династиясе гаскәрләре тарафыннан яулап алына. 679–89 да Көнчыгыш төркиләре, бәйсезлек өчен кискен көрәш нәтиҗәсендә, үз дәүләтләрен торгызалар. 7 йөз ахырында — 8 йөз башында Көнчыгыш Т.к. актив яулап алу сәясәтен алып бара. 688 дә — уйгырлар, 710 да кыргызлар тар-мар ителә; төркиләрнең отрядлары Сәмәркандка кадәр барып җитә, әмма гарәп гаскәрләре б-н сугышларда җиңелә (712–13). *Билге* каган (716–34) вакытында каршы тору барышында Тан империясе б-н солых төзелә. Билге вафатыннан соң дәүләттә үзара сугышлар башлана, үзәктән куучы процесслар Көнчыгыш Т.к.ның таркалуына китерә, аның урынында Уйгыр каганлыгы төзелә (745). Көнбатыш Т.к.та 630 да Дуло һәм Нушиби кабиләләре берлеге арасында хакимият өчен сугыш башлана. Үзара бәрелешләр нәтиҗәсендә хәлсезләнгән Көнбатыш Т.к. 638–39 да Кытай гаскәрләре тарафыннан яулап алына. 8 йөз башында Көнбатыш Т.к. Кытай бәйлелегеннән котыла. Тышкы басып алу һәм эчке каршылыклар аның таркалуына китерә (740). Каганлык юкка чыкканнан соң, яңа дәүләт берәмлекләре барлыкка килә: *Бөек Болгар* (7 йөзнең 1 нче яртысы) һәм *Хәзәр каганлыгы* (7 йөз уртасы). Т.к. Евразиянең төрки телле халыклары тарихында һәм мәдәниятендә мөһим роль уйный, хәзерге төрки телле халыкларга нигез булып торган этник төркемнәрнең үсешенә булышлык итә. Ш.у.к. *Орхон-Енисей ташъязма ядкәрләре*.

Әд.: Гумилёв Л.Н. Великая распря в первом Тюркском каганате // Византийский временник. 1961. Т. 20; шул ук. Древние тюрки. М., 1967; История татар с древнейших времён. К., 2002. Т. 1; Ганиев Р.Т. Восточно-тюркское государство VI–VIII вв. Екатеринбург, 2006.

ТӨРКИ́ ТЕЛЛӘ́Р, Төркия, Әзәрбайҗан, Казакъстан, Кыргызстан, Төрекмәнстан, Үзбәкстанда яшәүче күпсанлы халыкларның, ш.у. Россия, Молдавия, Иран, Әрмәнстан, Грузия, Украина, Белоруссия, Әфганстан, Монголия, Кытай, Болгария, Румыния, Югославия, Албаниядәге кайбер халыкларның якын кардәшлектәге телләре төркеме. Алтай телләренең зур семьялыгына керә дип фаразлана. РФдә Т.т.гә Татарстан, Башкортстан, Чуаш, Тува, Таулы Алтай, Хакас һәм Якутия респ-каларындагы төп халыкларның, ш.у. Дагстан, Кабарда-Балкар, Карачай-Черкас, Мордва, Мари, Удмурт респ-каларында, Ставрополь һәм Пермь крайларында, Әстерхан, Төмән, Омск, Новосибирск, Свердловск, Чиләбе, Курган, Томск, Кемерово, Волгоград, Саратов, Самара, Пенза, Рязань, Новгород һәм Киров өлкәләрендә гомер итүче кайбер халыкларның телләрен кертеп карыйлар. *Төрки телләрнең генеалогик классификациясе* тюркологларның (В.А.Богородицкий, В.В.Радлов, Ф.Е.Корш, А.Н.Самойлович, С.Е.Малов, М.Рясянен, И.Бенцинг, К.Г.Менгес, Н.А.Баскаков, М.З.Зәкиев һ.б.) хезмәтләрендә тикшерелә. Типологик яктан Т.т. *агглютинатив телләргә* керә, аларга *сингармонизм* хас. Төрки телләрдә сүзләр сонор [р], [л], [м], [н] тартыкларыннан, геминаталардан (икеләтелгән тартыклар) башлана алмый, сүз башында һәм ахырында бер иҗектә ике тартыкның янәшә килүе мөмкин түгел; Т.т. морфологиясендә грамматик род, префикслар (алкушымчалар) һәм предлоглар юк (бәйлекләр бар). Барлык төрки телләргә дә *изафә*, *тартым* категориясе, бер төрләнеш хас, алар синтаксик яктан катлаулы җөмләләргә ия; модаль мәгънәләр модаль сүзләр, еш кына фигыль формалары б-н белдерелә. Б.э.к. 3 нче меңъеллыктагы глозель рун ядкәрләре (Франция терр-ясендә табыла), б.э.к 2 нче меңъеллыктагы этруск ядкәрләре (Италия терр-ясендә табыла), Шумер чөй язулары, 7–11 йөзләрдәге Орхон-Енисей рун ядкәрләре (к. *Борынгы төрки рун язуы*) борынгы төрки язма ядкәрләрдән саналалар. Брахми, уйгыр алфавитлары б-н, гарәп яуларын нан соң гарәп алфавитлары б-н язылган ядкәрләр сакланып калган. СССРдагы төрки телле халыклар 1920–30 елларда — *латин язуыннан*, 1930 еллар ахырыннан *кириллицадан* файдаланалар. Төркиядә — 1928, Төрекмәнстанда — 2000, Әзәрбайҗанда 2001 еллардан латинлашкан әлифба кабул ителә. Ш.у.к. *Тюркология*.

Әд.: Языки народов СССР: Тюркские языки. М., 1966. Т. 2; Баскаков Н.А. Введение в изучение тюркских языков. М., 1969; Кононов А.Н. История изучения тюркских языков в России: Дооктябрьский период. Л., 1972; Дроздов Ю.Н. Тюркская этнонимия древнеевропейских народов. М., 2008; Севортян Э.В. Этимологический словарь тюркских языков: В 3 т. М., 1974–80.

М.З.Зәкиев.



ТӨРКИ́ ТЕЛЛӘРНЕ́Ң ГЕНЕАЛО́ГИК КЛАССИФИКА́ЦИЯСЕ, генетик принципка нигезләнгән классификация, аерым алганда, төрки телләрнең үзара кардәшлек мөнәсәбәтләрен (бер гаиләгә, төркемгә каравы) билгеләү, ягъни фараз ителгән баба телдән гомуми килеп чыгышы нигезендә төркемләнеше. Телләрне чагыштырма-тарихи һәм типологик тикшерүләр нәтиҗәсендә, ш.у. тел кардәшлеге төшенчәсе һәм дөнья телләре моногенезы турында концепция барлыкка килгәч, Т.т.г.к.нә ирешү мөмкинлеге туа. Телләрне алга таба аеруча тирәнтен чагыштырып өйрәнү Россия тел галиме В.М.Иллич-Свитычка Евразия һәм Африканың күпчелек телләренең ностратик макрогаиләсен ачу мөмкинлеге бирә. Аның фикеренчә, фараз ителгән ностратик баба телдән афразия, картвель, һинд-европа, дравид, урал, алтай арадаш баба телләре барлыкка килә. Әлеге телләрне төгәл чагыштырма-тарихи тикшеренүләрдән чыгып, күпчелек фин-угор, монгол телләре белгечләре, тюркологлар кайчандыр арадаш урал-алтай баба теле булган, аннан арадаш урал һәм алтай баба телләре барлыкка килгән дигән нәтиҗә ясыйлар. Бу гипотезаны тикшерүгә М.А.Кастрен, О.Бётлингк, Г.Винклер, Н.Поппе, Б.Я.Владимирцов, Г.Рамстедт, Ю.Немет, Ж.Г.Киекбаев һ.б. зур өлеш кертәләр.

Төрки телләрне классификацияләүгә беренче омтылыш 11 йөздә Урта Азия галиме Мәхмүд Кашгариның «Диване лөгать әт-төрк» («Төрки сүзләр җыелмасы») хезмәтендә күзәтелә. Әлеге мәсьәләне хәл итү б-н тел галимнәре бары тик 20 йөздә генә ныклап шөгыльләнә башлыйлар. Аларның күбесе (В.В.Радлов, М.Рясянен, И.Бенцинг, К.Г.Менгес, Ф.Е.Корш һ.б.) классификациянең генетик принцибын терр. яки хронологик принцип (С.Е.Малов) б-н бергә алып бара. Т.т.г.к.н төзегәндә А.Н.Самойлович, нигездә, фонетик үзенчәлекләрдән чыгып эш итә, Н.А.Баскаков исә төрки телләрнең фонетик, морфологик һәм лексик-семантик үзенчәлекләрен дә исәпкә алырга тырыша. Н.А.Баскаков классификациясе төрки телләрнең үзара генетик якtан бәйле төркемен аерып чыгарырга ярдәм итә (к. 1 нче таблица). Т.т.г.к.нә караган кайбер мәсьәләләр С.Н.Максуди, М.З.Зәкиев һ.б. татар галимнәренең дә өйрәнү предметына әверелә. Аларның хезмәтләрендә кыпчак һәм угыз төркемнәре б-н беррәттән чуаш һәм якут телләрен аерым төркемнәргә, ш.у. хәзәр, болгар, татар телләрен төрки телләрнең кыпчак төркеменә кертеп карау дәлилләнгән (к. 2 нче таблица).


Әд.: Корш Ф.Е. Классификация турецких языков // Этнографическое обозрение. СПб., 1910; Самойлович А.Н. Некоторые дополнения к классификации турецких языков. П., 1922; Баскаков Н.А. Введение в изучение тюркских языков. М., 1962; Иллич-Свитыч В.М. Материалы к сравнительному словарю ностратических языков (индоевропейский, алтайский, уральский, дравидский, картвельский, семитохамитский) // Этимология. 1965. М., 1967; Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Фонетика. М., 1984; Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Морфология. М., 1988; Закиев М.З., Кузьмин-Юманади Я.Х. Волжские булгары и их потомки. К., 1993; Иванов В.В. Генеалогическая классификация языков // Лингвистический энциклопедический словарь. М., 1990; Sadri Maksudi. Milliyet Duygusunun sosyolojik Esasları. Ist., 1955.

М.З.Зәкиев.

ТӨРКИ́ ТЕЛЛӘРНЕ́Ң КЫПЧА́К ТӨРКЕМЕ́, *төрки телләрнең* көнбатыш хун тармагына карый. 3 төркемчәгә бүленә: 1) кыпчак-болгар: Идел буенда таралган борынгы төрки телне, Алтын Урда төрки-татар әдәби теленең көнбатыш төрен, хәзерге татар һәм башкорт телләрен; 2) кыпчак-половец: үле *кыпчак телен*, хәзерге карачай-балкар, комык, кырым-татар, караим телләрен; 3) кыпчак-нугай: казакъ, каракалпак, нугай телләрен һәм хәзерге үзбәк теленең кыпчак диалектларын да үз эченә алалар.

Кыпчак төркеме телләре агглютинатив телләргә карый (к. *Агглютинация*); аларга сингармонизм, изафә, тартым категориясе хас, род грамматик категориясе юк. Сузыклар

Н. А. Баскаков. ТӨРКИ ТЕЛЛӘР ҮСЕШЕНЕҢ ГОМУМИ СХЕМАСЫ *1 нче табл.*



системасында (вокализм) бары кыска сузыклар гына сакланган, тартыклар системасында (консонантизм) саңгырау йомык тартыкларның күплеге күзәтелә. Исем категориясенең 6 килеше бар. Борынгы кыпчак глоссаларын (аңлаешсыз сүзләр) үз эченә алган беренче язма ядкәрләр Орхон-Енисей рун язуында башкарылган (к. *Орхон-Енисей ташъязма ядкәрләре, Орхон-Енисей язмалары*). Хәзерге кыпчак төркеме телләренең барысына да язу хас.

Әд.: Баскаков Н.А. Введение в изучение тюркских языков. М., 1962; Гарипов Т.М. Кыпчакские языки Урало-Поволжья: Опыт синхронической и диахронической характеристики. М., 1979; Кононов А.Н. История изучения тюркских языков в России. Дооктябрьский период. Л., 1982.


В.Х.Хаков.

ТӨРКИ́-ТАТА́Р АКЧА́-ҮЛЧӘ́Ү СИСТЕ́МАСЫ, Көнчыгыш Европаның урта гасыр-лар төрки дәүләтләрендә акча әйләнешен оештыруның тарихи формасы. Төрки-татар акча системасы нигезендә гомуми эквивалент булган билгеле бер акчалата товар ята. Аның билгеләнгән авырлыгын дәүләт акча берәмлегенең металл асылы тәшкил итә. Идел буенда табылган иң борынгы акчалар — б.э.к. 2 йөз ахырында — 8 йөздә сугылган Харәзем яки Туран акчалары, аларның күбесе 5–8 йөзләргә карый. Кулланылышта ш.у. Рим (3–4 йөзләр) һәм Византия (6–7 йөзләр) акчалары да була. 4–7 йөзләрдә Идел-Чулман төбәге терр-ясендә Сасанилар драхмалары (авырлыклары 4,19–4,30 *г*) киң тарала, алар җиз коелма (4,25 *г*) рәвешендәге беренче җирле металл акчаларның авырлыгы җәһәтендә нигез итеп алыналар. Төрки каганлык таркалганнан соң (7 йөз башы), 7 йөз уртасында Хәзәр каганлыгы барлыкка килү б-н, Идел буенда һәм Урал алдында Византия көмеш акчалары (гексаграммнар) киң кулланыла, алар император Ираклий (610–41) идарә иткән чорда сугыла башлый. Алтын солидлар һәм көмеш гексаграммнар таралу хәзәрләрдә Византия акчаларына охшаш беренче акчалар барлыкка килүгә китерә. Каганлыкта ислам дине кабул ителгәч (737), хәзәрләрнең үзләренең акча-үлчәү системасы барлыкка килә. Хәзәр акчалары гарәп куфи *дирһәмнәре* үрнәгендә сугыла, анда акча сугылган урын «Әрд әл-Хәзәр» («Хәзәр җире») рәвешендә күрсәтелә.

Идел буе Болгар дәүләтендә 8 йөз ахырында — 9 йөздә — гарәп дирһәмнәре, 10 йөздә саманилар акчалары төп акча-үлчәү берәмлеге була. Гарәп акчалары династияләр, хронология һәм авырлык нормасы буенча Өммияләр (661–750, авырлыклары 2,7–2,9 *г*) һәм Габбасилар (2,8–2,9 *г*) акчаларына бүленә. Фаразлар буенча, Идел буе Болгар дәүләтендә Өммияләр дирһәмнәре Габбасилар акчалары б-н бергә кулланылышта була. Бу Алексеев р-ны Биләр авылыннан 20 *км* ераклыкта урнашкан Әлмәт авылы янында табылган гарәп дирһәмнәре хәзинәсендә (8–9 йөзләргә караган 150 акча) чагыла. Куфи язулы дирһәмнәрне (8–9 йөзләр) болгарлар еш кына бизәнү әйбере буларак кулланалар (Олы Тархан, Танкеевка, Зур Тигәнәле каберлекләрендә тишекле яки элмәкле гарәп акчалары табыла). Саманилар акчалары авырлык нормасы ягыннан Габбасилар акчаларыннан беркадәр аерыла, шуның б-н бергә аларның эшләнешендә төгәлсезлекләр бар, бу иң элек акчаларның авырлыгында тайпылышлар зураюда күзәтелә (Әхмәд бине Исмәгыйль идарә иткән чорда 2,7–3,2 *г* чамасы, 907–14). 10 йөздә Идел буе Болгар дәүләтендә, Саманилар акчалары б-н берәттән, башка династияләр (Зыярилар, Җоландылар, Салларилар, Габбасилар, Бөвәйхиләр һ.б.) акчалары да әйләнештә була. Бер үк вакытта Идел буе Болгар дәүләте терр-ясендә болгарларның куфи язулы дирһәмнәргә охшатып сугылган акчалары кулланыла, бу хакта Болгар шәһәрендә табылган җиз штемпельләр сөйли. Болгарлар тарафыннан охшатып басылган тәңкәләр авырлыгы якынча 2,82–2,97 *г* тәшкил итә. Чит ил акчалары әйләнештә йөрү һәм аларга охшатып ясау болгарларның үз акчаларын сугу өчен шартлар тудыра. Беренче болгар акчалары 902–08 гә карый.

М. З. Зәкиев. НОСТРАТИК МАКРОГАИЛӘ КОНТЕКСТЫНДА ТӨРКИ ТЕЛЛӘРНЕҢ ГЕНЕАЛОГИК КЛАССИФИКАЦИЯСЕ СХЕМАСЫ

2 нче табл.



Алар Җәгъфәр бине Абдаллаһ (идарәче Ал - мыш бине Шилкинең мөселман исеме) исеменнән суктырыла. Болгар акчаларын сугуның төп үзәкләре Болгар һәм Суар шәһәрләре (якынча 980 елларга кадәр) була. Болгар идарәчеләре Микаил бине Җәгъфәр (918–20), Барсал (920), Мәмәктәй бине Җәгъфәр (921–22), Талиб бине Әхмәд (942–60, Суар), Абдуллаһ бине Микаил (948–49, Суар; 957–58, Болгар), Мөэмин бине Әхмәд (975–76, Суар; 976–77, Болгар), Мөэмин бине Хәсән (977–81, Болгар) исеменнән сугылган акчалар билгеле. 11 йөздә Идел буе Болгар дәүләтендә «акчасыз» чор (к. *Көмеш кытлыгы чоры*) башлана, Урта Идел буе терр-ясенә куфи язулы дирһәмнәр кертелү күпкә кими, һәм болгарларның үз акчаларын сугу да туктала. Бу дәвердә зур күләмле алыш-бирешләр вакытында көмеш (к. *Сум*), кургаш коелмалар (к. *Пломба-герләр*), ваклап сату сәүдәсендә затлы җәнлек (ш.и. тиен) тиреләре, муенсалар, кабырчыклар һ.б. файдаланыла. Багдад хәлифе Насыйрледдин (1180–1225) исеменнән бакыр һәм көмеш акчалар сугылганда 12 йөз ахырында Идел буе Болгар дәүләтендә акча әйләнеше кабат башлана.

Монгол яуларыннан соң Урта Идел буе терр-ясенә Жүчиләр акча-үлчәү системасы урнаша; Болгар, Сарай әл-Мәхрусә, Сарай әл-Җәдид, Гөлестан, Азак, Мухша һ.б. шәһәрләр Алтын Урда ханнары акчаларын сугу үзәкләренә әвереләләр. Яңа система хөкем сөргән дәвернең беренче унъеллыкларында Жүчиләр акчалары б-н бергә Насыйрледдин исеменнән сугылган көмеш һәм бакыр акчалар әйләнештә була. Жүчиләрнең беренче акчалары бөек монгол каганнары исеменнән сугыла (Арык Буга каганның 1259–60 та сугылган көмеш акчалары билгеле, Болгар). Алтын Урданың үз акча-үлчәү системасы Мәнгу Тимер хан идарә иткән дәвердә (1266–82) урнаша, акчаларда Жүчиләр *тамгасы* барлыкка килә. Алтын Урда ханнары Туда Мәнгу (1282–87), Күлнә (Күлпә) (1359–60), Нәүрүз (1360), Хызыр (1360–61), Килдебәк (1361–62), Мөрид (1361–64), Мирбулат (1364–65), Абдуллаһ (1363–67, өзеклекләр б-н), Толынбәк (1370), Мөхәммәдбүләк (1379–80, өзеклекләр б-н), Чиркәсбәк (1374–75), Каганбәк (1375–76), Гарәбшаһ (1377–78), Туктамыш (1380–97, өзеклекләр б-н), Тимер Котлыгъ (1397–98), Җәләлетдин (1411–12), Кәримбирде (1413), Кибәк (1413), Чокрый (1413–16), Кадыйрбирде (1419), Баракъ (1425), Дәүләтбирде (1426–29) һ.б., ш.у. Алтын Урда бәкләре Булат Тимер (1366–67, Болгар), Тагай (1361–68, Мухша), Гыяседдин (1422–23, Казан) исеменнән сугылган акчалар билгеле. Жүчиләр акча-үлчәү системасы Тукта (1310–11) һәм Туктамыш (1380–81) ханнар идарә иткән дәверләрдә җайга салына.

Алтын Урда таркалу һәм аның терр-ясендә татар ханлыклары барлыкка килү процессында Жүчиләр традицияләренә нигезләнгән төрки-татар акчалары сугуның җирле үзәкләре барлыкка килә. 15 йөзнең 1 нче яртысында, Казанда (к. *Болгар әл-Җәдид*) һ.б. олысларда яңа акча үрнәкләре барлыкка килү б-н, акча әйләнешенең бердәм Алтын Урда системасының тәмам таркалу һәм Урта Идел буенда акча сугу әйләнеше бүленү процессы бара. Казанда акчалар Алтын Урда ханнары исеменнән генә түгел, җирле идарәчеләр (Гыяседдин, Олугъ Мөхәммәд һ.б.) исеменнән дә сугыла. 15 йөз уртасында Казан ханлыгының үз акчаларын сугу туктатыла, түләүләр өчен рус акчалары кулланыла башлый. Ш.у.к. *Нумизматика*.

Әд.: Нумизматика мәкаләсеннән кара.

Р.М.Вәлиев.

ТӨРКИ́-ТАТАРЛАРНЫ́Ң «ИДЕ́Л-УРА́Л» КӨРӘ́Ш БЕРЛЕГЕ́ («Идел-Урал» ком-ты), фашистлар Германиясендә Идел буе һәм Урал алды татарларының сәяси оешмасы. Аның барлыкка килүе нацистлар режимы сәясәтендә төрки-мөселманнарга һәм Кавказ халыкларына карата мөнәсәбәт үзгәрү б-н бәйле; бу үзгәреш көнчыгыш легионнар, Оккупацияләнгән көнчыгыш терр-яләр эшләре буенча министрлык каршында милли арадашлыклар (к. *Татар арадашлыгы*), милли вәкиллекләр-ком-тлар оешуга китерә. Идел-Урал татарлары вәкиллеге рәсми булмаган рәвештә 1942 елда галим Әхмәт Тимер җитәкчелегендә оеша башлый. Аның составына Ш.Алмас, Р.Самат, И.Яушев һ.б. керә. Комитет әгъзалары немецларның хәрби тоткыннар б-н эшләү буенча комиссияләрендә катнашалар: көнчыгыш легионнарга хезмәткә яллыйлар, тоткыннар каршында лекцияләр б-н чыгышлар ясыйлар һ.б. 1943 нең җәендә Ә.Тимер Германиядән китә, оешма б-н Ш.Алмас җитәкчелек итә. 1944 нең уртасына ком-т составына С.Фәйзуллин, Г.Солтан, Г.Вафин, И.Скобелев, Ш.Алкаев, Г.Айдагулов, Ишмаев, С.Гунафин, Кашапов керә. 1944 нең мартында татарларның *Грайфсвальд корылтаенда* рәсми рәвештә Т.-т.«И.-У.» к.б.нең *Милләт Мәҗлесе* дәвамчысы буларак оешуы игълан ителә. Корылтайда кабул ителгән программаның төп нигезләмәләре күбесенчә Г.Исхакыйның Гражданнар сугышы елларында игълан ителгән бәйсез Идел-Урал дәүләтен оештыру турындагы идеяләренә кабатлый. Берлек, рәсми рәвештә юридик оешма яки Оккупацияләнгән көнчыгыш терр-яләр эшләре буенча министрлыкның бүлекчәсе булып саналмаса да, финанс мәсь әләсендә тулысынча немец хакимиятләренә бәйле була. 1945 нең гыйнварына кадәр аның б-н Ш.Алмас, аннары Татар арадашлыгы җитәкчелек итә. Берлек *«Идел-Урал легионы»н* төзү, Даргибел, Кринке, Беверунгендагы (легионерларның ял итү һәм дәвалану урыннары) ял йортларын карамакта тоту, яралыларны карауны оештыру; «Идел-Урал», «За национальную независимость» г-таларын, «Немецко-татарские известия», «Татар әдәбияты» ж-лларын бастыру буенча эш алып бара. Берлек ш.у. спектакльләр, әдәби-муз. кичәләр, легионерларны Германия б-н таныштыру сәяхәтләрен, пропагандалаучылар әзерләүне оештыра.

Әд.: Гилязов И.А. Куралтай в Грайфсвальде... // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2000. № 3/4; шул ук. Легион «Идел-Урал». М., 2008.

И.А.Гыйләҗев.

ТӨРКИ́-ТАТАРЛАРНЫ́Ң ҮЗӘ́К ХӘРБИ́-СӘЯСИ́ МӘКТӘБЕ́, Казандагы 1922–26 елларда Кызыл Армиянең милли хәрби частьлары өчен сәяси хезмәткәрләр әзерләүче уку йорты. Даими хәрби-сәяси агитаторлар курслары җирлегендә (1919–22; мөдирләре Г.С.Баембәтов, И.К.Фирдәүс) оештырыла. Респ-ка Революцион Хәрби Советының сәяси идарәсе карамагында була. Мәктәп башлыгы һәм комиссары Н.С.Еникиев. Татар, башкорт һәм Россиянең башка төрки халыклары вәкилләре курсантларыннан оеша. Мәктәптә гомуми белем бирү, сәяси һәм хәрби дисциплиналар укытыла. 200 дән артык сәяси хезмәткәр әзерләнә.

Әд.: Гиззатуллин И.Г. Мусульманские военные организации (1917–1921 гг.). К., 2002; Гилязов И.А. «Легион Идель-Урал». М., 2009; шул ук. Восточная политика Германии и Волго-татарский легион «Идель-Урал» // История татар с древнейших времён. В 7 томах. К., 2013. Т. 6.

И.Г.Гыйззәтуллин.

ТӨРКИЧЕЛӘ́Р, *милли-мәдәни мохтарият* тарафдарларыннан оешкан сәяси төркем. Җитәкчесе — С.*Максуди*. Оешкан сәяси көч буларак беренче тапкыр төркем әгъзалары Милләт Мәҗлесендә чыгыш ясыйлар (Уфа ш., 1917 елның ноябре — 1918 нең гыйнвары). Аларның сәяси таләпләре «*Тормыш*» г-тасында аеруча ачык яктыртыла (1917 нең 23 ноябре.): 1) Эчке Россия һәм Себер төркиләрен бер әләм астында берләштерү мөһим; 2) Россия респ-калар федерациясе булырга тиеш, анда Урал һәм Идел буе төркиләре өчен терр. мохтарият билгеләнергә тиеш; 3) Идел буе һәм Урал төркиләренең терр. мохтариятенә бәйсез рәвештә милли-мәдәни мохтариятне гамәлгә ашыруны дәвам итү. 1917 нең 26 ноябрендә «Тормыш» г-тасында басылган «Төркичеләр» мәкаләсендә дөньяда 100 млн.га якын төрки исәпләнүе билгеләп үтелә һәм шундый сорау куела: Милләт Мәҗлесендә оешкан төркичеләр фракциясе төркиләрнең эчке Россиядә генә мәдәни туплануына омтылачакмы, яисә барлык төрки һәм ислам илләрендәге төркиләрнең берләшүенәме? Әлеге позициягә бәйле рәвештә төркичеләр Башкортстан мохтариятенә каршы чыгалар. Делегатларның берсе Бөтенрос сия мөселманнары корылтаеның мөселманнар яшәгән читтәге өлкәләрнең федерациясе турындагы фикерне алга сөрүен, әмма Эчке Россия мөселманнарының язмышы турындагы мәсьәләнең хәл ителмәвен билгеләп уза. Казанда узган корылтай бу мәсьәләне 2 өлешкә бүлә һәм вакытлыча милли-мәдәни мохтарият игълан итә. Терр. мохтарият турындагы мәсь әлә Милләт Мәҗлесе утырышында хәл итүгә калдырыла. З.*Кадыйри* төркичеләр төрки бердәмлек мәнфәгатьләреннән чыгып эш йөртә, шу ңа күрә әлеге бердәмлеккә каршы юнәлтелгән барлык нәрсәләр бетерелергә тиеш дип исәпли һәм Башкортстан мохтариятен балаларча кылану дип атый. Т. татарларның һәм башкортларның берләштерелгән мохтариятен оештыруны яклауларын белдерәләр. Милләт Мәҗлесендә алар Идел-Урал Штаты оештыруны яклап тавыш бирәләр һәм алга таба әлеге мәсьәләдә үз гамәлләрен һәм карарларын территориячеләр (федералистлар) б-н яраклаштыралар.

И.Р.Таһиров.

ТӨРКИЯ́ (Төркия Республикасы), өлешчә Азиянең көньяк-көнбатышында, өлешчә Көньяк Европада урнашкан. Ил терр-ясенең төп өлеше Кара һәм Урта диңгезләр арасындагы Анатолия ярымутравына (Кече Азия ярымутравы) туры килә. Мәйданы — 780,6 мең *км*². Башкаласы — Әнкара шәһәре. Халкы — 83,3 млн. кеше (2018), ш.и. 5 меңләп татар. Татарлар Истанбул, Әнкара, Искешәһәр (Чифтәләр р-ны Госмания а.), Измир, Маниса (Алашәһәр р-ны Гүрсү а.), Борса, Балыкесир, Көтаһья (Гедиз р-ны Әфәнде Күпере а.), Самсун (Хафза р-ны Хилмия а.) шәһәрләрендә яшиләр. Идел-Урал татарлары б-н Т. арасында күптәннән тарихи, икътиса - ди һәм мәдәни элемтәләр урнашкан. *Казан ханлыгы* чорында бу багланышлар дәүләтара элемтәләр буларак билгеле; 1552 елда ханлык җимерелгәч, татар феодал аксөякләре һәм руханиларының кайбер вәкилләре Госман - лылар империясенә күчеп китәләр; бу күренеш 18 йөздә рус булмаган Идел буе халыкларын көчләп чукындыру сәясәте чорында активлаша. Татарларның Госманлылар импе - риясенә актив күченүләре (к. *Мөһа җирләр хәрәкәте*) 19 йөзнең 2 нче яртысында башлана, алар, башлыча, Истанбул, Измир, Борса һәм Анатолиянең башка шәһәрләренә урна - ша (күченүчеләрнең күбесе дини мәктәпләрдә укучылар һәм дин эшлеклеләре була). 1877–78 еллардагы рус-төрек сугышыннан соң Госмания авылына (Искешәһәр вилаяте) Казаннан 400 татар күчеп килә. 1891–92 дәге ачлык һәм 1897 дәге 1 нче халык санын алу чарасы (моны татарларның бер өлеше хакимиятнең мөселманнарны чукындырырга әзерләвенең яңа этабы дип кабул итә) Т.дәге татарларның Казан, Уфа, Оренбург, Самара губерналарыннан, Көнбатыш Себердән килгән кешеләр исәбенә артуын күрсәтә. Алар, башлыча, Искешәһәр, Әнкара вилаятьләренә, Трабзон, Сивас, Айдын, Борса шәһәрләренә урнаша. Татарларның күпләп күченүләре (2 меңләп кеше) Окт. рев-циясе, Гражданнар сугышы һәм 1921–22 дәге *ач - лык* б-н бәйле. 1950–1960 еллар башында илнең татар җәмгыяте (Истанбул, Әнкарада урнаша) Кытай, Корея, Япониядән күчеп килүчеләр исәбенә үсә. Т. татарларны үзенә тарта, аларны Якын Көнчыгышның башка илләре б-н бәйләп торучы тарихи урын булып китә. Төрек әдәбияты, архит-расы һәм гамәли бизәлеш сәнгате татар мәдәниятенә зур йогынты ясый. Татар мәдрәсәләре һәм мәктәп - ләрендә уку ярдәмлекләре буларак төрек авторлары (М.*Чәләби*, С.*Чәләби* һ.б.) хезмәтләре киң файдаланыла. 19 йөз ахырыннан милли яңарыш идеяләре, яңа ысуллы җирле мәктәпләрдә укыту барышы, газета һәм китап бастыру эшенең куелышы б-н кызыксынучы татар интеллигенциясенең күп кенә вәкилләре өчен Т. белем алу һәм ижади планнарны тормышка ашыру урыны булып тора.



Ф.Кәриминең «Истанбул мәктүбләре» китабы. Оренбург. 1913

Истанбулда татар телендә «*Казан*» ж-лы (1905) чыга, җирле уку йортларында укучы татар студентлары оешмасы эшли, татарлар төрек телендә «*Тәгарифе мөслимин*» (1910), «*Төрек юрду*» (1911–31) ж-лларын, гомумтөрки телдә «*Ислам*» (1914) дини-әдәби җы - ентыгын нәшер итүдә катнашалар. Язучы һәм публицист Ф.*Кәрими* «Истанбул мәк - түбләре» (1913) очеркында Т.дәге сәнәгать, сәясәт, мәдәният, мәгариф, тарих проблема - ларына үзенең карашын белдерә. Монда озак еллар язучы М.*Акъегетзадә*, сәясәтче һәм җәмәгать эшлеклесе Й.*Акчура* яши һәм эшли. 1917 дән соң татар интеллигенциясенең күп кенә күренекле вәкилләре (Ә.*Вәлиди*, Г.*Баттал*, Р.*Ибраһимов*, Г.*Исхакый*, С.*Максуди*, Ф.*Туктаров* һ.б.) Т.гә күчеп китә. Алар илнең сәяси тормышында актив катнашалар, мәдәният һәм мәгарифне үсте - рүгә, төрек телен һәм та - рихын фәнни тикшерүгә зур өлеш кертәләр. 1955 тә Т.дә Идел-Урал төркиләренә мәдәни һәм социаль ярдәм, 1957 дә «Сөембикә мәдәнияте» (1964 кә кадәр эшли) җәмгыятьләре, 1963 тә татар яшьләрен берләштерүче «Тукай яшь - ләре» клубы оештырыла. Казан татарларына мәдә - ни ярдәм җәмгыяте (1969 дан) актив эшчәнлек алып бара, ул «Тукай бюллетене» һәм 1970–80 елларда әшмәкәр Ә.*Мәңгәр* иганәсенә төрек телендә «*Казан*» ж-лын нәшер итә. 1997–2004 тә Истанбулда Ә.Мәңгәр исем. фонд эшли, аның ярдәме б-н татар халкының тарихына, мәдәнияте һәм теленә багышланган 26 китап нәшер ителә, язучы Г.Исхакыйның документлар архивы, шәхси әйбер - ләре Казанга кайтарыла (1997). Т.дә Казан татарлары мәдәнияте һәм үзара ярдәмләшү (1992 дән, Искешәһәр), Бёгрюделик мәдәният һәм бердәмлек (2007 дән) җәмгыятьләре эшли. Мондый оешмалар Әнкарада (1964 тән), Истанбулда (1992 дән) һәм Көтаһьяда (2005 тән) да бар. Истанбулда «Аяз Та һыр Төркестан Идел-Урал» фонды эшләп килә. 1990 еллардан ТР һәм Т. арасындагы элемтәләр шактый ныгый. 1992 һәм 2007 дә ТР Президенты М.Ш.Шәймиев Т. Респ-касына рәсми визит б-н бара, 2009 да Т. президенты А.Гюль Казанга килә. 1995 тә ТР һәм Т. арасында хезмәттәшлек турындагы килешүгә кул куела. 1996 да РФ төбәкләрендә беренче буларак, Казанда Т. Респ-касының Ген. консуллыгы ачыла. 1997 дән Истанбулда Татарстанның тулы вәкаләтле вәкиллеге эшли, ул Т. татарлары б-н тыгыз элемтәдә тора һәм Татарстан мәдәнияте көннәре, татар традицион һәм гамәли бизәлеш сәнгате күргәзмәләре, танылган сәнгать осталары һәм иҗат коллективлары катнашында концертлар, фәнни конференцияләр үткәрә, *Сабан туен* бәйрәм итүне оештыра, татар диаспорасын татарча китаплар, журналлар һ.б. басмалар, муз. язмалар б-н тәэмин итә. Татарстан б-н Т. арасындагы фәнни һәм мәдәни элемтәләр үсешенә «Евразия диалогы» («Диалог Евразии») оешмасы, «Ислам конференциясе» оешмасы каршындагы ислам тарихын, сәнгатен һәм мәдәниятен фәнни тикшерү үзәге (ИРСИКА), «ТЮРКСОЙ» төрки дөнья мәдәнияте халыкара оешмасы, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма ком-ты зур өлеш кертә. 2001 дә ТР б-н Т. арасында мәгариф өлкәсендә хезмәттәшлек турында килешүгә кул куела, шуның нәтиҗәсендә җирле югары уку йортларында укыту өчен студентлар б-н ал -



Татар интеллигенциясе вәкилләре. Утыралар: сулдан икенче Х.Фәйзи-Чистапули, Г.Буби, Ф.Кәрими. Истанбул. 1896.



Казан галимнәре Көтаһья шәһәрендә (Төркия) үткәрелгән Идел–Урал төбәге тарихы мәсьәләләренә багышланган симпозиумда катнашучылар арасында. 2006 елның 11–12 ноябре.

машу бара. Т. архивларында татар халкы тарихы б-н бәйле материаллар һәм документлар (ш.и. Казан ханлыгы һәм Алтын Урда ханнары ярлыклары, хатлары) саклана. Т. га - лимнәре (Н.*Дәүләт*, М.Гёрмез, И.*Мараш*, И.*Төрекуглы*, М.Онәр һ.б.) татар дин эшлек - леләренең һәм фикер ияләренең иҗади мирасын, Татарстандагы татарлар һәм ислам тарихын өйрәнүдә зур роль уйный. ТР Т. б-н икътисад, тышкы сәүдә һ.б. өлкәләрдә актив хез - мәттәшлек итә, 2007 дән аларның тышкы сәүдә әйләнеше елдан ел үсә, 2016 да 215,6 млн. доллар тәшкил итә, 2017 гә 40%ка арта. Татарстан Т. базарына нефть һәм нефть продукт - лары, химия һәм нефть химиясе сәнәгате продуктлары, йөк автомобильләре, вертолётлар, нефть-газ кудыру станцияләре өчен җи һаз - лар, мазут, изопарафин майлар, техн. күкерт, пыялалы җепселләр, автомобиль шиннары һ.б.ны чыгара; Т.дән Татарстанга көнкүреш техникасы, йорт җи һазлары, җи нәл һәм азык сәнәгате продуктлары кертелә. Татарстанда Т. капиталы б-н 280 гә якын пр-тие (ш.и. «Эфес» сыра кайнату холдингы, «Одак», «Оримекс-Сувар», «Монотек» һ.б. төзү фирмалары) эшли, Татарстан чит илләр кат - нашындагы уртак пр-тиеләр саны буенча РФ төбәкләре арасында 1 нче урынны били, респ-када һәр 5 нче уртак пр-тие Т. катнашында оештырылган. Т.нең «Тофаш» компаниясе Чаллыда «Fiat» җиңел һәм йөк авто - мобильләре җитештерүдә катнаша. Т.нең төзү компанияләре Казанның 1000 еллыгына багышланган һәм 2013 елгы Универсиада объектларын проектлау һәм төзүдә катнаша һәм бу эшчәнлек елдан ел үсә бара. Казан һәм Чаллыда «Кредит ЕвропаБанк» Т. банк бүлекчәсе эшли. Казан б-н Истанбул һәм Т. Респ-касының башка шәһәрләре арасында һава юллары ачыла. Хәрби эшлекле М.*Крыймов*, генерал-майор И.И.*Исламов*, генераллар Ф.Алтан, *Шакир Паша*, дипломатлар Г.*Айда*, Х.Г.*Гомәров*, драматург *Хәйдәр*, тарихчылар Г.Баттал, Н.Дәүләт, А.Инан, Х.Кошай, Ә.Н.*Курат*, җәмәгать эшлеклеләре А.*Акыш*, З.*Кадыйри*, М.*Салиәхмәт*, шагыйрә *Гыйффәт Уган*, эшмәкәр Ә.Мәңгәр, сәяси эшлеклеләр К.Г.*Абдрахманов*, Р.Б.*Рәхимку - лов*, тюрколог Р.*Арат*, тел галимнәре Ә.*Тимер*, С.*Чагатайның* тормышлары һәм хезмәт эш - чәнлекләре Т. б-н бәйле.

Әд.: Девлет Н. Татары и их исторические связи с Турцией // Российские соотечественники в Турции: история и современность. Стамбул, 2008; Камалов И. Современная татарская диаспора // шунда ук; Biezanis L. Soviet Muslim Emigres in the Republic of Turkey // Central Asian Survey. 1994. V.13; Devlet N. Türkiye'ye Katkıda Bulunan Tatar-Başkurtlar // Türkiye Cumhuriyeti Devletinin Kuruluş ve Gelişmesine Hizmeti Geçen Türk Dünyası Aydınları Sempozyumu Bildirileri. Kayseri, 1996; Tatarstan – Tərkiyə: Mədəni bağlanış - lar (1920–2003). Qazan, 2004.

И.М.Камалов.

ТӨРЛЕ́ АЯКЛЫ́ КЫСЛАСЫМАННА́Р, к. *Янйөзәрләр*.

ТӨРМӘ́ КАЛЬГАСЫ́, Казанда архит-ра истәлеге. Казансу елгасының сулъяк ярында, Нагорный һәм Япиев урамнары киселешен - дә урнашкан. Петербург архитекторы А.Д.Захаров 1803 елда эшләгән проект буенча 1807 дә арх. Я.М.Шелковников тарафыннан төзелә. 1917 гә кадәр губерна төрмәсе була, ш.у. сөргенгә озату төрмәләрендә урын җит - мәгәндә, Себергә җибәрелүче мәхбүсләрне урнаштыру өчен файдаланыла. Исеме соңрак күп тапкырлар үзгәрә. Хәзерге вакытта биредә пенитенциар учреждение урнашкан.

Башта Т.к. 8 *м* биеклектәге дивар б-н әй - ләндереп алынган дүртәр каланча б-н ныгытылган турыпочмаклыктан гыйбарәт була; төп корпус шуның үзәгендә урнаша. Каланчаларда сак бүлмәләре, карцерлар, цейхгауз урнаштырыла. Көнбатыш диварга тоташ капкалар б-н бикләнгән төрмә конторасы, чиркәү һәм үтәли аркалы каравыл биналары терәлеп тора. Комплексның әлеге өлеше уңышлырак, аның композициясе һәм декоратив бизәлеше корылманың классик схемасына буйсынган. Төрмә чиркәве бинаның икенче катында ур - наша. 1830 да арх. А.К.Шмидт проекты буенча чиркәүнең ике кыеклы түбәсенә гөмбәзле барабан куела. 19 йөзнең 2 нче яртысында бинаның төньяк һәм көньяк диварларына бер катлы янкормалар өстәлә, чиркәүгә яңа урыннан, ишегалды ягындагы бер-берсеннән аерым торган тышкы ике баскычтан керәләр. Төзелеп беткәннән соң, Т.к. көнчыгыш юнәлештә киңәйтелә, симметрик үзәк буенча, төп корпусның аргы ягында мунча, кер юу бүлмәсе һәм остаханәләр калкып чыга.

19–20 йөзләрдә комплекс кат-кат өстәп төзелә, бинаның катлары үзгәрә, әмма, ни - гездә, барлык элекке элементлары һәм күләм-планлаштыру структурасы саклана. Комплекс һәм аның үзәк фасады композициясе симметрия нигезендә төзелә. Корпус тимпанда «балкышлы» өчпочмаклы зур фронтон б-н төгәлләнгән, әре, чөйсыман ташлардан өелгән аркалы үтеп йөрү капкалары үзәк буйлап урнашканнар. Корпусның көн - чыгыш фасады алга чыгып торган ярымтүгәрәк апсидасын саклап калган. Төрмә чиркәвенең түбәсе (гөмбәзле барабан) югалган. Комплексның почмаклары дивар өсләрен - нән калкып торган каланчалар б-н ныгытылган. Квадрат каланчалар өскә таба бераз тарайганнар, зур кронштейннарга таянган чыгынтылы киң кәрнизләр б-н ябылганнар. Каланчалар, комплекс үскән саен, биеклекләрен югалтмыйча, соңрак корылган корпуслар сос - тавында кала бирәләр.

Төп корпус зур үзгәрешләр кичерми саклана. Көнчыгыш фасад үзәге ярымтүгәрәк ри - залитлы, ике катлы, турыпочмаклы кирпеч бина. Барлык биналар гөмбәз б-н ябылган. Фасадлар шома итеп штукатурланган, бертигез зурлыктагы кв. тәрәзәләр рәте аркатур билдәү б-н төгәлләнгән. Көнчыгыш фасад тәрәзәләрен ташлар б-н ныгытылган чыгынтылы зур тоташтырмалар саклап калган.

Т.к. күренекле тарихи шәхесләр исемнәре б-н бәйле. Ул 1841–45 тә кальга каршында - гы Горталов йорт-утарында яшәгән Л.Н.Толс - той тарафыннан сурәтләнә. 1826 да биредә сөргенгә китешли декабрист В.Ф.Раевский була, 1863–67 дә — *Казан фетнәсендә* кат - нашучыларны, 1930 елларда — репрессия - ләнгән меңнәрчә сов. гражданнарын, 1960–63 тә архиепископ *Иовны* (Кресович) ябып тоталар. 1913–18 дә төрмә чиркәвенең рухание газап чигүче изге Д.М.*Шишокин* була.

Әд.: Памятники истории и культуры Казани. К., 1989; Внимание! Зона! (из прошлого и настоящего Управления исполнения наказаний Министерства юстиции Российской Федерации по Республике Татарстан). К., 2004.

Е.В.Липаков, С.Г.Персова.

ТӨРНӘ́С авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 25 *км* төньяк-көнбатыштарак, Олы Сөлчә елгасы буенда. 2010 елда 1482 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, русслар — 67%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Тихвин Богородица чиркәве (архит-ра истәлеге; 1906–13, 1937–45 тә төзелә; 1962–88 дә эшләми). 18 йөз уртасында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Төрнәс Бистәсе, Александровка исемнәре б-н дә телгә алына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү-приход мәктәбе (1875 тә ачыла), пар һәм су тегермәне, ярма яргыч, тимерчелек, 2 вак-төяклә кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 620 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Ка - зан губернасының Чистай өязе Егоркино волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Октябрь, 1935 нең 10 февраленнән — Тельман, 1958 нең 16 июленнән — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән — Нурлат р-нында. Халык саны: 1782 дә — 169 ир-ат; 1859 да — 645, 1897 дә — 1039, 1908 дә — 1147, 1920 дә — 1254, 1926 да — 1224, 1938 дә — 1313, 1949 да — 2386, 1958 дә — 804, 1970 тә — 700, 1979 да — 518, 1989 да — 1350, 2002 дә — 1553 кеше.

ТӨСЛЕ́ МУ́ЗЫКА, сәнгать эшчәнлегенең тәжрибә төре, аның туу һәм формалашуы фәнни-техник алгарыш үсешенә бәйле рәвештә тормышка ашырыла. Т.м. нигезендә «гадәттән тыш әсәр» (А.Н.Скрябин билгеләмәсе буенча) романтик идеясе ята, аны кабул иткәндә барлык хис-кичерешләр дә *синестезия* эффектына берләшә. Т.м. үсешендә А.Н.Скрябин тарафыннан үзенең «Прометей» (1910) симф. поэмасын башкару өчен уйлап табылган махсус яктылык төсләре рәте зур роль уйный. Т.м. техник комплексның вакыт б-н исәпләнә торган фәзалы сәнгатьләренә, тәэсирле, интонацион чаралар классына карый. Т.м.ны шартлы рәвештә «инстру - менталь төсләр хореографиясе» яки «күзләр өчен музыка» дип атыйлар.

Т.м. казанышлары күпчелек өлкәләрдә, ш.и. туризм индустриясендә (борынгы архит-ра истәлекләре янында «аваз һәм төс» спектакльләре), театрда, поп-музыка концертларында файдаланыла. Бу планда үзенең аудиовизуаль объектлары һәм инвайронментлары төзелешен даими катлауландырып торучы кинетизм аеруча актив.

1960 елларның 2 нче яртысыннан илдә Т.м. аппаратурасын эшләү һәм Т.м.ның психол., эстетик һәм пед. проблемаларын фәнни өйрәнүнең танылган үзәге булып Казан «*Прометей*» фәнни-тикшеренү ин-ты тора.

Әд.: Г а л е е в Б.М. Светомузыка: Становление и сущность нового искусства. К., 1976; Светомузыка, синестезия, цветной слух: Аннот. библиогр. указ. (1742–2002). К., 2007. *Б.М.Галиев.*

ТӨТӘ́Ч (Fumaria), мәк чәчәклеләр семьялыгыннан берьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 55 кә якын төре билгеле, башлыча Урта диңгез буенда, ш.у. Евразиянең уртача поясында таралган. ТР терр-ясендә бер төре — дарулы Т. (F. officinalis) бар. Республиканың барлык терр-ясендә очрый. Кырларда, бакчаларда чүп үләне буларак үсә. 10–30 *см* биек лектәге үсемлек. Тамыры үзәк. Сабагы куыш, нәзек, шома, зәңгәрсу куныклы, төбеннән үк тармаклы. Яфраклары күгелҗем-яшел, чиратлашкан, өчәр каурыйсыман-теленмә. Чәчәкләре шәмәхә-алсу төстә, дөрес булмаган формада, чук чәчәк төркеменә җыйналган. Җимеше — чикләвексыман. Июнь аеннан көзгә кадәр чәчәк ата. Җимешләре июль–сентябрьдә өлгерә. Җир өсте өлешләрендә алкалоид, сумала, С һәм К витаминнары бар. Халык медицинасында үләнтөнәтмәсе үт һәм бәвел кудыру чарасы буларак кулланыла.

ТӨФӘ́Ң (фарсы تفنگ), 1 *м* озынлыгындагы юан көпшәнең аскы өлешендә дарыга ут төртү өчен тишеге һәм станга беркетү өчен җайланмасы булган борынгы утлы корал атамасы. Эче уелган агачка, сирәк кенә көпчәкле лафетка куела. Йомры ташлар һәм ядрәләр б-н ата. Шәрекъ илләрендә 13 йөздән кулланышта. Идел буе Болгар дәүләтендә 1376 елдан билгеле. Болгар шәһәрен рус гаскәрләреннән саклаучылар «күк күкрәтеп рус полкларының котын алалар» («гром пущаху страшаще русские полкы»). Яңа корал Идел буе Болгар дәүләтеннән Руська килеп эләгә (Т. куллану турында беренче тапкыр 1382 дә искә алына).

И.Л.Измайлов.

ТӨХБӘТУ́ЛЛИН Мөнир Габделфәт улы (1.4.1956, Кукмара р-ны Зур Кукмара а.), хирург, нур ярдәмендә диагноз кую белгече, мед. фән. д-ры (1998), проф. (2000), ТРның атказ. табибе. Проф. М.К.Михайлов шәкерте. Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1979), Казан ГИДУВының хирургия кафедрасында эшли. 1981 елдан 2 нче Респ-ка клиник хастаханәсендә (РКБ № 2, Казан) табиб-хирург, 1989 дан хирургия бүлеге мөдире, 1997 дән ультратавыш ярдәмендә диагноз кую табибе, 1999 дан Респ-ка мед. диагноз кую үзәгенең баш табиб урынбасары. 2000 нән 2 нче Респ-ка клиник хастаханәсендә диагноз кую эше буенча баш табиб урынбасары, бер үк вакытта Казан мед. академиясенең нур ярдәмендә диагноз кую каф. профессоры. ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының ультратавыш ярдәмендә диагноз кую буенча штаттан тыш баш белгече (2000 нән). ТР ультратавыш ярдәмендә диагноз кую белгечләре җәмгыяте рәисе (2000 нән). Хезмәтләре нур ярдәмендә комплекслы диагноз куюга (ультратавыш ярдәмендә тикшерү һәм компьютер томографиясе), агымлы лазер цитометриясе кулланып, ашказаны-эчәк тракты шешләреңә иртә стадияләрдә диагноз куюга карый. Т. ашказаны резекциясенең яңа ысулын, нурлар ярдәмендә күзәтчелек итеп, эчке әгъзаларга аз инвазияле операцияләр ясауны гамәлгә кертә. Үйлап табуга 3 авторлык таныклыгы, 2 рационализаторлык тәкъдиме бар.

Х е з м.: Комплексная лучевая диагностика новообразований желудка. К., 2001 (автордаш); Эхография в диагностике цирроза печени. М., 2003 (автордаш); Значение компьютерно-томографической и ультразвуковой ангиографии при раке желудка // Казан. мед. журн. 2006. № 6 (автордаш).

Г.Х.Галимуллина.

ТӨХБӘТУ́ЛЛИНА Рузалия Габделхак кызы (16.2.1960, Казан), провизор, икътисадчы, фарм. фән. д-ры (2007). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1983), шунда ук, дарулар технологиясе кафедрасында эшли. 1995 елда Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлый. 1987 дән Казандагы 350 нче даруханә мөдире урынбасары, 1997 дән — мөдире. 2001 дән ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының Фармация департаменты Респ-ка фарм. мәгълүмат үзәге директоры. 2001–03 тә «Татарстан медицина техникасы һәм фармация» дәүләт унитар пр-тиесе укыту-методик консультация үзәге директоры. 2003–04 тә ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының маркетинг бүлеге башлыгы. 2004–07 дә «Виола» ҖЧҖ директоры. 2007 дән Казан мед.-фарм. уч-щесендә, 2008 дән директор. Бер үк вакытта, 2004–07 дә, Казан мед. академиясенең җәмәгать сәламәтлеге, икътисад һәм сәламәтлек саклау б-н идарә итү кафедрасында. 1997–99 елларда ТР Фарм. оешмалары ассоциациясенең башкаручы директоры. Хезмәтләре халыкны дару матдәләре б-н тәэмин итүне камилләштерү мәсьәләләреңә, респ-каның аптека учреждениеләре эшчәнлеген һәм аларның финанс хәлен анализлауга карый.

Х е з м.: Анализ современного состояния сети аптечных организаций в Республике Татарстан // Фармация. 1999. № 5 (автордаш); Государственные закупки: проблемы и решения // Общественное здоровье и здравоохранение. 2006. № 1.

ТӨХВӘТУ́ЛЛИН Рид Кәшшаф улы (30.5.1934, Казан — 23.5.2011, шунда ук), геолог-нефтьче, геол.-минерал. фән. канд. (1972), ТАССРның атказ. нефтьчесе (1984), РФнең атказ. нефть һәм газ сәнәгате хезмәткәре (2000). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1957), Казакъстан ССРның «Актүбәнефтегазразведка» трестында эшли. 1960 елдан Казан ун-тында, геол. ф-ты деканы (1978–93). Хезмәтләре Идел буе — Урал терр-яләренең газ-нефтьлелеген өйрәнүгә карый. Карбонатлы коллекторларның сыйдырышлылык үзенчәлекләрен ачыклау методикасын, девонга кадәрге утырмаларның перспективаларын бәяләү критерийларын эшли, Мәләкәс батынкылыгы терр-ясендәге битум байлыкларын бәяли, Идел буе — Урал үзәк районнарында нефть-газ перспективаларын бәяләүдә геохимик һәм палеотектоник тикшеренүләрнең ролен ачыклый, чыганаклардан нефть чыгаруны яңарту буенча тәкъдимнәр кертә. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Вопросы геологии и нефтебитуминоности Волго-Уральской области. К., 1992 (автордаш); Нефтегазоносность Республики Татарстан. Геология и разработка нефтяных месторождений: В 2 т. К., 2007 (автордаш).

ТӨХВӘ́ТШИН Рөстәм Роман улы (5.6.1951, Казакъстан ССР, Ленгер ш.), патофизиолог, мед. фән. д-ры (1995), проф. (1999). Кыргыз мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1974), шунда ук эшли. 1985 елдан Казан мед. ин-тының (Үзәк фәнни-тикшеренү лаб-ясенең) эксперименталь клиник патология һәм терапия бүлеге мөдире, 1989–2000 дә Үзәк фәнни-тикшеренү лаб-ясе мөдире, 2000 нән Казан мед. академиясенең патологик физиол. каф. мөдире. Хезмәтләре хатын-кызларда бала табу б-н бәйле патологияләрне, аларга экологик факторлар тәэсирен өйрәнүгә, репродуктив яшьтәге хатын-кызларда бала табу б-н бәйле авыруларны кисәтү һәм лазер ярдәмендә дәвалауга карый. Уйлап табуга 4 патенты бар.

Х е з м.: Гипоксия: Адаптация, патогенез, клиника. СПб., 2000 (автордаш); Новые аспекты лазерной терапии. Бишкек, 2000 (автордаш); Репродуктивная функция женщин и перинатальные потери в условиях экологического неблагополучия. Бишкек, 2001 (автордаш).

ТӨХФӘТУ́ЛЛИН Мотыйгулла Төхфәтулла улы (1845, Зөя өязенең Кече Кайбыч а. — 1920, хәзер Казакъстан Респ-касы Уральск өлкәсенең Уральск ш.), дин эшлеклесе, педагог. «*Кышкар*» мәдрәсәсендә, Каһирәдәге «әл-Әзһәр» ислам ун-тында (Мисыр) укый. 1871 елдан Уральскидагы 1 нче (Кызыл) мәчеттә имам-хатиб. «*Мотыйгыя*» мәдрәсәсенә нигез сала һәм гомеренең ахырына кадәр әлеге уку йорты б-н җитәкчелек итә. Гарәп теле белгече, танылган Коръән укучы, музыка, шул исәптән рус һәм Европа музыкасын яратучы буларак мәгълүм. Г.Тукайның иҗтимагый һәм фәнни карашлары формалашуда мөһим роль уйный. К.*Мотыйгый* һәм Г.*Кайбицкаяның* әтисе. 2006 да Уральскидагы Т. йортында Г.Тукай музее ачыла.

Әд.: Н у р у л л и н И.З. Тукай. М., 1977.

ТӨХФӘТУ́ЛЛИН Рамил Чыңгыз улы (2.10.1966, Аксубай р-ны Аксубай а.), актёр, ТРның халык артисты (2003). 1987 елда Казан театр уч-щесен (М.Х.Сәлим җанов курсы) тәмамлый һәм Татар акад. театры труппасына кабул ителә. 2007–09 да ТР МК аппаратында: мәдәният, спорт һәм ТР халыклары телләрен үстерү идарәсе башлыгы, бер үк вакытта, 2008–10 да, Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тының кино һәм видео иҗаты каф. мөдире. 2015–2017 дә Казан Зур драма театрында. 2017 дән Татар акад. театрында. Читтән торып Казан ун-тының татар филологиясе (1999) һәм юридик (2008) факультетларын тәмамлый. Беренче ролен — Т.Миңнуллинның «Без китәбез, сез каласыз» пьесасы буенча куелган спектаклдә Тукай ролен театр уч-щесенең 3 курсында укыган вакытта башкара. Матур буй-сынлы, мөлаем, җыр-га оста актёр; иҗат эшчәнлегенең башлангыч чорында (беренче унъеллыгында), башлыча, мәхәббәт геройлары рольләрен башкара: Таһир («Таһир-Зөһрә», Ф.Бурнаш), Хәлил («Галиябану», М.Фәйзи), Булат («Зәңгәр шәл», К.Тинчурин), Алчын («Хуҗа Насретдин», Н.Исәнбәт), Акъегет («Ай тотылган төндә», М.Кәрим); аларның һәркайсын индивидуаль үзенчәлекләрен исәпкә алып гәүдәләндерә. Үз-үзенә ышанган, бераз әрсезрәк, көләч йөзле Җаграп («Гөргөри кияү-



Р.Ч.Төхфәтуллин.



И.Ж. Төхфәтуллина.

ләре», Т.Миңнуллин), Альфред («Казан егетләре», «Тагын Казан егетләре», М.Гыйләҗев) кебек характерлы рольләрдә образларның чын асылын ачып бирергә омтыла. Югары зәвык б-н башкарган Тибальт («Ромео һәм Джульетта», У.Шекспир), Норадын («Идегәй», Ю.Сафиуллин) рольләрендә Т. истә калырлык тышкы сурәт аша характер - ның күпкырлылыгын җиткерә. Көчле трагизм б-н сугарылган Рәхим җан («Эзләдем, бәгърем, сине», Т.Миңнуллин) образын иҗат итә: инвалидлар арбасында утырса да, нык ихтыяр көченә ия булган, рухи байлыгын җуй - маган кешенең катлаулы, драматик киеренке эчке дөньясын яктырта. Шулай ук Габдерәшит («Асылъяр», М.Фәйзи), Мостафа («Зөләйха», Г.Исхакый), Азат («Шәҗәрә», Т.Миңнуллин), Рәшит, Зыятдин («Килә ява, килә ява» һәм «Ява карлар, ява карлар», «Телсез күке», З.Хәким), Карл Моор («Юлбасарлар», Ф.Шиллер), Флориндо («Ике хуҗаның хезмәтчесе», К.Гольдони), Рокко («Гаугалы гаилә», Э.де Филиппо), Рабачёв («Җимерелгән бәхет», А.Н.Островский) рольләрен дә уңышлы башкара. Бер үк вакытта, 2000 нән, Казан кинохроника студиясендә кино режиссурасы б-н шөгыльләнә, «Упкын» (2001, РФ Эчке эшләр министрлыгының 200 еллыгына багышланган конкурста «Көмеш Георгий» призы), «Зөләйха» (2005, Берлинда узган кино фестивалендә тамашачы күңелен яулаган өчен приз), «Дилемма» (2007, 3 нче Халыкара «Алтын мөнбәр» мөселман киносы фестивалендә тамашачы күңелен яулаган өчен приз), «Бөркетләр» (2009) нәфис фильмнарын, ш.у. «Әни бәйрәме» (2005) һәм «Шүрәле» (2008) анимацион фильмнарын төшерә. ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (2009).



Р.Ч.Төхфәтуллин Булат ролендә («Зәңгәр шәл», К.Тинчурин; Мәйсәрә ролендә — И.Төхфәтуллина).

Әд.: Илялова И. Г.Камал театры артистлары = Артисты театра им. Г.Камала. К., 2005; Народные артисты: очерки. К., 2011. *И.И.Илялова.*

ТӨХФӘТУ́ЛЛИН Рафаил Газиз улы (1.1.1924, Арча р-ны Яңа Иябаш а. — 18.7.1994, Әлмәт ш.), язучы, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1984). 1941 елда Донбасска китә, Горловка шәһәрендә һөнәр уч-щесенә укырга керә, тәмамлаганнан соң шахтада забойчы булып эшли. 1945 тә туган авылына кайта. 1957 гә кадәр «Кызыл юл» район г-тасында җаваплы сәркәтип булып эшли. 1957–59 да Югары әдәби курсларда (Мәскәү) укый. 1960 тан Әлмәттә яши. 1954 тә татар авылына багышланган «Таныш гөрелте» дип аталган беренче хикәяләр җы - ентыгы дөнья күрә. «Авылым хикәяләре» (1959; русчага тәрҗемәсе «Рассказы моей деревни», 1960) җыентыгында, «Йолдызым» (1962; русчага тәр җемәсе «Звезда моя», 1963), «Тамчылар ни сөйли» (1965), «Агымсу» (1968), «Китә казлар» (1976), «Акбүзат» (1979) повестьларында, «Җиләкле аланнар» (1971, русчага тәр җемәсе «Ягодные поляны», М., 1973) автобиографик повестенда гади хезмәт кешеләренең тулы канлы образларын күрсәтә, колхоз тормышының мөһим мәсь әләләрен күтәрә. Т.ның күп кенә әсәрләре рус, казакъ, үзбәк, чуаш, башкорт телләренә, «Җиләкле аланнар» повесте инглиз, француз, немец, испан һәм чех телләренә тәрҗемә ителә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары б-н бүләкләнә.

Әсәр.: Хикәяләр һәм повестьлар. К., 1973; Сайланма әсәрләр: 2 томда. К., 1982–83.

Әд.: Әдипләребез: Биобиблиографик белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

ТӨХФӘТУ́ЛЛИН Рәфкать Сәфәр улы (20.3.1947, Яшел Үзән ш.), физик, техник фән. д-ры (2007). 1970 елда Казан ун-тын тәмамлый. 1970 тән Казан техник ун-тының техник физика кафедрасында, проф. (2007 дән). Хезмәтләре нәстационар плазмага оптик диагностика ясауга карый. Плазмотроннарны газ чыгымы һәм токлар үзгәре - шенең киң диапазонында тикшерә, темп-ра - ның плазма радиусы буенча бүленешенә пульсацияләрнең тәэсирен билгели. Нәстационар түбән темп-ралы плазмага оптик диагностика ясауның матем. модельләрен тәкъдим итә.

Хезм.: Влияние пульсаций интенсивности излучения плазмы на точность измерения радиальной температуры // Вестн. Казан. техн. ун-та. 2007. № 1 (автордаш); Излучения и температурные поля в нестационарной плазме. К., 2007; Исследование колебаний в нестационарной осесимметричной плазме // Вестн. Казан. техн. ун-та. 2007. № 2 (автордаш).

ТӨХФӘТУ́ЛЛИН Фәрит Хәйрулла улы (26.4.1936, Каракалпак АССРның Дүртküл ш.), физик, физика-матем. фән. д-ры (1991), проф. (1993). 1959 елда Сәмәрканд ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли: физика ф-ты деканы (1980–85), оптика һәм спектроскопия каф. мөдире (1995 тән). Хезмәтләре куертылган тирәлекләр спектроскопиясен өйрәнүгә карый. СССР югары мәктәбе отличнигы (1977).

Хезм.: Изучение межмолекулярной водородной связи в растворах бромоформа по спектрам комбинационного рассеяния // Изв. вузов. Физика. 1998. Т. 41, № 12 (автордаш); Неэмпирические расчёты молекулярных агрегатов муравьиной кислоты и их спектры комбинационного рассеяния // Хим. физика. 2007. Т. 25, № 1 (автордаш).

ТӨХФӘТУ́ЛЛИНА Илсөя Җиһангир кызы (10.9.1967, Апас р-ны Дәвеш а.), актриса, ТРның халык артисты (2016). 1988 елда Мәскәүдә М.Щепкин исем. Югары театр уч-щесенең татар студиясен тәмамлаганнан соң, Татар акад. театрына кабул ителә. Т. зур сәхнә осталыгына һәм югары вокаль күрсәткечләргә ия. Ул башкарган рольләр тирән драматизм һәм лиризм б-н сугарылган. Рольләре: Галиябану, Галимәбану («Галиябану», М.Фәйзи), Гөләндәм («Талак, талак!..», Х.Вахит), Мәйсәрә («Зәңгәр шәл», К.Тинчурин), Туганым («Банкрот», Г.Камал), Фәгыйлә, Гөлчирә, Нурсия, Шүрәлинә («Шулай булды шул», «Алты кызга бер кияү», «Эзләдем, бәгърем сине», «Җанкисәккәем», Т.Миңнуллин), Мөдир («Җәһәннәм биюе», К.Хоинский), Зәйтүнә («Һинд кызы», Г.Каюмов), Зөбәржәт («Хуҗа Насретдин», Н.Исәнбәт), Зәйнәп, Су анасы («Килә ява, килә ява...», «Ява карлар, ява карлар...», «Су төбендә сөйгәнем», З.Хәким), Миләүшә («Саташкан сандугач», Р.Зәйдулла), Фәүзия («Казан егетләре», М.Гыйләҗев), Дилфүзә («Кичер мине, әнкәй!», Р.Батулла),



И.Ж.Төхфәтуллина Миниямал ролендә («41 нең арбалы хатыннары», З.Зәйнуллин).

Татьяна («Өзелгән өмет», М.Горький), Учак Миниямал («41 нең арбалы хатыннары», З.Зәйнуллин), Маргарита («Ричард III», У.Шекспир).

Әд.: Илялова И. Г.Камал театры артистлары = Артисты театра им. Г.Камала. К., 2005; Татарский государственный академический театр имени Галиаскара Камала. Сто лет: В 2-х томах. К., 2009. Т. 2.

ТӨХФӘТУ́ЛЛИНА Лилия Мөхәммәтҗан кызы (5.6.1935, Казан), акушер-гинеколог, мед. фән. канд. (1969), ТАССРның атказ. табибе (1981). Проф. Н.Е.Сидоров шәкерте. Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1959), Актүбә шәһәре (Казакъстан ССР) бала тудыру йортында акушер-гинеколог булып эшли. 1960 елдан Казан ГИДУВының акушерлык-гинекол. клиникасында: 1972 дән —

1 нче, 1973 тән — 2 нче акушерлык һәм гинекол. кафедраларында, 1987 дән 2 нче акушерлык һәм гинекол. каф. мөдире. Бер үк вакытта ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының балалар һәм яшүсмерләр гинекологиясе буенча баш белгече (1995 тән). Хезмәтләре акушерлык һәм гинекологиядә нейроэндокринология һәм нур ярдәмендә диагноз куюга карый. Т. ТРда беренче булып аналык миомасы очрагында аналык артерияләре эмболизациясен гамәлгә кертә. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Нейроэндокринные нарушения и акушерско-гинекологическая патология ювенильного возраста. К., 2000 (автордаш); Тактика ведения беременности и родов при нейроэндокринных нарушениях и других заболеваниях: Практ. рук. К., 2004 (автордаш).

Әд.: П а в л у х и н Я.Г. История медицины Татарстана в лицах. К., 1977; Акушерская и гинекологическая патология у детей и подростков. К., 2010 (автордаш).

ТӨХФӘТУ́ЛЛИНА Резедә Ринат кызы (3.6.1970, Югары Ослан р-ны Ключище а.), актриса, эстрада артисты, ТРның халык артисты (2008). Казан театр уч-щесен (1989), Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тының социаль-мәдәни эшчәнлек ф-тын тәмамлый (2005). Уч-ще тәмамлаганнан соң, Татар драма һәм комедия театры труппасына кабул ителә. Т.ның беренче роле — М.Фәйзинең «Галиябану» пьесасы буенча куелган спектаклдә Галиябану образы. Ихлас күңелдән тәэсирле гәүдәләндерелгән әлеге образ аның ижади индивидуальлеген билгели. Алга таба ул шат күңелле Гөләндәм («Ике килен-килендәш», Х.Вахит), Зөһрә, Гөлчәчәк («Әйдә барыйк, кызлар карыйк!», «И машина, машина,



Р.Р.Т ө х ф ә т у л л и н а Хәмдия ролендә («Ак калфак», М.Фәйзи).

җитте минем башыма», Р.Вәлиев) рольләрен башкара. Сәрвәр («Сүнгән йолдызлар», К.Тинчурин), Хәмдия («Ак калфак», М.Фәйзи), Аппак («Ител суы ака торур», Н.Фәттах), Магдалена («Бернарда Альба йорты», Ф.Г.Лорка) рольләрендә Т.ның драматик сәләте, катлаулы психол. характерлар туды ру осталыгы ачыла. Мәйсәрә («Американ», К.Тинчурин), Эльвира («Бәйрәм белән, кызлар!», Ш.Фәрхетдинов, Р.Зә һидуллин) кебек көлкеле образларны истә калырлык тәэсирле итеп башкара. Эстрада җырчысы буларак чыгышлар ясый (репертуарында — халык җырлары, татар композиторларының әсәрләре). Т.ның соло концертлары Мәскәү, С.-Петербург, Уфа, Самара, Екатеринбург, Пермь шәһәрләрендә булып уза. «Татар җыры» фестивальләре лауреаты (1988, 2004).

Әд.: И л я л о в а И. Театр имени Тинчурина. К., 2002; Народные артисты: очерки. К., 2011.

И.И.Илялова.

ТӨХФӘТУ́ЛЛОВ Бәдретдин Садретдин улы (15.6.1918, Чуаш Респ-касының Батыр р-ны Чкалово, хәзер Шыгырдан а. — 29.9.1988, шунда ук), Дан орденының тулы кавалеры (17.7.1944, 27.9.1944, 27.6.1945), рядовой. Туган авылында колхозда эшли. 1941 нең сентябреннән Кызыл Армиядә һәм Бөек Ватан сугышы фронтларында, автоматчы, 1323 нче укчы полкның (61 нче армиянең 415 нче укчы дивизиясе) автоматчылар ротасында, отделение командиры. Брянск, Белоруссия, 1 нче Балтыйк буе һәм 1 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Орёл, Гомель-Речица (икесе дә 1943 тә), Белоруссия (1944) һәм Варшава-Познань (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 8 февралендә Павловка авылы (Белоруссия ССРның Гомель өлкәсе) янындагы сугышларда (дошманның каршы һөҗүмен кире кайтарганда, тормышын куркыныч астына куеп, яраланган рота командирын коткара, дошманның дистәдән артык солдатын юк итә), 1944 нең 22 июнендә Столин шәһәре (Брест өлкәсе) өчен барган сугышларда (дошманның пулемёт ноктасын сафтан чыгара һәм дистәдән артык солдатын юк итә) батырлык күрсәтә; 1945 нең 31 гыйнварында Регектанер-Тайрофен (Германия) торак пунктын кулга төшергәндә, башка сугышчылар б-н бергә, дошманның 3 каршы һөҗүмен кире кайтара — шуның б-н аларның җанлы көчләренә һәм сугышчан техникасына шактый зыян китерә; сиздермичә генә дошман урнашкан җиргә бәреп кереп, дзотны һәм андагы солдатларны шартлата. Демобилизацияләнгәннән соң (1947), туган авылында колхозда эшли. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

М.З.Хәбибуллин.

ТӨХФИ́ (Төхфәтуллин) Хәмит (15.11.1922, Семипалатинск ш. — 1994, Ташкент), шагыйрь, журналист. Гол җә шәһәрендә (Кытай) татар урта мәктәбен тәмамлый. Шәркый Төркестан халыкларының милли азатлык хәрәкәтендә катнаша (1944–45). 1945–49 да — «Азат Шәркый Төркестан» уйгыр г-тасында (Голҗа ш.), аннары — «Алга» (Гол җә ш.), 1950–55 тә «Шонҗан гәзите» (Өремче ш.) г-таларында әдәби хезмәткәр. 1955 тә СССРга күчеп килә, Ташкентта яши. Шигырьләрен Казан басмаларында бастыра. Иҗатында татар классик шигъриятенең эстетик-стилистик традицияләрен дәвам итәргә омтыла.

М.Г.Госманов.

ТӨЧЕ́ ТАМЫ́Р (Glycyrrhiza), кузаклылар семьялыгыннан күпъеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Якынча 15 төре билгеле, Евразия, Американың уртача һәм субтропик поясларында, Төньяк Африкада, Австралиядә таралганнар. Татарстан терр-ясендә бер төре — ябалаксыз Т.т. (G. glabra) Көнчыгыш Кама алдында очрый. Тозлы туфраклы бо-



Р.Р.Төхфәтуллина.



Б.С.Төхфәтуллов.

лыннарда, юл буйларында үсә. 50–80 *см* биеклектәге үсемлек. Сабагы туры, күп очрак-та ботаклы, сирәк кенә бизчекле. Яфраклары чиратлашкан, парсыз каурыйсыман, озынча яки эллипс, яки ланцетсыман, ике яктан да яфракларга ябышкаклык бирүче бизчекләр урнашкан. Чәчәкләре шәмәхә, ботак очындагы куентылы чук чәчәк төркеменә җыйналган. Җимеше — өлгергәндә ачылмый торган туры яки җиңелчә бөгелгән итчел кузаклар. Июнь–августта чәчәк ата. Җимешләре август–сентябрьдә өлгерә. Орлыктан һәм вегетатив юл б-н үрчи. Тамырларында флавоноид, органик к-талар, сумала, дуплау матдәләре бар. Алардан сулыш юлларын, ашкайнату системасы авыруларын, ревматизмны дәвалау препаратлары алалар. Азык-төлек сәнәгатендә сыра, лимонад, квас җитештерүдә файдаланыла.

ТӨЧЕ́ ЧИЯ, кошлар чиясе (Cerasus avium), розачалар семьялыгыннан яфрак коючы агачлар төрендәге чия ыругы; җимеш культурасы. Кыргый төре — Кырымда, аерым агачлар, нигездә, катнаш киң яфраклы һәм ылыслы-киң яфраклы урманнарда таралган. Ябалдашы йомыркасыман, сирәк ботаклы. Кәүсәсе 50–60 *см* диаметрда, биеклеге 10–15 *м*. Яфраклары кыска очлы, эллиптик-йомыркасыман, тешәүле, җиңелчә җыерчыклы; ботак төбендә сумалачыл күзәнәге бар. Чәчәкләре ак төстә, чатыр булып җыелган, яфрак ярганчы, бөреләре ачылганчы күренәләр. Җимеше — куе кызыл каты төшле, итләч, сусыл, алсу, кызыл, сары яисә кара төстә, озынча, шарсыман яисә йөрәксыман формада, составында 7–15% шикәр, 0,36–1,1% кислоталар, С витамины бар. Җимешләре яңа өлгергән килеш, компот, кайнатма, цукат, соклар әзерләүдә кулланыла. Утыртканнан соң 4–5 елдан җимеш бирә башлый, озак яши (50–70 ел). Уңышы 1 *га* дан 150 *ц*. Баллы үсемлек. Агачы столярлык эшендә, музыкаль инструментлар ясауда файдаланыла. Башлыча кыргый Т.ч. б-н мәгалеб чиясен ялгау юлы б-н үрчетәләр. Җылыга, яктыга, дым һәм туфракка талымчан. Күмәк һәм йорт яны бакча участокларында үстерелә. ТР шартларында өши. Т.ч.не карау: туфракны көпшәкләндерү, органик һәм минераль ашламалар б-н өстәмә тукландыру, сугару, кисү. Рәт араларындагы туфракны, гадәттә, кара пар астында тоталар. Салкынга чыдамрак сортлары — «Ревна», «Северная», «Тютчевка».

Әд.: Плодоводство. М., 1979.

Р.Ә.Әсретдинова.

ТӨШ КВАДРУ́ПОЛЬ РЕЗОНА́НСЫ (ТКР), электрик квадруполь моменты һәм электрик кристаллик кыры булган төшләрнең үзара тәэсир итешүе хасил иткән энергетик дәрәҗә күчешләре нәтиҗәсендә каты җисемнәрдә (кристаллар, структур пыялалар, аморф матдәләрдә) электромагнит энергия сен резонанслы йотылуы. ТКР 1949 елда Швейцария галимнәре Г.Демельт һәм Г.Крюгер тарафыннан ачыла. ТКР алымы атом-төш физикасында төшләрнең квадруполь моментларын билгеләү максатында кулланыла, бу алым ярдәмендә кристаллар симметриясе һәм төзелеше, макромолекулаларның тәртипкә салыну дәрәҗәсе һәм химик бәйләнешнең характеры тикшерелә. ТКР-спектроскопия шартлаучан матдәләр һәм наркотик кушылмаларны билгеләүче заманча датчикларның нигезен тәшкил итә, түбән һәм үтә түбән темп-раларны үлчи торган югары төгәллекле термометрларда кулланыла. ТКР алымы б-н иң күп тикшеренүләр Японияда, Германия, Швейцария, АКШ, Франциядә алып барыла. Казан — Россиядә ТКР алымын кулланучы иң зур үзәкләрнең берсе (Казан ун-ты, РФА КГҮнең Физика-техника ин-ты, Казан энергетика ун-ты). РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында И.А.Сафин ТКР-тикшеренүләрнең импульслы алымын эшли (1961) һәм аны минералогиядә магнитлану релаксациясен һәм кинетикасын өйрәнүдә куллана (1965), Д.Я.Осокин һәм И.Ә.Нуретдинов ТКР-тикшеренүләрнең импульслы алымын азоторганик кушылмаларның электрон төзелешен өйрәнүдә кулланалар (1968). Бу алым минераллар физикасында (И.Н.Пеньков), югары температуралы үтә үткәргечләрне өйрәнүдә (М.А.Теплов, А.В.Дуглав, В.Л.Матухин, Г.Б.Тейтельбаум) уңышлы кулланыла.

Әд.: Сёмин Г.К., Бабушкина Т.А., Якобсон Г.Г. Применения ядерного квадрупольного резонанса в химии. Л., 1972; Гречишкин В.С. Ядерные квадрупольные взаимодействия в твёрдых телах. М., 1973; Сафин И.А., Осокин Д.Я. Ядерный квадрупольный резонанс в соединениях азота. М., 1977; Спектроскопия ЯКР в минералогии: исследования в Казани // Нефть. Газ. Новации. 2009. Т. 9.

Р.Р.Гайнов, А.В.Дуглав.

ТӨШ МАГНИ́Т РЕЗОНА́НСЫ (ТМР), атом төшләренең магнит моментлары яңача ориентлашу нәтиҗәсендә матдәнең электромагнит энергиясен сайланышлы йотуы. ТМР күренешен ачкан һәм аңлаткан (1946) өчен Америка галимнәре Э.М.Пёрселл һәм Ф.Блохка Нобель премиясе бирелә (1952). ТМР алымы матдәнең фәзаи структурасын һәм электрон төзелешен өйрәнүдә кулланыла, аның нигезендә: а) ТМР сызыгы киңәюгә китерә торган — төш моментлары арасында (спин-спин релаксация); б) ТМР сызыгы авышуга (химик авышу) китерә торган — төшләр б-н молекуладагы электроннар арасында ; в) резонанслы ешлыкларның авышуына (Найт авышуы) китерә торган — үткәрүчәнлек электроннары б-н төш моментлары арасындагы үзара тәэсир итешүләр ята. ТМР алымы химиядә, физика, геология, биол., медицинада, материаллар белемендә кулланыла. 20 йөзнең 2 нче яртысында диагностика максатларында кулланыла торган ТМР-томография киң тарала. Казанда ТМР ысулы фәннәрнең нәорганик химия (Б.М.Козырев, А.И.Ривкинд, К.Ә.Вәлиев, А.А.Попель, Р.К.Мәҗитов һ.б.); органик химия (Й.Ю.Сәмитов, Ә.В.Ильясов, А.В.Аганов, В.В.Клочков һ.б.); каты җисем физикасы (Р.Ә.Даутов, В.Д.Корепанов һ.б.), полимерлар (А.И.Маклаков, В.Д.Скирда, Н.Ф.Фәткуллин һ.б.), Ван-Флек парамагнетиклары һәм сыек гелий-3 (М.А.Теплов, М.С.Таһиров һ.б.); биология (Н.А.Мальцев, В.Д.Федотов, А.В.Анисимов һ.б.); медицина (Ә.В.Ильясов, В.Д.Скирда, Я.В.Фәттахов һ.б.); минералогия (В.М.Винокуров һ.б.) кебек өлкәләрендә кулланыла. ТМР алымы кулланылган хезмәтләре өчен Казан галимнәре күп тапкырлар ТРның Дәүләт бүләкләренә лаек була. Ш.у.к. *Казан радиоспектроскопия фәнни мәктәбе*.

Әд.: Эрнст Р., Боденхаузен Дж., Вокаун А. ЯМР в одном и двух измерениях. М., 1990; Purcell E.M., Torrey H.C., Pound R.V. Resonance Absorption by Nuclear Magnetic Moments in a Solid // Phys. Rev. 1946. V.69, № 1–2; Bloch F., Hansen W.W., Packard M. Nuclear Induction // Phys. Rev. 1946. V.69, № 3–4.

А.В.Егоров, М.С.Таһиров.

ТРА́ВКИН Фёдор Петрович (1833–1894, Казан), педагог, нәкышьче. 1856 елда СА нең өяз уч-щеләрендә рәсем, сызым, матур язу дәресләре укытучысы таныклыгы ала; 1857 дә Казандагы Икенче ир балалар гимназиясендә сынау үтә. Бозаулык өяз уч-щесендә укыта (1857). Казанга кайткач, Казандагы Беренче ир балалар гимназиясендә рәсем дәресләре укыта. 1878 дә «Карчык портреты» өчен СА нең кече көмеш медален ала (ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда нәкъ менә шул медаль сакланулы ихтимал). 1880 дә СА нә 7 нәкышь әсәрен тәкъдим итә (алар арасында — Казан татар хатын-кызларының 3 портреты) һәм класслы рәссам дәрәҗәсенә лаек була. 1879 еллар башында Т. Зур Проломный урамындагы (хәзерге Бауман ур.) Карпов йортында шәхси рәсем һәм нәкышь мәктәбе ача. Рәсем укыту барлык уку йортларында гомуми белем бирү системасы буенча алып барылган бер вакытта, ул Казандагы бердәнбер рәсем мәктәбе була (1894 кә кадәр эшли). Т. үтенече буенча, СА ннән мәктәпкә уку әсбаплары, гипс күчермәләр җибәрелә. СА педагогы П.П.Чистяков б-н хат языша



Ф.П.Травкин. «Казан яныңдагы Савиново авылында борынгы чиркәү». 19 йөзнең 2 нче яртысы. ТР Дәүләт Сынлы сәнгать музее.



Ф.П.Травкин. «Билгесез карт портреты». ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

һәм, аның кебек, төп игътибарны үрнәкләрнең гади күчермәсен алудан бигрәк, натураны өйрәнүгә юнәлтергә өндәп, белем бирү алымнарының алгы сызыгында тора (нәтиҗәдә Т. мәктәбе укучыларының берсе СА нә укырга керә, икесе өяз уч-щеләрендә рәсем укытучысы дәрәҗәсе ала). Мәктәп укучылары Казан сәнгать күргәзмәләрендә уңышка ирешәләр, аерым алганда, 1885 елгы шәһәр күргәзмәсендә 45 эш экспозициягә куела. Рәссамның кызы В.Ф.Травкина ш.у. мәктәп педагогы була, шәһәрнең 2 нче, 4 нче, 12 нче, 22 нче башлангыч уч-щеләрендә рәсем дәресләре алып бара. 1890 елгы Казан фәнни-сәнәгать күргәзмәсендә Т.ның педагоглык эшчәнлеге Мактау кәгазе б-н билгеләп үтелә, В.Ф.Травкина бронза медаль б-н бүләкләнә.

Документаль чыганаклар заказ буенча пейзаж һәм портретлар эшләвен расласа да, останың сәнгать мирасы зур түгел. Т.га Казан ун-тының актлар залы һәм патология-анатомия ин-ты өчен профессорлар Н.А.Виноградов һәм А.В.Петров портретларына заказлар бирелә (1886). В.И.Заусайлов тупланмасында аның 1895 тә Казан шәһәр музеена бүләк ителгән (хәзер ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее коллекциясендә) «Царицино авылының борынгы чиркәве күренеше», «Казан янындагы Савиново авылында борынгы чиркәү» картиналары саклана. «Билгесез карт портреты»ның авторы да Т. Останың нәкышь картиналарына кайвакыт артык җентекләп эшләү алымына күчә барган деталь-ләштерү хас. Образларны сурәтләүдәге бер-кадәр катгыйлек һәм кырыслык Россия нәкышенең 19 йөз ахыры — 20 йөз башы реалистик мәктәбенә хас колорит саранлыгы, куе кара-раңгы төсләр б-н көчәйтелә. Т. Казанда уздырылган 1886 елгы — шәһәр, 1890 елгы фәнни-сәнәгать күргәзмәләрендә һ.б. катнаша.

Әд.: Казанская научно-промышленная выставка 1890 г.: Каталог. К., 1890; Могильникова Г.А. Русское искусство XVII — начала XX веков. Живопись: Каталог. К., 2005.

И.Ф.Лобашёва.

ТРА́ВКИНО авылы, Лаеш р-нында, Лаеш шәһәреннән 33 *км* төньяк-көнбатыштарак, Казан–Атабай автомобиль юлы буенда. 2010 елда 11 кеше (руслар, татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. 17 йөз ахырында нигез салына. 1861 елгы реформага

кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.да вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 390,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Әстерхан волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш р-нында. 1927 нең 14 февраленнән — Воскресенский, 1927 нең 1 августыннан — Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Столбище, 1959 ның 26 мартыннан — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 44 ир-ат; 1859 да — 76, 1897 дә — 185, 1908 дә — 187, 1920 дә — 237, 1926 да — 255, 1949 да — 194, 1958 дә — 203, 1970 тә — 150, 1979 да — 69, 1989 да — 35, 2002 дә — 20 кеше.

ТРАВМАТОЛО́ГИЯ, к. *Ортопедия.*

ТРАВМАТОЛО́ГИЯ ҺӘМ ОРТОПЕДИ́Я ҮЗӘГЕ́, фәнни-тикшеренү үзәге. Казанда 1918 елда протез ясау остаханәсе җирлегендә авырулар өчен 40 ятак-урынлы стационары булган ортопедия ин-ты буларак нигез салына; оештыручысы һәм беренче директоры — М.О.Фридланд (1937 гә кадәр). 1920 дә травматология һәм ортопедия кафедрасының клиник базасы сыйфатында Казан ГИДУВы составына кертелә. Ортопедик-травматологик авыруларга мед. ярдәме күрсәтү һәм протезлар ясау буенча Идел буендагы бердәнбер махсус учреждение була. 1935 тә Татарстан ортопедия һәм травматология ин-ты итеп үзгәртелә. Бөек Ватан сугышы елларында ин-т җирлегендә госпиталь эшчәнлеге җәелдерелә. 1943 тә госпиталь — сугыш инвалидларын дәвалау б-н шөгыльләнүче өлкә тернәкләндерү хирургиясе хастаханәсе, 1945 тә Казан травматология һәм ортопедия фәнни-тикшеренү ин-ты (1971 гә кадәр директоры Л.И.Шулутко) итеп үзгәртеп оештырыла. 1987 дән Бөтенсоюз Курган «Травматология һәм ортопедия» фәнни үзәге ф-лы буларак эшли. 1992 дән ТР ФА составындагы Татарстан «Травматология һәм ортопедия» фәнни-тикшеренү үзәге. 2009 дан Респ-ка клиник хастаханәсе составында (директорлары — Х.З.Гафаров, Р.Я.Хәбибьянов).

1920 елларда фәнни тикшеренүләрнең төп юнәлешләрен сугыш инвалидларына ярдәм оештыру, утлы корал яраларын, озакка сузылган яраларны, ортопедик деформацияләрне дәвалау ысулларын эшләү, тернәкләндергеч дәвалау физкультурасы тәшкил итә. Сөяк тукымасы регенерациясен куәтләндерү ысуллары терәк-хәрәкәт аппараты деформацияләре патогенезы теориясен баета (М.О.Фридланд, 1920). Ортопедия буенча илебез галимнәре тарафыннан әзерләнгән беренче кулланмалар — «Гомуми ортопедия» («Общая ортопедия», 1928) һәм «Хосусый ортопедия» («Частная ортопедия», 1932) нәшер ителә, аларда оригиналь оператив һәм консерватив дәвалау ысуллары (ш.и. ин-тта эшләнгән) тасвирлана. 1930 еллардагы фәнни эшләнмәләрдә терәк-хәрәкәт аппараты-ның тумыштан килгән имгәнү нәтиҗәсе булган деформацияләрен дәвалау һәм кисәтүгә, полиомиелит һәм сөяк туберкулёзы нәтиҗәләрен өйрәнүгә зур игътибар бирелә. Бөек Ватан сугышы елларында галимнәр тарафыннан утлы корал ярасы остеомиелитын, озакка сузылган яра һәм җәрәхәтләрне, нерв кәүсәләре яраларын, ялган буыннарны дәвалау тәжрибәсе гомумиләштерелә (Л.И.Шулутко, Л.В.Грубер, Г.С.Книрик). Шул ук вакытта Идел буендагы һәм якын-тирә респ-ка һәм өлкәләрдәге сәламәтлек саклау учреждениеләренә гамәли ярдәм күрсәтелә. Нефть сәнәгате пр-тиеләрендә, а.х.нда, төзелештә имгәнүләрне киметү, хезмәт шартларын яхшырту һәм травматологик ярдәм күрсәтүнең сыйфатын яхшырту буенча тәкъдимнәр эшләнә һәм гамәлгә кертелә (Ү.Я.Богданович, Д.Г.Тәхәвиева, А.И.Гордеева, Е.Н.Громова, 1960 еллар). Ортопедик авыруларны, озакка сузылган яраларны дәвалау практикасында лазер кулланыла башлый. Фәнни тикшеренүләр барышында электрон микроскопия, магнит-төш резонансыннан файдаланыла (В.И.Ракитянский, Ү.Я.Богданович, М.Г.Кәримов, 1970–80 еллар). Периферик кан әйләнеше, нерв-мускул аппаратының халәтен ачыклауның радиоэлектрон ысуллары эшләнә һәм гамәлгә кертелә (Г.С.Литвин, 1967). Сколиоз (Л.И.Шулутко, 1968), спондилоартрит (Бехтерев авыруы), сөяк шешләре патогенезы һәм бу авыруларны дәвалау мәсьәләләре өйрәнелә. Сынган сөякләрне функциональ дәвалау өчен Шулутко-Ципоркин шины, чәрдәкләнгән сөякләр репозициясе аппараты (Х.С.Рәхимкулов, Ф.Ф.Сафин, А.А.Крылов, А.Л.Гиммельфарб), компрессион остеосинтез аппараты (Ф.С.Йосыпов, А.А.Крылов, В.М.Сергеев, Р.А.Шәфигуллина), эксцентрик йозаклы компрессион остеосинтез пластинасы (Х.С.Рәхимкулов) киң кулланыш таба. Гигант күзәнәкле шешне хирургия юлы б-н дәвалау ысуллары гамәлгә кертелә. Сынган сөякләрне, зарарланган сеңерләрне, тире һәм сөяк пластикасын консерватив һәм оператив дәвалауның оригиналь ысуллары Үзәк эшчәнлеге практикасында ныгып урнаша. Үзәк галимнәре тарафыннан аяк сөякләренең торсион (борылулы) деформациясе механизмы турында оригиналь теория эшләнеп тәкъдим ителә (1990 еллар); гамәли әһәмияте зур бу ачыш Х.З.Гафаров һ.б.ның хезмәтләрендә чагылыш таба. Умыртка сөяге һәм күкрәк читлеге деформациясе патогенезы өйрәнелә. Ортопедик һәм нейрохирургик тайпылышларны микрохирургия методы нигезендә яңача дәвалау (А.А.Богов, 1980–90 еллар) уңай нәтиҗәләр бирә. Каты авыруларны эндопротез кую юлы б-н дәвалау буенча тәжрибә туплана. Оча-бот буыннары эндопротезларының яңа конструкцияләре эшләнә (Х.З.Гафаров, А.Л.Гиммельфарб, 1995). Әре буыннарны эндопротезлау программасы әзерләнә, протез конструкцияләре үзәк хезмәткәрләре тарафыннан ясала.

Умыртка баганасындагы тайпылышларның барлыкка килү сәбәпләрен ачыклау үзәк эшчәнлегендә әһәмиятле урын алып тора. Умыртка баганасы тайпылышларын дәвалау барышында, нейрохирургия клиникасында беренче буларак, Илизаров методикасы кулланыла: бу очракта зарарланган умыртка анатомик формасын һәм структурасын саклап үстерелә-тергезелә (Е.К.Вәлиев, Я.Х.Ибраһимов, 1998).

1970–90 елларда ин-тның матди-техник базасы ныгый: эксперименталь лаб. корпусы төзелә, биохимик, патогистологик, микробиол., электрофизиол. һәм эксперименталь лаб-яләр, әгъзалар һәм тукымалар консервациясе лаб-ясе оештырылып җи һазландырыла.

Үзәк ныклы клиник базага ия (300 ятак-урын) 7 дәвалау бүлегеннән тора: өлкәннәр өчен кичектергесез травматология, балалар өчен ортопедия һәм травматология, өлкәннәр өчен ортопедия, нейрохирургия, күл чугы хирургиясе, микрохирургия, катлауланган җәрәхәтләр бүлекләре.

Үзәктә 600 дән артык белгеч эшли. Яңа ысуллар эшләнә, билгеле ысуллар камилләштерелә һәм дәвалау бүлекләрендә, ш.у. Идел буеның Үзәк күзәтчелегендә торган төбәкләрендәге дәвалау учреждениеләрендә киң кулланыла.

Әд.: Казанский научно-исследовательский институт травматологии и ортопедии. К., 1970; Казанский филиал Всесоюзного Курганского научного центра. К., 1990; «10 лет спустя» // Мед. вести. 1998. № 21, нояб.; Тахавиева Д.Г. Казанскому научно-исследовательскому институту травматологии и ортопедии 40 лет // Казан. мед. журн. 1986. № 6; Гафаров Х.З., Богданович У.Я. 75 лет Казанскому институту ортопедии и травматологии // Казан. мед. журн. 1993. № 5.

Е.К.Вәлиев, А.Л.Гиммельфарб.

ТРАГЕ́ДИЯ (грек. — tragōdía, туры мәгънәсе — кәҗә җыры), драматургия жанры; героик шәхеснең җәмгыять, табигать көчләре, яз-мыш б-н кискен бәрелешенә нигезләнә. Трагик коллизия, гадәттә, баш геройның һәлакәте б-н тәмамлана. Татар драматургиясендә Т. язуның беренче тәжрибәсе Г.Исхакый иҗатына карый. «Зөләйха» пьесасының вакыйгалар үзәгендә — трагик героиня. Рус кешесенә көчләп кия үгә бирелгән хатын мөселман булып калу хокукы өчен кискен, ләкин тигезсез көрәш алып бара. Жанр үсешендә чираттагы адым булып Ф.Бурнашның «Tahir-Зөһрә» пьесасы тора. Совет чорында язылган Һ.Такташның «Җир уллары трагедиясе», К.Тинчуринның «Зар», Н.Исәнбәтнең «Спартак», «Идегәй», Н.Фәттахның «Кол Гали», Т.Миңнуллинның «Моңлы бер җыр», И.Юзеевның «Соңгы төн» пьесалары жанрның төп таләпләренә җавап бирәләр. К.Тинчуриннның «Сүнгән йолдызлар», Ә.Рахманколовның «Упкын», Н.Исәнбәтнең «Муса Җәлил», «Мәрьям», Р.Ишморатның «И мөкатдәс моңлы сазым», С.Шәкүровның «Зөһрә йолдыз» һ.б. пьесаларның жанрын татар әдәбияты галимнәре ш.у. Т. дип саныйлар; чөнки аларда бу жанрның төп элементлары: фажигале конфликт, төп геройларның үлеме бар, ләкин бу пьесаларга героик характерлар, трагик пафос, психол. анализ тирәнлеге җитеп бетми. Совет чорында хөкем сөргән «сәнгать шатлык кына китерергә тиеш» дигән идеологик күрсәтмә Т. жанры үсешен шактый тоткарлый. 1990 елларда бу жанрда яңа әсәрләр языла: Р.Хәмиднең «Ак тамырлар иле», «Җанкай улы Җанкыяр», Ә.Баян-

ның «Каракош», Ю.Сафиуллинның «Йөзек һәм хәнҗәр», З.Хәкимнең «Шайтан куенты-гы», Д.Салиховның «Чукрак» һ.б.

Әд.: Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990; Давыдова Т.Т., Пронин В.А. Теория литературы. М., 2003. *А.Г.Әхмәдуллин.*


ТРАГИКОМЕ́ДИЯ, *трагедия* һәм *комедия* үзенчәлекләрен органик рәвештә берләштергән драма әсәре. Т.ның асылында тормыштагы вакыйгаларның чагыштырмалылыгын тою ята; драматург бер үк хәлне комик һәм трагик якътан күрә. Трагикомик эффект геройның ситуациягә туры килмәве аркасында, конфликтның эчтән хәл ителмәгәнлегеннән бар-лыкка килә. Татар драматургиясендә Т. мисаллары — К.Тинчуриннның «Җилкәнсезләр», Ш.Хөсәеновның «Зөбәйдә — адәм баласы», З.Хәкимнең «Җүләрләр йорты» пьесалары.

Әд.: Әхмәдуллин А.Г. Сәхнә әдәбияты һәм тормыш. К., 1980. *А.Г.Әхмәдуллин.*

ТРАДЕСКА́НЦИЯ (Tradescantia), коммелиналар семьялыгыннан күпьеллык үлән-чел үсемлекләр ыругы. 60 ка якын төре билгеле. Чыгышы — Американың субтропик һәм тропик пояслары. Яфраклары көпшә җиңсәле, чиратлашкан, озынча түгәрәк яки киң ланцетсыман, ак сызыклы чуар төсләре б-н аерылып тораллар. Өч касә яфраклы һәм таҗчыклы чәчәкләре берле яисә чәчәк төркемендә урнашканнар. ТРда кайбер Т.не декоратив бүлмә гөле буларак үстерәләр. Ак чәчәкле Т. (T. albiflora) — шуышма сабаклы, яфраклары утырма диярлек, яшел, чәчәкләре ак (бик сирәк чәчәк ата). Елга буе Т.сенең (T. fluminensis) сабаклары нәзек, шәмәхә, яфраклары ваграк, күп итеп вак кына ак чәчәк ата (үрмәле үсемлек буларак асылмалы вазаларда үстерәләр). Виргиния Т.се (T. virginiana) — туры сабаклы үсемлек, яфраклары кыяк-ланцетсыман, чәчәкләре эре, зәңгәр һәм шәмәхә төстә. Барлык төрләре дә оч ботакларыннан җи ңел үрчи. Чуар яфраклыларын еш ашларга кирәк түгел, чөнки алар яшел төскә керәләр, чәчәк атулары начарлана. Тармакланып үссен өчен ботак очларын кискәлиләр, бер генә төстәге яфраклы үсентеләр күренә башлау б-н, аларны йолкып ату мөһим. Суны яздан көзгә кадәр мул, кышын уртача сибәләр.

ТРА́КТОРНЫЙ посёлогы, к. *«Ким» совхозы-ның икенче фермасы посёлогы.*

ТРАМ, ВЛКСМ өлкә ком-ты каршындагы Казан дәүләт эшче яшьләр театры. 1930 елда Елга аръягы Эшчеләр сарае каршында (элек-ке «Алафузов театры»нда) һәвәскәр агитация коллективы буларак оеша. Казан завод-фабрикаларында Татар пролетар язучылар ассоциациясе тарафыннан оешкан түгәрәкләрдә катнашучылар иҗат иткән пьесалар, инсценировкалар һәм әдәби монтажлар буенча спектакльләр куя. Авторлар арасында Б.И.Зернит, Н.В.Ростиславлев һ.б. була. 1931 дән элекке Яңа мәдәният йорты бинасында (хәзер Профсоюз урамындагы синагога) проф. театр буларак эшли башлый. Сән-гать җитәкчесе — Казан Зур драма театры актёры А.Ц.Бродецкий, спектакльләрнең ку-елышы буенча күрсәтмәләрне Казан Зур дра-ма театры актёры, респ-каның атказ. артисты П.Д.Муромцев бирә, рәссам — И.Власов, ком-



Казан эшче яшьләр театры. Ф.Ф.Кнорре пьесасы буенча куелган «Тревога» спектакленнән күренеш.

позиторлары — А.А.Поздеев һәм П.Сиротки-н, директоры — А.Н.Краев. 2 труппа (сек-тор): рус һәм татар труппалары оеша; татар секторы б-н С.Хөснетдинов җитәкчелек итә. Рус секторы актёрлары арасында — Е.С.Бе-локовыльская, И.Бельский, Л.В.Колосова, А.Крупина, С.С.Митюгов, А.Полосухина, М.М.Толпегин; татар секторында Җомакы-лова, Гобәйдуллина, Гәрәева, Максудов, Нигъмәтуллина, Сәгыйтов, Садриев, Хәби-буллина, Яруллин була. Театр репертуары-нда: «Бир бишне» («Дай пять», Н.В.Ростислав-лев), «Бердәм шугалак», «Көннәр эри» («Дружная горка», «Плавятся дни»,



1930–33 елларда Казан эшче яшьләр театры спектакльләре программасы.

Н.Ф.Львов), «Тревога» (Ф.Ф.Кнорре), «17 нчедәге кыз» («Девушка из 17-го», В.Пав-лов), «Галстук» (А.Г.Глебов), «Хакимлек ит, империя» («Правь, империя», А.И.Пиотровский) спектакльләре, «Тар-мар» («Разгром», А.А.Фадеев) романының инсценировкасы. 1932 дә театр, нигездә, А.В.Ухтомский исем. Тимерьюлчылар мәдәният йортында эшли, 1933 тә таркала. Революцион роман-тизм һәм соц. төзелеш рухындагы театраль эстетика тудыруда билгеле бер роль уйный.

Әд.: Миронова В. ТРАМ: Агитационный молодёжный театр 1920–1930-х годов. Л., 1977; Театральная энциклопедия. М., 1967. Т. 5. *Ю.А.Благов.*

ТРАМВА́Й, шәһәр җир өстә электр транспорты. 500–700 *В* көчәнешле даими электр тогы Т.га әленмә контакт челтәре (кире үткәр-геч — рельслар) аша бирелә. Т. хәрәкәте респ-каның өч шәһәрендә — Казан, Түбән Кама, Чаллыда гамәлгә кертелгән.

Казан губерна идарәсе беренче тапкыр Т. хәрәкәтен Зур Проломная урамыннан (хә-зер Бауман ур.) Идел пристаньнарына кадәр атлы тимер юл («конка») ярдәмендә кертер-гә тырыша (1867). 1870 елда Тимер юллар министрлыгы Казандагы атлы тимер юл про-ектын хуплый, 1875 тә ул юл ачыла (нигез са-лучысы — отставкадагы инженер, штабс-ка-питан П.П.Панаев). Вагоннар Мәскәүдән кай-тартыла, ике класста 40 ка кадәр кеше утыра ала. 1875–76 да «Идел» («Волжская», «Толчок»тан Иделдәге «Дальнее Устье» приста-нена кадәр) һәм «Проломная» («Толчок»тан Зур Проломная урамы буйлап Балык рәтлә-ре мәйданы (хәзер Тукай урамы) аша Постау-чылар бистәсендәге чиркәүгә кадәр) юлла-ры эшләп килә. 1876 ның сентябренә «Идел» линиясендә 5 вагонның расписание буенча хәрәкәте җайга салына. Соңрак рельслы яңа юллар Югары Фёдоров, Театр (хәзер Пуш-кин) урамнарында, Николай мәйданында (хәзер Ленин бакчасы), Евангелистлар (хәзер Татарстан), Тихвин (хәзер Тукай) мәйдан-нарында һ.б. урыннарда төзелә. Линияләргә те-леграф һәм телефон куела; төнге хәрәкәт участоклары якътыртыла. Юллар, башлыча, бер колеялы була, 300–600 *м* саен үткәреп җибәрүче икенче юллар эшләнә, 5 линиядә



Атлы тимер юл вокзалы. Казан. 1875.

43 тукталыш ясала. 1900 нең ахырына атлы тимер юлларның гомуми озынлыгы 18,3 *км* га җитә, уртача хәрәкәт тизлеге 7,5 км/сәг. тән артмый, 2 парк (3 вагон сарае, 200 һәм 300 атка исәпләнгән ат абзарлары) хезмәт күрсәтә. Атлы тимер юллар 1900 гә кадәр эшләп килә. 1892 дән башлап «*Казанда Бельгиянең атлы тимер юллар аноним җәмгыяте*» үз эшчәнлеген җәелдереп җибәрә. 1899 да Т. ихтыяҗларын тәэмин итү максатындагы махсус электр станциясе сафка кертелә, һәм электр б-н эшли торган беренче Т. җибәрелә. Ак рынлап яңа тарту көченә күчү бара. Моторлы вагоннар Бельгиядән кайтарыла. Үзәк урамнарда улаксыман рельслар салына, бер колеялы юл акрынлап ике колеялыга үзгәртелә, юллар озыная (1913 тә 50,3 *км*); Т.лар паркында 105 вагон исәпләнә. Беренче бөтендөнья һәм Гражданнар сугышы елларында хәрәкәт итүче составның күпчелеге сафтан



Театр мәйданында трамвай. Казан. 1905.

чыга, вагоннарның шактый өлеше йөк ташуга көйләнә. 1918 дә Т. хуҗалыгы национализацияләнә. Т. Казан Эшче һәм солдат депутатлары советының коммуналь бүлеге карамагына күчә; 1921 дә яңадан пассажирлар ташу башлана. Т.лар паркы моторлы 18 пассажир һәм 6 йөк вагоныннан тора; юллар озынлыгы 20 *км* була. 1922/23 нең кышында, кар көртләре калын булу сәбәпле, Т. хәрәкәте туктатылып тора, 1923 нең маенда хәрәкәт яңадан башлана һәм шуннан бирле өзелми. 1924 тә 24 вагон хәрәкәт итә. 1925 тә Казанда 4 Т. юлы була. 1926 дан контактлы үткәргечләрне алыштыру башлана (1940 ка 68 *км* үткәргеч алыштырыла), 1928 дә — яңа подстанция, 1929 да махсус электр станциясе (1959 га кадәр эшли) файдалануга тапшырыла. 1926 да шәһәр коммуналь хуҗалыгы карамагындагы «Эльводтрам» тресты төзелә. Т. идарәсе — Казан шәһәр тимер юллар идарәсе, ә 1932 дән шәһәр коммуналь хуҗалыгы каршындагы Казан Т. идарәсе дип йөртелә башлый. 1933 тән гамәлдәге станцияләп түләү тарифы урынына Т.да йөргән өчен бердәм тариф кертелә. 1934 кә 50 тагылма вагон, 71 моторлы вагон исәпләнә. 1941 нең башына гомуми вагоннар паркы 159 берәмлеккә җитә. Т. паркы Мәскәүдән кайтарылган «Х» серияле (арбалы, иң зур тизлеге 40 *км/сәг.*, 68 кеше сыйдыра, ике күчәрле) һәм Мытище з-ды җитештергән вагоннардан тора. Бер юлга күчереп исәпләгәндә, юллар озынлыгы 70,6 *км* тәшкил итә. Хәрәкәтне көйләү өчен диспетчерлык хезмәте кертелә, диспетчер станцияләре арасында телефон элемтәсе булдырыла. 1937 дә үзәктән (хәзерге Тукай мәй-



«РВЗ-6М2» трамвае.
Казан, К.Маркс урамы. 1988.

даны) Караваево бистәсенә кадәр Т. линиясе ачыла. 1939 да маршрут һәм поезд расписаниеләре кертелә. Бөек Ватан сугышы елларында күп вагоннар йөк һәм яралылар ташуга көйләнә, Т. маршрутларының бер өлеше ябыла. 1950 елларда Казан Т. паркы Рига вагон з-дының МВТ-82 һәм Усть-Катав з-дының КТМ-1, КТП-1 тибындагы вагоннары б-н тулыландырыла. Мех комб-тыннан Казан макарон ф-касына (1946), Зинин урамыннан Октябрь шәһәрчегенә (1948) кадәр; Ярминкә, Яңа Кремль урамнары буйлап тимер юл вокзалына (1958), Порт-Татарстан (1960), Вахитов мәйданыннан Урта Кабан ярлары буйлап Борисково бистәсенә (1963), Караваево бистәсеннән «Органик синтез» з-дына (1966) кадәр Т. юллары төзелә. 1948 дә, Казанда троллейбус хәрәкәте оештырылу б-н, 3 нче Т. паркы (Ленинград урамында) трамвай-троллейбус паркы дип атала башлый, беренче троллейбуслар шунда урнаштырыла. 1957 дә Т. һәм троллейбусларга — юл йөрү билетлары, 1960 та — кондукторсыз хезмәт күрсәтү, 1978 дә кассасыз



«АКСМ-843» трамвае.
Казан, «Тимер юл вокзалы» тукталышы. 2018.

хезмәт күрсәтү кертелә; 1993 тә кабаттан кондуктор хезмәте кайтарыла. 1960 еллардан Рига вагоннар з-ды җитештергән төрле модификацияле РВЗ-6 тибындагы вагоннар файдаланыла (2011 гә кадәр). 1973 тә Гвардия, 1976 да Зорге урамнары буйлап Җиңү проспектына кадәр Т. юлы төзелеп бетә (1980 дә ул 9 нчы микрорайон — Габишев урамына кадәр сузыла). 1979 да компрессорлар з-дыннан Ямашев урамы буенча Декабристлар урамына кадәр (Химиклар сарае) Т. юлы ачыла. 1987 дә Казанда Усть-Катав з-дының КТМ-5М тибындагы (өч ишекле, электромеханик күчергечле, иң зур тизлеге 65 *км/сәг.*, 128 кеше сыйдыра) (2014 кә кадәр файданыла), 1993 тә — КТМ-8 (2016 га кадәр), 1999 да КТМ-19 (2016 га кадәр), 2016 да КТМ-71-623 тибындагы яңа вагоннар сафка кертелә. 1993 тән Петербург трамвай-механика з-дының ЛМ серияле вагоннары, 2002 дән Екатеринбург шәһәре «Уралтрансмаш» з-дының «Спектр-71», 2017 дән «Спектр-71-407», 2018 дән «Спектр-71-407-01» (өч секцияле), вагоннары да файдаланыла башлый. 2013 тән ш.у. Минск шәһәрендә җитештерелгән ике типтагы вагоннар (АКСМ-62103 һәм өч секцияле АКСМ-843) кулланыла. 2016 да Т. паркы КТМ-71–623 тибындагы вагоннар б-н тулыландырыла.

Т.лар челтәре формалашу б-н бергә парк һәм энергетика хуҗалыклары да үсеш ала. Берничә Т. депосы һәм подстанциясе гамәлгә кертелә, 1982 дә аларда телеидарә системасы эшли башлый. 1989 да Трамвай-троллейбус идарәсе Казан шәһәр электр транспорты ҖБ итеп үзгәртелә, 1993 тән — Казан «Шәһәр электр транспорты җитештерү берләшмәсе» коммуналь пр-тиесе. 1999 да Казан трамваеның 100 еллыгына Җиңү проспекты буйлап Зорге урамыннан Себер трактына кадәр Т. юлы ачыла, шәһәрдә 21 Т. маршруты эшли башлый. 2005 тә, «Казан метрополитены» муниципаль унитар җитештерү берләшмәсе» коммуналь пр-тиесен берләштереп, «Метроэлектротранс» МУП оештырыла.

2018 нең 1 гыйнварына файдаланыла торган Т. юлларының гомуми озынлыгы 135 *км* (бер юллап исәпләгәндә); Казан Т. паркында 96 вагон исәпләнә, 1 Т. депосы эшли. Шәһәрнең транспорт челтәрен оптималләштерүгә бәйле рәвештә, 2005 тән башлап 15 тән артык Т. маршруты ябыла, Н.Островский, В.Качалов, Газовая (2005), К.Маркс, Н.Ершов урамнарыннан (Гвардия урамына кадәр, 2008), Ленин дамбасыннан (2010), Бутлеров, Волков, Пушкин, Татарстан (2011), К.Цеткин (2010), М.Гафури (2016) урамнарыннан Т. юллары сүтеп алына; 2010 да тимер юл вокзалыннан Киров дамбасы аша Декабристлар урамына кадәр Т. юлы ачыла. 2012 дә Зур Казан божрасын реконструкцияләү төгәлләнә, Җиңү проспекты буенча 2 Т. линиясе участогы, ш.и. Себер трактыннан Р.Зорге урамы буйлап сузылган 22,4 *км* лы, ш.у. Р.Зорге урамыннан Оренбург юлына кадәрге (Кояшлы шәһәр микрор-ны) 5 *км* лы участок файдалануга тапшырыла. 5 нче маршрут мәгълүмати видеотабло (вагонның килү вакытын күрсәтә) б-н җиһазландырыла. 2012 дә Җиңү проспекты аша тимер юл вокзалыннан Кояшлы шәһәргә кадәр югары тизлектәге Т.лар йөри башлый. 2013 кә 6 Т. маршруты эшли.

Түбән Кама шәһәрендә Т. хәрәкәте 1967 нең 23 февралендә ачыла (Трамвай депосы — ТЭЦ-1 маршруты буенча, ике юллап исәпләгәндә 9,4 *км* озынлыкта). 2016 ның 1 гыйнварына шәһәрне сәнәгать зонасы һәм елга порты б-н 8 маршрут бәйли, Т. юлларының гомуми озынлыгы 30 *км* (ике юллап исәпләгәндә); паркта 80 вагон исәпләнә. Тынычлык проспекты буйлап Т. юлы, подстанция төзү эшләре алып барыла; вагоннар составы яңартылып тора.

Чаллы шәһәрендә Т. хәрәкәте 1973 нең 8 октябрендә ачыла. 2016 ның 1 гыйнварына шәһәрдә 14 Т. маршруты гамәлдә, Т. юлларының гомуми озынлыгы 52 *км* (ике юллап санаганда); 6 тукталу станциясе бар, паркында 115 вагон исәпләнә. Казанның Т. һәм троллейбус челтәре (к. *Троллейбус*) радиаль-боҗра системасын хасил итә һәм барлык адм. районнарга хезмәт күрсәтә.

Әд.: 100 лет Казанскому трамваю. К., 1999; Клочков А.И. Казань из окон трамваая. К., 2018. *О.В.Ерёгин.*

ТРА́НСПОРТ, матди җитештерү тармагы, кешеләрне һәм йөк ташуны тормышка ашыра; ш.у.к. *Татарстан Республикасы, Автомобиль транспорты, Һава транспорты, Шәһәр транспорты, Юл-транспорт төзелеше, «Дуслык», Тимер юл транспорты, Горький тимер юлының Казан бүлеге, Метрополитен, Күпер, Елга транспорты, Төньяк-Көнбатыш магистраль нефтьүткәргече, «Татавтотранс», «Таттрансгаз», Трамвай, Троллейбус.*

ТРА́НСПОРТ ЭЛЕ́КТР ҖИҺАЗЛАРЫ́ ЗАВОДЫ́, к. *Татэлектромаш.*

ТРАУБЕНБЕ́РГ Пётр Викторович (13.12.1860, Казан — 1928), педагог, тарихчы. Казан ун-тын тәмамлый (1883). 1884–1912 елларда Казан татар укытучылар мәктәбендә тарих һәм география укыта, бер үк вакытта Казан ун-тының нәфис сәнгать һәм борынгылык музеенда саклаучы хезмәткәр (1885–1915), Казандагы Мария (Беренче) кыз балалар гимназиясендә география укытучысы (1897–1912), реаль уч-щедә тарих укытучысы (1907–17). 1918–25 тә Казан ун-ты рабфагында география укытучысы. Хезмәтләре Казан уку йортлары тарихы, Казан төбәге тарихы һәм этнографиясе мәсьәләләренә карый.

Хезм.: Татарская учительская школа в Казани. К., 1890; Казанская Мариинская женская гимназия: Краткий исторический очерк, её современное состояние и деятельность. К., 1900; Казанское реальное училище. 1875–1900: Краткий исторический очерк училища и его современное состояние. К., 1900.

Әд.: Исхакова Р.Р. Казанская татарская учительская школа и её роль в формировании национального образования. К., 2002.

«ТРЕВО́ГА», фронт газетасы. 2 нче Ерак Көнчыгыш фронтының Сәяси идарәсе органы. 1944 елның 13 июненнән 1945 нең сентябренә кадәр татар телендә нәшер ителә. Мөхәррире — язучы Б.*Корбанов*. Газетада хәрби хәбәрчеләр булып Х.Кәрим, М.Сабельев, М.Мазунов хезмәт итә. Штаттан тыш авторлар арасында — рядовой Г.Исмәгыйлев, сержант Ф.Шәрәфетдинов, лейтенант Я.Ягъфәров һ.б. бар. «Т.»да Г.Әпсәләмов, С.Баттал, Г.Кутуй, Ш.Мөдәррис, К.Нәҗми, Ә.Маликов, С.Сабиров, С.Урайский, Г.Хуҗи, А.Шамов очерклары, әдәби әсәрләре басыла. Совет Армиясе частьларының фронттагы: япон гаскәрләренә каршы Ерак Көнчыгышта, ш.и. Курил утрауларында, Маньчжурия һәм Кореяда барган сугышлар барышында күрсәткән батырлыклары яктыртыла.

ТРЕГУ́БОВА Резеда Зәбир кызы (16.10.1958, Казан), инженер-математик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2003). Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң (1981), шунда ук, гамәли матем. кафедрасында эшли. 1992 дән Респ-ка онкология диспансерының мәгълүмати технологияләр бүлеге башлыгы. Онкология өлкәсендә «Ел казанышы» номинациясендә Бөтенроссия «In vita veritas-2013» бүләге иясе.

ТРЕГУ́БОВА Татьяна Моисеевна (9.5.1955, Казан), педагог, пед. фән. д-ры (2002), проф. (2003), РФ урта һөнәри белем бирү системасының атказ. хезмәткәре (2001). 1977 елда Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң, Питрәч авылы урта мәктәбендә инглиз теле укыта. 1981 дән Казанның 122 нче урта мәктәбендә. 1987 дән РМАнең Һөнәри белем бирү педагогикасы һәм психологиясе проблемалары ин-тында, 2002 дән чит илләр тәҗрибәсен өйрәнү лаб-ясе мөдире. Бер үк вакытта, 1993 тән, Казан социаль-юридик ин-тында укыта. Хезмәтләре студентлар үзидарәсенең үсеше һәм укучыларның шәхес булып формалашуы, яшьләр б-н соц.-пед. эшләр, Европа һәм Америка илләрендә һөнәри белем бирүнең үсеше мәсьәләләренә карый. РФ Хөкүмәте бүләге лауреаты (2005).

Хезм.: Педагогический менеджмент и социализация личности. К., 1999; Теория и практика современной социальной работы за рубежом. К., 2002; Модернизация профессионального образования: глобализация, ключевые компетенции, образовательный перенос. К., 2003.

ТРЕГУ́ЛОВА Зөлфирә Исмәгыйль кызы (13.6.1955, Рига, Латвия ССР), сәнгать белгече, сәнгать фән. канд. Мәскәү ун-тын тәмамлый (1977). 1984-97 елларда Е.В.Вучетич исем. Бөтенсоюз сәнгать-җитештерү берләшмәсендә рус сәнгате халыкара күргәзмәләре кураторы. 1998-2000 дә А.С.Пушкин исем. Сынлы сәнгать музеенда чит илләр б-н багланышлар һәм күргәзмәләр бүлеге мөдире. 2002-13 тә «Мәскәү Кремле» тарих-мәдәният музей-саклаулыгы ген. директорының күргәзмәләр эше һәм чит илләр б-н багланышлар буенча урынбасары. 2013 тән «РОСИЗО» музей-күргәзмә үзәге ген. директоры, 2015 тән Бөтенроссия «Третьяков галереясы» музей берләшмәсе ген. директоры. 2018 дән РФ Президенты каршындагы Мәдәният һәм сәнгать советы әгъзасы. Дөньяның эре музейларындагы киң колачлы күргәзмәләрнең кураторы сыйфатында Т.ның югары оештыру осталыгы чагыла; ул «Кызыл Армия студиясе», «Казимир Малевич һәм рус авангарды», «Мине таң калдыр», «Россия», «Авангард амазонкалары», «Социалистик реализмнар» кебек танылган проектлар б-н җитәкчелек итә. Хезмәтләре галерея эшчәнлеге һәм арт-менеджмент мәсьәләләренә карый. Россия медальләре, чит илләрнең Франциск Скорина (Белоруссия), Италия Йолдызы, Pro Merito Melitensi (Мальта ордены) орденнары б-н бүләкләнә.

Хезм.: «Амазонки авангарда»: выставка и выставки (История совместного экспонирования) // «Амазонки авангарда». М., 2004.

ТРЕ́ЙМАН Василий Васильевич (27.10.1898, Пенза ш. — 1985), гигиена белгече, мед. фән. д-ры (1957), проф. (1961). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1927), шунда ук эшли, Идел бассейны елга хезмәте сәламәтлек саклау бүлеге (Түбән Новгород ш.) хезмәткәрләренең проф. авыруларын өйрәнә. 1927–32 елларда Социаль гигиена ин-тында, бер үк вакытта, 1930–38 дә, Казан мед. ин-тының социаль гигиена кафедрасында, 1929–32 дә Казан ГИДУВында. 1932–34 тә Социаль сәламәтлек саклау ин-тында (Казан). 1934–35 тә Үзәк сан. культурасы йорты директоры, 1935–38 дә — консультанты. 1937–38 дә мед. хезмәткәрләре мәктәбен (Казан) оештыручы һәм аның директоры. 1938–39 да — Горький мед. ин-тының, 1939–41 дә Казан ГИДУВының гомуми гигиена кафедраларында. 1941–42 дә эвакогоспиталь башлыгы урынбасары һәм табиб-диетологы, 1942 дән Үзәк сан. мәгарифе йорты (Казан) консультанты. 1950 дән — Казан, 1954 тән — Новосибирск, 1961–68 дә Рязань мед. ин-тларында сәламәтлек саклауны оештыру һәм мед. тарихы каф. мөдире. Хезмәтләре мед. тарихына, Татарстанда сәламәтлек саклауны үстерүгә, халыкны физик яктан чыныктыру, сан.-агарту мәсьәләләренә карый. Медаль б-н бүләкләнә.

Хезм.: К характеристике условий труда «водников» Волжского бассейна // Казан. мед. журн. 1929. № 9; Сороколетие Татарской АССР и охрана здоровья трудящихся. К., 1960.

ТРЕМА́СОВ Михаил Яковлевич (21.9.1951, Мордва АССР, Дубенки р-ны Дубенки а.), вет. фармакологы, токсиколог, биол. фән. д-ры (1993), проф. (1995), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1999). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1973), шунда ук эшли. 1985 елдан Хайваннарның токсикология һәм радиация куркынычсызлыгы федераль үзәгендә (2004 кә кадәр — Бөтенроссия вет. фәнни-тикшеренү ин-ты): микотоксиннар лаб-се мөдире, бер үк вакытта токсикология бүлеге мөдире һәм директор урынбасары (2007 дән). Тикшеренүләре хайваннарның техноген һәм табигый сәбәпләр б-н агулану очракларында индикация, диагностика, дәвалау һәм агуланы кисәтү ысулларын эшләүгә, агуларның катнаш тәэсирен өйрәнүгә карый. Уйлап табуга 18 авторлык таныклыгы һәм 4 патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Эндемические болезни сельскохозяйственных животных. М., 1990 (автордаш); Агроминеральные ресурсы Татарстана и перспективы их использования. К., 2002 (автордаш); Микотоксикозы животных. М., 2008 (автордаш).

Әд.: Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

ТРЕМАТО́ДАЛАР, имгеч суалчаннар (Trematoda) (элекке исеме — дигенетик имгечләр), яссы суалчаннар классы. Төрле мәгълүматлар буенча 4–5 мең төре билгеле. Умырткалы хайваннарның эндопаразитлары. Күбесенчә ашкайнату трактында, бавырда, сулыш системасында, кан юлында яшиләр. Озынлыгы берничә *мм* дан 5 *см* га (сирәк кенә зуррак) кадәр. Гадәттә, гәүдәсе яфраксыман формада, кайвакыт озынча. Төкчекләре юк, эпителий б-н капланган. Имгечләре (мускуллы үсентеләр) ике: авыз (мускуллы йоткылыкка илтүче авыз, үңәч, эчәклекнең 2 тармагы, йомык эчәклек) һәм корсак (гәүдәнең уртасында яисә алгы я арткы очында) имгече. Бүлеп чыгару системасы протонефридиаль типта. Гермафродитлар (кайберләре генә аерым җенесле). Тереклек циклы катлаулы,

буын чиратлашуы һәм хуҗаларның алышынуы б-н бәйле. Җенси җитлеккән Т. күкәй салалар, алардан исә төкле личинкалар (мирацидийлар) чыга. Суда алар моллюскларга үтеп керәләр һәм спороцистларга әвереләләр. Соңгылары, партеногенетик юл б-н үрчеп, редияләр буынын бирә, алардан исә церкарияләр барлыкка килә. Моллюск тәненнән церкарияләр тышкы тирәлеккә чыгалар, биредә төрле предметларга ябышалар яисә бөҗәк, җир-су хайваннарына, балык һ.б.ның тәненә үтеп керәләр һәм метацеркарияләргә әвереләләр. Т. кеше һәм хайван авыруларын — трематодозларны: фисциолёз (бавыр имгечләр), дикроцеолёз (ланцетсыман имгечләр), описторхоз (мәче имгечләре) һ.б. йоктыручылар. Йогышлану азык аша бара.

О.Д.Любарская.

ТРЕ́ПЕЛ (Төньяк Африкадагы Триполи шәһәре исеменнән), тау токымы. Бик җиңел, көпшәк яки аз гына цементланган, бик вак SiO_2 бөртекләреннән тора. Составында цеолитлар (30% ка кадәр), балчыксыл матдәләр, глауконит, кыр шпатлары бар. Төсе актан коңгырт-сорыга кадәр. Тыгызлыгы 1,2–2,5 мең *кг/м*^{3}, күзәнәклелеге 70 % ка кадәр. Т. чыганаклары диңгез утырмалары б-н бәйле. ТРның көньяк-көнбатышында мезозой утырмаларында очрый. Цемент сәнәгатендә, адсорбент буларак, җылы саклаучы һәм төзелеш материаллары җитештерүдә һ.б. кулланыла.

ТРЕСКИ́Н Эдуард Германович (1.4.1946, Казан), җырчы (баритон), педагог, ТАССРның халык артисты (1987). 1973 елда Казан консерваториясен тәмамлый. 1973 тән Татар филармониясе артисты, 1976–92 дә Татар опера һәм балет театры солисты. Төп баритон партияләрен башкара: Фигаро («Севилья чәчтарашы», Дж.Россини), Валентин («Фауст», Ш.Гуно), Грязной («Патша кәләше», Н.А.Римский-Корсаков) һ.б. Бер үк вакытта, 1983–88 дә, Казан консерваториясендә укыта. 1992 дән Чехиядә яши, Прага опера спектакльләрендә, ш.у. концертлар б-н чыгыш ясый. Будапешт, Вена, Казан, Прага һ.б. шәһәрләрдә халыкара опера һәм музыка фестивальләрендә катнаша. Опера һәм концерт эшчәнлеге б-н бергә 1990 еллар ахырыннан әдәби иҗат һәм тәрҗемә б-н дә шөгыльләнә; Чехия язучылар берлегенең рус секциясе әгъзасы. Праганың рус телле басмаларында мәкаләләре басыла. Сәнгать дөньясына һәм аның проблемаларына багышланган шигырьләр, повестьлар, хикәяләр яза («Ничек йолдыз булырга» — «Как стать звездой», Прага, 2006) һ.б. Прагада Рус чит ил үзәге уздырган Халыкара әдәби конкурс лауреаты (2005). 2005 тән опера режиссёры буларак Россиядә дә, Чехиядә дә эшли. Казан консерваториясенең опера студиясе б-н берлектә «Фауст» (Ш.Гуно), «Бала һәм тылсым» («Дитя и волшебство», М.Равель) операларын сәхнәләштерә. 2010 нан кабат Татар опера һәм балет театрында сәхнәгә куючы-режиссёр булып эшли.

Г.А.Балакин.

ТРЕТЬЯКО́В Владимир Всеволодович (6.1.1890, Казан губ. Зөя ш. — 31.1.1971, Уфа), акушер-гинеколог, мед. фән. д-ры (1942), проф. (1935), БАССРның атказ. табибе (1957). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1915), армия табибе булып эшли. 1920–35 елларда Томск ун-тының акушерлык-гинекол. клиникасы табибе. 1935 тән Төрекмән мед. ин-тының (Ашхабад) акушерлык һәм гинекол. каф. мөдире. 1946–67 дә Башкорт мед. ин-тында (Уфа). Хезмәтләре хатын-кызларны балага уза алмаудан дәвалауга, бала тудырган хатын-кызларда септик өзлегү очракларын кисәтүгә, бала табу вакытында авыртуны басуга, акушерлык һәм гинекологиядә вакуум-терапия куллануга карый. Бөтенроссия акушер-гинекологлар җәмгыятенең Башкортстан ф-лы рәисе (1946–67). Ленин ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: К вопросу о кистах шейки матки // Омский мед. журн. 1928. № 4/5; Некоторые материалы по обезболиванию родов. Аш., 1936; Новокаиновый блок нервной системы при лечении зуда наружных половых органов // Акушерство и гинекология. 1936. № 3.

Әд.: Профессор Владимир Всеволодович Третьяков // Казан. мед. журн. 1973. № 3.

ТРЕТЬЯКО́В Леонид Аполлонович (2.7.1856, Самара ш. — 4.3.1922, Казан), вет. анатомы, вет. фән. магистры (1888), проф. (1896). Казан вет. анатомнары мәктәбенә нигез салучы. Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1881), земство вет. табибе булып эшли. 1886 елдан Казан вет. ин-тында: прозектор, доцент, анатомия каф. мөдире (1896 дан). Өч тапкыр Берлин, Брюссель, Лион, Вена, Берн ин-тларында һәм чит илләрдәге башка ин-тларның анатомия кафедраларына командировкага җибәрелә. Фәнни тикшеренүләренең төп юнәлешләре хайваннарның нерв системасы морфологиясен өйрәнүгә карый. Ин-тның анатомия каф. Т. җитәкчелегендә фәнни кадрлар әзерләү үзәгенә әверелә. Аның шәкертләре арасында үз анатомия мәктәпләрен булдырган танылган галимнәр Д.М.*Автократов*, А.Ф.*Климов*, А.И.*Акаевский* һ.б. бар. Т. мөгезле эре терлек экстерьерына һәм биологиянең гомуми мәсьәләләренә караган кулланмаларның русчага тәрҗемәләре авторы.

Х е з м.: К лечению сапа // Уч. зап. Казан. вет. ин-та. 1886. Вып. 3, 6; Экстерьер: Определение возраста домашних животных // Уч. зап. Казан. вет. ин-та. 1894. Т. 11, вып. 1–2; О положении и нуждах ветеринаров в России в связи с интересами скотоводства и сельского хозяйства. К., 1910.

Әд.: Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

Р.И.Ситдыйков.

ТРИКОТА́Ж СӘНӘГАТЕ́, *җи ңәл сәнәгать нең* иң зур тармагы, *текстиль сәнәгатенә* керә. Бәйләнгән (трикотаж) тукыма яки әзер эшләнмәләр (оек-оекбаш, эчке һәм өс киемнәре, перчатка, шарф, баш киемнәре, сәнәгать һәм мед. максатларындагы эшләнмәләр) җитештерә. Т.с. эшләнмәләре өчен төп материал сыйфатында мамык, йон җепләре, химик сүсләр кулланыла. Трикотаж Көнбатыш Европа илләрендә 18–19 йөзләр аралыгында, ә Россиядә 19 йөз ахырында җитештерелә башлый. 1913 елда илдә 20 ләп трикотаж һөнәрчелеге пр-тиесе исәпләнә. Т.с. 1920 еллар ахырында — 1930 елларда, индустрияләштерү барышында формалаша. Казанда 1930 ел-



Э.Г.Трескин.

лар уртасында беренче тапкыр Татбытпромсоюзның «Иншвейпром» кооператив артеле трикотаж киемнәр җитештерә башлый. 1940 та респ-када трикотаждан 31 мең данә эчке кием һәм 160 мең данә өске кием эшләп чыгарыла. Бөек Ватан сугышы башлангач, Чистай шәһәренә — Киев эрләү-туку ф-касы, ә Казанга Харьков шәһәренең «Динамо» спорт киемнәре тегү ф-касы эвакуацияләнә. Алар фронт өчен трикотаж свитерлар, оекбаш, бияләй, шарфлар, танкистлар һәм очучылар өчен шлем астыннан кию өчен бүреклəр чыгаралар. 1945 тә бу тармак пр-тиеләрендә 240 кеше эшли. Сугыштан соңгы елларда Т.с. үсешен дәвам итә. 1947 дә тире иләү-тегү ф-касы җирлегендә Казан трикотаж-тегү ф-касы оештырыла. 1950–55 тә респ-када эчке кием трикотажы 123 меңнән 380 мең данәгә, трикотаж киемнәр чыгару күләме 453 меңнән 828 мең данәгә кадәр арта. 1950 еллар ахырыннан Т.с. пр-тиеләрендә җи һәзларны яңарту, җитештерүне механикалаштыру һәм автоматлаштыру, органик эреткечләр куллланып эшкәртү алымнарын кертү башлана. Фабрикаларда реконструкция уздырыла, югары җитештерүчән түгәрәкләп бәйләү машиналары, киптерү агрегатлары, заманча тегү һәм буяу җайланмалары б-н җи һәзланды рылып, таррак юнәлешкә күчерелә: Чистай ф-касы — трикотаж тукыма һәм аннан өске киемнәр, Казан ф-касы эчке кием трикотажы җитештерә башлый. Соңрак Чистай трикотаж ф-касы тагын да киңәя һәм бу тармакта респ-каның әйдәп баручы пр-тиесенә әверелә. Анда эшләүчеләрнең саны 1200 кешегә җитә, продукциясе илнең күп кенә төбәкләренә һәм чит илләргә чыгарыла. 1960–70 елларда районнарның халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү комб-тлары каршында трикотаж эшләнмәләр җитештерү һәм аларны төзәтү буенча ателъелар челтәре оештырыла. 1979–85 тә Әлмәт шәһәрендә зур оек-оекбаш ф-касы сафка кертелә (1990 да 26 млн. пар эшләнмә җитештерә). 1960–90 да респ-када трикотаж өс киемнәре җитештерү 1095 меңнән 2629 мең данәгә җитә. 1990 да Т.с. эшләнмәләре күләме респ-ка текстиль сәнәгате продукциясе күләменең 26,1% ын алып тора. 1990–2000 дә фабрикалар акционерлаша һәм хосусый милеккә күчәләр. Чимал бәясе үсү, аны кертүчеләр б-н элемтәләр өзелү, сорауның кимүе, чит илләрдән күпсанлы эшләнмәләр кертелү сәбәпле, 1990 ел б-н чагыштырганда 2000 гә респ-када трикотаж өс киемнәре җитештерү 55 тапкырдан артык, оек-оекбаш эшләнмәләр җитештерү 10 тапкыр диярлек кими. Бу чорда тармакның 32 зур, урта һәм кече пр-тиесендә 1,65 мең кеше эшли.

Татарстанда Т.с.нең әйдәп баручы пр-тиесе булып «*Алсу*» Әлмәт оек-оекбаш фабрикасы» АҖ исәпләнә, анда көндәшлеккә сәләтле эшләнмәләр ассортиментын һәм җитештерү күләмен арттыру максатында техник яктан яңартып җиһазландыру үткәрелә. Продукциясе («Носкофф» сәүдә маркасы б-н) илнең 20 ләп төбәгенә җибәрелә; ТР җ. җ. сәнәгатенең тулаем җитештерү күләмендә ф-каның өлеше 10% тирәсе; РФдә чыгарылган оек-оекбашларның 3% ы шунда җитештерелә (илдә 3 нче урынны били). «Казан трикотажы» АҖ, «Чистай трикотажы» АҖ һәм «Кама трикотажы» ҖЧҖ (Чистай ш.) читтән кертелгән трикотаждан эчке һәм өске киемнәр чыгара. Казан, Чаллы, Зәй, Түбән Кама, Алабуга, Түбән Кама шәһәрләрендә кече пр-тиеләр эшләп килә. 2000 елларда Казанда заманча технологияләргә һәм читтән кертелгән җиһазларга йөз тоткан яңа пр-тиеләр, ш.и. «Казан-Торгпром» АҖ (сәүдә марка сы — «Кояш»), «Авалон Продакшн» (балалар өчен елга 1,2 млн. данә эшләнмә чыгаруга сәләтле, «Peppy Woolton» сәүдә маркасы) ачыла. Тармакта эшләүчеләрнең гомуми саны 1 мең тирәсе кеше (2017). 2016 да респ-ка Т.с. пр-тиеләре 9,7 млн. пар оек-оекбаш һәм 527,5 мең данә трикотаж эшләнмә, ш.и. 184,3 мең данә өске трикотаж кием җитештерә. *С.Г.Белов, Р.С.Мансуров.*

ТРИЛО́ГИЯ (грек. trilogia, «өч» + «сүз», «хикәяләү»), авторның бер идея һәм сюжет б-н берләштерелгән, өч кисәктән торган мөстәкыйль әсәре. Татар әдәбиятында эпик (эпопея), драматик һәм лирик Т.ләр бар. Эпик Т.гә мисаллар: И.Газиның «Онытылмас еллар», Ф.Садриевның «Бәхетсезләр бәхете» Т.ләре. Драматик Т.гә Т.Гыйззәтнең «Шомлы көннәр», «Даулы көннәр» һәм «Данлы көннәр» драмалары, Т.Миңнуллиның «Милләүшәнең туган көне», «Дуслар җыелган җирдә», «Хушыгыз!» пьесалары карый. Лирик Т.не Х.Туфанның «Ике чор арасында», «Башлана башлады», «Бибиевләр» поэмалары тәшкил итә. *Р.Ә.Мостафин.*

ТРИ́НИЯ (Trinia), чатыр чәчәкләләр семьялыгыннан ике- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 12 төре билгеле, Евразиядә таралганнар. Татарстан терр-ясендә 2 төре бар: күпсабаклы Т. (T. multicaulis) һәм кытыршы Т. (T. muricata) Көньяк-Көнчыгыш Кама арьягында очрыйлар. Далаланган тау битләрендә үсәләр. 10–45 *см* биеклектәге күпьеллык үсемлек. Күпсанлы сабаклары ялангач, тобеннән үк диярлек тармаклы. Яфраклары сабакны чорнап алучы җиңсә рәвешендәге киң сапларда, өчпочмаклы-йомыркасыман, буй яки җепсыман-буй өлешле икешәр, өчәр каурыйсыман. Җимеше — ваклан-ган чикләвек. Июнь–июль башында чәчәк аталар. Чәчәк атканнан соң ук ата чәчәкләр үлә, ә ана чәчәкләрдә җимешләр барлыкка килә. Җимешләре июнь–августта өлгерә. Орлыктан үрчиләр. ТРның Кызыл китабына кертелгәннәр.

ТРИ́ПСЛАР, к. *Куыгаяклылар.*

ТРИТИКА́ЛЕ (Triticale), бодай б-н арыш гибриды. «Т.» терминында бодай (Triticum) һәм арышның (Secale) латинча атамалары берләштерелгән. Беренче фертиль арыш-бодай гибриды 1889 елда Германиядә селекционер В.Римпау тарафыннан чыгарыла. Россиядә бодай б-н арышны гибридлаштыру селекционер Г.К.Мейстер тарафыннан башлана. Ерак төрләрне гибридлаштыру һәм полиплоидия нигезендә бу культураны чыгару 20 йөз селекция-генетика фәненең зур казанышларыннан санала. Т. плоидия дәрәҗәсе һәм хромосома составы буенча шактый төрлелеге б-н характерлана. Төрле шартларда югары уңыш бирергә сәләтле, күп кенә зарарлы патогеннарга чыдам. Язгы һәм көзге формалары бар. Тамыр системасы чуклы. Сабагы — салам, 5–6 буын арасы бар, башак асты куыш, төкле. Бөртек сортларының саламы 60–125 *см*, бөртекле терлек азыгыныкы — 110–125 *см*, терлек азыгы сортлары саламының озынлыгы 120–160 *см* була. Яфрагы яфрак җиңсәсеннән һәм балавыз куныклы яшел пластинадан тора (яфрак пластинасы гадәттә бодай б-н арышныкыннан зуррак). Башагы (чәчәк төркеме) күп чәчәкле (2–6 чәчәк). Күбесенчә үз-үзеннән серкәләнә. Бөртеге эре (1000 орлыкның авырлыгы 36–62 *г*), бераз җыерчыклы, катнаш азык, азык буларак, сыра кайнату һәм спирт сәнәгатендә кулланыла. Составында 11,5% протеин, 2,2% май, 2,5% клетчатка, 58,6% крахмал, 3,5% шикәр бар. Т.дан пешерелгән икмәк күләме буенча бодайныкыннан калыша,



Тритикале чәчүлекләре.

арышныкыннан зуррак. Бөртеге һәм көрпәсе йорт хайваннары һәм кошлар өчен фураж буларак кулланыла. Яшел массасы — яшел килеш ашатуга, силос, сенаж, гранула һәм брикет ясауга яраклы. Республикада үстерелә торган төп сортлары: «Тальва 100» (1993), «Немчиновская 56» (2006), «Корнет» (2007).

Әд.: Шевченко В.Е., Павлюк Н.Г., Верзилин В.В. Тритикале. Воронеж, 1997; Возделывание озимой тритикале в Республике Татарстан (рекомендации). К., 2007.

Р.Ә.Әсретдинова, С.Н.Пономарёв.

ТРИТОННА́Р (Triturus), саламандрасыманнар семьялыгыннан койрыклы җир-су хайваннары ыругы. 12 төре билгеле, Евразиядә таралганнар. Татарстан терр-ясендә 2 төре бар. Гади тритон (T.vulgaris) республиканың барлык районнарында очрый. Дымсу урынарда яшиләр (урман, куаклык, яшелчә һәм җиләк-җимеш бакчалары, күлләвек һәм юл буйларындагы канауларда очратырга мөмкин). Гомуми озынлыгы 10,5 *см* га кадәр. Ата затлар аналарыннан кечерәк. Аркасы ачык көрән, корсагы аксыл-сарғылт төстә, вак тимгелле. Тиресе йомшак (тереклегенең суда яшәү фазасында) яки вак бөрчекле (корыда). Ата затларның сырты буйлап сырлы-сырлы тире кикрик сузылган, туй чорында ул аеруча яхшы беленә, Бу вакытта койрыкта (кайвакыт гәүдәдә) сәдәф ялтыравыклы зәңгәрсу сызык, дулкынлы сырт өстендә кызгылт-сары кайма бәреп чыга. Кикриге биеккә үсә барып, башының арткы өлешеннән койрыгына



Гади тритон.

кадәр сузыла. Сырлач сыртлы тритон (T. cristatus), нигездә, Көнбатыш Кама алдында очрый. Гади тритон яши торган биотопларда яши, әмма суның чисталыгына таләпчән. Гомуми озынлыгы 16 *см* га кадәр. Тиресе тупас бөрчекле, өсте карасудан карага кадәр, корсагы әрә кара тимгелле кызгылт-сары төстә. Ата зат койрыгының кара читле булуы һәм кара төстәге клоака кабарынкылыгы б-н аерыла (ана затларда ул кысылган һәм кызыл төстә). Т. туфрак бушлыкларында, сукыр тычкан һәм кыр тычканнары өннәрендә, черегән агач түмгәкләрендә кышлыйлар. Апрель-майда уяналар, суның темп-расы 6–8 °С булгач, сулыкларга күчәләр. Озакламый аларның туй чоры башлана. Бу вакытта ана затлар ачыграк төскә керә, аталарының исә кикриге үсеп чыга. Ана зат су үсемлекләренең яфракларына 30 дан 700 гә кадәр йомырка сала. Үрчем биргәннән соң, олы Т., сулыкларны калдырып, урманнарга таралалар. Коры җирдә — бөжәкләр, күбаяклылар, үрмәкүч, гусеницалар, суда кысласыманнар, моллюсклар б-н тукланалар. Яшәүләренең 2–3 нче елында җенси җитлегәләр. Сырлач сыртлы Т. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

ТРИ́ФОНОВ Василий Андреевич (1860–1922, Казан), архитектор, төзүче инженер. Новочеркасск реаль уч-щесен, инженер-механик белгечлеге алып Петербург технология ин-тын тәмамлый (төзүче инженер һәм архитектор һөнәрен мөстәкыйль үзләштерә). 1906–22 елларда *Казан дары заводы* архитекторы, бер үк вакытта Казан сәнгать мәктәбендә матем. укыта, 1919–22 дә Казан сәнгать-техника остаханәләре мөдире (ректор). Дары з-дында шартлау вакытында һәлак була. Казан шәһәр (Шамов) хастаханәсе төзелешендә прораб (1908–10, арх. К.С.Олешкевич). 1914–15 тә Россия Дәүләт банкының Казан бүлеге бинасы проектын эшләүдә катнаша (Н.А.Фролов, А.Г.Сапунов б-н бергә) һәм шул төзелеш б-н җитәкчелек итә (Ф.П.Гаврилов б-н бергә). Казанда Т. проектлары буенча Казан коммерция уч-щесе (1905–08, П.П.Голышев б-н, хәзер Казан аг-

рар ун-тының төп бинасы), Казан югары хатын-кызлар курслары (1913, хәзер анда Казан ун-тының Тарих ин-ты урнашкан) биналары, *Смоленцев йорты*, *Сапожников йорты*, Н.Я.Молотков йорты (1912); *Варвара чиркәве*, Ярлы һәм авыру балаларны тәрбия итү җәмгыяте (1907–10, хәзер «ГУМ» сәүдә комплексының бер өлеше) төзелә. Эклектизм һәм модерн юнәлешендә эшли.



В.А.Трифонов.

Әд.: Муртазина Л.М. Казанские архитекторы конца XVIII — начала XX века: Биогр. справ. К., 1999; Хайрутдинова Л.Ф. Два эпизода творческой биографии В.А.Трифонова // Сб. материалов итоговых конф. молодых учёных и аспирантов за 1999–2000 гг. К., 2001.

ТРИ́ФОНОВ Николай Александрович (23.2.1891, С.-Петербург — 9.12.1958, Казан), химик, химия фән. д-ры (1940), проф. (1928). 1920 елда Петербург политехник ин-тын тәмамлый. Саратов, Пермь, Ростов-Дон шәһәрләре ун-тларында эшли. 1945–48 дә Казан ун-тының физик химия каф. мөдире, бер үк вакытта СССР ФА Казан ф-лының Химия ин-тында физик химия секторы мөдире (1946–48). Хезмәтләре сыек системаларның физик-химик анализына карый. Т. сыек системалар компонентларының һәм химик тигезләнеш факторларының үзара химик тәэсир итешүе аларның физик үзлекләренә йогынты ясавын ача. Сыек системаларның магнит үзлекләрен, электр үткәрүчәнлеген, өслек тартылышын, үзлелеген өйрәнүгә һәм аларның физик-химик табигатен тикшерү методологиясен булдыруга зур өлеш кертә.

Әд.: Химический факультет Казанского университета: Хронология основных событий жизни и деятельности в документах. К., 2008. Т. 1.

ТРИХИНЕ́ЛЛАЛАР (Trichinella), трихинеллалар семьялыгыннан нематодалар ыругы. Нигездә, ерткыч һәм төрле азык б-н тукланучы имезүчеләрдә һәм кешедә паразит булып яшиләр. Ана затлар — 1,5–4,4 *мм*, аталары 0,6–1,6 *мм* озынлыкта. Төрле авторлар 2–3 төрен билгели. Аеруча T. spiralis билгеле. Паразитлар кеше һәм хайванның нечкә эчәклегендә җенси җитлегәләр. Аталанган ана зат үз гомерендә (якынча 50 көн) 2 меңгә кадәр личинка (озынлыгы 0,5 *мм*) тудыра, алар исә эчәклектән лимфа, аннары кан системасына үтеп керәләр һәм аркылы-буйлы мускулларда урнашып бөтен организм буенча таралалар. Биредә алар үсә, спиральсыман бөтерелә һәм тышча б-н капланып, бу халәттә алар тереклек эшчәнлеген бер елдан бернича дистә елларга кадәр саклыйлар. Җенси җитлеккән суалчаннарга әверелү өчен тышча б-н капланган личинкалар башка берәр имезүче эчәклегенә эләгергә тиеш. Җитәрлек дәрәҗәдә кыздырылмаган яки пешеп җитмәгән дуңгыз яки кыргый хайваннар (кабан дуңгызы, төлке, янутсыман эт, аю һ.б.) итен кулланып кеше авыру йоктырырга мөмкин. Т. трихинеллёз авыруын китереп чыгара. Татарстанда трихинеллёз хайваннарда күптәннән теркәлгән, кешедә беренче тапкыр 1964 елда табыла, ул вакытта Казанда, термик эшкәртелмәгән һәм начар эшкәртелгән янутсыман эт һәм төлке ите ашап, бер төркем (11) кеше авыру йоктыра.

О.Д.Любарская.

ТРИХОГРА́ММАЛАР (Trichogramma), хальцидлар семьялыгыннан паразит элпәканатлы сабакчыл корсаклы бөҗәкләр ыругы. 200 гә якын төре билгеле, Татарстан терр-ясендә 2: гади трихограмма (T. evanescens) һәм атасыз трихограмма (T. embryophagus). Буынлы мыекчыклы бик вак бөҗәкләр (1 *мм* га кадәр). Канат сеңерчәләре үсеш алмаган. Ана затларның күкәй салгычы корсагының арткы өлешендә. Личинкалары төрле бөҗәк һәм а.х. корткычлары күкәйләрендә паразитлык итә. Гади трихограмма ябалакчыклар семьялыгындагы күбәләкләрнең (уҗым, кәбестә, клевер ябалакчыгы һ.б.) күкәйләрен үз итә; атасыз трихограмма алма җимешашары һәм яфрак төргечләре семьялыгындагы кайбер төрләрнең күкәйләрен зарарлый. Т. үсемлекләрне саклауда биологик алым буларак кулланыла, аларны ясалма үрчетәләр һәм агроценозларга җибәрәләр.

ТРОЕПО́ЛЬСКИЙ Виктор Иванович (8.2.1905, Орёл губ. Чернав өязе Асланово а. — 10.5.1989, Казан), геолог-нефтьче, геол.-минерал. фән. д-ры (1963), проф. (1964), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1975). Казан ун-тын тәмамлый (1937). 1939 елдан Татгеолтрестта («Татнефтегазразведка»), фәнни-тикшеренү төркеме җитәкчесе (1946 дан). 1953 тән Казан ун-тында, нефть геологиясе һәм газ кафедрасының беренче мөдире (1954–79), проф. (1979 дан). Хезмәтләре нефть геологиясе, битум, күкертне өйрәнүгә, геология тарихына карый. Т. Татарстан терр-ясенең һәм аңа чиктәш өлкәләрнең нефть-газ һәм битумлылык перспективаларына бәя бирә, углеводородларны тикшерү, эзләү һәм чыгару буенча тәкъдимнәр эшли, төп нефть чыганакларын (Ромашкино, Яңа Елховой, Шөгер һ.б.) ачуда катнаша; коллекторларның токымнарын тикшерү методикасын камилләштерә. «Почёт билгесе» ордены, медальләр, ТАССР ЮС Президиумының ике Мактау грамотасы б-н бүләкләнә. Казанның Мактаулы гражданы. Казан ун-тында һәм Т. яшәгән йортта мемориаль такталар куелган.

Хезм.: Татария — республика нефти. К., 1957 (автордаш); Геологическое строение и нефтеносность Аксубаево-Мелекесской депрессии. К., 1964 (автордаш); Пермские битумы Татарии. К., 1976 (автордаш).

Әд.: Троепольская О.В., Гордеев Е.В. В.И.Троепольский. К., 2003.

ТРО́ИЦА ЧИРКӘВЕ́, Зөя шәһәрендәге архит-ра истәлеге. 16–18 йөзләрдәге борынгы рус архит-расының сирәк үрнәге. Агач чиркәү алдан әзерләнгән детальләрдән бер көн эчендә, 1551 елның 16 нчы маенда, *Зөя* кальгасендә салына. Төбәктә төзелгән беренче православие чиркәве. Башта чиркәү Зөя Троица ирләр монастырена карый. 16 йөз ахырында — 17 йөз башында җәйге Сергий Радонежский чиркәве төзелгәч, кышкы храм булып хезмәт итә. 18 йөз ахырыннан, Троица монастыре бетерелгәннән соң, Иоанн-Предтеча хатын-кызлар монастыре ансамбленең бер өлеше булып кала. Архит-ра истәлеге буларак, 1929 да — дәүләт саклавына, 2000 дә Зөя Успение ирләр монастырена тапшырыла. 18 йөздә храмның чатыр капламы барабанлы гөмбәзе булган сигез кыеклы сөзәк түбә б-н алыштырыла, 19 йөздә терәкле гөмбәзләр — калай б-н ябыла, 19 йөз башында чиркәү алдына болдыр корыла; диварлары тыштан такта б-н тышлана. 1880 елларда храм астына таш нигез кертелә, чиркәү алдының ачык болдыры пыяла б-н ябыла. Бер катлы сузынкы корылма ике бурадан: храм дүрткырлыгы һәм турыпочмаклы ашханә күләменнән тора, апсидасы биш кырлы. Храмга төньяктан



Зөядәге Троица чиркәве.

һәм көньяктан 2 болдыр, көнбатыштан — өйалды кушып салына. Үзәк күләм зур булмаган суганбашсыман гөмбәзле сигезкырлыкны күтәреп тора. 17 йөзнең 2 нче яртысына караган дүрт яруслы иконостас, гамәли бизәлеш сәнгатенең сирәк истәлеге булган иконалар һәм патша капкасы сакланып калган (ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда сакланалар).

Р.В.Билалов, Г.И.Середа.

ТРО́ИЦА ЧИРКӘВЕ́, Лаеш шәһәрендә. к. *София соборы.*

ТРО́ИЦК шәһәре, *Чиләбе өлкәсенең* көнчыгыш өлешендә, Чиләбе шәһәреннән 120 *км* көньяктарак урнашкан. Халкы — 75231 кеше (1.1.2017). Татарлар саны: 1833 елда — 159, 1861 дә — 4300, 1866 да — 1966, 1888 дә — 8043, 1897 дә — 7803, 1935 тә — 11160, 1979 да — 7650, 2002 дә — 6566, 2010 да — 5509 кеше. 1743 тә Уй чик буе ныгытмасының төп саклау кальгасе буларак нигез салына. Т.да татарлар 18 йөз уртасыннан яши. 18 йөзнең 2 нче яртысында алар Казакъстан һәм Урта Азия халкы б-н товар алмашуда төп рольне уйный башлый. Т. татар сәүдәгәрләре икмәк, туңмай, мануфактура, йон, көрдәк-ле сарыклар б-н сәүдә итә; Бохара, Коканд, Хива шәһәрләренә кәрваннар озаталар; 1845 тә Кытайдан (Чүгүчәк ш.) чәй ала башлыйлар. 19 йөздә Т.да татарлар саны Казан һәм Вятка губерналарыннан күченүчеләр исәбенә арта. 19 йөз башында шәһәрнең төньяк-көнчыгыш өлешендә «Татар төбәге», 1870 еллар уртасында Увелька елгасының сул ярында Елга аръягы татар бистәсе барлыкка килә, соңрак монда татарлар тупланып яшәү-

че «Амур» («Магъмурия») һәм Кузнецов (Яңа авыл) бистәләре урнаша. 19 йөз ахырында Т. Россиядә татарлар саны буенча, Казан (28,5 мең), Оренбург (12,7 мең) һәм Каргалы бистәсеннән (10 мең) кала, 4 нче урын били. Аеруча хәлле татарлар шәһәр үзәгендәге Татар тыкрыгында яшиләр. Товар алмашу йорты эшлекле тормыш үзәгенә әверелә. 1917 гә кадәр Т.да татар эшмәкәрләренең тире эшкәртү, туңмай эретү һәм сабын з-длары, он тегермәннәре була. Алар Урта Азиядә мамык чистарткыч з-длар, йон эшкәртү пр-тие-ләре, Урал шәһәрләрендә, Казакъстан һәм Төркестанда кибетләр тоталар. 1908 дә Т.да татар сәүдәгәрләре *Яушевлар* төзегән Пассаж иң зур кибетләрдән санала. Рев-циягә кадәр Т. Россия татарларының рухи яшәеш һәм мәгърифәт үзәгенә әйләнә. Россия мөселманнары арасында Т.ның беренче мәчете-нең имам-хатибы Әхмәтхуҗа Рахманкулов зур абруй казана, ул «Әхмәдия» мәдрәсәсенә (1858 дә аны З.*Рәсүлев* тәмамлый) нигез сала. 1917 гә кадәр Т.да 6 җамигъ мәчет: 1 нче (Ахун хәзрәт мәчете яки «Төп» мәчет, 1789 дан эшли, кайбер мәгълүматларга караганда, 1790 нан 1930 га кадәр), 2 нче («Югары мәчет», 1838–1929, 1919–21 дә, бүленеп), 3 нче (1863–1930, 1945 тә дин тотучыларга кире кайтарыла), 4 нче («Базар мәчете» яки Вәлиев мәчете; 1873 тән, кайбер мәгълүматларга караганда, 1879–1928), 5 нче («Амур мәчете», 1883–1937), 6 нчы (Гатаулла мәчете, 1895–1928, 1980 елларда дин тотучыларга кире кайтарыла); ш.у. 7 нче квартал мәчете (Яңа авыл мәчете, 1910–1930) була. Һәр җамигъ мәчет каршында мәдрәсә эшли, алардан иң аталклылары: 2 нче мәчет каршындагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе, 4 нче мәчет каршындагы мәдрәсә, 5 нче мәчет каршындагы «*Рәсүлия*» мәдрәсәсе. 1910 да Г.Н.*Әхмәров* тырышлыгы б-н сәүдәгәр Яушевлар иганәсенә «Сөембикә» мөселман кыз балалар дөнья-ви уку йорты, 1914 тә шундый ук мәдрәсә, 1915 тә «Дарелмөгаллимат» мөгаллимәләр семинариясе ачыла. Семинария б-н М.*Буби* җитәкчелек итә, монда Ә.*Рахманколов* укыта. Россиядәге мөселман мәктәпләренең күбесе Т. мөдәрисләре төзегән программа буенча эшли. 19 йөз ахыры — 20 йөз башында мөселман хәйрия мәдәни-мәгърифәт җәмгыятьләре: Т. мөселман хәйрия җәмгыяте, Мөселман мәгърифәт җәмгыяте, Мөселман хатын-кызлар җәмгыяте (Мөселман хатын-кызлар ком-ты буларак та билгеле), Т. кибетчеләр җәмгыяте, «әл-Ислах» оешмасы ф-лы, Т. татар сәхнә сәнгатен һәм музыкасын кызыксындыру җәмгыяте (икенче исеме — Мөселман музыка җәмгыяте; аның җирлегендә *Троицк татар театры* оештырыла), «Җәмгыяте гыйльмия» фәнни оешмасы («Рәсүлия» мәдрәсәсе шәкертләре нигез сала, җитәкчеләре арасында — М.*Гафури* һәм Х.Ф.*Искәндәров*) зур үсеш ала. 19 йөз ахырында «Нәҗат» татар китапханәсе (хәзер Т. үзәк китапханәсе системасының 1 нче ф-лы — Татар-башкорт китапханәсе) ачыла. 20 йөз башында Т.да «Мөселман китап сәүдәсе ширкәте», «Хезмәт» нәшрияты эшли, «*Акмулла*» ж-лы (1911–16) һәм «Хәр милләт» (1917) г-тасы чыга, татар телендә 6 китап нәшер ителә. 1917 дән соң шәһәрдә Милләтләр эше буенча халык комис-тының татар бүлеге һәм Мөселман комис-ты оештырыла. «*Ирек*» г-тасы чыга (1920). 1917–30 да татар телендә 10 китап нәшер ителә. Совет хакимиятенең беренче елларында Т.да җидееллык һәм берничә башлангыч татар мәктәбе, балалар бакчасы була. 1922–60 та Татар пед. техникумы (1930 еллар башыннан — Иптәш Луначарский исем. татар-башкорт агропед. техникумы, Бөек Ватан сугышы чорында ул рус пед. уч-щесенең татар бүлеге итеп үзгәртелә, 1948 дән — Татар-башкорт пед. уч-щесе) эшли. 1941 дә, Татар колхоз-совхоз күчмә театры ябылганнан соң, Троицк татар үзешчән театры эшчәнлеген башлый (1970 еллар ахыры — 1980 еллар башында ябыла). Хәзерге вакытта Т.да Татар һәм башкорт мәдәнияте иҗтимагый үзәге (1989 дан), «Дуслык» үзәге (1989), шәһәр мәдәният йорты каршындагы «Тулпар» татар ансамбле (1996), Татар-башкорт китапханәсе каршындагы «Сөембикә» хатын-кызлар клубы (1999 дан), «Троицк шәһәре татар-башкорт җәмгыяте» иҗтимагый оешмасы (2007) эшли. 2 мәчет бар. *Сабан туе* даими уздырыла. Шәһәр халкы «Татарстан-Яңа гасыр» телеканалы тапшыруларын карый ала. 2012 дән ел саен «Рәсүлев укулары: Ислам Россия тарихында һәм хәзер» бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе үткәрелә. Татар-башкорт китапханәсе ТРның Милли китапханәсе б-н тыгыз элемтәдә тора, «Дуслык» үзәге б-н «Милли мәдәниятне торгызу» шәһәр программасын тормышка ашыра (2000 нән). Т.да татарлар б-н бәйле тарихи-мәдәни истәлекләр: Сәүдә рәтләре (1866–68), бертуган Яушевлар Пассажы, йорты һәм дачасы, сәүдәгәр Уразаевлар утары, күп кенә күренекле татар эшлеклеләре җирләнгән мөселман зираты (18 йөз ахыры); 1 нче, 3 нче, 4 нче, 6 нчы җамигъ мәчетләр, мәдрәсәләр («Рәсүлия», «Әхмәдия», «Галия») һәм алар каршындагы мәктәпләр, «Нәҗат», «Гайшә абыстай мәктәпләре» татар-башкорт китапханәләре, «Дарелмөгаллимат» семинариясе, Татар-башкорт пед. техникумы биналары сакланган. Актёр И.Г.Илялов, актриса Һ.Й.Илялова (к. *Илляловлар*), геолог А.А.*Бакиров*, драматург С.Г.*Кальметов*, нәкышьче Ч.Г.*Әхмәров*, журналистлар М.К.*Бөдәйли*, Г.Т.*Гыйсмәти*, Г.И.*Идриси*, Х.Ф.Искәндәров, тарихчылар Г.*Баттал*, Г.С.*Гобәйдуллин*, шагыйрьләр М.К.*Акмулла*, Г.Г.*Афзал*, Ш.М.*Бабич*, Ә.М.*Галимов*, Б.Ш.*Рәфыйков*, Г.*Тукай*, педагоглар Ф.Г.*Аитова*, Габдулла һәм М.Буби, Л.К.Газизов, язучылар С.С.*Әдһәмова*, Р.Ш.*Вәлиев*, М.Н.Гафури, А.К.*Расих*, развед-чик И.Г.*Әхмәров*, дин эшлеклеләре З.Рәсүлев, Г.*Рәсүлев*, М.*Һадиев*, тел белгече Ф.Г.*Исхаковның* тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге Т. шәһәре б-н бәйле.

Әд.: Скобелькин Е., Шамсутдинов И. Возвращаясь к прошлому. Троицк, 1995; Абубакирова М., Шамсутдинов И., Хасанжанова Р. Историю оставить народу своему. Троицк, 2002; Аблина Н.А. Путешествуя по столетиям. Троицк, 2003.

Р.Г.Нашарова, Р.Н.Гыйззәтуллин.

ТРӨИЦК ТАТА́Р ТЕА́ТРЫ, 1910 елда Оренбург губернасының Троицк шәһәрендә театр һәм музыка сәнгате б-н кызыксындыру җәмгыяте каршында һәвәскәрләр түгәрәге буларак оеша. Җәмгыятьнең рәисе — М.Дәүләтшин. Түгәрәк әгъзаларыннан И.Әлмәшев, Исхак Илялов, Ш.Мәүлетов, И.Чанышев, А.Юнысов, И.Яушев була. Г.Камалның «Беренче театр», «Бәхетсез егет», С.Рәмиев пьесалары буенча спектакльләр куела. 1919 ның августында проф. театр буларак эшләүче «Троицк мөселман труппасы» оеша. Аның составында 16 актёр, ш.и. «характерлы рольләр һәм комедия» актёры И.Шаһдалиев, җырга-моңга оста «лирик героиня» Һ.Илялова, «мәхәббәт герое» З.Сабитов була; 1927 дә труппага Г.Надрюков кабул ителә. 1920 еллар ахырында – 1930 еллар башында аның составында Татар акад. театры актёрлары М.Мутин, Б.Тарханов, Г.Казанский, С.Садыйкова даими рәвештә чыгыш ясыйлар. «Җилкәнсезләр», «Казан сөлгесе», «Сүнгән йолдызлар» (К.Тинчурин), «Галиябану», «Асылъяр» (М.Фәйзи), «Та һир-Зөһрә» (Ф.Бурнаш), «Козгыннар оясында» (Ш.Камал), «Камил» (Һ.Такташ), «Аршин мал алан» (Г.Хаҗибәков), «Юлбасарлар» («Разбойники», Ф.Шиллер) спектакльләре куела. 1931 дә, Урал театрлары олимпиадасында уңышлы чыгыш ясаганнан соң, ВКП(б) Урал өлкә ком-ты карары б-н «Урал үзәк татар-башкорт эшче күчмә театры» исеме б-н Свердловск шәһәренә күчерелә. Театрның сәнгать җитәкчесе итеп Исхак Илялов билгеләнә, труппа составында — Ш.Габдрахманов, Һ.Илялова, Г.Казанский, Г.Надрюков, М.Сундуков, Ш.Госманаев, И.Шаһалиев, М.Шәйхетдинова. Актёрлар Асбест, Берда, Златоуст, Кизил, Миасс, Түбән Тагил, Чусовой, Шумиха, Ялан-Катай кебек шәһәр һәм посёлок төзүчеләр, агач материаллары әзерләү пунктлары хезмәткәрләре алдында чыгышлар ясыйлар; Троицк, Чиләбе, Пермь, Березники, Соликамск, Краснооуфимск, Сарапул, Магнитогорск шәһәрләренә гастрольләр б-н баралар. Репертуарын «Банкрот», «Уйнаш» (Г.Камал), «Зәңгәр шәл», «Ил» (К.Тинчурин), «Яшь йөрәкләр» (Ф.Бурнаш), «Галиябану» (М.Фәйзи), «Наёмщик» (Т.Гыйззәт), «Урманда» (Ф.Хөсни), «Данлы чор» (Р.Ишморат), «Козгыннар оясында» (Ш.Камал), «Шәмсе камәр» (М.Әблиев), «Икмәк» («Хлеб», В.М.Киршон) спектакльләре, ш.у. концерт программалары, сәнәгать финанс планына, кооперативларга һәм агымдагы башка мәсьәләләргә багышланган кечкенә күләмле пьесалар тәшкил итә. Актёрлар ш.у. иҗтимагый чаралар уздыралар: газеталарга язылуны оештыралар, партия сәясәтен аңлаталар, тамашачыларны халыкара яңалыклар б-н таныштыралар. Тиешле эш һәм көнкүреш шартлары булмау сәбәпле, 1933 тә театр вакытлыча ябыла, 1937–38 дә Рус драма театры бинасында эшли, 1939 да Өлкә күчмә драма театры итеп үзгәртелә. Бөек Ватан сугышы башлангач таратыла.

Әд.: Илялова И. Межнациональные связи татарского театра. К., 1985.

И.И.Илялова.

ТРО́ИЦКАЯ Августа Дмитриевна (28.10.1915, Ярославль губ. Романово-Борисоглебск ш. — 25.7.1979, Казан), химик-нәорганик, химия фән. д-ры (1969). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, проф. (1969). Хезмәтләре координацион кушылмалар химиясенә карый. Т. — координацион химиядә яңа фәнни юнәлешкә — платиналы металларның фосфорорганик лигандалар б-н комплексы кушылмаларын тикшерүгә нигез салучы. Фосфорорганик лигандалар б-н комплекслар хасил иткәндә платина (II), палладий (II), родийның (III) үзәк атомнары ролен өйрәнә, лигандалар транс-тәэсиренең гомуми закончалыкларын ача. Платиналы металларның комплексы кушылмаларының эчке координация сферасына транс-тәэсирле лиганданың әләгүе лигандаларның үзәк атом тирәсендә яңача төркемләнүен генә түгел, ә тулаем комплексны кушылманың үзгәрүен китереп чыгаруын күрсәтә (бу ачыш координацион химиядә яңа юнәлешкә — координацияләнгән лигандалар һәм аларның эчке сферадагы әверелешләренең реакциягә керү сәләтенә нигез сала). Платина (II), палладий (II) һәм родийның (III) фосфор к-тасының сулы эремәләрдәге органик чыгарылмалары б-н комплекслар хасил итү реакцияләрендә эчке сферада лигандалар гидролизы процессларын ачыклый һәм тикшерә. Тиоционат төркемнәрен координацияләү ысулына триалкилфосфитларның стерео-сыйфатлары көчле тәэсир итүен ача һәм платиналы металлар комплексында координацияле тиоцианат төркемнәренең изомерлашу мөмкинлеген күрсәтә. Платина (II һәм IV), палладий (II) һәм родийның (II һәм III), кобальт (II), никельнең (II) комплексы кушылмаларын синтезлау алымнарын эшли һәм 200 дән артык яңа кушылма таба; аларның күбесе биологик актив яисә нәзек органик синтез реакцияләрендә каталитик үзлекләргә ия. Үйлап табуга 11 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: О соединениях платины с фосфорсодержащими аддентами // Изв. АН СССР. 1946. № 3 (автордаш); Термографическое исследование роданидных комплексов палладия (II) с триэтил- и трифенилфосфином // Координационная химия. 1980. № 8 (автордаш); Термодинамическая устойчивость и кинетика быстрого лигандного обмена в роданидных комплексах палладия (II) с фосфитами // Журн. общей химии. 1980. № 5 (автордаш).

Әд.: Лидеры научных школ КХТИ-КГТУ. К., 2007.

ТРО́ИЦКИЙ посёлогы, Лаеш р-нында, Казан тимер юл станциясеннән 32 *км* көньякта-рак, Куйбышев сусаклагычыннан 2 *км* ерак-лыкта урнашкан. 2010 елда 44 кеше (руслар) яши. 1920 елларда нигез салына. Оешкан көненнән Казан авыл р-нында. 1938 нең 4 августыннан — Столбище, 1959 ның 26 мартыннан — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1926 да — 82, 1938 дә — 212, 1949 да — 91, 1958 дә — 112, 1970 тә — 124, 1979 да — 75, 1989 да — 42, 2002 дә — 48 кеше.

ТРО́ИЦКИЙ посёлогы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 72 *км* көньякта-рак, Кичү елгасы буенда. 2010 елда 93 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Клуб. 1920 елларда нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Чистай кантоны Зирекле волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Яңа Чишмә, 1944 нең 19 февраленнән — Ямаш, 1956 ның 7 декабреннән — Яңа Чишмә, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1983 нең 26 апреленнән — Яңа Чишмә, 1984 нең 3 июленнән Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1926 да — 399, 1949 да — 448, 1958 дә — 419, 1970 тә — 289, 1979 да — 220, 1989 да — 147, 2002 дә — 100 кеше.

ТРО́ИЦКИЙ Михаил Трофимович (31.5.1922, Курск губ., Льгов өязе Түбән Деревеньки а. — 9.2.1998, Мәскәү), партия хезмәткәре. Казан авиация ин-тын тәмамлый (1956). 1941–60 елларда (бүленеп) Казандагы 16 нчы з-дта нормировщик, цех башлыгы ярдәмчесе, бюро башлыгы, цех башлыгы урынбасары, цех башлыгы, партком секретаре булып эшли. 1960–62 дә КПССның Казан шәһәре Ленин район ком-тының 1 нче секретаре. 1962–76 да КПССның Татарстан өлкә ком-ты секретаре. Сәнәгать һәм төзелеш тармаклары өчен җаваплы, Татарстан сәнәгате үсешенә өлеш кертә. Кама зур йөк автомобильләре җитештерү з-длары комплексын (КамАЗ) төзүдә катнаша. 1976–78 дә РСФСР Халык контроле ком-ты рәисенең 1 нче урынбасары. 1978–86 да СССР химия һәм нефть химиясе машиналары төзелеше министры урынбасары. 1963–67 дә — ТАССР, 1967–80 дә РСФСР ЮСлары депутаты. Октябрь Революциясе, ике Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: Казанский государственный технический университет имени А.Н.Туполева — КАИ. К., 2007. *Е.Б.Долгов.*

ТРО́ИЦКИЙ-УРА́Й авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 5 *км* көнчыгыштарак, Куйбышев сусаклагычы ярында урнашкан. 2010 елда 486 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 57%, руслар — 39%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 17 йөз башында барлыкка килгән Урай пустыненнан оеша. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Урай, Урай-Монастырь, Троицкий, Богородицкий исемнәре б-н дә билгеле. 1700 дә Урай пусты-не бетерелә, аның урынында авылга нигез салына, шул ук чорда беренче агач чиркәү төзелә. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы удел (1797 гә кадәр — сарай) һәм дәүләт крәстияннәре катлавына керә; игенчелек, терлекчелек, балыкчылык, челтәр бәйләү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.-У.да Троица чиркәве (1864 тә төзелә), земство мәктәбе (1871 дә ачыла), агач ташу пристане, 1 мануфактура һәм 6 вак-тәкъләр кибете, Халык-та аек яшәү рәвеше тәрбияләүче попечительлек оешмасының уку залы эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3200 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Бәтке волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 1023 ир-ат; 1859 да — 1549, 1897 дә — 1607, 1908 дә — 1801, 1920 дә — 1817, 1926 да — 1685, 1938 дә — 1484, 1949 да — 930, 1958 дә — 615, 1970 тә — 410, 1989 да — 562, 2002 дә — 528 кеше. Т.-У. авылы янында *Троицкий-Урай комплексы* урнашкан.

ТРО́ИЦКИЙ-УРА́Й КО́МПЛЕКСЫ (археол.), Балык Бистәсе р-нының Троицкий-Урай авылыннан 2 *км* ераклыкта урнашкан. Т.-У.к. истәлекләре 1895 елда П.А.Пономарёв, 1941 дә А.В.Збруева, 1973 тә П.Н.Старостин һ.б. тарафыннан өйрәнелә. 2 шәһәрлек, 3 авыллык һәм Имәнкискә археол. культурасына нисбәтле каберлекне үз эченә ала. «Киң тау» («Широкая Гора») атамасы б-н билгеле иң зур шәһәрлек 1 *га* чамасы мәйданны били; кыр ягыннан дуга рәвешендәге туфрак ур (киңлеге 30 *м* га якын, биеклеге 5 *м* чамасы) һәм чокыр (киңлеге 40 *м* чамасы, тирәнлеге 7,5 *м* га җитә) б-н саклана. Шәһәрлек терр-ясендә 19 хуҗалык чокыры булуы ачыкланса, аларның берсендә Сасанилар дәүләтләре идарәчеләре Пероз (457–83) һәм Кавадның (488–97) 2 көмеш акчасы, икенчесендә күмер-ләнгән ашлык (тары һәм арпа) калдыклары табыла.

Әд.: С т а р о с т и н П.Н. Работы на Троицко-Урайском I городище в 1973 // Древности Волго-Камья. К., 1977; Археологическая карта Татарской АССР. Предкамье. М., 1981; К а з а к о в Е.П., С т а р о с т и н П.Н., Х а л и к о в А.Х. Археологические памятники Татарской АССР. К., 1987; С т а р о с т и н П.Н. Ташкирменьский могильник // Памятники древней истории Волго-Камья. К., 1994. *П.Н.Старостин.*

ТРОЛЛЕ́ЙБУС, рельсларсыз шәһәр электр транспорты төре, *трамвай* һәм автобус уңайлыкларын берләштерә. Двигателенең егәрлеге 170 *кВт* ка, тизлеге 70 *км/сәг.* кә кадәр җитә. Тарткыч двигательләр өчен даими ток контактлар челтәреннән асылма (троллей) үткәргечләр аша килә. Троллейбуслар хәрәкәте респ-каның ике шәһәрендә — Казанда һәм Әлмәттә җайга салынган. Казандагы 11 *км* лы беренче линия 1948 елның 27 ноябрендә ачыла, ул Куйбышев (хәзер Тукай) мәйданын Караваево бистәсе (хәзер Максимов ур.) б-н тоташтыра. Маршруттагы 8 машинага йөртүчеләр үзләре техник хезмәт күрсәтә. Төзәтү хезмәте һәм техник база булмаганлыктан, Т.лар озак вакытка сафтан чыга. 1949 да 9,5 *км* лы яңа Т. линияләре төзелә, 1 нче маршрут Куйбышев мәйданыннан Оренбург трактына (хәзер Павлюхин ур.) кадәр озайтыла; Куйбышев мәйданыннан Фрунзе урамына кадәр 2 нче маршрут ачыла, соңрак ул 4 нче божра маршрутына әйләнә. 1980 дә Казанның Т.лар челтәре гомуми озынлыгы 124 *км* булган 9 маршруттан тора. 1988 гә шәһәрнең барлык р-ннары үзара 10 Т. маршруты б-н тоташа (1986 да Бауман урамыннан Т. линияләре алына). 1957 дә Т. маршрутларына йөрү расписаниеләре кертелә, бер үк маршрутның ике юнәлеше өчен ике төстәге билетлар кулланыла башлый, 1960–93 тә пассажирларга кондукторсыз хез-

мәт күрсәтелә. Файдалану күрсәткечләрен һәм хәрәкәтнең даимилеген яхшыртуга зур игътибар бирелә. 1978–2002 дә юл йөрү бәя - сен кассаларсыз — компостерда тишелә торган абонемент талоннары б-н түләү гамәлдә була. 2005 тә айлык бердәм социаль билетлар кертелә, 2008 дә смарт-карталар буенча түләү системасы — өстенлекле категорияле гражданнар өчен, ә 2009 да барлык теләүчеләр өчен эшли башлый.

Т. транспорты үсү б-н, аның техник база - сы да киңәйтелә бара. 1963 тә яңа җитеште - рү корпусы төзелә, 3 нче трамвай-троллейбус депосыннан мөстәкыйль бүлекчә сыйфатында 1 нче троллейбус депосы аерылып чыга. 1974 тә 2 нче депо сафка кертелә, аның составында техника, механика, алдан билгеләнүле планлы ремонт, җитештерүгә әзерләү, электр җи һәзлары участоклары, төп (эксплуатацияләү) һәм ярдәмче хезмәтләр була. Эшләүчеләр саны (2008): 1 нче депода — 746 кеше (ш.и. 247 йөртүче һәм кондуктор), 2 нче депода — 546 кеше (ш.и. 342 йөртүче һәм кондуктор).



ТРОЛЗА-5275.03 «Оптима-2» троллейбусы. Казан, Академик Парин урамы. 2018.

Шәһәр электр транспорты челтәре киңәю һәм хәрәкәттәге состав паркы зураю б-н бер үк вакытта энергетика ху җалыгы да үсә. Казанда гомуми егәрлеге 71400 *кВт* булган 31 тарту подстанциясе эшли (23 е телеидарә системасына керә). Контактлар челтәренең гомуми озынлыгы — 348 *км*, кабельле челтәрнең — 280,5 *км* (2008). 1966 дан энергетика хуҗалыгында диспетчерлык хезмәте эшли. 1990 еллардан Т. хәрәкәте тагын да кызурак үсеш ала. Яңа линияләр төзелә, контакт линияләренә һәм кабель челтәрләренә реконструкция һәм капиталь ремонт үткәрелә.

2013 тә Казанда троллейбус маршрутлары тәртипкә китерелә (1–13 маршрутлар). Алга таба Т. паркы, башлыча, яңа модельле машиналар (Энгельс шәһәрендә эшләнгән ТРОЛЗА-5275.05 «Оптима» һәм ТРОЛЗА-5275.03 «Оптима-2», Вологдада чыгарылган ВМЗ-5298.01 «Авангард» һ.б.) б-н тәэмин ителә. 2018 дә 10 троллейбус маргруты эшли.

1976 да Әлмәт шәһәрендә Т. хәрәкәте ачыла, озынлыгы 31,5 *км* булган ике маршрутта 30 Т. эшли. 1982 дә 7,2 *км* озынлыктагы Хастаханәләр шәһәрчеге — Батырылма электр насослары з-ды маршруты буенча Т. хәрәкәте ачыла. 2001–02 дә Хастаханәләр шәһәрчеген «Радиоприбор» з-ды б-н (2,9 *км*) һәм 2 нче Сәүдә үзәге б-н (3,9 *км*) тоташтыручы Т. линияләре файдалануга тапшырыла. 2009 ның 1 гыйнварына шәһәрдә гомуми озынлыгы 22,9 *км* булган 6 Т. маршруты хезмәт күрсәтә.

2018 нең 1 гыйнварына респ-када Т.лар саны 250 берәмлек (Казанда 201), ике линиялегә күчереп исәпләгәндә файдалану линияләре — 130,2 *км* (Казанда 107,3 *км*). 26,1 млн. пассажирга хезмәт күрсәтелә. Татарстанда файдалану паркында Т.ларның иң зур саны 343 берәмлек була һәм 173,9 млн. кешегә хезмәт күрсәтелә (2001). Ш.у.к. *Трамвай*. *Г.Я.Мәүлетова, А.А.Турцева.*

ТРО́НИН Сергей Николаевич (11.10.1954, Киров өлкәсе Малмыж ш.), математик, физика-матем. фән. д-ры (2011). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, алгебра һәм матем. логика каф. мөдире (2012 дән). Хезмәтләре операдалар теориясе һәм аңа якын мәсь әләләр, матем. криптография, матем. философия өлкәләренә карый. Вербаль категорияләрдән өстәге операдалар һәм мультикатегория теориясен эшли. Супералгебраларның ирекле сигнатурасының гомуми теориясен һәм супералгебраларның операдалардан өстен теориясен төзи.

Х е з м.: Естественные мультипреобразования мультифункторов // Изв. вузов. Математика. 2011. № 11; Вебальные категории и тождества универсальных алгебр // Учёные записки Казанского университета. Серия Физико-математические науки. 2012. Т. 154. Кн. 2; Об алгебрах над мультикатегориями // Известия вузов. Математика. 2016. № 2.

ТРО́НОВ Валентин Петрович (7.10.1930, Белоруссия ССРның Гомель өлкәсе Калинковичи ш. — 5.5.2014, Бөгелмә ш.), геолог-нефтьче, техник фән. д-ры (1969), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (1992), ТАССР, РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1980, 1987), СССРның атказ. уйлап табучысы (1976). РФнең Мактаулы нефтьчесе (2000). Грозный нефть ин-тын тәмамлый (1959), ТатНИПИнефтьтә (бүленеп: 1965 тә Бөтенроссия углеводород чималы фәнни-тикшеренү ин-тында) эшли, баш фәнни хезмәткәр (2000 нән); бер үк вакытта, 1965 тән, Әлмәт нефть ин-тында укыта (1971 дән проф.). 1981–84 тә Гыйракта командировкада. Хезмәтләре нефть чыганакларын эшкәртүгә һәм экологияне өйрәнүгә карый. Т. катламнарны суландырып, нефть чыганакларын эшкәртүдәге негатив бәйлелекне ачыклый, сумалалы-парафинлы тоткарлыкларның формалашу механизмын билгели һәм алар б-н көрәш алымнарын тәкъдим итә. Битумлы нефтьләр әзерләү, H_2S тан агымсу һәм газларны чистарту технологияләрен эшли. Уйлап табуга 200 дән артык патенты һәм авторлык таныклыгы бар. СССР ФАнең акад. И.М.Губкин исем. бүләге иясе (1980), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1997). Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр, ТРның Почёт грамотасы б-н бүләкләнә. Бөгелмә шәһәренең мактаулы гражданы (2000). 1951–55 тә репрессияләнә, 1956 да аклана.

Х е з м.: Промысловая подготовка нефти за рубежом. М., 1983; Сокращение потерь нефти и газа за рубежом. М., 1988.

ТРОПЛА́Р (грек. tróros — сөйләм әйләнеше), сөйләмне аеруча сәнгатьле, тәэсирле һәм образлы итү өчен күчерелмә мәгънәдә кулланыла торган сүзләр һәм гыйбарәләр. Т. нигезендә якын, охшаш мөнәсәбәттәге төшенчәне чагыштырып, бер-берсенә тиңләп бирү ята. Татар телендә Т.ның берничә төре билгеле. **Метафора** — төрле билгеләре, формалары, урнашу урыннары, функцияләре һ.б. үзенчәлекләре охшашлыгыннан чыгып, бер предметның (күренешнең) үзлекләрен икенчесенә күчерү: самолёт канаты, алтын башаклар һ.б. **Метонимия** — сүзләрнең янәшә торуына нисбәтле барлыкка килгән мәгънә күчеше һәм бәйләнеше нигезендә бер сүзне икенчесе б-н алмаштыру: ике чынаяк әчтем (ике чынаяк чәй әчтем диясе урынга), көмеш алдым (көмеш алка алдым диясе урынга), Тукайны укыйм (Тукайның шигырен укыйм диясе урынга). **Синекдоха** — бөтеннең исеме б-н өлешне белдерү һәм киресенчә: урман кисү (урманда агач кисү урынына), мыек килә (мыеклы кеше килә урынына). **Аллегория** — читләтеп әйтү; абстракт идея, төшенчәләрне төгәл образлар аркылы сурәтләү. Әкият һәм мәсәлләрдә кирелек — ишәк, хәйләкәрлек — төлке, мәкер — елан образлары аркылы гәүдәләнә. Аллегориягә **сынландыру** — җансыз предмет һәм күренешләрне җанлы итеп бирү (җил улый) һәм **җанландыру (персонификация)** — предмет һәм табигать күренешләрен кешегә хас сыйфатлар б-н гәүдәләндерү (җир елый) якын тора. **Гипербола** — сурәтләнә торган предмет яки күренешнең нинди дә булса үзенчәлекләрен гадәттән тыш арттырып күрсәтү: җилкәмнән тау төште. **Литота** — сурәтләнә торган предмет яки күренеш үзенчәлекләрен махсус кечерәйтеп күрсәтү: кәтүк кадәр малай. **Перифраза** — нинди дә булса предмет яки күренешнең атамасын аларга хас билгеләр һәм сыйфатлар күрсәтелгән башка тәгъбирләр б-н алыштырып әйтү: кара алтын (нефть), урман сарыгы (шүрәле), бу юлларны язучы (автор). **Чагыштыру** — гомуми билгеләрдән чыгып, бер предметны икенче предметка охшату: әйткән сүз аткан ук кебек. **Эпитет** — предмет яки күренешнең нинди дә булса үзенчәлеген ассызыклаучы образлы сурәтләү чарасы: Ватан-ана, кара урман, нур чәчеп торган күзләр. Т. сәнгатьчәлек, тәэсирлелек һәм образлылыкны көчәйтү максатыннан сөйләм телендә дә, матур әдәбияттә да киң кулланыла.

Әд.: Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. К., 2007; К у р б а т о в Х.Р. Татарская лингвистическая стилистика и поэтика. М., 1978; Р о з е н т а л ь Д.Э., Т е л е н к о в а М.А. Словарь-справочник лингвистических терминов. М., 1976. *Р.Х.Мөхиярова.*

ТРОФИ́МОВ Анатолий Михайлович (22.7.1938, Казан — 10.05.2011, Казан), географ, геогр. фән. д-ры (1979), проф. (1980), ТАССР, РФнең атказ. фән эшлеклесе (1987, 1998). Казан ун-тын тәмамлый (1961), шунда ук эшли, икътисади геогр. каф. мөдире (1978–2005); бер үк вакытта, 2008 елдан, ТР ФАнең Экология проблемалары һәм җир ас - ты байлыкларыннан файдалану ин-тында әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре табигать һәм социаль-икътисади терр. систе-

маларны матем. модельләштерүгә карый. Россиядә геогр. буенча яңа фәнни юнәлеш — матем.-геогр. модельләштерүне нигезләүчеләрнең берсе. Әйләнә-тирә мохитне модельләштерүнең идарә аспектын тормышка ашыручы геоситуация концепциясе авторы. Хезмәт тәшләре б-н бергә махсус геоситуацион модельләштерү — матем.-геогр. модельләштерүнең «икенче буынын» эшли. Географиядә модельләштерүгә караган хезмәтләре җылмасы өчен СССР Геогр. җәмгыятенең Почётлы дипломы б-н бүләкләнә (1973). СССР Геогр. җәмгыятенең Татарстан ф-лы рәисе (1982 дән); Россия Экология академиясенең Татарстан бүлеге президенты (1997 дән). Казан ун-тының атказ. профессоры (2008).

Х е з м.: Концептуальные основы моделирования в географии. К., 2001 (автордаш); Общая география (вопросы теории и методологии). Пермь, 2007 (автордаш); Актуальные проблемы социально-экономической географии. К., 2008 (автордаш).

ТРОФИ́МОВ Владимир Алексеевич (30.1.1949, Казан), геофизик, геол.-минерал. фән. д-ры (1994), проф. (1996). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1971), «Татнефтегеофизика» АҖдә, баш геолог (1994 елдан). 1996 дан Казан ун-тының төбәк геологиясе кафедрасында, бер үк вакытта, 1997 дән, ТР Геология һәм җир асты байлыкларын файдалану министрлыгының нефть һәм газ геологиясе бүлеге башлыгы. 2000 нән Мәскәүдә, Янучан казылмалар геологиясе һәм разведкасы ин-тында директор урынбасары, 2002 дән «Консоль» ҖЧҖ (Көньяк Сахалинск ш.) ген. директоры. Хезмәтләре нефть чыганаклары геологиясе, геофизикасы һәм тектоникасына карый. Т. утырма тышлык һәм кристаллик нигезне өйрәнү һәм нефть эзләүнең яңа сейсмик алымнарын эшли. Татарстан терр-ясендә һәм чиктәш өлкәләрдә горизонталь кысылышның тектоник структураларын, нефть үтү каналларын ачыклый. ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Структура горизонтального сжатия на территории Татарстана и северной части Оренбургской области // Докл. РАЕН. 1999. Т. 329, № 4; Нефтеподводящие каналы: пространственное положение, методы обнаружения и способы их активизации // Георесурсы. 2002. № 1 (автордаш).

ТРОФИ́МОВ Иван Трофимович (23.9.1907, Казан губ., Ядрин өязе Виде-Сючь а. — 25.6.1991, Казан), вет. патологоанатомы, вет. фән. д-ры (1956), проф. (1957), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1970). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1931), вет. эпизоотия трестының Семипалатинск бүлегендә отряд башлыгы, инструктор-эпизоотолог булып эшли. 1932 елдан Казан вет. фән-ни-тикшеренү ин-тында. 1938 дән Казан. вет. ин-тында, патологик анатомия каф. мөдире (1959 дан), проф. (1979 дан). Фәнни тикшеренүләре яшь терлекләр авыруларын патогенезы, патоморфологиясенә, гемоспоридозлар һәм вируслы авыруларны өйрәнүгә карый. «Почёт билгесе» ордены, медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Патолого-анатомические и патолого-гистологические изменения гипофиза, щитовидной и шишковидной желёз при эпизоотическом энцефаломиелите лошадей // Тр. Казан. науч.-исслед. вет. ин-та. 1938. Вып. 3; Патоморфология и вопросы патогенеза энзоотической бронхопневмонии телят // Тр. 2 Всесоюз. конф. по патол. анатомии животных. М., 1969.

Әд.: Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

Г.Ж.Идрисов.

ТРОФИ́МОВ Николай Никифорович (20.12.1933, Беренче Май р-нының Акки-рәй а.), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, ТАССРның атказ. агрономы (1984). Тәтеш а.х. техникумын (1953), Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1980). Яңа Писмән р-нының «Политотдел» к-зында (1953 елдан), Беренче Май р-нының «Ивашкино» (1954 тән) һәм «40 лет Октября» (1958 дән) к-зларында агроном, Чирмешән р-нының Фрунзе исем. к-зында баш агроном (1959 дан), рәис (1967 дән), Ивашкино авыл советы башкарма ком-ты рәисе (1989–94). Т. җитәкче булганда хуҗалыкта 2 мең баш мөгезле эре терлек, 1,5 мең баш дуңгыз өчен биналар, кирпеч з-ды, 2 мәктәп һәм башка җитештерү, социаль-мәдәни һәм көнкүреш объектлары төзелә. 1981–85 тә 1966–70 еллар б-н чагыштырганда шикәр чөгендере җитештерү — 2, ит — 2,2 тапкыр, сөт 85% ка арта. Медальләр, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

ТРОФИ́МОВА Татьяна Александровна (17.1.1912 — 5.4.1984, Мәскәү), антрополог, биол. фән. д-ры (1948), проф. (1950). СССР ФА Этнография һәм антропология ин-тының антропология бүлегендә эшли. 1920–30 елларда Мәскәү ун-тының Антропология ин-ты экспедицияләрендә катнаша, Идел буе–Урал алды татарларының, ш.у. Себер татарларының кайбер этнографик төркемнәренең (Бараба, Тубыл һ.б.) төс-кыяфәт үзенчәлекләрен тикшерә. Т. татарлар антропологиясен өйрәнүгә зур өлеш кертә; ул беренче булып татар халкының төп төркемнәренә соматологик (антропометрик) тикшеренүләр үткәрә һәм аның 4 төп антропологик тибын (понтий, аксыл европеоид, сублапоноид һәм монголоид) аерып күрсәтә. Хезмәтләре Урта Азия һәм Көнчыгыш Европа халыклары палеоантропологиясе һәм антропологиясен өйрәнүгә карый.

Х е з м.: Этногенез татар Поволжья в свете данных антропологии // Тр. Ин-та этнографии и антропологии АН СССР. 1949. Т. 7; Антропологический состав населения г.Болгары в X–XV вв. // Тр. Ин-та этнографии и антропологии АН СССР. 1956. Т. 1; Ещё раз о черепах из Луговского могильника ананьинской культуры // Проблемы антропологии и исторической этнографии Азии. М., 1968.

ТРО́ЦКИЙ (чын фамилиясе Бронштейн) Лев Давидович (26.10.1879, Херсон губ., Елизаветград өязе Яновка а. — 20.8.1940, Койякана вилласы, Мексика), дәүләт, партия эшлеклесе. 1888–96 елларда Одесса, Николаев шәһәрләренең реаль уч-щеләрендә укый. 1896 дан Россиядәге социаль-демократик хәрәкәттә катнаша. 1908 дән күп кенә рус һәм чит ил газеталары һәм журналлары б-н хезмәттәшлек итә. Петроградта 1917 елгы Окт. кораллы күтәрелешен оештыруны, Учредительләр җыенын таратуны, оппозициячел партияләрне һәм матбугат органнарын бетерүне, халыкның «пролетар булмаган» социаль катлауларына карата сәяси репрессияләрне, «хәрби коммунизм» сәясәтен гамәлгә кертүне оештыручыларның берсе. 1917 нең октябрендә — 1918 нең мартында тышкы эшләр халык комиссары, 1918–25 тә Республика (1923 тән — СССР) Революцион Хәрби Советы рәисе, хәрби һәм диңгез эшләре халык комиссары. Бер үк вакытта, 1920 дән, арала-шу юллары халык комиссары. 1925 тән СССР ХХС Югары президиумы әгъзасы. Кызыл Армияне оештыруга һәм гражданнар сугышы чорында илнең оборонасын тәэмин итүгә өлеш кертә. 1918 нең августы–сентябрендә Зөя шәһәрендә (Казан губ.) була, Көнчыгыш фронтта Кызыл Армия частьларының сугышчанлыгын күтәрү (аның күрсәтмәсе б-н якынча 70 мең кешедән торган 5 нче армия оештырыла, хәрби тәртип урнаштырыла, хәрби белгечләр — патша армиясенең элеккеге офицерлары хезмәткә тартыла), Чех-словак корпусы гаскәрләре төркемен һәм КОМУЧ-ның Халык армиясе көчләрен тар-мар итү өчен *Казанны азат итү операциясен* әзерләү һәм үткәрү эшен җитәкли. Ф.Ф.Раскольников җитәкчелегендәге хәрби флотилиянең Казанга рейдында катнаша. Т. СССРның милли-дәүләт төзелеше процессында рус булмаган халыкларны тигезлек һәм суверенлык нигезендә катнаштыруда зирәк сәясәт үткәрүне мөһим дип саный. 1919 да Башкортстан АССР төзелү вакытында респ-каның совет һәм партия органнарында «татар кадрларының өстенлек итүе»нә каршы чыгыш ясый. 1923 тә М.Х.Султангалиевның эшчәнлеген кискен тәнкыйтьли, аны милләтчелектә гаепләп чыга. 1920 елларда СССРда социализм төзү юллары турында партия эчендәге бәхәсләрдә Т. һәм аның фикердәшләренең карашлары РКП(б)да «вак буржуаз тайпылыш» дип бәяләнә. 1917–27 дә Коммунистлар партиясе ҮК әгъзасы. 1917 дә, 1919–26 да ҮКның Политбюро, Бөтенроссия ҮБК һәм СССР ҮБК әгъзасы. 1927 дә Алма-Атага, 1929 да чит илгә сөрелә. Төркиядә, Мексикада яши. Сталинизмга каршы юнәлдерелгән оештыру һәм әдәби-публицистик эшчәнлек алып бара. НКВД кушуы буенча үткәрелгән террорчылык акциясе нәтиҗәсендә үтерелә. Хезмәтләре социализм һәм соц. төзелеш теориясенә һәм тарихына карый, хатирәләр авторы.

Х е з м.: Сочинения: В 21 т. М.–Л., 1925–27; К истории русской революции. М., 1990; Моя жизнь. Опыт автобиографии: В 2 т. М., 1990; Сталин: В 2 т. М., 1990; Дневники и письма. М., 1994.

Әд.: В а с е ц к и й Н.А. Троцкий: Опыт политической биографии. М., 1992; В о л к о г о н о в Д.А. Троцкий: Политический портрет: В 2 кн. М., 1992; Д о й ч е р И. Троцкий: В 3 т. М., 2006.

Е.Б.Долгов.

«ТРО́ЦКИЙЧЫ МИЛЛӘТЧЕЛӘРНЕ́Ң КОНТРРЕВОЛЮЦИО́Н-ТЕРРОРЧЫЛЫ́К ОЕШМАСЫ́» ЭШЕ́, бер төркем затларны ВКП(б) һәм Совет дәүләте җитәкчеләренә каршы, ш.и. И.В.Сталинга каршы террор актларын әзерләүдә, контрреволюцион троцкийчы-зиновьевчыларга ярдәм итүдә, үз оешмаларына тарафдарлар тартуда, советларга каршы басмалар әзерләү, саклау һәм таратуда гаепләү буенча мәхкәмә процессы; 1936–38 елларда НКВД тарафыннан оеш-

тырылган гаепләү эше. Бу эш буенча 35 кеше, К.А.*Абрамов*, О.Әлмөхәммәтов, С.С.*Атнагулов*, М.Ә.*Әхмәтшин*, Г.Г.*Байчурин*, И.И.Беганский, А.Т.Биктаһиров, Г.Б.*Баһаветдинов*, С.В.*Бор һан*, И.Р.Борнашев, Х.З.*Габидуллин*, И.Ш.*Галиев*, А.Г.*Ганиев*, С.С.*Гафуров*, З.З.Гыймранов, О.С.Дивеев, Г.Г.*Ибраһимов*, Г.С.*Касыймов*, Г.Г.*Кушаев*, З.М.Мөхсинов, К.Г.*Нәҗметдинов*, И.Ш.Рәхмәтуллин, М.С.*Сәгыйдуллин*, Ф.К.*Сәйфи-Казанлы*, Я.Ж.*Чанышев*, А.З.Шаһиәхмәтов, В.С.*Шәфигуллин*, М.Р.Йосыпов кулга алына. Мәскәмә утырышы Мәскәүдә 1937 нең 3 августыннан 1938 нең 3 августына кадәр (бүленеп) уза. СССР Югары мәхкәмәсенең Хәрби коллегиясе 28 кешене атарга хөкем итә, калганнарны (төрмәдә туберкулёздан үлгән Г.Г.Ибраһимовтан кала; К.Г.Нәҗметдинов б-н Я.Ж.Чанышевка карата эш 1939 да туктатыла) 5 елдан 10 елга кадәр ирекләреннән мәхрүм итәләр. 1950 елларда СССР Югары мәхкәмәсенең Хәрби коллегиясе карарлары б-н гаепләнүчеләрнең күбесенә карата хөкем карары юкка чыгарыла һәм гаепләнүчеләрнең гамәлендә җинаять составы табылмау сәбәпле эш туктатыла.

«ТРӨЦКИЙЧЫЛАРНЫҢ КОНТРРЕВОЛЮЦИӨН ТӨРКЕМЕ́» ЭШЕ́, 1935 елда НКВД органнары тарафыннан кайбер затларны 1931 дән Мәскәү, Свердловск, Казан фәнни хезмәткәрләренең троцкийчыл җинаятьчел төркемендә катнашуда, легаль булмаган җыелышлар, И.В.Сталинга яла ягу компанияләре уздыруда гаепләп оештырылган эш. Оешманың Казан ф-лы эше буенча 6 кеше уза — М.С.Бычкова, З.П.Винтайкин, Е.И.Медведев, З.Б.Надеева, Г.П.Щеперин, Н.Н.Эльвов. 1935 нең 15 октябрендә СССР Эчке эшләр халык комис-ты каршындагы махсус киңәшмә гаепләнүчеләрнең эшен карый һәм аларны төрле срокларга хөкем итә (3 тән 5 елга кадәр, З.Б.Надеевага карата эш туктатыла). ТАССР Югары мәхкәмәсе Президиумының 1958 ел 27 ноябрь карары б-н хөкем карары юкка чыгарыла һәм гаепләнүчеләр гамәлендә җинаять составы булмау сәбәпле эш туктатыла.

«ТРӨЦКИЙЧЫЛАРНЫҢ КОНТРРЕВОЛЮЦИӨН-ТЕРРОРЧЫЛЫ́К ОЕШМАСЫ́» ЭШЕ́, 1937 елда НКВД органнары тарафыннан кайбер затларны троцкийчыл контрреволюцион-террорчы оешма оештыруда, Совет дәүләте җитәкчеләренә каршы террор актларын әзерләүдә, ш.и. 1934 нең 1 декабрендә Ленинградта ВКП(б) УК секретаре С.М.Кировны үтерүдә катнашуда гаепләп оештырылган эш. Оешманың Казан ф-лы эше буенча 9 кеше уза — М.И.Аксянцев, Д.Ф.Белов, Н.Б.-З.*Векслин*, В.Ф.Зорин, М.К.*Корбут*, Г.М.Курочкин, П.А.Соловьёв, Х.Е.Чернышёв, С.М.Шварц. 1937 нең 1 һәм 14 августында СССР Югары мәхкәмәсенең Хәрби коллегиясе ябык утырышта гаепләнүчеләрнең эшен карый һәм 7 кешене, милекләрен конфискацияләп, атарга хөкем итә. Н.Б.-З.Векслин һәм М.И.Аксянцев 10 елга ирекләреннән һәм 5 елга хокукларыннан мәхрүм ителә. СССР Югары мәхкәмәсе Хәрби коллегиясенең 1956 ның 28 июль карары б-н хөкем карары юкка чыгарыла һәм гаепләнүчеләрнең гамәлендә җинаять составы булмау сәбәпле эш туктатыла.

ТРӨ́ШИН Евгений Иванович (5.3.1948, Горький өлкәсенең Зур Мурашкино р-ны Зур Мурашкино а.), вет. радиобиологы, биол. фән. д-ры (1993), Удмурт Респ-касы ФА академигы (1998). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1974), шунда ук, радиобиол. бүлегендә эшли. 1984–95 елларда Бөтенроссия вет. фәнни-тикшеренү ин-тында, радиобиол. лаб-ясе мөдире (1990–92). 1995 тән Кырым аграр ун-тында радиобиол. һәм тормыш куркынычсызлыгы каф. мөдире, проф. (1997). 1997 дән Ижевск а.х. академиясенең вет. санитариясе экспертизасы һәм радиобиол. каф. мөдире. Хезмәтләре синтезланган препаратларның хайваннардагы төрле авырулар һәм радиация б-н зарарлану очракларында дәвалау нәтиҗәлеген өйрәнүгә карый. Удмурт Респ-касының Дәүләт бүләге лауреаты (2002). РФнең югары һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре (2008).

Х е з м.: Лучевая болезнь домашних животных, зверей и птиц. Ижевск, 1998; Ионизирующие излучения и дозы радиации. Ижевск, 2002; Цитология. Гистология. Эмбриология. СПб., 2009 (автордаш).

Әд.: К и р ш и н В.А., Б у д а р к о в В.А. Ветеринарная противорадиационная защита. М., 1990.

ТРОЯ́НСКИЙ Александр Алексеевич (1779, Казан губ., Апаз а. — 2.10.1824, Казан), тел галиме, педагог. Казан руханилар академиясен тәмамлаганнан соң (1799), Казан губернасының Царёвококшайск өязендәге Сотнур авылына рухани итеп билгеләнә. 1800 елдан Казан руханилар академиясендә татар теле укыта. Беренчеләрдән булып дөнья күргән «Татар теле грамматикасы» (СПб., 1814) һәм татарча-русча сүзлек (1–2 т., 1833–35) авторы. 1814 тә митрополит Платонның «Катехизис»ын татарчага тәрҗемә итә һәм бастырып чыгара.

Әд.: Б л а г о в е щ е н с к и й А. История старой Казанской духовной академии. 1797–1818. К., 1875; М о ж а р о в с к и й А.Ф. Старая Казанская академия. М., 1877; К о н о н о в А.Н. История изучения тюркских языков в России: Дооктябрьский период. Л., 1982.

ТРУ́БИН Борис Николаевич (28.6.1930, Пенза өлкәсенең Терновка р-ны Золотарёвка пос.), композитор, педагог, проф. (1999), ТАССР, Мордва Респ-касының атказ. сәнәгать эшлеклесе (1987, 2007). 1956 елда Казан консерваториясен (А.С.Леман классы) тәмамлый. 1956–61 дә — Томск музыка уч-щесендә, 1961 дән Казан консерваториясендә укыта. Зур жанрларга омтыла («Бөгелмә коменданты» («Комендант Бугульмы») опера-сы, Я.Гашек әсәрләре буенча, 1979). 2 нче «Реквием» симфониясендә хәрби тематика гәүдәләнә (1985), 3 нче «ЭКО-774» симфониясенә тапкыр телле публицистик сатира хас (1990), 4 нче симфонияне комп. «Пастораль» буларак билгели (1997), 5 нче симфониядә Ватан темасының трагик аспектларын яңа сәнгатьчә ракурста ача. Т. Татарстанның рус композиторлары мәктәбенә карый. Аның иҗатына образлылык, интонацион тәэсирлелек, форманы төгәл тоемлау хас. Композиторның муз. теле рус аһәңенә тирәнтен үтеп керүе б-н аерылып тора, анда ш.у. татар пентатоника контексты, Россиядә яшәүче төрки халыклар көенә хас үзенчәлекләр урын ала. Иҗатының төрле жанрларында файдаланган фольклор көйләрен эшкәрткәндә композиторның югары проф. осталыгы шуның б-н аңлатыла. Т. — татар халык музыкасы оркестрлары һәм ансамбльләре репертуарына керүче халык музыка уен кораллары өчен язылган әсәрләр авторы. «Ага инеш» («Течёт речка», 1998) сюита-фантазиясе аеруча популярлык казана. Казан, Томск, Новосибирск драма һәм курчак театрларының 80 нән артык спектакльләренә язылган музыкада Т.ның образлы фикерләве ачык чагылыш таба. РФ милли респ-каларының композиторлар мәктәпләре үсешенә зур өлеш кертә. Шәкертләре арасында Р.*Кәлимуллин*, мордва композиторлары Н.Кошелева һәм С.Терханов, тува композиторы Б.Нухов һ.б. бар. Д.Д.Шостакович исем. бүләк, Юрий Башметның Халыкара хәйрия фонды бүләге лауреаты (2007).

Төп әсәрләре: балалар өчен муз. сәхнә опералары — «Гүзәл патша кызы һәм жиде баһадир турында әкият» («Сказка о прекрасной царевне и семи богатырях», 1978), «Поп һәм аның хезмәтчесе Балда турында әкият» («Сказка о попе и о работнике его Балде», 2002); симф. әсәрләр — 1 нче «Сибирская» (1965), 6 нчы «2001 елның салкын җәе» («Холодное лето 2001 г.», 2006) симфонияләре; «Зоя» поэмасы, «Әкиятләр дөньясында» («В мире сказок», 1965), «Пантомима» (1965) сюиталары; «Казаным минем» («Моя Казань», 2005) увертюра-гимны һ.б.; гобой һәм оркестр өчен (1989), труба һәм оркестр дуэты өчен (2002) инструменталь концертлар; С.Кошечкин шигырьләренә «Идел» («Волга») кантаталары (1956); «Истоки» хоры өчен концерт (1996), «Россия» циклы (2000); халык музыка уен кораллары оркестры өчен «Скерцо» (1993), «Ретро» сюитасы (1994), «Идел рапсодиясе» («Волжская рапсодия», 1997), «Болгарда бәйрәм» («Праздник в Булгарах», 1998) увертюрасы; камера-инструменталь әсәрләр — 2 кыллы квартет (1954, 1996) һ.б.; вокаль әсәрләр — җырлар, романслар, 50 дән артык халык җырларын эшкәртмәләре.

Әд.: К а н т о р Г. Борис Трубин // Композиторы и музыковеды Советского Татарстана. К., 1986; К и м С. Дело Трубиных // Казань. 2005. № 5; Композиторы Татарстана. М., 2009.

А.Л.Маклыгин.

«ТРУД», Татарстан сәнәгать, төзелеш, химия һәм газ пр-тиеләре һәм оешмалары хезмәткәрләре һәм эшчеләре профсоюзларының ирекле спорт җәмгыяте. 1957 елда оештырыла. 1967 дә «Т.»тан «*Зенит*» ирекле спорт җәмгыяте аерылып чыга. 1987 гә «Т.» 200 дән артык физик культура коллективларын берләштерә, аларда баскетбол, волейбол, тимераякта шуу спорты, чаңгыда узышу, фигуралы шуу, жиңел һәм авыр атлетика, гандбол, суда туплы уен, футбол, шайбалы хоккей, йөзү, көрәш (грек-рим көрәше, ирекле көрәш, дзюдо, самбо, татарча көрәш) җәелдерелә. 2 атказ. спорт остасы, 12 халыкара класслы спорт остасы, 377 СССРның спорт остасы әзерләнә. Иң яхшы тренерлар һәм спортчылар — Ә.Г.*Әхмәтов*, Б.С.Головин,

Р.З.*Камалов*, Н.Н.*Кибардина*, Н.А.*Колесников*, М.Т.Кузьмин, В.А.Лелюх, Нәкыйп Ә., Нәфыйк Ә., Рәфыйк Ә., Фәрит Ә. Мадьяровлар, Н.О.Осетинская, Г.С.*Тарасов*, А.В.*Фадеев*, Н.С.Чиков, Л.Е.*Шубина*, Р.М.*Яушев*. 1987 дә эшчәнлеген туктата (к. *Профсоюзларның физкультура-спорт җәмгыяте Татарстан Республика советы*). Рәисе: Р.Ф.Нури әхмәтов (1957–65), А.В.Салтыков (1965–81), В.Н.Чикаев (1981–87).

«ТРУД И ХОЗЯЙСТВО» («Хезмәт һәм хуҗалык»), журнал; к. *«Социалистическое хозяйство Татарстана»*.

ТРУДОВИКЛА́Р, «Хезмәт таифәсе» — 1 нче – 4 нче Дәүләт Думаларында (1906–17) үз сафларында крәстиян депутатларын һәм неохалыкчан интеллигенцияне берләштергән демократик фракция әгъзалары. Т.ның программасы гомуми сайлау хокукын һәм демократик иреклəр кертүне, «хезмәт нормасы буенча» имана җиреннән кала барлык җирлəрне национализацияләүне, 8 сәгатьлек эш көнен гамәлгә куюны, хезмәтне саклауны һ.б.ны күздә тота. 1 нче һәм 2 нче Думаларда 1905–07 еллардагы рев-ция шартларында сайланган хезмәт таифәләре аеруча күпсанлы була. Реакция чорында һәм реакцион 3 июнь сайлау законы буенча сайлау вакытында Т. депутатларының саны кискен кими. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң Т. халык социалистлары партиясе б-н Хезмәт халык-социаль фиркасенә берләшәләр. Казан губернасыннан 1 нче һәм 2 нче Думаларда депутатлар арасында Т. күпчелекне тәшкил итә: 1 нче Думада — крәстиян Я.А.Абрамов, писарь М.Н.Герасимов, укытучы И.Е.Лаврентьев, антлы ышанычлы К.В.Лаврский; сәүдәгәр Г.С.Бадамшин бер үк вакытта *мөселман хезмәт таифәсе* составына керә; с.-д. төркеме барлыкка килгәнче, «Хезмәт таифәсе»ндә дары з-ды сызымчысы П.А.Ершов тора; 2 нче Думада — крәстияннәр М.В.Батуров, Г.И.Петрухин һәм А.Ф.Фёдоров, Ядрин аракы з-ды хуҗасы Г.С.Бадамшин. 3 нче һәм 4 нче Думаларда Казан губернасыннан депутатлар арасында Т. булмый.

Р.А.Циунчук.

ТРУДОВО́Й посёлогы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 32 *км* көньякта-рак, Инеш елгасының (Зәйнең сул кушылдыгы) югары агымы буенда. 2010 елда 590 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча татарлар — 65%, руслар — 27%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1920 елларда нигез салына. Беренче исеме — Трудовые Уряклы, соңрак «ПриКамский» с-зының 2 нче фермасы посёлогы, 1966 дан хәзерге исемен йөртә. Оешкан көненнән ТАССРның Чистай кантоны Шәңгәлче волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1938 дә — 236, 1949 да — 573, 1958 дә — 804, 1970 тә — 554, 1979 да — 540, 1989 да — 713, 2002 дә — 627 кеше.

«ТРУДОВО́Й», Түбән Кама р-нындагы а.х. пр-тиесе. 1978 елда «ПриКамский» с-зын кечерәйтү нәтиҗәсендә оештырыла. 1996 да — ҖЧҖ, 2004 тә а.х. җитештерү кооперативы итеп үзгәртелә. 2005 тә «Бәхетле-Агро»га кушыла. Ху җалык составына Майская Горка, Выгороженный Ключ авыллары һәм Трудовой пос. (үзәк утары) керә; 223 хуҗалык, 739 кеше, ш.и. 293 кеше а.х. җитештерүендә эшли (1997). А.х. файдалануы җирләренең мәйданы 4147 *га*, ш.и. сөрүлек җирләр 3784 *га*. Хуҗалыкта 2,1 мең баш мөгезле эре терлек (730 сыер) асрала. Төп тармаклары — бөртекле ашлык, сөт, ит җитештерү. Бөртекле ашлык җитештерү 5,2 мең *т* га, сөт — 2,8 мең *т* га, ит — 276 *т* га җитә. Бөртекле культураларның уңышы 1 *га* дан 30 *ц* тәшкил итә. 2 кеше ТАССРның атказ. а.х. хезмәткәре исеменә лаек була. Хуҗалык җитәкчеләре: Р.И.Сабитов (1978–82), Н.М.Ихсанов (1982–88), Сафиуллин Х.Х. (1989–2005).

И.Н.Афанасьев.

«ТРУДОВО́Й ПУТЬ» («Хезмәт юлы»), иҗтимагый-сәяси көндәлек газета. Казан губернa земствосы органы. 1918 елның 15 февраленнән 30 мартына кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә. Нашире — Казан губернa земство идарәсе. Мөхәррире — большевиклар тарафыннан тыелган *«Крестьянская жизнь»* г-тасы башында торган В.Вегер («Т.п.» ул ябылганның икенче көнендә үк чыга башлый). Актив авторлары арасында — В.Базаров, Н.Волжин, С.Иванова, В.Ильин, Л.Корнеев, П.Леонтьев, В.Мар, К.Остров, А.Хабачёв. Материалларның бер өлеше Непоседа, Новый, В.К-н, И.С. һ.б. псевд. б-н чыга. Үзәк басмалардан Д.Бедный, М.Горький, Л.Мартов әсәрләре һәм чыгышлары күчереп басыла. Газета әсерлар (к. *Социалист-революционерлар партиясе*) карашларын чагылдыра һәм аларның уң әсерларны әзәрлекләгән большевиклар б-н ачыктан-ачык бәрелеше чорында чыга. Большевикларның «Правда», «Известия ВЦИК», «Знамя революции» г-таларыннан өзекләр тәнкыйди шәрехләүләр б-н басыла. Казан һәм Мәскәү авторларының Февр. рев-циясенә бер ел тулуга багышланган мәкаләләре чыга, алар аның самодержавие-монархия строе җимерелүдә һәм илнең конституцион респ-ка моделе буенча үсү мөмкинлеген булдыруда хәлиткеч роль уйнаучы демократик характерын ассызыклый. Большевиклар тарафыннан Учредительләр җыенының куып таратылуы, демократик Россия төзүгә комачаулаучы вакыйга буларак, кискен хөкем ителә. Газета Германия б-н Брест солыхын төзү һәм ратификацияләү (1918 нең марты) турында яза, укучыларны РКП(б)ның килешү төзүне хуплаган 7 нче съезды һәм Советларның 4 нче Бөтенроссия съезды материаллары б-н таныштыра, Брест солыхына каршы чыккан «сул коммунистлар» һәм сул әсерлар карашларын хуплый. Газетада Казан земстволары эшчәнлеге даими яктыртыла. Казан губернa земство җыены-ның чираттагы 53 нче утырышлары материаллары тәфсилләп бәян ителә, Казан Советы башкарма ком-тының аны куып тарату турындагы карарына каршы чыккан җыелыш әгъзалары чыгышлары бастырыла. Редакция большевистик булмаган матбугатка каршы репрессияләргә тискәре мөнәсәбәттә тора (мәс., *«Хыпар»* г-тасын тыю б-н бәйле хөкемне белдерә). Казан большевикларының «Знамя революции» г-тасы «Т.п.»ка даими рәвештә һөҗүм ясый һәм, провокацион басма буларак, аңа бойкот игълан итәргә чакыра. «Т.п.» Совет хөкүмәтенең җирле органнары тарафыннан ябыла. Казан КОМУЧның Халык армиясе тарафыннан алынганнан соң кабат торгызылган губернa земствосы яңа *«Народная жизнь»* г-тасын чыгара башлый.

Т.М.Насыйров.

«ТРУДОВО́Й СОЮ́З» («Хезмәт берлеге»), журнал. Казан «Хезмәт берлеге» («Трудовой союз») кулланучылар ширкәте органы. 1912 елның августыннан 1914 нең февраленә кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә, барысы 8 саны чыга. Мөхәррире — Н.А.Гурячков. «Кама-Идел төбәгендә барлык төр кооперацияләр һәм кооперация хәрәкәте мәсьәләләренә багышланган айлык журнал» дигән өстәмә исем б-н басыла. Актив авторлары арасында — Р.Абов, П.Венецианов, В.Владимиров, Ф.Исланкин. Журнал нәшер итү турындагы карар «Хезмәт берлеге»нең гомуми җыелышында 1912 нең 26 февралендә кабул ителә. Җәмгыять әгъзаларына һәм кайбер кооперация оешмаларына бушлай таратыла. Редакция укучыларны Россия һәм чит илләр кооперация теориясе һәм практикасы б-н таныштыра, кооперация хәрәкәтен киңәйтүгә булышлык күрсәтә. Журналда кулланучылар кооперациясен оештыру буенча теоретик һәм методик материаллар, «Хезмәт берлеге» эшчәнлеге, кооперация оешмалары съездлары турындагы хисаплар басыла. Беренче сан «Кулланучылар ширкәтен ничек ачарга?» («Как открыть общество потребителей?») язмасы б-н ачыла. Кызыклы мәкаләләр арасында — 1 нче Бөтенроссия кооперация, земство һәм а.х. вәкилләре съезды турындагы язма (С.-Петербург, 1912). Басманың төп темаларының берсен Казан губернасында кулланучылар оешмаларын берләштерү фикерен пропагандалау тәшкил итә, шул максаттан берлек әгъзасы өчен сораштыру анкетасы бирелә (1913, 6 сан). Казан төбәгендәге кооперация хәрәкәте хроникасы, студентлар арасында кооперация үзенчәлекләре, кредит сәясәте мәсьәләләре яктыртыла. Мәкаләләрдә губернада кредит кооперациясе үсеше билгеләп үтелә, кертемнәрдә көндәшлекне бетерү хакына аны берләштерү идеясе пропагандалана. Редакция кулланучылар кооперациясе вәкилләрен арадашчылык функцияләрен башкару б-н генә канәгатьләнмәскә, әүзләренең җитештерү эшен дә оештырырга чакыра. Кооперациягә кагылышлы матбугатны күзәтүләрдә кооперация эшендә хәбәрдарлыкны көчәйтү мөһимлеге ассызыклана; Россиядә чыга торган кооперация журналлары һәм газеталары исемлеге басыла (1913, 6 сан).

Р.А.Айнетдинов.

«ТРУДОВЫ́Е РЕЗЕ́РВЫ», к. *«Юность»*.

ТРУДОЛЮ́БОВО авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 22 *км* көньяк-көнбатыштарак, Карасу елгасы буенда. 2010 елда 299 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 54%, руслар —

39%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1920 елларда нигез салына. Беренче исеме — Труд (икенче варианты — Уголок Братского Труда). Оешкан көненнән ТАССРның Чистай кантоны Кәкрекүл волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1935 нең 10 февраленнән — Тельман, 1958 нең 16 июленнән — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнвареннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1926 да — 74, 1938 дә — 437, 1949 да — 262, 1958 дә — 190, 1970 тә — 256, 1979 да — 297, 1989 да — 262, 2002 дә — 295 кеше.

«ТРУДЫ́ КАЗА́НСКОГО О́БЩЕСТВА ПЧЕЛОВО́ДСТВА» («Казан умартачылык җәмгыяте хезмәтләре»), фәнни журнал. 1905–08 елларда Казанда рус телендә елына 2–4 тапкыр нәшер ителә, 14 чыгарылышы дөнья күрә. Беренче саны 1905 нең апрелендә чыга. Мөхәррире — Казан умартачылар җәмгыяте рәисе В.И.Логинов. Басманың максатлары — җәмгыять әгъзаларының тәжрибәсен гомумиләштерү, үзара элемтәләрне ныгыту, Казан губернасында җәмгыятьнең үзе һәм умартачылык б-н кызыксынуга булышлык итү. Җәмгыятьнең әгъзалык взносларын түләгән әгъзаларына басма бушлай таратыла. Журналда җәмгыять һәм аның бүлекләре эшчәнлеге турында тулы хисаплар, җыелыш беркетмәләре, күрсәтмәләре, Казан губерна умартачыларының 1 нче съезды эше турындагы хисаплар сериясе (Казан, 1908) һ.б. басыла. 1909 да тагын да киңәйтелгән программалы *«Журнал Казанского общества пчеловодства»* ж-лы басыла башлый.

Р.А.Айнетдинов.

«ТРУДЫ́ КАЗА́НСКОГО ФОТОГРАФИ́ЧЕСКОГО О́БЩЕСТВА» (Казан фотографлары җәмгыяте хезмәтләре»), журнал. 1896–97 елларда Казанда рус телендә нәшер ителә. Материаллар туплануга бәйле булганга, эзлекле басылмый. *Казан фотографлары җәмгыяте* (1895 тә оеша) эшчәнлеге хисаплары һәм күзәтүләре, идарә һәм җәмгыять әгъзалары исемлеге, ревизия комиссиясе беркетмәләре басыла. Яңа фототехника һәм технологияләргә зур игътибар бирелә. Финанс кыенлыклары сәбәпле, чыгудан туктый.

«ТРУДЫ́ КАЗА́НСКОЙ ГОРОДСКО́Й АСТРОНОМИ́ЧЕСКОЙ ОБСЕРВАТО́РИИ» («Казан шәһәре астрономия обсерваториясе хезмәтләре»), фәнни журнал. 1893–1993 елларда нәшер ителә. Иң элек аны Казан обсерваториясе директоры И.М.*Симонов* обсерваториянең эш йомгакларына караган материаллар нигезендә чыгарырга омтылыш ясап карый. Ул 1842 дә «Observations astronomiques faites a L'Observatoire de Kazan» («Астрономические наблюдения, проводимые в Казанской обсерватории») басмасының беренче һәм бердәнбер санын әзерли. Обсерватория директоры проф. М.А.*Ковальский* 1859 да ш.у. «Recherches astronomiques de L'Observatoire de Kazan» («Казан обсерваториясенең астрономик тикшеренүләре») ж-лының бердәнбер санын чыгара. Анда Ковальскийның үз теоретик мәкаләләре басыла. 1893 тә Д.И.*Дубяго* башлангычы б-н обсерватория галимнәренең хезмәтләре даими чыга башлый. Журналның исеме үзгәреп тора: 1893–94 тә — «Труды Астрономической обсерватории Императорского Казанского университета, издаваемые проф. Д.И.Дубяго, директором обсерватории», 1895–1915 тә — «Труды Астрономической обсерватории Императорского Казанского университета», 1930–61 дә — «Труды Астрономической обсерватории Казанского государственного университета имени В.И.Ульянова-Ленина», 1966–93 тә — «Труды Казанской городской астрономической обсерватории». Астрофизика, астрономия, күк механикасы, селенодезия, кометалар астрономиясе һәм геодезия өлкәләренә кагылышлы гыйльми тикшеренүләрнең нәтиҗәләре басыла.

«ТРУДЫ́ О́БЩЕСТВА ЕСТЕСТВОИСПЫТА́ТЕЛЕЙ ПРИ КАЗА́НСКОМ УНИВЕРСИТЕ́ТЕ» («Казан университеты каршындагы табигыятьчеләр җәмгыяте хезмәтләре»), фәнни басма. «Труды...» 1871 елдан нәшер ителә башлый. Авторлары — башлыча, *Табигыятьчеләр җәмгыятенең* үз тикшеренүләре турында вакытында мәгълүмат бастыру мөмкинлеге алган әгъзалары. 1 нче томда җәмгыятьнең 1 нче секретаре М.Н.Богдановның «Идел буе һәм Урта һәм Түбән Идел үзәне кара туфраклы зонасының кошлары һәм хайваннары» («Птицы и звери черноземной полосы Поволжья и долины Средней и Нижней Волги») хезмәте басыла. Фәнни мәгънәсен югалтмаган әлеге монография зоогеографияне үстерүдә зур роль уйный. Алга таба «Труды...» ел саен диярлек чыга. 1918 гә кадәр 49 том басыла. Гражданнар сугышы һәм халык хуҗалыгын торгызу елларында (1918–25) чыгарылмый. Аннан соңгы чорда (1940 ка кадәр) 7 томы дөнья күрә. Бөек Ватан сугышы елларында «Труды...» басмасы чыгудан туктап тора. Җәмгыять эшчәнлеге тукталганга кадәр (1966–67) тагын 11 томы басыла (57–67 нче саннар). 58 нче томнан (1951) «Труды...» *«Учёные записки Казанского университета»* б-н берләштерелә, басма ике гриф б-н чыга: «Учёные записки...» томнары һәм чыгарышларына, ш.у. «Труды...» томнарына аерым саннар куела. 1955–56 да басылган «Труды...» чыгарылышларына том саннары куелмаган (60 һәм 61 булырга тиешле саннар). Биол.-туфрак ф-тында «Учёные записки...» кабат торгызылгач, кайбер томнар кабат ике исем б-н бастырыла башлый. Мәс., «Труды...»ның соңгы том нары (2005, 68 нче һәм 2006, 69 нчы сан) — алар шул ук «Учёные записки...» (147 т., 2 кит. һәм 148 т., 3 кит.) — шул рәвешле чыга. «Труды...»ның барлыгы 308 дән дә ким булмаган чыгарылышы дөнья күрә.

«Труды...»дан кала, Табигыятьчеләр җәмгыяте үз утырышларының беркетмәләренә кушымталар нәшер итә. 1869–1916 да кушымталарның 500 дән артык басмасы дөнья күрә, аларның күбесе соңрак киңәйтелгән формада дөнья күргән тикшеренүләрнең авторлык тезисы булып тора. М.Н.Богданов, әйтик, 7 нче (1869/70), 15 нче (1870/71), 32 нче (1871/72) утырыш материалларында үз тезисларын урнаштырып, «Труды...»да (т. 1, 1871, т. 8, 1879) монографик характердагы мәкаләләр формасында аларның киңәйтелгән вариантын бастыра. М.Д.Рузский Казан губернасы амфибияләре һәм рептилияләре турындагы күзәтүләренең беренче өлешен (1893–94, ахыры басылмый кала), Зөя елгасы балыкларына (1887), Кабан күленең пелагиаль фаунасына (1889), Казан губернасы терр-ясендәге кошларга (магистрлык диссертациясе, 1893), бөҗәкләргә («Россия кырмыскалары» — «Муравьи России», т. 1–2, 1905–07) багышланган монографик характердагы башка хезмәтләрен бастырып чыгара. Соңыннан алар «Труды...»да чыга. Биредә үк зоолог А.А.Остроумов (1888) ботаниклар И.А.Буш (1888–94), С.И.Коржинский (1888–91), А.Я.Гордягин (1888–1933), туфрак белгече Р.В.Ризположенский (1887–1901), географ һәм геологлар П.И.Кротов (1876–85), А.А.Штукенберг (1874–1906), А.В.Нечаев (1887–1900), П.И.Чердынцев (1910–37) материаллары дөнья күрә. Авторлар арасында ш.у. — археологлар һәм этнографлар Н.М.Малиев (1872–88), Н.Ф.Высоцкий (1879–90), П.Л.Драверт (1902–16) бар. «Труды...»да Идел һәм Урал буеның төрки, фин-угор халыклары: чуаш, мари, удмурт, башкорт, коми һ.б.га нисбәтле күп кенә тикшеренүләр нәтиҗәләре бастырыла. 98 ел эчендә «Труды...»да 320 дән артык авторның хезмәтләре дөнья күрә.

Әд.: Указатель изданий Общества естествоиспытателей при Императорском Казанском университете. 1869–1882. К., 1882; Мишина Е.М. Систематический указатель к периодическим изданиям Казанского ордена Трудового Красного Знамени университета им. В.И.Ленина: 1815–1947. К., 1960.

В.И.Гаранин.

«ТРУ́ЖЕНИЦА ТАТА́РИИ», чия сорты. 1985 елда Татарстан а.х. ин-тында Л.А.*Севастьянова* һәм В.А.*Наумов* тарафыннан чыгарыла. Уртача иртә өлгерешле сорт. Куагы уртача биеклектә (2,5 *м*), җыйнак озынча түгәрәк ябалдашлы. Кәүсәсенең кайрысы һәм яшь үсентеләре көрән төстә. Яфраклары куе яшел төстә, тоныклык. Җимешләре уртача зурлыкта (3,5 *г*), җиңелчә яссы-түгәрәк, куе кызыл төстә. Җимешәне куе кызыл, сусыл, әчкелтем баллы. Җимешләре азык буларак кулланыла. Салкынга, коккомикоз авыруына чыдам, өлешчә үз-үзеннән серкәләнә; ел саен җимеш бирә; бер куактан 7 *кг* уңыш алына. ТРда 1993 тән районлаштырыла. Коллектив һәм йорт яны бакчаларында үстерелә.

Әд.: Фруктовый сад Татарстана. К., 2005.

ТРУ́НСКИЙ Юзеф Геннадьевич (31.1.1915, Чернигов губ. Мена а. — 2.11.1989, Казан), тарихчы, тарих фән. д-ры (1971), проф. (1972). В.Н.Подбельский исем. Инженерлык-техник академияне (Мәскәү, 1937), К.Либкнехт исем. ин-тны (Мәскәү, 1941), Мәскәү пед. ин-тын (1947) тәмамлый. 1930–32 елларда Мәскәүнең Дзержинский р-нында атарга өйрәтүче район инструкторы, 1932–35 тә Дзержинский р-ны снайпинг мәктәбе башлыгы, бер үк вакытта баллистика укытучысы, 1937–40 та атарга өйрәтүче инструкторлар мәктәбе башлыгы һәм баллистика укытучысы (Мәскәү). 1941 дән Төмән шәһәрендә:

«Красный тюменец» з-дында җитештерү башлыгы. 1944–47 дә 2 нче Голицыно олау-төзәлеш з-ды директоры урынбасары (Мәскәү). 1951 дән Казан пед. ин-тында гомумтарих кафедрасында. 19–20 йөзләрдәге француз авыллары тарихына багышланган хезмәтләр авторы. Аларда аграр кризис, а.х.нда техник үзгәртеп коруларның социаль-икътисади нәтиҗәләре, илгә Европа интеграциясенең тәэсире карала; француз авылларының социаль структурасы, крәстияннәр хәрәкәте, француз социалистлары һәм коммунистларының аграр программалары тәфсилләп тикшерелә. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Позиции французских социалистов в крестьянском вопросе в начале XIX в. // Уч. зап. Казан. гос. пед. ин-та. 1956. Вып. 11; Влияние аграрного кризиса конца XIX в. на положение французского крестьянства // Уч. зап. Казан гос. пед. ин-та. 1957. Вып. 12; Французская деревня в XIX–XX веках: Тенденции развития. М. 1986.

Л.М.Айнетдинова.

ТРУ́ТНЕВ Василий Кузьмич (7.3.1891, Калуга губ., Жиздра өязе Мокрое а. — 11.12.1960, Мәскәү), оториноларинголог, мед. фән. д-ры (1923), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1946). Саратов ун-тын тәмамлаганнан соң (1916), шунда ук, колак, борын һәм тамак авырулары клиникасында эшли. 1925 елдан Казан ун-тының колак, тамак һәм борын авырулары каф. мөдире. Бер үк вакытта, 1926 дан, Казан ГИДУВының ЛОР-авырулар кафедрасында. 1928 дә Германиядә, Данияда фәнни командировкада. 1938 дән Мәскәүдә, Үзәк табиблар белемен күтәрү ин-тының оториноларингология каф. мөдире, 1943 тән Мәскәү Колак, тамак һәм борын авырулары фәнни-тикшеренү ин-ты җитәкчесе, бер үк вакытта 3 нче Мәскәү мед. ин-тының оториноларингология каф. мөдире. Хезмәтләре төбәккә хас ЛОР-патологияләргә, югары сулыш юллары физиологиясенә, трахеобронхоскопиягә, хроник тонзиллитларны дәвалау һәм кисәтүгә карый. Татарстан теоретик һәм клиник мед. фәнни-тикшеренү ин-тының беренче директоры (1933 тән). СССРда беренче булып лабиринт фенестрациясе үткәрә (1934). СССР ЮС депутаты (1937–41).

Х е з м.: Симптом Кернига при заболеваниях носа, горла и ушей. Саратов. 1923; Слуховые аппараты. М., 1946; Трахеобронхоскопия. М., 1952; Трахеотомия. М., 1954; Ангина. М., 1959.

Әд.: Б о б р о в с к и й Н.А. Памяти профессора В.К.Трутнева // Журн. ушных, носовых и горловых болезней. 1961. № 2.

ТРУ́ТНЕВ Евгений Иванович (7.11.1929, Калуга өлкәсенең Песочня пос., хәзер Калуга өлкәсе Киров ш. — 11.11.1995, Казан), вет. эндокринологы, биол. фән. д-ры (1971), проф. (1988), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1989). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1952), Алтай краеның Рябинск р-нында баш вет. табибе булып эшли. 1954–57 елларда Алтай краеның Ключевский зоовет. мәктәбендә (Барнаул ш.) укытучы, директор. 1957–84 тә Казан вет. ин-тында, токсикология лаб-ясе мөдире (1973 тән). 1984–93 тә Бөтенроссия вет. фәнни-тикшеренү ин-тында пестицидлар токсикологиясе лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре хайваннар эндокринологиясе өлкәсенә, хайваннарның пестицидлар б-н агулану очракларында индикация һәм дәвалауга карый. Т. агулану очракларында дәвалау өчен антидотлар уйлап таба. Үйлап табуга 17 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Влияние некоторых одновременных первичных и гуморальных воздействий на лейкоформулу и на течение и исход острого асептического перитонита // Уч. зап. Казан. вет. ин-та. 1965. Т. 93; О нейрогуморальной регуляции андрогенной активности и спермиогенеза // Уч. зап. Казан. вет. ин-та. 1971. Т. 111.

Әд.: Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

ТРУФА́НОВ Андрей Андреевич (1884, Мәскәү — 22.3.1957, Казан), гидротехник, техник фән. д-ры (1940), проф. (1926), ТАССР-ның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1953). 1909 елда Мәскәү тимер юл инженерлары ин-тын тәмамлаганнан соң, Идел елгасының төрле гидротехник корылмаларында инженер булып эшли. Беренче бөтендөнья сугышында катнаша. 1919–26 да Казан политехник ин-тында укыта. Идел-Кама урман материаллары агызу ин-тын оештыра һәм аның директоры була (Казан, 1928–33). 1938–57 дә Казан химия-технол. ин-тының гидравлика, компрессорлар һәм насослар каф. мөдире, механика ф-ты деканы (1943–45). Бер үк вакыта, 1946–52 дә, СССР ФА Казан ф-лының су хуҗалыгы проблемалары бүлеге мөдире. Хезмәтләре урман материаллары агызганда елгаларда агым гидродинамикасын, гидравлик күренешләрне тикшерүгә карый. Ленин ордены, «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: Профессора, доктора наук. Политехнический институт — КХТИ — КГТУ (1919–2000): Краткий биогр. справ. К., 2000.

ТССР, к. *Татарстан Республикасы.*

ТУБАКЫ́ЕВ Ибраһим (18 йөз ахыры — 19 йөзнең 1 нче яртысы), язучы. «Кыйссаи Тәминдар» кулъязма поэмасы авторы. Эчтәлеге күп халыкларда киң таралган геройның теге дөньяга сәяхәт кылуы турындагы риваять сюжетына корылган. Әсәрнең герое — Гомәр хәлифә хакимлек иткән чорда (634–44) Мәдинә шәһәрендә яшәгән мөселман кешесе. Текстта поэманың 1831 елда тәмамлануы хәбәр ителә. Ул вакытта автор Мәскәүдә яши. Кулъязма Казан ун-тының Фәнни китапханәсендә саклана.

ТУБАЛА́К (Pedicularis), сыраҗчалар семьялыгыннан күпьеллык, сирәк кенә бер- һәм икееллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 600 гә якын төре билгеле, күбесенчә Төньяк ярым шарда таралганнар. ТР терр-ясендә 4 төре бар. Кауфман Т. (P. kaufmannii) барлык районнарда да очрый. Саз Т.ы (P. palustris), скипетрсыман Т. (P. sceptrum-carolinum), Урал Т.ы (P. uralensis) — сирәк төрләр. Куаклыкларда, болын, алан, уйсулыклы сазлыкларда, елга ярлары буенда, торфлы сазлыкларда үсәләр. 15–100 *см* биеклектәге үсемлек. Сабагы яфраксыз диярлек, барлык яфраклары аскы өлешкә җыелган һәм тамыр яны тарлагысы тәшкил итәләр. Яфраклары вак, чираттлашкан, каурыйсыман теленмә яки каурыйсыман бүленмә. Чәчәкләре дөрес булмаган формада, җете кызыл, алсу, сары төстә, башак яки чук чәчәк төркемендә; та җы ике иренле. Җимеше — йомыркасыман тартмачык. Июнь–августта чәчәк аталар. Җимешләре июль–сентябрьдә өлгерә. Орлыктан үрчиләр. Т.ның барлык төрләре дә паразитлыкка сәләтле: төрле үсемлекләрнең тамырларына гаусториялар (имгечләр) буларак берегәләр, сүлен суырып аларны хәлсезләндерәләр. Халык медицинасында кауфман Т. һәм саз Т.ы бәвел кудыру, ялкынсынуга каршы чара буларак кулланыла. Саз Т.ы, скипетрсыман Т. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

ТУБЕРКУЛЁЗ (лат. tuberculum — төер), кешедә һәм хайваннарда була торган, киң таралган йогышлы авыру, аны микобактерияләр китереп чыгара. Т. авыруы барышына полиморфизм, авыру билгеләренең күптөрлелеге хас; микроб төрле яшьтәге кешеләрне, барлык әгъзаларны зарарлый. РФдә кабул ителгән клиник классификация нигезендә сулыш әгъзалары, сидек-җенес әгъзалары системасы, күз, сөяк һәм буыннар, тире, ми тышчалары (Т. менингиты), баш мие, эчәклек, корсак ярысы, лимфа системасы Т.ы; балаларда, нигездә, Т. интоксикациясе аерып карала. Үпкә Т.ы аеруча еш очрый (авыру Т. бизгәге, какырыклы ютәл, кан төкерү б-н бара; авыруның көчәя баруы авыру кешенең хәлсезләнүенә китерә).

Төп инфекция чыганагы какырык б-н бергә Т. микобактерияләре (Mycobacterium tuberculosis, әлекке атамасы — Кох таякчыгы, Т. бацилласы) бүлеп чыгаручы авыру кеше. Авыру башлыча һава аша күчә. Аның әйләнә-тирәгә Т. микобактерияләре бүлеп чыгара яки бүлеп чыгармый торган төрләре була. Йорт хайваннары һәм кошлары ш.у. Т. б-н авырый (кош, үгез микобактериозлары билгеле). Кешегә авыру мөгезле эре терлекләрдән йогарга мөмкин. Микроб озак еллар буе тукымаларда һәм макрофагларда сакланырга, даруларга бирешмәү үзлегенә ия булырга сәләтле. Социаль-көнкүреш шартларының начар булуы, иммуносупрессия (аеруча СПИД очрагында), глюкокортикоидлар б-н озак дәвалану, шикәр диабеты, хроник бөер зәгыйфьлеге, ач тору, авырулар б-н якыннан аралашу Т. йоктыруга китерергә мөмкин. Бугаз, бронхлар Т.ы, үпкә Т.ының деструктив формалары аеруча куркыныч чыганак санала (СПИД тараланнан соң, Т. бу төр авырулар арасындагы үлем очракларының төп сәбәбенә әверелә).

Т. — иң борынгы авыруларның берсе, Т.га хас тайпылышлар таш гасыр кешеләре сөякләрендә, Мисыр мумияләрендә табылган. Т.ның беренче тасвирламасы Гиппократ хезмәтләрендә очрый. «Т.» терминын француз галиме Р.Лаэннек кертә («Үпкә һәм йөрәк авырулары аускультациясе һәм диагностикасы турында» — «Об аускультации и диагностике болезней лёгких и сердца», 1819). Р.Кох Т. авыруын күзгатучыны таба (1882).

Т. клиникасын өйрәнүгә илебез галимнәре зур өлеш кертә. Г.И.Сокольский «Күкрәк авырулары турында тәгълимат» («Учение о грудных болезнях», 1838) китабын нәшер итә; Н.И.Пирогов Т.ны гомуми авыру буларак өйрәнә, Т. төерендәге гигант күзәнәкләрне, кискен вак төерле (милиар) Т.ның авыру

билгеләрен, аның тифоид төрен, ш.у. сояк һәм буыннар Т.ын тасвирлый. А.И.Абрикосов, В.Г.Штефко, А.И.Струков, А.Н.Чистович Т. ялкынсынуын патологик процессның барлык фазаларын үз эченә алган гомуми процесс буларак тикшерәләр. Г.А.Захарьин реинфекциянең (кабат йоктыру) һәм эчке (эндоген) сәбәпләр, һәм тышкы (экзоген) факторлар нәтиҗәсендә барлыкка килү мөмкинлеген фаразлый. С.П.Боткин авыруның таралуы һәм ахыргы нәтиҗәләре мәсьәләләрендә социаль факторларга зур игътибар бирә. А.А.Кисель хроник Т. интоксикациясен Т.ның аерым төре буларак тасвирлый, балаларда бу авыру күпчелек очракта лимфа аппаратында туктала дип саный.

Татарстан терр-ясендә Т.га каршы актив көрәш башлану 1911 елда Бөтенроссия Т.га каршы көрәш лигасының Казан бүлеге оешу б-н бәйле (рәисе А.Н.*Казимбәк*, рәис урынбасары Р.А.*Лурия*). Бүлек ел саен «*Ак ромашка*» хәйрия акциясе уздыра. 1912–15 тә Казан губернасы Казан өязенең Колай волостендагы Тугаш авылында «күкрәк авырулы» балалар өчен җәйге балалар колониясе эшли. 1913 тә Казанда Т. диспансеры ачыла (мөдире В.В.*Фризе*), анда профессорлар А.Н.Казимбәк, С.С.*Зимницкий*, В.Ф.*Орловский*, Е.М.*Лепский* авыруларны бушлай кабул итә. Гомуми тернәкләндерү чаралары күрү һәм симптоматик дәвалаудан тыш, туберкулинотерапия дә кулланыла (А.Н.Казимбәк). 1913 тә, Казанда беренче буларак, В.Ф.Орловский һәм Л.Л.Фофанов тарафыннан үпкә Т.ы б-н авыручыларга дәвалау максатыннан пневмоторакс ясала. 1913 тә Казанда Т.лы авыруларга тәрбия күрсәтелә башлый. Т.га каршы көрәшкә патофизиол., биохимия, микробиол. һәм клиника өлкәсендә лаборатор һәм эксперименталь тикшеренүләр алып баручы гамәли табиблар һәм гыйльми хезмәткәрләр (М.О.Фридлан, М.И.Аксянцев, Н.М.Захаров, Н.М.Кудряшов, Б.Л.Мазур, В.М.Аристовский, Н.Н.Благовещенский, М.И.Мастбаум һ.б.) зур өлеш кертә. Шулай ук авыру тудыручының биологиясен, Т.га каршы вакцинация б-н бәйле мәсьәләләрне өйрәнү юнәлешендә дә эш алып барыла. 1950 елларда Казан мед. ин-тының Т. кафедрасында Б.Л.Мазур Т. бактерияләренең кислотага чыдамсыз штаммнарыннан «антивирус» әзерли, ул Т. лимфаденитын, сояк-буын, күз Т.ын дәвалауда кулланыла.

1918 дә Мәскәүдә РСФСР Сәламәтлек саклау халык комис-ты каршында һәм Казанда Т.га каршы көрәш бүлекләре оештырыла, Т.ны дәвалау хезмәте (диспансерлар) булдырыла. 1920 дә Татарстанда «*Каменка*» санаториен төзү тәмамлана. Шул ук елда Е.М.Лепский башлангычында Казанда Т. авырулы балалар өчен 2 сабыйлар йорты, 1921 дә Т. диспансеры (мөдире А.А.Кулагин, 1921–30) ачыла, сояк Т.ын дәвалый торган «*Обсерватория*» балалар санатории эшли башлый. Әгер җе волосте Иж-Бубый авылында 50 ятак-урынлы кымыз дәваханәсе терге-зелә. 1923 тә ТАССР Сәламәтлек саклау халык комис-ты карары б-н Казанда (Елга аръягында һәм Болак артында) диспансерлар оештырыла. 1924 тә Казан хәрби госпитале каршында 25 ятак-урынлы Т. бүлеге ачыла. Чистайда, Буада (1924), Арчада, Алабугада (1925), Лаешта (1927), Мамадышта, Чаллыда (1929) кантон диспансерлары оештырыла. Шуңа да карамастан, 1925 тә Т. авыруыннан үлү очраклары 100 мең кешегә 257 кеше тәшкил итә. 1927 дә яңа туган балаларны вакцинацияләү тәртибе кертелә, Т. б-н авыручыларны «Әгер җе», «Тарловка» (1922), «Обсерватория» (1930) санаторийларында һәм Ютазы кымыз дәваханәсендә (1932) кымыз б-н дәвалау башлана; алар фәнни тикшеренүләр өчен база булып тора. 1928 дә Т. ин-ты оештырыла (1940 та Респ-ка Т. клиник хастаханәсе итеп үзгәртелә), 1931 дә Казан ГИДУВы каршында Т. каф. ачыла; Т.ны дәвалаучы табиблар ш.у. Казан мед. ин-тында да әзерләнә (бу учреждениеләр респ-када һәм Идел буенда Т.га каршы көрәш чараларын оештыручы үзәк тә булып тора). 1936 да Татарстанда 15 диспансер эшли.

1930 елларда шәһәр сәнәгать пр-тиеләрендә Т. диспансерлары эше көчәя. 1935 кә авыручылар саны 2,5 тапкыр кими. Бөек Ватан сугышы елларында Т. б-н авыру очраклары кабат арта (100 мең кешегә — 539 кеше); пр-тиеләрдә төнге Т. санаторийлары (Казанда — 280 ятак-урын) һәм гомуми төрдәге санаторийлар ачыла. 1944 тә респ-кадагы Т.ны дәвалау учреждениеләрендә 600 дән артык ятак-урын исәпләнә. 1948 дән Татарстанда Т.га каршы вакцинация һәм ревакцинация кертелә. 1947 дән Зеленодольскида Т. диспансеры эшли башлый. 1948 дә Болак арты диспансеры — Идел буе төбәк диспансеры (баш табиб А.С.Кутуева), ә 1958 дән шәһәр диспансеры буларак эшли һәм Т.ны дәвалау буенча респ-ка методик үзәген тәшкил итә. Диспансер бүлеге дә булган Респ-ка Т. клиник хастаханәсе яңа статус ала — Респ-ка Т. диспансерына әйләнә (баш табиб З.М.*Кутуева*), 1956 да анда хирургия бүлеге ачыла (мөдире И.З.*Сигал*). 1957 дә — Әлмәттә, 1958 дә — Бөгелмәдә, 1964 тә Казанда Т. диспансерлары эшли башлый.

1980 гә Татарстанда Т. б-н авыручылар саны 100 мең кешегә 35,5 кеше нисбәтендә була. 1990 елларда, мед. күзәтчелеге кимү сәбәпле, әлеге күрсәткеч 211 кешегә җитә, 2007 дә 110,5 кеше тәшкил итә, шунлыктан респ-ка да диспансерлар эшчәнлеге көчәйтелә. 2000 нән Т.ның даруга бирешмәс хроник төрләрен дәвалауда яңа схемалар, дару матдәләрен киметү ысуллары (рациональ терапия) тәкъдим ителә, деструктив үпкә Т.ы, сулыш әгъзалары саркаидозының үзенчәлекләре һ.б. өйрәнелә. Казан галимнәренең Т.га диагноз кую һәм аны дәвалау буенча яңа фәнни эшләнмәләре оператив рәвештә гамәлгә кертелә.

Әд.: Шарафутдинова Р.М. Борьба с туберкулёзом в ТАССР в первое десятилетие советской власти // Материалы юбилейной науч. конф. Казан мед. ин-та. К., 1964; Визель А.А., Гурылёва М.Э. К 75-летию фтизиатрической службы Республики Татарстан. К., 1996; Валиев Р.Ш. Победить опасную эпидемию — наш долг // Науч. Татарстан. 1999. № 4; шул ук. Туберкулёз и меры борьбы с ним. К., 2000; Валиев Р.Ш., Хитров В.Ю., Горшенина Н.У. Профилактика внутрибольничной инфекции туберкулёза в стоматологических поликлиниках // Большой целевой журн. о туберкулёзе. 2000. № 11–12; Валиев Р.Ш., Гурылёва М.Э. Основные вехи развития противотуберкулёзной службы Республики Татарстан // Аптека. 2002. № 12.

Д.Р.Нуретдинова, Р.Ш.Вәлиев.

ТУБЕРКУЛЁЗ ХАСТАХАНӘСЕ́, к. «*Каменка*».

ТУБЕРКУЛЁЗГА́ КАРШЫ́ КӨРӘ́Ш ЛИ́ГАСЫ, хәйрия җәмгыяте. 1911 елдан Казанда Бөтенроссия Т.к.к.л. (1910 да С.-Петербургта төзелә) бүлеге буларак эш алып бара. А.Н.*Казимбәк*, М.А.*Хомяков* тарафыннан оештырыла. Җәмгыять туберкулёз турында аңлату эшләре алып бара, авыруларны дәвалау өчен акча җыя, санаторийларда дәвалауны оештыра. Акча җыю максатыннан «*Ак ромашка*» көннәре уздырыла. Лекцияләр Р.А.*Лурия* җитәкчелегендәге мәдәни агарту комиссиясе тарафыннан укыла, лектор сыйфатында В.Ф.Орловский, М.Н.*Чебоксаров*, Е.М.*Лепский*, П.З.Жаков, В.А.Баняев, М.А.Хомяков, Ә.Б. һәм Н.В.Терегуловлар чыгыш ясый. Туберкулёзга бирешчән балалар өчен җәйге мәктәп-колония (Казан өязе Тугыш авылы), килеп дәваланучылар өчен түләүсез амбулатория (Казан, мөдире В.В.Фризе) ачуга ирешелә. 1914 тә «*Каменка*» санатории оештырыла. 1918 дә губерна сәламәтлек саклау бүлеге каршында социаль авырулар бүлеге булдырыла һәм лиганың эшчәнлеге туктала. 1998 дә «Ак ромашка» гуманитар акциясе тергезелә, иҗтимагый хәйрия фонды төзелә (президенты Р.Ә.Җәлиев). Җыелган акчалардан «Каменка» хастаханәсенә матди ярдәм күрсәтелә. А.Н.Казимбәк исем. бүләк (елның иң яхшы фтизиатрына тапшырыла), Казан мед. ин-ты студентлары өчен махсус стипендия булдырыла. Ел саен 24 мартта ТРда Халыкара туберкулёзга каршы көрәш көне уздырыла.

Әд.: Исторический очерк к 75-летию фтизиатрической службы Республики Татарстан. К., 1996.

Д.Р.Нуретдинова.

ТУБЫ́Л МӨСЕЛМА́Н ТӘРӘККЫЙПӘРВӘРЛӘ́Р ҖӘМГЫЯТЕ́, хәйрия оешмасы. 1907 елның маенда оештырыла. Оештыручылары — Т.С.Айтмөхәммәтов, Б.Ш.Колмәмәтов, Х.М.Бакыев, В.М.Хәлилов. Максаты: мөселман уку йортларына һәм татар матбугатының алга китешенә һәм үсешенә булышлык итү. Эшчәнлеген Тубыл губернасының Тубыл өязе б-н Тубыл шәһәрендә дәвам иттерә. 1914 нең августында эшчәнлеге туктала.

ТУБЫ́Л РАЙОНЫ́, *Төмән өлкәсенең* төнъяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. 1923 елның 12 ноябрендә оештырыла. Мәйданы — 17,2 мең *км*². Үзәге — Тубыл шәһәре (Төмәннән 247 *км* төньяк-көнчыгыштарак урнашкан). Халкы — 21151 (1.1.2017), татарлар — 7627 (2010) кеше. Татарлар, тупланып, Тубылтора, Маслово, Әчир, Лайтамак, Ләңче (Иземеть), Нешшә (Ишменева), Сабанак, Юршак (Иртышатские Юрты), Күкрәнде (Чебурга), Ләчек (Тахтагул), Тәпкен (Топкинская), Тәпкенбаш (Топкинбашева), Вәрмәхли, Янгүтүм, Наскы (Носкинская), Үләртеш (Старицкая), Өстамак (Устамак), Пуш-

наш (Пушнятская), Черкашина, Сатлыган (Татарские Медянки), Торбы (Турбинская), Уба (Алга), Ирек, Подъёмка, Сөкләм (Суклем), Шаҥшы (Шамша), Бәек (Байгара), Кучайлан (Епанчина), Урманбаш (Ахманай), Ялан, Ишмәт (Нерда), Пәргәр (Исеневская), Меримы, Түбән Әрем ҡан авылларында; бер-кадәр өлеше Ворогушино, Санниково, Абалак, Хмелёва авылларында, Прииртышский, Надцы посёлокларында яшиләр. Элек Т.р. терр-ясе — *Алтын Урда, Көк Урда, Себер ханлығы*, 16 йөз ахырыннан Рус дәүләте составына керә. Себер татарлары б-н берҙәттән монда *бохари төркиләр* дә яши. Идел-Урал буе татарлары 18 йөзнең 2 нче яртысында, бигрәк тә 19 йөзнең 2 нче яртысында — 20 йөз башында күпләп урнаша башлыйлар. Халыкның төп шөғыле аучылык, балык тоту, терлекчелек була. Татар авылларының халҡы йомшак күн эшкәртү, аяк киеме тегү, ат дирбия-се ясау б-н шөғыльләнә; патша сараен шоңкар б-н тәэмин итеп тора. 19 йөз уртасыннан Себердә күпләп мәктәпләр һәм мәдрәсәләр ачыла башлый, аларны күбесенсә бай бохари төркиләр меценатлары тота. Түбән Әрем ҡан авылында Т.С.Айтмөхәммәтов иганәсенә мәсет төзелә. Мәшһүр дин эшлеклесе һәм мәғрифәтче Х.Хәлилов (аның башлангысында 1920 елларда Себер татарларының корылтае чакырыла) Торбы Йорты авылында мәдрәсә тота. Анда Тубыл, Төмән, Тара шәһәрләренән шәкертләр (укучыларның саны 300 гә ҡитә) укый, дин фәннәреннән тыш, рус теле һәм дөньяви фәннәр дә укытыла. Мәдрәсәләр Меримы, Юршак авылларында эшли (укытучылар арасында Истанбулдан килгәннәре дә була). 1907–14 тә Тубыл өязе һәм Тубыл шәһәрендә *Тубыл мөселман тәрәккыйпәрвәрләр ҡәмғыяте* эшли. 1934 тә Т.р.нда 44 татар мәктәбе була, аларда 76 укытучы эшли. Тубылда *«Колхоз юлы»* (1930–36) һәм *«Ленин юлы»* (1957–63) иҗтимагый-сәяси татар г-та-лары нәшер ителә. 1970–80 елларда Төмән өлкәсендә нефть-газ р-ннарын үҙләштерү б-н бәйле рәвештә татарлар саны шактый күбәя. Хәзерге вакытта монда Т.р. татарларының Милли-мәдәни автономиясе (рәисе А.М.Колмәмәтов) һәм «Наследие» («Мирас») төбәк татар иҗтимагый оешмасы (рәисе Л.А.Шәмсетдинова), «Умырзая» (Тубылтора а.), «Туган тел» (Ирек а.), «Шатлык» (Ворогушино а.), «Яшьлеккә сәяхәт» (Тубыл; җитәкче-се Р.Н.Яхина) вокаль ансамбльләре; Сәфәргалиевләрнең — «Сәфәр» (Булашово а.), гармунчы Баязитовларның (Прииртышский пос.) гаилә ансамбльләре эшли. *«Сабан туе»*, *Корбан бәйрәме*, Татар мәдәнияте көннәре, төркы халыкларның «Таң йолдызы» балалар иҗаты конкурсы, «Әмәл» («Садака», «Көлчә» дигән атамалары да бар) йола бәйрәме үткәрелә. Районда 7 мәчет (Сабанак, Торбы Йорты, Лайтамаҡ, Кучайлан, Күкрәнде, Тубылтора авылларында, Надцы посёлогында (18 йөздән)) эшли. Тубыл төбәк музее Себер татарлары һәм бохарилар тормыш-көнкүрешенә бәйле экспонатлар б-н таныштыра. Тубылдан 15 *км* да Себер ханлығы башкаласының хәрәбәләре — *Кашлык* (Искәр) шәһәре урнашкан. «Мирас» иҗтимагый оешмасы башлангысында б-н монда *Күчүм ханга* һәйкәл-стела куелган. Ел саен Себер татарлары тарихы һәм мәдәниятенә багышланган «Искәр ҡыены» халыкара фестивале уздырыла. Дин белгече Н.Айтикин, дәүләт эшлеклесе Б.Х.*Мансуров*, әдәбият галиме Ф.М.*Хатипов*, меценат Н.К.*Сәйдуков*, дин һәм ҡәмәгать эшлеклесе Р.*Ибраһимов*, педагоглар Н.*Атнометов*, И.И.*Гиганов*, язучы Я.К.*Зәнкиев*, шағыйрь М.*Юмачиков*, фольклорчы Ф.В.*Әхмәтова*, хирург Р.В.*Жиһаншин*, гамәли бизәлеш сәнгате рәссамы М.В.*Тимергазиев*, тел галимнәре Г.Х.*Әхәтов*, Г.Ф.*Саттаровның* тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге Т.р. б-н бәйле.

ТУБЫЛГЫ́ (Filipendula), роза чәчәкләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 20 гә якын төре билгеле, Төньяк ярымшарның уртача һәм субарктик поясларында таралганнар. ТР терр-ясендә 4 төре: ялангач Т. (F. denudata), дала Т.сы (F. stepposa), карама яфраклы Т. (F. ulmaria), гади Т. (ҙур чикләвеге) (F. vulgaris) бар. Республиканың барлык терр-ясендә очрыйлар. Сулык ярларында, даланланган һәм дымсу болыннарда, куаклыкларда үсәләр. 10 нан 180 *см* га кадәр биеклектәге үсемлек, тамырчасы горизонталь һәм ҙепсыман тамырлы; гади Т.ның тамырларында шарсыман кабарынкылар бар. Сабагы туры, кабыргалы. Яфраклары каурыйсыман теленмә, сабактагылары вак. Чәчәкләре ак, вак, хуш исле, себеркәч чәчәк төркеменә ҡыйналган. Ҡимеше — күпчикләвекчек. Май–июльдә чәчәк ата. Ҡимешләре июль–августта өлгерә. Яфрак һәм яшь ботакларында флавоноид, органик к-талар, каротин, дуплау матдәләре, гликозид, крахмал бар. Халык медицинасында ҙур өстендәге өлеше (каты сабакларыннан кала) бөер һәм үт куыгы авыруларыннан, ш.у. тирләтү чарасы буларак кулланыла. Баллы декоратив үсемлек.



Карама яфраклы тубылгы.

ТУБЫЛГЫ́ КУАГЫ́ (Spiraea), роза чәчәкләр семьялыгыннан куаклар ыругы. Якынча 100 төре билгеле, Төньяк ярымшарда таралганнар. Татарстан терр-ясендә 3 төре бар. Каяу яфраклы Т.к. (S. crenata) ара-тирә барлык районнарда да очрый. Даланланган тау битләрендә, урман буйларында, куаклыкларда үсә. Сары мәтрүшкә яфраклы Т.к.н (S. hypericifolia) һәм уртача Т.к.н (S. media) декоратив үсемлек буларак үстерәләр. Кайвакыт кыргыйланалар. 50–120 *см* биеклектәге үсемлек. Тамыр системасы чук, тирәнгә китми. Яфраклары чиратлашкан, сабакчалы, пычкы тешле, бөтен читле. Чәчәкләре ике жәнесле, ак, чатыр чәчәк төркеменә ҡыйналган. Ҡимеше — коры күп орлыклы табакча. Орлыклары вак, яссы, канатчалы. Май–июньдә чәчәк аталар. Ҡимешләре июльдә өлгерә. Орлыктан, ботак, үрентедән үрчиләр. Каяу яфраклы Т.к. ерым һәм сызаларны нығыту өчен файдаланыла. Барлык төрләре дә баллы. Сары мәтрүшкә яфраклы Т.к. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

ТУБЫЛГЫТА́У, урта гасырлар (11–14 йөзләр) Идел буе Болгар дәүләте шәһәре. Чишмә елгасының сул ярында урнашкан була. Эре бәклек үзәге. Археол. калдыклары Яңа Чишмә р-ны Тубылгытау авылы янәшәсендә саклана. Шәһәрчекнең мәйданы 2 *га* га якын; аның янында 14 йөзгә нисбәтле мөселман зираты урнашкан (1879 да В.А.Казаринов, 1880 дә П.А.Пономарёв, 1963 тә Р.Г.Фәхретдинов һ.б. тарафыннан тикшерелә).

Әд.: Пономарёв П.А. Данные о городах Камско-Волжской Булгарии: Тубулгу-Тау и неопределённые города // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан ун-те. 1893. Т. 11, вып. 4.

И.Л.Измайлов.

ТУБЫЛГЫТА́У авылы, Яңа Чишмә р-нында, Яңа Чишмә авылыннан 16 *км* төньяктарак, Чишмә елгасы буенда. 2010 елда 633 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөғыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. Т. тирәсенә халык Идел буе Болгар дәүләте чорында килеп урнаша (к. *Тубылгытау*). 15 йөздә — 17 йөзнең 1 нче яртысында бу җирләр ташландык хәлдә була, һәм татарлар монда, дингә табыну урыны буларак, вакыт-вакыт килеп торалар. Рус чыганакларында Т. беренче тапкыр 1680 дә Починок по речке Шешма исеме б-н телгә алына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда авыл иске Никиткино, Югары Никиткино (рәсми чыганакларда 1991 гә кадәр файдаланыла) атамалары б-н дә мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, сәүдә б-н шөғыльләнә. 20 йөз башында 2 мәчет (1906 һәм 1909 да төзелә), мәктәп, 7 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл ҡәмәгатенең имана ҙире 2758 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Зирекле волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 нең 10 августыннан — Яңа Чишмә, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1983 нең 26 апреленнән Яңа Чишмә р-нында. Халык саны: 1782 дә — 118 ир-ат; 1859 да — 1137, 1897 дә — 1683, 1908 дә — 1967, 1920 дә — 2008, 1926 да — 1279, 1938 дә — 447, 1949 да — 401, 1958 дә — 314, 1970 тә — 315, 1979 да — 204, 1989 да — 581, 2002 дә — 716 кеше. Т. янында 14–15 йөзләрдәге эпиграфик истәлекләр — кабер ташлары саклана.

ТУГА́Й, *елга үзәннәре* төбенең ташу вакытында су астында кала торган өлеше. Су биеклеге күтәрелгәндә елга юлының кырыйга авышуы һәм аллювий туплану нәтиҗәсендә барлыкка килә. Т.ның түбәнге өлешен төзүче ком-вакташ-чуерташлы елга юлы аллювиенең һәр җирдә булуы элегрәк Т.ның һәрбер участогында елга юлы узганлыкны күрсәтә. Ташу вакытында елга юлы кырыйга авышканнан соң, елга юлы аллювие үзе гори-зонталь-катламлы юка утырмалардан — вак

бөртекле ком, комсыл балчык, ләмнән тору - чы тугай аллювие б-н каплана. Ташу биеклеге тугай аллювие аккумуляциясенең һәм Т. өслегенең иң югары чиге булып хезмәт итә. Елга юлының иң тирән урыннары — плёслар төбе елга юлы аллювие аккумуляциясенең түбәнге чиге булып тора. Шулай итеп, Т.ның вертикаль киселешендә 2 горизонтны билгелиләр: түбәнге — елга юлы, югары — тугай үзе. Урыны-урыны б-н алар арасында карасу ләм линзалары — элеккеге ел - га юлындагы күл утырмалары ята. Т. төзүче аллювийның нормаль гомуми калынлыгы плёсларның уртача тирәнлеге һәм елганың суы иң аз вакытындагы тигезлегенә карата Т.ның уртача биеклеге суммасына тигез. Татарстан елгаларының барысының да Т.е бар, аларның киңлеге авышу зурлыгына бәйле. Иң киңнәре — Идел һәм Кама Т.лары (15–20 *км*), хәзерге вакытта алар тулысы б-н яки өлешчә Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычлары астында калды. Уртача һәм кече елгаларда Т.ның киңлеге, гадәттә, 1,5–2 *км* дан артмый. Т. Идел һәм Каманың суы иң аз вакытындагы тигезлеге өстеннән 7,5–8,5 *м* биектәрәк ята, аллювийның калынлыгы 20–23 *м* тәшкил итә. Уртача (Зөя, Чишмә, Зәй, Ык, Иж) һәм кече елгаларда ташу биеклеге зур булмаганлыктан, иң аз сулы тигезлектән Т. ярашлы рәвештә 3–6 һәм 2–3 *м* га күтәрелә. Елга юлыннан үзән сөзәклегенә (яки тугай өсте киртләченә) таба юнәлештә Т. рельефы элементларын билгелиләр: су юлы сайлыгы, елга юлы яны валы, төп Т. (яссы яки калкулыклы), терраса яны иңкүлеге. Кориолис тизләнеше (Бәр законы) йогын - тысында елга юлларының уң якка авышуы сәбәпле Идел, Кама, Вятка кебек зур елгалар - да сулъяк Т.лар өстенлек итә. Алар ш.у. Идел, Каманың аеруча зур кушылдыкларының: Зөя, Чишмә, Зәй, Ыкның түбәнге агымында үсеш алганнар. Зуррак елгаларда уң һәм сулъяк яр Т.лары азмы-күпме тигез дәрәҗәдә. Урманнарны кисү һәм җирләрне сукалау язгы ташуларны көчәйтә һәм китерелмәләрнең агышын арттыра, бу исә уртача һәм кече ел - галарда тугай аллювиенең күпләп туплануына китерә. Т.ның шактый өлешен болыннар били, алар яхшы печәнлек җирләр булып са - нала. Төп Т.ларда һәм терраса яны иңкүлек - ләрендә урыны-урыны б-н яфраклы урман - нар һәм куаклыклар сакланган. Т.ның елга юлы аллювиаль утырмалары: ком, вак чуер - таш һәм чуерташ төзелеш материалы буларак файдаланыла.



Алабуга шәһәре янында Кама елгасы тугае.

Әд.: Сементовский В.Н. Закономерности морфологии платформенного рельефа. К., 1963; Геология Татарстана: Стратиграфия и тектоника. М., 2003; Мозжерин В.И., Курбанов С.Г. Деятельность человека и эрозионно-русловые системы Среднего Поволжья. К., 2004.

А.П.Дедков.

ТУГА́Н-БАРАНО́ВСКИЙ Й.Л.АР, тарихчылар, язучылар, җәмәгать эшлеклеләре. Польша-Литва татарларыннан. Нәсел фамилиясе 1410 елда татар бәге Туган поляк княгинясы Барановскаяга өйләнгәннән соң башлана. Туган атлы гаскәр б-н поляклар, литвалылар һәм руслар б-н бергә немец рыцарьларына каршы Грюнвальд сугышында катнаша (1410). Поляк чыганакларында Т.-Б. берен - че тапкыр 15 йөз уртасында искә алына. **Да - вид** Т.-Б. 1662 дә шведлар б-н сугышта катнаша; аны «шведлар, тотып, диңгезгә алып китәләр, әмма үзен ярга чыгарырга ирек бирми, иптәшләре б-н дошман ягына бәреп керә... бөтен гаскәр күз алдында... тантаналы рәвештә кайтып керә». Поляк шагыйре А.Мицкевичның «Свитязь» балладасында Свитязь күле буенда замок һәм шәһәр биләгән Туган бәкләр турында язган булуы ихтимал (1821). Әлеге күл янында (хәзер Белоруссия Респ-касының Гродно өлкәсендә) Тугановичи дип аталган торак пункт бар. Польшадагы 1830 һәм 1863 тәге күтәрелешләрдә катнашканнары өчен кенәз титулыннан мәхрүм ителәләр. Баш күтәрүчеләр арасында аеруча **Якуб** Т.-Б. таныла (1863 тәге күтәрелеш җитәкчеләренең һәм оештыручыларының берсе), кыюлыгы һәм батырлыгы өчен аны Шайтан Туган дип тә атыйлар. Линтварис тирәсендәге (Лит - ва) сугышта ул, патша гаскәре ягына күчкәне өчен, үзенең бертуганын чабып үтерә.

Михаил Иванович Т.-Б. (8.1.1865, Харьков губ. — 8.1.1919, Одесса ш. тирәсе), икътисадчы, «легаль марксизм» лидерларының берсе. 1883–86 да Петербург ун-тының табигыять фәннәре бүлегендә В.И.Ленинның абыйсы А.И.Ульянов б-н бер курста укый. 1886 да Н.А.Добролюбовның вафатына 25 ел тулу уңаеннан демонстрация оештыруда катнашканы өчен университеттан куыла һәм С.-Пе - тербургтан сөрелә. 1888 дә Харьков ун-тын тәмамлый. 1895 тән Петербург ун-тының политэкономия кафедрасында приват-доцент, 1899 да, ышанычсыз саналып, ун-ттан чыга - рыла. 1901–05 тә Полтава губернасында сөр - гендә була. 1905 тә пед. эшчәнлеккә кире кай - та: Петербург ун-тында, Югары хатын-кыз - лар курсларында, Петербург политехник ин-тында (1913 тән проф.), А.Л.Шанявский халык ун-тында (Мәскәү) укыта. Кооперация хәрәкәтендә актив катнаша, аңа берничә фәнни хезмәт багышлый. 1909 дан «Вестник кооперации» ж-лын җитәкли (Мәскәү). Кадетлар партиясе әгъзасы. Окт. рев-циясен кабул итми. 1917 нең ахырын - да — 1918 нең башында Украина Үзәк Рада-



М.И.Туган-Барановский.

сының финанс министры. Шуннан соң актив сәяси эшчән - лектән ераклаша, Киев ун-тында укыта, юридик ф-т деканы була. Үзәк кооперация Украина ком-ты һәм Украина икътисадчылар фәнни җәмгыяте рәисе, «Украинска кооперация» ж-лы мөхәррире (Киев). 1918 нең ахырында кооперация ин-тын оештыру тәкъдиме б-н чыга, аның концепциясен эшли (хәзер М.И.Туган-Барановский исем. Донецк икътисад һәм сәүдә ун-ты). Украина ФАн оештыручыларның берсе, аның социаль-икътисад бүлеге рәисе, акад. (1919). 1919 да Украина Директориясе тарафыннан дипломатик миссия башында Парижга җибәрелә; юлда вафат була. Галимнең «Хәзерге Англиядә сәнәгать кризислары» («Промышленные кризисы в современной Англии», СПб., 1894) беренче зур фәнни хезмәте дөньяга таныта, Россиядә (1900; 4 нче басма, 1997) һәм чит илләрдә (Германия, 1900; 2 нче басма 1969; Франция, 1913; Япония, 1931; 2 нче басма 1972; АКШ, 1954; Англия, 1954) берничә тапкыр басыла. Хезмәттә бәян ителгән үзенчәлекле кризислар тео - риясе алга таба кризисларның барлыкка килүен һәм алардан чыгу юлларын (мәс., Россиядә 1910 дагы кризис) фаразларга мөмкинлек тудыра. Либераль народниклар б-н бәхәсләрдә галим Россиядә 19 йөз ахырында капитализмның реаль чынбарлык икәнен исбатлый, аның прогрессив үсеш булуын һәм тарихи бәйлелеген ассызыклый. 1898 дә Мәскәү ун-тында «Үткәндә һәм хәзерге вакытта рус фабрикасы» («Русская фабрика в прошлом и настоящем») темасына докторлык диссертациясе яклый (СПб., 1898; 8 нче басма, 1997; Германия, 1900; АКШ, 1970). Диссертация народниклык идеяләрен кире кагуда зур роль уйный. 1899 да «К.Марксның абстракт теориясенең төп хатасы» («Основная ошибка абстрактной теории К.Маркса») хезмәтен бастыра, анда марксизмның бәя һәм хак турындагы күп кенә постулатларын шик астына куя. Алга таба бу идеяләрне «Марксизмның теоретик нигезләре» («Теоретические основы марксизма», СПб., 1905) һәм «Үзенең тарихи үсешендә заманча социализм» («Современный социализм в своём историческом развитии», СПб., 1906) хезмәтләрендә үстерә, аларда марксизм б-н араны тәмам өзә, социалист булып кала. Аның социализмны аңлавы марксистик һәм большевистик карашлардан сизелерлек аерыла. Галим сәяси көрәштә этиканың роленә зур игътибар бирә һәм «кеше шәхесенең абсолют кыйммәте» турындагы тәгълиматны алып ташлаган очракта, «безнең заманның барлык демократик таләпләре гади сафсата булып кына калачак» дип саный. Киләчәктәге соц. дәүләттә чиктән тыш үзәкләштерүдән шикләнә, бу үзәкләштерү шәхес хокукларын чикләүгә китерергә мөмкин, дип исәпли.

Михаил Михайлович (21.11.1902, Полтава губ. — 5.10.1986, Саратов ш.), язучы. Прага ун-тының юридик ф-тын тәмамлый (1924). 1919–26 елларда эмиграциядә: Белградта, Прагада, 1925–26 да Парижда яши. Белградта әсерлар оешмасына керә, Прагада Б.Савинков, М.Цветаева б-н таныша. Парижга күченеп килгәннән соң, Франция коммунистлар партиясенә керә. Рус эмигрантлары арасында агитация алып барган өчен француз полициясе тарафыннан кулга алына һәм 1926 ның июлендә СССРга сөрелә. Ленинград, Мәскәү, Харьков, Казанда совет матбугаты оешмаларында эшли. Бөек Ватан сугышында катнаша. Рус эмиграциясе турында «Чик сызыгы артында» («За чертой», 1928) повестен, сугыштан соңгы Берлинның беренче көннәренә багышланган «Дуслыкның башлануы» («Начало дружбы», Сталинград ш., 1956) романын, Петроградтагы 1917 елгы Февр. рев-циясе турында «Таң алдыннан әңгер-меңгер» («Предрассветные сумерки», Сталинград, 1959) романын һ.б.ны бастыра. Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары б-н бүләкләнә.

Җучи Михайлович (18.9.1948, Вильнюс – 5.1.2015, Волгоград ш.), тарихчы, тарих фән.д-ры (1990), проф. (1993). Саратов ун-тын тәмамлый. 1983 елдан Волгоград ун-тында, 1992–2007 дә яңа һәм хәзерге заман тарихы каф. мөдире. Хезмәтләре Бөек Француз рев-циясе, бонапартизм тарихына карый. «Наполеон һәм республикачылар» («Наполеон и республиканцы», Саратов, 1980; 2 нче басма Волгоград, 2005), «Бонапартизмның яралгысы» («У истоков бонапартизма», Саратов, 1986), «Буржуазия һәм Бөек Француз революциясе» («Буржуазия и Великая Французская революция», М., 1989), «Наполеон һәм хакимият» («Наполеон и власть», Балашов, 1993), «Михаил Иванович Туган-Барановский» (Донецк, 2002; 2 нче басма, Донецк, 2009) китаплары авторы. РФнең Мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре. Медаль б-н бүләкләнә.

Әд.: Хрущов-Сокольников Г.А. Грюнвальдский бой, или Славяне и немцы: В 2 ч. СПб., 1910; Туган-Барановский М.И. К лучшему будущему. М., 1996; Думин С. Беларускія татары. Мінск, 1993; Herbarz rodzin tatarskich w Polsce. Opzacowal st. Dziadulewicz. Wilno, 1929; Amato S. Ricerca bibliografica su M.I. Tugan-Baranovskij. Firenze, 1980.

Д.М.Туган-Барановский.

ТУГА́Н-ТУМАЧАЛЫ́К, КОДА́-КОДАГЫЙЛЫ́К, тарихи шартларга бәйле рәвештә бер ата-анадан туган, бер нәселдән чыккан кешеләр арасындагы һәм яшьләр никахлашканнан соң аларның ата-аналары, туганнары арасында барлыкка килгән туганлык мөнәсәбәте (никах туганлыгы) терминнары системасы. Татарларда Т.-т., к.-к. һәм туганлык мөнәсәбәтләрен белдерүче терминология нигезендә гомумтөрки принциплар ята: кан кардәшлекне һәм ир яки хатын ягыннан туганлыкны төгәл аеру, туган-тумачаларны һәм кода-кодагыйларны яшькә карап аерып йөртү, төп нәсел сызыгының (ата-ана һәм балалар, борынгы һәм яшь буын) ян тармаклар б-н (ир һәм кыз туганнар, абый-апалар, ата-ана ягыннан бертуганнарның уллары яки кызлары) бергәлеге, кан кардәшлекнең ата яки ана ягына бүленмәве (керәшеннәр һәм Урал буе татарларының кайбер төркемнәреннән тыш), төрле дәрәҗәдәге туганлык мөнәсәбәтендәге кешеләрнең тулы бер төркемен бер сүз б-н атау. Кайбер төрки телләрдән (кыргыз, казакъ, көнчыгыш төрки һ.б.) аермалы буларак, татар телендә кыз туганны белдерү өчен кулланылучы терминнар сөйләүченең жәнесенә бәйле түгел. Туганлык системасы, урал-алтай телләре төркеме халыкларына хас булганча, бездә дә буыннар баскычын күздә тота: бер буынның кече тармагы үзеннән түбәндәге буынның өлкән тармагы б-н бер төркемгә берләшә. Хәзерге татар телендә бу күренешнең төгәл терминологик билгеләмәсе юк. Буыннар атамасы б-н мәгънәсе буенча туры килә торган терминнар буынның югары баскычында торучы индивидка беркетелә: ата — аталар буыны вәкиле, ә аның олы абыйсы бабайлар буынына карый. Димәк, абыйга һичкайчан «ата» дип, атага «ага» дип әйтелми. Буынның түбәнге ботаклары индивидларын белдерү өчен тасвирлы яки башкаларыннан ясалган терминнар (этинең энесе, бабайның энесе, зур әтәй, зур әти һ.б.) кулланыла. Татар телендә буын-нар күчешен һәм аларның чикләрен аеру эндәшү формаларында шактый системалы рәвештә чагыла. Мәс., абзый яки мишәр сөйләшендәге дәдәй сөйләүченең әтисенең энесенә карата кулланыла (ягъни аталар буынына мөнәсәбәттә); сөйләүченең әтисенең абыйсына һәм бабасының энесенә (ягъни бабайлар буынына мөнәсәбәттә) эндәшү формасы башка: дәдәй яки бабай, абыз дәдәй. Татар телендә Т.-т., к.-к. терминологиясенең тагын бер үзенчәлеге — никах туганлыгының ике төрле тел формасы б-н белдерелүе: 1) гомуми әдәби телдә, мишәр диалектында, Касыйм, Пермь һәм Себер татарлары сөйләшләрендә никах аркылы туганлык мөнәсәбәте терминнары кан кардәшлекне белдерүче терминнарга «кайын» алкушымчасы өстәлеп ясала, ике якның да ата-анасына «кайынана» һәм «кайната» диелә; 2) урта диалектта исә (Татарстан, Башкортстан, Оренбург ягында) кия үнең ата-анасына мөнәсәбәт «бий» алкушымчасы аркылы белдерелә — «бийата» һәм «бийана», ә кияү исә хатынының ата-анасына «бабай» һәм «әби» дип мөрәҗәгать итә. Кайбер терминнар аерым *сөйләшләрдә* үз әдәби эквивалентларыннан семантик планда аерыла, мәс., «балдыз» термины *көнчыгыш диалектта* ирнең яки хатынның се ңелләренә карата кулланыла, Пермь, Сафакүл, Эчкен сөйләшләрендә хатынның сеңлесенә карата гына түгел, хатынның энесенә карата да әйтелә. Хәзерге этапта азсанлы гаиләгә күчү, туганлык (бигрәк тә никах туганлыгы) терминологиясе туганлык мөнәсәбәтләре тараю б-н бәйле рәвештә татарларның барлык төркемнәрендә дә шактый кыскара.

Әд.: Ольдерогге Д.А. Основные черты развития систем родства // Советская этнография. 1960. № 6; Рамазанова Д.Б. Термины родства и свойства в татарском языке: В 2 кн., К., 1991.

ТУГА́Ш авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 19 *км* төньяк-көнбатыштарак, Ык елгасы буенда. 2010 елда 294 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, китапханә. Мәчет. 1735 кә кадәр нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы мишәрләр катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп, су тегермәне, ашлык саклау-сату һәм бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1665 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Иректе волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1859 да — 274, 1870 тә — 503, 1897 дә — 856, 1906 да — 960, 1920 дә — 1063, 1926 да — 742, 1938 дә — 814, 1949 да — 551, 1958 дә — 461, 1970 тә — 469, 1979 да — 392, 1989 да — 334, 2002 дә — 295 кеше.

ТУГЪЛЫ́ ХУ ЖА́ (Тугълы Хуҗа Хәрәзми) (14 йөз), Алтын Урда чоры төрки-татар шагыйре. *Газәл* жанрында язылган ике шигыре б-н мәгълүм, шигырьләрендә автор үзен Тугълы дип атый. Әсәрләренең берсе «Ядкәрнамә»гә, икенчесе «Китабе Гөлестан бит-төрки»гә кергән. Аңа ияреп, Сәйф Сараи назыйрә язган.

Әд.: Сараи С. Гөлестан. Лирика. Дастан. К., 1999.

ТУГЪРА́, җирбиләүчелек тамгасы, геральдик билге. Шәрекъ илләрендә — 11 йөздән, Алтын Урдада 14 йөздән кулланылышта. Хан һәм идарәче ыруларның документларга, тәңкә һәм әламнәргә төшерелә торган дәүләт гербы булып тора. Алтын Урдада хакимлек Т.сын дәүләт актлары һәм хатларга кую хокукына хан һәм 4 карачыбәк ия була. Җирбиләүче аксөякләр өчен Т. геральдик билге ролен үти.

И.Л.Измайлов.

ТУГЪЧИ́Н, урта гасырлар Идел буе Болгар дәүләте шәһәре. Кама елгасы тамагына якын булган көнбатыш Кама буенда урнашкан. Эре бәклек үзәге. Ныклы ныгытмалары була. Рус елъязмаларында рус гаскәрләренең Биләр шәһәренә явы (1183) б-н бәйле рәвештә телгә алына (алар Тугъчинны өч көн буе уңышсыз камап торалар). Археол. калдыклары Куралово шәһәрлегендә нисбәтләнә.

Чыг.: Полное собрание русских летописей. М., 1962. Т. 1.

И.Л.Измайлов.

ТУГЫ́З авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 38 *км* төньяктарак, Юкәче елгасы буенда. 2010 елда 188 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1680 нән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.да мәчет була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 566,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Лыябаш-Келәүш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән Мамадыш р-нында. Халык саны: 1859 да — 196, 1897 дә — 405, 1908 дә — 418, 1920 дә — 502, 1926 да — 445, 1949 да —

230, 1958 дә — 184, 1970 тә — 191, 1979 да — 168, 1989 да — 198, 2002 дә — 217 кеше.

ТУГЫЗЫНЧЫ́ ГЫЙНВА́Р, к. *Тенеш*.

ТУГЫЗЫНЧЫ́ КАЗА́Н СОВЕ́Т ШӘРКЫ́Й ХАЛЫКЛА́Р КАВАЛЕ́РИЯ КУ́РСЛАРЫ, 1919 елның декабрендә 1 нче Казан Совет кавалерия курслары җирлегендә оеш - тырыла. Курс җитәкчеләре: А.Г.Нагаев, А.Романович. Комиссарлар: Х.З.Габидуллин, М.Ш.Шаһиәхмәтов. Беренче чыгарылыш 1920 нең 1 апрелендә була (34 кеше). Барлы - гы 411 командир әзерләнә. 1922 нең май–сентябрендә алар лагерь җыеннарында шөгыль - ләнәләр һәм *Уналтынчы үрнәк мөселман ук - чы командирлар мәктәбе* б-н бергә Төркестан - да сугыш хәрәкәтләрендә катнашалар. 1923 нең гыйнварында аларның икесеннән *Казан - да мөселман командирларының берләшкән курслары* оештырыла.

И.Г.Гыйззәтуллин.

ТУДА́ МӘНГҮ́ ХАН (?–1287), Алтын Ур - да ханы (1282 елдан). Батый хан оныгы. Тә - хеткә, бертуганы *Мәнгу Тимер хан* вафатын - нан соң, әмир Нугай ярдәме б-н утыра. Акча суктыра. Ихтыярсыз, йомшак табигатьле идә - рәче була. Ханлык б-н чынлыкта Нугай бәк, ш.у. Мәнгу Тимер һәм Тарбу уллары ха - кимлек итә. Соңыннан Т.М.х. алар тарафын - нан тәхеттән төшерелә.

Әд.: Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960.

ТУЕМБА́Ш авылы, Кукмара р-нында, шә - һәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 12 *км* төньяктарак, Киров өлкәсе б-н чиктәш ур - нашкан. 2010 елда 593 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — сарык асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, ки - тапханә. Мәчет. 1678 дән Тома елгасы буен - дагы Пүчинкә буларак мәгълүм. Рев-циягә ка - дәрге чыганакларда Ураськино исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысын - да халкы дәүләт крәстияннәре катлавына ке - рә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, мәчет була. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең има - на җире 1604 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Кошки волостенда, 1920 дән ТАССРның — Арча, 1928 дән Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 фев - раленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварын - нан Кукмара р-нында. Халык саны: 1859 да — 740, 1905 тә — 1329, 1920 дә — 1317, 1926 да — 1026, 1938 дә — 951, 1949 да — 649, 1958 дә — 720, 1970 тә — 706, 1979 да — 660, 1989 да — 453, 2002 дә — 531 кеше.

ТУЕ́Р авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһә - реннән 37 *км* төньяктарак, Игәт елгасы буен - да. 2010 елда 59 кеше (татарлар) яши. Халкы - ның төп шөгыле — кырчылык. 18 йөз уртасы - на кадәр нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Таирпова исеме б-н дә мәгъ - лүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы асабалар катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, чабата үрү, агач күмере сату б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп, ба - калея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгате - нең имана җире 1186 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Күз - кәй волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзә - лә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1984 нең 4 июненнән Тукай р-нын - да. Халык саны: 1816 да — 37 ир-ат; 1834 тә — 92, 1859 да — 227, 1870 тә — 250, 1884 тә — 316, 1906 да — 434, 1913 тә — 503, 1920 дә — 533, 1926 да — 392, 1938 дә — 271, 1949 да — 258, 1958 дә — 220, 1970 тә — 163, 1979 да — 131, 1989 да — 66, 2002 дә — 62 кеше.

ТУЗГА́Н ТОРАКНЫ́ БЕТЕРҮ́ ПРОГРА́ММАСЫ, Татарстан Республикасында. ТР Президенты М.Ш.Шәй - миевнең «Тузган торакта яшәүче граждан - нарның торак шартларын яхшырту һәм туз - ган торак кварталларын реконструкцияләү чаралары турында»гы Указы б-н 1995 елның октябрендә кабул ителә. 1996–2004 елларга исәпләнә һәм 46,75 мең гаиләне бөтен уңай - лыклары булган торакларга күчерүне күздә тота. Программаны 1995 тә ТР Президенты каршында төзелгән Дәүләт торак фонды тор - мышка ашыра. Беренче тапкыр буларак фи - нанслауның төп чыганагы сыйфатында бюд - жеттан тыш акчалар — респ-ка пр-тиеләре кеременең 1% ы җәлеп ителә. Шактый сум - маларны «Татнефть» (1 млрд. сум), «Түбән - каманефтехим» (300 млн.), «Татэнерго» (171 млн.), «Түбәнкамашин» (99 млн.), «Ка - заноргсинтез» (84 млн. сум) АҖләре күчерә. Т.т.б.п.н тормышка ашыру барышында то - рак төзелеше фондына 20,3 млрд. сум акча ке - рә; инвестицияләр 18,8 млрд. сум тәшкил итә. 52,8 мең фатир төзелә, шуның 42,6 ме - ңе тузган торакта яшәүче гаиләләрне күчерү өчен бушлай бирелә (к. табл.). Моннан тыш, инженерлык-коммуникация корылмалары үстерелә, социаль һәм мәдәни-көнкүреш объ - ектлары: мәктәпләр, балалар бакчалары, по - ликлиникалар һ.б. төзелә. 1996–2004 тә фай - даланыга тапшырылган күп фатирлы йорт - ларның гомуми мәйданында дәүләт торак фондының өлеше 30% артыграк була. Төзе - леш, кагыйдә буларак, квартал саен планлаштырыла. Казанда 2 яңа — Азино һәм Яңа Савин эре торак массивлары калкып чыга. Тузган торакны бетерү нәтиҗәсендә тулаем республика буенча торак фондының тузу дә - рәҗәсе 60% тан 40% ка кадәр кими, бу исә то - рак фондын карап тотуга, агымдагы һәм капи - таль ремонт өчен бюджет акчасына ихтыяҗ - ны сизелерлек киметә, торак-коммуналь хуҗа - лык реформасы үткәрү перспективасын ача.





Тузган торакны бетерү программасы буенча Казанда төзелгән торак йортлар: 1. Челюскин урамы; 2. Ф.Әмирхан проспекты.

Т.т.б.п.н уңышлы тормышка ашыру торак төзелешен алга таба үстерүгә һәм респ-када яңа проект — социаль ипотеканы тормышка ашыруга нигез була. 2005 тән респ-када торак төзелешен үстерү программасы тормышка ашырыла, Социаль ипотека программасы — яшь гаиләләргә һәм бюджет өлкәсендә эшләү - челәргә торак сатып алуны финанслаганда өстәмә ташламалар ясау — шуның бер өлешен тәшкил итә. «Яшь гаиләләрнең торак шарт - ларын яхшыртуга дәүләт ярдәме турында» ТР Законы кабул ителгәннән соң, 2005 тә финанслауның гомуми күләме 145 млн. сум тәшкил итте.

Социаль ипотека программасы 2019 га кадәр исәпләнгән; программаның планлаштырыл - ган инвестицияләр күләме — 244519 млн. сум (2004 елгы бәяләрдә). Респ-ка хөкүмәте тара - фыннан торак шартларын яхшыртуга мохтаж гражданнарны исәпкә алу, торак бирү тәртип - ләрен билгеләүче норматив актлар расланган.

1996–2004 елларда ТРда Тузган торакны бетерү программасы үтәлешенең йомгаклары

Еллар	Яшәүчеләре күчерелгән тузган торакның гомуми мәйданы, $м^2$	Барлык уңайлыклары булган йортларга күчерелгән		Бирелгән торакның гомуми мәйданы, $м^2$
		гаилә	кеше	
1996	91468	3534	8678	179943
1997	96473	3505	10152	199363
1998	112155	5009	13031	263148
1999	122826	4650	13045	253957
2000	153804	5189	14446	282642
2001	189438	5149	14190	291898
2002	135919	4906	13072	277709
2003	133661	4854	12577	267997
2004	472627	5769	15256	327108
Барысы:	1508371	42565	244464	2343765

ТУЗГАНА́К (Taraxacum), оешма чәчәкләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 1000 нән артык төре билгеле, Евразия, Америка, Австралия, Төньяк Африкада таралганнар. Татарстан терр-ясендә 25 төре бар. Болыннарда, далаланган тау битләрендә, тимер юл өемнәре буенда, чүп үләне буларак яшелчә һәм җиләк-җимеш бакчаларында, буш урыннарда үсәләр. 5–30 *см* биеклектәге үсемлек. Тамыры үзәк, итчел, туфракта тирәнгә китә (60 *см* га кадәр). Сабагы яфраксыз, куыш, сабак очында бер (кайвакыт ике) күпчәчәкле кәрзинле. Яфраклары тамыр яны таралгысында, тешле-калаксыман яки каурыйсыман бүленмә. Чәчәкләре ике женесле, сары, сабак очындагы берле кәрзиннәргә җыйналган. Җимеше — ак йомшак төкчәләрдән торучы борынчыклы һәм бүрекчәле орлыкча, ерак араларга күчәргә сәләтле. Үсемлекнең барлык өлешләре дә сөтчел сыекчалы. Май–июльдә чәчәк ата. Җимешләре июнь–августта өлгерә. Орлыктан үрчиләр. Кара орлыклы Т. (T. euoplocarpum), карасу Т. (T. tenebricans), пумаласыман Т. (T. rectinatiforme) һ.б. фәнни һәм халык медицинасында файдаланыла. Тамырларында гликозид, инулин, флавоноид, органик к-талар, тимер, микроэлементлар бар. Тамырларыннан ясалган препаратлар аппетитны ачу һәм ашкайнату тракты эшчәнлеген яхшырту өчен кулланыла; халык медицинасында — бәвел куыгы, бөер авырулары вакытында һәм какырык куптару чарасы; сөтчел сыекчасы сөялләрне бетерүгә ярдәм итә. Баллы үсемлек. Яшь яфраклары ризык әзерләүдә файдаланыла. Көзге Т. (T. serotinum) ТРның Кызыл китабына кертелгән.



Дару тузганагы.

ТУЗМӨХӘММӘ́ТОВ Рәис Габделхак улы (29.4.1926, Казакъстан АССР, Семипалатинск ш. — 24.6.1996, Мәскәү), хокук белгече, юридик фән. д-ры (1976), проф. (1982). СССР Тышкы эшләр министрлыгының Мәскәү халыкара мөнәсәбәтләр ин-тын тәмамлый (1950). 1954–56 елларда Таиланд Корольлегендә совет миссиясе пресс-атташесы. 1958–63 тә Үзбәкстан ССР ФАнең Фәлсәфә һәм хокук ин-тында, 1968–79 да СССР ФАнең Дөнья икътисады һәм халыкара мөнәсәбәтләр ин-тында (Мәскәү). 1979–81 дә П.Лумумба исем. Халыклар дуслыгы ун-тының (Мәскәү), 1981–83 тә Әфганстан Халык Демократик партиясе ҮК каршындагы Иҗтимагый фәннәр ин-тының (Кабул) халыкара мөнәсәбәтләр каф. мөдире. 1984 тән РФАнең Дәүләт һәм хокук ин-тында (Мәскәү). Хезмәтләре халыкара хокукны, Совет-Таиланд һәм Совет-Иран мөнәсәбәтләре проблемаларын өйрәнүгә; дәүләтләрнең — Кушылмау хәрәкәте әгъзалары һәм үсеп баручы илләрнең халыкара хөкүмәтара оешмалары эшчәнлегенең халыкара хокук аспектларына карый. Аның «Милли суверенлык» («Национальный суверенитет», М., 1963), «Яла ягучыларга җавап: Урта Азия халыкларының үзбилгеләнүе һәм халыкара хокук» («Ответ клеветникам: Самоопределение народов Средней Азии и международное право», М., 1969), «Үсеп баручы илләр дөнья сәясәтендә: Үсеп баручы илләрнең халыкара хөкүмәтара оешмалары» («Развивающиеся страны в мировой политике: Международные межправительственные организации развивающихся стран», М., 1977) хезмәтләре 20 йөздә халыкларның милли суверенлыгы, тигезлеге һәм үзбилгеләнүе мәсьәләләренә багышлана. Т. — «Халыкара хокук курсы» («Курс международного права», т. 1–7, М., 1964–93) авторы, «Африка бердәмлеге оешмасы» («Организация африканского единства», вып. 1–3, М., 1970–78), «Кушылмау хәрәкәте буенча документлар һәм материаллар» («Движение неприсоединения в документах и материалах» (вып. 1–4, М., 1975–85) документ тупланмаларының мөхәррире.

Х е з м.: Советско-иранские отношения (1917–1921). М., 1960; Организация африканского единства. М., 1965; Движение неприсоединения и международное право. М., 1989.

Е.Б.Долгов.

ТУ́ИШЕВ Йосыф Әхмәтҗан улы (25.10.1906, Пенза губ. Пенза өязе Оз а. — 25.1.1984, Казан), педагог, халык мәгарифе эшлеклесе, пед. фән. канд. (1954). Пенза пед. техникумын тәмамлый. 1926–28 елларда техникум каршындагы үрнәк башлангыч мәктәптә укыта. 1931 дә Н.К.Крупская исем. коммунистик тәрбия академиясен тәмамлый (Мәскәү). Татар пед. техникумында, Татарстан халык мәгарифе кадрларының квалификациясен күтәрү ин-тында пед. фәнен укыта, ТАССР Мәгариф халык комис-тында эшли. 1937 дә советка каршы эшчәнлектә гаепләнеп кулга алына, бераздан азат ителә. 1941 дән Казан ның 9 нчы Хәрби-Һава көчләре махсус мәктәбе башлыгы. 1945–67 дә Казан пед. ин-ты ректоры, 1967–74 тә шул ин-тның пед. кафедрасында эшли. Т. җитәкләгән елларда ин-тның матди базасы, уку-укыту һәм фәнни потенциалы (шул исәптән татар тел белеме һәм әдәбият белеме) уңышлы үсә. Т.ның 1950 ләр уртасында фәннәрне татар телендә укытуны кертү омтылышлары, партия органнары каршы булу сәбәпле, уңышка ирешә алмый.

Х е з м.: Развитие народного образования в Татарской АССР. К., 1959; Общественно-педагогическая деятельность Габдуллы Тукая. К., 1963.

Әд.: Юсеф Ахметзянович Туишев. К., 2007.

ТУ́ИШЕВ Ростислав Иванович (18.7.1949, Казан), хирург, сәламәтлек саклау өлкәсе оештыручысы, ТРның һәм РФнең атказанган табибе (1999, 2005), мед. фән. д-ры (1990), Россия мед.-техн. фәннәр академиясе (РМТФА) академигы. Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1973), Казан шәһәре 15 нче хастаханәсенең ашыгыч хирургия бүлеген дә табиб-хирург булып эшли. 1981–87 елларда 15 нче Ашыгыч мед. ярдәме хастаханәсенең баш табибе, 1987–91 дә Казан шәһәре сәламәтлек саклау бүлеге мөдире. 1991–2004 тә Төбәкара клиник диагностика үзәге ген. директоры. 2004–08 дә ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының инновацион һәм бюджеттан тыш үсеш идарәсе башлыгы, 2008–10 да министр киңәшчесе, 2010 нан «ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының диспетчерлык үзәге» дәүләт учреждениесе директоры. ТРның фән һәм техника өлкәсендәге дәүләт бүләге лауреаты (2012). Фәнни хезмәтләре ашыгыч мед. ярдәме хастаханәсен, сугыш ветераннары өчен махсус поликлиника, студентлар поликлиникасын оештыру; Казанда эре төбәкара мед. үзәге төзетү һәм җиһазлауга, ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының РФдәге күп кенә системалы инновацион технол. проектларга башлангыч биргән, Россиядә беренче Диспетчерлык үзәген булдыруга багышлана. ТРның мед. хезмәткәрләре ассоциациясе идарәсе рәисе (1990).

Х е з м.: Организация больницы скорой помощи (БСМП) в г.Казани. К., 1986; Организация первой в России поликлиники для ветеранов войн. К., 1989; Создание, строительство, оснащение, организация Межрегионального клинико-диагностического центра (МКДЦ) в г.Казани. К., 1999; Межрегиональный клинико-диагностический центр // Вестник межрегионального клинико-диагностического центра. К., 2002 (автордаш); Организация мед. помощи больным с хирургической сосудистой патологией головного мозга в Казани: методические рекомендации. К., 2003 (автордаш).

ТУ́ИШЕВ Фәйзулла Кәбир улы (19.12.1884, Самара губ., Ставрополь өязе Иске Төгәлбуга а., башка мәгълүматлар буенча шул ук өязнең Мәләкәс посады, хәзер Ульянов өлкәсенең Димитровград ш. — 15.1.1958, Казан), концерт гармуннарында уйнау остасы, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1934), ТАССРның халык артисты (1944). Иҗат эшчәнлеген Т. 1900 елда ярминкә һәм цирк тамашаларында башлап җибәрә; шул вакытта, халык музыкантларына хас булганча, гармунда уйнау күнекмәләрен үзләштерә, соло концертлар б-н, ш.у. цирк һәм артистлар труппалары б-н гастрольләрдә йөри. 1937 дән Татар филармониясе солисты. Бөек Ватан сугышы елларында концерт бригадалары эшендә актив катнаша. Татарча концертлар бирүче беренче кеше. Ул тамашачыга төрле төзелешле концерт гармуннарында үзенчәлекле башкару формасын тәкъдим итә. Т. бик яхшы муз. хәтергә ия була, татар халык көйләрен, ш.у. музыка уен коралларында башка-



Ф.К.Туишев (сулда) һәм А.С.Ключарёв. 1927.



А.Х. Туишева.



З.Х. Туишева.

рыла торган җырларны («Агач башы», «Айһайлүк», «Алмагачлары», «Туганкай», «Иске кара урман», «Баламишкин», «Әпипә» һ.б.), ш.у. көнкүрештә киң таралыш алган рус («Есть на Волге утёс», «Стенька Разин», «Камаринская», «Эй, ухнем!», «То не ветер ветку клонит», «Ноченька», «Светит месяц»), украин («Виют витры», «Солнце низенько») һ.б. халыкларның җырларын; маршлар, биюләр, автор аранжировкасындагы популяр классик әсәрләрне, үзе иҗат иткән сюиталар, биюләр, маршлар, җырлар һ.б.ны эченә алган искиткеч зур репертуарны үзләштерә. Бөтенсоюз халык музыка уен коралларында башкаручылар смотры лауреаты (1939). 1987 дән даими рәвештә Т. исем. респ-ка гармунчылар конкурсы уздырыла. Конкурс бик күп катнашучыларны, проф. һәм һәвәскәр башкаручыларны үзенә тарта, милли музыка уен коралларында башкаруның популярлашуына, яшь талантлар ачылуга, күпкырлы муз. иҗат үсешенә булышлык итә. ТРның Милли музеенда Т. җыйган концерт гармунарының уникаль коллекциясе саклана.

Әд.: Рахманкулов Ш.З. Ф.К.Туишев. К., 1936; Татарский гармонист Ф.Туишев (исполнительские традиции). К., 1991; Зиангирова Г. «Я оставил хотя бы маленький след...» (к 125-летию со дня рождения Ф.К.Туишева) // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2009. № 2.

ТУЙШЕВА Ания Хәлиулла кызы (7.8.1946, Саратов ш.), җырчы, педагог, ТАССРның атказ. артисты (1987), ТРның халык артисты (1993). Казан муз. уч-щесенең К.З.Щербинина классын (1971), Казан мәдәният һәм сәнгать академиясенең вокал ф-тын (2000) тәмамлый. 1971–72, 1977–78, 1982–89, 1992–2001 елларда ТРның Җыр һәм бию ансамбле солисты, 2001–10 да педагогы. Бер үк вакытта, 1991 дән, Казан музыка уч-щесендә, 2002–06 дан Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тында укыта. Т. татар халык җырларын («Әзифә», «Әллүки», «Гөлҗамал», «Бөдрә тал», «Зөләйха килә») башкаруы б-н таныла. Көчле, тәэсирле тавышка ия. Аның репертуарын ш.у. классик ариялар һәм романслар тәшкил итә. Укучылары арасында Краснодар музыка театрының әйдәп баручы солисты Г.И.Низамова, ТР Җыр һәм бию ансамбленең әйдәп баручы солисты З.Борисова бар. Бөтенроссия җыр һәм бию ансамбле смотры лауреаты (Мәскәү, 1978, 1 нче бүләк).

Әсәр.: Народные мелодии — народу: Для голоса без сопровождения. К., 1996.

Әд.: Арсланова Ф. Государственный ансамбль песни и танца Республики Татарстан. К., 2007.

ТУЙШЕВА Зәкия Хафиз кызы (29.12.1919, Самара губ., Бөгелмә өязе Зәет а.), актриса, режиссёр, ТАССРның халык артисты (1969). 1937 елда Казанда фабрика-заводлар өчен белгечләр әзерләү мәктәбендә укый, 1938 дә — Татар акад. театры каршындагы студиягә, аны тәмамлаганнан соң, труппаның ярдәмче составына кабул ителә. 1946–51 дә — Татар респ-ка күчмә театры, аннары Мамадыш колхоз-совхоз театры актрисасы. 1951–76 да Әлмәт татар драма театры актрисасы; бер үк вакытта режиссура б-н шөгыльләнә башлый (1964 тә Мәскәүдә режиссёрлык курсларын тәмамлый). Т.ның актёрлык талантына тормышчан чынлык б-н лиризмның табигый үрелеп баруы хас. Ул башкарган Сәрби («Яшь йөрәкләр», Ф.Бурнаш), Әлфинур («Яланаяклы кыз», А.Гыйләҗев), Анна («Урланган бәхет», И.Франко), Машенька (шул исем. әсәр буенча, А.Н.Афиногенов) рольләре тамашачыны эчкерсезлек-



З.Х. Туишева (үзәктә) Сәрби ролендә («Яшь йөрәкләр», Ф.Бурнаш).

ләре һәм хисләр сафлыгы б-н җәлеп итәләр. Тулганай («Анам кыры», Ч.Айтматов), Тәнкәбикә («Ай тотылган төндә», М.Кәрим), Васса Железнова (шул исем. әсәр буенча, М.Горький) образлары психол. тирәнлекләре, эчке дөньяларының байлыгы б-н аерылып торалар. Д.Гоу һәм А.д'Юссоның «Тирән тамырлар» («Глубокие корни») пьесасы буенча Т. тарафыннан куелган беренче спектакль (1966) Мәскәүдә узган Бөтенроссия театр сәнгате фестивалендә 2 нче бүләккә лаек була. «Законлы никах белән» (Ә.Атнабаев, 1967), «Чаткылар» (Т.Гыйззәт, 1969), «Эх, Уфа кызлары!» (И.Абдуллин, 1970), «Диләфрүзгә дүрт кияү» (Т.Миңнуллин, 1970), «Ха жи әфәнде өйләнә» (Ш.Камал, 1972), «Трибунал» (А.Е.Макаёнок, 1973), «Барабанчы кыз» («Барабанщица», А.Д.Салынский, 1974) спектакльләре дә зур уңыш казана. 1976–90 да Т. Әлмәт шәһәрендә нефтьчеләр мәдәният йорты каршындагы һәвәскәр театр коллективы б-н җитәкчелек итә, 1990–96 да Әлмәт татар драма театрында яңадан режиссёр булып эшли, «Яшь йөрәкләр» (Ф.Бурнаш, 1991), «Дүрт әби һәм Әхмәди» (Ф.Бүләков, 1992), «Кирәксез тормыш» (Х.Ибраһимов, 1994) спектакльләрен куя. Бөек Ватан сугышында катнаша. Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: Народные артисты. К., 1980.

Д.Ә.Гыймранова.

ТУЙ ҖЫРЛАРЫ, муз.-поэтик фольклор жанры, *йола җырлары* төркеме. Татар халкы *туй йолаларының* барлык этапларында башкарыла. Пенза мишәрләрендә булачак киленнең йортына беренче тапкыр килгәндә, кода ху җаларга: «Алгы ишегегезне ача килдем, арткы ишегегезне яба килдем, кызыгызга баш кода булып килдем», — дип мөрәҗәгать иткән. Кайвакыт кода җырлары *чичән нәрнең* традицион импровизацияләре кебек яңгыраган. Балтач р-нында башта дога укылган, аннан соң гына кода үзенең «Ефәк бау лы былбыл кош бардыр синең илеңдә, каеш баулы лачын кош бардыр минем илемдә» җырын башлап җибәрә алган. Кыз ярәшү, кыз килешү этабында килен кияү егеткә һәм аның туганнарына бүләкләр (үзе тукыган, үзе чиккән сөлгеләр, ашъяулык, кулъяулыклар) тапшырганда тиешле Т.җ. башкара. Мәс., Мамадыш р-нында: «Сөлге сугам, сөлге сугам, сөлге сугам аклыкка, кызыл башлы сөлгеләрем язсын бәхет, шатлыкка», дип җырлаганнар. Т.җ.на ата-ана йорты б-н хушлашканда кәләшнең һәм аның дус кызларының елау һәм сыктаулары да керә (мәс., Пенза мишәрләрендә: «Ничек ят өйләрдә торырмын?»). Мәҗбүри йолалар тәмамлангач, кияү һәм килен вәкилләренә, туй башына багышланган гомуми эчтәлекле Т.җ. башкарыла (мәс., Пенза мишәрләре җыры: «Биеккәй тауларның башында өлгерә микән сабан ашлыгы? Син җырламасаң, кемгә җырларга соң, син бит туй башлыгы»). Совет чорында халык туй йолаларын яңа йолалар кысыклап чыгара. 1980 еллар башында Т.җ. б-н традицион туй йолалары яңадан тергезелә башлый.

Татар Т.җ.н И.Н.Надыйров һәм Ф.С.Баязитова өйрәнә. ТР ФА Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тының кулъязмалар мирасханәсендә һәм фольклор фондында Татарстан Респ-касы, Горький һәм Пенза өлкәсе р-ннарында язып алынган шактый күләмдә Т.җ. саклана.

Әд.: Татар халык җырлары: Лирик җырлар. Йола җырлары. К., 1965; Мөхәммәтҗанов Р. Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты (туй поэзиясе). Уфа, 1980; Татар халык иҗаты: Йола һәм уен җырлары. К., 1980.

Ф.И.Урманчеев.

ТУЙ ЙОЛАЛАРЫ, өйләнешү кагыйдәләре, туй гореф-гадәтләре. 20 йөз башына кадәр татар халкына яучылап-димләп өйләнешү хас булган. Егетнең туганнары кызны кия үгә сорап аның эти-әнисенә яучы җибәрә. Яучы кызны кияүгә бирергә күндерә, өйләнешү шартларын (*калым* күләмен, туй вакытын һ.б.) ачыклый. Шуннан кыз ярәшү һәм килешү йолалары башланып китә. Әлеге йолалардан соң ике якның бүләкләр алмашуы һәм туганнар б-н аралашу мәҗлесе (аклашу) үткәрелә. Кыз ярәшү, килешү һәм туй арасы төрлечә була, ләкин бик озак түгел. Бу вакытта бер як — *калым*, икенчесе бирнә, булачак туганнар өчен бүләкләр әзерли. Казан татарларында аерым йолалар, кунак итү, кунакка йөрешүләр гадәттә үткәрелми. Мишәрләрдә, Пермь һәм Чыпца татарларында бу вакыт аралыгында төрле йолалар бик күп була. Чыпца татарларында кызашка, ягъни кәләш һәм кызлар өчен мәҗлес табыны җыела, ул туганнар йортында үткәрелә; туй алдыннан

мунча ягыла (кәбен мунчасы). Мишәрләр һәм Пермь татарлары яши торган аерым районнарда кыз ярәшелгәннән соң кияү кәләш янына килеп йөри башлый. Төп Т.й. калымның бер өлеше түләнгәч, кыз йортында уздырыла: шәригать кушканча *никах* укыла һәм никах мәҗлесе үткәрелә. Казан артында туйның беренче көнендә ирләр генә чакырыла (мәҗлестә кияү б-н кәләш катнашмый, аларның әтиләре генә була). Туй берничә көн дәвам итә, кәләшнең туганнары кияүнең туганнарын чираттлашып кунак итәләр. Казан татарларында ир-атлар мәҗлесе — аерым, хатын-кызлар мәҗлесе аерым уздырыла. Мәҗлес көннәрендә туганнарны килен б-н таныштыру — кыз күрсәтү, кыз сөю, килен котлау йоласы үткәрелә. Кәләшне һәм аның ике дус кызын бер шәл б-н каплыйлар, каенана һ.б. туганнар аны «танырга» тиеш булалар: соңыннан бүләкләр алмашалар һәм килен һәм мәсен дә чәй табынына чакыра. Никах һәм туй мәҗлесе тәмамлангач кына, кияү берен че тапкыр кыз янына килә (Казан артында — каенатай атларында), каенатайга сандык б-н бүләкләр алып килә (кияү бүләге). Кәләш туганы ат йөртүчедән гайре кияүне беркем дә озата бармый. Кәләш йортына кияү төнлә килә һәм йолым түләгәннән соң гына кыз янына керә ала. Кәләшнең ахирәтләре кияү егетен яхшылап күздән кичерәләр, шаян сынаулар үткәрәләр, аннары кияү келәтенә озатып куялар. Кыз йортында кияү 4 көн кунак була, кәләшнең туганнарына бүләк өләшә (никах түшәге, яшь килен мунчасы һ.б. өчен йолым түле). Иң кыйммәтле бүләкне хатынына тапшыра. Кияү бүләкләренә каршы яшь килен үзе тукыган-чиккән бүләкләрне бирә. Шул рәвешле «кияүләп йөрү» башланып китә: кияү атнага 1 тапкыр (һәр пәнҗешәмбе) кәләше янына килеп йөри, әлеге йөрүләр калым түләнеп беткәнче дәвам итә. Гадәттә аны өлешләп түлиләр, кайвакыт ул шактый озакка сузылырга мөмкин. Ярлы крәстиян гаиләләрендә, кагыйдә буларак, әлеге йола үтәлми. Гадәттә өйләндерүне әти-әниләр, яңа эшче куллар алу өчен, җәйге а.х. эшләре башланган көннәргә туры китерәләр; кәләшне шунда ук каената йортына алалар. Зур туй яшь киленнең кияү йортына төшүе һәм кияү туганнарында туй мәҗлесләре уздыру б-н тәмамлана. Кияү йортына килен төшерү Казан татарлары яшәгән авылларның күбесендә яз гы-җәйге чорда үткәрелә торган халык бәйрәме *Җыенга* туры китерелә. Ул җирле үзенчәлекләргә ия күп йолалар б-н оештырыла. Аларның кайберләре кәләш йортында, кайберләре ул төшәчәк йортта уздырыла. Беренчесенә кәләшнең туган йорты һәм туганнары б-н саубуллашу йолалары керә. Мишәрләргә, керәшен татарлар, Касыйм, Пермь татарларына саубуллашканда такмаклап елау хас. Татарларның әлеге төркемнәре һәм Чыпца татарлары арасында кәләш киендерү, урын-җир әйберләре, бирнә җыю һ.б. кебек башка йолалар да киң тарала. Кияү йортында яшьләрне каршы алу да йола буенча башкарыла: киленнең аяк астына мендәр яки эче тышка әйләндерелгән тун салалар (яңа йортка керү җи ңел булсын өчен), кулларын онга батыралар (өйдә яхшы аш-су әзерләүче булсын өчен), бал-май каптыралар (теле татлы булсын өчен), нинди дә булса терлек бүләк итәләр, су юлы күрсәтәләр. Килен багу йоласына киленнең үзе чиккән, тукыган әйберләре б-н өйне бизәү — өй киендерү дә кергән. Керәшен татарларның туй йолаларындагы кайбер аерымлыклар (мәс., чиркәүдә никахлашу) христиан дине кануннары б-н бәйле. Татар халкында ябышып чыгу яисә кыз урлау сирәк хәл булган. Җәмәгатьчелек андый юл б-н өйләнешүне хупламаган. Хәзерге чорда Т.й. төзелеше һәм эчтәлеге ягыннан нык үзгәрә, никах гадәттә ЗАГС органнарында теркәлә, ләкин 1990 еллар ахырыннан, күпчелек очракта, шәригать кушканча, башта никах укыла.

Әд.: Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967; Уразманова Р.К. Современные обряды татарского народа: историко-этнограф. исслед. К., 1984; шул ук. Свадебные обряды // Татары. М., 2001. *Р.Р.Батыршин.*

ТУЙБА́КТИН (Туйбахтин) Касыйм (Мирзакасыйм) Шаһи җиһан улы (1888, Казан губ., Спас өязе Каргалы а. — 15.8.1918, Әстерхан ш.), сәясәт эшлеклесе. 1900 еллар башынан Казанда була: Апанай мәдрәсәсендә, аннары «*Мөхәммәдия*» мәдрәсәсендә укый, шәкертләр хәрәкәтендә катнашканы өчен аннан куыла. 1908 дә Әстерхан шәһәренә китә, укытучы булып эшли. 1911 дә Россия армиясенә алына. Беренче бөтендөнья сугышында катнаша. Чираттагы яраланудан соң 1916 да демобилизацияләнә һәм Казанга кайта. «Мәгариф» басмаханәсе мөдире була, «Аваз» г-тасын нәшер итүдә катнаша. 1917 нең җәендә Әстерханга күчеп китә. Әстерхан Мөселман социалистлар ком-тын, Әстерхан губерна башкарма ком-ты каршындагы Мөселман комис-тын җитәкли. 1918 нең 15 августында Әстерханда контрреволюцион фетнә вакытында һәлак була. *Беренче совет мөселман укчылары полкы*, Әстерханда бер урам, елга пароходы Т. исемен йөртә.

Әд.: Хәйретдинов Р., Кәримов Г. Комиссар Туйбактин // Көрәштәшләр: Мулланур Вахитов һәм аның көрәштәшләре турында истәлекләр һәм мәкаләләр. К., 1972.

Р.Г.Хәйретдинов.

ТУЙКӘ авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 6 *км* көньяктарак, Эстәрле елгасы буенда. 2010 елда 430 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1764 тән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Аблаева исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре һәм асабалар катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек, он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.дә 2 мәчет, 2 мәктәп, 5 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1551 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Азнакай волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 20 октябреннән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1795 тә — 220 кеше, 1822 дә — 133 ир-ат; 1859 да — 477, 1889 да — 825, 1897 дә — 813, 1910 да — 919, 1920 дә — 986, 1926 да — 929, 1938 дә — 813, 1949 да — 340, 1958 дә — 462, 1970 тә — 514, 1979 да — 384, 1989 да — 331, 202 дә — 418 кеше.

ТУ́ЙКИН Кәбир Кәрим улы (13.3.1878, Самара губ., Бөгелмә өязе Зәй-Каратай а. — 15.2.1938, Казан), педагог. Ф.К.*Туйкин*ның абыйсы. «Тайсуган» (Тайсуган а.) һәм «*Мөхәммәдия*» (Казан) мәдрәсәләрендә укый. 1898–1906 елларда армия хезмәтендә. 1907 дә Зәй-Каратай авылында мөгаллим, 1 нче мәхәллә мәчете каршында яңа ысуллы мәктәп оештыра. 1909 да хөкүмәткә каршы эшчәнлектә гаепләнеп кулга алына, 10 ай төрмәдә утыра. 1910–11 дә Оренбург шәһәрендә «Шура» ж-лы типографиясендә эшли. 1911 дә Зәй-Каратай авылының 2 нче мәхәлләсенә имам-хатиб итеп сайлана, ләкин, ышанычсыз дип, бу вазифага расланмый. Крәстиян хезмәте б-н шөгыльләнә. 1916 дан мәктәптә, 1917 дән Бөгелмәдә татар башлангыч мәктәбендә һәм пед. курсларда укыта. 1919 да энесе б-н бергә «Төрек тарихы» исемле уку ярдәмлеген бастыра. 1921 дән Бөгелмә халык мәгарифе кантон бүлегендә эшли, 1923 тән яңа ачылган 2 нче дәрәҗә татар мәктәбендә директор, бер үк вакытта укытучыларның квалификациясен күтәрү курслары җитәкчесе. 1929 да «ышанычсыз булганы өчен» эштән җибәрелә. 1930 дан Зәй-Каратай авылында колхоз хисапчысы. 1937 нең февралендә Бөгелмәдә Һ.*Атласовның* милләтчеләр оешмасында катнашуда гаепләнеп кулга алына, 1937 нең 28 октябрендә атарга хөкем ителә.

Әд.: Бөгелмә икенче баскыч татар мәктәбе турында // Мәгариф. 1927. № 12.

ТУ́ЙКИН Фазыл Кәрим (Әхмәтҗәрим) улы (22.6.1887, Самара губ., Бөгелмә өязе Зәй-Каратай а. — 15.2.1938), язучы, фольклорчы. К.К.*Туйкинның* бертуган энесе. «*Мөхәммәдия*» мәдрәсәсендә (Казан) укый. 1904 елдан туган авылында укыта. 1911–14 тә «Хәкимия» мәдрәсәсендә (Уфа), со ңыннан авыл мәктәпләрендә (бүгенге Азнакай, Бөгелмә, Ютазы, Әлмәт р-ннарында) укыта. 1911 дән башлап вакытлы матбугатта мәктәптә укыту мәсьәләләренә багышланган шигырьләрен, мәкаләләрен бастыра. *Җәдитчелек* тарафдары була, шул позициядән Корьәнне орфоэпик кагыйдәләр буенча укуга багышланган «Кечек тәҗвид» (1913) һәм «Әхкяме ислам» (1914) дәреслекләрен яза. 1919 да абыйсы б-н бергә «Төрек тарихы» китабын бастыра. Т.ның әдәби иҗаты («Сугышчы Сатыш әфәндә» хикәясе, «Ватан каһарманнары», «Тормыш корбаннары» драмалары; барысы да 1912) иҗтимагый проблемаларга, бигрәк тә хатын-кыз хокукына игътибар, табигать һәм сәнгатьне нечкә тоемлау б-н аерылып тора. Т. ш.у. татар фольклорын җыя һәм өйрәнә. «Җырлар әхтәрисе» (1912), «Нардуган: әдәбият кичәләре өчен җырлар мәҗмугасы» (1915) җыентыкларын төзүче. 1917 дән соң әсәрләрен бастыруда авырлыклар кичерә: иҗади мирасының күп өлеше югала. 1931 дә милләтчелектә гаепләнеп кулга алына, ярты елдан, әдәби иҗат б-н шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм ителеп, иреккә чыгарыла. Фольк-

лор җыюын дәвам итә. 1937 дә кабат күлга алына; атарга хөкем ителә. Үлгәннән соң аклана (1958).

Әд.: Х а н н а н о в а - Г а л и м җ а н о в а Э. Бертуган Туйкиннар: Фәнни-библиогр. җыентык. К., 2006. *Э.М.Галимҗанова.*

ТУЙКИЧИЛӘР, Казан сәүдәгәрләре, абыйлы-энеле бертуганнар. Мөхәммәтвәли (1824, Казан — 1897, шунда ук) һәм Мөхәммәтшәриф (1838, Казан — 1895, шунда ук) Бикбау уллары Т.нең уртак капиталлары була, һәм алар йон, тире һ.б. чималлар б-н сату итәләр. Мөхәммәтвәли эшмәкәрлек эшчәнлеге б-н 1857 елда шөгыльләнә башлый. Казан губернасында 15 мәчет төзетү өчен — 30 мең һәм 10 кое казыту өчен — 1,5 мең сум, «гомерлек капитал»дан 5 мең сум күләмендәге процентны Казандагы «*Зәңгәр мәчет*»кә һәм «Халидия» мәдрәсәсенә васыять итә. Мөхәммәтшәрифнең Яңа татар бистәсендә терлек мае эретү з-ды була; мәчет һәм мәктәпләр салдыру, аларны тәэмин итү өчен, акча васыять итеп калдыра. *Р.Р.Салихов.*

ТУЙМА́ елгасы, Көнчыгыш Кама алдында, Кама елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 106,2 *км*, ТРның чикләрендә — 74,9 *км*. Бассейнының мәйданы 1,4 *км*². Можга калкулыгыннан ага. Елга башы Удмурт Респ-касында, урта агымы Менделеев р-ны терр-ясендә, тамагы Алабуга шәһәре янында. Елга тамагының абс. биеклеге 205 *м*, тамагыныкы — 53 *м*.

Т.ның су җыелу мәйданы көрән алевролит, доломит һәм мергель катламлы баскычсыман калкулыклы тигезлектән гыйбарәт, ул исә кушылдыкларның үзәннәре, ерым һәм сызалар б-н ергаланган. Бассейны асимметрияле: уңъяк яр өлеше шактый зуррак. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 25%. Нигездә, караңгы ылыслы һәм караңгы ылыслы-киң яфраклы урманнар үсә. Елга үзәне киң, яхшы үзләштерелгән, көньяк-көнбатыш юнәлештә юыла; тирәнлеге — 60–70 *м*; сөзәкләкләр ерым-сыза челтәренең киң таралуы б-н аерыла, сул яктагылары — текәрәк һәм кыска. Т. Менделеев шәһәре тирәсендә Кама елгасына якын урнашкан (1,5–2 *км*), аннан фәкать биек таулар һәм тар тау сыртлы б-н генә аерыла. Түбән агымы — Кама тугае чикләрендә. Елга юлы бормалы, тармакланмаган. Ярлары текә. Тугайның тамак өлешендә күлләр күп.

Т.ның 0,4 тән 31,4 *км* га кадәр озынлыктагы 35 кушылдыгы бар, уң кушылдыклар зуррак һәм мул сулы: Юраш (31,4 *км*), Бу җәй (31,2 *км*), Көрен (25,6 *км*), Колтымак (19,7 *км*), Әлнаш (15,5 *км*), Чаллы (10,7 *км*). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,52 *км/км*². Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Бассейнда еллык су агымының урта-ча күпьеллык катламы 146 *мм*, ташу агымы катламы 117 *мм*. Т. бассейнында кар ныклап эрегән вакытта елгада су биеклеге уртача 2,5 *м* га (макс. 5–8 *м*) күтәрелә. Макс. чыгымы 533 *м*³/*с* (Алабуга р-ны Гусевка а., 1979). Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ун-көнлегендә башлана һәм якынча 30 көн дәвам итә. Җәйге чеплә тотрыклы, яңгыр ташулары сирәк һәм аларның әһәмияте юк. Яңгыр ташуы агымының катламы 4 *мм*. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача чыгымы 1,46 *м*³/*с*. Коры елларда җир асты сулары б-н туена, аның модуле 3–5 *л/с·км*². Т., гадәттә, ноябрьнең беренче ункөнлегендә туңа. Кыш ахырына бозның калынлыгы 50–60 *см* га (макс. 104 *см*) җитә. Суы Буҗай елгасы тамагыннан Менделеев шәһәренә кадәр гидрокорбанат-сульфат-кальцийлы, түбән агымында сульфат-гидрокорбанат-натрийлы типта, язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. Елгада суының күләме 3,6 млн. *м*³ булган 3 буа бар. Су ресурслары сугару һәм сәнәгать пр-тиеләрен тәэмин итү өчен файдаланыла.

ТРның табигать истәлеге (1978). Т. бассейнында «*Түбән Кама» милли паркы* урнашкан. *О.Н.Урбанова.*

ТУЙМА́ елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Оштырма елгасының (Вятка елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 16,4 *км*, ТР чикләрендә — 11 *км*. Бассейнының мәйданы 117,1 *км*². Елга башы Кукмара р-ны Туембаш авылыннан 3 *км* көнбатыштарак, урта һәм түбән агымы Киров өлкәсе терр-ясендә,



Туйма елгасы Алабуга шәһәре янында.

тамагы Вятские Поляны шәһәре янында. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 56 *м*. Су җыелу мәйданы калкулыклы тигезлектән гыйбарәт, ул исә урыны-урыны б-н кушылдык үзәннәре, ерым һәм сызалар б-н ергаланган. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 10%. Үзәне асимметрияле: сул сөзәклеге текәрәк. Т.ның 0,9 дан 5,6 *км* га кадәр озынлыктагы 5 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,27 *км/км*². Туенуы катнаш, якынча дүрттән өч өлеше кар сулары исәбенә туры килә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәенек саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 132 *мм*, ташу агымы катламы 98 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрь ахырында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,005 *м*³/*с*. Суы язын йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен уртача каты (3–6 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. Т. бассейнында суының гомуми күләме 3,6 млн. *м*³лы 3 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

ТУЙМА́ авылы, Менделеев р-нында, Менделеев шәһәреннән 18 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Туйма елгасы буенда. 2010 елда 145 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1680 нән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1846–60 елларда Т.да миссионерлар мәктәбе эшли. 20 йөз башында мәчет, мәктәп (1841 дә ачыла), тегермән, ашлык саклау-сату кибете була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1496,4 дис. тәшкил итә. 1916 да земство мәктәбе ачыла. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Күрәк волостенда, 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Бондюг, 1931 нең 20 гыйнварыннан — Алабуга, 1935 нең 10 февраленнән — Бондюг, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1985 нең 15 августыннан Менделеев р-нында. Халык саны: 1781 дә — 71 ир-ат; 1836 да — 286, 1859 да — 364, 1870 тә — 365, 1887 дә — 609, 1905 тә — 756, 1920 дә — 846, 1926 да — 343, 1938 дә — 836, 1949 да — 588, 1958 дә — 470, 1970 тә — 449, 1979 да — 285, 1989 да — 172, 2002 дә — 162 кеше.

ТУЙМАЗЫ́ РАЙОНЫ́, *Башкортстан Республикасының* көнбатыш өлешендә урнашкан. 1930 елның 20 августында оештырыла. Мәйданы — 2365 *км*². Үзәге — Туймазы шәһәре (Уфадан 170 *км* көнбатыштарак). Халык саны — 132463 кеше (1.1.2017). Татарлар — 50205 кеше (2010). Районда 114 торак пункт, ш.и. 36 татар, 38 башкорт-татар, 4 рус-татар, 1 татар-чуаш һәм 1 башкорт-рус-татар торак пункты исәпләнә. Иң зур татар авыллары (1.1.2009) — Карамалы Гобәй (1083), Илчембәт (1036), Төмәнәк (1046), Райман (949), Бишкурай (687), Татар-Олкан (651 кеше). Татарлар нигезләгән иң борынгы торак пунктлар: Атнагол, Кәлшәле (1626 да нигез салына), Үрге Сәрдек (1676) авыллары. Район үзәгендә *Туймазы татар драма театры* эшли. 2011 дә Татар мәдәнияте көннәре үткәрелә. Татар һәм рус телләрендә «Туймазы хәбәрләре» — «Туймазинский вестник» район г-талары нәшер ителә. Нәкышче Ә.С.*Арсланов*, актёр К.Ш.*Вәлиев*, әдәбият галимнәре Г.С.*Кашшаф* һәм С.Г.*Сафуанов*, техника һәм технология өлкәсе галиме Р.Х.*Гафиятуллин*, мотоузышчы Г.Ф.*Кадыйров*, социолог Р.Т.*Насыйбуллин*, Дан орденының тулы кавалеры, Соц. Хезмәт Герое Х.А.*Солтанов*, геолог-нефтьче Ф.З.*Хафизов*, тел галиме Ә.Ә.*Юлдашевның* тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге Т.р. б-н бәйле.

ТУЙМАЗЫ́ ТАТА́Р ДРА́МА ТЕА́ТРЫ, дәүләт карамагында, Башкортстан Респ-касының Туймазы шәһәрендә. 1990 елда оеша. М.Фәйзинең «Ак калфак» пьесасы буенча куелган беренче спектакль 1991 нең маенда күрсәтелә, беренче театр сезоны 1991 нең 2 декабрендә ачыла. Труппаның беренче составы үзешчән актёрлардан оеша. Аннан соңгы елларда Уфа сәнгать ин-тында әлеге театр өчен 2 чыгарылыш әзерләнә. 1990–94 тә һәм 1996 дан сәнгать җитәкчесе — И.С.Гәрәев. Башкортстан һәм Татарстанның башка театрларыннан да режиссёрлар чакырыла.

Репертуарын «Портфель» (Н.Исәнбәт), «Язмышларны язып булмый яңадан» (Ф.Ярullин), «Өч аршын җир» (А.Гыйләҗев), «Мәхәббәт өчпочмагы» (Ф.Галиев), «Һинд кызы», «Йолдызым» (Ш.Рәхмәтуллин), «Илгизәр+Вера» (Т.Миңнуллин), «Ай тотылган төндә» (М.Кәрим), «Ваня абзый» («Дядя Ваня», А.П.Чехов), «Мәкер һәм мәхәббәт» («Коварство и любовь», Ф.Шиллер), «Күзгә күренмәс ханым» («Дама-невидимка», П.Кальдерон), «Онытылган адәм» (Н.Хикмәт), балалар өчен «Алыш бармы, атыш бармы» (Н.Гаетбай әсәре буенча) һ.б. спектакльләр тәшкил итә. Соңгы елларда театр сәхнәсендә



Туймазы татар драма театры.

«Бөке», «Әрем исе» (И.Зәйниев), «Тиле яшьлек» (И.Абдуллин), «Яшьлек белән очрашу» (Т.Миңнуллин), «Тю-тю мәхәббәт, яки Тавыкбаш» («Курица», Н.Коляда), «Күз буучылар», «Урманнарга керсәң...» (Ә.Гаязов), «Синнән — фатир, миннән — ир» (Н.Гаетбай), «Туй күлмәген калдым кочаклап» (Р.Кинҗәбаев), «Гомерлек газап» (С.Әбүзәр), «Язлар моңы» (Ә.Гаффар), «Тискәрегә — авызлык» («Укрощение строптивой», У.Шекспир), «Каеннарым белән...» (Р.Миңнуллин), «Чиксез күк астында» («Под небесами», Н.Мошина), «Үтерүче» («Убийца», А.Молчанов), «Түтиләр» («Тётушки», А.Коровкин), «Пычкы» («Пила», Вл.Жеревцов), «Котырган акчалар» («Бешеные деньги», А.Островский), «Игезәкләр» (Ә.Атнабаев) спектакльләре дә зур уңыш б-н бара. Театр бөтенроссия һәм халыкара театр фестивальләрендә актив катнаша. «Онытылган адәм» спектакле Әнкарада (Төркия) Н.Хикмәтнең тууына 100 ел тулу уңаеннан уздырылган тантана бәйрәмнәрендә тәкъдим ителә. 2018 дә театр труппасында — БРның халык артисты А.Солтанов, БРның атказ. артистлары Г.Латыйпова, А.Зәйлалов, Д.Нурыйханов, М.Сидорова, Р.Сәлимгәрәева, Р.Ключарёва, Ф.Мөхәммәтдинов, актёрлар А.Гайсаров, А.Вәлиева, Ә.Гайсарова, Л.Сөләйманова, С.Мөхәммәтдинова, Р.Вахитов, Д.Вахитова һ.б., театрның баш режиссёры — И.Б.Муллабаев (2017 дән), директоры — БРның атказ. мәдәният хезмәткәре Ф.Ф.Габидуллин (2005 тән).

ТУЙМӘ́Т авылы, Чирмешән р-нында, Чирмешән авылыннан 16 *км* төньяктарак, Чишмә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 580 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1762 гә кадәр нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.тә 2 мәчет, 2 мәктәп, җил тегермәне, 2 ашлык саклау-сату кибете, 3 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1923 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Ерсубай волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән — Чаллы, 1924 тән Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Беренче Май, 1963 нең 1 февраленнән — Лениногорск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Чирмешән р-нында. Халык саны: 1834 тә — 411, 1870 тә — 707, 1897 дә — 993, 1906 да — 1092, 1920 дә — 1329, 1926 да — 630, 1949 да — 788, 1958 дә — 716, 1970 тә — 939, 1979 да — 810, 1989 да — 605, 2002 дә — 596 кеше.

ТУКА́ЕВ Мөхәммәтшакир Мөхәммәтхарис улы (1862, Оренбург губ., Эстәрлетамак өязе Эстәрлебаш а. — 1932, Оренбург ш.), җәмәгать һәм дин эшлеклесе, педагог. Күренекле татар руханилары Тукаевлар нәселеннән. Эстәрлебаш авылы мәдрәсәсендә, Оренбург татар укытучылар мәктәбендә укый. Эстәрлебаш мәдрәсәсендә укыта. 360 дис. җир били. Эстәрлебаш өяз земствосы гласные, Уфа губернасы стат. ком-ты әгъзасы була. «*Иттифак әл-мөслимин*» партиясе әгъзасы, 2 нче Бөтенроссия мөселманнар корылтаенда (1906, С.-Петербург) катнаша, анда рәсми рәвештә әлеге партия оештырылу турында игълан ителә (к. *Бөтенроссия мөселманнары корылтайлары*). Уфа губернасыннан 2 нче һәм 3 нче Дәүләт Думалары (1907–12) депутаты, мөселманнар фракциясе әгъзасы. 2 нче Думада — намус иреге, 3 нче Думада җир, крәстияннәр йөкләмәсе, дин эшләре, балыкчылык буенча комиссияләр эшендә, дин мәсьәләсендә гражданнар хокукларын чикләүгә караган закон актларын системага салу



Р.Г.Тукаев.

буенча кече аскомиссия эшендә катнаша. Дәүләт Думасы комиссиясе эшчәнлегенә тулы бәя биреп, «Дәүләт Думасының Уфа губернасыннан 2 нче һәм 3 нче чакырылыш депутаты, дини мәсьләләр буенча комиссия әгъзасы Мөхәммәтхарис улы Мөхәммәтшакир Тукаевның отчёты» («Отчёт члена комиссии по вероисповедным вопросам Государственной думы II и III созывов Мухаммет-шакира Харисовича Тукаева, депутата от Уфимской губернии», Уфа, 1912) брошюрасын нәшер итә. Мөселман дини оешмаларын реформалау мәсьәләләренә багышланган 4 нче Бөтенроссия мөселманнар корылтаенда (С.-Петербург, 1914) катнаша. Төбәк тарихына багышланган, төбәк тарихы буенча татар телендә басылган тәүге китапларның берсе — «Тарихы Эстәрлебаш» авторы (1899).

Әд.: Мусульманские депутаты Государственной думы России. 1906–1917: Сб. док. и материалов. Уфа, 1998. *Р.А.Айнетдинов.*

ТУКА́ЕВ Рифкать Галимҗан улы (10.10.1923, хәзер Башкортстан Респ-касының Балтач р-ны Түбәнге Карыш а. — 19.6.1995, Әндижан ш., Үзбәкстан Респ-касы), Дан орденының тулы кавалеры (18.3.1943, 22.8.1944, 5.12.1944 — 2 нче дәрәҗә; 1958 нең 26 ноябрендә 1 нче дәрәҗә орден б-н яңадан бүләкләнә), гв. старшинасы. Ташкент пед. ин-тын тәмамлый (1962). 1929 елдан Әндижан шәһәрендә яши. 1941 дән Кызыл Армия сафларында. 1942 нең августыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 330 нчы аерым разведка ротасында (10 нчы гв. һәм 3 нче удар армияләрнең 379 нчы укчы дивизиясе) төркем командиры. 2 нче Балтыйк буе һәм 1 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Смоленск (1943) һәм Рига (1944) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 21 февралендә Пустошка шәһәре (Псков өлкәсе) тирәсендәге сугышта (разведка төркеме б-н дошман тылына үтеп керә, кул сугышында дистәдән артык солдатны юк







Туймазы татар драма театры спектакльләреннән күренешләр: 1. «Яшь йөрәкләр», Ф.Бурнаш; 2. «Асылъяр», М.Фәйзи; 3. «Легионер», З.Хәким.

итәләр, 5 әсир алалар; сугышчан заданиене үтәп кайтканда яраланган рота командиры - ның тормышын саклап кала); 1944 нең 12 июлендә Янчево авылы янында (Псков өлкәсенең Себеж р-ны) разведка операцияләрендә (дошман б-н бәрелештә Т. үзе дошман пуле - мётыннан дистәдән артык пехотачыны юк итә һәм 2 офицерны әсирлеккә ала; Т. җи - тәкчелегендәге төркем дошман батареялары һәм инженер корылмаларының урнашулары турында мәгълүмат җыя һәм штабка тапшыра); 1944 нең 29 сентябрендә Мадлиена торак пункты янында (Ригадан төньяк-көнбатыштарак) (дошман тылында разведка операциясе вакытында гитлерчылар штабының блиндажын шартлата, 5 автоматчыны юк итә, 2 солдатны әсирлеккә ала) батырлык күрсәтә. 1945 тә демобилизацияләнә, Әндижанда яши, Әнди җан укытучыларның белемен күтәрү өлкә ин-тында методик кабинет җитәк - ли (1963–87). 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

ТУКА́ЕВЛАР МУЗЕ́Й-ЙОРТЫ́, Арча р-ны Кушлавыч авылындагы әдәби-мемориаль музей. Г.Тукайның 90 еллыгына 1976 елда ачыла. 1986 да музей экспозициясе үзгәртелә. Экспонатлар туплауда укытучы Г.Р.Шәһиә - ва җитәкчелегендәге мәктәп укучылары актив катнаша. 1992–2005 тә ТРның Дәүләт музее (2001 дән — ТРның Милли музее), 2006 дан — Габдулла Тукай әдәби-мемориаль музей-комплексы ф-лы. 1996 да Тукаевлар утары яңадан торгызыла, аның составына



Арча районының Кушлавыч авылында Тукаевларның музей-йорты. Гомуми күренеше.

бер катлы агач биналар: мулла йорты (алты почмаклы), авыл йортының эчке күренеше торгызылган йорт (дүрт почмаклы, чолан - лы), амбар-келәт, мунча керә. Экспозициянең фәнни концепциясе авторлары — ТР Дәүләт музеенның фәнни хезмәткәрләре А.Д.Хәйрул - лина, Г.Х.Еникиева, рәссамы — С.И.Матвеев. Музей-йортның төп экспозициясе мулла йор - тында урнашкан; өч өлештән тора: «Мәдрәсә - дә», «Г.Тукай тормышы һәм иҗаты», «Куш - лавыч — Тукайның туган авылы». Экспози - ция мәйданы 120 $м^2$, музей фондларында 900 тирәсе саклау берәмлеге исәпләнә. Йорт - ның ирләр ягы авыл мәктәбе рәвешендә күр - сәтелгән (Тукай — әтисе ягыннан да, әнисе ягыннан да муллалар нәселеннән). Шагыйрь - нең тормышы һәм иҗатына багышланган экспозиция өлешендә Г.Тукайның әти-әнисе һәм бабасы портретлары (рәссам М.К.*Мав - ровская*), Тукаевлар нәселенең шәҗәрәсе, та - нылган мәгърифәтчеләр Г.Курсави, Ш.Мәр - җани, Ш.Күлтәсиләрнең документлары, фо - тографияләре күрсәтелә. Йортның ха - тын-кызлар ягында татар гамәли-бизәлеш сәнгате үрнәкләре: өйдә тукылган сөлгеләр, паласлар күрсәтелгән. Аеруча кыйммәтле экспонатлар арасында — мемориаль әйберләр (шагыйрь әнисенең шәхси әйберләре: чәй - нек, аш тәлинкәләре), М.К.Мавровскаяның картиналар коллекциясе («Тукай туган йорт урыны», «Г.Тукай замандашлары», «Тукай чишмәсе», «Тукайның яшь чагы», «Шагыйрь Тукайның балачагы», «Кушлавычтагы иске йорт» һ.б.), Г.Тукайның фоторәсемнәре һәм үзе исән чакта басылган китаплары. Ел саен Г.Тукайның туган көне (26 апрель) һәм Ха - лыкара музейлар көне (18 май) билгеләп үте - лә. Директоры — Л.М.Мөхәммәтшина (1996 дан).

ТУКА́Й (Тукаев) Габдулла Мөхәммәтгариф улы (26.4.1886, Казан губ. Кушлавыч а. — 15.4.1913, Казан), шагыйрь, әдәби тәнкыйтьче, публицист, яңа татар әдәбиятына нигез салучыларның берсе. Мулла гаиләсендә дөнья - га килә. Дүрт яшьтән ятим кала. Үсмер чагы Җаек шәһәрендә уза, шунда 1895–1907 елларда күренекле «Мотыйгыя» мәдрәсәсендә укый, аның каршындагы рус мәктәбенә йөри, рус мөхәррирләре иҗаты б-н кызыксынып китә. Шушы чорда басмаханәдә эшли, Җаек - тагы алдынгы фикерле яшьләр б-н аралаша. 1902–1904 тә беренче иҗади тәжрибәләр ясый. 1905 ел үзгәрешләре йогынтысында чыга башлаган «Фикер», «әл-Гаср әл-җәдид», «Уклар» газета-журналларында эшли. Тәрҗе - мә б-н шөгыльләнә башлый, 1906–1907 дә «әл-Гаср әл-җәдид» ж-лында «Энҗе бөртек - ләре» исеме астында 77 тәрҗемә мәсәл басты - рып чыгара.

1907 нең башында Т. «Мотыйгыя» мәдрә - сәсеннән чыга: аның «ирекле тормышы» баш - ланып китә. Таныла башлый, әсәрләренең теле һәм стиле камилләшә. Яңа формалар һәм алымнар эзләп, ул рус һәм Көнбатыш Европа әдәбиятларына мөрәҗәгать итә, А.С.Пушкин һәм М.Ю.Лермонтов шигырьлә - рен тәр җемә итә («Пушкиннан» («Из Пуш - кина», 1906), «Кичке азан» («Вечерняя мо - литва», 1906), аларга багышлаулар яза («Пушкинә» («Пушкину», 1906), «Шагыйрь - гә» («Поэту», 1907)), А.В.Кольцовны һәм В.А.Жуковскийны үрнәк итеп өйрәнә, А.Н.Майков, А.Н.Плещеев, И.С.Никитин, И.А.Крылов, Дж. Байрон, И.Гёте, Г.Гейне, Ф.Шиллер һ.б.ның әсәрләрен тәр җемә итә һәм назыйрәләр яза. Т.ны немец романтик әдәбияты кызыксындыра: ул немец телен өй - рәнә башлый.

1907 нең ахырында Габдулла, солдатка ка - ралу уңае б-н, туган ягына кайта, Казанда яши. Ф.Әмирхан, Г.Камал, С.Рәмиев, С.Сүн - чәләй һ.б. б-н дустанә һәм әдәби мөнәсәбәт - ләр урнаштыра.

Казанда шагыйрь зур күңел күтәренкеле - ге, өметләр б-н эшкә чума. Үз идеалларына хезмәт итү, хәр, азат милли матбугатны үсте - рү теләге б-н яна. 1908–1909 да Г. Камал б-н бергә Т. «Яшен» сатирик ж-лын чыгара, ә 1910 нан «Ялт-йолт» ж-лында эшли, гомеренең ахырына кадәр аның рухландыручысы, җитәкчесе булып кала.

Ачлык-ялангачлыкта узган балалык еллары, Казан кунакханәләренең салкын номер - ларында яшәү эзсез узмый: шагыйрьнең сә - ламәтлеге какшый, ул туберкулез б-н авы - рый башлый. Дарулар һәм яхшы табиблар эзләп, 1911–1912 дә Т. сәяхәтләргә чыга. 1911 нең май башында пароход б-н Әстерханга юнәлә, юлда Идел буендагы тормыш б-н та - ныша. 1912 нең язында Уфа — Петербург маршруты буйлап уза. Аннан Троицкийга китә, июнь урталарында казакъ далаларына барып чыга, кымыз эчеп сәламәтләнә нык - тырга уйлый. Сәяхәттән Казанга 1912 нең августында гына кайтып төшә. Авыру булуына карамастан, иҗатын дәвам итә. 1913 нең 15 апрелендә Казанда үпкә авыруыннан вафат була.

Т.ның беренче шигырьләрендә мәгърифәт - челек һәм халыкның белем дәрәҗәсе («Го - лүмең бакчасында», 1905), милләтнең мәдә - ниятен үстерү («Шигырь», 1905), социаль үзгәрешләргә чакыру («Хөррият хакында», 1905), татар җәмгыятен яңарту («Дустларга бер сүз», 1905; «Иттифакъ хакында», 1905) идеяләре чагыла. Шагыйрь турыдан-туры халкына эндәшә:

И кардәшләр, кул тотышып алга барыйк,
Башка милләтләрнең хәлен карап карыйк;
Мәдәният мәйданында урын алыйк,—
Егъла-тора алга таба атлыйк имди.
(«Иттифакъ хакында»).

Беренче әсәрләрендә үк татар җәмгыятен гыйлем һәм мәдәният ярдәмендә үстерергә ча - кыру мотивы милли идеология ноктасын - нан яңгырый. Мәгърифәтчелек юнәлеше та - тар әдәбияты өчен традицион булган «Алла — кеше» мөнәсәбәтен үзәккә куйган дөнья сурәтен үзгәртүгә этәргеч бирә; мәс., «Алла гыйшкына» (1905) шигыре әхлаклылыкка, мәгърифәткә, милләт мәнфәгатен кайгырту - га омтылышны чагылдыра. Шагыйрь «Ал - лага гыйшык тоту фәлсәфәсен татар милләтенең иҗтимагый яшәеше яссылыгына» күчерә.

Лирик геройның күңеле милләтне күтә - рергә ашкына: «Милләти тәрфига күңлем ашыгадыр, ашкына...»

Шигырьдә бу омтылыш дини күзаллау чи - гендә аңлатыла: милләтнең алдынгы, әхлак - лы, белемле, һөнәрле булуы — илаһи таләп, Алла теләге. Милләт мәнфәгатен кайгырту, аны үстерү — мөселман өчен фарыз эш.

Охшаш караш «Хәзерге халемезә даир» (1905) шигырендә дә кызыл җеп булып сузы - лып бара. Татар җәмгыятендәге көнчелек, үчлек, язучыларга карата битарафлык кебек сыйфатларны шагыйрь дингә хезмәт итмәү дип бәяли. Каләм — дин сүзен халыкка җит - керүче, Коръәнне язучы, хөкем йөртүче; язу - чылар ислам терәк, куәт, идеалга юл күрсә - түче кебек тәкъдир ителә. Татар җәмгыятенә тәнкыйди бәя бирелеп, көнчелек, үчлек, на - данлык кебек сыйфатлар да, асылда, язучы - ларга хөрмәт булмауга нисбәт ителә.

Каләмгә мөрәҗәгать кебек язылган «И, каләм!» (1906) шигырендә лирик герой үзенең милләт һәм мөселманнар вәкиле булуын ассызыкласа да, шигырьдәге каләм — милләт мөнәсәбәтен үзәккә куя. Урта гасырлар шагыйрьләре өмет тулы карашларын Аллага төбәгән кебек, милләтнең бер вәкиле булган лирик геройның киләчәккә ышанычы да каләм б-н бәйләнгән. Аның өчен каләм, ягъни язма сүз — газаптан коткаручы, шатлык китерүче, туры юлга бастыручы, милләтне югары күтәрүче, аны авырудан терелтүче, бәхет һәм якты киләчәккә чыгаручы... Шигырь үзе үтенеч, ялвару, дога рәвешендә иҗат ителгән. 11 строфалы әсәр — лирик геройның каләмгә эндәшүе, теләкләрен бәян итүе. Каләмнән милләтне шатлыкка чыгаруын, туры юлга бастыруын, эшкә өндәвен, гыйлемгә чакыруын, яхшылык-явызлыкны («Караны яз кара дип һәм игътираф ит акны ак») һәм хакыйкатьне-ялганны («Җөпне җөп дип язмали сән һәм ушандак такны так») аерып бирүен, милләтнең чир-авыруларын күрсәтүен сорап, шагыйрь аның мондый зур вазифаларны үз өстенә алырлык олы көч икәнлеген дә искәртә. Моннан тыш, милләт хәлен Европаның үсеш дәрәҗәсе б-н чагыштыру, соңгы сынының язма сүз ярдәмендә «күкләргә кадәр» күтәрелүен әйтү шигырьдәге каләмнең дәрәҗәсен тагын да арттыра. Әйтерсең Аллага мөрәҗәгать шигырен Тукай каләмгә мөрәҗәгать б-н алыштыра, шуның аша язма сүзнең, әдәбиятның ролен югары күтәрә, аны ила һилаштыра. Шулай беренче шигырьләрендә үк яшь шагыйрь дөньяви мәсьәләләр куя, милләт проблемаларына кагылганда мәгърифәтче һәм мөселман, шагыйрь һәм нәбитараф кеше булып фикер йөртә.

Шундый ук омтылышлар аның публицистикасында да чагылыш таба. Әйтик, «Хиссияте миллия» (1906) мәкаләсендә ул болай ди: «...Милләт образованный кешеләргә һәм халык файдасын һәртөрле үзенең шәхси мәнафигыннан вә корсак файдаларыннан өстә тота торган, милләт файдасын күз өстендәге кашы дәрәҗәсендә газиз тота торган милләт арысланнарына мохтаҗ». «Безнең милләт тә башка милләтләрнең тәрәккыйларына сәбәп булган чын мөхәррирләргә, рәссамнарга, бардаканәдән чыкмаган яңа-яңа милли шигырьләргә, музыкаларга вә гайреләргә, вә гайреләргә мохтаҗ». «Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?» (1906) язмасында дәвам итә: «...без ул милләткә әдәбият гөл-сулары сибик, гәзитә мәрвәхәләре (вееррлары) илә йомшак җил истерик һәм авызына ит тихад вә иттифакъ сулары салыйк; җан рәхәте булган музыкалар илә дәртләндерик, хәтта рәсемнәр илә милләтнең үз сурәтен үзенә күрсәтик; тәмам күзе ачылсын, дүрт ягына карасын, гакылын җыйсын...».

Т.ның бу чор сатирик иҗаты халыкның иҗтимагый-мәдәни хәлен тәнкыйтьләү мотивы тирәсенә җыела, тәнкыйть угы наданлыкка («Япониядә мөселман идәчәк голяма нәрәдә?», 1906), әхлаксызлыкка («Кечкенә генә бер көйле хикәя», 1906; «Хатирәи «Бакырган», 1906), дини фанатизмга («Мөритләр каберстанынннан бер аваз», 1906; «Сорыкортларга», 1906; «Пыяла баш», 1906) каршы юнәлтелгән. Әкренләп шигырьләрдә демократик үзгәрешләргә чакыручы шагыйрьнең гражданлык һәм сәяси карашы кискенләшә («Государственная думага», 1907; «Китмибез!», 1907); мәс., Дәүләт Думасындагы карагруһчы депутатларның татарларны Россиядән куарга чакырып чыгыш ясавына җавап итеп шагыйрь болай ди:

Монда тудык, монда үстек, мондадыр безнең әҗәл;
Бәйләмеш бу җиргә безне тәңребез (гыйззе вә җәл).



Г.Тукай. 1908.

Т. халыкның бүгенгесе караңгы, ә киләчәге һәркемнең ныклыгына һәм активлыгына бәйле булган язмышы турында уйлана. Бушка, нәтиҗәсез вакыт уздыру хакындагы фикере сәясәтчеләр, сәүдәгәрләр, руханилар, шәкертләр адресына әйтелгән гаепләүләрдә чагыла. Шагыйрь хатын-кызларга ирләр б-н тигез хокуклар даулый («Татар кызларына», 1906; «Хатыннар хөрриятә», 1906); халыкка, милләткә ярдәм итәргә өнди («Гәзитә мөрәттибләренә», 1906; «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр», 1907); халыкка хезмәт итүне, аңа ярдәм итүне хуплый («Мөхәрриргә», 1906; «Әдәбият ахшамы ясаучы яшьләрә мезгә», 1906). Шигырьләрнең күп өлеше — багышлаулар, аларда татар җәмгыятенең төрле катлауларына юнәлтелгән риторик эндәш төп фикер буларак формалаша, татар җәмгыятен гыйлем һәм мәдәният ярдәмендә үстерергә чакыру мотивы әйдәп бара.

Шигырь төзелешендә милли традицияләрне барлап, ш.у. рус һәм Европа әдәбиятлары йогынтысында груздан силлабикага күчә; лирик геройның гражданлык кичерешләрен сурәтләгәндә чикли торган шәрекъ жанрлары — газәл, мәдхия, мәрсия, касыйдәнең кайбер билгеләре аның әсәрләрендә җуелып, шигырьләр Көнбатыш әдәби жанрлар системасында кабул ителә. Шагыйрь җитди рәвештә халык өслүбе, фольклор традицияләре б-н кызыксынып китә. Аның иҗатының халык иҗаты б-н якынаюы әсәрләр теленең чистаруына китерә, шигырьләр гарәп-фарсы һәм төрек алынмаларыннан котыла. Шуның б-н бергә, фикерләү үзенчәлеге үзгәрә: халыкка мәхәббәт, аның бай рухи мөмкинлекләренә, акылына, киләчәгенә ышаныч шагыйрь стилендәге эстетик доминантага әверелә.

Романтик лирик герой милләткә хезмәт итүгә омтыла. Иҗат темасына багышланган шигырьләрдә шагыйрьнең бөек миссиясе — халыкны алгарыш юлында җитәкләү омтылышы раслана («Бер татар шагыйренең сүзләре», 1907). Рухи хөрлек, тышкы шартларда ирекле булуга дан җырлап һәм социаль проблемаларга игътибарын юнәлтеп, Т. үз язмышының халык язмышыннан аерылгысызлыгын тирән тоеп иҗат итә («Көз», 1906; «Хөрриятә», 1907; «Теләнче», 1907). Фольклордан килгән образлар, детальләр, сюжетлар балалар өчен язылган әсәрләрендә аеруча калку бирелә («Шүрәле» әкият-поэмасы, 1907). Туган җиргә мәхәббәт туган телгә мәхәббәт, табигать гүзәллеге һәм гадәти көнкүрешнең гади матурлыгына соклану б-н бәйле: «Пар ат» (1907), «Туган җиремә» (1907) һ.б. Шулай итеп, Т. иҗатында өр-яңа язу рәвеше, стиль пәйда була, аңа «нюанслылык» (Й.Нигъмәтуллина), «антитезалар ярдәмендә фикерләү» (Х.Госманов), «афоризмнар, образның күпкатламлылыгы һәм вариативлыгы» (Р.Ганиева), «халык тормышына якынлык» (Г.Ибра һимов) хас була.

Т.ның сатирик таланты үсә, сатирик шигырьләрендә ул үзләрен милли мәнфәгатьләрне кайгыртучылар дип тәкъдим иткән икейөзле, әхлаксыз динчеләрдән көлә («Ысулы кадимче», 1908; «Милләтчеләр», 1910; «Яшьләр», 1910; «Казан вә Казан арты», 1912 һ.б.). Т.ның сатирик иҗаты эчтәлеге, көлү объектлары һәм иҗади сурәтләү формасы ягыннан төрле булса да, ул татар җәмгыятен яңарту идеясе б-н сугарылган. Социаль чынбарлыктан читләшкән лирик герой бу чынбарлыкны милли идеал яктылыгында тәнкыйть итә:

Бара милләт зәгыйфь, абныр-абынмас,
Сүнә яшьләрдә ут кабнып-кабынмас.
Кичә якты вә милли бер күңелдән
Бүген тычкан утыдай нур табылмас.
(«Яшьләр»).

Шагыйрь *назыйрә* остасы булып таныла. Урта гасырлар татар әдәбиятының шартлы романтик стилен, фантастик алымнарын иркен файдалана, сарказм, гипербола, ирония, аллегория, пародия, гротеск кебек алымнарга мөрәҗәгать итә. Аның иң тәэсирле сатирик әсәре — «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасы (1908) да борынгы шигъри яджкәрләрдән «Кисекбаш китабы»на назыйрә рәвешендә язылган. Поэмада эпик башлангыч өстенлек итә: әсәр сюжетлы. Нигезендә Печән базарында «булган» вакыйгалар ята. Дию пәрие бер кешенең гәүдәсен ашый, малаен кабып йота, хатынын коега алып төшеп китә. Әлеге кешенең башы — Кисекбаш, Печән базарына килеп, үзенең кайгысын сөйли. Цирк батыры Карәхмәт Диюне җиңә, хатынын алып кайта, Камчылы ишан, өшкереп, Башны гәүдәсе б-н ялгый, яшь егеткә әйләндерә. Бу фантастик сюжет авторга татар тормышындагы аерым катлам кешеләрен тәнкыйть-



Г.Тукай мәкаләсенә. 1. Г.Тукай. Казан. 1912; 2. Тукай һәм Г.Кариев. Уральск шәһәре. 1900–01; 3. Г.Тукай. Уральск шәһәре. 1905; 4. Г.Тукай театр труппасы артистлары арасында (уртанчы рәттә сулдан икенче). Әстерхан шәһәре. 1911; 5. Сулдан уңга: утыралар Г.Тукай, Ф.Әмирхан, басып торалар Г.Коләхмәтов, К.Коләхмәтов. Казан. 1912; 6. Г.Тукай. Казан. 1 апрель 1913; 7. Г.Тукайга һәйкәл. Скульпторы Е.И.Шулик. Архитекторы И.Г.Гайнетдинов. 1956; 8. «Г.Тукай портреты». Рәссам З.Ф.Гыймаев. 1986; 9. «Акыл ияләре». Рәссам А.Ә.Абызгилдин. 1986; 10. «Г.Тукай». Скульпторлары Б.И.Урманче, Ә.К.Заһиров, архитекторы Б.И.Урманче. Бронза. Арча районының Яңа Кырлай авылында Г.Тукай музей-комплексы. 1976; 11. «Г.Тукай». Скульпторы Б.И.Урманче. Бронза. 1964. 1990 елларда коелган; 12. «Шигърият алиһәсе белән саубуллашу. Г.Тукай». Рәссам Н.У.Әлмиев. 1998.

ләргә һәм халыкның әкият-кәмитләргә ал - данып яшәвен күрсәтергә ярдәм итә.

Әсәр тулаем XX йөз башы татар халкы тормышындагы тискәре яклардан көлү бу - лып яңгырый. Анда татар идеологлары, сәя - сәтче, сәүдәгәр, мулла-ишаннарның җыелма образлары тудырылган, прототипларына да ишарә ясала. Дию — фирка оештырган Гай - нан Вәисов, Камчылы ишан — Габдессаттар Хуҗаев. Садри Максуди, төрек көрәшчесе Карәхмәт, Ибра һим (Касыйм шәһәреннән), Ба һаветдин Вәисов исемнәре телгә алына. Алар «Печән базары» образының вариация - ләре сыйфатында тәкъдим ителәләр.

Шагыйрь татарлардагы сәүдәгәр-сәясәт - челәр, идеологлыкка дәгъва итүчеләр, шә - кертләр, Печән базары халкы катламнарын тәнкыйтьли һәм, татарлар кәмит кайгысы

һәм шатлыгы б-н түгел, милләт кайгысы һәм шатлыгы б-н яшәргә тиеш, дигән фикер белдерә, бу хәлләрдә халыкны — тирәлекне гаепле итеп күрсәтә. Охшаш, бер типтагы образлар кабатлану авторга чынбарлыктан аерылган татар җәмгыяте рәсемен «ясарга» мөмкинлек бирә. «Кәмит» исә «буш урында таптану», «буш шатлык» буларак бәяләнә. Шулай Т. татар җәмгыятендә традицияләрнең яшәүчәнлеген, 1905 ел инкыйлабыннан соң да тормышның иске рәвеше сакланууны җиткерергә омтыла.

Казан чоры (1908–1913) — аның иҗатының чәчәк ату чоры, анда романтик мотивлар көчәя, ул шигърияттә фәлсәфи тирәнлеккә ирешә һәм үзен халык тормышының җырчысы итеп таныта. Шигырьләрендәге мәгърифәтчел караш үзгәрә: ул фәлсәфи нәтиҗәләрнең сәбәбенә әверелә, беренче планга милләткә, халыкка хезмәт итү мотивы чыга. Мондый шигырьләрдә фа җигалелек пәйда була; мәс., «Ике юл» (1909) шигырендә традицион «мәгърифәтле — мәгърифәтсез» каршылыгы тудырыла. Шагыйрь аларның кеше өчен рухи үзгәрешкә яки торгынлыкка китерәчәк ике юл булуын күрсәтә. Ләкин әсәрнең идеясе үзенчәлекле. Мәгърифәткә омтылу — бәхетсез булу, мәгърифәтсезлек — бәхетле яшәү дигән фикер әсәрнең төп идеясенә әверелә. Мәгърифәтле, милләт өчен көрәшүче кешеләр борчу-газапта, башкалар мәнфәгате өчен хезмәттә, башкалар проблемаларын кайгыртып яшәргә дучар ителгән.

«Өмид» (1908) шигыре, Т. иҗатына хас булганча, риторик эндәш формасында язылган. Лирик герой «акыл кояшына» мөрәҗәгать итә, аннан дөньяны яктыртуын, җылытуын үтенә. Шигырь каршы куюга корылган, һәр тезмәдә капма-каршы куелган сурәтләр ярдәмендә караңгы бүгенге һәм «кояш»лы киләчәк бәяләнә. Аллага мөрәҗәгать вакытында кулланыла торган традицион гыйбарәләр өметнең кеше өчен иланһи булуын ассызыклый. Кеше акылын югары күтәрү, аның көчен бар нәрсәдән өстен санау чагылыш таба, акыл кояшы милләтне азатлыкка чыгарыр юл итеп аңлашыла. «Күңел» (1909) шигырендә риторик эндәш алымы б-н лирик герой күңеленә мөрәҗәгать итә, аны янарга, газапланырга, сызланырга чакыра. Өмет хисе күңелнең биектә калачагына, саф һәм кешелекле, ялкынлы һәм чыдам булачагына ышаныч кебек аңлашыла. Горурлану һәм үкенеч төсмерләре б-н күңелнең газаплары, авыртулары турында сөйләп киленә дә соңгы строфада төп фикер белдерелә: «Яхшы аңла! Юк сафа инсанлыгыңны җуймыйча, / И шушы җуймау юлында күп газапланган күңел!» — ягъни күңел үзенең кешелекләгән югалтканда гына рәхәткә чыга ала, аны югалтмас өчен газапланырга, янарга, телгәләнергә тиеш. Лирик герой үз күңеленең сызланачагына ышана, өметләнә, чөнки ул — башкаларны да үз артыннан ияртерлек көчле, бөеклеккә дә, биеклеккә дә ирешергә дәрманы булган, ләкин язмыш тарафыннан күп кыерсытылган, шулай да югарыга омтылган шәхес. Бигрәк тә күңелнең борчылып, газапланып яшәү ягы бүтәннәрдән үзгә итеп күрсәтелә. Шушы урында өметсезлекнең сәбәбе ачыла. Кешенең кешелеклелеген җую хисабына бәхетле була алуы лирик геройны борчуга сала. Күп кенә шигырьләрнең идеясе шушы принцип буенча белдерелә («Сәрләүхәсез», 1909; «Милли моңнар», 1909; «Өмид - сезлек», 1910 һ.б.). Аларда лирик геройның драматик, хәтта фа җигалеле кичерешләре халык тормышы, милләт тарихы б-н бәйләнгән; мәс., «Сәрләүхәсез» (1909) әдәбият-сәнгатьнең «хәсрәт көен» көйләргә тиешлеген искәртеп башлана: «Кызгатмакчы булсаң халык күңелләрен, / Тибрәтмәкче булсаң иң нечкә кылларын, / Көйләү тиеш, әлбәт, ачы хәсрәт көен, / Кирәк түгел мәгънәсе юк көлке, уен». Алга таба «ни өчен хәсрәт көе көйләү тиеш» булуның сәбәпләре ачыла. Икенче строфада лирик герой кеше гомерен «караңгы, күңелсез» дип атый, һәркемнең «җәрәхәтле күкрәгендә» кайгы булуны ассызыклый. Өченче строфа шушы фикерне үстерә, кайгыра белүне, гомумән, кешегә хас төп сыйфат итеп күтәрә: «Һич кайгысыз кеше булса — адәм түгел!». Дүртенче строфа яшәү шатлыгын кичерүнең хәмердән башка мөмкинлеген тапмау чарасызлыгын ача. Шулай итеп, дөнья, яшәеш камил түгел, кеше җиргә кайгы кичерү, газаплану өчен генә килә, димәк, тормышка каршы куелган кеше аны үзгәртә алудан гаҗиз, чарасыз, өметсез.

Шагыйрьне таныткан, аңа халык мәхәббәтен алып килгән шигырьләр — шиксез, гражданлык лирикасы үрнәкләре. Үз заманында «Татар шагыйрьләре» дигән мәгълүмәкаләсендә Ж.Вәлиди Т.ның шигарен, «Әхлакый, иҗтимагый түбәнлекләргә, хаксызлыкларга каршы» дип билгели. 1911 дән башлап шагыйрь иҗатында төп мотив — милләткә хезмәт итү — гади кешеләр образларына, татар җәмгыятендәге социаль хәлгә бәйле. Лирик герой, халыкның фа җигале хәле, социаль тигезсезлек турында кайгырып, кешелек язмышы хакында уйлана («Золым», 1911; «Сайфия», 1911; «Читен хәл»,1911; «Авыл халкына ни җитми», 1912; «Казан», 1913; «Хәстә хәле», 1913 һ.б.). Әйтик, халык язмышы өчен хәвефләнеп язылган «Көзге җилләр» (1911) шигыре көзге җил, туган җир, җир-ана, ил елавы кебек символик образга нигезләнә. Лирик геройның үксүе һәм көзге җилнең ыңгырашуы халыкның кайгысы, ачлык, иҗтимагый тигезсезлек б-н бәйле, бу елауда ил язмышы һәм кешенең кешелек алдындагы җаваплылыгы кебек мотивлар пәйда була.

Шагыйрьнең фәлсәфи лирикасында тормышның фа җигасен атлап чыгу һәрчак идеал б-н бәйләнгән. Нәкъ менә идеал аша Т. тормышның барлык күренешләрен, якларын бәяли. Әйдәп барган мотивы үткәннәр турында сагышлану булган шигырьләрдә тормыш икегә аерылган: лирик герой үзен бәхетле хис иткән чак һәм аның бәхетле булу мөмкин түгеллекне аңлау вакыты; мәс., «Бәйрәм вә сабыйлык вакыты» (1908), русчадан тәрҗемә итеп язылган «Исемдә» (1909) шигырьләрендә үткәннәрнең билгеләре идеаллаштырыла, аларның лирик герое бала чагын — бәхет көткән вакытын сагынуы хакында сөйли. «Исемдә» шигырендә «үткәннәр» билгеләре: саф һәм гөнаһсыз уен-көлке; якты бәхет көтү; беренче мәхәббәт; иланһи ләззәттән тамган яшь; ярату-яну «бүгенге»дәге салкынлык һәм битарафлыкка каршы куела. Инде бәхет килеренә өмете өзелгәнен, күңеле-йөрәгенең «мәңгелеккә салкын» булуын хәбәр итеп, лирик герой йөрәгенең тик истәлекләр б-н генә яшәвен әйтә. Шул рәвешле, кеше өчен балачак-яшьлек вакытының иң кадерле, гомер буе хәтердә яңарып, яшәргә көч бирүче вакыт булуы төп фикер төсендә формалаша. 6 строфадан торган шигырьдә 4 строфа үткәннәр хакында искә төшерә, соңгы 2 се исә бүгенгегә бәя бирә. Алар моң катыш үкенеч хисе б-н сугарылган. Әсәрдәге хәтер образы бәхетле вакытларны искә төшереп, яшәүне дәвам итәргә һәм сагышланырга мәҗбүр итүче кыйммәт төсен ала.

«Бәйрәм вә сабыйлык вакыты» шигырендә лирик герой Алладан бәйрәм көнне бала чагына кайтаруын үтенә. Бу әсәрдә дә үткәннәрнең билгеләре: уйнаулар, бәйрәм тәмнең, матур күлмәк, тәмле ризыкларга шатлану иң бәхетле мизгелләр сыйфатында гомумиләштерелә. Кеше бала чагында гына чын бәхетле була, дигән фикер алга сөрелә.

Идеал — үзен милләткә хезмәткә багышлаган кеше эзли торган хакыйкать; аның тормышны яктыртырга ярдәм итәрлек көч булуы хакында Т.ның күп кенә шигырьләрендә әйтелә. Тынгысыз, «гәүһәр кеби вөҗданлы» кеше идеалын Т. Х.Ямашев истәлегенә багышланган «Хөрмәтле Хөсәен ядкяре» (1912) мәрсиясендә, Ш.Мәржанигә һәм Г.Исхакыйга аталган «Шиһаб хәзрәт» (1913), «Улмы? — Ул» (1910), «Мөхәрриргә» (1906) әсәрләрендә күтәрә. Т. үзенең идеаль героенда халыкның тирәндәге потенциаль көчен гәүдәләндерергә омтыла.

Матди кыйммәтләргә каршы куелган хакыйкатьне яктырту өчен идеал уты эзләп киткән кешенең күңел халәте рухи хөрлеккә омтылыш буларак укыла («Дәһигә», 1913). Ул кешегә иң авыр минутларда таяныч булган һәм башкаларга ярдәм итәргә мөмкинлек биргән якты йолдызга тиңләштерелә («Күңел йолдызы», 1909):

Озайттылар миңа кул төрле мәлгунь көч,
кара көчләр,

Теләп сүндермәгә күңлемдә янган изге
йолдызны.

Вәләкин сүнмәде ул: йолдызым якты, һаман нурлы;

Гаҗәпме, юлга салса, ичмасам, бер данә юлсызны?

Т. каләме эчкерсез, саф, иланһи мәхәббәтне шигъри илһам («Мәхәббәт», 1908), бәхет чыганагы («Кулың», 1908), камилләшүгә этәргеч («...гә», 1908), ирешеп булмас идеал («Бер рәсемгә», 1908) һәм яшәү мәгънәсе («Иһтида», 1911) биеклегенә күтәрә. Ярату мотивы иҗат мотивы б-н кушылып китә. Шагыйрь фикеренчә, мәхәббәт тә, иҗат та — ила һи табигатьле. Табигать матурлыгына соклану мотивы өстенлек иткән, туган җир табигате идеаллаштырыла торган һәм гадәти күренешләрдәге матурлык ассызыкланган пейзаж лирикасында Т. табигатькә милли караш үзен -

чәлеген билгеләүгә ирешә («Ай һәм кояш», 1909; «Кышка бер сүз», 1909; «Җәйге таң хатирәсе», 1910 һ.б.). Табигатьнең матурлыгы тарихи үсештәге кырыслыкка каршы куела. Моннан тыш, тормышның ике катламлылыгы илаһи һәм җир, табигать һәм кеше каршылыгында чагылыш таба («Дошманнар», 1912).

Өмет — идеалның тагын бер чаткысы. Әгәр үткән — бәхетле вакыт икән, күңелсез бүгенге — өметләр өзелү вакыты, ул тәмуг, үлем б-н ассоциацияләнә («Өмидсезлек», 1910; «Теләү бетте», 1909). Мәрхәмәтлелек, өмет төсле үк, кешене иң авыр сынаулар вакытында яшәтә («Катиле нәфескә» (1910). Яшәешнең камил түгеллеге кешенең башкалар кайгысына сизгерлекне югалтуы б-н аңлатыла, ләкин башкалардан ярдәм көтүнең ялган булуын белдерүче шагыйрь кешенең, үз кайгысы турында сөйләп, ялгызлыктан арынуын, күңелен һәм уйларын чистартуын сөйли («Ачы тәҗрибә авазы», 1910). Шулай Т.ның иң фаҗигале шигырьләрендә дә мәхәббәтнең, мәрхәмәтлелекнең, матурлыкның, бәхет көтү мизгелләренең, өметнең көченә ышану көчле.

Т.ның фәлсәфи лирикасында төп мотивлардан булган фаҗигале ялгызлык һәм читләшү мотивы формалаша. Барыннан да элек ул битараф төркем уртасындагы ялгызлык төсен ала, аның сәбәбе — кешенең үзен рухи азатлык, милләтнең якты киләчәге, тормышны үзгәртү өчен көрәшкә багышлавында. «Кыйтга» (1913) шигырендә лирик герой гомеренең «кара көннәр»дән торган, дошманнары «эттән күбәйгән» пычрак дөньяда үтүен белдерә. Социаль яссылыкка күчереп, «өстеннәрне яклый» алмаганга тормыш авыр булу искәртелә. Шигырь үкенеч хисе б-н сугарылган. Аның иң югары ноктасы соңгы тезмәдә: «Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым». Көрәшнең нәтиҗәсен күрмәү хиснең югары дәрәҗәсен билгели. Шул ук вакытта «мин»-кешенең дөньяны агартырга омтылышы, гомерен шушы көрәшкә багышлавы әлеге үкенечкә горурлык хисе өсти.

Тәүбә һәм эчке үзанализга омтылыш мондый шигырьләрдә кризис — шәхси тормыштагы бәхетсезлек, дусларны югалту, кадерле булган барлык нәрсәләрне җую, тормыш максатына ирешеп булмаслыкны аңлау халәтенә барып ялгана. Әйтик, «Өзелгән өмид» (1910) шигырендә лирик герой яшьлеге үткәнне аңлау мизгелендә сурәтләнә. «Лирик герой образы белән тәңгәл килгән шагыйрь үз җисми яшәешенең һәм моңлы сазының, ягъни шигъриятенең кыска гомерле булачагын пәйгамбәрләрчә алдан сизә».

Шигырьдә үткәннең билгеләре булып килгән образлар бар: иҗат, күңел, мәхәббәт, милләт. Шушы дүрт образ идеал, өмет дигән баш астына берләшә. Лирик геройның идеалы — иҗат итү; иҗат ярдәмендә — күңел кошы милли агачлар өстенә кунып, аларны җанландыру — милләтне терелтү; җи һәнны үзгәртү; үз тормышында яктылык табу. Яшьлеге узган лирик герой әлеге идеалның, өметнең җимерелүен, тормышка ашмаячагын аңлап үкенү ноктасында тора. Шул идеалга каршы куелган символ — ананың кабер ташы. Хыялларын тормышка ашыра алмыйча, кешенең яшьлеге узганын; яшәешнең өметләрне аклардлык түгеллеген; тормышының иҗаттан, мәхәббәттән, милләт бәхетеннән, рух хөрлегеннән башка мәгънәсе юклыгын аңлап, иң юга-ры кыйммәт төсендә кабер ташына мөрәҗәгате әсәрдәге фәлсәфәне хасил итә. Кабер ташы б-н чагыштырганда алдагылары узгынчы, вакытлы кыйммәтләргә әверелә. Кабер ташы яшәештәге ана-бала арасындагы дәвамчанлыкның, тормышның өзелмәс-тукталмаслыгын, яшәүнең ниндидер олы, шушы дәвамчанлык б-н бәйле мәгънәсен беренче планга чыгара; кешенең үз эш-гамәлләре б-н (лирик герой идеалларын күрсәтү аша) шушы олы кыйммәткә лаек булырга тиешлегенә дә ишарә бар. Читләшү, үз-үзеңә йомылу тормышның яшерен, бөек максатын аңлауга алып килә.

Читләшү проблемасы мотивы иҗат, шагыйрь һәм поэзиягә багышланган шигырьләрендә дә үзәктә тора («Шагыйрь», 1908; «...гә (Ядкяр)», 1908; «Пәйгамбәр», 1909 һ.б.). Т.ның «Шагыйрь» (1908) шигырендә лирик герой поэзиягә нисбәтле яшь («Күңлем минем япь-яшь калыр, һич картаймас»), көчле («Җаным көчле булып калыр, хәлдән таймас»), куәтле («Күтәрәм мин, карт булсам да, авыр тауны»), өмет б-н тулы («Шагыйрь күңелендә кыш булмый да кар яумый»), эшлекле («Утырмам тик юк-бар теләк тели-тели»), башкаларга җылы таратучы («Менмәмен мин, Ходай күшса, мич башына»), башкалар хәлен кайгыртучы («Җырлый-җырлый үләрмен мин үлгәндә дә)» булачагын сөйли. Әлеге сыйфатлар халыкны үз артыннан ияртүче пәйгамбәргә хас. Нәкъ менә поэзиянең — лирик геройны башкалардан аерып куя торган билге, аның Алладан килә торган язмыш бүләге булуы искәртелә.

«Пәйгамбәр» (1909) шигыре шартлы рәвештә ике өлешкә бүленә: беренчесендә мин-пәйгамбәр үзе хакында сөйли, икенчесендә башкаларның үзенә мөнәсәбәтен күрсәтә. Структурасы б-н шигырь традицион пәйгамбәрләр тарихына охшый. Дини-суфичылык әдәбиятыннан таныш гыйбарәләр (аять уку, мәхәббәткә өндәү, гарше әгълага багу, нәби-кол һ.б.) «Лермонтовтан үзгәртелгән» шигырьне шәрекъ мәдәнияте чикләренә урнаштыра, ислам динендәге пәйгамбәрләр б-н ассоциацияләр уята.

Шигырьдә пәйгамбәрлекнең берничә сыйфаты аерып чыгарыла: пәйгамбәрлек Алладан бирелә; пәйгамбәр кешеләрнең гаебен күрсәтә, «ялкынлы аятьләр» укый; мәхәббәткә өндәү; ялгыз, читкә тибәрелгән; сахрада яши; хакыйкатькә төшенгән; бөтен тереклек аңа баш ия. Икенче өлештә халыкның пәйгамбәргә ышанмавы кискен гыйбарәләрдә кешеләрнең сүзләре кебек китерелә: «Ышандыр-макчы булды ул җүләр! — безне, имеш, Тәңре / Аның аузы белән сөйли, аңар килгән, имеш, әмре!» Кешеләрнең пәйгамбәргә баш игән җанварларга, йолдызларга каршы куелуы җәмгыять хәленә бирелгән тискәре бәяне көчәйтә. Кешеләр — Алла сүзен ишетүдән, олылаудан туктаган, көтү булып кына яши алучы («Тәкәббер ул: торасы килмәде безнең арамызда...»), матди байлыкларны өстен күрүче («Күрәмсез, нинди беткән һәм арыкланган, фәкыйрьләнгән, / Зәгыйфьләнгән, таланган, өсте-башы нинди керләнгән!»). Болар лирик геройның сызлану сәбәбенә әверелә.

Т.да Аллага мәхәббәт, дога уку, Коръән мотивларына мөрәҗәгать итеп язылган шигырьләр шактый зур урын алып тора. Позняковтан үзгәртелгән «Киңәш» (1909) шигырендә иң кадерле нәрсәләрен җүеп газаплану-чыга мөрәҗәгать итеп, шагыйрь аны кайгырмаска өнди. Соңгы юллары дини фәлсәфәне кабатлый: кешегә ярдәмгә һәрчак Алла килә! Кешенең Алла кушканча, Алла теләгәнчә яшәве хакындагы мәгълүм фикер шигъри формага төреп китерелә: «Түкмә күз яшь: ярдәмендә һәр заманда Алла бар; / Ал җәсарәт, алга омтыл, һич ялыкмый алга бар!». «Ана догасы» (1909) шигырендә улына Алладан бәхет сораучы ана образы тудырыла. Төнге тыныч авыл, йоклап беткән өйләр фонында намазлыкта утыручы карчык самими, ихлас, чын күңеленнән Аллага ышанган, аңа омтылучы булып күз алдына килеп баса. Лирик геройның соңгы строфадагы соравы аның да догалар кабул булуына ышанычын раслау булып яңгырый: «Тамадыр мискинәмнең тамчы-тамчы күзләреннән яшь; / Карагыз: шул догамы инде Тәңре каршына бармас?» Шигырьдә өстенлек иткән соклану хисе тирәлекнең тыныч матурлыгына да, догада утыручы карчыкның ихласлыгына да юнәлтелгән. Ләкин иң әһәмиятлесе: бу хис гомумән кеше күңелендәге Аллага ышанычның изгеленеген ассызыклый. «Таян Аллага» (1909) шигыре лирик геройның яшь балага риторик эндәше кебек язылган, традицион дини әсәрләр структурасында. Лирик герой укучысына Аллага таянырга, ышанырга, аннан юл күрсәтүен сорарга, дога кылырга куша. Шигырьнең эчтәлеге — соклану хисе, аның сәбәбе икә яклы: бер яктан, баланың сафлыгы булса («Пакь җаның һәм пакь тәнең — барлык вөҗүдең пакь синең; / Син фәрештә валчыгысың, йөзләрең ап-ак синең»), икенче яктан, Алланың бөеклеге. Ул шигырьне каймалап, «Рәхмәте бик киң аның, һәр дәм таян син Аллага!» тезмәсе кабатлану аша көчәйтелә.

Т.ның «Нәсыйхәт» (1910) шигырендә Хозыр Ильяс хакындагы дини миф уйнатыла. Мәгълүм ки, дини-суфичыл әдәбиятта Хозыр Ильясның кешеләрне сынау өчен теләнче киемендә капкаларын кагуы, үзенә ярдәм иткәннәргә мог җизалар ирештерүе хакындагы мотив бик киң таралган. Укучысына нәсыйхәт бирүче, теләнчеләргә ярдәм итәргә кирәклекне сөйләүче лирик герой, нәкъ традицион әсәрләрдәгечә, кисәтеп куюны кирәк таба: «Булса — бир, булмас исә, җайлап сөйлә булмаслыгын,— / Сизми калма ак сакаллы карт Хозыр Ильяслыгын!» Шигырь эчендә берничә фәлсәфи фикер әйтелә: кешеләр тигез («Син кеби һәм ул теләнчеләр дә — Алланың колы»); дөнья кеше өчен авыр («...бу вафасыз дөньяны»); тормыш үзгәреп тора («Әйләнә, көпчәк кеби, байлык вә шөһрәт, мәртәбә:/ Син бүген бай, бәлки шәйтаннан да ярлы иртәгә!»); һәр кешедә изгелек, илаһилык башлангычы бар. Шагыйрьнең «Мигъраҗ»

(1910), «Кадер кич» (1911) кебек шигырьләре дә дини фәлсәфәне белдерә, дини күзаллаудагы аерым күренешләрне иҗади тергезә. Хәтта соңгы шигырьләреннән булган «Тәфсирме? Тәр җәмәме?» (1913) ислам тәгълиматындагы берничә хакыйкатьне кабат лап язылган. Алла теләгенә каршы килер көч юк; кешеләр Алла исеме б-н туры юл таба; Ходайга рәхмәт укы, тәүбә кыл — шигырьнең 3 строфасы шушы 3 фикерне белдерүгә хезмәт итә.

Татар әдәбиятында беренчеләрдән булып Т. махсус рәвештә халык авыз иҗатының эстетик принципларын, аның язма әдәбият б-н бәйләнешләрен өйрәнүгә керешә. 1910 да танылган Шәрекъ клубында шагыйрь «Халык әдәбияты» дигән лекция укый, «Яшәсен халык әдәбияты, яшәсен туган тел!» лозунгын күтәрә. Үз иҗатында халык әкиятләренең сюжет схемаларын («Шүрәле», 1907; «Су анасы», 1908; «Кәжә белән сарык хикәясе», 1910 һ.б.), халыкның дөньяга карашы һәм дөньяны чагылдыру үзенчәлеген («Милли моңнар», 1909), татар фольклорына хас образларны һәм детальләрне, сурәтләү чараларын («Пар ат», 1907), «Эштән чыгарылган татар кызына», 1909) файдалана, халык җырларына охшатып стильләштерә («Авыл җырлары», 1908). Халык авыз иҗаты традицияләренә таянып, Т. татар шигъриятенең өслүбен һәм формасын тулысынча үзгәртүгә ирешә, милли әдәби-шигъри телне тудыручыга әверелә. Тукай иҗатында борынгы традицияләр аның заманына хас иҗади аң, аның билгеләре һәм кыйммәтләр системасы б-н тәңгәлләшә. Шуның б-н бергә, Шәрекъ әдәбияты контекстында таныла торган традицион структуралар һәм образлар, мотивлар, детальләр иҗади хәтерне, ш.и., жанр хәтерен яңарту чарасына әверелә. Т.ның гражданлык, мәхәббәт, пейзаж лирикасы шәрекъ жанрлары газәл, касыйдә, мәрсияләргә хас сыйфатларны да саклый. Ләкин аларны, барыннан да элек, 20 йөз башы формалаштырган милли идеяне белдерү өчен файдалана.

Т. әдәби тәнкыйть, публицистика, балалар әдәбияты өлкәсендә актив эшли. 1909 елны автобиографик характердагы «Исемдә калганнар» әсәренә керешә. Рус теленнән Байрон, Гёте, Гейне, Шиллер, Пушкин, Лермонтов, Крылов һ.б. шигырьләрен тәр җәмә итә. Башка төрки телле әдәбиятлар үсешенә зур йогынты ясый.

Әсәр.: Әсәрләр: 5 томда. К., 1985–86; Избранное: В 2 т. К., 1961.

Әд.: Ганиева Р.К. Шагыйрьнең рухи дөньясы. К., 2002; Лаисов Н. Габдулла Тукай. К., 1985; Ганиева Р.К. Сатирическое творчество Тукая. К., 1964; Нигматуллина Ю.Г. Национальное своеобразие эстетического идеала. К., 1970; Нафигов Р.И. Наш Тукай. К., 1998; Фридерих М. Габдулла Тукай как объект идеологической борьбы. К., 2011; Габдулла Тукай. Энциклопедия. К., 2016.

Д.Ф.Заһидуллина.

ТУКА́Й ГАБДУЛЛА́ ӘДӘБИ́ МУЗЕ́Е, Казанда. ТАССР МСның 1984 ел 4 июль карары нигезендә ТАССР Дәүләт музее (2001 дән — ТРның Милли музее) ф-лы хокукында оештырыла. Шагыйрьнең 100 еллыгына туры китереп, 1986 ның 11 июнендә





Казанда Габдулла Тукай әдәби музее.
1. «20 йөз башында Казанда әдәби салон» интерьеры; 2. Экспозиция фрагменты.

ачыла. Иске Татар бистәсендә *Шамил йорты* исеме б-н билгеле ике катлы бинада урнашкан. Экспозициянең фәнни концепциясе авторы — ТАССР Берләштерелгән дәүләт музее фәнни хезмәткәре Д.Б.Баһаветдинова, сәнгать проекты җитәкчесе Б.А.Глазков (Ленинград). Экспозиция мәйданы 630 $м^2$, музей фондларында 1200 ләп саклау берәмлеге исәпләнә. Экспозициянең Г.*Тукайның* тормышына һәм иҗатына багышланган төп өлеше икенче катның 4 залында урнашкан. «Тукайның балачагы» залындагы «Зиннәтулла бабасының почмагы» авыл мулласының яшәү рәвеше б-н таныштыра. Шагыйрьнең атасы Мөхәммәтгариф мулла 1886 ның 26 апрелендә улы Габдулла тууын үзе теркәп куйган метрика кенәгәсеннән бер бит; Габдулла 4,5 айлык чагында мулланың үзенең вафаты хакындагы документ; Г.Тукайның бабасы Зиннәтулла Әмировның шәхси китапханәсеннән үз билгеләрен куйган китаплар (ш.и. «Пәйгамбәрләр тарихы», 5 томда, 19 йөз ахырында Мисырда нәшер ителгән), кызы — Габдулланың әнисенең үлеменә (1890) багышлап язылган шигырьләр тәкъдим ителгән. Кибет күренеше Казандагы Печән базарын хәтерләтә, анда малайны асрамага бирер өчен алып киләләр. 19 йөз ахырындагы Казан күренешләрен сурәтләгән фоторәсемнәр Яңа Татар бистәсен күз алдына китерә, анда Габдулла үги әти-әнисе б-н яши. Экспозициянең икенче бүлеге Уральск шәһәренә багышланган, анда Тукай 12 ел яши (1895–1907). «Мотыгия» мәдрәсәсендә һәм аның каршындагы рус классында уку дәвере б-н уку йортының эчке күренеше, дәресләр тәртибе, глобус, «Әлгасрелҗәдид» кулъязма ж-лыннан Тукайның мәдрәсәдә укыган елларында язган беренче шигыре басылган бит таныштыра. Экспозициягә мәдрәсә бинасының һәм шагыйрьнең укытучылары М.Төхфәтуллин, А.Сиражетдинов, М.Чулпаныйның фоторәсемнәре; Тукай Уральскида укыган А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов, И.А.Крылов, А.В.Кольцов, В.А.Жуковский әсәрләре куелган. Тукайның тормышка карашы формалашуга йогынты ясаган Төхфәтуллиннар гаиләсенең мемориаль әйберләре тәкъдим ителә. Шагыйрь К.*Мотыйгый* нәшер иткән «Фикер» г-тасында, «Уклар» ж-лында эшли, шунда аның беренче әсәрләре басыла. «Казан чоры» бүлегендә 20 йөз башындагы татар әдәби салонының эчке күренеше тәкъдим ителә. Андагы бөтен предметлар — мемориаль (музейга Ф.Әмирхан, Х.Ямашев, Г.Коләхмәтов туганнары бүләк итә). Казандагы Тукай экспедитор булып эшләгән китап кибетенең һәм шагыйрь яшәгән «Болгар» кунакханәсенең 40 нчы бүлмәсенең эчке күренеше торгызыла. Тукай әсәрләренең беренче басмалары, «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасына иллюстрацияләр экспозициягә куелган. «Тукайның сәяхәтләре» залында шагыйрьнең Сембер губернасына фабрикант Акчуриннар утарына, Түбән Новгородка, Әстерханга, Уфага, Петербургка сәфәре б-н бәйле материаллар; төрле шәһәрләрдә татар телендә нәшер ителгән газеталар, журналлар; Тукайның хатлары; Казанның Клячкин хастаханәсендә төшкән соңгы фоторәсемнәре; некрологлар, шагыйрьнең үлгәннән соң алынган гипс битлеге тәкъдим ителгән. «Тукай һәм хәзерге заман» бүлегендә шагыйрьнең төрле телләрдә басылып чыккан әсәрләре, Тукай әсәрләре буенча куелган театр спектакльләренең афишалары (Ф.Яруллинның «Шүрәле», Ә.Бакировның «Су анасы», Р.Гобәйдуллинның «Кисекбаш» балетлары), аның турында китаплар урнаштырылган. Музейда «Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреатлары» тематик күргәзмәсе бар. Музейның күргәзмәләр залында ТРның Милли музее фондларыннан һәм шәхси коллекцияләрдән вакытлы күргәзмәләр эшли. Аеруча кыйммәтле экспонатлар арасында — Г.Тукайның төрле еллардагы фоторәсемнәре (1908–1913), кара бәрхәт түбәтәй, апасы Газизәгә беренче гонорарыннан бүләк иткән фаянс шкатулка, Петербургның 200 еллыгына бокал рәвешендә чыгарылган карандаш савыты, Петербургтагы татар мәктәпләре укучыларының бүләге — бронза кара савыты, юл кәрҗине, көмеш запонкалар. Музей каршында «Казан татарлары», «Туган тел» клублары эшли. «Тукай һәм аның замандашлары», «Тукай һәм аның мохите», «Белем бакчасында», «Мәгърифәт учагы» чаралар циклы, «Мияубикә кунакка чакыра», «Шүрәленең туган көне», «Исемдә калганнар», «Сабантуй мизгелләре», «Аулак өй», «Туган тел бәйрәме», «Әлифба бәйрәме» музей дәресләре үткәрелә. Ел саен Г.Тукайның туган көне (26 апрель) һәм Халыкара музейлар көне (18 май) билгеләп үтелә. Музей директорлары: Г.Ә.Хәбибуллин (1986–92), Ф.З.Яхин (1992–2000), М.Т.Низамиев (2000–04), Р.К.Аймәтов (2004–2013), Г.С.Төхфәтова (2013 тән).





Арча районының Яңа Кырлай авылында Габдулла Тукай музей-комплексы.
1. Комплексның баш бинасының гомуми күренеше; 2. Экспозиция фрагменты; 3. Сәгъди йортында.

Әд.: Татарстанда Габдулла Тукай музейлары: Сәяхәтнамә = Музеи Габдуллы Тукая в Татарстане: Путеводитель. К., 2006; Музей Г.Тукая: Путеводитель. К., 1989; Все музеи Казани: Справ.-путеводитель. К., 2004; Музей Г.Тукая: Буклет. К., 2006.
Р.К.Аймәтов.

ТУКА́Й ГАБДУЛЛА́ МУЗЕ́Е, Казакъстан Респ-касының Уральск шәһәрендә. 2006 елның 12 декабрендә РФнең һәм Казакъстан-ның татар җәмәгать оешмалары башлангычы б-н ачыла, Уральск шәһәренең Татар мәдәни үзәге карамагында. Музейны оештыруда Г.Тукай исем. Уральск татар иҗтимагый үзәге рәисе Р.А.*Әбүзәров*, эшмәкәр Р.У.Хәйруллин, Көнбатыш Казакъстан өлкәсенең тарих-төбәкне өйрәнү музее директоры С.Е.Танабаева, ТРның Милли музее директоры урынбасары А.Д.Хәйруллина катнашалар. «Старый Уральск» музее хезмәткәрләре зур ярдәм күрсәтәләр. Т.Г.м. Г.*Тукайның* остазы М.*Төхфәтуллин* йортында урнаша. Экспозициянең мәйданы 170 *м*², музей фондларында 400 саклау берәмлеге исәпләнә. Музей экспозициясендә — дүрт залда урнашкан 4 бүлек. «19 йөз ахыры — 20 йөз башы Уральск шәһәре татарларының тормышы һәм көнкүреше» бүлеге шәһәр халкының көнкүреш предметлары, тормыш тәртибе б-н таныштыра. Г.Тукайның тормышы һәм иҗатына багышланган бүлектә М.Төхфәтуллинның эш бүлмәсе күренеше торгызылган. Тукайның балачагы, Уральскийдагы тормышы һәм иҗади эшчәнлеге, шагыйрь гомеренең Казандагы соңгы еллары турында материаллар тәкъдим ителгән. Экспозициянең бер бүлеге Уральск шәһәрендә туган фән һәм сәнгать эшлеклеләренә, дин әһелләренә багышланган. Әлеге йортта туып үскән ТАССРның халык артисткасы Г.М.Кайбицкаяның, тарихчы Р.И.Нәфыйговның, комп. Н.Г.Җи һановның, скульптор Х.Ж.Шәмсетдиновның, шәһәр мәчетләренең имамнары Габдерәкыйп һәм Мөхәммәтгариф Толбаевларның һәм Гайнетдин Җәләлетдиновның шәхси әйберләре куелган. Экспозициянең бер өлешен — 1906–07 дә шушы йортның подвалында урнашкан басмаханә күренешен булдыру өчен экспонатлар туплау дәвам итә. Әлеге басмаханәдә «Уральский дневник», «Фикер» г-талары, «Әлгасрелҗәдид» һәм «Уклар» ж-ллары нәшер ителә. Музейда ел саен М.Җәлилне искә алу көне (15 февраль), Поэзия көне (26 апрель), Халыкара музейлар көне (18 май) билгеләп үтелә. Музей директоры — М.Р.Баһаветдинов (2006 елдан).

ТУКА́Й ГАБДУЛЛА́ МУЗЕ́Й-КО́МПЛЕКСЫ, Арча р-нының Яңа Кырлай авылында әдәби-мемориаль музей. Беренче музей экспозициясен 1960 елларның 2 нче яртысында авыл китапханәсе бинасында, авыл советы рәисе В.В.Вафина һәм китапханәче А.Н.Шакированың актив катнашы б-н Х.Х.Хәбриева оештыра. Музей җәмәгать башлангычында эшли, Казандагы А.М.Горький әдәби-мемориаль музее ф-лы буларак 1971 дә дәүләт статусы ала, 1976–2006 да ТАССРның Дәүләт музее (2001 дән ТРның Милли музее) ф-лы, 2007 дән ТРның Мәдәният министрлыгы карамагындагы мөстәкыйль учреждение. ТАССР МСның «Габдулла Тукай мемориаль үзәгенең алга таба үсеше, архитектура-сәнгать ягыннан эшләнеше һәм Яңа Кырлай авылын төзекләндерү буенча чаралар турында»гы 1978 ел 7 декабрь карары нигезендә рәссам Б.Урманче проекты буенча музей комплексы биналары төзелә (яңа экспозиция 1979 елның 25 апрелендә ачыла). 2006 да, Г.Тукай тууының 120 еллыгына туры китереп, музейда реконструкция үткәрелә. Экспозиция ике агач бинада урнашкан: мемориаль-көнкүреш экспозициясе — 1892–94 тә Г.Тукай-Апушны тәрбияләгән крәстиян Сәгъди Салиховның яңадан торгызылган (1976) йортында, әдәби-сәнгать экспозициясе — махсус төзелгән (1978) ике катлы бинада. Экспозициянең гомуми мәйданы 672,9 *м*², музей фондларында 900 гә якын саклау берәмлеге исәпләнә. Булачак шагыйрь Кырлайда игенче хезмәте б-н таныша, Фәтхерахман мулла мәдрәсәсендә укый. Әйтүенә карганда, Кырлайда аның «дөньяга күзләре ачыла». Шагыйрьне тәрбиягә алган атасы йортындагы мемориаль күренеш 19 йөз ахырындагы асыл типологик предметлар нигезендә торгызыла. Экспозициянең әдәби-сәнгать өлеше беренче катта урнашкан, өч бүлектән тора: «Шагыйрьнең балачак еллары», «Уральск», «Казан чоры». Икенче каттагы ике залда Г.Тукайның тормышына һәм иҗатына багышланган сынлы сәнгать әсәрләре тәкъдим ителә.

Иң кыйммәтле экспонатлар — Тукайның якын кешеләре: апасы Газизә Зәбировананың, Хөсәен Ямашев, «Мотыйгия» мәдрәсәсе мөдәррисе М.Төхфәтуллин гаиләсенең әйберләре; Г.Тукай яшәгән «Болгар» кунакханәсе җиназлары; 1905–07 елларда Уральск шәһәренә Тукай наборщик булып эшләгән басмаханәдән китап басу станогы; ул нәшер иткән, хезмәттәшлек иткән газета-журналлар; үзе исән чагында нәшер ителгән басмалар. Комплексның баш бинасы каршында Г.Тукайга һәйкәл куелган (скульпторы — Б.Урманче). Ел саен Поэзия көне билгеләп үтелә (26 апрель).

Музей директорлары: Р.М.Гарипова (1971–73), Р.Х.Якупов (1973–78), Б.В.Антонов (1978–83), Д.А.Шакиров (1983–2000), Г.Ф.Лотфуллин (2000–01), Д.З.Абдуллин (2001–06, 2006–14), Т.К.Гомәров (2006, 2014 тән).

Әд.: Татарстанда Габдулла Тукай музейлары: Сәяхәтнамә = Музеи Габдуллы Тукая в Татарстане: Путеводитель. К., 2006; Музей Тукая в Кырлае. К., 1984.

ТУКА́Й ГАБДУЛЛА́ ҺӘЙКӘЛЕ́, Казанда. Бөек татар шагыйрен монументаль скульптурада чагылдырган иң уңышлы һәйкәлләрнең берсе. 1958 елда куела. Авторлары — скульпторлар С.С.Ахун, Л.Е.Кербель, Л.М.Писаревский, арх. Л.Н.Павлов. Һәйкәлнең гомуми биеклеге 10 *м* га якын. Бронзадан коелган фигура (биеклеге 4 *м* дан артык) халык шагыйренең тирән психологизм һәм героик-романтик күтәренкелек катнаш образын чагылдыра. Кулларына ачылган китап тотып жи ңелчә ашкыну б-н борылган гәүдә, энергияле йөз-кыяфәт — бөтен торышы бу дөньядан яшьли киткән шагыйрьнең рухи көчен, иҗатының тормышчан характерын чагылдыра. Скульптура ниятнең аныклыгы, образның ачыклыгы, пластик гомумиләштерүнең кыскалыгы һәм экспрессиясе б-н аерылып тора. Кара лабрадорит постаменты скульптурага тулысынча тәңгәл китереп эшләнгән. Квадрат нигезгә урнаштырылган скульптура өчпочмаклы кисемнәр аша салмак кына сигезкырлыкка күчә (Болгар архит-расы һәйкәлләреңә хас конструктив чишелеш). Постаментның аскы өлеше шагыйрьнең рус һәм гарәп шрифты б-н татар телендә уеп язылган исеменә ятышып торган татар бизәге б-н әйләндереп алынган. Һәйкәл Г.Тукай мәйданы янындагы скверда урнашкан.
А.В.Гарзавина.

ТУКА́Й авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 19 *км* көньяк-көнбатыштарак урнашкан. 2010 елда 33 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1930 елларда нигез салына. Оешкан көненнән Тельман р-нында. 1958 нең 16 июленнән — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1938 дә — 162, 1949 да — 129, 1958 дә — 120, 1970 тә — 114, 1979 да — 99, 1989 да — 62, 2002 дә — 38 кеше.

ТУКА́Й посёлогы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 45 *км* көньяктарак, Иж елгасыннан 4 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 78 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб. Мәчет. 1923 тә нигез салына. Беренче исеме — Вязовой Ключ. Оешкан көненнән ТАССРның Әгерҗе кантоны Көчек волостенда, 1924 тән Алабуга кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартын - нан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1926 да — 35, 1938 дә — 81, 1958 дә — 46, 1970 тә — 41, 1989 да — 102, 2002 дә — 83 кеше.

ТУКА́Й авылы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 50 *км* төньяк-көнбатыштарак, Мордвасу елгасы бассейнында. 2010 елда 28 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. 1920 елларда нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Зөя кантоны Тәмте волостенда. 1927 нең 14 февраленнән — Тәмте, 1931 нең 20 октябреннән — Кама Тамагы, 1935 нең 10 февраленнән — Тәмте, 1958 нең 16 ию - леннән Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Ка - ма Тамагы р-нында. Халык саны: 1926 да — 141, 1938 дә — 214, 1949 да — 100, 1958 дә — 188, 1970 тә — 169, 1979 да — 117, 1989 да — 70, 2002 дә — 39 кеше.

ТУКА́Й авылы, Менделеев р-нында, Мен - делеев шәһәреннән 25 *км* төньяк-көнчыгыш - тарак, Чөмән елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 15 кеше (татарлар) яши. 1930 ел - ларда нигез салына. Оешкан көненнән Бондюг р-нында. 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1985 нең 15 августыннан Менделеев р-нында. Халык саны: 1938 дә — 217, 1949 да — 248, 1958 дә — 195, 1970 тә — 110, 1979 да — 50, 1989 да — 26, 2002 дә — 19 кеше.

ТУКА́Й посёлогы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 15 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Самара өлкәсе б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 70 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Мәчет. 1920 елларда нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Чистай кантоны Егоркино волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Октябрь (1997 нең 10 декабреннән — Нурлат) р-нында. Халык саны: 1938 дә — 102, 1949 да — 129, 1958 дә — 73, 1970 тә — 141, 1979 да — 120, 1989 да — 53, 2002 дә — 47 кеше.

ТУКА́Й авылы, Спас р-нында, Болгар шәһә - реннән 42 *км* көнчыгыштарак, Болгар-Базар - лы Матак автомобиль юлыннан 2 *км* ерак - лыкта урнашкан. 2010 елда 257 кеше (татар - лар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчы - лык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. 1928 дә нигез салы - на. Оешкан көненнән ТАССРның Спас кан - тоны Спас волостенда. 1930 ның 10 авгус - тыннан — Спас, 1935 нең 1 апреленнән — Куйбышев, 1991 нең 4 октябреннән Спас р-нында. Халык саны: 1938 дә — 323, 1949 да — 332, 1958 дә — 336, 1970 тә — 445, 1979 да — 361, 1989 да — 276, 2002 дә — 287 кеше.

ТУКА́Й посёлогы, Чирмешән р-нында, Чир - мешән авылыннан 23 *км* көнбатыштарак, Олы Сөлчә елгасы буенда. 2010 елда 52 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Мәчет. 1920 ләрдә нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Чистай кантоны Котыш волостенда. 1930 ның 10 авгус - тыннан — Беренче Май, 1963 нең 1 феврален - нән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Чирмешән р-нында. Халык саны: 1926 да — 134, 1949 да — 159, 1958 дә — 130, 1970 тә — 141, 1979 да — 123, 1989 да — 68, 2002 дә — 65 кеше.

«ТУКА́Й», Тукай р-нындагы кошчылык ф-касы. Аның төзелеше («Чаллы» исемен - дә) 1978 елда башлана, 1981 дә «Т.» итеп үз - гәртелә. 1992 дән АҖ, 2003 тән «Чаллы-бройлер» ҖЧҖ составында. 1980 дә 1 нче чира - ты файдалануга тапшырыла (елына 2,6 млн. баш бройлер), 1981 дә — 2 нче чираты (2,65 млн.), 1982 дә — 3, 4 нче чиратлары (1,85 млн. һәм 3,5 млн. баш) — барлыгы 10,6 млн. баш бройлер, елына 14 мең *т* кош ите җитештерелә. Фабрика составында 24 цехлы инкубаторий, 50 мең баш кош өчен — 4 бина (25 мең баш — үрчем тавыклары өчен — 8 бина), сәнәгать көтүе (12 ябык бина), кош сую (сәгатенә 6 мең баш), азык (тимер юл б-н), ыслау, эшкәртү цехлары. 1987 дә пр-тие проектта каралган егәрлегенә чыга. Ит (мең *т*) һәм йомырка сату (млн. дә - нә) 1990 да 16,3 һәм 10,3, 1993 тә 17,5 һәм 11,1, 2003 тә 13,1 һәм 41 тәшкил итә. Фабри - ка КПСС УК, СССР МС, ВЦСПС һәм ВЛКСМ УКларының Мактау грамоталары һәм күчмә Кызыл байрагы (1985–86), (1988–89), СССР ВДНХсының ике алтын, бер көмеш һәм бер бронза медале б-н бүләк - ләнә. Җитәкчеләре: Усанов А.А. (1978–79), Сабитов Х.Х. (1979–85), Филатов Г.И. (1985–2002), Хисамиев М.Х. (2002–03).

Б.А.Канеев.

ТУКА́Й РАЙОНЫ́, ТРның төньяк-көнчы - гышында урнашкан. Мәйданы — 1743,9 *км*². 23 авыл җирлеген, 88 торак пунктны бер - ләштерә. Үзәге — *Чаллы* шәһәре. 2018 елда 40633 кеше (район үзәген кертмичә; 2002 ел - гы халык исәбе буенча, татарлар — 74,7%, руслар — 21,9%) яши. Халыкның уртача ур - нашу тыгызлыгы — 1 *км*² га 22,8 кеше. 1930 ның 10 августында Чаллы р-ны буларак оеш - тырыла. 1920 гә кадәр район терр-ясе — Уфа губернасының Минзәлә өязенә, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонына керә. Оеш - кан вакытында район составында 66 авыл советы, 142 торак пункт була, аларда 78408 кеше (татарлар — 49795, руслар — 28577) яши. Чаллы р-ныны кикләре һәм адм. бүленеше берничә тап - кыр үзгәрә. 1935 тә терр-ясенең бер өле - ше кабат оештырылган Ворошилов һәм Зәй р-ннарына кушыла. 1940 та район 1706 *км*² җир били, халык саны — 54,6 мең кеше, 33 авыл советы, 87 торак пункт була. 1960 та районның мәйда - ны — 1744,7 *км*², аңа 1 шәһәр һәм 14 авыл советы, 88 торак пункт керә. 1963 нең 1 февралендә, ТАССРда адм. берәмлекләр эреләндерелү сәбәпле, Чаллы р-ны составына Зәй һәм Ширә - мәт р-ны биләмәләренең бер өлеше күчә. Мәйданы — 3753 *км*², халык саны — 78 мең ке - ше, авыл советы — 29, торак пунктларның саны 191 гә җитә. 1965 нең 12 гыйнварында район терр-ясенең бер өлеше яңа оештырыл - ган *Түбән Кама районына* кушыла, мәйданы 2214 *км*² га кадәр кими, халык саны — 65,3 мең кеше, 2 посёлок советы, 21 авыл советы, 123 торак пункт кала. 1972 нең 1 ноябрендә районның бер өлеше кабат торгызылган Зәй р-нына бирелә. 1976 ның 20 апрелендә Чал - лы р-ны Т.р. итеп үзгәртелә. 1982 дә район - ның мәйданы — 1751 *км*², халык саны — 26,7 мең кеше, 22 авыл советы, 88 торак пункт исәпләнә.

Т.р.ның рельефы — көньяктан төньякка та - ба авыш тигезлек (биеклеге 100–200 *м*). Кама елгасы (Түбән Кама сусаклагычы) һәм кушыл - дыклары Чаллы, Шилнә, Мәләкәс һ.б. елга - лар ага. Җирләре — күбесенчә селтесез кара, көр - рән-соры, кара болын һәм соры урман туф - раклы. Терр-ясенең 12,3% — урманлык. Из - вестьташ, бентонит, балчык, ком, вакташ, кө - рән күмер ятмалары бар. Саклаулы табигать истәлекләре: *Боровецкий чишмәләре* һәм *Түбән Кама милли паркы*. Район терр-ясендә не - олит, бронза, әүвәлге тимер гасырлар һәм бол - гар чорына караган 60 тан артык археол. истә - лек табыла. Сәнәгать пр-тиеләре, район үзәген - нән тыш, Сосновый Бор авылында («Кама бе - коны» АҖ) урнашкан. Урман хуҗалыгы. Мө - гезле эре терлек, дуңгыз асрау, кошчылык тар - маклары алга киткән. Ә.х. 100,8 мең *га* җир би - ли, ш.и. сөрүлекләр — 82,7 мең *га* (2016). Са - бан бодае, көзге арыш, арпа, солы игелә; бә - рәңге, яшелчә үстерелә. 2016 елда Т.р.нда төр - ле милектәге 75 а.х. пр-тиесе эшли. Т.р. жи - реннән Әгер җе-Акбаш тимер юлы уза, автомо - биль юллары Чаллыны Казан, Түбән Кама, Әлмәт, Минзәлә шәһәрләре б-н бәйли. Чаллы шәһәре — Кама елгасындагы эре портларның берсе. Районда 24 гомуми белем бирү мәктә - бе, ш.и. 1 мәктәп-бакча, 1 башлангыч, 5 тулы булмаган урта, 17 урта мәктәп; 12 китапханә, 47 клуб һәм 25 мәктәпкәчә тәрбия учрежде - ниесе, 5 халык театры, район үзәк хастаханәсе, 4 дәвалау амбулаториясе (Бәтке, «Татарстан», Күзкәй, Теләнчетамак) эшли. 42 мәчет, 4 чир - кәү бар. Татар һәм рус телләрендә «Якты юл» — «Светлый путь» район г-талары нәшер ителә.



ТУКА́Й РАЙОНЫ́, ТАССРда. 1935 елның 10 февралендә Кызыл Юл р-ны буларак оештырыла. Үзәге — Яңа Кенәр авылы. 1920 гә кадәр терр-ясе Казан губернасының Казан һәм Царёвококшайск өязләрендә, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында, 1930 дан Тукай (1938 нең 25 мартында Әтнә р-ны итеп үзгәртелә), Балтач һәм Арча р-ннарында. 1940 та районның мәйданы — 738 *км²*, халкы — 29,2 мең кеше, 23 авыл советын, 60 торак пунктны берләштерә. 1956 ның 18 июлендә Кызыл Юл р-ны Тукай р-ны итеп үзгәртелә. 1959 ның 12 октябрендә аның составына *Әтнә районы* кертелә, район үзәге Олы Әтнә авылына күчерелә. 1960 та Т.р. 1429,7 *км²* җир били, 22 авыл советы, 105 торак пункт керә. 1963 нең 1 февралендә район таркатыла, терр-ясе Арча р-нына бирелә.

ТУКЛАНУ́ ГИГИЕ́НАСЫ, гигиена тармагы, сәламәт кешенең рациональ туклануын оештыру, азык-төлекнең сыйфаты, кеше организмына туклануның тәэсире, дәва чарасы буларак туклану, ш.у. азык-төлек продуктлары җитештерү б-н бәйле өлкәләрдә сан. режимын тәэмин итү, азык-төлек б-н агулануны кисәтү мәсьәләләрен, сан. кагыйдәләренең үтәлешен күзәтү системаларын, азык-төлекнең сан.-гигиена таләпләренә җавап бирү-бирмәвен билгеләүдә күрсәткеч булган микроорганизмнар таралышын, азык-төлек продуктларында агулы химик матдәләр һәм бактерияләр булу-булмавын өйрәнә.

1870 елларда Т.г.н үстерү мәсь әләләре рус галимнәре В.В.Пашутин, А.Я.Данилевский, И.П.Павлов, М.Н.Шатерников, И.П.Разенков һ.б. хезмәтләрендә чагылыш таба. Т.г. буенча тикшеренүләр ш.у. 1920 дә Мәскәүдә ачылган Эксперименталь туклану физиологиясе ин-тында да уңышлы алып барыла.

1943 тә Казан мед. ин-ты каршында Т.г. каф. оештырыла (мөдире В.В.Милославский). Кафедра галимнәренең фәнни тикшеренүләрендә азык продуктларындагы микроэлементларны ачыклау, йод кытлыгы, йод һәм бром алмашының үзара бәйлелеге, эндемик зоб мәсьәләсе (1950–70 еллар) өстенлекле юнәлешләр итеп карала. Татарстанның зоб буенча эндемик районнарында яшәүче балаларның иммунологик статусын тикшерү нәтиҗәсендә бу күрсәткечнең түбәнәюе, балаларның физик үсеше тоткарлануы ачыклана (В.М.Смирнов, Р.Ш.Якупова, 1970). 1980 елларда мәктәп балаларының сәламәтлеген һәм Арча, Апас, Актаныш р-ннарында, Казанда, Түбән Камада туклану сыйфаты б-н балаларның физик халәте арасындагы бәйлелекне өйрәнүгә багышланган максатчан тикшеренүләр башлана (З.З.Мостафина).

Әд.: Штенберг А.И., Плотникова Ю.И., Мухоркина К.В. Руководство по гигиеническому питанию. М., 1961; Окорокова Ю.И., Ерёмин Ю.Н. Гигиена питания. М., 1981.

В.М.Смирнов, Р.Г.Исхакова.

ТУКМА́К авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 64 *км* төньяк-көнбатыштарак, Куак елгасы бассейнында. 2010 елда 9 кеше (татарлар) яши. 1928 дә нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Бөгелмә кантоны Түбән Чыршылы волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Шөгер, 1959 ның 16 октябреннән Лениногорск р-нында. Халык саны: 1938 дә — 235, 1949 да — 232, 1958 дә — 186, 1970 тә — 127, 1979 да — 59, 1989 да һәм 2002 дә — 2 шәр кеше.

ТУКМАКО́В Алексей Львович (18.2.1961, Казакъстан ССРның Кустанай ш.), механика өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (2004). Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң (1984), шунда ук, микроэлектроника проблемалы лаб-ясендә эшли. 1989 да Казан ун-тын тәмамлый. 1989 дан РФА КГҮдә: Физика-техника ин-тында, Механика һәм машиналар төзү ин-тында (1991 дән). Хезмәтләре нәсызыкча системалар динамикасына (ш.и. конструкция элементлары һәм кисәкчәләрнең газ б-н үзара тәэсир итешүенә), резонатордагы газларның нәсызыкча тирбәнүләренә карый. Т. газ динамикасы һәм аэросыгылмалылыгын исәпләү мәсьәләләре өчен программа комплекслары эшли, нәсызыкча системалар динамикасын модельләштерә һәм анализлый: динамик йөкләнеш астындагы сыгылмалы юка пластиналар һәм панельләрнең регуляр һәм хаотик нәсызыкча тирбәнү режимнарын ачыклый, нәсызыкча эффектларны сурәтли; газ тирбәнешләрен, шулай ук регуляр һәм хаотик тирбәнешләрнең аэросыгылмалы синхронлашу процессларын микъдари тикшерә; акустик резонаторда газның көчле тирбәнешләр режимын өйрәнә һәм газны тирбәнеш чыганагының үзгәрешсез ешлыгында җылытудан резонанслар килеп чыгу күренешен сурәтли; динамик системаның фаза фәсасындагы дискрет халәтләрен анализлау нигезендә сигнал һәм объектларга диагностика ясау алымын эшли, бу алымны куллану мөмкинлекләренең зур булуын (техника, медицина һ.б.) күрсәтә.

Хезм.: Нелинейные режимы колебаний упругой панели под действием периодической нагрузки // Прикладная механика и техн. физика. 2000. Т. 41, № 1; Генерация высокочастотных гармоник при колебаниях газа с большой амплитудой в закрытой трубе // Инженерно-физ. журн. 2001. № 5; Численное моделирование газодинамических процессов в закрытой трубе при неравновесных начальных условиях // Изв. РАН. Мат. моделирование. 2003. Т. 15, № 4.

ТУКРАННА́Р, тукран кошлар семьялыгындагы (Picidae) берничә яругка караучы урман кошлары төрләре төркеме. Евразия һәм Төнъяк Американың урман зонасында таралганнар. Агачта яшәүгә җайлашкан, типик урман кошлары. Аяклары кыска, озын бармаклы һәм очлы тырнаклы (ике бармагы алга, ике се артка караган); агачта хәрәкәтләнгәндә терәк булып хезмәт итүче нык томшык һәм көчле муен мускулатурасы, ш.у. каты каурыйлы койрык Т.га азык эзләгәндә яки оя өчен куыш корганда кайры һәм агачны чукып тишәргә мөмкинлек бирә. Теле озын, юка. ТР терр-ясендә 8 төре очрый: *ысылдавык кош* (Jynx torquilla), яшел тукран (Picus viridis), чал тукран (P. canus), *кара тукран* (Dryocopus martius), чуар, яки зур чуар тукран (Dendrocopus major), ак сыртлы тукран (D. leucotos), кечкенә яки кечкенә чуар тукран (D. minor), өч бармаклы тукран (Picoides tridactylus). Күп санлысы һәм иң киң таралганы — зур чуар тукран. Каурый капламы каралы-аклы бизәкле, кызыл аскойрыклы һәм башы артында кызыл тап (олы ата затларда) булган хәрәкәтчел кош. Нигездә, ылыслы һәм катнаш урманнарда, ш.у. елга тугайларында, шәһәр парклары, агачлык, бакчаларда яши. Җәйге чорда, башлыча, кабыгашарлар, коңгыз личинкалары, гусеницалар һәм кырмыскалар, көз ахырында һәм кышын ылыслы токымнарның орлыклары б-н туклана. Саны буенча ак аркалы тукран зур чуар тукраннан калыша. Ул берникадәр зуррак, койрык өслеге һәм аркасының түбәнге өлеше ак каурыйлы. Катнаш һәм яфраклы урман-



Зур чуар тукран.

нарда яши. Фәкатъ карт агачларның кабыгы астында яшәүче бөҗәкләр һәм аларның личинкалары б-н генә туклана. Кечкенә чуар тукран чыпчыктан аз гына зуррак, 28–30 *г* авырлыкта. Төсе буенча нәкъ зур чуар тукран. Елга үзәннәрендә, таллыкта, зиреклек, имән-лек, юкәлекләрдә, чикләвеклекләрдә очрый. Фәкатъ бөҗәкләр һәм аларның личинкалары б-н туклана. Өч бармаклы тукран — тайга урманнарының типик кошы, ТР терр-ясендә бик сирәк, күбесенчә күчү чорында очрый. Раифа урманында һәм Биектау р-ны чыршылыкларында билгеләнгән. Үзенчәлекле билгеләре — өч бармаклы аяклар һәм ата кошлардагы алтынсу-сары бүрекчек. Чал тукран һәм яшел тукран үзара бик охшаш. Ике төрендә дә гәүдәләренең өске өлеше яшел төстә һәм, аермалы буларак, яшел тукранның маңгаенан баш чүмеченә кадәр, томшыгыннан яңагы буйлап кызыл буй үтә. Ата чал тукранның маңгае кызыл сызыклы, ана кошларда ул юк. Чал тукран — ТРның бөтен терр-ясендә, яшел Т., гадәттә, Идел алдында гына очрый. Ике төре дә кырмыска һәм аларның личинкалары б-н генә диярлек тукланалар, телләре бик озын, 12 *см* га җитә.

Апрель башында Т. оя корырга тотыналар, аларны җирдән 2–10 *м* биеклектә карт агач куышларын чокып ясыйлар. Май башында ана кошлар 2–7 йомырка сала. Ата һәм ана кошлар икесе дә чиратлашып 12–13 көн дәвамында утыралар. Йомыркадан чыгып берәр ай үткәч, кош балалары ояны ташлыйлар һәм 2–3 атна урманда ата-аналары б-н күчеп йөриләр. Өч бармаклы тукран, яшел тукран һәм чал тукран ТРның Кызыл китабына кертелгән.

Әд.: Попов В.А., Лукин А.В. Животный мир Татарии. К., 1988; Аськеев И.В., Аськеев О.В. Орнитофауна Республики Татарстан. К., 1999.

ТУКСА́Н БИШЕНЧЕ́ ЗАПА́С УКЧЫ́ ПОЛК, Казан хәрби округында 1916 елда оештырыла. Казанда урнаша. 1917 нең 1 гыйнварына 10,4 меңгә якын кеше исәпләнә. 1917 нең мартында солдатлар полк ком-ты төзи, ул май башында Петроград Эшче һәм солдат депутатлары советының солдатларга гражданлык хокукы бирү, хезмәттән һәм сафтан тыш офицерлар б-н тигезлек, титуллаштыруны бетерү һ.б. турындагы 1 нче боеры - гы нигезендә устав төзи. Солдатлар сугышудан баш тарталар, 12 июньгә рөхсәтсез китүләрдә 1,4 меңнән артык кеше исәпләнә. Март–октябрьдә революцион эшчәнлек өчен полктан фронтка 11 марш ротасы җибәрелә. Сентябрьдә полк ком-ты хәрби диктатура урнаштыру максаты б-н генерал Л.Г.Корнилов җитәкчелегендә кораллы фетнәгә күтәрелүне гаепләп чыга. 1917 нең октябрь–нояб - рендә Казандагы Окт. кораллы күтәрелешендә полк большевиклар ягында катнаша. 1917 нең декабрендә Мөселман полкы дип үзгәртелә. Аның б-н 2 нче Дәүләт Думасының элекке депутаты Ә.М.*Биглов* җитәкчелек итә, хәрби ахун итеп Гатаулла Баһаветдинов бил - геләнә. Алар, Совет хакимиятен яклаган полк ком-ты рәисе Харис Әхмәтовтан аермалы буларак, бу хакимиятне танудан баш тарталар, хакимиятне Учредительләр җыенына бирү өчен көрәшәләр. «*Болак арты республикасы*» көннәрендә солдатларның төп массасы урталыкны саклый, полк коралсызландырыла һәм таратыла. Солдатларның бер өлеше Беренче Мөселман социалистлар полкы сафларына керә.

Әд.: М у х а р я м о в М.К. Октябрь и национально-государственное строительство в Татарии. М., 1969; Великая Октябрьская социалистическая революция: Энцикл. М., 1987.

ТУКСА́Н ДҮРТЕНЧЕ́ ЗАПА́С УКЧЫ́ ПОЛК, Казан хәрби округында 1916 елда оештырыла. Казанда урнаша. 1917 нең 1 гыйнварына 11 меңгә якын кеше исәпләнә. 1917 нең мартында солдатлар гарнизонда беренче полк ком-ты төзи. Мөселман солдатлар башлангычында мартта Казан Мөселман хәрби ком-ты төзелә. Солдатлар сугышудан баш тарталар, майда фронтка 1 мең кешене озатуны өзәләр, 12 июньгә рөхсәтсез китүләрдә 800 дән артык кеше була. Вакытлы хөкүмәтнең оборона рухын күтәрү һәм Россия союзниклары ның актив сугыш хәрәкәтләре турындагы таләпләрен канәгатьләндерү максатыннан Россия армиясенең июньдә оештырылган һөҗүме б-н бәйле рәвештә полк хөкүмәткә каршы демонстрациядә катнаша. Революцион чыгышлар өчен полктан фронтка 15 марш ротасы җибәрелә. Солдатлар ге - нерал Л.Г.Корнилов җитәкчелегендә корал - лы фетнәгә күтәрелүне гаепләп чыгалар. Ок - тябрьдә полк большевикларга булышлык күрсәтә, Казанда Совет хакимиятен урнаш - тыруда катнаша. 1918 нең язында таратыла.

Әд.: Великая Октябрьская социалистическая революция: Энцикл. М., 1987.

ТУКТА́ ХАН (якынча 1270 — 1312/13), Ал - тын Урда ханы (1291 елдан). *Мәнгү Тимер ханның* улы. Хакимияткә Нугай бәкнең *Телә - буга ханга* каршы оештырылган көрәше нәти - җәсендә килә. 1293 тә Т.х. һәм Нугай бәк Руська яу б-н баралар (10 нан артык шәһәр: Суздаль, Ростов, Тверь һ.б. талана). Т.х. үзәк хакимиятне ныгыту һәм шәһәрләрне үстерү сәясәте алып бара. 1290 елларда асылда Ал - тын Урда хакименә әверелгән Нугай бәккә каршы көрәшкә күтәрелә. Нугай сәясәте ак - сөякләрдә ризасызлык тудыра, алар акрын - лап Т.х. ягына күчеп бетәләр. Берничә яудан соң Нугай бәк җи нәлә, әсирлеккә төшә һәм үтерелә (1299/1300). Аның үлеменнән соң Т.х. феодалларның үзәктән качу омтылышларына каршы төшә. Т.х. заманында акча реформасы уздырыла һәм Алтын Урданың адм. төзелеше тәртипкә китерелә, Мәмлүкләр Ми - сыры б-н дипломатик мөнәсәбәтләре кабат торгызыла.

Әд.: Ф ә х р е т д и н о в Р. Алтын Урда ханнары. К., 1995; Г о с м а н о в М. Алтын Урда: башлангыч һәм мирас // Казан утлары. 2004. № 5; Г р е к о в Б.Д., Я к у б о в с к и й А.Ю. Золотая Орда и её падение. М.–Л., 1950; С а ф а р г а л и - е в М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; ш у л у к. Распад Золотой Орды // На стыке континентов и цивилизаций... М., 1996.

И.Л.Измайлов.

ТУКТАКЫ́Й БӘК (? — 1376/77), Күк Ур - да идарәчесе (1376 дан). *Ырыс Мөхәммәд ханның* өлкән улы. Туктамышка каршы көрәш алып бара. Тәхеткә атасы вафатыннан соң утыра; бик аз вакыт дәвамында идарә итә.

ТУКТАМО́ТОВ Туктамәт Гаффар улы (16.12.1918, хәзер Омск өлкәсенең Больше - речье р-ны Олымурлы а.), тарихчы, тарих фән. д-ры (1970), проф. (1971). Урта Азия ун-тын (Ташкент, 1947) тәмамлаганнан соң шунда ук, аннары Ташкент пед. ин-тында эшли. 1963–72 елларда Карши пед. ин-тын - да СССР тарихы һәм гомуми тарих каф. мө - дире. 1972–92 дә Дүшәнбе пед. ин-тында. Хезмәтләре 18–19 йөзләр Та җикстан һәм Үз - бәкстан тарихына, 20 йөз башы Бохара әмирлеге тарихына, совет хакимиятенең беренче елларында Таҗикстанда аграр мөнәсәбәтләр үсеше тарихына карый. Таҗик, үзбәк, кара - калпак халыкларының тарихи язмышларын, Россиянең 19 йөздә — 20 йөз башында Урта Азия ханлыклары б-н үзара мөнәсәбәтләрен өйрәнүгә өлеш кертә.

Х е з м.: Русско-бухарские отношения в конце XIX — начале XX вв. Таш., 1966; Россия и Хива в конце XIX — начале XX вв.; Победа Хорезмской народной советской революции. М., 1969; Россия и Бухарский эмират в начале XX в. Душ., 1977.

ТУКТАМЫ́Ш ХАН (якынча 1350–1406), Алтын Урда ханы (1380–97/98). *Ырыс Мө - хәммәд хан* тарафыннан хөкем ителгән Туй Ху җә бәк улы. 1370 елларда Урта Азия ида - рәчесе *Аксак Тимер* янына качып китә. Аның ярдәме б-н Ырыс Мөхәммәдкә каршы көрәш башлый һәм 1379 да Күк Урда тәхетенә килә. 1380 дә *Куликово кыры сугышында* җи нәлүгә дучар ителгән бәкләр бәге *Мамайны* 1380 дә җиңә һәм Алтын Урда тәхетен яулый. 1382 дә Мәскәүне басып ала, рус җирләренең элекке - чә Алтын Урдага бәйлелеген торгызса. Кавказ арты һәм Урта Азия җирләренә ху җә булу өчен 1380 еллар ахырыннан Аксак Тимергә каршы көрәшә. Алтын Урда аксөякләренең әмир *Идегәй* җитәкләгән бер өлеше, Т.х. сәя - сәтеннән канәгатьсезлек белдереп, аңа каршы күтәрелә, фетнә бастырылгач, Аксак Тимер янына китә. 1391 дә Т.х. *Кондырча елгасы буендагы сугышта* Аксак Тимер тарафыннан җиңелә, шуннан соң ил аерым олысларга бү - ленә. 1393 кә Т.х. хакимиятне кире кайтару - га һәм Алтын Урданы берләштерүгә ирешә (Идегәй олысы гына мөстәкыйльлеген саклап кала). *Терек елгасы буендагы сугышта* (1395) Т.х. кабат Аксак Тимер тарафыннан җи нәлә. Аксак Тимер гаскәре, Т.х.ны һәм аның гаскәр - ләрен әзәрлекләп барып, Алтын Урданың Азак, Мажар, Хаҗитархан, Сарай әл-Җәдид һ.б. шәһәрләрен талый, җимерә. Үзара баш - ланган сугышлар барышында (1395–97) Ал - тын Урдада хакимият Идегәйгә һәм аның бу - лышлыгы б-н тәхеткә утырган *Тимер Котлыгъ ханга* күчә. Т.х. Литвага куыла, анда ул Лит - ваның бөек кенәзе Витовт б-н килешү төзи. Аның ярдәме б-н Т.х. хакимиятне кире үз кулына кайтарырга омтылып карый, әмма *Бурсыклы (Ворскла) елгасы буендагы сугыш - та* (1399) җи нәлә. 1399 ның ахырында Лит - вадан китә һәм Көньяк Себердә качып яши; Идегәйгә каршы көрәштә Аксак Тимер ярдә - менә өметләнә. 1406 да *Шадибәк хан* һәм Иде - гәй гаскәрләре тарафыннан куып тотыла һәм үтерелә.

Әд.: Ф ә х р е т д и н о в Р. Алтын Урда ханнары. К., 1995; Г о с м а н о в М. Алтын Урда: башлангыч һәм мирас // Казан утлары. 2004. № 5; Г р е к о в Б.Д., Я к у б о в с к и й А.Ю. Золотая Орда и её падение. М.–Л., 1950; С а ф а р г а л и - е в М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; Ф ё д о р о в - Д а в ы д о в Г.А. Общественный строй Золотой Орды. М., 1973; С а ф а р г а л и - е в М.Г. Распад Золотой Орды // На стыке континентов и цивилизаций... М., 1996.

И.Л.Измайлов.

ТУКТАМЫ́Ш авылы, Биектау р-нында, Би - ектау тимер юл станциясеннән 25 *км* төнь - як-көнчыгыштарак, Тож елгасы буенда. 2010 елда 108 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек, кир - печ сугу. 20 йөз башында Т.та мәчет, мәктәп, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 541,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Ка - зан өязе Мүлмә волостенда, 1920 дән ТАССР - ның Арча кантонында. 1930 нең 10 августын - нан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Зе - ленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биек - тау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 39 ир-ат; 1859 да — 230, 1897 дә — 356, 1908 дә — 434, 1920 дә — 480, 1926 да — 482, 1938 дә — 398, 1949 да — 355, 1958 дә — 238, 1970 тә — 171, 1989 да — 127, 2002 дә — 114 кеше.

Әд.: Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

ТУКТАМЫ́Ш авылы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 39 *км* көнчыгыштарак, Нысы елгасы буенда. 2010 елда 116 кеше (татар - лар, руслар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. 1616 дан Нысы авылы буларак билгеле. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Туктамыш Нысысы исеме б-н дә мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, тер - лек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында су

тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1173 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Әбде волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1782 дә — 50 ир-ат; 1859 да — 375, 1897 дә — 532, 1908 дә — 513, 1920 дә — 525, 1949 да — 345, 1958 дә — 306, 1970 тә — 316, 1979 да — 262, 1989 да — 183, 2002 дә — 138 кеше.

ТУКТАМЫ́ШЕВ Наил Кадыйр улы (3.4.1954, Чүпрәле р-ны Иске Чокалы а.), педагог, математик, физика-матем. фән. канд. (1981), пед. фән. д-ры (2001), проф. (2001). Казан ун-тының механика-матем. ф-тын тәмамлый (1976). Казан архит.-төзелеш ун-тының югары матем. кафедрасында эшли, 2004 тән гомуми инженерлар әзерләү ф-ты деканы. Хезмәтләре кырый мәсьәләләргә, юга ры уку йортларында ике телдә укытуга күчүнең социаль-пед. нигезләрен эшләүгә карый. ТРның фән һәм техника өлкәсендә Дәүләт бүләге лауреаты (2009).

Х е з м.: Математик физика тигезләмәләре: уку кулланмасы. К., 2003; Решение задачи Гильберта для кольца в особом случае и его применение к одной задаче взрыва // Мат. заметки. 1999. Т. 8, вып. 1; Социально-педагогические основы преподавания в высших технических школах в условиях билингвизма. К., 2000.

ТУКТА́Р (Туктаров) Идрис Ильяс улы (20.9.1896, Уфа губ., Уфа өязе Булышлы а. — 20.10.1982, Яшел Үзән ш.), язучы. Казан пед. ин-тын тәмамлый (1936). Беренче бөтендөнья, Гражданнар һәм Бөек Ватан сугышларында катнаша. Уфада дүртьеллык уч-ще тәмамлаганнан соң (1915), Уралдагы Кучкар приискында эшли. 1919 елда кулга алына, үлем эшелоны б-н Владивосток шәһәренә җибәрелә, бер елдан кызыл партизаннар тарафыннан азат ителә. 1920–22 дә үзе теләп Кызыл Армия сафларында хезмәт итә. 1924–32 дә «Коммунист» г-тасы, «Шәпи агай» (Свердловск ш.) сатирик журналы редакцияләрендә әдәби хезмәткәр булып эшли. 1941–43 тә «Кызыл Татарстан» г-тасы хәбәрчесе. Сугыштан соң Киевта яши, суднолартөзү техникумында укыта. 1947 дән Яшел Үзән шәһәрендә яши, шәһәрнең үзәк китап ханәсен җитәкли, күптиражлы «Машиностроитель» г-тасында эшли. 1924 тә мәкаләләре басыла башлый. Татар язучыларыннан беренче булып эшче, шахтёрларга, аларның Окт. рев-циясе һәм Гражданнар сугышында катнашуларына багышлап әдәби әсәрләр яза. «Сиксән беренче штольня» повесте (1932) индустриаль Урал кешеләренә багышлана. «Ике егет» автобиографик романы (1964) үзәгендә — революцион бәрелешләрдә катнашкан эшче һәм крәстиян. Т. балалар өчен дә яза: «Нәни хикәяләр» (1947), «Җир җиләге» (1948), «Батырлыкта — матурлык» (1966, рус теленә тәр җәмәсе 1969) һ.б. җыентыклар. Татар теленә А.Куприннның «Белый пудель» («Ак пудель», 1950) хикәясен, И.Ликстановның «Малышок» («Бәләкәй малай», 1950) повестен, А.Волошинның «Земля кузнецкая» («Кузнецк җире», 1952) романын һ.б. тәрҗемә итә.

Әд.: Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

ТУКТА́Р УРДАЛАСЫ́ авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 40 *км* көньяк-көнбатыштарак, Чишмә елгасы буенда. 2010 елда 564 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1730 ларда нигез салына; 1880 елларга кадәр рәсми чыганакларда 2 авыл — Яңа Урдала (Иске Поляевка) һәм Туктар — исәпләнә. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлавына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.У.нда 2 мәчет, 2 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 5117 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Сходнево волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Шөгер, 1959 ның 16 октябреннән Лениногорск р-нында. Халык саны: 1748 дә — 49 ир-ат; 1795 тә — 320, 1859 да — 599, 1889 да — 1870, 1897 дә — 1598, 1910 һәм 1920 дә — 2070 әр, 1926 да — 963, 1938 дә — 1686, 1949 да — 1273, 1958 дә — 1103, 1970 тә — 1204, 1979 да — 976, 1989 да — 708, 2002 дә — 646 кеше.

ТУКТА́Р авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 20 *км* көньяк-көнчыгыштарак урнашкан. 2010 елда 12 кеше (татарлар) яши. 1923 тә Тайсуган авылыннан күчеп килүчеләр нигез сала. Оешкан көненнән ТАССРның Бөгелмә кантоны Габдрахман волостенда. 1930 ның 10 августыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1926 да — 61, 1938 дә — 141, 1949 да — 158, 1958 дә — 141, 1979 да — 22, 1989 да — 5, 2002 дә — 2 кеше.

ТУКТА́Р авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 5 *км* көнчыгыштарак, Казкаш елгасы буенда. 2010 елда 292 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Кирпеч з-ды. Башлангыч мәктәп, китапханә. 1664 тән Саба исеме б-н мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Иске Саба буларак та билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп, су тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 621,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Сатыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 37 ир-ат; 1859 да — 198, 1897 дә — 347, 1908 дә — 490, 1920 дә — 566, 1926 да — 602, 1938 дә — 576, 1949 да — 312, 1970 тә — 400, 1979 да — 354, 1989 да — 129, 2002 дә — 280 кеше.

ТУКТА́РОВ Барый Искәндәр улы (11.9.1945, Саратов өлкәсенең Дергачи р-ны Вергазовка а.), галим агроном, а.х. фән. д-ры (1996), проф. (1997), РФнең атказ. мелиорация бел гече (1999). Пугачёв а.х. техникумын (1965), Саратов а.х. ин-тын (1970) тәмамлый. 1975–77 елларда Саратов өлкәсенең Маркс р-ны «Мелиоратор» с-зында баш агроном. 1974 тән Саратов аграр ун-тында, 2000 нән җир төзү каф. мөдире. Хезмәтләре Саратов өлкәсендә а.х. мелиорациясе һәм сугарулы җирләрдән рациональ файдалану мәсь әләләренә карый. СССР ВДНХсының алтын һәм көмеш медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Лиманное орошение в Заволжье. Саратов, 1998; Окультуривание засорённых и деградированных орошаемых земель. Саратов, 2002; Ресурсо-водосбережение на орошаемых землях Саратовской области. Саратов, 2005.

ТУКТА́РОВ Рөстәм Хөсәен улы (14.2.1949, Буа р-нының Каенлык а.), галим агроном, а.х. пр-тиесе җитәкчесе, ТР, РФнең атказ. а.х. хезмәткәре (1994, 2002). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1971), Буа р-нында эшли: «Үзәк», К.Маркс исем. к-зларда агроном (1972 елдан), баш агроном (1974 тән), рәис урынбасары (1978 дән), к-з рәисе (1979 дан), «Маяк» крәстиян хуҗалыгы ассоциациясе рәисе (1991 дән), Буа нефть базасы директоры (2001 дән). Т. җитәкчелегендә хуҗалыкта үсемлекчелек һәм терлекчелектә җитештерү процесслары механикалаштырыла, юлларга асфальт салына, торак пунктларга газ кертү төгәлләнә, мәктәпләр, клублар һәм башка җитештерү, социаль-мәдәни һәм көнкүреш биналары төзелә. 1982–2001 лардә бөртекле культураларның уңышы — 1 *га* га 14 *ц* дан 51 *ц* га кадәр, шикәр чөгендере 140 *ц* дан — 340 *ц* га кадәр, еллык савым уртача һәр сыердан 1900 *кг* нан 4200 *кг* га кадәр арта. Табышлылык дәрәҗәсе 2001 дә 25,2% тәшкил итә. Медаль б-н бүләкләнә.

ТУКТА́РОВ Фуад (Мәхмүтфуад) Фәсах улы (5.2.1880, Казан губ., Чистай өязе Күлбай-Мораса а. — 19.12.1938, Әнкара, Төркия), җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, журналист. Чистай мәдрәсәсен, Казан татар укытучылар мәктәбен (1904), Казан ун-тының юридик ф-тын (1915) тәмамлый. Укытучылар мәктәбендә укыган вакытта иҗтимагый-сәяси эшчәнлек б-н мавыга, «Шәкертлек», «Хөррият» студентлар төркеме әгъзасы була; Г.Исхакый, Г.Терегулов, Ш.Мөхәммәдъяров, Х.Ямашев б-н таныша. 1905–07 еллардагы рев-ция вакытында әсерлар партиясенең җирле бүлегенә кушыла, Казанда «Таң», «Таң йолдызы» г-таларын нәшер итүдә катнаша. «*Таңчылар*» төркемен оештыручылардан һәм аның җитәкчеләреннән берсе (1905–07). Демократик



Ф.Ф. Туктаров (уңнан икенче) «Мөселман хезмәт таифәсе» әгъзалары арасында. 1907.

юнәлештәге «Казан мөхбире», «Ил», «Сүз» г-талары, «Ялт-йолт», «Мәктәп» ж-ллары б-н хезмәттәшлек итә. 1907 дә 2 нче Дәүләт Думасы сайлауларына тавышка куела, сәяси ышанычсызлыгы сәбәпле читләтерелә. Думада мөселманнар фракциясе секретаре булып эшли, фракциянең документлар эшен алып бара, депутатларга нотыклар текстларын яза. «Мөселман хезмәт таифәсе»н оештыручыларның берсе, аның катнашында хезмәт таифәсе әгъзалары «Дума» г-тасын нәшер итәләр. 1909 да «М.-Ф.Усал» тәхәллүсе б-н «Беренче, икенче вә өченче Думада мөселман депутатлар һәм аларның кылган эшләре» брошюрасын бастыра. Аның 1 нче өлешендә Т. Россиядә парламентаризм формалашуның алшартлары тарихын, 1 нче, 2 нче Дума язмышын һәм 3 нче Дума эшчәнлегенең башлангыч чорын бәян итә. 2 нче өлешендә мөселман депутатларның биографияләренә кагылышлы публицистик стильдә язылган мәгълүматлар тупланган. 1915 тән С.Ш.*Алкин* карамагында Казан суд палатасында адвокат ярдәмчесе. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң татар милли хәрәкәте лидерларының берсе. *Мөселманнар комитетын* (1917–18) оештыручы һәм аның рәисе, «Корылтай» г-тасының мөхәррире. Т. үзен демократ дип исәпли, рев-циядә татар халкы өчен милли мәсьәләне хәл итү әһәмиятле дип саный; татарлар арасында сыйнфый көрәш идеясен кире кага, аларны милли килешүгә чакыра. Бөтенроссия мөселманнарының 1 нче һәм 2 нче корылтайларында катнаша. 1917 дә Казан шәһәр Думасы гласные һәм Казан губерна Милли Шурасының башкарма ком-ты әгъзасы. Совет хакимиятен кабул итми, большевикларга ачыктан-ачык каршы чыга. 1918 дә КОМУЧ әгъзасы, «Маяк» г-тасы мөхәррире. 1919 ның август ахырында Харбин шәһәренә күчеп китә, анда Г.Исхакый б-н очраша, Россиядә яшәүче төрки-татар халкының мәнфәгатьләрен кайгырту өчен аның б-н Европага китә. Милләт Мәҗлесеннән сайланган вәкил буларак, С.Максуди һәм Г.Исхакый б-н бергә Парижда узган солых конференциясендә катнаша. Эмиграциядә Франциядә, Германиядә, 1920 еллар уртасыннан Төркиядә яши. Әнкарада журналистика б-н шөгыльләнә һәм укыта, Төркия респ-касы Мәгариф министрлыгы каршындагы китапханәдә идарәче булып эшли.



Ф.Ф.Туктаров.


Әд.: У с м а н о в а Д.М. Профессора и выпускники Казанского университета в Думе и Госсовете России, 1906–1917. К., 2002.

ТУКТАУЛЫ́К (археол.), таш, бронза гасырларның ныгытылмаган торулык калдыклары. Татарстан терр-ясендә беренче Т.лар 100 мең еллар чамасы элек барлыкка килә (к. «*Красная Глинка*»). Т.лар гадәттә күптәнге биек террасалардагы елга үзәннәре янында (палеолит) яисә үзән кырыйларында буйлап, ташу сулары керми торган урыннарда (мезолит, неолит) урнашкан булалар. Т.ларда борынгы аучылар, балыкчылар һәм җыючылар яши; алар, кагыйдә буларак, елга үзәннәренең биол. ресурсларын файдаланалар, үзләштерүле хуҗалык алып баралар. Бронза гасыр Т.ларында җитештерүче хуҗалык итү билгеләре (терлекчелек, һөнәрчелек һ.б.) табыла. Татарстан терр-ясендә төрле дәвер Т.лары Спас р-ныны Әҗмәр, Куралово авыллары, Актаныш р-нының Татар Ямалы, Минзәлә р-нының Дәвек, Биектау р-нының Кече Битаман авылларында һ.б. ачыклана; алар 20 йөздә А.Х.Халиков, М.Г.Косменко, Р.С.Габәшев, М.Ш.Галимова, Е.П.Казаков һ.б. тарафыннан тикшерелә. Т.ларның культура катламында керәч кисәкләре, чакматаш, сөяк һәм бронзадан хезмәт һәм сугыш кораллары, бизәнү әйберләре, хайван сөякләре, учак, торак урыннары калдыклары табыла.

Әд.: Х а л и к о в А.Х. Древняя история Среднего Поволжья. М., 1969; ш у л у к. Волго-Камье в начале эпохи раннего железа (VIII–VI в. до н. э.). М., 1977; ш у л у к. Приказанская культура // Свод археол. источников. М., 1980. Вып. 1–24; К о с м е н к о М.Г. О некоторых мезолитических памятниках Икско-Бельского междуречья // Об исторических памятниках по долинам Камы и Белой. К., 1981; Г а б я ш е в Р.С. Исследование памятников каменного века и эпохи раннего металла казанскими археологами в 1965–1981 гг. // Новое в археологии и этнографии Татарии. К., 1982; Г а л и м о в а М.Ш. Памятники позднего палеолита и мезолита в устье реки Камы. М.–К., 2001.

Е.П.Казаков.

ТУКУ́ СТАНЫ́, кул б-н туку җайланмасы. Идел-Урал төбәге татарларында борынгы заманнардан ук Т.с.ның ике төре: вертикаль һәм горизонталь станнар кулланыла. Соңгысы аеруча киң таралган; катлаулылыгы ягыннан 3 төргә бүлеп карала: рамсыз, өлешчә рамлы һәм тулы рамлы. Аюбаш һәм буй



Туку станы.

(нигез) җебен беркетә торган аскуйма конструкциясе үзенчәлекләре буенча рамсыз станнар арасында ике рәт аскуймалы (Көнчыгыш Кама аръягы керәшен татарларда), өч рәт аскуймалы (Көнчыгыш Кама аръягы мөселман татарларда), сәкегә беркетелә торган (Кама алды, Уфа ягы Урал буе татарларында) станнар була.

19 йөз ахыры — 20 йөз башында, тукыма әзерләү өчен югары технологияле һәм югары җитештерүчәнлекле фабрика-завод җиһазлары барлыкка килү б-н, вак һөнәрчелек һәм кәсепчелек сәнәгатендә Т.с. кулланыштан чыга башлый. Шулай да, 20 йөзнең 2 нче яртысына кадәр тукымага кытлык булу сәбәпле, авыл халкы күпчелек кул Т.с.ннан файдалана.

Әд.: Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967; С а ф и н а Ф.Ш. Ткачество татар Поволжья и Урала (конец XIX — начало XX вв.): Ист.-этногр. атлас татар. народа. К., 1996; ш у л у к. Ткачество // Татары. М., 2001.

ТУКУЧЫЛЫ́К, махсус станда тукыма туку ысулы; гамәли бизәлеш сәнгатенең бер төре. Татар халык иҗатының (туку, сугу) борынгы төре. Берничә этаптан тора: иң беренче — чималны эшкәртү (сарык йонын, киндер һәм җитенне, сирәк кенә — кычытканны, 19 йөзнең 2 нче яртысыннан — фабрикада эшләнгән киҗе-мамык җепләрне), шуннан җеп әзерләү (сортларга аеру, әрләү һәм сүсләрне буяу) һәм тукыма туку. Җеп әрләү өчен орчык, каба һәм җеп әрләү машинасы кулланыла, җыелма каба киң таралган була (ул төп өлештән һәм каналтан тора). 19 йөз уртасына кадәр әрләгән җепне буяу өчен үсемлек буяулары (ат кузгалагы яфраклары, имән, зелпе, сары буяк кайрысы), 19 йөз ахырыннан химик матдәләр файдаланыла. Тукымалар махсус туку станында (киндер урыны), буй һәм аркау җепләрне аралаштырып, кулдан эшләнә. 19 йөз урталарына кадәр өйдә эшләнгән тукымадан файдаланганнар. Т. б-н гадәттә хатын-кызлар шөгыльләнә, сату өчен һәм заказга тукыганда эшләнмәләр катлаулы һәм бизәкләргә бай итеп башкарыла. Фараз ителгәнчә, 19 йөз урталарыннан Казан һәм Зөя өязләрендә, Нурлат һ.б. волостьларда вак туку мануфактуралары эшли, аларда әйберләр гадәттә кулдан тукыла, бизәкле тукымалар б-н беррәттән комач тукымалар һәм баш яулыклары эшләнә.

Тукылган әйберләр (сакланганнардан иң элгәреләре 18 йөзнең 2 нче яртысына карый): сөлгеләр, җәймәләр, чаршау, эскәтер, тастымаллар, түрләмә һәм кашагалар, намазлыклар, япмалар, киемнәр һ.б. — татарларның көндәлек тормышында утилитар, йола һәм гамәли функция үтиләр: аларны кәләш бирнәсенә куялар; туйларда, бәби туйларында бүләк итәләр, женазаларда, Җыеннарда, Сабан туйларында өләшәләр, диварларга һәм бүлмәләргә, тәрәзә араларына эләләр, йортны бүлемнәргә бүләләр.

Т.ның төрки халыкларга хас иң борынгы төре — асалап сугу, бүлеп сугу: бизәкләр алдан билгеләнгән рәсем буенча төрле төстәге аркау җепләр б-н ясала, ике яклы тукыма хасил була, шул ук вакытта төсле бизәк кырыйларында ачыклыклар кала. Асалап сугу техникасы б-н ш.у. йон келәмнәр дә эшләнә. 18 йөздә — 19 йөз уртасында асалап сугылган тукымалар башкару техникасының камиллеге һәм бизәкләрнең ачыклыгы, матурлыгы (анда, кара төстән кала, барлык төсләр гаммасы кулланыла, бер әйбердә — 9–10 төсмер) б-н аерылып тора. Орнаментта Урта Азия һәм Әзәрбай җан келәмнәре, бизәкле башкорт тукымалары б-н билгеле бер охшашлык бар. Шулай да татарлар эшләгән әйберләрдә бизәкләр композициянең күп төслелеге, монументальлеге һәм динамикасы б-н аерыла, төп буйдагы ачык бизәкләр тыныч һәм вак рәсемле кайма б-н чикләнә. 19 йөз урталарыннан башкару өчен авыр булган асалап сугу





Тукучылык.
Бизәкле сөлгеләр фрагментлары:
1. Асалап сугу. 19 йөз ахыры. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее;
2. Кыялап сугу. 19 йөз ахыры – 20 йөз башы. ТР Милли музее;
3. Төсле чүпләм. 19 йөз ахыры – 20 йөз башы. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

кулланыштан чыга һәм келәм тукуда гына файдаланыла.

19 йөзнең 2 нче яртысыннан чүпләмле тукуның төсле чүпләм (күтәреп сугу, күтәрү) һәм түшәүле туку техникасы б-н башкарылган төрләре киң тарала. Чүпләмле бизәк ике төстән — фон хасил итүче ак буй (нигез) җепләр күбрәк кызыл яки зәңгәр, зәңгәрсу, яшел, сары аркау җепләр б-н аралаштырып тукыла. Чүпләмле техникада аркау җепләр күпләп файдаланыла, бизәкләр күп төсле килеп чыга. Түшәүле техникада (төсле чүпләмнең бер төре) буй яки аркау җепләрнең озын җөй б-н бер яклап түшәлүе исәбенә бизәкләр зур була. Зур әйберләрне: чаршау, ашъяулык, урын-җир җәймәләре, матча кашагалары, эскәтер һәм сөлге башларын чүпләмле туку ысулы б-н бизиләр. Урал буе татарларының кайбер төркемнәрендә һәм керәшен татарларда чүпләмле һәм төсле чүпләмле бизәкләр ш.у. хатын-кыз күлмәкләре, алъяпкычлары, тастар (нәфис итеп тукылган баш япмалары) башларын бизәү өчен кулланыла. Чүпләмләп тукылган бизәкләр күрше рус, мари, удмурт халыкларының эшләнмәләрендәге бизәкләр б-н охшаш. Кыялап сугу техникасы артык киң таралыш алмый, гадәттә, сөлге башларын кыялап бизиләр. Бизәкләр 6–8 ар кау җебеннән ясала, аларны буй җепләр б-н аралаштырганда, тоташ бизәкле тукыма барлыкка килә. Аңа ромб, карлыгач койрыгы рәвешендәге һ.б. бизәкләр хас.

Татар Т.гының үзенчәлеге эшләнмәләрнең күп төслелегендә һәм бизәк үрнәкләрендә чагылыш таба. Осталар бизәкне кабатламаска тырышалар, баскычлы-баскычлы өчпочмаклар, ромблар, квадратлар, йолдызлы, яфраклы үрнәкләр, свастикалар, Х-, S- һәм 8- ле стильләштерелгән чәчәк розеткаларын күп төрле вариантларда кулланалар, күппочмаклар арасын вак бизәкләр б-н тутыралар. Гадәттә кызыл, куе кызыл, ак, алтынсыман сары җирлеккә кызыл, зәңгәрсу, зәңгәр, яшел, кызгылт-сары бизәкләр төшерәләр.

Көндәлек кием-салым һәм куллану әйберләре өчен иң гади тукыма — алача сугыла. Ул шакмаклы яки буй-буйлы, ике яки өч төсле була (кызыл төс ак, зәңгәр, яшел, зәңгәрсу, сары төсләр б-н кушыла). Буй-буйлы алача хатын-кыз күлмәкләре тегү өчен файдаланыла. 19 йөз уртасыннан кулдан сугылган тукымаларны фабрика тукымалары алмаштыра. Т. әһәмиятен югалта башлый. Ул шәһәрдән ерак урнашкан Көнчыгыш Кама аръягы һәм Башкортстанның татар авылларында гына сакланып кала. Авыл осталары әле 20 йөз ахырына кадәр һәр җирдә диярлек эре бизәкле паласлар (асалап сугу техникасы б-н) һәм тукыма калдыкларыннан эшләнгән буй-буйлы тар озын паласлар (чүбек палас) сугалар. Т. традицияләре Алексеев бизәкләп туку ф-касы, «Туран» фонды сувенир әйберләрендә (бизәкле сөлгеләр, эскәтерләр, тастымаллар җыелмасы һ.б.), Казан өйдә эшләүчеләр сәнгати һөнәрчелек комбинаты продукцияләрендә дәвам итә.

Әд.: Воробьёв Н.И., Бусыгин Е.П. Художественные промыслы Татарии в прошлом и настоящем. К., 1957; Валеев Ф.Х. Народное декоративное искусство Татарстана. К., 1984; Валеева-Сулейманова Г.Ф. Декоративное искусство Татарстана (1920-е — начало 1990-х годов). К., 1995; Сафина Ф.Ш. Ткачество // Татары. М., 2001.

Г.Ф.Вәлиева-Сөләймановa.

ТУКШӘЙТОВ Рафаил Хасьян улы (16.1.1940, Баку), биофизик, биол. фән. д-ры (1989), проф. (1997), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1998). Казан авиация ин-тының радиотехника ф-тын тәмамлаганнан соң (1963), Ленинград оптика ин-тының Казан ф-лында инженер, өлкән инженер булып эшли. 1969–85 елларда Казан вет. ин-тында, физик тикшеренү исуллары лаб-ясе мөдире (1976 дан). 1985–2000 дә Бөтенроссия вет. фәнни-тикшеренү ин-тының биофизика һәм метрология лаб-ясе мөдире. 2000 нән Казан энергетика ин-тының экология һәм ресурслары саклау каф. профессоры, мед.-биол. электроникасы (2002–07), яктылык техникасы һәм мед.-биол. электроникасы (2007–13) кафедралары мөдире. Хезмәтләре гамәли биофизикага, мед.-биол. электроникага; эксперимент юлы б-н алынган мәгълүматларны стат. эшкәртү алымнарын метрологик тәэмин итү һәм оптималләштерүгә карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Основы динамической метрологии и анализа результатов статистической обработки (биология, медицина, химия, физика). К., 2001; Основы оптимального представления статистических показателей на графиках, диаграммах и таблицах. К., 2006; Разработки лаборатории автоматизированного стенда на базе шины Е/В // Проблемы и перспективы развития отечественной светотехники, электротехники и энергетики: Сб. науч. тр. Саранск, 2008 (автордаш).

Әд.: Яруллин Х.Х. Клиническая реоэнцефалография. М., 1983.

«ТУЛ» («Ут»), иҗтимагый-сәяси газета. Алабуга Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлары советы милләтләр эшләре бүлегенең мари секциясе органы. 1920 нең 12 маеннан 1921 нең 18 ноябренә кадәр Алабуга шәһәрендә мари теленең болын ягы диалектында нәшер ителә, барысы 20 саны чыга. Мөхәррирләре — М.Г.Терентьев, К.В.Исаев, соңгы саннарына мөхәрририят кул куя. Актив авторлары арасында — А.А.Атнашева, К.Ф.Данилов, И.А.Ижболдин, М.В.Кузнецов, П.Е.Песников, А.Я.Яковлев һ.б. Газета битләрендә совет хөкүмәте сәясәте аңлатыла (продразвёрстканы бердәм салым б-н алыштыру, кооперация мәсьәләләре). Советларның 8 нче съезды эше яктыртыла, Бөтенроссия ҮБК каршындагы Россия телеграф агентлыгы хәбәрләре урнаштырыла. Файдаланыла торган җирләрне нигезле куллану, шәхси хуҗалыкны нәтиҗәле алып бару, шәһәр һәм авыллар арасындагы элемтәне ныгыту турындагы язмалар чыга. Мари шагыйрьләре М.С.Герасимов-Микай, К.В.Исаев, С.Константинов, В.Михайлов һ.б.ның шигырьләре басыла. 1920 нең ноябрендә Мари автономияле өлкәсе оешкач, Алабугадан мари интеллигенциясенең күп кенә вәкилләре китә; газета актив хәбәрчеләрен һәм укучылар аудиториясен югалта. Бу исә газетаның ябылуына китерә.

Әд.: Сергеев М.Т. Возникновение и развитие печати Марийской АССР. Йошкар-Ола, 1971; Васин К.К. У истоков татаро-марийской литературной дружбы // Взаимодействие культур народов Поволжья и Приуралья (На материале автономных республик Поволжья). К., 2000.

ТУЛА́, к. *Өйдә тукылган постау.*

ТУ́ЛА ӨЛКӘСЕ́, РФнең Үзәк Европа өлешендә урнашкан. Мәйданы — 25750 *км*^{2}. Үзәге — Тула шәһәре. Халкы — 1491855 кеше (1.1.2018). 2010 елгы халык исәбе буенча, та-

тарлар — 7878 (1979 да — 10300, 1989 да — 9600, 2002 дә — 8968) кеше. Алар Тула (1364 кеше), Донской (995) шәһәрләрендә, ш.у. Узловой (1177), Новомосковский (1106), Киреевский (893), Щёкино (541), Кимовский (497), Богородицк (449), Алексин (401), Венёв (315), Ленинский (198), Заокский (152), Ясногорский (120), Плавский (112), Чернь (99), Дубна (94), Ефремов (87), Суворов (86), Белёв (62), Одоев (53), Арсеньево (48), Тёпло-Огарёво (34), Волово (30), Каменка (26), Куркино (14 кеше) р-ннарында яшиләр. Татар халкының иң мөһим тарихи сәхифәләре Т.ө. терр-ясе б-н бәйле. 1349–60 елларда Тула *Тайдула бикәнең* биләмәсе булып тора, 1380 дә Т.ө. терр-ясендә *Куликово кыры сугышы* була. РСФСРның атказанган артисты Р.Г.Әсфәндиярова, химик-технолог Й.М.*Байгильдинның* тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге Т.ө. б-н бәйле.

ТУЛА́Й РЕГИОНА́ЛЬ ПРОДУ́КТ (ТРП), регионның социаль-икътисади үсеш дәрәҗәсен күрсәтүче гомуми икътисади статистик күрсәткеч. Милли исәп-хисап системасының төбәк өлешен тәшкил итә. Хәзерге Россия статистикасында ТРП — төп бәяләрдәге өстәмә кыйммәт, ягъни билгеле бер вакыт эчендә регион территориясендә файдалану өчен җитештерелгән товарлар һәм хезмәт күрсәтүләрнең бәясе. Җитештерү б-н куллану арасындагы аерма буларак исәпләп чыгарыла. Икътисади эчтәлеге б-н ТРП илнең тулаем эчке продукты күрсәткеченә тиңдәш.

1990 еллар ахырыннан ТРның икътисади үсешен (2008–09 еллардагы икътисади төшенкелекне исәпкә алмаганда) ТРПның тотрыклы үсеше күрсәтә. 2000–13 тә респ-када ТРП күрсәткече — 191,6 млрд. сумнан 1,5 трлн. сумга, җан башына ТРП 50,7 мең сумнан 397,0 мең сумга арта а Әлеге күрсәткечләр буенча Татарстан 2013 тә РФ субъектлары арасында — тиңдәшле рәвештә 5 нче һәм 12 нче урыннарга һәм Идел буе федераль округы регионнары арасында 1 нче урынга чыга. ТРП-та инновацион продукция өлеше 16,0% хасил итә. Татарстан ТРП структурасында сәнәгать өлеше — 44,1%, төзелеш — 8,6%, транспорт һәм элемтә — 7,7%, а.х. 7,1% тәшкил итә.

2014 тә ТР ТРПының тармак структурасында иң зур өлеш — 22,8% — файдалы казылмалар чыгаруга туры килә. Эшкәртү производстволарының өлеше — 18,3%; ваклап-күпләп сату, автотранспорт ремонтлау, көнкүрештә кирәкле һәм шәхси файдаланудагы әйберләрне төзәтүнең — 16,2%; төзелешнең — 8,6%; күчемсез милек б-н операцияләрнең — 8,6%; транспорт һәм элемтәнең — 7,7%; авыл һәм урман хуҗалыкларының — 6,3%; электр энергиясе, газ һәм су җитештерү һәм бүлүнең — 2,7; Татарстан ТРПында кече һәм урта эшмәкәрлекнең өлеше — 25% тирәсе.

Соңгы вакытта, илдәге икътисади кыенлыкларга карамастан, ТР ТРПы тотрыклы рәвештә үсә һәм 2017 дә аның күрсәткече 2115,6 млрд. сумга җитә (аның структурасында сәнәгать өлеше — 40% чамасы, төзелеш — 10%, транспорт һәм элемтә — 6%, а.х. 7% тәшкил итә).

С.Г.Белов.

ТУЛБА́Й авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 35 *км* төньяк-көнбатыштарак, Шыя елгасы буенда. 2010 елда 208 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп-балалар бакчасы, клуб, китапханә. 1680 нән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.да мәчет, мәдрәсә, су тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1374 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Кабык Күпер волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 80 ир-ат; 1859 да — 439, 1897 дә — 736, 1908 дә — 776, 1920 дә — 861, 1926 да — 783, 1949 да — 388, 1958 дә — 422, 1970 тә — 345, 1979 да — 279, 1989 да — 234, 2002 дә — 205 кеше. Т.да шагыйрь Шәехи *Маннур* туган, аның исемендәге музей-китапханә эшли.

ТУЛБА́Й авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 19 *км* көнбатыштарак, Тиргәвеш елгасы буенда. 2010 елда 374 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. 17 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы асабалар һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, арба ясау, кирпеч яндыру, чабата ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.да 2 мәчет, мәктәп (1842 дә ачыла), 3 су тегермәне, 2 күмәч пешерү йорты, 4 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3738 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Күзкәй волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында, 1930 ның 10 августыннан Минзәлә р-нында. Халык саны: 1795 тә — 173, 1859 да — 660, 1870 тә — 756, 1884 тә — 906, 1897 дә — 1070, 1906 да — 1294, 1913 тә — 1803, 1920 дә — 1396, 1926 да — 1808, 1938 дә — 987, 1949 да — 759, 1958 дә — 598, 1970 тә — 629, 1979 да — 545, 1989 да — 382, 2002 дә — 379 кеше.

Әд.: Мензелинский край: История и современность. Мензелинск, 2006.

ТУ́ЛИН (Гыйззәтуллин) Сергей (Риф) Заһит улы (11.9.1957, Башкортстан АССРның Миякә р-ны Кече Гәйнә а.), РФ Герое (20.7.1996), генерал-майор (2000), юридик фән. канд. (2009). Казан суворовчылар хәрби уч-щесен (1976), Рязань югары һава-десант командирлар уч-щесен (1980), М.В.Фрунзе исем. хәрби акад. (Мәскәү, 1990) тәмамлый. 1980–87 елларда Карпат буе хәрби округының 39 нчы аерым десант-штурм бригадасы парашют-десант батальонында взвод командиры, разведка ротасы командиры, штаб башлыгы. 1990–91 дә Белоруссия хәрби округының 38 нче аерым һава-десант бригадасында командир урынбасары. 1992–93 тә БМОның Югославиядәге тыныч-лык урнаштыручы контингентына кергән



С.З.Тулин.

554 нче аерым пехота батальонында штаб башлыгы. Беренче Чечен кампаниясендә катнаша (1994–96), 76 нчы гв. һава-десант дивизиясенең 104 нче гв. парашют-десант полкы командиры. Россия Герое исеме Төньяк Кавказда полкның сугыш хәрәкәтләре б-н җитәкчелек иткәне, хәрби бурычын үтәгәндә тәвәккәллек һәм батырлык күрсәткәне өчен бирелә. 1997–98 дә РФ Кораллы көчләре Генштабының Халыкара хезмәттәшлек баш идарәсе офицеры. 2000–02 дә Төньяк Кавказ хәрби округында: 205 нче аерым мотоукчы бригада командиры, 58 нче армия командиры урынбасары. 2002–06 да Рязань өлкәсенең хәрби комиссары. 2007 дән запаста. 2007 дән «Хәрби-сәнәгать компаниясе» ҖЧҖтә проектлар департаменты директоры, 2008 дән проектларны идарә итү буенча ген. директор урынбасары. 2008–09 да «Арзамас машиналар төзү заводы» АҖнең директорлар советы әгъзасы. Рязань өлкәсенең Грек-рим көрәше федерациясе рәисе. Батырлык ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: Садыков К. Стал Гиззатуллин Тулиным // Республика Башкортостан. 2005. 22 февр. № 34; Иванов А.А. Герои Российской Федерации — Россия Федерациясе Геройлары. К., 2012; Бикбулатов Р. История суворовского училища: от благородных девиц до мужчин-героев // АиФ. 2014. 9 окт. № 9 (37).

Ф.Г.Миңнеханов.

ТУЛИ́СОВ Геннадий Васильевич (2.8.1947, Мордва АССРның Чамзинка р-ны Пичеуры а.), инженер, тимерьюлчы, «Казан Гипрониавиапромы» АҖнең Логистик тикшеренүләр үзәге директоры (2005 елдан), Чуаш АССРның, ТРның атказ. транспорт хезмәткәре (1990, 1993), РФнең мактаулы төзүчесе (1997). Алатырь тимер юл техникумын (1965), Бөтенсоюз тимер юл транспорты инженерлары читтән торып уку ин-тын (Мәскәү, 1978), КПСС ҮК каршындагы Иҗтимагый фәннәр академиясен (1986) тәмамлый. 1969–79 да Горький тимер юллары Казан бүлегенең Чамзинка, Канаш станцияләрендә станция дежурные, станция башлыгы. 1979–82 дә КПССның Канаш шәһәр ком-ты 2 нче секретаре, 1982–84 тә Чуаш АССРның Канаш шәһәр башкарма ком-ты рәисе. 1986 дан Горький тимер юллары Казан бүлеге башлыгының 1 нче урынбасары, 1994 тән — башлыгы. 1998–2003 тә ТР МК каршындагы Транспорт департаменты директоры. 2003–05 тә Казан шәһәр хакимияте каршындагы Метрополитен төзелеше идарәсе башлыгы. Т. җитәкчелегендә тимер юл линияләренә реконструкция үткәрелә, төп Канаш-Юдино-Кизнер юлының кайбер участоклары электрлаштырыла, сигнализация һәм блокировка чаралары б-н җиһазландырыла, локомотивлар паркы көчле электровозлар, уңайлы вагоннар һ.б. б-н тәэмин ителә. Медальләр б-н бүләкләнә.

ТУЛПА́Р, төрки халыклар мифологиясендә, фольклоры һәм әдәбиятында канатлы ат. Баһадир аты һәм «*Йиртөшлек*» дастанындагы Чалкойрык кебек ышанычлы ярдәмче, еш кына геройның яклаучысы, аны яман көчләрдән һәм албастылардан саклаучы. Башка дөнья вәкиле буларак, Т. җир өстендә, җир астында («Йиртөшлек» дастаны), су төбендә (татар халык әкияте «Аю батыр») һәм күктә («Алтаин Саин Сөмә» дастаны) яши ала. Кирәк вакытта аңа канатлар үсеп чыга, шуңа күрә ул ерак араларны мизгел эчендә уза (башкорт халык әкияте «Утлы-яшенле кылыч»). Кайвакыт Т. ярдәмендә геройга инициация йоласы уздырыла (башкорт әкияте «Кейеҙбай менән батша кыҙҙары» — «Киез-бай белән патша кызлары» герое чын батырга әйләнер өчен атның корсагы астыннан узарга тиеш була). Кайвакыт Т. Убыр рәвешенә керә.

Татар («Әйгәли батыр» һ.б.) һәм башкорт («Таз белән убырлы сеңлесе» һ.б.) халык әкиятләрендә очрый. Тылсымлы атның гаҗәеп сыйфатларын югары бәяләү татар халык мәкальләрендә чагыла (мәс., «Атның бары Тулпар булмас, кошның бары шоңкар булмас»). Татар әдәбиятында Т. турында беренче тапкыр М.Кашгариның «Диване лөгат әт-төрк» сүзлегендә (1072–74) телгә алына.

Әд.: Татар халык иҗаты: Дастаннар. К., 1984; Татар халык иҗаты: Мәкальләр һәм әйтемнәр. К., 1987; Башкорт халык иҗады: Әкияттәр. Өфө, 1976. 1 кит. *Ф.И.Урманчеев.*

«ТУЛПА́Р», әдәби-нәфис, иҗтимагый-сәяси яшьләр журналы. БРның Яшьләр эшләре дәүләт ком-ты органы. 1994 елның августыннан Уфада аена 2 тапкыр татар телендә нәшер ителә. Төрле еллардагы мөхәррирләре — Р.М.Кашапов, Р.Г.Ногманов, 2000 нән Р.Г.Миңне ғәмәтов. Башкортстанда татар телендә чыга торган бердәнбер журнал. «Т.» б-н татар әдәбиятчылары Т.Н.Галиуллин, Л.Лерон, Р.Миңнуллин, С.Х.Хафизов һ.б. хезмәттәшлек итә. Эчтәлегенең күп өлешен башлап язучы татар һәм башкорт авторларының проза, поэзия һәм публицистикасы алып тора. Журналның төп темалары — яшьләр тормышының актуаль проблемалары, татарларның милли үзаң үсеше, дин һәм әхлак мәсьәләре. Рубрикалары: «Социаль бәла-каза», «Сәхнә йолдызлары», «Күренекле якташлар», «Хобби», «Мәхәббәт — ул...», «Таһир-Зөһрә» һ.б. Журналда чыккан материаллар Башкортстан һәм Татарстандагы иҗтимагый-сәяси процесслар б-н бәйле проблемаларга, милләтара мөнәсәбәтләрнең актуаль аспектларына кагылып үтә. Балалар һәм яшүсмерләр өчен — «Тузганак», хатын-кызлар өчен «Ак калфак», сатира һәм юмор яратучыларга «Көлке дә, гөнаһ та» кушымталары чыга. ТР Журналистлар берлегенең «Бәллүр каләм — Хрустальное перо» (2003) бүләгә лауреаты.

ТУЛУНБӘ́К (Толынбәк) ХАН (?–1371 тирәсе), Алтын Урда ханы (1370 елдан). *Газиз шәех хан* тәхеттән төшерелгәннән соң, үзара көрәш барышында Сарай әл-Җәдид шәһәрендә хакимиятне үз кулына ала. Сарай әл-Җәдид даирәсендәге аксөякләрдән тыш аның таяныр көчләре булмый. Калган аксөякләр Мамай әмиргә буйсына. Тәхеттән Мамай тарафыннан төшерелә һәм, фаразлар буенча, үтерелә.

Әд.: Куликовская битва. М., 1980; Мухамадиев А.Г. Булгаро-татарская монетная система XII–XV вв. М., 1983. *И.Л.Измайлов.*

ТУМА́НОВ Дмитрий Александрович (21.11.1962, Ленинград), мәдәният эшлеклесе, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2008). Казан театр уч-щесен тәмамлаганнан соң, 1982–98 елларда Россия драма театрлары, ш.и. Казан Зур драма театры (1983–92, 1994–96) актёры. 1996 дан мәдәни учреждениеләр менеджеры, 2004 тән Иҗади сәләткә ия балалар һәм яшьләргә ярдәм күрсәтү буенча респ-ка «Созвездие — Йолдызлык» үзәге директоры. Т. җитәкчелегендә, иҗади сәләткә ия яшьләргә ярдәм күрсәтүнең иң отышлы формасы буларак, «Созвездие — Йолдызлык» ачык респ-ка яшьләр эстрада сәнгате фестивальләрен әзерләү һәм уздыру гамәлгә ашырыла (2016 да 16 нчы фестиваль була). Иң яхшы актёрлык эшчәнлеге өчен РСФСР театр эшлеклеләре берлеге бүләге (1990, В.Шашинның «Аздыручы» пьесасы буенча куелган спектакльдә Дмитрий роле өчен, Казан Зур драма театры), «Россия гаиләсе» («Семья России») милли бүләге (2009), РФ хөкүмәтенең мәдәният өлкәсендәге бүләге (2010), ТРның М.Җәлил исем. бүләге (2007) лауреаты.

ТУМА́ШЕВ Әнәс Ибраһим улы (25.2.1924, Чистай ш. — 12.10.2010, Казан), театр рәссамы, нәкышьче, педагог, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1967), ТАССРның халык рәссамы (1974), РСФСРның атказ. рәссамы (1982). Казан сәнгать уч-щесен (1942), И.Е.Репин исем. Ленинград нәкышь, скульптура һәм архит-ра ин-тын (1953, М.П.Бобышев остаханәсе) тәмамлый. 1953–76 елларда — Татар акад. театрында куючы-рәссам, 1976–85 тә — баш рәссам, бер үк вакытта, 1961–75 тә, Казан сәнгать уч-щесендә укытучы, 1964–75 тә театр-бизәлеш бүлеге җитәкчесе. 1961 дән ТАССР Рәссамнар берлеге әгъзасы, 1975–86 да идарә рәисе. Т. татар театр-бизәлеш нәкыше үсешенә лаеклы өлеш кертә. Аның иң яхшы декорацияләрендә фәзаи образларның монументаль масштаблылыгы сәнгати эшләнгән төсләр композициясе, көнкүреш детальләре, кием үзенчәлекләре б-н ярашып тора. Т.ның иҗат диапазоны татар драматурглары пьесаларын бизәүдән алып (Т.Гыйззәтнең «Ташкыннар», 1956, 1977; Ж.Фәйзинең «Башмагым», 1957; К.Тинчуринның «Җилкәнсезләр», 1958, 1971; Ф.Бурнашның «Таһир-Зөһрә», 1959, 1967; Н.Исәнбәтнең «Миркәй б-н Айсылу»; Н.Фәттахның «Кол Гали», 1974 һ.б.), Европа, рус һәм совет классикасына кадәрге араны колачлый (А.Островский, «Котырган акчалар», («Бешеные деньги», 1962); У.Шекспир, «Чама сына карап чарасы» («Мера за меру», 1967); Н.Погодин, «Баһадирлар» («Третья патетическая», 1970) һ.б.).

Танылган пейзаж нәкыше остасы Т. Идел буе һәм Кама аръягының елга киңлекләре матурлыгын чагылдыра («Кама аръягы офыклары», 1977; «Язгы көн», 1981; «Туган ягым», 1982; «Камада иртә», 1983; «Идел култыклары», 1998); Казан һәм аның тирә-ягы күренешләреп сурәтли («Бөреле авылы», 1963; «Яңа һәм борынгы Казан», 1976; «Казан Кремле дивар-лары янында», 1992); ил буйлап сәяхәт иткәндә пейзаж этюдлары яза («Сочи», 1962; «Алма-Ата тирәсе», 1964; «Кырым. Гурзуф», 1985); сюжетлы картиналарга мөрәҗәгать итә («Хушлашу», 1942; «Тукай типография эшчеләре арасында», 1943–44). 1990 елларда тарихи жанрда эшли: «20 гасыр Казаны» (1990), «Пётр I Болгарда» (1991), «Бөек Болгар базары» (1992).



Ә.И. Тумашев.



Ә.И.Т у м а ш е в. «Кояш баер алдыннан». 1999.

Респ-ка (1945 тән); зона — «Зур Идел» (1960–80); бөтенроссия — театр һәм кино рәссамнары (Мәскәү, 1956), «Советская Россия» (Мәскәү, 1980), РСФСРның 16 автономияле респ-касы рәссамнары (Мәскәү, 1971); бөтенсоюз — театр рәссамнары (Ташкент, 1958), театр, кино, телевидение рәссамнары (Мәскәү, 1967, 1979) һ.б. күргәзмәләрдә катнаша. Шәхси күргәзмәләре Казанда (1964, 1974, 1984, 2004) һәм Мәскәүдә (1984) үткәрелә. Әсәрләре А.А.Бахрушин исем. Үзәк театр музеенда (Мәскәү), ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда, Чуаш сәнгать музеенда (Чабаксар ш.), Ц.Сампилов исем. Сәнгать музеенда (Улан-Удэ ш.), Россия һәм чит илләрдәге шәхси тупланмаларда саклана. ТАССРның Г.Тукай исем. дәүләт бүләге лауреаты (1958). Медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: Анас Ибрагимович Тумашев // Народные художники. К., 1980; Червонная С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984; Анас Ибрагимович Тумашев: Живопись, театрально-декорационное искусство: Каталог выставки. К., 2004. *Г.Ф.Вәлиева-Сөләймановa.*

ТУМА́ШЕВ Ба һаветдин (?–?), җәмәгать эшлеклесе. Казакъстандагы Кызылъяр шәһәре мөселман ком-ты рәисе. 1917 елда Милләт Мәҗлесе депутаты булып сайлана. Шуннан соңгы язмышы билгесез.

ТУМА́ШЕВ Гомәр Гали улы (21.11.1910, Чистай ш. — 10.9.1984, Казан), механика өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (1946),

проф. (1947), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1951), РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1960). Казан ун-тында укый (1932–34), Казан авиация ин-тын тәмамлый (1937), шунда ук эшли, бер үк вакытта, 1942 елдан, Бөек Ватан сугышы елларында Казанга эвакуацияләнгән Үзәк аэрогидродинамика ин-ты (Мәскәү) ф-лында эшли. 1944 тән Казан ун-тында: теоретик механика каф. мөдире (1944–54), физика-матем. ф-ты деканы (1948–51), Математика һәм механика фәнни-тикшеренү ин-ты директоры (1954–60), бер үк вакытта аэрогидромеханика каф. мөдире (1954–82), проф.-консультант (1982 дән). Тоташ тирәкләр механикасында киң кулланыш тапкан кайтма кырый мәсьәләләр (ККМ) теориясенә нигез салучыларның берсе. Хезмәтләре газ динамикасына, җир асты гидромеханикасына, аэрогидродинамика ККМнә карый. Т. чикләнгән агым да һәм бары тик циркуляция ягалап агуында биплан һәм канат профилен төзү, өзек агым ягалап ага торган дуга формасын эзләп табу мәсь әләрен, моментын үзгәртү максатында профиль модификациясенең кире мәсь әләсен, газ агымы тизлеге тавыш тизлегенә кадәр булганда профиль төзү мәсь әләсен чишә. Сыеклык агымы чикләренең формасын бу чикләрдә тизлек һәм басым бүленеше буенча билгеләү мәсьәләсен формалаштыра һәм аның тулы анык чишелешен күрсәтә. Т. җитәкчелегендә газ динамикасы тигезләмәләрен якынча интеграллау проблемалары һәм төрле эчтәлекле мәсь әләләр: ш.и. агым ның каршылыкларны ягалап агуы һәм агымнарның туктавы, газның каналларда һәм соплоларда агуы, өермә агымнар, зур өзеклек өслеге б-н 1 нче һәм 2 нче семьялык характеристикалары арасындагы өлкәдә тавыш тизлегеннән зуррак тизлекле агым мәсь әләләре, әлеге агымда канатның иң зур җәеме теориясенә кире мәсьәлә зур үсеш ала. Сыеклыкның күзәнәкчел тирәкләрдәге хәрәкәтен өйрәнү б-н бәйле проблемалар өлкәсендә Т. су һәм нефть зоналарында басым кырларын билгеләү мәсьәләсен чишә, һәм бу нефть скважиналарын рациональ урнаштыруда уңышлы файдаланыла. ТАССР ЮС депутаты (1951–55). Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: К задаче о стягивании контура нефтеносности // Уч. зап. Казан. ун-та. 1953. Т. 113, № 10; Обратные краевые задачи и их приложения. К., 1965 (автордаш); Фильтрация несжимаемой жидкости в неоднородной пористой среде. К., 1972 (автордаш).

Әд.: К у з н е ц о в А.В. Гумер Галеевич Тумашев. 1910–1984. К., 2002.

ТУМА́ШЕВ Равил Рәхим улы (21.4.1923, Төркестан ССР, Семипалатинск ш. — 2.01.2016, Казан), режиссёр, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1966). 1952 елда Мәскәүдәге Дәүләт театр сәнгате ин-тының (ГИТИС) режиссёрлык ф-тын (А.Д.Попов, М.О.Кнебель курсы) тәмамлый. 1962 гә кадәр Татар акад. театрында эшли. Т. куйган «Тынгысыз картлык» («Беспокойная старость», Л.Н.Рахманов, 1953), «Отелло» (У.Шекспир, 1953), «Анджело» (В.Гюго, 1954), «Бажалар» (И.Абдуллин, 1954), «Мәхәббәт хикәясе» (Н.Хикмәт, 1955), «Ажаган» (К.Шамил, 1956), «Урал суы буенда» (М.Фәйзи, 1958), «Мәңгелек каләм» («Вечное перо», И.В.Шток, 1959), «Рабурден варислары» («Наследники Рабурдена», Э.Золя, 1959), «Җиз кыңгырау» (А.Гыйләҗев, 1960) һ.б. спектакльләр режиссёр җитәкерергә теләгән фикерләрнең аныклыгы һәм төгәллеге, актёрлар уеныңың психологик нечкәлекләре б-н аерылып торалар. 1963–85 тә Татар респ-ка күчмә театрының баш режиссёры. Тәүге спектакльләре: «Тынгысыз йөрәк» («Палата», С.И.Алёшин), «Көлкеле хәл» («Забавный случай», К.Гольдони), «Минем бичара Маратым» («Мой бедный Марат», А.Н.Арбузов), «Чит кеше баласы» («Чужой ребёнок», В.В.Шкваркин), «Мещаннар» («Мещане», М.Горький; барысы да 1963–67). 1964 тән яшь татар драматурглары б-н актив эшли башлый, аларның пьесаларын татар театры сәхнәсенә чыгара. А.Гыйләҗевнең «Кара күзле кызлар» (1964), «Шомырт чәчәк атканда» (1968), Т.Миңнуллин ның «Нигез ташлары» (1968), «Йөрәк янар өчен бирелгән» (1970), «Уйланыр чак» (1972), И.Юзеевның «Бөркетләр кыяга оялый» (1970) пьесаларын сәхнәләштерә. «Үзебез сайлаган язмыш», «Ак тәүбә, кара тәүбә» (Т.Миңнуллин пьесалары буенча; 1973, 1976), «Сары чәчәк ата көнбагыш», «Ефәк баулы былбыл кош» (А.Гыйләҗев пьесалары буенча; 1974, 1982), «Сандугачлар килгән безгә», «Кыр казлары артыннан» (И.Юзеев пьесалары буенча; 1974, 1976) спектакльләре татар театры репертуарын нигездән яңарткан әһәмиятле вакыйгалар буларак кабул ителәләр. Т.ның иҗат ысулына актёрлар б-н тирәнтен эш алып бару, әзерлек вакытында өстәмә белемнәр, мөһим күрсәтмәләр бирү, актёрларның проф. осталыкларын даими рәвештә камилләштерү хас. Татар респ-ка күчмә театрында ул шактый актёрлар тәрбияли, алар арасында Ә.Галиуллин, Х.Мәхмүтов, И.Мәхмүтова, Н.Сафин, З.Досаева, М.Жаббаров һ.б. бар. Т. бер үк вакытта, 1970–89 да, Казан мәдәният һәм сәнгать ин-тында укыта. ТАССРның Г.Тукай исем. бүләге лауреаты (1976). Бөек Ватан сугышында катнаша. Кызыл Йолдыз ордены, «Казанышлар өчен көмеш хач» Польша ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: И л я л о в а И. Театр имени Тинчурина. К., 2002. *Д.Ә.Гыйммранова.*

ТУМА́ШЕВА Диләрә Гариф кызы (19.7.1926, Төмән ш. — 19.6.2006, Казан), тел галиме, филол. фән. д-ры (1969), ТР ФАнең хакый кый әгъзасы (1992), ТАССР һәм РФнең атказ. фән эшлеклесе (1977, 1997). Мәскәү ун-тын тәмамлый (1949). 1952 елдан Казан ун-тында, татар теле каф. мөдире (1966–89 һәм 2001 дән), проф. (1970), көнчыгыш тел ләр каф. мөдире (1989–94), Көнчыгышны өйрәнү ин-ты профессоры (1994–2001). Т. күп еллар дәвамында Төмән, Омск, Новосибирск, Томск, Кемерово өлкәләре терр-ясендә тыгыз урнашып яшәүче Себер татарлары диалектларын өйрәнә. Аның «Көнбатыш Себер татарлары теле. Грамматик



Д.Г.Тумашева.



К.Ж.Тумашева.

очерк һәм сүзлек» («Язык западносибирских татар. Грамматический очерк и словарь», 1–2 кис., 1961–68), «Себер татарлары диалектлары. Чагыштырма тикшеренү тәҗрибәсе» («Диалекты сибирских татар. Опыт сравнительного исследования», 1977; карта б-н), «Себер татарлары диалектлары сүзлеге» («Словарь диалектов сибирских татар», 1992) монографияләре тикшеренүләренең нәтиҗәсе булып тора. «Татар фигыле» («Татарский глагол», 1986) хезмәтендә татар фигыленә хас наклонение, зат-сан һәм заман грамматик категорияләре модальлек, темпоральлек һәм персональлекне белдерүче функциональ-семантик категорияләр җирлегендә өйрәнелә. Хезмәтләре татар теле грамматикасы һәм морфологиясенә, диалекталь лексикографиягә, этнотопонимикага карый. Мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен уку ярдәмлекләре авторы. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1994). Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе. К., 1964; Роль Казанского университета в развитии отечественной тюркологии // Проблемы тюркологии и истории востоковедения. К., 1960 (автордаш); Исследования по татарскому языку. К., 1977; Взаимодействие лексической и грамматической семантики // Языковые уровни и их взаимодействие. К., 1990.

Әд.: Её призвание — лингвистика (О проф. Д.Г.Тумашевой) // Науч. Татарстан. 1996. № 3; Х и с а м о в а Ф.М. Диляра Тумашева: Путь к новым открытиям // Казань. 2001. № 12; Академик Тумашева. К., 2004.

ТУМА́ШЕВА Кәшифә Жамалетдин кызы (7.1.1903, Казан губ., Казан өязенең Нөнәгәр а. — 18.4.1978, Казан), актриса, режиссёр, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1957). 1904 елдан Иркутск шәһәрендә яши, рус мәктәбендә, кызлар җәдит мәдрәсәсендә («Мәдрәсәи Исламия»), кызлар гимназиясендә укый. 1919 да Иркутскида татар театр труппасына керә, «Канлы көннәрдә» (Ш.Усманов), «Яшьләр» (Ф.Әмирхан), «Артист» (Г.Кариев), «Ямьсез тормыш» (Ф.Сәйфи-Казанлы) спектакльләрендә кечерәк рольләр башкара. 1921–23 тә Семипалатинск шәһәрендә татар театрында. 1926 да Казанда Татар театр техникумын тәмамлый, шунда укытырга кала. 1929–31 дә Татар радиосы режиссёры. 1939 дан, Мәскәүдәге Дәүләт театр сәнгате ин-тының (ГИТИС) режиссёрлык ф-тын тәмамлаганнан соң, Татар акад. театрында режиссёр булып эшли (1955 кә кадәр). «Күзләр» (Х.Фәтхуллин, 1939), «Үги кыз» (А.Әхмәт, 1941), «Җавап» (Э.Шамил, 1941)

спектакльләрен, бер пәрдәле «Аю» һәм «Тәкъдим» («Медведь», «Предложение», А.П.Чехов; икесе дә — 1946) комедияләрен, «Тормыш җыры» (М.Әмир, 1947), «Көннәр һәм төннәр» («Дни и ночи», К.М.Симонов романы буенча), «Галиябану» (М.Фәйзи), «Җыр дәвам итә» (М.Әмир), «Зур гаилә» (Э.Шамил; барысы да — 1948), «Хафизәләм-иркәм» (Г.Камал, 1949), «Ак калфак» (М.Фәйзи, 1951), «Иске Казанда» (Г.Камал, 1952) спектакльләрен куя. Бер үк вакытта, 1949–50 дә, рус Яшь тамашачылар театрының татар төркеме б-н җитәкчелек итә, анда Г.Гобәйнең «Маякчы кызы» әсәре буенча спектакль куя, Татар театр уч-щесендә укыта. 1956–62 дә Татар респ-ка күчмә театрының баш режиссёры. Аның сәхнәсендә 18 спектакль куя: «Сакла, шартламасын!» (К.Тинчурин, 1956), «Яшел эшләпә» (Г.Насрый, 1957), «Карагол» (Д.Юлтый, 1957), «Үлмәс җыр» (Р.Ишморат, 1958), «Жорж Данден» (Ж.Б.Мольер, 1958), «Елмайган өчен миллион» («Миллион за улыбку», А.В.Софронов, 1959), «Рәйхан» (Н.Исәнбәт, 1960), «Тапшырылмаган хатлар» (Г.Минский, Г.Кутуй повесте буенча, 1961) һ.б. Т. Татар респ-ка күчмә театрының репертуарын яңарта. Актёрларның проф. белем алуларына, ш.у. спектакльләрнең сәхнәгә куелу дәрәҗәсенә зур игътибар бирә.

Әд.: И л я л о в а И. Театр имени Тинчурина. К., 2002. *Д.Ә.Гыймранова.*

ТУМБА́ елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Кече Чирмешән елгасының (Олы Чирмешән елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 9,9 *км*. Бассейнының мәйданы 43,1 *км*². Идел аръягы түбәнлегеннән, Әлки р-нында ага. Елга башы Яңа Тумба авылыннан 4 *км* көньяк-көнчыгыштарак, тамагы Иске Тумба авылыннан 2 *км* көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 135 *м*, тамагыныкы — 71 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 80%. Т.ның 0,6 дан 4,2 *км* га кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,39 *км/км*². Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену моделе 0,25–0,5 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен саегуы б-н характерлана. Корылыклы елларда елга урыны-урыны б-н кибә, суы бервакытта да тамагына кадәр барып җитми. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 83 *мм*, ташу агымы катламы 75 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,023 *м*³/*с*. Суы бик каты: язын 9–12 *мг-экв/л*, кышын һәм җәен 20–40 *мг-экв/л*. Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

ТУНАКО́В Алексей Павлович (11.3.1931, Казан – 25.2.2011, шунда ук), информацион технологияләр өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1974), ТР ФА мөхбир әгъзасы (1992), ТССРның һәм РФнең атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1991, 1999), Казан техник ун-тының атказ. профессоры (2001). 1954 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, турбомашиналар каф. профессоры (1973–75), автомобильләр һәм автомобиль двигательләре каф. мөдире (1975–85), проф. (1975), сызма геометрия һәм машиналар төзү сызымнары каф. мөдире (1985–98), шул кафедраның (1998–2000), пр-тиеләр икътисады каф. профессоры (2000 нән). Хезмәтләре газ турбиналы двигательләрне автоматлаштырып проектлауга, компьютер графикасына һәм логистикасына карый. Т. газ турбиналы двигательләр һәм аларның өлешләренең матем. модельләрен төзи, газ турбиналы двигательләргә техник диагностика ясау өчен программалар эшли. Уйлап табуга 18 авторлык таныклыгы бар. Медальләр, ш.и. СССР Космонавтика федерациясенең акад. В.П.Макеев исем. медале, СССР ВДНХсының ике көмеш медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Методы оптимизации при доводке и проектировании газотурбинных двигателей. М., 1979; Как работать над диссертацией. К., 2005; САПР газотурбинных двигателей. Уфа, 2005 (автордаш).

ТУНАКО́В Павел Дмитриевич (15.6.1907, Түбән Новгород губ. Дубенщино а. — 4.2.1984, Казан), хакимият-ху җәлык эшлеклесе, РСФСРның атказ. төзүчесе (1968). 1919–23 елларда «Красный печатник» басмаханәсендә эшли (Казан). 1925–30 да югары типтагы Казан индустрия техникумында (1929 дан — Казан политехник ин-ты) укый, бер үк вакытта «Татарстан төзелеш берләшмәсе»ндә эшли. 1931 дән Энгельс шәһәрендә һәм Белоруссия Хәрби округында хәрби төзелештә. 1937 дә нахакка гаепләнеп кулга алына. 1940 та, азат ителгәннән соң, Казанга кайта. 1940–57 дә 14 нче төзелеш трестында, трест җитәкчесе (1943 тән). 1957 дә Татарстан икътисади адм. район ХКСның Төзелеш индустриясе, урман һәм агач эшкәртү сәнәгате идарәсе башлыгы. 1957–65 тә Халык депутатларының Казан шәһәр Советы башкарма ком-ты рәисе. 1965–66 да ТАССР коммуналь хуҗалыгы министры. 1966–69 да Татарстан «Татстрой» җитештерү төзелеш-монтаж берләшмәсе башлыгы. 1970–78 дә СССР Сәнәгать төзелеше министрлыгының «Главтатстрой» төзелеш эшләре баш идарәсе башлыгы урынбасары; 1978–84 тә «Главтатстрой» планлаштыру-икътисади идарәсе башлыгы урынбасары. Т. Казанның капиталь, торак һәм мәдәни-көнкүреш төзелеше үсешенә зур өлеш кертә. ТАССР (1967–71) һәм РСФСР (1959–67) ЮСлары депутаты. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, өч Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Казандагы бер урам Т. исемен йөртә.

Х е з м.: Казань сегодня и завтра. К., 1960.

Әд.: Таким он запомнился: К девяностолетию П.Д.Тунакова. К., 1999.

ТУНАКО́ВА Юлия Алексеевна (11.9.1973, Казан), химик-аналитик, химия фән. д-ры (2007). 1995 елда Казан ун-тын тәмамлый. Казан техник ун-тында эшли. Хезмәтләре экологиягә карый. Т. мегаполисның — бала-чага яшәгән биотирәлекнең полиметаллик пычрануына яңа маркёр тәкъдим итә. Үзе эшләгән матем. модельләргә һәм төбәк нормативларының югары чикләренә нигезләнеп, әйләнә-тирә компонентларында металл күләменең балалар өчен чик кыйммәтләрен билгели. Халыкны һәм терр-яләрне полиметаллик пычранудан саклау алымнарын тәкъдим итә һәм сынап карый.

Х е з м.: Оценка степени вторичного загрязнения питьевых вод металлами на территории г. Казани. К., 2006; Оценка эффективности различных типов фильтров по доочистке питьевой воды в конечной точке потребления. К., 2006; Экологический мониторинг металлов на территории г.Казани. К., 2006 (автордаш).

ТУНГУ́СОВ Кузьма Максимович (Кузьма Максимов, Кузьма Тузинин) (1819–1881), дин эшлеклесе. 1840–80 елларда Казан иске дин тарафдарларының борынгы помор килешүендәге җәмгыятен җитәкли, Россиядәге әлеге җәмгыятьнең төп эшлекләреннән берсе. Дингә кагылышлы полемик памфлетлар һәм хатлар авторы. П.И.Мельников әсәрләрендәге күп кенә геройларның прототибы.

ТУ НЫЛЖА́ авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 20 *км* төньяктарак, Чаллы-Зәй автомобиль юлы буенда. 2010 елда 92 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб. 1678 дән Кушкачы исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, олаучылык, агач әзерләү, тимерчелек, балта эше б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында миссионерлык мәктәбе, ашлык саклау-сату һәм 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1942 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Тәкмәк волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августын нан — Чаллы, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1859 да — 345, 1897 дә — 701, 1906 да — 798, 1913 тә — 941, 1920 дә — 1009, 1926 да — 680, 1938 дә — 701, 1949 да — 561, 1958 дә — 434, 1970 тә — 399, 1979 да — 259, 1989 да — 133, 2002 дә — 98 кеше.

Әд.: Заинская энциклопедия. К., 1994.

«ТУП», сәяси, әдәби, икътисади һәм сатирик рәсемле журнал. РСДРПның Әстерхан комитеты татар төркеме органы. 1907 елның мартыннан 3 апреленә кадәр Әстерхан шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, барысы 3 саны чыга. Нашире — К.Иримбитов, мөхәррире — Х.Гомәров, фактик мөхәррире — М.*Галәү*. Әстерхан вице-губернаторы карары б-н П.А.Столыпинга каршы сатирасы өчен — беренче саны, хөкүмәткә каршы мәкаләләре өчен өченче саны кулга алына. Телеграф агентлыгы хәбәрләре, җирле яңалыклар басыла. Социаль һәм милли изүгә, наданлык һәм артта калганлыкка каршы юнәлтелгән материаллар да дөнья күрә. Мәкаләләр Ш.Бәйдинең (Ш.Гуниның тәхәллүсе) тематик карикатуралары б-н бизәлә. Әстерхан округ мәхкәмәсе карары б-н ябыла; Х.Гомәров кулга алына.

Әд.: Г ы й л ь м а н о в Ф. «Туп» журналы // Казан утлары. 1966. № 6.

ТУПАЛАКБАШЛА́Р (Cottus), керчаклар семьялыгыннан балыклар ыругы. 30 га якын төре билгеле, күбесенчә Төньяк ярымшарның төче сулыкларында таралганнар. Татарстан терр-ясендә бер төре — гади тупалакбаш (C. gobio) очрый. 19–20 йөз башында шактый таралган була, хәзерге вакытта сирәк очрый. Идел һәм аның кушылдыкларында, ташлар астында яши. Гәүдәсенең озынлыгы 10–12 *см*, авырлыгы 15 *г*. Сырты аксыл-соры төстә, вак-вак кара тимгелле; корсагы аксыл яки саргылт. Гәүдәсе уклаусыман, шома, башы киң, җәенке, чәнечкеле. Күзләре өскә караган. Тәңкәләре юк. Корсак йөзгечләреннән кала бөтен йөзгечләре дә күп санлы кара буй-буй сызыклы һәм тимгелле, күкрәкнекеләр — киң, озын, сырт йөзгечләре 2 (1 нчесе 2 нчесеннән кыскарак). Аерым, яшерен яшәү рәвеше алып бара. Уылдыкны язын, таш астына чәчә. Башка балыкларны куып, ата зат ояны саклый, зур күкрәк йөзгечләре б-н кагынып аны чистарта. Үрчемлелеге 40 тан 400 уылдык бөртегенә кадәр. Яшәвенең 3–4 нче елында җенси җитлегә. Су төбендәге умырткасызлар, балык уылдыгы һәм маймыҗлар б-н туклана, үзе чуртан һәм налим өчен азык булып тора. Сулыклар чисталыгының индикаторы. ТРның Кызыл китабына кертелгән.



Гади тупалакбаш.

ТУПА́С ЙӨНЛЫ́ САРЫКЛА́Р, бериш булмаган (мамыктан, мамык б-н кыл арасы йоныннан, кылдан торган) тупас йонлы йорт хайваннары. Т.й.с. үрчетүнең төп юнәлешләре: тун (романов токымы), илтер (бәрән тиресе) (каракүл, сокольский токымы), ит-май (гиссар, җайдар, эдильбай токымнары), йон-ит (кучугур, михново, дарваз токымнары), ит-йон-сөт (балбас, лезгин, карабах, тушин, карачай токымнары) тибына караган сарыклар асрау. Т.й.с. авырлыклары б-н бер-берләреннән шактый аерыла (45 *кг* лы романов токымыннан 140 *кг* га кадәрге гиссар токымы арасында). Бер сарыктан кыркылган йон микъдары зур түгел — 2,0–2,5 *кг*. Чиста йон чыгышы югары (80% ка кадәр). Йоннары киез һәм трикотаж эшләнмәләр, келәм, тупас постау, киез, чикмән (бурка) җитештерүдә кулланыла. Үрчемлелекләре 100–300 %. Үсешләре тиз бара (4–5 айлык ваккытагы авырлыклары 30–40 *кг* һәм аннан да артыграк тәшкил итә). ТРда асрала торган Т.й.с. тышкы рәвешләре һәм продуктлылык, зоологик классификация ягыннан бериш түгел, озын нечкә койрыклы токымнарга керә. Конституцияләре һәм продуктлылыклары буенча йон-ит тибына карый. Йон һәм итләреннән тыш, бу төр сарыкларны тун эшләнмәләр өчен тире алу максатыннан асрыйлар. Т.й.с. үрчетү Татарстанда сарык асраучылыкның электән килгән төп юнәлеше санала; хәзерге вакытта бу токымны шәхси хуҗалыкларда да, фермер хуҗалыкларында да үрчетәләр: баш саннары 1980 елда — 927,7 мең; 1990 да — 764,4 мең; 2000 дә — 420,8 мең; 2003 тә — 378 мең, 2014 тә 403,2 мең тәшкил итә. Ш.у.к. *Сарык асраучылык*.



Тупас йонлы тәкә.

Әд.: Фазулзянов А.Х., Миньякин А.Ф. Интенсификация овцеводства Татарии. М., 1990.

Әдх.Фазылҗанов.

ТУПА́Ч авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 18 *км* көньяк-көнбатыштарак, Минзәлә елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 205 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. 1719 дан мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп, ашлык саклау-сату һәм бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 884,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Минзәлә волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Минзәлә р-нында. Халык саны: 1795 тә — 95, 1859 да — 285, 1870 тә — 306, 1884 тә — 434, 1897 дә — 584, 1906 да — 659, 1913 тә — 812, 1920 дә — 912, 1926 да — 756, 1938 дә — 732, 1949 да — 735, 1958 дә — 575, 1970 тә — 604, 1979 да — 488, 1989 да — 331, 2002 дә — 298 кеше.

«ТУПЛА́Н», иҗтимагый-сәяси атналык газета. «Туплан» яшьләр оешмасы органы. 1918 елның 12 мартыннан 10 маена кадәр Оренбург шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, барысы 10 саны чыга. Мөхәррире — С.Рәхмәти. «Сәясәткә битараф булмаган яшьләр газетасы» өстәмә исеме б-н басыла. Редакция татар яшьләрен революцион вакыйгаларда катнашмаска чакыра. «Т.» б-н шагыйрь Шамун Фидаи (К.Х.Шакиржанов) актив хезмәттәшлек итә, башка авторлар күрсәтелми. «Яңа вакыт» г-тасы басмаханәсендә басыла. РСФСР ХКСның матбугат турындагы Декреты нигезендә ябыла.

ТУПЛЫ́ ХОККЕ́Й, боз мәйданчыгында (70×110 *м*) капкалы (3,5×2,1 *м*) спорт уены. Командаларда 11 әр кеше уйный. Уенның максаты — кәшәкә б-н көндәшләренең капкасына туп кертү. Т.х.ның бер төре — мини-хоккей (уен алкалы хоккей мәйданчыгында уза, билге, капка 1,22×1,83 *м*, командада 6 кеше уйнау кебек кайбер өстәмәләр була). Т.х. Казанда 1924 елдан билгеле. 1928 дән Казан беренчелеге, 1937 дән ирләр һәм хатын-кызлар арасында Татарстан Кубогы беренчелеге һәм ярышлар уздырыла. 1920–30 елларда-гы иң яхшы командалар: «Динамо», «Спартак», «Наука», «Азот», «Пишмаш», «Снайпер», «Темп» (барысы да — Казан). Татарстанның җыелма командасы — Идел буе Спартакиадалары җиңүчесе (1939), РФ Хөкүмәте призына турнирда көмеш медаль алучы (2000); «Динамо» командасы — РСФСР Кубогына ярышта бронза медаль алучы (1949). 1950–90 елларда СССРның, Россиянең төрле беренчелек лигаларында һәм чемпионатларында «Динамо», «Ленин районы», «Ракета» (барысы да — Казан), «Автомобилист» (Чаллы ш.) командалары уйный. Иң яхшы «Динамо-Казан» ирләр командасы (2008 гә кадәр — «Ракета», 1958 дә Казан оптика-механика з-ды каршында оеша) — Россия чемпионаты 1996 (1 нче лига) җиңүчесе, 2001 (бронза, мини-хоккей), 2008/09 (бронза), 2010/11, 2011/12 (көмеш) медальләр алучы, Коми губернаторы (2000), Викинглар (2000, көмеш), Россия 2009,2013 (2002, 2011 — көмеш), Эдсбюн (2009), дөнья (2010) кубоклары иясе. Балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбенең «Ракета» хатын-кызлар командасы (2002 дә оештырылган) — Россия чемпионатында 2003 (бронза, кызлар арасында), 2006/2007 (көмеш), Россия Спартакиадаларында 2004 (көмеш, кызлар арасында) Россия Кубогында (2006–07) медаль (көмеш) алучы. Т.х. буенча дөнья чемпионатлары 2005 һәм 2011 дә Казанда ясалма боз б-н «Ракета» (7,5 мең кеше сыешлы) һәм «Трудовые резервы» (6 мең кеше) стадионнарында уздырыла. Татарстанда 2018 гә Т.х. б-н шөгыльләнүчеләр саны якынча 700 кеше. Т.х. федерациясенең президенты — В.И.Матвеев.

Н.Д.Бобырев.

ТУ́ПОЛЕВ Андрей Николаевич (29.10.1888, Тверь губ. Пустомазово а. — 23.12.1972, Мәскәү), авиаконструктор, техник фән. д-ры (1933), СССР ФА академигы (1953; 1933 елдан СССР ФА мөхбир әгъзасы), РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1933), өч тапкыр Соц. Хезмәт Герое (1945, 1957, 1972), инженерлык-авиация хезмәте генерал-полковнигы (1968). 1918 дә Мәскәү юга-ры техник уч-щесен тәмамлый. 1909 дан проф. Н.Е.Жуковский җитәкчелегендә навада йөзү түтәрәгендә шөгыльләнә башлый (планерлар һәм самолёт элементларын төзүдә катнаша, 1910 да беренче тапкыр планерда очыш ясый). 1916–18 дә исәпләү-сынау бюросында эшли, биредә илдә беренче аэродинамик труба уйлап табыла һәм эшләнә. Үзәк аэрогидродинамика ин-тына (ЦАГИ) нигез салучыларның (1918) һәм җитәкчеләренең берсе. 1918–36 да тоташ металлдан тәжрибә самолётлары төзелеше башлыгы урынбасары, җи ңел һәм ник металл — кольчугалюминий (дюралюминий) җитештерүне оештыручы. 1922 дә төрле класслы: катнаш конструкцияле АНТ-1 (1922), тоташ металл АНТ-2 (1924), хәрби АНТ-3 (1925 елда Кызыл Армиянең Хәрби-һава көчләрендә коралануга кабул ителә) тоташ металл самолётлар проектлау һәм җитештерү буенча тәжрибә КБсын (ЦАГИ составында) оештыра һәм аны җитәкли. Дөньяда беренче булып Т. ирекле йөртүче моноплан канатлы тоташ металл самолёт схемасын фәнни нигезли: двигательне канатның алгы кырыена һәм

ягулык бакларын аның сыемына урнаштыру нәтиҗәсендә канатның эше кими һәм авырлык күтәрү сәләте арта. Әлеге схема буенча 1925 тә АНТ-4, 1930 да АНТ-6, 1935 тә АНТ-40 бомбардировщиклары төзелә (Казан, Воронеж, Новосибирск, Комсомольск-Амурда һ.б. шәһәр з-дларында сериялəп җитештерелүгә кертелә). Т. илнең самолёт төзү практикасына авиация з-дларында төп КБның ф-лларын һәм аларның үз очыш базаларын оештыруны кертә, шуның б-н завод сынауларының вакыты кыскара һәм машиналар җитештерү күпкә тизләтелә. Т. — илнең беренче күпмоторлы пасс. самолётларын: 3 моторлы АНТ-9 (1929), 5 моторлы АНТ-14 (1931), шул вакыт өчен иң зур пасс. самолёты АНТ-20 «Максим Горький»ны (1934, аның аналогы АНТ-20 бис Казан з-дында эшләнә) төзүче конструктор. АНТ (1922–41) һәм ТУ (1941 дән башлап) самолётларында 78 дөнья рекорды куела, 28 уникаль очыш башкарыла, ш.и.: «Челюскин» пароходында поляр экспедициядә катнашкан 1934 кеше коткарыла (АНТ-4); 1937 дә Мәскәүдән АКШка Төньяк котып аша В.П.Чкалов һәм М.М.Громов экипажлары тукталышсыз очып үтә (АНТ-25); 1937 дә И.Д.Папанин җитәкчелегендәге «Северный полюс» фәнни экспедициясе тиешле урынына төшерелә (АНТ-6); 1938 дә В.С.Гризодубова җитәкләгән хатын-кызлар экипажы рекордлы ераклыкны очып үтә (АНТ-37 бис «Родина»).

1937 дә Т. репрессияләнә (1955 тә аклана). Тоткынлыкта 29 нчы махсус Үзәк КБда (СССР НКВДсының Махсус техник бюросы) «103» проектын (фронт бомбардировщигы Ту-2) эшләүче конструкторлар төркемен җитәкли. 1941–43 тә Махсус КБ Омск шәһәренә эвакуацияләнә, Т. биредә Ту-2 не сериялəп җитештерү һәм авиаполкларны комплектлау б-н җитәкчелек итә. Бөек Ватан сугышы операцияләрендә ш.у. Г-4 и Г-5 торпеда катерлары һәм В.М.Петляков б-н бергә эшләгән ТБ-1, ТБ-3, СБ, ТБ-7 (АНТ-42) самолётлары да катнаша. Т. — илнең беренче тоташ металлдан эшләнгән гидросамолётлары АНТ-8, АНТ-22, АНТ-27 бис, самолёт-амфибия АНТ-44; сугыштан соңгы елларда — пешкәкле двигательле самолётлар: сугышчан Ту-85, пасс. очкычы Ту-70, бомбардировщик Ту-4 (атом коралын стратегик йөртүче) проектлары авторы. Илебез конструкторлары арасында беренчеләрдән булып самолётлар төзелешенә турбореактив двигательләр һәм уксыман канатлар (ерακка очучы торган бомбардировщик Ту-16, илдә беренче реактив пасс. самолёты Ту-104) кертә. Т. җитәкчелегендә беренче турбовинтлы континентара Ту-114 самолёты, якын һәм урта магистраль Ту-110, Ту-124, Ту-134, Ту-154 самолётлары, дөньяда беренче тавыш тизлегеннән зуррак тизлекле Ту-144 (А.А.Туполев б-н бергә) пасс. самолёты, махсус кулланылыштагы күп кенә яңа тип самолётлар (ерак араларда радиолокацион эзләү, су асты көймәләреннән саклану, пилотсыз разведчиклар) төзелә. С.П.Горбунов исем. Казан авиация ҖДә Т. тарафыннан эшләнгән күп төрле самолётлар сериялəп җитештерүгә кулəла; 1943–44 тә ул Казан авиация ин-ты аэродинамика лаб-я сендә Пе-2 модельләрен сынауда катнаша. Т. соңыннан самолётлар һәм ракеталар төзелешенә караган Махсус КБ һәм фәнни-техник шерену ин-тларын җитәкләгән бик күп талантлы конструкторларны (В.М.Петляков, П.О.Сухой, В.М.Мясищев, А.А.Архангельский, М.Л.Миль, А.П.Голубков, И.Ф.Незваль һ.б.) үстерә. 1935–37 дә СССР ҮБК әгъзасы. 1950–72 дә СССР ЮС депутаты. Ленин бүләге (1957), СССР Дәүләт бүләкләре (1943, 1948, 1949, 1952, 1972), проф. Н.Е.Жуковский исем. бүләк (1958) лауреаты. Сигез Ленин ордены, Октябрь Революциясе, 2 нче дәрәҗә Суворов, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары, илебезнең һәм чит илләрнең башка орденнары һәм медальләре б-н бүләкләнә. Хезмәт Герое (1926). Бөекбритания Корольлек авиация җәмгыятенең, ш.у. Америка аэронавтика һәм астронавтика ин-тының шәрәфле әгъзасы. Тверь өлкәсенең Кимры шәһәрендә Т.га бронза бюст, Мәскәү һәм Омскида Т. эшләгән пр-тие биналарына мемориаль такталар куелган; Т. исемен Мәскәүдә яр буе урамы, Киев, Ульянов, Кимры, Жуковский шәһәрләрендә урамнар, Мәскәүдәге Авиация фәнни-техник комплексы, Казан авиация ин-ты (хәзер Казан техник ун-ты), Карск диңгезенең Обь култыгындагы утрау йөртә. Казанда авиаконструкторның 120 еллыгына һәйкәл куела.



А.Н.Туполев.

Әд.: Кербер Л.Л. Ту — человек и самолёт. М., 1973; Андрей Николаевич Туполев: Жизнь и деятельность. М., 1990; Матяж А.И., Мельников А.М. Его именем назван университет: А.Н.Туполев — жизнь и деятельность. К., 2008.

ТУПЫЙБА́Ш, т ө й м ә б а ш (Knautia), төкчәчәләр семьялыгыннан бер-, ике- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 50 гә якын төре билгеле, Евразия һәм Төньяк Африканың уртача поясында, әмма, башлыча, Урта Диңгез буенда таралганнар. ТР терр-ясендә 2 төре бар. Кыргый Т. (K. arvensis) барлык районнарда, татар Т.ы (K. tatarica) — Көнбатыш Кама аръягында һәм бик сирәк Идел алдында очрый. 15–200 *см* биеклектәге үсемлек. Сабагы туры, өске өлешендә аз гына бутаклы, чәчечкеле төкчәләр б-н капланган-лыктан каты. Яфраклары каурыйсыман бүленмә, сирәк кенә бөтен. Чәчәкләре вак, ак, ал-су яки сары төстә, кәрзиннәргә җыйналган; җимеше — элпәле читле орлыкча. Июль–августта чәчәк ата. Җимешләре август–сентябрьдә өлгерә. Орлыктан үрчи. Кыргый Т. — баллы, татар Т.ы — декоратив үсемлек. Халык медицинасында кыргый Т.ның җир өсте өлешләре хроник тире авыруларыннан һәм бронхит вакытында какырык куптару чарасы буларак кулланыла. Татар Т.ы ТРның Кызыл китабына кертелгән.

ТУРА́Й авылы, Менделеев р-нында, Менделеев шәһәреннән 19 *км* көнчыгыштарак, Түбән Кама сусаклагычыннан 1,5 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 434 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Кирпеч з-ды. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1664 тән мәгълүм. 17 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы асабалар һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.да мәчет, мәктәп, 1913 тән земство мәктәбе эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2687 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Салагыш волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Бондюг, 1931 нең 20 гыйнварыннан — Алабуга, 1935 нең 10 февраленнән — Бондюг, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1985 нең 15 августыннан Менделеев р-нында. Халык саны: 1841 дә — 459 ир-ат; 1859 да — 843, 1887 дә — 1227, 1905 тә — 1445, 1920 дә — 1655, 1926 да — 1576, 1938 дә — 1186, 1949 да — 757, 1958 дә — 743, 1970 тә — 675, 1979 да — 607, 1989 да — 550, 2002 дә — 518 кеше. Т. янында *Турай каберлеге* сакланган.

«ТУРА́Й БАТЫ́Р», тылсымлы татар халык әкияте. Башка төркы халыклар фольклорында да («Әбүлхәсән батыр», башкорт; «Кырык егет», дагстан һ.б.) очрый торган гадәти сюжетка нигезләнгән. Фәкыйрь хатынның улы Турай батыр дөнья буйлап сәяхәткә чыгып китә. Юлда ул тагын ике батырны очрата, сәяхәтне өчәү дәвам итәләр. Күпсанлы мажаралардан соң батыр егет патша кызына өйләнә. Әкияттә традицион мотивлар һәм символлар күп: туган йорт матчасына герой кыстырып калдырган махсус билге (каз каурые), батырларның сынаулары һәм дуслыгы-хыянәте, Су асты патшалыгына сәяхәт, анда исəпсез байлык табу, кәләшне яулап алу һ.б.

Әкият 1939 елда Теләче р-нының Макса-баш авылында Г.Бәширов тарафыннан язып алына. Беренче тапкыр «Халык әкиятләре» (1940) китабында басылып чыга. Кулъязмасы ТР ФА Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тының фольклор фондында саклана.

Әд.: Татар халык иҗаты: Әкиятләр. К., 1977. 1 кит.; Брагинский И.С., Басилов В.Н. Дэвы // Мифы народов мира. М., 1987. Т. 1; Тресиддер Дж. Словарь символов. М., 2001.

Ф.И.Урманчеев.

ТУРА́Й КАБЕРЛЕГЕ́, археол. истәлек; Менделеев р-нындагы *Турай* авылы янындагы 4–5 йөзләргә нисбәтле каберләр. 1950–60 елларда В.Ф.Генинг тарафыннан тикшерелә. Курган астындагы тирән чокырлардагы каберләр (0,5–1,5 *м* биеклектәге 5–15 *м* диаметрлы курганнар бөжра ерымнар б-н әйләндереп алынган). Гадәттә курган өемнәре астында һәрберсе 3,6 *м* тирәнлектәге, 3 *м* га кадәр озынлыктагы һәм 1,2 *м* га кадәр киңлектәге 3 ләп кабер урнашкан. 14 ир-ат каберләре өйрәнелә (мәетләр башлары б-н көнбатышка юнәлдерелгән). Т.к.ндә зур күләмдә тимердән эшләнгән кораллар, ш.и. 3 көбә күлмәк, 2 шлем, 10 кылыч, 5 сугыш балтасы,

10 сөңге, 8 хәнҗәр, ш.у. алтын һәм көмеш б-н корланган әйберләр, ат авызлыклары, бронза һәм көмеш тагылмалы каеш һ.б. табыла. Мәрхүмнәрнең этномәдәни асылы ачыкланмаган (кораллардагы — шлемдагы, кылыч сабындагы бизәкләрдә сарматларның борынгы әйберләре б-н охшашлык сизелә). Курганнар янында йола һәм әйберләр нисбәтендә *Мазунино культурасы* истәлекләренә охшаш грунт каберлекләре урнашкан, алар фин-угор кабиләләре тарафыннан калдырылган.



Турай каберлегеннән шлем (алпак).

Әд.: Генинг В.Ф. Тураевский могильник V в.н.э. (захоронения военачальников) // Из археологии Волго-Камья. К., 1976; Казаков Е.П., Старостин П.Н., Халиков А.Х. Археологические памятники Татарской АССР. К., 1987; Казаков Е.П. К проблеме выявления древностей средневековых сармат Урало-Поволжья // Историко-археологические исследования Поволжья и Урала. К., 2006. *Е.П.Казаков.*

«ТУРА́Н АРТ», халык кәсепчелеге пр-тиесе. 1992 дә С.К.Хәйбрахманова башлангычы б-н нигез салына (2007 гә кадәр «Туран» милли-мәдәни үзәге фонды» ҖЧҖ). Максаты — милли сәнгатьне, һөнәрчелек традицияләрен яңарту, җитештерү (сувенирлар һәм бүләкләр), наширлек, химаячелек эшчәнлеген тормышка ашыру, сынлы һәм гамәли-бизәлеш сәнгате әсәрләрен туплау, сәнгать күргәзмәләре, конкурслар оештыру. «Т.а.» б-н төрле елларда проф. рәссамнар, дизайнерлар С.Гарбузова, Е.Гыймранова, С.Кузьминых, А.Липина, О.Марсова, Л.Фәсхетдинова, Х.Латыйпов, Л.Чубукова хезмәттәшлек итә, нәфис продукцияне (чигү, укалап чигү, аппликация б-н бизәлгән түбәтәй, калфаклар, бәй - рәм костюмнары, бүләк сөлгеләр, эскәтерләр, намазлыклар, тастымаллар җыелмасы һ.б.; каюлы күннән эшләнгән әйберләр: мендәр, читекләр, сумка-янчык, намазлыклар, китап каплары; шәмаилләр; агачны уеп бизәгән әйберләр: сандыклар, дивар тәлинкәләре) Биектау р-нының Ямаширмә авылындагы остаханәләрнең чигүчеләре һәм заказларны өйдә башкаручы һөнәрчеләр җитештерә.

1993 тән «Т.а.» — хәзерге заман татар рәссамнарының, татар гамәли-бизәлеш сәнгатенең Казан, Мәскәү, Самара, Тубылда, күп кенә чит илләрдә уздырылган ретроспектив («1930 еллар графикасы», «Ислам һәм хәзерге заман сәнгате», «Алтын Урда» һ.б.) һәм шәхси күргәзмәләрен, «Казан сувениры» күргәзмәсен (1995, 1998) һ.б. оештыра. Татар сәнгатенә керткән өлеш өчен «Туран» Милли премиясен (1994 тә бирелә), Гали Мәхмүдов (М.Мәхмүдов) исем. 1 нче респ-ка хаттатчылар конкурсын (1997) гамәлгә куя. 1994–95 тә «Т.а.» акчасына «Татарстан» ж-лының «Сәнәигы нәфисә» кушымтасы чыгарыла. Эшләнмәләре Казандагы «Туран» фирма кибетендә сатыла.

Әд.: Изделия народных художественных промыслов и декоративно-прикладного искусства Республики Татарстан: Каталог. К., 2002; Валеева-Сулейманова Г.Ф. Будут ли наши внуки знать, что такое «народные промыслы?» // Татарстан. 2008. № 7; Шагеева Р. Орнамент – это миф (репортаж из мастерской «Турана») // Идел. 2010. № 2. *Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

ТУРБЕЛЛЯ́РИЯЛӘР, к. *Төкле суалчаннар.*

ТУРГА́Й КОШЛА́Р (Alaudidae), чыпчык-сыманнар отрядыннан сайрар кошлар семьялыгы. 15 уруг һәм 75 төрне берләштерә. Башлыча, Азия, Европа һәм Африкада таралганнар. Т.к. юка һәм туры томшыклы, арткы бармакларының озын тырнаклы булуы б-н аерылып торалар. Гәүдә озынлыклары 12–25 *см*, йон-каурыйлары җир төсендә, бүксә һәм күкрәкләре тимгелле. Т.к.ның күп кенә төрләренең ата затлары өчен оялау терр-ясе өстеннән сайрап, дерелдәп очу хас. Т.к. — ачык киңлекләрдә: кыр, болын, дала, ара-тирә урман буйларында һәм аланнарында яшәүчеләр. ТР терр-ясендә 4 төре: сабан тургае (Alauda arvensis), урман тургае (Lullula arborea), бүрекле тургай (Galerida cristata), мөгезле тургай (Eremophila alpestris) очрый. Аеруча сабан тургае киң таралган. Кошчык соргылт-көрән-чуар, тәбәнәгрәк киң бүрекчәле. Гадәттә, апрель башында, карлар эреп, җирләр күренә башлагач очып килә. Коры үлән түшәлгән ояларын җирдә ясыйлар. 4–6 йомырка салалар. Йомыркалар өстендә ана зат утыра. Кош балалары чыкканда ук куе йон б-н капланган булалар, тиз үсәләр, 9–10 көннән ояларын ташлап чыгалар. Күп кенә кошлар елына 2 оя бала чыгаралар. Филчекләр һ.б. кыр культуралары корткычлары кош балалары өчен азык булып тора. Калган вакытта Т.к., нигездә, кыяклылар һ.б. үлән орлыклары б-н туеналар. Көзгә таба алар төркем булып җыелалар һәм, очып киткәнче, кыр-болыннарда күчеп йөриләр. Урман тургае кечерәк гәүдәле, аксыл-сары кашлы, кыскарак койрыклы булуы б-н аерыла. Урман аланнарында, киселдәләр, сирәк агачлы наратлыкларда яши.



Сабан тургае.

Яшел Үзән, Питрәч, Лаеш, Югары Ослан р-ннарында, Казан тирәсендә очрый. Сабан тургаеннан 10 көн чамасы соңрак, гадәттә, апрель уртасында, урманнарда җирләр күренә башлагач килә. Оясын җирдә кора. 3–5 йомырка сала. Күбесенчә бөҗәкләр б-н туклана. ТРның Кызыл китабына кертелгән. Мөгезле тургайның башында үзенчәлекле кара «мөгезчекләр» (исеме шуннан) бар. Чуар кош, сыерчыктан шактый кечерәк. ТР терр-ясендә язгы-көзге очып килү-китүләр вакытында гына күренә. Бүрекле тургайның башында биек бүрекчеге бар. Сирәк кенә Казан әйләнә-тирәсендә очрый.

ТУРГА́Й ТАРЫСЫ́ (Arenaria), канәферчәләр семьялыгыннан күпьеллык, сирәк кенә бер- яки икееллык үләнчел үсемлек, кайвакыт ярымкуакчыклар ыругы. 160 тан артык (кайбер мәгълүматлар буенча 250 гә кадәр) төре







«Туран арт» предприятиесе продукциясе.
1. «Казан сөлгесе». Ефәк, кәнитил, алтын тасма. Укалап чигү. Рәссам С.Д.Кузьминых. 1990 еллар;
2. Намазлык. Каюлы күн. 2000 еллар;
3. Декоратив тастымал (фрагмент). Ефәк, тукыма. Тырнак алмалау. 2000.

билгеле, Төньяк ярымшарның уртача һәм салкын поясларында һәм Көньяк Америка тауларында таралганнар. Татарстан терр-ясендә бер төре — чабыр яфраклы Т.т. (A. serpyllifolia) бар, ара-тирә барлык районнарда, еш кына Кама елгасыннан көньяктарак очрый. Нарат урманнарында, коры тау битләрендә, карбонатлы ачылмаларда, кырларда, яшелчә һәм җиләк-җимеш бакчаларында чүп үләне буларак үсә. 5–15 *см* биеклектәге берьеллык үсемлек. Сабагы туры, тармаклы, кыска төк-чәле. Яфраклары вак, утырма, йомыркасыман. Чәчәкләре вак, ак төстә, ботак очында, тармаклы чатыр чәчәк төркемендә. Җимеше — ике капкачлы, җиләчәкле ачылучан тартмачык. Июнь–сентябрьдә чәчәк ата. Җимешләре июль–сентябрь ахырында өлгерә. Орлыктан үрчи. Декоратив үсемлек.

ТУРИ́ЗМ (франц. tourisme, tour — чыгып йөреп кайту), актив ял итүнең һәм танып-белү эшчәнлегенең бер төре. Кагыйдә буларак, махсус маршрутлар буенча туристлык оешмалары тарафыннан гамәлгә ашырыла. Нинди максаттан булуына карап, Т. танып-белү яисә экскурсия (истәлекле урыннарда булу, мәдәни, тарихи, табигый һ.б. урыннарны карау), спорт (җәяү, велосипед, атта йөрү, тау, су, мотоцикл, автомобиль туризмы, спелеотуризм), һәвәскәр (аучылык, балыкчылык), ш.и. шәһәр яны Т. (зур коллективларның, төркемнәр, аерым кешеләрнең кыска вакытка шәһәр читенә, ш.и. ял итү зонасына чыгуы) төрләренә бүленә. «Т.» ш.у. эчке, халыкара, оештырылган, үзешчән, якын, ерак төрләргә аерыла. 1996 елдан ТРда Т. эшчәнлегенең дәүләт тарафыннан көйләнүен Физкультура, спорт һәм туризм ком-ты башкара. ТР Физик культура, спорт һәм туризм министрлыгы (2001 дә оештырылган) тарафыннан «2009–2011 елларга Татарстан Республикасында туризм өлкәсен үстерү» респ-ка мак-сатчан программасы эшләнә. Ул ТР Президенты М.Ш.Шәймиев юлламасы, ТР Дәүләт Советы (Казан, 2008), «Россия Федерациясендә туризм эшчәнлегенең нигезләре турында» 1996 ның 24 ноябрь һәм 2007 нең 5 февраль (үзгәртүләр кертү турында) федераль законнары, 2008 нең 6 май Федераль агентлык боерыгы нигезендә булдырыла. Программада (2008 нең 31 декабрендә ТР МК тарафыннан раслана) өстенлекле юнәлешләр билгеләнә: матди базаны үстерү (туристлык-рекреация зоналары — «Зөя», «Болгар», «Казан» һәм туристлык-сәламәтләндерү паркы «Кама Аланы»), эчке һәм халыкара туристлык базарларына респ-ка туристлык продуктларын кертүдә маркетинг стратегиясен тәэмин итү. Популярлыгы арта баручы «Татарстанның эн җе муенсасы» («Жемчужное ожерелье Татарстана») — Кече божра (Казаннан Раифа посёлогына, Зөя утрау-шәһәрлегенә, Арча, Лаеш, Ленино-Кокушкинога радиаль туристлык-экскурсия маршрутлары) һәм Зур божра (Болгар, Алабуга, Биләр, Зөя тарих-архитектура-археол. һәм сәнгать музей-тыюлыклары, «Казан», «Чистай» туристлык-экскурсия зоналары һ.б.); «Көмеш дуга» («Серебряная дуга» (Идел буе Болгар дәүләтенең болгар халкы формалашкан һәм мөселманлык кабул ителгән Болгар, Суар, Биләр, Җүкәтау шәһәрләре буйлап туристлык маршрутлары) перспективалы респ-ка туристлык маршрутларыннан санала. 2018 дә респ-кага 3 млн.нан артык турист килеп киткән. 2014 тән ТРда туризм өлкәсендәге идарә эшен ТРның Туризм буенча дәүләт ком-ты башкара.

Н.Д.Бобырев.

ТУ́РИН Василий Степанович (1780, Арзамас ш. — 1834 тән соң, Мәскәү), график, нәкышьче, педагог. Башлангыч белемне Арзамастагы халык уч-щесендә ала. САдә тарихи нәкышь профессорлары И.А.Акимов һәм Г.И.Угрюмовта укый. 1815 тә «академиклыкка билгеләнгән» исеменә лаек була. 1801–33 тә Казанда яши. Иҗат эшчәнлеген Богородица хатын-кызлар монастыренының салкын храмы диварларын бизәүдән башлый (эшен 1807 дә тәмамлый), Казан губерна идарәсендә хезмәт итә. Т. Казанда сәнгать белеме бирүнең башында тора. 1810 да Казан халык уч-щесенә эшкә урнаша, 20 елдан артык рәсем дәресе укыта, шәхси рәсем мәктәбе ача (мәктәп 1834 кә кадәр эшли), аны тәмамлаучыларның күпчелеге Казан уку-укыту округының урта уку йортларында эшли, байтагы укуларын дәвам иттерә (кайберләре рәссам О.Кипренскийда укыйлар). Казанда Т. чиркәү нәкыше остасы буларак таныла, храмнарда: Никола-Нисский чиркәвендә, Казандагы Беренче ир балалар гимназиясе һәм Родионова ин-ты чиркәүләрендә икона ясау һәм дивар бизәү б-н шөгыльләнә. Казан ун-ты чиркәвендә 2 хоругв һәм 4 картина-икона ясый (Казан Изге Мәрьям-Ана иконасы, изге Антоний, Изге Александр Невский һәм Воздвижение Честного Креста иконалары, 1823–25). Петропавел соборының җылы храмында 1815 тәге янгын вакытында зыян күргән дивар бизәкләрен, чиркәү иконостасын, хач бүлмәсенең урта ишеген яңарта.

19 йөзнең 1 нче яртысына караган сәнгать тарихына Т. «перспектив күренеш» дип аталган шәһәр пейзажы жанрында башкарылган хезмәтләре б-н кереп кала. Т.ның мирасын нәкышь алымнары кулланылган күп кенә эскиз караламалары һәм рәсемнәр, гравюралар, офортлар тәшкил итә. САндә укыганда күренекле уеплау остасы И.А.Акимов җитәкчелегендә үзләштерә башлаган офорт техникасында башкарылган хезмәтләре аеруча зур кызыксыну уята. Казанда Т. «Казан күренешләре» (1834, акватинта), «Сөембикә манарасы күренеше. Казанны буйсындырганнан соң исән калган бина фасадлары» (1834, акватинта), Казанны яулаганда һәлак булган рус сугышчыларына куелган һәйкәл сурәтләнгән офорт (1822) кебек берничә рәсем иҗат иткәннән соң да әлеге алымны үзләштерүен дәвам итә. Бер үк вакытта офорт стилендә дини һәм мифологик темаларга иҗат итә (православие дине изгеләре сурәтләре һ.б.).

Т. — 4 литография альбомы авторы (шуларның 2 се — Казанга багышланган). Беренче альбомга — Губерна шәһәре Казанның Баш халык уч-щесе укытучысы В.Турин тарафыннан натурадан һәм уеп ясалган перспектив күренешләренә — рулетка, офорт һәм лавис б-н башкарылган 10 сәхифә кергән. Альбомның «Казандагы гражданнар губернаторы йорты» сәхифәсе (1822, С.-Петербург-тагы Рус музее тупланмасында) автор рәсеме нигезендә башкарылган (Т.ның хәзер ТР Милли музее тупланмасындагы 8 картинасы — шул альбомдагы рәсемнәрнең буяулы оттискы). Рәссам, майлы сыек буяу б-н эшләп, акварель җиңеллегенә, үтә күренмәле саф, якты фәзаи күренешләрне ачуга ирешә. Альбомның автор тарафыннан акварель б-н бизәлеп, Петербургта Баш штабның картография остаханәләрендә басылган бер нөсхәсе сакланган. Ул Казан Кремле, Гостиный двор, университет, Елантау монастыре, мәчет һ.б. төшерелгән 8 литографик сәхифәдән торган, «Губерна шәһәре Казанның В.Турин тарафыннан натурадан ясалган, литографияләнгән һәм бастырылган перспектив күренешләре» дигән икенче бер альбомны төзү өчен нигез булып хезмәт иткән (М., 1834, А.С.Ястрембилов литографиясе). Альбом, Казан архит-расы һәм көнкүрешен күпьеллык өйрәнүләр нәтиҗәсе буларак, сәнгать дөньясында һәм киң җәмәгатьчелектә зур кызыксыну уята һәм 20 йөзнең башында ук сирәк библиографик чыганакка әйләнә. Аны хәтта Т.ның барлык график иҗатының сөземтәсе дип санарга мөмкин. 1885 тә альбом Колосов тарафыннан хромолитография техникасында репродукцияләнә һәм Н.Я.Агафонов көче б-н Казандагы Перов ташбасмаханәсендә бастырыла. «Чиркәү нәкышендә кулланылган төрле изге сурәтләр тупланмасы. В.Турин тарафыннан төзелде, литографияләнде һәм бастырылды» (СПб., 1834, Конрад Вингебер басмаханәсе) альбомы, ихтимал, алдан ук дини темаларга язучы нәкышьчеләр өчен дәреслек итеп тәгаенләнгән





В.С.Турин. 1. «Гостийный двор өлеше кергән Казан руханилар семинариясе». Агачтагы кәгазь. Офорт буявы. 1820 еллар. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 2. «Успение Елантау монастыре». Литография. «Губерна шәһәре Казанның ерактан күренеше...» альбомыннан (Мәскәү, 1834).

булгандыр. Ул 14 литографиядән тора, күп - челеге Т.ның үз хезмәтләре, берничә картина СА профессоры А.Е.Егоров хезмәтләренең төп нөсхәләре буенча башкарылган. Т. «За - волжский муравей» ж-лы өчен (1832, 1 нче т.) «Казан кальгасы күренеше» акватинтасын һәм «Казан хатын-кызлар монастыре күренеше» офортын эшли.

Т.ның әсәрләре Дәүләт Эрмитажында, С.-Петербургтагы Дәүләт Рус музеенда, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда, Казан ун-ты фәнни китапханәсендә, ш.у. С.-Петербург һәм Мәскәүдәге шәхси тупланмаларда саклана.

Әд.: Ровинский Д.А. Подробный словарь русских гравёров XVI–XIX веков. СПб., 1895. Т. 2; Дульский П.М. Василий Турин, казанский художник начала XIX века. К., 1916; Могильникова Г.А. Русское искусство XVII — начала XX века. Живопись: Каталог. К., 2005.

И.Ф.Лобашёва.

ТУРМИ́НКА УРМА́Н ДА́ЧАСЫ, табигать истәлеге. Кайбыч р-ны Турминский (Торма) авылы янында урнашкан. Гөбенә елгасының уңъяк ярындагы урман участогы (Кайбыч урманчылыгының Бәрлебаш участок урманчылыгы). 1989 елда билгеләнә. Мәйданы 56,5 *га*. Төрле яшьтәге нарат-каен



Турминка урман дачасы.

утыртмаларыннан (кайбер агачларның яше 150 ел) гыйбарәт, урман эчендә 2 нче яруста имән һәм каен катыш табигый нарат урманнары формалашып килә. ТРның урман-дала зонасында беренче утыртылган нарат урманнарыннан (19 йөз ахыры). Үлән капламында урман һәм болын үсемлекләренең 40 тан артык төре үсә. Объект фәнни танып-белү һәм эстетик әһәмияткә ия.

ТУРМИ́НСКИЙ (Торма) авылы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 22 *км* көнъяк-көнбатыштарак, Гөбенә елгасы буенда. 2010 елда 187 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 64%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Читеево, Чутеи исемнәре б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Троица чиркәве (1805 тә төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1872 дә ачыла), тимерчелек, су тегермәне, сыраханә, 1 казна шәраб һәм 3 вак-төякләр кибете эшли; җомга базары, 23–25 майда ярминкә үткәрелә. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 546 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Ульянково волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Ульянково, 1927 нең 1 августыннан — Кайбыч, 1944 нең 19 февраленнән — Подберезье, 1956 ның 17 маеннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 177 ир-ат; 1859 да — 622, 1897 дә — 902, 1908 дә — 1029, 1920 дә — 1097, 1926 да — 885, 1938 дә — 922, 1949 да — 525, 1958 дә — 438, 1970 тә — 291, 1979 да — 236, 1989 да — 194, 2002 дә — 214 кеше. Т.ның күренекле урыны — алпавыт Лебедев йорты (19 йөз башы архит-ра истәлеге).

ТУРНЕ́ПС, терлек азыгы шалканы (Brassica гора гара), әвернә чәчәкләр семьялыгыннан икееллык үсемлек. Ареалы киң, Евразияне колачлый. Культурада бар җирдә дә таралган. Беренче елда тамыр яны яфрак таралгысы һәм эре итләч калын тамыры, икенче елда сабакларында чәчәк оешмасы һәм орлыклары б-н җимешләре үсә. Тамыразыгының формасы цилиндрсыман, озынча, шарсыман; төсе ак, шәмәхә, сары. 100 *кг* тамыразыкка якынча 9 азык берәмлеге һәм 0,7 *кг* үзләштерелә торган протеин туры килә. Культура салкынга чыдам. Балчыксыл һәм комсу кәсле-көлсу туфракларда яхшы үсә. Фермаларның терлек азыгы басуларында һәм чәчү әйләнеше өчен игәләр. Май ахыры — июнь башында чәчәләр, кабат чәчкәндә — җәй көне. Орлыкларны чәчү нормасы — 1 *га* 2,3–3,5 *кг*, күмдерү тирәнлеге — 1,5–2,5 *см*. Рәт араларының киңлеге — 45–60 *см*. Чәчүлекләрне карауга рәтләрдәге үсемлекләрне сирәкләү (үсемлекләр арасы 18–20 *см*), рәт араларын көпшәкләндерү, чүпләрен утау, өстәмә тукландыру, сугару керә. Уңышы аскы яфраклары саргаеп кипкәч җыела. Тамыразыгының уңышы 1 *га* дан 400–500 *ц* (сугарулы җирләрдә — 1000 *ц* һәм күбрәк), сабакъяфракларының — 150–200 *ц*. Тамыразыгы һәм сабакъяфраклары терлек азыгы буларак кулланыла. Россиядә бар җирдә дә үстерелә, ТРда «Остерзундомский» сортын йорт яны бакчаларында чәчәләр.

ТУРНЕРЕ́ЛЛИ Эдуард Петрович (Turnerelli Edward Tracy) (13.10.1813, Лондон — 24.1.1896, Лимингтон ш., Англия), рәсемче, язучы, педагог. Тринити-колледжда укый (Дублин, Ирландия), махсус сәнгать белеме булмый. 1836 елдан Россиядә, инглиз һәм латин телләрен укыту хокукы алу өчен Петербург ун-тына имтиханнар тапшыра. 1837–44 тә Казан ун-тында инглиз теле лекторы. Т. үзенең Казан турындагы тәэсирләрен көндәлек язмалар һәм альбом рәсемнәре рәвешендә теркәп бара, шулар нигезендә аның «Казан шәһәре күренешләре» литографияләр альбомы һәм Казан турында истәлекләре барлыкка килә. Т. беренче рәсемнәр сериясен борынгы Болгар хәрабәләренә барып кайткач иҗат итә («Кече манара», «Кара пулат», 1837). Соңрак ул Казан Кремле корылмалары һәм аның тирә-ягы, шәһәр урамнары, монастырьлары һәм мәчетләре сурәтләнгән рәсемнәр сериясен эшли («Благовещение соборы» һ.б.). Әлеге рәсемнәр нигезендә тоныкландырылган фронтиспистан һәм 14 литографиядән торган «Эдуард Турнерелли тарафыннан натурадан карап төшерелгән Казан күренешләре» альбомын төзи (Лондонда Л.-М.Лефевр ташбасмаханәсендә басыла). Литографы тоныкландырылган литография техникасын кулланган беренче инглиз осталарының берсе Дж.Барнард (1807–90) булган дип фаразлана (моңа һәр бит астына урнаштырылган «GB» монограммасы ишарәли).

18 йөз ахырында — 19 йөзнең 1 нче яртысында сәяхәтләргә багышланган басмалар б-н кызыксыну аларны иллюстрацияләүдә литография техникасының киң таралуына китерә, тагын да таррак кысалардагы «сәяхәт нәкыше» жанры барлыкка килә. Т.ның Казан альбомы да әлеге жанр традицияләрендә төзелә. Казанда перспектив архит-ра пейзажы темаларын башка рәссамнар да яктырта (В.С.Турин, А.Н.Ракович, А.Дюран), ләкин Т. рәсемнәре архит-ра пейзажларының җанлы урам күренешләре һәм Казан халкының үзенчәлекле образлары гармониясен уңышлы чагылдырулары б-н аерылып торалар. Т.ның альбомы Россиядә зур уңыш казана һәм Европада ачыш буларак кабул ителә. Күп тапкырлар күчермәләре алыну һәм аның 20 йөз ахырында яңадан басылып чыгуы сәбәпле, ул хәзерге чорда да популяр булып кала (альбомындагы 12 репродукция «Казан күренешләре», (1994) альбомында яңадан басыла).

Литографияләр альбомы уңышыннан соң, Т. үзенең көндәлек язмаларын гомумиләште -





Э.П.Турнерелли. 1. «Сөембикә манарасы». Литография; 2. «Язгы ташу вакытында Казан күренеше». Литография.



М.С. Турунтаева.

ргә һәм чит ил кешеләре һәм Россия башкаласында яшәүчеләр өчен Казан турында истәлекләр китабы рәвешендә бастырып чыгарырга карар итә. Француз телендә дусларча әңгәмә жанрындагы «Казан һәм аның халкы», СПб., 1841 («Kazan et ses habitants») китабы әнә шулай дөнья күрә. Ул шаржлар һәм сатирик рәсемнәрне эченә алган, шәһәр тормышының төрле якларын, Казан халкының көнкүрешен һәм гореф-гадәтләрен яктырткан 12 бүлектән тора. Т. дворяннарның мәгънәсез яшәү рәвешен һәм жирле тәртипләрне дөрес тасвирлап бирә, бу Казан түрәләрендә ризасызлык уята. Татарлар турында кискен фикерләр әйтүе ш.у. аның файдасына булмый. «Казан губерна хәбәрләре»ндә Н.И.Второв Т. китабына катгый рәвештә тискәре бәя бирә. Казан җәмәгатьчелеге б-н ни-загка керү сәбәпле, 1844 нең сентябрендә Т. Казанны калдырырга, Россияне ташлап китәргә мәжбүр була.

Т.ның Лондонда басылган ике томдагы истәлекләре — «Казан, татар ханнарының борынгы башкаласы» (1854; 2 нче басма. 1888) — («Kazan, the Ancient Capital of the Tatar Khans») европалыларны урта гасырлардан башлап Казан жиренең тарихы б-н таныштыра.

Әлеге китапның Болгар дәүләтенә багышланган бүлегенең тәржемәсе 1901 дә басылып чыга (И.А.Ардашев, «Инглиз Э.П.Турнереллиның бәяны буенча Болгар хәрабәләре һәм борынгы болгарлар»). Т. ш.у. Ч.Диккенс хуплаган новеллалар һәм повестьлар, төрле илләргә сәяхәтнамәләр авторы буларак та билгеле. Сәяси эшчәнлек б-н шөгыльләнә, инглиз консерватив партиясенең уң канатына карый. Т.ның әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда, ш.у. С.-Петербург һәм Мәскәү музейларында һәм шәхси тупланмаларда саклана.

Әд.: Ровинский Д.А. Подробный словарь русских гравёров XVI–XIX веков. СПб., 1895. Т. 2; Дульский П.М. Эдуард Петрович Турнерелли. К., 1924; Вишленкова Е.А. Э.П.Турнерелли и его книга «Казань и её жители» // Гасырлар авазы — Эхо веков. 1999. № 3/4; Вербина О.Г. Живописные путешествия по старой Казани. К., 2006.


И.Ф.Лобашёва.

ТУРУНТА́ЕВА Мария Сергеевна (10.10.1926, Зөя кантонының Багай а.), сыер савучы, Соц. Хезмәт Герое (1971). 1940–73 елларда Кайбыч р-нының «Путь к коммунизму» к-зында эшли. Нәселле сыерлар көтүен булдыруда катнаша; алдынгы технологияләр кулланып, һәр сыердан савымны уртача 2810 *кг* нан (1961) 4000 *кг* га (1968), аннан соңгы елларда 4200 *кг* га җиткерүгә ирешә. 1970 елларда өч тапкыр «Районның иң яхшы сыер савучысы» исеменә лаек була. 1969–70 тә ТАССР-ның 50 еллыгы хөрмәтенә район терлекчеләре ярышының инициаторы була. Герой исеме җитештерүдә аеруча югары уңышларга ирешкәне өчен бирелә. Ленин ордены, медальләр, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Әд.: Румянцев Е. Турунтаева Мария Сергеевна // Герои Социалистического Труда Татарии. К., 1984. Кн. 2; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003; Туган җирем — Кайбычым — Кайбицы — край мой родной. К., 2007.

ТУРЫКАНАТЛЫЛА́Р (Orthoptera), бөҗәкләр отряды. Озынмыеклылар (Dolichocera) асотрядыннан — чикерткәсыманнар һәм *өй чикерткәләре*, кыскамыеклылардан (Brachycera) триперстлар һәм саранчалар өссемьялыкларын берләштерә. Дөнья фаунасында — 20 меңнән артык, Россиядә — 700 гә якын, Татарстан терр-ясендә 64 төре билгеле. Гәүдәсе сузынкы, 0,4–8 *см* озынлыкта, гадәттә, ян-яктан кысылган, күбрәк яшел яки коңгырт төстә. Күзләре зур. Авыз аппараты кимерүче типта. 1 нче, 2 нче пар аяклары — йөрүгә, 3 нчесе сикерүгә җайлашкан, ара-тирә казучы аяклары да була. Алгы канатлары тар, тыгыз, туры (исеме шуннан), арткылары — киң, йомшак, тыныч халәттә, җилпәзәсыман, алгылары астына җыела, кайбер төрләрендә канатлар юк. Корсагының арткы өлешендә күкәй салгычы булган ана затлар күкәйләрен туфракка яки үсемлек тукымасына салалар. Яшәү рәвеше буенча личинкалар олы затлардан аерылмый. Т.ның күпчелеге арткы аякларын канат өслегенә яки канат өслекләрен бер-берсенә ышкып чырылдавык тавыш чыгара. Күбесе үсемлекләр б-н туена, кайберләре — ерткычлар.

Татарстан терр-ясендә 6 семьялык вәкилләре очрый: чын чикерткәләр (Tettigoniidae), *аючикерткәләр*, чикерткәсыманнар, саранчалар, тетрикслар (Tetrigidae) һәм триперст-



Турыканатлылар мәкаләсенә. 1. Дүрт нокталы пластинка канатлы чикерткә (Phaneroptera quadripunctata), 1а — шул ук җәенке канатлары б-н; 2. Соры чикерткә (Decticus verrucivorus), 2а — ана зат нимфасы; 3. Яшел чикерткә (Tettigonia viridissima); 4. Сайрар чикерткә (Tettigonia cantaus); 5. Дала чикерткәсе (Saga pedo); 6. Чытырдавык саранча (Bryodema tuberculatum); 7. Өй чикерткәсе (Acheta domestica); 8. Күчмә саранча (Lacusta migratoria); 9. Пычкыкойрык чикерткә (Poecilimon intermedius).

лар (Tridactylidae) (к. табл.). Аеруча яшел чикерткә (Tettigonia viridissima), сайрар чикерткә (T. cantaus), соры чикерткә (Decticus verrucivorus) киң таралган. Урман буйларында, урман аланнарында, болын, көтүлекләрдә яшиләр. Шулай ук синантроп төр — өй чикерткәсе бар. Кайбер Т. а.х. культураларына зыян китерә, аеруча аючикерткәләр һәм саранчалар куркыныч: Азия саранчасы (Locusta migratoria), Себер вак чикерткәсе (Aeropus sibiricus) һәм Италия саранчасы (Calliptamus italicus), өер булып очып йөрүче төрләргә керәләр. Респ-каның көньяк-көнчыгышында Россиядә очрый торган иң зур чикерткә — дала чикерткәсе (Saga pedo) — РФ һәм МСОП Кызыл китапларына кертелгән бик сирәк төр билгеләнгән. ТР терр-ясендә сирәк, берәмләп кенә очраучы кыр чикерткәсе (Melanogryllus campestris), Лаксманн чикерткәсе (Onconothus laxmanni) далалан-ган җирләрдә, гади триперст (Trydactileus variegatus) сулык ярларында яши. Пычкыкойрык чикерткә (Poecilimon intermedius), чытырдавык саранча (Bryodema tuberculatum) ТРның Кызыл китабына кертелгән. К. илл.

Әд.: Сельскохозяйственная энтомология. М.–Л., 1955; Общая и сельскохозяйственная энтомология. М., 1983; Жизнь животных. М., 1984. Т. 3.

И.О.Кармазина, Н.В.Шулаев.

ТУТА́ЕВ Мөнәвәр Закир улы (21.6.1924, хәзер Казакъстан Респ-касы, Көньяк Казакъстан өлкәсенең Сайрам р-ны, Сайрам а. — 2.11.1994, Казан), тарихчы, тарих фән. д-ры (1972), проф. (1973), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1984). Чимкент укытучылар ин-тын (1941), Мәскәү халыкара мөнәсәбәтләр ин-тын (1950) тәмамлый. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1952 дән Казан ун-тының КПСС тарихы кафедрасында укыта. 1959–66 да КПССның Татарстан өлкә ком-тында: пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире, идеология секретаре (1960 тан). 1966–91 дә Казан пед. ин-тында: филос. каф. доценты, КПСС тарихы һәм фәнни коммунизм каф. мөдире (1971 дән). Хезмәтләре Татарстанда халык мәгарифе тарихына карый. «Татарияда мәдәни төзелеш. 1917–1941 еллар» («Культурное строительство в Татарии. 1917–1941», 1975) документлар җыентыгын, «Казан дәүләт педагогия институты» («Казанский государственный педагогический институт», 1974) хезмәтен төзүчеләрдән һәм авторларыннан берсе. Сугышка кадәрге чорда Татарстанда халык мәгарифе системасының формалашуын һәм үсешен өйрәнүгә зур өлеш кертә. 1963–67 дә ТАССР ЮС депутаты. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: У истоков русско-китайских революционных связей (1905–1911). К., 1961; Октябрь и просвещение: Очерки истории просвещения в Татарии накануне и в первые годы Советской власти. К., 1970; Развитие народного образования в Татарии (1917–1940). К., 1975.

ТУТА́Й авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 35 *км* көнбатыштарак, Бола елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 264 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Композитор С.Г.*Садыйкова* музее. Мәчет. 1647–53 тән билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.да мәчет, мәдрәсә, җил тегермәне, тимерче алачыгы эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 989 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Урта Балтай волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 77 ир-ат; 1859 да — 521, 1897 дә — 674, 1908 дә — 816, 1920 дә — 905, 1926 да — 830, 1938 дә — 613, 1949 да — 520, 1958 дә — 518, 1970 тә — 584, 1979 да — 405, 1989 да — 272, 2002 дә — 278 кеше.

ТУТА́Й авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 22 *км* төньяк-көнбатыштарак, Лашчы елгасы буенда. 2010 елда 177 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, чуашлар — 85%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 18 йөздә нигез салына. Халкы башта дәүләт крәстияннәре катлавына керә, 1835–1860 елларда Удел ведомствосы карамагында; игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәдрәсә, 7 сәүдә-сәнәгать йорты була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 840,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Ырынгы волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Буа р-нында. Халык саны: 1859 да — 366, 1897 дә — 543, 1913 тә — 780, 1920 дә — 717, 1926 да — 637, 1938 дә — 578, 1949 да — 462, 1958 дә — 409, 1970 тә — 363, 1979 да — 288, 1989 да — 220, 2002 дә — 233 кеше.

ТУТУБА́ЛИНА Валерия Павловна (19.4.1939, Владивосток ш.), химик-технолог, техник фән. д-ры (1990), проф. (1995). 1963 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң, СССР ФА Казан ф-лының Органик һәм физик химия ин-тында эшли. 1968 дән Казан химия-технол. ин-тында, 1973 тән Казан һәм 1985 тән Пенза төзүче инженерлар ин-тларында. 1992 дән Казан энергетика ин-тында, директор урынбасары (1994–96), җылылык электр станцияләре каф. профессоры (1996 дан). Хезмәтләре күкертле нефтьләр куллануның нәтиҗәлелеген күтәрүгә карый. Т. күкертле кушылмаларның нефть углеводородларын ачыту процессында ингибитор булып торуын һәм дизель ягулыгы, мазут, турбина һәм трансформатор майлары җитештергәндә күкертле нефть (күкерт 0,5–0,7% булган) куллануның искерү процесслары ингибирлануга һәм эксплуатация вакыты арту-га китерүен күрсәтә. Күкертле кушылмаларны турыдан-туры нефть фракцияләрендә ачыту реакторларын эшли. Ачыту продуктлары — сульфоксидлар һәм сульфоннар ачыту ингибиторлары сыйфатында һәм яңа полимер каплам составларын җитештерүдә кулланыла. Үйлап табуга 15 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Фәнни эшкәртмәләре җитештерүгә кертелә («Мединструмент» ФҖБ, җылылык челтәрләре, электр-җылылык үзәкләрендә һ.б.). Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Сжигание сернистых топлив в топках энергетических котлов ТЭЦ. К., 1998; Комплексный метод повышения термической стабильности трансформаторного масла электрооборудования ТЭЦ. К., 2006; Интенсификация работы ТЭЦ путём повышения эффективности маслохозяйства. К., 2007.

«ТУТЫЙНАМӘ» («Тутый кош китабы»), фарсы-тажик әдәбияты ядкәре. 1330 елда Зыя әд-Дин Нәхшәби тарафыннан Һиндстанда языла. «Т».нең нигезендә тезмә һәм чәчмә рәвештә язылган «Шукасаптати» («Тутый кошның җитмеш хикәясе») исемле кысалы кыйсса ята дип фаразлана. Ул керештән һәм 52 әкият-новелладан тора. Аларда акыллы, зирәк тутый кош үзенең хуҗабикәсенә шул әкиятләрне сөйли. Новеллаларның күбесе шактый үзгәртелгән яки автор тарафыннан уйлап чыгарылган. Татар теленә Г.Фәезханов тәр җәмә итә, 1887 елда Казанда нәшер ителә. Со ңыннан тагын берничә тапкыр бастырыла. Татар укучылары арасында киң таралган була, яратып укыла, башка әсәрләр тууга чыганак (сюжет) булып хезмәт итә.

Әд.: Нахшаби З.а.-Д. Книга попугая (Тути-наме). М., 1982.

ТУТЫРГА́Н ТАВЫ́К, татар халкының милли бәйрәм ризыгы. Гадәттә, хөрмәтле кунаклар килү уңаеннан әзерләнә. Каймакка яки сөткә тугланган йомырканы тавыкның ите б-н тиресе арасына (эченә кертмичә) тутыралар. Соңыннан түшкәне ак җеп б-н бәйләләр, формасын саклау өчен марляга яки тастымалга төрәләр һәм акрын гына кайнап торган суга салып пешерәләр. Гадәттә, табынга пешкән бәрәңге б-н чыгаралар.

Әд.: Татарская кухня. К., 1985.

ТУФА́ЙЛОВА (псевд., чын фамилиясе Шәйхетдинова) Зәкия Төфаил кызы (29.1.1907, Башкортстанның хәзерге Кушнаренко р-ны Илморза а. — 1.11.1977, Казан), шагыйрә. Свердловск пед. техникумын тәмамлаганнан соң (1930), Свердловск, Ленинград, Казан шәһәрләренең кичке мәктәпләрендә, һөнәр уч-щеләрендә укыта. 1952–62 елларда В.И.Ленин исем. Респ-ка фәнни китапханәсендә эшли. 1920 еллар ахырында «Игенчеләр атнасы» (Уфа) г-тасында басыла башлый. Балалар өчен язылган «Табышмаклар» (1962), «Әни сүзе» (1968), «Нәни капитан-нар» (1970), «Көмеш яңгыр» (1973) шигъри җыентыклар авторы. Т. әсәрләре балаларны мавыктыргыч формада дөнья б-н таныштыралар.

Әд.: К у к у ш к и н Р. Канатлы дөнья. К., 1984.

ТУФА́Н (Гөлзизин) Хәсән (Хизбулла) Фәхри улы (9.12.1900, Казан губ., Чистай өязе Иске Кармәт а. — 10.6.1981, Казан), шагыйрь. Башлангыч белемне туган авылы мәдрәсәсендә, 1914–16 елларда «Галия» (Уфа) мәдрәсәсендә ала. 1914 тән Урал рудникларында һәм заводларында, Лысьва металлургия комб-тында эшли. 1918 дән Урал, Себер мәктәпләрендә укыта. 1924 тән Казанди яши, 17 нче мәктәптә укыта (бер үк вакытта «Со-

вет әдәбияты» ж-лында хезмәттәшлек итә), РВ-27 радиостанциясендә эшли.

Т. иҗатын 3 этапка бүлеп карыйлар: 1940 еллар уртасына кадәр, 1950 еллар уртасына кадәр, соңгы чор иҗаты. Беренче шигырьләре матбугатта 1924 тә басылып чыга. 1925–27 еллар арасында тулаем бер цикл тәшкил иткән «Зәңгәр бүре», «Урал эскизлары», «Ике чор арасында», «Башлана башлады», «Иске Рәсәй үлде», «Бибиевләр» поэмалары языла. Аларда гадәти композиция, кульминация, чишелеш юк; хикәяләү беренче заттан алып барыла, юллар ритмикасы ирекле. Җәмгыятьтә барган социаль үзгәрешләр поэмада конкрет гаилә мисалында ачыла; хикәяләү геройлары — эш-гамәлләре психол. яктан дәлилләнгән эш челәр. Проблематиканың, сурәтләү чараларының катлаулылыгы, гади сөйләм һәм эксперессив лексиканың еш кулланылуы, романтик рухның өстенлек алуы поэмаларны кискен тәнкыйтьләү, Т.ны футуризм һәм конструктивизм кебек «төшенкелек рухы б-н сугарылган буржуаз сәнгать» агымына иярүдә гаепләү өчен сәбәп була. 1928–32 дә шагыйрь иҗади кризис кичерә. 1928–30 да ул Кавказ һәм Урта Азия якларына җәяүле сәяхәт кыла, аны «иҗатка сәяхәт» дип атый. Төрки халыклар тормышы һәм фольклоры б-н танышу Т. иҗатын яңа тема һәм идеяләр б-н баета. 1933 тән ул татар әдәбияты классиклары традицияләренә кире әйләнеп кайта. Лирикасының аһәңлелеге, моңлылыгы арта, ул төгәл, оста эшләнгән рәсемне хәтерләтә башлый, шагыйрь ешрак татар халык җырлары традициясенә мөрәҗәгать итә башлый («Ак каен», «Озату», икесе дә — 1933). Ул чорларга хас булган вульгар социологизм йогынтысыннан да азат булмый. Моны без гражданлык пафосы б-н сугарылган «Оборона маршы», «Комсомол маршы» (икесе дә — 1933) шигырьләрендә, «Ант» (1935) социаль-философик поэмасында, балалар өчен язылган «Юкмыш бабай малае» (1940) әкиятендә дә күрәбез. «Ант» поэмасы кискен тәнкыйткә дучар була: анда «җитди идеологик хаталар», «сәяси сукырлык», «бөек юлбашчыбыз иптәш Сталинга яла ягу» кебек «читкә тайпылулар» табыла. 1940 та Т.ны кулга алалар, 1942 дә үлемгә хөкем итәләр, шул ук елда үлем җәзасы ун ел төрмә һәм тагы биш елга хокукларын чикләү б-н алыштырыла. Казанга ул реабилитацияләнеп 1956 да кайта.

1940 еллар уртасыннан Т. иҗатында икенче чор башлана. Төрмә һәм сөрген еллары шагыйрьнең дөньяга карашына, лирикасына сизелерлек йогынты ясый, соц. стройның, аның идеологиясенең тискәре якларын күрергә ярдәм итә. Т.ның лирик поэзиясе фәлсәфи яктан тирәнәя төшә. Чорның җитди проблемалары лирик геройның кичерешләре һәм рухи эзләнүләре аша бирелә. «Алга барыш-лый» (1941), «Хәят» (1942), «Иртәләр җитте исә» (1944), «Гөлләр инде яфрак яралар» (1945), «Моабитны күрдем төшемдә» (1947), «Агыла да болыт, агыла» (1951), «Сүз кушасы килә талларга» (1953), «Сөйли торган материя» (1953), «Һиндстанны эзлим» (1956) шигырьләре эчке драматизм һәм трагизм б-н сугарылган.



Хәсән Туфан.

Кырыс чынбарлыкны тасвирлаганда шагыйрь, гайре табигый метафоралар һәм чагыштырулар эзләп азапланмый, вакыйгалар, күренешләрнең асылын һәм яшәеш драматизмын халыкка табигый образлар, «эзоп теле» аша бирә («Моабитны күрдем төшемдә»).

Гомәр Хәйям, Фирдәүси, Нәваи, ш.у. бер төркем урта гасыр төрки-татар шагыйрьләренә хас «бишәр юллы биш строфа» композициясен файдаланып, Т. татар совет поэзиясен яңа форма б-н баета. Бу строфика (строфаның беренче һәм бишенче юллары кабатлана, чираттагы һәр строфа беренче строфаның юлларыннан башлана) үзенчәлекле божра композициясе барлыкка китерә, укучының хисләренә көчле тәэсир итә, әсәр эчтәлегенең фәлсәфи тыгызлыгын арттыра:

Көзге төндә аккош моңая...
Кемгәдер ул эндәшә бугай.
Төннәр буе моңаеп шулай.
Эндәшми тик һичбер кем аңа,
Көзге төндә ялгыз мо ңая («Кырда ике ак канат ята», 1953).

Иҗатының өченче этабына публицистик яңгырашның көчәюе, заман турында киренке уйланулар хас. «Ә җир барыбер әйләнә» (1953) шигырендә шагыйрь «инквизиция чоры»ның китүе, яңа заман тууы турында хәбәр сала. 1960–70 еллардагы иҗатының үзәгенә милләт, туган тел язмышы турында уйланулар тәшкил итә. Татар халкының үткәне б-н кызыксыну, киләчәгә өчен кайгыру инде төрмә һәм сөрген чорларында ук сизелерлек яңгыраш таба. Бу чорда ул татар халкының рухы кимсетелгәнлеге, туган теленә карата кызыксыну юклыгы турында ачык итеп яза: «Алмаз» (1959), «Истәдер» (1967), «Ни булды сиңа?» (1970). Шәхес өчен туган телнең әһәмияте, дөньяга мәшһүр шәхесләр биргән татарның бай мәдәни мирасы турында ул «Гомер эзләре буйлап» (1968), «Кармәт истәлекләре» (1970) поэтик цикларында уйлана. «И тормыш» (1963), «Җилкәнен киерә...» (1967), «Еракларга алып киттеләр» (1967) шигырьләрендә кеше һәм табигатьнең аерылгысыз бердәмлеге, кешенең көче һәм бөеклеге, катлаулы, кырыс тормышның матурлыгы турында уйлана.

Шагыйрьнең мәхәббәт лирикасы драмага корылган. «Иртәләр җитте исә», «Ромашкалар», «Кайсыгызның кулы җылы?» (икесе дә — 1956), «Әйткән идең...» (1957) шигырьләре тирән метафора һәм эчкерсезлек б-н сугарылган.

Т. поэзиясе татар әдәбиятында тулаем бер этап тәшкил итә. Беренчеләрдән булып ул аңа эшче темасын кертә, тулы тавыш б-н милләтләр язмышы фаҗигасе турында сөйли, поэтик телне җыр гадилеге дәрәҗәсенә җиткерә. ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1966). Ике Кызыл Байрак ордены б-н бүләкләнә. 1987 дә Аксубай р-ны Иске Кармәт авылында шагыйрьнең музее ачыла.

Әсәр.: Сайланма әсәрләр. К., 1964; Әсәрләр: 5 томда. К., 2007–10.

Әд.: Сәгъди Г. Татар әдәбияты тарихы. К., 1926; Ак чәчәк атар иде: Хәсән Туфан турында истәлекләр. К., 1989; Гайнетдинов М. Давыллларда, җилләрдә. К., 1989.

А.А.Шәмсутова.

ТУФА́Н ХӘСӘ́Н ӘДӘБИ́ МУЗЕ́Е, Аксубай р-нының Иске Кармәт авылында 1987 елда оештырыла. 1990 да җәмәгать музее буларак ачыла, 1992–2006 да ТРның Дәүләт музее (2001 дән ТРның Милли музее) ф-лы; 2006 дан муниципаль музей. Башта мәдәният йортында урнаша. 2000 дә Х.Туфанның туган йорты урынында каралты-куралы агач йорт корыла, анда яңа экспозиция урнаша. Музей өчен материал туплауда «Авыл таңнары» район г-тасы мөхәррире урынбасары Р.К.Хәбибуллина, мәктәп директоры Р.К.Хәмәтшин, язучылар Г.С.Кашапов, Н.М.Гыйматдинова һ.б. катнашалар. Экспозициянең фәнни концепциясе авторлары — ТРның Дәүләт музее фәнни хезмәткәрләре Р.Г.Гариф җанова, А.Д.Хәйруллина, сәнгать проекты авторы — Ф.А.Зиязов. Музей фондларында 3 меңнән артык саклау берәмлеге исәпләнә. Экспозиция мәйданы 80,5 *м*², өч залда урнашкан (2 се — яңа бинада). Авыл тарихына караган архив материаллары, крәстиян көнкүреше әйберләре, татарларның һәм чуашларның милли киемнәре тәкъдим ителгән. Шагыйрьнең Казандагы фатирының эчке күренеше торгызылган, экспозициягә 1920–30 елларда нәшер ителгән китаплар, ш.и. Х.Туфанның беренче шигырьләр җыентыгы (1929); дуслары Г.Кутуй, Һ.Такташ, М.Җәлил фоторәсемнәре; 1940 та репрессияләнгән һәм 1956 да Сталин лагерьларыннан кайткан шагыйрьнең





Аксубай районының Иске Кармәт авылында Хәсән Туфан музее.
1. Гомуми күренеш; 2. Шагыйрьнең эш өстәле.

шәхси «эше»нең күчермәсе урнаштырылган. Аерым бүлек шагыйрьнең авылдашларына багышланган: якташларының фоторәсемнәре, документлары, әйберләре тәкъдим ителгән. Иң кыйммәтле экспонатлар арасында — Т.ның шәхси әйберләре (1956 да сөргендә шагыйрь теккән күлмәк; чемодан, сөргеннән кайткач алынган стена көзгесе, хатыны Луиза Салигаскәрованың ридикюле; будильник, самовар, чәйнек, китаплар), ире сөргендә чакта хатыны туплаган документлар (Л.Салигаскәрованы эштән җибәрү турында приказ, Х.Туфан гаиләсен Казаннан чыгарып җибәрү турында повестка һ.б.). Ел саен шагыйрьнең туган көне (9 декабрь) һәм искә алу көне (10 июнь), Җиңү бәйрәме (9 май), өлкән нәр көне (1 октябрь) билгеләп үтелә. Музей директоры — Р.Ф.Минханова (1988 дән).

ТУФЕТУ́ЛОВ Айдар Миргалим улы (13.8.1972, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2010), проф. (2011). 1994 елда Казан ун-тын, 1996 да Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлый. 1994 тән Казан финанс-икътисад ин-тында, 2001 дән Казан ун-тында эшли. 2012 дән – салым һәм хокук, 2014 тән — салым салу каф. мөдире. Фәнни хезмәтләре икътисад өлкәсенә, салымнар һәм җитештерүне оештыру мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Отраслевая реструктуризация региональной экономики России в пореформенный период. М., 2006; Концепция стратегического и оперативного контролинга отраслевой реструктуризации региональной экономики. М., 2007; Интеграционные процессы трансформации структуры региональной экономики. М., 2009.

ТУФИТУ́ЛЛОВА (Туфетулова) Роза Рәхмәтулла кызы (17.10.1945, Аксубай р-ны Үзи а.), журналист, язучы, җәмәгать эшлеклесе, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1969), Казан телестудиясендә балалар тапшырулары мөхәррире булып эшли. 1973 елдан «Яшь ленинчы» г-тасында: әдәби хезмәткәр, өлкән хәбәрче, баш мөхәррир (1977–86), «Ялкын» ж-лы (1986–88), «Сөембикә» ж-лы (1988–99) баш мөхәррире. Язмалары иҗтимагый-сәяси проблемалар, аналар һәм балалар, социаль ятимлек мәсьәләләренә багышлана. Әдәби эшчәнлеге документаль проза жанрына карый. 1992– 2002 дә «Ак калфак» татар хатын-кызлары ассоциациясе рәисе. 1999–2004 тә ТР Дәүләт Советы депутаты. РФ Иҗтимагый палатасында ТР вәкиле (2006–2007). Публицистик мәкаләләре һәм чыгышларының бер өлеше «Гражданлык җәмгыяте юлында» («На пути к гражданскому обществу», 2008) җыентыгы булып басылып чыга.

Әсәр.: Олы Мәңгәр — гомер бишеге. К., 1991 (автордаш); Бәйлисе бар йөрәкне. К., 2011.

Әд.: Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3; Даутова Р. Воспитав девочку — воспитаешь нацию: XX век — время взлёта женщин // Восточный экспресс. 2002. 22 нояб.; Кто есть кто в Республике Татарстан. К., 2000.


ТУФРА́К, литосфераның өске катламнарындагы су, һава, тере организмнар тәэсирендә тау токымнары үзгәрү нәтиҗәсендә формалашучы генетик яктан үзара бәйләнешле горизонтлардан торган табигать җисеме. Үзенә генә хас төзелеш, состав һәм үзлекләргә ия. *Туфракның уңдырышлылыгы* — үсемлекнең үсешен тәэмин итә алу сәләте — мөһим үзлек, шул сәбәпле Т. а.х.нда төп җитештерү чарасы булып тора. Барлык җир өстендә биоценозлары һәм тулаем биосфера компоненты буларак Т. алыштыргысыз функция башкара: туфрак капламы аша организмнарның, ш.и. кешенең литосфера, гидросфера һәм атм. б-н күпсанлы бәйләнешләре бара.


Т.ның төп массасын беренчел (кварц, кыр шпатлары, слюдалар һ.б.) һәм икенчел минераллар төзи. Т.ның состав өлеше булып *гумус* тора, ул исә органик калдыкларның (күбесенчә үсемлекләрнең) таркалуы нәтиҗәсендә барлыкка килә. Т.тагы минераль һәм органик матдәләр төрле зурлыктагы кисәкчекләрдән (механик элементлардан) тора: диаметры 1–0,05 *мм* дан (ком) алып 0,0001 *мм* дан кечерәккә кадәр (туфрак коллоидлары). Зурлыгы һәм кисәкчекләренең аеруча коллоидлы һәм ләмле фракцияләрнең, башка үзлекләре аркасында Т. йоту сәләтенә, ягъни төрле матдәләрне, ш.и. үсемлекләрнең туену элементларын тоткарлау үзлегенә ия. Т.тагы теге яки бу фракцияләрнең чагыштырмача күләмен аның гранулометрик составы (комлы, комсыл, балчыклы, балчыксыл) билгели, Т.ның физик һәм физик-механик үзлекләре: туфрак структурасы, күзәнәклелеге, һава үткәрүчәнлеге, дым сыйдырышлыгы, җылы сыешлыгы шулар бәйле. Т.ның барлык төрлелеге, аның теге яки бу терр-ядәге комбинацияләре (туфрак капламы) туфрак ясаучы факторларның — *ана токым*, климат, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы, җирлекнең (чорның) рельефы, ш.у. кешенең хуҗалык эшчәнлегенең — үзара йогынтысы нәтиҗәсендә формалаша, өстәвенә антропоген факторларның әһәмияте көчәя. Т.ның гранулометрик, минер. һәм химик составы ана токымга бәйле, со нынан алар *туфрак ясалу процессы* йогынтысында әкренләп үзгәрәләр. Дымлылык һәм темп-ра шартларының кушылмасы биол. процессларның юнәлешен һәм көчен билгели. Органик матдәләрнең тупланышы һәм минеральләшүе, биоген элементларның сайланма концентрациясе, минералларның таркалуы һәм яңалары барлыкка килү, матдәнең күчеше һәм тупланууы һ.б. организмнар эшчәнлегенә бәйле. Т.ның иң мөһим үзлеге буларак уңдырышлылыгын формалаштыруда нәкъ менә организмнар аерым роль уйный. Сөзәкләкләрнең экспозициясе һәм текәлегенә бәйле рәвештә кояш радиациясенең бүленешендә рельеф катнаша. Т.га билгеле бер инертлык хас; аның составы һәм үзлекләре озак үзгәрә. Төрле Т.ның яше төрлечә: берничә елдан млн. елларга кадәр. Бик зур җимергеч факторлар (бозлану, су эрозиясе, дефляция һ.б.) йогынтысына дучар булмаганлыктан, тропик Т.ның яше аеруча зур. РФ терр-ясендә хәзерге туфракның шактый өлеше дүртенчел системаның бозлану чорыннан соң формалашкан, аларның яше берничә мең елдан уннарча мең елларга кадәр җитә. Хәзерге елга тугайларындагы Т.лар яшь санала. Татарстан терр-ясенә Т.ның зоналы бүленеше хас. Биредә катнаш һәм киң яфраклы урманнар, урман-дала зоналары туфрагы: *соры урман туфраклары* (ТР терр-ясенең 39,6% ын били), *кара туфраклар* (31,7%), *көлсу туфраклар* (якынча 10%) таралган. Кама алдында туфрак катламының төп фонын кәсле-көлсу һәм үзлекләре буенча аларга якын аксыл-соры урман туфраклары тәшкил итә, аларда гумус күләме чагыштырмача зур түгел, ачы реакцияле. Идел алдының төньягында һәм көньяк-көнчыгышында уңдырышлырак соры һәм карасу-соры урман Т.лары, көньяк-көнбатышында селтесезләнгән кара Т. өстенлек итә. Көнбатыш Кама аръягында һәм Көнчыгыш Кама аръягының төньяк өлешендә субүләрдә соры урман Т.ларының төрле астөрләре, тигез урыннарда — көлсуланган һәм селтесезләнгән кара Т.лар, Көнчыгыш Кама аръягының көньяк-көнчыгыш өлешендә, болардан тыш, типик кара туфраклар да формалашкан. *Аллювиаль кәсле туфраклар, кәсле-карбонатлы туфраклар, кара болын туфраклары* шактый таралыш алган. Зур булмаган участокларда торфлы һәм болын-сазлык Т.лары, солодлар, тозлак, катыр Т.лар да очрый.

Т. капламы — планетаның иң әһәмиятле табигый байлыкларыннан берсе, чимал, азык-төлек продуктлары алу өчен төп чыганак, милләтләрнең, халыкның, дәүләтнең гаять кыйммәтле байлыгы. Т.ны саклау — биосфера экологик тигезлекне тәэмин итү һәм саклауда мөһим шарт. Т.ның биосфера компоненты һәм җитештерү чарасы буларак роле аны саклау, рациональ файдалану, уңдырышлылыгын югалтмау һәм арттыру чараларын тормышка ашыру зарурлыгын ассызыклый.

Әд.: Газизуллин А.Х. Почвенно-экологические условия формирования лесов Среднего Поволжья. Т. 1. Почвы лесов Среднего Поволжья, их генезис, систематика и лесорастительные свойства. К., 2005. *Ф.Г.Борһанов.*

ТУФРА́К БЕЛЕМЕ́, туфракның төзелеше, составы, үзлекләре, геогр. таралышы, килеп чыгышы закончалыклары, үсеше, табигатьтәге роле, аны саклау һәм кешенең хуҗалык эшчәнлегендә рациональ файдалану алымнары турындагы фән. Туфракны мөстәкыйль табигый-тарихи җисем буларак өйрәнүне 19 йөз ахырында табигыять тикшерүчесе В.В.Докучаев (1846–1903) һәм аның дәвамчылары башлый, 20 йөз башында табигыять белеменең яңа өлкәсе — генетик Т.б. булды рыла, ул исә туфракны авыл һәм урман хуҗалыгында җитештерү чарасы һәм биоценоз компоненты буларак өйрәнә. Мөһим бүлекләре — туфракларның формалашуы һәм үсеше (генезисы) турындагы тәгълимат, туфрак географиясе, туфракларның һәм туфрак капламының уңдырышлылыгы. Т.б. составында ш.у. туфрак үзлекләрен тикшерүче фундаменталь (физика, химия, биология, туфрак минералогиясе һ.б.) һәм гамәли (аграр, урман, мелиоратив Т.б. һ.б.) бүлекләргә аерып йөртәләр; туфрак классификациясе аерым бүлек булып тора. Идел-Кама төбәге туфракларын беренче тикшерүләр Казан ун-ты каршындагы Табигыятьчеләр җәмгыяте башлангычы б-н 1880 еллар уртасында оештырыла. 1886 да С.И.*Коржинский* Рос-


ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТУФРАК КАРТАСЫ
Масштаб 1:1 500 000
2008 ел
КАЗАН
Балтач
Олы Өтнә
Арча
Казансу
Биектау
Яшел Үзән
Питрәч
Югары Ослан
Олы Кайбыч
Лаеш
Балык Бистәсе
Алексеев
Кама Тамагы
Апас
Буа
Болгар
Тәтеш
Базарлы Матак
Иске Чүпрәле
Аксу
Төләче
Байлар Саба
Кубышев сусаклагычы
ТУФРАК АСТИПЛАРЫ
1 Кәсле-җиңелчә- һәм уртача көлсу
2 Кәсле-ныk көлсу
3 Кәсле карбонатлы
4 Аксыл соры урман
5 Аксыл соры һәм төрле төсмердәге соры урман
6 Соры урман
7 Кара-соры урман
8 Көлсуланган кара
9 Селтесезләнгән кара
10 Типик кара
11 Болын-кара
12 Аллювиаль сазлыклы
13 Аллювиаль кәсле
ТУФРАК ЯСАУЧЫ ТОКЫ
Балчыксыл һәм балч
Җиңел һәм уртача ба
Комсыл һәм комсу
Карбонатлы



Картограф: Р.Г.Нурмөхәммәтов.
Карта төзүдә 1:600000 масштаблы ТАССРның туфрак картасы(1985 ел), 1:1250000 масштаблы Туфрак картасы (Татарстан Республикасы атласы, 2005 ел) файдаланылды.

сиянең Европа өлешендәге көнчыгыш зона - да кара туфраклы-дала өлкәсенең төньяк чигендә ботаника-геогр. һәм туфракка мөнәсәбәтле классик тикшеренүләр үткәрә. 1887 дән даими туфрак һәм ботаник тикшеренүләрне күп еллар дәвамында Р.В.Ризположенский һәм А.Я.*Гордягин* алып бара. Туфракларның барлыкка килүе буенча Казан геоботаника мәктәбе вәкилләрендә аерым бер геобиол. күзаллау урнаша. Р.В.Ризположенский туфракның нәорганик һәм органик материя арасында бәйләүче звено буларак *биосферада* гаять зур масштабта урнашу идеясен беренче булып күтәрә, биосфера турындагы фән - нәр интеграциясендә Т.б.нең ролен күрсәтә. 19 йөз ахыры — 20 йөз башында Казан ун-ты галимнәре (В.И.Сорокин, А.Н.*Остряков*, В.П.*Ищереков*, Б.И.*Горизонтов*) туфрак химиясенә һәм ашламалар куллануга зур игътибар бирәләр. Казан ун-тында Т.б. каф. оештырылу (1928) б-н бөек галим һәм фәнне оештыручы И.В.*Тюринның* (соңыннан академик, СССР ФАнең Туфрак ин-ты директоры) эшчәнлеге башлана. Аның тарафыннан урман һәм урман-дала туфракларының генезисы һәм классификациясенә караган күп кенә мәсьәләләре хәл ителә, гумусны билгеләү алымы модификацияләнә, һәм ул киң кулланыш таба. 1930 елларда һәм соңрак И.В.Тюрин дәвамчылары тарафыннан зур масштаблы туфрак карталары төзелә, аграр туфраклы районнар билгеләнә, туфракның уңдырышлылыгын арттыру чаралары күрелә (В.Н.Николаева, А.М.Мясникова, В.С.Колосков, М.Г.Шендриков һ.б.), дәүләт сорт-тәжрибә участокларының туфраклары җентекләп тикшерелә (М.А.*Винокуров* һ.б.), туфракларны известьләү мәсьәләләре өйрәнелә (В.Т.Макаров). Казан а.х. ин-тында культуралаштыру юлы б-н кәсле-көлсу туфракларның уңдырышлылыгын арттыру алымнары эшләнә, икә катлап сукалау өчен махсус сука конструкцияләнә (И.В.Үтәй). Казан ун-ты галимнәре М.А.Винокуров һәм П.В.*Маданов* тарафыннан туфракларның йоту сәләтенә караган тикшеренүләр үткәрелә, туфракның йоту комплексының органик һәм минераль өлешләренең алмашу сәләте, туфрак коллоидларының ваклануын билгеләү алымнары тәкъдим ителә. 1964 тән Казан ун-тының туфрак белеме һәм агрохимия каф. мөдире А.В.*Колоскова* җитәкчелегендә туфрак генезисы буенча тикшеренүләр алып барыла, аларны культуралаштыру мәсь әләләре өйрәнелә. Т.б.ндә яңа фәнни юнәлеш — туфраклар - ның агрофизик үзлекләрен тикшерү форма - лаша; гомумиләштерүче зур хезмәтләр чыга: «Татарстан туфраклары» («Почвы Татарии», 1962), «Татарстан туфракларына агрофизик сыйфатлама» («Агрофизическая характеристика почв Татарии», 1968), «Татарстанның кара туфраклары» («Чернозёмы Татарии», 1976). 1940 елларның 2 нче яртысында оештырылган СССР ФА Казан ф-лының Биол. ин-ты лаб-ясендә туфракны тикшерү, аерым алганда Урта Идел буе туфракларының микроэлемент составын өйрәнү буенча шактый эш алып барыла (М.А.Винокуров, М.А.Коршунов, Р.К.*Даутов*, В.Г.Минибаев).

1960 еллар уртасыннан урман туфракларын комплексны тикшерү башлана. Урман хуҗалыгы идарәсе каршында оештырылган Татарстан урман туфраклары химиясе лаб-ясе тарафыннан 300 мең *га* дан артык мәйданда урман туфракларын 1:25000 масштаблы картага төшерү үткәрелә: аларны нигезле файдалану чаралары эшләнә (Ә.Һ.*Газизуллин*, М.М.Юнысов, Б.Д.Хәсәншин, Ф.Г.Борһанов һ.б.); Идел алды киң яфраклы урман туфракларында урман үсемлекләренең үсү үзенчәлекләре өйрәнелә (К.Ш.Шакиров, П.А.Арсланов); Урта Идел буе шартларында көрән туфрак барлыкка килү теориясе эшләнә, урман туфракларының генезисы һәм классификациясе мәсь әләләре өйрәнелә (Ә.Һ.Газизуллин). 1985 тә Идел буе җир төзү ин-тының Татарстан ф-лы Татарстан АССРның туфрак картасын (1:600000 масштаблы) чыгара. 1990 еллардан Казан ун-тында туфрак комплексының балчык-металлоорганик структурасы өйрәнелә (А.А.Шинкарёв һ.б.). Т.б. өлкәсендә тикшеренүләр ш.у. РАХФАның Татарстан агрохимия һәм туфрак белеме фәнни-тикшеренү, ТР ФАнең Экология һәм табигать системалары ин-тларында алып барыла.

Әд.: Ризположенский Р.В. Естественноисторическое описание Казанской губернии. Почвы Казанской губернии. Ч. 1. Понятие о почве и общее описание Казанской губернии // Тр. Об-ва естествоиспытателей при Казан. ун-те. 1892. Т. 24, вып. 6; Колоскова А.В. Кафедра почвоведения // Научная деятельность кафедр биолого-почвенного факультета. К., 1960; Почвы Татарии. К., 1962; Стасьев Г.Я. Р.В.Ризположенский и геобиологическое направление в почвоведении // Почвоведение. 1992. № 11.

А.А.Шинкарёв, Ә.Һ.Газизуллин, Ф.Г.Борһанов.

ТУФРА́К КҮБАЯКЛАРЫ́, геофилидлар (Geophilidae), иренаяклылар асклассы семьялыгы. Гәүдәсе бик тар һәм озын (9–200 *мм*), бик күп сегментлардан (31 дән 173 кә кадәр) тора. Т.к.ның күбесе туфракта яши, умырткасызлар, ш.и. яңгыр суалчаннары б-н туена. Ана Т.к., күкәй салганнан соң, оясын һәм яшь затларны ерткычлардан саклый. Күп кенә Т.к. аерым бизләрдән люминесценция ясаучы лайла бүлеп чыгара. Киң таралганнар. Якынча 1 мең, Россиядә 150 гә якын төре билгеле. Татарстан терр-ясендә 8 төре билгеләнгән, уртача дымсу урыннарны (киң яфраклы урманнар, тугайлы калкулыклар, күпьеллык үлән чәчүлекләре) үз итүче Pachymerium ferrugineum, корырак урыннарда (кашлак болыннар, кыр ышыклау урман полосалары, бөртеклеләр чәчүлекләре) яшәүче Geophilus longicornis, һәм G.proximus таралган.

Хезм.: Алейникова М.М., Изотова Т.Е. О фауне многоножек (Myriopoda) Татарской АССР // Зоол. журн. 1956. Т. 35, вып. 6; Изотова Т.Е. О многоножках (Myriopoda) Татарской АССР // Тр. Об-ва естествоиспытателей при Казан. ун-те. 1960. Т. 120, кн. 6.

С.М.Шәфигуллина.

ТУФРА́К СУАЛЧАННАРЫ́, к. *Яңгыр суалчаннары*.

ТУФРА́К ТЕМПЕРАТУ́РАСЫ, туфракның (яки кышын карның) өстендәге һәм билгеле бер тирәнлегендәге (0,2 дән 3,2 *м* га кадәр) темп-расы, ел дәвамында үлчәнә, 5, 10, 15, 20 *см* тирәнлектәге сөрүле катламда — елның җылы вакытында. Т.т. туфракның җылы кайтаручанлык сәләтенә (альбедо), җылы үткәрүчәнлегенә һәм үсемлекләр төренә бәйле. ТР терр-ясендә туфрак өслегендә уртача иң югары темп-ра 23–25 °С (июль), иң түбән темп-ра –14–15 °С (гыйн.) тәшкил итә. Яраш - лы рәвештә темп-раның абс. макс.ы 57 дән 63 °С ка кадәр (Аксубай, 1981), абс. миним.ы –48 дән –53 °С ка кадәр (Әгерҗе, 1979) үзгәрә. Суык булмаган чорның туфрак өстендә уртача озынлыгы 90–120 көн, һавадагы б-н чагыштырганда якынча 25 көнгә кимрәк. Тәүлек дәвамында туфрак өстендә миним. темп-ра: кояш чыкканнан соң 1 сәг., макс.: җирле төш вакытыннан соң 1–2 сәг. күзәтелә. Тирәндәрәк температураның тәүлеклек һәм еллык тирбәнешләр амплитудасы кими. Тәүлеклек тирбәнешләр — 0,5–1 *м*, еллык — 15–20 *м* тирәнлеккә таралалар. Астарак даими тәүлеклек һәм еллык темп-ра (4–7 °С) катламы ята. Тирәнлек б-н миним. һәм макс. темп-раның башлану чоры соңга кала: тәүлек барышында — тирәнлекнең һәрбер 10 *см* ы саен 2,5–3,5 сәг. кә, ел барышында — тирәнлекнең һәрбер метры саен 20–30 көнгә. Кышын туфрак уртача 74–114 *см* тирәнлектә ту ңа, иң зур туң тирәнлеге март аенда күзәтелә һәм 110–165 *см* тәшкил итә.

Э.П.Наумов, Ф.Г.Борһанов.

ТУФРА́К ЭРО́ЗИЯСЕ (лат. erosia — ашалу), туфракның су һәм җил б-н ашалуы, таркалу продуктларының күчеше һәм яңадан утыруы. Су Т.э. сөзәкләкләрдә күренә; яссы, өске (туфракның сеңәргә өлгермәгән су б-н чагыштырмача тигез юылуы); агымлы (тирән булмаган ашалган урыннар барлыкка килү) һәм тирән (су агымы б-н туфракның юылуы, чокырлар барлыкка килү) Т.э.нә бүленә. Таркалу дәрәҗәсе буенча Т.э.н нормаль табигый (акрын бара, уңдырышлылык кимеми) һәм урманнарны бетерү, туфракны дөрес эшкәртмәү, системасыз рәвештә көтү кертеп, үлән капламын зарарлау нәтиҗәсендә килеп чыккан тиз (антропоген) төрләргә бүләләр.

Т.э. вакытында аның уңдырышлылыгы түбәнәя, чәчүлекләр зыян күрә, а.х. файдалану җирләре уңайсыз җирләргә әверелә, елгалар һәм сулыклар ләмләнә. Җил Т.э., яисә дефляция, теләсә нинди типтагы рельефта тарала, туфрак җил б-н өрелеп таркала. Тузан бураннары шулай барлыкка килә.

Т.э.нә Татарстанда якынча 3 млн. *га* җир дучар булган, шуларның 1,5 млн. *га* сы уртача һәм көчле дәрәҗәдә. Чокыр һәм коры үзән - нәрнең гомуми озынлыгы якынча 30 мең *км* тәшкил итә. Чокырларның күбәю сәбәпле ел саен якынча 2 мең *га* җир әйләнештән чыга. Су Т.э.нә — Мамадыш, Алабуга, Кукмара, Әгерҗе, Арча, Биектау, Балык Бистәсе, Саба, Питрәч р-ннарының, җил Т.э.нә Баулы, Бөгелмә, Әлмәт, Лениногорск, Азнакай, Ютазы р-ннарының а.х. файдалану җирләре аеруча дучар. Т.э. б-н көрәш — а.х. оешмалары һәм пр-тиеләренең иң төп бурычларыннан берсе. Аны хәл итү өчен эрозиягә каршы бер-берсен тулыландыручы агротехника, мелиорация, гидротехника һәм оештыру-хуҗалык чара-

ларының зона комплекслары эшләнгән. Шуларның иң әһәмиятлеләре — 1800 дә — 49%, 1870 тә — 31,4%, 1968 дә — 16%, 2010 да 18,7% тәшкил иткән урманлылык дәрәҗәсен күтәрү, туфрак саклау чәчү әйләнешләрен, катламнарны әйләндереп салмыйча, туфракны яссы кисү, кыска срокта эшкәртү алымнарын, агроландшафтлы игенчелек элементларын, аның биологияләшүен кертү, чокыр төпләрендә гади үрелмә буалар, суны читкә җибәрүче канаулар, су тотучы валлар, плотиналар һәм башка гидротехник корылмалар төзү, террасалау, текә сөзәкләкләрне болынландыру һәм урманландыру. Т.э.нең теоретик нигезләрен һәм аның б-н көрәш чаралары комплексын эшләүгә Татарстан галимнәре В.Н.Сементовский, Ф.С.Хәбибуллин, В.А.Дуглав, А.П.Дедков, В.А.Ступишин, З.Н.Петров, Ф.Х.Шакиров, Р.Ш.Туктамышев, А.П.Пухачёв һ.б. аерым өлеш кертәләр.

Әд.: Комплекс противоэрозионной защиты земель Татарии. К., 1975; Шакиров Ф.Х. Противоэрозионное земледелие. К., 1979; Ступишин А.В., Дуглав А.А., Лаптева И.И. Географический анализ овражно-балочных систем в пределах Татарской АССР. К., 1980; Бухараева Л.Г., Пухачёв А.П. Почвам надёжную защиту. К., 1984; Шикула Н.К. Почвозащитная бесплужная обработка полей. М., 1990.

И.Н.Афанасьев, А.П.Пухачёв.

ТУФРА́К ЭШКӘРТҮ́ СИСТЕ́МАСЫ, туфрак һәм чәчү әйләнешендә үстерелә торган үсемлекләрнең үзенчәлекләреп исәпкә алып, аерым әзеклелектә кулланыла торган алымнар җыелмасы; *игенчелек* системасының состав өлеше. Чәчү әйләнеше өчен туфрак тибын, аның гранулометрик составын, эрозиягә бирешүен, басуларның үпләнешен, элгәрләрен һәм ашламалар кертү ысулын исәпкә алып эшләнә. Үсемлекләр үстерүдә яхшы шартлар булдыру, туфракны су һәм җил эрозиясеннән саклау, сөрүле катламның көчен арттыру, басуларның үпләнешен кимету, ашламаларның нәтиҗәлелеген күтәрү һәм, гомумән, туфракның уңдырышлылыгын арттыру максаты б-н кулланыла. Язгы культуралар өчен Т.э.с. — басуларны төп, чәчү алды һәм чәчүдән соңгы эшкәртүдән, көзге культуралар өчен басуларны төп һәм язгы-җәйге чәчү алды һәм чәчүдән соңгы чиста һәм биләүле пар һәм биләүсез пар элгәрләрен эшкәртүдән тора. Шулай ук Т.э.с.н эрозиягә каршы (катламнарны әйләндереп салмый торган эш кораллары кулланута нигезләнгән), контурлап, кыска срокта һәм энергия саклап эшкәртүгә аералар.

Туфракны контурлап эшкәрткәндә туфракны төп эшкәртү катлаулы сөзәкләкләргә каршы 70° ка кадәр юнәлештә уздырыла. Шуның б-н бергә туфрак югалышы, басуларның су эрозиясеннән юылуы кими, кар сулары һәм явым-төшемнәр тоткарлана, а.х. үсемлекләренең дым б-н тәэмин ителеше яхшыра. Иң яхшы агротехник нәтиҗәлелек су җыю буенча терр-я ху җәлыкларын контурлап оештыру вакытында ирешелә. Җир төзү схемада субүләрдән тальвегка кадәрге терр-яне били. Бу терр-ядә сөрү агрегатларының контурлары төшерелә.

Туфракны кыска срокта эшкәртү вакытында туфрак эшкәртү машиналары б-н аз эшләнә, көпшәкләндерү тирән булмый яисә бөтенләй көпшәкләндерелми, һәм а.х. культураларын турыдан-туры чәчүгә күчәләр. Бу хезмәт һәм энергия чыгымнарын киметү, туфракны эрозиядән саклау өчен уздырыла. Эшкәртүнең мондый ысулын куллану мөмкинлекләре туфракның тибына, аның тыгызлыгына, механик составына, басуларның культуралашу дәрәҗәсенә һәм кертелгән ашламалар күләменә бәйле. Туфракны кыска срокта эшкәртү туфрак тыгызлыгының кимүенә булышлык итә, сөрү катламының өске өлешен эшкәртүне яхшырта, әмма шул ук вакытта дымлылыкның кимүенә, басуларның чүпләнүенә, үсемлекләрнең азот б-н туенуы кимүгә китерә. Шуңа бәйле рәвештә туфракны кыска срокта эшкәртүне чәчү әйләнешендә туфракны тирән эшкәртеп башка агроысуллар б-н (парга, борчак астына, сызма культураларга) комплекста уздыралар, бу вакытта минераль ашламалар күбрәк кертелә, һәм үсемлекләрне саклауның химик чаралары кулланыла. Төп юнәлешләр: туфракны туңга сөрүнең тирәнлеген киметү һәм чәчү әйләнеше ротациясе өчен тирән эшкәртүне кыскарту; а.х. машиналарының йөреш санын кыскарту һәм бер йөрештә операцияләрне берләштерү максаты б-н катнаш агрегатларны куллану. Арыш басуындагы туфракны кыска срокта эшкәртү өчен төп эш кораллары: дисклы күмгечләр, дисклы сабаннар, эрозиягә каршы культиваторлар, АКП-2,5 яисә АКП-5 тибындагы катнаш агрегатлар. 12–14 *см* тирәнлектә туңга эшкәртү системасында культиватор-яссы кискечләр, катламнарны әйләндереп салмый торган сабаннар, модульле-блоклы комплекслар кулланыла. Күпчелек а.х. районнары һәм туфрак типлары өчен катламнарны әйләндереп сала торган һәм әйләндереп салмый торган эш кораллары б-н сызма культуралар һәм бөртекле культуралар өчен тирән эшкәртүне аралаштыруның югары нәтиҗәлелеге билгеләнгән.

Әд.: Данилов Г.Г., Каргин И.Ф., Немцев И.С. Система обработки почв. М., 1982; Изверков А.С. Зарубежный опыт почвозащитного земледелия на склонах // Почвозащитное земледелие на склонах. М., 1983; Куликов Е.Т. Основа противоэрозионного комплекса // Земледелие. 1984. № 3; Пухачёв А.П., Бухараева Л.Г. Почвам — надёжную защиту. К., 1984. Овсинский И. Новая система земледелия. Киев, 1889; Тулайков Н.М. Избранные произведения. М., 1963; Пупонин А.И. Минимальная обработка почвы. М., 1978; Аверьянов Г.Д. Пласты плодородия. К., 1983.

Г.Д.Аверьянов.

ТУФРА́К ЯСАЛУ́ ПРОЦЕССЫ́, туфрак барлыкка килә торган шартлар һәм факторлар (климат, *туфрак ясаучы токым*, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы, җирлекнең рельефы, терр-янең геол. яше, кешенең ху җалык эшчәнлеге) тәэсирендә туфракның беренчел хасил булуы, формалашуы һәм эволюциясе. Туфрак катламындагы матдәләр һәм энергиянең үзгәрүе һәм хәрәкәте күренешләре җыелмасыннан тора. Даими синтез һәм органик матдәләрнең таркалуы нәтиҗәсендә үсемлекләр һәм тау токымнары арасында баручы матдәләрнең биол. әйләнеше Т.я.п. үсешендә аеруча мөһим. Т.я.п. барышында тау токымнары кушылмалары үзгәрә, аларда үсемлекләрнең туклану элементлары туплана. Туфрак үсешенең башлангыч чорында өзек-өзек туфрак горизонтлары барлыкка килә. Соңрак әкренләп туфрак профиле формалаша, *туфракның уңдырышлылыгының* билгеле бер табигый тигезлеге урнаша. Экология шартлары (геоморфологик, гидрологик) үзгәргәндә туфрак күп кенә яңа сыйфат һәм үзлекләр ала, шул ук вакытта элеккеләре дә саклана. Аеруча мөһим Т.я.п.: тау токымнары минералларының үзгәрүе (соңынан туфрак үзе дә); туфракта органик калдыкларның тупланuуы һәм трансформацияләнүе; органик-минераль кушылмаларның катлаулы системасын барлыкка китерүче минераль һәм органик матдәләрнең үзара бәйләнеше; биофил элементларның тупланuуы; формалашып килүче туфрак профилендә су агымы б-н туфрак ясаучы продуктларның хәрәкәте. Бу процессларның төрле кушылмалары үзләренә генә хас генетик горизонт системалары булган билгеле бер туфрак типларын барлыкка китерүче Т.я.п.ның төрледән-төрле конкрет формаларын тудыра, алардан исә туфрак профиле төзелә. *Кара туфраклар* профиленең формалашуында кәсләнү процессы һәм гумус барлыкка килү өстенлек итә, нәтиҗәдә туфракта *гумус*, көлле элементлар һәм азот, нигезләр, нык кантарлы һәм бөртекле структура барлыкка килә. *Кәсле-көл-су туфраклар* һәм *соры урман туфраклары* ясалуда алардан башка профильнең өске өлешеннән (элювиаль горизонт) түбәнге өлешенә (иллювиаль горизонт) яки туфрак профиле чигеннән (селтесезләнү, көлсулану, лёсслану, солодлашу һ.б.) минераль һәм органик кушылмаларның юылуы б-н бәйле процесслар катнаша. Җыелып торган сулар б-н туфрак кирәгеннән артык дымланганда кислород утеп керү тоткарлана һәм туфрак глейлана, бу вакытта үзгәрүчән валентлы химик элементлар (тимер, марганец һ.б.) формалаша, беренчел минераллар таркала һәм үзгәчәлекле икенчел минераллар барлыкка килә. Глей горизонты төрле төстә (күгелҗем, зәңгәрсу, соры, кызыл, кара), аз күзәнәкле, су үткәрүчәнлеге структурасыз, сазга һәм сазланган туфракларга хас. Т.я.п.өзлексез баручы процесс һәм бөтен ландшафтның үсеше б-н бәйле.

Әд.: Почвоведение. Ч. 1. Почва и почвообразование. М., 1988; Газизуллин А.Х. Почвоведение. Общее учение о почве. М., 2007.

Ф.Г.Бөрһанов.

ТУФРА́К ЯСАУЧЫ́ ТОКЫ́М, ана токым, биол. һәм биохимик процесслар, ш.у. кеше эшчәнлеге йогынтысында *туфрак* хасил итүче тау токымының өске катламы; туфрак ясалу факторларының берсе.

Т.я.т.ны килеп чыгышы (мәс., аллювиаль утырмалар, лёсслар һәм лёссыман комсыл балчыклар), химик (карбонатлы, хлорид-сульфатлы һ.б.) һәм гранулометрик (комсыл, балчыксыл, балчыклы туфрак) составы буенча аералар. Минераль составы һәм җилләнү дәрәҗәсе буенча Т.я.т.ның төрләре билгеләнә: массив-кристаллик токымнар һәм

аларның беренчел минералларга бай эллювийлары; утырма вакланган токымнар; хәзерге заман континенталь элювиаль-делювиаль һәм аллювиаль китерелмәләр, боазлык, су-боазлык һәм эол утырмалары. Т.я.т.ның үзенчәлекләре төрле интенсивлыкта һәм формаларда күренә, бу исә туфракны классификацияләүдә, аның ыруын һәм төрдәшен билгеләүдә чагылыш таба.

ТР терр-ясендә Т.я.т.: төп токымнар (известьташ, доломит, мергель, балчык һәм комташлар), төп токымнарның элювиаль, делювиаль һәм эол ашалу продуктлары, елга үзән-нәренең аллювиаль утырмалары. Аеруча Пермь системасы югары бүлеге утырмалары киң таралган. Көнбатыш Кама һәм Идел алдында (аның үзәк һәм төньяк өлешләрендә) комсу-балчыксыл кызыл һәм карбонатлы-балчыксыл төрле төстәге токымнардан торучы татар ярусы утырмалары өстенлек итә. Көнчыгыш Кама аръягы һәм Көнчыгыш Кама алды терр-яләренең шактый өлеше известьташ катламлы комсу-балчыксыл Казан ярусы утырмаларыннан тора. Респ-каның көньяк-көнбатышында туфрак ясалу процессында юра һәм акбур системалары утырмалары — мергель һәм комташ катламлы соры, кара-соры балчыкларның ашалу продуктлары катнаша. Идел, Кама, Ык һ.б. елгаларның элекке үзәннәрендә Т.я.т. булып неоген системасының яшьрәк күл-диңгез һәм континенталь утырмалары тора. Хәзерге заман елга үзәннәрен дүртенчел чорга караган балчык һәм комсыл балчыклар тәшкил итә. Аеруча уңдырышлы кара туфраклар барлыкка килгән лёссыман комсыл балчыклар ш.у. дүртенчел чорга карый. Идел, Кама, Казансу, Илләт елгаларының югары террасалары урыны-урыны б-н көлсу туфраклардагы нарат урманнары үскән эоллы комсу китерелмәләр б-н капланган. Т.я.т.ның алмашынуы җирлекнең рельефына һәм абс. биеклегенә бәйле. Т.я.т. сыйфатында субүләрләрдә бик еш аз гына үзгәргән төп токымнар һәм аларның элювийлары, субүләрләрнең сөзәкләкләрендә төп токымнарның су агымы б-н утыргән ашалу продуктлары (делювий) тора.

Т.я.т. туфракның гранулометрик, химик һәм минераль составына, аның физик һәм физик-механик үзлекләренә, аеруча туфрак ясалуның беренче стадияләрендә су-һава, җылылык һәм туклану режимына йогынты ясый. Т.я.т.ның составы һәм үзлекләре туфрак ясалу процессының тизлегенә һәм аның юнәлешенә тәэсир итә. Озак вакытлар дәвамында ТР терр-ясендә доломит һәм тыгыз известьташ элювийларында бик үсеш алмаган кәсле-карбонатлы туфраклар формалашкан, аларның профиль калынлыгы 20–30 *см* дан артмый. Шул ук вакытта балчыксыл туфрактан һәм балчыксыл токымнардан торучы субүләр тигезлекләрендә һәм сөзәкләкләрендә соры урман туфраклары һәм кара туфраклар таралган, аларның профиле 1–1,5 *м* дан калынрак. Кальций һәм магний карбонатлы токымнарда нигезләр б-н туенган, нейтраль һәм ачы реакцияле, югары гумуслы һәм суга чыдам структуралы туфраклар формалаша.

А.П.Дедков, Ф.Г.Борһанов.

ТУФРАКНЫ́ ИЗВЕСТЬЛӘ́Ү, күпчелек а.х. культураларының үсешенә начар тәэсир итүче туфракның артык ачылыгын бетерү өчен туфракка известьле ашламалар кертү; ачы туфракларны химик мелиорацияләүysулы. Туфракның сеңдерү комплексының водород һәм алюминий ионнарын известьле ашламаларның кальций һәм магний ионнарына (известьле һәм доломит оны, акбур, мергель, күл известе, сәнәгать калдыклары — дефекат, цемент тузаны, сланец көле һ.б.) алыштыруга нигезләнә, нәтиҗәдә туфракның ачылыгын актив һәм потенциаль формада нейтральләштерү бара. Бу файдалы микроорганизмнарның тереклек эшчәнлеген көчәйтүгә һәм туфракны үсемлекләр өчен кирәк булган туклыклы матдәләр б-н баетуга, аның физик үзенчәлеген яхшыртуга, органик һәм минераль ашламаларның нәтиҗәлелеген күтәрүгә ярдәм итә. Татарстанда 1960 еллар ахырыннан, а.х.н химияләштерүне көчәйтүгә бәйле, известьләүнең күләме кискен арта. 1967–70 тә якынча 600 мең *га*, 1971–75 тә 1,5 млн. *га* ачы туфрак известьләнә. Шул елларда Т.и.нең фәнни нигезләрен һәм гамәли алымнарын эшләү өчен Үзәк а.х. агрохимик хезмәт күрсәтү ин-тының Казан ф-лы булдырыла, 1985 тә Бөтенроссия а.х.н химияләштерү фәнни-тикшеренү һәм проектлау-технология ин-тының Идел-Вятка ф-лы итеп үзгәртелә. Басудагы тәҗрибәләрнең нәтиҗәләрен гомумиләштерү процессында Т.и.нең аграр һәм икътисади нәтиҗәсе ачыклана, конкрет регионнар өчен туфрак тибын, аның механик составын, ачылыгын һәм башка үзенчәлекләрен исәпкә алып, известьле ашламалар кертүнең нормасы билгеләнә. Лизиметрик тикшеренүләр сөрүле җирләрдән кальций һәм магнийның югалу күләмен ачыкларга, аларга тәэсир итүче факторларны билгеләргә һәм беренче булып игенчелектә карбонатлар балансын төзергә мөмкинлек бирә. Известьләүнең заманча теориясе туфракка известьле ашламалар кертү юлы б-н культуралар өчен туфрак реакциясен нейтраль һәм шуңа якын (pH сол. 5,6–6,5) итүгә һәм шулай саклауга нигезләнә. ТРда Т.и. — кәсле-көлсу һәм соры урман туфракларын, селтесезләнгән һәм көлсуланган кара туфракларның уңдырышлылыгын арттыруда мөһим чара. 1980 еллар ахырында Россиядә беренче тапкыр буларак известьләүнең 5 еллык циклына күчү һәм ел саен бу эшләрне 300–350 мең *га* да башкару (1990 еллар ахырыннан күләме 210–180 мең га кадәр кими) гамәлгә ашырыла. Матди-техник база булдырыла («Татагрохимсервис» АҖ бүлекчәсе). Республикада җирле известьле ашламалар чыгару буенча 34 карьер эшли, елына якынча 2 млн. *т* чыгарыла. Ашлама кертү нормасы ($CaCO_3$ т/га): Т.и. мелиорация вакытында — 4–10, шул хәлдә тоту өчен (туфракта pH 5,6–5,8) — 3–6. Кертелгән известьнең һәр тоннасы басу чәчү әйләнешендә 1,5–2 *т* өстәмә уңыш алуны тәэмин итә; Т.и. чыгымнары 3–4 елда капланa.

Әд.: М е щ а н о в В.Н. Известкование кислых почв. М., 1982; Рекомендации по известкованию кислых почв в Татарской АССР. К., 1986.

Ф.Г.Борһанов, Е.И.Ломако.

ТУФРАКНЫ́Ң АЧЫЛЫГЫ́, туфрак үзенчәлеге, туфрак эремәсендә водород ионнары (туфракның актуаль яки актив ачылыгы), туфракның йоту комплексында водород һәм алюминий алмаш ионнары (туфракның потенциаль яки яшерен ачылыгы) булудан килеп чыга; туфракның физик-химик һәм агрохимик сыйфатламасында мөһим күрсәткеч. Туфракның актуаль ачылыгы (туфрак эремәсенең ачылыгы яки туфрактагы су саркымы) pH зурлыгы (H-ионнар активлыгының тискәре логарифмы) б-н бәяләнә. Туфрак эремәсенең реакциясе pH 7 булганда нейтраль, 7 дән түбән — ачы, 7 дән югары — селтеле. Туфракның потенциаль ачылыгы (туфракның каты фазасындагы ачылыгы) ачылыкның алмаш һәм гидролитик формаларына бүленә, алар — 100 *г* коры туфракка туры килгән мг-экв ларда, ә беренче форма ш.у. тозлы саркымның pH зурлыгы б-н дә күрсәтелә. Туфракның алмаш ачылыгы — туфракны нейтраль тоз эремәсе б-н эшкәрткәндә (аналитик эш практикасында, гадәттә, 141 н. KCl кулланалар), гидролитик ачылык туфракның гидролитик селтеле тозлар эремәсе (гадәттә, 141 н. CH_3COON) б-н үзара бәйләнеше вакытында килеп чыга. Гидролитик ачылык барлык ачылык формаларының суммасыннан гыйбарәт.

Ачы туфракларның таралышы туфрак барлыкка килүнең билгеле бер шартлары б-н бәйле: туфрак ясаучы токымның минерал. составы, терр-янең климат үзенчәлекләре, туфракта су режимы тибы, үсемлек бергәлекләре һ.б. Ачы туфракларга көлсу, сазлык, соры урман һ.б. туфраклар керә. Т.а. үзгәрешләре а.х. эшчәнлеге барышында да күзәтелә. Уңыш б-н бергә туфрактан нигезләрнең дә чыгарылуы, минераль, аеруча физиологик ашламалар куллану барлык ачылык формаларының артуына китерә. Туфракның ачы реакциясе күп кенә культуралы үсемлекләр һәм файдалы микроорганизмнарның (азотофиксаторлар, төерчек бактерияләре һ.б.) яшәү шартлары өчен уңайлы түгел. Алмаш алюминийның күләме артык булса, клевер һәм бөртекле уҗым культуралары кышлау чорында үләргә мөмкин. Ачылык дәрәҗәсе буенча туфраклар төркемнәргә бүленә: нык ачы (pH_{KCl} 4,5 тән аз), уртача ачылыктан (4,6–5), җиңелчә ачы (5,1–5,5), нейтральгә якын (5,6–6), нейтраль (6 дан күп). Т.а. дәрәҗәсе төп а.х. культуралары өчен pH_{KCl} 5,6–7,2 тәшкил итә. Ачылыкны киметү өчен *туфракны известьләү* үткәрәләр. Люцерна, чөгендер, клевер, горчица югары Т.а.н яраткылар һәм известьләүне күлай күрәләр; туфрак мохитенең нейтраль реакциясенә мохтаҗ һәм известьләүне яратучылар: бодай, кукуруз, борчак, ногыт борчагы, кәбестә, соя, ташкабак, томат, көнбагыш, тары, кындырак.

Татарстанда Дәүләт агрохимия хезмәте оештырылганнан соң (1964), а.х. оешмалары туфракларын күпләп тикшерү, картограммалар, ш.и. ачылык буенча картограммалар төзү башлана. Тикшеренүләрнең беренче туры нәтиҗәләре буенча (1970) респ-када сөрүлек җирләрнең 42% ында, ш.и. Кама алдында — 64%, Идел алдында — 58%, Кама аръя-

гында 25% туфрак ачы реакцияле (pH_{KCl} 5,5 һәм түбәнрәк). Аннан соңгы тикшеренүләр кара туфракларда, аеруча Кама аръягы р-ннарында, ачылыкның көчле үсешен күрсәтә. ВНИПТИХИМ Идел-Кама ф-лының кыр тәҗрибәләре буенча кара туфракларның ачылыгы арту механизмнары ачыла, аның сәбәпләре: игенчелекнең интенсивлашуы шартларында кальций һәм магний балансының бозылуы, минераль ашламаларны нормадан тыш куллану һәм бу туфракларда известьләү үткәрмәү. Соңыннан известьләү практикасы кара туфраклы р-ннарда да киң кулланыла башлый. 2014 ел башына ТРда ачы туфраклар 1437 мең *га* (44%), ш.и. нык ачы — 34,9 мең *га* (1%), уртача ачы — 256 мең *га* (7,9%), җиңелчә ачы туфраклар 1146 мең *га* (35,2%) мәйдан били. Туфракларны агрохимик тикшерү, ачылык картограммасы һәм известьләү өчен проект-смета кәгазьләрен төзү эшләрен «Татарский» агрохимик хезмәт үзәге (Идел алды һәм Кама алды) һәм «Әлмәт» агрохимик хезмәт станциясе (Кама аръягы) башкара.

Ф.Г.Борһанов, Е.И.Ломако.

ТУФРАКНЫ́Ң УҢДЫРЫШЛЫЛЫГЫ́, туфракның үсемлекләрнең туклану элементларына, суга булган ихтыяҗларын канәгатьләндерә, аларның тамыр системасын җитәрлек күләмдә һава, җылылык һәм үсеш өчен уңай физик-химик мохит б-н тәэмин итә алу үзлеге А.х. культуралары биоценозы һәм уңышының гомуми продуктивлыгын билгели. Табигый (потенциаль) һәм нәтиҗәле (актуаль, икътисади) төрләргә аерып йөртәләр. Табигый Т.у. һәрбер туфракка хас һәм туфрак ясалуда табигый процессларга бәйле. Ул гумуслы катламның калынлыгы, гумус күләме һәм үсемлекләрнең туклануы өчен кирәкле элементларның булуы, туфракның гранулометрик, минерал. һәм химик составы, аның физик-химик һәм агрофизик үзенчәлекләре б-н билгеләнә. Нәтиҗәле Т.у. ш.у. туфракны файдалану ысулына (эшкәртү, ашламалар куллану, игелүче үсемлекләр, мелиорация һ.б.) бәйле һәм а.х. культураларының уңышы б-н бәйләнә.

А.х. җирләренең, ш.и. сөрүлекләрнең Т.у. күрсәткечләре үзгәрешен системалы рәвештә агрохимик тикшеренүләр үткәрү б-н контрольдә тоталар, ТРда алар уртача 5–6 елга бер тапкыр уздырыла. 2007 ел башына респ-каның барлык сөрүле туфрагының 49% ында *гумус* күләме түбән була. Кама алды туфракларында аның күләме аеруча түбән (сөрүлек җирләрдә 1,6–3,3%, уртача — 2,5%), Идел алды туфракларында — уртача (яраш лы рәвештә 3,5–6,2 һәм 5,1%), кара туфраклы Кама аръягы туфракларында югары (ярашлы рәвештә 4,5–8,0 һәм 5,5%). *Туфракның ачылыгы* Т.у.ның күрсәткечләреннән бер се булып тора. ТРда ачы туфракларның мәйданы 1405,5 мең *га* (42,2%) тәшкил итә, шулардан 1121,5 мең *га* (33,7%) — җиңелчә ачылыкта, 249,3 мең *га* (7,5%) — уртача ачылыкта, 34,7 мең *га* (1%) — югары ачылыкта. *Туфракны известьләүнең* күләмен һәм тизлеген арттыру аеруча 1985–97 елларда (ел саен 250–350 мең *га*) ачы туфрак мәйданнарын шактый киметә. Респ-ка игенчелегендә 2000 еллар башыннан кальций карбонаты һәм магнийның аз гына тискәре балансы күзәтелә. 1965–2000 дә туфракларда хәрәкәтчел фосфор күләме 55 мг/кг га арта. Моңа күплән фосфорлы ашламалар куллану һәм зур күләмдә ачы туфракларны фосфоритлаштыру булышлык итә. Хәрәкәтчел фосфорның күләме түбән булган туфрак мәйданнары 924,7 мең *га* га кими, югары булганы 1180,5 мең *га* га арта. 2014 ел башына хәрәкәтчел фосфор бик түбән һәм түбән булган туфраклар — 141,3 мең *га* (4,3%), уртача — 930,2 мең *га* (28,6%), югарырак — 1037,0 мең *га* (31,9%), югары һәм бик югары — 1140,9 мең *га* (35,2%) мәйдан били. Алмаш калий бик түбән һәм түбән булган туфраклар 122,2 мең *га* (3,8%), уртача 551 мең *га* (16,9%), югарырак 1016,9 мең *га* (31,3%), югары һәм бик югары — 1559,3 мең *га* (48%) тәшкил итә. Хәрәкәтчел фосфор һәм алмаш калийның уртача югарылыктагы күрсәткечләре тиңдәшле рәвештә 134,6 һәм 140,5 *мг/кг* һәм бу элементлар б-н тәэмин ителгән туфраклар төп а.-х. культураларын игү өчен кулай булган төркемгә керәләр. Бу вакыт эчендә туфракның калий режимы шактый яхшырды. Кама алдында алмаш калий күләме 50 мг/кг *га*, Идел алдында 20 мг/кг га арта. Татарстанда алмаш калий түбән булган туфраклар сөрүлек мәйданнарның 4% тан азрагын, уртача һәм югары — 77% ка якынын били. Респ-ка туфраклары хәрәкәтчел микроэлемент формалары б-н төрле дәрәҗәдә тәэмин ителгән: бор, марганец һәм бакыр ның күләме югарырак (уртача), молибден, цинк һәм кобальтның — уртача. Туфракларда авыр металлар күләме рөхсәт ителгән концентрация чикләрендә, бу исә экологик чиста а.х. продуктлары алырга мөмкинлек бирә.

Әд.: Алиев Ш.А., Шакиров В.З., Нуриев С.Ш. Агрохимическая и агроэкологическая оценка почв Республики Татарстан. К., 2005.

Ф.Г.Борһанов, В.З.Шакиров.

ТУФРАКЧЫЛА́Р, территориячеләр, Уфа шәһәрендә 1917 елның ноябреннән 1918 нең гыйнварына кадәр эшләгән «*Милләт Мәҗлесе*» фракциясе. Фракция б-н Хәрби Шура рәисе И.*Алкин* җитәкчелек итә. Аның күренекле эшлеклеләре — Г.Абызов, С.Атнагулов, Һ.Атласи, Ш.Әхмәдиев, Г.Баттал, С.Җантурин, С.Енгалычев, З.Кадыйри, Ф.Мөхәммәдъяров, Ф.Сәйфи. Милләт Мәҗлесе уты рышында федералистлар башлангычы б-н терр. мохтарият буенча комиссия оеша (И.Биккулов аны Урал-Идел Штатын оештыру комиссиясе дип атарга тәкъдим итә), аның рәисе К.Ф.*Мөхәммәдъяров* була. Комиссия Штатны оештыру мәсь әләре буенча фракция һәм Башкорт Шурасы позицияләрен яраштыру мәсь әләләре б-н шөгыльләнә. Аның күрсәтмәсе буенча Г.Ибраһимов Ж.Вәлиди б-н сөйләшүләр алып бару өчен Оренбург шәһәренә бара. Территориячеләр Штат чикләре турындагы мәсь әлә буенча бердәм булмыйлар. Аларның бер өлеше Штатка Казан б-н Уфа губерналарын, Оренбург губернасының төньяк һәм көнчыгыш өлешләрен, Богырыслан өязенең бер өлешен, Самара губернасы Бөгелмә өязенең мөселманнар яшәгән өлешен, Пермь губернасы Уса өязен, Вятка губернасы Алабуга өязен, Сембер губернасының бер өлешен кертүне яклап чыгыш ясый. Икенчеләре Штат составына ш.у. Каспий диңгезенә кадәрге арада Самара һәм Әстерхан губерналарын да кертергә тәкъдим итә. Беренче фикергә өстенлек бирелә. Комиссиянең терр. мохтарият турындагы тәкъдиме буенча Милләт Мәҗлесендә Штат оештыру турында карар кабул ителә; территориячеләр б-н төркичеләр барлык төп мәсь әләләр буенча килешүгә ирешәләр һәм аны оештыру өчен актив көрәшкә керешәләр. 1918 нең мартында Идел-Урал Штатын оештыру омтылышы уңышсызлыкка очрагач, Т. фракциясе таркала. Аның күп кенә әгъзалары большевикларга кушыла.

И.Р.Тахиров.

ТУХАЧЕ́ВСКИЙ Михаил Николаевич (4.2.1893, Смоленск губ., Дорогобуж өязе Александровское а. — 11.6.1937, Мәскәү), хәрби һәм дәүләт эшлеклесе, Сов. Союзы Маршалы (1935). Дворяннар нәселеннән. Александр хәрби уч-щесен тәмамлый (Царское Село ш., 1914). 1914–18 еллардагы Беренче бөтендөнья сугышында катнаша. 1918 нең мае–июнендә Мәскәү р-ны оборонасы хәрби комиссары. 1918 нең июне — 1919 ның гыйнварында Көнчыгыш фронтның 1 нче армиясе командующие; Казанда аерым частьлардан армия оештыра, Чех-словак корпусына һәм КОМУЧның Халык армиясе гаскәрләренә каршы Кызыл Армиянең Богырыслан һәм Бәләбәй хәрби операцияләрендә катнаша. 1919 ның гыйнвары–мартында Көньяк фронт командующие ярдәмчесе, 8 нче армия командующие. 1919 ның апрель–ноябрендә 5 нче армия командующие; Көнчыгыш фронтның көньяк төркеме составында адмирал А.В.Колчакның акгвардияче гаскәрләреннән Идел буен һәм Уралны азат итү буенча Богырыслан, Бөгелмә һәм Бәләбәй хәрби операцияләрен уздыра. 1920 нең февраль–апрелендә Кавказ фронтының, 1920 нең апрелендә — 1921 нең мартында Көнбатыш фронтның, 1921 нең мартыннан 7 нче армия, 1921 нең маенда Тамбов р-ны гаскәрләре командующие. 1924–25 тә Эшче-Крәстиян Кызыл Армиясенең Штаб башлыгы ярдәмчесе, 1925–28 дә — башлыгы. 1928–31 дә Ленинград Хәрби округы гаскәрләре командующие. 1931–34 тә СССР Революцион Хәрби Советы рәисе урынбасары, Кызыл Армияне коралландыру башлыгы. 1934 тән СССР Оборона халык комиссары урынбасары, 1936–37 дә — 1 нче урынбасары. 1937 дә Идел буе Хәрби округы гаскәрләре командующие. Т. Кызыл Армияне техник яктан яңача коралландыруда, кораллы көчләрнең һәм гаскәрләрнең яңа төрләрен (авиация, механикалаштырылган һәм һава-десант гаскәрләре) үстерүдә сизелерлек роль уйный. Стратегия, оператив осталык, тактика һәм хәрби фәнне үстерүгә өлеш кертә. Гражданнар сугышы тарихы һәм хәрби-теоретик хезмәтләр авторы. 1934 тән ВКП(б) ҮКна әгъзалыкка кандидат. Бөтенроссия ҮБК һәм СССР ҮБК әгъзасы. Ленин ордены, Кызыл байрак ор-



М.П.Тушнов.

дены б-н бүләкләнә. Репрессияләнә, үлгәннән соң аклана.

Х е з м.: Избр. произведения: В 2 т. М., 1964.

Әд.: Т о д о р с к и й А.И. Маршал Тухачевский. М., 1966; П о п о в А. Труд, талант, доблесть. М., 1972; И в а н о в В.М. Маршал М.Н.Тухачевский. М., 1985. *Е.Б.Долгов.*

ТУШАКО́В (тәхәллүсе Тушаки) Эдуард Сәфәр улы (19.2.1948, Төмән өлкәсенең Тубыл р-ны Мөрим Йорты а.), нәкышьче, график, педагог. 1976 елда А.М.Горький исем. Омск пед. ин-тының сәнгать-графика ф-тын тәмамлаганнан соң, Ташкенттагы 1 нче балалар сәнгать мәктәбендә укыта. 1988 дән Тубыл шәһәрендәге В.Г.Перов исем. балалар сәнгать мәктәбе укытучысы, интерьер проектлары, архитектур эшләнмәләр б-н шөгыльләнә.

Себер татарларында станлы нәкышь сәнгатенә нигез салучыларның берсе, лирик пейзаж, портрет һәм тематик картиналар жанрларын синтезлаучы әсәрләр авторы. Т.ның хис б-н сугарылган романтик әсәрләре төсләр композициясе (ачык һәм якты тоннарның үзара ятышлы ярашулары) һәм символик-аллегорик эчтәлекләре б-н аерылып тора, халык күңеленең тирән катламнарын, тарихи тамырларның һәм традицияләрнең дәвамлылыгын ача: «Җәйге җайдаклар» (1985), «Көнәкәй (Б.Сөләймановка багышлау)» (1993), «Искер. Моң» (1996), «Миңсәлим тәгәрмәче» (1997), «Мәчет» (1999), «Галим Ф.Г.Вәлиев» (2001), «Покрау» («Колларда беренче кар», 2002), «Төш» (2007), «Балачак көймәсе», «Ак яран» (икесе дә — 2008).

Татар көнкүреше әйберләре һәм борынгы төрки артефактлар кергән натюрмортлар



Э.С.Т у ш а к о в. «Шәрекъ натюрморты». 1995.

ясый: «Хәтер. Дохым» (1992), «Шәрекъ натюрморты» (1995), «Искәләр. Борынгы бакыр» (1996), «Аваз. Балыклар» (1997). Акварель сериялəре авторы: «Азия пейзажлары — «Ху җәкәнт таулары», «Иссык-Күл», «Ялан-күл станциясе», «Урал Тансыкбаев остаханәсендә», «Чулпан-Ата», «Тут агачлары» (барысы да — 1980 еллар) һ.б.

Шәһәр — Ташкент, Тубыл; өлкә — Төмән (1996, 1997); «Төрки дөнья» (Казан, 1995), «Татарт» (Тубыл, 1998), «Түрк-арт» (Тубыл, 2002) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре Тубылда уздырыла (1997, 1999, 2005, 2008, 2009, 2013, 2018). Әсәрләре Тубыл тарих-архит-ра музей-саклаулыгында, Үзәк



Э.С.Т у ш а к о в. «Вакытлар бәйләнеше. Ата хан». 1998.

Себер татарлары мәдәнияте музеенда (Тубыл ш.), «Казан» милли мәдәният үзәгендә, Италия, Төркия, АКШ, Япониядәге шәхси тупланмаларда сакланa.

Әд.: Эдуард Тушаки. Двадцать лет творчества: Каталог персональной выставки. Тобольск, 1998; Б а я з и т о в Ф. Пейзаж на фоне заката // Татарские новости. 2007. № 3/4; Эдуард Тушаки. 60 лет: графика, живопись: Каталог персональной выставки. Тобольск. 2008; Ф и л и п п о в а И. Путь отдохновения // Град Тобольск. 2009. № 8. *Г.Ф.Вәлиева-Сөләймановa.*

ТУШНО́В Михаил Павлович (1879–1935), микробиолог, вет. патофизиологы, проф. (1917), ВАСХНИЛның хакыйкый әгъзасы (1935). Вет. микробиологлары һәм иммунобиологларының Казан фәнни мәктәбенә нигез салучы. Казан вет. ин-тын тәмамлый (1902). Ерак Көнчыгышта кавалерия часте вет. табибе (1902–05). Рус-япон сугышында катнаша (1904–05). 1905 елдан Казан вет. ин-тында, микробиол. каф. мөдире (1917–31). 1931 дән Бөтенсоюз эксперименталь мед. ин-тында (Ленинград) махсус бүлек мөдире, 1933–35 тә Мәскәү зоовет. ин-тының микробиол. каф. мөдире. ВАСХНИЛның вет. секциясен оештыра. А.х. терлекләрен дәвалау өчен гистолизатлар, төрле әгъзалардан алынган препаратлар турында тәгълимат эшли. Патоген микроорганизмнарның биол. һәм иммунологик үзлекләрен өйрәнә. Ш.у.к. *Тушнов гистолизатлары.*

ТУШНО́В ГИСТОЛИЗАТЛАРЫ́, а.х. терлекләрен дәвалау өчен кулланыла торган препаратлар. 1920 елларда Казан вет. ин-тында М.П.*Тушнов* тарафыннан аерып алына. Һәр гистолизат кайсы әгъзадан алынган — шул әгъза исеме б-н атала (овариолизат — күкәй-лекләрдән, тестолизат — тестикулалардан, тиреолизат — калкансыман биздән, миолизат — мускуллардан алына һ.б.). Ана затларның кысырлыгы, җенес системасы авырулары, гомуми хәлсезлек, йончу очракларында — овариолизат; сөт бизләре өлгереп җитмәгәндә, лактацияне арттыру өчен — маммолизат; ата затларның җенси көчсезлеге, хәлсезлеге һәм йончу очракларында — тестолизат; калкансыман биз гипофункциясе очрагында тиреолизат кулланыла һ.б. Мускулга яки тире астына инъекция өчен гидролизат микъдары терлекләрнең 1 *кг* тере авырлыгына 0,1 *мл* препарат исәбеннән билгеләнә (Х.С.Юлдыбаев, 1954). Караңгы һәм салкынча урында саклаганда Т.г.ның дәвалау активлыгы 2–3 елга җитә.

Р.Г.Госмановa.

ТУШНО́ВА Вероника Михайловна (14.3.1911, Казан — 7.7.1965, Мәскәү), шагыйрә, тәр җәмәче. 1928–31 елларда Казан ун-тының мед. ф-тында укый. 1931 дә Ленинградка күчә. 1 нче Мед. ин-тын тәмамлый (1934). 1941–1943 нең февраленда Казанда эвакуациядә була, хәрби госпитальләрдә эшли. Т. поэзиясе күпжанрлы (юллама, элегия, җыр, тәүбә, монолог-уйлану, пейзаж лирикасы). Ул «Беренче китап» («Первая книга», 1945), «Юллар, юллар» («Пути-дороги», 1954), «Йөрәк хатирәсе» («Память сердца», 1958), «Икенче сулыш» («Второе дыхание», 1961), «Йөз сәгатьлек бәхет» («Сто часов счастья», 1965), «Лирика» (М., 2003) шигъри җыентыклары авторы. Казан хатирәләре «Капитаннар» («Капитаны»: «И возникал перед глазами // причал на стынущей воде // и домик в городе Казани, // в Адмиралтейской слободе») «Мещаннар чәчәге» («Мещанские цветы»: шигырендә: «...перед глазами // Старинный пыльный пригород Казани, // Дом в три окошка, где отец мой рос, // А в окнах — шапки огненной герани. // В слободке не выращивали роз»); «Кайту» («Возвращение»: « Волга, Волга моя, // всюду — ты, вечно — ты, // Сколько в жизни тобою расставленных вех»); шулай ук «Мәктәп альбомындагы фоторәсемнәр» («В альбомчике школьном снимки»), «Гудок турында шигырьләр» («Стихи о гудке»), «Мог җизалар» («Чудеса»), «Ишкәк» («Весло»), «Хушлашу» («Прощание»), «Иске йорт» («Старый дом»), «Төн» («Ночь»), «Юл» («Дорога»), «Синең урам» («Твоя улица») һ.б. әсәрләрендә урын алган. Рус теленә Г.Тукай, М.Җәлил шигырьләрен тәрҗемә итә.

Э с э р.: Избранное. М., 1988.

Әд.: «Не отрекаются любя...». К., 1996.


И.И.Андреева.

ТУЫ́М, билгеле бер төркем халыкта балалар туу ешлыгы; халык санының гомуми күрсәткечләренең берсе. 1 елда 1000 кешегә туры килгән нисбәттә исән-сау туган балалар саны (Т. коэф.). 19 йөз ахырында Россиядәге һәр гаиләгә уртача 7–8 бала туры килә. Россиядә түбән Т.га күчү күп кенә башка алдынгы илләргә караганда соңрак башлана (19 йөз ахыры — 20 йөз башы). 20 йөздәге сугышлар, массакүләм ачлык һ.б. социаль катак-

лизмнар демографик түбән күрсәткечләргә күчүне шактый тизләтәләр, һәм Т.ның хәзерге дәрәҗәсенә Россия башка алдынгы дәүләтләр б-н якынча бер вакытта — 1960 еллар уртасында килә.

Татарстанда Т. коэф. 1950 елларда якынча 30 тирәсен тәшкил итә (1954 тә — 30,1, ш.и. шәһәрдә 28,2 һәм авыл җирлегендә 31,3). 1960 елларда Т. кими (1969 да 15,3 кә кадәр, ш.и. шәһәрдә 14,5 һәм авыл җирлегендә 16,1), бу Бөек Ватан сугышы елларында туган хатын-кызларның аз санлы буыны актив бала тудыру яшенә (20–29 яшь) җитү б-н бәйле. 1970 еллар уртасыннан 1980 еллар - ның икенче яртысына кадәр Т. коэф.ы берникадәр күтәрелә (1987 дә Т. коэф.ы — 19,4). Түбән Кама терр.-җитештерү комплексы объектларын төзергә килүчеләр хисабына яшь - ләрнең артуы, балалы гаиләләргә дәүләт ярдәмен көчәйтү буенча чаралар гамәлгә кертелү (1981 дә бала карау өчен өлешчә түләүле ял кертелә һ.б.), социаль-икътисади хәлнең яхшыруы Т.ның артуына булышлык итә. 1990 еллар башында Т. аеруча шәһәр халкы ара - сында кими; 1993 тән Т. *үлем* күрсәткеченнән калыша һәм халыкның табигый кимүе башлана. Т. 1950–60 та — авыл җирлегендә, 1970–80 дә шәһәрләрдә югары була (яшь - ләрнең авылдан шәһәргә китүе б-н бәйле); 2000 нән Т. күрсәткечләре шәһәрдә һәм авыл җирлегендә якынча бертигез.

1954–2015 елларда Татарстанда туым күрсәткечләре (1000 кешегә исәпләгәндә)



2015 тә ТРда 56598 бала туа, ш.и. 46477 — шәһәрләрдә һәм 10121 — авылларда (Т. коэф. — тиңдәшле рәвештә 14,7; 15,8 һәм 11,1%). Яңа туган балаларның 41,8%ы — гаиләдә беренче, 43,4%ы — икенче һәм 11,7%ы — өченче бала. Бала тудыручы ананың уртача яше — 28,8 (1990 да — 25,8). Никахтан тыш туган балалар саны арта, 2013 тә — 17,7%, 2015 тә 16,4 % (1990 да — 8,4 %) тәшкил итә. Соңгы дистә ел - ларда күпчелек алдынгы һәм икътисади як - тан тотрыклы илләрдә Т. күрсәткеченең түбән булуы күзәтелә, ул хәтта халыкның гадәти артуы өчен дә җитми. Мондый хәл Россия - гә, ш.и. Татарстанга да хас. 1990 еллар башыннан көтелгән балалар саны гаиләгә 2 дән кимрәккә туры килә. 1 хатын-кызга исәпләгәндә, тулай Т. коэф.ы: 1990 да — 2,05, 1995 тә — 1,47, 2007 дә — 1,36, 2015 тә 1,86 га тигез. 2015 тә ТРда халык артуның чиста коэф. — 0,895, ш.и. шәһәр халкы 0,891 һәм авыл халкы 0,896 тәшкил итә. Шулай итеп, Т. һәм үлемнең гамәлдәге халәтендә буыннар алмашыну дәрәҗәсе 90 %ка тигез. Мондый хәл махсус максатчан социаль һәм *демогра - фик сәясәт* чаралары кабул итү зарурлыгы - на китерә. 2007 дә РФдә 1,5 яшькә кадәрге балаларны карау буенча пособие арта, эшләмәүче аналар өчен пособие булдырыла, йөклелек һәм бала тудыру буенча пособиеләрнең макс. күләме арта (2015 тә 228,6 мең сумга кадәр), 2006 да гамәлгә кертелгән бала тудыру сертификатының бәясе арта (10 мең сумга кадәр). РФ Президенты тарафыннан 2025 елга кадәрге чорда РФнең демографик сәясәт концепциясе раслана. Аның максаты — халык санын тотрыклыландыру һәм аның үсеше өчен шартлар тудыру. 2007 нең 1 гыйнварыннан «Балалы гаиләләргә өстәмә дәүләт ярдәме чаралары турында»гы Федераль закон көченә керә, аның нигезендә икенче яки аннан соңгы бала туган (яки тәрбиягә алынган) очракта гаиләнең 250 мең сум ана (гаилә) капиталы алу хокукы раслана (2015 тә — 453 мең сум).

Әд.: Социальная энциклопедия. М., 2000.

Ф.Г.Борһанов.

ТҮБӘ́Н АБДУ́Л авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 55 *км* көнбатыштарак, Чишмә елгасы буенда. 2010 елда 878 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 2 мәчет. Авыл тарихы музее. 18 йөзнең 2 нче чиregендә нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Абдулово Багряш, Степановка Абдулово буларак та телгә алына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре (элеккеге йомышлы татарлар) катлавына керә, лашманлыкта эшли; игенчелек, терлекчелек, умартачылык, чыпта сугу, бау ишү, ат сбруе һәм арба ясау, эшләпә һәм өс киемнәре тегү, балта эше, такта яру һ.б. кәсепләр б-н көн күрә. 1740–50 елларда Т.А. халкы көчләп чукындырыла. Православие диненә күчүчеләр авылның Степановка дип аталган өлешендә яшиләр. 1840–60 елларда барысы да диярлек яңадан ислам диненә кайта. 20 йөз башында 2 мәчет, 2 мәдрәсә, земство мәктәбе, 2 ашлык саклау-сату һәм 5 бакалея кибете, су һәм җил тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3306,1 дис. тәшкил итә. 1918 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе — Ерсубай, 1918 дән Иске Баграж волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән — Чаллы, 1924 тән Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Беренче Май, 1963 нең 1 февраленнән Әлмәт р-нында. Халык саны: 1782 дә — 516, 1795 тә — 626, 1816 да — 685, 1834 тә — 851, 1859 да — 1218, 1870 тә — 1402, 1884 тә — 1457, 1900 дә — 2438, 1913 тә — 2938, 1920 дә — 2825, 1926 да — 1383, 1949 да — 1310, 1958 дә — 1432, 1970 тә — 1621, 1979 да — 1508, 1989 да — 803, 2002 дә — 912 кеше.

ТҮБӘ́Н АРБА́Ш авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 29 *км* көньяктарак, Баш-Арбаш елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 101 кеше (та - тарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кыр - чылык. Урта мәктәп, клуб, китапханә. 1619 дан билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре кат - лавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шө - гыльләнә. 20 йөз башында Т.А.та мәчет, су те - гермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 771,4 дис. тәш - кил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Петропавел волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Кукмара, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 54 ир-ат; 1859 да — 240, 1897 дә — 451, 1908 дә — 556, 1920 дә — 515, 1926 да — 514, 1949 да — 493, 1958 дә — 307, 1970 тә — 348, 1979 да — 287, 1989 да — 145, 2002 дә — 137 кеше.

ТҮБӘ́Н АТЫ́ авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 12 *км* көнбатыштарак, Аты елгасы буенда. 2010 елда 493 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, китапханә. 1678 дән билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.А.да мәчет, су тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1100,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Мүлмә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 108 ир-ат; 1859 да — 558, 1897 дә — 678, 1908 дә — 773, 1920 дә — 794, 1926 да — 734, 1938 дә — 691, 1949 да — 675, 1958 дә — 652, 1970 тә — 689, 1979 да — 605, 1989 да — 575, 2002 дә — 513 кеше.

ТҮБӘ́Н АФАНА́С авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 5 *км* көнь - як-көнбатыштарак урнашкан. 2010 елда 263 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, та - тарлар — 79%) яши. Халкының төп шөгы - ле — мөгезле эре терлек асрау. Клуб. 1678 дән Җәнәй Пучинкәсе буларак билгеле. 18 йөз - дә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәү - ләт крәстияннәре катлавына керә, игенче - лек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыль - ләнә. 20 йөз башында нефть б-н эшләүче те - гермән, май язу з-ды, 2 ярма яргыч, 2 ашлык киптергеч, тимерче алачыгы эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2586 дис. тәш - кил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Афанас волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кан - тонында. 1930 ның 10 августыннан — Чал - лы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1870 тә — 761, 1897 дә — 1262, 1913 тә — 1583, 1920 дә — 1548, 1926 да — 1466, 1938 дә — 1526, 1949 да — 1153, 1958 дә — 861, 1970 тә — 812, 1979 да — 787, 1989 да — 184, 2002 дә — 172 кеше.

ТҮБӘ́Н ӘЛКИ́ авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 16 *км* көньяк-көнчы - гыштарак, Ата елгасы буенда. 2010 елда 810 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шө - гыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. А.х. техникасы пр-тиесе. Урта мәктәп, мәдә - ният йорты, китапханә. Мәчет. 1710 нан бил - геле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә.

20 йөз башында Т.Ә.дә мәчет, 6 вак-төякләр кибете була; җомга базары эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1669 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Түбән Әлки волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан Әлки (1930–37 дә — район үзәге), 1944 нең 19 февраленнән — Юхмачы, 1956 ның 7 декабреннән — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 83 ир-ат; 1859 да — 593, 1897 дә — 907, 1908 дә — 1179, 1920 дә — 1200, 1926 да — 970, 1938 дә — 795, 1949 да — 870, 1958 дә — 696, 1970 тә — 1019, 1979 да — 958, 1989 да — 848, 2002 дә — 931 кеше.

ТҮБӘ́Н ӘЛМОРЗА́ авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 41 *км* көньякта-рак, Кече Чирмешән елгасыннан 1 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 277 кеше (2002 ел-гы халык исәбе буенча, татарлар — 79%, рус-лар — 20%) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Башлангыч мәктәп. 1710 нан билгеле. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Иске Әлморза исеме б-н дә мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек үрчетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында җамигъ мәчет, 2 тегермән, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1026,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Юхмачы волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас канто-нында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1935 нең 10 февраленнән — Кузнечиха, 1944 нең 19 февраленнән — Юхмачы, 1956 ның 7 декабреннән — Кузнечиха, 1960 ның 28 ок-тябреннән — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 76 ир-ат; 1859 да — 624, 1897 дә — 1042, 1908 дә — 1262, 1920 дә — 1491, 1926 да — 904, 1938 дә — 793, 1949 да — 452, 1958 дә — 760, 1970 тә — 823, 1979 да — 700, 1989 да — 440, 2002 дә — 348 кеше.

ТҮБӘ́Н ӘРНӘ́Ш авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 55 *км* көнбатыш-тарак, Бөрсет елгасы буенда. 2010 елда 23 ке-ше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда хә-зерге исеме б-н телгә алына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында су тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 558 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасы-ның Мамадыш өязе Шомырбаш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 62 ир-ат; 1859 да — 256, 1897 дә — 571, 1908 дә — 634, 1920 дә — 545, 1926 да — 490, 1938 дә — 427, 1949 да — 237, 1958 дә — 221, 1970 тә — 196, 1979 да — 117, 1989 да — 61, 2002 дә — 35 кеше.

ТҮБӘ́Н БАЛАНДА́ авылы, Аксубай р-нын-да, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 7 *км* көньяк-көнбатыштарак, Кече Сөлчә ел-гасы буенда. 2010 елда 258 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, чуашлар — 59%, рус-лар — 37%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлан-гыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, тер-лекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.Б.да тегермән, 2 ярма яргыч, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең има-на җире 1301 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Мук-шы волостенда, 1920 дән ТАССРның Чис-тай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 24 ир-ат; 1859 да — 581, 1897 дә — 937, 1908 дә — 1150, 1920 дә — 1210, 1926 да — 639, 1938 дә — 698, 1949 да — 515, 1958 дә — 474, 1970 тә — 584, 1979 да — 449, 1989 да — 329, 2002 дә — 268 кеше.

ТҮБӘ́Н БАЛТА́Й авылы, Апас р-нында, шә-һәр тибындагы Апас посёлогыннан 17 *км* көнбатыштарак, Чирмешән елгасы буенда. 2010 елда 106 кеше (татарлар) яши. Халкы-ның төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб. Мәчет. 17 йөзнең 1 нче яр-тысында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.Б.да мәчет, мәдрәсә, су тегермәне, ярма яргыч, 2 вак тө-яклəр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгате-нең имана җире 751 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Урта Балтай волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нын-да. Халык саны: 1782 дә — 75 ир-ат; 1859 да — 397, 1897 дә — 669, 1908 дә — 915, 1920 дә — 715, 1926 да — 544, 1938 дә — 485, 1949 да — 362, 1958 дә — 279, 1970 тә — 293, 1979 да — 195, 1989 да — 124, 2002 дә — 124 кеше.

ТҮБӘ́Н БАРЫ́Ш, к. *Ясаклы Барыш.*

ТҮБӘ́Н БӘРӘСКӘ́ авылы, Әтнә р-нында, Олы Әтнә авылыннан 8 *км* көнбатыштарак, Ашыт елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 881 кеше (татарлар) яши. Халкы-ның төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1556–57 еллардан рус чыганак-ларында Верески исеме б-н билгеле. 18 йөз-дә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәү-ләт крәстияннәре катлавына керә, игенче-лек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз ба-шында 2 мәчет, мәдрәсә, 2 җил тегермәне, ти-мерче алачыгы, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1472,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Олы Әтнә волос-тенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонын-да. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1938 нең 25 мартыннан — Әтнә, 1959 ның 12 октяб-реннән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1990 ның 25 октябреннән Әтнә р-нын-да. Халык саны: 1782 дә — 231 ир-ат; 1859 да — 682, 1897 дә — 930, 1908 дә — 1212, 1920 дә — 992, 1926 да — 1037, 1938 дә — 1205, 1949 да — 990, 1958 дә — 768, 1970 тә — 1538, 1979 да — 671, 1989 да — 939, 2002 дә — 915 кеше. Т.Б.нең истәлекле урыны — 1 нче җамигъ мәчет (1769 да сәүдәгәр Ибраһим Борнаев иганә-сенә төзелә; архит-ра истәлеге).

ТҮБӘ́Н БИКМӘ́Т посёлогы, Сарман р-нын-да, Сарман авылыннан 18 *км* төньяк-көнчы-гыштарак, Кәүҗияк елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 61 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлек-челек. Башлангыч мәктәп. 1740 елларда нигез салына. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар кат-лавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шө-гыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 912, 38 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әл-мәт-Муллино волостенда, 1920 дән ТАССР-ның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонын-да. 1930 ның 10 августыннан Сарман р-нын-да. Халык саны: 1913 тә — 252, 1920 дә — 254, 1926 да — 152, 1938 дә — 115, 1949 да — 101, 1958 дә — 75, 1970 тә — 241, 1979 да — 175, 1989 да — 99, 2002 дә — 74 кеше.

ТҮБӘ́Н БИКТИМЕ́Р авылы, Әлки р-нын-да, Базарлы Матак авылыннан 4 *км* көнь-як-көнчыгыштарак, Актай елгасы бассей-нында урнашкан. 2010 елда 125 кеше (татар-лар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчы-лык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 17 йөзнең 2 нче яртысында ни-гез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яр-тысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавы-на керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыль-ләнә. 20 йөз башында Т.Б.дә мәчет, мәктәп, 4 җил тегермәне, тимерче алачыгы, ярма яр-гыч, бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җә-мәгатенең имана җире 1581 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өя-зе Базарлы Матак волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 106 ке-ше; 1859 да — 461, 1908 дә — 894, 1920 дә — 889, 1926 да — 476, 1938 дә — 355, 1949 да — 278, 1958 дә — 245, 1970 тә — 248, 1979 да — 215, 1989 да — 149, 2002 дә — 142 кеше.

ТҮБӘ́Н БИШ авылы, Зәй р-нында, Зәй ти-мер юл станциясеннән 35 *км* төньяк-көнчы-гыштарак, Инеш елгасы (Зәйнең бассейны) буенда. 2010 елда 353 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлек-челек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китап-ханә. 1748 дән мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, умартачылык, олаучылык, арба, чана һәм тәгәрмәч ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.Б.тә волость идарәсе урна-ша; мәчет, чиркәү, миссионерлык мәктәбе, су тегермәне, әвен, тимерче алачыгы була; пән җәшәмбе базары эшли. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әхмәт волос-тенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә,

1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1859 да — 460, 1870 тә — 489, 1897 дә — 798, 1913 тә — 915, 1920 дә — 987, 1926 да — 930, 1938 дә — 904, 1949 да — 710, 1958 дә — 657, 1970 тә — 563, 1979 да — 465, 1989 да — 340, 2002 дә — 376 кеше.

Әд.: Заинская энциклопедия. К., 1994.

ТҮБӘ́Н БИЯБА́Ш авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 16 *км* төньяк-көнбатыштарак, Бөя елгасы буенда. 2010 елда 205 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1647–51 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Бәби-Биябаш исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, 4 җил тегермәне, 3 вак-тәякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 647 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Шәмбалыкчы волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 57 ир-ат; 1859 да — 353, 1897 дә — 620, 1908 дә — 769, 1920 дә — 771, 1926 да — 540, 1938 дә — 650, 1949 да — 510, 1958 дә — 498, 1970 тә — 516, 1979 да — 399, 1989 да — 251, 2002 дә — 239 кеше.

ТҮБӘ́Н ГӘРӘ́Й авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 18 *км* төньяк-көнбатыштарак, Шәбез елгасы буенда. 2010 елда 100 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Иске Гәрәй исеме б-н дә билгеле. 17–19 йөзләрдә халкы асабалар катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык һ.б. кәсепләр б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1402 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Такталачык волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында, 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 136, 1834 тә — 307, 1859 да — 423, 1884 тә — 512, 1897 дә — 620, 1906 да 743, 1913 тә — 796, 1920 дә — 823, 1926 да — 584, 1938 дә — 461, 1949 да — 302, 1958 дә — 280, 1970 тә — 249, 1979 да — 217, 1989 да — 117, 2002 дә — 124 кеше.

ТҮБӘ́Н КАБА́Н, к. *Бирге Кабан*.

ТҮБӘ́Н КАЗАКЛА́Р авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 21 *км* төньяк-көнбатыштарак, Бөре елгасы буенда. 2010 елда 153 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, иткә терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәргә чыганакларда Халфино исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1880 лардә авыл җәмәгатенең имана җире 445,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Сәрдәбаш волостенда, 1920 дән ТАССРның — Арча, 1928 дән Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1905 тә — 220, 1920 дә — 233, 1926 да — 256, 1938 дә — 216, 1949 да — 130, 1958 дә — 134, 1970 тә — 162, 1979 да — 166, 1989 да — 115, 2002 дә — 149 кеше.

ТҮБӘ́Н КА́МА шәһәре, респ-ка карамагындагы шәһәр. Каманың сулъяк ярында, Зәй елгасы тамагыннан төньяк-көнчыгыштарак, Круглое Поле станциясеннән (Әгерҗе — Акбаш юнәлешендә) 35 *км* көнбатыштарак, Казаннан 237 *км* ераклыкта урнашкан. Мәйданы — 61,2 *км*. 2018 елда халкы — 253181 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 50,5%, руслар — 42,9%, чуашлар — 2,6%). 1961 нең февраленнән нефть химиясе комб-ты б-н бергә төзелә. 1961 нең 19 апреленнән — шәһәр тибындагы Т.К. посёлогы, 1965 нең 12 гыйнваыннан — Т.К. р-ны үзәге, 1966 ның 22 сентябреннән — шәһәр. Т.К. — РФ нефть химиясе сәнәгатенең иң зур үзәге (*«Түбәнкаманефтехим», «Түбәнкамашин»*, «ТАНЕКО», «ТАИФ-НК», «Түбәнкама-техуглерод» ААҖләре; «Татнефть-Түбәнкаманефтехим-ойл», «Эластик заводы», «Полимерхолодтехника» ҖЧҖләре). Электр энергиясе (к. *Түбән Кама җылылык электр үзәге*), төзү материаллары җитештерү (*«Камэнергостройпром»*, «Камстройдеталь», «Камбит» ҖЧҖләре; тимер-бетон әйберләр җитештерү, эре панельле йортлар төзү җайланмалары, кирпеч з-длары һ.б.). *Түбән Кама механика заводында* машиналар эшләнә. Азык-төлек сәнәгате (сөт, икмәк комб-тлары, ликёр-аракы з-ды, «Химокам-Агро» ит эшкәртү пр-тиесе) һәм җи ңел сәнәгать (тегү ф-касы) үсә. Информацион технологияләр һәм телекоммуникацияләр ин-ты, *Түбән Кама химия-технология институты*; Икътисад, идарә итү һәм хокук ин-ты, *«ТИСБИ» идарә академиясе*, Мәскәү гуманитар-икътисад ин-ты ф-ллары; Е.Н.Королёв исем. *Түбән Кама политехник көллияте, Түбән Кама нефть химиясе көллияте, Түбән Кама медицина көллияте, Түбән Кама педагогия көллияте,* Т.С.Сәйдәшев исем. *Түбән Кама музыка көллияте,* агросәнәгать, технол., эретеп ябыштыру-монтаж, индустриаль көллиятләр, 36 гомуми белем бирү учреждениесе эшли. 2 балалар сәнгать мәктәбе, 5 музыка мәктәбе бар. *Түбән Кама татар драма театры*, шәһәр тарихын өйрәнү музее («Түбән Кама — нефть химиясе шәһәре»). *Түбән Кама җамигъ мәчете*, чиркәү. Т.К. халкына 21 дәвалау-профилактика учреждениесе, ш.и. 4 хастаханә, 5 диспансер, 7 шифаханә, 1 бала тудыру йорты, 1 шәһәр стомат. шифаханәсе мед. ярдәме күрсәтә. 3 санаторий-профилакторий эшли. Шәһәрнең мед. учреждениеләре заманча, соңгы технологияләр б-н җиһазландырылган (к. *Түбән Кама куппрофильле шәһәр хастаханәсе (№3)*). Т.К.да спортка зур игътибар бирелә: 3 стадион, 2 боз спорт сарае, җи ңел атлетика манежы, 11 йөзү бассейны, 5 ату тиры, 3 чаңгы базасы, 32 хоккей корты, 67 спорт залы, 200 дән артык башка спорт корылмалары урнашкан; 12 балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе эшли. Спортның төрле төрләре буенча халыкара һәм бөтенроссия ярышлары уздырыла. «Нефтехимик» хоккей клубы командасы алкалы хоккей буенча Россия беренчелегенең югары лигасында катнаша. Шәһәрдә 8 трамвай һәм 29 автобус маршруты исәпләнә. Т.К. алдан расланган план буенча төзелгән һәм үстерелгән шәһәрләр исемлегенә керә (шәһәр төзү проекты СССР ВДНХсының алтын медаленә лаек була). Энергияне саклап тоту, шәһәрне төзекләндерү, экология, торак-коммуналь хуҗалыкны үстерү, халыкка хезмәт күрсәтү һ.б. өлкәләрдәге күп кенә алдынгы технологияләрне ТРда кертүдә Т.К. башлап йөрүче һәм тәҗрибә мәйданчыгы булып тора. 2001, 2003 тә «Россиянең иң төзек шәһәре» конкурсында җиңүче, 2002 дә «Идел буеның мәдәни башкаласы» исемен ала, 2007 дә «Социаль өлкәдә иң яхшы муниципаль белем бирү» бөтенроссия конкурсында җиңүче. 9 вакытлы матбугат, ш.и. «Ленинская правда», «Туган як», «НижнеКамское время», «Нефтехимик»,



Түбән Кама шәһәре. Гомуми күренеше.





Түбән Кама шәһәре. 1. Шәһәр үзәге; 2. Шәһәр һәм район хакимияте бинасы; 3. Балалар мәйданчыгы.

«Шинник» һ.б. г-талар чыга. 3 телекомпания («Түбән Кама телерадиокомпаниясе», «Эфир», «Нефтехим»), 2 радиостанция эшли. Халык саны: 1970 тә — 49 мең, 1979 да — 136,2 мең, 1989 да — 192,5 мең, 2002 дә — 225,4 мең кеше.

Әд.: Белялов У.Б., Латыпов М.М., Сагитов Т.К. Со временем сверяя шаг. К., 1983; Нижнекамск: Ступени роста. Нижнекамск, 1986; НижнеКамские зарисовки. К., 1996.

А.И.Ногманов.

«ТҮБӘН КАМА», чия сорты, 1985 елда Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тының бакчачылык бүлегендә А.М.Тверитинов һәм Л.А.*Севастьянова* тарафыннан чыгарыла (ирекле серкәләнүдән «Морель ранняя» чәчкене). Салкынга чыдам, уртача иртә өлгерешле, коккомикозга бирешми. Куагы 1,5–2 *м*. Ябалдашы киң, түгәрәк. Үрентеләре уртача озынлыкта һәм юанлыкта, җи нәлчә дугасыман бөгелгән, соры куныклы һәм сирәк ачык соры ясмыкчалар б-н капланган. Яфраклары вак, озынча, ике башы да очлы, читләре вак-, ике- һәм өч каюлы. Чәчәкләре уртача зурлыкта, ак. Иртә чәчәк ата. Үз-үзеннән җимеш бирүе түбән (5–12%). Иң яхшы серкәләндерүче сортлар — «Маяк», «Труженица Татарии», «Ранняя сладкая», «Морель ранняя». Җимешләре уртача зурлыкта (3,1 *г*), түгәрәк, куе кызыл төстә, тәме эчкелтем-баллы. Җимешәне кызыл, сусыл, уртача тыгызлыкта. Орлыгы зур түгел, ирекле, җимешеннән аерылуы ярымкоры. 3 елдан җимеш бирә башлый. Уңышы 1 куактан 16 *кг*. Яшел чыбыкчалар б-н (тамырлануы 70–80%) һәм дала формаларын чәкченәргә ялгау б-н үрчетелә. Яңа өлгергән килеш һәм эшкәртелеп кулланыла. Татарстанда 1988 дән районлаштырылган.

Л.А.Севастьянова.

ТҮБӘН КАМА ГЭСЫ, «Татэнерго» АҖ ф-лы. Кама елгасында Чаллы шәһәре янында төзелә. Кама гидроэлектростанцияләре каскадының өченче баскычы. Эшләүчеләр саны 300 ләп кеше (2017). 1963 елда төзелә башлый. 1979 да беренче 2 гидроагрегаты сафка кертелә; соңгысы (16 нчы) 1987 дә эшли башлый (һәрберсенең егәрлеге 78 *мВт*). ГЭСның гомуми куәте 1205 мең *мВт* һәм ул ТР энергетика системасында барлык электр егәрлегенең 20% ы чамасын бирә. Суэтем корылмалары (3900 *м* озынлыкта) Түбән Кама сусаклагычын барлыкка китерәләр. Югары бьефның 62 *м* (2010 нан) арадаш билгесендә (проектта 68 *м* каралган) эшләтелә. Су җыелуга карап, электр энергиясе җитештерүнең уртача еллык күрсәткече 1,3–2 млрд. *кВт·сәг* (проектта 2,7). Файдалануга тапшырылганнан соң 60 млрд. *кВт* электр энергиясе җитештерелә. Гидротөйнәлешнең гомуми мәйданы 45 *га*; һәм аның составына елга төбеннән су чыгаргычлар һәм 16 вертикаль агрегат б-н кушылган ГЭС бинасы (озынлыгы



Түбән Кама ГЭСы. Гомуми күренеше.

486,6 *м*), иң зур суммар үткәрү сәләте 6190 *м*³ булган 8 өч аралыклы бетон су чыгару плотинасы (озынлыгы 76,2 *м*), 3000 *м* озынлыктагы өелмә плотина, бер камералы ике юллы шлюз керә. Плотина корылмалары буйлап тимер юл һәм автомобиль күперләре салынган. Төп һәм ярдәмче эш җиһазларының эше тулысынча автоматлаштырылган. Эшләп чыгарылган электр энергиясе 550 *кВ* көчәнешле линияләр буйлап Россиянең бердәм энергетика системасына тапшырыла. ГЭС төзелү ТРның көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш районнары, Түбән Кама терр.-җитештерү комплексы үсешенә зур этәргеч бирә. ГЭС — шәһәр барлыкка китерүче пр-тие, торак йортлар, шәһәрнең социаль инфраструктурасы объектлары төзетә. Пр-тиенең күп кенә хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә, ш.и. 4 кеше ТРның атказ. энергетигы исеменә лаек була.

Пр-тие җитәкчеләре: М.Е.Хотимский (1965–68), М.Г.Йосыпов (1969–88), Р.Г.Айсин (1988–2008), И.Р.Муллагалиев (2008 дән). Ш.у.к. *Түбән Кама сусаклагычы.*

М.Ж.Гаитов.

ТҮБӘН КАМА ҖАМИГЪ МӘЧЕТЕ, 1989–96 елларда архитекторлар Р.И.Макуев һәм Ф.Г.Ханов проекты буенча неоромантизм формаларында төзелгән мөселман гыйбадәтханәсе. Биек торак йортлар б-н әйләндереп алынган мәйданда урнашкан, гадәти булмаган күләм-фәза композициясе б-н аерылып тора. Хәзерге Татарстан терр-ясендә зал-лы, күп манаралы мәчетнең беренче үрнәге. Т.К.җ.м.н торгызу б-н 16 йөз уртасында югалган монументаль, күп манаралы татар җамигъ мәчетләре тибы яңара. Мәчет композициясе диагональ үзәк схема буенча төзелгән. Үзәктәге квадрат күләм почмакларында дүрт маршлы эчке баскычлы, чатыр б-н төгәлләнгән 4 биек квадрат манара калкып чыккан. Күләм залга диагональ урнашкан ике кыек-лы, сыртлы түбә б-н ябылган. Мәчетнең төп ишекләре һәм үзәге көнбатыш һәм көнчыгыш фасадларда. Вестибюльгә күзәтү залы, ху җалык биналары тоташкан. Өске катта — ике рәт тәрәзәле төп намаз залы. Зал интерьерындагы михраб алтын йөгертелгән Коръән язулары уелган кара мәрмәр б-н тышланган. Т.К.җ.м. бинасында болгар һәм ислам мәдәнияте һәм тарихы үзәге урнашкан. Намаз залы астындагы ике кат төрле хуҗалык бүлмәләреннән тора. Ниргәдән түбән катның биеклеге яртылаш җир астына кереп тора.



Түбән Кама җамигъ мәчете. Архитекторлары Р.И.Макуев, Ф.Г.Ханов. 1989–96.

Әд.: Мечети Татарстана / Сост. Х.Г.Надырова, Р.Р.Хайрутдинов, Р.Р.Салихов. К., 2000.

Х.Г.Надыйрова.

ТҮБӘН КАМА ҖЫЛЫЛЫК-ЭЛЕКТР ҮЗӘГЕ (ТКҖ-ЭҮ), электр энергиясе һәм җылылык (пар һәм кайнар су рәвешендә) эшләп чыгаручы, җылылык-пар электр станцияләре. 2005 елга кадәр — Түбән Кама шәһәренең 1 нче һәм 2 нче җылылык-электр үзәкләре. 2005–10 да «Татэнерго» холдингы

«Генерацияләүче компания» АҖ ф-лының 1 нче һәм 2 нче җитештерү-техник комплекслары (ҖТК).

ТКҖ-ЭҮ (ҖТК-1), 2010 нан «ТГК-16» АҖ ф-лы — ТРда иң эре сәнәгать-электр-җылылык үзәге, *«Түбәнкамнефтехим»*, «ТАИФ-НК» акц. җәмгыятьләре өчен энергия һәм пар бирүче төп пр-тие. Эшләүчеләр саны – 600 ләп кеше (2018). 1963 тә төзелә башлый. 1967 дә — беренче энергетика агрегаты, 1970 тә кайнар су җибәрү өчен беренче су җылыту казаны сафка кертелә, шул ук елда илдә беренче булып, басымга каршылыклы югары куәтле турбогенератор (Р-100–130/15 тибында) куела. 1977 тә 4 су җылыту һәм 14 пар энергетика казаннарын, 11 турбогенератор, 2 химик чистарту системасын төзү эшләре төгәлләнә. 1979 дан ягулык буларак — мазут, ә 1989 дан табигый газ кулланыла. 1986 да, Кама елгасында суның сыйфаты начараю сәбәпле, суны химик чистарту системасы



Түбән Кама җылылык-электр үзәге. Гомуми күренеше.

530 *т/сәг* кә киңәйтелә, 1987 дә известьне регенерацияләү җайланмасы корыла. 1988–94 тә төп пар үткәргечләр реконструкцияләнә; 1991 дә, кулланылган суларны нейтральләштерү өчен, җитештерүчәнлеге 34,2 мең *м³/тәүлек* булган махсус җайланма файдаланууга тапшырыла. 2006 да «Түбәнкамнефтехим» АҖ б-н берлектә 75 *МВт* куәтле газ-турбина җайланмалары файдаланууга кертелә. Гамәлдәге егәрлеге 880 *МВт* электр һәм 3746 *Гкал·сәг.* җылылык энергиясенә тигез. Кулланучыларга 4,6 млн. *МВт·сәг.* электр энергиясе, 16,2 млн. *Гкал* җылылык энергиясе җибәрелә. Директорлары: В.И.Суздальцев (1963–73), В.В.Лукшин (1973–77), В.П.Каюков (1977–80), М.А.Зелепугин (1980–85), Р.М.Хаҗиәхмәтов (1985–97), А.И.Калашников (1997–2001), Р.Р.Хөсәенов (2001–10), С.Ю.Олюнин (2011 дән).

ТКҖ-ЭҮ (ҖТК-2), 2010 нан «Татнефть» АҖнең бүлендек ҖЧҖ, Түбән Кама шәһәренең сәнәгать пр-тиеләрен, коммуналь хуҗалыгын энергия ресурслары һәм кайнар су б-н тәэмин итә. Эшләүчеләр саны — 500 ләп кеше (2018). 1976 да төзелә башлый. Беренче агрегат-казан, турбина һәм су җылыту казаны 1979 да файдаланууга тапшырыла. Респ-када беренче тапкыр югары экономияле өрдерүле пар казаннары (пар җитештерүчәнлеге 500 *т/сәг*) һәм шул чорда иң куәтле саналган пар һәм су җибәрүле турбиналар кулланыла. 1987 дә 9 энергетика казаныннан һәм 5 турбогенератордан торучы беренче чират төзелеп бетә. Эшне файдалырак итү өчен 1991 дә җылы бирүчәнлеге 180 *Гкал·сәг.* булган бойлер җайланмасы сафка кертелә. 1994 тә пычранмаган агынтылар өчен тондырыгыч буа төзелә. 2015 тә 220 *МВт* куәтле 2 турбоагрегат файдаланууга кертелә. Төп җиһазлары 9 энергетика һәм 2 су җылыту казаннарын, 7 турбоагрегатны үз эченә ала. Билгеләнгән электр егәрлеге — 724 *МВт*, җылылык егәрлеге — 1580 *Гкал·сәг.* Кулланучыларга 1,36 млн. *МВт·сәг.* электр энергиясе һәм 3,4 млн. *Гкал* җылылык энергиясе җибәрә (2017). Директорлары: Р.Г.Хәйруллин (1977–85), Н.И.Варламов (1985–91), П.М.Тюклин (1991–2006), Р.Р.Хөсәенов (2006–10), В.В.Будилкин (2010–14), А.Р.Юмангулов (2014 тән).

ТКҖ-ЭҮнең күп кенә хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә, ш.и. 20 кеше РСФСР, ТАССР, ТРның атказ. энергетигы исеменә, 1 кеше Ленин орденына, 1 кеше — Хезмәт Кызыл Байрагы, 2 кеше — «Почёт билгесе», 3 кеше 3 нче дәрәҗә Хезмәт даны орденнарына лаек була.

ТҮБӘН КАМА КҮППРОФИЛЬЛЕ ҮЗӘК РАЙОН ХАСТАХАНӘСЕ, 2009 елда 5 дәвалау учреждениесен — Үзәк район хастаханәсен, 2 нче һәм 3 нче шәһәр хастаханәләрен, ашыгыч ярдәм станциясен һәм стомат. поликлиникасын берләштерү юлы б-н оештырыла. Хастаханә составында һәркайсы сменага 720 авыру кабул итүгә исәпләнгән, 186 мең кешегә хезмәт күрсәтүче 2 поликлиника, 1 консультация-диагностика поликлиникасы, 1 көнлек хирургия стационары, стоматология поликлиникасы, 957 ятак-урынлы стационар, ашыгыч мед. ярдәме станциясе, 3 амбулатория, 2 фельдшер-акушерлык пункты һәм хуҗалык исәбендәге бүлекләр (офтальмология, отоларингология, стоматология һ.б., лаб-я бар. Баш миендәге кан әйләнеше бозылган авырулар өчен 60 ятак-урынлы (ш.и. 12 се реанимация бүлегендә) дәвалау үзәге, андрология, мамология, мед.-генетика, репродукция һәм гаиләне планлаштыру үзәкләре эшли; корсак куышлыгы әгъзаларын операция юлы б-н дәвалаганда аз инвазияле эндохирургик ысуллар куллану, лапароскопик операцияләр, ишемия синдромы очрагында әгъзалар һәм тукымаларны туннель ясап ачу, шунт кую операцияләре, тешләр һәм ясалма күз ясмыгы (хрусталик) имплантацияләү, экстракорпораль аталандыру (ЭКО), эре буыннарны эндопротезлау, нейрохирургик операцияләр, ясалма детоксикация (плазмофорез һәм гемофильтрлау, гемодиализ һәм гемосорбция) һ.б. гамәлгә кертелгән. 23 дәвалау бүлегендә ел саен 30 мең авыру дәвалана, 10 мең операция ясала. Хастаханәдә 2472 кеше, ш.и. 392 табиб, 1315 урта мед. хезмәткәре эшли; араларында 3 РФнең атказ. табибие, 24 ТРның атказ. табибе, 3 РФнең һәм ТРның атказ. сәламәтлек саклау хезмәткәре, 19 сәламәтлек саклау отличнигы, 6 мед. фән. канд. бар (2018).

Г.Г.Исмәгыйлев.



Түбән Кама күппрофильле хастаханәсе (№ 3).

ТҮБӘН КАМА МЕДИЦИНА КӨЛЛИЯТЕ, ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагында, урта һөнәри уку йорты. 1966 елда мед. уч-щесе буларак ачыла, 2004 тән хәзерге исемдә. Укыту дәвалау эше, шәфкать туташы эше, фармацевтика, акушерлык эше, лаборатор диагностика белгечлекләре буенча алып барыла. 2014 тә 700 студент укый (656 — көндезге, 44 кичке бүлекләрдә), ш.и. 200 — түләүле нигездә. Укытучылар коллективында 30 кеше эшли, ш.и. 1 РФнең, ТРның атказ. табибе.

ТҮБӘН КАМА МЕХАНИКА ЗАВОДЫ, нефть химиясе сәнәгатенең машина төзү пр-тиесе, Эшләүчеләр саны — якынча 500 кеше (2017). 1985 елда «Түбәнкамашин» ҖБнең ремонтлау-механика з-ды (1970 тә ремонтлау-механика цехы сыйфатында нигезләнә, 1972 дән механик производстволар блогы) җирлегендә Т.К.м.з. буларак төзелә, 2001 дән АҖ; 2002 дә завод «Татнефть» АҖ шиннар комплексы составына керә.

Структурасында: механик һәм кою производстволары, термик, гальваник һәм тимерчелек-пресслау участоклары. Т.К.м.з.да җитештерүнең йомык технол. цикл формасы кулланыла. Машиналар төзү продукциясе, шин, резина-техник һәм нефть химиясе сәнәгате пр-тиеләре өчен стандарт булмаган җиһазлар, запас частьләр, технол. җиһазлар чыгара, ремонтлый һәм аларга хезмәт күрсәтә. Завод РФдә шиннар җитештерү өчен резина катнаш камералар һәм алар өчен запас частьлар чыгаручы бердәнбер пр-тие булып тора.

Т.К.м.з. актив инновацион эшчәнлек алып бара, җиһазларын яңартып тора, ресурс саклаулы технологияләр кертә. 1982 дә автокамералар вулканлаштыруның автомат линиясен әзерләгәне өчен СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә, күп еллар буе пр-тиегә Нефть эшкәртү һәм нефть химиясе министрлыгы һәм Профсоюзлар ҮКның күчмә Кызыл байрагы тапшырыла (1986, 1987, 1988, 1989, 1990). Заводның күп кенә хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә лаек була, ш.и. 3 кеше — Хезмәт Кызыл Байрагы, 2 кеше — «Почёт билгесе», 1 кеше 3 нче дәрәҗә «Хезмәт даны» орденнары, 42 кеше — медальләр, 3 кеше ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Пр-тиенең җитәкчеләре: Я.М.Кадыйров (1972–73), Е.Ф.Журавлёв (1973–75), Ю.А.Косенков (1975–79), В.Е.Ларионов (1979–2003), А.В.Макаров (2004–2013), И.К.Гыйззәтуллин (2014 тән).

Әд.: Бортников Ю. Надёжность — величина постоянная // Нефть и жизнь. 2003. № 1; Ларионов В.Е. НМЗ сегодня — это полноцикли-ческое производство и широкие возможности // Лидер Татарстана. 2003. № 9.

М.Ж.Гаитов, В.И.Полякова.

«ТҮБӘН КАМА» МИЛЛИ ПАРКЫ, Каманың уң һәм сулъяк яры буенда Алабуга, Чаллы, Түбән Кама шәһәрләре янында урнашкан. 1991 елда ТРның төньяк-көнчыгыш өлешендә ландшафтлы табигать истәлеген саклау һәм торгызу, рекреацион, аң-белем тарату, фәнни һәм мәдәни максатлар өчен оештырыла. Зур урман массивларын, коры үзәнле сөзәкле-субүләр болын участокларын, тугай болыннары һәм күлләре булган Кама үзәненең сузынкы участогын, ш.у. Түйма, Таңай, Шилнә елгалары үзәннәренең табигать комплексларын берләштерә. Мәйданы 26587 *га*, ш.и. саклаулык зона — 1836 *га* (6,9%), аеруча саклаулы зона — 12995 *га* (48,9%), танып-белү туризмы зонасы — 5061 *га* (19,1%).

Парк терр-ясенә Кама елга террасаларының 125 *м* га кадәр биеклектәге баскычсыман аккумулятив рельефы хас. Уңъяк ярның төньяк өлеше (*Зур наратлык*) акрынлап абс. билгесе 163 *м* га кадәр булган төп платога күчә. Та һәй елгасыннан көнчыгышка таба Каманың уңъяк төп ярындагы калкулыкны Таңай урманы били. Рельефның төп формалары ерым һәм сызалар б-н ергаланган, алар Каманың текә сөзәкләренә туры килә. Шактый тирәнгә кисеп керүче аерым сыза-чокырларның озынлыгы берничә километрга җитә (Тулапин чокыры, Бай чокыр, Куралы чокыр һ.б.). Зур булмаган бүрәнкәләр рәвешендәге карст күренешләре Каманың сулъяк ярына хас. Каманың уңъяк ярында төрле төстәге Пермь ачылма утырмалары караңгы ылыслы агач токымнары һәм сулык киңлекләре б-н бергә гаҗәеп матур пейзаж тудыра.

Урманнар аерым массивлардан тора. Паркның төньяк-көнбатыш өлешендә, агымының юнәлешен көнбатыштан көньякка таба үзгәртеп, Кама зур борылма хасил иткән урында, биек елга террасаларында уникаль урман массивы *Кызыл тау* — Татарстанда Себер ак



«Түбән Кама» милли паркы. Кече наратлык.

чыршысы ареалының иң көньяк ноктасы урнашкан. Кама һәм Туйма елгалары арасында ылыслы урманнарның тагын бер зур массивы — Зур наратлык, Туйма уңъяк сөзәклегендә Алабуга янында — урта яшьтәге һәм өлгереп килүче нарат утырмаларыннан торучы Кече наратлык, Каманың текә уңъяк ярында аңа Та һәй елгасы кушылган урынында — 1930 лардан башлап, нигездә, утыртылган Таңай урманы (элек Таңай урман дачасы) урын алган. Кара тирәклек һәм имәнлек фрагментлары б-н тугай болыннары (Алабуга һәм Таңай, мәйданы 8063 *га*) паркның шактый өлешен тәшкил итә.



«Түбән Кама» милли паркы. Кама елгасының уңъяк ярында Алабуга шәһәре тирәсендә нарат урманы.

Нарат урманнары урман б-н капланган барлык мәйданның 60 % тан артыгын били. Ылыслы агачлар — нарат, чыршы һәм ак чыршы б-н беррәттән яфраклы токымнар — имән, юкә, каен, усак очрый. Юкә һәм имән катнаш катлаулы наратлыклар, чыршы, яфраклы токымнар катнаш һәм чиста куакчыл-мүкле наратлыклар, ара-тирә каен үскән мүкле наратлыклар (яшелмүклеләр) наратлыклар таралган. Зур наратлыкта субүләрнең төньяк калкулыклы өлешендәге комсыл балчыклы туфракларда 2 нче яруста чыршы б-н имән катыш һәм юкәле наратлыклар очрый; аерым наратларның яше 200 ел. Кама яры буена субүләрнең түбәсеннән чыршы, ак чыршы, киң яфраклы урманнар үскән чокырлар төшә.

Флорада көпшәле үсемлекләрнең 500 дән артык төре урын алган. Ылыслы урманнарның үлән капламында үсемлекләрнең тайга төрләре (нарат җиләге, кара җиләк, яшел кеш яфрак, урта каеш яфрак, кымызлык, тамырчалы күрән, плауннар, ике яфраклы май чәчәге) б-н беррәттән киң яфраклы (гади сәрдә, Европа тайтоягы, гаҗәеп миләүшә, тоныкүкебаш) һәм якты (киң яфраклы кестәрә, каурыйсыман кыска сабак, гади күрән, бөркет канаты) урман төрләре аралаша, болын үсемлекләре дә (яушан, кыңгырау чәчәк, кашкарый үләне, канәфер үләне, тишек яфраклы сары мәтрүшкә) шактый. Торфлы сазлыклар һәм дымлы болыннар флорасының типик вәкилләре: күл камышы, тар һәм киң яфраклы җикәнбаш, киндер басасы, ал чәчәкле кырлыган, зәрдә, күрән, җәенке яфраклы чәнчү үләне, утчәчәк, күке җитене, тубылгы, йогырт һ.б. Күл буенда — су сусыны, Себер сусыны, сай сулыкларда ап-ак һәм сары төнбоек үсә. Парк терр-ясендә РФ һәм ТРның Кызыл китабына кертелгән сирәк һәм югала баручы үсемлекләрнең 60 тан артык төре билгеләнгән: сөйрәлмә «мүк» һәм чукмарсыман плаун, сыргалы ачкыч үлән, башаклы бүре бөресе, Европа казаягы, төз тәпичә, үпкә гентианасы, рус кырыкбуыны, җете кызыл татлы тамыр, сөнгесыман какалия, сарана лалә, ике яфраклы төн миләүшәсе, тимгелле бармактамыр, киң яфраклы йод үләне, кызыл серкәбаш, калпаксыман неоттианта һ.б. Паркның фаунасы бай, имезүчеләрнең — 40, кошларның — 134, җир-су хайваннарының — 10, сөйрәлүчеләрнең — 6, балыкларның 14 төрен берләштерә. Биредә поши, кәҗәболан, кабан дуңгызы, күлләрдә ондатора, инешләрдә кондыз яши, очып үтүләре вакытында аккош, кыр казлары, торналар, шөлди, кыр үрдәкләре туктала. ТРның Кызыл китабына кертелгән сырлач сыртлы тритон, соры гөберле бака, бакыр кәлтә, бакыр елан, гади кара елан, төн лачыны, кыр карчыгасы, елга каракошы, соры көртлек, бытбылдык, соры торна, ак яңаклы акчарлак, һөдһөд, чал тукран, соры карабай, эрбетче, су тавыгы, су төн ярканаты, урман тычканчыгы очрый.

Парк терр-ясендә чишмәләр күп, алар арасында — Кече наратлыктагы «Имче изге Пантелеймон чишмәсе» (И.И.Шишкинның «Алабуга янында изге чишмә» картинасында сурәтләнгән, 1886), Таңай урманындагы тирән чокыр битендәге «Урман әкияте», Зур наратлыкның төньяк-көнбатыш өлешендәге «Толкушка» чишмәләре. Кама һәм Туйма тугайларында элеккеге елга юлларында сакланып калган күлләр бар (Бака күле, Двуисточное, Курья, Запесочье һ.б.). Зур наратлыктагы тугай өсте террасасында елганың элеккеге юлындагы Отарка һәм Подборное күлләре янында ял базалары һәм балалар сәламәтләндерү лагерьлары, Кама яры буенда «Тарловка» санаторие урнашкан. Та һәй урманында чаңгы трассасы сузылган. Кама киңлекләренең күренеше Кызыл таудагы күзәтү мәйданчыгыннан ачыла (И.И.Шишкинның «Алабуга янында Кызыл тау» картинасында сурәтләнгән, 1852). Танып-белү максатларында туристлар өчен экология сукмаклары оештырылган. Табигать музее эшли. 1998 дә агач-куакчыл үсемлекләрнең 80 нән артык төрен берләштерүче дендрология бакчасына нигез салына. Парк терр-ясендә якынча 20 археол. истәлек (б.э.к. 3–2 нче меңъелыкта яшәгән кешеләрнең торулык һәм каберлекләре) сакланган.

Әд.: Сафина С.А. Национальный парк «Нижняя Кама». Елабуга, 2003.

Ф.Г.Борһанов, Г.Г.Миңнекәев, Ю.А.Лукьянова.

ТҮБӘН КАМА МУЗЫКА КӨЛЛИЯТЕ, С.Ж.Сәйдәшев исем., муниципаль уку йорты. Оештыручысы — Түбән Кама шәһәре һәм Түбән Кама р-ны хакимияте. 1969 елда музыка уч-щесе буларак ачыла, С.Ж.Сәйдәшев исеме 1971 дә бирелә, 2008 дән хәзерге исемдә. 2015 тә укыту инструменталь башкару (фортепьяно, кыллы оркестр инструментлары, тынлы һәм бәрмә оркестр инструментлары, халык оркестры инструментлары), вокал сәнгате, хор дирижёрлыгы, музыка теориясе, эстрадада җырлау белгечлекләре буенча алып барыла; көндезге бү-

лектә 103 студент укый. Якынча 1800 белгеч әзерләнә. Уч-щене тәмамлаучылар арасында — Р.Ф.*Кәлимуллин*, Р.Ә.*Сәхәбиев*, З.Н.*Шәрифуллина*, Р.Галимова. Пед. коллективта 47 кеше, ш.и. 4 ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре эшли. Уч-щедә хор дирижёрлыгы һәм вокал сәнгате бүлекләренең студентлар хоры, халык уен кораллары оркестры, тынлы уен кораллары оркестры, камера оркестры, скрипкачылар ансамбле эшли. 1990 нан ике елга бер тапкыр уч-ще җырлегендә вокалистларның С.Ж.Сәйдәшев исем. респ-ка конкурсы уздырыла.

ТҮБӘН КӘМА МУНИЦИПӘЛЬ ИНСТИТУТЫ, дәүләт карамагында булмаган югары уку йорты. 1997 елда Түбән Кама хакимияте тарафыннан оештырыла. Ф-тлары: социаль-хокук эшләре, пед. белгечлекләр, өстәмә һөнәри белем бирү, югары уку йортына кадәрге әзерлек; 16 кафедра эшли (2014). Укыту юриспруденция, персонал б-н идарә итү, оешма менеджменты, социология, инглиз телен укыту теориясе һәм методикасы, татар теле һәм әдәбияты, информатика, физик культура белгечлекләре буенча алып барыла. 2014 тә 517 студент — көндезге бүлектә, 350 студент читтән торып уку бүлегендә укый, барысы да түләүле нигездә. Пед. коллективта 72 кеше эшли, ш.и. 5 фән. д-ры һәм 28 фән. канд. 2014 тә институт ябыла. Ин-т ректорлары: В.Б.Живетин (1997–99), Ф.Г.Ялалов (1999–2014).

Әд.: Ялалов Ф.Г. Муниципализация высшего профессионального образования: Нижнекамский муниципальный институт // Научный Татарстан. 2003. № 1.

ТҮБӘН КӘМА НЕФТЬ ХИ́МИЯСЕ КӨЛЛИЯТЕ́, урта һөнәри уку йорты, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагында. 1966 елда кичке нефть химиясе техникумы буларак ачыла (1968 дән — көндезге бүлек), 1990 нан хәзерге исемдә. 2015 тә укыту сәнәгать җиһазларын монтажлау һәм техник файдалану, суыту-компрессор машиналарын һәм җайланмаларын монтажлау һәм техник файдалану, электр һәм электр механикасы җиһазларын техник файдалану һәм аларга хезмәт күрсәтү, технол. процесслар һәм производстволы автоматлаштыру, мәгълүмат эшкәртү һәм идарә итүнең автоматлаштырылган системалары, органик матдәләрнең химик технологиясе, нефть һәм газ эшкәртү, полимер материаллардан эшләнмәләр һәм түшәмәләр җитештерү, хокук белеме, икътисад һәм бухгалтерлык исәбе белгечлекләре буенча алып барыла. 2015 тә 1371 студент укый (1034 — көндезге бүлектә, 337 — читтән торып уку бүлегендә, ш.и. 165 — түләүле нигездә. Пед. коллективта 67 кеше эшли, ш.и. 2 фән. канд.


ТҮБӘН КӘМА ПЕДАГО́ГИКА КӨЛЛИЯТЕ́, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагында. 1981 дә педагогия уч-щесе буларак ачыла, 2009 дан хәзерге исемдә. Укыту башлангыч сыйныфларда укыту, мәктәпкәчә белем бирү, адаптив физик культура белгечлекләре буенча алып барыла. 2015 тә 173 студент укый: 153 — көндезге һәм 20 читтән торып уку бүлегендә, ш.и. 48 — түләүле нигездә. Пед. коллективта 33 кеше эшли, ш.и. 2 фән канд., 1 ТРның атказ. укытучысы.

ТҮБӘН КӘМА ПОЛИТЕ́ХНИК КӨЛЛИЯТЕ́, урта һөнәри уку йорты, Е.Н.Королёв исем., РФ Энергетика министрлыгы карамагында, 1966 елда энергетика-төзелеш техникумы буларак ачыла. 1987 дән атом энергетикасы техникумы, 1990 нан Түбән Кама политехник техникумы, 1994 тән хәзерге исемдә. 2002 дән Е.Н.*Королёв* исем. Укыту электр станцияләре, күтәрү-транспорт, төзелеш, юл машиналарын һәм җиһазларын техник файдалану, автомобиль транспортын идарә итү һәм йөк ташуны оештыру, биналар һәм корылмалар төзелеше һәм аларны файдалануга тапшыру, гамәли информатика (тармаклар буенча), җылылык электр станцияләре белгечлекләре буенча алып барыла. 2015 тә 708 студент укый (628 — көндезге бүлектә, 80 — читтән торып уку бүлегендә), ш.и. 53 — түләүле нигездә. Пед. коллективта 35 кеше эшли, ш.и. 2 фән. канд., 1 ТРның атказ. укытучысы, 1 ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре, 1 РФнең мактаулы иҗтимагый мәгариф хезмәткәре, 1 РФнең мактаулы урта һөнәри белем бирү хезмәткәре.

ТҮБӘН КӘМА РАЙОНЫ́, ТРның үзәгендә урнашкан. Мәйданы — 1672,4 *км*². 1 шәһәрне (Кама Аланы штп), 15 авыл җирлеген, 65 авыл торак пунктын берләштерә. Үзәге — *Түбән Кама* шәһәре. 2018 елда 37091 кеше (район үзәген кертмичә: 2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 48,1%, руслар — 44,8%, чуашлар — 3,4%), ш.и. шәһәр халкы — 15624, авыл халкы — 22128 кеше. Халыкның уртача урнашу тыгызлыгы — 1 *км*² *га* 22,6 кеше. Район 1965 нең 12 гыйнварында оешты-рыла. 1920 гә кадәр терр-ясе Казан губернасының Чистай өязенә һәм Уфа губернасының Минзәлә өязенә керә. 1920 дән ТАССРның шул ук исемдәге кантоннары составында. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт һәм Чаллы, 1963 нең 1 февраленнән Чаллы һәм Чистай р-ннарында. Оешкан чорда Т.К.р.ның мәйданы — 1612 *км*² була, аңа 9 авыл һәм 1 посёлок советы, 79 торак пункт керә, 45 мең кеше яши. 1984 нең 3 июлендә аның составына Яңа Чишмә р-нының Ялантау, Кармалы, Сосновка авыл советлары бирелгәч, районның хәзерге чикләре билгеләнә.

Т.К.р.ның рельефы — төньякка һәм төньяк-көнбатышка таба Кама үзәненә тоташкан калку тигезлек (биеклеге 180–200 *м*). Кама һәм аның кушылдыклары Зәй, *Чишмә*, Уратма елгалары ага. Җирләре күбесенчә кәсле-көлсу, сары урман, селтесезләнгән кара туфраклы. Терр-ясенең 21% ы — урманлык. Известьташ, доломит, балчык, мергель ятмалары бар. Саклаулы табигать истәлекләре: *Дала Зәе* һәм Чишмә елгалары, *Борок урман дачасы*, *Ширәмәт авылчылык тыюлыгы*. Район терр-ясендә таш, бронза һәм әүвәлге тимер гасырга караган 60 тан артык археол. истәлек табыла. Мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау, кошчылык тармаклары алга киткән. А.х. 86,7 мең *га* җир били, ш.и. сөрүлекләр 64,7 мең *га* (2016). Сабан бодае, рапс, арыш, арпа, солы игелә; бәрәңге, яшелчә, шикәр чөгендере үстерелә. 2016 да районда төрле милектәге 63 а.х. пр-тиесе исәпләнә. Сәнәгать пр-тиеләре район үзәгендә, шәһәр тибындагы Кама Аланы посёлогында («Термокам», «Камдетальпроект», «Поток-К» ЖЧҖ, тегү ф-касы, эре панельле йортлар төзү з-ды) урнашкан. Т.К.р. җиреннән Түбән Кама – Круглое Поле тимер юлы, Чистай – Түбән Кама, Түбән Кама – Чаллы автомобиль юллары уза. Кама елгасы буенда Красный Ключ пристане эшли. Районда 18 гомуми белем бирү мәктәбе, ш.и. 7 тулы булмаган урта, 11 урта мәктәп, 1 прогимназия); мөмкинлекләре чикләнгән балалар мәктәп-интернаты, 2 балалар музыка мәктәбе, балалар иҗат үзәге; 24 мәктәпкәчә яшьтәгеләр учреждениесе, 40 клуб, 28 китапханә район үзәк һәм район (Кама Аланы) хастаханәләре хезмәт күрсәтә. 107 спорт корылмасы, 2 балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе эшли. «Туган як», «Нижнекамская правда» район г-талары нәшер ителә.

ТҮБӘН КӘМА СУСАКЛАГЫЧЫ́, *Кама* елгасындагы сусаклагычлар каскадының иң түбәнгесе. ТР терр-ясендәге акваторияне төп өлеше, сусаклагычның терәк сулары Кама елгасы буенча Удмурт Респ-касына, Агыйдел елгасы буенча Башкортстан Республикасына таралган. Чаллы шәһәре янында *Түбән Кама ГЭСы* плотинасы төзелгәч, 1978 елда барлыкка килә. 1978–79 да су б-н тула, терәк суы биеклеге 62 *м* тәшкил итә. Мәйданы 1084 *км*², күләме 3,6 *км*³, Кама елгасы буенча озынлыгы 185 *км*, Агыйдел буенча 87 *км*, иң зур киңлеге 15 *км*, иң зур тирәнлеге 20 *м*. Гадәти терәк биеклегендә проект күрсәткечләре 68 *м* тәшкил итә: мәйданы 2651 *км*², күләме 13,8 *км*³, Кама елгасы буенча озынлыгы



283 *км*, Агыйдел елгасы буенча 140 *км*, иң зур киңлеге — 20 *км* (су проект биеклегендә булганда Т.К.с.ның терәк сулары Пермь өлкәсе терр-ясендә дә тарала). Сусаклагычның барлык мәйданының якынча 50% ын 2 *м* га кадәр тирәнлектәге сай сулыклар били. Кама кушылдыкларының түбәнге агымында зур култыклар — Агыйдел, Ык, Иж һ.б. барлыкка килгән.

Т.К.с.на өстәрәк ятучы Воткинск һәм Кама сусаклагычлары суы б-н көйләнүче Кама, Павловка сусаклагычы б-н көйләнүче Агыйдел, ш.у. Сөн, Ык, Минзәлә, Иж елгаларының агымнары керә. Т.К.с.нда агымны сезонлы көйләү үткәрелә. Биеклек тирбәнешләренең амплитудасы 1,5 *м* дан артмый. Туенуы күбесенчә язгы кар сулары исәбенә. Көзге-язгы чорда су тиешле биеклеккә җиткерелә. Боз ката башлау уртача чоры 30 ноябрь (иртә булганда — 23 ноябрь, соңга калганда — 9 декабрь), боздан арчылу — 2 май (иртә булганда — 28 апрель, соңга калганда — 7 май); боз катуның уртача дәвамлылыгы — 213 көн (иң озыны — 222, иң кыскасы — 202 көн).



Түбән Кама сусаклагычы.

Энергетика ихтыяҗларына, су транспорты, су б-н тәэмин итү, сугару өчен кулланыла. Т.К.с.ярлары буенда санаторийлар, ял базалары, балалар сәламәтләндерү лагерьлары урнашкан. Сәнәгый балыкчылык алып барыла (корбан балык, судак, чуртан, чабак, густера, синец).

Терәк биеклеге 68 *м* да булганда ТР чикләрендәге 88 мең *га* җир Т.К.с. сулары астында кала. Т.К.с.нда даими терәк биеклеген 68 *м* га кадәр билгедә тоту проблемасы хәл ителмәгән. Билгеле бер икътисади максатларга ярашлы рәвештә (электроэнергия җитештерүне арттыру, суднолар йөртү шартларын, суның санитар торышын һәм сыйфатын яхшырту) су биеклеген күтәрү җир (тагын 90 мең *га* җир ТРда су астында калачак) һәм табигать байлыклары торышына тискәре йогынты ясарга мөмкин.

О.Н.Урбанова, Ф.Г.Борһанов.

ТҮБӘ́Н КА́МА ТАТА́Р ДРА́МА ТЕА́ТРЫ (Т.Миңнуллин исем. Түбән Кама татар дәүләт драма театры). 1989 елда Түбән Кама да «Түбәнкаманефтехим» АҖ каршында Яшьләр тәҗрибә татар театр-студиясе буларак оеша, 1994 тә Шәһәр яшьләр татар театры статусы ала, 1997 дән — татар драма театры, 2007 дә дәүләт театры статусына ия була, 2012 дән хәзерге исемдә. 1990 нан хәзерге та-





Түбән Кама татар драма театры спектакльләреннән күренешләр: 1. «Җир уллары трагедиясе», Һ.Такташ (Кабил ролендә — А.Кәримов, Әкълимә — Ф.Гыйниятуллина); 2. «Ай тотылган төндә», М.Кәрим (Дәрвиш ролендә — Р.Галиев, Дивана — Ф.Вафиев).

тар драматургиясе, татар һәм рус әдәбияты классиклары әсәрләре буенча 60 тан артык спектакль куела: «Кызлар кызык итәләр», «Яшьлегем-юләрлегем», «Ай булмаса, йолдыз бар», «Яшьлек белән очрашу», «Нәзер» (Т.Миңнуллин), «Адашкан чәчәкләр» (Г.Каюмов), «Әти диясем килә» (Ә.Хәсәнов), «Бәхетле килен», «Хатыным-алтыным», «Мөхлис һәм Иблис» (Х.Ибраһим), «Каракның бүреге яна» (Ф.Яруллин), «Өч хатын берлән тормыш» (Г.Исхакый), «Ил» (К.Тинчурин), «Кыз урлау», «Ай тотылган төндә» (М.Кәрим), «Җир уллары трагедиясе» (Һ.Такташ), «Кадер кичәсе» (Р.Галиев), «Хәерле юл!» (И.Зәйниев), «Тиле яшьлек» (И.Абдуллин), «Соңгы төн» (И.Юзеев), «Бүре каны» (Н.Гыйматдинова), «Үзем белән үзем» (Г.Хәйям), «Гөнаһлы мәхәббәт өрәге» («Призрак грешной любви», А.Иванов), «Ярсыз ярлар» («Любовь окаяная», Н.Угарин), «Назлыгөл» (М.Байҗиев) һ.б. Ю.Сафиуллин пьесасы буенча реж. Р.Фатыйхов куйган Чечня сугышы фаҗигаләренә багышланган «Йөзек һәм хәнҗәр» спектакле Түбән Новгород шәһәрендә узган «Россия яшьлеге» («Юность России») фестивалендә бүләккә лаек була. Репертуарында балаларга багышланган спектакльләр дә шактый урын алып тора: «Шомбай маҗаралары» (Р.Вәлиев), «Иң күңелле көн» («Самый лучший день», Е.Чеповецкий), «Карурман аша» (Р.Галиев), «Һау-һау-һау» (Т.Миңнуллин) һ.б. Театр ТР, РФ шәһәрләре һәм районнарында гастрольләрдә йөри; Россия һәм халыкара театр фестивальләрендә катнаша; ТР Мәдәният министрлыгының «Тантана» бүләге лауреаты («Иң яхшы хатын-кыз роле» номинациясендә — Г.Шәмәрданова, 2016). Театр үсешенә ТРның халык артисты А.Фәттахова, ТРның атказ. артисты М.Фәттахов, театрның директоры, атказ. мәдәният хезмәткәре Ф.Чабатов, рәссамнар Ә.Закиров, Л.Гыйльметдинов, М.Греньков, композиторлар А.Нәҗмиев, Ю.Чаплин, М.Минһаҗев, театрның баш рәссамы, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе Б.Нәсыйхов, костюмнар буенча рәссам Ф.Мөхәммәтшина зур өлеш кертәләр. 2018 дә театр труппасында — ТРның атказ. артистлары Г.Фәхразиева, Ф.Вафиев, Рәис Галиев, Д.Карпова, Ф.Гыйниятуллина, А.Ибраһимов, Н.Сәйфетдинов, актёрлар Г.Шәмәрданова, Г.Галиева, Р.Зәйнуллин, Ю.Павлов, А.Әгъләмова, А.Хөсәенов, Л.Чупашева һ.б.

Театрның җитәкчеләре: ТАССРның атказ. артисты А.С.Богатырёв (1990–95), Р.Ә.Фатыйхов (1996–2002), ТРның халык артисты, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе, Д.Сиражиев исем. театраль бүләк лауреаты, М.Сәлимҗанов исем. Респ-ка бүләге лауреаты, РФ Театр эшлеклеләре берлеге әгъзасы Р.В.Галиев (1990–95 һәм 2002 дән).

Әд.: И г л а м о в Р. Будни и праздники жанра // Аргамак. 1999. № 11–12.

Д.Ә.Гыймранова.

ТҮБӘ́Н КА́МА ТЕРРИТОРИА́ЛЬ-ҖИТЕШТЕРЕ́Ү КО́МПЛЕКСЫ, ТРның төньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан. Чаллы, Түбән Кама, Алабуга, Зәй, Менделеев шәһәрләрен, шәһәр тибындагы Кама Аланы посёлогын эченә ала. Комплексның формалашуы Түбән Кама шәһәре һәм нефть химиясе комбинаты төзелүгә бәйле рәвештә 1960 елларда башлана. 1963 елда — Зәй ГРЭСы, 1967 дә Түбән Кама ГЭЦы сафка баса. 1965 тә Чаллы ш. янында — *Түбән Кама ГЭСы* (1979 да сафка баса), 1969 да *Кама автомобиль заводы* төзелеше башлана. 1980 нән — Татарстанда АЭС (1990 да туктатыла) һәм шәһәр тибындагы Кама Аланы посёлогы, 1988 дән Кама трактор з-ды (1984 тә нигез салына) җирлегендә Алабуга автомобиль з-ды төзелеше башлана. 1960 лар ахырыннан транспорт инфраструктурасы бик тиз үсә: Әгерҗе–Круглое Поле–Акбаш тимер юлы, Казан–Алабуга–Чаллы автомобиль юлы салына, Бигеш аэропорты, Чаллы елга порты төзелә, куәтле төзелеш индустриясе булдырыла. Т.К.т.-ж.к.ның халкы 1960 тан 1990 нар башына 14 тапкырдан күбрәккә арта: 500 меңләп кеше, ш.и. моңа кадәр ТРдан читтә яшәгән 200 мең кеше даими яшәү өчен килә. 1990 нан халык саны 49,1 мең кешегә (5,9% ка) арта, 2006 ның башына ул 882,9 мең тәшкил итә (ТРның бөтен халкының 23,5% ы һәм шәһәр халкының 31,5% ы). Халык тыгызлыгы — 1 *км²* *га* 2750 кеше. Туучылар саны — 10,6, үлүчеләр саны — 8,7, халыкның табигый артуы — 1,9‰. Табигый арту Чаллы (2,5‰) һәм Түбән Кама (3,1‰) шәһәрләре исәбенә бара, башка шәһәрләрдә үлүчеләр саны туучылар саныннан күбрәк була. Миграция, күпчелек эчке (респ–ка) миграция, нәтиҗәсендә Чаллыда (2005 тә 2317 кешегә) һәм Түбән Камада (834 кешегә), тулаем Т.К.т.-ж.к. буенча 2777 кешегә халык саны кими. Гомуми халык санында эшкә яраклы яшьтәгеләрнең

өлеше 69%, өлкән яшьтәгеләрнең өлеше 14% тәшкил итә (уртача республикадагының — ярашлы рәвештә 62,8% ы һәм 19,8 % ы).

Төп минераль ресурслар: нефть (ТРда чыгарыла торган запасларның 11,6% ы), минераль сулар (20% тан артыграк — шифалы, 40% тирәсе — шифалы-эчә торган, 54% — шифалы-эчәргә яраклы сулар), төзелеш материаллары. Биредә респ. күләмендәге ком-гравий материалларының (Алабуга, Вишняково, Соболеково, Таңай чыганаклары) — 60% ыннан артыграгы, бетонит балчыкларының 90% тан артыграгы чыгарыла, карбонатлы һәм балчыклы токымнар, төзелеш комы запас лары бар. Нефтьне «Прикамнефть» һәм «Зәйнефть» НГДУлары чыгара. Эшкәртү сәнәгатенең төп тармаклары — нефть химиясе, химия, машиналар төзү. Нефть химиясе сәнәгатенең башында: «*Түбәнкамanefтехим*» (бензол, этилен һ.б. җитештерү), «Түбән Кама нефть эшкәртү з-ды» (сыегайтылган углеводород газлары, автомобиль бензины һ.б.), «*Түбәнкамашин*», Түбән Кама техн. углерод з-ды, «*Эластик*» з-ды (пластмасса, линолеум) акц. җәмгыятьләре. Менделеев шәһәренең 2 предприятиесе: «Л.Я.Карпов исемендәге химия заводы» һәм азотлы ашламалар җитештерүче «Менделеевазот» акц. җәмгыятьләре — химия сәнәгате вәкилләре. Машина төзелеше, нигездә, Чаллы һәм Алабугада туплана: «КамАЗ» автомобиль заводы, «Кече литражлы автомобильләр заводы», «Алабуга автомобиль заводы» ҖБ (автомобильләр җыю, махсус техника, тракторлар һәм алар га тагылма җи һазлар җыю) акционерлык җәмгыятьләре. Кама автоагрегат з-ды, «Камаз-Дизель», «КамАЗ-Металлургия», Кама пресс-рам з-ды, «КамАЗавтотехника» (Зәй ш.) кебек хезмәт күрсәтүче пр-тиеләр дә биредә урнашкан. Төзелеш материаллары сәнәгатен тимер-бетон эшләнмәләр һәм конструкцияләр, күзәнәкле бетон, керамик һәм силикатлы кирпеч, руда булмаган материаллар, керамзитлы гравий җитештерү тәшкил итә. Чаллы шәһәрендә респ-кадагы иң зур катыргы-кәгазь комбинаты эшли. Иң эре пр-тиеләр: Зәй шикәр з-ды, Чаллы элеваторы, Алабуга икмәк кабул итү пр-тиесе, Чаллы икмәк продуктлары комб-ты, «Булай» кондитер ф-касы, «Зәй крекеры» АҖ, «Алиса», «Шифалы су» алкогольсез эчемлекләр з-дла ры, «Челны-Холод» комб-ты. Сәнәгый нигез дә а.х. продукциясе җитештерүче пр-тиеләр: «Чаллы кошчылык фабрикасы» («Чаллыбройлер»), Түбән Кама «Красный Ключ» кошчылык ф-касы, «Регина» җитештерү коопера тивы (каз ите җитештерү), «Чаллы балык хуҗалыгы», «Весенний» (яшелчә культурала ры үстерү), «Ворошиловский» һәм «Түбән Кама» (консервлар, маринадлар) совхозлары. Шәһәрләрдә проект оешмалары күп. Юга ры квалификацияле белгечләр 10 нан артык уку йортында әзерләнә (*Кама икътисади инженерлар академиясе*, *Алабуга педагогия университеты* һ.б.).

Әд.: Производители и поставщики товаров и услуг Республики Татарстан: Каталог-справ. К., 2006.

Р.Г.Власова, Ф.Г.Борһанов.

ТҮБӘН КАМА ХИМИЯ-ТЕХНОЛОГИЯ ИНСТИТУТЫ, югары уку йорты, *Казан милли-тикшеренү технология университеты* ф-лы. 1963 елда гомуми техник ф-тның читтән торып уку ф-лы буларак ачыла, 1967 дән кичке гомуми техник ф-т, 1973 тән институт ф-лы; 1992 дән көндезге формада укыту башлана; 1995 тән хәзерге исемдә. Эшләү дәвамында 15 меңнән артык белгеч әзерләнә. 2015 кә механика, технол. идарә һәм автомат лаштыру, икътисад һәм идарә итү, квалификация күтәрү ф-ты, 16 кафедра, 1 цикл эшли. Квалификацияле эшчеләр, хезмәткәрләр әзерләү — 4 программа буенча, урта звено белгечләрен — 6 программа буенча, 19 юнәлеш буенча, 3 программа буенча белгечлекләр, 6 программа буенча магистратура әзерләү, һөнәри белем 4 программа буенча алып барыла. 2408 студент укый (536 — көндезге, 323 — кичке, 1549 — читтән торып уку бүлегендә), ш.и. 1773 — түләүле нигездә. Пед. коллективта 115 кеше эшли, ш.и. 18 фән. д-ры, 85 фән. канд.. Ректоры — В.И.Елизаров (1993 тән).

Әд.: Становление и развитие народного образования в городе Нижнекамске (1961–2003 гг.). Нижнекамск, 2004.

ТҮБӘН КАМА ШӘһӘРЕ ТАРИХЫ МУЗЕЕ, 1976 елның 5 гыйнварында нигез салынган, 1981 нең 22 сентябрендә, шәһәрнең 10 еллыгына туры китереп, ТАССР Дәүләт музее ф-лы буларак ачыла; 2007 дән — муни ципаль музей. 2004 кә кадәр экспозиция мәй даны 753 *м*², күргәзмә залы мәйданы 160 *м*², парк зонасы мәйданы 2 *га*. Коллекцияләрдә 26 меңгә якын саклау берәмлеге исәпләнә. Музей тупланмасында — археол., этнографик (халык кулдан тукучылыгы, бизәнү әй берләре, халык костюмнары һ.б.), табигыять-фәнни коллекцияләр (135 кош һәм вак хайван сөякләре, кабырчыклар, балык, краб, лангуст, диңгез ташбакасы һәм Һинд океанында яшәүче башка хайваннар сөякләре), шәһәр төзелеше һәм «Түбәнкаманефтехим» һәм «Түбәнкамашин» пр-тиеләре оешу та рихына багышланган фотодокументлар, иске басма китаплар (17 йөзгә караган «Изге Ефремның тормышы» — «Житие Св. Ефрема» һ.б.), сынлы сәнгать һәм гамәли-бизәлеш сәнгате әсәрләре (оста Т.Матвеева уен чыклары, кызыл балчыктан И.Матвееваның миниатюр пластикасы, ш.у. Филимоново, Каргополь, Абашево, Кострома, үзбәк уен чыклары тупланмалары), Татарстан рәссам нарының рәсемнәре һәм графикасы, рәссам Ә.С.*Фәтхетдинов* әсәрләренең тупланмасы. 2004 тән музей махсус бинада урнаша (мәй даны 2282 *м*²). Экспозициягә «Түбәнкаманефтехим» һәм «Түбәнкамашин» пр-тиеләренең җитештерү процессларын сурәтләгән ма кетлар комплексы куелган. Иң кыйммәтле экспонатлар — Имәнкискә археол. культурасы предметлары (8 берәмлек), И.Матвеева ның миниатюр пластикасы (174 берәмлек), җирле осталарның гамәли-бизәлеш сәнгате (900 гә якын берәмлек), нумизматика (1700 дән артык берәмлек), керәшен татарларның этнографик коллекцияләре (30 га якын берәмлек). Ел саен музей үзенең Оешу көнен (5 гыйн.) һәм Ачылу көнен (22 сент.), Халыкара музейлар көнен (18 май) билгеләп үтә.

Әд.: Исторические и краеведческие музеи СССР: Каталог. М., 1988.

ТҮБӘН КАМА ЭКСПЕДИЦИЯСЕ, Түбән Кама гидроэлектрстанциясенең су басу зонасында — Татарстанның Кама аръягының көнчыгыш өлешендә кырда тикшеренүләр өчен оештырылган археол. фәнни-эзләнү төркеме. 1968–72 елларда А.Х.Халиков һәм П.Н.Старостин җитәкчелегендә Татарстан археол. отряды составында эшли. Төркем составына Р.С.Габәшев, Е.П.Казаков, М.Г.Косменко, Р.Н.Баһаветдинов, О.Н.Евтюхова һ.б. керә. Т.К.э.ндә катнашучылар тарафыннан 10 мең *м*² тан артыграк мәйданда культура катламы ачыла, 100 дән артык яңа археол. истәлек ачыклана, мезолит, неолит, энеолит чорларына (Актаныш р-ныңң элекке Татар Әҗбие авылы янында), бронза гасырга (Актаныш р-ныңң Уразай авылы янында) нисбәтле туктаулыкларда һ.б.да казулар уздырыла. Ш.у. *Буралы курган культурасы* һәм *Чиркәскүл культурасы*, урта гасырлар болгар торулыклары, *Такталачык комплексы* истәлекләре тикшерелә.

Әд.: Отчёты НижнеКамской археологической экспедиции. М., 1972. Вып. 1; Древности Икско-Бельского междуречья. К., 1978; Казаков Е.П. Памятники болгарского времени в восточных районах Татарии. М., 1978; Об исторических памятниках по долинам Камы и Белой. К., 1981; Археологические памятники Восточного Закамья. К., 1989. *Е.П.Казаков.*

ТҮБӘН КАРАКИТӘ авылы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 21 *км* көнбатыштарак, Чуаш Респ-касы б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 546 кеше (татар-





Түбән Кама шәһәре тарихы музее. 1. Гомуми күренеше; 2. Экспозиция фрагменты.

лар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1653–54 еллардан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә (лашманлыкта эшли); игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.К.дә мәчет, мәдрәсә эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1664,1 дис. тәшкил итә. 1906 ның июнендә авылда җирле крәстияннәр хөкүмәткә каршы чыгыш ясыйлар, бу чыгышлар гаскәр тарафыннан бастырыла. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Мөчәли волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1859 да — 724, 1897 дә — 1273, 1913 тә — 1910, 1920 дә — 1520, 1926 да — 1456, 1938 дә — 1561, 1949 да 1205, 1958 дә — 1129, 1970 тә — 1262, 1979 да — 1271, 1989 да — 647, 2002 дә — 560 кеше.

ТҮБӘ́Н КАРАМАЛЫ́ авылы, Чирмешән р-нында, Чирмешән авылыннан 17 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Чишмә елгасы буенда. 2010 елда 294 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.К.да Никола чиркәве (1902–05 тә төзелә; архит-ра истәлеге), чиркәү-приход һәм земство мәктәпләре, 2 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатьнең имана җире 2882 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Югары Карамалы волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Беренче Май, 1963 нең 1 февраленнән — Лениногорск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Чирмешән р-нында. Халык саны: 1859 да — 408, 1889 да — 1397, 1897 дә — 1341, 1910 да — 1804, 1920 дә — 1729, 1926 да — 1358, 1949 да — 961, 1958 дә — 774, 1970 тә — 633, 1979 да — 496, 1989 да — 317, 2002 дә — 349 кеше.

ТҮБӘ́Н КАРА́Ч посёлогы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 27 *км* көнбатыштарак, Шәбез елгасы буенда. 2010 елда 8 кеше (татарлар) яши. 1770 елларга кадәр нигез салына. 18–19 йөзләрдә халкы типтәрләр катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тимерчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.К.та мәчет, 4 тимерчелек эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 580 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Семиостров волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 108, 1859 да — 176, 1870 тә — 165, 1884 тә — 185, 1897 дә — 216, 1906 да — 209, 1913 тә — 190, 1920 дә — 226, 1926 да — 120, 1938 дә — 96, 1949 да — 72, 1958 дә — 50, 1970 тә — 47, 1979 да — 43, 2002 дә — 7 кеше.

ТҮБӘ́Н КАРМАЧЫ́ посёлогы, Лаеш р-нында, Лаеш шәһәреннән 20 *км* төньяктарак, Казан–Оренбург автомобиль юлы буенда. 2010 елда 2 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кече Кармачы исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 204 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Державин волостенда. 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1859 да — 109, 1884 тә — 131, 1897 дә — 89, 1908 дә — 87, 1920 дә — 91, 1926 да — 126, 1938 дә — 92, 1949 да — 138, 1958 дә — 117, 1970 тә — 64, 1989 да — 20, 2002 дә — 8 кеше.

ТҮБӘ́Н КӘМИНКӘ́ авылы, Чирмешән р-нында, Чирмешән авылыннан 24 *км* төньяктарак, Олы Кәминкә елгасы буенда. 2010 елда 518 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1740 елларга кадәр нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.К.дә 3 мәчет, мәктәп, тегермән, ярма яргыч, 3 вак-төяклөр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1829 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Күтәмә волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Беренче Май р-ны үзәге, 1963 нең 1 февраленнән — Лениногорск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Чирмешән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 152 ир-ат; 1859 да — 1260, 1897 дә — 1637, 1908 дә — 1532, 1920 дә — 2205, 1926 да — 861, 1949 да — 773, 1958 дә — 873, 1970 тә — 1098, 1979 да — 889, 1989 да — 583, 2002 дә — 519 кеше.

ТҮБӘ́Н КӘЧИ́ авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 29 *км* көньяктарак, Шыя елгасы буенда. 2010 елда 333 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, чуашлар — 62%, руслар — 35%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Чиркәү. 1710 нан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстиянәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.К.дә Покров чиркәве, чиркәү-приход мәктәбе (1891 дә ачыла), тегермән, 2 вак-төяклөр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1596 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Юхмачы волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1935 нең 10 февраленнән — Кузнечиха, 1944 нең 19 февраленнән — Юхмачы, 1956 ның 7 декабреннән — Кузнечиха, 1960 ның 28 октябреннән — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 240 ир-ат; 1859 да — 436, 1897 дә — 952, 1908 дә — 1051, 1920 дә — 1139, 1926 да — 867, 1938 дә — 680, 1949 да — 645, 1958 дә — 609, 1970 тә — 609, 1979 да — 509, 1989 да — 380, 2002 дә — 385 кеше.

ТҮБӘ́Н КЕНӘ́ авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 12 *км* көнбатыштарак, Хәтнә елгасы буенда. 2010 елда 308 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Урта мәктәп, клуб. Мәчет. 1678 дән мәгълүм. 1930 елларга кадәр Байчура Чишмәсе буларак билгеле. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Починок Бискуринской, Анля исемнәре б-н дә телгә алына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау, умарта чылык, мич чыгару б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет (1855 тә төзелә), мәктәп, 3 вак-төяклөр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1940,2 дис. (Московский Ключ авылын да кертеп) тәшкил итә. 1912 дә икенче мәчет төзелә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Балтач волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1782 дә — 93 ир-ат; 1859 да — 444, 1897 дә — 739, 1908 дә — 852, 1920 дә — 1000, 1926 да — 917, 1938 дә — 889, 1949 да — 514, 1958 дә — 474, 1970 тә — 424, 1979 да — 331, 1989 да — 307, 2002 дә — 315 кеше.

ТҮБӘ́Н КОЗГЫНЧЫ́ авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 28 *км* төньяк-көнбатыштарак, Шыя елгасы буенда. 2010 елда 282 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты. 1619 дан Колгынчы буларак билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.К.да мәчет, тегермән, ярма яргыч, 3 вак-төяклөр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 640,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Җөри волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән Мамадыш р-нында. Халык саны: 1859 да — 289, 1897 дә — 541, 1908 дә — 695, 1920 дә — 676, 1926 да — 650, 1949 да — 469, 1958 дә — 577, 1970 тә — 501, 1979 да — 435, 1989 да — 344, 2002 дә — 343 кеше.

ТҮБӘ́Н КОЛАҢГЫ́, к. *Кече Колаңгы.*

ТҮБӘ́Н КОЛЧУРА́ авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 25 *км* көньяк-көнбатыштарак, Инча елгасы (Кече Чирмешән бассейны) буенда. 2010 елда 319 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. Чиркәү. 1740 елларга кадәр Югары Колчура авылы кешеләре нигез сала. Рев-циягә кадәрге чыганаклларда Башка Колчура исеме б-н дә билгеле.

1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 җил тегермәне, ярма яргыч, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1431,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының спас өязе Кузнечиха волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1935 нең 10 февраленнән — Кузнечиха, 1960 ның 28 октябреннән — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1859 да — 377, 1897 дә — 616, 1908 дә — 843, 1920 дә — 838, 1926 да — 657, 1938 дә — 531, 1949 да — 423, 1958 дә — 488, 1970 тә — 515, 1979 да — 440, 1989 да — 343, 2002 дә — 311 кеше.

ТҮБӘ́Н КОНДРАТА́ авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 52 *км* көньяктарак, Баганалы елгасының Кече Чирмешәнгә кой - ган урынында урнашкан. 2010 елда 433 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, яшелчәчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Чиркәү. 1710 нан Спирькина авылы буларак билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче ярты сыннан халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү (1912 дә ачыла), Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе, 3 тегермән, ярма яргыч, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1469 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Яңа Әдәм волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чистай, 1935 нең 10 февраленнән — Биләр, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан — Әлки, 1987 нең 23 февраленнән Чистай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 121 ир-ат; 1859 да — 523, 1897 дә — 662, 1908 дә — 812, 1920 дә — 950, 1926 да — 630, 1938 дә — 808, 1949 да — 616, 1958 дә — 638, 1970 тә — 923, 1979 да — 577, 1989 да — 547, 2002 дә — 507 кеше. 1990 елларда Т.К.да «Чуаш сандугачы» фольклор фестивале уздырыла.

Әд.: Чистополь и чистопольцы: Из прошлого и настоящего. К., 2004.

ТҮБӘ́Н КӨЕ́К авылы, Әтнә р-нында, Олы Әтнә авылыннан 15 *км* төньяк-көнбатышта - рак, Үртәм елгасы буенда. 2010 елда 308 ке - ше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1619 дан мәгълүм. 1930 еллар уртасына кадәр Олы Көек исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче ярты - сында халкы дәүләт крәстияннәре катлавы - на керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыль - ләнә. 20 йөз башында мәчет (1877 дә төзелә; архит-ра истәлеге), мәдрәсә, тимерчелек, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җә - мәгатенең имана җире 1171 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Царёво - кокшайск (1919 дан — Краснококшайск) өя - зе Күлле Киме волостенда, 1920 дән ТАССР - ның Арча кантонында. 1930 ның 10 авгус - тыннан — Тукай, 1938 нең 25 мартыннан — Әтнә, 1959 ның 12 октябреннән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1990 ның 25 октябреннән Әтнә р-нында. Халык саны: 1782 дә — 31 ир-ат; 1859 да — 686, 1897 дә — 829, 1908 дә — 967, 1920 дә — 947, 1926 да — 950, 1938 дә — 931, 1949 да — 719, 1958 дә — 552, 1970 тә — 527, 1979 да — 488, 1989 да — 399, 2002 дә — 337 кеше.

ТҮБӘ́Н КӨЧЕ́К авылы, Әгерҗе р-нында, Әгер җ̆е шәһәреннән 40 *км* көньяктарак, Бәрк - ләт елгасы буенда. 2010 елда 667 кеше (татар - лар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчы - лык, мөгезле эре терлек асрау, яшелчәчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1646 дан татар алпавытлары *Яушев - лар* биләмәсе буларак билгеле. Халкы иген - челек, терлекчелек, сумала кайнату, чыпта сугу, киез итек-киез җитештерү, күн эшкәр - тү, сәүдә б-н көн күрә. 20 йөз башында Т.К.тә 3 мәчет, 2 мәдрәсә (1790 нан мәгълүм), рус-татар земство мәктәбе (1910 да ачыла) эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 864,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губер - насының Алабуга өязе Мөшәк волостенда, 1921 дән ТАССРның — Әгерҗе, 1924 тән Алабуга кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1859 да — 1063, 1920 дә — 1594, 1926 да — 1387, 1938 дә — 1138, 1958 дә — 864, 1970 тә — 915, 1989 да — 769, 2002 дә — 663 кеше. Т.К.нең күренекле урыны — 20 йөз башы архит-ра истәлеге крәс - тиян Х.Саттаров йорты.

ТҮБӘ́Н КУМО́Р авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 8 *км* көньяк-көнбатыштарак, Оштырма ел - гасы буенда. 2010 елда 475 кеше (удмурт - лар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 1719 дан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче ярты сында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, тер - лекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.К.да вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1039,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасы - ның Мамадыш өязе Иске Юмья волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйн - варыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 69 ир-ат; 1859 да — 291, 1897 дә — 449, 1908 дә — 485, 1920 дә — 535, 1926 да — 578, 1938 дә — 477, 1949 да — 406, 1958 дә — 446, 1970 тә — 500, 1979 да — 560, 1989 да — 470, 2002 дә — 508 кеше.

ТҮБӘ́Н КУРСА́ авылы, Арча р-нында, Ар - ча шәһәреннән 10 *км* көнчыгыштарак, Кесмәс елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 226 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шө - гыле — терлекчелек. 1602–03 тән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче ярты сында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенче - лек, терлек асрау, умартачылык б-н шөгыль - ләнә, читкә китеп эшли. 20 йөз башында Т.К.да мәчет һәм вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире (Югары Курса авылын да кертеп) 4398 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кармыш волостенда, 1920 дән ТАССР - ның Арча кантонында. 1930 ның 10 авгус - тыннан — Арча, 1944 нең 19 февраленнән — Чүриле, 1956 ның 14 маеннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 164 ир-ат; 1859 да — 363, 1897 дә — 394, 1908 дә — 458, 1920 дә — 552, 1926 да — 495, 1938 дә — 528, 1949 да — 268, 1958 дә — 304, 1970 тә — 357, 1979 да — 317, 1989 да — 234, 2002 дә — 218 кеше.

ТҮБӘ́Н КҮЗМИ́С авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 24 *км* көнбатыштарак, Бөре елгасы (Вятка бассейны) буенда. 2010 елда 129 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — тер - лекчелек. 1930 елларга кадәр Т.К. Югары Күзмис авылы б-н бергә Казан ханлыгы чо - рыннан билгеле булган Күзмис авылын тәш - кил итә. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Кузмель исеме б-н дә билгеле. 18 йөз - дә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, тер - лек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Из - ге Гурий борадәрлеге мәктәбе (1908 дә ачыла), су тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1269,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губер - насының Мамадыш өязе Ядегәр волостенда, 1920 дән ТАССРның — Мамадыш, 1922 дән — Арча, 1928 дән Мамадыш кантонында. 1930 - ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнва - рыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 155 ир-ат; 1859 да — 262, 1897 дә — 431, 1908 дә — 424, 1920 дә — 568, 1926 да — 544, 1938 дә — 243, 1949 да — 199, 1958 дә — 166, 1970 тә — 189, 1979 да — 177, 1989 да — 159, 2002 дә — 160 кеше.

ТҮБӘ́Н КҮКЛЕ́К авылы, Алабуга р-нында, Алабуга шәһәреннән 40 *км* төньяк-көн - батыштарак, Күклек елгасы (Вятка бассейны) буенда. 2010 елда 10 кеше (руслар, татарлар) яши. 18 йөзнең 2 нче чиректә Иске Күклек авылы кешеләре нигез сала. Рев-циягә ка - дәрге чыганакларда Яңа Күклек исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, тер - лекчелек б-н шөгыльләнә, көнлекле эштә эш - ли. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Ала - буга өязе Чиркәс волостенда, 1920 дән ТАССРның — Мамадыш, 1921 дән — Алабу - га, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга, 1944 нең 19 фев - раленнән — Костенеево, 1944 нең 8 июнен - нән — Морт, 1954 нең 19 ноябреннән Алабу - га р-нында. Халык саны: 1859 да — 140, 1887 дә — 218, 1905 тә — 283, 1920 дә — 370, 1926 да — 401, 1938 дә — 336, 1949 да — 212, 1958 дә — 129, 1970 тә — 86, 1979 да — 41, 1989 да — 11, 2002 дә — 17 кеше.

ТҮБӘ́Н КҮЛ, к. Нижнее Озеро.

ТҮБӘ́Н ЛӘШӘ́Ү авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 21 *км* көньяктарак, Сал - кынсу елгасы буенда. 2010 елда 118 кеше (та - тарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кыр - чылык, иткә терлек, сарык асрау. Башлан - гыч мәктәп, мәдәният йорты. 1710–11 елларданмәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәү - ләт крәстияннәре катлавына керә, игенче -

лек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.Л.дә мәчет, мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 733,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Иске Кәшер волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Сарман р-нында. Халык саны: 1870 тә — 335, 1913 тә — 674, 1920 дә — 722, 1926 да — 522, 1938 дә — 565, 1949 да — 447, 1958 дә — 417, 1970 тә — 380, 1979 да — 272, 1989 да — 171, 2002 дә — 148 кеше.

ТҮБӘН ЛОЖЫ́ авылы, Зәй р-нында, Зәй шәһәреннән 28 *км* төньяктарак, Ложы елгасы буенда. 2010 елда 182 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб. 1680 нән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә; игенчелек, терлекчелек, умартачылык, олаучылык б-н, чана, агач савыт-саба, тәгәрмәч, мичкә ясау б-н шөгыльләнә, алпавыт утарында көнлекле эштә эшли. 1773–75 елларда гы *Крәстияннәр кузгалышында* Е.И.Пугачёв ягында сугышалар. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, Т.Л.да мәчет, мәдрәсә, су тегермәне була. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 969 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Тәкмәк волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1859 да — 381, 1870 тә — 414, 1897 дә — 690, 1913 тә — 953, 1920 дә — 827, 1926 да — 534, 1938 дә — 495, 1949 да — 476, 1958 дә — 464, 1970 тә — 372, 1979 да — 309, 1989 да — 188, 2002 дә — 185 кеше.

Әд.: Заинская энциклопедия. К., 1994.

ТҮБӘН МАКТАМА́, шәһәр тибындагы посёлогы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 10 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Казан–Оренбург автомобиль юлы буенда. 2010 елда 9924 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 69,1%, руслар — 21,2%, мордвалар — 7,1%) яши. Миңлебай газ эшкәртү, кирпеч з-длары. 2 урта һәм сәнгать мәктәбе, клуб, төбәк тарихы музее. Мәчет. 1746 га кадәр нигез салына. Беренче исеме — Мактаматамак. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкының бер өлеше — *типтәрләр*, икенче өлеше дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, чабата үрү, олаучылык, тарантас ясау б-н шөгыльләнә; авыл Бөгелмә өязендә иләк ясау үзәге булып тора. 1889 елгы мәгълүматларга караганда, Т.М.да мәчет, мәктәп, су тегермәне, май язу з-ды була. 20 йөз башында 2 мәчет, 2 мәдрәсә, 1 мануфактура һәм 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2628 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Т.М. Самара губернасының Бөгелмә өязе Әлмәт волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Әлмәт р-нында. 1966 ның 24 мартында шәһәр тибындагы посёлок статусы ала. 1984 нең 12 октябреннән Әлмәт шәһәр советы адм. буйсынуында. 2005 нең 26 гыйнварыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1746 да — 49, 1762 дә — 52 ир-ат; 1795 тә — 305, 1859 да — 817, 1889 да — 1548, 1910 да — 1735, 1920 дә — 1418, 1926 да — 1232, 1938 дә — 1163, 1949 да — 1147, 1958 дә — 1411, 1970 тә — 1111, 1979 да — 988, 1989 да — 7400, 2002 дә — 10580 кеше.

ТҮБӘН МӘРҖӘН КАБЕРЛЕГЕ́ (археол.), Алексеев р-нының элеккеге Түбән Мәржән авылы урынында урнашкан. 1964 елның көзендә Е.П.Казаков җитәкчелегендәге археол. отряд тарафыннан тикшерелә. Т.М.к. терр-ясендә Куйбышев сусаклагычы сулары кимү вакытында каберлек калдыклары, ш.и. кеше сөякләре, әвәләп эшләнгән чүлмәкләр, каберләр һ.б. табыла. Су тарафыннан юылган курган өеме астындагы, *Буралы курган культурасына* нисбәтле 33 кабер тикшерелә. Каберләрдә мәетләр янга яткырып бөгәрләнгән хәлдә, әйберләр — тараксыман һәм кисеп ясалган бизәкле балчык савытлар һ.б. б-н урнаштырылган.

Әд.: Археологические памятники Центрального Закамья. К., 1990. *Е.П.Казаков.*

ТҮБӘН МӘТӘСКӘ́ авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 6 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Казан–Пермь автомобиль юлы буенда. 2010 елда 454 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, иткә терлек асрау. Катнаш азык з-ды. Урта мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. Казан ханлыгы чорында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кече Мәтәскә исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, атлы почта станциясе, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 829,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кармыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 99 ир-ат; 1859 да — 339, 1897 дә — 397, 1908 дә — 517, 1920 дә — 461, 1926 да — 503, 1938 дә — 539, 1949 да — 490, 1958 дә — 522, 1970 тә — 442, 1979 да — 409, 1989 да — 419, 2002 дә — 428 кеше.

ТҮБӘН НАРАТБА́Ш авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 4 *км* төньяк-көнчыгыштарак урнашкан. 2010 елда 711 кеше (татарлар) яши. Халкы кырчылык, мөгезле эре терлек асрау б-н шөгыльләнә. Сыер ите җитештерү махсус ху җалыгы. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 17 йөздә нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы удел (1797 гә кадәр — сарай) һәм дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә; 19 йөз урталарына кадәр лашманчы хезмәтен үтиләр. 20 йөз башында Т.Н.та 2 мәчет, 2 мәдрәсә эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1258,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Иске Суыксу волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Буа р-нында. Халык саны: 1795 тә — 1015, 1859 да — 753, 1880 дә — 1054, 1897 дә — 1261, 1913 тә — 1699, 1920 дә — 1303, 1926 да — 1268, 1938 дә — 1118, 1949 да — 1038, 1958 дә — 865, 1970 тә — 1207, 1979 да — 870, 1989 да — 760, 2002 дә — 684 кеше.

Әд.: Буа ягым — тау ягым = Буинские просторы. К., 2000.

ТҮБӘ́Н НО́ВГОРОД ӨЛКӘСЕ́, РФдә Идел елгасы бассейнында урнашкан. Мәйданы — 76,9 мең *км*². 1929 елда оештырыла. Үзәге — Түбән Новгород шәһәре. Халкы — 3234676 (1.1.2018), татарлар — 44103 (2010) кеше. Татарлар Т.Н.ө. терр-ясен 13–15 йөзләрдә үзләштерә башлый. Шул ук вакытта Сараклыч (хәзер Саров) шәһәренә, Арзамас шәһәре янындагы татар авылларына нигез салына. 15–16 йөзләрдә өлкәнең көньяк-көнчыгыш өлешендә (Пьяна һәм Сура елгалары буе) татарлар саны Мещерадан, Кадом, Кормыш, Ядриннан һ.б. җирләрдән күченгән йомышлы татарлар исәбенә арта. Алар, таралып, рус, мордва, мари авылларына урнаша. 1612 дә Алатырь өязендә 13 йомышлы татар авылы, ш.у. Арзамас һәм Кормыш өязләренда татар авыллары була. 1780 дә Кормыш өязе, татар торак пунктлары б-н бергә, Түбән Новгород наместниклыгыннан Сембер наместниклыгына (1796 дан — губерна) күчерелә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, Кормыш өязендә — 20492, 1871 дә Түбән Новгород губернасында 35339 татар исәпләнә; 1897 елгы халык санын алу нәтиҗәләренә караганда, аларның саны 68435 кешегә җитә. 1844 тә Түбән Новгород губернасында Дәүләт милке министрлыгына караган 16 татар мәктәбе эшли, 1897 гә аларның саны 26 га җитә. 1915 тә Түбән Новгород губернасында һәм Сембер губернасының Кормыш өязендә 160 лап мәчет (ш.и. Түбән Новгородтагы Җамигъ һәм Ярминкә мәчетләре) исәпләнә, һәр мәчет каршында мөселман уку йорты (иң атаклылардан — 19 йөз башында Куйсуы (Овечий Овраг) авылында төзелгән мәдрәсә, хәзер Кызыл Октябрь р-нына керә) эшли. 1922 дә Кормыш өязе Түбән Новгород губернасына кергәч, татарлар 161,3 мең кеше (1926) исәпләнә. Совет чорында Т.Н.ө.ндә татар телендә «Октябрь коммунасы» (1931–63), «Сталин байрагы» (1945–55), «Коммунизм байра -



Түбән Новогород җамигъ мәчете. Архитекторы П.А. Домбровский. 1915. 1991 елгы реконструкция.

гы» (1955–57) г-талары нәшер ителә. 1937 елгы мәгълүматларга караганда, өлкәдә 35 татар мәктәбе була. 1921 дә Сафажай (Красная Горка) авылында татар пед. техникумы ачыла, 1923 тә ул Түбән Новгородка күчерелә; 1932 дән 1960 еллар башына кадәр хәзерге Сергач р-нының Кучкай Пожары авылында пед. уч-ще буларак эшли.

Хәзерге вакытта татарлар Түбән Новгород, Дзержинск, Балахна, Кстово, Бор шәһәрләрендә; Кызыл Октябрь (17 торак пунктта), Сергач (7), Спас (4), Пилнә (4), Княгинино (1), Первомайск (1), Сеченово (1 торак пунктта) р-ннарында яшиләр. Татар мәдәни үзәге (1989 дан), «Туган як» татар мәдәни оешмасы (1993), «Мишари-нижгары» («Мишәрләр-нижгарлар») иҗтимагый-сәяси хәрәкәте (1993), «Якташлар» татар мәдәни үзәге (1998), «Россия халыклары ассамблеясы» Түбән Новгород бүлекчәсе (2000), «Туган як» фольклор ансамбле (1991) эшли. Музыкаль «Туган як таңнары» (1993 тән), «Яшь талантлар» иҗат яшьләре (1993), татар мәдәнияте (1991) фестивальләре уздырыла; Сабан туе (1990) һәм Нәүрүз (1992) бәйрәм ителә. 2005 һәм 2015 тә Түбән Новгородта федераль Сабан туе булып уза. Түбән Новгород (1990) һәм Дзержинск (1991) шәһәрләрендә татар якшәмбе мәктәпләре эшли. 1994 тән татар теле һәм әдәбияты буенча ел саен олимпиадалар үткәрелә. Т.Н.ө. мөселманнары Диния нәзарәтенә берләшкән 50 ләп мәчет исәпләнә. Сеченово р-нының Кызыл Атау (Красный Остров) авылында К.Нәҗми исем. музей (1976 дан), Кызыл Октябрь р-нының Чүмбәли (1996) һәм Зур Рбишча (1998), Спас р-ның Бозлау (1999) авылларында төбәк тарихы музейлары, Пилнә р-нының Сафажай авылында Х.Фәезханов исем. музей эшләп килә. Сергач шәһәрендә «Туган як» (1990 нан) һәм Кызыл Октябрь р-нының Уразовка авылында «Авыл хәбәрләре» (1998) татар г-талары нәшер ителә. 2004 тән Түбән Новгородта рус телендә «Медина аль-Ислам» г-тасы, «Минарет» ж-лы, «Ислам в современном мире» һәм «Ислам на Нижегородчине» альманахлары чыга. Т.Н.ө. терр-ясендә Татарстан «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе тапшырулары кабул ителә. Мәгърифәтче галим, дини реформатор Х.*Фәезханов*, филолог, публицист Г.*Фәезханов*, җырчылар Р.В.*Ваһапов* һәм Х.А.*Бигичев*, язучы К.*Нәҗми*, дин эшлеклесе Г.*Сөләйманов*, шахматчы Р.Г.*Нәҗметдинов*, нәкышьче Л.Г.*Фәттахов*, баянчы Р.С.*Курамшин*, Сов. Союзы Геройлары Г.Г.*Аббасов* һәм С.Ф.*Әбелханов*, классик көрәш буенча Олимпия чемпионы Ш.С.*Сафин*, химия фән. д-ры Н.Х.*Әһлиуллов*, тарих фән. д-ры У.Б.*Билаловның* тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге Т.Н.ө. б-н бәйле.

Әд.: Баязитов Р.Ж., Макарихин В.П. Нижегородские татары-мишари в новое время. Н.Новгород, 1996; Хафизов М.З. Нижегородские татары. Н.Новгород, 1998; Орлов А.М. Нижегородские татары. Этнические корни и исторические судьбы: Очерки. Н.Новгород, 2001; Сенюткин С.Б. История татар Нижегородского Поволжья с последней трети XVI до начала XX вв.: Историческая судьба мишарей Нижегородского края. Н.Новгород, 2001; Казань и Нижний Новгород: История людей и судеб (к 1000-летию г.Казани). Н.Новгород, 2005.

ТҮБӘН НӨВГОРОД ҖАМИ́ГЪ МӘЧЕТЕ́, архит-ра истәлеге. 1913–15 елларда арх. П.А.Домбровский проекты буенча Печән мәйданы янәшәсендәге элеккеге Солдат бистәсе р-нында, Идел елгасының биек уң ярында төзелгән. Планда турыпочмаклы, тәбәнәк барабанга киле рәвешендәге гөмбәз утыртылган, дүрт кыек түбәле, зур кирпеч бина. Бинаның буй үзәге буенча, көньяк фасадта пландагы куыш астындагы ярымтүгәрәк михраб чыгып тора, төньяк фасадка өч яруслы, сигез кырлы биек манара тоташкан. Мәчет ишеге көнбатыш якта, манараның түбән ярусында авыш түбәсе фигуралы терәкләр б-н диварга беркетелгән. Манараның мәзәнәсе — чүкелгән челтәр б-н әйләндереп алынган. Аның өстен нәфис чатыр б-н төгәлләнгән киң нигезле җәенке кәрниз каплап тора. Залның ике рәт тәрәзәле күләме биек, берәрле һәм кечерәк-кечерәк а́ркалы тәрәзәләр б-н яктыртылган. Фасадларның тәрәзә аралыклары һәм поч-маклар киң пилястрлар б-н беркетелгән. Мәчет бизәлешендә эклектика һәм романтик юнәлештәге модерн сыйфатлары аралашып килгән.

Әд.: Мухетдинов Д.В. Азан над Волгой: К 90-летию основания Нижегородской соборной мечети. Н.Новгород, 2005.

Х.Г.Надыйрова.

ТҮБӘН НУРЛА́Т авылы, Нурлат шәһәре составында; Нурлат шәһәреннән 4 *км* көньяктарак, Кондырча елгасы буенда. 1989 елда 833 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 18 йөз уртасында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.Н.та 2 мәчет эшли. 1928 гә кадәр Самара губернасының Мәләкәс өязе Шлама волостенда, 1928 нең 23 гыйнварыннан ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Октябрь (1997 нең 10 декабреннән — Нурлат) р-нында, 2001 нең 27 июненнән Нурлат шәһәре карамагында. Халык саны: 1926 да — 1685, 1938 дә — 1462, 1949 да — 969, 1958 дә — 1079, 1970 тә — 1286, 1979 да — 1134 кеше.

ТҮБӘН ОРЫ́ авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 46 *км* төньяк-көнбатыштарак, Оры елгасы буенда. 2010 елда 291 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты. Казан ханлыгы чорында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Йомышлы Оры исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 мәчет, су тегермәне, тимерчелек, 4 олаучылар йорты, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2236,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Царёвококшайск (1919 дан — Краснококшайск) өязе Шиңшә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Юл, 1956 ның 18 июленнән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 267 ир-ат; 1859 да — 924, 1897 дә — 915, 1908 дә — 723, 1949 да — 411, 1958 дә — 430, 1970 тә — 391, 1979 да — 317, 1989 да — 319, 2002 дә — 276 кеше. Т.О.да 16–19 йөзләр эпиграфик истәлекләре сакланган.

ТҮБӘН ОСЛА́Н авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 12 *км* көньяктарак, Куйбышев сусаклагычы ярында урнашкан. 2010 елда 485 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау, бакчачылык. Консерв з-ды, минераль суны шешәләргә тутыру цехы, урман хуҗалыгы. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1637 дә Югары Ослан кешеләре нигез сала. Башта җирле халык Троица-Сергий монастырена карый, 1764 тә — экономик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә; бакчачылык, яшелчәчелек, балык тоту б-н шөгыльләнәләр, Казаннан килеп ял итүчеләрне фатирга кертәләр һәм азык-төлек б-н тәэмин итәләр. Күп кенә крәстияннәр өчен табыш чыганагы Идел судночылыгы була (капитан, лоцман, штурвалчы, машинист, водолаз, матрос һ.б. булып эшлиләр). 20 йөз башында Т.О.да Сергий Радонежский чиркәве (1768 дә төзелгән агач чиркәү урынына 1890 да таштан салына; архит-ра истәлеге), Белокриница иерархиясе иске дин тарафдарларының Никольский чиркәве (1907–08 дә төзелә; архит-ра истәлеге); земство (1865 тә ачыла) һәм чиркәү-приход (1887 дә ачыла) мәктәпләре, фельдшерлык пункты, 3 җил һәм 2 су тегермәне, 2 тимерче алачыгы, 3 икмәк пешерү йорты, 2 ашханә, 3 сыраханә, 1 казна шәраб һәм 11 вак төякләр кибете; пароходлар пристане (навигация туктаган чорда монда Идел судноларының кышлый) була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2261 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Югары Ослан волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Зөя, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 неңнән Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1782 дә — 398 ир-ат; 1859 да — 1335, 1897 дә — 1572, 1908 дә — 1753, 1920 дә — 1852, 1926 да — 2106, 1938 дә — 2622, 1949 да — 2460, 1958 дә — 2522, 1970 тә — 1915, 1979 да — 1502, 1989 да — 1012, 2002 дә — 619 кеше. Т.О.ның истәлекле урыннары — сәүдәгәр И.К.Савин йорты, земство уч-щесе бинасы (19 йөз ахыры — 20 йөз башы архит-ра истәлеге).

Әд.: Верхний Услон: край родной, навек любимый. К., 2001.

ТҮБӘН ОЧА́ авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 50 *км* төньяк-көнбатыштарак, Оча елгасы буенда. 2010 елда 223 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, умартачылык. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 1710–11 дән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.О.да Казан Богородица чиркәве, Изге Гу-

рий борадәрлеге мәктәбе (1876 да ачыла), су тегермәне, вак-тәякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 699,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Петропавел волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән Мамадыш р-нында. Халык саныы: 1782 дә — 36 ир-ат; 1859 да — 206, 1897 дә — 388, 1908 дә — 474, 1920 дә — 460, 1926 да — 511, 1949 да — 287, 1958 дә — 304, 1970 тә — 376, 1979 да — 335, 1989 да — 246, 2002 дә — 257 кеше.

ТҮБӘ́Н ӨСКЕБА́Ш авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 27 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Өске елгасы буенда. 2010 елда 424 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1680 нән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.Ө.та мәчет, тегермән, 2 вак-тәякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1400,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Лыябаш Келәүш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Кукмара, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән — Мамадыш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 65 ир-ат; 1859 да — 461, 1897 дә — 1015, 1908 дә — 1082, 1920 дә — 1200, 1926 да — 1206, 1949 да — 605, 1958 дә — 575, 1970 тә — 571, 1979 да — 548, 1989 да — 489, 2002 дә — 474 кеше.

ТҮБӘ́Н ПӘНӘЧЕ́ авылы, Зәй р-нында, Зәй шәһәреннән 26 *км* төньяктарак, Чаллы — Зәй автомобиль юлы буенда. 2010 елда 50 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1710–11 дән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, вак һөнәрчелек б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, Т.П.дә — мәчет, мәдрәсә, 20 йөз башында су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 372 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әхмәт волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1859 да — 111, 1870 тә — 126, 1913 тә — 256, 1920 дә — 277, 1926 да — 198, 1949 да — 117, 1958 дә — 175, 1970 тә — 179, 1979 да — 117, 1989 да — 81, 2002 дә — 56 кеше.

Әд.: Заинская энциклопедия. К., 1994.

ТҮБӘ́Н ПОШАЛЫ́М авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 17 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Пошалым елгасы буенда. 2010 елда 260 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. 1615–17 дән Шалым авылы буларак билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, балта эше б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, су тегермәне, 3 вак-тәякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 982,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кармыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 60 ир-ат; 1859 да — 288, 1897 дә — 388, 1908 дә — 461, 1920 дә — 500, 1926 да — 468, 1938 дә — 471, 1949 да — 400, 1958 дә — 412, 1970 тә — 401, 1979 да — 295, 1989 да — 271, 2002 дә — 281 кеше.

Әд.: История Арского края — Арча төбәге тарихы. К., 1996.

ТҮБӘ́Н САЛМА́Н авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 15 *км* төньяк-көнбатыштарак, Салман елгасы буенда. 2010 елда 37 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Клуб. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.С.да мәчет, 2 ярма яргыч, мануфактура һәм бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1187 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Базарлы Матак волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 59 ир-ат; 1859 да — 393, 1908 дә — 693, 1920 дә — 672, 1926 да — 257, 1938 дә — 229, 1949 да — 192, 1958 дә — 198, 1970 тә — 171, 1979 да — 104, 1989 да — 54, 2002 дә — 47 кеше.

ТҮБӘ́Н САСНА́ авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 5 *км* төньяктарак, Шушма елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 1050 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. «Мазһар мулла мәчете». 1619 дан Красная Сосна буларак билгеле. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Көчек Саснасы исеме б-н дә мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, сәүдә б-н шөгыльләнә. 1768 елгы мәгълүматларга караганда, 2 тегермән эшли, 1830 да агач мәчет төзелә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 1847 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Арбор волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартынан — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1766 да — 180, 1811 дә — 334 ир-ат; 1834 тә — 821, 1859 да — 1041, 1884 тә — 1179, 1905 тә — 1125, 1920 дә — 1261, 1926 да — 1007, 1938 дә — 1868, 1949 да — 1034, 1958 дә — 971, 1970 тә — 1001, 1979 да — 920, 1989 да — 904, 2002 дә — 1023 кеше.

ТҮБӘ́Н САУРЫ́Ш авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 25 *км* төньяк-көнбатыштарак, Саурыш елгасы буенда. 2010 елда 221 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб. 1710–11 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Мехедерово буларак та билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 613 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Яңа Әдәм волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 92 ир-ат; 1859 да — 702, 1897 дә — 920, 1908 дә — 1103, 1920 дә — 363, 1926 да — 316, 1938 дә — 372, 1949 да — 327, 1958 дә — 257, 1970 тә — 327, 1979 да — 277, 1989 да — 215, 2002 дә — 229 кеше.

ТҮБӘ́Н САУРЫ́Ш авылы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 23 *км* көнчыгыштарак, Мишә елгасы буенда. 2010 елда 183 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек, сарык асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 1680 нән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Башка Саурыш исеме б-н дә телгә алына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет (1893 тә төзелә), су тегермәне, тимерчелек, 3 вак-тәякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 302,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Елыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1782 дә — 49 ир-ат; 1859 да — 374, 1897 дә — 661, 1908 дә — 736, 1920 дә — 705, 1926 да — 655, 1938 дә — 620, 1949 да — 506, 1970 тә — 388, 1979 да — 282, 1989 да — 234, 2002 дә — 208 кеше.

ТҮБӘ́Н СИМЕ́Т авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 16 *км* көнбатыштарак, Кече Мишә елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 187 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 1616 дан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау, өс-баш киемнәре тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.С.тә мәчет, мәктәп, су тегермәне, 3 вак-тәякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1394,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Яңа Чүриле волостенда, 1920 дән ТАССРның — Мамадыш, 1921–22 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1944 нең 19 февраленнән — Чүриле, 1956 ның 14 маеннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 79 ир-ат; 1859 да — 487, 1897 дә — 781, 1908 дә — 846, 1920 дә — 908, 1926 да — 752, 1938 дә — 667, 1949 да — 537, 1970 тә — 412, 1979 да — 292, 1989 да — 243, 2002 дә — 202 кеше.

ТҮБӘ́Н СОКО́ЛКА авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 38 *км* көньяк-көнбатыштарак, Зәй елгасы (Дала Зәенең уң кушылдыгы) буенда. 2010 елда 7 кеше (руслар) яши. 1920 еллар башында нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Бөгелмә кантоны Бөгелмә волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1926 да — 107, 1938 дә — 216, 1958 дә — 128, 1970 тә — 99, 1979 да — 48, 1989 да — 12, 2002 дә — 6 кеше.

ТҮБӘ́Н СОН авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 45 *км* көнбатыштарак, Казан–Уфа автомобиль юлы буенда. 2010 елда 494 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1680 нән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.С.да 2 мәчет, су тегермәне, тимерче алачыгы, 7 вак-төяклəр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2007,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Түбән Сон волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 122 ир-ат; 1859 да — 1049, 1897 дә — 1440, 1908 дә — 1755, 1920 дә — 1665, 1926 да — 1553, 1938 дә — 1246, 1949 да — 970, 1958 дә — 1074, 1970 тә — 765, 1979 да — 725, 1989 да — 633, 2002 дә — 560 кеше.

ТҮБӘ́Н СУБА́Ш авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 24 *км* төньяктарак, Көшкәт елгасы (Шушманың сул кушылдыгы) буенда. 2010 елда 151 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 18 йөздә нигез салына. Рәсми чыганакларда 1920 еллар уртасына кадәр Югары Субаш авылы б-н бергә Субаш авылын тәшкил итә. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1880 елларда авыл җәмәгатенең имана җире 588,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Арбор волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1938 нең 4 августыннан — Чепья, 1958 нең 16 июленнән — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1905 тә — 295, 1920 дә — 653, 1926 да — 303, 1938 дә — 342, 1949 да — 198, 1958 дә — 195, 1970 тә — 169, 1979 да — 159, 1989 да — 141, 2002 дә — 153 кеше.

ТҮБӘ́Н СУКАЕ́Ш авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 17 *км* төньяктарак, Сукаеш елгасы буенда. 2010 елда 88 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1742 дән мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлавына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.С.та мәчет, мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1000 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Эстәрлетамак волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 20 октябреннән — Азнакай, 1935 нең 10 февраленнән — Тымытык, 1958 нең 16 июленнән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1859 да — 299, 1889 да — 425, 1910 да — 518, 1920 дә — 444, 1926 да — 260, 1938 дә — 350, 1949 да — 234, 1958 дә — 217, 1970 тә — 196, 1979 да — 136, 1989 да — 73, 2002 дә — 106 кеше.

ТҮБӘ́Н СУ́ШКА авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 25 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кече Чирмешән елгасыннан 2 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 23 кеше (руслар, чуашлар) яши. Урман хуҗалыгы. 1930 елларда нигез салына. Беренче исеме — Түбән Сушка. оешкан көненнән — Кузнечиха, 1944 нең 19 февраленнән — Юхмачы, 1956 ның 7 декабреннән — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1949 да — 94, 1958 дә — 96, 1970 тә — 100, 1979 да — 74, 1989 да — 52, 2002 дә — 39 кеше.

ТҮБӘ́Н СУЫКСУ́ авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 12 *км* көньяктарак, Мәләкәс елгасы бассейнында (Каманың сул кушылдыгы) урнашкан. 2010 елда 1069 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Катнаш азык з-ды. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1782 дән мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, Т.С.да мәчет, мәктәп, җил тегермәне эшли. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 1131 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Бәтке волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Чаллы (1976 ның 20 апреленнән — Тукай) р-нында. Халык саны: 1870 тә — 438, 1897 дә — 775, 1920 дә — 1194, 1926 да — 870, 1938 дә — 845, 1949 да — 629, 1958 дә — 521, 1970 тә — 539, 1979 да — 709, 1989 да — 939, 2002 дә — 1001 кеше.

ТҮБӘ́Н ТАБЫ́Н авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 16 *км* төньяк-көнбатыштарак, Табын елгасы буенда. 2010 елда 211 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1735 тән Олы Табын буларак билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлавына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 мәчет, мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1219,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Иректе волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1870 тә — 340, 1897 дә — 632, 1913 тә — 879, 1920 дә — 814, 1926 да — 550, 1938 дә — 594, 1949 да — 671, 1958 дә — 344, 1970 тә — 316, 1979 да — 262, 1989 да — 244, 2002 дә — 224 кеше.

ТҮБӘ́Н ТАРХА́Н авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 36 *км* көньяк-көнбатыштарак, Тархан елгасы буенда. 2010 елда 195 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 17 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кече Тархан исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт һәм удел (1797 гә кадәр — сарай) крәстияннәре катлавына керә, лашманлык йөкләмәсен үти; игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 мәчет, мәдрәсә эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1295,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Сембер өязе Олы Тархан волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәтеш, 1938 нең 4 августыннан — Олы Тархан, 1959 ның 12 октябреннән Тәтеш р-нында. Халык саны: 1859 да — 793, 1897 дә — 951, 1913 тә — 1200, 1920 дә — 1215, 1926 да — 1105, 1938 дә — 847, 1949 да — 613, 1958 дә — 615, 1970 тә — 569, 1979 да — 441, 1989 да — 313, 2002 дә — 241 кеше.

ТҮБӘ́Н ТАТА́Р МАЙНАСЫ́ авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 36 *км* төньяк-көнбатыштарак, Кече Чирмешән елгасы буенда. 2010 елда 286 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты. Мәчет. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Татар Чирмешәне исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәдрәсә, су тегермәне, 4 вак-төяклəр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1974 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Биләр волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан — Алексеев, 1977 нең 29 августыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 84 ир-ат; 1859 да — 384, 1897 дә — 699, 1908 дә — 900, 1920 дә — 956, 1926 да — 547, 1938 дә — 627, 1949 да — 416, 1958 дә — 552, 1970 тә — 574, 1979 да — 433, 1989 да — 283, 2002 дә — 287 кеше.

ТҮБӘ́Н ТӘКӘНЕ́Ш авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 44 *км* төньяк-көнбатыштарак, Оча елгасы буенда. 2010 елда 936 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. «Тәкәнеш авыл хуҗалыгы техникасы» агрофирмасы, яшелчә киптерү з-ды. Урта мәктәп, мәдәният йорты. Авыл тарихы музее. Мәчет. 1680 нән Иске Ошлан Пүчинкә-

се буларак билгеле. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Түбән Ошлан исеме б-н дә мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстиянҗәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 мәчет, су тегермәне, тимерче алачыгы, 3 ярма яргыч, 9 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1479,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Петропавел волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән Мамадыш р-нында. Халык саны: 1859 да — 487, 1897 дә — 1161, 1908 дә — 1234, 1920 дә — 884, 1926 да — 814, 1949 да — 1054, 1958 дә — 1463, 1970 тә — 1186, 1979 да — 1300, 1989 да — 999, 2002 дә — 982 кеше.

ТҮБӨН ТӘКЕРМӘН, к. *Тауасты Тәкермән.*

ТҮБӨН ТӘҮДЕ́ районы, *Төмән өлкәсенең* көньягында урнашкан. Мәйданы — 7,4 мең *км*². 1923 елда оештырыла. Үзәге — Түбән Тәүде авылы (Төмәннән 80 *км* төньяктарак). Халкы — 22813 (1.1.2017), татарлар — 3151 (2010) кеше. Татарлар, башлыча, Киндерле (383 кеше), Кыскыркүл (215), Түбән Тәүде (500), Тарман (671), Казанлы (115), Канчәбер (244 кеше, 2002) авылларында яшиләр. Т.Т.р. терр-ясендә алар 20 йөз башында Столыпин аграр реформасына бәйле рәвештә барлыкка килә. 1917 дә 3 мәчет була. Хәзерге вакытта районда 6 мәчет: Кәнчәбер (2004 тән), Казанлы (1995), Эске (Юрт-Иска) (2003), Киндерле (1999), Тарман (2 мәчет; 1993 һәм 1995 тән) авылларында эшли. Районда даими Сабан туе уздырыла. 2006, 2008, 2012 дә өлкә Сабан туе үткәрелә. 2011 дә Канчәбер һәм Кыскыркүл, 2016 да Киндерле авылларында Татар мәдәнияте көннәре булып уза. 2011 дә «Татар халкының мәдәнияте һәм көнкүреше» күргәзмәсе оештырыла. 7 татар иҗат үзешчән коллективы: Киндерле авыл мәдәният йорты каршында «Бәйрәм» бию коллективы, «Радуга» һәм «Оттепель» вокаль ансамбльләре, «Киндерле кичләре» фольклор ансамбле, «Инеш» фольклор-этнография түгәрәге, Тарман авыл мәдәният йорты каршында «Саз» фольклор-этнография коллективы, Чугунаево авыл мәдәният йорты каршында «Күбәләк» бию коллективы эшли. 6 мәктәптә татар теле фән буларак өйрәнелә. Мед. фән. д-ры, проф. Ф.Х.Низамовның тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге Т.Т.р. б-н бәйле.

Әд.: Низамов З.Х., Низамов Ф.Х. Оде-ревне нашей. Тюмень, 2003.

ТҮБӨН ТЕГЕРМӘНЛЕ́К авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 21 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Сулы елгасы (Сушаның уң кушылдыгы) буенда. 2010 елда 495 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, клуб, китапханә. 1565–67 гә кадәр Югары Тегермәнлек авылы кешеләре нигез сала. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстиянҗәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.Т.тә мәчет, мәктәп, тегермән, 11 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1745 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Урачы волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Мамадыш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1859 да — 713, 1897 дә — 1672, 1908 дә — 1375, 1920 дә — 1311, 1926 да — 784, 1938 дә — 1377, 1949 да — 979, 1958 дә — 860, 1970 тә — 1168, 1989 да — 599, 2002 дә — 556 кеше.

ТҮБӨН ТИГӘНӘЛЕ́ авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 20 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Шонталы елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 216 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 18 йөз башына кадәр нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстиянҗәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.Т.дә 2 мәчет, 7 җил тегермәне, 2 ярма яргыч, 9 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2028 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Полянка волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чистай, 1935 нең 10 февраленнән — Алексеев, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1782 дә — 117 ир-ат; 1859 да — 1061, 1897 дә — 1035, 1908 дә — 1416, 1920 дә — 1584, 1926 да — 1158, 1938 дә — 1116, 1949 да — 806, 1958 дә — 719, 1970 тә — 614, 1979 да — 473, 1989 да — 320, 2002 дә — 259 кеше.

ТҮБӨН УРАТМА́ авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 40 *км* көньяктарак, Уратма елгасы буенда. 2010 елда 953 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Кирпеч з-ды. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет (1890 елларда төзелә, 1988–89 да реконструкцияләнә; архит-ра истәлеге). 1646 дан мәгълүм. Рев-циягә кадәргә чыганакларда Татар Уратмасы, Чуаш Уратмасы, Камышевский Враг исемнәре б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстиянҗәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, балта эше б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1843,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Сухарево волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1870 тә — 671, 1897 дә — 1372, 1913 тә — 1738, 1920 дә — 1742, 1926 да — 1366, 1949 да — 1264, 1958 дә — 1807, 1970 тә — 1837, 1979 да — 1593, 1989 да — 1072, 2002 дә — 930 кеше.

ТҮБӨН УРЫСБАГА́ авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 25 *км* көньяк-көнбатыштарак, Буа елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 108 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1646 дан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстиянҗәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.У.да мәчет (1862 дә төзелә), мәктәп, 8 җил тегермәне, тимерче алачыгы, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 805,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Косякау волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Норлат-Ачасыр, 1927 нең 1 августыннан — Норлат, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 195 ир-ат; 1859 да — 533, 1897 дә — 784, 1908 дә — 996, 1920 дә — 940, 1926 да — 825, 1938 дә — 798, 1949 да — 494, 1958 дә — 430, 1970 тә — 320, 1979 да — 302, 1989 да — 222, 2002 дә — 169 кеше.

ТҮБӨН УТА́Р авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 18 *км* төньяк-көнбатыштарак, Кече Мишә елгасы буенда. 2010 елда 218 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстиянҗәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, өс-баш киемнәре тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп, почта бүлекчәсе, атлы станция, 2 су тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 734,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Яңа Чүриле волостенда, 1920 дән ТАССРның — Мамадыш, 1921–22 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1944 нең 19 февраленнән — Чүриле, 1956 ның 14 маеннан Саба р-нында. Халык саны: 1859 да — 298, 1897 дә — 484, 1908 дә — 591, 1920 дә — 569, 1926 да — 572, 1938 дә — 532, 1949 да — 392, 1970 тә — 321, 1979 да — 259, 1989 да — 257, 2002 дә — 245 кеше.

ТҮБӨН УШМА́ авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 6 *км* көнбатыштарак, Шушма елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 316 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Кирпеч з-ды. Башлангыч мәктәп. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәргә рус чыганакларында Околоток 1-я Ушма исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстиянҗәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1867–72 дә Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе эшли. 20 йөз башында земство мәктәбе (1891 дә ачыла), 2 тимерче алачыгы, бакалея кибете була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2573 дис. (Югары һәм Урта Ушма авыллары б-н бергә) тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Балтач волостенда,

1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1920 дә — 376, 1926 да — 392, 1938 дә — 413, 1949 да — 343, 1958 дә — 343, 1970 тә — 369, 1979 да — 353, 1989 да — 291, 2002 дә — 355 кеше.

ТҮБӨ́Н УШМА́ авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 9 *км* көнбатыштарак, Ушма елгасы буенда. 2010 елда 1057 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1680 нән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, балта эше б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.У.да 4 мәчет, 4 мәктәп, 2 тимерче алачыгы, 4 тегермән, 10 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3814,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Красная Горка волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 305 ир-ат; 1859 да — 2073, 1897 дә — 2754, 1908 дә — 3185, 1920 дә — 2736, 1926 да — 3040, 1938 дә — 2238, 1958 дә — 1531, 1970 тә — 1777, 1979 да — 1559, 1989 да — 1244, 2002 дә — 1071 кеше. Т.У.ның күренекле уры ны — 2 нче җамигъ мәчет бинасы (20 йөз ба шы архит-расы истәлеге).

ТҮБӨ́Н УРӨ́С авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 22 *км* көньяктарак, Ушман елгасы буенда. 2010 елда 228 кеше (202 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 61%, удмуртлар — 37%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, клуб. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Үрәс буларак та билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тимерчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, 2 су тегермәне, 10 тимерче алачыгы, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 921,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Петропавел волостенда, 1920 дән ТАССР ның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Кукмара, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән — Мамадыш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 36 ир-ат; 1859 да — 242, 1897 дә — 493, 1908 дә — 566, 1920 дә — 891, 1926 да — 610, 1949 да — 412, 1958 дә — 528, 1970 тә — 368, 1979 да — 284, 1989 да — 225, 2002 дә — 255 кеше.

ТҮБӨ́Н УРЬЯДЫ́ авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 34 *км* көнбатыштарак, Бәҗәнә елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 21 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1706 дан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы асабалар һәм типтәрләр катлавына бүленә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, вак һөнәрчелек б-н шөгыльләнә. 1773–75 еллардагы Крәстияннәр кузгалышында Е.И.Пугачёв ягында сугышалар. 20 йөз башында Т.Ү.да мәчет эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 460,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Семиостров волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1870 тә — 153, 1913 тә — 259, 1920 дә — 226, 1926 да — 358, 1938 дә — 224, 1949 да — 198, 1958 дә — 110, 1970 тә — 203, 1979 да — 129, 1989 да — 50, 2002 дә — 27 кеше.

ТҮБӨ́Н ЧАЛЛЫ́ авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 15 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Самара өлкәсе б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 611 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөздә Чаллы Пүчинкәсеннән (к. *Чал лы*) күченүчеләр нигез сала. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Яңа Чаллы исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тире иләү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1490 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Чаллы волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Октябрь (1997 нең 10 декабреннән — Нурлат) р-нында. Халык саны: 1859 да — 531, 1897 дә — 725, 1908 дә — 783, 1920 дә — 784, 1926 да — 802, 1938 дә — 615, 1949 да — 408, 1958 дә — 496, 1970 тә — 931, 1979 да — 782, 1989 да — 587, 2002 дә — 643 кеше.

ТҮБӨ́Н ЧАЛЛЫ́ авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 37 *км* көньякта рак, Зәй елгасы буенда. 2010 елда 273 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. 1680 нән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, мич чыгару б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.Ч.да мәчет, мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1658,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Тәкмәк волостенда, 1920 дән ТАССР ның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Ширәмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1870 тә — 558, 1897 дә — 1078, 1913 тә — 1432, 1920 дә — 767, 1949 да — 694, 1958 дә — 677, 1970 тә — 876, 1979 да — 705, 1989 да — 379, 2002 дә — 286 кеше.

ТҮБӨ́Н ЧӘКЕ́ авылы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 24 *км* көньяк-көн батыштарак, Олы Яклы елгасының уң ку шылдыгы буенда. 2010 елда 230 кеше (та тарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кыр чылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1666 дан мәгълүм. 18 йөз дә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә (лашманчы хезмәтен үти), игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.Ч.дә мәчет, мәдрәсә, тегермән эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1453,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Городище волостенда, 1920 дән ТАССР ның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1859 да — 593, 1897 дә — 857, 1913 тә — 1122, 1920 дә — 1220, 1926 да — 1131, 1938 дә — 1075, 1949 да — 848, 1958 дә — 666, 1970 тә — 635, 1979 да — 539, 1989 да — 320, 2002 дә — 306 кеше.

ТҮБӨ́Н ЧУРА́ авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 29 *км* төньяк-көнбатыштарак, Бөре елгасы буенда. 2010 елда 239 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1683 тән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Сюра исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тире иләү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 390,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Ядегәр волостенда, 1920 дән ТАССРның — Мамадыш, 1921–22 дән — Ар ча, 1928 дән Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварын нан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 38 ир-ат; 1859 да — 127, 1897 дә — 224, 1908 дә — 253, 1920 дә — 275, 1926 да — 329, 1938 дә — 343, 1949 да — 310, 1958 дә — 278, 1970 тә — 320, 1979 да — 285, 1989 да — 227, 2002 дә — 247 кеше.

ТҮБӨ́Н ЧЫГТА́Й авылы, Чирмешән р-нында, Чирмешән авылыннан 4 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Олы Чирмешән елгасы буенда. 2010 елда 241 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1740 елларда нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Түбән Чишмә, Мансур исемнәре б-н дә билгеле. 1860 ларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәдрәсә эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1657 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Мордва Афонькәсе волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Беренче Май, 1963 нең 1 февраленнән — Лениногорск, 1965 нең 12 гыйнварын нан Чирмешән р-нында. Халык саны: 1859 да — 1087, 1889 да — 890, 1910 да — 1089, 1920 дә — 1128, 1926 да — 548, 1949 да — 768, 1958 дә — 627, 1970 тә — 642, 1979 да — 543, 1989 да — 365, 2002 дә — 285 кеше.

ТҮБӨ́Н ЧЫРШЫЛЫ́ авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 25 *км* көн батыштарак, Куак елгасы буенда. 2010 елда 697 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шө-

гыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, яшелчәчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1730 елларда нигез салына. 1860 елларда халкы асабалар, типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 19 йөзнең 2 нче яртысында авыл мәдрәсәсе киң таныла, аның укучылары һәм укытучылары арасында Р.*Фәхретдин* дә була. 20 йөз башында Т.Ч.да волость идарәсе урнаша, 2 мәчет, 2 мәктәп, 2 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2770 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Түбән Чыршылы волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Шөгер, 1959 ның 12 октябреннән Лениногорск р-нында. Халык саны: 1859 да — 974, 1889 да — 1562, 1910 да — 2078, 1920 дә — 2240, 1926 да — 2014, 1938 дә — 1647, 1949 да — 1576, 1958 дә — 1340, 1970 тә — 1323, 1979 да — 1216, 1989 да — 808, 2002 дә — 774 кеше.

Әд.: Шөгер төбәге — хәзинәләр чишмәсе = Шугур — край сокровищ. К., 1997.

ТҮБӨН ЧЫРШЫЛЫ́ авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 18 *км* төньяктарак, Игәнә елгасы буенда. 2010 елда 53 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. 1762 дән мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау, умартачылык б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, Т.Ч.да су тегермәне эшли. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 619,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Язикәү волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Сарман, 1935 нең 10 февраленнән — Ворошилов, 1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл, 1959 ның 12 октябреннән Сарман р-нында. Халык саны: 1870 тә — 288, 1897 һәм 1920 дә — 538 әр, 1926 да — 448, 1938 дә — 376, 1958 дә — 191, 1970 тә — 176, 1979 да — 107, 1989 да — 54, 2002 дә — 61 кеше.

ТҮБӨН ШАШЫ́ авылы, Әтнә р-нында, Олы Әтнә авылыннан 8 *км* төньяктарак, Шашы елгасы буенда урнашкан. 2010 елда 426 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 17 йөздә нигез салына. 1930 лар уртасына кадәр Әхмәтху җа исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 874 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Царёвококшайск (1919 дан — Краснококшайск) өязе Кышлау волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1938 нең 25 мартыннан — Әтнә, 1959 ның 12 октябреннән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1990 ның 25 октябреннән Әтнә р-нында. Халык саны: 1782 дә — 18 ир-ат; 1859 да — 488, 1897 дә — 806, 1908 дә — 756, 1920 дә — 771, 1926 да — 692, 1938 дә — 547, 1949 да — 442, 1958 дә — 396, 1970 тә — 474, 1979 да — 434, 1989 да — 433, 2002 дә — 412 кеше.

ТҮБӨ́Н ШӘМӘРДӘ́Н авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 31 *км* көнбатыштарак, Балтач-Кукмара автомобиль юлы буенда. 2010 елда 230 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1678 дән рус чыганакларында Шамарданова Пустошь буларак билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тире иләү, баш киеме тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 мәчет, мәдрәсә, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1121,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Ядегәр волостенда, 1920 дән ТАССРның — Мамадыш, 1921–22 дән — Арча, 1928 дән Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 107 ир-ат; 1859 да — 807, 1897 дә — 924, 1908 дә — 1045, 1920 дә — 893, 1926 да — 634, 1938 дә — 466, 1949 да — 330, 1958 дә — 287, 1970 тә — 245, 1979 да — 208, 1989 да — 197, 2002 дә — 213 кеше.

ТҮБӨ́Н ШУБА́Н авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 9 *км* көнбатыштарак, Шушма елгасы буенда. 2010 елда 134 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 1710–11 дән Түбән Ядегәр исеме б-н мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау, умартачылык, бау ишү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет (1896 да төзелә), 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 642,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Балтач волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1782 дә — 45 ир-ат; 1834 тә — 167, 1859 да — 217, 1897 дә — 418, 1908 дә — 448, 1920 дә — 440, 1926 да — 392, 1938 дә — 318, 1949 да — 198, 1958 дә — 138, 1970 тә — 134, 1979 да — 151, 1989 да — 117, 2002 дә — 135 кеше.

ТҮБӨ́Н ШҮЛӘҢГЕ́Р авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 38 *км* төньяктарак, Юкәче елгасы буенда. 2010 елда 187 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1680 нән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.Ш.дә мәчет, тегермән, ярма яргыч, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1056,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Җөри волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 86 ир-ат; 1859 да — 503, 1897 дә — 839, 1908 дә — 936, 1920 дә — 899, 1926 да — 819, 1949 да — 457, 1958 дә — 391, 1970 тә — 387, 1979 да — 271, 1989 да — 216, 2002 дә — 223 кеше.

ТҮБӨ́Н ШЫТСЎ́ авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 16 *км* көньяктарак, Мишә елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 350 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты. 1680 нән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.Ш.да мәчет, мәктәп, 2 су тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1683,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Елыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 95 ир-ат; 1859 да — 528, 1897 дә — 870, 1908 дә — 980, 1920 дә — 965, 1926 да — 928, 1938 дә — 717, 1949 да — 533, 1970 тә — 517, 1979 да — 417, 1989 да — 368, 2002 дә — 344 кеше.

ТҮБӨ́Н ЭСТӘРЛЕ́ авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 38 *км* көнчыгыштарак, Эстәрле елгасы буенда. 2010 елда 89 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Түбән Эстәрлетамак исеме б-н дә билгеле. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар, типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 мәчет, 2 мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2392 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Эстәрлетамак волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 20 октябреннән — Азнакай, 1935 нең 10 февраленнән — Тымытык, 1958 нең 16 июленнән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1889 да — 649, 1910 да — 907, 1920 дә — 926, 1926 да — 429, 1938 дә — 490, 1949 да — 367, 1958 дә — 284, 1970 тә — 279, 1979 да — 207, 1989 да — 126, 2002 дә — 112 кеше.

ТҮБӨ́Н ЮШАДЫ́ авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 23 *км* көньяктарак, Минзәлә елгасы буенда. 2010 елда 83 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1748 дән мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 1773–75 елгы Крәстияннәр кузгалышы чорында Т.Ю.да 150 кешедән торган баш күтәрүчеләр отряды урнаша. 20 йөз башында 2 ярма яргыч эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1135,8 дис. тәшкил

итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Минзәлә волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1944 нең 19 февраленнән — Матвеевка, 1954 нең 19 ноябреннән Минзәлә р-нында. Халык саны: 1795 тә — 103, 1859 да — 258, 1870 тә — 273, 1884 тә — 330, 1906 да — 397, 1913 тә — 461, 1920 дә — 457, 1926 да — 402, 1938 дә — 391, 1949 да — 313, 1958 дә — 296, 1970 тә — 269, 1979 да — 197, 1989 да — 126, 2002 дә — 80 кеше.

ТҮБӨН ЯКЕ́ авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 26 *км* көнбатыштарак, Казан–Уфа автомобиль юлы буенда. 2010 елда 463 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1680 нән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә; игенчелек, терлекчелек, агач әзерләү, курыс төше рү — мунчала ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз ба шында Т.Я.дә 2 мәчет, су тегермәне, кирпеч сугу йорты, 5 вак-төякләр кибете була; якшәмбе базары эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1153 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мама дыш өязе Кече Кирмән волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 65 ир-ат; 1859 да — 572, 1897 дә — 1002, 1908 дә — 1232, 1920 дә — 1185, 1926 да — 1061, 1938 дә — 716, 1949 да — 572, 1958 дә — 616, 1970 тә — 753, 1979 да — 732, 1989 да — 567, 2002 дә — 484 кеше.

ТҮБӨН ЯКЫ́Й авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 30 *км* көнбатыштарак, Мәллә елгасы буенда. 2010 елда 287 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Мәдәният йорты. 18 йөзнең 1 нче яртысына кадәр нигез салы на. 1860 елларга кадәр халкы типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.Я.да мәчет, мәктәп, 3 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1404 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Әлки волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августын нан — Тымытык, 1931 нең 20 октябреннән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1859 да — 510, 1889 да — 870, 1910 да — 960, 1920 дә — 1751, 1926 да — 942, 1938 дә — 716, 1949 да — 648, 1958 дә — 619, 1970 тә — 592, 1979 да — 421, 1989 да — 373, 2002 дә — 304 кеше.

ТҮБӨН ЯМА́Ш елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Бөгелмә Зәе елгасының (Дала Зәе елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 18,7 *км*, бассейнының мәйданы 108,6 *км*². Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгыннан, Азнакай р-нында ага. Елга башы Каменка авылыннан 4,5 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Әлмәт-Азнакай автомобиль юлы янында, та магы Түбән Соколка авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 300 *м*, тамагыныкы — 151 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 30%. Т.Я.ның 1,3 тән 6,1 *км* га кадәр озынлыктагы 6 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,39 *км/км*². Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 1–3 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 100 *мм*, ташу агымы катламы 70 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь уртасында ту ңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,112 *м*³/*с*. Суы язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 700–1000 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк.

ТҮБӨН ЯХШЫ́Й авылы, Актаныш р-нын да, Актаныш авылыннан 40 *км* көньяк-көнбатыштарак, Сикия елгасы буенда. 2010 елда 116 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. 1753 тән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Улуйменево-Тамак исеме б-н дә билгеле. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар һәм типтәрләр катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, киндер сугу, тәгәр мәч тугымы ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 700 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр авыл Уфа губернасының Минзәлә өязе Байсар волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә канто нында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1834 тә — 25 ир-ат; 1859 да — 82, 1870 тә — 94, 1884 тә — 134, 1906 да — 236, 1913 тә — 280, 1920 дә — 266, 1926 да — 450, 1938 дә — 530, 1949 да — 537, 1958 дә — 225, 1970 тә — 321, 1979 да — 217, 1989 да — 122, 2002 дә — 122 кеше.

«ТҮБӘНКАМАНЕФТЕХИ́М», РФдә иң зур *нефть химиясе сәнәгате* пр-тиесе; нефть-газ чималын комплексны эшкәртү һәм төп органик синтез процессларына нигезләнеп, төрле төрдәге нефть химиясе һәм химия продуктлары җитештерү б-н шөгыльләнә. 1961 елда Түбән Кама химия комб-ты була рак нигез салына, 1967 дән нефть химиясе комб-ты, 1977 дән «Т.» ҖБ, 1993 тән АҖ, эшләүчеләр саны 14,9 мең кеше (2017), 3,35 мең *га* җир били.

1958 дә КПСС ҮК һәм СССР МС Кама елгасының түбәнге агымында химия заводлары комплексы төзү турында карар кабул итә, 1960 та Мәскәүнең «Гипрокаучук» ин-тында И.С.Каюков һәм К.П.Клим җитәкчелегендә төзелгән ген. проект раслана. Пр-тиене һәм эргәдәш объектларны проектлауда 30 дан артык оешма, ш.и. «Гипрогор», «Гипрохим», «Гипротрубопровод», «Гипроречтранс», «Электропроект» ин-тлары (барысы да Мәскәү), Эретеп ябыштыру ин-ты (Киев ш.) һ.б. катнаша. Торак йортлар һәм социаль инфраструктура объектларын, инженер-техник коммуникацияләр (1961 дән), сәнәгый объектлар (1963 тән) төзү эшләрен «Татнефтестрой», «Лениногорскнефтестрой», *«Татэнергострой»* трестлары бүлекчәләре алып бара. Комб-т төзелешендә кайбер тоташтырмала ры җир өстендә җыелган зур блоклы монтаж ысулы уңышлы кулланыла һәм сроклар ны күпкә кыскарта; дөньяда беренче тапкыр төзү-монтаж һәм эшләтеп җибәрү-көйләү эшләре бергә алып барыла. Үз егәрлеге юга ры булган агрегатлар төзү капиталь чыгым нарны 25–30% ка киметә. Пр-тиене техник җи һазлауда АКШ, Япония, Германия, Бөекбритания, Италия, Нидерланд һ.б. илләрдән сатып алынган агрегатлар, технол. ли нияләр, приборлар кин кулланыла. Күп кенә технологияләр һәм җи һазлар бу тармакта беренче булып гамәлгә кертелә.

1967–2006 да файдалануга кертелгән объектлар: ЦГФУ үзәк газ фракциясе җай ланмасы (егәрлеге елына 2,1 млн. *т*), ЭЛОУ-АВТ-7 электр б-н тозсызландыру җайланмасы (елына 7 млн. *т* нефтьне беренчел эшкәртеп, турыдан-туры бензин куу өчен), бер стадияле изопрен синтезы җай ланмасы; изопрен-мономер (егәрлеге елына 423 мең *т*), изопрен каучук (570 мең), пентан изомерлау (170 мең), ике стадияле дивинил (130 мең), этилен, пропилен, бензол (тиңдәшле рәвештә 450 мең, 197 мең, 187 мең), этилбензол һәм стирол (172 мең һәм 125 мең), этилбензол (172 мең), эшкәртүе б-н бергә этилен окисе (420 мең), пропилен окисе һәм стирол (50 мең һәм 138 мең), нормаль пентанны изомерлау (130 мең), алкилфеноллар (100 мең), актив өслекле матдәләр (250 мең), α-олефиннар (185,5 мең), полипропилен



«Түбәнкаманефтехим». Гомуми күренеше.

(плёнкалар һәм гомуми куллану өчен, 180 мең), полистироллар (бәрүгә чыдам һәм гомуми куллану өчен, егәрлеге 100 мең *т*), поливинилхлоридлы пластикаттан аяк киеме һ.б. производстволары; релин, плиталар, мастика цехлары. Чимал китертү өчен Түбән Кама–Миңлебай (к. *Миңлебай газ эшкәртү заводы*) продукт үткәргече һәм Түбән Кама–Әлмәт нефть үткәргече, продукция чыгару өчен Түбән Кама–Казан, Түбән Кама–Уфа–Стәрлетамак–Салават этилен үткәргечләр салына. 2007–17 дә полибутадиен каучукны литий катализаторында җитештерү (50 мең *т*) үзләштерелә, полиэтилен (230 мең *т*), АБС-пластиклар (60 мең *т*), формальдегид (100 мең *т*) производстволары, әйләнә тирә мохитне күзәтү автоматлаштырылган системасы гамәлгә кертелә, бутилкаучук, альфа-олефиннар һ.б. производстволары модернизацияләнә.

Яңа производстволар төзү б-н бер үк вакытта инде эшли торган технол. процесслар камилләштерелә, һәм нәтиҗәдә аларның җитештерү куәтләре 1,5–3 тапкыр арта, продукция сыйфаты күпкә яхшыра. 1970 еллар ахырында технол. процесслар һәм пр-тие б-н автоматлаштырылган идарә итү системасы гамәлгә кертелә. «Т.» б-н бергә Түбән Кама җылылык электр үзәге, төзелеш индустрия-се базасы (к. «*Камэнергострой*»), элемтә, су б-н тәэмин итү һәм канализация объектлары, тимер юллар, автомобиль юллары сафка кертелә; төп җитештерү мәйданыннан 5 *км* лы санитар саклау зонасы б-н аерып, 230 мең кеше гә исәпләнгән *Түбән Кама* шәһәре комплексы төзелә.

1967 дә пр-тие беренче продукциясен чыгара. 1978 гә эшләп торучы 6 һәм төзелеп килүче берничә з-дтан торган ҖБ җитештерү күләмнәре буенча тармакта 1 нче урынга чыга. 1981 дә 10 нчы бишъеллык йөкләмәләрен уңышлы үтәгәне, продукция күләмен үстерүдә һәм аның сыйфатын яхшыртуда ирешкән уңышлары, яңа җитештерү төрләрен сроглыннан алда үзләштергәне өчен берләшмә Ленин ордены б-н бүләкләнә. 1983 кә пр-тие өлешенә (СССРда чыгарылганнан % ларда): изопрен — 43, этилбензол — 39, бутаннан бутадиен — 27, этилен — 25,7, стирол — 25,5, ясалма каучук — 20, пропилен 20 туры килә; 1984 кә 1 млн. *т* дивинил, 1985 кә 1 млн. пар аяк киеме җитештерелә.

Берничә тапкыр реконструкция уздырганнан соң, «Т.» җитештерү комплексына түбәндәгеләр керә: бутилкаучук, дивинил һәм углерод чималы, изопрен ясалма каучук, этилен окисе, олигомерлар, ясалма каучуклар, стирол һәм полиэфир сумалалар, этилен, ремонт-механика з-длары, төзелүче полиолефиннар з-ды, 10 идарә (этиленүткәргечләр, химик һәм углеводород чимал, «Нефтехимресурс», экспорт һ.б.), 7 үзәк (ш.и. фәнни-техник һәм проектлау-конструкторлык). Пр-тие өчен сәнәгый җитештерү белгечләрен *Түбән Кама химия-технология институты*, *Түбән Кама нефть химиясе көллияте*, 2 һөнәри белем бирү база учреждениесе әзерли.

ТР нефть-газ химиясе комплексын үстерү программасының төп юнәлешләре нигезендә «Т.»ны 2020 гә кадәр перспектив үстерү планы эшләнә (стратегияле гамәлгә кертү кысаларында 2014 тә елга 5 мең *т* полистирол җитештерү куәтле производство сафка баса); бу планда гамәлдәге җитештерү куәтләрен тагын да үстерү һәм яңа зур тонналы комплекслар төзү, каучук һәм нефть химиясе җитештерүен интенсив үстерү, пр-тиедә алынган продукцияне эшкәртеп полимерлар ясау, продукциянең сыйфатын яхшырту һәм үзкыйммәтен төшерү, кулланучылар күбрәк сорый торган продукция чыгару күздә тотыла. Җитештерү күләмен елына 600 мең *т* га кадәр җиткерү максатында этилен комплексы, каучуклар — бутил һәм галобутил (120 мең), неодим катализаторында бутадиен (100 мең *т* га кадәр) з-дларын һ.б. модернизацияләнә.

«Т.» Татарстанның барлык энергетика системасы чыгарган электр энергиясенең 11,5% ка якынын куллана; продукциянең үзкыйммәтендә энергия чыгымнарының өлеше 15,5% ка җитә. 2007 дә Түбән Кама ТЭЦында «Т.» өчен 75 *МВт* егәрлекле когенерацион газ турбиналы җайланма төзелеп бетә. Экология программасы эшләнә (2015 кә кадәр исәпләнә), ресурс һәм табигать саклаулы технологияләр гамәлгә кертелә. Җитештерү калдыкларының 95% ы кабат файдаланыла. Судан кабат файдалануның йомык системасы Кама елгасыннан минималь су алуны тәэмин итә. Пр-тиенең әйләнә-тирәне саклау буенча эшчәнлеге — халыкара ИСО 14001:2004 сериясе стандартларына, сыйфат менеджменты системасы халыкара ИСО 9001:2008 стандартына туры килә. 2010 да компаниянең идарә системасының сыйфат, экология һәм куркынычсызлык өлкәсендә халыкара алымнарга туры килүен раслаган «Алтын сертификат» бирелә.

«Т.»да чыгарыла торган 120 дән артык исемдәге продукция арасында иң мөһимнәре: каучук җитештерүдә төп чимал булган мономерлар; «*Түбәнкамашин*» АҖ һәм резина-техник эшләнмәләр чыгара торган башка кулланучыларга җибәрү өчен гомуми һәм махсус кулланылыштагы ясалма каучуклар; пластиклар (полистирол, полипропилен, полиэтилен һ.б.); пластмасса, синтетик сүсләр, юу чаралары, плёнка һәм буяу-лаклау материаллары, ашламалар эшләп чыгару өчен чимал һ.б. Халык куллану товарларының һәм әзер продукциянең кайбер төрләре (грануллганган полиэтилен һәм сәвилен, полиэтилен һәм мәвилен плёнкалар, торбалар, җилем, буяулар, пластмассадан ху җалык кирәк-ярагы, шланглар) «Т.»ның бүлендек пр-тиеләрендә эшләп чыгарыла.

«Т.» РФдә җитештерелгән галобутил каучукның 100% ын, гади полиэфирларның — 97, этиленпропилен каучукның — 80, этилен окисеның — 45, бутил каучукның — 61, стиролның — 48, изопрен каучукның — 41, полистиролның — 47, моноэтиленгликольнең 24% ын эшләп чыгара. 1970 еллардан башлап пр-тие продукциясе экспортка чыгарыла. Аның гомуми күләменең 60% ы дөньяның 50 дән артык иленә җибәрелә. Иң зур импортёрлары — АКШ, Көнбатыш Европа, Көньяк-көнбатыш Азия илләре.

«Т.» өчен төп чимал кертүчеләр — «Татнефть», «Газпром», «Лукойл-нефть», «Метафракс» (Пермь өлкәсенең Губаха ш.) акц. җәмгыятьләре. Чит илләр б-н икътисади-сәүдә элемтәләрен үстерүгә зур өлеш керткәне өчен пр-тие халыкара «Алтын Меркурий» бүләгенә (1980, 1997) лаек була. «Т.» төрле халыкара оешмалар һәм РФнең күпсанлы призлары б-н бүләкләнә, алар арасында Европа «Global Resources Menegement» ассоциациясе, халыкара «Брюссель-Эврика» инновацияләр салоны (2005), «Россиянең иң яхшы ел экспортёры» (2002, 2004–06) конкурслары призлары һ.б. бар. Пр-тиенең күп кенә хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә лаек була, ш.и. 1 кешегә — Соц. Хезмәт Герое, 1 кешегә — РФнең атказ. химигы, 1 кешегә — РФнең атказ. төзүчесе исемнәре, 160 тан артык кешегә халык хуҗалыгының төрле тармаклары буенча ТАССР һәм ТРның атказ. хезмәткәре исемнәре, 5 кешегә — СССР Дәүләт бүләге, 3 кешегә — СССР МС, 3 кешегә — РФ Хөкүмәте, 8 кешегә ТР Дәүләт бүләге бирелә, 1140 тан артык кеше орденнар һәм медальләр, ш.и. 8 кеше — Ленин ордены, 9 кеше — Октябрь Революциясе, 77 кеше — Хезмәт Кызыл Байрагы, 27 кеше — Халыклар дуслыгы, 121 кеше — «Почёт билгесе», 103 кеше 3 нче дәрәҗә «Хезмәт даны» орденнары б-н бүләкләнә.

Пр-тие җитәкчеләре: И.А.Санников (1961–63), Н.В.*Лемаев* (1963–85), Г.Ж.*Сәхапов* (1985–97), Р.Г.*Галиев* (1997–99), В.М.*Бусыгин* (1999–2013), А.Ш.*Бикмурзин* (2014 тән).

Әд.: Лемаев Н.В. Устремлённость. К., 1985; Карташов С.М. Флагман отрасли. Л., 1986; Серебро колонн над Камой: Очерк истории ордена Ленина производственного объединения «Нижнекамскнефтехим». К., 1986; Нижнекамскнефтехим = Nizhnekamskneftekhim: Фотоальбом. К., 1999; Нижнекамск-Нефтехим = Nizhnekamsk-neftekhim. К., 2002.

С.Г.Белов.

«ТҮБӘНКАМАШИ́Н», Европада автомобильләр һәм башка тәгәрмәчле техника өчен пневматик шиннар җитештерүче иң зур пр-тиеләрнең берсе. Түбән Кама шәһәреннән 7,5 *км* ераклыкта урнашкан. Эшләүчеләр саны 2,5 мең кеше (2018). 1968 елда Түбән Кама нефть химиясе комб-ты составында төзелә башлаган шиннар з-ды җирлегендә 1971 дә Түбән Кама шиннар з-ды буларак төзелеп тапшырыла (ген. проектлаучы — Мәскәү «Резинпроект» ин-ты, ген. подрядчы — «*Татэнергострой*» төзелеш идарәсе). 1977 дән «Т.» ҖБ, 1994 тән «Т.» АҖ, 2002 дән — «Татнефть» АҖнең нефть химиясе комплексы составында. 1973 тә беренче автомобиль камералары чыгарыла; 1976 да з-д проектта каралган еллык куәтенә ирешә (җи һәл машиналар өчен 5,2 млн. покрышка һәм 7,5 млн. камера), Ленин комсомолы исем. (Мәскәү) һәм Тольятти шәһәре автомобиль з-длары өчен әлеге эшләнмәләрнең төп җитештерүчесенә әверелә. Гомуми продукция күләмендә прогрессив радиаль конструкцияле шиннарның өлеше 11% тәшкил итә.

1974–79 да, *КАМАЗ* төзелүгә бәйле рәвештә, йөк автомобильләре өчен, башлыча, Бөек-

британия, Франция, ГФР, Италия, Нидерландта эшләнүче җиһазлар б-н коралланды-рылган йөк автомобильләре өчен шин җитештерүче з-д төзелә (проекттагы еллык куәте 3,8 млн. шин һәм 5,5 млн. камера). Анда «КАМАЗ» автомобильләре өчен илдә беренче булып металл кордлы, норматив үтеш ераклыгы башка үрнәкләрнекеннән 5 тап-кыр артык булган шиннарны сериялән җи-ештерү үзләштерелә (1980). 1977 дә масса-күләм һәм йөк машиналары шиннары з-дла-ры һәм ремонтлау-механика з-ды (к. *Түбән Кама механика заводы*) ҖБ составына керә-ләр.

Яңа куәтләр өстәлү б-н берәрттән, пр-тие-дә эш җи һәзларын модернизацияләү алып барыла, сыйфат б-н комплекслы идарә итү системасы һәм җитештерү б-н идарә итүнең автоматлаштырылган системасы кертелә, шиннар конструкциясе һәм резин катнаш-маларының составы күпкә яхшыртыла. 1985–87 дә, җитештерүне туктатмыйча, «Пи-релли» компаниясе (Италия) технологияләре һәм җиһазларына нигезләнеп, массакүләм шиннар з-дында реконструкция үткәрелә һәм шуның нәтиҗәсендә җиңел автомобильләр өчен өстәмә рәвештә 2,5 млн. данә металл кордлы шин җитештерү үзләштерелә. 1991 дә ҖБ илнең шин сәнәгате тарихында рекорд-лы еллык күрсәткечләргә ирешә: 12,2 млн. шин, ш.и. җиңел автомобильләр өчен 7,4 млн., йөк машиналары өчен 3,99 млн., а.х. техникасы өчен 0,81 млн. шин эшләп чыгара.

1995 тә «Т.»да 7,9 берәмлек продукция җи-тештерелә. 2004 тә «Пирелли» фирмасы эш-ләгән технология нигезендә җиңел машина-лар өчен югары сыйфатлы радиаль «КАМА-EURO» шиннарын җитештерү ли-ниясе (елына 2 млн. данәгә исәпләнелгән) файдалануга тапшырыла. 2007 дә экологик яктан техник углеродка караганда күпкә зы-янсызрак кремнозём-силаннан (ак корым) резина катнашмалар алу өчен яңа әзерлек бүлеген төзү тәмамлана, 2009 да автобуслар һәм йөк машиналары өчен тоташ металл кордлы (ЦМК) шиннар җитештерү — «Түбән Кама ЦМК шиннар заводы» ҖЧҖ оештыры-ла (елына 1,2 млн. данә). 2011 дә мөстәкыйль «Түбән Кама йөк шиннары» ҖЧҖ аерып чыгарыла. «Т.» АҖ б-н бергә алар «Тат-нефть» АҖнең җитештерү ку әгъләренең зур-лыгы һәм җи һәзланышы, продукция күләме һәм ассортименты буенча БДБ илләренең тиңдәш пр-тиеләре арасында иң алдынгы урынны тоткан шиннар комплексына керәләр. Резина катнашмалары әзерләү, пок-рышкалар җыю һәм вулканлаштыру һ.б. техно-нол. операцияләр агымлы-механикалашты-рылган һәм автоматлаштырылган җиһазлар-да башкарыла. Ел саен пр-тиедә 10–15 төрдә-ге яңа эшләнмәләр җитештерү үзләштерелә. «Т.»да гамәлдә булган сыйфат һәм экологик менеджмент системасы халыкара ИСО стан-дарты сертификатына ия. Йомык цикллы су тәэминаты сәнәгый агынтыларны булдыр-мый. Россиядә тиңдәше булмаган «Рутнер» (Австрия) миче ярдәмендә күмәргә ярамый торган калдыклар үтилләштерелә.

2017 дә комплекс пр-тиеләре тарафыннан 370 ләп төрдәге җиңел, җиңел-йөк, катнаш-йөк, ЦМК йөк, а.х. өчен, индустриаль 9,7 млн. данә шин (КАМА, КАМА PRO, Viatti маркалары б-н) җитештерелә.

Россиядә эшләп чыгарылган барлык шин-нарның 20% тан артыгы «Т.» өлешенә туры килә. Продукция пр-тиенең Россиянең бар-лык төбәкләрендә сәүдә челтәре булдырган «Кама» сәүдә йорты ҖЧҖ (1999 да оешты-рыла) аша сатыла. Эшләнмәләрнең 45% ы шиннарның икенчел базарында сатыла, 30% тирәсе з-дларга, ш.и. «АвтоВАЗ» (17% чама-сы), «КамАЗ», «АвтоГАЗ», «Ижмаш», «УралАЗ», «Форд Соллерс Холдинг» АҖләре-нә һ.б.га җибәрелә. Продукция дөньяның 30 дан артык иленә (Бөекбритания, Чехия, Бельгия, Польша, Болгария, Төркия, Мисыр, Судан, Яңа Зеландия, Куба, ш.у. БДБ һәм Балтыйк буе илләре) чыгарыла. «Т.» — Венгриянең «Икарус» автобуслары өчен шиннар җитештерүче бердәнбер пр-тие.

«Т.»га төп чимал бирүчеләр арасында «*Түбәнкамнефтехим*» (30% тан артык), «Түбән Кама техник углерод заводы» (10% тирәсе) АҖләре бар.

«Т.» һәм аның продукциясе күпсанлы ха-лыкара һәм Россия бүләкләренә лаек бу-ла, ш.и. 1995 тә яхшы сыйфат һәм чит илләр б-н икътисади-сәүдә бәйләнешләрен үстерү-гә зур өлеш керткәне өчен «Алтын Мерку-рий», 1996–2001 дә — «Иң яхшы сыйфат өчен» (Швейцария), «Сыйфат өчен» (Мекси-ка, Франция, Италия), «Зур алтын клише» (Франция, Израиль, АКШ), «Технология һәм сыйфат өчен» (Германия) призлары б-н бүләкләнә, 2016–17 дә «Россиянең иң яхшы 100 товары» җитештерүче пр-тие дип таны-ла. Пр-тиенең күп кенә хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә лаек була, ш.и. 1 кешегә СССР Дәүләт бүләге, 1 кешегә СССРның атказ. сә-нәгать хезмәткәре исеме бирелә; 2 кеше — Октябрь Революциясе, 16 кеше — Хезмәт Кызыл Байрагы, 9 кеше — Халыклар дуслы-гы, 31 кеше — «Почёт билгесе», 31 кеше 3 нче дәрәҗә «Хезмәт даны» орденнары, 90 кеше медальләр б-н бүләкләнә. «Т.» — Түбән Кама шәһәрен төзүче пр-тиеләрнең берсе, үзенең поликлиникасы, спорт комплексы, сәламәт-ләндерү лагере, ял базасы, санаторий-про-филактории, көнкүреш хезмәте күрсәтү йор-ты һ.б. объектлары бар.

Пр-тие җитәкчеләре: Н.А.*Зеленов* (1971–97), Р.С.Ильясов (1997–2011), Р.Ф.Борһанов (2012–17), Ц.Б.Портной (2018 дән).

Әд.: Нижнекамский репортаж. К., 1978; Дорогу нижне ҡамским шинам. Нижнекамск, 2003.

С.Г.Белов.





«Түбәнкамашин». 1. Администрация бинасы; 2. Җиңел автомобильләр өчен «КАМА-EURO» шиннары җитештерү линиясе.

ТҮБӘТӘЙ, мөселман халыкларына хас бул-ган, татар халкында да киң таралган ир-ат баш киеме. Т.нең берничә төре билгеле, тәбә-нәк итеп киселгән конус (кәләпүш) һәм ярымшар рәвешендәгесе (такыя) аеруча киң таралган була. Кәләпүш ике өлештән тора, кырпу һәм түбә рәвешендә киселә, такыя



Ирләр түбәтәе. Бәрхет. Алтын җепләр, укалы тасма, ука, ялтыравык. 19 йөз. ТР Милли музее.

аерым чөйсыман ялгаулардан тегелә. Т. ике төрдәгесен дә барлык терр. төркем татар ир-ләре (керәшен татарларын исәпләмәгәндә) кия. 19 йөз ахырыннан, төрек-ислам тради-цияләре тәэсирендә, кәләпүш-Т.не күбрәк кия башлыйлар. Алар төрле тукымалардан, башлыча, бәрхеттән һәм кара яки караңгы төсмерле (көрән, зәңгәр, яшел) манчестер-дан эшләнә. Эчлеге караңгы төстәге бизәксез сатин яки саржадан тегелә. Татар Т., кырые һәм түбәсе бик вак җөйләр б-н сырылган-лыктан, катырак була. Т. тирләүдән җәлшәй-мәсен өчен кырыендагы җөйләр арасына ка-лын сүс җепләре яки бөтерелгән кәгазь ки-сәкләре, ә кыйммәтләрәкләреңә үргән ат кы-лы кыстырып сыралар. Яшьләргә дигән Т.ләр — ачык төсләр б-н, өлкәннәргә дигә-не — гадиерәк итеп чигелә. 20 йөз башында кара бәрхеттән тегелгән кәләпүшкә ихтыяҗ һәр җирдә зур була, татар яшьләре һәм ин-теллигенциясе арасында ул гомуми милли киемнең бер элементы буларак карала (кыс-ка казаки һәм европача тегелгән чалбар б-н киелә). Хәзерге ваытта Т. татарларда биг-рәк тә төрле йолаларны үтәгәндә, милли бәй-рәмнәр вакытында, кайвакыт көндәлек тор-мышта да киелә.

Әд.: Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967; Мухамедова Р.Г. Татарская народная одежда. К., 1997; Суслова С.В. Одежда // Татары. М., 2001; Рамазанова Д.Б. Названия одежды и украшений в татарском языке. К., 2002.
Р.Р.Батыршин.

ТҮГӘРӨК КУЛ, Көнбатыш Кама алдында, Идел елгасының югары террасасында, Лаеш р-ны Столбище авылыннан 1 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кече Куян күле янында. Су өслегенең мәйданы 1,06 *га*. Су күләме 27,5 мең $м^3$. Озынлыгы 130 *м*, иң зур киңлеге 50 *м*. Уртача тирәнлеге 2,6 *м*, иң зур тирәнлеге 5,5 *м*. Күл карст процессы нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Формасы озынча түгәрәк. Атм. явым-төшемнәре һәм грунт сулары исәбенә туена. Т.к.нең көньяк-көнбатыш ярына сыза тоташа, аның аша сулыкка яңгыр һәм кар сулары б-н бергә ком, балчык, ләм керә. Күл әкренләп ләмләнә бара.

ТҮГӘРӨК КУЛ, Көнбатыш Кама алдында. Идел-Кама саклаулыгының Раифа участогы саклау зонасында, урман массивында, Яшел Үзән р-ны Садовый посёлогыннан



Раифа урманында Түгәрәк күл.

көньяк-көнчыгыштарак. Су өслегенең мәйданы 0,8 *га*. Озынлыгы 100 *м*, иң зур киңлеге 70 *м*. Иң зур тирәнлеге 2,5 *м*. Күл карст-суффозия процессы нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Формасы озынча түгәрәк. Елгада табан балыклар бар.

«ТҮГӘРӨК УЕН», татар халык иҗатын яктыртучы мәгълүмати-популяр альманах. Гамәлгә куючы — ТР Мәдәният министрлыгы каршындагы татар фольклор үзәге (2011 елдан Респ-ка традицион мәдәниятне үстерү үзәге, җитәкчесе Җәүһәрова Ф.Х.). 2011 нең сентябреннән чыга. Мөхәррире — И.Иксанова. Басманың төп максаты — татар халкының рухи мирасын барлау, халыкка кире кайтару, яшь буынны милли традицияләргә якынайту. Альманах онытылып баручы гореф-гадәтләр, йола-бәйрәмнәр, Татарстаннан читтә яшәүче татарларның көнкүреше, кәсепләре, аларга гына хас гореф-гадәтләр, тел үзенчәлекләре турында язмалар бастыра. Шулай ук «Т.у.» битләрендә галимнәрнең (Ф.С.Баязитова, И.А.Гыйләҗев, М.Х.Бакиров, М.И.Әхмәтҗанов, Д.Ф.Заһидуллина, И.К.Заһидуллин һ.б.) хезмәтләре һәм матур әдәбият үрнәкләре бирелә.
Ф.Г.Камалетдинова.

ТҮКӘ авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 40 *км* көньяк-көнбатыштарак, Бәҗәнә елгасы буенда. 2010 елда 421 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөз ахырында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы асабалар һәм типтәрләр катлавына бүленә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 1773–75 еллардагы *Крәстияннәр кузгалышында* Е.И.Пугачёв ягында сугышалар. 20 йөз башында Т.дә мәчет, мәктәп, икмәк саклау-сату кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1404 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Пучы волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 182 кеше, 1816 да — 187 ир-ат; 1859 да — 352, 1870 тә — 470, 1884 тә — 609, 1897 дә — 576, 1906 да — 703, 1913 тә — 762, 1920 дә — 737, 1926 да — 555, 1938 дә — 646, 1949 да — 480, 1958 дә — 461, 1970 тә — 655, 1979 да — 573, 1989 да — 428, 2002 дә — 366 кеше.

«ТҮЛӘК», татарларда, башкортларда киң таралган борынгы мифологик дастан. Төп вакыйгалар Су асты патшалыгында бара. Җир өсте герое Түләкнең һәм Су асты патшалыгында яшәүче Сусылуның үзара мөнәсәбәтләре бәян ителә. Кайбер вариантларда батырлар көрәше мотивы чагыла: туй алдыннан кияү егете көрәштә кәләшне җиңәргә тиеш була. Күпмедер вакыт алар бәхетле яшиләр. Әмма яшь егет туганягын сагына башлый. Көтмәгәндә илчеләр килеп хәбәр сала: халык Түләкнең хан булуын үтенә. Батыр хатынын калдырып китә һәм, идарә эшләре б-н мавыгып, вәгъдә биргән вакытка кайтып җитә алмый. Сусылу үлә. Түләк бу кадәр зур югалтуны күтәрә алмый, Сусылу гәүдәсе янында үз-үзенә кул сала. Дастанның фаҗигале ахыры бу ике дөнья вәкилләре арасында гармонияне килешү урнаша алмауны белдерә.

Беренче тапкыр «Т.» (башкорт версиясе) 1843 елда «Москвитянин» ж-лында «Башкорт су кызы» исеме б-н («Башкирская русалка») В.Даль тарафыннан бастырып чыгарыла. Дастанның тулырак версиясен «Зая Түләк берлә Сусылу» исеме б-н М.Гафури бастыра (Уфа, 1910). «Т.»не Н.Исәнбәт өйрәнә, дастан сюжетына либретто яза (1942). Либреттога Н.Җиһанов «Түләк һәм Сусылу» операсын иҗат итә.

Әд.: Исәнбәт Н. Түләк // Сайланма әсәрләр. К., 1960. Т. 1; Татар халык иҗаты: Дастаннар. К., 1984; Урманче Ф. Әкияти-мифологик эпос «Түләк һәм Сусылу» // Татар халык иҗаты: Дәрес-лек. К., 2005.
Ф.И.Урманчеев.

ТҮЛӘКБӘК ХАН (?–1380), Алтын Урда ханы (1380). Куликово кырындагы сугышта *Мамай* җи һәлгәч (1380), Алтын Урданың көнбатыш өлешендә (үзәге Кырымда) идарә итә. Үз исеменнән акча суктыра. Тәхеттән Туктамыш хан тарафыннан төшерелә.

Әд.: Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960.
И.Л.Измайлов.

ТҮЛӘМӘ (Anthrax), спора йөртүче таякчык — антракс бацилласы (Bacillus anthracis) китереп чыгара торган аеруча куркыныч сапрозооноз йогышлы авыру; а.х. терлекләрен һәм кешеләрне зарарлый. Авыру барышында септицемия һәм тире (карбункулёз төр), эчәклекләр (эчәклек төре), үпкәләр, миндальсыман биз (висцераль, яки генерализацияләнгән төр) зарарлану кебек билгеләр күзәтелә. Русча исеме — «Сибирская язва» — 1846–66 елларда Себердә булган эпизоотия б-н бәйле. Т.нең таралышы киң, ул бары тик Америка континентының ерак төньягында һәм Антарктидада гына очрамый. Рев-циягә кадәр Россиядә иң таралган һәм иң куркыныч йогышлы авыру ел саен а.х. терлекләре һәм башка хайваннарның күпләп үлүен китереп чыгара, ш.у. кешеләрнең дә күпләп авыруына сәбәп була.

Авыру каты һәм тиз бара, еш кына үлем б-н тәмамлана. Висцераль төр очракларында үлем 85–100% тәшкил итә. Т. бациллалары башлангыч күзәнәкләрдәге генетик материалны озак вакытлар буена (40–60 ел) саклларга мөмкинлек бирүче һәм аларның төп үзлекләрен алдагы генерацияләрдә яңа буынга тапшыруны тәэмин итүче споралар хасил итә. Терлек организмында кислород булганда формалаша алмый торган капсулалар барлыкка килә. Антракс бациллалары көчле инвазивлык үзлегенә ия, тиредәге яра, сыдырылган урыннар һәм организмдагы лайлалы тышчалар аркылы җи ңел үтеп керә. Ашкайнату трактының җәрәхәтләнгән лайлалы тышчасы аркылы микроб лимфа системасына, аннары канга күчә, анда, лимфа-макрофаг системасы элементларына эләгеп, фагоцитлаша һәм бөтен организмга тарала, шуннан кабат канга күчеп, септицемия китереп чыгара. Авыру елның төрле вакытында, аеруча корылык шартларында барлыкка килергә мөмкин. Җир эшләре барышында споралар туфрактан җил б-н тарала һәм әйләнә-тирәне зарарлый.

Т. эпидемияләренә каршы көрәш чараларын иң элек авыру хайваннарны изоляцияләү, ш.у. терлек үләксәләрен кичекмәстән махсус яки яраклаштырып эшләнгән мичләрдә яндыру тәшкил итә. Авыру терлек үләксәләре табылган урыннарда туфракны 1 $м^2$ *га* 10 *л* исәбеннән 5% лы актив хлор эремәсе б-н эшкәртәләр. Аннары җирне 1:3 нисбәтендә коры хлорлы известь б-н кушып, 25 *см* дан ким булмаган тирәнлектә казып чыгалар һәм су сибеп дымландыралар. Хуҗалыкта карантин игълан ителә, хирургия операцияләре ясау, сугым сую, читкә сөт һәм мал азыгы чыгару тыела.

Т.не кисәтүнең ышанычлы чарасын вакцинацияләү тәшкил итә. Россиядә терлекләрне вакцинацияләү 1883 тә башлана (1 нче һәм 2 нче Л.С.Ценковский вакциналары). Бу терлекләр үлемен һәм кешеләрнең авыру очракларын беркадәр киметә, ләкин алдагы елларда илдә Т. эпизоотиясе һәм эпидемияләре күзәтелә. 1940–42 дә Сан.-техн. ин-тында (Киров ш.) Н.Н.Гинсбург капсуласыз СТИ-1 штаммыннан алынган махсус СТИ вакцинасын тәкъдим итә. 1950–55 тә Бөтен-

союз дәүләт фәнни-контроль ин-тында (Мәскәү) С.Г.Колесов, Н.А.Михайлов һәм Ю.В.Борисович капсуласыз Шуя-15 штаммыннан ВГНКИ вакцинасы әзерлиләр һәм күпләп җитештерүгә кертәләр.

1985 тән — 55-ВНИИВВ һәм М штаммыннан илебез галимнәре тарафыннан алынган яңа вакцина киң кулланылыш алган чорда эпизоотик халәтнең өзлексез яхшыруы күзәтелә; шуның нәтиҗәсендә 20 йөз ахыруннан Россиядә Т. спорадик очраклар яки зур булмаган авыру учаклары рәвешендә генә теркәлә. Вакцинаның авторлары — Бөтенсоюз вет. вирусологиясе һәм микробиологиясе фән-ни-тикшеренү ин-ты (Владимир өлкәсе Покров ш.) хезмәткәрләре И.А.Бакулов, В.А.Гаврилов, В.В.Селиверстов.

Т. авыруын өйрәнүгә Казан вет. ин-ты галимнәре зур өлеш кертә. 1892–1906 да проф. И.Н.Ланге соңрак «Ланге-1» һәм «Ланге-2» дип аталган Т. вакцинасын аерып алып тәкъдим итә. Авыру патогенезын өйрәнүне профессорлар Н.Д.Степанов (1906–17), М.В.Рево (1937–43), ш.у. Х.Х.Абдуллин (1945–69, беренче булып Т. очрагында мөгезле эре терлекләрдә бацилла саклану һәм авыруның сөт аша күчү мөмкинлеге мәсьәләләрен тикшерә) дәвам итә.

Т. авыруын дәвалау һәм кисәтүдә ш.у. антибиотиклар, Т.гә каршы гипериммун сыгынты һәм гамма-глобулин кулланыла.

1914–2004 еллар эчендә Татарстан терр-ясендә терлекләрнең Т. б-н авыруының 1927 учагы теркәлә: иң күп очраклар Кама алды (1004, яки 52%), Кама аръягы (701, яки 36%), Идел алды (222, яки 12%) зоналарында күзәтелә. Арча (224 очрак), Балтач (144), Минзәлә (95) иң хәвефле районнар рәтендә була.

1970–80 дә Т. б-н авыру очраклары Бөгелмә, Кукмара һәм Сарман р-ннарында теркәлә (авыру учагы — авыру терлекләр юк ителгән урын туфрагы). Авыру очракларында диагноз кую һәм инфекция сәбәпләрен ачыклауда инфекционистлар Х.Х.Абдуллин, Ж.Ш.Әхмәров, В.Я.Давыдов, Д.Ш.Еналева, Н.С.Садыйков, А.А.Сорокин, В.Х.Фазылов (Казан мед. ин-ты) катнаша.

Әд.: Абдуллин Х.Х. Эволюция возбудителя сибирской язвы // Уч. зап. Казан. вет. ин-та. 1976. Т. 122; шул ук. Микробиологическая диагностика сибирской язвы. М., 1999; шул ук. Сибирская язва: Актуальные аспекты микробиологии, эпидемиологии, клиники, диагностики, лечения и профилактики. М., 1999; Бакулов И.А., Гаврилов В.А., Селиверстов В.В. Сибирская язва (антракс): Новые страницы в изучении «старой» болезни. Владимир, 2001; Галиуллин А.К. Ретроспективный анализ сибирской язвы на территории Республики Татарстан // Ветеринария. 2009. № 1. *А.К.Галиуллин.*

ТҮЛЕШКӘ посёлогы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 12 *км* көнбатыштарак, Кече Мишә елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 7 кеше (татарлар) яши. 1678 дән рус чыганакларында Пустошь при речке Тулушке исеме б-н билгеле. Рев-цияга кадәрге чыганакларда Яңа Түлешкә буларак та мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 164,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Бөкмеш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1944 нең 19 февраленнән — Чүриле, 1956 ның 14 маеннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 23 ир-ат; 1859 да — 90, 1897 дә — 103, 1908 дә — 120, 1920 дә — 135, 1926 да — 95, 1938 дә — 114, 1949 да — 104, 1970 тә — 100, 1979 да — 77, 1989 да — 12, 2002 дә — 12 кеше.

ТҮМЕРҖӘ авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 16 *км* көнбатыштарак, Шәбез елгасыннан 1 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 58 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. Клуб. 17 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы асабалар катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, такта яру б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.дә мәчет (1836 дан мәгълүм), икмәк саклау-сату кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2034 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Шәрип волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 65, 1834 тә — 170, 1859 да — 246, 1870 тә — 253, 1884 тә — 269, 1897 дә — 293, 1913 тә — 291, 1920 дә — 298, 1926 да — 307, 1938 дә — 310, 1949 да — 250, 1958 дә — 216, 1970 тә — 214, 1979 да — 177, 1989 да — 89, 2002 дә — 60 кеше.

ТҮНДЕРБӘ́Ш, елан уты (Conium), чатыр чәчәклеләр семьялыгыннан икееллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 4 төре билгеле, Европа, Азия, Африкада таралганнар. ТР терр-ясендә бер төре — тимгелле Т. (C. maculatum) бар. Урман аланнарында, чүп үләне буларак бакчаларда үсә. Тамыры орчыксыман. Сабагы ялангач, тармаклы, 60–100 *см* биек лектә, түбәнге өлешендә кызгылт-көрән таплы. Яфраклары кат-кат каурыйсыман телемә. Чәчәкләре вак, ак, катлаулы калкансыман чатыр чәчәк төркемендә. Җимеше — ике орлыкча. Июнь–июльдә чәчәк ата. Үсемлек составында кониин, кумарин һ.б. агулы матдәләр бар. Тычкан исе килә. Халык медицинасында тыныч ландыру, көзән җыеруга каршы һәм авыртуны басу чарасы буларак кулланыла. Үсемлекләрнең барлык өлешләре дә кеше һәм хайваннар өчен агулы.

ТҮНТӘР авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 16 *км* төньяк-тарак, Көшкәт елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 591 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1678 дән Түнтәр елгасы буендагы Пүчинкә буларак билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, лашманлыкта эшли; игенчелек, терлекчелек, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Т.дә 2 мәчет (1831 һәм 1912 дә төзелә), мәдрәсә (1827 дә нигез салына), мәктәп, су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3204 дис. тәшкил итә. 19–20 йөзләрдә Т. *кадимчелек* һәм *җәдитчелек* тарафдарларының көрәш үзәгенә әверелә (к. *Түнтәр мәдрәсәсе*). Мәшһүр дин эшлеклесе И.*Динмөхәммәтов* җитәкчелегендәге мәдрәсә шул чор өчен зур дини үзәк булып тора һәм кадимчелекне яклый. Түнтәр авылы мәктәбен нигезләүче һәм мөдәррисе М.Ш.Шәмсетдинов яңача укыту ысулы тарафдары була. Мәктәп каршында «Шәмси» җәдит китапханәсе оештырыла. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Арбор волостенда, 1921 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр р-ны үзәге, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1938 нең 4 августыннан — Чепья, 1958 нең 16 июленнән — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1811 дә — 439, 1859 да — 1132, 1884 тә — 1341, 1905 тә — 1420, 1920 дә — 1609, 1926 да — 1441, 1938 дә — 1213, 1949 да — 827, 1958 дә — 559, 1970 тә — 527, 1979 да — 546, 1989 да — 536, 2002 дә — 564 кеше.

ТҮНТӘР МӘДРӘСӘЛӘРЕ́, Вятка губ., Малмыж өязе (хәзер Балтач р-ны) *Түнтәр* авылында. Беренче мәдрәсәгә 1827 елда Бохарада белем алган мөдәррис Г.Сафиулла (Сафиуллин) тарафыннан нигез салына. Тиздән мәдрәсә төбәктә иң зур һәм танылган мәдрәсәләрнең берсенә әверелә. 1859–75 тә мәдрәсәне Г.Сафиулланың кияве Ш.Рәхмәтуллин җитәкли. 1877–1918 дә мәчетнең имам-хатибы һәм мәдрәсәнең мөдәррисе И.*Динмөхәммәтов* була, ул чорда Түнтәр авылы кадимчелек үзәгенә әверелә, мәдрәсәдә катгый рәвештә укытуның Бохара системасы саклана. 1890 да Ш.Рәхмәтуллинның улы М.*Түнтәри* Түнтәр мәчетенең икенче имамы итеп сайлана һәм үзенең шәхси мәдрәсәсен ача, мәдрәсә *җәдитчелек* тәэсирендә үсеш ала; 1903 тә рәсми рәвештә яңа ысуллы укыту кертелә. Мөдәррисләр арасында мөнәсәбәтләр каршылыклы була, 1912 дә И.Динмөхәммәтовның астыртын эш йөртүе нәтиҗәсендә М.Түнтәри вазифасыннан азат ителә һәм Түнтәрдән китә. Яңа ысуллы мәдрәсә хәйрияче җәдитчеләр ярдәме б-н эшләвен дәвам итә. И.Динмөхәммәтовның мәдрәсәсе 1919 да мөдәррисне атканнан соң ябыла. М.Түнтәри авылына 1918 дә (1919 да?) әйләнеп кайта, 1922 дә мәдрәсәне совет законнарына туры китереп өлкәннәр өчен дини уку йорты буларак рәсми теркәтүгә ирешә, ләкин ул нибары 1 ел гына эшли. М.Түнтәри үзе балаларны һәм өлкәннәрне 1929 га кадәр укыта.

Әд.: Зарипов Р. Мөхәммәтнәҗип хәзрәт язмасы // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2003. № 1/2; Салихов Р., Хәйретдинов Р. «Верноподданническою правдою подтверждено...» (Ишмөхәммәт Динмөхәммәтов) // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2004. № 2.

ТҮНТӘР РАЙОНЫ́, ТАССРда. 1930 елның 10 августында оештырыла. Үзәге — *Түнтәр* авылы. 1920 гә кадәр — Казан губернасының Казан һәм Мамадыш, Вятка губернасының Малмыж өязләрендә, 1920 дән ТАССРның Арча һәм Мамадыш кантоннарында. Оешкан вакытында Т.р. 60 авыл советын,

99 торак пунктны берләштерә, аларда 61969 (татарлар — 52072, руслар — 936, башка халыклар — 8961) кеше яши. 1932 нең 2 мартында, район үзәге Балтач авылына күчү сәбәпле, район *Балтач районы* дип үзгәртелә.

ТҮНТӘРИ́ Мөхәммәтнәҗип (Шәмсетдинов Мөхәммәтнәҗип Шәмсетдин улы) (1862, Вятка губ., Малмыж өязе Түнтәр а. — 1930, фаразланганча, Казан), педагог, дин эшлеклесе, дин белгече. Түнтәр авылында мәдрәсәдә әтисендә (к. *Түнтәр мәдрәсәсе*), Казанда (ихтимал, «*Мөхәммәдия*» мәдрәсәсендә) укый. 1890 елдан Түнтәр авылы мәчетенең имамы; Г.Баруди ярдәме б-н авылда И.*Дин мөхәммәтовның* кадимчелек мәдрәсәсенә каршы *җәдитчелек* нигезендә мәдрәсә оештыра. 1911 дә И.Динмөхәммәтов әләге б-н «*Бубби эше*» буенча кулга алына, 1912 дә имам вазифасыннан читләштерелә. 1913–17 дә Казанда «*әд-Дин вә әл-Әдәб*» ж-лы хезмәткәре. 1917–18 дә (1919 да булырга мөмкин) Эчке Россия һәм Себер мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте хезмәткәре. 1918 дән (1919?) Түнтәр авылының 1 нче мәхәлләсе имам-хатибы, мәдрәсәне саклап калырга тырыша. 1930 да кулга алына, 10 елга хөкем ителеп, Төньяк крайга сөргенгә җибәрелә; төрмәдә үлә. Дин белеме буенча хезмәтләр авторы; Т.ның күп кулъязмалары басылып чыккан; басылмаганнары С.Г.*Вахиди* тарафыннан сакланган, ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында. Т.нең Түнтәр авылы тарихы буенча кулъязмасы — «Мөхәммәтнәҗип хәзрәт язмасы» кыскартып бастырыла («Гасырлар авазы» — «Эхо веков» ж-лында чыга, 2003, 1/2).

Х е з м.: Хәдүс галәмгә игътикад җә һатеенең бер назар. К., 1900; Төзкире әт төбь инфи-л-вагаз вә-т-тәгълим китабының 1 нче кисәгенең тәр җәмәсе. К., 1913; Исламда хатыннар хоқукы. Уфа, 1917.

ТҮРЕ́Ш авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 27 *км* көнчыгыштарак, Калмыя елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 191 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. 1920 елларда нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Минзәлә кантоны Әмәкәй волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1926 да — 193, 1938 дә — 274, 1949 да — 292, 1958 дә — 256, 1970 тә — 326, 1979 да — 222, 1989 да — 98, 2002 дә — 74 кеше.

«ТҮРК ЮРДУ́» («Төрек йорты»), фән-ни-популяр журнал. «Түрк юрду» һәм 1912 елдан «Түрк очагы» җәмгыяте органы. 1911–31 дә Истанбулда төрек телендә нәшер ителә, барысы 233 саны чыга. 1918–24 тә финанс кыенлыгы б-н бәйле рәвештә басылмый. Нашире һәм беренче мөхәррире — татар җәмәгать эшлеклесе Й.*Акчура* (1911–17). Оренбург сәүдәгәрләре *Хөсәеновларның* финанс ярдәме б-н оеша. Журналда А.Агаев, Г.Баттал, Ә.Вәлиди, И.Гаспринский, Г.Исхакый, Ф.Кәрими, С.Максуди, Х.Сабит, Ф.Туктаров, Г.Хәмиди һ.б. языла. Басма төркиләр-нең икътисади һәм мәдәни үсешенә, аларның фәнни-техник белемен баетуга булышлык итә. Россия төркиләренең матди, рухи һәм интеллектуаль хәле турында сөйләнелә, мәгариф, хатын-кызларның тоткан урыны, мед.-сан. хезмәте, фабрика, заводлар булдыру, механикалаштыру үсеше һ.б. мәсьәләләр яктыртыла. «Т.ю.» төркичелек концепциясенең формалашуы һәм эволюциясендә зур роль уйный, идеяне иң актив пропагандалаучы Й.Акчура була. «Сәясәтнең өч төре» теоретик мәкаләсендә төркиләрнең тоткан урынына тирән анализ ясый һәм төрки берләшмәнең үсеш перспективаларын билгели. Редакция, базар мөнәсәбәтләрен урнаштыруны таяну ноктасы итеп, икътисади һәм социаль үсешнең үз стратегиясен алга сөрә, аларның лидеры милли буржуазия булырга тиеш диелә. М.Акъегетзадә беренчеләрдән булып төркиләр арасында немец икътисадчысы Ф.Лист идеясен пропагандалый башлый. Ешкына Казан, Оренбург, Уфа татарлары тәҗрибәсе эшмәкәрлекне үстерү, сәнәгатьчеләр сыйныфын нығыту буенча үрнәк сыйфатында китерелә. Журналда татар газеталары мәкаләләрен күчереп бастыруга зур урын бирелә. «Төрки дөнья хәбәрләре» сәхифәсе язмалары Үзәк Азия һәм Россиягә ш.у. Госманлылар империясендәге эчке хәлгә багышлана; мәкаләләрнең 1/4 өлешенә якыны татар авторлары тарафыннан языла. Мәдәни яңартуны тәкъдим итеп, «Т.ю.» татар реформация хәрәкәтенең төп идеясен файдалана, әлеге тәжрибәне Госманлы империясендә кулланырга тәкъдим итә. Журнал госманлы телен реформалаштыруда, аны гарәп, фарсы сүзләреннән арындыруда актив катнаша.

Әд.: Х а з и е в а А. Процесс пробуждения тюркского народа на страницах журнала «Тюрк юрду» (первая треть XX века) // Тонус. 2004. № 9; М и н н у л л и н Р. «Очаги» являются проводниками идеи неопантюркизма...» // Гасырлар авазы — Эхо веков. 1996. № 3/4; М у х а м м е т д и н о в Р.Ф. Зарождение и эволюция тюркизма. К., 1996.

ТҮШЛЕ́К, татар хатын-кызларының вак көмеш тәңкәләре балык тәңкәседәй тезеп бизәлгән, арага киндер тукыма куеп сырылган күкрәкчә рәвешендәге борынгы бизәнү әйбере. Хатын-кызларның бәйрәм күлмәгенең бер өлеше. Казан арты керәшеннәрендә һәм Пермь татарларында киң таралган. Т.нең нигезе һәм читләре ука, ачык төсле ефәк яки йон тукыма б-н бизәлә. Керәшен татарларда Т. ике өлештән — тышкы ярымай формасында сырган тукымадан һәм юка материалдан әзерләнгән эчке җи өл ялгаудан тора. Тышкы яки өске ягы тулысынча көмеш тәңкәләр б-н бизәлә. Гадәттә, хатын-кызның бөтен күкрәген каплап торган бу зур бизәнү әйбере күлмәк өстеннән киелгән, ә керәшен татар хатын-кызлары ш.у. тышкы кием өстеннән дә киеп йөргәннәр. Түбән Идел буе мишәрләрендә шундый гадәт яшәгән: туй вакытында кәләш кияүнең әнисенә Т. бүләк иткән. 20 йөз башында кулланыштан чыга.



Алабуга төркеме керәшеннәренең түшлеге.

Әд.: С у с л о в а С.В., М у х а м е д о в а Р.Г. Народный костюм татар Поволжья и Урала. К., 2000.

ТЫЕЛГА́Н ТОВАРЛА́Р, 17–19 йөзләрдә Россиянең Идел-Урал төбәгендә яшәүче татар, чуаш, мари һәм рус булмаган башка халыкларга сатарга тыелган корал һәм корал буларак кулланылырдай металл эшләнмәләр. 1633 елгы устав грамотасы һәм 1645, 1649, 1677, 1686 да һәм 1697 дә воеводаларга җибәрелгән күрсәтмәләрдә Т.т.га көбә, калкан, сугышчы баш киеме, кылыч-хәнҗәр, ук очлыклары, мылтык, дары, күкерт, металлар (тимер, бакыр, кургаш, аккургаш) һ.б., ш.у. әҗнәбиләрнең «сугышырлык» («вогненного бою») һәм «сугышта кулланылырлык» («что годно к войне») әйберләре булмасын өчен аларга тимерчелек һөнәре б-н шөгыльләнү тыела.

Әд.: Д м и т р и е в В.Д. Заповедные товары и запрет кузнечного и серебряного дела в национальных районах Среднего Поволжья в XVII веке // Вопр. истории Чувашии. Чебоксары, 1977. Вып. 73.

Е.Б.Долгов.

ТЫЛАҢГЫ́Р авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 17 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Казансу елгасы буенда. 2010 елда 56 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, иткә терлек асрау. 1678 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кече Пошалым исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 229,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кармыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 32 ир-ат; 1859 да — 80, 1897 дә — 102, 1908 дә — 112, 1920 дә — 133, 1938 дә — 194, 1949 да — 173, 1958 дә — 179, 1970 тә — 144, 1979 да — 120, 1989 да — 98, 2002 дә — 79 кеше.

ТЫМЫТЫ́К авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 23 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Ык елгасы буенда. 2010 елда 1472 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, бакчачылык. Нефть чыгарыла, агач эшкәртү комб-ты. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 18 йөздә нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы асабалар, типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә; игенчелек, терлекчелек, дуга, тугым, чана табаны бөгү, чана һәм утын чанасы ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башын-

да Т.та волость идарәсе урнаша; 3 мәчет, 2 мәктәп, земство почта станциясе була; сишәмбе базары эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 5160 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Тымытык волостенда, 1920 дән ТАССР - ның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык р-ны үзәге, 1931 нең 20 октябреннән — Азнакай р-нында, 1935 нең 10 февраленнән — Тымытык р-ны үзәге, 1958 нең 16 июленнән — Азнакай, 1963 нең 1 фераленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1816 да — 231ир-ат; 1859 да — 1078, 1889 да — 1894, 1897 дә — 2475, 1910 да — 2705, 1920 дә — 2315, 1926 да — 1621, 1938 дә — 2046, 1949 да — 1838, 1958 дә — 2602, 1970 тә — 2052, 1979 да — 1865, 1989 да — 1390, 2002 дә — 1408 кеше.

ТЫМЫТЫ́К РАЙОНЫ́, ТАССРда. 1930 елның 10 августында оештырыла. Үзәге — Тымытык авылы. 1920 гә кадәр терр-ясе Самара губернасының Бөгелмә өязендә, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. Оешкан вакытында Т.р. 37 авыл советын, 111 торак пунктны берләштерә, аларда 49225 (татарлар — 44687, руслар — 4538) кеше яши. 1931 нең 20 октябрендә, район үзәген Азна - кай авылына күчерү сәбәпле, Азнакай р-ны итеп үзгәртелә. 1935 нең 10 февралендә Аз - накай, Мөслим һәм Сарман р-ннарының бер өлешеннән Т.р. кире кайтарыла. 1940 та рай - онның мәйданы — 787 *км*^{2}, халкы — 21,4 мең кеше, 14 авыл советы, 37 торак пункт була. 1956 да районның мәйданы — 830,3 *км*^{2}, 12 авыл советы, 39 торак пункт керә. 1958 нең 16 июлендә Т.р. таркатыла, терр-ясе Аз - накай һәм Ютазы р-ннарына бирелә.

ТЫНЧЕ́РОВ Әмин Хәлил улы (19.5.1907, Тамбов губ., Елатьма өязе Бастан а. — 1980, Мәскәү), дәүләт эшлеклесе. Рязань совет-пар - тия мәктәбен (1929), Татар коммунистлар ун-тын (Казан, 1932), Н.Е.Жуковский исем. Хәрби-һава академиясен (Мәскәү, 1955) тә - мамлый. 1924–26 елларда Бастан авылы ком - сомол ячейкасы секретаре, ВЛКСМның Ря - зань губернасы Сасово волость ком-ты инст - рукторы. 1932–33 тә ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-тының агитация-масса эшләре бү - леге инструкторы. 1933–35 тә ТАССР Бе - ренче май МТСы сәяси бүлеге башлыгы урынбасары. ВКП(б)ның Дөбъяз район ком-ты секретаре урынбасары (1935–36), Чистай район ком-ты икенче секретаре (1936–37), Тәкәнеш район ком-ты беренче секретаре (1937–38). 1938–40 та ТАССР ХКС рәисе. Бөек Ватан сугышы елларында Волхов фронты 4 нче аерым армиясенең пар - тия комиссиясе җаваплы секретаре, хәрби комиссар, Фронт тылы идарәсе башлыгы - ның сәяси бүлек буенча урынбасары, Ленин - град фронтының 8 нче армиясе хәрби советы әгъзасы. 1947–59 да СССР Хәрби-һава көч - ләре баш аэродромының Ерак авиация тылы идарәсе башлыгының сәяси бүлек буенча урынбасары. 1959 дан отставкада. 1961–70 тә Тышкы сәүдә министрлыгының реклама бас - малары җаваплы мөхәррире урынбасары (Мәскәү). *М.З.Хәбибуллин.*

ТЫНЫ́Ш БИЛГЕЛӘРЕ́, к. *Пунктуация*.

ТЫҢЛАМА́С авылы, Актаныш р-нында, Ак - таныш авылыннан 9 *км* көнчыгыштарак, Башкортстан Респ-касы б-н чиктәш урнаш - кан. 2010 елда 290 кеше (татарлар) яши. Хал - кының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты. Мәчет. 1722 дән мәгълүм. 18–19 йөз - ләрдә халкы асабалар һәм типтәрләр катлавы - на бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шө - гыльләнә. 1773–75 еллардагы *Крәстияннәр кузгалышы* чорында Е.И.Пугачёв ягында су - гышалар. 20 йөз башында мәчет, икмәк сак - лау-сату һәм бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1236 дис. тәш - кил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Актаныш волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 фев - раленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварын - нан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 243, 1884 тә — 466, 1897 дә — 788, 1906 да — 808, 1913 тә — 812, 1920 дә — 604, 1926 да — 559, 1938 дә — 560, 1949 да — 513, 1958 дә — 490, 1970 тә — 571, 1979 да — 467, 1989 да — 339, 2002 дә — 302 кеше.

ТЫРНА́К ГӨЛ (Calendula), бер- һәм күпь - еллык үләнчел үсемлекләр һәм астрачалар семьялыгыннан ярымкуак ыругы. 20 дән ар - тык төре билгеле, Үзәк Европада, Урта диңг - гез буенда үсә; РФдә 4 төре билгеле. ТРда күптәннән дару Т.г. үстерелә (C. officinalis), башлыча катмарлы сары һәм кызгылт сары чәчәк төркемле «Гамлет», «Золотой шар», «Сенсация», «Фаворит» сортлары. Т.г. чә - чәк төркемендә (кәрзинендә) каротиноид һәм флавоноидлар, шулай ук полисахарид, по - лифенол, сумала, лайла, органик матдәләр бар. Т.г.нең дәвалау үзлекләре борынгы грек - ларга ук билгеле була, аның турында Әбүга - лисина да яза. Төнәтмә рәвешендә Т.г. ял - кынсынуга каршы, үлекле яраларны, кисел - гән, пешкән урыннарны, ашказаны җәрәхәтен, ашказаныннан кан китүне, гастритны дәвала - ганда, авыз куышлыгын, ангина булганда та - макны чайкау өчен, үт кудыру чарасы була - рак кулланыла. Т.г.дән ясалган май б-н фу - рункулны дәвалыйлар. Т.г. шулай ук азык сәнәгатендә буяу (телле чәчәкләрдән май экстракты), аш һәм соусларга тәмләткеч (кип - терелгән кәрзин) буларак файдаланыла. Җы - лыга, дымга, туфракка таләпчән түгел, лә - кин якты лык ярата. Аны иртә язда чәчәләр, рәт аралары 60 *см*; чәчү нормасы — 1 *м*^{2} га 1 *г* орлык, чәчү тирәнлеге — 2–3 *см*. Тишелеп чыкканнан соң, үсемлекләр кушылганчы рәт аралары эшкәртелә һәм чүпләре утала. Уңы - шы яңа чәчәк оешмасы ачылуга карап күп тапкырлар җыела. Сабак төбеннән киселгән кәрзиннәр җилләтелгән бүлмәләрдә һәм 40 °C тан югары темп-рада киптергечләрдә кипте - релә.

Татарстанда 1991 елдан (ел саен) Буа р-ны - ның «Венец» фәнни-медицина фермер ху - җалыгы Т.г.не 5 *га* мәйданда үстерә, аннан күкрәк читлеге, бөер, ашказаны даруы, ты - нычландыра торган һәм витаминлы җыел - малар әзерләнә. Уңышның бер өлеше «Тат - химфармпрепаратлар» җитештерү хим.-фарм. берләшмәсенә җибәрелә.

Әд.: Зелёная аптека Татарии. К., 1990.

Ф.С.Зыятдинов.

ТЫРЫ́Ш елгасы, Көнчыгыш Кама аръягын - да, Мәллә елгасының (Ык елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 11,7 *км*. Бассей - нының мәйданы 46,6 *км*^{2}. Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгыннан, Азнакай р-нында ага. Елга башы Тырыш посёлогыннан 3 *км* көньякта - рак, тамагы Митрофановка авылыннан 1 *км* көньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 250 *м*, тамагыныкы — 117 *м*. Су җы - елу мәйданының урманлылыгы 50%. Т. елгасының 2,4 *км* озынлыктагы кушыл - дыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,3 *км/км*^{2}. Туенуы катнаш, кар сулары исә - бенә күбрәк. Җир асты сулары б-н туену мо - дуле 0,5–1 *л/с·км*^{2}. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык сае - гуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 87 *мм*, ташу агымы катламы 60 *мм*. Язгы ташу, гадәт - тә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрь уртасында ту ңа. Елга тамагын - да суының иң аз вакытындагы уртача күпь - еллык чыгымы 0,005 *м*^{3}*/с*. Суы язын каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минераль әшүе язын 400–500 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк.

ТЫРЫ́Ш посёлогы, Азнакай р-нында, Аз - накай шәһәреннән 30 *км* төньяк-көнбатыш - тарак, Мәллә елгасының сул кушылдыгы бу - енда. 2010 елда 18 кеше (татарлар) яши. 1920 елларда нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Бөгелмә кантоны Әлки волос - тенда. 1930 ның 10 августыннан — Тымы - тык, 1931 нең 20 октябреннән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1926 да — 55, 1938 дә — 506, 1949 да — 292, 1958 дә — 256, 1970 тә — 326, 1979 да — 221, 1989 да — 21, 2002 дә — 16 кеше.

ТЫРЫ́Ш авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 34 *км* төньяк-көнбатыштарак, Борбаш елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 255 кеше (та - тарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кыр - чылык, яшелчәчелек. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. 1929 да нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Мамадыш кан - тоны Сәрдек волостенда. 1930 ның 10 авгус - тыннан — кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1938 дә — 283, 1949 да — 260, 1958 дә — 243, 1970 тә — 341, 1979 да — 306, 1989 да — 247, 2002 дә — 264 кеше.

ТЫЧКА́Н ТАРЫСЫ́ (Setaria), кыяклылар семьялыгыннан бер- һәм күпьеллык үлән - чел үсемлекләр ыругы. 120 дән артык төре билгеле, Җир шарының тропик, субтропик, сирәк кенә уртача өлкәләрендә таралганнар. Татарстан терр-ясендә 3 төре бар. Кечкенә Т.т. (S. pumila), яшел Т.т. (S. viridis) барлык җирдә дә, Италия Т.т. (S. italica) — Көнбатыш Кама алдында очрый. Кырларда, сулык ярла - рында, чүпле урыннарда, юл буйларында үсә.

10–150 *см* биеклектәге берьеллык үсемлек. Яфраклары ланцетсыман яки кыяк-ланцетсыман. Чәчәк төркеме — цилиндр- яки калаксыман башак себеркәчтә. Башакчыклары ике чәчәкле, кытыршы төкчәләр б-н каплан-ган. Җимеше — бөртекчә. Июль–сентябрьдә чәчәк ата. Җимешләре август–сентябрьдә өлгерә. Орлыктан үрчиләр. Яшь яфраклары йорт хайваннары өчен азык булып тора. Яшел Т.т. яшелләндерү өчен файдаланыла.

ТЫЧКАНСЫМАННА́Р (Muridae), кимерүчеләр отрядыннан имезүчеләр семьялыгы. 480 гә якын төре билгеле, бөтен Җир шарында таралганнар. ТР терр-ясендә 6 төре бар: йорт тычканы (Mus musculus), кечкенә тычкан (Micromys minutus), кыр тычканы (Apodemus agrarius), урман тычканы (A. sylvaticus), сары муенлы тычкан (A. flavicollis), *соры күсе* яки пасюк (Rattus norvegicus). Урманнарда, куаклыкларда, елга тугайларында, кырларда, ш.у. торак корылмаларында



Урман тычканчыгы.

яши. Йорт тычканының сырты соры яки коңгырт-соры, корсагы аксылрак. Гәүдәсе 103 *мм* га кадәр озынлыкта. Өске кискеч тешләренең эчке ягында күренеп торган тешчеге б-н ул башка тычканнардан аерылып тора. Уңайлы шартлар булганда ел әйләнәсе үрчи, балалары (4 тән 14 кә кадәр) 20 көннән туа. Өч айдан соң яшь тычканнар да үрчи башлый. Кечкенә тычкан — Евразиядәге кимерүчеләрнең иң кечкенәсе. Озынлыгы 7 *см* дан артмый. Сырты көрән, корсагы ак төстә. Койрыгы гәүдәсеннән кечерәк һәм «бишенче очлык» булып хезмәт итә, аның ярдәмендә үсемлек сабаклары буйлап җитез хәрәкәтләнә. Шар формасындагы оясын җирдән 20–50 *см* биеклектә асып, үлән сабакларынан ясый. Кыр тычканы башка тычканнардан сыртындагы кара буе б-н аерыла. Озынлыгы 8 *см* дан артыграк. Елга 4 тапкыр үрчи, 3–11 бала китерә. Урман тычканы — очлы танаулы, зур колаклы, зур кабарынкы күзле, озын, шома (төксез диярлек) койрыклы. Гәүдәсе — 7–11 *см*, койрыгы 7–11 *см* озынлыкта. Төрле төсмерле җирән-соры төстә. Елга 2–4 тапкыр үрчи, 3–11 бала китерә. Сары муенлы тычкан — ТР терр-ясендә яшәүче тычканнарның иң зурысы. Гәүдәсе — 14,5 *см* га, койрыгы 15 *см* га кадәр озынлыкта. Күкрәгендә сары тап бар. Елга 2–3 тапкыр үрчи, 4–6 бала китерә. Соры күсе — семьялыкның иң зур вәкиле. Гәүдәсе 26 *см* га кадәр, койрыгы 20 *см* дан озынрак, авырлыгы 550 *г* га кадәр. Һава җылы булганда, ел әйләнәсе үрчи, 1–22 бала китерә. Т.ның теш системасы семьялыкның барлык төре өчен уртак билге булып тора, аларда алгы азау тешләр юк. Үсемлек һәм хайван азык б-н тукланалар. Табигый шартларда 1–3 ел яшиләр. Төнлә һәм эңгер-меңгердә активлар. Йокыга талмыйлар. Авыл һәм урман ху җалыгына зыян китерәләр. Ерткыч хайваннар — кеш, сусар, төлке, ләтчә һәм көзәннәр, ш.у. күп кенә кошлар, аеруча ябалаклар һәм елак карчыгалар өчен төп азыкларның берсе буларак хезмәт итәләр. Табигый тупланыш авыруларын (ш.и. талпан энцефалиты, бруцеллёз, түләрәмә, Себер түләмәсе) йоктыручылар.

ТЫЧКАНЧЫКЛА́Р (Sicista), тычканчыклар семьялыгыннан кимерүчеләр ыругы. 11 төре билгеле. Евразиянең урман, урман-дала һәм дала зоналарында таралган. Татарстан терр-ясендә 2 төре бар. Урман тычканчыгы (S.betulina) бөтен районнарда, дала тычканчыгы (S.subtilis) Кама аръягында очрый. Далаланган тау битләрендә, нарат урманнарының яфраклы агачлар үскән урыннарында, көтүлек һәм печәнлек җирләрдә яшиләр. Тышкы кыяфәте һәм зурлыгы (5–10 *см*) буенча тычканнарны хәтерләтәләр. Койрыгы гәүдәсенә караганда шактый озын (5,5 — 16 *см*), мөгезчел тәңкәчекләр һәм сирәк, кыска төкчәләр б-н капланган. Алгыларына караганда арткы аяклары шактый озын, шул сәбәпле алар сикереп хәрәкәтләнәләр. Танавы очлы, колаклары зур. Сырты буйлап кара «тасма» сузылган. Урман тычканчыгының гәүдә өсте саргылт-җирән, дала тычканчыгының тонык соры төстә. Ояларын иске агач төпләрендәге ярыкларда ясыйлар. Төнлә һәм эңгер-меңгердә активлар. Бөҗәкләр, личинкалар, үләнчел үсемлекләрнең яшел өлешләре, агач орлыклары б-н туеналар. Май аеннан июльгә кадәр үрчиләр. Буазлык чоры — 25–30 көн. Ана затлар уртача 5 бала китерә. Кышын йокыга талалар. Ике төре дә ТРның Кызыл китабына кертелгән.

ТЫШКЫ́ ИКЪТИСАДИ́ ЭЛЕМТӘЛӘ́Р, илләр арасындагы сәүдә-икътисади, валюта-финанс, җитештерү һәм фәнни-техник хезмәттәшлекнең юнәлешләре, формалары, ысуллары һәм чаралары. Т.и.э.гә тышкы сәүдә, кредитлар бирү һәм кредитлар алу, уртак пр-тиеләр төзү, яңа технологияләр сатып алу һәм сату, пр-тиеләр һәм корылмалар төзү, квалификацияле кадрлар әзерләү һәм туризм өлкәсендә хезмәттәшлек, икътисади һәм техник ярдәм керә. Төбәк икътисадының үсешендә мөһим роль уйный. ТР икътисады дөньядагы хуҗалык элемтәләре системасына интеграцияләнгән. Респ-ка сәнәгате продукциясенең 50% ы чамасы экспортка чыгарыла. 2016 елда респ-каның тышкы сәүдәдәге товар әйләнеше 12 млрд. АКШ доллары тирәсе тәшкил итә (экспорт – 9,3 млрд., импорт — 2,7 млрд.). Сәүдә партнёрлары — 140 лап ил, ш.и. аеруча мөһимнәре: Бөекбритания, Германия, Нидерланд, АКШ, Финляндия, Франция, Япония. Башлыча минераль продуктлар, химия һәм нефть химиясе комплексы продукциясе чыгарыла, машиналар, җиһазлар, приборлар һәм транспорт чаралары, кара һәм төсле металлар һ.б. кертелә.

2010–16 да 9 млрд. чамасы, ш.и. 2016 да 663 млн. АКШ доллары күләмендә чит илләр инвестицияләре җәлеп ителә. Чит илләр катнашындагы 1000 ләп пр-тие (ш.и. «Алабуга» һәм «Иннополис» аерым икътисади зона кысаларында) эшли. Респ-ка эре халыкара транспорт инфраструктурасын үстерү проектларын гамәлгә ашыруда катнаша. 2009 дан Казан Россиянең һәм Ислам хезмәттәшлек оешмасының халыкара икътисади саммитын уздыруда төп мәйдан булып тора.

Н.М.Якупова.

ТЮЛЬГА́Н РАЙОНЫ́, *Оренбург өлкәсенең* үзәгендә урнашкан. 1965 елда оештырыла. Мәйданы — 1,9 мең *км*^{2}. Үзәге — шәһәр тибындагы Тюльган посёлогы (Оренбургтан 150 *км* төньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 18033 кеше (1.1.2017). Татарлар саны: 1970 тә — 670, 1979 да — 851, 1989 да — 1513, 2002 дә — 1344, 2010 да — 1002 кеше. Алар, тупланып, Аустяново авылында, башка халыклар б-н бергә Тугызтимер һәм Алмалы авылларында яшиләр. Т.р.на татарларның килүе 18 йөзнең 2 нче яртысында башлана. Бу чорда Татар Каргалысыннан күченүчеләр Тугызтимер торак пунктына нигез сала ((1760 еллар). 1791 дә Алмалы авылы барлыкка килә, анда хатынының — эре татар җирбиләүчесе Тәфкилев кызының — бирнәсе сыйфатында җирле алпавыт малаена бирелгән татар крепостнойлары килеп урнаша. 1830–40 елларда Чебенле авылыннан (хәзер Оренбург өлкәсенең Сакмар р-ны) күченүче татарлар Аустяново авылына нигез сала. 2008/09 уку елында башлангыч мәктәптә татар теле фән буларак өйрәнелә (Бүтенге көндә татар теле укытылмый).

Т.В.Селезнёва.

ТЮЛЬПА́Н (Tulipa), лаләчәләр семьялыгыннан күпьеллык суганчалы үсемлек ыругы; декоратив үсемлек. Чәчәк үстерү сәнәгатендә төп культураларның берсе. Якынча 140 төре билгеле, Азиядә, Африкада, Европада үстерелә. Төрле формадагы (бокалсыман, касәсыман, шарсыман, лаләчә, пионсыман, попугай һ.б.) һәм төрле төстәге (кызылның бөтен төсмерләре, кызгылт, сары, көрән, шәмәхә, ак) зур чәчәкле күпсанлы сортлары төрле төргә карый, алар бер җыелма төргә — гибрид Т. (T. hibrilum) төренә берләшкән. Сабагының биеклеге 10–70 *см*. Яфраклары аз санда, тасмасыман, шома, соры-яшел төстә, балавыз кунык б-н капланган. Т. чәчәге 6 таҗ яфракчыгыннан тора, май–июньдә чәчәк ата. Җимеше — өч кырлы озынча тартмачык, бик күп яссы ярым үтә күренмәле өчпочмаклы орлыклары бар. Утырту өчен якты, тигез, уңды-рышлы, нейтраль һәм аз селтеле туфраклы урын сайлана. Уңдырышсыз туфракта үсемлек тиз ваклана. Табигатьтә орлыктан яисә вегетатив рәвештә, культурада суганчалардан үрчетелә, грунтка сентябрь–октябрьдә 8–15 *см* тирәнлектә утыртыла. Чәчәк аткannan соң (июнь–июль ахырында) суганчаларын казып алалар, киптерәләр һәм утырту өчен саклыйлар. Т. язгы клумбалар, кисеп алу өчен кулланыла. Биберштейн Т.ы ТРның Кызыл Китабына кертелгән.

Әд.: Малова Н. Тюльпаны. М., 2001; Атлас сосудистых растений Татарстана. К., 2008.

ТЮ́МИН Иван Александрович (2.12.1896, Ярославль өлкәсенең Молога р-ны Иванцево а. — 2.2.1976, Казан), авиация генерал-майоры (1945). Кавалерия (Петроград, 1918) һәм урта, өлкән командирлар составының беле мен күтәрү (1926) курсларын, Эшче-Крәстиян Кызыл Армиясенең проф. Н.Е.Жуковский исем. Хәрби-һава академиясен (Мәскәү, 1933) тәмамлый. 1918 елдан Кызыл Армиядә, 3 нче Мәскәү эшче полкының рота командиры. Гражданнар сугышында: 1918–20 дә 18 нче Төньяк фронтның аерым кавалерия дивизионында эскадрон командиры ярдәмчесе, эскадрон командиры, 1920–21 дә Көнбатыш фронтның 4 нче армиясе 3 нче кавалерия корпусында эскадрон командиры. 1921–22 дә 2 нче көнчыгыш курсантлар бригадасының 3 нче Баку кавалерия курсында взвод, эскадрон командиры. 1922–23 тә 2 нче Кавказ кавалерия курсларында эскадрон командиры ярдәмчесе. 1923–24 тә Омск кавалерия курсларында һәм 6 нчы Таганрог кавалерия мәктәбендә взвод командиры. 1926–30 да тау халыкларының Төньяк Кавказ кавалерия мәктәбендә эскадрон командиры ярдәмчесе, эскадроны командиры. 1930–32 дә Урта Азия хәрби округының Төрекмән кавалерия дивизиясендә 1 нче Төрекмән кавалерия полкы командиры ярдәмчесе. 1933–36 да Украина хәрби округының Одесса артиллерия мәктәбендә авиация бүлеге башлыгы, мәктәп башлыгы ярдәмчесе. 1936–41 дә Иркутск Хәрби авиация-техник хәрби әзерлек уч-щесендә курсантлар батальоны командиры, училище башлыгы ярдәмчесе. 1941–56 да Ерак араларга очу авиациясенең Хәрби авиация-техник уч-щесе башлыгы (Казан; 1947 гә кадәр — Чиләбедә). 1956 дан — запаста. 1951–59 да ТАССР ЮС депутаты. Ленин ордены, Ике Кызыл Байрак, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары б-н бүләкләнә.

М.З.Хәбибуллин.

ТЮ́НИН Николай Андриянович (3.9.1931, Оренбург өлкәсенең хәзер Северный р-ны Курская Васильевка а. — 23.6.1995, Әлмәт ш.), машинист-экскаваторчы, Соц. Хезмәт Герое (1976). Хезмәт эшчәнлеген туган авылында башлап җибәрә. 1955–93 еллар да «Татнефтегазстрой» берләшмәсенең 32 нче һәм 45 нче махсус идарәләрендә эшли (Бөгелмә ш.). Т. экипажы тарафыннан ОМ-202 экскаваторы камилләштерелә, җайланманың аерым частьларының эшләү сроГы озайтыла. Хезмәтне фәнни оештыру нәтиҗәсендә экскаваторны куллану коэффициенты 1,64 кә кадәр (тармак буенча — 0,85) күтәрелә, траншея казу тизлеге тәүлеккә 600 *м* га җитә. Т. — «Һәр көнне — ике норма» башлангычының инициаторы. «Дуслык» нефть үткәргече, Чаллы-Әлмәт су үткәргече, Миңлебай газ эшкәртү з-ды төзелешләрендә эшләгәндә Т. экипажы 8, 9, 10, 11 нче бишьеллыклар (1966–85) йөкләмәләрен сроГыннан алда (2,5–3,5 ел эчендә) үти. 5 ел эчендә (1971–75) җитештерү 1 млн. $м^3$ дан арта, тармакта бу рекордлы күрсәткеч була. Экипаж базасында Бөтенсоюз алдынгы хезмәт алымнары мәктәбе оештырыла. Герой исеме нефть промыселлары объектлары төзелешендә соц. йөкләмәләрне үтәүдәге һәм хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүдәге уңышлары өчен бирелә. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Әлмәт шәһәренең бер урамына Николай Тюнин исеме бирелә, Геройлар аллеясында аның бюсты куела.

Х е з м.: Труд — это счастье. К., 1980.

Әд.: Герои Социалистического Труда Татарии: Док. очерки. К., 1984. Кн. 2; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

ТЮ́РИКОВА Раиса Павловна (19.2.1940, Лаеш р-ны Лаеш эшчеләр пос.), химик-технолог, биол. фән. канд. (1972), ТР Дәүләт премиясе лауреаты (1996). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1962), 51 нче п/я пр-тиесендә (Горький ш.) инженер булып эшли. 1965 елдан Казан вет. ин-тында, нәорганик һәм биол. химия каф. доценты (1987 дән). Вирус б-н күзәнәкнең үзара тәэсире йогынтысын өйрәнә; мөгезле эре терлекләрдә туберкулёзга диагноз куюның экспресс-ысулын эшли. Дәүләт бүләге мөгезле эре терлекләрдә туберкулёзга диагноз кую, авыруны кисәтү һәм дәвалау чараларын эшләүдә катнашканы өчен бирелә.

Х е з м.: Основы молекулярной биологии: Репродукция пикорнавирусов. К., 1978 (автордаш); Общее правило развития материи: Примеры применения методов диалектики в молекулярной биологии (органическая и биологическая химия). К., 2002.

Әд.: Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.). К., 2006.

ТЮ́РИН Анатолий Николаевич (19.7.1956, Әлмәт ш.), геолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1998), геол.-минерал. фән. канд. (2003). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1981), «Севкавгеология» геол. җитештерү берләшмәсендә (Ессентуки ш.) эшли. 1984 елдан ЦНИИгеолнерудта, 1995 тән Татарстан геол. разведка идарәсендә (2001 дән партиянең баш, 2004 тән идарәнең әйдәп баручы геологы). Татарстан терр-ясендә цеолитлы токымнар чыганакларын беренче ачучылардан. Дәүләт бүләге ТРның утырма тышлыгында яңа төр файдалы казылмалар ачканы өчен бирелә.

ТЮ́РИН Иван Владимирович (3.11.1892, Уфа губ., Минзәлә өязе Югары Юшады а. — 12.7.1962, Мәскәү), туфрак белгече, СССР ФА академигы (1953; 1946 дан мөхбир әгъза). 1919 елда Петров а.х. академиясен (Мәскәү) тәмамлаганнан соң, Казан политехник ин-тында укыта. 1922–26 да а.х. һәм урман чылык ин-тында. Бер үк вакытта, 1922 дән, Казан ун-тында, 1928 дән үзе оештырган туфрак белеме каф. (ш.у. 1926 да үзе оештырган туфрак белеме кабинеты җирлеген дә) профессоры. 1930–41 һәм 1944–51 дә Урман техникасы академиясендә (Ленинград), бер үк вакытта, 1944–52 дә — Ленинград ун-тында. 1941–43 тә Красноярск шәһәрендә эвакуациядә, Себер урман техникасы ин-тында туфрак белеме һәм геол. каф. мөдире. 1930 дан ш.у. СССР ФАнең В.В.Докучаев исем. Туфрак ин-тында (Мәскәү; 1949 дан ин-тның директоры) эшли. Төп хезмәтләре урман һәм урман-дала зонасы



Н.А.Тюнин.



И.В.Тюрин.

туфракларының генезисы һәм классификациясе мәсьәләләренә, туфракларның барлыкка килүендә һәм уңдырышлылыгында органик матдәләрнең роленә карый. Т. тарафыннан туфракларда гумус һәм азот күләмен билгеләү алымнары, гумусның төркем һәм фракцион составын ачыклау методикасы эшләнә. Татарстан АССРда зур масштаблы туфрак-картографик эзләнүләр, туфрак капламын системалы өйрәнә башлау аның исеме б-н бәйле. Т. респ-каның төнъяк-көнбатыш р-ннары туфраклары, ш.и. Казан тирәсендәге, Кама аръягы р-ннарындагы (Спас, Чистай, Минзәлә кантоннарының) нарат урманнары туфракларын тикшерә. 1921–27 дә Респ-ка а.х. тәжрибә станциясендә туфрак тикшеренүләре алып бара. Бөтенсоюз туфрак белгечләре җәмгыяте президенты (1949 дан), «Почвоведение» ж-лының баш мөхәррире (1953 тән). Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр, ш.и. СССР ФАнең В.В.Докучаев исем. алтын медале б-н бүләкләнә. Польша ФА академигы (1956), ГДР Авыл хуҗалыгы академиясе мөхбир әгъзасы (1957). 1972 дән Казан ун-тында ел саен Тюрин укулары үткәрелә.

Х е з м.: Песчаные почвы сосновых боров в окрестностях Казани // Вестн. Казан. с.-х. опытной станции. 1922. № 1–2; К вопросу о генезисе и классификации лесостепных и лесных почв // Уч. зап. Казан. ун-та. 1930. Т. 90, кн. 3–4; Почвы северо-западной части Татреспублики. К., 1933; Почвы Чувашской Республики. М.–Л., 1935; Органическое вещество почвы и его роль в плодородии. М., 1965; Вопросы генезиса и плодородия почв. М., 1966.

Әд.: Колоскова А.В., Шакиров К.Ш. Иван Владимирович Тюрин — основатель кафедры почвоведения Казанского государственного университета // Генезис, свойства и плодородие почв: Материалы к 10 Междунар. конгрессу почвоведов. К., 1975. *Ф.Г.Бөрһанов.*

ТЮРКОЛО́ГИЯ, *төрки телләрдә* сөйләшүче халыкларның телләрен, тарихын, әдәбиятын, фольклорын һәм мәдәниятен өйрәнә торган гуманитар фәннәрнең җыелма атамасы. Баштарак бары филол. фәне рәвешендә, 19 йөз уртасыннан тарих-филол. фәне буларак үсеш ала. Т. тарафыннан өйрәнелүче төп чыганаклар һәм өлкәләр — *Орхон-Енисей ташъязма ядкәрләре*, борынгы һәм урта гасырлардагы төрки язма истәлекләр, урта гасырларда яшәп иҗат иткән гарәп, фарсы һәм төрки телле авторларның әсәрләре, хәзерге төрки телләр. *Мәхмүд Кашгариның* төрки кабиләләр турында шактый мәгълүматлар тупланган борынгы «Диване лөгать әт-төрк»



А.В. Тякин.

(1072–74) хезмәте аеруча зур кыйммәткә ия, анда барлык диярлек төрки телләр дә (якут һәм чуаш телләреннән кала, Кашгари алар ны төрки телләргә кертеп карамый) санап үтелә. Көнбатыш Европа халыклары төркиләр б-н 11–13 йөзләрдә «тәре походлары» вакытында һәм 15–16 йөзләрдә төрекләр нең басып алу сугышлары вакытында якыннан танышалар. Төрек әсирлегеннән яисә сәяхәтләрдән әйләнеп кайткан европалыларның — баварияле Г.Шильбергер, француз Бусино, саксонияле А.Олеарий, фламандлы Г.Рубрук һ.б.ның Төркиягә багышланган беренче язма ядкәрләре 15–16 йөзләргә карый. Төркия дәүләте тарихын фәнни өйрәнүне Й.Гаммер-Пургшталь башлап җибәрә. А.Лызловның «Скифлар тарихы» («История скифская») китабы Россиядә беренче тюркологик хезмәт булып тора, ул аның тарафыннан 1692 елда «оештырыла һәм языла»; анда «татар дип йөртелүче» скифларның төрки телле булулары исбатлана. 18 йөздә Петербург ФА Идел буе, Себер, Урта Азия, Кавказда яшәүче төрки халыкларны өйрәнү максатыннан фәнни экспедицияләр оештыра, борынгы һәм урта гасырлар төрки әдәби һәм язма ядкәрләрне (ш.и. болгар кабер ташъязмалары) планлы рәвештә җыю эшен башлап җибәрә. 18 йөзнең 2 нче яртысыннан, С.Хәлфин, И.Гиганов һ.б.ның эшчәнлекләренә бәйле рәвештә, Т.нең мөстәкыйль юнәлеше буларак *татар халкын өйрәнү гыйльме* формалаша. Казан ун-тында *Шәрекъ бүлеге* ачылганнан соң, Т. төрки телләрне, төрки халыкларның әдәбиятын, тарихын, археол. һәм этнографиясен өйрәнүче комплексы фән буларак үсеш ала. Т.не өйрәнүгә Х.Д.Френ, И.Н.Березин, К.Ф.Фукс, О.И.Сенковский, М.К.Казимбәк, А.О.Мухлинский, Л.З.Будагов һ.б. зур өлеш кертәләр. 1855 тә Петербург ун-тында шәрекъ телләре ф-ты оеша (1919 да 1 нче Петроград ун-тының иҗтимагый фәннәр ф-ты составына керә), акрынлап төрки телләр укыту даирәсе киңәя. 1920 дә Петроградта Үзәк җанлы көнчыгыш телләре ин-ты (1924 тән — Ленинград җанлы көнчыгыш телләре ин-ты, 1927 дән — Ленинград көнчыгыш ин-ты, 1938 дән Мәскәү көнчыгышны өйрәнү ин-ты составына керә) оеша. 1944 тә Ленинград ун-тында төрки филол. каф. б-н берлектә шәрекъ ф-ты дә тергезелә. Мәскәүдә Лазарев көнчыгыш телләре ин-тында ш.у. төрек һәм үзбәк телләре дә укытыла (1815–1918), анда 19 йөз ахырында — 20 йөз башында Т. үсешенә зур өлеш керткән галимнәр Ф.Е.Корш, А.Е.Крымский, В.А.Гордлевский эшли. Лазарев ин-ты җирлегендә Мәскәү көнчыгышны өйрәнү ин-ты төзелә (1921–54). 1943 тә Мәскәү ун-тының филол. ф-тында шәрекъ бүлеге ачыла, аның б-н Н.К.Дмитриев җитәкчелек итә, 1958 дә ул Мәскәү ун-ты каршындагы Азия һәм Африка илләре ин-тына үзгәртелә. Анда Совет чорында һәм соңрак та аз өйрәнелгән һәм өйрәнелмәгән төрки телләрнең фонетикасы, грамматик төзелеше, лексикасы өйрәнелә, төрки телле мәктәпләр өчен уку ярдәмлекләре төзелә. Т. фәнен өйрәнүгә В.В.Бартольд, А.Ю.Якубовский, Н.И.Ашмарин, В.А.Богородицкий, С.И.Руденко, А.Е.Крымский, Г.Г.Ибраһимов, Җ.Җ.Вәлиди, Ә.Р.Тенишев, Н.А.Баскаков, П.М.Мелиоранский, С.Е.Малов, А.Н.Самойлович, Л.Н.Гумилёв, Е.Д.Поливанов, Н.К.Дмитриев, А.Н.Кононов, А.М.Щербак һ.б. шактый өлеш кертәләр. Т. мәсь әләләре Мәскәү һәм С.-Петербургтагы РФ ФАнең Шәрекъне өйрәнү, Тел белеме, Этнография, Археол. ин-тларында, ТР ФАнең Тарих ин-тында, ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында, Казан ун-тында, ш.у. Әзәрбай җан, Казакъстан, Төрекмәнстан, Үзбәкстан, Башкортстан, Чуаш, Алтай, Тува, Хакас, Карачай-Чиркәс, Кабарда-Балкар, Дагстан һ.б. респ-каларның Шәрекъне өйрәнү ин-тларында һәм ФА бүлекләрендә өйрәнелә. Чит ил Т.се, нигездә, тарихи-филол. тикшеренүләр чикләрендә үсеш ала. Төркиядә төрек тарихы (1931 дә нигез салына) һәм лингвистика (1932) җәмгыятьләре, Әнкара һәм Истанбул ун-тларының тел, әдәбият, тарих һәм геогр. ф-тлары Т. үзәге булып тора. Тюркологик тикшеренүләр б-н ш.у. Австрия, Болгария, Бөекбритания, Венгрия, ГФР, Дания, Иран, Италия, Канада, Румыния, АКШ, Финляндия, Франция, Швейцария, Югославия, Япониядә дә шөгыльләнәләр.

1998 елга 7 тюркология конференциясе (ш.и. Казанда да) уздырыла (к. *Тюркологлар ның алтынчы конференциясе*).

Әд.: Кононов А.Н. Тюркская филология в СССР. 1917–1967. М., 1968; шул ук. История изучения тюркских языков в России: Дооктябрьский период. Л., 1972; Биобиблиографический словарь отечественных тюркологов. М., 1974; Милибанд С.Д. Биобиблиогр. словарь отечественных востоковедов с 1917 г.: В 2 кн. М., 1995; Юдакин А.П. Урало-алтайское (тюрко-монгольское) языкознание: Энцикл. М., 2001.

М.З.Зәкиев.

ТЮРКО́ЛОГЛАРНЫҢ АЛТЫНЧЫ́ КОНФЕРЕ́НЦИЯСЕ, 1992 елның 9–13 июнендә Казанда Тюркологларның бөтенсоюз съездларының (беренчесе 1926 да Бакуда, икенчесе — 1976 да Алма-Атада, өченчесе — 1980 дә Ташкентта, дүртенчесе — 1988 дә Бишкекта) дәвамы буларак уза. Советлар Союзы таркалганнан соң, Т.а.к.гә халыкара статус бирелә. Оештыручылары — РФА, ТР ФА; рәисе М.Х.Хәсәнов. Илебез һәм чит ил (Англия, Франция, Италия, Төркия, Япония, Венгрия, Германия, Кипр) тарихчылары, тюркологларның (Казаннан — Д.Г.Тумашева, А.Х.Халиков, М.Г.Госманов, Я.Г.Абдуллин, Ф.С.Хәким җанов, Ә.Г.Кәримуллин; Мәскәүдән — Ә.Р.Тенишев, В.В.Трепавлов; Төркиядән — Н.Дәүләт, Ә.Тимер, И.Бинарк; Венгриядән — М.Иванич; АКШтан — Ф.Аллан һ.б.) 262 доклады тыңлана. Тел белеме, әдәбият белеме, фольклор, историография һәм тарих секцияләре эшләгән элеккеге төрки съездлардан аермалы буларак, Т.а.к.ндә өстәмә рәвештә культурология, иҗтимагый һәм фәлсәфә фикер тарихы, дин һәм милләтара мөнәсәбәтләр секцияләре эшли. Гуманитар фәннәрнең төп максаты буларак һәр җирдә милләтләрне, милли телләрне һәм мәдәниятләрне саклау, үстерү, торгызу билгеләп үтелә; 23 пункттан торган тәкъдимнәр кабул ителә. Тәкъдимнәрдә тюркологларның бөтендөнья ассоциациясен булдыру; төрки халыкларының репрессияләнгән эшлеклеләре иҗатын тирәнтен өйрәнү; барлык төрки телләрнең акрынлап латин графикасына күчүләре; төркиләрнең объектив тарихын эшләү; элеккеге СССР терр-ясе буйлап барлык төрки топонимнарны торгызу; төрки халыкларның музыка сәнгатен өйрәнүне көчәйтү күздә тотыла. Т.а.к. беренче Бөтендөнья татар конгрессында катнашучыларга мөрәҗәгать кабул итә, анда конгрессның Татарстанның дәүләт суверенлыгын алга таба ныгыту турындагы резолюциясе хуплана. Конференция материаллары буенча «Төркиләрнең телләре, рухи мәдәниятләре һәм тарихчылары: традицияләр һәм хәзерге заман» («Языки, духовная культура и история тюрков: традиции и современность». Т. 1–3, 1992–97) басмасы нәшер ителә.

Ф.Г.Кәлимуллина.

ТЯ́КИН Анатолий Владимирович (9.3.1923, Казан — 9.6.1986, шунда ук), Дан орденының тулы кавалеры (23.8.1944, 16.11.1944, 29.6.1945), гв. кече сержанты. 1938–42 елларда Казанда авиация з-дында эшли. 1943 елның февраленнән Кызыл Армиядә, Бөек Ватан сугышы фронтларында, 59 нчы гв. танк бригадасында (2 нче гв. танк армиясенең 8 нче гв. танк корпусы) автотранспортлы автоматчылар батальоны разведчигы. 1 нче һәм 2 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Умань-Ботошани, Люблин-Брест (икесе дә — 1944 тә) һәм Көнчыгыш Померания (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 28 июлендә Миканув (Люблин шәһәреннән төньяктарак, Польша) торак пункты янындагы сугышта (беренчеләрдән булып, дошман траншеясына үтеп керә, граната б-н 7 дошман солдатын һәм офицерын, пулемётларын юк итә); 1944 нең 12 сентябрендә Прага (Варшава бистәсе) торак пункты өчен барган сугышта (дошман автоматчылары б-н сугышта дистәдән артык солдатны юк итә); 1945 нең 6 февралендә Ломп (Көнчыгыш Пруссия) торак пункты өчен барган сугышта (сугышның иң авыр мизгелендә взвод б-н җитәкчелекне үз өстенә ала, сугышчыларны һөҗүмгә күтәрә, берничә дошман солдатын юк итә, офицерын әсирлеккә ала) батырлык күрсәтә. 1949 дан запаста, Казанда авиация з-дында эшли. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

М.З.Хәбибуллин.

У

УБА́ авылы, Баулы р-нында, Баулы шәһәреннән 21 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Ык елгасы буенда. 2010 елда 311 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб, китапханә. 1920 елларда нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Бөгелмә кантоны Баулы волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1935 нең 10 февраленнән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Баулы р-нында. Халык саны: 1926 да — 120, 1938 дә — 232, 1949 да — 280, 1958 дә — 273, 1970 тә — 596, 1979 да — 531, 1989 да — 322, 2002 дә — 303 кеше.

УБА́ РАЙОНЫ́, *Новосибирск өлкәсенең* төньяк-көнбатышында, Бараба үзәнлегендә урнашкан. 1925 елда оештырыла. Мәйданы — 13,8 мең *км*^{2}. Үзәге — Уба авылы. Халкы — 14696 кеше (2017). Татарлар — 2002 дә —841, 2010 да — 703 кеше (2002). Тупланып Уба (326 кеше), Базиллар (Яңа Качёмка) (114) авылларында яшиләр. У.р. терр-ясенә Себер татарлары элек-электән килеп урнаша. Урта Идел буеннан күченүчеләр монда 20 йөз башында, Столыпинның аграр реформасы б-н бәйле рәвештә, барлыкка килә. 1912 дә алар Базиллар авылына нигез сала, мәчет төзи (1924 тә яңыла). 2011 дән Уба авылында Новосибирск өлкәсенең татар милли-мәдәни автономиясе бүлекчәсе эшли. 2009/10 уку елында 2 нче мәктәптә татар телен өйрәнү факультатив дәрес буларак оештырыла. Базиллар авылында «Шатлык» яшьләр коллективы (1998 дән), «Сандугач» вокаль коллективы, «Салават күпере» балалар татар теле түгәрәге (икесе дә 2010 нан) эшли, татар спектакльләре куела; мәчет эшли (1994 тән). *Ураза бәйрәме, Корбан бәйрәме, Сабан туе, Нәүруз* бәйрәм ителә.

УБЫ́Р, төрки халыклар мифологиясе һәм фольклорында кешеләрнең эченә кереп, алар б-н идарә итүче кан эчкеч явыз рух (У.га охшаш персонаж чуашлар (вупар) һәм славян-нар (упырь) фольклорында очрый). Эченә У. кереп утырган кешене «убырлы кеше» дип йөрткәннәр (к. *Убырлы карчык*). Көнбатыш Себер татарларында У. — үлгән сихерченең яки үз-үзенә кул салучының җаны. Ышанулар буенча, У.ны тотып булмый, ул ут йомгагына әверелә һәм очкын булып сибелеп юкка чыга. У. яшь терлекләрне урлый, сыерларның сөтен һәм канын суыра, кешеләргә авырулар җибәрә. Убырлы кеше үлгәннән соң, У. аның каберендә яши, төннәрен чыгып йөри; каберенә имән казык кагып кына аннан котылып була дип саналган. У. татар халык әкиятләрендә («Убыр» һ.б.), мәкаль һәм әйтемнәрдә («Убыр симермәс, угры баемас»; «Убыр упкан табылмас, пәри суккан сау булмас» һ.б.), йола фольклорында һ.б.да очрый.

Әд.: Татар халык иҗаты: Риваятьләр һәм легендалар. К., 1987. *Ф.И.Урманчеев.*

УБЫ́Р УТЫ́, к. *Шайтан таягы.*

УБЫРЛЫ́ КАРЧЫ́К, татар һәм башкорт фольклорында, эченә *убыр* кереп утырган карчык. Рус фольклорындагы Баба-яга образына якын. Төрле предметларга (дегет мичкәсе, утлы тәгәрмәч һ.б.), хайваннарга (бүре, мәче, тычкан һ.б.) әверелә ала. Әкиятләрдә У.к. — башлыча тискәре персонаж, кешегә дошман булган көч. Карчык рәвешенә кереп, геройның ышанычын яулый, канын суыра, аны ашый, суга батыра, ташка әйләндерә («Әйгали батыр», «Гөлчәчәк», «Ике туган» һ.б. татар халык әкиятләре). Кайбер әкиятләрдә У.к.ның асылда иблис икәнлеген аңлап алган герой, фаш итү б-н янап, аны үзенә хезмәт итәргә мәҗбүр итә. Ул «Таңбатыр» татар халык әкиятендә авыруларны йотып, аларны сау-сәламәт килеш төкереп чыгара; «Үги кыз» әкиятендә ярлы кызга байлык бирә. Кайбер тикшеренүчеләр әлеге образны зирәк карчыклар өстенлек иткән матриархат чоры б-н бәйлиләр.

Әд.: Татар халык иҗаты: Әкиятләр. К., 1977. 1 кит.; 1978. 2 кит.; Татар халык иҗаты: Риваятьләр һәм легендалар. К., 1987; Пропп В.Я. Исторические корни волшебной сказки. Л., 1946.

Ф.И.Урманчеев.

УВА́ РАЙОНЫ́, *Удмурт Республикасының* үзәк-көнбатыш өлешендә урнашкан. 1935 елның 23 гыйнварында оештырыла. Мәйданы — 2445 *км*^{2}. Үзәге — шәһәр тибындагы Ува посёлогы (Ижевскидан 96 *км* көнбатыштарак). Халкы — 38134 кеше (2017). Татарлар саны: 1959 да — 1279, 1970 тә — 926, 1979 да — 781, 1989 да — 886, 2002 дә — 919, 2010 да — 811 кеше. У.р. терр-ясендә татарлар 1920 елларда яшиләр, агач эшкәртү сәнәгатендә эшлиләр. 2010 да У.р. татарларының мили-мәдәни автономиясе оештырыла. Увада мәчет эшли, *Сабан туе* үткәрелә.

УВА́Т РАЙОНЫ́, *Төмән өлкәсенең* көнья-гында урнашкан. 1925 елның 14 гыйнварында оештырыла. Мәйданы — 48 мең *км*^{2}. Үзәге — Уват авылы. Халкы — 19125 мең кеше (2017), 2010 елгы халык исәбе буенча, 964 татар яши. Себер татарлары У.р.на 16 йөзнең 2 нче яртысында килеп урнаша, 18 йөздә — 20 йөз башында 4 авылда: Берёзовка Йорты (1782 дә — 75 кеше), Ясаул Йорты (1782 дә — 80, 1910 да — 162 кеше), Кәрбен Йорты (тиңдәшле рәвештә — 122 һәм 245), Өге Йорты (25 һәм 137 кеше) авылларында яшиләр. Авыл саен мәчет була. Халкының төп шөгыле — игенчелек, балыкчылык, сунарчылык, агач сату, кыргый үсемлекләр һәм әрбет чикләвеге җыю. Совет чорында татарлар саны кими. 1950 елларда — Берёзовка Йорты, 1983 тә — Ясаул Йорты, 2001 дә Кәрбен Йорты авыллары юкка чыга. У.р.нда бер генә татар авылы — Өге (Уки) (2010 да — 207 кеше) кала. 1930–2005 елларда татар мәктәбе, 1994 тән мәчет эшли. Ел саен *Сабан туе* уздырыла.



С.А. Уганин.

УГА́НИН Семён Артемьевич (7.1.1924, Буа кантоны Матак а. — 18.7.1959, Норильск ш.), Сов. Союзы Герое (13.9.1944), өлкән сержант. Туган авылында колхозда эшли. 1942 елның августыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 360 нчы укчы полк (40 нчы армия-нең 74 нче укчы дивизиясе) 2 нче миномётчылар ротасының миномётчылар расчёты командиры. 1 нче һәм 2 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Белгород–Харьков (1943), Умань–Ботошани (1944) һәм Дебрецен (1944) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 28–30 мартында Трестияны авылы янында (Молдавиянең Бричаны р-ны) Днестр елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә: беренчеләрдән булып үз расчёты б-н су киртәсен узып, басып алынган плацдармда ныгып урнаша. Капиотаны авылы янындагы терәк пунктына һөҗүм вакытында дошман тарафыннан камап алына. Миномётчылар берничә сәгать дәвамында, төп көчләр килеп җиткәнче, дошман һөҗүмен кире кайтаралар, күпсанлы солдатларын юк итәләр. Демобилизациядән соң «Таймыр» (Норильск) рудниги-нда проходчик булып эшли. Ленин ордены, Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

М.З.Хәбибуллин.

УГЛО́В Александр Тихонович (30.1.1884, Самара губ. Григорьевка-Колцовка а. — 21.2.1938), радиоинженер, конструктор. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1911), Сызрань һәм Самара шәһәрләрендә укыта. 1915 елдан Петроградтагы Офицерлар электр техникасы мәктәбендә эшли, 1918 дән Кызыл Армия баш хәрби-инженерлык идарәсендә радио техникасы лаб-ясен җитәкли. 1919–23 тә Казан радиотелеграф берләшмәләренең 2 нче базасы башлыгы. 1923–28 дә Үзәк радио лаб-ясенең хәрби бүлеге мөдире (Петроград). 1929 дан Түбән Новгородта: Үзәк хәрби-сәнәгый радио лаб-ясен оештыра һәм аны җитәкли, Коминтерн исем. радио з-дында эшли, уку йортларында укыта. Хәрби радио элемтәсе өчен кирәкле лампа аппаратурасын эшләүчеләрнең берсе. У. җитәкчелегендә Ка-



А.Т. Углов.

занда беренче репродукторлар җитештерелә, чыбыклы телефон буенча сөйләшү ераклыгын арттыру өчен чаралар күрелә, радиопеленгатор станцияләре төзелә, бөтен гаскәр төрләре өчен радиостанцияләр эшләнеп, сериялә җитештерүгә кертелә. 1921 дә У. «чыбыксыз ерак ара телефонының беренче рус схемасын» эшләгәне өчен, Халык Хуҗалыгы Югары Советы фәнни-техник бүлегенең уйлап табу эшләре буенча ком-тының бүләгенә лаек була (к. *Углов көчәйткече*). Репрессияләнә (1937); үлгәннән соң аклана. Түбән Новгород шәһәрендә бер урам аның исемен йөртә.

Х е з м.: Усилительные лампы в телефонии и телеграфии без проводов. П., 1917.

Әд.: О р л о в а А.Ф. Время и связь: Очерки по истории связи в ТАССР. К., 1988; А л е к с е е в Т.В. Александр Тихонович Углов: страницы биографии // Тр. Военно-косм. акад. им. А.Ф. Можайского. СПб., 2010. № 629; Связь России: Биогр. энцикл. М., 2008.

УГЛО́В КӨЧӘЙТКЕЧЕ́, электр сигналлары параметрларын ярдәмчел чыганак энергиясеннән файдаланып арттыручы прибор. 1920 елда Казан радиотелеграф формалаштырулары базасында А.Т.Углов тарафыннан 30 *Вт* чамасы чыгыш куәтендәге 12 лампалы өч каскадлы түбән ешлыклы сигналлар көчәйткече эшләнә. Бу җайланма чыбыклы телефон элемтәсенең ераклыгын шактый дәрәҗәдә арттыру мөмкинлеге тудыра. У.к.ннән файдалану нигезендә Россиядә тәүге репродукторлар ясала: көчәйткечнең чыгыш урынына телефон тоташтырылып, телефонның саклагыч капкачы кертелә торган рупор ясала. Бу җайланма ярдәмендә кычкырып әйтелгән сүзләр репродуктордан 500 *м* ераклыкта да яхшы ишетелә. 1921 дә У.к. Мәскәүдәге Үзәк телефон станциясенең халыкара линияләрендә, ш.у. Россия телеграф агентлыгының хәбәрләрен яңгырату өчен башкала-ның алты җирендә урнаштырылган репродукторлар конструкциясендә кулланыла.

Әд.: О р л о в а А.Ф. Время и связь: Очерки по истории связи в ТАССР. К., 1988; А л е к с е е в Т.В. Александр Тихонович Углов: страницы биографии // Тр. Военно-косм. акад. им. А.Ф. Можайского. СПб., 2010. № 629.

«УГРА́ БУЕНДАГЫ́ КАПМА́-КАРШЫ́ ТОРУ́», 1480 елда Угра елгасында (Ука (Ока) кушылдыгы) Олы Урданың *Әхмәд хан* б-н Мәскәүнең бөек кенәзе *Иван III* Василь-евич хәрби көчләренең капма-каршы торуы. Иван III нең Урдага тиешле еллык ясакны түләмәвеннән килеп чыга (1470 еллар). 1480 дә Әхмәд хан Руська яу б-н килә, ул хан өчен уңайлы шартларда үтә: Әхмәд хан Польша-Литва короле Казимир IV б-н солых килешүе төзи (Казимир хәрби ярдәм вәгъдә итә); Ливон ордены рус җирләренә һөҗүм ясый; удел кенәзләре — Иван III нең берутганнары Андрей Большой һәм Борис тарафыннан фетнә күтәрелә. Яуда шактый күп көчләр катнашкан дип фаразлана. Гаскәрләр рус чигенә Дон һәм Ука елгалары субүләре буйлап хәрәкәт итәләр. 1480 нең 8 октябрендә Угра елгасына чыгалар һәм аны кичәргә омтылалар, ләкин Иван III нең улы (Иван Молодой) һәм бертуганы (Андрей Меньшой) җитәкчелегендәге рус гаскәрләре аларны чигенергә мәҗбүр итәләр. 8–11 октябрьдә җәяче-ләр һәм артиллерия тарафыннан утка тотылган Әхмәд хан отрядларының Угра елгасының сулъяк ярына чыгарга омтылышы барып чыкмый. Соңыннан, чыганакларда күрсәтелгәнчә, Әхмәд хан «елганы кичү мөмкин булмаганлыктан, Угра елгасыннан ике чакрымга чигенә, Лузада туктап, гаскәрен бөтен Литва җиренә тарата». Хан рус оборонасын өзү омтылышын туктатмый, шундый һөҗүмнәрнең берсе Угра тамагыннан 60 *км* өстәрәк Опаков шәһәрчеге тирәсендә кире кайтарыла. Капма-каршы торганда Әхмәд хан б-н Иван III арасында сөйләшүләр була; Әхмәд ханның ставкасы б-н Лужа елгасы буендагы Кременцта урнашкан Иван III гә аның шәхсән килеп, үзенә буйсынуын белдерү һ.б. турындагы таләбе руслар тарафыннан кире кагыла. Угра елгасында туңгач, 26 октябрьдә рус гаскәрләре Кременцка, соңрак Протва елгасының уңъяк ярындагы Боровскка таба чигенәләр. Бу вакытка алар Новгород җирләренән килгән Андрей Большой һәм Борис отрядлары б-н көчәйтеләләр. Иван III алар б-н килешүгә ирешә. Әхмәд хан Угра елгасын кичеп сугышка керергә батырчылык итми. Аның гаскәрләре 9–11 ноябрьдә көньякка чигенә башлый. Планнарының үзгәрүе аркадаш булмау (король Казимир IV көтеп тору позициясенә баса), Русьта ызгыш-талашлар тукталу, каты салкыннар башлану, атларга азык җитмәү һәм гаскәрнең азык-төлеге бетү б-н бәйле булуы ихтимал. 1481 нең гыйнвары башында Әхмәд хан Себер ханы Ибакъ (башка мәгълүматлар буенча нугай морзасы Ямгурчы) тарафыннан үтерелә. Тарихчы К.В.Базилевич сүзләренә караганда, Әхмәд ханның үлеме б-н «...Рус җирендә хан хакимиятен торгызу... омтылышы уңышсыз тәмамлана».

Әд.: П р е с н я к о в А.Е. Иван III на Угре // С.Ф. Платонову ученики, друзья и почитатели. СПб., 1911; Б а з и л е в и ч К.В. Внешняя политика Русского централизованного государства: Вторая половина XV в. М., 1952; К а р г а л о в В.В. Конец ордынского ига. М., 1984; А л е к с е е в Ю.Г. Походы русских войск при Иване III. СПб., 2007.

И.Р.Вәлиуллин.

УГРЮ́МОВ Олег Викторович (12.7.1969), Мордовия АССРның Зубова Поляна р-ны, Зубова Поляна штп.), нефть химиясе белгече, техник фән. д-ры (2010). Казан технол. ун-тын тәмамлаганнан соң (1993) ГИПОда, 1995–99 елларда РФА КГҮнең органик һәм физик химия ин-тында эшли. 1999дан башлап «Нефть промыселы химиясе фәнни-тикшеренү институты» АҖсында (Казан): лаб. мөдире (2003тән), ген. директор урынбасары (2006 тән), бер үк вакытта «Химтехно» фән-ни-җитештерү үзәге» АҖнең ген. директоры (2011дән). Хезмәтләре органик синтез өлкәсенә карый. У. функциональ җәһәттән алмаш азотлы һәм фосфоразотлы продуктлар-ның нефть промыселы реагентлары компонентларының синтезын гамәлгә ашыра. У. бер төркем синтезлаштырылган кушылмаларның тозлы-әче, углекислоталы һәм күкерт-водородлы мохитләрдә коррозиягә каршы үзлекләре барлыгын, бактерицид активлык күрсәтүен һәм иярчен табылган суларда нефть продуктларының калдыкларын азайтуга сәләтле булуын ачыклый. Уйлап табуга 10 нан артык автор таныклыгы һәм патенты бар.

Х е з м.: Опыт применения новых ингибиторов коррозии марки СНПХ на месторождениях Западной Сибири // Нефт. хоз-во. 2004. № 6 (автордаш); Азотсодержащие ингибиторы коррозии нефтепромыслового оборудования. К., 2009 (автордаш); Исследование защитного действия ингибитора коррозии СНПХ-6438 в солянокислых средах // Изв. вузов. Химия и хим. технология. 2009. Т. 52, вып. 9 (автордаш).

УГРЮ́МОВА Валентина Степановна (21.6.1947, Мордовия АССРның Зубова Поляна пос.), вет. токсикологы, вирусолог, вет. фән. д-ры (1992), проф. (1993), ТР һәм РФнең атказ. фән эшлеклесе (1997, 2004). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1971), шунда ук эшли. 1984–2007 елларда Бөтенроссия вет. фәнни-тикшеренү ин-тында, 1997 дән вирусология лаб-ясендә баш фәнни хезмәткәр. 2007–09 да «Татарстан төбәкара ветеринария лабораториясе» Федераль дәүләт учреждениесендә токсикология, биохимия һәм микология бүлеге мөдире һәм директор урынбасары. 2010 нан «Фосфорос» ҖЧҖнең ген. директоры урынбасары. Хезмәткәре гамәли вет. өчен «Йодохлорин» (1993), «Натамин» (2003), «Глуфар» (2003), «Натопен» (2010) дәвалау-профилактика һәм дезинфекция препаратларын эшләүгә карый. Уйлап табуга 39 автор таныклыгы һәм патенты бар. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1997).

Х е з м.: Ультраструктуры внутренних органов при отравлении животных диоксином // Ветеринария. 2004. № 7 (автордаш); Действие йодохлорина на организм пчелы // Пчеловодство. 2003. № 3 (автордаш); Диагностика: точно и быстро // Agricultura. 2008. № 2 (автордаш).

Әд.: Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.): Биогр. словарь учёных. К., 2006.

Р.Г.Госманов.

УГЪЛА́Н (борынгы төркителдә — бала, яшүсмер, егет; поляк телендә — ulan), 1) Чыңгызыйлар дәүләтләрендә хан нәселеннән булган ир бала титулы. Дәрәҗәсе буенча әмир һәм морзалардан югарырак баскычта торган. Соңрак Алтын Урда б-н татар ханлыкларында У. атамасы хәрби хезмәттәге аксөякләргә һәм сөңге б-н генә коралланган атлы җиңел гаскәриләргә күчкән. 2) 18–20 йөзләрдә Европа армияләрендә (Россиядә 19 йөздән) җиңел кавалерия гаскәриләре атамасы.

М.Г.Госманов.

УГЫЗЛА́Р, Арал диңгезе тирәсендә һәм Урта Азиядә яшәгән төркиләр халык. 9 йөздә кабиләләрнең телес берләшмәсе таркалганнан соң, Арал диңгезе тирәсендәге далаларда һәм Устюрт яссы таулыгында оеша. Төп шөгыльләре — күчмә терлекчелек, Устюрт яссы таулыгындагы сәүдә юлларын саклау. Диннәре — мәҗүсилек, шаманлык зур роль уйный. У.ның мәет күмү йоласына хас элемент — үлгән кеше каберенә махсус элгечтә ат тире-

се, ат дирбиясе, сугыш кораллары (ир-атларга), бизәнү һәм көнкүреш әйберләре (хатын-кызларга), балчык савытларда азык салып калдыру. У.ның бер өлеше хәзәрләргә бәйле була, аларны *бәҗәнәкләр* б-н көрәштә хәрби көч буларак файдаланалар. 965 елда У., Киев кенәзе *Святослав I* б-н аркадаш булып, *Хәзәр каганлыгы* гаскәрләрен тар-мар итәләр. 985 тә кенәз *Владимир I* б-н *Идел буе Болгар дәүләтенә* яу б-н баралар. У. 11 йөз башында Арал диңгезе тирәсендәге *кыпчаклар* тарафыннан тар-мар ителә, шуннан соң аларның бер өлеше көнбатышка китә, алар анда «төркиләр» исеме б-н билгеле булалар. 1015 тә У.ның бер өлеше Төньяк Кара диңгез буе далаларын басып ала; сәлҗүкләр кланы җитәкчелегендәге икенче төркем Тогрул бәк б-н Хорасанга җитә, 1040 та анда тулысынча диярлек Алгы Азияне һәм Якын Көнчыгышны берләштергән Сәлҗүкләр дәүләте оеша. 11 йөз уртасында Төньяк Кара диңгез буе далаларындагы У. кыпчаклар тарафыннан тар-мар ителә. Кайберләре кыпчак кабиләләренә кушыла, кайберләре рус җирләренең көньяк чикләренә кадәр качалар һәм, бәҗәнәкләр б-н берләшеп, төркиләрнең тулы бер өлкәләрен хасил итәләр (Киев янындагы үзәге Торцк шәһәре булган «кара бүреклә» (рус елъязмаларында — «чёрные клобуки»), Чернигово янында «ковуйлар»), бер төркем Венгриягә кача. У. төрекмәннәр, әзәрбайҗаннар һәм төрекләр этногенезында мөһим роль уйный. У.ның кайбер төркемнәренең казакълар, каракалпаклар, үзбәкләр, башкортлар һәм татарлар этногенезында катнашуы сизелә.

Әд.: Расовский Д.А. Печенеги, торки и берендеи на Руси и в Угрии // Seminarium Kondakovianum. Praga, 1933. Т. 6; Плетнёва С.А. Печенеги, торки и половцы в южнорусских степях // Материалы и исследования по археологии СССР. М., 1958; шул ук. Древности Чёрных Клобуков. М., 1973; Гордлевский В.А. Государство Сельджукидов Малой Азии. М., 1960; Агаджанов С.Г. Очерки истории огузов и туркмен Средней Азии IX–XIII вв. Аш., 1969; шул ук. Государство Сельджукидов и Средняя Азия в XI–XII вв. М., 1991; История татар с древнейших времён. В 7 т. Т. 2: Волжская Булгария и Великая Степь. К., 2006. *И.Л.Измайлов.*

«УГЫЗНАМӘ» («Угыз кыйссасы»), 1) төрки-угызларның легендар шәҗәрәсе һәм аларның атасы Угыз каган (Угыз хан) турында эпик истәлекләр комплексы; 2) «*Китабе дәдам Коркыт*» төрки эпик ядкәренең 12 хикәятенең һәрберсе. «У.»нең урта гасырлардагы төрекмән, төрек, уйгыр телләрендәге кулъязмалары һәм аерым өзекләре сакланган. Иң борынгысы — 13–14 йөзләрдәге карлук-уйгыр версиясе (15 йөздә язып алынган, Париж милли китапханәсендә саклана). 17 йөздә Хива ханы Әбелгазый Баһадур хан эпосның «Төрекмәннәр шәҗәрәсе» («Шәҗәрә-и төрәкимә»), «Төркиләр шәҗәрәсе» («Шәҗәрә-и төрк») исемле мөселман версияләрен иҗат итә. Дастанның теле, төзелеше, аерым кисәкләре 18–20 йөзләр татар әдәбиятына йогынты ясый. «У.» мотивларына таянып, Ф.Бурнаш «Коркыт» (1916) поэмасын яза.

Әд.: Щербак А.М. Огуз-наме. Мухаббат-наме. М., 1959.

УГЯ́НСКИЙ Андрей Онуфриевич (1816, Вильно губ. — 7.10.1870, Казан), филолог. Казан ун-тының филос. ф-тын тәмамлый (1845). 1846 елдан — Сембердәге, 1849 дан Казандагы Беренче ир балалар гимназияләрендә эшли. 1861 дән Казан ун-тында грек теле һәм әдәбияты, борынгы ядкәрләрне өйрәнү өлкәсе профессоры. Литва теле сүзлеген төзү б-н шөгыльләнә, аның өчен якынча 100 мең сүз җыя.

Әд.: Казанский государственный университет (1804–2004): Библиогр. словарь. К., 2002. Т. 1.

«УДАЛО́Е», тары сорты. 1991 елда Татарстан А.х. фәнни-тикшеренү ин-тында Л.Г.Сәгъдиева, И.А.Щурина, Ф.М.Никитина, Л.С.Павлова тарафыннан чыгарыла. Тиз өлгерешле, вегетация чоры 60–65 көн, сөрлегүгә чыдам. Тәбәнәк, нечкә ныксабаклы, аз яфраклы үсемлек. Себеркәче салынкы, көпшәк (йомшак), аз бөгелүчән. Яфраклары, сабаклары һәм башак тәнкәләре антоциан төстә. Бөртеге аксыл сары төстә, ярым түгәрәк. 1000 бөртекнең авырлыгы 6,8–7 *г*. Ярмасында 16,5% аксым бар. «У.» сорты 1994 тә РФнең Идел-Вятка һәм Көнчыгыш Себер төбәкләрендә чәчәргә рөхсәт ителә.

Әд.: Каталог научно-технической продукции. К., 2005.

«УДА́РНИК», иҗтимагый-сәяси газета. ВКП(б)ның Чусовой шәһәр ком-ты, хезмәт ияләре депутатларының шәһәр советы һәм профсоюзларның шәһәр советы органы. 1931 елның сентябреннән 1939 га кадәр Чусовой шәһәрендә (Пермь өлкәсе) атнасына 1–3 тапкыр татар телендә нәшер ителә (600 дән артык сан). Мөхәррирләре — М.Кәһиров, А.Шакиров, М.Кумаитов, А.Әхсәнов, Т.Бикиев, И.Крымов һ.б. Актив авторлары арасында — М.Кумаитов, И.Йосыпов, А.Шакиров, Ш.Сөләйманов, Н.Кәбиров, М.Сафин. Газета үзенең максаты итеп эшчеләрнең җитештерү планын арттырып үтәүгә мобилизацияләүне куя. Төбәктә кара металлургия, урман әзерләүне үстерү мәсьәләләре яктыртыла. Эшче татарлар арасында партия-сәяси, мәдәни-агарту, профсоюз һәм комсомол эше проблемалары күтәрелә. Соц. ярыш барышына һәм алдынгылар казанышын пропагандалауга зур игътибар бирелә. Беренче елларында басманың күп кенә мәгълүматы төбәк характерында була (җирле пр-тиеләр проблемаларына багышлана); 1939 да бөтенсоюз һәм халыкара мөнәсәбәтләр югарылыгындагы сәяси тематика өстенлек ала. Партиянең җитәкче органнары, хакимиятнең җирле органнары материаллары һәм аларга аңлатмалар, партия лидерлары докладлары һ.б. урнаштырыла. Чусовой р-нында наданлыкны бетерү буенча алып барылган эшләр яктыртыла; 1939 да кириллицага күчү проблемалары турында фикер алышына, даими рәвештә татар театрлары спектакльләренә рецензияләр урнаштырыла. 1939 да, мәс., редакция Г.Камалның Чусовой шәһәрендә татар эшчеләренең үзешчән театр коллективы куйган «Банкрот» комедиясе турында фикер алышу уздыра. Казанда нәшер ителгән татар китаплары турында белешмә басыла. 1931 нең 1 октябреннән «У.» башлангычы б-н җирле радиода татар телендә радиогазета оештырыла. *З.З.Гыйләҗев.*

«УДА́РНИК», иҗтимагый-сәяси газета. Украина КП(б)ның Горловка шәһәр ком-ты, эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатларының шәһәр советы, профсоюзларның шәһәр советы органы. 1932 елның гыйнварыннан 1934 нең мартына кадәр Горловка шәһәрендә (Сталин өлкәсе) атна саен татар телендә нәшер ителә (100 дән артык сан). Мөхәррире — Х.Сигнатуллин, Фәхретдинов. Актив авторлары арасында — З.Хәлиуллин, Х.Садыйков, Х.Гыймадов һ.б. Газетада җитештерү ударниклары һәм отличниклары, соц. хезмәт алдынгылары хәрәкәте пропагандалана. Донбасс өлкәсендәге күмер тармагын үстерү мәсьәләләре яктыртыла. Сталин өлкәсендә яңа пр-тиеләр төзелешенә багышланган язмалар дөнья күрә, көнүзәк темалар арасында Горловкада беренче трамвай линиясе һәм стадион төзелеше, аэроклуб, автобус маршрутлары ачу була. Татар эшчеләре һәм авыл хезмәтчәннәре арасында партия-сәяси, мәдәни-агарту, профсоюз һәм комсомол эше мәсьәләләре күтәрелә, Татар эшчеләренең 1932 нең мартында узган Бөтенукраина конференциясе барышы турында хәбәр ителә, рапортлар, җитештерү планын арттырып үтәүгә чакырулар (алар арасында 2 нче төбәк съезды шахтёр-ударникларның Донбасс татар шахтёрларына мөрәҗәгате) басыла, балаларны тәрбияләү, мәгариф, наданлыкка каршы көрәшү, кооперацияне үстерү, колхозларга ярдәм һ.б. мәсь әләләр турында фикер алышына. Бөтенсоюз һәм җирле татар матбугатына күзәтү урын ала.

З.З.Гыйләҗев.

«УДА́РНИК», газета, к. «*Коммунизмга*».

«УДА́РНИК БАЙРАГЫ́», иҗтимагый-сәяси газета. Украина КП(б)ның шәһәр ком-ты, эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатларының шәһәр советы, профсоюзларның шәһәр советы органы. 1932 елның 29 гыйнварыннан 1934 нең мартына кадәр Сталин өлкәсе Рыково шәһәрендә (хәзерге Донецк өлкәсе Енакиев шәһәре) — 10 көнгә 1 тапкыр, 1932 нең 26 февраленнән — атнага 1 тапкыр, 1932 нең 29 июненнән 5 көнгә 1 тапкыр татар телендә нәшер ителә (якынча 50 сан). Мөхәррирләре — 1932 нең 29 гыйнварыннан — Әхмәт җанов, 1932 нең 26 февраленнән — Михайлов, 1932 нең 23 августыннан — Кауфман, 1932 нең 5 октябреннән — А.Котляр, 1933 нең 11 августыннан А.Ибраһимов. Актив авторлары арасында — Б.Җәмилев, Зәйнетдинов, А.Ибраһимов, М.Мостафин. «У.б.» татар эшчеләре һәм авыл хезмәтчәннәре арасында партия-сәяси, мәдәни-агарту, проф. һәм комсомол эше проблемаларын күтәрә. 1 һәм 2 нче бишьеллык планын үтәүгә, «Яшь коммунар», «Щигловка», «Кызыл Октябрь» шахталары эшенә, СССРдагы беренче металл кою, коксхимия һәм цемент, металлконструкция з-длары, агроф-ка төзелешенә һ.б.га; соц. ярышларга; татар халкының хезмәткә керткән өлешенә зур игътибар бирелә. Хезмәт җитештерүчәнлеген үстерү максатыннан техниканы үзләштерү, техник пропа-

ганда түгәрәкләрендә катнашу, колхозлар төзүне тизләтү, үз вакытында чүчүгә әзерләү, кооперация хәрәкәтен үстерү, кулаклар, дин әһелләре, наданлык б-н көрәшүгә чакыра. Татар мәктәпләрендә балалар укытуның торышына күзәтчелек итә.

З.З.Гыйләҗев.

«УДА́РНИКЛАР», эшче яшьләр өчен айлык рәсемле, иҗтимагый-сәяси, фәнни-әдәби журнал. ВЛКСМ ҮКы органы. «*Яшь эшче*» ж-лы дәвамчысы. 1930 елның маеннан 1932 нең декабренә кадәр Мәскәүдә татар телендә нәшер ителә, барысы 32 саны чыга. Мөхәррирләре — Г.Абдулаев, Ә.Ерикәй,



«Ударниклар» журналы.

Г.Ильясов, Г.Әхтәмов. Актив авторлары арасында — И.Агишев, М.Давыдов, И.Крымов, Б.Мансуров, В.Садри, Ф.Сәхибуллин, З.Шәркый (Йосыпов) һ.б. Журнал редакциясе б-н шагыйрь М.Җәлил хезмәттәшлек итә. «У.»да икътисади сәясәткә, индустриализациягә, алдынгылар хәрәкәтенә, соц. ярыш-лардагы уңышларга багышланган мәкаләләр басыла.

Т.М.Насыйров.

УДЕ́Л МӘКТӘПЛӘРЕ́, удел крәстиян балалары өчен башлангыч мәктәп, 1828 елдан булган кагыйдәләргә нигезләнеп булдырыла. 1844 тә Россиядә 200 дән артык уч-ще эш-ли, ш.и. якынча 10 уч-ще Казан губернасында. Удел Департаменты һәм удел крәстияннәреннән өстәмә җыем (җан башыннан 63 тиен) хисабына тотылалар. Җитәкчеләре башлыча җирле дин әһелләреннән билгеләнә. Һәр мәктәптә тотылган чыгымнар ярдәмендә аларда укыту дәрәҗәсе Дәүләт милке министрлыгы мәктәпләренә караганда югарырак була. 1866 да барлык крәстияннәрнең Эчке эшләр министрлыгы карамагына күчүе сәбәпле, У.м. земстволарга тапшырыла. Буа өязенең Борындык авылындагы У.м.ндә чуаш мәгърифәтчесе И.Я.Яковлев башлангыч белем ала.

УДЕ́ЛЬНОЕ НЕЧА́СОВО авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 10 *км* көнбатыштарак, Үләмә елгасы буенда. 2010 елда 120 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, бакчачылык. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1603 кә кадәр нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Починок Нечасов исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы удел (1797 гә кадәр — сарай) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Троица чиркәве (1904–12 дә төзелә; архит-ра ис-тәлеге), чиркәү-приход мәктәбе (1885 тә ачыла), 6 җил тегермәне, тимерче алачыгы, 3 чүлмәк ясау йорты, 3 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2236 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Колунец волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Тәтеш р-нында. Халык саны: 1646 да — 166, 1782 дә — 412 ир-ат; 1859 да — 528, 1897 дә — 917, 1908 дә — 1008, 1920 дә — 1056, 1926 да — 952, 1938 дә — 647, 1949 да — 333, 1958 дә — 302, 1970 тә — 235, 1979 да — 186, 1989 да — 181, 2002 дә — 159 кеше.

УДМУ́РТ РЕСПУ́БЛИКАСЫ, РФдә, Урал алдының көнбатыш өлешендә урнашкан. 1920 елның 4 ноябрендә Вотяк (1932 нең 1 гыйнварыннан — Удмурт) автономияле өлкәсе буларак оештырыла, 1934 нең 28 декабреннән — Удмурт АССР, 1991 нең 11 октябреннән — У.Р. Мәйданы — 42,1 мең *км*². Башкаласы — Ижевск шәһәре. Халкы — 1516826 кеше (2017). Татарлар саны: 1920 дә — 11007, 1933 тә — 22350, 1939 да — 41100, 1959 да — 71900, 1970 тә — 87100, 1989 да — 110490, 2002 дә — 109218, 2010 да — 98831 кеше. Татарларның һәм аларның борынгы бабаларының У.Р. терр-ясенә урнашулары берничә этапта бара. 10 йөздә — 13 йөзнең 1 нче чирегендә хәзерге У.Р.ның көньяк р-ннары Идел буе Болгар дәүләтенең сәяси, икътисади һәм мәдәни йогынтысында була, монда Болгар сәүдәгәрләренең вакытлы сәүдә-тәэминат пунктлары барлыкка килә. 1240–1430 елларда болгарлар төньяк-көнбатыш (Нократ елгасы буйлап) һәм төньяк-көнчыгыштагы (Чулман буйлап) җирләрне үзләштерә. 15–16 йөзләрдә хәзерге У.Р.ның көньяк өлеше Казан ханлыгының икътисади һәм сәяси контроле астында яши, хәзерге Можга, Сарапул шәһәрләре, Пирогово авылы (Ижевскидан көньяктарак) урыннарда татар авыллары була. Чыпца елгасы түбәнлегендә (хәзерге Киров өлкәсе терр-ясе) Карин бәклеге (Нократ җире) оештырыла, Карин яки Чыпца татарлары (к. *Нократ татарлары*) формалаша башлый, аларның этногенезында татарлар — *Арча кенәзләре* һәм *бисермәннәр* катнаша. 16 йөз уртасында — 17 йөздә элеккеге Арча кенәзләренең бер өлеше, яңа җирләр эзләп, көнчыгышка — Чыпца елгасы башы һәм урта агымы буена (У.Р.ның хәзерге Балезино, Юкаменск, Глазов һәм Яр р-ннары терр-ясе) күченә. Шул ук чорда элеккеге Казан ханлыгы татарлары Каракүл, Чулман буен һәм Иж, Туйма елгаларының түбән өлешен үзләштерә. Монда Рус дәүләте хезмәтендәге татар феодаллары да (морза Яушевлар) җир ала. Удмуртиянең көньяк-көнбатыш өлешендәге җирләр (хәзерге Алнаш, Грахов, Кизнер р-ннары) баштарак чукындырылган татарларның (Алабуга керәшеннәре) тупланып яшәү урынына әйләнә. 18 йөздә төбәктәге татарлар саны күченүчеләр һәм бисермәннәр ассимиляциясе исәбенә арта. 18 йөзнең 2 нче яртысыннан Удмуртиянең көньягында яшәүче татарлар Ижевск һәм Воткинск тимер эшкәртү з-длары тирәсенә урнаша башлый. Заводларга караган посёлокларда Татар бистәләре барлыкка килә, аларда 19 йөздә — 20 йөз башында Сарапул өязенең Әгерҗе волостеннан (күбесенчә Әгер җе, Иж-Бубый, Иж-Бәйки авылларыннан), Вятка губернасының Малмыж өязеннән, Казан губернасының Мамадыш, Чистай, Зөя, Лаеш өязләреннән, Уфа губернасының Минзәлә һәм Бөре өязләреннән татарлар килеп утыра. Ижевск заводы посёлогы Татар бистәсендә 1844 елда — 379, 1878 дә — 551, 1908 дә 947 татар яши. 1880 елларда Сарапулда шәһәр халкы (татарлар) саны Казан, Вятка, Самара, Уфа губерналарының төрле өязләреннән килүчеләр исәбенә арта. 19 йөздә Чыпца татарлары авыл халкы булып кала бирә, 31 торак пунктта яши, 1910 да аларның саны 9997 кешегә җитә. Совет чорында Удмуртиядәге (күбесенчә көньяк районнарда, Ижевск, Воткинск, Сарапулда) татарлар саны Гражданнар сугышы, 1920 еллар — 1930 еллар башындагы индустриялләштерү сәясәте гамәлгә ашырылу, оборона сәнәгатен үстерү кебек вакыйгалар б-н бәйле рәвештә миграция исәбенә арта. 1970 еллар ахырында Түбән Кама сусаклагычы төзелгәндә, кайбер торак пунктларның су астында калуы сәбәпле, ТАССРның Әгерҗе, Минзәлә, Актаныш р-ннары халкының бер өлеше У.Р.ның Сарапул, Каракүл, Алнаш һәм Завьялово р-ннарына күченә. Татарлар Удмуртия җирләрен үзләштерә башлагач, мөселман мәдәни һәм мәгариф үзәкләре барлыкка килә. Төбәктә мәчетләр булуын дәлилләүче иң борынгы язмалар 1743 (Кистем а.) һәм 1744 (Починошная а.) елларга карый. 1826 да Глазов өязендә 6 мәчет (3 җамигъ һәм 3 указсыз), 1901 дә — 7, 1917 дә 15 җамигъ мәчет һәм 6 гыйбадәтханә исәпләнә. 1917 дә Алабуга өязендә (хәзерге У.Р. чигендә) 4 мәчет, Сарапул өязендә 1 гыйбадәтханә (Сарапулда) һәм 3 мәчет (Ижевскида — 2, Воткинскида — 1) була. Һәр мәчет каршында иске ысуллы мәктәп эшли. 19 йөз ахырында — 20 йөз башында Сарапул өязенең Ижевск заводы посёлогында (1872), Глазов өязенең Починка (1915), Кистем (1916) авылларында рус-татар мәктәпләре оештырыла. 1908 дә Ижевск рус-татар мәктәбе мәдрәсә итеп үзгәртелә. Сарапулда (1908 дән), Ижевск



Ижевск шәһәрендәге җамигъ мәчет.

заводы посёлогында (1910 нан), Кистем авылында (1916 дан) мөселман татар халык китапханәләре эшли. 1911–12 дә Сарапулда бертуган Бубиларны хөкем итүгә бәйле мәхкәмә эше (к. *Бубилар эше*) карала. 1917 дә Глазов өязе Мөселман милли советы (шурасы) оештырыла, Ижевскида «Таң җиле» татар г-тасы нәшер ителә. Совет хакимиятенең беренче елларында татарлар тупланып яшәгән урыннарда милли колхозлар оештырыла; татар телендә «Ленин юлы» респ-ка г-тасы нәшер ителә (Бөек Ватан сугышына кадәр чыга), Татар клубы эшли. Совет хөкүмәтенең дингә каршы сәясәте күп кенә мөселман гыйбадәтханәләре эшчәнлеген туктату-га сәбәп була. 1922 дә Удмуртия терр-ясендә 19 мәчет, 1934 тә — 15, 1941 дә 6 дини оешма, 1944–90 елларда 8 мөселман җәмгыяте эшли. 20 йөзнең 2 нче яртысында респ-кадагы татар мәктәпләре саны шактый кими. Татарлар, башлыча, Ижевск (59,2 мең кеше), Сарапул (8,9 мең), Можга (6,9 мең), Глазов (5 мең), Воткинск (4 мең), Камбарка (1 мең) шәһәрләрендә, Балезино (3590 кеше), Кизнер (2756), Юкаменск (2070), Завьялово (1833), Камбарка (1789), Сарапул (1542), Ува (1315), Можга (1106), Игра (896), Алнаш (758), Кече Пурга (749), Кияс (620) р-ннарында яшиләр. 20 авыл торак пунктында татарлар халыкның 80% ын тәшкил итә. У.Р. иҗтимагый үзәге (1991 дән; татарлар күпләп яшәгән барлык шәһәр һәм районнарда төбәк бүлекчәләре), «Иман» Татар яшьләре берлеге (1994), «Йолдыз» Татар мәдәнияте үзәге (1996), Татарларның төбәк милли-мәдәни автономиясе (2005), «Якташлар» Ижевск шәһәр җәмгыяте, Аксакаллар шурасы, «Россия мөселманнары берлеге» бөтенроссия иҗтимагый хәрәкәтенең У.Р. бүлекчәсе эшли. Удмурт ун-тында татар теле һәм әдәбияты каф. эшләп килә, Ижевск пед. уч-щесе башлангыч сыйныфлар өчен татар теле укытучылары әзерли, 1998 дән шәһәрдә татар гимназиясе эшли, татар теле һәм мәдәнияте Ижевск, Сарапул, Можга шәһәрләренең, Балезино, Глазов, Юкаменск р-ннарының 20 мәктәпкәчә тәрбия һәм 29 мәгариф учреждениесендә укытыла. У.Р. Язучылар берлеге каршында татар язучылары бүлеге оештырыла, Р.Шәфи исем. әдәби берләшмә эшли, удмурт җирендә яшәп иҗат итүче татар композиторларының шигырь һәм муз. әсәрләр җыентыклары нәшер ителә. Татар телендә «Яңарыш» респ-ка г-тасы чыга (1991 дән), респ-ка радио һәм телевидение тапшырулары («Очрашу», «Хәерле кич»), Сарапул, Воткинск, Глазов, Можга, Алнаш, Каракүл һәм Юкаменск р-ннарында радиотапшырулар алып барыла. У.Р.ның көньяк р-ннарында «Татарстан» Дәүләт телерадиотапшырулар компаниясе, Ижевскида «Татарстан — Яңа гасыр» телеканалы тапшырулары трансляцияләнә. Ижевскида («Гүзәл», «Ләйсән», «Шатлык», «Умырзая», «Кичке моңнар», «Бәхет», «Мирас», «Сандугач», «Шаян йолдызлар»), Воткинскида («Дуслык», «Тургай»), Можгада («Йолдыз»), Глазовта («Татар ансамбле»), Сарапулда (музыка мәктәбенең балалар иҗат коллективы), Балезино р-нында (Кистем авылы фольклор ансамбле) татар иҗат коллективлары һәм ансамбльләре эшли. Даими рәвештә Р.Вәһапов исем. татар җыр һәм бию респ-ка фестивальләре, Балалар музыка фестивале, милли көрәш буенча турнирлар үткәрелә. Татарлар күпләп яшәгән торак пунктларда Сабан туе (2010 да Ижевскида 11 нче Федераль Сабан туе була) уздырыла. 1994 тә У.Р. мөселманнары Диния нәзарәте оештырыла. Мөселманнарның Төбәк диния нәзарәтенә (Ижевск мөфтияте) 17 дини оешма керә, шуларның берсе («Гадел», Ижевск) «Мәчетләр ассоциациясе» Мәскәү мөселманнары Диния нәзарәте әгъзасы булып тора. 24 мәчет (3 се төзелеп килә), «Ихлас» хәйрия фонды эшли. Мөслим г-тасы нәшер ителә. ТР б-н У.Р. арасында Дуслык һәм хезмәттәшлек турында, мәгариф министрлыклары, язучылар берлекләре арасында хезмәттәшлек турында килешүләр гамәлдә. Ижевскида «Татарстан» сәүдә йорты, «Ак Барс Банкы» ф-лы эшли. Сәясәт эшлеклеләре Г.*Касыймов* һәм С.*Касыймов*, Сов. Союзы Герое Х.З.*Заманов*, Соц. Хезмәт Герое З.Ш.*Хәсәнов*, нәкышьче Б.И.*Урманче*, астроном И.В.*Әхмәров*, а.х. фән. д-рлары И.Ш.*Фатихов* һәм Г.К.*Касыймов*, мед. фән. д-ры А.С.*Япиев*, физика-матем. фән. д-ры Р.С.Ильясов, юридик фән. д-ры З.З.*Зиннәтуллинның* тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге У.Р. б-н бәйле.

Әд.: Мәрданов Р.Ф. Иж шәһәре татарлары тарихыннан. К., 2006; Сорокин П.М. Татары Глазовского уезда // Календарь и памятная книжка Вятской губернии. Вятка, 1897; Бурганова Н.Б. Говор каринских и глазовских татар // Материалы по татарской диалектологии. К., 1962. Вып. 2; Степанов Р.Н. Каринское опричное княжество (вторая четверть XIV — вторая половина XVI вв.) // Вопросы социально-экономической и политической истории Среднего Поволжья и Приуралья периода феодализма. Чебоксары, 1973; Исхаков Д.М. О происхождении «арских князей» и их месте в этнополитической структуре Казанского ханства // Заказанье: проблемы истории и культуры. К., 1995; Касимова Д.Г. Татары в истории г.Глазова (1678–1920 гг.) // Материальная и духовная культура народов Урала и Поволжья: История и современность: История севера Удмуртии в XVI–XX вв. Глазов, 2008; шул үк. Ислам на Вятской земле // Самобытная Вятка. Киров, 2009; Удмуртская Республика: Энцикл. Ижевск, 2000. *Д.Г.Касыймова.*

УДМУ́РТ ТАШЛЫСЫ́ авылы, Баулы р-нында, Баулы шәһәреннән 20 *км* көнья-көнбатыштарак, Сола елгасы (Ык бассейны) буенда. 2010 елда 333 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 19 йөз башында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Заитово Узла исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, иген-челек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү-приход мәктәбе, су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 954 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Ивановка волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Баулы р-нында. Халык саны: 1859 да — 239, 1889 да — 323, 1897 дә — 433, 1910 да — 505, 1920 дә — 449, 1926 да — 525, 1949 да — 439, 1958 дә — 520, 1970 тә — 396, 1979 да — 315, 1989 да — 324, 2002 дә — 333 кеше.

УДМУ́РТ ТЕЛЕ́, Урал телләре семьялыгына кергән фин-угор телләре төркеменең Пермь төркемчәсенә карый. У.т.ндә сөйләшүчеләр — *удмуртлар*. У.т., гомумпермь нигез теле таркалганнан соң, аерым кабилә телләреннән эчке эволюцион үсеш кичерү нәтиҗәсендә 9–16 йөзләрдә барлыкка килә. Фонетик, лексик һәм грамматик үзенчәлекләре ягыннан коми-пермяк һәм коми-зырян телләренә якын тора. 14–19 йөзләрдәге язма ядкәрләрдә У.т. отяк яки вотяк теле буларак билгеле. У.т. 3 шивәгә: төньяк, көньяк, бисермән шивәләренә һәм арадаш урта сөйләшләргә бүленә. У.т.ндә 38 аваз (12 сузык һәм 26 тартык) бар. Башка телләрдән аерып торган фонологик үзенчәлеге — «ӧ», «ӝ», «ӟ», «ӵ», «й» хәрефләре б-н белдерелүче үзенчәлекле авазлары булу. Әдәби теленең формалашуы У.т.ндә беренче китаплар басылып чыгу б-н бәйле (18 йөз). 1775 елда С.-Петербургта У.т.нең беренче фәнни грамматикасы — «Вотяк теле грамматикасына караган әсәрләр» дөнья күрә. 1920–50 елларда Удмурт әдәби теленең формалашуы тәмамлана. Бу процесста удмурт язучылары Кузебай Герд, Кедра Митрей, М.Коновалов, М.Петров һ.б.ның әсәрләре зур роль уйный. У.т. рус теле б-н беррәттән Удмурт Респ-касының дәүләт теле санала. Бу телдә башлангыч мәктәпләрдә белем бирелә, уку-укыту әсбаплары, дәреслекләр, матур һәм публицистик әдәбият басыла, газета һәм журналлар (ш.и. ТРның Балтач р-нында «Азьлань») чыга, радио һәм телевидение тапшырулары алып барыла, театрларда спектакльләр куела. Удмурт тарих, тел, әдәбият фәнни-тикшеренү ин-ты, Удмурт ун-ты, Глазов пед. ин-ты У.т.н фәнни өйрәнү үзәкләре булып торалар.

Әд.: Грамматика современного удмуртского языка. Фонетика и морфология. Ижевск, 1962; Грамматика современного удмуртского языка: Синтаксис простого предложения. Ижевск, 1970; Удмуртско-русский словарь. М., 1983; Каракулова М.К., Каракулов Б.И. Сопоставительная грамматика русского и удмуртского языков. Ижевск, 2001.

УДМУРТЛА́Р (үзатамалары-утморт, укморт; элек руслар — вотяклар, отяклар дип, татарлар арлар дип атаганнар), фин-угор халкы; *Удмурт Республикасының* төп халкы. У.ның гомуми саны — 552,2 мең кеше (2010), ш.и. Удмурт Респ-касында — 410,6 мең кеше. Киров (13639 кеше), Пермь (20819), Свердловск (13789) өлкәләрендә, Башкортстан Респ-касында (21477), ш.у. Казакъстан Респ-касында һәм Украинада тупланып яшиләр. ТР да — 23,4 мең кеше, башлыча Әгерҗе, Баулы, Балтач, Кукмара, Менделеев р-ннарында. Антропологик яктан У. зур европеоид расага (Урал варианты), европеоид сыйфатлар өстенлек иткән, кайбер монголоид билгеләре булган Вятка-Кама сублапланоид тибына керәләр. Туган телләре — *удмурт теле*. Башлыча православие динен

тоталар, бер өлеше традицион мәҗүсилек инануларга тугрылык саклый.

Удмурт Респ-касы терр-ясенә халык мезолит дәвереннән килеп урнаша башлый. Борынгы удмурт халкының этник асылы ачыкланмаган. У. формалашуның нигезен Идел-Чулман төбәгенең җирле халкы тәшкил итә. Төрле тарихи чорларда төрле этник элементлар (һинд-иран, элгәреге төркы, соңгы төркы, славян, угор) кушыла. Килеп чыгышларының тамырлары *Ананьино культурасына* (б.э.к. 8–3 йөзләр) барып тоташа. Б.э. чигендә Ананьино культурасы нигезендә Чулман буенда җирле культуралар барлыкка килә. Алар арасында *Пьянобор культурасы* мөһим урын били, аның б-н У. арасында аерылгысыз генетик бәйләнеш булуы ачыклана.



Удмурт хатын-кызлары. Казан губернасы Мамадыш өязе. 20 йөз башы.

Б.э.ның 1 меңьеллыгының 2 нче яртысында яңа терр-ляләр үзләштерелү, көньяктан һәм Урал аръягыннан чит кабиләләр килү нәтиҗәсендә соңгы чор Пьянобор вариантлары (Полом культурасы, *Азелино культурасы*) җирлегендә борынгы удмурт этник тел бергәлеге формалаша, ул, ихтимал, Вятка елгасының һәм аның кушылдыкларының түбән һәм урта агымнар бассейнында урнаша.

У. турында иң элеккеге искә алуларның берсе 12 йөзгә (гарәп авторы Әбү-Хәмид әл-Гарнати хезмәтендә) карый. Рус елъязмаларында У. беренче тапкыр Нократ гаскәренең Арча җирендә сугыш хәрәкәтләре турындагы язмада арлар, Арча кешеләре (1379) буларак телгә алыналар (к. *Арлар*).

Удмурт этносы эчендә берничә төркем аерып карала, иң зурлары — төньяк һәм көньяк төркемнәр. Аларның үсеше төрле этник-тарихи шартларда уза: көньяк У.га — төркиләр (*бисермәннәр*), төньяк У.га руслар йогынтысы сизелә. Төньяк У. баштан ук үзенчәлекле сәяси һәм икътисади тарихи өлкә — *Нократ җире* составына керәләр. У.ның көньяк төркеме *Идел буе Болгар дәүләте*, соңрак *Алтын Урда* һәм *Казан ханлыгы* хакимлегендә була, 1552 елдан соң Рус дәүләтенә кушыла. Вятка наместниклыгы (1780), соңрак Вятка губернасы (1796) оештырылу б-н, У. Глазов, Алабуга, Малмыж һәм Сарапул өязләре халкының күпчелеген тәшкил итәләр; дәүләт крәстиянәре катлавына кертеләләр. 1920 дә Вотяк (1932 дән — Удмурт) автономияле өлкәсе оештырыла, 1934 нең 28 декабрендә автономияле респ-ка (1991 дән — Удмурт Респ-касы) итеп үзгәртелә.

20 йөз башына кадәр У.ның хуҗалыгы катнаш була, игенчелек өстенлек итә. Төп игенчелек кораллары: тырма, ике төрәнле тимер сука, сабан (19 йөз ахырыннан — тимер сабан). Чәчүне кулдан чәчәләр, күбесенчә салкынга чыдам бөртекле культуралар — арыш, арпа, солы, карабодай, бодай һ.б. чәчелә. Уңышны урак б-н уралар, кайвакыт чалгы кулланалар. Онны кул тегермәнендә, ш.у. су һәм җил тегермәннәрендә тарталар. Техник культуралардан — киндер, соңрак җитен игәләр. Яшелчәчелек зәгыйфь үсеш алган: кәбестә, бәрәңге, гәрәнкә, торма һ.б. үстерәләр. Терлекчелек удмурт хуҗалыгының аерылгысыз өлеше була: ат, сыер, дуңгыз, сарык, йорт кошлары асрыйлар. Аучылык, балыкчылык, умартачылык б-н шөгыльләнәләр. Кәсепчелек һәм һөнәрчелек зур роль уйный (урман кисү, агач материаллары әзерләү, сумала кайнату, әрләү, тукучылык һ.б.).

Традицион удмурт җәмгыятенең төп социаль ячейкасы җир буенча күршелек җәмәгатеннән (ул берничә кардәш гаиләне берләштерә) гыйбарәт була; җәмәгать эшләре б-н совет идарә итә. У. авыллары, кагыйдә буларак, елгалар буйларында, чишмәләр янында урнаша, урамнар булмый. 20 йөз башына кадәр удмурт авыллары өчен җәмәгать корылмалары — запас ашлык амбарлары, нәсел гыйбадәтханәләре хас. У.ның традицион торагы — җиргә утыртылган салкын өйалдылы бүрәнә йорт. 20 йөз башыннан таза тормышлы гаиләләр кышкы һәм җәйге яклардан торган алты почмаклы йортлар яки беренче каты кирпечтән эшләнгән ике катлы йортлар сала башлыйлар. Удмурт йортының планы төньяк рус планын кабатлый. Балчыктан чыгарылган мич ишек янында була, аңа диагональ буенча каршы якта өстәл һәм гаилә башлыгы өчен урындык куела; дивар буйлап озын эскәмияләр, алардан югарырак киштәләр сузылып китә. Сәкеләрдә һәм сәнде-рәдә йоклыйлар. Һәр йортның ишегалдында гаилә б-н гыйбадәт кылу өчен аерым корылма була, ул ш.у. җәен аш әзерләү бүлмәсе буларак файдаланыла.

У. киемнәрне кулдан тукылган киндердән, постаудан, ш.у. иләнгән сарык тиресеннән тегәләр. Традицион киемнәрдә төньяк һәм көньяк вариантлары аерылып тора, алар, үз чиратында, үзенчәлекле детальләр, орнаментлар, бизәмәләр, предметлар хас булган локаль костюмнарга бүленәләр. 20 йөз башында төньяк төркем удмурт хатын-кызлары кос тюмы ак киндер тукымадан тегелгән, туры җиңле туника кебек күлмәктән гыйбарәт була, күлмәкнең изүе өчпочмаклап яки түгәрәкләп уела, алынмалы чигүле күкрәкчә б-н каплана. Күлмәк өстеннән кыска җиңле ак киндер халат киялләр. Бу чорда көньяк төркем У.да ак кием йола киеме буларак кына киелә, башка очракларда алача күлмәкләр кияләр, күлмәкне комач һәм төсле ситсы аппликацияләр б-н бизиләр. Аның өстеннән билле камзул яки җиңсез кием киелә. Йон катыш һәм йон кафтаннар, туннар җылы өс киеме булып хезмәт итәләр. Аяк киемнәре — бизәкле оеклар, бәйләнгән яки тегелгән киндер оекбашлар, чабаталар, башмаклар, киез итекләр. Баш киемнәре — очлары чүпләмләп чигелгән бәйләвеч, каен тузыннан эшләнгән, киндер б-н тышланган һәм тәңкәләр, сәйләннәр, кабырчыклар б-н бизәлгән башлык (руслар кокошнигына охшаш); маңгай бәйләвече. Ирләр киеме гадирәк була: ак, соңга таба алача баусыз һәм төймәсез (соңыннан баулы, каптырмалы яки төймәле)



Халык бәйрәм тамашалары. 2000 еллар.

кыек якалы күлмәк; алача, еш кына ак буй төшкән зәңгәр төстәге ыштаннар. Баш киемнәре — киез эшләпәләр, иләнгән сарык тиресеннән тегелгән бүрекләр. Ирләр аяк киеме сыйфатында киндер һәм йон чолгаулар, күн итекләр киң тарала.

У.ның туклану нигезен терлекчелек продукциясе б-н бергә үсемлек продуктлары тәшкил итә. Традицион ашамлыклар: казылык, пилмән, ашлар, салкын ашлар, боткалар, әче камырдан пешерелгән, сөт б-н бирелә торган көлчәләр, төче камырдан шәңгәләр, пироглар, тозлаган яшелчәләр, киндер орлыгыннан татлы ризыклар; эчемлекләр: икмәктән һәм чөгендердән ясалган куас, сыра, ачы бал, җиләк-җимеш морслары һ.б.

Удмурт авыллары тормышында а.х. эшләре цикллары б-н бәйле календарь-йола бәйрәмнәре зур роль уйный. Йола бәйрәмнәре корбан чалуларны, дога һәм җыр рәвешендәге ялваруларны, хәвеф-хәтәр булдырмау, җирнең уңдырышлылыгын тәэмин итү, терлекләрне, гаилә әгъзаларының сәламәтлеген саклау максатындагы төрле магик гамәлләрне үз эченә ала (мәс., «толсур» — кышкы кояш торгынлыгы көне, ул көнгә туй билгеләләр; «гырыны потон» яки «акашка» — язгы кыр эшләре башлану вакыты; «зор курон» —

яңгыр теләү йоласы һ.б.). У.ның православиегә күчүе нәтиҗәсендә традицион йолалар сизелерлек дәрәҗәдә христианлык йогынтысына дучар ителә. 19 йөз ахырында — 20 йөз башында йола еш кына чиркәү бәйрәмнәре көннәренә (Раштуа, Пасха, Троица һ.б.) туры китерелә. Рәсми христиан дине б-н берләттән озак вакытлар үзенә бер төрле гаилә-нәсел һәм аграр культлар нигезендә формалашкан дини карашлар саклана. Хәзерге вакытта У. диненең үзенә генә хас үзенчәлеге — анда дин элементлары б-н бергә системалаштырылмаган фәнни белемнәрнең үзара үрелеп барган катлаулы синкретизм формалары булу.

2004 тә, Казандагы, Чаллы, Әгерҗе, Минзәлә шәһәрләрендәге һәм респ-каның күп кенә районнарындагы удмурт җәмгыятьләреп берләштерү өчен, ТР да төп бурычы туган телне һәм мәдәниятне саклау булган У.ның Милли-мәдәни автономиясе оештырыла.

Әд.: Пименов В.В. Удмурты: Опыт компонентного анализа этноса. Л., 1977; Христолюбова Л.С. Семейные обряды удмуртов: традиции и процессы обновления. Ижевск, 1984; Владыкин В.Е., Христолюбова Л.С. Очерк этнографии удмуртов. Ижевск, 1984; шул ук. Этнография удмуртов. Ижевск, 1997; Народы России: Энцикл. М., 1994; Удмуртская Республика: Энцикл. Ижевск, 2000.

Р.Р.Батыршин.

УДО́БНОВКА авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 19 *км* көньяк-көнбатыштарак, Мәллә елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда даими яшәүчеләр юк. 19 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Удобная исеме б-н билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, У.да 2 тегермән була. 20 йөзнең башында земство мәктәбе, май язу йорты, бакалея һәм икмәк саклау-сату кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 380 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Александр-Кармалы волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1870 тә — 170, 1906 да — 352, 1920 дә — 306, 1926 да — 255, 1938 дә — 194, 1949 да — 149, 1958 дә — 107, 1970 тә — 93, 1979 да — 44, 1989 да — 5, 2002 дә — 2 кеше.

УЕ́Н ҖЫРЛАРЫ́, төгәл ритм, тулы рифмалар ха смуз.-поэтик халык фольклоры жанры. Яшьләрнең җырлы-биюле уеннары вакытында башкарыла. У.ж. озын тарихлы. 1930–50 елларда аеруча киң таралалар. Уеннарның эчтәлегенә карап, У.ж.н 3 төркемгә бүләләр. Беренче төркемгә яшьләрнең җырлы-биюле уеннары вакытында башкарыла торган У.ж. керә: «Җыр әйтешү», «Сөясеңме, сөймисеңме» һ.б. Икенче төркемгә диалогка нигезләнгән У.ж. керә: кызлар һәм егетләр кара-каршы 2 сафка тезелеп, чиратлашып сайлап алган җырның куплетын башкарылар, мәс., «Җимчәчәк», «Челтәр элдем читәнгә», «Безгә кирәк бер иптәш». Өченче һәм иң күпсанлы төркемгә әйләп-бәйләп җырлары керә: «Төймә-төймә», «Зәлилә» һ.б.

Хәзерге заманда татарлар тормышында У.ж. сирәк яңгырый, башлыча Сабан туен бәйрәм иткәндә, театраль һәм телевизион спектакльләрдә, радиотапшыруларда башкарыла.

Әд.: Исәнбәт Н. Балалар фольклоры. К., 1941; Татар халкының җырлы-биюле уеннары. К., 1968; Фәйзи Ж. Халык җәүһәрләре. К., 1971; Татар халык иҗаты: Йола һәм уен җырлары. К., 1980.

Ф.И.Урманчеев.

УЕ́П ЯСАЛГА́Н КАБЕ́Р ТАШЛАРЫ́, истәлек язулары һәм бизәкләр б-н нәфис итеп уелган ташъязмалар; бизәлеш сәнгате, *хаттатчылык* һәм *эпиграфиканың* бер төре. Эшкәртелгән акташтан, кайвакыт мәрмәр плитәләрдән У.я.к.т. мәрхүмнең җирләнгән урынында, баш ягында урнаштырылган; гадәттә, өчпочмак, ярымтүгәрәк, уксыман яки кил рәвешендә төгәлләнгән туры почмаклык формасында. Уеп ясалган бизәк тирән уемлы һәм яссы рельефлы кисү техникасын, еш кына өслекнең сизелер-сизелмәс яктылык һәм күләгә бирүче фон яссылыгына авыш почмак ясап башкарылган. Ташның алгы ягындагы гарәпчә яки гарәп графикасының классик-каллиграфик төрләрендәге («куфи», «сөлес», «нәсех», тәгълик» һ.б.) язулар кайвакыт аның ян һәм эчке якларында да уелганнар. Таш яссылыгын, нәфис бизәк буларак, фәлсәфи һәм шигъри эчтәлектәге текстлар (мәс., «Фани дөнья дан бакыйлыкка күчте») каплап торган. У.я.к.т. татарларның барлык этник төркемнәрендә булган, ләкин Себер татарларында күп таралмаган, башлыча, күренекле кешеләр каберләренә генә куелган.

У.я.к.т. кую традициясе Идел буе Болгар дәүләте һәм Казан ханлыгы чорларыннан килә (к. Болгар сәнгате, *Алтын Урда сәнгате*). 13 йөздә — 15 йөзнең 1 нче яртысыннан сакланып калган ядкәрләрне бизәлеш һәм каллиграфия буенча 2 төргә бүләләр. Беренче төр формасының зурлыгы, тирән уемлау техникасы кулланылуы һәм «куфи» стилендә язылуы б-н аерылып тора. Икенчесе кил яки уксыман итеп каймаланган кабер ташының



Кабер ташы. Ташны уеп ясау. 16 йөз. Биектау районы Туктамыш авылы.



1 2

1. Кабер ташының икенче ягында вазондагы чәчәк бәйләме. 16 йөзнең беренче яртысы. Питрәч районы Пановка авылы. Ф.Х.Вәлиев реконструкциясе. 2. Кабер ташының бордюр бизәге. 16 йөзнең 1 нче яртысы. Биектау районы Кече Солабаш авылы.

мәчет михрабына охшатып эшләнүе, формасының төзек, туры почмаклы булуы, яссы рельефлы уемнарның камиллеге б-н (Болгардагы архит-ра истәлекләренә хас) таныла. Беренче төр кабер ташларының бизәкләрендә халык сәнгате сыйфатлары чагылдырылса, икенчесендә проф. шәһәр мәдәнияте эзләрен күргә мөмкин. 15–16 йөзнең 2 нче яртысындагы бизәкләрдә һәм эпиграфикада бердәм стиль хас булган кабер ташлары (Казан ханлыгы сәнгате) иске авыл зиратларында яки чәчелмәгән иген кырларында утраучык булып кереп калган борынгы каберлекләрдә сакланганнар. Алар формалары һәм уеп ясалган бизәкләре буенча: 1) болгарлардан күчеш чоры; 2) 15 йөз ахыры — 16 йөз башы; 3) 16 йөзнең 1 нче яртысы эпитафияләренә бүленә. Беренчеләре өчпочмак яки уксыман формада төгәлләнә, алгы яктан таш абрисы буенча геом. төсемлек үрнәкләре уелган тар кайма б-н бизәлә. 15 йөз ахыры — 16 йөз башындагы каберташлар тагын да бизәклерәк була бара: очланган урында чәчәк-үсемлек орнаменты үрнәкләреннән төзелгән ярымрозетка формасындагы бизәкләр барлыкка килә (ярымпальметталар, дәлия, кашкарый, лалә, чалма чәчәк тибындагы эре чәчәкләр, гөл бөреләре, сыгылма ботаклар һ.б.). 16 йөзнең 1 нче яртысындагы стелалар зурлыклары (биеклеге 2,5 *м* га җитә), уеп бизәү техникасы, биек рельефлыгы, язуларның «сөлес» стилендә башкарылуы, бай бизәлешле һәм катлаулы композицияле булуы б-н аерылып тора. Өске өлеше кил яки уксыман килбәткә ия. 16 йөз уртасына таба турыпочмаклы таш яссылыгында А рәвешендәге үсемлек үрнәкләре һәм үзәктә фестонсыман медальоннар төшерелгән орнаменталь панно барлыкка килә. Аның эчендә Коръәннән гарәпчә бормалы язулар урнаштырыла. Каллиграфик язма еш кына үсемлек бизәкләре б-н үрелеп бара (чәчәк атучы «куфи» яки «сөлес»). Бай бизәкле эпитафияләрне (гарәп бормалары б-н үрелгән яшь ботаклар яки арабескалар б-н бизәлгән кайма) еш кына ташның ян һәм арткы якларында да очратырга мөмкин. 15–16 йөз -

ләр кабер ташлары бизәкләрендә Төркия, Кырым, Урта Азия, Кавказ, Иран сәнгате йогынтысы сизелә. 16 йөзнең 2 нче ярты - сы — 18 йөз уртасының У.я.к.т. тулысынча диярлек узган чор бизәк-композицияләрен кабатлыйлар. Ләкин аларда ташка уеп бизәк - ләү дәрәҗәсенең төшүе һәм уеплау техника - сының гадиләштерелүе б-н бәйле эклектик агымнар барлыкка килә. 18 йөзнең 1 нче яр - тысы — 19 йөз башы кабер ташлары кечерәя (биеклеге уртача 1,6 *м* һәм киңлеге 0,5 *м*), ярымтүгәрәк итеп (яки шуңа якынлашты - рып) төгәлләнә, турыпочмаклы килбәттә киселә. Уеп ясалган бизәк алгы якның өске өлешендә һәм ян-як каймаларда урнаша. Калган яссылык язулар уелган турыпочмак - лы горизонталь сызыклар б-н бүленгән паннолардан тора; чәчәк-үсемлек бизәкләр еш кына стеланың аскы өлешендә урын ала. Бизәкләр кайвакыт ташның арткы ягына, еш кына гарәп язулы түгәрәк медальоннар рәвешендә төшерелә. Татарстанның көнчы - гыш районнарындагы кайбер авылларда ко - нус рәвешендәге, кайвакыт тамгалар уелган зур кабер ташлары очрый. 19 йөзнең 2 нче яртысыннан эпитафияләрдә күпшы бизәк - ләр әкренләп юкка чыга бара һәм 19 йөз ахырында – 20 йөз башында алар сирәк кул - ланыла. Кабер ташларының күпчелегенең авторлары билгесез, ләкин 17 йөзнең 2 нче яртысында – 20 йөз башында аерым осталар үзләренең исемнәрен язып калдыра: Аккучат, Әюб бине Исмәгыйль, *Гайсә, Габделба - ри*, Дәүләтша мулла, *Зәки җан* бине Морта - за, Ибраһим бине Мөхәммәт, *Килмөхәммәт* бине Ишман, Лотфулла әл Әлмәти, *Мөхәм - мәтхәнәфи*, Мөхәммәтзакир бине Шакир һ.б. (аларның исемнәре уелган кабер ташла - ры галим М.И.Әхмәтҗанов тарафыннан өйр - әнелә).

20 йөз башыннан У.я.к.т.ның алга киткән традицияләре әкренләп бетүгә йөз тота. Ка - зан, Әлмәт, Лениногорск һәм авыл зиратла - рында, башлыча, шәхси зәвыкларга юнәлде - релгән, борынгы ташларга хас традицион бизәкле хәзерге заман кабер ташлары үрнәк - ләрен күрергә мөмкин. Әлеге эпитафия - ләрнең бик сирәкләрен генә сәнгать әсәрлә - ренә тиңләргә мөмкин. Шул ук вакытта У.я.к.т.ндагы бизәү традицияләре заманча монументаль-бизәлеш сәнгатендә (җәмәгать биналары интерьерларында уеп бизәлгән гипстан, агачтан дивар паннолары), Казаннан Р.Ә.Килдебәков, Е.В.Киселёва, В.К.Фёдоров, Түбән Камадан Ю.Н.Галузин, Ә.С.Фәтхетди - нов, Чаллыдан Л.П.Владыкин, Р.З.Кругля - кова һ.б. рәссамнар ижатларында, ш.у. ар - хит-рада күпертмә декорда үсеш ала (Ка - зандагы Татар опера һәм балет театры фасад - лары һәм интерьерлары һ.б.). У.я.к.т. үрнәк - ләре ТРның Милли музеенда, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәгендә, Касыйм шәһәре му - зей-тыюлыгында, Түбыл тарих-архит-ра музей-тыюлыгында һ.б.да саклана. Ш.у.к. *Архитектура бизәлеше, Монументаль би - зәлеш сәнгате*.

Әд.: Әхмәтҗанов М.И. Үлгәннәрнең кабе - рен бел. К., 2000; Усманов В.М. Тарихи яд - кәрләр. Уфа, 2001. 1 кит.; Стәрлетамак, 2005. 2 кит.; Юсупов Г.В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. М.–Л., 1960; Мухаметшин Д.Г., Хакимзянов Ф.С. Эпиграфические памят - ники города Булгара. К., 1987; Валеев Ф.Х. Та - тарский народный орнамент. К., 2002; Вале - ев Ф.Х., Валеева-Сулейманова Г.Ф. Древнее искусство Татарстана. К., 2002.

Г.Ф.Вәлиева-Сөләймановa.

УЕПЛА́У (гравирлау), зәргәрчелек сәнга - тендә металл өслеген уеп рәсем яисә бизәк төшерү ысулы; зәргәрчелек техникасының бер төре. Эш коралы булып үткен, гадәттә, ко - рычтан ясалган, төрле кискечләр (штихель - ләр һ.б.) хезмәт итә. Татар зәркәнчелек сән - гатендә әлеге техника «уеплау» дип атала. У. еш кына *чүкеп бизәк төшерү*, кайвакыт башка металлар б-н *инкрустацияләү* (алтын б-н, мәс., билбауда — каптырма), каралту б-н бергә кулланылган. Каралту өчен әзерләнгән бизәкне башта уеплыйлар. Борынгы за - маннардан ук киң кулланылган. Безнең төбәктә У. техникасындагы сәнгатьле эшләнмә - ләрнең иң борынгылары болгар дәверенең башлангыч чорына карый (к. *Болгар сәнгате*). Алар — бакыр, көмеш һәм алтыннан эшлән - гән ат дирбиясе һәмияр бизәмәләре, ыңгыр - чаклар, билбау япмалары, каптырмалары һәм асылмалары, аеллар һ.б. Монголларга кадәр - ге дәвердә У. б-н көзгеләр, асылма йозаклар, товар тамгалау мөһерләре, сугыш балтала - ры һ.б. бизәлгән. Чәчәк-үсемлек рәсемнәре һәм геом. мотивлар б-н беррәттән, гадәттә, медальон композицияләрендә җәнлек сурәт - ләре дә кулланылган. Болгар алкаларындагы коелган яисә уелган сурәтләр яфрак мотив - ларындагы нәфис У. б-н бизәлгән; У. техни - касы б-н башкарылган бизәкләр такта белә - зекләр буйлап сузылган яисә аларның очла - рында урнашкан. 12 йөздән геом. бизәк, үсем - лек һәм җәнлек сурәте б-н беррәттән гарәп язуы да кулланыла. Югары үсеш дәрәҗәсенә У. Алтын Урда дәверендә күтәрелә (к. *Алтын Урда сәнгате*). Эшләнмәләр башкарылу төгәллеге, югары зәвыгы, бизәкләр байлыгы б-н аерылып торалар; У. еш кына алтын, ал - тын йөгертелгән, көмеш әйберләрдә башка - рылган (арыслан башы сурәтләнгән, очлары «А» рәвешендә бизәкләнгән, үсемлек рәсем - нәре б-н баетылган беләзекләр, Коръән тарт - малары, билбау асылмалары, металл борыс - лар һ.б.). Ишү, яфрак бөреләнү, спираль, «йө - герек дулкын» мотивлары киң тарала. У. б-н савыт-саба һ.б. көнкүреш әйберләре дә би - зәлә.

18 йөз башында — 20 йөздә У. көмеш һәм аның эретмәләреннән эшләнгән гаммәви би - зәмәләрдә киң кулланыла. Еш кына У. уры - нына бизәкне кислота б-н ашатып уйдыр - ганнар. Гәрчә тирән һәм нык кабарынкы рель - ефлы У. үрнәкләре очраса да, гадәттә, У. би - зәге шартлы һәм яссы характерда булган. Рә - семнәр, күләгә, күләм һәм тирәлек чагылды - рылмыйча, линияләр һәм контурлардан тор - ган. Үсемлек сурәтләре өстенлек иткән. Геом. рәсемнәрдә ярымдулкын, зигзаг, розетка, ромб һ.б. мотивлар популяр булган. У. юлы б-н изге теләкләр, Коръән гыйбарәләре, там - галар һ.б. төшерелгән. У. техникасында бизәк - ләр такта беләзекләрдә, яка каптырмаларын - да, Коръән тартмачыкларында, ярымайлы алкаларда, йөзекләрдә һ.б.да башкарылган. Асылташларны У. «*глиптика*» — уеп таш ки - сү дип атала.







Уеплау. 1. Асылма йозак. Бронза. Кою, уеплау. 10–12 йөзләр. ТР Милли музее; 2. Беләзек. Көмеш, асылташлар. Уеплау. 19 йөз уртасы. ТР Милли музее; 3. Алка. Көмеш. Уеплау. 19 йөз. ТР Милли музее; 4. Беләзек. Көмеш. Уеплау, чүкү. 19 йөзнең 2 нче яртысы; 5. Беләзек. Фрагмент. Көмеш. Уеплау. 19 йөзнең 2 нче яртысы. Икесе дә — Россия халыклары этнографиясе музеенда (С.-Петербург).

Әд.: Фёдоров-Давыдов Г.А. Искусство кочевников и Золотой Орды. М., 1976; Валеев Ф.Х., Валеева-Сулейманова Г.Ф. Древнее искусство Татарстана. К., 2002; Валеев Ф.Х. Татарский народный орнамент. К., 2003.

Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.

«УЖАРА́» («Таң»), иҗтимагый-сәяси, әдәби газета. 1917 елның 25 августыннан 1918 нең декабренә кадәр Казанда мари телендә нәшер ителә, барысы 72 саны чыга. Казан губерна земство органы буларак чыга башлый. Газета редакциясенә башта Вакытлы хөкүмәт һәм Учредительләр җыенын яклап чыккан Д.И.Адаев, В.М.Васильев, С.Г.Гаврилов, И.Н.Коведяев керә. Ушмар (Коведяев) «Учредительләр җыены нәрсә эшли?» («Что делает Учредительное собрание?») мәкаләсендә, Дәүләт Думасы эшчәнлеген характерлаганда, аның фикеренчә, Россиянең законнар чыгару органы эшенә каршылык күрсәтүче большевикларны тәнкыйтьли. Газета, эсерлар фикеренә таянып, соц. рев-ция идеяләрен кире кага. Редакция үз материалларында мариларның Үзәк союзы позицияләренә юнәлеш ала, Учредительләр җыены сайлауларына әзерлек чорында кооператорлар һәм бәйсез социалистлар партияләренә өстенлек бирә. 1917 нең 22 сентябрендә «У.» редакциясе җыелышында Казанның эсерлар ком-тының сайлау исемлеге кире кагыла, чөнки губерна крәстияннәр съездында мариларга исемлектә урын бирелми. 1917 елгы Окт. рев-циясе җиңгәннән соң, газета Совет хакимиятенә карата мөнәсәбәтен акрынлап үзгәртә башлый. 1918 нең 13 апреленнән ул крәстиян депутатлары Казан советының рәсми органы була, редакция б-н В.А.Мухин җитәкчелек итә. Бу вакытта «У.» совет хакимиятен ачыктан-ачык яклый, яңа тормыш төзүгә актив катнашырга чакыра. Укытучылар (И.Беляев, А.Конков, Г.Микай, Н.Мухин) һәм мари комис-ты хезмәткәрләре язмалары еш басыла. Казанны КОМУЧ халык армиясе һәм Чех-словак корпусы частьлары алган чорда басма эше туктала. Казанны Кызыл Армия алгач, «У.» РСФСР Милләтләр эшләре буенча халык комис-тының мари бүлеге органы буларак дөнья күрә башлый. Анда мари теленә тәр җәмә ителгән совет хөкүмәтенең декретлары, рәсми документлар, тарихи һәм мәдәни агарту характерындагы материаллар басыла. Редакция мари теле һәм әдәбияты үсешенә үзеннән зур өлеш кертә, ноталар б-н җыр текстлары, шигырьләр һ.б. басыла. «Йошкар кәче» мари г-тасы б-н бергә чыга. 1918 нең декабрендә (51 сан) алга таба мари телендә бары тик «Йошкар кәче» генә чыга дип хәбәр ителә, 52 нче саны (1918) «У.»ның соңгы саны була.

Әд.: Сергеев М.Т. Возникновение и развитие печати Марийской АССР. Йошкар-Ола, 1971.

УЖУ́Р РАЙОНЫ́, *Красноярск краеның* көньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. 1924 елның 4 апрелендә оештырыла. Мәйданы — 4235 *км*². Үзәге — Ужур шәһәре. Халкы — 31545 кеше (2017). Татарлар, тупланып, Берёзовый Лог (Кызыл Май) (1920 дә нигез салына, татарлар — 203 кеше) һәм Кызыл Күл (1925 тә нигез салына, татарлар — 120 кеше) авылларында яшиләр. Берёзовый Лог авылы мәктәбендә татар теле факультатив дәрес буларак укытыла (5–9 сыйныфларда), «Татар фольклоры» түгәрәге, татар мәдәнияте, көнкүреше һәм авыл тарихына багышланган «Чыганак» музее эшли. Торак пунктларның икесендә дә *Сабан туе* уздырыла. Кызыл Күл авылы б-н Соц. Хезмәт Герое Н.А.Демухаметовның тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге бәйле.

УҖЫ́М КУЛЬТУ́РАЛАРЫ, берьеллык а.х. үсемлекләре; үсә башлаганда яхшы үсеш өчен түбән температураның озак тәэсире кирәк. Көз көне чәчеләләр, уңышны икенче елда бирәләр. Актив вегетациянең 2 чоры бар: көзге (40–50 тәүлек) һәм язгы-җәйге (75–100 тәүлек) чорлар. ТРда уҗым *арышы* һәм *бодае* үстерелә. Уҗым рапсы чәчүнең җәйге һәм иртә көзге срокларында соңгы көзге яшел азык алу өчен генә чәчелә. У.к. кышка тармакланып һәм тамыр системасын үстереп керә. Арышны 10–15 августта, бодайны 15–30 августта яхшы әзерләнгән туфракка чәчкәндә, үсемлекләр әйбәт көзге чыныктыру шартларында яхшы кышлыйлар, яз көне беренче җылы көннәр башлануга үсә башлыйлар. У.к., язгы культуралардан аермалы буларак, язгы-җәйге корылыкны җи нәлрәк кичерә, уңышны күбрәк бирә; 7–10 көнгә иртәрәк өлгерә. Уҗым арышы иртә язгы яшел азык алу өчен бар җирдә дә арадаш пар биләүче культура буларак кулланыла. У.к. барлык язгы культуралар өчен яхшы элгәрләр санала. Казан губернасында бөртеклеләрнең тулай җыенында У.к.ның тоткан урыны 1866 елда — 48,4%, 1870–74 тә — уртача 48%, 1875–79 да — 47,8%, 1880–84 тә — 44,9%, 1890 да — 55%, 1913 тә — 59,8%, 1920 дә 62,3% тәшкил итә. Тулай җыем структурасында уҗым арышы 1866 да 100% тан 1920 дә 95,8% ка кадәр били. Татарстанда У.к. җитештерү буенча мәгълүматлар таблицада бирелә.

Ел	Бөртеклеләрнең тулай җыемында уҗым культураларының тоткан урыны (өлеше)	нисбәте	
		арыш	бодай
1928	49,7	90,2	9,8
1940	39,7	100,0	
1960	47,5	95,9	4,1
1970	18,6	88,4	11,6
1980	17,9	78,6	21,4
1990	39,8	94,5	5,5
1995	20,2	84,9	15,1
2000	20,3	83,7	16,3
2006	19,8	57,4	42,6
2015	40,0	38,8	59,8

Әд.: к. *Арыш*, *Бодай* мәкаләләрен.

И.Н.Афанасьев.

УЗАМБА́Р МИЛӘҮШӘСЕ́, к. *Сенполия.*

УИ́НСКИЙ (ӨЯ́) РАЙОНЫ́, *Пермь крае ның* көньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан. 1924 елда Көнгер округының Суда р-ны буларак оештырыла, 1926 дан хәзерге исемен йөртә. Мәйданы — 1555,3 *км*². Үзәге — Уинское авылы (Пермьнән 174 *км* көнчыгыштарак). Халкы — 10647 кеше. Татарлар саны: 2007 дә — 4468, 2010 да — 3793 кеше. Районда 7 татар торак пункты бар: Барсаи, Югары Сеп, Иштирәк (Җалнаер), Түбән Сеп, Чәйкә, Урта Сеп һәм Усть-Телес. Иң борынгысы — Чәйкә (элеккеге Карамыш) авылы, 1636 дан билгеле. Барсаи, Югары һәм Түбән Сеп, Иштирәк, Чәйкә, Усть-Телес авылларында мөселман дини оешмалары бар. Иштирәк авылында татар мәктәбе эшли. У.р. татар-башкорт иҗтимагый үзәге үзенең эшчәнлеген алып бара. У.р.нда Сов. Союзы Герое Л.С.*Сибгатуллин* һәм Дан орденының тулы кавалеры Х.С.*Садыйков* туган.

Әд.: Шумилов Е.Н. Населённые пункты Пермского края: Краткий ист. справ. Пермь, 2008; шул ук. Татары и башкиры Западного Урала. Пермь, 2008.

УЙ РАЙОНЫ́, *Чиләбе өлкәсенең* үзәгендә урнашкан. 1926 елда оештырыла. Мәйданы — 2637 *км*². Үзәге — Уй авылы (Чиләбедән 186 *км* көньяк-көнбатыштарак). Халкы — 23427 кеше (2017). 2002 дә — 2455, 2010 да 2128 татар яши. Татарлар, башлыча, 1746–47 еллардагы Уй чик буе ныгытмалары төзелеше б-н бәйле рәвештә нигезләнгән Әмин авылында (2002 дә — 894 кеше) яшиләр. 18 йөзнең 2 нче яртысында — 19 йөзнең 1 нче яртысында җирле халык типтәрләр һәм мишәрләр катлауларына керә, каравылда тора, игенчелек, терлекчелек б-н көн күрә. 1800 дә Әмин авылында мәчет төзелә, 1910 да мәдрәсә ачыла (1929 га кадәр эшли), 1930–1961 дә «Кызыл юл» к-зы була. 1990 елларда җирле гомуми белем бирү мәктәбендә татар теле яңадан укытыла башлый, милли мәдәният һәм тарих музее ачыла. Авылда мәчет эшли, *Сабан туе* уздырыла.

Л.И.Федотова.

УЙГЫ́Р ЯЗУЫ́, төрки халыклар файдаланган иң беренче язу системаларының берсе. Арамей язуының бер төренә барып тоташкан согдий алфавиты җирлегендә барлыкка килә. Датасы күрсәтелгән беренче ядкәрләр 8 йөз башына карый. Өстән аска таба языла, юллары сулдан уңга таба укыла. Уйгыр алфавиты 16 график элемент нигезендә төзелә, алар комбинациясеннән сүзнең башы, уртасы һәм ахыры өчен билгеләнгән төрле төрыштагы (формадагы) 24 графема (хәреф) ясала. У.я. рун язуы б-н якынча бер үк вакытта барлыкка килә һәм акрынлап аны кысрыклый. Ул, гомумкабул ителгән төп язу системасы буларак, озак вакыт дәвамында (8–10 йөзләрдә манихей, брахми, эстрангело һ.б. телләр б-н берьюлы) кулланыла, зур булмаган үзгәрешләргә дучар була. У.я. 8–14 йөзләрдә уйгыр һәм борынгы төрки кабиләләр тарафыннан Көнчыгыш Төркестан (Көнбатыш Кытай) терр-ясендә аеруча актив файдаланыла. 17 йөз ахырында язылган текстлар да билгеле. Безнең көннәргә кадәр уйгыр язулы дини (тәр җәмә ителгән «Алтын яруг» будда трактатлары, 10 йөз), фәнни (мед., астрономия, астрология буенча), матур (шигырьләр, легендалар), юридик әдәбиятлар, ш.у. ху җалык-эшлекле хатлар килеп җитә. Й.Баласагуни иҗат иткән «Котадгу белег» («Игелекле белем», 1069–70) поэмасының өч күчермәсеннән берсе У.я. б-н язылган. 13 йөздә У.я.н монголлар үзләренә ала һәм үзләштерә, аларда ул бүгенге актив кулланы-

лыштагы монгол язуына әверелә. У.я. Алтын Урдада 14 йөзнең 2 нче яртысына кадәр *гарәп язуы* б-н берлектә рәсми дәүләт язуы сыйфатында файдаланыла. Бу графикада күп кенә хан ярлыклары (Туктамыш, Тимер Котлыгъ), төрки-татар телендә хатлар (мөрәҗәгатьнамәләр) һ.б. языла. Төрки халыкларда У.я. гарәп язуы б-н кысрыклана.

Әд.: Малов С.Е. Памятники древнетюркской письменности. М.–Л., 1951; Усманов М.А. Жалованные акты Джучиева Улуса XIV–XVI вв. К., 1979; Щербак А.М. Краткий очерк уйгурской эпиграфики и замечания об уйгурском алфавите // Тюркская руника. СПб., 2001; Языкознание: Большой энцикл. словарь. М., 1998.

Р.Ә.Закиров.

УЙМА́К ЧӘЧӘ́К, дигиталис (Digitalis), сыраҗчалар семьялыгыннан ике- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр, куаклар һәм ярымкуаклар ыругы. 30 дан артык төре билгеле, Евразия һәм Төньяк Африкада таралганнар. ТР терр-ясендә бер төре — эре чәчәкле У.ч. (D. grandiflora) Идел алдында һәм Көнбатыш Кама аръягында очрый. Киң яфраклы һәм нарат урманнары буенда һәм кисенделәрендә, куаклар арасында, болыннарда үсә. 60–120 *см* биеклектәге күпьеллык үсемлек. Тамыр системасы кыска, чук. Сабагы туры, йомшак бөдрә төкчәле. Яфракларының өске ягы куе яшел, асты аксыл, тамыр янындагылар яфрак таралгысына җыйналган, сабактагылар чиратлашкан, озынча ланцетсыман, очланган, кыска саплы. Чәчәкләре эре, иенке, бер яклы озын чукта. Тажы сары, эчтә коңгырт сеңерчәле, кыңгыраусыман, уймак кебек (исеме шуннан). Җимеше — йомыркасыман, ике оялы күп орлыклы тартмачык. Июнь–июльдә чәчәк ата, июль–августта җимешләре өлгерә. Орлыктан үрчи. Яфракларында гликозид, сапонин, флавоноид, органик к-талар бар. Халык медицинасында төнәтмәсе йөрәк-кан тамырлары системасы авырулары вакытында һәм бәвел кудыру чарасы буларак кулланыла. Декоратив үсемлек. Агулы. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

УКАЛА́П ЧИГҮ́, гамәли-бизәлеш сәнгате төре; киемнәрне, көнкүреш әйберләрен бизәгәндә кулланыла торган бизәкләү ысулы. Татарларда «алтын җеп» мәгънәсендә йөрүче «ука» сүзе бар. Чигүнең бер төре «укалап чигү» дип атала. У.ч. бәрхеттә, сирәк кенә — ефәк, ки же-мамык, йон яки киндер тукыма өслегендә, ш.у. күндә башкарыла. Урта Азия, Төркия, Иран, Һиндстан, Көнбатыш Европадан кайткан югары сыйфатлы бәрхет фай - даланыла; күн һ.б. тукымалар җирле җитештерүчеләрдән алына. У.ч. киже-мамык яки ефәк җеп кушып эрләнгән металл җеп б-н башкарыла. Тукымага тыгыз итеп ефәк җеп б-н беркетелгән алтын (сирәк кенә — көмеш) чыбыктан торган ука яки укалы җеп чорнала (бөтерелгән һәм эчтән яшерелгән). Чигү техникасының 2 төре кулланыла: беренче алым беркетеп куеп чигү дип атала. Чүкелгән алтын яки көмеш чыбык (ука) тукыманың уң як өслегенә куела һәм нечкә ефәк җепләр б-н беркетелә. Мондыйysул б-н, башлыча, баш һәм аяк киемнәрен бизәгәннәр. Икенче алым — нәгыш; аның б-н йола сөлгеләре чигелгән: У.ч. алтын яки көмеш канитель б-н башкарылган, җеп инә б-н тукыма аша сапланган. У.ч.гә декоратив материаллар — спираль итеп бөтерелгән металл җеп (трунцал), басма бизәкле җиз тәңкәләр, сәйләп, энҗе, ялтыравык аеллар, алтын чуклар һ.б.ны өстәү хас.

У.ч. югары шәһәр культурасы шартларында үскән проф. һөнәрчелеккә хас. Болгар шәһәрендә сирәк очрый торган археол. табылдыклар арасында эрләнгән, алтын йөгертелгән көмеш җеп б-н чигелгән ефәк тукыма калдыклары табылу У.ч.нең үсеш дәрәҗәсе 14–15 йөзләрдә үк югары булуы турында сөйли. Урта гасырлардагы язма чыганакларда да алар турында мәгълүматлар сакланган. Терлек асрап көн итүче төркиләрдә күндә У.ч. аеруча популярлык казана (заказ бирүчеләр — Хан сарае вәкилләре һәм югары катлау кешеләре). ТРның Милли музее фондларында 16–17 йөзләргә караган уникаль япма саклана. Татарларда У.ч., классик милли сәнгать төре буларак, 18 йөзнең 2 нче яртысыннан үсеш ала. 19 йөз башыннан Казанда 1 меңнән артык һөнәрче хатын-кызны берләштергән читек-кәләпүш кәсепчелеге составында укалап чигү һөнәрчелеге барлыкка килә (к. *Каюлы күн кәсепчелеге*). Алар эчке һәм тышкы базар ихтыяҗларын канәгатьләндерәләр, эшләнмәләр Казан, Түбән Новгород, Мәскәү һәм Россиянең башка шәһәрләрендәге эре ярминкәләрдә сатыла. Укалап тегү һөнәренә чигүдәге кебек мәчетләр каршындагы *мәктәпләрдә* кыз балаларны өйрәтәләр.



«Казан сөлгесе». Укалап чигү. Ефәк, алтын җеп, ялтыравыклар, алтын тасма, чук. 19 йөзнең 2 нче яртысы. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

Музей тупланмаларында (ТРның Милли музее, С.-Петербургтагы Россия халыкларының этнография музее, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее һ.б.) 19 йөз — 20 йөз башы У.ч. эшләнмәләренең күпсанлы үрнәкләре саклана. Алар — хатын-кыз (калфак, тәкыя) һәм ирләр (түбәтәй, кәләпүш) баш киемнәре, хатын-кыз баш бәйләвечләре (маңгайлык), ш.у. йола (башлыча, туй) сөлгеләре, күкрәк япмалары (изү, күкрәкчә), янчыклар, бәрхет башмаклар һәм читекләр, затлы Коръән тартмалары (18 йөз ахыры — 19 йөз башы, ТРның Милли музее). У.ч.дә нәфис чәчәк — үсемлек бизәкләре төп рольне уйный. Ул бакча (кашкарый, алтын чәчәк, дәлия, гөлчәчәк һ.б.), кыр һәм дала (зәңгәр чәчәк, акчәчәк, күкчәчәк, лалә һ.б.) чәчәкләреннән төзелә. Сурәтләре шартлы һәм гомумиләштерелеп төшерелә. Калфаклардагы бизәкләрдә букет композициясе, «тормыш агачы» һәм «алтын каурый», 19 йөз ахырыннан — йолдызлар һәм ярымай үрнәкләре, еш кына «җәннәттәге бәхет кошлары» сурәтләнгән «җәннәт бакчасы» зур популярлык казана. Ир-атлар түбәтәе бизәге, гадәттә, гомумиләштерелеп ачылган чәчәк-үсемлек һәм геом. фигура үрнәкләреннән төзелә — шахмат тәртибендә, букет композицияләре, давыл чәчәкләре, спиральләр һ.б. рәвешендә урнаша. Төрки халыклардагы хатын-кыз киемнәренең борынгы бизәмәләренә караган күкрәкчәләрендә дини эчтәлектәге гарәп язулары б-н үрелгән «тормыш агачы» һәм «чәчәк букеты» рәвешендәге композицияләр чигелә. Соңгылары ш.у. тукымадан әзерләнгән Коръән тартмаларын бизәп торган. Бизәү тәэсирен орнаменттан кала төсләр фоны да көчәйткән. Еш кына ул, гадәттә, укалы бизәге аеруча аерылып торган яшел-зөбәрҗәт, куе алсу яки миләүшә төсләр б-н баетылган бәрхет тукымадан гыйбарәт булган. Тәэсир итү көче җеп астына кәгазь яки күн салып, бизәкләрнең рельеф өслеген булдыру нәтиҗәсендә ирешелгән. Озын һәм кыска атламнарның капма-каршылыгы, яссы, шома һәм үзенчәлекле өслекнең бер-берсенә ярашуы б-н барлыкка килгән бизәкләр нәфислеге, ачык чагылышлары б-н аерылып торган.

У.ч. әйберләре Казан татарлары яшәгән төбәктән ераклarda да киң таныла. Татарларның барлык этник төркемнәре — Әстерхан, Себер, ш.у. Кырым татарлары һәм башкортлар арасында популярлык казана. 1920 елларда баш киемнәре һәм күн аяк киеме тегүче кооператив артельләр кысаларында («Азат хатын», «Кызыл кустарь») укалап чигү эше үсеш ала; Рязань өлкәсендәге Касыйм өязенең Тарбай авылында Касыйм татарларының У.ч. һәм тегү традицияләре базасында уку-укыту–үрнәк остаханә оештырыла. 1930 еллардан башлап, У.ч. һөнәрчелек буларак әкренләп сүнә һәм 1950 елларның уртасына кадәр күбесенчә Татарстанның көнчыгыш районнарында, Башкортстанда һәм Көнбатыш Себердә традицион хатын-кыз һәм ир-ат баш киемнәре тегүен дәвам иттергән авыл осталарының шәхси шөгыле булып кала.

1931 дә Казанда күпләп җитештерүче ф-ка продукцияләре б-н бергә, татарлар өчен тегелгән, ш.и. укалап чигелгән эшләнмәләрне аз сериялəр б-н чыгаручы «Конфекцион» артеле төзелә. 1970 тән башлап, милли сувенирлар сыйфатындагы укалап чигелгән эшләнмәләргә ихтыяҗ арта. Алар өйдә эшләүчеләрнең Казан нәфис кәсепчелек комб-ты базасында, «Швейник» ф-касында һәм аерым үзеш - чән осталар тарафыннан (М.Бикбулатова, Ф.Калмурзина, В.Максимова, Р.Фәйзрахманова, Р.Фәйзуллина һ.б.) эшләп чыгарыла. 1990 нан башлап, У.ч. сәнгате проф. Казан рәссамнары иҗатында (С.Гарбузова, И.Галант, В.Кудряшова, С.Кузьминых, А.Липина, О.Марсова, Л.Фәсхетдинова һ.б.), иҗат остаханәләрендә, сувенирлар җитештерүчеләрдә («Туран» милли мәдәният үзәге, «Тради-



Укалап чигү. 1. Калфак. Бәрхет, укалап чигү. 19 йөз. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 2. Ирләр түбәтәе. Бәрхет, алтын җеп, укалы тасма. 19 йөз. ТР Милли музее; 3. Калфак фрагменты. Бәрхет, укалап чигү. 19 йөз. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 4. «Бәхет кошлары» ясалган калфак. Бәрхет, алтын җеп, ука. Укалап чигү. 19 йөз. ТР Милли музее; 5. Башмак. Бәрхет, ука, сәйләп, ялтыравык. Укалап чигү. 1980 еллар, «Арча милли аяк киемнәре» АҖ; 6. Күн итек өзерләнмәсе. Фрагмент. Күн. Алтын, көмеш һәм ефәк җепләр, трунцал, ялтыравыклар. Мозаика, чигү. 19 йөз ахыры. Дәүләт тарих музее. Мәскәү; 7. Калфакның маңгайлык үрнәкләре. Бәрхет, алтын җепләр, ялтыравыклар. Укалап чигү. 19 йөз. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 8. С.Д.К у з ь м и н ы х. «Казан сөлгесе». Ефәк, алтын җеп. Укалап чигү. 2001. «Туран» милли мәдәният үзәге фонды; 9. Л.И.Ч у б у к о в а. Сумка. Ефәк, алтын җепләр, ука, укалы тасма. Укалап чигү. «Туран» милли мәдәният үзәге фонды; 10. И.А.Г а л а н т. Коръән тышлыгы. Бәрхет. Алтын һәм ефәк җепләр, асылташлар. Укалап чигү. 2000; 11. С.Д.К у з ь м и н ы х. «Алтын гасыр». Читек. Күн, алтын җеп, сәйләп, ялтыравык. Чигү. 2001.



М. Укмасый.

ция» мәдәният фондының укалап тегү оста - ханәләре, ТРның Сәнгать фонды, «Салават» җыр театры һ.б.) үсеш ала. Коръән тартмалары, дивар панносы, хатын-кыз киеменә өстәмә бизәгечләр (сумкалар, путалар, юка шарфлар һ.б.) иҗат ителә. Гарәп язулары, сюжетлар һәм орнаментлы композицияләр б-н алтын һәм көмеш җептән бәрхеткә чигелгән шәмаиләр аеруча популярлык казана (А.Липина, Л.Фәсхетдинова).

Әд.: В а л е е в Ф.Х. Орнамент казанских татар. К., 1969; ш у л у к. Народное декоративное искусство Татарстана. К., 1987; ш у л у к. Татарский народный орнамент. К., 2003; В а л е е в а - С у л е й м а н о в а Г.Ф. Декоративное искусство Татарстана (1920-е — начало 1990-х годов). К., 1995.

Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.

УКЛА́Р (Agrionidae), әнә караклары отрядындагы тигезканатлылар асотрядыннан бөҗәкләр семьялыгы. Бүксәсенең озынлыгы 300 *мм* га кадәр, канатлары — 24 *мм*. Бик сүлпән оча. Канатлары бертигез, сабакчасыман нигезле һәм сирәк сеңерчәле; тыныч халәттә бүксә өстеннән күтәрелеп торалар. Бүксәсе кара бизәкле зәңгәр, коңгырт, аксыл-кызыл, яшькелт төстә. 700 гә якын төре билгеле, күбесенчә тропикларда таралганнар; Россиядә якынча 40, Татарстан терр-ясендә 5 төре билгеле. Агымсыз сулык ярлары буенда очрый. Вак бөҗәкләр, күбесенчә икеканатлылар б-н туеналар. Ана зат үсемлекләрнең су асты өлешләренә күкәй сала. Личинкаларының бүксәләре ахырында саңаклары бар, йөзгән вакытта алар койрык йөзгече буларак файдаланылалар. Татарстан терр-ясендә гади ук (Agrion hastulatum) һәм чибәркәй ук (Coenagrion puella) аеруча еш очрый.

Н.В.Шулаев.

«УКЛА́Р», рәсемле айлык сатирик журнал. 1906 елның июненнән ноябренә кадәр Уральск шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, барысы 6 саны чыга. Нашире һәм мөхәррире — К.*Мотыйгый*, фактик җитәкчесе — Г.*Тукай*. Журнал күләме — 16 бит, К.Мотыйгый басмаханәсендә басыла. Күп язмаларның авторлары — Г.Тукай һәм К.Мотыйгый; ш.у. Петербургның «Стрела» ж-лыннан да тәр җәмәләр басыла. Тукай мәкаләләре төрле псевд. (күп очракта — Шүрәле) б-н чыга . Сатирик язмалар, юмористик хикәя һәм шигырьләр, ш.у. текст язулары б-н эчке һәм тышкы сәясәт темасына карикатуралар басыла. «У.» материаллары татарлар арасында грамоталылыкны тарату, фәнни белемнәрне популярлаштыру, илдәге һәм дөньядагы хәлләрдән хәбәрдар булуны алга сөрә, анда торгынлыкка, аерым алганда, тәрәккыятькә комачаулаучы муллаларга каршы юнәлдерелгән язмалар дөнья күрә. Редакция фикеренчә, алар гади халыкка югарыдан карыйлар, мәдрәсә һәм мәктәпләрдә искергән алымнар б-н укытуны хуплыйлар. Журналда иске карашлы дин әһелләре арасында мөселман уку йортлары дини фанатиклык чыганагы булып тора дигән фикер яңгырый. «У.» мәгърифәтне реформалаштыру идеяләрен, дөньяви тәртип кертүне, шәкертләрнең иҗади уйлавын үстерүне яклый. Редакция 1905–07 еллардагы рев-циянең демократик казанышларын якларга, татар халкының милли һәм соц. үзаңын үстерүгә булышлык итәргә омтыла. «У.» иске карашлы һәм либераль юнәлешле «Бәянелхак», «Йолдыз», «Тәр җиман», «Өлфәт» кебек татар г-талары б-н актив бәхәсләшә. Журналда фельетон, памфлет, шаян шигырьләр кебек жанрлар, диалог, риторик сорау, хат формасындагы материаллар



«Уклар» журналы.

киң кулланыла. Күп карикатураларны рәссам Н.Г.Калентьев (псевд. Н.К.) ясый, рәсем астына язылган язулар татар һәм рус телләрендә басыла.

Әд.: Г и м а д и е в У.И. Сила сатирического слова. К., 1987; Г а л и е в а Р.М. Роль журнала «Уклар» в развитии татарской сатирической журналистики // Информационное поле современной России: Практики и эффекты. К., 2006.

Р.М.Галиева.

УКМАСЫ́Й (тәхәллүсе, чын исеме — Зәби - ров Миргазиз Габделкаюм улы) (14.6.1884, Казан губ., Лаеш өязе Кече Укмас а. — 1948, Казан), шагыйрь. Дин эшлеклесе улы. Башлангыч белемне туган авылында ала. Илләбәр, Сатыш (хәзер Саба р-ны), «*Мөхәммәдия*» (1908 елга кадәр) мәдрәсәләрендә укый, «Яшерен әдәби түгәрәк» һәм шәкертләрнең «әл-Ислах» яшерен сәяси оешмасы әгъзасы. 1907–14 елларда Саратов губернасының Татар Кынадысы авылында, Акмулла шәһәрендә укыта. Беренче бөтендөнья сугышында катнаша. 1923–25 тә туган авылында мулла була, игенчелек б-н шөгыльләнә. 1931 нең маенда кулга алына, 8 елга лагерьларга хөкем ителә (шартлы рәвештә). Со ңыннан Яшел Үзән һәм Казан шәһәрләрендә яши. Тукай шигърият мәктәбен дәвам итүче буларак билгеле. Беренче шигырьләрен 1905–07 дә «Казан мөхбире», «Бәянелхак», «Азат», «Йолдыз» һ.б. г-таларда бастыра. «Хатирә, яки Дустларыма сүзләрем» (1906), «Алданма кызыл алмага» (1907), «Миргазиз Укмасый шигырьләре» (1909), «Өмид йолдызым» (1912) шигырь җыентыклары, «Хәлифәлек өчен көрәш» (1917 дә «Сәйяр» труппасы куя) пьесалары авторы. К.Насыйри, Г.Тукай, Ф.Әмирхан турында истәлекләр, әдәби тәнкыйть мәкаләләре авторы.

Әс ә р.: Сайланма әсәрләр. К., 1958.

Әд.: Р ә м и З. Авыр язмышлы шагыйрь // Татарстан. 1994. № 5–6.

З.З.Рәмиев.

УКМАШУЧЫ́ ЧЕБЕННӘ́Р (Emhididae), икеканатлылар отрядыннан бөҗәкләр семьялыгы. Вак яки уртача зурлыктагы сирәк төкчәле, шәрә диярлек чебеннәр. Башы кечкенә, хортумчыгы бик зур, аска төшеп тора яки күкрәге астына таба бөгелгән. 2,8 меңгә якын төре билгеле, киң таралганнар, аеруча урманнарда күп. Күбесенчә ерткычлар (вак бөҗәкләр б-н туеналар). Җитлеккән У.ч. агач кәүсәсендә һәм яфракларында очрыйлар, кайберләре агачлар астында, һавада укмашып (исеме шуннан) күч хасил итәләр. Личинкалары туфракта, ара-тирә кечкенә елга һәм инешләр төбендә яши. Россиядә якынча 260 төре бар. Татарстан терр-ясендә гади укмашучан чебен (Empis tesselata) еш очрый: гәүдә озынлыклары 10–12 *мм*, кара-көрән төстә, күкрәк өсте соры, аркылы 5 кара сызыклы, аяклары кара, кызыл-сары балтырлы, канат төпләре җирән-сары. Чәчәкләрдә еш очрый.

С.М.Шәфигуллина.

УКРАИ́НА, Көнчыгыш Европадагы дәүләт. Көньякта Кара һәм Азов диңгезләре б-н юыла. Көньякта, көнчыгышта һәм төньяк-көнчыгышта — Россия, төньякта — Белоруссия, көнбатышта — Польша, Словакия һәм Венгрия, көньяк-көнбатышта Румыния, Молдавия һәм танылмаган Приднестровье Молдавия Респ-касы б-н чиктәш. Мәйданы — 575,5 мең *км*^{2}. Халкы — 45,2 млн. кеше (2014). 2001 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 73,3 мең (1959 да — 61,5 мең, 1970 тә — 76,2 мең, 1979 да — 90,5 мең, 1989 да — 86,9 мең) кеше. Башкаласы — Киев. У. терр-ясендә элек-электән *Кырым татарлары* яши, көньяк өлеше 3 гасырдан артык — 1443–1783 елларда, *Кырым ханлыгы* составында була. 1783 тә Кырым Россия империясенә кушыла, бу терр-ядә Таврия губернасы оештырыла. Октябрь рев-циясеннән соң, 1921 дә, РСФСР составында Кырым АССР төзелә. 1954 тә совет җитәкчелеге карары нигезендә Кырым АССР Украина ССР составына бирелә. 2014 нең мартында, бөтенхалык референдумы нәтиҗәләре нигезендә, Кырым кабат РФ составына кертелә. Идел-Урал буе татарлары (күбесенчә Казан, Түбән Новгород, Самарадан) У. җиренә 19 йөз уртасыннан урнаша башлый. Киевта татарлар Подол, Святошино бистәләрендә яшиләр, нигездә, сәүдә б-н шөгыльләнәләр. Татарларның күпчелеге У.ның көньягында һәм көнчыгышындагы сәнәгать р-ннарына күченә, Юзовкадан (хәзерге Донецк ш.) алып Александров-

скига (хәзерге Запорожье ш.) кадәрге җирләргә уннарча мең кеше килеп утыра. 1909–17 дә *Харьков мөселманнары хәйрия җәмгыяте* эшли. 1920 дә поляклар каршы сугыш хәрәкәтләрендә һәм Киевны азат итүдә Аерым татар ирекләр батальоны катнаша. Совет чорында Урта Идел һәм Урал буеннан килүчеләр шахталар, электр станцияләре, металлургия з-длары, тимер юл төзелешләрендә эшлиләр. 1921–24 тә Харьковта шахтёрлар һәм тау эшчеләре арасында идеология һәм мәдәни-агарту эшләрен тарату максатыннан оешкан *Украинада татар-башкорт коммунистлар секцияләренең үзәк бюросы* урнаша. Харьков шәһәрендә татар телендә *«Җәнуб тавышы»* (1918), *«Кызыл эшче»* (1920), *«Эшче тавышы»* (1920), *«Тау эшчесе»* (1921), Сталино шәһәрендә (хәзер Донецк) *«Донбасс эшчесе»* (1920–39, 1930–37 дә *«Пролетар»* исеме б-н чыга), Енакиево шәһәрендә *«Ударник байрагы»* (1932–34), Горловка шәһәрендә *«Ударник»* (1932–34), Кадиевка шәһәрендә *«Кадиевка пролетары»* (1931–34), Макеевка шәһәрендә *«Күмер ударнигы»* (1932–34), Чистяково шәһәрендә *«Күмер өчен»* (1932–35), Сорокино шәһәрендә *«Ленин байрагы»* (1932–33) г-талары чыга. Бөек Ватан сугышы чорында У.ның кайбер пр-тиеләре һәм уку йортлары ТАССРга эвакуацияләнә. Алар җирлегендә *Казан медицина инструментлары заводы* (КМИЗ), *«Сантехприбор»*, *Яшел Үзән судномалар төзү техникумы* барлыкка килә. У. өчен барган сугышларда күп кенә татарлар һәм Татарстаннан килүчеләр, ш.и. Сов. Союзы Геройлары Ш.М.*Әбдрәшитов*, З.Л.*Әсфәндияров*, Г.Г.*Вәлиев*, В.Ф.*Ежков*, Н.Ш.*Зиннуров*, П.А.*Иванов*, Ә.Х.*Ишмөхәммәтов*, А.Е.*Кошкин*, В.И.*Маринин*, Н.Н.*Нугаев*, А.З.*Петушков*, Н.П.*Сентюков*, Г.С.*Умеркин*, Н.Г.*Чунтонов*, Г.Н.*Шәмсетдинов*, Б.В.*Шульгин*, В.И.*Яницкий*; Дан орденының тулы кавалерлары А.Н.*Кадыйров*, Г.М.*Мотыйгуллин*, Х.Н.*Насыйбуллин*, Х.С.*Садыйков*, Б.М.*Салихов*, Г.В.*Сафонов*, Р.К.*Халитов*, Ә.Г.*Хөснетдинов*, Х.И.*Янаев* батырлык күрсәтә. Днепр плацдармындагы бәрелешләрдә, Киевны азат итүдә *Урта Дон бомбардировщиклар авиация дивизиясе* составында респ-ка хезмәт ияләре матди ярдәме б-н төзелгән «Советская Татария» авиаэскадрильясе катнаша. Уңъяк У.ны Казан һәм Дзержинск (Горький өлкәсе) шәһәрләрендә оештырылган *«Фастов исемендәге танк бригадасы»* азат итә. 1 нче Украина фронты сәяси идарәсе — *«Ватан намусы өчен»*, 3 нче Украина фронты сәяси идарәсе — *«Совет сугышчысы»*, 4 нче Украина фронты сәяси идарәсе *«Сталин байрагы»* татар г-таларын нәшер итә. С.А.Ковпак, А.Н.Сабуров һәм А.Ф.Фёдоров партизан берләшмәләрендә Сов. Союзы Герое Г.М.*Минаев* (Николай Орлов), Н.Маханов, Г.Спиридонов, Б.Х.Хәлиуллин һ.б. сугыша. Сугыштан соңгы чорда татарлар Украина ССРның халык хуҗалыгын торгызуда катнаша, бу — татар диаспорасының ишәюенә сәбәп була. Татарларның күпчелеген анда даими яшәргә калган Совет Армиясенең элеккеге хәрби хезмәткәрләре һәм аларның гаиләләре тәшкил итә.



«Туган тел» Бөтенукраина татар мәдәни үзәге (Татар йорты) бинасы. Киев.

Татарлар, тупланып, Киевта (2400); Донецк (19100), Луганск (8500), Херсон (5300), Запорожье (5100) Харьков (4100), Днепропетровск (3800), Одесса (2600), Николаев (1200) өлкәләрендә; азрак санда (1000 кешедән ким) Киев, Полтава, Львов, Винница, Кировоград, Черкассы, Житомир, Сумы, Хмельницкий, Чернигов, Волынь, Карпат арты, Ивано-Франковск, Ровно, Черновцы, Тернополь өлкәләрендә яшиләр. 1998 дән «Туган тел» Бөтенукраина татар мәдәни үзәге (БТМҮ, Киев, президенты — К.М.Хөснетдинов) эшли, аның составына илнең төрле төбәкләреннән 17 татар оешмасы керә: «Илдәш» (Киев), «Туган ил» мәдәни-агарту (Львов ш.) оешмалары, «Алтын Ай» татар мәдәни үзәге (Запорожье ш.), «Туган ил» (Кировоград ш.), «Дуслык» мәдәни-агарту (Харьков ш.) оешмалары, татар мәдәни оешмасы (Донецк өлкәсе Горловка ш.), «Агыйдел» (Николаев ш.), Г.Тукай исем. татар мәдәни оешмасы (Киев), Одесса өлкәсе татар-башкорт мәдәни оешмасы (Одесса ш.), «Нур» татар-башкорт яшьләр мәдәни үзәге (Киев), Донецк өлкә татар мәдәни үзәге (Донецк ш.), «Чишмә» татар мәдәни үзәге (Красный Луч ш.) һ.б. БТМҮ актив рәвештә агарту һәм хәйрия эшчәнлеге алып бара. Аның каршында телне, татар халкының гореф-гадәтләрен өйрәнүче якшәмбе мәктәпләре (Киев һәм Запорожье), «Шатлык», «Талир» (Киев), «Салават күпере» (Запорожье), «Донбасс татарлары» (Донецк), «Дуслык» (Харьков) үзешчән коллективлары оештырыла; «Дуслык» айлык ж-лы чыга, анда рус, татар һәм украин телләрендә У.дагы татар диаспорасы тормышы һәм Татарстандагы вакыйгалар яктыртыла. Үзәк татарлар тупланып яшәгән урыннарда Сабан туйлары һ.б. массакүләм мәдәни чаралар үткәрә. 1994 тә ТР б-н У. хөкүмәте арасында сәүдә-икътисади, фән-техника һәм мәдәният өлкәсендә килешүгә кул куела. Татарстан б-н У. арасындагы тарихи һәм мәдәни бәйләнешләр элек-электән килә. 19–20 йөзләрдә Казан б-н Харьков, Одесса, Киев югары уку йортлары, У.ның башка фәнни һәм мәгариф үзәкләре арасында тыгыз элемтә урнаша, фәнни-укытучы кадрлар алмашу активлашып бара. Татар халкының һәм Урта Идел буенда яшәүчеләр тарихын өйрәнүгә зур өлеш кертүчеләр — Г.И.*Перетяткович*, В.В.*Вельяминов-Зернов*, В.Ф.*Генинг*. Совет чорында Киев һәм Одесса театрларында «Шүрәле» балеты куела. Агроном Н.Г.*Гыйзбуллин*, агрохимик К.П.*Афендулов*, актриса Л.Б.*Кара-Гяур*, хәрби эшлеклеләр Ф.И.*Акчурин*, Ә.С.*Бикбулатов*, Ә.И.*Бичурин*, Р.С.*Җаббаров*, Җ.Х.*Кәримов*, Б.Ә.*Урманов*, А.Е.*Яковлев*, геолог-геофизик Р.С.*Сәйфуллин*, график Р.З.*Мәсәгутов*, нәкышчеләр Р.М.*Бәһетдинов*, Ә.Г.*Сәфәргалин*, СССРның атказанган спорт осталары С.М.*Закирова* һәм В.М.*Колотов*, зоотехник И.И.*Ибәтуллин*, тарихчы Н.М.*Якупов*, медиклар Н.Җ.*Мохтарова*, Р.Г.*Абызов*, гаилә, яшьләр эшләре һәм спорт министры Р.С.Сафиуллин, танылган эшмәкәр Р.Л.Әхмәтов, механика өлкәсендәге галимнәр Р.Ф.*Ганиев* һәм Ш.Г.*Галиев*, физик Ә.Г.*Азнакаев*, химик-технолог Н.Ш.*Сафиуллинның* тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге У. б-н бәйле.

К.М.Хөснетдинов, А.И.Ногманов.

УКРАЙ́НА ТАТА́Р-БАШКО́РТ КОММУНИСТЛА́Р СЕ́КЦИЯЛӘРЕНЕҢ ҮЗӘ́К БЮРОСЫ́, Украина КП(б) ҮК (ҮБ) каршында, 1921–24 елларда шахтёрлар һәм тау эшчеләре арасында идеология һәм мәдәни-агарту эшләрен координацияләү өчен Харьков шәһәрендә оештырыла. Әгъзалары: А.Нигъмәтуллин, С.Сабиржанов һ.б. Агитация-пропаганда һәм нәшрият эшләре б-н шөгыльләнә, төрки-татарларның 1 нче Бөтенукраина партия конференциясен әзерли һәм үткәрә. Татар телендә *«Эшче тавышы»* (1920) һәм *«Тау эшчесе»* (1921) г-таларын тәшкил итә.





1. «Туган тел» иҗат коллективы. Көньяк Украинада Бөтенукраин милли мәдәниятләр фестивале. Николаев шәһәре. 2009; Киевта «Сабантуй» бәйрәме. 2018.

УКРО́П (Anethum), чатырчалар семьялыгыннан берьеллык, сирәгрәк ике еллык үлән - чел үсемлекләр ыругы. Кыргый төрдә Үзәк Азиядә очрый. Культурада — Исле укроп, яисә Бакча укробы (A. graveolens). Берьеллык У. көчле хуш исле, салкынга чыдам, яктылык ярата, туфрактагы дымга таләпчән. Тамыры нечкә, орчык сыман; сабагы туры, ботаклы, биеклеге 2 *м* га кадәр. Яфраклары каурыйсыман телмә, саргылт-яшел яисә күк - сел-яшел төстә, чәчәкләре вак, яшькелт-сары, чәчәк оешмасы — чатыр; июнь–июльдә чәчәк ата. Җимеше — орлыкча, июль–августта өлгерә, шул вакыт ике өлешкә тарала. Яфракларында С, В1, В2, РР, Р витаминнары, каротин, фолиевая кислота, тимер, калий, кальций, фосфор бар. Яшь үсемлекләре салатлар әзерләгәндә тәмләткеч буларак, орлыклары өлгерә башлагач, яшелчә тозлаганда һәм маринадлаганда кулланыла. Орлыклары эфир майларына бай, кулинариядә, парфюмериядә, медицинада һәм консервлар әзерләгәндә файдаланыла. Ачык һәм ябык грунтта үстерәләр, җәй дәвамында чәчәләр. Яшелчә чәчүлекләрендә һәм парникларда урнаштыралар. Уңышы ачык грунтта — 1 *га* дан 150 *ц* га кадәр, ябык грунтта 1 *м*² дан 2–3 *кг* алына. ТРда чәчәргә тәкъдим ителгән сортлары: «Грибовский», «Лесногородский», «Самат», «Борей», «Кибрай». Корткычлары — чатыр көясе, чатыр утчылы һ.б.; авырулары — ончыл чык һ.б. Яшелчәчелек хуҗалыкларында һәм йорт яны бакчаларында үстерелә.


Хуш исле укроп.

Әд.: Справочник по овощеводству. Л., 1982; Овощеводство. М., 2003.

Р.Ә.Әсретдинова.

«УКУ́ УДА́РНИГЫ», иҗтимагый-сәяси, пед. журнал. ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты һәм ТАССР Мәгариф халык комис-ты органы. 1934–41 елларда Казанда ай саен татар телендә нәшер ителә. Җаваплы мөхәррире — Ш.Башкиров.

«УКУЧЫ́ СӘХИФӘСЕ́», пед. журнал. 1929–31 елларда Казанда татар телендә нәшер ителә. ТАССР Мәгариф халык комис-ты һәм Бөтенроссия мәгариф хезмәткәрләренең белемен күтәрү ин-ты бүлеге органы (мөхәррире — Х.С.Туюшев). Журнал Бөтенроссия мәгариф хезмәткәрләренең белемен күтәрү ин-ты бүлегенең читтән торып укучы студентларын уку барышында методик һәм мәгълүмати яктан тәэмин итә. «У.с.»ндә уку йортларын яңалифкә күчү барышын тизләтү планы, укучыларны контроль эшләргә әзерләү буенча тәкъдимнәр, уку барышын оештыру мәсь әләләрен яктыртқан мәкаләләр басыла.

З.З.Гыйләҗев.

УКЪЯФРА́К (Sagittaria), көтүче кубызчалар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Якынча 20 төре билгеле, Евразия, Америкада таралганнар. Татарстан терр-ясендә бер төре — гади укъяфрак (S.sagittifolia) бар. Барлык районнарда очрый. Сазлыкларда, сазлыклы болыннарда, елга, күл, буа ярлары буенда үсә, еш кына әрәмәләкләр хасил итә. 30–100 *см* биеклектәге үсемлек. Тамырчасы кыска, озын ботаклы, көзен аларның очында бүлбесыман төерләр барлыкка килә. Яфраклары тамыр яны таралгысында, су өстендәгеләре уксыман, озын сапларда, суга күмелгәннәре — кыяксыман. Чәчәкләре шәмәхә таплы ак төстә, 3 әр булып бөжрага җыйналган. Аскы бөжра ана, өскеләре ата чәчәкләрдән тора. Җимеше — күпчикләвекчек. Июнь–августта чәчәк ата. Җимешләре августта өлгерә. Орлыктан һәм вегетатив (бүлбеләрдән) юл б-н үрчи. Тамырчасында крахмал, аксым, май, шикәр бар. Су кошлары, ондатра, кондыз һ.б. хайваннар өчен азык булып тора.

«УКЫТУЧЫ́», айлык иҗтимагый-сәяси, пед., әдәби журнал. 1918 елның гыйнвар-июлендә Казанда татар телендә нәшер ителә, барысы 7 саны чыга. Нашире — Бөтенроссия мөселман укытучылар берләшмәсенең Үзәк бюросы. Басма турында карар мөселман укытучылар съездында кабул ителә. «Яшәсен мохтариятле төрки-татар милләтенең тулы хокуклы белемле укытучылары!» лозунгы б-н чыга. Актив авторлары арасында — Г.Баттал, Г.Газиз (Г.С.Гобәйдуллин), Г.Галәви, Г.Динмөхәммәтов, М.Корбангалиев, Ә.Мостафа, Г.Шөнаси. Журнал битләрендә татар мәгарифен үстерү һәм реформалаштыру стратегиясе: укыту һәм тәрбияләүнең бердәм системасын булдыру, заманча уку йортлары төзү, тәжрибә уртаклашу, үзара методик һәм матди ярдәм күрсәтү өчен Россиянең рус булмаган укытучыларын берләштерү, укытучы статусын күтәрү, пенсия б-н тәэмин итү (Россия империясендә рус булмаган уку йортларына дәүләт ярдәме күрсәтелми, аларны меценатлар гына финанслый) пропагандалана. Бөтенроссия мөселман укытучыларның 2 нче һәм 3 нче съездлары карарлары басыла. Укыту һәм тәрбия эшенең яңа алымнары, технологияләре һәм ысуллары тәфсилләп яктыртылган күпсанлы фәнни мәкаләләр (Ф.Дәүләткилдиев, Ә.Мостафа, Г.Хәбиб һ.б.), аерым фәннәр буенча методик җыентыклар (Л.Мостафа, Н.Шәрәф һ.б.), дәрес үрнәкләре дөнья күрә. Татар тел белеме — орфография, диалектология (Г.Динмөхәммәтов, Н.Хәким һ.б.), ш.у. татар әдәбияты тарихы, әдәбиятның үзара йогынтысы, дини тәрбия, татар хатын-кызларының хәле (Г.Газиз, З.Мәмәд, Ә.Мостафа һ.б.) турында фикер алышына. Китапханәләрне берләштерү, анда укучыларны җәлеп итү мәсьәләләре күтәрелә, педагогика буенча үзебезнең һәм чит илләр басмалары турында белешмә бирелә.

Әд.: Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926.

З.З.Гыйләҗев.

УЛАКЛЫ́ ЧИШМӘ́ авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 20 *км* көньяктарак, Зәй Каратай елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 60 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1927 дә Абрамовка авылыннан күченүчеләр нигез сала. Оешкан көненнән — ТАССРның Бөгелмә кантоны Габдрахман волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Әлмәт, 1935 нең 10 февраленнән — Яңа Писмән, 1959 ның 26 мартыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1938 дә — 114, 1949 да — 140, 1958 дә — 141, 1970 тә — 132, 1979 да — 85, 1989 да — 34, 2002 дә — 54 кеше.

УЛАКЧЫ́ ХАН (? — 1256/57), Алтын Урда ханы (1256 елдан). *Сартак* ханның улы. Хакимияткә этисе вафатыннан соң килә, тәхеткә бер төркем Алтын Урда аксөякләре һәм бөек монгол ханы Мункә ярдәмендә утыра. Озак идарә итәргә өлгерми. *Бәркә* хан тарафдарлары фетнәсе вакытында үтерелгән дип фаразлана.

Әд.: Грекова Б.Д., Якубовский А.Ю. Золотая Орда и её падение. М.–Л., 1950; Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960.

И.Л.Измайлов.

УЛА́НОВ Владимир Андреевич (10.10.1946, Олы Тархан р-ны Килдеш а.), физик, физика-матем. фән. д-ры (2004), проф. (2009). Казан ун-тын тәмамлый (1976). 1969–71 елларда Казан елга техникумының ВЛКСМ ком-ты секретаре. 1971 дән РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында. 1997 дән Казан энергетика ун-тында, проф. (2004 тән). Хезмәтләре кристаллар үсү, конденсацияләнгән мохитләрдә электрон парамагнит резонансы, үзара виброник тәэсирләшү һәм каты җисемнәрдә Ян-Теллер эффекты мәсь әләләренә карый. У. виброник тәэсирләшүләр нәтиҗәсендә супер ионик үткәрүчәнлеккә ия булган кристалларда катлаулы катнашмалы кластерлар һәм наноструктураларның синтезлашуы мөмкинлеген ачыклый.

Хезм.: Аномалии в магнитных свойствах кластеров примесной меди в кристаллах фтористого бария // Физика твёрдого тела. 2005. Т. 47, вып. № 9 (автордаш); Системы отображения информации. К., 2008; Электронные промышленные устройства. К., 2009.

УЛАХО́ВИЧ Николай Алексеевич (8.2.1947, Вологда ш.), химик-аналитик, химия фән. д-ры (1987), проф. (1990), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (1998). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1971), шунда ук эшли, нә-органик химия каф. мөдире (1994 тән), химия ф-ты деканы (1992–98). Хезмәтләре металларның координацион кушылмаларының электроаналитик химиясенә карый. У. сулы булмаган, атом үзәкле тирәлекләрдә гайри гадәти окисьлашу халәтендәге металл хелатларның барлыкка килүенең һәм шул вакыттагы электрохимик процессларның төп закончалыларын ачыклый. Комплекслар һәм реагентларның окисьлаштыру-торгызу үзлекләре һәм комплекслы хасил булу үзенчәлекләре нигезендә органик реагентны һәм эретүчене экстракцион вольтамперометрия шартларында сайлауның гомуми принципларын формалаштыра. Экологик контроль үткәрү һәм тирәлекләрне анализлау максатында югары дәрәҗә тоемлы селектив модификацияләнгән электродлар һәм биохимик сенсорлар эшли.

Х е з м.: Электрохимия хелатов металлов в неводных средах. М., 1980 (автордаш); Основы электроаналитической химии. К., 1986 (автордаш); Вольтамперометрия как метод определения пестицидов // Журн. аналит. химии. 1992. Т. 47, № 3 (автордаш).

У́ЛИК Вера Иосифовна (30.1.1928, Киев — 28.8.1995, Мәскәү), актриса, ТАССРның халык артисты (1970). Киев театр сәнгате ин-тын (К.П.Хохлов курсы) тәмамлаганнан соң, 1950 елда Л.Украинка исем. Киев рус театры труппасына кабул ителә. 1952–57 дә — Калинин, 1957–58 дә — Омск өлкә драма театрлары, 1958–72 дә Казан Зур драма театры актрисасы. У.ның Казан театры сәхнәсендә башкарган Клава Кумакина, Мария Михайловна («Бәһадирлар», «Тугрылык», Н.Ф.Погодин), Анисья («Караңгылык хакимлеге», Л.Н.Толстой), Ольга Карташёва («Елмаю өчен — миллион», А.В.Софронов), Беатриче («Шау-шулы көн», У.Шекспир), Ирина («Югалган угыл», А.Н.Арбузов), Василуца («Касса мааре», И.П.Друцэ) кебек беренче рольләре аның күпкырлы талант иясе булуын раслый. Аның башкаруында һәр образның тирән психол. ачылышы аларның тышкы рәсемен иҗат иткәндә актрисаның импровизациягә осталыгы б-н үрелеп бара. Сайлап алынган детальләрнең байлыгы һәм төгәллеге, тавыш интонациясенең төрлелеге У. башкарган һәр рольне кабатланмас итә. Мезальянсова («Мунча», В.В.Маяковский), леди Хеф («Караклар балы», Ж.Ануй), Живка Попович («Министр ханым», Б.Нушич) образларын иҗат иткәндә, актриса гротеск чараларыннан файдалана, гадәти булмаган социаль гомумиләштерүгә ирешә. Аның Софья («Зыковлар»,



В.И. У л и к Софья ролендә («Зыковлар», М.Горький; Антип ролендә — Г.Е.Егоров).

М.Горький), Либуше («Без туган йорт», П.Когоут), Мария Аркадьевна («Гадәти булмаган бүләк», Е.И.Габрилович, С.Г.Розен) рольләре тирән драматизм б-н сугарылган, алар киеренке рухи тормышлары б-н аерылып тора. Медея (Ж.Ануйның шул исем. пьесасы буенча) образында У. трагизмның югары ноктасына ирешә. Әлеге образ аркылы ул тормыштагы гаделлеккә ышанычын югалткан хатынның өметсезлеккә, күңел төшенкелегенә бирелүен бөтен тирәнлеге б-н ача. Казан Зур драма театры сәхнәсендә У. башкарган 40 ка якын роль Казанның театр тарихында тирән эз калдыра. У. Казан театр уч-щесендә, Казан ун-тында укыта. Аннан соңгы елларда Ленсовет исем. театрда (Ленинград), «Никитский капкасы янында» театрында, Еврей дәүләт театрында (Мәскәү) эшли.



В.И. Улик.

Әд.: Народные артисты. К., 1980; И н г в а р И., И л я л о в а И. Русский театр в Казани. К., 1991; Б л а г о в Ю. Качалов и качаловцы. К., 2008. *Ю.А.Благов.*

УЛИСЬЯ́Л авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 27 *км* төнъяктарак, Арбор елгасы буенда. 2010 елда 278 кеше (марилар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 18 йөз уртасына кадәр нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында У.да чиркәү-приход мәктәбе (1892 дә ачыла) эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана жире 1803,3 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Арбор волостенда, 1921 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1938 нең 4 августыннан — Чепья, 1958 нең 16 июленнән — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1763 тә — 40 ир-ат; 1795 тә — 105 кеше; 1811 дә — 62 ир-ат; 1859 да — 197, 1897 дә — 431, 1905 тә — 348, 1920 дә — 452, 1926 да — 438, 1938 дә — 308, 1949 да — 227, 1958 дә — 150, 1970 тә — 216, 1979 да — 200, 1989 да — 201, 2002 дә — 250 кеше.

УЛИ́ТИН Николай Викторович (18.8.1985, Казан), химик-технолог, химия фән. д-ры (2013). 2008 елда Казан технол. ун-тын тәмамлый, шунда ук эшли, полимерларны эшкәртеп чыгаруның технологиясе каф. профессоры (2012 дән). Хезмәтләре модульле матем. модельләштерүдән файдаланып, полимер һәм композитларны эшләүгә һәм эшкәртүгә карый. У. полимерларның молекуляр-топологик структурасын һәм синтез кинетикасын модельләштерү алымнарын эшли. Полимерларның үзлекләрен һәм молекуляр-массачыл сыйфатларын билгеләү өчен универсаль экспертлык системасын тәкъдим итә.

Х е з м.: Новый подход к формализации вязкоупругой податливости сетчатых полимеров с высокой степенью сшивки // Пластические массы. 2011. № 6 (автордаш); Моделирование радикальной полимеризации стирола, сопровождающейся обратимой передачей цепи в присутствии дибензилтритиокарбоната // Докл. РАН. 2012. Т. 446, № 6 (автордаш).

УЛИ́ТИНО авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 12 *км* көнбатыштарак, Куйбышев сусаклагычыннан 1 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 33 кеше (руслар) яши. 1646 дан рус чыганакларында Починок Улитин исеме б-н билгеле. Халкы башта Зөя Успение монастырена карый, 1764 тә — икономик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә; игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында У.да 2 тегермән, тире эшкәртү йорты, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана жире 615 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Шырдан волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Зөя, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 219 ир-ат; 1859 да — 701, 1897 дә — 720, 1908 дә — 787, 1920 дә — 589, 1926 да — 688, 1938 дә — 550, 1949 да — 311, 1958 дә — 325, 1970 тә — 242, 1979 да — 147, 1989 да — 36, 2002 дә — 18 кеше.

УЛУМБЕ́КОВ Эрнст Галим улы (31.8.1936, Казан — 26.3.2016, шунда ук), гистолог, мед. фән. д-ры (1976), проф. (1977). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1960), ТАССР Сәламәтлек саклау министрлыгының мәхкәмә-мед. экспертизасы бюросында мед. эксперты, Чистай шәһәренең 1 нче хастаханәсендә патологоанатом булып эшли. 1962–66, 1967–2000 елларда Казан мед. ин-тында, гистология каф. мөдире (1972–92), каф. профессоры (1992–2000). 2000 нән «ГЭОТАР-Медиа» нәшриятында (Мәскәү). Хезмәтләре нейрогистологиягә, биол. системаларда көйләү мөнәсәбәтләре мәсьәләләренә, холинэстеразаларның функциональ циохимиясенә карый. Компьютер системаларын татар телендә эш башкару, нәшер итү, укыту өчен яраклаштыруны башлаучыларның, «А дан башлап Я га кадәр 2000 авыру» («2000 болезней от А до Я». М., 1999) белешмәлегенең җаваплы мөхәррирләреннән берсе.

Х е з м.: Количественная цитохимия лактатдегидрогеназы в инкапсулированных механорецепторах (тельцах Фатер — Пачини) // Цитология. 1972. № 10; Частная гистология: Курс лекций. К., 1989.

Әд.: Казанский государственный медицинский университет (1804 — 2004 гг.): Заведующие кафедрами и профессора: Биогр. словарь. К., 2004; Профессор Эрнст Галимович Улумбеков // Казан. мед. журн. 2016. № 3.

УЛЬДА́НОВ Галим Аллаяр улы (15. 2. 1925, Чиләбе өлкәсе – 1999, Алма-Ата), офтальмолог, мед. фән. д-ры (1969), проф. (1969), Казакъстан ССРның атказ. фән эшлеклесе (1983). Алма-Ата мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1953), шунда ук эшли, 1969 елдан офтальмология каф. мөдире. 1974–88 дә Казакъстан офтальмология фәнни-тикшеренү ин-ты директоры. Хезмәтләре кератологиягә (мөгез катлау зарарлану), күздәге шешләрне дәвалауга, күз авыруларын кисәтүне оештыруга карый. Халыклар дуслыгы ордены, Казакъстан ССРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Onchocerciasis — речная слепота. А.-А., 1976. Исходы циркулярной тоннельной кератопластики // Вестн. офтальмологии. 1991. № 2 (автордаш).

Әд.: Галим Аллаярович Ульданов (к 50-летию со дня рождения) // Здравоохранение Казахстана. 1974. № 4.

УЛЬЯ́НИН Всеволод Александрович (20.1.1863, Мәскәү — 16.3.1931, Казан), геофизик, климатолог, табигыять философиясе д-ры (1888). Германиядә белем ала. Штутгарт шәһәрендә гимназиянең тулы курсын, Мюнхен ун-тының 3 курсын, Страсбург ун-тын (1888) тәмамлый. 1888 елдан Мәскәү ун-тында. 1894–96 да чит илдә фәнни тикшеренүләр үткәрә. «Lambert законы һәм Arago полярлашуы» хезмәте өчен физика магистры дәрәҗәсенә лаек була (1897). 1897 дән Казан ун-тында: физика һәм физик геогр. кафедрасы буенча приват-доцент, 1904 тән экстраординар, 1906 дан ординар проф., 1923 тән физика каф. мөдире. 1897 дән ун-тның Метеорология обсерваториясе, 1904 тән Россиянең көнчыгыш метеорология челтәре б-н җитәкчелек итә; Казан янында шәһәр яны Магнит обсерваториясен оештыруда (Займище тимер юл станциясе янында) аның өлеше зур. Хезмәтләре атм. физикасы, Татарстан климатына карый. У. электр магнитометры конструкциясен эшли, җир магнитизмы элементларын билгеләү ысулларын эшләү б-н шөгыльләнә; бөтерелмәләрне күзәтү алымы б-н аэрологик тикшеренүләр үткәрә, төбәкнең климатик үзенчәлекләрен һәм метеорологик күренешләрне (боз яву, көчле яңгыр һ.б.) тасвирлау буенча гомуми ләштерүче хезмәтләр башкара.

Х е з м.: Новая русская книга по динамической метеорологии. К., 1904; Новая загородная Магнитная обсерватория Казанского университета и магнитные наблюдения за 1898 по 1912. К., 1914; Термодинамика: Лекции 1914–1915 гг. К., 1915.

Әд.: П е р е в е д е н ц е в Ю.П. Метеорология в Казанском университете: Становление, развитие, основные достижения. К., 2001.

УЛЬЯ́НКОВО (Өлҗән) авылы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 10 *км* көнбатыштарак, Бәрле елгасы буенда. 2010 елда 522 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Рождество-Христово чиркәве. 1565–67 дән билгеле. Беренче исеме — Агишево. Халкы Зөя Троица-Сергий монастырена карый, 1764 тә — экономик, соңрак дәүләт крәстиннәре катлавына күчерелә; игенчелек, терлекчелек, тәгәрмәч тугымы һәм чана табаны ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша; Илия чиркәве, земство мәктәбе (1861 дә ачыла), фельдшерлык пункты, 2 су һәм 7 җил тегермәне, 2 тимерче алачыгы, сыраханә, казна шәраб һәм 6 вак-төяк ләр кибете була; шимбә базары, 20 июльдә ярминкә уздырыла. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2810 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Ульянково волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында, 1927 нең 14 февраленнән — Ульянково р-ны үзәге, 1927 нең 1 августыннан — Кайбыч, 1944 нең 19 февраленнән — Подберезье, 1956 ның 17 маеннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 225 ир-ат; 1859 да — 1022, 1897 дә — 1482, 1908 дә — 2351, 1920 дә — 2451, 1926 да — 2193, 1938 дә — 1706, 1949 да — 1342, 1958 дә — 985, 1970 тә — 882, 1979 да — 778, 1989 да — 691, 2002 дә — 555 кеше.

УЛЬЯ́НКОВО РАЙОНЫ́, ТАССРда. 1927 елның 14 февралендә оештырыла. Үзәге — Ульянково авылы. 1920 елга кадәр Казан губернасының Зөя һәм Тәтеш өязләренә, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонына керә. 1927 нең 1 августыннан, район үзәге Ульянководан Олы Кайбыч авылына күчү сәбәпле, Кайбыч р-ны дип үзгәртелә.

УЛЬЯ́НОВ ВЛАДИ́МИР-СТУДЕ́НТ ҺӘЙКӘЛЕ́, Казанда. Казан ун-тының (1887 елда анда Ленин укыган) 150 еллыгы уңаеннан 1954 тә куела. Төп бина каршында урнаштырылган. Һәйкәл ун-тның иске хастаханәсе һәм төп бинасы арасындагы кечкенә генә мәйданчыкта композицион үзәккә әверелгән. Ярымтүгәрәк мәйданчык гранит эскәмияләр б-н тоташкан, постамент янында чәчәкләр утыртылган. Һәйкәл ун-тның архит-ра ансамбленә табигый туры килеп тора. Ульянов бөтен буена иркен позада гәүдәләнгән. Уң кулында китап, сул кулы б-н иңбашыннан төшеп торган студент курткасын тоткан.



Ульянов Владимир-студент һәйкәле. Бронза. Скульпторы — В.Е.Цигаль, архитекторы — В.В.Калинин. 1954.

Бронза фигура көчле җилләргә каршы тора алу пластик мотивында хәл ителгән. Җилфердәп торган курткасы, киемендәге эре, хәрәкәтне белдерүче җыерчыклар яшь студентның тәвәккәллеген, рух ныклыгын чагылдыра. Шомартылган соры граниттан эшләнгән постамент баскычлы нигезгә урнаштырылган. Сынның биеклеге — 3,3 *м*, постаментныкы — 4,7 *м*. Постаментта «Владимир Ульянов. 1887 ел» дигән язу бар.

А.В.Гарзавина.

УЛЬЯ́НОВ Илья Николаевич (14.7.1831, Әстерхан ш. — 12.1.1886, Сембер ш.), педагог, Халык мәгарифе эшлеклесе. В.И.*Ленинның* әтисе. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1854), Пенза дворяннар ин-тында математика укыта, 1863 елдан Түбән Новгород гимназиясендә. 1869 дан Сембер губернасында: инспекторы, халык уч-щеләре директоры (1874 тән). Халык мәгарифе энтузиасты булда, земство һәм шәһәр башлангыч мәктәпләрен күпләп ачу һәм укытуның сыйфатын яхшырту буенча үзидарә органнары эшчәнлегенә ярдәм итә. У. башлангычында Порецк укытучылар семинариясе һәм Сембер чуаш укытучылар мәктәбе ачыла. Урта Идел буенда рус булмаган халыкларның балалары арасында Рус православие чиркәвенең миссионерлык эшчәнлеген оештыру буенча *Илья минский системасын* хуплый, чуаш һәм мордва халыклары мәгарифендә мөһим роль уйный. Сембер губернасының татар авылларында рус-татар уч-щеләре һәм мәдрәсәдә рус класслары ачтыруга ирешә. У. исеме Чуаш ун-тына бирелә.

Х е з м.: Избранное. Саратов–Ульяновск, 1983.

Әд.: К о н д а к о в А.И. Директор народных училищ И.Н.Ульянов. М., 1964; С е р г е е в Т.С. Илья Николаевич Ульянов и просвещение народов Поволжья. Чебоксары, 1972; Илья Николаевич Ульянов и просвещение народов Поволжья и Приуралья. К., 1985; П е р м я к о в К.М. Мировоззрение И.Н.Ульянова. Ульяновск, 1995.

Г.С.Сабиржанов.

УЛЬЯ́НОВ Сергей Михайлович (30.4.1946, Мәскәү өлкәсенең Коломна ш. – 5.1.2014, Казан), спортчы, тренер (акад. ишү), СССРның спорт остасы (1971), РСФСР, СССРның атказ. тренеры (1983, 1984). Коломна пед. ин-тын тәмамлый (1969). 1969–70 елларда Мәскәү өлкәсенең «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятендә тренер, 1977–82 дә Идел буе округының эчке гаскәрләр спорт командасында тренер, 1982 дән баш тренер. 1976–78 дә — СССРның яшүсмерләр, 1981–84 тә җыелма командаларында тренер. 1996 дан ТРның «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятендә өлкән тренер. Шәкертләре арасында — «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятенең үзәк советы, РСФСР, СССР, Россия, Европа, дөнья, Олимпия уеннары беренчелекләрендә халыкара регата, чемпионатларда катнашучылар, медаль алучылар, җиңүчеләр: Л.А.*Аверьянова*, В.Н.Валюкевич, А.В.Косов, А.В.*Устинов*, И.Ю.Шамрай. Медальләр б-н бүләкләнә.

УЛЬЯ́НОВ ӨЛКӘСЕ́, РФдә. Россиянең көньяк-көнчыгыш Европа өлешендә урнашкан, Идел елгасы б-н уңъяк һәм сулъяк ярларга (Идел аръягы) бүленә. 1943 елның 19 гыйнварында оештырыла. Мәйданы — 37,2 мең *км*^{2}. Үзәге — Ульянов (1924 кә кадәр — Сембер) шәһәре. Халкы — 1252887 кеше (2017). 2010 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 149873 (1939 да — 85180, 1959 да — 97180, 1970 тә — 122450, 1979 да — 154560, 1989 да — 159093, 2002 дә —168766) кеше. У.ө. терр-ясе Идел буе Болгар дәүләте, Алтын Урда, Казан ханлыгы составына кергән. 16 йөзнең 2 нче яртысында — 17 йөздә уңъяк районнарга Карсун-Сембер һ.б. чик буе хезмәтендәге йомышлы татарлар (башлыча, Темников өязеннән күченүчеләр) килеп утыра. 18 йөздә татарлар Терёшка елгасы буендагы җирләрне (хәзерге У.ө.нең көньяк районнары) һәм Идел аръягында төзелә торган чик буе киртәләре тирәсен үзләштерәләр. 1782 дә Сембер наместниклыгында — 39053, 1795 тә — 46419, 1833 тә (1833 тән — Сембер губ.) — 67654, 1857 дә — 90069,

1867 дә — 97553, 1897 дә 133977 татар исәпләнә. Аларның төп шөгыле игенчелек һәм терлекчелек була, кәсепләре — агач эшкәртү, чабата үрү, чыпта кап сугу, мич чыгару, балта эше, сарык тиресе, күн, йон һәм киез эшкәртү. Сәүдә киң җәелә. 19 йөзнең 2 нче яртысында төбәк икътисадында татар сәүдәгәрләре *Акчуриннар*, Абушаевлар нәселләреннең роле зур була. Эшмәкәр С.Г.Акчурин 1849 да Сенгилей өязенең Иске Тимошкино (Зөябаш) авылында *Иске Тимошкино (Зөябаш) постау мануфактурасына* нигез сала, нәсел дәвамчылары Сенгилей өязенең Тирәнкүл, Карсун өязенең Гурьевка (хәзер Барыш ш.), Сызрань өязенең Самайкино авылларында фабрикалар тоталар. 1871 дә Ш.А.Абушаев Сембер өязенең Бирючёвка авылында 4 басулы чәчү әйләнеше, ат з-ды, умарта һәм 8 меңләп алмагачы булган бакчасы б-н үрнәк а.х. фермасы оештыра. 1853 тә Сембердә сәүдәгәр К.Г.Акчуринның матди ярдәме б-н гыйбадәтханә (1865 елгы янгыннан соң манаралы мәчет итеп үзгәртеп корыла) төзелә. 1896 да Мәләкәс (хәзер Димитровград) шәһәрендә мәчет ачыла. 1898 дә Сембер губернасында 159 мәчет исәпләнә. 1861 дә — 91, 1898 дә — 132, 1904 тә — 148, 1915 тә 218 мәктәп һәм мәдрәсә эшли. 1908 дә хәйрия *Сембер мөселманнары җәмгыяте* оештырыла, ул мохтаҗларга, мәчет һәм дин башлыкларына матди ярдәм күрсәтә, Сембердә татар кыз балалары өчен мәктәп тота. 1910 елларда Сембердә — «Ирек» (җитәкчесе — Б.Ш.*Тарханов*, 1918 дә «Кызыл Йолдыз» итеп үзгәртелә), Гурьевка авылындагы Акчуриннар ф-калары клубы каршында, Иске Тимошкино авылында татар театр коллективлары эшли. Совет хакимиятенең беренче елларында төбәктә «Таң», «Көн», «Мәләкәс таһышы», «Яңа авыл» татар г-талары нәшер ителә. 1918 дә Сембердә татар китапханәсе ачыла, аның җирлегендә драма түгәрәге эшли, спектакльләр куела, концертлар, ял кичәләре үткәрелә. 1930–50 елларда Ульянов (1931–35 тә Татар пед. техникумы, 1943 тә шәһәр тибындагы Камышлы посёлогына күчерелә) һәм Мәләкәс (1943–58) шәһәрләре пед. уч-щеләрендә татар мәктәпләре өчен башлангыч сыйныф укытучылары әзерләүче төркемнәр була. Татарлар, тупланып, Ульянов (113106 кеше), Димитровград, Барыш һәм өлкәнең башка шәһәрләрендә; Иске Кулаткы, Яңа Малыклы, Николаевка, Базарлы Сызган, Чардаклы, Павловка, Мәләкәс, Барыш, Чынлы р-ннарында яшиләр. Өлкәнең 66 торак пунктында татарлар күпчелекне тәшкил итә. Татар өлкә милли-мәдәни автономиясе (1998 дән; У.ө.нең барлык районнарында бүлекчәләре бар), «Туган тел» (1988 дән), «Мәдәният» (1991), «Өмет» (1992) татар милли-мәдәни оешмалары, татар язучылары берләшмәсе (2000), «Ак калфак» хатын-кызлар оешмасы (2005), «Болгар яңарышы» иҗтимагый хәрәкәте, «Сембер» татар эшмәкәрләре ассоциациясе (2003), «Яңа дулкын» яшьләр оешмасы (2009), «Көрәш» спорт федерациясе (2008 дән) эшли. 1995 тә Татар мәдәни үзәге (2008 дән — Татар мәдәнияте үзәге) оештырыла, ул фольклор концертлары, тематик кичәләр үткәрү, татар халык иҗаты коллективларын оештыру б-н шөгыльләнә. 1989 дан У.ө.ндә *Сабан туе* (федераль дәрәҗәдә 2 тапкыр: 2003 тә Димитровградта, 2009 да Ульяновта, 2016 да Иске Кулаткыда VII Бөтенроссия авыл сабан туе) бәйрәм ителә. *Каз өмәсе, Нәүрүз* бәйрәмнәре, «Сембер җыры» һәм «Сембер кыңгыраулары» фестивальләре, авыл районнарында Татар теле һәм мәдәнияте көннәре үткәрелә. 2003 тә У.ө.ндә Татар мәдәнияте көннәре, 2007 дә ТР мәдәнияте көннәре уздырыла. 2008 дә Иске Кулаткы р-нында беренче Бөтенроссия «Түгәрәк уен» татар фольклоры фестивале булып уза. Ульянов шәһәрендә «Ялкын» татар театры (1992 дән), Урта Исәнтимер авылында һәм шәһәр тибындагы Иске Кулаткы посёлогында халык театрлары, 30 лап үзешчән сәнгать коллективы, «Сембер» (Ульянов ш.), «Гөлшаян» (Иске Кулаткы), «Айгөл» (Урта Исәнтимер), «Сүнмәс йолдызлар» һәм «Карлыгачлар» (Димитровград) фольклор ансамбльләре эшли. Иске Кулаткыда, Чынлы р-ныны Кәшә (Елховое Озеро), Барыш р-ныны Иске Тимошкино, Чардаклы р-нының



Ульянов өлкәсе.
Ульянов шәһәренең Татар мәдәни үзәге.

Татар Калмаюры, Иске Кулаткы р-нының Иске Мостяк авылларында татар тарихы музейлары ачыла. 2004 тән Димитровградта татар мәктәбе, 2006 дан Ульяновта татар этномәдәни компонентлы мәктәп эшли. 2010 да өлкәнең 205 мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты фән буларак һәм факультатив дәресләрдә өйрәнелә. Бу фәннәр буенча район, шәһәр, өлкә олимпиадалары үткәрелә. Татар мәктәпләре өчен пед. кадрлар Сенгилей һәм Ульянов пед. уч-щеләрендә, Ульянов пед. ун-тының милли бүлегендә әзерләнә. Өлкә телевидениесендә «Чишмә» тапшыруы чыга, татар телендә «Өмет» (Ульянов ш., 1989 дан), «Күмәк Көч» (Иске Кулаткы р-ны, 1930 дан) г-талары нәшер ителә. 2010 да У.ө.ндә 100 лап мәчет (10 сы — Ульяновта), 20 ләп мәктәп, «Биләр» мәдрәсәсе (2007 дә ачыла) була. 3 мөселман дини идарәсе, Ислам мәдәни үзәге (1996), «Ислам тавышы» хәйрия фонды (1999) эшли. 2007 дә У.ө. б-н ТР җитәкчеләге арасында сәүдә-икътисади, фән-техника һәм социаль-мәдәни хезмәттәшлек турында килешүгә кул куела. Өлкә терр-ясендә «Татнефть» һәм «Татнефтьпродукт» АҖ автоягулык салу челтәре, «Татарстан–Ульянов» сәүдә йорты, Чардаклы р-нының Октябрь посёлогында «Кызыл Шәрекъ–Агро» компаниясе матди ярдәме б-н төзелгән зур терлекчелек комплексы эшләп килә. Ульяновта ТР ФАнең төбәк бүлекчәсе (2000 нән), «Ак Барс» банкы ф-лы эшли. Сов. Союзы Геройлары А.К.*Әбдерәзәков*, М.И.*Аипов*, И.Б.*Бөркетов*, Х.С.Богданов, Н.Н.*Нугаев*, Г.С.*Умеркин*, В.С.Хәбиев, З.С.Хөсәенов, Н.З.*Юнысов*; Соц. Хезмәт геройлары В.З.Зыятов, Т.К.Рәшитова, С.Х.Фәизов, Н.К.Гарифуллина; генерал-лейтенант Ә.Н.*Рамазанов*, генерал-майор Р.Н.*Әбраров*, дәүләт һәм сәясәт эшлеклеләре К.Г.*Абдрахманов*, М.Ж.*Азизов*, Й.*Акчура*, Ә.В.*Алимбәков*, Ә.В.*Алимбәкова*, Г.Б.*Ашмасов*, С.Ш.*Гаффаров*, С.С.Гафуров, Ш.С.*Измайлов*, М.М.*Курманов*, Б.Х.*Мансуров*, Ш.Х.*Усманов*; шагыйрьләр Х.Й.*Абушаев*, М.С.*Алмаев*, Г.*Кандалый*, Г.Ш.*Сәгыйров*, М.Сөндекле, С.Х.*Сунчәләй*, С.*Урайский*, Д.*Фәтхи*, Р.М.*Харисов*, Х.С.Шаммасова; язучылар Р.К.Агишев, К.С.*Әмиров*, Р.Г.*Ибраһимов*, З.*Кадыйри*, Ж.Б.Миндубаев, Л.Х.*Хәмидуллин*, А.И.Йосыпов; әдәбият белгечләре М.В.*Гайнетдинов*, И.З.*Нуруллин*, беренче татар журналисты З.Ә.*Акчурина*, нәкышче Ж.Г.*Булат*, композиторлар Ф.К.*Туишев*, Ф.З.*Яруллин*, җырчылар А.С.*Измайлова*, актёрлар Б.Ш.Тарханов, Г.Р.*Шамуков*, режиссёр С.С.*Булатов*, архитектор И.Г.*Вәлиев*, тарихчылар Р.Г.*Әмирханов*, Р.А.Мөхәммәдов, Г.С.*Сабиржанов*, Р.В.*Шәйдуллин*, математик С.Г.*Вәлиев*, филолог Л.*Җәләй*, философлар К.Т.*Гыйззәтов*, В.А.*Бажанов*, физик М.Х.*Сәлахов*, биолог А.К.*Сәгыйтов*, зоотехник А.Г.*Курчаков*, зоогигиенист М.Г.*Хәбибуллов*, педагоглар Н.З.*Бакыева*, Я.И.*Ханбиков*, микробиолог Х.Х.*Абдуллин*, химик Н.Х.*Әлгиуллов*, электрон техника гыйлеме белгече В.Н.*Әбраров*, табиблар Т.Ф.*Сафин*, Н.З.Сибгатуллин, Р.Ш.*Хәсәнов*, РСФСРның атказ. уйлап табучысы Г.С.*Абдрахманов*, икътисадчы К.И.*Азизов*, дин эшлеклеләре С.*Абдуллин*, З.*Кадыйриның* тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге У.ө. б-н бәйле. 2008 дә Ульяновта шагыйрь Кол Галигә һәйкәл куела. Шәһәрнең бер урамы Б.Ш.Тарханов исемен йөртә.

Әд.: Край Симбирский: Краткий ист. очерк. Саратов, 1989; Из этнической истории Ульяновской области. Ульяновск, 1993; Кобзев А.В. Исламская община Симбирской губернии во второй половине XIX — начале XX вв. Н.Новгород, 2007; Мартынов П.Л. Симбирск: Сборник исторических сведений. Ульяновск, 2008; Этнография Симбирского-Ульяновского Поволжья. Ульяновск, 2008. Ульяновская-Симбирская энциклопедия: В 2 т. Ульяновск, 2000–04.

Н.В.Марянин.

УЛЬЯ́НОВКА авылы, Чирмешән р-нында, Чирмешән авылыннан 21 *км* төньяк-көнбатыштарак, Олы Сөлчә елгасы буенда. 2010 елда 338 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Чиркәү. 1730 елларда нигез салына; 1940 елларга кадәр Киреметь Тридцать Дубов дип атала. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе, 3 су тегермәне, тимерче алачыгы, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 2655,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чис -

тай өязе Котыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Беренче Май, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Чирмешән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 106 ир-ат; 1859 да — 752, 1897 дә — 1164, 1908 дә — 1210, 1920 дә — 1348, 1926 да — 930, 1949 да — 538, 1958 дә — 403, 1970 тә — 538, 1979 да — 441, 1989 да — 343, 2002 дә — 322 кеше.

УЛЬЯ́НОВЛАР, революционерлар һәм җәмәгать эшлеклеләре. Әтиләре — күренекле педагог И.Н.*Ульянов*. У.ның әниләре **Мария Александровна** (кыз чагындагы фамилиясе Бланк) (6.2.1835, С.-Петербург — 12.7.1916, Петроград). Өйдә белем ала. 1863 елда башлангыч мәктәпләр укытучысы исеме алу өчен экстерн тәртибендә Самара гимназиясендә имтихан тапшыра. Тормышын тулысынча гаиләсенә багышлый. Аның әтисе, **Александр Дмитриевич Бланк** (1799 — 17.7.1870, Казан губ., Лаеш өязе Кокушкино а.), Петербург мед.-хирургия академиясен тәмамлап, 20 елдан артык табиблек хезмәтендә була; күпьеллык хезмәте өчен нәселдән күчмә дворянлык дәрәҗәсе бирелә. 1847 елда, отставкага чыгу б-н, Лаеш өязе Кокушкино авылында зур булмаган утар сатып ала. Ул вафат булганнан соң, утар кызларына мирас булып кала. 1847–63 тә Мария Александровна Кокушкинода яши. 1863 елның җәендә анда аның И.Н.Ульянов б-н туе уза. Балалары 1870–80 елларда һәр җәйдә диярлек утарга кайтып йөриләр, Кокушкино гаиләнең яраткан ял итү урыны була. **Анна Ильинична** Ульянова-Елизарова (14.8.1864, Түбән Новгород ш. — 19.10.1935, Ленинград), В.И.*Ленинның* апасы. 1887 елның 1 мартында Александр Ильич Ульяновның Александр III гә һөҗүм итүе турындагы эш буенча кулга алына, 5 елга сөргенгә хөкем ителә, Кокушкинода, Казанда һәм Самарада полиция күзәтүе астында яши. Кокушкинода ул күп вакытын хуҗалык алып баруга багышлый, чигә, инглиз һәм итальян телләрен өйрәнә, тәрҗемә һәм әдәби эшчәнлек б-н шөгыльләнә (балалар өчен берничә әкият һәм шигырьләр яза). 1888 нең 12 октябрендә Казанга күченә, бу вакытта аларның бөтен гаиләсе Беренче таудагы (хәзер Ульяновлар ур.) Орлова йортында фатирга кереп яши. 1889 ның маендa Самара губернасы Алакаевка авылына китә. «Вперёд» нәшриятының редколлегия әгъзасы, «Просвещение» ж-лы секретаре, «Работница» ж-лы редколлегиясе әгъзасы. 1917–18 дә РСДРП(б) ҮКның Рус бюросы әгъзасы, «Правда» г-тасы секретаре. 1918–21 дә РСФСРның Социаль тәэминат һәм Мәгариф халык комис-тларында эшли. 1921 дән фәнни эштә. Окт. рев-циясе һәм РКП(б) тарихы комиссиясен (Истпарт), В.И.Ленин ин-тын оештыручыларның берсе; **Александр Ильич** (31.3.1866, Түбән Новгород ш. — 8.5.1887, С.-Петербург), В.И.Ленинның абыйсы, народоволец. Һәр җәйне диярлек гаиләсе б-н Кокушкинода үткәрә. 1883 тән Петербург ун-тында укый, халык азатлыгы идеяләре б-н мавыга. 1886 да «Народная воля» идеяләрен уртаклашучы төркем җитәкчеләренең берсе, император Александр III гә һөҗүм әзерләүдә катнаша, 1887 нең 1 мартында кулга алына; Шлиссельбург кальгасында асып үтерелә; **Ольга Ильинична** (4.11.1871, Сембер ш., хәзер Ульянов ш. — 8.5.1891, С.-Петербург), В.И.Ленинның сеңлесе. Сембер гимназиясен тәмамлаганнан соң (1887), күренекле педагог һәм дирижёр Орлов-Соколовский җитәкчелек иткән Казан музыка мәктәбенә керә. Концертларда катнаша. 1890 нан С.-Петербургтагы Югары (Бестужев) хатын-кыз курсларында укый. Корсак тифыннан вафат була. **Дмитрий Ильич** (4.8.1874, Сембер ш. — 16.7.1943, Мәскәү янындагы Горки), В.И.Ленинның әнесе. 1887–89 да Казанда гимназиядә укый. 1905–07 еллардагы



Ульяновлар гаиләсе: Мария Александровна, Илья Николаевич һәм аларның балалары: Ольга, Мария, Александр, Дмитрий, Анна, Владимир. 1879 елгы фоторәсем.

рев-циядә (Сембер) һәм 1917 елгы Окт. рев-циясе (Кырым) вакыйгаларында катнаша. 1920–21 елларда Кырымда Ревком һәм РКП(б)ның өлкә ком-ты әгъзасы, Кырымда ХКС рәисе урынбасары. 1921дән РСФСР Сәламәтлек саклау халык комис-тында. 1925–30 елларда Я.М.Свердлов исем. Коммунистик ун-тта эшли, шуннан соң гыйльми эштә. **Мария Ильинична** (6.2.1878, Сембер ш. — 12.6.1937, Мәскәү), В.И.Ленинның сеңлесе. Аңа 9 яшь тулгач, гаиләләре Казанга күченә. Кокушкинода Анна Ильинична һәм Владимир Ильич б-н бергә яши. 1905–07 еллардагы рев-циядә һәм 1917 елгы Окт. рев-циясе (Петроград) вакыйгаларында катнаша. 1917–29 да «Правда» г-тасының редколлегия әгъзасы һәм җаваплы секретаре. 1934 тән Совет контроль комиссиясе әгъзасы. 1929–34 тә ВКП(б)ның Үзәк контроль комиссиясе әгъзасы. СССР ҮБК әгъзасы. ТАССРда эшче һәм авыл газета-журнал хәбәрчеләре хәрәкәтен җәлдерүгә булышлык итә, берничә тапкыр Казанда була (1928, 1933, 1936), 2 нче Бөтентатар колхозчы ударниклар съездында (1933) чыгыш ясый. У. Казанда һәм Кокушкино авылында В.И.Ленин музейларын оештыруга булышлык итәләр.

Әд.: Шагинян М.С. Семья Ульяновых. М., 1959; Семья Ульяновых в Татарии: Документы, материалы и воспоминания. К., 1985.

Л.М.Айнетдинова.

УЛЯ́НИЦКИЙ Владимир Антонович (30.1.1854, башка мәгълүматлар буенча 1855, Мәскәү — 1920), хокук белгече, тарихчы, халыкара хокук д-ры (1900), хакыйкый статский советник (1906). Дворяннар нәселеннән. Мәскәү ун-тын тәмамлаганнан соң (1874), шунда ук эшли: 1875–77 елларда проф. стипендиаты, 1885–99 да халыкара хокук кафедрасының рәсми булмаган доценты. Бер үк вакытта, 1878–99 да, Тышкы эшләр министрлыгының Мәскәү баш архивында хезмәттә. 1888–1906 да Халык мәгарифе министрлыгының Археография комиссиясе әгъзасы. 1899–1900 дә Харьков ун-тының халыкара хокук кафедрасында приват-доцент, 1900–01 дә ординар проф. 1901–10 да Томск ун-тының халыкара хокук кафедрасында ординар проф., 1910–11 дә атказанган проф. 1911–17 дә Казан ун-тының халыкара хокук кафедрасында рәсми булмаган доцент. Хокук фәне үсешендә позитивизм карашларында тора. Хезмәтләре халыкара хокук, дипломатия тарихы мәсь әләләренә карый. Император Екатерина II нең дипломатик хатларын бастырып чыгара (1–5 т.; СПб., 1885–1893). Күпсанлы архив документларына нигезләнеп язылган «XVIII йөздә Дарданелл, Босфор һәм Кара диңгез» («Дарданеллы, Босфор и Чёрное море в XVIII веке», М., 1883), «XIV–XVI йөзләрдә Россия, Польша, Молдавия, Валахия һәм Төркиянең үзара мөнәсәбәтләре тарихына материаллар» («Материалы для истории взаимных отношений России, Польши, Молдавии, Валахии и Турции в XIV–XVI вв.», М., 1887), «XVI–XVII йөзләрдә Россиянең Урта Азия һәм Һиндстан белән багланышлары» («Сношения России с Среднею Азиею и Индиею в XVI — XVII вв.», М., 1889) хезмәтләре 14–18 йөзләрдә Россиядәге дипломатия тарихын чагылдыра. «XVIII йөздә чит илләрдә рус консуллыклары» («Русские консульства за границей в XVIII веке», кн. 1–2 ; М., 1899) монографиясендә Россия дипломатия вәкилләре эшчәнлеген анализлап, алар барыннан да элек дәүләтнең фискаль мәнфәгатьләрен үтиләр дигән нәтиҗәгә килә. У. — «Э.К.Симсон. Халыкара хокук системасы» («Э.К.Симсон. Система международного права», т. 1, СПб., 1901), «Халыкара хокук» («Международное право», Томск, 1911) лекция курслары авторы.

Хезм.: О международных отношениях во Владимиро-Московском великом княжестве. М., 1893; Материалы по истории Восточного вопроса в 1808–1813 гг. М., 1901.

Әд.: Ястржембский В.А. Уляницкий Владимир Антонович // Юридический факультет Харьковского университета за первые сто лет его существования / 1805–1905 / Харьков, 1908; Грабарь В.Э. Материалы к истории литературы международного права в России / 1647–1917/. М., 1958; Биобиблиогр. словарь профессоров и преподавателей Казанского университета. 1905–1917. К., 1986; Профессора Томского университета: Биогр. словарь. Томск, 1996. Вып. 1.

Е.Б.Долгов.

УМА́Й, борынгы төркиләр мифологиясендә хатын-кыз башлангычын һәм уңдырышлылыкны гәүдәләндергән алиһә; өй учагын һәм яшь балаларны саклаучы, сугышчыларны,

идарәчеләрнең хатыннарын яклаучы; башка карашлар буенча Тәңренең хатыны. Кайбер тикшеренүчеләр У. образын генетик яктан Иран мифологиясе персонажы — Һомай кошы (Гамаюн, бәхет кошы) б-н бәйле дип саныйлар. Аның күләгәсе төшкән кеше бәхетле була. У. беренче тапкыр 7–8 йөзләргә караган рун язмаларында искә алына. Орхон-Енисей язма истәлекләрендә каганның әнисе әлеге кошка тиңләп («Умайга охшаган») мактала. Кайбер төрки халыкларның У. турындагы карашлары бер-берсенә якын: казакъларда һәм телеутларда ул — баланың җаннын, кыргызларда — балаларны, гаилә учагын саклаучы, терлекләрне яклаучы (ислам дине кабул ителгәч, Мөхәммәд пәйгамбәрнең кызы Фатыйма б-н тиңләштерелә), Себер татарларында — кешедәге рух, аның физик һәм рухи көченең нигезе. Кайбер халыкларда У. образы башка төрле сурәтләнә: төрекләрдә У. б-н балаларны куркыталар, Алтай халыкларында ул — үлгән баланың җанын кабул итүче үлем фәрештәсе.

Әд.: Даренкова Н. Умай в культе турецких племён // Культура и письменность Востока. Баку, 1928. Т. 3; Абрамзон С. Киргизы и их этногенетические и историко-культурные связи. Л., 1971; Мифы народов мира. М., 1988. Т. 2.

Ф.И.Урманчеев.

УМАРТА́ КОРТЛАРЫ́ (Apoidea), чага торган элпәканатлы бөҗәкләр өссемьялыгы. 30 меңгә якын төре билгеле; чәчәкле үсемлекләр үскән барлык җирдә таралганнар. РФдә 3,5 меңнән артык, Татарстан терр-ясендә якынча 340 төре билгеле. Гәүдәсенең озынлыгы 1,5 *мм* дан 5 *см* га кадәр (гадәттә, 1–1,5 *см*). Башы күкрәге б-н хәрәкәтчел тоташкан. Катлаулы фасетлы күзләре зур, кабарынкы түгел, баш түбәсендә өчпочмак хасил итеп 3 гади күзчек урнашкан. Мыекчыгы буынтыклы. Бите каймалы. Югары төзелешле У.к.ның аскы казналыгы б-н аскы ирене хортумчык барлыкка китерә. Канат төбенә кадәр җитмәүче алкүкрәк күкрәкнең башка өлешләре б-н бербөтен хасил итә, алсырт аерылмаган. Корсагының беренче сегменты күкрәк составына керә һәм аның б-н кушыла (арадаш сегмент). Корсагы күкрәккә кыска сабакчык б-н берегә. Аяклары алты. Арткы аягының беренче буынчыгы яссы һәм киң, төкчәле йөнтәс капламлы; соңгы буынчыгы алдагысыннан озынрак һәм 2 тырнакчыклы. Аяк һәм төкчәләре серкә җыю аппараты барлыкка китерә, озын хортумчык нектар җыю өчен хезмәт итә. 2 пар канатлы, гадәттә, алар үтә күренмәле, тиречел, шәрә, сирәк урнашкан сеңер челтәрле; алгылары арткыларына караганда зуррак. Төрләрне билгеләүдә алгы канат күзәнәкләренең саны, формасы һәм чагыштырмача үлчәмнәре зур әһәмияткә ия. Эшче һәм ана кортларның корсак очында тешчексез ук (үзгәргән күкәй салгыч) бар, аның ярдәмендә алар күп тапкыр чагарга сәләтле һәм үлмиләр (искәрмә — *бал корты*). У.к.ның ялгыз гына яшәүче төрләре күп, аларның кайберләре колония булып яшиләр; калганнары җәмгыяви (мәс., *төклетуралар*). Барлык У.к. оя ясыйлар, биредә личинкаларга баллы азык (бал һәм серкә катнашмасы) ашаталар, искәрмә буларак, мәс., бал кортларында, ул махсус биз сыекчасы — бал сөте б-н алыштырыла. У.к. арасында У.к. күкесе — ирекле яшәүче төрләрнең клептопаразитлары очрый, алар оя ясамыйлар һәм личинкалар өчен азык җыймыйлар, ә күкәйләрен башка төрдәге ана затның оясына салалар. Җитлеккән У.к. чәчәк серкәсе һәм нектары б-н туеналар. Күбесе — чәчәкле үсемлекләрне, ш.и. культуралы үсемлекләрне серкәләндерәләр. У.к.ның 15 төре ТРның Кызыл китабына кертелгән (2006; 1 нче басмада 29 төр).

Әд.: Определитель насекомых. М.–Л., 1938; Фриш К. Из жизни пчёл. М., 1980; Кипяткова В.Е. Мир общественных насекомых. Л., 1991.

Е.А.Сапаев.

УМАРТАЧЫЛЫ́К, азык-төлек сәнәгатенә чимал буларак бал, балавыз, тома балавыз (прополис), бал икмәге (чыршын, перга), бал корты сөте, серкә, бал корты агуы җитештерү, ш.у. уңдырышлылыкны арттыру максатыннан энтомофиль а.х. үсемлекләрен серкәләндерү өчен бал кортлары үрчетү б-н шөгыльләнүче а.х. тармагы.

Элекке вакытта У. *чолыкчылык* рәвешендә хөкем сөргән. 16 йөз ахырында Урта Идел һәм Урал буенда чолык һәм багана умарталар акрынлап умарта оялары б-н алыштырыла башлый. 18 йөздә немец сәяхәтчесе Иоанн Фальк Казан төбәге турында: «Барча җирендә дә яхшылап караган, мул уңышлы җиләк-җимеш бакчалары бар, умарталыклар күп», — дип яза; рус натуралисты И.И.*Лепёхин*: «Чирмешән буенда урнашкан авыллар ның барысында да диярлек, аеруча татарлар арасында, умарта тотучыларны очратырга була», — дип билгеләп үтә. 19 йөз уртасында У. б-н төбәкнең барлык өязләрендә дә шөгыльләнәләр. Чистай һәм Мамадыш өязләрендә умарталар саны аеруча күп исәпләнә, анда һәр умартачыга 20–50 умарта туры килә, һәр умартадан 5–30 кадак һәм аннан да артыграк күләмдә кәрәзле бал алына. Шушы ук чорда җирле умарталыкларда беренче рамлы умарталар күренә башлый. 1854 елда танылган рус умартачысы П.И.Прокопович шәкерте Клыковский Казан тирәсендә У. мәктәбе ачып җибәрә. У. үсешендә А.М.*Бутлеров* аерым роль уйный. Ул, Лаеш өязе Бутлеровка авылында тәжрибә үткәрү һәм күзәтүләр алып бару өчен, умарталык булдыра, элек-электән кара төстәге Европа урман (урта рус) токымлы бал кортларын үрчетелә торган безнең төбәккә башка токымлы бал кортлары кайтарта, Барыш халык У. мәктәбе ача (1882); умартачылар өчен Россиядә беренче махсус басма — «Русский пчеловодческий листок» ж-лын оештыра (1886–1918 дә нәшер ителә), аерым хезмәтләр язып бастыра: «Россиядә отышлы умартачылыкны җәелдерү турында» («О мерах к распространению в России рационального пчеловодства», 1871); «Бал корты, аның тереклек итүе һәм эшлекле умартачылыкның төп кагыйдәләре» («Пчела, её жизнь и главные правила толкового пчеловодства», 1871); «Бал кортларын ничек карарга» («Как водить пчёл», 1885). Бу хезмәтләрнең халык арасында таралуы, умарта оялары җитештерүне оештыру, күчмә күргәзмәләр уздыру, 1904 тә Казанда умартачылар җәмгыяте һәм 1905–11 дә Лаеш, Мамадыш, Чабаксар, Чистай һәм Ядрин шәһәрләрендә аның бүлекләре оештырылу нәтиҗәле У. җәелдерелүгә һәм тармакның үсешенә этәргеч бирә. 20 йөз башына Казан губернасында 4167 умарталык (93724 умарта, шуларның 12487 се рамлы), 3,5 мең чолык; 1908 дә — 6873 умарталык (131803 умарта) исәпләнә. Шуннан соңгы дистә еллар эчендә респ-ка У.гы күтәрелеш һәм чигеш чорларын кичерә. Рекордлы үсеш дәрәҗәсе — 325,4 мең баш оя — 1965 елга туры килә.

1960 елларда Татарстан респ-ка а.х. тәжрибә станциясенең эксперим. умарталыгында төрле токым бал кортларының продуктлылыгын чагыштыру буенча тикшеренүләр уздырыла. Һәвәскәр умартачылар арасында коньяк токым ана кортлар кертелгәндә күрше умарталыклар арасында изоляция тәэмин ителмәү сәбәпле, Татарстанда бал корты оясының байтак өлеше метизлаша (токым чисталыгын югалта). Мамадыш, Саба, Балтач р-ннарында бал кортлары генофонды азрак зыян күрә. 1986 да, токым стандартларына туры килүе һәм хуҗалык өчен файдасы ягыннан перспектив токым буларак, урта рус токымлы бал кортларының Татарстан популяциясен саклау һәм тергезү максатыннан шул терр-яләрдә дәүләт заказнигы булдырыла;



Камил һәм Зөлфәт Сөнгатуллиннарның гаилә умарталыгы (Лаеш р-ны Державин а.).

2003 тә Россиядә урта рус токымын яхшыртуны буенча максатчан селекция-нәсел үрчетү эше алып баручы иң зур үзәкләрнең берсе — «Татарский» нәсел үрчетү үзәге оештырыла (10 мең бал корты оясын эченә алган 80 умарталык); эш тәжрибәсен респ-каның башка районнарына тарату өчен «Саба балы» ҖЧҖ төзелә. 2002 дән ТРда барлык төр милек формаларына караган умарталыкларда бердәм фәнни-техник сәясәт алып бару, технол. һәм зооветеринар оештыру чараларының тулы комплексын үтәүне Дәүләт У. идарәсе (1939 да Татарстан У. конторасы буларак гамәлгә куела) тормышка ашыра. 2010 га кадәр ТРда У.ны үстерү концепциясе урта рус токымлы бал кортының җирле популяциясе генофондын саклау һәм селекция юлы б-н яхшыртуны; бал корты ояларын төрле продуктлар алу, энтомофиль а.х. культураларын серкәләндерү һәм якын тирәлеккә мониторинг уздыру юнәлешендә комплекслы файдалану; биол. актив У. продуктлары нигезендә балалар өчен һәм диетик ашамлыклар, косметик препаратлар, азык-төлек өстәмәләре һәм әчемлекләр җитештерүне күздә тота.



Г.С. Умеркин.

2005 тә Татарстан бал корты оялары саны буенча илнең төбәкләре арасында 5 нче урынны били; респ-каның җәмәгать секторында — 653 (шуларның 75е — Экология һәм табигый ресурслар министрлыгының Урман хуҗалыгы департаментына карый), шәхси секторда 2456 умарталык исәпләнә. Бер умарталыкка уртача 51 оя туры килә. 2016 да бал корты оялары саны 252,8 меңгә җитә (2000 дә — 110 мең тирәсе); җитештерелгән тулай бал күләме — 15792 *т*, товарлыклы бал күләме — 7000 *т* тәшкил итә. Татарстан терр-ясендә баллы үләннәр һәм бал кортларына яраклы нектар запасы булу 400 мең бал корты оясы тотарга һәм алардан ел саен 80–100 мең *т* бал алырга мөмкинлек бирә. 2016 да ТРда 14,3 мең умарталык исәпләнә, ш.и. 13,2 мең шәхси ярдәмче хуҗалык карамагында була.

Мәскәүдә уздырылган Халыкара У. конгрессында (1971) Татарстан балы, сыйфатлы баллар арасында бәяләнеп, көмеш медальгә лаек була; «Интермёд2003» Халыкара күргәзмәсендә (2003) Дәүләт У. идарәсе урман уртарус токымлы бал кортын саклау һәм тергезү, ш.у. балның югары сыйфаты өчен көмеш, бронза медальләр һәм 1 нче дәрәҗә диплом б-н бүләкләнә.

Җирле У.ны фәнни һәм гамәли яктан үстерүгә 19 йөз ахырында — 20 йөз башында И.В.Любарский, А.Паленин, С.П.Болотников, А.Ф.Кунахович, В.Логинов, М.А.Дернов, Н.А.Соловьёв, С.В.*Жданов*; 20 йөзнең 2 нче яртысы — 21 йөз башында А.Н.Колесников, М.Г.Стекольщиков, Т.С.Жданова, А.Х.Гарифуллина, Н.А.Голикова, Н.Н.Гранкин, Р.Р.Сафиуллин, С.З.Стехин һ.б. зур өлеш кертә.

Әд.: Жданова Т.С. Сравнительное изучение разных рас пчёл в условиях Татарской АССР // Материалы итоговой науч. конф. зоологов Волжско-Камского края. К., 1970; Николаевский В.М., Гарифуллина А.Х., Гамзов А.А. Справочник по пчеловодству, К., 1979; Страницы истории: Пчеловодство в Казанском крае // Молодому пчеловоду. К., 1994; Сафиуллин Р.Р., Гамзов А.А., Хисматуллин Р.Г. Состояние пчеловодства РТ и пути его развития на основе комплексного использования пчелиных семей // Слагаемые эффективного агробизнеса: Обобщение опыта и рекомендации. Ч 2. Кормопроизводство и животноводство. К., 2006.

Р.И.Михайлова.


УМӘ́РОВ (Гомәров) Марс Таһир улы (23.3.1940, Чуаш Респ-касы Шомырша а. — 5.7.1995, Казан), генерал-майор (1985). В.И.Ленин исем. Ташкент югары гомумгаскәри командирлар уч-щесен (1962), М.В.Фрунзе исем. хәрби академияне (Мәскәү, 1976) тәмамлый. 1958 елдан СССР Кораллы Көчләре сафларында. 1962 дән Көньяк гаскәрләр төркемендә, 1967 дән Төркестан хәрби округында, 1976 дан Германиядәге совет гаскәрләре төркемендә хезмәт итә. 1981–85 тә Ерак Көнчыгыш хәрби округында мотоукчылар дивизиясе командиры урынбасары, командиры. 1985–90 да 8 нче, 35 нче армияләрнең командующие урынбасары. 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

УМЕ́РКИН Габделхак Сәгыйть улы (31.1.1917, хәзер Ульянов өлкәсенең Барыш р-ны Иске Тимошкино а. — 16.2.1982, Казан), Сов. Союзы Герое (13.9.1944), өлкән лейтенант, ТАССРның атказ. укытучысы. Сәмәрканд ун-тын тәмамлый (1940). Каракалпак АССРның Чимбай шәһәре пед. уч-ще сендә укыта. 1940 елдан Кызыл Армиядә. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 134 нче гаубица артиллерия полкы батареясы (Приморск армиясенең 172 нче укчы дивизиясе) командиры. 1942 нең маенда Төньяк Кавказ фронты гаскәрләре составында Севастополь шәһәре өчен барган сугышларда батырлык күрсәтә: Камыш-лы авылы янында ут позициясе алган У. артиллерия батареясы 3 һөҗүмне кире кайтара. Дошман күзәтү пунктын батареядан аеруга ирешә һәм соңгысын камап ала. Дошманның күпсанлы тере көчләрен һәм техниканы юк итеп, артиллеристлар камалыштан чыгалар. 1946 дан запаста. 1947–81 дә Казанның 116 нчы мәктәбендә укыта. 1945 нең 24 июнендә Кызыл мәйданда Җиңү Парадында катнаша. Ленин ордены, Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә. 116 нчы мәктәп У. исемен йөртә, анда аның музее оештырыла, мәктәп бинасы алдында У. бюсты урнаштырыла. Геройның исеме 1941–42 елларда Севастопольны саклаучыларга куелган һәйкәлдә чокып язылган.

Әд.: Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

М.З.Хәбибуллин.

УМЫРТКАСЫЗЛА́Р (Invertebrata), умырткалары булмаган күпсанлы хайваннар төркеме. «У.» терминын 19 йөз башында француз галиме Ж.Б.Ламарк кертә. Терминны системалаштыру әһәмияте юк, әмма ул киң кулланыла. У. 1,5–2 млрд. ел элек — әле протерозой эрасында ук күренә башлыйлар. 1 млрд. ел элек тирәсе колониаль беркүзәнәкләләрдән күпкүзәнәкле формалар килеп чыга. Иртә палеозой эрасы диңгезләрендә (якынча 0,5 млрд. ел элек) У.ның барлык типлары вәкилләре яши. Хайваннарның эволюция юлы У.да күзәтелә, төп билгеләре нурлы симметрияледән (чагучыларда) ике яклы гәүдәгә (күбесе югары төзелешле У.) күчү, икенчел гәүдә куышлыгы (целома) барлыкка килү, хәрәкәт, ашкайнату, җенес, нерв-сенсорлы, бүлеп чыгару, кан, сулыш системаларының барлыкка килүе һәм катлаулана баруы б-н бәйле. Борынгы, ике яклы-симметрияле, целомик У. — беренче хордалы хайваннарның бабалары (У. эволюциясенең төп этаплары «Хайваннар патшалыгының филогенетик агачы» таблицасында). У. Җирдә тереклек итүнең мөмкин булган барлык шартларын үзләштергәннәр, биосфераның мөһим компоненты буларак, аларның күп кенә төркемнәре биол. прогресс стадиясендә. У.ның барлыгы 2 млн.га якын төре (умырткалылар — 50 меңнән ким) тасвирланган; чама б-н тагын шул ук сандагы төр, башлыча, протистлар, бөҗәкләр, нематодалар фәндә билгесез булып кала дип фаразлана (башка мәгълүматлар буенча 3–4 тапкыр күбрәк). Беркүзәнәкләләрнең (протистларның) якынча 30 һәм күп күзәнәкле У.ның 30 дан артык төрен билгелиләр. Әмма тере организмнарның систематикасын һәм филогениясен өр-яңа алымнар б-н өйрәнү (РНК рибосомалар нуклеотидларының әзлеклелеге, киң таралган аксымнар өчен ДНК кодлары буенча h.б.) шактый көчле бара, шунлыктан тәкъдим ителгән системалар бик тиз искерә. Хәзер протистлар патшалыгын яңадан билгели башладылар, аңа исә иң түбән төзелешлеләр дә кертелә (протистлар һәм У. мегасистематикасын к. «*Протистлар һәм хайваннар патшалыгы системасына заманча караш*» — «Современное представление о системе царств протистов и животных» табл.). Татарстан терр-ясендә алар 19 типтан да ким түгел, әмма төр составы аз өйрәнелгән. Протистлар үз эченә ризопода (Rhizopoda; берничә типны берләштерә, төрләренең гомуми саны — берничә йөз, ТРда — берничә дистә), *камчылылар* (Mastigophora; берничә төрне берләштерә, төрләренең гомуми саны — якынча 7 мең, ТРда — берничә йөз), *инфузорияләр* (Ciliophora; 7,5 мең төр, ТРда — берничә йөз), апикомплекслар (Apicomplexa; 4,8 мең төр, ТРда — 100 тирәсе), микроспора (Microspora; якынча 800 төр, ТРда — берничә дистә), миксозояларны (Myxozoa, 875 төр, ТРда — берничә төр) ала. Соңгы 3 тип — спора барлыкка китерүче фәкать паразит формалар. Татарстанда күп күзәнәкле У.дан *буынтыгаяклылар* (Arthropoda; соңгы систематика буенча өч типка бүленәләр: Chelicerata, Uniramia, Crustacea, төрләренең гомуми саны — 1,5 млн.нан артык, ТРда — уннарча мең), *йомры суалчаннар* (Nematoda; якынча 1 млн. төр дип исәпләнә-лә, 15 меңгә якыны тасвирланган, ТРда — берничә мең), *моллюсклар* (Mollusca; якынча 100 мең төр, ТРда — 100 тирәсе), *ботерелчек суалчаннар* (Rotifera; 1,5 меңнән артык төр, ТРда — якынча 50), *бөҗралы суалчаннар* (Annelida, якынча 75 мең төр, ТРда — якынча 60), *әкрен йөрүчеләр* (Tardigrada; 600 төр, ТРда — 34, мөгаен 45 кә кадәр), *яссы суалчаннар* (Plathelminthes; якынча 25 мең төр, ТРда — 100 дән артык) — иң күп санлы типлар. Татарстанда башка тип вәкилләре яки бик аз санда, яисә бөтенләй өйрәнелмәгән. Аларга *болытсыманнар* (Spongia; якынча 10 мең төре билгеле, ТРда — 3), чагучылар (Cnidaria; якынча 10 мең төр, ТРда — 3), корсаккерфекле йомры суалчаннар (Gastrotricha, якынча 500 төр, ТРда — берничә дистә), *ырганкбашлар* (Acanthocephala; якынча 1 мең төр, ТРда — берничә дистә), *мүкчәләр* (Bryozoa; 4 меңгә якын төр, ТРда — 3), бишавызлар (Pentastoma; якынча 100 төр, ТРда — берничә дистә) керә. ТРда фән өчен яңа башхортум-



Умырткасызлар мәкаләсенә. Хайваннар патшалыгының филогенетик агачы.



А.С. Унженин.

лы Cephalorhyncha тибы *төкле суалчаннар* Nematomorpha классын (якынча 250 төре билгеле, ТРда — 10–20) үз эченә ала. У. — үлеп беткән органика деструкторлары, биосферада матдәләр әйләнешендә һәм энергиядә зур әһәмияткә ия. У. кешенең хуҗалык эшчәнлегендә үсемлекләрне серкәләндерүчеләр сыйфатында, әйләнә-тирә мохит халәтен бәяләүдә биоиндикатор һәм тест объекты буларак кулланыла. А.х. культуралары корткычлары б-н көрәштә биол. ысуллар буларак (*җайдаклар*), агымсуларны биол. чистарту, биогумус алу (божралы суалчаннар), мед. (сөлек һәм умарта кортлары), азык-төлек продуктлары (моллюсклар, кысласыманнар), терлек азыгы һәм дару препаратлары җитештерүдә файдаланыла. Кайбер У. — паразитлар һәм авыру таратучылар. Урман (*агач кортлары*, *кабыгашарлар* һ.б.) һәм авыл хуҗалыгына (*гөбләләр*, *җир борчалары*, *филчекләр*, *аючикерткәләр*, күп кенә күбәләкләрнең гусеницалары һ.б.), терлекчелеккә (бөгәлчәннәр, кигәвеннәр һ.б.) зур зыян китерергә мөмкин. У.ны өйрәнү б-н респ-ка-ның күп кенә галимнәре шөгыльләнә. Алар арасында Казан ун-тының зоол. мәктәбен нигезләүчеләр: Н.П.Вагнер, А.О.Ковалевский, В.В.Заленский, М.М.Усов, Э.А.Мейер, Н.А.Ливанов, В.Л.Вагин, химик А.М.Бутлеров (аның тарафыннан Идел-Кама төбәгендәге күбәләкләрнең бай коллекциясе тупланa); У.ның аерым таксономик һәм экол. төр-кемнәрен өйрәнүгә зур өлеш кертүчеләр: М.М.Алейникова, Н.М.Утробина, Т.И.Артемьева (туфрак мезофаунасы), Х.М.Корбангалиева, Н.М.Минһаҗева, В.А.Яковлев (төче су У.ы), О.Д.Любарская, Ф.Г.Соколина (паразит У.), И.П.Забусов, Н.А.Порфирьева, Р.Я.Дыганова (төкле суалчаннар), А.И.Голубев (У.ның нерв системасы эволюциясе), Ә.Б.Халидов (эшләпәле гөмбәләр энтомоценозы), Н.В.Шмелев, В.М.Басов (парканатлылар), И.В.Назарова (борчалар), В.А.Бойко (паразит талпаннар), А.К.Жеребцов (бызылдавыклар), Н.А.Лисов (урман корткычлары) һ.б. бар.

Әд.: Друшиц В.В. Палеонтология беспозвоночных. М., 1974; Краткий определитель водных беспозвоночных Среднего Поволжья. К., 1977; Определитель пресноводных беспозвоночных Европейской части СССР. Л., 1977; Догель В.А. Зоология беспозвоночных. М., 1981; Хаусман К. Протозоология. М., 1988; Малахов В.В. Загадочные группы морских беспозвоночных. М., 1990; Определитель пресноводных беспозвоночных России. Т. I. Низшие беспозвоночные. СПб., 1994; Дудичев А.Л., Бисеров В.И., Голубев А.И. Тихоходки Татарстана. К., 1999; Протисты: руководство по зоологии. СПб., 2000. Ч. 1; Карпов С.А. Строение клетки протистов. СПб., 2001; Ruppert E.E., Barnes R.D. Invertebrate Zoology. Pr. USA, 1994; Anderson D.T. Invertebrate Zoology. Melbourne, Australia, 1999.

Р.М.Сабиров.

УНАЛТЫНЧЫ́ ҮРНӘ́К МӨСЕЛМА́Н УКЧЫ́ КОМАНДИРЛА́Р МӘКТӘБЕ́, милли хәрби уку курслары. 1920 елда Казанда Кызыл Армия хәрби частьларына милли командирлар составы әзерләү өчен *Икенче мөселман совет укчылары курслары* җирлегендә оештырыла. Курслар башлыгы — Г.Л.Окнинский, комиссары — Н.К.Мөхетдинов. Респ-ка Запас Армиясе һәм Идел буе хәрби округы хәрби уку йортлары идарәсе карамагында була. 1920 дә курсларда 369 татар курсанты исәпләнә. 261 курсант махсус бурыч үтәүче Казан укчылар полкы составында Төмән губернасы крәстияннәре күтәрелешен (1921) бастыруда катнаша; курсантлар төркеме 160 тан артык кешесен югалта. 1921 нең яз һәм җәй айларында 2 чыгарылыш (27 кеше) була. 1922 нең май–сентябрь айларында курсантлар чик буендагы Кушка кальгасында лагерь җыеннарында була. 1923 ел башында *Тугызынчы Казан совет шәркый халыклар кавалерия курслары* б-н бергә *Казанда мөселман командирларының берләшкән курсларын* оештыралар.

Әд.: Гиззатуллин И.Г. Мусульманские военные организации (1917–1921 гг.). К., 2002.

И.Г.Гыйззәтуллин.

УНАЯКЛЫ́ КЫСЛАСЫМАННА́Р (Decapoda), югары төзелешле кысласыманнар отряды. Елга кыслалары, креветкалар, омар һәм лангустларның зур, аеруча оешкан төркемнәре. 8500 дән артык төре билгеле. Элек Татарстан терр-ясендә елга кыслаларының 2 төре очрый: киңаяклы кысла (Astacus astacus) һәм тараяклы кысла (A.leptodactylus) Идел, Кама һәм кече елгаларда таралганнар. Хәзер фәкать икенче төре генә очрый. Гәүдәсе 10–18 *см* озынлыкта, өске якtan карапакс б-н капланган башкүкрәктән һәм буынтыклы озын корсактан тора. У.к. — чиста су индикаторлары. Кыйммәтле азык продукты булган элек промысел әһәмиятенә ия булган. Хәзерге вакытта күбесенчә һәвәскәр балыкчылар тарафыннан махсус капкын — «кысла кыскычлар» б-н аулана. Параяклы кысла ТР-ның Кызыл китабына кертелгән.

В.А.Яковлев, Т.А.Кондратьева.

УНБАШЫ́, төрки-татар һәм монгол гаскәрләрендә 10 кешедән торган хәрби берәмлек башлыгы, ш.у. феодаль биләмәләр хуҗасы. Үз хакимлегендәге терр-ягә күзәтчелек итә.

«УНБИ́Ш ҖИТӘКЧЕ́ ХАТЫ́», РКП(б)-ның Татарстан өлкә ком-ты һәм ТАССР ҮБК әгъзаларының (барлыгы 15 кеше) 1923 елда И.В. Сталин б-н Л.Д.Троцкийга юлланган хаты. Аның авторлары — К.Г.*Мохтаров*, Г.Г.*Мансуров*, Р.Ә.*Сабиров* һ.б. М.Х.*Солтангалиевне* кулга алуның нигезле булуына шик белдерәләр, хатта ш.у. РКП(б)ның 12 нче съездында милли мәсь әләбуенча кабул ителгән карарларның үтәлеше турында тәнкыйть сүзләре урын ала (партиянең бөекдержавачыл шовинизм һәм җирле милләтчелек б-н килешмәүчән көрәш алып бару карары респ-ка партия оешмасында «милли тайпылыш» б-н көрәш китереп чыгара). 1923–24 тә хатка кул куючыларның барысы да җитәкче урыннардан азат ителә, түбәнрәк вазифаларга күчерелә һәм соңыннан репрессияләнә.

Б.Ф.Солтанбәков.

УНЖЕ́НИННАР, Казан сәүдәгәрләре һәм җәмәгать эшлеклеләре. Вятка губернасы Яранск шәһәренең элеккеге сәүдәгәрләр нәселеннән (фамилияләре Унжа елгасы атамасыннан). 1) **Авксентий Степанович** (1803, Яранск — 14.12.1858, Мәскәү, Казанда җирләнә), 1 нче гильдия сәүдәгәр. Казан сәүдәгәрләре П.И.Сухов, А.Л.Крупеников, А.И.Фёдоровта хезмәт итә. 1824 елда үз эшен башлый, 1829 дан 3 нче гильдия сәүдәгәр; чәй, шикәр, кофе б-н сәүдә итә. Акрынлап Казанның эре сәүдәгәренә әверелә, товарны Мәскәүгә, Түбән Новгород һәм Эрбет ярминкәләренә җибәрә. Казанда Гостиный дворда 7 вак кибет һәм 1 галантерея кибете була. Берничә тапкыр Казан шәһәр Думасына гласный итеп сайлана, 1854–56 да шәһәр башлыгы. Бер үк вакытта Казан шәһәр җәмәгать банкының директоры. Дәрәҗәле граждан исеменә лаек була. Бертуганының улы **Василий Николаевич** (1813, Яранск — 1891, Казан), 1 нче гильдия сәүдәгәр, Казанның дәрәҗәле гражданы, бакалея товарлары б-н сәүдә итә. 2) **Николай Васильевич** (1846, Казан — 1913, шунда ук), Казан сәүдәгәрләр банкы идарәсе рәисе (1889 дан), Казан шәһәр Думасы гласные (1879 дан). 1884 тән — Казан губернасындагы балалар ятимханәләренең, 1910 нан Ольга исем. хезмәт тәрбиясе балалар ятимханәсе идарәсенең шәрәфле әгъзасы, 1893 тән Мария исем. попечительләр җәмгыятенең Казан бүлеген оештыручы-әгъзасы. Казан коммерция уч-щесен тотуга акчалата ярдәм итә.

Әд.: Агафонов Н.Я. Казань и казанцы: В 2 вып. К., 1906–07.

Р.А.Айнетдинов.

«УН ҖИДЕНЧЕ́ ОКТЯ́БРЬ БЕРЛЕГЕ́» (октябристлар), 1905–15 елларда Россиядәге уң карашлы либераллар сәяси партиясе. 1905 нең ахырында оештырыла. Атамасы император Николай II нең эчтәлеге партиянең сәяси таләпләргә җавап биргән «Дәүләт тәртибен камилләштерү турында» 1905 ел 17 октябрь Манифестына нисбәтле. Берлекнең нигезе Манифестны «хокукый стройның тамырындагы башлангычлар» игълан ителү буларак кабул иткән алпавытлар, земство эшлеклеләре, чиновниклар, эре сәүдә-сәнәгать буржуазиясе вәкилләреннән, уртачыл карашлы либерал профессорлардан оеша. Лидерлары: А.И.Гучков, Д.Н.Шипов, П.Л.Корф, П.А.Гейден, бертуган В.П. һәм П.П. Рябушинскийлар һ.б. Партия үзенең программа күрсәтмәләрендә халык вәкилләге, демократик ирекләр, гражданнарның тигез хокуклылыгы һ.б. таләпләр б-н чыга. 1905–07 еллардагы рев-ция вакытында әгъзаларының гомуми саны 77 мең чамасы кеше исәпләнә; Берлекнең 260 җирле оешмасы эшли; иң зурлары Мәскәүдә һәм С.Петербургта була.

Казанда, Мәскәүдә һәм С.-Петербургта октябристлар оешмалары формалашу бер үк

вакытка туры килә. 1905 нең 10 ноябрендә Казан губернасы земство идарәсенең киңәйтелгән җыелышында «Казан 17 октябрь Манифесты партиясе» оештырылу турындагы карар кабул ителә, партия Берлеккә кушылырга ниятли (ул мөстәкыйль оешма дип игълан ителә). 1905 нең 13 декабрендәге гомуми җыелышта партия программасы раслана, ул Берлек программасыннан демократиячелрәк рухы б-н аерыла. Казан октябристлары конституцион монархияне; гомуми һәм ике буынлы сайлау хокукын (алга таба хатын-кызларга да шундый хокук бирү шарты б-н); законнар чыгара торган парламент һәм аның алдында җаваплы хөкүмәт гамәлгә кертелүне; закон алдында барлык гражданнарның тигез хокуклылыгын; аграр мәсьәләне тиз арада хәл итүне (кирәк булганда хәтта хосусый биләмәдәге җирләрнең бер өлешен экспроприацияләү юлы б-н) яклап чыгалар. 1905 тә 18 кешедән торган партия ком-ты (А.Н.*Боратынский*, П.И.Геркен, А.П.*Годнев*, М.Я.*Капустин*, В.А.Карякин, В.В.*Марковников*, Н.А.Мельников, В.В.Перцев, И.А.Праксин, В.И.Разумовский, А.В.*Смирнов* һ.б.) оештырыла, рәис итеп М.Я.Капустин сайлана. 1906 ның гыйнварында Чистай шәһәрендә партиянең бүлекчәсе ачыла, аны шәһәр башлыгы сәүдәгәр А.Я.Логутов җитәкли. Бу чорда Казан губернасы буенча оешмада якынча 540 кеше исәпләнә. Басма органнарын «*Казанский телеграф*» һәм «*Обновление*» г-талары тәшкил итә.

Казан губернасында октябристлар партиясе эшчәнлегенең иң актив чоры 1 нче, 2 нче һәм 3 нче Дәүләт Думаларына сайлаулар вакытына туры килә. 1 нче Дәүләт Думасына сайлау кампаниясе барышында партиягә «Казан шәһәренең пастырьлар һәм чиркәү старосталары берлеге» һәм Сәүдә-сәнәгать партиясе кебек уртача либераль оешмалар килеп кушыла. Бу вакытта оешманың структурасы (губерна ком-ты һәм 6 участок бүлекчәсе) тулысынча формалаша. Берләшүләренә карамастан, сайлауларда октябристлар партиясе җиңелүгә дучар була. Казанда сайлаулар вакытында барлыкка килгән 6 бүлекчәнең берсе генә эшли (житәкчеләре — профессорлар П.И.*Кротов*, Б.В.*Варнеке*).

1906 ның 10–12 сентябрендә Казанда Берлекнең 1 нче Идел буе съезды уздырыла, анда Мәскәүдән, Самарадан, Сембердән, Түбән Новгородтан, Малогадан, Сормоводан делегатлар, партиянең ҮКннан А.И.Гучков, А.С.Белкин катнашалар. Съезднең көн тәртибендә программа, устав, нәшрият эшчәнлеге, алга таба сайлаулар вакытында башка партияләр б-н мөнәсәбәт һәм тактика мәсьәләләре карала. Съездда «Унҗиденче октябрь берлегенең кыскача сәяси программасы» һәм Берлек Уставыннан әллә ни аерылмаган «Казан 17 октябрь Манифесты партиясе» уставы кабул ителә. 2 нче Дәүләт Думасына сайлауларда губерна буенча тулаем алганда октябристлар кабат җиңүгә дучар булалар. Алар Думага Казаннан бер генә депутатны — М.Я.Капустинны уздыра алалар, ул октябристларның кадетлар партиясенә якын торган сул канатын гәүдәләндерә (М.Я.Капустин Дәүләт Думасында октябристлар фракциясен җитәкли). 3 нче Дәүләт Думасына сайлаулар алдыннан партиянең губерна ком-тында кризис күзәтелә, ул идея ягыннан таркалуга китерә. Карагруһчылар идеясенә якын торган уң октябристлар төркеме — Б.В.Варнеке тирәсендә, ә суллары М.Я.Капустин тирәсенә берләшә. Губерна ком-ты үз кандидатлары исемлеген, уң октябристлар, бәйсез рәвештә җыелыш оештырып, мөстәкыйль исемлек раслыйлар; ләкин партия әгъзаларының күбесе губерна ком-тын яклый, нәтиҗәдә, көтелгән таркалу ахыргача төгәлләнми. 3 нче Дәүләт Думасына сайлау кампаниясе вакытында губернада октябристларның популярлыгы арта, алар М.Я.Капустинны, В.А.Карякинны, И.В.Годневны, А.Н.Боратынскийны депутат итеп уздыруга ирешәләр; оешмада 1 меңләп кеше исәпләнә. Сайлаулардан соң Казанда партия эшчәнлеге туктала диярлек. Думада партия рәсми курсның катгый таләпләренә буйсына. Хөкүмәткә тулысынча буйсыну һәм аны яклау нәтиҗәсендә халык алдында партиянең абруе төшә. Бу чорда губерна ком-тын проф. Н.Ф.*Высоцкий* җитәкли.

4 нче Дәүләт Думасына сайлаулар вакытында партия эшчәнлегендә җанлану күзәтелә. Карагруһчылар һәм октябристларны берләштереп, уң юнәлешле сайлау блогын оештыру өчен, 1912 нең августында Казанга Россия Эчке эшләр министрлыгы чиновнигы Д.П.Башинский килә. Аның идеясен Н.Ф.Высоцкий да яклый. М.Я.Капустин С.-Петербургтан кайткач, губерна ком-ты таркала: партия әгъзаларының күбесе Д.П.Башинский башлангычын хупламый һәм карагруһчылар б-н берләшүдән баш тарта. Н.Ф.Высоцкий партиядән чыга һәм «Казан рус сайлаучылар комитеты»н оештыра (нибары 8 кеше генә аның әгъзасы була). Губерна ком-ты «Октябристлар һәрвакыт хөкүмәткә генә ияреләр, дигәнгә ышанмагыз. Бу дөрес түгел!» дип язылган листовкалар чыгара. Сайлауларда октябристлар үзләренең кандидатлар исемлеген күрсәтәләр, аларның бер өлеше Прогрессив партиянең сайлау исемлегенә дә керә (кадетлар һәм октябристларны берләштерә). Думага партиядән П.Ф.Бычков, И.В.Годнев, В.В.Марковников, А.В.Смирнов сайлана.

Беренче бөтендөнья сугышы елларында октябристлар партиясе эшчәнлеге туктала. Аның иң актив әгъзалары үз эшләрен җирле үзидарә органнарында, «Земство берлеге», «Шәһәр берлеге» һ.б. оешмаларда дәвам итәләр. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң элекке октябристларның бер өлеше Конституцион-демократик партиягә керә.

Чыг.: Программа «Казанской партии Манифеста 17 октября». К., 1905; Первый Поволжский съезд «Союза 17 октября», созванный в Казани 10–12 сентября 1906 г. К., 1906.

Әд.: История политических партий России. М., 1994; Айнутдинова Л.М. Либеральное движение в Казанской губернии (1900–1917 гг.). К., 2003; Алексеев И.Е. Русское национальное движение в Казанской губернии и Татарстане: конец XIX — начало XX веков (опыт словаря). К., 2004.

Л.М.Айнетдинова.

УНИВЕРСИА́ДА, бөтендөнья студентлар спорт ярышлары. Беренче халыкара студентлар ярышлары 1905 елда АКШта уза. 1919 да студентлар конфедерациясе нигезендә (1924 тән Халыкара студентлар конфедерациясе), 1923 тә француз педагогы һәм галиме Жан Птижан башлангычында Парижда беренче Бөтендөнья университет уеннары үткәрелә (барлыгы 1939 га кадәр 8 шундый ярыш уздырыла). 1949 да Халыкара студентлар спорты федерациясе — ФИСУ нигезләнә, һәр 2 ел саен җәйге (1959 дан) һәм кыш кыскы (1960 тан) У. уздыра. Хәзер ФИСУ якынча 160 милли студентлар спорт оешмаларын, ш.и. Россия студентлар спорт берлеген (1993 тә булдырыла) берләштерә. 1973 тә 7 нче Бөтендөнья У. Мәскәүдә уздырыла.



Казанда 2013 елгы Бөтендөнья студентлар уеннары эмблемасы.

СССР, РФ спортчылары җәйге У.ларда рәсми булмаган гомумкоманда зачётында 13 тапкыр, кышкы У.ларда 14 тапкыр 1 нче урында булалар. Татарстан спортчылары — У.ларда медальләр алучылар: А.А.Бозин (грек-рим көрәше, 1977), И.А.Вострикова (җиңел атлетика, 1993), К.Ю.Гафуржанова (2011, 2013) һәм Н.Ф.Гыйләҗева (фехтование, 1979), А.Ю.Деманов (2011, 2013) һәм Е.С.Мигунова (җиңел атлетика, 2013), Ф.П.Симашев (чаңгы ярышлары, 1970, 1972) һ.б. 2008 нең 31 маенда Брюссель шәһәрендә ФИСУның башкарма ком-ты күпчелек тавыш б-н «Универсиада-2013» XXVII Бөтендөнья җәйге студентлар уеннарын уздыру урыны итеп Казанны сайлый («У.-2013»не уздыру хокукын ш.у. Испаниянең Виго шәһәре һәм Көньяк Кореяның Кванджу шәһәре дәгъвалый). «У.-2013» не уздыру һәм аңа әзерлек өчен 2008 дә «У.-2013» дирекциясе (2009 дан — «Казан-2013» башкарма дирекциясе, ген. директоры — В.А.Леонов); 2009 да оештыру ком-ты (рәисе — РФ Хөкүмәте рәисенең 1 нче урынбасары И.И.Шувалов, рәис урынбасарлары — Россия студентлар спорт берлеге президенты О.В.Матыцин, ТР Президенты Р.Н.Миңнеханов, РФ спорт министры В.Л.Мутко) булдырыла. Казанда У. чараларын уздыру өчен 34 спорт объекты реконструкцияләнә, 30 объект төзелә: «Казан-Арена» футбол стадионы (45 мең кешегә), Теннис академиясе (7200 кеше), «Санкт-Петербург» волейбол үзәге (5166 кеше), Спортның су төрләре сарае (3500 кеше), Гимнасти-



Универсиада. 1. Казан мэры И.Р. Метшинга Универсиада флагын тапшыру. Шэньчжэнь ш. Кытай. 2011; 2, 3. Казанда 2013 елгы Универсиада ачылу тантанасы. Студентлар спортының халыкара федерациясе флагын алып чыгу һәм күтәрү; 4. РФ Президенты В.В. Путин чыгышы; 5. Фейерверклар тамашасы; 6. РФ Премьер-министры Д.А. Медведев чыгышы; 7–9. 2013 елгы Универсиада чемпионнары: Илназ Галиев (татарча көрәш); Алия Мостафина (спорт гимнастикасы, шәхси күптөр ярыш, команда беренчелеге); Яна Мартынова (йөзү, 400 *м*, комплексы).

ка үзәге (3200 кеше), Бокс үзәге (1980 кеше), спортның ишү төрләре үзәге (1065 кеше), «Свияга» стендка ату комплексы (350 кеше).

53 *га* мәйданда У. авылы төзелә, ш.и. торак зона — 27,4 *га*, ул 20 торак корпустан торган заманча студентлар кампусын (13500 кеше сыйдырышлы) һәм Халыкара мәгълүмат үзәге бинасын үз эченә ала. Шәһәр инфраструктурасы киң масштабта яңартыла, Казанда транспорт һәм урам-юл челтәре төзекләнделә (10 транспорт чишелеше, 40 җәяүлеләр өчен күчү урыннары, 65 *км* озынлыктагы 20 автомобиль юлы, 60 урам төзелә һәм реконструкцияләнә), «Казан–Аэропорт» интермодаль тимер юл тармагы, «Казан-2» транзит–күчеп утыру тимер юл–автобус вокзалы, Казан метрополитенының 2 нче чираты, Казан тиз йөрешле трамвай линиясе төзелә; «Казан» халыкара аэропорты һәм «Казан-1» төп тимер юл вокзалы реконструкцияләнә.

2011 нең 23 августында Шэньчжэнь шәһәрендә (Кытай) 26 нчы Бөтендөнья җәйге У.ның ябылу тантанасында ФИСУ флагын РФ делегациясенә тантаналы тапшыру була, аны Казан мэры И.Р.Метшин кабул итеп ала. ФИСУ флагы эстафетасы Россиянең 16 зур студентлар шәһәрендә уза. Аның маршрутының озынлыгы 6 мең *км* тәшкил итә.

2012 нең 20 маенда «Сорбонна» ун-тында (Париж) ФИСУ тарихында иң зур «У.-2013» уты эстафетасы башлана. 2012 нең июль–ноябрендә «Седов» җилкәнле өйрәнү судносында У. уты Җирнең 5 континетында була һәм 2013 нең 25 гыйнварында Владивосток шәһәренә килеп җитә. 2013 тә аны Россиянең 27 зур студентлар үзәге, Татарстанның муниципаль районнары аша уздырып, 5 июльдә Казанга китереп җиткерәләр. У. уты эстафетасы 150 мең *км* дан артык юл үтә, дөньяның 57 шәһәрендә була, анда 2013 факел йөртүче катнаша.

У. идеяләрен пропагандалауда студентлар спортын, туризм һәм сәламәт яшәүнең кыйммәтләрен таратуда актив катнашкан өчен «Универсиада-2013 илчесе» дигән мактаулы исем 50 дән артык танылган спортчыга, мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләренә бирелә, ш.и. Татарстаннан спортчылар — А.А.Морозов, А.Ю.Деманов, И.Х.Зиннуров, К.Ю.Гафур җанова, Р.С.Шаронов, Ю.М.Зарипова, ТР Дәүләт симфоник оркестры дирижёры — А.В.Сладковский, җырчылар — А.Гарифуллина, Э.Кәлимуллина лаек була. XXVII Бөтендөнья җәйге студентлар уеннарының ачылыш тантанасы 2013 нең 6 сыннан 7 июль төнендә «Казан-Арена» стадионында уза. Ул Россия, Татарстан, Казан халыклары һәм тарихы турында театральләштерелгән-тематик тамашаны, катнашучылар командасы парадын, рәсми кешеләрнең чыгышын, Россия һәм У. флагларын күтәрү тантанасын, У. утын кабызуны, концертны үз эченә ала; Тантанада Россия Президенты В.В.Путин, ФИСУ президенты Клод-Луи Гальен, ТР Президенты Р.Н.Миңнеханов, ТРның 1 нче Президенты, ТР Дәүләт Киңәшчесе М.Ш.Шәймиев, Казан мэры И.Р.Метшин катнаша. ФИСУ флагын атаклы спортчылар А.М.Галләмова, В.В.Сальников, К.Ю.Гафуржанова, Зур театрның прима-балеринасы С.Ю.Захарова, пианист Д.Л.Мацуев, театр һәм кино актёры К.Ю.Хабенский алып чыга. У.да катнашучылар антын спорт гимнастикасы буенча олимпия чемпионы А.Ф.Мостафина, рефери антын билгеле спорт судьясы Е.В.Садовый игълан итә. «У.-2013» Утын кабызу хокукы РФ яшьләр җыелма хоккей командасы әгъзасы Н.Р.Якуповка (ТР), «Динамо-Казан» командасы волейболисты Е.А.Гамовага, кышкы Паралимпия уеннары-2009 да чаңгы ярышларында һәм биатлонда 4 тапкыр җиңүче И.А.Зариповка (БАССР) һәм дзюдо буенча олимпия чемпионы Т.К.Хайбуллаевка (Дагстан Респ-касы) тапшырыла.

Якынча 70 музыка, бию, театр һәм цирк коллективлары, 1,5 мең артист (ш.и. Д.Хворостовский, М.Максакова, А.Градский, Зур һәм Мария театрлары солистлары А.Гарифуллина, А.Шаһиморатова, И.Абдразаков) чыгыш ясый, барлыгы якынча 6 мең кеше катнаша.

«У.-2013» спорт ярышлары 5–17 июльдә уздырыла. Программага спортның 13 мәҗбүри төре (баскетбол, суда туплы уен, волейбол, спорт гимнастикасы, нәфис гимнастика, дзюдо, җи ңел атлетика, өстәл теннисы, йөзү, сугa сикерү, теннис, фехтование, футбол) һәм 14 кабул итүче якның тәкдиме буенча (бадминтон, бокс, көрәш (грек-рим һәм ирекле), татарча көрәш (билбау көрәше), пляж волейболы, академик ишү, байдаркада һәм каноэда ишү, синхрон йөзү, регби-7, самбо, пуля б-н һәм стендка ату, авыр атлетика, чирәмдә хоккей, шахмат) кертелә.

«У.-2013» тә уйнатылган медальләр саны 351 комплект, катнашучылар саны буенча — 11778 кеше, 160 илдән (7980 спортчы һәм 3798 рәсми зат), ш.у. РФ җыелма командасы яулаган медальләр саны буенча (155 алтын, 75 көмеш, 62 бронза) рекорд куя. Татарстан спортчылары 20 алтын, 10 көмеш, 10 бронза медаль яулый (Татарстаннан 51 спортчы катнаша). Е.Романченко (нәфис гимнастика), И.Галиев, И.Мортазин, Н.Миңлебаев, Р.Әхмәтшин, И.Гыйниатуллин (көрәш), Ю.М.Зарипова, Д.Буряк, Р.Кашефразов, В.Ганиева (җи ңел атлетика), Н.Тёплый, А.Фурасьев (стендка ату), Я.В.Мартынова (йөзү), М.Бородакова (волейбол), А.Ковязина (самбо), П.Антипов (баскетбол), Г.Давыдов, С.Янюшкин (регби), М.Омаров (бокс); М.Гафаров, И.Җамалетдинов, А.Корнилов, А.Корбанов, А.Майоров, Д.Мөхәммәтшин, А.Сюськин, Д.Щипачёв (чирәмдә хоккей буенча команда алтын медале) У. чемпионнары була. Спортның 4 төре буенча У.ның 67 рекорды куела, шуларның 39 ы Россия спортчылары тарафыннан (4 җи ңел атлетика, 19 авыр атлетика, 12 йөзү, 4 спортча ату буенча) башкарыла. Ярышларны 800 меңнән артык тамашачы карый. Телеаудитория 100 дән артык илдә 3 млрд. кеше тәшкил итә. У.ны уздыруда ярдәм итү өчен Россиянең 37 төбәгеннән һәм дөньяның 38 иленнән 19970 мең волонтёр җәлеп ителә. «У.-2013» көннәрендә Казанда 150 меңнән артык турист була. У. тарихында беренче тапкыр спорт ярышлары б-н бер үк вакытта «Мәдәни Универсиада» проекты гамәлгә ашырыла. Аның кысаларында татар милли бәйрәме Сабан туе, Рахманинов исем. III Халыкара «Ак сирень» фестивале, Халыкара «Шаляпин, Нуриев, Казан» опера-балет фестивале, «Музыка веры» фестивале, М.Җәлил исем. Татар опера һәм балет театрының баш дирижёры Р.Салаватов һәм В.Гергиев җитәкчелегендә Мария театры оркестры һәм солистларының галаконцерты һәм мәдәният, сәнгать өлкәсендәге башка чаралар уза. Даими рәвештә Казансу елгасы яр буена урнашкан Игенчеләр саrае каршындагы мәйданда У.ның Мәдәният паркы (терр-ясе — 5,9 *га*, 30 мең кеше) эшли. Монда А.Сладковский җитәкчелегендә Татарстанның Дәүләт симфоник оркестры башкаруында «Ак бүре» татар операсының премьерасы, скрипкачы-виртуоз Э.Акопян, опера җырчысы А.Гарифуллина, «Йолдызлык» фестивале җиңүчеләре, рок-төркемнәр концертлары, 200 дән артык вокаль, хореография, фольклор, инструменталь коллективлар чыгышлары, төрле халык һөнәрләре һәм кул эшләре мастер-класслары, «Дю-Солей» циркы чыгышы була. Интерактив «Футбол паркы», Татарстан халыкларының агач йортлары, гадәти һөнәрләре һәм фольклоры күрсәтелгән милли крәстиян хуҗалыклары, кышкы «У.-2017» узачак Алма-Ата шәһәре һәм кышкы «У.-2019»ны уздыру хокукына гариза биргән Красноярск шәһәре павильоннары даими эшләп тора. Мәдәният паркында 260 мең кеше була. 2013 нең 17 июлендә «Казан-Арена» стадионында РФ Премьер-министры Д.А.Медведев, ФИСУ президенты К.-Л.Гальен, Татарстан һәм Казан шәһәре җитәкчелеге катнашында дәүләт флаглары парады һәм спортчыларның гомуми парады уза; танылган эстрада башкаручыларының чыгышлары б-н матур шоу; рәсми кешеләрнең чыгышлары; У. флагын төшерү тантанасы һәм аны 28 нче «У.-2015» узачак Кванджу (Көньяк Корея) мэры Кан Ун Тэга тапшыру; «У.-2013» Утын сүндерү тантанасы була.

Н.Д.Бобырев, С.Г.Белов.

УНИВЕРСИТЕ́Т ШӘҺӘРЧЕГЕ́, 19 йөзнең 1 нче чиреге — 20 йөз башы архит-ра ансамбле, Казандагы рус классицизмы архит-расының комплексы истәлеге. 1820 еллар башында 1804 тә нигез салынган Казан ун-тын урнаштыру өчен Воскресенский урамындагы 3 шәхси йорт сатып алына һәм хәзерге Кремль, Профсоюз, Урниверситет һәм Астрономия урамнары чикләрендә квартал терр-ясе бүлеп бирелә. Ансамблнең башлангыч генпланы һәм төп корпусның проекты П.Г.Пятницкий тарафыннан эшләнә (1821–25), ул ун-тның төп корпусына гимназия, Тенишев йортларын (1822–25), Кастелли йортларын һәм ун-т ректоры өчен аларга көнбатыш якта кушылган ике колонналы портик янкормаларын берләштерү һәм реконструкцияләү юлы б-н формалаша. 1846 да арх. Гейденрейх җитәкчелегендә ректор йорты торгызыла. 1832 дә М.П.Коринфский ун-т архитекторы итеп билгеләнә, ул П.Г.Пятницкийның төп идеясен саклый һәм комплексның генпланын эшләп бетерә. Терр-янең тәкәрәк сөзәклегендә терәп торучы кырый ди-





Университет шәһәрчеге. Казан. 1. Университет биналары комплексы. Хәзерге күренеше. 2. Анатомия театры һәм Н.И.Лобачевский исемендәге фәнни китапханә.

вар урнаштырыла, мәйданның өслеге Воскресенский урамы биеклеге б-н тигезләнә. Химия лаб-ясе, физика кабинеты һәм китапханәнең симметрик корпуслары ярымтүгәрәк колонналар тезмәсе б-н берләштерелә. Фәнни китапханә һәм химия лаб-ясе ике кыеклы түбәләр астында тоскан ордерындагы колонналы портиклар б-н бизәлгән, ике зур өйалды баскычлы, биек эргәле, ике катлы биналарга урнашкан. Китапханә гөмбәзсыман түшәм һәм уксыман а́ркалар б-н бизәлгән ике рәт тәрәзәле төп залга ия, түшәм коринф ордерлы 24 колоннага тоташкан. Зал диварларына бизәкләр төшерелгән. 1894 тә өч катлы бинаның китапханә урнашкан көнчыгыш ягына эклектика стилендәге янкорма төзелгәннән соң, уку залы китаплар өчен металл стеллаж җайланмалар б-н реконструкцияләнә. Бинадагы портикларның берсе сүтелә. Үзәктә *Анатомия театры* бинасы калкып чыга (1834–36). Колонналар тезмәсе артында кирпечтән ике катлы хезмәт корпуслары урнаштырыла. Мәйданнан көнбатышка таба, калкулык өстендә астрономия обсерваториясе бинасы төзелә (1833–38). 1830 еллар ахырында У.ш. ансамбле классицизм стилендә формалаша. 1846 да ишегалды үзәгендә император Николай I күрсәтмәсе буенча Г.Р.Державинга һәйкәл куела (скульптор С.И.Гальберг, арх. К.А.Тон), 1871 дә аны Театр мәйданына күчерәләр, шул вакытта ук колонналар тезмәсен сүтәләр. Воскресенский урамында, ун-тның төп бинасы каршында зур булмаган бакчалы мәйдан корыла. Аның артында М.П.Коринфский проекты буенча ун-т клиникалары бинасы калкып чыга (1837). 1890 да арх. М.Н.Литвинов проекты буенча Университет урамы буенча ике, өч катлы физиол. лаб-яләре төзелә. 1904 тә арх. К.Л.Мюфке проекты буенча төп корпусның көнбатыш канатына таба ишегалды ягыннан неоклассицизм стилендәге физика-матем. ф-ты бинасы корыла.

Хәзерге вакытта У.ш.нең төп корпусы фронт буенча сузылган (160 *м*), ионик ордерлы өч портигы булган симметрик композицияле ике катлы бина: үзәге 12, ян-яклары 6 шар колоннадан тора. Вестибюльдә урнашкан баскыч икенче каттагы актлар залына һәм рев-циягә кадәр дорик ордерлы көчле колонналарда, цилиндрик гөмбәз б-н ябылы чиркәү урнашкан бинага алып менә.

Астрономия обсерваториясе симметрик композициягә ия. Бинаның төньяк яртысы турыпочмаклы формада, көньягы — очлары көньяк-көнчыгышка һәм көньяк-көнбатышка караган божра сегменты рәвешендә, түбәдә, үзәктәге кебек, астрономик күзәтүләр өчен әйләнеп торучы түгәрәк манараларурнаштырылган. Үзәк манарада телескоп-рефрактор өчен махсус кронштейннарда әйләнмәле агач балкон төзелгән. Түбәдәге квадрат мәйданчыкта ян манаралар әйләнәсе балюстрада б-н корып алынган. Көньяк фасад баскычлы киң террасаны колачлап алган. 1842 елгы янгын вакытында зыян күргән астрономия обсерваториясе бинасы со ңыннан торгызыла. Ун-тның 200-еллык юбилеена У.ш. бинасы реставрацияләнә һәм реконструкцияләнә. 2003 тә ишегалдында төп бинаның көнчыгыш канаты ягында янкорма төзелә.

Әд.: Загоскин Н.П. История Императорского Казанского университета за первые сто лет его существования. 1804–1904: В 4 т. К., 1902–04; Евсина Н.А. Здания Казанского университета // Памятники культуры: Исследование и реставрация. М.–Л., 1963. Вып. 4; Казанский университет. К., 1979; Куприянов В.Н., Агишева И.Н. Главное здание Казанского университета в ансамбле центрально-исторических площадей Казани // Изв. Казан. архитектурно-строительного ун-та. 2011. № 4.

Х.Г.Надыйрова.

УНИВЕРСИТЕТНЫ́Ң УЧИ́ЛИЩЕ КОМИТЕТЫ (Казан университетының училище комитеты), Казан ун-ты уставы нигезендә 1804 елда Казан уку-укыту округы терр-ясендә урнашкан, Халык мәгарифе министрлыгының барлык уку йортлары университет күзәтүендә була. Казан ун-тында училище ком-ты 1811 дә булдырыла, беренче елларда формаль эшли: ком-тка сайланган чит ил профессорлары рус телен белмиләр һәм ревизияләр уздыру өчен Казаннан чыкмыйлар. Ун-т советы 3 елга бер тапкыр ректор җитәкчелегендә 6 профессордан торган уч-ще ком-тын сайлый. Ком-т халык уч-ще ләре, гимназия директорларын билгели, уку йортларында финанс мәсьәләләреннән тыш, барлык мәсь әләләр буенча тикшерү уздыра, таләпләргә туры килмәгән укытучыларны эштән җибәрү хокукына ия була. 1818 дән ком-т утырышы һәм инспекторларның гимназияләргә (Әстерхан, Вятка, Пенза, Саратов, Сембер, Тубыл) килүләре даими була, бу халык мәгарифе үсешендә аерым роль уйный. Гимназияләр һәм халык уч-щеләре уставы 1828 дә башлангыч һәм урта уку йортларын университет күзәтүеннән чыгара, ком-т ябыла.

Әд.: Загоскин Н.П. История Императорского Казанского университета за первые сто лет его существования. 1804–1904. К., 1904. Т. 3; 1906. Т. 4.

«У́НИКС», баскетбол клубының ирләр командасы. 1957 елда Казан ун-ты каршында «Буревестник» исеме б-н оештырыла, 1971 дән — «Университет», 1991–96 да һәм 1988 дән — «УНИКС», 1996–97 дә — «УНИКС-Локомотив». 1966–67дә, 1969–70 тә «А» классында (2 нче төркем) СССР беренчелегендә, 1991 дән 1 нче лигада, 1996 да «А» дивизионында югары лигада, 1997 дән Россия чемпионатының суперлигасында. 2010 нан Профессиональ баскетбол лигасында, 2013 тән ВТБның Бердәм лигасында. Бөтенсоюз (1965) һәм бөтенроссия (1961–69) студентлар беренчелегендә җиңүче, РСФСР халыклары спартакиадаларында көмеш (1971), Россия чемпионатында бронза (1999/2000, 2002/03, 2004/05, 2008/09 — 2010/11,



Европа кубогына уен финалы: «УНИКС»–«Каха-соле» (Испания), Тревизо ш. (Италия). 17.4.2011.

2013/14), көмеш (2000/01, 2001/02, 2003/04, 2006/07, 2015/16), ВТБның Бердәм лигасы чемпионатында бронза (2010/11, 2013/14), көмеш (2009/10, 2011/12, 2015/16) медальләр ала. «Евролига-ФИБА» турниры (2003/04), Төньяк Европа баскетбол лигасы (2002/03) чемпионы, Россия (2002/03, 2008/09, 2013/14), Европа (2010/11) кубоклары иясе. Баш тренерлары: И.П.*Позняк* (1957–69), Л.Ф.*Арсланов* (1970–76), В.В.Левченко (1977–85), А.К.Крамник (1985–89), А.М.Зрядчиков (1994–95), Г.Н.Королёв (1996–98), Д.Вишневец (1998–2000), С.Г.Ерёмин (2000–05/06, 2012/13), А.Сирейка (2006/07), А.Петрович (2007/08–09, 2008/09), В.Хомичус (2009/10), Е.Ю.Пашутин (2010/11/ 2011/12, 2014/15 — 2016/17), А.Тринкьери (2013/14), Д.Прифтис (2017 дән). «УНИКС» баскетбол клубы президенты — Е.Б.Богачёв (1998 дән).

Н.Д.Бобырев.

«У́НИКС», к. *«Уникс» мәдәният-спорт комплексы.*

«У́НИКС» МӘДӘНИ́ЯТ-СПОРТ КО́МПЛЕКСЫ, Казан университеты каршында, 1989 елда файдалануга тапшырыла (арх. В.П.Скачков һ.б.). Башлангыч атамасы — КДУның мәдәният-спорт комплексы (1995 кә кадәр). Бинаның гомуми файдалы мәйданы — 15088,9 *м*^{3}. Физкультура-спорт һәм сәламәтләндерү билгеләнешендәге корылмалар: 10 спорт залы (гомуми мәйданы — 2920 *м*^{2}), скалодром, кием алыштыру, душ, сауна бүлмәләре, мед. лаб-яләре. Спорт блогындагы биналарда Казан ун-ты студентларының физкультура дәресләре, шәһәр, респ-ка, бөтенроссия һәм халыкара дәрәҗәдәге спорт ярышлары, спорт буенча конференция семинарлар уздырыла, спортның түбәндәге төрләре — аэробика, шейпинг, бодифлекс, бодибилдинг, волейбол, футбол, кыя тауга менү, ш.у. биюләр буенча өстәмә дәресләр бирелә.

Концерт блогына керүче бүлмәләр: 4 зал — зур (1107 урынлы), кече (448 урынлы), бильярд залы (1997 дә ачыла), уен автоматлары залы; кафе, студент-яшьләр күңел ачу үзәге, анда университет, шәһәр һәм респ-ка дәрәҗәсендәге чаралар, фәнни конференцияләр, концертлар уздырыла.

«УНИКС» м.-с.к. — «УНИКС» баскетбол клубының уку-шөгыльләнүләр һәм ярышлар базасы, ТР һәм РФнең зур физкультура-спорт һәм сәламәтләндерү үзәге.

УНКО́ВСКИЙ Николай Владимирович (28.10.1856, Калуга губ. — 13.6.1904, Калуга ш.), җырчы (баритон), режиссёр, антрепренёр, педагог. 1876 елда Диңгез уч-щесен (С.-Петербург) тәмамлый, А.Евгеньевның хосусый музыка мәктәбендә О.Палечекта, ирекле тыңлаучы сыйфатында Петербург консерваториясендә К.Эверардида (1878–80) җырлау күнекмәләрен үзләштерә (җырларга өйрәнә). 1880 нән Пенза шәһәрендә җыр дәресләре укыта. Сәхнә эшчәнлеген Казанда башлый: П.Медведевның опера труппасында 1884–85 тә — хормейстер, 1885–87 дә — солист. 1887–88 дә — Мария театры солисты, 1892–99 да Саратов шәһәрендә Рус опера артистлары ширкәте б-н җитәкчелек итә (бер үк вакытта әйдәп баручы солист һәм режиссёр). Россия шәһәрләрендә, ш.и. (берничә тапкыр) Казанда гастрольләрдә була. 1899 да пароходта Казаннан Архангельскига гастрольгә йөрүче «Н.В.Унковскийның опера йөзмә театры»н оештыра. 1901 дән Калугада вокал һәм опера классларын алып бара. Опера партияләре: Валентин («Фауст», Ш.Гуно), Эскамильо («Кармен» Ж.Бизе), Руслан («Руслан һәм Людмила», М.Глинка), Кенәз Игорь (шул исем. әсәр буенча, А.Бородин), Онегин («Евгений Онегин», П.Чайковский) һ.б. Көчле тавышка, югары муз. һәм сәхнә культурасына ия була.

Әд.: Боголюбов Н.Н. Шестьдесят лет в оперном театре: Воспоминания режиссёра. М., 1967.

УНӨЙЛЕ́, к. *Десятидворка.*

УНСИГЕЗЕНЧЕ́ УКЧЫ́ ДИВИ́ЗИЯ, 1939 елда ТАССРда оеша. Дивизия командиры — полковник К.В. Свиридов. 1941 елда Смоленск янында сугыша, 20 нче армия составында Днепр елгасының көнчыгыш ярында чик саклый. 10 июльдә генерал-полковник Х.В.Гудерианның 2 нче танк төркемендәге 18 танк дивизиясе һәм моторлаштырылган дивизиянең 29 нчы часте б-н сугышка керә. 15 июльдә У.у.д. чолганышта кала, генерал-лейтенант И.В.Болдинның җыелма отряды составында гаскәриләрнең аз өлеше генә август аенда чолганыштан чыга ала. 1941 нең сентябрендә У.у.д. таратыла.

Әд.: Казанцев В.Ю. Восемнадцатая дивизия. К., 1968. *В.Ф.Телишев.*

«УҢ ТРО́ЦКИЙЧЫ МИЛЛӘТЧЕЛӘРНЕ́Ң СОВЕ́Т ХАКИМИЯТЕНӘ́ КАРШЫ́ ОЕШМАСЫ́» ЭШЕ́, 1937–1938 елларда ТАССРның НКВД органнары тарафыннан респ-каның әлекке җитәкчеләренең күп кенә эшләрен берләштерү юлы б-н оештырылган гаепләү эше. Бер төркем кеше ТАССР халык хуҗалыгына корткычлык эшләү максаты б-н уң троцкийчыларның контрреволюцион оешмасында катнашуда гаепләнә. Хөкемгә 8 кеше тартыла: И.З.Әмирханов, Г.Әлмөхәммәтов, С.С.Атнагулов, А.Г.Ганиев, З.З.Гыйммранов, Г.Г.Ибраһимов, К.Х.Мәһдиев, З.М.Мөхсинов. Мәхкәмә утырышлары Казанда уза (1937 нең 3, 16 августында; 1938 нең 9 маенда һәм 9 ноябрендә). Гаепләнүчеләр (тикшерү вакытында төрмәдә туберкулёздан үлгән Г.Г.Ибра һимовтан кала) үлем җәзасына хөкем ителә. Репрессия корбаннары барысы да аклана.

«УҢЫ́Ш», 1957–92 еллардагы Мөслим р-нындагы колхоз. «Сатурн» һәм «Ленин бүләге» к-злары берләшү нәтиҗәсендә барлыкка килә. 1993 тә «Уңыш» күмәк пр-тиесе итеп үзгәртелә. «У.» эшчәнлегенең төп юнәлешләре — бөртекле ашлык, шикәр чөгендере, сөт, ит җитештерү. 1992 дә ху җ.лыкка Татар Бүләре (үзәк утары), Иске Сәет, Исәнсеф, Чишмә авыллары керә. Эшләүчеләр саны — 258 кеше, а.х. файдалану җирләренең мәйданы 4146 *га* (ш.и. сөрүле җирләр 3976 *га*), хуҗалыкта 1400 баш мөгезле эре терлек (ш.и. 320 сыер), 2900 баш дуңгыз, 20 баш юртак токымлы атлар бар. 1992–93 тә уртача уңыш бөртекле ашлыктан 1 *га* дан 22,5 *ц*, шикәр чөгендере 1 *га* дан 228 *ц* тәшкил итә; уртача еллык савым һәр сыердан 4020 *кг*. 1993 тә 100 *га* а.х. файдалану җирләренә 492 *ц* сөт һәм 110 *ц* ит җитештерелә. Җитештерүнең табышлылык дәрәҗәсе 1986–93 тә 43% ка җитә. Ху җ.лык 4 тапкыр күчмә Кызыл Байрак һәм 5 тапкыр КПСС ҮК, СССР МС, ВЦСПС һәм ВЛКСМ ҮК Мактау грамоталары б-н бүләкләнә. Хуҗалык үсешенә баш агроном Т.Н.*Фазуллин* зур өлеш кертә (1954–91). Җитәкчеләре — М.С.Сәләхов (1955–88), З.Н.Солтанов (1990–93).

И.Н.Афанасьев.

УПКЫ́Н КҮЛЕ́, Көнбатыш Кама аръягында. Кама елгасының сулъяк ярында, Алексеев р-ны Зотеевка авылында (даими яшәүчеләре юк). Су өслегенең мәйданы 0,2 *га*. Су күләме якынча 6 мең *м*^{3}. Озынлыгы 60 *м*, киңлеге 50 *м*, суының иң аз вакытындагы уртача тирәнлеге якынча 3 *м*, иң зур тирәнлеге 3,6 *м*. Җир өслегеннән казанлыгының тирәнлеге якынча 20 *м*, өске өлешенең диаметры



Упкын күле.

70 *м* дан артык. Күл карст процесслары нәтиҗәсендә, 1895 елда барлыкка килгән. Формасы түгәрәк. Ярлары текә һәм биек. Туенуы күбесенчә җир асты сулары исәбенә, тотрыклы, ш.у. казанлык битләрендә урнашкан зур булмаган сызалар буенча яңгыр һәм кар сулары да керә. Суы уртача минераль.лашкан (323 *мг/л*), чагыштырмача каты (5,3 *мг-экв/л*), җи нәлчә болганчык (үтә күренмәлелеге 32 *см*), гидрокарбонат-сульфат-магнийлы типта. Күл өчен су биеклегенең 3 *м* га кадәр ел буе тирбәлүе хас. Ял итү урыны. ТРның табигать истәлеге (1978).

УРАЗА́ (фарсы روزه — ураза), *ислам* динендә фарыз булган *Рамазан* аенда үтәлә торган, 5 гамәлнең (шәһадәт, биш вакыт намаз уку, ураза тоту, зәкят, хаҗ кылу) берсе. У. балигъ.лык яшенә җиткән барлык мөселманнарга да мәҗбүри. У.да тәүлекнең якты вакытында ашау-эчү, тәкъва булуга комачауланган барлык башка гамәлләр тулысынча тыела. Кояш баегач, У. тотучы мөселманнар авыз ача — бер йотым су, бер чеметем тоз, татлы җимеш б-н ифтар кыла. Аннары табынга төп ризык куела, әмма чамасыз ашау киңәш ителми. Иртән, таң якты.сы җәелә башлагач, «таң ризыгы» — сәхәр ашала. Мөхәммәд пәйгамбәр берничә тәүлек дәвамында тоташ У. тоту гадәтен хупламый; соңрак хәнифә мәзһәбенә нигез салучы Әбү Хәнифә аны мөселманнар өчен ярамый торган гамәлләр исәбенә кертә. Мөселманнар У. аеның соңгы ун көнендә күп вакытларын мәчеттә тәравих намазлары укып, күбрәк дога кылып һәм Аллаһы Тәгаләгә ялварып (игътикаф), изге эшләр башкарып үткәрергә тиеш. Әлеге йоланы

нинди дә булса җитди сәбәп б-н саклый алмаганнар (сугышта катнашу, ерак сәфәрдә булу һ.б.ш.), ш.у. авыру һәм сәламәтлегенә зыян килердәй кешеләр, йөкле һәм бала имезүче хатын-кызлар азат ителә. У. тәмамлангач, өч көнлек бәйрәм — *Ураза бәйрәме* үткәрелә. Татарстанда соңгы елларда У. тотучылар даирәсе киңәя бара. Ифтар мәҗлесләре һәм Ураза бәйрәме респ-ка күләмендә уздырыла.

Әд.: Ценности месяца Рамазан. К., 2001; Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991; Али-заде А.А. Исламский энциклопедический словарь. М., 2007.

УРАЗА́ БӘЙРӘМЕ́ (Рамазан бәйрәме, Ураза гаете; гарәп илләрендә ид әл-Фитр), *Рамазан* ае тәмамлану уңаеннан, *ураза* тоту тәмамлану хөрмәтенә уздырыла. *Ислам* динендә ике олугъ бәйрәмнең (*Корбан бәйрәме* б-н бергә) берсе. Өч көн дәвам итә. Аның тәрти-бе барлык мөселман халыкларында да бердәй: мәчеттә (яки аның янында) җәмәгать б-н укыла торган иртәнге бәйрәм намазы; аннары мәчеттәге күпчелек мөселманнар бер-берсен бәйрәм б-н котлыйлар, фәкыйрьләргә хәер-сәдака өләшәләр (зәкәт әл-фитр); хатын-кызлар өйдә бәйрәм сые әзерли. У.б. көннәрендә туган-тумача б-н очрашулар, бәйрәм ашлары үткәрү, ата-бабаларның каберләрен зиярат кылу, мәрхүмнәрне искә алу гадәткә кергән.

Әд.: Татары. М., 2001; Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991. Али-заде А.А. Исламский энциклопедический словарь. М., 2007.

УРАЗА́ЕВ Азат Зәки улы (24.6.1921, Минзәлә кантоны Морбаш а. — 27.5.1979, Казан), акушер-гинеколог, мед. фән. д-ры (1976), проф.(1977), ТАССРның атказ. табибе (1968), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1961). Казан мед. ин-тын тәмамлый (1943). Бөек Ватан сугышында катнаша; 1944–45 елларда 1 нче Белоруссия фронты медсанбатының сан.-химик саклану отделениесе командиры. 1945–46 да Сызрань шәһәренең (Куйбышев өлкәсе) сан. хезмәте башлыгы. 1946–76 да Казан ГИДУВында, 1973 тән 1 нче акушерлык һәм гинекология каф. мөдире. Бер үк вакытта, 1958–62 дә, ТАССР Сәламәтлек саклау министрлыгының баш акушер-гинекологы. Хезмәтләре хатын-кызларның җенес әгъзаларындагы шешләрне, имгәнүләрне, тумыштан булган аналык үсеше патологиясен өйрәнүгә, оператив урогинекологиягә карый. Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хез м.: Беременность и роды у женщин, страдающих близорукостью // Казан. мед. журн. 1977. № 4 (автордаш); Профилактика недержания мочи и кала у женщин при акушерско-гинекологической патологии. Л., 1977; Течение беременности и родов при врожденных пороках развития матки // Казан. мед. журн. 1978. № 1.

УРАЗА́ЕВ Андрей Николаевич (30.8.1955, Казан — 5.11.2002, шунда ук), вет. токсикологы, биол. фән. д-ры (1995), проф. (1997). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1979), 1981–2002 елларда, бүленеп, шунда ук эшли, 1995 тән зоогигиена каф. мөдире, 1999дан каф. профессоры. 1984–88, 1992–95 тә Бөтенсоюз вет. фәнни-тикшеренү ин-тында (Казан). Фәнни тикшеренүләренең төп юнәлешләре а.х. терлекләрендә микотоксикозларга диагноз кую һәм авыруларны кисәтү ысулларын эшләүгә карый.

Хез м.: Биогеоценотические аспекты зоогигиенической оценки аграрного ландшафта. К., 1996; Ветеринарная экология: Учеб. пособие. М., 2002 (автордаш).

Әд.: Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.): Биогр. словарь учёных. К., 2006.

Р.Г.Госманов.

УРАЗА́ЕВ Габдулла Гыймат улы (1904, Самара губ., Мәләкәс өязе Урта Кандалый а. — 1984, Ташкент ш.), язучы, тәр җәмәче, җәмәгать эшлеклесе, Үзбәкстан ССРның атказ. мәдәният хезмәткәре. «Исламия» мәдрәсәсен (Мәләкәс ш., 1918), Казан ун-тының эшчеләр ф-тын (1927), Ташкент пед. ин-тын (якынча 1935) тәмамлый. 1919–20 елларда Көнчыгыш фронтның 5 нче армиясенең «Кызыл Яу» фронт г-тасында хәреф җыючы булып эшли. 1927–30 да Зарафшан өлкә ком-тының вакытлы матбугат бүлеге мөдире, 1930–45 тә Үзбәкстан ССР (Ташкент ш.) Коммунистлар партиясенең Үзәк ком-тында Испарт бүлеге хезмәткәре. Бер үк вакытта, 1939 дан, «Кызыл Үзбәкстан» (1946 дан «Совет Үзбәкстаны») г-тасында баш мөхәррир. 1945–50 дә Үзбәкстан ССР МС каршында Радиотапшырулар ком-ты рәисе, 1950–60 та «Укытучы», Г.Голәм исем. нәшриятларны җитәкли. 1960 тан Үзбәкстан Язучылар берлегенең җаваплы сәркәтибе. 1920 елларда Казан матбугатында тыныч тормышка һәм халыклар дуслыгына дан җырлаган хикәяләре, пьесалары басыла; «Серле шалаш» пьесасы Мәскәүнең Үзәк нәшриятында аерым брошюра булып чыга. Үзбәк теленә Г.Тукай, Г.Ибраһимов, Ш.Усманов, Ә.Фәйзи, К.Нәҗми, Ф.Хөсни, Г.Ахунов, Ә.Еники әсәрләрен тәрҗемә итә.

Әд.: Әйди Т. Тылсымлы көч. К., 1987; Ишморат Р. Дусларым, остазларым. К., 1988; Хәмидуллин Л. Кичке шәфәкъ. К., 2009; Писатели Советского Узбекистана. Ташкент, 1977.

Л.Х.Хәмидуллин, Ф.Г.Кәлимуллина.

УРАЗА́ЕВ Дамир Әдип улы (6.11.1954, Үзбәк ССР, Ташкент — 14.11.2014, шунда ук), график, нәкышьче. Ташкентта П.П.Беньков исем. респ-ка сәнгать уч-щесен (1976), Харьков сәнгать-сәнәгать ин-тын (1981) тәмамлый. Ташкенттагы «Радуга» (1983–86), «Адолат» (1996–98) нәшриятларында баш рәссам, Респ-ка мәктәп укытучылары сараеның сынлы сәнгать студиясендә укыта (1986–96). Рәссамнар берлеге (1984), Журналистлар берлеге (1988), ЮНЕСКО Халыкара рәссамнар федерациясе (1994), Үзбәкстан Сәнгать академиясе, Үзбәкстандагы «*Ил*» татар рәссамнары берләшмәсе әгъзасы (1997). Ксилография (агачка уелган гравюра), акварельләр, тушь һәм каләм б-н рәсемнәр ясау остасы. У.ның сәнгать теленә образлы мәһабәт-ләштерү, композицияләрнең фәзаи киң колачлылыгы, форманың гади, ачык кырыслыгы, төсләр палитрасының бертөслелеге хас. Н.Нарзуллаевның «Шәрекъ хәбәрчесе» (1984), шагыйрә Зөлфиянең «Тамчы» (1985), Г.Нәваиның «Хәмсә» (1987), «Нурати» (1990) һ.б. үзбәк һәм чит ил классикларының 200 дән артык басмаларына иллюстрацияләр ясый. Станлы графикада актив эшли, фәлсәфи һәм дини темаларга цикллар, пейзажлар, портретлар иҗат итә. «Үзбәкстанның архитектура һәйкәлләре» (100 табактан артык, 1983–99), «Кавказның Кара диңгез ярлары буйлап» (1984–94), «Россиянең алтын бөҗрәсы буенча» (1995), «Үзбәкстанның архитектура магиясе» (2000–11); «Үзбәкстан Президенты Ислам Кәримов портреты» (1996), «Тантризм — Һиндстанның яшерен дине» (1991–2001) картиналар циклы һ.б. әсәрләр авторы. 2000 еллардан рухи-символик эчтәлектәге, нәкышь картиналары — «Аллаһка табыну», «Мерв миражы», «Кичке Гилон» триптихы, «Бердәмлек букеты» диптихы (барысы да — 2011), портретлар иҗат итә. Халыкара басма графика биенналенда (1986, Торунь ш., Польша; 1987, Прага, Чехия; 1992, 1994, 1997, Калининград ш.), Мәскәүдә бөтенсоюз графика һәм китап илл. күргәзмәләрендә (1986, 1988 дән 1991 гә кадәр — ел саен), «Ил» рәссамнарының Карлсроэ шәһәрендә (Германия), Казанда (1999) төркем б-н оештырылган күргәзмәләрдә катнаша. Шәхси күргәзмәләре 1981 (Харьков ш.), 1993, 1994 (Сочи ш.), 1994 (Краснодар ш.), 1985, 1996, 2001 (Ташкент ш.) елларда уздырыла. Әсәрләре Третьяков галереясында (Мәскәү), Үзбәкстанның сынлы сәнгать галереясында, «Казан» милли мәдәният үзәгендә, Харьков сынлы сәнгать музеенда, Нөкес, Ангрен, Ургәнеч, Бохара шәһәрләре сәнгать галереяла-



Д.Ә.Уразаев. Н.Нарзуллаевның «Шәрекъ хәбәрчесе» шигырьләр җыентыгына иллюстрация. Ксилография. 1984.



Д.Ә.Уразаев. «Бохара». Кәгазь, акварель.

рында, Прага (Чехия), Торунь (Польша) шәһәрләрендәге заманча басма графика галереяларында саклана. Үзбәкстан Респ-касы ЮСның «Шөһрәт» медале (2007), Үзбәкстан САнең көмеш медале һәм «Иң яхшы рәссам-график» дипломы (2008) б-н бүләкләнә. Халыкара «Дөнья халыклары сәнгате» ассоциациясенең атказ. рәссамы (2009).

Әд.: М у р т ы ш л ы Я. Возвращение // Татарские края. 1999. № 44, нояб.; Н у р и Н. Во имя добра и любви // Татарские края. 2001. № 18, май; Ф е д о т о в а С. Судьбы, зарифмованные в строки // Новый век. 2008. 23–29 окт.

Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.

УРАЗА́ЕВ Игорь Кәбир улы (28.2.1960, Мурманск өлкәсенең Печенга штп), РФ Герое (29.5.1995), гв. полковнигы (2005). 1978 елда Совет Армиясенә алына, 103 нче гв. һава-десант дивизиясенең 80 нче гв. аерым разведка ротасында хезмәт итә (Витебск ш.). 1979 да Новосибирск югары хәрби-сәяси уч-щесенә укырга керә. 1981 дә, укуын туктатып, үз теләге б-н армиягә хезмәт итәргә китә, Әфганстанда хәрби хәрәкәтләрдә катнаша. Демобилизациядән соң уч-щене тәмамлый (1985). 76 нчы гв. һава-десант дивизиясенең 104 нче гв. парашют-десант полкында хезмәт итә (Псков ш.). Чечен кампаниясендә катнаша (1994–96): 76 нчы гв. Чернигов һава-десант дивизиясенең 104 нче гв. парашют-десант полкында рота командиры. Грозный шәһәренә керү юлларындагы сугышларда батырлык күрсәтә. 1994 нең декабрендә — 1995 нең гыйнварында, канкойгыч сугышлар барган вакытта, У. ротасы 131 нче мотоукчы бригадасына ярдәм күрсәтү өчен шәһәрнең үзәк өлешенә үтеп керә. Сугышта контузия ала, әмма рота б-н җитәкчелек итүне дәвам итә. У. подразделениесе элекке партия архивы бинасын басып ала, шунда үзенең терәк пунктын урнаштыра һәм 4 көн дәвамында дошман һөҗүмен кире кайтара. 1996 дан РФ һава-десант гаскәрләренең разведка бүлегендә, штаб башлыгы һәм парашют-десант батальоны командиры. Мәскәүдә яши. «Шәхси батырлык өчен» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

УРАЗА́ЕВ Николай Андреевич (3.12.1925, Чистай кантоны Арбузов-Баран а. — 22.3.2002, Ставрополь ш.), вет. клиницисты, вет. фән. д-ры (1966), проф. (1968), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1989). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1949), Казан вет. фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1954 елдан Семипалатинск зоовет., 1964 елдан Витебск вет. ин-тларында. 1967–85 тә Казан вет. ин-тында, диагностика каф. профессоры (1967 дән), терапия каф. мөдире (1969 дан), бер үк вакытта вет. ф-ты деканы (1979–83). 1985–2002 дә Ставрополь а.х. академиясендә, 1992 гә кадәр — терапия һәм клиник диагностика кафедралары, 1992 дән экология каф. мөдире. Фәнни тикшеренүләренең төп юнәлешләре — а.х. терлекләрендә үпкә, йөрәк патологиясен, матдәләр алмашын өйрәнүгә, биогеоценология һәм патология мәсьәләләренә карый. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Биогеоценоз и болезни животных. М., 1978; Эндемические болезни сельскохозяйственных животных. М., 1990 (автордаш); Сельскохозяйственная экология: Учеб. пособие. М., 2000 (автордаш).

Әд.: Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2000 гг.): Биогр. словарь учёных. К., 2006.

Р.Г.Госманов.

УРАЗА́ЕВ Фәрит Язкар улы (4.11.1960, Сарман р-ны Мортышбаш а.), педагог, җәмәгать эшлеклесе, тарих фән. канд. (2012). Волгоград физик культура ин-тының Казан ф-лын тәмамлый (1982). 1982–87 елларда 130 нчы мәктәптә физкультура укытучысы, 1988–98 дә 15 нче Балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе директоры (Казан). 1998 дән Бөтендөнья татар конгрессы башкарма ком-тында, эшмәкәрлек вәкилләре б-н эшләү буенча бүлек башлыгы, бюро әгъзасы, бер үк вакытта Бөтендөнья татар эшмәкәрләренә ярдәм ассоциациясе директоры. Бөтентатар иҗтимагый үзәгендә актив катнашучы (1994–98), Россия татарларының федераль милли-мәдәни автономиясен оештыручы һәм җитәкчесе (1998–2002). Россия төбәкләрендәге милли-мәдәни автономияләрен булдыруга һәм аларның үсешенә, федераль милли бәйрәмнәрне (Сабан туе һ.б.) һәм татар халкының тупланып яшәгән урыннарында мәдәни-күңел ачу чараларын оештыруга зур өлеш кертә. Хезмәтләре татар халкының тарихы, мәдәнияте, этник үзтиңләштерү механизмнары мәсьәләләренә карый. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Родословная тюрко-татар: мировоззренческий аспект // Татарские мурзы и дворяне: история и современность: Сб. статей. К., 2010. Вып. 1; Общефедеральный Сабантуй: вчера, сегодня и завтра // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2011. № 1/2; Механизмы сохранения этнокультурной идентичности татарского народа (конец XX — начало XXI вв.). К., 2012.

УРАЗА́ЕВ Шәүкәт Зәкәрия улы (1.8.1927, БАССРның Бәләбәй кантоны — 11.5.2006, Ташкент), хокук белгече, юридик фән. д-ры (1964), Үзбәкстан Респ-касы ФА академигы (1989; 1966 елдан мөхбир әгъза), Үзбәкстан ССР һәм Каракалпак АССРның атказ. фән эшлеклесе (1977,1980). Ташкент юридик ин-тын тәмамлый (1947), 1949–55 елларда шунда ук дәүләт һәм хокук теориясе һәм тарихы кафедрасында эшли, 1955 тән Ташкент ун-тында, 1965 тән проф., 1970–90 да дәүләт һәм хокук теориясе каф. мөдире. Бер үк вакытта, 1966–70 тә, Үзбәкстан ССР ФАнең фәлсәфә, икътисад, хокук фәннәре бүлекчәләре рәисе. 1990–93 елларда Үзбәкстан Респ-касының Конституцион күзәтчелек ком-ты рәисе. 1993–94 тә Үзбәкстан Респ-касы Конституцион мәхкәмәсе рәисе вазифаларын башкаручы. 1994–95 тә Ташкент юридик ин-ты ректоры. 1994–2004 тә Үзбәкстан Респ-касы Эчке эшләр министрлыгы Академиясе профессоры. Хезмәтләре дәүләт һәм хокук теориясе һәм тарихына, СССР халыкларының милли дәүләтчелеге барлыкка килү һәм үсеш мәсьәләләре, Үзбәкстанда конституцион төзелеш һәм хокук системасы формалашу мәсь әләләренә карый. Үзбәкстан ССРның Бируни исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1973). Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.



И.К. Уразаев.

Х е з м.: Туркестанская АССР и её государственно-правовые особенности. Таш., 1958; Роль РСФСР и СССР в создании советской государственности в Узбекистане. Таш., 1965; В.И.Ленин и строительство советской государственности в Туркестане. Таш., 1967; Советская политическая система. Таш., 1980.

Әд.: Шавкат Закариевич Уразаев: Материалы к биобиблиографии учёных Узбекистана. Таш., 1987; Памяти патриарха юридической науки Узбекистана Ш.З.Уразаева (1927–2006) // Право и политика. 2006. № 10.

Е.Б.Долгов.

УРАЗА́ЕВ-КОРМАШИ́ Әхмәд Мөхәммәдзариф улы, к. *Кормаши.*

УРАЗА́Й авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 6 *км* көнчыгыштарак, Эстәрле елгасы буенда. 2010 елда 753 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау; нефть-газ чыгару. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөз ахырында — 18 йөз башында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Медведка, Аю исемнәре б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы асабалар, типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә; игенчелек, терлекчелек, таш, алебастр вату һәм эшкәртү, Богырыслан өязендә, Уфа шәһәрендә такта яру һ.б. б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 мәчет, мәктәп, 4 су тегермәне, күн з-ды эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3083 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Азнакай волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 20 октябреннән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1859 да — 773, 1889 да — 1135, 1897 дә — 1215, 1910 да — 1399, 1920 дә — 1465, 1926 да — 1504, 1938 дә — 1445, 1949 да — 1018, 1958 дә — 942, 1970 тә — 817, 1979 да — 667, 1989 да — 591, 2002 дә — 726 кеше.

УРАЗА́Й авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 10 *км* төньяк-көнбатыштарак, Агыйдел елгасыннан 3 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 406 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1674 тән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Иске Уразай, Моховой исемнәре б-н дә билгеле. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә, көнлекле эшкә һәм Агыйдел елгасында баржалар бушатуга яллана. 20 йөз башында 2 мәчет, мәктәп, 2 җил тегермәне, бакалея

кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2389 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Шәрип волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 179, 1834 тә — 412, 1859 да — 628, 1870 тә — 657, 1884 тә — 777, 1897 дә — 509, 1906 да — 549, 1913 тә — 548, 1920 дә — 586 (Яңа Уразай авылы халкын да кертеп), 1926 да — 570, 1938 дә — 650, 1949 да — 659, 1958 дә — 583, 1970 тә — 645, 1979 да — 586, 1989 да — 511, 2002 дә — 454 кеше.

УРАЗА́Й авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 68 *км* көньяктарак, Әзи елгасы буенда. 2010 елда 201 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кече Салагыш исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, сумала кайнату, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1561,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Салагыш волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Красный Бор, 1960 ның 28 октябреннән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1859 да — 228, 1887 дә — 370, 1905 тә — 488, 1920 дә — 776, 1926 да — 662, 1938 дә — 698, 1949 да — 527, 1958 дә — 460, 1970 тә — 431, 1989 да — 299, 2002 дә — 250 кеше.

Әд.: Мәрданов Р.Ф., Һадиев И.Г. Әгерҗе төбәге тарихы. К., 2003.

УРАЗА́Й авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 26 *км* төньяк-көнбатыштарак, Борбаш елгасы буенда. 2010 елда 258 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, яшелчәчелек. 18 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Иманшику исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет (1883 тә төзелә; архит-ра истәлеге) эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 734 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Сәрдекбаш волостенда, 1920 дән ТАССРның — Арча, 1928 дән Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1859 да — 177, 1920 дә — 443, 1926 да — 425, 1938 дә — 420, 1949 да — 316, 1958 дә — 265, 1970 тә — 281, 1979 да — 276, 1989 да — 266, 2002 дә — 291 кеше.



Кукмара районының Уразай авылы. Мәчет. 1883. Хәзерге фоторәсеме.

УРАЗБАХТЫ́ авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 25 *км* көньяк-көнбатыштарак, Омар елгасы буенда. 2010 елда 307 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 14 йөзгә кадәр нигез салына, 17 йөзнең 2 нче яртысында таркалганнан соң, кабат торгызыла. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Иске Омар исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тире эшкәртү, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 мәчет, тегермән, тире эшкәртү йорты, 10 вак-төяклэр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1022,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Омар волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 48 ир-ат; 1859 да — 726, 1897 дә — 1349, 1908 дә — 1496, 1920 дә — 1489, 1926 да — 1164, 1938 дә — 1311, 1949 да — 808, 1958 дә — 715, 1970 тә — 837, 1979 да — 670, 1989 да — 568, 2002 дә — 413 кеше. Авыл зиратында эпиграфик истәлекләр — кабер ташлары (14 йөз тирәсе) сакланган.

УРАЗГИЛДИ́ЕВ Заһидулла Исмәгыйль улы (1.1.1941, Пенза өлкәсенең Каменка р-ны Мачали а.), травматолог-ортопед, мед. фән. д-ры (1990), проф. (2000). Л.И.Шулутко һәм Ү.Я.Богданович шәкерте. Казан мед. ин-ты-ның педиатрия ф-тын тәмамлаганнан соң (1964), Мачали участок хастаханәсендә хирург һәм баш табиб булып эшли, 1969–71 елларда Казандагы Травматология һәм ортопедия фәнни-тикшеренү ин-тында. 1971 дән Мәскәүдә: Мәскәү шәһәр Бөек Ватан сугышы инвалидлары ортопедия госпитале каршындагы травмпунктта; 1972 дән РСФСР Сәламатлек саклау министрлыгының Н.Н.Пирогов исем. Үзәк травматология һәм ортопедия ин-тында, үлекләп катлауланган терәк-хәрәкәт аппараты травмалары бүлеге җитәкчесе (1987–2004). У. травматологик һәм ортопедик авырулардагы үлекле-ялкынсынулы процессларга диагноз кую һәм авыруларны дәвалау ысулларын эшли һәм камилләштерә, оча сөяге, аяк, түбәнге очлыклар сөяк-буыннарындагы үлекле процессларны өйрәнә. Уйлап табуга 5 авторлык таныклыгы, 1 патенты бар.


Хезм.: Применение коллапана для пластики остеомиелитических дефектов костей // Вестн. травматологии и ортопедии. 1998. № 2 (автордаш); Опорный неоартроз как альтернатива реэндопротезированию и артродезу при гнойных процессах в области тазобедренного сустава // Вестн. травматологии и ортопедии. 2003. № 2 (автордаш).

Әд.: Загидулла Исмагилович Уразгильдеев // Вестн. травматологии и ортопедии. 2011. № 1.

УРАЗГИ́ЛДИН Ильяс Әнис улы (28.11.1953, Үзбәкстан ССРның Әнди җан өлкәсе Сталин а. — 20.6.2010, Бөгелмә ш.), нефтьче, ТРның Дәүләт бүләге лауреаты (2006). Уфа нефть ин-тын тәмамлый (1984). 1973–2010 елларда Татарстан нефть фәни-тикшеренү һәм проект ин-тында (Бөгелмә) эшли. Хезмәтләре нефть скважиналарын беркетү өчен җи һазлар җитештерү процессларын эшләүгә карый. У. тәкъдим иткән техник җайланмалар скважиналар төзелгән вакытта проблемалы зоналарны изоляцияләү өчен БДБ илләрендә, Вьетнам, Иран, Кытайда кулланыла. Дәүләт бүләге нефть чыгару тармакларында яңа технологияләр һәм техник чаралар эшләгәне һәм гамәлгә керткәне өчен бирелә. Уйлап табуга 16 патенты бар.

Хезм.: Математическое моделирование процессов профилирования и редуцирования экспандируемых обсадных труб // Интервал. 2004. № 7–8 (автордаш); Теоретические исследования процесса выправления профильных труб в скважине под действием внутреннего давления // Интервал. 2006. № 1 (автордаш).

УРА́ЗИКОВ Хөсәен Ибраһим улы (7.1.1894, Саратов губ., Дергачёв өязе Сәфәр а. — 24.8.1977, Казан), драма актёры, режиссёр, ТАССРның халык артисты (1945), РСФСРның атказ. артисты (1950). Беренче бөтендөнья сугышында катнаша. Немец әсирлегеннән кайтканнан соң (1918), Самара татар драма һәм музыка студиясендә укый, 1930 елга кадәр Хива, Бохара, Ташкент, Верный (хәзер Алма-Ата), Пишкәк (Бишкәк), Оренбург, Әстерхан, Мәскәү шәһәрләрендәге татар театрларында эшли. 1930 дан Татар акад. театрында актёр һәм режиссёр, 1944–48 дә сән-



Х.И.Уразиков Кыям ролендә («Беренче чәчәкләр», К.Тинчурин).

гать җитәкчесе. Аның сәхнәсендә төрле пландагы 160 ка якын роль башкара. Актёр Бикәмәт («Зифа», Н.Исәнбәт), Әптерәш, Иманкол («Мактаулы заман», «Наёмщик», Т.Гыйззәт), Ишан, Мисбах хаҗи («Зәңгәр шәл», «Җилкәнсезләр», К.Тинчурин), Ха җи («Ха җи әфәнде өйләнә», Ш.Камал), Тихон, Лыняев, Коршунов («Яшенле яңгыр», «Бүреләр һәм сарыклар», «Ярлылык гаеп түгел», А.Н.Островский), Цыганов, Коломийцев («Варварлар», «Соңгылар», М.Горький), Президент, Вурм («Мәкер вә мәхәббәт», Ф.Шиллер) рольләрен аеруча сәнгатьле һәм тормышчан итеп башкара. У.ның беренче режиссёрлык тәҗрибәсе 1922 елга карый: Верный шәһәре театрында К.Тинчуриннң «Сакла, шартламасын!» комедиясен сәхнәләштерә. Татар акад. театрында 20 дән артык спектакль куя: «Мактаулы заман» (Т.Гыйззәт, 1936), «Миңлекамал» (М.Әмир, 1944), «Банкрот» (Г.Камал, 1944, 1962), «Ялгыз каен» (М.Кәрим, 1951), «Зифа» (Н.Исәнбәт, 1954, 1963), «Зөбәйдә — адәм баласы» (Ш.Хөсәенов, 1965). Алар тамашачыны сәхнәдәге күренешләрнең эчкерсезлеге һәм тормышчанлыгы б-н җәлеп итә, ситуациянең драматизмына карамастан, аларда күңел күтәренкелеге, өмет уята. Н.Исәнбәтнең «Ху җа Насретдин» пьесасына күп тапкырлар мөрәҗәгать итә (1940, 1952, 1957, 1966), аны чын халыкчан комедия буларак сәхнәләштерә. Традицион пландагы режиссёр. Төп игътибарын актёрлар б-н эшләүгә юнәлтә, аларның теге яки бу рольне башкарганда образлылыкка, хәрәкәтләрендә төгәл эзлеклелеккә ирешүләренә омтыла. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.



Х.И. Уразиков.

Әд.: Илялова И. Г.Камал театры артистлары = Артисты театра им. Г.Камала. К., 2005; шулук. Театр имени Камала. К., 1986; Арсланов М.Г. Хусаин Уразиков. К., 1986.

И.И.Илялова.

УРАЗЛА́ КҮЛЕ́, к. Ильинка күле.

УРАЗЛЫ́ авылы, Кама Тамагы р-нында, шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 7 *км* көнбатыштарак, Карамалы елгасы буенда. 2010 елда 81 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — сарык асрау. Китапханә. 16 йөз ахырында — 17 йөз башында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, йон тетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында У.да мәчет (1883 тә төзелә), мәдрәсә, май язу һәм 2 йон тетү йорты, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 567,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Богородский волостенда, 1920 дән ТАССР-ның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кама Тамагы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нында. Халык саны: 1782 дә — 56 ир-ат; 1859 да — 246, 1884 тә — 374, 1897 дә — 449, 1908 дә — 548, 1920 дә — 615, 1926 да — 476, 1938 дә — 430, 1949 да — 348, 1958 дә — 263, 1970 тә — 196, 1979 да — 171, 1989 да — 88, 2002 дә — 94 кеше.

УРАЗЛЫ́ авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 34 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Мари Респ-касы б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 163 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау, яшелчәчелек. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Уразлина исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, умартачылык, он тарту, балта эше б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, 3 җил тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 722 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кукмара волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1958 нең 16 июленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 35 ир-ат; 1859 да — 376, 1897 дә — 736, 1908 дә — 817, 1920 дә — 864, 1926 да — 927, 1938 дә — 726, 1949 да — 700, 1958 дә — 403, 1970 тә — 377, 1979 да — 317, 1989 да — 200, 2002 дә — 182 кеше.

УРАЗМА́НОВА Рәүфә Кәрим кызы (22.2.1936, Удмурт АССРның Можга ш.), этнограф, тарих фән. канд. (1968), ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1984), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2003). Казан ун-тын тәмамлый (1959). 1964 елдан ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында, 1997 дән Тарих ин-тында (1993–2000 елларда этнология бүлеге мөдире). Татар халык бәйрәмнәрен, гаилә гореф-гадәтләрен, йолаларын өйрәнүгә багышланган хезмәтләр авторы. Дәүләт бүләге «Татарлар» («Татары», М., 2001) коллектив монографиясен эшләүдә катнашканы өчен бирелә. Медаль б-н бүләкләнә.

Хезм.: Котлы булсын туегыз! К., 1977; Современные обряды татарского народа. К., 1984; Быт нефтяников-татар юго-востока Татарстана (1950–1960-е гг). К., 2000; Обряды и праздники татар Поволжья и Урала (Годовой цикл. XIX — нач. XX вв.). К., 2001.

УРАЗМӘ́Т авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 35 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Сикия елгасының югары агымы буенда. 2010 елда — 278 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1735 кә кадәр нигез салына. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп, су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 372,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әмәкәй волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1795 тә — 376 кеше; 1816 да — 189 ир-ат; 1859 да — 578, 1870 тә — 668, 1897 дә — 758, 1906 да — 892, 1920 дә — 1117, 1926 да — 994, 1938 дә — 938, 1949 да — 694, 1958 дә — 678, 1970 тә — 711, 1979 да — 524, 1989 да — 358, 2002 дә — 318 кеше.

УРАЗМӘ́Т ЧИШМӘСЕ́ авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 30 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Сикия елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 29 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1930 елларда нигез салына. Оешкан көненнән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1949 да — 125, 1958 дә — 353, 1970 тә — 282, 1979 да — 145, 1989 да — 91, 2002 дә — 50 кеше.

УРАЗМӘ́ТОВ Аит (? — 7.2.1774), 1773–75 еллардагы *Крәстияннәр кузгалышында* катнашучы. Бөгелмә идарәчелеге Абдул авылы ясаклы крәстияне. 1773 елның көзендә Е.И.*Пугачёв* ягына күчә, баш күтәрүчеләр отрядын туплый (иң элек 200 кешедән тора). Бөгелмә р-нында хәрәкәт итә. 1774 нең гыйнвары ахырында Чирмешән ныгытмасына бәрелештә катнаша. Әсир ителә һәм 2 февральдә Казан яшерен комиссиясенә җибәрелә; җәзалап үтерелә.

Әд.: Алишев С.Х. Татары Среднего Поволжья в пугачёвском восстании. К.,1973.

И.Р.Вәлиуллин.

УРАЗМӘ́ТОВ Надир (1687 — 1758), Нәдер волостена нигез салучы, Идел-Урал төбәгендә нефть чыгару эшен башлап җибәрүчеләрдән. Арча даругасы (хәзер Кукмара р-ны) Адай авылыннан. 1719 елга кадәр Казан һәм Уфа өязләре арасындагы Зәй, Шуша һәм Чирмешән елгалары буеннан «буш җирләр» эзләп таба. Соңыннан чыганакларда әлеге терр-я Нәдер волосте буларак искә алына. Шул җирләрдә берничә татар авылын (Яңа Нәдер һ.б.) нигезләве мәгълүм. 1735–40 еллардагы башкорт-татар кузгалышын бастыруда катнаша. 1736–46 да Нәдер волосте старшинасы. Идел-Урал төбәгендә нефтьне сәнәгый эшкәртүнең беренче омтылышлары У. исеме б-н бәйле. Уфа өязендә нефть таба, 1754 елда хөкүмәттән «нефть заводы» төзүгә рөхсәт ала; әмма авыру сәбәпле аны төзеп бетерә һәм файдалануга кертә алмый; 1757дә нефть эшкәртү хокукыннан мәхрүм ителә. 18 йөз ахырында У. нәселе Россия дворяннары составына керә (к. *Надыйровлар).*

Әд.: Амирханов Р., Габдуллин И. Надыр Уразметов // Әлмәт — Альметьевск.К.,2003.

И.Р.Вәлиуллин.

УРАЗМӨХӘММӘ́Д ХАН (? — 22.11.1610), Касыйм ханы (1600 елдан). Казакъ солтаны Онданның улы. 1580 еллар ахырыннан Россиядә (кайбер мәгълүматлар буенча, Себердә кулга алына һәм Мәскәүгә җибәрелә, башка мәгълүматлардан аңлашылганча, үз теләге б-н патша Фёдор Ивановичка хезмәткә яллана). Рус гаскәрләренең шведларга (1590) һәм Кырым татарларына (1598) каршы яула-

рында катнаша. Патша Борис Годунов тарафыннан 1600 елда Касыйм ханлыгы тәхетенә утыртыла. «*Болгавыр заман*»да Ялган Дмитрий II гә теләктәшлек белдерә (1606–10), аннары Польша короле Сигизмунд ягына, шуннан соң яңадан Ялган Дмитрий II ягына чыга. 1610 да Калуга шәһәрендә була. Хыянәт итүдә шикләнеп, Ялган Дмитрий II әмере б-н үтертелә. Касыйм шәһәрендә җирләнгән дип фаразлана.

Әд.: Вельяминов-Зернов В.В. Исследование о касимовских царях и царевичах. СПб., 1864. Ч. 2; Султанов Т.И. Чингиз-хан и Чингизиды: Судьба и власть. М., 2006.

УРА́ЗОВ Габделмәҗит Әбүбәкер улы (? — 1818 дән соң), Казан сәүдәгәре һәм эшмәкәре. Пләтән авылында (Казан чигендә) сабын кайнату з-ды хуҗасы. Пр-тие һәр ел саен 3 мең потка кадәр сабын җитештерә. 1810 елда У. Пләтән авылында «9 нчы завод мәхәлләсе»ндә мәчет төзүгә акчалата ярдәм итә. Ул авылда халыкның күпчелеген мөселман-нар тәшкил итә, алар сәүдәгәр Апанаевлар, Китаевлар, Юнысовларның сабын кайнату з-дларында эшлиләр. Мәчет 1851 гә кадәр эшли; 1887дә аның урынына *Әҗем мәчете* төзелә. Мәгълүм булганча, У.ның улы — Рәфыйкъ, Зөя сәүдәгәре, Казанда Зәңгәр мәчет каршындагы мөселман мәхәллә мәдрәсәсе өчен флигель төзүгә акчалата ярдәм күрсәтә (М.М.Әҗимов б-н бергә).

Л.М.Свердлова.

УРА́ЗОВ Усман Юныс улы (18.10.1952 — Дарган-Ата штп, хәзер Төрекмәнстан Респ-касының Чарҗоу өлкәсе), генерал-майор (2000). Маршал П.С.Рыбалко исем. Ташкент югары танк командирлары уч-щесен (1974), Сов. Союзы Маршалы Р.Я.Малиновский исем. Бронетанк гаскәрләре хәрби академиясен (Мәскәү, 1985), Украина оборона милли академиясен (Киев, 1997) тәмамлый. 1974–77 елларда Германиядәге совет гаскәрләре төркемендә танк взводы командиры. 1977–82 дә Төркестан хәрби округында: 1977 дән өйрәнү танклар взводы командиры, 1979 дан өйрәнү танклар ротасы командиры, 1980 нән өйрәнү танклар батальоны штабы башлыгы. 1985–93 тә Одесса хәрби округында: 1985 тән өйрәнү танклар полкының штаб башлыгы, 1989 дан өйрәнү мотоукчылар полкы командиры, 1991 дән 28 нче мотоукчылар дивизиясе командиры урынбасары. 1993–95 тә Карпат буе хәрби округында армия корпусының хәрби әзерлек бүлеге башлыгы. 1997–99 да Төньяк оператив командование штабы башлыгының 1 нче урынбасары. 1999 дан Украина Кораллы Көчләре Ген. штабының Гаскәр хезмәте һәм режим идарәсе башлыгы. 3 нче дәрәҗә Богдан Хмельницкий, 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» орденнары, медаль б-н бүләкләнә.

УРА́ЗОВА Рәсимә Зәки кызы (19.3.1954, Чиләбе ш.), стоматолог, мед. фән. д-ры (2002), проф.(2005). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1977), Казан шәһәрендәге стомат. поликлиникаларында эшли, 1983 елдан Казан мед. ин-тында, 1994 тән балалар стоматология-сы каф. мөдире. Балалар стомат. авыруларына диагноз кую һәм авыруларны дәвалауның, сөт тешләре кариесын кисәтүнең яңа ысулларын эшли. ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының мед. советы каршындагы балалар стоматологиясе буенча экспертиза төркеме җитәкчесе (1997–2001). Медаль б-н бүләкләнә.

Хезм.: Эффективность реминерализирующей терапии кариеса временных зубов // Стоматология. 1986. Т. 65. № 6; Лечение воспалительных заболеваний пародонта у детей, инфицированных Helicobacter pylori // Казан. мед. журн. 2001. № 3.

Әд.: Казанский государственный медицинский университет (1804–2004 гг.): Заведующие кафедрами и профессора: Биогр. словарь. К., 2004.

УРА́Й елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Кама елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 16,8 *км*. Бассейнының мәйданы 72,8 *км*^{2}. Балык Бистәсе р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Олы Осиновка авылыннан 4 *км* төньяк-көнчыгыштарак, тамагы Троицкий-Урай авылының көнбатыш чигендә. Елганың түбән агымы Куйбышев сусаклагычының терәк сулары астында калган. Елга башының абс. биеклеге 125 *м*, тамагыныкы — 53 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 10%. У. елгасының 0,2 дән 3,6 *км* га кадәр озынлыктагы 8 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,4 *км/км*^{2}. Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5 *л/с·км*^{2}. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,05 *м*^{3}*/с*. Язын суы уртача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минераль әшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. У. бассейнында суының күләме 0,5 млн. *м*^{3} булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

УРА́ЙСКИЙ (тәхәллүсе, чын фамилиясе Мәүлүтев) Сәхаб (Сәхабетдин) Камалетдин улы (21.12.1907, Самара губ., Мәләкәс өязе Иске Кызылсу а. — 15.2.1957, Казан), шагыйрь. Самара татар-башкорт пед. технику-мын тәмамлаганнан соң (1930), «Колхозчы» (Куйбышев ш.) г-тасы редакциясендә эшли (1938 гә кадәр), бер үк вакытта (1934–36) СССР Язучылар берлеге каршындагы Юга-ры әдәби курсларда укый. 1938 елда Казанга килә, «Яшь сталинчы» г-тасы редакциясендә эшли. Бөек Ватан сугышында катнаша. Демобилизациядән соң «Яшь сталинчы» г-тасында, аннан соң Татарстан китап нәшрияты-ның балалар һәм яшүсмерләр әдәбияты редакциясендә эшли. Лирик-публицистик шигырьләрендә, «Давыллар аша» (1939), «Порт-шәһәр» (1939) кебек поэмаларында совет яшьләренең хезмәттәге батырлыкларын, киләчәккә булган якты идеалларын, өметләрен чагылдырырга омтыла. Соңгы дәвердә шагыйрь җыр текстлары иҗат итә башлый. Аның шигырьләренә танылган композиторлар көйләр яза. М.Ю.Лермонтов, Т.Г.Шевченко, А.Т.Твардовский, М.В.Исаковский, А.Л.Барто һ.б.ның шигырьләрен татар телена тәрҗемә итә. Медальләр б-н бүләкләнә.

Әс әр.: Давыллар аша. К., 1939; Сайланма шигырьләр. К., 1956; Син кайтмадың. К., 2008.

Әд.: Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

Р.Р.Мусабәкова.

«УРА́К ҺӘМ ЧҮКЕ́Ч», Казандагы авыр машиналар төзү пр-тиесе. Эшләүчеләр саны: 1997 елда — 312, 2009 да — 30 кеше. 1851 дә А.Н.*Свешников* тарафыннан чуен кою, машина төзү, тимерчелек-казаннар җитештерү һәм механика з-ды буларак нигезләнә, 1910 да Н.П.Ярцев милкенә күчә. 1918 дә национализацияләнгәннән соң, 2 нче дәүләт механика з-ды итеп үзгәртелә, 1922 дән «У.һ.ч.» з-ды, 1937 дән «У.һ.ч.» канат юллар з-ды, 2003 тән «У.һ.ч.» заводы АҖ. Башта пр-тие берничә тимерчелек миче һәм сандалы булган агач бинада урнаша. 20 йөз башына кирпеч корпуслар төзелә, алар металл эретү мичләре, металл эшкәртү станоклары, күтәрү кранлары, пар машинасы һәм динамо-машиналар б-н җиһазландырыла. 1851–97 дә эшләүчеләр саны 20 дән 100 кешегә кадәр арта. 1900 дә квалификацияле эшчеләр әзерләү өчен һөнәр уч-щесе ачыла. Завод заказлар буенча пар суднолар, җирле сәнәгать пр-тиеләре өчен җиһазлар төзекләндерә һәм җитештерә, 1914–17 дә хәрби продукция эшләп чыгара. 1921 дә М.Я.Рамның элеккеге механика з-ды (1877 дә нигезләнә) б-н берләштерелгәннән соң, сабаннар һәм атка тагылмалы ашлык сугу машиналары (1927 дә тиңдәшле рәвештә 7436 һәм 119 данә) җитештерә башлый. 1930 елларда югары җитештерүчәнлекле электр б-н эретеп ябыштыру, кою, тимерчелек-пресслау һәм станок җиһазлары б-н коралландырылган һәм киңәйтелгән пр-тиедә тасмалы транспортерлар, шнеклар, йөк ташучы канат юллары (илдә бердәнбер) һәм йөк ташу өчен кул арбалары эшләү оештырыла. Бөек Ватан сугышы чорында 37 миллиметрлы миналар һәм трактор детальләре җитештерелә. 1950–80 елларда төрле — пластинкалы (ш.и. илдә беренче тапкыр химия сәнәгате өчен герметик), чүмечле, кою, йомычка җыю (заводта проектлаштырыла, 1978 дә СССР ВДНХсының алтын медаленә лаек була) конвейерларын, ш.у. пластинкалы энергия чыганаклары, көнкүреш җылыту казаннарын, авыр йөкләр (600 *т/сәг.* егәрлекле) һәм пассажирлар ташу өчен канат юллары эшләп чыгару үзләштерелә. Прогрессив технологияләр (күләмле штамповка, пневматик инструментлар б-н җыю, ярымавтомат рәвештә һәм углекислый газ шартларында эретеп ябыштыру) кулланууны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә пр-тиенең ку аткыч әләре 7 тапкыр арта. Аның продукциясе металлургия, автомобиль, химия комб-тларын, гидроэлектростанцияләрне һ.б. авыр индустрия пр-тиеләрен төзегәндә һәм җиһазландыруда файдаланыла, 1950 еллардан Көнчыгыш Европаның һәм Азиянең 10 нан артык иленә озатыла. 1990 елларда, төп продукциягә заказлар булмау сәбәпле, завод тукталып тора, 2001 дә банкрот дип таныла. 2007 дә төп корпуслар сүтелгәннән соң, калган мәйданнарында металл конструкцияләр, конвейер җиһазлары җыю башкарыла. Хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә лаек була, ш.и. 2 кешегә

Хезмәт Кызыл Байрагы, 2 кешегә «Почёт билгесе» орденнары бирелә.

Җитәкчеләре арасында: А.Н.Свешников (1851–77), Александр А.Свешников (1877–90), Алексей А.Свешников (1890–1910), Н.П.Ярцев (1910–18), Ю.И.Неометов (1940–42), Г.Лакомкин, В.Х.Леонтьев, Герасимов, М.М.Рәхимкулов, Ю.В.Дьяков, И.Н.Шишкин, И.В.Егоров, Ф.Г.Нәфыйков (2003 тән).

Әд.: Негуляев А.П. Завод-ветеран: Из истории Казанского завода «Серп и молот». 1851–1967. К., 1968.

С.Г.Белов.

«УРА́К ҺӘМ ЧҮКЕ́Ч», Биектау р-нындагы а.х. пр-тиесе. 1951 елда Жданов исем. (Шәпше а.), «Дружба» (Тимошкино а.), «Яңа тормыш» (Сидорова Пустошь а.), «Беренче май» (Петрова Белка а.), «Яңа Чишмә» (Н.Ключ а.), «Кызыл Шәрекъ» (Кызыл Шәрекъ а., 1958), «Таң» (Николаевка а.), «Шверник» (Дубровка а., 1961) к-злары берләшү нәтиҗәсендә барлыкка килә. 1994 тә колхоз а.х. җитештерү кооперативы итеп үзгәртелә, 2004 тә — ҖЧҖ. Аңа Тимошкино, Кызыл Шәрекъ, Шәпше (үзәк утары) авыллары



«Урак һәм чүкеч» ҖЧҖ. Биектау районы.

керә (2008). А.х. җитештерүендә эшләүчеләр саны 443 кеше (1993), 278 кеше (2008). А.х. файдалану җирләренең мәйданы 6,1 *га*, ш.и. сөрүле җирләр 5 мең *га*; якынча 2,5 мең баш мөгезле эре терлек, ш.и. 700 баш сыер бар. Төп юнәлешләре — сөт, ит, бөртеклеләр һәм бөртекле-кузаклы культуралар орлыгы җитештерү. 2007 дә 4527 *т* сөт, 344 *т* ит, 5358 *т* бөртекле ашлык, 303 *т* бәрәңге җитештерелә; бөртекле культураларның уңышы 24,9 *ц* тәшкил итә, уртача еллык савым һәр сыердан — 6468 *кг*; 100 *га* а.х. файдалану җирләренә 742 *ц* сөт, 49,7 *ц* ит җитештерелә; табыш 20 млн. сум тәшкил итә. Югары җитештерү күрсәткечләре өчен ху җалык берничә тапкыр КПСС ҮК, СССР МС, РСФСР, ВЦСПС һәм ВЛКСМ ҮК Мактау грамоталары, дипломнары б-н бүләкләнә. Хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә һәм мактаулы исемнәргә лаек булә, ш.и. РФ, ТАССР, ТРның атказ. хезмәткәрләре исеме — 16 кешегә; Ленин ордены — 1, Октябрь Революциясе ордены — 2, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены — 4, 3 нче дәрәҗә Хезмәт Даны ордены 3 кешегә бирелә. Ху җалык үсешенә А.П.Орлов (1962–82), А.А.Захарова (1988 дән) зур өлеш кертәләр.

И.Н.Афанасьев.

«УРА́К ҺӘМ ЧҮКЕ́Ч», атналык иҗтимагый-сәяси газета. РКП(б)ның Мәләкәс өяз ком-тының мөселман секциясе органы. 1919 елның ноябреннән 1921 гә кадәр Самара губернасының Мәләкәс шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, 1919 ның 13 гыйнварын нан мартына кадәр «Мәләкәс тавышы» исеме б-н басыла. Фәкыйрьләрнең мәнфәгатен яклаучы шәһәрдәге беренче татар газетасы. Авторлары арасында — Н.Бикчәнтәев, М.Борһан, З.Җаббаров, Г.Халитов. Мәкаләләрнең күбесе псевд. б-н дөнья күрә. Газета рәсми бүлекләрдән тора, анда хөкүмәтнең төбәк органнары карарлары, гомуми бүлекләрдә җирле хакимият органнарына сайлаулар, советлар эшчәнлеге, коммунистик идеяләрне пропагандалау турындагы материаллар чыга. Җирле партиясез татар һәм башкорт ларның конференцияләре эшчәнлеген яктырта, Гражданнар сугышы фронтларындагы вазгыять турында хәбәр итә. Газета битләрендә шәһәрнең мәдәни тормышы турында материаллар, сәяси шигырьләр, а.х.н алып бару буенча тәкъдимнәр басыла.

З.З.Гыйләҗев.

УРАКЧЫ́ авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 21 *км* көнчыгыштарак, Суша елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 325 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 64%, руслар — 32%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1619 дан рус чыганакларында Пустошь Уращи исеме б-н билгеле. Рев-циягә кадәр Богородский буларак та мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы алпавыт һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек, балык тоту, икмәк сату, слесарьлык эше һәм тимерчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша; Владимир Богородица чиркәве (1721 дә төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1867 дә ачыла), 2 сыраханә, 1 казна шәраб һәм 6 вак-төяклөр кибете, Аек яшәү рәвеше тәрбияләүче уку өе эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1509 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Уракчы волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 452 ир-ат; 1859 да — 798, 1897 дә — 1521, 1908 дә — 1624, 1920 дә — 1675, 1926 да — 1592, 1949 да — 993, 1958 дә — 636, 1970 тә — 470, 1989 да — 375, 2002 дә — 405 кеше.

УРАКЧЫ́ авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 16 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Казан–Оренбург автомобиль юлы буенда. 2010 елда 177 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. 1930 елларда нигез салына. Халык саны: 1938 дә — 652, 1949 да — 381, 1958 дә — 284, 1970 тә — 340, 1979 да — 133, 1989 да — 213, 2002 дә — 209 кеше.

УРА́Л посёлогы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 16 *км* көньяк-көнчыгыштарак урнашкан. 2010 елда 1 кеше (татар) яши. 1926 да Александр Бистәсеннән күченүчеләр нигез сала. Оешкан көненнән ТАССРның Чаллы кантоны Зәй волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1926 да — 40, 1949 да — 91, 1958 дә — 87, 1970 тә — 75, 1979 да — 48, 1989 да — 6, 2002 дә — 2 кеше.

УРА́Л посёлогы, Ютазы р-нында, шәһәр тибындагы Урыссу посёлогыннан 22 *км* төнъяк-көнбатыштарак, Ютазы елгасы буенда. 2010 елда 216 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 74%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб. 1920 елларда нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Бөгелмә кантоны Бөгелмә волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Бөгелмә, 1935 нең 10 февраленнән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Баулы, 1991 нең 6 апреленнән Ютазы р-нында. Халык саны: 1926 да — 205, 1938 дә — 348, 1949 да — 275, 1958 дә — 185, 1970 тә — 298, 1979 да — 203, 1989 да — 110, 2002 дә — 236 кеше.

«УРА́Л», татар телендәге беренче социал-демократик газета. 1907 елның 4 гыйнварыннан алып 27 апреленә кадәр Оренбургта атнасына 2–3 тапкыр нәшер ителә, барысы 31 саны чыга. Нашире — Т.*Соловьёв* (24 санга кадәр), соңрак Г.*Терегулов*, мөхәррире — Х.Ямашева; фактик җитәкчеләре — Х.Ямашев, Г.Сәйфетдинов. Конспирация максатыннан материаллар имзасыз гына басыла яки псевд. б-н бирелә (Кызыл, Сул һ.б.). Язмаларның күп



«Урал» газетасы.

өлешен Х.Ямашев бастыра; газета б-н Г.Коләхмәтов хезмәттәшлек итә. Газета рев.-демократик юнәлештә була, аның язмаларында халыкның тормышын яхшырту бары тик революцион көрәш аша гына мөмкин дигән фикер ята. Ул эшчеләренең стачка хәрәкәте, крәстияннәр һәм укучы яшьләр чыгышлары турында мәгълүмат бирә. 2 нче Дәүләт Думасына сайлаулар чорында агитация эшен алып бара, буржуаз партияләрнең Дума проектларын тәнкыйтьли. Редакция милли мәсьәләне милләтләрнең үзбилгеләнүгә хокукы контекстында карый, «Иттифак әл-мөслимин», Мөселман хезмәт төркеме партияләре вәкилләре, «Тәрҗеман», «Вакыт» г-талары, «Дин вә мәгыйшәт» ж-лы б-н бәхәскә керә, законсыз рәвештә җирләре тартып алынган казакъ һәм кыргыз крәстияннәрен яклап чыга. Редак-

ция даими рәвештә татар халкының рухи тормышын, мәдәнияте һәм сәнгатен үстерү кирәклеген ассызыклый, милли театр оештыру идеясен яклый, дөньяви мәгариф системасын киңәйтү турында чыгыш ясый. «Шәкертләрнең хәле турында» сәхифәсендә укучыларның үз тормышлары, җәмгыятьнең революцион үзгәрешендә катнашырга омтылулары турында хатлары басыла. Газета Идел буенда, Урал, Казакъстан, Төркестан, Әзәрбайҗанда тарала. Кушымта рәвешендә татар телендә революцион эчтәлектәге 5 брошюра басыла. Полиция берничә тапкыр газета редакциясендә тентүләр уздыра, газетаның тиражын конфискацияләп тора; хөкүмәт тарафыннан тыела.

Әд.: Ибраһимов Г. «Урал» һәм уралчылар. К., 1927; Нуруллина Р.М. Тарих яза каләмем. К., 2009; Хасанов Х.Х. Большевистская газета «Урал». К., 1967.

«УРА́Л», иҗтимагый-сәяси газета. РКП(б)ның Уфа губерна ком-ты каршындагы губерна ревкомы һәм татар-башкорт секциясе каршындагы татар-башкорт эшләре буенча Уфа губерна бүлеге органы буларак чыга башлый. 1919 елның июненнән 1922 нең июленә кадәр татар телендә нәшер ителә, башта атнага 2–4 тапкыр, аннан соң атналык булып басыла, барысы 139 саны чыга. Исеме үзгәрә: 1919–20 дә «Кызыл юл», 1920 нең мартыннан 1921 нең мартына кадәр — «Шәрекъ ярлылары», 1921 нең 5 апреленнән — «У.» Мөхәррирләре — Г.Алпаров, С.Атнагулов, Ф.Әхмәтов, С.Бәдриев, Г.Гомәров, Г.Касыймов, М.Тимербаев, Ә.Хәбиби, Г.Ходаяров, З.Шәркый һ.б. Актив авторлары арасында — Н.Бикми, М.Гафури, Х.Кәрим, Э.Рәмиев, М.Тимербай, Н.Хәким, Ш.Ходайбирдин, Ш.Чурай, Ф.Сәйфи-Уфалы һ.б. Төп сәхифәләре — «Кызыл фронтта», «Россиядә Советлар», «Партия тормышыннан», «Чит илдә», «Татар-Башкорт илендә» һ.б. БҮБК хәбәрләре, партия һәм хөкүмәт җитәкчеләре чыгышлары басыла. Газета буржуазия б-н көрәшкә чакыра, Уфа губерна партиясез хатын-кызларның 1 һәм 2 нче конференциясе, Уфа губерна советларының 6, 7, 8 нче съезд-ларын, 3 нче Интернационалның 2 нче Конгрессы эшен яктырта. Басманың беренче елларында татарлар һәм башкортлар тормышына зур игътибар бирелә, ш.и. Татар һәм Башкорт респ-калары статусы мәсьәләләре турында фикер алышына. Татар мәдәнияте турында материаллар, М.Гафури, Г.Гомәров, Х.Ильяси, А.Кормашев, Ә.Насыйри, Ә.Тангатаров һ.б. шигырьләре, башка авторларның фельетоннары һәм хикәяләре басыла.

З.З.Гыйләҗев.

«УРА́Л КОЧЕГА́РКАСЫ», иҗтимагый-сәяси газета. ВКП(б)ның Кизел шәһәр ком-ты һәм хезмәт ияләре депутатларының шәһәр советы органы. 1930 елның декабреннән 1941 нең 2 нче яртысына кадәр Кизел шәһәрендә (Пермь өлкәсе) 5 көнгә 1 тапкыр, 1935 нең 28 мартыннан айга 10 тапкыр, 1940 тан — 3 көнгә 1 тапкыр татар телендә (1200 дән артык сан) нәшер ителә. Латин графикасында, 1940 ның 28 июненнән — кириллицада чыга. Мөхәррирләре — Н.Мөхәммәтшин, В.Мөхәммәт җанов, К.Биков, Х.Галин, С.Мөхәммәтшин, В.Шәмсетдинов, А.Әхсәнов, К.Әгъләутдинов, М.Әгъләмов, С.Хисаметдинов һ.б. Актив авторлары арасында — А.Морат, Р.Фәйзрахманова, Ф.Шакиров, Г.Төхвәтуллин, Г.Палатов. Беренче елларда «У.к.»ндагы мәгълүматларның күп өлеше төбәк мәсь әләләренә һәм җирле пр-тиеләренең проблемаларына багышлана, 1930 еллар ахырына гомумсоюз сәяси тематикага, халыкара мөнәсәбәтләргә һ.б. игътибар бирелә башлый. Бөек Ватан сугышы башлануга, сугыш темасы өстенлек итә. Илне индустрияләштерү проблемаларына, 1 һәм 2 нче бишьеллык планнарны үтәүгә, шахталарны үстерүгә, төбәктә күмер чыгаруны арттыруга, күмер сәнәгате пр-тиеләрендә соц. ярышка багышланган, татар халкының әлеге тармакка керткән өлеше турында язмалар басыла. Газета яңа техника үзләштерергә, хезмәт җитештерүчәнлеген арттырырга чакыра. Колхоз төзелеше барышы турында хәбәрләр бирелә, кулакларны сыйныф буларак юк итүне яклый. Татар мәктәпләрендә уку барышын, Пермь өлкәсе татарларының мәдәни тормышын яктырта. Газетада Кизел шәһәрендә Сабан туе уздыру турында бәян ителә. Яшь шагыйрьләр А.Хисамов, М.Шаһиәхмәтов, М.Гайнуллина һ.б.ның шигырьләре, Ф.Хөсни, Ш.Шәһәр һ.б.ның хикәяләре басыла. «Кызыл Татарстан», «Коммуна», «Яшь ленинчы», «Совет әдәбияты» һ.б. татар г-талары һәм ж-лларыннан күчереп басылган язмалар дөнья күрә.

З.З.Гыйләҗев.

УРА́Л ЭШЧЕ́ ТЕА́ТРЫ (Урал үзәк татар-башкорт күчмә эшче театры). Иң элек Троицк шәһәрендә (к. *Троицк татар театры*) һәвәскәрләр түгәрәкләреннән оеша. 1920 еллар ахырына проф. театр буларак формалаша. 1931 дә ВКП(б)ның Урал өлкә ком-ты карары нигезендә Свердловск шәһәренә күчерелә һәм «Урал үзәк татар-башкорт күчмә эшче театры» исеме бирелә. Директоры һәм сәнгать җитәкчесе итеп актёр Исхак Илялов билгеләнә, труппа составына актёрлар Ш.Габдрахманов, Һ.Илялова, М.Надрюков, М.Сундуков, Ш.Усманова, И.Шаһдалиев, Х.Шаһдалиева, М.Шәйхетдинова керә. Театр Свердловск, Чиләбе, Троицк, Магнитогорск, Асбест, Түбән Тагил, Златоуст, Березники, Сарапул, Красноуфимск, Кизел, Пермь, Ялан-Катай, Соликамск шәһәрләрендә, ш.у. төзүчеләр посёлокларында һәм агач материаллары әзерләү пунктларында яшәүчеләргә хезмәт күрсәтә. Спектакльләр татар һәм башкорт телләрендә куела. Баракларда, завод цехларында оештырылган тамашалар ике бүлектән тора. Беренчесендә тешле тәгәрмәч рәсеме төшерелгән зәңгәр блузалы актёрлар көнүзәк проблемаларны яктырткан, җирле производство материалына нигезләнгән кыска сәхнә күренешләре, скетчлар күрсәтәләр. Тамашалар өчен текстлар актёрларның үзләре тарафыннан иҗат ителә һәм театрның әдәби хезмәткәрләре тарафыннан редакцияләнә. Чыгышлар муз. һәм бию номерлары, куплетлар б-н алып барыла. Икенче бүлектә М.Фәйзи, Г.Камал, К.Тинчурин кебек татар драматургларының пьесалары буенча спектакльләрдән аерым сәхнә күренешләре була. Актёрлар ш.у. стена газеталары чыгару б-н шөгыльләнәләр, вакытлы матбугатка язылуны оештыралар, иҗтимагый-сәяси темаларга докладлар б-н чыгышлар ясыйлар, яңа хәбәрләр җиткерәләр. Актёрларның гадәти көнкүреш шартлары һәм даими яшәү урыннары булмау, ш.у. агитация эшенең театральләштерелгән формаларының хаҗәте акрынлап кимү сәбәпле, 1933 нең ахырында У.э.т. ябыла.

УРАЛМА́ САБАКЛЫЛА́Р (Convolvulaceae), ике өлешле үсемлекләр семьялыгы. Нигездә, тропик һәм субтропикларда таралган 50 дән артык ыругны, 1500 төрне берләштерә. Бер- һәм күпьеллык үләннәр, ярымкуакчыклар, куаклар. ТР терр-ясендә 2 ыруг, 2 төре бар. Күпьеллык үләнчел үсемлекләр. Яфраклары чиратлашкан, ук- яки сөңгесыман. Яфрак һәм сабаклары сөтчел сыекча-лы. Чәчәкләре әре, ак яки алсу төстә, 1–3 әр булып яфрак куентыгына урнашканнар. Тажы дөрес формада, бүрәнкә- яки кыңгырау-сыман. Җимеше — тартмачык. Таҗ яфрак-чыкларының ачык төсе һәм нектары күпсан-лы бөҗәкләрне (умарта кортлары, күбәләк, чебеннәр) җәлеп итә. У.с.ның чәчәкләре яктылык җитмәүгә бик сизгер, болытлы һәм яңгырлы көннәрдә ачылмый. Эт әчәгесе — тамыр үсентесеннән үрчи торган чүп үләне. Халык медицинасында койма колмак үләне авырту басу чарасы буларак кулланыла. Декоратив үсемлек.

А.Ф.Йосыпова.

УРА́ЛЬСКИЙ И (чын фамилиясе Насыйбуллин) Габдулла Насыйбулла улы (1903, Әстерхан ш. — 30.3.1942, Казан), драма актёры, ТАССРның атказ. артисты (1940). Беренче проф. татар актёрларының берсе. Сәхнә эшчәнлеген 1917 елда Әстерхан татар театрында башлап җибәрә. 1920–30 елларда Әстерхан драма һәм Татар акад. (Казан) театрларында эшли, 1941 дән Әстерхан татар театрының баш режиссёры. Үзенчәлекле сәләткә ия буларак, У.И персонажның асылына тирәнтен үтеп керә белүе б-н аерылып торган шактый образлар иҗат итә, ул аларны истә калырлык ачык, вакыт-вакыт парадоксаль һәм үткен сатирик формада чагылдыра: Юныс («Шәмсекамәр», М.Әблиев), Туктамыш («Ил», К.Тинчурин), Самат («Бишбүләк», Т.Гыйззәт), Сатин («Тормыш төбендә», М.Горький), Вишневский, Беркутов («Төшемле урын», «Бүреләр һәм сарыклар», А.Н.Островский), Ляпкин-Тяпкин («Ревизор», Н.В.Гоголь), Президент («Мәкер вә мәхәббәт», Ф.Шиллер) образлары шундыйлардан. Хәлил («Галиябану», М.Фәйзи), Таһир («Таһир-Зөһрә», Ф.Бурнаш), Кыям («Беренче чәчәкләр», К.Тинчурин) рольләрен башкарганда, актёр жанр табигатен нечкә тоеп эш итә һәм тамашачы игътибарына зур төгәллек б-н җиткерә.

Әд.: Мәхмүтов Һ. Әстерханда татар театры (Тарихи очерк) // Мирас. 1994. № 1–3, 7–12; 1995. № 1–8; Илялова И. Г.Камал театры артистлары = Артисты театра им. Г.Камала. К., 2005; шулук. Театр имени Камала. К., 1986.

И.И.Илялова.

УРА́СИН Рэм Геннадьевич (15.5.1976, Казан), пианист, педагог, ТРның халык артисты (2006). Казан консерваториясе каршындагы урта махсус мәктәпне (1994) һәм Мәскәү консерваториясен (Л.Наумов классы, 1999) тәмамлый. У.ның репертуарында үзәк урынны романтик композиторларның (Ф.Шопен, И.Брамс, П.Чайковский, С.Рахманинов) әсәрләре алып тора. «Фредерик Шопен. 11 концерттан торган әсәрләрнең тулы җыелмасы» («Фредерик Шопен. Полное собрание сочинений в 11 концертах», 2009–10, композиторның 200 еллык юбилеена) циклын башкаручы буларак аеруча таныла. У.ның концерт программаларына татар композиторлары әсәрләре дә керә. Пианист Россиядә һәм чит илләрдә (Германия, Франция, Швейцария, Австрия, Италия, Польша, Чехия, Словакия, Япония, Австралия һ.б.) концертлар куя; компакт-дисклар яздыра: «Ф.Шопен әсәрләре» («Произведения Ф.Шопена», Япония, 1999), «Рус композиторларының әсәрләре» («Произведения русских композиторов», Япония, 2000), «Ф.Яруллин һәм Р.Яхин әсәрләре» («Произведения Ф.Яруллина и Р.Яхина», Мәскәү, 2003), «П.Чайковский әсәрләре» («Произведения П.Чайковского», Австралия, 2004) һ.б. Дөньяның әйдәп баручы оркестрлары (Россия милли оркестры; Мәскәү, Варшава, Сидней филармония оркестрлары; Вена һәм Краков камера оркестрлары һ.б.) б-н чыгыш ясый. Пианистның башкаруы тәэсирлелеге, әсәрләр шәрехләмәсенең индивидуальлеге б-н аерылып тора. 2003 тән Казан консерваториясендә укыта, бер үк вакытта Мәскәү филармониясе солисты. Фортепиано транскрипцияләре, ш.и. «Ф.Яруллинның «Шүрәле» балетыннан өч пьеса» («Три пьесы из балета Ф.Яруллина «Шурале», 2003) авторы. Ф.Шопен исем. (Мәскәү, 1992; Варшава, 1995), Хамамацу (Япония, 1997), Монте-Карло (Монако, 2001), Сидней (Австралия, 2004) һ.б. шәһәрләрдә узган халыкара конкурслар лауреаты.

УРАТМА́ елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Кама елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 40,7 *км*. Бассейнының мәйданы 284,7 *км*². Түбән Кама р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Югары Уратма авылыннан 4 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Поповка посёлогыннан 4 *км* төньяктарак Кама ермагы Простька кушыла. Елга башының абс. биеклеге 210 *м*, тамагыныкы — 53 *м*. Су җыелу мәйданы терән ерым һәм сызалар б-н ергаланган калкулыклы тигезлектән гыйбарәт, урманлылыгы 50%. У.ның үзәне асимметрияле, уңъяк сөзәкләкләр текәрәк. Елганың 0,8 дән 7 *км* га кадәр озынлыктагы 18 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,31 *км*/*км*². Туенуы катнаш, дүрттән өч өлеше кар сулары исәбенә туры килә. Җир асты сулары б-н туену модуле бассейнының төрле җирләрендә 0,5 тән 5 *л*/*с*·*км*² га кадәр. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәенык саегуы б-н характерлана. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,225 *м*³/*с*. Суы бик каты: язын 9–12 *мг-экв*/*л*, кышын һәм җәен 12–20 *мг-экв*/*л*. Гомуми минераль әшүе язын 300–400 *мг*/*л* дан артык.



Уратма елгасы.

УРБАНИЗА́ЦИЯ (лат. urbanus — шәһәр, шәһәрләшү), ил үсешендә шәһәрләр тоткан ролынең көчәю процессы, алардагы халык санының арта баруы, җәмгыятьтә шәһәрчә тормыш итү стандартларының таралышы. У. шәһәрләрдәге эре сәнәгый җитештерү үсеше, фән, югары, урта-махсус белем бирү һәм мәдәният учреждениеләренең артуы б-н бәйле.

У. процессы вакытында авыл халкының һәм якын-тирә посёлокларда яшәүчеләрнең шәһәргә күчүе, шәһәр яны терр-яләренең шәһәр составына кертелүе яки адм. буйсынуы күзәтелә.

1920 елда Казаннан башка ТАССР составына 11 шәһәр — Арча, Зөя, Буа, Бөгелмә, Алабуга, Лаеш, Минзәлә, Спас, Тәтеш, Мамадыш, Чистай керә. 1920–40 елларда — Әгерҗе, Менделеев, Чаллы, Зеленодольск, 1940–60 елларда — Әлмәт, Лениногорск, Түбән Кама, Норлат, 1970 елларда — Зәй, Азнакай, 1990 елларда Баулы шәһәр статусын алалар. 20 йөз уртасында нефть чыганакларын үзләштерү, ә аннары нефть химиясе комплексы һәм автомобиль төзелеше үсеше халыкның респ-ка шәһәрләренә яңадан агылуына сәбәп була. Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт шәһәрләре илнең эре сәнәгать үзәкләренә әверелә. 19 йөз ахырында Татарстан шәһәрләрендә 201,5 мең кеше (гомуми халык санының 8,5% ы) яши. 1920–30 елларда күп кенә торак пунктларны шәһәрләр исәбенә кертү, ш.у. халык хуҗалыгын индустрияләштерү нәтиҗәсендә шәһәр халкы шактый арта һәм 1939 да 614,3 мең кеше (21,1%) тәшкил итә; Казан халкы 1926 да 179 мең кешедән 1939 да 406 меңгә кадәр арта, 1980 еллар башына 1 млн. кешегә җитә. Респ-када шәһәр халкының көчле үсеше 1960 елларга (ел саен уртача 38,5 мең кешегә) һәм аеруча 1970 елларга (63,5 мең кеше) туры килә. Бу үсешкә Түбән Кама нефть химиясе комб-ты, Түбән Кама ГЭСы, Кама автомобиль з-ды һ.б. сәнәгать объектлары төзелешенә илнең башка төбәкләреннән килүче мигрантлар булышлык итә. Аннан соңгы елларда эре җитештерү объектлары төзелешләренең тәмамлануы, ш.у. туымының кимүе сәбәпле респ-када шәһәр халкы санының үсеш темпы, аеруча 1990 елларда, кими (1989 да 47,2 меңнән 2002 дә елга 10,2 мең кешегә кадәр). 2016 ның башында 23 шәһәрдә һәм шәһәр тибындагы 18 посёлокта 2961,1 мең кеше — барлык ТР халкының 76,4% ы яши. Шәһәр халкының 14,9% ы шәһәр тибындагы посёлокларда һәм кечкенә шәһәрләрдә (50 меңгә кадәр кеше яши торган), 9,6% — уртача (50–100 мең кеше яши торган, Бөгелмә, Алабуга, Лениногорск, Чистай), 16,5% — зур шәһәрләрдә (100–250 мең кеше яши торган, Түбән Кама, Әлмәт, Яшел Үзән), 17,8% — Чаллы, 41,2% — Казанда яши. Респ-када яшәүче төрле халык вәкилләренең У.ләшү дәрәҗәсенең аерыла; украин, башкорт һәм руслар арасында шәһәр халкы ТР буенча уртачадан югары. Татар халкында У. дәрәҗәсе: 1959 да — 29,4%, 1970 тә — 39%, 1980 еллар башында — якынча 50%, 2002 дә — 66,5%, 2010 да — 68,8% тәшкил итә. Удмуртлар (39,8%) һәм чуашлар (43,1%) иң аз урбанизацияләшкән халык, аларның шактый өлеше Татарстанның кечкенә һәм уртача шәһәрләрендә яши.

Ф.Г.Борһанов.



Р.Г.Урасин.

УРГЫДЫ́ елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Минзәлә елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 31 *км*. Бассейнының мәйданы 279 *км*². Минзәлә р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Казиле авылыннан 2 *км* көньяктарак, тамагы Балтай авылыннан 4,5 *км* төньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 185 *м*, тамагыныкы — 65 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 15%. Елганың 1,9 дан 13,4 *км* га кадәр озынлыктагы 8 кушылдыгы бар. Аеруча зурлары: Буклы (13,4 *км*), Борылык (11,9 *км*) — сул кушылдыклар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,43 *км*/*км*². Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 1 *л*/*с*·*км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы, җәен ныкаегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпеллык катламы 111 *мм*, ташу агымы катламы 90 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ункөнлегендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,2 *м*³/*с*. Суы язын каты (6–9 *мг-экв*/*л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв*/*л*). Гомуми минераль әшүе язын 300–400 *мг*/*л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг*/*л*. Елгада суының күләме 0,7 млн. *м*³ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

УРДА́, урта гасырларда төрки һәм монгол халыкларында ханның яки олыс хуҗасының күчмә станы атамасы. Берничә өлештән — ханның яраннары да кергән шәхси һәм аның хатыннары ставкаларыннан торган дип фа - разлана. У. да гаскәр башлыклары, түрәләр, гаскәрләр, күчмә мәчетләр, мөселман руханилары һ.б. була. У. б-н сәүдәгәрләр һәм һө - нәрчеләр күченеп йөри. 14 йөз гарәп сәяхәт - чесе Ибне Баттута Үзбәк хан ставкасын: «Алар урду дип атый торган ставка килде һәм без үзенең халкы б-н хәрәкәтләнүче зур шәһәр күрдек; анда мәчетләр һәм базарлар, аш пешерү урыннарыннан һавага төтен күтәре - ләү; алар барган көйгә ашарга пешерәләр, ә ат - лар алар төялгән арбаларны тартып бара. Туктау урынына җиткәч, чатырларны арба - лардан алып, җиргә урнаштыралар, чөнки алар бик җи ңел күчерешле. Алар мәчетләр һәм кибетләрне дә шул рәвешле коралар», — дип тасвирлый. Г.А.Фёдоров-Давыдов рас - лавы буенча, 14 йөз ахырында — 15 йөздә «У.» атамасы тулысынча дәүләткә күчерелә. 15 йөз башында язылган «Искәндәр анони - мы» әсәре авторы Мөгыйн әд-дин Натанзи Җүчи Олысы терр-ясендә барлыкка килгән дәүләтләр *Ак Урда* һәм *Күк Урда* дип атала - лар, дип яза. «У.» атамасы рус елъязмала - рында да чагылыш таба, аларда Мурат Урда - сы, Мамай Урдасы, Зәңгәр Урда, Олы Урда һ.б. искә алына.

Әд.: Ф ё д о р о в - Д а в ы д о в Г.А. Кочевая Орда в Улусе Джучи // Вестн. Моск. ун-та. 1970. № 5; Е г о р о в В.Л. Историческая география Золотой Орды в XIII–XIV вв. М., 1985.

И.Р.Вәлиуллин.

УРДА́ ВӘКИЛЛЕГЕ́, Мәскәүдә Алтын Урда ханнары вәкиллеге. *Бату хан* рус кенәзлек - ләрен яулап алганнан соң (13 йөз) оешты - рыла. Иң элек Мәскәү кремле терр-ясендә урнаша. Күзәтү, җыем һәм ясак җыю өчен килгән *баскакларны* — Алтын Урда наместник - ларын бөек кенәзләр аерым бер ка - дер-хөрмәт б-н каршы алырга тиеш булалар: Урда илчеләрен каршы чыгып алалар, хан ярлыкларын укыган вакытта «буйсыну күр - сәтү йөзеннән *басма* каршында тезләнәләр». Плано *Карпини* мәгълүматлары буенча, хан вәкилләре «киездән кеше рәвешендә потлар ясыйлар» һәм «әлеге карачкыларга (болван - нарга) табынырга» мәҗбүр итәләр. Мәскәү - дә яшәүче халык хан илчеләрен каршылау урынын «Болвановка» дип атый. Алтын Ур - даның кайбер ханнары Мәскәү кенәзлеген яклыйлар; Үзбәк ханның күзе авыртудан җә - фаланган хатыны *Тайдула* 1357 елда үзенә митрополит Алексейны чакырта. Тайдула бикәнең мог җизалы сәламәтләнүеннән соң, Алексей аның улыннан, *Җанибәк ханнан*, алдан килешү буенча, Архистратиг Михаил мог җизасы хөрмәтенә монастырь («Чудов монастырь») төзү өчен У.в.н «алырга» рөх - сәт сорый. Кремль терр-ясендәге У.в. ко - рылмалары, ш.и. Ярлык вәкиллеге һәм Җа - нибәк мосафирханәсе дә бөек Мәскәү ке - нәзләре биләмәсенә күчә. 1358 дә Мәскәү елгасы аръягындагы посадта яңа У.в. төзи - ләр (15 йөздә Татар вәкиллеге дип атала). Ханнар Мәскәү кенәзлеген кул астында то - ту өчен берничә тапкыр Мәскәүгә яу б-н ба - ралар. «Угра буендагы капма-каршы тор - у»дан соң (1480) Иван III Россиянең Ал - тын Урда ханнары хакимлегеннән тулысын - ча азат ителүенә ирешә. 1485 тә У.в. урын - нда Никола Гостунский чиркәве төзелә. Чиркәү янында Казан патшасы улы *Ытә - мешгәрәй хан* өчен аерым вәкиллек булды - рыла. 1565 тә Чудов монастыре зиратында Казан ханы *Ядегәр Мөхәммәд* (1552 дә әсир - леккә алына) җирләнә. 1918 дә Чудов монас - тыре ябыла, 1929 да сүтелә. Елъязмалардан күренгәнчә, Мәскәү аръягына «Урдадан кил - гән илчеләр һәм ш.у. Урда йомышлы кенәз - ләре» урнашкан урыннарга нисбәтле рәвеш - тә Олы һәм Кече Ордынка урамнары исем - нәре килеп чыккан.

Әд.: С ы т и н П.В. Откуда произошли названия улиц Москвы. М., 1959; С н е г и р ё в И.М. Памятники московской древности. М., 2007; Москва: Энцикл. М., 1997.

А.В.Гарзавина.

УРДА́ МӘЛИ́К ХАН (Урда Мәлик) (Урда Шәех) (?-1361), Алтын Урда ханы (1361). Күк Урда ханы Чимтайның бертуганы. Чим - тай гаскәре ярдәмендә Мамайны Сарай әл-Җәдидтән куып, Алтын Урда тәхетенә утыра. Сарай әл-Җәдид һәм Азак шәһәрлә - рендә үз исеменнән акча суктыра. Сарай ак - сөякләре ярдәменә таяна алмый; түнтәре - лештән соң 1 айдан, 1361 елның язында, фет - нә нәтиҗәсендә үтерелә.

Әд.: Г р е к о в Б.Д., Я к у б о в с к и й А.Ю. Золотая Орда и её падение. М.–Л., 1950; М у х а м - м а д и е в А.Г. Булгаро-татарская монетная систе - ма XII–XV вв. М., 1983.

И.Л.Измайлов.

УРДА́ РАЙОНЫ́, *Пермь краеның* көньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан. 1924 ел - ның 26 февралендә оештырыла. Мәйданы — 1419,9 *км*². Үзәге — Урда авылы (Пермьнән 125 *км* көньяк-көнчыгыштарак). Халкы — 14878 кеше (2017), ш.и. 2508 татар (2010). Татарлар, башлыча, Кече Ашап (1032 кеше; 1679 дан мәгълүм), Иске Авыл (Карьево) (947 кеше; Казан ханлыгы чорыннан билге - ле), Мәрәкәй (330 кеше; 17 йөз уртасында нигез салына), Шалканды (Щелканка) (215 кеше; 16 йөз ахырыннан мәгълүм) һәм Маринкино (80 кеше) авылларында яшиләр. 1917 гә кадәр барлык татар авылларында — мәчетләр, мәчетләр каршында мәктәпләр эш - ли. 2006/07 уку елында районның 3 мәктәбен - дә укыту татар телендә бара. У.р.нда Дан ор - денының тулы кавалеры Р.Суфиев туган.

И.Л.Измайлов.

УРДАЛА́ елгасы, Көнчыгыш Кама аръягын - да, Чишмә елгасының уң кушылдыгы. Озын - лыгы 12,7 *км*. Бассейнының мәйданы 49,6 *км*². Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгыннан, Ленино - горск р-ны терр-ясендә ага. Елга башы Ур - нәк-Күмәк авылыннан 4 *км* көньяк-көнчы - гыштарак, тамагы Туктар Урдаласы авылы - ның төньяк чигендә. Елга башының абс. би - еклеге 260 *м*, тамагыныкы — 123 *м*. Су җые - лу мәйданының урманлылыгы 35%. У.ның 1,2 дән 1,8 *км* га кадәр озынлыктагы 3 ку - шылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,35 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар су - лары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 3–5 *л/с·км*². Гидрологик режимы язын су муллыгы, җәен нык саегуы б-н характер - лана. Бассейнында еллык су агымының урта - ча күпьеллык катламы 114 *мм*, ташу агымы катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахы - рында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,06 *м*³/*с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (20–40 мг/экв/л). Гомуми минераль - ләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

УРДАЛА́ (Н а җ а р) елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Чишмә елгасының уң кушыл - дыгы. Озынлыгы 11,4 *км*, ТРда — 3 *км*. Бас - сейнының мәйданы 74,4 *км*². Бөгелмә-Бәлә - бәй калкулыгыннан ага. Елга башы Самара өлкәсендә, тамагы Лениногорск р-ны Поля - ево авылыннан 2 *км* көньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 240 *м*, тамагы - ныкы — 141 *м*. Су җыелу мәйданының урман - лылыгы 20%. У.ның 2,1 дән 6,1 *км* га кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар. Елга челтә - ренең тыгызлыгы 0,33 *км/км*². Туенуы кат - наш, өчтән ике өлеше диярлек кар сулары исәбенә туры килә. Җир асты сулары б-н ту - ену модуле 1–3 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 126 *мм*, ташу агымы катламы 80 *мм*. Язгы та - шу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь уртасында ту ңа. Елга тамагында суы - ның иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,104 *м*³/*с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (20–40 *мг-экв/л*). Гомуми минераль ләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

УРДАЛЫ́ ТА́У, М а р к о в сөзәкле - г е, ландшафтлы табигать истәлеге. Ютазы р-ны терр-ясендә, Акбаш авылыннан 2,5 *км* көнбатыштарак урнашкан. 1972 елда билге - ләнә. Мәйданы 2,5 *га*. Элеккеге нарат урма - ны урынында Дим елгасы үзәненең сулъяк яр



Урдалы Тау.

сөзәклегендәге болын һәм ташлы дала учас - тогын били. Дала үсемлекләренең 100 гә якын төре, ш.и. ТРның Кызыл Китабына кертелгән: иенке шалфей, тимгелле зәңгәрбаш, күпьел - лык җитен, тәбәнәк миндаль билгеләнгән. Фәнни һәм тарихи әһәмияткә ия. 1968 дә М.В.Марков җитәкчелегендә Казан ун-ты - ның геоботаник экспедициясе тарафыннан тикшерелә.

УРЕ́ЦКИЙ Ян Семенович (25.5.1937, Белоруссия ССР, Витебск ш. — 26.6.2001, Казан), радиоэлектроника өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1986), проф. (1989), РФнең атказ. фән эшлеклесе (1998), ТАССРның атказ. уйлап табучысы (1989). 1966 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли, 1987 дән идарә каф. профессоры. У. җитәкчелегендә талән ителгән стат. сыйфатламалы механик системаларның очраклы тибрәнешләрен тудыру алымнары һәм чаралары, тудыручы сигналны формалаштыру, эксплуатацион вибрация спектрын контрольдә тоту һәм күпнокталы скаляр вибрация кырларын бернокталы тудыру системаларын синтезлау алымнары эшләнә. Машиналарны һәм приборларны виброакустик яктан сынау максатында радиоэлектрон системалар һәм комплекслар булдыруда катнашканы өчен, ТР Дәүләт бүләгенә лаек була (1996). У.ның эшләнмәләре илнең төрле пр-тиеләрендә гамәлгә кертелә. Уйлап табуга 95 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр, ш.и СССР ВДНХсы медальләре б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Испытания аппаратуры радиосистем и испытательное оборудование. К., 1991; Имитация и компенсация эксплуатационной вибрации. М., 1995 (автордаш).

УРЖУ́М ӨЯЗЕ́, 1796–1928 елларда Вятка губернасында. Казан өязеннән (16 йөз ахыры) аерып чыгарыла. Үзәге — Уржум шәһәре (мари авылы буларак барлыкка килә, 1584 тән — рус кальгасы, 1780 нән — өяз шәһәре). Биләмәсендә Уржум кальгасы һәм Нократ, Кременка, Буя, Уржум, Немда, Юшут һ.б. елга буйларындагы җирләр керә. 18 йөз башыннан өяз терр-ясе Казан губернасы составында, 1780 нән — Вятка наместниклыгында. Көнбатыштан — Вятка губернасының Яранск, төнъякта н — Нолинск, көнчыгыштан — Малмыж өязләре, көньяктан — Казан губернасының Царёвококшайск һәм Казан өязләре б-н чикләшә. Мәйданы 10174 кв. чакрым. Халкы 289,2 мең кеше, ш.и. руслар — 69,5%, марилар — 25,2%, татарлар — 4,8% (1897). 22 волостька бүленә. Халкы игенчелек, вак һөнәрчелек (урман кәсепчелеге, күн итек тегү, тимерчелек һ.б.) б-н шөгыльләнә. Өяздә спирт, бәллүр һәм пыяла әйберләр ясау, поташ, май язу һәм күн эшкәртү пр-тиеләре була. 255 мәктәп эшли. 1928 дә бетерелә, өяз терр-ясе Вятка губернасының Малмыж һәм Нолинск өязләре составына керә.

Чыг.: Статистическое описание Вятской губернии и справочные сведения. Вятка, 1875.

Д.Г.Мостафина.

УРЖУ́М РАЙОНЫ́, *Киров өлкәсенең* көньягында урнашкан. 1929 елда оештырыла (1965 тән хәзерге чикләре саклана). Мәйданы — 3 мең *км*². Үзәге — Уржум шәһәре (Киров шәһәреннән 195 *км* көньяктарак). Халкы — 24096, ш.и. район үзәгендә 9981 кеше (2017). Татарлар саны: 2002 дә — 1293, 2010 да — 1293, 2016 да — 967 кеше. Алар күбесенчә Лазарево авылында (700 ләп кеше) һәм ш.у. Донаурово посёлогында, Шурма авылында яшиләр. 1930 елларга кадәр У.р. терр-ясендә татарлар күп булмый, 1930–40 елларда Лазарево һәм Донауровода агач эшкәртү пр-тиеләре төзелү б-н бәйле рәвештә татарлар саны арта башлый. Лазарево авылында мөселман җәмгыяте бар; җирле гомуми белем бирү мәктәбендә татар үзешчән сәнгать түгәрәге эшли. Нәкышьче К.Е.*Максимов*, рәссам Ф.Г.*Халиковның* тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге У.р. б-н бәйле.

К.А.Әхәтов.

«УРИ́ЦКИЙ ИСЕМЕНДӘГЕ́ СПОРТ КЛУБЫ́», к. «*Ак барс*».

У́РКИН (Куркин, Нуркин) Сөләйман (1680 еллар — 1751 дән соң), Казан сәүдәгәре. Татар бистәсе халкының 1749 елгы янгыннан соң шәһәр хакимиятенә Татар бистәсен бетерергә тәкъдим иткән миссионерларга каршы хәрәкәтен җитәкли (к. *Иске Татар бистәсе*). Мәсьәләне хәл итү өчен берничә мәртәбә С.-Петербургка бара һәм бистәнең янмаган өлешен шул урында саклап калуга ирешә.

УРМА́Н, үсемлекләр дөньясының төп типларыннан берсе, аның нигезен берникадәр куе (җыелган) урман чатыры хасил итүче һәм куак, ярымкуак, абага, үләннәр, мүк, лишайниклар б-н бергә У. бергәлеген формалашты ручы агачлар тәшкил итә. У. — геогр. ландшафт элементы, күп кенә кошлар һәм җәнлекләр өчен тереклек мохите, агач, җиләк, гөмбә һәм техник чимал чыганагы, туфрак ясалуга, климат, гидрологик режимга шактый йогынты ясый. Җирнең У. капламы биосфераның тотрыклылык факторы булып тора, атм.да кислород һәм углек-та балансы дәрәҗәсен билгели.

ТР У.нары өч урман үсемлекләре зонасында урнашканнар. Катнаш У.нар зонасы ылыслы-киң яфраклы У.нарның юкә катыш төньяк (субүләрләрдә агачлар составында имән катнашмый һәм елга тугайларына күчә) һәм юкә б-н имән катыш көньяк (биредә имән катнаш агач буларак субүләр У.нар составына керә) асзоналарына бүленә. Киң яфраклы У.нар зонасында иярченнәре — вак яфраклы юкә, очлы яфраклы өрәңге һәм элмә агачлары б-н имән өстенлек итә. Урман-дала зонасында, Бөгелмә платосында, имән һәм аның иярченнәре б-н беррәттән төп имән-каен һәм каен агачлыклары очрый. Татарстан терр-ясе буйлап Европа чыршысы ареалының көньяк-көнчыгыш, Себер чыршысы б-н Себер ак чыршысыныкының көньяк-көнбатыш, гади корычагачның көнчыгыш, тигезлек имәнлек-ләреңең төньяк-көнчыгыш чикләре уза.

ТР урман фондының гомуми мәйданы — 1270,3 мең *га*, ш.и. урман б-н капланган мәйдан — 1165,3 мең *га*. Гомуми мәйданының 1225 мең *га* ы һәм урман б-н капланган мәйданның 1123,8 мең *га* ы (кеше тарафыннан утыртылган урманнар 315 мең *га* тәшкил итә) ТР буенча Урман хуҗалыгы агентлыгы карамагына керә. Урман фонды мәйданының 23,5% ын ылыслы токымнар, 18,7% — каты яфраклылар, 57,5% — йомшак яфраклылар, 0,8% ын куаклар били. Идел-Кама саклау-лыгы (10,1 *га*) һәм «Түбән Кама» милли паркының (18,5 мең *га*) 28,6 *га* урманнары РФ Табигый байлыклар министрлыгының Дәүләт әйләнә-тирә мохит хезмәте, 16,7 мең *га* урманнар — башка ведомстволар карамагында.

Респ-каның урман фондын 1 нче һәм 2 нче төркем урманнар тәшкил итә. 1 нче төркем урманнар 536,6 мең *га* били. Аларның төп максаты — су саклау, ышыклану, санитар-гигиена, сәламәтләндерү һ.б. функцияләрне үтәү, аларга ш.у. аеруча саклаулы табигать терр-яләре (31 мең *га*) һәм торак пунктлар тирәсендәге яшеллек зоналары (134,1 мең *га*) керә. 2 нче төркемгә чикле күләмдә файдалануы урманнар карый, аларның гомуми мәйданы — 688,4 мең *га*. Гомуми агач запасы 168,8 млн. *м*³, уртача запас — 142,5 *м*³/*га*, уртача еллык үсеш 4,13 *м*³/*га*. Гомуми агач запасының 25,3% ы — ылыслыларга, 13,4% ы — каты яфраклыларга, 61,3% ы йомшак яфраклыларга туры килә. Өлгергән һәм картайган агачларның запасы 32 млн. *м*³ (ылыслылар — 7,6%, каты яфраклылар — 7,4% һәм йомшак яфраклылар — 85%) тәшкил итә. Өлгергән агачларның уртача запасы 192 *м*³/*га* (ш.и. ылыслыларга — 308 *м*³/*га*, каты яфраклыларга — 143 *м*³/*га*, йомшак яфраклыларга 203 *м*³/*га* туры килә). 1990 еллар башыннан төп урманнарны файдалану буенча дилән-келәрне кисү 35–40% ка үтәлә, шул сәбәпле көчле темплар б-н картайган урманнарның туплану процессы бара. Өлгергән һәм картайган агачларның 10 млн. *м*³ дан артык (31,4%) запасы кыйммәте аз булган усаклыкларга туры килә, аларда 1,5 млн. *м*³ дан артык картайган агачлар тупланган.

Урман җирләрендә (кисенделәр, яныкъ, буш урыннар һ.б.) урман яңартуның актив формасы буларак төп урман барлыкка китерүче токымнарны утырту һәм чәчү юлы б-н урман торгызу эшләре башкарыла. 1917 гә кадәр Татарстан терр-ясендә 500 *га* мәйданда урман культуралары булдырыла. Күп кенә урман ху җалыкларында югары продукцияле нарат, чыршы, ак чыршы участоклары сакланган, алар аеруча сакланулы терр-яләр (*Бохарай наратлыгы, «Утыртылма урман», Турминка урман дачасы, Чыршы һәм карагай урман культуралары,* 1910–13 еллар, *Карагай урман культуралары*, 1906) булып билгеләнгән. 1917–2002 дә 495 мең *га* дан артык мәйданда урман культуралары (күбесенчә нарат, чыршы, имән, өлешчә карагай, каен, тополь) булдырыла. Беренче чиратта, пошилар тап тавыннан, ш.у. корткыч бөҗәкләр зарарлаудан, гөмбәчек авыруларыннан, вак яфраклы токымнарның үсеп китүеннән утыртылган культураларның бер өлеше үлә. Респ-ка урман хуҗалыклары урман торгызу б-н берраттан саклаучы урманнарны җәелдерү, ерым, сыза һәм яр буйларына агачлар утырту, кыр ышыклау һәм юл буе полосалары булдыру эшләрен башкаралар. 1981–2002 дә 49,4 мең *га* мәйданда ерым-сыза утыртмалары һәм саклагыч (ышыклагыч) полосалар булдыралар. Урман хуҗалыклары питомниклары урман культуралары һәм саклагыч урманнар үстерү өчен чәчкеннәр һәм үсентеләр үстерәләр. Гомуми мәйданы 540 *га* булган 94 питомникта ел саен 100 млн.нан артык утырту материалы (агач һәм куакларның 60 төре) җитештерелә, аның бер өлеше шәһәр һәм авыл торак пунктларын яшелләндерү

өчен бирелә. Ш.у.к. *Яфраклы урман, Катнаш урманнар, Ылыслы агачлар урманы.*

Әд.: Г а я н о в А.Г. Леса и лесное хозяйство Республики Татарстан. К., 2001.

Ә.Һ.Газизуллин.

УРМА́Н посёлогы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 40 *км* көньяк-көнбатыштарак, Чуаш Респ-касы б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 17 кеше (чуашлар) яши. Күгәй урманчылыгының агач эшкәртү цехы. 1970 елларда нигез салына. Халык саны: 1989 да — 85, 2002 дә — 28 кеше.

УРМА́Н, АГА́Ч ЭШКӘРТҮ́ ҺӘМ ЦЕЛЛЮЛО́ЗА-КӘГА́ЗЬ СӘНӘГАТЕ́, сәнәгатьнең агач әзерләү, агачны механик, химик-механик, химик һәм кабат эшкәртү б-н шөгыльләнүче тармаклары җыелмасы. ТРның урман эшкәртү комплексы составында милекнең төр - ле формаларындагы 1000 нән артык (ш.и. 30 лап әре һәм уртача зурлыктагы) пр-тие. Эшләүчеләр саны — 11,5 меңнән артык кеше (респ-када сәнәгый җитештерүдә мәшгуль халыкның 3,3% ы чамасы). ТРда җитештерелгән барлык сәнәгать продукциясенең 2% ы (2004), ш.и. эшкә яраклы агач, такта материаллары, ябыштырылган фанера, катыргы, кәгазь, йорт җиһазлары, төзелеш детальләре, әрҗәләр, көнкүреш кирәк-яраклары (барлыгы 40,2 млрд. сумлык) җитештерелә; агач эшкәртүгә продукциянең 35% ы, целлюлоза-кәгазь җитештерүгә 65% ы туры килә (2016).

Татарстанның урман эшкәртү комплексы электән үк төбәкнең ху җалык тормышында бик мөһим роль уйнаган *урман-агач эшкәртү кәсепчелеге* җирлегендә үсә. 17 йөз ахырыннан Казан янында су көче б-н эшләүче «такта яру тегермәннәре» булуы мәгълүм. Соңрак алар суднолар төзү, С.-Петербург, Әстерхан верфьләре өчен корабльләр төзелешенә яраклы агач әзерләү һәм аны беренчел эшкәртү (тозлау), мичкәләр ясау һ.б. б-н шөгыльләнгән Казан адмиралтействосы карамагына тапшырыла. Корабльләр төзү өчен зур күләмдә агач Мамадыш өязендә әзерләнә; С.-Петербургка ул җиңгуле транспорт б-н җибәрелә, Әстерханга Идел елгасы буйлап агызыла.

18 йөз ахырына губернада су көче б-н эш - ләүче 80 ләп такта яру пр-тиесе исәпләнә. 1789 елда М.М.Рәхимов Уржум өязендә кәгазь җитештерү пр-тиесе ача. 1812 дә язу һәм төргәкләү кәгазен 3 ф-ка эшләп чыгара (ел - га 8300 поттан артык). Аларның җи һазлары мичләрдән, чаннардан, казаннардан, су дви - гательләреннән гыйбарәт була; чимал сыйфа - тында түпрәк кулланыла. Агач көлен эшкәр - түче 2 завод эшли, алар елга 1200 поттан ар - тык поташ җитештерә (эш барышында кыз - дыру мичләре, чуен казаннар, агач чаннар файдаланыла). Индустрия тармагы буларак, У., а.э.һ.ц.-к.с. 19 йөз уртасыннан үсеш киче - рә. 1845 тә Казанда Е.М.Цыгановның пар - кет ф-касы, 1876–78 дә Л.С.Розенбергның һәм Г.Ф.Локкеның столяр-паркет, мичкә ясау һәм паркет ф-калары нигезләнә, аларда 43 тән 133 кә кадәр кеше эшли. Такта яру тегермән - нәрен пар көче б-н эшләүче такта яру пр-тие - ләре алыштыра, 1888 гә аларның исәбе — җи - дегә, аларда эшләүчеләрнең саны 160 кеше - гә җитә. Беренче такта яру заводлары — бер - туган В. һәм А.Персоннар (Казан, 1894), Америка сәнәгатьчесе Э.В.Ропс (Яшел Үзән станциясе, 1899; к. *Яшел Үзән фанера заводы*), А.Лебедев, бертуган И. һәм А.Губиннар (Мамадыш өязенең Лубян а.) һ.б.ның пр-тиеләре барлыкка килә, аларның һәркайсында 50 дән 100 гә кадәр кеше хезмәт куя. 19 йөз ахырында Кама елгасында Чистай шәһәре тирәсендә баржада В.К.Багимовның пар көченә көйләнгән йөзмә такта яру з-ды эшли. Бу пр-тиеләрдә бүрәнә яралар, әрҗәләр, мичкә - ләр, чөйләр, такталар, пычкы чүбе, паркет, шкафлар, урындыклар, өстәлләр, тәрәзә рам - нары, ишекләр җитештерәләр. Бөгелмәле йорт җи һазлары ясау, шырпы, скипидар эш - ләү актив үсеш кичерә, поташ чыгару кими. Иң әре пр-тиеләр заказ буенча Мәскәү һәм Түбән Новгород механика з-дларында эш - ләнгән пар казаннары, машиналар, механизм - нар б-н җи һазландырыла. 1888 дә губернаның агач эшкәртү пр-тиеләрендә 304, 1913 тә 880 кеше эшли. 4,4 меңнән артык кеше агач әзерләү һәм аны беренчел эшкәртү б-н шө - гыльләнә. 400 мең сумлык продукция җи - тештерелә.

1918–20 дә У.,а.э.һ.ц.-к.с. пр-тиеләре национализацияләнә, аларның күбесе икътиса - ди кыенлыклар сәбәпле үз эшчәнлекләрен туктата. 1922 дә хуҗалык исәбе нигезендә «Татарстан урман сәнәгате тресты» (Урман тресты) оештырыла. Кыска вакыт эчендә ае - руча әре такта яру заводлары торгызыла, Яшел Үзән з-ды (элекке Ропс пр-тиесе) Бөтенроссия фанера тресты карамагына тапшырыла. Респ-када ягулык җитмәү сәбәпле, пр-тиеләр башлыча утын әзерләү б-н шө - гыльләнәләр. Агач материаллары җитештерү күләмнәре (мең куб футларда): 1923 тә — 2042, 1924 тә — 1587, 1925 тә — 2154, 1926 да — 2190. Урман тресты зыянга эшли, 1928 дә, төзелеш материаллары тресты б-н бергә, ул Урмансиликаттрест составына тапшырыла.

1928 дә респ-када урман фондын исәпкә алу уздырыла, урман хуҗалыгы оештыры - ла, урман эшкәртү сәнәгатенең яңа пр-тиеләрен төзү, булганнарын реконструкцияләү ко - лач җәя. Сугышка кадәрге бишьеллыкларда барлык процесслар да тулысынча механика - лаштырылган, илдәге иң зур 3 нче Идел буе фанера з-ды, ш.у. Мәскәү–Казан тимер юлы урман-агач эшкәртү з-ды, шпал әзерләү з-ды, Аракчино эшчеләр посёлогында такта яру комб-ты, Кайбыч урман-агач эшкәртү з-ды һ.б. төзелә. Васильево урман-агач эшкәртү комб-ты реконструкцияләнә, нәтиҗәдә анда җитештерү күләме 3 тапкыр арта. Агач өзер - ләү һәм эшкәртү б-н ш.у. Татлеспромсоюзның кооперация артельләре дә шөгыльләнә (1936 да 6989 эшче). 2 нче бишьеллык ахыры - на (1937) эшкә яраклы агач чыгару күләме 0,72 млн. $м^3$ ка, утын әзерләү — 1,6 млн. $м^3$ ка, такта материаллары җитештерү — 395 мең $м^3$ ка, фанера эшләү 54 мең $м^3$ ка җитә. 1913 ел б-н чагыштырганда, 1940 ка тармак - ның тулай продукция җитештерүе 21 тап - кыр арта. Респ-ка илнең фанера эшләү үзәк - ләренең берсенә әверелә. Бөек Ватан сугышы елларында тармак пр-тиеләре фронт ихтыяҗ - лары өчен эшлиләр: Яшел Үзән фанера з-ды Казанның 16 нчы авиация з-дын По-2 (У-2) самолётлары корпусларын эшләү өчен фа - нера б-н тәэмин итә, күп кенә пр-тиеләр чаң - гылар һ.б. эшләп чыгаруга күчәләр. Сугыш - тан соңгы чорда пр-тиеләр реконструкцияләнә, яңа техника б-н җи һазландырыла. 1950 ел - ларда агач эшкәртү пр-тиеләренең урнашу географиясе үзгәрә. Яңа, нефть чыгарылучы сәнәгый р-ннарда Урыссу һәм Бөгелмә агач эшкәртү комб-тлары, Бөгелмә, Чистай, Әл - мәт, Чаллы йорт җи һазлары ф-калары һ.б. пр-тиеләр төзелә. Казанда, Әлмәттә, Арчада агачтан төзелеш детальләре эшләп чыгаручы з-длар файдалануга тапшырыла. 1960 елларда Васильево урман-агач эшкәртү комб-тын - да пычкы чүбеннән плитәләр (ДСП) ясау үзләштерелә. *Чаллы картон-кәгазь комбинаты* сафка баса. 1929–80 елларда респ-када 15 тән артык агач эшкәртү комб-ты, йорт җи һазла - ры фабрикалары һәм фанера заводлары төзелә.

Татарстан урман запаслары чикле булган төбәкләргә керә, шуңа күрә 1956 дан агач әзерләү б-н урман ху җалыгы органнары һәм пр-тиеләре — урман хуҗалыклары (лесхоз - лар) шөгыльләнә (ТРда алар — 31). Респ-ка - да эшкә яраклы агач әзерләү күләмнәре үсә бара (табл. кара). Агач чималының 70–80% ы җирле пр-тиеләр тарафыннан кулланылып, аның калган өлеше Төньяк Кавказга, Украинага, Молдавиягә, Үзәк Кара туфраклы төбәк - нең төрле өлкәләренә озатыла. Нәтиҗәдә, 1970 еллар башына Татарстан урман кытлы - гы кичерүче төбәккә әверелә. 1988 дә респ-ка агач кертү 836 мең $м^3$ га, такта материал - ары кертү 213 мең $м^3$ га җитә. Агач чималы, башлыча, Коми, Мари, Удмурт респ-кала-

Урман, агач эшкәртү һәм целлюлоза-кәгазь сәнәгате продукциясенең төп төрләрен җитештерү

	1941	1960	1970	1980	1990	1995	2000	2004	2015
Чыгарылган агач күләме, мең $м^3$	1502	2893	2135	1926	1622	741,5	416,5	–	–
ш.и. эшкә яраклы агач мең $м^3$	507	1505,5	1170	1192	1056	704,1	317,5	347,5	533,6
такта материаллары, мең $м^3$	319	1373	1216	888	650	318,6	251,4	242,5	57,2
ябыштырылган фанера, мең $м^3$	43,3	80	95,1	61,6	72,4	63,8	74,7	94,7	–
пычкы чүбе плитәләре, мең $м^3$	–	0,005	53,7	89,6	115,3	10,5	–	–	–
катыргы, мең *т*	2,1	8,5	10,9	15,7	93,2	64,6	86,5	131	–
кәгазь, мең *т*	–	–	–	–	25	15	40	49,1	136,8

рыннан, Киров өлкәсеннән һ.б.дан кертелә. Урманнарның мәйданнары кимү аларның токым составы начараю б-н бергә бара, ылыслы агачлар һәм имән урманнары вак яфраклы агач урманнары б-н алышына. 2016 ның 1 гыйнварына Татарстанда урман фондының гомуми мәйданы 1236,4 *га* (терр-янең 17,5%ы), агач запасы 1 *га* га 164 $м^3$, 1 *га* га еллык үсеш 4,2 $м^3$ тәшкил итә.

Төп агач эшкәртү пр-тиеләре — «Идел буе фанера-йорт җи һәзлары комбинаты» ҖЧҖ, «Яшел Үзән фанера заводы» АҖ. Агач эшкәртү комб-тлары Түбән Кама, Чистай, Бөгелмә, Мамадышта, Яшел Үзән р-нының шәһәр тибындагы Васильево посёлогында, Лениногорск р-нының шәһәр тибындагы Шөгер посёлогында, Арча р-нының Яңа Кенәр, Азнакай р-нының Тымытык авылларында, кечкенә йорт җи һәзлары ф-калары Казан, Чаллы, Әлмәт, Чистай, Тәтеш, Алабуга, Бөгелмә шәһәрләрендә, Балтач р-нының Карадуган, Теләче р-нының Теләче, Мамадыш р-нының Келәүш авылларында, ш.у. Аксубай урман-агач эшкәртү комб-ты, Яшел Үзән шпал з-ды һ.б. эшли. Урман хуҗалыклары каршындагы ярдәмче цехлар (2002 дән — ҖЧҖ) такта материаллары, тәрәзә блоклары, паркет, сувенир продукция, йорт һәм хуҗалык корылмалары буралары җитештерәләр.

Респ-када целлюлоза-кәгазь продукциясе һәм катыргы әйберләр чыгаручы әйдәп баручы пр-тие — «Чаллы картон-кәгазь комбинаты» халык предприятиесе» АҖ. «Алабуга» аерым икътисади зонасындагы чит илләр катнашындагы пр-тиеләр МДФ-плитәләр, идән капламнары, кәгазь гигиена эшләнмәләре җитештерәләр.

Тармак продукциясе (башлыча, фанера һәм кәгазь) РФнең 40 тан артык төбәгенә, якын һәм ерак 18 чит илгә, ш.и. АКШ, Германия, Италия, Австрия, Испания, Мисыр һ.б. илләргә җибәрелә.

Агач эшкәртүче пр-тиеләр калдыксыз технологияләр булдыруга зур игътибар юнәлтәләр. Чималны тирән эшкәртүне тәэмин итүче җитештерү системаларын файдалануга, түбән сыйфатлы җирле агачны эшкәртү технологияләрен куллануга күчү башкарыла.

Тармак пр-тиеләре өчен техника һәм технологияләр эшләү б-н урман сәнәгатенең Идел-Кама фәнни-тикшеренү ин-ты шөгыльләнә (Казан). Инженер-техник кадрларны Казан аграр ун-ты, Казан технол. ун-ты һәм Лубян урман хуҗалыгы техникумы әзерли. Ш.у.к. *Агач әзерләү*.

Әд.: История Татарии в материалах и документах. М.–Л., 1937; Индустриализация ТАССР. 1926–1941 гг.: Док. и материалы. К., 1968; Рабочий класс Татарии. К., 1981; Промышленность и рабочий класс Татарии (1946–1980): Док. и материалы. К., 1986; Республика Татарстан. 1920–2000: Стат. сб. К., 2001.

К.Ф.Фәсхетдинов, С.Г.Белов.

УРМА́Н ЗӘ́Е елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Дала Зәе елгасының (Зәй) уң кушылдыгы. Озынлыгы 60,8 *км*, бассейнының мәйданы 812 $км^2$. Елга башы Әлмәт р-ны Кәске авылыннан көнчыгыштарак, тамагы Зәй шәһәреннән төньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 240 *м*, тамагыныкы — 63 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 25 %. У.З.нең 22 кушылдыгы бар. Аеруча зурлары: Багараж (21,5 *км*), Кече Ирнә (21,3 *км*), Мәлем (13,5 *км*) — уң кушылдыклар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,38 $км/км^2$. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–3 $л/с{\cdot}км^2$. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана.



Урман Зәе елгасы (Зәй шәһәре янында).

Елга режимын күзәтүләр Зәй р-ны Александр Бистәсе (Гуәрдин) авылы (1934–56) һәм Зәй шәһәре (1953–58) янындагы су үлчәгеч постларда алып барыла. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 103 *мм*, ташу агымы катламы 74 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,82 $м^3/с$. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 300–500 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк. Елга бассейнында суының гомуми күләме 2,2 млн. $м^3$ булган 4 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

УРМА́Н ИЯСЕ́, урман хуҗасы, Казан һәм Себер татарлары, башкортлар мифологиясендә һәм фольклорында түбән рухларның бер төре — *ия*; урман рухы — хуҗасы, *Шүрәле*. Көнчыгыш славяннар мифологиясе персонажы — лешийның аналогы.

Әд.: Урманче Ф.И. Татар халык иҗаты. К., 2002; Ендеров В.А. Проблемы классификации демонических персонажей: Учеб. пособие. Чебоксары, 2002.

Ф.И.Урманчеев.

УРМА́Н КОЗЛО́ВКАСЫ авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 29 *км* көнчыгышрак, Тоша елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 4 кеше (руслар) яши. 1930 елларда нигез салына. Оешкан көненнән Тәтеш р-нында. 1957 нең 30 октябреннән Буа р-нында. Халык саны: 1938 дә — 153, 1958 дә — 100, 1970 тә — 120, 1979 да — 40, 1989 да — 27, 2002 дә — 7 кеше.

УРМА́Н КҮГӘРЧЕННӘРЕ́, күгәрчен кошлар семьялыгыннан берничә кошлар ыругының гомуми исеме. Башка күгәрченнәрдән кечерәк (гәүдә озынлыгы 14–30 *см*, авырлыгы 150–200 *г*) булулары, муен каурыйларында һәм бүксәсендә металлсыман төсмернең юклыгы б-н аерылып тора, муенының ян-якларында буйлап төрле төсләргә кереп ялтырачы кара һәм ак төстәге таплар бар, күзләре тирәли кызыл кайма уза. ТР терр-ясендә ике төре бар: гади урман күгәрчене (Streptopelia turtur) һәм бөжралы урман күгәрчене (Streptopelia decaocto). Гади урман күгәрчене аеруча күп һәм еш очрый; ареалының төньяк чиге Көнчыгыш Европа тигезлегендә төньяк киңлекнең 60° на җитә.

У.к. — күчмә кошлар, майда киләләр, сентябрь ахырында китәләр. Кыр ышыклау урман полосаларында, урман буйларындагы агачларның горизонталь ботакларында (җирдән 2–5 *м* биеклектә) оя коралар. Гадәттә, ике йомырка салалар, гади урман күгәрчененнән аермалы буларак, бөжралы урман күгәрчене торак пунктлардагы агач ботакларына оялыйлар; муенындагы ярымбөжра бу кошның үзенчәлеге булып тора. Нигездә, культуралы үсемлекләр һәм чүп үләннәрнең орлыклары, сирәк кенә бөҗәкләр б-н тукланалар.

УРМА́Н КҮЛЕ́, Көнбатыш Кама алдында. Казанның Авиатөзелеш р-нының төньяк чигендәге урман массивында Коры елга үзәнендә урнашкан. Су өслегенең мәйданы 8,8 *га*. Суының күләме 130 мең $м^3$. Озынлыгы 700 *м*, киңлеге 100–150 *м*. Уртача тирәнлеге 1,5 *м*, иң зур тирәнлеге 2 *м* дан артыграк. Күл карст-суффозия процессы нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Формасы кысылган озынча түгәрәк, көньяк-көнбатыш өлешендә култык бар. Ярлары күтәренке, көнчыгыш өлешендә текәрәк. Күл аша йомшак Коры елга ага. Суы бик йомшак (0,9 *мг-экв/л*), аз минеральләшкән (100 *мг/л* га кадәр), гидрокорбанат-кальцийлы типта. Күл төбе грунты комсу-ләмле. Табан балык, кыслалар яши. Сирәк очраучы су үсемлекләреннән сусын үсә. Күл ял итү максатларында файдаланыла. Күл буенда «Каенлык» ял йорты һәм балалар сәламәтләндерү лагеры урнашкан.



Урман күле (Казан янында).

УРМА́Н КҮЛЕ́, Идел алдында. Коры Үләмә һәм Карамалы елгалары субүләрендә урнашкан, Кама Тамагы р-ны Олы Кариле авылыннан 2 *км* көньяк-көнчыгыштарак. Су өслегенең мәйданы 1,2 *га*. Су күләме 12,6 мең $м^3$. Озынлыгы 150 *м*, иң зур киңлеге 150 *м*. Уртача тирәнлеге 1 *м* тирәсе, иң зур тирәнлеге 1,8 *м*. Күл карст процессы нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Формасы озынча түгәрәк. Ярлары сөзәк, киң яфраклы урманнар б-н капланган. Туенуы җир асты сулары исәбенә, тотрыклы. Суы җиңелчә минеральләшкән




Урман күле. Кама Тамагы районы.

(62,7 *мг/л*), йомшак (2,8 *мг-экв/л*), аз рак болганчык. Ял итү максатларында файдаланыла. ТРның табигать истәлеге (1978).

УРМА́Н КҮЛЕ́, Көнбатыш Кама алдында. Лаеш р-нында, Мишә һәм Нокса елгаларының субүләрендә урнашкан, Питрәч р-ны Көек авылыннан 4 *км* көньяктарак һәм Лаеш р-ны Олы Кабан авылыннан 6 *км* төньяк-көнчыгыштарак. Су өслегенең мәйданы 4,7 *га*. Су күләме 249 мең *м*^{3}. Озынлыгы 470 *м*, иң зур киңлеге 100 *м*. Уртача тирәнлеге 5,3 *м*. Күл карст процессы нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Формасы озынча. Туенуы явым-төшемнәр һәм грунт сулары исәбенә. Суы йомшак (3 *мг-экв/л* тирәсе), җи ңелчә минераль ләшкән (70,8 *мг/л*), үтә күренмәле. ТРның табигать истәлеге (1978).

УРМА́Н КҮЛЕ́, Көнбатыш Кама алдында. Идел елгасының югары террасасында, Салман һәм Нохрат елгалары субүләрендә, Әлки р-ны Иске Баллыкүл авылында. Су өслегенең мәйданы 0,4 *га*. Су күләме якынча 16 мең *м*^{3}.



Урман күле. Лаеш районы.

Озынлыгы 85 *м*, иң зур киңлеге 65 *м*. Уртача тирәнлеге якынча 4 *м*, иң зур тирәнлеге 10 *м*. Күл карст процесслары нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Формасы түгәрәк. Туенуы җир астты сулары исәбенә, тотрыклы. Суы җи ңелчә минераль ләшкән, гидрокарбонат-хлорид-кальцийлы типта, нык болганчыклы, саргылт төстә. Үтә күренмәлелеге 7 *см*. Хуҗалык-көнкүреш максатларында файдаланыла.

УРМА́Н КҮЛЕ́, Көнбатыш Кама аръягында. Ашыт, Казансу һәм Питиял елгалары субүләрендә урнашкан, Биектау р-ны Ювас авылыннан 1,5 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кәрәкәле күленнән көнчыгыштарак. Су өслегенең мәйданы 0,68 *га*. Су күләме якынча 30 мең *м*^{3}. Озынлыгы 140 *м*, иң зур киңлеге 80 *м*. Уртача тирәнлеге 4,6 *м*, иң зур тирәнлеге 7 *м*. Күл карст процессы нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Формасы озынча түгәрәк. Көнчыгыш яктагы яры текәрәк һәм биек. Суы йомшак, җиңелчә минераль ләшкән, гидрокарбонат-хлорид-магнийлы типта. Үтә күренмәлелеге 120 *см*. Ял итү урыны.

УРМА́Н МОРКВАШЫ́ авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 14 *км* көньяк-көнбатыштарак, Морквашелгасы буенда. 2010 елда 52 кеше (руслар) яши. Казан ханлыгы чорында нигез салына. Беренче исеме — Морквашь. 1801 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тире эшкәртү һәм он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында У.М.нда Спас чиркәве (1786 да төзелә), земство мәктәбе (1867 дән эшләгән чиркәү-приход мәктәбе җирлегендә 1870 тә ачыла), тимерче алачыгы, йон тетү йорты, 7 тегермән,



Урман күле. Биектау районы.

4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1835 дис. тәэшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Югары Ослан волостенда, 1920 дән ТАССР-ның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Зөя, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1646 да — 120, 1782 дә — 234 ир-ат; 1859 да — 884, 1897 дә — 1032, 1908 дә — 1310, 1920 дә — 1253, 1926 да — 1363, 1938 дә — 1222, 1949 да — 1074, 1958 дә — 665, 1970 тә — 250, 1979 да — 136, 1989 да — 76, 2002 дә — 72 кеше.

Әд.: Верхний Услон: край родной, навек любимый... К., 2001.

УРМА́Н ҮРДӘГЕ́ (Gallinago media), чуллыклар семьялыгындагы кош. Европада һәм Азиядә таралган. Респ-ка терр-ясендә 20 йөзнең 1 нче яртысына кадәр кәсәбәчелек төре була, соңыннан саны кисәк кими, 1990 елларда беркадәр тотрыклана. Сазлыкларда, дымлы елга үзәннәрендә яши. Гәүдәсенең озынлыгы 35 *см* га кадәр, авырлыгы 200 *г* тирәсе. Каурый капламы кара бизәкле коңгырт-җирән төстә. Томшыгы бик озын, нәзек, туры. Кырый 16 ак койрык каурыйлары бар. Күчмә кош. Оясын куе үлән арасында яки түмгәкләрдә кора. Тимгелле 3 йомырка сала. Нигездә, сулачаннар, бөҗәкләр, әкәм-төкәмнәр б-н тукланалары ул озын томшыгы б-н туфракны чукып таба. Очып китү вакыты августтан октябрьга кадәр. Сунарчылык спорты объекты.

Әд.: Аськеев И.В., Аськеев О.В. Орнитофауна Республики Татарстан. К., 1999.

УРМА́Н ХУҖАЛЫГЫ́, халык хуҗалыгы тармагы; урманнарны өйрәнүне, исәп-хисап, яңадан торгызу, саклау, урманнардан файдалануны көйләүне башкара. Татарстан Россиянең аз урманлы төбәге санала. А.х. файдалануы өчен системалы рәвештә урманнарны чистарту, урманнарда зур янгыннар, климат факторлары (корылык, түбән темп-ра), сәнәгатьтә урманнардан күп файдалану, корабльләр төзү өчен агач әзерләү, урман фонды җирләрен сәнәгать һәм гражданлык корылмалары төзелеше өчен, ш.у. Куйбышев сусаклагычы һәм Түбән Кама ГЭСы тарафыннан су басу зоналары өчен актив куллану урманнарның кимүенә китерә. Элек Казан губернасы терр-ясенең күп өлешен урманнар били. Генераль межалау (ызан салу) мәгълүматлары буенча 1793–1803 елларда 3265,1 мең *га* урман исәпкә алына (губерна терр-ясенең 51,2% ын били). 2004 кә урманлылык ТР терр-ясенең 17,2% ын тәшкил итә. Урман фондының гомуми мәйданы 1269,5 мең *га*, ш.и. урман б-н капланган өлеше — 1144,4 мең *га* (90%), ясалма булдырылган урманнар мәйданы — 311 мең *га* (27%). Ылыслы агачлар — 265,2 мең *га* ны (23,3%), каты яфраклылар — 209,8 мең *га* (18,4%), йомшак яфраклылар — 649,8 мең *га* (57,1%) били. Урман утыртмалары яшь төркемнәре буенча бүленәләр: яшь урман — 391,1 мең *га*, урта яшьтәгеләр — 415,8, өлгереп килүчеләре — 167,6, өлгергәннәре һәм картлары (озак торганнары) — 162,8 мең *га* (картлары — 22,1). Урман утыртмаларының гомуми запасы 160,87 млн. *м*^{3} (18,8%) тәшкил итә. 1991 дән ТРда урманнарны яңадан торгызу урман кисү мәйданы 1,5–1,7 тапкыр артык булганда башкарыла. Ел саен 4,4 мең *га* мәйданда урман, 1,5 мең *га* мәйданда а.х. файдалану җирләрен саклаучы урман утыртмалары утыртыла; 1 мең мәйданда юл яны кардан саклаучы урман полосалары булдырыла; питомникларда 100 млн. данәдән артык стандарт утырту материалы, 60 тан артык агач-куак төрләре үстерелә. Урманнарда һәм урман б-н капланмаган дәүләт урман фонды җирләрендә агач һәм икенче дәрәҗәдәге урман материаллары (агач төпләре, кайры, кабык) әзерләү, урманнан өстәмә файдалану (печән чабу, терлекләрне көтү, умарталыклар урнаштыру, агач сулары (соклары) әзерләү, кыргый җимешләр, чикләвек, җиләк, гөмбә, дару үләннәре, техник чимал җыю), урманнан фәнни-тикшеренү һәм мәдәни-сәламәтләндерү максатларында, ау хуҗалыгы ихтыяҗлары өчен файдалану эшләре башкарыла. 1996 га кертелгән исәпле урман бүлемтеге 1371,7 мең *м*^{3} тәшкил итә, ылыслы хуҗалыклар буенча — 56,1 мең *м*^{3}, каты яфраклылар буенча — 105 мең *м*^{3}. 1998–2002 дә якынча 40% исәпле урман бүлемтекләре үзләштерелә (аннан файдаланып бетермәү картайган агачларның туплануына китерә һәм урман фондының сыйфат күрсәткечләрен түбәнәйтә). Гомумән, урман фонды буенча уртача агач үсеше 1 *га* га 3,7 *м*^{3} тәшкил итә, 1 *га* дан 1,2 *м*^{3} киселә.

Янгын куркынычы чыганаклары: автомобиль һәм тимер юллар челтәре, электр бирү-

нең югары вольтлы линияләре, газ эшкәртү пр-тиеләре, янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен бозу (97%), кырларда салам яндыру (3%). ТРда У.х. дәүләт идарә органы булып Урман хуҗалыгы министрлыгы санала. Респ-када 30 урманчылык исәпләнә (ху җалык гомуми мәйданы 1,1 млн. *га* урманнарда алып барыла). У.х. буенча кадрлар әзерләүне һәм квалификация күтәрүне Лубян урман хуҗалыгы техникумы, Казан а.х. академиясе гамәлгә ашыра. Ш.у.к. *Урманчылык, Агач әзерләү, Урман үрчетү.*

Әд.: Государственный доклад «О состоянии природных ресурсов и охраны окружающей среды Республики Татарстан в 2003 г.». К., 2004.

И.Н.Зарипов.

УРМА́Н ЧӘ́Е (Circaea), ике таҗ яфраклы чәчәк, кырлыганчалар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 12 төре билгеле, нигездә, Европа һәм Азиянең уртача поясында таралган. ТР терр-ясендә 2 төре бар: Альп У.ч. (C.alpina) һәм Париж У.ч. (C.lutetiana). Сирәк очраучы үсемлекләр. Киң яфраклы һәм ылыслы-киң яфраклы урманнарда очрыйлар. 10–50 *см* биеклектә, нәзек, шушшма тамырчалы. Яфраклары йөрәксыман яки эллипс формасында. Чәчәкләре вак, ак яки алсу төстә, оч яки куентылы чукларда. Җимеше — күп орлык-лы ачылучан тартмачык. Июнь–августта чәчәк ата. Җир өсте өлешләрендә кумарин, органик к-та һәм аларның тозлары бар. Халык медицинасында җәрәхәтләрне дәвалау өчен кулланыла. Декоратив, баллы үсемлек. ТР-ның Кызыл китабына кертелгән.

УРМА́Н ЧИШМӘСЕ́, комплекслы табигать тыюлыгы. Югары Ослан р-ны терр-ясендә урнашкан. 2002 елда табигать комплексларын саклау, биол. төрлелекне торгызу һәм саклау, хайваннар дөньясының хуҗалык өчен әһәмиятле һәм сирәк вәкилләрен яңадан булдыру, табигать шартларында ял итүне көйләү максаты б-н оештырыла. Мәйданы 6442 *га*. Идел буе урманчылыгының Шыланҗы (2504 *га*), Ключище (1741 *га*) урман фонды участок урманчылыкларын һәм башка категориягә караган җирләрне берләштерә. Ылыслы-киң яфраклы һәм киң яфраклы урманнар нарат, имән, юкә, каен һәм усактан тора. Үлән капламында ТРның Кызыл китабына кергән төрләр: чәйнәлгән какыча, известь мәкәсе, тау бөҗәк чәчәге, гади күке чәчәге, татар кашкарый үләне, нәфис сары мәтрүшкә, каз юасы, Париж урман чәе, кызыл серкәбаш, чын башмакчәчәк, чын оялаш уты, матур кылган, Европа казаягы, урман алмагачы һ.б. үсәләр. Тыюлык терр-ясендә кәҗәболан, кабан дуңгызы, поши, үр куяны һәм ак куян, төлке, тимгелле йомран; балыкчы карчыга, көртлек, бытбылдык, ак ябалак, байгыш, соры ябалак, һөд-һөд кошлар, бакыр елан, гади кара елан очрый. Ерым һәм сыза-ларда чишмәләр күп.

УРМА́Н ЧИШМӘСЕ́ елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Чишмә елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 52,1 *км*, ТРда якынча 40 *км*. Бассейнының мәйданы 700,5 *км*^{2}. Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгыннан ага. Елга башы Самара өлкәсендә, тамагы Лениногорск р-ны шәһәр тибындагы Зелёная Роща посёлогының төньяк чигендә. Елга башының абс. биеклеге 230 *м*, тамагыныкы — 104 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 30%. У.Ч.нең 23 кушылдыгы бар. Аеруча зурлары: Бор (12,3 *км*), Киса (15,9 *км*), Инеш (8,5 *км*) — уң кушылдыклар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,35 *км/км*^{2}. Туенуы катнаш, яртысыннан артыгы кар сулары исәбенә туры килә. Җир асты сулары б-н туену модуле 3–5 *л/с·км*^{2}. Гидрологик режимы ташу вакытында сулыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 138 *мм*, ташу агымы катламы 75 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь уртасында



Урман Чишмәсе елгасы.

туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 1,81 *м*^{3}*/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (20–40 *мг-экв/л*). Гомуми минераль әшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. Елга бассейнында суының гомуми күләме 1,1 млн. *м*^{3} булган 4 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

УРМА́Н ЧЫПЧЫКЛАРЫ́ (Prunella), урман чыпчыклары семьялыгыннан сайрак кошлар ыругы. 12 төре билгеле, Европа, Азия, Төньяк Американың уртача поясларында таралганнар. ТР терр-ясендә 3 төре бар. Себер урман чыпчыгы (P.montanella) — Кама елгасы тамагында очрый; кара муенлы урман чыпчыгы (P.atrogularis) — көзге очып үтүләр вакытында, нигездә, Кама һәм аның кушылдыклары Мишә һәм Ык үзәннәрендә күренә; урман чыпчыгы (P.modularis) аз санда оялый, аны, гадәттә, көзге очып китүләр вакытында күрергә була. У.ч.ның гәүдә озынлыгы 17 *см* га кадәр, авырлыгы 20 *г* тирәсе. Арка һәм канатлары кара таплы җирән-көрән төстә, муены һәм күкрәге соры, бүксәсе аксыл, койрыгы көрән. Томшыгы нәзек, томшык өстенең очы берникадәр яссы һәм түг әрәк. Оя-ларын куакларда, агачта яки үлән арасында кора. Яшелсу-зәңгәр 4–6 йомырка сала. Бөҗәкләр, үрмәкүч, вак моллюсклар, көзен җиләкләр һәм орлыклар б-н туклана.

УРМА́Н ШӨЛДИЕ́, к. *Тәлләтәвеч.*

УРМА́Н-АГА́Ч ЭШКӘРТҮ́ КӘСЕПЧЕЛЕГЕ́, урман кисү һәм чыгару, көнкүреш өчен кирәкле агач әйберләр җитештерү, мунчала-курыс чыгару, дегет һәм скипидар куу (к.*Сумала куу кәсепчелеге*), селте (к.*Селте-поташ кәсепчелеге*), агач күмере әзерләү һ.б. б-н бәйле эшчәнлек. Казан губернасы терр-ясендә 16 йөз ахырында — 17 йөз башында барлыкка килә. 19 йөздә көчле үсеш ала. Курыс җитештерүдә — Казан өязе Олы Караужа авылы, мунчаладан бау ишүдә — Спас өязе Чуаш Кичүе авылы (әлеге кәсеп ш.у. Казан һәм Мамадыш өязләрендә киң тарала; продукция алыпсатарлар аша Казан з-дларына һәм Түбән Новгород ярминкәсенә; бер өлеше җирле базарларга җибәрелә); юкә курысыннан бау ишүдә — Спас өязе Урта Йорткүл авылы (продукция Казанга әзер тиреләрне җыеп төрү өчен күн эшкәртү з-дларына, сал бәйләү өчен урман сәнәгатьчеләренә һәм күп өлеше Түбән Новгород ярминкәсенә җибәрелә), чабата үрүдә — Тәтеш өязе Олы Тояба һәм Спас өязе Иске Бәрән авыллары (татарлар үргән чабаталарның башы туры, теләсә нинди аякка яраклы, тузып беткән табанын гына алыштырырга мөмкин; рус крәстияннәренең матур итеп үрелгән чабаталары кыйммәтрәк йөри; шуңа күрә татарлар үргән чабаталарга ихтыяҗ зуррак), өрлек-борыслар ясауда — Зөя өязе Норлат авылы; чыпта-каплар үрүдә Казан һәм Мамадыш өязләре (эшләүчеләр саны буенча иң күп таралган кәсеп, милли «төсмер»гә ия: Түбән Иделдә ашлык ташу өчен «татарлар эшләгән» капларны файдаланганнар) җитештерү үзәкләренә әверелә. Кәсепчелек б-н, башлыча, аерым гаиләләр шөгыльләнгән. Крәстиян хуҗалыкларында зур күләмдә балта эшләре (йорт, тегермән, мәчет, кое бураларын бурау, аеруча Көнбатыш Кама аръягында киң тарала) һәм агач эше (җи һәзлар, тәрәзә рамнары һ.б. ясау эше азрак тарала, Мамадыш, Казан һәм Спас өязләренең аерым авылларында) б-н шөгыльләнәләр, такта яру, чана һәм арба, ху җалык һәм а.х.кораллары, йорт кирәк-яраклары һәм савыт-саба җитештерелә (к. *Мичкә-кисмәк кәсепчелеге, Экипажлар ясау кәсепчелеге*). У.-а.э.к. өчен чимал табу масштабы шулкадәр зур була ки, 19 йөз уртасына Казан губернасының төньяк өязләрендә юкә запасы сизелерлек кими, шул сәбәпле курыс һәм мунчаланы Вятка һәм Уфа губерналарыннан китертә башлыйлар. 19 йөз уртасында Казан өязеннән Казанга ел саен күбрәк татар һөнәрчеләре тарафыннан эшләнгән 200 меңнән артык чыпта һәм кап җибәрелә. У.-а.э.к. керемнәре зур булмый, чөнки чимал алу һәм продукцияне сату эше арадашчылар аркылы башкарыла (Урман уставының 235 нче маддәсендә агачтан эшләнгән әйберләргә пошлина түләү турында искәртелә, шул сәбәпле крәстияннәр үз товарларын алыпсатарларга ярты бәясенә сатып җибәрергә мәҗбүр булалар). 19 йөз ахырында мондый һөнәр-кәсепчелек б-н Казан губернасында 50 меңнән артыграк кеше шөгыльләнә. 20 йөз башында У.-а.э.к. әкренләп капиталистик кооперациягә һәм таралган мануфактурага әверелә. Нәтиҗәдә, аерым һөнәрчеләр продукция

сатудан читләшәләр, яллы эшчеләргә әйләнәләр.

Әд.: Х а л и к о в Н.А. Хозяйство татар Повожья и Урала (середина XIX — начало XX в.). К., 1995; ш у л у к. Промыслы и ремёсла татар Поволжья и Урала. К., 1998. *Ф.Г.Кәлимуллина.*

УРМАНА́Й авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 20 *км* көнчыгыштарак, Эстәрле елгасы буенда. 2010 елда 607 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Яңа Урманай исеме б-н дә билгеле. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар, типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 мәчет, су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 6311 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Чәкән волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 20 октябреннән — Азнакай, 1957 нең 8 июненнән — Тымытык, 1958 нең 16 июленнән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1795 тә — 101, 1822 дә — 144 ир-ат; 1859 да — 886, 1889 да — 1258, 1897 дә — 1373, 1910 да — 1277, 1920 дә — 1658, 1926 да — 1268, 1938 дә — 1093, 1949 да — 774, 1958 дә — 529, 1970 тә — 565, 1979 да — 402, 1989 да — 608, 2002 дә — 619 кеше.

УРМАНАСТЫ́, к. *Подлесный.*

УРМАНАСТЫ́ ЙОРТКӨ́Л авылы, Спас р-нында, Болгар шәһәреннән 56 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Ульянов өлкәсе б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 103 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында У.Й.дә мәчет, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1428,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Йорткүл волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1935 нең 10 февраленнән — Кузнечиха, 1960 ның 28 октябреннән — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1991 нең 4 октябреннән Спас р-нында. Халык саны: 1859 да — 398, 1897 дә- 575, 1908 дә — 602, 1926 да — 350, 1938 дә — 452, 1949 да — 249, 1958 дә — 255, 1970 тә — 222, 1979 да — 190, 1989 да — 149, 2002 дә — 130 кеше.

УРМАНАСТЫ́ ҮТӘМЕ́Ш авылы, Чирмешән р-нында, Чирмешән авылыннан 17 *км* көнчыгыштарак, Үтәмеш елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 223 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, чөгендер үстерү, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1760 елларга кадәр нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Югары Чишмә, Яңа Үтәмеш исемнәре б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә, лашманлык йөкләмәсен үти. 20 йөз башында 2 мәчет, 5 сәүдә-сәнәгать йорты эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2935 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Мордва Афонькәсе волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Шөгер, 1935 нең 10 февраленнән — Беренче Май, 1963 нең 1 февраленнән — Лениногорск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Чирмешән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 91 ир-ат; 1795 тә — 275, 1859 да — 736, 1889 да — 1165, 1910 да — 1775, 1920 дә — 1741, 1926 да — 886, 1949 да — 944, 1958 дә — 874, 1970 тә — 802, 1979 да — 598, 1989 да — 305, 2002 дә — 290 кеше.

УРМАНАСТЫ́ ШОНТАЛЫСЫ́ авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 33 *км* көньяк-көнчыгыш-тарак, Шонталы елгасы башланган урында урнашкан. 2010 елда 425 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1710 нан Шонталы Пүчинкәсе исеме б-н билгеле. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Иске Шонталы буларак та мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1730–40 елларда У.Ш. халкының күпчелеге ирексезләп православие диненә күчерелә (исламга 1850 ләрдә генә кайта). 20 йөз башында 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1768 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Кызылъяр волостенда, 1920 дән ТАССРның — Спас, 1925 тән Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чистай, 1935 нең 10 февраленнән — Биләр, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1782 дә — 126 ир-ат; 1859 да — 528, 1897 дә — 883, 1908 дә — 987, 1920 дә — 1141, 1926 да — 756, 1938 дә — 827, 1949 да — 779, 1958 дә — 811, 1970 тә — 875, 1979 да — 706, 1989 да — 464, 2002 дә — 488 кеше.

УРМАНАСТЫ́-ШИГАЛИ́ авылы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 16 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Чуаш Респ-касы б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 203 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 17 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы удел (1797 гә кадәр — сарай) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 718,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Үби волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1859 да — 266, 1897 дә — 483, 1913 тә — 647, 1920 дә — 711, 1926 да — 686, 1938 дә — 612, 1949 да — 566, 1958 дә — 520, 1970 тә — 340, 1979 да — 346, 1989 да — 231, 2002 дә — 239 кеше.

УРМА́Н-ДАЛА́ ЗО́НАСЫ, урман һәм дала зоналары арасында күчмә табигый зона. Күбесенчә Төньяк ярымшарның уртача поясында таралган. Евразиядә У.-д.з. Карпатның көнчыгыш тау алдыннан Алтайга кадәр көнбатыштан көнчыгышка таба тоташ полоса булып сузыла, көнчыгыштарак (Урта Себер, Байкал аръягы, Ерак Көнчыгыш) таулар арасындагы казанлыклар һәм зур елга үзәннәре өчен типик күренеш. Татарстанда У.-д.з. Кама аръягы терр-ясен, Идел алдының көньяк өлешен били.

У.-д.з. өчен карлы салкын кыш, җылы һәм чагыштырмача дымлы җәй хас. Язын кар сулары эрү нәтиҗәсендә елгаларның ташуы, җәен су кимегәнлектән урыны-урыны б-н кибүе күзәтелә. Соры урман туфраклары, кара туфраклар (көлсуланган, селтесезләнгән һәм типик), урыны-урыны б-н болын-кара туфраклар, катыр һәм солодлашкан туфраклар таралган. Туфраклар гумус күләменең



Урман-дала участогы. Апас районы.

югары булуы, үсемлек коелдыкларының ак-рын минеральләшүе, нык структуралары б-н аерылалар. Туфракның югары табигый уңдырышлылыгы аларны а.х. өлкәсендә киң кулланырга мөмкинлек бирә, әмма чамадан тыш күп кенә районнарда көчле туфрак эрозиясенә китерә.

У.-д.з.ның табигый үсемлекләр дөньясы зур булмаган урман массивларының далаланган болыннар һәм болынлы дала участоклары б-н чиратлашуыннан гыйбарәт. У.-д.з.ның Европа өлешендә урман үсемлекләре составында имән, юкә, ш.у. көнбатышта корычагач (Татарстан терр-ясе буйлап ареалының төньяк-көнчыгыш чиге уза) һәм күгәгач, Себердә каен, усак, карагай һәм нарат үсә. Урман үсемлекләре еш кына субүләргә туры килә. Табигый үләнчел үсемлекләр, башлыча, саклаулы терр-яләрдә, елга үзәннәре, ерым һәм сыза сөзәкләкләрендә сакланганнар. Алар өчен үсемлек төрләренең төрлелеге, тамырчалы кыяклыларның һәм төрле төс-тәге үсемлекләрнең күплеге хас. Кыяклыларның гадәти вәкилләре — йонча, солыча, күрән, нечкә сабак, кылганнар үсә. Урман (мәс., тиен, ак куян, поши) һәм ш.у. дала (ш.и. үр куяны, зур кушаяк, йомраннар) хайваннары төрләре яши.

У.-д.з. — аеруча үзләштерелгән һәм кеше күп яши торган терр-я. А.х. тармакларының көчле үсеше нәтиҗәсендә, кеше тарафыннан У.-д.з.ның табигый шартлары нык үзгәргән.

УРМАНДӘЙ авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 20 *км* төньяктарак, Саурыш елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 578 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында У.дә чиркәү-приход мәктәбе (1898 дә ачыла), 2 тегермән, 2 вак-төяклəр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1305 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Яңа Әдәм волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1859 да — 39, 1897 дә — 734, 1908 дә — 931, 1920 дә — 813, 1926 да — 932, 1938 дә — 720, 1949 да — 887, 1958 дә — 709, 1970 тә — 814, 1979 да — 821, 1989 да — 574, 2002 дә — 495 кеше.

УРМАНЛЫЛЫ́К, терр-янең урман б-н капланган дәрәҗәсе; урманнар биләп торган мәйданның гомуми терр-ягә (ил, респ-ка, район) нисбәте. Язма чыганаклар буенча борынгы заманнарда Татарстан терр-ясенең шактый өлеше урманнар б-н капланган була. Әмма халкы, нигездә, урман-далалы Кама аръягында яшәгән Идел буе Болгар дәүләтендә 10–13 йөзләрдә үк игенчелек һәм терлекчелек үсеш ала, һәм бу терр-янең урмансызлана башлавы б-н бәйле. Монголлар Идел буе Болгарын басып алганнан соң (1237), Кама аръягы халкының бер өлеше, урнашу һәм а.х. җирләре өчен участокларны чистартып, төнякгы урманлы далаларга күченә. Казан ханлыгы чорында, башлыча, Казан артында шактый гына торак пунктлар барлыкка килә, шул сәбәпле урманнарның бетерелүе дәвам итә. Казан ханлыгы яулап алынганнан соң (1552), урманнар аеруча күпләп юк ителә. Казан тирәсендә һәм зур елга үзәннәрендә яшәүче төп халык үзләштерелмәгән урманлы ерак җирләргә куыла. Казан губернасы буенча 1838 елдан йозьеллык ахырына кадәр крәстияннәрнеке булган 604 мең *га* дан артык урман-нар чистарту өчен билгеләнә. Мамадыш, Казан, Лаеш, Чистай, Спас, Тәтеш һәм Зөя өязләрендә урманнарны бетерү аеруча тиз бара. Казан губернасы терр-ясендә Генераль ызанлау (1793–1803) вакытында 3265,1 мең *га* урман исәпкә алына, У. 51,2% тәшкил итә. 1914 елга урман мәйданы 1854 мең *га* га, У. 29,1% ка кадәр кими. Со ңыннан Мари һәм Чуаш респ-каларына күчкән Царёвококшайск һәм Чабаксар өязләренең (аларның У.ы хәзер дә югары — 55,6 һәм 31,3%) Казан губернасы составына кергәнлеген исәпкә алып, Татарстан составындагы терр-ялəрнең У.ы 29% тан шактый ким булган диярга мөмкин.

1922–28 дә респ-када тагын 54,3 мең *га* урман мәйданы торак пунктлар өчен биреләе. 1928 дәге урман фонды исәбе мәгълүматлары буенча урман б-н капланган мәйдан 1029,9 мең *га* тәшкил итә, терр-янең У.ы — 15,2%. 1953 ел мәгълүматлары буенча У. — 17,1%. Куйбышев сусаклагычын төзегәндә, урманнарны бетерү нәтиҗәсендә У. 15,8% ка кадәр кими. 1970 елларда 28,3 *га* урман җирлəре Түбән Кама сусаклагычына бирелə. Аннан тыш сәнәгать һәм гражданлык төзелеше, нефть чыгару һ.б. максатлар өчен дәүләт урман фондыннан 56 мең *га* дан артык җир алына. Шушы чор эчендә а.х. җирләрендә урман хуҗалыгы тарафыннан булдырылган якынча 50 мең *га* урман фондка алына. 2004 кə урманнарның гомуми мәйданы 1270 мең *га* дан артык тәшкил итə, У. — 17,2%. Терр-я буенча У. нык үзгəрə — Чүпрәле һәм Әтнә р-ннарында 2,6 дан һәм 3,4%, Зәй һәм Нурлат р-ннарында 26,9 га кадəр һəм 40,3%. Терр-янең экологик тотрыклылыгын билгеләүче оптималь У. 25% тан (тигезлекле Кама аръягы һәм Идел алды районнары) 30% ка кадəр һəм артыграк (калкулыклы, ергаланган рельефлы Идел алды һəм Кама алды районнары), респ-ка буенча уртача 27,8% тәшкил итə. Ш.у.к. Агач өзерлəү.

Әд.: Г а я н о в А.Г. Леса и лесное хозяйство Республики Татарстан. К., 2001.

Ә.Һ.Газизуллин.

УРМА́НОВ Борис Әхмәт улы (24.6.1939, Украина Респ-касының Хмельницкий өлкәсе Славута ш.), авиация генерал-майоры (1986). Ейск очучылар хәрби авиация уч-щесен (1959), Ю.А.Гагарин исем. Хәрби-Һава академиясен (Мәскәү өлкәсенең Монино шт‌п, 1973) тәмамлый. 1977–83 елларда Киев хәрби округында истребительләр полкы командиры, авиация берләшмәсе команды урынбасары, командиры; 1983–86 да Төркестан хәрби округы Хәрби Һава Көчләре командующие урынбасары, штаб башлыгы урынбасары. 1988 дән РФ Хәрби Һава Көч-ләре авиация берләшмәсе штабы башлыгының урынбасары. 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» ордены, медальләр б-н бүләкләнə.

УРМА́НОВ Илдар Илһам улы (15.3.1961, Ташкент), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1997), проф. (1999). Мәскәү автомобиль-юллар төзү ин-тын (1983), Бөтенроссия тышкы сәүдә академиясен (1992) тәмамлый. 1985–2009 елларда «КамАЗ» АҖдə (бүленеп, 2001–2003 тə Горький һəм Урал автомобильләр з-дларында: «ГАЗ» АҖдə экспорт буенча департамент директоры, 2003 тəн «УралАЗ сəүдə йорты» ҖЧҖнең директор урынбасары). 1992 дән бүлек мөдире. «КамАЗ-экспорт» фирмасы директоры урынбасары, 1996 дан Маркетинг һəм сату дирекциясе директоры, 1997–2000 дə директорлар советында стратегик үсеш ком-ты рəисе, 2003 тəн стратегик үсеш хезмəте җитəкчесе, 2006 дан ген. директорның дəүлəт структуралары б-н эшлəү буенча урынбасары. 2009 дан «Вольво Восток» (Мəскəү) АҖнең продукт һəм коммуникацияләрне үстерү директоры. Бер үк вакытта, 1999 дан, Кама политехник ун-тының тышкы икътисади эшчәнлек б-н идарə итү каф. профессоры. Хезмəтлəре автомобильлəр төзү сəнəгатендə идарəне һəм инвестиция хезмəттəшлеген оештыру мəсьəлəлəренə багышлана. У. машиналар төзелеше пр-тиеләрендə тышкы икътисади эшчəнлек б-н идарə итүнең структураларын һəм механизмнарын формалаштыруның методологик нигезлəрен эшли. Медаль б-н бүлəкләнə.

Х е з м.: Комплексный технологический процесс — объективная основа финансово-промышленной группы // Рос. эконом. журн. 1994. № 4; Инвестиционное сотрудничество в автомобильной промышленности: Стратегическое управление. К., 1996; Международные инвестиционные проекты в отечественном машиностроении // Рос. эконом. журн. 1996. № 8.

Ф.С.Зыятдинов.

УРМА́НЦЕВ Юнир Габдулла улы (28.4.1931, БАССРның Эстəрлетамак ш.), философ, биолог, биол. фән. канд (1963), филос. фән. д-ры (1976). Мəскəү ун-тының филос. (1954) һəм биол.-туфрак (1959) ф-тларын тəмамлый. 1960–2008 елларда РФАнең К.А.Тимирязев исем. Үсемлекләр физиологиясе ин-тында, 1990 нан əйдəп баручы фəнни хезмəткəр. Хезмəтлəре биол., матем., филос., экология, тарих фəннəренə карый. У. гамəли симметрияләштерүче факторларның (уңлык һəм суллык булдыручы), эзлексез үсеш кануннарының (үсешнең күпьяклы симметриясен), хаос, поли- һəм изоморфизм системалары теорияләрен эшли. «Почёт билгесе» ордены б-н бүлəкләнə.

Х е з м.: Симметрия природы и природа симметрии. М., 1974; Девять плюс один этюд о системной философии. Синтез мировоззрений. М., 2001; Эволюционика или общая теория развития систем природы, общества и мышления. М., 2009.

Әд.: А л е к с е е в П.В. Философы России XIX–XX столетий: Биографии, идеи, труды. М., 1995.

УРМАНЧЕ́ Бакый (Габделбакый) Идрис улы (10.2.1897, Казан губ., Тәтеш өязе Күл Черкене а. — 6.8.1990, Казан), нəкышьче, сынчы, график, педагог, ТАССРның һəм РСФСРның халык рəссамы (1960, 1982). Проф. татар нəкышенə нигез салучыларның берсе. Авыл мулласы гаиләсендə туа, башлангыч белемне өендə ала. Казандагы «Мөхəммəдия» мəдрəсəсендə укый (1907–14), 1915–16 елларда Тамбов губернасының Ша-ча өязе Татар Тарханы мəктəбендə мөгаллимлек итə. 1916–17 дə — Россия армиясендə, беренче рəсем һəм нəкышь дəреслəрен Казакъстанда хезмəт иткəндə, андагы австрияле хəрби əсирлəрдən ала. 1917–19 да Глазов һəм Тəтеш шəһəрлəрендə мəгариф халык комис-ты инструкторы, бизəү эшлəре б-н шөгыльләнə (бəйрəм демонстрацияләре, клублар, мəктəпләр). 1919–20 дə Казан иреклe сəнгать остаханəлəрендə (нəкышътән — Тимофеевта, скульптурадан — Г.А.Козловта, графикадан — Н.С.Шикаловта) укый. Бер үк вакытта Респ-каның Запастагы Армия штабы сəяси бүлегендə һəм Үзəк мөселман хəрби коллегиясендə эшли; ул бетерелгəнəн соң (1920), Мəскəүгə Революцион хəрби советка күчерелə. 1920–26 да Мəскəүдəге Югары сəнгать-техника остаханəлəренең (ВХУТЕМАС) берьюлы ике бүлегендə — нəкышь (С.В.Герасимовта һəм А.В.Шевченкода) һəм скульптура (Б.Д.Королёвта) бүлекләрендə укый. Аларны 1926 да тəмамлаганнан соң, Казан сəнгать-театр техникумында укы-

тучы, уку-укыту бүлеге мөдире булып эшли, керәч өйрәнү остаханәсен оештыра. У. талантлы шәкертләр әзерләп чыгара (М.*Абдуллин*, М.*Кәримов*, Г.*Йосыпов*, Ш.*Мөхәммәт җанов*, М.Рахманкулов, М.*Әмир*, М.*Сутюшев* һ.б.). 1920 дә Татар мәдәнияте йортында сәнгать секциясен җитәкли, гарәп графикасы шрифтын камилләштерү комиссиясе эшендә катнаша. У. иҗатының чишмә башы — татар җәдитчелеге. Европа нәкышьче алымнарын үзләштерү б-н бәйле. 1920 елларда станлы нәкышь һәм китап иллюстрацияләү өлкәсендә иҗат итә. Аның «Сепаратор янында», «Бикбулатов портреты» (икесе дә — 1927), «Көймә кичүендә» (1928), «Татар хатын-кызы», «Җилкәнле көймәләрдә йөрү», «Сары күлмәкле кыз» (барысы да — 1929) һ.б. картиналары совет һәм татар нәкышенең алтын фондына кергән. Г.Тукайның беренче булып У. тарафыннан бизәлгән «Шүрәле» китабы 1923 тә Казанда дөнья күрә. Шул ук елларда Татарстанның беренче гербы эскизын иҗат итә (керәчтә). 1927 дә И.Сталинга 82 кеше исеменнән язган хатка кул куя. Шуның өчен 1929 да кулга алына, 1930 да «милли дошманлык җәелдергән өчен» 5 елга лагерьларга ябылуга хөкем ителә, тоткынлык срогын 1933 кә кадәр Соловки утрауларында үткәрә. 1990 да аклана. 1933–41 дә Мәскәүдә яши, «Бөтенроссия сынлы сәнгать хезмәткәрләренең кооперация ширкәте берлегендә» («Всекохудожник») эшли. 1937 дә Мәскәү рәссамнар берлегенә кабул ителә, яшь рәссамнарның 1 нче Бөтенсоюз күргәзмәсендә катнаша (аның графикасы «Творчество» ж-лында һәм «Комсомольская правда» г-тасында репродукцияләнә). 1937–41 дә Мәскәүдә Бөтенсоюз а.х. күргәзмәсендә БАССР (К.Ә.Дәүләткилдиев б-н берлектә), Карел-Фин ССР, механикалаштырылган а.х. машиналары, терлекчелек павильоннарын бизи (дивар бизәкләре, скульптура). 1941–52 дә һәм 1953–56 да У. Алма-Атада, 1952–53 тә — Сәмәркандта, 1956–58 дә Ташкентта яши; Театр-сәнгать ин-тында укыта, ин-тка нигез салган көннән башлап, үз башлангычы б-н оештырылган скульптура остаханәсенә җитәкчелек итә. 1958 дә ТАССР хөкүмәте чакыруы буенча У. Казанга әйләнеп кайта.

Казакъстанда яшәгән вакытында респ-кадагы күренекле эшлеклеләрнең нәкышь һәм скульптур портретлары галереясын, пейзажлар, натурадан төшерелгән этюдлар иҗат итә; казакъ авторларының (Абай, М.Ауэзов, С.Муканов) әсәрләренә, халык әкиятләренә, Г.Тукайның казакъ теленә тәрҗемә ителгән шигырьләренә иллюстрацияләр ясый. Үзбәкстанда аның тарафыннан «Йөзем җыю» (1951), «Бану» (1952), «Карт мираб портреты» (1952) кебек үзенчәлекле сюжетлы картиналар, портретлар, пейзажлар, скульптура әсәрләре (Г.Тукай бюсты, Алма-Атада Виноградовка һәйкәл, Балхаш бакыр эретү з-дын монументаль-декоратив бизәү) иҗат ителә.

У.ның Казан чорындагы җитлеккән һәм күпкырлы иҗаты сынлы сәнгатьтә һәм, тулаем, респ-каның мәдәнияте үсешендә яңа бер баскыч буларак бәяләнә. Әйдәп баручы скульптор (100 дән артык әсәр авторы). Урал мәрмәреннән, бронзадан, гипстан татар мәдәнияте эшлеклеләре: Г.Тукай (1959, 1964, 1980, 1981), Н.Исәнбәт (1959), Ф.Әмирхан (1961), М.Җәлил (1962), Кол Гали (1965), Ш.Бабич (1966), Дәрдемәнд (1967), Ш.Мәрҗани (1968), К.Насыйри (1970), С.Сәйдәшев (1985, 1999) һ.б.ның портретлары галереясын (бюстлар, ярымфигуралар) барлыкка китерә. Агачтан эшләнгән күләмле сәнгать әсәрләрен югары сәнгать дәрәҗәсенә күтәрә. Аның «Г.Ибраһимов» (1963), «Сагыш» (1966), «Язгы моңнар» (1968), «Тулпар» (рельеф, 1968), «Сөембикә» (1978), «Нияз (Тугрылык)» (1980), «Нәфисә» (1981) сыннары татар скульптурасының классик үрнәкләренә әверелә. Казанда М.Җәлилгә, Түбән Камада һәм Менделеев р-нының Песәй авылында Г.Тукайга, Мамадыш шәһәрендә Ш.Маннурга куелган монументаль һәйкәлләр, Яңа Кырлайда *Габдулла Тукайның музей-комплексы* архитектур-сәнгать ансамбле (Г.Тукай һәйкәле, агачтан скульптура паркы һәм Ш.Фәрхетдинов б-н автордашлыкта архит-ра чишелеше) авторы.



Бакый Урманче.

У. станлы нәкышькә (барлыгы якынча 300 картина иҗат итә) татар халык сәнгате һәм шәрекъ миниатюралары традицияләренә нигезләнгән образлы күзаллауны өсти. 1970 еллар ахырында аның нәкышь иҗатындагы иң югары казанышы булган «Татарстан» триптихында (1976, 1985) ышанды-рырлык камиллеккә ирешкән «Печән базары» (1975), «Истәлекләр» картиналар циклыннан (1978–79) «Урал-тау итәгендә», «Күл Черкен. Атлар коендыру», «Сабан туе», «Салтыкта печән өсте» әсәрләре барлыкка килә. У. — психол. портретлар остасы; фән, мәдәният вәкилләре, хәрби эшлеклеләр, табиблар — Ф.Кудашева, С.Кудаш, К.Вәлиев, Д.Тумашева, С.Рәфыйков, Ф.Әхмәтова, Г.Сафиуллин һ.б. бик күпләр образларының зур күләмле галереясын барлыкка китерә. У.ның графика мирасы (акварель, каләм, кыл-каләм, күмер, сангина б-н ясалган рәсемнәре) 3 меңнән артык хезмәтен үз эченә ала. Г.Тукайның «Шүрәле» поэмасына гына да ул 100 дән артык график сәхифә багышлый, аның «Кисекбаш» поэмасына, Дәрдемәнд шигырьләренә (1954–68), «Коркыт» эпосына (1972), «Сак-Сок» бәетенә (1973) илл. сериясе иҗат итә. Татар мәдәнияте эшлеклеләре портретлары сериясе (Х.Туфан, Ч.Әхмәров, Г.Бәширов, Ә.Еники, Г.Шамуков һ.б.), «го-хуа» кытай нәкыше традицияләрендә башкарылган станлы картиналар циклы (1976–86) һ.б. авторы. У.ның хаттатчылык өлкәсендәге осталыгы кәгазьдә башкарылган шәмаилләрдә чагылыш таба («Аятел-Көрси», акварель, тушь, бронза, 1989). Монументаль дивар бизәкләре (Г.Тукайның Казандагы әдәби-мемориаль музее өчен «Печән базары»), У.Хаҗибәковның «Аршин мал алан» (1942), К.Тинчуриннның «Беренче чәчәкләр» (1959) спектакльләренә театр декорацияләре; татар сәхнә костюмнары (1939–75) эскизлары эшли. Казан ун-тында гарәп каллиграфиясен укыта. Шигырьләр, хатирәләр, әдәби-тәнкыйть хезмәтләре авторы.

100 дән артык күргәзмәдә (1934 тән): 1930 елларда Мәскәү рәссамнары күргәзмәсендә, Алма-Ата, Караганда һ.б. шәһәрләрдә казакъ рәссамнарының респ-ка күргәзмәсендә (1942–53), Татарстан сәнгате күргәзмәсендә (1952–53), Үзбәкстан рәссамнары күргәзмәсендә (1957–87), «Советская Россия» күргәзмәсендә (1960), Мәскәүдәге бөтенсоюз «Индустрия социализма» (1939), «Героический фронт и тыл» (1943), Совет рәссамнарының 1 нче бөтенсоюз съездына (1957), «Театр, кино һәм телевидение рәссамнары» (1967) күргәзмәләрендә; халыкара совет сынлы сәнгате күргәзмәсендә (Дәһли, Калькутта, Бомбей, 1952), «Зур Идел» күргәзмәсендә (1980 нән) катнаша.


Шәхси күргәзмәләре 1958, 1982 (Алма-Ата), 1983 (Балхаш, Тимертау ш.), 1985 (Түбән Кама ш.); 1967–2007 (Казан, юбилейлар б-н бәйле), 2012 (Третьяков галереясы, Мәскәү) елларда уздырыла.

У.ның әсәрләре Россиянең 20 дән артык музеенда, элеккеге СССР илләрендә, ш.и. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәгендә, ТРның Милли музеенда, А.Кастеев исем. Казакъстан дәүләт сынлы сәнгать музеенда (Алма-Ата), Шәрекъ халыклары сәнгате музеенда (Мәскәү), Үзбәкстанның Сәнгать музеенда, шәхси галереяларда саклана.

У.ның портретлары Р.Вахитов, З.Гыймаев, А.Абзгильдин, Х.Нәфыйков, Р.Баһаветдинов тарафыннан язылганнар. Аның турында «Сагыш» (1968, реж. В.В.Стрелков); «Бакый Урманче» (1987, реж. Р.Хисамов, Казан кинохроника студиясе); «Урманче өстендә салават күпере» («Радуга над Урманче», 2009, Казан, ТНВ); «Бакый Урманче. Көйгә тиң тормыш...» («Баки Урманче. Жизнь — это музыка...», К., 2012, реж. Н.Морозов, «Таткино») телефильмнары төшерелә. Казанда Б.Урманче музее (1999), скульптура һәйкәле (М.М.Гасыймов, 1997), Күл Черкен авылында У. Музей-йорты ачыла (2012). Казанда акад. Королёв урамындагы У. яшәгән йортка мемориаль такта куела. Казан, Буа, Яшел Үзән, Чаллы, Түбән Кама шәһәрләрендәге урамнар аның исемен йөртә. ТР Мәдәният министрлыгы тарафыннан сынлы сәнгать өлкәсендә Б.Урманче исем. бүләк булдырыла (1998). ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләгенә лауреаты (1967). Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Казан шәһәренең мактаулы гражданы (1987).

Х е з м.: Балалар сәнгате хакында ата-аналар, тәрбиячеләргә ни белергә кирәк? М., 1924; Татарстанның сынлы сәнгате // Совет әдәбияты. 1960. № 10; Из творческой работы // Искусство. 1936. № 1.

Әд.: Баки Урманче. Юбилейная художественная выставка. Каталог. К., 1969; Баки Урманче: Альбом. К., 1982; Искусство, рождённое Октябрём (к 30-летию Б.И.Урманче): Сб. статей. К., 1989; Н о в и ц -




Б.И.Урманче. 1. «Сепаратор янында». 1928; 2. «Бикбулатов портреты», 1927; 3. «Көймә кичүендә», 1929; 4. «Автопортрет», 1947; 5. Балыкчылар Иделдә». Гипс. 1960 нчы еллар; 6. «Язгы моңнар». Агач. Уеплау. 1968; 7. «Сагыш». Агач. Уеплау. 1966; 8. «Г.Тукай портреты». Эскиз. Бронза. 1964; 9. «Урал тавы итәгендә», 1979; 10. «Татарстан». Триптих. Уң як. 1977; 11. «Ибне Фадланның Болгарга килүе», 1973; 12. «Атлар коендыру». Картон. Темпера. 1975; 13. «Салтыкта печән өсте». Темпера. 1979; 14. «Г.Тукайның «Шүрәле» әкиятенә иллюстрация». Кәгазь. Акварель, тушь. 1966; 15. «Балалыкка бала бирәм». Г.Тукайның «Исемдә калганнар» хатирәләренә иллюстрацияләр сериясеннән. Кәгазь. тушь, каләм. 1984; 16. К.Тинчуринның «Ил» драмасына Туктамыш бабай (Умартачы) костюмы эскизы. Кәгазь. Акварель, карандаш, тушь, каләм. 1928; 17. Г.Тукайның «Шүрәле» әкиятенә иллюстрация. Кәгазь. Акварель, тушь. 1980; 18. «Коркыт». Кәгазь. Тушь, пумала, акшар, бронза буяу. 1975. 1–4, 6, 7, 9, 11–14, 17 — ТР Дәүләт сынлы сәнгать музенда; 5, 10 — Б.Урманче музеенда, 16 — ТР Милли музеенда; 18 — Мәрҗани фонды тупланмасында (Мәскәү).

кий А. Баки Урманче. К., 1994; Баки Урманче и татарская культура. К., 2005; Духовный мир Баки Урманче. К., 2005; Баки Урманче и национальная художественная культура. К., 2008; Баки Урманче. Живопись. Графика. Скульптура. Декоративно-прикладное искусство. К., 2012; Баки Урманче. Живопись, графика. Скульптура. Литературное наследие. Альбом-исследование. К., 2017.

Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.

УРМАНЧЕ́ БАКЫ́Й МУЗЕЕ́, Казанда, «Казан» милли мәдәният үзәге ф-лы. Казан шәһәр хакимиятенең «Урманче Бакый Идрис улы истәлеген мәңгеләштерү турында» 1997 ел 10 июль карары нигезендә 1997 дә оешты - рыла. 1999 ның февралендә ачыла. Ике кат - лы чарлаклы бинада — элекке В.В.Печатни - ков йортында (1920 еллар; архит-ра истәле - ге) урнашкан. Экспозиция мәйданы 147,1 *м*², музей фондларын 274 саклау берәмлеге тәш - кил итә. Экспозицияне булдыруда Ф.В.Әхмә - това-Урманче һәм Р.Г.Шаһиева катнашалар. 5 залда урнашкан экспозиция ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музее һәм «Казан» милли мә - дәният үзәге музей комплексы коллекция - ләреннән алынган әсәрләренең төп нөсхәлә - ре нигезендә Б.Урманче иҗатын рәссам, гра - фик, скульптор буларак ачып бирә. Беренче катта Б.Урманче биографиясенә бәйле фото - документлар экспозициясе, аның скульптура - лары: татар мәдәниятенең күренекле эш - леклеләре Кол Гали, Ш.Мәрҗани, К.Насый - ри, Дәрдемәнд, Ф.Әмирхан, Н.Исәнбәт, Г.Ибра һимов, Ш.Бабич бюстлары урнаштырыл - ган. Г.Тукайга багышланган иҗаты (шагыйрь - нең бюсты, аның әсәрләренә иллюстрация - ләр) аерым залда тупланган. Икенче катта



Казанда Бакый Урманче музее. Бинаның гомуми күренеше.

рәсемнәр (алар арасында — «Алма-Ата шәһә - ре чите», «Тут агачлары» картиналары), ш.у. респ-каның фән һәм мәдәният эшлеклеләре портретлары тәкъдим ителә. Бинаның чарла - гында мемориаль предметлар ярдәмендә рәс - сам остаханәсенең фрагменты торгызылган. Б.Урманченың соңгы эшләреннән берсе — «Хатыным Ф.Әхмәтова-Урманче портреты» (1987) куелган. Музейда хәзерге заман рәс - самнарының күргәзмәләре, әдәби-муз. кичә - ләр уздырыла. Музей директорлары: Ф.Ф.Сә - фәргалиева (1997–98), Г.Ш.Закирова (1998–2004), Г.Р.Әсфәндиярова (2004 тән).

Әд.: Все музеи Казани: Справ.-путеводитель. К., 2004; Музей Баки Урманче: Буклет. К., 2004.

УРМАНЧЕ́ БАКЫ́Й ҺӘЙКӘЛЕ́, Казанда. Рәссамга 100 ел тулу уңаеннан 1997 елның 28 февралендә Зур Кызыл урамындагы сквер - да куела. Урманче зурайтылган бронза скульптура рәвешендә иҗат процессында тәкъдим ителгән: пумала тоткан уң кулы б-н бер ягына Шүрәле рәсеме төшерелгән агач кә - вәрәгә таянган, сул кулы тезе өстендә ята. Урманченың карашы ераккатөбәлгән. Һәй - кәлнең авторы Урманченың рухи күтәрен - келеген, иҗат дәртен чагылдыруга, татар сын - чысының кыяфәтен, холык-табигатен брон - зада оста гәүдәләндерүгә ирешә. Постаменты



Б.И.Урманче һәйкәле. Бронза. Скульпторы М.М.Гасыймов. Архитекторы Г.А.Бакулин. 1997.

аксыл-соры граниттан эшләнгән. Скульптор - ы М.М.Гасыймов, архитекторы Г.А.Баку - лин. Һәйкәлнең гомуми биеклеге 2,5 *м*. Сквер башында «Бакый Урманче» дип язылган аер - ым таш блок куелган.

А.В.Гарзавина.

УРМАНЧЕ́ Илдар Бакый улы (23.4.1937, Мәскәү — 27.7.2001, шунда ук), график, театр һәм кино рәссамы. Б.*Урманче* улы. Бөтенсо - юз кинематография ин-тын тәмамлый (1961), И.П.Иванов-Ванода укый. Рәссамнар бер - легә (1962), Кинематографистлар берлегә (1965), Журналистлар берлегә (1972) әгъ - засы. Ил кинематографиясенең күренекле остасы. Заманча анимация киносының чиш - мә башында тора. «Кәҗә бәтие» («Козлё - нок») (1961), «Баранкин, кеше бул! («Ба - ранкин, будь человеком!») (1963, Венеция - дә узган 15 нче Халыкара балалар һәм яшүс - мерләр өчен фильмнар фестиваленең призы - на һәм бронза медаленә лаек була), «Кояш кызы» («Дочь Солнца», 1963), «Мин кош баласын көтәм» («Я жду птенца», 1966; Франциянең Тура шәһәрендә узган 12 нче Халыкара кыска метражлы фильмнар кино - фестиваленең иң яхшы балалар фильмы өчен көмеш медальгә лаек була), «Утлы еллар җырлары» («Песни огненных лет», 1971), «Ай По бабай әкияте» («Сказка дедушки Ай По», 1976), «Артист турында гыйбрәтле хи - кәя (Актёр)» (1989, Россиянең «Ника» кино - бүләгенә лаек була), «Макбет» (1992) һ.б. мультфильмнарның (Мосфильм) кую - чы-рәссамы. Үзәк Мәскәү нәшриятлары «Молодая гвардия», «Детская литература», «Советская Россия», «Библиотека Друж - бы народов», «Известия» б-н хезмәттәш - лек итә. 70 тән артык китапка: Т.Трунка - товның «Гук маҗаралары»на («Приклю - чения Гука», 1968), Ю.Тупицинның «Ерак юлга чыгар ал - дыннан» («Перед дальней дорогой», 1978) романына, С.Мадалиевның «Үзбәк повестьлары»на («Узбекские повести, 1984), Д.Көгелтинов - ның «Калмык халык әкиятләре»нә («Кал - мыцкие народные сказки», 1986), Ч.Айтма - товның «Гасырдан да озын көн» («И дольше века длится день», 1986) романына, Анарның «Цейтнот» әсәрләр җыентыгына (1989) һ.б. китапларга бизәкләр төшерә һәм иллюстра - цияләр ясый. «Знание — сила», «Человек и закон», «Пионер», «Колобок» ж-лларында рәссам булып эшли. Моссовет исем. театрда «Аксак Орфей» («Хромой Орфей», 1969), Совет армиясе Үзәк йортында «Юлбасар» («Разбойник», 1970) һ.б. спектакльләрне би - зи. Нәкышь һәм график картиналар авторы. У. үз стилен һәм танылган образларын бул - дыра. Аның сәнгать теленә төгәллек, ачык - лык, форма яңалыгы һәм үзенчәлеге, милли мәдәният традицияләре б-н бәйлелек хас. 1967 елдан бөтенсоюз кино һәм театр күргәз - мәләрендә катнаша. Парижда (1968), Лейп - цигта (1969) узган халыкара кинофести-



И.Б.Урманче.





И.Б.Урманче. 1. «Кеше бул, Баранкин!» («Баранкин, будь человеком!») мультипликация фильмына рәсем. Союзмультфильм. 1963; 2. «Кояш кызы» («Дочь солнца») мультипликация фильмына рәсем. Союзмультфильм. 1963.

вальләр бүләкләренә; «Пионер» (1970), «Колобок» (1980) ж-ллары бүләкләренә лаек була.

Әд.: Справочник Союза кинематографистов СССР. М., 1981.

Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.

УРМАНЧЕ́ЕВ Фатих Ибраһим улы (28.5.1936, хәзер Омск өлкәсенең Тәүриз р-ны Кызыл Маяк а.), фольклорчы галим, әдәби - ят белгече, филол. фән. д-ры (1990), проф. (1991), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1996). Омск пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1960) Сосновка урта мәктәбендә (Омск өлкәсе) эшли. 1965 елдан Казанда, 1971–72 дә Казан пед. ин-тында укыта. 1972–91 дә Алабуга пед. ин-тында (1980–84 тә Венгриядә Эгер пед. ин-тында командировкада). 1992–2009 да ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында халык иҗаты бүлеге мөдире, бер үк вакытта ТР ФАнең Татар энциклопедиясе ин-тының тел белеме һәм әдәбияты бүлегенең өлкән фәнни хезмәткәре. Хезмәтләре татар халык иҗатына, төрки-татар мифологиясенә һәм фольклор б-н әдәбиятның үзара бәйләнешләренә карый. «Татар мифологиясе: Энциклопедик сүзлек» (1–3 т., 2008–11) хезмәте авторы.

Х е з м.: Каһарманнар йолдызлыгы: Тарихи-фольклористик очерклар. К., 2006; Эпические сказания татарского народа: Сравнительно-ист. очерки. К., 1980; Героический эпос татарского народа. К., 1984; Лиро-эпос татар Среднего Поволжья. К., 2002.

Әд.: Балачак әдипләре: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2005. Т. 3; Әдәби Алабуга. К., 2005.

УРМАНЧИ́ЕВА Адилия Фәттах кызы (4.1.1951, Ленинград), онкогинеколог, мед. фән. д-ры (1994), проф. (1995). Ленинград педиатрия мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1974), Н.Н.Петров исем. Онкология фән - ни-тикшеренү ин-тында (Ленинград) эшли. Хезмәтләре аналык муентыгы шешләренә, саркомаларга карый.

Х е з м.: Новые подходы к лечению гинекологического рака. СПб., 1993 (автордаш); Саркомы матки. СПб., 1996 (автордаш); Гормональная контрацепция и онкологические заболевания. СПб., 2002 (автордаш).

УРМАНЧЫ́ авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 56 *км* көньяк-көнбатыштарак, Бөрсет елгасы буенда. 2010 елда 236 ке - ше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Мәдәният йорты. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Троицкий, Көек, Бөрсет-Кыерлы, Түбәнавыл исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катла - вына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Троица чиркәве (1818–25 елларда сәүдәгәр А.И.Сухопаров иганәсенә төзелә; архит-ра истәлеге), зем - ство мәктәбе (1868 дә ачыла), 2 тимерче алачыгы, тегермән, 1 казна шәраб һәм 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгате - нең имана җире 1203,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мама - дыш өязе Түбән Сон волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 85 ир-ат; 1859 да — 559, 1897 дә — 862, 1908 дә — 860, 1920 дә — 900, 1926 да — 892, 1938 дә — 827, 1949 да — 2057, 1958 дә — 4483, 1970 тә — 695, 1979 да — 441, 1989 да — 345, 2002 дә — 265 кеше.

УРМАНЧЫ́ посёлогы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 5 *км* көньяк-көнбатыштарак урнашкан. 2010 елда 234 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 59%, руслар — 38%) яши. Торак пункт буларак 2001 дә теркәлә. 2002 дә 190 ке - ше яши.

УРМАНЧЫЛЫ́К, беренчел терр.-җитештерү бүлекчәсе, урман хуҗалыгының төп мөстәкыйль структура берәмлеге булып тора. У. обходларга бүленә торган участоклардан тора. ТРда 126 У., алар составында 258 участок һәм 1297 обход бар. У.ның мәйданы респ-када 4 мең *га* дан 12 мең *га* га кадәр, уртача мәйданы 10 мең *га*. У.ка кисү өчен өлгергән урман участоклары керә, кисенделәрдә яңадан урман утырту, аларны карау, урман үрчетү һәм урманның продуктлылыгын күтәрүче башка чаралар башкарыла. У.та ш.у. ярдәмче-сәнәгый җитештерү — урман кисү барышында алынган вак товарлыклы агач эшкәртү б-н шөгыльләнәләр. У. эшчәнлеге б-н урманчы җитәкчелек итә, ул бер үк вакытта урманны саклау һәм күзәтчелек буенча дәүләт инспекторы да санала. У. штаты составына урманчы ярдәмчесе, хисапчы, урманда эшләүче осталар (участоклар саны буенча), урманчылар (обходлар саны буенча) керә.

Әд.: Лесная энциклопедия. М., 1986. Т. 1.

И.Н.Зарипов.

УРМА́Т АВЫЛЛЫГЫ́, к. *Рус Урматы авыллыгы*.

УРМЫШЛЫ́, к. *Ормышлы*.

«УРОЖА́Й», колхозчылар, эшчеләр, уку - чыларның ирекле спорт җәмгыяте. Татарстанда 1956 елда оештырыла. 1987 дә «У.» «Зенит», «Спартак», «Труд», «Локомотив» ирекле спорт җәмгыятьләре б-н берләштерелә (к. *Профсоюзларның физкультура-спорт җәмгыяте Татарстан Республика советы*). 1978 гә «У.» составына 1359 физик культура коллективы керә (ш.и. 846 — колхоз һәм сов - хозлардан). Көрәш (грек-рим, ирекле көрәш, татарча көрәш), велосипед, бура уены, ату, чаңгы спорты, җиңел атлетика, шахмат үсте - релә. 4 атказ. спорт остасы, 4 халыкара класслы спорт остасы, 122 СССР спорт остасы әзерләнә. Иң яхшы тренерлар һәм спортчылар: А.А.*Бозин*, Л.Г.*Володина*, С.А.*Дёмина*, С.Ю.Протасов, М.М.*Сәхәбетдинов*, Ю.В.Шеguров, С.С.*Яруллин*. Рәисе: В.И.Кудров (1957–60), М.Н.Госманов (1960–78), И.Х.Сафин (1978–83), С.Г.Әһлиуллин (1983–85), К.С.Хөснетдинов (1985–87).

«УРОЖА́Й», к. *«Уңыш»*.

УРОЛО́ГИЯ (грек. urón — сидек һәм *...логия*), клиник мед. өлкәсе, сидек (ирләрдә сидек-же - нес) әгъзалары системасының нормаль һәм патологик физиологиясен, бу төр авыруларның этиологиясен өйрәнә, диагноз кую һәм дәвалау ысулларын эшли. Европа илләрендә У.нең интенсив үсеш алуы 19 йөз ахырына туры килә: Л.Мерсье һәм Ф.Гюйон (Франция) — урологик авыруларның симтомнарын һәм аларга диагноз кую ысулларын, Г.Томпсон (Англия) — бөер ташы авыруын, П.Дж. Фрейер (Англия) мәни бизе (простата) авыруларын хирургик юл б-н дәвалау ысулларын өйрәнә; немец урологы М.Нитце цитоскоп уйлап таба. Россиядә У.гә караган беренче тикшеренүләр Петербург мед.-хирургия академиясенең (1798 елда ачыла) хирургия кафедрасында (мөдире — И.Ф.Буш) уздырыла башлый. Илебез У.сенә нигез салыну Н.И.Пирогов, Ф.И.Иноземцев, И.П.Матюшенков һ.б.ның эшчәнлеге б-н бәйле. 1867 дә Мәскәү ун-тында Россиядә беренче У. клиникасы булдырыла. С.П.Фёдоровның сидек һәм үт юллары хирургиясенә караган хезмәтләре аерым әһәмияткә ия (ул беренче булып эндоскопик тикшеренүләр — цитология кул - лана).

У. үсешенә Казан галимнәре зур өлеш кертә. 1890 да Казан ун-ты укытучысы Г.Г.Рад - зевич бөер ташы авыруы һәм Россиядә аны дәвалау ысулларына багышланган хезмәтләрнең (586 хезмәт) библиографик күрсәткечен төзи. 1902 дә проф. В.И.*Разумовский* тарафыннан тәкъдим ителгән — күкәйгә, күкәй өстәмәсен һәм мәни юлларындагы анастомозны гына кисеп алып, әгъзаның үзен саклап калу мөмкинлеге бирүче операция ясау ысулы операция ясау техникасы өлкәсендә яңа этап булып тора.1904 тә В.Л.*Боголюбов* сидек-җенес системасына әгъзаларның функ - цияләрен тергезү операцияләренең ориги - наль реконструктив ысулларын тәкъдим итә. Илебездә нефрологиягә нигез салучыларның берсе С.С.*Зимницкий* бөерләрне тикшерүнең функциональ ысулларын эшли. А.В.*Вишневский* тарафыннан уролитиазны дәвалаганда киң кулланылыш тапкан новокаин блокадасы тәкъдим ителә. 1930 еллар башыннан Татарстан халкына урологик ярдәм күрсәтүне оештыру хирург-онколог Ю.А.Ратнер исеме б-н бәйле. 1932 дә аның башлангычында (Н.Х.Ситдыйков б-н берлектә) Казан ГИДУВының хирургия клиникасында сидек-җенес системасы әгъзаларында авыру булган пациентларны амбулатор кабул итү оештырыла, 1937 дә 2 нче поликлиника каршында У. кабинеты ачыла. Казан галимнәре С.М.*Алексеев*, И.Ф.*Харитонов*, В.С.Ефимов У. үсешенә зур өлеш кертә. 5 нче шәһәр клиник хастаханәсендә 1946 дан У., 1967 дән нефрология бүлекләре эшли. 1960 елларда Респ-ка клиник хастаханәсе каршында У. бүлеге һәм поликлиника хезмәте оештырыла. Казан шәһәре 6 нчы клиник хастаханәсе базасында 1965 тән « Ясалма бөер» лаб-ясе, 1973 тән гомодиализ бүлеге, 1993 тән Орга - низмны бөердән башка чистарту үзәге эшли.

У. каф. 1953 елда Казан ГИДУВында (хәзер Казан мед. академиясе) ачыла, оештыручысы һәм мөдире — Н.Х.Ситдыйков, аннары А.А.Айдаров, В.Е.Кузьмина, В.С.Гыйрфанов, С.И.Белых, 1996 дан — Р.Х.*Галиев*. 1970 тә У. каф. Казан мед. ин-тында оештырыла (мөдире Э.Н.*Ситдыйков*, 1996 дан М.Э.*Ситдыйкова*). 1984 тә Казан мед. ин-тының У. каф.

өчен 7 катлы махсус бина төзелеп кулланышка тапшырыла (хәзер шәһәр У. ұзәге). Чаллы, Яшел Үзән, Чистай, Түбән Кама, Алабуга, Әлмәт, Бөгелмә Үзәк район хастаханәләре каршында У. бүлекләре ачыла. ТР урологларының төп фәнни эшчәнлек юнәлешләрен эндоурология, сидек куыгындагы яман шешләргә, ялкынсынуларга, мәни бизе авыруларына диагноз кую һәм дәвалау, бөер ташы авыруын комплекслы дәвалау, реконструктив пластика, балалар У.се тәшкил итә.

Казан мед. ин-тының У. кафедрасында 1996 елдан гамәли У.нең актуаль мәсьәләләренә караган тикшеренүләр алып барыла; 6 монография нәшер ителә, уйлап табуга 7 авторлык таныклыгы алына. Казан мед. академиясе составындагы У. һәм нефрология кафедрасының төп фәнни юнәлешен дәвалау практикасына сидек-җенес системасы әгъзаларына әгъзаны башка төр әгъза б-н алыштыру һәм реконструктив операцияләр ясауны кертү (бөер күчереп утырту, сидек каналын алыштыру һ.б.) тәшкил итә. Бөер артерияләре авырулары, сидек куыгы дисфункцияләре, сидек куыгы шешләре һәм башка төр урологик авырулары булган пациентларга ярдәм күрсәтелә.

ТРда балалар У.се 1935 елда Казан мед. ин-тының факультет хирургиясе клиникасы базасында балалар хирургиясе каф. ачылу б-н бәйле рәвештә үсеш ала. Казандагы 15 нче хастаханәдә (1974), Респ-ка балалар клиник хастаханәсендә (1977) һәм респ-ка-ның башка шәһәр хастаханәләрендә балалар У.се бүлекләре ачыла. М.Р.*Рокицкий* һәм А.Ә.*Ахун җанов* 1977–78 елларда Казанда балалар уронефрологиясе хезмәте структурасын төзиләр; әлеге хезмәт СССР ВДНХсында күрсәтелә (1987), күргәзмәнең 1 көмеш, 3 бронза медаленә лаек була һәм Диплом б-н бүләкләнә. ТРның баш балалар хирургы, Казан мед. ун-тының балалар хирургиясе курсы мөдире А.Ә Ахунҗанов тарафыннан балалар урологик авыруларына диагноз кую һәм хирургик юл б-н дәвалауның 15 өр-яңа ысулы эшләнә. Ул сидек бүлеп чыгару әгъзаларының обструктив авыруларына һәм тумыштан булган үсеш аномалияләренә диагноз кую һәм хирургик юл б-н дәвалау буенча тикшеренүләр алып бара, бөер күчереп утырту һәм хроник бөер җитешсезлеге очракларында экстракорпораль детоксикацион терапия кысуларын эшли. Татарстанда 1967 дә Урологлар һәм нефрологлар фәнни җәмгыяте оеша.

Әд.: История отечественной урологии, М., 2007; Актуальные вопросы урологии: Материалы юбилейной науч.-практ. конф. К., 2009; Ахунзянов А.А. Детская хирургия и урология в Казани: Этапы становления. М., 2009.

М.Э.Ситдыйкова, Р.Х.Галиев.

УРСА́Й авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 31 *км* төньяктарак, Ык елгасы буенда. 2010 елда 753 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы асабалар, типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек, тәгәрмәч, чүлмәк ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 3 мәчет, 2 мәктәп, су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 7165 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Тымытык волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 20 октябреннән — Азнакай, 1935 нең 10 февраленнән — Тымытык, 1958 нең 16 июленнән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1795 тә — 186, 1816 да — 349 кеше; 1834 тә — 235 ир-ат; 1859 да — 874, 1889 да — 1619, 1897 дә — 1833, 1910 да — 2407, 1920 дә — 2185, 1926 да — 1789, 1938 дә — 1652, 1949 да — 1174, 1958 дә — 1166, 1970 тә — 1329, 1979 да — 1005, 1989 да — 775, 2002 дә — 740 кеше.

УРСА́Й авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 43 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Урман Зәе елгасы буенда. 2010 елда 404 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөз башында нигез салына. Рев-цияга кадәрге чыганакларда Елизаветина исеме б-н дә билгеле. Башта халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, 1859 да алпавыт тарафыннан ирекле игенчеләр катлавына күчерелә; игенчелек, терлекчелек, умартачылык, киндер сүсе эрләү, бау ишү, мунчала, чана, балчык савыт-саба ясау б-н шөгыльләнә. 1773–75 еллардагы *Крәстияннәр кузгалышында* Е.И.Пугачёв ягында сугышалар. 20 йөз башында чиркәү-приход мәктәбе (1887 дә ачыла), су тегермәне, тимерче алачыгы, икмәк саклау-сату һәм бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 4201 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Яңа Спас волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1959 ның 26 мартыннан — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1859 да — 585, 1897 дә — 1158, 1906 да — 1182, 1913 тә — 1418, 1920 дә — 1491, 1926 да — 1212, 1938 дә — 890, 1949 да — 713, 1958 дә — 646, 1970 тә — 546, 1979 да — 346, 1989 да — 358, 2002 дә — 439 кеше.

Әд.: Заинская энциклопедия. К., 1994.

УРСАЛЫ́ елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Дала Зәе елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 26,6 *км*. Бассейнының мәйданы 358,4 *км*². Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгыннан, Әлмәт р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Урсалыбаш авылыннан 2 *км* көнчыгыштарак, тамагы Яңа Нәдер авылыннан 1 *км* көньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 265 *м*, тамагыныкы — 98 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 35%. У.ның 0,7 дән 21,1 *км* га кадәр озынлыктагы 11 кушылдыгы бар. Аеруча зурлары: Кама (21,1 *км*) — сул, Болгар (7,9 *км*) — уң кушылдыклар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,34 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1–3 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен ныклы саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 73 *мм*, ташу агымы катламы 55 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз



Урсалы елгасы.

вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,027 *м*³/*с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 700–1000 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк.

УРСАЛЫ́ елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Дала Зәе елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 10,9 *км*. Бассейнының мәйданы 43,3 *км*². Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгыннан, Әлмәт р-ны терр-ясендә ага. Елга башы Акчишмә авылыннан 3 *км* көньяк-көнбатыштарак, тамагы Урсалы авылыннан көньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 270 *м*, тамагыныкы — 79 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 65%. У.ның 1,7 дән 4,1 *км* га кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,46 *км/км*². Туенуы катнаш, дүрттән өч өлеше кар сулары исәбенә туры килә. Җир асты сулары б-н туену модуле 13 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен ныклы саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 73 *мм*, ташу агымы катламы 55 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,027 *м*³/*с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 700–1000 *мг/л*. кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк.

УРСАЛЫ́ авылы, Әлмәт шәһәре составында, шәһәрдән 2 *км* төньяктарак, Урсалы елгасы буенда. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1751 елдан татар авылы буларак билгеле. 1785 тә У. тирәсендәге җирләрне поручик А.Г.Петрово-Солововo сатып алгач, рус крәстияннәре килеп урнаша. 1831 дә алар алпавыт тарафыннан иреккә

чыгарыла һәм ирекле игенчеләр, 1848 дә дәүләт крәстияннәре катлауларына күчерелә. Халык, башлыча, игенчелек, терлекчелек, тәгәрмәч, чүлмәк, чана ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша; земство мәктәбе, китапханә, 4 су тегермәне, тимерче алачыгы, 3 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3070 дис. тәшкил итә. 1910 да балта-столярлык эшенә өйрәтүче һөнәр мәктәбе ачыла. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Урсалы волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Әлмәт р-нында, 2003 нең 3 сентябрен нән Әлмәт шәһәре составында. Халык саны: 1816 да — 112 ир-ат; 1834 тә — 203, 1859 да — 446, 1889 да — 796, 1897 дә — 1062, 1910 да — 1330, 1916 да — 1301, 1920 дә — 1420, 1926 да — 1472, 1938 дә — 1466, 1949 да — 1540, 1958 дә — 1806, 1970 тә — 2113, 1979 да — 1920, 1989 да — 1492, 2002 дә — 2345 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 69%, татарлар — 26%). У.ның күренекле урыны — Изге чишмә.

УРСАЛЫБА́Ш авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 40 *км* төньяк-көнчыгышта рак, Урсалы елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 416 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. 1735 кә кадәр Казан өязенең Алат даругасы Сәрдек авылыннан күченүчеләр нигез сала. 1860 елларга кадәр халкы типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп, су тегермәне була; 1908 дә икенче мәчет ачыла, 1914 тә аның каршында мәктәп эшли башлый. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1768 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Мәсгут волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1746 да — 30, 1762 дә — 42 ир-ат; 1795 тә — 229 кеше; 1816 да — 118, 1850 дә — 156 ир-ат; 1859 да — 310, 1889 да — 681, 1897 дә — 697, 1910 да — 765, 1920 дә — 985, 1926 да — 1004, 1938 дә — 881, 1949 да — 851, 1958 дә — 722, 1970 тә — 845, 1979 да — 690, 1989 да — 388, 2002 дә — 373 кеше.

УРТА́ АЛА́Т авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 32 *км* төньяк-тарак, Ашыт елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 323 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Мәдәният йорты. Мәчет. 1646 дан билгеле. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Курманаево, Починок по ключу Поварни исемнәре б-н дә билгеле. У.А. татарлары 18 йөздә — 19 йөзнең яртысында дәүләт крәстияннәре катлавына керә. Авылның бер өлешенә (Барское Курманаево дип йөртелә) рус алпавыт крәстияннәре килеп урнаша, игенчелек, терлекчелек, тимерчелек, он тарту, балта эше, арба, илək ясау, киндер сугу, олаучылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет (19 йөз башында төзелгән иске бина урынына 1911–12 дә яңасы төзелә), мәктәп, ярма яргыч, тимерче алачыгы, 2 җил тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 987,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губенасының Казан өязе Алат волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Яшел Үзән, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 108 ир-ат; 1859 да — 497, 1897 дә — 714, 1908 дә — 1227, 1920 дә — 1099, 1926 да — 1025, 1938 дә — 82, 1949 да — 686, 1958 дә — 454, 1970 тә — 411, 1989 да — 312, 2002 дә — 339 кеше.

Әд.: Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

УРТА́ АТЫ́ авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 13 *км* көнбатыштарак, Аты елгасы буенда. 2010 елда 219 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Мәдәният йорты. Казан ханлыгы чорында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, баш киеме тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында У.А.да мәчет, тимерче алачыгы, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 840,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Мүлмә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 67 ир-ат; 1859 да — 387, 1897 дә — 558, 1908 дә — 809, 1920 дә — 654, 1926 да — 556, 1938 дә — 436, 1949 да — 407, 1958 дә — 367, 1970 тә — 305, 1979 да — 273, 1989 да — 245, 2002 дә — 210 кеше. У.А. янында 16 йөзнең 1 нче яртысы эпиграфик истәлеге — кабер ташы сакланган.

УРТА́ ӘЛКИ́ (Китәнче) авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 13 *км* көньяк-көнчыгыштарак урнашкан. 2010 елда 106 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, клуб. Мәчет. 1710–11 дәге рус чыганакларында Исенчина (Исейчина) исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. Реформадан соңгы чорда У.Ә. 1878–79 еллардагы *татар крәстияннәре кузгалышлары* үзәкләреннән берсе була. 20 йөз башында мәчет, мәдрәсә, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1524 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Әлки волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 92 ир-ат; 1859 да — 617, 1897 дә — 1070, 1908 дә — 1032, 1920 дә — 1330, 1926 да — 827, 1938 дә — 664, 1949 да — 414, 1958 дә — 363, 1970 тә — 303, 1979 да — 230, 1989 да — 189, 2002 дә — 160 кеше.

УРТА́ БАГРА́Ж (Түбән авыл) авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 18 *км* көнчыгыштарак, Зәй–Сарман автомобиль юлы буенда. 2010 елда 186 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 1680 елга кадәр нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Сарсаз Тамак исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, чана, мичкә ясау, столяр һөнәре б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 1174 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Зәй волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Сарман, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1859 да — 232, 1870 тә — 395, 1884 тә — 539, 1897 дә — 674, 1913 тә — 635, 1920 дә — 631, 1926 да — 632, 1938 дә — 652, 1949 да — 458, 1958 дә — 517, 1970 тә — 498, 1979 да — 379, 1989 да — 185, 2002 дә — 193 кеше.

Әд.: Заинская энциклопедия. К., 1994.

УРТА́ БАЛТА́Й авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 19 *км* көнбатыштарак, Чирмешән елгасы буенда. 2010 елда 474 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, дәваханә, китапханә. Мәчет. 1646 дан Яңа Балтай исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша; мәчет, мәдрәсә, су тегермәне, кредит ширкәте, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1348 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Урта Балтай волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 148 ир-ат; 1859 да — 847, 1897 дә — 1177, 1908 дә — 1434, 1920 дә — 1236, 1926 да — 1078, 1938 дә — 885, 1949 да — 672, 1958 дә — 558, 1970 тә — 618, 1979 да — 621, 1989 да — 544, 2002 дә — 514 кеше. У.Б.да Сов. Союзы Герое Р.А.*Абзалов* туган.

УРТА́ БИКТИМЕ́Р авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 6 *км* көньяктарак, Актай елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 31 кеше (руслар, татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1710 нан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Югары Биктимер исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә. 20 йөз башында чиркәү-приход мәктәбе (1893 тә ачыла) эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1388 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Әлки волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 73 ир-ат; 1859 да — 380, 1897 дә — 591, 1908 дә — 771, 1920 дә — 715, 1926 да — 507, 1938 дә — 350, 1949 да — 272, 1958 дә — 196, 1970 тә — 166, 1979 да — 123, 1989 да — 56, 2002 дә — 56 кеше.

УРТА́ БИРӘЗӘ́ авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 5 *км* төньяк-көнбатыштарак, Бирәзә елгасы буенда. 2010 елда 204 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 1678 елдан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, олаучылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында У.Б.дә мәчет, мәктәп, су тегермәне, 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1225,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Арча волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 165 ир-ат; 1859 да — 521, 1897 дә — 727, 1908 дә — 837, 1920 дә — 610, 1926 да — 585, 1938 дә — 604, 1949 да — 401, 1958 дә — 409, 1970 тә — 336, 1979 да — 282, 1989 да — 215, 2002 дә — 208 кеше.

УРТА́ БИЯБА́Ш авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 19 *км* төньяк-көнбатыштарак, Бөя елгасы буенда. 2010 елда 122 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 72%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау, умартачылык. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-ция гә кадәрге рус чыганакларында Мусеевы, Новопоселённые Биабаши исемнәре б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, чиркәү-приход мәктәбе, 4 су тегермәне, тимерче алачыгы, ярма яргыч, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1243 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Шәмбалыкчы волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1935 нең 25 гыйнварыннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 16 ир-ат; 1859 да — 493, 1897 дә — 1036, 1908 дә — 1298, 1920 дә — 624, 1926 да — 492, 1938 дә — 644, 1949 да — 685, 1958 дә — 506, 1970 тә — 357, 1979 да — 232, 1989 да — 199, 2002 дә — 174 кеше.

УРТА́ ДӘҮЛӘТЬЯ́Р авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 19 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Әшнәк елгасы буенда. 2010 елда 60 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1646 дан мәгълүм. Рев-ция гә кадәрге рус чыганакларында Поспеловка исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында су тегермәне, 1 казна шәраб һәм 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 341 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Зюзино волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 32 ир-ат; 1859 да — 207, 1897 дә — 286, 1908 дә — 315, 1920 дә — 384, 1926 да — 344, 1949 да — 259, 1958 дә — 215, 1970 тә — 126, 1979 да — 30, 1989 да — 54, 2002 дә — 63 кеше.

УРТА́ ДЕВЯ́ТОВО авылы, Лаеш р-нында, Лаеш шәһәреннән 17 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Казан–Оренбург автомобиль юлы буенда. 2010 елда 559 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1560 елларда Казан ханлыгы чоры авылы урынында алпавыт Ф.С.Змеев нигез сала. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Тевкечь, Ларионово исемнәре б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1880 елларда У.Д.дагы утар һәм биләмәләрне танылган Казан сәүдәгәре һәм игелек кылучы П.В.*Щетинкин* сатып ала. 20 йөз башында земство мәктәбе (1884 тә ачыла), җил тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 112,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Державин волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Лаеш, 1944 нең 19 февраленнән — Салтан, 1946 ның 5 апреленнән — Корноухово, 1954 нең 19 ноябреннән — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1859 да — 189, 1897 дә — 278, 1908 дә — 309, 1920 дә — 347, 1926 да — 414, 1938 дә — 443, 1949 да — 313, 1958 дә — 257, 1970 тә — 405, 1979 да — 568, 1989 да — 627, 2002 дә — 597 кеше.

УРТА́ ДИАЛЕ́КТ, татар телендәге диалект, *Казан татарларының* субэтник төркеме сөйләшләре җыелмасы. Хәзерге татар әдәби теленең нигезендә ята. Шактый зур терр-ядә таралыш алган һәм күп сандагы сөйләшләргә бүленә. У.д.ның үзәк сөйләшләре — балтач, мамадыш, лаеш һ.б. (Казан арты районнарында таралган), бәрәңге (Мари Респ-касында), норлат, кама тамагы, тархан (Татарстанның Тау ягы терр-ясендә), минзәлә (Татарстанның көнчыгыш районнары һәм Башкортстанның көнбатыш районнары рәтендә) һәм бөре (Башкортстанның төньяк-көнчыгыш районнарында) сөйләшләре әдәби телгә аеруча якын. Башкорт теле б-н әлемтә урнашкан җирдә У.д.ның златоуст, учалы, сафакүл һәм типкәй сөйләшләре барлыкка килә. Урал артында (Курган өлкәсе) У.д.ның — эчкен, Көньяк Уралда — каргалы һәм абдуллин, Түбән Идел буе һәм Ставрополь терр-яләрендә әстрехан сөйләшләре киң таралган. Нократ, пермь, касыйм, керәшен сөйләшләре аерым төркемгә кертеп карала.

У.д.ның барлык сөйләшләренә дә хас гомуми үзенчәлекләре бар. Фонетика тармагында: ж-ләштерү — җөрәк (йөрәк), [а] авазын о-лаштырып әйтү — [а^{o}] (ка^{o}р), увуляр (кечетел) [қ], [ғ], [х] авазларын куллану: қаты, ғалим, ҳәл һ.б. күзәтелә. Минзәлә сөйләшендә тел алды тартыгы [з] урынына интерденталь (теш арасы) [d] авазы кулланыла: дирәк (зирәк), бед (без) һ.б. Морфология тармагында инфинитив фигыльнең төрле формалары кулланыла: -мага/-мәгә: бармага, кил-мәгә; -ма/-мә: укыма (укыма китте); -ыш/-еш: барыш. У.д.ның таралыш ареалларын һәм үзенчәлекләрен татар галимнәре Ж.Ж.Вәлиди, Л.Ж.Җәләй, Л.Т.Мәхмүтова, Н.Б.Борһанова, Д.Б.Рамазанова, Ф.Й.Йосыпов, Ф.С.Баязитова, Т.Х.Хәйретдинова, З.Р.Садыйкова һ.б. өйрәнә.

Әд.: Татар халык сөйләшләре: 2 китапта. К., 2008; Бурганова Н.Б., Махмутова Л.Т. К вопросу об истории образования и изучения татарских диалектов и говоров // Материалы по татарской диалектологии. К., 1962. Вып. 2; Рамазанова Д.Б. Татарские диалекты // Татары. М., 2001.
Д.Б.Рамазанова.

УРТА́ ДОН БОМБАРДИРО́ВЩИКЛАР АВИА́ЦИЯСЕ ДИВИ́ЗИЯСЕ, ТАССР ЮС исемендә, 1940 елның җәендә 202 нче бомбардировщиклар авиация дивизиясе буларак оештырыла. Дивизия командирлары — генерал С.И.Нечипоренко, полковник В.И.Александрович. Минск, Смоленск, Мәскәүне саклауда катнаша. 1943 нең 19 апреледә ТАССР хезмәт ияләре үтенече б-н, Сталинград һөҗүмендә катнашканы өчен, У.Д.б.а.д. дип атала башлый, оборона халык комиссары фәрманы нигезендә ТАССР ЮС исеме бирелә. 1943 нең 1 маенда Казан аэродромында дивизиягә тантаналы рәвештә респ-ка халкының матди ярдәме б-н төзелгән 102 бомбардировщик тапшырыла. Курск һөҗүме вакытында ВКП(б) Татарстан өлкә ком-ты секретаре С.Ш.Гафаров һәм ТАССР ЮС Президиумы секретаре Г.Г.Шәмсиева дивизиягә ЮС Президиумы байрагын тапшыралар. Дивизия сугышчыларының Татарстанлыларга язган хатында мондый юллар бар: «Кызыл Байракны кабул итеп, без аны фашистлар Германиясен тулысынча тар-мар иткәнче, изге Ватаныбызны тулысынча азат иткәнче кулыбыздан төшермәскә вәгъдә бирәбез». Дивизия Украина, Чехословакия, Польшаны азат итүдә катнаша. 1943 тә Кызыл Байрак ордены, 1945 тә 2 нче дәрәҗә Суворов ордены б-н бүләкләнә. 1945 нең җәендә Казанга дивизия вәкилләре килә. Тантаналы җыелышта командование исеменнән полковник С.Ермак ТАССР ЮС Президиумына һәм җыелыштагыларга дивизия сугышчыларының Татарстан хезмәт ияләренең ышанычын намус б-н аклауларын җиткерә.

Әд.: Белостоцкий Ю.В. Боевые крылья. К., 1971.
В.Ф.Телишев.

«УРТА́ ИДЕ́Л», иҗтимагый-сәяси, а.х. һәм әдәби журнал, «Урта Идел» г-тасына айлык кушымта (к. «*Колхозчы*»). 1928 елның декабреннән 1929 ның августына кадәр Самара шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, барысы 8 саны чыга. Мөхәррире — З.Шәрыкый. Индустриализация барышы турында материаллар, СССРда икътисад үсеше тенденциясе турындагы аналитик һәм бәхәсле язмалар, Гражданнар сугышында катнашучыларның хатирәләре, Коммунистик интернационалның 10 еллыгына, Кызыл Армиянең 11 еллыгына багышланган мәкаләләр басыла. А.х. үсеше мәсьәләләре, агроном һәм ветеринарларның тәфсилле тәкъдимнәре яктыртыла. Башлап язучылар: шагыйрьләр (К.Чирочин, И.Ихсан, Я.Мансуров, С.Мәүлетов һ.б.), прозаиклар (Г.Ахунов, Ф.Латыйпов һ.б.) әсәрләре, авыл җирлегендә мәдәни төзелешкә, үзеш-

чән театрларга багышланган материаллар дөнья күрә, яңалифне укытуны камилләштерү проблемалары күтәрелә; фән һәм техника яңалыклары яктыртыла.

З.З.Гыйләҗев.

«УРТА́ ИДЕ́Л», газета; к. *«Колхозчы»*.

УРТА́ ИДЕ́Л ҺӘМ УРА́Л БУЕ́ ТАТА́Р ХАЛКЫ́ СӨЙЛӘШЛӘРЕ́ А́ТЛАСЫ, татар телендәге урта һәм мишәр диалектлары таралышын күрсәтүче диалектологик карталарның системага салынган җыелмасы. Материал туплау 1958–85 елларда Рязань-Киров-Саратов-Курган-Оренбург ареалында 845 торак пунктта ТР ФА Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тының (1997 гә кадәр Тел, әдәбият һәм тарих ин-ты) диалектологик экспедицияләре вакытында билгеле бер тәртиптә башкарыла. Атласта 6 ярдәмче (тарихи-этнографик), 224 тел күренешләре һәм 17 җыелма изоглоссалар карталары тупланган. Тел күренешләре карталарында тел системасының бер күренеше буларак каралган диалект аермаларының закончалыклары һәм характеры күрсәтелгән. Лексик яктан чикләнмәгән материалда күзәтелүче фонетик күренешләргә шактый урын бирелгән. Җыелма карталарда охшаш сызыклы изоглоссалар берләштерелгән. Атлас 1989 да 2 томда басылып чыга. Фәнни наширләре — Л.Т.Мәхмүтова, Н.Б.Борһанова, төзүчеләре — Ф.С.Баязитова, Д.Б.Рамазанова, Т.Х.Хәйретдинова, З.Р.Садыйкова. Шул ук елны «Атласка аңлатмалар...» басылып чыга, аларда карталарга кереш мәкаләләр һәм белешмә материаллар, ш.у. тикшеренү программасы, торак пунктларның исемлекләре һ.б. бирелгән.

Әд.: Борһанова Н.Б. Татар теле диалектологик атласын төзү өчен материал җыйнау программасы. К., 1959; Бурганова Н.Б., Залял Л.З. О принципах составления диалектологического атласа татарского языка // Вопр. диалектологии тюркских языков. К., 1960; Махмутова Л.Т. Несколько слов о диалектологических атласах татарского и других тюркских языков. К., 1972.

Д.Б.Рамазанова.

УРТА́ ИЯ́ авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 22 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Ия елгасы буенда. 2010 елда 26 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1646 дан билгеле. 1861 елгы реформага кадәр алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында У.И.дә икмәк саклау-сату һәм 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 116,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Аркатау волостенда, 1920 дән ТАССР-ның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 66 ир-ат; 1859 да — 175, 1897 дә — 340, 1908 дә — 364, 1920 дә — 494, 1926 да — 341, 1949 да — 280, 1958 дә — 283, 1970 тә — 207, 1979 да — 79, 1989 да — 52, 2002 дә — 36 кеше.

УРТА́ ЙОРТКӘ́УЛ авылы, Спас р-нында, Болгар шәһәреннән 55 *км* көньяк-көнчыгыш-тарак, Ульянов өлкәсе б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 251 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты. Мәчет. 1700 еллар тирәсендә нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Вершина речки Нараткули исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, бау ишү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 мәчет, мәдрәсә, 3 җил тегермәне, ярма яргыч, 2 мануфактура һәм 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1852,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Йорткүл волостенда, 1920 дән ТАССР-ның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1935 нең 10 февраленнән — Кузнечиха, 1960 ның 28 октябреннән — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1991 нең 4 октябреннән Спас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 310 ир-ат; 1859 да — 583, 1897 дә — 1009, 1908 дә — 1233, 1926 да — 653, 1938 дә — 452, 1949 да — 360, 1958 дә — 405, 1970 тә — 449, 1979 да — 392, 1989 да — 310, 2002 дә — 291 кеше.

УРТА́ КАБА́Н, к. *Аргы Кабан*.

УРТА́ КАМЫШЛЫ́ авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 9 *км* төньяктарак, Олы Чирмешән елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 596 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөз уртасында Вишнёвая Поляна авылыннан күченүчеләр нигез сала. Рус чыганакларындагы беренче исеме — Новопоселённая Камышла. 1860 еллар-га кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, он тарту, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында У.К.да укырга-язарга өйрәтү мәктәбе (1892 дә ачыла), 4 ярма яргыч, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2135 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Егоркино волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Октябрь (1997 нең 10 декабреннән — Нурлат) р-нында. Халык саны: 1782 дә — 32 ир-ат; 1859 да — 519, 1897 дә — 863, 1908 дә — 890, 1920 дә — 1065, 1926 да — 998, 1949 да — 629, 1958 дә — 486, 1970 тә — 633, 1979 да — 558, 1989 да — 463, 2002 дә — 572 кеше.

УРТА́ КӘШЕ́Р авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 15 *км* көньяк-көнбатыш-тарак, Камышлы елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 191 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кәшербаш исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәдрәсә, мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 529,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Иске Кәшер волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Сарман р-нында. Халык саны: 1834 тә — 100, 1870 тә — 233, 1920 дә — 612, 1926 да — 464, 1938 дә — 492, 1949 да — 467, 1958 дә — 356, 1970 тә — 372, 1979 да — 277, 1989 да — 197, 2002 дә — 199 кеше.

УРТА́ КИРМӘ́Н авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 20 *км* көнбатыш-тарак, Казан–Уфа автомобиль юлы буенда. 2010 елда 412 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1680 нән билгеле. 18 йөз-дә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында У.К.дә мәчет, 2 су тегермәне, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1324 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Кече Кирмән волостенда, 1920 дән ТАССР-ның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 107 ир-ат; 1859 да — 566, 1897 дә — 1202, 1908 дә — 1378, 1920 дә — 1394, 1926 да — 1312, 1938 дә — 1219, 1949 да — 850, 1958 дә — 819, 1970 тә — 876, 1979 да — 682, 1989 да — 542, 2002 дә — 476 кеше. У.К. янында 13–14 йөзләр Болгар шәһәрлеге хәрабәләре һәм 14 йөзнең 1 нче яртысы эпиграфик истәлекләре б-н каберлек («Ханнар зираты») саклана.

УРТА́ КОЛАҢГЫ́ (Зур Колаңгы) посёлогы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 14 *км* көнчыгыштарак, Колаңгы елгасы буенда. 2010 елда 39 кеше (руслар) яши. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында У.К.да 3 җил тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 502 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Кошман волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 56 ир-ат; 1859 да — 188, 1908 дә — 427, 1920 дә — 389, 1926 да — 333, 1938 дә — 218, 1949 да — 139, 1959 да — 90, 1970 тә- 83, 1979 да — 57, 1989 да — 68, 2002 дә — 55 кеше.

УРТА́ КӨШКӘ́Т авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 13 *км* төньяктарак, Көшкәт елгасы буенда. 2010 елда 222 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, дуңгыз асрау. Урта мәктәп, клуб, китапханә. 18 йөз башында Иске Көшкәт авылыннан күченүчеләр нигез сала. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Карлыган исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында су тегермәне, бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1209,4 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Сизнер волостенда, 1921 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның

10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1938 нең 4 августыннан — Чепья, 1958 нең 16 июленнән — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1746 да — 113, 1763 тә — 123 ир-ат; 1795 тә — 364 кеше; 1811 дә — 171 ир-ат; 1859 да — 371, 1884 тә — 352, 1897 дә — 321, 1905 тә — 465, 1920 дә — 567, 1926 да — 541, 1938 дә — 524, 1949 да — 330, 1958 дә — 215, 1970 тә — 248, 1979 да — 216, 1989 да — 186, 2002 дә — 222 кеше.

УРТА́ КУМО́Р авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 10 *км* көньяк-көнбатыштарак, Оштырма елгасы буенда. 2010 елда 248 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — дуңгыз асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты. 1719 дан билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында У.К.да Архангел чиркәве, ярма яргыч, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 646,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Иске Юмья волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 51 ир-ат; 1859 да — 218, 1897 дә — 335, 1908 дә — 384, 1920 дә — 390, 1926 да — 393, 1938 дә — 368, 1949 да — 281, 1958 дә — 283, 1970 тә — 388, 1979 да — 325, 1989 да — 216, 2002 дә — 260 кеше.

УРТА́ КУРСА́ авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 11 *км* көнчыгыштарак, Кесмәс елгасы буенда. 2010 елда 217 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты. 1940 елларга кадәр *Түбән Курса* авылы составында. Аерым торак пункт буларак аерылып чыккач, Чүриле р-нына керә. 1956 ның 14 маеннан Арча р-нында. Халык саны: 1949 да — 369, 1958 дә — 240, 1970 тә — 101, 1979 да — 173, 1989 да — 190, 2002 дә — 201 кеше.

УРТА́ КҮЛ, Көнбатыш Кама алдында. Идел елгасының югары террасасында, Лаеш р-ны Комлы Кавал авылыннан төньяк-көнчыгыштарак. *Кавал күлләре* системасына керә, ермак б-н *Зимница* һәм *Кавал күле* б-н тоташа. Су өслегенең мәйданы 19,5 *га*. Су күләме якынча 185 мең *м*^{3}. Озынлыгы 920 *м*, уртача киңлеге 220 *м*, уртача тирәнлеге 1 *м* тирәсе. Күл төбендә 2,6 һәм 3 *м* тирәнлектәге 2 чокыр бар. Күл карст-суффозия процесслары нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Формасы озынча, төньякка таба кысыла. Ярлары күтәренке, кайбер урыннары тал куаклары б-н капланган. Туенуы, нигездә, явым-төшемнәр исәбенә. Күл акрынлап ләмләнә бара. Ял итү максатларында файдаланыла.

УРТА́ МИШӘ́ (Кече Яңавыл) авылы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 18 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Мишә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 158 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. 1680 нән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Новая, Дянга Аул исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет (1864 тә төзелә), мәктәп, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 810,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Елыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1782 дә — 47 ир-ат; 1859 да — 390, 1897 дә — 507, 1908 дә — 553, 1920 дә — 576, 1926 да — 558, 1938 дә — 544, 1949 да — 365, 1970 тә — 310, 1979 да — 242, 1989 да — 165, 2002 дә — 172 кеше.

УРТА́ НЫРТЫ́ (Чиратнай) авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 22 *км* көнчыгыштарак, Мишә елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 175 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, умартачылык. Башлангыч мәктәп, клуб. 1680 нән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Каменный Ключ, Вершина речки Ныртs исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 725,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Әбде волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 36 ир-ат; 1859 да — 388, 1897 дә — 372, 1908 дә — 436, 1920 дә — 482, 1926 да — 520, 1938 дә — 432, 1949 да — 316, 1970 тә — 289, 1979 да — 254, 1989 да — 199, 2002 дә — 183 кеше.

УРТА́ ПӘНӘЧЕ́ авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 28 *км* төньяктарак, Чаллы–Зәй автомобиль юлы буенда. 2010 елда 130 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. 18 йөз уртасына кадәр нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Черемисская Пустошь, Тимерсу, Тимирсу-Тамак исемнәре б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, олаучылык һ.б. кәсепләр б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, су тегермәне була. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 738 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әхмәт волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1762 дә — 17, 1782 дә — 31 ир-ат; 1834 тә — 127, 1859 да — 234, 1870 тә — 272, 1897 дә — 509, 1913 тә — 627, 1920 дә — 685, 1926 да — 552, 1938 дә — 452, 1949 да — 284, 1958 дә — 385, 1970 тә — 246, 1979 да — 211, 1989 да — 141, 2002 дә — 131 кеше.

Әд.: Заинская энциклопедия. К., 1994.

УРТА́ ПОШАЛЫ́М авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 18 *км* төньяктарак, Пошалым елгасы буенда. 2010 елда 178 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты. 1630–50 елларда нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Средняя в вершине речки Ныртs, Пшалым Новой исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, балта эше, чана ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1038,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кармыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 49 ир-ат; 1859 да — 369, 1897 дә — 565, 1908 дә — 593, 1920 дә — 648, 1926 да — 680, 1938 дә — 773, 1949 да — 645, 1958 дә — 466, 1970 тә — 344, 1979 да — 540, 1989 да — 192, 2002 дә — 182 кеше.

УРТА́ РУ́ЖЕВКА посёлогы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 18 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Брустан елгасы буенда. 2010 елда 5 кеше (руслар) яши. 18 йөз ахыры — 19 йөз башында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Ружевщинский Починок, Ружевщинский буларак билгеле; 1902–34 елларда Ружевка исемен йөртә. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт һәм дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 164 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Матвеевка волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1944 нең 19 февраленнән — Матвеевка, 1954 нең 19 ноябреннән Минзәлә р-нында. 1968 елның 16 апреленнән У.Р. составына Зур Ружевка һәм Кече Ружевка посёлоклары кертелә. Халык саны: 1859 да — 68, 1884 тә — 131, 1897 дә — 156, 1906 да — 183, 1913 тә — 179, 1920 дә — 185, 1926 да — 141, 1938 дә — 119, 1949 да — 87, 1958 дә — 100, 1970 тә — 134, 1979 да — 74, 1989 да — 21, 2002 дә — 9 кеше.

Әд.: Мензелинский край: История и современность. Мензелинск, 2006.

УРТА́ САБА́ (Шайтан Елга) авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 4 *км* көньяктарак, Саба елгасы буенда. 2010 елда 134 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Шайтан Елгасы исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, өс-баш киемнәре тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1321

дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Сатыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 57 ир-ат; 1859 да — 401, 1897 дә — 574, 1908 дә — 652, 1920 дә — 655, 1926 да — 551, 1938 дә — 489, 1949 да — 408, 1970 тә — 250, 1979 да — 230, 1989 да — 135, 2002 дә — 141 кеше.

УРТА́ СӘРДӘ́ авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 18 *км* көнбатыштарак, Кызылсу елгасы буенда. 2010 елда 279 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. 1678 елдан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, кирпеч сугу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында У.С.дә мәчет, мәктәп, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1645,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Мүлмә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 20 ир-ат; 1859 да — 683, 1897 дә — 882, 1908 дә — 899, 1920 дә — 1056, 1926 да — 974, 1938 дә — 971, 1949 да — 760, 1958 дә — 612, 1970 тә — 567, 1979 да — 480, 1989 да — 334, 2002 дә — 302 кеше.

УРТА́ СОН авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 40 *км* көнбатыштарак, Сон елгасы буенда. 2010 елда 256 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1680 елдан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында У.С.да мәчет, мәктәп, су тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгыятенең имана җире 1376,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Түбән Сон волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 101 ир-ат; 1859 да — 608, 1897 дә — 808, 1908 дә — 928, 1920 дә — 999, 1926 да — 908, 1938 дә — 824, 1949 да — 690, 1958 дә — 567, 1970 тә — 490, 1979 да — 422, 1989 да — 301, 2002 дә — 296 кеше.

УРТА́ ТАЛКЫ́Ш авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 23 *км* көнчыгыштарак, Талкыш елгасы буенда. 2010 елда 110 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганаклары нда Новопоселённый Толкиш исеме б-н билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү-приход мәктәбе (1889 да ачыла), җил тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1101,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Олы Талкыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан Чистай р-нында. Халык саны: 1859 да — 280, 1897 дә — 535, 1908 дә — 534, 1920 дә — 615, 1926 да — 472, 1938 дә — 438, 1949 да — 310, 1958 дә — 181, 1970 тә — 137, 1979 да — 86, 1989 да — 83, 2002 дә — 113 кеше.

УРТА́ ТӘКӘНЕ́Ш авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 45 *км* төньяк-көнбатыштарак, Оча елгасы буенда. 2010 елда 97 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Китапханә. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына, 1930 елларга кадәр Урта Ошман исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп, су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 405,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Петропавел волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Кукмара, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән Мамадыш р-нында. Халык саны: 1859 да — 184, 1897 дә — 351, 1908 дә — 426, 1920 дә — 310, 1926 да — 283, 1949 да — 199, 1958 дә — 156, 1970 тә — 138, 1979 да — 156, 1989 да — 125, 2002 дә — 108 кеше.

УРТА́ ТИГӘНӘЛЕ́ авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 18 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Шонталы елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 602 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет 1700 еллар тирәсендә нигез салына. Рус чыганакларындагы беренче исеме — Аккозина. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, он тарту, йон тегү, сәүдә б-н шөгыльләнә. Реформадан соңгы чорда У.Т. 1878–1879 еллардагы *татар крәстияннәре кузгалышлары* үзәкләреннән берсе була. 20 йөз башында 2 мәчет, мәдрәсә, 7 җил тегермәне, 2 ярма яргыч, йон тегү йорты, 14 вак-төякләр кибете була; дүшәмбе базары эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3392 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Полянка волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чистай, 1935 нең 25 гыйнварыннан — Алексеев, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. Халык саны: 1782 дә — 246 ир-ат; 1859 да — 1385, 1897 дә — 1987, 1908 дә — 2426, 1920 дә — 2681, 1926 да — 1850, 1938 дә — 1347, 1949 да — 1088, 1958 дә — 1119, 1970 тә — 1244, 1979 да — 963, 1989 да — 744, 2002 дә — 689 кеше.

«УРТА́ ТИГӘНӘЛЕ́ БӘЕТЕ́», тарихи татар җыры, бәет. 1878–79 елларда Олы, Урта, Түбән Тигәнәле һәм Гаделша авылларында (хәзер Алексеев р-ны терр-ясе) булган вакыйгаларны яктырта. Крәстияннәр өстәмә җыемнар турында яңа күрсәтмәләргә каршы баш күтәрәләр; аларны бастыру өчен, хәрби отряд җибәрелә. Бәеттә крәстияннәргә карата булган башбаштаклыклар һәм җәберләүләр турында хикәяләнә; ахырында җирле шәкертләр тарафыннан язылуы күрсәтелә. Әсәрнең исеме, эчтәлеге, идея юнәлеше охшаш берничә варианты бар. Бәетне кулъязмадан Лаеш р-нының Хәерби авылында Г.Вафин күчереп ала, Казан ун-ты Фәнни китапханәсенең кулъязмалар мирасханәсендә саклана. «Урта авыл бәете»нең варианты беренче тапкыр Г.Толымбайский тарафыннан «Бәетләр» җыентыгында нәшер ителә (1935). «У.Т.б.» «Халык иҗаты» җыентыгында басыла (1938).

Әд.: Мозаффаров М., Виноградов Ю., Хәйруллина З. Татар халык көйләре. М., 1964; Татар халык иҗаты: Бәетләр. К., 1983; Аграрный вопрос и крестьянское движение в Татарии XIX в. М.–Л., 1936; Смыков Ю.И. Крестьянское движение в Казанской губернии в 1878–1879 годах. К., 1959.

Ф.И.Урманчеев.

УРТА́ УШМА́ (Шуйгырт) посёлогы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 7 *км* көньяк-көнбатыштарак, Шушма елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 40 кеше (удмуртлар, татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 18 йөз уртасында нигез салына, 1920 елларга кадәр рәсми рәвештә Кече Лызи авылы составына керә. 1876 елгы мәгълүматларга караганда, У.У.да 7 хуҗалык була. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Балтач волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1920 дә — 281 (Югары Ушма а. халкын да кертеп), 1926 да — 52, 1938 дә — 58, 1958 дә — 40, 1970 тә — 47, 1979 да — 71, 1989 да — 103, 2002 дә — 38 кеше.

УРТА́ ЧАЛЛЫ́ авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 15 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Самара өлкәсе б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 239 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында У.Ч.да мәчет, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 767 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Чаллы волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан Октябрь (1997 нең 10 декабреннән — Нурлат) р-нында. Халык саны: 1859 да — 277, 1897 дә — 494, 1908 дә — 557, 1920 дә — 759, 1926 да — 521, 1938 дә — 353, 1949 да — 321, 1958 дә — 282, 1970 тә — 354, 1979 да — 267, 1989 да — 198, 2002 дә — 289 кеше.

УРТА́ ЧАЛЛЫ́ авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 35 *км* көньякта-рак, Чаллы елгасы (Зәйнең сул кушылдыгы) буенда. 2010 елда 56 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык.

Клуб. 1680 нән мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы алпавыт һәм дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, У.Чда мәчет, мәктәп, су тегермәне эшли. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 503,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Тәкмәк волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1922 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1870 тә — 304, 1920 дә — 453, 1926 да — 208, 1949 да — 209, 1958 дә — 187, 1970 тә — 109, 1979 да — 84, 1989 да — 91, 2002 дә — 67 кеше.

УРТА́ ШҮЛӘҢГЕ́Р авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 43 *км* төнъяктарак, Юкәче елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 19 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1680 нән рус чыганакларында По речке Шуденгер исеме б-н билгеле. 1930 елларга кадәрге чыганакларда Урта Шәләнгүр буларак мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 283,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Җөри волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 27 ир-ат; 1859 да — 160, 1897 дә — 258, 1908 дә — 299, 1920 дә — 290, 1926 да — 276, 1949 да — 224, 1958 дә — 152, 1970 тә — 110, 1979 да — 76, 1989 да — 46, 2002 дә — 20 кеше.

УРЫ́ВКИНО авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 27 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Сеин елгасы буенда. 2010 елда 4 кеше (рус-лар) яши. 1841 еллар тирәсендә Пановка, Новосёлки, Щиры авылларыннан күченүчеләр нигез сала. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Иске Урывкино исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү-приход мәктәбе, 2 ашлык саклау-сату кибете, су тегермәне, 1 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 738,25 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Пановка волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1859 да — 180, 1897 дә — 412, 1908 дә — 421, 1920 дә — 532, 1926 да — 588, 1949 һәм 1958 дә — 339 ар, 1970 тә — 215, 1979 да — 116, 1989 да — 26, 2002 дә — 10 кеше.

УРЫ́С (Үрсу, Ырыс) авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 17 км көнбатыштарак, Тиргәвеш елгасы буенда. 2010 елда 282 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле – кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты.1732 дән мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы асабалар һәм типтәрләр катлавына бүленә, игенчелек, терлекчелек, чабата һәм кәрзин үреп сату б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп, 2 су тегермәне, тимерче алачыгы, 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1905 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Күзкәй волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Минзәлә р-нында. Халык саны: 1795 тә – 122, 1816 да – 100, 1834 тә – 130 ир-ат; 1859 да – 474, 1870 тә – 514, 1884 тә – 532, 1897 дә – 551, 1906 да – 716, 1913 тә – 716, 1920 дә – 707, 1926 да – 472, 1938 дә – 503, 1949 да – 372, 1958 дә – 349, 1970 тә – 374, 1979 да – 311, 1989 да – 196, 2002 дә – 248 кеше.

Әд.: Мензелинский край: История и современность. Мензелинск, 2006.



Шәһәр тибындагы Урыссу посёлогы. Гомуми күренеше.

УРЫССУ́ шәһәр тибындагы посёлогы, Ютазы р-ны үзәге. ТРның көньяк-көнчыгышында, Казаннан 382 *км* ераклыкта, БР б-н чиктәш, Ык елгасының сул ярында урнашкан. Ульянов–Уфа юнәлешендәге тимер юл станциясе. 2010 елда 10681 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 57,4%, руслар — 36,8%) яши. 124 нче һөнәр уч-щесе, татар гимназиясе, 3 урта һәм 1 махсус коррекция мәктәбе, музыка мәктәбе, «Олимп» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе, «Энергетик» мәдәният йорты, 3 китапханә, «Энергия» стадионы, район үзәк хастаханәсе. Мәчет, чиркәү, хатын-кызлар мәдрәсәсе. *Урыссу ГРЭСы*, «Урыссу химия заводы», «Электр тоташтыргычлар», «Урыссу руда булмаган материаллар предприятиесе» АҖләре, тимер-бетон эшләнмәләр з-ды, «Бетон+» һәм «Транспорт» ҖЧҖләре. 1945–46 елларда Урыссу ГРЭСы төзелеше б-н бәйле рәвештә нигез салына. 1947 нең 19 августыннан — шәһәр тибындагы посёлок. Оешкан көненнән Ютазы р-нында (1958 нең 28 февраленнән — район үзәге), 1963 нең 1 февралендә Әлмәт шәһәр советы адм. карамагына бирелә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Баулы р-нында, 1991 нең 6 апреленнән — Ютазы р-ны үзәге. Халык саны: 1989 да — 10,7 мең, 2002 дә — 11,3 мең кеше.

УРЫССУ́ ГРЭСЫ́, җылылык электр станциясе, ТРда беренче ГРЭСларның берсе. Ык елгасының сул ярында, Ютазы р-ныың шәһәр тибындагы Урыссу посёлогында урнашкан. Эшләүчеләр саны 300 ләп кеше (2014). 1943 елда төзелә башлый. Элек Власов ГРЭСында (Украина) файдаланылган энергетика җиһазлары урнаштырыла. 1944–45 тә 4 *МВт* егәрлекле 1 нче чираты, 1957 дә 6 нчы чираты сафка бастырыла. 1965–72 дә макс. егәрлеккә (251,5 *МВт*) ирешелә, 1992 дә иң зур күләмдә җылылык (332 мең *Гкал*) җитештерелә. Станция берничә тапкыр киңәйтелә һәм модернизацияләнә. 1996 да беренче ике чиратның искергән җиһазлары сүтелә. 1950–53 тә ГРЭС Урыссу энергетика комб-ты карамагында була, 1953 тән мөстәкыйль пр-тие, 1957–63 тә Татарстан ХХСның Энергетика сәнәгате идарәсе карамагында, 1963–2007 дә «*Татэнерго*» составына керә. 2007 дән «Урыссу ГРЭСы территориаль генерацияләүче компаниясе» АҖ. Энергияне 7 казанлы агрегат, 4 пар турбоагрегаты эшләп чыгара. Төп ягулык — табигый газ, резервта мазут тотыла. Суыту өчен Ык елгасы суы файдаланыла. Станциянең билгеләнгән электр егәрлеге — 161 *МВт*, җылылык егәрлеге — 127 *Гкал/сәг*., елга 349 млн. *кВт·сәг.* һәм 11,8 млн. *Гкал* энергия җитештерелә (2011). Эшләп чыгарылган электр энергиясе 110 *кВ* (8 линия), 35 *кВ* (2 линия) көчәнешле линияләр буенча РФ Үзәк энергетика системасына, 6 *кВ* көчәнешле линияләр буенча җирле кулланучыларга тапшырыла.

ГРЭС — шәһәр төзүче пр-тие, шәһәр тибындагы Урыссу посёлогында торак, мәгариф, сәламәтлек саклау, социаль-мәдәни максатлардагы объектлар, мәктәпкәчә учреждениеләр, спорт корылмалары һ.б. төзелешләр заказчысы. Хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә лаек була, ш.и. 10 кешегә — ТРның атказ. энергетигы, 1 кешегә — атказ. ягулык-энергетика комплексы хезмәткәре исемнәре бирелгән.



Урыссу ГРЭСы. Гомуми күренеше.

лә, 2 кеше — Ленин ордены, 1 кеше — Октябрь Революциясе, 7 кеше — Хезмәт Кызыл Байрагы, 1 кеше — Халыклар дуслыгы, 17 кеше — «Почёт билгесе», 2 кеше — 3 нче дәрәҗә Хезмәт Даны орденнары, 221 кеше медальләр б-н бүләкләнә.

Пр-тие җитәкчеләре арасында: Н.Т.Черкасов (1944–46), В.И.*Мишин* (1948–57), В.К.*Шибанов* (1947–48, 1957–62), В.И.Суздальцев (1962–63), Л.М.Островский (1963–71), В.С.Кожарин (1971–85), Е.В.Цыганов (1985–98), В.П.Тюклин (2002–06), А.Н.Галләмов (2008–2011), Э.Ф.Шакиров 2011 дән).

Әд.: Развитие энергетики Татарской АССР. К., 1961; Энергетике Татарии 50 лет. К., 1970; История энергетики Татарстана (1920–2000). К., 2001; Петров В.И. Уруссинская ГРЭС: Энергия для нефтяного края // Энергетика Татарстана. 2006. № 5. *Г.Я.Мәүлетова, М.Ж.Гаитов.*

УРЮ́М (Ырым) авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 19 *км* көньяктарак, Тәтеш–Ульянов автомобиль юлы буенда. 2010 елда 572 кеше (мордвалар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау; урманчылык. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында У.да Никольский чиркәве, чиркәү-приход (1896 да ачыла) һәм земство (1875 тә ачыла) мәктәбе, 9 җил тегермәне, 2 тимерче алачыгы, май язу йорты, ярма яргыч, 1 казна шәраб һәм 7 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 5341 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Пролей Каша волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәтеш, 1938 нең 4 августыннан — Олы Тархан, 1959 ның 12 октябреннән Тәтеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 417 ир-ат; 1859 да — 1475, 1897 дә — 2595, 1908 дә — 2948, 1920 дә — 2594, 1926 да — 2273, 1938 дә — 2094, 1949 да — 1632, 1958 дә — 1616, 1970 тә — 1318, 1979 да — 1010, 1989 да — 749, 2002 дә — 629 кеше.

УСА́ елгасы, Көнчыгыш Кама алдында, Барҗы елгасының (Иж елгасы бассейны) сул кушылдыгы. озынлыгы 14,5 *км*, ТРның чиклә рендә — 3 *км*. Бассейнының мәйданы 38 *км*^{2}. Можга калкулыгыннан ага. Елга башы Әгерҗе р-ны Яңа Бәзәкә авылыннан 0,5 *км* төнъяктарак, тамагы Удмурт Респ-касы терр-ясендә. Елга башының абс. биеклеге 190 *м*, тамагыныкы — 82 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 7%. У.ның 0,7 дән 5,1 *км* га кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,55 *км/км*^{2}. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,25–0,5 *л/с·км*^{2}. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен ныкаегуы б-н характерлана.

Язгы ташу, гадәттә, апрель башында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,05 *м*^{3}*/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*) кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*).

УСА́Д авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 12 *км* төньяктарак, Сола елгасы (Казансуның уң кушылдыгы) буенда. 2010 елда 1095 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 70%, руслар — 28%) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Спирт з-ды. Урта мәктәп, 70 нче һөнәр уч-ще се, мәдәният йорты, китапханә, автодром. Мәчет, чиркәү. 1677 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Троицкий исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау, он тарту б-н шөгыльләнә. 19 йөзнең соңгы чирегендә авыл халкы сәүдәгәр Журавлёвларның зур пар тегермәненда эшли (1870 тә У.та алпавыт А.А.Ширинская-Шихматовадан җир сатып ала). 20 йөз башында Троица чиркәве (1789–93 тә төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1885 тә ачыла), 2 тимерчелек, аракы з-ды (пар тегермәне җирлегендә 1902 дә нигез салына), 2 су тегермәне, телефон, сыраханә, казна шәраб һәм бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 357,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Собакино волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1935 нең 10 февраленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 196 ир-ат; 1859 да — 317, 1897 дә — 307, 1908 дә — 263, 1920 дә — 348, 1926 да — 334, 1938 дә — 712, 1949 да — 454, 1958 дә — 197, 1970 тә — 175, 1989 да — 852, 2002 дә — 1122 кеше.

Әд.: Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

УСА́Д авылы, Лаеш р-нында, Казан тимер юл станциясеннән 14 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Казан–Оренбург автомобиль юлы буенда. 2010 елда 1485 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 68%, татарлар — 30 %) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык; юл-төзелеш участогы. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты. 18 йөз башында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында У.та укырга-язарга өйрәтү мәктәбе (1891 дә ачыла), 4 җил тегермәне, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1895 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Столбище волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Воскресенский, 1927 нең 1 августыннан Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Столбище, 1959 ның 26 мартыннан — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 101 ир-ат; 1859 да — 553, 1897 дә — 788, 1908 дә — 852, 1920 дә — 910, 1926 да — 1112, 1949 да — 628, 1958 дә — 1037, 1970 тә — 1127, 1979 да — 1202, 1989 да — 1239, 2002 дә — 1296 кеше.

Әд.: История Лаишевского края. Чебоксары, 1997.

УСА́ЕВ Канзафар (Ханзафар) (1738 — 10.7.1804, Балтыйк Порты, хәзер Палдиски ш., Эстония), 1773–75 елгы *Крәстияннәр кузгалышында* катнашучы, Е.И.*Пугачёв* көрәштәше. Оренбург губернасының Уфа өязе Бозаяз авылы йозбашы. Е.И.Пугачёв хәрәкәтенә 1773 нең көзендә килеп кушыла. Оренбург шәһәрен камауда катнаша, Е.И.Пугачёв тарафыннан полковник «чины бирелә», соңрак «...фетнә күтәргән, халыкны җыеп, аларны Пугачёвның чын Петр Фёдорович икәнлегенә ышандырырга, ә каршы торучыларны асарга» Уфа өязенә җибәрелә. 1774 тә У. Көнгер, Екатеринбург һәм Уфа тирәләрендә сугыша. 1774 нең июнендә Е.И.Пугачёв аны баш полковник итеп билгели; У. «халык фетнәсе турында манифест» ала. Ул «...Уфага һөҗүм итеп Россия гаскәрләрен тар-мар итәргә» ниятли, шуның өчен 400 кешедән торган отряд туплый. 1774 нең август башында әсир ителә. Сенат хөкеме б-н Балтыйк Портына сөргенгә озатыла.

Чыг.: Крестьянская война 1773–1775 гг. на территории Башкирии: Сб. док. Уфа, 1975.

Әд.: Оренбургская Пушкинская энциклопедия. Оренбург, 1997. *И.Р.Вәлиуллин.*

УСА́Й авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 20 *км* көньяк-көнбатыштарак, Минзәлә елгасы буенда. 2010 елда 168 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб, китапханә. 1755 елга кадәр нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы асабалар һәм типтәрләр катлавына бүленә, игенчелек, терлекчелек, чабата үрү, киез итек-киез җитештерү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, бакалея һәм ашлык саклау-сату кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 634,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Минзәлә волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Минзәлә р-нында. Халык саны: 1795 тә — 52 кеше, 1816 да — 65 кеше; 1834 тә — 106 ир-ат; 1859 да — 318, 1870 тә — 391, 1884 тә — 424, 1897 дә — 585, 1906 да — 608, 1913 тә — 717, 1920 дә — 776, 1926 да — 757, 1938 дә — 629, 1949 да — 520, 1958 дә — 427, 1970 тә — 397, 1979 — 281, 1989 да — 172, 2002 дә — 207 кеше.

Әд.: Мензелинский край: История и современность. Мензелинск, 2006.

УСА́Й авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 18 *км* төньяк-көнбатыштарак, Игәнә елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 116 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1870–80 елларда нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Яңа Усай исеме б-н билгеле. Халкы игенчелек, терлекчелек, чабата үрү, киез итек басу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәдрәсә, бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 529 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Языково волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Сарман, 1935 нең 10 февраленнән — Ворошилов, 1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл, 1959 ның 12 октябреннән — Сарман р-нында. Халык саны:

1870 тә — 391, 1897 дә — 585, 1906 да — 336, 1926 да — 248, 1938 дә — 283, 1949 да — 206, 1958 дә — 181, 1970 тә — 302, 1979 да — 213, 1989 да — 143, 2002 дә — 121 кеше.

УСА́К (Populus tremula), талчалар семьялыгыннан яфрак коючы агач. Евразиянең урта ча поясында үсә. Татарстан терр-ясендә бөтен җирдә таралган. Тамырлары җир өстенә якын, ябалдашының проекциясе чигеннән шактый ераккa җәелгән. Кәүсәсе цилиндрсыман, 30 *м* га кадәр биеклектә. Яшь агачларның кабыгы шома, яшькелт-соры, карт агачларның төбенә таба (кәүсәнең төбе) кара-соры, тирән яргаланган. Ябалдашы түгәрәк яки озынча түгәрәк формада. Яфраклары соры-яшел, түгәрәк, кырыйлары тупыйк очлы эре тешчекле. Сабы озын, уртасында яссыланган, шунлыктан аз гына җил булганда да яфраклары шаулый. Ике өйле үсемлек. Ата алкаларның озынлыгы 7–10 *см*, кара-кызыл серкәлекле, ана алкалар — кыскарак һәм нәзегрәк, яшькелт төстә. Бик иртә, яфрак ярганчы чәчәк аталар. Җимеше — тартмачык. Орлыктан, тамыр үрентеләреннән, өзелеп төшкән яшь ботаклардан (көзен) үрчи. У. — яктылык яратучы, тиз үсүче, әмма озак яшәмәүче агач. Бушаган урман мәйданнарында беренче булып (каен б-н беррәттән) үсеп чыгалар (шушы үзлеге өчен аны урманлану пионеры дип йөртәләр). Ылыслы һәм киң яфраклы урман кисенделәре урынында вак яфраклы урманнар формалаштыра. ТРда урман барлыкка китерүче төп токымнарның берсе. У. урманнары якынча 239,5 мең *га* билиләр, бу урман б-н капланган мәйданның 21% ын тәшкил итә; утыртмаларның аеруча зур мәйданнары һәм запасы Кама аръягында (Аксубай, Әлки, Биләр, Кәләй, Нурлат урман хуҗалыклары) тупланган. У.ның үзагачы ак, үзәге юк, йомшак, җиңел ярыла һәм киселә, кипкәч бик катылана. Шырпы һәм целлюлоза-кәгазь сәнгатендә, төзелеш һәм вак-төяк әйберләр ясау өчен материал буларак файдаланыла. У. йөрәксыман (авыру тудыручы — ялган усак агач гөмбәсе) һәм төп (баллы гөмбә) черек авыруларына бирешүчән. Халык медицинасында кайры һәм бөреләре төнәтмәсе темп-ра төшерү чарасы, ш.у. подагра, дизентерия вакытында кулланыла. У. күп кенә урман хайваннары (куян, кондыз, поши һ.б.) өчен азык булып тора.

Әд.: Осинники Республики Татарстан, их хозяйственное значение, современное состояние и проблемы повышения их эк ономического потенциала // Леса, лесной сектор и экология Республики Татарстан: Сб. науч. статей. К., 2005. Вып. 1.

УСА́К ГӨМБӘСЕ́ (Leccinum aurantiacum), болетачалар семьялыгыннан көпшәле гөмбәләр. Төньяк ярымшарда таралган. Яфраклы һәм катнаш урманнарда, кагыйдә буларак, яшь усаклыкларда үсә. Татарстан терр-ясендә 2 формасы таралган: кызыл У.г. һәм сары-коңгырт У.г. Июньнең икенче яртысыннан октябрьгә кадәр, зур булмаган төркемнәрдә еш очрыйлар. Эшләпәсенең диаметры 25 *см* га кадәр, сабына ныклап береккән, кызыл У.г.нең коңгырт-кызыл яки кызгылт сары төстә, сары-коңгырт У.г.нең шома яки берникадәр бәрхетсыман. Йомшагы тыгыз, ак, сындырганда зәңгәрләнә, аннары карала. Споралы порошогы коңгырт. Сабы 20 *см* га кадәр озынлыкта, аска таба юанаеп тора, соргылт-ак, карасу тәңкәчекләр б-н капланган. Ашарга яраклы. Илл. к. *Гөмбәләр* мәкаләсендә.

УСАКЛЫ́К посёлогы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 26 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Мөшеге елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 47 кеше (марилар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп. 1930 еллар башында нигез салына. Оешкан көненнән Мөслим р-нында. 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1938 дә — 123, 1949 да — 96, 1958 дә — 123, 1970 тә — 193, 1979 да — 137, 1989 да — 62, 2002 дә — 47 кеше.

УСА́ТОВ Дмитрий Андреевич (10.2.1847, С.-Петербург янындагы Алексеевка а. — 10.8.1913, Ялта ш.), җырчы (тенор), антрепренёр, педагог. Чыгышы б-н крепостной крәстияннәрдән. Вокал буенча күнекмәләр не — җыр мәктәбендә, соңрак граф Н.Шереметевның Г.Ломакин җитәкчелегендәге капелласында ала. Петербург консерваториясен (1873, П.Репетто һәм К.Эверарди класслары) тәмамлый. 1873–74, 1876, 1879 елларда — Киев операсында, 1875–78 һәм 1901 дә Казанда П.Медведевның опера труппасында җырлый. Труппа составында Түбән Новгород, Саратов, Әстерхан һ.б. шәһәрләрдә чыгышлар ясый. 1880–89 да Зур театр солисты. Опера партияләре: Фауст (шул исем. әсәр буенча, Ш.Гуно), Радамес («Аида», Дж.Верди), Андрей, Вакула («Мазепа», «Башмаклар» («Черевички»), П.Чайковский, беренче башкаручы). У.ның камера репертуарын А.Даргомыжский, М.Балакирев, П.Чайковский романслары, рус халык җырлары һ.б. тәшкил итә. 1890–92 дә Тифлис шәһәрендә музыка уч-щесендә укыта. 1892 дә шунда ук опера студиясе ача, анда җыр дәресләре укыта, 1892–93 тә Ф.Шаляпин да аннан җыр дәресләре ала. 1902 дән Ялта шәһәрендә пед.-агарту эшчәнлеге алып бара. Рус шагыйрьләренең шигырьләренә язылган романслар һәм җырлар авторы.

Әд.: Гозенпуд А.А. Русский оперный театр XIX века. 1873–1889. Л., 1973; Нечаев Г. Учитель Шаляпина // Московский журн. 1992. № 2.

УСАЧЁВ Александр Евгеньевич (21.2.1951), Казан), физик, физика-матем. фән. д-ры (2005). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1973), РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында эшли. 1996 елдан Казан энергетика ун-тында, проф. (2000 нән), кичке электр энергетикасы ф-ты деканы (2000–01). Хезмәтләре структур фаза күчешләренә, Ян-Теллер эффектына; югары вольтлы җиһазларның халәтен диагностикалауга һәм яшен сугулардан сакланууга карый. У. перовскит һәм эльпасолит монокристалларындагы Cu 2+, Ni 3+ ионнарының эзлекле структур фаза күчешләрен һәм Ян-Теллер эффектын тикшерә. Атомнар структурасын тәшкил итүче тотрыклы конфигурацияләрнең параметрларын һәм атомнарның күчешләрен билгели. Күчешле һәм сирәк табылучы элементларның ионнары белән баетылган диамагнит кристалларда структур фаза күчеше шартларында доменнар хасил булуга магнит кыры йогынты ясавын ачыклый. Электр энергиясен исәпләү һәм контрольдә тоту автоматлаштырылган системаларында үлчәүнең ялгышлыгы ихтималын киметүче үлчәү алымнары эшли.

Хезм.: Моделирование кооперативных свойств неорганических соединений // Координационная химия. 1997. Т. 23, вып. 1 (автордаш); Микрофазовое разделение и магнитные ян-теллеровские полироны в LaSrAl 1-x Cu x O 4-delta // Физика твёрдого тела. 1998. Т. 40, вып. 4 (автордаш); Систематические погрешности измерительных трансформаторов тока: зависимость от величины первичного тока // Изв. вузов. Проблемы энергетики. 2004. № 7–8 (автордаш).

УСИ́НСК, *Коми Республикасындагы* шәһәр. *Сыктывкар* шәһәреннән 757 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Уса елгасының уң ярында урнашкан. 1966 елда нефтьчеләр посёлогы буларак төзелә, 1984 тән — шәһәр. Халкы — 38800 кеше (2017). Татарлар саны: 1979 да — 3040, 1989 да — 6157, 2002 дә — 3860, 2010 да — 3170 кеше. У.да татарлар 1960 еллардан яши. Коми Респ-касы татар-башкорт милли-мәдәни автономиясе (1991 дән), «Болгар» татар-башкорт иҗтимагый-мәдәни үзәге (1992), татар-башкорт яшьләр оешмасы (2002) эшли. Татар теле шәһәрнең бер мәктәбендә (1992–96 да — 3, 1996–98 дә 2 мәктәптә) факультатив дәрес буларак укытыла. 1995–97 елларда «Туган як аваздары» телевидение (айга 1 тапкыр) һәм «Җомга» радио (җомга көннәрендә) тапшырулары эфирга чыга. «Болгар» иҗтимагый-мәдәни үзәге каршында шул ук исемдәге татар-башкорт җыр ансамбле, «Таң йолдызлары» татар эстрада һәм халык җырларын яшь башкаручылар ансамбле, «Агыйдел» балалар халык биюләре хореографик ансамбле, «Ләйсән» балалар татар җыры ансамбле эшли. У. татарлары турында — «Халкым минем», «Болгар» иҗтимагый-мәдәни үзәге эшчәнлеген чагылдырган документаль фильмнар төшерелә (1997). 1992 дән респ-ка күләмендә *Сабан туе* үткәрелә. Мөселман диния нәзарәте, Ислам мәдәни үзәге, мәчет эшли.

УСМА́Н Гыйләҗетдин Рәхмәтулла улы (1938, Кытай), тел галиме. Кытай Халык Респ-касында яши һәм эшли: 1981–91 елларда — уйгыр телендәге журналлар нәшриятында (Шөнҗән-Уйгыр автономияле р-ны). 1993–97 дә ТР ФА Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тының әйдәп баручы фәнни хезмәткәре. Хезмәтләре кытай теленнән уйгыр теленә һ.б. төрки телләргә тәр җәмә нигезләренә, Кытайдагы татар диаспорасы тарихына карый.

УСМА́НОВ (Госманов) Айтуган Гариф улы (19.12.1920, Казан — 1.10. 1996, шунда ук), җылылык физикасы белгече, техник фән. д-ры (1960), проф. (1960), ТАССРның һәм РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлекләсе (1968, 1975). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1942), Я.М.Свердлов исем. з-дта эшли (Горький өлкәсе Дзержинск ш.). 1943–96 елларда Казан технол.

ун-тында, җылылык техникасы каф. мөдире (1953–59), директор (1959–62), җылылык техникасының теоретик нигезләре каф. мөдире (1952–95), каф. профессоры (1995 тән). Хезмәтләре газсыман һәм сыек органик кушылмаларның җылылык һәм масса алмашуына, җылылык-физик үзенчәлекләренә, фаза әверелешләрендәге җылылык алмашу процесларына карый. Стат. физика һәм мәгълүмат теориясе алымнары нигезендә У. яңа фәнни юнәлеш — молекуляр күчереш процесслары охшашлыгын эшли. Химик технологияләрнең теоретик нигезләрен эшләве һәм «Түбәнкаманефтехим» АҖ дә бутилкаучук, пропилен оксиды һәм стирол җитештерүне камилләштергәне өчен ТР Дәүләт бүләгенә бирелә (1994). Уйлап табуга 3 авторлык таныклыгы бар. «Химия технологиясендә җылылык һәм масса алмашу» («Тепло- и массообмен в химической технологии») җыентыгының баш мөхәррире. Өч Хезмәт Кызыл Байрагы, Почёт орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Теплопроводность органических жидкостей. Л., 1971 (автордаш).

Әд.: Выпускники — гордость Казанского технологического университета: Краткий биогр. справ. К., 2009.

УСМА́НОВ Борис Фатыйх улы (14.7.1939, Төрекмәнстан ССРның Красноводск р-ны Джебел тимер юл станциясе), социолог, филос. фән. канд. (1976), социол. фән. д-ры (1995), проф. (1997), РФ Югары проф. белем бирү министрлыгы мактаулы хезмәткәре (1999). Казан авиация ин-тының очу аппаратлары ф-тын тәмамлый (1962). 1964 елдан В.Н.Челомей исем. Үзәк КБда (Мәскәү). 1967–71 дә Балашиха шәһәрендә: ВЛКСМ шәһәр ком-тының 1 нче секретаре. 1974 тән Яшьләр ин-тында (хәзер Мәскәү гуманитар ун-ты). Хезмәтләре яшьләр социологиясе, иҗтимагый оешмалар б-н идарә итү, сайлау технологияләре өлкәсенә карый.

Х е з м.: Стиль и время: проблемы организации комсомольской работы в условиях демократизации и развития самодеятельных начал. М., 1990; Стиль управления: методологические и социологические аспекты. М., 1993; Социальная инноватика: Учеб. пособие. М., 2000.

УСМА́НОВ Вил Нургали улы (18.3.1968, Баулы р-ны Хансүәр а.), җырчы, композитор, спортчы (милли көрәш). ТРның халык артисты (2018). ТРның спорт остасы (1993). Әлмәт физик культура техникумын (1986), Казан музыка уч-щесен (1995), Татар гуманитар-пед. ун-тын (2007) тәмамлый. 1986–88 елларда Баулы р-нының Яңа Чүте урта мәктәбендә физик культура укытучысы, 1988–90 да «Баулынефть» НГДУнда тренер, 1990–91 дә Баулы р-нында М.Җәлил исем. мәдәният йортында баянчы, 1995-2013 тә — «Казан» милли мәдәният үзәгендә (соңрак Казан шәһәр филармониясендә) солист-вокалист булып эшли. 2003 тән шәхси эшмәкәр. 2008–13 тә Халыкара «Татар моңы» яшь башкаручылар конкурсының башкарма директоры. Композитор буларак «Яныңа үзем барам» («Юлымда синең эзләрең...», З.Нури сүзләре), «Сез һаман бергә икән» (С.Хәким сүзләре), «Учак сүнмәгән» («Кил әле...», В.Фатыйхов сүзләре), «Күпер» («Ике урам арасы»), «Ашыкмыйм китәргә бу җирдән», «Яратмыйча яшәп кара син», «Югалтасым килми» (барысы да — Р.Зәкуан сүзләре), «Ак чәчәкләр» (А.Әхмәтвәлиева сүзләре), «Без дигәнчә түгел» (Н.Төхфәтуллов сүзләре), «Синең өчен» (К.Шәмсуар сүзләре), «Без бу җирдә кунак кына» (Д.Йосыпова сүзләре) һ.б. җыр көйләре авторы; ш.у. «Ялан аяклы кыз», «Ак чәчәкләр», «Остазбикә» фильмнарына һәм «Әпипә» мюзиклына музыка яза. Репертуарын танылган композиторларның «Юкка түгел» (Н.Нәҗми сүзләре, Р.Хәсәнов көе), «Әй язмыш, язмыш» (С.Хәким сүзләре, С.Садыйкова көе), «Агыла да болыт агыла» (Х.Туфан сүзләре, А.Акчурин көе), «Китмә сандугач» (Г.Зәйнашева сүзләре, Р.Яхин көе), «Кичер мине, әнкәй, гафу ит» (Г.Идрисов сүзләре, Р.Хәсәнов көе), «Җырлыйм туган якта» (Р.Миңнуллин сүзләре, И.Закиров көе) һ.б.; ш.у. «Кара урман» «Тәфтиләү», «Шахта», «Олы юлның тузаны», «Әй гүзәлем», «Ак калфак» кебек халык җырлары тәшкил итә.

У. ТРның милли көрәш буенча биш тапкыр чемпионы (1993, 1995, 1997-99). Медаль б-н бүләкләнә.

УСМА́НОВ Габделәхәт Шаһи улы (16.5.1896, Әстерхан губ., Красноярск өязе Кече Сентовка а. – 16.2.1996, С.-Петербург), геолог, геофизик, Эстония ССР Дәүләт бүләге лауреаты (1958), геол.-минерал. фән. канд. (1934). Ленинград тау ин-тын тәмамлый (1930), шунда ук укыта (1968 гә кадәр), геол.-разведкалау ф-ты деканы (1953–58) һәм нефть геофизикасы каф. мөдире (1955–57). Хезмәтләре разведкалауның геофизик алымнарына, янучан сланецларның үзенчәлекләренә карый. Дәүләт бүләге сланецларның җимерелгән катламнарын билгеләүнең физикысулларын эшләгәне өчен бирелә. Гражданнар сугышында, Бөек Ватан сугышында катнаша. Ике 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Кызыл Йолдыз, ике «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Курс электроразведки: Учеб. М., 1938 (автордаш).

УСМА́НОВ Гайса Идрис улы (20.8.1922, Оренбург өлкәсенең Северный р-ны Керәжле а. — 1993, Оренбург өлкәсенең Абдулин р-ны 2 нче Степановка а.), Дан орденының тулы кавалеры (9.7.1944, 16.11.1944, 26.6.1945), гв. өлкән сержанты. Колхозда тракторчы булып эшли. 1941 елның июленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, разведчик-күзәтүче, 122 нче гв. артиллерия полкының (6 нчы гв. армиясенең 51 нче гв. укчы дивизиясе) разведка отделениесе командиры. Воронеж, 1 нче һәм 2 нче Балтыйк буе фронтлары гаскәрләре составында Курск сугышында (1943), Витебск-Орша (1944), Полоцк (1944), Рига (1944) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 22–25 июнендә Сиротино авылы (Витебск өлкәсенең Шумилино р-ны) янында дошман оборонасын өзгәндә батырлык күрсәтә: аның разведка мәгълүматлары нәтиҗәсендә дошманның танкка каршы батареясы һәм 3 пулемёты утка тотылып юк ителә; беренчеләрдән булып Көнбатыш Двина елгасын



В.Н. Усманов.



Гайса И. Усманов.

кичә; расчёты б-н бергә дошман пулемётын сафтан чыгара; 1944 нең 7 октябренә каршы төндә Тришкяй торак пункты янындагы сугышта дошман танклары туплануы турында мәгълүмат таба һәм аны үз вакытында хәбәр итә; 1945 нең 22 февралендә Межиниеки (Латвия ССР) торак пункты янындагы һөҗүм алдыннан 2 дзотның һәм миномёт батареяларының кайда урнашуын ачыклый, һәм алар сафтан чыгарыла; һөҗүм сугышларында дошманның 10 лап солдатын юк итә. Демобилизацияләнгәч (1945), туган авылы сәүдә пр-тиесендә шофёр булып эшли. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

М.З.Хәбибуллин.

УСМА́НОВ Гомәр Исмәгыйль улы (16.3.1932, Чистай ш. — 23.2.2015, Казан), партия, дәүләт эшлеклесе. Чистай а.х.н механикалаштыру техникумын (1950), Казан а.х. ин-тын (1961) тәмамлый. 1950 елдан Усад а.х.н механикалаштыру мәктәбендә укытучы, 1953–54 тә ВЛКСМның Биектау район комы 1 нче секретаре, 1954 тән Чистай а.х.н механикалаштыру техникумында укытучы. 1956–62 дә КПССның Чистай шәһәр ком-тында: 1960 тан — 2 нче, 1961 дән 1 нче секретарь. 1962 дән Чаллы колхоз-совхоз җитештерү идарәсе башлыгы, 1965 тән КПССның Буа райкомы 1 нче секретаре. 1966–82 дә ТАССР МС рәисе. 1982–89 да КПССның Татарстан өлкә ком-ты 1 нче секретаре, 1989–90 да КПСС ҮК секретаре. 1986–90 да КПСС ҮК әгъзасы. 1966–90 да СССР ЮС депутаты, 1984–89 да СССР ЮС Президиумы әгъзасы. 1990 да СССР ЮС халык депутаты итеп сайлана. 1967- 85 тә ТАССР ЮС депутаты.

ТАССР МСнда, КПССның Татарстан өлкә ком-тында ул җитәкчелек иткән елларда респ-ка икътисады һәм социаль-мәдәни төзелеш гаять зур күтәрелеш кичерә: ТАССР илдә нефть б-н төп тәэмин итүче була; 1970 елда респ-када 100 млн. *т* «кара алтын» чыгарыла; илдә «Органик синтез», «*Түбәнкаманефтехим*», *КамАЗ*, «*Түбәнкамашин*» кебек иң эре пр-тиеләр төзелә; 1989 да «*Менделеевазот*» минераль ашламалар з-ды сафка баса. А.х. җитештерүендә механикалаштыру һәм интенсивлаштыру дәрәҗәсе шактый күтәрелә; Казан, Чаллы, Түбән Кама шәһәрләре янында эре агросәнәгать комплекслары оештырыла, а.х. җитештерүенең яңа тармаклары — сугарулы игенчелек һәм сәнәгый ни-

гездә кошчылык тармагы барлыкка килә, зур терлекчелек комплекслары төзелеше киң җәелә. КПССның Татарстан өлкә ком-ты 1 нче секретаре буларак, 1989 ның февралендә, КПСС ҮК җитәкчелеге белән килештермичә генә, У. Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият, тарих ин-ты һәм Казан мәдәният ин-ты галимнәренең Татар совет энциклопедиясен булдыру башлангычын хуплау турында күрсәтмә бирә.



Гомәр И. Усманов.

1970–80 елларда а.х. җитештерүен химияләштерү, концентрацияләү һәм махсуслаштыру гамәлгә ашырыла. 1976 да бөртеклеләрдән респ-ка өчен рекордлы уңыш алына (1 *га* дан 17,2 *ц*), ашлыкның тулаем җыемы 4217 мең *т* тәшкил итә; кул хезмәтенә нигезләнгән кечкенә терлекчелек фермаларын планлы рәвештә механикалаштырылган зур комплексларга алыштыру бара. Илдә азык-төлек кытлыгы шартларында 1960 еллар ахырыннан респ-ка Чаллы һәм Түбән Кама кебек яңа зур шәһәрләр төзүче халыкның ихтыяҗын үзендә җитештерелгән иң кирәкле продуктлар б-н тәэмин итә. 1970–80 елларда авыл мәдәниятен үстерү буенча зур эш алып барыла, авыл җирлекләрендә гомуми белем бирү мәктәпләре ачуга аерым игътибар юнәлтелә. 1970–80 елларда гомуми тип проект буенча 1100 мәктәп төзелә. Яңа уку елына әзерлек, яшьләргә гомуми мәҗбүри урта белем бирүне уңышлы тормышка ашыру һәм авыл мәктәпләрендә эш шартларын яхшырту буенча ТАССР күп тапкырлар Бөтенроссия соц. ярышында җиңүче дип табыла, РСФСР МС һәм ВЦСПСның күчмә Кызыл Байрагын яулый.

Югары мәктәпләр, һөнәри техник белем бирү учреждениеләре үсешендә дә сизелерлек уңышларга ирешелә. Ел саен халык хуҗалыгы тармакларына һөнәри техник уч-щеләрдән 36 меңнән артык квалификацияле эшче килә. 1980 еллар башына респ-ка халкын мәктәпкәчә тәрбия учреждениеләре б-н тәэмин итү мәсь әләсе тулысынча диярлек хәл ителә. Казанда һәм респ-каның башка шәһәрләрендә подваллар һәм баракларда яшәүче халкының уңайлыклары булган фатирларга күчерү бара. 1980 елларның 2 нче яртысында коммуналь торак төзелешендә ТАССР иң югары күрсәткечләргә ирешә — ел саен 40 меңнән артык фатир сафка баса. Халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтүне оештыруда зур үзгәрешләр була: 1960 елларда халыкка хезмәт күрсәтү күләме буенча ТАССР РСФСРда 56 нчы урында булса, 1980 елларга 7 нче урынга чыга. Сәламәтлек саклау системасы да үсә: 1980 еллар башына ТАССРның барлык районнарында да үзәк район хастаханәләре, һәр авылда һәм зур терлекчелек фермаларында мед. пунктлары ачыла. Күперләр һәм юллар төзелә.

1980 еллар ахырына икътисади потенциалы, фән, мәдәният һәм сәнгать үсеше дәрәҗәсе буенча ТАССР күп кенә союздаш респ-каларны узып китә. Икътисад һәм мәдәният үсеше өлкәсендәге казанышлары өчен ТАССР 1970 елда — Октябрь Революциясе ордены, 1972 дә Халыклар дуслыгы ордены б-н бүләкләнә; 1970–80 елларда аңа берничә тапкыр КПСС ҮК, СССР МС һәм ВЦСПСның күчмә Кызыл Байрагы тапшырыла.

У. Октябрь Революциясе, ике Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе», «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: Чернобровкина Е. Гумер Усманов: «Мне знакомы все тропы Родины моей...» // Татарский мир. 2007. № 7; Ахмадуллин Н. Секретарь союзного значения // Татарстан. 2010. № 6; Султанбеков Б.Ф. Гумер Усманов. К., 2017.

Г.С.Сабирҗанов.

УСМА́НОВ Зәкәрия Абдулла улы (16.6.1947, Буа р-ны Адав-Толымбай а. — 12.2.2013, шунда ук), галим агроном, ТРның һәм РФнең атказ. агрономы (1994, 2005), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2003). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1979). Буа р-нында эшли: «Буа» терлек симертү с-зында өлкән агроном (1970 елдан), район башкарма ком-тының а.х. идарәсендә игенчелек бүлеге башлыгы (1983 тән), Коминтерн исем. к-з рәисе (1986 дан), «Буа» терлек симертү с-зында баш агроном (1989 дан). 1991 дән Буа р-ның а.х. һәм азык-төлек идарәсе башлыгы урынбасары. Дәүләт бүләге Буа р-нының а.х. җитештерүенә ресурс саклау технологияләрен керткәне өчен бирелә. Медаль б-н бүләкләнә.

УСМА́НОВ Зәкәрия Нургали улы (18.7.1925, Ульянов ш. — 30.9.2005, Казан), Татарстанда физик культура һәм спортны оештыручы, биол. фән. канд. (1971), ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1975). РСФСРның атказ. физик культура хезмәткәре (1983). Казан пед. ин-тының физик тәрбия һәм спорт ф-тын тәмамлый (1953), Казан авиация ин-тында эшли, физик тәрбия һәм спорт каф. мөдире (1972–86), проф. (1996). ТАССР (1951–60), Татарстан өлкә һәм «Буревестник» ирекле спорт җәмгыяте үзәк советлары җыелма командаларында (1954–65, тимераякта тизлеккә йөгерү буенча) тренер. Тәрбияләнүчеләр арасында — СССРның спорт осталары В.И.Рысьев (10 мең м га йөгерүдә СССР халыклары спартакиадаларында көмеш медаль алучы), Г.С.Сухова, О.Х.Ягофаров. Медальләр б-н бүләкләнә.

УСМА́НОВ Исмәгыйль Мөхәммәдйосыф улы (25.3.1875, Казан — 20.12.1944, шунда ук), терапевт. А.Н.Казимбәк, М.Н.Черкасов, З.И. Малкин шәкерте. Казан вет. ин-тын тәмамлый (1904), Ставрополь губернасының 17 нче участогында вет. табибе булып эшли. Казан ун-тының мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1912), Казан губернасы сан. ополчениесенә хәрби хезмәткә алына. 1914–17 еллар да Беренче бөтендөнья сугышы фронтларында хәрби табиб. 1918–20 дә Петербург мөселман гвардиячеләр җыелма полкы өлкән табибе. 1921–44 тә Казан ун-тының (1930 дан Казан мед. ин-тының) терапия клиникасында («Иске клиника») эшли. Бер үк вакытта, 1920–35 тә, Болак арты мәктәп амбулаториясе мөдире, 1936–44 тә Казан тимер юл поликлиникасында табиб-терапевт. Хезмәтләре ашказаны-эчәк авыруларын биохимик ысуллар б-н дәвалауга карый.

1910 елда, Казан ун-тында уку чорында, Казанда хәйрия мед. җәмгыяте — мохтаҗ татар-мөселманнар өчен амбулатория ача (1912–14 тә баш табиб).

Әд.: Султанбеков Б.Ф. Народный доктор Усманов Исмагил Юсупович // Гасырлар авазы — Эхо веков. 1997. № 1/2.

УСМА́НОВ Йосыф Абдрахман улы (7.7.1903, Уфа губ., Бәләбәй өязе Иске Килем а. — 1.2.1993, Уфа ш.), агрохимик, а.х. фән. д-ры (1966), проф. (1960), БАССРның һәм РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1957, 1971). К.А.Тимирязев исем. Мәскәү а.х. академиясен тәмамлаганнан соң (1930), Башкорт а.х. ин-тының агрохимия каф. мөдире, проф.-консультант (1978–84). Бу югары уку йортын оештыручыларның берсе. Хезмәтләре үсемлекләрне азот һәм фосфор б-н тукландыру, туфракка известь һәм гипс кертү мәсьәләләреңә карый. 1946–50 елларда БАССР ЮС депутаты. Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы орденнары, ике «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә. Туган авылында бер урам У. исеме б-н аталган.

Хезм.: Ашинские фосфориты и их применение на удобрение. Уфа, 1961; Лекции по агрохимии. Уфа, 1971; Зелёное удобрение. Уфа, 1988.

УСМА́НОВ Мәхмүт Госман улы (25.10.1918, Вятка губ., Малмыж өязе Адай а. — 1.9.2009, Казан), нәкышьче, график, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1975), ТАССРның халык рәссамы (1980), РФнең атказ. рәссамы (1999). Казан сынлы сәнгать уч-щесен тәмамлый (1938). Бөек Ватан сугышында катнаша. Хәрби хәбәрчеләрнең «Ватан өчен көрәшләрдә» («В боях за Родину»), «Сталинград өчен сугышта» («Битва за Сталинград») исемле очерклар китапларына иллюстрацияләр авторы (икесе дә — 1943). 1944–45 тә армия газетасы рәссамы. 1946 да Казанга кайта, Татарстан сәнгать фондында эшли. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1947).

Иҗатының башлангыч чорында баталь жанрдагы «Советлар Союзы Герое Газинур Гафиятуллин батырлыгы» (1945), «Совет артиллериясе утка тота», «Днепр өчен сугыш» (икесе дә — 1946) картиналарын иҗат итә. У. пейзаж, аеруча индустриаль пейзаж жанры үсешенә зур өлеш кертә. Беренче булып нефть темасын ачуга керешә, бу юнәлешкә «Татарстан нефтьчеләре иртәсе» (1951), «Баулы юлы», «Нефть промыселенда» (икесе дә — 1954 тә), «Атаклы бораулау остасы М.Гыймазов бригадасы» (1956), «Камада нефть вышкалары» (1962; 1964), «Иделдә бораулау скважиналары» (1967) һ.б. зур масштаблы картиналарын багышлый. КамАЗ төзелеше темасына, башка сәнәгать объектларына мөрәҗәгать итеп, «Зәй ГРЭСы төзелеше» (1958), «Портта», «Миңлебай газ-бензин заводы» (1964) картиналарын яза. Күптөсмерле палитралы, үзенчәлекле нәкыш алымнары осталарча файдаланылган «Яңа

Кама» картинасы (1970) У.ның этаплы әсәрләреннән берсе булып тора. «Казан» (1971), «Камада яңа кала» (1974), «Түбән Кама нефть химиясе заводы» (1978) триптихлары һ.б. авторга хас алымнар б-н иҗат ителә. Идел, Кама күренешләреннән гыйбарәт пейзажлар («Иделдә шәфәкъ», 1971; «Шишкинның туган ягында», 1980); Россиянең урта полосасындагы табигать матурлыгына мәдхия җырлаган камера-лирик картиналар («Урман читендә», 1959; «Күл өстендәге каеннар», 1968; «Иделдә шәфәкъ», 1971) авторы. 1980 еллар ахырыннан натюрмортлар яза. 1990 еллар ахырыннан сюжетлы-символик эчтәлекле «Очу», «Аждаһа» (икесе дә — 1998) һ.б. картиналар иҗат итә. Китап графикасы өлкәсендә (төсле литография, цинкография, тушь) эшли, Татарстан китап нәшрияты б-н хезмәттәшлек итә, Г.Тукай тәр җемәсендә «Алтын әтәч» әкиятенә, татар халык әкиятләренә, Д.Аппакованың «Тапкыр малай» китабына (барысы да — 1950) иллюстрацияләр авторы.

Фронтовик рәссамнарның Киевта уздырылган этюдлар һәм рәсемнәр күргәзмәсендә (1944), ТАССР (1947 дән), «Зур Идел» (1967 дән), «Советская Россия» һ.б. күргәзмәләрдә, Япониядә (Токио, 1974–81), Италиядә (1972), Финляндиядә (1980) уздырылган замандаш совет күргәзмәләрендә катнаша. Гамәли һәм китап графикасы әсәрләре Венгриядә, Чехословакиядә, ГДРда уздырылган күргәзмәләргә куела. Шәхси күргәзмәләре 1968, 1971, 1978, 1980, 1989, 1998, 2006, 2008, 2018 дә (Казан), 1981 дә (Әлмәт)





М.Г.У с м а н о в. 1. «Яңа Кама». 1970; 2. «Казан — борынгы һәм яшь шәһәр». Триптихның үзәк өлеше. 1986. Икесе дә – ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда.

уздырыла. Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәгендә, Әлмәт картиналар галереясында, Кораллы Көчләр Үзәк музеенда (Мәскәү), Япония, Франция, Италия, АКШ һ.б.дагы шәхси тупланмаларда сакланa. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: Махмуд Усманович Усманов: Родной край: Каталог выставки. К., 1974.

Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.

УСМА́НОВ (Госманов) Муллаян Әхмәтьян улы (16.8.1910, Әгер җе ш. — 13.5.1977, Свердловск өлкәсенең Первоуральск ш.), Дан орденының тулы кавалеры (19.9.1944, 23.12.1944, 10.4.1945), гв. рядовое. Первоуральскида заводта эшли. 1941 елның июлен нән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 175 нче гв. укчылар полкы (5 нче гв. армиясенең 58 нче гв. укчылар дивизиясе) разведчигы. Воронеж, 1 нче һәм 2 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Курск сугышында (1943), Кировоград (1944), Львов-Сандомир (1944) һәм Түбән Силезия (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 11 сентябренә каршы төндә Мелец шәһәреннән (Польша) көнбатыштарак барган сугышта батырлык күрсәтә: дошманның 10 лап солдатын юк итә, «тел»не кулга төшерә; 1944 нең 28 октябренә каршы төндә Новы-Корчин (Польша) шәһәре тирәсендәге разведка операциясендә разведка төркеме б-н дошман урнашкан җиргә үтеп керә, берничә солдатны юк итә, берсен әсирлеккә ала; Дёберн (хәзер Добжень-Вельки, Польша) торак пункты янында Одер елгасын кичкәндә дошманның 10 лап солдатын юкка чыгара. Демобилизацияләнгәч (1945), Первоуральскида заводта эшли. Медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

М.З.Хәбибуллин.


УСМА́НОВ Ноэль Кәриб улы (21.2.1932, Мәскәү — 16.2.2012, шунда ук), гарәп теле белгече, филол. фән. канд. (1964). Мәскәү халыкара мөнәсәбәтләр ин-тын тәмамлый (1955). 1957 елдан Совет армиясендә: хәрби частьта гарәп теле укыта. 1965 тән Мәскәү ун-тының Көнчыгыш телләре ин-тында. 1970–74, 1991–96 да Мисыр һәм Ливанда Россия халыкара фәнни һәм мәдәни хезмәттәшлек үзәге вәкиле. 1975–91 дә һәм 1996 дан Мәскәү халыкара мөнәсәбәтләр ин-тында: Якын һәм Урта Көнчыгыш илләре телләре каф. мөдире (2004 кә кадәр), проф. (1989 дан). 1995 тә У.ка киңәшче дипломат рангы бирелә. Хезмәтләре гарәп теле һәм әдәбияты, лексикографиясенә карый. Халыклар дуслыгы ордены, медальләр б-н бүләкләнә. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре.

Х е з м.: Учебное пособие по арабскому языку (для старших классов). М., 1960 (автордаш); Лексическая разработка по фотоделу на арабском языке. М., 1963; Лексическая разработка по египетскому диалекту. М., 1977; Проза Тауфика аль-Хакима. М., 1979; Современный тунисский роман. Дамаск, 1996.

Әд.: С а б и р о в а А. Тёплый ветер с Востока // Татарские новости. 2003 № 11.



М.Г. Усманов.



М.Ә. Усманов.

УСМА́НОВ Рамил Габдрахман улы (1.9.1946, Кызыл Армия, хәзер Чистай р-ны Каргалы а.), физик, физика-матем. фән. д-ры (2002). Казан ун-тын тәмамлый (1970). 1965 елдан Казан ЭХМ з-дында эшли. 1967 дән СССР ФА Казан ф-лының Физика-техника ин-тында. 1985 тән ГИПОда. 1993 тән ТР ФАнең Татар энциклопедиясе ин-тында, табигыять-техник фәннәр бүлеге мөдире (1993-2006), баш фәнни хезмәткәр (2014–15). Бер үк вакытта, 2007 дә Россия мәгариф академиясенең Һөнәри белем бирү педагогикасы һәм психологиясе ин-ты директоры урынбасары, 2002-09 да Казан гуманитар-пед. һәм энергетика ун-тлары профессоры. Хезмәтләре нәсызыкча һәм когерент оптикага карый. У. гелий темп-ралы активлаштырылган кристалларда фотон кайтавазы күренешен тикшерү өчен эксперименталь җайланма эшли (В.А.Пирожков б-н берлектә). Активлаштырылган кристалларда фотон кайтавазы сигналлары авырлык үзәге урнашкан урынының иртәләве һәм кичегүе эффектын; фотон кайтавазы сигналлары формасын кыска ярсыткыч лазер импульслары формасы б-н корреляцияләү эффектларын ача. Фотон кайтавазы сигналлары формалашуына кызыл якут кристаллын гамма-нурлар б-н нурландыру йогынтысын билгели. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Световое эхо в рубине // Физика твёрдого тела. 1972. Т. 14, № 6 (автордаш); Обращённое световое эхо в рубине // Письма в журн. эксперим. и теорет. физики. 1980. Т. 31, вып. 11 (автордаш); Корреляция формы сигналов светового эха с формой возбуждающих импульсов // Письма в журн. эксперим. и теорет. физики. 1980. Т. 32, вып. 4 (автордаш); Многоканальная запись информация на основе эффекта «запирания» сигналов фотонного эха // Оптический журн. 2010. Т. 77, № 2 (автордаш).

УСМА́НОВ Рәфыйк Хаммат улы (18.7.1955, Әстерхан өлкәсенең Иске Күчергән а.), сәясәт белгече, тарих фән. канд. (1988), сәясәт фән. д-ры (2002), проф. (2008). Әстерхан пед. ин-тын (1995 тән — Әстерхан ун-ты) тәмамлый (1982). 1988 елдан шунда ук эшли. Бер үк вакытта, 2001 дән, «Астраханские политические исследования» ж-лының баш мөхәррир урынбасары. Хезмәтләре Россиядәге сәяси партияләрнең теорияләре һәм гамәли эшчәнлегенә, милләтара мөнәсәбәтләргә карый.

Х е з м.: Политические партии и политические процессы (история, теория и современность). М., 2001; Региональный партогенез в политическом процессе современной России. М., 2002; Геополитика Каспийского региона: Взгляд из России. Астрахань, 2004 (автордаш).

УСМА́НОВ Рөстәм Фатыйх улы (22.6.1915, Әстерхан губ., Красноярск өязе Красный Яр а. — 31.3.2006, Мәскәү), метеоролог, геогр. фән. канд. (1948). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1936), Гидрометеорол. хезмәтенең Татарстан идарәсе җитәкчесе. 1938–40 елларда һава торышын билгеләү үзәк ин-тында (Мәскәү). 1940–41 дә Казан ун-тында. 1942–45 тә Иранда Совет Армиясенең гидрометеорол. хезмәте җитәкчесе урынбасары. 1946–76 да СССР Гидрометеорол. үзәгендә баш синоптик (Мәскәү). Антарктида (1955–56), Һинд океанында (1959–61), «Воейков» һәм «Шокальский» һава торышын күзәтү корабларында экспедицияләрдә катнаша. Хезмәтләре гравитация метеорологиясе, атмосфераның планетар циркуляциясе, Кояш-Җир бәйләнешләренә карый. У. тропик циклоннарны, Җирнең әйләнү тизлеге үзгәрешләре һәм Кояш балкышлары йогынтысында атмосферада һәм Җирнең башка сфераларында аеруча куркыныч күренешләрне алдан әйтү методикасын эшли. Бөек Ватан сугышында катнаша. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: О влиянии вращения Земли на общую циркуляцию атмосферы // Тр. Центр. ин-та прогнозов. 1961. Вып. 104; Пангеометрия — наука универсальная // Науч. Татарстан. 1996. № 1.

Әд.: П е р е в е д е н ц е в Ю.П. Метеорология в Казанском университете: Становление, развитие, основные достижения. К., 2001.

УСМА́НОВ Хәйрулла (1848, Уфа губ., Эстәрлетамак өязе Ибрай а. — 1.11.1907, Уфа ш.), дин эшлеклесе, педагог. Вятка губернасының Малмыж өязе «*Мәчкәрә*» мәдрәсәсен тәмамлый. 1877 елдан Эстәрлетамак шәһәре мәчетендә имам хатиб һәм мөдәррис, 1888 дән Уфа 1 нче җәмигъ мәчетендә имам-хатиб, 1890 нан ахун. «Госмания» мәдрәсәсен оештыручы һәм җитәкчесе (1906 га кадәр), анда ул 1895 тә укытуның яңа алымнарын кертә. 1906 дан Оренбург Мөселманнар Диния нәзарәтендә казый. Мәдрәсәләр өчен гарәп теле буенча яңа алымлы уку ярдәмлекләре авторы.

Әд.: М и ң н у л л и н Ж., М ә р д а н о в Р. Хәйрулла хәзрәт Госманов // Казан утлары. 1991. № 3; Ф а р ш а т о в М.Н. Народное образование в Башкирии в пореформенный период: 60–90 годы XIX в. М., 1994.

УСМА́НОВ Шамил Хәйрулла улы (26.12.1898, Саратов губ., Кузнецк өязе Пәлдәңге а. — 3.12.1937, Казан), хәрби-сәясәт эшлеклесе, язучы. «Хөсәения» мәдрәсәсендә (Оренбург ш.) укый. Һөнәр уч-шесен тәмамлаганнан соң (1914), Актүбә шәһәрендә тегермәндә, Гурьев текстиль ф-касында (Сембер губ.) слесарь булып эшли. 1917 елдан РСДРП әгъзасы; Сызрань тимер юл депосында, Россия армиясенә мобилизацияләнгәннән соң — Сызрань гарнизонында агитация б-н шөгыльләнә һәм революцион эшчәнлек алып бара. Окт. рев-циясе вакытында Идел буенда Совет хакимияте өчен көрәштә катнашучы. 1918–19 да 3 нче Интернационал легионы, Идел буе татар укчыларының беренче аерым бригадасы комиссары. 1919–20 дә Үзәк мөселман хәрби коллегиясенең сәяси бүлеге башлыгы, ТАССР Вакытлы революцион ком-ты секретаре, 1921 дән Казан укчы командирлар курсларының сәяси бүлеге башлыгы, аннары Берләшкән татар-башкорт хәрби мәктәбендә (Казан) комиссар. 1925 тә У.ка дивизия комиссары исеме бирелә, ул Кызыл Армия милли хәрби уку йортларының (Мәскәү) инспекторы итеп билгеләнә. 1926–27 дә Шәрекъ ин-тының (Ташкент) хәрби курслар сәяси бүлеге башлыгы. 1927 дә армиядән демобилизацияләнә, Татарстан тамаша пр-тиеләре идарәсе рәисе була, Казанда радиостанция төзү буенча махсус вәкил. 1930 дан әдәбият өлкәсендә. 1934 тән СССР Язучылар берлеге әгъзасы. «Канлы көннәр дә» (1919), «Беренче адым» (1920), «Бай кызы» (1923), «Туган ил» («Страна родная», М., 1935) пьесалары, «Памирдан радио», (1925; рус теленә тәр җәмәсе «Радио с Памира», М., 1926) , «Легион юлы: Тургай далаларында» (1936) повестьлары, күпсанлы хикәяләр һәм публицистик мәкаләләр авторы. У. иҗатында Совет хакимияте өчен көрәш темасы мөһим урын алып тора. Репрессияләр чоры корбаны (1937); үлгәннән соң аклана.

Әсәр.: Сайланма әсәрләр. К., 1964.

Әд.: Я х и н А.Г. Шамил Усманов (1898–1937). К., 1963; М о с т а ф и н Р.Ә. Репрессияләнгән татар әдипләре. К., 2009; С а г а й д а к А.Ш. Глазами памяти. К., 1982.

УСМА́НОВ Шәфикъ Ситдыйк улы (25.10.1947, Ульянов өлкәсенең Иске Кулаткы р-ны Иске Терешка а.), терапевт, мед. фән. канд. (1998), РФнең атказ. табибе (1994). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1971), Иске Кулаткы Үзәк район хастаханәсендә эшли. 1981–87 елларда Монголия Халык Респ-касында (Дархан ш.) СССР илчелегенең Берләштерелгән хастаханәсе баш табибе. 1987–98 дә «Ульянов-курорт» АҖнең В.И.Ленин исем. санаторие баш табибе. 1999–2000 дә Ульянов ун-тының Медицина һәм экология ин-ты директоры. 2000 нән «Татнефть» АҖ санаторий-профилактории баш табибе (Әлмәт ш.). Хезмәтләре курортология мәсьәләләренә карый. «Почёт билгесе» ордены, медаль б-н бүләкләнә.

УСМА́НОВА Рауза Фатих кызы (27.1.1923, Әстерхан губ. Красный Яр ш. — 16.8.2014, Казан), театр белгече, театр тәнкыйтьчесе, педагог, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1968), РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1984). Мәскәүдәге Дәүләт театр сәнгате ин-тының (ГИТИС) театр сәнгате гыйлеме ф-тын тәмамлый (1948). 1953–54 елларда — Татар акад. театрында әдәби бүлек мөдире, 1954–70 тә — Казан пед. ин-тында, 1970–90 да Казан мәдәният ин-тында укыта, әдәбият һәм сәнгать тарихы каф. мөдире, проф. (1982 дән). Хезмәтләре татар театры тарихына, дөнья драматургиясе мәсьәләләренә карый. У.Шекспир, Дж.Байрон, У.Моррис, Б.Шоу, Г.Камал иҗатларына багышланган мәкаләләр авторы. Алар «Театр», «Театральная жизнь», «Казан», «Совет әдәбияты» ж-лларында басыла. Дж.Байронның 4 томлык әсәрләр җыентыгын басмага әзерли (М., 1981): кереш сүз, 1 нче һәм 4 нче томнарга аңлатмалар авторы, гомуми мөхәррир.

Х е з м.: Из истории татарского драматического театра в первые годы советской власти. К., 1958; Первые постановки произведений русской драматургии на сцене татарского театра // Казань в истории русской литературы. К., 1965; Островский на сцене татарского театра // Театр. 1969. № 8; Фатыма Ильская // Труд актёра. 1970. Вып. 18.


И.И.Илялова.

УСМА́НОВЛАР, Казан сәүдәгәрләре һәм эшмәкәрләре. **Җиһанша Бикмөхәммәт улы** (1817, Казан губ., Казан өязе Кариле а. — 1870, Казан), 1853 елдан Казанда; 2 нче гильдия сәүдәгәр, элек ваклап сату б-н шөгыльләнә. Сабын кайнату з-ды, тукыма ф-касы, кареталар остаханәсе, берничә табыш йорты хуҗасы. 1862 дән Печән базарында сәүдә корпусы төзелешендә подрядчы була. Шәһәр хакимиятеннән 45 кибет урнашкан әлеге корпусны 15 елга (1862–77) арендага ала; кибетләрнең бер өлешен башка сәүдәгәрләргә арендага бирә. Пр-тиеләренең еллык товар әйләнеше 500 мең сумга җитә. 1867 дә Казанда мәчет төзүгә акча бирә, ул мәчет «*Госман мәчете*» дип атала (хәзер Солтан мәчете). Аның башлангычы б-н мәчет янында «Госмания» мәдрәсәсе төзелә башлый (төзелеш 1871 дә төгәлләнә). Шулай ук җирле имамнар файдасына торак йорт һәм 2 кибет иганә кыла. Аның турында Ш.Мәржани: «Бу кешенең күпме изге гамәл кылганына Аллаһ шаһит!» — дип яза. Казанның дәрәҗәле граждане исеменә лаек була. **Солтангабделгазиз Җиһанша улы** (1868, Казан — 1917 дән соң), сабын кайната, мануфактура б-н сәүдә итә. Бик күп көчен һәм акчасын «Госман мәчете»н тотуга бирә, соңыннан мәчет аның хөрмәтенә Солтан мәчете дип йөртелә башлый. Иң абруйлы татар конфессиональ уку йортларының берсе булып исәпләнгән «Госмания» мәдрәсәсенең попечителе һәм тотучысы. «Казан шәһәренең ярлы мөселманнарына ярдәм җәмгыяте» идарәсе әгъзасы.

Әд.: М ә р җ а н и Ш. Мөстафад әл-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. К., 1989; С в е р д л о в а Л.М. Купечество Казани: дела и люди. К., 1998; Золотые страницы купечества, промышленников и предпринимателей Татарстана, К.,2001.

Р.А.Айнетдинов.

У́СОВ Михаил Михайлович (18.8.1845, Түбән Новгород губ., Макарьевск өязе Работки а. — 28.9.1902, Казан), зоолог, философия д-ры (1874), зоология д-ры (1885). Зоологиядә эволюцион-морфологик юнәлешкә нигез салучыларның берсе. Петербург ун-тын тәмамлаганнан соң (1869), белем алуны чит илләрдә дәвам итә, Цюрих (Швейцария), Вена (Австро-Венгрия) һәм Лейпциг (Германия) ун-тларында лекцияләр тыңлый. 1874–77 елларда Гёттинген ун-тында (Германия). 1877 дән Петербург ун-тының зоология магистры. Неаполь шәһәрендә зоология станцияләрендә (Италия, 1879) эшли. 1880 нән Казан ун-тында, чагыштырма анатомия һәм эмбриология каф. профессоры (1885–1900). Диңгез фаунасын өйрәнә (Италия, 1883–86). Хезмәтләре балыкларның үзәк нерв системасы анатомиясе һәм гистологиясенә, сүрүлеләрнең (Tunicata, Urochordata) төзелеше һәм үсешенә, башаяклы моллюскларның эмбриональ үсешенә карый. У. яшәү рәвешенә нисбәтле, аерым алганда, табигый ярсыткычларның (яктылык, тавыш һ.б.) тәэсире аз

Успение (Елантау) монастыре. Гомуми күренеше. 1. 1911 елгы фоторәсем; 2. Хәзерге күренеше.

булганда сүрүлеләрнең кайбер, күбесенчә күрү һәм ишетү органнарының регресслашуын (гадиләшүен) һәм хәтта юкка чыгуын билгели. Polypodium hydriformeның үрчүе, үсеше, төзелеше үзенчәлекләрен ача һәм тасвирлый, аларның чөгә балыкларның уылдыкларында паразитлык итүче 24-, 12- һәм 6 кармавычлы гидрасыман организм булуын исбатлый, алар исә күптапкыр үрчергә мөмкин. Зоотомия кабинетын, Казан ун-ты лаб-ясен һәм музеен оештыручы, аларны булдыру өчен үзеннән дә шактый акча кертә. Университетның зоотомия кабинетына китапханәсен тапшыра. Н.А.*Ливанов* аның укучысы. И.И.Мечников б-н фәнни бәйләнештә була, А.О.*Ковалевскийның* дусты.

Х е з м.: Прибавление к познанию организации оболочников // Изв. Имп. Об-ва любителей естествознания, антропологии и этнографии. 1876. Т. 18, вып. 2; Наблюдения над развитием головоногих моллюсков // Изв. Имп. Об-ва любителей естествознания, антропологии и этнографии. 1879. Т. 32, вып. 1; Введение в изучение сравнительной анатомии. К., 1884.

Әд.: О с т р о у м о в А.А. К истории Зоологического кабинета Казанского университета // Уч. зап. Казан. ун-та. 1926. Т. 86, кн.1.

И.Ф.Галанин, В.И.Гаранин.

УСПЕ́НИЕ ИРЛӘ́Р МОНАСТЫРЕ́ (Елантау монастыре), Казанда. Төбәктәге беренче православие монастырьларының берсе. 1552 елда нигез салына. Иң башта Казансу елгасы ярындагы Казанны буйсындырганда һәлак булган рус гаскәриләре һәйкәл-төрбәсе янында урнаша. Язгы ташу вакытында су баса торган була, шул сәбәпле 1559 да аны Елан тавының көнбатыш ягына күчерәләр, аның кончы-гыш өлешендә зират урнаша. 17 йөздән элекке агач корылмалар кирпеч биналар б-н алмаштырыла. 20 йөз башында У.и.м. туры почмаклы мәйдандагы (1 *га*) үзәктә Успение соборы торган, түгәрәк яруслы манаралар, калын кирпеч диварлар б-н әйләндереп алынган архит-ра комплексын гәүдәләндерә. Монастырьның төп ишеге көньякта, өстенә чаң манарасы төзелгән Изге капкага урнашты-рыла. Капкадан уңдарак, ике манара арасындагы дивар буенда монастырь башлыгы корпусы салынган. Торак корпуслар дивар периметры буенча төзелгәннәр.

Баштагы агач Успение чиркәве урынында 1623–25 тә Псков-Новгород мәктәбе стилендә, ак таштан көнбатыш ягында чаң манарасы торган, шул исемдәге собор төзелә. Формасы буенча ул бер гөмбәз б-н төгәлләнгән, өч ярымтүгәрәк апсидалы биек дүрткырлыктан гыйбарәт була. Храм түбәсе ярымтүгәрәк гөмбәз рәвешендә ябыла, 18 йөз ахырында — 19 йөз башында дүрт кыеклы чатыр түбә б-н алмаштырыла. 1829 да чаң манарасы сүтелә. 1681 дә собордан көньяк-көнбатышка таба ачык галерея б-н тоташтырылган Барлык Изгеләр чиркәве төзелә. 19 йөз башына чиркәү искерә, һәм аны 1829 да классицизм стилендә реконструкциялиләр. Дүрткырлыкның 1 нче катында ашханә һәм хөҗрәләр, 2 нче катта биек гөмбәз б-н ябылган храм урнаша. Көнчыгыш фасадны зур, ярымтүгәрәк апсидалар бизәп тора. Храмның төп күләме өстенә шпильле квадрат чаң манарасы урнаштырыла, аның авырлыгыннан чиркәү бинасы җимерелә башлый, ул 1895 тә сүтелә. 1898 дә арх. Ф.Н.Малиновский проекты буенча яңа бина төзелә: чатыр һәм ян-яктагы дүрт гөмбәз б-н очланган квадрат храм калкып чыга. Храмның көнбатыш ягына ике катлы ашханә салына, 2 нче катка тышкы яктагы баскыч алып менә. Барлык Изгеләр чиркәвенең фасады эклектика стилендә, урта гасырлар рус архит-расы элементлары б-н бизәлгән.

1720 еллар башында диварның көнчыгыш ягыннан 1 нче катта биек дүрткырлыкта өстенә күп яруслы Мәскәү митрополиты Алексий храмы, 2 нче катта апсидалы чиркәү урнашкан. Дүрткырлык өстендә биек барабандагы гөмбәз б-н очланган 2 сигезкырлы, баскыч-баскыч ярус корылган. Көнбатыш яктан дүрткырлыкта галерея ясалган. 1829 да искергән храм реконструкцияләнә: Изге капканы томалап куялар, 1 нче катта барлыкка килгән буш урында ашханә оештырыла. Храм өстендәге югары ярусларга урнашкан Виль-нюс янкормасына тар, Сырлы баскыч алып менә. 1808 дә көньяк диварның ике башня арасына монастырь башлыгы корпусы төзелә. Ул классицизм стилендә кирпечтән салынган өскормалы һәм зур ярымтүгәрәк тәрәзәле, ике катлы бинадан гыйбарәт. 2 нче катта 4 колоннага терәлгән өч тәрәзә киңлегендәге балкон куелган.

1822 дә монастырь коймасы туптан ату урыннары, ябулы галереялары һәм цилиндрик формадагы почмак башнялары булган кирмән дивары рәвешен ала. Монастырь башлыгы корпусыннан көнбатыштарак диварга турыпочмаклы капкалар куела, алар 1855 тә кирпеч формасындагы таш җәелгән юлларга тоташалар. 1865 тә монастырь зираты терр-ясен агач диварлар б-н корып алалар. 1894 тә У.и.м.ның төньяк диварлары буенча беркатлы кирпеч һәм 2 агач хөҗрәләр корпусы, 1910 да борадәрләрнең беркатлы агач хөҗрәләр корпусы төзелә.

1898 дә арх. Ф.Н.Малиновский проекты буенча көньяктагы турыпочмаклы капкалар урынына урта гасырлар рус архит-расы элементлары булган чаң манарасы төзелә; аркалы капкадан һәм ян-якта икешәр хөҗрәдән торган дүрткырлык формасындагы 1 нче яруста биек сигезкырлык һәм биек чатыр астындагы чаң кагу ярусы корыла.

У.и.м. башлыгы Амвросий (Сретенский) башлангычында һәм җитәкчелегендә 1809–28 дә Казанны буйсындыруда һәлак булган *Рус гаскәриләр һәйкәл-төрбәсе* төзелә. 1917 гә кадәр У.и.м. карамагында була. 1918 нең 10 сентябрендә Кызыл Армия гаскәрләре Казанны штурмлаганда монастырьда урнашкан пулемёт утына эләгәләр; моның өчен бу вакытта ашханәдә туры килгән 10 монах-ны һәм руханины атып үтерәләр (*Елантау монастыреның шәһит киткән изгеләре*). 1928 дә монастырь ябыла, аның терр-ясендә НКВД төрмәсе, соңрак балаларны хезмәт б-н төзәтү колониясе, 1950 еллар ахырыннан төзелеш һәм транспорт оешмалары урнаша.

Хәзерге вакытта У.и.м.ның күпчелек корылмалары һәм диварлары юкка чыккан, Успение соборы һәм Алексий чиркәве сүтелгән. 20 йөз ахырына кадәр Барлык Изгеләр чиркәвенең һәм монастырь башлыгы корпусының харәбәләре сакланып калган. 1998 дә монастырь Казан епархиясенә кайтарыла һәм яңадан хатын-кызлар монастыре буларак

ачыла. Монастырь башлыгы корпусы реконструкцияләнә (2000), Барлык Изгеләр чиркәве торгызыла (2001, Успение чиркәве буларак изгеләндерелә). Дүрт яруслы чаң манарасы төзелә (2001), биек сигезкырлыкка ялган рус формаларындагы чатыр астында 3 яруслы чаң куела, ике капкалы койма б-н әйләндереп алына (2001, У.и.м. терр-ясе көньяк юнәлештә киңәйтелә), ш.у. Адриан һәм Наталиянең өй чиркәве б-н шәфкать туташлары корпусы (2002, көнчыгыш фасады бизәксез, кырыс формалардагы ярымтүгәрәк гөмбәзле, бер апсидалы, ике рәт тәрәзәле чиркәү б-н тоташкан, дүрт кыеклы түбә астындагы ике катлы, сузынкы кирпеч бина) төзелә. Сүтелгән Успение соборы урынында 2003–06 да Троица-Сергий лаврасының Троица чиркәве (15 йөз) күчермәсе буларак Троица соборы корыла. 2004 тә псевдо рус формаларындагы Архангел Михаил чиркәве б-н дүрт яруслы капка өсте чаң манарасы (2004, ике барабанлы гөмбәз астындагы таррак дүрткырлыкны, биек чаң сигезкырлыгын күтәреп торучы, беренче каты арка аша йөрешле, икенче каты чиркәүле дүрткырлык), чукындыру йоласын башкаручы Изге князь Владимир чиркәве (2004, ялган рус формаларында гы чатыр б-н төгәлләнгән бер апсидалы дүрткырлы кирпеч храм), кирпечтән 2 ике катлы хезмәткәрләр корпусы (2005–06) калкып чыга. Төзелеш хатын-кызлар монастыре башлыгы игуменья Нина (Нефёдова) җитәкчелегендә эшмәкәр Н.В.Девятых акчасына башкарыла.

Әд.: Гавриил (Воскресенский). Историческое описание Казанского Успенского второклассного Зилантова монастыря и Казанского памятника, сооружённого... на общей их могиле. К., 1840; Фехнер М.В. Великие Булгары. Казань. Свияжск. М., 1978; Рощектаев А.В. История Свято-Успенского монастыря, что на Зилантовой горе города Казани. К., 2004.

Х.Г.Надыйрова, Е.В.Липаков.

УСПЕ́НИЕ ИРЛӘ́Р МОНАСТЫРЕ́, Зөядә, Татарстан терр-ясендәге иң әүвәлге православие архит-расы комплексларының берсе. Зөя Богородица, Богородица-Успение монастыре һ.б. буларак мәгълүм. Зөянең көньяк-көнбатышында урнашкан. 1555 елда архиепископ *Герман* тарафыннан нигезләнә. Иң элек комплекс терр-ясе яклары тигезсез өч-почмак рәвешендә манаралы агач диварлар б-н әйләндереп алынган була. 1555–61 дә комплекс үзәгендә И.Я.Постник һәм И.Ширяй җитәкчелегендәге Псков осталары — ташчылары тарафыннан Успение соборы, ә 1555–56 да аннан көньяк-көнбатышка таба — Никола трапеза чиркәве салына. 17 йөз ахырында — 18 йөз башында монастырьның агач диварлары кирпеч диварлар б-н алмаштырыла, көньяк-көнчыгыш дивары янында өлкән монахлар өчен торак бина төзелә. 1742 дә аны таш өч катлы борадәрләр корпусы б-н бер түбә астына берләштерәләр, 18 йөз ахырында көнчыгыш яктагы кыска ян фасадына изгеләр Герман Казанский һәм Митрофан Воронежский чиркәве кушып салына. 1763 тә У.и.м.ның көньяк өлешендә архиерей корпусы, 1796 да аннан төньяк-көнбатыш-тарак монастырь башлыгы корпусы төзелә. 18 йөздә бер гөмбәзле Вознесение чиркәве б-н Изге капка корыла.

1764 тә чиркәү биләмәләрен конфискацияләгәнгә кадәр, У.и.м. төбәктә иң ереләрдән һәм байлардан санала, 17 йөздә — 20 йөз башында төп изге әйбере Герман җәсәденнән гыйбарәт булган табыну үзәгенә әверелә. 1731–64 тә монастырьда *Яңа чукындырылганнар конторасы* урнаша. 1917–18 дә монастырь башлыгы 1918 нең 27 июлендә Л.Д.Троцкийның шәхси боерыгы буенча атылган епископ Амвросий (Гудко, 1999 да канунлаштырыла) була. У.и.м. 1924 тә ябыла, аның терр-ясендә совхозның ярдәмче каралтылары, 1929 дан — хезмәт б-н төзәтү колониясе, 1953–93 тә психоневрология диспансеры урнаша. 1930 елларда Вознесение, Герман Казанский, Митрофан Воронежский чиркәүләре сүтелә. 1997 дә У.и.м. Казан епархиясенә тапшырыла.



Никола трапеза чиркәве (1555–56), уңда — Успение соборы (1555–61). Хәзерге күренеше.

Успение соборы — 16 йөз архит-расының уникаль истәлеге. Бер гөмбәзле, дүрт баганалы, өч апсидалы храм Псков-Новгород мәктәбе стилендәге шомартылган ак таштан төзелгән. Барлык янкормалары һәм реконструкцияләре соңыннан кирпечтән төзелә башлый. 1661 дә көнбатыш өлешенә кушып салына. Көньяк-көнчыгыш апсида соңрак туры-почмаклы янкорма б-н алмаштырыла. Храмның нигезен акташ дүрткырлык тәшкил итә, фасадлар өстә ике, өч калаклы аркалар б-н кысылган өч киң терәк б-н ныгытылган. Апсидаларда һәм барабаннардагы өч кат тасмалы таш каймалардан, өчпочмаклы куышлар һәм уклаусыман аркатур бизәкләрдән торган тәрәзә асты «кашагалары» элекке хәлендә сакланганнар. 18 йөз уртасында барабан өстенә сигезкырлы цилиндр төзелә, ә шлемсыман гөмбәз украина бароккосы стилендәге грушасыман гөмбәз б-н алмаштырыла. Бер үк вакытта собор диварлары иконалар куя өчен махсус куышлары булган борокко стилендәге ярымтүгәрәк калкан б-н төгәлләнә. Храм һәм ашханә тәрәзәләре кечкенә киштәле һәм «әтәч кикрикле» кыяфәт ала. 19 йөздә собор бинасына килесыман гөмбәзле болдыр кушып салына. Төньяк һәм көньяк фасадлар буенча ачык мәйданнар урнаша. Успение соборы Россиядә Иван Грозный чорындагы дивар бизәге нәкышенең тулы циклы сакланган ике храмның берсе (1000 *м*^{2} дан артыграк). 1890 елларда Д.В.Айналов җитәкчелегендәге рәссамнар Н.М.Сафонов һәм Г.О.Чириков тарафыннан реставрацияләнә. 18 йөздә уеп ясалган иконостаска 16–17 йөзләр иконалары куела. Ашханә диварларындагы интерьерда 19 йөзнең майлы буяу нәкыше сакланган.



Изгеләр Герман Казанский һәм Митрофан Воронежский чиркәүле борадәрләр корпусы.

Никола трапеза чиркәве монастырь терр-ясендәге иң әүвәл салынган корылма. Элек ул квадрат күләмле, бер баганалы, төбәнәк ашханә булып саналган, храм аның төнь-як-көнчыгыш почмагына кушып төзелгән. Ашханә һәм храм хуҗалык бүлмәләре урнашкан биек келәт өстенә урнашкан. Соңрак храмга симметрияле рәвештә һәм аннан тар бүлмә аерып торган келәт астына хуҗалык мөдире бүлмәсе эшләп куелган. Элек Никола чиркәве ишегенең традиция буенча көнбатыш якта урнашкан булуы ихтимал. 16 йөз ахырында чиркәүнең көнчыгыш фасадына кушып, дүрткырлык рәвешендә дүрт яруслы биек чаң манарасы төзелгән. Аның як-ягына келәт биеклегендәге 2 бер катлы янкорма өстенә кирпечтән храмга тоташкан өч апсидалы күләм күтәрелгән. Чиркәүгә чаң манарасының аскы ярусы аша агач баскыч алып менә. 17 йөз башында чаң манарасына кирпечтән өч рәтле ярымтүгәрәк калкан б-н төгәлләнгән, сигез кырлы ярус өстәп салалар. Зур барабан һәм манара гөмбәзе, стиле буенча фикер йөрткәндә, соңрак калыккан. Чаң манарасының биеклеге 43 *м*. Аның өченче ярусында 18 йөздә Йоанн Богослов храмы урнаша. 19 йөздә манараның көньяк-көнчыгыш янкормасы өстендә 17 йөзнең өч апсидалы күләмен симметрияле рәвештә кабатлаган чиркәү җиһазлары саклана торган бина калкып чыга. Никола трапеза чиркәвенең дивар бизәкләре, вак фрагментларны санамаганда, югалып бетә. 2010 нан М.Ш.Шәймиев җитәкчелегендә «Яңарыш» фонды тарафыннан реставрацияләү һәм төзекләндерү буенча киң күләмле эшләр җәелдерелә.

Әд.: Яблоков А.П. Первоклассный мужской Успенско-Богородицкий монастырь в городе Свияжске, Казанской губернии. К., 1906; Фехнер М.В. Великие Булгары. Казань. Свияжск. М., 1978; Куприянов В.Н., Копсова Т.П., Агишева И.Н. Свияжск, К., 2005.

Е.В.Липаков, Х.Г.Надыйрова.

УСПЕ́НКА авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 8 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Казан — Түбән Новгород автомагистрале буенда. 2010 елда 74 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1920 еллар башында нигез салына. Оешкан көненнән Казан губернасының Казан өязе

Ильинка волостенда. 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Воскресенский, 1927 нең 1 августын - нан Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1958 нең 16 июленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1926 да — 151, 1938 дә — 145, 1949 да — 70, 1958 дә — 116, 1970 тә — 110, 1979 да — 81, 1989 да — 51, 2002 дә — 54 кеше.

УСПЕ́НСКИЙ Борис Вадимович (15.6.1951, Сахалин өлкәсенең Корсаков ш.), геолог-нефтьче, геол.-минерал. фән. д-ры (2005), проф. (2009), ТРның атказ. нефтьчесе (2002). Казан ун-тын тәмамлый (1973), шунда ук эшли. Хезмәтләре геологиягә, углеводород чималы чыганакларының геохимиясенә карый. Табигый битумнарны эзләү, разведкалау һәм үзләштерүнең фәнни-методик нигезләрен эшли. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре.

Х е з м.: Геолого-геохимические основы освоения битумных месторождений Среднего Поволжья. К., 1988 (автордаш); Геофизические методы подготовки и контроля процессов эксплуатации месторождений природных битумов. М., 2000 (автордаш); Геология месторождений природных битумов Республики Татарстан. К., 2008 (автордаш).

УСТИ́НОВ Александр Викторович (26.1.1968, Казан — 16.12.1996, шунда ук), спортчы (акад. ишү), СССРның халыкара класслы спорт остасы (1988). «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятендә тәрбияләнә (Казан), тренеры — В.А.*Гоголин*. Россия (1992–96), дөнья (1986; 1993–94 тә — көмеш медаль), Россия (1992–96) чемпионы, СССР Кубогы иясе (1988–90). Олимпия уеннарында катнашучы (1996). 1987 дән МВД хезмәткәре.

УСТИ́НОВ Фёдор Александрович (4.6.1916, Калуга губ. Медынь өязе Теренино а. — 29.3.1985, Казан), очучы, Казан аэропорты башлыгы (1953–72). Одесса хәрби авиация мәктәбен тәмамлый (1937), шунда ук очучы-инструктор булып эшли. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында бомбардировщиклар авиациясендә: звено командиры, эскадрилья командиры урынбасары, штурман, полк командиры урынбасары. 1946–76 елларда гражданнар авиациясендә: Украина ССРның махсус эш йөкләнгән 266 нчы авиаотряды командиры урынбасары, Гражданнар һава флотының Мәскәү идарәсендә бүлек башлыгы, Пенза аэропорты башлыгы (1952 дән), Казан аэропортының диспетчерлык үзәге башлыгы урынбасары (1972 дән). ТАССРны аэрофикацияләүгә зур өлеш кертә. У. җитәкчелегендә өр-яңа техник чаралар б-н җиһазландырылган Казан аэровокзалы һәм җирле һава юллары аэропорты эшли башлый; нәтиҗәдә, респ-када пассажирлар, почта һәм йөк ташу күләме 2 тапкыр арта. Октябрь Революциясе, Ике Кызыл Байрак, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: В ночном небе войны: Воспоминания ветеранов 719-го авиационного полка ночных бомбардировщиков. Хар., 1988.

УСТЬ-ИШИ́М РАЙОНЫ́, *Омск өлкәсенең* төньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. 1924 елның 24 сентябрендә оештырыла. Мәйданы — 7846 *км*². Үзәге — Усть-Ишим авылы. Халкы — 11601 кеше (2017), ш.и. татарлар — 3269 кеше (2010). У.-И.р. терр-ясендә *Себер татарлары* элек-электән яши. 14 йөзнең 2 нче яртысында Ишим елгасы тамагында Себер ханнары нәселен нигезләгән Тайбуга исеме б-н бәйле Кызыл Тура шәһәрчегенә нигез салына. 1631 дә, *Себер ханлыгы* Рус дәүләтенә кушылганнан соң, У.-И.р.нда күчмә тормышлы көньяк халыклары һөҗүменнән саклану өчен Тибенде, Курдак һәм Ишим (хәзер Усть-Ишим а.) кальгалары төзелә. 17 йөз ахырындагы тарихи чыганакларда татар авыллары (йортлар): Бизиләковлар, Кызылтуковлар, Шабановлар, Коташевлар, Ярышкиннар, Кыркыннар, Үтәевләр, (Ишим елгасы тамагында), Ебәргуловлар, Кысмаковлар, Каметовлар (Ишим елгасы тамагыннан Иртеш буйлап өскә таба), Шуршановлар, Мотыйковлар, Измәтовлар, Төлегановлар, Каинскийлар, Буленевлар, Миллияровлар, Карабашевлар, Таушеневлар (Ишим елгасы тамагыннан Иртеш буйлап аска таба) авыллары, Олы Бүрән Йорты (Ишим елгасы буйлап өскә таба) телгә алына. Татарлар терлекчелек, сунарчылык һәм балыкчылык б-н шөгыльләнә. 1795 елгы мәгълүматларга караганда, 14 татар авылында — 1526, 1869 да 19 авылда 2380 кеше яши. 20 йөз башында 5 торак пунктта (Кайнавыл Йорты, Олы Бүрән (Тюрметяки), Усть-Ишим, Ебәргул, Илчебага) мәчетләр була. 1917 дә Усть-Ишимда, 1920 елларда Саргат һәм Олы Бүрән авылларында татар мәктәпләре ачыла. 1924 тә яңадан оештырылган У.-И.р.на Саргат һәм Карагай волостьлары татар авыллары, 1925 тә таркатылган Загваздинский р-нының Тибенде, Паново, Еланка авыл советларына караган татар торак пунктлары керә. 1926 да районда 16 татар авылы исәпләнә, аларда 3522 кеше яши. 1950 еллар уртасына кадәр 3 татар авыл советы (Олы Бүрән, Тибенде, Ебәргул) була. 1950 еллар башына кадәр Ебәргулда җидееллык татар мәктәбе эшли. Татарлар, тупланып, Саургач (459 кеше), Әшеван (380), Ярково (367), Тибенде (285), Ебәргул (259), Илчебага (234), Кайнавыл (192), Бакшеево (179), Җәйләү (Летние) (165), Олы Бүрән (70), Утар (Хутор) (54) авылларында яшиләр. Усть-Ишим Халык иҗат йорты каршында — Татар мәдәни үзәге һәм «Чишмә» халык ансамбле (1993 тән), Әшеван, Илчебага, Ебәргул, Ярково, Җәйләү, Кайнавыл, Саургач, Тибенде авылларында вокаль үзешчән сәнгать коллективлары эшли. Районның 4 мәктәбендә (Саургач, Илчебага, Әшеван, Тибенде) татар теле фән буларак өйрәнелә. Усть-Ишим, Илчебага, Тибенде, Кайнавыл авылларында мәчетләр бар. Ебәргул, Ярково, Илчебага, Кайнавыл, Әшеван, Тибенде авыллларында *Сабан туе*, *Корбан бәйрәме*, *Ураза бәйрәме* үткәрелә. 2010 да Усть-Ишимда Татар ашлары район бәйрәме уздырыла.

Әд.: Томилов Н.А. Тюркоязычное население Западно-Сибирской равнины в конце XVI — первой четверти XIX вв. Томск, 1981; Фатеев В.А. В краю таёжном. Омск, 1996.

УСТЬ-КАТА́В шәһәре, *Чиләбе өлкәсенең* көнбатыш өлешендә, Чиләбе шәһәреннән 301 *км* көнбатыштарак урнашкан. 1758 елда нигез салына. Халкы — 22,5 мең кеше (2017). Татарлар саны: 2002 дә — 1219, 2010 да — 1006 кеше. У.-К.та татарлар 20 йөздә урнаша башлый (1917 дә 14 кеше яши), 1930 елларда аларның саны арта, күчеп килүче татарларның күбесе У.-К. вагоннар төзү з-дында эшли. Бөек Ватан сугышы елларында алар, башлыча — Нәсибаш, Лаклы, Мияшәгәр (хәзер БРның Салават р-ны) авылларыннан һәм Чиләбе өлкәсенең *Троицк* шәһәреннән У.-К.ның 6 нчы һөнәр уч-щесен тәмамлаган 14–15 яшьлек егетләр; сугыштан соңгы чорда — демобилизацияләнгән Кызыл Армия сугышчылары һәм командирлары; 1960–80 елларда — югары һәм урта техник уку йортларын тәмамлагач, У.-К.ка билгеләнгән яшь белгечләр. 1959 да вагон төзүчеләр мәдәният йорты каршында татар-башкорт җыр һәм бию ансамбле оештырыла. 1989–95 тә «Дуслык» татар-башкорт мәдәни үзәге эшли, аның ярдәме б-н У.-К.та Сабан туе уздырыла (1990–91), бию коллективы һәм татар сәнгать коллективлары гастрольләре оештырыла, 5 нче мәктәптә системалы рәвештә татар һәм башкорт телләре өйрәнелә. 1990 еллар ахырында «Умырзая» татар-башкорт хатын-кызлар клубы эшли, 2001–02 дә У.-К. һәм БРның Салават р-ны башкорт-татар корылтае (2002–06 да корылтай башкарма ком-ты «Корылтай» мәдәни ял үзәге буларак билгеле) булып уза. 2006 да «Дуслык» татар-башкорт мәдәни үзәге (бүленеп, 2010 га кадәр) яңадан эшли башлый. У.-К.та татар телендә Чиләбе өлкә («Хәзинә» һ.б.) һәм Башкорт спутник («Рәйхан», «Алкын») телевидениеләре тапшыруларын карарга мөмкин. 1995 тән мәчет эшли. Шәһәр Татарстан б-н күптәнге сәүдә-икътисади элемтәләр тота. У.-К. вагоннар төзү з-ды Казан, Чаллы, Түбән Кама шәһәрләрен трамвай вагоннары б-н тәэмин итә.

А.П.Соколов.

УСТЬ-ТА́РКА РАЙОНЫ́, *Новосибирск өлкәсенең* көнбатыш өлешендә урнашкан. 1936 елда оештырыла. Мәйданы — 4 мең *км*². Үзәге — Усть-Тарка авылы. Халкы — 11520 кеше (2017). Татарлар саны: 2002 дә — 543, 2010 да — 436 кеше. У.-Т.р.ндагы татар җәмгыяте 1918–20 дә Уфа губернасыннан килеп, төбәкнең монда төпләнгән төп халкы — Себер (Бараба) татарлары; 1925–30 һәм 1960 елларда, ТАССРдан күчеп, район терр-ясендә торып калучылар исәбенә оештырыла. Татарлар, тупланып, Күнле (1968 гә кадәр була) һәм Угуй Йорты (1988 гә кадәр) авылларында яшиләр. 1965 кә кадәр — Күнледә, 1974 кә кадәр Угуй Йортында татар башлангыч мәктәпләре эшли. Татарлар Камышево, Яңа Силиш, Усть-Тарка, Угуй, Яркүл, Черниговка, Янабино авылларында, Майский, Октябрьский посёлокларында яшиләр.

У́СТЬЕ елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Чөкәнеш елгасының (Чишмә елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 10,6 *км*. Бассейнының мәйданы 84,7 *км*². Идел буе түбәнлегеннән, Яңа Чишмә р-ны терр-ясендә ага. Елга башы Бүре Бистәсе авылыннан

көньяктарак, тамагы Гарь посёлогы янында. Елга башының абс. биеклеге 118 *м*, тамагынкы — 79 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 5%. У.ның 0,8 дән 8,7 *км* га кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,25 *км/км*^{2}. Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,1 *л/с·км*^{2}. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Язгы ташу, гадәтә, март ахырында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,013 *м*^{3}*/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минераль-ләшүе язын 300–400 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. У. үзәнендә ландшафтлы табигать тыюлыгы *Коржинский сөзәкләкләре* урнашкан.

УСЫ́ авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 40 *км* көньяк-көнбатыштарак, Бәҗәнә елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 308 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау, умартачылык. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1755 елга кадәр нигез салына. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар һәм типтәрләр катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп (1858 дә ачыла), 2 су тегермәне, тимерчелек, бакалея кибете, ашлык саклау-сату кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2806 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Пучы волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1935 нең 10 февраленнән Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 266, 1816 да — 201 кеше, 1834 тә — 260 ир-ат; 1859 да — 734, 1870 тә — 756, 1884 тә — 1033, 1897 дә — 1110, 1906 да — 1249, 1913 тә — 1364, 1920 дә — 1235, 1926 да — 866, 1938 дә — 897, 1949 да — 622, 1958 дә — 545, 1970 тә — 628, 1979 да — 542, 1989 да — 364, 2002 дә — 344 кеше.

УТА́Р (хутор), хосусый җир биләмәсе. Рос - сиядә авыл җәмәгате җиреннән аерып алын - ган, торак һәм ху җалык корылмалары ком - плексы кергән шәхси крәстиян җир биләмә - се. 20 йөз башында *Столыпинның аграр ре - формасын* гамәлгә кертү барышында тара-лыш ала. «Крәстияннәрнең җир биләве һәм җирдән файдалануы турында» 1906 ел 9 но - ябрь фәрманы б-н крәстияннәргә җәмәгать җирен *отруб* һәм У. рәвешендә хосусый ми - лек итеп беркетеп, җәмәгатьтән чыгу хокукы бирелә. У. ху җалыкларын оештыру *Крәсти - яннәр җир банкының Казан булеге* ссудалар сәясәте, ш.у. хөкүмәт ярдәме б-н хуплана. Аз чыгымлы булганга, Казан губернасы крәс - тияннәре отруб хуҗалыклары оештыруга өс - тенлек бирәләр. 1907–15 тә Казан губерна - сында 984 крәстиян ху җалыгы У. оештыра (аерым җир биләмәләре алып аерылып чык - кан 13400 ху җалыктан), шуның б-н бергә У. ху җаларына 9 мең дис., отруб биләүчеләренә 83 мең дис. җир туры килә. У.лар Лаеш, Спас, Чистай өязләрендә аеруча киң тарала. Бе-ренче бөтендөнья сугышы елларында У.лар оешу прорцессы тукталып тора. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң У.ларны бетерү һәм аерылып чыгучыларның җирләрен авыл җә-мәгате карамагына кайтару башлана. Яңа икътисади сәясәт елларында бу процесс дәвам итә (1924 кә ТАССРда У.лар гомуми сөрүлек җирләрнең нибары 0,25% гына (283215 дис.) били). *Крәстиян хуҗалыкларын күмәкләште-рү* чорында У.лар тәмам бетерелә.

Чыг.: Обзоры Казанской губернии за 1904–1914 гг. К., 1905–15.

Әд.: П е р ш и н П.Н. Аграрная революция в России: В 2 кн. М.,1966; К а б ы т о в П.С. Аграр-ные отношения в Поволжье в период империализ-ма (1900–1917 гг.). Саратов, 1982; Ш а й д у л - л и н Р.В. Крестьянство Татарстана: экономи-ческий и общественно-политический аспекты (1920–1929 гг.). К., 2004.

Р.Р.Батыршин.

УТА́Р АТЫ́ авылы, Арча р-нында, Арча шә-һәреннән 16 *км* төньяк-көнбатыштарак, Аты елгасы буенда. 2010 елда 307 кеше (татар-лар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчы - лык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1678 дән рус чыганакларында Пустошь на Сенных Покосах исеме б-н билгеле. Рев-циягә кадәр-ге рус чыганакларында Сенный Покос, Отар-Аты, Старые Аты буларак та мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенче-лек, терлекчелек, умартачылык, пыяла ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәк - тәп, 3 вак-төяклар кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1832,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасы - ның Казан өязе Олы Мәңгәр волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 223 ир-ат; 1859 да — 916, 1897 дә — 1094, 1908 дә — 1233, 1920 дә — 1097, 1926 да — 1054, 1938 дә — 818, 1949 да — 612, 1958 дә — 484, 1970 тә — 461, 1979 да — 422, 1989 да — 363, 2002 дә — 318 кеше.

У́ТКИН Егор Васильевич (27.7.1932, Ала-буга р-ны Брюшли а. — 23.12.1977, Менделе - ев ш.), шагыйрь. Алабуга пед. ин-тын тәмам - лый (1963). Хезмәт эшчәнлеген 1955 елда Бондюг химия з-дында эшче буларак баш-лап җибәрә. «Кырлар сәламе» (1967), «Төн - ге яшен» (1969), «Минем романтикам» (1971), «Офыкларда алсу болытлар» (1976), «Күңелемә коя чишмәләр» (2007) шигырь җыентыклары авторы. У.ның шигырь һәм поэмалары туган як табигатенә, дуслыкка, халыклар туганлыгына, тормыш матурлы-гына багышланган.

Әд.: С а ф и н М. «Радуясь солнцу дней...» // Аргамак. 1997. № 7.

У́ТКИНО авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 10 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Кече Сөлчә елгасы - ның уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 1 кеше (рус) яши. 1920 елларда нигез салына. Оеш-кан көненнән ТАССРның Чистай кантоны Аксубай волостенда. 1930 ның 10 августын - нан — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1926 да — 261, 1938 дә — 241, 1949 да — 184, 1958 дә — 149, 1970 тә — 75, 1979 да — 31, 1989 да — 18, 2002 дә — 2 кеше.

УТКОЙРЫКЛА́Р (Phoenicurus), миләш чыпчыклары семьялыгыннан кошлар ыру-гы. 13 төре билгеле, Европа, Азия һәм Төнь - як Африкада таралганнар. ТР терр-ясендә 2 төре — гади уткойрык (Ph. phoenicurus) һәм кара уткойрык (Ph. ochruros) — барлык районнарда да очрый. Урманнарда, бакча-ларда, әрәмәлекләрдә, кеше яшәгән тораклар тирәсенә оялый. Гәүдәсенең озынлыгы 14–18 *см*, авырлыгы 20 *г* га җитә. Ата кошның аркасы караңгы- яки аксыл-соры, түше җирән яки кара-коңгырт, карасу канатлары аксыл каймалы яисә тимгелле; ана кош бер төстә ге - нә, җирән төсмерле коңгырт. Гади уткойрык-тан аермалы буларак, кара уткойрыкның маң-гае соры, түше кара. У. — күчмә кошлар. Оя-ларын агач куышларында, ярыкларда кора-лар, каралты түбәләре астына оялыйлар.



Гади уткойрык. 1. Ата кош; 2. Ана кош.

4–6 зәңгәр йомырка салалар, 2 атнадан кош балалары чыга. У. бөҗәкләр, үрмәкүчләр һәм вак әкәм-төкәмнәр, көзен аю баланы, кара карлыган җимешләре һ.б. б-н тукланалар. Урман һәм а.х.на файда китерәләр.

УТЛЫ́ КОҢГЫЗЛА́Р (Lampyris), элек йом-шактәнлеләр семьялыгына караган, шул ук исемдәге семьялыктан коңгызлар ыругы. Гәү-дәсенең озынлыгы 10–20 *мм*. Ата затлар як - шы очалар, ана коңгызлар канатсыз, личин - касыманнар. У.к.ның корсак сегментлары-ның очында яктырту органы бар (исеме шун-нан). Төнге яшәү рәвеше алып баралар. Ерт - кычлар, вак умырткасызлар б-н туеналар. Личинкалары берничә ел яши, туфракта кышлый. Туфракны механик эшкәрткәндә үләләр, алар өчен үзенчәлекле резерват булып хезмәт итүче агачлар төбендә сакланып кала-лар. Татарстан терр-ясендәге агачларда һәм үләнчел үсемлекләрдә яшәүче гади утлы коң-гыз (L.noctiluca) саклауга мохтаҗ бик сирәк төр.

Әд.: Б е й - Б и е н к о Г.Я. Общая энтомология. М., 1980; Кадастр полезных насекомых Республи-ки Татарстан. К., 2004.

Р.М.Зелеев.

УТРО́БИН Иван Михайлович (4.9.1897, Вятка губ., Слободской өязе Заозёрное а. —

1972, Казан), стоматолог, мед. фән. д-ры (1936), проф. (1936), РСФСРның атказ. табибе (1940), ТАСС ның атказ. фән эшлекле се (1945). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1923), шунда ук, ортодонтология клиникасында калдырыла, 1930 елдан Казан мед. ин-тының ортодонтология каф. мөдире. 1933–39, 1953–63 тә Казан ГИДУВында (1934–39 да дәвалау һәм бала лар стоматологиясе каф. мөдире). Бер үк вакытта, 1936–50 елларда Казан стомат. ин-тында (1936–38 дә директор, 1939–50 дә хирургик стомат. каф. мөдире). 1950–53 тә Казан Травматология һәм ортопедия фәнни-тикшеренү ин-тының казналык-бит хирургиясе клиникасы мөдире, бер үк вакытта ТАССР Сәламәтлек саклау министрлыгы баш стоматологы (1946–55). Хезмәтләре каз налык-бит имгәнү-җәрәхәтләнүләрен хирургик юл б-н дәвалауга карый. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Огнестрельные комбинированные ранения лица-носа, придаточных пазух и жевательного аппарата, К., 1945 (автордаш); К вопросу о хи рургической профилактике злокачественных новообразований жевательного аппарата. К., 1951.

Әд.: Памяти Ивана Михайловича Утробина // Стоматология. 1973. № 5.

УТРО́БИН Иван Степанович (10.3.1934, Чаллы р-ны Орловка а.), спортчы (чаңгыда узышу), СССРның атказ. спорт остасы (1966). 1960 елдан Мәскәү өлкәсенең Красногорск шәһәрендә яши. СССР чемпионы — 1960 (30 *км*), 1961 (50), 1962 (50, х10 эстафе тада), 1963 (50), 1965 (30, 50, 70), 1966 (15,50), 1967–68 (70), СССР чемпионатларында көмеш медаль алучы — 1960 (50), 1963 (70), 1965 (4х10 эстафетада), 1966 (30), СССР чемпионатларында бронза медаль алучы — 1960 (15), 1968 (15, 50), дөнья (1962), Олимпия уеннары (1964, 4х10 эстафетада) чемпионы. 1969–70 тә Мәскәү өлкәсе, шәһәр советларының «Труд», «Зенит» ирекле спорт җәмгыятьләрендә тренер-укытучы. 1970 тән Красногорск механика з-дында: махсуслаштырылган Балалар-яшүсмерләр спорт мәк тәбендә директор (1970–72), Балалар-яшүс мерләр спорт мәктәбендә тренер-укытучы (1972–82), слесарь-ремонтлаучы (1982–95). 1995 тән Красногорск шәһәренең «Зоркий» спорт-сәламәтләндерү оешмасы хезмәткәре. У. Мәскәү өлкәсе Красногорск р-нының мак таулы граждане (2009). У. исем. призга ярышлар 1978 дән Татарстанда Тарловка пос. янында, 1992 дән «Солнечный» сәламәтлән дерү лагерының чаңгы трассасында (Тукай р-нының «Түбән Кама» милли паркы терр-ясендә), 1985 тән Красногорск шәһәрендә уздырыла.

УТРО́ПИНА Татьяна Николаевна (9.3.1912, Лодзь ш., Польша — 27.1.1995, Казан), җыр чы (лирик-колоратуралы сопрано), педагог, ТАССРның атказ. артисты (1945). 1940 елда Мәскәү консерваториясен (К.Н.Дорлиак классы) тәмамлый. 1941–57 дә Татар опера һәм балет театры солисты. 1959–74 тә Казан консерваториясендә ялгыз җырлау буенча дәресләр бирә, 1970–74 тә опера җырчылары әзерләү каф. б-н җитәкчелек итә. Бер үк ва кытта соло концертлары б-н чыгыш ясый. Опера сәхнәсендә Көнбатыш Европа һәм рус композиторларының әсәрләрендәге төп партияләрне башкара: Джильда, Виолетта («Риголетто», «Травиата», Дж.Верди), Розина («Севилья тәүтарашы», Дж.Россини), Кар кызы, Марфа (шул исем. әсәр буенча, «Пат ша кәләше», Н.Римский-Корсаков), Микаэла («Кармен», Ж.Бизе), Недда («Паяцы», Р.Леонкавалло) һ.б. Актив рәвештә концертлар куя, грампластинкалар әзерләү өчен Дәүләт радио тапшырулары һәм тавыш яздыру йорты нында (Мәскәү) фонд әсәрләрен яздыра. У.ның иҗаты эчкерсез, саф, тәэсирле җырлавы, нечкә сәнгати зәвыгы, күтәренке рухлы актёрлык осталыгы б-н аерылып тора. Медаль б-н бүләкләнә.

УТЧӘЧӘ́К (Coronaria), канәферчәләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 5 төре билгеле. Евразиянең уртача поясында очрыйлар. ТР терр-ясендә бер төре — күке үләне (C.flos-cuculi) барлык районнарда таралган. Дымсу болыннарда, сазлык кырыйларында, елга тугайларында үсә. 30–90 *см* биеклектәге үсемлек. Сабагы туры, буразналы, өсте тармаклы. Тамыр яны таралгысындагы аскы яфраклары — калаксыман озынча, сабактагылар — ланцетсыман кыяк. Чәчәкләре алсу, ара-тирә ак, куе булмаган ярымчатырга җыелган. Җимеше — бер оялы ачылучан тармачык. Май–июньдә чәчәк ата. Үсемлек дәвалау максатларында файдаланыла. Составында алкалоид, сапонин, ти мер, С витамины бар. Халык медицинасын да сары авыруын дәвалауда, бөердәге авыр тулар вакытында, тир кудыру чарасы буларак кулланыла. Декоратив, баллы үсемлек. Тер лек азыгы.

УТЫ́З ИМӘ́Н авылы, Чирмешән р-нында, Чирмешән авылыннан 24 *км* төньяк-көнбатыштарак, Сөлчә елгасы (Олы Сөлчәнең уң кушылдыгы) буенда. 2010 елда 495 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына; 2000 гә кадәр Яңа Кади исеме б-н мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 мәчет, ти мерче алачыгы, 9 вак-төяклөр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2822,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Котыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай канто нында. 1930 ның 10 августыннан — Беренче Май, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Чирмешән р-нын да. Халык саны: 1782 дә — 26 ир-ат; 1859 да — 831, 1897 дә — 1476, 1908 дә — 1559, 1920 дә — 2099, 1926 да — 1199, 1949 да — 1409, 1958 дә — 1415, 1970 тә — 1644, 1979 да — 1260, 1989 да — 727, 2002 дә — 634 кеше. У.И.дә шагыйрь һәм фикер иясе Г.*Утыз Имә ни* туган.

УТЫ́З ИМӘНИ́ Габдеррәхим бине Госман әл-Болгари (1.8.1754, Казан губ., Чистай өя зе Утыз Имән а. — 8.4.1834, Оренбург губ., Бөгелмә өязе Тимәш а.), шагыйрь, фикер иясе, дин белгече. Бик иртә әти-әнисез кала, туганнарында яши. Туган һәм күрше авылы, Каргалы бистәсе (Оренбург губ.), 1788 елдан Бохара, Сәмәрканд, Һират, Кабул, Бәлх һ.б. шәһәрләр мәдрәсәләрендә укый. 1798 дә туган авылына кайтып, Казан һәм Оренбург губерналары авылларында имам-хатиб, мөдәррис булып тора. Татар һәм гарәп телләрендә яза. Поэмалар, шигырьләр, дини трактатлар, фәлсәфә мәсь әләләфенә караган гыйльми хезмәтләр, Газәли, Гаттар, Җами, Руми, Алла һияр китапларына шәрехләүләр авто ры. У.И. иҗатында татар әдәбиятында социаль мәсь әләләргә игътибар арту, әдәби әсәрләрнең тел-стиленә, формасында демократияләшү ачык чагыла. У.И.иҗатында һәр кешегә тормышта һәм теге дөньяда кирәк булган мәгърифәткә, белем алуга өндәү төп



Г. Утыз Имәнинең «Төхфәт әл-әхбаб» китабының титул бите. 1900.

мотивларның берсе булып санала. «Әбъят-е төрки фи фазыйләт-е гыйлем» («Белемнәрнең өстенлеге турында төрки шигырьләр») шигырендә шагыйрь: «Белем — якты лык, ул кешеләрнең күңелләрен яктырта; белемсез лек — ут, кешеләрнең йөрәкләрен яндыра», — дип яза. Мәгърифәт һәм аң — У.И. этик системасының иң югары өстенлеге. У.И.фикеренчә, алар кешене әхлакый яктан камилләштерәләр, гомумән, җәмгыятне савыктыралар. Үзенең «Тәнзиһ әл-әфкяр фи нәсаих әл-әхъяр» («Фикерләрне пакьләндерү өчен файдалы нәсыйхәтләр») һәм «Җәнах әл-фәл ләх фи зәммил мөбах» («Котылуга юл — рөх сәт ителгәнне гаепләү») поэмаларында әдип замандашларының кимчелекләрен, икейөзлелекне, комсызлыкны, мәкерлелекне, үч алучанлыкны һ.б. фаш итә.

Гадел мөселман кешенесенең әхлакый-этик идеалына («инсани камил») күләмле (27 бүлек, 986 юл) һәм популяр «Мөһиммәт әз-за ман» («Заманның мөһим билгеләре», 1820) поэмасы багышланган. Шагыйрь мәгърифәтчелекне, тәрбияне, дуслыкны, кыюлыкны мактый, ваемсызлыкны, хәйләкәрлекне, ачуны, икейөзлелекне кабул итми. У.И. поэмалары композициясе урта гасырлар шәрекъ әдәбияты өчен традицион: башта вакыйга, аннан соң вакыйгадан алынган әхлак бәян

ителә. Үзенең гарәп телендә язылган дини тракталарында У.И. үзе яшәгән заман җәмгыятенең кимчелекләре турында яза һәм үзен аларны төзәтергә бурычлы дип саный. У.И. татар җәмгыятен ислам дине генә торгыза ала дип уйлый (соңгы дәверләрдә өстәлгән үзгәрешләрдән чистарыну шарты белән). «Җәва һир әл-бәян» («Аңлату җәүһәрләре») исемле дини трактатында замандашларының көнкүреш тормышын шәригать, Коръән һәм Сөннә нормаларына туры китерергә өнди. У.И. татарларның этноконфессиональ үзенчәлеген саклау юлларын дини кануннарны катгый үтәүдә күрә, ә кануннарга туры килмәгән әйберләр — «тыелган яңа гадәт» (*«бидгать»*), ялгышу. «Гавариф әз-заман» («Замана бүләкләре») исемле шигъри әсәрендә шагыйрь бидгатьнең 14 төрен санап китә: тәравих намазын мәчеттән тыш башка урыннарда уку, исерткеч эчемлекләр куллану, Коръән укыган өчен акча алу, мәчеттә мәҗлесләр уздыру, намазны пычрак кием киеп уку, Рамазан аенда «ләйләт әл-кадр» («кадер кичәсе»н) зурлап бәйрәм итү һ.б.

«Инказ әл-халикин» («Һәлакәткә юлыгучыларны коткару») трактатында У.И. җәмгыять өчен кирәкле фәннәр дип медицинаны һәм арифметиканы саный, ә *калам* (дини кануннарны (догматларны) рационалистик аңлату), мантыйк һәм фәлсәфәнең татар җәмгыяте өчен файдасы юк, алар аз белемле мөселманнарны ялгыштыралар дип раслый. У.И. җәмәгать фикеренең торгынлыгын җиңеп чыгуны, татарларның дини һәм милли үзенчәлекләрен торгызу һәм саклауны заманның әһәмиятле мәсьәләсе дип саный. Шул максат б-н ул *фикх*, *тәфсир* һәм *хәдисләрне* өйрәнүне пропагандалый. «Рисалә-и шәфәкыйа» («Шәфәкъ турында рисалә») әсәрендә җәй көне, кояш чыкканга кадәр вакыт аралыгы кыска булган чакта Идел-Урал төбәге мөселманнары өчен төнге намазның мәҗбүри түгеллеге турындагы фикерен белдерә. У.И.нең әлеге карашы башка дин белгечләре фикерләренә каршы килә, шу ңа күрә ул шәригатьнең төп законнарын ревизияләүдә гаепләнә, күлга алына һәм төрмәгә ябыла (Бөгелмә шәһәрендә дип фараз ителә). Төрмәдә «Горбәтнамә» («Мосафир язмалары») исемле пессимистик поэмасын яза, анда ул төрмә тормышының авырлыкларыннан зарлана, Алла һы Тәгаләнең мәрхәмәтенә һәм үзенең тиздән төрмәдән чыгачагына ышана. У.И.нең мәгърифәтчел идеяләре аның замандашлары һәм соңгырак чор фикер ияләренең дөнья-га карашларына тәэсир итәләр. Аның хезмәтләре татар иҗтимагый-сәяси һәм эстетик фикеренең яңа, җәдиди юнәлеше формалашуга этәргеч була.

Әсәр.: Шигырьләр, поэмалар. К., 1986; Габдрахим Утыз-Имяни аль-Булгари. К., 2007.

Әд.: Шарипов А. Габдрахим Утыз Имяни аль-Булгари (1754–1834) // История татарской литературы нового времени (XIX — начало XX века). К., 2003. *Ә.М.Шәрипов.*

«УТЫ́З ТУГЫ́З ҖИТӘКЧЕ́ ХАТЫ́», (1924 елның 8 гыйнвары), РКП(б) ның Татарстан өлкә ком-ты һәм ТАССР ҮБК һ.б. дәүләт структуралары әгъзаларының (Г.Б.*Баһаветдинов*, М.Ю.*Борындыков*, Ф.З.*Бурнаш*, Ю.Н.*Вәлидов*, Н.Г.*Вахитов*, А.Г.*Ганиев*, Г.М.*Енбаев*, Г.Г.Максудов, Г.Г.Мансуров, К.Г.Мохтаров, Р.А.Сабиров, Ш.Х.Усманов һ.б.) РКП(б) ҮК Политбюросы һәм Секретариаты әгъзалары И.В.Сталин, Н.И.Бухарин, А.И.Рыков, В.М.Молотов, Я.Э.Рудзутак, В.В.Куйбышевка юлланган хаты. Хатта ТАССРдагы сәяси һәм икътисади хәлләргә, Татарстан өлкә ком-ты эшчәнлегенә анализ ясала. Кадрлар б-н эшләүдә өлкә ком-тының татарларга ышанмавы сизелү, бары тик «интернационалистларга» гына таяныу, кайбер күренекле татар эшлеклеләренең милләтчелектә нигезсез гаепләнеп респкадан ераклаштырылуы билгеләнә. Авторлар Татарстан партия оешмасында үзара килешмәүчәнлеккә һәм конфликтларга чик кую буенча 6 пунктта торган чара тәкъдим итәләр. Хатны юллаучылар Татарстан өлкә ком-ты бюросы әгъзаларыннан К.Г.Мохтаров, Р.А.Сабиров, Г.Г.Мансуров һәм Г.М.Енбаевка Политбюро утырышында катнашу һәм хәлне аңлату мөмкинлеге бирүне үтенәләр. Хат РКП(б) ҮКның Оештыру бюросында карала һәм тискәре бәяләнә. РКП(б) ҮК күрсәтмәсе буенча ул өлкә партия оешмасында тикшерелә, мондый мөрәҗәгатьләрнең ярамаганлыгы хакында авторлар кисәтелә. Озакламый күл куючыларның кайберләре үкенүләрен белдерәләр. 1924 ел дәвамында М.Ю.Борындыков, Г.М.Енбаев, Г.Г.Мансуров, К.Г.Мохтаров һәм Р.А.Сабиров урыннарыннан азат ителә һәм Мәскәүгә икенче дәрәҗәдәге вазифаларга күчерелә. 1930 елларда «У.т.җ.х.»нда катнашу партиягә һәм советка каршы чыгу буларак карала, репрессияләү өчен стандарт гаеп булып тора. Хатка күл куючыларның күбесе репрессияләнә.

Әд.: Тагиров И.Р. Очерки истории Татарстана и татарского народа (XX век). К., 1999.

Б.Ф.Солтанбәков.

«УТЫРТЫЛМА́ УРМА́Н», ландшафтлы табигать истәлеге, Арча һәм Балтач р-ннары терр-ясендә. 1987 елда билгеләнә. Арча урманчылыгының Балтач (78–81 нче кварталлар) һәм Сорнар (77 нче квартал) урманчылык участоклары составында. Мәйданы 613 *га*. Генетик-селекция сыйфаты ягыннан эталон булган югары җитештерүчәнлеккә ия нарат һәм чыршы культураларын берләштерә. Нарат чиста, ш.у. катнаш (чыршы, сирәк кенә ак чыршы, каен һәм юкә б-н) утыртмалар барлыкка китерә. Бонитет классы 1 а буенча үсә, 60 яшендә 26 *м* биеклеккә җитә, көүсә диаметры 24–26 *м*. Урман эчендә яңа



«Утыртылма урман».

дан чыршы, ак чыршы уңышлы гына үсеп чыгалар, яшь агачларның урнашу тыгызлыгы 1 *га* га — 5–6 меңгә кадәр экземпляр. Нараттан аермалы буларак, чыршы, каен, усак, юкә, урыны-урыны б-н ак чыршы катыш агачлыклар хасил итә. Куаклыклар сирәк, милләш һәм зелпедән тора. Чыршы бонитет классы 1 буенча үсә, өлгергән агачларның биеклеге 24 *м* га җитә, көүсә диаметры 26 *см*. Фауна катнаш, ылыслы (суер, боҗыр, поши, тиен) һәм киң яфраклы (шәүлегән кош, гади урман күгәрчене) урман вәкилләре очрый; өч бармаклы тукран ТРның Кызыл китабына кертелгән. Объект — урманчылык культурасы җитештерү истәлеге.

УТЫРЫШЧЫЛА́Р МӘХКӘМӘСЕ́ (ант-лы утырышчылар мәхкәмәсе), гадел хөкем чыгаруда турыдан-туры халык катнашу принцибына нигезләнгән мәхкәмә системасындагы ин-тларның берсе. Россиядә 1864 елда Мәхкәмә реформасы уздырылган вакытта оештырыла. Казан губернасында 1870 тән җинаятьләрне тикшерү өчен Округ мәхкәмәсе каршында эшли. У.м. составына даими судьялардан тыш антлы утырышчылар (12 се төп һәм 2 се алмаш) — җәмгыятьнең билгеле бер таләпләргә (25–70 яшьтә булу, рус телен яхшы белү, җинаять кылган өчен хөкемгә тартылмау, билгеле бер мөлкәт цензы) туры килгән, һәр конкрет эшкә жирәбә юлы б-н сайлана торган барлык катлау вәкилләре керә. Кайбер категорияләрдәге чиновниклар, халык мәктәбе укытучылары, крәстияннәр (крәстиян иҗтимагый идарәсендә вазифалар биләмәүчеләр), «аерым затларда хезмәтче булып торган» кешеләр утырышчылар була алмыйлар. Антлы утырышчылар исемлеге гомуми (утырышчы булу хокукына ия барлык кешеләр дә кертелә) һәм чираттагыга (киләсе елга) бүлеп алып барыла. Антлы утырышчылар судьялар б-н берәртән җинаять эзләрен, матди һ.б. төрле дәлилләрне тикшерә алалар. Гомуми кагыйдә буенча, гаепләнүченең гаебе яки гаепсезлеге, акылы саулыгы һәм аерым шартлар, җинаять фактын тану турында өчтән ике тавыш б-н карар кабул итәләр; җәза чарасын судья билгели. Антлы утырышчылар катнашындагы Округ мәхкәмәсе карарлары кассация тәртибендә Сенат тарафыннан юкка чыгарыла ала. У.м. ХКСның 1 нче номерлы «Мәхкәмә турында» 1917 ел 22 ноябрь Декреты б-н гамәлдән чыгарыла һәм кабат Россия Федерациясендә РФнең 1993 ел 16 июль Законы б-н торгызыла. Татарстанда У.м., РФнең 2002 ел 27 декабрь Законына туры китереп, ТР Югары мәхкәмәсе каршында 2003 нең 1 гыйнварыннан эшли. Гомуми исемлектән (ТР Президенты Указы нигезендә һәр 4 ел саен төзелә) «очраклы» методика буенча фәкать билгеле бер эшне тикшерү һәм фактларны хәл итү өчен 12 төп һәм 2 алмаш утырышчы, хокук мәсьәләләрен чишү өчен бер (кайвакыт берничә) проф. судья сайлап алына. Судьялар утырышчылар вердиктына нигезләнеп хөкем чыгаралар һәм җәза чарасын билгелиләр. Кагыйдә буларак, У.м. җитди җинаять эшләрен 1 нче инстанциядә карый һәм аның карарларына апелляция шикаяте бирергә рөхсәт ителми.

Чыг.: Полное собрание законов Российской империи. Собр. 2. СПб., 1867. Т. 39. № 41475, 41476.

Әд.: Реформа судебная: В 2 ч. М., 1915.

Е.Б.Долгов.

УТЯ́ШКИНО авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 17 *км* көньяктарак, Дала Зәе елгасы буенда. 2010 елда 62 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. 1755 кә кадәр Сембер губернасының Мәдәнә авылыннан күченүчеләр нигез сала. Беренче исеме — Уткино. Халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, 19 йөз башында алпавыт Мельгунов аларны ирекле игенчеләр катлавына күчерә, 1848 дә дәүләт крәстияннәре катлавына керә; игенчелек, терлекчелек, тәгәрмәч, чана, дуга ясау, олаучылык б-н шөгыльләнә; Зәй-Чишмә бакыр рудасы з-дында эшлиләр. 1773–75 еллардагы Крәстияннәр кузгалышында Е.И.Пугачёв ягында сугышалар. 20 йөз башында укыр-га-язарга өйрәтү мәктәбе, су тегермәне, бакалея кибете, ашлык саклау-сату кибете эшли. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 1970 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Яңа Спас волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1959 ның 26 мартыннан — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1834 тә — 196, 1859 да — 293, 1870 тә — 345, 1884 тә — 496, 1897 дә — 683, 1906 да — 737, 1913 тә — 864, 1920 дә — 801, 1926 да — 710, 1938 дә — 613, 1949 да — 370, 1958 дә — 469, 1970 тә — 427, 1979 да — 235, 1989 да — 128, 2002 дә — 97 кеше.

Әд.: Заинская энциклопедия. К., 1994.

УФА́ шәһәре, *Башкортстан Республикасы* башкаласы. Халкы — 1125612 кеше (2017). Татарлар саны: 1970 елда — 185 мең, 1979 да — 240,9 мең, 1989 да — 291,2 мең, 2002 дә — 294,4 мең, 2010 да — 286,4 мең кеше. Татар халкы тарихында У. аерым урын алып тора, ул Казан кебек үк милли, мәдәни, дини һәм иҗтимагый тормышның иң эре үзәкләреннән берсе булып кала. 1788 дә Уфа Дини Мөхәммәди канун Җыены (к. *Россия һәм БДБның Европа илләре мөселманнары Үзәк Диния нәзарәте*) оештырыла, аның утырышчылары булып Казан губернасыннан чыккан кешеләр тора. 1872 дә *Уфа татар укытучылар мәктәбе* ачыла, 1887 дә — «*Гос-мания*» мәдрәсәсе, 1906 да татар, башкорт, казакъ һ.б. төркы халыкларның иң зур мәгърифәт учакларыннан берсе булган «*Галия*» мәдрәсәсе эшли башлый. 20 йөз башында



Уфа шәһәре. Галия мәдрәсәсе. 1908 елгы фоторәсем.

У.да татар китапханәсе һәм китап сату конторасы, «*Акча*», «Алга», «*Иршад*», «*Каләм*» татар нәшриятлары, «*Тормыш*» басмаханәсе була; «*әл-Галәме әл-Ислами*», «*Дус*», «*Мәгълүмате җәдидә*», «*Мәгълумате мәхкәмәи шәргыяи Ырынбургия*», «*Сибирия*», «*Тормыш*» г-талары, «*Уфаның авыл көнкүреше журналы*» нәшер ителә; 1912–22 елларда татар драма театры эшли. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң У. татар милли-сәяси тормыш үзәкләреннән берсе була. 1917–18 елларда монда төрки-татарларның милли парламенты — *Милләт Мәҗлесе* җыела, 1917 дә *Татар социал-демократ эшчеләр партиясе съезды* узды-рыла, 1917 нең августыннан декабрена кадәр *Милли-мәдәни мохтарият нигезләрен эшләү комиссиясе* эшли. Совет хакимиятенең беренче елларында «*Безнең юл*» (1917–18), «*Ирек*» (1917) г-талары; «*Уфа кооператоры*» (1917–18), «*Мохтарият*» (1917–18),



Уфа шәһәре. «Нур» татар драма театры.

«*Бабич*» (1922), «*Ислам мәҗәлләсе*» (1924–28), «*Сәнәк*» (1926–37) һ.б. журналлар нәшер ителә. 1918 дән «*Кызыл таң*» г-тасы чыга. 1980 еллар ахырыннан У.да татар халкының милли-мәдәни тормышында күтәрелеш күзәтелә. 1988 дән Г.Тукай исем. шәһәр татар әдәбиятын һәм мәдәниятен сөючеләр клубы эшли, 2002 дә У. татарларының милли-мәдәни автономиясе теркәлә, шәһәрдә күп кенә респ-ка иҗтимагый-мәдәни оешмаларының җитәкче органнары туплана. Башкорт ун-тының филол. ф-тында татар теле һәм әдәбияты укытучылары әзерләнә. Уфаның 1 нче пед. көллияте татар мәктәпкәчә тәрбия учреждениеләре өчен — тәрбиячеләр, татар мәктәпләре өчен башлангыч сыйныф укытучылары әзерләп чыгара. Уфада 2 татар гимназиясе, Татар телен тирәнтен өйрәнү үзәге, 3 татар якшәмбе мәктәбе, 4 татар телен өйрәтүче мәктәпкәчә тәрбия учреждениесе эшли. 60 гомуми белем бирү мәктәбендә татар теле фән буларак укытыла. 2008 дән респ-ка һәм шәһәр күләмендә «Татар теле һәм әдәбияты ел укытучысы» конкурсы үткәрелә. У.да татарлар б-н бәйле тарих һәм архит-ра истәлекләре: Тәфкилевләр йорт-утары, Г.Х.Терегулов, М.М.Йосыпов йортлары, Еникиевләр утары урнашкан. «*Нур*» татар театры эшли. Ел саен — «Башкортстанда татар яшьләре көннәре», 2 елга бер тапкыр «Туган тел» татар жырын башкаручылар конкурсы үткәрелә. Татар халкының күп кенә күренекле вәкилләре: шагыйрь һәм мәгърифәтче *Акмулла*, дин белгече һәм җәмәгать эшлеклесе Р.*Фәхретдин*, педагог Г.*Буби*, дәүләт эшлеклесе С.С.*Сәетгалиев*, шагыйрь Ш.М.*Бабич*, язучылар М.*Гафури* һәм Н.*Исәнбәт*, драматург Р.Ф.*Ишморат*, балет артисты Р.Х.*Нуриев* һ.б.ның тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге У. б-н бәйле.

Әд.: Асфандияров А.З. История сёл и деревень Башкортостана: В 7 кн. Уфа, 1990–97; Якупов Р. Татары // Ватандаш. 1999. № 8; Сафин Ф.Г. Вопросы этнической и языковой идентификации тюркского населения Республики Башкортостан. К., 2005; Башкортостан: Краткая энцикл. Уфа, 1996; Башкирская энциклопедия. Уфа, 2010. Т. 6.

«УФА́ КООПЕРА́ТОРЫ», журнал. 1917 елның сентябреннән 1918 нең декабренә кадәр Уфада татар һәм рус телләрендә аена 2 тапкыр нәшер ителә, барысы 20 саны чыга. Уфа губернасы кооперативлары берлеге органы. Наширләре: Уфа губерна җәмәгать кибетләре һәм Златоуст, Уфа, Эстәрлетамак шәһәрләренең җәмәгать кибетләре һәм вак кредит ширкәтләре берләшмәләре. «Тормыш бердәмлектә! Кооперация — яңа тормышка юлдыр!» лозунгы б-н чыга. Мөхәррирләре — А.Т.Ветошников, Л.А.Егоров, тәр җәмәче — С.Шәрәфетдинов. Журналның максаты булып кооперация хәрәкәтен пропагандалау тора. Сәяси мәсь әләләр турында бәхәс алып барудан тайчынырга омтылса да, редакция большевиклар вакытында кооперативларның хәле күпкә начараюын билгеләп үтә һәм Учредительләр җыенын илне торгызуда булышлык итәргә чакыра («Безнең максатлар» мәкаләсе, 1917, 12 сан һ.б.).

Әд.: Рәмиев И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926.

З.З.Гыйләҗев.

«УФА́ МӨСЕЛМА́Н ГАСКӘРИ́ ШУРАСЫ́ ХӘБӘРЛӘРЕ́», к. «*Солдат теләге*».

УФА́ ӨЯЗЕ́, 1865–1922 елларда Уфа губернасындагы адм.-терр. берәмлек. Үзәге — Уфа шәһәре. Уфа кальгасын төзегәннән соң, 16 йөзнең 2 нче яртысында оеша башлый. Биләмәсенә Агыйдел, Өршәк, Бикә, Сим, Уфа, Дим, Йөрүзән, Танып һ.б. елгалар буенда-гы җирләр керә. Өяз биләмәсе 1708–44 елларда Казан губернасына, 1744–81 һәм 1796–1865 тә Оренбург губернасына, 1781–96 да — Уфа наместниклыгына керә. Көнбатыш һәм көньяк-көнбатышта — Бәләбәй, төньякта — Бөре, төньяк-көнчыгыш һәм көнчыгышта — Златоуст өязе, көньякта — Уфа губернасының Эстәрлетамак өязе һәм Оренбург губернасының Югары Урал өязе б-н чикләнә. Мәйданы 17184 кв. чакрым. Халкы 375718 кеше (1897), ш.и. руслар — 58%, татарлар һәм башкортлар — 37,5% тан күбрәк, мордва, мари, чуаш, удмуртлар һ.б. — 4,5% чамасы. 25 волостька бүленә. Халкы игенчелек, терлекчелек, бакчачылык, яшелчәчелек, чолыкчылык, сунарчылык һәм һөнәрчелек (агач әйберләр, мичкә ясау һ.б.) б-н шөгыльләнә. Өяздә 19 йөз уртасында спирт, аракы, сыра, бакыр һәм чуен эретү, тимер эшкәртү, поташ, сабын кайнату, май эретү, шәм, тире, кирпеч, шырпы з-длары эшли. У.ө. терр-ясе 1922 дә Башкортстан АССР составына керә.

Чыг.: Сборник статистических сведений по Уфимской губернии. Уфа, 1898. Т. 1.

Д.Г.Мостафина.

УФА́ РАЙОНЫ́, *Башкортстан Республикасының* үзәгендә урнашкан. 1930 елның 20 августында оештырыла. Мәйданы — 1513 *км*². Үзәге — Уфа шәһәре. Халкы — 87798 кеше (2017). Татарлар саны: 1970 тә — 8704, 1979 да — 10680, 1989 да — 14981, 2002 дә — 17926, 2010 да — 22568 кеше. Район составында 90 торак пункт исәпләнә, ш.и. 6 татар, 27 рус-татар, 4 — башк.-татар, татар-чуаш, рус-татар-чуаш һәм башк.-рус-татар торак пункты. Иң зурлары (2010): Комлыкүл авылы (748 кеше), Кармасан посёлогы (706). 2014/15 уку елында У.р.ның 20 мәктәбендә татар теле фән буларак укытыла.


УФА́ (ОРЕНБУ́РГ) ТАТА́Р УКЫТУЧЫЛА́Р МӘКТӘБЕ́, 1872 елның 27 мартында Татар укытучылар мәктәпләре турындагы карар нигезендә ачыла. Рус-татар уч-щеләре өчен укытучылар әзерләү өчен билгеләнә. Мәктәптә шул ук Казан татар укытучылар мәктәбе программалары файдаланыла. Уфада укучылар 1 нче җамигъ мәчеткә йөриләр, мөфти С.Тәфкилев һәм Оренбург мөселманнары Диния Нәзарәте казыйлары йогынтысында булалар, аларның күбесе укытучы түгел, ә мулла булып китә. 1877 дә мәктәп Оренбургка күчерелә, 1890 да ябыла, бинасына Орск шәһәре Кыргыз (Казакъ) укытучылар мәктәбе урнаша. Анда Уфа укытучылар мәктәбе укытучылары эшләвен дәвам итә, ә укучылар Казан татар укытучылар мәктәбенә күчерелә. У.т.у.м.н 350 дән артык кеше тәмамлый, алар арасында сәяси эшлеклеләр, педагоглар Г.Х.Еникеев, М.М.Тукаев, Ш.Мәхмүдов бар.

Әд.: Фаршатов М.Н. Народное образование в Башкирии в пореформенный период: 60–90 гг. XIX в. М., 1994; Болодурин В.С. Образование в Оренбуржье (XVIII–XX века). Оренбург, 2008.

«УФА́ ХӘБӘРЛӘРЕ́», иҗтимагый-сәяси газета. 1918 елның июнь–декабрендә Уфада татар телендә атнасына 2–3 тапкыр нәшер ителә. Нашире — Мөселман республикачылар оешмасы. Мөхәррире — Ж.Фәхретдин. «Яшәсен милли мохтарият! Яшәсен күпмилләтле республика!» лозунглары б-н дөнья күрә. Актив авторлары арасында — И.Бикколов, Х.Сафиуллин, Г.Фәхретдинов, Г.Хәбиров, М.Хәнәфи. Редакция Милли Мәҗлес идеяләрен пропагандалый, совет хакимиятенә каршы чыгыш ясый, большевиклар партиясенең татар-башкорт вәкилләрен тәнкыйтьли. Газета Уфаны Кызыл Армия частьлары алганнан соң чыгудан туктый.

Әд.: Рәми И.Г., Даутов Р.Н. Әдәби сүзлек. К., 2001.

УФА́ Я́РУСЫ (Уфа шәһәре исеменнән), *Пермь системасы (чоры)* түбән (Урал буе) бүлегенең югары өлешендәге утырмалары, *Казан ярусы* алдыннан түбән Пермьнең Көнгер ярусы токымнарыннан соң килә. Яше 270,6–272 млн. ел. Казан геологы А.В.*Нечаев* тарафыннан билгеләнә (1915). Татарстан терр-ясендә У.я. токымнары (калынлыгы 90 *м* га кадәр) көнчыгышта Шөгер-Сокола-Тәкәнеш линиясенә кадәр таралган, сульфатлы-карбонатлы һәм төрле төстәге токымнарның: яшькелт-соры доломитлар һәм доломитлы мергельләр, шәмәхә, аксыл шәмәхә, кызгылт известьташлар, яшькелт һәм көңгырт-соры балчыклар, яшькелт-зәңгәрсу-соры комташлар һәм алевролитлар, гипс, ангидрит һәм брекчияләрнең комлы-балчыксыл катламыннан тора. У.я. утырмаларында елга моллюсклары, кысласыманнар (остракода),



Уфа ярусы: Чишмә горизонтында кызыл төстәге утырмалар (аста). Түбән Кама районы.

мүк, абагасыманнар калдыклары очрый, минераль су («Ижевский №1» һәм «Яр Чаллы») бакыр рудалары һәм битумнар чыганаклары, Ba, Sr, Au чагылмалары билгеләнә.

Әд.: Геология Татарстана: Стратиграфия и тектоника. М., 2003; Стратиграфический кодекс России. СПб., 2006.

«УФАНЫ́Ң АВЫ́Л КӨ́НКҮРЕШЕ ЖУРНАЛЫ́», рәсемле а.х. журналы. Уфа губернасының земство идарәсе органы. 1914 елның апреленнән 1918 нең декабренә кадәр Уфада татар һәм рус телләрендә нәшер ителә, якынча 130 саны чыга. Рус варианты «Уфимский сельскохозяйственный листок» исеме б-н чыгарыла. Мөхәррире — П.Ф.Коропачинский, 1917 дә кайбер саннарның мөхәррире П.П.Толстой. Журналның татар вариантының мөхәррир-сәркәтибе һәм тәрҗемәчесе — С.*Рәмиев*. Журнал а.х. һәм социаль-икътисади белемнәрне пропагандалый. Басма битләрендә авыл халкының тормыш һәм хезмәт шартларын яхшырту мәсьәләләре күтәрелә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, яшелчәчелекне алып бару буенча киңәшләр басыла. Ildәге иҗтимагый-сәяси вазгыять, волостьларны үзгәртеп оештыру барышы, земство хәрәкәте һәм кооперация-ләр үсеше яктыртыла. Уфа губернасының авыл һәм шәһәр тормышы вакыйгасы, төрле стат. материаллар урын ала. Журналда С.Рәмиевнең «Туп һәм сабан», «Күлмәк турында җыр» (алга таба халык арасында популяр җырга әверелә) шигырьләре дөнья күрә. Журналга кушымта (әмма даими түгел) чыга; аерым алганда, 8–9 саннар (1914, 15 июнь) кушымтасы тулысы б-н земствоның 50 еллыгына багышлана. Басма земство учреждениеләрен тарatканнан соң чыгудан туктый.

З.З.Гыйләҗев.

«УФИ́МСКИЙ КООПЕРА́ТОР», журнал; к. «*Уфа кооп фаторы*».

«УФИ́МСКИЙ СЕЛЬСКОХОЗЯ́ЙСТВЕННЫЙ ЛИСТО́К», к. «*Уфаның авыл көнкүреше журналы*».

УХА́НОВ Д.С. БАСМАХАНӘСЕ́, Казанда. 1909 елда Казан басмаханәләрендә 30 елдан артык эшләгән (*Кәримовлар басмаханәсе, ташбасмасы һәм хәреф кою ширкәте, Харитонов И.Н. басмаханәсе*, «Бәянелхак» һ.б.) басма осталарының проф. оешмасының актив катнашучысы булган хәреф җыючы Д.С.Уханов тарафыннан оештырыла. 1910 нан басмаханә — И.Л.Евдокимовка, 1911 дән — Я.Н.Подземскийга күчә. 1911 дә анда 7 кеше эшли, 1913 кә кадәр хезмәт күрсәтә. Татар һәм рус телләрендә китаплар (54 исемдә), «*Самодеятельность*», «*Трудовой союз*» ж-ллары (җирле кулланучылар җәмгыяте тарафыннан чыга, аларның берсенең җитәкчесе Д.С.Уханов була), «*Волжский вечер*», «*Казанская вечерняя почта*» һ.б. г-талар басыла.

Әд.: Габдельганеева Г.Г. Полиграфия и печать в Казанской губернии. 1800–1917 гг. К., 2005. *Г.Г.Габделганиева.*

У́ХОВ Евгений Григорьевич (1941, Киров өлкәсенең Сангурск р-ны Вордушино а.), журналист. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1967), «Комсомолец Татарии» г-тасында хәбәрче, бүлек мөдире, җаваплы сәркәтип, баш мөхәррир (1970 елдан) булып эшли. 1975–2006 да «Труд» (Мәскәү) г-тасының Татарстан һәм Мари респ-калары буенча үз хәбәрчесе. «Республика Татарстан» г-тасы, «Панорама» (Мәскәү) нәшрият йорты журналлары б-н хезмәттәшлек итә. Мәкаләләре Идел буе респ-каларының иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни тормышын яктырткан киң спектрлы проблемаларга, дәүләт сәясәтенең яшьләргә мөнәсәбәте мәсьәләләренә багышлана. Россия Журналистлар берлеге (1996) бүләге лауреаты.

УЧАЛЫ́ РАЙОНЫ́, БРның көнчыгышында урнашкан. 1930 елның 20 августында оештырыла. Мәйданы — 4505 *км*². Үзәге — Учалы шәһәре (Уфадан 376 *км* көнчыгыштарак). Халык саны — 71291 (2017), ш.и. район үзәгендә — 39722 кеше (2010). Татарлар саны: 1970 тә — 13330, 1979 да — 11654, 1989 да — 15142, 2002 дә — 9062, 2010 да — 11543 (ш.и. Учалыда — 7818) кеше. Районда 2 — Аҳун (2852 кеше) һәм Кыйдыш (128) татар авылы бар; 4 авылда (Танычау, Урал, Байсакал, Учалы) татарлар башкортлар б-н берлектә яши. 2015/16 уку елында У.р.ның Аҳун авылы мәктәбендә татар теле фән буларак өйрәнелә.

Әд.: Башкирская энциклопедия. Уфа, 2010. Т. 6.

«УЧЁНЫЕ ЗАПИ́СКИ КАЗА́НСКОГО УНИВЕРСИТЕ́ТА» («Казан университетының гыйльми язмалары»), фәнни басма. 1834 елдан бирле нәшер ителә. Басма инициаторы ун-т ректоры Н.И.Лобачевский була, ул «Учёные записки...» үз эчләренә «чын әсәрләр, тәр җәмәләр, кабат басылган әсәрләр һәм фәнгә кагылышлы булган хәбәрләрне алырга тиеш» дип саный. 1835 ел өчен чыккан 1 нче китапта Лобачевскийның «Күзаллаулы геометрия» («Воображаемая геометрия»), 1836 да — «Күзаллаулы геометрияне кайбер интегралларда куллану» («Применение воображаемой геометрии к некоторым интегралам») хезмәтләре дөнья күрә. Аның иң күләмле хезмәтләреңең берсе — «Параллельләрнең тулы теориясе белән геометриянең яңа башлангычлары» («Новые начала геометрии с полной теорией параллельных») 1835–38 дә басыла. Журналның беренче дистә елында

Лобачевский нәшрият ком-ты б-н үзе җитәкчелек итә, фәнни язмаларны рецензияли. Аның фикеренчә, басма «фән өчен хезмәт куючылар һәм танылу, галим исеменә лаек булучылар»га йөз тота. 1917 гә кадәр төрле еллардагы мөхәррирләре — А.П.Чебышев-Дмитриев, Н.П.Вагнер, Н.Н.Булич, Н.М.Ильминский, Н.А.Осокин, А.М.Осипов, Ф.Г.Мищенко һ.б. 1834–61 дә, бүлекләргә бүленмичә генә, елына 4 китап дөнья күрә. 1862–64 тә ректор А.М.Бутлеров башлангычы б-н язмалар 2 бүлеккә бүленә: 1) тарихи филол. һәм сәяси-хокук; 2) физ.-матем. һәм мед. фәннәре. 1865 тән язмаларның рәсми өлеше «Известия Императорского Казанского университета» дип атала башлый. «Известия...» һәм «Учёные записки...» елына 6 тапкыр нәшер ителә, ел ахырына алар 2 аерым томны тәшкил итә. 1884–89 да ф-тлар


УЧЕНЫЯ ЗАПИСКИ,
ИЗДАВАЕМЫЯ
ИМПЕРАТОРСКИМЪ
КАЗАНСКИМЪ УНИВЕРСИТЕТОМЪ
1835.
КНИЖКА I.
КАЗАНЬ.
1835.

«Учёные записки Казанского университета» журналы. 1835.

буенча аерым җыентыклар басыла: тарих-филол., хокук, физ.-матем., мед. 1890–94 тә журнал ф-тларга бүленмичә чыга, елына 6 тапкыр, 1895–1916 да — 12 шәр басма. Рәсми өлештә ун-т советы утырышларының боерыклары, карарлары, беркетмәләр басыла. Рәсми булмаган өлешне «Фәннәр бүлеге», «Тәнкыйть һәм библиография», «Университет елъязмасы» һәм кушымталар тәшкил итә. Басманың зур өлешен алып торучы фәнни бүлек тикшеренүләр материаллары, чыгышлар һәм лекцияләр, студентлар эшләрен бирләштерә. Библиографик бүлектә диссертацияләргә рецензияләр, командировкалар турында хисаплар, биографик характердагы язмалар басыла. «Университет елъязмасы» бүлегендә ун-т тормышы, китапханә, кабинетлар, музейлар, студентлар түгәрәге яктыртыла, бәхәсләр турындагы хисаплар, биогр. очерклар һәм некрологлар, акт чыгышлары һ.б. урын ала. Кушымтада лекцияләр конспектлары, тарихи һәм әдәби чыганаклар дөнья күрә. Казан авторлары язмаларыннан тыш, ватандаш һәм чит ил галимнәре эшләре дә басыла. Һәр бүлекнең үз пагинациясе (битләр саны) була. Басмага аеруча зур абруйны И.Н.Березин, В.М.Бехтеров, А.М.Бутлеров, Н.А.Васильев, А.М.Зайцев, Н.Н.Зинин, Н.Ф.Катанов, К.К.Клаус, Э.А.Эверсман һ.б. язмалары бирә.

1918–24 тә «Учёные записки...» басылмый. 1925–30 да кафедраларга һәм ф-тларга бүленмичә чыга, һәр том һәр елны берничә китап булып (2 дән 9 га кадәр) басыла. Аларда язмалар 5 шәр бүлеккә урнаша: физ.-матем., табигыять белеме — тарих, мед., җәмгыять белеме — сәясәт фәннәре. Совет чорында басмада фәкать фәнни язмалар һәм некрологлар гына басыла. 1931 дән һәр китапны аерым каф. бастыра, аларның һәрберсе үз саннарын алып бара. 1951 дә «Учёные записки...» «*Труды Общества естествоиспытателей при Казанском университете*» б-н берләштерелә: басма ике гриф б-н чыга, «Учёные записки...»ның да, «Труды...»ның да үз томнары, саннары була. 1958 дән «Учёные записки...» университет өчен бердәнбер журнал булудан туктый. Галимнәр язмаларының төп формасы булып каф. җыентыклары тора, аларның бер өлеше язмаларның чираттагы томнары кебек урнаштырыла (башта җыентыкларның үз атамалары була). 1972 дә, 130 нчы томда басма чыгудан кабат туктый. Совет чорында «Учёные записки...»да күренекле Казан галимнәре С.А.Альтшулер, А.Е. һәм Б.А.Арбузовлар, В.И.Баранов, М.П.Гагаев, К.З.Галимов, Н.А.Гуляев, Е.К.Завойский, Г.Х.Камай, Н.А.Ливанов, М.В.Марков, Д.Я.Мартынов, Л.М.Миропольский, А.З.Петров, А.Н.Пудовик, Г.С.Салихов, В.Н.Сементовский, Г.Г.Тумашев, Н.Н.Фирсов, М.М.Хвостов, Н.Г.Чеботарёв һ.б.ның хезмәтләре басыла. 1990 елларда «Учёные записки...»ны торгызырга омтылып карыйлар. 1955–2004 тә 19 том «чәчелеп» чыга. 2005 тән басма даими рәвештә 3 сериядә нәшер ителә: «Гуманитар фәннәр», «Табигыять белеме фәннәре», «Физика-математика фәннәре». Һәр серия аерым журнал сыйфатында, саннары сакланган хәлдә дөнья күрә.

Әд.: Загоскин Н.П. История Императорского Казанского университета за первые сто лет его существования. 1804–1904. К., 1903. Т. 2; 1906. Т. 4; Парамонова Н.Б. Книгоиздательская деятельность Казанского университета в первой половине XIX в.: Дис. ... Л., 1977; Габдельганеева Г.Г. «Учёные записки» Казанского университета (Из истории научного книгоиздания в России) // Книжное дело в России во второй половине XIX — начале XX в. Л., 1989; Указатель статей, напечатанных в «Учёных записках Казанского университета» за время 1834–1899 гг. включительно. К., 1900; Указатель статей к «Учёным запискам...» Казанского ордена Трудового Красного Знамени государственного университета им. В.И.Ульянова-Ленина за 1900–1950 гг. К., 1955; «Учёные записки» Казанского государственного университета, 1851–1972 гг.: Указ. содержания. К., 2002.

Р.А.Айнетдинов.

УЧРЕДИ́ТЕЛЬЛӘР ҖЫЕНЫ́ ӘГЪЗАЛАРЫ́ КОМИТЕТЫ́ (КОМУЧ), («Самара учредилкасы»), Урта Идел буе һәм Урал алды төбәгендәге вакытлы хакимият органы. 1918 елның 8 июнендә Самараны Чех-словак корпусы басып алгач, Самара шәһәрендә оештырыла. Учредительләр җыены чакырылышына кадәр КОМУЧ үзен Самара губернасының вакытлы хөкүмәте дип игълан итә. 1918 нең июнь–август айларында ком-т хакимияте Самара, Сембер, Казан һәм Уфа губерналарына тарала. КОМУЧ демократик иреклләр торгызылуын игълан итә, кызыл төстәге дәүләт флагын кабул итә, 8 сәгатьлек эш көнен билгели, эшчеләр конференцияләрен һәм крәстиян съездларын уздыруны, фабрика-завод ком-тларын һәм профсоюзлар эшчәнлеген рөхсәт итә, Халык Армиясен формалаштыра, совет хөкүмәте декретларын юкка чыгара, хосусый сәүдә иреген игълан итә. Ком-тта 5 кеше (беренче рәисе — эсер В.К.Вольский), август башында — 29, сентябрь башында — 71, сентябрь ахырында 96 кеше исәпләнә.

1918 нең 7 августында Казан Чех-словак корпусы гаскәрләре тарафыннан басып алынгач, КОМУЧ вәкиле Б.К.Фортунатов Казан губернасында совет хакимияте бәреп төшерелүе хакында игълан итә. Губернада эшләрне тәртипкә салу максатында ике урынбасары — татар халкы б-н эшләү өчен И.С.*Алкин* һәм чуаш халкы б-н эшләү өчен Г.Ф.Алюнов б-н бергә гражданнар идарәсен оештыру буенча вәкаләтле В.Архангельский җибәрелә. Администрация идарәсен капитан *Е.П.Калинин*, кооперация эшен кооператор М.Пасков җитәкли. Казан гарнизоны командующие итеп генерал-лейтенант В.В.Рычков билгеләнә. Казан шәһәр думасы, земство органнары эшчәнлеге яңадан башлана. Гражданнар иҗтимагый оешмаларының барысы да махсус күрсәтмә буенча КОМУЧның махсус вәкилләренә буйсынырга тиеш була, аларның вазифаларына ком-т хакимиятен нигъыту, Халык армиясен формалаштыруга һәрьяклап ярдәм итү, Вакытлы хөкүмәт чорында эшләгән хакимият органнарын яңадан торгызу, совет хакимияте органнарын һәр җирдә юкка чыгару керә. КОМУЧка эсерлар җитәкчелек итүгә карамастан, алар кабул иткән карарларның күбесе капиталистик мөнәсәбәтләрне яңадан торгызуга юнәлтелә: Казандагы завод-фабрикаларның күбесе хуҗаларына кайтарып бирелә (шуның б-н бергә аларга эшчеләрдән интенсив һәм яхшы сыйфатлы хезмәт таләп итү, дисциплинага буйсынмаучыларны һәм артык эшчеләрне эштән чыгару хокукы бирелә), күп кенә банклар киредән хосусыйлаштырыла. Совет хакимиятен яклаучыларга карата комуччылар кырыс репрессив чаралар кулланалар (к. *Кызыл һәм ак террор*), М.М.*Вахитов*, А.П.*Комлев*, М.И.Межлаук (к. *Межлауклар*), Я.С.*Шейнкман* һ.б. үтерелә. Казанга эсерлар үкы партиясе әгъзалары Н.Н.Иванов, В.М. Зензинов, С.Н.Каллистов килә. Шунда ук Б.В.Савинков һәм «*Ватан һәм хөрриятне саклау берлеге*» әгъзалары А.П.Перхуров, А. Дикгоф-Деренталь, Ф.Клепиков һ.б. була. КОМУЧ сәясәтен Хезмәт халык-социалистик партиясе әгъзалары, меньшевиклар, кайбер татар, чуаш һәм мари милләтчеләре дә яклый. КОМУЧ б-н Ж.С.*Алкин*, А.Мамлиев, А.Килдишев актив хезмәттәшлек итә. Комуччылар Россия мөселманнарының тулы вәкаләтле вәкиле итеп Ә.*Вәлидине* таныйлар. И.С.Алкин вакытында Халык армиясенә матди ярдәм күрсәтү



С.Н. Ушаков.



П.К. Ушков.

һәм кадрлар б-н тәэмин итү өчен махсус мөселман коллегиясе оештырыла. Коллегия татарлар арасында агитация эшләре алып бара, җыелышлар һәм митинглар уздыра: 1918 нең 21 августында митингларның берсендә Г.*Баттал* иганә җыюны оештырырга, корал йөртә алырдай барлык ир-атларны Халык армиясенә керергә чакыра. И.С. Алкин Халык армиясе составында мөселман частьларын булдыру идеясе б-н чыга (әмма ул тормышка ашырылмый кала). Гомумән, Казан губернасында халыкны һәм матди ресурсларны мобилизацияләү акрын бара. Казанлылар Халык армиясе ихтыяҗларына нибары 1255 мең сум акча җыялар. Бигрәк тә алпавытлар һәм крәстияннәргә карата алып барылган сәясәт бик уңышсыз була. «Җирне социализацияләү»не яклау б-н бергә, ком-т чынлыкта алпавыт җирбиләүчеләге кире кайтуга комачауламый. Комуччылар алпавытларга 1917 елгы уҗым ашлыгы уңышын җыеп алу хокукы биреп, крәстияннәрне үзләреннән читләштерәләр. Крәстияннәр Халык армиясенә керүдән баш тарталар, кайбер өязләрдә (Тәтеш өязе Пролей-Каша авылында һ.б.) авыл халкы б-н КОМУЧ отрядлары арасында кораллы бәрелешләр була. 1918 нең 3 сентябрендә Казанда Елга аръягы эшчеләре Халык армиясенә мобилизацияләнүгә каршы баш күтәрәләр. Аларга җавап итеп генерал-лейтенант В.В. Рычков шәһәрдә сугыш хәле игълан итә, атып үтерү б-н янап эшчеләргә коралларын тапшырырга тәкъдим итә, шул рәвешле эшчеләр каршылыгының яңа дулкынын китереп чыгара. Баш күтәрү бастырыла. Шулай да 1918 нең 5 сентябрендә Казанда камалыш хәле кертелә. Халык армиясе берничә мәртәбә Кызыл Армия тарафыннан тар-мар ителә, һәм 12 сентябрьдә КОМУЧ Казаннан китә. Уфа директориясе оештырылганнан соң, атамасы «Учредительләр җыены әгъзалары съезды» дип үзгәртелә (Уфа, аннары Екатеринбург шәһәрендә утырышлар уздыра). Адмирал А.В.Колчак түнтәрелешеннән соң, 1918 нең декабрендә, «Съезд...» әгъзалары кулга алына, аларның бер өлеше акгвардиячеләр тарафыннан атып үтерелә. Оешма юкка чыгарыла.

Әд.: Борьба за Казань. К., 1920; Кузнецов А. Казань под властью чехоучредиловцев // Пролетарская революция. 1922. № 8; Мухарямов М.К. Из истории иностранной военной интервенции и гражданской войны на территории Татарии (1918–1920). К., 1954; Литвин А.Л., Мухарямов М.К. Решающий рубеж. К., 1978.

Л.М.Айнетдинова.

УШАКО́В Сергей Николаевич (4.9.1893, Кострома ш. — 16.9.1964, Ленинград), химик-органик, технолог, химия фән. д-ры (1938), СССР ФАнең мөхбир әгъзасы (1943), РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1943), РСФСРның атказ. уйлап табучысы (1963). Петроград политехник ин-тын тәмамлаганнан соң (1921), Ленинград технол. ин-тында эшли, проф. (1930 дан), бер үк вакытта, 1931–41 елларда, Пластик массалар фәнни-тикшеренү ин-тында (1938 гә кадәр директор). 1941–44 тә Казан химия-технол. ин-тында пластмассалар каф. мөдире, бер үк вакытта, 1942 дән, СССР Химия сәнәгате министрлыгының целлюлоза продуктлары тармак лаб-ясе (Яшел Үзән ш.) директоры. 1945–49 да СССР Химия сәнәгате министрлыгының эксперименталь з-дын һәм Полимеризацион пластиклар фәнни-тикшеренү ин-тын оештыручы һәм директоры, 1948–53 тә СССР ФАнең Югары молекуляр кушылмалар ин-ты (Ленинград) директоры, 1961–63 тә полимерлар чылбырларында реакцияләр лаб. мөдире. Хезмәтләре фенол-альдегид конденсациясе, винил кушылмалары полимерларын, гади целлюлоза эфирларын өйрәнүгә һәм синтезлауга, туендырылмаган кушылмаларның полимеризациясенә һәм катлаулы полимеризациясенә карый. У. җитәкчелегендә майда эрүчән фенол-формальдегид сумалалары, фенол пресс-порошок, гади целлюлоза эфиры, аның нигезендә эшләнгән капламалар һәм пластиклар, винилацетат һәм аның полимерлары, синтетик камфара, акрил һәм метакрил кислоталары эфирлары һ.б.ның технологияләре эшләнеп җитештерелә башлый. Ш. тарафыннан яңа материаллар («винол» синтетик җепселләре, органик пыяла, «триплекс» кыйпылчыксыз пыяласы, үтә күренмәле эссегә чыдам полимерлар һ.б.), ш.у. коагуляциягә каршы, склерозга каршы тәэсирле полимер кушылмалар, полимер антибиотик формалары (СССР Дәүләт бүләге, 1950) тәкъдим итә. Казанда эшләгән елларда У. винил кушылмалары синтезының оригиналь алымнарын эшли, сугыш кирәк-яраклары җитештерү буенча үзенә бирелгән бурычларны үти (СССР Дәүләт бүләге, 1942). Фәнни эшләнмәләре авиация, автомобиль һәм электр техникасы сәнәгатендә, атом энергетикасында, ракета техникасында, медицинада кулланыла. «Пластические массы» ж-лы (1931–35), «Пластические массы» җыентыгы (1935–41) мөхәррире. Өч Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз, «Почёт Билгесе» орденнары, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсы алтын медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Эфиры целлюлозы и пластические массы на их основе. Л.-М., 1941; Поливиниловый спирт и его производные: В 2 т. М.–Л., 1960; Синтетические полимеры лекарственного назначения. Л., 1962.

Әд.: Сергей Николаевич Ушаков // Материалы к биобиблиогр. учёных СССР. Сер. хим. наук. 1966. Вып. 36.

УШБА́ЕВА Гөлнара Гадил кызы (1941, Казакъстан ССР, Алма-Ата ш.), фармаколог, биол. фән. д-ры (1992). 1970–72 елларда Алма-Ата мед. ин-тында эшли. 1972 дән Казакъстан фәнни-тикшеренү онкология һәм радиология ин-тында. Уйлап табуга патенты бар. Хезмәтләре шешләр химия терапиясенә карый.

УШКО́В Пётр Капитонович (15.1.1840, Вятка губ., Алабуга өязе Бондюг а. — 23.1.1898, Мәскәү; Алабуга өязе Тихие Горы авылында, хәзерге Менделеев шәһәрендә җирләнә), эшмәкәр, Россиядә химия сәнәгатен оештыручыларның берсе. Күренекле эшмәкәрләр Ушковлар нәселеннән; Алабуга өязе Кокшан авылында химия з-дын нигезләгән Капитон Яковлевич Ушковның улы. Алабуга шәһәр уч-щесендә укый. Россиядә, Англия, Германиядә химия сәнәгатен оештыру серләрен өйрәнә. 1868 елда Бондюг авылы янында химия з-дын (хәзер Л.Я.Карпов исем. *химия заводы*) нигезли, анда Россиядә беренчеләрдән булып сәнәгый масштабта күкерт к-тасы җитештерүне оештыра, колчедан калдыкларыннан гидрометаллургия юлы б-н бакыр аерып чыгаруysулын эшли. У. з-дларында купорос мае, тоз һәм азот к-талары сульфаты, хлорлы известь, калий һәм натрий хромпигы, хромлы ачуташ, күкерт к-тасы катнашмалы алюминий окисе, бакыр һәм тимер купоросларын һ.б. җитештерелә. Пр-тиеләрендә завод ихтыяҗлары өчен кирпеч сугалар, күкерт камералары өчен табаклы кургаш прокатлыйлар, чуен эшләнмәләр һ.б.ны җитештерәләр. У. 1883 тә төп капиталы 2,4 млн. сум булган «П.К.Ушков һәм К° химия заводлары ширкәте»н оештыра. Аның з-дларында 1890 еллар башына 1,5 меңнән артык кеше эшли, 2,5 млн. сумлык продукция җитештерелә. Танылган химиклар һәм химик-технологлардан Д.И.Менделеев, А.М.Зайцев, И.И.Канонников һ.б. б-н хезмәттәшлек итә. 1879 да Менделеев (Бондюг з-дында фәнни консультант була) б-н Италиягә, күкерт рудникларына бара. Күренекле химик У.ка төтенсез дары җитештерүне җайга салырга ярдәм итә, аның тәкъдиме б-н Кокшан з-дында балчык әйберләр җитештерү (идән плиткалары, савыт-саба, торбалар, борма көпшәләр һ.б.) үзләштерелә. У. з-длары продукциясе Вена (1873), Филадельфия (1876), Париж (1878), Чикаго (1893) шәһәрләрендә узган бөтендөнья күргәзмәләрендә күрсәтелә. Алабуга шәһәрендә реаль уч-ще, шәһәрдә өч сыйныфлы уч-ще, Алабуга өязе Илнәт авылында мәктәп-чиркәү бинасы, укытучы өчен фатир, укучылар өчен тулай торак, Яңа Кокшан посёлогында Кокшан з-ды эшчеләренең балала-



Казанда Ушкова йорты. Архитекторы К.Л. Мюфке. 1904–07. 20 йөз башы фотосы.

рына мәктәп төзү, Тихие Горы авылында Богоявление чиркәвен үзгәртеп кору өчен акча бирә. *Р.А.Айнетдинов.*

УШКО́ВА ЙОРТЫ́, Казандагы архит-ра истәлеге. Шәһәр үзәгендә Кремль урамында урнашкан. 1907 елда эре эшмәкәр А.К.Ушковның хатыны З.Н.Ушкова өчен арх. К.Л.Мюфке проекты буенча төзелгән. Модерн һәм барокко элементлары кушылган, романтик юнәлештәге эклектика стилендә бизәлгән бай шәһәр йорты. Ике катлы, кирпечтән төзелгән һәм штукатурланган бина, Кремль урамы ягыннан эчке ишегалдына кергәндә чуен капкалы а́ркасы бар. Йортның икенче катындагы сулъяк өлешенә урнашкан кунак һәм торак бүлмәләренә вестибюльдән шәрекъ стилендә эшләнгән үзәк баскыч алып менә. Төп зал ампир стилендә хәл ителгән. Аңа мавритания стилендәге зал һәм тау токымнары асылынып торган мәгарә рәвешендә бизәлгән кышкы бакча кушылып киткән. Төрек стилендәге кунаклар кабул итү залы почмагында челтәр рәшәткәле балкон б-н әйләндереп алынган чыгынты — эркер бар. Эркер түгәрәк тәрәзәләр — люкарналар урнаштырылган уксыман биек гөмбәз б-н төгәлләнгән. Биналарның интерьерлары биек көзгеләр, бронза сыннар, төсле витражлар, кара имәннән әзерләнгән панельләр, мул итеп алтын йөгертелгән әвәләмәләр б-н бизәлгәннәр. Интерьерларның күшылыгы биек аркалы һәм туры почмаклы тәрәзәләр, вазалы аттик парапетлар б-н төгәлләнгән чыгынты-ризалитлы фасадларына туры килеп тора. Фасадларның яссылыгы үсемлек рәвешендәге рельефлы әвәләмәләр б-н бизәлгән. Йорт ху жасы аны 1915 тә Казан губерна земствосына сата. 1919 да бинада губерна китапханәсе, хәзер Татарстан Респ-касының Мил-ли китапханәсе урнаша.

Әд.: Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982. *Х.Г.Надыйрова.*

УШКУ́ЙНИКЛАР (борынгы рус телендә ушкуй — ишкәкле көймә), Новгородның кораллы дружина әгъзалары. У. отрядларын боярлар төньякта яңа җирләр яулау һәм Идел-Чулман буйларындагы халыкларны, сәүдә көймәләрен талау өчен 1320 елларда туплыйлар. Алтын Урда көчсезләнгәч, У., аның терр-ясендә юлбасарлык кылып йөриләр. 1360 та *Жүкәтау* шәһәренә һөҗүм итәләр; чыганаклардан билгеле булганча, алар «...Жүкәтау шәһәренә бәреп кереп бик күп татарларны кырып, байлыкларын талап китәләр...». Алтын Урда ханы *Хызыр* таләбе буенча рус кенәзләре У.ны фаш итәләр, Ур-дада алар җәзалап үтерелә́ләр. Чираттагы һөҗүм 1366 да була. «Шундый ук юлбасар» У. Түбән Новгородны талыйлар һәм Болгар шәһәренә юнәләләр. 1374 тә Болгарда яшәүче-ләр У.дан йолым түләп котылалар. У. 1375 тә Кострома һәм Түбән Новгород шәһәрләрен талап, *Ха жәтархан* шәһәренә барып җитәләр, шунда тар-мар ителә́ләр. 1391 дә Жүкәтау һәм *Кашан* шәһәрләрен басып алалар, Идел буендагы халыкны талап, өйләренә күп та-быш б-н кайталар. У.ның соңгы һөҗүмнәреннән берсе 1409 да була. Новгород посад-нигы Анфал Никитин җитәкчелегендәге У. төркеме 250 каекта Идел-Чулман буйлап



Нурлат шәһәрендә Уяв бәйрәме. 2011.

Болгарга юнәлә. Чулманда У.ның бер өлеше тар-мар ителә. У. яулары Идел һәм Чулман буендагы шәһәрләргә һәм сәүдәгә зур зыян китерә.

Әд.: Смирнов А.П. Волжские булгары. М., 1951; Фахрутдинов Р.Г. Очерки по истории Волжской Булгарии. М., 1984.

И.Р. Вәлиуллин.

УШМА́ елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Вятка елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 30 *км*, бассейнының мәйданы 210,3 *км*^{2}. Мамадыш р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Хәсәнша авылыннан көнбатыштарак, тамагы Мамадыш шәһәре чигендә. Елга башының абс. биеклеге 200 *м*, тамагыныкы — 54 *м*. Ерым һәм сызалар б-н ергаланган калкулыклы тигезлек буйлап ага. Елга үзәне асимметрияле, сулъяк сөзәклеге текәрәк. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 25%. У.ның 1,6 дан 12,7 *км* га кадәр озынлыктагы 15 кушылдыгы бар. Иң зурысы — Сипса елгасы (уң кушылдык). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,5 *км/км*^{2}. Туенуы катнаш, яртысыннан артыгы кар сулары исәбенә туры килә. Бассейнының төрле өлешләрендә җир асты сулары б-н туену модуле 1 дән 10 л/скм^2 га кадәр тәшкил итә. Елганың гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 137 *мм*, ташу агымы катламы 88 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. У. ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,36 *м*^{3}/*с*. Суы гидрокарбонат-сульфат-кальцийлы типта, язын суы йомшак, (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*). Гомуми минераль́ләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. У. бассейнында суының гомуми күләме 0,79 млн. *м*^{3} булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен кулланыла.

УЯ́В (чуаш. «уя» — «үтәү», «тоту»), традицион чуаш милли бәйрәме; яз-җәй айларында әйләп-бәйләп һәм үеннар рәвешендә үткәрелә. У.ны үткәрү вакыты төрле этнографик һәм терр. төркемнәрдә төрлечә билгеләнә. У. язгы кыр эшләре тәмамланганнан соң башлана, җәйге кызу эш вакыты-печән өсте, уракка төшү алдыннан төгәлләнә; еш кына Питрау көненә туры китерелә. У. 3, 5, 7 (так сан булу мәҗбүри) атна дәвам итә.

Гадәттә, көндезге һәм төнге У.лар уздырыла. Төнге У. вакытында яшьләр күбрәк җырлап-биеп күңел ачалар. У.ны үткәрү вакыты һәм төрле тыюлы көннәр авылның өлкән кешеләре тарафыннан билгеләнә.

Көндезге У. өчен 2 (җомга һәм якшәмбе) яки 3 (чәршәмбе, җомга, якшәмбе) көн билгеләнә. У. мул уңыш сорап гыйбадәт кылудан башлана, корбан чалу б-н дәвам итә, чама б-н бер атнадан яңгыр сорап гыйбадәт кылу б-н төгәлләнә. Бу вакыт аралыгында җир эшләре башкару, караңгы төслә́рдәге һәм чуар тукымадан тегелгән киемнәр кию, кер юу, биналарны җыештыру һәм юу тыела. Ш. у. ут кабызу, самавыр кую, кайнар азык ашау рөхсәт ителми. Алдан әзерләгән ризыкны җылытмыйча ашыйлар. Бәйрәм авылның көнчыгышында үткәрелә.

Йола эволюциясендә көндезге У.лар һәм алардагы тыюлар бетерелү һәм төнге У.лар үткәрү вакыты кыскару күзәтелә. Акрынлап йоланың дини ягы, бигрәк тә гыйбадәт кылулар һәм корбан чалулар юкка чыга. Безнең көннәрдә У. еш кына яз-җәй айларында үткәрелә торган башка милли бәйрәмнәр — *Сабан туе* һәм Акатуй б-н тәңгәлләшә. ТРда бәйрәм чуашлар тупланып яшәгән Аксубай, Чүпрәле, Нурлат һ.б. р-ннарда үткәрелә. 1993 елдан ТР Мәдәният министрлыгы һәм Чуаш милли-мәдәни автономиясе ярдәме б-н ТРда елсаен (2006 дан Нурлат р-нында) респ-ка күләмендә «Уяв» чуаш милли бәйрәме уздырыла. Бу бәйрәмдә Татарстаннан, Чуаш Респ-касыннан һәм РФнең башка төбәкләреннән килгән фольклор коллективлары чыгышлар ясый, «Уяв пике» («Чуаш чибәре») конкурсы оештырыла.

Әд.: Чуваши Татарстана: Книга-альбом. Чебоксары, 2006; Гафова Е.А. Уяв // Чувашская энциклопедия. 2011. Т. 4. С. 336.

Р.Р.Батыршин.

Үзе

ҮБИ́ авылы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 20 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Кече Чынлы елгасы буенда. 2010 елда 400 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек; яшелчә киптерү, тире эшкәртү з-длары. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1674 тән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Церковные Убеи, Служилые Убеи исемнәре б-н дә билгеле. 1720 еллардан халкы дәүләт крәстиянәре катлавына керә, 1835–60 елларда Удел ведомствосы карамагында; игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында волость идарәсе, тоткыннар йорты урнаша; 2 чиркәү, мәктәп, земство хастаханәсе, почта бүлекчәсе, 31 сәүдә-сәнәгать һәм 1 ипи сату йорты була; Воздвижение ярминкәсе, дүшәмбе базары эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 929,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Үби волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1859 да — 434, 1897 дә — 636, 1913 тә — 1010, 1920 дә — 944, 1926 да — 924, 1938 дә — 915, 1949 да — 830, 1958 дә — 721, 1970 тә — 653, 1979 да — 644, 1989 да — 435, 2002 дә — 419 кеше.

ҮВӘ́К, к. *Үкәк*.

ҮГЕ́З КУАГЫ́ авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 18 *км* төньяктарак, Лашчы елгасының сул кушылдыгы буенда урнашкан. Даими яшәүчеләр юк. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Иванов (Иванаев) Пүчинкәсе исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстиәннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Ү.К.нда мәчет була. 20 йөз башында, мәчеттән тыш, мәдрәсә, бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 646,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Килдураз волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Буа р-нында. Халык саны: 1782 дә — 67 ир-ат; 1859 да — 274, 1908 дә — 592, 1926 да — 352, 1938 дә — 298, 1949 да — 183, 1958 дә — 140, 1970 тә — 154, 1979 да — 88, 1989 да — 16, 2002 дә — 1 кеше.

ҮГЕ́З-ЕЛГА́ авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 40 *км* төньяктарак, Шушма елгасы буенда. 2010 елда 65 кеше (татарлар) яши. 2010 елда 65 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1678 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Угузиловка, Чеур Илги исемнәре б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстиәннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, су тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 619,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Мәмсә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Юл, 1956 ның 18 июленнән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 37 ир-ат; 1859 да — 181, 1897 дә — 264, 1908 дә — 310, 1920 дә — 348, 1926 да — 303, 1938 дә — 384, 1949 да — 254, 1958 дә — 238, 1970 тә — 203, 1979 да — 147, 1989 да — 89, 2002 дә — 70 кеше.

ҮГИ́ АНА́ ЯФРАГЫ́ (Tussilago), оешма чәчәкләләр семьялыгыннан күпьеллык үлән-чел үсемлекләр ыругы. Бердәнбер гади Ү.а.я. (T.farfara) төре билгеле. Евразия, Төньяк Африка, Төньяк Америкада очрый. Балчыксыл тау битләрендә, кыяларда, буш урыннарда, елга һәм инеш ярларында, тимер юл өемнәрендә үсә. Тамыр системасы озын, горизонталь, ныктармаклы. Сабагы туры, 10–25 *см* биеклектә. Тыгыз урнашкан тәнкәсыман коңгырт яфраклар б-н капланган, очында чәчәк кәрзине. Тамыр яны яфраклары түгәрәк — йөрәксыман, кырыйлары уемтылы-тешчәле, озын саплы. Яфрак пластинкасының асты киезсыман, йомшак («ана»), өсте яшел, шома, салкын («үги ана»). Чәчәкләре вак, алтынсу-сары, ике типта: кырыйдагылары телле, ана чәчәкләр, уртадагылар — көпшәле, ике җенесле, әмма ата чәчәкләр функциясен үтиләр. Җимеше — бүрекчәле озынча кабыргалы орлыкча. Кар сулары күренә башлау б-н, май башына кадәр безнең флорада беренчеләрдән булып чәчәк ата. Җимешләре май–июньдә өлгерә. Чәчәк ботаклары шиңгәннән соң (май ахыры — июнь), фотосинтез процессын башкаручы яшел тамыр яны яфраклары чыга һәм алар җәй ахырына кадәр торалар. Орлыктан һәм вегетатив юл (тамырчалардан) б-н үрчи. Яфракларында сапонин, гликозид, эфир мае, органик к-талар бар. Халык медицинасында яфраклары һәм чәчәк кәрзиннәреннән ясалган төнәтмәсе какырык кубару чарасы буларак кулланыла. Чәчәкләре, яфраклары тир кудыру өчен һәм сулыш юллары ялкынсынганда файдаланылучы җыелмалар составына керә. Яңа өзелгән яфракларын яраларга, чуаннарга ябалар. Баллы, декоратив үсемлек.



Гади үги ана яфрагы.

ҮЗАРА КРЕДИТЛАШҮ КАЗА́Н ҖӘМГЫЯТЬЛӘРЕ́, хосусый эшмәкәрләрнең үзара кредитлашуын гамәлгә ашыручы оешмалар. Беренчел (әйләнештәге) капиталлары әгъзаларының башлангыч кертеме һәм керем чигеремнәре исәбенә, ш.у. процентка алынган банк ссудалары исәбенә туплана. Җәмгыять әгъзаларына кредит бирелә, кертемнәр кабул ителә, агымдагы счётлар ачыла, вексельләр исәпкә алына; вексельләр, кыйммәтле кәгазьләр, милек, товар, товарга бирелгән документлар бәрабәренә ссудалар бирелә. 1913 елда 1 нче җәмгыятьтә (1871–1919) 515 әгъза теркәлә, төп капиталы 1,4 млн. сумнан арта. 2 нче җәмгыять (1912–18) 198 әгъзаны берләштерә, төп капиталы 350 мең сум чамасы тәшкил итә (әйләнештәге капиталы 16 млн. сумнан арта). 1917 елгы Окт. рев-циясеннән соң Ү.к.К.җ. асылда эшчәнлекләрен туктаталар, РСФСР Финанс халык комис-тының 1918 ел 10 октябрь карары б-н рәсми рәвештә гамәлдән чыгарылалар. 3 нче җәмгыять (1923–29) 1926 да 10 мең кешене берләштерә, үз капиталы (активы) 4 млн. сумга җитә (ш.и. 3374 мең сумы — дәүләт займнары облигацияләре). 1924 тә хосусый сәнәгатькә һәм дәүләт сәнәгатенә 159 мең сум, шәхси сәүдә тармагына 338 мең сум ссуда бирелә. РСФСР Финанс халык комис-тының дәүләт финанс учреждениеләренең үзара кредитлашу җәмгыятьләренә матди ярдәмен тыю турындагы карары кабул ителгәннән соң (1928 ел, 16 май) Казан җәмгыятьләре эшчәнлекләрен туктатырга мәҗбүр булалар.

В.А.Шагалов, Р.В.Шәйдуллин.

ҮЗӘ́К посёлогы, Теләче р-нында, Теләче авылыннан 5 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Мишә елгасы буенда. 2010 елда 947 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 84%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1919–23 елларда нигез салына, 1931 дән Сталин исем. совхоз посёлогы, 1957 нең 24 декабреннән хәзерге исемен йөртә. Оешкан көненнән ТАССРның Лаеш кантоны Теләче волостенда, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Саба, 1935 нең 10 февраленнән — Теләче, 1959 ның 12 октябреннән — Саба, 1991 нең 4 октябреннән Теләче р-нында. Халык саны: 1958 дә — 744, 1970 тә — 1039, 1979 да — 959, 1989 да — 948, 2002 дә — 988 кеше.

«ҮЗӘ́К БАСМАХАНӘ́», к. *Домбровский Б.Л. басмаханәсе*.

ҮЗӘ́К МӨСЕЛМА́Н КОМИССАРИАТЫ́, к. *Эчке Россия мөселманнары эшләре комиссариаты*.

ҮЗӘК МӨСЕЛМА́Н ХӘРБИ́ КОЛЛЕ́ГИЯСЕ, 1918 елның гыйнварында Петроградта оештырыла. РСФСРның Милләтләр эшләре буенча халык комис-ты карамагындагы Үзәк мөселман комис-тының хәрби бүлеге буларак барлыкка килә. Исеме 28 апрельдән — хәрби коллегия, 31 майдан — Ү.м.х.к., 20 ноябрьдән РСФСРның хәрби эшләр буенча халык комис-ты итеп үзгәртелә. 1918 нең 22 октябреннән Ү.м.х.к. Мәскәүдә, 1919 ның апреленән Казанда эшли; гаскәри берәмлекләр оештыру, хәрби бүлек (пехота һәм кавалерия), артиллерия, инженер, интендант, санитар, оештыру-агитация, мобилизация бүлекләре эшли. Рәисләре — М.М.Вахитов (1918 нең 6 августына кадәр), М.Х.Солтангалиев. Әгъзалары: Й.И.Ибраһимов, М.Г.Алиев, М.Г.Конов, И.Әбдрәшитов, А.К.Маликов (1918 нең 30 маена кадәр); Н.Г.Вахитов, С.Ловчицкий, А.К.Маликов, А.Х.Алмаев, К.Л.Якубов (1918 нең 31 маеннан). Мөселманнар күпчелекне тәшкил иткән төбәкләрдә милли гаскәри берәмлекләр оештыру эшен җитәкли, халык арасында сәяси-агарту эшләре алып бара. Ү.м.х.к. эшчәнлеген 1918 нең гыйнвар-сентябрендә Казан, Самара, Әстерхан Пермь һәм Бөгелмәдә оештырылган мөселман комис-тлары каршындагы хәрби бүлекләр аша гамәлгә ашыра. 1918 нең август башында коллегия Кызыл Армиянең мөселман частьләре б-н якыннан торып идарә итү өчен Казанга килә; Казан өчен сугышта Ү.м.х.к. рәисе М.М.Вахитов акгвардиячеләр тарафыннан кулга алына һәм атып үтерелә, коллегия хәрби җитәкчесе С.Ловчицкий КОМУЧчылар ягына күчә. 1918 нең гыйнварыннан 1919 ның июленә кадәр коллегия җитәкчелегендә Казанда Идел буе татар укчыларының 1 нче һәм 2 нче аерым бригадалары; 1 нче мөселман социалистик полкы һәм 1 нче Казан совет мөселман укчыларының запас полкы; Әстерханда К. Туйбактин исем. Мөселман полкы һәм 8 аерым атлылар эскадроны; Саратов һәм Самара губерналарында ике мөселман укчылар полкы; Пермьдә 21 нче мөселман укчылары полкы; Мәскәүдә, Уфада, Оренбургта татар-башкорт батальоннары һ.б. оештырыла. 1919 да Казанда Икенче мөселман совет укчылары командирлары курслары һәм шәркый халыклар кавалерия курслары ачыла. «*Кызыл Армия*» г-тасын нәшер итә. 1920 елның 1 октябрендә эшчәнлеге туктатыла, аның урынына Респ-ка Революцион-хәрби Советы Сәяси идарәсенең Шәрекъ бүлеге һәм Бөтенроссия баш штабы оештыру идарәсенең шәрекъ бүлеге оештырыла.

Әд.: Гиззатуллин И.Г. Мусульманские военные организации (1917–1921 гг.). К., 2002; Гражданская война и военная интервенция в СССР: Энцикл. М., 1987.

Л.М.Айнетдинова.

ҮЗӘК СТАДИО́Н, Казанда. Файдаланугa 1960 елның 25 июнендә тапшырыла (проект авторлары — П.А.Саначин, А.А.Сориус, Г.И.Солдатов, О.И.Берим). 1997 гә кадәр В.И.Ульянов-Ленин исем. Үзәк стадион, 2008 дән «Үзәк стадион» спорт комплексы — «Казан «Ак Бүре» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе» балаларга өстәмә белем бирү муниципаль автономияле учреждениесенең аерымланган бүлекчәсе. 1997 дә футбол кыры чирәме яңартыла һәм аны җылыту системасы булдырыла (2005 тә реконструкцияләнә). Футбол кырын (110×73 *м*), Motomatik (Швейцария) үлән капламын; 4 трибунаны (30 мең урынлык), ш.и. төньяк трибунаның 6 нчы (кунаклар өчен) секторын (1321 кеше), вакытлы матбугат (12 кеше), дәрәҗәле кунаклар (133 кеше) ложаларын, телевидение позицияләрен (13 кешегә кадәр), комментатор урыннарын (2 кеше); йөгерү юлын (400 *м*); төсле электрон-мәгълүмат видеотаблосын, күзәтү камераларын (13 тышкы, 18 эчке); залларны: 1 нче — гимнастика залын (аэробика, шейпинг, брейкданс, спорт һәм нәфис гимнастика) һәм 2 нче — уен залын (волейбол, баскетбол, өстәл теннисы); ябык футбол-җиңел атлетика манежын (2007 дә ачыла; 178,0×91,24 *м*, биеклеге 24 *м*, 1100 кешегә), Fieldturf-Tarkett (Франция) фирмасының Prestige XM (Evolution) ясалма өслекле футбол кырын (105×68 *м*), йөгерү юлларын (7 — 100 метрлы, 5 — 400 метрлы), сикерү һәм ядрә ату өчен секторларны, 4 чишенү-киенү бүлмәсен (һәрберсе 24 кешегә) үз эченә ала. Стадионда җиңел атлетика, волейбол, баскетбол, футбол (Премьер-лига командалары арасында һәм Россия Кубогына матчлар, УЕФА Кубогына Европа турнирларында катнашучылар, чемпионнар лигалары матчлары) буенча бөтенроссия һәм халыкара дәрәҗәдәге спорт чаралары, Казанның балалар-яшүсмерләр спорт мәктәпләрендә укучыларның тренировкалары һәм ярышлары уздырыла.

ҮЗӘК ШӘРЕ́КЪ КИТАПХАНӘСЕ́, Казанда. 1913 елда Г.*Баруди* җәмәгать Шәрекъ китапханәсен оештырырга омтылыш ясый, әмма хөкүмәт моңа рөхсәт бирми. 1920 дә ул үзенең китап тупламасын Үзәк губерна китапханәсенә тапшыра (1917 гә кадәр Казанның шәһәр җәмәгать китапханәсе). 1906 да оешкан «Көтебханәи исламия» буларак билгеле мөселманнар китапханәсе ф-лы 1919 да 5 нче шәһәр китапханәсе итеп үзгәртелә; 1920 дә Үзәк мөселман китапханәсе исемен ала, 1921 нең октябреннән — Ү.ш.к., 1922 нең 1 маеннан М.Вахитов исем. китапханә. Соңрак аның каршында бай материалларга ия булган музей оештырыла, 1923 нең апреленән — Г.Тукай исем. Үзәк балалар китапханәсе (аның ачылуы шагыйрьнең вафатына 10 ел тулуга туры килә). Ү.ш.к. фондының нигезен, Г.Баруди китапханәсеннән тыш (1920), профессорлар Н.Ф.Катанов һәм В.Ф.Минорский (1922) җыелмалары, китап сатучы бертуган Кәримовлар складындагы китаплар (1924) тәшкил итә. 1925 нең маена китапханә фондында 20 телдә 21303 исемдәге (40 мең том) китап исәпләнә, алар арасында күпчелекне гарәп графикалы басма һәм кулъязма китаплар (ш.и. кыйммәтле әсәрләр һәм сирәк басмалар) тәшкил итә; татар, төрек, гарәп, фарсы һ.б. телдәге даими матбугат өстенлек итә.

1925 кә китапханәдә 10 бүлек була: төрки-татар, гарәп-фарсы, рус-европа, шәрекъне өйрәнү (белгечләр өчен махсус кабинет эшли), балалар китапханәсе, архив, татар китаплары коллекторы, татар китапларын өйгә бирү; газеталар, уку залы. Ү.ш.к. Кәримовларның китап нәшер итү һәм сәүдә комплексының беренче катында урнаша. 1924 тә китапханә бинаның икенче катын да били, анда 150 урынга уку залы ачыла.

Китапханә хезмәткәрләре һәм анда йөрүчеләр — татар мәдәниятенең күренекле вәкилләре, Казан, Мәскәү, Петроградның атаклы шәркыятьче галимнәре һәм сәнгатьне өйрәнүчеләр (В.М.Борисов, Б.Ф.Адлер, П.М.Дульский һ.б.). Китапханә б-н Ә.Максуди, 1925–30 да Вафа Борнаш җитәкчелек итә. 1923–24 тә Г.Тукай исем. Үзәк балалар китапханәсендә китапханәче булып драматург М.Фәйзи эшли; анда төрле чараларга багышланган күргәзмәләр оештырыла. 1927 дә Ү.ш.к. Татар мәдәният йортына бирелә. 1929–30 да аның фондлары шәһәрнең эре китапханәләре арасында таратыла, 1933–34 тә Казан ун-ты һәм Татарстан респ-касының Фәнни китапханәсен берләштерү нәтиҗәсендә Ү.ш.к. фондларының күп өлеше Казан ун-ты китапханәсендә урын ала.

Әд.: Бурнаш В. 5 ел эчендә Мулланур Вахидов исемендәге үзәк шәрык көтебханә-музее // Мәгариф. 1925. № 6–7; Выставка культуры народов Востока: Путеводитель по выставке. К., 1920.

Н.Г.Гәрәева.

ҮЗӘКЛӘШТЕРЕЛГӘН КИТАПХАНӘЛӘ́Р СИСТЕ́МАСЫ (ҮКС), бер адм. райондагы массакүләм китапханәләрне гомуми-оештыру-адм. җитәкчелек һәм хезмәткәрләр штаты, бердәм китап фонды, әдәбиятны үзәкләштереп туплау, белешмә-библиография эшен оештыру б-н бердәм челтәргә берләштерүче китапханә учреждениесе. 1976 елда Казан шәһәре мәдәният бүлегенең барлык 38 китапханәсе (шәһәр районнары) Үзәк шәһәр китапханәсе җирлегенә берләштерелә. Китапханәләр барлык яшь категорияләреннән дәгъвакучыларга да хезмәт күрсәтә. 1977 дән 2 система: олы яшьтәге укучыларга хезмәт күючы ҮКС һәм Үзәкләштерелгән шәһәр балалар китапханәсе б-н 23 ф-л китапханәдән торган Үзәкләштерелгән балалар китапханәсе системасы (Ү.б.к.с.) эшли башлый. 2010 да Ү.к.с. һәм Ү.б.к.с. Казанның барлык адм.-терр. районнарына урнашкан муниципаль китапханәләрнең (2 Үзәкләштерелгән китапханә һәм 48 ф-л китапханә) бердәм системасына берләштерелә. 2011 гә шәһәрнең Ү.к.с. бердәм китапханә фондында 2457794 саклау берәмлеге исәпләнә.

ҮЗБӘ́К авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 18 *км* төньяктарак, Зәй-Каратай елгасы буенда. 2010 елда 38 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1925 тә Зәй-Каратай авылыннан күченүчеләр нигез сала. Оешкан көненнән ТАССРның Бөгелмә кантоны Габдрахман волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Әлмәт, 1935 нең 10 февраленнән — Яңа Писмән, 1955 нең 18 августыннан Лениногорск р-нында. Халык саны: 1926 да — 387, 1938 дә — 406, 1949 да — 430, 1958 дә — 468, 1970 тә — 282, 1979 да — 213, 1989 да — 53, 2002 дә — 42 кеше.

ҮЗБӘ́К ХАН (Мөхәммәд Солтан) (? — 1342), Алтын Урда ханы (1313 елдан). Мәнгу Тимер ханның оныгы. Хакимияткә, Тукта

хан үлгәннән соң, тәхет түнтәрелеше нәтиҗәсендә килә. Ү.х. идарә иткән вакытта Алтын Урда үз ку әтенең иң югары дәрәҗәсенә ирешә. Илдә үзәкләштерү, акча берәмлеген ныгыту, салым системасын тәртипкә салу сәясәтен уздыра. Исламны дәүләт дине буларак кабул итә. Аның заманында Алтын Урда башкаласы — Сарай әл-Җәдид шәһәренә (1330 еллар тирәсе) нигез салына. Актив тышкы сәясәт алып бара. 1317 дә бөек Владимир кенәзлегенә Мәскәү кенәзе Юрий Данилович ны тәкъдим итә, аны үзенең сеңлесе Кончакка (христиан диненә күчкәч — Агафья) өйләндерә һәм аңа 13 йөз ахырында — 14 йөз башында Алтын Урда осталары тарафыннан ясалган, соңрак русларның бөек кенәзләре һәм патшаларының хакимият билгесенә әверелгән, Василий III заманында туган риваять буенча Византия императоры Константин тарафыннан Киев кенәзе Владимир Мономахка бүләк ителгән дип саналган «Мономах бүреге»н тапшыра. 1327 дә Мәскәү кенәзе Иван I Калита гаскәре ярдәмендә Тверь шәһәрендә Урдага каршы кабынган күтәрелешне бастыра. Һулагуларның Кавказ аръягындагы җирләренә яулар оештыра (1319, 1335). Ү.х. вакытында Алтын Урданың Европа илләре, Византия, Һиндстан һәм мәмлүк ләр Мисыры б-н илчелек мөнәсәбәтләре активлаша.

Әд.: Греков Б.Д., Якубовский А.Ю. Золотая Орда и её падение. М.-Л., 1950; Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; Фёдоров-Давыдов Г.А. Общественный строй Золотой Орды. М., 1973.

ҮЗБӘКСТА́Н РЕСПУ́БЛИКАСЫ, Урта Азиянең үзәк өлешендә урнашкан. Мәйданы — 447,4 мең *км*². Башкаласы — Ташкент шәһәре. Халкы — 32345000 кеше (2017). Татарлар саны: 1989 да — 467,8 мең, 2002 дә — 324 мең, 2012 дә — 211 мең, 2016 да —195 мең кеше. Алар, башлыча, шәһәрләрдә (Ташкент, Алмалык, Әндиҗан, Бохара, Гөлстан, Сәмәрканд һ.б.) яшиләр. Татарлар һәм Татарстанны Үзбәкстан б-н күптәнге тарихи, сәяси, икътисади, фәнни, мәдәни һ.б. элемтәләр бәйли. 920–21 дә Болгар бәге *Габдулла би не Башту Бохарага һәм Багдадка Алмыш илтәбәр илчелеген* җитәкли. Татар сәүдәгәрләре һәм дипломатлары (Ш.*Арсланов*, М.*Бикчурин*, Ә.*Каргалый*, Б.Тайшев, М.*Йосыпов*) Россиянең төбәк идарәчелеге (Коканд, Хива ханлыгы, Бохара әмирлеге) б-н сәяси һәм сәүдә бәйләнешләрен җайлауда мөһим роль уйный. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында күп кенә татар егетләре, ш.и. булачак таныклан илаһият галимнәре һәм дин эшлеклеләре Габденнасыйр *Курсави*, Габделхаликъ *Курсави*, Ш.*Мәр җани*, *Утыз Имәни*, М.*Камалов*, *Мөхсин аш-Шаши*, *Фәхретдин Ибраһим бине Ху җаш*, *Хәмзә әл-Бирәзәви*, М.*Хөсәенов* һ.б. Бохара, Сәмәрканд һ.б. Урта Азия шәһәрләре мәдрәсәләрендә дин белеме ала. Россия Төркестанны яулавының башлангыч чорында (1865) монда 5 меңләп татар яши. 1860–70 еллардан Урта Азиягә татарлар күпләп күченә башлый. Татар җәмгыятен үстермәс һәм аның икътисади йогынтысын кимәтү өчен, 1886 да патша хөкүмәте татарларга Төркестан краенда күчемсез милек сатып алуны тыя. Идел-Урал төбәгеннән күченүчеләрнең күбесе Үзбәкстан терр-ясенә совет чорында килеп төпләнә. Миграциянең төп сәбәпләре: Татарстандагы *ачлык* (1921–22), культура рев-циясе һәм 1920–30 еллардагы крәстиян хуҗалыкларын күмәкләштерү, 1944 тә Кырым татарларын туган җирләреннән сөрү, 1950–80 елларда яңа сәнәгать объектлары төзелү. Татарлар үзбәк милли мәдәниятен формалаштыру һәм үстерүгә зур өлеш кертә. Беренче үзбәк басма китаплары Казан ун-ты басмаханәсендә нәшер ителә. Ш.*Ибраһимов* «Мең дә бер кичә» китабын үзбәк теленә тәрҗемә итә, ул — үзбәк телендәге беренче «1871 елгы календарь» басма китабы авторы. 1880 елларда Ш.Б.*Бикколов* Ташкент һәм Хивада беренче «Михбосма» үзбәк басмаханәләрен оештыруда катнаша. 19 йөз ахырыннан *җәдитчелек* идеологиясе таралу б-н бәйле рәвештә татарларның сартларга (үзбәкләр) һ.б. Урта Азия халыкларына мәдәни йогынтысы көчәя. Хәзерге Ү.Р. терр-ясендә татар җәдитчеләре җирле халык һәм татар балалары өчен дистәләгән мәктәп ача. Вакытлы матбугат эшен (к. *«Асия»*, *«Киңәш»*, *«Олуғъ Төркестан»*, *«Шураи Ислам»*), беренче җәмәгать уку биналарын оештыруда шактый зур эш башкарыла. Күп кенә җирле басмаханәләрдә хәреф җыючылар һәм китап басучылар татарлар була. Рев-циягә кадәрге татар вакытлы матбугатында (*«Вакыт»* г-тасы, *«Шура»* ж-лы) Урта Азиядә яшәүче төрки халыкларның мөһим проблемаларын күтәрү ин-тының татар теле курсларында (1999 да ябыла) 38 кеше укый. Хәзерге вакытта Ү.Р. башкаласының гомуми белем бирү мәктәпләрендә татар теле өйрәнелми. 1990 да Ташкентта Татар иҗтимагый мәдәни-агарту үзәге оештырыла. Татар милли үзәкләре ш.у. Җиззах, Бохара, Нәваи, Янгиюл, Алмалык; татар-башкорт үзәге — Карши, башкорт-татар мәдәни үзәкләре Сәмәрканд һәм Зәрәфшан шәһәрләрендә эшли. Бу иҗтимагый берләшмәләр Үзбәкстандагы татар диаспорасын берләштерүгә, татар телен һәм мәдәниятен саклап калуга зур өлеш кертә. Алар иҗат кичәләре, конкурслар, фестивальләр, татар рәссамнары әсәрләре буенча күргәзмәләр оештыра. Аларның ярдәме б-н «Яшьлек» татар-башкорт фольклор ансамбле, «Дуслык» татар эстрада театры, «Якташ», «Ләйсән», «Безнең мирас» үзешчән ансамбльләре (Ташкент), «Шатлык» (Сәмәрканд) һәм «Ләйсән» (Алмалык) фольклор ансамбльләре эшли. 1992 дән ТР-ның Ү.Р.ндагы даими вәкиллеге үзенең эшчәнлеген алып бара. 1994 тә ТР һәм Ү.Р. Мәдәният министрлыклары арасында мәдәният өлкәсендә хезмәттәшлек турында килешүгә кул куела. 1994 тән Ү.Р. телерадиокомпаниясендә татар-башкорт редакциясе эшләп килә, респ-ка татарлары өчен «Безнең мирас» тапшыруы чыга. Үзбәкстанда Казан «Татарстан авазы» радиотапшыруларын тыңларга мөмкин. Ташкентта уздырылган халыкара фестивальләрдә Татар академия театры (1993), Казан консерваториясенең татар музыка оркестры (2001) катнаша. 2001 дә Казанда Г.*Нәваиның* тууына 560 ел тулуга багышланган чаралар уздырыла. Архитектор М.С.*Булатов*, нәкышьче Ч.Г.*Әхмәров*, нәкышьче, сынчы, *нәлмиләл»*, *«Мәгариф атнасы»*, *«Очкын»* ж-ллары чыга. Үзбәкстан язучылар берлегендә берничә дистә язучыны берләштергән татар секциясе эшли. 1930–1940 елларның 2 нче яртысында татар мәктәпләре, театрлар, газета-журналлар һ.б. мәдәни учреждениеләрнең күбесе ябыла. Сугыштан соңгы чорда Татарстан б-н Үзбәкстан арасында традицион мәдәни һәм ху җалык-икътисади бәйләнешләр тагын да үсә. Татарлар Үзбәкстан ССРның иҗат оешмалары, фән һәм мәгариф учреждениеләре эшчәнлегендә күренекле роль уйныйлар, респ-ка сәнәгатен үстерүдә актив катнашалар. Күп кенә татар дин эшлеклеләре (Г.*Галиулла*, Г.Г.*Исхаков*, Т.*Таҗетдин* һ.б.) мөселман уку йортларында (Бохарада «Мир-Араб» мәдрәсәсе, Ташкентта Ислам ин-ты) дин белеме ала. 1980 елларның 2 нче яртысыннан Үзбәкстаннан татарлар күпләп китә башлый, бу респ-када яшәүче татарлар (ш.и. гуманитар һәм техник интеллигенция) санының кимүенә китерә. 1989 ның августында Үзбәкстан ССРның Халык мәгарифе министрлыгы 10 яки аннан да күбрәк татар укучысы булган мәктәпләрдә мәҗбүри рәвештә татар телен өйрәнү буенча факультатив сыйныфлар ачу турында әмер чыгара. 1990 еллар башында Ү.Р.ның 37 мәктәбендә татар теле факультатив дәресләрдә укытыла. Шул ук чорда Казан пед. ин-тын да туган телне укытырга хокуклы 20 укытучы үз белемен күтәрә. 1998 дә Ташкентта Респ-ка укытучылар белемен күтәрү ин-тының татар теле курсларында (1999 да ябыла) 38 кеше укый. Хәзерге вакытта Ү.Р. башкаласының гомуми белем бирү мәктәпләрендә татар теле өйрәнелми. 1990 да Ташкентта Татар иҗтимагый мәдәни-агарту үзәге оештырыла. Татар милли үзәкләре ш.у. Җиззах, Бохара, Нәваи, Янгиюл, Алмалык; татар-башкорт үзәге — Карши, башкорт-татар мәдәни үзәкләре Сәмәрканд һәм Зәрәфшан шәһәрләрендә эшли. Бу иҗтимагый берләшмәләр Үзбәкстандагы татар диаспорасын берләштерүгә, татар телен һәм мәдәниятен саклап калуга зур өлеш кертә. Алар иҗат кичәләре, конкурслар, фестивальләр, татар рәссамнары әсәрләре буенча күргәзмәләр оештыра. Аларның ярдәме б-н «Яшьлек» татар-башкорт фольклор ансамбле, «Дуслык» татар эстрада театры, «Якташ», «Ләйсән», «Безнең мирас» үзешчән ансамбльләре (Ташкент), «Шатлык» (Сәмәрканд) һәм «Ләйсән» (Алмалык) фольклор ансамбльләре эшли. 1992 дән ТР-ның Ү.Р.ндагы даими вәкиллеге үзенең эшчәнлеген алып бара. 1994 тә ТР һәм Ү.Р. Мәдәният министрлыклары арасында мәдәният өлкәсендә хезмәттәшлек турында килешүгә кул куела. 1994 тән Ү.Р. телерадиокомпаниясендә татар-башкорт редакциясе эшләп килә, респ-ка татарлары өчен «Безнең мирас» тапшыруы чыга. Үзбәкстанда Казан «Татарстан авазы» радиотапшыруларын тыңларга мөмкин. Ташкентта уздырылган халыкара фестивальләрдә Татар академия театры (1993), Казан консерваториясенең татар музыка оркестры (2001) катнаша. 2001 дә Казанда Г.*Нәваиның* тууына 560 ел тулуга багышланган чаралар уздырыла. Архитектор М.С.*Булатов*, нәкышьче Ч.Г.*Әхмәров*, нәкышьче, сынчы,

график Б.И.*Урманче*, сынчылар З.Р.*Басыйров* һәм М.М.*Гасыймов*, кинодраматурглар Г.Ә.*Агишев* һәм Р.Г.*Хөснетдинова*, театр режиссёрлары И.Г.Илялов (к. *Ияловлар*) һәм Г.Г.*Исмәгыйлев*, кинорежиссёр Р.И.*Батыров*, язучылар Җ.Х.*Ильясов*, А.Мохтар, З.Х.*Сәгыйдә*, З.Р.*Фәтхуллин*, театр рәссамы А.А.Назыйров, җырчы Ә.Х.*Бәхтизина*, балет артисты Г.Б.*Измайлова*, пианист Ф.Х.Фәйзи, композиторлар Р.Ж.*Вилданов* һәм Э.Ш.*Салихов*, актёрлар Х.Г.*Әбҗәлилов*, З.С.*Садриева*, Һ.Һ.*Солтанов*, шагыйрьләр Г.Л.*Габид*, З.Ш.*Ярмәки*, журналистлар Җ.Г.*Байбулатов*, М.Ф.*Хәсәнов*, Г.Б.*Ашмасов*, М.Ю.*Борындыков*, Ш.З.*Мөхәммәдъяров*, И.К.*Неометов*, М.Г.*Яһудин*, Олимпия уеннары чемпионнары Э.Ф.*Сәгәди*, Ш.К.*Сериков*, К.М.*Фәткуллин*ның тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге Ү.Р. б-н бәйле. Үзбәкстанда фән үсешенә агроном С.Г.*Яһудина*, биологлар Н.И.*Акҗегетова*, Р.Н.*Әхмәров*, И.Җ.*Әхмәтов*, З.У.*Бикмөхәммәтова*, Р.У.*Булханов*, М.Х.*Гайнетдинов*, А.К.*Сәгыйтов*, биохимик Н.К.*Әбүбәкеров*, зоолог С.З.*Җәлилов*, сәнгать белгечләре Р.Һ.*Такташ* һәм Д.Ә.*Фәхретдинова*, тарихчылар Р.Г.Мөэминова, Р.Г.*Нуруллин*, Ф.З.*Сәләхетдинов*, Б.М.*Сәлиев*, Т.Г.*Туктамәтов*, әдәбият белгече Ж.Д.*Алмазов*, табиблар Ф.Ф.*Әмиров*, И.М.*Байбиков*, Э.М.*Байбикова*, Р.А.*Капкаев*, Ә.Г.*Курмуков*, В.З.*Мәзгутов*, психолог М.Г.*Дәүләтшин*, механика өлкәсендәге галимнәр Ә.Г.Азизов, М.С.*Ганиев*, Н.А.Коламәтов, машиналар гыйлеме белгече Р.З.*Бурнашев*, текстиль чималын эшкәртү технологиясе гыйлеме белгече И.К.*Хафизов*, физиклар Б.С.*Мәҗитов*, Ф.Х.*Төхфәтуллин*, М.Г.*Хәлиуллин*, филологлар Г.С.*Әмиров*, Г.Г.*Сәгъди*, философ Ж.М.*Гыйләҗетдинов*, химиклар А.К.Ташмөхәммәдова, Ә.Х.*Тимбиков*, икътисадчылар Р.И.*Алтынбаев*, Ф.К.*Каюмов*, хокук белгечләре Р.Г.*Тузмөхәммәтов* һәм Ш.З.*Уразаев*, тел галиме Б.З.*Халидовның* тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге Ү.Р. б-н бәйле. ТРда күпсанлы үзбәк диаспорасы (1959 да — 512, 1970 тә — 502, 1979 да — 1165, 1989 да — 2692, 2002 дә — 4842 кеше) барлыкка килә, Ү.Р.ннан күпләп эшче көчләр килү дәвам итә. 1998 дә — Казанда үзбәк милли-мәдәни автономиясе оештырыла, 2000 дә ТР Милли-мәдәни оешмалары ассоциациясенең якшәмбе мәктәбе каршында үзбәк сыйныфы ачыла. 2001 дә ТРда Үзбәк милли-мәдәни автономиясе теркәлә, ул милли-мәдәни яшәешне оештыру, үзбәк җәмгыяте әгъзаларына хокукый һәм матди ярдәм итү б-н шөгыльләнә. Аның катнашында 2005 тә Казанда Ү.Р.ның халык артисты Ю.Усманова, 2006 да «Ялла» вокаль-инструменталь ансамбле гастрольләре булып уза; ел саен Нәүрүз бәйрәм ителә, «Шәрекъ ашлары» үзбәк кафесы, «Ән-ди жан» ансамбле, «Шәрекъ», «Үзбәкстан» сәүдә йортлары эшли.

А.И.Ногманов, Э.В.Габдрәхимова.

ҮКӘК (Үвәк), урта гасырлардагы (13–14 йөзләр) Алтын Урда шәһәре. Хәзерге Саратов шәһәре тирәсендә, Үвәк елгасы тамагында урнашкан. 14 йөз башында мөһим сәүдә һәм сәяси үзәк була. Ү. шактый зур мәйдан били, шәһәрдә кирпечтән төзелгән биналар, таш түшәлгән урамнар, су б-н тәэмин итү һәм канализация системасы, һөнәрчелек остаханәләре, акча сугу йорты булуы мәгълүм. 1395 елда Урта Азия идарәчесе *Аксак Тимер* гаскәрләре тарафыннан җимерелә һәм таркалу хәленә килә. Ү. урынында йортлар, һөнәрчелек остаханәләре харәбәләре, савыт-саба кисәкләре, тәңкәләр, 14 йөзгә караган төрбәләр булган аксояклар зираты табыла. Х.М.Френ, П.С.Савельев, Г.С.Саблуков, П.А. Пономарёв, Ф.В. Баллод һ.б. тарафыннан өйрәнелә.

Әд.: Недашковский Л.Ф. Золотоордынский город Укек и его округа. М., 2000; История татар с древнейших времён. Т. 3: Улус Джучи (Золотая Орда). XIII — середина XV в. К., 2009.

ҮЛӘКСӘ АКЧАРЛАКЛАРЫ (Stercorarius), үләксә акчарлаклары семьялыгыннан кошлар ыругы. 3 төре билгеле, Евразия, Төньяк Америкада таралганнар. ТР терр-ясендә 2 төре бар: кыска койрыклы үләксә акчарлагы (S. parasiticus) һәм уртача зурлыктагы үләксә акчарлагы (P. pomarinus). Идел елгасының һәм Куйбышев сусаклагычының яр буе зоналарында очрый. Сирәк очып килүче төр. Гәүдәсенең озынлыгы 35 *см* га кадәр, авырлыгы 380–960 *г*. Карасу төстә. Канатлары озын, кыска койрыклы үләксә акчарлагының уртадагы парлы койрык каурыйлары очлы һәм чагыштырмача кыска, уртача зурлыктагы үләксә акчарлагы очында киңәюче, түгәрәкләнгән һәм койрык өслегендә вертикаль рәвештә күтәрелеп торучы үзәк койрык каурыйлары б-н аерыла. Муены шактый кыска. Томшыгы көчле, очында ыргаксыман. Тиз, җи ңел, оста очалар. Яхшы йөзәләр. Сазлыклы, уйсулыклы урынларда аерым парлар булып оя коралар. Оясы — җиргә уелган кечкенә генә чокыр рәвешендә. Кара таплы ике коңгырт яки яшькелт йомырка сала. Балык, умырткасызлар, кимерүчеләр, җиләкләр б-н тукланалар, башка кошларның ояларын туздыралар.

ҮЛӘКСӘАША́Р КОҢГЫЗЛА́Р (Silphidae), төрле азык б-н тукланучылар асотрядыннан коңгызлар семьялыгы. 1,5 мең гә якын төре, Россиянең Европа өлешендә якынча 50 төр билгеле. Киң таралганнар. Гәүдәсенең озынлыгы 6 *мм* дан 40 *мм* га кадәр; мыекчыклары чукмарсыман яки очына таба акрын гына калыная бара, барлык аяклары биш буынлы. Личинкалары яссы, хәрәкәтчел, тышкы кыяфәте буенча кыргаякларны хәтерләтә. Коңгызлар һәм личинкалар үләксәләр, ара-тирә тирес, гөмбә, кайвакыт бакча һәм урманнарга зыян китерүче гусеницалар б-н туена; яшелчә культураларын зарарлаучы үсемлекләр б-н туенучылар да очрый. Татарстан терр-ясендә аеруча Герман үләксәашары (Necrophorus germanicus L.), эзләнүче үләксәашар (N. Vestigaror Hersch), кызыл күкрәкле үләксәашар (Oeceoptoma thoracica L.), дүрт ноктаны үләксәашар (Xylodrepa quadripunctata L.) таралган.

ҮЛӘМӘ елгасы, Идел алдында, Зөя елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 72 *км*. Бассейнының мәйданы 890,9 *км*². Идел буе калкулыгыннан ага. Елга башы Тәтеш р-ны Красные Дворики (даими яшәүчеләр юк) авылы читендә, тамагы Апас р-ны Шонгаты авылыннан 1 *км* төньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 170 *м*, тамагыныкы — 57 *м*. Су җыелу терр-ясе тирән ерымнар, киң чокырлар һәм сызалар б-н ергаланган. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 10%. Үзәне асимметрияле, уңъяк сөзәкләкләре текәрәк һәм күтәренке. Елга юлы бормалы, киң түгел (7–8 *м*). Ү.нең 1,6 дан 22,6 *км* га кадәр озынлыктагы 29 кушылдыгы бар. Аеруча зурлары — Кече Үләмә (17,7 *км*), Шонгаты (9,4 *км*) — уң; Табар (22,6 *км*), Тормы (19,8 *км*), Бисәр (9,5 *км*) — сул кушылдыклар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,38 *км/км*². Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир ас-ты сулары б-н туену модуле 0,5–3 *л/с·км*².



Үләмә елгасы.

Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана; 1945–92 елларда Нармонка авылы янындагы су үлчәгеч постта өйрәнелә, 1992 дән Тәтеш р-ны Алабирде авылы янындагы пост эшли. Ел фасыллары буенча агымның таралышы бертигез түгел. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 123–147 *мм*, ташу агымы катламы 50–130 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Кыш ахырына бозның калынлыгы 70 *см* га җитә. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,39 $м^3/с$. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. Ү. бассейнында суының гомуми күләме 6,2 млн. $м^3$ булган 9 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла. ТРның табигать истәлеге (1978). Ү. елгасы үзәнендә *Гран-Тау* ландшафтлы табигать истәлеге урнашкан.

ҮЛӘТ БӨРКЕТЕ́ (Aquila heliaca), карчыга кошлар семьялыгындагы кош. Евразия һәм Төньяк-Көнбатыш Африкада очрый. Татарстан терр-ясендә якынча 30–40 пар оялый; барлык районнарда, ешрак Кама аръягында күренә. Ачык киңлекләр янындагы урманнарда яши. Еш кына гүр курганнарында уты-



ра. Күчмә кош. Апрельдән октябрьгә кадәр очрый. Гәүдәсенең озынлыгы 70–80 *см*, авырлыгы 3 *кг* чамасы, канат җәеме 2 *м* га кадәр. Койрыгы чагыштырмача кыска, тигез кисекле. Куе коңгырт төстә. Башының өсте аксыл-сары, җилкәләрендә ак таплар бар. Ү.б. ояларын агачларда юан ботаклардан кора. Апрельдә 1–3 ак йомырка сала. Ү.б. йомран, байбак, куян, кошлар, ш.у. үләксәләр б-н туклана. Кимерүчеләрне юк итеп файда китерә. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

Әд.: Аськеев И.В., Аськеев О.В. Орнитофауна Республики Татарстан (конспект современного состояния). К., 1999.


ҮЛЕ́М, халыкның үлү процессы, *туым* б-н беррәттән халык санының табигый үзгәрешенең гомуми күрсәткечләреннән берсе. Бер елда 1000 кешегә туры килүче үлүчеләр саны (Ү. коэф.).

20 йөзнең беренче унъеллыкларына кадәр Россиядә буыннарның югары үлү ешлыгы, түбән *гомер озынлыгы* б-н сыйфатланучы гадәти Ү. төре өстенлек итә. 1930 еллар уртасыннан ачлык, эпидемия, пневмония, туберкулёз, ашказаны-эчәк һәм йогышлы балалар авырулары аркасында үлүчеләр саны кими; Ү.нең артуында кан әйләнеше системасы авырулары әйдәп баручы рольне ала. Илнең социаль-икътисади үсешендәге казанышлар, медицинадагы уңышлар барлык яшь категорияләрендә Ү.нең шактый гына кимүенә китерә. Бу үзгәрешләр 1960 елларның уртасына кадәр дәвам итә, аннары озакка сузылган стагнация чоры башлана, көтелгән гомер озынлыгы үсеше туктала.

1950 дә Татарстанда Ү. коэф. 10,1, ш.и. шәһәр халкы арасында 9,1 һәм авылда 10,6 тәшкил итә; 1964 тә Ү. бик түбән дәрәҗәгә төшә — уртача 1000 кешегә 7,1 үлем туры килә (тиңдәшле рәвештә 5,9 һәм 8,1). 1993 тә туым күрсткеченнән артып китә (тиңдәшле рәвештә коэф. 11,9 һәм 11), респ-ка халкының табигый кимүе башлана. ТРда 2015 тә 48,5 мең кеше (Ү. коэф. 12), ш.и. ир-атлар 24 мең һәм хатын-кызлар 24,5 мең кеше үлә. Соңгы 50 елда авыл халкы Ү.е шәһәр халкы Ү.еннән 1,4–1,5 тапкыр, аеруча, 1970–80 еллар ахырында 1,6–1,7 тапкыр узып китә. Бу шәһәр халкының яшәү дәрәҗәсе югары булу, хәзерге заман сан. һәм гигиена казанышларын кулланылуы, сыйфатлырак мед. хезмәте күрсәтелү б-н бәйле. Ир-атлар Ү.е хатын-кызлар Ү.енә караганда югарырак һәм ул тотрыклы рәвештә үсә бара: 2015 тә Ү. коэф. тиңдәшле рәвештә 13,4 һәм 10,8 тәшкил итә, ир-атлар һәм хатын-кызлар арасындагы гомер озынлыгы аермасы 1990 да 10,9 дан 2015 тә 12,7 гә кадәр үсә. 2015 тә хезмәткә яраклы яшьтәге үлүчеләр 27,6%, ш.и. ир-атлар 22,6% һәм хатын-кызлар 5%; хезмәткә яраклы яшьтәге 1000 кешедән чыгып исәпләгәндә югалту уртача 4,8 кеше, ш.и. ир-атлар – 7,5, хатын-кызлар – 1,8 кеше (1990 да тиңдәшле рәвештә 4,3, 6,8, 1,7). Ир-атлар Ү.енең күрсәткечләре югары биол. һәм социаль-икътисади сәбәпләр б-н аңлатыла. Беренчесе — тышкы тирәлеккә алар организмның каршы торучанлыгы түбән булу; икенчесе — хезмәткә яраклы яшьтәгеләрнең производство имгәнүләрдән үлү куркынычы югары, тәмәке тарту һәм эчкечелек кебек социаль зарарлы гадәтләрнең киң таралуы.

Ү. сәбәпләре арасында йөрәк-кан тамырлары системасы (2015 тә 51,1%), шеш (16,4%) авырулары, бәхетсезлек очраклары, агулану һәм травмалар (8,2%, шуларның алтыдан бер өлеше — үз-үзенә кул салу), сулыш (4,1%), ашкайнату (5,3%) органнары авырулары өстенлек алып тора. Күп очракта халык сәламәтлеге медицина хезмәтенә бәйле, әмма хәлиткеч рольне сәламәт яшәү рәвеше, хезмәт куркынычсызлыгы дәрәҗәсе, көнкүрешнең уңайлылыгы, әйләнә-тирә мохитнең торышы уйный. РФнең 2025 елга кадәрге Демографик сәясәт концепциясе (РФ Президенты тарафыннан 2007 дә раслана) нигезендә Ү. дәрәҗәсен киметүдә барыннан да бигрәк хезмәткә яраклы яшьтәгеләр, ана һәм *балалар үлемен* киметү буенча чаралар кабул итү беренчеләрдән булып карала.

Ф.Г.Борһанов.



ҮЛМӘСГӨ́Л, ц м и н (Helichrysum), оешма чәчәкләләр семьялыгыннан күпьеллык, сирәк кенә берьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 500 гә якын төре билгеле. Австралиядә һәм Европа, Азия, аеруча Көньяк Африканың җылы һәм уртача зоналарында таралганнар. ТР терр-ясендә бер төре — комлык Ү.е (шиңмәс чәчәк) (H. arenarium) бар. Сирәк кенә Алабуга һәм Лаеш р-ннарында очрый. Нарат урманнарында һәм урман ышыклау полосаларында коры комлы туфракта үсә. Тамыры үзәк, тармаклы. Сабагы 15–30 *см* биеклектә, туры. Яфраклары чиратлашкан, кыяк яки кыяк-ланцетсыман, ак киезсыман. Чәчәк кәрзине ачык сары яки кызгылт-сары, тыгыз калкан чәчәк төркеменә җыйналган, кипкән вакытта да үзенең төсен һәм формасын үзгәртми. Яктылык яратучы үсемлек. Җимеше — күпсанлы очкалак төкчәле орлыкча. Майдан август ахырына кадәр чәчәк ата. Җимешләре июль–сентябрьдә өлгерә. Дару үсемлеге, чәчәк төркемнәрендә эфир мае, С һәм К витаминнары, органик к-талар, сумала, микроэлементлар, дуплау матдәләре һ.б. бар. Үсемлектән ясалган төнәтмә, сыек экстракт һәм коры концентрат үт кудыру, бәвел кудыру, тир кудыру чарасы буларак кулланыла. Кышкы чәчәк бәйләмнәре, такыя, чәчәкләр үреме өчен файдаланыла. ТРның Кызыл китабына кертелгән.



Комлык үлмәсгөле.

ҮМӘ́К елгасы, Көнчыгыш Кама алдында, Вятка елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 71,5 *км*, ТР чикләрендә — 35 *км*. Бассейнының мәйданы 1210 *км*². Можга калкулыгыннан ага. Елга башы Удмурт Респ-касында, тамагы Алабуга р-ны Үмәк (Өмәк) авылыннан 3 *км* көньяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 54 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 30%.



Үмәк елгасы.

Ү.нең 1,5 тән 27,2 *км* га кадәр озынлыктагы 18 кушылдыгы бар. ТРда аеруча зурлары: Күклек елгасы (11,9 *км*, сул кушылдык). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,31 *км*/*км*². Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә күбрәк. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 103 *мм*, ташу агымы катламы 71 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 1,76 *м*³/*с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минераллэшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. Елгада суының гомуми күләме 1,3 млн. *м*³ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

ҮМӘ́К (Өмәк) авылы, Алабуга р-нында, Алабуга шәһәреннән 42 *км* төньяк-көнбатыштарак, Үмәк елгасы буенда. 2010 елда 62 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 47%, татарлар — 33%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Башлангыч мәктәп,

клуб. 1672 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Петропавловский исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Петропавел чиркәве (1859–68; архит-ра истәлеге), тегермән, почта станциясе, земство мәктәбе, земство халык китапханәсе (1911 дә ачыла) эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1740 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Чиркәс волостенда, 1920 дән ТАССРның — Мамадыш, 1921 дән — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга, 1944 нең 19 февраленнән — Костенеево, 1944 нең 8 июненнән — Морт, 1954 нең 19 ноябреннән Алабуга р-нында. Халык саны: 1859 да — 324, 1887 дә — 484, 1905 тә — 560, 1920 дә — 596, 1926 да — 662, 1938 дә — 613, 1958 дә — 223, 1970 тә — 155, 1979 да — 149, 1989 да — 114, 2002 дә — 99 кеше.

ҮМӘ́РОВ Зәки Әхмәр улы (6.2.1952, Горький өлкәсенең Спас р-ны Татар Маклагы а.), спортчы (самбо), СССРның атказ. спорт остасы (1983), РФнең атказ. физкультура һәм спорт хезмәткәре. Ленинград физкультура ин-тын тәмамлый (1982). Дзержинск шәһәрендә яши (Түбән Новгород өлкәсе, 1968 ел - дан). «Труд» ирекле-спорт җәмгыятендә тәр - бияләнә (тренеры — А.М.Криворотов). СССР (1974, 1977, 1980–82), дөнья (1974, 1982), СССР халыклары спартакиадалары (1979) чемпионы, СССР (1972, 1975, 1979 — көмеш, 1973 — бронза), Европа (1979 — бронза), СССР халыклары спартакиадаларында (1975 — көмеш), чемпионатларында медальләр ала, СССР (1976–77, 1981), дөнья Кубоклары (1975, 1980, 1982) иясе. 1984 тән Дзержинск шәһәрендә «Органик» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе, 1987 дән — «Химик» үзәк стадионы, 2009 дан — «Ока» физкультура-сәламәтләндерү комплексы директоры. Дзержинск шәһәренең мактаулы гражданы.

ҮРӘСБА́Ш авылы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 18 *км* көньяктарак, Ушман елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 327 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Үрәс елгасы буендагы авыл исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында ярма яргыч, 2 вак-тәкләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 998,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Петропавел волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Кукмара, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән — Мамадыш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 100 ир-ат; 1859 да — 390, 1897 дә — 730, 1908 дә — 782, 1920 дә — 745, 1926 да — 814, 1949 да — 597, 1958 дә — 101, 1970 тә — 549, 1979 да — 464, 1989 да — 375, 2002 дә — 379 кеше.

ҮРГӘЛӘ́К (Ajuga), иренчәчәкләр семьялыгыннан бер-, ике- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Якынча 50 төре билгеле, Төньяк ярымшарның уртача поясында тараллганнар. ТР терр-ясендә 2 төре бар. Женева Y.e (A. genevensis) (йөнтәс Y.) респ-каның һәр җирендә, шуышма Y. (A. reptans) (яра үләне), нигездә, Кама алдында очрый. Ылыслы, киң яфраклы һәм катнаш урманнарда, куаклар арасында, болыннарда үсәләр. 5–40 *см* биеклектәге күпьеллык үсемлек. Шуышма Y. озын, шуышма, тамырланучан ботаклы, сабагы шома. Женева Y.е горизонталь җәенке тамырлы, сабагы барлык яктан көдрә төкчәләр б-н капланган. Y.нең яфраклары бөтен читле, кырыйлары эре тешчәле, таралгыдагылары — озын сапларда, сабактагылары утырма. Чәчәкләре зәңгәр, күк, ара-тирә ак яки алсу төстә, сабак очындагы чук чәчәк төркеменә җыйналган. Җимеше — күпчикләвекчек. Май–июльдә чәчәк аталар. Орлыктан һәм вегетатив ысул б-н үрчиләр. Җир өсте өлешләрендә эфир мае, дуплау матдәләре, флавоноидлар бар. Үләне төнәтмәсе бөерештергеч, бәвел кудыру һәм яра төзәтү чарасы буларак кулланыла. Декоратив, баллы үсемлекләр. Шуышма Y. ТРның Кызыл китабына керт өтгән.

ҮРГӘНЕ́Ч БОТА́НИКА ТЫЮЛЫГЫ́, Яңа Чишмә р-ны терр-ясендә, Үргәнеч авылыннан көнбатыштарак урнашкан. 1991 елда язгы адонис популяциясен саклау максатыннан булдырыла. Мәйданы 9,14 *га*. Кичү елгасы үзәнендәге көньяк текә сөзәклегендәге урман участогын били. Югары төзелешле үсемлекләрнең 50 дән артык төре, ш.и. ТРның Кызыл китабына кертелгән: каурый кылган, исет ялмачасы билгеләнгән. Объект дару үсемлекләре резерваты буларак фәнни-гамәли әһәмияткә ия.

ҮРГӘН ЖӢ́ Әхмәд (14 йөзнең 2 нче яртысы), төрки-татар шагыйре. Алтын Урда төрки-татар шагыйрьләренең куљъязма *«Ядкәрнамә»* җыентыгында теркәлеп калган бер газәле һәм иҗтимагый-публицистик характердагы 2 шигыре б-н мәгълүм.


ҮРДӘ́К КОШЛА́Р (Anatidae), казсыманнар отрядыннан кошлар семьялыгы. 150 гә якын төре билгеле, бөтен Җир шарында тараллганнар. Татарстан терр-ясендә *каз*лар ыругына керүче 29 төре (очып килүче төрләрне дә кертеп), чын үрдәкләр, *чумгалаклар*, *чумгалак үрдәкләр*, турпаннар һ.б. бар. Гәүдәсенең озынлыгы 29–150 *см*, авырлыгы 0,2–13,5 *кг*. Тимгелле, ак, соры, коңгырт, кара төстә. Кайбер төрләренең канатлары зәңгәр, яшел яки ак таплы («көзгечекле»). Тәпиләре кыска, йөзү элпәләре б-н тоташкан 3 бармаклы. Яхшы йөзәләр, чумалар. Канатлары чагыштырмача кыска һәм киң. Озын муенлы. Каурый катламы тыгыз. Койрыкча бизеннән бүленеп чыгучы май катламы аны тышкы яктан тулысы б-н суга чыланудан саклый. Томшыгы киң, кырыйларында тешчекләр яки мөгез пластинкалар урнашкан. Җенси диморфизм ачык беленә (ата затлар зуррак һәм ачыграк төстә). Җирдә, агач куышларында яки өннәрдә оялый. Бертөсле ак, яшькелт яки саргылт 2–16 йомырка салалар. Үсемлек һәм хайван азык б-н тукланалар. Ындыр казы, кыр үрдәге, соры үрдәк, киңборын, ала чумгалак һ.б. кәсепчелек һәм спорт аучылыгы объектлары. Чыелдык каз, ак яңаклы казарка, кызыл бүксәле казарка, ысылдык аккош, нәфис аккош ТРның Кызыл китабына кертелгән.

ҮРИ́ ЧАЛЛЫСЫ́ авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 40 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Кече Шомбыт елгасы буенда. 2010 елда 63 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, иткә терлек асрау. Клуб, китапханә. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Богородский, Игим исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Казан Богородица чиркәве (1771 дә төзелә), земство мәктәбе (1867 дә ачыла), су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1100 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Шомбыт волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Мамадыш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 120 ир-ат; 1859 да — 555, 1897 дә — 738, 1908 дә — 836, 1920 дә — 735, 1926 да — 559, 1938 дә — 558, 1949 да — 349, 1958 дә — 266, 1970 тә — 433, 1989 да — 110, 2002 дә — 89 кеше.

ҮРМӘВЕ́Ч (Hedera), аралиячәләр семьялыгыннан мәңге яшел үрмәле лианалар. Чыгышы — Африка һәм Евразиянең субтропик пояслары. 15 төре билгеле. Яфраклары тиречел, төрле форма, үлчәм һәм төстә. Өй шартларында бик сирәк чәчәк ата. Бик күп өстәмә тамырлар җибәрә, шулар ярдәмендә терәкләргә үрмәли. Y.не биналарны вертикаль яшелләндерү өчен файдаланалар, яшь экземпляр ларын асылмалы үсемлек буларак кулланалар (асылма чәчәк вазаларында). ТРда еш кына декоратив бүлмә гөле буларак үстерелә. Гади Y. (H.helix) — шуышма, үрмәләүчән сабаклы. Яфраклары чиратлашкан, гади, 3–7 калаклы, куе яшел, ачыграк төстәге се нерләрдән торган челтәрле. Елның телә-



Үрдәкләр.



Үрмәкүчләр мәкаләсенә. 1. Poecilochroa conspicua; 2. Үрмәкүч-краб (Misumena vatia); 3. Үрмәкүч-бүре (Trochosa terricola); 4. Үрмәкүч-җайдакчык (Evarcha arcuata); 5. Tibellus oblongus; 6. Яшел микромата (Micrommata virescens); 7. Theridion impressum; 8. Dyctina arundinacea; 9. Tetragnatha extensa; 9.Гади крестовик (Araneus diadematus); 11. Эрезус (Eresus sp.).

сә кайсы вакытында ботаклардан үрчи, суда һәм комда җи ҷел тамырлана. Чуар яфраклы төрләре якты лык ярата, күләгәдә аларның төсе тоныклана. Ү. корылыкны һәм югары темп-раны авыр кичерә.

ҮРМӘКҮЧЛӘ́Р (Aranei), үрмәкүчсыманнар классыннан буынтыгаяклылар отряды. 40 меңнән артык төре билгеле. 3 асотрядны берләштерә: буынтыккорсаклы Ү. (Mesothelae, Liphistiomorphae) — иң гадиләр, корсагы төгәл буынтыклы, карбон чоры утырмаларыннан билгеле; кошашар Ү. (Mygalomorphae) дөньяда иң эреләрдән санала, озынлыгы 10 *см* га кадәр; ике үпкәле Ү. (Araneomorphae) — вертикаль хелицерлы (казналыклы). Татарстан терр-ясендә 3 нче асотряд вәкилләре очрый; тасвирланган 160 семьялыкның 31 е Урта Идел буе терр-ясендә теркәлгән.

Ү.нең гәүдәсе 0,37–110 *мм* озынлыкта, ике өлештән — сабакчык б-н тоташкан башкүкрәк һәм корсактан тора. Очлыкларның беренче пары — хелицералар, икенче пары — педипальпалар (үзгәргән очлыклар). Хелицерлар Ү.гә табышын тишкәләү, аңа агу һәм ашкайнату согы (эчәклектән тыш ашкайнату) сибү өчен хезмәт итә. Йөрү аяклары (4 пар) 7 сегменттан тора һәм 2 (гизүче Ү.дә) яки 3 (аучы Ү.дә) тырнакчык б-н тәмамлана. Шома өслекләрдә хәрәкәтләнү өчен кайбер Ү.нең махсус щёткасы (скопула) бар. Күзләре, гадәттә, 8 яки 6 (Dysderidae, Segesteriidae). Чапкын Ү.дән кала, башкаларының күрү сәләте начар. Үпкә б-н беррәттән күпчелек Ү.дә трахеялар бар. Корсагының арткы өлешендә, гадәттә, 3 пар пәрәвез сөяле урнашкан, пәрәвез бизләренең юлы шуларга ачыла, алар ау ятьмәләре һәм аулак оялар ясау өчен, корбанын чорнап алу, кузы үрү, җил ярдәмендә урнашу өчен пәрәвез бүлеп чыгаралар. Аерым желәслеләр; кагыйдә буларак, ата затлар аналарыннан кечерәк. Кайбер төрләренең ана заты, парлашудан соң, ата затны ашый, нәсел дәвамына карата еш кына кайгыртучанлык күрсәтә: күкәй кузыларын саклый яки үзе б-н корсагында йөртә.

Татарстанда яшәүче Ү.дән аеруча гадиләре (к. *рәсем*): *әвернәле үрмәкүч* — яшәү тирәлеген сайлауда нәзберек булмавы б-н аерыла; Araneus angulatus һәм Araneus marmoreus — типик урман һәм бакча тереклек ияләре; ачык төстәге янйөрешле Misumena vatia — чәчәкләргә урнашып аулый, аучы үрмәкүч Tetragnatha extensa — типик гигрофил; Pholcus phalangoides — торак һәм каралтыларда очрый. Матурлыгы өчен Европада «кама-үрмәкүч» исеме алган бик сирәк очраучы эрезус Ү.е (Eresus sp.), ш.у. төсе б-н җәлеп итүче зур шөпшә-үрмәкүч Ardiope brunnichii күренгәли. ТРның Кызыл китабына кертелгән: төче сулыкларда яшәүгә жайлашкан *көмеш үрмәкүч*; сазлык ярлары буенда шактый киң таралган *доломед*; Татарстан фаунасында иң зур, респ-кадагы бердәнбер каты авырттырып тешләүче (агуы кеше өчен куркыныч түгел) үрмәкүч — бөе. Барлык Ү. дә — ерткычлар, бөҗәкләрне күпләп юк итүче һәм кайбер зарарлы төрләрнең саны артуны чикләүче мөһим энтомофагларга керәләр.

Э.Ф.Мельничнова.

ҮРМӘКҮЧСЫМАННА́Р (Arachnida), хелицерлылар астибыннан умырткасызлар классы. Борынгы төркем, югары силур чорыннан билгеле, карбонда хәзерге отрядларның барлык вәкилләре табыла. Төрле авторларның мәгълүматлары буенча 9 (яки 13): *талпаннарның* 3 отряды, ялган чаяннар (к. *Ялган чаяннар*), печәнче үрмәкүчләр, үрмәкүчләр, талифоп, фрин, тартарида, пальпигради, рициптыльләр, сальпуга һәм берничә үлеп беткән отрядка берләшкән 30 дан 60 меңгә кадәр төр исәпләнә. Киң таралганнар. Татарстанда беренче алты отрядының вәкилләре очрый. Тышкы билгеләре һәм зурлыклары буенча аерылалар. Озынлыгы мм ның өлешләреннән алып, 20 *см* га кадәр. Гәүдәсе башкүкрәк һәм корсактан тора, төрле дәрәҗәдә бүлгәләнгән. Мыекчалары юк, гади күзле. Башкүкрәгендә хелицерлар (казналыклар), педипальпалар (үзгәргән очлыклар) һәм 4 пар йөрү аяклары бар. Корсак очлыклары үсеш алмаган яки үпкәгә, тәрәш сыман органнарга, пәрәвез сөялләренә үзгәргән. Трахеялар, үпкә капчыкларына сулыш органнары булып тора. Кан системасы бар. Бүлеп чыгару органнары — мальпиги кан тамырлары һәм коксал бизләре. Күп кенә Ү.дә тәннәренең төрле урыннарында агу бизләре урнашкан. Ү. аерымҗенеслеләр, күбрәк күкәй салып үрчиләр, кайберләре терелә туды ручы, күпчелеге коры җирдә яши, ара-тирә суда яшәүчеләре дә очрый. Ерткычлар (умыртказсызлар б-н туклана), паразитлары күп, фитофаглар бар.

О.Д.Любарская.

ҮРМӘЛӘЧЛӘР (Sitta), үрмәләч кошлар семьялыгындагы куыр. 25 төре билгеле, Евразия, Төньяк Америка, Төньяк-Көнбатыш Африкада, Австралиядә таралганнар. ТР терр-ясендә бер төре — гади үрмәләч (S.europaea) бар. Яфраклы һәм катнаш урманнарда, ш.у. парк һәм бакчаларда очрый. Утрак һәм күчеп йөрүче кош. Гәүдәсенең озынлыгы 13–16 *см*, авырлыгы 19–25 *г*. Каурый капламы куе, йомшак, аркасы зәңгәрсу, бүксәсе ак, ян-яклары ачык җирән, канатлары һәм койрыгы коңгырт төстә. Күзе туры сыннан башы буйлап кара буй уза. Томшыгы озын, конуссыман, көчле. Койрыгы кыска, туры. Аяклары кыска, көчле. Ү. озын, киң итеп аерылган бармаклары ярдәмендә агач кайрысында нык торалар һәм кәүсә әйләнәсе, ботаклар буенча аска, өскә җитез үрмәлиләр. Оясын агач куышында кора, анда керү юлын балчык б-н сылап куя. Көрән-кызгылт тимгелле 5–8 ак йомырка сала. Бөҗәкләр (кырмыска, кандала, күбәләкләр һәм аларның гусеницалары, филчекләр һ.б.), үрмәкүчләр, ш.у. орлыклар һәм тыгыз тышчалы чикләвекләр б-н туклана.

ҮРНӨК посёлогы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 7 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кече Сөлчә елгасының сул кушылдыгы буенда. 1920 елларда нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Чистай кантоны Кәкрекүл волостенда, 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. 2001 нең 27 июнендә торак пунктлар исемлегеннән сызыла. Халык саны: 1926 да — 74, 1938 дә — 109, 1949 да — 120, 1958 дә — 143, 1970 тә — 107, 1979 да — 55, 1989 да — 13 кеше (руслар, чуашлар).

ҮРНӨК посёлогы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 18 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Казансу елгасы буенда. 2010 елда 1005 кеше (татарлар) яши. Арча урман хуҗалыгы, агач эшкәртү цехы. Арча агросәнәгать һөнәр көллияте, урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 18 йөз уртасына кадәр нигез салына. Башта авыл Кече Казанбаш дип йөртелә. Беренче булып монда Түбән Новгород губернасыннан алпавыт И.К.Горталов тарафыннан күчерелгән рус крәстияннәре килеп урнаша. 1850–70 елларда Г.И.Горталов авыл халкын Гавриловка авылына (8 *км* төньяк-көнчыгыштарак) куа һәм Казанбаш авылы урынында 19 йөздә — 20 йөз башында Казан сәүдәгәре Г.Ә.*Ишмораторов* милкенә әйләнгән алпавыт утары гына торып кала. Ү.тә ат, май һәм такта яру з-ды, пар тегермәне, бәз ф-касы, балык үрчетү сулыгы эшли. 1917 елдан соң утар җирлегендә — «Үрнәк» ашлык с-зы, 1931 дә Арча урман хуҗалыгы оештырыла. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кармыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 14 ир-ат; 1859 да — 96, 1897 дә — 122, 1908 дә — 161, 1920 дә — 124, 1926 да — 135, 1938 дә — 183, 1949 да — 88, 1958 дә — 233, 1970 тә — 1033, 1979 да — 782, 1989 да — 530, 2002 дә — 990 кеше.

ҮРНӨК авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 33 *км* көнчыгыштарак, Суша елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 1 кеше (татар) яши. 1927 дә нигез салына. Оешкан көненнән Балык Бистәсе р-нында. 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Мамадыш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1938 дә — 91, 1949 да — 75, 1958 һәм 1970 тә — 108 әр, 1989 да — 32, 2002 дә — 14 кеше.

ҮРНӨК авылы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 15 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Казанчы елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 1 кеше (рус) яши. 1920 елларда нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Минзәлә кантоны Мөслим волостенда, 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1963 нең 1 февраленән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1926 да — 89, 1938 дә — 209, 1949 да — 233, 1958 дә — 199, 1970 тә — 150, 1979 да — 22, 1989 һәм 2002 дә — 2 шәр кеше.

ҮРНӨК авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 19 *км* төньяктарак, Олы Чирмешән елгасы буенда. 2010 елда 153 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 1930 елларда нигез салына. Оешкан көненнән — Октябрь (1997 нең 10 декабреннән — Нурлат) р-нында. Халык саны: 1938 дә — 395, 1949 да — 363, 1958 дә — 338, 1970 тә — 448, 1979 да — 358, 1989 да — 181, 2002 — 192 кеше.

ҮРНӨК авылы, Спас р-нында, район үзәге. Болгар шәһәреннән 14 *км* көньяк-көнбатыштарак, Куйбышев сусаклагычыннан 2 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 157 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1925 тә нигез салына, 1940 еллар уртасына кадәр Кызыл Сука исеме б-н билгеле. Оешкан көненнән ТАССРның Спас кантоны Өчкүл волостенда. 1930 ның 10 августыннан Спас (1935 нең 1 апр. — 1991 нең 4 окт. — Куйбышев) р-нында. Халык саны: 1926 да — 59, 1949 да — 329, 1958 дә — 283, 1970 тә — 279, 1979 да — 265, 1989 да — 168, 2002 дә — 164 кеше.

ҮРНӨК посёлогы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 17 *км* көнчыгыштарак, Казан — Түбән Новгород автомагистрале буенда. 2010 елда 246 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1920 еллар башында нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Арча кантоны Ильинка волостенда. 1927 нең 14 февраленнән — Воскресенский, 1927 нең 1 августыннан — Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1958 нең 16 июленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1926 да — 27, 1938 дә — 43, 1949 да — 20, 1958 дә — 99, 1970 тә — 159, 1979 да — 172, 1989 да — 161, 2002 дә — 227 кеше.

«ҮРНӨК», Казандагы басмаханә. 1906 елда бертуган Гыйльметдин һәм Бор һанетдин Шәрәфләр тарафыннан «*Мәгариф*» нәшрияты җирлегендә «Матбагаи Шәрәф» исеме б-н оеша, 1908 дән — «Үрнәк». Беренче басмасы — М.Гафуриның «Яшь гомерем» шигырьләр җыентыгы. 1906–08 дә гомуми тиражы 338045 данә булган 106 исемдәге китап басыла. 1908 нең июнендә губернатор боерыгы б-н «Фөруъядлар» шигырьләр җыентыгын бастырган өчен ябыла. Б.Шәрәф бинаны Г.Ю.Саиновка сату турында белдерә, басмаханә «Үрнәк» исеме б-н атала башлый, әмма фактик хуҗасы булып Г.Шәрәф исәпләнә. 1908–10 да басмаханәдә гомуми тиражы 480665 данә булган 152 татар китабы дөнья күрә. 1911 нең ноябрендә «Төрле-төрле шәп җырлар» халык җырлары җыентыгын нәшер иткән өчен Г.Шәрәфкә һәм Г.Саиновка карата җинаять эше ачыла, басмаханә ябыла. Соңрак аның рәсми хуҗасы хәреф җыючы В.Е.Казаков була, шул вакытта басмаханәдә 2 тиз баса торган машина, 112 пот 16 кадак татар һәм рус шрифты, башка җиһазлар һәм материаллар исәпләнә. 1906–11 дә анда Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Камал, И.Казаков, М.Гафури, Н.Думави, М.Укмаси әсәрләре, М.Горький, Л.Н.Толстой, А.С.Пушкин, Л.Н.Андреев һ.б.ның тәрҗемә әсәрләре, Г.Курсави, М.Чокрый, Х.Әбүзәров, Ә.Исхаков һ.б.ның иҗат әсәрләре, география, математика дәреслекләре, уку китаплары, фәнни-популяр әдәбият; татар газеталары һәм журналлары: «*Казан мөхбире*», «*Әхбәр*», «*Тәрбия*» дөнья күрә. Заказларның яртысын диярлеген бертуган Шәрәфләр басмалары, калганнары «*Мәгариф*», «*Гасыр*», «*Сабах*», «*Юл*», «*Шәрекъ*», «*Милләт*», «Уку», «Гаилә» басмалары тәшкил итә. 1911 дә басмаханәдә гомуми тиражы 49500 данә булган 14 исемдәге китап басыла. 1912 нең 24 июнендә «Ү.» бөтенләйгә ябыла.

Әд.: Каримуллин А.Г. Татарская книга начала XX века. К., 1974; Габдельганеева Г.Г. Полиграфия и печать в Казанской губернии. 1800–1917 гг. К., 2005.

Г.Г.Габделганиева.

ҮРНӨК ТЕАТРЛАР, РСФСР ХКСның «Театр эшен берләштерү турында»гы 1919 ел 29 август Декреты нигезендә дәүләт карамагына күчкән театрларның 1920 еллардагы атамасы. Казанда татар театры (Беренче татар дәүләт драма труппасы, хәзер *Татар академия театры*), опера театры, Зур театр (хәзер *Казан Зур дәрама театры*), Елга аръягындагы Эшче театры шундый театрлардан санала. Аларны тәэмин итү өчен акча шәһәр бюджетыннан бүлеп бирелә. Ү.т. эшчәнлеген башта Казан шәһәр эшче һәм солдат депутатлары Советы каршындагы губерна мәгариф бүлегенең театр секциясе, 1920 дән ТАССР Мәгариф халык комис-тының театр бүлеге турыдан-туры контрольдә тота. 1922 дә, шәһәр бюджетында акча булмау сәбәпле, Ү.т.ны финанслау вакытлыча туктала, чыгымнарны каплау тулысынча үзләренә тапшырыла; шулай да алар эшчәнлеген контрольдә тоту дәвам итә. Со ңыннан бу театрлар дәүләт театрларына үзгәртелә.

Ю.А.Благов.

ҮРНӨК-КҮМӘК авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорскидан 21 *км* көньяк-көнбатыштарак, Урман Чишмәсе елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 246 кеше (татар-

лар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты. 1924 тә Юлтимер авылыннан күченүчеләр нигез сала. Оешкан көненнән ТАССРның Бөгелмә кантоны Шөгер волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Шөгер, 1959 ның 16 октябреннән Лениногорск р-нында. Халык саны: 1926 да — 50, 1938 дә — 109, 1949 да — 135, 1958 дә — 31, 1970 тә — 24, 1979 да — 106, 1989 да — 219, 2002 дә — 228 кеше.

ҮРСУ́, к. *Урыс*.

ҮРТАМА́К авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 27 *км* көньяктарак, Ык елгасы буенда. 2010 елда 21 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. 1746 га кадәр, татар авылы буларак нигезләнә. Беренче исеме — Урмәт тамагы, 19 йөздә — 20 йөз башында Наталъевка атамасы б-н дә билгеле. 1773–75 еллардагы Крәстияннәр кузгалышында халкы Е.И.Пугачёв ягында сугыша. 1784 тә У. тирәсендәге җирләрне дворяннар Никита һәм Матвей Можаровлар сатып ала һәм монда рус (1861 елгы реформага кадәр алпавыт крәстияннәре) килеп утыра. Халыкның төп шөгыле — игенчелек, терлекчелек була. 20 йөз башында ашлык саклау-сату кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 247,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Матвеевка волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1944 нең 19 февраленнән — Матвеевка, 1954 нең 19 ноябреннән Минзәлә р-нында. Халык саны: 1859 да — 105, 1870 тә — 142, 1884 тә — 186, 1906 да — 252, 1913 тә — 334, 1920 дә — 281, 1926 да — 263, 1938 дә — 276, 1949 да — 344, 1958 дә — 157, 1970 тә — 124, 1979 да — 85, 1989 да — 23, 2002 дә — 32 кеше.

Әд.: Мензелинский край: История и современность. Мензелинск, 2006.

ҮРТӘ́М елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Ашыт елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 16,2 *км*, ТР чикләрендә — якынча 10 *км*. Бассейнының мәйданы 116,2 *км*^{2}. Вятка увалы калкулыгыннан ага. Елга башы Мари Эл Респ-касы терр-ясендә, тамагы Әтнә р-ны Түбән Көек авылыннан 1 *км* көньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 140 *м*, тамагыныкы — 95 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 5%. Ү.нең 1 дән 7,6 *км* га кадәр озынлыктагы 4 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,39 *км/км*^{2}. Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км*^{2}. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы, җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнында еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 159 *мм*, ташу агымы катламы 140 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрель башында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,08 *м*^{3}*/с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. Ү. бассейнында суының гомуми күләме 0,6 млн. *м*^{3} булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

ҮСӘЛИ́ (Өчиле) авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 42 *км* көнбатыштарак, Бөрсет елгасы буенда. 2010 елда 501 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау; «Үсәли-агрохимсервис» АҖ, май з-ды. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. Латыйф мулла йорты (19 йөз ахыры архит-ра истәлеге). 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Үсәлә исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә; игенчелек, терлекчелек, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша; мәчет, мәктәп, су тегермәне, тимерчелек, 13 вак-төяклар кибете була; сишәмбе базары эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 897,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Түбән Сон волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мамадыш, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 81 ир-ат; 1859 да — 520, 1897 дә — 970, 1908 дә — 1158, 1920 дә — 1236, 1926 да — 1208, 1938 дә — 1019, 1949 да — 772, 1958 дә — 828, 1970 тә — 815, 1979 да — 813, 1989 да — 668, 2002 дә — 553 кеше.

ҮСЕМЛЕКЛӘ́Р ДӨНЬЯСЫ́, Җир яки аның аерым терр-яләрендәге үсемлек бергәлекләренең (фитоценозларның) җыелмасы (бу терр-ядәге үсемлек төрләре — *флорадан* аермалы буларак). Ү.д.ның таралуы, нигездә, гомумклиматик шартларга бәйле һәм зональ характерга ия. Төп классификация берәмлекләре — үсемлекләрнең тибы, формациясе һәм ассоциациясе. Ү.д. — биосфераның мөһим компоненты, табигатьтә матдәләр алмашында һәм энергиядә зур әһәмияткә ия, органик матдәләрнең башлангыч синтезында мөһим роль уйный.

Татарстан терр-ясе үсемлек капламы формациясенең төрлелеге һәм чуарлыгы б-н сыйфатлана. Территориядә катнаш ылыслы-киң яфраклы һәм киң яфраклы урманнар, урман-дала зоналарының ландшафтлы үсемлек берәмлекләре берләшә: көньяк тайга формацияләреннән киң яфраклы урманнар б-н үзенчәлекле тезмәдә дала формацияләренә кадәр. Комлы һәм комсу туфраклы тугайөстете елга террасаларында һәм субүләрләрнең төп сөзәклекләрендә нарат урманнары формацияләре таралган, төп урман кисенделәре урынында — юкә, ш.у. вак яфраклы токымнар, нигездә, каен һәм усак катыш икенчел урманнар үсә. Караңгы ылыслы формацияләр составында чыршы өстенлек итә, ак чыршы очрый, ул чыршыдан аермалы буларак аерым утыртмалар хасил итми. Катнаш типтагы, ш.и. имән катыш юкәле-имәнле, каенлы-имәнле, усаклы-имәнле урман формацияләре шактый зур мәйдан били. Чикләвек агачы һәм имән үскән куаклыклар, елга үзән нәрендә һәм уйсулыкларда зиреклек һәм таллыклар үсә. Республика терр-ясеннән коры чагач (Идел буенча) һәм имән ареалларының төньяк-көнчыгыш һәм ак чыршы б-н чыршының көньяк чикләре уза. 19 йөздә Казан губернасы терр-ясенең якынча 50% ын каплаган урман үсемлекләре хәзер ТР терр-ясенең 17,2% ын били, өстәвенә урманнар тигезсез һәм урыны-урыны б-н генә урнашкан (Нурлат р-нында 40,3% тан Чүпрәле р-нында 2,6% ка кадәр).

Болын үсемлекләренең төп массивы ерым-сыза системаларына туры килә. Болар көтүлек җирләр булып файдаланылучы тау яки материк болыннары. Төрле болын үләннәре б-н тар яфраклы-йончалы-кызыл солычалы бергәлекләр өстенлек итә; грунт сулары якын яткан тугайдан тыш участокларда елан телле — кызыл солычалы, кырчыллы-елан телле, елан телле-күрәнчәле уйсулык болыннары урнашкан; текә көньяк сөзәклекләрдә төрле болын-дала үләннәре б-н кыгланлы һәм солычалы далаланган болыннар; кече һәм уртача зурлыктагы елга тугайларында төрле болын үләннәре б-н төрле кыяклы-кыңдыраклы, йончалы-кызыл солычалы һ.б. болыннар өстенлек итә. Зур елга тугайларындагы югары уңдырышлылыкка ия болыннарның күпчелеге (350 мең *га* мәйдан) Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычлары суы астында калды. Кама елгасы тугаенда күбрәк күрән, кенәри үләне, сарут-кыңдырак үсүче төрле үләнле болын участоклары сакланып калган. Сазлык үсемлекләре ТР терр-ясенең 1% тан азрагын билиләр, башлыча, күрәнле, кураклы уйсу һәм наратлы-торф мүкле үрге сазлыкларда (нигездә, Кама алдының нарат урманнарында) үсәләр. Сазлыкларның күбесе күлләрнең сазлыклануы процессында барлыкка киләләр. Кайбер күлләрнең һәм зур сусаклагычларның сай сулыклары су үсемлекләре: тар яфраклы җикәнбаш, гади курак, гади укъяфрак, озын комай үләне, чәчәкле камыш, өч өлешле бака тәңкәсе, сырлы су кәбестәсе һ.б. б-н капланган. Сөрүле җирләрне төрле агрофитоценозлардан торучы кыр үсемлекләре били, алар составына культуралы (бөртеклеләр һәм терлек азыгы культуралары өстенлек итә) һәм күпсанлы чүп үләннәре төрләре, башлыча, бер- һәм икеел лык (дарулы төтәч, көтүче сумкасы, ак онлыча, гади алабута һ.б.) һәм тамыр үсентеле (кыр эт әчәгесе, кыр каклавычы, кыр билчәне һ.б.) үсемлекләр керә.

Әд.: Гордягин А.Я. Растительность Татарской Республики // Географическое описание Татарской Республики. Ч. 1. Природа края. К., 1922; Марков М.В. Луга Татарской АССР. К., 1946; шул ук. Растительность Татарии. К., 1948; шул ук. Флора и растительность пойм рек Волги и Камы в пределах Татарской АССР // Уч. зап. Казан ун-та. 1955. Т. 115, кн. 1; Петров А.П. Кайбицкие дубравы // Уч. зап. Казан гос. пед. ин-та. 1950. Вып. 9; Порфирьев В.С. Темнохвойно-широколиственные леса северо-востока Татарии // шунда ук. С. 47–119.

Е.Л.Любарский, Ф.Г.Борһанов.

ҮСЕМЛЕКЛӘ́Р ИНТРОДУ́КЦИЯСЕ (лат. introductio — кереш) (биол.), хайваннар һәм үсемлекләрне табигый ареалыннан читтә, алар элек очрамаган яңа тереклек урынында таралышы: акклиматизациянең башлангыч этабы. Кеше тарафыннан хуҗалык максатларында теге яки бу җирлектә биол. төрлелекне мак-

сатчан юнәлештә киңәйтү, ш.у. ясалма резерватларда, алар арасында әйдәп баручы рольне ботаника бакчалары һәм зоопаркларалып тора, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы генофондын саклау өчен актив кулланыла.


Хайваннар интродукциясе вакытында терлекләр, балыкларның кәсәбәчелек төрләре, кысласыманнар, файдалы бөҗәкләр һ.б.ның перспектив төрләре һәм токымнары яңа районнарга кертелә. ТРда хайваннар интродукциясен Вет. академиясе, Күл һәм елга балыкчылык ху җалыгы дәүләт фәнни-тикшеренү ин-тының Татарстан бүлеге, аучылык ху җалыклары, Үсемлекләрне саклау станциясе биоф-касы гамәлгә ашыра.

Үи. вакытында үсемлекләрнең, ш.у. җирле флора үсемлекләренең яңа төрләре һәм формалары культурага кертелә. Үи. кешелек җәмгыяте үсешенең башлангыч этапларында, утрак тормыш итү рәвешенә күчү һәм тораклар янында азык-төлек һәм техник үсемлекләрне үстерә башлау б-н бер үк вакытта диярлек стихияле рәвештә туа. Беренче тапкыр Үи. теориясе 1885 елда Швейцария галиме А.Декандоль тарафыннан «Игелүче үсемлекләрнең килеп чыгышы» («Происхождение возделываемых растений») дигән китапта нигезләнә. 1894 тә немец тикшеренүчесе Г.Краузеның Үи.нең Көнбатыш Европада борынгы заманнардан алып 20 йөз башына кадәр 7 чорын тәгаенләгән хезмәте чыга. Декандоль һәм Краузеның эшен атаклы совет ботанигы Н.И.Вавилов дәвам итә, аның культуралы үсемлекләрнең килеп чыгу үзәкләре турындагы теориясе (1926) Үи.нең фәнни нигезләрен булдыруда зур роль уйный. Вавилов буенча беренчел үзәкләрдә — культуралы үсемлекләрнең борынгы формаларының төп генофонды, икенчел үзәкләрдә селекция өчен перспективалы яңа билгеләр таратучылар тупланган. Кеше эшчәнлеге нәтиҗәсендә бу үзәкләрдәге үсемлекләр, үзләренең ареалларын киңәйтеп, яңа өлкәләргә күчәләр. Культуралы үсемлекләрнең күп өлеше башка район һәм континентлардан интродукцияләнгән. Мәс., 16–17 йөзләрдә Америкадан Европага — кукуруз, бәрәңге, көнбагыш, кабак, ногыт борчагы, томат, тәмәке һ.б., Африкага батат, маниок, арахис кертелә. Көньяк Азиядән Үзәк һәм Көньяк Америкага шикәр камышы керә. 17 йөздә үк Төньяк Америкада Европадан китерелгән слива, алмагач, груша, ат кәстәнәсе һ.б. үстерелә. Үи. вакытында табигый ареалдан яңасына күчкәндә еш кына төрләрнең (сортларның) тереклек сәләте һәм интродукция үткәрелүче ху җалык өчен мөһим билгеләрнең яхшыруы күзәтелә: җимешләрнең (орлыкларның) уңышы, фитомасса, мохитнең тискәре факторларына, авыруларга, корткычларга каршы торучанлыгы һ.б. арта. Тискәре нәтиҗәләр булдырмас өчен, Үи. карантин кагыйдәләрен үтәү б-н башкарыла. Ботаника бакчалары, а.х. фәнни-тикшеренү һәм уку-укыту ин-тлары, тәҗрибә станцияләре һәм интродукция питомникларында Үи. буенча фәнни эшләр үткәрелә. Татарстан терр-ясендә Үи. б-н Казан зообатаника бакчасы (декоратив, дару үсемлекләре), Казан ун-тының ботаника бакчасы (терлек азыгы, дару, техник һәм декоратив үсемлекләр), Татарстан урман-тәжрибә станциясе (дендрарий бакчасында Амур бәрхет агачы, Маньчжур чикләвеге, Себер карагае, көнбатыш туясы һ.б. үстерелә), Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-ты (бөртекле-кузаклы үсемлекләр — люпин, нут, маш; җимеш агачлары — әлүчә, абрикос, зелпе, виноград, актинидия, лимонник), Идел-Кама саклаулыгы (дендрарийда агач һәм куакчыл үсемлекләрнең 400 дән артык төре), «Түбән Кама» милли паркы, «Горводзеленхоз» шөгыльләнәләр.

Әд.: Базилевская Н.А. Теории и методы интродукции растений. М., 1964; Жуковский П.М. Культурные растения и их сородичи. Л., 1971; Зайцев Г.Н. Оптимум и норма в интродукции растений. М., 1983; Вавилов Н.И. Пять континентов. М., 1987; Интродукция амаранта в ТАССР. К., 1989.

С.И.Кадошников.

ҮСЕМЛЕКЛӘР ФИЗИОЛО́ГИЯСЕ, үсемлек организмнарының гомумтереклек эшчәнлеге закончалыклары турындагы биол. фәне. Үсемлекләрнең су алмашы һәм минераль тукланыун, *фотосинтез* һәм сулау, үсемлекләрнең үсеше һәм мохитнең тискәре шартларына яраклашуын өйрәнә. Игенчелек һәм үсемлекчелекнең теоретик нигезе булып тора. Үф. 17–18 йөзләрдә туа. 1800 елда Швейцария ботанигы Ж.Сенебьеның «Үсемлекләр физиологиясе» («Физиология растений») дигән 5 томлык хезмәте басыла. Россиядә Үф. фән буларак 19 йөзнең 1 яртысында А.С.Фаминцын (үсемлекләрдә энергия һәм матдәләр алмашы турында фундаменталь тикшеренүләр) һәм К.А.Тимирязев (фотосинтез процессында хлорофиллның ролен өйрәнә, яшел үсемлекләрнең космик ролен нигезли) хезмәтләренә нисбәтле туа. 19 йөзнең 70 елларында Казан ун-ты галимнәре Н.Ф.Леваковский (экологик физиол. өлкәсендәге тикшеренүләр), В.А.Ротерт (үсемлекләр хәрәкәте формаларын һәм фотопериодизм күренешен өйрәнә), Е.Ф.Вотчал (үсемлекләрнең каналлар системасы буенча су хәрәкәте механизмын тикшерә), М.С.Цвет (хроматографик анализ алымын эшли, аның ярдәмендә *а* һәм *б* хлорофиллары, сары пигментлар — каротиноидлар билгеләнә) Үф.нең формалашуына һәм үсешенә зур өлеш кертәләр. В.В.Лепёшкин соңрак протоплазманың коллоид-химик төзелеше турында күзаллау формалаштыра. А.П.Пономарёв төрле тозлар, су б-н тәэмин ителеш һәм темп-ра шартлары йогынтысы б-н багланышта хлоропласт-ларның сулылыгын һәм коллоид үзенчәлекләрен өйрәнә. 1932 дә Казан ун-тында Үф. каф. ачыла, аны А.М.Алексеев җитәкли. 1950 елларда СССР ФА Казан ф-лының Биол. ин-тында, Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында, ш.у. Казанның башка югары уку йортларында (а.х., пед., вет. ин-тлары) физиол. тикшеренүләр алып барыла. А.М.Алексеев *үсемлекләрнең су режимының* теоретик нигезләрен эшләүгә шактый зур өлеш кертә, аның тарафыннан су алмашын өйрәнүдә термодинамика алымы кулланыла, термодинамика күрсәткечләре — суның активлыгы һәм химик потенциалы кертелә, үсемлекләр метаболизмында су режимының роле һәм матдәләр алмашы ингредиенты буларак, су алмашы турында яңа күзаллау тәкъдим ителә. Авыр су кулланылган тәҗрибәләрдә күзәнәкләрдә төрле су фракцияләренең тизләтелгән алмашы һәм хәрәкәтчәнлеге, күзәнәкләр һәм атм. арасында су алмашы билгеләнә, күзәнәкләрдә су алмашы һәм су халәте б-н үсемлекләрнең энергия алмашы арасында үзара бәйләнеш раслана (Ф.Д.Самуилов), илдә беренче тапкыр су режимының углеродның постфотосинтетик юлына йогынтысы тикшерелә (И.А.Тарчевский), авызчыктан тыш транспирация механизмы һәм транспирациянең нәтиҗәлелеге ачыклана (А.А.Җәләлов). Бер үк вакытта а.х. өчен зур әһәмияткә ия булган үсемлекләрнең су режимы һәм минераль тукланыу арасындагы үзара багланышлар өйрәнелә (А.М.Алексеев, Н.А.Гусев, Ф.Д.Самуилов).



РФА академиклары И.А. Тарчевский һәм А.Н. Гречкин оксилипиннар лабораториясендә.

1960 елларда хәзерге физик алымнарны (ТМР, диэлектрик һәм инфракызыл спектроскопия) кулланып, үсемлекләрнең су алмашын молекуляр дәрәҗәдә өйрәнү башлана, күзәнәкләрдә суның структурасы, төрле факторлар йогынтысында аның үзгәрешләре тикшерелә (В.Д.Корепанов, Н.А.Мальцев, Л.А.Абецедарская, Ф.Д.Самуилов, А.В.Анисимов, Л.П.Хохлова, И.Н.Ишмөхәммәтова, Н.В.Седых, Г.А.Великанов, Ф.Г.Мифтахетдинова, В.Д.Федотов). Күзәнәк һәм организм-нарда суның функциональ роле буенча тикшеренүләр дәвам итә: сулау ферментлары активлыгы өчен суның әһәмияте күрсәтелә (И.Г.Сөләйманов), үсемлекләр функциясе координациясендә су роленең концепциясе эшләнә (А.П.Петров), калий циркуляциясенең физиол. процессы һәм аның б-н бәйле су агымы механизмы билгеләнә (А.А.Җәләлов), күзәнәк эчендә су алмашын көйләүдә күзәнәк мембранасы ионнарны транспортлау системаларының роле ачыклана (Л.Х.Гордон), цитоскелет (Л.П.Хохлова), плазмодесма (А.В.Анисимов, Г.А.Великанов) роле күрсәтелә.

Су алмашы һәм минераль туклану тикшеренүләре б-н берәттән фотосинтез өлкәсендә фәнни эзләнүләр үткәрелә. 1950 елларда И.А.Тарчевский тарафыннан фотосинтез продуктларын өйрәнүдә тамгалы атомнар алымы кулланыла, мохитнең тискәре факторлары (корылык һ.б.) тәэсирендә фотосинтез метаболизмының үзенчәлекле булмаган үзгәреш-

ләре билгеләнә. Тамгалы атомнар алымы кулланып, Казан а.х. ин-тының ботаника каф. аспиранты Ю.С.Карпилов CO_2нең фиксациясе һәм формалашуының беренчел продуктлары булып кукурузда дүрт углеродлы кушылмалар — кузгалак, серкә, алма һәм аспирин к-талары торуын раслый. Со ңыннан фотосинтез метаболизмының бу тибы — C_4 фотосинтез тибы дип атала. Бу фотосинтез тибы үсемлекләре CO_2 не тулырак үзләштерәләр, транспирациядә суны азрак кулланалар һәм югарырак продуктлылыкка ия. Фотосинтезны көйләү механизмнары һәм үсемлекләрнең продуктивлыгы тикшерелә: фотосулауның яфраклардан шикәрләр экспортына бәйлелеге күрсәтелә, үсемлекләрнең нитрат б-н тукланулары очрагында яфраклардан ассимилятлар экспорты тоткарлану күренеше ачыклана (В.И.Чиков). Хлорофиллы фотосинтетик потенциаллар ярдәмендә үсемлекләр продуктлылыгын бәяләү алымы тәкъдим ителә, һәм ул селекция үзәкләрендә кулланыла башлый (И.А.Тарчевский, Ю.Е.Андрианова).

1970 елларда беренче тапкыр үсемлекләр фотоэнергетикасы буенча тикшеренүләр үткәрелә башлый. Фотомикрокалориметрик алым кулланып, үсемлек күзәнәкләрендә бу үсемлекләрнең тискәре йогынтыларга чыдамлылыгы механизмнарын ачыклауда зур әһәмияткә ия булган энергия алмашы үзенчәлекләре билгеләнә (В.Е.Петров). Чыдамлылыкның фотосинтез һәм окисьлы фосфорильләшүдән, күзәнәкләрдә макроэргик кушылмалар күләменнән һәм динамикасыннан, сулау вакытында энергетика балансы үзгәрешеннән, фосфорильләшү һәм окисьлашуның иярмә тизлегеннән бәйле булуы күрсәтелә (Ф.Д.Самуилов, Л.Х.Гордон, В.Е.Петров). Үсемлекләрдән аденилотциклаз сигнал системасы интермедиаты булараk циклик аденозинмонофосфат аерып алына (Ф.Г.Кәримова). Үсемлек күзәнәкләре сигнал системасының эшчәнлек концепциясе һәм аның уңайсыз һава шартларына чыдамлылык һәм патоген микроорганизмнарга иммунитет тәэмин итүдәге роле ачыклана (И.А.Тарчевский). Күп кенә табигый һәм химик юл б-н синтезлашкан кушылмалар йогынтысында антипатоген аксымнар барлыкка килү исбатлана, бу процесста эшчәнлеге энергия алмашы б-н уңай бәйләнешле протон сигнал системасы мөһим роль уйный. Стресс вакытында актив кислород формалары, аерым алганда, пероксидаза катнашында баручы супероксид генерациясе активлаша. (Л.Х.Гордон). Казан ун-тының үсемлекләр физиологиясе кафедрасында көзге бодайның түбән темп-раларга яраклашуы вакытында мембрана фосфолипидлары динамикасы, үсемлекләрнең чыдамлылык һәм яраклашу механизмнары формалашуда цитоскелетның физиол. роле буенча тикшеренүләр үткәрелә (Л.П.Хохлова, О.В.Олиневич). 1988 елда Россия үсемлекләр физиологлары җәмгыятенең Казан бүлеге оештырыла (рәисе Г.А.Великанов).

Әд.: Алексеев А.М., Гусев Н.А. Влияние минерального питания на водный режим растения. М., 1957; Самуилов Ф.Д. Водный обмен и состояние воды в растениях в связи с их метаболизмом и условиями среды. К., 1972; Гордон Л.Х. Дыхание и водно-солевой обмен растительных тканей. М., 1976; Зялалов А.А. Физиолого-термодинамический аспект транспорта воды по растению. М., 1984; Чиков В.И. Фотосинтез и транспорт ассимилятов. М., 1987; Водный обмен растений. М., 1989; Тарчевский И.А. Метаболизм растений при стрессе. К., 2001; шул ук. Сигнальные системы клеток растений. М., 2002.

Ф.Д.Самуилов.

ҮСЕМЛЕКЛӘРДӘ БАКТЕРИА́ЛЬ АВЫРУЛА́Р, бактериозлар, авыру тудыручы бактерияләр китереп чыгара торган авырулар. Үсемлекләрне зарарлаучы күпчелек бактерияләр таякчыксыман формада була, хәрәкәтчән, төкчәләре капма-каршы урнашкан, аэроблар. Һаваның дымлылыгы югары, темп-ра 20–25 °С булганда нейтраль һәм аз селтеле мохиттә яхшы үрчиләр. Әчелекне яратмыйлар. Һава агымнары, су, бөҗәкләр, кешеләр, утырту материаллары һәм орлыклар ярдәмендә таралалар, үсемлекләргә мыекчалары, ясмыкчыклар аша, ш.у. каплагыч тукымаларны зарарлап үтеп керәләр. Үсемлек калдыкларында, орлыкларда, туфракта, бөҗәкләр тәнендә, чүп үләннәрдә сакланалар. Бактериаль инфекция еш кына системалы характерда; төп симптомнары: таплылану (некрозлар), шиңү, черек (ешрак юеш черек), хлороз, шеш барлыкка килү, экссудат тамчылары күренү. Яшелчәләр, җиләк-җимешләр, техник культуралар бик нык зарарлана. ТРда таралганнары: бәрәңге караягы, бәрәңгенең бөжрасы череге, яшелчә культураларының юеш череге (сакланган вакытта), кыяр бактериозы, томатның бактериаль рагы, көбестәнең тамыр һәм лайлалы бактериозы, җимеш культураларының тамыр рагы. Көрәш чаралары: а) авыруларга бирешмәүче сортларны куллану; б) чәчү әйләнешен саклау һәм дөрес агротехника; в) орлыкларны һәм утырту материалларын химик яисә термик ысул б-н зарарсызландыру; г) бактерияләрнең аз патогенлы штаммалары б-н үсемлекләрне вакцинацияләү; д) авыруларны күчерүче (таратучы) бөҗәкләргә каршы көрәш; е) орлыкчылык чәчүлекләреннән механик рәвештә авыру үсемлекләрне юк итү; ж) үсемлекләрне химик препаратлар б-н эшкәртү; з) эш коралларын, әрҗә-тартмаларны, саклау урыннарын дезинфекцияләү; и) яхшы режимда саклау.

Р.Сафин.

ҮСЕМЛЕКЛӘРДӘ ВИ́РУСЛЫ АВЫРУЛА́Р, үсемлекләрдә вируслар китереп чыгара торган авырулар. Симптомнары күптөрле — үсеш тукталу, төсе үзгәрү һәм органнар үзгәрү, некроз, үрчү функцияләре бозылу (үрчү сәләте бетү, орлыксызлык, чәчәкләр һәм җимешләр коелу). Үв.а.ны зарарланган организмга тәэсир итү характеры буенча ике зур төркемгә бүләләр — мозаикасыман һәм сары авырулы типтагы. Сары авырулы вируслы авырулар тамыр системасын зарарлый һәм бик көчле зыян китерә: үсемлек тулысынча яисә аерым өлешләре үзгәрә. Мозаикалы вируслы авырулар паренхима күзәнәкләрен зарарлыйлар, үсемлекләрнең төсе үзгәрә яки яфраклары җыерчыклана. Күпчелек фитопатологик вируслы авырулар зарарланган үсемлекнең орлыклары б-н алдагы буынга күчми, ләкин орлыктан күчә торган 90 вирус билгеле, ш.и. фасоль мозаика вирусы, соя мозаикасы, кыяр вирусы, тәмәке мозаика вирусы, салат мозаика вирусы. Вирусларның авыру үсемлектән сәламәтенә күчүнең берничә ысулын аералар: үзара бәйләнеш-ле-механика-үсемлекләрнең үзара бәйләнеше вакытында һәм векторлы-күчерүчеләр ярдәмендә (гөбләләр, цикодалар, кандалалар, трипслар, талпаннар, нематодлар, туфрак гөмбәләре). Вируслы инфекцияләр үсемлек калдыкларында, чүп үләннәрдә — резерваторларда (вирусларның табигый чыганагы) саклана. Вируслы авыруларның диагности -



Үсемлекләрдә бактериаль авырулар. 1.Томатта бактериаль рак; 2. Бәрәңге караягы; 3. Алмагачның тамыр рагы; 4. Томатның өстәге череге.



Үсемлекләрдә вируслы авырулар. 1. Бәрәңгенең җыерчыклы мозаикасы; 2. Бәрәңге яфраклары бөтерелү; 3. Чия мозаикасы.

ка алымнары: күз б-н карап, серологик, ш.и. иммун ферментлы анализ, үсемлек-индикаторлар алымы, электрон-микроскопик, күзәнәк эчендәге кушылу, полимероз чылбырлы реакция. Үз.в.а. бигрәк тә вегетатив ысул б-н үрчи торган культураларга, ш.и. бәрәңгегә зыян китерә. Аның вирус б-н зарарлануы ТРда 80–100% тәшкил итә, бу бәрәңге уңышын уртача 70–80% ка киметә. Х-, Ү-, М- бәрәңге вируслары иң күп таралган, шәхси бакчаларда туфрак вируслары табылган, алар нематодлар һәм кутыр споралары б-н күчәләр.

ТРда орлыклык бәрәңгене сәламәтләндерү өчен меристема нигезендә орлыкчылык системасы кертелә, аның нигезендә өстәге меристеманы аерып алу алымы б-н сәламәт башлангыч материал алу, авырулар б-н кабат зарарланудан саклаучы чаралар комплексы, орлыклык материалны сертификацияләү карала. Орлыклык бәрәңге кыска 6 еллык схема буенча җитештерелә: башлангыч материал — суперсуперэлита – суперэлита – элита – 1 нче репродукция – 2 нче репродукция. 2000 елда Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү институның бәрәңге биотехнологиясе үзәге 560 *т* сәламәтләндерелгән орлыклык бәрәңге җитештерә, бу 2002 дә респ-када — 104 мең *га* да, ш.и. 18 мең *га* җәмәгать бакчаларында һәм 86 мең *га* шәхси секторларда тулысынча сәламәтләндерелгән утырту материалы б-н тәэмин итәргә мөмкинлек бирә.

Әд.: Вирусные болезни сельскохозяйственных растений и меры борьбы с ними: Тр. V Всесоюз. совещания по вирусным болезням растений. Киев, 1966; Замалиева Ф.Ф., Сафиуллина Г.Н., Назмиева Р.Р. Внедрение системы семеноводства картофеля на оздоровлённой основе в РТ // Докл. на юбилейной науч. конф., посв. 200-летию РАН. К., 1999.

Ф.Ф.Җамалиева, Р.Сафин.

ҮСЕМЛЕКЛӘРДӘ ГӨМБӘ АВЫРУЛАРЫ, фитопатоген гөмбәләр китереп чыгара торган авырулар; а.х. үсемлекләренең иң зарарлы авырулары. Авыру тудыручы гөмбәләр тәэсирендә үсемлекләрдә патологик процесслар башлана (үсемлекләрнең төзелеше һәм физиол. функцияләре бозыла). Гөмбәләр — фитопатоген организмнарның күпсанлы төркеме. Ешрак башка авыруларны споралы гөмбәләр (ялган-ончыл чык) китереп чыгара. Кайберләре черек барлыкка китерә (паслён - чалар фитофторозы); сумкалы гөмбәләр (аскомицетлар) яфракларның бөтеркәләнүен, шомырт һәм сливада «кесәләр», ончыл чык, кыяклыларның арыш анасы, алма кутыры авыруларын китереп чыгара; базидиаль гөмбәләр корымбаш (кисәү), тутык авыруларын, ә җитлекмәгән гөмбәләр таплылыкны, черек авыруларын барлыкка китерә. Үг.а. урыны б-н (алма һәм груша кутыры, ончыл чык, тутык) яисә тулысынча (үсемлекләрнең җиңүе) зарарлау б-н характерлана. ТРда корымбаш (кисәү гөмбәсе), кутыр, ончыл чык, рак, тутык, аскохитозлар, фитофторозлар (к. 280 биттәге рәсемне) таралган. Авырулар бүлбеләр, орлыклар, суганчалар, чыбыкчалар, үсентеләр һәм үсемлекләрнең башка өлешләре ярдәмендә күчәләр (таралалар). Патоген гөмбәләр үсемлекләр тукымасына күзәнәкләр, ясмыкчыклар, кутикула (бәрәңге рагы, кәбестә киласы (лайлачлар), боз сугудан, каты эсседән, салкыннан барлыкка килгән җәрәхәтләр, ярыклар (алмагачтагы кара рак) аша үтеп керә. Авыруларны төп таратучылар булып бөҗәкләр санала: алар үсемлекләрне зарарлап инфекция кертәләр. Үсемлекләрне гөмбә авыруларыннан саклау өчен агротехник (авыруларга бирешмәүче сортлар үстерү, туфракны дөрес эшкәртү, яхшы карау, ашламалар куллану), биол. (микробиопрепаратлар куллану) һәм химик (орлыкларны, туфракны фунгицидлар б-н эшкәртү; саклау урыннарын, эш коралларын йогышсызландыру) чаралар комплексын куллану карала.

Әд.: Поспелов С.М., Арсентьева М.В., Груздев Г.С. Защита растений. Л., 1973; Справочник агронома по защите растений. М., 1979; Защита растений и охрана природы в Татарстане. К., 2000.

О.Л.Горшевникова, Ф.С.Зыятдинов.


ҮСЕМЛЕКЛӘРНЕҢ СУ РЕЖИМЫ, күзәнәктә суның халәтен һәм ролен, үсемлек организмының су алмашы экологиясен һәм механизмын өйрәнүче үсемлекләр физиологиясе бүлеге. Тәгълиматның формалашуы 19 йөз ахыры — 20 йөз башына карый.

Татарстанда Үг.р. тикшеренүләре 1930 еллар да сабан бодаеның чәчәк ату динамикасына туфрак корылыгының йогынтысын өйрәнүдән башлана (А.М.Алексеев). Куаклану фазасына туры килгән корылык чәчәк ату чорын тизләтә, ә башаклану фазасында — аның озынлыгын киметә; корылыкның ике фазага да (куаклану һәм башаклану) йогынтысы вакытында чәчәк ату сузыла, яфрак үсешендә корылыкка элек уйлаганча тартылу түгел, ә аеруча эмбриональ үсеш этабы сизгер. Корылык тәэсирендә яфраклардан килүче пластик матдәләр каналларын тоткарлау фактлары ачыклана, ул бу шартларда фотосинтез интенсивлыгының (А.М.Алексеев, 1939), тамырларның минераль туклану элементларын (Р.Ш.Гилдиев, Х.Г.Хәйруллин, 1940) һәм суны (Н.А.Гусев, 1940) йоту факторларының кимүендә төп сәбәп булып тора.

Үг.р. турындагы тәгълимат үсешенең икенче этабы булып үсемлекләр физиологиясенә «суның химик потенциалы» төшенчәсен (А.М.Алексеев, 1948) кертү һәм үсемлек организмы тереклеге процесслары суның күләме б-н түгел, ә аның термодинамик халәте (энергия берәмлекләрендә яки чагыштырма зурлык — активлык б-н бәяләнә) б-н билгеләнүе турындагы фикер тора. Гадәти күрсәткечләр (суыру көче, су потенциалы, диффузия басымы дефициты) су халәтен зур төгәлсезлекләр б-н бәялиләр, бу күзәнәктә суның парциаль мольле күләменең зурлыгы алмашынучан булуы б-н бәйле һәм суның мольле күләме зурлыгына тигез түгел (А.А.Җәләлов, 1984).

Суның термодинамик халәте мәсьәләләрен чишү б-н бер үк вакытта үсемлекчелек практикасына турыдан-туры бәйле минераль туклану һәм су режимының үзара багланышлары тикшерелә (А.М.Алексеев һәм Н.А.Гусев, 1957; Ф.Д.Самуилов, 1972). Үсемлекләрнең билгеле бер үсеш фазасында фосфорлы һәм азотлы ашламалар кертү юлы б-н а.х. культураларының су режимын оптималләштерү буенча гамәли рекомендацияләр бирелә. Матдәләр алмашы ингредиенты буларак су алмашы һәм метаболизмда су режимының роле турында өр-яңа нигезләмә булдырыла (А.М.Алексеев, 1960). Энергия алмашулы үсемлек күзәнәкләрендә су алмашы һәм су халәте арасындагы үзара бәйләнеш билгеләнә (Ф.Д.Самуилов, 1968, 1972). СССРда беренче тапкыр углеродның постфотосинтетик юлына су режимының йогынтысы тикшерелә (И.А.Тарчевский, 1964); күзәнәкләрдә төрле су фракцияләренең хәрәкәтчәнлеге һәм тиз алмашынучанлыгы, күзәнәкләр һәм атм. арасында су алмашы билгеләнә (Ф.Д.Самуилов, 1962). Үсемлекләрнең су тоту үзлеге су тоту көче б-н түгел, ә структураларның су үткәрүчәнлеге б-н билгеләнүе исбатлана (А.А.Җәләлов, 1969), авызчыктан тыш транспирация механизмы ачыклана (А.А.Җәләлов, 1977).

И.Г.Сөләйманов тарафыннан эшләнгән ферментлар активлыгының күзәнәктәге су халәтенә бәйлелеге концепциясе, хәзерге заман физик алымнарны (ТМР, диэлектрик инфракызыл спектроскопия) куллану зарурлыгын нигезләү Үг.р. өйрәнүдә «молекуляр» этап ачалар. Казан галимнәре В.Д.Корепанов, Н.А.Мальцев, Л.А.Абецедарская, А.В.Анисимов, Ф.Д.Самуилов, Л.П.Хохло -



Кыяклыларда, яшелчәләрдә, җимеш һәм җиләк культураларында гөмбә авырулары. 1. Бодайның яфрак көрән гөмбәсе; 2. Кыяклыларның сабак гөмбәсе; 3. Бодайда тузанлы корымбаш; 4. Бодайда каты кисәү гөмбәсе; 5. Алмагачта кара рак; 6. Груша паршасы; 7. Алмагач паршасы; 8. Алмагачның җимеш череге; 9. Бәрәңге паршасы; 10. Бәрәңге фитофторозы; 11. Томат фитофторозы; 12. Кара карлыганда антракноз; 13. Крыжовникта ончыл чык; 14. Каен җиләгендә соры черек; 15. Сливада клястероспориоз; 16. Чия коккомикозы.

ва, И.Н.Ишмөхәммәтова, Н.В.Седых, Г.А.Великанов, В.Д.Федотов дөньяда беренчеләрдән булып күзәнәктә су структурасын, аларның структурасына аксым һәм суның үзара йогынтысын тикшерәләр. Молекуляр механизмнарны өйрәнү б-н берәттән организм һәм күзәнәктә суның функциональ роле тикшеренүләре дәвам ителә: функцияләр координациясендә су роле концепциясе эшләнә (А.П.Петров, 1972); су агымының калий агымы б-н бәйләнеше механизмы һәм калий циркуляциясенең физиол. процессы билгеләнә (А.А.Җәләлов, 1979); көзге кыяклы культураларның кышкы шартларга әзерләнү чорында адаптив стратегия механизмнарының берсе ачыклана, ул күзәнәкләрнең су үткәрүчәнлеге һәм су тоту үзлегенең кимүенә китерүче мембраналар «липидизациясеннән» гыйбарәт (Л.П.Хохлова, 1976); күзәнәк мембранасы ион транспортлаучы системаларның тамыр (Л.Х.Гордон, 1976) һәм циклик аденозинмонофосфат һәм кальций (Ф.Г.Кәримова, 1994), цитоскелет (Л.П.Хохлова, 1997), плазмодесманы (А.В.Анисимов, 1992; Г.А.Великанов, 1998) үз эченә алучы икенчел система — арадашчыларда күзәнәк эчендә су алмашын көйләүдә роле ачыклана һәм бәяләнә. И.А.Тарчевский җитәкчелегендә үсемлекләрдә тискәре факторларга, ш.и. корылыкка каршы чыдамлылыкны формалаштыру буенча молекуляр механизмнар өлкәсендә яңа мәгълүматлар алына. ТР ФАнең *Экология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану проблемалары ин-тында* су мохитендәге автономияле торышына нигезләнеп, үсемлекләрнең коры җирне үзләштерүе теориясе эшләнә (А.А.Җәләлов, 2005).

Үс.с.р. юнәлеше СССР ФАнең биол. бүленгенең күчмә сессиясендә фәнни мәктәп буларак формалаша (Казан, 1960).

Әд.: Алексеев А.М. Водный режим растений и влияние на него засухи. К., 1948; Алексеев А.М., Гусев Н.А. Влияние минерального питания на водный режим растения. М., 1957; Тарчевский И.А. Фотосинтез и засуха. К., 1964; Самуилов Ф.Д. Водный обмен и состояние воды в растениях в связи с их метаболизмом и условиями среды. К., 1972; Гусев Н.А. Состояние воды в растении. М., 1974; Сулейманов И.Г. Состояние и роль воды в растении. К., 1974; Гордон Л.Х. Дыхание и водно-солевой обмен растительных тканей. М., 1976; Хохлова Л.П. Роль структурно-функционального состояния митохондрий при адаптации растений к низкой температуре. К., 1976; Зялалов А.А. Физиолого-термодинамический аспект транспорта воды по растению. М., 1984; Анисимов А.В., Раткович С. Транспорт воды в растениях. Исследования импульсным методом ЯМР. М., 1992; Тарчевский И.А. Сигнальные системы клеток растений. М., 2002.

А.А.Җәләлов.

ҮСЕМЛЕКЧЕЛЕ́К, 1) а.х.ның төп тармаклары ннан берсе, халыкны — туклану продуктлары, терлекчелекне — азык, сәнәгатьнең азык, җи ңел, катнаш азык, фармацевтика тармаклары пр-тиеләрен чимал б-н тәэмин итә. Үз эченә *бөртекле ашлык хуҗалыгын, бәрәңге үстерүчелекне*, яшелчәчелекне, *чүгендер үстерүчелекне*, бакчачылыкны, *терлек азыгы* җитештерүне, болынчылыкны ала. 2) культуралы үсемлекләр, югары, тотрыклы уңыш алу өчен аларны үстерү алымнары турындагы фән; агрономия бүлеге. Үс. *туфрак белеме, игенчелек, метеорология, үсемлекләр физиологиясе, биохимия, үсемлекләр генетикасы* һәм *селекциясе, орлыкчылык*, а.х. *микробиологиясе, агрофизика, агрохимия, үсемлекләрне саклау* б-н тыгыз бәйләнгән.

Городец культурасы кабиләләренең *бодай* (борай), *арпа, тары* үстергәннәре билгеле. Идел буе Болгар дәүләте һәм *Казан ханлыгында* шулай ук *арыш, борчак, ясмык, карабодай* игәләр. Аннан соңгы йөзләрдә а.х. культураларының саны *солы, бәрәңге, клевер, җитен, киндер, мәк* б-н тулыландырыла. Төп азык культурасы арыш була. Язгы культуралардан солы әйдәп баручы урынны алып тора. А.х. культураларының шундый җыелмасы Татарстанда а.х. *күмәкләштерүгә* кадәр кала. 1930 елларда үлән басулы чәчү әйләнеше кертелүгә бәйле терлек азыгы культураларының мәйданы, бигрәк тә вика һәм күпьеллык үләннәр: клевер, люцерна, тимофеевка, солыча мәйданнары арта. 1940–60 та бәрәңге басуларының мәйданнары сизелерлек арта. 1958 дә шикәр чүгендере үстерелә башлый, 1960 та терлек азыгы максатында кукуруз җитештерү гамәлгә кертелә. Бу чорда тамыразыклар, силос өчен көнбагыш, сенаж өчен азык катнашмалары һәм үлән оны культуралары чәчелгән мәйданнар арта, чиста пар мәйданнары, күпьеллык үләннәр игү кими; бөртеклеләргә пар биләүче культуралар буларак борчак мәйданнары 106,2 мең *га* дан (1960) 464,7 мең *га* га (1970) арта. 1970–80 дә Үс.нең яңа тармагы барлыкка килә — сугарулы игенчелек: сугарулы культуралы көтүлекләр барлыкка килә, ачык ябык грунтта яшелчә культураларын җитештерү күп тапкырлар арта. А.х. культураларының гомуми чәчүлек мәйданы 3655,6 мең *га* га (1970), бөртекле культуралар — 2393,6 мең *га* га (1980) җитә. 1990 да чәчүлекләр мәйданы 3402,4 мең *га*, ш.и. бөртекле культураларның мәйданы 1954,8 мең *га* тәшкил итә. ТРда *а.х. җирләре* 4538,8 мең *га* били (2009), шулардан табигый терлек азыгы җирләре — 1057,9 мең *га*, сөрүлек җирләр — 3441,6 мең *га*, ш.и. а.х. культуралары чәчүлекләре 3028,5 мең *га* (88%) били, шулардан бөртекле культуралар — 1656,4 мең *га*. Республикада чәчүлек мәйданнарының структурасы (барлык категория хуҗалыкларда, % ларда): бөртекле культуралар — 54,7, ш.и. уҗым культуралары — 18,8 (бодай — 11,7, арыш — 5,8); язгы бөртекләләр — 35,9 (бодай — 16,7, арпа — 13,2, солы — 1,8, тары — 0,1, карабодай — 0,6, ашлыкка кукуруз — 2,0, бөртекле-күзаклылар — 1,5, ш.и. борчак — 1,3); техник культуралар — 6,5 (шулардан шикәр чүгендере — 2,4, май культуралары — 4,1, кольза (язгы рапс) — 3,8); бәрәңге һәм яшелчә культуралары — 3,6 (бәрәңге — 3,2, яшелчә — 0,4); терлек азыгы культуралары — 35,2 (тамыразыклар, терлек азыгына шикәр чүгендерен кертеп — 0,1, терлек азыгына кукуруз һәм сенаж — 7,7, берьеллык үләннәр — 7,1, узган елгы чәчүлекләрдәге күпьеллык үләннәр — 18,2). 2009 да Үс. продукциясе 57,6 млрд. сумга җитештерелгән (барлык а.х. продукциясенең 49,5% ы). Үс. тармаклары (культуралары) буенча продукция бәясендә тоткан урыны — бөртекләләр — 31,5%, техник культуралар — 4,2%, бәрәңге — 34,1%, яшелчә — 15,0%, җиләк-җимеш — 4,2%, терлек азыгы 7,9% тәшкил итә. Татарстанның Үс. тарихы җир сөрү, тырмалау кебек туфрак эшкәртүдә кулланыла торган коралларның күплеген күрсәтә (к. *Авыл хуҗалыгы, Бөртекле ашлык хуҗалыгы, Крәстияннәр, Машина-трактор станциясе, Кулбай-Мораса* а.). Үс.не механикалаштыру дәрәҗәсе даими күтәрелә бара, 1960 тан Татарстан Үс.ндә бөртекле ашлык, терлек азыгы җитештерү, чәчү һәм а.х. культураларын карау буенча барлык а.х. эшләре механикалаштырыла.

1990–2000 дә респ-када яңа технологияләр куллану нәтиҗәсендә шикәр чүгендерен үстерү һәм уңышын җыюны механикалаштыруда сизелерлек алга китеш була. Үс.кә яңа техника һәм алдынгы технологияләрне кертү 2001 дә барлык а.х. культураларын җитештерүдә хезмәт чыгымнарын киметүгә мөмкинлек бирә. Әмма сатыла торган а.х. продукциясенә һәм а.х. пр-тиеләре тарафыннан сатып алына торган техника; ашлама, үсемлекләрне саклау чараларына бәяләрнең үзара ярашмавы нәтиҗәсендә Үс. продукциясенең үзкыйммәте структурасында матди чыгымнарның тоткан урыны кинәт арта, ул 1995 тә 58%, 2000 дә 76%, 2007 дә 73% тәшкил итә.

Үс.нең фән буларак төп тикшеренү объектлары — а.х. үсемлекләре (аның биологиясе, әйләнә-тирә мохиткә — аграр шарталарга мөнәсәбәте), үсемлекләрне классификацияләү, а.х. культураларының биологик һәм экологик үзенчәлекләрен билгеләү, сортларны (гибридларны) районлаштыруны фәнни нигезләү, хуҗалык-кыйммәтле үсемлекләрне интродукцияләү; Үс. продукциясен җитештерү технологияләрен (агротехника системасын) эшләү. Басу культураларын классификацияләү нигезенә җитештерү билгеләре салынган: бу культураларны үстерү максаты һәм алымнары, үсемлелкәрнең биологик үзенчәлекләре, аларның химик составы. Аерым культураларның өйрәнелә торган биол. үзенчәлекләре: а.х. үсемлекләренең вегетация чоры дәвамлылыгы; органогенез, аларның үсеш ритмнары; морфогенез һәм вегетация фазалары өзлеклелеге; тамыр системасы һәм ассимиляция өзлеге, ш.у. үсемлекләрнең хуҗалык-файдалы органнары һәм өлешләренең формалашу динамикасы, фотосинтез һәм сулавы, коры матдәнең тупланыу; матдәләр алмашы; су һәм башка режимнар; кышка, салкынга, корылыкка чыдамлылыгы. Үстерелә торган культураларның биол. һәм экологик үзенчәлекләренә анализ, туфрак-климатик һәм җитештерү шартлары, селекция казанышларын һәм җитештерү сынаулары нәтиҗәләрен сынау һәм саклау буенча Дәүләт комиссиясе мәгълүматлары нигезендә үсемлекләрнең сортлары һәм гибридлары чәчәргә рөхсәт ителә, а.х. культураларын үстерүнең рациональ технологияләре эшләнә. Татарстанда Үс. үсешенә галимнәрдән И.И.*Штуцер*, И.И.Благовещенский, В.П.*Мосолов*, Б.И.*Горизонтов*, Н.М.Феофанов, П.А.Трухин, К.И.Попов, Н.И.Благовещенский,

А.К.*Вершинин*, А.В.*Ватагин*, Аб.А.*Җиһаншин*, П.М.*Тихонов*, В.П.Краюшкин, М.З.Гайнетдинов, В.Н.*Мещанов*, П.М.Крайнов, Г.Д.*Аверьянов*, Ал.А.*Җиһаншин*, селекция белгечләреннән Е.Н.Борисова, Х.Х.*Байчурова*, Ш.В.*Вәлиев*, П.С.Зубков, Г.И.Попов, Е.И.Ивенина, М.Н.*Шумкова*, А.Ф.*Шубина*, Н.Н.*Петелина*, В.З.*Шәкуров*, Г.С.*Галиев*, Ж.Х.*Шәрәф*, Ф.М.Киселёв, Х.Г.Бакжанов, А.Ф.*Демидович*, Г.Н.*Розанова*, Э.Ф.*Ионов*, В.М.Суркова, Ф.З.*Кадырова*, Л.Г.*Сәгъдиева*, К.Г.*Азиев*, Э.Д.Неттевич өлеш кертәләр.

Ү. проблемалары Казан аграр ун-тында, Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында, Россия А.х. академиясенең Татарстан агрохимия һәм туфрак белеме фәнни-тикшеренү ин-тында, «Татарский» агрохимия хезмәте үзәгендә һәм респ-каның башка фәнни уч-реждениеләрендә өйрәнелә.

Әд.: Растениеводство. М., 1958; Система ведения отраслей агропромышленного комплекса Республики Татарстан. К., 1992; З и г а н ш и н А.А. Современные технологии и программирование урожайности. К., 2001; Слагаемые эффективного агробизнеса: Обобщение опыта и рекомендации. Ч. 1. Земледелие и растениеводство. К., 2005.

И.Н.Афанасьев.

ҮСКӘ́ авылы, Түбән Кама р-нында, Түбән Кама шәһәреннән 22 *км* көньяктарак, Зәй елгасы буенда. 2010 елда 173 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 92%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, яшелчәчелек, мөгезле эре терлек асрау. 1678 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Түбән Аты, Оскина буларак та билгеле, 1997 гә кадәр рәсми исеме — Кече Аты. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү-приход мәктәбе, тимерче алачыгы, ашлык саклау-сату һәм 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1080,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Сухарево волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Ширәмәт, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1965 нең 12 гыйнварыннан Түбән Кама р-нында. Халык саны: 1859 да — 402, 1870 тә — 340, 1897 дә — 676, 1906 да — 630, 1920 дә — 759, 1926 да — 434, 1949 да — 453, 1958 дә — 416, 1970 тә — 453, 1979 да — 407, 1989 да — 240, 2002 дә — 223 кеше.

«ҮСҮ́ ЮЛЫ́», яшь татар язучылары альманахы. ТАССР Язучылар берлеге органы. 1950–58 елларда Казанда татар телендә нәшер ителә. Елына 3–4 чыгарылыш әзерләү ниятләнә, чынлыкта елга 1–2 тапкыр гына басыла (13 чыг.). Мөхәрририят б-н 1950 дә ТАССР Язучылар берлегендә әдәби консультант булып эшләүче язучы һәм тәнкыйтьче Г.*Иделле* җитәкчелек итә. Мөхәрририяткә төрле елларда күренекле татар язучылары — Г.Әпсәләмов, Ә.Әхмәт, И.Гази, А.Гомәров, Ә.Давыдов, Ә.Еники, Ш.Маннур, Г.Минский, Ш.Мөдәррис керә. Альманахның төп эчтәлеген кечкенә жанр поэзиясе һәм прозасы: шигырьләр, зур булмаган хикәяләр, очерклар тәшкил итә. Аның битләрендә Ә.Баян, Р.Гәрәй, Ә.Еники, Г.Зәйнашева, Р.Ишморат, Х.Камалов, К.Латыйп, Н.Мадъяров, З.Мәҗитов, З.Мансур, М.Миншин, С.Поварисов, М.Хөсәен, И.Юзеев һ.б.ның әсәрләре бастырыла. «Ү.ю.»нда дөнья күргән эре жанрдагы әсәрләр арасында С.Кальметовның «Соңгы очрашу», Ю.Әминовның «Язылмаган законнар» драмалары, Г.Зәйнашеваның «Көйсез кияү», Я.Гыйззәтуллинның «Гашыйклар» пьесалары бар. «Яшь язучыга ярдәмгә» сәхифәсендә атаклы язучылар һәм тәнкыйтьчеләр, ш.и. Ә.Еники («Хикәя жанры турында кайбер фикерләр», 1954, 7 чыг.), И.Нуруллин («Г.Тукай әдәби осталыкның кайбер мәсьәләләре турында», 1955, 8 чыг.), Г.Минский («Иҗат һәм таләп», 1956, 10 чыг.), Н.Юзиев («Поэтик әсәрнең интонацион-ритмик рәсеме турында», 1957, 12 чыг.), С.Сафуанов



«Үсү юлы» альманахы.

(«И.Газинең «Онытылмас еллар» повесте теле һәм стиле», 1958, 13 чыг.) әдәби иҗатның үзенчәлекләре турындагы фикерләрен бәян итәләр. Альманахның 12 чыгарылышында (1957) Г.Әпсәләмовның ТАССР яшь язучыларының 2 нче респ-ка семинары эше нәтиҗәләре турындагы мәкаләсе дөнья күрә. 1958 дә «*Идел*» альманахы итеп үзгәртелә.

Р.А.Айнетдинов.

ҮТӘБА́Й-КӘРИМИ́ Равил Алексеевич (30.8.1933, Теләче р-ны Казаклар а. — 4.3.2005, Уфа ш., туган авылында жирләнә), тарихчы, ислам дине белгече. 1950–52 елларда Мәскәү көнчыгыш телләр ин-тында, аннары Казан пед. ин-тында укый, аны тәмамлаганнан соң (1956), Башкортстан АССР-ның халык мәгарифе системасында эшли. 1988–91 дә РФА Уфа фәнни үзәгенең Тарих, тел һәм әдәбият ин-тында. 1992–94 тә Уфада мәдрәсә б-н җитәкчелек итә, бер үк вакытта Россия һәм БДБның Европа илләре мөселманнары Үзәк Диния нәзарәтенең гыйльми шурасы әгъзасы була. 1996–97 дә әл-Фатих ун-тында (Истанбул ш., Төркия). Татар, башкорт халыклары мәдәнияте тарихына, ислам дине белеменә, Шәрекъ халыкларына аң-белем таратуга багышланган хезмәтләр авторы. Р.Фәхретдин, М.Гафури, З.Кадыйри һ.б.ның хезмәтләрен бастыруга әзерли. Шәрекъ галимнәренең хезмәтләрен рус, татар, башкорт телләренә тәрҗемә итә.

Х е з м.: Мәгрифәтселек әҗҗәренән. Өфө, 1991; Ислам: Белешмә-сүзлек. К., 1993.

Әд.: Б а т у л л а Р. Коръәндә хата булганмы? // Ватаным Татарстан. 2007. 5 май; Шәркыять илчесе: мәгълүматлар җыентыгы / Төз. Р.Х.Тимергалин, И.Г.Һадиев. К., 2008; Учёный-востоковед и исламовед Равиль Утябай-Карими: Сб. статей и биобиблиогр. материалов. К., 2008; Башкирская энциклопедия. Уфа, 2010, Т. 2.

ҮТӘГӘ́Н авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 85 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Бимә елгасы буенда. 2010 елда 287 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп. 17 йөз ахырында — 18 йөз башында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы типтәрләр һәм асабаларга бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәдрәсә, мәктәп, рус-татар земство мәктәбе, тегермән эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3593 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Сарапул өязе Исәнбай волостенда, 1921 дән ТАССРның — Әгерҗе, 1924 тән — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Красный Бор, 1960 ның 28 октябреннән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1859 да — 249, 1887 дә — 487, 1905 тә — 1093, 1920 дә — 1195, 1926 да — 1295, 1938 дә — 1106, 1949 да — 1051, 1958 дә — 793, 1970 тә — 713, 1989 да — 408, 2002 дә — 364 кеше.

Әд.: М ә р д а н о в Р.Ф., Һ а д и е в И.Г. Әгерҗе төбәге тарихы. К., 2003.

ҮТӘГӘ́НОВ Эдмас Хәмит улы (16.2.1931, Казан — 11.7.2012, шунда ук), кинорежиссёр, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1992). Мәскәүдәге Дәүләт театр сәнгате ин-тының (ГИТИС) театр сәнгате гыйлеме ф-тын (1964), Ленинградта телевидение режиссёрлары курсларын (1963) тәмамлый. 1958–60 елларда — Татар респ-ка күчмә театрында режиссёр ярдәмчесе. 1960–91 дә Казан телевидение студиясе режиссёры, бер үк вакытта, 1978–2002 дә, Казан кинохроника студиясе кинорежиссёры, 1991–97 дә ТР Гос-киносында иҗади мәсьәләләр буенча белгеч. 2008 дән Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тында (хәзер Казан мәдәният ин-ты) укыта. Ү. тарафыннан Казан кинохроника студиясендә төшерелгән беренче «Халык комиссары турында хикәят» (Мулланур Вахитовка багышлана, 1966) фильмы Куйбышев шәһәрендә (Самара) узган зона кинофорумында 1 нче дәрәҗә дипломга лаек була. Хөсәен Ямашев турында фильмның (1967), «Совет Татарстаны» (2 серияле, 1969), «Сезнең йортыгызга тыныч-лык» (1972), «Якты юл» (1976) фильмнарының, ТАССР телевидениесендә күрсәтелгән «Кадерле кичәләр» (1971–76), «Әллүки-бәллүки» (1977–79) тапшырулары цикларының режиссёры. «Киң Иделдә» кинож-лының 50 дән артык чыгарылышын эшләүдә катнаша. 1988–2003 тә Ү. Татарстанның танылган фән һәм мәдәният эшлеклеләре турында фильмнар сериясен төшерә: «Галимҗан Ибраһимов» (1988), комп. Сара Садыйкова турында «Моңсара» (1996), «Рәссам Илдар Ханов», «Композитор София Гобәйдуллина», «Шагыйрь Ренат Харис», «Салих Сәйдәшев» (барысы да —

2001 дә), «Академик Мансур Хәсәнов» (2003); 13 Советлар Союзы Герое — Бөек Ватан сугышында катнашкан Татарстанлылар (2 сериял е, 1993) турында фильм, «Җиңү киләсенә мин ышандым» (1995) фильмы. Медаль б-н бүләкләнә.

Әд.: Алексеева Е.П. Союз кинематографистов Республики Татарстан: 25 лет. К., 2006.

Е.П.Алексеева.

ҮТӘГӘ́НОВЛАР, Казан сәүдәгәрләре һәм эшмәкәрләре. **Фәхретдин Исмәгыйль улы** (? — 1906, Казан). Башта Казанның 2 нче гильдия сәүдәгәре М.Бигаевта эшли, 1875 елда Шәрекъ халыклары баш киемнәре, галантерея һәм химия товарларын күпләп сату өчен үз пр-тиесен ача. Казан һәм Уфа губерналары базарларында сәүдә итә. Сәүдәгәрләр катлавында тормый, шулай да Казанның иң эре сәүдәгәрләренең берсенә әверелә. Гаилә эшен Фәхретдиннең уллары **Габдулладжан** (9.8.1874, Казан – 11.9.1937, шунда ук), **Габдрахман** (23.1.1878, Казан – 1960, шунда ук) һәм **Сәләхетдин** (1880, Казан – 1928) дәвам иттерәләр. 1908 нең 21 гыйнварында әнә-галантерея һәм химия товарлары б-н сәүдә итүче «Борадәр Үтәгәновлар» сәүдә йорты (устав капиталы 15 мең сум) оештыралар. Продукцияне Казан, Мәскәү, С.-Петербург фабрикантларыннан сатып алалар, аны Казанда, Уфада, Вяткада, Пермьда, Себер һәм Урта Азия шәһәрләрендә саталар. Сәләхетдин Үк. «Казан шәһәренең ярлы мөселманнарына ярдәм итү җәмгыяте» идарәсе әгъзасы була. Габдуллажан Үтәгәнов 1933 тә оештырылган «*контрреволюцион фетнәчеләр оешмасы*» эше аша үтә; үлгәннән соң аклана.

Әд.: Латыпова Р. Трагедия купцов Утягановых // Идель. 1992. № 1–2; Золотые страницы купечества, промышленников и предпринимателей Татарстана. К., 2001. Т. 1.

Р.Р.Салихов.

ҮТӘ́Й Ибраһим Вәлиәхмәт улы (24.5.1896, Уфа губ., Бәләбәй өязе Зильдярово а. — 7.11.1981, Казан), туфрак белгече, а.х. фән. канд. (1939), проф. (1966), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1966). 1919 елда укытучылар семинариясен (Оренбург өлкәсенең Троицк ш.) тәмамлаганнан соң, Голҗа шәһәрендә (Кытай) укытучы булып эшли. Мәскәү а.х. академиясен тәмамлаганнан соң (1929), туфрак тикшерү буенча экспедицияләрдә катнаша. 1931–73 тә Казан а.х. институның туфрак белеме каф. мөдире, бер үк вакытта, 1931–32 дә, Казан ун-тының туфрак белеме каф. һәм туфрак-агрохимия бүлеге мөдире. Көлсу, кәсле-көлсу һәм урман-дала туфракларын культуралаштыру алымнарын эшли. 1953 тә ПУ-2Я-3–35 тибындагы ике яруслы сабан ясый. Беренче бөтендөнья сугышында катнаша. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, РСФСР, ТАССР ЮС Президиумнары Мактау грамотасы б-н бүләкләнә. Казан аграр ун-тының төп бинасына мемориаль такта куела.

Хезм.: Основы почвоведения. К., 1935; Новый метод создания высокоплодородного пахотного слоя. К., 1941; Агропроизводственная характеристика почв Татарии и их рациональное использование. К., 1968.

Әд.: Рафиков А.Х. Цель его жизни. К., 1979; Казанский государственный аграрный университет. 1922–2007. К., 2007. Гаитов М.Я. Безнең яраткан укытучыбыз // Идел. 2008. № 3.

Р.Ә.Әсретдинова.

ҮТӘ́Й Рөстәм Ибраһим улы (14.12.1943, Казан), дирижёр, скрипкачы, педагог, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1993). Казан консерваториясен тәмамлый (1973). 1962 елдан — Ульянов өлкәсенең Иске Кулаткы авылындагы музыка мәктәбендә, 1965 тән Казанның 5 нче музыка мәктәбендә укыта. 1966–75 тә Татар филармониясенең симф. оркестры артисты, 1976–78 дә — Мари муз.-драма театры (Йошкар-Ола ш.), 1978–83 тә Татар опера һәм балет театры дирижёры, 1983–90 да Казан музыка уч-щесендә укыта. 1990–2010 да ТРның Дәүләт эстрада-симф. оркестрының сәнгать җитәкчесе һәм дирижёры. Оркестр репертуарын популяр джаз классикасы, халык көйләренең заманча эшкәртмәләре, татар композиторларыннан Б.Мөлеков, А.Монасыйпов, Р.Абдуллин, Л.Батыр-Болгари, Л.Хәйретдинова һ.б.ның эстрада музыкасы тәшкил итә. Үк. җитәкчелегендәге оркестр радио һәм телевидение өчен шактый күләмдә фонд язмаларын гамәлгә ашыра, актив концерт эшчәнлеге алып бара.

ҮТӘ́К елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Идел елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 51,7 *км*, ТР чикләрендә — 15,6 *км*. Бассейнының мәйданы 582,4 *км*². Идел аръягы түбәнлегеннән ага. Елга башы Әлки р-ны Катюшино авылы читендә, урта агымы — Ульянов өлкәсе терр-ясендә, тамагы Спас р-ны Танкеевка (Тәнкәй) авылыннан 7 *км* көнбатыштарак. Елганың түбән агымы Ульянов өлкәсе б-н Татарстан арасында табигый чик булып тора. Елганың тамак өлеше участогын Куйбышев сусаклагычы сулары күтәрә. Елга башының абс. биеклеге 145 *м*, тамагыныкы — 53 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 20%. Үнең 1,2 дән алып 14,5 *км* га кадәр озынлыктагы 7 кушылдыгы бар. Аеруча зурысы — Ясачка елгасы (уң кушылдык). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,16 *км/км*². Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Коры вакытта елганың аерым участоклары һәм аның кушылдыклары еш кына кибәләр. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,17 *м*³/*с*. Язын суы каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*. Елгада суының гомуми күләме 0,3 млн. *м*³ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

ҮТӘ́К (Өтәк) авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 20 *км* көнбатыштарак, Олы Бахта елгасы буенда. 2010 елда 1 кеше (рус) яши. 1680 елларда йомышлы татар Үтәчкә Мөрәсов нигез сала; 18 йөздән — рус авылы. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Үтә земство мәктәбе, су һәм җил тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 182 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Иваново волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан Чистай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 37 ир-ат; 1859 да — 310, 1897 дә — 323, 1908 дә — 490, 1920 дә — 478, 1926 да — 538, 1938 дә — 363, 1949 да — 264, 1958 дә — 188, 1970 тә — 122, 1979 да — 74, 1989 да — 25, 2002 дә — 6 кеше.

ҮТӘ́К МӘДРӘСӘСЕ́, Уфа губ., Эстәрлетамак өязе Үтәк а. (хәзер БАССРның Гафури р-ны). Якынча 1890 елда Үтәк авылындагы җамигъ мәчет каршында имам-хатип *Үтәки* тарафыннан нигезләнә. Үм.нда укыту яңа алым б-н алып барыла, башка мәдрәсәләрдән аермалы буларак, анда а.х. фәннәре, 1912 дән рус теле укытыла. Бер үк вакытта 200 дән артык шәкерт укый; Казан сәүдәгәрләре М.М.Галикәев (к. *Галикәевләр*) һәм М.Усманов акчасына 7 таш бинадан комплекс төзелә. Үтәки үлгәнче эшли (1921). Шәкертләре арасында — Ә.Ә.Вәлиди (Үтәкинең оныгы), Г.*Гомәри*.

Әд.: Сулейманова Л.Ш. Исламские учебные заведения в крае в начале XX века // Медресе Южного Урала: история и современность: Хрестоматия. Уфа, 2010.

ҮТӘКИ́ (Эстәрлетамакый) Хәбибеннажәр бине Мөхәммәдкәфи (12.9.1862, Уфа губ., Эстәрлетамак өязе Үтәк а. — 29.6.1921, шунда ук), дин эшлеклесе, язучы. «Мәр җания» мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли. Ш.*Мәрҗани* шәкертләреннән берсе, аның үлеменнән соң, туган авылына кайта (1889), Үтәк мәдрәсәсен оештыра, шәкертләр укыта, имам-хатип булып тора. 20 йөзнең 1 нче яртысында татар газета-журналларында мәкаләләрен бастыра. «Китабе мифтах әт-тәварих» («Тарихка ачкыч китабы», 1889) әсәре, «Нәвадир тәрҗемәсе» исемле үгет-нәсыйхәт рухындагы хикәяләр җыентыгы, Ш.Мәржани турында истәлекләр авторы.

Әд.: Фәхреддин Р. Асар. 3 һәм 4 томнар. К., 2010.

А.М.Ахунов.

ҮТӘМЕ́Ш елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Олы Чирмешән елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 10,3 *км*. Бассейнының мәйданы 57,9 *км*². Идел аръягы түбәнлегеннән, Чирмешән р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Урманасты Үтәмеш авылыннан көнчыгыштарак, тамагы Иске Үтәмеш авылыннан 3 *км* көнъяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 220 *м*, тамагыныкы — 100 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 15%. Үнең 2,4 тән 4,8 *км* га кадәр озынлыктагы 2 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,3 *км/км*². Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,1 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 76 *мм*, ташу агымы катламы 70 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,033 *м*³/*с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (20–40 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе

язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

ҮТӘМЕ́Ш авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 18 *км* төньяктарак, Бөя елгасы буенда. 2010 елда 151 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1646 дан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ү.тә мәчет, мәдрәсә, җил тегермәне, 3 вак-төяклөр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 207,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Шәмбалыкчы волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 50 ир-ат; 1859 да — 294, 1897 дә — 596, 1908 дә — 695, 1920 дә — 705, 1926 да — 494, 1938 дә — 415, 1949 да — 315, 1958 дә — 243, 1970 тә — 261, 1979 да — 206, 1989 да — 156, 2002 дә — 174 кеше.

ҮТӘМЕ́Ш авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 41 *км* көньяк-көнбатыштарак, Бидәңге елгасы буенда. 2010 елда 193 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. 1698–99 еллар тирәсендә нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче чиректә халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, 1835 тә Удел идарәчелеге карамагына тапшырыла; игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ү.тә 2 мәчет, 2 мәдрәсә, 9 сәүдә-сәнәгать йорты эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1154,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Сембер өязе Олы Тархан волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Буа, 1938 нең 4 августыннан — Олы Тархан, 1959 ның 12 октябреннән — Тәтеш р-нында. Халык саны: 1859 да — 550, 1897 дә — 858, 1913 тә — 1068, 1920 дә — 1029, 1926 да — 1048, 1938 дә — 930, 1949 да — 517, 1958 дә — 633, 1970 тә — 489, 1979 да — 354, 1989 да — 253, 2002 дә — 212 кеше.

ҮТӘМЕ́Ш МӘДРӘСӘСЕ́, Казандагы *Печән базары мәчете* каршында. 1850 еллар уртасыннан эшли, 40–50 шәкерт укый. Г.Сәгыйтов (1856–71) һәм Х.Мозаффаров (1871–93) мөдәррислек иткәндә, иске алымлы гади уку йорты була. 1893–1908 елларда аны Печән базары мәчете имамы Г.Г.*Апанаев* җитәкчелек итә, ул «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе үрнәгендә яңа алымлы укыту кертә, Ү.м.н туганы М.Г.Апанаев һәм үз акчасына тота (к. *Апанаевлар*). Г.Г.Апанаев сөргенгә җибәрелгәч, 1908 дә М.Ш.Алтынбаев мөдәррис була; ул җитәкчелек иткәндә яңа алымлы укыту һәм дөньяви фәннәр кыскартыла, мәдрәсә үзенең популярлыгын югалта.

Әд.: Салихов Р.Р., Хайрутдинов Р.Р. Памятники истории и культуры татарского народа (конец XVIII — начало XX веков). К., 1995.

ҮТӘМЕШГӘРӘ́Й ХАН (1546 — 11.6.1566), Казан ханы (1549–51). *Сафагәрәй хан* б-н *Сөембикәнең* улы, Нугай бәге *Йосыфның* оныгы. Әтисенең көтелмәгән вафатыннан соң өч яшьлек чагында хан дип игълан ителә. Чынлыкта идарәче Сөембикә була. 1551 елның җәендә Казанның Мәскәү яклы аксөякләре тарафыннан тәхеттән төшерелә. Казанның яңа хөкүмәте тарафыннан анасы Сөембикә б-н бергә Иван IV карамагына тапшырыла, 1551 нең 11 августында аларны Мәскәүгә озаталар. Ү.х.ның бабасы Йосыфның кызын һәм оныгын кире кайтару омтылышы уңышсыз тәмамлана, Иван IV болай дип җавап бирә: «...аның оныгы Үтәмешгәрәйне улыбыз урынына үзебездә тотабыз ...үскәч, без аңа асыл милек бирергә телибез...». 1553 тә Ү.х. Александр исеме б-н чукындырыла. Мәскәүдә Архангельск соборында җирләнә.

Чыг.: Посольские книги по связям России с Ногайской Ордой. 1551–1561 гг. К., 2006.

Әд.: Худяков М.Г. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923.

И.Р.Вәлиуллин.

ҮТӘМИ́ШЕВ Мөхәммәтгариф Ибра һим улы (1830 — 3.2.1893, Казан), сәүдәгәр һәм эшмәкәр. Сәүдәгәр *Үтәмишевләр* нәселеннән. 1850–80 елларда 2 нче гильдия Арча сәүдәгәре. Шикәр һәм үз фабрикасында җитештерелгән тукымалар б-н сәүдә итә. Аннары Казанга күченә. 1888 дә татар сәүдәгәрләре Г.Х.Якупов һәм М.Г.Усманов б-н берлектә мануфактура товарлары җитештерүче һәм сатучы «Казанда «Үтәмишевләр вә К° мануфактурасы» ширкәтен оештыра (устав капиталы 30 мең сум). *Яңа Татар бистәсендә* киже-мамык тукымалар ману ф-касын төзи һәм сабын кайнату эшенә керешә. Фабриканың еллык тулаем капитал әйләнеше 250 мең сум тәшкил итә, 200 меңләп аршин бәз маныла, эшчеләр саны 60 кешегә җитә. Ү. пр-тиеләре мирас булып аның улы Исмәгыйльгә күчә.

Әд.: Золотые страницы купечества, промышленников и предпринимателей Татарстана. К., 2001. Т. 2.

Р.Р.Салихов.

ҮТӘМИ́ШЕВ Рөстәм Исмәгыйль улы (23.4.1926, Арча кантоны Мәчкәрә а. — 10.8.1999, Мәскәү), инженер-конструктор, РСФСРның атказ. уйлап табучысы (1966). Ленинград авиация приборлары төзү ин-тын тәмамлый (1951). 1951–67 елларда СССР Дәүләт Хәрби-Һава көчләре фәнни-тикшеренү һәм сынау ин-тында, 1967–84 тә СССР Сәламәтлек саклау министрлыгының Бөтенсоюз фәнни-тикшеренү һәм мед. техникасын сынау ин-ты директоры; 1984–90 да СССР МФАнең Хирургия фәнни үзәгендә, фән-ни-техник совет рәисе. 1990 нан «Фән һәм техника казанышларын гамәлгә кертү үзәге» фәнни-җитештерү комплексы директоры. Бөтенсоюз мед. техникасы төзү җәмгыяте рәисе (1969–84). Хезмәтләре авиация һәм ракета приборлары төзү өлкәсенә карый. Ү. җитәкчелегендә космик корабль экипажларын очышка әзерләү өчен тренажёрлар, сынау һәм борт техникасы эшләнә; сәнәгать-нең оборона тармаклары пр-тиеләрендә мед. техникасы җитештерү оештырыла; үзкөй-ләнешле криоген техник җайланмалар, хирургия инструментлары, физиол. процесслары күзәтү аппаратлары төзү өчен тикшеренүләр алып барыла. Мед. барокамералары комплексы, гипербарик мед. техникасы, гемосорбция җайланмаларын төзү буенча баш конструктор. Үйлап табуга 120 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Техника измерений скоростей вращения. М., 1961; Радиоэлектронная аппаратура для исследования физиологических процессов. М., 1967; Современные приборы и техника физиологического эксперимента. М., 1969 (автордаш).

ҮТӘМИ́ШЕВЛӘР, Малмыж сәүдәгәрләре һәм эшмәкәрләре. **Габдулла Габдессәлам улы** (?, Вятка губ., Малмыж өязе Мәчкәрә а. — 1832, шунда ук), сәүдәгәрләр нәселен нигезләүче, 1 нче гильдия сәүдәгәр. Ш.Мәржани фикеренчә, ул «төбәктәге иң күренекле эшмәкәр һәм үзенең байлыгы, юмартлыгы, дингә һәм фәннәргә мөнәсәбәте б-н дан казана». Мәчкәрә авылында яши. Өяздә берничә туку ф-касы оештыра, продукциясен Казанда, Себердә, Урта Азиядә, Кытайда сата. Казан һәм Вятка губерналары авылларында дистәләрчә, ш.и. туган авылында мәчет (1791, к. *Мәчкәрә мәчете*), Казанда зур Иске Таш мәчетен төзүгә акчалата ярдәм итә. 19 йөз башында татарча белем бирүче уку йортлары арасында иң билгеле «*Мәчкәрә*» мәдрәсәсенә матди ярдәм күрсәтә. **Муса Габдулла улы** (?, Мәчкәрә а. — 1835, шунда ук), 1 нче гильдия сәүдәгәр, дин галиме. Г.*Курсавиның* дусты һәм ул башлаган эшне дәвам итүче. Христиан дине турындагы дин кануннары җәһәтендә фәлсәфи бәхәс мәсьәләләрен үз эченә алган күләмле китаплар авторы. 1800 елда 60 лап авылдашын — мәҗүси удмурtларны ислам диненә күчәргә күндерә һәм алар өчен авылда икенче мәчет салдыра.

Әд.: Мәржани Ш. Мөстәфад әл-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар., К., 1989; Мечети Татарстана / Сост. Х.Г.Надырова, Р.Р.Салихов, Р.Р.Хайрутдинов. К., 2000; Золотые страницы купечества, промышленников и предпринимателей Татарстана. К., 2001; Беляев А.Б. Историческая генеалогия татарского народа: Родственные династии и их роль в истории семьи, нации и государства. К., 2012.

Р.Р.Салихов.

ҮТӘНГЕ́Ш авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 32 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Мари Респ-касы б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 13 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 18 йөз уртасында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Новопоселённый Починок по речке Утенгиш исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, вак-төяклөр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 238,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кукмара волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1958 нең 16 июленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 9 ир-ат; 1859 да — 112, 1897 дә — 198, 1908 дә — 221, 1920 дә — 208, 1926 да — 293, 1938 дә — 296, 1949 да — 300, 1958 дә — 249, 1970 тә — 215, 1979 да — 138, 1989 да — 52, 2002 дә — 32 кеше.

ҮТӘШЕВ Әмир Галимҗан улы (15.9.1919, Уфа губ. Каргалы а. — 6.2.1996, Казан), Икенче бөтендөнья сугышы елларында Франциянең Каршылык хәрәкәтендә катнашучы. Бөек Ватан сугышы елларында кече политрук, 1942 елда әсирлеккә эләгә. Совет әсирләреннән төзелгән гаскәри берәмлектә — «*Идел-Урал легионы*»нда хезмәт итә. Хәрби әсирләр арасында алып барылган яшерен хәрәкәттә катнаша; 1943 тә Едлино лагеренда (Польша) М.М.*Җәлил* б-н очраша (соңрак легионерлар Г.Шәрипов һәм Н.Терегулов б-н бергә аның шигырьләре язылган блокнотны коткаруда катнаша (к. «*Моабит дәфтәре*»). 1943 тә легион батальоннарының берсе составында Франциягә Ле-Пюи шәһәренә (Югары Луара департаменты) җибәрелә. 1944 тә Y. легионерлар төркеме б-н бергә француз партизаннары ягына чыга; партизаннар отряды командиры була; француз армиясе капитаны исемен ала. Сугышчан казанышлары өчен Франциянең ике хәрби хачы б-н бүләкләнә. 1945 тә Ватанга кайта. 1948 дә әсирлектә булганы өчен кулга алына, 25 елга иреген мәхрүм ителә. 1955 тә иреккә чыгарыла, 1962 дә аклана. Франция Каршылык хәрәкәте ветераннарының төбәкара «Комбатан волонтёр» ассоциациясенең Идел-Урал секциясе рәисе (1993–96).

Әд.: Мостафин Р.Ә. Өзелгән җыр эзеннән. К., 2011; шул ук. По следам оборванной песни. К., 2004; Черепанов М.В. Зачем живым Долина смерти? К., 2006.

ҮТӘШЕВ Мирабо Хөсәен улы (21.9.1933, Томск ш.), металлар эшкәртү өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1984), проф. (1985). Томск политехник ин-тын тәмамлаганнан соң (1955), Томск шәһәренең урта һәм югары уку йортларында укыта. 1964 елдан Төмән нефть һәм газ ун-тында, сәнәгать һәм инжиниринг ин-тының станоклар һәм инструментлар каф. профессоры. Хезмәтләре металл эшкәртү инструментларының җимерелүе һәм аларны проектлау теориясенә карый. У. инструментның эшкә яраклылык дәрәҗәсен арттыру максаты б-н контакт көчәнешләр буенча аның кисүче өлеше ныклыгын исәпләп чыгаруның фәнни нигезләрен эшли. Уйлап табуга авторлык таныклыклары бар. СССР ВДНХсы медале белән бүләкләнә. Хикәяләр, хатирәләр, тормыш һәм үлем мәгънәсе хакындагы уйланулар авторы («Әхмәтнең яшел ботагы» — «Зелёная ветка Ахмета», Төмән, 2009).

Хезм.: Напряжённо-деформированное состояние и прочность режущих элементов инструментов. М., 2001 (автордаш); Исследование напряжений, деформаций и прочности сменных режущих пластин методом конечных элементов. Тюмень, 2002 (автордаш).

ҮТИНКӘ СӨРКӘ (БАЙБАК) КОЛОНИЯСЕ, табигать истәлеге. Буа р-ны терр-ясендә, элеккеге Үтинкә авылыннан төньяктарак урнашкан. 1987 елда билгеләнә. Мәйданы 50 *га*, сакланулы зонасы 50 *м* киңлектә. Сөркә-байбак колониясе Карлы елгасының сул кушылдыгы булган елгачык үзәненең далаланган сөзәкләкләрен били. ТРның Кызыл китабына кертелгән үсемлек төрләреннән язгы адонис, чәчсыман кылган, хайваннардан кыр карчыгасы, ысылдавык аккош (очып үтеп китү вакытында), тимгелле йомран, кыр тычканы очрый. Объект 100 еллык өйрәнү тарихына ия.

ҮТЛЕ́ ГӨМБӘ́ (Tylopilus felleus), болетачалар семьялыгыннан эшләпәле гөмбә. Европа, Азия һәм Төньяк Америкада таралган. ТР терр-ясендә июльдән сентябрьгә кадәр ылыслы һәм катнаш урманнарда берәрләп очрый, нарат, каен, имән б-н микориза хасил итә. Эшләпәсенең диаметры 5–10 *см*, яшь гөмбәнең эшләпәсе ярымтүгәрәк, со ңыннан кабарынкы булып җәелә, җи ңелчә кызгылт төсмерле коңгырт яки зәйтүнсыман көрән. Гөмбә сабы 3–7 *см* биеклектә, кабарынкы, кара-көрән челтәр бизәкле аксыл сары. Йомшагы тыгыз, ак, сындырганда алсулана, гөмбә исле. Споралы порошогы соргылт яки алсу-көрән. Яшь гөмбә ак гөмбәгә охшаш, әмма йомшагының нык ачы тәме һәм сабындагы коңгырт челтәре б-н аерыла. Ашарга яраксыз. Медицинада үт кудыру чарасы буларак кулланыла.

ҮЧӘЛЛЕ́ елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Ык елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 13,8 *км*. Бассейнының мәйданы 59,3 *км*^{2}. Азнакай р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Үчәлле авылыннан көнбатыштарак, тамагы Сарлы авылы янында. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 86 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 15%. Y.нең 3,2 *км* озынлыктагы 1 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,29 *км/км*^{2}. Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,1 *л/с·км*^{2}. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елганың түбән агымы кар эрегән чорда, язын һәм көчле яңгырлар булганда гына сакланa, калган вакытта су тамагына кадәр барып җитми. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минераль әүтүе язын 400–500 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк. Елгада суының гомуми күләме 0,8 млн. *м*^{3} булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

ҮЧӘЛЛЕ́ авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 20 *км* көнчыгыштарак, Үчәлле елгасы буенда. 2010 елда 345 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1104 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Эстәрлетамак волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 нең 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 20 октябреннән — Азнакай, 1935 нең 10 февраленнән — Тымытык, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1816 да — 83 ир-ат; 1859 да — 315, 1889 да — 593, 1897 дә — 692, 1910 да — 902, 1920 дә — 988, 1926 да — 694, 1938 дә — 638, 1949 да — 545, 1958 дә — 577, 1970 тә — 547, 1979 да — 418, 1989 да — 348, 2002 дә — 340 кеше.

ҮШНӘ́ елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Норма елгасының (Мишә елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 26,9 *км*. Бассейнының мәйданы 272,1 *км*^{2}. Елга башы урман массивында, Биектау р-ны Николаевка авылыннан (даими яшәүчеләр юк) 2,5 *км* көнбатыштарак, тамагы Питрәч р-ны Рус Тау Иле авылыннан 3 *км* көньяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 70 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 15%. Y.нең 0,2 дән 18,3 *км* га кадәр озынлыктагы 12 кушылдыгы бар, иң зурысы — Ия елгасы (сул кушылдык). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,42 *км/км*^{2}. Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 13 *л/с·км*^{2}. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 139 *мм*, ташу агымы катламы 130 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,08 *м*^{3}/*с*. Язын суы йомшак (1,5–3 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минераль әүтүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. Y. бассейнында суының гомуми күләме 3,2 млн. *м*^{3} булган 5 буа бар. Су ресурслары сугару һәм балык үрчетү өчен файдаланыла. Y. елгасы буенда *Ленино-Кокушкино табигый-тарихи тыюлыгы* урнашкан.

ҮШНӘ́ посёлогы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 12 *км* төньяктарак, Үшнә елгасы буенда. 2010 елда 56 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 63%, татарлар — 35%) яши. Халкының төп шөгыле — балык тоту. 1950 елларда балык хуҗалыгы посёлогы буларак нигез салына. Халык саны: 1958 дә — 50, 1970 тә — 226, 1979 да — 200, 1989 да — 29, 2002 дә — 59 кеше.

Ф

ФАВО́РСКИЙ Алексей Васильевич (10.2.1873, Әстерхан губ., Әстерхан өязе Седлистое а. — 17.2.1930, Казан), невропатолог, медицина д-ры (1900). Казан невропатологлар мәктәбенә нигез салучыларның берсе. Проф. Л.О.*Даркшевич* шәкерте. Казан ун-ты ның мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1896), шунда ук эшли; 1903 елдан соң нерв авыру лары клиникасында. Германиядә (Берлин, 1904; Мюнхен, 1910), Франциядә (Париж, Пастер ин-ты, 1905), Петербургта (И.П.Павлов лаб-ясе, 1911) фәнни стажировка үтә. 1907–30 да Казан ун-тында: нерв-психик авырулар каф. мөдире (1916 дан), проф. (1918); 1926 дан Казан ун-тының мед. ф-ты деканы. Бер үк вакытта нерв-психик авыру лар каф. мөдире (1922–30); 1924 тән Казан ГИДУВының нерв авырулары клиникасы директоры. 1907–17 елларда Казан югары хатын-кызлар курсларында укыта. Ф. имгәнү очракларында арка миендәге үзгәрешләр не, ботулизм токсинының түбән төзәлешле умырткалыларга тәэсирен өйрәнә, арка мие кибүне дәвалау ысулын эшли. Казан ун-ты каршындагы невропатологлар һәм психиатр лар җәмгыяте рәисе (1918–30).

Х е з м.: К учению об остром ртутном полинев рите. К., 1898; Материалы к вопросу о патолого-анатомическом изменении спинного мозга при сдавлении его. К., 1901; Действие ботулинического токсина на низших позвоночных в связи с изменением нервной системы их. К.,1909.

Әд.: Ю д и н Т. Памяти профессора А.В Фаворского // Казан. мед. журн. 1930. № 2; И с м а г и л о в М.Ф., Я м а л е е в а Г.Р., К а д ы р о в а Л.М. Жизненный и творческий путь профессора А.В.Фаворского // Неврологический вестн. 1995. Т. 27, вып. 3/4.

ФАДЕ́ЕВ Александр Владимирович (4.1.1964, Казан), спортчы (тимераякта фигуралы шуу), СССРның атказ. спорт остасы (1985). Балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә тәрбияләнә (Казан), тренерлары — Г.С.Тарасов (1970–80, Казан), С.А.Жук, С.Н.Волков, С.В.Леонович (Мәскәү). СССР (1983, 1986–90), Европа (1984, 1987–89), дөнья (1980, яшүсмерләр арасында, 1985) чемпионы, СССР (1981 — көмеш, 1982 — бронза), Европа (1983, 1986 — бронза), дөнья (1979, яшүсмерләр арасында, 1983, 1986–87 — бронза) чемпионатларында медальләр ала, ялгыз шууда Олимпия уеннарында катнаша (1984, 1988). 1991 елдан АКШта яши, тренер булып эшли. АКШның ачык чемпионатында жиңүче (1993, профессионаллар арасында).

ФАДЕ́ЕВ Василий Павлович (1.1.1920, Казан губ., Лаеш өязе Көек а. — 3.11.2003, Казан), хакимият-ху җалык эшлеклесе, РСФСРның атказ. көнкүреш хезмәте күрсәтү хезмәткәре (1979). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1955). 1938–39 елларда Көек урта мәктәбе (Лаеш р-ны) укытучысы. 1946–48 дә Казанда ВЛКСМның Ленин райкомы секретаре, 1948–50 дә 1 нче секретаре. 1950–52 дә ВЛКСМның Казан шәһәр ком-ты секретаре, 1952–54 тә 1 нче секретаре. 1954–57 дә КПССның Ленин райкомы секретаре, 1957–62 дә хезмәт ияләре депутатларының Ленин р-н советы башкарма ком-ты рәисе. 1962–66 да ТАССР МС каршындагы Халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү идарәсе башлыгы. 1966–84 тә ТАССР халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү министры. Ф. вакытында Татарстан район һәм шәһәрләрендә 13 зур махсуслаштырылган ҖБ, көнкүреш хезмәте күрсәтү комб-тлары; колхозларда һәм посёлок урман сәнәгате хуҗалыкларында авыл көнкүреш хезмәте күрсәтү йортлары ачыла. 1967–85 тә ТАССР ЮС депутаты. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин ордены, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, өч Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Е.Б.Долгов.

ФАДЕ́ЕВ Владимир Гелиевич (5.6.1961, Әлмәт ш.), тау инженеры, техник фән. д-ры (2004), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2000). Әлмәт төзелеш техникумын (1980), Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тын (1990), РФ Хөкүмәте каршындагы Халык хуҗалыгы академиясен (2001) тәмамлый. Хезмәт эшчәнлеген эретеп ябыштыру-монтажлау тресты автотранспорт колоннасының 2 нче автобазасында автослесарь булып башлый (Кыргызстан ССР, Фрунзе ш.). 1983–84 елларда Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тының Татарстан кичке ф-тында лаборант. 1984 тән «Татнефть» АҖдә: нефть һәм газ чыгару буенча оператор, нефть һәм газ чыгару цехында, катламнар басымын саклау һәм катламнарның нефть бирүчәнлеген арттыру, нефть һәм газ чыгару һәм җитештерүне үстерү бүлекләрендә мастер, инженер-технолог, башлык, «Әлмәтнефть» НГДУында башлык урынбасары, АҖнең җитештерү идарәсе башлыгы (2000 нән). Уйлап табуга 10 патенты бар. Дәүләт бүләге тирәндәге штанга лы насослы җайланмаларның ышанычлы эшләвен арттыру буенча техник чаралар һәм технологияләр комплексын эшләүдә һәм сәнәгатьтә куллануга кертүдә катнашканы өчен бирелә.

Х е з м.: Новые технические средства одновременно-раздельной эксплуатации, разработанные в ОАО «Татнефть» // Нефт. хоз-во. 2008. № 7 (автордаш); Новые системы сканирующей магнитной интроскопии эксплуатационных колон скважин // Сб. науч. тр. ТатНИПИнефть. М., 2009 (автордаш).

ФАДЕ́ЕВ Сергей Михайлович (8.4.1919, Самара өлкәсенең Ставрополь ш., хәзерге Тольятти ш. — 10.10.1952, Куйбышев ш.), Сов. Союзы Герое (8.9.1943), рядовой. Актаныш авылында (Актаныш р-ны) яши һәм эшли. 1939 елдан Кызыл Армиядә. 1943 тән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 729 нчы аерым танк һөҗүменә каршы дивизионның туп төзәүчесе (2 нче танк армиясенең 16 нчы танк корпусы). Үзәк фронт гаскәрләре составында Курск сугышында катнаша (1943). 1943 нең 6 июлендә Ольховатка авылы янындагы (Курск өлкәсенең Поныри р-ны) сугышларда батырлык күрсәтә: дошман танклары һөҗүмен кире кайтарганда туп расчёты б-н 11 дошман машинасын (ш.и. 5 авыр) сафтан чыгара. Яралана, сугыш кырында кала. Позиция саклана.



С.М. Фадеев.

Демобилизацияләнгәннән соң (1944), Куйбышев шәһәрендә яши һәм эшли. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Самара (1935–90 да Куйбышев) шәһәрендәге бер урам Ф. исемен йөртә, аның хөрмәтенә мемориаль такта куела.

Әд.: Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

М.З.Хәбибуллин.

ФАДЕ́ЕВА Александра Николаевна (25.9.1956, Кукмара р-ны Иске Юмья а.), биолог, селекция белгече, биол. фән. канд. (2001), ТРның атказ. агрономы (2001), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2006). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1979), Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында эшли, бөртекле-кузаклы культуралар селекциясе лаб-ясе мөдире (1998 елдан). Хезмәтләре борчак селекциясе мәсьәләләренә карый. Борчакның 11 сорты авторларының берсе, шуларның 7 се («Татарстан 2», «Казанец», «Таң», «Сәламәт», «Венец», «Батыр», «Ватан») селекция казанышлары дәүләт реестрына кертелә. Дәүләт бүләге ТРда игенчелекнең биол. факторлары нигезендә бөртекләләрне җитештерүдә ресурс саклау технологияләрен эшләүдә һәм гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә.

ФАДЕ́ЕВА Нина Александровна (11.11.1940, Казан — 4.5.2007, шунда ук), өлге ясаучы, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1984). 1962–95 елларда «Киемнәр» Татарстан ҖБнең 8 нче тегү ф-касында эшли. Алдынгы рациональ хезмәт алымнарын кулланып, 11 нче бишьеллык елларында 2 бишьеллык йөкләмә үти (1981–85). Дәүләт бүләге хезмәттәге югары казанышлары өчен бирелә. 3 нче дәрәҗә «Хезмәт Даны» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: Советская Татария в одиннадцатой пятилетке. К., 1986.

ФАДЕ́ЕВКА авылы, Спас р-нында, район үзәге Болгар шәһәреннән 50 *км* көньяк-көн-

чыгыштарак, Бизнә елгасы буенда. 2010 елда 52 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ф.да су һәм җил тегермәне, бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 466,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Гусиха волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Спас, 1935 нең 10 февраленнән — Кузнечиха, 1960 ның 28 октябреннән — Куйбышев, 1991 нең 4 октябреннән Спас р-нында. Халык саны: 1859 да — 403, 1897 дә — 439, 1908 дә — 508, 1920 дә — 523, 1926 да — 471, 1938 дә — 296, 1949 да — 150, 1958 дә — 193, 1970 һәм 1979 да — 203 әр, 1989 да — 106, 2002 дә — 74 кеше.

ФАДЕ́ИЧЕВА (ире ягыннан Белоусова) Алевтина Семёновна (18.6.1943, Кукмара пос.), җырчы (меццо-сопрано), педагог, ТАССРның һәм РСФСРның атказ. артисты (1981, 1982). 1972 елда Казан консерваториясен (В.Лазько классы) тәмамлый. 1972–94 тә Татар опера һәм балет театры солисты. Партияләре: Амнерис («Аида», Дж.Верди), Кармен (шул исем. әсәр буенча, Ж.Бизе), Марина Мнишек («Борис Годунов», М.Мусоргский), Няня («Евгений Онегин», П.Чайковский), Любаша («Патша кәләше», Н.Римский-Корсаков), Тугзак («Алтынчәч», Н.Җиһанов) һ.б. А.Шнитке исем. Мәскәү музыка ин-тында, Г.Вишневскаяның Опера җырлау үзәгендә укыта. Концерт эшчәнлеге (ш.и. Казанда) алып бара. Россиядә һәм чит илләрдә мастер-класслар б-н чыгыш ясый. Даими рәвештә Казанда *Шаляпин Ф.И. исемендәге опера фестивалендә* катнаша.

ФАЗА́ЛОВ Гакий Таһир улы (1.3.1929, БАССРның Мәчетле р-ны Яңа Мөслим а. – 23.10.2018, Междуреченск ш.), тау инженеры, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1984), РСФСРның атказ. шахтёры (1984). Свердловск тау ин-тын тәмамлаганнан соң (1953), «Башкируголь» (Күмертау ш.) трестының «Ермолаево» киселешендә эшли. 1957–90 елларда «Кемеровоуголь» ҖБдә (Кемерово өлкәсе): «Томусауголь» трестының «Краногорский» киселешендә тау инженеры, участок башлыгы, баш инженер (1968 дән), «Кемеровоуголь» комб-тында баш инженер урынбасары (1969 дан), «Междуреченск» киселеше директоры (Междуреченск ш., 1975 тән). Дәүләт бүләге Кузбас сәнәгатенә ачык ысул б-н ташкүмер (ш.и. коксланa торган) чыгару буенча зур сәнәгать һәм социаль-икътисади комплекс булдыруда катнашканы өчен бирелә. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Г.Я.Мәүлетова.

ФАЗЛА́ЕВ Нурулла Гарифулла улы (6.3.1909, Сембер губ., Буа өязе Мөчәли а. — 1997, Казакъстан Респ-касының Җамбул, хәзер Тараз ш.), Сов. Союзы Герое (10.4.1945), старшина. 1929–36 елларда Донбасс шахталарында забойчы һәм ташкүмер чаба торган машина йөртүче, 1937–40 та Җамбулда ремонт-төзелеш конторасында ташчы булып эшли. 1941 нең августыннан Кызыл Армиядә. 1943 нең июленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 281 нче аерым штурм инженер-сапёрлар батальоны отделениесе командиры (13 нче армиянең 19 нчы инженер-сапёрлар бригадасы). Курск сугышында (1943), Польшаны азат итүдә (1944), Берлин һөҗүм операциясендә (1945) катнаша. 1945 нең 26 гыйнварында Хохбаушвиц торак пункты янында (Польшаның Сьцинава шәһәреннән 6 *км* төньяктарак) Одер елгасын кичеп чыкканда батырлык күрсәтә: үз расчёты б-н паром кичүен кора, 5 тәүлек әчендә аннан сугыш кирәк-яраклары һәм кораллар төягән йөзләп машина үтә, бу плацдармны саклап калырга булышлык итә. Демобилизацияләнгәннән соң (1945), Җамбул шәһәрендә яши. Ленин ордены, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Кызыл Йолдыз орденнары б-н бүләкләнә. Җамбулда Ф. яшәгән йортка мемориаль такта куела.

Әд.: Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

М.З.Хәбибуллин.

ФАЗЛУ́ЛЛИН Мөхәммәтхан Әшрәф җан улы (2.12.1883, Казан губ., Цивильск өязе Тугаево а. — 16.2.1964, Казан), педагог, тел белгече, ПФА мөхбир әгъзасы (1950), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1940). 1895–1903 елларда *«Касыймия»* мәдрәсәсендә укый, шунда ук укыта, 1908 дә экстерн тәртибендә Казан татар укытучылар мәктәбен тәмамлый. 1908 дән Казан губернасының Мамадыш өязе Тарлау авылында рус-татар уч-щесендә укыта, 1911 дән Мамадыш шәһәрендә. 1917–19 да Мамадыш өязенең мөселман мәктәпләрендә инспектор. Пед. курслар, Мамадыш татар укытучылар семинариясе (1918 дә ачыла), 1919–30 да *Казан татар педагогика техникумы* б-н җитәкчелек итә. Бер үк вакытта башка уку йортларында да эшли, 1920–21 дә «Мәгариф» ж-лында җаваплы сәркәтип. 1930–64 тә Казан пед. ин-ты профессоры, 1934–54 тә татар теле һәм әдәбияты каф. мөдире. Ф. гомуми белем бирү мәктәпләрендә татар телен ана теле буларак укыту методикасын эшли, әлифбалар, уку китаплары, укытучылар өчен ярдәмлекләр төзи. Татар телен яңалифкә һәм кириллицага күчерү эшләрендә актив катнаша. Хезмәтләре татар филологиясе, татар язма әдәбият тарихы мәсьәләләренә карый. Татар мәктәпләре укытучылары өчен пед. һәм психол. буенча беренче ярдәмлекләр авторы. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезмәт.: Дидактика кагыйдәләре: Укытучы һәм тәрбиячеләр өчен кыскача кулланма. К., 1920; Кызыл юл: Балалар әлифбасы. К., 1929; Башлангыч мәктәптә татар теле: Инструктив-методик материал. К., 1934; Зурлар өчен әлифба. К., 1940; Грамота мәктәпләре өчен әлифба. К., 1945; Татар теле методикасы. К., 1954.

Әд.: Рамазанова Д. Татар телен укытуны фәнни-методик нигезгә салган галим // Фәнни Татарстан. 2004. № 1/2; Сагитов М.А. М.А.Фазлуллин // Советская тюркология. 1983. № 6; Шарафутдинов З.Г. История педагогики Татарстана. К., 1998.

ФАЗЛУ́ЛЛИН Хәсби (Хәзби) Вәлиулла (Вәли) улы (16.12.1909, Казан — 26.6.1995,



Н.Г.Фазлаев.



Х.В.Фазлуллин.

шунда ук), дирижёр, кларнетчы, педагог, ТАССРның һәм РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1950, 1960), ТАССРның халык артисты (1989). Тәүге татар проф. дирижёрларының берсе. Мәскәү консерваториясенең С.Розановта кларнет классын (1936), Л.Штейнбергта дирижёрлык классын (1941) тәмамлый. 1941–46 елларда Башкорт опера һәм балет театры дирижёры; Ф. җитәкчелегендә «Айсылу» (М.Вәлиев һәм Н.Пейко, 1943), «Ашказар» (А.Эйхенвальд, 1944), «Алтынчәч» (Н.Җиһанов, 1946) һ.б. опералар куела. 1946–73 тә Татар опера һәм балет театры дирижёры; анда аның җитәкчелегендә «Коппелия» (Л.Делиб, 1948, 1963), «Таш чәчәк» («Каменный цветок», С.Прокофьев, 1961), «Пер Гюнт» (Э.Григ музыкасына, 1961), «Раушан» (З.Хәбибуллин, 1961), «Бакыр җайдак» («Медный всадник», Р.Глиэр, 1963) һ.б. балетлар, «Шагыйрь» (Н.Җиһанов, 1947), «Самат» (Х.Вәлиуллин, 1957) опералары, «Идел буенда» (Ж.Фәйзи, 1949) һ.б. муз. комедияләр сәхнәгә куела. 1946–70 тә — Казан консерваториясендә, 1970–90 да Казан мәдәният ин-тында укыта. Театр-музыка сәнгате үсешенә керткән өлеше өчен ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләгенә ия була (1973).

Ф.Ш.Салитова.

ФАЗЛЫ́ЕВ Рабис Тимерхан улы (19.4.1937, БАССРның Шаран р-ны Зирекле а. – 19.4.2012, Бөгелмә ш.), нефтьче, техник фән. д-ры (1980),ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1987). ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1994). Уфа нефть ин-тын тәмамлый (1959). 1959–2009 елларда ТатНИПИнефтьтә: нефть чыганакларын эшкәртү бүлеге мөдире (1986 дан), баш фәнни хезмәткәр (2003 тән). 1967–70, 1981–86 да Алжирда командировкада була. Хезмәтләре нефть чыганакларын эшкәртүгә карый. Ф. тарафыннан эшкәртелүче объектларны билгеләү критерийлары, аларны җитештерүгә кертүдә чират принциплары нигезләнә. Горизонталь һәм авыш юнәлешле скважиналарны бер-берсенә бәйле урнаштыруда өпочмаклы челтәр алымы куллануның югары нәтиҗәлелеген исбатлый. Медальл әр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Площадное заводнение нефтяных месторождений. М.-Ижевск, 2008.

ФАЗЛЫ́ЕВА Гүзәл Мидхәт кызы (17.7.1962, Казан), химик-органик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2010), химия фән. канд. (2006). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый (1985), РФА КГУнең Органик һәм физик химия ин-тында эшли. Хезмәтләре составын-

да цитотоксик төркемнәр булган 2,3,4,6-тетраацетил-1-β-D-глюкозамин фосфор к-тасы продуктларын синтезлауга, аларның шешләргә каршы активлыгына; фуллереннарның продуктларын синтезлау һәм үзлекләрен тикшерүгә карый. Дәүләт бүләге «Фуллереннарның органик продуктлары — органик электроника һәм биомедицина өчен нанома - териалларны эшләүнең «төзү» блоклары» хезмәтенә өлеш керткәне өчен бирелә.

Х е з м.: Синтез новых функциональнозамещённых производных фуллерена C60 // Изв. РАН. Сер. хим. 2002. № 9 (автордаш); Полимерные водорастворимые производные метенофуллеренов фуллеропирролидинов // Журн. прикладной химии. 2005. Т. 78, № 12 (автордаш); Синтез, строение и свойства новых тиофосфорилированных пирролидинофуллеренов. Первый пример реакции Пищимуки в ряду производных фуллерена // Изв. РАН. Сер. хим. 2006. № 3 (автордаш).

ФАЗЛЫ́ЕВА Луиза Кирам кызы (27.4.1937, Шөгер р-ны Иске Шөгер а.), педиатр, мед. фән. д-ры (1989), проф. (1991), ТРның атказ. табибе (1991). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1962), 2 нче балалар поликлиникасында (Казан) участок педиатры булып эшли.1967 елдан Казан мед. ин-тының госпиталь педиатриясе кафедрасында, 1969–70 тә Казандагы 3 нче бала тудыру йортында балалар бүлеге мөдире, неонатология курсы мөдире, каф. профессоры. Хезмәтләре неонатологиягә, балаларда аллергия авыруларын кисәтү һәм дәвалауга карый. Ф. яңа туган балаларның иммунологик реактивлыгын өй - рәнә, үзәк нерв системасында перинаталь тайпылышлар булган яңа туган балаларны тернәкләндерү ысулларын эшли.

Х е з м.: Реакция повреждения нейтрофилов плацентарными антигенами у детей неонатального возраста // Казан. мед. журн. 1981. № 2; Пренатальная дистрофия плода при позднем токсикозе беременных // Казан. мед. журн. 1986. № 5.

Әд.: Казанский государственный медицинский университет (1804–2004 гг.): Заведующие кафедрами и профессора: Биогр. словарь. К., 2004.

ФАЗЫЛЖА́НОВ Әмсар Хәким улы (9.5.1937, Арча р-ны Иске Ашыт а.), сарык асраучылык буенча белгеч, а.х. фән. д-ры (1988), ТАССРның атказ. зоотехнигы (1980), РФнең атказ. фән эшлеклесе (1995). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1959), Тува авто - номияле өлкәсенең Овюр р-ны «Торгалыг» к-зында баш зоотехник, Пий-Хем р-ны а.х. инспекциясендә баш зоотехник, 1961 елдан Себер терлекчелек фәнни-тикшеренү ин-тын - да (Новосибирск ш.). 1968 дән Казан вет. ин-тында, 1969 дан Татарстан а.х. фәнни-тик - шеренү ин-тында сарык һәм эре терлек асраучылык лаб-ясе мөдире, 1976 дан Татарстан дәүләт нәсел үрчетү берләшмәсендә баш зоо - техник. 1978 дән Бөтенроссия терлекчелек нәсел үрчетү эше фәнни-тикшеренү ин-ты - ның (Мәскәү ш.) а.х. терлекләре үрчетү буенча Татарстандагы лаб-ясе мөдире, 1997–2000 дә Горький тимер юлы Казан бүлекчәсен - дә а.х. бүлеге башлыгының беренче урынба - сары, 2000–06 да Казан вет. медицинасы ака - демиясенең а.х. терлекләре генетикасы һәм селекциясе каф. профессоры. Бер үк вакыт - та, 1996–2013 тә, ТР ФАнең Татар энцикло - педиясе ин-тында. Хезмәтләре сарыкларны үрчетү, тукландыру, нәселен яхшырту өлкә - сенә карый. Ф. илебезнең һәм чит илләрнең барлык категория сарыклары өчен туклану рационы төзи, сарыкчылык буенча көтүне яңартуның нәтиҗәле технол. аспектларын эшли. Медальләр, СССР ВДНХсының Мактаулы дипломы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Овцеводство в условиях интенсивного земледелия. К., 1976; Овцеводству — новую технологию. К., 1981; Опыт выращивания ягнят. К., 1985 (автордаш); Интенсификация овцеводства в Татарии. М., 1990 (автордаш); Переработка продукции животноводства: Учеб. для вузов. К., 2001 (автордаш).

Әд.: Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.): Биогр. словарь учёных. К., 2006; Учёные России. М., 2008. Т. 4.

ФАЗЫЛЖА́НОВ Фәрит Мансур улы (24.6.1967, Казакъстан ССР, Петропавловск ш.), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, ТРның атказ. элемтә хезмәткәре (2009). Казан авиация ин-тын (1992), РФ Хөкүмәте кар - шындагы Халык хуҗалыгы академиясен (Мәскәү, 2006) тәмамлый. 1992–96 елларда «КамАЗ» АҖнең (Чаллы) металл кою з-дын - да инженер, бюро башлыгы, мәгълүмати технологияләр хезмәте җитәкчесе. 1996–2000 дә «АлАЗ» ҖБ (Алабуга) мәгълүмат һәм элемтә департаментының Мәгълүмати системалар үзәге директоры. 2000–03 тә «Татэнерго» АҖнең Мәгълүмати технологияләр һәм ав - томатлаштыру идарәсе башлыгы. 2003–05 тә ТР элемтә һәм мәгълүматлаштыру министры урынбасары, 2005–10 да министры. 2010 нан «Связьинвестнефтехим» АҖ ген. директо - рының 1 нче урынбасары. Хезмәтләре мәгъ - лүматлаштыру процесслары үсеше мәсьәлә - ләренә карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Е.Б.Долгов.

ФАЗЫЛЖА́НОВ Фәтхерахман Фазылҗан улы (14.1.1923, Дөбъяз р-ны Дөбъяз а. — 6.4.2002, Казан), журналист, җәмәгать эш - леклесе, РСФСРның атказ. мәдәният хез - мәткәре (1973). Арча пед. уч-щесен (1941), КПСС ҮК каршындагы Югары партия мәк - тәбен (Мәскәү, 1956) тәмамлый. 1946–47 ел - ларда «Колхозчы» Дөбъяз район г-тасы мө - харрире. 1949–50 дә КПССның Татарстан өлкә ком-ты инструкторы, 1950–51 дә һәм 1953–54 тә ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-ты 2 нче секретаре, 1952–53 тә ВЛКСМ - ның Чистай р-н ком-ты 1 нче секретаре, 1954–56 да КПССның Ворошилов р-н ком-ты 2 нче секретаре, 1956–57 дә ТАССР Мәдәният министрлыгының радиомәгълү - мат бүлеге мөдире, 1957–84 тә ТАССР Радио - тапшырулар дәүләт ком-ты рәисе урынбаса - ры. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ике Кызыл Байрак ордены, «Почёт билгесе» һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, ме - дальләр б-н бүләкләнә.

ФАЗЫ́ЛОВ Валерий Рәүф улы (26.2.1951, Казан), математик, физика-матем. фән. д-ры (1999). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1973), шунда ук эшли, икътисади киберне - тика каф. мөдире (2004–09), каф. профессо - ры (2009 дан). Хезмәтләре хисаплау матема - тикасына һәм җитештерү идарәсен автомат - лаштыруга карый. Ф. алдан билгеләнгән төр - ле класстагы кабарынкы оптималъләштерү мәсь әләрен төгәллек б-н хәл итү алымна - рын эшләп, аларны нигезли, механик эшкәр - түнең сыгылмалы җитештерү системалары б-н идарә итү методикасын тәкъдим итеп га - мәлгә кертә.

Х е з м.: Выпуклая оптимизация с заданной точностью // Журн. вычисл. математики и мат. физики. 1990. Т. 30, № 5 (автордаш); Отыскание минимакса с заданной точностью // Журн. вычисл. математики и мат. физики. 1994. Т. 34, № 5; Задача манипулятора гальванической линии. К., 2000.

ФАЗЫ́ЛОВ Вилдан Хәйрулла улы (22.10.1947, Казакъстан ССР, Кашкадәрья өлкәсенең Китаб штп), инфекционист, мед. фән. д-ры (1995), проф. (1997), ТРның ат - каз. табибе (2005). Иркутск мед. ин-тын тә - мамлаганнан соң (1972), Иркутск өлкәсенең Усольск, 1976–79 елларда Краснодар крае Новомихайловск, 1979–84 тә ТАССРның Лениногорск Үзәк район хастаханәләрендә табиб-инфекционист булып эшли. 1984 тән Казан мед. ин-тының йогышлы авырулар ка - федрасында, каф. мөдире (1995 тән). Ф. йо - гышлы авыруларның патогенез үзенчәлек - ләрен (гемостаз, иммунитет, эндотоксине - мия) өйрәнә; этиотроп патогенетик терапия - нең рациональ ысулларын тәкъдим итә, В гепатитын иммунологик кисәтү юлларын, стрептококклы йогышлы авыруларны дәва - лау ысулларын эшли, ксимедонны дәвалау чарасы буларак кулланууны дәлилли. Үйлап табуга авторлык таныклыгы, патенты бар.

Х е з м.: Инфекционные болезни. К., 2006 (автордаш); Влияние озонотерапии на показатель гемостаза при системной воспалительной реакции // Казан. мед. журн. 2007. № 4 (автордаш); Геморрагическая лихорадка с почечным синдромом. К., 2008 (автордаш).

ФАЙДАЛЫ́ КАЗЫЛМАЛА́Р, җир кабы - гының табигый һәм техноген минераль то - кымнары, химик составы һәм физик үзлекләре аларны җитештерү өлкәсендә кулланырга мөмкинлек бирә. Физик халәте буенча Ф.к.ны каты, сыек һәм газсыманнарга аералар; килеп чыгышы буенча — утырма, магматик, контакт, метасоматик, метаморфик һәм техноген (антропоген); куллану характеры буенча — янучан, металл булмаган, металл һәм *җир асты сулары*. Күләме, сыйфаты, ят - маның урнашу шартларына һәм билгеле бер икътисади шартларга нисбәттә Ф.к.ның ча - гылмаларын һәм чыганакларын аералар. Та - тарстан терр-ясендә Ф.к.ның 40 ка якын төр - ре (20 се чыгарыла) буенча 2 мең тирәсе чы - ганак ачыкланган. Янучан Ф.к.ның 5 төре: янучан газлар, *нефть*, *янучан сланецлар*, *торф*, *казылма күмерләр*; металл булмаган Ф.к.ның 50 дән артык төре, ш. и. *алевролит*, *ангидрит*, *аргиллит*, *битумнар*, *гипс*, *балчык*; кыйммәтле ташларның 10 төре: *алмаз*, *малахит*, *мәрмәр оникс* һ.б.; металл Ф.к.ның якынча 30 төре, ш.и. 3 кара металл (Fe, Mn, Cr), 10 төсле (ванадий, *бакыр рудалары*, цинк һ.б.), 4 сирәк (Sr, Zr, Ge, Cd), 3 чәчелмә һәм җирдә сирәк очраучы (Ca, Se, Cs), 5 затлы (ал - тын, *көмеш*, Pt, Pd, Ro), 2 радиоактив (U, Th) Ф.к.; җир асты суларының 4 төре, янмый тор - ган газларның 4 төре (N2, He, Ra, CO2; к. *Янучан табигый газлар*) билгеләнгән. Ф.к. ачык (карьерлар) һәм ябык (шахта, скважиналар)

ысуллар б-н чыгарыла. Табигый халәттә яки эшкәртелгәннән соң кулланыла. Ш.у.к. *Файдалы казылмалар геологиясе*, *Табигый байлыклар*.

Әд.: Геология твёрдых полезных ископаемых Республики Татарстан. К., 1999; Геологическое изучение земных недр Республики Татарстан. К., 2002; Минерально-сырьевая база Республики Татарстан. К., 2006.

Э.Х.Рәхмәтуллин.

ФАЙДАЛЫ́ КАЗЫЛМАЛА́Р ГЕОЛО́ГИЯСЕ, Җир астында файдалы казылмалар (ФК) чыганаклары барлыкка килү шартларын, аларның төзелеше һәм составын өйрәнүче фән; геол. бүлеге. Каты, сыек һәм газсыман ФК чыганакларының килеп чыгышын һәм урнашу закончалыкларын өйрәнә. Геол. белеменең *геохимия*, минерал. һәм *петрография-не* үз эченә алучы матди һәм структур геологияне, *тектоника*, тарихи һәм төбәк геологиясен берләштерүче фәзаи тармакларына таяна. ФК турындагы фән җәмгыятьнең минераль чималга ихтыяҗы арту һәм тау эшләренең үсүе сәбәпле формалаша. ФК барлыкка килү шартлары турында беренче күзаллаулар грек философлары (Фалес, Гераклит), урта гасырлар (Г.Агрикола, Р.Декарт), 18 йөз (А.Вернер, Дж.Геттен, М.В.Ломоносов), 19 йөз галимнәре (Д.И.Соколов, Г.Щуравский) хезмәтләрендә күренә. Татарстанда ФКны системалы өйрәнү Казан ун-ты оештырылудан, 1840 елда минерал. һәм геогнозия каф. булдырудан башлана, аның хезмәткәрләре җирле төбәк геологиясе буенча тикшеренүләр үткәрәләр (П.И.Вагнер, Ф.Ф.Розен, А.М.Зайцев, А.В.Лаврский, П.И.Кротов). 19 йөз ахыры — 20 йөз башында минераль чимал төрләре буенча ФКны тикшеренүләрнең дифференциациясе була: нефть һәм газ, ташкүмер геологиясе, 20 йөз уртасында металл булмаган ФК геологиясе; яңа тармак — металлогения (минерагения) — ФК чыганаклары турында тәгълимат барлыкка килә. 1945 тә СССР ФА Казан ф-лы каршында Геол. ин-ты (хәзер ЦНИИгеолнеруд) булдырыла; 1952 дә Казан ун-тында — ФК кафедрасы, руда казылмалары геологиясе (Л.М.Миропольский, И.Н.Пеньков, В.Г.Изотов, В.Г.Чайкин һ.б.), нефть һәм газ геологиясе (к. *Нефть һәм газ геологиясе*), күмер геологиясе, руда булмаган геол. (Е.М.Аксёнов, Н.Б.Вәлитов, Н.Н.Ведерников, У.Г.Дистанов, В.Г.Изотов, Н.В.Кирсанов, Л.М.Миропольский, А.С.Михайлов, В.А.Полянин, Ю.В.Сементовский, И.Н.Тихвинский, Е.И.Тихвинская, Р.М.Фәйзуллин һ.б.), минераль ресурслар икътисады (А.П.Плёнкин, Р.К.Садыйков, П.П.Сенаторов, Р.З.Фәхретдинов, Н.С.Чуприна, И.Л.Шаманский һ.б.) юнәлешләре шактый үсеш ала. ТРда ФК чыганакларын эзләү һәм разведкалау Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы җитәкчелегендә гамәлгә ашырыла. Фәнни тикшеренүләр Казан ун-тында, ЦНИИгеолнеруд, «Татнефть» АҖнең фәнни һәм геол. җитештерү берләшмәләрендә, «Татнефтегеофизика» ФҖБдә алып барыла. Руда булмаган Ф.к.г. өлкәсендәге казанышлар ТР Дәүләт бүләге (1995, 1998), СССР МС, СССР ВДНХсының алтын һәм көмеш медальләре б-н билгеләнә.

ФАЙДАЛЫ́ КАЗЫЛМАЛА́Р ЧЫГАНАГЫ́, күләме, сыйфаты һәм яту шартлары буенча сәнәгый кулланылыш өчен яраклы өслектә яки Җир астында табигый яки техноген минераль матдәләрнең тупланышы. Матдәләр төре һәм файдалы казылмаларны куллану буенча руда (металлар) һәм руда булмаган (металл булмаган), ягулык-энергетика (янучан газлар, янучан сланецлар, нефть, торф, күмер, уран), гидроминерал. (бром һәм йод, җир асты сулары), инерт газлар, техноген Ф.к.ч.ларына аерыла; физик халәте буенча — газсыман (янучан һәм янмый торган), сыек (нефть, битум, җир асты сулары) һәм каты; яту формасы буенча — штоклар, катлам, тамыр һ.б.ш.; ачылу дәрәҗәсе буенча — ачык (өслектә ачылучы) һәм ябык (күмелгән); геол. барлыкка килү шартлары буенча — седиментоген (экзоген), магматоген (эндоген) һәм метаморфик; төзүче матдәләр чыганаклары буенча — магматик һәм утырма тышлык; формалашу урыны буенча — геосинклиналь (җыерчыклы өлкәләр) һәм платформа. Ф.к.ч. Җир тарихы дәвамында һәм хәзерге вакытка кадәр (ш.и. техноген) барлыкка киләләр. Татарстан терр-ясендә 1 меңнән артык Ф.к.ч. билгеле, ягулык-энергетика (ачык платформа астибындагы) чыганаклары икътисад өчен аеруча әһәмиятле, руда булмаган (ачык һәм ябык), гидроминерал., техноген (ачык) чыганакларның әһәмияте берникадәр азрак; руда (ябык), инерт газларның әһәмияте аз.

ФАЙДАЛЫ́ КАЗЫЛМАЛА́Р ЯТМАСЫ́, җир кабыгында әйләнә-тирәдәге токымнардан ачык чикләнүче минераль матдәләрнең табигый яки техноген тупланышы. Ятмалар сәнәгый (эшкәртү өчен икътисади әһәмият-ле) һәм сәнәгый булмаган, руда (металлар), руда булмаган (кыйммәтле ташлар, ком, балчык һ.б.) һәм янучаннарга (*нефть*, газ, *битум*, сланецлар, күмер, торф) бүленәләр. Табылу формасы буенча каты, сыек һәм газсыман булалар; геометрик формасы буенча — изометрик (штоклар, оялар), баганасыман, плитәсыман (тамырлар, катламнар) һәм катлаулы (штоклар, баскычлы тамырлар); генетик формалашу үзенчәлекләре буенча — структур (җыелма, моноклиналь һ.б.), литологик, стратиграфик, рифоген һәм катнаш типта. Татарстан терр-ясендә нефть, битум, *балчык*, *казылма күмерләр*, төзелеш материаллары ятмалары һ.б. бар.

ФА́ЙНБЕРГ Аркадий (Авраам) Борисович (27.4.1930, Рязань өлкәсенең Скопин ш. — 20.6.2010, Израиль, Ашдод ш.), сәнгать белгече, сәнгать фән. канд. (1979), шагыйрь, ТР-ның атказ. сәнгать эшлеклесе (1987). 1942 елдан Казанда. Казан ун-тының тарих-филол. ф-тын (1954), СССР САнең И.Е. Репин исем. Ленинград нәкышь, скульптура һәм архит-ра ин-тын (1965) тәмамлый, ТАССР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда фәнни хезмәткәр (1959–72), Казан мәдәният ин-тында (1972–94) укытучы булып эшли. СССР Рәссамнар берлеге әгъзасы (1971). 1995 тә Израильгә күченеп китә, Израильнең рус телле Язучылар берлеге әгъзасы (1997).

«Казан рәссамнарының сәяси плакаты» («Политический плакат Казанских художников. 1941–1945», 1965), «Татарстан рәссамнары» («Художники Татарии», Л., 1983), «Лотфулла Фәттахов» («Лотфулла Фаттахов», 1990) китаплары авторы. Ф.ның беренче шигырьләр җыентыгы — «Бәхет формуласы» («Формула счастья») 1995 тә Казанда бастырыла. Израильдә аның «Яһүд йөрәге» («Еврейское сердце», 1997), «Шагыйрь күңеле» («Душа поэта», 2007), «Минем Израилем» («Мой Израиль», 2008) шигырьләр һәм поэмалар китаплары, «Яһүд геннары» («Еврейские гены», 1998) автобиографик повесте һ.б. нәшер ителә. 1999 да Мәскәүдә 4 шигырьләр җыентыгы дөнья күрә. Израильдә үткәрелгән 1 нче Халыкара рус шигърияте конкурсы лауреаты (2006). Ф. шигырьләренә 20 дән артык җыр язылган: «Мәхәббәт гимны» («Гимн любви», комп. Э.Казачков), «Очрашу» («Встреча», комп. И.Прудникова).

Әд.: Червонная С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984; «Авраам Файнберг в зеркале мнений». Ашдод, 2001; Венок памяти. Ашдод, 2011.

ФАЛНАМӘ́ (фарсы. فالنامـــه — фал, багу, күрәзәлек итү һәм фарсы. намә — хат, китап), багу китабы. Урта гасырларда Якын һәм Урта Көнчыгыш илләрендә гарәп, фарсы һәм төрек телләрендә язма рәвештә тарала. Шәхси, дөньяви тормышта, шәрекъ идарәчеләре сарайларында кулланылышта йөри. Ф. буларак ш.у. Коръән, күләмле шигъри әсәрләр, төш юрау китаплары һ.б. файдаланыла. Төрки телдә сакланган иң борынгы Ф. — «Ырк битик» (9 йөз «Багу китабы», Британия музеенда саклана, Лондон), татар телендә — «Козгын фалы», «Комалак салу», «Уникә еллык хайван белән аталган фалнамә», «Йосыф тәгъбирнамәсе», «Нәүширван тәгъбирнамәсе» һ.б.

Әд.: Төш юрау китабы: тәгъбирнамә, юрамышлар, ырымнар. К., 1991; Әхмәтҗанов М. Татарда күрәзә ысуллары // Идел. 1996. № 12; Ырк битиг: Древнетюркская гадательная книга. М., 2004.

М.И.Әхмәтҗанов.

ФАМИ́ЛИЯ (лат. familia — гаилә, нәсел), кешенең бер нәселгә, бер гаиләгә караганлыгын күрсәткән нәсел атамасын буыннан-буынга күчерү функциясен башкара торган антропонимик категория. Шәхеснең исем-фамилиясе б-н берләттән аның охшашлык билгеләрен дә ачыклау өчен хезмәт итә. Ислам кабул ителгәнгә кадәрге чорда төрки-татарларда Ф. функциясен туганлыкны белдерүче сүзләр, катлау титулы атамалары, кушаматлар (морза, чура, углан, хан, би, бәк, тархан һ.б.) үти, алар шәхеснең исеменә ялганып килә торган була: Тургай хан, Аккош би, Котлы тархан, Тимер Котлыгъ углан, Ырыс бәк. Туганлык терминнарының (улы, кызы, баласы) кеше исеменнән соң кулланылуы тагын да соңгырак чорга хас: Рәхмәтулла бине Йагъкуб кызы Бибигайшә, Сәет Ишман углы, Таһир углы Исмәгыйль мелла.

Идел буе Болгар дәүләтенә ислам кабул ителгәннән соң (10 йөз), хәзерге татарларның борынгы ата-бабалары теленә Ф. функциясен башкаруда охшашлыкны белдерүче -ибне, -бине, -бинте кебек сүзләр, туган җир, нәсел, титул б-н бәйле атамалар үтеп керә башлый: Кара бине Канбар бәк, Суфый

бине Гали би, Касыйм шәех, Мәхмүд ибне Гали ибне Гомәр әл-Болгари әс-Сараи. Әдәбият, сәнгать һәм фән эшлеклеләре, туган шәһәрләре, авыллары яки ата-бабалары исемнәренә фарсы телендәге -и/-ый, -ви кушымчалары өстәп, фамилияләргә охшаш атамалар йөртә башлыйлар: Габдерахман әл-Кирмәни, Габделҗаббар Кандалый һ.б. Сирәк кенә кушымчасыз Ф.ләр дә кулланыла: Габдулла Тукай, Шәриф Камал, Гамил Афзал, Зөлфәт Хәким.

16 йөзнең 2 нче яртысыннан татарлар арасында -ов/-ова, -ев/-ева, -ин/-ина, -ский/-ская кушымчалы Ф.ләр таралыш ала. Аларның ясалышына ата-бабалар исемнәренең тулы яки кыскартылган формалары (Солтанов, Тәфкилев, Кашаев), кушаматлар (Сатыймов, Тәкыев), топонимнар (Казанский, Крымский), этнонимнар (Нагаев, Татаринов, Башкиров), уртаклык исемнәр (Кунаков, Качкынчиев) нигез була. Язма ядкәрләрдән күренгәнчә, рус суффиксы ялганып ясалган беренче Ф.ләр йомышлы татарлар арасында таралган була: Бичурин, Булатов, Тенишев, Еникиев. Хәзерге кулланылыштагы татар Ф.ләре бары 19 йөзнең 2 нче яртысы — 20 йөз башында гына формалашып бетә.

Хәзерге татар Ф.ләре берничә төрле юл б-н ясала: 1) -ов/-ова, -ев/-ева, -ин/-ина кушымчаларына тәмамланган Ф.ләр. Бу очракта кушымчалар гарәп һәм фарсы сүзләре нигезенә ялгана: Галиев, Хафизов, Гатауллин (аеруча киң таралган төр); 2) -ский/-ская, -лы/-ле кушымчалы Ф.ләр иҗат б-н шөгыльләнүче зыялылар арасында очрый: Камский, Кайбицкая, Уральский, Казанлы, Иделле, Мулилле; 3) кушымчалары кыскарган Ф.ләр псевдоним буларак кулланыла, алар 20 йөздә — 21 йөз башында рәсми рәвештә кулланыла башлый: Муса Җәлил, Зәйни Солтан, Сибгат Хәким, Айдар Хәлим. Икеле Ф.ләр (Терегулова-Булатова, Богданова-Сафина, Вәлиева-Сөләйманова) татарлар арасында сирәк кулланыла. Татар ономастикасы үсешенә Г.Ф.Саттаров, Г.Р.Галиуллина зур өлеш кертәләр.

Әд.: Саттаров Г.Ф. Татар антропонимикасы. К., 1990; Мазитова Ф., Юсупов Г.В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. М., 1960; Татарско-русский словарь личных имён и фамилий. К., 2006; Галиуллина Г.Р. Татарские личные имена в контексте лингвокультурных традиций. К., 2008.

Г.Р.Галиуллина.

ФАНАГО́РИЯ (Фәнагор), Тамань ярымутравында, хәзерге Краснодар крае Сенной посёлогы янында урнашкан антик чор һәм урта гасырлар шәһәре. Б.э.к. 540 елларда борынгы Иониянең Теос шәһәреннән күчеп килүчеләр тарафыннан нигезләнә. Б.э.к. 5 йөздән башлап Боспор дәүләте (Төньяк Кара диңгез буе) составында була. 4 йөздә Ф. шәһәре һуннар тарафыннан җимерелә. Соңрак Ф. кабат торгызыла. 7 йөздә *Бөек Болгар дәүләте* башкаласы (630–60 еллар); ул таркалганнан соң, *Хәзәр каганлыгына* буйсынды-рыла. 10 йөздә бәҗәнәкләр тарафыннан җимерелә.

Әд.: Фанагория. М., 2008.

И.Л.Измайлов.

ФАНИ́ ДӨНЬЯ́, к. *Ахирәт.*

ФАНТА́СТИКА (грек. phantastiké — күзаллау осталыгы), тормыш-чынбарлыкны сәнгатьчә гәүдәләндерүнең үзенчәлекле формасы. Фантастик әсәрдә тормыш-чынбарлык гажәеп, гадәттән тыш һәм табигый булмаган элементлар б-н төрле һәм органик рәвештә аралаштырыла. Фантастик жанрларның эстетик доминантасы — фантастик фаразлау, ягъни гомумән яисә билгеле бер шартларда булуы мөмкин түгел фактор. Татар әдәбиятында Ф. элементлары Коръәннән алынган дини-мифологик образларны, персонажларны һәм мистик сюжетларны файдалануда чагыла (Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф», Мөхәммәдъярның «Төхфәи мәрдан» поэмалары). Г.Исхакыйның «Ике йөз елдан соң ин кыйраз» әсәре — роман-утопиянең типик мисалы. Хәзерге татарларның ерак бабалары тәэҗрибәсен тасвирлап һәм ерак киләчәккә күз салып, автор татар теленең, мәдәниятенең һәм, гомумән, милләтнең юкка чыгу ихтималын искәртә. Ф.Әмирханның «Фәтхулла хәзрәт» повестенда Ф. сатирик максатларда кулланыла. Киләчәккә күчерелгән баш геройның тискәре яклары урынсыз һәм мәгънәсез тоела. Шулай итеп, фантастик фаразлау әдипкә әсәрнең проблемаларын яхшырак ачарга ярдәм итә. Совет чорында фантастик һәм фәнни-фантастик повесть һәм хикәяләр авторлары А.Расих («Бәхет орлыклары»), Г.Кутуй («Рөстәм мажаралары»), Г.Гомәр («Юлбарыс тырнагы») үзләренең утопик идеалларын фәнни гипотеза кулланып чагылдыралар, бу исә аларның әсәрләренә танып-белү әһәмияте бирә. Р.Батулла һәм Г.Гыйльманов татар халык әкиятләре, мифлар һәм тарихи риваять мотивлары буенча Ф. элементлары кулланылган әсәрләр иҗат итәләр. Фантастик алымнар (гротеск, фантасмагория, фантастик персонажлар) З.Хәкимнең «Су төбендә сөйгәнем» комедиясендә файдаланыла. Ф. жанрында аеруча А. Тимергалин нәтиҗәле эшли: «Ерак планетада», «Космостан кунаклар», «Адашкан йолдыз», «Таш алиһә» һ.б. Аның әсәрләре нигезендә, кагыйдә буларак, нинди дә булса фәнни идея, гипотеза яисә техник уйлап табу, ягъни киләчәккә күчәргә мөмкинлек тудыручы табигый-фәнни фаразлау ята. Иҗатының төп проблемалары — техник алгарыш нәтиҗәсендә тормыш-чынбарлыкның үзгәрүе һәм кеше психологиясенә тәэсире. А.Тимергалин иҗатында Ф. реалистик матур әдәбияттан аерымлана һәм татар прозасының мөстәкыйль жанрына әверелә.

Әд.: Хузин М. Ант һәм өмет // Казан утлары. 2001. № 1; Вәлиев М. Элкер — өмет йолдызы // Гамәл дәфтәре. К., 2003.

Р.Ә.Мостафин.

ФАРАЗЛАНГА́Н ЛО́ГИКА, к. *Математик логика.*

ФАРМАКОЛО́ГИЯ (грек. pharmakon — дару һәм *...логия*), дару препаратларының кеше һәм хайваннар организмына тәэсирен өйрәнүче фән. Ф.нең төп бурычларыннан берсе — нәтиҗәле дәвалау чаралары уйлап табу һәм аларны гамәлгә кертү. Дару матдәләрен өйрәнүче фармакологик химия, физиол., биол. һәм башка фән тармаклары б-н тыгыз бәйләнештә тора. Ф. медицинаның иң борынгы юнәлешләреннән санала. Дару матдәләре турында беренче системалаштырылган мәгълүматлар Борынгы Мисыр папирусларында очрый; Гиппократ, Диоскирид һ.б.ның хезмәтләрендә 300 ләп дару үләне искә алына. Ф. буенча Татарстан терр-ясендә билгеле иң борынгы язма ядкәр — *Таҗетдин бине Юныс әл-Болгариның «Әт-Тиръяк әл-кәбир»* («Агуланулардан көчле дәва») хезмәте.

Татарстан терр-ясендә алып барылган фармакологик фәнни тикшеренүләр үсеше Казан ун-тында Ф. кафедрасы оештырылу б-н бәйле (1884, мөдире И.М.*Догель*). Фармакологик фәнни юнәлешне нигезләүчеләр һәм бу өлкәдә беренче җитәкчеләр — медицина д-ры А.Я.*Данилевский* (1864–68) һәм Россиядә беренчеләрдән булып эксперименталь Ф. һәм рецептура кертүче И.М.Догель (1869–1916). Догельның «Кан һәм лимфа юлларының чагыштырма анатомиясе, физиологиясе һәм фармакологиясе» («Сравнительная анатомия, физиология и фармакология кровеносных и лимфатических сосудов», 1896), «Фармакология һәм рецептура нигезләре» («Основы фармакологии и рецептуры», СПб., 1900) хезмәтләре Россия Ф.се үсешенә сизелерлек өлеш кертә. Догель беренче булып, тәэҗрибәләр юлы б-н борынның лайлалы тышчасындагы нерв очларын хлороформ парлары б-н ярсытканда, йөрәкнең рефлектор рәвештә туктау ихтималы булуын дәлилли. Аның шәкертләре тарафыннан туендырылмаган бер атомлы спиртлар, кураре агуы, строфантин, атропин, мышьяк, камфора, беренчел амин тозлары тәэсире; препаратлар тәэсирендә күз карасын кечерәйтүче һәм киңәйтүче, күзнең кан басымын, күз конъюнктивасының кан әйләнешен үзгәртүче нерв һәм мускуллар өйрәнелә.

В.М.Соколов алып барган фәнни эзләнүләрнең төп тематикасын Ф.нең гомуми мәсьәләләре тәшкил итә; А.А.*Вишневский*, В.И.Пшеничников, И.И.Корнилов, Т.В.Распопова, И.М.*Утробин* аерым урын анестезиясе проблемаларын өйрәнәләр. Дару матдәләре чыганагы буларак фосфорорганик кушылмаларны өйрәнү Казанда башлана. Аерым урынны анестезияләүче матдәләрнең тәэсир итү механизмы һәм аларның адреналин б-н үзара йогынтысы өйрәнелә (М.А.*Алуф*, Т.В.Распопова, Л.С.Афонская). М.А.Алуф җитәкчелегендә үсемлекләрдән алынган һәм синтетик нигездәге яңа дару матдәләре, фосфорорганик кушылмаларның биол. активлыгы тикшерелә. Глаукоманы дәвалауда кулланылучы дарулардан иң элек гамәлгә кертелгән армин препараты беренче тапкыр Казанда синтезлана (1955). И.В.*Заиконникова* һәм аның кул астындагы хезмәткәрләр дәвалау практикасына 1962 елда кертелгән, токсикологик яктан арминга караганда зыянсызрак нибуфин (дибутилфосфин к-тасының паранитрофенил эфиры) препараты өстендә эшлиләр.

1960 еллардан фосфорорганик кушылмаларның микробларга каршы активлыгын өйрәнү башлана (И.В.Заиконникова, Л.С.Афонская), аларның микроб һәм вирус -

ларга каршы активлык спектры билгеләнә (Г.Ф.*Ржевская*). Фосфолен һәм 1,1-диметил-3-кетобутилфосфон к-тасы нигезендәге, башлыча үзәк нерв системасына тәэсир итүче препаратлар эшләнә (И.А.*Студенцова*, В.Г.Дунаев, Р.С.Гәрәев, 1964); аларның көзән җыеруга каршы активлыгы, антихолинэстераза матдәләре б-н агулану очракларында антидот буларак куллану мөмкинлеге бирүче үзлекләре ачыклана. Фосфорорганик кушылмалардан кайберләренең спазмалитик, адреналин бүленеп чыгу активлыгын тоткарлаучы үзлекләргә ия булуы дәлилләнә (И.В.Березовская, Г.Ф.Ржевская, Л.Г.Уразаева). Яман шешләргә каршы препаратларны өйрәнү башлана. Тире рагын һәм тиредәге рак алды авыруларын дәвалау өчен цидифос, глицифон (И.А.Студенцова, Р.С.Гәрәев, И.С.Мокринская, Л.Н.Җәләлетдинова, В.И.Романов һ.б.), тәэсир итү спектры гаять киң булган димефосфон (И.А.Студенцова, Р.С.Гәрәев, Р.Х. Хафизҗанова, ТР Дәүләт бүләге, 1994), көндезге транквилизатор буларак мебикар (И.Е.Зимакова, «Татхимфармпрепаратлар» АҖ, Казан) препаратлары тикшерелә. Токсинлылыгы һәм антихолинэстераза активлыгы түбән булган кушылмалар-ның киң фармакологик тәэсир итү спектрына ия булулары ачыклана (А.Б.Арбузов, А.О.*Визель*, И.В.Заиконникова, И.А.Студенцова). Әлеге идеянең нәтиҗәлелеге химиклар (А.О.Визель, А.А.Муслинкин, Э.А.Гурылев һ.б.) һәм клиницистлар (В.А.Панкова, В.И.Данилов, М.Ф.Исмәгыйлев һ.б.) катнашында илебездә эшләнгән цидифос, глицифон, димефосфон, мебикар, таспир (И.А.Студенцова, Р.С.Гәрәев, Р.Х.Хафизҗанова, Л.Е.Җи һаншина, А.З.Байчурина һ.б.) кебек оригиналь препаратларның мед. практикасына кертелүе б-н раслана. И.А.Студенцова тарафыннан кайбер фосфорорганик эпоксидларның бластомага каршы һәм агулау тәэсире эксперименталь юл б-н тикшерелә. Антихолинэнтеразалы булмаган фосфорорганик кушылмалар рәтендәге яңа дару матдәләре эшләнә (А.Е.Арбузов исем. Органик һәм физик химия ин-тында синтезлана, А.О.Визель). Г.Ф.Ржевская алкогольгә каршы фосфабензид (фосфорильләшкән карбон к-талары гидразидыннан алынган) матдәсен китереп чыгара. «Даруларны сайлап алу һәм нәтиҗәле куллануның яңа технологиясе — формуляр системасы төзү һәм ТРның сәламәтлек саклау өлкәсендә гамәлгә кертү» хезмәте өчен Л.Е.Җи һаншина, Н.И.Галиуллин, А.Г.Җи һаншин, М.В.Кормачёв ТРның Фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт бүләгенә лаек була (2007).

2012 дә Казанда фармакологларның IV Бөтенроссия съезды уздырыла.

Казан (Идел буе) федераль ун-тының Фундаменталь һәм клиник Ф. кафедрасында (2011 дә оештырыла) «Россия Федерациясендә фармацевтика һәм медицина сәнәгатенең 2020 елга кадәр һәм алга таба үсеше» Федераль максатчан программасын тормышка ашыру буенча эш алып барыла.

Әд.: Студенцова И.А. Антибластомное и токсическое действие некоторых фосфорорганических эпоксидов в эксперименте. К., 1966; Зиганшина Л.Е., Студенцова И.А., Заиконникова И.В. Влияние димефосфона на воспалительную реакцию // Фармакология и токсикология. 1988. № 3; Зиганшин А.У., Зиганшина Л.Е. Фармакология рецепторов АТФ. М., 1999.

Р.С.Гәрәев.

ФА́РСИНА Люция Габдулла кызы (30.9.1930, Казан — 5.3.2005, шунда ук), драма актрисасы, ТАССРның халык артисты (1980). Татар театр уч-щесен тәмамлый (Казан, 1951). 1951–58, 1961–2005 елларда — Татар драма һәм комедия театры, 1958–61 дә Татар акад. театры актрисасы. Матур тышкы кыяфәткә ия Ф., башлыча, Сара («Беренче чәчәкләр», К.Тинчурин), Пари («Сулган чәчәкләр», Ж.Җаббарлы), Сәкинә («Тугыз гашыйк», З.Шаһиморатов), Зөлхия («Кыр казлары артыннан», И.Юзеев), Зөһрә («Таһир-Зөһрә», Ф.Бурнаш), Рәхилә («Беренче мәхәббәт», Х.Вахит), Разия («Киек каз юлы»,



Л.Г. Фарсина Пари ролендә («Сулган чәчәкләр» Ж. Җаббарлы; Бәһрам ролендә — Ф. Фарсин).

А.Гыйләҗев), Кручинина («Гаепсездән гаеплеләр», А.Н.Островский), Лика («Минем бичара Маратым», А.Н.Арбузов) кебек яшь һәм социаль героинялар рольләрен башкара. Кручинина язмышын гәүдәләндергәндә, Ф. актрисаның рев-циягә кадәрге театрдагы социаль хәлен генә ачып калмый, ә хатын-кызның сәхнәгә булган мәхәббәте б-н газиз баласын өзелеп ярату хисе арасындагы әхлакый сайланыш проблемасын да күтәреп чыга. Тыныч, күзгә артык бәрелми торган Зөлфия образында актриса авыр тормыш юлы узган кешенең ялгызлыгын ассызыклый. Аның башкаруында күтәренке рух, хисләрнең романтик үстерелеше геройларның тормыш-көнкүрешләренә психол. яктан тирәнтен үтеп керү һәм рольнең тышкы рәсемен төгәл гәүдәләндерү б-н үрелеп бара.

Әд.: Илялова И.И. Театр имени К.Тинчурина. К., 2002.

ФАРСЫ́ АЛЫНМАЛАРЫ́, фарсы теленнән кергән сүзләр һәм сүзтезмәләр. Ф.а. татар-болгарлар һәм кыпчакларның борынгы ата-бабалары арасында 8–9 йөзләрдән Идел буе (ш.и. Идел буе Болгар дәүләте) халыкларының фарсы телле халыклар б-н Идел-Каспий су юллары аша сәүдә һәм мәдәни багланышларына бәйле рәвештә таралыш ала. Тематик яктан Ф.а. түбәндәге төркемнәргә бүленә: мифология (фәрештә, дию, аждә һ.); дин (Ходa(й), пәйгамбәр, ураза, намаз); а.х. (бакча, чөгендер, шалкан); көнкүреш (палас, таба, тастымал); сәүдә (сәүдәгәр, бәя, базар); культурология (тамаша, тантана); иҗтимагый-сәяси төшенчәләр (патша (падишаһ), шура); канцелярия (кәгазь, мөһер, дәфтәр); абстракт төшенчәләр (рәвеш, җи һән, бәхет, начар); вакыт (заман, якшәмбе, дүшәмбе, сишәмбе, чәршәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә); зоология (җанвар, күсе); география (дәрья, чишмә); шәхси сыйфатлар (миһербанлылык, пәһлеван, каһарман, дус, дошман); антропология (тән, җан); антропонимия (Азат, Раушан, Зифа, Бану); һөнәр (хезмәткәр, ху җа) һ.б. б-н бәйле алынма сүзләр.



Л.Г. Фарсина.

Тел белемендә теркәгечләр (һәм, ки, яки, чөнки, әгәр, гүя, гүяки, гәрчә, мәгәр) һәм алмашлыклар да (нич, һәммә, һәр) Ф.а. булып тора.

Хәзерге татар әдәби телендә 600 дән артык Ф.а. бар, аларның күпчелеге, татар теленең фонетик һәм грамматик йогынтысын кичереп, шушы телдә ныгып кала һәм татар теленең төп сүзлек фондын (хәйләкәр, арзан, бакча, сәүдә, дус, тамаша һ.б.) тәшкил итә башлый. 1930 еллардан соң Ф.а., гарәп алынмаларыннан аермалы буларак, татар теленнән кысрыкланып чыгарылуга дучар ителми.

Әд.: Әхмәтьянов Р.Г. Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге. К., 2001; Серебренников Б.А., Гаджиева Н.З. Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Баку, 1979; Щербак А.М. Очерки по сравнительной морфологии тюркских языков. М., 1979; Языки мира: Тюркские языки. М., 1997.

Р.Т.Йөзмөхәммәтов.

ФАРСЫ́ ТЕЛЕ́, иранлылар теле. Һинд-Европа телләре гаиләсендәге иранилар төркеменә карый. Иран (рәсми телләре), Әфганстан, Пакъстан, Һиндстан, Гыйрак, Оман һ.б. илләрдә таралыш алган. Дөнья күләмендә Ф.т.ндә сөйләшүчеләр исәбен якынча 40 млн. кеше тәшкил итә. Ф.т. тарихында 3 чор — борынгы фарсы теле өстенлек иткән борынгы (б.э.к. 6–4 йөзләр), урта (урта дәвер фарсы теле, б.э.к. 4–3 йөзләр — б.э.ның 8–9 йөзләре) һәм яңа (классик һәм хәзерге фарсы телләре, 8–9 йөзләрдән алып хәзерге көнгә кадәр) чорлар аерып карала. Ф.т.ндә 6 сузык фонема, 2 дифтонг, 22 тартык бар. Исем сүз төркеменә сан, билгелелек һәм билгесезлек грамматик категорияләре хас. Басым күпчелек сүзләрдә соңгы иҗеккә төшә. Килеш һәм род грамматик категорияләре юк. Фигыль сүз төркеменә зат, заман, юнәлеш һәм наклоне -

ние грамматик категорияләре хас. Җөмләдә сүзләрне үзара бәйләү өчен изафә, бәйлекләр (предлог, послелог) кулланыла. Сүзлек составының төп өлешен телдә ныгып калган борынгы фарсы сүзләре тәшкил итә, ш.у. гарәп, төрек, француз, инглиз һ.б. телләрдән кергән алынмалар да күп. Ф.т.нең шактый гына сөйләшләре (тегеран сөйләше аеруча өйрәнелгән), ш.у. борынгы язма традициясе (Ф.т.ндә бай әдәбият сакланган) бар. Беренче язма ядкәрләр 9 йөзнең 1 нче яртысына карый. Язуы гарәп алфавитына нигезләнгән (к. *Гарәп язуы*), ул гарәп телендә булмаган авазларны белдерү өчен берничә билге б-н тулыландырылган. 20 йөз башына кадәр Г.Курсави, Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Г.Тукай, М.Бигиев, Р.Фәхретдин һ.б. үзләренең фәнни трактатларында һәм әдәби әсәрләрендә Ф.т.ннән күчкән алынмаларны киң кулланалар. Татар теленә Ф.т.ннән шактый сүзләр кергән (к. *Фарсы алынмалары*).

Әд.: Бертельс Е.Э. Грамматика персидского языка. Л., 1926; Основы иранского языкознания: Древнеперсидский язык. М., 1981; Рубинчик Ю.А. Грамматика современного персидского литературного языка. М., 2001.

Г.Г.Зәйнуллин.

ФАРУ́КШИН Мидхәт Хәбиб улы (30.10.1939, Казан), философ, политолог, публицист, хокук фән. канд. (1965), филос. фән. д-ры (1977), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (1998), ТАССРның һәм РФнең атказ. фән эшлеклесе (1989, 2001). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1961), шунда ук эшли (1965 елдан Казан авиация ин-тында, 1966–69 да Казан төзүче инженерлар ин-тында), проф. (1979), 1979–90 да фәнни коммунизм, 1990–2009 да политология каф. мөдире. Татарстан Совет Социалистик Респ-касының дәүләт суверенитеты турында Декларацияне (1990), Татарстан Респ-касы Конституциясе проектын (1992) һ.б. мөһим документларны әзерләүчеләрнең берсе. Хезмәтләре теоретик политологиягә, аерым алганда, Россиядә һәм чит илләрдә федерализм мәсьәләләренә карый; югары уку йортлары өчен дәреслекләр авторы. АКШ, ГФР, Испания, Бельгия, Франция, Швейцария ун-тларында лекцияләр укый.

Хезм.: Интернационализм вместо национализма (или почему иллюзорны надежды противников социализма). К., 1989 (автордаш); Современный федерализм: Российский и зарубежный опыт. К., 1998; Федерализм: Теоретические и прикладные аспекты. М., 2004.

Әд.: Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

ФАРФО́Р-ФАЯ́НС СӘНГАТЕ́, к. «*Бөгелмә фарфоры*».

ФАСИ́ЕВ Камил Фатих улы (10.5.1919, Самара губ., Бөгелмә өязе Тимәш а. — 2.4.2005, Казан), дәүләт эшлеклесе, философ, филос. фән. д-ры (1972), проф. (1973), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1979). ВКП(б) ҮК каршындагы Югары партия мәктәбен (Мәскәү, 1944), КПСС ҮК каршындагы Иҗтимагый фәннәр академиясен (Мәскәү, 1953) тәмамлый. 1939 елдан партия эшендә: 1957–59 да КПССның Татарстан өлкә ком-ты секретаре, 1959–60 та ТАССР ЮС Президиумы рәисе, бер үк вакытта РСФСР ЮС рәисенең беренче урынбасары, 1961–63 тә СССР ФА Казан ф-лының Тел, әдәбият һәм тарих ин-ты директоры, 1963–91дә Казан ун-тында фәнни коммунизм каф. мөдире (1979 га кадәр). 1959–63 елларда ТАССР һәм РСФСР ЮС депутаты. Хезмәтләре СССРда милләтара мөнәсәбәтләр, ТАССРда мәдәният, тел үсеше мәсьәләләренә карый. Ике «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Национальное и интернациональное в социалистической культуре. К., 1970; На путях пролетарского интернационализма. К., 1971; Иллюзии идеологов антикоммунизма. К., 1978.

Әд.: Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

ФАСИ́ЕВ Фазыл Салих улы (18.10.1925, хәзер Лениногорск р-ны Сугышлы а. – 2016, Казан), тел галиме, лексикограф, филол. фән. канд. (1962). Казан ун-тын тәмамлый (1950). 1952–55 елларда ТАССР МС каршындагы Радиофикация ком-тында эшли, Казан фельдшер-акушерлар мәктәбендә татар теле укыта. 1955–86 да СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында (бүленеп: 1964–65 тә Башкорт ун-тында). Хезмәтләре текстология, лексикология һәм лексикография, тарихи ономастика һәм терминологиягә карый. 4 томлы русча-татарча сүзлек (1955–59) мөхәррирләренең берсе. Ф. «Кыссаи Йосыф» поэмасы җыелма текстының беренче тулы акад. басмасын чыгаруга зур өлеш кертә (1983): ул вакытта инде билгеле булган барлык текстларга да (160 тан күбрәк кулъязма) чагыштырма анализ бирә, поэманы хәзерге татар әдәби теленә тәрҗемә итә (А.Х.Нуриева б-н берлектә), текстның кириллица б-н башкарылган транскрипциясен эшли, кереш мәкалә яза һәм аңлатмалар бирә. Татар мәктәпләре, гимназияләре һәм пед. уч-щеләре өчен татар теле дәреслекләре һәм программалары авторы. Бөек Ватан сугышында катнаша. Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Татар телендә терминология нигезләре. К., 1969; Старотатарская деловая письменность XVIII века. К., 1981.

Л.К.Бәйрәмова.

ФАСО́ЛЬ (Phascolus), кузаклылар семьялыгыннан бер- һәм күпьеллык лиана һәм ярым куакчыклар ыругы. 150 дән артык төре билгеле, Америка, Азия, Африка тропик ларында үсә. Культурада якынча 20 төре бар. ТРда, нигездә, гади Ф. үстерелә (P.onlgaris) — язгы берьеллык, корылыкка чыдам, яктылык һәм җылылык яратучы үләнчел үсемлек. Тамыр системасы 1 *м* тирәнлеккә китә. Сабаклары 20–45 *см* лы куаклык формасында, үрмәле — 2,5 *м* га кадәр. Яфраклары өчәрле. Чәчәкләре (ак, алсу, шәмәхә) чуксыман чәчәк төркемендә. Җимеше — кузак, туры, кылычсыман, цилиндрик формада, озынлыгы 7–28 *см*, 3–7 эре (1000 данәнең авырлыгы 300–500 *г*) бөерсыман, төрле төстәге орлыклы. Вегетация чоры 90–95 көн. Үсеше өчен иң яхшы темп-ра 25–30 °С. Ф.не орлыгын грунтка чәчеп үстерәләр. Җиңел, яхшы җылытылган туфракны ярата. 100 *г* бөртегендә 24 *г* аксым, 1 *г* май, 60 *г* углевод, ш.у. B_5, B_9 витаминнары, кальций, тимер бар. Ф.нең аксымы үзенең составы буенча ит аксымына якын һәм организм тарафыннан 75% ка үзләштерелә. Ф. кулинариядә кулланыла. Корткычлары — фасоль, борчак көясе, авырулары — антракиоз һәм бактериоз. ТРда җитештерүдә куллану өчен гади Ф.нең «Уфа» сорты тәкъдим ителгән (1998). Халык хуҗалыкларында азык өчен һәм декоратив культура буларак үстерелә.



Гади фасоль.

Әд.: Справочник по овощеводству. Л., 1982; Овощеводство. М., 2003.

Р.Ә.Әсретдинова.

ФА́СТОВ ИСЕМЕНДӘГЕ́ ТАНК БРИГА́ДАСЫ, Бөек Ватан сугышы елларында Кызыл Армиянең танк берләшмәсе. 1942 елның март-май айларында Казанда һәм Дзержинск шәһәрендә (хәзер Горький өлкәсе) 91 нче аерым танк бригадасы буларак оештырыла. Командирлары — полковник И.И.*Якубовский*, полковник В.И.Тутушкин. 1942–45 тә Сталинград һәм Курск дугасы сугышларында, Украина һәм Польшаны азат итүдә, Берлинны штурмлауда һәм Прага хәрби операциясендә катнаша. 1943 нең ноябрендә оккупацияләнгән Фастов шәһәрен (Украина) азат иткәне өчен Фастов исеме бирелә. Сугышчан казанышлары өчен Ленин ордены, Кызыл Байрак, Суворов һәм Богдан Хмельницкий орденнары б-н бүләкләнә.

Әд.: Якубовский И.И. Земля в огне. М., 1975.

В.Ф.Телишев.

ФАТИХА́ (гарәп. فاتحه — ачучы), Коръәннең беренче, әүтәлегендә ислам тәгълиматы кыскача бәян ителгән сүрәсе. Анда Аллаһка табынырга чакырыла, Аллаһның берлеге раслана, аны инкарь итүчеләр һәм гөнаһлыларның Кыямәт көнендә җәзага тартылачагы әйтелә, гадел тормыш б-н яшәүнең тугры юлын күрсәтүне сорап, Аллаһка ялвару китерелә. Ф. — исламда төп дога һәм барлык мөселман йолаларын үтәгәндә дә укыла. Татар телендә «Ф.» ш.у. ризалык — «хәер-фатиха» бирүне дә аңлата.

Әд.: Тафсир. Аль-Коран. Аль-Мунтахаб. М., 2003; Али А.Ю. Тафсир Священного Корана. Н.Новгород, 2007; Михайлов Ю.А. Пора понимать Коран. М., 2007.

ФАТИ́ХОВ Илдус Шамил улы (5.10.1953, Киров өлкәсенең Көлмез р-ны Яңа Тормыш а.), галим агроном, а.х. фән. д-ры (2002), проф. (1999), Удмурт Респ-касының атказ. фән эшлеклесе (2004). Ижевск а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1979), шунда ук эшли, 1999 елдан проректор һәм үсемлекчелек каф.

мөдире. Хезмәтләре Урал алдында а.х. культураларын үстерү технологиясе мәсьәләләренә карый. Солының «Улов» сорты авторы (Удмурт Респ-касы Дәүләт бүләге, 1966). РФнең Югары һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре (2003).

Х е з м.: Лён-долгунец в Среднем Предуралье. Ижевск, 2002 (автордаш); Ячмень яровой в адаптивном земледелии Среднего Предуралья. Ижевск, 2002; Приёмы ухода и уборки овса в Предуралье. Ижевск, 2003 (автордаш).

Әд.: Кто есть кто в Удмуртии: Справ. Ижевск, 2001.

ФАТИ́ХОВ Тәлгать Кәрим улы (30.11.1929, Тымытык р-ны Тымытык а.), агроном, а.х. пр-тиесе җитәкчесе, ТАССРның атказ. а.х. хезмәткәре (1986). Чабаксар партия мәктәбен тәмамлый (1964). Азнакай р-нында эшли: «Авангард» к-зында (1943 тән), Тымытык МТСында (1954 елдан) һәм «Авангард» к-зында (1958 дән) тракторчы, «Уразман» к-зы рәисе (1964–91). Ф. җитәкчелегендә к-зда алга киткән җитештерү-техник база һәм социаль-мәдәни инфраструктура булдырыла; Үчәлле, Ишкәй, Якты Күл авыллары газлаштырыла. 1964–90 да бөртекле ашлык җитештерү 25,4 мең *ц* дан 29,4 мең *ц* га кадәр, шикәр чөгендере — 4,5 тапкыр (6100 меңнән 27579 мең *ц* га кадәр), сөт — 6,5 мең *ц* дан 12,1 мең *ц* га кадәр, ит — 6,2 тапкыр, шикәр чөгендере уңышы — 1 *га* дан 120 *ц* дан 220 *ц* га кадәр, һәр сыердан уртача еллык савым 2056 *кг* нан 3016 *кг* га кадәр арта. 1981–85 тә ТАССР ЮС депутаты. СССР МС бүләге лауреаты (1986). Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

ФАТИ́ХОВ Шәһит Фатих улы (2.3.1927, Буа кантоны, хәзер Апас р-ны Болын-Балыкчы а. — 3.6.1988, шунда ук), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, ТАССРның атказ. а.х. хезмәткәре (1985). Алабуга пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1954), Болын-Балыкчы урта мәктәбендә укыта. 1969–88 елларда Апас р-ның Куйбышев исем. к-зы рәисе. Ф. җитәкчелегендә колхозда алга киткән җитештерү-техник база һәм социаль-мәдәни инфраструктура булдырыла. 1987 дә, 1969 ел б-н чагыштырганда, ит җитештерү 2,4 тапкыр, шикәр чөгендере — 2,9, аның уңышы 1 *га* дан 196 *ц* га кадәр, һәр сыердан уртача еллык савым 3040 *кг* нан 3909 *кг* га кадәр арта. 1975–80 дә ТАССР ЮС депутаты. Октябрь Рев-циясе, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

И.Н.Афанасьев.

ФАТИ́ХОВА Сәгыйдә Фоат кызы (1.10.1936, Буа р-ны Исәк а.), инженер-технолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1994). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый (1965). Хезмәт эшчәнлеген 1955 елда п/я 735 з-дында фрезерчы булып башлый (Казан). 1966–96 да Казан «Татхимфармпрепаратлар» ҖБдә: инженер-химик, өлкән инженер-технолог, сектор башлыгы, үзәк лаб-ядә өлкән инженер-технолог. Дәүләт бүләге *димефосфон* даруын эшләүдә катнашканы өчен бирелә. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының бронза медале б-н бүләкләнә.

ФАТЫЙМА́ СОЛТА́Н (Фатыйма Солтанбикә) (? – 1681, Касыйм ш.), Касыйм ханлыгының соңгы идарәчесе (ханша) (1679 елдан). Акмөхәммәд сәетнең кызы. Ире Арслан хан вафатыннан соң (1627), Ф.С. һәм Акмөхәммәд сәет балигъ булмаган Сәед Борһан өстеннән идарәче булалар. Ф.С. улын рус патшасы кызына өйләндерү, чукындыру омтылышларына каршы була, мөселманнарның мөлкәти һәм дини хокукларын якларга тырыша. Олы яшьтә тәхеткә утыра, Сәед Бор һанга алмашка килә. Аз гына идарә итә. Ф.С. вафатыннан соң Касыйм ханлыгы яшәүдән туктый.

Әд.: В е л ь я м и н о в - З е р н о в В.В. Исследование о касимовских царях и царевичах. СПб., 1866. Ч. 3; У ч о к Б. Женщины-правительницы в мусульманских государствах. М., 1982.

И.Л.Измайлов.

ФАТЫЙХОВ Вәли Галим улы (31.12.1905, Оренбург ш. — 6.7.1983, шунда ук), актёр, режиссёр, драматург, РСФСРның атказ. артисты (1967). Мәскәүдә режиссёрлык курслары тәмамлый (1933). Сәхнә эшчәнлеген 1922 елда Оренбургта С.Кудашев-Гаспринский җитәкчелегендәге «Шәрекъ» труппасында башлый. Матур җырлау сәләтенә ия; «Таһир-Зөһрә» (Ф.Бурнаш), «Аршин мал алан» (У.Хаҗибәков), «Галиябану» (М.Фәйзи) спектакльләрендә баш рольләрдә яшь герой образларын гәүдәләндерә. 1933 тән Урта Идел төбәгендәге күчмә колхоз-совхоз театры директоры һәм баш режиссёры (1936 дан — Чкалов өлкә колхоз-совхоз театры, 1949 дан — Чкалов өлкә филармония - се каршындагы татар драма коллективы). «Кыю кызлар», «Наёмщик», «Чаткылар» (Т.Гыйззәт), «Асылъяр», «Галиябану» (М.Фәйзи), «Сүнгән йолдызлар», «Зәңгәр шәл», «Кандыр буе» (К.Тинчурин) спектакльләрен куя. «Шәүрәкәй», «Качкын Насыйр», «Ватан улы», «Сылу Гыйззелбанат», «Геройның яшьлеге» пьесаларының авторы һәм аларны сәхнәгә куючы. *Оренбург татар драма театры* тарихында зур роль уйный. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

Әд.: Р а ф и к о в а Р. Из истории Оренбургского государственного татарского театра. Оренбург, 2008.

ФАТЫ́ЙХОВ Миңневазыйх Ха җип улы (15.1.1958, Балык Бистәсе р-ны Югары Тегермәнлек а.), шагыйрь, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (2008). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1980), җирле радиотапшырулар редакциясендә, Балык Бистәсе р-ныңң партия органнарында һәм идарә учреждениеләрендә эшли. 1994 елдан «Авыл офыклары» Балык Бистәсе район г-тасында мөхәррир. «Тормыш-ормыш» (2000), «Яшерен сөю» (2003), «Яфрак күләгәсе» (2005), «Язлар көтә күңел» (2008) шигырь җыентыклары, башлыча, мәхәббәт лирикасына багышлана. Балалар өчен язылган «Патша-кырмыска» (2003) әкияте авторы.

Әд.: Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

ФА́УНА, билгеле бер терр-ядә (акваториядә) яшәүче хайваннар төрләре җыелмасы. ТР Ф.сы умырткалыларның 470 тән артык төрен берләштерә: балыклар (50 дән артык төр), җир-су (11), сөйрәлүчеләр (8), кошлар (321), имезүчеләр (75–81), ш.у. умырткасызларның күпсанлы төрләре (иң түбән төзелешләр, болытсыманнар, эчәккуышлылар, моллюсклар, буынтыгаяклылар һ.б.). Умыртказлылар Ф.сында төп 4 төркемне билгелиләр: тайга урманнарында (соры гөберле бака, үлән бакасы, терелә тудыручы кәлтә, гади кара елан, суер, чукрак күке, кара һәм өч бармаклы тукран, карабүрек, чыршы чукыры, очкалак тиен, борынлык, селәүсен, поши), киң яфраклы урманнарда (буа бакасы, җизбаш, урман күгәрчене, яшел тукран, кара миләш чыпчыгы, кара уткойрык, ак муенлы чебенче, шәүлегән, чикләвек йоклачы, зур йоклач), далаларда (яшел гөберле бака, җитез кәлтә, дала кара еланы, балабан, дала торымтае, дала каракошы, кыр, болын һәм дала карчыгасы, соры көртлек, зур шөлди, сары корташар, һөд-һөд, таш чыпчыгы, болын күпшысы, үр куяны, байбак, тимгелле һәм зур йомраннар, дала тычканчыгы, зур кушаяк, сукыр әрлән, соры әрлән, Эверсман әрләне, корсак, дала көзәне), суда һәм су яны тирәлегендә (балыклар, тритоннар, яшел бакалар, тузбаш, саз ташбакасы, гагаралар, чомгалар, соры чәлән, үрдәкләр, казлар, аккошлар, акчарлаклар, крачкалар, куликлар, балыкчы карчыга, елга каракошы, саз карчыгасы, кара тилгән, соры торна, көтүче кош, кашкалак, су тавыгы, саз-лык ябалагы, яр чыпчыгы, яр карлыгачы, песнәк, су тургае, күктүш, су чикерткәсе, камыш чыпчыклары, чәперчек, камыш һәм имәнлек чыпчыгы, гади шолган, төн ярканатлары, сусар, чәшке, кама, кондыз, ондатра, су тычканы, кабан дуңгызы, поши) яшәүчеләр. Ф.ның кушылу (яшел һәм зур йомран янәшә яшиләр), «далалану» — көньяк дала төрләренең төньякка һәм көнчыгышка таба хәрәкәте (яшел гөберле бака, сасы бака, дала көзәне һ.б.), синантропизация — хайваннарның (соры козгын, йорт тычканы һ.б.) кеше янында яшәүгә яраклашуы көчәю процесслары бара. Ш.у.к. *Хайваннар дөньясы.*

В.И.Гаранин.

ФА́УСТОВ Василий Алексеевич (11.1.1930, Липецк өлкәсенең Задонск р-ны Гнилуша а. – 18.5.2018, Мәскәү), инженер-механик, сәнәгый җитештерүне оештыручы. Новочеркасск политехник ин-тын тәмамлаганнан соң (1952), Ярославль моторлар з-дында: мастер, пролёт башлыгы, цех башлыгы урынбасары, баш инженер урынбасары. 1961 елдан Ярославль ягулык аппаратурасы з-ды директоры. 1966 дан автомобиль двигательләре җитештерү идарәсендә баш инженер, бер үк идарә башлыгының беренче урынбасары, 1976–81 дә баш технолог идарәсе башлыгы, бер үк вакытта, 1979 дан, СССР Автомобиль сәнәгате министрлыгы коллегиясе әгъзасы (Мәскәү). 1981–84 тә СССР автомобиль сәнәгате министры урынбасары, бер үк вакытта, 1981–87 дә, «КамАЗ» ҖБ ген. директоры. 1987–91 СССР дәүләт матди-техник тәэминат ком-ты рәисенең беренче урынбасары (Мәскәү). Ф. җитәкчелек иткән чорда Кама автомобильләр з-ды куәтләрен тизләтелгән үзләштерү тәэмин ителә. «КАМАЗ» ның автомобильләр техникасына авто үзәкләр челтәре, ремонт заводлары аша хезмәт күрсәтү-

нең фирма системасы камилләштерелә. 1750 мең $м^2$ торак йорт, 13 мәктәп, 32 балалар бакчасы, пионер лагерьлары, хастаханә, 3 поликлиника, санаторий-профилакторий һ.б. файдалануга кертелә. 1984–89 да СССР ЮС депутаты. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: Барун В.Н. Ступени: Записки главного конструктора. Наб. Челны, 1997; Энциклопедия города Набережные Челны. К., 2007.

ФАФУ́РИН Андрей Викторович (16.9.1936, Казан), җылылык физикасы белгече, техник фән. д-ры (1974), проф. (1978), ТАССРның һәм РФнең атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1983, 1995), Казан технол. ин-тының атказ. профессоры (2006). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1963), шунда ук махсус двигательләр кафедрасында эшли. 1969–75 елларда Бөтенсоюз физик-техник һәм радиотехник үлчәмнәр фәнни-тикшеренү ин-тының Казан ф-лында термогазодинамик тикшеренүләр лаб-ясе мөдире. 1975 тән Казан технол. ун-тында мәгълүмати-үлчәү системалары (1983 кә кадәр), автоматлаштыру һәм мәгълүмати технологияләр (1984 тән) кафедралары мөдире, декан (1979–82, 1988–91). Хезмәтләре стационар булмаган гидрогазодинамикага, энергетика җайланмаларында термогазодинамик һәм җылылык физикасы процессларына карый. Ф. сыеклык һәм газларның турбулент агымнарына, төрле тайпылдыручы тәэсирләр шартларында җылылык һәм масса алмашуга караган теоретик һәм эксперименталь тикшеренүләр алып бара. Пульсацияле режимда эшләүче объектларда табигый газ чыгымын метрологик бәяләүнең яңа ысулларын эшли. Тикшеренү нәтиҗәләре авиация һәм ракета техникасында кулланылыш таба. РФАнең җылылык физикасы һәм җылылык энергетикасы буенча гыйльми советы әгъзасы (1975–83), Югары аттестация комиссиясенең энергетика буенча экспертлар советы әгъзасы (1987–93). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Турбулентный пограничный слой в трубе в условиях существенной неизотермичности и вдува. Новосиб., 1969; Нестационарный турбулентный пограничный слой в начальном участке трубы // Инженерно-физ. журн. 1973. Т. 25, № 3 (автордаш); Новый метод граничных элементов для моделирования стационарных течений несжимаемой жидкости // Проблемы нелинейного анализа в инженерных системах. 1996. Вып 1.

ФАФУ́РИН Виктор Андреевич (3.1.1971, Казан), җылылык техникасы белгече, техник фән. д-ры (2003), проф. (2011). Казан техник ун-тын тәмамлаганнан соң (1994), Казан технол. ун-тында автоматлаштыру һәм технол. процесслар белән идарә итү системалары каф. мөдире (2006 елдан). Бер үк вакытта Бөтенроссия чыгымнарны үлчәү фән-ни-тикшеренү ин-ты директоры урынбасары (2002–09), Үлчәү чараларын сынау үзәге директоры (2009 дан). Хезмәтләре сыеклык-лар б-н газлар микъдарын һәм чыгымын үлчәүне метрологик тәэмин итүгә карый. Энергетика һәм чимал ресурслары күләмен һәм тотылышын үлчәү чараларының метрологик сыйфатларын ачыклау алымнарын эшли. Ф. эшләгән фәнни-гамәли проектлар ТРда, РФдә һәм якын чит илләрдә гамәлгә ашырыла. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Выбор сетки и модели турбулентности для расчёта коэффициента расхода стандартной диафрагмы // Изв. вузов. Авиац. техника. 2008. № 4 (автордаш); Обеспечение норм точности при измерениях расхода и объёма энергетических и сырьевых ресурсов // Законодательная и прикладная метрология. 2008. № 2 (автордаш).

ФАЦЕ́ЛИЯ (Phacelia), сусыл яфракчалар семьялыгыннан бер- яисә күпъеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 80 төре билгеле, Төньяк һәм Көньяк Америкада таралган. ТРда бер төре — гөлбадран яфраклы Ф. яисә миләш яфраклы Ф. (P. tanacetifolia) үстерелә. Беръеллык үсемлек. Сабаклары туры, таралгы ботаклы, кыска төкләр яисә кылсыман төкләр б-н капланган. Яфраклары чиратлап яисә капма-каршы урнашкан, тоташ читле яисә эре тешле, аерчалы яисә каурыйсыман телмә, тар ланцетсыман өлешле. Чәчәкләре кыска чәчәк сабына урнашкан, башаксыман чәчәк төркеменә җыелган, зәңгәр яисә шәмәхә төстә; себеркәче кыңгыраусыман. Җимеше — тартмачык. 1000 орлыкның авырлыгы 1,4 *г*. Балга иң бай үсемлекләрдән, 1 *га* Ф. чәчүлегеннән якынча 250 *кг*, кайвакыт 500 *кг* бал алалар. бал алу өчен җәй дәвамында 4 тапкыр, умарталыкларга якын урыннарда, җиләк-җимеш бакчасының рәт араларына чәчәләр. 6 атнадан соң чәчәк ата, чәчәк ату вакыты дәвамлы. Тирлек азыгы буларак, бал кортлары нектар җыеп алганнан соң чабып алына. 100 *кг* яшел массасында чәчәк атып бетергәндә 15,8 азык берәмлеге, 2,5 *кг* үзләштерлә торган протеин бар. Яшел массасының уңышы 1 *га* дан 200 *ц* га кадәр. ТРда Ф. чәчүлекләре күп түгел.



Гөлбадран яфраклы фацелия.

Әд.: Жирмунская Н.М. Зелёные удобрения на садовом участке. М., 1998.

Р.Ә.Әсретдинова.

ФА́ЦИЯ (лат. facies — йөз, күренеш), 1) физик-геогр. мохит үзенчәлекләре чагылышы булган тау токымнарының барлыкка килү шартлары. Рус геол. әдәбиятында Ф. төшенчәсен беренче булып (1868) Н.А.Головкинский куллана (к. *Головкинский законы*). 2) Билгеле бер физик-геогр. шартларда барлыкка килүче утырмалар. Ф.нең 50 дән артык төрен билгелиләр. Ф.не өйрәнү (фациаль анализ) — тарихи геол. һәм файдалы казылма чыганакларын фаразлауның төп алымнарының берсе. Ф.нең генетик комплекслары *формацияләр* хасил итә. ТР терр-ясендә Ф.нең күп кенә төрләре очрый: геосинклиналь, платформа, диңгез, глауконит, известь-доломит, сидерит, фосфорит, цеолит, ташкүмер һ.б. 3) *Географик ландшафтның* элементар морфологик берәмлеге.



Г.Ф. Фәезханов.

ФӘЕЗХА́НОВ Габделгалләм Фәезхан улы (1850, Сембер губ., Кормыш өязе Сафа җәй а. — 12.1.1910, Уфа ш.), тарихчы, филолог, тәрҗемәче, публицист. Татар икътисади фикеренә нигез салучыларның берсе. Х.*Фәезхановның* энесе. Казандагы 1 нче җамигъ мәчет каршындагы мәдрәсәдә Ш.Мәрҗанидә укый (1862–68), укытучылар уч-щесен тәмамлый (Уфа, 1877). 1868 елдан Уфада: сәүдәгәр Нәзировның сәүдә конторасында эшли; берничә тапкыр эш б-н Төркестан һәм Сүриягә бара, анда Шәрекъ телләре һәм әдәбиятын өйрәнә, мәдәнияте б-н таныша; 1877 дән — Себер банкында. 1884–86 да «Мәрҗания» мәдрәсәсендә (Казан) укыта. 1887 дән кабат Уфада: Оренбург Мөселман Диния Нәзарәте казначее; 1906 да мәгърифәтче З.*Камали* б-н «*Галия*» мәдрәсәсен оештыруда катнаша, анда татар теле, тарих һәм география укыта. Татар календареның мөхәррире һәм нашире (1893). Хезмәтләре татар тел белеме, фольклор, географиягә карый. Ф. мөселман мәгарифе системасына, гарәп, фарсы, татар һәм рус телләреннән тыш, Көнбатыш Европа телләренең берсен уку программасына кертергә кирәк, дип саный. «Татар телигә кыскача гилми сарыф» («Татар теленең кыскача грамматикасы», 1887) уку әсбабы, икътисади һәм публицистик әсәрләр; Шәрекъ халыклары язма ядкәрләренең татар теленә тәрҗемәләре авторы. Аның «Мәҗәлис әс-сәрвәт вә әл-мәгаиш» («Муллык һәм тереклек чыганаклары турында әңгәмәләр») кулъязмасында мөһим сәяси һәм икътисади төшенчәләргә, категорияләргә, законнарга анализ бирелә. «Мөхәррик әл-әфкар» («Фикерләр уятучы», 1893) китабы иҗтимагый-мәгърифәтчелек фикере тарихы мәсьәләләренә карый. 14 йөздәге фарсы-тажик әдәбияты ядкәре «*Тутый-намә*» һәм гарәп-фарсы әдәбияты ядкәре «*Кәлилә вә Димнә*» Ф. тәрҗемәсендә берничә тапкыр басылып чыга, алар татарлар арасында гына түгел, башкортлар, казакълар һ.б. төрки халыклар арасында да киң тарала.

Х е з м.: Гомуми җәгърафия рисаләсе. К., 1888; Тарих шәҗәрәи төрек. К., 1891; Хикәят вә мәкаләт. К., 1896.

Әд.: Мифтахова И. Габделгалләм Фәезхановның беренче татар грамматикасы // Мәгариф. 1997. № 9; Газизуллин Ф.Г. Г.Фаизханов и формирование системы экономических взглядов в татарской литературе // Уч. зап. Казан. пед. ин-та. 1975. Вып. 141; шул ук. Становление и развитие социально-экономической мысли татарского народа. СПб., 2004; Сабиров С.В. Мулла Габдулгаллям Фаизханов (к 155-летию со дня рождения). Н.Новгород, 2005.

ФӘЕЗХА́НОВ Хөсәен Фәезхан улы (1823, башка мәгълүматларга караганда, 1828, Сембер губ., Кормыш өязе Сафажәй а. — 28.8.1866, шунда ук), тарихчы, филолог, педагог. Г.*Фәезхановның* абыйсы. Ш.*Мәрҗани* шәкерте. Туган авылында, аннары Казанда



Х.Ф. Фәезханов.

(1848–53) мөселман мәгърифәтчеләре Мөхәммәткәрим әт-Тәкәнеши һәм Байморат бине Мөхәррәмдә, 1850 елдан Ш. Мәржанидә укый. 1840 еллар ахырынан Казан ун-тының шәркыятьче галимнәре И.Н.Березин, А.К.Казимбәк, 1854 тән — акад. Б.А.Дорн, В.В.Вельяминов-Зернов, М.И.Броссе, А.А.Куник (С.-Петербург) б-н хезмәттәшлек итә. 1854 тән С.-Петербург ун-тының Шәрекъ телләре ф-ты укучыларына лекцияләр укый. 1858 дә ФА йөкләмәсе буенча Мәскәүдә Тышкы эшләр министрлыгы архивында сакланган урта гасырларда төрки телдә язылган документлар текстларының тасвирламасын төзи. 378 текст ачыклана һәм «мулла Хөсәен Фәезханов ярдәме белән» В.В.Вельяминов-Зернов мөхәррирлегендә аерым китап булып басыла («Кырым ханлыгы тарихы буенча материаллар» («Материалы для истории Крымского ханства», 1864)). 1860 та Рус археол. җәмгыяте йөкләмәсе буенча Касыйм шәһәре татар зиратындагы кабер ташлары язмаларын күчереп ала. Ф. тарафыннан табылган 29 эпиграфик текст Касыйм ханлыгы тарихының чыганак базасын бик баета; алар Вельяминов-Зерновның «Касыйм патшалары һәм ханзадәләре турында тикшеренүләр» («Исследования о касимовских царях и царевичах», ч. 1–4, СПб., 1863–87) хезмәтендә урын ала. 1862 дә Тархан һәм Урюм (Ырым) авылларында яңа болгар эпитафияләрен ача, аларны «Өч болгар кабер ташындагы язу» («Три надгробных булгарских надписи») мәкаләсендә тасвирлый, мәкалә «Известия Русского археографического общества» (1863, 4 чыг.) ж-лында басыла. Беренчеләрдән булып болгар эпитафияләрендәге чуаш теле элементларны булган «серле» компонентларны укый һәм аңлата, бу моһим фәнни ачыш булып тора. Бер үк вакытта гарәп кулъязмаларын (Петербург ун-ты китапханәләре фондларында саклаланар), татар халкы, Казан һәм Кырым ханлыклары тарихы буенча материаллар җыю һәм тасвирлау б-н шөгыльләнә. Ф. беренчеләрдән булып татарларның килеп чыгышы мәсьәләсе буенча тикшеренүләргә керешә. 1862 дә ташбасма ысулы б-н «Татар теленең кыскача грамматикасы»н бастыра (СПб.), аның кушымтасында үз тәр җәмәсендә гарәп-фарсы әдәбияты ядкәре «Кәлилә вә Димнә» текстыннан өзекләр, Кырым ханы Җанибәкгәрәй грамотасы текстын (17 йөз), Г.Нәваинең «Мәҗалис ән-нәфис» поэмасыннан өзек урнаштыра. Мөселман мәгарифен реформалау проекты авторы: «Ислах әл-мөдәррис» («Мәктәп реформасы», СПб., 1862; 2006 да басыла) хезмәтендә татар мәгърифәтчеләреннән беренче булып Европа мәгарифе алымнарын татар мәгариф системасына кертү зарурлыгы турында нәтиҗә ясый, дин нигезләрен дөньяви фәннәр б-н бергә укытуны тәкъдим итә. 1860 елларда татар телендә газета яки журнал («Чулпан», «Таң йолдызы», «Файда») чыгару фикеренә килә. Хезмәтләре Касыйм, Казан, Кырым ханлыклары тарихына, төрки филологиягә һәм болгар эпиграфикасына багышлана («Мәдрәсәләр ихласы», «Риса лә», «Касыйм ханлыгы», «Казан тарихы», «Борынгы болгар ташлары»). Ф.ның фәнни тикшеренү нәтиҗәләре В.В.Вельяминов-Зернов һәм Ш. Мәр җанинең күптомлы фундаменталь хезмәтләрендә урын ала.

Әд.: Фәхретдинов Р. Асар. Оренбург, 1908; шул ук. Хөсәен әфәнде Фәезханов // Шура. 1916. № 15–19; Хөсәен Фәезханов: Тарихи документаль җыентык. К., 2006. Усманов М. Заветная мечта Хусаина Фаизханова. К., 1980; Мулла Хусейн: Материалы книжной выставки, посв. 175-летию со дня рождения Х.Фаизханова. Н.Новгород, 2003; Юзеев А.Н., Мухетдинов Д.В. Хусаин Фаизханов — первый татарский просветитель. Н.Новгород, 2011.

Ф.Г.Миңнеханов.

ФӘЙЗОВ Әнвәр Зыятдин улы (30.4.1928, Чуаш АССРның Батыр р-ны Шыгырдан а. — 14.6.2011, Чабаксар ш.), философ, психолог, филос. фән. д-ры (1993), проф. (1994), Чуаш АССРның атказ. югары мәктәп хезмәткәре (1989). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1952), Чуаш пед. ин-тында эшли. 1960 елдан Чкаловское авылы (Чуаш АССР Батыр р-ны) урта мәктәбендә директор, 1962 дән Мәскәү энергетика ин-тының Чабаксар ф-лында, 1970 тән Чуаш пед. ин-тында филос. каф. мөдире. 1979 дан Чуаш ун-тында (1983–93 тә Мәскәү кооперация ун-тының Чабаксар ин-тында) филос. һәм методология (1993 тән) кафедралары мөдире, бер үк вакытта, 2001 дән, филос. буенча комплексны тикшеренүләр алып бара. Хезмәтләре баш миен һәм кеше аңын тикшерү мәсьәләләренә, фән ни танып-белүнең методологияләренә багышлана. Чуаш АССР ЮС, Чуаш Респ-касы Дәүләт Советы Мактау грамоталары б-н бүләкләнә.

Хезм.: Психофизиологическая проблема. Чебоксары, 1993; Мозг, психика, физика. М., 1994; Методология научного познания: В 3 ч. М.-Чебоксары, 2001 (автордаш).

ФӘЙЗОВ Илдус Әхмәт улы (29.1.1963, Тәтеш р-ны Олы Тархан а.), дин эшлеклесе. Казан театр уч-щесен (1989), Ислам кабул ителүнең 1000 еллыгы исем. югары мөселман мәдрәсәсен (2000) тәмамлый. 1989 елдан «Адым» театр-студиясендә, 1991 дән Татар драма һәм комедия театрында актёр. 1998 дән Татарстан Респ-касы Диния нәзарәтендә, 1999 дан дәгъват (пропаганда һәм мәгълүмат) бүлеге мөдире, 2002 дән «Болгар» мәчете имам-хатибы. 2010 нан мөфтинең беренче урынбасары, 2011–13 тә ТР мөфтие. Дуслык ордены б-н бүләкләнә.

ФӘЙЗОВ Радик Хәбибрахман улы (15.5.1931, Әтнә р-ны Дусым а. – 17.2.2011, Арча), язучы, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1981). Казан ун-тын тәмамлый (1973). 1950 елларда Магнитогорск шәһәрендә сәнәгать пр-тиеләрендә эшли. 1965–92 дә «Коммунизмга» Арча район г-тасында әдәби хезмәткәр, аннан соң җаваплы сәркәтип. Балалар һәм яшүсмерләр өчен «Беренче адымнар» (1963), «Яшьлек юллары» (1967), «Бәхет» (1970), «Дусларым» (1972), «Юлда» (1979), «Галәм кызы» (1983), «Күңелем кыры» (1985), «Адымнарым» (1991), «Ак каз» (2001), «Ике әни» (2005) повесть һәм хикәяләр җыентыклары авторы. Гадәти авыл тормышыннан булган эпизодлар яисә киләчәк турында фантастик күзаллаулар нигезендә Ф. халык гореф-гадәтләрен һәм әхлакый нигезләрен саклап калу әһәмиятен күрсәтергә омтыла.

Әд.: Шәрәфиев Р. Ак казлар чакыруы // Казан утлары. 2002. № 12; Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

ФӘЙЗОВ Тәфкил Тәхи улы (4.4.1955, Кыргызстан ССР, Фрунзе ш.), стоматолог, казналык-бит хирургы, мед. фән. д-ры (1998), проф. (1999). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1978), шунда ук, хирургик стомат. кафедрасында эшли; 1985–88 елларда Казан ГИДУВының хирургик стомат. кафедрасында. 1998 дән Казан мед. ин-тының казналык-бит хирургиясе каф. мөдире, бер үк вакытта ТРның Реконструктив, пластик һәм эстетик хирурглар җәмгыяте рәисе. 2002 дән Косметологик хирургия үзәге (Казан) җитәкчесе. Хезмәтләре казналык-бит имгәнү-җәрәхәтләре, реконструктив, пластик һәм эстетик хирургия өлкәсенә карый. Ф. кискен одонтоген процесслар барган авыруларны раптен рапид һәм озон кулланып комплексны дәвалау ысулларын тәкъдим итә; новокаинлы тригемин-вагосимпатик блокада ысулын эшли һәм гамәлгә кертә. Уйлап табуга авторлык таныклыгы бар.

Хезм.: Регионарные блокады в хирургии. К., 2003; Новый метод иммунокорригирующей терапии в оценке содержания макро- и микроэлементов смешанной слюны пациентов с одонтогенной остеофлегмоной // Рос. стоматолог. 2004. № 1 (автордаш); Современные аспекты ортопедической стоматологии. К., 2008 (автордаш).

ФӘЙЗЕРАХМА́НОВ Әгъзам Фәтхерахман улы (27.9.1937, Арча р-ны Иске Йорт а.), журналист, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1980). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1960), «Социалистик Татарстан» г-тасында эшли. 1962–88 елларда Казан телевидение студиясендә өлкән мөхәррир, баш мөхәррир. 1990 нан «Шәһри Казан» г-тасында әдәби хезмәткәр, бүлек мөхәррире, баш мөхәррир урынбасары. 1998–2001 дә «Татарстан» ж-лы баш мөхәррире урынбасары, 2001 дән — «Хокук һәм хәят» ж-лында. «Советская Россия», «Советский спорт» г-таларында, «Советское радио и телевидение» ж-лында мәкаләләре басыла. ТРның күренекле эшлеклеләре, ш.и. В.Н.Лихачёв, Ф.Х.Мөхәммәтшин, Ә.Г.Кәримуллин, М.Г.Мөлеков, Р.Г.Юсупов, ТР мөстәкыйльлеге турындагы очерклар авторы. «Татарстан — минем республикам», «Безнең замандаш», «Сәяси портретлар» телетапшырулары, цикллар, җырле һәм Үзәк телевидение өчен «Татарстан сугыш һәм тынычлык юллары буйлап», «Органик синтез» һ.б. документаль фильмнар авторларының берсе. «Шәһри Казан» г-тасы, «Казан утлары», «Татарстан» ж-лларында басылган очерклар циклы өчен (1991, 1999, 2000) ТРның Журналистлар берлеге бүлә-



Ә.Ә. Фәйзи.



Ж. Х. Фәйзи.

генә лаек була. «Бөек Тукай ватаны син, Арча» (2007), «Татарстан Республикасы Югары Советы журналистлар күзлегеннән» (2007) һ.б. җыентыкларны туплый. Медальләр, ТРның Мактау грамотасы (2000) б-н бүләкләнә.

Әд.: Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

ФӘЙЗИ́ (Фәйзуллин) Әхмәт Әхмәтсафа улы (11.3.1903, Уфа ш. – 11.8.1958, Мәскәү, Казанда җирләнә), язучы, әдәбият тәнкыйтьчесе, ТАССРның һәм РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1953, 1957). Уфада мәдрәсәдә (1911–15), рус-татар мәктәбендә (1915–17), татар гимназиясендә (1917–21) укый. 1922–28 елларда Урта Азиядә, Донбасста укыта. 1929–31 дә Мәскәү, Казан, Арча мәдәни-агарту учреждениеләрендә эшли. 1931 дән Мәскәүдә. Беренче шигырьләрен 1916 да М.Гафури поэзиясе тәэсирендә яза. Ф. тормыш-көнкүрештәге социаль үзгәрешләрнең, яңалыкларның эчке мәгънәсен, фәлсәфи юнәлешен нечкә сиземли. Бу аңа үз заманының рухын, аның төп иҗтимагый һәм әхлакый проблемаларын дөрес тотып алырга һәм аларны үз әсәрләрендә заманга хас яңгырашлы итеп якыртырга мөмкинлек бирә. «Чор турында җыр» (1932), «Флейталар» (1934), «Эзләр» (1939), «Дулкыннар ни сөйлиләр?» (1945); «Дала һәм кеше» (1936), «Кара таш ник дәшми?» (1940), «Туу сулышы» (1943) кебек поэма һәм балладаларында әлеге поэтик сыйфатлар бик ачык төсмерләнә. Ф. поэзиясенә халыкчанлык, лирик яңгыраш, фольклор-җыр композициясе хас. Ул татар интеллектуаль шигырь язылышы традицияләрен үстерә һәм тулыландыра. Рев-ция һәм интеллигенция темасы, аның фәлсәфи эзләнүләре гәүдәләнгән «Флейталар» поэмасы Ф. иҗатының үзенчәлекле казанышларыннан берсе булып исәпләнә. Әлеге тема «Еллар бусагасында» (1927) поэмасында дәвам иттерелә. Ф. — күпсанлы драма әсәрләре авторы. Беренче бер пәрдәле пьесаларын агитацион характерда яза. 1930 еллар драматургиясенә тематик һәм жанр ягыннан төрлелек күзәтелә: «Матурлык дөньясында» (1920 дә куела), «Төтен» (1930), «Беренче елмаю» (1940), «Акчарлаклар» (1944 тә куела) комедияләре, «Тукай» (1939 да куела), «Пугачёв Казанда» (1948 дә куела) тарихи-биографик драмалары һ.б. Сугыштан соңгы елларда Ф. эхлакый мәсь әләләргә багышланган «Күршеләр» комедиясен (1951), «Рәүфә» драмасын (1958 дә куела) яза. Гомеренең соңгы елларын «Тукай» романы (1952; ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге, 1958) өчен материал туплауга багышлый. «Качкын» (1939, Н.Җиһанов музыкасы), «Зөлхәбирә» (1943, М.Мозаффаров музыкасы), «Шагыйрь» (1947, Н.Җиһанов музыкасы), «Җәлил» (1957, Н.Җиһанов музыкасы) операларына, «*Шүрәле*» (1945, Ф.Яруллин музыкасы), «Кисекбаш» (1958, Р.Гобәйдуллин музыкасы) балетларына либретто, җыр текстлары авторы. Әдип А.С.Пушкин, Н.В.Гоголь, Т.Г.Шевченко, В.В.Маяковский, А.Л.Барто әсәрләрен татар теленә тәр җәмә итә. Әдәбият белеме, әдәби тәнкыйть, публицистика («Әдипнең эрудициясе» җыентыгы, 1973) өлкәләрендә бай мирас калдырган язучыларның берсе. Ф. балалар өчен дә яза («Аучы Мәргән белән Болан кыз әкияте», 1948 һ.б.). Бөек Ватан сугышында катнаша. Медальләр б-н бүләкләнә.

Әсәр.: Әсәрләр: 5 томда. К., 1983–87; Сайланма әсәрләр — Избранные произведения. К., 2003.

Әд.: Хөсни Ф. Әхмәт Фәйзи — драматург // Ни әйтергә? Ничек әйтергә? К., 1974; Юзиев Н. Тормышка мәхәббәт // Шигърият дөньясы. К., 1981; Шәйхелисламов З. Аңлыем дип шагыйрь җанын... К., 2001; Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

ФӘЙЗИ́ (чын фамилиясе Сатыев) Габдулла Габделкәбир улы (13.6.1886, Уфа губ., Эстәрлетамак өязе Арслан а. — 28.7.1958, Казан), педагог. Эстәрлебаш мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң (1899–1906), шунда ук укыта. Истанбул ун-ты каршындагы укытучылар семинариясен (1909), шул ук ун-тның физика-биол. ф-тын (1912) тәмамлый. 1912 елдан «Хөсәения», 1913 тән «Госмания» (Уфа ш.), 1915 тән «Исхакыя» (Верный ш., хәзерге Алма-Ата ш., Казакъстан) мәдрәсәләрендә табигать белеме һәм физика укыта, шунда ук татар пед. курсларын оештыра. 1918 дә Бөгелмәдә татар пед. курсларында, 1918–20 дә «Галия» мәдрәсәсендә (Уфа), 1921–31 дә Башкорт пед. техникумында (Уфа) укыта. 1933–48 дә Казанның гомуми белем бирү һәм урта махсус уку йортларында физика, география укытучысы. Татар телендә табигать белеме буенча беренче уку ярдәмлекләре авторы. 1920–30 елларда ТАССР мәгариф органнары кушуы буенча физика, химия буенча мәктәп дәреслекләрен, ш.у. фотография һәм умартачылык буенча ярдәмлекләрне татар һәм башкорт телләренә тәр җәмә итә.

Хезм.: Йорт хайваннарының килеп чыгуы һәм яңа токым хайваннар чыгару. К., 1926; Табигатьне күзәтү һәм тәҗрибәләр ясау (1 нче баскыч эш мәктәпләре өчен кулланма). Уфа, 1926; Минералогия һәм геология: 2 нче баскыч мәктәпләр һәм педтехникумнар өчен. К., 1927.

Әд.: Әхмәтҗанов М.И. Күренекле мәгърифәтчеләр. Габдулла Фәйзи // Мәдрәсәләрдә китап киштәсе. К., 1992.

ФӘЙЗИ́ (Фәйзуллин) Җәүдәт Харис улы (4.1.1910, Оренбург ш. — 30.4.1973, Казан), композитор, фольклорчы, ТАССРның һәм РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1944, 1957), ТАССРның халык артисты (1964). Башлангыч музыка белемен Оренбургта Татар шәрекъ музыкасы мәктәбендә (Х.Булатова-Терегулова классы) ала. 1925 елда «Күз яшьләре» пьесасын яза, ул Оренбургта татар драма труппасы тарафыннан сәхнәләштерелә. 1933 тә Казан юридик ин-тын тәмамлый. 1934–38 дә Мәскәү консерваториясе каршындагы Татар опера студиясендә (Б.Шехтер классы) укый, бер үк вакытта уку-укыту бүлеге б-н җитәкчелек итә. 1939–41 дә Татар акад. театрының музыка бүлеге мөдире һәм дирижёры, 1944–47, 1952–57 дә Татар филармониясе директоры һәм сәнгать җитәкчесе. Иҗатының башлангыч чорында ук Ф. вокаль музыкага зур игътибар бирә. Аның Һ.Такташ шигыренә язылган «Урман кызы» (1932) җыры популярлык казана. 1936 да композитор шагыйрь М.Җәлил б-н иҗади берлектә пионер җырлары альбомын иҗат итә. Аның Ә.Ерикәй шигырьләренә язылган «Комсомолка Гөлсара», «Шауласын безнең җыр» җырларында, С.Хәким шигыренә язылган «Мулланур истәлеге» балладасында һ.б.да гражданлык, патриотик тематика чагылыш таба. Ф. — «Башмагым» беренче татар муз. комедиясе авторы (1942; Х.Ибраһимовның шул исем. пьесасы үрнәгендә язылган Т.Гыйззәт либреттосы), ул татар муз. театрының иң танылган әсәрләреннән берсенә әверелә. Ф.нең «Тапшырылмаган хатлар», 1960 (Г.Кутуйның шул исем. повесте буенча үзе язган либреттога) операсында авторның үзе тарафыннан лирик планда шәрехләнгән замана темасы гәүдәләнеш таба. Ф. милли муз. фольклорны җыя, өйрәнә һәм пропагандалый; хәзерге татар халык җырлары тупланган «Халык җәүһәрләре» (1971) җыентыгын бастырып чыгара. Татар муз. культурасына караган мәкаләләр, әдәби әсәрләр (пьесалар, либреттолар, хикәяләр, шигырьләр) авторы. Әсәрләре: Ә.Фәйзи либреттосына «Акчарлаклар» (1944; 2 нче редакция 1955), Г.Насретдинов либреттосына «Идел буенда» (1949; 2 нче редакция «Алтын көз» исеме б-н, 1951) муз. комедияләре; спектакльләргә (30 дан артык), ш.и. «Ташкыннар» (Т.Гыйззәт пьесасы буенча, 1937), «Шәмсекамәр» (М.Әблиев пьесасы буенча, 1938), «Хужа Насретдин» (Н.Исәнбәт пьесасы буенча, 1941) спектакльләренә музыка; камера-инструменталь әсәрләр; 200 дән артык җыр һәм романслар; татар халык көйләренең эшкәртмәләре һ.б. ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1966). Казанда бер урам Ф. исемен йөртә. Оренбургта һәм Казанда Ф. яшәгән йортларга мемориаль такталар куела.

Әд.: Народные артисты. К., 1980; Композиторы Татарстана. М., 2009.

ФӘЙЗИ́ (Фәйзуллин) Мирхәйдәр Мостафа улы (19.10.1891, Оренбург губ., Орск өязе Күкшел а. – 9.7.1928, БАССРның Зилаир кантоны Баймак пос.), драматург. 1902–04 елларда Орск шәһәре мәдрәсәсендә, 1904–07 дә «Хөсәения» мәдрәсәсендә (Оренбург ш.) укый. 1907 дән Орск шәһәрендә яши, мәгариф мәсьәләләренә багышланган мәкаләләре б-н көндәлек матбугатта чыгышлар ясый, 1912–27 дә фольклор әсәрләре җыя, татар халкының этнографиясен өйрәнә. 1914 тән Орскида мәдәни-агарту эшендә (китапханәче, үзешчән театр җитәкчесе, музыкант, «Кызыл Урал» г-тасы хезмәткәре һ.б.). 1910 елларда Ф. бер пәрдәле берничә пьеса, шигырьләр һәм бәетләр иҗат итә, соңыннан алар «Минем шигырьләрем» (1912), «Яшь

күңел» (1913) җыентыкларына кертелә. Бер яктан әдип Г.Тукай, С.Рәмиев, М.Гафури, икенче яктан Ш.Бабич, С.Сүнчәләйнең иҗади традицияләрен дәвам итә. Аның поэзиясе мотивлар төрлелеге б-н аерыла: «Табигать манзарасы» (1912), «Чәчәкләр җыры» (1912), «Җәйге төн» (1915) шигырьләре мәхәббәт, табигать, сәнгать романтикасы б-н сугарылган; «Фәрештә» (1912), «Мөнбәр вә мендәр» (1912) шигырьләрендә социаль контрастлар урын ала. Авыл темасы «Илем» (1915), «Юклык» (1919) һ.б. шигырьләрендә ачык чагыла. Яшәү һәм үлем, кеше язмышына багышланган әсәрләрендә («Үткән вакыт» (1910), «Рәхәт кайда?» (1912), «Соңгы теләк» (1912), «Үз иркемә күй» (1912) һ.б.) лирик геройның хис-кичерешләре импрессионизм, экзистенциализм һәм модернизмга хас сәнгать чаралары аша белдерелә. Ф. иҗатының төп жанры — драматургия. «Ике Хәсән» (1909), «Яшьләр алдатмыйлар» (1912) комедияләре, «Кызганыч», «Тәкъдирнең шаяруы» (икесе дә — 1913) мелодрамалары «аталар һәм балалар» конфликтын алга куя, мәхәббәтне каршылыкларга бирешми торган көч сыйфатында чагылдыра. 1913–16 да Ф. иҗатындагы үзәк урынны авыл тормышы били, пьесалары этнография һәм халык авыз иҗаты элементлары б-н баетыла. Әсәрләренә татар халык җырларын кертеп җибәрә, алар вакыйгаларның лирик лейтмотивына әверелә. «Авыл бәйрәме» муз. комедиясендә (1915) татар халкының этнографиясе һәм фольклоры бай сурәтләнә, әсәрдә тәүге тапкыр җыр куллануга омтылыш ясала. Муз. башлангыч «Галиябану» пьесасында (1916; 1918 дә куела) аеруча ачык чагыла. Галиябану б-н Хәлилнең чын һәм саф мәхәббәте кызның әтисен үз ягына аударган, явыз һәм мәкерле Исмәгыйльгә каршы куела. Конфликт Хәлилнең үлеме б-н тәмамлана. Пьеса геройларының фаҗигасе җәмгыятьтә хөкем сөргән феодаль-патриархаль тәртипләрне фаш итә. Геройлар арасындагы киеренке мөнәсәбәтләр, драматик вакыйгалар мәхәббәт турындагы җырлар б-н үрелеп бара. «Галиябану» драмасы беренчеләрдән булып татар сәхнә сәнгатендә яңа бер жанрга — муз. драмага нигез сала. Г.Ибраһимов Ф.нең вакыйгалар б-н музыканы табигый рәвештә берләштерүгә ирешүе, шул рәвешле аның пьесаларының эмоциональ яңгырашы, халыкчанлыгы көчәюе турында яза. Алардагы музыка фон булып кына калмый, ә вакыйганың мөһим өлешен тәшкил итә. 1917 дән соң Ф. иҗаты зур үзгәрешләр кичерә. Илдә барган вакыйгалар (Гражданнар сугышы, соц. төзелеш, күмәкләштерү) әдипнең дөньяга карашына йогынты ясый. «Урал суы буенда» (1917), «Асылъяр» (1920; 1924 тә куела), «Ак калфак» (1923, 1925 тә куела) пьесаларында авылдагы яңа тормышның беренче чаткылары гына түгел, төрле катлау вәкилләренең мәхәббәте күрсәтелә. «Кызыл йолдыз» (1923), «Адашкан күңел» (1923; 1924 тә куела), «Кәкре каен» (1923), «Коммунага» (1924) һ.б. әсәрләрендә ул үзенең гуманистик карашларына тугры кала. Ф. балалар өчен пьесалар һәм хикәяләр яза. Татар теленә К.В.Лукашевич, Н.А.Соловьёв-Несмелов пьесаларын тәрҗемә итә. 1991 дә Балтач р-нының Шода авылында драматургның музей-утары ачыла.

Әсәр.: Сайланма әсәрләр: 2 томда. К., 1957; Әсәрләр. К., 2007.

Әд.: Ибраһимов Г. «Галиябану» хакында бер-ике сүз // Әсәрләр. К., 1978. Т. 5; Ханзафаров Н. Мирхәйдәр Фәйзи // Татар әдәбияты тарихы. К., 1989. Т. 4; Гыйлажев Т. Мирхәйдәр Фәйзи шигъриятенең идея-эстетик үзенчәлекләре // Әдәби мирас: тарих һәм заман. К., 2005; Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2; Файзуллин М., Абдуллина Д. Мирхайдар Файзи: Повествование о жизни. К., 1987.

Т.Ш.Гыйлажев.

ФӘЙЗИ́ МИРХӘЙДӘ́Р МУЗЕ́Й-УТАРЫ́, Балтач р-нының Шода авылында. Мемориаль музей. 1991 елда ТРның Дәүләт музее (хәзер ТРның Милли музее) ф-лы буларак ачыла, 2006 дан муниципаль музей. М.*Фәйзинең* бертуганы — Шода авылының 2 нче җамигъ мәчете имам-хатибы С.Фәйзуллинның бер катлы агач йортында урнашкан. Бу йортта Фәйзи 1906, 1916, 1923, 1924 нең җәйләрендә яши. Өч залда урнашкан экспозициянең мәйданы — 138 *м*², фондларында 480 саклау берәмлеге исәпләнә. Асыл типологик предметлар нигезендә имам-хатиб бүлмәсенең, 20 йөз башында татар гаиләсе яшәгән бүлмәләрнең, ш.у. бертуганы янына кайткында драматург яшәгән чарлактагы кунак бүлмәсенең интерьеры торгызылган. М.Фәйзинең әдәби эшчәнлегенә багышланган бүлектә әдип үзе исән чакта басылган әсәрләре, көндәлекләр, документлар, фоторәсемнәр куелган. Аерым бер зал «Галиябану» пьесасы буенча куелган спектакльләргә багышланган: экспозициядә төрле елларда Казан һәм Уфа театрлары сәхнәләрендә куелган спектакльләрдә Галиябану ролен башкарган актрисаларның фоторәсемнәре, театр костюмнары, декорация эскизлары урын алган.





Балтач районының Шода авылында Мирхәйдәр Фәйзи музей-утары. 1. Гомуми күренеше; 2. Экспозиция күренеше.



М.М. Фәйзи.



А.Ф. Фәйзрахманов.

Аеруча кыйммәтле экспонатлар арасында М.Фәйзи әнисенең сөт савыты, шигырьләр альбомы, открытка, Фәйзуллиннар йортыннан предметлар бар.

Музей ел саен драматургның туган көнен (1 ноябрь), Шода авылы бәйрәмен (июль башында) үткәрә. Музей-утары директоры — Ф.Ф.Рәшитов (1991 дән).

ФӘЙЗИ́-ЧИСТАПУЛИ́ (псевд.; чын фамилиясе Фәйзуллин) Харис Зариф улы (25.11.1871, Казан губ., Чистай өязе Шахмай а. — 9.7.1933, Казан), педагог, журналист. Татар композиторы Ж.Фәйзинең, мед. фән. д-ры М.Фәйзуллинның әтисе. Чистай, 1891 елдан Истанбул мәдрәсәләрендә укый. 1897 дән «Хөсәения» мәдрәсәсендә (Оренбург ш.) математика, физика, география укыта. Мәскәү хисапчылар курсларын тәмамлаганнан соң (1899), сәүдәгәр Ә.Хөсәеновта Мәкәрҗә ярминкәсендә эшли. 1906 дан Казанда: «Казан мөхбире» г-тасы редакциясендә сәркәтип, 1907–08 дә «Әхбәр» г-тасының нашире һәм мөхәррире. 1909 дан Оренбургта, Октябрь рев-циясенә кадәр сәүдәгәр М.Хөсәенов конторасында эшли. 1924 тән Казан китап комб-тында кассир. Мәдрәсәләр өчен татар теле, тарих, география буенча дәреслекләр авторы.

Хез.: Тәгълим җәгърафия. К., 1903; (К., 1915); Ысул җәгърафия. К., 1911 (3 нче басма).

М.В.Гайнетдинов.

ФӘЙЗРАХМА́НОВ Айдар Фәтхерахман улы (30.1.1955, Арча р-ны Урта Бирәзә а.), җырчы (тенор), музыкант, дирижёр, педагог, ТРның халык артисты (1996), РФнең атказ. артисты (2009). Казан пед. ин-тының музыка-пед. ф-тын (1976), Казан консерваториясен (З.Хисмәтуллина классы) тәмамлый (1981). 1981–2009 елларда Татар опера һәм балет театры солисты. Партияләре: Мисаил («Борис Годунов», М.Мусоргский), Галимҗан («Башмагым», Ж.Фәйзи), Урмай («Алтынчәч», Н.Җиһанов), Шүрәле («Шагыйрь мәхәббәте», Р.Ахиярова) һ.б. Бер үк вакытта, 2002 дән, ТР Дәүләт фольклор музыкасы ансамбленең сәнгать җитәкчесе, 1999–2002 дә Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тында укыта, 2002–11 дә Татар гуманитар-пед. ун-тында вокаль әзерлек каф. мөдире, проф. 2011 дән Казан ун-тында, бер үк вакытта — Татар филармониясенең сәнгать җитәкчесе. Россия шәһәрләрендә, якын һәм ерак чит илләрдә концертлар б-н чыгышлар ясый. Репертуарын чит ил, рус, татар композиторларының камера-вокаль әсәрләре, халык һәм эстрада җырлары тәшкил итә.



Җ.И. Фәйзрахманов.



Җ.З. Фәйзуллин.

Радио һәм телевидение тапшыруларын (ш.и. «ТНВ» каналында «Җырлыйк әле»не), концерт һәм театральләштерелгән программаларны сәхнәгә куючы һәм алып баручы. Компакт-дисклар, видеоклиплар чыгаруны гамәлгә ашыра. Укучылары арасында — Э.Гафурова, Г.Шәрәпова, Г.Уразова һ.б. Медальләр б-н бүләкләнә. ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (2019).

ФӘЙЗРАХМА́НОВ Габделбәр Лотфи улы (9.12.1930, Арча р-ны Иске Кырлай а. — 9.9.2007, Казан), тарихчы, тарих фән. д-ры (2005). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1954). 1948 елдан Арча, Зәй, Питрәч р-ннары мәктәпләрендә тарих укытучысы. 1954–55 тә ВЛКСМның Питрәч райкомы 2 нче секретаре. 1955 тән Арча р-ны Куйбышев исем. к-з рәисе. 1982–85 тә ТАССР МС каршындагы ЗАГС бүлеге мөдире. 1986 дан Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында, өлкән фәнни хезмәткәр (1989–92), 1992 дән ТР ФАнең Тарих ин-тында, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (2006 дан). Респ-каның иҗтимагый-сәяси тормышында актив катнаша: Бөтентатар иҗтимагый үзәген оештыручыларның берсе һәм аның идарәсе әгъзасы; Бөтендөнья татар халкы корылтае, Татар иҗтимагый үзәге, Милли Мәҗлес, Төрки халыклар ассамблеясына делегат итеп сайлана. Төрки-татар дөньясы тарихын, Казан, Себер ханлыклары һәм Нугай Урдасының үзара мөнәсәбәтләрен өйрәнүгә зур өлеш кертә. Хезмәтләре Себер һәм Үзәк Азия төрки халыклары, Себер татарлары, урта гасырлар татар дәүләтләре тарихын өйрәнүгә карый. Күптомлы «Татарлар тарихы» («История татар», 2002, Т. 1) авторларының берсе, «Татарстан Республикасының тарих һәм мәдәният истәлекләре җыелмасы» («Свод памятников истории и культуры Республики Татарстан») басмаларын төзүче. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Древние тюрки Сибири и Центральной Азии. К., 2000; История сибирских татар (с древнейших времён до начала XX века). К., 2002; История татар Западной Сибири (с древнейших времён до начала XX века). К., 2007.

Әд.: А л и ш е в С. Галим, җәмәгать эшлеклесе, милләт хадиме // Шәһри Казан. 2007. 16 нояб.; Нация. Эпоха. Личность: Сб. памяти доктора ист. наук Г.Л.Файзрахманова. К., 2008.

Ф.Г.Миңнеханов.

ФӘЙЗРАХМА́НОВ Җәүдәт Ибра һим улы (27.6.1948, Арча р-ны Носы а.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1991), ТР ФА академигы (2013; 1998 елдан мөхбир әгъза), ТРның һәм РФнең атказ. фән эшлеклесе (1998; 2003), РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (1997). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1972). 1966 елдан Арча р-ны «1 Май» к-зында, Биектау р-ны «Беркутовский» с-зында икътисадчы булып эшли. 1973 тән Казан аграр ун-тында (бүленеп): икътисади кибернетика, а.х. җитештерүе б-н идарә итү каф. мөдире, 1996–2018 дә ректор. 1990–96 да Казан вет. медицинасы академиясендә, проф. (1993), икътисад һәм маркетинг каф. мөдире (1995 тән). Хезмәтләре терлекчелекнең һәм терлек азыгы җитештерүнең икътисади нәтиҗәлелеген күтәрү, компьютер технологияләрен кертүгә, АСКны үзгәртеп кору мәсьәләләренә багышлана. «ТР аграсәнәгать системасы комплексы белән идарә итү»не эшләүдә катнаша. Медальләр һәм ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Оптимизация состава машин в кормопроизводстве. К., 1990 (автордаш); Аграрный сектор Татарстана в условиях развития рыночной экономики. К., 1997 (автордаш); Инновационный менеджмент в АПК. М., 2003 (автордаш); Организация молочного скотоводства на основе технологических инноваций. К., 2007 (автордаш).

Әд.: Наука в долгу перед землёй-кормилицей // Деловой Татарстан. 1998. № 1.

ФӘЙЗРАХМА́НОВ Илдар Габделкәбир улы (31.3.1952, Казан), физик, физика-матем. фән. д-ры (2005). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1974), Казан авиация ин-тында эшли. 1977 елдан РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында, радиацион физика лаб-ясе һәм материалларга радиация тәэсире бүлеге мөдире (2007 дән). Хезмәтләре каты җисемнәрдә радиация стимуллаштырган процессларга карый. Ф. ионнар стимуллаштырган синтез процессларын, ш.у. оптик көзгеләрне, фильтрларны һәм дифракцион оптиканы җитештергәндә файдаланылган төрле астарлыклы юка капламалар (ярымүткәргечле, металл һәм диэлектр) киң классының адгезион ныклыгын арттыру һәм полировкалау нәтиҗәлелеген эксперименталь һәм теоретик тикшерү эшләре алып бара; ярымүткәргечле һәм металл ярылар нигезендә формалаштырылган күп катлаулы периодик структураларның селектив ион бөркелүе процессларын өйрәнә; саклаучы һәм яктыртучы ярымүткәргечле алмазсыман углерод ярыларының синтезы алымнарын тәкъдим итә. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2000). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Ионно-стимулированная адгезия тонких металлических плёнок // Поверхность. Физика. Химия. Механика. 1994. № 10–11 (автордаш); Модификация нано-структуры алмазоподобных плёнок углерода бомбардировкой ионами ксенона // Физика и техника полупроводников. 2003.Т.37 (автордаш); Лазерный отжиг кварцевого стекла с ионно-синтезированными нано-частицами меди // Физика твёрдого тела. 2009. Т. 51, вып. 9 (автордаш).

ФӘЙЗРАХМА́НОВА (Сәлим җанова) Фоадия Фәйзрахман кызы (1.2.1935, Балтач р-ны Көшкәт а.), спортчы (чаңгы спорты, узышу), СССРның халыкара класслы спорт остасы (1959). Үзәк физкультура ин-тын тәмамлый (Мәскәү, 1980). Арча пед. уч-щесенең физкультура коллективында тәрбияләнә (тренер — З.К.Корбангалиева). Бөтендөнья кышкы универсиадада (1958, 1960, 1962), СССР профсоюзлары спартакиадаларында (1967, 5 *км* га, 10 *км* га, 3×5 *км* лы эстафета да узышу), «Төньяк бәйрәме» халыкара ярышларында (1959–60) җиңүче. СССР чемпионатларында (1957, 4×5 *км* лы эстафета; 1959, 10 *км* га узышу), СССР беренчелекләрендә (1958, 1967, 4×5 *км* лы эстафета) көмеш медаль ала, СССР чемпионатларында (1957, 10 *км* га узышу; 1968, 5 *км* га узышу, 4×5 *км* лы эстафета; 1969, 4×5 *км* лы эстафета) бронза медаль ала. Олимпия уеннарында катнаша (1968). 1956 елдан Мәскәүдә: Үзәк физкультура ин-тының чаңгы спорты кафедрасында (1960–66), «Спартак» ирекле-спорт җәмгыятендә (1966–75), 14 нче мед. уч-щесендә (1976–90) тренер-укытучы. Медальләр б-н бүләкләнә.

ФӘЙЗУЛЛА́ЕВА Маргарита Павловна (28.4.1946, Казан), музыка белгече, педагог, сәнгать фән. канд. (1982), профессор (1999), ТССРның һәм РФнең атказ. сәнгать эшлеклесе (1991, 2002). Казан консерваториясен тәмамлаганнан соң (1970), Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тында (хәзер Казан мәдәният ин-ты) укыта, музыка теориясе һәм тарихы каф. мөдире (1982–2012). Хезмәтләре татар фольклоры традицияләренә һәм Татарстан композиторлар мәктәбенә багышлана; татар композиторларының иҗатларына, респ-каның опера культурасына һ.б.га багышланган рецензияләр, мәкаләләр; укыту-методик хезмәтләр авторы. ТАССР һәм РСФСРның Композиторлар берлеге (1977), РФнең Театр эшлеклеләре берлеге (2003) әгъзасы.

Х е з м.: Татарский музыкальный фольклор: Учеб. пособие для вузов культуры и искусств. К., 1998; Звуковое пространство композиторов Татарстана: Очерки. Интервью. Воспоминания. К., 2014.

Әд.: Н и г м е д з я н о в М.Н. Маргарита Файзулаева // Композиторы и музыковеды Советского Татарстана. К., 1986.

ФӘЙЗУ́ЛЛИН Җиһанша Закир улы (11.3.1904, Әстерхан ш. — 29.9.1985, шунда ук), Сов. Союзы Герое (10.4.1945), гв. өлкән сержанты. Әстерхан урман сәнәгате хуҗалыгында эшли. 1941 елның августыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 170 нче гв. укчы полкта отделение командиры (8 нче гв. армиясенең 57 гв. укчы дивизиясе). 3 нче Украина һәм 1 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Днепр елгасы өчен сугышта (1943), Никополь-Кривой Рог (1944), Белоруссия (1944) һәм Варшава-Познань (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 1 августында Магнушев шәһәре янында (Польша) Висла елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә: отделение б-н елганы кичеп чыга һәм дошманның пулемёт расчётын юк итә; сугыш барышында взводны җитәкли һәм дошман ныгытмасын яулап алырга булышлык итә. Демобилизацияләнгәннән соң (1945), Әстерханда яши һәм эшли. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Ватанында Геройга бюст куела.

Әд.: Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

М.З.Хәбибуллин.

ФӘЙЗУ́ЛЛИН Илфат Нәгыйм улы (17.6.1953, Әлмәт р-ны Кама-Исмәгыйль а.), нефтьче, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2012), геол.-минер. фән. канд. (2010). Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тының Татарстан кичке ф-тын (Әлмәт ш., 1982), Казан ун-тын (1996) тәмамлый. «Татнефть» АҖдә (1974 елдан), Катламнарның нефть бирүчәнлеген арттыру алымнары идарәсе башлыгы (2009 дан). Хезмәтләре геол., геофизика, экология һәм углеводородлар чыганакларын эшкәртү мәсь әләләренә карый. Дәүләт бүләге «ТР нефть чыгынакларын эшкәртүне тикшергәндә һәм гидрогеологиядә индикатор тикшеренүләрнең аппаратура-методик комплексын булдыру һәм кин кулланышка кертү» эшендә катнашканы өчен бирелә.

ФӘЙЗУ́ЛЛИН Ирек Әнвәр улы (8.12.1962, Казан), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, икътисад фән. канд. (1999), ТРның атказ. төзүчесе (2004). Казан төзүче инженерлар ин-тын тәмамлаганнан соң (1985), шунда ук металл конструкцияләр һәм корылмаларны сынау кафедрасында эшли (1989 елга кадәр). 1989–93 тә «Татстройпроект» проект-төзәлеш оешмасында баш инженер, директор. 1993–95 тә «Татавтодор» АҖ, 1995–97 дә «Казстройдекор» АҖ идарәсе рәисе. 1997–2002 дә «Татавтодор» берләшмәсе башлыгының 1 нче урынбасары. 2002–10 да «Татинвестгражданпроект» дәүләт баш терр. проектлау-эзләнү һәм фәнни-җитештерү фирмасының ген. директоры. Бер үк вакытта, 2005–10 да, ТР төзелеш, архит-ра һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары, 2010 нан министры. Хезмәтләре кризиска каршы төзелеш оешмалары б-н идарә итүдә икътисади стратегияләр формалашу ысуллары мәсь әләләренә карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

ФӘЙЗУ́ЛЛИН Ирек Солтан улы (10.9.1936, Ташкент), геофизик, физика-матем. фән. д-ры (1983), проф. (1992). Мәскәү ун-тын тәмамлаганнан соң (1959), СССР ФАнең Ерак Көнчыгыш ГҮнең Сахалин фәнни-тикшеренү ин-тында (Южно-Сахалинск ш.) эшли. 1965 елдан Мәскәүдә: СССР ФАнең Җир физикасы ин-тында, 1969 дан лаб. мөдире, Бөтенсоюз атом-төш геофизикасы һәм геохимиясе (2004 тән — Бөтенроссия геосистемалар фән-ни-тикшеренү ин-ты) бүлеге мөдире. Хезмәтләре файдалы казылмалар чыганакларын геофизик алымнар б-н эзләү һәм разведкалау өлкәсенә карый. Ф. чиктәш аркылы дулкынарның, тау токымнарында сейсмик дулкынарның экренәюе механизмын билгели; импульслы скважинаара геол. тикшеренү алымын, катламга сейсмоакустик тәэсир итү юлы б-н нефть чыгаруны арттыру технологиясен эшли һәм гамәлгә кертә; чатнаклы зоналарны (ш.и. нефть-газ чыганакларындагы) эзләү һәм контурлау өчен яннан күзәтүле сейсмик локациянең теоретик нигезләре алымын тәкъдим итә һәм эшли. СССР МС бүләге лауреаты (1991). РФнең җир асты байлыклары мактаулы разведчигы (1990).

ФӘЙЗУ́ЛЛИН Искәндәр Газиз улы (27.2.1911, Тубыл ш. — 25.7.1986, Норильск ш.), спортчы (йөзү, марафон), СССРның атказ. спорт остасы (1949). Үзәк физик культура ин-тын (Мәскәү), 2 нче Мәскәү мед. ин-тын тәмамлый (1940 еллар). Су астында йөзеп узуда СССР рекордлары куя — 91,4 *м* (Мәскәү, 1934), ераккә йөзүдә: Кара диңгез буйлап 70 *км* (Туапсе, 1937), Дунай елгасы буйлап 100 *км* (1945), Амур елгасы буйлап 200 *км* (1953, Европа рекорды), Долгое күленда 25 *км* (Норильск ш., 1960), Обь елгасы буйлап 60 *км* (Новосибирск ш., 1968). 1959 елдан Норильск шәһәрендә яши. 1959–63 тә Норильск йөзү бассейнында директор, 1970–86 да тренер; 1963–69 да шәһәр хастаханәсендә дәвалау физкультурасы табибе һәм Балалар хастаханә-поликлиника берләшмәсенең дәвалау физкультурасы кабинеты мөдире; 1986 да «Заполярник» СКның тарих-методик үзәге мөдире. Бөек Ватан сугышында катнаша. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Дальние проплывы. М., 1949; Плавание и гребля. М., 1952; Массовые и дальние проплывы. М., 1954.

ФӘЙЗУ́ЛЛИН Мидхәт Харис улы (7.3.1908, Казан губ., Чистай өязе Шахмай а. — 8.5.1990, Казан), нейрорентгенолог, мед. фән. д-ры (1949), проф. (1950), ТАССРның, РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1968, 1973). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1933), Балтач р-ны Чепья хастаханәсе мөдире булып эшли, 1934–38 елларда Юдино р-ны Юдино тимер юл станциясе поликлиникасы табибе. 1938 дән Казан ГИДУВында: 2 нче хирургия кафедрасында (бер үк вакытта, 1941–45 тә, 1673 нче эвакогоспиталь һәм 361 нче хәрби госпитальләрдә рентгенология бүлеге башлыгы), 1945 тән рентгенология кафедрасында, 1950–53 тә дәвалау ф-ты деканы, 1953 тән рентгенология һәм радиология каф. мөдире, 1982–84 тә проф.-консультант. Хезмәтләре нейрорентгенология өлкәсенә: баш мие шешләренә рентген ярдәмендә диагноз куюга, борынның өстәмә куышлыклары авыруларын, баш сөяге-баш миенең ябык җәрәхәтләрен дәвалау ысулларына карый. ТАССР Рентгенологлар һәм радиологлар җәмгыяте рәисе (1953–83). Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Рентгенодиагностика опухолей головного мозга. К., 1967; Череп и мозг в рентгеновском изображении. К., 1971; Рентгенодиагностика последствий закрытой черепно-мозговой травмы.К., 1985(автордаш).

Әд.: Профессор Мидхат Харисович Файзуллин: Некролог // Казан. мед. журн. 1990. № 4.

ФӘЙЗУ́ЛЛИН Равил Габдрахман улы (4.8.1943, Балык Бистәсе р-ны Балтач а.), шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе, РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1985), ТРның халык шагыйре (1999), ТР ФАнең шәрәфле әгъзасы (2007). Казан ун-тын тәмамлый (1965). 1968–72 елларда ТАССР Язучылар берлеге Әлмәт бүлегенең, 1973–77 дә ТАССР Язучылар берлеге идарәсенең җаваплы сәркәтибе. 1989–2013 тә «Казан утлары» ж-лының баш мөхәррире. Беренче шигырьләрен 1950 елларда бастыра башлый. Ф.ның «Нуанслар иле» (1964) шигъри циклы; «Рәсем ясыйм» (1965), «Аҗаган» (1966), «Монологлар һәм диалоглар» (1967), «Кыска шигырьләр» (1978) кебек шигырь җыентыклары (бер-, ике-, өчәисә дүртъюллык шигырьләре) укучылар-ның һәм тәнкыйтьчеләрнең игътибарын традицион булмаган ирекле формасы һәм үзенчәлекле поэтикасы б-н үзләренә җәлеп итәләр. Шигъри детальләрнең һәм метафораларның муллыгы, тирән фикерләрне кыска һәм аңлаешлы итеп әйтеп бирә алуы яшь шагыйрьнең осталыгын һәм иҗатының камиллеген чагылдыра. «Хрущёв җепшеклеге» чорында әдәбиятка килгән Ф. өчен кыю гражданлык, чорны һәм кеше яшәешенең үзкыйммәтен нечкә тоемлау хас. Беренче шигырьләрендә автобиографик чалымнар ачык гәүдәләнә («Яшьлек дәфтәреннән» шигырьләр циклы, 1962–68; «Солдат дәфтәреннән», 1966–68; «Әлмәт дәфтәреннән», 1968–71).



Р.Г. Фәйзуллин.

Иҗатының башлангыч чорында шигырь төзелеше өлкәсендә үзен сынап карый. Алга таба ул традицион булмаган формалардан ераклаша башлый. 1970 елларда иҗатының тематикасы киңәя, идея-фәлсәфи эчтәлеге тирәнәя. Ф.ның күләмнәре ягыннан зуррак, традицион формада, рифма һәм ритм б-н язылган бу чор шигырьләренә читләтеп әйтү (киная), татар поэзиясенә яшерен эчтәлек, тел яшерү кебек яңа алымнар куллану нәтиҗәсендә ирешелгән күпмәгънәлелек, абстракцияләү хас: «Мәрмәр» (1969; Татарстан комсомолының М. Җәлил исем. бүләге, 1970), «Шигырьләр һәм поэмалар» (1976; ТАССРның Г. Тукай исем. Дәүләт бүләге, 1978), «Кошлар юлы» (1981). Акрынлап Ф. әсәрләрендәге поэтик образлар тагын да гомумиләштерелә, яңа сәнгать мәйданы — вакыйгаларга, предметларга, төрле социаль төркем һәм һөнәр ияләре образларына бай Җир шары барлыкка килә. «Гадиләргә гимн» (1971) һәм «Көрәшчеләр» (1975) лиро-эпик поэмалары шундыйлардан, алар публицистик характерда һәм әхлакый җаваплылык, дөньяда ирек, тигезлек һәм туганлык идеаллары урнашу кирәклеге турында монолог-уйлану рәвешендә. Ф.ның күләмле «Сәйдәш» эпик поэмасы (1981) татар проф. муз. культурасына нигез салучы комп. Салих Сәйдәшевкә багышлана. Ф. поэзиясенең төп казанышы — аның лирик герое, ягъни актив яшәү позицияле, югары идеалларга омтылучы, милли мәдәниятнең, әдәбиятның һәм сәнгатьнең якты киләчәгә өчен көрәшергә әзер яшь кеше: «Айлы тирәкләр» («Лунные тополя», М., 1990), «Җил — Вакыт ул» (1996) җыентыклары. Шагыйрьнең күпчелек шигырьләрендә элегик тональлек саклана, аларда гомернең тиз узуы, бәхет, мәхәббәт, дуслык турында сөйләнә: «Кайту мизгеле» («Миг возвращения», М., 1976), «Минем йолдызлы сәгатем» («Мой звёздный час», М., 1978) һ.б. Мәхәббәт лирикасына ихласлык хас: «Наз» (1973), «Чишмәләр иле» (1987), «Сөю көчле иманнан» (Уфа,



Х.Ш. Фәйзуллин.

1997), «Мәхәббәтнамә» (2003), «Калейдоскоп»(2004). Ф. татар поэзиясен ритмомелодика, җыр эпиграфлары һ.б. стиль үзенчәлекләре б-н баета. Аның шигырьләре еш кына үзе тапкан яисә халык авыз иҗатыннан, классик поэзиядән алынган мул сәнгатьчә чаралар куллану исәбенә өзек-өзек, марш рәвешендә яисә моңлы-салмак яңгырый.

Композиторлар аның иҗатына еш мөрәҗәгать итә, Ф. шигырьләренә күп кенә популяр җырлар языла: «Аккошлар» (Ф.Әхмәтов көе), «Мин сине ничек яраттым!» (С.Садыйкова көе), «Менә без дә үсеп җиттек, әни» (Л.Хәйретдинова көе), «Сагыш» (Ж.Фәйзи көе), «Синең өчен яшим» (Р.Абдуллин көе), «Якты моң» (Ш.Шәрифуллин көе) һ.б. Ф. балалар өчен язылган «Күмәч пешерүчеләр җыры» (1977), «Ага да, ага елгалар» («Текут, текут реки», М., 1987), «Газиз китабы» (2005) шигырь җыентыклары, әдәби-тәнкыйть мәкаләләре, публицистик әсәрләр һәм юлъязмалар тупланган «Җырларда — ил гаме» (1984), «Илбагар уйлар» (2011) җыентыклары авторы. Шигырьләре рус, башкорт, украин, эстон, кыргыз, грузин, инглиз, гарәп, немец, поляк, француз, төрек һ.б. телләргә тәрҗемә ителә. 1990–95 тә ТР ЮС депутаты. ТР Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең Г. Исхакый исем. бүләге лауреаты (2012). Дуслык ордены, медальләр, ТРның, РФнең Мактау грамоталары б-н бүләкләнә.

Әсәр.: Сайланма әсәрләр: 5 томда. К., 1992–2001; Сайланма әсәрләр: 6 томда. К., 2005.

Әд.: Равил Фәйзуллин: Заман. Иҗат. Шәхес. К., 2002; Урманче Ф. Борынгы миф һәм бүгенге шигырь: Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин шигъриятенә бер караш. К., 2002; Хуҗина М. Равил Фәйзуллинның шигъри дөньясы. К., 2011.

Ф.Г.Галимуллин, Н.М.Йосыпова.

ФӘЙЗУ́ЛЛИН Рөстәм Габдрахман улы (тәхәллүсе Акъегет) (5.3.1951, Балык Бистәсе р-ны Балтач а.), шагыйрь, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1987). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1974), «Татарстан» ДТРКда эшли: «Тел күрке — сүз», «Туган тел дәресләре» радио тапшырулары мөхәррире. «Ак болыт шәүләсе» (1987), «Төнге сулар» (1990), «Янды бер шәм таңнарда» (2001), «Агыла болыт офыкларга» (2012) шигырь җыентыкларында — яшәү турында уйланулар.

Әд.: Кутуй Р. Шигъри сурәт остасы // Мирас. 2006. № 7.

ФӘЙЗУ́ЛЛИН Рөстәм Мәхмүд улы (8.6.1933,Үзбәкстан ССР, Коканд ш. — 6.10.2005, Казан), геолог, геол.-минерал. фән. д-ры (1988), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1996). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1956), «Дальстрой» (Магадан өлкәсе), Көнчыгыш Себер (Иркутск өлкәсе һәм Бурят АССР), Үзбәкстан, Байкал аръягы (Чита өлкәсе) геол. партияләрендә эшли. 1972 елдан Руда булмаган файдалы казылмалар геологиясе үзәк ин-тында (ЦНИИгеолнеруд, Казан), 1997 дән баш фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре руда һәм руда булмаган чыганаклар геологиясенә карый. Колыма елгасының югары агымында геол. съёмкалар үткәрә, Себердә алтын һәм бериллий чыганакларын ачуда катнаша. Апатитка СССР терр-ясен минерагеник районлаштыру үткәрә, запасларын прогнозлау һәм күләмен бәяләү методикасын, геол.-сәнәгый типтагы апатит рудаларын классификацияләү методикасын эшли.Фосфат чималына СССР минерагеник картасын төзүдә,ТР терр-ясендә минераль пигментлар һәм башка руда булмаган файдалы казылмаларны бәяләүдә катнаша (ТР Дәүләт бүләге, 1998). Уйлап табуга патенты бар. Халыклар дуслыгы, «Почёт билгесе» орденнары б-н бүләкләнә.

Хезм.: Геология месторождений апатита, методика их прогнозирования и поисков. М.,1980 (автордаш); Геолого-промышленная оценка месторождений апатита.М., 1985 (автордаш); Методическое руководство по поискам, оценке и разведке месторождений твёрдых нерудных полезных ископаемых Республики Татарстан: В 3ч. К., 1999–2001 (автордаш).

ФӘЙЗУ́ЛЛИН Фердинанд Хәнифулла улы (27.1.1957), балет артисты, ТРның халык артисты (1994). 1968–73 елларда Казанда Мехчылар мәдәният сараеның Н.Наумов җитәкчелегендәге һәвәскәрләр коллективында биергә өйрәнә. 1974–97 дә ТРның Җыр һәм бию ансамбле солисты, 1996–98 дә ТР Мәдәният министрлыгының Халык иҗаты фәнни-методик үзәгендә традицион халык хореографиясе буенча баш белгеч, 1998–2001 дә «Казан» милли мәдәният үзәге каршындагы шәһәр филармониясенең «Казан» бию ансамбле директоры. «Егетләр», «Кияү», «Әпипә», «Мәдрәсәдәге хәл», «Казан кунаклары», «Өйгә җиңү белән» һ.б. хореография композицияләрендә соло партияләрен башкара. Ф.ның башкаруы техник төгәллеге, актёрларча сәнгатьлелеге, катлаулы па хәрәкәтләрен җиңел башкаруы, үз иҗатына аеруча талләпчәнлеге б-н аерылып тора. Ансамбль составында Россия буйлап һәм чит илләрдә, ш.и. Үзәк һәм Төньяк Африка (Нигерия, Бенин, Сенегал, Тунис һ.б.), Европа (Франция, Германия, Финляндия, Италия һ.б.) илләрендә гастрольләрдә йөри.



Ф.Х. Фәйзуллин.

В.Н.Горшков.

ФӘЙЗУ́ЛЛИН Хәниф Шакир улы (9.4.1921, хәзер Оренбург өлкәсенең Сакмар р-ны Үргебашы Чебенке а. — 17.10.1943), Сов. Союзы Герое (22.2.1944, үлгәннән соң), гв. өлкән лейтенанты. Укытучылар ин-тын (Оренбург ш., 1939), Куйбышев хәрби-пехота уч-щесен (1941) тәмамлый. 1939 елдан Кызыл Армия сафларында. 1941 нең августыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 280 нче гв. укчы полкында рота командиры (37 нче армиянең 92 нче гв. укчы дивизиясе). Ростов (1941) һәм Барвенково-Лозовая (1942) һөҗүм операцияләрендә, Днепр өчен сугышта (1943) катнаша. 1943 нең 17 октябрендә Днепр елгасының уңъяк ярында урнашкан Лиховка авылы янында (хәзер Днепропетровск өлкәсенең Пятихатки р-ны Лиховка штп) плацдармны киңәйтү өчен барган сугышларда батырлык күрсәтә: Ф. ротасы дошманның оборонасын өзеп, берничә танк һәм пехота һөҗүмен кире кайтара, авылны азат итә. Кул сугышында үлем ярасы ала. Ленин ордены, медаль б-н бүләкләнә. Туган ягында Геройга бюст куела.

Әд.: Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

М.З.Хәбибуллин.

ФӘЙЗУ́ЛЛИНА Елена Владимировна (12.6.1964, Казан), педиатр, мед. фән. д-ры (2002). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1987), ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының Респ-ка тире-венерология диспансерында дерматовенеролог булып эшли. 1991 елдан Казан мед. ин-тының тире-венерология авырулары кафедрасында. Хезмәтләре онихомикозны, кандидозлы инфекцияләрне (таралышы, йогу ихтималы, диагностика, дәвалау, мед. ярдәме күрсәтүне оптимизацияләү) өйрәнүгә карый. Уйлап табуга патенты бар.

Хезм.: Онихомикозы: эпидемиология, факторы риска, пути оптимизации медицинской помощи. К., 2010.

ФӘЙЗУ́ЛЛИНА (Тәр җеманова) Мәрзия Низам кызы (11.6.1930, Арча р-ны Шушма-баш а.), шагыйрә, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1990). Әдәбият ин-тын тәмамлый (Мәскәү, 1964). 1950 елдан Казанда: 1951–72 дә китапханәче, балалар бакчасында тәрбияче, Совет р-ны эчке эшләр бүлегенең балалар бүлекчәсе инспекторы булып эшли. Балаларга багышланган беренче «Салават күпере» (1955) китабында ук Ф.ның табигый, чын дидактикалы шигъри интонациясе ачык чагыла. «Чәчәкләр сәгате» (1959, рус теленә тәрҗемәсе «Цветочные часы», 1964), «Ике көрәк» (1961), «Саф мәхәббәт» (1967), «Энҗе чәчәк» (1970), «Синең өчен генә» («Только для тебя», 1978), «Болытсыз яңгыр» (1981), «Чиккән яулык» (1991), «Га-

илә әлифбасы» (1999) шигырь җыентыклары авторы. Ф. әсәрләрендәге лирик башлангыч дөньяны балаларча — күңелле, шаян, шат күзаллау б-н яраша. Шигъри иҗаты балалар поэзиясе б-н генә чикләнми, сугыш елларының ачы чынбарлыгын чагылдырган лирик шигырьләр җыентыгы «Сугыш юлларының тузаны» (1985; икенче исеме — «Солдат хатлары») — Ф. шигъриятендә яңа юнәлеш.

Әсәр.: Тик сиңа гына. К., 2004.

Әд.: Кукушкин Р. Канатлы дөнья. К., 1984; Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2; Баруздин С. Люди и книги. М., 1982.

ФӘЙЗУ́ЛЛИНА Раушания Самат кызы (6.12.1963, Арча р-ны Сименбаш а.), драма актрисасы, ТРның халык артисты (2008). Казан театр уч-щесен тәмамлаганнан соң (1985), Әлмәт татар драма театры труппасына чакырыла. Актрисаның беренче рольләре үк аның милли үзенчәлеген, халык иҗатына якынлыгын гәүдәләндерә. Ф. иҗат иткән образларда рухи җылылык һәм эчке оптимизм, хисләр муллыгы һәм тормышчан хаклык ачык чагылыш таба: хәйләкәр, шаян, таза гәүдәле Шәмсия («Кодача», З.Исмәгыйлев), «Яшь



Р.С.Фәйзуллина Гөлҗиһан ролендә («Яшь хатын алам – типтерәм дөньясында», Г.Камалның «Банкрот» пьесасы буенча; Җамалетдин ролендә – Ф.Зарипов).

хатын алам — типтерәм дөньясында» (Г.Камалның «Банкрот» пьесасы буенча) спектакльдә үзәк урынны биләгән гаугалы һәм мәгънәсез Гөл җиһан, ялгызлыгын мәзәкчәнлеге һәм тынгысызлыгы артына яшергән Әкълимә («Әбиләргә ни җитми?», Ф.Бүләков) — шундыйлардан. Уңганбикә («Кыз урлау», М.Кәрим) роле күңелле шаянлыгы б-н аерылып тора, Бибинур («Безнең авыл кызлары», Ф.Садриев), Сабира («Татар хатыны ниләр күрми», Г.Ибраһимов), төрек фахишәсе Нариман («Юмарт хатыннар», Т.Җүҗән-оглы) образлары тирән драматизм б-н сугарылган. Аеруча зур рольләре — Фәния («Зәхмәт», З.Хәким), Саймә («Сагынырсың әле син дә бер», Г.Каюмов), Тайбә («Мәхәббәтем калды адашып», И.Йомагылов), Сәгыйдә («Тальян моңы», Ш.Бикчурин), Сәмига («Исәнмесез!», Т.Миңнуллин), Ашайрә («Их, Алла боерса», Г.Каюмов), Мәстүрә («Кыз-лар килде авылга», Н.Гаетбай), Дая («Ромео һәм Джульетта», У.Шекспир) һ.б.

И.И.Илялова.

ФӘЙЗУ́ЛЛИНА Рәмзия Мәхмүт кызы (2.1.1962, Сарман р-ны Янурыс а.), курчак театры актрисасы, ТРның халык артисты (2001). Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тын тәмамлый (2004). 1979 елдан Татар «Әкият» курчак театры актрисасы. Ф. матур җырлый, сөйләмнең төрле интонацион үзенчәлекләрен бик тә һәм оста файдалана, бу аңа үз чираттында истә калырлык, пластика һәм сөйләм характеристикасы буенча индивидуаль образлар галереясын иҗат итәргә мөмкинлек тудыра. Театрда иҗат эшчәнлеге алып барган елларда спектакльләрдә барлык диярлек баш рольләрне башкара, курчак уйнату алымнарын яхшы үзләштерә, төрле төрдәге курчаклар б-н эш итә. Курчак театрлары фестивальләрендә билгеләп үтелгән (Казан, Оренбург, Төркиядә Адан ш., Финляндиядә Иисалми ш.) Найман Ана («Анам кыры», Ч.Айтматов повесте буенча), Зөләйха («Ак күлмәктә кара елан», Р.Корбан, З.Думави), Су анасы, Зөһрә («Ат өреккән шомлы төн», «Таңга — Чулпан, айга — Зөһрә», Зөлфәт), Чикерткә («Җырлап узган җәй», Н.Дәүли), Нарый («Абай бабай аланы», Р.Харис), Саяко («Ана күзләре», З.Думави), Кәҗә («Кәҗә белән Сарык», Г.Тукай), Су анасы (шул исем. әсәр буенча, Г.Тукай) рольләрен башкаруы актрисаның зур казанышы була. «Иң яхшы курчак театры актрисасы» номинациясендә ТР Мәдәният министрлыгының «Тантана» бүләге лауреаты (2012).

Әд.: Иглам ов Р.М. Искусство играющих кукол. К., 2004.



Р.С.Фәйзуллина.



Р.М.Фәйзуллина.



Т.Х.Фәйзуллина.

ФӘЙЗУ́ЛЛИНА Резеда Габделәхәт кызы (6.7.1963, Казан), педиатр, мед. фән.д-ры (2002). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1986), 1 нче балалар авырулары кафедрасында эшли. 1988–91 елларда 2 нче Мәскәү мед. ин-тының балалар авырулары пропедевтикасы кафедрасында. 1991–96 да Казан мед. ин-ты дәвалау ф-тының балалар авырулары кафедрасында. 1996–2001 дә Респ-ка гаиләне, аналар һәм балаларны саклау үзәгендә өлкән фәнни хезмәткәр, сәламәтлек саклау бүлеге мөдире. 2001 дән Казан мед. ун-тының педиатрия кафедрасында, 2009 дан балалар авырулары пропедевтикасы һәм факультет педиатриясе каф. мөдире. Хезмәтләре мәктәп яшендәге балаларда хроник гастродуоденаль патология очракларында матдәләр (микроэлементлар) алмашы бозылуны өйрәнүгә, матдәләр алмашын көйләү ысулларын эшләүгә карый.

Хезм.: Особенности обмена тяжёлых металлов у детей с хроническим гастродуоденитом // Казан. мед. журн. 2001. № 1 (автордаш); Хронические запоры у детей // Мед. фарм. вестн. Татарстана. 2004. № 10 (142); Возможности использования нитрофугинов в терапии заболеваний органов пищеварения у детей // Практ. медицина. 2008. № 2 (26); Возможности фитотерапии в педиатрической практике // Практ. медицина. 2009. № 7. (автордаш).

ФӘЙЗУ́ЛЛИНА СӨЗӘКЛЕКЛӘРЕ́, к.*Гран-тау.*

ФӘЙЗУ́ЛЛИНА Тәслимә Хәләф кызы (17.7.1953, БАССРның Бишбүләк р-ны Дүсән а. — 13.10.2018, Казан), драма актрисасы, педагог, ТРның халык артисты (2008). Уфа сәнгать уч-щесен тәмамлаганнан соң (1972), Башкорт драма театры труппасына кабул ителә (Салават ш.). 1977 дән Татар драма һәм комедия театры актрисасы. Рәхилә («Беренче мәхәббәт», Х.Вахит), Сәрби («Яшь йөрәкләр», Ф.Бурнаш), Гөлчирә («Ташкыннар», Т.Гыйззәт), Ләлә («Гашыйклар тавы», И.Юзеев) кебек яшь героиняләр рольләрендә Ф. образларны индивидуальләштерергә омтыла, аларның дөньяга караш үзенчәлекләрен, характер сыйфатларын җиткерергә тырыша. Тәслимә («Сөярка», С.Шәкүров), Тәзкирә («Шикәрем син, балым син», А.Гыйләҗев), Бикә («Әстәгъфирулла!», Н.Гаетбай), Убыр, Рабига («Сихерче», «Бер тамчы ярату», Н.Гыйматдинова романнары буенча), Мәдинә («Яз галәмәте», Р.Сәгъди), Флюра («Тол хатыннар көймәсе», И.Греково повесте буенча) һәм аеруча Бернарда Альба, Бернарда («Бернарда Альба йорты», «Өметсез хыяллар», Ф.Г.Лорка) рольләрендә актрисаның драматик сәләте, героиняларының катлаулы эчке дөньяларын тиешле дәрәҗәдә ачу, хис-кичерешләренең тотрыклылыгына карамастан, теге яки бу образның рухи халәтен ышандырырлык итеп гәүдәләндерү осталыгы ачык чагылыш таба. Пед. һәм әдәби эшчәнлек б-н шөгыльләнә. 1993–2003 тә Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тында актёрлык осталыгы буенча укыта, бер үк вакытта, 1999 дан, Казан театр уч-щесендә. Инсценировкалар (2004 тә узган «Яңа татар пьесасы» конкурсында «Иң яхшы инсценировка» номинациясендә Н.Гыйматдинованың «Бер тамчы ярату» романының инсценировкасы өчен 1 нче бүләк), танылган эстрада



Т.Х.Фәйзуллина Бернарда Альба ролендә («Бернарда Альба йорты», Ф.Г.Лорка).

җырчылары репертуарындагы популяр җырлар авторы, Ф.Г.Лорканың «Канлы туй» («Кровавая свадьба»), «Бернарда Альба йорты» («Дом Бернарды Альба») пьесаларын татар теленә тәр җәмә итүче.

Әд.: И л я л о в а И. Театр имени Тинчурина. К., 2002. *И.И.Илялова.*

ФӘКЫЙҺ (гарәп. فقيـــه — белүче, аңлаучы), мөселман хокукы белгече, мөселман дине кагыйдәләре комплексы — фикъһ мәсьәләләре буенча белгеч. Беренче Ф.лар — Мөхәммәд пәйгамбәрнең аеруча белемле сәхабәләре, нигездә, шәһәр сәүдә-һөнәрчелек даирәсеннән чыккан кешеләр (7 йөзнең 2 нче яртысы). Коръән һәм Сөннә нигезендә Ислам кагыйдәләре буенча яшәү рәвешен булдыру аларның дини бурычларын үтәүнең бер өлеше, диндарлык шөгыльләре була. Алар якынча 130 кеше дип исәпләнелә, аеруча күренекле-леләре — Гомәр бине Хаттаб, Гали бине Әбү Талиб, Әбү Бәкер әс-Ситдыйк, Зәед бине Сабит, Габдулла бине Мәсгуд, Габдулла бине Габбас һәм Габдулла бине Гомәр. Мөселман илләрендә яшәүчеләр арасында дини-хокукый мөнәсәбәтләр киңәя башлау б-н, фикъһ өлкәсендә проф. шөгыльләнүчеләр саны да арта. 8 йөз ахыры — 9 йөз башында Ф.лар шәһәр халкының тәэсир көченә ия катлавын тәшкил итә, алар арасыннан дәүләт хезмәтенә кандидатлар да күрсәтелә. Бу чорларда хәлифәлекнең төрле төбәкләрендә дини-хокукый мәктәпләр — мәзһәбләр оеша башлый. Аларның идеологлары күренекле мөселман хокукы белгечләре Малик бине Әнәс (Мәдинә ш.), Хәсән әл-Басри (Басра ш.), Әбү Хәнифә (Күфә ш.), әл-Авзаи (Сүрия), әш-Шәфигый (Мисыр), Әхмәд бине Хәнбәл (Багдад ш.) һ.б. була. Ф.лар берничә категориягә бүленә: иң югарысы — мөҗтәһидләр. Хокукый боерыклар — фәтвалар чыгарганда, мөҗтәһидләрнең карарларына нигезләнү сорала. Хәзерге вакытта Ф. вазифаларын мөфти, казыйлар, голәмалар башкара.

Әд.: М ө х ә м м ә д Г. Ислам Шәригате. Һәркемгә ирешерлек фикыһ мәсь әләләре: 2 кис. К., 1999; А д ы г а м о в Г.К. Исламское право. К., 2011; А л и - З а д е А. Исламский энциклопедический словарь. М., 2007.

ФӘЛӘҲОВ Инил Фәләх улы (8.3.1941, Балтач р-ны Пыжмара а.), химик-технолог, химия фән. д-ры (1984), проф. (1986), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1995), Казан технол. ун-тының атказ. профессоры (2010). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1964, хәзер Казан технол. ун-ты), шунда ук эшли, азот органик кушылмаларының химиясе һәм технологиясе каф. мөдире (1986 елдан). Хезмәтләре махсус продуктлар химиясенә һәм технологиясенә карый. Ф. ароматик һәм гетероциклик кушылмаларны нитрлаштыру теориясе үсешенә һәм аларны барлыкка китерү технологиясен булдыруга өлеш кертә. Пиридинның функциональ нитро продуктларын барлыкка китерү алымнарын тәкъдим итә; җылылыкка чыдам югары егәрлекле кушылмаларны синтезлый, аларны барлыкка китерү технологияләрен эшли. 380 нән артык фәнни хезмәт авторы. Уйлап табуга 122 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. РСФСРның югары белем бирү отличнигы (1990), РФнең мактаулы югары белем бирү хезмәткәре (1997), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2004).

Әд.: Специалисты по взрывчатым материалам, пиротехнике и боеприпасам: Биогр. энцикл. М., 2006.

«ФӘН ҺӘМ ДИН», журнал, к. «*Сугышчан алласыз*».

«ФӘН ҺӘМ МӘКТӘ́П — НАУ́КА И ШКО́ЛА», айлык фәнни-методик журнал. 1996 елның октябреннән Чаллы шәһәрендә татар һәм рус телләрендә нәшер ителә. Оешт-ручысы — Өзлексез пед. белем бирү ин-ты (Чаллы ш.). Мөхәррирләре — Ф.М.Сафин, Г.Х.Сәмигуллин. Журнал үз максаты итеп модернизацияләү шартларында мәгариф учреждениеләренең эшен оештыруны яктырта. Басмада мәгариф системасы б-н технол. идарә итү, белем бирү эчтәлегенең яңарту мәсьәләләре, пед. новация һәм эксперимент-ларның төрле аспектлары, хуҗалык эшчәнлеге үзенчәлекләре карала. Мәгариф учреждениеләре эшчәнлегe турында оператив мәгълүматлар, пед. проблемалары буенча яңа фәнни-методик эшләнмәләр, пед. фәне б-н практика алдында торган катлаулы проблемалар һәм алдынгы пед. тәҗрибә турындагы материаллар басыла. Идарә мәсь әләләре буенча юридик-хокукый документлар һәм тәкъдимнәр, гаилә тәрбиясенә багышланган язмалар, укучы яшьләр өчен танып белү мәкаләләре чыга.

«ФӘН ҺӘМ ТЕЛ», фәнни-мәгълүмати журнал. Оештыручылары — Казан дәүләт архит-ра-төзелеш академиясе, Татарстан Респ-касы Фәннәр академиясе, Бөтендөнья Татар конгрессы башкарма ком-ты. 1997 елдан Казанда нәшер ителә, текстлары рус һәм татар телләрендә басыла. Баш мөхәррирләре — Р.Ә.*Шакиржанов*, Ф.Г.*Әхмәдиев* (1999 дан). Журналда фәнни тикшеренүләрнең киң спектры буенча мәкаләләр басыла. Редакция табигыять-фәнни, техник һәм гуманитар өлкәләрдә хезмәттәшлеккә булышлык итәргә омтыла. Журналның төп максатлары — Татарстанда фән һәм мәгарифне үстерүдә татар теленең потенциалын кулланыр өчен татар фәнни терминологиясен камил-



«Фән һәм тел» журналы.

ләштерү, күренекле татар галимнәренең казанышларын популярлаштыру.

«ФӘН» нәшрияты. 1991 елда оеша, ТР ФАнең структур бүлекчәсе. Рус һәм татар телләрендә фәнни әдәбият, ТР ФА, фәнни белемнәрнең бөтен өлкәләренә караган башка фәнни учреждениеләр һәм югары уку йортлары галимнәренең монографияләрен, халыкара, Россия һәм респ-ка фәнни конференцияләр материаллары җыентыкларын (елына 40 ка якын исемдәге), «*Научный Татарстан*» ж-лын (144 сан, гомуми тиражы — 14400 дә-нә) чыгаруда махсуслаша. 400 дән артык монография һәм җыентык чыгара. Баш мөхәррирләре — А.И.*Афанасьев* (1991–2002), Б.Л.*Хәмидуллин* (2002–2014).

ФӘН-ТЕ́ХНИКА КОМИ́ССИЯСЕ, ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты бюросы һәм СССР ФА Президиумының бердәм карары нигезендә ТАССРда фәнни эшләр б-н җитәкчелек итү һәм СССР ФАнең Казанга эвакуацияләнгән фәнни оешмалары эшчәнлеген координацияләү максатында 1941 елның сентябрендә оештырыла. Рәисе — акад. О.Ю.Шмидт, рәис урынбасары — ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты секретаре А.А.Абецедарский. Комиссия әгъзалары: академиклар Е.А.Чудаков, А.Ф.Иоффе, Н.Н.Семёнов, ВКП(б)ның өлкә ком-ты секретаре Р.Г.Хәмидуллин, Казан шәһәр ком-ты секретаре А.И.Греньков һ.б. Комиссия фәнни-оборона характерындагы барлык эшләрне берләштерә, Татарстанның сәнәгый пр-тиеләренә фәнни-техник һәм консультатив ярдәм күрсәтә, фәнни эшләнмәләрне тиз арада җитештерү өлкәсендә гамәлгә кертүгә булышлык итә. Эшчәнлеге 1944 тә туктала.

Әд.: И о н е н к о И.М., П о п о в В.А. Казанский университет в годы Великой Отечественной войны. К., 1985; П о п о в В.А. Мобилизация и использование трудового потенциала производственно-технической и научной интеллигенции в годы Великой Отечественной войны. К., 1991.

В.Ф.Телишев.

ФӘННИ́-ҖИТЕШТЕРУ́ БЕРЛӘШМӘСЕ́ (ФҖБ), фәнни тикшеренү, проект-конструкторлык, технология оешмаларын, тәҗрибә һәм күпләп продукция чыгару пр-тиеләрен эченә алган бердәм җитештерү һәм хуҗалык итү комплексы. Горизонталь, вертикаль, конгломерат берләшмәләр була. Горизонталь берләшмәләргә — җитештерүнең бер үк стадияләрен тормышка ашыручы һәм бер фирмага караган; вертикальгә — җитештерүнең төрле стадияләрен тормышка ашыручы һәм бер фирмага караган пр-тие төркемнәре керә. Конгломерат берләшмә — бер фирмага караган һәм төрле төр, ягъни бер-беренә көндәш булмаган продуктлар җитештерүнең бер яисә берничә стадиясен тормышка ашыручы пр-тиеләр төркеме. Икътисади мәнфәгатьләре буенча берләшмәләр җитештерү һәм сәүдә пр-тиеләре тарафыннан чыгарылган продукцияне бергәләп сату, җитештерүне махсуслаштыру һәм кооперацияләштерү, уртак тикшеренү эшләре алып бару, үзара финанс ярдәме һәм хезмәт күрсәтү һ.б. өчен киң файдаланылалар.

Татарстанда ФҖБләр 1980 елларда тарала башлый ала. Иң билгеле ФҖБләр: В.И.Ленин исем. Казан фәнни-җитештерү берләшмәсе (1976), «Вакууммаш» (1981), «Татарстан кыры» (1987), Казан хисаплау техникасы һәм информатика ФҖБ (КНПО ВТИ, 1987), «Элекон» (1995) һ.б.; мәс., КНПО ВТИның төп юнәлешләре: мәгълүмати белешмә системалар, автоматлаштырылган өйрәтү системалары һәм укыту курслары, гамәли программалар, программ-техн. комплекслар иҗат итү буенча фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләре алып бару, идарә һәм оештыру эшчәнлеген автоматлаштыру мәсьәләләрен хәл итү. 1990 еллар ахырында бик күп ФҖБләр ачык акционерлык җәмгыятьләре итеп үзгәртелә.

Ф.С.Зыятдинов.

ФӘННИ́-ТЕ́ХНИК РЕВОЛЮ́ЦИЯ (ФТР), фәнне иҗтимагый җитештерүнең әйдәүче факторына әверелдерү нигезендә җитештерүче көчләрне сыйфат җәһәтендә тамырдан үзгәртеп кору. ФТР башлану 20 йөз уртасына карый, фәнне турыдан-туры җитештерүче көчкә әверелдерү процессында ФТР фәнни-техник алгарышның кискен тизләнешенә китерә, кешеләрнең мәдәниятен, көнкүрешен, технологиясен, җәмгыятьнең табигать б-н үзара мөнәсәбәтләрен кертеп, кешелек җәмгыяте тормышының барлык якларына көчле йогынты ясый.

ФТРне әзерләүдә 19 йөз ахырында — 20 йөз башында табигыять белеме уңышлары, фәннең микродөнья һәм зур тизлекләр өлкәсенә үтеп керүе аеруча әһәмияткә ия, нәтиҗәдә, материягә карашларда тамырдан борылыш була, һәм дөньяның яңа манзарасы барлыкка килә. 1920 елларда *физика* өлкәсендәге ачышлар йогынтысында *химиянең* теоретик нигезләре зур үзгәрешләр кичерә. Нәселдәнлек механизмына үтеп керү, *генетиканың* интенсив үсеше башлана, хромосома теориясе формалаша. Сәнәгатьтә һәм транспортта электрның киң файдаланылуы техникада революцион үзгәрешкә китерә (к. *Электрлаштыру, Электр энергетикасы*). Радио уйлап табыла һәм киң таралыш ала (к. *Радиоэлектроника*). *Авиация* барлыкка килә. 1940 елларда фән атом төшен таркату мәсь әләсен хәл итә һәм кешелек атом энергиясенә ху җа булу чигенә килеп җитә. *Кибернетиканың* барлыкка килүе гаять зур әһәмияткә ия була. 1940–50 елларда ракеталар төзелеше өлкәсендәге ыргым галәм киңлеген үзләштерә башлауга китерә. Шул ук вакытта, 1950 елларда, электрон хисаплау машиналары (ЭИМ) эшләнә һәм фәнни тикшеренүләр уздырганда, җитештерүдә, аннары идарәдә дә киңрәк кулланыла башлый (к. *Хисаплау техникасы*). Аларның барлыкка килүе машинага эзлекле рәвештә логик функцияләр башкаруны тапшыру һәм җитештерүне, идарәне комплексны автоматлаштыру башлануын (к. *Ихтималый автомат, Ихтималый процессор, Техник кибернетика*), ш.у. җитештерү процессында кешенең урыны һәм роле үзгәрүен чагылдыра. 1940–50 елларда эре фәнни һәм техник ачышлар йогынтысында фәннәрнең һәм фәнни-тикшеренү эшләренең зур өлеше структурасында принципиаль үзгәрешләр була, кеше эшчәнлегендәге мөһим өлкәләрнең бердәм системасы: табигать һәм җәмгыять законча лыкларын танып белүләр (фән), табигатьне үзгәртеп коруның техник чаралары һәм бу юнәлештәге тәҗрибә (техника), матди байлыклар процессы (җитештерү) һәм җитештерү процессында гамәлләрне рациональ рәвештә үзара бәйләүысуллары барлыкка килү (идарә) өчен алшартлар тудырыла башлый.

ФТР шартларында, аңа кадәрге чордан аермалы буларак, фәнгә тамырдан үзгәртү вазифасы күчә. Бу аның тарафыннан матдәләрнең яңа класслары, яңа процесслар ачылуда, бигрәк тә фундаменталь фәнни тикшеренүләр нәтиҗәләре нигезендә җитештерүнең принципиаль яңа, моңарчы тупланмаган гамәли тәҗрибә шартларында хасил була алмаган, атом реакторларын, радиоэлектроника һәм хисаплау техникасын, квант электроникасын, нанотехнологияләрне һ.б.ны куллану нәтиҗәсендә барлыкка килгән тармакларда чагылыш таба. ФТР шартларында фән үсешенең техника, җитештерү үсешеннән алда баруын, җитештерүнең торган саен фән казанышларының технол. әверелеше төсен алуын тормыш үзе таләп итә. Фән йогынтысының үсүе тар специальләшү үсеше, фәнни учреждениеләрнең һәм аларның тикшеренү базасының катлауланууы б-н үрелеп бара. Бу процесс, фундаменталь тикшеренүләрне җитештерү б-н бәйләүче буыннар буларак, гамәли тикшеренүләрнең тизләтелгән үсешендә, проектлау-конструкторлык һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләрендә чагыла (к. *Фәнни-тикшеренү берләшмәләре*). Комплексны дисциплинаара тикшеренүләрнең әһәмияте гаять арта, табигыять фәннәре, техник һәм иҗтимагый фәннәрнең үзара бәйләнешләре көчәя, ниһаять, фәнни эшчәнлек үсешенең закончалыкларын, аның нәтиҗәлелеген күтәрүнең шартларын һәм факторларын өйрәнүче махсус дисциплиналар барлыкка килә.

Фәнни-техник борылыш, а.х. хезмәтен индустриаль хезмәтнең аерым бер төренә әверелдереп, ш.у. а.х. җитештерүен дә яңарта (к. *Агросәнәгать комплексы, Агросәнәгать интеграциясе*). Шул ук вакытта авылча тормыш рәвешенең урынын торган саен шәһәрчә тормыш рәвеше били бара. Фән, техника һәм сәнәгать үсеше — авыл халкының интенсив *урбанизациясенә*, массакүләм коммуникацияләр һәм заманча инфраструктура үсеше авылда мәдәни тормышның тиз күтәрелешенә булышлык итә.

ФТР шартларында төрле процессларның һәм күренешләрнең үзара бәйләнеше үсү иҗтимагый, табигыять һәм техник фәннәрнең җитештерүнең нәтиҗәлелеген күтәрүгә, тормыш һәм хезмәт шартларын яхшыртуга юнәлтелгән бердәм тәэсирен көчәйтә. Хезмәтнең эчтәлеге эзлекле рәвештә прогрессив технол., яңа материаллар һәм энергия төрләре, хезмәт кораллары һәм чараларын эшләү һәм гамәлгә кертү рәвешен ала. Биредә кеше факторы йогынтысын көчәйтү зарури шарт булып тора. Хезмәткәрләрнең һөнәри белемнәренә, квалификациясенә, оештыру сәләтләренә, ш.у. гомуми мәдәни һәм интеллектуаль дәрәҗәсенә карата таләпләрне үстерә барып, ФТР төп җитештерүче көчләрнең — эшчеләрнең һәм инженер-техник кадрларның җитештерү асылын һәм функцияләрен тамырдан үзгәртү өчен алшартлар булдыра. Мәҗбүри гомуми белем күләменең артуы б-н бер үк вакытта хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү һәм үзгәртү, бигрәк тә хезмәтнең интенсив үсеш кичерүче өлкәләрендә аларны периодик рәвештә яңадан әзерләү мәсь әләсе туа.

Хәзерге вакытта Россиядә һәм Татарстанда ФТР казанышларын куллану барыннан да элек монополияләр мәнфәгатьләренә буйсындырылган, аларның икътисади һәм сәяси позицияләрен нык ытуга юнәлтелгән. Татарстан югары дәрәҗәдә оешкан җитештерү механизмына һәм нигезле фәнни-тикшеренү базасына ия (к. *Югары уку йортлары*, *Казан фәнни мәктәпләре*). 1990 еллардан респ-када эре монополистик берләшмәләрнең дәүләт катнашында җитештерүче көчләр үсешендә тоткарлыкларны бетерергә мөмкинлек биргән оештыру формаларын эзләп табуга омтылышлары тагын да көчәя. Техник үсешне һәм фәнни тикшеренүләрне программалаштыру һәм фаразлау таралыш ала. Татарстанның аерым эре холдинглары һәм фирмалары кысаларында фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшен тиешле югарылыкта алып баруга, көндәшлек көрәше зарурлыгы куйган шартларда яңа техниканы һәм технологияне нәтиҗәле рәвештә гамәлгә кертүгә ирешелә. ФТР шартларында җитештерүне җәмәгатьләштерү һәм интернациональләштерү ихтыяҗы транснациональ корпорацияләрнең үсешенә сәбәпче була.

ФТР процессында техник цивилизациянең табигатькә тәэсире контрольдә булмау тискәре техноген нәтиҗәләргә китерә (к. *Әйләнә-тирә мохитнең пычрануы, Техноген калдыклар*), Татарстан алдына кискен рәвештә экологик проблема, яки яшәү тирәлеген саклау һәм фәнни нигездә көйләү мәсьәләсе килеп баса (к. *Экологик программалар, Табигатьне саклау*).

Икътисади үсеш өлкәсендә заманча инновацион эшчәнлек фәнни, технол., оештыру, финанс һәм коммерция чараларының тулы бер комплексын күздә тота. Аның соңгы нәтиҗәсе технол. яңалыклардан — гамәли эшчәнлектә кулланылучы яңа яки камиллә терелгән продуктлан, технол. процесслан гыйбарәт (к. *Технопарк*).

В.П.Модестов.

ФӘННИ́-ТЕ́ХНИК СОВЕ́Т, 1941 елның ноябрендә ТАССРның Дәүләт план комиссиясе каршында оештырыла. Максаты — халык хуҗалыгы һәм оборона өчен мөһим техник, икътисади һәм оештыру өлкәләренә караган теоретик һәм гамәли мәсь әләләрне хәл итү юлларын эшләү; фронт һәм тыл ихтыяҗлары өчен Татарстанның ресурсларын ачыклау һәм мобилизацияләү; халык хуҗалыгының төрле тармаклары буенча фәнни консультацияләр һәм экспертизалар оештыру. Ф.-т.с.ны ТАССР Дәүләт план комиссиясе рәисе П.П.Цыбин җитәкли, урынбасары итеп проф. Л.М.Миропольский билгеләнә. Ф.-т.с. минераль чимал, нефть, энергетика,

үсемлек чималы, транспорт һәм башка секцияләргә бүленә. Секцияләрнең активы 250 тирәсе фәнни хезмәткәрдән һәм төрле оешмаларның 25 вәкиленнән тора. Ф.-т.с. эшендә академиклар А.Е.Арбузов, А.Е.Порай-Кошиц, профессорлар В.И.Баранов, З.Н.Блюмштейн, Н.А.Ливанов, М.Д.Винокуров, Н.Н.Качалов һ.б. катнаша. Әлеге совет эшләгән дәвердә җитештерү өлкәсендә ак маскировка буявы, янгынга каршы япмалар, гематоген, теш цементы, ланолин, абразив материаллар, химик тәэсирдән саклаучы пакетлар, керамик эшләнмәләр, мед. гипсы һәм эфир алуның яңа ысуллары гамәлгә кертелә. Эшчәлеге 1944 нең апрелендә туктатыла.

Әд.: Иоженко И.М., Попов В.А. Казанский университет в годы Великой Отечественной войны. К., 1985; Попов В.А. Мобилизация и использование трудового потенциала производственно-технической и научной интеллигенции в годы Великой Отечественной войны. К., 1991.

В.Ф.Телишев.

әл-ФӘРАБИ́ (الفـــارابى) Әбү Наср Мөхәммәд (870, Отрар оазисы Фәраб ш., хәзерге Көньяк Казакъстан терр. — 950, Димәшкъ яки гарәп хәлифәлеге Гаскыйлан шәһәренә бару юлында), философ, галим-энциклопедист; Шәрекъ аристотелизмының күренекле вәкиле. Чыгышы буенча төрки. Сәмәркандта, Бохарада, Иран шәһәрләрендә белем ала. Гарәп, фарсы, грек, сүрия һ.б. телләрне белә. 941–42 елларда әл-Ф. Димәшкъ шәһәренә күченеп килә, андагы хөкемдар Сәйф әд-Дәүла Гали Һәмдани (943–67) химаясендә фән б-н шөгыльләнә. Үзенең хезмәтләрендә гарәп, фарсы, грек, һинд һәм төрки мәдәниятләре казанышларын гомумиләштерә. Арифметика, геом., логика, астрономия, физика, химия, оптика, мед., мөселман хокукы, сәясәт, филол., поэтика, риторика, каллиграфия, музыка, этика, педагогиканы үстерүгә зур өлеш кертә; Аристотель, Платон һәм башка борынгы грек философларының хезмәтләренә аңлатмалар яза. Фәнне өйрәнү буенча гарәп-мөселман философиясендә беренче, шул чордагы фәнне өйрәнү белемененең төп тармаклары санап чыгылган һәм һәрберсенең тикшеренү предметы билгеләнгән «Фәннәрне классификацияләү турында» (Багдад) трактаты авторы. Димәшкътә Аристотель һәм Платон идеяләренә нигезләнеп дөньяның яратылышы һәм үсеше, камил җәмгыять корылышы турында үзенең күзаллавын бәян иткән сәяси-этик «Игелекле шәһәрдә яшәүче кешеләрнең карашлары турында трактат» язып тәмамлый. Диннең бурычын кешеләр арасында әхлакый-хокукый мөнәсәбәтләрне җайлауда күрә. Әл-Ф. буенча филос. һәм дин бер хакыйкатьнең ике ягын: филос. — асыл эчтәлеген, ә дин — символика һәм риторикасын чагылдыра. Әбүгалисина һәм Ибне Рөшднең фәлсәфи карашларына сизелерлек йогынты ясый.

Хезм.: Математические трактаты. А.-А., 1972; Логические трактаты. А.-А., 1975; Историко-философские трактаты. А.-А., 1985; Трактаты о музыке и поэзии. А.-А., 1992.

Әд.: Касымжанов А.Х. Абу-Наср аль-Фараби. М., 1982; Хайруллаев М.М. Абу Наср аль-Фараби, 873–950. М., 1982; Fakhry M. Al-Farabi, Founder of Islamic neoplatonizm: His life, works and influence. Oxf., 2002.

ФӘРД (гарәп. فـرد — икеюллык), Якын һәм Урта Көнчыгыш илләре әдәбиятында шигъри жанр; бербөтен тәмамланган фикер белдергән аерым *бәйт*, афористик яңгырашлы мөстәкыйль шигырь. Еш кына экспромт рәвешендә барлыкка килә. Кайвакыт, төп фикерне ассызыклау өчен, дидактик характердагы һәм проза әсәрләрендә кулланыла. Афористик яңгырашлы булуы аркасында Ф. еш кына мәкальгә, канатлы сүзгә әверелә (Сәгъди, Хафиз, Низами һ.б.). Татар әдәбиятында Ф. жанрына Сәйф Сараи, Дәрдемәнд, Г.Тукай, Р.Фәйзуллин, М.Мирза һ.б. мөрәҗәгать итә.

Илдә бер дуст булмаса гәр,
Ил бөтен — дошман түгел! (Дәрдемәнд)

Әд.: Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990.

ФӘРДИ́ЕВ Илшат Шәех улы (31.8.1960, Актаныш р-ны Әнәк а.), хакимият-ху җәлык эшлеклесе, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2003), ТРның атказ. энергетигы (2004). Мәскәү энергетика ин-тының Казан ф-лын тәмамлаганнан соң (1983), «Тукай» кошчылык ф-касында (Тукай р-ны) эшли. 1985–95 елларда Чаллыда: 1990 га кадәр тимер-бетон эшләнмәләр з-дында баш энергетик, 1990 нан «Татсельхозводстрой» трестының механикалаштырылган колоннасы башлыгы. 1995–97 дә а.х. кооперативы рәисе, 1997–98 дә Актаныш р-ны хакимияте башлыгы. 1998–99 да Әлмәт р-ны һәм Әлмәт шәһәре хакимияте башлыгы. 1999–2010 да «Татэнерго» АҖ ген. директоры. 2010–12 дә ТР Премьер-министры урынбасары, ТР энергетика министры. 2012 дән «Сетевая компания» АҖ ген. директоры. 2000–10 да ТР халык депутаты. Дәүләт бүләге югары басымлы казаннар өчен суны термик әзерләү технологиясен эшләүдә һәм гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә (2003). Почёт ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Чаллы шәһәренең мактаулы гражданы (2007).

ФӘРЕШТӘ ЧӘЧӘГӘ́, к. *Цикорий*.

ФӘРРА́ХОВ Айрат Зәки улы (17.2.1968, Әгерҗе ш.), дәүләт һәм сәясәт эшлеклесе, мед. фән. д-ры (2015), ТРның атказ табибе (2008). Казан мед. ин-тын (1993), РФ Президенты каршындагы Россия халык хуҗалыгы һәм дәүләт хезмәте академиясен (2011), Мәскәү «Сколково» идарә мәктәбен (2016) тәмамлый. РФнең 3 нче класслы хакыйкый дәүләт киңәшчесе. Мед. ин-тын тәмамлаганнан соң, шунда ук, хирургия кафедрасында эшли. 1995–97 елларда Респ-ка клиник хастаханәсенең (РКБ) эндоскопик хирургия, абдоминаль хирургия бүлегендә. 1997–2002 дә Казан мед. ун-тының хирургик авырулар каф. ассистенты. 2002 дән РКБ баш табибенең хирургия ярдәме күрсәтү, 2004 тән дәвалау мәсьәләләре буенча урынбасары. 2006–07 дә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма ком-тының Сәламәтлек саклау идарәсе башлыгы, 2007–13 тә ТР сәламәтлек саклау министры, 2013–14 тә РФ сәламәтлек саклау министры урынбасары, 2014–2016 да РФ финанс министры урынбасары. 2016 дан РФ Дәүләт Думасы депутаты. Хезмәтләре операциядән соңгы катлаулану очракларына иртә срокларда диагноз кую һәм комплексны дәвалау, балалар сәламәтлеген саклау мәсьәләләренә карый. ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2012). Медальләр б-н бүләкләнә.



А.З. Фәррахов.

Хезм.: Гепатобилисцинтиграфия в диагностике желчеистечения в раннем послеоперационном периоде у больных желчнокаменной болезнью // Казан. мед. журн. 2000. № 2 (автордаш); Ранние послеоперационные осложнения у больных калькулезным холециститом и холедохолитиазом. К., 2008 (автордаш); Модернизация детского здоровья в Республике Татарстан: первые результаты // Казан. мед. журн. 2013. № 2.

ФӘРХЕТДИ́НОВ Бакир Фәррах улы (15.5.1925, Лениногорск р-ны Түбән Чыршылы а. — 14.8.2008, Мәскәү), спортчы (авыр атлетика), СССРның атказ. спорт остасы (1954). «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятендә тәрбияләнә (Мәскәү). Физик культура техникумын һәм тренерларның Югары мәктәбен тәмамлый. СССР 1953–54 (1952 һәм 1959 — көмеш), Европа (1984), дөнья (1954) чемпионатларында, Кытайның ачык чемпионатында (1956), Бөтендөнья җәйге студентлар уеннарында (1951, 1953) җиңүче. 1950 еллар да җиңел авырлыкта (56 *кг* га кадәр) СССРның 7 рекордын куя. 1966–84 тә «Динамо» футбол командасында 1985 тән «Спартак»та массаж ясаучы. Медальләр б-н бүләкләнә.

ФӘРХЕТДИ́НОВ Равил Гыйльметдин улы (11.11.1920, Уфа губ., Бәләбәй өязе (хәзер Башкортстан Респ-касының Бүздәк р-ны) Ялтыркүл а. — 16.09. 2010, Уфа), терапевт, мед. фән. д-ры (1971), проф. (1972). БАССРның атказ. фән эшлеклесе (1984). Башкорт дәүләт мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1944), Уфаның Беренче совет хастаханәсендә (Үзәк клиник хастаханәсендә) эшли, бер үк вакытта мед. ин-тының анатомия кафедрасында ассистент. 1953–57 елларда Уфа шәһәр сәламәтлек саклау идарәсе баш терапевты. 1958 дән мед. ин-тының госпиталь терапия кафедрасында, 1968–84 тә эчке авырулар пропедевтикасы каф. мөдире. Фәнни тикшеренүләре йөрәк-кан тамырлары авыруларын кисәтү һәм дәвалауга, «Янгантау» курорты газлы термаль ванналарының ашказаны һәм бөер эшчәнлегенә тәэсирен өйрәнүгә, респ-ка-ның сәнәгать пр-тиеләре хезмәткәрләрен диспансеризацияләү мәсьәләләренә карый.

Башкортстан терапевтлар җәмгыяте рәисе (1974–84).

ФӘРХЕТДИ́НОВ Рәфагать Равил улы (14.2.1949, Башкортстан АССР, Уфа ш.), биофизик, патофизиолог, мед. фән. д-ры (1988), проф. (2000). Башкорт мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1972), шунда ук эшли, 1991 елдан фәнни-тикшеренү лаб-ясендә, 2010 нан лаб. мөдире. Патологик процессларның механизмын, метаболик, физиол. һәм патологик процессларда ирекле радикаллар окисьлашуы-

ның роле һәм әһәмиятен өйрәнә, биол. материалларны (кан, сидек) тикшерүнең хемилюминесцент ысулларын, экспресс-ысуллар эшләп тәкъдим итә. Уйлап табуга 30 авторлык таныклыгы бар.

ФӘРХЕТДИ́НОВ Риф Галләм улы (11.7.1943, Сарман р-ны Югары Чыршылы а.), инженер-геолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1997). Казан ун-тын тәмамлый (1971). 1961–2001 елларда «Татнефть» АҖдә (бүленеп), баш инженер, АҖнең Азнакай идарәсендә җитештерү-техника бүлеге, скважиналарны капиталь һәм җир астында ремонтлау буенча җитештерү бүлеге башлыгы (1992 дән). 1971–72 дә Кострома нефть эзләү экспедициясенең инженер-геологы. 1978–81 дә катламнарның нефть бирүчәнлеген күтәрү һәм скважиналарны капиталь ремонтлау буенча Нижневартовск идарәсенең баш технологы, «Нижневартовскнефтьгаз» АҖнең «Повхнефть» НГДУы геол. бүлеге башлыгы. 1981–82 дә «Татнефтегазразведка»ның көнбатыш Себердә скважиналар төзү буенча Бөгелмә бораулау эшләре идарәсенең район инженер-техник хезмәте башлыгы. Дәүләт бүләге аз дебитлы скважиналарның җитештерүчәнлеген күтәрүдә яңа термоимплозион һәм перфорацион-имплозион экспресстехнологияләр эшләү һәм киң кулланылышка кертүдәге казанышлары өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

ФӘРХЕТДИ́НОВ Самдун Җамалетдин улы (23.2.1937, Әлмәт р-ны Кичүчат а. — 23.8.2000, Әлмәт ш.), журналист, музыкант, һәвәскәр рәссам, скульптор, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1995). Мәскәү сәнгать ун-тының музыка (1961), журналистика (1972) ф-тларын тәмамлый. Казанда Татар филармониясендә (1960–64) эшли, «Социалистик Татарстан», «Строитель», «Төзүче» г-талары фотохәбәрче була. 1968 елдан Әлмәттә. «Нефтяник», «Хәзинә» (1968–85), «Хезмәт байрагы» (1968–90), «Әлмәт таңнары» (1990–98) г-таларында, «Нефтяник» ж-лында (1972–85), бер үк вакытта «Елховнефть» идарәсендә (1968–98) журналист һәм фотожурналист булып эшли. «Социалистик Татарстан», «Татарстан яшьләре», 1994 елдан Оренбургта чыгучы «Яңа вакыт» г-талары белән хезмәттәшлек итә. ТР Журналистлар берлеге әгъзасы.



С.Ж. Фәрхетдинов. Әлмәт районы Кичүчат авылындагы мәчет. 1992.

Ф. — Ризаэтдин Фәхретдин мемориаль музеен нигезләүче һәм аның архитекторы, Риза бине Фәхретдин исем. мәчетнең (1992), Кичүчат авылында Бөек Ватан сугышында җиңүнең 59 еллыгына күелган, урта гасырлар татар мавзолей-төрбәсе рәвешендә эшләнгән һәйкәлнең (1995) архитекторы; Тымытык авылы мәчетенең манара (1999) проекты авторы. Әлмәт районындагы мәчетләрнең (Кичүчат а., 1991; Чупай а., 1992; Мәмәт а., 1995; Әлмәт ш., 1998) интерьерларын (витражлар, шәмаилләр, агачны уеп бизәк ясау, тимердән декоратив формалар) бизәү авторы. Ф.ның сәнгать эшләре шәхси күргәзмәсе 1995 елда Әлмәттә була: 77 шәмаил һәм 32 гамәли-бизәлеш сәнгать әсәре күрсәтелә.

Ф. — маршлар, җырлар авторы, «Казаньхимстрой» берләшмәсендә эстрада һәм тынлы оркестрлар белән җитәкчелек итә (1960–66). Төбәкнең танылган кешеләре турында «Мәшһүр якташларыбыз мизгелләре», Р.Фәхретдиновның тормышына һәм эшчәнлегенә багышланган очерклары кулъязма хәлендә саклана.

Әсәр.: Ризаэтдин Фәхретдин музей-йорты: Буклет. Әлмәт, 1995; Сайланма мәкаләләр. Әлмәт, 2000.

Әд.: Ибраһимов М. Эх, Самдуннар күбрәк булсачы // Әлмәт таңнары. 1995. 27 июнь; Таҗи Д. Күпкырлы талант иясе // Әлмәт таңнары. 1997. 22 февр.

ФӘРХЕТДИ́НОВ Усман Равил улы (18.12.1954, Уфа), терапевт, мед. фән. д-ры (2003), БРның атказ. табибе (2001), БРның сәламәтлек саклау отличнигы (2003). Р.Г.Фәрхетдиновның улы. Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1978), Уфа шәһәренең 5 нче, 13 нче хастаханәләрендә эшли, 1983 тән 21 нче хастаханәдә пульмонология бүлеге мөдире, бер үк вакытта, 2006 дан, Башкортстан дәүләт мед. ун-тында эчке авырулар пропедевтикасы каф. профессоры. Уфа шәһәр сәламәтлек саклау идарәсенең штаттан тыш баш пульмонологы. Фәнни хезмәтләре бронх-үпкә авырулары очрагында авыру барышының молекуляр механизмнарын өйрәнү һәм көйләүгә карый. Ф. катнашында үпкә ялкынсынуының стадияләренә дифференциацияле диагноз кую, хроник бронхит б-н авыручыларда ялкынсыну процессының активлыгын һәм төрен ачыклау һ.б. ысуллар эшләнә. Уйлап табуга 5 авторлык, 2 рационализаторлык тәкъдиме таныклыгы бар.

Х е з м.: Саногенез (о науке и практике врачевания). СПб., 2009 (автордаш).

ФӘРХЕТДИ́НОВ Хәлил Хәйри улы, (8.6.1948, хәзер БРның Яңавыл р-ны Кисәкаен а.), генерал-майор (1991). Вольск тыл хәрби уч-щесен (1970), Тыл һәм транспорт хәрби академиясен (Ленинград, 1980) тәмамлый. 1968–96 елларда чик буе гаскәрләрендә: Балтыйк буенда, Тянь-Шань, Памир, Камчатка, Әрмәнстан, Грузиядә, 1992 дән Төньяк Кавказ чик буе округында командующий



З.Ф. Фәрхетдинова.

урынбасары. Уфа шәһәрендә яши. 1997–98 дә БР матди ресурслар һәм төбәкара элемтәләр министры урынбасары. 1998 дән БР МК аппаратының мобилизацияләүгә әзерләү бүлеге мөдире. «Шәхси батырлык өчен», 1 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

ФӘРХЕТДИ́НОВ Ягъфәр Фәсхетдин улы (15.10.1936, Әлмәт р-ны Бигәш а. — 18.12.2004, Казан), хокук белгече, юридик фән. д-ры (2003), ТРның атказ. юристы (1997). Казан ун-тын тәмамлый (1963). 1962–71 елларда Чистай шәһәре халык мәхкәмәсе халык судьясы, 1994–98 дә Казан шәһәре Идел буе р-ны мәхкәмәсе судьясы. Бер үк вакытта, 1973 тән, Казан ун-тында гражданлык хокукы һәм процессы кафедрасында. 2004 тән Россия хокук академиясенең Казан ф-лында директор урынбасары. Хезмәтләре гражданлык процессуаль хокукы, гражданнарга транспорт-экспедиция һәм конкүреш хезмәте күрсәтүне хокукый яктан көйләү мәсьәләренә карый.

Х е з м.: Правовое регулирование транспортно-экспедиционного обслуживания граждан. К., 1977; Законодательство и судебная практика по некоторым вопросам бытового обслуживания. К., 1983; Возникновение и развитие источников гражданского процессуального права России. К., 2001.

Әд.: Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

Е.Б.Долгов.

ФӘРХЕТДИ́НОВА Зәйнәп Фазлетдин кызы (17.8.1967, Үзбәкстан ССР, Ташкент өлкәсенең Красногорск пос.), җырчы, ТРның халык артисты (2009). Казан мәдәният ин-тын тәмамлый (1989). 1990–92 елларда — Татар филармониясе, 1992–95 тә — «Казан» милли мәдәният үзәге ансамбле, 1995–96 да — Татар акад. театры каршындагы эстрада ансамбле солисты, 1996 дан «Аваз» җыр студиясенең сәнгать җитәкчесе. Репертуарын Татарстан композиторларының вокаль әсәрләре: «Зилә́лүк», «Гөлҗамал», «Сандугачлар», «Мин сине яратам» һ.б.; үзе язган көйләргә җырлар: «Алкалар», «Кайту», «Сагындым» һ.б. тәшкил итә. Ялгыз җырлый, ш.у. ире З.Билалов б-н бергә дә чыгыш ясый. Актив рәвештә концертлар куя, аудио- һәм видеоязмалар әзерләп чыгара. Концерт программалары: «Мәхәббәт күпере» (1996), «Янымда син булсаң» (2001), «Син ми ңа кирәк» (2006), «Мәхәббәт хакына, мәхәббәт хакында» (2010) һ.б. Халыкара «Татар җыры» конкурсы лауреаты (2000–2015). Төрки телле халыкларның Бөтендөнья «Тюрковизион-1996» җыр конкурсы дипломанты (Төркия).

ФӘРХИ́ (Биктаһирова) Хәния Фәрхислам кызы (10.6.1960, БАССРның Тәтешле р-ны Үрге Сәләй а. — 27.7.2017, Башкортстан; Казанда җирләнә), җырчы, ТРның халык артисты (2000). Казан театр уч-щесен (Р.М.Батулла курсы) тәмамлый (1985). 1986–1989 елларда Татар драма һәм комедия театры актрисасы. 1989 дан «Җыр һәм мәрхәмәтлелек» театр-студиясе артисты (Чаллы), аннары Мәскәү өлкә филармониясендә эшли. 1992 дән «Бәйрәм» театраль иҗат коллективы артисты (Казан), 2000 нән «Энергетик» мәдәният сараенда (Чаллы), 2006 дан «Бәйрәм» театр-студиясенең сәнгать җитәкчесе (Казан). Ф. киң диапазонлы көчле тавышка ия; репертуарын татар халык җырлары, Татарстан һәм Башкортстан композиторларының муз. әсәрләре тәшкил итә, ш.у. үз шигырьләренә язылган җырлар авторы да. «Әлдермешкә кайтам әле», «Сагынам сине, Питрәч», «Үпкәләсәң, әйдә, үпкәлә», «Онытылыр димә», «Кышкы чия», «Син дөньяда яшиясәләр» һ.б. җырлары аңа аеруча зур популярлык китерә. БДБ илләре, Бельгия, Финляндия, Хорватия шәһәрләрендә һ.б.да концерт программалары б-н чыгыш ясый. Төбәк «Сандугач» җыр фестивале (1999, 2000; Казан), Халыкара «Татар җыры» конкурсы (2000–2016) лауреаты. Медальләр б-н бүләкләнә. Казанның Йолдызлар аллеясында Ф. хөрмәтенә исемле йолдыз куелган.

Әд.: Низаметдинова М. Татар күңелендә бәйрәм ясаучы // Татар иле. 2005. № 5.

ФӘРХУ́ЛЛИН Ринат Гаяз улы (25.12.1943, Биләр р-ны Биләр а.), радиофизик, техник фән. канд. (2003). ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2016). ТРның атказ. нефтьчесе (1998). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1970), «Татнефть» ҖБнең, «Татнефть» АҖ «Ямашнефть» НГДУының фәнни-тикшеренү бүлекләрендә эшли (1974–2014). 2014 елдан РФА КГҮнең Механика һәм машиналар төзү ин-ты җир асты гидромеханикасы лаб-ясендә. Хезмәтләре Татарстанның авыр чыгарыла торган нефть запаслары чыганакларын үзләштерү барышын термодинамик исуллар б-н контрольдә тотуга карый. Уйлап табуга 8 авторлык таныклыгы һәм патенты, ш.и. файдалы модель таныклыгы бар. СССРның атказ. уйлап табучысы (1982).

Хезм.: Гидродинамические исследования скважин и методы обработки результатов измерений. М., 1999 (автордаш); Комплекс промысловых исследований по контролю за выработкой запасов нефти. К., 2002; Контроль за разработкой нефтяных и газонефтяных месторождений. К., 2009 (автордаш).

ФӘСА́ХОВ Касыйм Мингалим улы (18.3.1930, Октябрь р-ны Түбән Әмзә а. – 30.7.2004, Казан), язучы, публицист, тарих фән. канд. (1974). Казан ун-тын тәмамлый (1961). Татар һәм рус телләрендә яза. 1955 елдан Тельман районы «Коммуна байрагы» г-тасында җаваплы сәркәтип. 1959–70 тә «Социалистик Татарстан» г-тасында бүлек мөдире, Казан телестудиясендә әдәбият-сәнгать тапшырулары баш мөхәррире, Татарстан китап нәшриятында баш мөхәррир урынбасары. 1970–93 тә Казан финанс-икътисад ин-тында укыта. Тормышка, туган як табигатенә мәхәббәт, иҗат бәхете турында шигырь һәм поэма җыентыклары авторы: «Дулкыннар кочагында» (1964), «Тормыш серләре» (1965), «Мишә җыры» (1966, А.Сәләхетдинов б-н бергә), «Уяныгыз!» (1967), «Текә ярлар» (1968). «Авылым легендалары» китабы (1969) балаларга һәм яшүсмерләргә багышлана. «Көнбагышлар чәчәк ата» очерк һәм юморескалар җыентыгының (1971) төп темасы — замандашларының кызыклы тормышы, дуслык һәм мәхәббәт. Сов. Союзы Герое Д.М.Карбышев батырлыгына «Карабаш батыр» поэмасы (1972), Идел буе Болгары һәм Казан ханлыгы тарихына «Болгарстан — минем чыгышым» (1997), «Олуг Мөхәммәднең олуг җиңүе» (1999), «Шәһри Бану — болгар каласы» (2000) поэмалары багышлана. «Яшәү белән бер аяктан» («С жизнью в ногу», 1979), «Дөреслек дөреслек булып калачак» («Правда останется правдой», 1987), «Хакыйкать каршында» (1991) публицистика җыентыкларында милли үзаң үсеше мәсьәләләре яктыртыла. Бертуган Гриммнар әкиятләрен татар теленә тәр җәмә итә.

Н.Ф.Краева.

ФӘСӘ́ХОВ Нил Шәфыйк улы (16.11.1932, Казан), спортчы (волейбол). СССРның атказ. спорт остасы (1960). Мәскәү өлкә пед. ин-тын тәмамлый (1962). 1948 елдан «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятендә тәрбияләнә (Казан, тренеры — И.Б.Брен). 1956–63 тә ЦСКА (Мәскәү) командасы составында уйный. СССР чемпионатларында 1958, 1960–62, 1957 (көмеш), СССР халыклары спартакиадаларында 1963, 1959 (көмеш), дөнья 1960, 1956 (бронза), Европа 1958 (бронза) чемпионатларында медальләр ала, Европа (1959), Европа чемпионнары Кубогы (1960, 1962) иясе. 1956 дан Мәскәүдә яши. 1968–71 дә «Буревестник» командасында тренер, 1971–80 дә Олимпия резервы 73 нче «Виктория» махсуслаштырылган балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә өлкән тренер, 1981–94 тә директор, 1994–2007 дә методист.

Казанда 2005 тән Ф. Кубогына халыкара турнир уздырыла; 2009 да «Зенит» (Казан), чемпион 2008/09) һәм «Динамо» (Мәскәү, Кубок иясе 2008/09) командалары арасында Россия суперкубогына Ф.га багышланган матч уздырыла. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

ФӘССА́ХОВ Рафаэль Хәйретдин улы (12.4.1939, Мөслим р-ны Тегермәнлек а. — 20.3.2003, Казан), химик-технолог, химия фән. д-ры (1991), проф. (1994), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1998). Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң (1967), шунда ук эшли, азотның органик кушылмалары химиясе һәм технологиясе каф. профессоры (1992 дән). Хезмәтләре махсус продуктлар химиясенә һәм технологиясенә карый. Ф. функциональ нитроимидазоллар-1,3 классына караучы югары энергияле, җылылыкка чыдам кушылмаларның максатчан синтезының фәнни-методик нигезләрен һәм аларны барлыкка китерүнең технологияләрен эшли; яңа реакцияләр тәкъдим итә, аларның закончалыкларын һәм механизмнарын тикшерә, имидазол һәм аның нитр алмашлы продуктларының синтезы алымын эшли. Уйлап табуга 36 авторлык таныклыгы бар.

Әд.: Специалисты по взрывчатым материалам, пиротехнике и боеприпасам: Биогр. энцикл. М., 2006.

ФӘССА́ХОВ Рөстәм Сәлах улы (7.5.1955, Минзәлә ш.), аллерголог, мед. фән. д-ры (1994), проф. (1995). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1978), шунда ук патофизиол. кафедрасында эшли. 1987 елдан Казан ГИДУВында (хәзер Казан мед. академиясе), аллергология һәм иммунология каф. мөдире (1994 тән), бер үк вакытта, 2002 дән, Роспотребсоюзның Казан эпидемиология һәм микробиология фәнни-тикшеренү ин-ты директоры. 1996 дан ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының аллергология-иммунология буенча баш белгече. Хезмәтләре аллергологиягә карый. Ф. Татарстан буенча аллергик авырулар таралышын өйрәнә, диагноз кую һәм дәвалау аллергеннарының яңа формаларын, бронхиаль астманы дарулар б-н дәвалау ысулын эшләп тәкъдим итә. Уйлап табуга ике авторлык таныклыгы бар.

Хезм.: Экстрогенитальная патология и беременность. М., 1998; Анафилактический шок: этиология, клиника, неотложная терапия, профилактика. К., 2000 (автордаш); Заболевания органов дыхания при беременности, М., 2010 (автордаш).

ФӘССА́ХОВ Фәйзеләхәт Гаяз улы (30.8.1941, Яңа Чишмә р-ны Зирекле а.), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, ТРның атказ. а.х. хезмәткәре (1994). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1963), Чистай р-нында эшли: Ленин исем. «Дуслык» к-зларында (1964 елдан), «Буревестник» с-зында (1966 дан) баш агроном, «Дуслык» к-зы рәисе (1967 дән), «Каргалы» с-зы (1970 тән), «Чистай» кошчылык ф-касы (1974–2006 да) директоры. Ф. кошчылык ф-касы б-н җитәкчелек иткән вакытта җитештерү-техник база һәм социаль-мәдәни инфраструктура булдырыла. Кошларның баш саны — 2,2 тапкыр, йомырка җитештерү — 4,3, ит 1,5 тапкыр арта. Ленин ордены, ике Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының бронза медале б-н бүләкләнә.

ФӘСХЕТДИ́НОВ Әнвәр Сәгъди улы (19.9.1919, Минзәлә ш. — 4.4.1995. шунда ук), актёр, ТАССРның халык артисты (1959), РСФСРның атказ. артисты (1976). Хезмәт



Ә.С.Фәсхетдинов Ворохов ролендә («Мин — солдат хатыны», Н.П.Анкилов; Марийка ролендә — И.А.Саттарова).

эшчәнлеген 1933 елда башлап җибәрә. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1946 да демобилизацияләнгәннән соң, Минзәлә колхоз-совхоз театрына чакырыла. Беренче роле — Хәлил — М.Фәйзинең «Галиябану» драмасы буенча куелган спектакльдә актёрның драматик һәм муз. сәләтен ача. Ф. башкарган Әскәр («Аршин мал алан», У.Хаҗибәков), Галимҗан («Башмагым», Х.Ибраһимов), Гариф («Алтын көз», Г.Насрый), Зиннәт («Акчарлаклар», Ә.Фәйзи), Булат («Зәңгәр шәл», К.Тинчурин) рольләре аны лирик-романтик герой итә. «Шайтан шәкерте» (Б.Шоу) мелодрамасы буенча куелган спектакльдә актёр,



Ә.С.Фәсхетдинов.



Ә.С.Фәсхетдинов Посәт ролендә («Кара бүре» Н.Арбан).

Ричард Даджен ролен романтик рухта башкарып, герое кылган гамәлләрне психол. дәлилли, образның драматизмын оста ача. Подколёсин («Өйләнү», Н.В.Гоголь), Карандышев («Бирнәсез кыз», А.Н.Островский) образларын характерның асылына тирәнтен үтеп кереп гәүдәләндерә. Гаяз («Соңгы карак ош», Г.Баһәветдинов) образы актёрның зур казанышы була, ул герой күңелендәге каршылыкларның төп сәбәпләрен ачуга, холкының төрлелеген күрсәтүгә ирешә. Ф. ш.у. Гомәр, Илдар («Тамырлар», «Кошның үз канаты була», Ю.Әминев), Шаһнияз («Куендагы елан», Ә.Мирза һитов), Салават («Җыр дәвам итә», Х.Сафина), Арслан («Һәйкәл», Ә.Баян), Наил («Ана йөрәге», С.Кайтов), Сәлим, Шәрәф («Зөһрә йолдыз», «Уракчы кыз», С.Шәкүров), Добротин («Мария», А.Д.Салынский), Ата («Бусага төбендә», А.А.Дударев), Алексей («Хәтер», З.Шаһираторов), Посәт («Кара бүре», Н.Арбан) һ.б. рольләр башкара. 3 нче дәрәҗә Дан ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: Гыймранова Д. Сабир Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт драма театры. К., 2007. *Д.Ә.Гыймранова.*

ФӘСХЕТДИ́НОВ Габдулла Канәфи улы (23.6.1932, Ташкент), спортчы, тренер (парашют спорты), СССРның спорт остасы (1962), Үзбәк ССРның атказ. тренеры (1970). Ташкент аэроклубында тәрбияләнә. 1968 елда СССР ДОСААФның берләштерелгән очу-техник мәктәп үзәген (Калуга ш.) тәмамлый. Парашют б-н җиргә төгәл төшү буенча 4 тапкыр дөнья рекордчысы (1962; 2000, 1500 һәм 1000 *м* биеклектән көндез һәм төнлә төркемләп сикерү). 1948–51 дә авиатехник, 1955–78 дә Респ-ка аэроклубында (Ташкент) очучы-инструктор, башлык; 1980–86 да БАССРның ДОСААФ авиация бүлеге башлыгы. Медальләр б-н бүләкләнә.

ФӘСХЕТДИ́НОВ Гыйлаҗ Фәсхетдин улы (1899, Вятка губ., Алабуга өязе Бондюг а. — 9.5. 1938, Казан), яшьләр хәрәкәте эшлеклесе. Бондюг авылында Мөселман яшьләре түгәрәген оештыручыларның берсе (1917). 1918 елда РКСМның Казан губерна ком-ты Мөселманнар бюросы җитәкчесе. 1918–21 дә РКСМның Татарстан өлкә ком-тында бүлек мөдире. 1921–22 дә РЛКСМ ҮКның Себер бюросында татар-кыргыз бюросы секретаре, РЛКСМ ҮКнда Яшьләр коммунистик интернационалы мөдире, 1922 дә РКСМның Татарстан өлкә ком-ты секретаре. 1922–28 дә ТАССР Хезмәт халык комис-тында бүлек мөдире, профсоюзларның Татарстан Советы секретаре. 1933 тән Казанда хуҗалык эшендә. 1936 да «милләтчел Солтангалиевчеләр төркеме җитәкчесе» буларак кулга алына, 1938 дә атып үтерелә; үлгәннән соң аклана.

ФӘСХЕТДИ́НОВ Ибраһим Канәфи улы (7.2.1940, Ташкент), спортчы (парашют спорты), СССРның спорт остасы (1964), Үзбәкстан ССРның атказ. тренеры (1972). Фирганә пед. ин-тын тәмамлый (1974). Ташкент аэроклубында тәрбияләнә, парашют б-н җиргә төгәл төшү буенча 6 тапкыр дөнья рекордчысы (1964–65, 600 һәм 1500 *м* биеклектән көндез һәм төнлә төркемләп сикерү һәм 1000, 1500, 2000 *м* биеклектән катнаш көндезге төркемләп сикерү). 1958–62 елларда Ташкент кинотехникумы киномеханигы. 1962–86 да Сов. армиясендә хезмәт итә. Медальләр б-н бүләкләнә.

ФӘСХЕТДИ́НОВ Ирек Абзалетдин улы (19.10.1960, Ульянов ш.), спортчы, тренер (туплы хоккей, чирәмдә туплы хоккей), СССРның атказ. спорт остасы (1988). «Труд» ирекле спорт җәмгыятендә тәрбияләнә (Ульянов ш.). Туплы хоккей буенча команда со ставында уйный: «Волга» (Ульянов, 1977–81; 1977–79; ш.у. чирәмдә туплы хоккей буенча), «Зоркий» (Красногорск, 1982–83, 1984–91), «СКА» (Свердловск, 1983–84), «Хаммарбю» (1991), «Транос Бойс» (Швейция, 1991–97). Дөнья чемпионы (1985, 1989, 1991), СССР (1983, 1985, 1991 — көмеш; 1987, 1989 — бронза), дөнья (1987 — бронза) чемпионатларында медальләр ала. Швециянең «Транос Бойс» (1997–2000) һәм «Йерхаги» (2000–01) командаларында тренер; «Ракета» (Казан, 2001–02) командасында баш тренер.

ФӘСХЕТДИ́НОВ Фәһим Нуретдин улы (25.1.1944, Апас р-ны Аюкөйдергән а.), скульптор, график, бизәүче, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1996). Татарстан респ-ка мәдәни-агарту уч-щесен тәмамлый (Алабуга ш., 1968). 1974–2004 елларда Татарстан сәнгать фондында эшли. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1992). Ф. Татарстан Респ-касының станлы, монументаль һәм монументаль-бизәлеш скульптурасы үсешенә өлеш кертә, үзенчәлекле стилистика, образларның милли чагылышы б-н аерылып торган әсәрләр иҗат итә: Балтач посёлогындагы Г. Тукай һәм Апас авылында «Хатын-кыз-ана» һәйкәлләре (1994), Татар филармониясендә Ш.Усмановка (1977), Һ.Такташка (1982), Г.Тукайга (1997) С.Максудига (1999) куелган бюстлар, Г.Камал исем. Татар акад. театрында «Татар мәдәниятенең бөек эшлеклеләре» сериясе (Ф.Әмирхан, Ф.Бурнаш, Н.Исәнбәт, К.Тинчурин, М.Фәйзи һ.б., 1990 еллар), ТР Милли китапханәсендә мәшһүр татар әдәбияты вәкилләренең рельефлы портретлары (Кол Гали, Сәйф Сараи, Дәрдемәнд, Һ.Такташ, М.Җәлил һ.б., 1998–99), «Г.Тукай» композициясе (1986), «Онытма» триптихы (1994), «Игезәкләр» вак пластикасы (1980) һ.б. Казанның җәмәгать биналарын: «Казан» ресторан һәм кунакханә комплексын (1984), «Бегемот» ресторан-бар фасадын (1985), «Пиццерия» кафесы фасадын һәм интерьерын (гипска уеп бизәк төшерү, 1987) һ.б.ны бизәүдә катнаша. Казан «Агитплакат» оставанәсенең сәяси плакатлар сериясе авторы (1970 еллар). 1980 нән төбәк, Респ-ка «Зур Идел» (1984–2004) күргәзмәләрендә катна-



Ф.Н.Фәсхетдинов. «Г.Тукай». Шамот. ТР Милли китапханәсе. 1998–99.

ша, Казанда шәхси күргәзмәләре (1984, 1994, кызы Л.Фәсхетдинова б-н, 2000) үткәрелә. Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәгендә саклана. Яшь рәссамнарның Бөтенсоюз конкурсы лауреаты (Мәскәү, 1978).

Әд.: Муллануров а Р. Ташлардан да саркып моң чыга... // Сөембикә. 1993. № 8; Художники Татарстана: Справ. К., 2011.

Г.Ф. Вәлиева-Сөләйманова.

ФӘСХИ́ЕВ Тәлгать Бәдретдин улы (28.8.1938, Әлмәт р-ны Сөлә а.), нефтьче, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1985), ТРның атказ. нефтьчесе (1993). Бораулау эшләре



Ә.Ә. Фәткуллин.

буенча кадрлар әзерләү мәктәбен тәмамлый (1968). Хезмәт эшчәнлеген «Узбекшахтастрой»ның 4 тресты Ангрен төзелеш идарәсендә эшче булып башлый. 1962–96 елларда «Татнефть» АҖнең «Җәлилнефть» НГДУында скважиналарны җир астында һәм капиталь ремонтлауга әзерләү буенча оператор, скважиналарны җир астында ремонтлау буенча оператор ярдәмчесе, оператор, мастер. Дәүләт бүләге нефть тармагы үсешенә шәхси өлеш керткәне өчен бирелә. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

ФӘТВӘ́ (гарәп. فتـــــه — аңлатма), теге яки бу гамәлнең яки күренешнең шәригать кагыйдәләренә туры килүе турында дини-хокукый нәтиҗә. Ислам урнашуның әүвәлге елларында Ф. тәкъва хәлифәләр (Әбү Бәкер әс-Сит дыйк, 632–34; Гомәр бине Хаттаб, 634–44; Госман бине Гаффан, 644–56; Гали бине Әбү Талиб, 656–61) тарафыннан чыгарыла. Соңга таба моның белән абруйлы дин-хокук белгечләре — фәкыйһьлар шөгыльләнә башлый. Хокукый мәсьәләләрне хәл иткәндә куллану өчен, Ф.лар махсус аерым җыентыкларга туплана. Аеруча билгеле булган җыентыклар әл-Мәрәвәруди, Ибне Рөшд, әл-Мәргыйнани (11–12 йөзләр башы) тарафыннан төзелә. Хәзерге Ф.лар казый яки аерым кешеләр һ.б. соравына җавап рәвешендә, нигездә, Диния нәзарәтләре, мөфти яки фәкыйһьлар тарафыннан бастырып чыгарыла.

Әд.: Маргинани Б. Хидоя: Комментарии мусульманского права: В 2 ч. М., 2010; Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

ФӘТКУ́ЛЛИН Әнвәр Әсәдулла улы (5.8.1922, БАССРның Иске Бүздәк а. — 12.12.1986, Украина ССР, Волынь өлкәсенең Луцк ш.), Сов. Союзы Герое (10.4.1945), гв. полковнигы. Свердловск очучылар хәрби авиация мәктәбен (1942), Офицерларның югары очу-тактик курсларын (1950), Авиация полклары командирларының үзәк очу-тактик курсларын тәмамлый (1956). 1941 елдан Кызыл Армия сафларында. 1942 нең октябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 140 нчы штурм авиациясе полкында эскадрилья командиры урынбасары (2 нче һава армиясе 1 нче гв. штурм авиакорпусының 8 нче гв. штурм авиациясе дивизиясе). 1945 нең гыйнварына 1 нче Украина фронтының очучылар берләшмәсе составында дошман аэродромнарына, ягулык һәм сугыш кирәк-яраклары складларына, тере көчләр һәм техника тупланган урыннарга разведка ясау һәм аларны штурмлау максаты б-н 148 сугышчан очыш ясый. 23 төркемле һава сугышында 8 дошман самолётын бәреп төшерә. Сугыштан соң СССР Хәрби Һава Көчләрендә хезмәтен дәвам итә. 1973 тән запаста, Луцк шәһәрендә эшли. Ленин ордены, ике Кызыл Байрак, Александр Невский, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

М.З.Хәбибуллин.

ФӘТКУ́ЛЛИН Илдар Фәрит улы (13.8.1953, Казан), акушер-гинеколог, мед. фән.д-ры (1997), проф.(1998), ТРның атказ. табибе (2003), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2009). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1976), шунда ук, 2 нче акушерлык һәм гинекол. кафедрасында эшли. 1993 елдан 1 нче клиник бала тудыру йорты баш табибе, 1995–2008 дә директор; бер үк вакытта Казан мед. ин-тының 2 нче акушерлык һәм гинекол. каф. мөдире; 1984–87 дә Ангола Респ-касында командировкада була. 1 нче бала тудыру йорты базасында Лазер б-н дәвалау гинекол. үзәген оештыручы һәм җитәкчесе (1991 дән). Хезмәтләре акушерлык һәм гинекол. операцияләр вакытында лазер куллануга карый (операциядән соңгы катлауларны кисәтү, тукымаларны лазер ярдәмендә ялгау). Россия акушерлар һәм гинекологлар ассоциациясенең Респ-ка бүлеге рәисе (2001 дән). Уйлап табуга авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Наследственные и приобретённые дефекты системы гемостаза в акушерско-гинекологической практике. М., 2002 (автордаш); Экспериментально-клиническое обоснование применения Nd: YAG-лазера при операциях на матке // Лазерная медицина. 2006. Т. 10, № 3 (автордаш); Кесарево сечение. М., 2007 (автордаш).

Әд.: Казанский государственный медицинский университет (1804 — 2004): Заведующие кафедрами и профессора: Биогр. словарь. К., 2004.

ФӘТКУ́ЛЛИН Камил Мәхмүт улы (1.7.1957, Ташкент), спортчы (грек-рим көрәше), СССРның атказ. спорт остасы (1980). «Буревестник» ирекле спорт җәмгыятендә тәрбияләнә (Ташкент); тренеры — М.Аблаев. Европа (1976), СССР (1977, 1979, 1983) чемпионатларында, 7 нче һәм 8 нче СССР халыклары спартакиадаларында (1979, 1983), «Дружба-84» уеннарында җиңүче, Дөнья кубогы иясе (1984), СССР (1978 — көмеш, 1981 — бронза), Европа (1977 — көмеш), дөнья (1977, 1979, 1983 — көмеш) чемпионатларында медальләр ала. 1985 елдан тренерлык эшендә, 1991–2009 Үзбәкстан милли җыелма командасында баш тренер. Үзбәкстан Респ-касының Дуслык, Хезмәт Даны орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

ФӘТКУ́ЛЛИН Марс Нургали улы (14.5.1939, Будённый р-ны Иске Шәймерза а. — 15.4.2003, Мәскәү), физик, физика-матем. фән. д-ры (1978), проф. (1988). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1961), СССР ФАнең Җир магнетизмы, ионосфера һәм радио дулкыннары таралуы ин-тында (Мәскәү өлкәсенең Троицк ш.) эшли, 1990 елдан бертөрле булмаган ионосфера физикасы лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре ионлашкан сфера физикасына, физик процесслар модельләштерүгә һәм кыска дулкыннарның ионлашкан сферада таралуына карый. 1967–68 дә Ф. Космонавтлар әзерләү үзәгендә махсус сайлаудан узып СССР ФА галимнәреннән космонавтлыкка кандидатлар төркеменә кертелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Эмпирические модели среднеширотной ионосферы. М., 1981 (автордаш); Распространение радиоволн в многомасштабной неоднородной ионосфере. М., 1990 (автордаш).

Әд.: Советские и российские космонвты, 1960–2000. М., 2001; Памяти М. Фаткуллина // Новости космонавтики. 2003. № 6.

Р.Г. Усманов.

ФӘТКУ́ЛЛИН Махиян Фатих улы (25.4.1928, БАССРның Краснокама р-ны Яңа Актанышбаш а.), философ, филос. фән. д-ры (1999). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1951), Теләче р-ны Янсуар авылы мәктәбендә эшли. 1953–64 елларда Казан химия-технол. (1954 кә кадәр), Казан төзүче инженерлар (1957 дән), Казан авиация (1962 дән) ин-тларында укыта. 1964 тән Уфа авиация ин-тында. 1970 тән Мәскәүдә: ВЛКСМ ҮК каршындагы Югары комсомол мәктәбенең конкрет социол. тикшеренүләр лаб-ясендә; 1974–99 да Югары мәктәп проблемалары фәнни-тикшеренү ин-тында (1990 нан Югары белем бирү фәнни-тикшеренү ин-ты) эшли. Хезмәтләре онтология һәм танып-белү теориясендә, социаль филос., пед. һәм югары белем проблемаларына карый. Медальләр белән бүләкләнә.

Х е з м.: Воспитание специалиста. К., 1990; Основы концепции биографической детерминации творческой активности человека: В 4 ч. М., 1999.

ФӘТКУ́ЛЛИН Наил Фидаил улы (10.12.1954, Яшел Үзән ш.), физик, физика-матем. фән. д-ры (1995), проф. (2000). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1977), шунда ук эшли, молекуляр физика каф. профессоры (1988 нән). Хезмәтләре спин кайтавазы теориясенә, спин-челтәрле релаксациягә; полимер эретемнәре динамикасына карый. Ф. магнит кырының импульс градиентлы спин кайтавазы алымы белән нейтроннар чәчелеше арасында аналогия билгели. Полимер системалардагы спин кайтавазының квант-статик теориясен, полимер эретемнәрдәге спин диффузиясе теориясен, эләктерелгән полимер эретемнәрдәге спин-челтәрле релаксация теориясен эшли. ТР Дәүләт бүләгә «Катлаулы молекуляр системалар динамикасын һәм структурасын тикшерүдә градиентлы төш-магнит резонансы үсеше» исемле хезмәтләр циклында катнашканы өчен бирелә (2008).

Х е з м.: Theory of stimulated spin echo in polymer systems // Journ. of Experimental and Theoretical Physics. 1991. V. 72, № 3; Theory of field-gradient NMR diffusometry of polymer segment displacements in the tube-reptation model // Physical Review E. 1995. V. 52, № 3 (автордаш); Polymer Chain Dynamics and NMR // Advances in Polymer Science. 2004. V. 170 (автордаш).

ФӘТКУ́ЛЛИН Рөстәм Мөгыйн улы (1.4.1940, Оренбург өлкәсенең Октябрь р-ны Биккол а.), график, нәкышьче, гамәли-бизәлеш сәнгате рәссамы, педагог. Түбән Тагил пед. ин-тының сәнгать-графика ф-тын тәмамлый (1968). 1970 елдан Уфада: 1976 дан Башкорт дәүләт пед. ин-тында (хәзер М. Акмулла исем. Башкорт дәүләт пед ун-ты),

1976–81, 1987–90 елларда сәнгать-графика бүлеге деканы, 1981–83 тә сынлы сәнгать каф. мөдире. 1985–87 дә РСФСР Рәссамнар берлеге Сәнгать фондының Башкортстан бүлеге директоры. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1997).

Ф. — басма графика остасы (линогравюра, офорт, акватинта, тушь), «Оренбург шәле» (1968), «Татар язучылары портретлары» (Г.Тукай, М.Җәлил, М.Кәрим, М.Гафури, Акмулла, 1982), станлы сериялəре «Авылым» (1968–91), «Бабам өе» (1970), «Яз» (1980), «Тракторчы» (1984) рәсемнəре, пейзаж, портрет жанрындагы акварельлəр («Хатыным портреты», 1975), китап һəм газета иллюстрацияләре авторы, 1990 еллардан агачка уеп бизəк ясау һəм скульптура сәнгатенә мөрәҗәгать итә, тоныкландыру, балавыз һəм лак белəн каплау ысулларын куллана. Тематик жанрдагы дивари һəм күләмле-фəзаи композицияләр, символик-аллегорик образлар барлыкка китерə: «Су юллары» (1994) диптихы, «Хəзрəт», «Тəңре» (икесе дə — 1998), «Тукай иле» сериясе («Кырлай», «Шагыйрь» һ.б., барысы 30 га якын эш. 1994–96), «Рудольф Нуриев» («Парлы очыш», «Күтəрү» һ.б.; 1990–97), «Пушкиниана» («Эпиграмма», «Музалар» һ.б.; 1998). Уеп ясалган эшләрендə Ф. татар мифологиясен, фольклорын, Шəрекъ сюжетларын үзенчə аңлата: «Гасыр тузаны», «Курай моңы», «Нəфисə» (барысы да — 2006), «Пар ат», «Мең дə бер кичə» (икесе дə — 2008), «Шүрəле» (2011) һ.б. Аның композицияләре нəфис формалары б-н аерылып тора; Ф.ның уеп ясалган үтə күренмəле челтəрləре кайвакыт көзгеләр б-н тулыландырыла («Шəмаил», «Вена урманы əкиятлəре» декоратив ширмасы, 1990 еллар һ.б.). Агачтан рельефлы дивар көзгеләре, трюмолар ясый («Мəктəп», 1999; «Əңгəмə», 2000; «Күкләрдə», 2007; «Умырзая», 2010).

1968 дəн күргəзмəләрдə төбəк — «Социалистик Урал» (Уфа, 1974), «Зур Урал осталары» (Курган, 1998) күргəзмəләрендə, бөтенроссия педагог рəссамнар күргəзмəләрендə (Мəскəү, 1977, 1987), төбəкара бөтентатар «Татарт» күргəзмəсендə (С.-Петербург-Казан, 1991), «Шүрəле һəм Мин» күргəзмəсендə (Казан, 2011) катнаша. Шəхси күргəзмəләре Уфада (1996–2000, 2010, 2011, 2017), Мəскəүдə (2002), Нефте Камскида (2005), Казанда (2007), Бөредə (2009) уза.

Картиналары Башкортстан Респ-касы М.В.Нестеров исем. Башкорт Дəүлəт сәнгать музеенда, «Урал» галереясында (Уфа), «Казан» милли мəдəният үзəгендə, Бөтенроссия гамəли-бизəлеш һəм халык сәнгате музеенда (Мəскəү) һ.б. саклана.

Əд.: Ахмерова К. Богат талантами Урал // Рампа. 1998. № 12; Рустям Фаткуллин // Тулпар. 1999. № 5; Фенина Э.П. Художники Башкортостана. XX век. Уфа, 2002; Янбухтина А. Художественный дуэт // Рампа. 2002. № 12.

Г.Ф. Вəлиева-Сөләйманова.

ФӘТКУ́ЛЛИН Фəрит Мөхəммəт җан улы (17.3.1914, Казан — 27.7.1942), Сов. Союзы Герое (20.11.1941), капитан. Сталинград очучылар хəрби авиация мəктəбен тəмамлый (1934). 1931–32 елларда «Заря» Казан конditер ф-касында эшли. 1932 дəн Кызыл Армия сафларында. Совет-фин сугышында катнаша. 1941 нең июненнəн Бөек Ватан сугышы фронтларында, 44 нче истребительләр авиациясе дивизиясендə эскадрилья командиры (6 нчы армия). 1941 нең октябренə Көньяк-көнбатыш фронт очучылары составында 42 сугышчан очыш ясый, дошман аэродромнарындагы 17 самолётны юк итə. 1942 нең җəендə Сталинград янындагы һава сугышында дошманның 2 самолётын бəреп төшерə. 1942 нең 27 июлендə дошманның 3 самолётын бəреп төшерə һəм һава сугышында һəлак була. Ленин ордены, Кызыл Йолдыз ордены б-н бүләкләнə. Казандагы бер урам Ф. исемен йөртə.

Əд.: Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

М.З.Хəбибуллин.

ФӘТКУ́ЛЛИН Фəрит Хəсбиулла улы (6.6.1920, Казан – 28.3.2017, шунда ук), хирург, сəламəтлек саклау өлкəсе эшлеклесе, ТАССРның атказ. табибе (1966). Казан мед. ин-тын тəмамлаганнан соң (1952), Казан шəһəре Дзержинский р-нының сəламəтлек саклау бүлеге мөдире булып эшли, бер үк вакытта 7 нче шəһəр хастаханəсендə табиб-хирург. 1956–82 елларда ТАССР сəламəтлек саклау министры урынбасары, 1984–97 дə Респ-ка мед. профилактикасы үзəге методика кабинеты мөдире. Хезмəтləре Татарстанда сəламəтлек саклау тармагының барлыкка килүе һəм үсешен өйрəнүгə, дəвалау-физкультура эшчəнлеген оештыру мəсьəлələренə карый. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дəрəҗə Ватан сугышы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнə.

Хезм.: Успехи и перспективы развития здравоохранения Татарии // Казан. мед. журн. 1969. № 3; Организация борьбы с трахомой в ТАССР // Казан. мед. журн. 1970. № 4 (автордаш); Некоторые итоги и задачи борьбы с туберкулёзом в Татарской АССР // Казан. мед. журн. 1977. № 2.

Əд.: Павлухин Я.Г. История медицины Татарстана в лицах. К., 1997.

ФӘТКУ́ЛЛИН Фидаи Нургали улы (1.1.1931, Чүпрəле р-ны Иске Шəйморза а. — 26.11.2000, Казан), хокук белгече, юридик фəн. д-ры (1966), проф. (1968), ТАССРның атказ.фəн эшлеклесе (1979). Казан ун-тын тəмамлый (1953). 1947–49 елларда Будённый р-ны халык мəхкəмəсе секретаре һəм мəхкəмə башкаручысы. 1956–59 да Бөтенсоюз читтəн торып уку юридик ин-тының Иваново ф-лында укытучы. 1959–88 дə Казан ун-тында: 1962–65 тə юридик ф-ты деканы, 1967–75 тə җинаять эшləре процессы һəм криминалистика, 1975 тəн дəүлəт һəм хокук теориясе һəм тарихы каф. мөдире. 1988–93 тə Казан пед. ин-тының политология һəм социология каф. профессоры. 1994–98 дə Казан финанс-икътисад ин-тының хокук каф. мөдире. 1998 дəн Казан социаль-юридик ин-тының гражданлык-хокук дисциплиналары каф. мөдире. «Татарстанда милли дəүлəтчелек тарихы» («История национальной государственности в Татарии», 1982) уку ярдəмлеге авторларының һəм мөхəррирлəренең берсе. Хезмəтləре җинаять хокукы һəм процессына, дəүлəт һəм хокук теориясенə, хокук белеме мəсь əлəлəренə карый.



Ф.М. Фəткуллин.



А.Н. Фəттах.

Хезм.: Обвинение и изменение его в суде. К., 1963; Изменение обвинения. М., 1971; Общие проблемы процессуального доказывания. К., 1973; Проблемы общей теории социалистической правовой надстройки. К., 1980.

Əд.: Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3; Багаутдинов Ф.Н. Школа профессора Фаткуллина. К., 2009.

Е.Б.Долгов.

ФӘТТА́Х (Фəттахетдинов) (псевд. — Азон Фəттах, Əгъзам Фəттах) Азантин Нуретдин улы (6.9.1923 (башка чыганаклар буенча 1.4.1922), Тəтеш кантоны Шəмəк а. — 12.3.2013, Мəскəү), композитор, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1983). 1952 елда Мəскəүдə Гнесиннар исем. Музыка-пед. ин-тының тарих-теория ф-тын (Г.Литинский классы) тəмамлый (М.Гнесинда да шөгыльләнə). 1952–54 тə Казан музыка уч-щесендə укыта, 1954–60 та «Музгиз» нəшрияты (Мəскəү) хезмəткəре. Муз.-сəхнə, инструменталь (ш.и. эстрада-симф. оркестр һəм электромузыка уен кораллары ансамбльləре өчен) əсəрләр; «Колумб» шхунасындагы юнга» («Юнга со шхуны «Колумб», 1963), «Мальчиш-Кибальчиш турында əкият» («Сказка о Мальчише-Кибальчише», В.Рубин б-н берлектə, 1964), «Су төбендəге акваланглар» («Акваланги на дне», реж. Е.Шерстобитов, 1965) кинофильмнарына (барысы да — А.Довженко исем. киностудиядə) музыка; татар халык җырлары эшкəртмələре һ.б. авторы. О.Фокина, Ə.Ерикəй, С.Хəким һ.б.ның шигырьləренə язылган җырлар Ф. иҗатында аеруча мөһим урын алып тора. Ф.ның В.Семернин шигырьləренə язылган «Колыбельная», «Лебеди-берёзы», «Хороши вечера на Оби» җырлары танылган эстрада җырчылары (Г.Великанова, А.Иошпе, И.Бржевская, М.Суворова һ.б.) башкаруында аеруча популярлык казана.

Əд.: Забавских Э. Улыбчивая музыка // Советская музыка. 1975. № 7; Викторов В. Воспитание искусством // Дошкольное воспитание. 1978. № 12.

ФӘТТА́Х Нурихан Садрилмəн улы (25.10.1928, БАССРның Яңавыл р-ны Күчтавыл а. – 18.2.2004, Казан), язучы, ТРның халык язучысы (1998), РСФСРның атказ. мəдəният хезмəткəре (1978). Казан ун-тын тəмамлый (1951). 1953 тəн Казанда. Беренче романы — студентлар тормышына багышланган «Сезнеңчə ничек?» (1957) əсəрендə үк Ф. үзен өлгергəн əдип, психол. анализ остасы буларак таныта. «Əттə» (1956), «Буранда», «Бер тамчы күз яше» (икесе дə — 1958), «Мəдинə» (1960), «Лəйлə» (1964) хикəяləрендə, «Мөдир Са җидə» (1968) повестенда язучы



Н.С. Фәттах.



Л.Ә. Фәттахов.

яшь кешеләрнең тормышта үз урыннарын ничек эзләүләрен күрсәтә.

1950 елларда Ф. Казакъстанда чирәм, ят кын җирләрне күтәрүдә катнаша. Шуларның нәтиҗәсе буларак, әдипнең «Бала күңеле далада» романы языла (1962). Анда Ф. татар прозасында беренчелердән булып замандаш шәхесен яңача ачып бирә. «Идеаль» герой концепциясеннән баш тартып, ул аны бөтен катлаулыгы һәм каршылыгы б-н, реаль чынбарлык контекстында күрсәтә. Антропоморфизм алымын куллану да татар романы өчен яңалык була: Ф. даланың җанландырылган образын тудыра, кеше б-н табигатьнең аерылгысызлыгын, әйләнә-тирә дөньяның нәзберекләгән чагылдыра.

«Кырык дүртнең май аенда» (1965) повесте һәм «Кичү» романы (1978; 1990 да басыла) Ф. иҗатында аерым урын билиләр. Автор татар авылы тормышы мисалында соц. җәмгыять системасының үсә баручы рухи кризисын гәүдәләндерә. Аларда татар теле язмышы өчен борчылу да ачык чагыла. 1950 еллар ахырында — 1960 еллар башында Ф. актив рәвештә фәнни экспедицияләрдә катнаша, тарихи һәм этнографик материалларны, елъязмаларны җыя һәм өйрәнә, тарихчылар б-н аралаша, тарихи вакыйгалар булган урыннарга сәяхәт кыла. «Элекке һәм хәзерге Болгар» («Татарстан яшьләре», 1956, 15 июль), «Болгарга сәяхәт» («Совет Татарстаны», 1956, 8 авг.), «Археологик экспедиция» («Совет Татарстаны», 1957, 3 сент.) һ.б. мәкаләләрендә милли тарихның аерым сәхифәләрен яңадан тергезә, аларга җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итә. Милли тарихка булган кызыксыну Ф.ның алдагы бөтен иҗатын билгели. 1969 да аның «Итил суы ака торур» романы басылып чыга, анда Идел буе Болгар дәүләтенең оешу дәвере, 10 йөз башында ислам кабул итү сәнгатьчә яктыртыла. Борынгы бабаларның яшәү рәвешен, гореф-гадәтләрен һәм йолаларын тасвирлаганда, Ф. шактый гына этнографик детальләр куллана. Аның сәнгатьчә сурәтләү алымының төп үзенчәлеге мифларга мөрәҗәгать итү, фольклор материалыннан, борынгы төрки тел лексикасы элементларыннан файдалану тәшкил итә. Борынгырак дәверләрне (б.э.к. 3–2 йөзләр) үз эченә алган «Сызгыра торган уклар» роман-дилогиясендә һуннар тормышы, аларның социаль хәле, матди көнкүреше һәм рухи-әхлакый яшәеше тасвирлана. Автор хикәяләүне бай этнографик материал (туй, корбан чалу йоласы) б-н тулыландыра. Геройларның үзара мөнәсәбәтләрен, аларның табигать б-н аерылгысыз булуын романтик буяулар б-н тасвирлый. Фидакарь мәхәббәт һәм тугрылык үрнәге буларак, хатын-кыз персонажлар аеруча ачык сурәтләнә.

«Кол Гали» трагедиясе (1972; 1974 тә куела) үзәгендә — шагыйрь һәм хакимият, шагыйрь һәм халык арасындагы мөнәсәбәтләр. Ф. сарайдагыларның астыртын эшләре һәм якыннарының хыянәте аркасында корбан булган геройның фажигасен күрсәтеп бирә. Ф.ның иҗади эшчәнлегенең тагын бер мөһим юнәлеше — төрки халыкларның, ш.и. татарларның килеп чыгышы, тарихы һәм теле өлкәсендә фәнни тикшеренүләр. Шуларның нәтиҗәләре буларак, «Фест дисбесенең сере» (1986), «Шәҗәрә» (1991), «Аллалар һәм фиргавеннәр теле» («Язык богов и фараонов», 1999) хезмәтләре дөнья күрә. Аларда төрки халыклар һәм телләр, Атлантида, Мисыр пирамидалары турында (соңгы хезмәтендә) сүз бара. ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1994).

Әсәр.: Язык богов и фараонов. К., 1999; Сайланма әсәрләр — Избранные произведения: 5 томда. К., 2002; Аклан. К., 2009.

Әд.: Нәҗипова-Зиннәтуллина Ә. Нурихан Фәттах: тормышы һәм эшчәнлеге. К., 2004; Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2. *Ә.Н.Нәҗипова-Зиннәтуллина.*

ФӘТТА́ХОВ Вәсил Вәли улы (24.3.1951, Чирмешән р-ны Югары Кәминкә а.), хирург, мед. фән. д-ры (2000), проф. (2002). Казан мед. ин-тын тәмамлый (1974). 1975 елдан Респ-ка онкология диспансеры табиб-хирургы. 1978–91дә Казан ГИДУВында: оператив хирургия һәм топографик анатомия кафедрасында, хирургия ф-ты деканы урынбасары (1986–91). 1993–1997дә РФ Сәламәтлек саклау министрлыгының Респ-ка катастрофалар медицинасы үзәгендә тернәкләндерү буенча директор урынбасары, ТР Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының тернәкләндерү клиникасы мөдире. 1997–2005 тә ТР Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Респ-ка тернәкләндерү үзәге директоры, бер үк вакытта Казан мед. академиясенең катастрофалар медицинасы кафедрасы каршындагы тергезү медицинасы курсы мөдире. 2005 тән РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы Социаль белем бирү академиясенең тергезү медицинасы каф. мөдире, 2008 дән Казан мед. академиясенең клиник анатомия һәм амбулатория-поликлиника хирургиясе каф. мөдире. Ф. экстремаль факторлар тәэсирендә кан микроциркуляциясе бозылу механизмнарын өйрәнә; нур ярдәмендә диагноз кую, коррекцияләү һәм авырулар ны тернәкләндерү ысулларын эшли. Россия табигыять фәннәре академиясенең (2000), Европа табигыять фәннәре академиясенең (2003) хакыйкый әгъзасы. Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы бүләге (2000); энергия-мәгълүмат фәннәре өлкәсендәге казанышлары һәм фәнгә керткән яңалыклары өчен РФАнең В.Вернадский исем. бүләге (2004) лауреаты. Медальләр б-н, ш.и. Россия табигыять фәннәре академиясенең акад. И.П.Павлов исем. көмеш медале б-н бүләкләнә (2001).

Хезм.: Кишечный шов: Учеб. пособие. Л., 1984 (автордаш); Медико-психологическая поддержка и амбулаторная реабилитация спасателей: Учеб. пособие. К., 2002 (автордаш); Обтурационная асфиксия. Пути спасения: Пособие для врачей. К., 2003.

ФӘТТА́ХОВ Илдар Барый улы (1.2.1946, Казан), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, техник фән. д-ры (2004). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый (1975). 1965–77 елларда Куйбышев исем. Казан химия з-дында: 1968 дән инженер, 1973 тән лаб. башлыгы. 1977–80 дә Казанда КПССның Мәскәү район ком-тында инструктор, 1980–86 да бүлек мөдире, 1986–87 дә секретарь, 1990–91 дә 1 нче секретарь. 1987–90 да КПССның Казан шәһәр ком-ты бүлек мөдире. 1991–92 дә Казан «Татхимфармпрепаратлар» ҖБнең ген. директоры урынбасары. 1992–96 да Казан шәһәре Мәскәү р-ны хакимияте башлыгы. 1996–2001 дә ТР Премьер-министры урынбасары. Бер үк вакытта, 1996–98 дә, ТР Дәүләт милке б-н идарә итү дәүләт ком-ты рәисе, 1998–2005 тә ТР МК аппараты җитәкчесе. 2005–10 да «Связьинвестнефтехим» АҖ ген. директорының 1 нче урынбасары. Хезмәтләре табигатьтән рациональ файдалану ны җайга салу, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм экологик куркынычсызлык мәсьәләләренә карый. 1992–95 тә ТР ЮС депутаты. 1995–97 дә ТРның халык депутаты. Дуслык ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: Выпускники — гордость Казанского технологического университета: Краткий биогр. справ. К., 2009. *Е.Б.Долгов.*

ФӘТТА́ХОВ Лотфулла Әбделмән улы (27.9.1918, Түбән Новгород губ., Сергач өязе Анда а. — 17.6.1981, Казан), нәкышьче, график, ТАССРның һәм РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1957, 1957), РСФСРның халык рәссамы (1980). Беренче рәсемнәре һәм хикәяләре «Пионер каләме» ж-лында басыла (1930 еллар). 1931 елдан Казанда. Казан сынлы сәнгать уч-щесен тәмамлый (1939). Совет-фин һәм Бөек Ватан сугышларында катнаша: немец әсирлегенә эләгә, Линген үлем лагереннан кача, Франциядә Каршылык хәрәкәтендә катнаша. 1946 да Казанга кайта. СССР Рәссамнар берлеге әгъзасы (1946), «Татхудожник» иҗат-җитештерү остаханәләрендә эшли (1953 тән Татарстан сәнгать фондында), Татарстан китап нәшрияты, «Чаян» ж-лы (1951 дән) б-н хезмәттәшлек итә. 1950–80 дә Татарстанның әйдәп баручы рәссамнарыннан берсе, тематик картина остасы. Ф.ның татар авылларына, тарихи-революцион темага багышланган әсәрләре совет сәнгате классикасына әверелә: «Сабан туе» (1957), «Яңа буралар» (1959), «Революция комиссары Мулланур Вахитов» (1964), «Совет хакимиятенең беренче елларында» (1967). Ф. соц. реализм кысаларында авылның милли-романтик образын, анда яшәүчеләрнең характерын чагылдыруга ирешә: «Татар авылында 9 нчы май иртәсе» (1947), «Ватан турында җыр» (1948), «Иген нәр өлгерде», «Рауза», «Рәхимҗан бабай» (барысы да — 1952), «Авыл почтальоны» (1954), «Галимулла абый» (1956), «Авыл» (1960) һ.б. Рәссамның күп картиналарында лирик тема чагылдырыла: «Тынгысыз яшьлек», «Яз көне» (икесе дә — 1958). Портрет жанрына да мөрәҗәгать итә, В.Ульянов,



Л.Ә.Фәттахов. 1. «Сабан туе». 1957; 2. «Яңа буралар». 1959; 3. «Күчмә лаборатория янында». 1954; 4. «Шәһәрдән кайту». Картон. Майлы буяу. 1963; 5. «Хезмәт ветераны Р.Бикмөхәммәтов портреты». 1949; 6. «Революция комиссары Мулланур Вахитов». 1964; 7. «Совет хакимиятенең беренче елларында». 1967; 8. Галимҗан Ибраһимов портреты. 1971; 9–13. Иллюстрацияләр: 9. А.Әхмәтнең «Солдат хикәяләре»нә. 1948; 10. Г.Гобәйнең «Замана балалары» китабына. Кәгазь. Кара акварель. 1948; 11. «Татар халык әкиятләре» китабына. Акварель. 1956–58; 12. «Турай батыр» татар халык әкиятенә. Кәгазь. Акварель. 1956–58; 13. «Сунарчы улы» татар халык әкиятенә. Кәгазь. Акварель. 1956–58. 1, 2, 3, 5, 6, 7, 12, 13 – ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда.



А.Г. Фәттахова.



Ф.Р. Фәттрахманов.

А.С.Пушкин, М.Горький, Г.Тукай, М.Җәлил, замандашлары, дуслары — рәссамнар Х.Якупов, К.Максимов, В.Лаптев һ.б.ны тасвирланган картиналар сериясе яза. Балалар юморы жанрында («Булышчы», 1954; «Җанатарлар», 1955; «Әни күрмәгәндә», 1956), сатирик темага («Озакка сузылган утырыш», «Яла ягучы», икесе дә — 1953) да иҗат итә. Ф.ның киң графика мирасы татар язучыларыннан К.Нәҗминең «Язгы җилләр» (1952), Г.Бәшировның «Намус» (1954), Г.Әпсәләмовның «Ак төннәр» (1965), Г.Ахуновның «Хәзинә» (1966) һ.б., ш.у. Г.Нәваиның «Фәр һәд вә Ширин» (1948), Л.Толстойның «Ха җәмират» (1953) әсәрләренә, «Мең дә бер мәзәк» (1966) җыентыгына ясалган иллюстрацияләрне, сатирик темага «Безнең хакта...» циклын (тушь, акварель) (1958); портретлар, карикатуралар, шаржлар, «Чаян» ж-лы рәсемнәрен үз эченә ала. 1947 дән респ-ка, «Зур Идел» (1964–80), РСФСР рәссамнары әсәрләре (Мәскәү, 1949–65), «Совет Россиясе» (1965), Бөтенсоюз сәнгать (1950–65) күргәзмәләрендә катнаша. 1968, 1978, 1983, 2008, 2018 дә (100 еллыгына багышлап) Казанда шәхси күргәзмәләре үткәрелә. Әсәрләре ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда, Дәүләт Шәрекъ халыклары сәнгате музеенда (Мәскәү), Чуаш сәнгать галереясында (Чабаксар) һ.б. саклана. «В.И.Ленинның Татарстан АССР төзелү турындагы декрет-ка кул куюы» (1951; Х.Г.Якупов б-н берлектә) картинасы өчен Сталин бүләгенә, «Татар халык әкиятләре» (1–2 т., 1957) китабына илл. (1958; Х.Г.Якупов б-н) өчен Г.Тукай исем. ТАССР Дәүләт бүләгенә лаек була. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр белән бүләкләнә. 2008 дә Казанның бер урамына аның исеме бирелә.

Әд.: Елькович Л. Лотфулла Фаттахов. М., 1960; Лотфулла Фаттахов // Искусство Советской Татарии. Народные художники. К., 1981; Черновная С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984; Файнберг А.Б. Лотфулла Фаттахов. К., 1990.

ФӘТТА́ХОВ Рафаэль Вәли әхмәт улы (6.1.1949, Чирмешән р-ны Югары Кәмин-кә а.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1993), проф. (1995). Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлаганнан соң (1970), шунда ук эшли. 1983 елдан РСФСР Икмәк продуктлары министрлыгының Квалификация күтәрү ин-тында, 1988–96 да РФАнең Үзәк икътисад-матем. ин-тында (Мәскәү), бүлек мөдире (1993 тән). 1997–2004 тә РФА Уфа гыйльми үзәгенең Социаль-икътисади тикшеренүләр ин-ты директоры. Бер үк вакытта, 1999 дан, «Төбәк икътисады» уку-укыту гыйльми үзәгендә, шул исемдәге каф. мөдире. Хезмәтләре төбәк икътисадын һәм проектка нигезләнеп финанслауны модельләштерү теориясе һәм методологиясенә карый.

Хезм.: Экспериментальное построение динамической модели межотраслевого баланса Татарской АССР. Н., 1979; Постановки, решения и анализ задач оценивания инвестиционных проектов в новых условиях хозяйствования. М., 1996; Крупномасштабные инвестиционные проекты: Моделирование и экономическая оценка. М., 2003 (автордаш); Государственный финансовый контроль. Системный подход. М., 2006 (автордаш).

ФӘТТА́ХОВ Рифат Әхмәт улы (17.11.1966, Горький өлкәсе Уразавыл а.), журналист, филос. фән. канд. (2005), ТРның, РФнең атказ. мәдәният хезмәткәре (2000, 2007). Казан ун-тын тәмамлый (1989). 1987–1989 елларда ТАССРның телевидение һәм радиотапшырулар Дәүләт ком-тының нәфис радиотапшырулар редакциясендә. 1990–91 дә Казан ун-тының күптиражлы «Ленинчы» г-тасы мөхәррире, 1990–98 дә вузара «*Мәгърифәт*» г-тасы баш мөхәррире, 1998–2009 да «Татарстан» ж-лы баш мөхәррире. 2009–11 дә «*Идел*» ж-лында. Язмалары иҗтимагый-сәяси мәсьәләләргә, татар мәдәнияте үсешенә, татар халык җырчысы Р.Вахапның тормышын һәм иҗатын өйрәнү һәм яктыртуга багышлана. Р.Бәһәпов исем. татар мәдәнияте иҗтимагый фонды рәисе, Р.Бәһәпов исем. халыкара татар җыры фестивален оештыручыларның берсе. Респ-каның М.Җәлил исем. бүләгә лауреаты (2005). Медаль б-н бүләкләнә.

ФӘТТА́ХОВ Рөстәм Бари улы (15.5.1957, Бөгелмә ш.), нефтьче, техник фән. канд. (1994), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2010). Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тын тәмамлаганнан соң (1980) СССР ФА Себер бүлеге Себер энергетика ин-тында эшли. 1985 елдан ТатНИПИнефтьтә: промысел коммуникацияләре һәм катлам басымын саклау системалары лаб-ясе мөдире (1998 дән). Хезмәтләре нефть чыгару процессларының экологик иминлегенә һәм энергетик нәтиҗәлелегенә карый. Дәүләт бүләге нефтьне промысел шартларында транспортлауның ышанычлылыгын арттыруга караган технологияләр комплексын тикшергәне һәм сәнәгатьтә гамәлгә керткәне өчен бирелә. Катлам басымын саклау технологияләре «Татнефть»АҖдә гамәлгә кертелгән. Уйлап табуга 95 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Учёт энергетических затрат на добычу нефти. М., 2007 (автордаш); Повышение надёжности промыслового транспорта нефти при реконструкции и эксплуатации. М., 2011 (автордаш).

ФӘТТА́ХОВ Энгель Нәвап улы (12.6.1961, Актаныш р-ны Чишмә а.), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, техник фән. канд. (1994), ТРның атказ. а.х. хезмәткәре (2002). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1983). 1983–89 елларда Актаныш р-нында: 1984–85 тә ВЛКСМның район ком-ты 2 нче секретаре, 1987 дән Җиңүнең 40 еллыгы исем. к-зда партком секретаре. 1995–97 дә Сарман р-ны хакимияте башлыгы урынбасары. 1993–95 тә, 1997–98 дә Актаныш р-ны хакимияте башлыгының беренче урынбасары, 1998–2006 да хакимият башлыгы, 2006–12 дә «Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгы. 2012–17 дә ТР мәгариф һәм фән министры. Бер үк вакытта, 2013 тән, ТР Премьер-министры урынбасары. 2017 дән Актаныш муниципаль р-ны башлыгы. Хезмәтләре агрономия мәсьәләләренә карый. 2000–04 тә ТРның халык депутаты. Медальләр б-н бүләкләнә.

ФӘТТА́ХОВ Яхъя Вәли улы (22.3.1955, Ворошилов р-ны Кадрәк а.), физик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2005), физика-матем. фән. кандидаты (1990). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1977), шунда ук эшли. 1980 елдан РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында, мед. физикасы бүлеге мөдире (2000 нән). Хезмәтләре мед. диагностикасында һәм дәвалау процессында куллану максатында яңа физик алымнарны тикшерү һәм эшләү өлкәсенә карый. Дәүләт бүләге медицинада «ТМР-0,06 — КФТИ» магнит-резонанслы томографын эшләү, ясау һәм гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә. Медаль б-н бүләкләнә.

ФӘТТА́ХОВА Ания Гарифулла кызы (6.2.1940, Минзәлә р-ны Аю а. — 10.3.2000, Түбән Кама ш.), актриса, ТРның халык артисты (1993). Алабуга мәдәни-агарту уч-щесен тәмамлаганнан соң (1960), Минзәлә татар драма театрында эшли, 1996 дан — Түбән Кама татар драма театрында. Актриса Хәят (шул исем. әсәр буенча, Ф.Әмирхан; З.Шаһиморатов инсценировкасы), Венера («Уракчы кыз», С.Шәкүров), Мәйсәрә («Зәңгәр



А.Г. Фәттахова (уртада) Җиһан ролендә («Башмагым», Х. Ибраһимов; Сәрби ролендә – В. Нигъмәтуллина, Сәрвәр – Р. Муллина).

шәл», К.Тинчурин), Җи һан, Сәрвәр («Башмагым», Х.Ибраһимов), Зөһрә («Качаклар», Н.Исәнбәт) рольләрендә мөлаем татар кызлары образларын иҗат итә. Гөлсем («Сафиулла малае», Г.Сәгыйдуллин), Зөһрә («Тапкыр егет», Д.Аппакова), Нәзифә, Тәзкирә, Са җидә («Тамырлар», «Кошның үз канаты була», «Кеше күңеле», Ю.Әминев), Исламия («Дус кызым киявгә чыга», А.Гыйләҗев) рольләрендә тормышның катлаулы мизгелләрендә югалып калмаган максатчан һәм түзем яшьтәшләре образларын оста гәүдәләндерә.

Әд.: Гыймранова Д. Сабир Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт драма театры. К., 2007.

ФӘТТА́ХОВА Наилә Нурихан кызы (5.4.1953, Чистай ш.), тел галиме, филол. фән. д-ры (2002), проф. (2007). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1975), Казан пед. ин-тында эшли, 2008 елдан хәзерге рус теле һәм аны укыту методикасы каф. мөдире, 2011 дән Казан ун-тының шул ук исем. каф. мөдире. Хезмәтләре рус һәм татар телләрен чагыштырма-типологик өйрәнү, төрле төзелешле телләрдә халык сынамышлары семантикасы һәм синтаксисы мәсьәләләренә карый. Урта мәктәпләр өчен рус теле дәреслекләре һәм уку-укыту ярдәмлекләре авторы.

Х е з м.: Семантика и синтаксис народных примет в русском и татарском языках: сопоставительный аспект. К., 2004; Современный русский язык: Морфология. Синтаксис. К., 2005 (автордаш); Народные приметы: принципы классификации, структурирования, функционирования. К., 2012.

ФӘТТРАХМА́НОВ Фердинанд Рафаэль улы (сәхнә псевд. Фердинанд Фәтхи) (5.9.1959, Арча р-ны Иске Ашыт а.), җырчы (баритон), ТРның халык артисты (2012). Казан мәдәният ин-тын тәмамлый (1982). 1982–87 елларда музыка укытучысы, 1987–90 да Иске Ашыт авыл мәдәният йорты директоры. 1990–94 тә — ТРның Дәүләт җыр һәм бию ансамбле, 1994–2003 тә Татар филармониясе солист-вокалисты. 2008 дән «Казан» милли мәдәният үзәгенең Казан шәһәр филармониясе солисты. Актив рәвештә концертлар куючы татар җыр - чыларының берсе. Ф.ның зур репертуарын татар халык көйләре, Татарстан композиторлары С.Сәйдәшев, Р.Яхин, З.Хәбибуллин, М.Мозаффаров, Н.Җиһанов, С.Садыйкова һ.б.ның вокаль әсәрләре тәшкил итә. ТР, РФ шәһәрләре, якын һәм ерак чит илләр буйлап гастрольләрдә йөри. Мәктәп укучылары өчен «Халкым җыры — моң чишмәсе» дип аталган махсус программа эшли. Халыкара «Татар җыры-95» конкурсы лауреаты.

ФӘТХЕЛКАДЫ́ЙР (19 йөзнең 2 нче яртысы — 20 йөз башы), хаттат, ташка уеп язучы. Казан өязе Мүлмә авылы мәзине. Казан арты авыллары каберлекләрендә сакланган эпи - тафияләр авторы. Кабер ташлары ясау өчен Ф. известьташ куллана, өске өлешен ярымтүгәрәк итеп эшли. «Сөлес» язу ысулы б-н башкарылган 7–9 юллык язуларны ташның алгы ягына турыпочмаклы кысага уя. Ян-яклары - на икеюллы шигырьләр яза. Алар еш кына фәлсәфи шигъри строфалар б-н тулыландырылган бай эчтәлеге б-н аерылып тора. Коръән өземтәләре 15–20% тан артмый. Орна - мент б-н бизәлеш сирәк очрый. Арча р-ны Орнашбаш авылы зиратында Ф. тарафыннан ясалган 30 дан артык кабер ташы сак-



Ф ә т х е л к а д ы й р. Кабер ташы. Уеп язу. Арча районы Орнашбаш авылы.

ланган. Кайберләрендә «Мүлмәдән мәзин Фәтхелкадыйр язды» диелгән.

М.И.Әхмәтҗанов.

ФӘТХЕТДИ́НОВ Әхсән Сарим улы (7.6.1939, Чирмешән р-ны Вагаповка пос. — 15.7.2012, Түбән Кама ш.), нәкышче, монументалист, скульптор, ТАССРның атказ. сән-



Ә.С. Ф ә т х е т д и н о в. 1. «Яшүсмерләр. Тукай оныклары». 1971–73; 2. «Тукай шигырьләре». 1976; 3. «Әти портреты». 1974; 4. «Бакча иясе». Киндер. Майлы буяу. Агач. 1991. ТР Президенты каршындагы мәдәнияткә ярдәм фондында; 5. «Кырым татарларына багышлау». Картон. Майлы буяу. Агач. 1990; 6. «Кыр батыры». Агач. Уеп бизәк төшерү. 1990 еллар.



Ә.С. Фәтхетдинов.



С.З. Фәтхетдинов.

гать эшлеклесе (1987), ТРның халык рәссамы (2001). Түбән Тагил пед уч-щесенең сәнгать-графика бүлеген тәмамлагач (1966), шунда ук рәсем буенча укыта. 1969 елдан Түбән Камада, Татарстан сәнгать фондында эшли (2000 гә кадәр). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1983). Иҗат эшчәнлеген рәссам-бизәүче, монументалист буларак башлый. «Күл» (1973), «Шүрәле» (1974, Түбән Кама шәһәре 21 нче балалар бакчасы), «Урман әкияте» (1975, «Бигеш» аэропорты) агач декоратив панноларын, «Татар моңнары» (1971, ТРның С.Сәйдәшев исем. Зур концерт залы), «Яз» (1974, Түбән Кама шәһәре 2 нче хастаханә) темпера бизәлеше һ.б. авторы. Бер үк вакыт-та индустриаль («Түбән Кама җирендә», 1973; «Кичке химкомбинат», 1974; «Шәһәр үсә», 1975) һәм лирик («Аяз көн», 1973; «Язгы яңгыр», 1975) пейзажлар, жанрлы картиналар — «Тукай шигырьләре» (1976), «Балачак хыялы» (1977) романтик сериялә ре иҗат итә. Соңрак «Шүрәле» поэмасы сюжетына («Шүрәлеләрем», «Шүрәле бусагада», «Посып торучы» һ.б., 1983–86) картиналар циклы, портретлар — «Кош белән автопортрет» (1982), «Үз-үзем белән сөйләшү» (1997), «Яшь Хәсән Туфан» (1982), «Рәссам Бакый Урманче», «М.Әгъләмов шигърияте рухы» (икесе дә — 1997) барлыкка китерә. Ф.ның сәнгатьчә тасвирлауда үзенә генә хас алымы чагылыш таба. Агачка уеп эшләнгән кысаларга урнаштырылган 60 картинадан торган «Ияләр» (1987–89) циклы ТР сәнгать үсешендә үзенчәлекле күренеш булып тора. Сурәтләү тәртибе борынгы төрки һәм татар фольклоры архетип образларына нигезләнгән («Өй иясе», «Капка иясе», «Юл иясе», «Йорт иясе», «Бичура», «Кычкыручы», «Алмагач бакчасы иясе», «Рух мо ңы» һ.б.). Ф. иҗатында агачка уеп кисү сәнгате аерым урын били: Г.Тукай әкиятләре һәм поэмалары темаларына рельефлар («Шүрәле», «Су анасы»), сәяси репрессия корбаннары истәлегенә «Җәбер ителгәннәр» (1989–91) скульптур композицияләр циклы. Эпитафия рәвешендә иҗат ителгән 60 эштән гыйбарәт «Кабер ташлары» (1988–99) циклында Р.Фәйзуллин шигырьләре файдаланыла Шәһәр (Түбән Кама, 1970–2011), респ-ка (1969 дан), төбәк «Зур Идел», 1980, 1985), бөтенроссия (монументалистларның 3 нче Бөтенроссия күргәзмәсе, Казан, 1977; РСФСР автономияле респ-калары рәссамнары күргәзмәсе, Мәскәү, 1989), төбәкара «Татарт» бөтентатар, С.-Петербург-Казан, 1990) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре Түбән Камада (1976, 1993, 2011), Казанда (1978, 1989, 1992, 1999, 2009), Будапештта (Венгрия, 1993) үткәрелә. Картиналары ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәгендә, Түбән Кама шәһәр тарихы музеенда, Габдулла Тукай музей комплексында (Яңа Кырлай а.), Россия һәм чит илләрдәге шәхси тупланмаларда саклана. 1997 дән Түбән Кама шәһәренең Г.Тукай исем. үзәк китапханәсендә әсәрләренең даими күргәзмәсе эшли. 1998 дә С.-Петербургта Ф. иҗаты турында док. фильм төшерелә. «Ияләр» циклы өчен ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге бирелә (1993). 2016 да Түбән Кама шәһәрендә Ф. музее ачыла. Түбән Кама шәһәренең мактаулы гражданы.

Әд.: Ф ә й з у л л и н Р. Нарасый хаким // Казан утлары. 1999. № 6; Ш а һ и е в а Р.Г. Әхсән Фәтхетдинов. Ахсан Фатхутдинов. Akhsan Fatkhutdin. К., 2002; Фатхутдинов Ахсан Саримович: Каталог выставки. Нижнекамск, 1976; Ахсан Фатхутдинов: Каталог выставки. Наб. Челны, 1993; К у т у й Р. В обнимку с Шурале // Казань. 2000. № 7.

Р.Г.Шаһиева.

ФӘТХЕТДИ́НОВ Дамир Хәсән улы (5.5.1933, Балык Бистәсе р-ны Тәберде Чаллысы а. — 27.6.1991, Казакъстан ССР, Кустанай ш.), геолог, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1984). Казан ун-тын тәмамлый (1956), «Севказгеология» геол. җитештерү берләшмәсендә (Кустанай) эшли, баш геолог (1974–90). Уйлап табуга авторлык таныклыгына ия. Дәүләт бүләге файдалы казылмалар чыганакларын ачуда катнашканы өчен бирелә. Медальләр, «Чыганакны беренче ачучы» билгесе б-н бүләкләнә (ике тапкыр).

ФӘТХЕТДИ́НОВ Зөфәр Мәгъсүм улы (6.11.1940, Кострома ш.), хокук белгече, юридик фән. д-ры (1982), проф. (1983), язучы. Казан ун-тын тәмамлый (1967). 1965–69 елларда Кострома шәһәре прокуратурасында тикшерүче, прокурор ярдәмчесе. 1972–80 дә СССР Дәүләт план ком-тының Планлаштыру фәнни-тикшеренү ин-тында (Мәскәү), сектор мөдире (1973–76), бүлек мөдире (1976 дан). 1980–84 тә СССР Дәүләт матди-техник тәэминат ком-тының Җитәкче хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү ин-тында хуҗалык законнары каф., 1984–91 дә Мәскәү электрон машиналар төзү ин-тында экология һәм хокук каф. мөдире. 1991 дән Мәскәү ун-тының гражданлык хокукы каф. профессоры. Бер үк вакытта, 1994–99 да, РФ Федераль Җыенының Федерация Советы рәисе урынбасары ярдәмчесе, 1998–2005 тә Казан ун-тында гражданлык хокукы һәм процессы каф. профессоры, 1999–2010 да Икътисад, идарә һәм хокук ин-тының гражданлык хокукы каф. мөдире, 2010 нан ин-т ректоры киңәшчесе (Казан). Хезмәтләре хуҗалык һәм эшмәкәрлек хокукына карый. Детектив жанрында язылган «Үлем элмәге» («Тайна стоит жизни», 1982), «Үтерүчене кем әйтер?» («Кто назовёт убийцу?», 1989), «Иске йортта үтереш» («Убийство в старом доме», 1991), «Унынчы мәет» («Десятый мертвец», 1996) повестьлары; «Куркуны җи ңеп» («Сквозь страх», М., 1991) романы һ.б., ш.у. «XX гасыр серләре» («Откровения XX века», Л., 1991), «Афоризмнар һәм максималар, яки XX гасыр серләре» («Афоризмы и максимы, или Откровения XX века».1996) китаплары авторы. СССР, РФ, ТР (1990 нан) Язучылар берлеге әгъзасы.

Х е з м.: Договор подряда между социалистическими организациями. М., 1976; Право и автоматизированная система плановых расчётов. К., 1977; Источники предпринимательского права. К., 2006 (автордаш); Правовое положение хозяйствующих субъектов естественных монополий топливно-энергетического комплекса. К., 2006 (автордаш).

Әд.: С у р к о в а Н.А. Мир права, свободы, истины в систематическом изложении мыслителя и учёного-юриста З.М. Фаткудинова. М., 2003; Ш е р г е н г Н.А., Б о р о х о в Э.А. Мировая афористика как грань развития человечества: В аспекте творчества З.М. Фаткудинова. М., 2005; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

Е.Б.Долгов.

ФӘТХЕТДИ́НОВ Салават Зәки улы (сәхнә псевд. — Салават) (10.1.1960, БАССРның Тәтешле р-ны Аксәет а.), җырчы, ТРның һәм БРның халык артисты (1995, 2019), РФнең һәм БРның атказ. артисты (2005, 2010). Казан мәдәният ин-тының режиссёрлык бүлеген тәмамлый (1989). 1977–89 елларда Башкортстан Респ-касының Тәтешле р-нында мәдәни-агарту учреждениесе б-н җитәкчелек итә, 1989–2000 дә Чаллы эксперименталь концерт берләшмәсенең концерт төркеме җитәкчесе һәм солисты, 1992 дән «Салават» җыр театрын оештыручы һәм аның җитәкчесе. 2002 дән Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тында татар театр эстрадасы каф. мөдире, 2005 тән проф. Россиядә һәм чит илләрдә актив концерт эшчәнлеге алып бара. Ф. заманча татар һәм башкорт эстрада җырларын (В.Әхмәтшин, И.Закиров, Р.Гобәйдуллин, И.Хәбибуллин, Ф.Мортазин һ.б.ның көенә; Р.Миңнуллин, Г.Зәйнашева, Ә.Нигъмәтуллин, Р.Вәлиева, Р.Чурагулов һ.б.ның шигырьләренә) башкаручы буларак киң катлау тамашачының ихтирамын казана. Концерт программалары: «Күңеленә авыр алма» (1994), «Соңгы мәхәббәт» (1995), «Мин яратам» (1996), «Сезгә илтә юлларым» (2000), «Соңлама» (2002) һ.б. Укучылары арасында җыр конкурслары лауреатлары һәм дипломантлары бар. Ф. — күп кенә татар җыры конкурслары һәм фестивальләре лауреаты. БРның Ф.Кәрим исем. бүләге (1989), ТРның М.Җәлил исем. Респ-ка бүләге (1998), ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге (2008) лауреаты. Автоузыш буенча халыкара класслы спорт остасы. БРның Бүздәк р-ны һәм ТРның Әгерҗе р-ны мактаулы гражданы. ТРның Гер спорты федерациясе президенты, Россия балалар фондының Татарстан бүлеге директоры, Казанның Йолдызлар аллеясында Ф. хөрмәтенә исемле йолдыз куелган. «Әл-Фәхр» ордены б-н бүләкләнә.

ФӘТХЕТДИ́НОВА Венера Габделхак кызы (7.7.1960, Кемерово өлкәсенең Новокузнецк ш.), тел галиме, филол. фән. д-ры (2008). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1983), шунда ук эшли; хәзерге рус теле каф. мөдире (2009 елдан). Фрибург (Швейцария, 1990–91), Шанхай (Кытай, 1995–96), Гранада (Испания, 1999–2001) шәһәрләрендә фәнни командировкаларда була. Хезмәтләре төрле төзелешле телләрдәге комплексны сүз

ясалыш берәмлекләренең чагыштырма дериватологиясенә, рус һәм татар телләре морфологиясенә карый.

Х е з м.: Комплексные единицы словообразования в русском и татарском языках. К., 2005; Словообразовательное гнездо в ментально-культурном языковом контексте // Рус. словесность. 2006. № 3; Лексико-словообразовательные гнезда параметрических прилагательных в межъязыковом сравнении. К., 2014 (автордаш); Морфология русского языка: глагол, наречие, слова категории состояния: учебно-методическое пособие для студентов-филологов. К., 2016.

ФӘТХЕТДИ́НОВА Лилия Минвәгыйзь кызы (16.10.1965, Казан), гигиенист, мед. фән. д-ры (2001). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1987), шунда ук, гигиена, мед. экологиясе курслы хезмәт медицинасы кафедрасында эшли, каф. профессоры (2005 тән), каф. мөдире (20013 тән). Хезмәт шартларының хезмәткә һәм хезмәт ияләренең сәламәтлегенә, түбән ешлыклы электромагнит тирбәлешләренең, тавышның һ.б.ның эшләүче кешенең психол. халәтенә һәм организмның иммунологик киеренкелегенә тәэсирен өйрәнә.

Х е з м.: Клинические проявления вегетативной дизрегуляции у работающих с видеодисплейными терминалами // Неврол. вестн. 2000. Т. 32, вып. 3/4 (автордаш); Индивидуальные факторы риска вегетативных нарушений у пользователей видеодисплейных терминалов // Медицина труда и промышленная экология. 2004. № 5.

ФӘТХИ́ ДЕМЬЯ́Н (тәхәллүсе, чын исеме һәм фамилиясе Фәтхетдинов Касыйм Фәтхетдин улы) (10.10.1906, Самара губ. Татар Колмаеры а. – 1943), шагыйрь. Әдәби тәхәллүсе — Демьян Бедный поэзиясе б-н мавыгу нәтиҗәсе. 1920 елларда яза башлый. 1926 дан Казанда эшчеләр ф-тында укый, бер үк вакытта «Кызыл Татарстан» г-тасы редакциясендә, аннан соң күптираҗлы газеталарда эшли. Беренче шигырьләре ил язмышына, ватандашларының тормышына багышлана. Баш геройлар — соц. җитештерү эшчеләре, крәстияннәр. Шагыйрь җәмгыятьтәге үзгәрешләргә — авылның яңарышына, яңа кеше тууга, яңалык б-н искелек көрәшенә дан җырлый («Ызансыз кырлар» поэмасы, 1929). Ф.Д. әсәрләрендә эшчеләр образлары, завод цехлары заманча рухта гәүдәләнә. «Тальян» (1929), «Бояр урманында» (1930), «Металл тавышлары» (1931) җыентыкларындагы шигырьләре образлы фикерләү, үзенчәлекле стиль б-н аерылып тора. 1930 елларда туган як табигате, гаилә һәм әхлак мәсьәләләре, ил оборонасын ныгыту ихтыяҗы, тынычлык саклауның әһәмияте турында күп яза. Ф.Д.ның төп эстетик принцибы — шигырьне сөйләм теленә якынайту. Бу үз чиратында строфика, ритмика, рифмаланыш үзгәрешләрендә чагыла. Кайвакыт халык сүзләре б-н күп мавыгу артык гадилеккә, прозаизмга, шигърият өлкәсендәге югалтуларга, ә үзен акламаган «оригинальлек» сәнгать образын катлауландыруга, язылганны кабул итү кыенлыгына китерә. Темалар һәм идеяләр өлкәсендә, сәнгатьчә сурәтләү алымнары кулланууда (риторик сораулар һәм мөрәҗәгатьләр) Һ.Такташ иҗатының йогынтысы сизелә. Бөек Ватан сугышында катнаша; 1943 тә Кантемирово авылы (Воронеж өлкәсе) янындагы сугышларның берсендә батырларча һәлак була.

Әд.: Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2. *Р.Р.Мусабәкова.*

ФӘТХИ́ЕВ Альберт Сәет улы (8.7.1937, Актаныш р-ны Такталачык а. — 20.1.1992, Казан), археограф, әдәбият белгече. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1959), шунда ук эшли, Н.И.Лобачевский исем. Фәнни китапханәдә кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегенең шәрекъ секторы мөдире. Гарәп хәрефләре б-н язылган кулъязма мирасның каталогларын һәм татар мәдәнияте эшлеклеләренең архив тасвирламаларын төзи. «Татар язучылары һәм галимнәренең кулъязмалары: КДУның Фәнни китапханәсендә туплан ган тасвирламалар (1959–1969 еллар)» («Рукописи татарских писателей и учёных: Описание поступлений в Научную библиотеку КГУ (1959–1969 гг.)», 1986) хезмәтен әзерли һәм бастыра. Әлеге хезмәттә 17 йөздә — 20 йөз башында яшәгән 130 дан артык автор кулъязмаларына тулы тасвирлама бирелә. Аның «Мәгариф учаклары һәм әдәби багланышлар» («Очаги просвещения и литературные контакты», «Казан утлары» ж-лында басыла, 1968, № 2) мәкаләсе 19–20 йөз башында татар мәдәни-агарту хәрәкәтен һәм милләтара әдәби багланышлар тарихын өйрәнүгә керткән зур өлеше булып тора.

Әд.: Г о с м а н о в М. Файдалы хезмәт // Казан утлары. 1969. № 7; Ш ә р и п о в Ә. Борынгы кулъязмалар илендә // Совет мәктәбе. 1970. № 2. *М.Г.Госманов.*

ФӘТХУЛЛА́ бине́ әл-ХӨСӘЙ́Н әл-ОРЫВИ́ (1767/68 — 10.5.1843, Казан губ., Казан өязе Югары Ары а.), дин эшлеклесе. Каргалы бистәсе (1785), Бохара (1786, 1790–94) мәдрәсәләрендә укый. 1795 елдан Югары Ары авылы мәчетендә имам-хатиб һәм мәдрәсәдә мөдәррис, бер үк вакытта, 1814 тән, Казан губернасы Царёвококшайск шәһәрендә ахун була. Мөселман хокукы буенча мәкаләләр һәм Коръәнгә аңлатмалар, фикъһ, каллиграфия, болгарлар тарихы, мед., геом. һ.б. буенча мәгълүмат тупланган компилятив характердагы җыентык авторы.

Х е з м.: Рисалә мөхиммә. К., 1872.

Әд.: М ә р җ а н и Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. К., 1989; Ф ә х р е т д и н Р. Асар. К., 2006. Т. 2.

ФӘТХУ́ЛЛИН Вәгыйзь Шәйхулла улы (24.3.1937, Азнакай р-ны Мәсгут а. — 21.9.2005, Казан), төзелеш механикасы өлкәсе галиме, техник фән. канд. (1973), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1996). 1964 елда Казан төзүче инженерлар ин-тын (хәзер Казан архит-ра-төзелеш ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, төзелеш ф-ты деканы (1984–2005), тимер-бетон конструкцияләр каф. профессоры (1994–2005), бүленеп, 1980–83 тә Аннаба шәһәрендә (Алжир) укыта. Хезмәтләре җыелма монолит тимер-бетон конструкцияләрнең ныклыгын тикшерүгә карый. Югары уку йортларында техник фәннәрне татар телендә укытуның инициаторы һәм оештыручысы. «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Респ-касы Законын гамәлгә ашыру буенча ТР ФАнең Фәнни-методик советы рәисе. Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма ком-ты әгъзасы (1999–2005). Медальләр б-н бүләкләнә. РФнең Югары һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре (2001).



Г.Н. Фәтхуллин.

Х е з м.: Железобетонные конструкции. К.,1993; Концепция организации высшего образования на татарском языке. К.,1999 (автордаш).

Әд.: З ы я т д и н о в а Г. Техник белем — татарча! // Шәһри Казан. 2006. 26 апр.; Мәшһүр татар галимнәре. К., 2011.

ФӘТХУ́ЛЛИН Габдулла Нигъмәт җан улы (8.8.1915, Казан — 1.2.1996, шунда ук), актёр, ТАССРның халык артисты (1976). Татар сәнгать техникумының театр бүлеген тәмамлаганнан соң (1939), Татар акад. театры труппасына кабул ителә. 1949–51 елларда Татар респ-ка күчмә театры режиссёры, 1951 дән кабат Татар акад. театры труппасында. Күзәтүчәнлеге һәм сәхнәдә үз-үзен табигый тотышы аңа Шәйхулла («Миңлекамал», М.Әмир),



Г.Н. Фәтхуллин Төрмәче ролендә («Чамасына күрә чарасы», У. Шекспир).

Әхтәри, Ризван («Ташкыннар», «Кыю кызлар», Т.Гыйззәт), Бики, Аблай («Ху җа Насретдин», «Качаклар», Н.Исәнбәт), Суфый («Шәмсекамәр», М.Әблиев), Шаһвәли («Татар хатыны ниләр күрми», Г.Ибраһимов), Аликбәр («Айдын», Ж.Җаббарлы) кебек кышандырырлык, тормышчан образлар иҗат итәргә мөмкинлек бирә. Эпизодлар остасы буларак, Ф. зур булмаган рольләрдә тәмамланган социаль типажлар тудыра: Редозубов («Варварлар», М.Горький), Салай Салтаныч («Соңгы корбан», А.Н.Островский), Антонио («Фигароның өйләнүе», П.Бомарше) һ.б.



Д.З. Фәтхуллин.

Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: И л я л о в а И. Г.Камал театры артистлары = Артисты театра им. Г.Камала: Биогр. белешмәлек. К., 2005.

ФӘТХУ́ЛЛИН Данил Зыяф улы (2.1.1949, Чуаш АССРның Козловка р-ны Кармыш а.), коючы, Хезмәт Даны орденының тулы кавалеры (1976, 1981, 1988). Хезмәт эшчәнлеген 1966 елда 4 нче төзелеш трестының 42 нче төзелеш идарәсендә эшче булып башлый (Чабаксар ш.). 1967 дән В.И.Ленин исем. Казан фәнни-җитештерү пр-тиесенең кою цехында, 1995–2001 дә «AdS» реклама фирмасы» ҖЧҖдә слесарь-монтажчы. Кою производствосында катнаш һөнәрләрне үзләштерә: стерженщик, формовкалаучы, эретеп коеп ямаучы, эретеп кисүче, миче, эретүче. 9 нчы (1971–75), 10 нчы (1976–80), 11 нче (1981–85) бишьеллык йөкләмәләрен үтәгәндә югары җитештерү күрсәткечләренә ирешә. Медальләр б-н бүләкләнә. Ф. портреты Геройлар аллеясына куелган (Чуаш Респ-касының Козловка ш.).

Әд.: Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

ФӘТХУ́ЛЛИН Дилшат Зиннәт улы (6.4.1940, Ташкент), кинооператор, РФнең атказ. сәнгать эшлеклесе (1992). Мәскәүдә Бөтенсоюз кинематография ин-тын тәмамлый (1963). 1957–58 елларда «Үзбәкфильм» киностудиясендә оператор ассистенты, 1962–72 дә оператор-куючы, 1972 дән «Мосфильм» киностудиясендә оператор. Аеруча зур фильмнары: «Ап-ак ләкләкләр» («Белые, белые аисты», 1965), «Наз» («Нежность», 1966), «Бу данлыклы егет» («Этот славный парень», 1972), «Мистер Мак-Кинлиның качуы» («Бегство мистера Мак-Кинли»; реж. М.Швейцер, 1975; кинооператорлык эше өчен СССР Дәүләт бүләге, 1977), «Бурычлары быз» («Долги наши»; реж. Б.Яшин, 1976), «Икмәк тәме» («Вкус хлеба»; реж. А.Сахаров, 1979), «Граф Невзоров маҗаралары» («Похождения графа Невзорова»; реж. А.Панкратов-Чёрный, 1982), «Үле җаннар» («Мёртвые души»; реж. М.Швейцер, 1984), «Тынгысыз укчы» («Стрелец неприкаянный»; реж. Г.Шенгелия, 1993), «Миллениум» (реж. Л.Костюков, 2000). Ф.ның операторлык сәнгате төрле жанрларны колачлый: фантастика элементлары кергән притча, киноэпопея һәм публицистик драма, сатирик комедия һәм телесериал.

Е.П.Алексеева.

ФӘТХУ́ЛЛИН Зиннәт Равил улы (25.3.1903, Түбән Новгород губ., Сергач өязе Андреевка а. — 1.1.1988, Ташкент), язучы, Үзбәкстан ССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1963), Үзбәкстан ССРның халык язучысы (1983). Үзбәк телендә яза. Югары пед. курсларны (Түбән Новгород, 1922), Хәрби пед. ин-тын (Ташкент, 1942) тәмамлый. 1922 елдан Үзбәкстанда: 1927 дән партия эшендә, 1934 тән Үзбәкстан ССРның Язучылар берлегендә (1934–80 дә идарә әгъзасы, 1934–53 тә президиум сәркәтибе, жаваплы сәркәтип). «Чәчәк бөреләре» («Гунчалар», Таш., 1930), «Бөркет изелде» («Никоб йиртилди», Таш., 1932), «Сатлыклар» («Соткинлар», Таш., 1937), «Сынау көннәрендә» («Синов кунларида», Таш., 1946), «Тамаша дәвам итә» («Томоша давом этади», 1973) һ.б. пьесалар, «Сүнмәс хәят» («Сунмас хаёт», Таш., 1951) повесте, «Кояш белән кайт» («Ой бориб омон кайт», Таш., 1970) киносценарие авторы. Бөек Ватан сугышында катнаша («За честь Родины» фронт г-тасы хәрби хәбәрчесе). 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз, ике «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Әсәр.: Танланган асарлар: 2 жилдли. Таш., 1983–84. *Р.Р.Мусабәкова.*

ФӘТХУ́ЛЛИН Илфат Фәйзулла улы (8.10.1931, Сарман р-ны Зур Нөркәй а.), механика гыйлеме белгече, физика-матем. фән. д-ры (1986), проф. (1987), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1988). Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң (1957), шунда ук эшли, кибернетика каф. мөдире (1975 тән). 1979–91 елларда Кама политехник ин-тының (Чаллы ш.) теоретик механика каф. мөдире, 1992 дән Россия кулланучылар кооперациясе ун-тының Казан кооперация ин-ты матем. каф. профессоры. 1999 дан Россия гуманитар ун-тының Казан ф-лы матем. һәм табигыять фәннәре каф. мөдире. Хезмәтләре матем. һәм гамәли механикага карый. Ф. робот техникасының теоретик нигезләрен эшли, алдан билгеләнгән үзлекле системалар синтезлый (тикшеренүләрнең нәтиҗәләре оборона махсус конструкцияләрендә кулланыла).

Хезм.: Допустимость и реализация заданных движений по части координат систем. К., 1983; Силы инерции в задачах прикладной механики. К., 1986; Построение математических моделей в технике и эконометрике. К., 2011.

ФӘТХУ́ЛЛИН Нариман Садри улы (26.8.1936, Оренбург өлкәсе Орск ш.), философ, социолог, филос. фән. д-ры (1991), проф. (1993), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1996). Мәскәү ун-тын тәмамлаганнан соң (1967), Казан авиация ин-тында эшли (1970 елга кадәр). 1973 елдан Казан финанс-икътисад ин-тында. 1974–77 дә Чаллы шәһәрендә, КамАЗда социол. тикшеренүләр бүлеге башлыгы, 1977 дә Җитәкче хезмәткәрләр һәм белгечләр белемен күтәрү ин-ты ф-лында, 1978 дән Казан финанс-икътисад ин-тында, 1979 дан РФ Эчке эшләр министрлыгы Юридик ин-тының Казан ф-лында, 1998 дән Мәскәү коммерция ун-тының Казан коммерция ин-тында гуманитар дисциплиналар каф. мөдире. 2002 дән ТР Президенты каршындагы Дәүләт һәм муниципаль идарә академиясендә социол. һәм филос. каф. мөдире. 2010 нан Казан ун-тында, бер үк вакытта Икътисад, идарә һәм хокук ин-тында. Хезмәтләре социаль төркемнәр, хокук, җәмгыятьтәге деструктив процесслар социологиясенә карый. Медальләр белән бүләкләнә.

Хезм.: Малая социальная группа как форма общественного развития. К., 1989; Групповые корыстные преступления против социалистической собственности: опыт изучения сознания и поведения участников, проблемы предупреждения. М., 1990 (автордаш).

«ФӘҮЗ ән-НӘҖӘ́Т» («فوز النجات» — «Котылу шатлыгы»), 18 йөзнең соңгы чирегендә язылган дини-дидактик әсәр. Әбү Гали Мискавейхның (932/36–1030) гарәп телендә язылган хезмәтенең фарсы, аннан соң татар теленә ирекле тәрҗемәсе (тәрҗемәчеләре билгесез). Әсәрдә ислам дине тарафыннан рөхсәт ителгән яисә тыелган төп нигезләр, әдәп һәм әхлак кагыйдәләре һ.б. кыскача бәян ителә. Дини үгет-нәсыйхәт әдәби хикәяләү б-н үрелеп бару нәтиҗәсендә укучы тарафыннан җиңел кабул ителә. Китап татар мәдрәсәләрендә уку ярдәмлеге итеп файдаланыла. Беренче тапкыр 1802 елда Казанда нәшер ителә. Соңрак та берничә тапкыр басыла. Әсәр күчермәләре Казан һәм Санкт-Петербург архивларында һәм китапханәләрендә сакланa.

Әд.: Дмитриева Л.В. Каталог тюркских рукописей Института востоковедения. М., 2002; Инсафутдинова М.Т. Поэтический памятник XVIII в. «Фаузен-наджат» // Уч. зап. Казан. ун-та. Гуманитарные науки. 2008. Т. 150, кн. 8.

А.М.Ахунов.

ФӘХРЕТДИ́Н (Фәхретдинов) Ризаэтдин (Риза) (4.1.1859, Самара губ., Бөгелмә өязе (хәзер Әлмәт р-ны) Кичүчат а., — 12.4.1936, Уфа ш.), мәгърифәтче галим, тарихчы, дин белгече һәм җәмәгать эшлеклесе. Бөгелмә өязендә Түбән Чыршылы мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң, укыту эшчәнлеге б-н шөгыльләнә, 1887 елда имам вазифасына сынау үтә. 1887–88 дә Казанда аның гарәп телен укыту һәм мөселман хокукы мәсьәләләренә багышланган тәүге «Әт-төхфәт әл-әнисия» («Дусларга бүләк») һәм «Китаб әл-игътибар» («Ышаныч китабы») хезмәтләре басыла. 1889–91 елларда Бөгелмә өязенең Илбәк авылындагы мәчеттә имам-хатип. 1891 дә Уфа шәһәрендә Оренбург мөселман Диния нәзарәтендә казый. Диния нәзарәте архивын тәртипкә сала, аның фондларын археографик эшкәртүгә һәм аеруча кыйммәтле документларны бастыруга башлангыч бирә. Шул ук елларда Идел буе Болгар дәүләте заманыннан алып 20 йөз башына кадәр яшәгән күренекле шәхесләр турындагы материалны үз эченә алган «*Асар*» биобиблиографик хезмәтен яза («Әзләр», 1–2 т., 1900–08 дә өлешчә; 1–4 т., 2006–10 да тулысынча нәшер ителә). 1906 да бертуган Шакир һәм Закир Рәмиевләр чакыруы б-н Оренбург шәһәренә күчеп килә, «Вакыт» г-тасында эшли. 1908–18 дә «Шура» ж-лының баш мөхәррире, бер үк вакытта «Хөсәения» мәдрәсәсен җитәкли. Фәнни белемнәрне пропагандалый, мөселман мәгарифе системасын реформалауны яклап чыга, татар халкы, тарихы, мә-

дәнияте һәм фәлсәфәсе мәсьәләләренә, үз чорында Россиядә мөселманнар б-н бәйле мәсьәләләргә зур игътибар бирә. Бу елларда аның «Русия мөселманларының ихтыяҗлары вә аларның хакында интикад» (Оренбург, 1906), «Исламлар хакында хөкүмәт тәдбирләре» (Оренбург, 1907) һ.б. хезмәтләре басыла. Рев-циягә кадәрге чорда Ф.нең 60 тан артык китабы (аларның кайберләре бишәр-алтышар, хәтта ун-унике тапкыр басылган), ш.у. газета һәм журнал битләрендә 700 дән артык мәкаләсе нәшер ителә. Милләт Мәҗлесе депутаты (аның эшендә катнашмый), Диния нәзарәте әгъзасы. 1918 дә Уфага күчеп килә. 1922 дән Эчке Россия мөселманнары Үзәк Диния нәзарәте мөфтие. 1923 тә аның баш лангычы б-н Диния нәзарәте «*Ислам мәҗәллә*ләсе» («Ислам җыентыгы») ж-лын бастыра башлый. Ф. башлангыч мөселман мәгарифе



Үзәк мөселман Диния нәзарәте мөфтие Ризаэтдин Фәхретдин (сулдан беренче). Габдрахман Әхмәров (баскан), Ибраһим Терегулов (утырган) белән бер төркемдә . Уфа.

системасын, мәчетләр санын, Диния нәзарәтенең кадрлар составын һәм идарәнең структурасын сакълап калуга ирешә. 1925 тә ул ФАнең 200 еллыгына багышланган тантаналарда мактаулы кунак буларак катнаша. 1926 да Мәккәдә узган Бөтендөнья мөселманнар конгрессында СССР делегациясен җитәкли, конгрессның вице-президенты итеп сайлана. Хезмәтләре Россиядә яшәүче мөселманнарның Россиядәге иҗтимагый тормышы һәм хәле, тарих һәм мөселман фәлсәфәсе; шәригать нигезләмәләрен һәм хәдисләрне шәрехләү, этика, әхлак, пед. нигезләре мәсьәләренә карый. Үзенең фәнни хезмәтләрендә Ф. шәхес роленә аерым игътибар юнәлтә: «Мәшһүр ирләр» сериясендәге китаплар шул хакта сөйли: Казанда Ибне Рөшд (1905), Оренбургта әл-Мәгари (1908), әл-Гәзали (1910), Ибне Таймийә (1911), Ибне Фазлан (1915), Ибне Баттута (1917) тормышы һәм эшчәнлеге турындагы, ш.у. күренекле мөселман хатын-кызларына багышланган «Мәшһүр хатыннар» (Оренбург, 1905) һ.б. китаплары чыга. Шушы ук циклга «Шура» ж-лының «Күренекле шәхесләр һәм зур вакыйгалар» рубрикасында басылган дистәләрчә мәкаләләре керә. Ф.нең тарихи хезмәтләренә фактик материалның күплеге, хикәяләүнең төгәллеге, автор позициясенең ачыклыгы хас. Ул Казан татарлары килеп чыгышына караган болгар теориясенең эзлекле тарафдары, аларның борынгы бабаларын «төркиләр» дип саный. Аның «Җәвамигъ әл-каләм шәрехе» («Гыйбарәләр җыелмасына шәрехләр», Оренбург, 1911; 3 басма., 1917) китабы тикшеренүләре арасында аерым урынны били, анда авторның дини карашлары яктыртыла. Ул диннең мәгарифтән башка, мәгарифнең диннән башка тулы булмавын раслый. Мөхәммәд пәйгамбәр вакытыннан ук исламның хәзерге чынбарлыкка каршы килмәвен, киресенчә, хәзерге заман белемнәренә туры китереп дин кануннарын аңлату мөһимлеген искәртә. Мәҗүсилек калдыкларын тәнкыйтьли, төрле изгеләргә — «тау хуҗалары»на һәм «изгеләр чишмәсе»нә һ.б.га табынуга каршы чыга. Татар әдәби теле барлыкка килү һәм үсеше мәсьәләләрендә аның позициясе төрле. Ф. берникадәр вакыт барлык төрки халыклар өчен бердәм әдәби тел булдыру идеясе б-н янып йөри; әлеге мәсьәлә буенча 1909–10 да «Шура» ж-лы битләрендә махсус конкурс оештыра (ул әлеге идеянең нәтиҗәсез булуын күрсәтә). Соңыннан Казан татарларының сөйләм теленә якын телдә яза һәм аны «казан төркисе» дип атый. «Сәлимә, яки Гыйффәт» (1899) һәм «Әсма, яхуд Гамәл вә җәза» (Оренбург, 1903) повестьларында Европа белеме алган мөселман хатын-кыз идеалын сурәтли. 11 хезмәтен шәхесне мораль-әхлакый һәм эстетик тәрбияләү мәсьәләләренә багышлый; алар арасында «Тәрбияле хатын» (1899), «Гаилә» (Оренбург, 1902) хезмәтләре мәдрәсәдә дәреслек буларак файдаланыла. (Ш.у.к. *Фәхретдин Ризаэтдин мемориаль музее*).

Әд.: Ризаэтдин Фәхретдин: Фәнни-биографик җыентык = Ризаэтдин Фахретдинов: Науч.-биогр. сборник. К., 1999; Ризаэтдин Фәхреддин: Мирасы һәм хәзерге заман. К., 2003; Творчество Ризы Фахретдинова: Исследования, материалы. Уфа, 1988; Баишев Ф.Н. Общественно-политические и нравственно-этические взгляды Ризы Фахретдинова. Уфа, 1996; Татарские интеллектуалы: исторические портреты. К., 2005; Байбулатова Л.Ф. «Асар» Ризы Фахретдина: источниковая основа и значение свода. К., 2006.

Л.М.Айнетдинова.

ФӘХРЕТДИ́Н бине́ ИБРАҺИ́М бине́ ХУҖА́Ш (1754 еллар тирәсе — 1844, Бохара ш.), дин эшлеклесе. Башлангыч дини белемне әтисеннән ала. Казан, Бохара мәдрәсәләрендә укый. Хаттат һәм Коръәнукучы буларак билгеле. Бохара әмире Хәйдәр бине Мәгъсүмгә Коръәнигезләрен өйрәткән. Хезмәтләре фикъһ (мөселман хокукы) мәсьәләләренә карый.

Әд.: Фәхретдин Р. Асар. К., 2006. Т. 2.

ФӘХРЕТДИ́Н РИЗАЭТДИ́Н МЕМОРИА́ЛЬ МУЗЕ́Е, Әлмәт р-нының Кичүчат авылында. «Елховнефть» нефть-газ чыгару идарәсе хезмәткәре С.Ж.*Фәрхетдинов* башлангычы б-н нигез салына. Экспонатларны туплауга мәктәп директоры Р.Ш.Шәһиев зур өлеш кертә. 1995 елның 25 маенда ТР Дәүләт музее (хәзер ТР Милли музее) ф-лы буларак ачыла; 2006 дан муниципаль музей. 1940 елларда Фәхретдиновлар йорты урынында төзелгән агач бинада урнашкан. Экспозиция мәйданы — 100,3 *м*², фондларында 1974 саклау берәмлеге исәпләнә. 5 залда урнашкан экспозиция, 19 йөз ахыры — 20 йөз башы татар крәстияне йорты интерьерын чагылдырган тарихи-этнография һәм мәгърифәтче галим, тарихчы, дин һәм җәмәгать эшлеклесе Р.*Фәхретдин* тормышы һәм эшчәнлегенә багышланган биографик 2 бүлектән гыйбарәт.



Кичүчат авылында Ризаэтдин Фәхретдин музее.

725 исем теркәлгән Фәхретдиновлар гаиләсенең шәҗәрәсе турында материаллар куелган. Коллекцияне мемориаль предметлар б-н тулыландыруга мәгърифәтченең кызлары — Зәйнәп Фәхретдинова, Әсма Шәрәф, оныклары Арыслан Шәрәф һәм Җанибәк Фәхретдинов булышлык итәләр; аеруча кыйммәтле экспонатлар арасында галимнең үзе исән чакта басылган китаплары, 1926 да Согуд Гарәбстан короле Бөтендөнья мөселманнары конгрессы вице-президенты Р.Фәхретдингә бүләк иткән хушбуй таратучы кувшин б-н поднос; эш өстәле, галим үз кулъязмаларын саклаган сандык, гаилә архивыннан документлар һәм кечерәйтелгән Коръән, намазлык, шәхси китапханәдән китаплар, көнкүреш әйберләре һ.б. Музей ел саен (2005 тән) Р.Фәхретдин пед. укуларында катнаша. 2009 да укулар РФ Журналистлар берлеге каршындагы Мөселман журналистлары лигасы тарафыннан оештырыла.

Музей директорлары: Г.В.Хөснуллина (1994–2001), Д.Г.Гыймранова (2001 дән).

Әд.: Мустаева А. Музей в Кичучатове // Нефть и жизнь. 2009. № 4.

ФӘХРЕТДИ́НОВ Альберт Ринат улы (16.4.1962, Казан), физик, физика-матем. фән. канд., ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2005). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1984), РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында эшли. Хезмәтләре релаксация процесслары, фаза күчешләре, түбән кырлы ЯМР-томографиясенә карый. Дәүләт бүләге медицинада «ТМР-0,06 — КФТИ» магнит-резонанслы томографны эшләүдә, ясауда һәм гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә.

ФӘХРЕТДИ́НОВ Әнвәр (Адольф) Нурет дин улы (13.2.1928, Пермь ш. — 2.4.1987, Уфа ш.), балет артисты, БАССРның халык артисты (1959), РСФСРның атказ. артисты (1969). 1946–65 елларда Башкорт дәүләт халык биюе ансамбле артисты, 1965–70 тә — репетиторы, 1975–79 да — сәнгать җитәкчесе.



И.Х. Фәхретдинов.

Җиңел сикерү сәләтенә, сыгылмалылыкка, ачык темпераментка, актёрларга хас сәйкемлелеккә ия була. 1980–85 тә Дүртөйле, Ишембай, Күмертау шәһәрләрендә балалар хореография ансамбльләре оештыручы. Халыкара яшьләр һәм студентлар фестивальләре (Бухарест, 1953, алтын медаль; Мәскәү, 1957, алтын медаль; Вена, 1959, көмеш медаль), Бөтенроссия эстрада артистлары конкурсы



Ә.Н.Фәхретдинов һәм Ф.М.Нәфыйкова «Бүләк» биюендә.

(Мәскәү, 1960) лауреаты. «Почёт билгесе», Вьетнам Демократик Респ-касының 1 нче дәрәҗә Хезмәт орденнары б-н бүләкләнә.

В.Н.Горшков.

ФӘХРЕТДИ́НОВ Габдрахман Ризаэтдин улы (18.3.1887, Самара губ., Бөгелмә өязе Түбән Чыршылы а. — 1937), журналист, тәрҗемәче. Р.*Фәхретдин* улы. «Хөсәения» мәдрәсәсен (Оренбург) тәмамлый; 1906–13 елларда «Вакыт» г-тасы җаваплы сәркәтибе, 1913 тән 2 нче мөхәррире, мәдәният һәм эчке хәбәрләр сәхифәләрен алып бара. «Шура» ж-лында «Граф Лев Толстой» (1910, 23–24 нче саннар), «Рабиндранат Тагор» (1913, 23 сан) һ.б. язмаларын бастыра. Беренче бөтендөнья сугышында катнаша, 1916–17 дә Румыния фронтының баш мулласы, аннары 3 нче Бөтенбашкорт Учредительләр корылтае рәисе, кече корылтай әгъзасы. 1918 нең августыннан Башкортстан хөкүмәтенең мәгълүмат бүлеге мөдире, «Башкортстан хөкүмәтенең теле» («Вестник Башкирского правительства») г-тасы мөхәррире. 1919 ның сентябреннән коллегия әгъзасы, октябрьдән вакытлыча Башкортстан Респ-касы соц. тәэминат халык комиссары вазифаларын башкара, 1920 дә БАССР дәүләт нәшрияты мөдире. 1923–24 тә Башкорт ХКС тәрҗемәчесе. Соңрак «Башкортстан» г-тасы редакциясендә эшли, «Яңа авыл» г-тасында мәкаләләре басыла. Дәреслекләр һәм фәнни әдәбиятны башкорт теленә тәрҗемә итә. «Башкорт тарихы» (Уфа, 1925) хезмәте авторы. Репрессияләнә, үлгәннән соң аклана.

Х е з м.: Ибра һим мирза Терегуловның 30 сәнәлек хезмәте гыйльмиясенә ядкәр. Оренбург, 1908; Фәлсәфәдән бер кыйтга (Яшьләремез, дин вә монизм). Оренбург, 1908.

Әд.: Татар әдипләре, мәгърифәтчеләре (XX йөз башы): Биобиблиогр. сүзлек. К., 2005; Башкирская энциклопедия. Уфа, 2011. Т. 7.

ФӘХРЕТДИ́НОВ Инсаф Ильяс улы (27.4.1951, Молотов өлкәсе, хәзер Пермь крае Губаха ш.), актёр, ТРның халык артисты (1997), РФнең атказ. артисты (2013). Ленинград театр, музыка һәм кинематография ин-тын тәмамлый (1973). 1973–90 елларда Минзәлә татар драма театры актёры, 1988–90 да аның директоры. Актёр театр сәхнәсендә классик һәм заманча репертуарны тәшкил иткән спектакльләрдә 40 тан артык роль башкара. Алар арасында Шәкә («Ил», К.Тинчурин), Муса Җәлил («Соңгы төн», И.Юзеев), Мулланур Вахитов («Сары чәчәк саплары», Ә.Гаффар), Кочкарёв («Өйләнү», Н.В.Гоголь), Буслай («Упкын читендә», А.А.Дударев) кебек тирән эчтәлекле зур рольләре бар. 1990 нан Чаллы татар драма театрында. Реж. Ф.М.Ибраһимов б-н бергә яңа коллектив формалаштыру һәм аны иҗади торгызу эше б-н шөгыльләнә. Бу чорда башкарган аеруча зур рольләре — Каюмов («Ут төртүче», В.И.Шашин), Шагыйрь («Гашыйклар тавы», И.Юзеев), Габдуллажан («Американ», К.Тинчурин), Әнвәрбик («Корт», Ф.Галиев), Ягъкуб («Йосыф», Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәре буенча), Иртуган («Без бит авыл малае», Т.Миңнуллин), Кәбот («Богауланган мәхәббәт», Ю.О'Нил), Локман («Абага алмасы ачы була», Р.Сабыр), Ярми («Язлар моңы», Ә.Гаффар), Уразгөл, Харамша («Күбәләк булып җаның кайтыр», «Ярым ятларга кала», Р.Батулла), Котлыбай («Аты барның — дәрте бар», Н.Гаетбай), Ансельем («Саран», Ж.-Б.Мольер), Мирза («Тирәкләр шаулый җилдә», Ж.Сиблейрас әсәре буенча), Шәйхразый бай («Өч аршын җир», А.Гыйләҗев әсәре буенча), Демьян Потапыч



И.И.Фәхретдинов Мостафа Рәхимов ролендә («Хәят», Р.Сабыр; сулда – Салих ролендә Ф.Сәхәбетдинов).

(«Бурлак», М.Гыйләҗев), Гыйззәт («Хыялый», С.Әбүзәров) һ.б. Матур тышкы кыяфәте, сәхнәдәге мөлаемлыгы, жанрны төгәл тоемлавы, югары проф. осталыгы актёрга драматик һәм комик рольләрдә үзен ышанычлы хис итү, киң гомумиләштерелгән образлар тудыру мөмкинлеге бирә. Д.Сира җиев исем. театраль бүләк лауреаты (2013), «Тирәкләр шаулый җилдә» спектакле өчен «Иң яхшы актёрлар ансамбле» номинациясендә ТР Мәдәният министрлыгының «Тантана» бүләгенә лаек булучыларның берсе (2014), ш.у. «Намус һәм тугрылык. Фидакарь хезмәт өчен» номинациясендә «Тантана» бүләге лауреаты (2017).

Әд.: Гыйлаев О. Моңлы муенса // Аргамак. 1997. № 4; Гыймранова Д. Сабир Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт драма театры. К., 2007.

ФӘХРЕТДИ́НОВ Ирек Хәйрулла улы (5.6.1933, Чүпрәле р-ны Зур Чынлы а.), конструктор, машина төзү өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1987), ТР ФА академигы (1991), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1981), РФнең атказ. фән эшлеклесе (1993). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1958). 1958–96 елларда Казан «Союз» тәҗрибә КБсында эшли, баш конструктор урынбасары (1971 дән), баш конструктор (1983 тән), ген. директор (1992 дән). Бер үк вакытта, 1975–2000 елларда, Казан техник ун-тының махсус двигательләр каф. укытучысы, проф. (1985 тән). 2001 дән Австралиядә яши. Хезмәтләре авиация һәм ракета двигательләренең, ш.у. зур егәрлекле энергетика җайланмаларының киренке-деформацияле халәтен һәм эчке процессларын тикшерүгә карый. Ф. җитәкчелегендә яңа ракета двигательләре, лазер җайланмалары, геол. разведка өчен электр турбогенераторы һ.б. яңа техника үрнәкләре булдырыла. Югары нәтиҗәле конструкцияләр төзү максатынан чыгып, металл булмаган җепселле композицион материалларны (пыяла пластиклар, күмер пластиклар, органик пластиклар) тикшерү буенча эшләр алып барыла. Ракета техникасында һәм халык хуҗалыгы өчен юга-ры конструктив технологияле һәм куллану сыйфатлы махсус эшләнмәләр чыгарыла. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1984). Совет чорыннан соңгы Россиядә халык хуҗалыгын торгызу, ш.у. оборона сәнәгате мәсь әләләренә багышланган публицистик хезмәтләр авторы «Карьера, максатлар һәм чаралар» («Карьера, цели и средства», 2007); «Максатлар һәм чаралар» («Цели и средства», 2009); «Россияне яңарту һәм кешелек гомерен озайту эшен ничек башкарырга?» («Как возрождать Россию и продлевать жизнь человечества», 2012). Уйлап табуга 70 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Үзешчән рәссам буларак, респ-ка, Идел буе зона һәм бөтенроссия күргәзмәләрендә катнаша. ТР Рәссамнар берлеге әгъзасы (1995). Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш һәм алтын медальләре, «Ю.А. Гагарин очышының 30 еллыгы», РФ Космонавтика федерациясенең акад. С.П. Королев исем. медальләре, ТР Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Ракетные двигатели твёрдого топлива. М., 1981; Конструкция и проектирование ракетных двигателей твёрдого топлива. М., 1987 (автордаш); Лекции по созданию машин. К., 1997.

ФӘХРЕТДИ́НОВ Павел Сәгыйть улы (23.2.1942, БАССРның Зилаир р-ны Берё зовка а.), химик-органик, химия фән. канд. (1997), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1997). Киев ун-тын тәмамлаганнан соң (1975), Бөтенсоюз өслек актив матдәләре фәнни-тикшеренү ин-тының Волгодонск ф-лында, 1979 елдан — Ростов ун-тында, 1982 дән — РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында эшли. Хезмәтләре гетероатом төркемле азотлы өслек актив матдәләре химиясенә карый. Ф. углеводород радикаллары гидрофоблыгы поляр гетероатомлы фрагментлар (доменнар) тарафыннан парчаланган нәклассик катионлы өслек актив матдәләре концепциясен эшли. Аның нигезендә биол. актив матдәләр, яңа югары нәтиҗәле реагентлар булдырылып, нефть һәм нефть химиясе сәнәгатендә кулланыла. ТР Дәүләт бүләге йогышсызландыручы, дәвалау-профилактика һәм химия-технол. препаратларын эшләүдә һәм гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә. Үйлап табуга 41 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Ингибиторы коррозии ряда [N-изононилфеноксиполи (этиленокси) карбонилметил] аммоний хлоридов. 1. Ингибирование стали в солянокислотных средах // Защита металлов. 2001. Т. 37, № 4 (автордаш); Новые реагенты для улучшения добычи и транспортировки тяжёлых нефтей путём регулирования их реологических свойств // Интервал. 2003. № 12 (автордаш); Четвертичные аммониевые соединения — перспективное направление в ветеринарной дезинфектологии // Ветеринарный врач. 2005. № 1 (автордаш).

ФӘХРЕТДИ́НОВ Равил Габдрахман улы (14.3.1937, Балтач р-ны Кариле а. — 10.3.2014, Казан), археолог, тарихчы, тарих фән. д-ры (1990), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1997). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1963). 1966 елдан Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында, 1997 дән ТР ФАнең Тарих ин-тында (1992 дән әйдәп баручы фәнни хезмәткәр). Татар археол. экспедициясе отряды б-н җитәкчелек итә; экспедиция 1959–72 дә, Идел буе Болгар дәүләте, Алтын Урданың Болгар олысы һәм Казан ханлыгы археол. истәлекләре җыелмасын (картасын) төзү максаты б-н, Татарстан, Ульянов, Самара өлкәләре һәм Чуаш АССР терр-ляренә археол. яктан тоташ тикшереп чыга, 1200 дән артык истәлек ачыклана һәм тикшерелә. 1970–2000 дә Камай шәһәрлегендә, Рус Урматы авыллыгында, Биләр шәһәрлегендә казу эшләре б-н җитәкчелек итә, Болгар, Царёв һәм Селитренное шәһәрлекләрендә h.б.да алып барылган археол. тикшеренүләрдә катнаша. Биектау р-нында Иске Казан тарих-мәдәният һәм табигать музей-саклаулыгын оештыручылар-ның берсе. Хезмәтләре Идел буе Болгар дәүләте, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы тарихына һәм археологиясенә карый. 6 томлык «Татарстан Республикасының археологик картасы»н («Археологическая карта Республики Татарстан», 1981–90; ТР Дәүләт бүләге, 1994) эшләүдә катнаша. Татар халкының һәм Татарстанның борынгы һәм урта гасырлар тарихы буенча дәреслекләр һәм уку яр-дәмлекләре, ш.и. «Татар халкы һәм Татарстан тарихы» («История татарского народа и Татарстана», 1995; татар телендә 1996) авторы. «Татарская археология» ж-лының баш мөхәррире (1997–2006). Һ.Атласи исем. бүләк лауреаты (1996). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Ташлар мо ңы. К., 1978; Кичке азан. К., 1997; Татар тарихы (кыскача басма). К., 1999; Археологические памятники Волжско-Камской Булгарии и её территория. К., 1973; Очерки по истории Волжской Булгарии. М., 1984.

ФӘХРЕТДИ́НОВ Раил Равил улы (28.5.1962, Казан), тарихчы, этнолог, тарих фән. д-ры (2009). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1984), Балтач р-ны Чепья урта мәктәбендә эшли, 1987 елдан директор. 1992 дән ТР Мәгариф һәм фән министрлыгында бүлек башлыгы. 1996–2003 тә Казан социаль-юридик ин-тында гуманитар фәннәр каф. мөдире, 2003 тән проректор. Хезмәтләре татарлар тарихы, иҗтимагый-сәяси фикер, 19–20 йөзләр чигендә татар халкының этносәяси тарихы мәсьәләләреңә карый. Биектау р-ны Камай авылында тарихи-этнографик музей оештыруда катнаша.

Х е з м.: Татарский либерализм в конце XIX — начале XX века (Очерки политической истории). К., 1998; Татарское просветительство и реформаторство XIX начала XX веков: Историогр. обзоры. К., 2005; Политическое самосознание татар на рубеже веков (вторая половина XIX — начало XX вв.). К., 2006.

ФӘХРЕТДИ́НОВ Рево Җиһанша улы (26.2.1939, Чүпрәле р-ны Иске Чүпрәле а.), химик-технолог, техник фән. канд. (1969), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2010). Казан хисап-кредит техникумын (1958), Казан химия-технол. ин-тын (1963, хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли, нефть һәм газ эшкәртү химик технологиясе каф. профессоры (2003 елдан). Хезмәтләре нитрокушылмалар химиясе, нефть битумнары җитештерү химиясе һәм химик технологиясе, углеводород газларын чистарту, дулкын технологияләре өлкәләреңә карый. Дәүләт бүләге авыр нефть чималын чыгару һәм эшкәртү процессларында интенсив парга әйләнүнең һәм электр магнетик активлаштыруның инновацион, энергия саклаучан технологияләрен эшләүдә катнашканы өчен бирелә. Үйлап табуга 70 тән артык авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Химия нефти. Л., 1984 (автордаш); Изучение поверхностно-активных свойств неионогенных ПАВ // Журн. прикладной химии. 2001. Т. 74, № 8 (автордаш); О расчёте резонансной частоты «углерод-водород» в углеводородах нефти // Нефтепереработка и нефтехимия. 2010. № 8 (автордаш).

ФӘХРЕТДИ́НОВ Тимержан Җиһанша улы (10.3.1919, БРның хәзерге Бүздәк р-ны Олы Өстүбә а. — 27.11.1979, Уфа), Дан орденының тулы кавалеры (6.11.1944, 11.4.1945, 15.5.1946), кече сержант. Туган авылында колхозда эшли. 1939 елдан Кызыл Армиядә. 1941 нең июленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында: 329 нчы артиллерия полкында (3 нче удар армиянең 150 нче укчы дивизиясе) һәм 328 нче артиллерия полкының



Р.Г. Фәхретдинов.



Т.Ж. Фәхретдинов.

(2 нче удар армиянең 150 нче укчы дивизиясе) 4 нче батареясында туп төзәүче. Төньяк-Көнбатыш, 2 нче Балтыйк буе һәм 1 нче Белорус фронтлары гаскәрләре составында Торопец-Холм (1942), Невель (1943), Рига (1944), Берлин (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 18 сентябрендә Эргли шәһәре (Латвия) өчен барган сугышларда батырлык күрсәтә; расчёт составында һөҗүм тубын юк итә, 1945 нең 15 февралендә Радовнитце торак пункты (Шнайдемюльдан, хәзерге Пила ш., Польша, төньяк-көнчыгыштарак) янында, тубы б-н ачык кырга чыгып, дошманның үзиөрешле тубын сафтан чыгара, сугыш кирәк-яраклары б-н 2 автомашинаны һәм вездеходны яндыра; 15 ләп дошман солдатын һәм офицерын юк итә, яралана, әмма сафта кала; 1945 нең 1–2 маенда Берлин өчен барган сугышларда расчёт составында дошманның 10 лап пулемёт ноктасын һәм 20 ләп солдатын юк итә. Демобилизацияләнгәч (1946), Уфа сыра з-дында эшли.

Әд.: Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

М.З.Хәбибуллин.

ФӘХРЕТДИ́НОВ Харис Фәтхи улы (30.3.1935, Яшел Үзән р-ны Чирүче а. — 26.10.2005, Казан), кинорежиссёр, ТАССР һәм РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1974, 1978). Казан пед. ин-тын (1959), Мәскәүдәге Бөтенсоюз кинематография ин-тының режиссёрлык ф-тын (1968) тәмамлый. 1959–62 елларда Горький өлкәсенең Кучкай Пожары интернат мәктәбендә укытучы-тәрбияче булып эшли. 1962–63 тә һәм 1968 дән Казан кинохроника студиясендә: кинооператор ассистенты, документаль һәм нәфис фильмнар режиссёры. «Габдулла Тукай» (1970), «Җылылык юлы» («Дорога тепла», 1973), «Турыдан-туры элемтә» («Прямая связь», 1974), «Бригадир Рәис Ганиев» (1974), «Татарстан нефтьчеләре» («Нефтяники Татарии», 1981), «Бу — КамАЗ» («Это — КамАЗ», 1982), «Рәссам — Иван Шишкин» («Художник — Иван Шишкин», 1982), Байкал-Амур магистрале төзелеше турында «Беренче сквозной» («Первый сквозной», 1984), Татар акад. театры актёрлары турында «Сәйяр» йолдызлыгында» («В созвездии «Сайяр», 1995), «Тамырлар» (2000), «Яман» (2000) фильмнарын төшерә. Милли традицияләр б-н кызыксыну, вакыйгаларның асылын җиткерергә омтылу Ф. фильмнарына сюжет һәм композиция төзүдә үзенчәлекле иҗади юнәлеш бирә. Ф. 40 тан артык документаль, фәнни-популяр һәм уку-укыту юнәлешендәге фильмнар, ки-

ножурналлар өчен сюжетлар төшерә; нәфис фильмнарны татар телендә дубляж ясаучы режиссёр була. ТР Кинематографистлар берлеге идарәсе рәисе (1986–98).

Әд.: Союз кинематографистов Республики Татарстан: 25 лет. К., 2006.

Е.П.Алексеева.

ФӘХРЕТДИ́НОВА Анастасия Викторовна (1.4.1984, Казан), педагог, пед. фән. д-ры (2013). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1996), шунда ук пед. кафедрасында эшли. 2000 елдан Казан ун-тының чит телләр кафедрасында; 2011 дән Казан вет. медицина - сы академиясендә чит телләр каф. мөдире. Хезмәтләре инглиз телле илләрдә укучылар - га гражданлык тәрбиясе бирү мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Гражданское воспитание учащихся в США на рубеже XX–XXI веков. К., 2007; Академическая мобильность студентов высших учебных заведений: отечественный и зарубежный опыт её формирования. К., 2008 (автордаш).

ФӘХРЕТДИ́НОВА Антонина Николаевна (14.1.1937, Чуаш АССРның Порецкий р-ны Гарт а.), физик, физика-матем. фән. д-ры (1992). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1960), шунда ук эшли, 1990 елдан әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре атмо - сфераның динамик структурасына һәм Ко - яш-Җир бәйләнешләренә карый. Ф., метеор эзләрен радиолокацияләүнең техник чараларын кулланып, югары мезосфера — түбән термосфера (80–110 *км*) динамикасының югары структурасын тикшерүнең радиофи - зик алымын эшли. Вакыт масштабларының (күтәрелеш, планетар дулкыннарның һәм сезонга бәйле тирбәлешләрнең) киң аралыгында дулкын кырларының биеклеге һәм озынлыгы үзенчәлекләрен, ш.у. динамик процесслар комплексының биеклек-вакыт структураларын (күтәрелеш, сезон һәм елара үзгәрешләр масштаблы ятма, асма һәм дулкын хәрәкәтләрен) билгели. Җирнең түбән һәм урта атмосферадагы термодинамик күрсәт - кечләренең биеклек-вакыт төрләнешләрендә гео- һәм гелиоэффектларны ачыклый.

Х е з м.: Высотно-сезонная структура волновых потоков, создаваемых долгопериодными волновыми возмущениями // Изв. РАН. Физика атмосферы и океана. 1992. Т. 28, № 7 (автордаш); Долговременные изменения преобладающего ветра в верхней мезосфере — нижней термосфере и связь с солнечной активностью // Изв. РАН. Физика атмосферы и океана. 1998. Т. 34, № 5 (автордаш); Features of height — temporal structure of dynamics of mid — latitude upper mesosphere — lower thermosphere by radiometeor measurements during 1986–1995 in Kazan (56N, 49E) // Adv. Space Res. 1999. V. 24, № 5.

ФӘХРЕТДИ́НОВА Гүзәлия Җәүдәт кызы (15.9.1960, Бөгелмә р-ны Карабаш пос.), пе - дагог, пед. фән. д-ры (2004), проф. (2006). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1984), 24 нче урта һөнәри техник уч-щедә укыта. 1986 елдан Казанда ПФАнең Һөнәри-тех - ник пед. ин-тында. 1991 дән Казан пед. ин-тында, 2010 нан Казан ун-тының белем бирү менеджменты кафедрасында. Хезмәтләре татар халык педагогикасы, сәяси-мәдәни мәгариф үсеше мәсь әләләренә карый.

Х е з м.: Видные татарские педагоги XIX века. К., 1999; Развитие поликультурного образования в Поволжье. К., 2004.

ФӘХРЕТДИ́НОВА Диләрә Әхәт (Габдел - әхәт) кызы (18.12.1923, Уфа ш. — 22.10.2002., Ташкент, Үзбәкстан), сәнгать белгече, сән - гать фән. д-ры (1988). Р.Фәхретдин оныгы. Мәскәү ун-тын тәмамлый (1951). Бөтенсоюз кинематография ин-тында, Мәскәү текстиль ин-тында, Үзбәкстан ССР Сәнгать музеенда (Ташкент) эшли. 1961 дән Хәмзә исем. Сән - гать белеме ин-тында (Ташкент). СССР рәс - самнар берлеге әгъзасы (1965). Тикшеренү - ләренең төп юнәлеше — гамәли-бизәлеш сән - гате, Үзбәкстан сәнгате тарихы. Күптомлы «СССР халыклары сәнгате тарихы» («Ис - тория искусства народов СССР», М., 1977–84, т. 8–9), «Дөнья халыклары сәнгате» («Искусство народов мира», М., 1978, т. 4), «Үзбәкстан ССР тарихы» («История Узбекской ССР», т. 1–4, Таш., 1967–68), «Бо - хараның иң борынгы заманнардан хәзерге көннәргәчә тарихы» («История Бухары с древнейших времён до наших дней»), «Хива тарихы» («История Хивы», икесе дә — Таш., 1976) һәм «Үзбәк совет энциклопедиясе» («Узбекская советская энциклопедия», т. 1–14, Таш., 1971–80) хезмәтләре автордашы.

Х е з м.: Декоративно-прикладное искусство Узбекистана. Таш., 1972; Искусство Советского Узбекистана. М., 1976 (автордаш); Песнь о металле. Народное искусство Узбекистана. Таш.. 1986 (автордаш); Ювелирное искусство Узбекистана. Таш., 1988.

ФӘХРЕТДИ́НОВА Елена Валерьевна (27.8.1971, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2011). Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлый (1992). 1993 елдан Казан ун-тының икътисад кафедрасында. Хезмәт - ләре социаль-икътисади проектларның һәм хезмәт мөнәсәбәтләренең нәтиҗәлелеген күтәрү мәсьәләләренә карый. Халыкның күп - төрле ихтыяҗларына, керемнең яңа төрләренең социаль-икътисади система модель - ләренә бәйле рәвештә тормыш сыйфаты дә - рәҗәсенең үсеш корреляциясе механизмын ача. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Приоритетный национальный проект «Здоровье»: теория и практика реализации в РФ. К., 2008; Приоритетные национальные проекты в социальной сфере РФ как фактор повышения качества жизни населения. К., 2009; Качество жизни населения: институциональный подход. К., 2010 (автордаш).

ФӘХРЕТДИ́НОВА Резидә Әхәт кызы (24.6.1959, Яшел Үзән р-ны Октябрь пос.), пе - дагог, пед.-фән. д-ры (1999), проф. (2001). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1981), Казан мәктәпләрендә һәм урта махсус уку йортларында инглиз теле укыта. 1988 елдан Казан пед. ин-тында, 2000–10 да психол.-пед. ф-тында пед. каф. мөдире. 2011 дән Казан ун-тының Филол. һәм сәнгать ин-тында. Хез - мәтләре укучыларның шәхес булып форма - лашу мәсь әләләренә карый.

Х е з м.: Зарубежный опыт социализации личности. К., 1988; Социально-педагогический аспект: теория и практика. К., 1998; Социальное становление личности школьников. К., 1998; Сетевое полилингвальное обучение одарённых детей: теория и практика. К., 2015 (автордаш).

Л.М.Айнетдинова.

ФӘХРИ́ Әсгать Йосыф улы (13.10.1901, Казан губ., Спас өязе Иске Алпар а. — 25.9.1926, Казан), язучы. 1913–17 елларда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә (Казан) укый. «Тормыш кочагында» (1925), «Сүзләрдән чәчәкләр» (1927) җыентыкларына кергән һәм Граждан - нар сугышы, татар авылындагы сыйнфый көрәш, нэп дәвере турында бәян ителгән хи - кәяләр һәм нәсерләр авторы. Ф.гә образлы фикер йөртү һәм эчке тоемлау хас.

Әд.: Фәхри Әсгатьнең тууына 80 ел // Казан ут - лары. 1981. № 10.

«ФӘХРИ́ ЯРЫ́», ерым-сызалар системасы, табигать истәлеге. Питиял елгасы үзәненең сулъяк яр сөзәклегендә, Яшел Үзән р-ны Олы Җәке авылыннан көньяк-көнчыгыштарак. 1981 елда билгеләнә. Мәйданы 15,7 *га*. Имән,



«Фәхри яры» ерым-сызалар системасы.

юкә, каен һәм усак утыртмаларыннан тор - ган урман-болын биоценозы. 1970 елларда үткәрелгән мелиорация эшләре туфрак эро - зиясен туктатырга мөмкинлек бирә. Объект фәнни-танып белү әһәмиятенә ия.

ФӘХРУ́ЛЛИН Равил Фәрит улы (11.4.1981, Украина ССР, Ракитное ш.), биохимик, биол. фән. д-ры (2011). Казан ун-тын (2003), Халл шәһәре ун-тын (Бөекбритания, 2007) тәмам - лый. 2006 дан Казан ун-тында. Хезмәтләре күзәнәк өлеге инженериясенә, нанотокси - кологиягә карый. Ф. тарафыннан күзәнәк биосенсорлары, тукыма инженериясе алы - мы, ш.у. коллоидлы микрокисәкчеләр — ци - тозомалар классы эшләнә. Үйлап табуга 3 па - тенты бар. ТР ФАнең Яшьләр бүләге лауре - аты (2010). Табигыять фәннәре буенча «ТР - ның иң яхшы яшь галиме» конкурсында җи - ңүче (2011).

Х е з м.: Hybrid Cellular-Inorganic Core-Shell Microparticles: Encapsulation of Individual Living Cells in Calcium Carbonate Microshells // Langmuir. 2009. V. 25 (12); «Face-Lifting» and «Make-Up» for Microorganisms: Layer-by-Layer Polyelectrolyte Nanocoating // ACS Nano. 2012. V.6 (автордаш); Microworms swallow the nanobait: the use of nanocoated microbial cells for the direct delivery of nanoparticles into Caenorhabditis elegans // Nanoscale. 2013. V.5.

ФЕВРА́ЛЬ РЕВОЛЮ́ЦИЯСЕ, Россиядәге 1917 елгы буржуаз-демократик рев-ция. Рев-ция барышында илдә самодержавие бете - релә. Ф.р.нең сәбәпләре: өлгереп җиткән проб - лемаларны реформалар ярдәмендә хәл итүгә сәләтсезлектә чагылган хакимият кризисы; озакка сузылган *Беренче бөтендөнья сугышы* аркасында илдә икътисади хәлнең кисәк кенә начараюы һәм сәяси вазгыятнең кискенләшүе. Төп революцион вакыйгалар Петроградта бара: 23 февральдә эшчеләрнең беренче зур колачлы демонстрациясе булып уза, аны уздыруга икмәк җитмәү сәбәп була. 2 мартта император Николай II тәхеттән ваз кичә, шул ук көнне Вакытлы хөкүмәт оештырыла. Рев-ция нәтиҗәсендә халык сүз, матбугат, җыелыш-

лар һәм берлекләр иреге ала; дин тоту һәм милли аерымлыклар буенча чикләүләр, үлем җәзасы бетерелә, сәяси амнистия игълан ителә; элеккеге режимның барлык җәза органнары гамәлдән чыгарыла. 1 мартта Петроградтан Казанга рев-циянең җиңүе турында телеграмма килә, ул демократик түнтәрелеш өчен сигнал була. Казан губернаторы П.М.Боярский һәм Казан хәрби округы командующие генерал А.Г.Сандецкий Вакытлы хөкүмәт һәм Дәүләт Думасы адресына котлау телеграммалары җибәрәләр. 2 мартта Казанның Театр мәйданында эшчеләрнең һәм студентларның сәяси демонстрациясе булып уза. Казан гарнизоны гаскәрләрендә чуалышлар башлана, өч полкның (94, 95 һәм 164 нче полклар) солдатлары үзләренең командирларын кулга алалар. Полиция һәм жандармерия коралсызландырыла, төрмәләрдән сәяси тоткыннар иреккә чыгарыла. 4 мартта баш күтәргән солдатлар Казан хәрби округының округ штабын тар-мар китерәләр, генерал А.Г.Сандецкийны, ш.у. генераллар Язвин, Файдыш, Комаровны кулга алалар. Командованиенең барлыгы 100 гә якын вәкиле вазифаларыннан читләштерелә. 6 нчы мартта кенәз Г.Е.Львов имзасы б-н губернатор хакимияте гамәлдән чыгарылу һәм аның вәкаләтләре Вакытлы хөкүмәтнең губерна комиссарларына тапшырылу турында Петроградтан алынган телеграмма нигезендә Казан губернаторы П.М.Боярский үз вәкаләтләрен Казан губерна земствосы идарәсе рәисе полковник В.В.Молоствовка тапшыра (30 марттан бу вазифаны А.Н.Плотников, май ахырыннан В.А.Чернышёв били). 2 мартта Казан шәһәр думасы утырышы була, анда шәһәр баш лыгы В.Д.Боронин тәкъдиме б-н Петроградта булып узган үзгәрешләрне тану турында карар кабул ителә. 5 мартта шәһәр думасының эшчеләр оешмалары вәкилләре катнашындагы киңәйтелгән утырышында Җәмәгать иминлеге ком-ты төзелә (рәисе — В.Д.Боронин); ул шәһәрдә хакимият вәкаләтләренең зур өлешен үз өстенә ала. Март дәвамында шундый ком-тлар барлык өяз шәһәрләрендә оештырыла (к. «*Җәмәгать иминлеге комитетлары*»). Вакытлы хөкүмәт мәнфәгатьләрен чагылдырган хакимият органнары төзелү б-н бергә губернада революцион рухтагы халык массаларының хакимият органнары формалаша. 2 мартта — Эшче депутатлары советы, 4 мартта Казан хәрби гарнизонының Вакыт лы хәрби ком-ты оештырыла (рәисе — полковник А.Г.Григорьев). 8 мартта Эшче һәм солдат депутатлары советларының берләштерелгән утырышы була, Президиум составы сайлана (рәисе — прапорщик К.Поплавский). Казанда яңа партияләр, төркемнәр, иҗтимагый хәрәкәтләр торгызыла һәм төзелә. Алар арасында иң йогынтылылары кадетлар, эсерлар һәм социал-демократлар була. *Карагруһчылар* оешмалары тыела. Иске *профсоюзлар* торгызыла һәм яңалары оештырыла башлый, күп кенә сәнәгать пр-тиеләрендә фабрика-завод ком-тлары барлыкка килә, алар ху җаларның икътисади хакимиятен чиклиләр, актив рәвештә пр-тиеләр б-н идарә итүгә катнашалар, алдан килешенмичә 8 сәгатьлек эш көнен гамәлгә кертәләр.

Еш кына эшчеләр оешмалары үз сәясәт ләрендә пр-тиеләрнең икътисади хәлен исәпкә алмыйлар, бу җитештерүнең кимүенә китерә. Бөтен илдәге кебек үк, Казан губернасында ике хакимиятлелек урнаша.



Высочайшій Манифестъ.

БОЖІЕЮ МИЛОСТІЮ

МЫ, НИКОЛАЙ ВТОРЫЙ,

ИМПЕРАТОРЪ И САМОДЕРЖЕЦЪ

ВСЕРОССІЙСКІЙ,

Николай II нең тәхеттән ваз кичүе турындагы манифест.

Татар милли-демократик хәрәкәте активлаша, *Мөселманнар комитеты, Мөселман социалистлар комитетлары, Бөтенроссия мөселманнары хәрби шурасы (Хәрби Шура), Бөтенроссия мөселманнарының милли шурасы (Милли Шура)* һ.б. оешмалар төзелә. Россиядә 1917 елгы Ф.р. барышында гамәлгә ашырылган үзгрешләрне Россия мөселманнары рухланып кабул итәләр. Мөселманнар яшәгән җирләрдән, бигрәк тә 3 нче мартта дини һәм милли чикләүләр бетерелү турындагы пункт урын алган хөкүмәт декларациясе чыкканнан соң, Вакытлы хөкүмәт, Дәүләт Думасы, Эшче һәм солдат депутатларының Петроград Советы адресына котлау телеграммалары килә. 7 мартта Петроградта мөселманнарның Дәүләт Думасы депутатлары тарафыннан демократик үзгәртеп коруларны яклау максаты б-н оештырылган митингы була. Март уртасында *Россия мөселманнарының вакытлы мәркәз бюросын* (рәисе — Ә.Цаликов) оештыру максатында мөселман эш леклеләренең киңәшмәсе булып уза, бюро алдына тиз арада Мәскәүдә Бөтенроссия мөселманнары корылтаен чакыру бурычы куела. Халык массаларына илдә барган вакыйгаларның асылын аңлату һәм яңа хакимиятнең абруен ныгыту максаты б-н татар милли хәрәкәте лидерлары татар телендә популяр брошюралар бастырып тараталар. Россия мөселманнарын бөтен Россия җәмгыятен борчыган мәсьәләләр дулкынландыра: сугышка карата мөнәсәбәт, җир мәсь әләсе, демократик үзгәртеп корулар һ.б., әмма иң төп мәсьәләләрнең берсе дәүләт төзелеше турындагы мәсьәлә була. Мөселманнар хәрәкәте оешу ягыннан төрле рәвешләргә керә, милли үзидарә органнарын төзү процессы бөтен илнең мөселман халкын колачлый. Мөселман хәрбиләре дә аңа актив кушылалар; яздан алып хәрәкәттәге армиядә һәм тылда мөселман хәрби оешмалары төзелә башлый, алар мөселман солдатларны агымдагы вакыйгалар б-н таныштыралар, Учредительләр җыенында катнашуга әзерлиләр. Тылда барлыкка килгән беренче хәрби оешма — 8 мартта төзелгән Казан мөселман хәрби ком-ты була. 27–30 апрельдә Мәскәүдә И.Алкин рәислегендә Бөтенроссия мөселманнарының хәрби киңәшмәсе булып уза, анда Бөтенроссия мөселманнарының вакытлы хәрби шурасы сайлана (рәисе — И.Алкин). Аерым төбәкләрдә мөселманнарның корылтайлары уздырыла башлый; апрельдә 1 нче Уфа губерна мөселманнары корылтае (рәисе — И.Әхтәмов), Телән че Тамак авылында Минзәлә өязе мөселманнары корылтае һ.б. үткәрелә. Казанда 20 апрельдә Бөтенроссия мөселман укытучылар корылтае булып уза, анда Бөтенроссия мөселман укытучылар берлегенең мәркәз бюросы төзелә. 1917 елгы Ф.р.ннән соң мөселман хатын-кызлар да активлаша. Апрельдә Казанда Мөслимәләрнең мәркәз бюросы оештырыла, ул Бөтенроссия мөселман хатын-кыз лар корылтаен әзерли һәм уздыра (24–27 апрель, Казан); корылтай эшендә Россиянең барлык мөселман халыкларыннан 300 гә якын делегат катнаша, ир-атлар б-н тигез хокукларга ирешү турында карар кабул ителә. *Вәсиләр хәрәкәте* активлаша: 27 апрельдә Казанда Болгар дәүләте тарафдарларының «Фиркаи На җия» («Котылган партия») тарафыннан чакырылган 1 нче корылтае була, анда катнашучылар «халык хөкүмәте» җитәкчелегендә Болгар дәүләтен торгызуны таләп итәләр.



Казан Кремле янында митинг. Февраль. 1917.

Вакытлы хөкүмәтнең Учредительләр җыены катнашыннан башка җир һәм солых турындагы мәсь әләләрне хәл итү җаваплылыгын үз өстенә алырга теләмәве һәм Учредительләр җыенын сугыш тәмамланганчы чакырудан баш тартуы илдә революцион процессларның активлашуына һәм Окт. кораллы түнтәрелешенә, соңгысы нәтиҗәсендә хакимияткә большевиклар килүгә китерә. Ш.у.к. *Казанда 1917 елгы Октябрь кораллы баш күтәрелеше*.

Әд.: История Казани. К., 1991. Кн. 2; Тагиров И.Р. Очерки истории Татарстана и татарского народа (XX век). К., 1999; Исхаков С.М. Российские мусульмане и революция (весна 1917 г. — лето 1918 г.). М., 2004.

Л.М.Айнетдинова.

ФЕ́ДИН Михаил Александрович (22.9.1920, Спас кантоны Базяково а. — 19.7.1948, Мари АССР, Волжск ш.), Сов. Союзы Герое (10.1.1944), гв. сержанты. Казанда машина-трактор остаханәсендә эшли. 1937 елда Лопатино посёлогына (1940 тан Волжск ш.) күченеп китә, Мари кәгазь комб-тын төзүдә катнаша. 1940 тан Кызыл Армия сафларында. Ерак Көнчыгышта Тын океан флотының торпеда катерларында хезмәт итә. 1943 нең февраленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 7 нче гв. һава десанты полкының отделение командиры (60 нчы армиянең 2 нче гв. һава десанты дивизиясе). Воронеж фронты гаскәрләре составында Курск сугышында катнаша (1943). 1943 нең 8 октябрендә Медвин авылы янында (Украина ССРның Киев өлкәсе Чернобыль р-ны) Днепр елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә: беренчеләрдән булып елганы кичеп чыга, взвод б-н җитәкче лекне үз өстенә ала, дошманның 8 һөҗүмен кире кайтара, аңа зур зыян китерә. Яралана, сугыш б-н җитәкчлек итүне дәвам итә. Демобилизациядән соң (1945), Волжск шәһәрендә яши, кирпеч з-ды директоры булып эшли. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Волжск шәһәрендәге бер урам Ф. исемен йөртә, шәһәр паркында Геройга бюст куела.



М.А. Федин.

Әд.: Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

М.З.Хәбибуллин.

ФЁДОР ПЁСТРЫЙ (Палецкий Фёдор Давыдович) (15 йөз), кенәз. 1429 елда Галич шәһәренә яу б-н баручы Алтын Урда отрядын тар-мар итә. 1431 дә Мәскәү бөек кенәзе Василий II әмере б-н Болгар бәклегенә килә, Болгар шәһәрен һәм аның тирәсендәге авыл-бистәләрне җимерә, яндыра; Ф.П. явыннан соң Болгар сәяси, икътисади, мәдәни әһәмиятен югалта һәм ташландык хәлгә килә.

Әд.: Фахрутдинов Р.Г. Очерки по истории Волжской Булгарии. М., 1984.

ФЁДОРОВ Виктор Кронидович (29.2.1940, Казан — 5.10.2001, шунда ук), монументалист, нәкышьче, график, педагог, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1978), ТРның халык рәссамы (1991). Казан сынлы сәнгать уч-щесен (1959), И.Е. Репин исем. Ленинград нәкышь, скульптура һәм архит-ра ин-тын (А.А.Мыльников җитәкчелегендәге монументаль нәкышь остаханәсе, 1966) тәмамлый. 1967 елдан Татарстан сәнгать фондында эшли, бер үк вакытта Казан сынлы сәнгать уч-щесендә укыта (1970–96). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1974). Ф. — күпкырлы рәссам; Татарстанда станлы нәкышь буенча әйдәп баручы осталарның берсе. ТР-да монументаль сәнгатьнең чишмә башында тора, дивар мозаикасы (смальта), бизәкләр, сграффито, шәһәр яны тимер юл вокзалы бинасы фасадындагы «Казан — совет Татарстаны башкаласы» (1967, автордашлар С.М.Бубеннов, Р.Ә.Килдебәков), Химиклар мәдәният сарае фасадындагы «Бакчалар утыртыйк!» (1960, автордаш С.М.Бубеннов), «Татарстан» кунакханәсенең ресторан залындагы «Чәй эчү» (1970), Зәй шәһәрендәге «Октябрь» мәдәният сарае фасадындагы «Октябрь» (1975), Казан ун-ты интерьерындагы «Фән» (1977) витражлары авторы һ.б.

Нәкышьтә тарихи-патриотик теманы үстерә — «1918 ел» (1968), «Русь — бишек җыры» (1970) триптихы, «Казанда Федосеевның марксистик түгәрәге» (1977), «Бабам-ның этисе Ефим Табейкин» (1980), «Комиссар Камил Якубов» (1981), «Емельян Пугачёв һәм Бәхтияр Канкаев» (1982), «Пушкин. Пугачёв эзләреннән» (1983–88), «Тукай сүзе» («Г.Тукай һәм «Сәйяр» труппасы») (1991) һ.б.ны иҗат итә. Беренчеләрдән булып КамАЗ төзүчеләр турында картиналар яза («КамАЗ-ның беренче төзүчеләре», 1973; «Төзүче», 1977; «Чираттагы йөкләмә», 1979). Ф. иҗатында замандашларының образлары — рәссам Н.Кузнецов (1970), драматург Д.Вәлиев (1977), җырчы Р.Ибраһимов (1982), актриса М.Кобчикова, сәнгать белгече В.Цой (икесе дә — 1988), актриса Р.Җи һаншина (1997) мө-



В.К. Фёдоров. 1. «Казан – совет Татарстаны башкаласы». Казан тимер юл вокзалы бинасы диварындагы композиция. Сграфитто. Мозаика. 1967; 2. «Чәй эчү». Смальта. Мозаика. Казандагы «Татарстан» кунакханәсе ресторан; 3. «Кызыл шәүләле автопортрет». 1993; 4. «Ана». «Русь башлангычы» триптихының үзәк өлеше. 1970; 5. «Тукай сүзе» (Тукай һәм «Сәйяр» труппасы). 1986; 6. «Оныгым Сергей портреты». 1994. 4, 5, 6 – ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда.

һим урын били. Автопортретларында (1971–93) тормышының төрле елларындагы кәефен, рухи халәтен чагылдыра. Ф. — пейзаж остасы, пленэрда «саф» табигатьне дә, шәһәр күренешләрен дә күп сурәтли: «Иске Казан почмаклары» (1968–72), «Гыйнвар кары» (1998), «Җиңелчә салкын» (1999), «Октябрь» (2001), «Имән. Урман» (2000 еллар), «Яшь канәфер» (2001) сериялә ре. Рәссам параллель рәвештә графика өлкәсендә дә эшли: «Пешков крәстияннәр белән» (1979), «Шәкүр» (1980), «Скрипкачы Р.А.Бренинг» (1981), «Түбәтәйле автопортрет» (1982), «Кызыл киемле биюче» (1983), «Якуб Сәйфи фатирында» (1986). 1960–70 елларда агитплакатлар авторы: «КамАЗ төзүчеләр! Беренче автомобильне тапшырыйк!» (1974). Шигырьләр иҗат итә, үзенең рәсемнәре б-н бизәп, берничә шигырь җыентыгы бастыра.

Респ-ка күргәзмәләрендә (1959 дан), зона — «Зур Идел» (1967, 1980, 1985), бөтенроссия — «Совет Россиясе» (Мәскәү, 1960), РСФСР автономияле респ-калар рәссамнары әсәрләре (Мәскәү, 1971), РСФСР монументалист рәссамнары иҗатының 3 нче (Казан, 1977) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре 1968 (Р.Ә.Госманов, Э.Я.Зарипов б-н бергә), 1978, 1982 (Н.И.Гаделев б-н бергә), 1983, 1990, 2000, 2002, 2005, 2010 да Казанда; 1983 тә Йошкар-Олада уздырыла. Картиналары ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәгендә, Чуаш сәнгать музеенда, Әлмәт картиналар галереясында һ.б.да, шәхси тупланмаларда саклана (Россия, АКШ, Германия, Израиль).

Әсәр.: Миг. К., 1997; Осенние костры: Стихи. К., 2002; Птицы памяти: Стихи. К., 2002.

Әд.: Червонная С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984; Выставка произведений Виктора Кронидовича Фёдорова: Каталог. К., 2000; Валеева Д.К. «Я ведал Свет Небесной Высоты» // Казань. 2005. № 6; Виктор Фёдоров (1940–2001). Живопись. Рисунок: Каталог выставки произведений к 70-летию со дня рождения. К., 2010. *Т.В.Голубцова.*

ФЁДОРОВ Дмитрий Михайлович (1891, Казан — ?), архитектор, рәссам. 1907–12 елларда Казан сәнгать мәктәбенең архит-ра бүлегендә укый. Бер үк вакытта арх. В.А.Трифоновта җитештерүче һәм проектлаучы булып эшли. 1919 дан Ирекле дәүләт сәнгать остаханәсендә укыта. «Подсолнечник», «Всадник» берлекләре әгъзасы. 1921–23 тә ТАССР ХКСының Шәһәр һәм авыллар төзелеше ком-тының бүлек мөдире. 1924 тән «Татинженер» идарәсе, 1934 тән «Стройтрест» архитекторы. 1936–38 дә Казанның баш архитекторы (совет чорының беренче баш архитекторы). Бер үк вакытта 1922 дән Казан архит-ра-сәнгать ин-тында укыта, 1935 тән Казан шәһәр советының архит-ра советы эксперты, 1937 дән рәисе. 1934 тән Совет архитекторларының татар бүлеген оештыру бюросын гамәлгә куючыларның берсе һәм рәисе урынбасары. Ф. проектлары буенча Казанда Ленин бакчасындагы баскыч (1924, Ф.П.Гаврилов б-н бергә), «Чекистлар йорты» (1934–36) һ.б. объектлар төзелә. Конструктивизм юнәлешендә эшли.

Әд.: Саначин Э. Экскурс в архитектурную жизнь Советской Казани. К., 2014.

ФЁДОРОВ Иван Михайлович (31.6.1924, Кайбыч р-ны Турминский а. — 1.2.1971, Мәскәү өлкәсенең Павлов Посад ш.), Сов. Союзы Герое (24.3.1945), сержант. 1939 елда гаиләсе Канаш шәһәренә (Чуаш АССР) күченеп китә. 1942 нең сентябреннән Кызыл Армиядә һәм Бөек Ватан сугышы фронтларында, 25 нче гаубица артиллерия бригадасының 877 нче гаубица артиллерия полкы радист-койләүчесе (46 нчы армиянең 7 нче артиллерия һөҗүм дивизиясе). Көньяк-Көнбатыш, 3 нче Украина, Карелия һәм 2 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Днепр өчен сугышта (1943), Яссы-Кишинёв (1944) һәм Будапешт (1944–45) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 5 декабренә каршы төнендә Эрчи шәһәре янында (Венгрия) Дунай елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә: дошманның көчле уты астында беренчеләрдән булып радиостанция б-н елганы кичеп чыга һәм штурм төркеме б-н батарея арасында элемтә урнаштыра. 3 сәгать дәвам иткән аяусыз сугыш барышында мәгълүматлар җибәрә, артиллерия утын көйли. Плацдарм яулап алына, дошманга зур зыян килә. Сугыштан соң Совет Армиясендә хезмәтен дәвам итә. 1947–48 дә Канаш шәһәрендә кондитер ф-касында склад мөдире, 1948 дән Павлов Посад шәһәрендә яши, туку ф-касында слесарь булып эшли. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Шәһәр тибындагы Апас посёлогында Геройга бюст куела.

Әд.: Батырлар китабы — Книга Геров. К., 2000. *М.З.Хәбибуллин.*

ФЁДОРОВ Игорь Владимирович (5.4.1957, Казан), хирург, мед. фән. д-ры (1998), проф. (2002). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1980), Буа үзәк район хастаханәсендә эшли,1983 елдан тимер юл хастаханәсендә (Казан). 1986 дан Казан ГИДУВының (хәзер Казан мед. академиясе) хирургия кафедрасында, 1997 дән эндоскопия, эндоскопик һәм гомуми хирургия кафедрасында. Хезмәтләре билиар система патологиясенә, хирургик дәвалау ысулларына (оператив лапароскопия) карый. «Татарстан Республикасында эчке авырулы пациентларны эндохирургик дәвалау өчен яңа төр инструментлар, җайланмалар, ысуллар уйлап табу һәм клиник практикага кертү» хезмәте өчен ТР Дәүләт бүләгенә лаек була (2004).

Х е з м.: Клиническая электрохирургия: Практ. рук. М., 1997 (автордаш); Повреждения желчных протоков при лапароскопической холецистэктомии. М., 2003 (автордаш); Оперативная лапароскопия. М., 2004 (автордаш).

ФЁДОРОВ Михаил Иванович (1.8.1921, Пенза губ., Терновка р-ны Золоторёвка а. — 24.6.1969, Казан), мәхкәмә табибе, мед. фән. д-ры (1966), проф. (1966). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1950), шунда ук эшли, 1961 елдан мәхкәмә медицинасы каф. мөдире. Бер үк вакытта, 1954–59 да, ашыгыч мед. ярдәме станциясе директоры (Казан). Хезмәтләре странгуляцион асфикция буенча мәхкәмә-мед. экспертизасына карый. Туган вакытта асфикция кичергән балалардагы неврологик үзгәрешләрне һәм аларның физик үсешен өйрәнә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Бөтенсоюз мәхкәмә табибләре җәмгыятенең Татарстан бүлеге рәисе (1961–69). Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.



И.М. Фёдоров



Г.А. Фёдоров-Давыдов.

Х е з м.: О физическом развитии детей, перенёсших асфиксию при рождении // Казан. мед. журн. 1965. № 2; Судебно-медицинское и клиническое значение постасфиктических состояний. К., 1967; Неврологические изменения после асфиксии // Казан. мед. журн. 1969. № 5 (автордаш).

ФЁДОРОВ-ДАВЫ́ДОВ Герман Алексеевич (17.7.1931, Мәскәү — 23.4.2000, шунда ук), тарихчы, археолог, нумизмат, тарих фән. д-ры (1966), проф. (1969). Мәскәү ун-тын тәмамлый (1954). 1955–60 елларда СССР ФАнең Археол. ин-тында эшли. 1957 дән Мәскәү ун-тында. 1950 елларда Урта һәм Түбән Идел буе төбәкләренә, Төньяк Кавказга, Кырымга һәм Урта Азиягә археол. экспедицияләр инициаторы, оештыручы һәм аларда катнашучы. 1959–90 да СССР ФА Археол. ин-тының Идел буе археол. экспедициясен җитәкли (1970 елларга кадәр остазы А.П.Смирнов б-н бергә). Аның А.П.Смирнов б-н бергә язылган «Алтын Урданы археологик өйрәнү бурычлары» («Задачи археологического изучения Золотой Орды», «Советская археология» ж-лының 1959 елгы 4 нче санында басыла) дип аталган программ мәкаләсе Алтын Урда шәһәрләрендә, ш.и. Сарай әл-Мәхрусә, Сарай әл-Җәдид, Бәлҗәмин, Болгарда киң колачлы казу эшләре оештыруда зур роль уйный. Алтын Урда шәһәрләренең гаять бай матди мәдәниятен һәм социаль структурасын өйрәнүгә зур өлеш кертә. Рев-циягә кадәрге шәркыятьче галимнәр-нумизматлар (Х.М.Френ, П.С.Савельев һ.б.) традицияләрен дәвам итеп, Алтын Урдадагы акча сугу эшен һәм акча әйләнешен өйрәнүнең яңа юнәлешләрен алга сөрә. Аның «Нумизматика и эпиграфика» ж-лында дөнья күргән «Жүчиләр акчалары хәзинәләре» («Клады джучидских монет», 1960, т. 1), «Жүчиләр акчалары табылдыклары» («Находки джучидских монет», 1963, т. 4) хезмәтләрендә Алтын Урданың 1960 еллар башына мәгълүм булган барлык акчаларының топографиясе бирелә. Бер үк вакытта 14–15 йөзләрдәге рус акча сугу эшен өйрәнү б-н шөгыльләнә, Россия акчаларының рус кенәзлекләренең социаль-икътисади һәм сәяси тарихы буенча әһәмиятен күрсәтә. Күп кенә фәнни басмаларның, ш.и. «Советская археология», «Российская археология», «Татарская археология», «Известия Московского университета», «Вопросы истории» ж-лларының редколлегияләре әгъзасы була. Хез-



Н.Е. Федосеев.

мәтләре Алтын Урда шәһәрләре археологиясенә, тарихына һәм мәдәниятенә, урта гасыр лар нумизматикасына һәм археол. тикшерен нүләр методикасына карый; АКШта, Англиядә, Германиядә, Белгиядә, Венгриядә, Польшада, Эстониядә нәшер ителә һәм кабат басыла. Германия археол. җәмгыяте мөхбир әгъзасы (1983). Мәскәү ун-тының М.В.Ломоносов исем. бүләге лауреаты (1998).

Х е з м.: Кочевники Восточной Европы под властью золотоордынских ханов. М., 1966; Общественный строй Золотой Орды. М., 1973; Искусство кочевников и Золотой Орды. М., 1976; Монеты Московской Руси. М., 1981; Статистические методы в археологии. М., 1987; Золотоордынские города Поволжья. М., 1994.

Әд.: Д в о р н и ч е н к о В.В., Е г о р о в В.Л., Я б л о н с к и й Л.Т. Памяти Германа Алексеевича Фёдорова-Давыдова // Рос. археология. 2000. № 4.

Р.Г.Фәхретдинов.

ФЁДОРОВКА авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 26 *км* көньяк-көнчыгыштарак урнашкан. 2010 елда 48 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1920 елларда нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Чистай кантоны Котыш волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1926 да — 73, 1938 дә — 111, 1949 да — 112, 1958 дә — 151, 1970 тә — 131, 1979 да — 145, 1989 да — 21, 2002 дә — 34 кеше.

ФЁДОРОВКА авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 42 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Сармаш елгасы буенда. 2010 елда 82 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. 17 йөз ахырында — 18 йөз башында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Иванаева исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә; игенчелек, терлекчелек, умартачылык, чана, тәгәрмәч ясау, чыпта-кап сугу б-н шөгыльләнә. 1773–75 елларда Крәстияннәр кузгалышында Е.И.Пугачёв ягында сугышалар. 20 йөз башында миссионерлык мәктәбе, су тегермәне, ашлык саклау-сату һәм бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1239 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губерна сының Минзәлә өязе Яңа Спас волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Сарман, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1859 да — 328, 1897 дә — 735, 1906 да — 805, 1913 тә — 916, 1920 дә — 958, 1926 да — 590, 1938 дә — 484, 1949 да — 389, 1958 дә — 362, 1970 тә — 257, 1979 да — 207, 1989 да — 88, 2002 дә — 89 кеше.

Әд.: Заинская энциклопедия. К., 1994.

ФЁДОРОВКА авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 19 *км* көнбатыштарак, Үләмә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 136 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1618–19 еллардан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Яңа Усад исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү-приход мәктәбе (1891 дә ачыла), 2 җил тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 917 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Кызыл Алан волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Тәтеш р-нында. Халык саны: 1646 да — 11, 1782 дә — 94 ир-ат; 1859 да — 486, 1897 дә — 656, 1908 дә — 683, 1920 дә — 667, 1926 да — 791, 1938 дә — 780, 1949 да — 600, 1958 дә — 526, 1970 тә — 382, 1979 да — 250, 1989 да — 175, 2002 дә — 160 кеше.

ФЁДОРОВКА РАЙОНЫ́, БРның көньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. 1935 елның 31 гыйнварында оештырыла. Мәйдане — 1691 *км*². Үзәге — Фёдоровка авылы (Уфадан 230 *км* көньяк-көнбатыштарак). Халкы — 17951 кеше (2013). Татарлар саны: 1970 тә — 8924, 1979 да — 7783, 1989 да — 6895, 2002 дә — 6527 кеше. Район составында 70 торак пункт, ш.и. 10 татар, 7 рус-татар һәм 1 башкорт-татар авылы исәпләнә. Иң зур татар авыллары (2009): Балыклы (754 кеше) һәм Юрматы (748). Урта Идел буеннан татарлар Ф.р. терр-ясенә 18 йөзнең уртасында һәм 2 нче яртысында күпләп күченәләр. Алар, кердәшләр буларак, башкорт авылларына урнаша, соңрак бу авыллар татар авыллары (Балыклы, Каралачык, Әтәч, Явыш һ.б.) булып китә. Акбулат (1782), Балыклыбаш (1795) авылларына татарлар нигез сала. 2004/05 уку елында Ф.р.ның 7 мәктәбендә укыту татар телендә бара, 8 мәктәптә татар теле фән буларак өйрәнелә. Татар һәм рус телләрендә «Җиңүгә» – «К победе» район г-таларының нәшер ителә.

ФЁДОРОВСКИЙ авылы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 15 *км* көнчыгыштарак, Бәрле елгасы буенда. 2010 елда 922 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 68%, татарлар — 27%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау; урман ху җалыгы. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1646 елга кадәр нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Яңавыл, Каратун исемнәре б-н дә билгеле. Баштa халкы Зоя Троица-Сергий монастырена карый, 1764 тә — экономик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә; игенчелек, терлекчелек, он тарту, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Троица чиркәве, земство мәктәбе (1868 дә ачыла), хастаханә, 1 су һәм 3 җил тегермәне, салат з-ды, чәйханә, 1 казна шәраб һәм 10 вак-төякләр кибете була; чәршәмбе базары эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1753 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зоя өязе Әҗил волостенда, 1920 дән ТАССРның Зоя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Ульянково, 1927 нең 1 августыннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 264 ир-ат; 1859 да — 644, 1897 дә — 1141, 1908 дә — 1441, 1920 дә — 1380, 1926 да — 1421, 1938 дә — 1196, 1949 да — 566, 1958 дә — 660, 1970 тә — 625, 1979 да — 542, 1989 да — 718, 2002 дә — 900 кеше.

ФЁДОРОВСКИЙ посёлогы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 11 *км* көнчыгыштарак, Кече Сөлчә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 201 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, умартачылык. Башлангыч мәктәп. 1920 елларда нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Чистай кантоны Аксубай волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1926 да — 86, 1938 дә — 111, 1949 да — 131, 1958 дә — 182, 1970 тә — 196, 1979 да — 145, 1989 да — 104, 2002 дә — 171 кеше.

ФЕДОСЕ́ЕВ Леонид Федорович (16.3.1930, Горький өлкәсенең Городец р-ны Дрюково а.), корабльләр төзүче-инженер, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1979). Горький су транспорты инженерлары ин-тын тәмамлаганнан соң (1953), Калининград корабльләр ремонтлау з-дында эшли. 1955–75 елларда Яшел Үзән проектлау-конструкторлык бюросында, баш конструктор урынбасары, баш конструктор. 1975 тән Мәскәүдә эшли. Дәүләт бүләге корабльләр төзү өлкәсендәге хезмәте өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

ФЕДОСЕ́ЕВ Николай Евграфович (27.4.1869, Вятка губ. Нолинск ш. — 21.6.1898, Иркутск губ. Верхоленск ш.), революционер, Россиядә беренчеләрдән булып марксизм тәгълиматын пропагандалаучы. Казанда 1 нче гимназиядә укыган елларында (1880–88) үз тирәсенә илдәге тәртиптән риза булмаган яшьләрне берләштерә башлый: алар аның фатирында тыелган әдәбият укыйлар, иҗтимагый тормыш мәсьәләләре турында фикер алышалар. Тиздән Ф. марксизм б-н мавыга һәм Казанда беренче марксистик түгәрәк оештыра. 1888 елда аның фатирында тентү була, шул ук елның декабрендә «сәяси ышанычсызлыгы, фикерләренең зыянлы юнәлештә булуы һәм рөхсәт ителмәгән китаплар укыганы» өчен гимназиядән куыла. Тормыш итәр өчен аерым дәресләр бирә. Ф. марксистик әдәбият таратуда актив катнаша, яшерен басмаханә оештыру омтылышы ясый. 1889 ның 13 июлендә кулга алына һәм төрмәгә ябылуга хөкем ителә. 1892 елга кадәр Петербургның «Кресты» төрмәсендә утыра. Азат ителгәннән соң, Владимир шәһәренә килеп урнаша. 1892 нең сентябрендә Никольское

шәһәрендәге Морозов ф-касында стачка вакытында Ф. беренче тапкыр эшчеләрне оештыручы буларак чыгыш ясый, марксизм тәгълиматына нигезләнеп эшләнгән пролетар көрәш программасын ачыктан-ачык бәян итә. 1892 нең 10 сентябрендә яңадан кулга алына һәм Сольвычегодск шәһәренә 3 елга, шуннан 1895 нең июлендә марксистик түгәрәкләр б-н элемтәдә булганы өчен Көнчыгыш Себергә 5 елга, 1898 нең 21 июнендә Иркутск губернасының Верхоленск шәһәренә сөргенгә җибәрелә. Шунда үз-үзенә кул сала (сәбәбе сөргенгә җибәрелгән кешеләрнең берсенең «сәяси» сөргенгә җибәрелгәннәр арасында иганәләрнең эшчеләргә караганда күбрәк интеллигенция вәкилләренә бирелүе һәм моңа Ф. гаепле дип яла таратуыннан гыйбарәт була). Россиянең икътисади һәм сәяси үсеш үзенчәлекләрен марксизм күзлегеннән анализлап, народниклар карашларын тәнкыйтьләп күп кенә хезмәтләр яза. Партия программасы проектын төзи; киләчәктә В.И.Ленин Ф. тәкъдим иткән принципларны бердәнбер дөрес вариант дип таный. Ф. программасының төп фикерләре: самодержавие б-н революцион көрәштә пролетариатның җитәкче ролен тану; крәстияннәрне эшчеләр сыйныфының төп союздашы буларак карау; индивидуаль террорны кире кагу. Казан шәһәренең бер урамына Ф. исеме бирелә. Ш.у.к. *Федосеев түгәрәкләре.*

Әд.: Валиев А.М. Н.Е.Федосеев — один из первых марксистов в России. К., 1952; Клюкин В.И. Н.Е.Федосеев (1869–1898 гг.). Киров, 1969; Муравьёв В. Н.Е.Федосеев. М., 1969; Власов П.Т., Скворцов В.К. Заре навстречу (Повесть о Н.Е.Федосееве). К., 1984.

Л.М.Айнетдинова.

ФЕДОСЕ́ЕВ Н.Е. ТҮГӘРӘГЕ́ КИТАПХАНӘСЕ́, Казанда. Китапханә фондын «Студентлар клубы» китапханәсеннән китерелгән китаплар тәшкил итә. Легаль һәм легаль булмаган фондлары тарих, икътисад, сәясәт, хокук, беллетристика буенча китап һәм журналлардан туплана. Китапханәдән А.М.Стопани, Н.Э.Бауман, В.И.Ленин һ.б. файдалана. 1889 елның июлендә түгәрәк таркатылганнан соң, китапханәнең төп легаль өлеше полиция кулына эләгә. Легаль булмаган әдәбиятның күпчелеге студентларның шәхси фатирларында саклана (К.И.Кобелев һ.б.), һәм китапханәнең бу өлешеннән 1912 гә кадәр Казан РСДРП(б) ком-ты әгъзалары файдалана.

Әд.: Фёдоров М.К. Нелегальные библиотеки с начала 70-х годов до второй половины 90-х годов прошлого столетия // Из истории нелегальных библиотек революционных организаций в царской России. М., 1956; Каримуллин А.Г. Книги и люди: Исследование. К., 1985.

ФЕДОСЕ́ЕВ ТҮГӘРӘКЛӘРЕ́, беренче марксистик түгәрәкләр. Казанда һәм Идел буеның башка шәһәрләрендә Н.Е.*Федосеев* һәм аның фикердәшләре башлангычында 1888–89 елларда оештырыла. Шундый 10 лап түгәрәк билгеле, һәрберсендә 10–15 кеше була. Җитәкчеләре арасында: Н.Е.Федосеев, Г.Волков һ.б.; түгәрәк әгъзалары: П.Скворцов, А.Санин, В.Ульянов (В.И.Ленин), П.Семеновский, А.Скворцов, Е.Санина, А.Соловьёв һ.б. Түгәрәк әгъзалары «Хезмәтне азат итү» («Освобождение труда», Женева) төркеме, Ростов-Дон һәм Харьков шәһәрләрендәге эшчеләр түгәрәкләре, Петербург һәм Мәскәү марксистлары б-н элемтә урнаштыралар. К.Маркс, Ф.Энгельс, К.Каутский, Г.Плеханов, П.Лафарг хезмәтләрен өйрәнәләр, рев-цияне пропагандалау б-н шөгыльләнәләр, листовкалар һәм прокламацияләр чыгаралар, сәяси тоткыннарга матди һәм медицина ярдәме күрсәтүне оештыралар. Федосеев җитәкчелегендәге түгәрәкнең китапханәсе, акча кассасы (акчалар түләүле студент кичәләреннән алынган җыемнардан һәм түгәрәк әгъзаларының үз теләкләре б-н иганә итүеннән туплана). 1889 ның июлендә Федосеев һәм түгәрәк әгъзаларының бер өлеше кулга алына. Әлеге эш буенча тикшерү бер елга кадәр дәвам итә. Түгәрәкләрнең күбесенең эшчәнлеге туктатыла. 1890 да Казанда И.Сигорский җитәкчелегендәге яшерен түгәрәк эшли. 1891 дә яшерен басмаханә оештырыла, тыелган әдәбиятны бастыру эше җайга салына, «Кресты» төрмәсендә утырган Федосеевка, ш.у. Петербургның забастовка игълан иткән 300 эшчесе гаиләләре өчен акча җыела.

Әд.: Нафигов Р.И. Тайны революционного подполья. К., 1981; Летопись борьбы и свершений: Хроника партийной организации Татарии. 1883–1895. К., 1985. Кн. 1.

Л.М.Айнетдинова.

ФЕДОСЕ́ЕНКО Наталья Викторовна (4.1.1960, Оренбург өлкәсенең Тоцк р-ны Свердлов исем. с-зы), технолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2008). Оренбург политехник ин-тын тәмамлаганнан соң (1982), «ВНИИнефть» Төбәк фәнни-технол. үзәгендә эшли, 1990 елдан ТатНИПИнефтьтә (Бөгелмә ш.) әйдәп баручы инженер. Үйлап табуга 4 авторлык таныклыгы бар. Дәүләт бүләге авыр чыгарылышлы нефть запасларын табу нәтиҗәлеген күтәрү максатында яңа технологияләр һәм җиһазлар комплексын эшләү һәм гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә.

Хезм.: Применение цепных приводов насосов при эксплуатации скважин с высоковязкой продукцией // Нефт. хоз-во. 1999. № 6 (автордаш); Применение цепных приводов для эксплуатации малодебитных скважин // Нефть Татарстана. 2001. № 1 (автордаш).

ФЕДО́Т авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 23 *км* төньяктарак, Зичә елгасы буенда. 2010 елда 37 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 76%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Архангельский, Алексеевка исемнәре б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1773–75 еллардагы Крәстияннәр кузгалышында Е.И.Пугачёв ягында сугышалар. 1870 елгы мәгълүматларга караганда, су тегермәне, 20 йөз башында Казан Богородица чиркәве (1868 дә төзелә), чиркәү-приход мәктәбе, тимерчелек алачыгы, су тегермәне, ашлык саклау-сату кибете, 1 шәраб һәм 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 405 дис. тәшкил итә. 20 йөз башында Ф. авылыннан чыгучыларның кайберләре император Николай II нең шәхси сакчылары булып хезмәт итә (алар арасында — Изге Георгий орденының тулы кавалеры А.Д.Атласов, П.В.Кустовский, П.В.Васильев). 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әхмәт волостенда,



Федот авылы. Казан Богородица чиркәве.1868.

1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Чаллы, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1859 да — 316, 1906 да — 256, 1913 тә — 314, 1920 дә — 308, 1926 да — 242, 1938 дә — 249, 1949 да — 179, 1958 дә — 102, 1970 тә — 107, 1989 да — 53, 2002 дә — 21 кеше.

Әд.: Заинская энциклопедия. К., 1994.

ФЕДО́ТОВ Александр Сергеевич (р. 25.1.1955, Эстония ССР, Выру ш.), нәкышьче, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2005), РФнең атказ. рәссамы (2016). Рязань сынлы сәнгать уч-щесен (1975), В.И.Суриков исем. Мәскәү сәнгать ин-тын (проф. Д.К.Мочальский остаханәсе, 1983), Россия САнең Х.Г.Якупов җитәкчелегендәге Ижат остаханәсен (1986) тәмамлый. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1990). Пейзаж остасы. Ф. картиналарына образларның монументальлеге, форманың кыска һәм ачык гомумиләштерелүе, графикага якын торган төгәл тел хас. Төп



А.С.Федотов. «Печән өсте». 1986. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда.

әсәрләре: «Авылда төн» (1988), «Капка», «Айлы төн» (икесе дә — 1990), «Көймәләр» (1993), «Ай калыкканда» (1995), «Кышкы кояш» (1996), «Су буендагы тирәкләр» (1997), «Иртә төшкән кар. Яр» (1999), «Томан» (2002), «Казан киче» (2005), «Болытлар. Кибәннәр» (2006), «Парк. Агачлар» (2010), «Зәңгәр кар» (2011).

Бөтенсоюз — «Ил яшьлеге» (1982), «Җиңүнең 45 еллыгы» (1990); бөтенроссия — «Ватан образы» (1989) пейзаж, Россиянең үзәк өлкәләре рәссамнары (1997), «Россия-9» (1999), «Россия-10» (2004), «Россия-11» (Мәскәү, 2009), «Синең исемеңә» (2000), «Яшел аваз» (Плёс ш., 2002), зона — «Зур Идел» (1985–2011), халыкара — «Җиңү» (Мәскәү, 2005) һ.б. күргәзмәләрдә катнаша.



А.С. Ф е д о т о в. «Болыт». 1996.
ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда.

Шәхси күргәзмәләре Түбән Кама шәһәрендә (1991), Казанда (2002, 2006) уздырыла. Картиналары ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Әлмәт картиналар галереясында, Россия, Германия, Норвегия, Англия һ.б. илләрдәге шәхси тупланмаларда саклана. Медаль б-н бүләкләнә.

Әд.: И л ь и н а М. Табигать белән күзгә-күз // Идел. 2002. № 7; В ә л и е в а - С ө л ә й м а н о в а Г.Ф. Табигатьтән илһам алып // Идел. 2014. № 6; Семейная страсть — живопись // Татарстан. 1994. № 3–4; И в а н о в М. Превыше всякой лжи // Казань. 1998. № 5–6.

ФЕДО́ТОВ Владимир Дмитриевич (1.1.1940, Кыргызстан ССРның Җәлалабад ш. — 8.8.2012), физик, физика-матем. фән. д-ры (1981), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (1992), РФнең атказ. фән эшлеклесе (1995). Казан ун-тын тәмамлый (1962), РФА КГҮнең Биохимия һәм биофизика ин-тында эшли (бүленеп: 1970–85 елларда Казан химия-технол. ин-тында), 1985–92 дә молекуляр биофизика лаб-ясе мөдире, проф. (1986), 1992–2002 дә ин-т директоры, 2002 дән фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре югары молекуляр гетероген системаларга (табигый һәм синтетик полимерларга, катлаулы биологик системаларга) карый. Ф., беренче буларак, ТМР алымы ярдәмендә үсемлек һәм хайван тукымаларында гы су күрсәткечләренең чиста суныкына якынлыгын күрсәтә. ТМРда яңа тикшеренү өлкәсе — югары молекуляр гетероген системаларның комплексы спектроскопиясен булдыра. Аксымнарның динамикасын һәм гидратациясен тикшергәндә аксымнарда һәм синтетик полипептидлардагы локаль хәрәкәтнең 3 тибын идентификацияли һәм микъдар җәһәтеннән тасвирлый (корреляция функцияләре атамаларын кулланып), электростатик кыр флуктуацияләре б-н корулы һәм котыплашкан аксым төркемнәренең конформацион хәрәкәтенең корреляцион функциясе арасында микъдари бәйләнешне билгели. Ф. аксымнарның үзара электр статик тәэсирләшүе нәтиҗәсендә эремәдәге аксым макромолекулаларының Броун әйләнмәле хәрәкәте анизотропиягә дучар була дигән ачыш ясый.

Х е з м.: Структура и свойства микроэмульсий масло-вода // Журн. общей химии. 2002. Т. 72, № 7; Сорбция паров воды и ацетонитрила сывороточным альбумином человека // Журн. физ. химии. 2002. Т. 76, № 12.

ФЕДО́ТОВ Владимир Сергеевич (13.1.1950, Куйбышев өлкәсенең Октябрьск ш.), баянчы, дирижёр, педагог, ТРның халык артисты (1993), РФнең атказ. артисты (2001), проф. (2003). Казан консерваториясенең Н.Черняевта баян классын, С.Хәбибуллинда дирижёрлык классын тәмамлый (1984). 1971–76 елларда ТАССР Җыр һәм бию ансамбле баянчысы, 1976–79 һәм 1988–93 тә Татар филармониясе концертмейстеры һәм солисты. 1984–88 дә — Казан консерваториясендә, 1993 тән — Татар гуманитар-пед. ун-тында, 2011 дән Казан ун-тында укыта. Шәкертләре арасында халыкара һәм бөтенроссия конкурслар лауреатлары бар. Ф. — Россиядә баянда уйнап концерт куючы күренекле вәкилләрдән берсе. Илдә беренчеләрдән булып проф. автономияле радиосистема куллана башлый, төрле жанр һәм стильдәге муз. әсәрләрне шәрехләүдә сценография һәм режиссурага яңалыклар кертә. Ф.ның иҗат диапазоны акад., эстрада-джаз программаларын, дөнья халыклары музыкасын колачлый. Төрле елларда Ф. соло концертлары б-н, иҗат коллективлары составында һәм концертмейстер буларак (И.Шакиров, Р.Ибраһимов, З.Сөнгатуллина, В.Шәрипова, Ф.Әгъләмова, Г.Ильясов, Э.Җәләлетдинов, З.Нурмөхәммәтов һ.б. җырчылар б-н) Россия шәһәрләрендә һәм чит илләрдә (Япония, Австрия, Германия, Италия, Греция, Кипр, Венгрия, Польша, Төркия һ.б.) гастрольләрдә була. РФ һәм ТР телерадиокомпанияләре өчен язмаларны гамәлгә ашыра, соло альбомнары чыгара: «Владимир Федотов уйный» («Играет Владимир Федотов»), «Баянның сихри моңнары» («Чарующие звуки баяна»), «Дустыма» һ.б. Үзенчәлекле әсәрләр, концерт транскрипцияләре, баян һәм төрле музыка уен кораллары өчен күчермәләр авторы: «Сиртаки», «Идел сюитасы» («Идель-сюита»), «Еврей көйләре» («Еврейские наигрыши»), «Рус лирик көе» («Русский лирический»), «Татар темаларына попурри» («Попурри на татарские темы»), «М.Имашев темаларына фантазия» («Фантазия на темы М.Имашева»), «Тәфтиләү», «Су буйлап», «Кичке Казан» («Вечерняя Казань», С.Сәйдәшев истәлегенә концерт вальсы) һ.б.



В.С. Федотов.


Ф. әсәрләре ТРның Җыр һәм бию ансамбле, башка иҗат коллективлары һәм аерым башкаручыларның репертуарында урын ала. Баянда башкару һәм пед. мәсьәләләренә караган методик хезмәтләр һәм мәкаләләр, баян һәм аккордеон өчен әсәрләр җыентыклары (уку-укыту һәм концерт репертуары) авторы. Башкаручы һәм композитор буларак бөтенроссия һәм халыкара конкурслар лауреаты: 12 нче Бөтендөнья яшьләр һәм студентлар фестивале (Мәскәү, 1985), Кастельфидардо (Италия, 1995), Клингенталь (Германия, 1996), Монтезе (Италия, 1 нче бүләк, 2005), Нью-Йорк (АКШ, Көмеш диплом, 2007), Ланчано (Италия, Гран-при, 2011) һ.б. шәһәрләрдә. Татарстан комсомолының М.Җәлил исем. бүләге (1990), ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге (2010) лауреаты.

ФЕДО́ТОВ Евгений Михайлович (4.2.1956, Үзбәкстан ССРның Әндижан ш.), матем., физика-матем. фән. д-ры (1998), проф. (2000). 1978 елда Казан ун-тын тәмамлый, шунда ук эшли, проректор (2002–04). Хезмәтләре матем. физиканың нәлинияле мәсьәләләрен хәл итүнең челтәр алымнарына карый. Ф. нәлинияле эволюцион тигезләмәләр өчен тулысынча консерватив челтәр схемалар классын төзи, ике катламлы нәлинияле оператор-аермалы схемаларның корректлыгы теориясен эшли.


Х е з м.: О корректности нелинейных двухслойных операторно-разностных схем // Дифференциальные уравнения. 1981. Т. 17, № 7 (автордаш); Корректность одного класса консервативных нелинейных операторно-разностных схем // Изв. вузов. Математика. 1985. Т. 10 (автордаш); Исследование сходимости разностной схемы для трёхмерных уравнений динамики вязкой жидкости // Изв. вузов. Математика. 1999. № 1.

ФЕДО́ТОВ Юрий Степанович (17.8.1938, Казан — 5.10.2008, шунда ук), актёр, ТАССРның һәм РФнең халык артисты (1979, 1996). 1957 елда Казан Зур драма театры труппасының ярдәмче составына алына, 1961 дә театр каршындагы студияне тәмамлый һәм төп составка кабул ителә. Ул башкарган яшь герой образлары үзләренең эчкерсезлекләре һәм табигыйлекләре, беркатлы ачык һәм сөйкемле булулары б-н игътибарны җәлеп итәләр: техник-төзүче Гусев («Сипкелле кыз», А.Успенский), табип Карпов («Хезмәттәшләр», В.П.Аксёнов, Ю.М.Стабовой), Михаил («Левониха орбитада», А.Е.Макаёнок), студент Золотарёв («Давылга табан», Р.Ишморат), Борис Забродин, Володя Воробьёв («Ленинград проспекты», «Нәфрәттә аңлашу», И.В.Шток), Володя Белов («Сау булыгыз, егетләр», Б.И.Балтер, В.Н.Токарев), Владик («Мәхәббәт турында 104 бит», Э.С.Радзинский), Леонидик («Минем бичара Маратым», А.Н.Арбузов) һ.б. Кешенең шик-шөбһәләр һәм кирәксезлеген тою хисе

б-н тулы эчке дөньясын актёр Михаил («Зыковлар», М.Горький, 1966) образында ача. Ул башкарган Голубков («Качу», М.А.Булгаков, 1967) образы әхлакый инанганлык, зыялылык б-н аерылып тора. Лукашин («Бервакытны, Яңа ел киченде», Э.В.Брагинский, Э.А.Рязанов, 1969) һәм Уилл («Булыргамы, булмаскамы?», У.Гибсон, 1976) образларында лирик герой темасы алга таба үсеш ала. Иҗади шәхеснең үз-үзен танытырга омтылуы, герой - ның әйләнә-тирә мохит б-н мөнәсәбәте, үз-үзеңне корбан итәргә һәм батырлык күрсәтергә әзер тору мәсь әләвре Ф. иҗатында аерым урын ала һәм Иван Позднышев («Көчле яңгырлар арасында», А.П.Штейн, 1969), Саттаров һәм Муса Җәлил («Дәвам», 1972; «Билгесез көн», 1984; Д.Вәлиев), Саккулин («Вакыйгада катнашучылар», А.И.Гельман, 1977), Троян («Астория» кунакханәсе», А.П.Штейн, 1980) образларында аеруча көчле чагылыш таба. Ф.ның Кәлин Абабий («Изгеләрдән изге», И.П.Друцэ, 1977), Иван Климов («Иван һәм Мадонна», А.И.Кудрявцев, 1985), Тевье («Мәрхүмне искә алу догасы», Г.И.Горин, 1992) кебек геройлары социаль характеристикаларының төгәллеге, тормышчан, көчле гаделлек хисенә ия булуллары б-н аерылып тора. Актёр Алексей Орлов («Патша ауда», Л.Г.Зорин, 1980), Томас Мор («Һәр заман кешесе», Р.Болт, 1986) образларында героик характерның төрле, кайвакыт кеше ышанмаслык дәрәҗәдә каршылыклы яклары н, Фёдор патша (шул исем. әсәр буенча, А.К.Толстой, 1988) образында үзенә йөкләнгән бурычны (миссияне) башкарырга сәләтсез икәнен аңлаган кешенең рухи фаҗигасен оста гәүдәләндерә. Ф. тарафыннан иҗат ителгән Пахомов («Урмандагы веранда», И.М.Дворецкий, 1971), Андрей («Иң бәхетле», Э.Я.Володарский, 1975), Лёня Шиндин («Без, түбәндә кул куючылар», А.И.Гельман, 1980), Шабельников («Карагыз, кем килгән», В.К.Арро, 1983) кебек замандашлары образлары тормышка актив мөнәсәбәтләре, тормышта тоткан урыннарын раслауда ярсу, ялкынлы булулары б-н бәйләнәләр. Жорж Дюруа («Сөекле дустым», Г.Мопассан романы буенча, 1981), Муромский («Эш», А.В.Сухово-Кобылин, 1986), Войницкий («Ваня абзый», А.П.Чехов, 1993), Президент («Мәкер вә мәхәббәт», Ф.Шиллер, 1996) рольләре образларның үзенчәлекле шәрехләнүе б-н билгеләп үтелә. Татарстан комсомолының М.Җәлил исем. бүләге (1970), ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге (1981) лауреаты. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары б-н бүләкләнә.



Ю.С. Федотов.





Ю.С. Федотов: 1. Голубков («Качу», М.А. Булгаков); 2. Иван Климов («Иван һәм Мадонна», А.И. Кудрявцев) рольләрендә.

Әд.: Народные артисты. К., 1980; Цекиновский Б. Чем дышит трагедия // Театральная жизнь. 1988. № 21; Ингвар И., Илялова И. Русский театр в Казани. К., 1991; Благов Ю. Грани таланта: Творческий портрет Юрия Федотова // Казань. 2002. № 3/4.

Ю.А.Благов.

ФЕДО́ТОВКА (Аланлык) авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 58 *км* көнбатыштарак, Куак елгасы буенда. 2010 елда 419 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Чиркәү. 1730 елларда нигез салына. Беренче исеме — Аналыкова, 1750 елларда җирле халыкның православие диненә күчүе сәбәпле, хәзерге атамасын ала. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү (1910 да төзелә), чиркәү-приход мәктәбе (1890 елларда ачыла), 3 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1267 дис. тәшкил итә. Совет хакимияте чорында Ф. халкы 1920 елгы «Сәнәкчеләр» фетнәсендә актив катнаша. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Яңа Чыршылы волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Шөгер, 1959 ның 16 октябреннән Лениногорск р-нында. Халык саны: 1859 да — 460, 1889 да — 720, 1910 да — 1088, 1920 дә — 1209, 1926 да — 1144, 1938 дә — 1139, 1949 да — 888, 1958 дә — 1072, 1970 тә — 844, 1979 да — 667, 1989 да — 482, 2002 дә — 477 кеше.

ФЕДЯ́ЕВ Владимир Леонидович (29.1. 1950, Мари АССРның Новый Торъял р-ны Маскакнур а.), механика өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2002). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1972), РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында эшли, 1985 елдан робот техникасы проблемалары лаб-ясе мөдире; 1989 дан технол. процессларны модельләштерү лаб-ясе мөдире. 1991–98 дә РФА КГҮнең Механика һәм машиналар төзү ин-тында шул ук исемдәге лаб-янең мөдире һәм директор урынбасары. Хезмәтләре сыекчалы сүрүләрнең үзара тәэсирләшүенә, биомеханикага, технол. процессларның җылылык һәм масса алмашуына һәм модельләштерелүенә багышлана. Ф. дулкынсыман-деформацияле озынча җисемнәрнең үзле сыекчада хәрәкәте теориясен; электр дугалы мичләрдә эреткән һәм эретеп ябыштырган вакытта булган процессларның математ. модельләрен; җылы алмаштыргычларның үзлекләрен хисаплауның аныкланган алымнарын; югары нәтиҗәле фильтрларны һәм градирняларны (ТР пр-тиеләрендә гамәлгә кертелгән) эшли. ТР Дәүләт бүләге иясе (2012). 2 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» ордены медале б-н бүләкләнә. Уйлап табуга 4 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Хезм.: Математическое моделирование рабочих процессов и реконструкция теплообменников. К., 2001; Гидравлический расчёт водораспределительных систем промышленных градирен // Актуальные проблемы механики сплошной среды. К., 2006 (автордаш); Экспериментальное исследование оросителей градирен // Проблемы тепломассообмена и гидродинамики в энергомашиностроении. К., 2006 (автордаш).

ФЕДЯ́ЕВО авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 40 *км* көньяк-көнбатыштарак, Чангар елгасы буенда. 2010 елда 17 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. 1565–67 еллардан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Федяево-Ключ исеме б-н дә билгеле. Башта халкы Зоя Троица-Сергий монастыре карамагында була, 1764 тә — экономик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына керә; игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 җил тегермәне, 2 вак-тояклар кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1348 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зоя өязе Келәнче волостенда, 1920 дән ТАССРның Зоя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Тәмте, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1646 да — 90, 1782 дә — 156 ир-ат; 1859 да — 382, 1897 дә — 556, 1908 дә — 668, 1920 дә — 717, 1926 да — 643, 1938 дә — 486, 1949 да — 226, 1958 дә — 177, 1970 тә — 123, 1979 да — 78, 1989 да — 38, 2002 дә — 27 кеше.

ФЕ́ЙГИН Владимир Аронович (5.1.1947, Казан — 3.9.2002, шунда ук), актёр, ТССРның халык артисты (1991). Казан мәдәният ин-тын тәмамлый (1978). Иҗат эшчәнлеген Казан җитен комб-ты клубындагы үзешчәннәр коллективында башлап җибәрә, анда шактый гына күренекле рольләр башкара: Сгана-

рель («Иреҡсеҙдән табип», Ж.Б.Мольер), Пётр («Соңғылар», М.Горький), Миловидов («Кеше күп ҡыелған ҡырҙә», А.Н.Островский), Володя Ульянов («Таң атканда — яшенле яңғыр», Е.Г.Зильберман, В.Холявин). 1969 елда Казан Зур драма театры труппасына чакырып алына. 1976 дан — Казан яшь тамашасылар театрында (ТЮЗ). Шактый гына зур рольләр башкара, тиз арада театрның әйдәп баручы остәлары сафына баса. Матур тышкы кыяфәте, сәхнәҙәге мөлаемлығы, теге яки бу роль тудырған шартларда импровизация ясау остәлығы актёрның һәр эшен сәхнәҙә күренекле вакыйға итә. Ф. башкарған Журналист («Малаховны туктатығыз», В.А.Аграновский), Массовик («Сөйгәннәрегез белән аерылыш магыз», А.М.Володин), Тезей-Оберон («Ҡәйге төндә кергән төш», У.Шекспир), дон Гомес («Сид», П.Корнель), Шервинский («Турбиннар көне», М.А.Булгаков), Роберт Кеплен, Дэвид Макбейн («Хәтәр борылыш», «Пыяла читлек», Дж.Б.Пристли), Аждаһа (шул исем. әсәр буенча, Е.Л.Шварц), Белобрыков («Ҡимерү», «Кич тә булды, иртә дә...», Б.Л.Васильев повесте буенча), Ксанф («Төлке һәм йөзем ҡимеше», Г.Фигейредо) рольләре истә калырлык сәнгатьле тышкы форманың



В.А.Фейгин.



В.А.Фейгин Ксанф ролендә («Төлке һәм йөзем ҡимеше», Г. Фигейредо; уңда – Клея ролендә Т.Н. Угнивенко).

күңел халәтен гәүдәләндерҙүче психол. нигез б-н үрелеп баруы ягыннан үзенсәлекле. Актёр тудырған Чарлз Кейдемин («Тынгысыз ҡан», Н.Коуард), Король («Золушка», Е.Л.Шварц), Аллаһ («Сыҡуаньнан килгән мәрхәмәтле кеше», Б.Брехт), принц Валламбрёз («Капитан Фракасс», Т.Готье романы буенча) кебек комедия рольләре ҡи ңеллеге, импровизациянең табигыйлеге, ачык театральлеге, юмор хисе б-н аерылып тора. Ф. еш кына әкиәтләрҙәге образларны гәүдәләндерә, хәтта тискәре геройлар да (А.Н.Толстой романы буенча куелған «Ахмаклар илендәге Буратино ма ҡаралары» спектаклендә Карабас, Ю.Ч.Михайлов әсәре буенча куелған «Патша улы Иван» спектаклендә Аггей патша) аның башкаруында ми һербанлылык б-н сугарылған була. Еш кына нәфис сүз остасы буларак чығышлар ясый, концертлар алып бара.

Әд.: Благов Ю. Казанский театр юного зрителя: Очерк истории. К., 1986.

Ю.А.Благов.

ФЕ́ЛЬДМАН Давид Исаакович (1. 10.1922, Киев — 14.10.1994, Казан), хоҡук белгече, юридик фән. д-ры (1966), проф. (1967), ТАССР һәм РСФСРның атҡаз. фән эшлеклесе (1979, 1991). Мәскәү юридик ин-тын тәмамлый (1945). 1949–52 елларда Казан юридик ин-тында уҡыта. 1952 дән Казан ун-тында: 1964–75 тә дәүләт һәм хоҡук теориясе һәм тарихы, 1975–91 дә дәүләт хоҡуҡы, совет төзелеше һәм халыҡара хоҡуҡ каф. мөдире, 1991 дән дәүләт һәм халыҡара хоҡуҡ каф. профессоры. Хезмәтләре халыҡара хоҡуҡ теорияһе һәм тарихына, СССРның тышкы сәясәте, халыҡара хоҡуҡ субъектлығы, халыҡара хоҡуҡны тану, халыҡара хоҡуҡны нормативсистемалаштыру мәсьәләләренә ҡарый. «Халыҡара хоҡуҡ» («Международное право», М., 1982) дәреслеге һәм «Халыҡара хоҡуҡ курсы» («Курс международного права», т. 1–7, М., 1989–93) авторларының берсе. «Халыҡара хоҡуҡ» («Международное право», 1917–1972, М., 1976; 1973–1985, М., 1987; 1986–1990, СПб., 1992) библиографик белешмәсен төҙөне башлап йөрөүче һәм ҡәвәтлы мөхәррире. Бөек Ватан сугышында катнаша. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Современные теории международно-правового признания. К., 1963; Признание государств в современном международном праве. К., 1965; Теоретические проблемы методологии исследования государства и права. М., 1975 (автордаш); Система международного права. К., 1983.

Әд.: Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3; Турина Н.Е. Давид Исаакович Фельдман, 1922–1994. К., 2005.

ФЕНОЛЯТЛА́Р, феноллардың гидроксил төркемендә водород атомын металлар белән алыштыру продуктлары. Составын серкә, углеводородлы фракцияләр һәм су тәшкил иткән натрий фенолятытехник эремәсе (НФТЭ) Хайваннарның токсикологик, радиацион һәм биол. куркынысызлығы буенса федераль үҙәк (Казан), Казан вет. ин-ты галимнәре (Х.Х.Абдуллин, И.Н.Зыков, Г.З.Равилев, А.С.Селиванов, В.С.Угрюмова, И.М.Шермергорн) тарафыннан дезинфектант буларак тәкъдим ителә. Респ-када сунигезендәге натрий фенолятыэремәсен «Казаноргсинтез» АҖ ҙитештерә. НФТЭның авыру китереп чығаручы гөмбәчекләргә, вирусларға, хламидияләргә ҡаршы торучанлығының юғары нәтиҙәлелеге дәлилләнә. 1969–2000 елларда вет. өлкәсендә бруцеллёз, түләмә һәм башка йоғышлы авыруларны китереп чығаручыларға, тилһә вирусына, парагрипп-3, мөгезле эре терлекләр ринотрахеиты, хламидиоз авыруларына ҡаршы чара буларак, ш.у. терлекчелек корылмаларын, терлекләрне һавада йөртү урыннарын һәм туфракны дезинфекциялау өсөн ҡулланыла.

Әд.: Селиванова А.С., Равилов А.З., Угрюмова В.С. Изыскание химических соединений, оказывающих инактивирующее действие в отношении вируса ящура // Материалы докладов Всесоюз. науч. конф., посвящённой 100-летию Казан. вет. ин-та. К., 1974; Дезинфектанты широкого спектра действия // Ветеринария. 1979. № 5.

В.С.Угрюмова, Ә.Х.Фазылҙанов.

ФЕНО́МЕНОВ Николай Николаевич (21.3.1885, Орёл губ. Ливин ш. — 30.11.1918, Петроград), акушер-гинеколог, медицина д-ры (1880). Хәрби-мед. академияһен тәмамлаганнан соң (1878, С.-Петербург), шунда ук, акушерлыҡ һәм гинекол. кафедрасы каршында калдырыла (1883 елда Германиялә стажировкала була).1885 тән Казан ун-тының акушерлыҡ һәм хатын-кызлар авырулары кафедрасында, ординар проф. (1892 дән), шәрәфле лейб-акушер (1902 дән), атҡаз. проф. (1904). 1899 дан С.-Петербургта: Хатын-кызлар мед. ин-тының акушерлыҡ һәм хатын-кызлар авырулары каф. мөдире, бер үк вакытта Петербург бала тудыруда булышлыҡ күрсәтү йорты директоры. Хезмәтләре оператив акушерлыҡка,онкологияға ҡарый. Казан ун-ты клиникасында хирургия практикасына асептика ҡулланыуны кертә. Табибләрнең Петербург акушерлыҡ-гинекол. ҙәмгыяте рәисе (1909).

Х е з м.: К патологии и терапии фаллопиевых труб // Врач. 1885. № 43, 47, 49; 34 чревосечения // Врач. 1888. № 1–3; Оперативное акушерство. К., 1892.

ФЕОДАЛИ́ЗМ (лат. feodúm — лен, феодаль ҡир биләү), урта гасырларда Көнбатыш һәм Үҙәк Европадағы социаль система. «Ф.» термины 18 йөз ахырында, Француз рев-циясе алдыннан барлыҡҡа килә; дәүләт б-н идарә итүдә «иске тәртипләрне» (абс. монархия, дворянлыҡ хакимлеге) саҡлау күҙ алдында тотыла. Ф. марксистик әҙәбиәттә икътисадта а.х. ҡитештерүе өстенлеге, натураль хуҡалыҡ хакимлек итү, төп ике социаль сыйныф (феодаллар һәм крәстиәннәр) булу, икътисади булмаған мәжбүриләү алымнары файдалану, юғары хакимиятне ҡир биләү б-н берләштерү һ.б. хас булған социаль-икътисади формация буларак карала. Бу формация крепостной крәстиәннәрнең эре ҡир милекселәренә тулысынча бәйле булуына нигеҙләнә. Классик Ф.га катлауларның хоҡук тәртибендә беркетелгән юридик тигезсезлеге һәм рыцарьлар хәрби оешмасы хас. Ф.ның идеологик һәм әхлаҡый нигезен урта гасырлар мәҙәниәтенең характерын билгеләгән христианлыҡ тәшкил итә. Европада Ф., Рим империяһен варварлар яулап алганнан соң, 5–9 йөҙләрҙә формалаша. Тәүәк ату чорында (12–15 йөҙләр) шәһәрләр икътисади һәм сәяси яктан нығый, шәһәр халҡы формалаша, сословиеле вәкилләр ҡыелышлары (Англия парламенты, Франциядәге Ген. Штатлар, Новгородта вече, Алтын Урда, Казан һ.б. татар ханлыҡларында корылтай) рәсмиләштерелә. Сословиеле монархия аксөйәкләр мәнфәгәтьләре б-н генә түгел, ш.у. башка катлаулар фикере б-н дә исәпләшергә тиеш була. Шәһәрләрҙә икътисад үсеше капиталистик типтағы эшмәкәрлек эшүәнлеге үсүгә китерә, аксөйәкләр хакимлегенең натураль хуҡалыҡ нигеҙләрен ҡакшата. 16–18 йөҙләрҙәге рев-циялә р б-н Ф. чорының төгәлләнүе тәғәйенләнә.

Урта Идел буенда Ф. формалашу беренче феодаль дәүләтләр — *Хәзәр ҡағанлығы* һәм *Идел буе Болғар дәүләте* барлыҡҡа килү чо-

рына туры килә. Анда 9 йөздә феодаль вотчина рәвешендәге җир биләү (к. *Җир биләү, Җирдән файдалану*) барлыкка килә. Үсеш алган феодаль мөнәсәбәтләргә күчү 13–16 йөзләргә карый. Алтын Урдада күчмә терлекчелек һәм җәмгыятьнең хәрби-аксөяк оешмалары б-н бәйле феодаль мөнәсәбәтләр яши. Хәрби йомышлылар катлавы төп рольне уйный. Алтын Урда таркалганнан соң барлыкка килгән татар ханлыклары, ш.и. Казан ханлыгы аның дәүләт төзелешенең төп сыйфатларын мирас итеп алалар. Аларда социаль оешу тәртибе җир биләүгә хокуклар булу б-н бәйле иерархия системасына ия була, җирбиләүчеләр шул хокуклар өчен үзләренең сюзеренарына хезмәт итәргә тиеш булалар. Югары хакимият *Җүчиләр* нәселе ханнары кулында кала. Иң югары дәрәҗәле аксөякләр катлавына *үгланнар*, *солтаннар*, *бәкләр* керә. Халыкның күпчелеге ирекле була һәм чыганакларда «*ясаклы кешеләр*» термины б-н күрсәтелә. Ясак түләүчеләр («*кара халык*») ханга яки феодалга салым түли.

Казан ханлыгы Рус дәүләте тарафыннан яулап алынганнан соң (1552), ханнар, җирле аксөякләр һәм ирекле авыл җәмәгатьләре җирләре күбесенчә руслар яшәгән сарай, алпавыт һәм чиркәү-монастырь биләмәләренә күчә; татар крәстияннәре дәүләт крәстияннәре катлавына кертелә, алар шәхси яктан бәйсез булып калалар.

17–18 йөзләрдә өлкәдә социаль-икътисади мөнәсәбәтләрнең төп тенденциясе Ф.ның алга таба эволюциясе б-н билгеләнә. Әлеге чор өчен алпавытлар җир биләүчелегенең киңәюе, крепостнойлыкның тулысынча формалашуы (к. *Крепостнойлык хокукы*), крәстияннәрнең икътисади һәм социаль-хокукый хәле начарлану, колониаль һәм милли-дини изүләр көчәю хас була — болар барысы да халыкта ризасызлык тудыра һәм массакүләм халык хәрәкәтләренә этәрә (к. *Җангали хәрәкәте*, *Крәстияннәр кузгалышы* (1670–71), *Крәстияннәр кузгалышы* (1773–75)). 18 йөз ахырында барлыкка килгән капиталистик мөнәсәбәтләр (к. *Капитализм*) Ф. кризисына китерә. 1861 елгы Крәстиян реформасы аның нигезен җимерә. Шулай да абсолют монархия, алпавыт җир биләве, дворяннар хакимлеге, хакимиятне катлауларга бүлү һ.б. кебек феодаль социаль-икътисади һәм сәяси система элементлары илдә 1917 елгы Окт. рев-циясенә кадәр саклана.

Әд.: Халиков А.Х. Древняя история Среднего Поволжья. М., 1969; Кабузан В.М. Крепостное крестьянство России в XVIII — 50-х гг. XIX вв.: Численность, состав, размещение // История СССР. 1982. № 3; Смыков Ю.И. Крестьяне Среднего Поволжья в период капитализма: Социально-экон. исслед. М., 1984; Еникеев С. Очерк истории татарского дворянства. Уфа, 1999; Габдуллин И.Р. От служилых татар к татарскому дворянству. М., 2006.

Ф.Г.Миңнеханов.

ФЕОКТИ́СТОВ Игорь Леонтьевич (20.07.1928, Красноярск краеның Минусинск ш. — 3.01.2013, Түбән Новгород), спортчы (байдаркада һәм каноэда ишү), СССРның спорт остасы (1950). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1954). «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятендә тәрбияләнә (Казан). РСФСР 1951, 1953, 1957–60 (1952, 1954–55, 1963 — көмеш, 1960–63 — бронза), СССР — 1951, 1954, 1957–60 (1963 — көмеш, 1960–63 — бронза), Европа (1957 — көмеш, бронза) чемпионатларында җиңүче, медальләр иясе, 6 нчы Бөтендөнья яшьләр һәм студентлар фестивале программасы ярышларында (Мәскәү, 1957) җиңүче, Олимпия уенларында катнаша (1952). 1954 елдан Түбән Новгород шәһәрендә яши. 1954–99 да «Сокол» авиатөзелеш з-дында конструктор, баш технолог бүлегендә бюро башлыгы.

ФЕОФА́Н (Александров Фёдор) (1786 еллар тирәсе, Мәскәү губ., Кашира өязе Городище а. — 23.10.1852, Тверь губ. Калязин ш.), дин эшлеклесе, чиркәү композиторы. Троица-Сергий семинариясен тәмамлаганнан соң (1808), шунда эшли, чиркәү хорының регенты була. 1809–14 елларда С.-Петербургта Александр Невский руханилар уч-щесендә укыта, 1814 нең мартыннан ректор, бер үк вакытта, 1812 дән, Петербург руханилар семинариясендә эшли. Ярославль руханилар семинариясе ректоры, 1816 дан Чернигов руханилар семинариясе профессоры. 1817 дән Казанда: Казан руханилар академиясе (1818 дән — семинария) ректоры, бер үк вакытта, 1819–13 тә, Казан ун-ты профессоры. Үзенең хезмәт хакының күп өлешен семинарияне яхшырту өчен сарыф итә: аерым алганда, Спас-Преображение монастыре тулай торагына флигель төзетә. Ф. Казанда чиркәү композиторы булып җитешә. 1832 дән Донской ставропигиаль монастыре (Мәскәү), 1850 дән Чернигов епархиясендәге Нежинский Назарет-Богородичный ирләр монастыре, шул ук елда берничә айдан соң Тверь епархиясендә Троица Макарий монастыре башлыгы була. Дин гыйлеменә караган хезмәтләр, православие дине гыйбадәтләре вакытында хәзер дә башкарыла торган чиркәү музыка әсәрләре авторы. 2 нче дәрәҗә Изге Анна, 3 нче дәрәҗә Изге Владимир орденнары белән бүләкләнә.

Хезм.: Собрание поучительных слов на Господские и Богородичные праздники. М., 1841; Собрание поучительных слов на воскресные дни: В 2 т. М., 1849.

Әд.: Смирнов А.П. Архимандрит Феофан, церковный композитор. К., 1909; Голубцов С. Церковный композитор архимандрит Феофан (к 150-летию со дня смерти) // Моск. журн. 2002. № 12.

ФЕОФА́Н (Ашурков Иван Андреевич) (21.5.1947, Курск өлкәсе Дмитриев-Льговский ш.), дин эшлеклесе, митрополит (2012). Мәскәү руханилар академиясен тәмамлый (1976). 1973 елдан Феофан исеме б-н монахлыкта. 1977–82 дә Иерусалимда Рус рухани миссиясендә. 1984–87 дә Үзәк һәм Көньяк Америка экзархатында сәркәтип. 1887–99 да Мәскәү Патриархатының чиркәү тышкы дини багланышлар бүлегендә (1989–93 тә Мәскәү Патриархатының Александрия һәм Бөтенафрика Патриархы каршындагы экзархы), 1993 тән бүлек рәисе урынбасары. 1999–2000 дә Мәскәү Патриархының Антиохия һәм Бөтеншәрекъ Патриархы каршындагы вәкиле. 2000 нән Магадан һәм Синегорск, 2003 тән Ставрополь һәм Владикавказ, 2011 дән Чиләбе һәм Златоуст кафедраларында. 2010 да Владикавказ руханилар уч-щесендә ректор. 2012 дә Чиләбе митрополиясе башлыгы. 2012–14 тә Троицк епархиясенең вакытлыча җитәкчесе. 2014 тән Сембер, 2015 тән Татарстан митрополиясе башлыгы.



Феофан (И.А.Ашурков).

4 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен», Дуслык орденнары, «Ватан алдындагы казанышлары өчен» ордены медале, ш.у. 3 нче дәрәҗә Изге Сергий Радонежский, 2 нче дәрәҗә Изге тәкъва кенәз Даниил Московский, 2 нче дәрәҗә Изге Иннокентий Московский, 2 нче дәрәҗә Изге Серафим Саровский рухани орденнары б-н бүләкләнә.

ФЕРЕНЕ́Ц Валентин Антонович (17.6.1923, Украина ССР, Киев өлкәсенең Ставышанск р-ны Роскошно а. — 31.7.2008), авиация приборлары төзү өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1976), проф. (1977), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1980), РСФСРның атказ. уйлап табучысы (1975), Казан техник ун-тының атказ. профессоры (2004). 1953 елда Мәскәү авиация ин-тын тәмамлый. 1954 тән Казан авиация ин-тында, приборлар һәм автоматлар каф. профессоры (1974 тән). Мәгълүмати-үлчәү приборлары буенча хезмәтләр авторы. Фәнни тикшеренүләренең төп юнәлешләре — термоанеморезистив әверелдергечләр теориясе, аларны проектлау һәм куллану. Уйлап табуга 211 авторлык таныклыгы бар. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Полупроводниковые струйные термоанемометры. М., 1972; Погрешности измерительных преобразователей. К., 1981.

ФЕ́РМА-2, Россия империясе Дәүләт милке министрлыгының Төньяк-көнчыгыш (Казан) укыту-тәэрибә ху җәлыгы. 1846 елда эшли башлый, император Николай I нең 1841 елгы карары нигезендә, Көнбатыш Европа уку-укыту а.х. фермалары үрнәгендә, илдә а.х.ын камилләштерү, дәүләт крәстияннәрен фәнни нигездә ху җәлык алып баруга өйрәтү өчен булдырыла, Россиядә оештырылган шундый биш ферманың берсе. Аны оештыруда әйдәп баручы роль *Казан икътисадчылар җәмгыятенә* бирелә. Ф.-2 өчен шәһәрдән 9 чакрым ераклыкта Борисково һәм Таулар (Горки) авыллары арасында (Аргы Кабан күле янында) 725 дис. 857 кв. сажин җир бүлеп бирелә. Беренче идарәче-агроном А.И.Горнборг, Дерпт ун-тын тәмамлый. Казан, Вятка, Пермь, Вологда губерналарының Көньяк-көнчыгыш өлешенә, Себер өлкәләренә хезмәт күрсәтә; ш.у. ул Казан ун-тының һәм Казан икътисадчылар җәмгыятенең тәэрибә-фәнни базасы булып тора. А.М.Бутлеров, Н.П.Вагнер, М.Я.Киттар, П.А.Пель, Е.И.Гремячинский, А.К.Чугунов, Е.С.Фальков һ.б. галимнәр анда үсемлекчелек өлкә-

сендә тикшеренүләр б-н шөгыльләнә: күпьеллык а.х. культуралары агротехникасы, чәчү әйләнешләренең өч басулы схеманы алыштыру өчен аларны үзләштерү максаты б-н күп басулы схемасы өйрәнелә, үсемлекләрнең яңа сортлары (1849 да Ф.-2 каршында орлык депосы оештырыла), терлекләрнең токымнары, а.х. кораллары һәм машиналары (сабаннар, тырмалар, ургычлар, сугу машиналары, җилгәргечләр, чәчкечләр) сынала, крәстияннәр арасында аларны тарату буенча чаралар эшләнә. Метеорологик күзәтүләр алып барыла. Ф.-2 бәрәңге үстерүне популярлаштыруга ярдәм итә. 1864 тә аның җирлегендә *Казан җир эшләре училищесе* ачыла. 1919 да *Казан политехника институтының* авыл һәм урман хуҗалыгы ф-ты була. 1922 дә ф-т Казан а.х. һәм урманчылык ин-ты итеп үзгәртелә, 1925 нең 1 маенда Ф.-2 аның карамагына күчә (хәзер Казан аграр ун-ты).

Әд.: Казанский государственный аграрный университет: история и современность. К., 2007.

Р.Ә.Әсретдинова, И.Н.Афанасьев.

ФЕХТОВА́НИЕ (нем. fechten — көрәшү, сугышу), спорт төре, спорт рапирасы, шпагасы, кылычы б-н кара-каршы көрәшү. Ф. физик күнегүләрнең гамәли төре буларак Казанда 19 йөздән билгеле, Казан ун-ты спорт түгәрәкләрендә (1907 дән), «Бөркет» (1908 дән), «Көч һәм сәламәтлек» (1911 дән) җәмгыятьләрендә җәелдерелә. Спорт төре буларак Татарстанда 1940 еллардан үстерелә, башлап җибәрүчесе — Д.А.Вашш. 1960 тан һәр ел саен Татарстан Кубогына беренчелекләр һәм турнирлар уздырыла. 1940–60 елларда иң яхшы спортчылар һәм теренерлар: В.Базаревич, М.Х.Сәлимҗанов, Р.Хәбибуллов, Э.Харахашьян, Е.Харьков, А.Л. һәм М.Л.Шалман. 1970 еллардан респ-ка фехтовальщиклары СССР (Россия), Европа, дөнья чемпионатларында, бөтендөнья универсиадаларында, Олимпия уеннарында катнашалар һәм медальләр алалар. 1972 дән И.Б.Брен истәлегенә ир балалар һәм кыз балалар арасында Ф. буенча Бөтендөнья Яңа ел турниры, 1997 дән Н.Ф.Гыйләҗева призына көчле рапирачылар (яшүсмерләр) халыкара турниры уздырыла. 2012 гә Татарстанда Ф. Казанда Респ-ка махсуслаштырылган Олимпия резервы балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә (1966 да ачыла), Казан Олимпия резервы уч-щесендә (2005), «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятендә; Чаллыда Казан Респ-ка махсуслаштырылган Олимпия резервы балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә (2005) җәелдерелә. Ф. б-н шөгыльләнүчеләрнең гомуми саны якынча 1 мең кеше. Иң яхшы спортчылар: СССРның атказ. спорт осталары — Н.Ф.*Гыйләҗева*, В.Г.*Никонова*, О.Н.Князева; халыкара классы спорт осталары (РСФСР, РФ) — А.М.Габделмәнов, Н.В.Балмасова, Э.Ә.Баянов, А.С.Великанов, О.Б.Вощакина, К.Ю.Гафуржанова, М.В.Мартьянова, И.В.Мокрецов, А.Е.Падеров, И.И.Радугин, И.Р.Шәймәрданов, Е.А.Шурупина, Е.А.Шашарина. Атаклы тренерлар: РСФСР, СССРның (Россия) атказ. тренерлары — Л.Н.Белоусов, Д.А.Вашш, В.В.Житлов, А.С.Кисмонин, И.А.Радаева, И.И.Радугин, Ф.М.Хәсәнов, И.Р.Шәймәрданов.



Олимпия уеннары чемпионнары очрашуы. Беренче рәттә (сулдан уңга): Н.Ф. Гыйләҗева, О.Н. Князева, В.Г. Никонова, В.В. Житлов (тренер). Казан. 1976.

ФЕ́ШИН Николай Иванович (26.10.1881, Казан — 5.10.1955, АКШның Санта-Моника ш., 1976 елда Казанга күчереп җирләнә), рәссам, скульптор, педагог, сынлы сәнгать академигы (1916). Иконостас эшләү-алтынлау остаханәсе хуҗасы гаиләсендә туа. Казан сынлы сәнгать мәктәбенең нәкышь бүлеген (1901), С.-Петербургта СА каршындагы Югары сынлы сәнгать уч-щесен (И.Е.Репин остаханәсе, 1909) тәмамлый.«Кәбестә тозлау» конкурс эше өчен рәссам исеме һәм пенсионер буларак чит илгә бару хокукы ала, Австриядә, Германиядә, Италиядә, Франциядә була (1910). 1909–22 дә Казан сынлы сәнгать мәктәбендә (1918 дән — Казан ирекле сәнгать остаханәләре, соңрак Казан югары сынлы сәнгать-техник остаханәләре, 1921 дән Казан сынлы сәнгать-техник ин-ты) нәкышь һәм рәсем укыта. 1923 тә АКШка күченеп китә, Нью-Йорк (1923–26, 1934), Таос (Нью-Мексика штаты, 1927–33), Лос-Андželес (1934–48), Санта-Моника (Калифорния штаты, 1948–55) шәһәрләрендә яши һәм эшли. Гранд Централь Галлериз (1923–24), Лос Анджелестагы Стендаль Галлериз (1934 — 1940 еллар ахыры) галереялары каршындагы студияләрдә укыта, 1940 еллар ахырында үзенең студиясен ача.

Ф.ның иҗаты рус акад. мәктәбе, «күчмә күргәзмәләр»дә катнашкан демократик реалист рәссамнар традициясенә һәм импрессионизм ысулларына нигезләнә, төп хасияте төрле стиль системаларын катыштыру, чынбарлык һәм шартлылык дуализмы булган модерн контекстына керә. Нәкышьтә жанрлы күп фигуралы композицияләр, пейзажлар, натюрмортлар, ню иҗат итә, ләкин барыннан да элек ул күренекле портрет остасы була. Казанда аның модельләре коллегалары (Н.Белькович, П.Радимов, Г.Медведев, П.Абрамычев, В.Тихов), Казан сынлы сәнгать мәктәбендә укучы кызлар (Н.Сапожникова, Н.Подбельская, Т.Попова, М.Быстрова, Е.Ошустович), якыннары — әтисе, хатыны А.Белькович, кызы Ия; АКШта — рус эмигрантлары (рәссам Д.Бурлюк, балериналар В.Фокина, А.Микешина, җырчы Е.Хатаева, театр режиссёры Н.Евреинов һ.б.), Американың мәдәният әһелләре һәм иганәчеләре (кино артисты Л.Гиш, язучы У.Кэйсер, М.Д.Люхан һ.б.) була. Россиядә яшәгәндә Ф.ның нәкышь картиналарына контраст фактуралы иркен пастоз сурәтләү, эн же-күк яки кызгылт-коңгырт колоритлы тон системасы кулланылган катлаулы төсләр катнашамасы куллану хас, ә Америка чорында яшел-кызыл, сары-күк, кызгылт-зәңгәр өстәмә ачык контраст төсләр типик күренеш тәшкил итә. Ф.ның эшләре этюдка хас тәмамланмаганлык эффекты, образларны гротесклы кискенләштерү (жанрлы композицияләрдә) яки ясалма стиль (портретларда) б-н аерылып тора.

Аеруча мөһим нәкышь әсәрләре: «Чирмеш туе» (1908), «Билгесез хатын-кыз портреты (Шәмәхә күлмәкле ханым)» (1908), «Кәбестә тозлау» (1909), «Чүлмәнчек» (1914), «Сапожникова портреты» (1908, 1916), «Варя Адоратская портреты» (1914), «Әти портреты» (1918), «Җәй (А.Н.Фешинаның кызы белән портреты)» (1924), «Кукуруз биюен биюче» (1927–33).

Ф. — натурадан күмер б-н классик рәсем һәм психол. портрет ясауның күренекле остасы. Гамәли-бизәлеш сәнгатендә Абрамцево һәм Талашкино (Е.Д.Поленова, С.В.Милютин) осталары артыннан модерннең яңа рус вариантын (агачка уеп ясау) үстерә, ш.у. тимер, керамик өслектә эшли (АКШ). Аның гамәлгә ашырылган бердәнбер архитектур проекты — җирле испан-индеец архит-расы традицияләрен, адоба һәм яңа рус модернын (архит-ра формалары, интерьерда агачтан уеп ясалган элементлар, бизәкле агач мебель, скульптура) кушып, Таос шәһәрендә төзелгән үз йорты рәссамның иң гүзәл сәнгать әсәрләреннән берсе санала. Төрле күргәзмәләрдә — Римда Интернациональ күргәзмәдә (1911), Амстердамда Халыкара күргәзмәдә (1912), Күчмә сынлы сәнгать күргәзмәләре ширкәте (1912 дән), Бәйсезләр ширкәте (1912, 1914) күргәзмәләрендә, Мюнхен халыкара күргәзмәсендә (1909, 1910, 1913), Карнеги ин-тының еллык күргәзмәләрендә (Питсбург ш., 1910–14), Нью-Йорк Милли дизайн академиясе күргәзмәсендә (1911) һ.б. актив катнаша.

Шәхси күргәзмәләре Чикаго шәһәрендәге Сәнгать ин-нда (1925), Лос-Анджелеста Стендаль Галлеризда (1930–40) уздырыла. Мюнхендагы халыкара күргәзмәдә (1909) «Билгесез хатын-кыз портреты (Шәмәхә күлмәкле ханым)» өчен Кече алтын медаль, Филадельфиядәге халыкара күргәзмәдә парлы «Җәй» портреты өчен Зур көмеш медаль б-н бүләкләнә (1926) һ.б. 1924 тә АКШ Милли дизайн академиясе күргәзмәсендә портрет нәкыше буенча «Гравёр» (У.Д.Уоттс) портреты өчен Томас Р.Проктор призына лаек була. Ф. картиналары тупламының шактый өлеше ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ш.у. Рус музеенда, Россия САнең фәнни-тикшеренү музеенда (С.-Петербург), Третьяков галереясында, Чуаш сәнгать музеенда, В.М. һәм А.М.Васнецовлар исем. Киров өлкә сәнгать музеенда, Карнеги ин-тында (Питсбург ш., АКШ), Фрай Арт музеенда (Вашингтон штаты Сиэтл ш.) һ.б., Россиядә һәм АКШтагы шәхси тупланмаларда сакланa. 1981 дә Ф.ның Таос шәһәрендәге йортында музей һәм белем бирү үзәге булган Фешин ин-ты оештырыла.



Н.И. Ф е ш и н. 1. «Варя Адоратская портреты». 1914; 2. «Чүлмәнчек». 1911; 3. «Автопортрет», 1920; 4. «Әти портреты». 1918; 5. «Надежда Михайловна Сапожникова (рояль янында) портреты». 1916; 6. «Маникюр ясап утыручы ханым» (M-lle Жирмонд портреты)». 1917; 7. «Билгесез хатын-кыз портреты (Шәмәхә күлмәкле ханым)». Этюд. 1908. Рус Дәүләт музее. С.-Петербург; 8. «Катенька портреты». 1912; 9. «Ия крәстиян күлмәгендә». 1933 еллар; 10. «Агач». 1925; 11. «Рәссам Д.Д. Бурлюк портреты (лекция укучы Бурлюк)». 1923. Нью-Мексико сәнгать музее, Санта-Фе ш., АКШ; 12. «Салаватулла». 1921–22. Агач; 13. Фешинның Таостагы үз проекты буенча төзелгән йорты. Нью-Мексико, АКШ. 1927–33; 14. «Бали утравыннан башы бәйләнгән малай». 1938 елдан соң. Кәгазь. Күмер; 15. «Индеец портреты». Кәгазь. Күмер; 16. «Бали утравы карты». 1938 (?). Кәгазь. Күмер, акбур. 1, 2, 4, 5, 12 – ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда.

Әд.: Дульский П.М. Николай Фешин. К., 1921.; Николай Иванович Фешин: Документы. Письма. Воспоминания о художнике. Л., 1975; Тулузакова Г.П. Николай Фешин. 1881–1955. Живопись, рисунок. М., 2004; Николай Фешин. СПб., 2007; Fenn F. The Genius of Nicolai Fechin. Santa Fe, 2001. *Г.П.Тулузакова.*

ФИ́ГНЕР (ире фамилиясе буенча Филиппова) Вера Николаевна (25.6.1852, Казан губ., Тәтеш өязе Христофоровка а. — 15.6.1942, Мәскәү), Россиядә народниклык хәрәкәтендә катнашучы, «Народная воля» оешмасының Башкарма ком-ты әгъзасы, язучы. Дворяннар нәселеннән. 1863–69 елларда Родионованың затлы нәсел кыз балалар ин-тында укый. 1870 тә проф. П.Ф.Лесгафтта мед. буенча лекцияләр тыңлый. 1872–75 тә Цюрих ун-тының мед. ф-тында; 1875 тә, укуын тәмамларга ярты ел калгач, революцион хәрәкәттә катнашу өчен Россиягә кайта. 1876 дан «Земля и воля» җәмгыятенә кушылган народникларның Саратов төркеме әгъзасы. Самара һәм Саратов губерналарында фельдшер булып эшләп, «халык арасына чыгу» тактикасына теләктәшлек итә (1877–79), актив рәвештә халыкны агарту һәм крәстияннәрне восстаниегә әзерләү б-н шөгыльләнә. Бу тактиканың дөрес булмавын аңлап, үзенең көчен Петербург һәм Одессада интеллигенция, студентлар һәм офицерлар арасында революцион пропаганда алып баруга юнәлтә, әлеге шәһәрләрдә император Александр II гә һөҗүмнәр оештыруны әзерләүдә катнаша. Народоволецлар тарафыннан Александр II үтерелгәннән соң башланган репрессияләр барышында, 1883 нең февралендә кулга алына һәм үлем җәзасына хөкем ителә (гомерлек каторгага алыштырыла). Шлиссельбург крепостенда 20 ел ябылуда тотыла. 1904 нең сентябреннән Архангельск губернасында, Казан губернасында үзенең абыйсы утарында, Түбән Новгородта сөргендә була. 1906–15 тә Лондонда һәм Европаның кайбер башка шәһәрләрендә Россиядәге сәяси төткыннарны яклау кампанияләре алып бара, митинглар да чыгышлар ясый, «Рус төрмәләре» («Русские тюрьмы») брошюрасын чыгара, авыру каторжаннарга ярдәм йөзеннән акча җыюны оештыра. Беренче бөтендөнья сугышы башлангач, Россиягә кайтырга карар кыла, чикне чыкканда кулга алына һәм Петербургка озатыла. Аңа башкалаларда һәм университетлы башка шәһәрләрдә яшәү тыела. Окт. рев-циясеннән соң әдәби иҗат б-н шөгыльләнә. 1921 дә читтә яза башлаган, соңрак рус мемуаристикасы үрнәге итеп танылган «Хәтердәге төеннәр» («Запечатлённый труд», ч. 1–3, М., 1921–22) китабын язып тәмамлый. Китап күп кенә чит телләргә тәр җәмә ителә һәм авторны бөтен дөньяга таныта. Ф. — иҗтимагый көрәш тарихына багышланган очерклар, күп кенә революционерларның биографияләре һ.б. авторы.

Совет хакимияте елларында Апас р-ны Ровные Ключи, Тәтеш р-ны Христофоровка авылларындагы үз исемен йөрткән колхозларга, Буа р-ны Фроловка авылы мәктәбенә, Тәтеш р-нының балалар йортына, китапханәсенә, төбәк тарихы музеена шефлык итә; гонорарларының төп өлешен Тәтеш шәһәренең гомуми белем бирү мәктәбе төзелешенә, столярлык һәм слесарьлык остаханәләрен җиһазлауга тапшыра. Тәтеш шәһәренең бер урамы аның исемен йөртә.



В.Н. Фигнер.

Әсәр.: Стихотворения. СПб., 1906; Полн. собр. соч.: В 7 т. М., 1932.

Әд.: Матвеева И.Е. Вера Фигнер (1852–1942). М., 1961; Павлюченко Э.А. Вера Фигнер. М., 1963; Войнович В.Н. Степень доверия: Повесть о Вере Фигнер. М., 1972. *Г.С.Сабиржанов.*

ФИГЫ́ЛЬ, зат, предмет яки күренешнең эшен, хәрәкәтен, хәлен яисә торышын процесс буларак белдерә торган сүз төркеме, җөмләдә күбесенчә хәбәр (предикат) булып килә. Төрле телләрдә Ф. төрле грамматик категорияләргә ия, татар телендә исә аңа *зат*, *сан*, барлык-юклык, наклонение, *заман*, *юнәлеш* һәм дәрәҗә категорияләре хас. Юклык категориясе -ма/-мә кушымчасы ярдәмендә бел дерелә, басым бу кушымча алдындагы иҗекка төшә: яз — яз**ма**. Наклонение категориясе эш-хәлнең чынбарлыкка мөнәсәбәтен сөйләүче аша белдерә. Зат категориясенә мөнәсәбәте ягыннан Ф. затланышлы һәм затланышсыз төрләргә бүленә. Затланышлы Ф.ләргә — зат б-н төрләнә торган хикәя, боерык, теләк һәм шарт Ф.ләр, затланышсыз Ф.ләргә зат б-н төрләнми торган *сыйфат фигыль*, *хәл фигыль*, исем Ф., инфинитив керә. Зат категориясе эш-хәлне үтәүченең (субъектның) сөйләүчегә мөнәсәбәтен белдерә. Сан категориясе эш-хәлне башкаручы затның (субъектның) берләгән яки күплеген белдерә, һәм ул үзара каршы куелган берлек һәм күплек сан мәгънәсен бирүче ике фигыль формасыннан гыйбарәт. Татар телендә Ф.ләрдә зат б-н сан икесе дә берьюлы белдерелә һәм ике төркем зат кушымчасы б-н бирелә (Мин барыр**мын**. Без барыр**быз**.). Заман категориясе татар телендә 9 заман формасы б-н белдерелә. Дәрәҗә категориясе лексик-грамматик категория санала, чөнки аны белдерүдә һәм грамматик (кушымчалар), һәм лексик (модификацияләүче фигыльләр) чаралар катнаша. Ул эш яки хәлнең үтәлү дәрәҗәсен белдерә. Юнәлеш категориясе эш-хәлнең субъектка мөнәсәбәтен белдерә. Татар телендә төр (вид) категориясе юк. Татар телендә Ф.нең башлангыч формасы (нигезе) боеру интонациясе б-н әйтелми торган 2 нче зат берлек сандагы боерык фигыль формасына охшаш: бар, кайт һ.б. Барлык сүз ясагыч кушымчалар һәм грамматик формантлар (кушымчалар) Ф.нең нигезенә ялгана: ур+ак, ашла+ма. Ясалышы буенча Ф.нең түбәндәге төрләре була: 1) тамыр Ф.: бар, кил; 2) ясалма Ф.: таш+ла, эш+лә; 3) кушма Ф.: шак+ка ту, күз+ал+лау; 4) парлы Ф.: ялыну-ялвару, ашау-эчү; 5) тезмә Ф.: ял итү, карар кылу. Ф.нең түбәндәге семантик төркемнәрен аерып карыйлар: 1) хәрәкәт (керү, сикерү), 2) эш-гамәл (казу, укыту), 3) процесс (кайнау, яшәрү), 4) хәл-торыш (йоклау, сагыну), 5) мөнәсәбәт (хөрмәт итү, хыянәт итү), 6) социаль хәл-торыш (хәйләләү, мактану), 7) яңгыраш (шаулау, сайрау), 8) сөйләм эшчәнлеге (ялганлау, боеру), 9) акыл эшчәнлеге (уйлау, белү), 10) хис-кичереш (тою, сизү) һ.б.ны белдерүче Ф.ләр, 11) образ ияртемнәреннән ясалган Ф.ләр (елкылдау, дер-дер калтырау). Лексик мәгънәне белдерү тулылыгыннан чыгып, Ф.ләр тулы мәгънәле һәм ким мәгънәле Ф.ләргә бүленә. Тулы мәгънәле дип, мөстәкыйль лексик мәгънәгә ия Ф.ләрне атыйлар; алар җөмләдә җөмлә кисәкләре булып килә ала (йөгерү, уку). Ким мәгънәле дип, мөстәкыйль лексик мәгънәгә ия булмаган, мөстәкыйль рәвештә җөмлә кисәкләре булып килә алмаган, төрле грамматик, модаль һәм сүз ясагыч мәгънәләрне белдерү өчен генә хезмәт иткән Ф.ләр атала. Аларга ким һәм функциональ-ярдәмче Ф.ләр керә. Беренчеләренә иде, исә, имеш, икән, бул Ф.ләре карый. Икенчеләренең өч төре билгеле: 1) модаль (эшли ала), 2) модификацияләүче (укып чыгу), 3) сүз ясаучы (операция ясау) Ф.ләр. Үзләренең лексик мәгънәләрен саклаган хәлдә, әмма эшнең үтәлү дәрәҗәсен — башлануын, дәвам итүен, тәмамлануын (эшләргә кереш, эшли тор, эшләп чык) белдерү максатыннан ярдәмче Ф. функциясендә килә ала торган Ф.ләр дә шактый.

Әд.: Тумашева Д.Г. Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе. К., 1964; Вәлиуллина З.М., Зиннәтуллина К.З., Сәгыйтов М.Ә. Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе. К., 1972; Татар грамматикасы: Морфология. М.–К., 2002. Т. 2; Хисамова Ф.М. Татар теле морфологиясе. К., 2006. *Ф.М.Хисамова.*

«ФИДАКА́РЬ ХЕЗМӘ́Т ӨЧЕ́Н» медале, к. *Намуслы хезмәт өчен медале.*

ФИДРО́ВСКАЯ Анна Степановна (7.8.1900, Польша, Люблин ш. — 1986, Казан), тел галиме, филол. фән. канд. (1947). Белорус ун-тын тәмамлый (1927). 1919 елдан — мәктәпләрдә, 1930 дан Белоруссия а.х. академиясенең эш челәр ф-тында (Горки ш.) эшли. 1934–38 дә Минск пед. ин-тында, бер үк вакытта, 1935–36 да, Белоруссия пед. фәнни-тикшеренү ин-тында. 1938–42 дә Казан пед. ин-тында, 1942–44 тә эвакуация госпиталендә шәфкать туташы. 1944–60 та Казан ун-тында: рус теле һәм гомуми тел белеме каф. мөдире (1957–60). 1953–55 тә фәнни командировкада, Польша югары уку йортларында белорус теле укыта. Хезмәтләре рус теле морфологиясенә, славян телләренең чагыштырма грамматикасына карый. Медаль б-н бүләкләнә.

Хезм.: О полногласных и неполногласных формах в белорусском и украинском языках // Уч. зап. Казан. ун-та. 1959. Т. 119, кн. 5; Имена существительные мужского рода с формами на -а в именительном падеже множественного числа. К., 1961.

Әд.: Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

ФИ́ЗИК ГЕОГРА́ФИЯ, Җирнең тулаем географик тышчасы һәм аның структур өлешләре — барлык ранглардагы *табигый территориаль* комплексларның табигый характеристикасын өйрәнүче табигыять-геогр. фән нәре системасы. Ф. г. бурычларына аерым төбәкләр табигатенә караган комплексны

тикшеренүләр, кешенең табигый мохиткә йогынтысы һәм табигатьтән нәтиҗәле файдалану мәсьәләләрен өйрәнүләр керә. Төп бүлекләре: гомуми җир белеме (Җирнең геогр. тышчасы б-н гомуми закончалыкларны өйрәнү), ландшафт белеме (төбәк Ф.г.се), палеография; ул ш.у. чиктәш фәннәрне: *геоморфология*, *климатология*, коры җир гидрология се, океанология, гляциология, туфрак географиясе, *биогеографияне* үз эченә ала. Ф.г. Казан ун-тында фән буларак 19 йөз башын нан үсеш ала. Бу чорга чиктәш фәннәрдә: биол. һәм геологиядә физика-геогр. белемнәренең тупланышы хас. Казан ун-ты проф. И.М.Симонов катнашкан Ф.Ф. Беллинсгаузен экспедициясенең Антрактиданы ачуы (1819 – 21) 19 йөзнең иң зур вакыйгасы булып тора. Ботаник һәм зоологларның хезмәтләре тикшеренүләрнең ландшафтны өйрәнү юнәлешенә башлангыч бирә. Идел буе, Көньяк Урал, Арал-Каспий, Урта Азия, Алтай, Кавказ терр-яләрендә табигатьне комплексны өйрәнүләр үткәрелә (Э.И.Эйхвальд, Э.А.Эверсман, М.Н.Богданов, С.И.Коржинский һ.б.). 1860 еллардан җир кабыгының тирбәнешле тектоник хәрәкәтләре һәм аларның рельеф барлыкка китерүдәге роле турындагы тәгълимат булдырган геолог Н.А.Головкинский башлап җибәргән геоморфологик тикшеренүләр үсеш ала. 1888 дә Казан ун-тында геогр. һәм этнография кафедрасы ачыла, аны Урал-Идел буе геоморфологиясен өйрәнүгә шактый өлеш керткән П.И.Кротов җитәкли. 1930 еллар ахырында геоморфологиядә тикшеренүләрнең 2 юнәлеше билгеләнә: Казан ун-тының геол. ф-тында рельеф формалашуда тектониканың роле, елга үзәннәре үсеше тарихы, борынгы бозланулар өйрәнелә (Б.В.Селивановский, С.Г.Каштанов, Е.И.Тихвинская, Н.Н.Нелидов һ.б.); геогр. ф-тының физик геогр. кафедрасында экзоген процесслар нәтиҗәсендә барлыкка килгән рельефны морфологик һәм морфометрик тикшерү үткәрелә (В.Н.Сементовский, А.В.Ступишин, В.В.Батыр, В.А.Дуглав һ.б.). 20 йөзнең 2 нче яртысыннан климатик һәм динамик геоморфология үсеш ала. Тигезлек карсты (А.В.Ступишин, Н.П.Торсуев), платформаның экзотектоник җыерчыкланулы (А.П.Дедков, Г.В.Бастраков), Идел алдында экзоген рельеф барлыкка килү (А.П.Дедков), эре кисәкле материал анализы (Г.П.Бутаков, А.П.Дедков), денудацион тигезлекләрнең климатик геоморфологиясе (А.П.Дедков, В.И.Мозжерин, А.В.Ступишин, А.М.Трофимов), эрозия һәм Җирдәге агым китерелмәләр (А.П.Дедков, В.И.Мозжерин), гумида тигезлекләрнең химик денудациясе (В.И.Мозжерин, А.Н.Шәрифуллин) буенча зур хезмәтләр дөнья күрә. 20 йөз башыннан Ф.г. юнәлешләреннән Идел буе һәм Көньяк Урал күлләрен өйрәнү киң үсеш ала (В.Н.Сементовский, А.В.Ступишин, Н.Н.Лаптева һ.б.). 1940–70 елларда Урта Идел буе һәм аның төбәкләрен физик-геогр. ландшафтлы районлаштыруга караган тикшеренүләр үткәрелә (В.Н.Сементовский, Н.И.Воробьёв, А.П.Дедков, А.В.Ступишин һ.б.). 20 йөз ахырыннан геоэкологик юнәлеш — кеше эшчәнлеге нәтиҗәсендә барлыкка килгән табигый күренешләрнең тизлеген һәм характерын сыйфат һәм сан ягыннан бәяләү билгеләнә.

Әд.: Дедков А.П. Избранные труды. К., 2008.

ФИ́ЗИК КУЛЬТУ́РА КОЛЛЕКТИВЛАРЫ́ (ФКК), физик культура һәм спорт б-н идарә итү системасының беренчел звеносы, физкультура-массакүләм һәм укыту-спорт эшләрен гамәлгә ашыра. Казанда беренче һәвәскәр ФКК 19–20 йөзләр чигендә барлыкка килә: Казандагы беренче ир балалар гимназиясендә, Казан ун-тында, юнкерлар пехота уч-щесендә физик үсеш түгәрәкләре, ат чабышларын сөючеләр (1867), шахмат уеннарын сөючеләр (1884), һәвәскәр-велосипедчылар (1893), «Яхт-клуб» (1907), «Беркут» (1908), «Көч һәм сәламәтлек» (1911), «Сокол» (1913), «Урта уку йортлары яхт-клубы» (1913), һавада очуны сөючеләр (1914) һ.б. спорт җәмгыятьләре. 1920 еллар башында физкультура-спорт эшләре респ-ка гомуми хәрби белем бирү органнары тарафыннан оештырылган хәрби-спорт клубларында, коммерциячел нигездә оештырылган «Маккаби», «Флорида», «Сокол», «Гладиатор», «Санитас» һ.б. спорт коллективларында, «Татпечать», «Железнодорожник» («Тимер юлчы»), «Спартак» профсоюз коллективларында, «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятендә алып барыла.

1936–37 дә Татарстанда оешкан төстә ФКК җитештерү (тармак) принцибы буенча берләштерелгән «Буревестник», «Пламя», «Молния», «Старт», «Азат», «Темп», «Медик», «Крылья Советов», «Нефтяник», «Пролетарская победа», «Шерстянник», «Пищевик», «Наука», «Локомотив», «Водник» профсоюзларның ирекле спорт җәмгыятьләре барлыкка килә. 1940 еллар ахырында ТАССРда якынча 500 башлангыч ФКК санала. Шуларның физкультура-массакүләм һәм спорт эшләрендә югары күрсәткечләргә ирешкәннәре СК статусын ала: «Рубин» (1962), Урицкий исем. (1963), Я.Юдин исем. (1963), Воровский исем. (1965), «КАМАЗ» (1975), «Электрон» (1987), «Нефтехимик» (1988), «Ракета» (1988), «Стрела» (1991) (к. *Спорт клублары*). 1957 дә, профсоюзларның спорт җәмгыятьләрен төзүдә тармак принцибыннан терр. җитештерү принцибына күчү сәбәпле, профсоюзларның бөтенсоюз һәм респ-ка ирекле спорт җәмгыятьләре булдырыла (к. «*Буревестник*», «*Динамо*», «*Зенит*», «*Локомотив*», «*Спартак*», «*Труд*», «*Трудовые резервы*», «*Урожай*»). 1987 дә алар бетерелә, ФКК дәүләт һәм дәүләтнеке булмаган физик культура һәм спорт идарәсе органнары карамагына күчә (к. *Татарстан Республикасы яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы, Профсоюзларның физкультура-спорт җәмгыяте Татарстан Республика советы*).

ФИ́ЗИК КУЛЬТУ́РА ҺӘМ СПОРТ, Татарстан Республикасында. Физкультура — кешенең хәрәкәт эшчәнлеген үз халәтен һәм үсешен оптималләштерүе, тормышка физик әзерлек сыйфатында файдалануы. Спорт — ярышу эшчәнлеге, аңа әзерлек, ш.у. бу эшчәнлек б-н бәйле үзенчәлекле мөнәсәбәтләр, нормалар һәм казанышлар. Казан губернасында физкультура-спорт хәрәкәтенең барлыкка килүе һәм үсеше Казанда 19 йөз ахырында — 20 йөз башында ирекле спорт җәмгыятьләре һәм бер -









1. Кызылармиячеләр сарае каршындагы гимнастика түгәрәге чыгышы. 1921; 2. «Марат» спорт түгәрәге әгъзалары. 1924; 3. «Пролетарий» җәмгыяте спортчылары төркеме. 1922; 4. «Сокол-1» гимнастика җәмгыяте. 1922. Җитәкчесе В.А.Бекасов. Барысы да – Казан.

ләшмәләрен оештыру б-н бәйле. Булдырылган оешмалар җи ңел һәм авыр атлетика, фехтование, көрәшнең төрле төрләрен, бокс, йөзү, велосипед, ишү, парус, чаңгы, тимераяктa узышу спортын, гимнастика, атта йөрү, спорт уеннарын (лаун-теннис, крикет, гольф, лапта, бура) һ.б.ны җәелдерә башлый (к. *Спорт клублары*). Окт. рев-циясеннән соң һәм Бөек Ватан сугышы елларында физкультура-спорт эше б-н җитәкчелек итүче оешмалар: Казан губерна хәрби комис-ты каршындагы физик үсеш һәм спорт бүлеге һәм Казан губернасы спорт берлеге (1919 елда оештырыла); ТАССР Сәламәтлек саклау һәм Мәгариф халык комис-тлары каршындагы физик тәрбия бүлекчәләре (1920); Югары физик культура советы (1923–25 тә ХКС каршында, 1925–36 да ТАССР УБК каршында); ТАССР ХКС каршында Физик культура һәм спорт эшләре ком-ты (1936–46); Оборонага, авиация һәм химия төзелешенә ярдәм җәмгыяте (ОСОАВИАХИМ) (1927); 2013 тән — «*Татарстан Республикасының Армия, авиация һәм флотка булышлык итү ирекле җәмгыяте (ДОСААФ)» төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсе*. 1921 гә Казанда һәм губернада 30 дан артык спорт җәмгыяте һәм оешмасы эшли. Иң зурлары: Үзәк, Дары з-ды, Балтач, Лаеш, Тәтеш хәрби СКлары; «Флорида», «Сокол» (хатын-кызлар, Зөя ш.), укучы яшьләр (СКУМ), Казанның 1 нче «Бой-Герль-Скаутлар» отряды спорт түгәрәкләре. Сугышка кадәрге чорда респ-када Ф.к.h.c. үсешенә «Хезмәткә һәм СССРны саклауга әзер» физкультура комплексы (ГТО, 1931–34), Бердәм Бөтенсоюз спорт классификациясе (1935–37) кертелү, рәсми рәвештә Профсоюзларның ирекле спорт җәмгыятьләре оештырылу (к. *Физик культура коллективлары, Спорт клублары, «Зенит», «Локомотив», «Спартак», «Труд», «Урожай»* ирекле спорт җәмгыятьләре, *«Динамо»* физкультура-спорт җәмгыяте) көчле стимул бирә.

1930 елларның 1 нче яртысында гомуми белем бирү мәктәпләрендәге укучыларның 80%ы физик культура б-н мәҗбүри шөгыльләнә. Авыл җирлекләрендә физкультура хәрәкәте 196 колхоз-совхоз физик культура коллективлары һәм 33 район физик культура советлары б-н тәэмин ителә.

1920–30 елларда Татарстанның аерым спортчылары һәм командалары илдәге зур ярышларда — бөтенсоюз һәм Идел буе җәйге һәм кышкы спартакиадаларында, милли респ-калар һәм Идел буе хәрби округы олимпиадаларында җиңүчеләр булалар һәм медаль алалар. Бөек Ватан сугышы елларында ТАССР физкультура һәм спорт оешмалары (Ирекле спорт җәмгыятьләре, гомуми хәрби укыту пунктлары) Кызыл Армия өчен резерв әзерләү, яраланган хәрби хезмәткәрләрнең сәламәтлеген тергезү бурычларын хәл итүгә күчә. Чаңгы, җи ңел атлетика һәм хәрбиләштерелгән кросслар, узышлар, эстафеталар, ату, штык һәм кул көрәше буенча ярышлар уздырыла. Сугыштан соңгы унъеллыкларда спортның һәм аның казанышларының массачыл үсеше күзәтелә. Респ-ка шәһәр һәм районнарында физкультура-спорт һәм сәламәтләндерү эшләре төрле контингент арасында уздырыла: балалар-яшүсмерләр спорт мәктәпләре, югары спорт осталыгы мәктәпләре булдырыла, аларда спортның якынча 40 төре җәелдерелә (к. *Спорт мәктәпләре*). Татарстан командалары һәм респ-каның аерым спортчылары СССР чемпионатлары һәм беренчелекләрендә, ирекле спорт җәмгыятьләре үзәк советларында, Европа, дөнья, Олимпия уеннарында ишү, чаңгы спорты, баскетбол, җиңел һәм авыр атлетика, бокс, йөзү, фехтование, футбол, шахмат буенча бәйгеләрдә уңышларга ирешәләр (к. *Баскетбол, Бокс, Ирекле көрәш, Суда туплы уен, Волейбол, Спорт гимнастикасы, Академик ишү, Дзюдо, Җи ңел атлетика, Чаңгы спорты, Спортча йөзү, Фехтование, Футбол, Хоккей*). Спорт казанышлары буенча 1980 еллар ахырында Татарстан илнең автономияле респ-калары арасында 1 нче урынны били (*Татарстан Республикасы*, IX «Физик культура һәм спорт» бүлеге).

2000 еллардан ТРда Ф.к.h.c. үсеше өчен тиешле шартлар булдыру дәүләт социаль сәясәтенең өстенлекле юнәлешен тәшкил итә. Татарстанда 2008–2013 нең 1 нче яртысында «Казанда Универсиада-2013» (к. *Универсиада*) киң күләмле халыкара проектын тормышка ашыру, спортның су төрләре буенча 16 нчы дөнья чемпионаты (2015), футбол буенча Конфедерацияләр Кубогы уеннары, футбол буенча (ФИФА) 21 нче дөнья чемпионатының төркем турниры, 1/8 финал һәм 1/4 финал матчлары уздырылу Ф.к.h.c. үсешен стимуллаштыручы фактор булып тора. 2018 ел мәгълүматлары буенча ТРда массакүләм рәвештә физкультура һәм спорт б-н шөгыльләнүчеләрнең гомуми саны 1,5 млн. кешедән артык тәшкил итә (гомуми халык санының якынча 43,4% ы); спорт индустриясе өлкәсендә 11 меңнән артык кеше (шуларның якынча 9 меңе югары һәм урта махсус белемле), якынча 11 мең спорт корылмалары; 143 балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе һәм 29 Олимпия резервы махсуслаштырылган балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе эшли (аларда спортның 72 төре җәелдерелә), шөгыльләнүчеләрнең гомуми саны — якынча 9 мең кеше (мәгариф учреждениеләрендә укучылар контингентының 24% ы).

Халыкның спорт корылмаларындагы мәйданчыклар б-н тәэмин ителеше РФ нормативлары һәм социаль нормалары буенча: спорт заллары б-н — якынча 60% (фактик мәйданы — якынча 900 мең $м^2$); спорт корылмалары б-н — 80% тан артык (гомуми мәйданы — якынча 6 млн. $м^2$); ябулы йөзү бассейннарында су мәйданы буенча — якынча 15% (гомуми мәйданы — якынча 44 мең $м^2$); барлык спорт корылмаларының берьюлы үткәрү сәләте — 250 меңнән артык кеше (нормативлардан якынча 35%) тәшкил итә. Казанның югары лигаларда чыгыш ясаучы клуб командаларының спорт казанышлары Татарстан турында РФнең спорт б-н аеруча актив шөгыльләнүче төбәкләренең берсе дип әйтергә мөмкинлек бирә. «Ак Барс» (хоккей), «Уникс» (баскетбол), «Рубин» (футбол), «Синтез» (суда туплы уен), «Зенит» (волейбол, ирләр), «Динамо-Казан» (волейбол, хатын-кызлар) клублары командалары, чирәм-дәге хоккей, туплы хоккей командалары Россия чемпионатларында, халыкара турнирларда җиңүләргә ирешәләр, медальләр алалар, Европа һәм дөнья кубоклары ияләре булалар.

Ралли-рейдлар буенча «КАМАЗ-Мастер» командасы йөк ташучы спорт автомобильләре классында дөнья автоспортында иң көчеләрдән санала (Чаллы ш.), команда составына 5 Дөнья кубогы иясе, 15 халыкара класслы спорт остасы, 11 Россиянең атказ. спорт остасы, 14 Россиянең спорт остасы, «Дезерт-Челлендж», «Хазарские степи 2010», «Калмыкия» Россия чемпионаты этабы, Россия кубогы, «Оптик 2000» (Тунис), «Итальян Бажа», Мастер-Рали, Пор Лас Пампас, Трансориенталь, «Ралли Востока-Каппадокия» һ.б. автораллиларда күп тапкырлар җиңүче һәм медаль алучылар керә. Соңгы елларда 2011–15 кә исәпләнгән «Уңайлы мохит» респ-ка программасы нигезендә физик мөмкинлекләре чикләнгән кешеләр б-н эшләү активлаша (2018 гә Ф.к.h.c. б-н шөгыльләнүче инвалидлар саны 33 меңнән артык кеше тәшкил итә, аларның гомуми санының якынча14,1%). 2011 дән ел саен Спартакиадалар (5 меңнән артык кеше катнаша), пауэрлифтинг, мини-футбол (тулысынча сукырлар), бочча, шахмат һәм шашка композицияләрен хәл итү (100 һәм 64 шакмаклы), начар күрүчеләр, бик начар күрүчеләр, ДЦП б-н авыручылар арасында футбол, өстәл теннисы, ядрә б-н ату, җи ңел атлетика, туристлык, армспорт, рус шашкасы, халыкара шашка, шахмат һ.б. (барлыгы спортның 30 төре) буенча ТР чемпионатлары уздырыла. 2013 елгы чараларда (физкультура-спорт җәмгыятьләре генә) ТРның 31 районыннан (шәһәр) 2,5 мең кеше катнаша. 2015 тә Казанда Респ-ка балалар-яшүсмерләр спорт-адаптация мәктәбе (директоры Ф.И.Сафиуллина) ачыла, анда дүрт бүлек эшли: ишетмәүчеләр спорты (ирекле көрәш, керлинг, йөзү), терәк-хәрәкәтләнү аппараты зарарланган кешеләр спорты (бочча, йөзү, җи ңел атлетика), интеллектуаль зәгыйфь кешеләр спорты (җи ңел атлетика, өстәл теннисы, йөзү), сукырлар спорты (йөзү, җиңел атлетика). 2011 дә ТР Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы каршындагы Үзәк спорт клубы үзгәртелә һәм ул Спорт әзерлек үзәге буларак эшли башлый, аның максаты — РФдә спортның төп 28 төре буенча Татарстанның әйдәп баручы спортчылары арасыннан Россиянең спорт җыелма командалары резервын әзерләү. Физкультура һәм спорт оешмаларын квалификацияле белгечләр б-н тәэмин итүдә Казан физик культура һәм спорт техникумы (1931–34) һәм Казан пед. уч-щесенең физкультура бүлеге (1934–37) зур роль уйный. Хәзерге вакытта Ф.к.h.c. буенча белгечләр әзерләү Идел буе физик культура, спорт һәм туризм академиясе (аның структурасында Чаллы шәһәрендә филиал һәм физик культура көллияте бар), Казан ун-тының Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы ин-ты (1949–2011 дә Татар гуманитар-пед. ун-ты каршындагы факультет), Казан Олимпия резервы уч-щесе,

Әлмәт физик культура көллияте (1996–2010 да техникум), Тәтеш пед. көллиятенең физик культура бүлеге (1966–2010 да уч-ще) тарафыннан гамәлгә ашырыла. 2018 ел башына ТРда 381 СССР, РФ, халыкара класслы спорт остасы, 91 СССР, РФнең атказ. спорт остасы, ТРның 102 атказ. спорт остасы, 283 спорт остасы әзерләнә. СССР, РФнең атказ. тренеры исеме 115 кешегә, ТРның атказ. тренеры — 133, ТРның атказ. физик культура хезмәткәре — 566, РФнең атказ. физик культура хезмәткәре исемнәре 23 кешегә бирелә. Олимпия уеннарында Татарстанда туган һәм яшәүчеләрдән якынча 100 спортчы катнаша; 1952 дән алар 52 медаль ала; шуларның 24 е алтын, 14 е көмеш, 18 е бронза (к. *Олимпия уеннары*).

Н.Д.Бобырев.

ФИ́ЗИК ХИ́МИЯ, матдәләрнең төзелешен һәм химик әверелешләрен билгеләүче кануннар турындагы фән; химия һәм физиканың теоретик һәм тәҗрибәви алымнарына нигезләнә. Ф.х.нең төп бүлекләре: матдә төзелеше, химик термодинамика, эретмәләр тәгълиматы, өслек күренешләре, химик кинетика һәм катализ. Ф.х. базасында *квант химиясе*, *электр химиясе*, фотохимия, радиация химиясе, кристалл химиясе, коллоид химиясе, физик-химик анализ. Фән буларак Ф.х. 18 йөздә формалаша (М.Ломоносов, А.Лавуазье, Т.Ловиц, К.Бертолле, Дж.Дальтон). Төп төшенчәләре һәм законча лыклары 19 йөздә формалаша (П.Гесс, В.Нернст, В.Оствальд, Я.Вант-Гофф, С Аррениус, Д.Менделеев, Д.Гиббс). Ф.х.нең үсешенә *Казан химия фәнни мәктәбе* вәкилләре (К.К.Клаус, Н.Н.Бекетов, А.М.Бутлеров, И.И.Канонников, Ф.М.Флавицкий, А.Ф.Герасимов, А.Я.Богородский) мөһим өлеш кертә. Татарстанда химик термодинамика (Г.К.Дьяконов, А.И.Коновалов, Б.Н.Соломонов, В.В.Овчинников, Е.В.Сагадеев), *химик кинетика һәм катализ* (Ә.М.Мазһаров, Г.М.Храпковский, В.Н.Никулин, Б.Л.Кондрацкий, Х.Э.Харлампиди, Г.С.Дьяконов, Я.Д.Самуилов, А.А.Ламберов), эретмәләр тәгълиматы (А.М.Васильев, В.Ф.Торопова, В.П.Барабанов, Ю.И.Сальников, В.М.Центовский), үзеннән-үзе оешучы системалар Ф.х.се (А.И.Коновалов, В.П.Барабанов, Л.А.Кудрявцева, И.С.Рыжкина, Ю.Г.Галяметдинов, Л.Я.Захарова, Р.Ф.Бакеева, А.Я.Третьякова), *химиядә физик тикшеренү алымнарын* эшләү һәм куллану (Б.А.Арбузов, А.Н.Верещагин, С.Г.Вульфсон, Й.Ю.Сәмитов, Р.Р.Шәһидуллин, А.Б.Ремизов, В.А.Наумов, В.И.Коваленко, И.А.Литвинов), квант химиясе (М.С.Шапник, А.М.Кузнецов, Г.А.Чмутова, Р.М.Әминова, А.Г.Шамов, Р.Р.Нәҗметдинова) үсеш ала. Физика һәм физик органик химия өлкәсендә систематик тикшеренүләр Казан ун-тында, Казан технол. ун-тында, РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында, югары уку йортларында һәм тармак фәнни-тикшеренү ин-тларында, респ-ка сәнәгать пр-тиеләрендә алып барыла.

Әд.: Смирнова Н.А. Методы статистической термодинамики в физической химии. М., 1982; Эмануэль Н.М., Кнорре Д.Г. Курс химической кинетики. М., 1984; Стромберг А.Г., Семченко Д.П. Физическая химия. М., 2003; Atkins P. Physical Chemistry. N.Y., 2007.

ФИ́ЗИК-ГЕОГРА́ФИК РАЙО́Н, физик-геогр. районлаштыруның иң түбән таксономик берәмлеге. Бертөрле геол. төзелеш, бердәй климат, бер үк типтагы туфрак, биоценозлар тезмәсе б-н сыйфатлана. Татарстан терр-ясе Идел һәм Кама елгаларының үзәннәре б-н билгеле бер табигый үзенчәлеккә ия төп 3 физик-геогр. өлешкә бүленә — *Идел алды*, Кама алды, Кама аръягы Ф.-г.р.ы. Идел алды Иделнең уңъяк ярында урнашкан. Идел буе калкулыгының төньяк-көнчыгыш өлешенә туры килә. Климаты чагыштырмача җылы һәм дымлы җәй, суык һәм уртача кар лы кыш б-н сыйфатлана. Нигездә, урман-дала зонасы өчен хас кара һәм кара соры урман туфраклары өстенлек итә. Яфраклы урманнарның (имәнлекләрнең) зур булмаган массивлары сакланган. Кама алды — Иделнең сулъяк һәм Каманың уңъяк ярында, төньяк өлешендә ылыслы-киң яфраклы һәм көньякта киң яфраклы урманнар үсә; кәсле-көлсу һәм соры урман туфраклары. Вятка елгасы үзәне б-н *Көнчыгыш Кама алды* һәм *Көнбатыш Кама алды* Ф.-г.р.ына бүленә. Көнчыгыш Кама алды — җи ңелчә калкулыклы тигезлектән гыйбарәт, климатик күрсәткечләренә чагыштырмача кискен үзгәрешләр хас. Көнбатыш Кама алды — ТРда аеруча тыгыз ерым челтәре, эрозияләнгән туфраклар, салкынча һәм дымлы җәй, уртача салкын һәм карлы кыш б-н сыйфатлана. Кама аръягы — Каманың уңъяк һәм Иделнең сулъяк ярында. Урман-дала зонасында урнашкан, болын-дала яки далаланган участоклар урманнар б-н чиратлаша. Кара туфраклар, субүлләрдә кара соры урман туфраклары өстенлек итә. Чишмә елгасы үзәне б-н 2 Ф.-г.р.га бүленә: *Көнчыгыш Кама аръягы* һәм *Көнбатыш Кама аръягы*. Көнчыгыш Кама аръягының төп өлешен Бөгелмә яссы калкулыгы били, рельефы ТРдагы иң зур биеклекләр, кискен асимметрияле елга үзәннәренең тирән уемнары б-н сыйфатлана. Төбәкнең климаты чагыштырмача салкын һәм төньяк өлешендә аз карлы, көньякта карлы. Көнбатыш Кама аръягы тирән булмаган елга үзәннәре, сызалар (ТРда иң тыгыз), ерымнар б-н бүлгәләнгән уйсу тигезлектән гыйбарәт. Климаты җылы һәм аз дымлы җәй, уртача салкын һәм чагыштырмача карлы кыш б-н аерылып тора. Кайвакыт «Ф.-г.р.» термины *географик ландшафт* синонимы буларак кулланыла.

ФИ́ЗИКА (грек. phýsike, phýsis — табигать), табигать турындагы фән, матди дөньяның иң гади һәм ш.у. иң гомуми үзлекләрен өйрәнә. Ф. һәм аның законнары табигать фәннәренең нигезен тәшкил итәләр. Өйрәнү объектларына карап, Ф. элементар кисәкчәләр, атом төш, атом, молекуляр, каты җисем, плазма һ.б. Ф.сына бүленә. Теоретик Ф.ның төп бүлекләре: классик механика, электродинамика, термодинамика, стат. физика, чагыштырмалылык теориясе, квант механикасы, квант кыр теориясе. Ф. б.э.к. үк үсеш ала башлый (Демократ, Архимед һ.б.); 17 йөздә классик механика булдырыла (И.Ньютон); 19 йөз ахырында нигездә классик Ф.ны формалаштыру тәмамлана. 20 йөз башында квант Ф.сы нигезләре эшләнә (М.Планк, Э.Резерфорд, Н.Бор). 1920 елларда квант механикасы — микрокисәкчәләр хәрәкәте теориясе үсеш ала (Л. де Бройль, Э.Шредингер, В.Гейзенберг, В.Паули, П.Дирак). Бер үк вакытта (20 йөз башында) фәза һәм вакыт турындагы яңа тәгълимат — чагыштырмалылык теориясе барлыкка килә (А.Эйнштейн). 20 йөзнең 2 нче яртысында Ф.ның алгарышын атом төше төзелешен, элементар кисәкчәләрнең үзлекләрен (Э.Ферми, Р.Фейнман, М.Гелл-Ман һ.б.), куертылган мохитләрне (Дж.Бардин, Л.Д.Ландау, Н.Н.Боголюбов) танып белү процессы билгели. Ф.ның үсеше дөньяның бердәм табигый-фәнни картинасын булдыруга, ш.у. техниканы үзгәртүгә китерә. Атом-төш энергетикасы (И.В.Курчатов), квант электроникасы (Н.Г.Басов, А.М.Прохоров һәм Ч.Таунс), микроэлектроника, радиолокация, идарә ителүле термик төш синтезы, югары температуралы үтә үткәрүчәнлек, наноструктуралар һәм нанотехнологияләр, квант компьютерлары һ.б.ш. юнәлешләр булдырыла.

Казанда физик тикшеренүләр 19 йөз башыннан алып барыла. Биредә 1806 елда метеостанция төзелеп, Россиядә климатологик һәм метеорологик тикшеренүләр башлана (И.И.Запольский), астрономия (1814) һәм магнит (1828) обсерваторияләре төзелә, аларда астрономия һәм геофизика өлкәләренә караган фундаменталь тикшеренүләр алып барыла (И.М.Симонов). Ф.Ф.Беллинсгаузен б-н М.П.Лазарев җитәкчелегендәге дөнья тирәли экспедиция вакытында (1819–21) И.М.Симонов Җирнең Көньяк геомагнит котыбы торышын билгеләү максатында хисаплаулар ясый. Казан ун-тында Ф. һәм механиканы үстерү юнәлешләрен Н.И.Лобачевский идеяләре билгели, бу исә Ф.ның яңа бүлеге — чагыштырмалылык һәм гравитация теориясе барлыкка килүгә сәбәп була (А.П.Котельников, А.З.Петров). 19 йөз башыннан электр һәм электромагнит күренешләре тикшерелә башлый (А.С.Савельев, Р.А.Колли, Н.П.Слугинов, Д.А.Гольдгаммер, В.А.Ульянин). Нейтронның магнит моменты барлыгы алдан әйтелә (И.Е.Тамм, С.А.Альтшулер, 1934). Бөек Ватан сугышы елларында ТРда СССР ФА учреждениеләренең эшчәнлеген илнең оборонасы бурычларын хәл итү белән шөгыльләнгән җирле сәнәгать пр-тиеләре һәм фәнни оешмалар эше б-н көйләү өчен Фәнни-техник комиссия төзелә, һәм ул ТРда Ф. фәне үсешенә уңай йогынты ясый. Казан ун-тында күренекле совет галимнәре — академиклар А.П.Александров, Л.А.Арцимович, С.И.Вавилов, В.И.Векслер, В.Л.Гинзбург, А.Ф.Иоффе, П.Л.Капица, И.В.Курчатов, Л.Д.Ландау, Г.С.Ландсберг, М.А.Леонтович, Л.И.Мандельштам, Н.Д.Папалекси, Н.Н.Семёнов, И.Е.Тамм, В.М.Тучкевич, В.А.Фок, Г.Н.Флёров, И.М.Франк, Ю.Б.Харитон эшлиләр. 1945 тә СССР ФАнең *Казан физика-техника институты* төзелә. 1944 тә

Казан физигы Е.К.Завойский *электрон парамагнит резонансы* (ЭПР) күренешен ача. Бу ачыш сугыштан соңгы чорда бөтендөнья Ф.сының төп тикшеренү өлкәсен билгели. Шуннан соң Казан ун-тында һәм РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында магнит резонансы Ф.сы һәм аның химиядә, биологиядә, геологиядә һәм медицинада кулланылышы эшләнә (к. *Казан радиоспектроскопия фәнни мәктәбе*). Аның беренче казанышлары — ЭПР спектрына төш спины йогынтысын билгеләү, ш.у. акустик парамагнит резонансы күренешен алдан әйтү (С.А.Альтшулер, 1952), төрле табигатьле парамагнетиклар мисалында ЭПР теориясен эшләү. Казан — оптик электроника үзәкләренең берсе («КОМЗ», «Элекон», «Гамәли оптика институты» ФҖБ АҖләре). Югары уку йортларында, акад. һәм тармак ин-тларында газларның оптик спектроскопиясе һәм куертылган мохитлар өлкәсендә (РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында, Органик һәм физик химия ин-тында һ.б.), яңа лазерлар булдыру өлкәсендә (Казан техника ун-ты) тикшеренүләр алып барыла.

Казанда хәзерге фәнни тикшеренүләрнең төп юнәлешләре: парамагнитик диэлектрик кристалларда, нормаль металларда, ярымүткәргечләрдә, түбән һәм югары температуралы үтә үткәргечләрдә ЭПР, ТМР һәм спин-рәшәткәле релакслашу; магнит материалларның Мёссбауэр спектроскопиясе, оптик спектроскопия; югары пиксельле ТМР һәм органик кушылмалардагы молекулаара тәэсирләшүләр; полимерларда магнит кырының импульс градиентлы ТМР; биомед. радиоспектроскопия һәм оптика; катламлы наноструктураларның һәм наноконтактларның квант үзлекләре; чагыштырмалылык теориясе һәм гравитация; радиоэлемтәнең гомуми теориясе, катлаулы радиосистемаларны проектлау, метеорларны радиолокацияләү, мохитларда дулкын реакцияләре, атмосфераның радиодулкынлы мониторингы; нефть һәм газ чыганакларын кулай эшкәртүнең фәнни нигезләре; радиоэлектрон һәм квант җайланмалары һәм схемалары; микроэлектроник аппаратура һәм аны җитештерү технологиясе; ярымүткәргечләр буенча материаллар белеме; югары температуралы плазма физикасы һәм техникасы; оптик интерференцион капламалар технологиясе; голография һәм голограммалар техникасы.

Казанда Ф. буенча вакытлы фәнни басмалар чыга: «Applied Magnetic Resonance», «Environmental Radioecology and Applied Ecology», «Magnetic Resonance in Solids. Electronic Journal», «Георесурсы», «Учёные записки Казанского университета. Сер. Физико-математические науки», «Новости ЯМР в письмах» бюллетене һ.б.; фәнни хезмәтләр җыентыклары: «Парамагнитный резонанс», «Гравитация и теория относительности», «Приём и обработка информации в сложных информационных системах» һ.б.

Әд.: Развитие физики в России: В 2 т. М., 1970; История физики и астрономии в Казанском университете за 200 лет. К., 2007.

Л.К.Әминов, А.Л.Ларионов, Б.З.Малкин.

ФИЗИОЛО́ГИЯ (кеше һәм хайваннар физиологиясе; грек. phýsis һәм *...логия*), аерым организмның, аның аерым системалары, әгъзалары, тукымалары, күзәнәкләренең тереклек итү процессларын (функцияләрен), организмның әйләнә-тирә дөнья б-н үзара тәэсир итешү чикләрен, төрле факторлар йогынтысына карата тотрыклылыгын һәм адаптацияләнү мөмкинлекләрен өйрәнүче фән. 19–20 йөзләрдә Казан ун-тында физиологларның фәнни кызыксынулары нерв системасы, йөрәк һәм кан әйләнеше, сулыш юллары Ф.сен, яшькә бәйле психофизиологияне, нейрофизиологияне өйрәнүгә юнәлдерелә. Беренче Ф. каф. 1806 елда ун-тның мед. ф-тында, икенчесе — 1875 тә табигыять-матем. бүлегендә оештырыла (укытучылары И.П.*Каменский*, О.Б.Браун, К.Ф.*Фукс*, А.Е.Лентовский, В.Ф.Берви).

Ф. өлкәсендәге эксперименталь тикшеренүләр Россиядә беренче Ф. лаб-ясе төзегән каф. мөдире Ф.В.*Овсянников* исеме б-н бәйле (1858). Хайваннарның баш мие тукымасы структурасын, сулыш алуның рефлектор регуляциясен, йөрәк-кан тамырлары системасын морфофизиол. яктан өйрәнүгә башлангыч бирелә. Күз авырулары каф. мөдире Е.В.*Адамюк* — күз эчендәге кан йөрешен һәм кан басымын (1867), В.В.*Чирковский* күз алмасы хәрәкәте иннервациясен өйрәнә. Н.О.*Ковалевский* сулыш алуны өйрәнүгә нигез сала (1865), сулыш алу һәм кан әйләнеше арасындагы рефлектор бәйләнешне, төрле авырулар барышындагы кан составы үзгәрешләрен тикшерә (1880), аның тикшеренүләрен Ф.В.Овсянников дәвам итә. В.М.*Бехтерев* Россиядә беренче, Европада икенче булып психофизиол. лаб-ясе ача, анда арка һәм баш миенең үткәргеч юллары тикшерелә. Н.А.*Мислављский* эксперименталь юл б-н сулыш алу үзгәненең озынча мидә урнашуын һәм төзелешен дәлилли (1885). Аның җитәкчелегендә клиницистлар эчке эгъзалар иннервациясе процессларын өйрәнәләр. Н.К.*Гоpяев* хәзерге вакытта да кулланылышта булган кан элементларын санау камерасын эшли. Бөер өсте бизләренең секреция нервларын ачыклау эчке секреция бизләре Ф.се һәм патологиясен өйрәнүгә юл ача (М.Н.*Чебоксаров*, 1910). И.В.*Домрачев* тарафыннан — мәни бизе (простата) иннервациясе (1921), А.В.Вишневский тарафыннан туры эчәкнең перифер ик иннервациясе өйрәнелә (1930). Бөер авыруларына диагноз куюның С.С.Зимницкий тәкъдим иткән ысуллары киң таныла. К.Р.*Викторов*, М.В.*Сергеевский*, Т.Б.Кисе лёв, А.Р.Лурия, М.А.Юровская, И.А.Аршавский тарафыннан тикшеренүләрнең төрле һөнәрләр өчен кадрлар әзерләгәндә кулланылучы физиол., психофизиол. һәм психол. ысуллары эшләнә; эшкә сәләтлелек, ару халәте, эш урыннарын рациональ оештыру ысуллары, эш һәм ял режимы өйрәнелә. 20 йөз башында Казан ун-тының электрофизиол. лаб-ясе электрокардиография һәм электроэнцефалография уздыручы табиблар әзерли торган бердәнбер үзәк булып тора. А.Ф.*Самойлов* һәм М.А.Киселёвның (1920 еллар) тикшеренү объектын нерв системасындагы ярсыну һәм тоткарлану процесслары, антагонист мускулларның координация механизмнары, ш.у. күп тармаклы нерв ярсынуының йөрәккә тәэсире тәшкил итә; илебез Ф.сенә электрофизиол. тикшеренү ысуллары кертелә. Актив рәвештә медиаторлар һәм синаптик процесслар Ф.се өйрәнелә. А.Ф.Самойлов нейронара бәйләнешләрдә ярсыну тапшырылуның химик механизмына аңлатма бирә (1920). А.В.*Кибяков* вегетатив төеннәрнең нейронара контактларында медиаторлар ролен ачыклый (1933). И.Г.Вәлидов нерв-мускул тоташмасының сигнал тапшыру механизмында кальций ионнары катнашуын дәлилли (1930–40 еллар). 1950 еллардан башлап Казан мед. ин-ты физиологлары нерв-мускул тоташмасының эшчәнлек принципларын өйрәнәләр (И.Н.Волкова, Г.И.Полетаев, А.Л.Зефиров, Е.Е.Никольский, Е.М.Волков, Р.Ә.Гыйниятуллин һ.б.); алар тарафыннан нерв күзәнәкләренең бер-берләре яки шулар ярдәмендә иннервацияләнүче (үзәк нерв системасы б-н бәйләнешкә керүче) тукымалар б-н тәэсир итешүен өйрәнүче яңа фәнни юнәлешкә — синаптологиягә нигез салына. Г.И.Полетаев Ф. өлкәсендә микроэлектродлы тикшеренүләрнең төп ысулын эшли (1960 еллар). Х.С.Хәмитов, Л.Н.*Зефиров*, Г.Ф.Ситдыйкова — медиаторларның физиол. һәм трофик әһәмиятен, Е.Е.Никольский квантлы булмаган секрециясен өйрәнәләр. Профессорлар Л.Н.Зефиров, В.И.*Алатырев* һәм алар кул астында эшләүче хезмәткәрләр, Мәскәү Космик мед. һәм биол. ин-ты б-н берлектә, төрле шартларда хәрәкәтләрне көйләүнең үзәк механизмнарын өйрәнү буенча тикшеренүләрне дәвам итәләр.

21 йөз башыннан Казан мед. ун-тының хезмәт гигиенасы һәм һөнәри авырулар кафедрасы галимнәре проф. Н.Х.Әмиров җитәкчелегендә Ф. һәм хезмәт гигиенасы мәсьәләләрен өйрәнәләр; алар тарафыннан хезмәт медицинасы һәм сәнәгать экологиясенең комплексы проблемаларына кагылышлы фәнни юнәлешләр булдырыла. Г.Ф.Ситдыйкова медиаторларның яңа классы — составында азот оксиды, углерод монооксиды, күкертле водород булган газсыман арадашчыларның физиол. роле концепциясен эшли, ярсынулы төрле системаларда газ тәэсиренең нәтиҗәләрен өйрәнә (2009). РФА КГҮнең Физика-техника ин-ты биофизика лаб-ясендә кешенең үз-үзен тотышы, хәтерләп калу һәм өйрәнү механизмнары һ.б.да баш миенең серотонин һәм дофаминергик системалары катнашы тикшерелә (Х.Л.Гайнетдинов, 1990).

1950 еллардан башлап Казан пед. ин-тында (хәзер Казан федераль ун-ты составында) йөрәк эшчәнлегенең нерв һәм химик механизмнары, йөрәкнең кан куу функциясе, Ф.нең яшькә бәйле мәсьәләләре, кече яшьтәге балаларда физик һәм акыл эшчәнлеге йөкләнешләренә адаптация механизмнары (О.Ж.Курмаев, Ф.Г.Ситдыйков, Р.А.Абзалов, Т.Л.*Зефиров*), нормаль халәттә, миокард инфаркты һәм йөрәк зәгыйфьлеге очрагында йөрәк эшчәнлеген көйләүне тәэмин итүче нечкә күзәнәк-молекуляр процесслар

(Р.Р.Нигъмәтуллин), өске сулыш юллары рецепциясенең физиол. роле (В.К.Трутнев) өйрәнелә. 1970 елларда ин-тның психофизиол. лаб-ясендә сөйләм эшчәнлеге һәм кыска вакытлы хәтернең физиол. механизмнарын өйрәнүләр дәвам иттерелә (Г.А.Әминов, Р.Русинова).

Вет. Ф.се өлкәсендә ш.у. күппланлы тикшеренүләр алып барыла. Вет. ин-тының Ф. кафедрасына проф. Н.О.Ковалевский тарафыннан нигез салына (1873); төрле елларда аның б-н И.Г.Навалихин (1876–84), О.Н.Ворошилов (1884–1910), К.Р.*Викторов* һ.б. җитәкчелек итә. Хәзерге Казан вет. медицинасы академиясенең физиол. һәм зоофизиол. кафедралары галимнәре тарафыннан мөһим физиол. тикшеренүләр алып барыла. 1900 еллардан ашказаны-эчәк тракты Ф.се мәсьәләләре өйрәнелә. К.Р.Викторов беренче булып ашказанының эчке катламы күзәнәкләренең тоз кислотасы бүлеп чыгаруын исбатлый. Ул а.х. терлекләре әгъзалары эшчәнлеге һәм регуляциясе закончалыкларын өйрәнүче фәнни юнәлешне нигезли. Казан физиологы Е.Н.Павловский, эчке әгъзаларның нерв-хи мик регуляциясен анализлап, симпатик системаның ашказаны секрециясенең химик фазасында катнашуын күрсәтә. В.Ф.Лысов һәм Т.Е.Костина ашкайнату үзәгенең эшчәнлеккә сәләтлелеген тәэмин итүдә карын нервларының ролен дәлилли (1960–80 еллар). Х.С.Хәмитов ашказаны-эчәк трактының шома мускулларында кыскару активлыгы өчен медиаторларның трофик ролен исбатлый (1980 еллар). В.Ф.Лысов һәм аның җитәкчелегендәге хезмәткәрләр тарафыннан төрле үсеш стадияләрендә терлекләрнең әгъза һәм функциональ системалары формалашуда нейрогуморальфакторларның роле һәм структур-физиол. үзенчәлекләре ачыклана. 2000 еллардан тышкы шартлар төрле булганда системаларның структур-функциональ халәте һәм организмның нерв-гуморальстатусы бәйләнешләренә күкерторганик тоташтыргычларның биол. эффектына бәя бирелә; яшәү дәверендә терлек организмының төрле функциональ системаларын коррекцияләү ысуллары эшләнә (Т.В.Гарипов). Терлек организмының серотонин, гистамин һәм адренергик (В.А.Гудин) һәм нитроксидергик (Р.Г.Кәримова) системалары өйрәнелә.

2001 дә Казанда И.П.Павлов исем. Физиологлар җәмгыятенең 18 нче Бөтенроссия съезды була. Казан физиологларының фәнни-тикшеренү нәтиҗәләре «Казанский медицинский журнал», «Неврологический вестник», «Учёные записки Казанского университета. Сер. Естественные науки» журналларында басыла.

Әд.: Валидов И.Г. Исследование феномена посттетанического усиления сокращения мышцы // Уч. зап. Казан. ун-та. 1948. Т. 108, кн.4; Курмаев О.Д. Механизмы нервной и гуморальной регуляции деятельности сердца. К.,1966; Хамитов Х.С., Билич И.Л. Ацетилхолин и серотонин в норме и патологии желудочно-кишечного тракта. К., 1977; Григорян Н.А. Казанская физиологическая школа. М., 1978; Волкова И.Н. Медиаторы и регуляция синаптических функций // Казан. мед. журн. 1983. № 2; Абзалов Р.А., Ситдиков Ф.Г. Развивающееся сердце и двигательный режим. К.,1998; Синхронизация вызванной секреции квантов медиатора как механизм облегчающего действия симпатомиметиков // Рос. физиол. журн. 1998. № 10; Зефиров А.Л., Черанов С.Ю. Молекулярные механизмы квантовой секреции медиатора в синапсе // Успехи физиол. наук. 2000. Т. 31, № 3; Физиология и этология животных. М., 2004.

А.Л.Зефиров, Н.В.Звёздочкина.

«ФИКЕ́Р», иҗтимагый-сәяси, әдәби газета. 1905 елның 26 ноябреннән 1907 нең 13 маена кадәр Уральск шәһәрендә татар телендә башта атна саен, аннары атнага 3 тапкыр нәшер ителә, 73 саны басыла. Хуҗасы алмашыну сәбәпле, 1907 нең 22 февраленнән 8 мартына кадәр чыгудан туктап тора. Төрле вакыттагы наширләре — К.*Мотыйгый*, В.Хәмидуллин, М.Гобәйдуллин, Н.Һидиятуллин, актив авторлары арасында — Г.Тукай, З.Бәшири, Ф.Алушева, Г.Шәрипова һ.б. Газета укучыларны хәбәрләр б-н таныштыра, мөселман халыклары иреге өчен көрәшкә чакыра, Дәүләт Думасы эшчәнлеген, с.-д.ның крәстияннәрнең җирне сатып алмыйча гына аңа ия булу хокукы өчен көрәшен яктырта.



«Фикер» газетасы.

Депутатлар, ш.и. мөселман мәгарифен дәүләт финанславы өчен чыгыш ясаган Алексинский, татар-мөселманнарны укытуның миссионер алымнарын тәнкыйтьләп чыккан, халыкларның үз туган телләрендә белем алуга хокукларын яклаган К.Хәсәновның чыгышлары; «Иттифак» партиясенең җимерелүе һәм трудовиклар төркеме барлыкка килү турындагы материаллар, «Казакъ конституцион-демократик партиясе» программасы, аны оештыручы Б.Каратаевның «Кардәшләр», «Татар-казакъ аталарының уллары» («Сородичи», «Сыны отцов казахов и татар»), ш.у. казакълар сәяси хәрәкәте активистлары Г.Бирдеевның «Конституцион-демократик партия яклы казакъларның беренче җыены» («Первое собрание казахов, примкнувших к конституционно-демократической партии»), Алчи Ха җи Ногманның «Тагын бер явызлык» («Ещё одно зло») һ.б. чыгышлар басыла. Язмалар казакъ телендә чыга, чөнки редакция казакъ халкының үзәнең уятырга һәм азатлык хәрәкәте идеяләрен таратырга омтыла. «Ф.» кадетлар партиясенә оппозициядә тора, актив сәяси агитация алып бара башлаган беренче татар газетасы була, анда социаль-демократик брошюралардан өзекләр басыла. Редакция, 1905 нең 17 октябрь Манифесты сүз иреген игълан итсә дә, самодержавиенең элеккечә татар вакытлы матбугатының үсешенә киртә булуын кабул итми. 1906 да Идел буенда булган ачлык, игенчелек культурасын яхшырту алымнары, һөнәрчелек һәм сәүдә эшчәнлеген камилләштерүгә багышланган язмалар дөнья күрә. Хатын-кызларны укытуны пропагандалауга зур игътибар бирелә. Әлеге уңайдан язмаларда башка илләрдә яшәүчеләрнең тормышыннан мисаллар китерелә, инглиз хатын-кызларының сайлау хокукы өчен көрәшүләре турында сөйләнә. «Ф.» хатын-кызларның тигез хокуклылыгына чакыра. Г.Тукай, М.Мостакаев һ.б. татар халкына хас булмаган чадра киеп йөрүгә каршы чыгыш ясыйлар. Редакция шәригать кануннарына каршы идеяләрне пропагандалаганы өчен «Ф.»не тәнкыйтьләп чыккан «Бәянелхак» г-тасы б-н бәхәскә керә. Газетаны идея ягыннан рухландыручы Г.Тукай була. Уральскида яшәгән вакытта язган шигырьләре беренче тапкыр «Ф.»дә басыла («Ирек турында», «Интәшләргә сүз», «Яз» һ.б.). Анда З.Бәшири, Н.Думави, Х.Максудов, З.Насыйри, К.Патии, Г.Сәләхетдинов, Ф.Туйкин, Г.Хәмидуллин, М.Чулпани, М.Шакиржанова һ.б. шигырьләре дөнья күрә. Әдәбият, театр һәм музыка сәнгате, мәгариф һәм фән мәсьәләләре турында фикер алышына. «Йолдыз», «Вакыт», «Урал» һ.б. г-талар материаллары күчереп бастырыла. Даими рубрикалары: «Җирле һәм гомуми характердагы мәсьәләләр буенча баш мәкаләләр», «Үзәк хөкүмәт һәм аның җирле органнары карарлары», «Тәр җәмәләр, телеграммалар, җирле хроника», «Газета һәм журналлар арасында» һ.б. Ш.у.к. «*Яңа тормыш*».

Әд.: Әмирханов Р. «Фикер» газетасында хатын-кыз мәсьәләсе // Азат хатын. 1975. № 6; Яхин Ф. Татарсткая литература в периодической печати Уральска (1905–1917 гг.). К., 1992.

ФИ́КОВ-КО́ЛОК посёлогы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 15 *км* көнчыгыштарак, Талкыш елгасы буенда. 2010 елда 92 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 82%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, ит терлеге, дуңгыз асрау. Тулы булмаган урта мәктәп. 19 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1940–2001 дә Галактионов исем. совхозның икенче бүлекчәсе исеме б-н билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 260 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Олы Талкыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан Чистай р-нында. Халык саны: 1859 да — 35, 1897 дә — 120, 1908 дә — 129, 1920 дә — 112, 1926 да — 125, 1938 дә — 346, 1949 да — 325, 1958 дә — 382, 1970 тә — 429, 1979 да — 323, 1989 да — 213, 2002 дә — 143 кеше.

ФИ́КУС (Ficus), тутчалар семьялыгыннан мәңге яшел (кайберләре яфрак коючы) үсемлекләр ыругы. Күбесенчә агач һәм куаклар, кайвакыт лианалар. Якынча 1000 төре билгеле. Чыгышы — ике ярымшарның да дымлы тропик һәм субтропик пояслары. Күп кенә формалары (буучы Ф.) кәүсәне нык итеп ураучы һава тамырлары барлыкка китерә



В.П. Филимонов.

һәм агач соңыннан корый. Яфраклары бөтен, кайбер төрләрендә 60–70 *см* озынлыкта, калын, ялтыравыклы яки бәрхетсыман (төкчәле), яфрак җәймәсе күптөрле формада. Чәчәкләре түгәрәк яки грушасыман эче куыш чәчәк төркемендә, яфрак куентыгында ботак яки кәүсәләрдә барлыкка килә. ТРда декоратив бүлмә гөле буларак үстерәләр: каучуклы Ф. (F. elastica) — ялтыравыклы калын яфраклары зур озынча түгәрәк яки эллипссыман формада, төрле төстә, уртадагы җепселе яхшы ук күренеп тора; лирасыман Ф. (F. lyrata) — зур яфраклары скрипкага охшаган, 50–60 *см* озынлыкта; Бенджамин Ф.ы (F.benjamin) — нәзек иенке ботаклы, яфрак - лары кечкенә, яшел төстә, кайбер формаларында ак яки сары тимгелле; кытыршы Ф. (притуплённый) (F. retusa) — Бенджамин Ф.ыннан горизонталь җәенке, туры ботаклы һәм яфракларының күерак булуы б-н аерыла; кечкенә Ф. (крохотный) (F. pumila) — тиз үсүче һәм бик чыдам, түшәлмә яки үрмәле куак, куе вак яфраклары төрле форма һәм төстә. Җәен яки көзен оч ботаклардан үрчетәләр. Сөтчел сыекчасы чыгып беткәнче ботакларны җылы суда тоталар, аннары тамырлану өчен салкынрак суга куялар яки дымлы комга утырталар. Яшь үсемлекләрне ел саен, картларын 4–5 елга бер тапкыр күчерәләр.

ФИКЪҺ (гарәп. فقه — аңлау, белем), 1) Коръ әнгә, Сөннәгә, иҗмагъка (мөселман җәмәгатьчелегенең бердәм фикере) һәм кыяска (Коръәнне логик-аналогик аңлату) нигезләнгән мөселман хокукы; 2) мөселманнарның үз-үзләрен тотышларын һәм үзара мөнәсәбәтләрен көйләүче дини, хокукый, әхлакый һәм этик нормаларны үз эченә алган кагыйдәләр. Ф.не үзләштергән дин һәм хокук белгечләре фәкыйһ була. Ф.нең башлангыч этабы Мөхәммәд пәйгамбәр (570–632) һәм Гарәп хәлифәлегендәге (661–750) беренче дүрт хәлифә — Әбү Бәкер әс-Ситдыйк (632–34), Гомәр бине Хаттаб (634–44), Госман бине Гаффан (644–56), Гали бине Әбү Талиб (656–61) эшчәнлеге б-н бәйле. Гарәп хәлифәлегендә Өммәвиләр династиясе идарәсе елларында Ф.нең яшанычлы чыганакларын эзләү бара. Алар тарафыннан хәдисләр (Мөхәммәд һәм аның сәхабәләре әйткән сүзләр, карарлар һәм гамәлләр) таныла. Габбасилар идарә иткән чорда (749–1258) хәдисләр бер системага китерелә, алар Коръ ән һәм Сөннәнең төп нигезләренә яраклы рәвештә сайлап алына. Әш-Шәфигый (820 елда вафат) «әр-Рисалә» дигән трактатында Ф.нең төп категорияләрен формалаштырып, аның үсешенә зур өлеш кертә. 8 йөз — 9 йөзнең беренче яртысында Ф. мөстәкыйль хокукый дисциплинага әверелә. 8–9 йөзләрдә сөнни Ф.не канунлаштыру белән төп дини-хокукый мәктәпләр — *мәзһәбләр* (хәнифи, мәлики, шәфигый һәм хәнбәли) оеша, алга таба Ф. мәзһәбләр кысасында үсеш кичерә. 11 йөздән Ф.не эшкәртү туктала, ул гамәли шәригать нормаларын аңлатуга кайтып кала. Ф. карый торган предмет мөселманнарның Аллаһка мөнәсәбәте, кешеләр, дәүләтләр һәм конфессияләр арасында үзара мөнәсәбәтләр була. 19 йөзнең 2 нче яртысыннан мөселман илләрендә Ф.нең кулланылыш даирәсе акрынлап тарая башлый, Европа илләре хокук нигезендәге дөньяви хокук кагыйдәләренә урын бирелә һәм дәүләт, административ, җинаять һ.б. хокук төрләреннән (Ф.не шәхси мөнәсәбәтләрне көйләүдә файдаланучы Согуд Гарәбстаны, Фарсы култыгы илләреннән башка) алына. Шулай да күп кенә ислам дәүләтләрендә Ф. кануннар чыгаруда төп чыганак булып тора.

Әд.: Филипс А.А.Б. Эволюция фикха. Киев, 2001; Вайс Б.Дж. Дух мусульманского права. СПб., 2008; Абд аль-Хамид Махмуд Тахмаз. Ханафитский фикх. М.-Н.Новгород, 2010. Т. 1; Урусова Э.А., Иванов И.В. Мусульманское право: Библиогр. указ. М., 2010; Адыгамов Г.К. Исламское право. К., 2011.

ФИЛАРЕ́Т (Амфитеатров Фёдор Георгиевич) (17.04.1779, Орёл губ., Кромы өязе Высокое а. — 21.12.1857, Киев), дин эшлеклесе, дин гыйлеме д-ры (1814). Севск руханилар семинариясенә тәмамлаганнан соң (Орёл губ., 1797), шунда укыта, 1802–04 елларда ректор. 1798 елда монахлык кабул итә. 1804 тән Оренбург руханилар семинариясе (Уфа ш.) ректоры, 1810–13 тә Тубыл руханилар семинариясендә, 1814 тән Петербург, со ңыннан Мәскәү руханилар академиясе инспекторы, 1816–19 да Мәскәү руханилар академиясе ректоры, 1819 дан Калуга һәм Боровск, 1825 тән Рязань епископы (1826 дан архиепископ), 1828 дән Казан һәм Сембер, 1832–36 да Казан һәм Зөя архиепископы, 1837 дән Киев митрополиты булып тора. Казан төбәгендә актив рәвештә миссионерлык эше алып бара. Рус булмаган халыкларны көчләп чукындыру чараларын хупламый. Дини әдәбиятны Идел буе халыклары телләренә тәр җемә итү тәкъдиме б-н чыга. Казан епархиясе уку йортларында укыту торышын яхшыртуга зур игътибар бирә. Изгеләштерелә (1994 тә).

Х е з м.: Слова, беседы и речи. Киев, 1883.

Әд.: Сергий (Василевский). Высокопреосвященнейший Филарет, в схимонашестве Феодосий (Амфитеатров), Митрополит Киевский и Галицкий, и его время: В 3 т. К., 1888; Липаков Е.В. Архипастыри Казанские. 1555–2007. К., 2007.

ФИЛА́ТОВ Анатолий Николаевич (3.10.1946, Әлки р-ны Урта Биктимер а.), тарихчы, тарих фән. д-ры (1990), проф. (1993). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1972), 1976 елдан Казан технол. ин-тында эшли. 1993 тән Казан бизнес һәм идарә итү ин-ты ректоры. 1999 дан Социаль һәм гуманитар белемнәр ин-ты проректоры, 2000 нән Социаль-гуманитар көллият (Казан) директоры. Хезмәтләре политология һәм социологиягә карый.

Х е з м.: Социология труда и управления. К., !994 (автордаш); Социология: Учеб. курс. К., 1997 (автордаш); Политология: Учеб.пособие. К., 2003 (автордаш).

ФИЛИМО́НОВ Виктор Петрович (7.3.1940, Куйбышев өлкәсенең Сергиевск р-ны Успенка а.), төзүче инженер, Соц. Хезмәт Герое (1977). Казан төзүче инженерлар ин-тын тәмамлый (1981). Хезмәт эшчәнлеген 1957 елда 25 нче трестның 8 нче төзелеш идарәсендә ташчы булып башлый (Самара өлкәсенең Новокуйбышевск ш.). 1958 дән Казакъстан ССРның Караганда өлкәсе Тимертау шәһәре төзелеш оешмаларында. 1970 тән «Камгэсэнергострой» ҖБдә: 61 нче, 62 нче төзү-монтаж идарәләрендә монтажчылар бригадиры, 46 нчы төзү-монтаж идарәсе башлыгы (1979 дан). 1995–98 дә «Челныгорстрой» АҖдә: баш инженер, 61 нче төзү-монтаж идарәсе башлыгы урынбасары. Ф. җитәкләгән бригада 1971–75 тә 150 мең $м^2$ дан артык тораксыз файдаланууга тапшыра, Чаллы шәһәрендә тимер-бетон конструкцияләрдән бораулап сугылган субайлы фундаментларда гомуми мәйданы 540 мең $м^2$ булган беренче биек (9–12 катлы) торак йортлар, илдә беренче булып колонналарга утыртылган 17–26 подъездлы җыелма уникаль торак йортлар төзелә.

Герой исеме КамАЗның 1 нче чиратын төзегәндә ирешкән уңышлары өчен бирелә. 1976–81 дә КПСС ҮКның ревизия комиссиясе әгъзасы. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының бронза медале б-н бүләкләнә. Чаллы шәһәренең мактаулы гражданы (1999).

Әсәр.: Путёвка в жизнь // Поступь Батыра. Год 1972. К., 1973; Третья высота // Мы строим КамАЗ. К., 1974; Почётная и ответственная обязанность // Коммунист Татарии. 1977. № 7.

Әд.: Тажи Насих. Өмет // Җидегән йолдыз. К., 2004; Паушкин Г. Три встречи на высоте // Батыр на Каме. Год 1971. К., 1972; Лисин Е. Градостроитель // Останутся в памяти. К., 1978; Алаев Ю. Филимонов Виктор Петрович // Герои Социалистического Труда Татарии (1938–1978 гг.): Док. очерки. К., 1980; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003; Энциклопедия города Набережные Челны. К., 2007.

М.Ж.Гаитов.

ФИЛИМО́НОВ Юрий Геннадьевич (27.7.1941, Казан), фоторәссам, журналист. «Кинофотоматериаллар технологиясе» белгечлеге буенча Казан химия-технол. техникумын тәмамлый (1979). 1971–79 елларда спорт авиациясе КБ кинолаб-ясе башлыгы, 1979–2002 дә — КПССның Татарстан өлкә ком-ты нәшриятында (хәзер «Идел-Пресс» ДУП полиграфия-нәшрият комб-ты) фотограф булып эшли, бер үк вакытта, 1969–75 тә, Казан «Волга» фотоклубында, 1975 тән «Тасма» фотоклубында әгъза булып тора. Журналистлар берлеге (1988), Фоторәссамнар берлеге әгъзасы (1992). 1979 дан респ-ка журналлары һәм газеталары б-н хезмәттәшлек итә, «Казан утлары» (1988 дән), «Азат хатын» (хәзер «Сөембикә»), «Ялкын» ж-ллары, «Вечерняя Казань», «Советская Татария» (хәзер «Республика Татарстан»), «Социалис-

тик Татарстан» (хәзер «Ватаным Татарстан») һ.б. г-талары фотохәбәрчесе. 2012 дән Казанда В.И.Ленин исем. мәдәният-ял үзәге каршында «Волга» фотостудиясе җитәкчесе. Ландшафт күренешләре һәм архит-ра пейзажын сурәтләүдә үз юнәлешен булдыра; портретлар һәм сюжетлы композицияләр авторы, фоторепортаж остасы. Нәшриятта эшләгәндә, беренчеләрдән булып, төсле фоторәсемнәр б-н шөгыльләнә башлый, «Татарстан



Ю.Г.Филимонов. «Сабан туенда». 1970 еллар.

шәһәрләре» (1982), «Туган ягым» (1987), «ТАССР Сынлы сәнгать музее тупланмасыннан» (1990), «Зоя утравы» (1991), «Казан — туган шәһәрем» (1997), «Татарстан» (2001, 2002), «Казан» (2003) һ.б. фотокалендарьлар иҗат итә. Казан пейзажлары, ш.и. биектән төшерелгән күренешләр, Казан Кремленең беренче фотопанорамасы авторы. Ф.ның күп кенә әсәрләре шәһәрнең визит



Ю.Г.Филимонов. «Казан Кремле». 2002.

карточкасына әверелә, популяр басмаларга кертелә, алардан «Казан: үткәне һәм хәзерге се» альбомы төзелә (1997). «Сабантуй» («Сабантуй» китап-альбомында басыла, (1999), «Матюшино авылында Троица бәйрәме» (2006) һ.б. сериялләр авторы. 1973 тән шәһәр һәм респ-ка, ш.и. «Татарстан нефтьчеләре» (Әлмәт, 1982) фотокүргәзмәләрендә, Халыкара Берлин (ГДР, 1985) фотокүргәзмәсендә катнаша.

Шәхси күргәзмәләре 2006, 2011 дә Казанда уздырыла. Ф.ның фоторәсемнәре ТР Милли музеенда саклана.

Х е з м.: Три страсти седоусого художника: дневник отпетого путешественника // Казань. 2009. № 6; Двадцать два дня и столько же ночей с осли цей Меридой: фантастическое путешествие в столицу Сибирии // Казань. 2010. № 9.

Әд.: Щ е р б а к о в а Р. Детские мечты фотомастера // Казань. 2001. № 6; К о л и н а С. Любовь без виз // Казань. 2011. № 9.

Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.

ФИЛИМО́НОВА Мария Николаевна (20.2.1954, Мәскәү), микробиолог, биохимик, биол. фән. д-ры (1999). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1976), шунда ук эшли, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1999 дан). Хезмәтләре нуклеизалар — микроб ферментларының физик-химик үзлекләрен билгеләү һәм өйрәнүгә карый. Ф. тарафыннан беренче тапкыр Serratia marcescens гомоген эндонуклеаза алына, аның молекуляр формалары кителә һәм ферментларның металл катионнары б-н активлашу механизмы тасвирлана; эндонуклеазаларны алуны җитештерү алымнары гамәлгә кертелә. «Микроблы биотехнология» («Микробная биотехнология», 2007) уку ярдәмлеге автордашы (2007). Үйлап табуга 9 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Нуклеазы Serratia marcescens. 1. Сравнение природной и рекомбинантной нуклеаз с использованием электроспрей-масс-спектрометрии // Биоорган. химия. 1995. Т. 21, № 5 (автордаш.); Нуклеазы Serratia marcescens полидисперсны при оптимальном значении pH // Прикладная биохимия и микробиология. 1999. Т. 35, № 1 (автордаш.).

ФИЛИМО́НОВКА авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 42 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Ташъелга елгасы буенда. 2010 елда 88 кеше (марилар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. башлангыч мәктәп, клуб. 1911 дә нигез салына. Беренче исеме — Яңа Калтак. 1913 тә авыл җәмәгатенең имана җире 119 дис. тәшкил итә. Оешкан көнен нән — Уфа губернасының Минзәлә өязе Пучы (1919 дан — Әтрәкле) волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Мөслим, 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1944 нең 19 февраленнән — Матвеевка, 1954 нең 19 ноябреннән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән Минзәлә р-нында. Халык саны: 1913 тә — 48, 1920 дә — 129, 1926 да — 130, 1938 дә — 195, 1949 да — 149, 1958 дә — 97, 1970 тә — 141, 1979 да — 115, 1989 да — 68, 2002 дә — 82 кеше.

ФИЛИ́ППОВ Андрей Васильевич (27.12.1957, Сведловск өлкәсенең Карпинск ш.), физик, физика-матем. фән. д-ры (2004). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1980), шунда ук эшли (бүленеп: 1982–85 елларда Казан химия-технол. ин-тының Түбән Кама ф-лында, 1995–2001 дә РФ Эчке эшләр министрлыгының Казан юридик ин-тында), 2008 дән молекуляр физика каф. профессоры. Хезмәтләре катлаулы молекуляр системаларда ТМР алымын кулланып үзлегеннән диффузия күренешен барлыкка китерүгә карый. Ф. сыек кристалл фазасының тәртипкә салынган һәм тәртипкә салынмаган фазага бүленүе шартларында модель итеп алынган биомембраналардагы липидларның латераль диффузиясе коэффициентын үлчи. Кыр импульсы градиентлы ТМР мәгълүматларына таянып биомембраналарның фаза диаграммаларын төзи. Тәҗрибә нигезендә латераль диффузия коэффициентының икеле бәйләнешләргә һәм липид мембраналардагы холестерин концентрациясенә бәйле булуын ачыклый. ТР Дәүләт бүләгенә лаек була (2008).



Г.И.Филиппов.

Х е з м.: Исследование структуры пористого вещества методом ЯМР криодиффузометрии // Коллоидный журн. 2000. Т. 62, № 6 (автордаш); Свойства бислоёв ненасыщенных фосфолипидов: влияние холестерина // Биолог. мембраны. 2007. Т. 24 (автордаш); Особенности латеральной диффузии липидов в трёхкомпонентных бислоях // Журн. физ. химии. 2011. Т. 85, № 3 (автордаш).

ФИЛИ́ППОВ Вадим Львович (29.8.1941, Краснодар ш.), физик, физика-матем. фән. д-ры (1987), проф. (1993), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (2003). Ленинград электр техникасы ин-тын тәмамлый (1987). 1965 елдан «ГИПО» фәнни-җитештерү берләшмәсендә: 1985 тән бүлек мөдире, 1991 дән Оптика-физика тикшеренүләре фәнни-тикшеренү ин-ты директоры, 1995 тән бүлекчә башлыгы. Бер үк вакытта, 1993 тән, Казан техника ун-ты профессоры. Хезмәтләре оптик-электрон җиһазлар төзүгә һәм атм. оптикасына карый. Ф. дистанцион хәрәкәтле оптик-электрон җиһазлар булдыру максатында атмосфераның оптик сыйфатларын комплекслы рәвештә тикшерә; атмосфераның оптик сыйфатлары үзгәрешләренең закончалыкларын һәм аларны фаразлау мөмкинлекләрен аңлатып бирә. «Почёт билгесе» ордены, медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Экспериментальные данные о прозрачности приземных атмосферных трасс различной протяжённости в диапазоне 1–25 мкм. М., 1979 (автордаш); Введение в технику разработки и оценки сканирующих тепловизионных систем. К., 1998; Оптическая погода в нижней тропосфере. К., 1998.

ФИЛИ́ППОВ Василий Никитич (1900, Казан губ., Лаеш өязе Олы Мирәтәк а. — 9.5.1938, Казан), хакимият эшлеклесе. Татар коммунистлар ун-тын тәмамлый (1925). 1925–27 елларда Татарстан а.х. хезмәткәрләре берлегенең Чистай кантоны бүлеге рәисе, 1927–28 дә Эшче, крәстиян һәм кызыл-армияче депутатларының Чистай кантоны башкарма ком-тының халык мәгарифе бүлеге рәисе. 1928–29 да ВКП(б)ның Чистай канткомы оештыру бүлеге мөдире. 1929–34 тә ТАССР юстиция халык комиссары. Бер үк вакытта, 1929–32 дә, ТАССР прокуроры. 1934–37 дә ТАССР ҮБК секретаре. Репрессияләнә, үлгәннән соң аклана.

Е.Б.Долгов.

ФИЛИ́ППОВ Гордей Иванович (1.1.1904, Казан губ., Спас өязе Катюшино а. — 14.9.1982, Мәскәү өлкәсенең Щёлково ш.), Сов. Союзы Герое (27.6.1945), рядовой. 1921 елдан Черноралинск торф чыгару һәм эшкәртү пр-тиесендә (Горький, хәзер Түбән Новгород өлкәсе), 1932 дән Ярославль өлкәсендә торф чыгару урыннарында эшли. Бөек Ватан сугышы башында туган авылына

кайта. 1942 нең октябреннән Кызыл Армия - дә һәм Бөек Ватан сугышы фронтларында, 530 нчы танк һөҗүменә каршы артиллерия полкының (28 нче армия) туп төзәүчесе. 1 нче Украина фронты гаскәрләре составында Сталинград (1942–43), Ростов (1943), Белоруссия (1944), Мемель (1944), Варшава-Познань (1945) һәм Берлин (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1945 нең 30 апрелендә Куммерсдорф торак пункты янындагы (Берлиннан 40 *км* көньяккарак) сугышта батырлык күрсәтә: дошман һөҗүмен кайтарганда, расчёт б-н танкны сафтан чыгара, 2 үзиөреш - ле артиллерия җайланмасын яндыра, дошманның дистәләрчә солдатын юк итә. Рас - чёттан үзе генә калып, сугышны дәвам итә һәм позицияне саклый. Демобилизацияләнгәннән соң (1945), Рыбинск шәһәрендә яши һәм эшли, аннан соң Щёлково шәһәренә күченеп китә. Ике Ленин ордены, Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Базарлы Матак авылында бер урам һәм Щёлково шәһәрендә укучылар йорты Ф. исемен йөртә.

Әд.: Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

М.З.Хәбибуллин.

ФИЛИ́ППОВ Николай Леонтьевич (11.12.1928, Чистай кантоны, хәзер Нурлат р-ны Иске Чаллы а. — 15.12.1989, шунда ук), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, РСФСРның ат - каз. а.х. хезмәткәре (1983). Минзәлә совхоз-техникумын тәмамлый (1973). 1948–89 елларда Октябрь р-нында: тракторчы, бригадир ярдәмчесе (1952 дән), МТСта трактор лар бригадасы бригадиры (1956 дан), «Борьба» к-зында (1958 дән), Синдряков исем. к-зда (1965), аның рәисе (1967). Ф. җитәкчелегендә ху җалыкта матди-техник база һәм соци - аль-мәдәни инфраструктура булдырыла; 150 гаилә өчен торак төзелә, Иске Чаллы, Урта Чаллы, Түбән Чаллы авылларына электр кертелә; газлаштыру башлана; товар - лыклы-сөтчелек фермаларында ике смена - лы эш, бригада подряды һәм җитештерү б-н идарә итүдә цех структурасы кертелә. Хуҗа - лык үсемлекчелек һәм терлекчелек продук - циясен җитештерүдәге югары күрсәткечләре өчен РСФСР МСның күчмә Кызыл Байра - гы, дуңгызчылык фермасы — СССР ВДНХ - сының 1 нче, 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә диплом - нары б-н бүләкләнә. 1975–80 дә СССР ЮС депутаты. Ленин, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары; медальләр, ш.и. СССР ВДНХ - сының көмеш медале б-н бүләкләнә.

И.Н.Афанасьев.

ФИЛИ́ППОВ Сергей Иванович (10.2.1957, Казан), механика өлкәсе галиме, физика-ма - тем. фән. д-ры (2004), проф. (2006). Казан ун-тын тәмамлый (1979). 1982–84 елларда Казан химия продуктлары фәнни-тикшере - нү ин-тында. 1984–96, 1998–2005, 2007–08 дә Казан ун-тының Матем. һәм механика фән - ни-тикшеренү ин-тында. 1996–98 дә Казан югары артиллерия инженер-командирлар училищесендә (соңрак Казан югары артилле - рия командирлары уч-щесе). 2005 тән Казан архит-ра-төзелеш ун-тының югары матем. каф. профессоры. Хезмәтләре су асты кана - тына һәм матем. модельләштерүгә багышла - на. Ф. авырлык көчләрен һәм өслек киеремен исәпкә алган хәлдә күпкатламлы һәм чикләнелгән сыекча агымнарында җисемнәр хәрә - кәте турындагы мәсьәләләрне чишүнең ана - литик-сан алымнарын эшли. Агымның гидродинамик күрсәткечләренә Фруд критик саннарының йогынтысын тикшергән хәлдә төрле типтагы өч бүленү чикләренә ия булган авырлыклы сыекчада җисемнәрнең ста - ционар хәрәкәтен өйрәнеп тикшерә.

Х е з м.: Установившиеся колебания плоского контура вблизи границы раздела сред при наличии горизонтального дна // Прикладная механика и техн. физика. 1995. Т. 36, № 2; Обтекание подводного профиля двухслойным потоком весомой жидкости // Изв. вузов. Авиац. техника. 2000. № 3; Гидродинамика крылового профиля вблизи границ раздела. К., 2004.


ФИЛИ́ППОВА Надежда Константиновна (31.7.1961, Казан), биотехнолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2007), техник фән. канд. (2004). Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң (1986), шунда ук эшли. Хезмәтләре микро - биол. сәнәгатендә ресурс саклаучан интенсив технологияләрне эшләүгә карый. Ф. аэроб ферментлау процессына кислород күчерү - ченең (актив өслекле матдәнең) кечкенә до - заларын кертү нәтиҗәсендә кислородның массакүләм төстә газ фазасыннан сыекчага күчүенең интесивлашуын, шул рәвешле мак - сатлаштырылган продукт чыгышының ар - туын, технол. циклның кыскаруын, чимал һәм энергетика ресурсларының янга калуын ачыклый. Фәнни тикшеренү нәтиҗәләре дару препаратлары, аминокислоталар, азык һәм спирт чүпрәсе, ферментлар җитештерүдә кул - ланылыш таба. Дәүләт бүләге чүпрә генерациясенең аэроб технологиясен эшләүдә һәм аны спирт җитештерүдә гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә. Медальләр б-н бү - ләкләнә.

ФИЛИ́ППОВКА посёлогы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогын - нан 27 *км* көньяк-көнбатыштарак, Мишә ел - гасының югары агымы буенда. 2010 елда 73 кеше (удмуртлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Клуб. 1925 тә Югары Кумор авылыннан күченүчеләр нигез сала. Оешкан көненнән ТАССРның Мамадыш кантоны Кукмара волостенда. 1930 ның 10 ав - густыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кук - мара р-нында. Халык саны: 1926 да — 83, 1938 дә — 107, 1949 да — 113, 1958 дә — 100, 1970 тә — 102, 1979 да — 113, 1989 да — 71, 2002 дә — 83 кеше.

ФИЛИ́ППУС Георгий Юрьевич (?-1886 дан соң), рәссам-педагог. Мәскәү нәкыш, скульп - тура һәм архит-ра уч-щесен тәмамлый (1860). 1873 елдан Казан урта уку йортларында — Укытучылар ин-тында, Беренче һәм Икенче ир балалар гимназияләрендә, Александр исем. һөнәр уч-щесендә укыта. Дәресләрне «Гермс, Жульен һәм башка үрнәк мәктәпләре ори - гиналларыннан» Мужак, Сапожников, Эбер - линг ысуллары буенча алып бара. Укыту про - граммасына ш.у. архит-ра ордерларының, «үрнәк биналар» планнары һәм киселешләр - ренең сызымнарын эшләү, натурадан төрле предметлар һәм пейзажлар ясау керә.

Х е з м.: Курс рисования для классных и домашних занятий с детьми от 6-летнего возраста: В 2 ч. К., 1881–82.

ФИЛЧЕКЛӘ́Р (Curculionidae), үсемлекләр б-н туенучы якынча бер- һәм күпьеллык коңгызлар семьялыгы. Дөнья фаунасында 45 мең төр, БДБда — 3,5 меңнән артык, Татарстан - да 150 төре билгеле. Аларның күбесе а.х. үсемлекләре корткычлары, кузаклы культу - ралар, чөгендер чәчүлекләренә шактый зыян китерәләр. Гәүдәсенең озынлыгы 1,8–2 *см* га кадәр, еш кына металлсыман ялтыравыклы, башының алгы өлеше берникадәр озын көп - шә булып сузылган, аның төбендә коңгыз - ларга хас кимерүче авыз аппараты урнашкан. Ф.ның күбесе — фитофаглар, ягъни чәчәкле үсемлекләрнең төрле өлешләре б-н туе - наланар. Гадәттә, Ф. күкәйләрен җиргә яки үсемлек тукымасына салалар. Личинкалары аяксыз, С сыман формада, итчел, җыерчык - лы капламлы, ак яки аксыл сары, сары яки кө - рән төстәге баш капсуласы яхшы үсеш ал - ган. Ф. туфракта яки туенучы үсемлекнең тукымаларында курчаклана. Ф., гадәттә, по - лифаглар, кайбеләре олифаглар; мәс., Sitona ыругыннан бүлбе Ф.е кузаклы үсемлек та - мырларындагы бүлбеләрдә, чөгендер Ф.е



Филчекләр. 1. Орлыгашар тукранбаш филчеге; 2. Яфрак-люцерна филчеге; 3. Кура җиләге чәчәгашары; 4. Гади чөгендер филчеге; 5. Соры чөгендер филчеге; 6. Буйлы бүлбе филчеге; 7. Чәчәгашар алма филчеге.

(Bothynoderes punctiventris) кайбер алабутачалар тамырларында гына үсеш алалар һ.б.ш. Күп кенә төрләре аерым бер азык б-н туенуга җайлашкан, монофаг диярлек тар олигофаглар бары тик үсемлекләрнең билгеле бер төрләре һәм өлешләре б-н генә туеналар. Ф.нең үсемлек яфракларында ачык үсеш чагыштырмача сирәк күренеш (мәс., люцерна яфрагы Ф.енең үсеш шундый); шунда ук корылган пәрәвезле кузыларда курчакланалар. ТРда таралган, куркыныч а.х. кортларына чөгендер, тукранбаш һәм бүлбе Ф.е, корткыч коңгыз, җиләк һәм бөре Ф.е, алмагач чәчәге коңгызы керә. Амбар Ф.е ашлык һәм бөртекле продуктларны зарарлый.

Көрәш чаралары: агротехник — чәчү әйләнешен саклау, кырны изоляцияләү, юга-ры шытымлы орлыкларны иртә срокларда чәчү, орлыкларны күмдерүдә иң кулай тирәнлек булдыру, чәчүлекләрне, басуларны чүп үләннәрдән саклау, туфракны туңга сөрү; химик — чәчүлек орлыкларны һәм аеруча шытымнарны комплекслы агулау матдәләре, ш.у. бакча, складларны инсектицидлар б-н эшкәртү һ.б.

Әд.: Жизнь животных. М., 1968. Т. 1; Алейникова М.М., Утробина Н.М. Животное население почв в агробиоценозах Среднего Поволжья // Животное население почв агробиоценозов и его изменение под влиянием сельскохозяйственного производства. К., 1969; Всеволодова-Перль Т.С. Дождевые черви фауны России: Кадастр и определитель. М., 1977; Прогноз появления основных вредителей и болезней сельскохозяйственных растений в Республике Татарстан. К., 2002. *А.К.Жеребцов.*

ФИ́ЛЬЧЕНКОВ Сергей Яковлевич (18.3.1915, Тверь өлкәсенең Оленино р-ны Б.Воробьи а. — 30.11.1965, Казан), Сов. Союзы Герое (26.10.1944), лейтенант. Ржев шәһәрендә аэроклуб, кече авиация белгечләре мәктәбен (1938), укчы-бомбардирлар хәрби авиация мәктәбен (1940) тәмамлый. 1938 дән Кызыл Армия сафларында. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 241 нче бомбардировщиклар авиациясе дивизиясенең 128 нче бомбардировщиклар авиациясе полкы (16 нчы һава армиясенең 3 нче бомбардировщиклар авиациясе корпусы) экипажы штурманы. Калинин һәм 1 нче Белоруссия фронтларының очу берләшмәләре составында Мәскәү (1941–42) һәм Курск (1943) сугышларында, Гомель-Речица (1943), Бобруйск (1944) һәм Берлин (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең июленә 212 сугышчан очыш ясый, шәхсән 1, иптәшләре б-н бергә дошманның 4 самолётын бәреп төшерә. 1945 нең 16 апрелендә Берлин өчен барган сугышта немец зениткалары тарафыннан бәреп төшерелә, авыр яралана. Демобилизациядән соң Казанда яши һәм эшли. Ленин ордены, Кызыл Байрак, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000. *М.З.Хәбибуллин.*

ФИН Яков Исаакович (1891, Вильно губ. Дисна ш. — 26.10.1937, Мәскәү), профсоюз эшлеклесе. Февр. һәм Окт. рев-цияләрендә катнаша. 1905 елдан РСДРП әгъзасы. 1918–28 дә совет һәм профсоюз органнарында, Мәскәүдә төрле газета редакцияләрендә эшли; 1919–22 дә Совет сәүдәсе хезмәткәрләре профсоюзы ҮК рәисе, бер үк вакытта «Правда» г-тасының төнге мөхәррире, «Труд» г-тасы һәм «Вестник труда» ж-лы мөхәррире. 1922 дән ВЦСПС аппаратында, РСФСР ХКСнда эшли. 1922–29 да Профсоюзларның Татарстан Советы рәисе, ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты бюросы һәм секретариаты әгъзасы. «Уң тайпылыш»та гаепләнә, вазифаларыннан азат ителә. Репрессияләнә, үлгәннән соң аклана.

Ф.Г.Миңнеханов.

ФИ́НКЕ Иоанн Христофор (Иван Арнольдович) (1773, Гёттинген ш., Германия — 17.9.1814, Казан), хокук белгече, хокук д-ры (1798). Гёттинген ун-тын тәмамлый (1798). 1799–1809 елларда Ганновер һәм Гёттинген шәһәрләрендә мәхкәмә һәм адвокат эшчәнлеге б-н шөгыльләнә. 1809 дан Казан ун-тының табигый, сәяси һәм халык хокукы каф. профессоры һәм бер үк вакытта, 1813 тән, әхлакый-сәяси бүлек деканы. Хезмәтләре халык, дәүләт һәм хосусый хокукларга карый.

Х е з м.: Естественное частное, публичное и народное право. К., 1816.

Әд.: Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2.

ФИНЛЯ́НДИЯ (Финляндия Респ-касы), Европаның төньягындагы дәүләт. Мәйданы — 338430,5 *км*². Башкаласы — Хельсинки шәһәре. Халкы — 5430 мең кеше (2013), татарлар — 1000 ләп кеше. Башлыча, Хельсинки, Турку, Тампере шәһәрләрендә яшиләр. Татарлар Ф.гә 1809 да, Россия империясенә кушылганнан соң, хәрби хезмәткәрләр, Аланд утраулары һәм Хельсинки тирәсендәге утрауларда хәрби ныгытмалар төзү эшендә эшче көчләр сыйфатында килеп урнаша. Татар диаспорасы нигездә 1870 елларда, башлыча, Түбән Новгород губернасының Сергач өязеннән килеп, мех, күн, тукыма, кием б-н сәүдә итүчеләр исәбенә формалаша башлый. 1925 тә Хельсинкида — Finlandiya Islam Çemaati беренче мөселман җәмгыяте, 1935 тә Finlandiya Türkleri Birliği татар мәдәни оешмасы оештырыла. Фин татарларының мәдәни тормышында Совет хакимияте урнашкач, Ф.гә килеп чыккан сәяси эмигрантлар: сәясәт эшлеклесе С.*Максуди*, мөселман дин галиме М.*Бигиев*, журналист һәм язучы Г.*Баттал* зур роль уйный. 1939–40 еллардагы совет-фин сугышы чорында Выборг шәһәрендә яшәүче татарлар Хельсинки һәм Тампере шәһәрләренә күчеп утыра; 1940 елларда Тампереда иң зур татар җәмгыяте формалаша. Кечерәк оешмалар Котка, Турку, Раума, По-ри һ.б. шәһәрләрдә барлыкка килә. 1944 тә Ярвенпяя шәһәрендә мәчет ачыла. 1948–69 да Хельсинкида татар башлангыч мәктәбе эшли, 1950 елларда татар балалар бакчасы ачыла. 1934 тә Ф. татарлары — «Алтын Урда» футбол командасын, Икенче бөтендөнья сугышыннан соң «Йолдыз» спорт җәмгыятен оештыра. 1970 елларда Ф. татарлары 2 оешмага: «Г.Тукай исем. җәмгыять» һәм Ф. татарларының «Исламия» милли-дини җәмгыятенә берләшә (хәзерге вакытта алар бергә кушылган). Алар тырышлыгы б-н үзешчән фольклор ансамбле һәм театр, «Fin tatar birligi» яшьләр оешмасы, якшәмбе балалар бакчалары һәм мәктәпләре, җәйге балалар лагере эшли, анда Швециядән, Германия, Төркия, АКШ, Канададан килгән мәктәп укучылары татар тарихын, мәдәниятен, телен өйрәнә. 1950–80 елларда «Mähallä habärläre» ж-лы чыга, 2012 дән «Yaña Mähallä habärläre» ж-лы нәшер ителә. Ф. һәм ТР татарлары арасында мәдәният һәм фән өлкәсендә тыгыз элемтәләр урнаша; Хельсинки үзешчән яшьләр театры Г.Камал исем. Татар акад. театры сәхнәсендә Казан тамашачысына «Галиябану» спектаклен күрсәтә; Ф. һәм ТР татарларының уртак ижади эшләре Нью-Йорк һәм Сан-Франциско кодa күрсәтелә; «Исламия» җәмгыяте Татарстанның фән, мәдәният һәм сәнгать өлкәсендәге танылган шәхесләр б-н очрашулар уздыра. Төрле елларда татар рок-төркемнәре: «Bashkarma» (1970 еллар), «Kazan Gruppasi Bedretdin» (1992 дән) эшли. Ф. татар диаспорасы әгъзалары арасында эре бизнес вәкилләре, дәүләт чиновниклары бар, «Йолдыз» футбол клубында (шул ук исемдәге спорт җәмгыяте каршында) тәрбияләнгән Атик Исмаил 1978–83 елларда Ф. җыелма командасында уйный. Татарлар тулысынча фин җәмгыятенә яраклашкан, туган телләреннән тыш, фин һәм швед телләрендә сөйләшәләр.



С.Я. Фильченков.

«ФИНЛЯ́НДИЯ ИСЛА́М МӘХӘЛЛӘСЕ́», җыентык. 1949 елда Тампере шәһәрендә (Финляндия) татар телендә нәшер ителә, барысы 6 саны чыга. Наширләре — Х.Шакир һәм Ф.Арат. Тематика татар диаспорасының иҗтимагый тормышы вакыйгаларына мөнәсәбәттә билгеләнә. Мәдәни, дини һәм эстетик мәсьәләләргә игътибар бирелә. Матур әдәбият әсәрләре, аерым алганда, Х.Шакир шигырьләре басыла. Япония һәм Төркиядә дә тарала. Басманың дәвамчысы 1950–51 дә чыккан «Ислам мәхәлләсе» җыентыгы була (11 сан).

ФИО́НОВКА авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 12 *км* көнбатыштарак, Минзәлә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 9 кеше (руслар) яши. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ф.да су тегермәне, ашлык саклау-сату кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 680,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Минзәлә волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Минзәлә р-нында. Халык саны: 1859 да — 176,



И.К. Фирдәүс.

1870 тә — 105, 1884 тә — 138, 1906 да — 211, 1913 тә — 202, 1920 һәм 1926 да — 226 шар, 1938 дә — 224, 1949 да — 104, 1958 дә — 81, 1970 тә — 57, 1979 да — 38, 1989 һәм 2002 дә — 4 әр кеше.

ФИРДӘҮС Измаил Кәрим улы (2.12.1888, Симферополь ш. — 27.10.1937), дәүләт эшлеклесе. Татар укытучылар семинариясен (Симферополь ш.) тәмамлаганнан соң, Симферопольдә «Рөшди» мәдрәсәсендә, аннары Ялта шәһәренең Аутко бистәсендә укытучы булып эшли. Үзлегеннән немец, француз, төрек, итальян һәм латин телләрен өйрәнә. Революцион хәрәкәттә катнашканы өчен кулга алына һәм 4 елга сөргенгә җибәрелә. Беренче бөтендөнья сугышы елларында Таврия губернасының Крәстиян эшләре буенча кабулханәсендә, аннары Таврия Җир банкын да эшли. 1918 елның гыйнварында Кырымда Совет хакимияте урнаштыруда актив катнаша: революцион ком-тка сайлана, Эшче, солдат һәм крәстиян депутларының Симферополь Советы рәисе иптәше (урынбасары), бер үк вакытта кырым татарлары арасында контррев-ция б-н көрәш комиссары һәм тикшерү комиссиясе рәисе. 1918 дә Таврия Совет Респ-касының тышкы эшләр халык комиссары һәм ҮБК Президиумы секретаре, 1919 да Кырымның Вакытлы эшче-крәстиянәр хөкүмәте әгъзасы. Респ-ка таркалганнан соң Мәскәүгә күченә: Эчке Россия мөселманнары эшләре комис-ты секретаре. М.Сөбхи б-н бергә Төркиядә соц. рев-ция әзерләү буенча тоткынлыктагы төрекләр б-н эш алып бара. Гражданнар сугышында катнаша. 1919–20 дә Казанда, РКП(б)ның губерна ком-ты һәм губерна Гадәттән тыш комиссиясе коллегиясе әгъзасы, Мөселман командир лар курслары комиссары. ТАССР төзүне оештыручыларның берсе, ТАССР мәгариф халык комиссары урынбасары. 1920–24 тә РКП(б)ның мөселманнар бюросы секретаре, Кырым АССРның юстиция халык комиссары, прокуроры. Кырым Респ-касын кырым татарларының тулы хокуклы дәүләтенә әверелдерүне яклый. Милли мәсь әләләр не хәл итүдә М.Х.Солтангалиев б-н әлемтәдә булганы һәм аның идеяләрен яклаганы өчен, Мәскәүгә чакыртып алына, РСФСР А.х. банкында эшли. 1927 дә Кавказ арты эшче-крәстиян контроле комиссиясе испекторы, аннары Ростов шәһәрендәге Төньяк Кавказ крае халык мәгарифе бүлеге инспекторы. Репрессияләнә. 1930 да Югары мәхкәмә коллегиясе тарафыннан үлем җәзасына хөкем ителә, карар 10 еллык сөрген б-н алыштырыла.Соловки лагерендә тотыла. 1937 нең октябрендә «өчлек» карары б-н икенче тапкыр үлем җәзасына хөкем ителә. Үлгәннән соң аклана.

Әд.: Деятели крымскотатарской культуры (1921–1944 гг.): Биобиблиогр. словарь. Симферополь, 1999; Тагиров И.Р. Измаил Фирдевс // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2005. № 1.

Л.М.Айнетдинова.

ФИРДӘҮСИ́ Әбүлкасыйм Хәсән ибне Мөхәммәд Туси (940 тирәсе, Тус ш., Иран – 1020 яисә 1030, шунда ук), фарсы-тажик шагыйре. Дөнья әдәбиятында иң зур поэмаларның берсе, «Шаһнамә» (1 нче редакциясе — 994; 2 нче редакциясе — 1010) авторы (60 меңгә якын *бәйт*). Анда мөселманлыкка кадәрге Иран тарихы бәян ителә. Поэма 3 тематик өлешкә бүлеп карала. Мифологик өлешендә борынгы Ирандагы космо- һәм теогоник күзаллаулар, кешелек җәмгыяте барлыкка килү, ш.и. Пишдадидлар (борынгы тәкъвалык патшалары) турындагы мифлар урын алган. Батырлар турындагы өлеше утрак (Иран) һәм күчмә (Туран) иранлылар сугышларына багышлана. Тарихи өлешендә Саманилар нәселе, гарәпләр тарафыннан Иранның буйсындырылуы, әлеге нәсел хакимиятенең бетүе турында хикәяләнә.

«Шаһнамә» поэмасы Яхшылык (Иран) б-н Яманлык (Туран) арасындагы көрәш идеясе б-н сугарылган. Ф.нең камил идарәче турындагы уйлары гадел патшалар образларында чагыла. Поэманың икенче төп идеясе — туган илгә, Иранга мәхәббәт. «Шаһна мә»дәге батырлар һәм шаһлар Ватанны чит илбасарлар яуларыннан саклауны үзләренең изге бурычы дип исәпләгән. «Шаһнамә» нең беренче фәнни басмасы 1829 елда Һиндстанда 17 кулъязма күчермә нигезендә эшләнә. 1838–78 дә Парижда 30 күчермәне үз эченә алган басма дөнья күрә. Икесе дә наширләр тарафыннан тасвирланмаган соңгы кулъязмалар (15 йөздән соң) текстларына нигезләнеп әзерләнә. Немец галиме И.А.Вуллерс Макан һәм Моль басмаларын чагыштыру юлы б-н төзелгән текст нәшер итә (9 томның 3 се нәшер ителә, Лейден, 1877–84). Әлеге тәмамланмаган басма 1934–36 елларда Тәһранда Фирдәүсинең меңьеллык юбилеена төгәлләнә. «Шаһнамә» текстын борынгы кулъязма күчермәләрне (13–14 йөзләр) кертеп, текстологиянең заманча фәнни алымнары нигезендә нәшер итү эшен СССР ФАнең Көнчыгышны өйрәнү ин-ты башкара (т. 1–9, М., 1960–71). Ф. ш.у. лирик шигырьләр, Библия һәм Коръәндәге мәгълүм сюжетка нигезләнеп язылган «Йосыф һәм Зөләйха» поэмасының авторы булган дип исәпләнә. Ф. поэмасының йогынтысы билгеле бер дәрәҗәдә Кол Гали, Мөхәммәдъяр, Утыз Имәни, Г.Кандалый иҗатларында чагыла. 18–19 йөзләрдә «Шаһнамә»гә ияреп язылган күп кенә *кыйссалар* барлыкка килә (М.Йомачиков, К.Минзәләви, Й.Таңчуларов һ.б.).

Әд.: Фердовси, 934–1934. Л., 1934; Бертельс Е. Э. Абу-л-Касим Фирдоуси и его творчество. М.–Л., 1935; Дьяконов М. Фердоуси: Жизнь и творчество. М.-Л., 1940; Османов М.-Н.О. Фирдоуси: Жизнь и творчество. М., 1959; Шукуров Ш.М. «Шах-наме» Фирдоуси и ранняя иллюстративная традиция. М., 1983; Mansur Abu'l Qasem Ferdowsi // Classical and Medieval Literature Criticism. Detroit, 2001. 43.

А.М.Ахунов.

ФИ́РСОВ Вячеслав Анатольевич (9.1.1949, Тәтеш ш.), очу аппаратларының ныклыгы өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1992), проф. (1995), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (2004). 1972 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук очу аппаратларының төзелеш механикасы кафедрасында эшли, каф. профессоры (1993 тән). Хезмәтләре нәкласик иркен беркетелүле пластиналар һәм сүрүләр механикасына; төзелеш механикасында кырый мәсьәләләрен чишүнең санлы алымнарына; экранопланнарны тарту көченә карап проектлауга карый. Ф. тарафыннан сүрү элементлары механикасы мәсь әләләрен, аларның конструкция каркасында иркен беркетелүен исәпкә алып чишү теориясе һәм алымнары, төзелеш механикасының кырый мәсьәләләрен хәл итү өчен аеручы матрицалар аппараты, экранопланнар конструкциясенә йөкләнеш бирү нормаларының нигезләре эшләнә. Уйлап табуга патенты бар. «Известия высших учебных заведений. Авиационная техника» ж-лының баш мөхәррире (1997дән). Медальләр, ш.и. РФ Космонавтика федерациясенең Ю.А.Гагарин исем. медале б-н бүләкләнә.

Хезм.: Оболочки из стекла. Расчёт напряженно-деформированного состояния. М., 1993 (автордаш); Аппарат дифференцирующих матриц для решения двумерных краевых задач строительной механики // Изв. вузов. Авиац. техника. 2001. № 1.

ФИ́РСОВ Николай Алексеевич (27.10.1831, Пермь ш. — 24.4.1896, Казан), тарихчы, рус тарихы д-ры (1869), хакыйкый статский советник (1873). Руханилар катлавыннан. Баш пед. ин-тын (С.-Петербург, 1855) тәмамлый. 1855–59 елларда Пермьдәге Ир балалар гимназиясендә өлкән укытучы. 1859 дан Казан ун-тында: доцент (1867–69), экстраординар проф. (1869–70), ординар проф. (1870–86), рус тарихы каф. атказанган проф. (1886 дан), тарих-филол. ф-ты деканы (1871–72, 1878–81), проректор (1872–75,1881–84). Бер үк вакытта Казандагы Беренче (1859–63, 1864–67) һәм Икенче (1863–64) ир балалар гимназияләрендә укыта. 1895 тән «Кама-Волжский край» г-тасын редакцияли һәм нәшер итә. Казан ун-ты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең оештыручы-әгъзасы (1878) һәм рәисе (1888–96). Студентлар хәрәкәтендә катнаша, С.-Петербургта Н.А.Добролюбов һәм Казанда А.П.Щапов түгәрәкләре б-н элемтәдә тора. Россия историографиясендә дәүләт мәктәбенең демократик юнәлеше вәкиле. «Пермь губернасында халык училищеләре ачылу» («Открытие народных училищ в Пермской губернии», Пермь, 1859), «Пермь гимназиясе тарихына материаллар...» («Материалы для истории Пермской гимназии...», Пермь, 1894) хезмәтләре 18–19 йөзләрдә Пермь губернасы мәгариф оешмалары тарихына карый. Ф. ның «Мәскәү дәүләтендә төньяк-көнчыгыш Русь әҗнәбиләре торышы» («Положение инородцев северо-восточной Руси в Московском государстве», 1864), «Карамзин

төньяк-көнчыгыш Русь тарихы турында» («Карамзин об истории северо-восточной Руси», 1867) хезмәтләрендә Идел буе халыкларының Рус дәүләтенә кушылганчыга кадәр иҗтимагый мөнәсәбәтләре һәм социаль-икътисади үсеш тарихы яктыртыла. «Яңа Россиядә 1762 елга кадәр элекке Казан ханлыгы әҗнәбиләре һәм хәзерге вакытта Кама аръягы җирләрен колонияләштерү» («Инородческое население прежнего Казанского царства в новой России до 1762 г. и колонизация заКамских земель в это время», 1869), «И.И.Неплюевның колонияләштерү эшчәнлегенең сәяси һәм финанс ягыннан әһәмияте» («Политическое и финансовое значение колонизационной деятельности И.И.Неплюева», 1894) монографияләрендә русларның колонияләштерү характеры һәм җирле халык өчен аның нәтиҗәләре тикшерелә, 18 йөздә Идел буе әҗнәбиләренең «рус тормышына» этномәдәни йогынтысы анализлана.

Х е з м.: Воззрения В.Н.Татищева на историю вообще и русскую, в особенности, и связь их с реформой Петра Великого. К., 1886; Памяти Петра Дмитриевича Шестакова: Мысли его об общественном воспитании в России вообще и о просвещении инородческого населения Северо-Восточной России в частности. К., 1891.

Әд.: Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 1; Ермолаев И.П. Н.А.Фирсов как историк местного края // Вопр. истории, филологии и педагогики. К., 1967. Вып. 2. *Е.Б.Долгов.*

ФИ́РСОВ Николай Николаевич (18.9.1864, Казан — 7.6.1933, шунда ук), тарихчы, рус тарихы д-ры (1902), статский советник (1903). Н.А.*Фирсовның* улы. Дворяннар нәселеннән. Казан ун-тын тәмамлый (1888); шунда ук эшли: проф. стипендиаты (1891 елга кадәр), 1891–1902 дә рус тарихы каф. приват-доценты, 1902–03 тә экстраординар профессоры, 1903–14, 1916–18 дә ординар профессоры, 1918–22 дә иҗтимагый фәннәр ф-ты һәм эшчеләр ф-ты (рабфак), 1928 дән Россиядә сыйнфый көрәш тарихы каф. профессоры. Шулай ук Казандагы Мария кыз балалар (1893–95) һәм Икенче ир балалар (1895–1903) гимназияләрендә, реаль уч-щедә (1894–95) укыта. 1914–16 да Археол. ин-ты профессоры (Мәскәү), бер үк вакытта, 1915–16 да, Мәскәү ун-тының рус тарихы каф. приват-доценты. Окт. рев-циясеннән соң Казанда Төньяк-Көнчыгыш археол. ин-тын (1917–20), Шәрекъ академиясен (1920–22; 1921 дән ректор вазифаларын башкаручы), Шәрекъ пед. ин-тын (1922–24 тә тарих каф. мөдире, 1924 тән проф.) оештыручыларның һәм аларның җитәкчеләренең берсе. 1890 елларда «Волжский вестник», «Камско-Волжский край» г-талары б-н хезмәттәшлек итә. Либераль сәяси карашлары тарафдары, иҗатында Россия историографиясенең дәүләт мәктәбе, народниклык һәм марксизм йогынтысын кичерә. «Мәскәү Россиясе хөкүмәте һәм Бөек Пётр сәүдә-сәнәгать сыйныфына каратамөнәсәбәттә» («Правительство московской России и Пётр Великий в их отношениях к торгово-промышленному классу», 1891), «XVIII йөзнең 1 нче яртысында рус сәүдә-сәнәгать компанияләре: сәүдә-сәнәгать сәясәте һәм иҗтимагый мөнәсәбәтләр тарихыннан очерклар» («Русские торгово-промышленные компании в 1-ю половину XVIII столетия: Очерки из истории торгово-промышленной политики и соответствующих общественных отношений», 1896), «Идел буе сәүдә-сәнәгать тормышы тарихыннан кайбер үзенчәлекләр» («Некоторые черты из истории торгово-промышленной жизни Поволжья», 1898), «Император Екатерина II патшалык иткән вакытта хөкүмәт һәм җәмгыять Россиядәге тышкы сәүдәгә карата мөнәсәбәттә. Сәүдә сәясәте тарихыннан очерклар» («Правительство и общество в их отношениях к внешней торговле России в царствование императрицы Екатерины II. Очерки из истории торговой политики», 1902) хезмәтләрендә сәүдә-сәнәгать компанияләренең барлыкка килүе, Россия буржуазиясенең катлау буларак оешуы һәм дәүләт сәясәте нәтиҗәсе буларак тышкы сәүдәнең активлашуы процессын тикшерә. «Яңа Канун-нар мәҗмугасы проектын (1767 ел) төзү өчен оештырылган Комиссиядә күтәрелгән качкыннар һәм юлбасарлардар мәсьәләсе» («Вопрос о беглых и разбойниках, поднятый в Комиссии для составления проекта Нового Уложения (1767г.)», 1890), «Халык тормышында социологик һәм психологик күренеш буларак Разин фетнәсе» («Разинщина, как социологическое и психологическое явление народной жизни», СПб., 1906), «Пугачёв фетнәсе: Социологик-психологик характеристика тәҗрибәсе» («Пугачёвщина: Опыт социолого-психологической характеристики», СПб., 1908) һ.б. монографияләре 17–20 йөзләрдә Россия крәстиәннәренең иҗтимагый-сәяси көрәш тарихына багышлана. Ф.ның «Иделнең Урта һәм Түбән агымын яулап алу: XVI йөз Көнчыгыш Европа тарихыннан очерк» («Завоевание Среднего и Нижнего течения Волги: Очерк из истории Восточной Европы XVI-го столетия», 1893), «Себер тарихына багышланган укулар» («Чтения по истории Сибири», вып. 1–2, М., 1915–21), «Идел өчен көрәш. Казан ханлыгын буйсындыру» («Борьба за Волгу. Покорение Казанского ханства», 1918), «Идел өчен көрәш. Мәскәү Русенең Әстерханны буйсындыруы һәм Урта һәм Түбән Идел буеның буйсындырылган халыкларының Мәскәүдән аерылу омтылышлары» («Борьба за Волгу. Покорение московской Русью Астрахани и попытки покорённых народов Среднего и Нижнего Поволжья отбиться от Москвы», 1918), «Урта һәм Түбән Идел буе тарихына багышланган укулар» («Чтения по истории Среднего и Нижнего Поволжья», вып.1–2, 1919–20), «Татарстанның үткәне: Кыскача фәнни-популяр тарихи очерк» («Прошлое Татарии: Краткий научно-популярный исторический очерк», 1926), «Идел-Кама төбәген колонияләштерү һәм аның белән бәйле сәясәт» («Колонизация Волжско-Камского края и связанная с ней политика», 1930) хезмәтләрендә 16–18 йөзләрдә Идел буе, Урал буе, Себер һәм төрки халыкларының сәяси һәм социаль-икътисади тарихы мәсьәләләре тикшерелә. «Рус тарихының гомуми курсы. Мәскәү Русендә самодержавие үсеше» («Общий курс русской истории. Развитие самодержавия в Московской Руси», 1907), «Тарихка багышланган укулар. XV–XVI йөзләрдә самодержавие үсеше һәм XVII йөз башындагы революция» («Чтения по истории. Развитие самодержавия в XV–XVI вв. и революция в начале XVII в.», 1924), «Рус тарихы. Россиядә башлыча сыйнфый көрәш тарихы буенча кулланма» («Русская история. Руководство преимущественно по истории классовой борьбы в России», М., 1928) лекция курсларында Россия тарихын чагылдырганда вульгар-социологик методологиягә таяна, крәстияннәрне халык чуалышларында һәм рев-циядә хәлиткеч көч дип саный, төп игътибарын сыйнфый көрәшкә юнәлтә (Рус дәүләтенең аерым өлкәләре тарихына юнәлеш ясала). Шәхеснең тарихта һәм әдәбияттә файдалы эшчәнлеге күзлегеннән чыгып язылган биографик очеркларның (Н.Я.Агафонов, Н.Н.Шестаков, Г.Р. Державин, Н.М.Карамзин, В.О.Ключевский, Г.Ибраһимов, Петр I, Екатерина II, В.И.Ленин һ.б. турында) зур фәнни-популяр циклы авторы. 1923–29 да Татар халкын гыйльми өйрәнү җәмгыяте, 1924–30 да Казан ун-ты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте рәисе. 1929–31 дә мат-бугатта «фирсовчылык»ка каршы кампания башлана: Ф. Совет хакимияте дошманы дип күрсәтелә, аның карашлары вак буржуаз караш буларак тәнкыйтьләнә, хезмәтләре басылу туктатыла.



Н.Н. Фирсов.

Х е з м.: Царь Иван Васильевич Грозный. К., 1892; Пётр I Великий, московский царь и император Всероссийский (Личная характеристика). М., 1916; Г.Р.Державин как выразитель настроения российского дворянства в Екатерининскую эпоху. К., 1919; Студенческое движение в Казанском университете в 1887 г. К., 1920; Исторические характеристики и эскизы (1890–1920 гг.): В 3 т. К., 1921–26.

Әд.: Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 1; Чернышёв Е.И. Профессор Н.Н.Фирсов как историк Поволжья // Вестн. Науч. об-ва татароведения. 1930. № 9–10; Ермолаев И.П., Литвин А.Л. Профессор Николай Николаевич Фирсов: Очерк жизни и деятельности. К., 1976; Зарипова Л.Д. Российская история в трудах Н.Н.Фирсова: Дис. ... К., 1996; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2002. Т. 1.

Е.Б.Долгов.

ФИ́РСОВА-САМСО́НОВА Клавдия Фёдоровна (7.11.1898, Казан губ. Козьмодемьянск ш. — 18.10.1990, Казан), микробиолог, мед. фән. д-ры (1962), проф. (1964). Е.Ф.Аристов шәкерте. Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1925), Зөя кантонында сан. табибе булып эшли, 1929 елдан — Төбәк микробиол. ин-тында; 1932–36, 1943–72 дә Казан ГИДУВында, микробиол.

каф. мөдире (1964 тән). 1936–41 дә Хәрби-мед. академиясенең микробиол. кафедрасында (Ленинград). Бөек Ватан сугышы елларында Казандагы эвакогоспитальдә табиб-бактериолог. Казан Эпидемиология һәм бактериология фәнни-тикшеренү ин-тында гангренаны дәвалау өчен сыркынды әзерләп чыгаруны оештыра (1941–45). Хезмәтләре гангренаны дәвалау һәм кисәтү өчен сыркынды табу технологиясенә карый. Газлы гангренаны кисәтүдә антибиотикларның ролен, анаэроб инфекцияләр патогенезын, яраларның микроблар ассоциациясен, дифтерия интоксикациясен өйрәнә. Бөтенсоюз эпидемиологлар, микробиологлар, инфекционистлар җәмгыятенең Казан ф-лы рәисе (1965–72). Медальләр, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: О роли микробных ассоциаций при экспериментальной газовой гангрене // Тр. Казан. НИИ эпидемиологии и микробиологии. 1949. Вып. 1; Адреналовая функция хромафинного аппарата надпочечников при экспериментальной дифтерийной интоксикации // Тр. Казан. ГИДУВа. 1958. Т. 13; Материалы к патогенезу дифтерийной интоксикации. К., 1962.

Әд.: Профессор Клавдия Фёдоровна Фирсова // Казан. мед. журн. 1979. № 1.

ФИТОТЕРАПИ́Я (грек. phyton — үсемлек, үренте һәм therapeia — тәрбияләү, дәвалау), дару үләннәре кулланып дәвалау. Ф. фармокогнозия, фарм. химия, токсикология б-н тыгыз бәйләнгән. Россия фармакопея реестрына (1982), химиотерапевтик матдәләр б-н берәттән, Россия фарм. ком-ты тарафыннан расланган 300 дән артык дару үләне дә теркәлгән. Патентлаштырылган химик дәвалау препаратларының 80% тан артыгы үсемлекләрдәге актив матдәләрдән ясала.

Авыруларны үләннәр ярдәмендә дәвалау бик борынгыдан килә (үлән сулары һәм төнәтмәләре эч йомшарту, яраларны ябу, ютәлне басу чарасы һ.б. буларак кулланылган). Идел буенда фәнни яктан нигезләнгән Ф. дәвере Казан ун-ты ачылу (1804) б-н бәйле рәвештә башлана, 1810 елда ун-т терр-ясендә «аптека» бакчасы һәм теплица булдырыла һәм анда К.Ф.*Фукс* һәм Ф.Х.*Эрдман* җитәкчелегендә шул заманда яхшы билгеле булган дару үләннәре (песи үләне, мәтрүшкә, бөтнек, дару ромашкасы һ.б.) үстерелә. Фармаколог И.М.Догель әремнең спиртлы экстракты үзлекләрен өйрәнеп, «абсентның» баш мие функцияләренә тәэсирен (үзәк нерв системасы эшчәнлегенең аерым үзенчәлекләре булган зәгыйфьлеге) дәлилли.

В.М.*Флоринский* дару ясау өчен чимал булган үләннәрне өйрәнә. Дәвалау практикасына кан китүне туктатучы матдә — су борычы экстракты (Н.П.Кравков), уймак чәчәктән йөрәк гликозидлары (С.П.Боткин), онкопротектор — канлы үлән (канлут) экстракты кертелә. К.А.*Дрягин* һәм В.А.Ломакина (Казан) хезмәтләрендә барбарис яфракларының дәвалау үзлекләре (хроник холециститны дәвалау өчен) исбатлана, М.А.*Алуф* һәм Д.Д.Яблоков какырык кубару өчен читтән кертелүче ипекакуанага алмашка термопсис үләне порошогын тәкъдим итәләр. Ф принциплары хәзерге вакытта да актуаль булып кала. ТР табибләренең дәвалау практикасында җирле ареал кыргый дару үләннәренең 187 төре кулланыла. РФдә җитештерелә торган патентлы химик дәвалау препаратларының 80% тан артыгы (атропин, винкапан, ситостерин, кортизол һ.б.) дару үләннәре һәм тере организмнардан алына торган актив матдәләр нигезендә эшләнә.

Үләннәрнең күпчелеге, мәс., үлән чәйләре, универсаль үзлекләргә ия (ашау-эчү чыганагы һәм дәвалау чарасы). Чит илләрдән кертелә торган даруларның (бронхикум, доктор МОМ, новопассит һ.б.) барлык диярлек ингредиентлары ш.у. Татарстан һәм Россия терр-ясендә дә үсә. Үләннәрдәге биол. актив матдәләр аларның үзләре һәм биогеноценозларда организмнарның үзара бәйләнеше өчен гаять зур әһәмияткә ия (Б.П.Токин, 1928). Күзәнәк протоплазмасының экскретор булмаган фитонцидлары («тукыма соклары») һәм атмосферага, туфракка, суга (сүүсемнәрдә) бүленеп чыгучы очкалак фракцияләр аерып карала. Очкалак фитонцидлар ерактан тәэсир итү сәләтенә ия. Ф. дә уңыш һәм нәтиҗәлелек чималның дөрес җыелуыннан (әзерләнүеннән), саклануыннан (стерильлекнең тәэмин ителүе) һәм әзерләнүеннән тора. Күп кенә үләннәрнең фитонцидлары ашказаны-эчәк трактының хәрәкәт һәм секретор активлыгын, йөрәк эшчәнлеген көчәйтәләр. Мәс., медицинада суган, сарымсак, керән, ачы торма һ.б. ның фитонцидларыннан ясалган препаратлар киң кулланыла.

Ф., башлыча, төп дәвага әзерлек чорында һәм пациент каты авыру кичереп, реабилитация чоры узганда; диспансер күзәтүендә торучыларны авыруның көчәеп китүеннән кисәтү өчен һәм ш.у. дәвамлы тернәкләндерү чарасы буларак билгеләнә. Ашыгыч мед. ярдәме кирәк булган очракларда антибиотиклар, химиотерапия кулланырга тәкъдим ителә.

Әд.: А л у ф М.А. Лекарства растительного происхождения. М., 1943 (автордаш); Д р я г и н К.А., Л о м а к и н а В.А. Лечение холециститов спиртовой настойкой листьев барбариса. Улан-Удэ, 1960; А с а д у л л и н М.Г. Экологический мониторинг дикорастущих лекарственных растений Татарстана // Казан. мед. журн. 1995. № 5; Б о г о я в л е н с к и й В.Ф., Н и к о л а е в М.А., Х а м и д у л л и н Р.И. Растения и здоровье: Применение лекарственных растений в терапевтической практике. К., 1998; З и н н а т у л л и н а Г.И. Народные медицинские знания тоболо-иртышской группы сибирских татар. Томск, 2010.

В.Ф.Богоявленский, О.В.Богоявленская, Р.Г.Исхакова.

ФИТОФТОРО́З, фитофтора (Phytorhtora) төрендәге гөмбәләр китереп чыгара торган үсемлек авырулары. Татарстан шартларында — бәрәңге һәм томатларның төп авыруы (P.infestans китереп чыгара), яфракларда зур җәенке таплар һәм явымлы һава шартлары һәм артык су сипкәндә яфракның аскы өлешендә ак кунык (катлам) барлыкка килү б-н характерлана. Бәрәңге бүлбеләрендә Ф. күргашынсыман-соры таплар барлыкка килүдән башлана, акрынлап алар көрән череккә әверелә. Томатта Ф. булганда сабакларында көрән сузынкы, куныксыз таплар, җимеш яләрендә көрән черек барлыкка килә. Көрәш чаралары: Ф.га чыдам сортлар булдыру, бәрәңге һәм томат басуларын башка культура участокларыннан аеру, күп микъдарда фосфорлы-калийлы ашламалар кертү, шәхси участокларда көл куллану, аз микъдарда бакыр яисә микроашламалар комплексы, фунгицидлар (планриз, фитофторин, бордо сыекчасы, бакыр хлорокисе һ.б.) б-н эшкәртү, утырту өчен сәламәт бәрәңге бүлбеләрен сайлап алу, уңыш җыю алдыннан бәрәңге сабагын җыеп юк итү, бәрәңге һәм томатларны иртә җыеп алу.

Әд.: Д е м е н т ь е в а М.И. Фитопатология. М., 1970.

ФИ́ШМАН Александр Израилович (29.5.1951, Казан), физик, физика-матем. фән. д-ры (1993), проф. (1996), ТРның атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2004). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1973), шунда ук эшли, гомуми физика каф. профессоры (1993 тән). Хезмәтләре молекуляр спектраль анализ һәм лазер спектроскопиясенә карый. Ф. молекулалар йотылуның инфракызыл спектрларына таянып, конформацион күчешләрнең термодинамик һәм кинетик күрсәткечләрен билгеләү алымнарын эшли. Беренче буларак конформация җәһәтеннән бертөрле булмаган кушылмаларның комбинацияле чәчелешенең катлаулы төзелешле линияләрен анализлау өчен когерент яктылык чәчелеше алымнарын куллана. Компакт-дискларда физика буенча белем бирү ресурсларын эшли (ТР һәм РФ мәктәпләрендә гамәлгә кертелә).

Х е з м.: Исследование конформационно-неоднородных систем методом активной спектроскопии КР // Докл. АН СССР. 1985. Т. 283, № 6 (автордаш); Конформационный анализ в жидкости методом поляризационной активной спектроскопии комбинационного рассеяния: экспериментальная реализация принципа голографической спектроскопии // Оптика и спектроскопия. 1989. Т. 66, № 5 (автордаш); FTIR Investigation of the Fluorocyclohexane Ring Inversion in Liquid Kr // Journ. Phys. Chem. A. 2002. V. 106, № 18 (автордаш).

ФИ́ШМАН Израиль Самуилович (20.8.1914, Могилев губ., Гомель өязе Хойники бистәсе — 27.8.2004, Казан), физик, физика-матем. фән. д-ры (1967), проф. (1969), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1984). Ленинград ун-тын тәмамлаганнан соң (1938), Воронеж 16 нчы моторлар з-дының спектраль лаб-ясе башлыгы булып эшли (1961 елга кадәр; 1941 дә з-д Казанга эвакуацияләнә). 1961–91 дә Казан ун-тында, оптика һәм спектроскопия каф. профессоры (1968 дән). Хезмәтләре спектраль анализ һәм плазма спектроскопиясенә багышлана. Ф. плазманы диагностикалау алымнарын эшли. Спектраль линияләрнең Штарк константаларын тикшерә, аларга бәяләмә бирү алымнарын эшләп гомуми закончалыкларын ачыклый. Алмаш ток дугасы базасында яңа атомизатор эшли (аның физик һәм химик сыйфатларын тикшерелә), һавада элементлар (ш.и. терекөмеш) концентрациясен билгеләүнең абсолют алымын, атом абсорбциясе нигезендә төрле температурадагы металл парларының эластиклыгын билгеләүнең яңа алымын уйлап таба. Медальләр, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Методы количественного спектрального анализа. К., 1961; Статистическая регуляризация при обработке эксперимента в прикладной спектроскопии. К., 1986 (автордаш); Краткие очерки биографии. К., 1997; Electric arc atomization: experimental, theory. Analytical prospects // Progress in Analytical Atomic Spectroscopy. 1989. V. 12 (автордаш).

ФЛАВИ́ЦКИЙ Флавиан Михайлович (18.1.1848, Тамбов губернасының Усмань ш. — 1.11.1917, Казан), химик, химия д-ры (1881), Петербург ФАнең мөхбир әгъзасы (1907). Харьков ун-тын тәмамлый (1869). 1870 елдан Петербург ун-тының А.М.Бутлеров лаб-ясендә эшли. 1873 тән Казан ун-тында, проф. (1884), бер үк вакытта, 1884–1912 дә, Казан вет. ин-тында химия каф. мөдире. Хезмәтләре чиксез углеводородлар, спиртлар, терпеннар, эфир майлары химиясенә карый. Ф. амил спиртларының берсен синтезлый. Чикле бер атомлы спиртларның изомерлары санын билгеләү ысулын тәкъдим итә. Француз химигы Ш.А.Вюрц тапкан амиленгидратның изопропилэтиленга әйләнеп дегитратланучы өченче дәрәҗә амил спирты («Флавицкий амилены») булуын күрсәтә. Изомер углеводородларының иң тотрыклы формасы соң дәрәҗәдә метиллаштырылган углеводород, мәс., пентаннар арасында тетраметилметан була дигән кагыйдәне формалаштыра; бу кагыйдә изомеризация реакцияләренең юнәлешен алдан күрергә һәм чылбыр азагында метил группалары булган җылыга чыдам кумуленнар синтезлауга юл ача. Каты матдәләрнең үзара тәэсирләшүен тикшерә, сыйфат анализы ясар өчен кесә лаб-ясен эшли (патенты чит илдә бирелә, Россиядә исә Ф.га патент бирү тәкъдиме кире кагыла). Терпеннар химиясе өлкәсендә фәнни юнәлешкә нигез сала, аларның классификациясен тәкъдим итә, беренче буларак моноциклик һәм бициклик терпеннарның үзара әверешләрен башкара, пиненнән оптик актив лимонен алуга ирешә. Ылыслы агачны киртләү белән шөгыльләнә, сумалаларны тикшерә. Ф. тикшеренүләренең нәтиҗәләрен илнең урман химиясен үстерүдә кулланырга тырыша, ләкин чиновниклар аңа ярдәм итүдән баш тарта. Ф.ның химик формалар теориясе, эретмәләрнең химик теориясе буенча, криогидратлар һәм эвтектикалар өлкәсендәге хезмәтләре булуы мәгълүм. Аның хөрмәтенә Казан ун-тының Химия ин-ты бинасына мемориаль такта куела.

Х е з м.: Связь форм кислородных и водородных соединений // Журн. Рус. физ.-хим. об-ва. 1891. Т. 23; Классификация галоидных солей по теории химических форм // Журн. Рус. физ.-хим. об-ва. 1893. Т. 25; Общая или неорганическая химия. К., 1907.

Әд.: К л ю ч е в и ч А.С. Флавиан Михайлович Флавицкий. К., 1978; В о л к о в В.А., В о н с к и й Е.В., К у з н е ц о в а Г.И. Выдающиеся химики мира: Биогр. справ. М., 1991.

ФЛЕ́ТЧЕР (Fletcher) Джайлс (Джильс) (Giles) (1548, Уотфорд ш., Англия — 1611, Лондон), инглиз дипломаты, гражданлык хокукы д-ры. Кембридж ун-тын тәмамлый (1568). 1588–89 елларда Мәскәүдә Англия илчесе, Мәскәүдәге инглиз сәүдә компаниясендә өстенлекләрне киңәйтүгә омтыла. «Рус дәүләте турында» («Of the Russe Common Wealth», Лондон, 1591; рус теленә тәрҗемәсе — «О государстве Русском», СПб., 1905) хезмәте — чит ил кешесенең 16 йөздәге Россия турындагы иң тәфсилле әсәрләреннән берсе. Анда Россиянең геогр. шартлары һәм дәүләт төзелеше, рус җәмгыятенең төрле катлау вәкилләренең көнкүреше һәм гореф-гадәтләре тасвирлана; татарлар (башлыча Кырым татарлары), аларның күршеләре б-н сугышлары, гореф-гадәтләре һәм холыклары, 16 йөз ханнары, мордвалар, чирмешләр, пермяклар турында мәгълүматлар бар.

Әд.: С е р е д о н и н С.М. Сочинение Джильса Флетчера «Of the Russe Common Wealth», как исторический источник. СПб., 1891.

ФЛОКС (Phlox), күкчечләләр семьялыгыннан башлыча күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 60 төре билгеле, Төньяк Америка һәм Азиядә таралган. Россия терр-ясендә (Себердә) 1 кыргый төре — Сибер Ф.ы (Ph. sibirica) үсә. Сабаклары туры, өскә үсүче яисә шушшма, биеклеге 10–20 дән 120–150 *см* га кадәр. Яфраклары тоташ читле, капма-каршы урнашканнар, ланцетсыман, озынча-ланцетсыман, йомыркасыман-озынча. Чәчәкләре хуш исле, калкансыман яисә себеркәчле чәчәк төркеменә җыелган, сирәгрәк ялгыз була, сирень-аксыл шәмәхә, куе кызыл төснең төрле төсмере, ак төстә; себеркәче тар көпшә һәм тәгәрмәчсыман, кәсасыман яисә йолдызсыман биш өлешле булып бөгелгән; җимеше — 3 оялы озынча тартмачык, яшькелт-соры яисә көрән төстәге 1–3 эре орлыклы. Татарстанда Ф.ны бакчаларда декоратив үсемлек буларак үстерәләр. Язын яисә көз көне куакларын аеру һәм чыбыкча ялгап, көз көне яисә язын орлыкларын чәчеп үрчетәләр. Клумбалар яисә газоннарда үстерү өчен кулланалар.

Әд.: К и с и л ё в Г.Е. Цветоводство. М., 1964; Д ь я к о в а Г.М. Флоксы. М., 2006.

ФЛО́РА, нинди дә булса терр-ядә (акваториядә) үсүче яки үткән геол. чорларда үскән үсемлек төрләренең тарихи рәвештә барлыкка килгән җыелмасы. ТР Ф.сы 578 ыругка, 124 семьялыкка, 78 рәт, 8 класс һәм 5 бүлеккә караган көпшәле үсемлекләрнең 1610 төрен берләштерә. Шуларның 37 төре споралы үсемлекләр (плаунсыманнар, наратбашсымаллар), 6 төр ачыкорлыклылар, 1567 төр ябыкорлыклылар яки чәчәкле үсемлекләр. Төр төрлелеге буенча иң күп санлы семьялыклар: *оешма чәчәклеләр* яки кашкарыйчалар (236 төр), *кыяклылар* яки йончалылар (149), кузаклылар (93), *роза чәчәклеләр* (91), *күрәнчәләр* (83), *әвернә чәчәклеләр* (80), *канәферчәләр* (67), *сыражҗчалар* (59), *иренчәчәклеләр* (55), *чатырчәчәклеләр* (45), *казаякчалар* һәм *алабутачалар* (39 ар), *карабодайчалар* (35), *сәхләбүгәләр* һәм *кыярчалар* (30 ар). Фитоценотик ярашканлык буенча ТР Ф.сында урман, болын, дала, сазлык, су һәм су яны, чүп үлән-кыр, рудераль төрләрне билгеләр, алар тереклек тирәлегенең киң спектрын тәшкил итәләр һәм үсемлекләр бергәлеге барлыкка китерәләр (к. *Үсемлекләр дөньясы*).

Е.Л.Любарский.



Ф.М. Флавицкий.

ФЛОРИ́НСКИЙ Василий Маркович (16.2.1834, Владимир губ., Юрьев өязе Фроловское а. — 3.1.1899, С.-Петербург), акушер-гинеколог, медицина д-ры (1861). Хәрби-мед. академиясен тәмамлаганнан соң (1858, С.-Петербург), шунда ук, институт табибе вазифасында эшли. 1861–63 елларда фәнни командировкада була (Берлин, Эрлаген, Вюрцбург, Париж, Лондон, Неаполь), 1865–77 дә Казан ун-тының акушерлык һәм гинекология каф. ординар профессоры, проф. (1867), 1877–85 тә акушерлык һәм хатын-кыз авырулары каф. мөдире. 1885–98 дә Көнбатыш Сибер уку-укыту округы попечителе, Томск ун-тына нигез салучыларның берсе. Хезмәтләре акушерлык, Россиядә мед. мәгарифен оештыру мәсь әләләренә, халык медицинасын, мед. тарихын, археологияне, этнографияне өйрәнүгә карый. 3 нче, 2 нче һәм 1 нче дәрәҗә Изге Анна ордены, 2 нче һәм 1 нче дәрәҗә Изге Станислав ордены, 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә Изге Владимир ордены, Ак Бөркет ордены, медаль б-н бүләкләнә. Себер ун-тын оештыруга куйган хезмәте өчен Томск шәһәренең мактаулы гражданы исеменә лаек була.

Х е з м.: Об оживлении мнимоумерших новорожденных детей // Мед. вестн. 1865. № 35–36; Домашняя медицина. К.,1879; Русские простонародные травники и лечебники: Собр. мед. рукописей XVI и XVII столетия. К., 1879; Курс акушерства. К., 1883.

Әд.: Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2.

ФО́ГЕЛЬ Густав Людвигович (Львович) (1805 — 1859 дан соң), хокук белгече, хокук д-ры (1839), статский советник (1840). Кёнигсберг ун-тын тәмамлый (1827). 1828–37 елларда адъюнкт, 1837–50 дә экстраординар проф., 1850–53 тә ординар проф., 1853–59 да Казан ун-тының җинаять һәм полиция законнары каф. атказ. профессоры. Хезмәтләре Рим, җинаять хокукы, Россия законнары тарихы мәсь әләләренә карый.

Х е з м.: Опыт восстановления текста и объяснения Правды Русской. К., 1848; Артикул 135-й Уголовного уложения императора Карла V, постановления позднейших, до конца XVIII ст. германских местных законодательств и воззрения практики касательно самоубийства. К.,1857.

Әд.: Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2.

ФО́ГЕЛЬ Людвиг (Лев) Лаврентьевич (6.1.1771, Арнштадт ш., Германия — 3.9.1840, Гота ш., шунда ук), фармаколог, медицина һәм хирургия д-ры (1794, 1821). 1816 елдан рус гаскәрләренең Гота янындагы хәрби ла-

геренда баш табиб. 1822–37 дә Казан ун-тын - да, проф. һәм дару атамалары, фармация һәм табиблек теле каф. мөдире, 1822–28 дә хирургия белеме укытучысы, 1823–25, 1834–35 тә табиблек фәннәре бүлеге деканы. Сергиев - ский минераль су чыганакларының дәвалау үзлекләрен өйрәнә.

Әд.: Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904, Ч. 2.

ФОЙГТ (Voigt) Карл Карлович (7.4.1808, Петербург губ. Нарва ш. — 30.10.1873, С.-Петербург), тел галиме, философия д-ры (1839). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1826), Казандагы Беренче ир балалар гимназиясендә фарсы теле укыта (1848 елга кадәр), бер үк вакытта, 1828–52 дә, Казан ун-тында: проф. (1841 дән), проректор (1845, 1847–49), тарих-филол. ф-ты деканы (1849 дан). 1852 дән Харьков ун-ты ректоры. 1859 дан Харьков уку округында попечитель ярдәмчесе, 1863 тән попечитель.

Х е з м.: Отчёт Казанского университета с 1827 по 1 января 1844 г. К., 1844; Обозрение хода и успехов преподавания азиатских языков в Казанском университете за десятилетие с 1842 по 1852 г. К., 1852.

Әд.: Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2002. Т. 1.

ФО́КИН Дмитрий Анатольевич (1.11.1964, Казан), механика өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (2000). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1986), шунда ук, Матем. һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тының кырый мәсьәләләре бүлегендә эшли. 2001 елдан Германиядә. Хезмәтләре аэрогидродинамиканың кире кырый мәсьәләләренә, канат профильләрен хисаплау һәм оптималь әштерү алымнарына карый. Ф. пассажирлар иминлеген тәэмин итү һәм машина элементларын ныклыгын хисаплаганда динамик бәрелүне микъдари модельләштерү буенча эшләр башкара.

Х е з м.: Итерационный метод решения краевых задач аэрогидродинамики // Журн. вычисл. математики и мат. физики. 1995. Т. 35, № 11 (автордаш); Вариационные обратные краевые задачи аэрогидродинамики // Докл. РАН. 2001. Т. 377, № 6 (автордаш).

ФОЛЬКЛО́Р (ингл. folklore — халык зирәклеге), халык тарафыннан телдән иҗат ителеп, күп еллар, хәтта, гасырлар буе халык хәтерендә сакланып килгән сүз, музыка, сынлы сәнгать һ.б. сәнгать төрләре әсәрләре җыелмасы. Ф., нигездә, өч төркемгә бүленә: халык авыз иҗаты (халыкның поэтик иҗаты), муз. иҗат, халык биюләре. Язу барлыкка килү б-н тарихи яктан халык авыз иҗаты б-н бәйле әдәбият барлыкка килә. Ф. терминын фәнгә 1846 елда инглиз галиме В.Томсон кертә. Татар филологиясендә Ф. терминын тәүге тапкыр 1926 да Г.Рәхим куллана. Элегрәк «халык әдәбияты», «халык иҗаты» төшенчәләре дә әйләнештә була. 1950 еллар уртасыннан, фәндә Ф. термины б-н бергә «татар халык иҗаты» термины да киң тарала. Халык авыз иҗаты эпос һәм лирикага бүленә. Эпоска архаик-героик (*«Ак күбек»*, *«Алтаин Саин Сөмә»* һ.б.), тарихи (*«Идегәй»* һ.б.) һәм мәхәббәт-лирик (*«Кузы Күрпәч белән Баянсылу»* һ.б.) тематикалы *дастаннар* керә. Татар Ф.ының шактый өлешен халык лирикасы тәшкил итә. Ху җалык эшләре һәм гаилә тормышы б-н бәйле йолалар вакытында *йола җырлары* башкарыла. Яңа елны каршылау уңаеннан уздырыла торган Нәүрүз бәйрәме б-н бәйле җырлар, борынгы бәйрәм йолаларын яңадан торгызганда башкарыла торган *туй җырлары* сакланган. 1920–30 елларда йола җырларына нигезләнеп, яшьләрнең җырлы-биюле уеннары вакытында, кич утырганда (к. *Аулак өй*) башкарыла торган *уен җырлары* («Челтәр элдем читәнгә» һ.б.) формалаша, 1950 елларга кадәр кулланышта булалар. Татар проза Ф.ында әдәби һәм тарихи-эстетик кыйммәте ягыннан әһәмиятле урыннарның берсен *әкиятләр* алып тора. Хайваннар турында (*«Аю белән Хатын»* һ.б.) һәм тылсымлы (*«Таңбатыр»* һ.б.) әкиятләр борынгы заманнарда барлыкка килеп, шул заман кешесенең фикерләү үзенчәлекләрен чагылдыралар.



«Татар халык иҗаты». 1–13 томнар. 1976–93.

Лиро-эпик жанрның үзенчәлекле төре — *тарихи җырлар* (*«Качкын Хәмидулла»*, «Лашман бәетләре» һ.б.). Тарихи җырларның эчтәлеге сугышларга, социаль һәм милли җәберләүләргә, төрле катлау кешеләренең тормыш-көнкүреш хәлләренә, аерым шәхесләрнең язмышларына бәйле. Охшаш тематика кайбер лиро-эпик жанрларга хас: *риваять - ләр* — реаль фактларга һәм вакыйгаларга ешкына хыялый уйдырмалар өстәп, аларны дөреслеккә охшатып, телдән сөйләнә торган хикәяләр («Болгар каласының корылуы» һ.б.); *легендалар* — дөреслеккә дәгъва итүче фантастик характердагы хикәяләр («Җир ничек яралган» һ.б.); *бәетләрдә* эмоциональ яктан бай итеп фа җигале язмышлар, дөнья, яшәү һәм үлем турында лирик уйланулар бәян ителә (*«Урта Тигәнәле бәете»* һ.б.); *мөнәҗәтләрнең* асылында Аллаһка һәм аның пәйгамбәрләренә мөрәҗәгать итү, ялварып ярлыкауны сорау ята («Йә Рәсүлем»).

Ф.да драма дип атарлык үзенчәлекле әсәрләр сакланмаган. Аның кайбер элементлары йола һәм уен җырлары, бию *такмакларында* (*«Әнисә»* һ.б.), диалог рәвешендәге *кыска җырларда* («Җырлыйк әле, җырлыйк әле»), героик-эпик «Идегәй» дастанында һ.б. күзәтелә.

Татар Ф.ында афористик жанрлар системасы формалаша: *мәкальләр*, *әйтемнәр*, *табышмаклар*, *тизәйткечләр*, *санамышлар*, *им-томнар* һ.б.

Ф.ны туплау, теркәү, бастыру, тикшерү, тасвирлау һәм классификацияләү б-н фольклористика фәне шөгыльләнә. Борынгы төрки-татар Ф.ы 6–8 йөзләрдәге Орхон-Енисей ташъязма истәлекләрдә теркәлгән. Болгар чоры (10 йөз) легендалары һәм риваятьләре Ибне Фазлан, әл-Гарнати (мәс., алыплар турында) әсәрләрендә китерелә; төрки шагыйрь Й.Баласагунинең «Котадгу белег» («Игелекле белем», 1069/70) поэмасында төрки мәкаль һәм әйтемнәр; Урта Азия галим-филологы Мәхмүд Кашгаринең «Диване лөгать әт-төрк» (1072–74) сүзлегендә төрки кабиләләрнең, ш.и. Идел буе болгарларының йола һәм лирик җырлары, героик эпос әсәрләреннән өзекләр, тарихи риваятьләре һәм легендалары китерелгән. Алтын Урда чорында төрки-татар Ф.ының аерым үрнәкләре Европа сәяхәтче-галимнәре Плано Карпини, Марко Поло язмаларында теркәлгән. Казан ханлыгы чоры татар Ф.ы аз өйрәнелгән.

Татар фольклористикасына, фән буларак, К.Насыйри нигез сала. Тарихта беренчеләрдән булып, ул татар Ф.ына караган материалларны туплый, тикшерә һәм бастыра. Татар фольклористикасы үсешенә шәркыятьче галим-тюрколог В.В.Радлов зур өлеш кертә. Аның Себер һәм Алтайга экспедицияләре вакытында туплаган материалы 10 томлы «Төрки кабиләләрнең әдәбият үрнәкләре» җыентыгының (1866–1907) 4 нче томына кергән (1872). 20 йөз башында Казанда 87 фольклор җыентыгы нәшер ителә; Г.Тукай, Г.Ибраһимов, Ф.Әмирханның халык иҗатлары турында махсус мәкаләләр барлыкка килә. Әдәбият белгече Г.Рәхимнең «Халык әдәмиятымызга бер караш» («Аң» ж-да басыла, 1914, № 14) мәкаләсе татар фольклористикасы үсешендә мөһим этапка әверелә. 1939 да ТАССР ХКС каршындагы Татар тел һәм әдәбият фәнни-тикшеренү ин-тында (хәзер ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты) Х.Х.Ярми җитәкчелегендә Ф. төркеме булдырыла (1968 дән — сектор, 1988 дән — бүлек). Төркем Себергә, Татарстан районнарына фольклор экспедицияләре оештыра. Экспедицияләр нәтиҗәләре буенча Ф. материаллары җыентыклары нәшер ителә: «Татар халык әкиятләре» (1946), «Бәетләр» (1960), «Татар халык җырлары. Лирик җырлар. Йола җырлары» (1965), «Татар халык иҗаты» (1951) һ.б. 1976–93 тә бүлек тарафыннан татар Ф.ының фундаменталь жанрларын эченә алган 13 томлы *«Татар халык иҗаты»* дөнья күрә.

Татар Ф.ын җыю, Ф. әсәрләрен туплап нәшер итү б-н язучы һәм галим, фундаменталь фәнни хезмәтләр авторы Н.Исәнбәт шөгыльләнә («Татар халык мәкальләре». 1–3 т., К., 1959–67; «Татар халык табышмаклары», К., 1970; «Балалар фольклоры һәм җырлы-сүзле йөз төрле уен», К., 1984). А.Яхин татар Ф.ы әсәрләрен һәм жанрларын системага сала.

16 йөздән алып хәзерге вакытка кадәр татар фольклористикасы тарихын фольклорчы һәм әдәбиятчы галимнәр Х.Ярми, Ф.Урманчеев, Л.Җамалетдинов, И.Надиров, Х.Мәхмүтов һ.б. өйрәнәләр. Татар фольклористикасы үсешендә татар халкының җыр иҗаты турында монографияләр нәшер итү кебек яңа юнәлеш барлыкка килә (И.И.Надировның

«Халык һәм җыр», 1960; Х.Ярминең «Татар халкының поэтик иҗаты», 1967).

2010 нан бүлек хезмәткәрләре тарафыннан татар телендә татар Ф.ы жанрларын эченә алган 25 томлы «Татар халык иҗаты», рус телендә 15 томлы «Татарское народное творчество» җыентыкларын әзерләү буенча эш алып барыла.

Татар фольклористикасын өйрәнүгә Казан ун-ты профессоры М.Х.Бакиров зур өлеш кертә. Аның «Татар фольклоры» («Татарский фольклор») китабы (2013) татар халык авыз иҗатын тәүге тапкыр монографик тикшерү була.

Әд.: Ярми Х. Татар фольклорын туплау һәм өйрәнү тарихы // Татар халкының поэтик иҗаты. К., 1967; Яхин А. Фольклор жанрларын система итеп тикшерү тәҗрибәсе. К., 1979 (автордаш); Урманче Ф. Татар халык иҗатын өйрәнү тарихы // Татар халык иҗаты: Дәреслек. К., 2002; Миңнуллин К. Һәр чорның үз җыры. К., 2003; Яхин А. Система татарского фольклора. К., 1984.

Ф.И.Урманчеев.

ФОМА́ авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 21 *км* көнбатыштарак, Самара өлкәсе б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 917 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Вершина речки Ерыклы исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 мәчет, 2 җил тегермәне, 2 ярма яргыч, 2 вак-тояклар кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире (Иске Зирекле авылын да кертеп) 3946 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Максимкино волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августын нан Октябрь (1997 нең 10 декабреннән — Нурлат) р-нында. Халык саны: 1859 да — 885, 1897 дә — 1607, 1908 дә — 1811, 1920 дә — 2049, 1926 да — 1440, 1938 дә — 1595, 1949 да — 1249, 1958 дә — 1341, 1970 тә — 1840, 1979 да — 1600, 1989 да — 961, 2002 дә — 963 кеше.

ФОМЕ́НКО Владислав Александрович (17.9.1932, Дагстан АССРның Махачкала ш. — 30.10.1988, Мәскәү), инженер-гидротехник, төзелеш производствосын оештыручы, Соц. Хезмәт Герое (1977). 1955 елда Одесса гидротехник ин-тын тәмамлаганнан соң, Чир-Юртовск ГЭСы төзелешендә эшли: мастер, 2 нче төзелеш идарәсендә прораб (Дагстан АССРның Кизил-Йорт ш.). 1959–66 да «Братскгэсстрой»да: өлкән прораб, участок башлыгы, баш инженер, «Гидропромстрой» төзү-монтаж идарәсе башлыгы (1963 тән); 1966–71 дә Братск урман сәнәгате комплексының төзелеш идарәсе башлыгы. 1971 дән КамАЗ төзелешендә: «Автоводстрой» төзелеш идарәсе башлыгы, «Камгэсэнергострой» ҖБ башлыгы (1974 тән). 1979–88 дә бөтенсоюз «Главгидроэнергострой» берләшмәсе башлыгы, бер үк вакытта «Зарубежэнергостроймонтаж» берләшмәсе башлыгы (Мәскәү). Ф. җитәкчелегендә КамАЗның 1 нче чираты, Зәй ГРЭСы, КамАЗ ТЭЦы, Түбән Кама ТЭЦы, социаль-мәдәни, коммуналь билгеләнештәге, шәһәр яны а.х. зоналары объектлары, 2 млн. $м^2$ торак төзелә. Герой исеме КамАЗның 1 нче чиратын төзегәндә ирешкән уңышлары өчен бирелә. КПССның 25 нче съезды делегаты (1976). 1975–80 дә ТАССР ЮС депутаты. СССР МС бүләге лауреаты (1982). Ленин ордены, ике Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Чаллы шәһәрендә бер проспект Ф. исеме б-н атала (2007).

Әд.: Ганина М. Дождливой осенью. М., 1975; Шул ук. Мои знакомые диспетчеры. М., 1976; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003; Энциклопедия города Набережные Челны. К., 2007.

Г.Я.Мәүлетова.

ФОМИ́Н Алексей Максимович (14.8.1946, Мордва АССРның, Краснослободск р-ны Красная Подгора а.), эпизоотолог, вет. фән. д-ры (2008), РФнең атказ. вет. табибе (2007). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1970), СССР а.х. министрлыгының Казан вет. фәнни-тикшеренү ин-тында (хәзер Хайваннарның токсикологик һәм радиацион куркынычсызлыгы буенча федераль үзәк) эшли, штаммнар лаб-ясе мөдире (1977–79), әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1990 нан). Хезмәтләре бруцеллёзга каршы көчле булмаган агглютиноген штаммыннан коры тере вакцина эшләүгә карый. Уйлап табуга авторлык таныклыгы бар.

Хезм.: Усовершенствованная система специфической профилактики и ликвидации бруцеллёза крупного рогатого скота с применением живых вакцин из штаммов слабоагглютиногенного B. abortus 82 и инагглютиногенного B.abortus R-1096 // Уч. зап. Казан. гос. акад. вет. медицины. 2012. Т. 211 (автордаш); Comparative study of the immunobiological properties of live brucellosis vaccines // Vaccines. 2010. V. 28.

Әд.: История ветеринарии Татарстана. Ч. 3. К., 2010.

ФОМИ́Н Анатолий Алексеевич (2.2.1947, Казан), хакимият эшлеклесе, тарих фән. канд. (1998), юридик фән. канд. (2003). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1971). 1971–91 елларда Казан радиоэлектроника фәнни-тикшеренү ин-тында инженер, бүлек башлыгы урынбасары, профсоюз ком-ты рәисе. 1991–2000 дә ТР Профсоюзлар федерациясендә бүлек мөдире, секретарь, рәис урынбасары. 2000–12 дә ТР Үзәк сайлау комиссиясе рәисе. 2013 тән ТР Иҗтимагый палатасы рәисе. Хезмәтләре базар икътисадына күчү шартларында профсоюзлар хәрәкәте, Россия һәм Татарстанда сайлау законнары мәсьәләләренә карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

ФОМИ́Н Василий Михайлович (5.11.1940, Краснодар ш.), механика өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (1984), РФА академигы (2006; 1994 елдан мөхбир әгъза). 1942 дән Казанда (немец оккупациясе алдыннан әнисе Краснодар шәһәреннән алып чыга). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1963), шунда ук, аэрогидромеханика кафедрасында эшли. Г.Г.*Тумашев* шәкерте. 1970 тән РФАнең Себер бүлегендә (Новосибирск ш.): Теоретик һәм гамәли механика ин-тында, тиз



В.А. Фоменко.



В.М. Фомин.

үтүчән процесслар физикасы лаб-ясе мөдире (1976–79), директор урынбасары (1979–89), проф. (1987), директор (1989 дан), баш гыйльми секретарь (1997–2008), Президиум рәисе урынбасары (2008 дән). Бер үк вакытта, 1974 тән, Новосибирск ун-тында, аэрофизика һәм газ динамикасы каф. мөдире (2006 дан); Новосибирск техника ун-тында аэрогидродинамика каф. профессоры (1983 тән). Хезмәтләре тоташ мохитләр механикасына һәм машиналар төзүгә багышлана. Ф. газ һәм каты кисәкчә катнашмалары тибындагы мохитләрдә комбинацион өзелмәләр һәм бәрмә дулкыннар теориясен; бәрмә дулкыннарны дифференциаль анализлау алымын; төп бәрмә дулкынга кисәкчәләр системасы, нәзек сыекча агынтылары яисә пыскулы электр бушануы б-н тәэсир итү ярдәмендә тавыш тизлегеннән зуррак газ агымы эчендә җисемнәр каршылыгын киметүысулын тәкъдим итә һәм эшли. Югары тизлекле бәрелешү күренеше очрагында җисемнәр җимерелүенең импульслы механизмын нигезли; деформацияләнгән каты җисемнең һәм күп фазалы мохитләрнең газ динамикасына караган күп үлчәмле нәстационар мәсьәләләрнең физик-матем. модельләрен, санлы алымнарын һәм аларны электрон хисаплау машинасында исәпләү программаларын эшли (илнең машиналар төзү КБларында һәм фәни-тикшеренү ин-тларында гамәлгә кертелә). Уйлап табуга 19 патенты һәм авторлык таныклыгы бар. Халыкара «An International Journal on Shock Waves» һәм «Advances in Adaptive Data Analysis» ж-лларының редколлегиясе әгъзасы.

Казан галимнәре белән тыгыз элемтәдә тора: механика мәсьәләләре буенча методик һәм консультатив ярдәм күрсәтә, Казан югары уку йортларында һәм фәнни оешмаларда кадрлар әзерләүгә өлеш кертә (В.И.*Игнатьев*, А.К.*Шалабанов*, В.Ф.*Шәрәфетдинов* һ.б.), Казан ун-тында лекцияләр оештыруда һәм Бөтенроссия механиклар фәнни конференцияләрен үткәрүдә катнаша.

Яңа техника эшләнмәләрен проектлауны автоматлаштыру буенча хезмәтләре циклы өчен СССР Дәүләт бүләгенә (1981), җисемнәрнең югары тизлектә тәэсирләшүен микъдари модельләштерү өлкәсендәге хезмәтләре өчен СССР Министрлар Советы бүләгенә (1990), РФ Хөкүмәтенең фән һәм техника өлкәсендәге бүләгенә (2010), гомоген, гетероген һәм күзәнәкле мохитләрдә кабыну һәм яну процессын физик-матем. җәһәттә тасвирлаган хезмәтләре циклы өчен РФАнең



В.М. Фомин.



М.С. Фомин.

В.А.Коптюг исем. бүләгенә (2009) лаек була. Почёт ордены, 2 дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» ордены медале, Кытай Халык Респ-касының Дуслык ордены, медальләр; РФ Дәүләт думасы грамотасы б-н бүләкләнә. Ф. — байдаркада ишү буенча спорт остасы (1968).

Х е з м.: О нелинейных законах фильтрации специального вида и решении краевых задач // Тр. семинара по краевым задачам. К., 1972. Вып. 9 (автордаш); Сверхзвуковые двухфазные течения в условиях скоростной неравновесности частиц. Новосиб., 1980 (автордаш); Сопряжённые и нестационарные задачи механики реагирующих сред. Новосиб., 1984 (автордаш); Ударно-волновые процессы в двухкомпонентных и двухфазных средах. Новосиб., 1992 (автордаш); Высокоскоростное взаимодействие тел. Новосиб., 1999 (автордаш); Foundation of fluid mechanics with applications (Problem solving using mathematica). Boston, 1999 (автордаш).

ФОМИ́Н Владимир Михайлович (19.2.1931, Ставрополь крае Благодарное а. — 16.11.2015, Казан), генерал-лейтенант (1988). Новоросийск суднолар ремонтлау уч-щесен (1946), 2 нче Ленинград артиллерия уч-щесен (1952), Хәрби артиллерия академиясен (Ленинград, 1964) тәмамлый. 1949 елдан — СССР Кораллы Көчләрендә. 1952–59 елларда Балтыйк буе хәрби округында разведка взводы командиры, дивизиядә разведка башлыгы, батарея командиры. 1964–83 тә Ерак Көнчыгыш хәрби округында, 1977–83 тә 51 нче утрау (Сахалин һәм Курил утраулары, Камчатка, Чукотка ярымутраулары; Магадан өлкәсе) армиясенең ракета гаскәрләре һәм артиллерия командующие. 1983–89 да Казан ракета гаскәрләре югары хәрби инженер-командирлар уч-щесе башлыгы. Венгрия махсус операцияләрендә (1956), СССР б-н Кытай Халык Респ-касы арасындагы дәүләт чикләрен саклау өчен барган сугыш хәрәкәтләрендә (1976, 1978) катнаша. 1989 дан — запаста. Казанда яши. 1991–94 тә ТР Запастагы офицерлар белемен күтәрү төбәк үзәге б-н җитәкчелек итә. 1997–2003 тә Россия Армия, оборона сәнәгате һәм хәрби укуларга булышлык күрсәтү хәрәкәте иҗтимагый-сәяси оешмасының төбәк бүлекчәсе рәисе, 1995 тән ТРның Сугыш ветераннары һәм хәрби хезмәт ком-ты президиумы әгъзасы. Ике Кызыл Йолдыз, 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

ФОМИ́Н Владимир Николаевич (23.10.1955, Куйбышев р-ны «КИМ» с-зы пос.), галим агроном, а.х. фән д-ры (1999), проф. (2002). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1980), шунда ук эшли, үсемлекчелек каф. мөдире (1990–96). 1999 елдан интенсив технологияләр һәм агроэкология каф. мөдире, Татарстан агробизнес кадрларын яңадан әзерләү ин-тында проректор (2004 тән). Хезмәтләре уңышны программалаштыру, төп бөртекле культураларны игүдә фәнни нигезләнгән ресурс саклау, адаптив-ландшафтлы технологияләрне эшләү һәм гамәлгә кертү мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Овёс. К., 1999; Состояние производства и пути повышения качества зерна в Республике Татарстан. К., 2000 (автордаш); Технология выращивания пивоваренного ячменя в Республике Татарстан. К., 2003 (автордаш).

ФОМИ́Н Вячеслав Анатольевич (21.3.1950, Рига — 30.9.2006, Казан), химик-технолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1998), химия фән. канд. (1980). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1972), Бөтенроссия углеводород чималы фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. Хезмәтләре нефть химиясенә һәм нефть эшкәртүгә карый. Ф. углеводородларны, дисульфидлар барлыкка китереп, меркаптаннардан арындыру технологиясен эшләүдә катнаша. Ленин комсомолы бүләге (1981) һәм ТР Дәүләт бүләге углеводород чималын күкертле кушылмалардан арындыру һәм җитештерү максатында процесслар һәм катализаторлар эшләүгә керткән өлеше өчен бирелә («Татнефть» АҖдә, Казакъстан Респ-касының «Тенгизшевройл» уртак Россия-Америка пр-тиесендә, РФнең газ, нефть эшкәртү һәм нефть химиясе пр-тиеләрендә гамәлгә кертелә). Үйлап табуга 15 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. СССРның нефть эшкәртү һәм нефть химиясе сәнәгате отличнигы (1981).

ФОМИ́Н Михаил Сергеевич (25.9.1923, Алабуга кантоны Бондюг пос., хәзер Менделеев ш. — 7.7.1943, Курск өлкәсенең Поныри р-ны Ниж.-Смородино а.), Сов. Союзы Герое (7.8.1943, үлгәннән соң), гв. сержанты. Заводта янгын сүндерү бүлегендә эшли. 1942 елның гыйнварыннан Кызыл Армия сафларында һәм Бөек Ватан сугышы фронтларында, 159 нчы гв. артиллерия полкының (13 нче армиянең 75 нче укчы дивизиясе) туп төзәүчесе. Үзәк фронт гаскәрләре составында Сталинград (1942–43) һәм Курск (1943) сугышларында катнаша. 1943 нең 7 июлендә Поныри авылы янындагы (хәзер Курск өлкәсенең шәһәр тибындагы Поныри посёлогы) сугышларда батырлык күрсәтә: дошманның 12 контрһөҗүмен кире кайтара, турыдан төзәп 5 урта һәм 2 авыр танкны, 2 пулемётны сафтан чыгара, 1 ротадан артык солдатны юк итә. Сугышта каты яралана, госпитальдә үлә. Ленин ордены, медаль б-н бүләкләнә. Менделеев шәһәрендәге бер урам Ф. исемен йөртә.

Әд.: Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000. *М.З.Хәбибуллин.*

ФОМИ́НОВКА, к. *Югары Фоминовка.*

ФОНЕ́МА (грек. phṓnēma — аваз, тавыш), *тел белемендә* сүзләрне, морфемаларны төзүче, аларны бер-берсеннән аерырга мөмкинлек бирүче иң кечкенә аваз берәмлеге. Хәзерге мәгънәсендә «Ф.» термины 1870–80 елларда *Казан лингвистика фәнни мәктәбе* вәкилләре (И.А.Бодуэн де Куртенә, Н.В.Крушевский) тарафыннан кулланыла башлый. Татар тел белемендә «Ф.» төшенчәсе Ү.Ш.Байчура һәм Р.Ф.Шакирова тарафыннан кертелә. Ф. сүзләрне бер-берсеннән аера торган билгеләр җыелмасы буларак каралырга мөмкин. «Ф.» төшенчәсе сөйләмдәге күптөрле авазларны аз санлы аваз типларына берләштерү мөмкинлеге бирә. Әйтик, **балаларга** дигән татар сүзформасында 4 төрле [а] авазы бар: беренчесе көчле иренләшкән (о-лашкан), икенчесендә иренләшү азрак, өченчесе иренләшмәгән һәм басымсыз, дүртенчесе иренләшмәгән һәм басымлы. Барлык бу сузык [а] авазлары шул бер үк [а] Ф.сының бер төсмере (варианты, аллофоны) булып тора.

Ф. дифференциаль билгеләр җыелмасыннан гыйбарәт, алар бер-берсеннән шул билгеләре б-н аерыла, мәс., [у] — арткы рәт сузыгы, югары күтәрелешле, иренләшкән (дифференциаль билгеләре — рәте, күтәрелеш дәрәҗәсе һәм иренләшүе). Ф.ның дифференциаль, мәгънә аера торган функцияләрен үтәү өчен уңайлы позиция көчле позиция (мәс., басымлы иҗектәге сузыклар өчен) дип атала, мо ңа бәйле рәвештә бу позициядәге Ф. ш. у. көчле санала. Ф.ның дифференциаль функцияләрен үтәү өчен уңайсыз позиция көчсез позиция (мәс., сүз ахырында һәм тартыкларның яңгыраулык-саңгыраулык билгеләре буенча шаулы тартыклар алдында) дип атала, бу халәттәге Ф. ш. у. көчсез була. Көчле Ф.ның аңа тиңдәш көчсезләре б-н чиратлашуы фонемалар рәтен барлыкка китерә: бер тамырлы сүзләрдә н — н' — м': ун — ун'ике — унбер [умбер]. Хәзерге татар әдәби телендә 9 сузык (к. *Вокализм*) һәм 26 тартык Ф. аерып карала. Хәзерге татар Ф.сының составы Х.Х.Сәлимов тарафыннан тасвирлана.

Әд.: Ш а к и р о в а Р.Ф. Хәзерге татар теле фонетикасына кереш. К., 1954; С ә л и м о в Х.Х. Фонология // Татар грамматикасы. К.–М., 1998. Т. 1.; ш у л у к. Тел гыйлеме терминнары сүзлеге. К., 2005; Х ә к и м җ а н Ф. Татар әдәби теле: Фонетика. К., 2001; С а ф и у л л и н а Ф.С., З ә к и е в М.З. Хәзерге татар әдәби теле. К., 2006; Б а й ч у р а У.Ш. Звуковой строй татарского языка. К., 1959. Ч. 1. *Р.Ә.Закиров.*

ФОНЕ́ТИКА (грек. phōnētikós — авазлы, тавышлы), *тел белеменең* авазларны, аларның үзгәрешләрен өйрәнә торган тармагы. Татар тел белемендә Ф. мәсь әләләре беренче тапкыр 18 йөзнең 2 нче яртысы — 19 йөз башында өйрәнелә башлый һәм С.Х. һәм И.И.*Хәлфинәр*, И.И.*Гиганов*, АА.*Троянский* һ.б.ның хезмәтләрендә яктыртыла. Татар Ф.сына караган беренче фәнни мәгълүматлар К.Г.*Насыйриның* «Кыскача татар грамматикасы»нда (1860) барлыкка килә. Анда авазларның чиратлашуы, бер-берсенә йогынтысы, сүз *басымы* законча лыклары карала. Галимнең «Әнмүзәҗ» («Үрнәк», 1895) хезмәтендә авазларны төркемләүнең кайбер принциплары хакында язылган. Г.Ш.*Нугайбәк*, Ж.Ж.*Вәлиди* дәреслекләрендә, В.В.*Радлов*, Г.Х.*Алпаров* хезмәтләрендә төп игътибар авазларны төркемләүгә, сингармонизм законына, сүз басымына һәм орфоэпиягә караган кайбер мәсьәләләргә юнәлтелә. Казан ун-ты профессо-

ры В.А.*Богородицкий* татар телен эксперименталь-фонетик яктан өйрәнә башлый. Аның хезмәтләрендә сүзләрдә тон хәрәкәте хакында тасвирлана, авазлар тибрәнешләренең озынлыгы һәм амплитудасы (колачы), сингармонизм законының төп үзенчәлекләре яктыртыла. В.А.Богородицкий карашларын укучысы Г.Ш.Шәрәф уңышлы үстерә, аның хезмәтләре авазлар артикуляциясе үзенчәлекләренә багышлана. Р.Ф.Шакирова, Ү.Ш.*Байчура*, Ә.Ш.*Әфләтунов* хезмәтләрендә телнең аваз составы тасвирлана, сингармонизм законына, интонациягә караган кайбер мәсьәләләр яктыртыла. Л.Т.*Мәхмүтова*, М.З.*Зәкиев*, Ә.Ә.*Юлдашев* хезмәтләрендә татар теленең фонетик системасына гомуми бәяләмә бирелә. Х.Х.*Сәлимов* татар вокализмын өйрәнү өчен беренчеләрдән булып спектраль анализ ысулын куллана һәм алынган мәгълүматлар нигезендә татар теленең сузык авазларына сыйфатлы бәяләмә бирә, аларның комбинатор һәм позицион үзгәрешләрен өйрәнә, рус һәм кайбер төрки телләрдәге сузыклар б-н чагыштыра. В.А.Богородицкий тарафыннан башлангыч алган татар һәм рус телләре Ф.сын чагыштырып өйрәнү Р.С.*Газизов*, З.М.*Вәлиуллина* грамматикаларында, Ф.С.*Фасиев* һәм Ә.М.*Ахунҗанов* хезмәтләрендә дәвам ителә. Д.Х.Бакыева татар һәм инглиз телләренең фонетик системаларын чагыштырып өйрәнә.

Л.Ж.*Җәләй* тарафыннан башланып киткән татар теленең тарихи Ф.сын өйрәнүне алга таба Л.И.*Яфаров* һәм В.Х.*Хаков* дәвам итә. Татар теленең фонетик системасы турында кайбер мәгълүматларны *диалектологиягә* караган хезмәтләрдә (Л.Т.Мәхмүтова, Д.Г.*Тумашева*, Ф.Й.*Йосыпов*, Г.Ф.*Саттаров* хезмәтләре) табарга мөмкин. Ф. б-н тыгыз бәйләнештә бирелгән татар графикасы, орфографиясе һәм орфоэпиясе мәсьәләләре Л.Ж.Җәләй, Х.Р.*Курбатов*, Б.М.Мифтахов хезмәтләрендә чагылыш таба. «Татар грамматикасы» (1–3 т., 1998–2002; «Татарская грамматика», т. 1–3, 1993–95) коллектив монографиясенең 1 нче томында татар теленең фонетик системасы төгәл тасвирлана, авазларның артикуляцион һәм акустик характеристикасы бирелә; Ф.ның функциональ аспектына — телнең аваз берәмлекләрен, ягъни *фонемаларны* өйрәнүче фонологиягә, *интонация* һәм сүз басымын үз эченә алган просодикага күп игътибар юнәлтелә.

Әд.: Ш а к и р о в а Р.Ф. Хәзерге татар теле фонетикасына кереш. К., 1954; С ә г ы й т о в М.Ә. Фонология, аның идея һәм проблемалары. К., 1972; С ә л и м о в Х.Х. Татар теле фонетикасы. Алабуга, 1998; С а ф и у л л и н а Ф.С., З ә к и е в М.З. Хәзерге татар әдәби теле. К., 2006; Б о г о р о д и ц к и й В.А. Введение в татарское языкознание в связи с другими тюркскими языками. К., 1953; Б а й ч у р а У.Ш. Звуковой строй татарского языка: В 2 ч. К., 1959–61.

Х.Х.Сәлимов.

ФОНО́Н ТАШКЫНЫ́, энергиянең спин кимәлләрендәге кисәкчәләре инверсиясе шартларында парамагнит кристаллында спин-рәшәткә релаксациясе барышында фононнар (кристаллик рәшәткә тирбәнеше квантлары) санының кискен артуы күренеше. Америка галимнәре В. Брайа б-н П. Вагнер тарафыннан кристаллның тышкы магнит кырына нисбәттән магнитлашу юнәлеше инверсиясеннән соң ЭПР сигналының вакыт барышындагы эволюциясен анализлау нигезендә очраклы рәвештә ачыклана. Казан галимнәре С.А.Альтшулер, Р.М.Вәлишев, Б.И.Кочелаев һәм А.Х.Хәсәнов Мандельштам-Бриллюэннның яктылык чәчелдерү алымын (яктылык квантлары ешлыгының үзгәрүе хәлендә фононнардагы нәсыгылмалы чәчелеш) кулланып, Ф.т.н беренче тапкыр турыдан-туры күзәтәләр (1971). Ф.т. электромагнетик дулкыннарны туендыручы импульсны ЭПР линиясе үзәгенә карата тайпылган ешлыкта ялгаганнан соң барлыкка килә, бу исә ЭПР линиясе канатына тайпылган ешлыкларда энергиянең спин кимәлләрендәге кисәкчә микъдарының инверсияләнүе б-н нәтиҗәләнә. С.А.Альтшулер һ.б. Ф.т. үсеше процессында ташкын фононнарының ешлык спектры кискен рәвештә тараеп, ташкын иң югары ноктага җиткәч фононнарның җылынуы дәрәҗәсе парамагнит кристаллы температурасыннан ун меңнәрчә тапкыр артыграк була дигән ачыш ясыйлар. Бу күренешнең теориясе спин темп-ра концепциясе нигезендә үстерелә, ягъни тәжрибә күрсәткән нәтиҗәләрне тасвирлый.

Әд.: А б р а г а м А., Б л и н и Б. Электронный парамагнитный резонанс переходных ионов. М., 1972. Т. 1; A l t s h u l e r S.A., K h a s a n o v A., K o c h e l a e v B.I. Studies of spin systems by means of light scattering in paramagnetic crystals // Spectroscopy of Solids Containing Rare Earth Ions. Amst., 1987.

ФО́РМА ЯСАГЫ́Ч КОМ, төрле дәрәҗәдә шомарган кварц (98% ка кадәр), кыр шпаты (7% ка кадәр), 0,05–2,5 *мм* үлчәмендәге башка минераллар һәм тау токымнары бөртекләреннән торучы көпшәк утырма токымнар. Гадәттә, составына кушылма сыйфатында циркон, рутил, слюда һ.б. керә. Зарарлы кушылмалар: Na_2O, K_2O, CaO, MgO (2% ка кадәр), Fe_2O_2 (1% ка кадәр), сульфидлы күкерт (0,05% ка кадәр), органик матдәләр һ.б. Кисәкчекләренең зурлыгы буенча вак (0,1–0,25 *мм*), уртача (0,25–0,5 *мм*), эре (0,5–1мм) һәм тупас бөртекле (1–2,5 *мм*) комнарга бүленә. Ф.я.к.га барыннан да бигрәк туену кирәк, бу вакытта зарарлы кушылмалар юкка чыга һәм комсыл кисәкчекләрнең күләме тотрыклана. ТРда бер — «*Алтын утрау*» чыганагы бар. Ф.я.к. металл коюформалары, металл һәм таш коелмалар нигезе ясау өчен кулланыла.ТРда Ф.я.к. куллану елына якынча 100 мең *т* тәшкил итә (2010).

Әд.: С е м е н т о в с к и й Ю.В., Ш а б а н б е к о в Г.Г. Минеральное сырьё. Материалы формовочные. М., 1999; Горно-добывающая промышленность России: Ежегодник. М., 2006. Вып. 1.

Г.Н.Бирюлёв.

ФОРМА́ЦИЯ (лат. formatio — җыелма, төр), 1) үсемлекләр бергәлеген классификацияләү берәмлеге (мәс., гади нарат, сөялле каен, сабакчалы имән Ф.ләре һ.б.); 2) утырма тупланунең физик, геогр. һәм тектоник шартлары б-н үзара бәйле тау токымнары *фацияләренең* табигый һәм закончалыклы җыелмасы. Ф.нең 350 дән артык тибын билгелиләр. Калынлыгы берничә йөз метрга кадәр, җәелү мәйданы меңәрчә кв. километр. Ф. анализы аерым төбәкләрнең геол. эволюциясен торгызуда, файдалы казылмаларның урнашу үзенчәлекләрен ачыклауда файдаланыла. ТРда платформа Ф.ләре мәгълүм: диңгез-терриген, диңгез-карбонатлы, күмерле, нефть һәм газлы, фосфоритлы, кызыл төстәге һ.б. Казан геологлары Н.А.*Головкинский*, М.Э.*Ноинский*, Н.Б.*Вәлитов* (20 йөз ахырында Татарстан терр-ясе утырма тышлыгын структур-формацион районлаштыру үткәрә) Ф. анализына шактый зур өлеш кертәләр.

Әд.: Геология Татарстана: Стратиграфия и тектоника. М., 2003.

ФОРТУНА́ТОВ Алексей Михайлович (17.3.1850, Новгород губ. — 22.5.1904, Казан), анатом, медицина д-ры (1884). Санкт-Петербург ун-тын тәмамлаганнан соң (1876), шунда ук эшли, 1884 елдан анатомия һәм физиол. кафедрасында прозектор. 1885 тән Санкт-Петербург ун-тының кеше анатомиясе кафедрасының приват-доценты. 1891 дән Казан ун-тының физиол. анатомия кафедрасында, проф. (1894). Хезмәтләре кешенең умыртка сөяге морфологиясен, эчәклек эшчәнлеген өйрәнүгә карый.

Х е з м.: К аномалиям первого шейного позвонка человека. СПб., 1886; Случай извращённого положения суставных поверхностей в обоих плечевых суставах. К., 1895.

Әд.: Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2.

ФОСФОРИТЛА́Р, кальций фосфатына (18% тан артык) утырма тау токымы. Геологик разведкалау хезмәтендә составында P_2O_5 5 тән 34% ка кадәр булганда фосфорит руда ларын еш кына Ф. дип атыйлар. Чиста Ф.ның төсе ак, табигатьтә алар, гадәттә, кара яки соры, ара-тирә яшел, кызыл һ.б. төстә очрыйлар. Структурасы, нигездә, күләмле, төерле, бөртексыман, текстурасы катламлы, саркыма. Диңгез, континенталь-диңгез һәм континенталь шартларда барлыкка килә. Ф. коры җирдә, диңгез һәм океан төпләрендә киң таралганнар. ТРның көньяк-көнбатышында 20 фосфорит чагылмалары табылган, алар гомуми запасы 4,5 млн. *т* дан артык булган мезозой яшендәге 7 чыганак, ш.и. *Сөендек фосфорит лар чыганагы* барлыкка китерә. Ф. б-н бергә глауконит һәм кварцлы комнар очрый. Ф. *фосфорлы ашламалар* җитештерүдә, ак һәм кызыл фосфор алуда, терлекчелектә терлек азыгына өстәмә буларак кулланыла.

Әд.: Агроминеральные ресурсы Татарстана и перспективы их использования. К., 2002.

ФО́СФОРЛЫ АШЛАМАЛА́Р, минераль һәм органик матдәләр, үсемлекләрне туклан дыруны яхшырту өчен кулланылалар. Туфракта фосфор запасын тулыландыруның бер дәнбер чыганагы булып тора, башлыча сәнәгый юл б-н тау руда чималыннан — фосфоритлар һәм апатитлардан җитештерелә. Ф.а. сыйфатында ш.у. органик матдәләр кулланыла: сөяк оны, тирес, кош тизәге, фосфор күп булган сәнәгать калдыклары, фосфоршлак, томасшлак һ.б. Ф.а. суда эрүчән (суперфосфат), цитратта эрүчән (преципитат, фторсызландырылган фосфат), авыр эрүчән (фосфорит оны) ашламаларга бүленә. Яңа югары

концентрацияләнгән Ф.а. (полифосфатлар), составында 50–80% P_2O_5 булган, һәм полифосфорлы к-талар нигезендә әзерләнә торган сыек ашламалар перспективалы. Ф.а. — сәнәгый юл б-н алынган (суперфосфат) беренче минераль ашламалар беренче тапкыр 1842 елда Бөекбританиядә эшләнә, Россиядә 1868 дә чыгарыла (аңа кадәр 19 йөзнең 1 нче яртысында Ф.а. сыйфатында башлыча сөяк оны кулланыла). Ашламалар җитештерү өчен фосфоритларны 1855 тә Франциядә эшли башлыйлар. Россиядә вакланган фосфорит - ларны куллану буенча тәҗрибәләр 1866 да Петербург галиме агроном А.Н.Энгельгардт тарафыннан башлана. 1867–69 да Ф.а.ның а.х. үсемлекләре уңышына тәэсирен Д.И.Менделеев өйрәнә; үзенең хезмәтләрендә ул игенчелектә тарттырылган фосфоритлар һәм суперфосфат куллануны тәкъдим итә. 1920 еллардан башлап, Ф.а.ның Татарстан шартларында а.х. культуралары уңышына тәэсирен өйрәнү б-н Казан а.х. ин-тының агрохимия каф. мөдире Б.И.*Горизонтов* шөгыльләнә. Җитештерү шартларында Ф.а. респ-када фосфорит оны Вурнар з-дында (Чуаш АССР, 1930), сөяк һәм шлам оны преципитаты Казанның фотожелатин з-дында (1960–80) җи - тештерелә башлаганнан алып кулланыла. 1960–80 елларда «Полимерфото» з-дында (Казан) а.х. ихтыяҗлары өчен калдыклардан фосфорга бай преципитат, сөяк һәм шлам оны эшләп чыгарыла.

Ф.а. Татарстанның барлык туфрак типларында нәтиҗәле, теләсә кайсы а.х. культураларына керткәндә, аеруча үсемлекләр азот һәм калий б-н тәэмин ителгәндә һәм туфракка тирән керткәндә (микъдарының күләме туфракка, шартларга, а.х. культураларының биол. үзенчәлекләренә бәйле) P_2O_5 төп ашлама сыйфатында (1 *га* га 10 *кг*) кертелә. Ф.а.ны җитәрлек куллану 2000 елларда туфракта фосфорның кимүенә китерә. 2000–05 тә туфракны агрохимик тикшерүләр фосфор күп булган сөрүлек җирләрнең мәйданы 1985–90 ел күрсәткечләре б-н чагыштырганда 956,8 мең *га* га кими (45,3% ка).

Әд.: Горизонтов Б.И. Опыты получения суперфосфата и преципитата из фосфоритов Чувашской АССР. К., 1935; Шорин В.М. Динамика доступного фосфора в серой лесной почве // Сб. статей по агрохимии и земледелию. К., 1966. Вып. 52; Продуктивность пашни и баланс азота, фосфора и калия по природно-экономическим зонам ТАССР (1976–1980 гг.). К., 1981.

И.Н.Афанасьев.

ФОСФОРОРГА́НИК КУШЫЛМАЛА́Р, молекуласында углеродка турыдан-туры яисә азот, кислород, күкерт һ.б аша фосфор элементы тоташкан матдәләр. Ф.к.ның бердәм номенклатурасы юк, алар төрле билгеләргә: молекулада фосфор-углерод бәйләнешләре санына, фосфорның валентлы халәтенә, фосфор функциясенең характерына карап классификацияләнә. Фосфор атомы божра эчендә булган Ф.к.га божраның зурлыгын чагылдырган исемнәр тагыла: өч буынлылар — фосфиран, дүрт буынлылар — фосфетан дип атала һ.б. Р-Р бәйләнешле дифосфин, трифосфин һәм тетрафосфин һ.б. Ф.к. мәгълүм. Беренче Ф.к. 1845 елда француз химигы Л.Ж.Тенар тарафыннан синтезлана. Ф.к.ның химиясе буенча систематик тикшеренүләрне 1874–1914 тә немец галиме Л.Михаэлис алып бара. Теоретик һәм гамәли тикшеренүләр Казан ун-тында А.Е.*Арбузов* һәм аның шәкертләре тарафыннан башкарыла. 1905 тә Ф.к.ның яңа классларын булдырырга юл ачкан *Арбузов реакциясе* билгеле була. Бер төркем синтезлаштырылган кушылмаларның югары биол. активлыгы ачыклана, аларның шактый сандагысының агулылык сыйфаты югары була, кайберләре агулы матдәләр рәтенә керә. Табигый Ф.к. (нуклеин к-талары, фосфолипидлар һ.б.) тормыш өчен әһәмиятле булган биол. процессларда катнаша. Казанда Ф.к.ның химиясе буенча фәнни юнәлеш формалаша. *Камай реакциясе, Пудовик реакциясе, Абрамов реакциясе* ачылуына ирешелә. Б.А.Арбузов, Р.Р.Шәһидуллин, Й.Ю.Сәмитов, В.А.Наумов Ф.к.ның реакцияләре механизмын, спектрларын һәм структураларын; Е.А.Красильников, Р.Ә.Черкасов, Э.С.Батыева фосфорлы-күкертле кушылмаларны; Н.И.Ризположенский, Н.П.Гречкин, А.О.Визель, В.К.Хәйруллин, А.Н.Пудовик, А.М.Кибардин, О.А.Ерастов фосфорлы гетероцикларны; Э.Т.Мөэминов, В.Ф.Миронов полициклик структураларны; Б.А.Арбузов, Э.Н.Дианова, О.А.Ерастов гадәти булмаган координацияле фосфор кушылмаларын (ике координацияле фосфор); В.А.Кухтин, Н.П.Гречкин, Н.А.Полежаева, В.Ф.Миронов фосфораннарны тикшерүгә зур өлеш кертәләр. Кушылу һәм цикллы кушылу реакцияләре (В.А.Кухтин, Б.А.Арбузов, А.О.Визель, И П.Гозман), фосфорлы полимерлар (Б.Е.Иванов, Я.А.Левин, И.М.Шермергорн, П.А.Кирпичников, А.А.Муслинкин), фосфорилирланган каликсареннар һәм фулеренар (А.И.Коновалов, И.Ә.Нуретдинов, А.Р.Бурилов, А.Р.Мостафина, И.П.Романова) өйрәнелә. Ф.к.ның элементлы фосфор катнаштырылган электр синтезлары ясала (О.Г.Синяшин, Ю.Г.Будникова). Дәвалау препаратлары (А.Е. һәм Б.А.Арбузовлар, А.И.Разумов, К.В.Никоноров, Н.И.Ризположенский, А.О.Визель, А.А.Муслинкин, Р.И.Тарасова, И.В.Заиконникова, И.А.Студенцова, Р.С.Гәрәев), фосфорлы макроциклар нигезендә металлокомплекслар (О.Г.Синяшин, А.А.Карасик) булдырыла. Р-S бәйләнеше булган өч валентлы фосфорның тиол чыгарылмалары химиясенә караган яңа класс Ф.к. тиофосфогидридлар ачыла һәм тикшерелә (О.Г.Синяшин). Элементлы ак фосфор һәм элементлы күкертнең протонлы реагентлар (спиртлар, тиоллар, тиофеноллар һ.б.) б-н реакциясеннән файдалану нәтиҗәсендә Ф.к. синтезы башкарыла (Э.Батыева һәм хезмәттәшләре). Тиофосфитларның альдегидлар б-н реакциясе нәтиҗәсендә тиоалкилфосфонатларның хасил булуы тикшерелә, α-тиоалкилфосфонатларны катали - тик алым б-н барлыкка китерү тәкъдим ителә (В.А.Альфонсов, И.С.Низамов). Рудаларны флотацияләгәндә кулланылган комплексоннар һәм экстрагентлар; майлагычлар өчен кушылгыч өстәлмәләр; полимерларны җитештергәндә деструкциясен һәм эксплуатацияләгәндә янучанлыгын киметүче антиоксидантлар; карбонил кушылмалары нигезендә олефиннарны синтезлау өчен реагентлар, карбодиимидларны һәм махсус күбекле материалларны барлыкка китерү өчен катализаторлар синтезлаштырыла. Ветеринария өчен вируска каршы препаратлар, а.х. өчен пестицидлар (акарицидлар, инсектицидлар, дефолиантлар) тәкъдим ителә. Глаукоманы дәвалау өчен антихолинэстераз тәэсиргә ия дару кушылмалары (пирофос, армин), гөмбәчек авыруына каршы препарат (хлорацетофос), бластомага каршы препаратлар (циклофосфан, глицифон), терапевтик активлыкның киң спектрына ия метаболик тәэсир тибындагы препарат (димефосфон) һ.б. ясала. Фосфор органик химиясе өлкәсендәге эшләр Казан ун-тының А.М.Бутлеров исем. Химия ин-тында, РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында, Казан технол. ун-тында, Казан мед. ин-тында, Казан вет. мед. академиясендә алып барыла. Химиянең төрле мәсьәләләре, ш.и. Ф.к.ны куллану мәсьәләләре буенча Казанда, илебезнең һәм чит илләрнең башка шәһәрләрендә регуляр рәвештә фәнни конференцияләр үткәрелә. 1976 дан халыкара «Phosphorus» ж-лы чыгарыла. 1997 дә ТРда Ф.к. химиясе өлкәсендә *Халыкара Арбузов бүләге* гамәлгә куела.

Әд.: Плец В.М. Органические соединения фосфора. М., 1940; Арбузов А.Е. Избр. труды. М., 1952; Нифатьев Э.Е., Кухарева Т.С. Обзор монографий и обзоров по химии фосфорорганических соединений. М., 1989.

ФОТО́ СӘНГАТЕ́, фотографиянең сурәтләрне гәүдәләндерү мөмкинлекләрен файдалануга нигезләнгән сәнгати иҗат төре. Ф.с. — тарихта фән (физика, химия һәм оптика) һәм техниканың аерым казанышлары нәтиҗәсендә барлыкка килгән беренче «техник» сәнгать. Сурәтләрне төшерүнең яңа ысулына әүвәл сынлы сәнгать вәкилләре мөрәҗәгать итә. Фотографияне уйлап табучыларның берсе рәссам Л.Ж.Дагер була һәм аның беренче сурәтләре нәкъшыш өчен традицион булган портрет, пейзаж һәм натюрморт жанрында төшерелә.

Казанда беренче фотоательелар 1850 елларда барлыкка килә. Аларның төп эш юнәлеше портрет жанры була (беренче портретлар дагерротипларда ясала). 1860 елларда Казанда натурадан фотосурәтләр ясау техникасы тарала башлый. 1895–1917 дә *Казан фотографлар җәмгыяте* эшли. Бу җәмгыять тарафыннан 1906 һәм 1909 да Казанда оешытырылган фотосурәтләр күргәзмәсендә Казан фотографларыннан В.П.Бебин, Г.Ф.Локке, А.П.Вяткина, А. Миңлегалиев һ.б. катнаша. 20 йөз башында И.М.Якобсонның «Сәнгати фотография», А.Х.Зимсонның «Рембрандт» дигән фотоательелары билгеле була.

Совет чорында Ф.с. һәвәскәр фотоклублар эшчәнлеге кысаларында үсә — ТАССР Дәүләт музее каршында — респ-ка, Казан Галимнәр йорты каршында шәһәр (1950 еллар уртасы) фотоклублары. Ф.с.нең хәзерге үсеше 1965 тә С.Р.Степанов җитәкчелегендә «Волга» шәһәр фотоклубы төзегән Казан фотографлары эшчәнлеге б-н бәйле. Фотоклуб сәнгати фотография үсешенең үзәгенә әве -



Фото сәнгате. 1. А.И. Б р е н и н г. «Зур Проломный урамы». 20 йөз башы; 2. З.Г. Б ә ш и р о в. «Тегермәннән кайту » (Балтач районы Яңгул авылы). 1972; 3. Ф.С. Г о б ә е в. «Казан. Чыгарылыш сыйныф укучылары». 1969; 4. В. Щ у р о в. «Курочкино авылы дачниклары. Иделдә». 1965; 5. Р.Г. Якупов «101 нче яз». 1971; 6. Ю.Г. Ф и л и м о н о в. «Карга боткасы» (ТАССР, Сарапул авылы). 1990; 7. В.Н. З о т о в. «Юрий Гагарин». 1967; 8. Р.С. М ө х ә м м ә т ж а н о в. «Милли көй». 1993; 9. Ш у л у к. «Кайту». 1980; 10. М.Б. К о з л о в с к и й. «Төштә һәм өндә очу». 2002; 11. Э.М. Х ә к и м о в. «Синхронлык». 1970 еллар; 12. Е.А. К а н а е в. «Колшәриф мәчете. Казан Кремле». 21 йөз башы; 13. З.Г. Б ә ш и р о в. «Сәгъди йортында». Арча районы Яңа Кырлай авылында Г.Тукай музей комплексы. 1984; 4. Л.М. К у з н е ц о в а. «Чегәннәр» сериясеннән. Уральск шәһәре. 1979; 15. Ш у л у к. «Риштат керәче» циклыннан. 1998; 16. А.Г. С е м ё н о в. «Май башы». 21 йөз башы; 17. М.Б. К о з л о в с к и й. «Ат чабышы». 2010 еллар.

релә, фотокүргәзмәләр (мәс., 1967 дә Россия зур күргәзмәсе) һәм конкурслар оештыра. 1970 еллар уртасында «Волга»дан З.Бәширов, А.Баһаветдинов, Б.Давыдов, Ф.Гобәев, В.Зотов, *Л.Кузнецова*, В.Михайлов, Р.*Мөхәммәт-җанов*, В.Никифоров, В.Разумейченко, А.Грек (Тамбулидис), Ю.Филимонов, Э.Хәкимов, Р.Якупов кебек фоторәссамнар аерылып чыга һәм «Тасма» фототөркеменә берләшә. Аның оештыручысы В.Богданов була. 1976 дан башлап, 10 ел буена аны Ф.Гобәев җитәкли. СССР һәм чит илләрдә киң танылу алган «Тасма» фоторәссамнарына «Казан фотография мәктәбе» дип аталган бөтенләкле стиль юнәлешле — эчтәлеге ягыннан реализм һәм драматизм, психол. образлылык белән аерылып торган көнкүреш жанрында-гы (шәһәр һәм татар авыллары тормышыннан сюжетлар) үткен социаль фотосурәтләр хас. Казан осталары «салон» фотографиясенең гүзәллегеннән ерак булган, чорны ачыклаучы гадел образлар барлыкка китереп, Ф.с.н сәнгати гомумиләштерүдә яңа дәрәҗәгә күтәрә. «Тасма» фотографларының беренче күргәзмәсе 1977 дә Мәскәүдә «Советское фото» журналы редакциясендә була. 1980–90 ахырлары Казан фоторәссамнарының Европа һәм Америкада үткәрелгән күргәзмәләрдә катнашуы, ш.у. дөньядагы әйдәп баручы нәшрияларның фотоальбомнарында басылулары белән билгеләнә: «Another Russia» («Башка Россия», Лондон, 1987), «Die zeitgenossishe Photographie in der Sowjetunion» («Советлар Союзында заманча сурәт», Цюрих, 1988), «Different Thinking» («Башкача фикерләү», Хельсинки, 1988), «Zwischen Elbe und Volga» («Эльба белән Идел арасында», Браус, 1988), «Changing Reality» («Үзгәрүче чынбарлык», Вашингтон, 1991), «Shaking the Dust of Ages» («Гасыр тузанын кагып», Нью-Йорк, Лондон, 1998) һ.б. Казан эчтәлегенең психол. реализмы, милли-төбәк үзенчәлеге, Көнчыгыш һәм Көнбатыш мәдәниятләре бергәлеге ягыннан аерылып торган сәнгати фотосурәтләр үзәгенең берсенә әверелә. З.Бәширов, В.Богданов, Ф.Гобәев, Б.Давыдов, В.Зотов, Е.Канаев, Л.Кузнецова, В.Мартинков, Р.Мөхәмәтжанов, Ю.Филимонов, Э.Хәкимов, Р.Якупов һ.б. — шәһәрнең танылган фоторәссамнары. 2000 елларда Казанда зур иҗат проектлары гамәлгә ашырыла — 1–4 нче төбәкара «Заман портреты» фотосурәт фестивальләре (күргәзмә-конкурс) (Казан, 2000, 2002, 2004, 2006; проектлар авторы һәм кураторы Р.Г.Сафиуллина) үткәрелә, 2003 тә Мәскәүдә («Казан — портрет сызыклары», 2005 тә РФ Дәүләт Думасында («Меңьеллык Казан»), Куала Лумпур (Малайзия), Истанбул, Әнкара (Төркия) шәһәрләрендә Казанның 1000 еллыгына багышланган фотокүргәзмәләр оештырыла. Ф.с. ТРның башка шәһәрләрендә дә үсешкә этәргеч ала. Яшел Үзәндә А.Семёнов җитәкчелегендә фотостудия эшли (Е.Канаев, Э.Закиров, М.Хәялетдинов), Чаллыда А.Веретенников, Н.Туганов, В.Салман, К.Ситдыйков, С.Цепков, А.Шлыков, Н.Брик иҗат итә. Дәрвишләр бистәсендә (Казан) В.О.*Ковалевский* оештырган «Казан» фотостудиясе (2005 тән җитәкчесе С.Н.Исхаков) 1962 дән бирле уңышлы эшли. 2007 дән фоторәссамнар Г.Козлов җитәкчелегендәге «Казан фотоклубы»на берләшә. Ф.с.ндә сәнгати образлар үсеше, форма эстетикасы, эчтәлек символикасы эзләү б-н бәйле яңа исемнәр һәм яңа юнәлешләр барлыкка килә (А.Акманова, Е.Балашов, Ш.Бәширов, А.Вахитова, Р.Галиев, С.Ермолаев, С.Исхаков, А.Кузнецов, С.Максимов, А.Титов, Ф.Төхфәтуллин, Г.Сәгыева һ.б.). Респ-ка фоторәссамнарының эшләре 1988 дә Р.М.Мөхәммәтжанов төзегән хосусый «Волга» сәнгать галереясында күрсәтелә. 2009 да ТР Дәүләт сынлы сәнгать музееның Күргәзмәләр залында Фотосурәтләр галереясы ачыла.

Әд.: Гольдшмит И.П. Корифеи Казанской фотографии // Казань. 1997. № 8/9; Мухаметзянов Р. Размыкание круга // Казань. 1998. № 9/10; Первый региональный фестиваль-фотоконкурс: «Портрет эпохи». Каталог фотовыставки. К., 2000; Второй региональный фестиваль-фотоконкурс: Каталог фотовыставки. К., 2002; Ерунов Б. Казанские светописцы в прошлом и настоящем // Казанские истории. 2005. № 9; Карточки и фотографии // Казань. 2009. № 9.

Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.

ФОТОЖЕЛАТИ́Н ЗАВОДЫ́, к. «*Полимер-фото*».

ФОТО́Н КАЙТАВАЗЫ́ (яктылык кайтавазы), фазаландырылган импульслы оптик нурланыш; ике яки аннан да артык лазер импульсын төрле вакытта эшкә кушып матдәне нурландырганнан соң, аның кичектерелгән жавабы формасында барлыкка килә; спин кайтавазының оптик аналогы. 1962 елда Казан галимнәре У.Х.Копвиллем һәм В.Р.Нагибаров (СССР ФА Казан ф-лының Физика-техника ин-ты) тарафыннан фараз ителә; Америка тикшеренүчеләре Н.А.Кенит, И.Д.Абелла һәм С.Р.Хартманн аны кызыл якут кристаллында табалар (1964). Илебездә тәүге тәжрибә 1972 дә кызыл якут кристаллында В.А.Пирожков, В.В.Самарцев һәм Р.Г.Усманов тарафыннан үткәрелә (СССР ФА Казан ф-лының Физика-техника ин-ты).



Яктылык кайтавазы (ике импульслы) барлыкка килүнең (ФК) иң гади схемасы: τ – ялкынсындыру импульслары (I, II) арасындагы вакыт интервалы; t – вакыт.

Ф.к.н күзгату өчен лазер импульсының йөртүче ешлыгы эшче ионнарның нинди дә булса энергетик күчеше ешлыгына тәңгәл килергә, ш. у. лазер импульсларының дәвамлылыгы һәм алар арасындагы интерваллар (*t*) матдә релаксациясенең кайтмас процесслары вакытыннан кимрәк булырга тиеш. Ф.к.ның яктырту юнәлешен фәзаи синхронизм шарты билгели: $k_{ФЭ}=2k_2-k_1$, биредә $k_{ФЭ}$ һәм k_n (n=1,2) — Ф.к.ның дулкын векторлары, беренче һәм икенче күзгатучы лазер импульслары. k_1 б-н k_2 арасындагы почмакны үзгәртү нәтиҗәсендә югары (күп пиксельле) почмакча кайтаваз-спектроскопия тормышка ашырыла (В.В. Самарцев, Е.И. Штырков, 1979). Практикада Ф.к.ның 3 импульслы күзгату режимы күпкә уңайлырак. Ул режимда t_1+2t (биредә t_1 — 2 нче һәм 3 нче лазер импульслары арасындагы интервал) вакыты мизгелендә фазаландырылган электродиполь мизгел Ф.к.ның стимуллаштырылган сигналын (СФК) $k_{СФЭ}=k_1+k_2+k_3$ юнәлешендә яктырта (биредә k_3 — 3 нче лазер импульсының дулкын векторы). СФК сигналлары оптик кайтаваз-процессорлар эшендә файдаланыла. Кодлаштырылган мәгълүмат я 2 нче лазер импульсының вакытлы формасына, я аның дулкын фронтына языла. Куллану өлкәсе: үтә югары зурлыктагы оптик когерент спектроскопия, динамик фәзаи-вакытлы голография, оптик хәтер һәм мәгълүматларның оптик когерент эшкәртелеше.

Әд.: Копвиллем У.Х., Нагибаров В.Р. Световое эхо на парамагнитных кристаллах // Физика металлов и металловедение. 1963. Т. 15, № 2; Световое эхо в рубине // Физика твёрдого тела. 1972. Т. 14, вып. 6; Маныкин Э.А., Самарцев В.В. Оптическая эхо-спектроскопия. М., 1984; Femtosend photon echo in dye-doped polymer film at room temperature // Laser Physics Letters. 2006. V. 3, № 1.

ФОТОСИ́НТЕЗ, Кояш энергиясе исәбенә яшел үсемлекләр һәм фотосинтезлаучы бактерияләр катнашында тереклек өчен мөһим булган органик матдәләрнең барлыкка килү процессы; Җирдә органик матдәнең төп чыганагы. Ф. күзәнәктән тыш структураларда — хлоропласт һәм хроматофорларда (көрән һәм яшел суусемнәрдә) бара. Аның нигезендә оксидлашу-кайтарылу реакцияләре ята, бу вакытта водород доноры һәм кислород бүленү чыганагы булып су хезмәт итә, ә CO_2 — водород акцепторы һәм углерод чыганагы. Күпчелек үсемлекләрдә CO_2 ассимиляциясе Кальвин циклы буенча бара, бу очракта Ф.ның беренче тотрыклы продуктлары булып өч углеродлы кушылмалар тора. Бу үсемлекләрне C_3-үсемлекләр дип атау кабул ителгән. Аларга көчле фотосулау хас (ФС — яктылык көчәйтүче һәм Ф. б-н бер үк вакытта яфраклардан CO_2 бүленү процессы), аның барышында Ф.да ассимиляцияләшкән углеродның яртысы диярлек югалырга мөмкин. Башка, C_4 дип йөртелүче үсемлекләрдә (кукуруз, шикәр камышы, сорго һ.б.), Ф.ның беренчел продуктлары — дүрт углеродлы кушылмалар (алма һәм аспирин к-тасы), алар мезофилл күзәнәкләрендә барлыкка киләләр һәм үткәрү көпшәчекләрен ураучы күзәнәкләрдә торгызылалар. C_4-үсемлекләр C_3-үсемлекләрдән югары фотосинтез продуктлылыгы б-н аерыла. C_4-үсемлекләрдә (кукурузда) Ф.ның беренчел продуктлары барлыкка килү үзенчәлекләрен беренчеләрдән булып 1960 елда Казан а.х. ин-ты аспиранты Ю.С.Карпилов ачыклый. Аның тарафыннан мондый Ф. «кооператив Ф.» дип атала, үткәрүче яфрак бәйләмен ураучы күзәнәк һәм мезофилл күзәнәкләренең үзара хәрәкәте үзенчәлекле CO_2 «насосы» барлык-

ка китерәләр, нәтиҗәдә, Кальвин системасында аны үзләштерү тизлеге арта. 1953–57 дә Казан ун-ты галимнәре тарафыннан CO_2нең фотосинтез юлы б-н үзләштерелү корылык һ.б. тискәре факторлар тәэсирендә үзгәрүе исбатлана (И.А.Тарчевский), бу вакытта чынбарлыктагы фотосинтез энергиясе туплану турындагы мәгълүматларның кислородлы газ алмашу исәпләүләре б-н туры килмәү дәрәҗәсе арта (В.Е.Петров). Казан Биол. ин-ты хезмәткәрләре тарафыннан яфраклардан ассимилятлар экспортына һәм азотлы туендыру дәрәҗәсенә ФСның бәйле булуы ачыклана (В.И.Чиков). Уңышны формалаштыруның төп факторы буларак, Ф. проблемасына Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-ты (1969–72), соңрак Казан Биол. ин-ты тикшеренүләре багышлана. И.А.Тарчевский һ.б. тарафыннан продуктлылык өчен яфракларның гына түгел, ә бәлки хлорофилл булган башка органнар (сабак, башак һ.б.ш.) Ф.ының да зур әһәмияткә ия булуы күрсәтелә. Яфраксыз органнар Ф.ы онтогенезның аерым чорларында, тулы бер үсемлек Ф.ының 30–60% ын тәшкил итәргә мөмкин һәм аның корылыкка чыдамрак булуы исбатлана (Ю.Е.Андрианова). Бу учреждение галимнәренең тикшеренүләре б-н берлектә Ф.ның тамыр һәм үрчү органнары арасында ассимилятларның урнашуына бәйле булуы билгеләнә: үрчү органнарының көчле үсүе вакытында тамырларның ассимилятлар б-н тәэмин ителеше азая, бу исә Ф.ның һәм уңышның кимүенә китерә (С.Б.Чемикосова). 1970 еллар башында үсемлекләрнең азотлы туену дәрәҗәсе күтәрелү б-н яфраклардан ассимилятлар экспортының интенсивлыгы кимүе (А.П.Иванова); тагын да соңрак Казан Биохимия һәм биофизика ин-тында үткәрелгән тикшеренүләрдә яфракның күзәнәктән тыш фәзасында барган процессларның Ф.ны көйләүдә әһәмияте зур булуы күрсәтелә (Н.П.Иванова). Яфраклардан килүче шикәр каналларына азотлы ашламаларның нитратлы формалары гына тискәре йогынты ясавы (Т.Н.Нестерова) һәм моның флоэма тамырларында тишемнәрнең томалануы б-н бәйле булуы ачыклана (Ф.А.Габдрәхимов), шул ук вакытта күзәнәк аралыгында инвертаза ферментының активлыгы үсә, ул исә сахарозаны гидролаштыра һәм яфрактан аның экспортына каршылык тудыра (С.Н.Баташева). Шушы мәгълүматлар нигезендә комплексы матдәләр (аммиакатлар) эшләнә, алар, каталитик күләмдә, күзәнәктән тыш мохит кислоталылыгын үзгәртеп, яфраклардан килүче шикәр каналларын стимуллаштыра (В.И.Чиков). Татарстан агрохимия һәм туфрак белеме фәнни-тикшеренү ин-тының кыр тәҗрибәләрендә аммиак тәэсирендә (туфрак микрофлорасы б-н керүче атм. азотын үзләштерүне көчәйтү исәбенә) тамырларга өстәмә шикәр кертү нәтиҗәсендә шикәр чөгендере уңышының арту эффекты билгеләнә (В.И.Чиков, И.Т.Храмов, Ә.Х.Җаббаров).

Әд.: Карпилов Ю.С. Распределение радиоактивного углерода ^{14}C среди продуктов фотосинтеза кукурузы // Тр. Казан. с.-х. ин-та. 1960. Т. 41, вып. 1; Тарчевский И.А. Фотосинтез и засуха. К., 1964; Шул ук. Метаболизм растений при стрессе. К., 2001; Чиков В.И. Фотосинтез и транспорт ассимилятов. М., 1987; Шул ук. Эволюция представлений о связи фотосинтеза с продуктивностью растений // Физиология растений. 2008. Т. 55, № 1.

В.И.Чиков.



Фра-Мауро картасы фрагменты.

ФОФА́НОВ Лев Львович (30.10.1887, Әстерхан ш. — 13.1.1919, Казан), терапевт, медицина д-ры (1908). Казан ун-тының мед.ф-тын тәмамлаганнан соң (1903), шунда ук, госпиталь терапиясе клиникасында эшли. 1907 елдан Казан бактериология ин-тының Пастер бүлегендә. 1909–1910 да Германиядә фәнни командировкада була. 1910 нан Казан ун-тында, табиблек диагностикасы һәм пропедевтик дәвалау каф. мөдире (1914 тән), факультетның терапия клиникасы мөдире (1915 тән), ординар проф. (1918 дән). Ф. ашкайнатуның физиол. процессларын, ашказаны эчәк тракты авыруларын тикшерә, организмның физиол. процессларында нерв системасының ролен, депрессор нервның әһәмиятен һәм аның үзәк кан тамырларындагы хәрәкәтне тәэмин итүгә мөнәсәбәтен өйрәнә.

Хезм.: К вопросу об отделении желудочного сока у здоровых людей // Рус. врач. 1906. Т. 5, № 50; К вопросу об усвоении сырых крахмалов различного вида при нормальной и болезненно-изменённой деятельности желудочно-кишечного тракта // Рус. врач. 1910. Т. 9, № 50; К вопросу о лечении выпотных плевритов бугорчаткового происхождения // Рус. врач. 1914. № 9.

Әд.: Анисимов В.Е., Салихов И.Г. Профессор Лев Львович Фофанов // Казан. мед. журн. 1986. № 6.

ФРА-МА́УРО ПОРТОЛАНЫ́, геогр. карта. 1457–59 елларда Португалия короле Афонс V әмере б-н Венеция монахы Фра-Мауро тарафыннан төзелә. Аны төзегән вакытта автор классик геогр. хезмәтләрне, аерым алганда, Птолемейның (2 йөз) «География буенча яр-дәмлек» («Руководство по географии») китабыннан һәм заманча мәгълүматлардан (13 йөздә Марко Поло сәяхәтләре, 15 йөзнең 1 нче яртысында Португалия экспедицияләре нәтиҗәләре һ.б.) файдалана. Портолан түгәрәк дөнья картасы рәвешендә була, анда Кара диңгез һәм Каспий диңгезе, Идел елгасы, Мәскәү дәүләте сурәтләнә; Алтын Урдага караган топонимнардан Saray Grando, Lordo de Saray, Saray, Belciman һ.б. атамалар күрсәтелә.

Әд.: Чекалин Ф.Ф. Нижнее Поволжье по карте космографа XV века Фра-Мауро // Тр. Саратов. уч. арх. комиссии. 1890. Вып. 2; Хеннинг Р. Неведомые земли. М., 1962. Т. 3.

ФРАЗЕОЛОГИ́ЗМ, фразеологик берәмлек, идиома; бер сүз б-н дә алыштырып була торган, әмма мәгънәсе компонентларының мәгънәләреннән чыгарылмый, ягъни алар суммасына тигез була алмый торган тотрыклы сүзтезмә. Татар Ф.ына сөйләмдә әзер килеш кулланылу, мәгънә бөтенлеге һәм тотрыклы төзелешкә ия булу хас, шуның б-н берәртән компонентлары арасында да чагыштырмача тотрыклылык күзәтелә: тәмуг газабы, сабак алу, кул кую, яңакка салу, аягыңны юрганыңа карап сузу һ.б. *Афоризмнар*, *канатлы сүзләр*, *мәкальләрне* дә Ф.га кертеп карыйлар. Татар Ф.ының түбәндәге чыганакларын аерып күрсәтәләр: тотемистик күзаллауларның борынгы формасы (аю мае сөртү); төрледән-төрле гадәттән тыш көчләр, затлар турындагы күзаллаулар (кот очу); хорафатлар, ышанулар, йолалар һәм әфсен-төфсеннәр (сул аяктан тору); дин б-н бәйле (Алла сакласын, Алла хакы өчен); язма традицияләр (әлифне таяк дип белмәү); тарихи фактлар (Әндри казнасы); хайваннар дөньясына күзәтүләр (тавык күзе); әки -

ятләр һәм легендалар (дию йокысы); алынмалар (Демьян ухасы); калькалаштыру һәм ярымкалькалаштыру (үле җаннар, Дамокл кылычы). Татар теленең фразеологик составы, даими рәвештә яңадан-яңа берәмлекләр б-н тулыланып, халыкның мәдәни-тарихи тәжрибәсен, аның тарихи үсеш закончалыкларының үзенчәлекләрен яктырта. Ф.ны өйрәнү һәм классификацияләү б-н *фразеология* шөгыльләнә.

Әд.: Борһанова Н., Мәхмүтова Л., Җәләй Л. Татар теленең фразеологиясе, мәкаль һәм әйтемнәре. К., 1957; Ахунҗанов Г.Х. Татар теленең идиомалары. К., 1972; Әхәтов Г.Х. Татар теленең фразеологик әйтелмәләр сүзлеге. К., 1982; Исәнбәт Н. Татар теленең фразеологик сүзлеге: 2 томда. К., 1989–90.

Л.К.Бәйрәмова.

ФРАЗЕОЛО́ГИК СҮЗЛЕКЛӘ́Р, телнең фразеологик составын яктырткан сүзлек төрләре. Татар фразеологик лексикологиясен өйрәнү Г.Миниевнең татар мәкальләре (1904), Х.Бәдигый (1912), Х.Галинең (1941) мәкаль һәм әйтемнәре тупланган җыентыкларыдан башлана. Л.Ж.Җәләй, Н.Б.Бор һанова, Л.Т.Мәхмүтованың байлык, ярлылык, туган ил, чит җир, көлү, елау, хезмәт, тырай тибү кебек темаларга багышланган якынча 6000 лексик берәмлекне үз эченә алган «Татар теленең фразеологиясе, мәкаль һәм әйтемнәре» (1957) сүзлеге системага салынган беренче фәнни хезмәт булып санала. Соңрак Н.С.Исәнбәтнең 3 томлык «Татар халык мәкальләре» (1959–67) дип аталган татар мәкальләренең тематик сүзлеге басылып чыга. Анда мәкальләрнең, искергән сүзләрнең мәгънәләре аңлатыла, аерым мәкальләрнең этимологиясе китерелә, башка телләрдән параллельләр уздырыла. 1980 елларда Г.Х.Әхәтовның «Татар теленең фразеологик әйтелмәләр сүзлеге» (1982) һәм Н.С.Исәнбәтнең «Татар теленең фразеологик сүзлеге» (1–2 т., 1989–90) нәшер ителә, аларда фразеологизмнарның мәгънәләренә аңлатма бирелә. Н.Б.Бор һанова һәм Л.Т.Мәхмүтова тарафыннан төзелгән икетелле «Русча-татарча фразеологик сүзлек» (1959) түбәндәге принцип буенча эшләнә: татар фразеологизмнары алфавит тәртибендә урнаштырыла; сүзлекнең русча һәм татарча өлешләренә фразеологик синонимия китерелә; сүзлекнең татарча өлешенә фразеологик эквивалентлар бирелә, андый очрак күзәтелмәгәндә, ирекле сүзтезмәләр ярдәмендә аңлатмалар һәм шәрехләмәләр китерелә. 1980 дә Л.К.Бәйрәмованың «В.И.Ленин теленең русча-татарча фразеологик сүзлеге» («Русско-татарский фразеологический словарь языка В.И.Ленина») басыла. Анда алфавит тәртибендә бер ояга туплап бирү принцибы файдаланыла, авторның фразеологизмнарны куллану ешлыгы күрсәтелә, аларның татарча эквивалентлары, калькалар, ярымкалькалар, алынмалар һәм тасвирый аңлатмалар, ш.у. оригиналдан (төп нөсхәдән) контекстлар рәвешендә фоторәсемнәр һәм аларның татарчага тәрҗемәләре бирелә. 20 йөз ахыры — 21 йөз башында Л.К.Бәйрәмованың «Уку-укыту буенча тематик русча-татарча фразеологик сүзлек»е («Учебный тематический русско-татарский фразеологический словарь», 1991), Ф.С.Сафиуллинаның фразеологизмнарның татарча һәм русча эквивалентлары тәкъдим ителгән «Татарча-русча фразеологик сүзлек»е (2001), Ф.Ф.Гаффарова һәм Г.Г.*Саберованың* «Татарча-русча идиомалар сүзлеге» нәшер ителә. 1990 еллар уртасыннан башлап Х.Ш.Мәхмүтовның татар мәкальләре, әйтемнәре һәм канатлы сүзләре этимологиясенә багышланган «Язылмаган кануннар» (1995), «Канатлы сүз — хикмәтле сүз» (1999), «Гыйбарәләр тарихыннан сәхифәләр» (2008) хезмәтләре дөнья күрә. Бу хезмәтләрдә фразеологизмнарның килеп чыгышы өйрәнелә, аларның татар шагыйрьләре, язучылары һәм журналистлары тарафыннан кулланылуына мисаллар китерелә.

Әд.: Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле: Лексикология. К., 1999.

Л.К.Бәйрәмова.

ФРАЗЕОЛО́ГИЯ (грек. phrásis — тәгъбир һәм *...логия*), аерым бер телнең фразеологизмнары җыелмасы; 2) *тел белеменең* телнең фразеологик составын өйрәнүче тармагы. Ф.нең предметы булып фразеологизмнарның беренчел, элекке формаларын һәм мәгънәләрен өйрәнү, кулга төшерергә мөмкин булган барлык ядкәрләр аша аларның чыганакларын билгеләү, әлеге тел гамәлдә булган төрле чорларда Ф.нең кулланылыш өлкәсен ачыклау тора. Фразеологизмнар төзелеше — сүзләр тезмәсе яки җөмлә төзелеше б-н, ә мәгънәсе лексик төрләр мәгънәсе б-н туры килгәнгә күрә, Ф. *лексикология*, *синтаксис* һәм *сүз ясалышы* б-н бәйле. Ф. фразеологик берәмлекләрне аеру принципларын, аларны өйрәнү, классификацияләү һәм фразеографияләү, ягъни сүзлекләрдә тасвирлау ысулларын тикшерә. Татар теле Ф.сен фәнни җирлектә өйрәнүне 19 йөз ахырында К.Г.Насыйри башлап җибәрә һәм 20 йөздә Ш.Г.Рамазанов, Ж.Ж.Вәлиди, Г.Х.Алпаров дәвам итә. Ф.нең татар тел белеменең мөстәкыйль тармагы буларак үсеш алуы 1960 елларга карый. Фразеологик сүзлекләр төзү б-н бәрәттән Г.Х.Әхәтов, Г.Х.Ахунҗанов, Н.С.Исәнбәт, К.С.Сабиров һ.б. галимнәрнең татар Ф.сенең гомуми мәсьәләләренә багышланган хезмәтләре басыла. Ф.нең күпчелек аспектлары язучыларның әсәрләре телен тикшерү чикләрендә камилләштерелә (Г.С.Әмиров, В.Х.Хаков, М.Г.Мөхәммәдиев, С.Ш.Поваристов һ.б.ның хезмәтләре). 1980 елларда яңа бер юнәлеш — татар һәм рус телләре Ф.сен чагыштырма-типологик өйрәнү күзәтелә (Р.Г.Юсупов, Л.К.Бәйрәмова, Г.И.Бичурина һ.б.). Татар Ф.сен Көнбатыш Европа телләре б-н чагыштырып өйрәнүгә З.З.Гатиятуллина, И.И.Ибраһимова, Д.А.Хафизова һ.б. тел галимнәренең мәкаләләре багышлана.

Әд.: Борһанова Н., Мәхмүтова Л., Җәләй Л. Татар теленең фразеологиясе, мәкаль һәм әйтемнәре. К., 1957; Ахунҗанов Г.Х. Татар теленең идиомалары. К., 1972; Әхәтов Г.Х. Татар теленең фразеологик әйтелмәләр сүзлеге. К., 1982; Исәнбәт Н.С. Татар теленең фразеологик сүзлеге: 2 томда. К., 1989–90; Байрамова Л.К. Источники славянской и восточной фразеологии. К., 2007.

Л.К.Бәйрәмова.

ФРА́УЧИ Виктор Христофорович (22.4.1902, Тверь губ., Калинино өязе Юрино а. — 11.5.1986, Казан), анатом, мед. фән. д-ры (1949), проф. (1949). 1 нче Мәскәү мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1931), СССР Сәламәтлек саклау министрлыгы каршындагы 4 нче Баш идарәдә табиб булып эшли, 1933 елдан Үзәк ГИДУВның (Мәскәү) оператив хирургия һәм клиник анатомия кафедрасында. 1941 дән — Төньяк Осетия (Орджоникидзе ш.), 1958 дән — Смоленск, 1962–73 тә Казан (1974–82 дә проф.-консультант) мед. ин-тларының оператив хирургия һәм топографик анатомия каф. мөдире. Хезмәтләре кан тамырлары системасы морфологиясе өлкәсенә һәм эксперименталь хирургиягә карый. Топографик анатомия һәм эксперименталь хирургия буенча дәреслекләр авторы.

Хезм.: Топографическая анатомия и оперативная хирургия головы и шеи. К., 1967; Топографическая анатомия и оперативная хирургия груди и конечностей. К., 1968; Курс топографической анатомии и оперативной хирургии. К., 1976.

Әд.: Казанский государственный медицинский университет (1804 — 2004 гг.): Заведующие кафедрами и профессора: Биогр. словарь. К., 2004.

ФРЕ́ЗЕ Александр Устинович (3.4.1826, Ревель ш. — 4.2.1884, Казан), психиатр, медицина д-ры (1858). Мәскәү ун-тын тәмамлаганнан соң (1851), Калуга алпавыты Каншин утарларында, 1856 елда — Мәскәүнең Преображенский психиатрия дәваханәсендә, 1862 дән Россия Эчке эшләр министрлыгы карамагында эшли. 1865 тән Казан ун-тының терапия кафедрасында, 1872 дән проф., психиатрия каф. мөдире. Хезмәтләре психиатрия ярдәме күрсәтүне оештыру мәсьәләләренә, мәхкәмә психологиясе һәм психиатриясенә карый. Ф. — Казанда Россиядәге беренче округ психиатрия дәваханәсен оештыручы һәм аның директоры (1866–84). Россиядә беренче буларак психик авыруларны иректән сезләмәү системасын гамәлгә кертә.

Хезм.: К открытию Казанского дома умалишённых. К., 1869; О предсказании в душевных болезнях. К., 1875; Первое десятилетие Казанской окружной лечебницы (1869 – 1879). К., 1880; Очерк судебной психиатрии. К., 1881.

Әд.: Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2.

ФРЕН Христиан Мартин (Христиан Данилович, Christian Martin Joachim Frahn) (23.5.1782, Мекленбург-Шверин герцоглыгы, Росток ш. — 16.8.1851, С.-Петербург), шәркыятьче галим, нумизмат, филос. һәм дини тәгълимат д-ры (1804), Петербург ФАнең хакыйкый әгъзасы (1817). Росток, Гёттинген, Тюбинген ун-тларында (1802 елга кадәр) укый. 1807 дән Казан ун-тында, шәрекъ телләре ординар профессоры, гарәп, фарсы, яһүд, сүрия телләрен, палеография, Алтын Урда нумизматикасын укыта; 1807–17 дә шәрекъ телләре каф. мөдире; бер үк вакытта, 1815 тән, филос. ф-ты деканы. Азия басмаханәсендә (Казан) аның гарәп телендә 17 самани һәм буид акчаларына багышланган беренче «Саманиларның кайбер көмеш тәңкәләре тасвирламасы» («Описание некоторых серебряных монет Саманидов», 1808) монографиясе басыла. Соңрак

Казанда һәм Идел буендагы башка шәһәрләрдә сакланучы берничә шәхси акча коллекцияләре тасвирламасын тәкъдим итә, Гарәп хәлифәлеге, Саманилар, Идел буе Болгар дәүләте акчаларын җентекләп тикшерә. Шушы ук чорда аның шәхси нумизматика коллекциясенә нигез салына. 1818 дән С.-Петербургта, Азия музеен оештыручы һәм аның беренче директоры. 1818–28 дә Император гавам китапханәсенең шәрәфле китапханәчесе: шәрекъ китапларын һәм кулъязмаларын, ш.и. Ардебиль китапханәсен эшли (Персиядән кайтарылган шәрекъ кулъязмалары җыелмасы) тасвирлау б-н шөгыльләнә. Беренче лардән булып Эрмитаждагы һәм Азия музейларындагы шәрекъ акчаларын, медальләрне, Петербург ФАнең Шәрекъ Минц-кабинеты кулъязмаларын өйрәнүгә керешә. Одесса тарих һәм борынгылык җәмгыяте әгъзасы (1839). Рус археол.-нумизматика (соңрак археол.) җәмгыятен оештыручыларның берсе (1848). Хезмәтләре урта гасырлар шәрек нумизматикасына, чыганакларны өйрәнү гыйлеменә һәм эпиграфикага карый. Россия тарихын өйрәнүдә шәрекъ чыганакларын җәлеп итүдә зур роль уйный. Ф. хезмәтләре Россиядә шәркыятьчелек гыйлеме һәм шәрекъ (ш.и. Алтын Урда) нумизматикасы үсешенә җирлек әзерли.

Әд.: Дорн Б.А. Академик Френ и его учёная деятельность. СПб., 1855; Савельев П.С. О жизни и трудах Френа. СПб., 1855; Валеев Р.М. Казанское востоковедение: истоки и развитие (XIX в. — 20 гг. XX в.). К., 1998; Куликова А.М. Российское востоковедение XIX века в лицах. СПб., 2001.

Р.М.Вәлиев.

ФРЕНКЕ́ЛЬ Арон Гдалевич (7.2.1937, Ленинград ш.), техник фән. канд. (1989), РФнең атказ. машина төзүчесе (2002). СССРда һәм РФдә микрохирургия инструментлары җитештерүгә нигез салучыларның берсе. 1966 елда Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый. 1962–69 да компрессорлар эшләү буенча махсус КБда эшли. 1969 дан Бөтенсоюз мед. инструментлары фәнни-тикшеренү ин-тында, 2004–09 да Казан мед. инструментлары з-дында (микрохирургия эшләнмәләре җитештерү буенча ген. директор урынбасары, 2000 нән). «Офтальмологик операцияләр өчен микрохирургия инструментлары буенча тикшеренүләр уздырганы һәм эшләп чыгарганы өчен» РФ Хөкүмәтенең фән һәм техника өлкәсендәге бүләге лауреаты. «Кан тамырлары һәм йөрәк кан тамырларын дәвалау өчен яңа микрохирургия технологияләре һәм инструментлары буенча тикшеренүләр уздыру, аларны эшләү һәм клиник практикага кертү» хезмәте өчен ТРның Фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт бүләге лауреаты (2017).

ФРЕ́СКА (итал. affresco — саф, яңа), суда эретелгән буяу б-н юеш штукатуркага төшерелгән бизәк; коры җирлеккә темпера б-н бизәк төшерүнең капма-каршысы булган дивари бизәк техникасы. Кипкән вакытта штукатуркадагы известь бизәкләрне тышкы тәэсирләрдән саклый торган үтә күренмәле кальций элпәсе хасил итә. Андый бизәк техникасы Россиядә 18 йөздән бөтенләй диярлек кулланылыштан чыга, аны майлы буяу б-н эшләү алыштыра, әмма термин үзе киң аңлатма ала — еш кына теләсә нинди дивар бизәге шулай атала башлый. Татарстан җирлегендә Ф. техникасында башкарылган иң әүвәлге бизәкләр Болгар шәһәрендәге Кызыл пулат мунча интерьеры фрагментларында сакланган (к. *Болгар бизәлеш сәнгате*). Орнаментлы бизәк гөмбәз җилкәннәренә төшерелгән һәм ул үсемлек сурәтләрен һәм геом. фигураларны гәүдәләндерә. Ф. 16 йөзнең 2 нче яртысыннан христиан гыйбадәтханәләренең интерьерларында һәм тышкы бизәлешендә таралыш ала. Башкаручылары Мәскәү осталары була. Зөя шәһәрендә *Успение монастыреның* Успение соборындагы Ф. ансамбле төбәк җирлегендәге иң борынгы Ф.ларның берсе. Бизәк үзенең сакланышы (1080 $м^2$) һәм сәнгати үзенчәлеге — башкарылыш манерасы һәм төсләр колориты б-н уникаль. Ф. фрагментлары монастырының кайбер башка корылмалары диварларының тышкы бизәкләрендә: Никола чиркәвенең төп ишеге өстендә (Деисус композициясе фрагментлары — түгәрәк эчендәге Мәрьям ана һәм Иоанн-Предтеча сурәте), монастырьның көньяк (Изге) капкасы гөмбәзләрендә сакланган. Зөя шәһәрендә *Иоанн-Предтеча хатын-кызлар монастырендагы* Сергий чиркәвенең көнбатыш диварында Ф. фрагменты — эчтәлеге Иске Тәүраттан булган өч өлешле композиция бөтен килеш калган. 1640 елларда Казан осталары И.Гаврилов, К.Фомин, Ф.Рябухин Мәскәү Кремлендәге Успение һәм Архангел соборларын Ф.лар б-н бизәүдә катнашу өчен Мәскәүгә чакыртыла. Казан Кремлендәге 17 йөзгә караган Благовещение кафедраль соборының бизәк фрагментлары сакланган. Собор берничә мәртәбә төзекләндерелә; соңгы бизәү эшләре Н.Л.Софонов артеле тарафыннан 1869–70 елларда башкарыла. Торак һәм җәмәгать биналарында 18 йөз ахыры — 19 йөз башы классицизм стиленә хас орнаментлы-сюжетлы Ф. Казан биналары интерьерларында таралыш алмаган диярлек. Искәрмә буларак, сәүдәгәр С.Е.Александров йортының (1849) бизәлешен күрсәтергә мөмкин: урам якка караган бүлмәләренең түшәмнәре чәчәк сурәтле һәм орнаментлы гирляндалар һәм мифологик сюжетлы күренешләр белән бизәлгән. 1840 елларда Казанда эшләгән «бүлмә рәссамы» Н.П.Волковның исеме билгеле.

Казан гыйбадәтханәләре Ф. ансамбльләренең күп өлеше, шәһәрдәге зур янгыннардан соң яңартылуга карамастан, сакланып калмаган, Совет хакимияте елларында чиркәүләр үзләре дә юк ителә. 19 йөзнең 1 нче яртысында Казан гыйбадәтханәләрен бизәгән осталарның әдәби чыганаклардан билгеле булган исемнәре: Г.Артемьев (Никола-Вишняков чиркәвенең алтарь гөмбәзе), Ф.Колосов (Владимир соборы), Б.Марков (Казандагы Беренче ир балалар гимназиясенең Крестовоздвижение чиркәве), Е.Новиков һәм А.Соколов (Вознесение чиркәве), Н.Огородников (Никола-Ляпунов чиркәве гөмбәзе). А.Тимофеев (Раифа монастыреның Троица соборы), С.Тимофеев (Изге Рухның Иңүе чиркәве янкормасы) һ.б. 19 йөзнең 2 нче яртысында — 20 йөз башында Казан осталар артеле һәм икона язу остаханәләре Казаннан читтә дә эшли: А.Пресняков (Мамадыш өязендә Тау Иле авылында Никола чиркәве), А.Е.Семёнов остаханәсе (Казан өязе Борисоглебский авылындагы Борисоглебский чиркәве, Чистай шәһәрендәге Никола соборы), С.Я.Спиридонов (Кизик монастырендагы Введение соборы бизәкләрен яңарта), П.А.Ковалинский остаханәсе (Арча шәһәрендәге Богоявленский чиркәве, Түбән Ослан авылында Сергий Радонежский чиркәвенең сулъяк янкорылмасы, Сембер губернасы Курмыш өязе Можаров Мәйдан авылындагы чиркәве) һ.б.

Гыйбадәтханәләрне бизәүгә проф. рәссамнар — Казан сынлы сәнгать мәктәбе укытучылары Г.А.*Медведев*, И.А.*Денисов* (Яңа ун-т клиникалары каршындагы Варсонофий чиркәве), укучылары А.Г.*Платунова* һәм К.К.*Чеботарёв* та (Мари-Төрек авылындагы чиркәү) алына. Казан Кремлендәге Спас манарасы янындагы кәшәнәне бизәү эскизларын (1910) Е.П.Фирсов башкара (ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее тупланмасында). Ул ш.у. 1909 елда Казанда үткәрелгән Халыкара күргәзмәнең үзәк павильоны бизәлешенең авторы да. Рәссамнар И.А.Осокин, бертуган В.П. һәм П.П.Верещагиннар, К.Ф.Гун һәм И.А.Бруни 1870 елларда Алабугада *Спас соборын*, В.П.Верещагин — *Никола чиркәвен*, К.Ф.Гун, В.П.Верещагин һәм И.А.Осокин — Алабугада Покров чиркәвен бизиләр. *Казан Богородица монастыре* монахинялары тарафыннан 1911–13 тә мог җизалы *Казан Мәрьям Ана иконасы* табылган урындагы кәшәнә интерьеры бизәлә.

Күп көч таләп итә торган Ф. техникасына хәзерге сәнгатьтә мөрәҗәгать итү очраклары юк диярлек. 1920 еллар башында Казан архит-ра-сәнгать остаханәләре укытучылары (К.Чеботарёв, С.Герштейн) һәм укучылары тарафыннан Казан җәмәгать бинала ры интерьерларын бизәү эскизлары ясала. Казан сәнгать мәктәбе бинасы залларының берсендә «Совет авылы» һәм «Уңыш җыю» Ф.лары (янгында юкка чыгалар) 1925 тә В.Лаптев тарафыннан ясала, Казанда М.Җәлил исем. Татар опера һәм балет театры интерьерларындагы (фойе, «музалар залы») «Музыка», «Бию», «Рәссам» Ф.ларын 1956 да Ч.*Әхмәров* башкара.

Илл. 356 биттә к.

Әд.: Малов Е.А. Историческое описание церквей г. Казани. К., 1884; Историко-археологические очерки церквей г. Казани. К., 1913; Егерев В.В. Внутреннее архитектурное убранство зданий Казани. К., 1927; Валеева-Сулейманова Г.Ф. Монументально-декоративное искусство Советской Татарии. К., 1984; Лепёхин С., Аникина М. Благославенная Богом. Духовная жизнь Елабуги в прошлом и настоящем. Елабуга, 2006; Фрески и иконы Свияжского Успенского собора. СПб., 2009.

Е.П. Ключевская.

ФРИ́ДЛАНД Михаил Осипович (22.9.1888, Әстерхан ш. — 13.11.1967, Мәскәү), травматолог-ортопед, медицина д-ры (1921), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1945). Казан травматолог-ортопедлар мәктәбенә нигез салучы. Казан ун-тының мед. ф-тын тә-



Фреска. 1–9. Яшел Үзән районы Зөя авылындагы Успение соборы фрескалары. 16 йөз: 1. «Изге Христофор» (әлеге изге зат башы белән сурәтләнгән дөньяда хәзергәчә сакланган бердәнбер фреска); 2. Югары яруснең гөмбәзе, барабаны, җилкәне һәм аркасы бизәлеше; 3. Храмның төньяк дивары бизәлеше. Мәрьям ананың әти-әнисе тормышындагы төп вакыйгаларга багышланган эзлекле композиция фрагменты; 4. Алтарь бизәлеше фрагменты (диндарлар төркемендә патша Иван Грозный сурәтләнгән); 5. «Ожмахка алып керү»; 6. «Изге Георгий Победоносец»; 7. «Смоленск һәм Ярославль изге кенәзе Фёдор, изге Константин һәм изге Давид»; 8. «Табуттагы Христос»; 9. «Илаһи билге»; 10. Казанның Благовещение кафедраль соборында «Изге Мәрьям Ана» фрескасы. 17 йөз; 11–12. Спас Преображение чиркәве фрескалары. 19 йөзнең 2 нче яртысы; 13–15. Ч.Ә х м ә р о в. Казандагы Татар опера һәм балет театры фойесындагы фрескалар: «Музыка», «Рәсем», «Нәкыш». 1955–56.

мамлаганнан соң (1911), шунда ук эшли. 1918 елда ортопедик протезлар остаханәсе булган, 40 урынга исәпләнгән стационар б-н җитәкчелек итә башлый (1920 дән Казан ГИДУ Выныңортопедия һәм травматология каф. мөдире). 1922–1937 дә Казан мед. ин-тында (1924 тән проф.), 1933–37дә травматология һәм ортопедия каф. мөдире. 1937–53 тә Мәскәүдә, Үзәк табиблар белемен күтәрү ин-тында, ортопедия һәм травматология каф. мөдире. Хезмәтләре травматологиягә, ортопедиягә карый.

Х е з м.: Биомеханика пневмоторакса. К., 1925; Ортопедия. М., 1954.

Әд.: В и н ц е н т и н и К.М., М о р о з о в а Е.М. Профессор М.О.Фридланд // Ортопедия, травматология и протезирование. 1976. № 11.

ФРИ́ДЛАНД Сергей Владимирович (25.11.1937, Казан), химик-технолог, химия фән. д-ры (1980), проф. (1982), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1998), Казан технол. ун-тының атказ. профессоры (2010). 1960 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң, шунда ук эшли, инженерлык экологиясе каф. мөдире (1989 дан). Хезмәтләре экология мәсьәләләренә карый. Ф. фосфор-углерод бәйләнешле биол. актив кушылмаларны синтезлаштыруның яңа алымнарын эшли. Берничә кушылманы синтезлый һәм аларның ташландык суларны чистарту өчен куллану мөмкинлеген тикшерә. Ташландык суларны, а.х. продукциясе калдыкларын кулланып, авыр металлар ионнарыннан һәм нефть компонентларыннан арындыру технологиясен тәкъдим итә. Үйлап табуга 37 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Лабораторный практикум по физикохимии компонентов окружающей среды. К., 2005; Промышленная экология: Основы инженерных расчётов. М., 2008 (автордаш); Экология. К., 2009 (автордаш).

Әд.: Выпускники — гордость Казанского технологического университета: Краткий биогр. справ. К., 2009.

ФРОЛО́В Александр Иванович (7.8.1949, Ульянов өлкәсенең Мәләкәс р-ны Мулловка а.), тау инженеры, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2000), ТРның атказ. нефтьчесе (1944). Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тын (1977), Уфа нефть ин-тын (1990) тәмамлый. 1967–2009 елларда «Татнефть» АҖдә (1990 еллар ахырына кадәр ҖБ): диспетчерлык элемтәсе, җиһазлар һәм телеавтоматика электромонтёры, җитештерүне автоматлаштыру цехында өлкән инженер, башлык урынбасары, башлык, техник бүлек башлыгы, «Иркеннефть» НГДУының баш инженеры (1985 тән), «Татнефтебитум» НГДУының (2001 дән), АҖнең катламнарның нефть бирүчәнлеген арттыру алымнары идарәсе башлыгы (2002 дән). Үйлап табуга 5 патенты бар. Дәүләт бүләге тирәндәге штангалы насослы җайланмаларның ышанычлы эшләвен арттыру буенча техник чаралар һәм технологияләр комплексын эшләүдә һәм сәнәгатьтә кулланыга кертүдә катнашканы өчен бирелә. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының бронза медале, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

ФРОЛО́В Виктор Петрович (5.11.1936, Горький крае, Лукоянов р-ны Салдо-Майдан а.), радиобиолог, вет-сан. эксперты, биол. фән. д-ры (1982), проф. (1982), ТРның, РФнең атказ. фән эшлеклесе (1992, 1998). РФнең Югары һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре (2002). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1966), шунда ук эшли: вет.-сан. экспертизасы каф. мөдире (1979–2005), каф. профессоры (2005–2009). Фәнни тикшеренүләренең төп юнәлешләре: терлекләрнең радиациядән зыян күрүе, аеруча куркыныч инфекция очракларында терлекчелек продуктларының сыйфатын тикшерү һәм вет.-сан. тикшерүне уздыру ысулларын камилләштерү. СССР Дәүләт бүләге (1979) махсус темаңы өйрәнгән өчен бирелә. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Экспертиза доброкачественности и радиационной безопасности продуктов. Их стандартизация и сертификация: В 3 т. Алматы, 2008 (автордаш); Ветеринарно-санитарная экспертиза с основами технологии и стандартизации продуктов животноводства. СПб., 2010.

ФРОЛО́В Георгий Аркадьевич (1.3.1939, Ростов өлкәсенең Морозов р-ны Резанкин хуторы), әдәбият белгече, филол. фән. д-ры (1991), проф. (1993), Казан ун-тының атказ. профессоры (2009), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2004). 1962 елда Казан ун-тын тәмамлый, 1964 тән шунда ук эшли. 1982–84 тә Грайсфальд ун-тында, 1991–2001 дә Гиссен ун-тында (Германия) лекцияләр укый. Хезмәтләре рус һәм чит ил әдәбиятында романтизм мәсьәләләренә, диахроник аспектта немец-рус әдәби багланышларына, әдәби диалогларга багышлана.

Х е з м.: Критический реализм в литературе ФРГ. К., 1975; Наследие романтизма в литературе ГДР. К., 1987.

Әд.: Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

ФРОЛО́В Никита Васильевич (1914, Уфа губ. Минзәлә өязе Каран-Азик а. — 22.3.1945), Дан орденының тулы кавалеры (13.8.1944, 16.2.1945, 27.6.1945), гв. рядовое. Туган авылында колхоз рәисе булып эшли. 1939–40 елларда һәм 1942 дән — Кызыл Армиядә. Совет-фин сугышында катнаша. 1942 нең ноябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 1277 нче укчы полкта (3 нче гв. армиясенең 389 нчы укчы дивизиясе) җәяүле разведка взводы разведчигы. 4 нче һәм 1 нче Украина фронты гаскәрләре составында Львов-Сандомир (1944), Сандомир-Силезия (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 1–3 августында Хвалевице авылы (Сандомир шәһәреннән 15 *км* төнья-көнчыгыштарак, Польша) янындагы сугыш операциясендә батырлык күрсәтә: дошман уты астында Висла елгасын кичүче укчы подразделениеләр арасында элемтә урнаштыра. 1945 нең 18–19 гыйнварында Жаркув торак пункты (Кельце шәһәреннән 50 *км* төньяк-көнбатыштарак, Польша) янындагы сугышта разведка төркеме б-н дошман солдатларын әсир итүдә һәм әсирләрне азат итү омтылышларына каршы һәҗүмдә катнаша; 1945 нең 21 гыйнварында Глогау шәһәре (Германия, хәзер Глогув ш., Польша) тирәсендә сугыша: ут системасын күзәтү өчен, дошман позициясенә якын килә һәм, үзенә каршы ут ачтырып, үлем ярасы ала.



Николай В. Фролов.



П.Г. Фролов.

Әд.: Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М. 2000.

ФРОЛО́В Николай Васильевич (13.12.1931, Югары Ослан р-ны Волково а.), фрезерчы, Соц. Хезмәт Герое (1971). Хезмәт эшчәнлеген 1948 елда «Спартак» күн аяк киемнәре комб-тында эшче булып башлый. Сов. Армиясендә хезмәт иткәннән соң (1951–55), «Радиоприбор» АҖдә фрезерчы (1955–2000). Герой исеме 8 нче бишьеллык (1966–70) планын үтәгәндә ирешкән хезмәтләре өчен бирелә.

Әд.: Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003. *М.Ж.Гаитов.*

ФРОЛО́В Павел Григорьевич (17.7.1909, Казан — 14.9.1991, Менделеев ш.), Сов. Союзы Герое (10.4.1945), гв. лейтенанты. Кече лейтенантлар курсларын тәмамлый (1943). 1926–33 елларда Казанда киномеханик булып эшли, 1933 тән Чаллы шәһәрендә кинотеатр директоры. 1940–42 дә шәһәр тибындагы Бондюг посёлогында (хәзер Менделеевск ш.) сөт-ит комб-ты директоры. 1942 нең апреленнән Кызыл Армия сафларында. 1942 нең октябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 23 нче гв. мотоукчы бригадасының (3 нче гв. танк армиясенең 7 нче гв. танк корпусы) ут взводы командиры. 1 нче Украина фронты гаскәрләре составында Сталинград сугышында (1942–43), Висла-Одер һөҗүм операцияләрендә (1945) катнаша. 1945 нең 23 гыйнварында Грошовице торак пункты янында (хәзер Польшаның Ополе шәһәре эчендә) Одер елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә: беренчеләрдән булып дошман уты астында елганы кичеп чыга. Ф. җитәкчелегендәге взвод, сугышып, дошманның үзәгенә тубын, бронетранспортёрын сафтан чыгара, 3 пулемётын һәм 50 гә якын солдат һәм офицерларын юк итә; Ф. сугышта яралана. Демобилизацияләнгәннән соң Бондюг посёлогында яши, Л.Я.Карпов исем. химия з-дында гражданнар оборонасы штабы башлыгы. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Менделеев шәһәрендәге Геройлар аллеясында Ф. хөрмәтенә стела куела.

Әд.: Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000. *М.З.Хәбибуллин.*

ФРОЛО́ВА Анна Ивановна (2.6.1944, Удмурт АССРның Алнаш р-ны Байтирәк а.), вет. хирургы, вет. фән. канд., СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1979), ТРның атказ. вет. табибе (1998). Казан вет. ин-тын тәммамлаганнан соң (1967), шунда ук эшли, 2005–10 елларда вак хайваннар һәм оператив хирургия каф. мөдире, 2010 нан акушерлык һәм вак хайваннар патологиясе кафедрасында. Хезмәтләре а.х. терлекләре авыруларын дәвалау ысулларын эшләүгә карый. Дәүләт бүләге махсус теманы өйрәнүдә катнашканы өчен бирелә.

Х е з м.: Лечение вывихов и переломов конечностей // Тр. 1 съезда ветеринарных врачей Республики Татарстан. К., 1995 (автордаш); Кариес у собак и кошек // Ветеринария Поволжья. 2002. № 2 (автордаш).

ФРОЛО́ВА Оксана Александровна (25.7.1976, Донецк өлкәсенең Шахтёрск ш.), гигиенист, мед. фән. д-ры (2009). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1999), гигиена, хезмәт медицинасы кафедрасында эшли, 2011 елдан Казан мед. академиясенең гомуми гигиена каф. профессоры. РФ Президентының яшь докторларга бирелә торган гранты иясе (2011). Тикшеренүләре авырлы хатын-кызларның туклануы мәсь әләвренә карый, антиоксидантлар дефициты исәпкә алынып, Ф. тарафыннан туклану рәвешен коррекцияләү буенча тәкъдимнәр кертелә. Уйлап табуга патенты бар.

Х е з м.: Обеспеченность женщин во время беременности фолиевой кислотой и цинком // Вопр. детской патологии. 2009. № 4; Демографический потенциал Республики Татарстан // Здравоохранение РФ. 2009. № 5; Медико-социальные и гигиенические аспекты питания. К., 2011 (автордаш).

ФРОНТ ГАЗЕ́ТАЛАРЫ, татар телендә, Бөек Ватан сугышы фронтларында Кызыл Армиянең Баш сәяси идарәсе вакытлы матбугат басмалары. Ф.г.ның зур өлеше сугыш вакытында хәрби округлар, кайберләре армия басмалары нигезендә, кайберләре яңабаштан оеша. Фронт газеталарына хәрби төркем басмалары да тиңләштерелә. 1943 елның 14 гыйнварыннан ВКП(б) УК карары б-н Ф.г.ның форматы, тиражы һәм чыгу ешлыгы бердәм нормага китерелә. 30×42 *см* форматта, 4 бит ле, 5–10 сугышчыга 1 газета исәбеннән нәшер ителә һәм таратыла. Татар телендә беренче Ф.г. «*Ватан өчен*» исеме б-н 1942 нең 10 июлендә Төньяк-Көнбатыш фронтта чыга. 1942–45 тә татар телендә 16 фронт газетасы нәшер ителә, алар рус телендәге Ф.г. басмаларын кабатламый. Алар арасында — «*Алга, дошман өстенә*» (1 нче Балтыйк буе), «*Ватан намусы өчен*» (Воронеж, 1 нче Украина), «*Ватан өчен сугышка*» (Карелия), «*Ватанны саклауда*» (Ленинград), «Җиңү байрагы» (Төньяк Хәрби группа), «Кызыл Армия» (1 нче Белорус), «*Кызыл сугышчы*» (Мәскәү хәрби округы), «*Совет сугышчысы*» (3 нче Украина), «*Сталин байрагы*» (Көньяк, 4 нче



«Ватан намусы өчен» фронт газетасы редакциясе: Г. Хуҗин, М. Садри, Р. Ишморат (мөхәррир).

Украина), «Сталин сугышчысы» (1 нче Ерак Көнчыгыш), «Суворовчы» (2 нче Балтыйк буе), «*Суворовча кысрыклау*», «*Тревога*» (2 нче Ерак Көнчыгыш), «*Фронт правдасы*» (Волхов), «*Фронт хакыйкате*» (2 нче Белорус). Ф.г.ның милли басмалары җитәкчеләре мөхәррир урынбасары вазифасында була. Татар газеталары мөхәррирләре арасында күренекле әдипләр Ә.Ерикәй, Р.Ишморат, Б.Корбанов, М.Максуд була. Хәрби хәбәрчеләре булып танылган язучылар Г.Әпсәләмов, Ә.Әхмәт, Г.Бакир, И.Гази (псевд. И.Зарипов), Г.Галиев, Г.Иделле, М.Кәрим, Г.Кутуй (псевд. К.Гаделшин), М.Мазунов, Г.Насрый, Ш.Маннур, Ш.Мөдәррис, М.Садри, Х.Госман, Ә.Фәйзи, Г.Хуҗи, А.Шамов, Ә.Юныс эшли. Газета битләрендә штаттан тыш хәбәрчеләр М.Ногман, С.Минһа җәв, Н.Гайсин, ш.у. күренекле язучылар М.Әмир, Г.Бәширов, Т.Гыйззәт, К.Нәҗми, Х.Хәйри, Г.Хуҗин, Ф.Хөснинең мәкаләләре басыла. Ф.г.нда илдәге һәм дөньядагы вазгыять яктыртыла, Башкомандующийның боерыклары чыга, фронтлардагы хәлләр турында сөйләнелә. Материалларның күп өлеше татарларның сугышчан батырлыкларына, хәрби һәм сәяси әзерлек мәсь әләләренә, интернациональ тәрбиягә, фронт һәм тыл бердәмлегенә һ.б.га багышлана. Күренекле татар язучыларының газеталарны чыгаруда катнашуы материал-



ларның әдәби дәрәҗәсенә уңай йогынты ясый. Газеталарда күпсанлы очерклар, хикәяләр, новеллалар, шигырьләр, ш.и. рядовой сугышчыларның иҗаты да басыла. Барлык Ф.г.ның сатира һәм юмор бүлекләре була, «Чаян сугышта», «Хуҗа Насретдин фронтта», «Уклар», «Шарсыман яшен» һ.б. сәхифәләр алып барыла; сатирик диалогларда, эпиграммаларда, памфлет, пародияләрдә фашизм көлке утына алына. Солдат һәм тыл хезмәтчәнәре хатларына күп урын бирелә. Татар телендәге Ф.г. Россия милли китапханәсендә (Мәскәү) һәм РФ Оборона министрлыгының Үзәк хәрби архивында (Подольск) саклана.

Әд.: А й н у т д и н о в А.К. Летопись подвига (Исторический очерк по страницам татарских фронтовых газет). К., 1984; Ш а м о в а А. Печать, рождённая в огне // Казань. 2007. № 7.

Р.А.Айнетдинов.

«ФРОНТ ПРА́ВДАСЫ», газета. Волхов фронтының сәяси идарәсе органы. 1943 елның гыйнварыннан 1944 нең февраленә кадәр татар телендә нәшер ителә. Мөхәррире — Г.Хәбиб. Газета редакциясендә татар язучылары Ә.*Фәйзи* эшли, ул газетада очерклар, шигырьләр, эпиграммалар бастыра, карикатураларга рәсем асты яза. Билгеле язмалар арасында — М.Максудның Һ.Такташ турындагы «Шагыйрь яши» мәкаләсе. 1944 нең февралендә Волхов һәм Карелия фронтлары кушылганнан соң, «Ф.п.» «*Ватан өчен сугышка*» г-тасы б-н берләштерелә.

Р.А.Айнетдинов.

«ФРОНТ ХАКЫЙКАТЕ́», газета. 2 нче Белоруссия фронты сәяси идарәсе органы. 1944 елның маеннан 1945 нең 5 июненә кадәр татар телендә нәшер ителә. Мөхәррире — Г.Гыйльманов. «Ф.х.» редакциясе составына Төньяк-Көнбатыш фронтның таратылган «*Ватан өчен*» г-тасы хезмәткәрләре Г.Гыйльманов, Ә.Әхмәдиев, Ш.Мөдәррис, Ә.Сәлиев, Г.Насрый күчерелә. 1945 нең июнендә Германиядәге совет гаскәрләренең Төньяк төркеме органы була һәм «Җиңү байрагы» дигән яңа исем ала. 1947 нең февраленә кадәр чыга. Кызыл Йолдыз ордены б-н бүләкләнә (1945 нең июнендә).

Р.А.Айнетдинов.

ФРОНТОВИ́К ТАТАРЛАРГА́ ХАТ («Татар халкының фронтовик татарларга хаты»), Бөек Ватан сугышы фронтларында сугышкан татар сугышчыларына юлланган. Аны әзерләүдә татар мәдәниятенең күренекле вәкилләре К.Г.*Нәҗми*, Г.С.*Кашшаф*, Х.Х.*Ярми* катнаша. Рус теленә тәрҗемәне язучы К.А.Федин әдәби яктан эшкәртә. 1943 елның 5 мартында «Правда» г-тасында басылып чыга. Шулай ук Татгосиздат һәм Воениздат тарафыннан аерым брошюра рәвешендә нәшер ителә. Хат «...синең язмышыңның ху җасы булырга җыенган, синең якты хыялларыңны пычракка салып таптарга», «Идел-Йорт»ны — ирекле Ватанны хәрабәләргә, зиратка, төрмәгә әйләндерергә теләгән» дошманны аяусыз кырырга чакыра. Хатта руслар һәм татарларның тарихта уртак дошманга каршы беренче генә сугышы булмавы ассызыклана. 1558 — 83 еллардагы Ливон сугышы вакытында «немецларга каршы рус гаскәрлә-

ре б-н бергә күп кенә татар егетләре дә көрәшә... Кыюлыклары һәм куркусызлыклары б-н безнең бабаларыбыз немецларның котын ала». Бу сугышта да татарлар үзләрен Ватанны кыю һәм батыр саклаучылар буларак таныта. Хатта Сов. Союзы Геройлары И.М.*Маннанов*, С.Х.*Кәримов*, сугышларда танылган пулемётчы Ә.Җәләлиев, очучы Камалетдинов, солдат А.Хәлимов, старшина Курмаев һ.б. телгә алына. «Татар халкының өч меңнән артык улы Ватан сугышында Сов. Союзының орден һәм медальләре б-н бүләкләнүе» турында билгеләп үтелә. Хатта тыл хезмәтчәннәренең фронтка һәм Кызыл Армия сугышчыларына көчләреннән килгәнчә ярдәм күрсәтүләре, токарь Ф.Абдрахманов, фрезерлаучы Бирюков, колхозчылар Нуриев һәм Абдуллинның тырыш хезмәтләре б-н танылулары хакында әйтелә, «... Ватанга тирән мәхәббәт һәм дошманга нәфрәт хисләре б-н ... респ-ка колхозчылары ... танклар һәм самолётлар төзү өчен ку әгле фонд оештырырга дигән фикергә килделәр», — диелә. ТАССР колхозчылары шәхси акчаларыннан «Татарстан колхозчысы» танк колоннасы төзелешенә 100 млн. сумнан артык акча кертә. Сталинның ТАССР колхозчыларына һәм колхозчы хатын-кызларына сәламләвен һәм рәхмәтен алгач, респ-ка хезмәтчәннәре үзләренең шәхси акчаларыннан хәрби самолетлар эскадрильясы төзелешенә өстәмә 85 млн. сум акча җыеп тапшыра. Моннан тыш Бөек Ватан сугышы чорында оборона фондына 39 млн. сум акча җыйнала, фронтовикларга 24 млн. сумлык бүләкләр, 23 мең кыска тун, 54 мең пар киез итек, 56 мең телогрейка һәм җылы чалбар, 106 мең пар җылы эчке кием һәм бик күп башка җылы әйберләр җибәрелә. Тыл хезмәтчәннәре 1943 тә сугыш кораллары һәм кирәк-яраклары җитештерүне икеләтә арттыру һәм аларның югары сыйфатын тәэмин итү; икмәк, яшелчәләр, бәрәңге, ит һ.б.ны «өзлексез арта бару күләмендә» дәүләткә тапшыру йөкләмәсе алалар. Хат «Бүген сезнең б-н бергә, бабаларыбыз гадәтенчә, Идел-анабыз ярына басып һәм безне туендыручы җиребезне үбеп, ант итәбез: без кайсы гына фронтта булсак та, нинди генә корал-га каршы сугышсак та, Туган илебез өчен, аның намусы һәм азатлыгы өчен тормышыбызны да кызганмабыз! ...Туган җиребезне тулысынча азат итми торып, без кылычларыбызны кыныга тыкмабыз» дигән сүзләр б-н тәмамлана. Хатка 1 млн. 511 мең 137 кеше имза куя, алар арасында — А.Е.*Арбузов*, Г.*Болгарская*, С.Х.*Гафиятуллин*, Г.А.*Динмөхәммәтов*, Н.Г.*Жи һанов*, Г.Х.*Камай*, К.Г.*Нәҗми*, Э.Б.*Терегулов*, Т.К.*Гыйззәт*, Х.Х.*Ярми* һ.б.

Чыг.: Письмо татарского народа фронтовикам-татарам. К., 1943.

Әд.: Гильманов З.И. Татария в Великой Отечественной войне (1941–1945 гг). К., 1977; Айнутдинов А.К. Летопись подвига (Исторический очерк по страницам татарских фронтовых газет). К., 1984. *И.Р.Вәлиуллин.*

ФРУ́МКИН Александр Наумович (12.10.1896, Кишинёв ш. — 27.5.1976, Тула ш., Мәскәүдә җирләнә), физик химия белгече, СССР ФАнең академигы (1932), Соц. Хезмәт Герое (1965). 1915 елда Новороссия ун-тын (Одесса ш.) тәмамлый, шунда ук эшли. 1920 дән Одесса халык мәгарифе ин-тында, 1922–46 да Л.Я.Карпов исем. Физика-химия ин-тында (Мәскәү), проф. (1930). Бер үк вакытта, 1930 дан, Мәскәү ун-тында, электр химиясе каф. мөдире (1933–76); 1939–49 да СССР ФАнең Физик химия ин-ты (1945 кә кадәр Коллоидлар химиясе ин-ты) директоры. 1958–76 да СССР ФАнең Электр химиясе ин-тының (хәзер А.Н. Фрумкин исемен йөртә) оештыручысы һәм директоры. Электр химиясе процесслары тәгълиматын эшли: икеле электр катламын тикшерү алымнарын булдыра, Гиббс термодинамик тигезләмәсенең реаль адсорбцион күренешләргә туры килүен исбатлый, адсорбцияләнгән катлам-ның тигезләмәсен («Фрумкин изотермасы») чыгара. Металл өслегенең иң мөһим күрсәткечен — «нульле корылма потенциалы» төшенчәсен фәнгә кертә, 120 ел дәвамында фәни бәхәс объекты булып килгән электр химик чылбырларның электр этәргеч көче табигате турындагы Вольт мәсь әләсен чишә. Ф. илдә электр химиклары мәктәбенә нигез сала; аның идеяләре токның химик чыганаклары, техн. электролиз, флотация, полярография, гетероген катализ, коллоид химия һәм биоэлектр химиясе буенча язылган хезмәтләрдә файдаланыла. Бөек Ватан сугышы елларында (1941–45) Казанда эшли, радиацион химия өлкәсендә тикшеренүләрне һәм аларның нәтиҗәләрен хәрби максатлар өчен куллану эшләрен җитәкли, ш.у. радиоактив нурланышның атом реакторлары материалларына йогынтысын өйрәнә. «Электрохимия» ж-лының нигезләүчесе һәм мөхәррире. Электр химик термодинамика һәм кинетика буенча Халыкара ком-т президенты. Чит илләрдәге күп кенә фәннәр академияләре һәм фәнни җәмгыятьләрнең әгъзасы. В.И. Ленин исем. бүләккә (1931), СССР Дәүләт бүләгенә (1941, 1949, 1952) лаек була. Өч Ленин ордены, өч Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр, ш.и. Америка электр химиясе җәмгыяте медале б-н бүләкләнә. 2000 дә Халыкара электр химиясе җәмгыяте теоретик һәм гамәли электр химиясе өлкәсендә эшләүче яшь галимнәр өчен Ф. мемориаль медален гамәлгә куя.

Х е з м.: Электрокапиллярные явления и электродные потенциалы. Од., 1919; Потенциалы нулевого заряда. М., 1982; Электродные процессы: Избр. труды. М.. 1987; Перенапряжение водорода: Избр. труды. М., 1988.

Әд.: Александр Наумович Фрумкин: Материалы к биобиблиогр. учёных СССР. Сер. хим. наук. М., 1970. Вып. 44; Волков В.А., Вонский Е.В., Кузнецова Г.И. Выдающиеся химики мира: Биогр. справ. М., 1991; БСЭ. 3 изд. М., 1978. Т. 28.

ФРУ́НЗЕ Михаил Васильевич (21.1.1885, Семиречье (Җидесу) өлкәсенең Пишпек ш. — 31.10.1925, Мәскәү), дәүләт, партия, хәрби эшлекле. Гимназия тәмамлаганнан соң (Верный ш. (хәзер Алма-Ата), 1904), Петербург политехник ин-тында укый; революцион эшчәнлеге өчен С.-Петербургтан сөрелә. 1904 елдан С.-Петербургта, Иваново-Вознесенскида, Шуяда, Иркутскида, Читада, Мәскәүдә, Белоруссиядә революцион хәрәкәттә катнаша. 1918 дә РКП(б)ның Иваново-Вознесенск губерна ком-ты рәисе, башкарма ком-ты һәм губерна ХКС рәисе, Иваново-Вознесенск губернасы хәрби комиссары. 1918 нең августыннан Ярославль Хәрби округының хәрби комиссары. 1918 нең декабреннән 4 нче армия командующие, 1919 ның мартыннан Көнчыгыш фронт гаскәрләренең көньяк төркеме командующие. 1919 ның апрель-маенда Кызыл Армиянең контрһөҗүме вакытында Ф. җитәкчелегендә Богырыслан, Бөгелмә һәм Бәләбәй хәрби операцияләре уздырыла, Бөгелмә шәһәре тирәсендә А.В.*Колчакның* көнбатыш армияләренең төп көчләре тар-мар ителә. 1919 ның июленнән Көнчыгыш фронт гаскәрләре б-н җитәкчелек итә; акгвардиячеләрдән Төньяк һәм Урта Урал азат ителә. 1919 ның августы — 1920 нең сентябрендә Төркестан фронты, 1920 нең сентябрендә Көньяк фронт, 1920 нең декабреннән 1924 кә кадәр Украина һәм Кырым гаскәрләре командующие. Бер үк вакытта, 1922–24 тә, Украина ССР ХКС һәм Украина икътисад советы рәисе урынбасары. 1924 тән СССР РВС рәисе урынбасары һәм СССР хәрби һәм диңгез эшләре буенча халык комис-ты рәисе урынбасары; Эшче-Крәстияннәр Кызыл Армиясе штабы һәм Хәрби акад. башлыгы. 1925 тә СССР хәрби һәм диңгез эшләре буенча халык комиссары. 1921 дән РКП(б) ҮК әгъзасы. 1924 тән ҮК Политбюросы әгъзалыгына кандидат. Бөтенроссия ҮБК, СССР ҮБК Президиумы әгъзасы. 1924–25 елларда СССРда Хәрби реформа әзерләү һәм уздыру б-н җитәкчелек итә. Совет Хәрби көчләрен төзүгә өлеш кертә. Ике Кызыл Байрак ордены б-н бүләкләнә. Казан шәһәренең бер урамына Ф. исеме бирелә.



А.Н. Фрумкин.



М.В.Фрунзе.

Х е з м.: Собр.соч.: В 3 т. М.–Л., 1926–29; Избр. произведения: В 2 т. М., 1957; Избр. произведения. М., 1965.

Әд.: Б е л и ц к и й С.М. Фрунзе. М., 1930; М.В.Фрунзе: Жизнь и деятельность. М., 1962.

Е.Б.Долгов.

ФТИЗИАТРИ́Я (грек. phthísis — хәлсезләнү, чахотка һәм iatreia — дәвалау), клиник медицинаның туберкулёз авыруын кисәтү һәм дәвалауның нәтиҗәле ысулларын булдыру максатыннан авыруның этиологиясен, патогенезын, эпидемиологиясен, диагноз куюн һәм дәвалауны өйрәнүче бүлеге. 20 йөз башында Ф. мед. фәненең мөстәкыйль бүлегенә әверелә. Туберкулёз — бик күптәннән билгеле һәм киң таралган авыру. Бу авыруны дәвалау тасвирламасы һәм авыруны дәвалап терелтү мөмкинлеге турындагы беренче мәгълүматлар Гиппократ (б.э.к. 460–377 еллар)

һәм Әбүгалисина (980–1037) хезмәтләрендә очрый. Россиядә Ф.не нигезләүче булып диссеминацияләнүче инфильтратив һәм каверналы туберкулёзны тасвирлаган галим — Г.И.Сокольский санала («Күкрәк куышлыгы авырулары турында тәгълимат» — «Учение о грудных болезнях», М., 1838). Авыруларны дәвалау барышында ул туклану режимына һәм уңайлы климат шартларына зур әһәмият бирә. Н.И.Пироговның патоморфологик тикшеренүләре туберкулёз авыруы барышы турындагы белемнәрне киңәйтә, тикшеренүләрдә клиник-анатомик юнәлеш ныгып урнаша. Рус галимнәре А.И.Абрикосов, В.Г.Штефко, А.И.Струков, А.Н.Чистович һ.б.лар үз тикшеренүләре аркылы туберкулёзны өйрәнүгә зур өлеш кертәләр.

Казан ун-тында туберкулёзны өйрәнүгә багышланган тикшеренүләр 1814 елдан алып барыла. 1860 еллардан башлап земство хастаханәләре һәм амбулаторияләр оештырыла, туберкулёзга диагноз кую, авыруны дәвалау, ш.у. авыру һәм үлем турындагы беренче стат. мәгълүматларны фәнни нигездә анализлау өчен шартлар барлыкка килә. В.И.Алянскийның «Үпкә туберкулёзының сәбәпләрен эзләүгә карата кайбер фикерләр» («Некоторые мысли по поводу изыскания причин лёгочного туберкулёза», 1871) хезмәтендә бу патология аерым авыру буларак тәкъдим ителә. А.В.*Петров,* хайваннар өстендә тәҗрибәләр уздырып, Кох тарафыннан авыру китереп чыгаручы бактерияләр ачыкланганчы (1882) ук, туберкулёзның үзенчәлекле һәм йогышлы булуы турында фикер әйтә. Н.М.*Любимов* туберкулёз авыруы барышында эндотелиаль күзәнәкләрдән аерылып чыгып, гигант күзәнәкләр барлыкка килүне тасвирлый һәм «туберкулёз агуы»ның лимфа юллары буйлап таралуын ачыклый. 1890 да кулланылу ихтималы фәнни бәхәсләр тудырган туберкулин препараты тәкъдим ителә. А.М.Дохман һәм И.Н.Лангеның туберкулин реакциясе үзенчәлегенә кагылышлы фикерләре проф.С.С.*Зимницкийның* «Үпкә туберкулёзын бактериобиологик ысуллар белән ачыклау нигезләре» («Основы бактериобиологического распознавания туберкулёза легких», 1913), проф. В.М.*Аристовский*ның «Туберкулин реакциясе үзенчәлеге турында» («О специфичности туберкулиновой реакции», 1926) һәм М.И.*Мастбаум* хезмәтләрендә раслана. 20 йөз башыннан Казанда туберкулёз бактериемиясенә багышланган хезмәтләр дөнья күрә (А.А.Козлов, В.А.Беляев, А.Э.Леман). Туберкулёзга каршы көрәштә Рус халык сәламәтлеген саклау җәмгыятьләре зур роль уйный (1877 дә табибларнең 7 нче съездында нигезләнә), туберкулёзны өйрәнү өчен махсус комиссия төзелә. 1911 елның октябрендә Казанда Бөтенрос сия туберкулёзга каршы көрәш лигасының Казан бүлеге вакытлы идарәсе оештырыла.

1913 елда Казанда авыруларны түләүсез кабул итүче туберкулёз диспансеры ачыла (җитәкчесе А.И.*Фрезе*). Галимнәр тарафынан туберкулёзны операция юлы б-н дәвалау (В.Д.*Владимиров*, Н.И.*Студенский*, П.И.Тихов, Т.П.Краснобаев, И.А.Праксин, В.Л.*Боголюбов*), тире туберкулёзын дәвалау (И.М.*Гиммель*, В.Ф.*Бургсдорф*, М.С.*Пильнов*) ысулларын эшлиләр, туберкулёз авыруы барышында бавырдагы үзгәрешләр өйрәнелә (И.П.Гаузнер); кымыз һәм кефирны дәвалау чарасы буларак куллануның нәтиҗәлеле тикшерелә (Н.А.Толмачёв, Н.В.Сорокин, В.Д.Орлов, хәрби табибләр Д.А.Керрик, М.Н.Наумов) һ.б.

Мед. ф-тында туберкулёз курсын П.Н.Николаев, Б.А.*Вольтер* һәм Б.Л.*Мазур* алып бара. ГИДУВта балалар туберкулёзы мәсьәләләре Е.М.*Лепский* һәм М.И.Мастбаум тарафыннан өйрәнелә. Т.Д.Эпштейн һәм М.И.Ойфебах респ-кадагы туберкулёз учреждениеләре эшен оештыралар һәм туберкулёзга каршы көрәшне җитәклиләр. 1927 дә Казанда беренче тапкыр яңа туган балаларга туберкулёзга каршы вакцинация уздырыла. Массакүләм вакцинацияләү 1937 нең гыйнварында башлана. 1930 да «Сөяк-буын туберкулёзы булган авыруларны исәпкә алу һәм төркемнәргә аеру өчен күрсәтмәләр» («Инструкция для учёта и группировки больных костно-суставным туберкулёзом») эшләнә. 1932 дә ГИДУВта туберкулёз кафедрасы оештырыла, ТАССР фтизиатрлары җәмгыяте төзелә. Патофизиол., микробиол., туберкулёзны дәвалау һәм туберкулёзга каршы вакцинация юнәлешләрендәге лаб. һәм эксперименталь тикшеренүләр алып барыла. Н.К.Соколова травматик пневмоторакска дифференциаль диагноз кую критерийларын эшли (1939). М.Ю.Розенгартен үпкәгә ясалган операцияләрдән соңгы кайбер өзлегү очраклары һәм авыруларны операциягә әзерләү арасындагы бәйлелекне дәлилли (1965). Т.П.Басова-Жакова үпкә туберкулёзы очракларында ашкайнату трактына нейрогистологик тикшерүләр уздыра (1940). П.Д.Буев туберкулёз б-н зарарланган очрагында бугазның лимфатик системасын өйрәнә (1946). Н.И.Любина бөер туберкулёзына диагноз кую һәм авыруны дәвалау ысулларын эшли (1949). 1960 елларда Р.К.Алхан-Кемал, М.Г.Шром, В.И.Катеров, А.А.Кулагин, Г.Ф.Солтанкәтиева, М.А.Черкасова тарафыннан туберкулёз авыруына диагноз куюның бактериологик һәм биохимик ысуллары тикшерелә. Бөек Ватан сугышы елларында туберкулёзга каршы аеруча киеренке көрәш алып барыла. Сугышның беренче елында вакытлыча кыскартылуга дучар ителгән туберкулёз учреждениеләре челтәре алга таба кабат киңәйтелә башлый һәм 1944 ел башына сугышка кадәрге чордан күпкә артып китә (1940 та — 200 ятак-урын, 1944 тә — 668). 1950 гә туберкулёз б-н авыру 2 тапкырдан артыкка, бу авырудан үлем очраклары 4 тапкырга кими. 1961 дә Казан шәһәре буенча туберкулёзны кисәтү һәм дәвалауга караган чараларның комплекслы планы раслана (ш.и. мәҗбүри вакцинация һәм ревакцинация). Фтизиопульмонологиягә караган фәнни тикшеренүләр уздыруда, оештыру-методик һәм дәвалау-консультация эшендә, мед. кадрларын әзерләүдә Казан мед. академиясе һәм Казан мед. ун-ты кафедраларының роле зур була. Проф. Г.А.Смирнов (ГИДУВ, 1964 тән каф. мөдире) җитәкчелегендә Ф. һәм пульмонологиянең актуаль мәсь әләлрenә (туберкулёзга дифференциаль диагноз кую һәм дәвалау) багышланган тикшеренүләр алып барыла. 1971 дә С.Е.Марголин җитәкчелегендә дис - пансер бүлегенең пансионатлы яңа бинасы сафка баса (42 ятак-урын). Казан мед. ин-тында сиал к-талары һәм гиалуронидаза күрсәткечләре (В.Н.Стратопопов), гемокоагуляция (А.В.Шеметов), туберкулёз процессындагы катнаш инфекцияләр (Р.И.Слепова), димедролның кайбер йогышлы-токсик һәм аллергик реакцияләргә тәэсире (Е.И.Родионова), туберкулёз очрагында теш казналыгы системасы зарарлану (Л.М.*Демнер*) мәсь әләләре өйрәнелә. Дәвалау барышында атуберкулин антивирусы, бактериофаглар, «Рузам» препараты куллану тәкъдим ителә (Б.Л.Мазур). 1972 дә мед. ин-тында мөстәкыйль туберкулёз кафедрасы оештырыла (мөдире Ф.Т.*Краснопёров*). Казан фтизиатрлары яңа дәвалау чаралары булдыру һәм авыруларны комплекслы дәвалау барышында кулланылучы препаратларның нәтиҗәлелеген күтәрү өстендә эшлиләр. 1980 еллардан туберкулёз һәм специфик булмаган үпкә авырулары очракларында йөрәк-кан тамырлары системасы эшчәнлеге һәм сулыш алу механикасы тайпылышлары өйрәнелә. Ф.Т.Краснопёров гепаринның ялкынсынулар, экссудатлар, токсиннарга каршы эффектын, десенсибилизацияләү үзлеген дәлилли; туберкулёзга дифференциаль диагноз кую һәм авыруны дәвалауның төрле ысуллары эшләнә. Туберкулёзның L-формалы микобактерияләре өйрәнелә. Е.И.Родионова һәм З.Х.Кәримованың тома балавыз (прополис) препаратларын, бактериофагларны, рифампицин һәм этамбутолны дәвалау өчен куллану, шикәр диабеты һәм туберкулёз барышының үзенчәлекләре турындагы хезмәтләре дөнья күрә. А.Ю.Довгалюкның «Туберкулёз авыруы барышында бактерияләргә каршы аминогликозид төркеме антибиотиклары кулланылганда ишетү әгъзаларын тикшерү» («Исследование органов слуха при туберкулёзе и в процессе антибактериальной терапии с использованием антибиотиков аминогликозидной группы», 1983), И.М.Вайденерның «Үпкә туберкулёзы белән авыручыларда одонтоген чыганак һәм аны дәвалау» («Одонтогенный очаг и его устранение у больных туберкулёзом лёгких», 1989), М.Э.Гурылёваның «Сулыш әгъзалары туберкулёзы белән авыручыларның бавыр эшчәнлеге бозылу һәм аны димефосфон белән дәвалау» («Нарушения функций печени у больных туберкулёзом органов дыхания и их коррекция димефосфоном», 1994) хезмәтләрендә теоретик нигезләмәләр һәм практик киңәшләр бирелә. А.А.Визель (Казан мед. ун-тының туберкулёз каф. мөдире) туберкулёз б-н авыручының сулыш алу һәм кан әйләнеше физиологиясен өйрәнү ысулларын гамәлгә кертә (1989) һәм дәвалау өчен беренче булып үз илебездә эшләнгән димефосфон препаратын куллана. Е.М.Галковның «Фтизиохирургик дәвалау барышында карар кабул итү процессын автоматлаштыру нигезендә катлаулы оч-

ракларны кисәтү һәм авыруга диагноз кую ысулларын камилләштерү» («Совершенствование методов профилактики и диагностики осложнений на основе автоматизации процесса принятия решений во фтизиохирургической клинике», 1995) хезмәте туберкулёз авыруын хирургик ысуллар кулланып дәвалауга багышлана. Р.Ш.*Вәлиев* (Казан мед. академиясенең Ф. һәм пульмонология каф. мөдире, 1996) нерв-психика тайпылышларын өйрәнә, деструктив үпкә туберкулёзының төрле вариантлары барышының үзенчәлекләрен һәм хәзерге шартларда аларны дәвалауның нәтиҗәлелеген тасвирлый (2001). 2000 еллардан башлап, ТР галимнәре тарафыннан резистентлы Mikobacterium tuberculosis штаммнары китереп чыгарган туберкулёзны дәвалау ысуллары эшләнә (М.С.Филатов), туберкулёз проф. авыру буларак өйрәнелә (Г.А.Идиятуллин), туберкулёзга диагноз куюның генетик методологиясе тәкъдим ителә (Р.Ш.Вәлиев); Ф.дә сулыш алуның клиник физиологиясе (М.Ф.Яушев), ВИЧ-инфекцияле авырулардагы туберкулёз үзенчәлекләре тикшерелә (И.М.Хәертинова).

Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы (ВОЗ) тарафыннан 1993 тә туберкулёз глобаль проблема дип белдерелә, 1997 дән 24 март Бөтендөнья туберкулёзга каршы көрәш көне дип игълан ителә.

2016 елда респ-када туберкулёз б-н авырып китүчеләр саны (1427 кеше, ш.и. 613 ендә — ачык формалы туберкулёз) 2015 ел б-н чагыштырганда (1524 кеше) 6,6% ка, балалар һәм яшүсмерләр арасында 6,8% ка, туберкулёздан үлү очраклары 20,4% ка кими.

Әд.: В и з е л ь А.А. Лечение больных туберкулёзом органов дыхания., 1988; С м и р н о в Г.А., В а л и е в Р.Ш. О разделении деструктивного туберкулёза лёгких на группы по качественной и количественной характеристике с целью разработки дифференцированных методов лечения // Проблемы туберкулёза. 1999. № 5.

Р.Ш.Вәлиев, Д.Р.Нуретдинова.

ФУЖЕНКО́ВА Александра Васильевна (25.12.1929, Чаллы кантоны Яковлево а. — 23.7.2013, Казан), химик-органик, химия фән. д-ры (1990). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1953), шунда ук, А.М. Бутлеров исем. химия фәнни-тикшеренү ин-тында эшли (1997 елга кадәр), 1992–98 дә Казан химия мәктәбе музее директоры. Хезмәтләре фосфор органик кушылмалар химиясенә карый. Ф. өч валентлы к-талар эфирларының α, β-чикләүсез кетоннар, ш.и. циклопентадиененнар (циклоннар) б-н үзара тәэсирләшүен тикшерә. Фосфорлы к-таның тулы булмаган эфирларының циклик һәм антициклик төзелешле α, β-чикләүсез кетоннарның (α-ененннар) карбонил төркеме буенча кушылу мөмкинлеген күрсәтә. Карбонил төркеме яисә углерод-углерод бәйләнеше катнашындагы реакцияләрнең региоюнәлгәнлеген билгеләүче факторларны ачыклый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: О региоселективности присоединения диметилфосфита к α,β-непредельным кетонам // Журн. общей химии. 1978. Т. 48, № 3 (автордаш); Взаимодействие диметилфосфита и метилфенилфосфонита с трициклоном в присутствии оснований // Журн. общей химии. 1983. Т. 53, № 1 (автордаш); Взаимодействие триалкилфосфитов с циклопентадиенонами в присутствии протонодонорных реагентов. Реакции триметилфосфита и диметилфенилфосфонита с тетрациклоном в присутствии уксусной трифторуксусной кислот // Журн. общей химии. 1986. Т. 56, № 10 (автордаш).

Әд.: Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

ФУ́КИН Анатолий Иванович (25.7.1942; Питрәч р-ны Гильдеево а.), психолог, психол. фән. д-ры (1997), проф. (2000), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2004). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1969), шунда ук эшли. 1984 елдан Алабуга пед. ин-тының психол. каф. мөдире, 1991 дән Кама физкультура ин-тының гуманитар фәннәр каф. мөдире һәм проректоры (Чаллы ш.). 2001 дән Икътисад, идарә һәм хокук ин-тында (Казан), психол. ф-ты деканы (2007 гә кадәр). Бер үк вакытта, 2008 дән, Казан техник ун-тының инженерлык психологиясе һәм педагогикасы кафедрасында. Хезмәтләре хезмәт психологиясенә карый. Ф. тикшеренүләренең нәтиҗәсе КамАЗның двигательләр з-дында һәм «Теплоконтроль» з-дында гамәлгә кертелә.

Х е з м.: Дифференциальная психофизиология профессиональной деятельности. К., 2004; Психология конвейерного труда. М., 2004.

ФУКС Александра Андреевна (1788, башка мәгълүматлар буенча, 1805 тирәсе, Чабаксар ш. яисә Чабаксар өязе – 4.2.1853), язучы. Дворян Апехтиннар нәселеннән, К.Ф.*Фукс* хатыны. Казанда әдәби салон хуҗабикәсе, андагы кичәләрдә танылган Казан язучылары Г.Н.Городчанинов, Э.П.Перцов, И.А.Второв, Е.А.Боратынский һ.б. катнаша. Е.И.Пугачёв турында тарихи-документаль роман өчен материал җыю максаты б-н Казанга килгән Пушкин 1833 елның 7 сентябрендә Фукслар өендә була. «Заволжский муравей» ж-лында, «Казанские губернские ведомости» г-тасында мәкаләләрен бастыра. 1834 тә «Александра Фукс шигырьләре» («Стихотворения Александры Фукс») җыентыгы басылып чыга. Ф. лирикасы һәм поэмалары (шигъри повестьлары) романтик һәм иярү рухында язылганнар. Татарларның, чуашларның, чирмешләрнең, Идел буенда яшәгән башка халыкларның көнкүреше һәм гореф-гадәтләре турында «Казаннан Чабаксарга сәфәр» («Поездка из Казани в Чебоксары», 1834), «Казан шәһәренең барлыкка килүе: Татар риваятьләреннән алынган шигъри повесть» («Основание города Казани: Повесть в стихах, взятая из татарских преданий», 1836), «Александра Фуксның Казан губернасы чуашлары һәм чирмешләре турында язмалары» («Записки Александры Фукс о чувашах и черемисах Казанской губернии», 1840), «Кенәз кызы Хәбибә: Татар риваятьләреннән алынган шигъри повесть» («Княжна Хабиба: Повесть в стихах, взятая из татарских преданий», 1841) очерклары һәм матур әдәбият әсәрләре авторы.

Әд.: Г о л и ц и н Н.Н. Биографический словарь русских писательниц. СПб., 1889.

Л.Е.Бушканец.

ФУКС Карл Фёдорович (Fuchs Karl Fridrich) (6.9.1776, Германия, Нассау кенәзлеге, Герборн ш. — 24.4.1846, Казан), табиб, табигыять фәннәре белгече, төбәк тарихчысы, этнограф, медицина д-ры (1798), Казан ун-тының атказ. профессоры (1833). Герборн академиясен (1795), Гёттинген ун-тын (1797) тәмамлый, медицина д-ры дәрәҗәсен Марбург ун-тында ала. 1800 елдан С.-Петербургта; 1801 дә Россиянең көнчыгыш өлеше буйлап ботаника экспедициясендә катнаша. 1804 тә Кытайдагы рус илчелегенә табиб итеп алына һәм 1805 нең җәендә узып барышлый Казанда була. 1805 нең 4 сентябрендә Казан ун-тының табигыять фәннәре тарихы һәм ботаника кафедрасына ординар проф. итеп билгеләнә. Аның ботаника буенча лекцияләр программасына студентлар б-н Казан тирәсенә чыгып йөреп кайтулар да керә (бу турыда элекке студент С.Т.Аксаков «Күбәләкләр җыю» («Собирание бабочек») хикәясен яза, 1858). Ф. тарафыннан эшләнгән биол. мәгариф системасы ун-тта хәзергәчә гамәлдә. Аның акчасына ун-т каршында Казандагы беренче ботаника бакчасы оештырыла, парниклар һәм теплицалар төзелә; 1808 дә бакчада үләннәрнең — 178, куакларның — 46 һәм агачларның 22 төре исәпләнә. 1829 да Кабан күле буенда яңа бакча төзү б-н шөгыльләнә. Ф. Казан ун-тында табигыять фәннәренә нигез салучы булып исәпләнә. 1818 дә ул патология, терапия һәм клиника каф. мөдире итеп билгеләнә, Казан ун-тында дәвалау буенча белем бирүне башлап җибәрә, 1819 да ун-т клиникасын җитәкли. Аның башлангычы б-н авыруларны стетоскопик күзәтү ысулы кертелә. Ф.ның мед.-геогр. һәм мед.-стат. тикшеренүләре аны төбәк тарихчысы, галим буларак таныта. Ул 1812 дән «Казанские известия» г-тасында Казанда яшәүче халыкның сәламәтлеге хакында хәбәрләр бастыра. Россиядә беренче ләрдән булып һөнәри авыруларга багышланган тикшеренүләр үткәрә. «Урал тау сәнәгате эшчеләренең авырулары хакында» («De morbis incolarum montium Uralensium», 1824) хезмәтендә тау сәнәгате эшчеләре тормышының һәм хезмәтенең гаять авыр шартларын сурәтли (Германиядә яңадан бастырыла һәм «Россиянең медицина географиясе»нә әһәмиятле өлеш кертү буларак бәяләнә). Ф. мед. этнографиясен барлыкка китерүче дә, беренче булып игътибарны төрле халыкларның көнкүреше һәм яшәү рәвешендә авырулар килеп чыгуга сәбәпче булган үзенчәлекләргә җәлеп итә. Россиядә беренче холера (ваба) эпидемиясе вакытында (1829–31) әлеге авыруны дәвалау ысулларын эшли, терапиясенә мөһим төзәтмәләр кертә. Ф. — илдә бальнеология фәнен башлап җибәрүчеләрнең берсе: 1811 дә ул беренчеләрдән булып Сергиевск минераль сулары үзлекләрен һәм авыруларны дәвалаганда аларны куллану алымнарын җентекләп тасвирлый. Факультет деканы итеп сайлана, ректор була (1823–27, бүленеп). 1833 тә отставкага чыга, мед. практика-



К.Ф.Фукс.

сы, фәнни эшчәнлек б-н шөгыльләнә. «*Казан шәһәренең кыскача тарихы*» («Краткая история города Казани») китабы авторы. Ф.ны Казан татарларының көнкүрешен һәм мәдәниятен беренче булып өйрәнүче дип саныйлар. 1814 тә этнографиягә караган мәкаләләрен бастыра башлый, «Казан татарлары статистик һәм этнографик нисбәттән» («Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях», 1844) китабы күпьеллык тикшеренүләренең нәтиҗәсе булып тора. Ф. — Казан журналистикасына нигез салучы. 1811 дән аның турыдан-туры катнашында беренче җирле «Казанские известия» г-тасы бастырыла башлый. 1828 дән «Прибавление к Казанскому вестнику» г-тасының актив авторы була. Бу матбугат басмасында аның сәнәгать пр-тиеләре, алар җитештергән товарларның ассортименты һәм характеры турында тулы мәгълүмат бирелгән «Казан губернасындагы барлык фабрика һәм заводларга статистик күзәтүләр» («Статистические обозрения всех в Казанской губернии находящихся фабрик и заводов») мәкаләсе басыла. 1830–40 елларда Ф. һәм аның хатыны Александра Андреевна йорты шәһәрнең фәнни һәм әдәби тормыш үзәге булып тора (1821 дә Ф. Казан шагыйрәсе А.А.Апехтинага өйләнә; к. *Фукс Александра Андреевна*). Әдәби кичәләрдә шул заманның күп кенә күренекле шәхесләре — Е.А.Боратынский, Э.П.Перцов, Н.И.Лобачевский һ.б. катнаша. 1833 тә Фукслар йортында А.С.Пушкин да була. С.-Петербург Медик-филантроплар ком-ты (1804), Мәскәү табигатьне өйрәнүчеләр җәмгыяте (1807), С.-Петербург Фармацевтлар җәмгыяте (1819) һ.б. әгъзасы. Аның укучылары арасында С.Т.Аксаков, В.И.Тимьянский, Н.А.Скандовский, Н.И.Второв бар. 2 нче дәрәҗә Изге Анна, шул ук орденга тәгаенләнгән алмаз бизәнү әйберләре, 4 нче дәрәҗә Изге Владимир орденнары б-н бүләкләнә. Казанда бер урам һәм Казансу елгасы буендагы сквер (шунда аңа һәйкәл куела, 1996) Ф. исемен йөртә.

Әд.: Лаврский К.В., Пономарёв П.А. К.Ф.Фукс и его время // Казанский литературный сборник. К., 1878; Гарзавина А.В. В Казань, профессору К.Ф.Фуксу... К., 1987; Памяти профессора К.Ф.Фукса. К., 1996; Карл Фукс о Казани, Казанском крае: Труды. Документы, Воспоминания. Исследования. К., 2005.

А.В.Гарзавина.

ФУКС К.Ф. ШӘХСИ́ КИТАПХАНӘСЕ́, Казан ун-ты профессоры К.Ф.*Фукс*ның нумизматика, минералогия, этнографиягә караган төрле коллекцияләренең төп өлешен тәшкил итә. Фәнни максатларга хезмәт итә һәм сирәк басмаларга бай булуы б-н әһәмиятле. Анда Россия тарихы, топографиясе һәм этнографиясенә караган, ш.и. чит телдәге китаплар, К.Ф.Фукс тарафыннан фәнни эйләнешкә кертелгән татар кулъязмаларының кыйммәтле коллекциясе; иске дин тарафдарларына караган кулъязма һәм басма китаплар (К.Ф.Фукснының хатыны танылган иске дин тарафдарлары Крохиннар нәселеннән булганлыктан, иске дин тарафдарлары мондый китапларны К.Ф.Фукска үзләре китереп бирә торган була, шулай итеп бу китаплар юка чыгарылудан котылып кала); елъязма күчермәләре, ш.и. «Зөя шәһәренең писцовый кенәгәсе»ннән күчермәләрнең берсе сакланa. Китапханәнең раритетларына түбәндәгеләр керә: В.Гогарт гравюраларының бай җыелмасы (Лондон, 1820–22), Бюффонның рәсемле «Табигый тарих» («Естественная история») әсәре, «Острог библиясе» («Острожская библия», Острог ш., 1580–81).

К.Ф.Фукс китапханәсе б-н М.М.Сперанский, А.Гумбольдт, А.С.Пушкин, Е.А.Боратынский, А.Гакстгаузен, М.Кастрен һ.б. танышкан.

Китапханә К.Ф.Фуксның йортында сакланa. Үзенең вафатыннан соң йорты һәм күпсанлы коллекцияләре сатылу сәбәпле, китапханәдәге китапларның төгәл саны билгеле түгел, каталогы да юк. 1820 һәм 1833–34 елларда К.Ф.Фукс Казан ун-тының Фәнни китапханәсенә зоология, ботаника, медицина, фәлсәфә, тарих буенча 40 китап тапшыра (нигездә, чит телләрдә, күпчелеге немец телендә).

Әд.: Лаврский К.В., Пономарёв П.А. Карл Фёдорович Фукс и его время // Казанский литературный сборник. К., 1878.

ФУКС КАРЛ ФЁДОРОВИЧ ҺӘЙКӘЛЕ́, Казанда. 1996 елның 11 декабрендә Казан ун-тының атказ. профессоры, медицина д-ры, төбәк тарихчысы һәм хәйрияче К.Фуксның тууына 220 ел һәм үлүенә 150 ел тулу уңаеннан ачыла. Һәйкәл Казандагы К.Фукс исем. немец җәмгыяте һәм Казан ун-ты башлангычы б-н куела. «Казан» милли мәдәният үзәге бинасыннан ерак түгел, Казансу елгасы яры янында, Фукс исемен йөрткән скверда урнаштырылган. Авторлары — Мәскәү скульпторлары А.В.Балашов һәм И.А.Козлов, архитекторы Р.М.Нургалиева.



Казанда К.Ф.Фукс һәйкәле. Бронза. Скульпторлары А.В.Балашов, И.А.Козлов. Архитекторы Р.М.Нургалиева. 1996.

К.Ф.Фукс бөтен буена, яланбаш гәүдәләнә-дерелгән, уң кулына эшләпә тоткан, сул куллы б-н таякка таянган. Бронза скульптура югары сәнгати дәрәҗәдә башкарылган. К.Ф.Фукс йөзендәге елмаю мәрхәмәтле, яратучы кеше образы тудыра. Постаменты таш кирпечтән эшләнгән. Һәйкәл ачылышында Германиядән килгән кунаклар, Германия Федератив Респ-касы илчесе Эрнест-Йорг фон Штуднитц һ.б. була.

А.В.Гарзавина.

ФУ́РЕР Виктор Львович (20.8.1949, Казан), физик химия белгече, химия фән. д-ры (1993), проф. (1995). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1971), Казан архит-ра-төзелеш ун-тында эшли, физика каф. профессоры (1993–2014), 2014 тән физика, электроника һәм автоматика каф. профессоры, 2016 дан мөдире. Хезмәтләре полимерлар һәм дендримерларның тирбәнешле спектроскопиясенә карый. Спектроскопия һәм квант химиясе ысуллары б-н фосфорлы дендримерларның спектраль күрсәткечләренең төзелешен һәм закончалыкларын билгели.

Хезм.: Расчёт спектров комбинационного рассеяния ориентированных макромолекул // Высокомолекулярные соединения. Сер. А. 1997. Т. 39, № 6; Расчёт ИК-спектров ориентированных макромолекул // шунда ук. С. 990–992; Синтез и сравнительная характеристика фосфорсодержащих дендримеров с фенокси- или дейтерофенокситерминальными группами // Рос. хим. журн. 2008. Т. 102, № 1 (автордаш).

ФУ́РМАН Михаил Владимирович (24.3.1939, Молдавия ССРның Каменск р-ны Рашков а.), төзүче инженер, ТР Дәүләт бүләгеләуреаты (2000), ТССРның атказ. төзүчесе (1991). Казан төзүчеләр ин-тын тәмамлаганнан соң (1962), «Башнефтепромстрой»ның 3 нче төзелеш идарәсе трестында мастер, җитештерү-техник бүлек башлыгы булып эшли. 1966–2004 елларда Казан «Инвестжилстрой сервис» йортлар төзелеше комб-тында: җитештерү-техник бүлек инженеры, 7 нче, 5 нче төзү-монтаж идарәләрендә баш инженер, җитештерү-диспетчерлык бүлеге башлыгы, комб-тның баш инженеры (1996 дан). Дәүләт бүләге торак, җәмәгать, сәнәгать биналары һәм корылмаларының нәтиҗәле системаларын булдыруда һәм гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә. ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

ФУ́РМАНОВ Юрий Александрович (3.2.1932, Украина ССРның Херсон ш.), инженер-механик, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1984). Запорожье машина төзелеше ин-тын тәмамлый (1966). 1949 елдан Украина ССРның сәнәгать пр-тиеләрендә: Кременчуг ш. (Полтава өлкәсе), 1966 дан «Коммунар» автомобиль з-дында (Запорожье өлкәсе). 1977–86 да «КамАЗ» ҖБнең пресс-рам з-ды баш инженеры. 1986 дан Львов шәһәрендә яши (Украина). Дәүләт бүләге югары нәтиҗәле авыр уникаль механик прессларны һәм автомат линияләр һәм комплексларны булдыруда һәм җитештерүгә кертүдә катнашканы өчен бирелә. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: Казаков Б. Так нам сердце велело. Наб. Челны, 1996; шул ук. Твоя строка в историю. Наб. Челны, 2001; Энциклопедия города Набережные Челны. К., 2007.

ФУРШТА́ТОВ Леонид Никифорович (18.6.1941, Чистай р-ны Изгар а.), нефтьче, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1986), ТРның атказ. нефтьчесе (1992). Хезмәт эшчәнлеген

1957 елда Чистай р-ныны «Алга» с-зында төрле эшләр башкаручы булып башлый. 1964–98 дә «Татнефть» АҖнең Елховнефть НГДУында скважиналарны җир астында ремонтлау операторы. 2 нче, 3 нче дәрәҗә «Хезмәт Даны» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

ФУТБО́Л, туп б-н командалы спорт уены. Татарстан терр-ясендә 20 йөз башыннан җәелдерелә. Ф. буенча Казан губерна һәм Казан шәһәре беренчелеге 1919 елдан, Татарстан Кубогына чемпионатлар һәм ярышлар 1950 еллардан уздырыла. Татарстанда Ф. 2000 еллар башыннан тизләнешле үсеш ала. ТРның әйдәп баручы командалары: «*Рубин*» Ф. командасы (Казан) — 2003 тән Премьер-лигада, Россия чемпионатларында жиңүче (приз иясе) (2008, 2009; 2003 һәм 2010 — бронза), Россия суперкубогы (2011/12) һәм Дуслык кубогы (2010) иясе, УЕФА кубогы (2004), Чемпионнар лигасы дебютанты (2009, 2010); УЕФА чемпионнар лигасы (2009, 2010, 2013), УЕФА Европа (2012/2013) төркемле этабында катнашучы, «КАМАЗ» Ф. командасы (Чаллы) — 2004 тән Россия чемпионатының 1 нче дивизионда, «Нефтехимик» Ф. командасы (Түбән Кама) — 2004 тән 2 нче дивизионда; «Рубин-2» Ф. командасы (Казан) — 2003–2004 тә 2 нче дивизионда. «КНИТУ-КАИ» (2010 да оеш тырыла) — ТР Студентлар Ф. лигасы беренчелеге һәм чемпионаты жиңүчесе (2010, 2012), Милли студентлар Ф. лигасы кубогы иясе (2011), югары уку йортлары командалары арасында бөтенроссия беренчелегендә көмеш медаль алучы (2015). 2009 да ТР Ф. федерациясе каршында Ф. арбитры мәктәбе, «Рубин» Ф. клубы каршында — Яшь футболчылар әзерләү үзәге ачыла. 2018 гә Татарстанда 43 стадион (ш.и. трибуналы, 1500 урынлы; Казанда 1 ябык Ф.-җи ңел атлетика манежы; 22 ясалма ябылган Ф. кыры) бар. 2013 тә Казанда 45 мең тамашачы сыешлы Ф. стадионы («Казан Арена») файдаланугa тапшырыла. Анда «Универсиада-2013» 27 нче Бөтендөнья җәйге студентлар уеннарының ачылу һәм ябылу тантаналары, Спортның су төрләре буенча 16 нчы Дөнья чемпионаты-ның йөзү һәм синхрон йөзү буенча ярышлар (2015), «Конфедерацияләр кубогы — 2017» Ф. турниры уеннары, 2018 дә ФИФА 21 нче дөнья чемпионатының төркем турниры (Франция–Австралия, Иран–Испания, Польша–Колумбия, Корея Респ-касы–Германия), 1/8 финал (Франция–Аргентина), 1/4 финал (Бразилия–Бельгия) матчлары уза, аларны стадионда барлыгы 254448 кеше (һәр матчны уртача 42409 кеше) карый.



УЕФАның Европа лигасы матчы «Рубин» (Казан) – «Интер» (Милан). Казан. Үзәк стадион. 2012.

Респ-када Ф. б-н 49,4 мең кеше шөгыльләнә, ш.и. 7050 бала һәм яшүсмер, шуларның 590 ы кыз балалар. 49 спорт-Ф. мәктәбе һәм Ф. бүлеге, 233 тренер-укытучы эшли. 46 стадион, 1 футбол-җиңел атлетика манежы, 42 ясалма өслекле Ф. кыры бар (2017). Татарстанда туган иң яхшы футболчылар — Г.Е.Еврюжихин, В.М.Колотов, Р.К.Нигъмәтуллин, Н.В.Осянин. Татарстанда Ф. буенча иң яхшы тренерлар — К.Б.Бердыев, Г.С.Зонин, Н.И.Сентябрёв. 2011 дән ТР Ф. федерациясе президенты — А.П.Гусев.

Н.Д.Бобырев.

ФУТУРИ́ЗМ (лат. futurum — киләчәк) 20 йөз авангард сәнгатендәге агымнарның берсе. Аны Италия шагыйре Ф. Маринетти нигезли. Ф. традицион сәнгатьтән демонстратив рәвештә аерылуын игълан итә. Аның матур әдәбияттагы актив һәм агрессив-сугышчан шәхес концепциясе урбанизация, индустрияләштерү процессларын идеаллаштыруга, матди байлыкларның өстенлеген пропагандалауга, куркыныч хәлләргә, көрәшкә, фетнәгә, хәтта сугышларга дан җырлауга китерә. Россиядә Италия футуристларының эстетик идеяләре бертуган Д.Д. һәм Н.Д.Бурлюклар, М.Ф.Ларионов, Н.С.Гончарова һ.б. рәссамнарның эзләнүләрендә яңгыраш таба. Рус әдәбиятында Ф. терминын беренче тапкыр 1911 елда И.Северянин куллана.

Татар матбугатында Ф. турындагы беренче мәкаләләр 1910 елларда «Йолдыз» г-тасында дөнья күрә: Ф.Сәйфи-Казанлының «Футуризм», Н.Думавиның «Бер мөляхәзә» («Бер фикер»), Ж.Вәлидинең «Шәрекътән Гаребкә», Н.Думавиның «Шәрекътән Гаребкә мөнәсәбәте белән», Саматның «Зәңгәр кош, яисә Безнең көннәр» язмалары һ.б. Аларда авторлар татар әдәбиятына карата Ф. концепциясе турында фикер алышалар: футуристик эзләнүләрне, көндәлек күренешләрне идеаллаштыруны кабул итмиләр, милли поэзия өчен аларны «ят» дип исәплиләр. Татар әдәбиятында Ф. әдәби күренеш буларак 1920 елларда, башлыча, рус әдәбияты йогынтысында формалаша. Форма өлкәсендә эзләнүләр алып барган Г.Кутуйның «Көннәр йөгергәндә» (1925) шигъри җыентыгында Ф. шигъри иҗатының яңа юнәлешен билгели. Аның «Күптән шулай», «Җан сатам», «Мин — шәһәрләр кияве», «Сул марш», «Тимер чәчәкләрдән» шигырьләре әлеге әдәби юнәлешнең иң якты үрнәкләре булып тора. Кайбер шигырьләрендә Г.Кутуй аһәңдәшлек мөмкинлекләреннән файдалана («Май»), шәһәр тавышларын («Биш минутка дөнья туктады») һәм хезмәт ритмын («Балта остасы») иҗат итә, саннар уйната («Эшче кызы Дилләр»), шигърияткә төрле аваз ияртемнәре кертә. 20 йөз башы татар әдәбиятына хас цитаталар кулланулы, сүз уйнатулы «Татар шагыйрьләренең кулак базына» шигырендә файдалана.

Традициянең капма-каршы чагылышы булган деэстетизация күренеше К.Нәҗми-нең «Ләш җәрәгән читекләр» (1924) футуристик сатирик поэмасында чагылыш таба. Х.Туфан иҗатының башлангыч чорында сүзнең тамыры һәм мәгънәсе сакланган хәлдә яңа футуристик сүзләр ясау юлларын эзли. Әлеге эзләнүләр озак дәвам итми. 1930 еллар башында татар әдәбиятында Ф. юкка чыга, әмма яңа сүзләр ясау өлкәсендәге эзләнүләр 20 йөз татар поэзиясенә йогынты ясый, аны яңа мөмкинлекләр б-н баета.

Әд.: Нигъмәти Г. Әдәбият мәйданында. М., 1925; Сәгъди Г. Символизм турында. М., 1932; Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. К., 2007.

Д.Ф.Закидуллина.

Х

ХАБА́РОВ Андрей Александрович (15.5.1919, хәзер Түбән Новгород өлкәсенең Кормыш р-ны Вороніха а. — 5.5.1998, Казан), ташчы-монтажчы, Соц. Хезмәт Герое (1958). 1936–80 елларда Казан йортлар төзү комб-тында эшли: ташчы (1939 дан), монтажчы (1962 дән), монтажчылар бригадиры (1964 тән). 1971–80 дә Х. җитәкләгән бригада берничә тапкыр «СССР Сәнәгать төзелеше министрлыгының иң яхшы бригадасы» исеменә лаек була. Герой исеме төзелештә югары нәтиҗәләргә ирешкәне өчен бирелә. КПССның 21 съезды делегаты (1959). Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: Кузьмин В. Хабаров Андрей Александрович // Герои Социалистического Труда Татарии (1938–78 гг.): Док. очерки. К., 1980. Кн. 1; Ислямов И.И. Созидатели. К., 1983; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

ХАБА́РОВСК КРАЕ́, РФ субъекты, Ерак Көнчыгышта урнашкан. Терр-ясен Охот һәм Япон диңгезләре юа. 1938 елның 20 октябрендә оештырыла. Мәйданы — 787,6 мең *км*². Үзәге — Хабаровск шәһәре. Халкы — 1328302 кеше (2018). Татарлар саны: 1989 да — 16092, 2002 дә — 10972, 2010 да — 7836 кеше. Х.к.нда татарлар 19 йөз ахырыннан яшиләр. 1917 гә кадәр Хабаровскида мәчет (совет чорында җимертелә) эшли. 1930 елларда күп кенә татарлар, ш.и. Казан югары уку йортларын тәмамлаучылар, Комсомольск-на-Амуре шәһәре төзелешендә, авиация, металлургия, судноләр һәм нефть эшкәртү з-дларында катнаша. 1930 еллар ахырында шәһәрдә татар посёлогы барлыкка килә; 1940 елларда «Амурсталь» з-ды каршындагы мәктәптә укыту татар телендә бара. Х.к.нда Татарларның Ерак Көнчыгыш конгрессының (2009 дан) «Хәбәр» (Хабаровск, 2002 дән), «Сабантуй» (Комсомольск-на-Амуре, 1998 дән) милли-мәдәни автономияләре; Хабаровскида Бизнес-клуб, Татар яшьләр үзәге, татар мәктәбе, «Чулпан» бию ансамбле, Россия мөселманнары Үзәк диния нәзарәтенең Ерак Көнчыгыш бүлеге, «Мәхәллә — «әл-Фуркан» мөселман оешмасы (2008 дән, «Минарет Ислама» г-тасын чыгара), мәчет (2008 дән) һәм мәдрәсә (2009 дан), Комсомольск-на-Амуре шәһәрендә татар мәктәбе, мөселман гыйбадәтханәсе эшли. *Корбан бәйрәме*, *Ураза бәйрәме* (Хабаровскида, Комсомольск-на-Амуре, Чегдомын, Бикинда), *Сабан туе* (2002 дән Хабаровскида, 2006 дан Комсомольск-на-Амуреда) бәйрәм ителә. Тарих фән. д-ры З.Ш.*Янгузов*, инженер-механик Т.Ф.*Сәфинең* тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге Х.к. б-н бәйле.

ХАҖ (гарәп. حج), борынгы гыйбадәтханә *Кәгъбәдә* табыну йоласын үтәү максатында мөселманнарның төп дини үзәгенә — ислам -



А.А. Хабаров.



В.Х. Хаҗиәхмәтов.

ны нигезләүче Мөхәммәд пәйгамбәр туган Мәккә шәһәренә (Согуд Гарәбстаны) бару. Х. — мөселманга фарыз булган биш гамәлнең (иман китерү, намаз, ураза, зәкят, хаж) берсе. Х. кылу традициясе Кәгъбәне төзегән һәм кешелек дөньясы тарихында беренче мәртәбә Х. кылган Адәм һәм Һауага барып тоташа дип исәпләнелә. Мөселман ай календаре буенча зөлхиҗә аенда башкарыла һәм, мөселман риваятьләренә күрә, Мөхәммәд пәйгамбәр 632 елда «хушлашу» Х.ы вакытында билгеләгән йолалардан тора. Х. кылучылар зөл-хиҗә аеның сигезенче көненнән башлап Мәккәдәге әл-Харам мәчетендә Мина һәм Мөздәлифә үзәнлекләрендә, Гарәфә тавында булалар. Х.ның барлык гыйбадәтләре зөл-хиҗә аеның уныченче көнендә тәмамлана. Х. кылу традициясе татарларның ата-бабаларына Идел буе Болгары чорыннан ук билгеле, ул 1552 дә Казан ханлыгы җимерелгәннән соң да дәвам иттерелә. Ләкин 1917 елгы Окт. рев-циясеннән 1980 еллар ахырына кадәр СССР гражданнарына чит илгә чыгу чикләнә, 1990 нан РФ мөселманнарына Х. гамәлләрен кылу мәсь әләләрен хәл итүдә дини оешмалар, мөселман җәмгыятьләре, ш. и. ТР Диния нәзарәте каршындагы «Идел-Хаҗ» Төбәкара Х. кылу үзәге катнашында тулы иркенлек барлыкка килә. Х. мөселман илләрендә мөселманнар арасында исламны нығытуда зур роль уйный, бөтендөнья мөселманнарын берләштерүнең үзенчәлекле бер мөһим формасы. 2018 елда РФ дән — 22500, ТР дан 1800 кеше Х. кылырга бара.

Әд.: Путеводитель паломника. К., 2005; Якупов В.М. Хадж и умра: Путеводитель по Мекке и Медине. К., 2017; Хадж российских мусульман: Сб. путевых заметок. Н.Новгород, 2008.

ХА ҖИӘХМӘ́ТОВ Вагыйзь Ха җи әхмәт улы (15.5.1916, Самара губ., Бөгелмә өязе, хәзер Азнакай р-ны Сарлы а. — 1.12.2003, шунда ук), а.х. җитештерүен оештыручы, Соц. Хезмәт Герое (1966). Хезмәт эшчәнлеген 1930 елда туган авылында башлый, тракторчы булып эшли (1936 дан). 1946–51, 1972–82 дә Сарлы авыл советы рәисе, 1951–72 дә Азнакай р-нының «Алга» к-зы рәисе. Х. җитәкче - легендә колхозда а.х. культураларының югары уңышына ирешелә, терлекчелектә продуктлылык арта; хуҗалык исәбе гамәлгә кертелә, көчле матди-техник база, социаль-мәдәни инфраструктура булдырыла. Герой исеме бөртекле ашлык һәм терлек азыгы культураларын җитештерүне һәм әзерләүне артты - руда ирешелгән уңышлары һәм техниканы югары нәтиҗәле файдаланганы өчен бирелә. Ленин ордены, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш һәм бронза медальләре б-н бүләкләнә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Х. бюсты Азнакай шәһәренең Геройлар аллеясында куела.

Әд.: Белокопытов С. Хазиахметов Вагиз Хазиахметович // Герои Социалистического Труда Татарии (1938–1978 гг.): Док. очерки. К., 1980. Кн. 1; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003; Хакимов М.С., Сафаров М.А. Татары: Воины, труженики, патриоты: Биогр. справ. М., 2006.

ХАҖИӘХМӘ́ТОВ Ришат Нуриәхмәт улы (15.10.1939, Казан), режиссёр, педагог, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2000). Казан театр уч-щесен (1965, педагоглары А.Д.Гусев, Е.А.Простов) һәм Мәскәүдәге Дәүләт театр сәнгате ин-тының (ГИТИС) режиссёрлык ф-тын (1970) тәмамлый. 1970 елдан Татар акад. театрында режиссёр, бер үк вакытта Казан театр уч-щесендә укыта, 1979 дан Казан мәдәният ин-тында эшли. Үзенең иҗат практикасында Х. психол. реализм принципларына, сәхнә хәрәкәтенең логик эзлеклелегенә катгый таяна; актёрлар б-н эшне Станиславский системасы буенча алып бара. Х.ның «Борчылма, әни!» («Не беспокойся, мама!», Н.Думбадзе, 1971), «Ешрак елмаегыз» («Сослуживцы», Э.В.Брагинский, Э.А.Рязанов, 1973), «Канлы күләгәләр» («Интервью в Буэнос-Айресе», Г.А.Боровик, 1975), «13 нче председатель» («Тринадцатый председатель», А.Абдуллин, 1980) спектакльләрен сәхнәгә куйганда әлеге принципларга нигезләнеп эш итүе аеруча ачык сизелә. Чит ил классикасыннан «Фигароның өйләнүе» («Женитьба Фигаро», П.Бомарше, 1970), «Хатыннар гайбәте» («Бабьи сплетни», К.Гольдони, 1977) әсәрләрен сәхнәләштерә. Татар драма һәм комедия театрында, Әлмәт татар драма театрында, Казан яшь тамашачылар театрында спектакльләр куя.

ХАҖИ ӘХМӘ́ТОВ Тавил Гыйният улы (3.2.1936, Саба р-ны Йосыф-Алан а. — 25.5.2007, Казан), график, нәкышьче, театр рәссамы, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1978), ТАССРның халык рәссамы (1984). Казан сынлы сәнгать уч-щесен (1957), И.Е.Репин исем. Ленинград сәнгать, скульптура һәм архит-ра ин-тын (проф. М.А.Тара -

нов остаханәсе, 1963) тәмамлый. «Яшь ленинчы» (1963–67) г-тасында, «Ялкын» (1980–2005) ж-лында рәссам булып эшли. 1981–84 елларда Казан сынлы сәнгать уч-щесендә укыта. Татарстан китап нәшрияты б-н хезмәттәшлек итә (1961 елдан), 1993–99 да «Раннур» нәшриятында рәссам. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1971).

Үзенчәлекле талантка ия рәссам, графика өлкәсендә әйдәп баручыларның берсе. Х.ның иҗаты татар халык сәнгате б-н тыгыз бәйләнгән. Аның картиналары образларның гадилеге, орнаменталь стилистика һәм төсләр ачыклыгы б-н аерылып тора. Тематик эстамп, басма графика остасы — агачка гравюра төшерүне, офортны, линогравюраны, ксилографияне, литографияне үзләштерә. Х.ка танылу китергән эшләренең беренчесе агачка төшерелгән «Кранчы Гөлсинә» гравюрасы (1964). Шул ук ысул б-н татар халкының тарихына, фольклорына багышланган «Халык әйтсә — хак әйтә» (1969) циклы, «Йосыф–Зөләйха» (1964–71), «Татар кызлары биюе» (1970) сериясе, татар табышмаклары мотивлары буенча «Хезмәт Батыр» (1975), «Халык әкиятләре театры» (1999) сериясе һ.б. иҗат итә. Татар балалар китабын бизәүдә дә милли образлылыкны алга куя: Татарстан китап нәшриятында басылган Г.Тукай шигырьләреннән «Эш беткәч уйнарга ярый» (1971), «Күңелле Сабантуй» (1973) альбомы, Н.Исәнбәтнең «Мыраужан батыр» һәм «Татар халык әкиятләре», Ш.Галиевнең «Серле көзге» (барысы да — 1974 тә), К.Насыйриның «Әбүгалисина» (1975), «Татар халык әкиятләре» (1989), «Бишек җырлары» (1990) һ.б.; «Әлифба» («Мәгариф» нәшрияты), дөнья халыклары әкиятләре буенча 6 балалар комиксы китабы («Раннур» нәшрияты) һ.б. Татар прозасы һәм шигъри әсәрләренә ясаган иллюстрацияләре ш.у. зур казаныш булып тора: Г.Ибраһимовның «Безнең көннәр» (1963) романы, М.Җәлилнең кече форматта сувенир итеп эшләнгән «Моабит дәфтәрләре» (1975; Бөтенроссия китаплар конкурсы дипломы) һәм «Җырларым» (1976; СССР халыклары телләрендә) китаплары, М.Фәйзинең «Галиябану» драмасы (1981), Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы (1983) һ.б. Г.Камал исем. Татар акад. театры (Н.Фәттахның «Кол Гали» (1973); Т.Миңнуллинның «Бәхтияр Канкаев», «Ител суы ака торур» (икесе дә — 1975) әсәрләре), Казан курчак театры (Г.Тукайның «Кәҗә белән Сарык» әкияте, 1976) спектакльләренә костюм эскизлары; портретлар — «Галия Әдһәмова» (1973), «Татар шагыйре Равил Фәйзуллин» (1974) ясый. Х. — ТР Дәүләт флагы авторы (1991), аның «Кышкы кич» әсәре буенча Казан метрополитенының «Г.Тукай» станциясендә мозаика эшләнә.



Т.Г.Хаҗиәхмәтов.



В.Х.Хаҗиев.



Г.М.Хаҗиев.

Респ-ка күргәзмәләрендә (1958 дән), «Совет Татарстаны» (Ленинград, 1972–73), Татарстан рәссамнары әсәрләре (Мәскәү, 1980–81), «Зур Идел» (1964 тән), 1 нче Бөтенроссия китап графикасы (Ленинград, 1976), «Россия-9» (1999) һ.б. күргәзмәләрдә катнаша.

Шәхси күргәзмәләре 1967, 1977 (С.О.Лывин б-н бергә), 1978, 1984, 1989 (улы Н.Хаҗиәхмәтов б-н бергә) Казанда уздырыла. Картиналары ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәгендә, Әлмәт шәһәре картиналар галереясында һ.б. саклана. ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1987).

Әсәр.: Мин ничек художник булдым // Ялкын. 1968. № 9.

Әд.: Вәлиева Д. Үткәннәргә олы ихтирам // Социалистик Татарстан. 1986. 8 февр; Шәһиева Р. Рәссам Тавил Хаҗиәхмәтов // Казан утлары. 1998. № 1.; Юзеев Н. Мудрость поэта // Литературная Россия. 1983. 14 окт.; Червонная С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984; Елькович Л. Из вечного родника // Советская Татария. 1984. 1 апр.

ХА ҖИГӘРӘЙ ХАН (? — 1466), Кырым ханлыгына һәм *Гәрәйләр* династиясенә нигез салучы. Гыясетдин улы, *Таштимер хан* оныгы. 1430 елларда Кырымда хакимият өчен көрәш башлый. 1433 тә Кырымдагы җирле халыкның генуялыларга каршы күтәрелешен яклый. 1434 тә Х.х. генуялылар гаскәрен тар-мар итә. Соңрак үзара сугыш нәтиҗәсендә ул Кырымнан куыла, Литвага кача, анда Литваның бөек кенәзе Сигизмунд Кейстутовичтан биләмәгә Лида шәһәрен ала. 1440 еллар башында җирле татар аксөякләре һәм бөек Литва кенәзе Казимир IV ярдәмендә Кырымда хакимияткә килә, Алтын Урдадан бәйсез дәүләт — Кырым ханлыгын оештыра. Тышкы сәясәттә Литвага юнәлеш тота.

Әд.: Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск,1960.

И.Л.Измайлов.

ХА ҖИЕВ Вәли Хаҗи әхмәт улы (9.7.1925, Мамадыш кантоны Оет а. – 16.5.1995, Яшел Үзән ш.), Сов. Союзы Герое, рядовой. Туган авылында колхозда бригадир булып эшли. 1943 елның гыйнварыннан Кызыл Армиядә. 1944 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 1126 нчы укчы полк рядовое (43 нче армиянең 334 нче укчы дивизиясе). 1 нче Балтыйк буе фронты гаскәрләре составында Белоруссия һөҗүм операциясендә катнаша (1944). 1944 нең 25 июнендә Гринёво авылы янында Көнбатыш Двина елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә: беренчеләрдән булып елганы кичеп чыга, плацдармдагы сугышта катнаша, дошманның 2 пулемёт ноктасын юк итә, яралана, ләкин, хәрби бурычын тулысынча үтәп бетермичә, сугыш кырын ташламый. Демобилизацияләнгәннән соң (1945), Яшел Үзән шәһәрендә яши. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Яшел Үзән шәһәрендә бер урам Х. исемен йөртә.

Әд.: Батырлар китабы - Книга Героев. К., 2000.

М.З.Хәбибуллин.

ХАҖИЕВ Галимҗан Мөхәммәтша улы (11.7.1930, БАССРның Туймазы р-ны Исмәгыйль а.), бораулау остасы, Соц. Хезмәт Герое (1971), ТАССРның атказ. нефтьчесе (1985). Икееллык мастер-бораулаучылар курсларын тәмамлый (1968). Хезмәт эшчән - леген 1942 елда туган авылында башлый. 1949–94 тә «Татнефть» АҖнең Әлмәт бо-







Т.Г. Хаҗиәхмәтов. 1. «Халык әйтсә – хак әйтә». Татар мәкальләре мотивлары буенча «Хезмәт Батыр» линогравюралар сериясенән. 1975. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 2. Г.Тукайның «Сабыйга» китабына иллюстрация. Кәгазь, тушь, акварель, гуашь. 1982; 3. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы тышлыгы. Тушь, гуашь. 1983.

раулау эшләре идарәсендә, бораулау остасы (1966 дан). Беренчеләрдән булып югарымоментлы торба бораулауны, җир астына тиз узуны үзләштерә. Коммерциячел бораулау тизлеге 1 станок-айга 2525 *м* тәшкил итә.

1970 тә бригада тарафыннан Әлмәт идарәсендә елына рекордлы 30,8 мең *м* казу эшләре алып барыла. Х. Җитәкчелегендәге коллектив «Татнефть» АҖдә иң яхшылар исәбендә, берничә тапкыр тармак буенча бораулаучыларның Бөтенсоюз соц. ярышларында призлы урыннарга лаек була. Герой исеме нефть чыгару буенча 8 нче бишьеллык йөкләмәләрен (1966–70) үтәгәндә керткән өлеше һәм югары техник-икътисади күрсәткечләргә ирешкәне өчен бирелә. Ленин ордены, «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Х. бюсты Дан аллеясында куела (Әлмәт ш.).

Әд.: Миролюбов И. Хазиев Галимзян Мухаметшинович // Герои Социалистического Труда Татарии (1938–1978): Док. очерки. К., 1980. Кн. 1; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

ХА ҖИ́ЕВ Мадияр Шәрип улы (1.3.1949, Саба р-ны Керәнле а.), рәссам, педагог, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1999), ТРның халык рәссамы (2013). Казан сынлы сәнгать уч-щесен тәмамлаганнан соң (1976), Чаллы шәһәрендә яши, 1 нче балалар сәнгать мәктәбендә укыта. Рәссамнар берлеге (1996), «Тамга» төбәкара иҗат төркеме (2000) әгъзасы. Сюжетлы-тематик картиналар остасы. Иҗатының башлангыч чорында реализм традицияләрендә иҗат итә («Улым портреты», «Гүзәл», икесе дә — 1987; «Әни портреты», 1989). Соңрак Европа авангардына мөрәҗәгать итә, аны мөселман мәдәнияте традицияләре (нигездә китап миниатюралары) һәм татар гамәли сәнгате б-н берләштерә. Кайбер тәнкыйтьчеләр Х. эшләренең стилен «этник авангард» буларак билгели. Ләкин картиналарда образларның экспрессив-эмоциональ чагылышы, орнаменталь-яссы композиция, төсләрнең ритмик күчеше аны постмодернизм юнәлеше рәссамы итеп күрсәтә — «Татар йөге» (1995), «Тәрәзә янындагы кыз» (1996), «Алсу кич» (1999), «Ай кызы» (2002), «Күңел моңы» (2005), «Рәссам һәм муза», «Хәят», «Кош оясы» (барсы да — 2006), «Баручылар», «Ватан турында җыр» (икесе дә — 2007), «Ай тулган көн» триптихы, «Тормыш фәлсәфәсе», «Сак-Сок», «Бишек җыры», «Чишмә буе» (барысы да — 2008), «Сөембикә ханбикә улы Үтәмеш белән» (2009), «Мәхәббәт турында җыр» сериясе (2011). Иҗатының төп темалары Г.Тукайга («Г.Тукайның балачагы» (2004–08), «Тукай иске Казанда», «Тукай белән очрашу» (икесе дә — 2011) һ.б. сериясе), татар мәдәниятендә төрки һәм болгар чыганакларына («Казан — Болгар арасы» (1996); «Мизгел» триптихы (2002), «Болгар турында истәлекләр», «Борынгы бабалар авазы» (икесе дә — 2008), халык бәйрәмнәренә һәм йолаларына («Каз өмәсе» (2000), «Йола» (2008), «Сабантуй» триптихы (2010); ана образына («Әнкәй догасы» (1995), «Әнкәй сагышы» (1996), «Яшь ана», «Ана һәм бала» (икесе дә — 2011), «Балачак хатирәләре» (2002–06) сериясе) багышлана. Портретлар («Кызыл эшләпәле портрет» (2004), «Лиля портреты» (2009), «Сары киемле портрет» (2011)), пейзажлар («Татар ихатасы» (1995), «Печән өсте» (1996), «Чаллыда көз» (2000), «Казанда беренче кар» (2001), «Кышкы авыл» (2006), «Иске капкалар» (2009); натюрмортлар (кайвакыт ул фольга файдалана (татар шәмаилләренә хас ысул) («Шәрекъ чүлмәге белән натюрморт» (2000), «Подноста натюрморт» (2009), «Яран гөл», «Кичке натюрморт» (икесе дә — 2011) һ.б. авторы.



М.Ш.Хажиев.

1990 еллардан төбәкара «Зур Идел» (1998–2011); бөтенроссия «Классика һәм хәзерге заман» (Мәскәү, 2000), «Россия-11» (2009), «Сөйкемле Шүрәле» (2011) күргәзмәләрендә, халыкара (Ижевск, Пермь, 2003–11), «Күчмә истәлекләр. Хәбәр» (Мәскәү, Казан, Нефтекамск, Якутск, Ижевск, 2005–09) этнофутуризм фестивальләрендә, «Тамга» төрке-ме (2000 нән) күргәзмәләрендә һ.б.да катнаша. Шәхси күргәзмәләре 1998, 2002, 2004, 2005, 2006, 2009, 2010, 2014, 2017 дә Казанда, Чаллыда, Лениногрскида, Алабугада, Бөгелмәдә һ.б. шәһәрләрдә уздырыла. Картиналары ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәгендә, Уральск шәһәрендәге (Казакъстан) Г.Тукай музеенда һ.б.да, чит илләрдә шәхси тупланмаларда саклана.

Әд.: Солтанова Р.Р. Шигъри хасиятле рәссам // Татарстан. 1999. № 4; Сафин М. Канатлар нығыган чак // Татарстан. 2002. № 4; Нигматуллина Ю.Г. «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве. К., 2002; Мадияр Хазиев: Каталог юбилейной выставки. Наб. Челны, 2009.

Г.Ф.Вәлиева-Сөләймановa.

ХА ҖИ́ЕВ Фәнгать Хаммат улы (27.4.1936, БАССРның Балтач р-ны Ялангач а.), туфрак белгече, агроэколог, биол. фән. д-ры (1983), проф. (1990), Башкортстан Респ-касы ФАнең мөхбир әгъзасы (1991), БАССРның, РФнең атказ. фән. эшлеклесе (1985, 1997). Казан ун-тын тәмамлый (1960). 1963 елдан РФА Уфа гыйльми үзәгенең Биол. ин-тында, туфрак белеме лаб-ясе мөдире (1977–2003) һәм директор урынбасары (1984–92), экология бүлеге мөдире (2003 тән). Бер үк вакытта, 1995 тән, БР ФАнең Биол. фәннәре бүлеге акад. секретаре. Хезмәтләре туфрак биохимиясе, туфрак энзимологиясе, агроэкология, туфрак уңдырышлылыгын күтәрүгә карый. Туфракның ферментатив активлыгы, туфрак энзимологиясе алымнары һәм методологиясе буенча төпле тикшеренүләр авторы. Туфракның ферментатив потенциалы формалашуы һәм хәрәкәтенең системалы-экологик һәм җир өсте экосистемалар биотөрлелегенең туфраклар б-н структур-функциональ бәйләнеше турындагы концепцияләрне эшли һәм нигезли. Х. җитәкчелегендә Башкортстан туфракларын комплексы тикшерү үткәрелә, аларның уңдырышлылыгын күтәрү буенча зоналы-экологик аспектлар эшләнә. Бөтенсоюз туфрак белгечләре җәмгыятенең Башкортстан бүлеге рәисе (1983 тән). Үйлап табуга 10 авторлык таныклыгы бар. БР Дәүләт бүләге лауреаты (2001). СССР ВДНХсының бронза һәм көмеш медальләре; БАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Хезм.: Ферментативная активность почв. М., 1976; Системно-экологический анализ ферментативной активности почв. М., 1982; Почвы Башкортостана: В 2 т. Уфа, 1995–97 (автордаш); Методы почвенной энзимологии. М., 2005; Биологические ресурсы Южного Урала: Фундаментальные основы рационального использования. Уфа, 2009 (автордаш).

Әд.: Хазиев Фангат Хаматович: Биобиблиогр. указ. Уфа, 2006.







М.Ш.Хажиев.
1. «Әби». Картон, ДВП. Майлы буяу. 2003;
2. «Тулган ай». Картон. Майлы буяу. 2008;
3. «Яшь ана». «Ана һәм бала» триптихы. Сул як өлеше. 2011.

ХАҖИМӨХӘММӘ́Д БӘК (? — 1430), Себер ханлыгына нигез салучы. *Жүчи хан* нәселеннән. Күк Урданың уң канатының Себер олысы идарәчесе. Алтын Урдада хакимият өчен үзара көрәш барышында *Идегәйне* яклый, 1419–20 елларда *Кадыйрбирде ханга* каршы сугыша. Идегәй үлеменнән соң аның улы Мансур ярдәмендә дәүләткә нигез сала (1420). 1420 елларда үз хакимиятен ныгытып, Баракъ ханга каршы тора; Жумадык ханны тар-мар итә. 1429–30 да Себер аксөякләре *Әбелхәерне* яңа хан дип игълан итә; 1430 да аның гаскәрләре Х.б. көчләрен җиңәләр, ул кулга алына һәм җәзалап үтерелә.

Әд.: Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960.

И.Л.Измайлов.

ХАҖИ́ПОВ Нариман Җәлил улы (2.1.1928, Бөгелмә кантоны Кәрәкәшле а.), биохимик, вет. фән. д-ры (1968), проф. (1974), ТАССРның, РФнең атказ. фән эшлеклесе (1981, 1995). Казан вет. ин-тын (хәзер Казан вет. медицинасы академиясе) тәмамлаганнан соң (1954), шунда ук, биохимия кафедрасында эшли. 1970–84 елларда лаб. мөдире, бер үк вакытта, 1973–75 тә, ин-тның проректоры, 1975–88 дә ректоры, 2007 дән каф. профессоры. Хезмәтләре тилчә, бруцеллёз, мөгезле эре терлекләр туберкулёзы, түләмә, хламидиоз вируслары һәм бактерияләре биохимиясенә карый. 14 монография авторы, уйлап табуга патенты һәм 16 авторлык таныклыгы бар. СССР, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1979, 1996). Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Взаимодействие вируса ящура с клеткой. К., 1973 (автордаш); Хламидиозы сельскохозяйственных животных. М., 1984 (автордаш); Биохимия животных: Учеб. для вузов. К., 1999 (автордаш); Геноидентификация вируса бычьего лейкоза. М., 2017 (автордаш).

ХАҖИ́ПОВ Нәҗип Нәкыйп улы (13.9.1957, Саба р-ны Сатыш а.), галим зоотехник, биол. фән. канд. (2009), ТР дәүләт бүләге лауреаты (2013), ТРның атказ. зоотехнигы (1999). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1983), Саба р-нының «Марс» к-зында баш зоотехник булып эшли (1985 елга кадәр), КПСС район ком-тында а.х. бүлеге инструкторы (1986 га кадәр), Ленин исем. тәҗрибә-җитештерү хуҗалыгында партия оешмасы секретаре (1989 га кадәр), Ильич исем. к-з рәисе (1992 гә кадәр). 1992 дән Теләче р-нында а.х. һәм азык-төлек идарәсенең а.х. продуктларын сатып алу һәм сыйфат буенча бүлек башлыгы, 2000 нән халык депутаталарының район советы рәисе урынбасары, 2001 дән хакимият башлыгы урынбасары — а.х. һәм азык-төлек идарәсе башлыгы. 2003 тән ТР а.х. һәм азык-төлек министры урынбасары. Дәүләт бүләге ТРда сөтчелек тармагында нәтиҗәлелекне арттыру өчен инновацион технологияләр эшләү һәм гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

ХА ҖИ́ПОВ Нәҗип Ха җип улы (10.2.1924, Свердловск өлкәсенең Әчет р-ны Яманъелга а. — 25.3.1945, Нойдорф торак пункты, Германия), Сов. Союзы Герое (27.6.1945, үлгәннән соң), гв. лейтенанты. 1942 елның сентябреннән Кызыл Армиядә. 1943 тә Сталинград танк уч-щесен тәмамлый. 1943 нең декабреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 24 нче гв. танк бригадасының танк взводы командиры (4 нче гв. танк армиясенең 5 нче гв. механикалаштырылган корпусы). 1 нче Украина фронты гаскәрләре составында Проскуров-Черновцы (1944), Львов-Сандомир һәм Сандомир-Силезия (икесе дә — 1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1945 нең 24–25 мартында Силезиядә (Германия) барган сугышларда батырлык күрсәтә: Х. җитәкчелегендәге взвод беренче булып Владен торак пунктына килеп керә, 3 үзйөрешле артиллерия җайланмасының утын бастыра, танкны сафтан чыгара, бронетранспортёрны яндыра һәм дошманның берничә ротадан артык солдатын юк итә. 25 мартта ул сафтан чыккан танкның авыр яраланган экипаж әгъзаларын эвакуацияли һәм 4 сәгать дәвамында берүзе дошман б-н сугыша, штурм тубын һәм берничә взводтан артык солдатны юк итә; сугышта һәлак була. Ленин ордены, Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Туган җирендә Х.ка мемориаль такта куела.

Әд.: Батырлар китабы - Книга Героев. К., 2000.

М.З.Хәбибуллин.

ХА ҖИ́ПОВ Рөстәм Нариман улы (21.3.1965, Казан), терапевт, мед. фән. д-ры (1998). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1988), шунда ук, нормаль физиол. кафедрасында эшли. 1992 елдан Франция Медицина фәннәре академиясенең эксперименталь нейропатология лаб-ясендә (Париж), 1999 дан Урта диңгез нейробиол. ин-тында (Марсель). 2011 дән КФУның әйдәп баручы фәнни хезмәткәре. Хезмәтләре үзәк нерв системасы, гиппокамп эшчәнлегенә, гипоксия, эпилепсия һ.б. авыру очракларында нейроннар челтәре функциясен өйрәнүгә карый. Патологияләрне башлангыч чорында превентив дәвалауның төп принципларын эшләп тәкъдим итә.

Х е з м.: Особенности действия ионов кальция на миниатюрные токи концевой пластинки после нарушения гидролиза медиатора // Нейрофизиология. 1990. Т. 22, № 4 (автордаш); ГАМК — основной медиатор возбуждения на ранних этапах развития гиппокампа // Успехи физиол. наук. 1998. № 2 (автордаш); Генетические и эпигенетические механизмы формирования соматосенсорных карт в коре головного мозга // Гены и клетки. 2015. Т. 10, № 3 (автордаш).

ХА ҖИТАРХА́Н (Аштархан, Гитархан), урта гасырлар (13–16 йөзләр) шәһәре. Иделнең уң ягында хәзерге Әстерхан шәһәре тирәсендә урнашкан була. Мөһим кәрван һәм су юллары буенда уңайлы географик урын биләгәнлектән, икътисади яктан үсеш кичерә. 13–14 йөзләрдә Алтын Урданың эре сәяси һәм сәүдә үзәге. Гарәп сәяхәтчесе Ибне Баттута (14 йөз) Х.ны Идел буендагы «зур базарлары булган иң яхшы шәһәрләрнең берсе» дип атый; аңа Персия, Казан, Кырым һ.б. җирләрдән сәүдәгәрләр килә. 1395 елда Х. Урта Азия идарәчесе *Аксак Тимер* гаскәрләре тарафыннан җимертелә. Шәһәрдә тормыш дәвам итә, ләкин ул элеккеге әһәмиятен югалта. И.*Барбаро* Х. «тулысынча диярлек җимерелгән шәһәр» дип яза (15 йөзнең 1 нче яртысы); А.*Контарини* аны балчыктан салынган өйләре булган кечкенә шәһәр буларак тасвирлый (15 йөзнең 2 нче яртысы). 1460 еллар башында *Әстерхан ханлыгы* барлыкка килгәннән соң, Х. аның башкаласына әверелә. 1547 дә Кырым ханы *Сәхибгәрәй* гаскәрләре тарафыннан яулап алына һәм бөлдерелә. 1556 да Әстерхан ханлыгы Рус дәүләтенә кушыла. 1558 дә Идел буендагы рус кальгасына, хәзерге Әстерхан шәһәренә нигез салына. Х. әкренләп ташландык хәлгә килә. Х. калдыклары, Шареный бугор шәһәрчеге Әстерханның төньяк-көнбатыш читендә, Ст релецкое һәм Новолесное посёлоклары арасында урнашкан.

Әд.: Гузейров Р.А. Золотоордынский город Ходжи Тархан и его округа: Дис. ... К., 2004.



Н.Ж.Хаҗипов.



Н.Х.Хаҗипов.

ХАҖИЧИРКӘ́С ХАН (? — 1379/80), Алтын Урда ханы (1374–75). 1370 елларда Хаҗитархан әмире була, үз исеменнән акча суктыра. Үзәк хакимият кризисыннан файдалана; гарәп тарихчысы Ибне Халдун мәгълүматы буенча, Х.х. Мамайны җиңә һәм аңардан Сарайны тартып ала. 1375 ел ахырында Х.х. хакимияте көчсезләнә, ул *Каган бәк* тарафыннан Сарай әл-Җәдидтән куыла. *Туктамыш хан* б-н бәрелештә һәлак була.

Әд.: Греков Б.Д., Якубовский А.Ю. Золотая Орда и её падение. М.–Л., 1950; Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960.

И.Л.Измайлов.

ХА́ЗОВКА посёлогы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 17 *км* төньяктарак, Урман Зәе елгасы буенда. Даими яшәүчеләр юк. 1920 елларда нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Чаллы кантоны Акташ волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1959 ның 26 мартыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1926 да — 96, 1938 дә — 109, 1949 да — 73, 1958 дә — 45, 1970 тә — 36, 1979 да — 54, 1989 да — 2 кеше.

ХАЙБУ́ЛДИНО (Кималу) авылы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 3 *км* көнбатыштарак, Кече Чынлы елгасы буенда. 2010 елда 141 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Клуб. 1664 тән мәгълүм. 1720 еллардан халкы дәүләт крәстиянәре катлавына керә, 1835–60 елларда Удел ведомствосы карамагында; игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Х. да 2 сәүдә-сәнәгать йорты була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 459 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Үби волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында.

1930 ның 10 августыннан — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1859 да — 173, 1897 дә — 295, 1913 тә — 331, 1920 дә — 323, 1926 да — 325, 1938 дә — 412, 1949 да — 380, 1958 дә — 321, 1970 тә — 367, 1989 да — 185, 2002 дә — 168 кеше.

Әд.: Г а ф а р о в И.Ә. Туган як мирасы. К., 2017.

ХАЙВАННА́Р ДӨНЬЯСЫ́, нинди дә булса терр-ядә яки акваториядә тарихи барлыкка килгән хайваннар бергәлеге җыелмасы.

Респ-ка Х.д. составын һәм төрлелеген ТРның ике биогеографик зона — урман һәм дала чикләрендә урнашуы, ландшафт төрлелеге, зур елгалар һәм сусаклагычлар булу, кеше тарафыннан терр-янең югары үзләштерелүе билгели. Үзенчәлекләренең берсе — төр байлыгы. Күпчелек төрләр умырткасыз хайваннарга карый. Умырткалыларның 470 кә якын төре исәпләнә: балыклар (52 төр), җир-су хайваннары (11), сөйрәлүчеләр (8), кошлар (очып үтүчеләрне дә кертеп 321 төр), имезүчеләр (77–79 төр). ТР Х.д.ның икенче бер үзенчәлеге — тереклек итү формаларының төрлелеге. Тайга урманнарына хас хайван төрләре очрый — соры гөберле бака, үлән бакасы, тереләй тудыручы кәлтә, гади кара елан, суер, божыр, чукрак күке, кара һәм өч бармаклы тукран, эрбетче, чыршы чукыры, очкалак тиен, борындык, кызыл кыр тычканы, селәүсен, поши; хайваннарның Европаның киң яфраклы урманнарына хас төрләр — буа бакасы, җизбаш, урман күгәрчене, яшел һәм ак аркалы тукран, шәүлегән, кара миләш чыпчыгы, ак муенлы чебенче, имәнборын, зур һәм чикләвек йоклачлары, кондыз, сары муенлы тычкан; далага хас төрләр — яшел гөберле бака, җитез кәлтә, дала кара елаңы, дала, болын һәм кыр карчыгалары, балабан, дала торымтае, сары көртлек, зур шөлди, күк карга, сары каракош, һөдһөд, кыр тургае, таш чыпчыгы, үр куяны, сөркә-байбак, зур һәм тимгелле йомраннар, дала кечкенә тычканчыгы, зур күшаяк, дала чуар тычканы, сукыр тычкан, соры һәм Эверсман вак әрләне, карсак, дала көзәне. Су һәм су яны хайваннары да шактый — балыклар, тритон, кызыл корсаклы су «үгезе», яшел бака, гади тузбаш, сазлык ташбакасы, гагара, чомгалар, ләкләксыманнар һәм казсыманнар, елга каракошы, балыкчы карчыга, соры торна, көтүче кошлар, акчарлаклар, шөлдиләрнең күпчелеге, сазлык ябалагы, яр чыпчыгы, яр карлыгачы, чәперчек кошлар, су тургае, күктүш, камыш чыпчыклары, яр песнәге, солы чыпчыгы, имәнлек чыпчыгы, җофар, гади шолган, чәшке, кама, ас, төн ярканатлары, су тычканы, ондатра. ТР терр-ясенә көньяк (дала) төрләренең үтеп керүе сәбәпле фаунаның күшылу күренеше күзәтелә. Еш кына соры һәм яшел гөберле бакалар, тереләй тудыручы һәм җитез кәлтәләр, бо җыр һәм соры көртлек, кара һәм яшел тукран, борындык һәм зур йомран, кызыл кыр тычканы һәм сары муенлы тычкан, селәүсен һәм дала көзәне янәшә яшиләр. ТР терр-ясеннән умырткасызларның күп кенә төрләре ареалларының чикләре уза. Ареалның көньяк чигендә дербник, божыр, шөлди, фифи, мородунка, тәлләтәвеч, чукрак күке, чырайсыз ябалак һәм төкле аяклы ябалак, карчыгасыман ябалак, озын койрыклы соры ябалак, өч бармаклы тукран, эрбетче, кычыткан чыпчыгы, карабүрек, чи-чи чыпчыклар, көрән аю, селәүсен, борындык, очкалак тиен, кызыл кыр тычканы һ.б.; ареалның төньяк чигендә — буа бакалары һәм ашарга яраклы бакалар, сазлык ташбакасы, дала кара елаңы, зур ак челән, дала каракошы, гүр каракошы, балабан, божралы күгәрчен, йорт ябалагы, күк карга, кыр тургае, колаклы керпе, соры һәм Эверсман әрләне, байбак, зур кушаяк, дала чуар тычканы, сары муенлы тычкан, карсак һ.б. Синантропизация — күп кенә хайваннарның кеше янында яки үзгәртелгән ландшафтта яшәүгә яраклашу күренеше көчәя. Күпчелек төрләр яңа, үзгәргән шартларда яшәп китәргә сәләтле, өчтән бере яңа шартларга яраклаша, бер өлеше (13% ка кадәр) үзләрен табигый мохиткә караганда да яхшырак хис итә (мәс., соры күсе, соры карга).

Табигый сәбәпләр һәм антропоген факторлар тәэсирендә берөзлексез үзгәреп тору сәбәпле, хайваннарның төр составы даими кала алмый. ТРның хәзерге терр-ясе чикләрендә 10–12 мең ел элек «мамонтлар чоры фаунасы» юкка чыга, аерым вәкилләре Арктикада сакланган (ак төлке, сарыкүгез һ.б.). Соңрак промысел төрләре — кабан дуңгызы, тур, сайгак, тарпан һ.б., 18–20 йөздә — хәзер ТРның Кызыл китабының «кара исемлегенә» кертелгән төрләр: кеш, комагай, Себер боланы, кечкенә чыелдык, кара күсе, кызыл түшле гагара, гади агач бакалары кимиләр яки тулысынча юкка чыгалар. Җофар, Европа чәшкесе юкка чыгу чигендә торалар (юкка да чыккан булырга мөмкин). Бер үк вакытта аерым төр хайваннар — Себер көҗәболаны, кабан дуңгызының саны торгызыла. ТР терр-ясенә 19 йөздә бетерелгән кондыз, Америка чәшкесе, янутсыман эт, ондатра кертелә. Элек юкка чыккан кошлар — дала каракошы, дүдәк, сиртмәкойрык яңадан очрый башлый. Иделдә сусаклагыч корылмалар төзелү нәтиҗәсендә Каспийдан Идел сельде, кара аркалы сельд, Төньяк Каспий сельде, акбалык, Каспий сөләйман балыгы, мәрсин балыклар — укборын, орчыкбалык, миногалар керми, әмма каналлар системасы аша сусаклагычларга күл чабагы, чуар балык, еланбалык, вак балык, Кара диңгез энәбалыгы, түгәрәк ташбаш, төн балыгы керә. Гади һәм чуар юанбашлар, ак амур, пелядь үрчетелә; кисәүбаш балык кертелә һәм сулыкларга җибәрелә. Фауна составының үзгәрүе ш.у. аре аллар (җитез кәлтә, зур йомран, аксыл сасы көзән, имәнлек чыпчыгы, яшел нарат чыпчыгы һ.б., соңрак — зур ак челән, ысылдавык аккош, божралы күгәрчен, колаклы керпе һ.б.) чикләренең табигый үзгәрешләренә бәйле.

ТРда Х.д.ның төр составын саклау һәм аның торгызу максатыннан *аеруча саклаулы табигать территорияләре һәм акваторияләре* челтәре булдырыла. Умырткалы һәм умырткасыз хайваннарның күп кенә төрләре ТРның Кызыл китабына кертелгән.

Әд.: Н а з а р о в а И.В. Блохи Волжско-Камского края. М., 1981; Б о й к о В.А., И в л и е в В.Г., А ю п о в А.С. Иксодовые клещи в лесах Среднего Поволжья (Лесостепная зона). К., 1982; П о п о в В.А., Л у к и н А.В. Животный мир Татарии. Позвоночные. К., 1988; К р а с н о б а е в Ю.П., М а т в е е в В.А. Каталог пауков Среднего Поволжья. Самара, 1993; А с ь к е е в И.В., А с ь к е е в О.В. Орнитофауна Республики Татарстан. К., 1999; Р а х и м о в И.И., П а в л о в Ю.И. Хищные птицы и совы Татарстана. К., 1999; А с ь к е е в И.В., А с ь к е е в О.В., Б е л я е в А.Н. Каталог млекопитающих Татарстана. К., 2000; Г а р а н и н В.И., Е г о р о в И.Я., Р я б о в а Г.А. Животный мир Восточного Закамья. Альметьевск, 2000; Ж е р е б ц о в А.К. Определитель жужелиц (Coleoptera, Carabidae) Республики Татарстан. К., 2000; К у з н е ц о в В.А. Рыбы Волжско-Камского края. К., 2000–01. Ч. 3–5; П а в л о в А.В., З а м а л е т д и н о в Р.И. Животный мир Республики Татарстан. Амфибии и рептилии. К., 2002; Красная книга Республики Татарстан: животные, растения, грибы. К., 2016; Природа и природные ресурсы Республики Татарстан: иллюстрированная энциклопедия. К., 2017.

В.И.Гаранин.

ХАЙВАННАРНЫ́Ң ТОКСИКОЛО́ГИК, РАДИАЦИО́Н ҺӘМ БИОЛОГИК КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫГЫ́ ФЕДЕРА́ЛЬ ҮЗӘГЕ́, к. *Бөтенроссия ветеринария фәнни-тикшерену институты.*

«ХАК», рәсемле, иҗтимагый-сәяси, фәнни, икътисади, әдәби атналык газета. 1911 елның апреленнән 1 июленә кадәр Әстерхан шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, барысы 20 саны чыга. Нашире һәм мөхәррире — М.*Исмәгыйлев-Ширванский*. Газета либераль-буржуаз юнәлештә була. Шәһәр халкы көнкүрешен, шәһәр үзидарәсе органнары эшчәнлеген, төбәктәге татарлар тормышын, мәдәният һәм мәгариф үсешен яктырта. Аның битләрендә татар язучылары әсәрләре басыла. Башлыча, Әстерхан губернасында тарала.

ХАККЫ́Й (Hakki) Ибра һим (18.5.1703, Эрзурум ш., Төркия — 22.6.1781, Сиирт ш., Төркия), төрек суфи шагыйре, философ. Ислам фәннәренең нечкәлекләрен өйрәнеп, бер суфи остаздан икенчесенә күчеп ил буенча сәяхәт итә. Хаҗ кыла. Төрек, гарәп, фарсы телләрендә яза. Мөселман дөньясында Х.ның астрономия, матем., анатомия, психол., филос. һәм ислам мистицизмы турында мәгълүматлар тупланган «Мәгърифәтнамә» (1756) хезмәте киң таныла. Х. әсәрләре татарларда бик популяр була. «Мәгърифәтнамә» поэмасына татар шагыйре Сәхибгәрәй бине Әхмәд *назыйрә* яза. Казанда аның «Кыяфәте инсан хакында» (1884) китабы нәшер ителә, Х.ның аерым шигырьләре «Диван Ризаи» (1860) җыентыгына керә.

Әд.: K o p r u l u M.F. Early Mystics in Turkish Literature. L.–N.Y., 2006.

ХА́КОВ Вахит Хөҗҗәт улы (16.8.1926, Буа р-ны Күзби а. — 20.6.2008, Казан; туган авылында җирләнә), тел галиме, тюрколог, филол. фән д-ры (1972), проф. (1974), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1987). Казан ун-тын тәмамлый (1957). 1949 елдан Буа р-ны мәктәпләрендә укытучы, уку-укыту бүлеге мөдире булып эшли. 1960 тан Казан ун-тында, 1989–94 тә татар теле каф. мөдире, бер үк вакытта, 1996 дан, ТР ФАнең Татар энциклопедиясе ин-тында. Хезмәтләре татар әдәби теле стилистикасына, сөйләм культу-



В.Х. Хаков.

расына, текстологиягә һәм мәктәптә матур әдәбият телен өйрәнү методикасына карый. «Татар әдәби теле тарихы» (1993) монографиясендә беренче тапкыр татар әдәби теленең үсеш тарихын һәм андагы мөһим күренешләрне яктырта, татар һәм башка төрки телләрнең үзара генетик бәйләнешен ачыклый. 6–9 йөзләрдәге борынгы төрки рун язуы истәлекләренә багышланган «Тел — тарих көзгесе» (2003) хезмәтендә, тел белемендә беренчеләрдән булып, аларның фонетика, грамматика һәм лексикасына чагыштырма-тарихи лингвистик анализ ясый. «Татар әдәби теле диахрон һәм синхрон аспектларда» («Татарский литературный язык в диахроническом и синхроническом аспектах») хезмәтләр циклында татар әдәби теле тарихын чорларга бүлү мәсьәләләрен карый, аның традицияләрен яктырта, сөйләм һәм язма формаларын тасвирлый (ТР Дәүләт бүләге, 2006). Югары уку йортлары һәм урта мәктәп-ләр өчен татар теле дәреслекләре авторы. Х. Татарстан радиосында «Тел күрке — сүз» тапшыруын оештыра һәм даими рәвештә катнаша (30 ел дәвамында). 2009 дан алып, Казан ун-ты каршында ел саен төбәкара «Хаков укулары» фәнни-гамәли конференциясе уздырыла. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Татар стилистикасына кереш. К., 1963; Татар милли әдәби теленең барлыкка килүе һәм үсеше. К., 1972; Стилистика һәм сүз сәнгате. К., 1979; Хәзерге татар әдәби теле: Стилистика. К., 1999.

Әд.: Ф ә й з у л л и н Р. Тел сагында тора солдат // Казан утлары. 2006. № 8; Хаков укулары-2011: Хаков истәлегенә багышланган төбәкара фәнни-гамәли конференция материаллары. К., 2011; Казанская лингвистическая школа. К., 2008.

«ХАКЫЙКА́ТЬ. БЕЗНЕ́Н ГАЗЕ́ТА», хәрби, иҗтимагый-сәяси газета. Югары башкомандующий адмирал А.А.Колчак армиясе штабы карамагындагы гаскәри имам идарәсе органы. 1919 елда Омск шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, барысы 10 саны чыга. «Рус җәмгыяте» басмаханәсендә басыла. Мөхәррире — гаскәри имам Г.Сәлимгәрәев, прапорщик Ф.Габдуллин. Консерватив-монархиячел юнәлеше б-н аерылып тора.

Т.М.Насыйров.

«ХАКЫЙКА́ТЬ ЙОЛДЫЗЫ́», 1927–28 елларда Казанда укучы яшьләрнең рәсми булмаган оешмасы. «*Ислам баласы*» ж-лы мөхәрририяте башлангычы б-н совет җитәкчелегенең дингә каршы пропагандасына протест йөзеннән татар яшьләрен берләштерү максатыннан оештырыла. «Х.й.»ның беренче җыелышы 1927 нең 24 апрелендә булып уза; анда 14–18 яшьлекләр әлеге оешманың әгъзалары була алуын раслаган Устав кабул ителә (журнал хезмәткәрләре өчен чыгармалар карала). Башлап йөрүчеләре: Исхак Закиров, Гомәр Габитов, Зөфәр Абдуллин. «Х.й.» әгъзалары исламның гуманистик идеяләрен пропагандалап, дәүләт гражданнарының дини инануларына карата битараф булырга тиеш дип исәпләделәр; алар мәдәни-агарту чаралары үткәрәләр, татар кинематографиясен үстерү идеясен яклыйлар, алфавитны латинлаштыруга каршы чыгалар. 1928 нең маенда оешмага каршы җинаять эше кузгатыла, башлап йөрүчеләре хөкем ителә һәм хезмәт б-н төзәтү колонияләренә җибәрелә.

Әд.: К а ш а п о в Р. Дитя ислама // Татарстан. 1995. № 5–6.

ХАЛАБУДА́ Эдуард Петрович (20.3.1937, Омск ш. — 8.5.2008, Бөгелмә ш.), геолог-геофизик, «Татнефтегеофизика» АҖ ген. директоры (1968–95), Татарстанда геофизика хезмәтен оештыручыларның берсе. ТАССРның атказ. нефтьчесе (1979), РСФСРның атказ. нефть һәм газ сәнәгате хезмәткәре (1979), СССРның мактаулы нефтьчесе (1987). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1959), «Татнефтегеофизика» АҖдә эшли: 1966 елдан идарәче, 1968 дән ген. директор, 1995 тән баш консультант. Хезмәтләре геофизикага карый. Х. җитәкчелегендә Татарстан терр-ясендә, Оренбург өлкәсендә һ.б. төбәкләрдә уннарча нефть чыганаклары ачыла, ТРда геофизика хезмәт өлкәсендә яңача техник җиһазланды-ру үткәрелә, куәтле исәпләү үзәге булдырыла, нейтроннарның кече габаритлы генератор, төш-магнит һәм элетромагнит каротаж аппаратурасы эшләнә һ.б. Уйлап табуга 5 авторлык таныклыгы бар. СССР ФАнең акад. И.М.Губкин исем. бүләге лауреаты (1980). Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы орденнары; медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын һәм көмеш медальләре б-н бүләкләнә. Бөгелмә шәһәренең мактаулы гражданы (1997).

ХА́ЛЕВ Василий Дмитриевич (14.1.1913, Казан — 2.7.1944, Полоцк ш., Белоруссия ССР), Сов. Союзы Герое (24.3.1945, үлгәннән соң), гв. кече лейтенанты. 1938–40 елларда Алексеев р-нының Алексеев авылында эшли. 1935–37 дә һәм 1940 тан Кызыл Армиядә. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 47 нче аерым утаткыч танк полкының утаткыч Т-34 танкы командиры (6 нчы гв. армиясенең 23 гв. укчы корпусы). 1944 тә танкист офицерларның фронт курсларын тәмамлый, 2 нче һәм 1 нче Балтыйк буе фронтлары гаскәрләре составында дошманның Невель төркемен тар-мар итүдә (1944), Витебск-Орша һәм Полоцк һөҗүм операцияләрендә (икесе дә — 1944) катнаша. 1944 нең 2 июлендә Витебск өлкәсен (Белорусия ССР) азат итү сугышларында батырлык күрсәтә: Х. җитәкчелегендәге танк экипажы беренчеләрдән булып Полоцк шәһәренә бәреп керә, дошманның күпсанлы сугышчыларын юк итә; танк сафтан чыга, Х. сугыш машинасында тереләй янып үлә. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Полоцк, Казан шәһәрләрендә һәм Алексеев авылындагы урамнарга Х. исеме бирелә.

Әд.: Батырлар китабы – Книга Героев. К., 2000.

М.З.Хәбибуллин.




В.Д. Халев.



П.А. Халезов.

ХА́ЛЕЗОВ Павел Александрович (30.12.1916, хәзер Ярославль өлкәсенең Некрасов р-ны Клюшниково а. — 18.1.1999, Казан), инженер-оптик, икътисадчы, сәнәгый җитештерүне оештыручы, Соц. Хезмәт Герое (1966), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1960). Кораллану сәнәгате академиясен (Мәскәү, 1950), Мәскәү инженерлар-икътисад ин-тын (1956) тәмамлый. Ленинград төгәл механика техникумын тәмамлаганнан соң (1937), Красногорск оптика-механика з-дында эшли (Мәскәү өлкәсе). Бөек Ватан сугышы башлангач, завод б-н бергә Новосибирск шәһәренә эвакуацияләнә, өлкән мастер, цех башлыгы урынбасары, башлыгы булып эшли. Казан оптика-механика з-ды директоры (1950–61, 1963–69). 1961–63 елларда Татарстан ХХСның 1 нче Машиналар төзелеше идарәсе башлыгы. Х. җитәкчелегендә пр-тиедә реконструкция уздырыла, җитештерү һәм ярдәмче хезмәтләр корпуслары төзелә, электроника һәм автоматика нигезендәге яңа тип приборларны сериялән җитештерү үзләштерелә; Дербышки посёлогында (Казанның Совет р-ны) торак йортлар, социаль-көнкүреш объектлары, спорт корылмалары һ.б. төзелә. Уйлап табуга 12 авторлык таныклыгы бар. Герой исеменә илнең оборона сәләтен ныгытудагы казанышлары өчен лаек була. 1955–59, 1959–63 тә ТАССР ЮС депутаты. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын медале б-н бүләкләнә. Казанда бер урам Х. исемен йөртә.

ХАЛИДИ́ Корбангали (1846 елның ноябре, Аягуз ш., хәзер Казакъстан Респ-касының Семипалатинск өлкәсе — 14.3.1913, Чүгүчәк ш., Кытай), тарихчы, этнограф, дин эшлеклесе. Чыгышы б-н Казан губернасының Казан өязе Орнашбаш авылыннан булган сәүдәгәр Халит гаиләсендә туа. Башта Аягуз, аннан соң Семипалатинск мәдрәсәләрендә укый. 1874 елдан Чүгүчәк шәһәрендәге мәчетләрнең берсендә имам-хатип булып тора, 1884 тән шәһәр һәм округ казые. 1897–88 дә Мәккә һәм Мәдинәгә хаҗ кыла, Көнбатыш Европаның кайбер илләре башкалаларында, ш.у. Якын Көнчыгыш шәһәрләрендә була. Истанбулда төрек мәгърифәтчесе, тарихчы Әхмәд Мидхәт б-н очраша. Көнчыгыш Төркестан буйлап сәяхәт итә, җирле халыкларның тарихы һәм көнкүрешенә кагылышлы материал туплый. Казакъларга, күчеп утырган татарларга, Урта Азия һәм Көнчыгыш Төркестандагы дәүләт берәмлекләренә



Ф.Х. Халиди.



Әнәс Б.Халидов.

багышланган «Тарихы җәридәи җәдидә» («Яңа тарих язмалары», 1889), «Тәварихы хәмсәи шәркыя» («Биш Шәрык халкы тарихы», 1910) китаплары авторы. Хезмәтләрендә Х. алаш, үзбәк, казакъ, нугай кабилә исемнәре, «жуз» атамасы; ураннар; нугайларның һәм казакъларның берләшүләре, соңыннан исә аерымланулары; казакълар шәҗәрәсе; Үзәк һәм Төньяк Казакъстандагы археол. һәм архит-ра истәлекләре; Чыңгызхан һәм аның варислары; казакъ ханнары; Аблай хан; Әбелфәез хан; Әсән ата һәм ул әйтеп калдырган сүзләр; ханнарны сайлау; түрә һәм туләнгутлар; Урта Йөз (Жуз) казакъларының Россиягә кушылуы һәм адм. округлар, ныгытмалар һәм шәһәрләргә нигез салыну; чалаказакъ этник төркеме хасил булуы тарихы турында яза. Этнографик язмалары рухи мәдәнияткә багышлана (гореф-гадәтләр, йолалар, инанулар, халык белемнәре, шигърият һ.б.), аларда кием-салым, кирәк-ярак, терлекчелек ху җәлыгы хакында мәгълүматлар бар.

Әд.: К а р м ы ш е в а Д.Х. Казахстанский историк-краевед и этнограф Курбангали Халиди // Советская этнография. 1971. № 1.

ХАЛИДИ́ Фатих Хаммат улы (1850, Тәтеш өязенең Олы Яңасала а. — 7.4.1923, Казан), мәгърифәтче әдип, тәрҗемәче, татар әдәбиятында драматургия жанрына нигез салучыларның берсе. Мулла улы. Казандагы Зәңгәр мәчет (әтисе мәчетнең имамы һәм мөд әррисе була) каршындагы мәдрәсәдә укый. Укуын Кышкар мәдрәсәсендә дәвам итә. Соңрак Казанда приказчик булып эшли, үзлегеннән белем ала, рус телен өйрәнә. Җитлеккәч, кеч кенә генә китап кибете ача, 1893 елдан татар телендә дивар һәм өстәл календарьлары бастыра башлый, аларда кызыклы мәгълүмат урнаштыра. 1880 еллардан әдәби иҗат б-н шөгыльләнә башлый. Х. әсәрләренең күпчелеге дидактик юнәлештә: автор акча өстенлегенә каршы чыга, гади халык арасында белем һәм мәгърифәт тарату, хатын-кызлар эмансипациясе өчен көрәшә. Х.нең «Рәдде бичара кыз» драмасы (1888) Г.Ильясиның «Бичара кыз» (1887) драмасына нәзыйрә рәвешендә иҗат ителә. Драма, 19 йөз ахырын да татар приказчикларының һәм шәһәр ярлыларының тормышын чын һәм дөрес гәүдәләндерүе, гади һәм аңлаешлы теле, диалогларның кыскалыгы б-н аерылып тора. Баш героиня — чибәр һәм акыллы ярлы кыз Хәлимә, тормыш авырлыкларына карамастан, җәмгыятьтә үз урынын һәм бәхетен таба. Автор фикеренчә, кешенең абруе — аның гыйлемле булуында. «Морат Сәлимов» драмасында (1905) үзенең тырышлыгы б-н югары белем алган баш герой, дуамал Сабирга, «Саран, надан Теллә бай» хикәятендәге (1906) хезмәтче хатын Җамал авыл баеның надан кызларына каршы куела. Х. пьесаларында наданлыкны фаш итә, белемнең байлыктан өстен булуын ассызыклый.

Х. — «Җи һанабад падишаһы угыллларының кыйссасы» (1896), «Болгарның Солтан Гадел Туктамыш хан кызы Хәлимәнең бәхәсе» (1898), «Кемгә тиеш?» (1904) һ.б. хикәя һәм повестьлар авторы. «Әлфе сәхәр вә сәхәр», ягъни «Мең дә бер сәхәр» (1903–04) новеллалар җыентыгы «Мең дә бер кичә» әкиятләре тәэсирендә языла. Х.нең татар драматургиясенең башлангыч чорында язылган пьесаларында җитди җитешсезлекләр очрый: аларда эш-хәлләрне ачык дәлилләү юк, күп образлар, схематик рәвештә генә бирелеп, автор идеяләренә иллюстрация генә, конфликтлар реалистик хәл ителми. Шуңа да карамастан, аның иҗаты яңа заман татар реалистик әдәбияты һәм татар әдәби теле формалашуда зур роль уйный.

Әд.: Татар әдәбияты тарихы. К., 1985. Т. 2; М ө х ә м м ә т ш и н З. Фатих Халидинең иҗат мирасы. К., 2001; Ә х м ә д у л л и н А. Ф. Халиди турында берничә сүз // Офыклар киңәйгәндә. К., 2002; Г а й н у л л и н М.Х. Татарская литература XIX в. К., 1975. *А.М.Ахунов.*

«ХАЛИДИЯ́», Казанда, *Зәңгәр мәчет* каршындагы мәдрәсә. 1825 ел тирәсендә ачыла, мөдәррисләре Зәңгәр мәчетнең имам-хатипларыннан Г.Рахманколый (1825–35), Х.Рахманкулов (1835–50), Х.Халитов (1850–64), Г.Рахманкулов (1864–70), М.Халитов (1870–94), И.Халитов (1894–1918). Мәхәллә дә кеше күп булу сәбәпле мәдрәсә Казанда иң зурлардан санала: 20 йөз башында анда 150 шәкерт укый. Аның тарихында иң яхшы чор Ш.*Мәрҗанинең* яраткан укучысы Г.Х.Рахманкулов җитәкчелек иткән вакытка туры килә, калган вакытларда ул гади иске алымлы мәдрәсә була. Мәдрәсә мәчет янында сәүдәгәр Арсаевлар төзеткән йортта, 19 йөз ахырыннан — Екатерининский урамындагы (хәзерге Тукай ур.) Мөстәкыйймовлар йортында урнаша, бинасы сакланмаган. Шәкертләре арасында — Г.*Камал*, Г.*Гобәйдуллин*, Ф.*Халиди* (Х.Халитовның улы), Г.*Сөнгати.*

Әд.: С а л и х о в Р.Р., Х а й р у т д и н о в Р.Р., Республика Татарстан: Памятники истории и культуры татарского народа (конец XVIII — начало XX веков). К., 1995.

ХАЛИ́ДОВ Әнәс Бакый улы (25.2.1929, Буа кантоны Казма а. — 1.12.2001, Казан), шәркыятьче галим, гарәп теле һәм ислам дине белгече, филол. фән. д-ры (1984), проф. (1987). Ленинград ун-тын тәмамлый (1951). 1955 елдан СССР ФА Көнчыгышны өйрәнү ин-тында (соңрак РФА Көнчыгышны өйрәнү ин-тының Ленинград ф-лы, аннары РФА Көнчыгышны өйрәнү ин-тының С.-Петербург ф-лы дип үзгәртелә), 1961 дән Гарәп теле кабинеты (1978 дән Якын Көнчыгыш секторы дип үзгәртелә) мөдире, бер үк вакытта, 1959 дан, Ленинград ун-тының көнчыгыш ф-тында. 2000 нән Казанда: Казан ун-тының Көнчыгышны өйрәнү ин-ты профессоры. Хезмәтләре археографиягә (гарәп кулъязмалары), гарәп классик әдәбиятына, Көнчыгыш Европада ислам динен өйрәнүгә карый. В.В.Бартольд, А.Е.Крымский, И.Ю.Крачковский, В.И.Беляев хезмәтләрен басмага әзерли. Тарихчы М.Г.*Госманов* б-н берлектә болгар галиме *Та җәтдин бине Юныс әл-Болгаринең «әт-Тирьяк әл-кәбир»* («Агуланулардан көчле дәва», дару әзерләү буенча трактат, 13 йөзнең 1 нче яртысы) исемле кулъязма хезмәтен фәнни әйләнешкә кертә. Ул Х. тәрҗемәсендә һәм аның шәрехләмәләре б-н 1997 дә Казанда «Зур тирьяк» исеме б-н басыла.

Х е з м.: Арабские рукописи и арабская рукописная традиция. М., 1985; Словари Исхака ал-Фараби и Махмуда ал-Кашгари. М., 1987.

Әд.: З а й н у л л и н Г.Г. Анас Бакиевич Халидов. 1929–2001. К., 2003.

ХАЛИ́ДОВ Әхмәт Бакый улы (14.3.1935, Казан — 14.12.2010, шунда ук), энтомолог, биол. фән. д-ры (1990), проф. (1992), ТРның атказ. фән. эшлеклесе (1997). К.А.Тимирязев исем. а.х. академиясен тәмамлаганнан соң (Мәскәү, 1958), Татарстан Республика а.х. тәжрибә станциясендә эшли, 1961–62 елларда Яңа Чишмә р-ны «Кызыл Октябрь» с-зында агроном. 1966 дан Казан ун-тында, умырткасызлар зоологиясе каф. профессоры (1991 дән). Хезмәтләре фаунага һәм туфракта яшәүче умырткасыз хайваннар экологиясенә, лицетобионт бөҗәкләр комплексларын өйрәнүгә карый. Х. тарафыннан беренче тапкыр югары төзелешле гөмбәләр б-н бәйле икеканатлы бөҗәкләр фаунасы ачыклана, урманнарда аларның биоценотик роле билгеләнә. «Гомуми энтомология буенча практикум» («Практикум по общей энтомологии», 1988) уку-укыту методик ярдәмлеге авторы. «Татар энциклопедия сүзлеге»н («Татарский энциклопедический словарь») төзүгә зур өлеш кертә (Татарстанның умыртасыз хайваннарына караган мәкаләләр авторы). «Русча-татарча, татарча-русча биология терминнары сүзлеге»н («Русско-татарский, татарский-русский словарь биологических терминов», кит. 1–5, 1996–2001) төзи.

Х е з м.: Насекомые — разрушители грибов. К., 1984; Практикум по курсу зоологии (членистоногие, иглокожие). К., 1987 (автордаш).

ХАЛИ́ДОВ Бакый Закир улы (9.3.1905, Сембер губ., Буа өязе Казма а. — 23.1.1968, Ташкент), тел галиме, шәркыятьче галим, филол. фән. канд. (1952), Казан ун-тының физика-матем. ф-тын тәмамлаганнан соң (1941), Ташкент астрономия обсерваториясендә эшли. Төркестан Хәрби округында (Иран) тәрҗемәче. 1947 елдан Ташкент ун-тында, 1953–56 дан — иран-әфган, 1958 дән гарәп филологиясе кафедралары мөдире. Хезмәтләре иран һәм гарәп тел белеменә карый. Югары уку йортлары өчен гарәп теле дәрес-лекләре авторы.

Х е з м.: Учебник арабского языка. Таш., 1977; Очерки истории арабской культуры. М., 1982; Фонетика и письмо арабского языка. Махачкала, 2000.

ХАЛИ́КОВ Альфред Хәсән улы (30.5.1929, хәзер Нурлат р-ны Кизләү а. — 24.7.1994, Казан), археолог, тарихчы, тарих фән. д-ры (1966), ТР ФА мөхбир әгъзасы (1992),

ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1974). Казан ун-тын тәмамлый (1952). 1951–94 елларда РФА КГУнең Тел, әдәбият, һәм тарих ин-тында: директор урынбасары (1962 дән), археол. бүлеге мөдире (1965–88), баш гыйльми хезмәткәр (1990–94). Бер үк вакытта Казан ун-ты профессоры. Олы Тархан каберлегендә, Биләр шәһәрлегендә, Казанда, Алабугада археол. казу эшләре алып бара (Е.А.*Халикова* б-н бергә *Казан яны культурасын* аерып чыгара), 12 йөз гарәп географы әл-Идриси картасы буенча мәгълүм борынгы Болгар-Киев сәүдә юлларын тарихи-археол. яктан тикшеренүләр (Украина галимнәре б-н бергә) уздыра; Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычлары тәэсирендә җимерелүче археол. истәлекләрне саклап калу буенча систематик эшләр оештыра; урта гасырлар Биләр шәһәре һәм аның тирә-ягы, Казан Кремле терр-яләрендә музей-саклаулыклар оештыруга башлангыч бирүчеләрнең берсе. Х. җитәкчелегендә беренче тапкыр болгар истәлекләрен аэрофотога төшерү гамәлгә ашырыла. Таш гасырдан алып Рус дәүләтенә кушылганчыга кадәрге дәвердә Урта Идел буе һәм Урал алды төбәге халыкларының социаль үсеше фәнни концепциясен эшләүгә зур өлеш кертә. Хезмәтләре Көнчыгыш Европаның төрки телле һәм фин-угор халыклары археологиясенә, борынгы һәм урта гасырлар тарихына, ш.и. татарларның килеп чыгышына, Идел буе Болгар дәүләте һәм Алтын Урда тарихына карый. «Татарстан Республикасының археологик картасы»н («Археологическая карта Республики Татарстан», Т. 1–6, 1981–90) эшләүдә һәм төзүдә катнашуы өчен ТР Дәүләт бүләгенә лаек була (1994). Медальләр б-н бүләкләнә. Алексеев р-ны Биләр авылындагы урам Х. исемен йөртә, Казандагы ул яшәгән йортка мемориаль такта куела.

Х е з м.: Древняя история Среднего Поволжья. М., 1969; Волго-Камье в начале эпохи раннего железа. М., 1977; Приказанская культура. М., 1980; Татарский народ и его предки. К., 1989; Булгар-Киев: пути, связи, судьбы. Киев, 1997 (автордаш); Монголы, татары, Золотая Орда и Булгария. К., 1997; Altungarn an der Kama und im Ural: Das Graberfeld von Bolschie Tigani. Bdpst., 1981 (автордаш).

Әд.: К у з ь м и н ы х С.В., С т а р о с т и н П.Н., Х у з и н Ф.Ш. Альфред Хасанович Халиков. К., 1999; Альфред Хасанович Халиков: учёный и учитель. К., 2009.

ХАЛИ́КОВ Габделхак Әбҗәлил улы (9.2.1931, БАССРның Гафури р-ны Корман-тау а. — 30.9.2007, Уфа), нефтьче, техник фән. д-ры (1972), Башкортстан Респ-касы ФАнең мөхбир әгъзасы (1991), БАССРның атказ. фән. эшлеклесе (1979). Уфа нефть ин-тын (1956), Удмурт ун-тын (1979) тәмамлый. Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тында (1958–62), Казакъстан политех-ник ин-тында (1962–72, 1984–91) эшли, Башкорт ун-тының физик гидродинамика кафедрасын җитәкли (1973–83 һәм 1991–2001), проф. (1973). Хезмәтләре фильтрлау, күләмле җылылык күчерү теориясенә, нефть һәм газ чыгаруга карый. Х. грунтның термоэрозия күренешләре модельләрен, ирекле параболик типтагы чикле тигезләмәләрне чишүнең



А.Х. Халиков.



И.Ш. Халиков.



И.Р. Халиков.



Ф.Г. Халиков.

якынча алымнарын эшли. Күп фазалы агым вакытында күчү зонасы барлыкка килү динамикасын тикшерә, катламнардагы аерым урыннарны газдан арындыру теориясен тәкъдим итә. Медальләр, ш.и. СССР ФАнең акад. П.Л.Капица исем. медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Термоэрозия дисперсных пород. М., 1982 (автордаш); Физико-химическая механика переходных процессов. Уфа, 1995.

Әд.: М е л у а А.И. Геологи и горные инженеры. Нефтяники. М.–СПб., 2003. Т. 2; Башкирская энциклопедия. Уфа, 2011. Т. 7.

ХАЛИ́КОВ Илдар Шәфкать улы (21.11.1967, Әгерҗе ш.), дәүләт эшлеклесе. Казан ун-тын тәмамлый (1993). 1993–95 елларда «Чаллыбанк» акц. коммерция банкы идарәсенең (Чаллы) әйдәп баручы белгече, башлыгы. 1995–2003 тә «КамАЗ» АҖдә: 1996 га кадәр идарә башлыгы урынбасары, 1996–97 дә финанс директоры, 1997 дән ген. директор урынбасары. 2003–06 да Чаллы шәһәре хакимияте, 2006–10 да «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге хакимияте башлыгы. «КамАЗ» АҖ бурычларын реструктуризацияләүдә катнаша. Халыкның милли үзенчәлекләрен исәпкә алып, Чаллы шәһәрен Европа форматындагы мегаполиска әверелдерү идеясен тәкъдим итә. Сәнәгать үсешенә, шәһәрдә күпләп торак йортлар һәм социаль-мәдәни объектлар төзүгә өлеш кертә. 2010–17 дә ТР Премьер- министры. 2017 дән «Татэнерго» идарә компаниясе» АҖ ген. директоры. Почёт ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: Энциклопедия города Набережные Челны. К., 2007.

ХАЛИ́КОВ Ислам Рәхим улы (15.11.1918, Самара губ., Бөгелмә өязе Иске Шөгер а. — 29.8.1944, Украина ССРның Одесса өлкәсе Сарата штп), Сов. Союзы Герое (24.3.1945, үлгәннән соң), өлкән сержант. 1935–38 елларда Шөгер битум з-дында эшли. 1939 дан Кызыл Армиядә. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 83 нче диңгез укчы бригадасы аерым танкка каршы артиллерия дивизионының туп командиры (46 нчы армия). 3 нче Украина фронты гаскәрләре составында Новороссийск (1943), Ялта (1944), Севастополь (1944) шәһәрләре өчен барган сугышларда катнаша. 1944 нең 29 августын да Успенка авылы (Одесса өлкәсенең Сарата р-ны) өчен барган сугышта батырлык күрсәтә: Х. җитәкчелегендәге туп расчёты дошманның күпсанлы тере көчләрен һәм хәрби техникасын юк итә; Х. сугышта һәлак була. Ленин ордены, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медаль б-н бүләкләнә. Туган авылында Х. музее ачыла. Шөгер битум з-дында Геройга мемориаль такта куела. Шәһәр тибындагы Сарата посёлогындагы һәм Лениногорск шәһәрендәге урамнарга Х. исеме бирелә; Лениногорск шәһәрендә Геройлар аллеясында обелиск куела.

Әд.: Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

М.З.Хәбибуллин.

ХАЛИ́КОВ Наил Альфред улы (29.10.1951, Казан), тарихчы, этнограф, тарих фән. канд. (1980), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2003). Казан ун-тын тәмамлый (1974). 1977–96 да СССР РФА Казан ф-лында, РФА КГУдә (1985 елдан фәнни хезмәткәр), 1997 дән ТР ФАнең Тарих ин-тында. Хезмәтләре ху җалык культурасына, Идел буе, Урал һәм Себер татарларының традицион авыл торак пунктлары һәм эшмәкәрлек тарихына карый. 19 йөз уртасы — 20 йөз башы татар халкы кәсепләрен тикшерүгә мөһим өлеш кертә. Дәүләт бүләге «Татарлар» («Татары», М., 2001) коллектив монографиясен эшләүдә катнашканы өчен бирелә.

Х е з м.: Земледелие татар Среднего Поволжья и Приуралья XIX — начала XX вв.: Ист.-этногр.исслед. М., 1981; Хозяйство татар Поволжья и Урала (середина XIX — начало XX вв.). К., 1995; Промыслы и ремёсла татар Поволжья и Урала (середина XIX — начало XX вв.). К., 1998; Земледелие. Промыслы // История татар с древнейших времён. В 7 томах. К., 2006. Т. 2.

ХАЛИ́КОВ Фиринат Гаптухай улы (28.8.1957, Украина ССРның Донецк ш.), рәссам, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2001), Россия СА мөхбир әгъзасы (2012). Киров сәнгать уч-щесен (1984), Х.Г. Якупов җитәкчелегендә Россия САнең нәкышь иҗат остаханәсен (1996) тәмамлый. Мәскәүдәге Җамигъ мәчетнең баш рәссамы (2009). СССР Рәссамнар берлеге (1989), «Москворечье» иҗат берләшмәсе (1988–93) әгъзасы. РСАнең Казандагы Иҗат остаханәләре җитәкчесе (2014 тән). Академик реализм традицияләрендә эшләүче, тарихи жанр тематикасы картиналары остасы, әйдәп баручы рәссамнарның берсе. Башта пейзажга мөрәҗәгать итә, «Үлеп баручы авыл» (1982–93) картиналар сериясен иҗат итә. 1992 елда Казанга күченеп килә, иҗатында төбәкнең урта гасырларга караган тарихын сәнгатьтә чагылдыруга багышланган яңа этабы башлана. Монда археолог А.Х.Халиков мөһим роль уйный — аның фәнни хезмәтләрен иллюстрацияләр б-н бизәү өчен Х. Болгар шәһәренә багышланган графика эшләре (акварель, гуашь) циклы башкара (басылмаганнар) — «Алмыш хан»,



Ф.Г.Халиков.
«Казанда Зоя Космодемьянская урамы». 1994.

«Болгардагы Кара пулат», «Төньяк мавзолей», «Иерусалим ермагы» (барысы да — 1993), «Шайтан каласы» (1994) һ.б.ны иҗат итә. 1994 тән Х. сюжетларны сурәтләүдә калыплашкан кануннар һәм Казан ханлыгының сәнгатьчә елъязмасын иҗат итү б-н мавыга, масштаблы тарихи һәм тематик жанрда күп фигуралы картиналар һәм архитектур пейзажлар иҗат итү өчен әдәбият, археол., сәнгать һ.б. буенча мәгълүмат туплый. Алар барысы да Казанның барлыкка килүеннән башлап, 16 йөз уртасында җимерелүенә кадәрге тарихын сурәтләүгә багышланган циклга берләштерелә: «16 йөздә Арча кырыннан Казан күренеше», «Болак ягыннан кышкы Казан күренеше», «Ханның чыгуы» (барысы да — 1996); «16 йөздә Казан күренеше», «Борынгы Кремль» (икесе дә — 2000), «Иртә язда Казан Кремленең эчке ягы», «1552 елгы октябрь вакыйгалары», «Казанны саклаучыларга багышлана. Реквием» (барысы да — 2001), «Казның ярдәмгә килүе», «Кышкы иртә» (икесе дә — 2003), «Без тарихта эзлебез» (2007). Х.ның баталь жанрдагы зур форматлы «Казан өчен сугыш» (1996) картинасы ТР сынлы сәнгатендә шул юнәлештәге иң беренче әсәрләрнең берсе. Ханлык дәвере башкаласының чәчәк аткан чорларына караган синтезлашкан образы «Нурлы Казан» дивар монументаль панносында гәүдәләнде -



Ф.Г.Халиков. «16 йөздә Казан күренеше». Кәгазь. Акварель. 2000. «Казан» милли мәдәният үзәге.

релгән (1997, «Казан» милли мәдәният үзәгенең музей экспозициясе залы). Х. эшләреннең бер өлеше 16 картиналы «Мәңгелек Казан» сериясенә берләштерелә. Аңа киң панорамалы һәм күп сюжетлы күренешләр б-н бергә тарихи шәхесләр б-н бәйле вакыйгаларга багышланган картиналар да керә: «Сөембикәнең хушлашуы», «Шаһгали һәм Иван Грозный Казан янында», «Олуг Мөхәммәд», «Ядегәр ханның бирелүе» (барысы да — 1998), «Сөембикә һәм Утәмеш» (2007) һ.б. Акварель, гуашь, карандаш б-н башкарылган картиналар һәм эскизлар циклы иҗаты ның аерым бер төркемен хасил итә: «Болгар һәм Казан» (1995), «Казанның башлангычы» (1997), «Казан 10 йөздә», «16 йөздә кышкы Казан күренеше» (икесе дә — 1998), «Сөембикә кәнәфие» (2000), «Кышкы Казан бистәсе», «Хач күтәрү» (икесе дә — 2001), «Казан Кремле. Соңгы сугыш» (2002).



Ф.Г.Халиков. «Сөембикәнең хушлашуы». Фрагмент. 2003.

Казан, Болгар күренешләре б-н пейзажлар: «Кызыл йорт», «Мәржани мәчете», «Казанда Зоя Космодемьянская урамы», «Алтын кич» (барысы да — 1994), «Казандагы ишегалды» (1995), «Болгар иртәсе», «Болгарда Көнчыгыш төрбә» (икесе дә — 2003); портретлар: «Җилпәзә белән портрет» (1993), «Света верандада», «Люда. Милли кием «Сүрәкә», «Татьяна Розенберг портреты» (барысы да — 1994); натюрморт һәм интерьерлар авторы. Казан метрополитенында «Тукай» һәм «Кремль» станцияләрен бизәү эскизларын, Казанда «Колшәриф» мәчете интерьерларын, Алабуга шәһәренә нигез салган Ибра һим хан һәйкәлен (автордаш М.М. Гасымов) эшләүдә катнаша, Мәскәүдә яңа Җамигъ мәчет фасадлары һәм интерьерлары дизайн-проекты (2008 дән), Болгарда яңа Җамигъ мәчет (2009) интерьерлары авторы, «Цивилизация һәм меңьеллыклар кисешкән дә» документаль фильмының 4 нче сериясе куючы-рәссамы (2005).

Өлкә — (Киров ш., 1982–88); төбәкара — «Совет Төньягы» (1984, 1989), «Россия яшьлеге» (1989), «Зур Идел» (2003); «Москва - речье» рәссамнар берләшмәсе (Мәскәү, 1988–93), Познань шәһәрендә (Польша) халыкара күргәзмә-ярминкәдә, Вюнсдорф (ГДР) шәһәрендә совет сәнгате күргәзмәсендә (икесе дә — 1989); бөтенроссия — «Ватаны саклаучыларга» (Мәскәү, 1990), «Борынгы Казан» (Казан, 1999); «Ислам кабул ителүнең 1400 еллыгы» (Мәскәү, 2000), «Ислам сәнгате» (Пиза ш., Италия); Казанның 1000 еллыгына (Мәскәү, 2005), Россия САнең 250 еллыгына (лауреат, Саратов ш., С.-Петербург, 2007) күргәзмәләрендә катнаша. Мәскәү, Будапешт, Пиза, Истанбул, Хельсинки, Парижда ЮНЕСКО штаб-квартирасында һ.б.да узган 70 тән артык күргәзмә проектларының авторы һәм катнашучысы. Шәхси күргәзмәләре 1988 (Советск ш.), 1994 (Йошкар-Ола ш.), 1995 (Киров ш.), 1996, 2002, 2005, 2006, 2008 (Казан), 2017 дә (Мәскәү) уздырыла. Картиналары Рус музеенда (С.-Петербург), Тарих музеенда (Мәскәү), ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәгендә, ТР Милли музеенда, Мари Респ-касы Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Киров шәһәре Бертуган Васнецовлар исем. сәнгать музеенда һ.б.да саклана. ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (2006). Медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: Мамаева Т. Сказания о земле Казанской: Островки любви и надежды художника Фирината Халикова // Казань. 1998. № 2; Фиринат Халиков. Живопись. Графика. Скульптура. Дизайн. К., 2012; Шагеева Р., Магдеев Р. Фиринат Халиков. М., 2017.

Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.

ХАЛИ́КОВ Хәкимҗан Шәяхмәт улы (16.1.1933, Әтнә р-ны Мамыш а. — 12.2.2002, Казан), шагыйрь, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1984). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1960), Әтнә р-нының Иске Өҗем мәктәбендә укыта. 1963 елдан Казанда яши. «Ялкын» ж-лында, «Яшь ленинчы» (1972 дән) г-тасында бүлек мөдире, Татарстан Язучылар берлегенең матур әдәбиятны пропагандалау бюросы мөдире (1979 дан), «Идел» альманахы мөхәррире (1981 дән), «Мәгариф» ж-лының бүлек мөхәррире (1983–99). Беренче шигырьләре вакытлы матбугатта 1960 елларда басыла. Х. балалар өчен төрле жанрларда яза: санамышлар, тизәйткечләр, табышмаклар, җырлар, әкиятләр. Х. мәңгелек кыйммәтләр, кеше яшәешенең төп закончалыклары, табигатькә сакчыл мөнәсәбәт, яхшылыкның яманлыктан өстен булуы, бәхет турындагы уй-хисләрен образлы һәм эмоциональ рәвештә, балалар аңларлык формада үзенең яшь укучысына җиткерә белә. «Йолдызлар ничәү?» (1969), «Шук бабай» (1970), «Тынычлык гөле» (1971), «Энәбикә» (1973), «Озын колаклы батыр» (1974), «Эшләпәле дуслар» (1976), «Конфет агачы» («Конфетное дерево», рус теленә тәрҗемәдә, 1977), «Иң шатлыклы көнем» (1983), «Канатлы мәче» (1989), «Зиһен ачкычлары» (1993), «Сакчы күркә» (1997), «Сакаллы малай» (2002), «Иң гадел дус» (2005), «Канатлы куян» (2007) җыентыклары авторы.

Әд.: Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

ХАЛИ́КОВА Елена Александровна (28.8.1930, Горький ш. — 24.6.1977, Казан), археолог, тарих фән. канд. (1976). Горький ун-тын тәмамлаганнан соң (1953), Горький өлкә төбәкне өйрәнү музеенда эшли. 1960 елдан ТАССР Дәүләт музеенда, 1968 дән Казан пед. ин-тында укытучы, бер үк вакытта Казан ун-тының археол. музее мөдире. Археол. тикшеренүләрен Х. 1950 елларда Мари

экспедициясендә А.Х.*Халиков* җитәкчелегендә башлап җибәрә. Җитәкчеләрнең берсе буларак, Х. *Биләр шәһәрлегендә, Зур Тигәнәле каберлегендә, Танкеевка каберлегендә* һәм Урта Идел буендагы башка археол. истәлекләрдә казуларда катнаша (А.Х.Халиков б-н бергә *Казан яны культурасын* аерып чыгара). Хезмәтләре Идел буе болгарларының мөселман каберләрен, Урта Идел буе һәм Урал алды төбәгенең борынгы венгрлар мирасын өйрәнүгә карый.

Х е з м.: Мусульманские некрополи Волжской Булгарии X — начала XIII вв. К., 1986; Le cimetiere de Tankeevka // Le anciens Hongrois et les ethnies voisines a l'Est. Bdpst., 1977 (автордаш); Altungarn an der Kama und im Ural (Das Graberfeld von Bolschie Tigani). Bdpst., 1981 (автордаш).

Әд.: Елена Александровна Халикова // Советская археология. 1978. № 1.

Е.П.Казаков.

ХАЛИ́Т (Халитов) Гали Мөхәммәтгали улы (26.6.1915, Казан губ., Тәтеш өязе Үтәмеш а. — 24.8.1992, Казан), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1968), ТАССР һәм РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1975, 1981). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1936), Арча пед. уч-щесендә укыта. 1942 елдан РФА КГҮнең Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында. Г.Тукай, М.Гафури, Г.Ибра һимов, Һ.Такташ иҗатларын; 20 йөз башы татар әдәбиятын, иҗтимагый-сәяси һәм милли-азатлык хәрәкәте б-н тыгыз бәйләнештә аның идея-эстетик үзенчәлеген; иҗади алымнарның (мәгърифәтчелек һәм тәнкыйди реализм, романтизм, романтик реализм) эволюциясен өйрәнә. Хезмәтләре 20 йөз башы һәм 1920–30 еллар татар поэзиясе тарихына карый.

Х е з м.: Татар әдәбиятында реализм мәсьәләләре. К., 1948; Кешегә һәм чынлыкка мөхәббәт белән. К., 1975; Яңа гасыр поэзиясе. К., 1979; Тукай и его современники. К., 1966; Поэзия дерзаний. К., 1980; Многоликая лирика. К., 1990.

Әд.: Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

ХАЛИ́ТОВ Иттаки Габделхәй улы (23.12.1919, Актаныш р-ны Чөгәнә а. — 19.4.2005, Казан), виолончелист, педагог, кыллы музыка уен коралларын ясау һәм реставрацияләү остасы. 1941 елда — Казан музыка уч-щесен, 1950 дә Казан консерваториясен (А.Броунда виолончель классы) тәмамлый. 1949–68 дә Казан музыка уч-щесендә, бер үк вакытта, 1956–79 да, Казан консерваториясендә укыта. 1975–79 да Казан консерваториясе каршындагы махсус урта музыка мәктәбе директоры. Актив концерт эшчәнлеге алып бара, грампластинкаларга языла. Татар композиторларының виолончель өчен язылган күп кенә әсәрләрен беренче булып башкаручы. Борынгы һәм сирәк очрый торган (ш.и. итальян) музыка уен коралларын (скрипка, виолончель, альт) ясау һәм реставрацияләү б-н шөгыльләнә. П.И.Чайковский исем. 19 нчы Халыкара конкурс кысаларында скрипкада уйнау остала-ры конкурсы дипломанты (Мәскәү, 1990). Бөек Ватан сугышында катнаша. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Ф.Ш.Салитова.

ХАЛИ́ТОВ Нияз Ха жи улы (8.12.1950, Казан — 8.8.2017, шунда ук), архитектор, архит-ра д-ры (1992), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2000). Казан төзүче инженерлар ин-тын тәмамлаганнан соң (1974), СССР ФА КГҮнең Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында эшли. 1982–85 елларда «Росреставрация» берләшмәсенең Татарстан махсус фәнни реставрация җитештерү остаханәсендә. 1985 тән СССР Архитекторлар берлегендә. 1988–90 да ТАССР Госстроеның Архит-ра һәм шәһәр төзелеше үзәгендә тарих-архит-ра бүлеге башлыгы. 1993–94 тә ТР ФАнең Социаль-икътисад һәм хокук фәннәре ин-тының мәдәният, архит-ра һәм сәнгать бүлеге мөдире, 1995 тән «Казан Кремле» музей-саклаулыгы директорының фәнни эшләр буенча урынбасары, фәнни эшләр бүлеге мөдире, 2007 дән ТР ФА Тарих ин-тының баш фәнни хезмәткәре. Бер үк вакытта, 2009 дан, Казан архит-ра-төзелеш ун-тында укыта. Чистай, Лаеш шәһәрләре тарихи үзәкләренең саклаулы зонасын һәм төзелешен көйләү проектлары авторы. Шамил һәм Апанаев йортларын, Казанда Солтан мәчетен реставрацияләү проектлары һ.б. авторы. Хезмәтләре архит-рада милли лилек теориясе, ислам тарихы, төрки һәм татар архит-расы мәсьәләләренә карый. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Очерки по архитектуре ханской Казани: Гипотезы. Факты. Размышления. К., 1999; История начинается с Кремля. К., 2005; Мечети средневековой Казани. К., 2011; Татарская мечеть и её архитектура: историко-архитектурное исследование. К., 2012.

ХАЛИ́ТОВ Рәгъдә Фатих улы (17.2.1942, Әгерҗе ш.), баянчы, этноорганолог, педагог, сәнгать фән. канд. (1987), проф. (1998), ТАССРның һәм РФнең атказ. сәнгать эшлеклесе (1983, 1998). РФ югары һөнәри мәктәбенең мактаулы хезмәткәре. Казан пед. ин-тының музыка-пед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1964), шунда ук укыта: 1985–2000 елларда музыка ф-ты деканы, бер үк вакытта музыка уен кораллары (1998–99), татар музыка сәнгате (2006–09), музыка уен кораллары һәм татар музыка сәнгате (2009–11) кафедралары мөдире; 2011 дән Казан ун-тының Филол. һәм сәнгать ин-тында: Идел буе халыклары сәнгате каф. мөдире (2011 дән). Җырчылар һәм музыка уен кораллары-нда уйнаучылар ансамблендә солист һәм концертмейстер буларак концерт эшчәнлеге алып бара. Татар традицион музыка уен кораллары-нда уйнауны яңадан тергезүгә булышлык итә. Медальләр б-н бүләкләнә.

Ф.Ш.Салитова.

ХАЛИ́ТОВ Рәхим Хәсән улы (21.5.1917, Казан губ., Цивильск өязенең Бакырчы а. — 29.3.1989, Казан), инженер-технолог, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1951). Лысьва механика техникумын тәмамлый (Пермь өлкәсе, 1935), 1938–40 елларда Казан химия-технол. ин-тында укый. 1931–35 тә Пермь өлкәсенең сәнәгать пр-тиеләрендә эшли. 1935–38, 1946–83 тә Казан мех комб-тында: хронометражчы, нормалаучы, башлыгы, партком секретаре (1950 дән), 2 нче ф-ка мөдире, директоры (1957 дән). Дәүләт бүләге сарык тиресенең йон катламын нәфис эшкәртүнең яңа алымын эшләүдә һәм сәнәгатькә кертүдә катнашканы өчен бирелә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.



Г.М. Халит.



Р.Ф. Халитов.

ХАЛИ́ТОВ Ринат Арифулла улы (8.6.1957, Чуаш АССРның Канаш ш.), дирижёр, педагог, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1997), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2009), проф. (2001). 1982 елда Казан консерваториясен (Т.Сөләймановта халык музыка уен кораллары классы, С.Хәбибуллинда дирижёрлык классы) тәмамлый. 1983 тән Казан консерваториясендә укыта: 1996 дан проректор, 1993 тән «Tatarica» халык музыка уен кораллары оркестрының сәнгать җитәкчесе һәм дирижёры. Аның б-н ул Россия шәһәрләренә һәм чит илләргә (Финляндия, Балтыйк илләре, Нидерланд, Германия һ.б.) гастрольләргә чыга. Оркестр репертуарын Казан, Кырым, Себер һәм Әстерхан татарларының халыкчан һәм заманча музыкасы, Шәрекъ мөселманнарының традицион музыкасы, рус, Көнбатыш Европа, Латин Америкасы музыкасы һ.б. тәшкил итә. «Tatarica» оркестры Кастельфидардо (Италия, 1995, 1нче бүләк), Страсбург (Франция, 1997, Гран-при) һ.б. шәһәрләрдә узган халыкара конкурс һәм фестивальләрдә бүләкләргә лаек була; язмалар «Татарстан» дәүләт телерадиокомпаниясенең фонограмма фондына кертелгән. Х., симф. дирижёр буларак, концерт эшчәнлеге алып бара. Укучылары арасында Р.Сөләйманов, Ф.Вәлиев, Л.Куликова, М.Бабушкина, О.Лялина, Е.Титова, А.Шәрәфетдинов һ.б. бар. Казан консерваториясе базасында халыкара, бөтенроссия һәм төбәк музыкант-башкаручылар конкурсларын оештыручыларның берсе.

Ф.Ш.Салитова.

ХАЛИ́ТОВ Рифкать Габдрахман улы (6.9.1950, Казан), химия технологиясе аппаратлары һәм процесслары өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2004). 1973 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлый, шунда ук химия з-дларын җ һазлары кафедрасында эшли (1975 тән). 1973–75 елларда Казан химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында. Хезмәтләре химик процесслар ны интенсивлаштыру максатында нитрокушылмалар җитештергәндә файдаланылган к-таларны регенерацияләүне, кальцийлаштырылган сода җитештерүдә аммиакны һәм углерод диоксидын абсорбцияләүне; күкерт к-тасын күп тоннажлы итеп җитештерүдә күкертнең өчле оксидын абсорбцияләүне интенсивлаштыру, ш.у. аерылучы газларны чәчрәмә судан, пардан һәм кислота томанынан чистарту өчен техно-



Р.К. Халитов.



Ф.И. Халитов.

логияләр һәм югары нәтиҗәле өермә аппаратлары эшләүгә карый. Уйлап табуга 9 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Аерылучы газларны токсик матдәләрдән чистартучы комплекс системасын эшләүдә һәм аны Эстәрлетамак «Авангард» ҖБдә гамәлгә ашыруда катнашканы өчен СССР Дәүләт бүләгенә лаек була (1991).

Х е з м.: Энерготехнологическое комбинирование в производстве нитроэфиров // Промышленная энергетика. 2000. № 1 (автордаш); Вихревая малоотходная технология концентрирования серной кислоты // Вестн. Белгород. технол. ун-та. 2004. № 8 (автордаш).

ХАЛИ́ТОВ Рөстәм Касыйм улы (30.10.1920, Казан — 22.5.1981, шунда ук), Дан орденының тулы кавалеры (10.11.1944, 5.2.1945, 16.6.1945; 1956 елның 31 мартында 1 нче дәрәҗә орден б-н кабат бүләкләнә), гв. старшинасы. 1941 нең июненнән Кызыл Армиядә. В.И.Ленин исем. 1 нче Ульянов бронетанк уч-щесен тәмамлагач (1943), шунда ук инструктор булып эшли. 1944 нең октябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 37 нче гв. танк бригадасының (46 нчы армиянең 2 нче гв. механикалаштырылган корпусы) танк механик-йөртүчесе. 2 нче һәм 3 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Будапешт (1944–45) һәм Вена (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 1 ноябрендә Кечкемет (Венгрия) шәһәреннән 16 *км* төньяктарак барган сугышларда (тягачы б-н дошманның 2 тубын, штаб автобусын, 10 лап солдатын юк итә), 1944 нең 24 декабрендә Будапешт шәһәре өчен барган сугышларда (экипаж составында 2 танкны, 3 танкка каршы тупны сафтан чыгара, дошманның бер отделениедән күбрәк солдатын юк итә), 1945 нең 28 мартында Дьёр шәһәре (Венгрия) янындагы разведка операциясендә (танкы б-н шәһәргә беренче булып бәреп керә, экипаж составында гы урам сугышларында дошманның авыр танкын, 2 штурм һәм 3 танкка каршы атучы тубын сафтан чыгара, күп кенә солдат һәм офицерларын юк итә) батырлык күрсәтә. Кызыл мәйданда Жиңү Парадында катнаша (1945 нең 24 июне). Демобилизацияләнгәч (1946), туган җиренә кайта. Казан авиация ин-тын тәмамлый (1954), Арча МТСында баш механик, соңрак Казан пр-тиеләренең берсендә мастер һәм цех башлыгы булып эшли. Сугыш ветераннары ком-тының Казан секциясе президиумы әгъзасы. Медальләр б-н бүләкләнә. Казанның бер урамы Х. исемен йөртә.

Әд.: Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

М.З.Хәбибуллин.

ХАЛИ́ТОВ Фәрит Госман улы (31.1.1946, Казан), физик химия белгече, химия фән. д-ры (2000), проф. (2007). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1969), СССР ФА Казан ф-лының Органик һәм физик химия ин-тын да эшли. 1982–94, 1996–2001 дә Казан технол. ун-тында, 1994–96 елда Бөтенроссия углеводород чималы фәнни-тикшеренү ин-тын да. 2001 дән Казан энергетика ун-тында: Җылылык энергетикасы ин-ты директоры (2004 тән), җылылык техникасының теоретик нигезләре каф. мөдире (2006 дан). Хезмәтләре фосфор һәм мышьяк органик кушылмалар стереохимиясенә карый. Х. мышьяк органик кушылмаларының конформацион төзелеше закончалыкларын билгели. Төрле изомерларларның тигезләнешле катнашмасындагы нәсимметрияле кушылмаларның диполь моментларының график алымын эшли. Молекулалар ионлашуның беренче потенциаллары б-н аларның валент почмаклары, диполь моментлары һәм молекулаара үзара тәсирләшү энергияләре арасындагы үзара микъдари бәйләнешләрен ачыклый.

Х е з м.: Заторможенное вращение в ациклических производных мышьяка // Конформационный анализ элементоорганических соединений. М., 1983; О графическом анализе дипольных моментов конформационно равновесных систем // Изв. АН СССР. Сер. хим. 1987. № 8 (автордаш); Векторный анализ дипольных моментов и строение ароматических производных мышьяка. К., 2004.

ХАЛИ́ТОВ Фуад Ибраһим улы (9.2.1909, Казан — 15.3.1981, шунда ук), драма актёры, ТАССРның, РСФСРның һәм СССРның халык артисты (1956, 1957, 1975). Сәхнә эшчәнлеген Казан мех ф-касында һәвәскәр эшчеләр коллективында башлап җибәрә, 1932 елда Татар сәнгать эшче театры труппасына керә, анда проф. осталык күнекмәләре ала. Театры ябылганнан соң, 1937 дә Татар акад. театры труппасына кабул ителә. Сәхнәдә үзен табигый тотуы, күзәтүчәнлеге, Ә.Г.*Мәҗитов* җитәкчелегендәге эшче театрында саран сәнгать чаралары ярдәмендә образ тудыру осталыгы аңа труппаның әйдәп баручы актёрларыннан берсе булу мөмкинлеген бирә. Х.ның Незнамов («Гаепсездән гаеплеләр», А.Н.Островский, 1939), Герман («Таня», А.Н.Арбузов, 1939), Ромео («Ромео и Джульетта», У.Шекспир, 1940), Сәлим («Күзләр», Х.Фәтхуллин, 1940) кебек беренче яшь герой рольләре романтик пафосы һәм тормышчанлыгы б-н аерылып тора. Кент («Король Лир», У.Шекспир, 1944), Скроботов («Дошманнар», М.Горький, 1946) рольләрендә актёр иң элек геройларының социаль асылын ача. Бу М.Әмирнең «Миңлекамал» (1944) драмасы буенча куелган спектаклдә Х.ның колхоз милкеннән файдаланып калырга тырышкан байлык җыючы Хәлим образында аеруча ачык чагыла. Н.Ф.Погодинның «Мылтыклы кеше» әсәре буенча Ш.М.Сарымсаков тарафыннан 1947 дә куелган спектакльдәге Шадрин роле Х.ның ижади эшчәнлеге үсешенә зур этәргеч бирә. Аның башкаруында әлеге образ башта үз ху җалыгы турында гына кайгыртучы бәйләнчек, гаугачыл ир-ат буларак күзаллана, В.И.Ленин б-н очрашканнан соң, рухи үсешкә ирешкән, үзен баш-ка масштабта — барлык Россия крәстиянәре вәкиле буларак кабул итүче кеше сыйфатында ачыла. Сәгъдетдин («Шамил Усманов», А.Гыйләҗев, А.Яхин; 1967) образында мохтаҗлыктан изелгән, әмма кешеләргә карата яхшы мөнәсәбәтен җуймаган хокуксыз татар крәстияне язмышы гәүдәләнә. Х. башкаруында сәүдәгәр Прибытков («Соңгы корбан», А.Н.Островский, 1968) образы төрле



Ф.И. Халитов Әһлиулла ролендә («Миләүшәнең туган көне», Т.Миңнуллин; Миләүшә – Н.Ихсанова).

яктан ачыла: актёр, аның характерын һәрьяклап яктыртып, тамашачыда бөтен нәрсәне дә акчага сатып алып булмый дигән фикер уятырга тырыша. Сатирик һәм комик характерлар иҗат иткәндә, Х. игътибарны җәлеп итәрлек, кайвакыт хәтта кискен фарс элементларыннан ышандырырлык итеп файдалана: Бики, Хуҗа («Хуҗа Насретдин», Н.Исәнбәт, 1940, 1952, 1957), Шәех мирза («Американ», К.Тинчурин, 1969), Расположенский («Агай-эне — ак мыек», А.Н.Островский, 1972) һ.б. Аеруча зур рольләре — Муса («Муса Җәлил», Н.Исәнбәт), Әһлиулла, Әхтәм («Миләүшәнең туган көне», «Ир-егетләр», Т.Миңнуллин), Миңлегали («Зәңгәр шәл», К.Тинчурин), Вано («Борчылма, әнием», Н.Думбадзе повесте буенча), Карлос Бланко («Канлы күләгәләр», Г.Бо-





Ф.И. Халитов: 1. Шадрин («Мылтыклы кеше», Н.Ф. Погодин); 2. Хуҗа («Хуҗа Насретдин», Н. Исәнбәт) рольләрендә.

ровик), Мәгънәви карт («Синең урыны һәр кайттым», Р.Хәмид) һ.б.

Әд.: Илялова И. Г.Камал театры артистлары = Артисты театра им. Г.Камала. К., 2005; Шул ук. Театр имени Камала. К., 1986; Народные артисты. К., 1980; Арсланов М.Г. Татарское режиссёрское искусство. 1941–1956. К., 1997.

И.И.Илялова.

ХАЛИ́ТОВ Яхъя Мөхәммәтгали улы (22.8.1929., Тәтеш р-ны Үтәмеш а. — 2.1.2016, Казан), тәрҗемәче, ТАССР һәм РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1980, 1990). Казан ун-тын тәмамлый (1952). 1955–76 елларда «Совет әдәбияты» ж-лында (бүленеп), 1976–89 да Татарстан китап нәшриятында мөхәррир. В.Каверинның «Два капитана» («Ике капитан», 1954), М.А.Шолоховның «Тихий Дон» («Тын Дон», 1962), «Поднятая целина» («Күтәрелгән чирәм», 1968), М.Галәүнең, 30 елларда репрессияләр вакытында татар телендәге оригиналы юкка чыгып, фәкать рус телендәге тәрҗемә китабы гына сакланып калган «Муть» («Болганчык еллар», 1968), М.Ридның «Всадник без головы» («Башсыз җайдак», 1971), А.Дюманың «Три мушкетёра» («Өч мушкетёр», 1979), Ю.Бондаревның «Горячий снег» («Кайнар кар», 1984) романнарын; Ч.Айтматов повестьларын (1976) рус теленнән татар теленә тәрҗемә итә.

Әд.: Мицлебаев К. Тәрҗемә үрләре // Казан утлары. 1979. № 6; Хәмидуллин Л. Үрнәк кеше // Ак төннәр хәтере. К., 2002.

ХАЛЫ́К, халыкның урнашуы, билгеле бер терр-ядә яшәүче кешеләр җыелмасы. Сан динамикасы, җенси структура, яше, шөгыле буенча, терр-я һәм торак пунктларда урнашуы, табигый хәрәкәтләр, миграция һ.б. күрсәткечләр б-н сыйфатлана.

2017 ел башына ТРда Х. саны 3885,3 мең кеше тәшкил итә. Х. саны буенча Татарстан, Мәскәү һәм Мәскәү өлкәсеннән, Краснодар крае, Санкт-Петербург, Свердловск һәм Ростов өлкәләре, Башкортстан Респ-касыннан калышып, РФ субъектлары арасында сигезенче урынны алып тора.

1926–2010 елларда халык санын исәпкә алу мәгълүматлары буенча Татарстанда Х. саны 1199 мең кешегә яки 46% ка арта. Х. саны тарихның төрле этапларында төрлечә үзгәрә: ул 1921 дәге һәм аннан соңгы елларда гы һәлакәтле корылык һәм ачлык нәтиҗәсендә, ш.у. Бөек Ватан сугышы елларында (сугышка кадәрге Х. саны хәтта 1959 дагы халык санын исәпкә алу вакытында да торгызылмаган була) шактый кими. 1970 елларда Х. санының тиз һәм тотрыклы үсүе күзәтелә, мо ңа Татарстанга Түбән Кама терр.-җитештерү комплексы объектлары төзелешенә чиктән мигрантлар килүе сәбәп була. Шәһәр халкы һәм респ-када яшәүчеләрнең гомуми санында аның өлеше өзлексез арта, авыл халкының саны кими.

1990 елларда Х. саны үсеше зур булмый — уртача елга 13,6 мең кеше яки 0,37%. 1992 дән ул башлыча мигрантлар агымы (к. *Халык миграцияседе*) бәрабәренә, 1993 тән фәкать мигрантлар исәбенә генә бара, чөнки үлүчеләр саны туучылар санын узып китә һәм халкның табигый кимүе башлана (к. *Халыкның табигый артуы*). 2000 нән ТРда Х. саны кими башлый. Х.ның табигый кимүенең төп сәбәбе — *туымның* шактый кимүе һәм *үлемнең* артуы. Туымның сизелерлек түбәнәюе 1990 елларда күзәтелә (шуңа охшаш күренеш 1970–1980 еллар башында була). 1000 кешегә туры килгән туучылар саны 1987 дә — 19,4, ә 1993 тә фәкатъ 9,3 кеше тәшкил итә. 1990 елларда туучыларның кимүе аз санлы «сугыш чоры оныклары» буынының никахлашу яшенә җитүе (к. *Халыкның яшь структурасы*), ш.у. илдә социаль-икътисади шартларның начарлануы, барыннан да бигрәк, халыкның яшәү дәрәҗәсе төшү б-н аңлатыла. 2000 еллар башында туучылар саны тотрыклылана башлый (туым коэф. 2004 тә — 10,3, 2005 тә — 9,8), 2012 дә — 14,5, 2016 да — 14,3).

Татарстанда халык саны

Еллар	Барлык халык, мең кеше	Ш.и. шәһәр халкы, %ларда
1920	2700,0	8,5
1926	2587,5	10,8
1939	2914,2	21,1
1959	2850,4	41,8
1970	3131,2	51,5
1979	3445,4	63,4
1989	3637,8	73,0
2002	3779,3	73,8
2007	3760,5	74,6
2010	3786,5	75,4
2016	3868,7	76,4

ТР югары урбанизация дәрәҗәсе б-н аерылып тора. 2017 нең башына шәһәр халкы саны 2976,2 мең кеше яки гомуми Х. санының 76,6%ын тәшкил итә. Респ-ка башкаласы Казанда 1231,9 мең (барлык ТР халкының 31,7%ы), Чаллыда — 529,8 мең (13,6%), Түбән Камада — 237,3 мең (6,1%), Әлмәттә — 154,3 мең (4%), Яшел Үзәндә 99,2 мең кеше (2,6%) яши.

Респ-када 80 нән артык милләт вәкиле исәпләнә. Төп этник төркемне татарлар (респ-када яшәүчеләрнең 53%ы) һәм руслар (39,7%) алып тора. Чуашлар — 3,1%, башка милләтләр (удмурт, мордва, мари, украин, башкортлар һ.б.) 1%тан азрак тәшкил итә. Х.ның уртача урнашу тыгызлыгы — 1 *км*² га 57 кеше.

Х. структурасында балалар — 19%, хезмәткә яраклы яшьтән өлкәнрәкләр — 24,3%, хезмәткә яраклы яшьтәгеләр — 56,7%, 1000 ир-атка 1160 хатын-кыз туры килә.

Икътисад өлкәсендә хезмәт куючыларның гомуми санының (1806,6 мең кеше) 21,9% ы табигый казылмалар чыгару һәм эшкәртү сәнәгәтендә, 9,5% — а.х.нда, 9,7% — төзелештә, 17,4% — сәүдә өлкәсендә, 7% — транспорт һәм элемтә пр-тиеләрендә, 17,9% — мәгариф, социаль хезмәтләр, сәламәтлек саклау учреждениеләрендә эшли. Мәшгульлек үзәгендә теркәлгән эшсезләр саны — 16,5 мең кеше (хезмәткә яраклыларның 0,8% ы). Х.ның белем дәрәҗәсе арта. 2015 тә икътисади актив Х.ның 33,7% ы — югары һөнәри (1989 да — 11,1%), 19,3% ы — урта һөнәри (1989 да — 16,3%), 24,6% ы — урта (1989 да — 38,3%) белемгә ия.

Х. санының артуы туым күрсәткечләренең югары булуы б-н бәйле. 2016 да 55592 бала туа, туым коэф-ты 14,3 тәшкил итә; үлүчеләр саны — 44949, үлем коэф-ты — 11,6; халыкның табигый артуы — 10643, 1000 кешегә исәпләгәндә, арту коэф-ты 2,7. Көтелгән гомер озынлыгы арта, ул 73,6 ел (2010 да — 70,40) тәшкил итә.

Әд.: Мустафин М.Р., Хузеев Р.Г. Всё о Татарстане: Экономико-геогр. справ. К., 1994; Республика Татарстан. 2004: Стат. сб. К., 2005; Численность, состав и движение населения в Республике Татарстан в 2016 году: Стат. сб. К.,2017.

Ф.Г.Борһанов.

«ХАЛЫ́К», иҗтимагый-сәяси, әдәби, икътисади газета. 1914 елның апреленнән 1915 нең 20 февраленә кадәр Әстерхан шәһәрендә атнага 2 тапкыр татар телендә нәшер ителә, барысы 65 саны чыга. Нашире һәм мөхәррире — Ш.Бәһаутдинов. Актив авторлары арасында — Г.Бәширов, Х.Кәримов, К.Култакый, Г.Фәйзи һ.б. Газета Әстерхан төбәгендә яшәүче мөселман, төрки халыклар вәкилләренең берләшүе һәм һәрьяклап белемле булуы, аларның мәдәнияте һәм теле үсеше идеяләрен пропагандалый. Татарлар өчен мөһим булган иҗтимагый-сәяси вакыйгалар, аерым алганда, Бөтенроссия мөселманнар съезды барышы (С.-Петербург, 1914) киң яктыртыла; мәгълүмат, нигездә, Казан газеталарыннан килеп ирешә. Беренче бөтендөнья сугышы башлану б-н, сугыш темасы төп урын ала: «Сугыш барышы», «Сугыш һәм мөселманнар» сәхифәләре барлыкка килә. Газета җәмгыятьтә зур яңгыраш тудырган вакыйгалар турында хәбәр итә, мәс., И.Н.Харитонов басмаханәсендә күп хаталар б-н чыккан Коръән нәшер ителү б-н бәйле бәхәс тәфсилләп яктыртыла. Редакция татар һәм рус телләрендә басылган яңа китапларга һәм газета мәкаләләренә күзәтүләр урнаштыра, татар матбугаты органнары («Сөембикә» ж-лы, «Милләт» г-тасы һ.б.) эшенә бәя бирә, татар матбугатының башка газеталары, ш.и. «*Ил*» б-н, «Сәйяр» театр труппасы эшчәнлегенә бәя бирү уңаеннан бәхәскә керә. Вафаты б-н бәйле рәвештә, «Х.» күп игътибарны күренекле мәгърифәтче И.*Гаспринский* эшчәнлегенә юнәлтә. Редакция үз язмаларында төбәктәге мәгариф системасы хәленә карата борчылуын белдерә. «Х.»та В.Җәлал, Г.Сөнгати һ.б.ның шигырьләре басыла. Хакимият тарафыннан «зарарлы мәслә ре өчен» ябыла.

З.З.Гыйләҗев.

ХАЛЫ́К ДЕПУТАТЛАРЫ́ СОВЕТЛАРЫ́ Татарстанда, 1917–2006 елларда дәүләт хакимиятенең сайлаулы вәкиллекле органнары. 1917 нең Февр. рев-циясе барышында Эшче һәм солдат депутатлары советлары (1917 нең марты), Крәстиян депутатлары советлары (1917 нең мае) буларак оештырыла. 1917 нең ноябрь-декабрендә Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары советлары, 1918 нең июлендә Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлары советлары, 1937 дә Хезмәт ияләре депутатлары советлары, 1978 дә Х.д.с. итеп үзгәртелә. Баштарак эшче депутатлары — пр-тиеләрдә эшчеләрнең гомуми җыелышларында, солдат депутатлары — хәрби частьларда, крәстиян депутатлары волость һәм авыл җыеннарында сайлана. Окт. рев-циясеннән соң Советлар дәүләт хакимияте органнарына әвереләләр, аларның эшчәнлеге ил

тормышының барлык өлкәләрен колачлый. Элеккеге хакимият һәм җирле үзидарә (земстволар, думалар) органнарын гамәлдән чыгарып, Советлар яңа аппарат формалаштыралар. РСФСРның 1918 елгы Конституциясе буенча Советларның түбәндәге системасы оеша: Советларның губерна, өяз, волость съездлары; шәһәр, посёлок һәм авыл советлары. Советларның губерна съезды Советларның волость һәм өяз съездлары (10 мең кешегә 1 делегат) һәм шәһәр советлары (2 мең сайлаучыга 1 делегат) вәкилләреннән тора. Советларның өяз съездларына авыл һәм шәһәр советлары делегатлары (1 мең кешегә 1 делегат) җыела. Советларның волость съездларына авыл советлары вәкилләре (советның 10 әгъзасына 1 делегат) җибәрелә. Шәһәр советлары 1 мең кешегә 1 депутат исәбеннән оештырыла. Шәһәр һәм авыл советлары турыдан-туры сайлана. Нинди диндә, милләттән булуга, утрак тормышта яшәү-яшәмәүгә карамастан, сайлау һәм сайлану хокукыннан РСФСРның җәмгыятьтәге файдалы хезмәттә мәшгуль гражданнары, солдатлар файдалана. Табыш алу максатында яллы хезмәттән файдаланган, хезмәттән гайре керемнәр хисабына яшәгән затлар, шәхси сәүдәгәрләр, руханилар, полиция, жандармерия, шымчылык бүлекчәләренең хезмәткәрләре һәм элеккеге агентлары, акылга зәгыйфьләр, төрле җинаятьләр өчен хөкемгә тартылганнар сайлау хокукыннан мәхрүм ителә. Советлар съездлары губерналарда һәм өязләрдә елга кимендә 4 тапкыр, волостьларда ай саен чакырыла. Губерна һәм җирле съездларда башкарма ком-тлар — шул терр-ядә съездлар арасындагы чорда югары хакимият органнары сайлана (к. *Казан губернасы Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлары советы башкарма комитеты*). Татарстан АССР төзелгәннән соң (1920), респ-када Советлар системасының югары буыны — *Татарстан АССР Советлары съездлары* (съездлар арасында — *Татарстан АССР Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлары советларының Үзәк башкарма комитеты*), җирле хакимият органнары — кантон (1930 га кадәр), район (1930 дан), волость (1930 га кадәр) советлары съездлары, шул ук сайлау системасы буенча сайланган шәһәр, посёлок һәм авыл советлары (съездлар арасында — аларның башкарма ком-тлары) гамәлгә кертелә. СССРның 1936 елгы Конституциясе Советлар системасын үзгәртеп кора. Сайлаулар гомуми, тигез, турыдан-туры, яшерен тавыш бирү юлы б-н үткәрелә; Советлар хәзер инде чикләүләрсез һәм читләштерүләрсез илнең бар халкын гәүдәләндерә. Татарстанда респ-каның 1937, 1978, 1992 елгы Конституцияләре нигезендә Советлар дәүләт хакимияте органнарының бердәм системасын хасил итә, соңгысының югары буыны ТАССР, ТР ЮСннан (1995 кә кадәр) (к. *Татарстан Республикасы Югары Советы*), *Татарстан Республикасы Дәүләт Советыннан*, түбәнге буыннары район, шәһәр, шәһәрләрдәге район һәм 1995 кә кадәр посёлок һәм авыл советларыннан гыйбарәт. Җирле советларның вәкаләт срогы 2 (1978 гә кадәр), 2,5 (1990 га кадәр) һәм 5 ел (1990 нан) тәшкил итә. Алар үз карамакларындагы терр-яләрдә дәүләт идарәсе, җирле хуҗалык һәм социаль-мәдәни төзелеш мәсь әләләрен карыйлар һәм хәл итәләр, ш.и. социаль-икътисади үсеш планнарын, җирле бюджетны һәм аларның үтәләше турындагы хисапларны раслыйлар; җирле салымнарны һәм җыемнарны билгелиләр; үзләренә буйсынудагы дәүләт органнары, пр-тиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар б-н җитәкчелек итәләр; законнарның үтәлешен, дәүләт һәм җәмәгать тәртибен саклауны, гражданнарның хокукларын яклауны тәэмин итәләр; илнең оборона сәләтен ныгытуга ярдәм күрсәтәләр; респ-ка һәм дәүләткүләм дәрәҗәдә әһәмиятле мәсьәләләрне тикшерүдә катнашалар һ.б. Совет-лар үз эшчәнлекләрен сессияләр тәртибендә һәм закон тарафыннан билгеләнгән башка оештыру формаларында гамәлгә ашыралар. Район советы сессияләре — елга кимендә 6 тапкыр, посёлок, авыл советларыныкы ай саен, аннары елга кимендә 6 тапкыр (Казан шәһәр советы сессияләре елга кимендә 4 тапкыр) чакырыла; 1978 дән район, шәһәр, шәһәрләрдәге район советлары сессияләре елга кимендә 6 (1990 нан — 3) тапкыр, посёлок һәм авыл советларыныкы кимендә 6 (1990–95 тә — 4) тапкыр чакырыла. Советлар башкарма-боеру органнарын (башкарма ком-тларны һәм 1991 дән хакимиятләрне) сайлыйлар, даими һәм вакытлы комиссияләр, ком-тлар һәм үзләренә буйсынулы башка структуралар оештыралар. Х.д.с. 2006 да РФнең «Җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел 6 октябрь Законы һәм ТРның «Җирле үзидарә турында» 2004 ел 28 июль һәм 2005 ел 4 февраль законнары нигезендә гамәлдән чыгарыла, вазифалары *муниципаль берәмлекләргә* тапшырыла.

Чыг.: Конституция (Основной Закон) Татарской Автономной Советской Социалистической Республики. К., 1937; Образование и государственно-правовое положение Татарской АССР: Сб. док. и материалов. К., 1960. Ч. 1; Конституция (Основной Закон) Татарской Автономной Советской Социалистической Республики. К., 1978; Конституция Республики Татарстан. К., 1992.

Әд.: Л е п ё ш к и н А.И. Советы — власть трудящихся. 1917–1936. М., 1966; Х а ф и з о в Ш.Ш. Развитие советской государственности татарского народа. К., 1966; Ж е л е з н о в Б.Л. Правовой статус Республики Татарстан. К., 1996.

Е.Б.Долгов.

ХАЛЫ́К ҖЫРЛАРЫ́, татар фольклорының муз.-поэтик жанры. Халыкның милли сыйфатларын, гореф-гадәтләрен чагылдыра; жанрга хас үзенчәлекле эчтәлеге, муз. теле, төзелеше б-н аерылып тора. Татар Х.җ.на сабырлык, эчке кичерешләрне тирән чагылдыру, муз. бизәкләрнең мул булуы хас. Х.җ.ның иң борынгы төре — *йола җырлары*. Алар 10 йөздән үк билгеле *уен җырлары* б-н тыгыз бәйләнгән. Татар халкы тормышындагы тарихи вакыйгалар *тарихи җырларда* чагылыш таба. Аларга 20 йөзнең 1 нче яртысында үзеш-чән һәм проф. муз.-поэтик иҗат чигендә бар-лыкка килгән революцион җырлар кушыла. Татар лирик Х.җ. 2 зур төркемгә: дүртьюллык җырларга — *кыска җырларга* һәм «сюжетлы җырларга» — озын җырларга бүленәләр. Х.җ., телдән телгә күчеп йөреп, төрле үзгәрешләр кичерә. Күп җырлар («Кара урман», «Әллүки», «Тәфтиләү», «Рәйхан», «Су буйлап» һ.б.) халык тарафыннан яратып кабул ителә һәм проф. җырчыларның репертуарына кертелә.

Әд.: Татар халык иҗаты: Кыска җырлар (дүртьюллыклар). К., 1976; Татар халык иҗаты: Йола һәм уен җырлары. К., 1980; Татар халык иҗаты: Тарихи һәм лирик җырлар. К., 1988; У р м а н ч е Ф. Татар халык иҗаты. К., 2002.

ХАЛЫ́К ИҖАТЫ́ ЙОРТЫ́, к. *Татарстан Республикасының Традицион мәдәниятне үстерү үзәге*.

ХАЛЫ́К ЙОЛАЛАРЫ́, халыкның дини күзаллауларына һәм традицияләренә нигезләнгән тотрыклы гамәлләр, гореф-гадәтләр комплексы. Х.й. *туй йолалары*, *бала тууга бәйле йолалар, мәет күмү һәм мәрхүмне искә алу*, ислам дине кабул ителгәнче *Тәңре* культы б-н бәйле календарь йолалар, ел исәбенең хайваннар циклы календаре һәм ай исемнәрен зодиак системасы б-н атау йолаларына бүленә. Татарларга мөселманлык б-н тыгыз үрелгән Х.й. хас. Гаилә йолаларында татар халкы тарихындагы традицияләр һәм үткән-дәге социаль-хокукый нормалар чагылыш таба. Шул ук вакытта татарларның бергә тупланып яшәүче һәр аерым төркемендә диярлек үзенчәлекле терминологиясе б-н йолаларның үзенчәлекле комплексы барлыкка килә. Шулай булуга карамастан, бу йолаларның структурасын тәшкил иткән элементлар бер үк. Бала туу б-н бәйле Х.й.ның борынгылары — «исем кушу» йоласы, малайлар өчен ш.у. *сөннәт*. Туй йолалары 3 төркемгә бүленә: туй алдыннан, туй, туйдан соң. Аларда үзәк урында кодалау, килешү, ярәшү һәм *никах* йолалары тора. Мәет күмү (җирләү) һәм мәрхүмне искә алу йолалары мөселман татарларда ислам кануннары, керәшен татарларда христиан (кайбер өстәмәләр б-н) йолалары буенча башкарыла. Х.й.нда *Корбан бәйрәме* һәм *Ураза бәйрәме* аерым урын алып тора. Бәйрәм көннәрендә ир-атлар мәрхүм туганнарының каберләренә дога кылырга бара. Керәшен татарларда зиратта искә алулар «ата-аналар көне» (христианлыкта — мәрхүмнәрне искә алу көне) дип аталган көнне башкарыла. Төп календарь Х.й. яз-җәй фасылларына туры килә (чөнки уңыш һәм нәсел-ыруның тормыш муллыгы язның ничек килүенә бәйле). Яңа ел бәйрәме Нәүрүз язгы көн-төн тигезлеге вакытында үткәрелә; чәчүгә кадәр *карга боткасы* йоласы үткәрелә; ул Казан татарларында *Сабан туе* бәйрәме йолалар циклының (ш.у. к. *Сөрән*) бер өлешен тәшкил итә. Чәчү алды Х.й. зур әһәмияткә ия була: уңыш мул булсын өчен җиргә бөртекләр б-н бергә күкәйләр дә ташлыйлар. Зур булмаган җиргә чәчкәннән соң, пешкән күкәй һәм икмәк б-н уртак табын корыла. Игеннәр үсеп, башак чыгарыр алдыннан татар авылларында җәмәгать б-н корбан чалу («корбанлык», «шөкрана», «теләк») үткәрелә. Мишәрләрдә сарык, татарларның башка төркемнәрендә, гадәттә, сыер яки үгез чалына, соңыннан намаз укыла һәм тәгам җыю башлана. Казан татарларында бу йола бары тик

кайбер авылларда гына башкарыла. «Яңгыр боткасы», «теләк боткасы», «киләмәт боткасы» уңыш турында кайгыртуга бәйле йолалардан санала; аны башкару вакытында традицион ботка ашаганнан соң, йолада катнашучылар һәм авыл кешеләре бер-берсе өстенә су сибә. Язгы кыр эшләреннән соң, печәнгә һәм урып-җыюга төшәр алдыннан үткәрелә торган *Җыен* бәйрәменең үзенә аерым йолалары була. Бер яки берничә гаиләнең табигатькә чыгып, тәкә чалып яки тавык суеп мәҗлес ясавы — «тәкәгә» яки «тавыкка чыгу» дигән үзенчәлекле йолаларның берсе. «Хозурга чыгу» («сәхрә», «сахрага чыгу») йоласы хатыннар яки кызларның табигатькә чәй эчәргә чыгуын аңлата. Керәшен татарларда православие Троицасына бәйле «каен башын бәйләү» дип аталган каен бизәү йоласы башкарыла. Көзге-кышкы Х.й. сан ягыннан азрак, аларның иң әһәмиятлесе — *Нардуган* йолалары. Аңардан тыш күрше рус авылларында уздырыла торган ярминкәләргә бәйле үзара кунакка йөрешү традицияләре була. Ярминкәдән соң чиратлашып кунакка йөрүләр «әртилле йөрү» дип атала. Бу фасылларга караган Х.й.нда *өмә* (үзара ярдәмләшү), «каз өмәсе» (суелган казларны күмәкләшеп эшкәртү) «тула өмәсе» (күмәкләшеп киез басу), «киндер тукмаклау» (күмәкләшеп киндер эшкәртү) аерым урын алып тора. Совет чорында татар Х.й. комплексына совет бәйрәмнәре (Яңа ел, 8 Март) һәм коммунистик бәйрәмнәр кертелә (ш.у. вакытта дини йолалар һәм бәйрәмнәр тыела). Совет чорыннан соң Х.й., нигездә, авыл җирлекләрендә саклана, трансформация кичерә.

Әд.: К о б л о в Я.Д. О татарских мусульманских праздниках. К., 1907; Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967; У р а з м а н о в а Р.К. Современные обряды татарского народа. К., 1984; Татары. М., 2001.

А.В.Климин.

ХАЛЫ́К КОМИССАРЛАРЫ́ СОВЕТЫ́ (ХКС), ТАССРда дәүләт хакимиятенең 1920–46 еллардагы югары башкарма һәм күрсәтмә органы. 1920 нең 28 сентябрендә *Татарстан АССР Үзәк Башкарма Комитетының беренче пленар утырышында* С.С.Сәетгалиев (ХКС рәисе), Г.Й.Измайлов (эчке эшләр халык комиссары), А.С.Изюмов (азык-төлек халык комиссары), М.Г.Рошаль (ХХС рәисе), Х.Ш.Солтанов (мәгариф халык комиссары), А.Н.Нехотяев (юстиция халык комиссары), В.И.Исхаков (социаль тәэминат халык комиссары), А.И.Бочков (Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатларының Казан губерна советы башкарма ком-ты рәисе урынбасары), А.И.Догадов (Профсоюзларның Татарстан советы рәисе), К.Г.Мохтаров (сәламәтлек саклау халык комиссары), Ю.Н.Вәлидов (игенчелек халык комиссары), А.С.Гордеев (финанс халык комиссары), Г.М.Иванов (Бөтентатар контрреволюцион, спекуляция һәм вазифаи җинаятьләр б-н көрәш гадәттән тыш комиссиясе рәисе), К.Г.Харев (Татарстан хәрби комиссары), И.Я.Вейцер (ХКС Президиумы әгъзасы) составында оештырыла. Башта ТАССР ХКС аңа ТАССР ҮБК тарафыннан бирелгән вәкаләтләр чиклә рендә респ-ка б-н гомуми идарә итү хокукына ия була. ТАССР ҮБКның башкарма органы буларак, ул *Татарстан АССР халык комиссариатларының* җирле Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатлары советлары башкарма ком-тларының эшчәнлеге б-н җитәкчелек итә; респ-ка законнарын эшләүдә катнаша (декретлар һәм карарлар чыгару хокукына ия була); респ-ка халык хуҗалыгы үсеше планын карый, аны ТАССР ҮБК һәм аның Президиумы раславына чыгара; респ-ка һәм җирле бюджетларны, аларның үтәлеше турындагы хисапны алдан тикшерә; аерым терр. берәмлекләр һәм ведомстволар арасында чыгымнарга тотылучы акча бүлү б-н шөгыльләнә; дәүләт салымнарыннан һәм табышларыннан алынган керемнәрдән респ-ка ихтыяҗларына җибәреләчәк суммаларның күләмнәре буенча бәяләмә бирә һәм аны ТАССР ҮБК каравына кертә; Татарстан терр-ясендәге Союзга һәм РСФСРга буйсынулы барлык пр-тиеләр һәм оешмалар (хәрәкәттәге армия учреждениеләреннән тыш) эшчәнлеген контрольдә тота һ.б. ТАССРның 1937 елгы Конституциясе кабул ителгәннән соң, ТАССР ҮБК һәм аның Президиумы гамәлгә ашырып килгән хакимият вәкаләтләренең күп өлеше ТАССР ХКСна күчә, ул респ-каның барлык дәүләт идарәсе органнары б-н югарыдан турыдан-туры җитәкчелек итү вазифаларына керешә. ХКС ТАССР халык комис-тларын, аңа буйсынулы башка хуҗалык һәм мәдәният учреждениеләрен, гомумсоюз һәм союз-респ-ка халык комис-тлары вәкаләтле вәкилләрен берләштерә һәм аларның эшенә юнәлеш бирә; халык хуҗалыгы планын, респ-ка бюджетын һәм җирле бюджетларны гамәлгә ашыру, җәмәгать тәртибен тәэмин итү, дәүләт мәнфәгатьләрен һәм гражданнарның хокукларын яклау буенча чаралар күрә; хезмәт ияләре депутатларының җирле советлары башкарма ком-тлары эше б-н җитәкчелек итә; карарлар, боерыклар чыгара һәм аларның башкарылуын контрольдә тота һ.б. ХКС ның персональ составы — рәис, рәис урынбасарлары, халык комиссарлары һ.б. идарә органнары җитәкчеләре — ТАССР ҮБК (1938 гә кадәр), ТАССР ЮС (1938 дән) тарафыннан раслана. 1920 дән — 15, 1922 дән — 13, 1923 тән — 16, 1925 тән — 19, 1927 дән — 17, 1929 дан — 18, 1931 дән — 16, 1934 тән — 12, 1938 дән — 16 әгъзадан тора. ХКС каршында Икътисади киңәшмә (ЭКОСО) (1921–26), үзәк эквивалент (1921–23), эксперт (1921, 1928–35), законнар әзерләү (1921–27), йортларны һәм корылмаларны демуниципализацияләү (1924–29) комиссияләре һ.б. эшли. ТАССР Советлары съездына, ТАССР ҮБКна һәм аның Президиумына, Бөтенроссия Советлары съездына, Бөтенроссия ҮБКна һәм аның Президиумына (1938 гә кадәр), ТАССР ЮСна һәм аның Президиумына (1938 дән), РСФСР ХКСна (1920 дән) һәм СССР ХКСна (1923 тән) буйсына. СССРның 1946 ел 15 март Законы, ТАССР ЮСы Президиумының 1946 ел 28 март Указы, РСФСР ның 1946 ел 25 июнь Законы һәм ТАССР ның 1946 ел 19 июль Законы нигезендә *Татарстан АССР Министрлар Советы* итеп үзгәртелә.

Рәисләре: С.С.Сәетгалиев (1920–21), К.Г.Мохтаров (1921–24), Х.З.Габидуллин (1924–27), Ш.Ш.Шәймәрданов (1927–28), К.Х.Исмаев (1928–30), К.А.Абрамов (1930 — 37 нең июле), Ә.М.Дәүләтъяров (1937 нең сентябре — декабре), Ә.Х.Тынчеров (1938–40), С.Х.Гафиятуллин (1940–43), С.М.Шәрәфиев (1943–46). Ш.у.к. *Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты.*

Чыг.: Конституция (Основной Закон) Татарской Автономной Советской Социалистической Республики. К., 1937; Образование и государственно-правовое положение Татарской АССР: Сб. док. и материалов. К., 1960.Ч.1.

Әд.: Х а ф и з о в Ш.Ш. Развитие советской государственности татарского народа. К., 1966.

Е.Б.Долгов.

ХАЛЫ́К КОНТРОЛЕ́, совет хакимияте чорында дәүләт контролен пр-тиеләрдә, учреждениеләрдә һәм төрле оешмаларда хезмәт ияләренең җәмәгать контроле б-н бергә бәйләп алып баручы органнар системасы. *Татарстан АССР Эшче-крәстияннәр инспекциясе халык комиссариатының* эшчәнлеге туктатылганнан соң, СССР ҮБК һәм ХКСның 1934 ел 27 февраль карары нигезендә СССР ХКС каршындагы Совет контроле комиссиясенең ТАССР буенча вәкиле вазифасы кертелә. Вәкил дәүләт дисциплинасын ныгыту, хөкүмәт карарларының совет һәм хуҗалык аппаратының барлык тармаклары тарафыннан үтәлешен контрольдә тоту һәм оперативтикшерү б-н шөгыльләнә. Ул җирле хакимият органнарыннан бәйсез рәвештә эш итә һәм СССР ХКСна гына буйсына. Әлеге вазифа СССР дәүләт контроле халык комиссарының 1940 ел 25 ноябрь карары б-н гамәлдән чыгарыла.

Респ-када контроль органнары үсешенең чираттагы этабы КПССның Татарстан өлкә ком-ты бюросы, ТАССР ЮС Президумы һәм ТАССР МСның 1963 ел 30 гыйнвар карары, ТАССРның 1963 ел 21 март Законы карары нигезендә КПССның ТАССР өлкә ком-ты һәм ТАССР МС каршында Партия-дәүләт контроль ком-ты төзелүдән гыйбарәт. Ком-т халык хуҗалыгы тармакларына караган 12 бүлекне; хезмәт ияләренең хатларын, шикаятьләрен һәм гаризаларын карауны контрольдә тоту буенча җәмәгать комиссиясен, 1965 елдан координация советын үз эченә ала. Аның составына Казандагы 5 район, респ-кадагы 8 шәһәр, 3 сәнәгать зонасы, 17 колхоз-совхоз җитештерү идарәсе ком-тлары керә. КПСС ҮК һәм СССР МС ның шул ук исемдәге ком-тына буйсына.

СССРның 1965 ел 9 декабрь Законы һәм ТАССР ның 1966 ел 19 гыйнвар Законы нигезендә партия-дәүләт контроле органнары урынына Х.к. органнары: ТАССР Х.к. ком-ты, 25 район, шәһәр, шәһәр районнары Х.к. ком-тлары оештырыла. Посёлок, авыл советлары каршында 4361 Х.к. төркеме, пр-тиеләрдә, колхозларда, учреждениеләр һәм оешмаларда 5792 Х.к. төркеме һәм 7705 Х.к. посты булдырыла. Алар социаль-икътисади үсеш буенча дәүләт планы һәм пландагы йөкләмәләр үтәлешен тикшерәләр, халык хуҗалыгындагы резервларны ачыклыйлар һәм аларның кулланышка кертелүенә ирешәләр; дәү-

ләт дисциплинасы бозылу очраклары, хуҗасызлык, әрәм-шәрәм итүләр һәм бюрократизм, дәүләт милкен үзләштерүгә каршы көрәш алып баралар; дәүләт аппаратының эшен камилләштерүгә ярдәм итәләр; ведомство контроленең торышын тикшерәләр; гаебе булган дәүләт хезмәткәрләренә карата чара күрә, акчаларын кисә, вазифаларыннан азат итә алалар һ.б. Х.к.нең тәкъдимнәрен һәм күрсәтмәләрен үтәү мәҗбүри итеп куела. Х.к. ком-тларын җирле советлар оештыра, халык контролёрлары хезмәт коллективлары тарафыннан сайлана. ТАССР Х.к. ком-ты оештыру; сәүдә, җәмәгать туклануы һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү; машина төзелеше һәм энергетика сәнәгате; төзелеш, төзелеш материаллары, агач эшкәртү, йорт җи һазлары җитештерү һәм урман сәнәгате; коммуналь хуҗалык; нефть һәм газ сәнәгате; химия сәнәгате, җиңел һәм җирле сәнәгать, а.х. б-н җитәкчелек итү һәм механикалаштыру; терлекчелек; ит-сөт, азык-төлек һәм балык сәнәгате; транспорт һәм элемтә бүлекләреннән; хезмәт ияләренең шикаятьләрен һәм тәкъдимнәрен карау бюросыннан тора. Ул ТАССР ЮС һәм аның Президиумы, ТАССР МС һәм РСФСР ның шундый ук ком-ты җитәкчелегендә эшли. Респ-када Х.к. эшчәнлеге ТАССР ЮСның 1990 ел 30 август карары һәм ТССР ның 1991 ел 6 февраль Законы нигезендә туктатыла.

Х.к. ком-ты рәисләре: М.М.*Репеев* (1963–83), И.П.*Наумов* (1983–91).

Әд.: Образование и развитие органов социалистического контроля в СССР (1917–1975): Сб. док. и материалов. М., 1975.

Е.Б.Долгов.

«ХАЛЫК МӘГАРИФЕ́», пед. журнал. Әстерхан губерна башкарма ком-тының мөселман мәгариф бүлеге органы. 1919 елда Әстерхан шәһәрендә атнага 2 тапкыр татар телендә нәшер ителә. Мөхәррирләре һәм төп авторлары — әлеге бүлек хезмәткәрләре. Журналда Әстерханда һәм Әстерхан төбәгендә татар мәктәпләре эшен оештыру, мәктәп программаларын һәм пед. кадрлар әзерләү мәсьәләләре яктыртыла.

ХАЛЫК МӘГАРИФЕ́ ЮГАРЫ́ ИНСТИТУТЫ́, пед. югары уку йорты. 1919 елда Казан пед. ин-тын үзгәртү юлы б-н оештырыла. 1921 дән кабат Казан пед. ин-ты булып ата ла башлый. 1922 дә *Шәрекъ педагогика институты* составына керә. Төп оештыру документлары: 1918 дә РСФСР Мәгариф халык комис-ты каршындагы Мәгариф буенча дәүләт комиссиясе тарафыннан расланган Пед. ин-тлары уставы, РСФСР Мәгариф халык комис-тының пед. ин-тларын халык мәгарифе югары ин-тлары итеп үзгәртү турындагы 1919 елгы карары.

5 бүлеге була: мәктәпкәчә, 1 нче баскыч мәктәп укытучылары, 2 нче баскыч мәктәп укытучылары, хезмәт процесслары буенча инструкторлар, мәктәпкәчә белем бирү хезмәткәрләре (1921 дә ябыла). Уку срогы 4 ел. Студентларның пед. практикасы өчен 2 нче баскыч күргәзмә мәктәп (җитәкчесе С.П.Синогалевич), институт каршында әзерлек курслары эшли. Х.м.ю.и. составына Казан ун-тының ябылган ф-тлары (филол., физика-матем.), Казан югары хатын-кызлар курслары, Казан укытучылар семинариясе, халык укытучыларын укыту өчен Казан земство мәктәбе пед. персоналы һәм студентлары, ш.у. шушы уку йортларының биналары керә.

1922 гә: 152 укытучы, шуларның 56 сы проф., 477 студент. Институт б-н коллегиаль тәртиптә бүлек мөдирләре составындагы Совет идарә итә. Совет рәисе А.П.Машкин, әгъзалары М.П.Якубовская, А.М.Вилькен, Д.А.*Гольдгаммер*, В.Т.*Дитякин*, С.П.*Сингалевич*. Укытучылары: В.В.*Адоратский*, А.Е.*Арбузов*, В.А.*Богородицкий*, Е.Ф.*Будде*, М.Д.Бушмакин, Г.С.*Гобәйдуллин*, В.В.*Ивановский*, А.А.*Красновский*, Н.А.*Ливанов*, А.О.*Маковельский*, Н.Н.*Парфентьев*, М.Д.Прыгунов, С.А.*Пионтковский*, А.Ф.*Самойлов*, Н.Н.*Фирсов*, Е.И.*Чернышёв*.

Әд.: Казанский государственный педагогический институт // Уч. зап. Казан. гос. пед. ин-та. 1974. Вып. 132.

ХАЛЫ́К МЕДИЦИ́НАСЫ, сәламәтлекне саклау, гомерне озайту, авыруларны кисәтү һәм дәвалауга юнәлдерелгән эмпирик белемнәр, ш.у. дәвалау һәм гигиенага кагылышлы гамәли табиблек нисулларының күпләгән буынннар тарафыннан тупланган җыелмасы. Х.м.ның күп кенә чаралары фәнни медицинада кулланыла. Урта Идел буе терр-ясендә меңнәрчә еллар буена көнчыгыш һәм көнбатыш Х.м. бер-берсен баета килгән. Төрки телле халыкларда (ш.и. болгар һәм татарларда да) табиблек б-н мәҗүси йола башлыклары (шаманнар, апасу, бахшилар) һәм табиблар шөгыльләнгән. Алардан тыш тагын кендек әбиләре, тайган сөякне утыртучылар, сөяк тишүчеләр, кан агызучылар булган. Болгар табибләре дару чарасы итеп төрле үләннәр (мәтрүшкә, андыз, песи үләне, чабыр, артыш, канлы үлән, көтүче сумкасы һ.б.) һәм минераллар, «сыр» — эри торган кызыл таш (киноварь); яраларны эшкәртү һәм тазарту өчен көл, агач череге, кондыз сыекчасы, терлекнең эч маеннан ясалган майлар, мускус, бал, тома балавыз, дегет, мышьяк кушылмалары, бакыр купоросы кулланганнар. Канны чистартуның венесекция юлы б-н кан чыгару һәм сөлек ярдәмендә кан суырту һ.б. нисуллары билгеле булган. Минераль сулар кулланылу турында да мәгълүматлар бар. Дәвалауның им-томчылык, өшкерү-әфсенләү, догалар, төрле йола һәм табынулар, сихер кебек магик нисуллары яшәп килгән. Х.м. формалашуга *Бор һанеддин Ибра һим бине Йосыф әл-Болгари*, бертуган *Та җ́ддин* һәм *Хәсән бине Юныс әл-Болгари* кебек болгар табибләренең хезмәтләре йогынты ясаган. 19–20 йөзләрдә Көнбатыш Европа (Т.Сиденхем, А.Паре һ.б.), Россия (М.Я.Мудров, Г.А.Захарьин, С.П.Боткин һ.б.) галимнәренең дәвалау эшчәнлеге, татар мәгърифәтчесе К.Насыйри һәм табиблә рнең (Н.А.*Виноградов*, В.М.*Флоринский*. К.Ф.*Фукс*, М.С.*Хомяков* һ.б.) тикшеренүләре Х.м.н табигыять гыйлеме һәм техника казанышларына, клиник-эксперименталь һәм клиник анатомия белемнәре үсешенә нигезләнгән фәнни медицинага әверелүенә булышлык итә. Урта гасырларда формалашкан Х.м. нисуллары фәнни медицинада үсте релә. Алар психотерапиядә, гипнотерапия - дә, фитотерапиядә, фунготерапиядә (гөмбә экстрактлары б-н дәвалау), апитерапиядә (умартачылык продуктлары б-н дәвалау), гирудотерапиядә (сөлек б-н дәвалау) файдаланыла. Парафин һәм озокерит б-н дәвалау заманча фәнни физиотерапиянең нәтиҗәле юнәлешен тәшкил итә. Медицинада ш.у. гиттиотерапия — балчык б-н дәвалау (аппликацияләр, төрү, ванналар) кулланыла. Х.м.ннан фәнни мед. практикасына мануаль терапия һәм диета б-н дәвалау, ач тору, массаж кебек нисуллар кабул ителә. Казан ун-тында (1941 дән) һәм Казан мед. ин-тында (1975 тән) респ-када үсүче кыргый һәм ашарга яраклы үләннәрнең үзлекләрен өйрәнү эше алып барыла. Х.м.н сәламәтлек саклау практикасында куллану өчен аның алдан фармакол., токсикология һәм клиник-эксперименталь яктан тикшерелүе мәҗбүри шарт булып тора. РФ законнары нигезендә мед. белеме булмаган затларның табиблек эшчәнлеге б-н проф. дәрәҗәдә шөгыльләнүе җинаять җаваплылыгына тартылырга тиешле гамәл санала.

Әд.: Әхмәтҗанов М.И. Татар халык медицинасы // Мирас. 2008. № 5; Флоринский В.М. Русские простонародные травники и лечебники: Собрание медицинских рукописей XVI — XVII столетия. К., 1880; Народная медицина: Пути содействия и развития. Женева–М., 1980; Галиуллин А.К. Медицина Волжской Булгарии и Казанского ханства. К., 1997; Анисимова М.Д. Вехи истории фармации Татарстана (Взгляд специалиста). К., 2001; Анисимова М.Д., Сафиуллин Р.С. Страницы летописи фармации. К., 2004; Большая энциклопедия народной медицины. М., 2005.

В.Ф.Богоявленский.

ХАЛЫ́К МИГРА́ЦИЯСЕ (лат. migratio — күчү), кешеләрнең (мигрантларның) даими яшәү урынын алыштыру нәтиҗәсендә килеп чыккан күчеше. Эчке (билгеле бер адм. терр-я — район, өлкә, ил) һәм тышкы (эмиграция — башка илгә күчү, иммиграция — илгә керү) Х.м.нә бүленә. Миграция агымының формалашуына урбанизация, яшәү дәрәҗәсенең төбәкара аерымлыклары, хезмәт базары, укуга, армиягә (хәрби хезмәткә), гаилә кору максаты б-н китү күренешләре һ.б. йогынты ясый. Ш.у. сәяси, милли, дини, хәрби һ.б. характердагы сәбәпләр дә мөһим роль уйный. РФдә мигрантларга даими яшәү урынына, эшкә, укуга һәм 1,5 айдан да озаграк вакытка китүчеләр һәм килүчеләр керә. РФ законнарына ярашлы рәвештә, эчке мигрантлар яшәү урыны буенча өч көн эчендә теркәлергә тиешләр. Х.м.ндә килүчеләр, китүчеләр, ш.у. алар арасындагы аерманы — Х.м. артуын билгелиләр.

СССРдагы зур масштаблы Х.м., нигездә, илне индустриялә штерү, зур халык хуҗалыгы объектлары төзелеше, Казакъстан һәм Көнбатыш Себер чирәм җирләрен үзләштерү б-н бәйле. Бер яктан, этник конфликтлар, икътисади кризис һәм яшәү дәрәҗәсенең төшүе б-н бер вакытта СССРның таркалуы, икенче яктан, яшәүнең либераль әшүе һәм ачык ишекләр сәясәтенә күчү, миграция күренешләрендә шактый үзгәрешләр тудыра: мәҗбүри миграцияләр таралыш ала, качаклар барлыкка килә. ТРда 1990–91 елларда ки-

сәк кимегән миграция (тиңдәшле рәвештә 1000 кешегә һәм 5,5 мең кеше, яисә 0,3 һәм 1) яңадан үсә һәм 1993 тә иң югары ноктасына җитә (1000 кешегә 23,1 мең кеше яки 6,4). 1990 еллар ахырында аеруча 2000 еллар башында миграция әйләнеше (килүчеләр һәм китүчеләр суммасы) өзлексез кими (1000 кешегә 1993 тә 205 тән 2003 тә 95 кешегә кадәр). Тулаем алганда, Х.м. артуы исәбенә 1990–99 да ТРның халкы 145 меңнән күбрәк кешегә арта, 1993–98 дә миграция халыкның табигый кимүен каплый.

2015 тә ТР ға 37,6 мең кеше килә, респ-кадан 34 мең кеше китә. Килүче мигрантларның гомуми санының 79%ы — РФ төбәкләреннән; 19,6%ы БДБ илләреннән (ш.и. 7,6%ы — Үзбәкстаннан, 3,4%ы — Украинадан, 3,1%ы — Таҗикстаннан, 1,5%ы — Казакъстаннан, 1,4% ы — Кыргызстаннан); 1,3% ы — башка илләрдән (ш.и. Төркиядән — 102 кеше, Грузиядән — 84 кеше, Германиядән — 30 кеше, Вьетнамнан — 25 кеше, Мисырдан — 19 кеше). Идел буе (50,4%), Үзәк (14,8%), Урал (13%), Себер (4,6%), Ерак Көнчыгыш (3,1%) федераль округлары исәбенә ТРда Х.м.нең артуы күзәтелә. Шул ук вакытта Татарстаннан Мәскәүгә һәм Мәскәү өлкәсенә, С.-Петербург һәм Ленинград өлкәсенә, Краснодар краена китәләр.

2010–2015 елларда ТРда халыкның миграция үсеше

Еллар	Миграция үсеше	шул исәптән		
		РФ өлкәләре һәм респ-каларыннан	БДБ илләреннән	башка илләрдән
2010	4691	3045	1766	–120
2011	11998	3429	8134	435
2012	9786	2853	6667	266
2013	5926	2666	3208	52
2014	7248	4853	2514	–119
2015	3573	1564	2066	–57

14 яшьлек һәм өлкәнрәк мигрантларның якынча 15% ы респ-кага укырга яки эшкә килә, шуның 50% тан артыграгы элекке яшәү урынына китә. Тышкы мигрантларның 65–70%ка кадәре — хезмәткә яраклы яшьтәгеләр, 20–25%ы хезмәткә яраклылардан яшьрәк. Миграция артуының төп өлешен татар-лар һәм руслар (2003–04 тә беренче тапкыр руслар миграциясе кимүе күзәтелә), берникадәр өлешен Урта Азия һәм һәм Идел буе респ-калары халкы тәшкил итә. Ерак чит илләр б-н алмашу нәтиҗәсендә ТРның халкы кими: 2015 тә 497 кеше килә, 554 кеше, нигездә, Германия, АКШ, Израильгә китә.

2015 тә ТРда эчке мигрантлар 59,7 мең кеше тәшкил итә. Эчке миграция исәбенә Казан (1492 кеше), Питрәч (1077 кеше), Яшел Үзән (1021 кеше), Биектау (902 кеше), Лаеш (877 кеше) р-ннары халкы арта, Чаллы (1051 кеше), Түбән Кама (705), Бөгелмә (397) шәһәрләреннән халкы кими.

Ф.Г.Борһанов.

ХАЛЫК МУЗЫКАСЫ, музыкаль фольклор, халыкның вокаль (җыр), инструменталь, вокаль-инструменталь һәм музыка-бию иҗаты. Идел буе Болгар дәүләтендә һәм Алтын Урдада ике рухи мәдәният — шәһәр һәм авыл мәдәниятләре формаша. Шәһәр мәдәниятендә ислам аеруча киң чагыла, авылларда мәҗүсилек озаграк саклана. Идел буе Болгар дәүләтендә яшәгән авыл халкының җир б-н бәйле йолалары җырлардан гына тормый, үз эченә мәкаль-сынамышлар, сөрән сугулар, теләкләр, келәү сүзләре, им-томнар, биюләр һ.б.ны да ала. Көндәлек көнкүреш сезон саен кабатланучы йола һәм җырлардан торган еллык игенчелек тәртипләренә буйсына. Шул рәвешчә Идел буе Болгар дәүләтендәге авыл халкының рухи мәдәниятендә үзенчәлекле аваз семантикасы б-н аерылып торган гаилә җырларыннан һәм гаиләдән читтә җырлана торган җырлардан гыйбарәт үз жанр системасы формалаша. Күмәк хезмәт күмәк (гетерофон) җыр тудыра. Әлеге йолалар һәм җырларның кайтавазы керәшен татарларда бүгенге көнгә кадәр сакланган. Ислам алга яңа идея-эстетик бурычлар куя. Гарәп һәм фарсы телләрен өйрәнүгә зур игътибар бирелә. Идел буе Болгар дәүләтендәге шәһәр халкы Шәрекъ мөселман шагыйрьләренең (Рудаки, Фирдәүси, Руми, Сәгъди, Нәваи һ.б.) әсәрләрен төп нөсхәдә уку мөмкинлегенә ия була. Аларның шигырь төзелеше көйләп укуга, сөйләү интонациясе б-н башкаруга корылган. Китап әсәрләре нигезендә әдәби телдә башкарыла торган проф. әсәрләр һәм фольклор жанрлар — бәетләр, мөнәҗәтләр, ш.у. билгеле бер китапларның шул ук көйләп укыла торган фольклор вариантлары (дастаннар) барлыкка килә. Көйнең язма рәвештә теркәлгән тексттан бәйлелеге ритмиканы тотрыклыландыра, ул исә көйләрнең типлашуына һәм консервациясенә этәргеч бирә. Болар барысы да көйләрнең төгәл үзлеге, билгеле бер «стилистик код»ы формалашуга сәбәпче була, бу үз чиратында иҗат итүне дә, кабул итүне дә җиңеләйтә. Шәһәр халкының дөньяга караш һәм социаль бердәмлектән чыгып оешуы, нигездә, соло, монодияле башкару традициясе формалашуга этәрә; Коръәнне, ш.у. башка дини әсәрләрне көйләп уку тыңлау һәм кабул итү өчен хезмәт итә, бу үз чиратында функцияләр бүленүгә китерә: башкаручы һәм тыңлаучы барлыкка килә. Такмак та (биюләр, уен-көлкеле кушымталар, такмазалар) борынгы жанрга карый, анда исламга кадәр-ге бармак метрик системасы файдаланыла.

Казан ханлыгы халыкларының муз. мәдәнияте социаль һәм конфессиональ билгеләре буенча халык иҗатына хас жанрлар системасы һәм муз. семантикасы булган авыл (мәҗүси) һәм шәһәр (мөселман) муз. мәдәнияте-нә бүленеп алга таба үсеш кичерә. Мөселман халкының рухи мәдәниятендә дә бердәмлек булмый. Күпчелек урта гасырлар язма ядкәрләрендә феодаль аксөякләрнең көндәлек тормышында оркестрлар эшчәнлеге турында еш искә алына һәм быргы, кубыз, кыңграгу (кыңгырау), куру (курай), нәй, саз, сорнай, уд, чәчәнә кебек музыка уен кораллары саналып үтелә. Шәрекъ мөселман муз. мәдәниятендәге кебек үк Казанда да халык музыкасын һәм проф. музыканы аерып карау төгәл билгеләнә. Чыганакларда җырчылар һәм музыкантлар турында еш искә алыну бу чорда һәм вокаль, һәм инструменталь өлкәдә проф. авыз иҗатының үсешенә дәлил булып тора. Бу үзенчәлекләр Казан татарлары муз. мәдәниятендә акрынлап лирик интонация б-н җырлана торган озын көй жанры формалашуга этәргеч бирә. Бу жанр яңача муз. фикер йөртү үсешенә этәргеч бирә. Ул көйнең яңгырау киңлеге һәм төрлелегендә җырчының иҗат фантазиясенә бәйле рәвештә аерым иҗекләрне сузып җырлауда гәүдәләнә. Әдәби сүзнең үзгәрешсез иҗек-ритм формулалары, көйгә салынып җыр итеп җырланганда Казан татарларында «моң» (ягъни тексттагы иҗекләрне яңгырату сәләте) дип аталучы башкару осталыгын тудырып, иң югары үсешкә ирешә. Кайбер җырчылар «моң» тудырганда аерым камиллеккә ирешәләр. Әлеге традиция безнең көннәрдә дә үз көчендә кала. Бу И.Шакиров, Ф.Кудашева, Г.Сөләйманова, Х.Бигичев, Г.Ибушев һ.б. җырчыларның иҗатларында аеруча ачык чагылыш таба.

Казан ханлыгы җимерелгәннән соң, татар халкының шәһәр мәдәнияте традицияләре озак вакытка өзелеп тора. Казан халкының бер өлеше Казан артына китә, икенче бер өлеше мари, удмурт, башкорт җирләренә һ.б.га кача. Казан татарларының рухи мәдәнияте үзәген читтәрәк урнашкан Әтнә, Саба һ.б. җирлекләр тәшкил итә. Анда һөнәрчелек, сәүдә, әдәбият, сәнгать үсеш ала (әлеге процессның идеологик таянычы булып дин тора, бу үз чиратында дини җырлар, аның башка формалары, фольклор мелосының милли үзенчәлекләре сакланууга булышлык итә).

Христианлаштыру сәясәте уздырылу нәтиҗәсендә Алтын Урда һәм Казан ханлыгындагы мәҗүсилекне һәм аның рухи мәдәниятен саклап калган авыл халкы традицияләрен дәвам итүче, православие динендәге керәшен татарлар төркеме оеша. Керәшен татарлар Х.м.на үзенчәлекле артикуляцияле, лад-интонацияле һәм ритмик киңлеккә ия булган, күмәк башкарыла торган күптавыш-лы җырлар йола системасы хас. Керәшеннәр яшәгән һәр район тарихи, социаль-икътиса-ди һәм табигый-географик үзенчәлекләргә ия була, бу билгеле бер үзгәлек б-н аерылып торган җирле төркемнәр формалашуда чагыла. 18 йөздә «йомышлы» статусы бетерелү б-н бәйле рәвештә татар-мишәрләрнең икътисади хәле кинәт начарлану аларны чит җирләргә акча эшләргә чыгып китәргә, вак сәүдә б-н шөгыльләнергә этәрә. Социаль-икътисади тормыш үзенчәлекләре аларның җыр лирикасының (җырларының) эчтәлегенә һәм муз. стилистикасына әз сала. Әлеге җырларның тематикасы шактый тормышчан һәм новеллистик характерга ия. Бер төркем җырлар баллада характерындагы драматик хикәят рәвешендә булса, икенче төркем җырларда социаль тигезсезлек, качкыннарның ачы язмышлары, алыпсатарларның, сатучыларның авыр тормышлары һ.б. турында җырлана.

Илдә барган социаль үзгәрешләр Казан татарларының җыр мәдәнияте үсешендә чагылыш таба. Аеруча җыр лирикасы (җырлары) сизелерлек үзгәреш кичерә. 18 йөздә шәһәр мәдәнияте кабат тергезелү б-н, Казан та-

тарлары лирикасында 2 җыр жанры: салмак көйләр һәм авыл көйләре барлыкка килә. 19–20 йөзләр чигендә Казанның татарлар яши торган өлешендә шәһәр бакчаларында ачык эстрадалар, музыка яңгырап торган трактир, чәйханәләр барлыкка килә. Муз. мәдәният үсешендә әдәби-муз. кичәләр аеруча мөһим роль уйный. Аларны оештыруда татар язучылары һәм шагыйрьләре, рус зыялылары актив катнаша. Муз. мәгърифәтчелек үсешендә *Шәрекъ клубы*, Яңа клуб кебек клублар ачылуның да әһәмияте зур була. Алар каршында инструменталь ансамбльләр эшли: татар халык җырлары б-н бергә шәрекъ, рус классик һәм көнкүреш муз. әсәрләрен дә башкаралар. 1906 да үз инструменталь ансамбле булган беренче проф. татар «*Сәйяр*» театр труппасы оешу татарларның мәдәни тормышында зур вакыйга буларак кабул ителә. Ул музыка б-н драма театры арасында үзара тыгыз бәйләнеш тудыра. Казанда муз. культураның сизелерлек үсеше татар музыка сәнгатендә яңа юнәлеш — көнкүреш музыкасы (вокаль һәм инструменталь) барлыкка килүгә этәргеч бирә. Бу жанрдагы әсәрләрнең көе чагыштырмача гади, ритмикасы катлаулы түгел, шул сәбәпле алар киң халык массалары арасында тиз таралыш ала һәм бик популяр була: көндәлек тормышта да, эстрадада да, ялгыз һәм күмәк рәвештә дә башкарыла. Озын көйдән аермалы буларак, алар кыска көй дип атала башлый.

Окт. рев-циясеннән соңгы чорда хор түгәрәкләре оештыру массакүләм төс ала. Татар халкының көндәлек тормышына социализм төзелешен, Кызыл Армияне һ.б.ны данлаган җырлар үтеп керә башлый. Ул елларда шәһәр көнкүреш лирикасының популярлыгы сизелерлек кими: яңа җырлар иҗат ителми, рев-циягә кадәр аеруча көчле яңгыраган җырлар гаилә кысаларында гына сакланып кала. Сәясәтнең сәнгатькә йогынтысы авыл халкының җыр сәнгатендә дә сизелми калмый. 1920 елларның 2 нче яртысыннан авыл көйләре, бию такмаклары кебек традицион жанрларны «заманчалаштыру» процессы башлана: ул текстларны яңартканда аеруча сизелә. Колхоз эшеннән ямь табу, бәхетле тормыш, хезмәттәге уңышлар өчен горурлык хисе, Ватанга мәхәббәт һ.б. турында җырлар барлыкка килә.

Такмак кебек борынгы жанр яңа сулыш ала: бию б-н үрелеп бару кебек традицион функциясеннән тыш юмор б-н сугарылган күңелле җырлар рәвешендә башкарыла башлый. Авыл халкының җыр иҗатында 1930 елларда түгәрәк уеннар барлыкка килү яңа бер этап тәшкил итә. Аның башкарылу формалары төрле була: түгәрәк буенча әйләп-бәйләп җырлап әйләнү һәм уен җырлары б-н бергә үрелеп барган парлы уен төрләре. Төп текст б-н кушымтаның башкарылу тизлеге төрле булган әйләп-бәйләп җырлары аеруча киң таралыш ала. Әгәр төп текст, әйләп-бәйләп б-н үрелеп, уртача тизлектә башкарылса, кызу башкарылган кушымта бию такмакларыннан гыйбарәт була. Андый җыр башкарылганда түгәрәк уртасындагы пар гына бии, калган катнашучылар кул чабып җырлап тора.

20 йөзнең 2 нче яртысында татар халкының җыр тормышында зур үзгәрешләр күзәтелә. Авыр сугыш елларыннан соң әйләп-бәйләп уеннары, такмаклар, авыл көйләре көчле яңгыраш ала. Салмак көйләр һәм кыска көйләр элеккечә яратып башкарыла. Сугыштан соңгы унъеллыкта бу жанрларда яңа җырлар аеруча күп иҗат ителә. Шул ук вакытта Казан татарларының халык җыры иҗаты үсешендә нәкъ шушы чор яңа жанр — вальс жанры барлыкка килү б-н истәлекле. Аның төп сәбәбе — русларның 1930 еллардагы һәм сугыш елларындагы җыр иҗатында вальсның («Бөдрә чәчле егет» («Парень кудрявый»), Г.Носов; «Минем сөеклем» («Моя любимая»), М.Блантер һ.б.) күп булуы һәм, татарларның көнкүрешенә дә үтеп кереп, киң таралыш алуы. 1960 тан башлап һәвәскәрләрнең һәм өлешчә проф. башкаручыларның җыр иҗаты массачыл төс ала, аларга массакүләм мәгълүмат чараларының — радио, телевидениенең көчле үсеше зур йогынты ясый. Шушы вакыттан алып, муз. фольклорның әйләп-бәйләп уеннары, бию такмаклары, авыл көйләре кебек жанрлары акрынлап үз көчен югалта бара. Фольклор җырлары авторы булган көнкүреш җырлары тарафыннан кысыклана: көйләрне проф. яки үзешчән шагыйрьләрнең әзер шигырьләренә проф. композиторлар, музыкантлар, җырчылар, мәдәният хезмәткәрләре яза. Электрон техникадан актив файдалану сәбәпле, көнкүреш җырлары совет чорыннан соң аеруча киң таралыш ала (композиторлар һәм башкаручылар практикасында). Җырлар (асылда көйләр) иҗат итү процессы сизелерлек дәрәҗәдә гадиләшә, бу үз чиратында аранжировщиктан бер үк дәрәҗәдә бәйле проф. һәм һәвәскәр иҗатчылар арасында аерма юкка чыгуга китерә. Ш.у.к.: *Халык җырлары*.

Әд.: Исхакова-Вамба Р.А. Татарское народное музыкальное творчество: Традиционный фольклор. К., 1997; Сайдашева З.Н. Песенная культура татар Волго-Камья: Эволюция жанрово-стилевых норм в контексте национальной истории. К., 2002; Нигмедзянов М.Н. Татарская народная музыка. К., 2003.

З.Н.Сәйдәшева.

ХАЛЫ́К НӘФИ́С КӘСЕПЧЕЛЕГЕ́, халык иҗатының бер төре; халык традицион сәнгатенең һөнәрчелек остаханәләрендә, цехларда, артельләрдә эшләнмәләр җитештерү б-н бәйле өлкәсе. Товар-акча мөнәсәбәтләре үсү, нигездә, аз җирлелек һәм крәстияннәрнең катлауларга бүленүе нәтиҗәсендә барлыкка килә. 19 йөз уртасыннан кустарчылык дип атала башлый. Ул гомуми кустарчылыкның бер юнәлеше буларак эш стадиясе нигезендәге хезмәт бүленешле мануфактура җитештерүен тәшкил итә. Казан губернасында (Казанда һәм якын-тирәдәге татар авылларында) 19 йөздә читек-кәләпүш (к. *Каюлы күн кәсепчелеге*, *Каюлы күн*) һәм укалы баш киемнәре (к. *Укалы чигү*) җитештерү алга китә. Рус Х.н.к. төрләре арасында 19 йөзнең 2 яртысы — 20 йөз башында Балык Бистәсендә зәркән эшләнмәләр һәм челтәр бәйләү, Мамадыш өязе Нырты авылында челтәр бәйләү кәсепчелеге (к. *Челтәр бәйләү*), *Питрәч чүлмәк ясау кәсепчелеге*, *Чабакса тимерчелек кәсепчелеге* үсеш ала, һәм 20 йөз башында алар нигезендә земство сәнгати һөнәр мәктәпләре ачыла. Кустарчылар, башкару техникасында да, бизәлештә дә тарихи традицияләрне файдаланып, сәнгатьчә бизәлгән тормыш-көнкүреш әйберләрен күпләп җитештерәләр. Әмма эш процессында хезмәт бүленеше барлыкка килү һәм осталарның базар мөнәсәбәтләренә җәлеп ителүе кәсепчелектә сәнгатьнең җуелуына китерә; шул ук вакытта, Казан губернасы һәм өяз земстволарының тырышлыкларына карамастан, алар 20 йөз башында, фабрикаларда җитештерелгән арзанлы товарлар б-н конкуренцияне күтәрә алмыйча, әкренләп сүлпәнәюгә таба баралар. Окт. рев-циясеннән соң вак һөнәрчеләрнең товарлары б-н эш итүче арадашчылар ин-ты бетерелә; осталарны хезмәт артельләренә һәм берләшмәләргә оештыра торган кооперацияләр барлыкка килә. 1919 елда, вак һөнәр сәнәгатенә булышлык итү турында Бөтенроссия ҮБК карары кабул ителгәннән соң, осталарга дәүләт заказлары бирелә башлый, аларга үз продукцияләрен базарларда сатарга рөхсәт ителә, һәм бу артельләр (бизәкле аяк һәм баш киемнәре, чигү эшләнмәләре җитештерү буенча Казан өязе Кавал волостенда «Эш», Казанда «Читекләр», «Кустарь» һ.б.) оешуга китерә. Әмма шул заман карашыннан совет чынбарлыгы өчен ят дип игълан ителгән башка күп традицион әйберләр җитештерү (шәмаилләр, намазлыклар, йола тастымаллары, киез җәймәләр, комганнар һ.б.) туктатыла. Х.н.к. эшләнмәләре бизәлешенә халык сәнгате әсәрләренең электән ныгып урнашкан системасын җимерә торган совет эмблематика мотивлары (урак һәм чүкеч, биш почмаклы йолдыз, юлбашчыларның портретлары һ.б.) кертелә. 1920–23 тә үткәрелгән сәнәгать исәбен алу вакытында 23 е хосусый, 1 се дәүләтнеке булган 24 «сәнгать һәм гамәли фәнни сәнәгать» оешмасы теркәлә. 1923–25 тә кустарь нәфис кәсепчелегендә эшләүче халык осталары арта; ТАССРда аларның гомуми саны 35 мең кешедән арта (50% татарлар, 45 % руслар). 1926 елгы Бөтенсоюз халык санын алу нәтиҗәләре буенча респ-када 51,5 мең кустарь исәпләнә. Алар башлыча халык аеруча тыгыз урнашкан элекке Арча һәм Мамадыш кантоннарында туплана. Х.н.к. үсешенең алга китүе 1920 елларда чит илләргә Европа һәм Америкада ихтыяҗ зур булган кустарчылык эшләнмәләрен экспортка чыгару б-н бәйле була. Зәркән бизәнү әйберләре (Балык Бистәсе) һәм каюлы күн эшләнмәләр (читекләр, диван мендәрләре) Мәскәүдәге «Главкустпром» аркылы экспортка озатыла. Осталарның артельләргә берләшүе 1920 еллар ахырында тәмамлана. Стат. мәгълүматлары буенча, Х.н.к. эшләнмәләре төрләреннән аеруча чигелгән аяк һәм баш киемнәре (түбәтәйләр, калфаклар) җитештерү зур үсеш ала. Эре артельләр арасында Казанда «Азат хатын» (укалап чигү), «Кызыл кустарь» (каюлы күн, чигү), «Шәрекъ аяк киемнәре», Арча р-нында «Тукай», Лаеш р-нында «Татар», Дөбъяз һәм Питрәч р-ннарында «Суыксу» (барысы да — бизәк-

ле аяк киемнәре җитештерү буенча), Минзәлә р-нында «Текстиль», Чаллы р-нында «Кызыл тукучы», Дөбъяз р-нында «Кызыл киезче», Саба р-нында «Савытчы», Арча р-нында «Көмеш» һ.б. була. Париж күргәзмәсеннән башлап (1925), Х.н.к. товарлары халыкара күргәзмә-ярминкәләрдә күрсәтелә. Каюлы читекләр һәм укалап чигелгән туфлиләр 1920 еллар ахырында — 1930 еллар башында Монце-Милано, Лейпциг ярминкәләрендә, Рига, Прага, Вена күргәзмә-сатуларында «кызыл мал» санала. Ләкин ил эчендә бу товарларга ихтыяҗ кимү һәм чит илләргә экспорт бетерелү сәбәпле, Х.н.к. 1930 еллардан акрынлап кимүгә бара. 1930–50 елларда Х.н.к. вак һөнәрчелек кооперациясе системасында, әмма Татпромсоюз карамагында кала. Бу кул хезмәтен машина б-н башкаруга алыштырып, күпләп товар җитештерүгә китерә, Х.н.к.нең традицион нигезен җимерә, аны сәнәгать пр-тиеләре: мех һәм җитен комб-тлары, галантерея, тегү, киез басу, фетр ф-калары һ.б. алыштыра (к. *Дизайн*). Бөек Ватан сугышы елларында Х.н.к.нең эшчәнлеге туктала һәм ул сугыш тәмамлангач та, бизәкле аяк киеме җитештерүдән башка, торгызылмый. 1950 елларда беренче мәртәбә Х.н.к. торгызу мәсьәләсе күтәрелә, 1965 тән ул Җирле сәнәгать министрлыгына тапшырыла һәм фабрикалар, комбинатлар итеп үзгәртелә (Арча һәм Дөбъяз милли аяк киеме ф-калары). 1969 да *Алексеев бизәклəп туку фабрикасы*, Саба районы Шәмәрдән посёлогында зәркән цехы, 1974 тә өйдә эшләүчеләр комб-ты оештырыла. 1970 елларда Х.н.к. эшләнмәләренә ихтыяҗ арта башлый, ләкин аларны «фабрикалаштыру», милли традицияләрдән читләшү процессы эстетик сыйфат түбәнәюгә китерә. КПСС ҮКның (1975) һәм ТАССР МСның «Халык нәфис кәсепчелеге турында»гы (1976) карарлары б-н Х.н.к. эшләнмәләренең ассортиментын һәм сыйфатын күтәрү буенча чаралар билгеләнә. Әмма алар күп очракта гамәлгә ашырылмый, һәм Х.н.к. үстерү проблемалары хәзерге вакытта да актуаль булып кала. ТР МК тарафыннан 2000–06 еллар өчен Х.н.к.н гамәли-бизәлеш сәнгатен саклау, яңарту, үстерү Программасы 2000 дә кабул ителә. Һөнәрләр һәм Х.н.к. кече һәм урта бизнеска ярдәм итүдә дәүләт ярдәменең өстенлекле юнәлешләреннән берсе итеп билгеләнә. 2000 дә ТР МК каршында Х.н.к. буенча Сәнгать-эксперт советы оештырыла, 2003 тә Дәүләт Х.н.к.н үстерү үзәге һәм Һөнәрләр иҗтимагый палатасы булдырыла, 2004 тә ТРның «Халык нәфис кәсепләре һәм һөнәрләре турында» Законы кабул ителә, анда «Х.н.к.» өлкәсендә дәүләт һәм җирле үзидарә хакимиятләренең вәкаләтләре билгеләнә, оешмалар һәм осталар эшчәнлеге регламентлаштырыла. Ләкин үз вакытында фабрикаларга күчерелгән традицион кәсепчелек икътисади яктан да, иҗат юнәлешендә дә кыенлыклар кичерә. Бу Арча милли аяк киемнәре ф-касының ябылуына китерә. Шул ук вакытта татар каюлы күн, татар һәм рус укалап чигелгән, сөяккә һәм агачка уеп ясалган сувенирлар, бүләк һәм күргәзмә эшләнмәләре җитештерү буенча яңа Х.н.к. пр-тиеләре ачыла (балчыктан уенчыклар ясау буенча «Актүбә уенчыгы», «Азнакай киез аяк киемнәре» АҖ һ.б.), хосусый фирмалар («Туран» милли-мәдәни үзәге фонды» ҖЧҖ, «Экоскин» ҖЧҖ, «Презент» АҖ, «Традиция» фонды, «Эбиволь» АҖ, «Карина» ҖЧҖ), остаханәләр («Болгарлар» А.Липина, С.Федотовның һ.б) барлыкка килә. Халык осталары үз эшләнмәләрен елсаен уздырыла торган респ-ка (Казанда «Осталар шәһәре»), илкүләм (2002 дән, Мәскәү, Бөтенроссия «Ладья») һәм халыкара (2002, Франция, Дижон ш. һ.б.) күргәзмә-ярминкәләрендә күрсәтәләр, 2001 дән Х.н.к. эшләнмәләренең иң яхшы үрнәкләренә конкурслар оештырыла, аерым эшләнмәләргә дәүләт заказлары бирелә. Х.н.к. эшчәнлеге Халык нәфис кәсепчелеге үзәге тарафыннан көйләнә. Ш.у.к.: *Бизәлеш сәнгате*, *Гамәли-бизәлеш сәнгате*, *Рус халык сәнгате*, *Татар халык сәнгате*.

Әд.: Воробьёв Н.И., Бусыгин Е.П. Художественные промыслы Татарии в прошлом и настоящем. К., 1957; Валеев Ф.Х. Народное деко-



Халык нәфис кәсепчелеге. 1. Хатын-кыз такыясы. Бәрхет, ука, сәйләп. Укалап чигү. 19 йөз ахыры – 20 йөз башы. ТР Милли музее; 2. Читек чигү өчен әзерләмәләр үрнәкләре. Каюлы күн. 20 йөз башы. ТР Милли музее; 3. Читекчеләр. 20 йөз башы фоторәсеме; 4. Беләзек һәм йөзек. Көмеш. Каралту, уеплау. Балык Бистәсе һөнәр-сәнгать остаханәсе. 20 йөз башы. ТР Милли музее; 5. Ваза һәм кувшин. Балчык. Ангоб, уеплау, бизәү, рельеф. Питрәч чүлмәк ясау кәсепчелеге. 1930 еллар. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 6. Элекке Казан хәрби округы командующие йорты рәшәткәсе фрагменты. Чуен. Кою, чүкү. Чабакса тимерчелек кәсепчелеге; 7. Сөлге. Киндер тукыма, киҗе-мамык җеп. Чүпләмле туку. Алексеев нәфис туку фабрикасы. 2005; 8. Сувенир уенчыклар. Балчык. Әвәләп ясау, бизәү. Шәмәрдән балчык уенчыклар остаханәсе. 2000 еллар.

ративное искусство Татарстана. К., 1984; Валеева-Сулейманова Г.Ф. Декоративное искусство Татарстана (1920-е — начало 1990-х годов). К., 1995; Российские промыслы: Спец. вып., посвящённый Татарстану. 2001. Окт.-нояб.; Изделия народных художественных промыслов и декоративно-прикладного искусства Республики Татарстан: Каталог. К., 2002.

Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.

ХАЛЫ́К САНЫ́Н ИСӘПКӘ́ АЛУ́, дәүләт органнары тарафыннан ил яки аерым терр-я халкын билгеле бер чорда сыйфатлаучы демографик, икътисади һәм социаль стат. мәгълүматларны кабатланулы яки бер тапкыр җыю процессы. Хәзерге Татарстан терр-ясендә иң элгәреге халык санын исәпләүләр Алтын Урда чорына (1250 еллар, Бәркә ханның идарә итүе) карый. 15 йөздән ясак түләүче халык турындагы мәгълүматлар *писцовый кенәгәләрдә* туплана. Император Пётр I чорында халык санын исәпләүләр даими рәвештә үткәрелә. 1719–1860 та, ш.и. Казан губернасы терр-ясендә, барлыгы 10 «ревизия» уздырыла. Х.с.и.а. программасы халыкның җенес, яшь, никахта булу-булмау, яшәү урыны, дин, ана теле, укый-яза белү дәрәҗәсе, шөгыльләр буенча бүленеше турында мәгълүматлар алуны күздә тота. Х.с.и.а. татарлар арасында чираттагы ирексезләп христианлаштыру омтылышы буларак кабул ителә. Казан губернасында аңа каршы 200 дән артык татар авылы күтәрелеп чыга (к. *Татарларның 19 йөздәге баш күтәруе*).

Чираттагы, Бөтенроссия Х.с.и.а. совет хакимияте заманында — 1920 дә уздырыла; анда демографик һәм а.х. программасы бергә башкарыла һәм кыскача тәртиптә сәнәгать пр-тиеләре исәпкә алына. 1926 елгы Бөтенсоюз Х.с.и.а. киң программа буенча, халык турында гына түгел, шәһәрләрдәге корылмалар хакындагы мәгълүматларны да теркәп үткәрелә. Аның алдыннан аңлату эшләре алып барыла (җәмәгатьчелек фикерен әзерләү, халык алдында лекцияләр уку, сынау өчен исәпкә алу һ.б.). Исәпкә алуның нәтиҗәләре югары ышанычлылык дәрәҗәсе һәм басылган мәгълүматларның тулылыгы б-н аерылып тора. Моннан тыш 1920 елларда шәһәрләр, партия, профсоюз оешмалары буенча исәпкә алулар уздырыла. Алга таба Х.с.и.а.лар 1937 дә (аның мәгълүматлары игълан ителми), 1939, 1959, 1970, 1979 һәм 1989 да, РФ дә 2002 дә һәм 2010 да үткәрелә.

Н.А.Фёдорова.

ХАЛЫ́К САНЫ́Н ТЕРКӘ́Ү КЕНӘГӘЛӘ́РЕ́ (Ревизские сказки), Россиядә яшәгән халыкның 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында исәбен алу (ревизияләү) вакытында төзелгән исемлекләр. 1724 елда салым — җан башына салынган түләү (түбән сословиегә кергән барлык ир затлары яшенә карамый түләргә тиеш була) кертү халык санын алуны таләп итә. 1719–1857 дә 10 ревизия үткәрелә. Крәстияннәр, шәһәр кешеләре, сәүдәгәрләр исәп алуны үтәргә тиеш була. Х.с.т.к. алпавытлар яки аларның управляющийлары, старосталар, шәһәр идарәсе чиновниклары тарафыннан тапшырыла. Х.с.т.к.нә кертелгән затлар «ревизияләүдәге җаннар» дип йөртелә. Кенәгә материаллары өязләр, губерналар һәм бөтен ил буенча гомумиләштерелә. Х.с.т.к. халыкның саны, геогр. урыны, сословие һәм милли составы, яше, гаилә хәле турында мәгълүматларны эченә ала. ТР Милли архивында Вятка губернасы буенча 3 нче һәм 4 нче ревизияләр, Вятка губернасы Алабуга өязе һәм Казан губернасы Лаеш өязе буенча 5 нче ревизия Х.с.т.к. саклана.

Казан губернасында һәм Татарстанда халык саны динамикасы (мең кеше)

Ел	Барлыгы	Шәһәрләрдә	Авылларда	Татарлар	Руслар	Башкалар
1897	2370,0	201,5	2168,5			
1920	2700,0	256,0	2444,0			
1926	2587,5	280,5	2307,0	1265,3	1115,2	207,0
1939	2914,2	614,3	2299,9	1421,5	1251,3	241,4
1959	2850,4	1190,3	1660,1	1345,2	1252,4	252,8
1970	3131,2	1613,9	1517,3	1536,4	1328,7	266,1
1979	3445,4	2185,0	1260,4	1641,6	1516,0	287,8
1989	3637,8	2656,6	981,2	1816,0	1615,0	206,8
2002	3779,2	2790,6	988,6	2000,1	1492,6	286,5
2010	3786,4	2853,6	932,8	2012,5	1501,3	272,6

Әд.: Подъяпольская Е.П. Ревизские сказки как исторический источник // Академику Борису Дмитриевичу Грекову ко дню семидесятилетия: Сб. статей. М., 1952; Кабузан В.М. Народы России в XVIII веке: Численность и этнический состав. М., 1990; шул ук. Народы России в первой половине XIX в.: Численность и этнический состав. М., 1992.

«ХАЛЫ́К СҮ́ЗЕ», атналык иҗтимагый-сәяси, әдәби газета-журнал. Семипалатинск шәһәренең мәдәният җәмгыяте органы. 1917 елның июненнән 1919 ның октябренә кадәр Семипалатинск шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, барысы 136 саны чыга. Нашире — Ф.Айтикин, 1918 нең октябреннән нашире — «Мәдәният» мөселман мәдәни-агарту җәмгыяте, мөхәррире — Г.Мусин. Актив авторлары арасында — Ә.Нәҗип, М.Сәйдәшев һ.б. «Халык сүзе — аның теләге» лозунгы б-н чыгарыла. 1 нче һәм 2 нче Бөтенроссия мөселман һәм 1 нче Бөтенроссия мөселман хәрби корылтайлары эшчәнлеген уңай яктан яктырта. Газета мохтарият булдыру һәм Учредительләр җыены чакыруны яклап чыга. Төрле сәяси партияләр һәм агымнар, Россиянең башка төбәкләрендәге татарлар эшчәнлеге, аерым алганда, Тубыл мөселманнарының 2 нче съезды эшенә багышланган язмалар, Семипалатинск мөселманнар съезды, шәһәр думасы карарлары басыла. Хатын-кызларның сайлау һәм сайлану хокукы турындагы мәсьәлә күтәрелә. «Хатын-кыз дөньясы» сәхифәсендә татар хатын-кызлары тормышы яктыртыла, аларның аз белемле булуларына борчылу сизелә. «Әдәбият» бүлегендә, нигездә, җирле авторлар, ш.и. Ә.Нәҗип, Ш.Шәрәф, К.Мөхәммәт, М.Чарканд, Ж.Юмашев һ.б.ның хикәяләре һәм фельетоннары, Г.Илмәтов, Ж.Габделмәнов, Г.Әлмәт, С.Кудаш һ.б.ның шигырьләре, ш.у. әдәби мәкаләләр, спектакльләргә рецензияләр урнаштырыла. «Вакыт», «Ил», «Милләт», «Безнең тавыш» һ.б. г-таларда чыккан язмалар күчереп басыла. Гражданнар сугышы чорында «Х.с.» җирле халык укый ала торган бердәнбер басма була.

З.З.Гыйләҗев.

ХАЛЫ́К ТЕА́ТРЫ, һәвәскәр (үзешчән) театр коллективы статусын билгеләүче атама. РСФСР мәдәният министрының 1959 ел 20 апрель боерыгы б-н кабул ителә; 1959 ның 25 маенда РСФСР Мәдәният министрлыгы тарафыннан расланган «Һәвәскәрләрнең үзешчән драма театры турында» һәм 1961 елның 9 гыйнварында ВЦСПС секретариаты тарафыннан расланган «Халык үзешчән профсоюзлар театрлары турында» нигезләмәләре б-н регламентлаштырыла. Аннан соңгы елларда бу документларга өстәмәләр һәм төгәллекләр кертелә (СССР Мәдәният министрлыгының 1990 ел 29 март боерыгы). Хәзерге вакытта ТРда Х.т. статусы ТР Мәдәният министрлыгы коллегиясе тарафыннан 2000 нең 29 декабрендә расланган «ТР Мәдәният министрлыгы системасының мәдәни-агарту учреждениеләрендә үзешчән халык коллективы турында үрнәк нигезләмә» нигезендә регламентлаштырыла. Х.т. статусы даими башкаручылар составы, репертуары, күпьеллык эш тәжрибәсе, иҗади башкару эшчәнлегендә югары сәнгати дәрәҗәгә ирешкән, ш.у үзенең катнашучылары арасында даими рәвештә укыту-һөнәри эшчәнлек һәм халык арасында актив тәрбия эше алып барган һәвәскәр театр коллективына ТР Мәдәният министрлыгы тарафыннан, үзешчән сәнгать коллективларының респ-ка смотрлары нәтиҗәләреннән чыгып, район һәм шәһәр хакимиятләре тәкъдиме б-н һәм Нигезләмә таләпләрен исәпкә алып бирелә. Х.т. статусы алган коллектив штатында — режиссёр, рәссам, муз. Х. т. составында — дирижёр, аккомпаниатор, балетмейстер булу каралган. Х.т. үз статусын 3 елга 1 тапкыр раслый һәм смотр комиссиясе карары нигезендә бу исемнән мәхрүм ителергә мөмкин. Татарстанда әлеге исемгә лаек булган беренче коллективлар — Чистай рус халык театры (1959, җитәкчесе Ц.М.Могилевская) һәм Алабуга татар халык театры (1959, җитәкчесе Л.Г.Сәйфуллина). Аннан соңгы елларда Х.т. статусын Чаллы (1962), Азнакай (1965), Әтнә (1966), Нурлат (1968) татар театрлары, Чистай муз. татар театры (1979), Казанның профсоюзлар системасына караган берничә коллектив ала. Эшләү дәверендә Х.т.лары коллективлары (кайберләре 1918 дән үк оешкан — Олы Әтнә авылында, Чаллы шәһәрендә) татар һәм дөнья классик әдәбияты, ш.у. хәзерге драматургларның әсәрләреннән торган зур репертуар туплыйлар. ТАССРның 10 еллыгы исем. мәдәният йортында (Казан) татар муз. театр коллективы тарафыннан Т.Гыйззәтнең «Башмагым» (Ж.Фәйзи музыкасы) комедиясе буенча куелган спектакль зур вакыйгага әверелә. 1957 дә коллектив Мәскәүдә узган Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында катнашу өчен чакырып алына. «Раз-

лом» (Б.А.Лавренёв; Чистай халык театры), «Чаткылар» (Т.Гыйззәт; Алабуга халык театры), «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин), «Ялкын» (Т.Гыйззәт) (икесе дә — Чаллы халык театры), «Банкрот» (Г.Камал; Әтнә халык театры; хәзер дәүләт театры), «Татар хатыны ниләр күрми» (Г.Ибра һимов; Әтнә халык театры), «Тормыш бусагасында» (С.Шәкүров; Нурлат халык театры), «Миңлекамал» (М.Әмир; Баулы халык театры), «Тамырлар» (Ю.Әминев; М.Урицкий исем. мәдәният йортының халык театры, Казан) һ.б. спектакльләр югары башкарылу осталыгы б-н аерылып тора. Х.т.ларының җитәкчеләре булып проф. театрларның актёрлары һәм режиссёрлары эшли. Алар арасында ТАССРның һәм РФнең халык артисты Ю.С.Федотов, ТАССРның халык артисты Һ.И.Солтанов, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе С.Е.Ярмолинец, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе Р.Ә.Бикчәнтәев, ТАССРның атказ. артистлары Б.В.Лохин, Б.П.Шамин, А.В.Люлюкин, В.А.Истомин, Б.З.Роскин, халык театрларының элекке үзешчән актёрлары, ш.и. ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре исеменә лаек булган актёрлардан К.З.Саттаров, Г.Х.Мәрданов, Г.М.Бакунина, Г.Ш.Ялалов, М.Г.Әлиуллина, Н.Ф.Йосыпов, Р.С.Сәләхетдинов, С.И.Мурзина, В.А.Закиров, В.Г.Муллахмәтова, И.М.Хаҗиев, Н.А.Зотеева һ.б. бар. Х.т.лары телне, милли мәдәниятне саклау һәм үстерүдә, халыкны тәрбияләү эшендә мәдәни-эстетик бурычларны хәл итүдә зур роль уйныйлар, Татарстанның мәдәни тормышында мөһим урын алып торалар. 2017 гә ТРда 145 Х.т. исәпләнә: 104 татар, 37 рус, 3 чуаш һәм 1 удмурт театрлары.

Ю.А.Благов.

«ХАЛЫ́К ТЕЛӘГЕ́», атналык иҗтимагый-сәяси газета. Казан губернасы Спас өязе крәстияннәр депутатлары советының мөселман бүлеге органы. 1918 елның 7 апреленнән 1919 ның 16 гыйнварына кадәр Казан губернасының Спас шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, барысы 20 саны чыга. Мөхәррирләре — Х.Сафа, Г.Сөләйманов. Башлангыч чорда газета вак буржуаз юнәлештә була; большевиклар йогынтысы б-н акрынлап совет хакимиятен яклый башлый, Кызыл Армиягә булышлык күрсәтергә һәм ак чехларга каршы көрәшергә чакыра. Мәгариф мәсьәләләренә игътибар бирә, заманча мәктәпләр төзергә, яңа тип укытучылар һәм укытучылар оешмалары булдырырга өнди, укытучылар конференциясе эшен яктырта. Спасны КОМУЧның Халык армиясе частьлары алу вакытында газета чыкмый. 1920 дән «Х.т.» урынына Россия телеграф агентлыгының «Эш» г-тасы чыга башлый.

З.З.Гыйләҗев.

ХАЛЫ́К УЕННАРЫ́. Өлкәннәр һәм балалар уеннарына бүленәләр; спорт (мәйдан) уеннары, драматик һәм җырлы-биюле уеннар. Урта гасырлар чыганакларында традицион уеннарны тәртипкә салган язма кагыйдәләр һәм кулланмалар булуы күрсәтелә. Гомумтөрки тамырлы күп кенә мәйдан уеннарының күпгасырлык тарихы һәм бай традицияләре бар, алар фольклорда сакланган, атамалары сүзлекләрдә теркәлгән. Мәс., *Мәхмүд Кашгарының* «Диване лөгать әт-төрк» сүзлегендә (1072–74) сөякле уен, чикләвекле уен, таганлы уен, бармаклы уен, агач кәшәкә б-н туплы уен, Болгар шәһәреннән Якуб бине Гали Хаҗҗәмнең «Җәядән ату ярышларында батырлык» китабында (10 йөз) атта туплы хоккей хакында искә алына. Хәзерге татар телендәге кебек үк, борынгы төркиләрдә «уен» атамасы «ярыш» мәгънәсен белдергән.

Күңел ачуларның аерым төркемен халык календарена туры килгән уеннар хасил итә, мәс., *Сабан туе*, *Җыен* Сабан туе яки мәйдан Х.у. б-н үрелеп бәйрәм ителгән, аларның характерлы үзенчәлекләре — бөтенлек (кереш — уен — йомгак) һәм катгый рәвештә бәйгегә һәм җиңүгә ирешүгә корылганлык. Ул уеннарның телдән буыннан-буынга тапшырылган үз кагыйдәләре барлыкка килгән. Аерым алганда, шул кагыйдәләр буенча, аксакаллар-судьялар көрәштә башлангыч ярышларда авыр һәм җиңел авырлыктагы батырларның бил алышуларына юл куймаганнар: бердәйрәк бәдәнле һәм авырлыктагы парлар сайлап алынган. Элеккеге традиция буенча, кагыйдә буларак, ат чабышларында җайдаклар сыйфатында җиңел авырлыктан ир-атлар яки 10–12 яшьлек малайлар катнаша. Сабан туеның традицион уеннары — төрле дистанцияләрдә тизлеккә һәм чыдамлыкка йөгерү, узышып тауга чабып менү, тоткарлыклар аша йөгерү һ.б. Сабан туенда катнашучылар бик теләп кросс йөгерешләрендә ярышалар. Гадәттә, төрле яшьтәгеләр өчен берничә йөгереш оештырыла. Аны балалар башлап җибәрә. Ара чама б-н билгеләнә: якынча ярты чакрымнан — бер һәм бер чакрымнан ике чакрымга кадәр. Әлеге йөгерешнең барлык нечкәлекләрен — аңа әзерләнүдән финишка кадәр — 20 йөз башында татар язучысы М.Гали тасвирлый. М.Кашгари «тауга чабыш»ны сурәтли. Ул, батырлар бәйгесенең бер төре буларак, татар эпосында урын алган (мәс., «*Алпамша*»). Аның тамырлары борынгы тарихка барып тоташа, килеп чыгышы татарларның бабаларының «тау рухы»на табынулары б-н бәйле. Элек-электән Сабан туенда авырлык — ташлар күтәрүдә ярышканнар. Ярышучылар якынча 20–30 *кг* авырлыктагы ташны бер кул б-н күтәргәннәр. Хәзерге Сабан туенда герләр яки штангалар кулланыла. Борынгыдан «сикерешләр» популяр була. Борынгы төркиләрнең башка милләт спорт төрләре кебек үк алар М.Кашгари сүзлегендә чагылыш таба. Казан Сабан туендагы ярышлар төре буларак, 1907 елда Д.Я.Коблов биеклеккә сикерү турында яза. М.Кашгари ш.у. «аркан тартыш» уены, «ук атыш» ярышлары хакында искә ала. Башка төрки халыклардагы кебек үк татарларда йодрык сугышы җәелдерелә. Хәзерге вакытта да күңел ачу уеннары программасына торба аша шушуда җитезлеккә, челән аякта йөрүдә тизлеккә ярышлар, аркылы борыс аша атлап чыгу, бүрәнә кисү ярышы, парлап «өч аяклап» яки аякларны бәйләп йөгерү, зур итекләр киеп йөгерү, күзләрне бәйләп тактага кадак кагу, күзләрне йомып кашык б-н яки көянтәләп чиләк б-н су ташу керә. Сабан туе капчык киеп йөгерү, күзләрне бәйләп чүлмәк вату, бүрәнәдә капчык сугышы, баганага үрмәләп менү һ.б. традицион уеннардан башка узмый. Кайбер мәйдан уеннары, мәс., «ашык», «кузна» онытылып, гамәлдән чыктылар.

Авыл яшьләре арасында күп кенә җырлы-биюле уеннар таралган була. Гадәттә, алар табигатьтә оештырылган язгы-җәйге әйләнә-бәйләнә уеннарын ачып җибәрәләр. Көзге-кышкы чорда аулак өйләр уздырыла. Яшьләр уеннары традицион халык бәйрәмнәре — Сабан туеның һәм Җыенның аерылгысыз өлешен тәшкил итә. Алар татарларның барлык төркемнәре өчен хас була. Җыенда «түгәрәк уен», «таклы уйнау», «көтүле уйнау», «тәкәле уйнау» уйнала. Ул уеннарда егетләрнең кызлар б-н йөреп керүе рөхсәт ителә, алар «озын уен», «куышка бару» дип атала. «Кичке уен»нар кыр эшләреннән бушаган чорда аяз көннәрдә оештырыла. Атна саен уздырылган җомга уеннарында авылның барлык яшьләре катнаша («ындыр арты», «кала тавы» уеннары һ.б.). Борынгыдан нард, шахмат, шашка, сөякле уеннары тарала.

Ачык һавада уздырылган балалар уеннары һәм күңел ачулары массачыл төс ала һәм шул асылын саклый. Алар үсеп килүче буынны физик һәм әхлакый-эстетик тәрбияләү, ш.у. өйрәтү бурычларын башкаралар. М.Кашгари сүзлегендә балаларның «моңуз-моңуз» («мөгез-мөгез») уены искә алына. Аның асылы түбәндәгедән гыйбарәт: балалар елга буенда чүгәләп утыралар, араларыннан берсе «мөгез-мөгез» дип әйтә, башкалар «Нинди мөгез, нәрсә мөгезе?» дип сорыйлар. Алып баручы мөгезле хайваннарны санап чыга, калганнар аның сүзләрен кабатлыйлар. Ара-тирә алып баручы дөя, ишәк кебек хайваннарны да телгә ала. Әгәр дә кемдер, онытылып китеп, аның артыннан мөгезсез хайван исемен кабатласа, аны суга төртеп төшерәләр. Эчтәлеге буенча уен татар балалары арасында популяр «очты-очты» уенына тартым. Күп кенә төрки телле халыклар арасында «ак тирәк, күк тирәк» уены таралган була. Бу уенда балалар бер-берсенә каршы ике сафка тезеләләр һәм үзара сөйләшәләр. Катнашучыларның берсе әледән-әле алар янына йөгереп килә һәм уйнаучылар чылбырын өзәргә тырыша, ниятенә ирешсә, уйнаучыларның берсен үз төркеменә (лагерена) ала. Ихтимал, уенда күчмә кабиләләр көнкүрешенең аерым күренешләре сакланган (әсирләр алмашу яки туй йоласы). Гадәттә, җырлы-биюле уеннарның алдан билгеләнгән сюжеты була; көй һәм җырның ритмы уен хәрәкәтләре ритмына туры килә, аларның эчтәлеге хәрәкәтләрдә күрсәтелә (мәс., «Габдулла» уены). Драматик уеннарда гәүдә хәрәкәтләре, диалоглар һәм монологлар аша нинди дә булса вакыйга бәян ителә. Андый уен сюжетында төенләнеш, кульминация һәм чишелеш ачык чагыла (мәс., «бүре-аю» уены). Бу уеннар безнең көннәргәчә баштагы рәвешләрендә килеп җитмәгәннәр, аларның бер өлеше җуелган, башка өлеше, кайбер элементлары гына сакланып, үзгәрешләр кичергән.

Әд.: Татар халык уеннары. К., 2002; Галеев Э.Х., Ханбиков Я.И. Татарские народные

игры и праздники. К., 1975; Татары. М., 2001; Шарафутдинов Д.Р. Исторические корни и развитие традиционной культуры татарского народа XIX — начало XXI вв. К., 2004; Этнография татарского народа. К., 2004.

Л.М. Айнетдинова.

ХАЛЫ́К УЧИ́ЛИЩЕЛӘРЕ (1786 ел уставы), Россиядә башлангыч уку йортлары. Император Екатерина II нең 1786 ел 26 апрель Указы б-н өяз шәһәрләрендә кече Х.у., губерна шәһәрләрендә әсасый Х.у. ачыла. Укытуның структурасы һәм эчтәлеге 1786 ның 5 август Уставы б-н билгеләнә. Х.у. ачу губерна хакимиятенә тапшырыла, уч-щеләр губерна җәмәгать кайгыртуы приказы хисабына тотылырга тиеш була. Акча җитмәү һәм Уставта каралган үзәкләштерелгән җитәкчелек булмау сәбәпле, программа үтәлми. Барлык губерна шәһәрләрендә ачылган төп Х.у.нең күпчелеге Устав таләпләренә җавап бирми, кече уч-щеләр бары тик берничә шәһәрдә генә барлыкка килә. Казан губернасында *Казан әсасый халык уч-щесе* (1786), Чабаксар, (1789). Козьмодемьянск (1791), Ядрин (1791), Чистай (1796) шәһәрләрендә кече Х.у. ачыла. Кече Х.у. 2 еллык башлангыч мәктәпләр була, аларда уку, язу, арифметика, катехизис, дин тарихы, рус грамматикасы, матур язу, рәсем укытыла (2 шәр укытучы эшли). Төп Х.у. 5 сыйныфны үз эченә ала, беренче 2 сыйныф кече Х.у.нә туры килә; уку срогы 6 ел була — соңгы сыйныф 2 еллык була (5 укытучы эшли). Өлкән сыйныфларда катехизис, дин тарихы, арифметика, рус грамматикасы, тарих, география, геометрия, механика, физика, табигать тарихы, гражданлык архит-расы укытыла. Гимназиягә һәм университетка укырга теләүчеләр латин телен өйрәнә. Әсасый Х.у. каршындагы пед. сыйныфларны тәмамлаучылар кече Х.у. укытучылары булыр дип фаразлана. 1786 да әсасый Х.у.нә укытучылар әзерләү өчен С.-Петербургта укытучылар семинариясе ачыла. Гамәлдә барлык укытучылар да руханилар семинариясендә укучылар арасынан билгеләнә. 1803 тән барлык Х.у. Халык мәгарифе министрлыгы тарафыннан финанслана башлый. 1818 дә Казан губернасының кече уч-щеләре *өяз училищеләре* итеп үзгәртелә. 1835 тә Казан әсасый Х.у. җирлегендә *Казандагы икенче ир балалар гимназиясе* һәм өяз уч-щеләре ачыла.

Әд.: Толстой Д.А. Городские училища в царствование императрицы Екатерины II. СПб., 1886; Рябинский К.С. К столетию Козьмодемьянского городского училища: Историческая записка об училище. 1791–1890. К., 1891.

ХАЛЫ́К ХУ ҖАЛЫГЫ́ СОВЕТЫ́ (ХХС, Совнархоз), ТАССРда 1918–32, 1957–63 елларда сәнәгать һәм төзелеш эшләре б-н идарә иткән дәүләт органы. Казан губернасы Эшче, солдат һәм крәстиян депутатлары советының (үз эшен 1918 нең 20 июнендә башлый) 1918 ел 19 февраль карары нигезендә төзелә; Бөтенроссия ҮБК һәм РСФСР ХКСның 1920 ел 20 май Декретына һәм ТАССР ҮБКның 1920 ел 28 сентябрь карары б-н ТАССР ХХС дип үзгәртелә. Башта сәнәгатьне национализацияләү, җитештерүне җайга салу, сәнәгый продукцияне бүлү б-н җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра, хәрби максатларда хәзерләүләр б-н шөгыльләнә; 1920 елларда респ-кага буйсынулы дәүләт пр-тиеләре, җирле трестлар һәм дәүләт сәүдә оешмалары б-н җитәкчелек итә, респ-ка кысаларында барлык сәнәгать үсешен координацияли, кооператив һәм хосусый сәнәгать эшчәнлеген контрольдә тота; 1920 еллар ахырыннан ш.у. җирле сәнәгатьне реконструкцияләү, пр-тиеләр төзү һәм файдалануга тапшыру б-н шөгыльләнә. Составына Президиум, тармак бүлекләре (1918 дә — 12, 1920 дә — 36); 1920 еллар башында — оештыру-адм., финанс-хисап, җитештерү, исәп һәм стат. идарәләре; 1920 еллар уртасыннан — эшләр (гомуми, финанс-хуҗалык бүлекләре), дәүләт сәнәгате (җитештерү-техник, ягулык, план-икътисад, стат., икътисад һәм һөнәри-техник белем бирү, кустарь сәнәгать һәм кәсепчелек кооперациясе, кантоннар сәнәгате, сәнәгатьне мобилизацияләү бүлекләре) идарәләре, мобилизацияләү, рационализация бюролары, бухгалтерия керә. 1930 еллар башында ХХС составында: эшләр башкару идарәсе, бухгалтерия, махсус, рационализация һәм уйлап табулар бюролары, ягулык һәм энергетика, хезмәтне экономияләү, кадрлар, исәп-икътисад, эшчәнлеккә контроль, районнар сәнәгате һәм кустарь сәнәгать, капиталь төзелеш, тәэминат һәм транспорт, план-җитештерү секторлары. Губерна (1920 дән — респ-ка) ХХС карамагында өяз ХХСлары (1918–20), кантоннарның (1920–30) һәм районнарның (1930 дан) вәкаләтле вәкилләре, ш.у. металл эшкәртү, химия, урман, агач эшкәртү, полиграфия, җиңел һәм азык-төлек сәнәгате, төзелеш материаллары һәм сәнәгатьнең башка тармаклары пр-тиеләре була. РСФСР Югары ХХСна, ТАССР ҮБКна, ТАССР ХКСна буйсына. ТАССР ХХС СССР ҮБК һәм ХКСның 1932 ел 5 гыйнвар һәм 27 март, ТАССР ҮБК һәм ХХСның 1932 ел 6 апрель карарлары б-н гамәлдән чыгарыла, вазифалары *Татарстан АССР Җиңел сәнәгать халык комиссариаты*на тапшырыла.

СССРда икътисади адм. районнар буенча терр. идарә итү принцибына күчү нәтиҗәсендә СССР ЮС Президиумының 1957 ел 10 май Указына һәм СССР МСның 1957 ел 22 май карары б-н Татарстан икътисади адм. р-ны ХХС төзелә (үз эшен 1957 нең июне-июлендә башлый). Ул сәнәгатьнең районлап махсуслашуы һәм кооперациясе үсеше, эчке чимал һ.б. ресурсларны мобилизацияләү, пр-тиеләрнең техник җиһазландырылу дәрәҗәсен күтәрү б-н шөгыльләнә. ХХСның тармак һәм функциональ бүлекләре, идарәләре була. Тармак идарәләре нефть, энергетика, машиналар төзү, химия, урман, йорт җиһазлары җитештерү һәм агач эшкәртү, җиңел, азык-төлек, ит һәм сөт сәнәгатьләренең, төзелеш материаллары, комплектлау, тәэминат һәм сату, хезмәт тәэминаты, транспорт тармакларының бертөрле пр-тиеләрен берләштерә. Функциональ төрдәгеләр — җитештерү-техник идарә (яңа техника, җитештерү, баш механик һәм энергетик, фәнни-тикшереңү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләре, куркынычсызлык техникасы бүлекләре); адм.-хуҗалык, план- икътисад, финанс, капиталь төзелеш, җитәкче кадрлар һәм уку йортлары, хезмәт һәм хезмәт хакы, тышкы багланышлар һәм кооперация, үзәк бухгалтерия бүлекләре — респ-кадагы 175 пр-тиенең эшчәнлеген координациялиләр, планлаштыралар һәм аларның ХХС карарларын үтәүләрен контрольдә тоталар. ХХС каршында тармак идарәләренә тәңгәл секцияләрдән торган техник-икътисади совет эшли. РСФСР МСна һәм 1960 тан РСФСР ХХСна буйсына. РСФСР ЮС Президиумының 1962 ел 25 декабрь Указы һәм РСФСР МСның 1962 ел 26 декабрь карары б-н Татарстан икътисади адм. районы ХХС Урта Идел икътисади адм. районы ХХСна кертелә; үзәге — Куйбышев (Самара) шәһәре. КПСС ҮКның 1965 тәге сентябрь Пленумында сәнәгать б-н тармак системасы буенча идарә итүгә кайту турында карар кабул ителә. СССРның 1965 ел 2 декабрь Законы б-н совнархозлар бетерелә һәм сәнәгать министрлыклары оештырыла. Рәисләре: С.М.Брауде (1918–19), М.Г.Рошаль (1919–21), В.В.Сериков (1921- 22), Е.Н.Забицкий (1922–1924 нең гыйнвары), А.Н.Злобин (1924 нең гыйнвары–июне), М.С.Мансырев (1924 нең июне–декабре), Г.С.Дукальский (1925–1927 нең феврале), Я.С.Щербинин (1927 нең феврале–ноябре), И.А.Булгаков (1927 нең ноябре — 1929 ның гыйнвары), А.Г.Ганиев (1929 ның гыйнвары–декабре), А.А.Терский (1929 ның декабре — 1930), Ю.Н.Паперный (1930–32), А.Т.Шмарёв (1957–60), С.Л.Князев (1960–63).

Е.Б.Долгов.

ХАЛЫ́КАРА АРБУ́ЗОВ БҮЛӘГЕ́, фосфорорганик химия үсешенә зур өлеш керткән галимнәргә бирелә торган бүләк. 1997 елның 11 июлендә (А.Е.*Арбузовның* тууына 120 ел тулганда) ТР Президенты тарафыннан респ-када химия фәнен алга таба үстерү, фосфорорганик химия өлкәсендә фәнни хезмәтләр, ачышлар һәм уйлап табулар иясе галимнәрне кызыксындыру, А.Е.Арбузов һәм



Халыкара Арбузов бүләге медале.

Б.А.Арбузов истәлеген мәңгеләштерү максатында гамәлгә куела. Илебезнең һәм чит илләрнең күренекле галимнәреннән торган Х.А.б. бирү ком-ты карары буенча Казанда 2 елга бер тапкыр Россия яки чит илдән булган 1 галимгә бирелә. Ком-т дөньяның фосфорорганик химия өлкәсендә эшләүче, әй-

дәп баручы галимнәренә өч кандидат күрсәтүне сорап, язма рәвештә мөрәҗәгать итә. Кандидатуралары агымдагы елның маена кадәр күрсәтелгән галимнәрнең хезмәтләре карала. Кандидатның казанышларын күрсәтүче кыскача резюмене үз эченә алган тәкъдим ком-тның җаваплы секретарена җибәрелә. Июнь аенда уздырыла торган ком-т утырышы кандидатуралар буенча фикер алышканнан соң, лауреат сайлана (нәтиҗәләр респ-ка матбугатында басылып чыга). Аңа диплом, медаль һәм акчалата бүләк тапшырыла; лауреат үз казанышлары турында лекция укый. ТРның югары дәрәҗәле рәсми вәкиле рәислегендәге тантаналы җыелышта лауреат исеме игълан ителә. Тантанада илебез һәм чит ил галимнәре, студентлар катнаша. 1997 дә, А.Е.Арбузовның тууына 120 ел тулу уңае б-н, Х.А.б. ике кешегә: А.Н.Пудовикка һәм Төнъяк Каролина ун-ты (АКШ) профессоры Льюис Квинга тапшырыла. Төрле елларда бүләккә Польша ФАнең Молекуляр һәм макромолекуляр тикшеренүләр үзәге (Лодзь ш., 1999) профессоры Ян Михальский, Франция химия җәмгыяте президенты, Экология политехник ин-ты профессоры Франсуа Матей (Париж, 2001), Бонн шәһәрендәге Нәорганик химия ин-ты директоры, химия профессоры Эдгар Ника (Германия, 2003), Тохоку ун-ты профессоры Масааки Йошифуджи (Япония, Сендай ш., 2005), проф. Жао Юфен (Кытай, Сямынь ун-ты, 2015), проф. Манфред Шеер (Германия, Регенсбург ун-ты, 2017) лаек була. *В.Г.Абзалова.*

ХАЛЫ́КАРА АСТРОНО́МИЯ БЕРЛЕГЕ́ (ХАБ), фәнни җәмгыять, астрономия үсешенә, төрле илләр астрономнарының эшлекле аралашуына булышлык итә, күп обсерваторияләр катнашуын таләп иткән астрономик тикшеренүләрне координацияли. 1919 елда оештырыла. Берлекнең әгъзалары — 70 тән артык илнең милли фәнни оешмалары галимнәре (10000 нән артык әгъза), шул исәптән ТР галимнәре: О.И.Белькович, М.И.Лавров, А.И.Нефедьева, Н.Г.Ризванов, Н.А.Сәхибуллин.

ХАБның эш органнары — эшчәнлекләре астрономия өлкәсендәге төрле проблемаларны хәл итүгә юнәлтелгән башкарма ком-т, 50 дән артык тармак комиссиясе һәм эшче төркемнәр; ХАБ эшчәнлеге б-н Ген. ассамблеяләр җитәкчелек итә, алар берлек әгъзасы булган илләрнең берсендә 3 елга бер җыелалар (1958 дә — Мәскәүдә). Анда астрономиянең актуаль мәсь әләләре буенча фәнни докладлар тыңлана, хисаплар раслана, төрле илләрнең астрономнары катнашындагы тикшеренүләрнең программасы тәкъдим ителә.

Р.Г.Усманов.

ХАЛЫ́КАРА МӨСЕЛМА́Н КИНОСЫ́ ФЕСТИВАЛЕ́, Казанда уздырыла. 2005 елда РФнең мөселман җәмәгать оешмалары башлангычы, Президент һәм ТР Хөкүмәте, РФ Мәдәният министрлыгы, РФнең Мәдәният һәм кинематография буенча федераль агентлыгы ярдәме б-н оештырыла. Фестивальне оештыручылар — Россия мөфтиләр шурасы, «Ислам дөньясы» телевидеокомпаниясе, Ислам мәдәният үзәге. Фестивальнең президенты — Россия мөфтиләр шурасы рәисе мөфти Равил *Гайнетдин*, вице-президенты — Ислам мәдәният үзәге президенты Габделвахид Ниязов, ген. директоры — «Ислам дөньясы» телевидеокомпаниясе президенты Җәуди Мамиргов. Оештыру ком-ты рәисе — З.Р.*Вәлиева*. Мөселман кинематографистларының ел саен була торган форумы рәвешендә уздырыла (Россиядәге, ш.у. якын һәм ерак мөселман чит илләрендәге мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләренең даими очрашу һәм тәҗрибә алмашу урыны). Аның максатлары —



«Алтын мөнбәр» фестиваленең төп призы. Авторы — Ж. Мамиргов.

мөселман кинематографистларының иҗади казанышларын күрсәтү, Россия һәм дөнья күләмендә ислам һәм мөселманнар турында объектив караш тудыру, Россиядә ислам диненең рухи-әхлакый һәм мәдәни традицияләрен популярлаштыру. Конкурс нәтиҗәләре буенча иң яхшы нәфис фильм, иң яхшы режиссёрлык эше, иң яхшы документаль фильм, иң яхшы ир-ат роле, иң яхшы хатын-кыз роле, иң яхшы анимацион фильм, иң яхшы оператор эше (нәфис фильмда) номинацияләрендә призлар тапшырыла; ш.у. ТР Президентының «Кино сәнгатендә гуманизм өчен», халыкара ТЮРКСОЙ оешмасының «Төрки дөнья кинематографиясе үсешенә керткән өлеше өчен» махсус призлары, «Ислам мәгърифәтен үстерүгә керткән өлеше өчен», «Кино сәнгатендә яңа формалар тапкан өчен» һ.б. призлар бирелә. Фестивальнең жюри составында — дөнья кино сәнгатенең күп кенә танылган эшлеклеләре. 2005 тә узган 1 нче фестивальдә реж. Октай Миркасыймның «Сихерче» (Әзәрбайҗан) фильмы лауреат була. Алга таба фестиваль ел саен уздырыла. Анда «Салкынның күз яше» («Слеза холода», реж. Азизулла Хәмиднәзадә, Иран, 2006), «Азиз баба» (реж. Нәсер Хәмир, Франция-Германия-Тунис-Венгрия-Иран-Бөекбритания, 2007), «Әни өчен «ми» («Ми» для мамы», реж. Рәсүл Моллаголипур, Иран, 2008), «Джодха акбар» (реж. Ашутош Говарикер, Һиндстан, 2008), «Бер сугыш» («Одна война», реж. Вера Глаголева, Россия, 2009), «Бибинур» (реж. Юрий Фетинг, Россия, 2010), «Минем тәэсирле кинотеатрым» («Мой впечатляющий кинотеатр», реж. Лу Янг, Кытай, 2011), «Шикәр бөртеге» («Крупица сахара», реж. Сәед Риза Мир-Кәрими, Иран, 2012), «Боҗралар» («Круги», реж. Срджан Голубович, Сербия, Германия–Франция–Хорватия–Словения, 2013), «Хәлимә юлы» («Хәлимә юлы», реж. Арсен Остойич, Хорватия, 2014), «Таулар алиһәсе» («Королева Гор», реж. Садыйк Шер-Нияз, Кыргызстан, 2015), «Үлемсез» («Бессмертный», реж. Һади Мохагех, Иран, 2016) фильмнары җиңү яулый.

2017 нең сентябрендә 13 нче фестиваль була. Конкурс программасында дөньяның 27 иленнән 60 фильм катнаша. Реж. Мостафа Караның «Кандагар салкыны» («Холод Кандагара», Төркия-Венгрия) фильмы иң яхшы фильмнардан дип табыла, тулы метражлы уен фильмының иң яхшы актёры — Дулига Акмолда («Ораlман», Казакъстан). «Хатын-кызлар көне» («Женский день», Мисыр) фильмындагы хатын-кызлар ансамбле — Илһам Шахин, Нахед Эль-Себо һәм Нелли Кәрим «Иң яхшы хатын-кыз роле» призы б-н бүләкләнә. (2010 га кадәр — «Алтын мөнбәр» фестивале).

ХАЛЫ́КАРА ЭШЧЕЛӘ́Р ХӘЙРИЯ́ ОЕШМАСЫ́ (Межрабпом), эшчеләр теләктәшлеге оешмасы. 1921 елның сентябрендә Берлинда Совет Россиясенең ачлыктан интегүче районнары халкына ярдәм ком-тларының Халыкара конференциясендә төзелә. ҮК рәисе — Коминтерн Башкарма ком-ты әгъзасы Клара Цеткин, секретаре — Вильгельм Мюнценберг. Җитәкчелек составына Мартин Андерсен-Нексё (Дания), Анри Барбюс, Поль Вайян-Кутюрье, Ромен Роллан һәм Анатоль Франс (Франция), Теодор Драйзер (АКШ), Альберт Эйнштейн (Германия), Бернард Шоу (Англия) һ.б. керә. Оешма акча



XIII Халыкара мөселман киносы фестивале. Казан. 2017 ел.

җыю, транспорт табу һәм Россиянең ачлыктан интегүче районнарына азык-төлек йөкләре озату буенча эш алып бара. 1921–22 дә ТАССРга 1 млн. 772 мең 361 пот азык-төлек, кием-салым, медикаментлар һ.б. йөкләр китерелә. Моннан тыш, Х.э.х.о.ның Казан бүлеге респ-када кустарчылык сәнәгате һәм а.х. үсешенә ярдәм итә: 3 һөнәри-техник мәктәпне, аяк киеме, тегү һәм механика остаханәләрен тәэмин итеп тора, «Корноухово» (Лаеш кантоны), «Сахарный» (Чистай кантоны), «Коминтерн» (Спас кантоны) с-зларын шефлыкка ала. 1923 тән Х.э.х.о. эшчәнлегендә капиталистик илләр хезмәт ияләренең сыйнфый көрәшен яклау үзәк урынны ала. Оешма эшчәнлеген 1935 тә туктата.

Әд.: Вторые полгода работы Наркомпрода ТАССР в условиях голода. К., 1922; Климов И.М. Помощь Советского правительства и великого русского народа трудящимся Татарской республики в борьбе с голодом 1921–1922 годов // Уч. зап. Казан. ун-та. 1954. Т. 114, кн. 5.

М.А.Сәйдәшева.

«ХАЛЫКЛА́Р ДУСЛЫГЫ́» МУЗЕ́Е, Балтач р-нының Чепья авылында. 1965 елның 1 маенда оештырыла, 1967 нең 24 маенда ачыла. 1989–2006 да ТР Милли музее ф-лы; 2007 дән муниципаль музей. Экспозиция мәйданы — 450 *м*², коллекцияләрендә 15480 саклау берәмлеге исәпләнә. Аларның нигезен укытучы һәм музейны оештыручы Г.Г.Галиев туплаган бер мең экспонат тәшкил итә. Махсус төзелгән ике катлы бинаның 9 залында урнашкан экспозиция төбәк тарихын яктырта. Төп бүлекләр: «Төбәк территориясендә археологик казу эшләре», «Төбәк халыклары этнографиясе», «Төбәк Беренче рус революциясе елларында (1905–07)», «Төбәк Бөек Ватан сугышы елларында», «Төбәк табигате», «Төбәктә авыл хуҗалыгы». Экспозициянең зур өлешен палеонтологик һәм археол. коллекцияләр: Шушма елгасы буенда казу эшләре вакытында табылган мамонт теше (озынлыгы 2 *м* га якын, авырлыгы 137 *кг*), ук очлыклары, ыргаклы сөңге, таш чүкеч һәм балта һ.б. тәшкил итә. Табигый фонд экспонатлары арасында — көрән аю (биеклеге 2 *м* 32 *см*), бүре, селәүсен һ.б. хайваннар сөкәтләре. Этнографик комплекслар төбәк терр-ясендә яшәүче татарларның, удмуртларның, мариларның, русларның, чуашларның 19 йөз — 20 йөз башы көнкүреш һәм матди мәдәният предметларын (кием-салым, хезмәт кораллары, өй җиһазлары, халык гамәли бизәлеш сәнгате предметлары: туку, чигү, камали — удмуртларда тимер акчадан күкрәк бизәнү әйберләре) үз эченә ала. 19 йөз Тула самоварлары, 1820 дә Согуд Гарәбстанында эшләнгән комган, 19 йөз уртасы Швейцария сәгате экспозициягә куелган. Интерьер комплексы М.Мөлековның 19 йөз ахыры — 20 йөз башы сәүдәгәр кибете күренешен чагылдыра. Кораллар коллекциясе төрле елларда район терр-ясендә табылган үрнәкләрне колачлый. Экспонатлар арасында — 1773–75 тәге Крәстияннәр сугышыннан калган тимер кистән, русларның Тулада эшләнгән тантана кылычы (1840), француз хәнҗәре (1855), төрек кылычы (1858), ш. у. соңгы елларда Америка, Бельгия, Төркия, Германиядә җитештерелгән кораллар: винтовкалар, наганнар, маузерлар һ.б. Төбәк терр-ясеннән Себер тракты үткән, бу ш. у. экспозициядә чагылыш таба: кул богаулары, Малмыж вакытлыча тоту төрмәсеннән 19 йөз ахыры зынҗырлары, 1905–07 дә сәяси сөргендәге грузиннарның көнкүреш әйберләре урын алган. Язма чыганаклар һәм китаплар арасында — чиркәү-приход мәктәбен тәмамлау турында таныклык (1880), «Вотякларда алар турында беренче тарихи хәбәрләр заманыннан 19 йөзгә кадәр христианлык» («Христианство у вотяков со времени первых исторических известий о них до





Чепья авылында «Халыклар дуслыгы» музее. 1. Халыкның көнкүреш әйберләре экспозициясе; 2. Удмурт һәм татар милли костюмнары.

19 в.», 1899), «Романовлар Йортының патшалык итүенең өч йөз еллыгы» («Трёхсотлетие царствования Дома Романовых», 1913) һ.б. 19 йөз уртасыннан а.х. үсеше, колхозлар оешу һәм кулакларны бетерү тарихы, сугыштан соңгы чор тулы итеп чагыла. Авыл хуҗалыгы кораллары арасында — агач сабан, имән китмән һ.б. Экспозициянең зур бер бүлеге Гражданнар һәм Бөек Ватан сугышлары (төбәктә яшәүчеләр дә катнаша) тарихына багышлана. Бик зур бүлекне авыл тарихында тирән эз калдырган шәхесләргә багышланган материаллар тәшкил итә. Музейның аеруча кыйммәтле коллекцияләре: этнография (1170 берәмлек), археол. (150 берәмлек) экспонатлар, сирәк китаплар (200 якын берәмлек), кораллар (24 берәмлек), нәкышь әсәрләре (53 берәмлек). Музей ел саен музей оешу һәм ачылу көннәрен, Г.Тукайның туган көнен (26 апр.), Җиңү көнен (9 май), Халыкара музейлар көнен (18 май) билгеләп үтә.

Музей тарафыннан «Халыклар дуслыгы» музее» буклеты нәшер ителә (2003).

ХАЛЫКЛАРНЫ́Ң БӨЕ́К КҮЧЕШЕ́, 2–7 йөзләрдә Евразия терр-ясендә төрки, герман, славян һ.б. кабиләләрнең массакүләм күченүләренең тарихи атамасы. Ерак Көнчыгыштан алып Көнбатыш Европага кадәрге терр-яне колачлый. Колбиләүчелек һәм ыруглык социаль-икътисади мөнәсәбәтләре таркалу һәм феодализм барлыкка килү чорында бара. Х.б.к. шартлы рәвештә 3 чорга бүленә: **1 нчесе** (2 йөз — 4 йөз уртасы) герман кабиләләрендә хәрби-кабилә берлекләре оешу (Рейнның югары өлешендә алеманнар, урта һәм түбән Рейнда франклар, Эльбаның түбәнге өлешендә сакслар, Дунай уртасы тирәсендә вандаллар, Кара диңгез буенда готлар) һәм аларның Рим империясе чикләренә актив үтеп керүләре, ш.у. Көньяк Уралда һәм Идел аръягында *һуннарның* этносәяси берләшмәсе барлыкка килү б-н сыйфатлана; **2 нчесе** (4 йөз уртасы — 5 йөз уртасы) һуннарның Европага килеп чыгуы, Рим империясенең таркалуы һәм «варварларның» империя чикләреннән чыгып күченүе б-н билгеләнә. Һуннарның Дон буена бәреп керүе б-н башланып китә, алар анда аланнарны җиңеләр, Эрманарихның (Германарихның) остготлар дәүләтен (375) яулап алалар һәм Төньяк Кара диңгез буен үзләренә буйсындыралар, аннары вестготларны (гервингларны) тар-мар итәләр. 377 елда һуннар һөҗүме аркасында Рим империясе чикләренә чигенгән вестготлар император Валентны Адрианополь янында (378) җиңеләр, Балканда урнашалар. Рим империясенә варварлар үтеп керү аның кризисына һәм Көнбатыш һәм Көнчыгыш өлешләргә бүленүенә (395) китерә. Башында Аларих торган вестготлар Төньяк Италиягә бәреп кераләр (395), Римны алалар (410), ә 418 дә Көньяк Франциягә килеп урнашалар. 4 йөз ахырында Урта Дунай буенда һуннар державасы барлыкка килә. Ругила (Руа), Бледа һәм *Аттила* идарә иткәндә ул иң югары куәтенә ирешә һәм зур хәрби-сәяси көчкә әверелә, күп тапкырлар Көнбатыш һәм Көнчыгыш Рим империяләре терр-яләренә бәреп керә. Аттиланың вафатыннан соң (453), һуннар державасы таркала; **3 нчесе** (5 йөз уртасы — 7 йөз) Көнбатыш Рим империясенең юкка чыгуы (476) һәм Х.б.к.нә славян кабиләләренең кушылып китүе б-н бәйле, бу аларның Балканга күчеп китүенә һәм «варварлар дәүләтләре» дип аталган берләшмәләр барлыкка килүгә китерә. Бу Дунайда чикләр югалуга һәм славяннарның (сербларның, хорватларның, склавиннарның һ.б.ның) Балканга массакүләм эмиграциясенә (626–30 еллар), славяннарның беренче дәүләти берләшмәләре — Само дәүләте, ш.у. «Җиде кабилә» конфедерациясе һәм болгарларның — *Беренче Болгар патшалыгы* (681) барлыкка килүгә сәбәп була. Бу чорда Көнбатыш Европада германнарның әлеккеге Рим империясе җирләренә: франкларның — Галлиягә, аланнарның, вандалларның — Испания һәм Төньяк Африкага, вестготларның — Көньяк Франция һәм Испаниягә, англосаксларның — Британиягә, остготларның Италиягә таралып урнашу процессы көчәя, алар үз корольлекләрен төзиләр. Х.б.к. вакытында Идел-Урал төбәгендә шактый гы-

на этномәдәни үзгәрешләр бара, алар Азелино, Имәнкискә, Турбаслы һ.б. археол. культуралар, яңа тип истәлекләр барлыкка килү (Андреевка һәм Турай курганнары һ.б.), Урта Идел буена төрки телле кабиләләр, ш. и. *болгарлар* килеп урнашу б-н билгеләнә. Х.б.к. элгәреге феодаль төрки дәүләтләр — *Төрки каганлыгы, Бөек Болгар дәүләте* һ.б.оешуга булышлык итә. Ул Евразиядә глобаль этносәяси һәм социаль үзгәрешләргә сәбәп була, Рим империясенең һәм антик цивилизациянең юкка чыгуы, Евразиянең этносәяси картасы үзгәрү һәм урта гасырлар феодаль дәүләтләре оеша башлау б-н төгәлләнә.


*Әд.:*Ременников А.М. Борьба племён Северного Причерноморья с Римом в III в. М., 1954; Корсунский А.Р., Гюнтер Р. Упадок и гибель Западной Римской империи и возникновение германских королевств (2 в. до н. э. — 5 в. н. э.). М., 1984; Буданова В.П. Готы в эпоху Великого переселения народов. М., 1990; Седов В.В. Славяне в древности. М., 1994; Буданова В.П., Горский А.А., Ермолова И.Е. Великое переселение народов. Этнополитические и социальные аспекты. М., 1999; История татар с древнейших времён. Народы степной Евразии в древности. К., 2002; Lot F. Les invasions barbares et le peuplement de l'Europe. P., 1937. V. 1; Thompson E.A. A History of Attila and the Huns. Oxf., 1948; Demougeot E. La formation de l'Europe et les invasions barbares. P., 1979. V. 1–2; Burns Th.S. A history of the Ostrogoths. Bloomington, 1984.

И.Л.Измайлов.

ХАЛЫКНЫҢ ТАБИГЫЙ АРТУЫ (кимүе), билгеле бер чорда туучылар б-н үлүчеләр арасындагы абс. зурлык аермасы. Шул чор эчендә уртача халык санына карата табигый артуның чагыштырмасы Х.т.а. коэф.ы б-н сыйфатлана. Гадәттә, коэф. промилледә (санның меңнән бер өлеше, % билгесе б-н күрсәтелә) бирелә; *туым* һәм *үлем* дәрәҗәсенә һәм динамикасына нисбәттә ул уңай, тискәре һәм нульгә тигез (мәс., 1993 елда ТРның шәһәр халкы өчен) булырга мөмкин.

Татарстанда Х.т.а. 1950 елларда макс. дәрәҗәгә җитә (1 мең кешедән чыгып исәпләгәндә, якынча 20 кеше). 1960 елларда бу күрсәткеч кискен кими, 1969 да 7,3 кеше тәшкил итә һәм 1980 еллар ахырына кадәр шушы чиктә саклана (1983–88 еллар керми, ул чорда Х.т.а. югары була). 1990 нан ТРда Х.т.а. яңадан кими башлый, ә 1993 тән (авыл җирлегендә 1992 дән) беренче тапкыр үлем туымннан артып китә (к. схема): 2000 дә ТРда халыкның табигый кимүенең абс. зурлыгы — 14277 (чагыштырмача зурлыкларда: респ-ка буенча — 3,8, шәһәрдә — 3,0, авылда — 6,2). 2000 елларда халыкның табигый кимүе саклана: 1000 кешегә исәпләгәндә, 2005 тә 4 тән 2010 да 0,2 гә кадәр. 2011 дән югары туым һәм кими баручы үлем исәбенә респ-ка халкының артуы күзәтелә. Авыл җирлегендә халыкның табигый кимүе дәвам итә: 2015 тә 10121 кеше туа, 14395 кеше үлә; табигый үлем 1000 кешегә исәпләгәндә 4,6 тәшкил итә.

Чыг.: Республика Татарстан. 1920–2000: Стат. сб. К., 2001; Численность, состав и движение населения в Республике Татарстан в 2000 году: Стат. сб. К., 2001.



1991–2015 елларда ТРда халыкның табигый артуы (кимүе) (1000 кешегә исәпләгәндә).

ХАЛЫКНЫҢ УРНАШУЫ, к. *Халык.*

ХАЛЫМБАДЖА́ Вячеслав Георгиевич (6.8.1929, Донецк өлкәсенең Богатырь а. — 15.10.1997, Казан), геолог-палеонтолог, геол.-минерал. фән. д-ры (1982), проф.(1983). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1952), шунда ук эшли (1962 елга кадәр һәм 1968 дән), тарихи геол. һәм палеонтология каф. мөдире (1978 дән). 1962–68 дә СССР ФАнең Казан ф-лы Геол. ин-тында. Хезмәтләре палеонтология, палеозоогеография, палеоэкология, палеозой биостратиграфиясе һәм минералогиясенә, палеозоогеографиядә математик алымнарны куллануга һ.б. карый. Х. конодонтлар (микроскопик казылма организмнар) таралышының төп геохронологик һәм геогр. закончалыкларын һәм аларның стратиграфик әһәмиятен билгели. Конодонтларның охшашлык коэффициенты нигезендә Җир терр-ясендә 2 зоогеогр. өлкәне, соңгы девонда 4 провинцияне һәм конодонтларның 3 төркемен аерып күрсәтә. Татарстанда геол. буенча беренче мәктәп олимпиадасын оештыручы. Казылма конодонтларның яңа төренә һәм Казанның 15 нче татар гимназиясенең геол. музеена Х. исеме бирелә (1998).

Х е з м.: Конодонты верхнего девона востока Русской платформы, Южного Тимана, Полярного Урала и их стратиграфическое значение. К., 1981.

Әд.: Лукин В.А. Вячеслав Георгиевич Халымбаджа, 1929 — 1997. К., 2003; Верхний палеозой России: стратиграфия и палеогеография: Материалы Всерос. конф., посвящённой памяти В.Г.Халымбаджи. К., 2007.

ХАМА́ЕВ Азат Кыям улы (1.1.1956, Актаныш р-ны Пучы а.), хакимият-ху җәлык эшлеклесе, ТРның атказ. а.х. хезмәткәре (1995). Казан авиация ин-тын (1978), Казан ун-тын (2000) тәмамлый. 1978–80 елларда «КамАЗ» ҖБнең Автомобильләр җыю з-ды мастеры. 1980–82 дә Чаллы тәжрибә-эксперименталь ремонт-механика з-ды баш механигы, 1984–95 тә директоры. 1982–84 тә «Волгоэнергомонтаж» трестының Кама монтаж идарәсе баш механигы. 2000–04 тә ТР Дәүләт Советының экологик куркынычсызлык, җир реформасы, табигый ресурслар һәм табигатьтән файдалану буенча даими комиссия рәисе. 2004–08 дә «Татхимфармпрепаратлар» АҖнең ген. директоры. 2008–09 да ТР җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр министрының 1 нче урынбасары, 2009 дан министры. 1995–99 да РФ Федераль Җыенының Дәүләт Думасы депутаты, 1999–2004 тә ТР халык депутаты. Медальләр б-н бүләкләнә.

ХАМА́ТШИН Тәлгать Гали улы (1.5.1955, БАССРның Бүздәк р-ны Түреш а.) радио дикторы, ТРның халык артисты (2008). Башкорт ун-тын (1979), Бөтенсоюз Радио һәм телевидение хезмәткәрләре белемен күтәрү ин-тын (1988) тәмамлый. 1979 елда «Алга» (БАССРның Бүздәк р-ны) г-тасында мөхәррир урынбасары, бер үк вакытта районда радио тапшырулары алып бара. 1987–2018 дә «Татарстан» ДТРКда: мәгълүмати, публицистик һәм әдәби тапшырулар, ш.и. гаилә турында — «Пар канатлар», туган тел байлыгы турында «Тел күрке сүз»не алып баручы диктор. Тирән мәгънәле текстларны оста укучы, халык күңеленә үтеп керә торган тембрлы тавыш иясе буларак, тыңлаучылар арасында зур популярлык казана. ТР Журналистлар берлегенең «Бәллүр каләм — Хрустальное перо» (2013) бәйгесе («Һөнәргә тугрылык» номинациясе буенча) бүләге лауреаты.



Т.Г.Хаматшин.

Әд.: Хыял канаты ныклы булгач... // Сөләйманов Ә. Ерэәге йондоҗҗар: ижади портреттар, очерктар, зарисовкалар, энциклопедик белешмәләр. Өфө, 2010.

ХАММА́ТОВ Айрат Касыйм улы (2.2.1965, Казан), спортчы (бокс), СССРның атказ. спорт остасы (1989), халыкара категорияле судья (2001). Казан пед. ун-тының физик культура ф-тын тәмамлый (2001). «Ракета» СКда, «Зенит» ирекле-спорт җәмгыятендә (Казан) тәрбияләнә, тренерлары — М.З.Вәлиуллин (1978–80), В.В.Краснов (1980 елдан). СССР (1991), дөнья (1989) чемпионы, РСФСР халыклары спартакиадасында (1989), СССР беренчелекләрендә (1987–88), СССР-АКШ матч очрашуларында (1989–91), халыкара (1987, Чехия), (1988, Болгария-Франция), (1989, Тайланд, Филиппин), (1990, Норвегия) турнирларда җиңүче. СССР Кубогы иясе (1988). СССР чемпионатларында (1986, бронза), (1989, көмеш), (1990, көмеш), (1992, көмеш), Игелекле уеннарда (1990, көмеш), СССР Халыклары спартаки-

адасында (1987, бронза) медальләр ала, Европа чемпионаты финалисты (1991). 1992–93 тә проф. боксчы. 1999 дан ТР җыелма командасында өлкән тренер. «ТР бокс федерациясе-21» иҗтимагый оешмасы рәисе (2000 нән), ТР Иҗтимагый палатасы әгъзасы (2006–08). 2002 дән А.К.Хамматов призына «А» классында бөтенроссия турниры уздырыла.

ХАММА́ТОВ Шамил Шәмси улы (27.8.1946, Казан), журналист, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1996). Казан ун-тын тәмамлый (1974). 1969 елдан (бүленеп) «Советская Татария» г-тасында эшли: хәбәрче, бүлек мөдире. 1986 дан КПССның Татарстан өлкә ком-ты матбугат, телевидение һәм радиотапшырулар секторы мөдире. 1989 дан ТАССРның Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре дәүләт ком-ты рәисе, 1991 дән ТРның мәгълүмат һәм матбугат министры. 1993–98 дә «Татар-информ» агентлыгы ген. директоры урынбасары. 1998–2011 дә гомумтатар «*Татар иле — Татарские края*» г-тасы берләштерелгән редакциясенең баш мөхәррире. Язмалары Татарстанның соц.-икътисади үсеше, милләтләр арасындагы мөнәсәбәтләр мәсь әләләренә, татар теле проблемаларына, Россия өлкәләрендәге татар диаспоралары милли-мәдәни автономияләре һәм оешмалары эшчәнлегенә багышлана. ТР Журналистлар берлеге идарәсе рәисе (1992–95), ТР Өстәл теннисы федерациясе җитәкчесе (1986–2003). Медаль б-н бүләкләнә.

ХАММА́ТОВ Шәмси Хәбибулла улы (15.4.1919, хәзер Свердловск өлкәсенең Аккул а. — 21.11.1988, Казан), журналист, публицист, тарих фән. канд. (1955), РСФСР-ның атказ. мәдәният хезмәткәре (1968). Казан пед. ин-тын (1942), КПСС ҮК каршындагы Югары партия мәктәбен (Мәскәү, 1945), КПСС ҮК каршындагы Иҗтимагый фәннәр академиясен (Мәскәү, 1955) тәмамлый. 1937 елдан Шәкүр авылы урта мәктәбе директоры, 1940 тан ВЛКСМның район ком-ты секретаре, ВКП(б)ның Свердловск өлкәсе Түбән Сырга район ком-ты инструкторы. 1945–49 да «Кызыл Татарстан» г-тасында эшли. 1951 дән ВКП(б) Татарстан өлкә ком-тының мәктәпләр бүлеге мөдире. 1958–59 да «*Коммунист Татарии*» ж-лы баш мөхәррире. 1959 да КПССның Татарстан өлкә ком-ты каршындагы Партия тарихы ин-ты директоры. 1960–63, 1967–83 тә «*Социалистик Татарстан*» г-тасы мөхәррире, 1963–67 дә «Социалистик Татарстан» һәм «Советская Татария» г-таларының берләштерелгән редакциясе мөхәррире. Татарстан массакүләм мәгълүмат чараларының үсешенә зур өлеш кертә. М.Җәлил турындагы китап, Татарстан матбугаты, эшчеләр хәрәкәте һәм партия оешмалары турындагы язмалар авторы. ТАССР Журналистлар берлеге идарәсе рәисе (1959–83). 1976–85 тә ТАССР ЮС депутаты. Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Газета һәм әдәбият дуслыгы. К., 1979; Муса Җәлил, аның каләмдәшләре. К., 1986; Казанская организация большевиков в годы первой русской революции. К., 1955; Муса Джалиль — солдат партии. К., 1984.

Әд.: Х а б и б у л л и н И. Шамси Хабибулович Хамматов // Гасырлар авазы = Эхо веков. 1999. № 1/2. *Р.А.Айнетдинов.*

ХАММА́ТОВА Венера Васил кызы (4.2.1966, Чиләбе өлкәсенең Магнитогорск ш.), технолог, дизайнер, техник фән. д-ры (2007). Магнитогорск җиңел сәнәгать техникумын (1987), Казан технол. ун-тын (1993), Чиләбе гуманитар ун-тын (2005) тәмамлый. 1983–93 елларда Магнитогорск кием ремонтлау һәм тегү ф-касында, мәктәпара уку-укыту-җитештерү остаханәләрендә эшли. 1993 тән Казан технол. ун-тында, дизайн каф. мөдире (2005 тән). Хезмәтләре тигезләнешсез түбән температуралы плазма агымын өйрәнүгә һәм текстиль материалларын эшкәртү һәм модификацияләү өчен плазма технологияләрен булдыруга карый. Х. югары ешлыклы сыйдырышлы (ЮЕС) корылманың плазма агымының текстиль материаллары б-н тәэсир итешкәндәге үзенчәлекләрен тикшерә. Калыплау мөмкинлеген көйләү, текстиль материалларны эшкәртү, тукымаларны төслеләндерү, аларга рәсем басуны интенсификацияләү, эшкәртелеш процессының экологик проблемаларын хәл итү өчен плазма технологияләрен эшли. Түбән температуралы плазманы кулланып, синтетик материалларны микробка каршы тору сәләтенә ия эшкәртү ысулларын, ЮЕС корылмалы плазма ярдәмендә яңа композицион материаллар җитештерүне тәкъдим итә. Халыкара дизайнерлар һәм модельерлар конкурсларында (Мисыр, Хургада ш., 2007, Ташкент ш., 2008) күргәзмә өчен яшьләр киеме коллекцияләрен әзерли. Казан технол. ун-тының Өстәмә белем бирү ин-тында югары сәнгать мәктәбен җитәкли. «Дизайн» әзерлек көллияте, «Язгы сюрприз» еллык респ-ка мода фестивале (2004–09), ТРда «Islamic fashion» мөселман модасы конкурсын оештыручы. Уйлап табуга 5 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр, ш.и. Бөтенроссия күргәзмәләр үзәгенең алтын һәм бронза медальләре б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Формирование творческих способностей студентов в условиях технологического вуза. К., 2003; Дизайн костюма: Учеб. пособие. Ростов н/Д., 2006; Влияние потока высокочастотной плазмы пониженного давления на формовочную способность текстильных материалов из шерстяных и синтетических волокон. К., 2008 (автордаш).


ХАММА́ТОВА Чулпан Наил кызы (1.10.1975, Казан), драма актрисасы, РФнең халык артисты (2012). Мәскәүдәге Дәүләт театр сәнгате ин-тын (ГИТИС; 1997, А.В.Бородин курсы) тәмамлаганнан соң, Россия акад. яшьләр театры труппасына кабул ителә. Аның сәхнәсендә Дуня Раскольникова («Җинаять һәм җәза», Ф.М.Достоевский романы буенча), Анна Франк («Анна Франк көндәлеге», Ф.Гудрич, А.Хаккет), Андрия («Әни әтиугылэт», Б.Срблянович; РФ Театр эшлеклеләре берлегенең «Алтын битлек» — «Золотая маска» милли бүләге, 2004) рольләрен башкара. Бер үк вакытта «Луна» театрында, А.Чехов театрында (Мәскәү) уйный. 1998 дә Мәскәү «Современник» театрына чакырып алына, анда Патриция Хольман («Өч дус», Э.М.Ремарк романы буенча), Катерина («Яшенле яңгыр», А.Н.Островский), Маша Мухина («Шәрә пионерка», М.Б.Кононов), Маша, Ирина («Өч сеңел», А.П.Чехов) рольләрен башкара. 2008 дән Милләтләр театрында: «Шукшин хикәяләре» (реж. А.Херманис) спектаклендә катнаша, 10 хикәятнең 9 ында уйный (2009 да «Иң яхшы хатын-кыз роле» номинациясендә «Бәллүр Турандык» театраль бүләге), «Ярлы Лиза» (Н.Карамзин) хореографик новелласы буенча куелган спектаклдә Лиза образын гәүдәләндерә һ.б. 1996 дан кинога төшә (30 дан артык фильм), В.Тодоровскийның «Чукраклар иле» картинасындагы Рита роле Х.га зур танылу һәм популярлык китерә (1998); «Биюче заманы» фильмында (1997, реж. В.Әбдрәшитов; «Иң яхшы хатын-кыз роле» номинациясендә Россия кинематография сәнгате академиясенең «Ника» милли бүләге) Катя, «Айлы әти» фильмында (1999, реж. Б.Ходайназаров, «Иң яхшы хатын-кыз роле» номинациясендә Россия кинематография сәнгате академиясенең «Ника» милли бүләге) Мәмләкәт Бикморадова; «Рәштуа мистериясе» фильмында (2000, реж. А.Кравчук) Маша, «Арбат балалары» фильмында (2004, реж. А.Эшпай) Варя Иванова, «Империянең һәлакәте» фильмында (2005, реж. В.Хотиненко) Ольга Нестеровская, «Табиб



Ч.Н.Хамматова.



Ч.Н.Х а м м а т о в а Катя ролендә («Биюче заманы», В.Әбдрәшитов; Валерий ролендә – Ю.К.Степанов).



Ч.Н.Х а м м а т о в а Танечка ролендә («Кукоцкийның буталчык вакыйгасы», Ю.Грымов; Елена ролендә – Е.Дробышева).

Живаго» фильмында (2006, реж. А.Прошкин) Лара, «Күп ноктalар» фильмында (2006, реж. А.Эшпай; икенче пландагы иң яхшы хатын-кыз роле өчен «Алтын бөркет» («Золотой орёл») кинематография бүләге) Урсула, «Достоевский» фильмында (2011, реж. В.Хотиненко) Мария Дмитриевна Исаева, Г.Яхинаның «Зөләйха күзләрен ача» романы буенча төшерелгән шул исем. күп серияле Россия фильмында (2018–19, реж. Е.Анашкин) Зөләйха рольләрен башкара. Чит ил кинематографистлары б-н хезмәттәшлек итә: «Тувалу» (1999, реж. Ф.Хельмер), «Англия» (2000, реж. А. фон Борис), «Хуш, Ленин!»



Ч.Н.Хамматова Зөләйха ролендә («Зөләйха күзләрен ача», Е.Анашкин).

(«Гуд бай, Ленин!», 2003; реж. В.Беккер) һ.б. немец фильмнарында төшә. Экспрессив темпераменты, чынбарлыкны нечкә тоемлавы, тәэсирле итеп образга керә белү осталыгы актрисага социаль масштабтагы һәм тирән психологизм б-н сугарылган образлар иҗат итү мөмкинлеге бирә. Х. — яман шеш һәм гематологик авырулы балаларга социаль һәм психол. ярдәм күрсәтү б-н шөгыльләнүче «Тормыш бүләк ит» («Подари жизнь», 2006) фондын гамәлгә куючыларның берсе. 2008–09 да РФ Иҗтимагый палатасы әгъзасы. РФ Дәүләт бүләге лауреаты (2004, 2014). Дуслык ордены б-н бүләкләнә. Казан шәһәренең мактаулы гражданы (2017). Х. исеме б-н астероид аталган.

Ю.А.Благов, Л.М.Айнетдинова.

ХАММА́ТОВА Эльмира Мифтах кызы (11.1.1946, Казан), телевидение дикторы, тележурналист, актриса, ТАССРның халык артисты (1991), РФнең атказ. артисты (2005). Казан театр уч-щесен тәмамлаганнан соң (1966), Татарстан респ-ка күчмә театрында эшли. 1969 елдан ТАССР МС каршындагы Радиотапшырулар һәм телевидение ком-ты дикторы, 1992 дән «Татарстан» ДТРКда диктор, баш мөхәррир, хатлар, әдәби-драматик тапшырулар бүлекләре мөдире. 1997 дән «Ил һәмият» иҗади берләшмәсендә мөдир, 2003–05 тә «Татарстан» ДТРКда нәфис тапшырулар дирекциясе җитәкчесе. 2006 дан Казан мәдәният һәм сәнгать ун-тында. Шул ук вакытта, 1970–2010 да (бүленеп), Казан театр уч-щесендә сәхнә теле укытучысы. Х. җитәкч елегендә һәм аның катнашында оештырылган телепрограммалар: «Хатлар аша очрашу» тапшыруы, «Күзгә-күз, сүзгә-сүз», «Бер күрешү — үзе бер гомер» авторлык программалары, «Йолдызлар чакыра» шоу-программасы һ.б. зур уңышка ирешә. Мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләре турында тапшырулар сериясе, танылган артистлар, җырчылар, язучылар, галимнәр һ.б. катнашында, театр режиссёрлары һәм актёрлары турында «Сәхнә» циклы, рәссамнар турындагы «Рәссамнар тормышыннан эпизодлар» циклы, «Җомга көн кич белән» телесалонын әзерли.

ХАММАТУ́ЛЛИН Хафиз Хәниф улы (6.5.1961, Актаныш р-ны Яңавыл а.), актёр, ТРның халык артисты (2009). Казан театр уч-щесен тәмамлаганнан соң (1985), Минзәлә татар драма театрына чакырып алына. Качак Әптери, Сәфәргали («Зәңгәр шәл», «Йосыф белән Зөләйха», К.Тинчурин), Зөлфәт («Сөйгәнемнең туган көне», И.Юзеев), Гайрәт («Баласын җуйган болан эзеннән», А.Гыйләҗев), Зөфәр («Кызлар күңеле — тирән сер», Ф.Яруллин) кебек беренче рольләрен зур уңыш б-н башкара. Х. тудырган Скапен («Скапен хәйләләре», Ж.Б.Мольер), Корбанколый («Сөннәтче бабай», Г.Исхакый) образлары гадәти булмаган чишелешләре б-н аерылып тора. Х. — киң иҗат диапазонына ия актёр. Ул һәм драматик, һәм көнкүреш комедия рольләрен бер үк дәрәҗәдә оста башкара: Галимҗан («Башмагым», Х.Ибра һимов), Закир («Тигезсезләр», Ф.Әмирхан), Шаһгали («Хан кызы», Р.Хәмид), Сафа («Ашыгасың, Сафа!», Э.Яһудин), Абруйлы карт («Остазбикә», Г.Исхакый), Вәлиәхмәт («Мулла», Т.Миңнуллин), Мәхмүт («Тилмереп дога көткәннәр...», Р.Кинҗәбаев), Каракай («Каерылмасын канатың», Р.Батулла), Сәүбән («Өзелгән йөзем», Д.Салихов), Рәсим («Өй салуның ние бар?», Ф.Шәфигуллин), Финат («Пар канат», Ю.Сафиуллин), Минханович («Безнең әти мировой», И.Юзеев), Илгиз («Кияүләр», Х.Вахит), Конвоир, Усманов («Күзләреңнән үбеп...», Р.Харис), Өлкән ир («Ташкын», Т.Җүҗәноглы), Нигезен югалткан кеше («Яр», Б.Саләхов), Хөсәен («Акъярда ахырзаман», Р.Сәлимҗанов), Кыям («Микулә дәдәйнең бөер ташы», Д.Салихов), Бәхти («Хатын түгел — ажда һа», Д.Салихов), Күктимер («Гашыйклар кәмите», Р.Батулла), Вальс Валерьянович («Җүләр хатын — һәрчак алтын», Х.Ибраһимов), Туктуган («Шомбай», К.Мәргән) һ.б. Актёр ш.у. балалар өчен спектакльләрдә дә уйный: Шүрәле («Җен алыш -



Х.Х.Хамматуллин Корбанколый ролендә («Сөннәтче бабай», Г.Исхакый).



Э.М.Хамматова.



Х.Х.Хамматуллин.

тырган», Т.Миңнуллин), Албасты («Тылсымлы төрән», Р.Шәриф), Кояш батыр («Сарык арыслан», Г.Коготов), Мыргали («Чәпәләй һәм Тәпәләй маҗаралары», Л.Лерон), Пычкытеш («Ак баба иле», Г.Каюмов) кебек үзенчәлекле әкияти образлар тудыра. С.Өметбаев исем. бүләк лауреаты.

Әд.: Гыймранова Д. Сабир Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт драма театры. К., 2007.

И.И.Илялова.

ХАН (хаган, каган, хакан — хөкемдар, монарх) — төркиләрдә, монголларда титул. Башта кабилә юлбашчысын, аннары югары идарәчене, падишаһны белдергән; сәл җуклар һәм харәземшаһлар дәүләтләрендә кенәз титулы буларак кулланылган. Монголлар империясендә Х. дип каганга буйсынган *олыс* идарәче - ләрен атаганнар. Алтын Урдада һәм ул таркалганнан соң барлыкка килгән татар ханлыкларында Х. — таҗ кидерелгән идарәче титулы. Кайбер төрки халыкларда (татарларда, казакъларда һ.б.да) «Х.» сүзе катлаулы ир-ат исемнәренең бер өлеше буларак та (мәс., Касыймхан, Миңнехан), уйгырларда — хатын-кыз исемнәрендә дә (мәс., Алимхан) кулланыла башлый, әмма бу исем йөртүчеләрнең социаль килеп чыгышы б-н бәйле түгел.

Әд.: Худяков М.Г. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923; Бартольд В.В. Хан // Сочинения. М., 1968. Т. 5.

М.Г.Госманов.

«ХАН КЫЗЫ́», татар фольклорында бәет, дастан, уен һәм лирик җырларга хас үзенчәлекләргә ия лиро-эпик әсәр. Кайсы жанрга кертелү мәсь әлҗе буенча белгечләрнең фикерләре аерыла. Әсәрнең эчтәлеге кыз б-н егетнең диалогыннан гыйбарәт. Егет, кызның матурлыгына карап сокланыр өчен, аны үз янына кертүен үтенә. Кыз ишекне ачарга ризалык бирми. Гәүдәсенең сыгылмалылыгын елга ярындагы талга, чәчләрен кара ефәккә, күзләрен күктәге йолдызларга охшатып, егет кызның матурлыгын күз алдына китерә ала. Әсәрнең берничә варианты бар, ул һәр җирдә таралган. Кулъязмалары ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты мирасханәсендә, Казан ун-ты Фәнни китапханәсенең сирәк китаплар бүлегендә саклана. Беренче тапкыр Х.Бәдигый тарафыннан «Халык әдәбияты. Бәетләр» җыентыгында басыла (1913). Күптомлы «Татар халык иҗаты» хезмәтенең тарихи һәм лирик җырлар томында әсәрнең төрле исемдәге 4 варианты урын ала.

Әд.: «Хан кызы» // Бәетләр. К., 1960; «Хан кызы» җырлары // Татар халык иҗаты: Тарихи һәм лирик җырлар. К., 1988.

Ф.И.Урманчеев.

ХАН ТӨРБӘЛӘРЕ́, *Казан Кремлендәге*, фа - разланганча Хан мәчете янындагы аксояк - ләр зираты терр-ясендәге 15–16 йөзләргә ка - раган корылмалар. 1552 елда Казан рус гас - кәрләре тарафыннан яулап алынганнан соң җимертелә. 1977 дә Сөембикә манарасы төбе янында кешеләр җирләнгән ике Х.т.се ачыла. Белгечләр исәпләгәнчә, 15 йөздә таштан беренче хан төрбәсе (анда 1462 дә Мәхмүд хан җирләнә), 16 йөз башында аның янында икенчесе төзелә. Х.т.нең үсемлек-геом. бизәкле сырлы штукатуркасы өлешләре сакланып калган. 2004 тә бу төрбәләрнең калдыклары чынлыкта ак таштан корылган 6×18 *м* үлчәмле бер бина булганлыгы ачыклана. Ихтимал, 16 йөз башында төрбәнең беренче бинасына икенче өлеше терәп төзелгән һәм анда 1518 дә Мөхәммәдәмин хан җирләнгән. Хан мәчетенең һәм төрбәләрнең буй диварлары бер-берсенә параллель корылган, бу исә аларның әчке бүлмәләре мәчет итеп файдала - нылган булуы турында сөйли.

Әд.: Тематическая подборка, посвящённая мав - золеям Казанского Кремля // Панорама-Форум. 1997. № 3; Ситдиков Г. Казанский кремль: ист.-археол. исслед. К., 2006; Надырова Х.Г. Ханская Казань: Мифы и реальность // Градостроительное искусство: Новые материалы и исслед. М., 2007. Вып. 1.

Х.Г.Надыйрова.

ХАН ТӨРБӘСЕ́ Болгар шәһәрендә, Алтын Урда чоры комплекслы архит-ра истәлеге. 14 йөзнең 1 нче яртысында төзелгән таш би - на, шәһәрнең көньяк-көнчыгышында югары катлаулар зираты терр-ясендә Кече манарадан 15 *м* төньяктарак урнашкан. 14 йөз урта - сында бер-берсенә терәлеп торган һәм гөмбәз - ләр б-н капланган төрбәләр комплексының



Ханнар төрбәсе. Болгар шәһәре. 14 йөз.

бер өлешенә әверелә, «Хан төрбәсе» дигән шартлы исем ала. Баштарак түр ишеге булма - ган гөмбәзле куб рәвешендәге 8,5х8,5 *м* күләм - дәге дүрт чатлы тоташкан гөмбәз астындагы корылма. Төрбәнең интерьерында дүртлектән гөмбәзгә күчеш почмактагы сөзәкләр — тромплар б-н 8 һәм 16 кырлык аша башка - рылган; диварлар һәм гөмбәз акшарланган. Үсемлек һәм геом. бизәкле, гарәп язулы, баш - лыча, зәңгәр һәм куе зәңгәр төстәге чынаяк кирпечләр тәрәзә уентыларын каймалап то - ра. Диварларның әчке ягын рельефлы бизәк - ле гипс плитәләр бизи, тышкы ягы яхшы итеп шомартылган известь блоклар б-н тыш - ланган. Төньяк фасадтагы ишек уентысы башта сырланган известьташ б-н каймалан - ган, со ңыннан аны томалап, уентыны көньяк диварда ясаганнар. Көнбатыштан көньяк почмакка терәп зур булмаган төрбә корылган. Соңрак диварның көнчыгышында Х.т. зурлы - гында тагын бер төрбә барлыкка килгән. Аскы цоколь өлеше яхшы эшкәртелгән известь блоклар б-н тышланган. Төньяк фасадтагы керү урыны а́ркалы биек порталның ике пило - ны б-н фланкланыштырылган. Төрбәдә 8 әрҗә-табутта җирләнгән каберләр ачыла, аларның кайберләре өстенә кирпеч кабер ташлары куелган. Төрбәнең төньяк-көнбатыш тарафында тагын бер шундый ук бина булган. Ул башта мәчет һәм гыйбадәт кы - лырга килүчеләр өчен мосафирханә итеп файдаланылган, тыштан ягыла торган миче булып, идән астыннан җылыту каналлары узган. Соңыннан ул төрбәгә әйләндерелгән һәм барлык төрбәләр бер комплексга бер - ләштерелгән. Озак вакытлар дәвамында Х.т.сенең бары тик тышлыксыз һәм бизәк - сез интерьерлы диварлары, ш.у. башка би - наларның нигезләре генә сакланып кала. 1968 елда анда археол. казу эшләре үткәрелә. 1968–71 дә археолог С.С.Айдаров тарафын - нан Х.т. реставрацияләнә һәм төзекләндерелә, ярымсфералы гөмбәзе торгызыла, 1990 да С.С.Айдаров һәм Р.В.Билалов аны консервациялиләр һәм өлешчә реставрациялиләр.

Әд.: Айдаров С.С., Аксёнов Н.Д. Вели - кие Булгары: Путеводитель по Булгар. ист.-архит. заповеднику. К., 1983; Айдаров С.С. Исследование и реставрация памятников монументального зодчества Болгара // Город Болгар: Монументальное строительство, архитектура, благоустройство. М., 2001.

Х.Г.Надыйрова.

ХАН ҮЛӘНЕ́, *кырлыган* (Chamerion), кырлыганчалар семьялыгыннан күпьеллык үлән - чел үсемлекләр ыругы. 20 гә якын төре билгеле, Европа, Азия, Төньяк Америкада таралган. ТРда 1 төре — тар яфраклы Х.ү. (копор чәе) (Ch. angustifolium) таралган; урман буйларында, елга ярларында, чүпле урынларда, юл кырыйларында, янган урманнар урынында үсә. 60–150 *см* биеклектәге үсем - лек, юан, шуышма тамырчалы. Сабагы туры яисә тармаклы. Яфраклары чиратлашкан, тар ланцетсыман, очлы, се ңерләре яхшы үк күренеп тора. Чәчәкләре алсу-кызыл, озын чукка җыелган. Җимеше — озын, тар күп ор - лыклы тартмачык (бер үсемлек 20 меңгә ка - дәр орлык бирә). Июнь-августта чәчәк ата. Орлыктан һәм тамыр үрентеләреннән үрчи. Яшь ботаклары һәм яфракларында танин, С витамины, дуплау матдәләре, лайла, мик - роэлементлар, орлыкларында 40% ка кадәр май бар. Халык медицинасында яфракла - рыннан ясалган төнәтмә йокысызлыктан, баш авыртканда кулланыла, ш.у. ялкынсыну - га каршы шифасы зур. Чәй итеп файдалана - ла. Баллы үсемлек, терлек азыгы. Сөзәклек - ләрне ныгыта.

«ХАНӘКӘ СОЛТА́Н БӘЕТЕ́», әсирлеккә төшкән Ханәкә солтан исемле кыз турында - гы бәет. Сюжет нигезендә борынгы «әсир ха - тын-кыз» мотивы ята. Анда үзара сугышларда җи ңелгән ыругтан бай хатын-кызларны әсир төшерү гадәте чагылган. Бәетнең бар - лыкка килү вакыты 14–16 йөзләргә карый, хатын-кыз исеменә «солтан» титулын кушу да шуны дәлилли. Ханәкә исеменең төрки халыклар эпосында Каныкәй, Ханыкәй, Җа - ныкәй, Таныкәй төрләре дә киң таралган. Бә - ет, әсирлеккә төшкән кызның фаҗигале яз - мышын, аның әлекке бай һәм әсир төшкәннән соңгы ярлы тормышын чагыштырып ачып бирә. Яхшы шартларда яшәп, сафьян артык каты, шикәр балсыз тоелган назлы кыз чаба - та кияргә һәм кипкән ипи ашарга ияләшергә тиеш була («...Сәхтиян кимәс наз идем, Чаба - та тапмай барамын...Шикәр лә капмас наз идем, Сохари тапмай барамын»). Әсәргә хас лиризм, хатын-кыз язмышы турындагы бәет - ләр циклында аеруча үсеш ала. «Х.с.б.» нең жанр үзенчәлекләре һәм Ханәкә солтан образы төрки-монгол халыклары эпосына бик якын (үзбәк дастаны «Кёр-оглы», кыргыз эпосы «Манас» һәм татар дастаны «Идегәй»). Бәетнең кулъязмалары ТР ФА Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тының фольклор фондында саклана. «Х.с.б.»н беренче тапкыр Һ. Атласи «Казан ханлыгы» китабында (1920) «Илаһи йыру» исеме б-н бастыра.

Әд.: Рәхим Г., Газиз Г. Татар әдәбияты та - рихы. Феодализм дәвере. К., 1925; «Ханәкә-солтан бәете» // Татар халык иҗаты: Тарихи һәм ли - рик җырлар. К., 1988; Урманче Ф. Бәетләр // Татар халык иҗаты: Дәреслек. К., 2005.

Ф.И.Урманчеев.

ХАНБИКӘ́, урта гасырлар татар дәүләтләренда хан хатынының яисә берәр ил б-н идарә иткән хатын-кыз титулы. Сүз ике компонентнан тора — «хан» һәм «бикә», соңгысы «*бәк*» терминыннан ясалган булса кирәк.

ХАНБИ́КОВ Якуб Исхак улы (18.3.1928, Ульянов өлкәсенең Иске Кулаткы р-ны Ис - ке Кулаткы а.), педагог, пед. фән. д-ры (1969), проф. (1970), ТАССР, РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1978, 1983). Ульянов пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1951), туган авы - лы мәктәбендә эшли. 1954 елдан Казан пед. ин-тының пед. кафедрасында (2011 дән Ка - зан (Идел буе) федераль ун-тында), 1964–90 да каф. мөдире. Татар халкының пед. фикер тарихы һәм Татарстанда халык мәгарифе тарихы буенча монографияләр ав - торы. «Педагогика энциклопедиясе»ндәге («Педагогическая энциклопедия», т. 1–4, М., 1964–68) татар педагоглары һәм халык мәга - рифе эшлеклеләре турында мәкаләләр авто - ры. ТР Мәгариф министрлыгының К.Насый - ри исем. бүләге лауреаты (2003). ПФАнең К.Д.Ушинский һәм А.С.Макаренко медаль - ләре б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Из истории педагогической мысли та - тарского народа. К., 1967; Русские педагоги Татарии и их роль в развитии просвещения и педагогической мысли татарского народа. К., 1968; История развития педагогической мысли татарского народа. К., 1975; Татарские народные игры и праздники. К., 1975 (автордаш).

ХАНБИ́КОВА Шифа Сабиржан кызы (5.12.1928, Бөгелмә кантоны Габдрахман а. — 9.4.2008, Казан; туган авылында җирләнә), тел галиме, филол. фән. канд. (1963). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1951), Азна - кай шәһәрендә һәм туган авылында мәктәп укытучысы булып эшли. 1958–86 да СССР

ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында. Хезмәтләре татар теле лексикологиясенә һәм лексикографиясенә карый. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» (1–3 т., 1977–81) мөхәррирләреннән берсе; татарча-русча, синонимнар, терминологик сүзлекләр төзүче. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Синонимия татарского языка. К., 1962; Синонимнар сүзлеге. К., 1999 (автордаш).

ХАНГИ́ЛДИН Вәли Нигъмәтулла улы (6.6.1891, Уфа губ., Бәләбәй өязе Иске Сынлы (Сынны) а. — 2.6.1971, Казан), тел галиме, филол. фән. канд. (1934), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1961). 1911–14 елларда «Галия» мәдрәсәсендә (Уфа ш.) укый. 1915 тән мәктәп укытучысы булып эшли, 1917 дән — казакъ теле укытучылары әзерләү курсларында, 1918 нең уртасыннан — рус-башкорт ятимнәр йортында, татар-башкорт пед. техникумында, Өлкә башкорт пед. техникумында уку-укыту бүлеге мөдире (Пермь, Акмулла, Уфа, Екатеринбург ш.). 1931 дән Казан пед. ин-тында эшли (1955 кә кадәр), бер үк вакытта, 1944 тән, СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында татар теле секторы мөдире (1951 гә кадәр). Хезмәтләре татар теле морфологиясе, синтаксисы, грамматикасы һәм сөйләм культурасына карый. Башлангыч сыйныфлар өчен татар һәм башкорт телләре дәреслекләре һәм программалары авторы, «Русча-татарча педагогика һәм психология терминнары сүзлеге»н («Русско-татарский словарь терминов по педагогике и психологии», 1950) төзүчеләрнең берсе.

Х е з м.: Башкорт теленең методикасы. Уфа, 1926; Татар теленең грамматикасы һәм орфографиясе. К., 1934; Татар теле грамматикасы: морфология буенча очерклар. К., 1954; Татар теле грамматикасы. К., 1959; Татар теле культурасының кайбер мәсьәләләре. К., 1976.

Әд.: Казанская лингвистическая школа. К., 2008.

ХАНЕ́ЕВ Владимир Петрович (21.5.1925, Ленинград — 30.3.1990, Казан), инженер-механик, Татарстан «Свияга» ҖБ ген. директоры. Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң (1949), Казан оптика-механика з-дында: револьвер участогы мастеры, автомат-штамповкалау цехы башлыгы, план-җитештерү бүлеге башлыгы урынбасары, директор (1961 елдан). 1963–90 да Татарстан «Свияга» ҖБ дә. Х. җитәкчелегендә берләшмәдә пр-тиене реконструкцияләү уздырыла, яңа җитештерү ку әгләре төзелә, радиоэлектрон төзәү (СССР Дәүләт бүләге, 1970) һәм радиолокацион тану-аеру системаларын, халык кулланы товарларын (электрофоннар, стереосистемалар һ.б.) сериялап эшләп чыгару үзләштерелә. Ленин ордены, Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Элекке завод идарәсе бинасына (Петербург ур.) Х. хөрмәтенә мемориаль такта куела.

ХА́НЖИН Павел Семёнович (20.6.1924, Тәтеш ш. — 15.10.2007, Дүшәмбе ш., Таҗикстан Респ-касы), Сов. Союзы Герое (20.12.1943), гв. полковнигы. Кече лейтенантлар курсларын (1943), В.И.Ленин исем. Хәрби-сәяси академияне (Мәскәү, 1956) тәмамлый. 1941 елның 22 июненнән Кызыл Армиядә. 1941 нең октябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, взвод командиры, 38 нче гв. укчы полкның разведка ротасы командиры (57 нче армиянең 14 нче гв. укчы дивизиясе). Көнбатыш, Сталинград, Дала һәм Воронеж фронтлары составында Мәскәү (1941–42) һәм Сталинград (1942–43) сугышларында, Белгород-Харьков һөҗүм операциясендә (1943) катнаша. 1943 нең 24 сентябрендә Пушкарёвка авылы янында (хәзер Верхнеднепровск шәһәре эчендә) Днепр елгасын кичеп чыккан батырлык күрсәтә: елганың уң ярында плацдармны яулауда катнаша, ике тәүлек дәвамында Х. җитәкчелегендәге разведчиклар взводы, полкның төп көчләре килеп җиткәнче чик сызыгын саклый. Сугыштан соң Совет армиясендә хезмәтен дәвам итә. 1950–52 дә 201 нче тау-укчы дивизиянең сәяси бүлек башлыгы ярдәмчесе. 1956–63 тә мотоукчы полк командиры урынбасары. 1963–71 дә хәрби частьның сәяси бүлеге башлыгы. 1971 дән запаста, проектлау ин-тында (Дүшәмбе) инженер булып эшли. Ленин ордены, ике 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, Таҗикстан Респ-касының «Шәрәф» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

М.З.Хәбибуллин.

ХАНЗАФА́РОВ Назыйм Габдрахман улы (12.9.1937, Кайбыч р-ны Олы Кайбыч а.), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1996). 1962–71 елларда «Родина» Мәдәният йортында (Зеленодольск ш.) эшли. 1973–2004 тә ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында. Хезмәтләре татар драматургиясе, комедиографиясе тарихына; Н.Исәнбәт, К.Тинчурин, М.Фәйзи, Т.Гыйззәт иҗатларына карый. М.Җәлил (1976, 2, 4 т.), Г.Камал (1979, 2 т.) әсәрләренең җыентыкларын басмага әзерләүдә катнаша. ТР Дәүләт гербы концепциясе авторларының берсе (1992). «Татар комедиясе» («Татарская комедия», 1996) монографиясе өчен ТР Дәүләт бүләге тапшырыла (1997).

Х е з м.: Драматургия Н.Исанбета. К., 1982.

Әд.: Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

ХАНКИРМӘН, к. *Касыйм шәһәре*.

ХАННА́НОВ Васил Миргазиян улы (26.10.1956, БАССРның Октябрьский ш.), нәкышьче, график, БРның атказ. рәссамы (1999). Уфа сәнгать уч-щесен тәмамлый (1979). РСФСР Рәссамнар берлегенең Башкортстан иҗат-җитештерү комб-тында эшли (1980–89). Рәссамнар берлеге (1990), «Чыңгызхан» иҗат берләшмәсе (1990) әгъзасы, рәисе (1992). С.-Петербургта һәм Казанда 1 нче Бөтентатар «Татарт» (1991) күргәзмәсен оештыручыларның берсе. Башкортстан Респ-касының Н.Лотфуллин исем. заманча сәнгать музеен оештыручы һәм аның директоры (2002). 2005 елдан Башкортстан сынлы сәнгатенә багышланган «ВХ» («Высокохудожественный журнал») басмасының мөхәррире.

Сынлы сәнгатьтә образларны нәкышь-графика аша күзаллауда үзенең сәнгати концепциясе булган авангард юнәлешенең күренекле вәкиле. Иҗатының башлангыч чорында реалистик манерада — портрет, пейзаж, тематик композиция жанрларында эшли («Беренче», 1979; «Тирә-юньдәге кыш», 1979; «Студент кыз портреты», 1981; «Автопортрет», 1982; «Утырышу. Г.Тукайга багышлау», 1986). Соңрак модернизм сәнгать үзенчәлеген үзләштерә: «Җәйге өйлә вакытында кыз портреты», «Кыз гитара белән» (икесе дә — 1981), «Гуля (зәңгәр канатлы)» (1988) һ.б. 1980 еллардан супрематизм традицияләренә мөрәҗәгать итә: «Блюз стилендәге композиция» (1989), «Башлангыч дәвер» (1989–96) циклы, «Дүрт квадраттан композиция» (1990), «М. тамгасы» (1994), «Г.Тукай турында сагышлану» (2005), «Мадонна (классикларга ияреп)» (1984–2006).



П.С. Ханжин.



Н.Г.Ханзафаров.

1990 еллар башында Х. иҗатында дөньяны танып белү, чынбарлыкны аңлауда абстракт-метафорик күзаллауга нигезләнгән яңа этап билгеләнә: «Көтү» (1992–2003), «Җир-су» (2005) сериялә, «Сыер» (1992–2003), «Ай яктысы» (2002–04) проектлары. Х. Коръән темасына «Апокриф язмалар» (1994), «Вәхи» (1995–2002), «Әби Коръ әне» (2009–11) цикллары; Библия сюжетларына «Чаң кагу» (1999–2001) циклы, «Бәйрәм рәте» (2002) сериясе, «Бали», «Яратылыш» проектлары (икесе дә — 2010–12).

Офорт техникасында иҗат ителгән графика әсәрләре — «Автопортрет» (1986), «Тапшырылмаган хатлар» сериясе, «Далада», «Шәрекъка» (барысы да — 1987), уникаль авторлык һәм катнаш (акварель, темпера) техникада — «Трансильвания мотивлары» (1989), «Аңлау» (1990), «Шәһәр мотивы» (2001) һ.б. авторы.

Респ-ка (1980 нән); «Чыңгызхан» төркеменең С.-Петербургта (1990, 2000), Казанда (1992, 1993, 1996, 2008), Истанбулда (1994),



В.М.Х а н н а н о в. «Европаны урлау». 1993.

Мәскәүдә («Арт-Манеж», 1996 дан 2002 дә ел саен; Үзәк рәссамнар йорты, 2007, РСА, 2008) һ.б. күргәзмәләрдә, Бөтентатар — «Татарт» (С.-Петербург, Казан, 1991), халыкара — «Таныш түгел Россия» (Нью-Йорк ш., АКШ, 1998), «Евро-Арт 99» (Барселона ш., Испания, 1999) күргәзмәләрендә, каллиграфия күргәзмәләрендә (Мәскәү, 2009; Түбән Новгород, 2010) катнаша.«Ай яктысы» (Уфа, Мәскәү, Истанбул, 2001–07), «Күчмә язмалар — Хәбәр» (Мәскәү, Казан, Әнкара, 2006–10) һ.б. халыкара күргәзмәләренең оештыручысы, кураторы һәм катнашучысы. Шәхси күргәзмәләре 1981, 1988, 1998, 1999, 2002, 2006–18 (Уфа), 2007 (Новосибирск), 2008 (Чаллы), 2009 (Ижевск), 2010, 2012 (Пермь), 2009, 2010, 2011, 2018 (Мәскәү), 2012 дә (Омск) уздырыла.



В.М.Ханнанов. «Омтылыш» (Н.Лотфуллин истәлегенә). Киндер. Майлы буяу, җиз. 1996.

Картиналары М.В.Нестеров исем. БР Дәүләт сәнгать музеенда, Уфада Н.Лотфуллин исем. заманча сәнгать музеенда, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, АКШның Джерси-Сити шәһәрендә заманча рус сәнгате музеенда, Көнчыгыш халыклары музеенда, заманча сәнгать музеенда, Каллиграфия музеенда (барысы да — Мәскәүдә) һ.б., Россиядә (Уфа, Казан, С.-Петербург, Мәскәү һ.б.) һәм чит илләрдә (Франция, Испания, Төркия) шәхси тупланмаларда саклана.

Әс әр.: Как это всё начиналось // ВХ (Высоко-художественный журнал). 2005. № 1; О природе цвета в живописи в свете культуры // ВХ (Высокохудожественный журнал). 2006. № 3; Музею современного искусства РБ им. Н.Латфуллина 5 лет // ВХ (Высокохудожественный журнал). 2007. № 6.

Әд.: Вәлиева-Сөләйманова Г. Васил Ханнанов. Европаны урлау // Казан утлары. 1993. № 2; Василь Ханнанов // Современные художники Республики Башкортостан. Живопись. Графика: Каталог выставки. Уфа, 2000; Василь Ханнанов. Альбом-каталог. Уфа, 2006; Василь Ханнанов // Чингисхан: Альбом. М., 2008; Василь Ханнанов. «Фазкуруни-эзкуркум». Вспомните Меня, и я вспомню вас: Альбом-каталог. М., 2011.

Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.

ХАННАНО́В Марс Тәлгать улы (2.5.1970, Әлмәт ш.), геофизик, геол.-минер. фән. канд. (2002), ТРның атказ. геологы (2007), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2016). И.М.Губкин исем. Мәскәү нефть һәм газ ин-тын тәмамлаганнан соң (1993), «Татнефтегеофизика» ҖБнең Әлмәт геофизик эшләр идарәсендә инженер-геофизик булып эшли. 1995 елдан «Татнефть» ГАҖнең (гавами акционерлык җәмгыяте) «Ямашнефть» НГДУында: геолог, әйдәп баручы геолог (1995–99), эшкәртү бүлеге башлыгы (2000–05), баш геолог — идарә башлыгының беренче урынбасары. Бер үк вакытта, 1993–99 да һәм 2004–13 тә, Әлмәт нефть ин-тында укыта. Хезмәтләре, термогидродинамик һәм дулкын алымнары кулланып, авыр чыгарылучы югары үзле нефть чыганакларын эшкәртүнең нәтиҗәлелеген күтәрүгә карый. Татарстанның Пермь утырмаларында газ интерваллары бүленүнең методик нигезләрен эшли. Скважиналарны дулкын технологияләре кулланып эшләтү ысулларын гамәлгә кертә. Дәүләт бүләге ТРның авыр чыгарыла торган нефть запасларын чыганакларын үзләштерүне контрольдә тоту өчен скважиналарны һәм ятмаларны термогидродинамик ысуллар б-н тикшерү технологияләренең теоретик нигезләрен эшләүдә һәм аларны сәнәгатькә кертүдә катнашканы өчен бирелә.

Хезм.: Особенности организации добычи высоковязких нефтей при разработке месторождений с трудноизвлекаемыми запасами. Альметьевск, 2013 (автордаш).

ХАННА́НОВ Расих Нургали улы (28.10.1931, БАССРның Кырмыскалы р-ны Кырмыскалы а.), журналист, язучы, БРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1981). КПСС ҮК каршындагы Югары партия мәктәбен тәмамлый (1969). 1958 елдан Кырмыскалы р-нының «Хезмәт даны» г-тасында партия тормышы бүлеге мөдире, мөхәррир урынбасары. 1961–95 тә «*Кызыл таң*» (Уфа) г-тасы әдәби хезмәткәре, махсус хәбәрче, әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире, мөхәррир урынбасары, баш мөхәррир. Иҗтимагый-сәяси, социомәдәни темаларга очерклар, әдәби һәм театраль рецензияләр, новеллалар, хикәяләр, повестьлар, романнар, фәлсәфи дүртьюллыклар — робагыйлар авторы. Х. пьесалары Башкортстан, Татарстан, Үзбәкстан, Кыргызстан театрлары репертуарларына керә. Башкорт милли геройлары С.Юлаев, Ю.Азналин һәм К.Усаевка багышланган «Рогервик» героик драмасы (2006), балалар өчен язылган «Салават һәм Карасакалның җәясе» тарихи пьесасы билгеле. Күп кенә җырлар авторы («Җырлар» җыентыгы, 2001). Х.ның «Ялгыз аккош күлләрдә» шигыренә язылган җыр ТРда ел җыры исеменә лаек була (1989), Швециядәге халыкара «Күр әле бер генә» милли җырлар конкурсында Гран-при ала, «Минем Өфөм — Уралның саф гөле» Башкортстан башкаласы гимны була.«Расих Ханнанов җырлары» (2006; комп. Р.Хәсәнов), «Язмышлар» (2006; комп. Т.Шәрипов) компакт-дисклары чыга. «Мәслихәт» татар-башкорт дуслыгы җәмгыятен оештыручыларның берсе. БРның Ш.Ходайбирдин исем. (1994), Ә.Атнабаев исем. (2003) бүләкләре лауреаты.

Әс әр.: Рубаи. Уфа, 2006; Раскаты грома. Уфа, 2006; Тропинки, прошедшие сквозь сердце. Уфа, 2010; В котле ада. Уфа, 2011.

ХАННА́НОВ Рөстәм Госман улы (4.4.1949, Минзәлә ш.), геолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2009), техник фән. канд. (2005), ТРның атказ. геологы (1999). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1972), Урал терр. геол. идарәсенең экспедициясендә гидрогеолог булып эшли. 1973–82 елларда һәм 1988 дән «Татнефть» АҖдә: ТатНИПИнефть оешмасында өлкән инженер, геолог, фәнни-тикшеренү һәм җитештерү эшләре, нефть һәм газ чыгару, скважиналарны капиталь ремонтлау цехларында өлкән геолог, нефть чыганакларын эшкәртү буенча технол. бүлеге башлыгы урынбасары; 2000 нән «Баулынефть» НГДУда баш геолог. Бөгелмә-Тымытык эзләнү запаслары терр-ясендә нефть чыганакларын ачуда катнаша. Уйлап табуга 35 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Дәүләт бүләге нефть чыгару скважиналарының нәтиҗәлелеген арттыру, яңарту һәм саклауны тәэмин итә торган техник һәм технол. карарлар комплексын эшләүдә һәм сәнәгатькә кертүдә катнашканы өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

ХА́НОВ Алмаз Муллаҗан улы (1.1.1949, Актаныш р-ны Актаныш а.), технолог, техник фән. д-ры (1995), проф. (1998). Пермь политехник ин-тын тәмамлаганнан соң (1976), РФАнең Себер бүлеге гидродинамика ин-тында (Новосибирск ш.) эшли. 1982–85 елларда Ижевск металлургия технологиясе ин-тында, 1985–97дә РФАнең Урал бүлеге Техник химия ин-тында (Пермь ш.) композицион материаллар лаб. мөдире. 1997 дән материаллар каршылыгы һәм машиналар конструкцияләү каф. мөдире, бер үк вакытта, 2003 тән, Пермь техник ун-ты деканы. Хезмәтләре композицион материаллар һәм түшәмәләр өлкәсенә карый. Х. титан һәм аның катнашмалары нигезендә композицион материалларны, оксидлы системалар нигезендә кәрәзсыман конструкцияләрне, төерчекле материалларны барлыкка китерү һәм эшкәртүнең технол. процессларын эшли (бу эшләнмәләр Мәскәү, Ижевск, Казан пр-тие-ләрендә гамәлгә ашырыла). Уйлап табуга 23 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. РФ Хөкүмәте бүләге лауреаты (2008). Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Композиционные материалы и конструкции на основе титана и его соединений. Новосиб., 2001 (автордаш); Проблемы порошкового материаловедения. Екатеринбург, 2006 (автордаш); Оксидные композиционные материалы: Учеб. Пособие. Пермь, 2007 (автордаш).

ХА́НОВ Илдар Мәснәви улы (3.11.1940, Иске Аракчино пос. — 9.2.2013, Мәскәү, Казанда җирләнә), монументалист, рәссам, скульптор, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1994). Казан сынлы сәнгать уч-щесен (1960), В.И.Суриков исем. Мәскәү сынлы сәнгать ин-тын (1968) тәмамлый. 1995 елдан Казанда. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1968). Иҗаты күпкырлы, монументаль сәнгатьтә әйдәп баручы осталарның берсе. Күпләгән картиналар, Казандагы һәм ТРның башка шәһәрләр һәм районнарындагы скульптура композицияләре авторы. Х.ның башлангыч чор иҗатына глобаль, масштаблы темаларга омтылыш хас. Модерн агымнар, «кырыс стиль» б-н кызыксыну 20 йөз Мексика сәнгате традицияләре рухында (аеруча рәссам Д.Сикейрос) үзенчәлекле чагылыш таба: «Татар эш-





И.М.Х а н о в. 1. «Шигърият агачы» скульптура композициясе. Бетон, смальта. 1986. Арча районы Яңа Кырлай авылы; 2. «Зодиак циклыннан Прометей». Киндер. Майлы буяу. 1998.

чесен җирләү» (1962), «Ленин подпольеда», «Ленин һәм революция» (икесе дә — 1963). 1970 еллардан Х.ның Көнчыгыш һәм Көнбатыш Европа сәнгате (кубистлар, Ф.Леже), татар мифологиясе традицияләрен үзенә туплаган авангардизм стиле формалаша. Символлар файдаланып кискен деформацияләнгән пропорцияле, тирән тәэсирле образлар иҗат итә: «Гасыр туу», «Аваз», «Кешелек учагы», «Апокалипсис» (1963–68). Символик образларның фәлсәфи мәгънәләре аеруча скульптура композицияләрендә күренә. «Ватан-ана» һәйкәлендә (1975, арх. Р.С.Насыйров) форма һәм сызыклар тыгызлыгы халыкның патриотик хисләрен чагылдыра. Чаллы шәһәрендә куелган монументаль-декоратив композицияләрдә галәм гармониясен эзләү аллегорик формада бирелә («Регби», 1980; «Гармония», «Эволюция», «Уяну», «Кара-каршы», барысы да — 1982; «Тормыш агачы», 1988; «Энергия», 1988). Милли тема Х.ның «Шигърият агачы» скульптура композициясендә (Арча р-ны Яңа Кырлай а., 1986) аеруча ачык чагылыш таба. Отышлы пластик чишелеш нәтиҗәсендә смальта файдаланып тимер-бетоннан (яраткан материалы) эшләнгән скульптура композицияләре бик җиңел күренә. Х.ның эшләре архит-ра һәм әйләнә-тирә б-н бәйле. Иске Аракчинода ул төзегән Галәм гыйбадәтханәсе (Барлык диннәр гыйбадәтханәсе) — архит-ра һәм декоратив сәнгатьнең уникаль симбиозы.

Шәхси күргәзмәләре 1993, 2011 (Чаллы ш.), 1994, 2010 (Казан), 2011 дә (Алабуга ш.) уздырыла. Картиналары ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Чаллы шәһәре Тарих музеенда саклана.



И.М.Х а н о в. «Ату» рельефы. Бетон. 1974. Казанның Горький исем. үзәк мәдәният һәм ял паркы.

Х.ның иҗат эшчәнлеге турында төшерелгән документаль фильмнар: «Илдар Ханов турында сүз» (реж. Ю.Манусовның шәхси студиясе, Чаллы ш., 1994), «Галәм рәссамы» (реж. Э.Үтәгәнов, Казан кинохроника студиясе, 2000), «Илдар Ханов һәм аның күңел гыйбадәтханәсе» (реж. Ю.Захаров, С.-Петербург, Леннаучфильм, 2006), «Илдар Ханов — Яктылык Җыры» (реж. Л.Усова, Мәдәният һәм кинематография федераль агентлыгы, М., 2007), «Илдар Хановның Галәм гыйбадәтханәсе» (реж. Е.Петровская, М., Центрнаучфильм-Анима, 2009).

ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт премиясе лауреаты (2010), БМО оешмасы каршындагы Бөтендөнья Тынычлык Федерациясенең «Тынычлык илчесе» мактаулы исеменә лаек була (2010).


Әд.: В а л е е в а Д.К. Говорящий с космосом // Искусство Татарстана (XX век). К., 1999; С у л т а н о в а Р.Р. «Древо жизни» Ильдара Ханова. К., 2000; Н и г м а т у л л и н а Ю.Г. Мир глазами Ильдара Ханова // Казань. 2008. № 7.

Р.Р.Солтанова.

ХА́НОВНЫҢ БА́РЛЫК ДИННӘ́Р ГЫЙБАДӘТХАНӘСЕ́, дини һәм мәдәни-агарту комплексы. Казан шәһәре янындагы Иске Аракчино поселогында урнашкан. Төзелеш рәссам-скульптор И.М. Ханов проекты буенча, аның чыгымнары һәм шәхси кертемнәр хисабына 1992–2013 елларда алып барыла. Авторның концепциясе бөтен дөньяга изгелек тарату, сугышларны туктату, диннәр арасында берләштерү идеясенә нигезләнә. Аның фикеренчә, комплексна дөньяның төп диннәренең (православие, католик, буддизм, ислам, иудаизм, зороастризм һ.б.) 16 гыйбадәтханәсе һәм ш.у. Тереза ана гыйбадәтханәсе керергә тиеш була. Х.Б.д.г. гыйбадәт кылу урыны түгел, ә дини һәм мәдәни танып белү үзәге буларак төзелә.

Төзелгән өлеше ике катлы, максатка яраш лы төрле күләмле ике кыеклы түбә өстендә яктылык барабаннары һәм каплаулы утыр тылган ярымсфералы, сугансыман гөмбәзле, чатыр рәвешендә очланган күпкатлы манаралар күтәрелгән комплекс тәшкил итә. Алар известьташтан, силикат һәм кызыл кирпечтән эшләнгән. Корылмалар И.М.Ханов тарафыннан фрескалар, мозаикалар, скульптуралар һәм төсле витражлар б-н бизәлгән. Төрле төстәге гөмбәзләр һәм чатырлар комплекска әкияти кыяфәт бирә.

Х.Г.Надыйрова.



Хановның Барлык диннәр гыйбадәтханәсе. Казан. Архитекторы И.М. Ханов. 1992–2013. Хәзерге күренеше.

ХАНСҮ́Р авылы, Баулы р-нында, Баулы шәһәреннән 55 *км* көньяктарак, Югары Кандыз елгасы буенда. 2010 елда 382 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, сарык асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 мәчет, су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2325 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Салих волостенда, 1920 дән ТАССР-ның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Баулы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965нең 12 гыйнварыннан Баулы р-нында. Халык саны: 1859 да — 622, 1889 да — 992, 1897 дә — 1134, 1910 да — 1560, 1920 дә — 1506, 1926 да — 1209, 1938 дә — 1108, 1949 да — 952, 1958 дә — 795, 1970 тә — 711, 1979 да — 572, 1989 да — 417, 2002 дә — 402 кеше.

ХАНТЕМИ́РОВ Иван Салих улы (2.4.1926, Төмән өлкәсенең Түбән Тәүде р-ны Киндерле а. — 25.10.1995, Казан), график, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1976). Свердловск сынлы сәнгать уч-щесендә укый (1942–44), Бөек Ватан сугышы елларында «Окна сатиры» өчен плакатлар ясый. 1945 елдан Казанда. Татарстан китап нәшриятында бизәүче рәссам (1948–70). 1950–53 тә Совет Армиясендә, күптиражлы армия газеталарында рәссам. 1953–59 да «Комсомолец Татарии», «Советская Татария»,

«Правда», «Комсомольская правда», «Советская Россия» г-таларында, «Чаян» ж-лында рәссам. Казан «Агитплакат»ы б-н хезмәттәшлек итә (1961–70), «Чаян» ж-лында баш рәссам (1970–82). Журналистлар берлеге (1968), Рәссамнар берлеге (1974) әгъзасы.

Сатирик графика остасы буларак китап иллюстрациясен, агитация плакатын, газета графикасын үстерүгә зур өлеш кертә. Сәясәт (халыкара) һәм көнкүреш темаларына



И.С.Хантемиров. «Яшь чагында утырып калыйк – картайгач басып торырга өлгерербез әле». 1971. «Чаян» журналы.

үткен характерлы гротеск һәм юморлы карикатуралар авторы. Татарстан китап нәшрияты, Воениздат һәм Иркутск дәүләт нәшриятларында басылган китапларга иллюстрацияләр ясый (тушь, акварель, карандаш): К.Ушинский «Хикәяләр» («Рассказы», 1948), М.Горький «Әкиятләр» («Сказки», 1949), Ә.Еникәй «Язгы күкрәү» (1949, автордаш М.Рәхимов), И.Кычаков һәм А.Чмыхало «Хакас әкиятләре» («Хакасские сказки», 1952), А.Гайдар «Кайнар таш» («Горячий камень», 1959). С.Михалков «Стёпа агай» («Дядя Стёпа», 1959), И.Нуруллин «Тукай турында хикәяләр» (1965), А.Фадеев «Яшь гвардия» («Молодая гвардия», 1965). «Хуҗа Насретдин мәзәкләре» (1966), «Татар елмаюлары» (1969) һ.б.



И.С.Хантемиров. «Көньяк Африка Республикасында» («Мин монда шушы номер өчен генә килдем»). 1973.

1955 тән «Татарстан рәссамнарының сатирик графикасы» (Мәскәү, 1963), Татарстан рәссамнарының ТАССРның 60 еллыгына багышланган әсәрләре (Мәскәү, 1980–81), төбәкара – «Зур Идел» (1980), бөтенсоюз «Ут сызыгында» (Мәскәү, 1971), халыкара «Сатира тынычлык өчен көрәштә» (1969, 1973, 1977), «Дөнья көлгәнгә күрә исән калды» сатира һәм юмор (Болгария, Габрово ш., 1973, 1977), «Чили халкына азатлык!» (Мәскәү, София, 1973–74) күргәзмәләрендә катнаша. Картиналары ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда, Әлмәт шәһәре картиналар галереясында, Габроводагы Сатира һәм юмор музеенда саклана. Медаль б-н бүләкләнә.

Әд.: Художники «Чаяна». Л., 1960; Художники «Чаяна». Цепкой клешнёй. Л., 1963; Стыкалин С., Кременская И. Советская сатирическая печать. 1917–1963. М., 1963; Елькович Л. На линии огня. К., 1977; Червонная С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984; Большая энциклопедия карикатуры. М., 2008.

ХАНТИМЕ́РОВ Рим Гаяз улы (4.6.1939, Чкалов өлкәсенең Александровка р-ны Тукай а.), оториноларинголог, мед. фән. д-ры (1981). Башкорт мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1963), БАССРның Аскын үзәк район хастаханәсенең баш табибе булып эшли. 1966–1981 елларда Ленинград оториноларингология фәнни-тикшеренү ин-тында, 1969 дан өске сулыш алу юллары патологиясе һәм ЛОР-әгъзалар пластик хирургиясе клиникасы җитәкчесе. 1982 дән Дипломнан соң белем алу академиясенең (Ленинград) клиника мөдире. Хезмәтләре маңгай-борын куышлыклары, борын һәм бугаз сулыш юллары патологиясенә карый. Уйлап табуга патенты бар.

Хезм.: Инфекционное поражение возвратных гортанных и подъязычных нервов как редкое осложнение флегмон клетчаточных пространств шеи // Вестн. хирургии. 2000. № 4.

ХАНТИМЕ́РОВА Галия (Көбра) Закир кызы (30.12.1921, Кызыл Урда өлкәсенең Казалы ш. – 3.7.2012, Мәскәү), тәрҗемәче, әдәбият тәнкыйтьчесе, филол. фән. канд. (1972). Читтән торып Бөтенсоюз юридик ин-тын тәмамлый (Алма-Ата, 1943). 1944–50 елларда СССР Югары мәхкәмәсендә Җинаять эшләре буенча мәхкәмә коллегиясендә тәр җәмәче, 1942–56 да «Инюрколлегия» консультанты, 1956–91 дә А.М.Горький исем. Әдәбият ин-тында (Мәскәү) доцент. Ф.Әмирханның «Татар кызы» («Татарка», 1957), «Габделбасыйр гыйшкы» («Любовь Габдельбасыра»), «Танымаганлыктан таныштык» («Познакомились...»), «Урталыкта» («На перепутье», барысы да – 1959), «Хәят» («Хаят»), «Фәтхулла хәзрәт» («Преосвященный Фатхулла»), «Рәхәт көн» («Счастливый день», барысы да 1968) һ.б. әсәрләрен, Г.Исхакый, Ф.Хөсни, А.Шамов, Р.Төхфәтуллин хикәяләрен; кыргыз, үзбәк һәм казакъ язучыларының проза әсәрләрен рус теленә тәр җемә итә. Хезмәтләре әдәби тәр җемә теориясе һәм практикасына, Г.Тукай, Г.Исхакый, Ә.Еники, Г.Бәширов, А.Шамов, З.Нури һ.б. әдипләрнең иҗатларына карый. «Мәхәббәт йөзе» («Лики любви», 2002) романы авторы.

Хезм.: Национальное своеобразие оригинала и проблемы перевода. К., 1974.

Әд.: Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

ХАНТИМЕ́РОВА Сания Хәсән кызы (13.2.1945, Казан), балет артисты, педагог, балетмейстер, ТАССРның халык артисты (1980). 1965 елда Ленинград хореография уч-щесен (педагог Н.Балтачеева), 1993 тә Петербург консерваториясен («балет режиссурасы» белгечлеге) тәмамлый. 1965–86 да Татар опера һәм балет театры солисты, 1987–90 да педагог-репетиторы, бер үк вакытта, 1975 тән – Казан музыка, 1993 тән Казан хореография уч-щеләрендә укыта. Төп партияләре: Жизель (шул исем. әсәр буенча, А.Адан), Одетта-Одиллия («Аккош күле», П.Чайковский), Мерседес («Дон Кихот», Л.Минкус), Золушка (шул исем. әсәр буенча, С.Прокофьев), Ширин («Мәхәббәт турында легенда», А.Меликов), Сөембикә («Шүрәле», Ф.Яруллин) һ.б. Х.ның сәхнәдәге осталыгы актёрларча сәнгатьчә башкаруы, нәзакәтлелеге, индивидуаль техникасы б-н аерылып тора. Татар опера һәм балет театрында – «Ялганчылар илендә Джельсомино» («Джельсомино в стране лжецов», И.Якупов, 1991), «Борис Годунов» (М.Мусоргский, 1993), «Алтынчәч» (Н.Җиһанов,





С.Х.Хантимерова: 1. Маша («Щелкунчик», П.Чайковский); 2. Сөембикә («Шүрәле», Ф.Яруллин; Былтыр – Н.С.Сәрвәров) рольләрендә.

1994) һ.б. операларда бию күренешләрен, Казан хореография уч-щесендә — «Джонатан Ливингстон исемле акчарлак» («Чайка по имени Джонатан Ливингстон»), «Тәүбә» («Покаяние»; икесе дә — С.Терханов музыкасына), «Умырзая» («Подснежник», П.Чайковский музыкасына), «Менуэт» (Дж.Больцони музыкасына) һ.б. композицияләрне; Самара опера һәм балет театрында «Шүрәле» балетын (Ф.Яруллин; Л.Якобсон редакциясендә, 1992) куя.



С.Х.Хантимерова.

В.Н.Горшков.

ХАНТЫ́-МАНСИ́ АВТОНО́МИЯЛЕ О́КРУГЫ – ЮГРА́, *Төмән өлкәсе* составындагы РФ субъекты. Көнбатыш Себердә, Обь һәм Иртыш елгалары бассейнында урнашкан. 1930 елның 10 декабрендә оештырыла (1940 ка кадәр — Остяко-Вогульск милли округы). Мәйданы — 534,8 мең *км*². Үзәге — Ханты-Мансийск шәһәре. Халкы — 1597051 кеше (2013), ш.и. 107637 татар (1939 да — 2227, 1959 да — 2938, 1970 тә — 14046, 1979 да — 36898, 1989 да — 97689, 2002 дә — 107637, 2010 да — 108899 кеше). *Себер татарлары* Х.-М.а.о. — Ю. терр-ясенә элек-электән килеп урнаша. 1960 еллардан Идел-Урал төбәгеннән автономияле округның нефть һәм газ чыганакларын үзләштерергә килүчеләр исәбенә татар җәмгыяте бик тиз үсә. Хәзерге вакытта татарлар тупланып Когалым, Лангепас, Лянтор, Мегион, Нижневартовск, Нягань, Покачи, Сургут, Урай, Югорск шәһәрләрендә, Акъяр, Фёдоровский һ.б. торак пунктларда яшиләр. Х.-М.а.о. — Ю. да ТРның Сәүдә-икътисад вәкиллеге (Сургут, 2001 дән), Х.-М.а.о. — Ю. татарларының төбәк милли-мәдәни автономиясе (Сургут, рәисе Т.Г.Саматов), Лянтор (2001), Мегион («Болгар», 2010), Нижневартовск («Мирас»), Сургут (1999) шәһәрләрендә, шәһәр тибындагы Акъяр посёлогында («Болгар», 2002) татар милли-мәдәни автономияләре; «Ватан» татар мәдәни-агарту җәмгыяте (Нягань, 2003), «Дуслык» татар иҗтимагый оешмасы (Урай, 2002), «Ак калфак» милли-мәдәни оешмасы (Нижнесортымский пос.), «Якташлар» оешмасы (Лангепас, 1992), «Болгар» (Югорск, 2004) һәм «Туган як» (Покачи, 2007) татар-башкорт иҗтимагый оешмалары, татар-башкорт җәмгыяте (Пойковский пос.), «Якташ» татар-башкорт милли-мәдәни үзәге (Фёдоровский штп, 1998), «Нур» татар-башкорт милли-мәдәни оешмасы (Когалым, 2007) эшли. Татар һәм татар-башкорт иҗтимагый оешмалары каршында «Сандугач» вокаль-хореографик ансамбле, «Көрәш» спорт секциясе (Сургут), «Тулпар» үзешчән театры (Югорск), «Йолдыз» үзешчән сәнгать ансамбле (Когалым, 2007), «Дуслык» ансамбле (Лянтор), «Якташлар» халык ансамбле (Лангепас, 1989), «Болгарлар» хореографик ансамбле (Мегион, 2010), «Каприз» балалар хореографик ансамбле һәм «Туган як» вокаль төркеме (Покачи); «Ләйсән» (Акъяр штп, 1997), «Ләйсән» (Урай, 2002), «Туган моңнар» (Нягань, 2004), «Якташ» (Фёдоровский штп, 1998), «Якташлар» (Нягань, 2006), «Асылъяр», «Сандугач» һәм «Умырзая» (Югорск, 2004) ансамбльләре эшли. Сургут, Лангепас, Мегион, Нягань, Югорск шәһәрләрендә — татар якшәмбе мәктәпләре, Сургутта татар китапханәсе эшләп килә. Татар һәм рус телләрендә «Татарлар» г-тасы нәшер ителә (Сургут, 2010 нан). Лангепаста «Туган тел» телетапшыруы эфирга чыга (1991 дән). Сургутта «Соцветие» милли мәдәниятләр фестивале, Лангепас һәм Мегионда Татар мәдәнияте көннәре, Мегионда Г.Тукай бәйрәме, Когалым, Лангепас, Лянтор, Мегион, Нягань, Покачи, Сургут, Югорск шәһәрләрендә һәм шәһәр тибындагы Акъяр посёлогында *Сабан туе* уздырыла. Х.-М.а.о. — Ю. терр-ясендә 27 мөселман җәмгыяте теркәлгән (2001), мөселманнарның Төбәк диния нәзарәте (Сургут, 1999; 2000 нән «Мәгърифәт» г-тасын чыгара), Ханты-Мансийск, Сургут, Нижневартовск, Нягань, Лангепас, Когалым, Радужный, Нефтеюганск, Мегион, Урай, Покачи, Лянтор, Советский, Югорск шәһәрләрендә; шәһәр тибындагы Фёдоровский, Пойковский посёлокларында, Салым, Нижнесортымский, Ульт-Ягун посёлокларында мәчетләр һәм гыйбадәтханәләр эшли. Һәр мәктәп каршында — ислам нигезләрен өйрәтүче якшәмбе мәктәпләре, Сургутта мәдрәсә (2012) ачыла. *Ураза бәйрәме* һәм *Корбан бәйрәме* үткәрелә.

Әд.: Татары Сибири. К., 2010.

ХАНЦЕВЕ́РОВ Фирьяз Рәхим улы (21.4.1926, Урда ш., Казакъстан ССР), генерал-майор (1978), техник фән. д-ры (1971), проф. (1973). Ярославль хәрби-пехота уч-ще сен (1946), Ленинград хәрби инженерлар элемтә академиясен (1958) тәмамлый. Сугышка кадәр Х. гаиләсе Мәскәүгә күченә. 1958–74 елларда Стратегик максаттагы ракета гаскәрләре һәм Космик гаскәрләр ин-тларында эшли. 1974–84 тә СССР Кораллы Көчләре Ген. штабының баш разведка идарәсе аппаратында, 1984–88 дә СССР ФАнең Космик күзәтүләр фәнни үзәгендә. 1989 дан Бөтенсоюз гамәли эниология ассоциациясе рәисе. 1992 дән Халыкара энергомәгълүмат фәннәре академиясе президенты. «Ренессанс» фәнни үзәге (Мәскәү) җитәкчесе. Хезмәтләре космик системаларны модельләштерү, биоэнергетика һәм эниология мәсьәләләренә һәм аларның нәтиҗәлегеген өйрәнүгә карый.

Х е з м.: Эниология: непознанные явления биолокации, телекинеза, уфологии, ясновидения, телепатии, астрологии. Таганрог, 1995; Эниология: чудеса без мистики. Книга научных версий. М., 1999.

ХАНШӘ́(ханча, ханишә), урта гасырлар татар феодаль дәүләтләрендә хан хатыны титуллы. Иң беренче формасы — ханише (сөйләм телендә ханиш, ханыш). «Х.» сүзенең синонимнары *ханбикә* һәм ханым. Соңгысы хәзерге вакытта кияүгә чыккан хатын-кызга хөрмәтләп эндәшү формасы буларак кулланыла.

ХА́РА (Chara), суусемнәр ырыгы. Төче һәм тозлы суларда үсүче 100 дән артык төре билгеле. Татарстан терр-ясендә гади Х. (C. vulgaris) һәм сасы исле Х. (C. foetida) очрый. Чиста сулык төпләрендә үсә, аларның таралуы суның үтә күренмәлелегенә бәйле. Ләмле грунтта киң әрәмәлекләр хасил итә. «Сабагы» кабыклы, 50 *см* га кадәр биеклектә. «Яфраклары» озын, буынлы, бөжралы. Х. вегетатив (вегетатив үрчү тамырчалар барлыкка килүне хәтерләтә) һәм җенси ысул б-н үрчи. Су кошлары өчен азык. Гади Х. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

ХАРАХАШЬЯ́Н Эдуард Георгиевич (7.11.1934, Ростов-Дон ш. — 16.8.1982, Казан), физик, физик-матем. фән. д-ры (1982). Мәскәү ун-тын тәмамлаганнан соң (1958), СССР ФА Казан ф-лының Физика-техника ин-тында эшли, металлар физикасы каф. мөдире (1974 елдан). Хезмәтләре нормаль һәм үтә үткәрүчән металларны ЭПР алымы б-н тикшерүгә карый. Х. беренче буларак ЭПРны үтә үткәргечләрдә күзәтә, үткәрүчәнлек электроннарында спин кайтавазы сигналларын терки. Үтә үткәргечләрнең наноүлчәмле үзлекләр табигатен магнит резонансы алымнары б-н тикшерү циклы өчен ТР Дәүләт бүләгенә лаек була (2007, үлгәннән соң).

Х е з м.: Об упорядочении магнитных примесей в сверхпроводниках // Письма в журн. эксперим. и теорет. физики. 1976. Т. 24 (автордаш); Прямое наблюдение замораживания спин-решёточной релаксации электронов в малых металлических частицах // Письма в журн. Эксперим. и теорет. физики. 1986. Т. 43, вып. 7 (автордаш).

ХАРӘЗМИ́ (14 йөз), төрки-татар шагыйре. Алтын Урданың башкаласы Сарай әл-Җәдид шәһәрендә яшәп иҗат итә. «Мәхәббәтнамә» (1353) поэмасының авторы. Поэмадагы мәгълүматлар буенча, әсәр Алтын Урда ханы *Җанибәкнең* туганы Мөхәммәд Хуҗа бәк үтенече б-н языла. «Мәхәббәтнамә» сөйгән кызга аталган 11 хаттан тора, аларның 8 төрки телдә, 3 фарсы телендә язылган. Автор олуг мәхәббәткә, яшәү бәхетенә мәдхия җырлый, гашыйкның хис-кичерешләрен тасвирлый. Әсәрнең уйгыр (1432) һәм гарәп язуындагы (1508) ике кулъязма күчермәсе Британия музеенда (Лондон) саклана. Поэманың тулы тексты фәнни аңлатмалар б-н беренче тапкыр 1957 дә Неаполь шәһәрендә (Италия), аннан соң Мәскәүдә, Ташкентта һәм Казанда басылып чыга.

Ә с ә р.: Мухаббат-наме. М., 1961.

Әд.: Средневековая татарская литература VIII–XVIII вв. К., 1999.

ХАРӘЗМИ́ Хәйдәр (Мирхәйдәр) (14 йөз ахыры — 15 йөзнең 1 нче яртысы), төрки-татар шагыйре. Низами поэмасына *назыйрә* рәвешендә язылган «Мәхзән әл-әсрар» («Серләр хәзинәсе», 1409–14) поэмасы авторы. Поэмасында Х. гуманизм, мәрхәмәтлелек, гаделлек идеяләрен тарата. Поэманың борынгырак күчермәләре Идел буе төбәкләрендә табыла, бер кулъязма нөсхәсе Британия музеенда (Лондон) саклана, 1858 елдан берничә тапкыр Казанда басылып чыга.

Әд.: Үзбек адабиёти: 4 томлик. Тошкент, 1959. Т. 1.

ХА́РИН Георгий Михайлович (12. 4.1947, Казан), мәхкәмә табибе, мед. фән. д-ры (1993), проф. (1993), ТРның атказ. табибе (1997). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1971), шунда ук, патологик анатомия кафедрасында эшли. 1974 елдан СССР МФАнең Эксперименталь патология һәм терапия фәнни-тикшеренү ин-тында (Сухум ш.). 1977 дән Казан Травматология һәм ортопедия фәнни-тикшеренү ин-тының патоморфология лаб-ясе мөдире. 1981 дән Казан мед. ин-тында, мәхкәмә медицинасы каф. мөдире (1992 дән). Хезмәтләре шоктан соңгы чорда бавырның структурасын һәм функцияләрен тикшерүгә, шок халәтендә канның диссеминацияле ою синдромына диагноз куюга карый. Бөтенроссия мәхкәмә табибләре җәмгытенең Татарстан бүлеге рәисе (1992 дән).

Хезмәтләре: Влияние стимуляции фагоцитов на неспецифическую резистентность организма к шокогенным воздействиям // Бюл. эксперим. биологии и медицины. 1998. Т. 126, № 11; Курс краткой судебной медицины. М., 2006.

Әд.: Профессор Георгий Михайлович Харин // Казан. мед. журн. 2007. № 2.

ХА́РИНО авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 43 *км* көньяк-көнбатыштарак, Чангар елгасы буенда. 2010 елда 88 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. 1646 дан Никонов Пүчинкәсе буларак мәгълүм. Рев-циягә кадәр ге рус чыганакларында Харино-Ключ исеме б-н дә билгеле. Башта халкы Зөя Троица монастырена карый, 1764 тә — экономик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә; игенчелек, терлекчелек, он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 4 җил тегермәне, 3 вак-тәякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1178 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Келәнче волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Тәмте, 1931 нең 20 октябреннән — Югары Ослан, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1782 дә — 66 ир-ат; 1859 да — 369, 1897 дә — 701, 1908 дә — 796, 1920 дә — 797, 1926 да — 613, 1938 дә — 418, 1949 да — 298, 1958 дә — 261, 1970 тә — 152, 1979 да — 81, 1989 да — 44, 2002 дә — 109 кеше.

ХАРИС (Харисов) Габдулла (Габдуллажан) Харис улы (1893, Тәтеш өязе, хәзер Апас р-ны Ябалак а. — 1931, шунда ук), шагыйрь. Мулла улы. Башлангыч белемне туган авылы мәдрәсәсендә ала, аннан соң Казан мәдрәсәләренең берсендә укый. 1913 елдан укыта. Беренче бөтендөнья сугышында катнаша. Сугыштан кайткач, укыта, төрле газета һәм журналлар редакцияләрендә эшли. Х.ның беренче «Фәкыйрьлек вә ятимлек» шигыре 1911 дә «Йолдыз» г-тасында басыла. 1912–16 да «Аң», «Ялт-Йолт», «Сөембикә», «Кояш» һ.б. татар газета һәм журналларында шигырьләре дөнья күрә. Әлеге шигырьләренең бер өлеше «Күңел көзгесе» җыентыгына кертелә (1913). «Өрәк» һәм «Гаилә хатирәләре» поэмалары авторы. А.С.Пушкин һәм Л.Н.Толстой әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә. 1917 дән соң матбугатта Совет хакимиятенә мәдхия җырлаган шигырьләре басыла.

Әд.: Татар шигърияте: XX гасыр башы. К., 2004; Татар әдипләре, мәгърифәтчеләре (XX йөз башы): Биобиблиогр. сүзлек. К., 2005.

ХАРИ́С (Харисов) Ренат Мәгъсүм улы (6.5.1941, Ульянов өлкәсенең Богдашкино р-ны Кәшә (Зирекле Күл) а., шагыйрь, әдәбият тәнкыйтьчесе, драматург, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1972), Каракалпак АССРның (1980), Чуаш АССРның (2002) атказ. мәдәният хезмәткәре, ТРның халык шагыйре (2004). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1963), Арча пед. уч-щесендә рус теле һәм әдәбияты укыта, 1964 елдан ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-тында пропаганда һәм агитация бүлеге инструкторы, 1965 тән «Татарстан яшьләре» г-тасында әдәби хезмәткәр, «Яшь ленинчы» г-тасында җаваплы сәркәтип. 1971 дән ТАССР Язучылар берлеге идарәсендә җаваплы сәркәтип. 1973 тән ТАССР мәдәният министры урынбасары, 1982 дән «Казан утлары» ж-лының баш мөхәррире, 1989 дан КПССның Татарстан өлкә ком-тында идеология бүлеге мөдире, 1991 дән «Татарстан хәбәрләре» г-тасының баш мөхәррире, бер үк вакытта ТАССР ЮСның мандат комиссиясе рәисе, 1995 тән ТР Дәүләт Советы рәисе урынбасары, 1999–2004 тә дәүләт телләрендә ТР законнарын тәңгәлләштерү (идентификацияләү) комиссиясе рәисе. Дәүләт флагын, Дәүләт гербын, Дәүләт гимнын булдыру буенча ТР Конституция комиссиясенең эшче төркемен җитәкли, *Бөтендөнья татар конгрессы*, *Шаляпин Ф.И. исемендәге опера фестивале* идеясе һәм концепциясе авторы. Х.ның басылган беренче әсәрләре (1960 еллар уртасы) дөньяга фәлсәфи караш, яңа шигырь формалары һәм сәнгать чаралары эзләү б-н укучының игътибарын җәлеп итәләр. Аның лирикасының үзәк темалары — мөһим тормыш мәсьәләләре, татар халкының үткән һәм хәзерге заман контекстында кеше язмышлары, туган як табигате («Кайтаваз», 1969; русчага тәр җәмәдә «Войди в мой дом», М., 1980; «Алтын төрән», 1983; «Көзге мәхәббәт», 1991; «Хисемнең исеме», 1996; «Тоткасыз ишек», 1999; «Сандугачлар тынган вакыт», 2011 һ.б.).

1980–1990 еллар ахыры үзгәреш чоры һәм аннан соңгы заман кешесенең драматик образы «Исемсезләр» (2002) шигъри романында, «Борылышта» (1987), «Чехов базары» (1997), «Карлыган сатучы кыз» (2000), «Татар «Титанигы» (2011), «Урам» (2012) поэмаларында тудырыла. Бөек Ватан сугышы геройларына һәм тыл хезмәтчәннәренә «Җәлилчеләр» (1980), «Ат иярләү» (1983), «Шөкер» (1999), «Җиңү күргәзмәсе» (2007), «Кадрия» (2007) поэмалары багышлана. «Мулланур» (1968), «Камил Якуб» (1975), «Ант суы» (1984), «Татарлар» (1988), «Идегәй» (1989), «Худяков» (2001) поэмаларында Х. күптән үткән вакыйгаларга һәм төбәкнең хәзерге тарихына мөрәҗәгать итә. «Рәссам» (1976), «Зөләйха» (1987), «Өч үбешү» (1992), «Сәйдәш яры» (1996), «Тукайның мәхәббәт төшләре» (1999), «Тәүбәсез мәхәббәт» (2001), «Рәшит Ва һапов» (2002), «Нарспи эзләре» (2007) поэмаларында мәхәббәт лирикасының көчәюе күзәтелә. Х. — татар язучылары Г.Тукай, Дәрдемәнд, Г.Ибра һимов, М.Җәлил, Ф.Кәрим, М.Кәрим, С.Хәким, Х.Туфан, Ә.Еники, рус язучысы В.Шамшурин, чуаш язучылары М.Сеспель, П.Афанасьев, Ю.Семендер, В.Тургай, комп. Н.Җи һанов, рәссам Н.Фешин, артист Р.Таҗетдинов һ.б. иҗатлары турындагы мәкаләләр авторы.



Р. Харис.

Х. иҗатына тирән хисләр, образлы фикерләүнең күпкатлылыгы һәм афористиклыгы хас. Гади тормыш күренешләре, табигать картиналары аның каләме астында зур социаль, сәяси һәм фәлсәфи мәсьәләләргә шигъри карааяга әверелә. Тормышны тирән кабул итү, лирик, фәлсәфи һәм публицистик башлангычларның бергә үрелеп бирелүе аның әсәрләренең җәлеп итәрлек асылын һәм актуальлеген хасил итә.

Х. — балалар өчен популяр китаплар һәм пьесалар авторы («Матур өй», 1988; «Лап-лап», 1992; «Әбәк», 2001 җыентыклары). Аларга хикәяләүнең гадилеге, төслелек, ачык образлылык, балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алу хас. 1990 еллар ахырыннан шагыйрь иҗатының мөһим юнәлеше — төрле жанрдагы музыка әсәрләре өчен либретто язу: «Кеше» (комп. М.Яруллин), «Мулланур» (комп. Е.Кожевникова) ораторияләре, «Шагыйрь мәхәббәте» операсы (комп. Р.Ахиярова, 2006), «Кыйссаи Йосыф» балеты (комп. Л.Любовский, 2001; РФнең Әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә Дәүләт бүләге), «Алтын Казан» рок-операсы (комп. Э.Низамов, 2011), «Сөембикә» операсы (комп. Р.Ахиярова, 2018). Х. шигырьләренә Н.Җиһанов «Әйтмә миңа», «Мәңгелек язым», Ф.Әхмәтов «Гашыйк бул син миңа», Р.Ахиярова «Заңгәр томан», «Ак кәгазь» җырларын, Р.Яхин 7 романстан торган «Кояшлы яңгыр» вокал циклын иҗат итәләр һ.б. Х. пьесалары буенча «Умырзая» (Казандагы Яшь тамашачылар театры, 2008), «Илдус һәм Windows» (шунда ук, 2011), «Күзләреңне үбеп...» (Минзәлә татар драма театры, 2009), «Серле алан» (Казан «Әкият» курчак театры, 2011), «Абай-бабай аланы» (шунда ук, 2011), «Кәкрүшкә» (шунда ук, 2012) спектакльләре куела, «Сабантуй юлы» («Дорога на Сабантуй», хроник-документаль фильм, Казан киностудиясе, 1980), Г.Тукай турында «Күңелемне җыр белән яктырт» («Озари мне душу песней», муз.-шигъри фильм, Казан киностудиясе, 1986) төшерелә. Поэзия б-н беррәттән Х. иҗатында аерым урынны графика алып тора. Х.ның А.М.Горький исем. әдәби-мемориаль музейда узган графика әсәрләре күргәзмәсе (Казан, 1996) нәтиҗәләре буенча «Ши-

гырь язган каләм белән...» китап-альбомы иҗат ителә (1998).

Х. үзен тәрҗемәче буларак та киң таныта. Г.Державин, А.Пушкин, М.Лермонтов, Ф.Тютчев, С.Есенин, И.Северянин, М.Цветаева, А.Ахматова, Н.Хикмәт, Г.Лорка, Р.Гамзатов, П.Хузангай, О.Сөләйманов, Ю.Семендер һ.б. әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә. Х. әсәрләре рус, инглиз, белорус, башкорт, чуаш һ.б. телләргә тәрҗемә ителә.

1968 дән ТР, РСФСР, СССР Язучылар берлеге әгъзасы, аларның берничә съездына депутат итеп сайлана, иҗади берлекләрнең җитәкче органнары, «Наш современник», «Дружба народов», «Казан утлары», «Татарстан» һ.б. ж-ллар редколлегияләре составына керә. 2004–13 тә РФ Язучылар берлеге секретаре. 2012–18 дә РФ Президенты каршындагы Мәдәният һәм сәнгать советы әгъзасы.

1990–95 тә ТР Дәүләт Советының халык депутаты. Татарстан комсомолының М.Җәлил исем. бүләге (1972), Башкортстан Язучылар берлегенең Ф.Кәрим исем. бүләге (1994), ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге (1997), РФнең Дәүләт бүләге (2005), Чуашстанның М.Сеспель исем. халыкара бүләге (2009), Р.Гамзатов исем. Зур әдәбият бүләге (2011), «Алтын Дельвиг» бүләге (2015) лауреаты. «Татарстан Республикасы алдынгы казанышлары өчен» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Әсәр.: Сайланма әсәрләр: 7 томда. К., 2006; Присядь к очагу моему. М., 1984; Испивший молнию. К., 2007; Юрату сукмаке. Чебоксары. 1995; Сярэбраны прамень. Минск, 2008; Певчая ночь. М., 2011.

Әд.: Фәйзуллин Р. Заманга иш иҗат // Казан утлары. 2001. № 5; Хәсәнова Ф. Ренат Харис шигърияте. К., 2005; Дементьев В. В середине судьбы своей // Литературная Россия. 1989. 7 апр.; Переяслов Н. Поэт — он равен ростом Богу // Лит. газета. 2007, 24–30 окт.; Ренат Харис һәм татар шигърияте: Татарстанның халык шагыйре... Ренат Хариска 70 яшь тулуга багышланган Россияқүләм фәнни-гамәли конф. материаллары. К., 2011.


Т.Н.Галиуллин.

ХАРИ́СОВ Зөфәр Назыйм улы (16.11.1956, Мөслим р-ны Түбән Табын а.), актёр, ТРның халык артисты (2004), РФнең атказ. артисты (2017). 1978 елда Казан мәдәният ин-тын дагы мәдәни-агарту эшләре ф-тының театр бүлеген тәмамлый һәм Әлмәт татар драма театрына актёр итеп алына. 1981 дән Татар драма һәм комедия театрында. Х., күпплан лы актёр буларак, хәзерге һәм классик репертуарны тәшкил иткән 70 тән артык роль башкара; игътибарны җәлеп итәрлек, истә калырлык сокланучан Гәскәр («Аршин мал алан», У.Ха җибәков), мәгънәсезрәк, әмма беркатлы Рәшит («Назлы кияү», К.Тинчурин), хыялый Сәйяр («Әниемнең ак күлмәге», Ш.Хөсәенов) образларын тудыра. Х. иҗатына герой характерын төрле яклап ачу, кайвакыт хәтта каршылыклы итеп бирү хас. Актёр башкаруында Ямгырчы би («Ителсуы ака торур», Н.Фәттах романы буенча) образы тапкыр, елгыр, шул ук вакытта баласын өзелеп сөюче ата, Исхак («Ай булмаса, йолдыз бар», Т.Миңнуллин) тыштан караганда акыллы, төпле күренгән, әмма асылда исә комсыз, үз файдасын гына кайгыртучы хирыс кеше, Бубнов («Кояш төшмәгән җирдә», М.Горький) икейөзле демагог буларак ачыла. Х. башкарган рольләр арасында Пурсоньяк («Галиҗәнап де Пурсоньяк», Ж.Б.Мольер) образы аерым урын алып тора; бу образны иҗат иткәндә, актёрның импровизация остасы булуы ачыла, көтелмәгән, кайвакыт хәтта мәгънәсез кебек тоелган сәхнә ситуацияләрендә дә үзен табигый һәм ышанычлы тотуы күренә. Ул, Мирвәли («Ташкыннар», Т.Гыйззәт), Инсаф («Җәяүле Мәхмүт», М.Кәрим), Әдһәм, Әмирхан



З.Н.Харисов Бикбулатов ролендә («Сандугачлар килгән безгә», И.Юзеев; Хәмзин ролендә – Н.Шәйхетдинов).

(«Ефәк баулы былбыл кош», «Шикәрем син, балым син», А.Гыйләҗев), Йагъкуб («Йосыф-Зөләйха», Н.Хисамов; «Икенче пландагы иң яхшы ир-ат роле» номинациясендә ТР Мәдәният министрлыгының «Тантана» бүләге, 2013), Сольмажор Бимольский («Әллә язмыш, әллә ялгыш...», Н.Нестерова), Полоний, Антонио («Гамлет. Күренешләр», «Гаугалы мәхәббәт», У.Шекспир), Йозеф Штайнер («Без барыбыз да кешеләр», Эрих Мария Ремарк), Бартоли («Фигароның өйләнүе», П.Бомарше), Җамали («Кия ұләр», Х.Вахит), Өмет, Бикбулатов, Ким Ханыч («Гашыйклар тавы», «Сандугачлар килгән



З.Н.Харисов Йагъкуб ролендә («Йосыф-Зөләйха», Н.Хисамов).

безгә», «Безнең әти мировой», И.Юзеев), Юныс бай, Габдуллажан, Шакиржан, Низам («Американ», «Сакла, шартламасын!..», «Хикмәтле доклад», К.Тинчурин), Азат («Әстәгъфирулла», Н.Гаетбай), Миннәт («Бала баласы балдан татлы», М.Гыйләҗев) һ.б. рольләрне дә уңышлы башкарып, тамашачы ихтирамын казана. Х. ш.у. режиссёр, тәрҗемәче булып эшли, концертларда халык җырлары б-н чыгышлар ясый.



З.Н.Харисов.

Әд.: Илялова И. Театр имени Тинчурина. К., 2002. *И.И.Илялова.*

ХАРИ́СОВ Миргалим Харис улы (16.3.1939, Актаныш р-ны Чат а. — 14.9.2009, Казан; туган авылында җирләнә), язучы, тәрҗемәче, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1988). М.С.Щепкин исем. Югары театр уч-щесен тәмамлаганнан соң (1961), Татар дәүләт акад. театрында артист. 1964 елдан Респ-ка халык иҗаты йортында методист, 1967 дән «Ватаным Татарстан» г-тасы хезмәткәре (бүленеп), 2004–09 да ТР ФАнең Татар энциклопедиясе ин-тында тәр җәмәче. «Тәзкирә» повесть һәм хикәяләр җыентыгы (1966), «Кызыл планетага сәяхәт» мажаралы повесть (1967), «Сабыйлар хакына» пьесалар җыентыгы (1969) авторы. Н.В.Думбадзенең «Я вижу солнце» («Мин кояшны күрәм», 1968), Г.Шәрипованың «Семья Гафура» («Гафурлар гаиләсе», 1981) романнарын, Л.И.Гумилевскийның «Зинин» повестен (1986), З.И.Воскресенскаяның «Пароль — Надежда» («Ялкынлы яшьлек», 1990) романын, С.Чикинның «Д.И.Ульянов» документаль повестен (1990), Н.Чуковскийның «Отважные капитаны» («Кыю капитаннар», 1995) повестьлар җыентыгын, А.П.Чехов, В.В.Маяковский, А.Н.Арбузов, В.С.Розов, Д.Н.Вәлиев һ.б.ның пьесаларын татар теленә тәрҗемә итә. М.Галәү, Г.Әпсәләмов, Г.Бәширов, А.Гыйләҗев, А.Расих, К.Нәҗми һ.б.ның әсәрләре буенча радио-телеспектакльләр сценарийлары авторы.

Әд.: Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

ХАРИ́СОВ Ринат Гата улы (1.4.1949, Чирмешән р-ны Иске Үтәмеш а.), геолог, геофизик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2004), ТРның атказ. геологы (1998). Казан ун-тын тәмамлый (1974), «ТНГ-Групп» АҖдә эшли, ген. директор (1995 тән). Х. Татарстан, Көнбатыш Себер, Оренбург өлкәсе, Ливия, Төркия һ.б. илләрдә углеводород чыганакларын эзләү һәм разведкалауда катнаша. Дәүләт бүләге Татарстанның углеводород чыганакларында экологик хәл мониторингы өчен геофизик комплекслар эшләү һәм гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Хезм.: В ритме времени (50 лет ОАО «Татнефтегеофизика») // Нефт. хоз-во. 2003. № 8.

ХАРИ́СОВ Ринат Зөфәр улы (12.6.1953, БАССРның Борай р-ны Ленин-Бүләк а.), нәкышьче, педагог, БРның һәм РФнең атказ. сәнгать эшлеклесе (2003, 2014). Уфа сәнгать ин-тының нәкышь бүлеген тәмамлый (1978). 1978–2008 елларда Башкорт пед. ун-тының сынлы сәнгать кафедрасында нәкышь буен - ча укыта. Рәссамнар берлеге (1989), «Инзәр» иҗат төркеме (1989–93), «Чыңгызхан» иҗат



Р.З.Харисов. «Хәерле иртә». 1984. «Казан» милли мәдәният үзәге.


берләшмәсе (1990) әгъзасы. 2008 дән Торонто шәһәрендә (Канада) эшли. Хәзерге көнкүреш жанры картиналары остасы. Халыкчан «наив» сәнгать традицияләрен үстереп, шул сәнгать манерасында эшли. Х.ның иҗат ме - тоды рус авангарды рәссамнары (М.Ларионов, Н.Гончарова, М.Шагал) картиналарына барып тоташа, ләкин ул фольклор сюжетларына һәм татар сәнгатенең (чигү, туку, кос - тюм, торакны бизәү) орнаменталь-декора - тив принципларына мөрәҗәгать итеп, үзенең сәнгати-стиль парадигмасын төзи. Күп кенә картиналарында совет чорының үзәктән читтәге маргиналь мәдәнияте ачыла; авыл һәм шәһәр көнкүреше күренешләре популяр символлар, татар җыр-мәкаль текстлары, хәзерге күргәзмә агитация б-н тулыландырыла. Геройлары саф күңелле итеп, реклама дәрәҗәсендәге ирония төсмерләре б-н тасвирлана. Татар халыкының тарихына һәм



Р.З.Харисов. «Казан трамваенда автопортрет». 1989.

мәдәниятенә багышланган картиналар сериясендә Х. символик-метафорик яңгырашлы лирик образлар барлыкка китерә. Төп картиналары: «Чигүле кулъяулык», «Кунак - лар» (икесе дә — 1982), «Аклы-каралы кино», «Сугыш тәмамлангач кичке сәгать алтыда», «Хәерле иртә» (барысы да — 1984), «Ак кал - фак. Г.Тукайга багышлау», «Чишмә. Кәләш» (икесе дә — 1985), «Кое янында», «Пастораль мотив» (икесе дә — 1986), «Олы юлның тузаны», «Казан трамваенда автопортрет» (икесе дә — 1989), «Талоннар белән натюрморт» (1992), «Победа» туктап калды» (1993), «Казан Кремле» (1994), «Алсу төстәге ат», «Җиләккә» (икесе дә — 1996), «Болгарга сәяхәт» (1998), «Алсу кич» (2000), «Агыйделдә ак пароход» (2007), «Төнлә баручы» (2008), «Сөембикә — Казан ханбикәсе», «И мөкат - дәс моңлы сазым. Тукай истәлегенә», «Торонтодагы мәчет» (барысы да — 2008–10), «Кыз һәм казлар», «Яңа гасыр» (икесе дә — 2011), «Баламишкин» (2012).

Респ-ка (1978 дән); бөтентатар — «Татарт» (С.-Петербург, Казан, 1991); төбәкара — «Урал» (1997, 2004, 2008), «Зур Идел» (2008, 2011); бөтенроссия — «Россия-IX, X, XI» (Мәскәү, 1999, 2004, 2009); халыкара —



Р.З.Харисов. «Классика». Киндер. Акрил. 2002.

«Арт-Манеж» (Мәскәү, 1997, 1998) күргәзмәләрендә, «Макдуглас» рус классик һәм за - манча сәнгать аукционында (Лондон, 2010), Торонтодагы күргәзмә-конкурсларда (2009, 2010, 2011) катнаша. Шәхси күргәзмәләре 1988, 1993, 2001, 2004, 2006, 2009, 2012. 2017 дә (Уфа), 1993 тә (Вена, Австрия) узды - рыла.

Картиналары М.В.Нестеров исем. Башкортстан Дәүләт сәнгать музеенда (Уфа), Но - восибирск сынлы сәнгать музеенда, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәгендә, «Мирас» музей-галерея - сында (Мәскәү), Джерси-Сити шәһәрендәге (АКШ) һәм Париж (Франция) заманча рус сәнгате музейларында, «Мирас» галерея - сында (Уфа, Мәскәү), Россиядәге һәм чит илләрдәге (Австрия, Германия, Голландия, Канада, Франция, Финляндия, Төркия) шәх - си тупланмаларда саклана.

Әд.: Харисов Ринат Зуфарович // Галерея традиционного и современного искусства фонда «Восток»: Каталог. Уфа, 1997; Ф е н и н а Э.П. Художники Башкортостана. XX век. Уфа, 2002; Ринат Харисов. Живопись: Каталог. Уфа, 2004; Ринат Харисов // Чингисхан: Альбом. М., 2008.

Г.Ф. Вәлиева-Сөләймановa.

ХАРИ́СОВ Тahир Бopһан улы (20.9.1953, Чаллы р-ны Күперле а.), педагог, пед. фән. д-ры (2004), проф. 2006), ТРның атказ. мәктәп укытучысы (2002). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1976), Биектау р-нының Чыпчык авылы мәктәбендә, 1980 елдан Казанның 27 нче мәктәбендә эшли. 1982 дән Татарстан укытучыларының белемен күтәрү ин-тында методика кабинеты мөдире, 1985 тән Биектау р-ны халык мәгарифе бүлеге мөдире, 1988 дән Казан пед. ин-тының пед. каф. мөдире, 1995 тән ТР Мәгариф министрлыгының оештыру-укыту бүлеге башлыгы. 1997 дән ТР Мәгариф үсеше ин-тының белем бирү б-н идарә каф. мөдире. 2005 тән Татар гуманитар-пед. ун-тында: проректор (2009 га кадәр), Мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү һәм яңадан һөнәри әзерләү ин-ты директоры (2012 гә кадәр). 2012 дән Халык мәгарифе системасы кадрларының квалификациясен күтәрү һәм яңадан һөнәри әзерләү үзәге җитәкчесе. Хезмәтләре мәктәп б-н идарә итү, педагогларның квали - фикациясе һәм әзерлек сыйфатын күтәрү мәсь әләренә карый.

Х е з м.: Интеграция контроля, аттестации и повышения квалификации педагогических кадров в системе внутришкольного управления. К., 2003; Управление общеобразовательным учреждением в современном (информационном) обществе. К., 2004.

ХАРИ́СОВ Фарис Фәхразый улы (3.1.1956, БАССРның Яңавыл р-ны Истәк а.), педагог, халык мәгарифе эшлеклесе, пед. фән. д-ры (1999), РМА мөхбир әгъзасы (2001), ТРның, РФнең атказ. мәктәп укытучысы (1995, 2002). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1979), Саба р-ны мәктәпләрендә эшли; 1987 елдан Казандагы 2 нче мәктәп, 1991 дән 5 нче татар гимназиясе директоры, 1995 тән Казан шәһәре Авиатөзелеш р-ны хакимиятенең мәгариф бүлеге башлыгы. 1997–2004 тә ТР мәга - риф министры, проф. (2001). 2006–09 да РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының Федераль мәгариф үсеше ин-ты директоры (Мәскәү), 2009 дан Мәгариф системасында сәламәтлек нығытуга булышлык итү гомумроссия иҗтимагый оешмасы рәисе, 2012 дән РФ Дәүләт Думасының мәгариф буенча ком-ты каршындагы эксперт советы рәисе.

Х е з м.: Образовательный ресурс национальной культуры. К., 1999; Региональная система образования: состояние и стратегия эволюции. М., 2005.

ХАРИ́СОВ Фираз Фәхразый улы (24.5.1952, БАССРның Яңавыл р-ны Истәк а.), педагог, пед. фән. д-ры (2001), проф. (2001), ТРның атказ. мәктәп укытучысы (2002), ТРның атказ. фән. эшлеклесе (2008). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1978), Казанның Ленин р-ны башкарма ком-тында эшли. 1987–2011 елларда Татар гуманитар-пед. ун-тында, проректор (1991–98), рус мәктәпләрендә татар теле укыту каф. мөдире (2000–09). 2011 дән

Казан (Идел буе) федераль ун-тында, Татаристика, тюркология һәм этномәдәни белем бирү фәнни-мәгариф үзәге җитәкчесе урынбасары. 2012 дән хәзерге заман татар теле һәм укыту методикасы каф. мөдире. Хезмәтләре татар телен татар булмаганнарга укыту методикасы мәсь әләлфенә карый. 1–5 сыйныфлар өчен татар теле дәреслекләре җыелмасы (Ч.М.Харисова б-н бергә), уку-укыту сүзлекләре авторы. ТР Мәгариф министрлыгының К.Насыйри исем. бүләге лауреаты (1998).

Х е з м.: Психолого-педагогические и лингвистические основы обучения татарской устной речи в русской школе. К., 1998; Научные основы начального обучения татарскому языку как неродному. К., 2000; Развитие этнорегионального образования: история и современность. М., 2011 (автордаш).

ХАРИ́СОВА Людмила Алексеевна (22.9.1956, Буа ш.), педагог, пед. фән. д-ры (2002), проф. (2008). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1980), Саба р-ныңың Олы Нырсы урта мәктәбендә эшли. 1987–91 елларда Казанның Мәскәү р-ны халык мәгарифе бүлегендә, 1992–98 дә 5 нче татар гимназиясе директоры урынбасары. 1998–2005 тә ТР Мәгарифне үстерү ин-тының пед. культурология каф. мөдире. 2005 тән РМА Мәгарифтә инновацион эшчәнлек ин-тының гомуми белем бирүдә инновацион процессларга анализ лаб-ясе мөдире (Мәскәү). Хезмәтләре гуманитар циклдагы фәннәрдә татар мәдәнияте кыйммәтләрен интеграцияләү, дини мәдәният нигезләрен гомуми дәүләт мәгарифе системасына кертү мәсьәләләренә карый. РМАнең К.Д.Ушинский исем. медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Религиозная культура в содержании образования. М., 2002; Педагогический потенциал ислама. М., 2008; Развитие этнорегионального образования: история и современность. М., 2011 (автордаш).

ХАРИ́СОВА Фирдәвес Ильяс кызы (26.6.1955, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2006), проф. (2007). РФнең Мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2006). Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлаганнан соң (1976), Ленинград финанс-икътисад ин-тында эшли. 1980 елдан Казан финанс-икътисад ин-тында, проф. (2007 дән). Хезмәтләре икътисади анализ ревизиясе һәм контроль, аудит өлкәсенә карый. Корпоратив кыйммәтле кәгазьләр аудиты буенча теоретик-методологик һәм практик тәкъдимнәр эшли.

Х е з м.: Аудит эмиссионных операций организаций с ценными бумагами. К., 2002; Аудит корпоративных ценных бумаг. М., 2005; Аудит производных финансовых инструментов. М., 2005.

ХАРИ́СОВА Чулпан Мөхәррәм кызы (17.3.1953, Кукмара р-ны Зур Сәрдек а.), педагог, пед. фән. д-ры (2002), проф. (2003), ТРның атказ. мәктәп укытучысы (2003), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2008). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1975), туган авылы урта мәктәбендә эшли. 1979–2010 еллар да Татар гуманитар пед. ун-тының татар теле кафедрасында. 2011 дән Казан (Идел буе) федераль ун-тының хәзерге татар теле һәм аны укыту кафедрасында. Хезмәтләре татар теле укыту методикасына карый. Рус мәктәпләренең 1–5 сыйныфлары өчен татар теле буенча дәреслекләр җыелмасы әзерли (Ф.Ф.Харисов б-н бергә). ТР Мәгариф министрлыгының К.Насыйри исем. бүләге лауреаты (1998).

Х е з м.: Методика обучения русскому произношению учащихся начальных классов русских школ. К., 2000.

ХАРИТО́НОВ Андрей Порфирьевич (11.12.1903, Казан губ., Лаеш өязе Казиле а. — 12.4.1976, Казан), икътисадчы, икътисад фән. канд. (1940), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1963). Мәскәү ун-тын (1930) һәм Казан юридик ин-тын (1937) тәмамлый. 1922 елда Көнчыгыш пед. ин-тына укырга керә. 3 нче курстан ТАССРның Лаеш кантоны халык мәгарифе инспекторы итеп билгеләнә. 1925–26 да Кызыл Армия сафларында хезмәт итә. Демобилизацияләнгәннән соң, Лаеш р-нында эшли: ВКП(б) район ком-тының бүлек мөдире, район халык мәгарифе инспекторы. 1934 тән Казан юридик ин-тында: политэкономия каф. мөдире, иҗтимагый фәннәр ф-ты деканы. 1942 дән Казан пед. ун-тының, 1943–68 дә Казан ун-тының политэкономия кафедралары мөдире. Бер үк вакытта, 1950 елларда, Казан авиация ин-тында һәм Казан консерваториясендә укыта. Хезмәтләре Татарстанда икътисади фикер тарихына, колхозлар төзелеше, хуҗалыкны рациональ алып бару мәсьәләләренә карый. Бөек Ватан сугышында катнаша. «Почётбилгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Экономическая мысль в Казанском университете // Уч. зап. Казан. ун-та. 1957. Т. 117, кн.3; Колхозный строй в Татарии и новый этап его развития. К., 1958; Рациональное использование земли — важное условие роста колхозных доходов. К., 1966 (автордаш).

Ф.С.Зыятдинов.

ХАРИТО́НОВ Иван Николаевич (20.6.1859, Казан — 9.9.1927, шунда ук), китап басу остасы, хәреф җыючы. 1869 елдан хәреф җыючы өйрәнчеге, 1873 тән Казан ун-ты басмаханәсендә хәреф җыючы, рус, немец, француз, грек, татар, монгол, Европа телләрендәге текстларны җыярга өйрәнә, татар телендә иркен сөйләшә. 1881 дән *Казан губерна ведомостьләрендә* хәреф җыючы. 1888 дән *Вечеслав Г.М. ташбасмаханәсе* идарәчесе. Х. аркасында басмаханә заказчылар арасында абруй казана һәм керемнәре күбәя. Басмаханә эшен өйрәнүне дәвам итә, гальванопластик ысуллары, шрифтлар коюны, ксилография, цинкография, китап тышлау эшен үзләштерә. 1896 да үз басмаханәсен ача, анда хәреф кою һәм китап тышлау цехы оештыра. 1902 дә басмаханә эшен өйрәнергә Вена, Дрезден, Лейпциг, Берлинга бара. Х. басмаханәсендә беренче тапкыр татар шрифтлары реформасы башлана. Г.*Камал* һәм И.*Юзиев* катнашында гамәлгә кертелеп, алар татар наширләре арасында гына түгел, Урта Азия, Якын һәм Урта Көнчыгышта да абруй казана. Татар китапларында илл. куллану, китап бизәлешен яхшырту Х. исеме б-н бәйле. Х.ның казанышларына бәя биреп, Г.Камал ул «мөселман басмасын яңа юнәлешкә чыгарды, аны дөньяның алдынгы халыклары басмасы дәрәҗәсенә күтәрде», дип яза. Г.Ибраһимов, Ф.Хәмиди, Ә.Максуди, И.Казаков, Ш.Әхмәров, Г.Нугайбәк, Ш.Шаһидуллин һ.б. басмаханәнең заказчылары була. Х. рус басмаханәсе эшен дә алга җибәрә. Аның рәсемнәре буенча ясалган һәм хәреф коюда аның рус шрифтлары Казанның басма йортларында гына түгел, башкала басмаханәләрендә дә киң кулланыла.

Әд.: К а р и м у л л и н А.Г. Татарская книга начала XX века. К., 1974; Иван Николаевич Харитонов // Камал Г. Әсәрләр. К., 1951. Т. 2.

Г.Г.Габделганиева.

ХАРИТО́НОВ И.Н. БАСМАХАНӘСЕ́, Казанда, 20 йөз башында Идел-Кама төбәгендәге иң эре басмаханә. 1896 елда И.Н.Харитонов Александров пассажында арендаланган бинада үз басмаханәсен ача. 1898 дә басмаханә каршында — ташбасма һәм китап тышлау цехы, 1900 нең башында хәреф кою ширкәте оештырыла. 1907 дә басмаханә өчен өч катлы йорт сатып алына. Анда басу бүлеге (5 машина, 2 «американка», 1 «бостонка», аларда көненә 50 меңгә кадәр бит бастырып алырга була); хәреф җыю һәм акцидент бүлекләре



Харитонов И.Н. басмаханәсе бинасы. 20 йөз башы фоторәсеме.

(төрле нәфис басма һәм китап басу эше башкарыла); китап б-н бергә газета бүлеге; ташбасма, хәреф кою, китап тышлау бүлекләре; бланклар нәшер итү бүлеге була. 1896 да басмаханәдә 6 кеше, 1899 да — 40, 1904 тә — 57, 1908 дә — 123, 1909 да — 131 кеше, ш.и. 32 татар эшли. Г.*Камал* һәм И.*Юзиев* катнашы б-н дистәләрчә төрле кегельдәге һәм язылыштагы шрифтлар гарнитурасы булдырыла. Алар татар наширләре арасында гына түгел, Урта Азия, чит Шәрекъ басмаханәләрендә дә киң кулланылышта була. Татар китапларын Харитонов 1902 дә бастыра башлый. 15 ел эчендә шәрекъ телләрендә гомуми тиражы 3300 мең данәдән артык 666 басма чыга, аларның күп өлешен татар язучылары, педагог-мәгърифәтчеләр, галимнәр: Г.Камал, Г.Ибраһимов, Г.Тукай, Ф.Әмирхан, З.Бәшири, Г.Рәхим, Г.Харис, М.Гафури, Р.Фәхретдин, Н.Думави һ.б.ның әсәрләре тәшкил итә. Дистәләрчә әлифба, татар, гарәп, фарсы һәм рус телләре грамматикасы, сүзлекләр, М.Корбангалиев, Ә.Максуди, С.Рахманкулов, Н.Надиев, Г.Алпаров һ.б.ның дәреслекләре; рус классиклары әсәрләре, шәрекъ һәм рус фольклоры тәрҗемәләре, календарьлар, халык җырлары, әкиятләр һәм мәкальләр басыла. Заказчы-наширләр: Г.Ибраһимов, Ф.Халиди,



Я.М. Харитонов.

Ә.Максуди, Ш.Әхмәров, Г.Нугайбәк, Ш.Шаһидуллин, «Гасыр», «Мәгариф», «Сабах», «Юл», «Милләт» нәшриятлары, башка шәһәрләрдән татар наширләре. Басмаханәдә татар газеталары һәм журналлары: «Хокук вә хәят», «әд-Дин вә әл-әдәб», «Азат», «Азат хатын», «Йолдыз» һ.б. нәшер ителә. Башлангыч мәктәп өчен киренең үзе катнашында төзелгән, орфографик сүзлек тә урнаштырылган «Кыскача татар нәхүе» («Краткий татарский синтаксис», 1913) дөнья күрә. Харитонов Һәфтияк һәм Коръәннең берничә басмасын бастыра. Басмаханә рус китапларын нәшер итү буенча да алда бара. 1901–16 да анда 1590 фәнни, уку, популяр, белешмә, гамәли, рәсми-ведомство басмалары чыга, «Волжско-Камская речь», «Вечерняя почта», «Восточный курьер» һ.б. Казан г-талары һәм ж-ллары нәшер ителә. 1899 да Харитонов Саратов а.х. һәм сәнәгать күргәзмәсендә көмеш медальгә ия була, 1912 дә Римдагы күргәзмәдә эшләренең нәфис бизәлеше өчен алтын медаль һәм акчалата бүләк ала. 1916 да Харитонов басмаханәсен сата, басмаханә, шул елның августында «Өмид» басмаханәсе б-н берләштерелеп, «Сабах» нәшрияты милкенә әверелә.

Әд.: Каримуллин А.Г. Татарская книга начала XX века. К., 1974; Габдельганеева Г.Г. Полиграфия и печать в Казанской губернии, 1800–1917 гг. К., 2005.

Г.Г.Габделганиева.

ХАРИТО́НОВ Иван Фёдорович (7.9.1898, Минзәлә ш. — 22.9.1985, Казан), хирург, мед. фән. д-ры (1959), проф. (1960), ТАССРның атказ. табибе (1958), ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1967). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1922), Пьяный Бор (хәзер Красный Бор) посёлогындагы ваба (холера) барагында табиб булып эшли. 1925 елдан Минзәлә халык хастаханәсе һәм аның хирургия бүлеге мөдире. 1933 тән Казан ун-тында, факультет хирургия клиникасында (1935 тән), хирургия курсы мөдире, 1939 дан балалар хирургиясе каф. мөдире, бер үк вакытта, 1949–51 дә, топографик анатомия һәм оператив хирургия каф. мөдире вазифаларын башкаручы; 1961–71 дә факультет хирургиясе каф. мөдире, 1972–74 тә проф.-консультант. Бөек Ватан сугышы елларында Казан госпитальләренең әйдәп баручы хирургы һәм урологы, Казан мед. ин-ты укытучысы. Хезмәтләре сидек юллары функцияләре тайпылышлары мәсьәләләренә карый. Казанда беренче булып, Ру-Гер-цен-Юдин ысулы б-н үңәчкә уңышлы пластик операция ясый. ТАССР Хирурглар җәмгыяте рәисе (1963–74). Ленин ордены, «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: К вопросу о лечении повреждений уретры // Хирургия. 1943. № 6; Клиника расстройств моторной функции мочеточников // Казан. мед. журн. 1961. № 1; Роль интерорецепторов мочеточников в их моторной функции // Урология. 1962. № 2; Атония мочеточников: Клиника, патогенез и патогенетическая терапия. К., 1971.

Әд.: Медведев В.Н. Профессор Иван Фёдорович Харитонов // Казан. мед. журн. 1998. № 5.

ХАРИТО́НОВ Михаил Васильевич (12.11.1941, Балык Бистәсе р-ны Керәшен Казысы а.), вет. эпизоотологы, вет. фән. д-ры (1998), проф. (1999), ТРның атказ. вет. табибе (1991), РФнең атказ. югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2001). Казан вет. ин-тын (хәзер Казан вет. медицинасы академиясе) тәмамлаганнан соң (1970), ин-тның уку-укыту хуҗалыгында өлкән вет. табибе булып эшли. 1973–75 елларда Бөгелмә, Балык Бистәсе вет. станцияләрендә өлкән вет. табиб-эпизоотологы. 1975 тән Казан вет. медицинасы академиясендә, эпизоотология каф. профессоры (1999 дан). Фәнни тикшеренүләренең төп юнәлешләре мөгезле эре терлекләр һәм дуңгызлар туберкулёзына диагноз кую, авыруны кисәтү һәм дәвалауның комплексы чараларын эшләүгә карый (ТР Дәүләт бүләге, 1996). Уйлап табуга патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: О дифференциации специфических реакций на туберкулин от неспецифических // Ветеринария. 1983. № 1; Туберкулёз сельскохозяйственных животных. М., 1990.

Әд.: Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.): Биогр. словарь учёных. К., 2006.

ХАРИТО́НОВ Яков Моисеевич (25.7.1921, Зөя кантоны Өтәк а. — 1992, Яшел Үзән ш.), Дан орденының тулы кавалеры (14.9.1944, 13.12.1944, 29.6.1945), гв. старшинасы. Туган авылында агач эше остасы булып эшли. 1940 елдан Кызыл Армиядә. 1941 нең июленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында: разведчик, 540 нчы армия миномёт полкы (49 нчы армия) батареясының өлкән разведчик-күзәтүчесе. Көнбатыш һәм 2 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Смоленск (1943), Белоруссия (1944), Көнчыгыш Пруссия һәм Көнчыгыш Померания (икесе дә 1945 тә) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 23 июнендә Головичи авылы (Белоруссия ССРның Могилёв өлкәсе Рясна торак пунктыннан 10 *км* төньяк-көнбатыштарак) янындагы Проня елгасын кичүгә каршы көндә (координатларын ачыклап, дошманның 2 пулемёт ноктасын юк итә), 1944 нең 9 октябренә каршы төндә Новогруд (Польша) шәһәре тирәсендәге Нарев елгасын кичкәндә (елганы беренчеләрдән булып кичә, дошманның 3 солдатын юк итә, 4 пулемётның, миномёт батареясының урыннарын ачыклый, һәм алар бирелгән координатлар нәтиҗәсендә юк ителә), Ольпух авылы, Банин тимер юл станциясе (Картузы шәһәренән (Польша) 14 *км* төньяк-көнчыгыштарак) өчен барган сугышларда һәм ш.у. 1944 нең 7, 15, 17 мартында Цоппот (Германия, хәзер Сопот ш., Польша) шәһәреннән 7 *км* көнбатыштарак барган сугышларда (дошманның 2 пулемёт ноктасының, 105 миллиметрлы тубының, дошманның 4 танкы һәм пехотасы тупланган урынның координатларын ачыклый һәм батареяның ату позициясенә хәбәр итә) батырлык күрсәтә. Берүзе 7 дошман солдатын юк итә. Демобилизацияләнгәч (1946), Яшел Үзәндә яши, заводта эшли. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

М.З.Хәбибуллин.

ХА́РИУСЛАР, пәрделәр (Thymallus), хариуслар семьялыгыннан балыклар ыругы. 6 төре билгеле, Евразия, Төньяк Америка елгаларында таралган. Татарстан терр-ясендә бер төре — Европа хариусы (T. Thymallus) очрый. Чиста һәм салкын сулы елгаларда (Кама кушылдыклары: Лубян һәм Зәйнең югары агымында, ш.у. Кече Сөлчәдә) яши. Гәүдәсенең озынлыгы 50–60 *см*, авырлыгы якынча 2 *кг*. Яшькелт-көрән төстә, ян-якларында соры, корсагы ак. Башы зур түгел. Тешләре үсеш алмаган. Сырт йөзгече, аеруча ата затларда, биек. Майлы йөзгече бар. 3–5 яшьтә җенси яктан өлгерәләр. Ата затлар аналарына караганда зуррак. Уылдыгын май аенда вак ташлы сай сулыкларда чәчә. Абс. үрчемлелеге 250 дән 6 мең уылдык бөртегенә кадәр. Кысласыманнар, моллюсклар, балык уылдыклары, җир өсте һәм су кандалалары, коңгызлар б-н туклана. Промысел әһәмияте юк. 12 ел яши. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

Әд.: Кузнецов В.А. Рыбы Волжско-Камского края. К., 2005.

ХАРЛАМПО́ВИЧ Константин Васильевич (18.7.1870, Гродно губ., Брест өязе Рогачи а. — 1932, Себер), тарихчы, чиркәү тарихы д-ры (1914), Петербург ФА мөхбир әгъзасы (1916 елдан), Украина ФА академигы. Петербург руханилар академиясен тәмамлаганнан соң (1894), Казан руханилар академиясендә (1914 елга кадәр), бер үк вакытта, 1900–22 дә, Казан ун-тында укыта, 1909 дан проф. 1922–24 тә Казан ун-ты каршындагы Археол., тарих һәм этнография җәмгыяте рәисе. 1920 еллар уртасында советларга каршы эшчәнлек алып баруда гаепләнеп эзәрлекләнә, 1925–28 дә Казакъстанда (Актүбә, Тургай шш.) сөргендә була. 1928 дән Украинада. Соңыннан Себергә сөрелә. Хезмәтләре Казан төбәгендә православие миссионерлыгы һәм дини белем тарихына карый.

Хезм.: Западно-русские церковные братства и их просветительная деятельность в конце XVI и начале XVII в. СПб., 1899; Казанские новокрещенские школы. К., 1905; Малороссийское влияние на великорусскую церковную жизнь. К., 1914.

ХАРЛАМПИ́ДИ Харлампий Эвклидович (13.12.1940, Грузия ССРның Батуми ш.), химик-технолог, химик фән. д-ры (1988), проф. (1991), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1996), РФнең атказ. фән эшлеклесе (2002), Казан технол. ун-тының атказ. профессоры (2010). 1967 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлый, шунда үк эшли, 1991 дән гомуми химик технол. каф. мөдире, «Панхимтех» фәнни-җитештерү үзәге фәнни җитәкчесе

(1993 тән), ун-тның һәм РФАнең Г.К.Боресков исем. Себер бүлеге Катализ ин-тының уртак «Химик технологияләр һәм катализ» фәнни-җитештерү үзәге башлыгы (Новосибирск ш., 2008 дән). Хезмәтләре мономерлар химиясе һәм технологиясенә карый. Х. кинетиканы, алкилароматик углеводородларның оксидлашу механизмын өйрәнә; этилбензолны оксидлаштыру эше нәтиҗәләре хәзер пропилен һәм стирол җитештерүдә кулланыла. Оксидлашу, гидратлашу, эпоксидлашу, дегидратацияләү реакцияләренең гомоген һәм гетероген катализын тикшерә. Метилфенилкарбинолны стиролга дегидратацияләү процессы өчен катализатор тәкъдим итә. α-метистиролны изопропилбензол дәрәҗәсенә кадәр гидратлаштыру, бензолны аерып чыгару өчен пироконденсатны гидратлаштыру, нефть сульфидларын сульфоксидлар дәрәҗәсенә кадәр оксидлаштыру технологияләрен эшли. Х. бораулау эретмәләренең, консервация майларының, күкерт эчтәлекле утыртмаларның нигезе буларак югары α-олефиннардан файдалану буенча тикшеренү эшләрен җитәкли. Нәтиҗәләре «Түбәнкамнефтехим»АҖдә гамәлгә ашырыла. Уйлап табуга 28 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Химия технологиясенең теоретик нигезләрен эшләгәне һәм бутилкаучук, пропилен оксиды һәм стирол җитештерүне камилләштергәне өчен ТР Дәүләт бүләгенә лаек була (1994). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Введение в теорию химико-технологических систем. К., 1997 (автордаш); Синтез высших алкилнафталинов с использованием модифицированных бентонитов // Химия и хим. технология. 2003. Т. 46, вып. 2 (автордаш); Теоретические основы энерго- и ресурсосбережения в химической технологии. К., 2004 (автордаш).

Әд.: Выпускники — гордость Казанского технологического университета: Краткий биогр. справ. К., 2009.

ХАРРА́СОВА (тәхәллүсе Рахман) Рифә Фәтхерахман кызы (18.9.1962, Кукмара р-ны Мәмәшир а.), шагыйрә, әдәбият галиме, филол. фән. канд. (2002), ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2017). Казан ун-тын тәмамлый (1987), шунда ук эшли (1993 елдан). «Шук алма, моңсу алма» (1995), «Күзләрең төймәләнсә» (1996), «Төнге кояш» (1999), «Кер фекле тәрәзәләр», «Коела йолдыз» (икесе дә — 2002), «Мине генә уйла!» (2003), «Сиңа» (2004) шигырь җыентыклары авторы. Х. шигъриятенә эчкерсезлек, романтик рух, эмоциональ киеренкелек хас. Шигырьләре тематикасы — туган җир, халык язмышы, мәхәббәт, яшәү мәгънәсе. Х.ның хикәяләре («Айлы күлдәвекләр», 2006; «Онытырмын димә», 2011 җыентыклары) якты образлары, фикерләүнең кыюлыгы б-н җәлеп итәләр. Автор эчке бушлыкка, ваемсызлыкка, комсызлыкка каршы чыга. Хезмәтләре Г.Исхакый иҗатына, аның иҗат лабораториясе мәсьәләләренә карый. Публицистик мәкаләләре хәзерге әдәби процесска, татар теле мәсьәләләренә багышлана. Ф.Хөсни (2012), Г.Исхакый (2014), С.Сөләйманова (2008), Ж.Вәлиди (2018) исем. әдәби бүләкләр лауреаты.

Әд.: Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

ХА́РЬКОВ МӨСЕЛМАННАРЫ́ ХӘЙРИЯ́ ҖӘМГЫЯТЕ́, 1909 елның ноябрендә оештырыла. Оештыручылары: Р.Үзбәков, С.Орлов, С.Биошев, А.Таниев, Х.Рәхмәтов, А.Агишов, С.Бәһаветдинов, И.Ибраһимов, З.Юнысов, Х.Җанбулатов, А.Цурбаев, Я.Азизбаев, Б.Шәрәфетдинов, Ш.Шабаев, Ф.Тугиев, И.Хисаметдинов, Г.Тугиев. Максаты — мохтаҗ мөселманнарга, мөселман мәдәни-агарту оешмаларына матди ярдәм күрсәтү. Эшен Харьков шәһәрендә һәм төбәгендә алып бара. 1917 дән эшчәнлеге туктала.

Ж.С.Миңнуллин.

ХАСТАХАНӘ́, халыкка стационар мед. ярдәме күрсәтүче дәвалау-мед. учреждениесе. Урнашкан җире, эшчәнлегенең юнәлеше һәм күләме ягыннан респ-ка, шәһәр, район (шәһәр һәм авыл), авыл, участок; гомуми һәм махсус (йогышлы авырулар, күз авырулары, стомат. һ.б.); ашыгыч ярдәм; балалар (гомуми һәм махсус) Х.ләренә бүленә. Структурасында поликлиника булган Х.ләр (берләштерелгән Х.ләр) стационар һәм поликлиника мед. ярдәме б-н тәэмин итү, авыруларга өйләренә барып хезмәт күрсәтү, ш.у. хезмәт күрсәтү районында авыруларны кисәтү һәм эпидемияләргә каршы чаралар уздыру б-н шөгыльләнә. Клиник Х.ләр студентлар һәм табибләргә уку-өйрәнү базасы булып хезмәт итә. Мед. техникасын, ятак-урыннарны, мед. кадрларын һәм матди чараларны рациональ һәм нәтиҗәлерәк файдалану максатыннан 1970 елдан башлап күппрофильле Х.ләр оештырыла.

Казан өязендә 1800 елда Х.ләр гомумән булмый. Өяз табибе кабул итә торган беренче табиблек пункты Казанда 19 йөз башында ачыла. 1806 да — Казан шәһәр Х.се, 1809 да — пехота полкы лазареты, 1830 да — Чистай, 1833 тә — Спас, 1854 тә Бөгелмә Х.ләре төзелә. 1860 еллардан — Казан җәмәгать тәрбиясе приказы һәм губерна Земство Х.се; 1890 еллардан — Адмиралтейство Х.се, 1899 дан — Казан йогышлы авырулар Х.се, 1900 дән — Казан ун-ты каршындагы клиника («Иске» клиника), 1910 нан «Шамов» Х.се эшли башлый.

1900 елга ТР терр-ясендә 79 Х. (ш.и. 3 се махсус) исәпләнә, алардагы 1871 ятак-урын га 270 табиб хезмәт күрсәтә. Совет хакимияте елларында Х.ләр һәм анда эшләүче табиблар саны сизелерлек арта. 1940 елда 161 Х. исәпләнә, аларда 726 табиб эшли (10 мең кешегә — 36,2 ятак-урын, 6,2 берәмлек табиб туры килә); 1970 тә — 262 Х., 1824 табиб (10 мең кешегә — 100,3 ятак-урын, 22,6 берәмлек табиб); 1990 да — 299 Х., 1750 табиб (10 мең кешегә — 133 ятак-урын, 39,1 берәмлек табиб). ТР да 150 дән артык дәвалау-профилактика учреждениесе (ш.и. Казанда һәм Чаллыда 3 ашыгыч ярдәм Х.се), 58 амбулатория-поликлиника учреждениесе, 21 стомат. поликлиникасы, 8 диспансер исәпләнә, аларда 15 меңнән артык табиб, 40 меңнән артык урта мед. хезмәткәре эшли (2015) Ш.у.к. *Земство медицинасы*, *Казан хәрби госпитале*, *Сәламәтлек саклау* һ.б.

Әд.: Врачебная помощь в городских поселениях // Ежегодник России. СПб., 1911; Степанова Е.А., Морозов В.В., Галлямов А.Б. Становление санитарных организаций в Казанской губернии и Татарской республике. К., 2000; Республика Татарстан: Стат. сб. 1920–2000. К., 2001.

Р.Г.Исхакова.

ХАСТАХАНӘ́ КА́ССАЛАРЫ, 1) революциягә кадәрге Россиядә эшчеләрне социаль иминиятләштерү өчен оештырылган учреждениеләр. Авырган һәм бәла-казалар б-н бәйле очракларда пособиеләр бирәләр, эшчеләр өчен хастаханәләр төзелешен финанслыйлар. Х.к.ның ике тибы була: а) аерым — бер пр-тие эшчеләренә хезмәт күрсәтә; б) гомуми — кагыйдә буларак, бер өлкәгә караган берничә пр-тиегә карый. Эшчеләрне иминиятләштерү турында 1923 елның 23 июне законы буенча Х.к. үзидарәле оешмалар сыйфатында яшәп килә: эшчеләр яисә вәкаләтле вәкилләрнең гомуми җыелышы кассаның идарәсен һәм ревизия комиссиясен сайлап куя. Гомуми җыелыш һәм Х.к. идарәсе составына ш.у. эшмәкәрләр вәкилләре дә (азчылыкны тәшкил итәләр) керә. Урыннарда Х.к. оештыру иминият кабулханәләренә тапшырыла. Х.к. капиталы эшчеләр кертемнәреннән (хезмәт хакыннан тотып калу), штрафлардан һәм эшмәкәрләрдән килгән кертемнәрдән туплана. Казан губернасында Х.к. 1913–19 да гамәлдә була, 1912 нең ахырында губернатор рәислегендә иминият кабулханәсе төзелә. Иминият законнары 177 пр-тиегә (17 мең эшче) карата гамәлгә ашырыла. Беренче Х.к. 1913 нең 1 июлендә «Казанда коммерция советнигы И.В.Александров варислары» сәүдә йортының сыра кайнату, спирт чистарту з-длары һәм ясалма минераль су з-ды каршында оештырыла. 1913 нең ахырына Казан губернасында 18 Х.к. (14415 әгъза) исәпләнә, пособиеләр 12 кассада бирелә. 1915 нең башына Х.к. саны 23 кә җитә, гамәлдә аларның 19 ы эшләп килә: 10 касса гомуми була һәм 97 пр-тиене берләштерә (6068 кеше), 9 ы — аерым (8458 кеше). Эшчеләрне социаль иминиятләштерү турында законнар Россиядә социаль яклау һәм табиб ярдәме системасын оештыруга билгеле бер алшартлар тудыралар. Законнарны гамәлгә ашыру Окт. рев-циясенә кадәр төгәлләнми кала. Совет хакимиятенең гомуми социаль иминиятләштерү турындагы декреты кабул ителү б-н Х.к.на ихтыяҗ бетә.

2) 1990 нан ТР Х.к. — респ-ка сәламәтлек саклау системасына кермн торган коммерцияле булмаган мәҗбүри мед. иминиятләштерүе оешмалары, мөстәкыйль субъектлары. Х.к.ның төп бурычлары түбәндәгеләр: шул терр-ядә яшәгән гражданнарның гомуми мәҗбүри мед. иминиятләштерүен тәэмин итү; мәҗбүри мед. иминиятләштерүе системасында гражданнарның ТР законнарында каралган хокукларын тәэмин итү; мәҗбүри мед. иминиятләштерүе системасында барлык гражданнарның социаль гаделлегенә һәм тигезлегенә ирешү; мәҗбүри мед. иминиятләштерүе системасында финанс тотрыклылыгын тәэмин итү. 1993 нең октябрендә иминиятләштерү турында ТР Законы кабул ителә. ТР терр-ясендә беренче дәүләт Х.к. 1993 тә Чаллы шәһәрендә оештырыла. 1994 нең февралендә ТР Дәүләт Советы Респ-ка Х.к. идарәсе составын раслый.

Мәҗбүри мед. иминиятләштерүенә иминият кертемнәре эшләүчеләр өчен хезмәткә түләү фондыннан 3,6% күләмендә билгеләнә һәм эшләмәүчеләр өчен РФдә билгеләнгән минималь хезмәт хакының 23 % ы күләмендә карала. Терр. Х.к. адм. башлыклары тарафыннан оештырыла, юридик затлар булып тора, тиешле вәкиллекле һәм башкарма хакимият органнары алдында хисап бирә, аларның финанс чаралары ТР дәүләт милке булып тора, бюджет һ.б. фондлар составына керми, тартып алына алмый.

Респ-ка Х.к. эшчәнлеген идарә һәм аның даими эшләүче органы — директор җитәкчелегендәге башкарма дирекция гамәлгә ашыра. Респ-ка Х.к. терр. Х.к. йөкләмәләре өчен җавап тотмый. 1997 елга мәҗбүри мед. иминиятләштерүе системасында шәһәрләрдә һәм районнарда ТР буенча барлыгы 382 дәвалау-профилактика учреждениесе, 45 терр. Х.к. хезмәт күрсәтә, алар тарафыннан барлык авыруларның 63% тан артыгын стационар дәвалауга һәм амбулатор-поликлиника учреждениеләрендә 24 млн. тапкыр булуга түләү тәэмин ителә.

Мәҗбүри мед. иминиятләштерүен кертү сәламәтлек саклау инфраструктурасын тәрәтипкә салырга, артык стационар ятакларның профилен үзгәртергә һәм кыскартырга, мед. ярдәме күрсәтүнең икътисади яктан отышлы формаларын гамәлгә куюга булышлык итә.

Чыг.: Закон Республики Татарстан «О медицинском страховании граждан Республики Татарстан» от 20.10.93 г. № 1991-XII; Положение о Республиканской больничной кассе (Утв. ВС РТ 09.02.94 г. № 2070-XII); Положение о Территориальной больничной кассе (Утв. ВС РТ 09.02.94 г. № 2070-XII); Сборник законодательных актов и нормативно-методических документов системы обязательного медицинского страхования Республики Татарстан. К., 1997.

Әд.: К у п р и я н о в а Л.В. Российские предприниматели и проблемы социального страхования 1880–1905 гг. // Отеч. история. 1996. № 5; К р а с и л ь н и к о в С.Н. Создание больничных касс в Казанской губернии // Проблемы медицинского и социального страхования — прошлое и настоящее: Материалы конф. К., 1997; Т е л и ш е в В.Ф. Проблемы социального страхования и врачебной помощи в России: от частного добровольного страхования до обязательного законодательства // шул ук.

В.Ф.Телишев, Н.В.Гобәев.

ХАТАЕ́ВИЧ Мендель Маркович (10.3.1893, Гомель ш. — 30.10.1937, Мәскәү), партия эшлеклесе. Яһүд башлангыч мәктәбен тәмамлый (Гомель), газеталар сата. 1913 елдан большевиклар партиясенең Гомель оешмасы әгъзасы, 1914 тә кулга алынып, Көнчыгыш Себергә сөрелә. 1917 елгы Февраль рев-циясеннән соң Гомельдә РСДРП(б)ның Подлесье ком-ты рәисе урынбасары, 1918 дә РКП(б)ның Самара шәһәр ком-ты рәисе, 1918–19 да РКП(б)ның Гомель өяз ком-ты рәисе. 1920 нең маенда Көнбатыш фронтка мобилизацияләнә, дивизия сәяси бүлеге башлыгы. 1921 нең июленнән Одесса губерна ком-ты секретаре. 1924 нең маеннан ВКП(б) ҮК нда, оештыру-бүлү бүлеге мөдире урынбасары. 1925 нең октябреннән ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты җавап лы секретаре. Үзәк Комитет Х.ны партиянең Татарстан оешмасына андагы вазгыятьне җайга салу, «төркемчелекне» («уң һәм сул тайпылышлар») бетерү өчен җибәрә. ВКП(б)ның 14 съездында Х. Татарстан делегациясен җитәкли, ҮКның Зиновьев-Каменев «яңа оппозиция»сен гаепләү ҮК линиясен яклап чыга; алга таба Татарстан өлкә ком-ты әгъзаларын һәртөрле оппозициягә каршы аяусыз көрәш алып барырга чакыра. *Индустияләштерү* сәясәтен актив рәвештә тормышка ашыра, 1928 дә ВКП(б) ҮК аша Бондюг химия з-дын саклап калуга һәм тулы реконструкцияләүгә ирешә, 1926–28 дә респ-каның тагын 17 пр-тиесе (Казан «Урак һәм чүкеч» механика з-ды, Казан сабын кайнату з-ды һ.б.) реконструкцияләнә, 8 яңа сәнәгать пр-тиесе һәм элек-тростанцияләр төзелә башлый. Акчаны янга калдыруга зур игътибар бирә (1926–28 дә адм.-идарә чыгымнарын кыскарту юлы б-н 5 млн. сумнан артык экономия ясауга ирешелә). 1928–32 дә ВКП(б)ның Урта Идел өлкә край ком-ты 1 нче секретаре. 1930 дан ВКП(б) ҮК әгъзасы, 1932–37 дә Украина КП(б) ҮК Политбюросы әгъзасы. 1933 тән Днепропетровск өлкә ком-тының 1 нче секретаре, 1937 нең 17 мартыннан Украина КП(б) ҮКның 2 нче секретаре. Ленин ордены б-н бүләкләнә. Репрессияләнә; үлгәннән соң аклана.

Әд.: Б е л я л о в У. Хатаевич Мендель Маркович // Борцы за счастье народное. К., 1983. Кн. 2.

Л.М.Айнетдинова.

ХАТИ́П (гарәп. خطيب), 1) вәгазьче; оста оратор, сүз остасы; 2) яучы; 3) мәчеттә хотбә-вә-газь (җомга намазы) укуга хаклы мулла, имам-хатип; 4) кеше исеме. Х. гади мулла һәм имамнардан дәрәҗәлерәк саналган. Исламга кадәрге чорда да гарәпләрдә Х.лар булган, ул заманнарда Х.лар дип сүз осталарын атаганнар. Алар халык арасында булган низагларны бетерүдә, шура җыелышларында, сугыш вакытларында халыкны гайрәтләндерүдә зур роль уйнаганнар.

Әд.: Миллият сүзлеге: Аңлатмалы сүзлек. К., 2007.

ХАТИ́ПОВ Фәрит Миргалим улы (1.1.1930, Минзәлә кантоны Пучы а.), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1968), проф. (1987), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2000). Язучылар берлегe әгъзасы (1982). Казан ун-тын тәмамлый (1952). 1955 елдан Тубыл пед. ин-тында, 1959 дан Башкорт ун-тында. 1972–2011 дә Татар гуманитар-пед. ун-тында (1972–91 дә татар әдәбияты каф. мөдире). Хезмәтләре әдәбият теориясенә, хәзерге заман татар прозасына, Г.Тукай, Ш.Бабич, Г.Ибраһимов, Ш.Камал, Һ.Такташ, М.Җәлил, С.Кудаш, Ф.Хөсни, М.Әмир, Ә.Еники һ.б. әдипләрнең иҗатларына карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Мирсәй Әмир. К., 1964; Эпик жанрлар. К., 1973; Әдәбият теориясе. К., 2000; Мөлкәтебезне барлаганда. К., 2003; Әдәби әсәрнең эстетик энергиясе: фәнни мәкаләләр. К., 2014; Духовный мир героя: психологизм в современной татарской прозе. К., 1981.

Әд.: Я к у п о в К. Җитди теоретик хезмәт // Мирас. 2002. № 11.

ХАТТАТЧЫЛЫ́К (гарәп. خطاط — матур язу остасы, каллиграф), матур һәм ачык-төгәл язу сәнгате; татар телендә — «хуш язу», «хөснe хат», «хаттатчылык». Татар мәдәниятенә Идел буе Болгар дәүләтенең ислам динен кабул итүе (10 йөз) һәм бөтен мөселман дөньясы язма мәдәниятенең аерылгысыз бер өлеше булган гарәп графикасы, гарәп-фарсы әдәбияты б-н бергә керә. Рун язмалары б-н бергә йөрүче гарәп графикасындагы беренче язмалар 8 йөз урталарына карый һәм алар иң элгәрге болгар каберлекләрендәге археол. казу эшләре вакытында табылган көнкүреш кирәк-яракларында очрый. Х. сәнгатенең алга таба үсеше Алтын Урда (13–14 йөзләр), Казан ханлыгы (15–16 йөзләр) чорларында дәвам иттерелә. Сәнгатьнең бу төре чәчәк ату 19 йөзгә туры килә. Татар кулъязма Х.ы гарәп шрифтының үсеше һәм камыш, каурый, 19 йөздән тимер каләмнең камилләшүенә бәйле. Урта гасырлар Х. үрнәкләре һәм Алтын Урда чоры биналарының фасад һәм интерьерлары бизәлешендә — ташка уеп язуда, ш.у. керәч әйберләрендә, кабер ташларында, бронза көзгеләр, йозаклар, тәңкәләр һәм зәркән бизәнү әйберләре (беләзек, йөзек һ.б.), Коръән савытлары, кулъязма Коръән нөсхәләре, хан ярлыклары һәм туграларда һ.б.да сакланып калган. Безгә билгеле булган иң элгәрге хаттатлар — Иванай Арсай (17 йөз), Гыйльми Үтәмеш (1700–40); 18 йөздә — 19 йөзнең 1 яртысында — *Габденнасыйр бине Сабит бине Сәфәргали әл-Әчкени, Утыз Имәни* һәм аның улы Әхмәтҗан бине Габдерәхим Утыз Имәни, Сөбхан Мәрҗани, Гобәйдулла бине Кәримулла, Ш.Мәрҗанинең шәкерте Мостафа Чутаи кебек галимнәр һәм фикер ияләре, дин эшлеклеләре дә хаттат ролен башкарган. Х. татар кулъязма китабында, аеруча халык арасында, еш кына исемнәре билгесез калган күчереп язучылар иҗатында киң таралыш ала. 19 йөздән гарәп Х. проф. мәктәбе традицияләрен яңарту башлана, аның башында Казан ун-ты укытучысы, классик *гарәп язуы* үрнәкләренә (нәсех, тәгълиқъ, шикәстә, дивани, рәйхани һәм рикъга һ.б.) өйрәтүче М.*Мәхмүдов* тора. Бу чорда Х.ның *кытта* дигән төре торгызыла, хилйа һәм *шәмаил* барлыкка килә. 19–20 йөзләрдә Казанда кулъязма китапта, шәмаилләрдә һәм кыттада югары Х. үрнәкләре булдырган мәшһүр хаттатлар әшли: Г.Сәлиев, М.Яхъя, Морадым бине Ибраһим, М.Хуҗасәетов, бертуган Габделвәли һәм Мөхәммәтгали Әхмәтовлар, Иблеяминов, Исмәгыйль Нәҗметдин бине Шәмсетдин, Йосыф Йасари, Кыямкарый Зөлфәкар, М.*Идриси*, *Нургали бине Мөхәммәд* әл-Морасави, Ха җи Шәмсетдин ибне Хөсәен һ.б. Каберташларда уеп язу үрнәкләре калдырган хаттатлар да Х. үсешендә мөһим роль уйный (к. *Эпиграфика*). Гарәп язулы Х. 1920 елларда, эчтәлегендә советча юнәлеш алып, үсешен дәвам иттерә. Бу чор конструктивизм сәнгате тәэсиренә бәйләнешле рәвештә новаторлык эксперименталары б-н характерлы. Рәссамнар (Г.Арсланов, Х.Алмаев, Б.Баһаветдинов, М.Кәримов, Ш.Мөхәммәтҗанов, Г.Сә-



Хаттатчылык. 1. Казан ханы Сәхибгәрәй ярлыгы. Кәгазь, язу карасы. Нишан. Хан мөһере. 1523. ТР Милли музее; 2. Кабер ташы. Яссы рельефлы уеп язу. Дөбъяз районы. 1543. ТР Милли музее; 3. Коръән гонваны. Ташбасма. 19 йөз. Казан университетының Н.И.Лобачевский исем. фәнни китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге; 4. «Шигъриять диваны»ннан кулъязма хаттатчылык язуы үрнәге (фарсы телендә). Төсле кәгазь, акварель, язу карасы. 1880 еллар. ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать институты архивы; 5. Кулъязма китапның башлам бизәге. Кәгазь, акварель, тушь. 18 йөз. ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать институты архивы; 6. «Нух көймәсе» шәмаиле. Рәссам Хуҗа Сәидов. Ташбасма. Казан университеты басмаханәсе. 1908. ТР Милли музее; 7. «Коръән тәфсире» текстына башлам бизәге. Кәгазь, акварель, язу карасы. 19 йөз. ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать институты архивы; 8. Шәмаил. Басмаханә басмасы. 1894. ТР Милли музее; 9. Кулъязма Коръәннең куш бите. Кәгазь, акварель, язу карасы. 19 йөз. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 10. Шәмаил. Пыяла,төсле фольга. Рәссам Госман Сәлиев. 20 йөз башы. Казан. Шәхси коллекция; 11. «Аллаһ матур һәм матурлыкны ярата» шәмаиле. Кәгазь, акварель, тушь, бронза буяу. Рәссам Б. Урманче. 1970 еллар. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 12. «Шәһадәт» – тугра. Оргалит, темпера. Рәссам В.А. Попов. 1998; 13. «Кәгъбә» шәмаиле. Пыяла, фольга, майлы буяу. Рәссам Р.И. Шәмсутов. 2002; 14. «Машалла» шәмаиле. Кулдан эшләнгән кәгазь (конгрев). Рәссам С. Гыйләҗетдинов. 2001.



Ф.К.Хатыйпов.



Р.М.Хатыйпова.

етов, Ф.Таһиров, К.Йосыпов һ.б.) китап, журнал тышлыкларындагы, плакат һәм афишалардагы язмаларны конструктивизм формаларында стильләштереп, гарәп графикасын киң файдаланалар. Ф.Таһиров, Б.Урманче һ.б. полиграфиядә гарәп хәрефләрен кулланууны теоретик эшкәртүдә катнашалар. 1920 еллар ахырыннан латин, соңыннан кириллица хәрефләренә күчү сәбәпле, гарәп Х. сәнгате татар мәдәниятендә бөтенләй диярлек юкка чыга. Ул аерым очракларда авылларда шәмаилләр язу белән шөгыльләнүче кайбер осталарда гына сакланып кала. 1970 елларда Б.Урманче гарәп графикасының орнаменталь-бизәү мөмкинлекләре булган гарәп хәрефләреннән 9 шәмаил (тушь, кәгазь) сериясе ясап, Х.ның милли традициясен торгыза. 1980 еллар ахырында хәзерге татар мәдәниятендә Х. сәнгатен яңарту киң масштаблы төсмер ала. Рәссамнар С.Гыйла җитдинов, Ф.*Гыйрфанов*, Р.Мәрданов, Р.Мөхәммәтҗанов, Н.*Исмәгыйлев* (Нәкъкаш), В.Попов, Р.Сәлахетдинов, Л.Фәсхетдинова, А.Хәлиуллина, В.*Ханнанов*, Р.*Шәмсетдинов*, Р.Шәмсутов һ.б. тарафыннан Х.ны яңа үсеш дәрәҗәсенә күтәргән тулы бер юнәлеш барлыкка килә. Х. традицияләрен камилләштерү яңа сюжет-композицияләр, төсле һәм орнаменталь өстәмәләр кертү, классик язу үрнәкләрен яңача фикерләү, яңа технология һәм материаллар кулланып алып барыла. Гарәп язуы Х. нигезләре 1990 елларда Татар гуманитар ин-тында һәм Казан ун-тының татар филологиясе ф-тында, хәзерге вакытта Казандагы Россия ислам ин-тында һәм «Мөхәммәдия» югары мәдрәсәсендә укытыла.

Әд.: Фәхретдин Р. Асар. К., 1904. 1 җилд., 8 җөзья; Әхмәтҗанов М. Татар кулъязма китабы. К., 2000; Дульский П.М. Казанский каллиграф Али Махмудов. К., 1930; Гараева Н.Г. Рукописные коллекции Казани // Ислам в Среднем Поволжье: история и современность. К., 1999; Ключевская Е.П. Фаик Тагиров – архитектор книги // Дизайн и новая архитектура. 2000. № 9; Монасыпов Ш. Шамаили Баки Урманче в свете духовного знания // Исламское искусство в Волго-Уральском регионе. К., 2002; Валеева-Сулейманова Г.Ф. Мусульманское искусство татар Среднего Поволжья // Ислам и мусульманская культура в Среднем Поволжье. К., 2003; Шамсутов Р.М. Слово и образ в татарском шамаиле: от прошлого до настоящего. К., 2003; Valeeva-Suleyvanova G. Arabic epigraphics in the Tatar decorative and applied arts // Islamic arts recources in Central Asia and Eastern & Central Europe. Jordan, 1996.

Р.М.Шәмсутов.

ХАТЫЙПОВ Фәрит Канәфи улы (1.1.1948, Саба р-ны Түлешкә а.), баянчы, композитор, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1993), ТРның халык артисты (2013). Казан музыка уч-щесен тәмамлый (1972). 1964–67 елларда Теләче һәм Саба р-ннарының балалар музыка мәктәпләрендә баянчы, сәнгать җитәкчесе һәм укытучы булып эшли. 1970–71 дә М.Я.Калинин исем. мәдәният йортында баянчылар ансамбле җитәкчесе, баянчы-аккомпаниатор. 1972–2003 тә Г.Тукай исем. Татар филармониясендә аккомпаниатор-концертмейстер. Татар халык һәм заманча музыканы нечкә тоемлап интерпретацияләү остасы. Татар шагыйрьләре шигырьләренә язылган 500 дән артык җыр авторы. Алар арасында «Һаман яратам» (Зөлфәт шигыре), «Гөлнарым» (Г.Афзал шигыре), «Синең нурың» (Х.Туфан шигыре), «Карлар ява» (М.Әгъләмов шигыре), «Яңа бүләк» (М.Миншин шигыре), «Авыл кызы» (Д.Хәбибуллин шигыре), «Шулай шул» (Р.Миңнуллин шигыре) җырлары аеруча популяр. Күп кенә танылган шәхесләр, ш.и. хатыны Р.М.*Хатыйпова* (Сибгатуллина) б-н концертлар куя.

Әсәр.: Һаман яратам. К., 1998; Моңлану. К., 2003; Парлы гашыйк. К., 2008.

ХАТЫЙПОВА (Сибгатуллина) Рабига Миндияр кызы (27.1.1948, Арча р-ны Иске Ябаш а.), җырчы (лирик сопрано), ТРның халык артисты (2013). 1970 елда Бөтенроссия эстрада сәнгате остаханәсен (Мәскәү) тәмамлый. 1969–94 тә Г.Тукай исем. Татар филармониясе солист-вокалисты. Х.ның вокаль үзенчәлегенә башкарыла торган әсәрнең драматургиясенә тирәнтен үтеп керү, үз интерпретациясен табарга омтылу хас. Аеруча танылган җырлары: «Гөлҗамал», «Бер тауда ун чишмә» (Ә.Фәттах көе), «Назлы гөлкәем» (Ф.Әхмәтов көе) һ.б. Х. репертуарын С.Сәйдәшев, Н.Җиһанов, Р.Яхин, М.Мозаффаров, Ф.К.*Хатыйпов* кебек татар композиторларының, ш.у. рус һәм совет композиторларының җырлары тәшкил итә. Медаль б-н бүләкләнә.

ХАТЫН-КЫЗЛАР ХӘРӘКӘТЕ (феминизм), хатын-кызларның сәяси, социаль-икътисади тигез хокуклылыгы өчен көрәш. Россиядә 19 йөз уртасында оеша. Хатын-кызлар эмансипациясе идеяләре җәмгыять тарафыннан социаль-сәяси һәм гаиләдәге тигезлек мәсьәләләрен аңлауга барып тоташа, ягъни ул нинди булырга тиеш, гомумән, аның булуы зарурмы, «тигезлек» төшенчәсенең эчтәлеге нәрсәдән гыйбарәт. 18–19 йөзләр чигендә бу мәсь әләләр Көнбатыш Европаның күп кенә илләрендә һәм Россиядә көн тәртибенә куела.

19 йөзнең 1 нче яртысында Россиядә хатын-кызларны гаиләдәге патриархаль йомыклыктан азат итүдә социаль хәрәкәтләр түгел, күренекле хатын-кызлар шәхесләре аерым әһәмияткә ия, аларның гамәлләре тегеяки бу сәбәпләр б-н гажәпләнү һәм кызыксыну уята. Гадәти булмаган үз-үзләрен тотышлары белән алар «үзэмансипация»нең тере мисалларын гәүдәләндерәләр (к. Н.А.*Дурова*), шул рәвешле җәмәгатьчелекне хатын-кызлар мәсь әләсен көн тәртибенә куюга һәм тикшерүгә җәлеп итәләр. 19 йөздә Россия феминизмының төп юнәлеше, башлыча, белем алуда, ш.и. югары белем өлкәсендә, хатын-кызларга тигез хокук бирелү өчен көрәштән гыйбарәт була. Хатын-кызларның белем алуга хокукы, аларны изелүдән коткаруның һәм азат итүнең мөһимлеге турында матбугатта беренче булып А.И.Герцен, Н.П.Огарёв, Т.Н.Грановский, Н.А.Добролюбов, Н.Г.Чернышевский һ.б. белдерәләр. 19 йөз башында С.-Петербургта, Мәскәүдә, Харьковта, Казанда хатын-кызларның беренче урта уку йортлары (к. *Родионованың затлы нәсел кыз балалар институты*) ачыла, хатын-кызлар өчен журналлар чыгарыла башлый. Бу чорда дворян һәм сәүдәгәр гаиләләре хатын-кызлары өчен төп иҗтимагый эшчәнлек иганәчелек була.

1860 еллардагы реформалардан соң иҗтимагый-сәяси тормышта зур үзгәрешләр күзәтелә, шәһәр халкы катлаулары тормышында

ТАССР татар хатын-кызларының 1 нче өлкә корылтае делегатлары. Казан. 1921.





Казан Солдат хатыннары берлеге идарәсе. Беренче рәттә сулдан дүртенче — М.А.Панфилова.

яңа социаль тәртипләр оеша (үзидарә органнары барлыкка килә), матбугатта илне үзгәртеп коруның мөһим мәсьәләләре, ш.и. җәмгыятьтәге хәл ителмәгән мәсьәләләрнең берсе буларак кабул ителгән хатын-кызлар мәсьәләсе буенча фикер алышулар башлана. Х.-к.х.нә гомуми идеология булмау хас, элекчә үк төп басым агарту-иганәчелек эшчәнлегенә ясала. Россиядә феминизм тарафдарлары ир-атлар ия булган хокукларга ирешүне алга сөрәләр (мәгариф, хезмәт, үзидарә органнарына сайлану хокукы). 19 йөзнең 2 нче яртысыннан феминизм идеяләре, башлыча, актив, үз даирәләре б-н элемтәләре өзелгән, яшәүгә матди мөмкинлекләре калмаган, шуның б-н бергә элеккеге мохиткә хас әхлакый максатлардан, идеаллардан һәм үз-үзеңне тоту кагыйдәләреннән читләшкән, дворян булмаган катлау вәкилләре арасында таныла ала. Үзләренең гражданлык һәм сәяси хокукларын танып-белергә омтылган хатын-кызлар шул хокукларга ирешү юлларын белем алуда һәм ирекле рәвештә һөнәр сайлауда күрәләр. 1860–70 елларда беренче хатын-кыз табибләрнең, телеграфчыларның, канцелярия хезмәткәрләренең эшчәнлеге башлана. Югары белем алудан мәхрүм хәлдә хатын-кызларның интеллектуаль хезмәт б-н бәйле һөнәрләр үзләштерүгә, дәүләт хезмәтенә керүгә мөмкинчелеге булмый. 19 йөз уртасында югары уку йортларына белем алырга керүдә хатын-кызларга тигез хокук бирү мәсь әтәсе зур иҗтимагый яңгыраш ала. 1863 тә Казан ун-ты советы вәкилләре хатын-кызларга ирекле тыңлаучы хокукында студентлар б-н бергә лекцияләр тыңларга һәм барлык гыйльми дәрәҗәләр алуга рөхсәт бирергә тәкъдим итәләр, әмма хөкүмәт бу тәкъдимне чор таләбенә туры килми дип таба. Хатын-кызлар түгәрәкләр оештыралар, шунда лекцияләр укыйлар; дәүләти булмаган махсус хатын-кыз курслары — Мәскәүдә Лубянка (1869) һәм Герье (1872), С.-Петербургта Владимир (1870) һәм Бестужев (1878) курслары, *Казан югары хатын-кызлар курслары* (1876) һ.б. ачылуга ирешәләр. Кайбер хатын-кызлар (С.К.*Шакулова*) белем алуны чит илләрдә төгәллиләр, алар анда Көнбатыш феминизм идеяләре б-н танышалар. Ләкин белем алганнан соң да, кагыйдә буларак, эшкә урнашканда алар зур кыенлыклар кичерәләр. 1871 дә Россиядә рәсми рәвештә хатын-кызларга хәйрия оешмаларында һәм хатын-кызлар уку йортларында укытучылык, акушерлык, фельдшерлык эшчәнлеге б-н шөгыльләнергә рөхсәт ителә; бер үк вакытта аларны башка хөкүмәт һәм җәмәгать учрежденияләренә кабул итү тыела (киләчәктә хатын-кызларны эшкә алу һәм хезмәттә тоту кагыйдәләрен һәр ведомство мөстәкыйль рәвештә үзе эшли). 19 йөз ахырына Россиядә үз хезмәт хакына яшәүче хатын-кызлар саны арта (1897 дә алар 6 млн. чамасы кеше исәпләнә), аларның зур өлеше фабрика-завод сәнәгатендә эшли. Хатын-кызларны сәнәгый җитештерүгә җәлеп итү җәмгыять һәм дәүләт алдында аларның хезмәтен саклау мәсьәләсен куя. 1885 тә текстиль һәм тау сәнәгатендә төнге вакытта хатын-кызлар һәм балалар хезмәте тыелу турында беренче закон чыгарыла. 1904 тән хатын-кызларга Почта-телеграф ведомствосында дәүләт хезмәтенә керү рөхсәт ителә. Асылда, һәр җирдә хезмәт хакы түләүдә хатын-кызларны кимсетү хөкем сөрә; гаилә һәм гражданлык хокукы мәсьәләләрендә тигезсезлек саклана (хатын-кыз иреяки әтисе ризалыгы б-н генә паспортлы була ала; әти-әниләре исән кече яшьтәге балалар мөлкәте өстеннән опека хокукы әтигә генә бирелә; хатын-кызның балигъ булуы — 21 яшьтән, ир-атныкы 17 яшьтән билгеләнә; хатын-кызларның милек мираслыгы хокукы чикләнә; земство һәм шәһәр үзидарә органнарында аларның вәкилләре булмый.

19 йөздә хатын-кызлар мәсь әтәсе татар мәгърифәтчеләре (Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Г.Ильяси һ.б.) тарафыннан да күтәрелә, алар хатын-кызны белемле итү аны азат итүнең генә түгел, барлык милләт алгарышының нигезе булырга тиеш дип исәплиләр. Бу идеяләрне җәдитчелек вәкилләре хуплыйлар һәм үстерәләр. Татар феминизмының үзенчәлеге шунда: ул барыннан да элек милли мәсь әләне хәл итү б-н бәйле һәм аңа буйсынулы була. 19 йөз ахырында татар кызларын тулы сыйфатлы дөньяви урта белем алуга, алга таба югары рус уку йортларында укуга әзерләүгә тәүге омтылышлар күзәтелә; шул юнәлештә 1873 нең гыйнварында Казанда Б.Ә.Әбсәләмова башлангычында беренче рус-татар мәктәбе ачыла (бер ел гына эшли). 1901 дә Х.Ш.Әхмәрова, Абдрахманова һәм Максудова башлангычында татар кызлары өчен рус башлангыч уч-щесе ачыла, аны тәмамлаучылар еш кына укуны рус гимназияләрендә дәвам итәләр. 1914 тә Казан губернасында 8 рус-татар мәктәбе эшли. 1905–07 дәге Рев-циядән соң татарлар яшәгән күп кенә җирләрдә яңа ысуллы хатын-кыз мәктәпләре барлыкка килә. Хатын-кызлар мәдрәсәсе ачу турындагы мәсь әтә туа: 1911 дә Уфа шәһәрендә Оренбург мөфтие М.Солтанов юбилеенда хатын-кызлар мәдрәсәсе ачу буенча махсус комиссия төзелә; 1912 дә «Кояш» г-тасы тирәсендә җәмәгать эшлеклеләре төркеме (С.Алкин, И.Терегулов, Ә.Максудов, М.Сәйдәшев) оеша, аның әгъзалары Романовлар Йортының 300 еллыгы хөрмәтенә хатын-кызлар гимназиясен ачу идеясен алга сөрәләр (инициативаларның икесе дә гамәлгә ашырылмый). 1916 да гына Ф.*Аитова* башлангычында татар хатын-кызлар мәктәбе беренче хатын-кызлар гимназиясе итеп үзгәртелә (к. *Аитова Фатиха гимназиясе*). Белемле мөселман хатын-кызларның эшкә урнашу мәсьәләсе кискен тора. Иң күпсанлы төркемне хатын-кыз укытучылар хасил итә, табибәләр, акушеркалар, фельдшерлар барлыкка килә. Ләкин гамәлдәге законнар буенча, гимназия тәмамлаганнан соң да, татар хатын-кызлары фәкать диндәшләре арасында гына эшли алалар. 20 йөз башында әдәбиятка тәүге татар әдибәләренең (Галимәтелбәнат Биктимерия, Фәхрелбәнат Сөләймания, Маһруй *Мозаффария*, Мәхмүдә *Мозаффария*, Хәбирә Насыйрия, Фәрхәнә Алушева, Мәхбүбҗамал *Акчурина* һ.б.) әсәрләре чыга. Кайбер татар прогрессив газеталары (*«әл-Ислах»*, *«Казан мөхбире»*) татар хатын-кызлары проблемаларын чагылдырган рубрикалар булдыралар.

1905–07 дәге Рев-ция елларында Х.-к.х. сәяси төсмер ала; ике юнәлеш — буржуаз феминистик хәрәкәт һәм хатын-кыз эшчеләр хәрәкәте (эшчеләр хәрәкәтенең бер өлеше

Татар крәстиян хатын-кызларының 1 нче корылтае делегатлары. Казан. 1921.



буларак) аныклана. Үзәктә һәм урыннарда феминистик хатын-кызлар оешмалары — «Хатын-кызлар тигез хокуклылыгы берлеге» («Союз равноправности женщин»), «Хатын-кызлар прогрессив партиясе» («Женская прогрессивная партия»), «Россия хатын-кызлар тигез хокуклылыгы лигасы» («Российская лига равноправия женщин») барлыкка килә, алар хатын-кызларның ир-ат лар б-н тигез хокуклы булуы таләбен берен че планга чыгаралар. 1908 дә 1 нче Бөтенроссия хатын-кызлар съезды булып уза, анда социаль-икътисади мәсьәләләр б-н бергә хатын-кызларның сәяси тигез хокуклылыгы мәсь әләсе дә көн тәртибенә куела. Россиянең кайбер сәяси партияләре дә (с.-д., эсерлар, кадетлар) хатын-кызларның җәмгыятьтәге хәле турындагы мәсь әләне үз про граммаларына кертәләр. Алар хатын-кызлар ның сәяси һәм гражданлык тигез хокуклылыгы, хатын-кызлар һәм балалар хезмәтен саклау турында законнар эшләү таләпләрен ал га сөрәләр. «*Иттифакъ әл-мөслимин*» мөселман хатын-кызларга сайлау хокукы бирелү өчен көрәшә. Хатын-кызларның сәяси тигез хокуклылыгы турындагы мәсьәлә берничә тапкыр Дәүләт Думасында тикшерелә: 1 нче Думада хатын-кызларның гражданлык ти гез хокуклылыгы турындагы закон проек тын эшләү өчен комиссия төзелә; 3 нче Дума хатын-кызларны варислык хокукларында тигезләү (крәстияннәргә кагылмый), хатын-кызларның адвокатлык хезмәтенә хокук ы турындагы закон проектларын хуплый. 1913 нең 23 февралендә Россиядә беренче тапкыр Халыкара хатын-кызлар көне билгеләп үтелә.

1917 нең 23 февралендә Петроградта ха тын-кызлар чыгышлары революцион шартлауны һәм Февр. рев-циясе башлануны тизләтә. 1917 нең мартыннан октябренә кадәрге чорда Россиянең иҗтимагый-сәяси даирәләрендә хатын-кызларның хокуклары турындагы мәсь әләәлеккесенә караганда кискенрәк рәвештә куела. 1917 нең апрелендә Вакытлы хөкүмәт хатын-кызларга барлык сайлануны органнарга, ш.и. Учредительләр җыенына сайлау-сайлану хокукы биргән карар бастырып чыгара. Хатын-кызларның һәм ир-ат ларның тигез дәрәҗәдә урта һәм югары белем алу мөмкинлеге турындагы мәсь әләне хәл ите лә; моннан тыш 1917 нең 5 августында Вакыт лы хөкүмәт «Хатын-кыз женесеннән булган затларга дәүләт хезмәтенә керүгә бирелгән хокукларны киңәйтү турында» карар кабул итә. Ләкин хатын-кызларның һәм ир-атлар ның хокуклары тулысынча тигезләштерелми. 1917 нең апрелендә Казанда мөселман ха тын-кызларның 1 нче Бөтенроссия корыл тае уза, анда Мөслимәләр берлеге төзелә. Төп максат мөселман хатын-кызларны аларның гражданлык һәм сәяси хокуклары өчен көрәштә берләштерүдән гыйбарәт була. Мөсел маннарның 1 нче Бөтенроссия корылтае эшендә (1917 нең мае, Мәскәү) катнашу өчен делегация сайлана. Әлеге корылтайда ха тын-кызлар мәсь әләсе буенча фикер алыш канда өч юнәлеш билгеләнә: мөселман ха тын-кызларга сәяси һәм гражданлык тигез хокуклылыгы бирү (Мөселман социалистлар ком-тыннан докладчы Ә.Ф.*Мөхетдинова*), сәяси тигез хокуклылык һәм хатын-кызларның гаиләдәге хәлендә кайбер үзгәрешләр (Мөслимәләр берлегеннән — И. Туктарова), тигез хокуклылыкка каршы юнәлеш (консерватив руханилар) тарафдарлары. Корылтай резолюциясе демократик карашны чагылдыра. Мөселманнарның 2 нче Бөтенрос сия корылтаенда (1917 нең июль–августы, Казан) мөселман руханилар башлангычында хатын-кызлар хокуклары буенча кабат кискен бәхәс кабына. Нәтиҗәдә, 1 нче Бөтен россия корылтаеның хатын-кызлар мәсь әләсе буенча резолюциясе үзгәртелә: хатын-кызларның сәяси хокуклары саклана, ләкин аларның гаилә хәлендәге үзгәрешләр турындагы пунктлар алына. Крәстиян хатын-кызларга авыл җәмәгатенең җирен биләүдә тигез хо куклар бирү турындагы мәсьәлә хәл ителми.

Хатын-кызлар Окт. рев-циясендә актив катнашалар: 1917 нең көзендә Казанда М.А.Панфилова җитәкчелегендә Солдат хатыннары берлеге, А.С.*Сәйфи* җитәкчелегендә Мөселман солдат хатыннары берлеге төзелә; Ә.Ф.Мөхетдинова Мөселман социалистлар ком-ты рәисе иптәше (урынбасары) була. Совет хакимиятенең беренче закон актларында ук иҗтимагый тормышның барлык өлкәләрендә хатын-кыз хезмәт ияләренең ти гез хокуклылыгы таныла: РКП(б) программасында партия хатын-кызларның закон бу енча формаль тигез хокуклылыгын тану б-н чикләнми, тигез хокуклылыкны хатын-кызларны йорт хуҗалыгы авырлыкларыннан коткарып һәм аларны яңа җәмгыять тормы шының барлык өлкәләренә җәлеп итеп га мәлгә ашырырга омтыла дип күрсәтелә, аналарны һәм балаларга дәүләт яклавы гарантияләнә. Һәр партия ком-ты каршында хатын-кызлар бүлекләре оештырыла. 1919 ның язында РКП(б)ның Казан губерна оешмасы составында хатын-кызлар секциясе төзелә (бюро рәисе — Н.А.Ванькова). Татар Х.-к.х. дә алга таба үсеш кичерә. 1920 дә Шәрекъ халыклары коммунистик оешмалары Үзәк бюросы каршында мөселман хатын-кызлар б-н эшләү өчен бүлек булдырыла (җитәкчесе — Ш.Кәримова). Казан губернасы хатын-кызлар бүлеге каршындагы секцияне З.Ә.*Баембәтова* җитәкли. 1920 нең сентяб рендә Казанда татар хатын-кыз эшчеләре конференциясе, 1921 нең гыйнварында татар хатын-кызлары корылтае булып уза. Ху җалык төзелеше, җимереклекләр б-н көрәш һәм татар хатын-кызларының бурычлары, мәгариф һәм социаль тәэминат, аналар һәм балалар хокукларын яклау турындагы мәсь әләләр тикшерелә. Алга таба татар Х.-к.х. го мумроссия хәрәкәте б-н кушыла. СССРда 1920–30 елларда аның төп формасы шәһәр лләрдә, районнарда, пр-тиеләрдә, җирле Совет лар каршында оештырылган делегат җые лышларыннан гыйбарәт була. Хатын-кыз лар клублары булдырыла, аларда хатын-кыз ны укырга-язарга өйрәтәләр, мәдәнияткә тар талар. Махсус «Работница», «Коммунистка», «Крестьянка», «*Азат хатын*» ж-ллары һ.б. басмалар оештырыла, аларның төп бу рычы хатын-кызларны сәяси тәрбияләү, иҗтимагый-дәүләт эшләренә җәлеп итү була. СССРда Х.-к.х.ндә феминистик лозунглар куелмый; Коммунистлар партиясе җитәкчелегендә ул хатын-кызларны макс. дәрәҗәдә хезмәткә һәм иҗтимагый эшләргә тартырга омтыла. Бөек Ватан сугышы көннәрендә мил лионнарча совет хатын-кызлары халык хуҗа лыгында фронтка киткән ир-атларны алыш тыралар. Меңнәрчә хатын-кызлар туры дан-туры фронтта һәм партизан отрядларында фашист илбасарлары б-н сугышларда катнашалар. 1950–60 елларда шәһәрләрдә һәм районнарда, пр-тиеләрдә һәм учреждениеләрдә, колхозларда һәм совхозларда хатын-кызлар советлары оештырыла башлый. Хатын-кызлар халык хуҗалыгы, фән, техника һәм мәдәният үсешендә актив катнашалар. Дәүләт хатын-кызларны җитештерү өл кәсенә, җәмгыятьнең иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни тормышына киңрәк күләмдә җәлеп итү өчен шартлар тудыра (мәктәпкәчә учреждениеләр ачыла, балалар учреждениеләре челтәре киңәя һ.б.).

Үзгәртеп корулардан соңгы елларда Х.-к.х. нең кабынуы күзәтелә, аның вәкилләре хәзер гәчә хатын-кызларны кыерсыту хөкем сөрә, ул эшкә урнашканда, хезмәт хакы түләгәндә һ.б. очракларда чагыла, дип белдерәләр. Алар иҗтимагый-сәяси тормышта хатын-кызның ролен күтәрү, дәүләт идарә органнарында хатын-кызлар санын күбәйтү өчен актив чыгыш ясыйлар. 1995 тә респ-када күпчелек хатын-кызлар җәмәгать оешмаларын берләш тергән «*Татарстан хатын-кызлары*» оешмасы төзелә.

Әд.: М ө х е т д и н о в а Ә. Эшче татар хатыны Бөек Октябрь алдыннан // Азат хатын. 1927. № 14; Б и к т и м и р о в а Т.Ә. Ил язмышын салып иңнәренә. К., 2006; М ә х м ү т о в а А.Х. Вакыт инде: без дә торыйк (җәдитчелек һәм хатын-кызлар хәрәкәте формалашу): очерклар. К., 2012; ш у л у к. Пора и нам зажечь зарю свободы! Джадидизм и женское движение. К., 2006; С м и р н о в а В.Н. Женщины Татарии в революционном движении 1910 — 1914 годов // Общественно-политическое движение и классовая борьба на Средней Волге (конец XIX — начало XX века). К., 1972; ш у л у к. Женщины Татарии на трудовом фронте в период гражданской войны. К., 1973; М а х м у т о в а А.Х., С м и р н о в а В.Н. Женщины в общественно-политической жизни края в первые годы Советской власти // Очерки по истории социалистического строительства в Поволжье. К., 1974.

Л.М.Айнетдинова.

ХАФИ́З, (гарәп. حافظ). 1) 15–16 йөзләрдә та татар ханлыкларында «Х.» термины хан канцеляриясендә язу-сызу эшләрен башкаручы һәм күчереп язучы мәгънәсендә кулланыла. *Бакши* һәм *кәтиб* терминнарының синонимы булып тора; 2) көнкүрештә «Х.» белемле, га лим кеше, Коръәнне яттан белүче — «Коръән хафиз». Хәзерге татар телендә «Х.» сүзе ялгызлык исем буларак кулланыла.

ХАФИ́З (Күчтем) авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 12 *км* көнбатыш тарак, Ушма елгасы буенда. 2010 елда 77 ке ше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. 1930 елларда нигез салына. Халык саны: 1938 дә — 259, 1949 да — 176, 1958 дә —

157, 1970 тә — 159, 1979 да — 133, 1989 да — 125, 2002 дә — 96 кеше.

ХАФИ́З ШИРАЗИ́ (Шәмседдин Мөхәммәд) (якынча 1325, Шираз ш., Иран — 1390, шунда ук), фарсы суфи шагыйре. Тулы дини белем ала. Коръәнне һәм күп кенә хәдисләр - не яттан белә — «Хафиз» («Коръ ән аятьләрен хәтерендә саклаучы») тәхәллүсе дә шу ңа бәйле. «Диван»га («Җыентык») тупланган газәл, касыйдә, кыйтга, робагый, мәснәви жанрларында күпсанлы шигъри әсәрләр авторы. Шагыйрьнең үзәк темасы — социаль гаделсезлеккә каршы протест, тагын да яхшырак иҗтимагый төзелешкә омтылу, ирекле, бәхетле шәхескә ышану. Шуның б-н бергә Х.Ш. иҗатына пессимистик мотивлар да хас: кеше язмышының, бәхетенең үзгәрүчән булуына кайгыру. Аның лирик герое — капма-каршы көчләргә бирелгән аскет һәм мистик, скептик, хыялый, хәр фикерле кеше. Х.Ш. газәл формасын камиллеккә җиткерә. Әлеге жанрда иҗат ителгән шигырьләренә аффористик үткенлек һәм кыскалык, суфичылык, сатирик, натуралистик һәм фәлсәфи мотивларның үрелүе, мәхәббәтне илаһилаштыру (капма-каршы чагылышта мәхәббәт — ләззәт һәм мәхәббәт — газап), кинаяләр һәм ярымтоннар хас. Х.Ш. шигырьләре күп кенә Шәрекъ һәм Европа телләренә тәрҗемә ителә. 16 йөздә шагыйрь Суди тарафыннан «Диван» төрек теленә шәрехләүләр б-н тәрҗемә ителә. Гёте, үзенең «Көнбатыш-көнчыгыш диван»ының (1819) 2 нче өлешен «Хафизнамә» дип атап, шагыйрьнең исемен мәңгеләштерә. Х.Ш. әсәрләрен А.С.Пушкин, А.А.Фет, А.Н.Майков һ.б. тәр җемә итә. Татарлар арасында Х.Ш. поэзиясе фарсы телендә күләзма күчермәләрдә таралган була; аның хезмәтләре берничә тапкыр журналларда һәм җыентыкларда нәшер ителә, аерым басмалар булып чыга. Х.Ш.ның М.Бигиев, Г.Рәхим, Ф.Бурнаш, Х.Туфан һ.б. тарафыннан тәрҗемә ителгән шигырьләре С.Рәмиев, М.Гафури, М.Җәлил, Р.Гатауллин һ.б. шагыйрьләр иҗатларына көчле йогынты ясый.

Әсәр.: Избранное. Таш., 1985; Диван. М., 1998; Лирика. М.–СПб., 2000.

Ә.М.Шәрипов.

ХАФИЗ ЖӘНОВА Руфия Хафиз җән кызы (2.1.1949, Мари АССРның Мари-Төрек р-ны Татар Кетнәсе а.), фармаколог, мед. фән. д-ры (1992), проф. (1994), ТРның атказ. фән эш - леклесе (2002). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1972), шунда ук, фармакол. кафедрасында эшли, 1994 тән каф. профессоры. Хезмәтләре яңа синтетик дару препаратларының тәэсир итү механизмнарын өйрәнүгә карый. Уйлап табуга 5 патенты, 7 авторлык таныклыгы бар. Димефосфон дару препаратын уйлап табуга керткән өлеше өчен ТР Дәүләт бүләгенә лаек була (1994). РФ Президенты фәнни стипендиаты (2002).

Хезм.: Итоги клинической апробации димефосфона как вазоактивного средства, нормализующего функции нервной системы // Казан. мед. журн. 1995. № 3; Фармакотерапия хронической фетоплацентарной недостаточности // Казан. мед. журн. 2003. № 6 (автордаш); Математическая статистика в экспериментальной и клинической фармакологии. К., 2006 (автордаш).

ХАФИ́ЗОВ Азат Ралиф улы (7.8.1966, Казан, инженер-технолог, эколог, ТР Дәүләт бүләгеге лауреаты (1999). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый (1988). ТАССР Дәүләт телерадиосында хәбәрче (1985 тән), «Табигать һәм без» тапшырулар циклының алып баручысы һәм мөхәррире (1989), ТАССР Дәүләт табигать ком-тында дәүләт инспекторы (1989 дан), ТР экологлар ФҖБ Советы рәисе һәм Халыкара «Идел буе-Германия» ассоциациясе президенты (1991 дән), ТР Инвестиция-финанс корпорациясе ген. директоры (1995 тән), директорлар советы рәисе (1997 дән). Дәүләт бүләге туфракны чәчү алдыннан эшкәртү өчен модульле-блоклы культиваторлар булдыруда, технол. нигезләүдә һәм җитештерүне үзләштерүдә катнашканы өчен бирелә.

ХАФИ́ЗОВ Айдар Садри улы (Айдар Хафиз) (20.5.1943, Питрәч р-ны Күн а.), актёр, ТРның халык артисты (2001), РФнең атказ. артисты (2014). Казан театр уч-щесен тәмамлый (1970). 1971–74 елларда — Казанда Ленин исем. мәдәният сараенда режиссёр,



А.С.Хафизов Борһан ролендә («Кылый Кирам балдагы», Аманулла).

1974–75 тә — Казан курчак театрында баш администратор, 1975–76 да — Татар филармониясендә концертлар алып баручы һәм нәфис сүз остасы. 1976–78 дә Татар респ-ка күчмә театры актёры, 1978 дән Татар акад. театры труппасында. Образлар иҗат иткәндә, табигый тышкы күркәмлегеннән һәм тормышчан күзәтүләреннән оста файдалана. Нигездә, характерлы рольләр башкара, Татар акад. театры сәхнәсендә шактый гына зур образлар тудыра: Азамат («Китмәгез, тургайлар!», А.Гыйләҗев), Дерамо («Болан-Патша», К.Гоцци), Камаев («Булмас димә, дөнья бу!», А.В.Вампилов), Хәлиулла, Шәһит («Илгизәр+Вера», «Хушыгыз!», Т.Миңнуллин), Пеппино («Гаугалы гаилә», Э.де Филиппо), Кадыйрбирде («Идегәй», Ю.Сафиуллин), Адаш («Өч аршын җир», А.Гыйләҗев), Якуб Акчурин («Без китәбез, сез каласыз», Т.Миңнуллин), Фәтхерахман Ишмаев («Гөлҗамал», Н.Исәнбәт), Нургали («Шулай булды шул», Т.Миңнуллин), Тимуш («Зәңгәр шәл», К.Тинчурин), Гайни бай («Курчак туе», М.Гыйләҗев, Р.Хәмид; Г.Исхакый әсәрләре буенча), Борһан («Кылый Кирам балдагы», Аманулла), Зәйнулла («Арбалы хатыннар», З.Зәйнуллин), Җәләй мулла («Үлеп яратты», Р.Зәйдулла), Алтын Хан («Хан кызы Турандык», К.Гоцци), Әниште («Минем исемем Кызыл», О.Памук), Колый тархан («Хуҗа Насретдин», Н.Исәнбәт) һ.б.



А.С. Хафизов.

Әд.: И л я л о в а И. Г.Камал театры артистлары =Артисты театра им. Г.Камала. К., 2005.

И.И.Илялова.

ХАФИ́ЗОВ Габдрахман Габбас улы (21.9.1956, Апас р-ны Әҗем а.), тарихчы, публицист, тарих фән. д-ры (2007). Казан ун-тын тәмамлый (1993). 1996–2000 елларда Казан банк мәктәбе укытучысы, директор урынбасары. 2000 нән ТР ФА нең Тарих ин-тында. 2002 дән Казан ун-тында, археол. музее директоры (2005 кә кадәр), ватан тарихы каф. укытучысы. Бер үк вакытта, 2010 нан, Казан аграр ун-тының тарих һәм мәдәният каф. мөдире. Хезмәтләре Алтын Урда, Татарстан, татар авыллары тарихын, татар интеллигенциясенең мәдәни-агарту эшчәнлеген өйрәнүгә карый.

Хезм.: Распад Монгольской империи и образование Золотой Орды. К., 2000; Культуртрегерская деятельность татарской интеллигенции в XIX — первой четверти XX вв. К., 2003; Әҗем авылы: тарихи сәхифәләр. К., 2003.

ХАФИ́ЗОВ Дәфикъ Фатих улы (5.9.1944, Чистай р-ны Дүртөйле а.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2006), проф. (1998), ТАССРның атказ. икътисадчысы (1986), РФнең мактаулы югары проф. белем бирү хезмәткәре (2004). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1968), Әлмәт р-ныың «Правда» к-зында икътисадчы, ВЛКСМ өлкә ком-ты инструкторы булып эшли. 1969 елдан Казан аграр ун-тында: җитештерүне оештыру каф. мөдире (1985–89), идарә каф. профессоры (1990–96), эшмәкәрлек һәм маркетинг каф. мөдире (1996–2005). 2005 тән а.х. җитештерүен оештыру каф. профессоры, бер үк вакыт - та икътисад (1992–2003) һәм хисап-финанс (2003–05) ф-тлары деканы. Хезмәтләре аграр өлкәдә күпукладлы икътисад формалашу



А.С.Хафизов Гайни бай ролендә («Курчак туе», М.Гыйләҗев, Р.Хәмид; Г.Исхакый әсәрләре буенча; Вафа ролендә – Р.Бариев).



Ш.С. Хафизов.

мәсь әләләренә карый. «ТР агросәнәгать комплексының 1996–2000 елларга исәпләнгән тотрыклылык һәм үсеш программасы»н һәм «ТР аграр секторының реформаларын камилләштерү концепциясе һәм методологиясе»н (1997) эшләүдә катнаша. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Аренда и арендный подряд. К., 1990 (автордаш); Формирование и эффективное функционирование многоукладной экономики в аграрной сфере. М., 2003; Многоукладная экономика в аграной сфере. К., 2006; Предпринимательство в аграрной сфере. К., 2007 (автордаш).

ХАФИ́ЗОВ Ирек Кыяметдин улы (28.3.1940, Чүпрәле р-ны Түбән Чәке а.), текстиль чималы эшкәртү технологиясе өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1984), проф. (1989), Үзбәкстан ССРның атказ. инженеры (1981). Таҗик политехник ин-тын тәмамлый (1963). 1963–65 елларда Та җикстан ССР мамык з-дларында эшли. 1965 тән Мамык сәнәгате үзәк фәнни-тикшеренү ин-тында (Ташкент), 1971 дән лаб. мөдире. 1989 дан Ташкент а.х. ирригациясе һәм механизациясе ин-тында автоматика һәм телемеханика каф. профессоры. Хезмәтләре нечкә җепселле мамык чималын эшкәртү технологиясенә карый. Чималны әзерләү һәм чистартуның теоретик нигезләрен, мамык чистарту з-длары өчен җепселне беренчел эшкәртү технологияләрен эшли. Татар иҗтимагый-мәдәни үзәге идарәсе әгъзасы (Ташкент).

ХАФИ́ЗОВ Камил Габделхак улы (22.3.1959, Саба р-ны Байлар Сабасы а.), а.х.н механизацияләү өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2007), проф. (2009), ТР атказ. а.х. механизаторы (2002). 1981 елда Казан а.х. ин-тын (хәзер Казан аграр ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли, а.х.н механизацияләү (1997–2003), техник сервис (2004–07) ф-тлары деканы, бер үк вакытта тракторлар, автомобильләр һәм энергетик җайланмалар каф. мөдире (2007дән). Хезмәтләре а.х.нда җитештерү процессында техникадан файдалануны энергетик яктан бәяләү алымнарына карый. Х. а.х. культураларын игүдә технол. операцияләрне башкару өчен машина-трактор агрегатларының системалы матем. модельләрен эшли. Параметрларын исәпкә алып, илдә һәм чит илләрдә чыгарылган тракторларны куллануның энергетик нәтиҗәлелегенә анализ ясый. А.х. инженерлары өчен ярдәмлек булган «Агроэнергоменеджер» хисаплау-белешмә программа кушымтасын эшли. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Пути снижения технических энергетических затрат на производственных процессах в сельском хозяйстве. К., 2007; Энергетический анализ использования техники в сельском хозяйстве. К., 2007.

ХАФИ́ЗОВ Рәис Габбас улы (17.3.1966, Апас р-ны Әҗем а.), стоматолог-ортопед, мед. фән. д-ры (2002), проф. (2011). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1991), шунда ук, ортопедик стомат. кафедрасында эшли. 2012 елдан КФУның Фундаменталь мед. һәм биол. ин-тында стомат. һәм имплантология каф. мөдире. Хезмәтләре катнаш составлы, форма саклаучы механик актив имплантлар һәм сөяк тукымасының бер-берсенә тәэсирен өйрәнүгә карый. Тешләрнең ике фазалы имплантациясе өчен Т. тарафыннан Миргазизов системасы имплантлар комплекты һәм инструментлары тәкъдим ителә.

Х е з м.: Формирование ложа для дентальной имплантации // Казан. мед. журн. 2002. № 3; Направленная тканевая регенерация в стоматологии // Рос. вестн. дентальной имплантологии. 2008. № 114 (автордаш).

ХАФИ́ЗОВ Фәез Зәки улы (25.8.1938, БАССРның Туймазы р-ны Иске Туймазы а.), геолог, геол.-минерал. фән. д-ры (1987), проф. (1997), РФнең атказ. геологы (1999), РФнең мактаулы җир асты байлыклары разведчигы (1993). Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тын тәмамлаганнан соң (1965), «Главтюменьгеология» ҖБдә эшли, 1974–76 елларда Кубада командировкада. 1989 дан «Нефтеотдача» тармакара фәнни-техник комплекста (Мәскәү). 1994 тән Төмәндә: Көнбатыш-Себер төбәк геол. үзәге рәисе, 2002 дән Төбәк җир асты байлыкларын файдалану фәнни-аналитик үзәге фәнни консультанты. Хезмәтләре нефть геологиясенә карый. Х. углеводород чыганакларының төп урнашу зончалыкларын һәм үзенчәлекләрен ачыклый, аларның запасларын барлау алымнарын камилләштерә, гидрогеол. комплекслар төзелешендә неотектоник хәрәкәтләрнең ролен билгели, углеводород ятмаларының формалашу тарихын палеогидрогеол. анализлау алымын эшли. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1984). Кызыл Байрак ордены, медальләр, «Чыганакны беренче ачучы» билгесе б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Повышение эффективности разведки залежей крупных нефтегазоносных комплексов. Л., 1991; Нефтегазопромысловая геология: Учеб. пособие. Тюмень, 2001; Анализ запасов нефти. Тюмень, 2011.

ХАФИ́ЗОВ Шәриф Сәгыйрь улы (25.6.1920, Чистай кантоны Шәрбән а. — 25.3.1984, Нурлат ш.), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, Соц. Хезмәт Герое (1965). 1937–55 елларда Тельман р-ны «Коммунизм байрагы» г-тасы редакциясендә эшли. 1955–83 тә Октябрь р-нының «Дружба» к-зы рәисе. Х. җитәкчелегендә хуҗалыкта матди-техник һәм социаль-мәдәни инфраструктура булдырыла. Колхоз Татарстанда беренчеләрдән булып хезмәткә акчалата түләүгә күчә. 1966–70 тә елына уртача 6302 *т* бөртекле ашлык, 17601 *т* шикәр чөгендере җитештерелә; җитештерүнең уртача табышлылыгы 71% тәшкил итә. 1969 да колхозга «Югары культуралы игенчелек хуҗалыгы» дигән мактаулы исем бирелә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ике Ленин ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.

Әд.: Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

ХАФИ́ЗОВА Роза Сәет кызы (6.2.1929, Бөгелмә ш. — 20.8.2005, Казан), язучы, ТАССРның, РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1974, 1983). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1951), Тубыл шәһәрендә укыта. 1952–60 елларда «Яшь сталинчы», «Сталин байрагы» (Чистай ш.), «На стройке» (Казан) г-таларында, КПССның Татарстан өлкә ком-ты Партия тарихы ин-тында эшли. 1962 дә Югары партия мәктәбен (Мәскәү) тәмамлый. 1962–88 дә «Ялкын» ж-лының баш мөхәррире. «Таң билгесе» (1968), «Әкиятләр» (1979), «Кашкарыйлар озын гомерле» (1984), «Сак-Сок тавышы» (1987), «Киек каз юлы» (1988), «Актәпи ник моңая?» (1991), «Ачылмаган серләр» (2004) повестьлар, хикәяләр һәм әкиятләр җыентыклары авторы. Х. әсәрләре казакъ, үзбәк, украин һ.б. телләргә тәр җемә ителә.

Әд.: Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

ХАЦРИ́НОВ Алексей Ильич (14.12.1961, Ташкент), химик-технолог, техник фән. д-ры (1997), проф. (1998). 1984 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли, инженерлар химия-технол. ф-ты деканы (1992–97), проректор (1997–99), нәорганик матдәләр һәм материаллар технологиясе каф. мөдире (2000 нән), бер үк вакытта, 2003 тән, Химик продуктлар фәнни-тикшеренү ин-ты директоры урынбасары. Хезмәтләре дарылар һәм авыр эрүчән силикат материаллар технологиясенә карый. Х. спектрның күренә торган һәм якын инфракызыл өлкәсендәге гетероген ялкыны нурланышының моделен, керамик чималга бәяләмә бирүнең экспресс-методикасын эшли. Ату системалары өчен 15 марка сферик дарыларның рецептурасын һәм технологиясен эшләүгә, ш.у. аларны җитештерү процессына кертүгә катнаша. Уйлап табуга 11 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. РФ хөкүмәте бүләгенә (2007), ТР Дәүләт бүләгенә (2010) лаек була. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Пламя: Учеб. пособие. К., 1999 (автордаш); Малоотходные технологии переработки серы в неорганические сульфиды и полисульфиды. К., 2007 (автордаш); Химическая технология неорганических веществ: В 2 кн. М., 2008 (автордаш).

Әд.: Выпускники — гордость Казанского технологического университета: Краткий биогр. справ. К., 2009.

ХАЧАТРЯ́Н Агаси Аванесович (4.4.1940, Әзәрбай җан ССРның Мартуни р-ны Мачкалашен а.), философ, филос. фән. д-ры (1983), проф. (1990). Баку пед. ин-тын тәмамлый (1963). 1963–65 елларда Ереванда 4 нче һөнәр уч-щесендә укыта, 1965–96 да Ереван ун-тында, 1969–94 тә Ереван пед. ин-тында, филос. каф. мөдире (1979 дан). 1994–2007 дә Волгоград ун-тында, теоретик филос. каф. мөдире (1996 дан). 2008 дән Казан вет. медицинасы академиясендә, философия һәм тарих каф. мөдире (2009 дан). Хезмәтләре гомумтеоретик философиягә, әхлак философиясенә карый.

Х е з м.: Принцип индивидуализма в этических теориях. Ереван, 1978; Философия как стремление к мудрости в зеркале философской рефлексии. Волгоград, 2006; Социально-гуманитарные науки в системе сельскохозяйственного образования. К., 2012 (автордаш).

Әд.: А л е к с е е в П.В. Философы России XIX–XX столетий: Биографии. Идеи. Труды. М., 2002.

«ХӘБӘРЛӘР», иҗтимагый-сәяси газета. РСДРПның Уральск милләтләр ком-ты органы. «Яшәсен милли мохтарият, яшәсен халык республикасы!» лозунгы б-н 1917 елның 5 апреленнән 23 сентябренә кадәр Уральскида татар телендә нәшер ителә, барысы 15 саны чыга. Мөхәррирләре — А.Габдүшев, Х.Самакаев, Г.Әбүбәкеров, А.Ишмөхәммәтов. Актив авторлары арасында — М.Әлмөхмүтов, М.Гаделшина, Р.Рәмзани, Г.Хөсәенов һ.б. Бөтенроссия мөселманнары корылтае, Учредительләр җыены чакырылышлары идеяләренә теләктәшлек белдерергә, сайлауларда гомуми һәм тигез тавыш бирергә чакыра. «Х.»дә Җир турында декрет, Бөтенроссия мөселманнары корылтае, Бөтенроссия мөселманнарының вакытлы хәрби шурасы һ.б. документлары басыла. Урал мөселманнары корылтаеның эш барышы яктыртыла, Уральскида шәһәр идарәсе оешу турында сүз алып барыла. Хатын-кызлар мәсь әләсенә, татар уку-укыту оешмаларындагы вазгыятькә багышланган язмалар урнаштырыла.

«ХӘБӘРЛӘР», иҗтимагый-сәяси газета. 1917 елның сентябреннән 3 декабренә кадәр Минзәлә шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, барысы 7 саны басыла. Минзәлә өязе крәстиян депутатлары советының керәшен секциясе органы, 4 нче саннан — крәстиян депутатларының Минзәлә өяз советы каршындагы комиссия органы. Совет чорындагы беренче керәшен газетасы, кириллицада басыла. Мөхәррире — М.Чернов. Газета крәстияннәр мәнфәгатен якларга чакыра, социалист-революционерлар идеяләрен пропагандалый, Учредительләр җыенына солдат һәм эшчеләрне сайлауга каршы чыгыш ясаган кадетлар позициясен яктырткан керәшен г-тасы «*Дус*» б-н бәхәскә керә. «Х.» редакциясе берничә тапкыр мөрәҗәгать итеп караса да, керәшен интеллигенциясе һәм руханиларының күпчелеге аңа акчалата ярдәм күрсәтми, чөнки кадетлар яклы була. «Х.»дә Рига, Кавказ, Румыния һ.б. фронтлардагы хәрби хәрәкәтләр барышы яктыртыла. Сәяси язмалар б-н бергә фельетоннар (Двоеглазовның «Купей агайның эше турында» һ.б.), төрле, ш.и. көлкеле шигырьләр (С.Маевның «Кадетлар гимны» һ.б.) басыла.

З.З.Гыйләҗев.

ХӘБЕТДИ́НОВ Айдар Юрий улы (30.4.1972, Казан), тарихчы, тарих фән. д-ры (2002), проф. (2010). Казан ун-тын тәмамлый (1994). 1996 елдан РФ Эчке эшләр министрлыгының Казан юридик ин-тында эшли. 2003 тән Россия хокук академиясенең Казан ф-лы профессоры. Хезмәтләре татар милләтенең формалашуы, татар иҗтимагый-сәяси хәрәкәте мәсь әләләренә, 18 йөзнең 2 нче яртысы — 20 йөзнең 1 нче чиректә Идел-Урал төбәгендәге мөселман институтларын өйрәнүгә карый.

Х е з м.: Лидеры нации. К., 2003; От общины к нации: татары на пути от Средневековья к Новому времени (конец XVIII — начало XX вв.). К., 2008; История Оренбургского магометанского духовного собрания (1788–1917): институты, люди, идеи. М.–Н.Новгород, 2010.

ХӘБЕТДИ́НОВ Равил Низам улы (15.12.1928, Себер краеның Зимник а. — 5.8.1997, Башкортстан Респ-касының Октябрьский ш.), спортчы (авыр атлетика), СССРның спорт остасы (1952). 1948–60 елларда армия СК өчен чыгыш ясый (Новосибирск ш.). РСФСР (1955 — көмеш), 1959, СССР (1956 — бронза), 1957, Европа (1957) чемпионатларында, СССР халыклары спартакиадаларында (1956 — бронза), Олимпия уеннарында (1956 — көмеш) җиңүче һәм призёр, ике кул б-н салмак күтәрүдә 8 тапкыр дөнья (1956–58), Олимпия уеннары (1956) рекордчысы. 1961–65 тә «Спартак» ирекле спорт җәмгыятендә (Октябрьский) тренер. Медальләр б-н бүләкләнә.

ХӘБИ́Б (Хәбибуллин) Габдулла Ярулла улы (1894–1941), язучы, тәр җемәче. «Яңа авыл» (1926), «Авыл хикәяләре» (1929) хикәяләр җыентыклары, балалар өчен «Мырау батыр» (1928), «Әбием кәҗәсе» (1928) китаплары авторы. М.Горький хикәяләрен, Л.Н.Сәйфуллинаның «Правонарушители» («Закон бозучылар», 1930), А.Н.Толстойның «Хлеб» («Икмәк», М., 1939) повестьларын, А.Серафимовичның «Железный поток» («Тимер ташкын», 1932) В.Гюгоның «Девяносто третий год» («Туксан өченче ел», 1933), Э.Синклерның «Джимми Хиггинс» (1934), В.Бредельның «Испытание» («Сыналу», 1936), Н.А.Островскийның «Как закалялась сталь» («Корыч ничек чыныкты», 1937, автордаш), «Рождённые бурей» («Давылда туганнар», 1937, автордаш) романнарын һ.б.ны татар теленә тәр җемә итә. Репрессияләр чоры корбаны; үлгәннән соң аклана.

Р.Н.Даутов.

ХӘБИБЕЛХА́КОВА Рәхилә Әхмәт кызы (6.8.1937, Иркутск ш.), техник-механик, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1982). Казан химия-технол. техникумын тәмамлый (1964). 1958–94 елларда «Кварт» АҖдә эшли: хисапчы, чорнаучы, смена мастеры, 4 нче цехта чорнау машинасы машинисты. Дәүләт бүләге хезмәттә югары казанышларга ирешкәне өчен бирелә. Ленин ордены, Халыклар дуслыгы ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының бронза медале б-н бүләкләнә.

ХӘБИБЕННӘҖА́Р әл-Эстәрлетамакый (әл-Үтәки) (1861–29.6.1921, БАССР, Эстәрлетамак кантоны Үтәк а.), дин эшлеклесе. Ш.Мәрҗани шәкерте. Үтәк авылында имам һәм мөдәррис; бу уку йортының кайбер шәкертләре танылган Коръән укучылар, галимнәр (тарихчы Ә.Вәлиди һ.б.) булып җитешә. Хезмәтләре мөселман диненә карый.

Әд.: Ф ә х р е т д и н Р. Асар. К., 2010. Т. 3–4.

ХӘБИБРАХМА́Н әл-Мәсгуди (19 йөз), татар дин белгече. Гарәп телендәге «Җир һәм таулар тыныч торгандагы тикшеренүләрдә эталон үлчәмнәр» (1897) дини-фәлсәфи трактаты авторы.

Әд.: Ф ә х р е т д и н Р. Асар. К., 2010. Т. 3–4.

ХӘБИБРАХМА́НОВ Азат Гомәр улы (5.12.1975, ТАССРның Әлмәт р-ны Түбән Мактама пос.), нефтьче, фән һәм техника өлкәсендә ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2017). Әлмәт төзелеш техникумын (1994), Әлмәт нефть ин-тын (2001) тәмамлый. 1997–99 елларда Әлмәт геофизик эшләр идарәсендә, 1999–2009 да — «Әлмәтнефть» НГДУында, 2009–2015 тә — «Елховнефть» НГДУында баш инженер, 2015–2016 — «Баулы-нефть» НГДУы башлыгы, 2016 дан — «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыятенең (ГАҖ) «Елховнефть» НГДУы башлыгы. Дәүләт бүләге ТРның нефть чыганакларында нефть чыгару темпларын һәм нефть алу күләмен арттыру өчен технологияләр комплексы эшләүдә һәм сәнәгатькә кертүдә катнашканы өчен бирелә. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Сабанчинское нефтяное месторождение: история, анализ разработки, перспективы. К., 2016 (автордаш); Оценка эффективности уплотнения сетки скважин на низкопроницаемых карбонатных коллекторах (на примере месторождений Республики Татарстан). К., 2017 (автордаш).

ХӘБИБРАХМА́НОВ Равил Мирзаһит улы (3.1.1957, БАССРның Краснокама р-ны Шушнур а. — 18.12.2005, Мәскәү), скульптор, график. Свердловск сынлы сәнгать уч-щесендә укый (1971–74). Мәскәү югары сынлы сәнгать-сәнәгать уч-щесен тәмамлаганнан соң (1986), Мәскәүдә яши. Андагы «Музеон» берләшмәсе б-н актив хезмәттәшлек итә, Мәскәүдә Кырым яр буе парк сәнгате музеенда куелган «Төш» («Ат»), «Сальвадор Дали», «Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 60 еллыгына» скульптуралары авторы. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1992). Х. станлы, монументаль-декоратив скульптура остасы, постмодернизм традицияләрендә башкарылган оригиналь әсәрләр авторы буларак таныла. Мәхәббәт, ана, дөнья корылышы гармониясе кебек мәңгелек образларны кыю яңа формаларда символик рәвештә гәүдәләндерә.



Р.М.Хәбибрахманов. «Икәү». Керәч. 1996.



Р.М.Хәбибрахманов. «Медаль сәнгате». Алюминий. 2000.

Шамот белән оста эш итә, бронза, таш, тимер, агач, гипс, балчык кулланып эшли. Төп әсәрләре — «Күрешү» (1989), «Литва. 1990 елның 13 гыйнвары», «Карт һәм диңгез» (икесе дә — 1990), «Европаны урлау», «Төнге сөйләшү» (икесе дә — 1991), «Яңгыр», «Дулкын» (икесе дә — 1992), «Эскәмия», «Матур кыз» (икесе дә — 1994), «Реквием» (1995), «Икәү» (1996), «Шашкын мәхәббәт» (2000), «Утырып тору» (2002), «Георгий Победоносец», «Хач алып баручы» (икесе дә — 2003), «Җиткән кыз» (2004), «Иртә», «Формалар үрелеше» (икесе дә — 2005), 6 композицияле «Бөек дала скульптуралары» (2005) сериясе. График рәсемнәр авторы.

Мәскәү скульпторлары берләшмәсенең даими күргәзмәләрендә (1980 еллар уртасыннан), Бөтентатар «Татарт» (С.-Петербург, Казан, 1991) күргәзмәләрендә, халыкара һәм бөтенроссия скульптура симпозиумнарында (Мәскәү, «Театр: пәрдәнең ике ягы», 2004; «Таш скульптура», 2005; Казан, «Таш скульптура», 1996; Рига, Нефтекамск, 1998) һ.б.да катнаша. Шәхси күргәзмәсе 2006 да Мәскәүдә (вафатыннан соң) уздырыла. Әсәрләре «Казан» милли мәдәният үзәгендә, М.В.Нестеров исем. Башкортстан Дәүләт сәнгать музеенда, Төркиядәге шәхси тупланмаларда саклана. Х.ның туган авылы Шушнурда скульпторлар Р. һәм Х.Хәбибрахмановларның музей-йорты эшли.

Әд.: Пространство и форма: Каталог выставки современной российской скульптуры. Уфа, 2006.

ХӘБИБРАХМА́НОВ Хәниф Мирза һит улы (12.11.1948, БАССРның Краснокама р-ны Шушнур а.), скульптор, монументалист, Башкортстан Респ-касының атказ. рәссамы (2006). Мәскәү югары сынлы сәнгать-сәнәгать уч-щесен тәмамлаганнан соң (1978), Уфада яши. Башкорт пед. ин-тының сәнгать-графика ф-тында укыта (1978–84), Башкортстан иҗат-җитештерү комб-тында скульптор (1984–2004). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1982). Әйдәп баручы монументалистларның берсе. Х. пластик сәнгать төрләрендә һәм жанрларында әһәмияткә ия әсәрләр иҗат итә. Алар арасында — Башкортстанның Малаяз авылында С.Юлаев музее б-н бер комплекста 6 фигурадан торган аллегорик төркем: «Көрәш», «Чакыру», «Ирек», «Хушлашу», «Җыр», «Истәлек» (бронза, 1988–91); татар *«Нур»* театры порталы өстендәге «Комедия», «Театр музасы» композицияләре; «Аркаим» (мәрмәр, 1999), «С.Юлаевка, шагыйрь һәм сугышчыга» (гранит, чүкелгән бакыр, 2000), «Һәлак булган янгын сүндерүчеләргә» (гранит, бронза, 2003),



Х.М.Хәбибрахманов. М.Г.Гәрәев. Гранит. 1999. Уфа.



Х.М.Хәбибрахманов. Габдулла Тукай һәйкәле моделе. Бронза. 2012.

«З.Г.Исмәгыйлевка» (бронза, 2008) һәйкәлләре; Ф.*Кәримгә* (чүкелгән бакыр, 1987), ике тапкыр Сов. Союзы Герое М.Г.*Гәрәев* (гранит, 1999) һ.б. бюстлар (барысы да — Уфада); Башкортстанның Дүртөйле р-ны Ми җәшт авылында шагыйрь Н.*Нәҗми* мемориаль комплексы (2008) һ.б. Бронза, гранит, габбро, алюминий, чүкелгән бакыр, агач, гипстан станлы тематик скульптур композицияләр («Комсомол яшьлеге» триптихы, 1978; «Курайчы», 1981; «Төзүче», 1982; «Рудольф Нуриев. Мәңгелеккә очыш», 2000; «Сөембикә», 2004; «Театраль ритмнар», 2008; «Далалар җыры», 2009; «Икәү», 2010), портретлар («М.Габе», 1983; «Скульптор В.Корнаков», 1987; «Аксакал», 1997; «Х.Ф.Мостаев», 2000; «Мостай Кәрим», 2011). «Бөтенсоюз удар төзелешләре» (1979), «Балачак» (1982), «Усть-Илим» (1980) һ.б. бронза, җиз, бакыр медальләр сериясе авторы.

Респ-ка күргәзмәләрендә (1978 дән); бөтентатар — «Татарт» (С.-Петербург, Казан, 1991), «Зур Идел-9» (2004, дипломант) күргәзмәләрендә, бөтенсоюз — «Совет Россия-се-6» (1980), «Туган ил буйлап» (1981), «Рәсам һәм вакыт» (1987), «Бердәм гаиләдә» (1982), «Скульптура күргәзмәсе» (1983) (барысы да Мәскәүдә) күргәзмәләрендә, «Таш скульптура» (Уфа, 1988; Нефтекамск, 1998; Истанбул, Төркия, 2009) халыкара симпозиумнарында катнаша. Шәхси күргәзмәсе 2009 да Уфада уздырыла. Әсәрләре М.В.Нестеров исем. Башкортстан Дәүләт сәнгать музеенда, шәхси тупланмаларда саклана. Башкортстан Респ-касының С.Юлаев исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1992). 2009 да туган авылында аңа һәм туганы — скульптор Р.Хәбибрахмановка багышланган музей-йорт ачыла.

Әд.: Шарипова Л. Гранитная лирика, бронзовой эрос // Рампа. 1998. № 10/11; Фенина Э.П. Художники Башкортостана. XX век. Уфа, 2002; Хантимиров Р. Созидательные маяки истории // Истоки. 2010. 27 янв.

Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.

ХӘБИБРАХМА́НОВ Хәсән Хәбибрахман улы (5.8.1927, Мамадыш кантоны Катмыш а.), галим агроном, а.х. фән. д-ры (1983), проф. (1984), ТАССРның атказ. агрономы (1977), РФнең атказ. фән эшлеклесе (1995). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1950), Кызыл Йолдыз р-нында агроном булып эшли. 1959–62 елларда Бөтенсоюз ашламалар һәм туфрак белеме ин-тында (Мәскәү). 1962–2008 дә Казан аграр ун-тының гомуми игенчелек кафедрасында, каф. мөдире (1963–69, 1978–97), декан (1972–87), каф. профессоры (1997 дән). Хезмәтләре ТРда чүп үләннәренә каршы көрәш оештыру мәсьәләләренә карый. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Сорная растительность и борьба с ней в условиях Татарии. К., 1970; Современные меры борьбы с сорными растениями. К., 1979; Элементы биологизации земледелия дали высокий эффект // Земледелие. 2005. № 2 (автордаш).

Әд.: Казанский государственный аграрный университет: история и современность. К., 2007.

ХӘБИБРАХМА́НОВА Роза Хәбибрахман кызы (21.12.1941, Дөбъяз р-ны Ювас а. — 21.1.2011, Казан), актриса, ТРның халык артисты (2002). Хезмәт эшчәнлеген 1963 елда Татар респ-ка күчмә театрында башлый. Махсус театр белеме булмаса да, күзәтүчәнлек сәләтенә ия, теге яки бу сәхнә персонажының үз-үзен тотыш үзенчәлекләрен оста гәү-



Р.Х.Хәбибрахманова Мөслимә ролендә («Саташу», Т.Миңнуллин; сулда – Гүзәл ролендә И.Сафиуллина).



Р.Х.Хәбибрахманова Гөлнур ролендә («Сүнгән йолдызлар», К.Тинчурин; уңда – Фәрхи ролендә Н.Вәлиева).

дәләндерә, кул хәрәкәтләре, мимика, костюм деталеннән төгәл һәм сәнгатьчә файдалана белә. Шуңа күрә аның сәхнәдәге һәр чыгышы тамашачыда кызыксыну уята. 1982 елдан аңа эпизодик рольләрдән тыш төп рольләр дә бирә башлыйлар. Татар авторларының дра ма һәм комедияләре буенча куелган спектакльләрдә Х., тышкы сурәтләү чараларын аз гына кулланып та, гади авыл һәм шәһәр хатын-кызларының бай рухи дөньяларын оста ачып бирә. Үзе уйнаган героиняларының хаклы булуларына инанып, сәхнәдә аларны тулаем образга кереп гәүдәләндерә. Х. тудырган Гөлнур, Фәйзә («Сүнгән йолдызлар», «Хәйләсез — дөнья файдасыз», К.Тинчурин), Сәмәрия («Бер тамчы ярату», Н.Гыйматдинова романы буенча), Суфия («Гайфи бабай, өйләп давай!» Г.Зәйнашева), Фәхрия («Башмагым», Т.Гыйззәт), Фәридә, Мөслимә («Нигез ташлары», «Саташу», Т.Миңнуллин), Саймә («Әни килде», Ш.Хөсәенов) һ.б. образлар аның талантлы актриса булуын дәлилли.

Әд.: Илялова И. Театр имени Тинчурина. К., 2002. *И.И.Илялова.*

ХӘБИБУ́ЛЛИН Булат Нурмый улы (24.5.1958, Ютазы р-ны Бәйрәкә а.), матем., физика-матем. фән. д-ры (1995), проф. (1996). Башкорт ун-тын тәмамлаганнан соң (1980), СССР ФА Башкорт ф-лының Физика һәм матем. бүлегендә эшли. 1983 елдан Башкорт ун-тында, югары алгебра һәм геом. каф. мөдире (1994 тән). Хезмәтләре функциональ анализга багышлана. Х. вектор рәшәткәләрдәге функционалларның икеле күренешенең гомуми схемасын эшли, Рубел-Тейлорның күпләгән алмашлы меро морф функциясе иң ким булган ихтимал үсешнең тулы функциясенең хосусый рәвеше булуы мәсь әләсен чишә, Пәлинең күпләгән алмашлыларның мероморф һәм плюрисубгармоник функцияләре мәсьәләсен хәл итә; экспоненталар системаларының голоморф функцияләре фәзаларындагы тулылыгы шартларын билгели, бер алмашлының голоморф һәм дифференцияләнүче функцияләре алгебрасындагы йомык идеалның типологик җәһәттән икедән дә артык булмаган функция тарафыннан тудырылуы шартларын ачыклый.

Х е з м.: Двойственное представление суперлинейных функционалов и его применение в теории функций // Изв. РАН. Сер. мат. 2001. Т. 65, № 4–5; Подпоследовательности нулей для классов голоморфных функций, их устойчивость и энтропия линейной связности // Алгебра и анализ. 2008. Т. 20, № 1 (автордаш); Полнота систем экспонент и множества единственности. Уфа, 2008.

ХӘБИБУ́ЛЛИН Габдрахман Сөләйман улы (25.12.1903, Томск ш. — 16.9.1969, Уфа ш.), җырчы (бас), БАССР һәм РСФСРның халык артисты (1947, 1955). 1938 елда Мәскәү консерваториясе каршындагы Башкорт опера студиясен (Е.Милькович классы) тәмамлый. 1938–68 дә Башкорт опера һәм балет театры солисты. Опера партияләре: Дон Базилио («Севилья чәчтарашы», Дж.Россини), Кончак («Кенәз Игорь», А.Бородин), Юлай Азналин («Салават Юлаев», З.Исмәгыйлев),



Г.С.Хәбибуллин судья ролендә («Гүзәл тегермәнче хатыны», Дж.Паизиелло).

Аблай («Качкын», Н.Җиһанов) һ.б. Х.ның концерт репертуарын башкорт һәм татар халык җырлары тәшкил итә.

ХӘБИБУ́ЛЛИН Җәүдәт Ибраһим улы (14.3.1927, Чистай кантоны Каргалы а. — 28.6.2005, Казан), спортчы, тренер (ат спорты), ТАССР, РФнең атказ. зоотехнигы (1977, 2001). 1951 елда Хреновое атта йөрүчеләр мәктәбен (Воронеж өлкәсенең Бобровский р-ны Хреновое а.), 1964 тә Минзәлә а.х. техникумын тәмамлый. 1943–49 да Чистай шәһәренең дәүләт конюшнясында ат караучы булып эшли. Спорт б-н 1949 да Казан ипподромында шөгыльләнә башлый. 1949–68 дә берничә тапкыр юртаклар сынавы буенча һәм рус тройкасы ярышларында Татарстан һәм Идел буе кубокларын ота, 30 рекорд куя (ш.и. 2 бөтенсоюз рекорды). 1952–68 дә Казан ипподромында тренер-атта йөргергә өйрәтүче. Х. 20 дән артык атта йөрүче оста, ш.и. Россия чемпионатларында, бөтенроссия һәм төбәк чабышларында күп тапкыр җиңүчеләр — С.Н.Бакурин, А.И.Булыгин, Е.В.Гришаеваны әзерли. 1968–2000 дә Казан ат з-дында җитештерү бүлеге башлыгы, баш зоотехник. Х. — Казанда ТРның ат үрчетү һәм ат спорты тарихы музеен ачуны (2000) башлап җибәрүче һәм аның беренче директоры. Медальләр б-н бүләкләнә.

Р.Х.Хәбибрахманова.



ХӘБИБУ́ЛЛИН Заур Александрович (Мөхәммәтшәриф улы) (22.11.1937, Красноярск ш. — 8.7.1988, Кыргызстан ССР, Фрунзе ш.), скульптор, монументалист, Кыргызстан ССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1982). В.Серов исем. Ленинград нәкышь сәнгать уч-щесен (1959), И.Е.Репин исем. Ленинград сәнгать, скульптура һәм архит-ра ин-тын (1966) тәмамлый. 1966 елдан Кыргызстанда. С.А.Чуйков исем. сынлы сәнгать уч-щесендә укыта. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1970). Х. Кыргызстанда милли скульптура мәктәбенә нигез салучыларның берсе. Монументаль һәм жанрлы скульптурада, станлы портрет, вак фигуралар өлкәсендә эшли. Төп әсәрләре: монументаль скульптура — Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар истәлегенә һәйкәлләр (1967, Кара-Балта ш.; 1970, Җомгал р-нының Кызыл Тау а.; 1972, Тоң р-нының Ак Тирәк а.) һәм мемориаль комплекс (1975, Тоң р-ны К.Маркс исем. колхоз а., автордашлар С.Бакашев, А.Воронин, А.Каменский; СССР ВДНХсының бронза медале); портрет-бюст (1974, Геройлар аллеясы, Фрунзе ш.) һәм Сов. Союзы Герое Ч.Түлебердиев хөрмәтенә мемориаль комплекс (1978, Киров р-ны Чымгент а.); «Дуслык» монументы (1974, автордашлар — рәссам Т.Садыйков, С.Бакашев, арх. А.Нежурин, Фрунзе ш.), «Өзелгән жыр» скульптур композициясе (1980 еллар); монументаль-декоратив скульптура — фасад рельефлары, М.Фрунзе портреты (1970, Бишкәк шәһәрендәге М.В.Фрунзе мемориаль музее, Бишкәктәге Кыргыз драма театры бинасы фойе-





З.А.Хәбибуллин. 1. «Ишәккә атланган карт». Шамот. 1974. Кыргыз сынлы сәнгать музее; 2. Чолпанбай Түлебердиев һәйкәле. Гипс. Эш моделе. 1974.



З.В. Хәбибуллин.



З.Х.Хәбибуллин.

сындагы металл рельефлар һәм бина фасадындагы бизәкле рәшәткәләр (1980, автордашлар С.Бакашев, А.Воронин, А.Каменский), Мәскәүдәге «Киргизия» кинотеатры фасадында керамик рельефлар һәм фойесындагы композицияләр (1973, автордашлар С.Бакашев, А.Воронин, А.Каменский) һ.б. Х. әсәрләре башкару алымнарының оригинальлеге һәм сәнгатьчә эшләнеше, фигураларның иркенлеге һәм җиңеллеге, формаларның гадилеге б-н аерылып тора. Станлы скульптурада һәм кечкенә фигураларда «Хатын-кыз портреты» (1966), «Карт» (1968), «Биек йортлар төзүче (Кайтаваз)» (1969), «Акробатлар» (1971), «Кунакчыллык» (1973), «Гуля» (1978), «Скульптор Г.Бурлин» (1980), «Алга баручы (К.Жусубалиев)» (1984), «Г.Айтиев», «Ялвару» (икесе дә — 1987), «4 фигуралы композиция», «Яз» (икесе дә — 1988) кебек хисләргә бай якты образлар барлыкка китерә. Әсәрләрен бронза, мәрмәр, бетон, бакыр һәм тимер (чоку, эретеп ябыштыру), шамот, туф һәм агачтан иҗат итә.

Респ-ка күргәзмәләрендә (1966 тан), бөтенсоюз — «ВЛКСМның 50 еллыгына» (1969), «Кече формалардагы скульптуралар» (1972), «Хезмәткә дан» (1975), 1 нче монументаль сәнгать күргәзмәсе (1975), «Скульптура күргәзмәсе» (1983), «Советлар иле» (1984) күргәзмәләрендә (Мәскәү), бөтенсоюз скульптура симпозиумында (Фрунзе ш., 1984), халыкара -«Кыргызстан рәссамнары» (Мәскәү, 1982), 20 нче Олимпия уеннарына (Лейпциг ш., 1972) багышланган күргәзмәләрдә катнаша.

Шәхси күргәзмәләре вафатыннан соң, 1989, 2007 дә Бишкәк шәһәрендә уздырыла. Әсәрләре Г.Айтиев исем. Кыргыз сынлы сәнгать музеенда саклана. СССР САнең М.Б.Греков исем. көмеш медале, Г.Айтиев исем. Диплом б-н бүләкләнә.

Әд.: Прыткова Л.А. Национальные традиции в творчестве Заура Хабибуллина // Советская скульптура-74. М., 1976; Воронина А.А. Заур Хабибуллин. Скульптура: Каталог выставки. Фрунзе, 1989; Гузева Л.П. Заур Хабибуллин: Буклет. Бишкек, 2007.

Г.Ф.Вәлиева-Сөләймановa.

ХӘБИБУ́ЛЛИН Заһид Вәли (Вәлиулла) улы (20.9.1910, Орск ш. — 20.11.1983, Казан), композитор, скрипкачы, ТАССР һәм РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1950, 1981), ТАССРның халык артисты (1970). 1936–40 елларда Мәскәү консерваториясе каршындагы Татар опера студиясендә (Г.Литинский классы) укый. Х. музыкасына аһәңлелек, образлылык, халык җырларына якынлык хас. Ул үзенең иҗаты б-н скрипка өчен язылган татар музыкасы үсешенә зур өлеш кертә (аеруча танылганы — «Скрипка һәм фортепиано өчен поэма», 1940). Х.ның «Сагыну» (М.Җәлил сүзләре), «Бормалы су» (Н.Исәнбәт сүзләре), «Яшьләр вальсы» (М.Хөсәен сүзләре), «Казан кызы» (Н.Арсланов сүзләре) һ.б. җыр һәм романслары (200 дән артык) зур популярлык казана. Х. татар композиторлары арасында Г.Тукай шигырьләренә язылган җырлар цикларының беренче авторы була. ТАССРның Дәүләт җыр һәм бию ансамбле репертуарын формалаштыруга зур өлеш кертә: «Сабантуй», «Халыклар дуслыгы», «Туй» һ.б. муз.-хореографик композицияләр иҗат итә. Х. әсәрләре арасында «Язгы җилләр» балеты (1950, Ф.Гаскәров либреттосына, Н.Пейко б-н берлектә; куелмый), балалар өчен «Раушан» балеты (1961; 2 нче редакция, «Сихерләнгән малай», 1974, Г.Сәлимов либреттосына); инструменталь пьесалар; драматик спектакльләргә музыка, татар халык җырлары эшкәртмәләре һ.б. бар. Концертларда чыгыш ясый; нигездә, татар халык көйләренә һәм композиторлар язган көйләргә иҗат ителгән әсәрләрдән торган репертуар б-н скрипкачы (солист һәм ансамблист) буларак радиога яздырыла. ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1968).

Әд.: Народные артисты. К., 1980; Нигмедзянов М.Н. Хабибуллин Загид // Композиторы и музыковеды Советского Татарстана. К., 1986; Композиторы Татарстана. К., 2009.

ХӘБИБУ́ЛЛИН Зәйтүләк Әмир улы (9.7.1939, БАССРның Бәләбәй р-ны Акбасар а. — 7.12.1999, Уфа), нефтьче, техник фән. д-ры (1988), проф. (1990). 1967 елда Уфа нефть ин-тын (хәзер Уфа нефть техника ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли, газ һәм конденсат чыганакларын эксплуатацияләү һәм эшкәртү каф. мөдире (1989 дан). Хезмәтләре нефть һәм газ табу процессларын камилләштерү өчен чыганакларны эшкәртү һәм нефть үзлекләрен регуляцияләүгә карый. Х. ятмаларны эксплуатацияләгәндә углеводородларның аномаль үзле үзлекләренә тәэсир итүче югары нәтиҗәле технологияләр һәм химик реагентлар тәкъдим итә. Уйлап табуга 10 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. РФнең мактаулы нефтьчесе.

Хезм.: Аномальные нефти. М., 1975 (автордаш); Подземная гидрогазодинамика. Уфа, 1987 (автордаш); Оптимизация режима работы малодебитных скважин на залежах аномальных нефтей. Уфа, 1989 (автордаш).

ХӘБИБУ́ЛЛИН Зәки Хәбибулла улы (28.7.1911, Казан губ., Мамадыш өязе Курсабаш а. — 1.5.1945, Старгард-Щециньски ш., Польша), Сов. Союзы Герое (27.2.1945), подполковник. Хәрби-сәяси уч-ще (1935), сәяси состав курсларын (1940), М.В.Фрунзе исем. Хәрби академия каршындагы курсларны тәмамлый (Мәскәү, 1944). 1931 елдан Кызыл Армиядә. Совет-фин сугышында катнаша. 1941 нең октябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 1069 нчы укчы полк командиры (61 нче армиянең 311 нче укчы дивизиясе). Брянск, Көнбатыш, 2 нче һәм 1 нче Белоруссия, 3 нче һәм 1 нче Балтыйк буе фронтлары гаскәрләре составында Мәскәү янында гы сугышта (1941–42), Орёл, Гомель-Речица (икесе дә — 1943), Белоруссия (1944) һәм Варшава-Познань (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1945 нең гыйнварында Польша терр-ясендә барган сугышларда батырлык күрсәтә: 14 гыйнварда Конары торак пункты янында (Варка шәһәреннән 11 *км* төньяктарак) Х. җитәкчелегендәге полк дошман оборонасын өзә һәм, аны эзәрлекләп, 26 гыйнварда Германия чигенә килеп җитә; 28 гыйнварда полк Шнейдемюль шәһәре (Пила ш.) өчен барган сугышларда катнаша. Старгард-Щециньски шәһәре өчен барган сугышта һәлак була. Ленин ордены, Кызыл Байрак ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Невель шәһәренең (Псков өлкәсе) бер урамына Х. исеме бирелә, анда Геройга мемориаль такта, ватанында бюст куела.

Әд.: Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

М.З.Хәбибуллин.

ХӘБИБУ́ЛЛИН Иршат Гыйният улы (19.4.1944, Чүпрәле р-ны Иске Кәкерле а.), химик, химия фән. д-ры (1989), проф. (1993), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2006). 1968 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли (1969 дан). 1994 тән Казан аграр ун-тында: гомуми химия каф. мөдире (2008 гә кадәр), аграр ф-т деканы (1994–97), проректор (1997–2005). 2008 дән Казан энергетика ин-тында. Хезмәтләре нәорганик композицион материалларга, электр химиясенә карый. Х. югары температуралы коррозиягә чыдам каплагычлар (титан эретмәләреннән ясалган компрессорларның калакчыкларын эрозиядән, ниобий эретмәсеннән ясалган турбина калакчыкларын һәм бакыр эретмәсеннән эшләнгән соплоларны оксидлашудан саклау өчен), нәорганик полимерлар нигезендә композицион материалларны ясауның энергия саклаучы технологияләре, алмазлы кискечләр эшли. Фәнни эшчәнлек нәтиҗәләре авиация сәнәгате пр-тиеләрендә гамәлгә кертелә, машиналар төзүдә кулланыла. Уйлап табуга 15 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Оборудование производств неорганических веществ. Л., 1987 (автордаш); Коррозионная стойкость металлов с дисперсно-упроченными покрытиями. М., 1991 (автордаш); Химические основы экологии К., 2009 (автордаш).

Әд.: Выпускники — гордость Казанского технологического университета: Краткий биогр. справ. К., 2009.

ХӘБИБУ́ЛЛИН Марс Зәбир улы (10.7.1977, Казан), тарихчы, тарих фән. канд. (2003). Казан пед. ун-тын тәмамлый (1999). 1999 елдан ТР ФАнең Татар энциклопедиясе ин-тында, 2011 дән гыйльми секретарь. Бер үк вакытта халык депутатларының Казан советы тарих һәм социологик тикшеренүләр бүлегенең әйдәп баручы белгече (2001–03), ТР ФАнең гуманитар фәннәр бүлеге гыйльми секретаре (2005 тән). Хезмәтләре Казан руханилар академиясе укытучыларының (М.А.Машанов, Н.П.Остроумов, П.К.Жузе, В.Т.Тимофеев һ.б.) фәнни-пед. эшчәнлегенә, Урта Идел буенда яшәүче та-

тарлар һәм башка халыкларның тарихына һәм мәдәниятенә, Казан шәркыятьчелек белеменә карый.

Х е з м.: Михаил Александрович Машанов — профессор Казанской духовной академии, миссионер и исламовед. К., 2006; Казанское востоковедение XIX — первой половины XX вв.: П.К.Жузе. К., 2012 (автордаш); Народы Среднего Поволжья и Приуралья в ракурсе этнополитических и историко-конфессиональных исследований преподавателей Казанской духовной академии (1842–1921 гг.). К., 2013.

ХӘБИБУ́ЛЛИН Мидхәт Гобәйдулла улы (5.3.1936, Үзбәкстан ССРның Термез ш.), двигательләр төзү өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2000), ТР атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1996), РСФСРның атказ. уйлап табучысы (1986). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1959). 1959–66 елларда Казан моторлар төзү з-дының тәҗрибә КБда инженер-конструктор булып эшли, 1966–86 да Казан машиналар төзү проектлау бюросында, баш конструктор урынбасары (1976 дан). 1986–2004 тә Казан моторлар төзү ҖБдә: баш инженер (1993 кә кадәр), техник директор. 2004 тән «Казанкомпрессормаш» АҖнең ген. директоры урынбасары. «Реверсив җайланма (РҖ) — газ турбиналы двигатель (ГТД) — самолет» системасын анализлауның фәнни тикшерү һәм эшләү нигезләре буенча хезмәтләр авторы. Х. РҖнең Ту-154 һәм Ил-86 самолётларында РҖнең конструкциясе һәм идарәсе элементларын эшли, ГТДның компрессоры һәм турбинасының хәрәкәтләндерүче калакларын җитештерү технологиясен камилләштерә; аның тарафыннан ГТДны җир өсте кулланылышы, ш.и. «Волга» ГПА-16 газ кудыручы агрегат ясау өчен конверсияләү эшләре башкарыла. Уйлап табуга 116 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының ике алтын һәм бер бронза медале б-н бүләкләнә. Газ сәнәгатенең мактаулы хезмәткәре (2001).

Х е з м.: Некоторые результаты совместной деятельности потребителей и производителей в области создания новых и реконструкции действующих ГПА для предприятий РАО «Газпром» // Тр. 5 межд. симп. «Потребители — производители компрессоров и компрессорного оборудования». СПб., 1999 (автордаш); Проблемы комплексной доводки газотурбинного двигателя с реверсом тяги на стадии серийного освоения и производства. К., 2000.

ХӘБИБУ́ЛЛИН Мөсәгыйть Мөдәррис улы (25.12.1927, Оренбург өлкәсенең Абдуллин р-ны Габдрахман а. – 4.1.2019, Казан), язучы, ТАССР һәм РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1978, 1988), ТРның халык язучысы (2008). Казан ун-тын тәмамлый (1971). 1944–46 елларда Магнитогорск, Октябрьск (БАССР), Баулы (ТАССР) шәһәрләрендә яши, токарь, шофёр, автомеханик булып эшли. 1967–69 да «Маяк» Азнакай район г-та сында сәнәгать бүлеге мөдире. 1969–71 дә Ленинабад (Таҗикстан) шәһәрендә урта мәктәптә тарих укыта. 1971 дән Казанда, ТР Язучылар берлеге идарәсенең җаваплы сәркәтибе (1989 га кадәр). 1995–99 да «Мирас» ж-лының проза бүлеге мөдире. 1950 еллардан вакытлы матбугатта басыла. 1969 да «Казан утлары» ж-лында «Унсигезенче яз» (русчага тәрҗемәдә «Восемнадцатая весна», 1975) исемле беренче күләмле әсәре басылып чыга. Х. — шәхеснең әхлакый үсешенә, замандашларының тормышы һәм хезмәтенә багышланган «Җиде юл чатында» (1969), «Икмәк кадере» (1969), «Тау белән тау очрашмаса да» (1974), «Сәгъди» (русчага тәрҗемәдә «Сагди», М., 1975), «Хәтер ярлары» (1981) повестьлары һәм хикәяләре; «Сулар үргә акса да» (1984) романы авторы. «Чоңгыллар» (1976; русчага тәрҗемәдә «Водовороты», М., 1978) романы укучылар тарафыннан яратып кабул ителә. 1980 еллар башында Х. иҗатында хәзерге заманнан тарихи тематикага күчә. Моңа Л.Н.Гумилёв б-н булган очрашу нык тәэсир итә. Елъязмалар, архив материаллары, кытай, фарсы, әрмән, гарәп авторлары әсәрләре, рус һәм татар галимнәре хезмәтләре нигезендә борынгы болгарлар турында матур әдәбият әсәрләре иҗат итә. Бөек Болгар дәүләтенә нигез салучы һәм аның идарәчесенә «Кубрат хан» романы багышлана (1985; русчага тәрҗемәсе, М., 1990; Г.Тукай исем. ТР Дәүләт бүләге, 2003). Теманы 12 йөз ахыры — 13 йөз башы Идел буе болгарлары турында «Илчегә үлем юк» (1990), монгол яулары турында «Шайтан каласы» (1993; русчага тәрҗемәдә «Чёртово городище», 2005) тарихи романнары дәвам итә. «Хан онығы Хансөяр» (1997), «Аллаһы бүләге» (1999; русчага тәрҗемәдә «Божий дар», 2007), «Батый хан һәм Ләйлә» (2002), «Айбиби» (2004), «Казан һәм хан кызы кыйссасы» («Сказание о Казани и дочери хана», 2005) романнарында Казанның барлыкка килүе, төрки мәдәниятнең үсеш юллары турында бәян ителә, тарихи шәхесләр — Батый хан һәм шагыйрь Кол Гали образлары ачык сурәтләнә. «Сөембикә ханбикә һәм Иван Грозный» (1992) романында Казан ханлыгының соңгы айлары тасвирлана. Һуннарның атаклы гаскәр башлыгына «Атилла» романы (1–2 кис., 2001) багышлана. Әдипнең тарихи романнары үткен, мавыктыргыч сюжеты, фәнни дөреслеге, тел һәм образларның үзенчәлеге б-н аерылалар. 1980 елларда Казанда булып узган вакыйгаларга нигезләнеп, «Серыйны кем үтергән?» (русчага тәрҗемәдә «Кто убил Серого?», 2007) детектив романын яза. Татар халкы тарихына, хәзерге җәмгыятьтәге әхлакый нигезләргә багышланган публицистик мәкаләләр авторы. Х. әсәрләренең күбесе рус, башкорт, болгар телләренә тәрҗемә ителә. РФ Язучылар берлегенең әдәби бүләге лауреаты (1984).

Әд.: Гамбәр Н. Бәхеткә юл — гел алда // Казан утлары. 1977. № 12; Урманче Ф. Тарихи хәтеребезне терелтүче // Мирас. 1997. № 12; Мостафин Р. Каләмдәшем-якташым // Мәгариф. 1998. № 2; Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2. *Р.Х.Сверигин.*

ХӘБИБУ́ЛЛИН Озад Гариф улы (26.7.1949, Үзбәкстан ССРның Гиждуван ш.,), монументалист, нәкышьче, Үзбәкстанның халык рәссамы (2004), ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2017). Дүшәнбе сынлы сәнгать уч-щесен (1968), А.Н.Островский исем. Ташкент театр-сәнгать ин-тын (Ч.*Әхмәров* остаханәсе, 1973) тәмамлый. Рәссамнар берлеге әгъзасы



М.М. Хәбибуллин.



О.Г. Хәбибуллин.

(1975). 2005 елдан Казанда. Монументаль-декоратив сәнгатьнең танылган вәкиле буларак Х. аның мозаика (смальта, керамика), бизәк төшерү (фреска, темпера, энкаустика, автор техникасында термофосфатлы нәкышь, шамоттан рельеф (ш.и. ялтыравык б-н капланган, алтын йөгертелгән), металлны сәнгатьчә эшкәртү (бакырга чокып бизәк төшерү, бронза коелма), скульптура (барельеф, горельеф) төрләрендә нәтиҗәле эшли. Урта Азия, Россия һәм Татарстан шәһәрләрендәге җәмәгать биналарын бизәп торучы 60 ка якын монументаль әсәр авторы: Ташкент метрополитенында «Сабир Рәхимов» (1975, бетон рельеф, смальта мозаика, бакырны чокып бизәк төшерү, бронза коелма), «Айбек», «Ташкент» (шамот горельеф, барельеф, икесе дә — 1982) станцияләре бизәлеше; «Шәрекъның бөек галимнәре» (1994, ФА интерьеры), «Бөек ефәк юлы» (1996, Интернацио-





О.Г. Хәбибуллин. 1. «Шәрекънең бөек галимнәре» панносы. Энкаустика. Бизәк төшерү. Үзбәкстан Фәннәр академиясе бинасы интерьеры. 1994; 2. «Илһам алиһәсе» панносы. Шамот. Глазурь. Рельеф, бизәк төшерү. Ташкент шәһәрендәге консерватория бинасы интерьеры. 2002.

наль мәдәни үзәк), «Тере планета» (1998, Үзбәкстанның Матбугат үзәге) дивар бизәкләре (энкаустика); «Үзбәкстан» (1992, Аэропорт-2 фасады), «Илһам алиһәсе» дивар рельефлары (шамот, ялтыравык) һәм «Сәнгать төрләре» фреска бизәкләре (2002, дәүләт консерваториясенең атриумлы заллары); Гиждуван шәһәрендә «Уңыш бәйрәме» (1980, «Шатлык» ресторан фасады) рельефлы мозаика (смальта); С.-Петербургта Б.Ельцин исем. китапханә бинасының интерьерында барельефлар (8 композиция, 2009) һ.б. Казан



О.Г.Хәбибуллин. «Айбек» панносы. Фрагмент. Шамот. Горельеф, барельеф. Ташкент метрополитены станциясе интерьеры. 1982.

метрополитенының «Г.Тукай», «Кремль» станцияләре интерьерларын византия мозаикасы (600 *м*²) техникасы б-н (барысы 24 композиция, 2005); «Корстон» комплексының «Наполеон» залы (2008) һәм «Үзбәкстан» ресторан интерьеры плафоннарын остазы Ч.Әхмәров истәлегенә атап бизи һ.б. Х. реализм стиле тенденцияләрен үстерә, Урта Азия сәнгате традицияләрен, китап миниатюраларын файдалана. Аның әсәрләре образларның калку экспрессиясе, формаларның масштаблы булуы, фәзаи композициянең шартлылыгы, символик-аллегорик һәм фәлсәфи эчтәлеге б-н аерылып тора. Станлы сәнгатьнең тематик һәм көнкүреш жанрларына, пейзажга мөрәҗәгать итә: һинд фәлсәфәсенә багышланган 12 картиналы цикл («Шамбала», «Мәхәббәт сарае», «Реанкарнация» һ.б., барысы да — 1994), «Мираж» (1995), «Эфганчы һәм гыйбадәт», «Намус күпере» (икесе дә — 1997), «Сөембикә» (1999), «Томан», «Җәйхун», «Сәйхун» (барысы да — 2010), «Ил һәм. Г. Тукай» (2011).

Респ-ка күргәзмәләрендә (1974 тән), бөтенроссия — «Рәссамнар съездга» (Мәскәү, 1984), «Зур Идел» (Мәскәү, 2010), Үзбәкстандагы татар рәссамнарының «Ил» иҗат төркеме (Казан, 1999) һ.б. күргәзмәләрдә катнаша. Шәхси күргәзмәләре Ташкентта (1987), Казанда (1999, 2015), Мәскәүдә (2015) уздырыла. Картиналары Үзбәкстан Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәгендә, Англиядә, Япониядә, Грециядә, Швейцариядә, АКШта шәхси тупланмаларда саклана. Шамоттан «Айбек» горельефы өчен СССР Рәссамнар берлегенең «Скульптурада елның яхшы эше» премиясенә лаек була (1984). Медаль б-н бүләкләнә.

Әд.: Вяткина Н. Озад Хабибуллин // Наш дом — Татарстан. 2009. № 4; Единый художественный тейтинг. Справочник. Вып. 18. М., 2011.

Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.

ХӘБИБУ́ЛЛИН Равил Гата улы (4.1.1941, Красный Бор, хәзер Әгер җ. р-ны Салагыш а.), галим агроном, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2001), ТРның атказ. а.х. хезмәткәре (2000). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1970). 1960–77 елларда Әгерже р-нында эшли: Пушкин исем. к-зда баш зоотехник; ВЛКСМның Әгер җ. район ком-ты инструкторы (1964 тән), бүлек мөдире (1965 тән), 1 нче секретаре (1966 дан); «Әгерже» с-зы директоры (1970 тән). 1978–83 тә КПССның Татарстан өлкә ком-тында инструктор. 1983–85 тә Алексеев р-ны башкарма ком-ты рәисе. 1985–98 дә Респ-ка а.х.н химияләштерү проектлау-тикшеренү станциясе директоры. 1990–2001 дә ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында: терлек азыгы җитештерү бүлеге башлыгы — игенчелек бүлеге башлыгы урынбасары (1998 дән). Дәүләт бүләге үләнчел сорго орлыкчылыгын оештыру, үстерү технологияләрен эшләүдә катнашканы һәм аны җитештерүне зур күләмдә гамәлгә керткәне өчен бирелә. «Почёт билгесе» ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале, ТАССР ЮС Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

ХӘБИБУ́ЛЛИН Равмер Хәсән улы (10.7.1933, БАССРның Чакмагыш р-ны Чакмагыш а. — 31.8.2011, Уфа ш.), партия, хуҗалык эшлеклесе, СССРның мактаулы нефтьчесе. Уфа нефть ин-тын тәмамлый (1961). 1961–70 тә «Әлмәтнефть» идарәсендә инженер, цех башлыгы, идарә башлыгы урынбасары. 1970–77 елларда катламдагы басымны саклау өчен сыекча әзерләү идарәсе башлыгы, «Татнефть» ҖБдә ген. директор урынбасары. 1977–86 да «Пермьнефть» берләшмәсе ген. директоры. 1987–90 да КПССның Башкортстан өлкә ком-ты 1 нче секретаре. СССР, БАССР ЮСлары депутаты, 1989–91 дә СССР халык депутаты, СССР ЮС Президиумы әгъзасы. Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары б-н бүләкләнә.

Ф.Г.Миңнеханов.

ХӘБИБУ́ЛЛИН Радик Габдулла улы (1934, Уфа ш. – 7.3.2017, шунда ук), пианист-ансамблист, концертмейстер, педагог, БАССРның халык артисты (1986). Мәскәү консерваториясен (1957), Гнесиннар исем. Музыка-пед. ин-тын (Мәскәү, 1966) тәмамлый. 1958 елдан Башкорт респ-ка мәдәни-агарту уч-щесында укыта (Эстәрлетамак ш.), 1960–2004 тә Башкорт филармониясендә концертмейстер, бер үк вакытта, 1991 дән, Уфа сәнгать академиясендә укыта, проф. Бөтенсоюз, бөтенроссия, халыкара опера-камера җырларын башкаручы вокалистлар конкурслары дипломанты (концертмейстер буларак). Репертуарын чит ил, рус, башкорт композиторларының әсәрләре тәшкитл итә. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

ХӘБИБУ́ЛЛИН Рафис Җәүдәт улы (2.10.1963, Апас р-ны Пүчинкә-Енай а.), эчке хезмәт генерал-майоры (2008). СССР Эчке эшләр министрлыгының Омск югары милиция мәктәбен (1988), РФ Эчке эшләр министрлыгы Идарә академиясен (Мәскәү, 2000) тәмамлый. 1988–94 елларда Чаллыда: 1990–92 дә Автозавод р-ны эчке эшләр бүлегенең җинаятьчеләрне эзләү бүлеге башлыгы урынбасары, 1992–93 тә башлыгы, 1993 тән ТР Эчке эшләр министрлыгының шәһәр идарәсе Җәмәгать тәртибен саклау бүлеге башлыгы. 1994–95 тә ТР Эчке эшләр министрлыгының Җәмәгать тәртибен саклау идарәсе бүлеге, 1995–97 дә Оператив-техник чаралар идарәсе, 1997–98 дә Җинаятьчеләрне эзләү идарәсе башлыгы, 1999–2002 дә ТР Эчке эшләр министрлыгы каршындагы Хакимият органнары объектларын саклау идарәсе башлыгы урынбасары, 2002–07 дә башлыгы. 2007 дән РФ Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының ТР буенча Баш идарәсе башлыгы, ТР гражданнар обороносы һәм гадәттән тыш хәлләр министры. «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

ХӘБИБУ́ЛЛИН Салават Зәһит улы (23.7.1961, Свердловск ш. — 21.5.1997, Макалу тау массивы — Һималай, Кхумбу р-ны, Непал һәм Кытай чиге), спортчы (альпинизм), Россиянең халыкара класслы спорт остасы (1996). Урал политехник ин-тын тәмамлый (1984). СССР (1989, Биткай түбәсе, 5986 *м*, югары-техник класста), РСФСР (1989, 4810 тау түбәсе, Крицука маршруты, техник класста), Россия (1995, Барунтзе түбәсе, 7220 *м*) чемпионы. РСФСР (1988, 26 Баку комиссарлары түбәсе, 6834 *м*, югары класста; 1990, Чапдар биеклеге, 5050 *м*, техник класста), Россия (1994, Хан-Тәнре түбәсе, 6995 *м*) чемпионатларында көмеш медаль, РСФСР чемпионатында (1988, Асан түбәсе, 4230 *м*, кыя тау классында) бронза медаль ала. Х. 5Б һәм аннан да югарырак категория-дә якынча 30 тапкыр күтәрелә. Алар исәбендә: 1990 — Корженевский түбәсе (7105 *м*), Коммунизм түбәсе (7495 *м*), 1991–92 — Хан-Тәнре түбәсе (6995 *м*), 1993 — 4810 тау түбәсе, 1994 — Пти-Дрю түбәсе (Америка диретрисимасы, 6Б, 3733 *м*), 1996 — Ирекле Корея түбәсе (4740 *м*). Россиянең иң яхшы альпинисты (1997, биеклек классында). «Алтын бозкискеч» призы иясе (1997). 1984–88 елларда Свердловск кирпеч з-дында инженер-механик, 1988–93 тә «Высотник» кооперативы хезмәткәре, 1993 тән «Крокус» АҖ дә баш инженер, Екатеринбургның «Манарага» фирмасында менеджер. 1997 дә Екатеринбургның Широкореченский зиратында кенотаф (символик төрбә) урнаштырылган. Батырлык ордены б-н бүләкләнә (үлгәннән соң).

ХӘБИБУ́ЛЛИН Фәрит Әхмәтҗан улы (31.5.1941, Камчатка өлкәсенең Усть-Камчатск р-ны Козыревское а. — 27.12.2007, Казан), актёр, режиссёр, педагог, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1997). Мәскәү мәдәният ин-тын тәмамлый (1978), бер үк вакытта,

1967–78 елларда, Ульянов, Тубыл шәһәрләре театрларында актёр булып эшли. 1978–85 тә Татар драма һәм комедия театры режиссёры, аның сәхнәсендә 9 спектакль куя: «Беренче мәхәббәт» (Х.Вахит), «Трибунал» (А.Е.Макаёнок), «Өч сорауга бер җавап» (Ә.Гаффар), «Кайту» (Р.Ишморат) һ.б. 1985 тә ТАССР Мәгариф министрлыгы каршында студия оештыра, 1991 дә ул ТР МК карары нигезендә *Казан татар яшь тамашачылар театрына* үзгәртелә. Әлеге театрның бер үк вакытта директоры да, сәнгать җитәкчесе дә буларак, Х. труппаның проф. үсешенә күп көч куя, иҗади белем бирүне оештыра, репертуар булдыра. «Намус хөкеме» (Д.Вәлиев), «Уеннан уймак» (З.Шә һиморат), «Мәхәббәт моңнары» (Ә.Айдар), «Атылган йолдыз» (Ф.Бәйрәмова), «Кырларым-тугайларым» (Т.Миңнуллин), «Шау-шулы көн» («Шумный день», В.С.Розов) спектакльләрен куя. 2001 дән Казан театр уч-щесендә укыта.

ХӘБИБУ́ЛЛИН Фоат Хамат улы (24.12.1940, Красный Бор, хәзер Әгерҗе р-ны Салагыш а.), галим агроном, а.х. фән. д-ры (2004), ТРның атказ. агрономы (1991). Мәскәү а.х. академиясен тәмамлаганнан соң (1968), шунда ук эшли. 1972–87 һәм 2007–11 елларда Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тының терлек азыгы җитештерү лаб-ясе мөдире. 1988–2007 дә Казан вет. медицинасы академиясенең терлек азыгы җитештерү һәм ботаника каф. мөдире. Хезмәтләре Урта Идел буе шартларында табигый һәм картайган үлән капламын яхшырту мәсьәләләреннән карый.

Х е з м.: Укосное и пастбищное использование травостоев // Кормопроизводство. 1980. № 7 (автордаш); Улучшение естественных и старовозрастных травостоев в условиях Среднего Поволжья. К., 2003 (автордаш).

ХӘБИБУ́ЛЛИН Хәйдәр Сафа улы (4.10.1927, Буа кантоны Каратал а. — 30.9.1992, Казан), хакимият-хуҗалык эшлеклесе. Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлый (1949). 1949–50 елларда Хезмәт ияләре депутатларының Свердловск шәһәре Чкалов район советы башкарма ком-ты финанс бүлеге өлкән инспекторы. 1951–56 да Хезмәт ияләре депутатларының Казан шәһәре Ленин районы советы башкарма ком-ты инспекторы, 1956–60 та финанс бүлеге мөдире, 1960–64 тә рәис урынбасары, 1964–69 да Казан шәһәре Бауман районы советы башкарма ком-ты рәисе. 1969–79 да ТАССР МСның Тәэминат һәм сату идарәсе башлыгы. 1979–84 тә ТАССР Дәүләт матди-техник тәэминат ком-ты рәисе. 1984–88 дә ТАССР финанс министры. 1985–90 да ТАССР ЮС депутаты. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. *Е.Б.Долгов.*

ХӘБИБУ́ЛЛИН Шәүкәт Таип улы (25.1.1915, Ташкент — 7.3.1996, Казан), астроном, физика-матем. фән. д-ры (1958), проф. (1959). ТАССРның, РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1970, 1975). Казан ун-тын тәмамлый (1940), 1946 елдан шунда ук эшли, 1949–58 дә В.П.Энгельгард исем. Астрономия обсерваториясенең астрономия бүлеге һәм үзгәрүчән йолдызлар бүлекчәсе мөдире, астрономия каф. мөдире (1958–87), физика ф-ты деканы (1960–65), проректор (1965–86). Бер үк вакытта, 1957–87 дә, Казан шәһәре астрономия обсерваториясе директоры. Хезмәтләре йолдыз астрономиясе, селенодезия, күк механикасы, айның әйләнү теориясенә карый. Х. Галактика яссылыгына карата төньяк һәм көньяк галактик ярымшарларның симметриясен, Галактика үзәгенә таба йолдызларның арта баруын, Кояшның Галактиканың ике спираль җиңсәсе арасында — йолдызларның түбән тыгызлыгы өлкәсендә урнашканын күрсәтә.Меркурий һәм Венераның әйләнеш теориясен эшли. Бөек Ватан сугышында катнаша. Мәскәү янындагы, Курск дугасындагы сугышларда, Варшаваны азат итүдә, Берлинны алуда катнаша. Ленин ордены, Октябрь Революциясе, Кызыл Байрак, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Лунная картография и селенографические координаты // Луна. М., 1960; Нелинейная теория физической либрации Луны // Тр. Казан. гор. астрон. обсерватории. 1966. № 34; Наблюдение кометы Галлея на Зеленчукской астрономической станции КГУ // Позиционные наблюдения в СССР кометы Галлея в появлении 1986 г. Киев, 1990 (автордаш).

Әд.: Р и з в а н о в Н.Г. Человек. Воин. Учёный // Казань. 2001. № 7.

Р.Г.Усманов.

ХӘБИБУ́ЛЛИН Ярулла Хәбибулла улы (1894, Казан губ., Казан өязе Әлдермеш а. — 7.5.1943. Оренбург ш.), хәрби эшлекле, бригада командиры (1936). Беренче бөтендөнья һәм Гражданнар сугышларында катнаша. 1918–1919 елларда полк советы рәисе, А.Гинцбург исем. Казан җыелма полкы комиссары, Фирганә фронтының РВС әгъзасы. Атаман А.И. Дутов армиясенә, чит ил интервентларына, Урта Азиядә хәрби берләшмәләргә каршы сугыша. 1920–31 дә Төркестан хәрби округында төрле командирлык вазифаларын башкара. 1932–38 дә 1 нче Казан дивизиясенең штаб башлыгы урынбасары, 1938–39 да ТАССР хәрби комиссары, 1939–41 дә Идел буе хәрби округының туплау бүлеге башлыгы (Куйбышев ш.). Сталинград янында сугышкан (1942–43) 21 нче армияне туплауда актив катнаша. БАССР хәрби комиссары (1942 дән). Кызыл Байрак, Төркестан АССРның Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары б-н бүләкләнә.

Ф.Г.Миңнеханов.

ХӘБИБУ́ЛЛИНА Фәндилә Садри кызы (23.5.1936, Азнакай р-ны Әсәй а.), тарихчы, тарих фән. канд. (1989), ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1987), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2000). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1958), «Хезмәт байрагы» г-тасында (Әлмәт ш.) эшли, 1963 елдан — Бендеры шәһәрендә (Молдавия) «Победа» г-тасында һәм шәһәр радиосында, 1968 дән — Кандалакша шәһәрендә (Мурманск өлкәсе) шәһәр радиосында. 1970 тән Казанда: КПССның Татарстан өлкә ком-ты архивында фәнни хезмәткәр (1971–91), ТР «Хәтер китабы» редакциясе фәнни хезмәткәре, баш мөхәррир урынбасары (1991–2001). Шул ук вакытта Казан төзүче инженерлар (1991–95), Татар гуманитар ин-тларында (1999–2001) укыта. Мәкаләләре Татарстанның иҗтимагый-сәяси, соц.-икътисади, мәдәни үсешенә, күренекле җәмәгать эшлеклеләренә багышлана. «Татарстанның яшьлеге» («Юность Татарстана», 1979), «Көрәш һәм казанышлар елъязмасы: Татарстанның партия оешмасы хроникасы, 1883–1985» («Летопись борьбы и свершений: Хроника партийной организации Татарии, 1883–1985», 1985) һ.б. гомумиләштерелгән басмаларны әзерләүдә катнаша. «Татарстан партия оешмасы документларда һәм саннарда» («Партийная организация Татарии в документах и цифрах», 1978), «Матбугат, телевидение һәм радиотапшырулар» («Печать, телевидение и радиовещание», 1981), «Татарстан партоешмасы фәнни-техник алгарыш өчен көрәштә (1955–1987)» («Парторганизация Татарии в борьбе за научно-технический прогресс (1955–1987)», 1988) һ.б. документлар җыентыгын төзүчеләрнең берсе. ТР Дәүләт бүләге «*Хәтер–Память*» китабын әзерләүдә катнашканы өчен бирелә. Медаль б-н бүләкләнә.

ХӘБИБУ́ЛЛИНА Эльмира Хәмзә кызы (1.12.1951, Балык Бистәсе р-ны Балык Бистәсе штп), тел галиме, филол. фән д-ры (2002), проф. (2002), ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1997), РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2001). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1974), Казанның 99 нчы мәктәбендә француз һәм немец телләре укыта. 1977 елдан Казан ун-тында, 1999 дан француз теле каф. мөдире, 1993–97 дә Көнчыгыш телләре һәм көнчыгыш цивилизациясе ин-тында (Париж) рус һәм татар телләре, татар цивилизациясе тарихы укыта (бүленеп). Хезмәтләре чагыштырма-типологик, чагыштырма-тарихи тел белеме, мәдәниятара коммуникацияләргә карый. ТР югары уку йортларының Француз теле укытучылары җәмгыяте рәисе (1998 дән). «Академик Пальмалар», «Сәнгать, әдәбият өлкәсендәге казанышлары өчен» француз орденнары, медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Сопоставительная характеристика абстрактных имён существительных множественного числа во французском и русском языках. К., 1998; Статус абстрактных субстантивов множественного числа в разносистемных французском, русском и татарском языках. К., 2001; Цивилизация Татарстана = Civilisation du Tatarstan: география, история, экономика, культура. К., 2005; Россия-Франция: историко-культурный экскурс. К., 2011.

ХӘБИБУ́ЛЛОВ Мөбарәкша Галиәкбәр улы (29.11.1930, Ульянов өлкәсенең Карсун р-ны Нугай Иле а. — 26.1.1996, Казан), зоогигиенист, вет. фән. д-ры (1983), проф. (1985). Ульянов а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1956), Алтай крае Смоленский р-нының вет. дәваханәләрендә эшли. 1965 елдан Казан вет. ин-тында, вак терлекчелек технологиясе (1983) һәм зоогигиена (1988) кафедраларын мөдире. Хезмәтләре сәнәгать нигезендә кроликлар асрауның оптималь шартларын гигиена ягыннан нигезләүгә карый.

Х е з м.: Гигиена в промышленном кролиководстве. М., 1979; Влияние температуры воздуха на ор-

ганизм кроликов различного возраста // Уч. зап. Казан. вет. ин-та. 1981. Т. 134; Температурный режим для молодняка // Кролиководство и звероводство. 1982. № 1.

Әд.: Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.): Биогр. словарь учёных. К., 2006.

ХӘБИБЬЯ́НОВ Равил Ярхәм улы (23.3.1959, Әгерҗе ш.), травматолог-ортопед, мед. фән. канд. (1991). Ижевск мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1982), Удмурт АССРның Респ-ка клиник хастаханәсендә эшли (Ижевск ш.). 1983 елдан Кияс шәһәре (Удмурт АССР) Үзәк район хастаханәсендә хирург, рентгенолог булып эшли. 1985 тән Устинов мед. ин-тының травматология һәм ортопедия кафедрасында (Устинов ш.). 1888 дән Бөтенсоюз Курган «Травматология һәм ортопедия» фәнни үзәгенең Казан ф-лы каршындагы махсус җайланмалар яр дәмендә остеосинтез уздырганда биохимик системаларны модельләштерү лаб-ясе мөдире. 1993 тән Казан «Травматология һәм ортопедия» фәнни-тикшеренү үзәгенең биохимик системаларны модельләштерү төркемендә; 2003 тән ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы каршындагы «Республика клиник хастаханәсе № 4» Дәүләт мед. учреждениесенең травматология бүлеге травматолог-ортопеды. 2005–09 да ТР ФАнең «Травматология һәм ортопедия» фәнни-тикшеренү үзәге Дәүләт учреждениесе директоры. 2009–11 дә ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының Респ-ка клиник хастаханәсе дәүләт сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибенең мед. буенча урынбасары, 2011 дән шунда ук фәнни-тикшеренү бүлеге мөдире. Хезмәтләре оча-бот буынын эндопротезлау биомеханикасына, оча сөякләре сынуның катлаулы очраклары на карый. Уйлап табуга 32 патенты һәм авторлык таныклыгы бар. ТРның травматолог-ортопедлар ассоциациясе рәисе (1985 тән). Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Лечение переломов вертлужной впадины со смещением // Материалы науч.-практ. конф. НИЦТ «ВТО». К., 2006 (автордаш); История становления Научно-исследовательского центра Татарстана «Восстановительная травматология и ортопедия» // Казан. мед. журн. 2009. № 1; Смертность детского населения РТ от травм, отравлений и некоторых последствий воздействия внешних причин // Общественное здоровье и здравоохранение. 2009. № 1 (автордаш).

ХӘБИ́РОВ Рәис Әхәт улы (16.11.1959, Лениногорск р-ны Шөгер пос.), терапевт, мед. фән. д-ры (1997), проф. (2000). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1982), шунда ук, 1 нче госпиталь терапиясе кафедрасында эшли, 1998 елдан каф. профессоры. Бер үк вакытта, 2001 дән, ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы сәламәтлек саклау идарәсенең Казан шәһәре Вахитов р-ны сәламәтлек саклау бүлеге башлыгы урынбасары. 2006 дан «Медицина университеты клиникасы» муниципаль сәламәтлек саклау учреждениесе баш табибе. Хезмәтләре мускул тукымасы зарарлану патогенезына, буыннар һәм умыртка сөяге ялкынсынулары һәм дегенератив авыруларына карый. Уйлап табуга 2 патенты бар. «ТРда ревматология хезмәтен камилләштерүнең фәнни-гамәли һәм оештыру аспектлары» («Научно-практические и организационные аспекты совершенствования ревматологической службы в РТ») хезмәте өчен ТР Дәүләт бүләгенә лаек була (2000).

Х е з м.: Мышечная боль. К., 1995 (автордаш); Клинико-ультразвуковая характеристика мышечного синдрома при ревматоидном артрите и остеопорозе // Эхография. 2002. № 3 (автордаш); Подагра. М., 2008 (автордаш).

ХӘБИ́РОВ Фәрит Әхәт улы (14.10.1949, Лениногорск р-ны Шөгер пос.), невропатолог, мед. фән. д-ры (1992), проф. (1995), ТРның ат-каз. фән эшлеклесе (2002). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1973), шунда ук, нерв авырулары бүлегендә (1985 елга кадәр), бер үк вакытта Үзәк фәнни-тикшеренү лаб-ясендә (1975–80) эшли. 1986 дан «Татнефтепроводстрой» трестында табиб. 1987 дән Казан шәһәре 1 нче поликлиникасының электронейрофизиол. кабинеты мөдире; 1988 дән Бөтенсоюз Курган «Травматология һәм ортопедия» фәнни-тикшеренү үзәгенең Казан ф-лында әйдәп баручы фәнни хезмәткәр, 1991 дән реабилитация лаб-ясе мөдире. 1997 дән Казан мед. академиясенең неврология һәм мануаль терапия каф. мөдире. Хезмәтләре умыртка сөяге һәм терәк-хәрәкәт аппараты авыруларына диагноз кую һәм аларны дәвалауга карый. Уйлап табуга 4 патенты һәм 2 авторлык таныклыгы бар. «Нерв системасының вертеброген авырулары барышында невраль һәм мускул тукымасы синдромнары (функциональ һәм гамәли аспектлар)» («Невральные и мышечные синдромы при вертеброгенных заболеваниях нервной системы (функциональные и прикладные аспекты)» хезмәте өчен ТР Дәүләт бүләгенә лаек була (2008).

Х е з м.: Мышечная боль. К., 1995 (автордаш); Клиническая неврология позвоночника. К., 2003; Лечебные блокады при болевых миофасциальных и туннельных синдромах. К., 2009.

ХӘБИ́РОВА Галимә Фәтхулла кызы (17.8.1928, БАССРның Мәсәгут кантоны, хәзер Салават р-ны Татар Малаязы а.), травматолог-ортопед, мед. фән. д-ры (1982), ТАССРның атказ. табибе (1985). Башкорт мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1956), Башкортстан АССРның Туймазы р-ны мед. учреждениеләрендә эшли. 1958 елдан Баулы үзәк район хастаханәсе хирургы. 1960 тан Казан ГИДУВының ортопедия һәм травматология кафедрасында, 1962 дән Казан травматология һәм ортопедия фәнни-тикшеренү ин-тында, өлкәннәр травматологиясе бүлеге мөдире (1982–87). 1994–96 да Терр. хастаханә касса-



И.М.Х ә б и с о в. «Ике кувшин» натюрморты. 1997.



И.М. Х ә б и с о в. «Тубыл мәчете күренеше». 1999.

сының экспертиза буенча баш белгече (Казан). 1998 дән Казан шәһәре Вахитов р-ны 2 нче поликлиникасы хирургы. Хезмәтләре буынның эчке зарарлануларын магнит ярдәмендә дәвалауга карый. Уйлап табуга 3 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Магнитные поля в лечении внутрисуставных повреждений. Ижевск, 1977; Лечение больных с внутрисуставными переломами коленного сустава // Казан. мед. журн. 1980. № 1 (автордаш). Отдалённые результаты лечения свежих разрывов связок коленного сустава // Советская медицина. 1980. № 8.

ХӘБИ́СОВ Илдар Мөнир улы (7.1.1966, Төмән өлкәсенең Вагай р-ны Карагай а.), нәкышьче, график, педагог. М.Горький исем. Омск пед. ин-тының сәнгать-графика ф-тын тәмамлый (1991). Д.И.Менделеев исем. социаль-пед. ин-тында (Тубыл; 1992 елдан) — нәкышь кафедрасында укытучы, дизайн һәм һөнәри белем бирү кафедрасында (1993 тән). Рәссамнар берлеге әгъзасы (2003). Х. тематик жанрлы станлы картиналар, портрет, пейзаж остасы. Супрематизм, абстракт нәкышь традицияләренә мөрәҗәгать итеп, авангард сәнгате стилистикасында эшли, Себер татарлары халык сәнгате образлар системасына хас символиканы, башка халыкларның фольклор мотивларын файдалана. Бер үк вакытта реалистик манерадагы картиналар иҗат итә (натурадан пейзаж, натюрморт, портрет, гамәли композиция). Эшләрендә мифологик, фольклор (Сабан туе һ.б. этник мотивлар), дини сюжетлар (суфи шәехләр һ.б. турында риваятьләр) — «Фаэтон» (1990), «Минотавр белән биюләр» (1998), «365 шәех» (2002), «Сабан туе» (2006), «Этләр кая чаба» (2010) һ.б.ны чагылдыра. Иҗат иткән пейзажлары — «Чагылышлы пейзаж» (1997), «Абрамка аръягында җәй» (1998), «Тубыл мәчете күренеше» (1999), «Мисыр күзе белән натюрморт» (2001), «Раштуа төне» (2007); натюрмортлар: «Реквием» (1990), «Ике чүлмәк» (1997), «Розалар һәм помидорлар» (2002), портрет — «Кош тоткан кеше» (1996) һ.б. Төс, композицияләрнең экспрессив динамикасы, форма һәм образларның сәнгати чагылышы — Х. иҗатының төп сурәтләү чаралары гәүдәләнеше. Станлы һәм китап графикасында уңышлы эшли. «Гармония» (1990) пастельләр се-

риясен, Себер татарлары тарихына багыш - ланган әсәрләр (карандаш, гельле каләм, мар - керлар) — «Күчем һәм Ермак», «Иртештә сәяхәт» (икесе дә — 2006), «Сүзге — Себер ха - ны кызы» (2009), «Лайтамак авылы» (2008) сериялəрен иҗат итә. Иллюстрацияләр һәм китап бизәлешләре авторы — «Себер әкиятләре һәм риваятьләре» («Сказки и легенды Сибири»), «Себер татарлары әкиятләре һәм риваятьләре» («Сказки и легенды сибирских татар») (инглиз телендә укуга китаплары; икесе дә — Тубыл ш., 2012) һ.б.

Шәһәр һәм өлкә күргәзмәләрендә (1990 нан), бөтентатар — «Татарт» (С.-Петербург, Казан, 1991), «Көнбатыш Себер халыклары мәдәнияте» (Тубыл, 2002) фәнни симпозиу - мы кысаларында «Татарт», «Яшел тау» за - манча пейзаж нәкыше (Плёс ш., 2008); төбәкара — «Гасырлар алышыныр алдыннан» (Омск, 1994); бөтенроссия — «Мәктәп. Укы - тучы. Сәнгать» (Чабаксар, 2004), оригиналь рәсем биенналесе — (Томск, 2007–10); төбәк — «Урал-10» (Чиләбе, 2008); халыкара — «Яңа Себер сәнгате» (Варшава, Польша, 1991) күргәзмәләрендә, 6 нчы «Арт-Ту - был-2010» фестиваль-пленэрында катнаша.

Шәхси күргәзмәләре 1998, 2008 дә (Ту - был), 2006 да (Төмән) уздырыла. Картиналары Сургут сәнгать музеенда, Тубыл тарих-архит-ра музей-тыюлыгында, «Омск сәнгате» заманча сәнгать галереясында, «Күчем» галереясында (Омск) саклана.

Әд.: А л е к с а н д р о в а Л. Жёлтый – цвет радости // Татарские края. 1998. № 35/36.

Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.

ХӘБРИ́ КҮЛЕ́, Көнбатыш Кама алдында. Вятка увалының көньяк өлешендә, Ашыт һәм Питиял елгалары бассейнының субүләрендә, Биектау р-ны Каракүл авылыннан 2,2 *км* көнбатыштарак. Су өслегенең мәйданы 0,68 *га*. Су күләме якынча 7 мең *м*^{3}. Озынлыгы 170 *м*, иң зур киңлеге 70 *м*. Уртача ти - рәнлеге якынча 1 *м*, иң зур тирәнлеге 1,3 *м*. Күл карст процесслары нәтиҗәсендә барлык - ка килгән. Сузынкы формада. Көнбатыш як - тан яры берникадәр күтәренке, катнаш ур - ман б-н капланган. Туенуы күбесенчә җир асты сулары исәбенә, тотрыклы. Суы гидро - карбонат-сульфат-кальцийлы типта, уртача минераль‌ләшкән, йомшак, уртача болганчык, саргылт төстә. Үтә күренмәлелеге 15 *см*. Ял итү урыны.

ХӘБРИ́ЕВ Рамил Усман улы (18.5.1953, Кукмара р-ны Таиш а.), сәламәтлек саклау өл - кәсе эшлеклесе, мед. фән. д-ры (1995), фарм. фән. д-ры (2004), РМФАнең хокукый эгъ - засы (2000), ТРның һәм РФнең атказ. таби - бе (1995, 2004). Казан мед. ин-тын тәмамла - ганнан соң (1976), шунда ук, мәхкәмә меди - цинасы кафедрасында эшли, 1984–88 елларда — социаль гигиена һәм сәламәтлек сак - лауны оештыру кафедрасында. 1989–94 тә ТР сәламәтлек саклау министры. 1994–2001 дә РФ Сәламәтлек саклау ми - нистрлыгында: Дару матдәләре һәм мед. тех - никасына дәүләт контроле инспекциясе баш - лыгы (1997 гә кадәр), Дарулар һәм мед. тех - никасына дәүләт контроле идарәсе башлыгы (1997–98), Даруларның сыйфаты, нәтиҗә - лелеге һәм куркынычсызлыгына дәүләт кон - троле департаменты җитәкчесе (1998–2001). 2001–04 тә «Биопрепарат» АҖ ген. директо - ры (Мәскәү); 2004–07 дә РФ Сәламәтлек саклау министрлыгының Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәте (Росздравнадзор) җитәкче - се. 2007–09 да РФ Хөкүмәтенең Социаль үсеш һәм әйләнә-тирә мохитне саклау депар - таменты директоры урынбасары — социаль үсеш һәм демография бүлеге башлыгы. 2009–12 дә Н.И.Пирогов исем. Россия мил - ли тикшеренү мед. ун-тының беренче про - ректоры. 2013 тән РМФАнең Милли иҗти - магый сәламәтлек фәнни-тикшеренү ин-ты директоры. Хезмәтләре сәламәтлек саклау өлкәсендәге оештыру мәсь әләләренә карый. 1990–93 елларда РФ халык депутаты, РФ ЮСның Миллəтлəр Советы әгъзасы. 4 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Профилактическая вертеброневрология. К., 1992 (автордаш); Антибактериальные лекарственные средства: Методы стандартизации препаратов. М., 2004 (автордаш); Молекулярные механизмы нежелательных эффектов лекарственных средств. М., 2005 (автордаш).

ХӘБРИ́ЕВА Миләүшә Наил кызы (31.10.1960, Арча ш.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2000), проф. (2002). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1984). 1978–80 елларда ТАССР Сәүдә министрлыгы җәмәгать тукла - ныу пр-тиеләренең ху җалык исәбендәге бер - ләшмәсе бухгалтеры (Биектау р-нының Би - ектау а.), 1980–82 дә ТАССР А.х. министрлы - гының Биектау «Сельхозхимия»сендә икътисадчы. 1982–85 тә Казан вет. фәнни-тикшере - нү ин-тында бухгалтер. 1986–91 дә «Идел» аг - росәнәгать комб-тында икътисадчы. 1995–2000 дә Казан а.х. академиясендә укыта; 2000–06 да — «ТИСБИ» идарә академиясен - дә маркетинг, 2007 дән Казан кооп. ин-тының бухгалтерлык исәбе һәм финанслар кафедра - лары мөдире. Хезмәтләре Агросәнәгать ком - плексында эшмәкәрлек структураларының барлыкка килүе һәм үсеше проблемаларына ка - рый. Х. базар мохитендә эшмәкәрлек струк - туралары ның конкурентлык көчен бәяләү ме - тодологиясен фәнни нигезли һәм сыный.

Х е з м.: Экономика научных исследований // Актуальные проблемы экономики и права. 2007. № 1; Теоретические основы формирования и развития экономического потенциала предприятия // Вестн. Казан. гос. аграр. ун-та. 2009. № 3 (автордаш); Конкурентная сила: организации, предприятия, предпринимательские структуры. К., 2010.

ХӘБРИ́ЕВА Талия Ярулла кызы (10.6.1958, Казан), хокук белгече, юридик фән. д-ры (1997), РФА академигы (2011; 2008 дән мөх - бир әгъза), РФ нең атказ. юристы (2003). Ка - зан ун-тын тәмамлаганнан соң (1980), шун - да ук эшли: 1985–96 елларда дәүләт һәм ха - лыкара хокук кафедрасында. 1996–98 дә РФА Дәүләт һәм хокук ин-тының Гавами хокук үзәгендә әйдәп баручы фәнни хезмәт - кәр, сектор мөдире, җитәкче урынбасары. Бер үк вакытта, 1997 дән, РФ Тышкы эшләр министрлыгының Мәскәү халыкара мөнәсә - бәтләр ин-тында (ун-т) конституцион хокук кафедрасында, проф. (2000). 1998–2001 дә РФнең федерация, милли һәм миграция сәясәте эшләре ми - нистры урынбасары. 2001 дән РФ хөкүмә - те каршындагы За - коннар чыгару һәм ча - гыштырма хокук бе - леме ин-ты директо - ры. Бер үк вакытта, 2013 тән, РФА ви - це-президенты. Хез - мәтләре дәүләт һәм хокук теориясе, хо - кукка аңлатма бирү теориясе; законнарга телеологик (максатлы) аңлатма бирү һәм аның хокук мөмкинлекләрен ачу, хокук ин-тларына һәм нормаларына карата кыйм - мәтләр мөнәсәбәтен гамәлгә ашыру, гамәл - дә хокуктан файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру; конституцион хокук, ш.и. консти - туция теориясе, аңа аңлатма бирү һәм хокукый саклау, парламентаризм, федерализм, дәүләтләрнең милли-мәдәни үсешенең хокук аспектлары мәсь әләләренә карый. 3 нче һәм 4 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен», Александр Невский, Почёт, Дуслык орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.



Т.Я.Хәбриева.

Х е з м.: Телеологическое (целевое) толкование советского закона. К., 1988; Конституционный контроль. К., 1992; Правовая охрана Конституции. К., 1995; Толкование Конституции Российской Федерации: теория и практика. М., 1998; Национально-культурная автономия в Российской Федерации. М., 2003; Миграционное право России: теория и практика. М., 2008.

Е.Б.Долгов.

ХӘДИ́С (гарәп. حديث), *Мөхәммәд* пәйгамбәр - нең мөселманнарның дини-хокукый тормы - шының төрле якларына кагылышлы фикер - ләре һәм гамәлләре турында риваять. Х. җы - ентыкларын төзүче иң күренекле затлар: әл-Бохари (810–870), Мөслим (821–875), әт-Тирмизи Әбу Дау (824–892), ән-Нәсаи (915 елда вафат), Ибне Мәҗи (886 да вафат), Ибне Хәнбәл (855 тә вафат). Исламда хокук буенча *Коръәннән* соң икенче чыганак. Х.тә ислам принциплары һәм идеяләренең шак - тый өлеше тупланган. Ислам илаһият гыйле - мендә Х.не өйрәнү буенча махсус хәдис фә - не шөгыльләнә. Ш.у.к. *Сөннә.*

Әд.: Сахих аль-Бухари. Мухтасар: Полный вариант. М., 2003; Бёртон Дж. Мусульманское предание: Введение в хадисоведение. СПб., 2006; ан-Навави Абу Закарийа бин Шараф. Сады праведных. М., 2008; Муслим ибн аль-Хаджжадж. «Са - хих» имама Муслима: Краткое изложение, составленное имамом аль-Мунзири. М., 2011.

ХӘЕРБИ́ авылы, Лаеш р-нында, Казан тимер юл станциясеннән 32 *км* төньяк-көнбатыш - тарак, Мишә елгасыннан 3 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 789 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау, яшелчәчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет (1908 дә төзелә; ар - хит-ра истәлеге). Казан ханлыгы чорыннан билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысын - да халкы дәүләт крәстияннәре катлавына ке - рә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Х. дә мәчет, мәдрәсә, җил те - гермәне, 6 вак-төякләр кибете эшли. Бу чор - да авыл җәмәгатенең имана җире 1857 дис.

тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасы - ның Лаеш өязе Әстерхан волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Лаеш, 1938 нең 4 августынан — Столбище, 1959 ның 26 мартыннан — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында.



Хәерби авылы. Мәчет. 1908.

Халык саны: 1782 дә — 123 ир-ат; 1859 да — 254, 1897 дә — 1002, 1908 дә — 1227, 1920 дә — 1430, 1926 да — 1549, 1949 да — 1389, 1958 дә — 1342, 1970 тә — 1155, 1979 да — 934, 1989 да — 784, 2002 дә — 812 кеше.

ХӘЕРБИ́ КҮЛЕ́, Столбище күле, Көнбатыш Кама алдында. Идел елгасының югары террасасында, Лаеш р-ны Столбище авылын - да урнашкан. Су өслегенең мәйданы 6,2 *га*, күләме 119,3 мең *м*^{3}. Озынлыгы 525 *м*, уртача киңлеге 125 *м*, уртача тирәнлеге 2 *м* тирәсе, иң зур тирәнлеге 5 *м*. Күл карст-суффозия процесслары нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Дөрес булмаган озынча түгәрәк формада. Ярлары сөзәк һәм тәбәнәк. 20 йөз урталарына кадәр Х.к. ермак аша Куян күле б-н тоташкан



Хәерби күле.

була, со ңыннан Олы Кабан авылы янындагы ерымнан комсу-балчыксыл китерелмәләр б-н акрынлап бүленә һәм йомык сулык булып кала. 16–17 йөзнең 1 нче яртысында Х.к. яр - ларында шул ук исемдәге йомышлы татарлар авылы (күлнең исеме шуннан) урнашкан. Туенуы тотрыклы, явым-төшемнәр һәм грунт сулары исәбенә туена. Суы җи ңелчә минераль ләшкән (115,2 *мг/л*), йомшак (5,6 *мг-экв/л*), азрак болганчык, саргылт төс - тә. Сугару һәм су кошлары өчен файдаланы - ла. ТРның табигать истәлеге (1978).

ХӘЕРТДИ́НОВ Равил Әнвәр улы (1.8.1948, Актаныш р-ны Үмәнәй а.), генетик, биол фән. д-ры (1993), ТРның, РФнең атказ. фән эш - леклесе (1997, 2004). Казан вет. ин-тын (хәзер Казан вет. медицинасы академиясе) тә - мамлаганнан соң (1971), Гомуми генетика ин-тында эшли (Мәскәү). 1987 елдан Казан вет. медицинасы академиясендә, генетика һәм селекция каф. мөдире (1987 дән), бер үк вакытта проректор (1999 дан). Хезмәтләре сөт аксымнары генетикасы өлкәсенә, а.х. тер - лекләренең булган токымнарын камилләш - терү һәм яңа токымнар китереп чыгаруга ка - рый.

Х е з м.: Белки молока. К., 2009 (автордаш); Генеалогия, племенные качества, ДНК-маркеры продуктивности быков производителей Татарстанского типа, чёрно-пёстрой и мясных пород скота. К., 2011 (автордаш).

Әд.: Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.): Биогр. словарь учёных. К., 2006.

ХӘЕ́РОВА (Хайрова) Йолдыз (Юлдус) Абдулла кызы (21.2.1925, Саратов губ. Карлыган а. – 3.10.2001, Казакъстан Респ-касы, Караганда ш.), табиб, педагог, мед. фән. д-ры (1971), проф. (1972); Казакъстан Респ-касында мед.-тернәкләндерү һәм спорт медицинасы хезмәтен оештыручыларның берсе. Алма-Ата мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1950), Караганда өлкә дәвалау-физкультура диспансерында баш табиб булып эшли. 1953 елдан Караганда мед. ин-тында (1997 дан Караганда мед. академиясе); 1970–99 да дәвалау физкультурасы һәм табиб күзәтчеле - ге каф. мөдире. Хезмәтләре физик культу - рага һәм спорт медицинасына карый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Физическая культура в профилактике и лечении пневмокониозов. М., 1962 (автордаш); Производственная гимнастика шахтёра. М., 1966; Применение физической культуры в комплексе оздоровительных мероприятий у шахтёров. М., 1974; Физкультура – труд – здоровье. М., 1979; Умеете ли вы отдыхать. М., 1983; Союзники здоровья. Алма-Ата, 1984. *И.Р.Вәлиуллин.*

ХӘЕРТИ́НОВА Илсөяр Мансур кызы (11.4.1958, Казан), инфекционист, мед. фән. д-ры (2009), ТРның атказ. табибе (2015). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1982), Казан шәһәре 1 нче йогышлы авырулар хастаханәсенең оештыру-методик кабинеты табиб-инфекционисты булып эшли. 1985 елдан Казан ГИДУВының йогышлы авырулар кафедрасында, каф. мөдире (2008 дән). Хез - мәтләре вируслы гепатитны, ВИЧ-инфек - цияне, туберкулёзны (ВИЧ-инфекцияле авы - руларда туберкулёзга иртә срокларда диа - гноз кую ысуллары, үзенчәлекле гумораль иммунитет формалашу) өйрәнүгә карый. Уй - лап табуга 4 патенты һәм 2 авторлык танык - лыгы бар.

Х е з м.: ВИЧ-инфекция и туберкулёз (эпидемиология, клиника, диагностика). К., 2008; Клинико-иммунологические особенности ВИЧ-инфекции, сочетанной с туберкулёзом // Туберкулёз и болезни лёгких. 2009. № 6 (автордаш).

ХӘЗӘ́Р КАГАНЛЫГЫ́, Көнчыгыш Европадагы элгәреге феодаль төрки дәүләт. 7 йөз уртасында Түбән Идел буе һәм Кавказ ал - дының көнчыгыш өлеше терр-ясендә Көн - батыш Төрки каганлык (к. *Төркн каганлык*) таркалу нәтиҗәсендә барлыкка килә. Х.к. ба - шында Ашина династиясе тора. Башкала - сы — *Сәмәндәр* шәһәре, 8 йөз башыннан — *Итил* шәһәре. 7 йөзнең 2 нче яртысында *хә - зәрләр — Бөек Болгар дәүләтен, савирлар, бә - рәнҗәрләрнең* дәүләти оешмаларын, 8 йөздә Идел буе һәм Дон буе халыкларын (*болгар - лар*, *бортаслар*, мордвалар һ.б.ны), кайбер славян кабиләләрен (поляннар, северяннар, вятичлар, радимичлар һ.б.ны) буйсындыра - лар. Иң ку әтле чорында, 8 йөздә — 10 йөз ба - шында, Х.к. Төньяк Кавказны, Азов янын, Кырымның зур өлешен, Көнбатыш Европа - ның Днепр елгасына кадәрге дала һәм ур - ман-дала терр-ясен һәм ш.у. Төньяк-Көнба - тыш Казакъстан терр-ясен били. Х.к.нда өч монотеистик дин (православие, ислам, иу - даизм) һәм мәҗүсилек янәшә тыныч яши. 8 йөздә — ислам, 8 йөз ахырында — 9 йөз ба - шында — иудаизм (нигездә, хакимлек итүче югары катлау арасында), 10 йөз ахырыннан ислам дәүләт дине була. Һәр дини община үз судьяларын тота һәм автономия саклый. Х.к. икътисады күпукладлы була, аның нигезен күчмә терлекчелек тәшкил итә. Түбән Идел үзәнендә, Кырымда, Дон һәм Донец ел - галары арасында игенчелек, бакчачылык, йө - зем үстерү һәм һөнәрчелек (Итил, Бәләнҗәр, Сәмәндәр шәһәрләрендә) үсеш ала. Каган - лык башкаласы Итил мөһим халыкара (ш.и. транзит) сәүдә үзәге булып тора. Х.к. Визан - тия, Көнчыгыш Европа, Скандинавия, Урта Азия, Кавказ арты илләре б-н актив сәү - дә-икътисади бәйланышлар булдыра. Аның терр-ясе аша товарларны транзит уздырган өчен пошлиналар зур керемнәр китерә (ко - рабльләрдән һәм сәүдә кәрваннарыннан то - варларның уннан бер өлеше алына). Каган - лыктан эре һәм вак мөгезле эре терлек, мех - лар, балык клее чыгарыла. Болгар һәм славян җирләреннән ашлык, кыйммәтле мехлар, бал һәм балавыз, Көнчыгыш илләрдән — зиннәт - ле әйберләр, аш тәмләткечләр, ефәк, сугыш кораллары кертелә. Х.к. халкының мәдәният - не һәм көнкүреше *Салтау-маяк культура - сына* караган археол. истәлекләрдә чагылыш таба. Аның вәкилләренең таралыш терр-ясе Х.к.терр-ясе б-н тулысынча туры килә. Әле - ге культура истәлекләре төрле: сөзәк елга яры буйлап күчмә яшәү урыннары (сезонлы көтүлекләр) калдыклары, югары борыннар - да шәһәр һәм кальгалар хәрабәләре, каберлек - ләр. Тораклар күбесенчә җир өстендә, таш яисә чыбыктан үреп, балчык б-н сыланган диварлы, ш.у. туры почмаклы ярым землян - калар һәм юрта рәвешендәге түгәрәк тораклар. Башкала Итил шәһәре Иделнең ике як яры буйлап һәм идарәче резиденциясе — таш сарай салынган утрауда урнашкан була. Шә - һәр кешеләре балчык б-н сыланган йортлар - да һәм юрталарда яшиләр. Шәһәрнең көнчыгыш өлешендә җамигъ мәчет, 30 мәхәллә мәчете һәм алар каршындагы мәдрәсәләр, ш.у. христиан, яһүди гыйбадәтханәләре һәм мәҗү - силәрнең табыну урыннары була.

Баштарак Х.к. типик күчмә ханлык рәве - шендә яши. Сәяси традицияләр һәм титуллар җыелмасын ул Төркн каганлыктан мирас итеп ала. Дәүләт башында формаль яктан хәрби һәм адм. хакимияткә тулысынча ия каган тора, әмма хакимият номиналь һәм сак-

раль була. 8 йөз ахырына кадәр Х.к.нда хакимият чынлыкта җирле хәзәр һәм болгар аксөякләре кулында тупланган. Иудаизм кабул иткәннән соң, хакимият чынбарлыкта дәүләттә икенче дәрәҗәдәге зат — бәк (яки хаканбәк, ивритта «мелех» — патша) кулына күчә. Х.к.нда югары катлау булып *тарханнар* — бер нәселдән чыккан аксөякләр һәм патшалык итүче нәселнең туганнары исәпләнә; ил-төбәрләр — вассал халыклар идарәчеләре һәм тудыннар — аерым терр-ядә каган наместниклары бер баскычка түбәнрәк тора.

Х.к. терр-ясе үзәк хакимиятнең контроллек итү дәрәҗәсенә карап аерылган өлкәләргә бүленә. Терр-ясендә хәзәрләр үзләре яшәгән, башкала, каган резиденциясе урнашкан Түбән Идел буе төп өлкә була. Стратегик пунктлар турыдан-туры каган тарафыннан контрольдә тотыла, аларда хәзәр гарнизоннары (Донда Саркел һәм Керчь бугазы янындагы Самкерс кальгалары) урнаша. Буйсындырылган халыклар (аланнар, болгарлар, бортаслар, венгрлар, славяннар һ.б.) үзләренең социаль-сәяси структурасын саклап кала. Аларның идарәчеләре Х.к.на ясак җыеп җибәрергә, каган өчен гаскәр тупларга тиеш була.

Х.к.ның үзенчәлекле геосәяси урыны аның идарәчеләрен Кара диңгез буенда һәм Кавказ артында йогынты даирәсе, ш.у. коры җир һәм су сәүдәсе юлларын контрольдә тоту өчен даими көрәш алып барырга мәҗбүр итә. Төньяк Кара диңгез буенда хәзәрләр Византия б-н бәрелешә. 7 йөз ахырында — 8 йөздә алар Боспорны, Көнчыгыш Кырымны басып алалар, Кырымдагы төп грек шәһәре — Херсонесны үзләреңә итмәкче булалар. 8 йөздә Х.к. б-н Византиянең уртак дошманы — Гарәп хәлифәлегә барлыкка килә. Гарәпләр Урта Азияне буйсындыра, хәзәрләрне Кавказ артыннан кысрыклап чыгара, 735 елда Каспий буе далаларына үтеп керә һәм каган армиясен тар-мар итә (к. *Гарәп-хәзәр сугышлары*). Әмма алар далаларда озак тора алмыйлар һәм Кавказ артына чигенәләр. Каган Төньяк Кавказда һәм башка өлкәләрдә үз хакимиятен торгыза. Актив халыкара сәясәт сугышка сәләтле армия булуны таләп итә. 7–8 йөзләрдә ул бәйле халыклардан мәҗбүр итеп төзелгән ополчениедән тора. Гаскәрләрнең күләме 100–300 мең кешегә җитә ала. 9–10 йөзләрдә хәл үзгәрә: хәзәр идарәчеләре, киң колачлы басып алу яуларыннан баш тартып, яллы сугышчыларны файдалана башлыйлар; гаскәрнең төп көче авыр атлы гвардия була, ул ларисий-лардан — Харәземнән чыккан мөселман кабиләсе вәкилләреннән тора. Алар махсус шартлар-да хезмәт итәләр, аларның үз вәзирләре һәм бер диндәгеләр б-н сугышмау хокукы була, бу каганлыкка актив тышкы сәясәт алып барырга мөмкинлек бирә. Әмма Европа б-н Азия чигендәге бәйсез сәясәт алып барган дәүләт күрше илләрнең каршылыгына очрый. Дәүләт дине хакындагы мәсьәлә сәяси яктан бик тә мөһим була. Гарәпләр Х.к.нда — ислам динен, ә Византия христианлыкны урнаштырырга омтылалар. Хәзәрләр-нең идарәче катлавы үзен Хәлифәлек б-н дә, Византия б-н дә дини мөнәсәбәтләр аша бәйләргә теләми. 8 йөз ахырында — 9 йөз башында каганлык башында торучы Булан каган варисы Обадия, иудаизмны дәүләт дине дип игълан итә, бу хәзәр аксөякләренең бер өлешендә һәм түбән катлауларның күпчелегендә ризасызлык китереп чыгара. Озакка сузылган үзара көрәш башлана, аның бары-шында Обадия баш күтәрүчеләрне һәм аларның аркадашларын — мәҗарларны тар-мар итә. Х.к.ндагы фетнәдән Византия хакимлегенә күчкән Кырым готлары һәм элегрәк хәзәрләргә ясак түләгән башка кайбер халыклар (ш.и. Днепр буе славяннары) файдалана. 9 йөз ахырында Кара диңгез буе һәм Дон далалары бәҗәнәкләр хакимлегендә кала. Каганлыкның көчсезләнүен теләгән Византия хәзәрләргә каршы аларны урап алган күчмә халыкларны котырта башлый. Шуның б-н беррәттән, Х.к. Борынгы рус дәүләте ягыннан да хәрби һөҗүмнәргә дучар була: 913–14 һәм 943–44 тә рус гаскәрләре бөтен Х.к. аша узалар һәм Каспий яр буйларын бөлдерәләр. 964–65 тә кенәз Святослав Иделгә яу б-н бара һәм Х.к.н тар-мар итә: Итил, Сәмәндәр шәһәрләре талана, Саркел шәһәре яулап алына. 10 йөз ахырында эчке үзара сугышлардан, Святослав явыннан, бәҗәнәкләр һәм угызлар бәреп керүеннән көчсезләнгән Х.к. яшәүдән туктый. 13 йөз башына кадәр Түбән Идел буенда кечерәк кенә биләмә — Саксин шәһәре һәм өлкәсе сакланып кала.

Әд.: Плетнёва С.А. Хазары. М., 1976; Новосельцев А.П. Хазарское государство и его роль в истории Восточной Европы и Кавказа. М., 1990; Сабирзянов Г.С. Народы Среднего Поволжья и Южного Урала в панораме веков. К., 1995; Фахрутдинов Р.Г. История татарского народа и Татарстана. К., 2000; Артамонов М.И. История хазар. СПб., 2001; Гумилёв Л.Н. Открытие Хазарии. М., 2006.

Ф.Г.Миңнеханов.

ХӘЗӘ́Р ТЕЛЕ́, Түбән Идел буе, Дагстан, Әзәрбайҗан, Кубань буе, Азов буе далалары, өлешчә Төньяк Кара диңгез буе һәм Кырым далаларын биләгән Хәзәр каганлыгы (7 йөзнең 2 нче яртысы — 10 йөз уртасы) халкының теле. Болгар төркеменә караган үле төрки телләрнең берсе. Язуы — рун язуы (к. *Борынгы төрки рун язуы*), ш.у. яһүдләр язуы да файдаланылган. Х.т. турында мәгълүматлар бик аз. Ул болгар һәм күрше фин-угор халыклары телләре б-н үзара тығыз мөнәсәбәттә була. Хәзәр чыгышлы сүзләрнең шактый гына тарихи топонимнары бар дип фаразлана, мәс., Идел / Ител (Әтил) — бөек елга, Саркел / Сарыг-ил — сары ил яки сары йөзле кешеләр иле, Бәк Тарлыв / Тарлув — сөрүлек җирләргә бай, Сәмәндәр / Самандар — салам б-н тулган урын һ.б.

Әд.: Артамонов М.И. История хазар. Л., 1962; Баскаков Н.А. Введение в изучение тюркских языков. М., 1969; Плетнёва С.А. Хазары. М., 1976; Закиев М.З. История татарского народа. М., 2008.

М.З.Зәкиев.



ХӘЗӘРЛӘ́Р, 4 йөздә *Халыклар-ның бөек күчеше* барышында Көнчыгыш Европага килеп чыккан һәм Көнбатыш Каспий буе далаларында Сулак (Төньяк Дагстан) һәм Идел (аның түбән агымында) елгалары арасында күчмә тормыш алып барган төрки телле халык. *Хәзәр каганлыгының* төп халкы. Х. өч этник компонентның — җирле иран телле халык, күчеп килгән угор һәм төрки кабиләләрнең үзара йогынтысы нәтиҗәсендә формалаша. Х.нең этник яктан килеп чыгышына нисбәттә бернинчә караш яшәп килә. Танылган археолог М.И.Артамоновның һәм тарихчы А.П.Новосильцевның Х.нең уйгырлар, *савирлар* һәм Алтай төркиләре тарафыннан оешкан кабилә берлегеннән килеп чыгуы турында фикерләре өстенлек итә; ш.у. *барсиллар* һәм *бәрән-җәрләр* дә Х. б-н тыгыз этник бәйләнештә була. Кабилә берлеге буларак Х. бик борынгы заманнардан билгеле. Х. һәм барсилларның 193 һәм 213 елларда Әрмәнстанга уртак яулары хакында беренче тапкыр Моисей Хоренскийның «Әр-

мәнстан тарихы»нда (5 йөз) искә алына. 4–5 йөзләрдә Х. Дәрбәнттән төньяктарак яшиләр, 6–7 йөзләрдә Кырымда, Донда һәм Түбән Идел буенда урнашалар. 6 йөзнең 2 нче яртысында Төркн каганлык барлыкка килгәч, Х. дә аның составына керә. 7 йөзнең уртасында, Көнбатыш Төркн каганлык таркалганнан соң, алар Көнчыгыш Европадагы беренче урта гасырлар феодаль дәүләтен — Хәзәр каганлыгын төзиләр. *Бөек Болгар дәүләте* таркалгач (660 еллар), Х. Азов яны далаларын, Төньяк Кара диңгез буен, Кырым далаларының бер өлешен яулап алалар һәм 7 йөз ахырында — 8 йөз башында терр. яктан Византиягә якынаялар, аның б-н союздаш мөнәсәбәтләр урнаштыралар. Х.нең башлангыч дини ышанулары Тәңрегә табыну һәм каганны ила һилаштыруга корылган гомумтөркн мәжүси ритуаллардан тора. Аннары Хәзәр каганлыгында өч монотеистик дин (православие, ислам, иудаизм) һәм мәжүсилек янәшә яши. Х.нең Византия б-н үзара тыгыз бәйләнеше алар даирәсенә христианлык үтеп керүгә булышлык итә. 8 йөзнең 1 нче яртысыннан башлап, Х. каганлык терр-ясенә басып кергән Гарәп хәлифәлеге гаскәрләренә каршы сугыш алып баралар (к. *Гарәп-хәзәр сугышлары*). 737 дә гарәпләр каган армиясен тар-мар итәләр; шул чордан башлап, Хәзәр каганлыгының төркн телле кабиләләре (хәзәр, болгар һ.б.) арасында ислам дине киң таралыш ала. Шул ук вакытта яһүд общинасы позицияләре дә ныгый. 8 йөз ахырыннан — 9 йөз башыннан алып каганлыкның хакимлек итүче аксөякләре арасында раввиннар иудаизмы дәүләт дине булып китә. 8 йөздән Х.дә элгәреге феодаль мөнәсәбәтләр туа башлый (утраклыкка күчү, шәһәрләр барлыкка килү, эчке һәм тышкы сәүдә үсеше һ.б.). Төп шөгыльләр күчмә терлекчелек, игенчелек, бакчачылык, шәраб ясау, балыкчылык була; *Итил*, *Бәрәнҗәр*, *Сәмәндәр*, *Саркел* шәһәрләрендә һөнәрчелек җитештерүе үсеш ала. Сөрү җирләре һәм көтүлекләр, балыкчылык һәм аучылык биләмәләре ырулар арасында бүленә. Салым сыйфатында һәр хәзәр гаиләсе каганга кеш тиресе бирә. 9–10 йөзләрдә Хәзәр каганлыгы икътисады халыкара (ш.и. транзит) сәүдәгә таяна. Х. Византия, Көнчыгыш Европа, Урта Азия, Кавказ арты илләре б-н актив сәүдә-икътисади багланышлар үстерәләр. Х.нең Дон буенда, Азов яны һәм Түбән Идел буенда казу эшләре вакытында табылган археол. истәлекләр *Салтау-маяк культурасына* карый. Торулык һәм торак калдыклары, каберлекләр, аларда табылган бронза, көмеш һәм алтын бизәнү әйберләре, металл, түлмәкчелек эшләнмәләре, катлаулы төзелешле җәяләр, Византия акчалары, балалар уенчыклары һ.б. җитәрлек дәрәҗәдә бай игенчелек һәм һөнәрчелек культурасы, алга киткән сәүдә, хәрби эшнең югары үсешкә ирешүе хакында сөйли. Дини культларның төрлелеге төрле мәдәниятләр йогынтысы таралуга китерә. Х. нең болгарлар һәм Евразиянең башка төркн каби лә ләре б-н якын этник туганлыгы аларда рун язуы таралуга булышлык итә (к. *Борынгы төркн рун язуы*), аксөякләр яһүд язуыннан файдалана; Итилдәге мөселман мәктәпләрендә укыту гарәп телендә алып барыла. Бердәм мәдәниятнең, әдәби телнең һәм язуның булмавы Х.нең мәдәни яктан тупланuының җитлекмәве турында сөйли, бу дәүләт таркалуда төп сәбәпләрнең берсе була. 9 йөз ахырында Көнчыгыш Европа далаларына бәҗәнәкләр басып керә, алар, С.А.Плетнёва фикеренчә, «чынлыкта (Хәзәр) каганлыгын юкка чыгаралар», аның икътисадын җимерәләр. Каганлык халкының бер өлеше юк ителә, бер өлеше күчмә бәҗәнәкләр составына керә. Хәзәр каганлыгына Киев кенәзләре Святослав (965) һәм Владимир (985) яуларыннан соң бу дәүләт юкка чыга, аның җирләре башка дәүләтләр һәм кабилә берлекләре составына керә. Түбән Идел буенда Идел буе Болгар дәүләте йогынтысы көчәя, Азов яны, Дон буе, Төньяк Кавказ җирләре бәҗәнәкләргә буйсына, Х. үзләре болгарлар, бәҗәнәкләр, кыпчаклар, башка халыклар һәм кабилә берлекләре даирәсендә йотыла.

Әд.: Плетнёва С.А. Хазары. М., 1976; Сабирзянов Г.С. Народы Среднего Поволжья и Южного Урала в панораме веков. К., 1995; Артамонов М.И. История хазар. СПб., 2001; Гумилёв Л.Н. Открытие Хазарии. М., 2006.

Ф.Г.Миңнеханов.

ХӘЗЕРГЕ ЗАМАН МУЗЫКАСЫ ҮЗӘГЕ, София Гобәйдуллина исемендә, Казанда. ТР МКның 2002 ел 31 май һәм композиторга 70 яшь тулу уңаеннан Казан шәһәре хакимияте башлыгының 2001 ел 13 апрель карарлары нигезендә оеша. Казан шәһәре хакимиятенең мәдәният бүлеге карамагында. Хәзерге заманның мәшһүр композиторы София *Гобәйдуллинаның* балачагы һәм яшьлеге узган (1932–53) Тельман урамындагы 29 нчы йортта урнашкан. Үзәк не оештыру эше б-н «Прометей» экспериментальэстетика фәнни-тикшеренү ин-ты директоры Б.М.*Галиев*, ТРның Композиторлар берлеге рәисе Р.Ф.*Кәлимуллин* һ.б. шөгыльләнә. 2003 тә Үзәк җирлегендә А.Волченко җитәкчелегендәге «Яңа музыка ансамбле» оеша. 2011 дә С.Гобәйдуллинаның 80 еллыгына Үзәк үзгәртеп корыла, аның эшчәнлеге (эшчәнлегенең төрләре) шактый киңәя: фестивальләр һәм заманча музыка концертлары, мастер-класслар, халыкара заманча музыка фестивальләре чикләрендә фәнни укулар (*«Европа-Азия»*, «MUS-Transit», «XXI гасырда классик гитара» («Классическая гитара в XXI веке»); зурлар өчен «Брависсимо» якшәмбе абонементы) оештыра. Төп проектларының берсе — «София Гобәйдуллинаның музыка дөньясы» («Мир музыки Софии Губайдулиной») программасы. Ул композиторның мемориаль бүлмәләре б-н таныштыру,



Казанда София Гобәйдуллинаның Хәзерге заман музыкасы үзәге бинасы.

«тере» музыкага кушылып баручы видеоматериаллар күрсәтү рәвешендә төрле вариантта эшләнә. 2011 дә Үзәк каршында «Полутон» ижади һәм социаль технологияләр лаб-ясе төзелә. «София Гобәйдуллина дуслары клубы» («Клуб друзей Софии Губайдулиной») эшли. Гобәйдуллина музыкалары һәм рәсемдә балалар фантазияләре темаларына күргәзмә оештырыла. Директоры — Л.И.Гарифуллина (2011 дән).

Ф.Ә.Әхмәтшина.

ХӘЗЕРГЕ ЗАМАН ТЕАТРЫНЫҢ КОНСТРУКТИВ-ТӘҖРИБӘ ОСТАХАНӘСЕ (КЭМСТ), актёрлар, рәссамнар, шагыйрьләрнең иҗат берләшмәсе. Казанда 1923–26 елларда Сәнгатьнең сул фронты (*ТатЛЕФ*) эшчәнлегенең бер юнәлеше буларак эшли. Иң элек Б.Н.Симолин, И.В.Пшеничный, М.В.Барашов, С.В.Виноградов, С.Д.Казаков, К.И.Сотониннар башлангычында «КЭМСТ театр тамашалары остаханәсе» исемендәге төркем оеша. Аның максатлары — театрның сәнгатьчә чараларын төптән яңарту, сәхнәдә революцион репертуарны раслау, театрның рев-ция бурычларына һәм яңа тормыш төзүгә хезмәт итүе. Төркем Казан Зур драма театры студиясен, совет партия мәктәбенең клуб бүлеген тәмамлаучылардан, һә-



«КЭМСТ» театры труппасы. 1924.

вәскәрләрдән тора. КЭМСТ каршында студияләр оеша, анда В.Э.Мейерхольд һәм Н.М.Фореггер методикалары буенча дәрес ләр уздырыла. Төркем, нигездә, Тимерьюлчылар йортында, Үзәк коммунистлар клубында, «Пассаж», Татар дәүләт, «Весёлый сатир» театрларында тамашалар күрсәтә. Театрның сәнгать җитәкчесе Б.Н.Симолин була. Рәссамнары — М.В.Барашов, К.К.Чеботарёв, А.Г.Платунова; күп кенә спектакльләрнең текст авторлары — В.А.Симолин, И.В.Пшеничный. Беренче спектакльләре — «Хан кызы Турандык» («Принцесса Турандот», К.Гоцци), «Степан Разин» (В.В.Каменский), «150000000» һәм «Мистерия-буфф» (В.В.Маяковский) (барысы да — 1923 тә). Әлеге спектакльләр үзләренең гадәти булмаган формалары (бизәлеш шартлылыгы, хәрәкәт байлыгы, мизансценаларның плакатлылыгы, вакыйгага табигый рәвештә кушылып киткән җырлы һәм биюле номерларның киң кулланылышы) аркасында кискен бәхәсләр тудыра. Аннан соң куелган «Тормыш җырчысы» («Жизнепев», И.В.Пшеничный, 1923), «Ач күзеңне!» («Разуй глаза!», Б.Н.Симолин, 1924), «Противогазлар» (С.М.Третьяков,



«КЭМСТ» театры спектакленә афиша. «Гамлет», У.Шекспир. 1925.

1924) спектакльләре яңа тормыш өчен революцион көрәш пафосы һәм чынбарлыкның тискәре якларына үткен сатирик караш б-н суга рылган. Беренче бөтендөнья сугышы башланугa 10 ел тулу уңаеннан, 1924 нең августын да КЭМСТ Казан урамнарында һәм мәйданнарында массакүләм театраль тамашалар күрсәтә. Репертуарының шактый өлешен скетчлардан, такмаклардан, бию номерларыннан торган программалар тәшкил итә. Алар арасында Казан тормышының көнүзәк актуаль мәсь әләләрен яктырткан «машиналар биюе» дип йөртелгән кыска сәхнә номерлары аеруча уңыш казана. Спектакльләр эшчеләр клубларының, гаскәри частьларның сәхнә мәйданчыкларында, студентлар аудиторияләрендә уза. Ахырдан дискуссияләр үткәрелә, күргәзмәләр оештырыла, театр сәнгатенең үсеш юллары, совет сәнгатендә яңа юнәлешләр турында әңгәмәләр, бәхәсләр алып барыла.

КЭМСТ идеологлары К.И.Сотонин, Я.П.Гамза (Гамсахурдия), В.В.Маяковский, В.Э.Мейерхольд, С.М.Третьяков, С.М.Эйзенштейн идеяләренә таянып, футуризм һәм пролеткульт турында докладлар б-н чыгышлар ясыйлар. КЭМСТның төп казанышларын яктырткан «Гамлет» (шул исем. әсәр буенча, У.Шекспир) һәм «Дөньяны шаулаткан 10 көн» («10 дней, которые потрясли мир», Д.Рид) спектакльләре (икесе дә — 1925 тә) Казанның театр тормышында зур вакыйга була. Шуның б-н бергә төркемнең үз эчендә заманча һәм классик драматургия материалы нигезендә театраль осталыкка ирешү ягында булганнар б-н театрны фәкать көн кадагына суга торган фактик материалны гына кече формаларда файдаланучы агитацион коллективка әверелдерүне хуплаучылар арасында каршылыклар туа башлый. 1925 нең көзендә КЭМСТ һәм «Кызыл блуза» («Красная блуза») коллективлары В.П.Пономарёв җитәкчелегендә берләштерелә. 1926 ның февралендә Б.Н.Симолин төркемне тарката, аның кайбер әгъзалары Казаннан китә, кайберләре 1927 дә кабат оешкан ТСПС (Татарстан проф. оешмалары советы) Күчмә театрына эшкә күчә. 1924–28 елларда КЭМСТның кайбер эшлеклеләре, ш.и. Б.Н.Симолин, И.Г.Ингвар, К.К.Чеботарёв Татарстан театр техникумында эшли (аларның шәкертләре — Х.Сәлимҗанов, Р.Ишморат, Ф.Саллави, К.Тумашева һ.б.). КЭМСТ эшчәнлеге 1920 елларда Казанның театр тормышында аеруча сизелерлек эз калдыра, ул рус һәм татар театрлары үсешенә шактый гына йогынты ясый, хореография сәнгатен баета.

Әд.: Ингвар И. Три «Мистерии» в один день // Театральная жизнь. 1973. № 13; шул ук. 1924 год, Казань // Театр. 1977. № 6; Благов Ю. КЭМСТ. К., 2005.

Ю.А.Благов.


ХӘЗИНӘ (тарихи), яшерелгән, ешрак җиргә күмелгән, иясе тарафыннан югалтылган һәм соңрак очраклы рәвештә табылган кыйммәтле әйберләр. Татарстан терр-ясендә зур тарихи кыйммәткә ия шактый күп Х.ләр табылган. Иң элгәреләре бронза һәм элгәреге тимер гасыры чорларына нисбәт ителә (мәс., Әлмәт р-нында Дербедень бронза эшләнмәләр Х.се). Болгар чорына караган Х.ләрнең күпчелек өлеше, нигездә, эәркән эшләнмәләр һәм акчалардан гыйбарәт; мәс., Көнбатыш Кама аръягында *Бутаиха хәзинәсе*, болгар осталарының Юеш Көрнәле (Кочнаевский) һ.б. эәркән эшләнмәләре Х.ләре табыла. Татарстан терр-ясендә 20 дән артык көмеш дирһәмнәр (10 йөзнең 2 нче яртысы — 11 йөз башы) Х.ләре, республиканың көнчыгышында — Урта Азиядән һәм Ираннан китерелгән Репьевка (9 йөз) һәм Мәлкән (13 йөз) көмеш савыт-саба Х.ләре табыла. *Жүкәтау хәзинәсе*, *Карашәм хәзинәсе* һ.б., 25 меңгә якын жүчиләр акчаларыннан торган Каратун Х.се (кайбер галимнәр аны Туктамыш хан казнасы дип саный) Алтын Урда чорына карый.

Әд.: Даркевич В.П. Художественный металл Востока. М., 1976; Клады: состав, хронология, интерпретация. СПб., 2002.

Е.П.Казаков.

«ХӘЗИНӘ», Казанда милли сәнгать галереясы. 2004 елда ТР МК Карары нигезендә *Татарстан Республикасының Дәүләт сынлы сәнгать музее* ф-лы буларак оештырыла. 2005 нең 23 августында ачыла. *«Казан Кремле»* музей-саклаулыгы терр-ясендә элекке юнкерлар уч-щесе бинасында урнаша. Экспозиция мәйданы — 2665 *м*^{2}. Фондларында 4 меңнән артык саклау берәмлеге исәпләнә. Даими экспозициядә — 18 йөз — 21 йөз башы Татарстан сынлы сәнгать һәм гамәли бизәлеш





«Хәзинә» милли сәнгать галереясы. 1. Гомуми күренеше. 2. Экспозиция фрагменты.

сәнгате әсәрләре. Татар сынлы сәнгатенә нигез салучы Б.И.Урманче иҗаты монографик рәвештә тәкъдим ителә. Х.Г.*Якуповның* үз әсәрләреннән торган шәхси галереясы да бар. «Х»нең күргәзмәләре хәзерге заман милли һәм төбәк, туган як һәм дөнья сынлы һәм гамәли бизәлеш сәнгатьләрене ң үсеш процессларын чагылдыра.

ХӘЙБУ́ЛЛИН Илдус Барый улы (11.10.1937, Норлат р-ны Норлат а. — 23.2.2007, Казан), физик химия белгече, физика-матем. фән. д-ры (1985), РФА мөхбир әгъзасы (1992), ТР ФА академигы (2001; 1994 тән мөхбир әгъза), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1995), ТАССРның атказ. уйлап табучысы (1991). Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң (1960), 296 нчы з-дта (хәзер «Элекон» җитештерү берләшмәсе) эшли. 1966 елдан РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында, директор урынбасары (1988–92), бер үк вакытта радиацион физика лаб-ясе мөдире (1989–2007), проф. (1991). 1992 дән ТР ФА баш гыйльми сәркәтибе. ТР ФАн оештыруга зур өлеш кертә. Хезмәтләре югары энергетикалы ион һәм импульс бәйләмнәре б-н матдә арасындагы тәэсирләшү физикасына карый. 1973 тә М.М.Зарипов б-н берлектә ярымүткәргечләрне лазер б-н яндырып чыныктыру күренешен ача (СССР Дәүләт бүләге, 1988). Х. материалларның (ярымүткәргечләр, металлар һәм диэлектрикларның) ионлы-импульслы модификацияләшүенең физик нигезләрен эшли. Ионнар яудырганда ярымүткәргечле кристаллар аморфлашуының механизмнарын һәм төп закончалык-


И.Б. Хәйбуллин.


Г.Х. Хәйдәршин.


Ә.М.Хәйретдинов.


З.Г.Хәйретдинов.

ларын билгели; нурландырылган ярымүткәргечләрдә оптик үзлекләр үзгәрешенең табигатен ачыклый. Аномаль югары вакансион кабару, имплантацияләнгән ярымүткәргеч - ләрне лазер б-н яндырып чыныктырганда алыштыру катышмаларының аномаль югары эрүчәнлеге эффектларын; германийның ультрадисперс халәткә структуралы күчүен, германийның металл модификациясенә поли - морф рәвештә күчү күренешләрен ача. Күчемле металлар силицидларының ион синтезы процессының төп закончалыкларын билгели; юка ярыларның ионнар б-н стимуллаштырылган адгезия эффектының табигатен һәм закончалыкларын, импульслы якты лык б-н эшкәрткәндә ярымүткәргечләрнең җирле анизотроп эрүе эффекты механизмын ачыклый. Голограммалы дифракцион рәшәткәләрне ясау технологиясенең фәнни нигезләрен эшләгәне өчен СССР ФАнең һәм Германия Демократик Респ-касы ФАнең Халыкара бүләкләре (икесе дә 1988 дә), ТР Дәүләт бүләге (1998), Электроника һәм электрон техника инженерлары ин-тының Дж.Гиббонс исем. бүләгенә (АКШ, 2009, үлгәннән соң) лаек була. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Локальный лазерный отжиг полупроводниковых ионно-легированных слоёв // Физика и техника полупроводников. 1975. Т. 9, вып. 10 (автордаш); Влияние имплантации ионов меди на оптические свойства и низкотемпературную проводимость углеродных плёнок // Физика и техника полупроводников. 2006. Т. 40, вып. 4 (автордаш); Окрашивание кристаллов рутила путём имплантации ионов марганца, железа и кобальта // Уч. зап. Казан. ун-та. Сер. Естеств. науки. 2006. Т. 148, кн. 1 (автордаш).

Әд.: Учёный-новатор // Науч. Татарстан. 1997. № 3/4. *Р.Г.Усманов.*

ХӘЙБҮ́ЛЛИН Ринат Рәшит улы (10.7.1960, Казакъстан ССР, Семипалатинск өлкәсенең Жармин р-ны Боко пос.), спортчы (альпинист), СССРның атказ. спорт остасы (1989), халыкара класслы спорт остасы, Казакъстан ССРның атказ. тренеры. Тау түбәләрен яулаучы «Ак барыс» титулы иясе. Алма-Ата энергетика ин-тын тәмамлый. 7 мең *м* биеклектәге тау түбәләренә һәм 8 мең *м* биеклектәге пикларга 30 тапкырдан артык күтәрелә. Һималай экспедицияләрендә катнаша. 1989 елда 2 нче совет Һималай экспедициясендә катнаша, Канченджанга тау массивының Көньяк һәм Баш түбәләренә күтәрелә; әлеге казанышы өчен «Хезмәттәге батырлык өчен» медале б-н бүләкләнә. 1990 да ВЦСПС җыелма командасы составында Лхоцзеның көньяк сыртына күтәрелүдә катнаша. 1991 дә Казакъстан экспедициясе составында Дхаулагири тау массивының аңа кадәр яуланмаган көнбатыш сыртына күтәрелә. Корженевская, Коммунизм, Хан-Тәңре, Җиңү пикларына ялгыз күтәрелә. 1992 дән — «Аллиберт Азия» казакъ-француз туристик фирмасы, 1996–2002 дә «Азия туризм» туристик фирмасы җитәкчесе. 1996–2007 дә Казакъстан Респ-касы Оборона министрлыгы Үзәк армия спорт клубының альпинизм буенча тренеры. 2002–08 дә Алма-Атаның коткару хезмәте директоры.

ХӘЙБҮ́ЛЛИН Рөстәм Илдус улы (16.12.1962, Казан), физик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2011), физика-матем. фән. канд. (1991). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1985), шунда ук эшли. 1992 елдан РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында. Хезмәтләре үзле һәм каты полимерларда магнит нанокисәкчәләренең ион-нур синтезы процессларына, ион бәйләмнәре б-н радиацион-хи - мик йогынты ясаганда төрле минераллар-ның төссез кристалларында буялыш үзәкләре барлыкка килүнең физик механизмнарын өйрәнүгә карый. Дәүләт бүләге «Зәркән ташларын яхшырту нанотехнологиясе» хезмәтләре циклы өчен бирелә.

Х е з м.: Возможности ионной имплантации в геммологии // Уч. зап. Казан. ун-та. Сер. Естеств. науки. 2006. Т. 148, кн. 4 (автордаш); High Curie-temperature ferromagnetism in cobalt-implanted single-crystalline rutile // Journal of Physics: Condensed Matter. 2004. V. 16 (автордаш).

ХӘЙДӘ́Р (тулы исеме Зәетгали Хәйдәрбәк) (19 йөз), төрек язучысы. Казан ханлыгы чорының фаҗигале вакыйгалары турында «Шahгали хан» тарихи драмасы авторы. 1910–20 елларда күп кенә татар театрларында куела.

ХӘЙДӘ́РОВ Рафик Әхмәт улы (21.2.1950, Казан), геолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2003), РФнең мактаулы җир асты байлыклары разведчигы (2009). Казан ун-тын тәмамлый (1972), ЦНИИгеолнерудта эшли, минерал-петрографик тикшеренүләр лаб-ясе мөдире (1990 елдан). Хезмәтләре геология, минералогия, файдалы казылмалар технологиясенә карый. Дәүләт бүләге ТРның руда булмаган файдалы казылмалары кулланылышының яңа минераль-технол. чишелешләрен булдыруы һәм гамәлгә кертүе өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

ХӘЙДӘ́РШИН Гайнанша Хәйдәрша улы (5.2.1911, хәзер БРның Яңавыл р-ны Байгуҗа а. — 4.12.2006, шунда ук), Сов. Союзы Герое (22.2.1944), гв. рядовое. Сапёрлар курсларын тәмамлый (1941). Туган авылында колхозда эшли. 1941 елның июненнән Кызыл Армиядә. 1942 нең февраленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 117 нче гв. аерым сапёрлар батальонының отделение командиры (37 нче армиянең 110 нчы укчы дивизиясе). Төньяк Кавказ һәм Дала фронтлары гаскәрләре составында Кавказ (1942–43) һәм Днепр елгасы (1943) өчен барган сугышларда катнаша. 1943 нең 9 октябрендә Дериевка авылы янында (Украина ССРның Полтава өлкәсе, Кременчуг шәһәреннән көньяктарак) Днепр елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә: дошман уты астында кешеләрне, хәрби техниканы һәм сугыш кирәк-яракларын төяп, 27 тапкыр елга аша чыга. Плацдармдагы стратегик калкулык өчен барган сугышта шәхсән дошман танкын сафтан чыгара. Контузияләнә, әмма сафта кала. Демобилизацияләнгәннән соң (1944), Фрунзе исем. к-зда (Яңавыл р-ны) эшли. Ленин ордены, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000. *М.З.Хәбибуллин.*

ХӘЙРЕТДИ́НОВ Афзал Насретдин улы (3.1.1924, Буа кантоны Түбән Чәке а. – 29.5.2017, Казан), виолончелист, музыка белгече, педагог, ТАССР һәм РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1970, 1977), сәнгать фән. канд. (1955), проф. (1977). Казан консерваториясен (1950), П.И.Чайковский исем. Мәскәү консерваториясендә С.М.Козолупов классы буенча аспирантура (1954) тәмамлый. 1954 елдан Казан консерваториясендә укыта (1955–93 тә — кыллы музыка уен кораллары каф., 1993–98 дә альт, виолончель, контрабас һәм квартет каф. мөдире). Концерт эшчәнлеге алып бара, ш.и. соло программалар б-н дә чыгышлар ясый. Музыка сәнгате һәм музыка белеме бирү мәсьәләләренә караган мәкаләләр, рецензияләр, уку-укыту һәм методик ярдәмлекләр, татар музыкасы материалында виолончель өчен нота җыентыклары авторы. Халыкара һәм бөтенроссия виолончелистлар конкурслары жюрие әгъзасы. Укучылары арасында Россия һәм Татарстанның халык һәм атказ. артистлары, халыкара һәм бөтенроссия конкурслары лауреатлары һәм дипломантлары А.Әсәдуллин, А.Виноградов, А.Дворников, Л.Исмәгыйлова, И.Лаптева, Л.Маслова, С.Товстуха һ.б. бар. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз, «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Әс ә р.: Музыкальное образование в Татарии // Уч. зап. Казан. консерватории. 1970. Вып. 4; Сборник пьес композиторов Татарстана для виолончели с фортепиано. М., 1982; Казанская государственная консерватория. К., 1988 (автордаш); Истоки // Казань. 1996. № 5/6; Первые // Казань. 2005. № 5.

Әд.: Война и мир Афзала Хайрутдинова. К., 2009. *Ф.Ш.Салитова.*

ХӘЙРЕТДИ́НОВ Әкрам Мин һаҗ улы (1924, Бөгелмә кантоны Түбән Чыршылы а. – 26.3.1944, Украина ССР, Николаев ш.), Сов. Союзы Герое (20.4.1945, үлгәннән соң), матрос. 1943 елдан Бөек Ватан сугышы фронтла-

рында Хәрби-диңгез флотында. 1944 нең 26 мартына каршы төндә 3 нче Украина фронты 28 нче армиясе диңгез пехотасының 384 нче аерым батальоны составында Николаев портында (Украина ССР) батырлык күрсәтә: десантчылар төркеме б-н дошман тылына төшерелә, ике тәүлек отряд портта сугыш алып бара, дошманның 18 һөҗүмен кире кайтара; Х. сугышта һәлак була. Ленин ордены, медаль б-н бүләкләнә. Николаевта Сугыш һәм хезмәт даны халык музее ачыла, герой-моряклар һәйкәл куела. Лениногорск шәһәренең бер урамына Х. исеме бирелә. Сходнево-Чертанла авылында (Лениногорск р-ны) обелиск куела.

Әд.: Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

М.З.Хәбибуллин.

ХӘЙРЕТДИ́НОВ Зөфәр Гыйльметдин улы (5.8.1959, Питрәч р-ны Татар Казысы а.), җырчы, продюсер, ТРның халык артисты (2002). 1982 елда Казан төзүче инженерлар ин-тын, 1988 дә Казан консерваториясен (Ә.Заһидуллина классы) тәмамлый. 1987–96 да Татар опера һәм балет театры солисты. Төп опера партияләре: Кассио («Отелло» Дж.Верди), Рулевой («Очучы голландец», Р.Вагнер), Алтынбәк («Ерактагы кәккүк авазы», Р.Кәлимуллин); С.Сәйдәшевнең «Наёмщик» муз. драмасында Гәрәй роле һ.б.

1996–2002 дә ТРның С.Сәйдәшев исем. Зур концерт залы директорының концерт-иҗат эшчәнлеге буенча урынбасары, 2002 дән Россия авторлык җәмгыятенең Татарстан ф-лы җитәкчесе. Концерт программалары: «Сәфәр» (1997), «Язмыш җиле» (1999–2000) һ.б. Иҗади проектлар оештыручы, 1994–98 дә Казан, Уфа, Оренбург, Төмән, Самара, Саратов, Пермь шәһәрләрендә узган «Идел-Урал» татар җыры фестивален сәнгать җитәкчесе. «Су буенда учак яна» (Н.Касыймов шигыре), «Кайда син, гармун?» (Х.Әюпов шигыре), «Карлы яңгыр» (Н.Камал шигыре), «Кура җиләк» (С.Әхмәт җанова шигыре), «Абага чәчәге» (Р.Гаффар шигыре), «Шомырт бәйләме» (И.Хөснетдинов шигыре), «Мишәр кызы» (М.Шиһапов шигыре) һ.б. популяр җырлар авторы. 1 нче Бөтенроссия яшь җырчылар конкурсы (Пермь, 1987), М.Глинка исем. Бөтенсоюз вокалистлар конкурсы (Баку, 1987) дипломанты, Респ-ка «Татар жыры» конкурсы лауреаты (1989).

Ф.Ш.Салитова.

ХӘЙРЕТДИ́НОВ Ирек Габделхак улы (11.3.1932, Октябрь р-ны Норлат пос.), геолог, геол.-минерал. фән. д-ры (1988), проф. (1991). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1954), шунда ук эшли. 1957 елдан Урал геол.-топография экспедициясендә, 1962 дән СССР ФА Себер бүлеге Геол. һәм геофизика ин-тының Красноярск комплексы лаб-ясендә, 1964 тән Красноярск геол. идарәсендә. 1969 дан СССР ФАнең Башкорт ф-лы Геол. ин-тында, 1973 тән РФА Уфа гыйльми үзәгенең Геол. ин-тында геохимия лаб-ясе мөдире. Бер үк вакытта, 1988 дән, Башкорт ун-тында, геол. һәм геоморфология каф. мөдире (2010 га кадәр). Х. геохимиядә яңа фән-ни юнәлеш — электрохимия булдыра һәм гамәлгә кертә, аның минерал., геохимия, петрология һәм башка геол. фәннәре б-н бәйләнешен билгели. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Введение в электрогеохимию. М., 1980; Основы электрогеохимии литогенеза и гидротермального процесса. М., 1982; Электрохимические модели рудообразования. Уфа, 1997 (автордаш).

ХӘЙРЕТДИ́НОВ Марат Самат улы (22.3.1939, Казан), математик, информатика өлкәсе белгече, техник фән. д-ры (1994), проф. (1995). Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң (1962), Казан электрофизика фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1965 елдан РФАнең Себер бүлекчәсендә (Новосибирск ш.): Автоматика һәм электрометрия ин-тында, 1978 дән Хисаплау математикасы һәм матем. геофизика (лаб. мөдире, өлкән фәнни хезмәткәр), шул ук вакытта, 1995 тән, Новосибирск техник ун-тының челтәрле мәгълүмати технологияләр каф. мөдире. Хезмәтләре тоташ мохитләрдә дулкынлану процесслары, мәгълүматларны интеллектуаль анализлау һәм образларны танып белү мәсьәләләренә; геомәгълүмати һәм хисаплау технологиясе һәм системаларына карый. Х. табигый һәм техноген фаҗигаләрне фаразлау мәсьәләләрен хәл итү өчен Җирнең өске сүрүенә активмониторинг ясау алымнарын һәм мәгълүмати технологияләрен; катлаулы эшләнмәләрне акустик дефектоскопияләү максатына нисбәттә образларны танып белү алымнарын һәм мәгълүмати системаларын; биол. объектлар халәтенең классификацияләрен эшли. Халык хуҗалыгы һәм оборона мәсъәләләрен хәл итү өчен физик (акустик, сейсмик, гидроакустик, электромагнит) кырларның үзара тәэсир итешүен тикшерә.

Х е з м.: Активная сейсмология с мощными вибрационными источниками. Новосиб., 2004 (автордаш); Сейсмические процессы и катастрофы. М., 2008; Методы решения прямых и обратных задач сейсмологии, электромагнетизма и экспериментальные исследования в проблемах изучения геодинамических процессов в коре и верхней мантии земли. Новосиб., 2010 (автордаш).

ХӘЙРЕТДИ́НОВ Мәснәви Хәйретдин улы (3.3.1924, Сарман р-ны Шыгай а. — 26.6.1983, Казан), рәссам, педагог, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1968), ТАССРның халык рәссамы (1977). 1930 елдан Иваново шәһәрендә яши, сынлы сәнгать уч-щесендә укый (1939–43). 1945 тән Харьков шәһәрендә, Харьков сынлы сәнгать ин-тын тәмамлый (1951). 1951–52 дә Казан сынлы сәнгать уч-щесендә укыта, 1952 дән Харьков сәнгать фондында. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1957).



М.Х.Хәйретдинов. «Йорт төзелә». 1961.



М.Х.Хәйретдинов.

1959 дан Татарстанда, Бөгелмә сәнгать остаханәсендә (1959–73). Лениногорск музыка-сәнгать пед. уч-щесендә сәнгать-графика ф-тын оештыручыларның берсе һәм укыту-чысы (1960–76). Аның исемен йөрткән балалар сынлы сәнгать мәктәбен нигезләүче һәм директоры (1976–80). ТАССР Рәссамнар берлегенең нефть төбәге берләшмәсе (Әлмәт, Бөгелмә, Лениногрск) сәнгать советы рәисе, ТАССР Рәссамнар берлегенең Лени-



М.Х.Хәйретдинов. «Ана назы». 1971. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

ногорск сәнгать-җитештерү участогын оештыручы һәм рәссамы (1973–76). 1981–83 тә Казан сынлы сәнгать уч-щесе директоры.

Х. ТРда сынлы сәнгать үсешенә зур өлеш кертә, нефть төбәге рәссамнары коллективының иҗат эшчәнлеген оештыруда катнаша. Тематик жанрлы станлы рәсем остасы. Нефтьчеләр тормышы турында («Эштән кайту», 1961; «Оператор», 1963; «Вахтадан соң», 1967), совет авылы хезмәтчәннәре турында («Беренче», 1960; «Йорт төзелә», 1961; «Кызлар», 1965; «Татарстанда (Көтүчеләр)», 1964; «Игенче», 1971; «Печән өсте. Эштән соң», 1981), тарихи темаларга («Пётр I Полтава янында», 1951; «А.П.Чехов һәм И.И.Левитан», 1952; «Казан университеты студентлары сходкасы», 1952; «Урсалы фаҗигасе», 1975; «Габдулла Тукай», 1976), пейзажлар («Елга өстендә болытлар», 1955; «Идел өстендә», 1957; «Җәй ахыры», 1958; «Кич», «Әлмәткә юл», икесе дә — 1960; «Дала иртәсе»,



Минһаҗ Х.Хәйретдинов.

1965; «Ана назы», 1971; «Ыкта июль», 1978; «Ай калку», 1981; «Туган як», 1982) һ.б. иҗат итә. Портрет жанрына да мөрәҗәгать итә («Эшче (Букчеев) портреты», 1964; «Тукай», 1977). Х. картиналарына тирән эчтәлек һәм образларның монументаль бөеклеге, фәзаи киңлекне төс һәм яктылык аша күрсәтү, пейзажларда нечкә лиризм хас. Харьков Тимерьюлчылар сараендагы нәкышь панно авторы (1953; автордаш — А.Набивачев), Украина ССРның Горловка шәһәрендә Шахтёрлар мәдәният сарае плафонын, Лениногорскида җәмәгать биналары диварларын бизи (1970).

Респ-ка күргәзмәләрендә (1961 дән), Алма-Атада Татарстан рәссамнары (1962), «Зур Идел» (1964, 1967, 1980), РСФСРның автономияле респ-калары рәссамнары (Мәскәү, 1971), ТАССР рәссамнарының Мәскәүдә әдәбият һәм сәнгать көннәре (1980) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре 1974 тә (Лениногорск), 1983, 1991, 1999 да, 2004 тә (вафатыннан соң) (барысы да — Казанда) уздырыла. Картиналары ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Харьков сәнгать музеенда, Украина (Киев) Дәүләт тарих музеенда, Симферополь сынлы сәнгать музеенда, Әлмәт һәм Чаллы картиналар галереяларында, Лениногорск туган як музеенда һ.б. саклана. Халыклар дуслыгы ордены, медальләр белән бүләкләнә.

Әд.: Маснави Хаертдинов // Искусство Советской Татарии. Народные художники: Буклет. К., 1980; Червонная С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984; Горюнова Н., Саярова Э. Маснави Хаертдинов (1924–1983). К., 2009. *Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.*

ХӘЙРЕТДИ́НОВ Минһаҗ Хәйретдин улы (15.8.1905, хәзер Оренбург өлкәсенең Абдуллин р-ны Яңа Якуп а. — 4.2.1970, шунда ук), Сов. Союзы Герое (24.3.1945), сержант. 1943 елның февраленнән Кызыл Армиядә, маеннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 597 нче артиллерия полкының (3 нче Белоруссия фронты составындагы 5 нче армиянең 159 нчы укчы дивизиясе) туп командиры. 1944 нең 7–16 августында Рудзе һәм Бойтеле авыллары янында (Литва ССРның Шакяй р-ны) барган сугышларда батырлык күрсәтә: 3 немец танкын сафтан чыгара, 15 ут ноктасын баса-ра, дошманның күп санлы солдатын юк итә. Демобилизацияләнгәннән соң (1945), туган авылында яши һәм эшли. Ленин ордены, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000. *М.З.Хәбибуллин.*

ХӘЙРЕТДИ́НОВ Миргасыйм Насретдин улы (15.3.1926, Казан губ., Баулы өязе Уба а. — 15.6.2006, Казан), геолог, СССРның мактаулы нефтьчесе (1976), ТАССРның атказ. нефтьчесе (1979), РСФСРның атказ. геологы (1982). Львов политехник ин-тын тәмамлаганнан соң (1949), «Татнефтегазразведка» трестында эшли, 1967 елдан идарәче. 1986–91 дә Казан геол. экспедициясе башлыгы. Х. җитәкчелегендә ТР, Удмурт Респ-касы һәм Көнбатыш Себер терр-ялә-рендә 100 дән артык углеводород чыганаклары ачыла. 2 Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр; ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

ХӘЙРЕТДИ́НОВ (Хәйретдин) Мөҗәй (Мөжәһит) Хәйретдин улы (26.3.1901, хәзер БРның Октябрьский ш. — 4.9.1944, Дахау), шагыйрь. 1919 елдан Кызыл Армия сафларында. Гражданнар һәм Бөек Ватан сугышларында катнаша. 1920 еллар ахырыннан вакытлы матбугатта шигырьләр, хәрбиләр тормышыннан очерклар, хикәяләр бастыра башлый. 1942 дә Харьков янындагы сугышларда әсирлеккә төшә, Дахау концлагерена ябыла. «Хәрби әсирләрнең туганлык союзы» («Братский союз военнопленных») эшендә катнашканы өчен үлем җәзасына дучар ителә. Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән үк «Сугыш язмалары» исемле көндәлек (1968) алып бара. Аерым шигырьләре «Алар сафта» (1961), «Өч яугир шагыйрь» («Три поэта-воина», 1979) коллектив җыентыкларына керә.

ХӘЙРЕТДИ́НОВ Мөслим Гатият улы (27.9.1948, Куйбышев өлкәсенең Келәүле р-ны Яңа Усман а.), инженер-механик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2008), ТРның атказ. химигы (2008). Куйбышев политехника ин-тын тәмамлаганнан соң (1971), «Кварт» АҖдә эшли: цехта инженер-механик, баш механик урынбасары, баш механик, баш инженер (1988 елдан), ген. директор (2005 тән). Уйлап табуга 5 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Дәүләт бүләге яңа буын композицион материаллар — ТРда җитештерелә торган зур тонналы полимерлар нигезендә динамик термоэластопластырь эшләүдә һәм җитештерүне оештыруда катнашканы өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

ХӘЙРЕТДИ́НОВ Рамил Равил улы (16.6.1964, Буа р-ны Килдураз а.), тарихчы, тарих фән. канд. (1993). ТРның фән һәм техника өлкәсендәге (2008), Г.Тукай исем. (2016) Дәүләт бүләкләре лауреаты. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1986), ТР ФАнең Тел, әдәбият, һәм тарих ин-тында эшли. 1997 елдан ТР ФАнең Тарих ин-тында: Тарихи һәм мәдәни истәлекләр тупланмасы бүлеге мөдире, директор урынбасары (1998–2011), бер үк вакытта, 2007–12 дә, *«Казан Кремле»* музей-саклаулыгы директоры; 2011–13 тә Казан ун-тының Тарих ин-ты, 2013 тән Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү ин-ты директоры. Хезмәтләре Казан төбәгендә 18–19 йөзләрдәге җирле идарә, татар сәүдәгәрләре, Татарстан финанс оешмалары тарихына карый. Татар халкы һәм Татарстан тарихи истәлекләрен, мәдәни мирасны саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен өйрәнүгә мөһим өлеш кертә. Казан ун-тының археографик экспедицияләрендә (1981–86), Тарих ин-ты тарафыннан Урта Идел терр-ясендә татар халкы тарихына кагылышлы истәлекләрне барлау максатында оештырылган экспедицияләрдә (1997 дән) катнаша. 1996–2001 дә ТР МК каршындагы «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» ТР Законын гамәлгә ашыру ком-тының Респ-ка ономастика комиссиясе рәисе, топонимика өлкәсендә норматив-хокукый база булдыруда катнаша. ТР Президенты каршындагы Геральдика советы рәисе (2006 дан). Казан, Алабуга шәһәрләренең 1000 еллык юбилейлары, «Бөек Идел юлы» проекты кысасында үткәрелгән чараларны координацияләүчеләрнең берсе. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Республика Татарстан: памятники истории и культуры татарского народа (конец XVIII — начало XX вв.). К., 1995 (автордаш); Очерки истории Национального банка Республики Татарстан. К., 2000 (автордаш); Управление государственной деревней Казанской губернии (конец XVIII — первая треть XIX в.). К., 2002; Исторические мечети Казани. К., 2005 (автордаш).

ХӘЙРЕТДИ́НОВ Рафаил Фәттах улы (1947, Магнитогорск ш. — 2006, Мәскәү), физик химия белгече, физика-матем. фән. д-ры (1980), проф. (1991). 1970 елда Мәскәү физика-техника ин-тын тәмамлый, 1974 тән РФАнең Химик физика ин-тында, 1987 дән электрон процесслар динамикасы лаб-ясе мөдире, бер үк вакытта, 1991 дән, Мәскәү физика-техника ин-тында. Хезмәтләре конденсацияләнгән фәзадагы химик процессларның кинетикасына һәм механизмнарына, нанокисәкчәләр фотохимиясенә, фотосинтезга, электронны туннельләү физикасына карый. Х.ның пычрак суларны чистарту буенча фәнни эшләре текстиль сәнәгать пр-тиеләрендә гамәлгә кертелә. Уйлап табуга 5 авторлык таныклыгы һәм патенты бар.

Х е з м.: Туннельный перенос электрона на большие расстояния в химических реакциях // Успехи химии. 1978. № 47, № 6 (автордаш); Химия полупроводниковых наночастиц // Успехи химии. 1998. № 67, № 2.

ХӘЙРЕТДИ́НОВ Риф Галәветдин улы (25.1.1935, Балтач р-ны Кенәбаш а. — 19.1.2007, Казан), тарихчы, тарих фән. д-ры (1979), проф. (1982), ТССР, РФнең атказ. фән эшлеклесе (1990, 2003). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1963), шунда ук эшли (бүленеп: 1980–86 елларда Казан төзүче инженерлар ин-тының КПСС тарихы каф. мөдире), 1987 дән КПСС тарихы каф. (1991 дән — сәяси партияләр һәм иҗтимагый хәрәкәтләр тарихы каф.), 1997 дән Татарстан тарихы каф. мөдире. Хезмәтләре Идел һәм Урал буенда милли-дәүләт төзелешенә, милләтара мөнәсәбәтләр тарихына карый. «Авыр яңарыш (1917 елның феврале — 1920 еллар)» («Трудное возрождение (февраль 1917 — 1920 гг.)», 1992) китабында Х. Гражданнар сугышы һәм татар халкының социаль һәм милли азатлык өчен көрәше шартларында совет дәүләте уздырган милли сәясәтнең үзенчәлекләрен яңа яктан ача. Г.Әхмәровның сайланма әсәрләрен әзерли һәм бастырып чыгара.

Х е з м.: На путях к советской автономии: Проведение ленинской национальной политики Центральным татаро-башкирским комиссариатом в 1918–1919 гг. К., 1972; Осуществление Коммунис-

тической партией ленинской программы по национальному вопросу в 1917–1920 гг.: По материалам Поволжья и Приуралья. К., 1976.

Әд.: Тюркологи современного Татарстана: Справ. М., 1997; Профессора исторического факультета Казанского университета (1939 — 1999): Биобиблиогр. словарь. К., 1999.

ХӘЙРЕТДИ́НОВ Фәрит Миргасыйм улы (27.3.1950, Апас р-ны Ишеево а.), геолог-нефтьче, ТР, РФнең атказ. геологы (1994, 2002). Казан ун-тын тәмамлый (1972), «Татнефть» АҖдә эшли. 1997 елдан ТРның Геол. һәм җир асты байлыкларыннан файдалану дәүләт ком-ты рәисе. 2001–10 да «Россия инновацион җылылык-энергетика компаниясе» АҖнең (Мәскәү) Геология, нефть чыганакларын эшкәртү һәм лицензияләү департаменты директор-координаторы. Яңа Елховой чыганагын һәм Ромашкино чыганагының аерым участокларын файдалану системаларын камилләштерүдә катнаша. Уйлап табуга 6 авторлык таныклыгы бар. АКШның Хьюстон геол. җәмгыяте шәрәфле әгъзасы (1992). Медальләр б-н бүләкләнә.

ХӘЙРЕТДИ́НОВА Клара Әкрам кызы (27.7.1948, Казан), җырчы (лирик-драматик сопрано), педагог, ТРның халык артисты (1995), РФнең атказ. артисты (2011). Казан консерваториясен (В.Лазько классы) тәмамлый (1979). 1971–72, 1979–80 елларда — Татар филармониясе, 1980–2006 да Татар опера һәм балет театры солисты, бер үк вакытта, 1997 дән, Казан консерваториясендә укыта.



К.Ә.Хәйретдинова Ярославна ролендә («Кенәз Игорь», А.Бородин).

Башкарган партияләре: Аида, Дездемона («Аида», «Отелло», Дж.Верди), Тоска, Мюзетта («Тоска», «Богема», Дж.Пуччини), Лиза («Пиковая дама», П.Чайковский), Ярославна («Кенәз Игорь», А.Бородин), Купава («Кар кызы», Н.Римский-Корсаков) һ.б. Татар опера һәм балет театры труппасы составында илебез һәм чит ил шәһәрләренә гастрольләр б-н бара; Төркиядә халыкара опера фестивальләрендә (1992, 1996); Венециядә «Ла Фениче» театрында (Италия, 1994) һ.б.да чыгышлар ясый. Х.ның эстрада җырларыннан торган һәм камера-вокаль репертуары татар халык җырларын («Бөдрә тал», «Сөмбел» һ.б.), татар композиторлары романсларын («Киек казлар», «Күзләрем тик сине эзлиләр», Р.Яхин; «Ак дулкынлар», Р.Еникиев һ.б.) үз эченә ала. 2 нче дәрәҗә «Ватан алдында казанышлары өчен» ордены б-н бүләкләнә.

Ф.Ш.Салитова.



К.Ә.Хәйретдинова.



Л.Ә.Хәйретдинова.



Р.К.Хәйретдинова.

ХӘЙРЕТДИ́НОВА Луиза Әхмәтҗан кызы (19.9.1948, Бөгелмә ш.), композитор, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1992). Уфа сәнгать ин-тын (З.Исмәгыйлевтә композиция классы) тәмамлый (1974). Х.ның муз. әсәрләре музыка теленең демократик һәм милли юнәлештә булуы, музыкага хас сәнгатьчә чараларның төрлелеге, нигездә, балалар һәм яшүсмерләр өчен язылуы б-н аерылып тора. Композиторның әсәрләре күп кенә әйдәп баручы башкаручыларның концерт һәм уку-укыту репертуарына кертелә. Х. беренче татар «Мәкерле песи» (Зөлфәт (Д.Маликов) либр., Һ.Такташның шул исем. әкиятенә нигезләнә, 1974) операсы; төрле состав өчен иҗат ителгән хор әсәрләре, ш.и. балалар өчен Р.Миңнуллин һәм Г.Садә шигырьләренә «Мин кояшны яратам» (1992), татар шагыйрьләре шигырьләренә «Балачак бәйрәмнәре» (2005) кантаталары (нәфис сүз осталары, хор һәм симф. оркестр өчен); симф. оркестр өчен «Яшьләр увертюрасы» («Молодёжная увертюра», 1983), «Борын-борын заманда...» (1998) симф. сюитасы авторы буларак киң танылу ала. 200 дән артык җыр яза, аларның күбесе башкаручылар һәм тыңлаучылар арасында зур популярлык казана: «Каршы ал, туган калам» (И.Юзеев шигыре), «Менә без дә үсеп җиттек, әни» (Р.Фәйзуллин шигыре), «Ниләр булды ми ңа?» (Ш.Биккол шигыре), «Казанга мәдхия» (Зөлфәт шигыре; Казан турында иң яхшы җыр конкурсында 2 нче урын, 2005), «Гөлем чәчәк аткан» (Р.Миңнуллин шигыре) һ.б. Әсәрләре: Концерт (1969), Концерт-поэма (1979), симф. оркестр б-н виолончель өчен «Элегия» (2008); виолончель һәм фортепиано (1966), флейта һәм фортепиано (1970), соло виолончель (1971) өчен сонаталар; хор цикллары; камера-инструменталь әсәрләр; татар һәм башкорт халык җырлары эшкәртмәләре, спектакльләргә музыка, җырлар (200 дән артык) һ.б.

Әд.: Нигмедзянов М.Н. Луиза Хайрутдинова // Композиторы и музыковеды Советского Татарстана. К., 1986; Композиторы Татарстана. М., 2009.

Ф.Ш.Салитова.

ХӘЙРЕТДИ́НОВА (ире ягыннан Ганиева) Рауза Котдус кызы (3.1.1928, Балык Бистәсе р-ны Яңа Ырга а. — 15.11.2018, Казан), актриса, ТАССРның халык (1970), РСФСРның атказ. (1979) артисты. Татар акад. театры каршындагы студияне тәмамлаганнан соң (1948), театр труппасына кабул ителә. 1991–2003 елларда «Инсаният» труппасында. Җырлау сәләтенә ия буларак, Х. муз. спектакльләрдә бай рухлы, мөлаем, нәфис Мәйсәрә («Зәңгәр шәл», К.Тинчурин), Галиябану (шул исем. әсәр буенча, М.Фәйзи), Гөлчирә («Ташкыннар», Т.Гыйззәт), Гөлбану («Татар хатыны ниләр күрми», Г.Ибраһимов), Хәдичә («Гүзәлем Әсәл», Ч.Айтматов повесте буенча) образларын тудыра. Сания, Кәләмзә («Качаклар», «Зифа», Н.Исәнбәт),





Р.К.Хәйретдинова: 1. Гөлбану («Татар хатыны ниләр күрми», Г.Ибраһимов); 2. Мәйсәрә («Зәңгәр шәл», К.Тинчурин) рольләрендә.

Гөлбикә («Таң атканда», Ш.Шаһгали), Рәмзия («Күк капусы ачылса», Х.Вахит), Волчанская («Рәхәт яшибез», М.Гыйләҗев), Селия («Җүләр кыз», Лопе де Вега), Әкълимә («Әбиләргә ни җитми», Ф.Бүләков) кебек характерлы рольләрдә актриса комедия уйнау остасы буларак ачыла.

Әд.: Илялова И. Г.Камал театры артистлары = Артисты театра им. Г.Камала. К., 2005.

И.И.Илялова.

ХӘЙРЕТДИ́НОВА Тәнзилә Хәсән кызы (10.10.1941, Биектау р-ны Урал а. — 4.12.2015, Казан; Биектау р-ны Ямаширмә авылында җирләнә), тел галиме, диалектолог, филол. фән. канд. (1980), ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (2000). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1966), Арча р-нының Яңа Сала авылы мәктәбендә эшли. 1969–2011 елларда ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында. Хезмәтләре татар теле диалектологиясенә һәм лексикологиясенә карый. «Урта Идел һәм Урал буе татар халкы сөйләшләре атласы» («Атлас татарских народных говоров Среднего Поволжья и Приуралья», 1989), «Татар теленең диалектологик сүзлеге» (1993), «Татар теленең зур диалектологик сүзлеге» (2009), «Татар халык сөйләшләре» (2008) һ.б. хезмәтләрне төзүчеләрнең берсе.

Х е з м.: Говор златоустовских татар. К., 1985; Названия пищи в татарском языке. К., 1993; Бытовая лексика татарского языка. К., 2000.

ХӘЙРИ́ (Хәйруллин) Әнвәр Нәҗип улы (2.12.1947, Аксубай р-ны Шәрбән а. — 20.7.2014, Казан), филолог, текстолог, язучы, ТРның атказ. фән эшлеклесе (1999), ТРның һәм РФнең атказ. мәдәният хезмәткәре (1991, 2008). Казан ун-тын тәмамлый (1973). 1974–91 елларда — СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында, 1991–95 тә — «Мирас» ж-лында, 1996 дан ТРның Милли китапханәсендә эшли, бер үк вакытта, 1970–2003 тә, «Татарстан — Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе б-н хезмәттәшлек итә. Хезмәтләре татар халкының рухи мәдәнияте, Идел буенда ислам тарихы, пед. мәсьәләләренә карый. Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Р.Фәхретдин, Г.Ибраһимов һ.б.ның хезмәтләрен текстологик басмага әзерли (кереш сүз, шәрехләмәләр). «Әхмәд ибне Фазланның 921–922 елларда Болгар дәүләтенә сәяхәте вакытында язылган бәян» («Повествование о путешествии Ахмеда ибн Фадлана, написанное во время поездки в 921–922 годах в Булгарское государство», 2013) китабы авторы. Әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә М.А.Шолохов исем. халыкара бүләк лауреаты (2014).

Әд.: Х у җ и н Ф. Күпкырлы галим // Казан утлары. 2008. № 5.

ХӘЙРИ́ (Хәйретдинов) Гайнан Бәдретдин улы (15.6.1903, хәзер БРның Нуриман р-ны Иске Күл а. — 16.12.1938, Уфа ш.), язучы. Башкорт телендә яза. Башлангыч белемне авыл мәдрәсәсендә ала, Оренбург башкорт пед. техникумын тәмамлый (1924). «Яңа авыл», «Башкортостан йәштәре» г-талары редакцияләрендә эшли, 1928–33 елларда «Сәсән», «Трактор» ж-лларының җаваплы сәркәтибе, бер үк вакытта Башкорт пед. ин-тында укыта. Пролетар язучыларның Башкортстан ассоциациясен оештыручыларының берсе һәм идарә әгъзасы. Беренче хикәяләренең лейтмотивы — хезмәт пафосы, дингә каршы юнәлеш, илне тышкы һәм эчке дошманнардан саклау, хатын-кызларның тигез хокуклы булулары, патриархаль искелек калдыкларын тәнкыйтьләү темалары. Яшьләргә багышланган «Уралда» (1925), «Бухгалтер» (1926), «Баксасы йыры» (1926), «Аҙашҡандар» (1926), «Һиңә хат» (1927) шигырь һәм поэмаларында вульгар социологизм тәэсире сизелә. Х. проза жанрында уңышлы иҗат итә. «Кооператорҙар» (Уфа, 1926), «Ҡатын» (Уфа, 1930) повестьларында шәхес формалашуны күрсәтә, аның рухи байлыгын ачып бирә. «Боролош» романы — Беренче бөтен дөнья сугышыннан 1920 еллар уртасына кадәрге чорны үз эченә алган эпик әсәр. Роман чын вакыйгаларга нигезләнгән, катнашучылар — тарихи шәхесләр (З.Вәлиди, З.Камали һ.б.). Х. иҗаты өчен жанрлар төрлелеге (документаль повесть, новеллалар, легендалар, публицистика) хас. «Бүлмә» (1930), «Өсәүҙең тарихе» (1938) повестьлары тәнкыйди реализм рухында язылган: беренчесендә автор түрәләрнең бюрократизмын кискен тәнкыйтьли, икенчесендә иҗтимагый һәм әхлакый конфликтларны ачып бирә. «Башҡорт ауылында», «Онотолған әкият» (икесе дә — Уфа, 1927), «Сабата» (М., 1928) очерклар җыентыкларында авторы. Н.В.Гоголь әсәрләрен башкорт теленә тәрҗемә итә.

Ә с ә р.: Һайланма әҫәрҙәр: Шиғырҙар, хикәйәләр. Өфө, 1953.

Әд.: С а ф у а н о в С.Г. Ғәйнан Хәйри. Тормошо һәм ижады. Өфө, 1983; Писатели земли башкирской: Справ. Уфа, 2006.

Р.К.Әмиров.

ХӘЙРИ́ (Хәйруллин) Хәсән Фәхретдин улы (5.2.1910, Урал губ., Лбищенск өязе Лбищенск ш. — 26.10.1994, Казан), әдәбият галиме, тәнкыйтьче, ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1970). 1953–73 елларда СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында, директор (1959 га кадәр). Хезмәтләре татар әдәбияты тарихына һәм теориясенә (соцреализм, партиялелек, халыкчанлык, интернационализм мәсьәләләренә), Г.Ахунов, Г.Бәширов, К.Нәҗми, Һ.Такташ иҗатларына карый. Урта мәктәпләр өчен татар әдәбияты дәреслекләре, шигырьләр, очерк һәм хикәяләр җыентыклары («Зур Кузбасс өчен», 1934; «Тавышлы ялкын», 1934) авторы. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Эзләнүләр. К., 1941; Татар совет әдәбиятында социалистик реализм мәсьәләләре. К., 1960; Язучы һәм тормыш. К., 1979; Һади Такташ. К., 1984; Поиски и свершения. К., 1970.

Әд.: Ә г ъ з а м о в Ф. Заман сулышын тоеп // Яшәү көче. К., 1977.

ХӘЙРУЛЛА́ бине́ ГЫЙЗӘТУЛЛА́ (19 йөзнең 2 яртысы, Сембер губ. Буа өязе, хәзер Чүпрәле р-ны Зур Чынлы а. дип фараз лана — 1930 еллар), педагог, хаттат, ташка уеп язу остасы. Язучы һәм революционер Ш.Усмановның әтисе. 1898 дә Саратов губернасы Кузнецк өязе Пәндәлге авылында укыта. 1906 да гаиләсе б-н Әстерхан шәһәренә, соңрак Оренбург шәһәренә күченә, «Хөсәения» мәдрәсәсендә укыта. Кабер ташларына уеп язу б-н шөгыльләнә. Аның тарафыннан ясалган кабер ташларының берсе Чүпрәле районы Зур Чынлы авылы зиратында саклана. Таштагы текстлар гарәп һәм татар телләрендә тәгъликъ ысулы б-н язылган. Язу техникасы — уеплау, бизәкләрсез. Текстта мәрхүм турында белешмәдән соң 1600 елда 18 татар гаиләсенең Темников, Рязань шәһәрләреннән Зур Чынлы авылына күченүләре турында мәгълүмат китерелә. Бу ядкәр беренче мәртәбә археограф М.Госманов, со ңыннан М.Әхмәтҗанов тарафыннан өйрәнелә. Х.б.Г. үзен «әл-Чынлыви» тәхәллүсе б-н күрсәтә. Репрессияләр елларында һәлак була.

Әд.: Ә х м ә т җ а н о в М. Ташларда тарих эзләре // Мирас. 2002. № 7; У с м а н о в М.А. Татарские исторические источники XVII–XVIII вв. К., 1972. *М.И.Әхмәтҗанов.*

ХӘЙРУ́ЛЛИН Әскәр Гафиятулла улы (20,10. 1958, Аксубай р-ны Түбән Кирәмәт а.), философ, социолог, филос. фән. д-ры (2000), проф. (2011), РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2005). Казан ун-тын тәмамлый (1991). 1978 елдан Чаллыда, КамАЗда эшли (1985 кә кадәр). 1991 дән Кама инженерлык-икътисад академиясендә: 1998 дән финанс һәм бухгалтерлык исәбе кафедрасы мөдире, бер үк вакытта 1992–94 тә машина төзелеше ф-тында декан урынбасары, 2003–06 да һәм 2007–11 дә проректор. Хезмәтләре логика, шәхес генезисында индивид иреге мәсь әләләрен социол.-философик анализлауга багышланган.

Х е з м.: Парадигмы философского мышления и проблема бытия личности. К., 1999; Онтология личности: классика и современность. К., 2000; Логика: Учеб. пособие. Наб. Челны, 2010 (автордаш.).

ХӘЙРУ́ЛЛИН Әсфәндияр Хәлиулла улы (7.9.1941., Лениногорск р-ны Сугышлы а.), авиация төзелешендә автоматлаштырылган сынау системалары өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1989), проф. (1992), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1984). Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң (1966), Авиация техникасы һәм җитештерүне оештыру фәнни-тикшеренү ин-тының Казан ф-лында эшли. 1990 елдан Кама инженерлык-икътисад академиясендә (Чаллы ш.): проректор, ректор (1996–2007), бер үк вакытта информацион технологияләрне автоматлаштыру каф. мөдире (2001 дән). Хезмәтләре авиация һәм автомобиль двигательләрен җитештерүнең һәм сынауның технологик процессларын автоматлаштыруга карый. Уйлап табуга 4 авторлык таныклыгы бар. Х.ның эшләре илнең авиация з-дларында һәм махсус КБларында гамәлгә ашырыла. Аның җитәкчелеге елларында академиядә 11 яңа белгечлек буенча укыту оештырыла, 3 факультет, Әлмәт, Азнакай, Бөгелмә шәһәрләрендә вәкиллекләр, Чистайда филиал ачыла; 1997 дә татар телендә белем алган инженерларның беренче чыгарылышы була. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының өч алтын медале б-н бүләкләнә. Чаллы шәһәренең мактаулы граждане (2001).

Х е з м.: Аналитическое и машинное проектирование автоматизированных систем испытаний авиационных двигателей. М., 1980 (автордаш); Автоматизированные испытания в авиастроении. М., 1989 (автордаш); Математическое обеспечение автоматизированных систем исследований и испытаний двигателей внутреннего сгорания. М., 1995 (автордаш).

ХӘЙРУ́ЛЛИН Вазыйх Кашшаф улы (22.5.1921, Мамадыш кантоны Түбән Тәкәнеш а. — 8.8.2004, Казан), химик-технолог, химия фән. д-ры (1969), проф. (1973), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1974). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1951), шунда ук эшли. 1959 елдан РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тын -

да, нефть химиясе синтезы лаб-ясе мөдире (1971–83), әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1991 дән). Хезмәтләре фосфор һәм күкертле органик кушылмаларга карый. Х. алкил(арил)дихлорфосфиннарның α, β-чикләнмәгән к-талар, мондый к-таларның амидлары һәм дикарбониль кушылмалар б-н реакциягә кергәндә аларның реакциягә сәләтен тикшерә. Каучукларның тиокарбоматларны файдаланып күкертле вулканизациясе механизмын аныклый. Резина, каучуклар, полисульфид каучуклар (үзлектән вулканизациягә сәләтле) искерүен тоткарлаучы матдәләрне, каучуклар вулканизациясен нәтиҗәле тизләтә торган фосфор эчтәлекле матдәләрне, органик һәм фосфор органик радиопротекторларны эшләүдә катнаша. Уйлап табуга 50 дән артык авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены; медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале; РСФСР ЮС Президиумы Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Реакции галоидангидридов кислот фосфора с непредельными соединениями // Успехи химии. 1968. Т. 37, № 5 (автордаш); Фосфонметилирование анестезина и радиозащитная активность продуктов реакции // Химико-фармацевт. журн. 1988. Т. 22, № 2 (автордаш); Синтез и молекулярная структура диметиламида хлортиомуравьиной кислоты и продукта его реакции с роданидом калия // Изв. АН СССР. Сер.хим. 1989. № 4 (автордаш).

М.А.Пудовик.

ХӘЙРУ́ЛЛИН Газинур Гарифҗан улы (10.9.1961, Чүпрәле р-ны Иске Чүпрәле а.), РФ Герое (22.8.1996), капитан. Балашов югары очучылар хәрби авиация уч-щесен тәмамлый (1983). 1979 елдан Совет армиясендә. 3 нче гв. Смоленск хәрби-транспорт авиация дивизиясенең 339 нчы хәрби-транспорт авиация полкында (Белоруссия ССРның Витебск ш.) хезмәт итә. 1983 тән Ил-76 самолёты экипажы командиры урынбасары, 1987 дән командиры. Совет гаскәрләренең хәрби хәрәкәтләре вакытында Әфганстан Респ-касында шәхси состав һәм йөкләр илтүдә, 1989 да Әрмәнстанның җир тетрәгән төбәкләренә йөкләр ташуда катнаша. Кораллы көчләрне кыскарту сәбәпле, 1992 дә запаска чыгарыла. 1994 тән «Аэростан» авиакомпаниясенең Ил-76 самолётында икенче пилот булып эшли. 1995 нең 3 августында экипаж составында Тирана шәһәреннән (Албания Респ-касы) Кабулга (Әфганстан Респ-касы) рейс ясый. Очыш вакытында самолёт исламчыларның «Талибан» хәрәкәте истребительләре тарафыннан Кандагар шәһәре (Әфганстан Респ-касы) аэропортына төшәргә мәҗбүр ителә. Командирлары В.И.*Шарпатов* б-н бергә экипаж талибларда 378 көн әсирлектә була. 1996 ның 16 августында әсирлектән качкан вакытта Х. батырлык күрсәтә: очучылар сакчыларны коралсызландырып, самолётны һавага күтәреп, Берләшкән Гарәп Әмирлекләренә, шуннан Ватанга очалар. Экипажның әсирлектәге тормышыннан эпизодлар һәм аның качуы «Кандагар» фильмында күрсәтелә (2010, реж. А.О.Кавун). 1997 дән Х. очышларын дәвам итә, Ил-76 самолёты командиры, 2008 нең июненнән 2009 ның мартына кадәр «Татарстан» авиакомпаниясе» АҖ ген. директоры. Медальләр б-н бүләкләнә.

ХӘЙРУ́ЛЛИН Галиулла Хәйрулла улы (2.5.1909, Самара губ., Бөгелмә өязе Чалпы а.–2.5.2004, Казакъстан Респ-касы, Караганда ш.), шахтёр, почётлы шахтёр (1948), Соц. Хезмәт Герое (1948). 1920 еллар башыннан Донбасста: шахтада лампа б-н яктыртучы, чаначы, вагончы һәм забойчы. 1931 дә Караганда шәһәренә яшь шахтёрларны өйрәтергә җибәрелә. 3, 18, 20, 64, 37 нче Караганда шахталарында забойчы һәм казучы булып эшли. Бөек Ватан сугышы елларында тизлеккә казу буенча ярышып эшләүне, соңрак казу эшләренең күпзабойлы ысулларын кертүне башлап җибәрүче. Караганда күмер бассейнын үзләштерүгә зур өлеш кертә. КПССның 20 нче съезды делегаты (1956). Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә; «Шахтёр даны» билгесенең тулы кавалеры.

И.Р.Вәлиуллин.

ХӘЙРУ́ЛЛИН Гриф Тимерза Һит улы (1.10.1937, БАССРның Дүртөйле р-ны Казаклар а.), тарихчы, педагог, пед. фән. д-ры (1993), проф. (1994), Татарстан Респ-касының атказ. укытучысы (2004), шагыйрь, җәмәгать эшлеклесе. Бөре пед. уч-щесен (1955), Бөре пед. ин-тын (1960, БАССР) тәмамлый. 1955–56 елларда Байкыбаш р-ны, 1959–60 та Бөре р-ны мәктәпләрендә укыта. 1960–76 да Үзбәкстан ССРда: укытучы; пед. ин-тында каф. мөдире, ф-т деканы (1967–71); Ангрен шәһәрендә мәктәп директоры (1971–76). 1976 дан Казакъстан ССРда. 1976–86 да уку-укыту мөдире, мәктәп директоры; район һәм шәһәр халык мәгарифе бүлекләре инспекторы; Алма-Атада мәктәпара укыту-җитештерү комб-ты директоры. 1986 дан Абай исем. Казакъ пед. ин-тында (хәзер Казакъ милли пед. ун-ты, Алма-Ата ш.): өлкән укытучы, доцент, ф-т деканы; 1993 тән пед. кафедрасында. Казакъстан халыклары ассамблеясе әгъзасы (1995 тән); Казакъстан татарлары һәм башкортлары ассоциациясе вице-президенты, президенты (2013 тән). Бөтендөнья татар конгрессы съездлары, Казанда Бөтендөнья татар галимнәре форумы делегаты (2007, 2011). «Фикер» респ-ка г-тасы баш мөхәррире. «Татарлар Казакъстанда: энциклопедик сүзлек» басмалары мөхәррире (2011, 2014, 2015). Хезмәтләре хезмәт тәрбиясе проблемаларына карый; татар һәм башкорт халыклары тарихы буенча фәнни-популяр хезмәтләр. Шигырь җыентыклары авторы. Медальләр, «Казакъстан Республикасы фәнен үстерүдәге казанышлары өчен», Үзбәкстан Республикасының мәгариф отличнигы», Казакъстан Республикасы мәгарифе мактаулы хезмәткәре», ТР Мәдәният министрлыгының «Мәдәният өлкәсендәге казанышлары өчен» күкрәк билгеләре б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Ученические коллективы в условиях УПК. А.-А., 1989; Очерки истории и культуры башкирского народа. Астана, 2004; Общение и самопознание. Алматы, 2005; История татар. Алматы, 2010; Педагогика общеобразовательной школы. Астана, 2013.

Әд.: Кто есть кто в зарубежной российской диаспоре. М., 2008; Почитаемые люди земли казахской. Алматы, 2014. Т. 21.



Г.Г.Хәйруллин.



Г.Х.Хәйруллин.

ХӘЙРУ́ЛЛИН Зыятдин Ялалетдин улы (13.3.1940, Чуаш АССРның Комсомол р-ны Албус-Сөрбәй (Әләбаш) (?) а.), химик-технолог, техник фән. д-ры (2010). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1963), Химия-технол. фәнни-тикшеренү ин-тында (Мәскәү өлкәсенең Дзержинский ш.), 1973 елдан Мәскәүнең «Эмитрон» з-дында. 1975 тән «Союз» икеле технологияләр федераль үзәгендә (Дзержинский ш.), төркем башлыгы (1977 дән), әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (2011 дән). Хезмәтләре техник химиягә бағышлана. Х. корылманы двигательнең эчке өслегенә беркетү өчен югары нәтиҗәле составлар эшләүдә катнаша, адгезион беркетүнең физик-химик процессларын тикшерү алымнарын тәкъдим итә. Көч сүрүләре өслекләрен югары пластификацияле махсус составлар б-н тәэмин итүгә әзерләүнең технологиясен эшли һәм тармак пр-тиеләрендә гамәлгә кертә. Уйлап табуга 11 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

ХӘЙРУ́ЛЛИН Илгиз Вильдан улы (1.10.1963, Әтнә р-ны Түбән Бәрәскә а.), төзүче инженер, ТРның атказ. а.х. хезмәткәре (2006), а.х. пр-тиесе җитәкчесе. Казан төзүче инженерлар ин-тын тәмамлый (1986). 1986 елдан Әтнә р-ны «Ленин исем. нәсел заводы» а.х. җитештерү кооперативында (1990 га кадәр Арча р-ны Ленин исем. к-зы): төзүче инженер, к-з (1990 нан), җитештерү кооперативы (2004 тән) рәисе. Х. җитәкчелегендә пр-тиедә а.х. культураларының уңышы һәм терлекчелекнең продуктлылыгы арта. 2012 дә бөртекләләрнең уңышы 1 *га* дан 31,4 *ц*, савым 1 сыерга 6202 *кг* тәшкил итә. Нәсел з-дында киң күләмдә игенчелектә, азык җитештерүдә, терлекчелектә алдынгы технологияләр гамәлгә кертелә. Техник база заманча техника б-н комплектлана. Хезмәт нәтиҗәләре буенча хезмәткәрләрне һәм белгечләрне матди стимуллаштыру схемасы эшләнә. Дуслык ордены б-н бүләкләнә.

ХӘЙРУ́ЛЛИН Илгиз Кәлимулла улы (2.1.1940, Биектау р-ны Ямаширмә а.), хакимият, җәмәгать эшлеклесе; ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1981). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1964). 1957–58 елларда интернатта тәрбияче, 1958–59 да Ямаширмә урта мәктәбендә укытучы. 1964–65 тә Казан пед. ин-тының комсомол ком-ты секретаре. 1966–72 дә ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-ты инструкторы, сектор мөдире, бүлек мөдире урынбасары, секретаре. 1972–78 дә



И.З. Хәйруллин.



И.И. Хәйруллин.

КПССның Татарстан өлкә ком-ты пропаганда һәм агитация бүлеге инструкторы, 1978–82 дә сектор мөдире, бер үк вакытта, 1980–81 дә бүлек мөдире вазифаларын башкаручы. 1982–92 дә ТАССР (1990 нан ТССР) Телевидение һәм радиотапшырулар дәүләт ком-ты рәисе. 1992–2001 дә ТР Премьер-министры урынбасары. Социаль-мәдәни блок ны җитәкли. Ул эшләгән вакытта телевидение төсле тапшыруга күчә, С.Сәйдәшев исем. Зур концерт залы, Яшь тамашачылар театры, М. Җәлил исем. опера һәм балет театры, В.И.Качалов исем. Зур драма театры реконструкцияләнә; Г.Тукай исем. Дәүләт филармониясе яңа бинага күчерелә; Төбәкара клиник диагностика үзәге, Респ-ка клиника хастаханәсе перинаталь үзәге, Респ-ка онкология клиник диспансеры, респ-ка районнарында күп кенә хастаханә һәм мәктәп биналары төзелә; Благовещение соборын реставрацияләү эше башлана, «Казан Кремле» музей-тыюлыгы оештырыла. 2001–04 тә «Зенит» банкының ТР буенча вәкиллеге директоры. 2005–06 да ТР Иҗтимагый палатасы әгъзасы, 2006–13 тә рәисе. ТР Журналистлар берлеге идарәсе рәисе (1984–90). «Почёт билгесе», 2 нче дәрәҗә «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» орденнары, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы, ТРның Мактау грамотасы, медальләр б-н бүләкләнә. *Е.Б.Долгов.*

ХӘЙРУ́ЛЛИН Илдар Зиннур улы (6.6.1950, Казан), драма актёры, режиссёр, педагог, ТССРның халык артисты (1991), РФнең атказ. артисты (1999). Казан театр уч-щесен тәмамлаганнан соң (1970), Татар акад. театры



И.З. Хәйруллин Закир ролендә («Бәхетсез егет», Г.Камал).

труппасына кабул ителә. Тайм ораз («Борчылма, әнием!», Н.Думбадзе повесте буенча), Алим («Эңгер-меңгер», А.Гыйләҗев), Плетнёв («Мин — солдат хатыны», Н.П.Анкилов) кебек беренче рольләрендә үк тамашачының игътибарын сәхнәдәге активлыгы, хәрәкәтчәнлеге, геройларының үз-үзләрен тотышындагы психол. үзенчәлекләрен ышандырырлык итеп җиткерә белүе б-н җәлеп итә. Актёр гәүдәләндергән Исмәгыйль («Сүнгән йолдызлар», К.Тинчурин), Кияү («Кияү белән кәләш», М.Байҗиев), Шагыйрь («Моңлы бер җыр», Т.Миңнуллин) образларында драматик конфликт бөтен кискенлеге б-н ачыла. Абдулич («Һиҗрәт», Н.Исәнбәт), Мөхәммәтҗан («Банкрот» Г.Камал), Труффальдино («Ике ху җаның хезмәтчесе», К.Гольдони) образларын иҗат иткәндә, Х., персонажларына



И.З. Хәйруллин Инсаф ролендә («Әни килде», Ш.Хөсәенов).

хас сыйфатларны якътырту максатыннан, фарс алымнарыннан оста файдалана, аның сәнгатьчә сурәтләү чаралары б-н проф. эш итә белүе күренә. Ул башкарган Хәбир («Сөяркә» Т.Миңнуллин), Пеппино («Гаугалы гаилә», Э. де Филиппо) рольләре психол. тирәнлекләре б-н аерылып тора. Аеруча зур рольләре — Исмәгыйль («Диләфрүзгә дүрт кияү», Т.Миңнулин), Ильяс («Казан сөлгесе», К.Тинчурин), Инсаф («Әни килде», Ш.Хөсәенов), Җанбай («Идегәй», Ю.Сафиуллин), Худобаев, Карандышев («Җимерелгән бәхет», «Бирнәсез кыз», А.Н.Островский), Вершинин («Өч сеңел», А.П.Чехов), Петруччо («Тискәрегә — авызлык» У.Шекспир), Петро («Искән җил ләр көенә», З.Хәким), Макаев («Үлеп ярат ты, Р.Зәйдулла»), Вәли әхмәт Габделхәтович («Мулла», Т.Миңнуллин), Сәфәр («Әрем исе», И.Зәйниев), Җи һангир («Ху җа Насретдин», Н.Исәнбәт), Буранлы Идегәй («Мәңге лек буран», Ч.Айтматов романы буенча) һ.б. 1975 тән даими рәвештә режиссёрлык эше б-н шөгыльләнә; Татар акад. театры сәхнәсендә 20 гә якын спектакль куя: «Сөембикә егет сайлый» (Ф.Яруллин), «Урланган бәхет» («Украденное счастье», И.Франко), «Кыю кызлар» (Т.Гыйззәт), «Сагыш» (А.М.Галин) һ.б. Татар драма һәм комедия театры, Минзәлә татар драма театры сәхнәләрендә дә спектакльләр куя. Бер үк вакытта, 1975 тән, Казан театр уч-щесендә укыта.

Әд.: Илялова И. Г.Камал театры артистлары = Артисты театра им. Г.Камала. К., 2005; шулук. Театр имени Камала. К., 1986.

И.И.Илялова.

ХӘЙРУ́ЛЛИН Ирек Әкрам улы (20.11.1954, Әлмәт ш.), инженер-технолог, ТР Дәүләт бүләгә лауреаты (1997), ТРның атказ. нефтьчесе (2000). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1976), Северодвинск машиналар төзү пр-тиесендә мастер булып эшли (Архангельск өлкәсе). 1979 елдан «Татнефть» ҖБдә: электрбатырма җайланмаларны прокат һәм ремонтлау буенча хезмәт күрсәтү үзәк базасында инженер, 1980 нән «Ямашнефть» НГДУда башлык урынбасары, цех башлыгы, ҖБдә җитештерү бүлеге башлыгы урынбасары (1989 дан). 1990 нан «Татех» АҖдә (Әлмәт ш.), ген. директор урынбасары, 1999 дан ген. директор. Уйлап табуга 4 патенты бар. Дәүләт бүләге Татарстанның нефть промыселларында зур сәнәгый күләмдә энергия саклау технологияләрен эшләүдә һәм гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә. СССР ФАнең акад. И.М.Губкин исем. бүләге лауреаты (1990). Медальләр б-н бүләкләнә.

ХӘЙРУ́ЛЛИН Ирек Хәниф улы (10.8.1938, Үзбәкстан ССР, Фирганә өлкәсе Өч Күпрүк а.), электротехника өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1981), проф. (1983), БРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1991). Иваново энергетика ин-тын тәмамлаганнан соң (1963), Куйбышев, Уфа, Эстәрлетамак шәһәрләрендә пр-тиелә рдә һәм югары уку йортларында эшли. 1970 елдан Уфа авиация техник ун-тында, электр машиналары һәм аппаратлары (1983–91), электромеханика (1992–2000) кафедралары мөдире. Хезмәтләре электромеханик әверелдергечләргә карый. Х. галәм аппаратларын тоташтыру процессында кинетик энергияне киметү өчен махсус электр машиналары, демпферлар, магнитлы абразив белән шомарту җиһазлары эшли. Уйлап табуга 140 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр, ш.и. РФ Космонавтика федерациясенең Ю.А.Гагарин һәм атаклы галим, конструктор М.С.Рязанский исем. медальләре б-н бүләкләнә.

Хезм.: Магнитоэлектрическое демпфирование в амортизаторах стыковочных механизмов // Космические исслед. 1977. Т. 15, вып. 4 (автордаш); Переходные процессы в малоинерционном электромагнитном тормозе с полым ротором // Электричество. 1978. № 10; Электромагнитные расчеты в электрических машинах: Учеб. пособие. Уфа, 1988; Оптимальные соотношения в дисковом генераторе // Энергет. строительство. 1994. № 1.

ХӘЙРУ́ЛЛИН Искәндәр Илдар улы (31.8.1974, Казан), драма актёры, ТРның халык артисты (2015). Казан мәдәният һәм сәнгать академиясен тәмамлаганнан соң (1995), Татар акад. театрында эшли. Студент чагында ук Татар акад. театрында куелган спектакльләрдә уйный, күмәк күренешләрдә катнаша. Актёрның проф. башкару осталыгы төрле пландагы образлар иҗат итү мөмкинлеге тудыра, алар тормышчан, кабатланмас һәм тирән мәгънәле булулары б-н аерылып тора: Бальтазар («Ромео һәм Джульетта», У.Шекспир), Шәрәф («Асылъяр», М.Фәйзи), Андроньо («Биюче», Лопе де Вега), Атиллио («Гаугалы гаилә», Э.де Филиппо), Җирән чичән («Җирән чичән һәм Карачәч сылу», Н.Исәнбәт), Сәйяр («Әни килде», Ш.Хөсәенов), Интизар («Саташкан сандугач», Р.Зәйдулла), Франц

(«Юлбасарлар», Ф.Шиллер), Серый («Мәхәббәт хатирәсе», Ф.Бүләков), Альфред («Казан егетләре», М.Гыйләҗев), Фатыйх («Беренче театр», Г.Камал), Шәкүр («Яра», А.Гыйләҗев), Гарәфи («Банкрот», Г.Камал; «Икенче пландагы иң яхшы ир-ат роле» номинациясендә ТР Мәдәният министрлыгының «Тантана» бүләге, 2014), Бармен («Мылтык», З.Хәким), Зәйнәгый («Хуҗа Насретдин», Н.Исәнбәт, С.Ваннус), Мисбах хаҗи («Җил - кәнсезләр», К.Тинчурин; «Икенче пландагы иң яхшы ир-ат роле» номинациясендә ТР Мәдәният министрлыгының «Тантана» бүләге, 2017), Вәлиәхмәт Габделәхәтович («Мулла», Т.Миңнуллин), Сафа («Яшь йөрәкләр», Ф.Бурнаш), Марс («Ут күршеләр», С.Юзеев), Сәлахетдин («41 нең арбалы хатыннары»,



И.И.Хәйруллин Сганарель ролендә («Дон Жуан», Ж.-Б.Мольер; сулда — Дон Жуан ролендә Р.Бариев).

З.Зәйнуллин), Сехисмундо («Тәкъдир», П.Кальдерон), Оргон («Тартюф», Ж.Б.Мольер), Вил («Дивана», Т.Миңнуллин), Түзәр («Кара чикмән», Г.Хугаев; 2005 елда төрки халыкларның VIII Халыкара «Нәүрүз» театр фестивалендә «Иң яхшы ир-ат роле», 2007 дә Мәскәүдә узган Бөтенроссия «Театрның музыкаль йөрәге» милли фестивалендә «Төп ир-ат ролен иң яхшы башкаручы», 2008 дә Брестта (Белоруссия Респ-касы) уздырылган XIII Халыкара «Белая Вежа» театр фестивалендә «Ир-ат ролен иң яхшы башкаручы» номинацияләрендә җиңүче), Ричард-герцог Глостер («Ричард III», У.Шекспир), Сганарель («Дон Жуан», Ж.-Б.Мольер), Тайфур Кормаш («Ак калфагым төшердем кулдан...», И.Юзеев; «Иң яхшы ир-ат роле» номинациясендә ТР Мәдәният министрлыгының «Тантана» бүләге, 2018), Хәлим («Тормышмы бу?..», Г.Исхакый повесте буенча) һ.б. ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (2019).

ХӘЙРУ́ЛЛИН Исхак Нәбиулла улы (1900, Чистай ш. — 15.11.1938, Казан), шагыйрь. Туган шәһәрендә мәдрәсәдә, аннан соң пед. уч-щесендә укый, укыта. 1925–35 елларда актив иҗат итә. «Тамгалар» (1927), «Утлы төннәр», «Безнең җәй», «Алтын башаклар» (барысы да — 1928), «Язгы җырлар» (1929) шигырьләр, «Табышмак» (1928) әкиятләр, балалар өчен «Фукуякку» (М., 1927) хикәя җыентыклары, фельетоннар, мәкаләләр, очерклар авторы. 1937 дә репрессияләнә, 1938 дә атып үтерелә (к. «*Идел-Уралчылар оешмасы эше*»); үлгәннән соң аклана.

Әсәр.: Шигырьләр һәм поэмалар. К., 1960.

ХӘЙРУ́ЛЛИН Мәлик Бари улы (1.12.1940, Кайбыч р-ны Кече Кошман а.), тел галиме, филол. фән. д-ры (2000), проф. (2001). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1964), Яшел Үзән һәм Кайбыч р-ннары урта мәктәпләрендә эш - ли. 1970 елдан ТАССР Мәдәният министрлыгы каршындагы Респ-ка халык иҗаты йортында өлкән методист, 1977 дән Алабуга пед. ин-тында, 1979 дан Казан ун-тында, 1993–2011 дә ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында. Татар лексикасын диахрон һәм синхрон аспектларда, татар әдәби телендә Көнбатыш Европа һәм шәрекъ алынмаларын өйрәнә.

Х е з м.: Проблемы развития лексической системы татарского литературного языка. К., 2000; Развитие татарской лексики: взаимодействие исконно национального и иноязычного. К., 2001; Возрождение и развитие национальных языков. К., 2005.

Әд.: Казанская лингвистическая школа. К., 2008.

ХӘЙРУ́ЛЛИН Мөхәммәт Хыйльми улы (9.11.1951, Казан), механика өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1993), проф. (2007), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1998), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2016). Казан ун-тын тәмамлый (1974). 1975 елдан РФА КГҮндә эшли: 1975–90 елларда Физика-техника ин-тын - да, 1991 дән Механика һәм машиналар төзү ин-тында, җир асты гидродинамикасы лаб-ясе мөдире (1995). Хезмәтләре күзәнәк - ле мохитләрдә фильтрация процессларын матем. модельләштерүгә, катлам системала - рын идентификацияләүгә карый. Х. нефть һәм газ катламнарының фильтрацион-сыйды - рыш параметрларын ачыклау алымын («Татнефть» АҖдә гамәлгә ашырыла); бертөрле булмаган нефть катламнарының төзелешен һәм геол.-физик үзенчәлекләрен ачыклау һәм аныклау өчен сан алгоритмнарын (агымдагы файдалану процессында килүче мәгълүматлар буенча) эшли.

Х е з м.: О решении обратных задач подземной гидромеханики с помощью регуляризующих по А.Н. Тихонову алгоритмов // Журн. вычисл. математики и мат. физики. 1986. Т. 26, № 5; О регуляризации обратной коэффициентной задачи нестационарной фильтрации // Докл. АН СССР. 1988. Т. 299, № 5; О решении обратных задач фильтрации многослойных пластов методом регуляризации // Докл. АН РАН. 1996. Т. 347, № 5; Интерпретация результатов гидродинамических исследований скважин методами регуляризации. М.–Ижевск, 2006 (автордаш).

ХӘЙРУ́ЛЛИН Наил Гомәр улы (11.7.1945, Казан), инженер-конструктор, техник фән. канд. (1994), Казан авиация ҖБ Федераль унитар пр-тиесе директоры (1996 -2007), ТР ның атказ. машина төзүчесе (2001). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1974), шунда ук эшли (1967 елдан). 1974 тән Татарстан «Тат - автотранс» автотранспорт пр-тиеләре асso - циациясенең махсус «АСУ-проект» КБ инже - неры, әйдәүче конструкторы. 1976 дан Ка - зан мед. инструментлары з-дында үзәк з-д лаб-ясе башлыгы, профком рәисе. 1983 тән Казан киез итек-киез комб-тының баш инженеры, директоры. 1987 дән КПССның Идел буе райкомы 2 нче секретаре, 1989 дан Казан шәһәр советы башкарма ком-ты рәисенең 1 нче урынбасары. 1991–96 да Казан хаки - мияте башлыгының 1 нче урынбасары. Х. җи - тәкчелегендә Казан авиация ҖБдә, җитештерү ку әтләрен күпкә үстереп, җитештерүне реконструкцияләү һәм яңартып коралландыру буенча эшләр дәвам иттерелә, самолётларның канатларын һәм фюзеляжларын сыйфатлы җыюны тәэмин итүче җиһазлар урнаштырыла; ТУ-214 самолётын сертификацион сынаулар төгәлләнә, аны сериялəп чыгару җайга салына. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

ХӘЙРУ́ЛЛИН Наил Гыйндулла улы (10.4.1939, БАССРның Чишмә р-ны Тәпәреш а. — 19.9.2011, Казан), икътисадчы, икътисад фән. канд. (1974), проф. (1991), ТАССРның атказ. икътисадчысы (1991), РФнең атказ. фән эшлеклесе (1996). Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлаганнан соң (1964), шунда ук эшли, хуҗалык анализы каф. мөдире (1981 елдан), 1990–2007 дә ректор. Хезмәтләре икътисади анализ һәм ау - дит мәсьәләләрен камиллəштерүгә карый. Х. фәнни тикшеренүләренең нәтиҗәсе ТР азык-төлек җитештерү сәнәгате пр-тиеләрендә һәм «Татарстан җиләк-җимеш, яшел - чә сәнәгате» концернында гамәлгә кертелә. Дуслык ордены, медальләр һәм ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Коллективный подряд: производительность и оплата труда. К., 1985; АПО: конечные результаты и стимулы. К., 1988; Концепция обоснования и выбора инвестиционных проектов стратегической программы социально-экономического развития территории. К., 2003 (автордаш).

Ф.С.Зыятдинов.

ХӘЙРУ́ЛЛИН Рәфыйк Гомәр улы (15.2.1939, Грозный ш., Чечен-Ингуш АССР), инженер-электромеханик, «Татэнерго» җи - тештерү энергетика берләшмәсенең (ҖЭБ) ген. директоры (1988–97), СССРның мактаулы энергетигы (1991), РФ Ягулык һәм энергетика министрлыгының атказ. хезмәткәре (1993). Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тын тәмамлый (1967). Хезмәт эшчән - леген 1958 дә Нефть сәнәгате министрлыгының Татарстан нефтьүткәргечләр идарәсе Әл - мәт район идарәсендә электр монтёры буларак башлый. 1963 тән Миңлебай газ эшкәртү з-дында: мастер, электр цехы башлыгы урынбасары, баш энергетик (1976 дан). 1977 дән Түдән Кама 2 нче җылылык-энергетика үзәге директоры. 1985–97 дә «Татэнерго» ҖЭБдә: баш инженер, идарәче (1986 дан). Уйлап табуга 2 патенты бар. Х. җитәкчелегендә ГЭСта, Түбән Кама шәһәренең 1 нче һәм 2 нче энер - гетика үзәкләрендә, Казанның 3 нче җылылык-энергетика үзәгендә күәтләр сафка баса, Казанда «Савиново», «Азино» котельныйлары һ.б. төзелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

ХӘЙРУ́ЛЛИН Рөстәм Наил улы (11.10.1972, Казан), кардиохирург, мед. фән. д-ры (2010), ТРның атказ. табибе (2008), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2016). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1996), 6 нчы шәһәр хастаханәсенең (Казан) Йөрәк-кан тамырлары хирургиясе үзәгендә эшли, 1997 елдан Кардиология фәнни-тикшеренү ин-тында. 2001 дән Төбәкара клиник диагностика үзәгендә (Ка - зан), ген. директор (2004 тән). Хезмәтләре атеросклерозның симптомсыз формаларын


С.З. Хәйруллин.


Х.Н. Хәйруллин.


Х.З. Хәйруллин.


А.Х. Хәйруллина.

ачыклауга, авыру куркынычы булганнар төркемендәгеләрнең атеросклеротик үзгәрешләрен коррекцияләп тергезүгә, авыруны кисәтүнең даруларсыз беренчел чараларының нәтиҗәлелеген бәяләүгә, авыруга диагноз кую һәм аны дәвалауның яңа ысулларын эзләүгә карый. Микрохирургия инструментын уйлап табуга РФ патенты бар.

Х е з м.: Диагностика и лечение медиастенита у пациентов после операции коронарного шунтирования // Клиническая микробная и антимикробная химиотерапия. 2003. Т. 5. Прил. 1 (автордаш); МРТ – динамика объёма очагов острой ишемии в головном мозге // Неврол. вестн. 2008. № 3 (автордаш); Пульсогемоиндикация – диагностика и лечение // Казан. мед. журн. 2008. № 6.

ХӘЙРУ́ЛЛИН Салават Хәйрулла улы (29.2.1900, Казан губ., Зөя өязе Кече Кайбыч а. – 1937, Казан), шагыйрь. Гражданнар сугышында катнаша. 1928–35 тә Казан шәһәр советы рәисе урынбасары булып эшли. Х.ның заман рухын чагылдырган шигырьләре «Инкыйлаб чаткылары» (1920), «Көрәш җырлары» (1932) күмәк җыентыкларында басыла.

ХӘЙРУ́ЛЛИН Салих Зарифулла улы (16.11.1931, Казан – 2.4.1978, Одесса ш.), балет артисты, ТАССРның халык артисты (1968). Ленинград хореография уч-щесен тәмамлый (1950). 1951–71 елларда – Татар опера һәм балет театры, 1971 дән «Таврия» бию ансамбле балет солисты (Херсон ш.), 1973–77 дә Одесса хореография уч-щесенең уку-укыту бүлеге мөдире һәм педагогы. Казандагы хореография партияләре: Базиль, Солор («Дон Кихот», «Баядерка», Л.Минкус), Евгений («Бакыр җайдак», Б.Асафьев), Убырлы карчык («Раушан», З.Хәбибуллин), Зигфрид («Аккош күле», П.Чайковский), Пер-Гюнт (шул исем. балет буенча, Э.Григ музыкасы), Штраус («Зур вальс», И.Штраус музыкасы), Сарацин рыцаре Әбдерахман һәм Прованс рыцаре де Бриен («Раймонда», А.Глазунов), Шүрәле (шул исем. балет буенча, Ф.Яруллин) һ.б. Искиткеч сыгылмалылыкка, актёрлык осталыгына ия, камил бию техникасы б-н аерылып тора.

В.Н.Горшков.


С.З. Хәйруллин Шүрәле ролендә (шул исем. әсәр буенча, Ф. Яруллин).

ХӘЙРУ́ЛЛИН Хәбибулла Нәбиулла улы (14.2.1923, Чистай кантоны Коры Көрнәле а. – 22.2.1945, Бреслау, хәзер Вроцлав ш., Польша), Сов. Союзы Герое (10.4.1945, үлгәннән соң), өлкән сержант. Туган авылында колхозда эшли. 1941 елның декабреннән Кызыл Армиядә. 1942 дән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 1248 нче танкка каршы артиллерия полкында туп командиры (6 нчы армия). Воронеж, Коньяк-Көнбатыш, 3 нче һәм 1 нче Украина фронтлары гаскәрләре составында Воронеж-Ворошиловград, Урта Дон (икесе дә – 1942), Донбасс (1943), Никополь-Кривой Рог (1944) һәм Сандомир-Силезия (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1945 нең 7 февралендә Сьцинава шәһәреннән көньяктарак (Польша) плацдармда Одер елгасы өчен барган сугышларда батырлык күрсәтә: дошманның 2 тубы утын бастыра һәм тере көчләренә зур зыян китерә, бу аңа совет укчы подразделениеләре килеп җиткәнче биләгән урынны саклап торырга мөмкинлек бирә. Ленин ордены, медаль б-н бүләкләнә.

Әд.: Батырлар китабы – Книга Героев. К., 2000.

М.З.Хәбибуллин.

ХӘЙРУ́ЛЛИН Хәлил Зиннәтулла улы (14.6.1920, Зөя кантоны Күгәй а. – 29.9.1984, Яшел Үзән р-ны Норлат а.), Сов. Союзы Герое (24.3.1945), гв. рядовое. 1937–40 еллар да Мәскәү төзелешләрендә бетончы булып эшли. 1940 ның августыннан Кызыл Армиядә. 1941 нең сентябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 245 нче гв. укчы полк пулемётчысы (11 гв. армиясенең 84 нче укчы дивизиясе). Вязьма һәм Гжатск (хәзер Гагарин ш.) шәһәрләре янында барган сугышларда чолганышта кала (1941), яралана һәм әсирлеккә эләгә. 1942 нең февралендә кача һәм 1943 нең көзенә кадәр партизаннар отряды составында Витебск–Орша–Смоленск терр-ясендә сугыша. 3 нче Белоруссия фронты гаскәрләре составында Городок һөҗүм операциясендә (1943), Белоруссияне, Литваны (икесе дә – 1944), Көнчыгыш Пруссияне (1945) азат итүдә катнаша. 1944 нең 14 июлендә Алитус ш. янында (Литва ССР) Неман елгасын кичкәндә батырлык күрсәтә: полкта беренчеләрдән булып елганы кичеп чыга, сапёрлар эшләгәндә һәм подразделениеләр елганы кичкәндә пулемёт уты б-н аларны ышыклый, дошманның контрһөҗүмен кире кайтара; плацдармдагы сугышта яраланган командирын алмаштыра, үзе дә яралана. Демобилизацияләнгәннән соң (1945), Яшел Үзән шәһәрендә төзелеш идарәсендә эшли.

Әд.: Батырлар китабы – Книга Героев. К., 2000.

М.З.Хәбибуллин.

ХӘЙРУ́ЛЛИН Хәниф Гыйздулла улы (12.9.1931, Сарман р-ны Сарман а. – 25.6.1998, шунда ук), язучы, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1981). Казан ун-тын тәмамлый (1956). Туган авылында укыта, «Югары уңыш өчен» (Сарман а.), «Ленинчы» (Сарман а.), «Байрак» (Буа ш.) район г-таларында эшли. «Канатлар талмасын» (1974), «Картлык – кемгә шатлык...» (1976) повестьлары авыл хезмәтчәннәренә багышлана. Авыл хуҗалагы үсешенең көнүзәк мәсьәләләре турында публицистик мәкаләләр авторы.

Әд.: Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

ХӘЙРУ́ЛЛИНА Асия Хәсән кызы (15.7.1921, Тәтеш кантоны Ясаклы Барыш а. – 4.11.2004, Казан), актриса, педагог, ТАССРның атказ. артисты (1971), ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1992). Мәскәүдәге Дәүләт театр сәнгате ин-тының (ГИТИС) татар студиясен тәмамлаганнан соң (1949), Казан яшь тамашачылар театрының (ТЮЗ) татар төркеменә кабул ителә, 1950 елда Татар акад. театры труппасына күчерелә. Башта рак яшүсмерләр рольләрен башкаручы актриса буларак, зирәк, тапкыр, бар җирдә дә өлгер Садри, Малай («Галиябану», «Ак калфак», М.Фәйзи), Миңлеәхмәт («Миңлекамал», М.Әмир), Идел («Зифа», Н.Исәнбәт), Зөлкагыйдә («Кыю кызлар», Т.Гыйззәт) кебек малайлар һәм кызлар образларын гәүдәләндерә. Соңрак характерлы рольләргә күчә: Нурсәнә, Гүзәл («Беренче мәхәббәт», «Рәхим итегез!», Х.Вахит), Екатерина («Яшь йөрәкләр», Ф.Бурнаш). К.Тинчуринның «Җилкәнсезләр» пьесасы буенча куелган спектакльдәге Рокыя роле актрисаның зур казанышы була (ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге, 1958). Х. 1971 дә театрдан китә. 1962–98 дә Казан театр уч-щесендә сәхнә теле укыта, бер үк вакытта, 1969–76 да, Казан мәдәният ин-тында эшли. Сәхнә теле буенча методик кулланмалар («Тел күрке – сүз», 1978; «Дөрес сөйләргә өйрәнегез», 1992) авторы.

Әд.: И л я л о в а И. Г.Камал театры артистлары = Артисты театра им. Г.Камала. К., 2005; ш у л у к. Театр имени Камала. К., 1986; Асия Хәйруллина. Ничек тиз узасың син, гомер... К., 2012.

И.И.Илялова.

ХӘЙРУ́ЛЛИНА Зәйнәп Шәйхулла кызы (22.3.1916, Пермь ш. – 15.8.2010, Казан), музыка белгече, ТССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1991). 1932–58 елларда Татарстан радиосында (бүленеп): диктор, мөхәррир, әдәбият-сәнгать тапшырулары җитәкчесе; 1958–61 дә Казан телевидение студиясендә: директор, мөхәррир; бер үк вакытта, 1962–73 тә, ТАССР Композиторлар берлеге идарәсенең җаваплы сәркәтибе; в 1944–76 да

Татар филармониясендә концерт программалары алып баручы һәм лектор. Югары уку йортлары өчен беренче «Татар совет музыкасы тарихы» («История татарской советской музыки», 1956; Я.Гиршман һәм В.Виноградов б-н берлектә) курсы программасын төзүчеләрнең берсе. Татар муз. культурасы мәсьәләләренә караган хезмәтләр: «Салих Сәйдәшев иҗатына карата» («Совет әдәбияты» ж-лы. 1952. № 7; Ч.Бәхтиярова б-н автордашлыкта), «Татарстан композиторларының җыр иҗаты» («Совет Татарстанының музыкаль культурасы» — «Музыкальная культура Советской Татарии», М., 1959; М.Җи һаншина б-н автордашлыкта) мәкаләләре; татар композиторлары һәм башкаручыларыннан Ә.Бакиров, А.Вәлиуллин, Х.Вәлиуллин, С.Габәши, А.Монасыйпов, Ж.Фәйзи, И.Шәмсетдинов, У.Әлмиев, Р.Вахапов, Э.Җәләлетдинов, Г.Кайбицкая, М.Рахманкулова, Г.Сөләймановa, З.Хисмәтуллина һ.б.ның иҗатлары турында «Совет Татарстаны композиторлары» («Композиторы Советского Татарстана», 1957), «Халык артистлары» («Народные артисты», 1980) һ.б. китапларга кергән очерклар; татар вакытлы матбугаты материалларына күзәтүләр; муз. басмаларның рус теленнән татар теленә тәрҗемәләре һ.б. авторы. Х. ш.у. нота һәм муз. тәнкыйть җыентыкларын төзүче.

Әд.: Исанбет Ю.Н. Зайнаб Хайруллина // Композиторы и музыковеды Советского Татарстана. К., 1986; шул ук. Зайнаб Шайхулловна Хайруллина (к 75-летию со дня рождения): Буклет. К., 1991.

ХӘЙРУ́ЛЛИНА Миңнура Гали кызы (8.8.1926, Мамадыш кантоны Артошка а. — 20.6.2016, шунда ук), дуңгыз караучы, Соц. Хезмәт Герое (1966). Хезмәт эшчәнлеген 1943 елда Мамадыш р-нының «Агробаза» с-зында башлый, 1955–81 дә «Мамадыш» с-зында эшли. Күп еллар дәвамында районның дуңгыз караучылары арасында алдынгы була. Ел саен һәр ана дуңгыздан уртача 8–9 дуңгыз баласы ала (1960–80 дә якынча 8 мең чиста токымлы дуңгыз баласы үстерелә). 1965 тә 23 ана дуңгыздан 390 дуңгыз баласы ала һәм үстерә, һәрберсенең ике айлык вакытта авырлыгы 20 *кг* нан артык тәшкил итә. Герой исеме җитештерүдәге югары казанышлары өчен бирелә. 1980 дә районның дуңгыз караучылары арасындагы ярышта җиңүче өчен Хәйруллина Миңнурый исем. кубок булдырыла. 1967–75 тә ТАССР ЮС депутаты. Ленин ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш һәм бронза медальләре б-н бүләкләнә. Мамадыш шәһәрендә бер урам Х. исеме б-н атала.

Әд.: Есть на Вятке городок. К., 1981; Абзянов М. Хайруллина Миннури Галеевна // Герои Социалистического Труда Татарии: Док. очерки. К., 1984. Кн. 2; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003; Мамадышым — язмышым = Мамадыш — судьба моя. Ижевск, 2005.

М.Ж.Гаитов.

ХӘЙРУ́ЛЛИНА Роза Вәкил кызы (12.9.1961, Красноярск крае Норильск ш.), драма актрисасы, ТАССР һәм РФнең атказ. артисты (1989, 2007). Казан театр уч-щесен тәмамлаганнан соң (1981). Казан яшь тамашачылар театрында (ТЮЗ) эшли башлый. Оля («Ямансулама, шишок, мин кайтырмын», А.Л.Александров), Ирина («Сайлау», А.А.Дударев), Черепашка («Ике ук», А.М.Володин) кебек беренче рольләрендә үк актрисаның теге яки бу образны тудырганда героиняның рухи дөньясына үтеп керергә омтылышы күзәтелә. Х. башкаруында Варенька («Ярлы кешеләр», Ф.М.Достоевский романы буенча) һәм Лаура («Пыяла читлек», Т.Уильямс) рольләренең тирән психологизм б-н сугарылуы, актрисаның автор стилен яхшы тоеп эш итүе билгеләп үтелә; Гарасиха («Сычиха», Н.Глазова) һәм Мария («Күктәге иртәнге йолдызлар», А.М.Галин) образлары эчке драматизмның байлыгы б-н аерылып тора; Роза Треф («Җимерү»; «Кич тә булды, иртә дә» повесте буенча, Б.Л.Васильев; РФ Дәүләт бүләге, 1992), госпожа Ян («Сычуаньнан килгән мәрхәмәтле кеше» пьесасы буенча, Б.Брехт), Панночка (шул исем. әсәр буенча, Н.Садур; Н.В.Гогольнең «Вий» повестена нигезләнеп), Кызыл Ариэль («Давыл», У.Шекспир) рольләрендә актрисаның образга керү, сюрреалистик, фантазиягә бай сәхнә ситуацияләрендә ышандырырлык итеп яши белү осталыгы күзәтелә. 1996 елдан Чиләбе яшь тамашачылар театрында (ТЮЗ), 1997 дән «Самарт» театрында (Самара ш.). 2009 дан Мәскәүдә О.П.Табаков җитәкчелегендәге Театр-студиядә. Нәфис фильмнарда төшә. Тайдула ханша («Урда», реж. А.Прошкин; «Иң яхшы хатын-кыз роле» номинациясендә Россия кинематография сәнгате академиясенең «Ника» мили бүләге, 2013), Убырлы («Зөләйха күзләрен ача», реж. Е.Анашкин) һ.б. рольләрне башкара. К.С.Станиславский исем. бүләк иясе (2006). РФ Театр эшлеклеләре берлегенең «Алтын битлек» – «Золотая маска» милли бүләге лауреаты (2013).



М.Г.Хәйруллина.



Р.В.Хәйруллина.



Ф.Х.Хәйруллина.

ХӘЙРУ́ЛЛИНА Фирдәвес Хәбибулла кызы (4.1.1951, Лаеш р-ны Татар Агайбашы а. — 15.7.2003, Казан), актриса, ТРның халык артисты (1995), РФнең атказ. артисты (2002). Казан театр уч-щесен тәмамлаганнан соң (1970), Татар акад. театры труппасына кабул ителә. Иҗатының башлангыч чорында башкарган яклаучысы булмаган Зөһрә һәм сокланучан Мәстүрә («Һиҗрәт», «Портфель», Н.Исәнбәт), Клавдия («Мин — солдат хатыны», Н.П.Анкилов), Вера («Бер төн», Б.Л.Горбатов), Финея («Җүләр кыз», Лопе де Вега) кебек яшь героиня рольләрендә актриса һәр характерның үзенә генә хас үзенчәлекләрен бирергә омтыла. Зур осталык б-н Гөлбану («Татар хатыны ниләр күрми», Г.Ибраһимов) образын тудыра: героинясының бәхетле яшьлек елларыннан алып, татар хатын-кызын кимсетә, аның абруен түбәнсетә торган явыз чынбарлык белән котылгысыз бәрелешкә керүдән һәлак булганга кадәрге катлаулы тормыш юлын, шул юлны узган вакытта характерының даими үсеш-үзгәрешен дәлилле яктырта. Кәләш («Кияү белән кәләш», М.Бай җиев) образын ышандырырлык һәм ялкынлы итеп башкара, Зөләйха (шул исем. әсәр буенча, Г.Исхакый) ролендә, героинясының четерекле язмышын гәүдәләндереп, трагизмның югары ноктасына ирешә. Х. иҗатына хас зыялылык, сәхнәдә үз-үзен тотышында тыйнаклык, образның нечкә психол. рәсемен бирергә, беренче чиратта аның рухи эчтәлеген ачарга омтылу аның һәр ролен, ш.и. характерлы образны да, комедия персонажын да үзенчәлекле итә. Актриса Катарина («Тискәрегә авызлык», У.Шекспир),



Ф.Х.Хәйруллина Нәфисә ролендә («Канат җәйгәндә», Н.Асанбаев; Җәүдәт ролендә – И.Вәлиев).



Р.В.Хәйруллина Варенька ролендә («Ярлы кешеләр», Ф.М.Достоевский романы буенча; Макар Девушкин ролендә – А.Н.Купцов).



Д.С. Хәйруллов.



З.З.Хәким.

Халисә, Җәмилә («Су төбендә сөйгәнем», «Чапты атым Казанга», З.Хәким), Кәтернә («Горгөри кияүләре», Т.Миңнуллин), Эсмеральда («Зифа», Н.Исәнбәт) образларын аруча мавыгып уйный. Истә калырлык зур рольләре арасында Мөршидә («Мәхәббәтең чын булса», Х.Вахит), Гөлчирә («Ташкыннар», Т.Гыйззәт), Әнисә («Сөяркә», Т.Миңнуллин), Элена («Гаугалы гаилә» Э. де Филиппо), Мәрфуга («Кишер басуы», З.Хәким), Гөлемхан («Ахырзаман», Ч.Айтматов романы буенча) һ.б. бар.

Әд.: И л я л о в а И. Г.Камал театры артистлары = Артисты театра им. Г.Камала. К., 2005.

И.И.Илялова.

ХӘЙРУ́ЛЛИНА Эльмира Роберт кызы (5.11.1973, Казан), тегүчелек эшләнмәләре технологы, педагог, пед. фән. д-ры (2007). Казан технол. ун-тын тәмамлаганнан соң (1995), шунда ук модалар һәм технологияләр кафедрасында эшли, 2005 елдан дизайн һәм программалы инженерия ф-ты деканы. Хезмәтләре һөнәри белем бирү методикасына карый.

Х е з м.: Содержание и структура профессионального призвания. К., 2005; Системная ориентация проектно-творческой деятельности на саморазвитие конкурентоспособности студентов инженеров-технологов. К., 2007.

ХӘЙРУ́ЛЛОВ Дамир Сәйфулла улы (20.1.1954, Актаныш р-ны Аккүз а. — 20.4.2015, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1997), проф. (2000), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1999). Казан авиация ин-тын (1977) һәм Россия идарә академиясен (1992) тәмамлый. 1977–79 елларда «Союз» тәҗрибә КБда инженер, 1979–84 тә комсомол эшендә. 1983–86 да «Электроприбор» з-дын да цех башлыгы, 1986–89 да ТАССР МСның оештыру бүлеге инструкторы. 1992–2006 да ТР ФА президенты урынбасары, аны оештыручыларның берсе. 2007 дән Татар гумани-тар-пед. ун-тында дөнья һәм милли икътисад каф. профессоры, 2011 дән Казан ун-тында. Төп хезмәтләре ТР халык хуҗалыгы һәм аның тармакларының соц.-икътисади үсешен дәүләт тарафыннан көйләү һәм фараз-лау мәсьәләләренә карый. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Государственное регулирование процессов социально-экономической трансформации и развития Республики Татарстан. К., 1997; Новый метод анализа баланса кругооборота финансовых ресурсов // Науч. Татарстан. 1998. № 3 (автордаш); Проблемы управления социально-экономическим развитием региона. К., 2004 (автордаш).

ХӘЙЯ́М Гомәр Гыяседдин улы (якынча 1048, Нишапур ш., Иран — 1122 елдан соң, шунда ук), фарсы-та җик шагыйре, математик, философ. Нишапур мәдрәсәсендә мөселман хокукы һәм медицинасы курсын тәмамлый. Гомеренең күп өлешен Урта Азиянең һәм Иранның Бәлх, Сәмәрканд, Исфаханә һ.б. шәһәрләрендә уздыра. Х. поэтик әсәрләр, фәлсәфи һәм матем. трактатлар, ш.у. робагыйлар авторы буларак мәгълүм. Аның әсәрләрен азатлык пафосы һәм дөньяның гаделсезлегенә протест, шәхесне азатлыкка өндәү берләштерә. Дүртьюллыкларына яшәүнең мәгънәсе турында тирән уйланулар, хакыйкатькә омтылыш, икейөзле кешеләрне фаш итү, ш.у. катып калган рәсми дини карашлар б-н килештергесез бәхәс хас. Робагыйлары Коръәннән алынган өземтәләргә бай, теле ачык, сурәтләүләр һәм символлар күп. Х. поэзиясе тәэсирендә Гёте үзенең «Көнбатыш-көнчыгыш диван»ын иҗат итә. 19 йөз уртасында Х.нең исемен дөньяга үзенең тәр җемәләре б-н Э.Фицджеральд таныта («The Rubaiyat of Omar Khayyam» — «Гомәр Хәйям робагыйлары», 1868). Х.нең шигырьләре дөньяның күп кенә телләренә тәрҗемә ителә. Аның иҗаты татар әдәбиятында күп кенә поэтик жанрлар формалашуга зур йогынты ясый. Акмулла, Г.Тукай, М.Гафури, Дәрдемәнд, Ш.Бабич, Х.Туфан аның робагыйларын татар теленә тәрҗемә итәләр, аңа ияреп үзләренекен язалар. Н.Арсланов тәр җемәсендә Х.нең аеруча танылган робагыйлары дөнья күрә («Робагыйлар», 1986). Комп. Б.Мөлеков шагыйрьнең робагый текстларына берничә җыр иҗат итә.

Ә с ә р.: Трактаты. М., 1961; Рубайят. Душ., 1965; Рубайят. М., 1972.

Ә.М.Шәрипов.

ХӘКИ́М (гарәп. حكيم), дәүләт чиновнигы. Чыңгызыйлар дәүләтендә Х. дип өлкә, шәһәр идарәчесе аталган; ул салымнар җыю эшләре өчен җавап биргән, түбәнрәк дәрәҗәдәге чиновникларның эшенә күзәтчелек иткән. Казан ханлыгында Х. идарә, хокукый күзәтчелек, һәм, мөгаен, хәрби-оештыру эшләренә дә башкарган. Хәзерге татар теленда «Х.» сүзе ялгызлык исем буларак кулланыла.

Әд.: Г р е к о в Б.Д., Я к у б о в с к и й А.Ю. Золотая Орда и её падение. М.–Л., 1950.

И.Л.Измайлов.

ХӘКИ́М (Хәкимханов) Зөлфәт Зөфәр улы (11.8.1960, Түбән Кама р-ны Шаңгәлче а.), язучы. Түбән Кама химия-технол. ин-тын тәмамлый (1988). 1980 елдан Түбән Кама шәһәрендә яши, «Түбәнкаманефтехим», «Түбәнкамашин» ҖБдә эшли. 1982–88 дә Төзүчеләр клубында сәнгать җитәкчесе. 1988 дән Казанда: Татар дәүләт филармониясендә автор-башкаручы, җырчы, К.Тинчурин исем. драма һәм комедия театрында әдәби бүлек мөдире. Беренче әсәрләре 1980 елларда «Идел», «Сөембикә», «Чаян», «Казан утлары» ж-лларында басыла. Х.нең чынбарлыкны поэтик тоюының нигезендә — хәзерге заманны һәм көнкүрешне экзистенциаль һәм трагик кабул итү: «Сентябрь алмалары» исемле шигырьләр, афоризмнар һәм җырлар җыентыгы (2004). Иҗатының башлангыч чоры прозасына совет чорын сатирик сурәтләү, коммунистик идеологияне мифлардан арындыру, иҗтимагый аң стереотипларын җимерү хас. Х. әсәрләрендәге чынбарлык — буталчык халәттә, социаль, икътисади, әхлакый элемтәләр җимерелгән сурәттә күз алдына килеп баса. Шагыйрь вакыйгаларның асылына керергә, рухилыкны, күпгасырлык халык гореф-гадәтләрен югалтуның сәбәпләрен ачарга тырыша. Х. иҗатының лейтмотивы кеше үз-үзен үзгәртеп кенә дөньяны яңадан төзи ала дигән фикердән гыйбарәт: «Курку» (1992), «Әулия кабере» (1994) повестьлары, «Агымсуда ни булмас» (1995), «Гөнаһ» (1997; русчага тәрҗемәдә «Трясина», 1999) романнары. Әлеге чор драматургиясенә экспериментальлек, мифологик сюжетларга нигезләнгән тәҗрибәләр үткәрү, мәдәни модель эзләү юлы б-н дөнья буталчыклыгында гармония табарга омтылу хас. Мифларга таяну дөньяны милли кабул итүне чагылдыру алымы булып тора; мәс., «Мәңгелек кәкә изге сәфәр» романтик драмасының (1996) сюжеты (вакыйгалар 10 йөздә бара) Болгар дәүләтендә ислам дине кабул итү турындагы мифларга һәм гарәп сәяхәтчесе Ибне Фазлан язмаларына нигезләнә. Шагыйрь тудырган яңа миф заманча пьесаның тарихи материалын конкретлаштыруга, детальләштерүгә хезмәт итә. Х.нең күпчелек пьесалары Г.Камал исем. Татар дәүләт акад. театры сәхнәсендә куела. Алар арасында — «Су төбендә сөйгәнем» (1992 дә куела), «Кишер басуы» (1994 тә куела), «Җүләрләр йорты» (1996 да куела), «Күрәзәче», «Килә ява, килә ява» (икесе дә 1998 дә куела). 2000 еллар башыннан язучы иҗатында үзәк урынны милли мәсьәләләр били. Автор аларны гомумкешелек дәрәҗәсенә күтәрергә омтыла — «Мин төш күрдем» (2000 дә куела), «Чапты атым Казанга» (2001 дә куела), «Ява карлар, ява карлар» (2002 дә куела), «Телсез Күке» (2004 тә куела; ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге, 2009), «Бит» (2004 тә куела), «Мылтык» (2008 дә куела) һ.б. Х. пьесалары Татарстан Респ-касы, Башкортстан шәһәрләре театрларында, Мәскәү, Баку, Оренбургта һ.б. шәһәрләрдә куела. Милли драматургиянең барлык жанрларын һәм жанр формаларын үзләштереп, актив гражданлык позициясе булган Х. үз сәнгать дөньясын 20–21 йөзләр чигендәге Европа һәм рус мәдәниятләренең авангард алымнары ярдәмендә төзи. Комедия һәм трагикомедия жанрында чынбарлыкны тәнкыйтьләү һәм индивидуаль психол. анализ өчен автор «сүз карнавалы» алымыннан файдалана. Сатира объектын җәмгыять һәм ил масштабына кадәр киңәйтү җүләрләр йорты («Җүләрләр йорты», 1995), коммуналь фатир («Китәм инде, китәм!», 2000), авыл («Чапты атым Казанга», 2001), маскалар («Бит», 2003) кебек тотрыклы социум образларын куллану хисабына башкарыла. Аларның һәрберсе зур метафорик көчкә ия, гомуми яссылыкта тоталитар режимның һәм, аерым алганда, кеше җанының моделен күрсәтеп бирә («Гасыр мо ңы» драмасы, 2006). Х. — сүзләрен һәм музыкасын үзе иҗат итүче автор-башкаручы. Җырларына фәлсәфи эчтәлек, фольклор мотивларына һәм символикасына мөрәҗәгать итү, халык җырлары -

на охшатып башкару хас. Публицистик иҗа - ты традицион кыйммәтләрне һәм әхлакый нигезләрне саклау мәсь әләләренә багышлана.

Әсәр.: Сайланма әсәрләр: 3 томда. К., 1997.

Әд.: Әхмәдуллин А.Г. Офыклар киңәйгәндә. Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. К., 2002; Закиржанов Ә.М. Заман белән бергә: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. К., 2004; Нигматуллина Ю.Г. «Запоздалый модернизм» в татарской литературе и изобразительном искусстве. К., 2002; Сатторова А.М. Современная татарская драматургия (1985–2000 гг.): Концепция эпохи и героя. К., 2003.

Д.Ф.Заһидуллина.

ХӘКИ́М (Хәкимов) Сибгат Таҗи улы (4.12.1911, хәзер Әтнә р-ны Күлле Киме а. — 3.7.1986, Казан), шагыйрь, публицист, җәмәгать эшлеклесе, ТАССРның халык шагыйре (1986). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1937), Татарстан китап нәшриятында, «Совет әдәбияты» ж-лы редакциясендә эшли. 1938 елда «Беренче җырлар» тәүге шигырь җыентыгы дөнья күрә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Сугыш елларында катлаулы сы - науларда рухи көчен саклап кала алган солдатның хис-кичерешләрен чагылдырган шигырьләр циклын иҗат итә: «Фронтовик», «Хат», «Куллар», «Колын». Сугыштан соңгы елларда совет солдатларының, тыл хезмәтчәннәренең батырлыгы темасын дәвам итә: «Курск дугасы» (1948), «Дала җыры» (1949), «Бакчачылар» (1952), «Дуга» (1968), «Торыгыз, Мусалар!» (1969), «Немец дәфтәреннән» (1969), «Карловы Вары шигырьләре» (1970), «Эзлиләр Европа буйлап» (1981), «Күги» (1983).

1952 дә актуаль темага — нефть чыгаруга багышланган «Баулы юлында» шигырьләр циклын язып бастыра. Сугыштан соңгы иҗа - тына күтәренке рух, тыныч хезмәткә кайту сөенечче, җыр мотивлары көчәю хас. Х. шигырьләренә күренекле татар композиторлары җырлар иҗат итә: «Оренбург шәле», «Кем уйлаган» (икесе дә — комп. Ж.Фәйзи), «Әй, язмыш, язмыш» (комп. С.Садыйкова), «Юксыну» (комп. Ш.Мәҗитов), «Башка берни дә кирәкми» (комп. М.Мозаффаров), «Өзелгәнсең сиреньнән» (комп. Н.Җи һанов) һ.б.

Лирик героеның тормышта ялгышкан кешеләрнең, аеруча татар хатын-кызларының ачы язмышы өчен тирән борчылуын чагыл - дырган «Суд залында» шигырьләр циклы 1950 еллар уртасында татар лирик поэзиясе - нә зур өлеш кертә. Нәкъ шушы чорда Х.нең лиризмы психол. тирәнлек, социаль эчтәлек б-н байый, тагын да киеренкеләнә, тыныч яшәү сөенечен генә түгел, аңа юлдаш булган кайгы-борчуларны да үз эченә ала. Күп ши - гырьләре туып үскән Казан арты төбәгенә, татар халкының хәзерге һәм үткән тормы - шына, туган телгә багышлана: «Үрләр аша» (1967; русчага тәр җемәдә «Через кручи», 1968), «Дәверләр капкасы» (1974; русчага тәр җемәдә «Врата времён», М., 1977). Х. иҗа - тындагы үзәк урынны Ленин темасы алып тора: «Ленин фәрманы белән» (1958), «Күңе - лем Ленин белән сөйләшә» (1965) җыентык - лары һ.б.

Тукай образы, Тукай темасы шагыйрь иҗа - тында зур урын били: «Пар ат» (1939), «Шагыйрьнең балачагы» (1940; русчага тәр же - мәдә «Детство поэта», 1947), «Тукай турын - да поэмалар» (1953), «Тукай һәйкәле янында» (1960), «Тукай дәфтәре» шигъри циклы (1971). Тукай феноменын лири - рик-фәлсәфи аңлауның иң югары ноктасы — «Кырыгынчы бүлмә» (1971) поэмасы. Татар халкының күренекле вәкилләре - нә «Ибраһим Йосфи», «Сары капкалы йорт» поэмалары (икесе дә — 1958), «Баһавиның мо ңы» (1963), «Җәлил шәһәре» (1964) шигырьләре һ.б. багышлана



С.Т. Хәким.

Х. поэзиясенә дөньяны оптимистик кабул итү, милли үзенчәлек, халыклар дуслыгына дан җырлау хас. Стиль тотнаклыгы һәм кыс - калыгы эмоциональ эчтәлек, ритмик рәсемнең ачыклыгы, шигъри детальләрнең байлыгы һәм үзенчәлеге б-н үрелеп бара. Х. татар әдәбияты вәкилләре, рус һәм күпмилләтле совет әдәбияты, иҗат психологиясе турындагы «Үз тавышың белән» (1969), «Халык язмышы — шагыйрь язмышы» (1979), «Яшә, борчулы җаным» (1988) публицистик мәка - ләләр авторы. Х. әсәрләре татар, рус, баш - корт һ.б. телләрдә нәшер ителә. 1963–67 дә ТАССР ЮС депутаты. ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1960). РСФСРның М.Горький исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1970). Ленин ордены, Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары б-н бүләкләнә. 1981 дә Әтнә р-нының Күл - ле Киме авылында Х. музее ачыла.

Әсәр.: Сайланма шигырьләр һәм поэмалар. К., 1954; Җил исми, яфрак селкенми. К., 1960; Фазыл чишмәсе. К., 1974; Сайланма әсәрләр: 2 томда. К., 1986; Десять ключей на горе. К., 1981.

Әд.: Сибгат Хәким. К., 1971; Таныш өянкеләр: истәлекләр. К., 1997; Галиуллин Т. «Бәрелде җан, сугылды җан ярсып...» // Казан утлары. 2006. № 11; Мустафин Р. Сибгат Хаким. М., 1979.

Ф.Г.Галимуллин, З.З.Рәмиев.

ХӘКИ́М СИБГА́Т МУЗЕЕ́, Әтнә р-нының Күлле Киме авылында. 1981 елда җәмәгать акчасына оештырыла. Башта булачак шагыйрь укыган мәктәптә урнаша. 1995–2006 елларда ТР Дәүләт музее (хәзер ТР Милли музее) ф-лы, 2007–10 да муниципаль музей, 2010 нан Әтнә төбәк тарихы музее ф-лы. 1996 да ике катлы яңа мәктәп бинасында экс - позиция ачыла (фәнни концепция авторлары — Л.Ә.Шәмсиева, язучы В.Н.Нуруллин, сәнгать проекты авторы — Ф.Ә.Зыязов). Экс - позиция мәйданы — 90 *м*^{2}, фондларында 2417 саклау берәмлеге исәпләнә. Тематик экспози - ция «Шагыйрьнең нәсел шәҗәрәсе», «Күлле Киме — Сибгат Хәкимнең туган ягы», «Уку еллары (1921–1930)», «Шагыйрьнең Казан чоры тормышы (1930–1975)», «Сибгат Хә - ким Бөек Ватан сугышы фронтларында (1941–1946)», «Шагыйрьнең иҗат лабораториясе», «Безнең көннәрдә Сибгат Хәким - нең иҗади мирасы» бүлекләреннән тора. Бү - лекләрнең берсе мәктәпне тәмамлаучыларга: Ә.Ә.*Сәфәровка*, Л.Г.Шагыйрь җанга, Л.Г.*Ша - киржановага* багышлана. Музейның аеруча кыйммәтле экспонатлары арасында — шагыйрь китапханәсеннән китаплар (424 саклау берәмлеге), мемориаль әйберләр: аның би - шеге, китап шкафы, язу өстәле, урындыклар, өстәл лампасы, киемнәр, документлар һ.б. Музей ел саен шагыйрьнең туган көнен (4 де - кабрь), Җиңү бәйрәмен (9 май), Халыкара музейлар көнен (18 май) билгеләп үтә.



Сибгат Хәким мемориаль музее. Экспозиция фрагменты.

Музей директоры — Л.Ә.Шәмсиева (1981 дән).

ХӘКИМ ҖА́НОВ Илгизәр Нургизәр улы (9.3.1960, Яшел Үзән р-ны Норлат а.), нефтьче, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2007), техник фән. канд. (2002). Казан ун-тын тәмамлый (1986), ТатНИПИнефтьтә эшли. Хезмәтлә - ре нефть чыганакларыннан файдалануга ка - рый. Дәүләт бүләге автоматлаштырылган проектлау нигезендә нефть чыганакларыннан файдалану алымнарын булдыруда һәм сәнә - гать күләмендә кулланышка кертүдә катнаш - каны өчен бирелә.

Хезм.: К проектированию профиля горизонтальной скважины // Интервал. 2002. № 9 (автордаш); Опыт строительства и эксплуатации многозабойных скважин // Нефть и жизнь. 2005. № 3 (автордаш).

ХӘКИМҖА́НОВ Фәрит Сабиржан улы (29.7.1945, Казан), тел галиме, тюрколог, филол. фән д-ры (1992), проф. (2008), ТРның ат - каз. фән эшлеклесе (2004). Казан ун-тын тә - мамлаганнан соң (1971), «Татарстан яшьләре» г-тасы редакциясендә эшли. 1976 елдан СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында. 1989–92 дә РФА КГУнең Тел, әдәбият һәм тарих ин-ты каршындагы Татар совет энциклопедиясе бүлеге мөдире. Төркиядә эшли: Әнкара ун-ты профессоры (1992–96), «Коджатеп» ун-тында (Афьонка - рахисар ш., 2010 нан); 1996 дан Казан гума - нитар-пед. ун-тында, татар тел белеме ка - федрасын оештыра һәм аның б-н җитәкчелек итә, 2011 дән Казан ун-тында укыта. «Мил - ли мәдәният» (2001 дән), «Türkoloji üzerine araştırmalar» («Тюркологик тикшеренүләр», Афьонкарахисар ш., 2012 дән) ж-лларының баш мөхәррире, «Российская тюркология» (Мәскәү, 2009 дан) ж-лының баш мөхәррир урынбасары. Хезмәтләре Идел буе болгар - лары эпиграфикасына, этногенезына һәм Идел буе Болгар дәүләте халыкларының тел - ләре тарихы мәсьәләләренә карый. Чит ил студент-тюркологлары өчен төрек-татар-рус сөйләүлекләре (Әнкара, 1994) һәм татар те-



З.Р. Хәкимҗанова.



К.Г. Хәкимов.

ле буенча уку-укыту ярдәмлекләре авторы. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Татар тел белеме библиографиясе (1981–1997). К., 1998 (автордаш); Татар теле: фонетика. К., 2000; 1001 әйтем. К., 2004; Хәзерге татар әдәби теле: пунктуация. К., 2004 (автордаш); Язык эпитафий волжских булгар. М., 1978; Эпиграфические памятники Волжской Булгарии и их язык. М., 1987.

Әд.: Тюркологи современного Татарстана. М., 1997.

ХӘКИМ ҖӘНОВА Зөләйха Рәфыйк кызы (30.6.1950, Әстерхан өлкәсенең Нариман р-ны Ярлы Түбә (Осыпной Бугор) а.), драма актрисасы, ТРның халык артисты (2003). 1974 елдан Татар респ-ка күчмә театрында (хәзер Татар драма һәм комедия театры) режиссёр ярдәмчесе булып эшли, эпизодларда һәм массакүләм сәхнә күренешләрендә зур булмаган рольләр башкара, 1980 дә актриса вазифасына күчерелә. Театр сәхнәсендә Х. тышкы





З.Р. Хәкимҗанова: 1. Маһирә («Яңадан мәхәббәт турында», Х. Вахит; Рафаэль ролендә – И. Хафизов); 2. Рәмзия («Париж егете Әлфәнис», М. Гыйләҗев) рольләрендә.

рәсеменнән үк игътибарны җәлеп иткән, югары сәнгатьчәлеге б-н аерылып торган истә калырлык образлар тудыра: Маһирә («Яңадан мәхәббәт турында», Х.Вахит), Айсылу («Ташкыннар», Т.Гыйззәт), Гөлчирә («Әни - емнең ак күлмәге», Ш.Хөсәенов), Балбикә («Аты барның — дәрте бар», Н.Гаетбай), Клариче («Ике хуҗаның хезмәтчесе», К.Гольдони), Алсубикә («Карт гашыйк», С.Шәкүров), Әминә («Ак тәүбә, кара тәүбә», Т.Миңнуллин), Рәмзия («Бала баласы балдан татлы», Х.Вахит), Аида («Тол хатыннар көймәсе», И.Грекова), Урсула («Гаугалы гаилә», У.Шекспир), Надя («Хыянәтче», А.Макаёнок), Сәхилә («Хуҗа Насретдин», Н.Исәнбәт), Министр урынбасарының хатыны («Әллә язмыш, әллә ялгыш...», Н.Нестерова), Фәүзия («Төш», Т.Миңнуллин), Хатимә («Сөяркә», С.Шәкүров), Гөләндәм («Бер тамчы ярату», Н.Гыйматдинова), Ху җәбикә («Без барыбыз да кешеләр», Эрих Мария Ремарк), Нурзадә әби, Убырлы («Эх, алмагачлары!», «Шүрәле-online», Ш.Фәрхетдинов) һ.б.

ХӘКИ́МОВ Исмәгыйль Насыйбулла улы (29.1.1963, Куйбышев (хәзер Самара) өлкәсенең Кошки р-ны Тёплый Стан а.), мөгезле эре терлекләр үрчетү буенча белгеч, а.х. фән. д-ры (2011). Куйбышев а.х. ин-тын (хәзер Самара а.х. академиясе) тәмамлаганнан соң (1985), шунда үк зоогигиена кафедрасында эшли; бер үк вакытта, 1995–2010 елларда, проректор урынбасары. 2012 дән а.х. терлекләрен үрчетү һәм тукландыру каф. профессоры. Тикшеренүләре Самара өлкәсе шартларына яраклаштырылган җирле һәм читтән кертелгән махсус ит терлекләре токымнарының генетик потенциалын файдаланып, нәтиҗәле юллар б-н югары сыйфатлы сыер ите җитештерүнең фәнни яктан нигезләнгән технологияләрен эшләүгә карый.

Х е з м.: Эффективность использования биологических и биотехнологических приёмов при разведении мясного скота. Самара, 2010 (автордаш); Химический и аминокислотный состав мяса быков ангусской и лимузинской пород // Изв. Самар. гос. с.-х. академии. 2010. № 4 (автордаш); Эффективность гормональной обработки и пересадки эмбрионов по канадской технологии // Аграрная наука. 2010. № 10 (автордаш).

ХӘКИ́МОВ Кәрим Габдерәүф улы (28.11.1892, Уфа губ., Бәләбәй өязе Дүсән а. — 10.1.1938, Мәскәү өлкәсе Бутово полигоны), дипломат. «Галия» мәдрәсәсендә (Уфа ш., 1910–11), Кызыл профессорлар ин-тында (Мәскәү, 1932–35) укый; Тубыл гимназиясен экстерн тәртибендә тәмамлый (1917). 1918–19 елларда Оренбург өлкәсендә: Мөселманнар хәрби-революцион ком-ты әгъзасы, халык мәгарифе комиссары, Оренбург фронты интернациональ полкының 2 нче баталоны командиры, Идел буе татар укчылар бригадасы 1 нче бүлегенең сәяси бүлекчәсе баш - лыгы. 1920 дән дипломатик эштә: Төркестан Коммунистлар партиясе ҮК әгъзасы (1920–21), РСФСРның Бохара Халык Совет Җөмһүриятендәге вәкаләтле вәкиле урынбасары. 1921–23 тә РСФСРның Мәшһәд шәһәрендәге ген. консулы, 1923 тә СССР ның Решт шәһәрендәге (Иран) ген. консулы. 1924–25 тә СССРның Хи җаз, Нәҗд король - лекләрендәге (Согуд Гарәбстаны) ген. консулы, 1926–28 дә вәкаләтле вәкиле. 1929–32 дә СССРның Йәмәндәге Якын Көнчыгыш илләрендә сәүдә вәкиле. 1936–37 дә СССРның Согуд Гарәбстанындагы вәкаләтле вәкиле. Репрессияләнә; үлгәннән соң аклана.

Әд.: Г а д и л о в Л.З., Г у м е р о в Ф.Х. Революционер-дипломат К.А.Хакимов: Ист.-биогр. очерк. Уфа, 1977; Воспоминания о Кариме Хакимове. Уфа, 1982; К.Хакимов — первый советский полпред в Саудовской Аравии // Гасырлар авазы = Эхо веков. 1995. Май; В а л е е в Р. Миссия в Джидде // Татары у себя дома. К., 2005.

ХӘКИ́МОВ Мансур Сәләхетдин улы (15.4.1946, Красная Горка а., хәзер Түбән Новгород өлкәсенең Пилнә р-ны Сафажай а.), генерал-полковник (2006), юридик фән. д-ры (2002), проф.(2003). Мәскәү совет сәүдәсе читтән торып уку ин-тын (1979), СССР Эчке эшләр министрлыгы академиясен (1980) тәмамлый. 1972 елдан Мәскәү эчке эшләр органнарында, 1982 дән СССР Эчке эшләр министрлыгының Социаль милекне урлаулар б-н көрәш баш идарәсендә эшли. 2000 нән Иминлек, оборона һәм хокук тәртибе проблемаларын өйрәнү академиясе вице-президенты, бер үк вакытта, 2000–03 тә, РФ Дәүләт Думасының Хезмәт һәм социаль сәясәт ком-тында консультант. 2009 дан «Экос» фәнни-техник үзәге рәисе. 2002 дән «Родничок» халыкара хәйрия фонды президенты. Сталин репрессияләре корбаннарына (1995) һәм татар мәгърифәтчесе Х.*Фәезхановка* (2001, Сафажай авылында куела) үз акчасына һәйкәлләр төзетә. 2004 тән Россия Эчке эшләр министрлыгының хокукый яклау буенча үзәк аппаратының Ветераннар советы рәисе киңәшчесе. Мәскәүдә яшәүче Түбән Новгород татарлары якташлыгының попечительләр советы рәисе (2001 дән). Хезмәтләре Россиянең икътисади иминлеге һәм икътисади җинаятьләр б-н көрәштә заманча алымнар (мәгълүмат һәм компьютер технологияләрен кулланы) мәсьәләләренә карый. 2 нче дәрәҗә Александр Невский, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Бөек Пётр орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Татары: Воины, труженики, патриоты: Биогр. справ. М., 2006 (автордаш); Провал операции «Шаровая молния»: Татары в партизанских отрядах Белоруссии в годы Великой Отечественной войны. К., 2010 (автордаш).

Әд.: Великая Россия. Имена: Энцикл. справ. М., 2004; Золотая книга наций. М., 2006. Т. 2; С е н ю т к и н С.Б., С е н ю т к и н а О.Н., С а б и р о в С.В. История татарской деревни Сафаджай-Красная Горка в XV–XX вв. Н.Новгород, 2006.

ХӘКИ́МОВ Михаил (Исмәгыйль) Кәбир улы (1.11.1916, Сембер губ., Сембер өязенең Зур Чынлы а. — 19.11.1986, Казан), Сов. Союзы Герое (20.5.1945), матрос. Баку портында буксир капитаны ярдәмчесе булып эшли. 1942 елның маеннан Хәрби-диңгез флотында һәм Бөек Ватан сугышы фронтларында; Батуми һәм Новороссийск шәһәрләре яр буе оборонасында, аннан соң диңгез пехотасында хезмәт итә. 1944 нең 26 мартына каршы төндә 3 нче Украина фронтының 28 нче армиясе 384 нче аерым диңгез пехотасы батальоны составында Николаев шәһәре портында (Украина ССР) барган хәрби

хәрәкәтләрдә батырлык күрсәтә: десантчылар төркеме б-н дошман тылына төшерелә (отряд ике тәүлек шәһәр портында сугыш алып бара, дошманның 18 һөҗүмен кире кайтара), дошман танкын сафтан чыгара һәм немец тубын юк итә. Демобилизацияләнгәннән соң (1945), Казанда яши һәм эшли. Ленин ордены, ике 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Николаев шәһәрендә һәм Зур Чынлы авылында сугышчан һәм хезмәт даны музейларында Х.ка багышланган экспозиция ачыла. Николаев шәһәренең мактаулы гражданы; шәһәрдә Геройга һәйкәл куела.

Әд.: Батырлар китабы – Книга Героев. К., 2000.

М.З.Хәбибуллин.

ХӘКИ́МОВ Нигъмәтулла Гыйниятулла улы (псевд. Нигъмәт Хәким) (26.121889, Уфа губ., Златоуст өязенең Еланлы а. — 3.8.1937, Мәскәү), тел галиме, шагыйрь. «Галия» мәдәсәсендә укый (Уфа ш.). 1913–25 елларда Уфа мәктәпләрендә, Златоуст шәһәрендә татар-башкорт пед. курсларында, Үзбәкстан кыз балалар ин-тында һәм Милли азчылык өчен мәгариф ин-тында (икесе дә — Ташкент) татар теле укыта. Ленинград шәрекъ ун-тын тәмамлаганнан соң (1930), Казанда яши; Шәрекъ-пед. ин-тында, Казан коммуналь төзелеш инженерлары ин-тында, Казан ун-тының Фәнни китапханәсендә эшли. «Идегәй» эпосының бер нөсхәсен язып ала һәм фәнни әйләнешкә кертә. Хезмәтләре ислам тарихына, татар тел белеменә карый. «Күңел дулкыннары», «Күңел музыкасы» (икесе дә — Уфа, 1913) шигъри җыентыкларының авторы. Репрессияләнә, үлгәннән соң аклана.

Х е з м.: Борынгы шәрык коммунасы. Уфа, 1913; Ислам диненең килеп чыгуы. К., 1926.

Әд.: С а г и т о в М.А. Нигматулла Гиниятуллович Хакимов (к девяностолетию со дня рождения) // Советская тюркология. 1979. № 6; ш у л у к. Возвращено имя твоё истории. Уфа, 2002.

М.Ә.Сәгыйтов.

ХӘКИ́МОВ Рафаил Сибгат улы (12.2.1947, Казан), тарихчы, политолог, публицист, филос. фән. канд. (1980), тарих фән. д-ры (2009), ТР ФА хакыйкый әгъзасы (2011; 2010 елдан мөхбир әгъза), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1997). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1970), «Татгрансуправление» проект-конструкторлык бюросында өлкән инженер булып эшли. 1973 тән Казан ун-тында, 1981 дән Казан мәдәният ин-тында филос. каф. мөдире һәм проректор, 1989 дан КПССның Татарстан Респ.-ка ком-тында идеология һәм иҗтимагый берләшмәләр һәм хәрәкәтләр б-н багланыш мәсь әләләре буенча комиссия рәисе урынбасары. 1991–2008 дә ТР Президенты киңәшчесе, бер үк вакытта ТР ФАнең Ш.Мәр җәни исем. Тарих ин-ты (2014 тән ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагында) директоры, ТР ФА вице-президенты (2013 тән). 1990 елларда татар милли хәрәкәте идеологларының берсе. *Татарстан Совет Социалистик Республикасының Дәүләт суверенитеты турында Декларация* (1990), *«Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында» Шартнамә* (1994, 2007) эшләүдә, Татарстан Респ-касы Конституциясен (1992) һ.б. мөһим документларның текстларын әзерләү буенча комиссия эшендә актив катнаша. Хезмәтләре Татарстанның иҗтимагый-сәяси тарихы, политология, менеджмент өлкәсенә карый. Х. — «Иң борынгы заманнардан алып татарлар тарихы» («История татар с древнейших времён», т. 1–7, 2002–15), «Tatarica: татарлар һәм Евразия халыклары тарихы. Татарстан кичә һәм бүген: атлас» («Tatarica: история татар и народов Евразии. Республика Татарстан вчера и сегодня: атлас» (М., 2006) фундаменталь хезмәтләренең баш мөхәррире. ТР Дәүләт Советы депутаты (2009–14). Казанның барлыкка килүен, шәһәрнең үсеш этапларын нигезләгән, аның тарихи-мәдәни мирасына караган хезмәтләр циклы өчен ТР Дәүләт бүләгенә лаек була (2008). ТРның Мактау грамотасы (2002), медальләр б-н бүләкләнә.



М.С. Хәкимов.



М.К. Хәкимов.



Р.С. Хәкимов.



И.Ш. Хәкимова.

Х е з м.: Сущность и социальная роль управленческих отношений. К., 1985; Сумерки империи: К вопросу о нации и государстве. К., 1993; Тернистый путь к свободе (Сочинения. 1989–2006). К., 2007; Российский федерализм в условиях социально-политической трансформации. К., 2009; Джадидизм (реформированный ислам). К., 2010; Наука управления (Курс лекций). К.. 2011.

Әд.: Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К.. 2004. Т. 3.

ХӘКИ́МОВ Эдвард Мурат улы (12. 4. 1938, ТАССР, Чистай ш.), геолог, философ, филос. фән. д-ры (1993), проф. (1994). Казан ун-тын тәмамлый (1962), Көнбатыш Себер геол. идарәсендә эшли (1965 елга кадәр, Кемерово өлкәсенең Новокузнецк ш.). 1968–2011 дә Казан пед. ин-тында, физик геогр. һәм геол. каф. мөдире (1985–2011). 2011 дән Казан ун-тының Экология һәм геогр. ин-тында геогр. һәм төбәкне өйрәнү каф. профессоры. Хезмәтләре табигыять белеме философиясе мәсь әләләренә карый. Гомуми теорияләр системасын тәшкил итүче иерархик системаларның гомумфәнни теориясен тәкъдим итә. Х. тарафыннан үсеш теориясе һәм методологиясе, динамика һәм төрле дәрәҗәдәге катлаулы системаларны модельләштерү тикшерелә, алар нигезендә геол., геогр., биол. һәм социол. объектларны структуралы оештыру өйрәнелә. Балалар һәм яшүсмерләр өчен хикәяләр, үзәк журналларда басылган, илкүләм һәм халыкара күргәзмәләрдә тәкъдим ителгән табигать турындагы фотографик хезмәтләр авторы. РФнең Мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2004).

Х е з м.: Наедине с природой. К., 1979; Моделирование иерархических систем: теоретические и методологические аспекты. К., 1986 (автордаш); Диалектика иерархии и неиерархии в философии и научном знании. К., 2007.

ХӘКИ́МОВА Айсылу Мурат кызы (22.3.1928, Казан — 4.6.2003, шунда ук), гигиенист, мед. фән. д-ры (1984), проф. (1986). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1952), шунда ук, гомуми гигиена кафедрасында эшли, курс мөдире.(1965 тән), балалар һәм яшүсмерләр гигиенасы каф. мөдире (1985 тән). Хезмәтләре респ-када әйләнә-тирә мохитнең балалар сәламәтлегенә тәэсирен өйрәнүгә карый. Х. тарафыннан әйләнә-тирәнең авыр металлар б-н зарарлануының төбәк аспектлары өйрәнелә, профилактика чаралары тәкъдим ителә. ТР мисалында азык-төлек составындагы микроэлементларны өйрәнү нәтиҗәләре РМФАнең Туклану гигиенасы ин-ты тарафыннан бастырып чыгарылган азык продуктларының химик составы таблицаларында чагылыш таба (1979, 1992).

Х е з м.: Микроэлементозы человека. К., 1989; Геохимическая экология как основа профилактики эндемических болезней населения. К., 1990; Региональные аспекты загрязнения среды тяжёлыми металлами и здоровье населения // Казан. мед журн. 1994. № 1 (автордаш).

ХӘКИ́МОВА Ирина Шәриф кызы (29.3.1951, Чиләбе өлкәсенең Йөрүзән ш.), балет артисты, педагог, ТАССРның атказ. артисты (1974), ТАССР һәм РСФСРның ха-



И.Ш. Хәкимова Жизель ролендә (шул исем. әсәр буенча, А.Адан).

лык артисты (1976, 1987). 1970 елда Пермь хореография уч-щесен (педагог Л.П.Сахарова), 2007 дә Казан консерваториясен тәмамлый. 1970–96 да балет солисты, 1997–2003 тә Татар опера һәм балет театрының балет труппасында педагог-репетитор, бер үк вакытта, 1990 нан, Казан музыка уч-щесендә, 1993 тән Казан хореография уч-щесендә. Хореография партияләре: Одетта-Одиллия, Аврора, Маша («Аккош күле», «Йокыга талган гүзәл», «Щелкунчик», П.Чайковский), Жизель (шул исем. әсәр буенча, А.Адан), Сильфида (шул исем. әсәр буенча, Х.Лёвеншель), Джульетта («Ромео һәм Джульетта», С.Прокофьев), Сөембикә («Шүрәле», Ф.Яруллин), Сәрви («Су анасы», Ә.Бакиров), Китри («Дон Кихот», Л.Минкус) һ.б. Х.ның биюе классик па хәрәкәтен чиста башкаруы, югары техникасы, образлы сәнгатьчәлеге б-н аерылып тора. Бөтенсоюз «Ак төннәр» («Белые ночи»), «Киев язы» («Киевская весна»), «Россиянең яшь балеты» («Молодой балет России»), «Россия йолдызлары» («Звёзды России») һ.б. балет фестивальләрендә катнаша. Чит илләрдә (Италия, Франция, Португалия, Германия, Япония, АКШ, Сенегал, Марокко, Нигерия, Кипр һ.б.) гастрольләрдә була. ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1997). 1980–85 тә ТАССР ЮС депутаты.

Әд.: О н ч у р о в а Н. Ирина Хакимова // Советский балет. 1988. № 1.

В.Н.Горшков.

ХӘКИ́МОВА Резеда Фидаил кызы (19.1.1964, Казан), аллерголог, мед. фән. д-ры (2002). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1987), 7 нче шәһәр балалар хастаханәсендә (Казан) эшли. 1988 елдан ГИДУВның балалар аллергологиясе кафедрасында, 1998 дән Казан мед. ун-тының клиник иммунология һәм аллергология кафедрасында, каф. профессоры (2007 дән). Хезмәтләре ТР терр-ясендә балалар аллергия авыруларының таралышын һәм төбәк үзенчәлекләрен өйрәнүгә карый. Х. тарафыннан авыруны дәвалау һәм кисәтүне оптимизацияләү ысуллары тәкъдим ителә.

Х е з м.: Окружающая среда и здоровье, К., 2001 (автордаш); Экология и аллергопатология детей. К., 2003 (автордаш); Факторы риска формирования атопического дерматита у детей раннего возраста // Общественное здоровье и здравоохранение. 2010. № 4.

ХӘКИ́МОВА Фатыйма Миргасыйм кызы (4.4.1922, Бөгелмә кантоны Сәпәй а. — 10.10.2011, Казан), вет. патологоанатомы, вет. фән. д-ры (1974), проф. (1976). Казан вет ин-тын тәмамлаганнан соң (1946), шунда ук эшли, 1976–88 елларда патологик анатомия каф. профессоры. Хезмәтләре а. х. терлекләренең ата затларында җенес бизләре онтогенезы һәм патоморфологиясенә карый. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Патоморфологические изменения при мышьяковом отравлении сельскохозяйственных животных // Уч. зап. Казан. вет. ин-та. 1957.Т.65; Патоморфологическая оценка методов частичной кастрации самцов сельскохозяйственных животных // Ветеринария. 1973. № 5 (автордаш).

Әд.: Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.): Биогр. словарь учёных. К., 2006.

ХӘКИ́МОВА Фәизә Гани кызы (14.3.1917, Уфа губ., Минзәлә өязе Сәмәкәй а. — 13.7.1979, Казан), хакимият эшлеклесе. КПСС ҮК каршындагы Югары партия мәктәбен (Мәскәү, 1956) тәмамлый. 1934–45 елларда (бүленеп) Минзәлә р-нында: «Ленин байрагы» г-тасы редакциясе секретаре (1935 кә кадәр), 1935–36 да Дәвек урта мәктәбе укытучысы, 1936–38 дә ВЛКСМның район ком-ты бүлеге мөдире, 1938–39 да 1 нче секретаре, 1939–42 дә һәм 1943 тән ВКП(б)ның район ком-ты инструкторы. 1942–43 тә «Татарстан» с-зының (Чаллы р-ны) сәяси бүлеге башлыгы урынбасары. 1945–49 да КПССның Ширәмәт, 1951–52 дә Тәтеш, 1953–59 да Кайбыч район ком-тларының секретаре. 1952–53 тә Чистай өлкәсе хезмәт ияләре депутатлары советы башкарма ком-тында бүлек мөдире. 1959–77 дә ТАССР социаль тәэминат министры. ТАССР (1938–59, 1963–71), СССР (1958–62) ЮС лары депутаты. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Е.Б.Долгов.

ХӘКИ́МОВА Фирдәвес Харис кызы (27.6.1938, Чаллы р-ны Биклән а.), химик-технолог, техник фән. д-ры (2008), проф. (1994), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (1999). 1965 елда Урал урман техникасы ин-тын (Свердловск ш.) тәмамлаганнан соң, Ленинград урман техникасы академиясендә эшли. 1970 тән Пермь политехник ин-тында (хәзер Пермь милли политехник тикшеренү ун-ты), целлюлоза-кәгазь җитештерү технологиясе каф. мөдире (1977 дән). Хезмәтләре целлюлоза-кәгазь җитештерү өчен экологик яктан зыянсыз технологияләр эшләүгә карый. Яшь үзагачтан сульфит һәм бисульфит целлюлоза, төрле тармак сәнәгать өчен порошок целлюлоза җитештерүнең технологияләрен тәкъдим итә. Уйлап табуга 28 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Возможность расширения сырьевой базы целлюлозного производства за счёт использования молодой древесины // Целлюлоза. Бумага. Картон. 2007. № 6; Исследования отделки бисульфитной целлюлозы хлоритом натрия // Целлюлоза. Бумага. Картон. 2011. № 5 (автордаш); Hydrogen Peroxide and Sodium Chlorite ECF Bleaching of Sulphate Hardwood Pulp // World Applied Sciences Journal. 2013. № 22 (автордаш).

ХӘКИМУ́ЛЛИН Юрий Нури улы (30.8.1946, Южно-Сахалинск ш.), химик-технолог, техник фән. д-ры (2003), проф. (2007). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1970), шунда ук эшли. 1975–80 елларда Казан химия фәнни-тикшеренү ин-тында, 1980–2002 дә Махсус кулланышлы каучуклар фәнни-тикшеренү ин-тында (1982 дән лаб. мөдире), 2002–04 тә Казан ясалма каучук з-ды баш инженеры, бер үк вакытта Казан технол. ун-тында эластомерларны эшкәртү химиясе һәм технологиясе каф. профессоры (2003 тән). Хезмәтләре югары молекуляр кушылмалар химиясенә карый. Х. полисульфид олигомерлар составының герметикларның катылануына, модификацияләшүенә һәм алар нигезендә тулуына йогынтысын өйрәнә. Файдаланылган бутилкаучуклы резиналарның радиацион деструкциясен вулканлаштыручы агентның табигате, тутыргычның сыйфат һәм микъдари составына карап тикшерә; бутилкаучукның радиацион деструктантлары структурасын билгели. Эластомер нигезендә җитештерелгән һәм төрле максатта кулланылган композицион материаллар технологиясен эшли һәм аларны ТР һәм РФ пр-тиеләрендә гамәлгә кертә. Х. тәкъдим иткән полисульфид олигомерлар нигезендәге катыланучы герметиклар төзелештә, тракларны, сәнәгый биналарны һәм корылмаларны ремонтлаганда файдаланыла. Уйлап табуга 25 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Некоторые аспекты влияния рецептурных факторов на прочностные свойства шин. К., 2001 (автордаш); Влияние молекулярных характеристик каучуков на реологические свойства наполненных композиций и физико-механические свойства резин. К., 2007 (автордаш); Герметики на основе полисульфидных олигомеров: синтез, свойства, применение. М., 2007 (автордаш).

Әд.: Выпускники — гордость Казанского технологического университета: Краткий биогр. справ. К., 2009.

ХӘЛ ФИГЫ́ЛЬ, төп *фигыльдән* аңлашылган эш яки хәлгә өстәмә эшне белдерә, аны ачыклый торган фигыль формасы (мәс., калдырып кайту, барып алу). Татар телендә Х.ф.нең 5 төре бар. Алар түбәндәге кушымчалар ярдәмендә ясала: 1) -ып/-еп, -п: барып, килеп, сайлап; 2) -а/-ә, -ый/-и: бара-бара, көтә-көтә, сайлый-сайлый; 3) -гач/-гәч, -кач/-кәч: баргач, күргәч, кайткач, үскәч; 4) -ганчы/-гәнче, -канчы/-кәнче: барганчы, килгәнче, кайтканчы, киткәнче; 5) -ышлый/-ешли: барышлый, үтешли. Лексик-семантик яктан Х.ф. башка фигыль формалары кебек үк баш каручыга бәйле эш-хәлне, процессны белдерә, әмма махсус морфологик күрсәткечләре булмый: (мин, син, ул, без, сез, алар) кайткач. Татар Х.ф.е фигыль б-н белдерелгән эш-хәлне башкаручының эшен дә, ш.у. башка зат яки предметның эшен дә белдерә ала: кайткач күрдем — мин кайткач күрдем; син (ул һ.б.) кайткач күрдем. Морфологик яктан Х.ф.дә фигыльгә хас грамматик категорияләр чагылыш таба: барлык-юклык б-н төрләнә (кайткач-кайтмагач), юнәлеш формаларын ала (күреп, күренеп, күрелеп, күрешеп, күрсәтеп), эшнең үтәлү дәрәҗәсен белдерә (кайтыштыргач, кайтып беткәч, кайтып торгач). Х.ф.гә вакыт грамматик категориясе хас түгел. Эш-хәлнең сөйләм моментына мөнәсәбәтеннән чыгып, Х.ф. үзе ачыклаган икенче фигыль б-н вакыт ягыннан төрле мөнәсәбәттә була, мәс., елмаеп сөйли (ике эш тә бер үк вакытта, ягъни сөйләм моментында башкарыла); елмаеп сөйләде (Х.ф. төп эштән алдагы эшне, ягъни сөйләм моментына кадәрге эшне белдерә) һ.б. Синтаксик яктан Х.ф. җөмләдә хәл һәм иярчен җөмләнең хәбәре булып килә.

Әд.: Татар грамматикасы: Морфология. М.–К., 2002. Т. 2; Х и с а м о в а Ф.М. Татар теле морфологиясе. К., 2006; Ю л д а ш е в А.А. Соотношение деепричастных и личных форм глагола в тюркских языках. М., 1977; Т у м а ш е в а Д.Г. Татарский глагол. К., 1986.

Ф.М.Хисамова.

ХӘЛӘ́Л (гарәп. حلال), мөселманнарга рөхсәт ителгән эшләр, гамәлләр. Х.нең капма-каршысы хәрам (тыелган). Тар мәгънәдә — ислам кануннары буенча рөхсәт ителгән ризык. Мондый күрсәтмәләр нигездә иткә һәм ит ризыкларына кагыла. Бары тик ислам кануннары буенча чалынган мал гына (дуңгыз, ишәк яки мул, казык тешле ерткыч хайваннар, ш.и., мәчеләр һәм этләр, ерткыч кошлардан башка) кулланырга рөхсәт ителә. ТРда хәләл азык ны җитештерү һәм сатуга контрольлек итү максатында 2005 елдан ТР Диния нәзарәте каршында «Хәләл» стандарт ком-ты эшли.

Әд.: К а р д а в и Ю. Дозволенное и запретное в исламе. М., 2007.

ХӘЛИ́Л ХАН (? — 1467), Казан ханы (1467). *Мәхмүд* ханның өлкән улы. Аның турында тарихи мәгълүматлар сакланмаган.

ХӘЛИЛИ́ Вәлиулла (? — 1934, Зеленодольск ш.), шагыйрь. Берникадәр Кустанай шәһәрендә яшби. «Акмулла» һәм «Шура» ж-ллары б-н хезмәттәшлек итә, аларда шигырьләрен бастыра. 1917 елдан соң берничә тапкыр кулга алына. 1930 дан Зелёный Дол посёлогында (1932 дән Зеленодольск шәһәре) яши, фанера з-дында эшли. Троицк шәһәрендә нәшер ителгән Ш.Бабич, С.Кудаш һ.б. татар шагыйрьләренең шигырьләре кергән җыентыкны төзүче буларак мәгълүм.

Әд.: Татар шигърияте: XX гасыр башы. К., 2004.

ХӘЛИЛИ́ Ягъкуб Ибраһим улы (10.12.1877, Вятка губ., Сарапул өязе Иж-Бубый а. — 15.1.1938, Казан), журналист, нашир. Иж-Бубый мәдрәсәсен тәмамлагач, шунда ук укыта. 1913–18 елларда татар хатын-кызларының беренче «*Сөембикә*» ж-лы нашире һәм мөхәррире, шул ук вакытта, 1917–18 дә, «*Балалар дөньясы*» ж-лы чыгара. «Сөембикә» ж-лы ябылганнан соң, Казан һәм Буа дәүләт уч режденияләрендә, сәүдә оешмаларында эшли. «Юл» ширкәте әгъзасы буларак, китаплар нәшер итүдә актив катнаша. Татар мәктәпләре өчен китаплар һәм уку дәреслекләре: «Тәгълим әс-сарыф» (1909), «Гыйльми хәл», «Иң яңа әлифба», «Мисаил хисап» (1910), «Әнбия тарихы» (1913), «Ислам тарихы» (1917) һ.б. авторы һәм төзүчесе. Күп кенә китапларны татар теленә тәрҗемә итеп, басмага әзерли («Хакыйкать өчен җан фида», 1908) һ.б. 1937 нең 22 декабрендә советка каршы сүзләр сөйләүдә, Болак арты респ-касын оештыруда катнашуда, «Сөембикә» ж-лында буржуаз идеяләрне пропагандалауда, Г.Исхакый, Һ.Атласи, М.Бигиев, С.Максуди, Г.Баттал б-н элемтәдә торуда гаепләнеп кулга алына; атарга хөкем ителә. Үлгәннән соң аклана.

Әд.: Р э х и м к у л о в а М. Тәүге мөхәррир // Сөембикә. 1991. № 1; А х у н о в А., З а м а л д ы н о в а Ч. Якуб Халили: новые штрихи к биографии // Эхо веков = Гасырлар авазы. 2004. № 4; Книга памяти жертв политических репрессий. К., 2005. Т. 15.

ХӘЛИ́ЛОВ Ил һам Әдһәм улы (2.10.1960, Апас р-ны Алабирде а.), нейрофизиолог, биол. фән. канд. (1988). Казан ун-тын тәмамлый (1984), 1991 елга кадәр кеше һәм хайваннар физиологиясе кафедрасында эшли. 1991–2002 дә РФА КГУнең Биохимия һәм биофизика ин-тында. 2002 дән Урта диңгез буе нейробиол. ин-тында (Марсель ш., Франция). Бер үк вакытта, 2011 дән, Казан ун-тының Фундаменталь мед. һәм биол. ин-тында. Фәнни тикшеренүләренең төп юнәлешләре: хәрәкәтләндерүче нерв очлары электрогенезының ионлы механизмнары; яңа туган балаларда эпилоптогенезның синаптик һәм синаптик булмаган механизмнары. Х., беренче булып, җитлеккән минең төп тоткарлаучы нейромедиаторы ГАМКның (гамма-аминомай к-тасы) җитлекмәгән мидә ике төрле — ярсытучы һәм тоткарлаучы роль уйнарга мөмкинлеген күрсәтә. Аның тарафыннан җитлекмәгән мидә икенчел эпилептогенезның зарури шартларын һәм механизмнарын өйрәнү өчен яңа препарат һәм яңа эксперименталь моделе in vitro эшләнә. Яңа туган балаларда эпилептик форма активлыгын дәвалауда эпилеп өягә каршы препаратларны (барбитуратлар һәм бензодиазепиннар) куллануны яхшырту буенча тәкъдимнәр күрсәтелә. Франция эпилепсиягә каршы лига (2000), Франция эпилептологлар җәмгыяте (2002) бүләкләре иясе.

Х е з м.: In vitro formation of a secondary epileptogenic mirror focus by inter-hippocampal propagation of seizures // Nature Neurosci. 2003. V. 6 (автордаш); Epileptogenic actions of GABA and fast oscillations in the developing hippocampus // Neuron. 2005.V. 48 (автордаш); Neuronal chloride accumulation and excitatory GABA underlie aggravation of neonatal epileptiform activities by fenobarbital // Brain. 2011. V. 134 (автордаш); Postsynaptic GABA(B) Receptors Contribute to the Termination of Giant Depolarizing Potentials in CA3 Neonatal Rat Hippocampus. 2017.

ХӘЛИ́ЛОВ Леонард Мөхиб улы (1.1.1951, БАССРның Салават р-ны Михайловка станциясе), физик химия белгече, химия фән. д-ры (1991), проф. (2002). Башкорт ун-тын тәмамлаганнан соң (1972), СССР ФА Башкорт ф-лиалының Химия ин-тында эшли. 1992 елдан БР ФАнең Нефтехимия һәм катализ ин-тында, структура химиясе лаб-ясе мөдире (1993 тән). Хезмәтләре структуралы органик химиягә, металл комплекслы катализ өлкәсенә карый. Х. алюминий органик кушылмаларның углерод төшләрендә ТМР спектрларын тикшерә, алюминий атомының углерод төшләренең спектраль параметрларына тәэсир итүе закончалыкларын ачыклый, бу исә алюминий органик кушылмаларының (ш.и. биш әгъзалы алюмоциклоалканнар, алюмоциклоалкеннарның) яңа классларын ышанычлы рәвештә билгеләү мөмкинлеген бирә. Олефиннарны һәм ацетиленнарны металл комплексты катализаторлар тәэсирендә алкилгалоидаланнар белән цикло- карбо- һәм гидрометаллаштыру реакцияләренә кертү механизмын билгели. Комплексты Zr-катализаторлар катнашында олефиннарны триэтилалюминий белән циклоалюминлаштыру механизмын ачыклый. Уйлап табуга 37 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр һәм Башкортстан Респ-касының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Синтез и превращения металлациклов. Сообщ. 22. Исследование механизма катализируемого Cp_2ZrCl циклоалюминирования олефинов триэтилалюминием в алюминоциклопентаны методом спектроскопии ЯМР // Изв. РАН. Сер. хим. 2000. № 12 (автордаш); Механизм реакции циклоалюминирования алкенов триэтилалюминием в алюмациклопентаны, катализируемой Cp_2ZrCl_{12} // Докл. РАН. 2001. Т. 381, № 3 (автордаш); Синтез и превращения металлациклов. Сообщ. 27. Квантово-химическое исследование механизма каталитического циклометаллирования стирола триэтилалюминием в присутствии Cp_2ZrCl_{12} // Изв. РАН. Сер. хим. 2001. № 12 (автордаш).

ХӘЛИ́ЛОВ Мансур Сафа улы (8.8.1942, Алексеев р-ны Түбән Тигәнәле а.), икътисадчы, а.х. пр-тиесе җитәкчесе, ТАССРның атказ. а.х. хезмәткәре (1986). Чуаш сов.-партия мәктәбен тәмамлый (1973. 1960–2009 елларда Алексеев р-нының «Алга» к-зында эшли: механизатор, баш икътисадчы (1973 тән), рәис (1977 дән). Х. җитәкләгән елларда колхозда җитештерү-техник һәм социаль-мәдәни инфраструктура булдырыла; Түбән Тигәнәле, Урта Тигәнәле авылларында электр, газ, телефон кертелә. 2008 гә бөртекле ашлык җитештерү 2,2, сөт — 1,9, ит — 2,9 тапкыр арта. Бөртекләләрнең уңышы 1 *га* дан 11 *ц* дан 50,5 *ц* га кадәр, уртача еллык савым һәр сыердан 2382 *кг* нан 5003 *кг* га кадәр арта. «Татарстан Республикасы алдынгы казанышлары өчен» ордены, медальләр, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә. Алексеев р-нының мактаулы гражданы (2002).

ХӘЛИ́ЛОВ Равил Вәли улы (16.5.1941, Голҗа ш., Кытайның Шөнҗан-Уйгыр р-ны — 24.1.2006, Мәскәү), график, рәссам. Казан эмигрантлары гаиләсендә ту а 1960–63 елларда Пекин милли сынлы сәнгать ин-тында укый. 1963 тән Казакъстанда, Чолдар шәһәрендә, 1964 тән Үзбәкстанда, 1982 дән Мәскәүдә. А.Н.Островский исем. Ташкент театр-сәнгать ин-тын тәмамлый (1969). Рәссамнар берлеге (1973), Мәскәү «Рәссам» Татар-башкорт рәссамнар берлеге (2001), «Ак бөҗра» (1993) берләшмәсе әгъзасы. 1996 да «Яңа Император Сәнгать академиясе»н нигезли һәм җитәкли.

Х. — танылган китап графикасы остасы, балалар һәм өлкәннәр китапларын бизәүдә әйдәп баручы рәссамнарның берсе (80 нән артык басманы бизи). Кытай сынлы сәнгате һәм Шәрекъ миниатюралары традицияләренә нигезләнеп иҗат иткән иллюстрацияләре (темпера, акварель, тушь, гуашь) югары башкару дәрәҗәсе б-н аерылып тора. Әсәрләрнең эчтәлегенә карап, Х. сурәтче автордаш буларак, хис төсмерләрен зур осталык белән чагылдыра һәм образларның психологиясен ача, эчтәлекне форма ысулларының байлыгын кулланып яктырта. Х.ның күпләгән эш ләре арасында — Г.Тукайның «Курайда уйнаучы малай» («Мальчик с дудочкой», М., 1979), «Кытай халык әкиятләре» («Китайские народные сказки», М., 1979), «Төлке һәм көртлек. Табасаран халык әкиятләре» («Лиса и куропатка. Табасаранские народные сказки», М., 1980), «Айога. Нанай халык әкияте» («Айога. Нанайская народная сказка», М., 1983), Г. Сафиеваның «Кояш артыннан» («За солнцем вслед», М., 1984), «Гэсэр. Бурят героик эпосы» («Гэсэр. Бурятский героический эпос», М., 1988, 2 томда), «Мәхәббәт бакчасы» («Сад пленённых сердец», М., 1989), «Текә кыяда. Һинд -

стан язучылары хикәяләре» («На стремнине. Рассказы писателй Индии», М., 1990), «1001 кичә әкиятләре» («Сказки 1001 ночи», М., 1993), «Алтын утрау. Кытай халык әкиятләре» («Золотой остров. Китайские народные сказки», М., 2002) китапларына иллюстрацияләр бар. Х.ның станлы графикасы шагыйрә Римма Казакова шигырьләр багышлаган «Чернобыль» (1986) сериясендә гәүдәләнә. Х. күп сәяхәт итә (Алтай, Һималай, Урта Азия, Австралия), үзенең кичерешләрен графика һәм нәкышь б-н иҗат иткән карталарында чагылдыра. Х.ның нәкышь әсәрләре модерн стилендә башкарыла, символизм һәм образларның фәлсәфи тирәнлеге, формаларның нәфислеге б-н аерылып тора — бу тематик картиналар: «Иблиснең тууы», «Австралия» (икесе дә — 1990), «Карфаген рухы» (1991), «Кышкы ауда» (1998), «Дога. Иерусалимда Тәүбә Дивары янында», «Ат чабышы» (икесе дә — 2001); портретлар: «Шәрекъ гүзәле ат белән» (1999), «Иисус Христос. Хакыйкать эзләүче» (2001); пейзажлар: «Кышкы пейзаж» (1985), «Елга өстендәге томан» (1998), «Карфаген», «Яшен алдыннан. Утар» (икесе дә — 2000). Беренче Бөтенсоюз (Мәскәү, 1979) һәм халыкара китап иллюстрацияләре (Берлин,1973; Мехико, 1974; Мәскәү-Берлин, 1988), акварель б-н иҗат ителгән картиналарның 4 нче Бөтенсоюз (Мәскәү, 1975) күргәзмәләрендә, Мәскәү халыкара китап ярминкәсендә (1975), халыкара күчмә — «Үзбәкстан манзарасы» (1977, 95 илдә), «Рәссамнар — балаларга» (1979, 100 илдә), интернациональ — «Ефәк юлы буйлап» (Мәскәү, 2004) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре 1982, 1993 (Мәскәү), 1990 (Аделаида ш., Австралия), 1992 (Тунис), 1994 (Варшава), 1996 (Пекин), 2004 тә (Мәскәү өлкәсе Дубна ш.) уздырыла.

Картиналары Көнчыгыш халыклары Дәүләт сәнгать музеенда, Ц.С.Сампилов исем. Респ-ка сынлы сәнгать музеенда (Улан-Удә ш.), Г.Нәваи исем. әдәбият музеенда (Ташкент), Брянск өлкә музей-күргәзмә үзәгендә, шәхси галереяларда (Россия, Тунис) һәм шәхси тупланмаларда (Англия, Италия, Кытай, Германия һ.б.) саклана. СССР СА Дипломы (1972), ВДНХның көмеш медале (1975), халыкара Тәһран «Алтын роза» биенналесе алтын медале (1991, Ч.Айтматовның «Мөгезле ана болан» («Рогатая олениха», М., 1989) китабына иллюстрацияләр өчен) б-н бүләкләнә, «Континентлар һәм цивилизацияләр тоташкан урында» («На стыке континентов и цивилизаций», К., 1996) китабына иллюстрацияләр өчен «Бәллүр Шүрәле» бүләгенә лаек була.

Әд.: Садыкова Л. Читая «Апокалипсис». Литература и современность // Литературная учёба. 1990. № 4; Звонарёва Л. Прилежная кисть // Детская литература. 1990. № 6; Апанаев Ш. Художник Равиль Халилов: Отразивший целую эпоху // Татарский мир. 2006. № 3.

Г.Ф.Вәлиева-Сөләймановa.

ХӘЛИ́ЛОВА Миләүшә Хәмит кызы (4.6.1964, Актаныш р-ны Актаныш а.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2002), проф. (2005). Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлый (1985). 1987–2002 елларда Казан ун-тында эшли. 2002 дән Петербург ун-тында, предмет теориясе һәм финанс менеджменты каф. профессоры. Хезмәтләре банк менеджменты һәм банк эшчәнлеге куркынычсызлыгы б-н идарә итүгә карый. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Банковский кредит: Что необходимо знать финансовым менеджерам компаний и банкирам. К., 2001 (автордаш); Организация системы управления рисками в коммерческом банке. СПб., 2005 (автордаш).

Әд.: Финансовая наука в Санкт-Петербургском университете: 15 лет кафедре теории кредита и финансового менеджмента. СПб., 2006.

ХӘЛИ́М Айдар (тәхәллүсе; чын фамилиясе һәм исеме Хәлимов Борис Нәҗметдин улы), (1.1.1942, БАССРның Миякә р-ны Кече Кәркәле а.), язучы, публицист, җәмәгать эшлеклесе. Татар һәм рус телләрендә яза. Казан ун-тын (1968), А.М.Горький исем. Әдәбият ин-ты каршындагы Югары әдәби курсларны (Мәскәү, 1985) тәмамлый. 1968–71 елларда Түбән Кама шәһәрендә нефть химия комб-ты төзелешендә эшли. 1971 дән Уфада яши: «Совет Башкортстаны» г-тасында әдәби хезмәткәр, Урал-Себер магистраль



А. Хәлим.

нефть үткәргечләр идарәсендә өлкән инженер (1975–82), Башкорт акад. драма театрында әдәби бүлек мөдире (1982–83). 1991 дән Чаллы шәһәрендә яши, «Аргамак» ж-лы мөхәррире (1995 кадәр). Беренче шигырьләре 1960 елларда нәшер ителә. Тормышны сөю пафосы б-н сугарылган «Беренселәр» (башкорт телендә, Уфа, 1974), «Курай» (М., 1978; русчага тәр җәмәдә), «Йөрәгемдә етмеш параллель» (башкорт телендә, Уфа, 1978), «Мәэббәттән язмыш башлана» (Уфа, 1982), «Таң сәфәре» (Уфа, 1985), «Яфраклар җиле» («Ветер листьев», М., 1987), «Йөрәк ташы» (1990), «Тилергән сирень» (2003), «Колмак җыя кызлар» (2009) шигырь җыентыклары; «Набат белән Нәүфисә турында риваять» (1969), «Печән чапканда» (1970), «Эксперимент — 86» (1988) поэмалары авторы. Х. поэзиясенә поэтик фикерләүнең хислелеге һәм кинаялек, лирик башлангычның өстенлеге, арузның верлибр б-н кушылуы хас. «Өч аяклы ат» повесте (1998), «Татар вакыты» романы (2002; русчага тәр җемәдә «Московское время», 2005) геройлары — иҗади хезмәт кешеләре, дөреслек, гаделлек өчен, сугышларга һәм ирексезләүләргә каршы көрәшүчеләр. «Хунвейбин» социаль-психол. роман-эпопеясында (2011) эмигрант татар гаиләсенең берничә буыны үрнәгендә 20 йөз вакыйгалары чагылдырыла. «Сагыш китабы, яки Абориген язмалары» («Книга печали, или Записки аборигена», Вильнюс, 1991), «Гомеремнең ун көне, яки Бер җинаять әзеннән» (Тольяти, 1996), «Җиңелмәс чечен» («Этот непобедимый чеченец», Чаллы, 1996), «Империяне үтерү» («Убить империю», Йошкар-Ола, 1997), «Минем Түгәрәк Имәнем» (Уфа, 1999), «Яңа сагыш китабы, яки Минзәлә Гаагадан ерак-мы?» (2002), «Паспортны төзәтербез дә, башкорт булыр» («Переправим паспорт, вот и будет башкорт», Чабаксар, 2002) һ.б. публицистик әсәрләре СССРдагы милли мәсьәләләргә, татар һәм башкорт халыклары язмышларына, Чечен Респ-касындагы сугышка багышлана. «Мәңгелек мизгел» әдәби портретлар (1986), тәнкыйть мәкаләләре, әсселар авторы. Х.нең «Җанчишмә» (1983) һәм «Пәри туе» (1990) пьесалары төрле елларда Башкорт акад. театры сәхнәсендә куелалар, балалар өчен язылган «Биктырыш» поэмасының (1975) сәхнәләштерелгән варианты Уфа курчак театрында куела. Х. әсәрләре казакъ, төрек, литва, кырымтатар телләренә тәр җемә ителә. 1997–2001 дә Милли Мәҗлес рәисе. ТР Язучылар берлегенең Г.Исхакый исем. бүләге лауреаты (2003).

Э с ә р.: Пьесалар, яки Мин нигә драматург булалмадым? К., 2004; Жить хочется!.. Наб. Челны, 2010.

Әд.: Талант. Шәхес. Язмыш: 2 томда. Яр Чаллы, 2007; Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

Р.Х.Сверигин.







Р.В. Хәлилов. 1. «Гәсәр. Бурят героик эпосы» китабына иллюстрация. Кәгазь. Гуашь. 1988; 2. «Мәхәббәт бакчасы» җыентыгына иллюстрация. Шәрекъ классик мәхәббәт прозасы. Кәгазь. Катнаш техника. 1989; 3. «Тунислы». 1991.

ХӘЛИ́МОВ Илек Мәҗит улы (19.3.1931, Уфа ш.), геолог-нефтьче, геол.-минерал. фән. д-ры (1969), проф. (1971), РСФСРның атказ. фән. эшлеклесе (1974), СССРның мактаулы нефтьчесе (1991). Мәскәү нефть ин-тын тәмамлаганнан соң (1954), «Башнефть» ҖБдә эшли. 1965 елдан БашНИПИнефть директоры урынбасары. 1975–81 дә Мәскәүдә, СССР Нефть сәнәгате министрлыгында, министр урынбасары (1977 дән); 1981 дән Бөтенсоюз нефть фәнни-тикшеренү ин-тында, 1986 дан «Нефтеотдача» тармакара фәнни-техник комплексы ген. директоры урынбасары, 1988 дән Янучан казылмалар геология эшләнү ин-ты директоры урынбасары. 2005–07 дә Бөтенсоюз геол.-разведкалау нефть фәнни-тикшеренү ин-тында (С.-Петербург). Хезмәтләре нефть чыганаклары геологиясе, аларны эзләү һәм файдалануга карый. Х. Урал-Идел буе нефть чыганакларының геол. төзелеш үзенчәлекләрен һәм закончалыкларын ачыклый, углеводород чыгаруның яңа геотехнологияләрен, нефть запасларының классификациясен һ.б. эшли. Уйлап табуга 30 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. СССР ФАнең акад. И.М.Губкин исем. бүләге лауреаты (1971, 1981, 1988). Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары; медальләр, ш.и. ВДНХның көмеш һәм бронза медальләре б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Геология месторождений высоковязких нефтей СССР. М., 1987 (автордаш); Управление запасами нефти. М., 1991 (автордаш); Вторичная разработка нефтяных месторождений. СПб., 2006.

ХӘЛИУ́ЛЛИН Валентин Илдар улы (21.11.1948, Мурманск өлкәсенең Саам р-ны Гремиха а.), авиация технологиясе өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1997), проф. (2000). 1973 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли, самолётлар һәм двигатель төзү ф-ты деканы (1987–90), очу аппаратлары ф-ты деканы (1997–99), Авиация, җир өсте транспорты һәм энергетика ин-ты директоры урынбасары (1999–2001), очу аппаратларын җитештерү каф. мөдире (2000 нән). Хезмәтләре композицион материаллардан җыелма конструкцияләр төзү, интеграл типлы композит конструкцияләрне проектлау һәм җитештерүгә карый. Х. җитәкчелегендә трансфер формалаштыруның технол. схемалары, ш.у. аларны гамәлгә ашыру өчен җи һазлар булдырыла. Уйлап табуга 45 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Технологические схемы изготовления многослойных конструкций. К., 1999; О классификации регулярных рядовых складчатых структур // Изв. вузов. Авиац. техника. 2003. № 2.

ХӘЛИУ́ЛЛИН Гыйниятулла Гатият улы (19.9.1948, Чепья р-ны Арбор а.), физик, физика-матем. фән. д-ры (1993). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1974), шунда ук эшли. 1979 елдан РФА КГҮнең Физика-техника ин-тында, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1993–2008). 2008 дән Германия Федератив Респ-касында. Хезмәтләре металларның электрон, магнит һәм үтә үткәрүчәнлек үзлекләре теориясенә карый. Х. үтә үткәргечләрдә спин дулкыннары барлыкка килүен алдан әйтә (1984). Авыр фермион системалар теориясен эшли.

Х е з м.: Образование локального момента вблизи вакансии в спиновой жидкости // Письма в журн. эксперим. и теорет. физики. 1995. Т. 62, вып. 9 (автордаш).

ХӘЛИУ́ЛЛИН Илгизәр Әһлиулла улы (6.9.1943, Казан — 28.10.2008, шунда ук), педагог, пед.фән. д-ры (2000), проф. (2001), ТРның атказ. мәктәп укытучысы (1996). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1970). 1964 елдан Татарстан нефть машиналары төзү фәнни-тикшеренү ин-тында, 1974 тән 50 нче техник уч-ще директоры урынбасары, 1979 дан РМАнең Казан урта махсус белем бирү ин-тында, 1998 дән РМАнең Идел буе бүлеге һәм ТР ЮХИДИ идарәсенең Балалар тормышы иминлеге фәнни үзәге директоры. Хезмәтләре һөнәри белем бирү мәсьәләләренә карый. Юлларда куркынычсызлык кагыйдәләре буенча дәреслек авторы (Р.Н.Миңнеханов б-н автордаш).

Х е з м.: Теория и практика современного урока производственного обучения в профессиональной школе. К., 1998.

ХӘЛИУ́ЛЛИН Илшат Хәкимулла улы (10.5.1963, Казан), тарихчы, тәрҗемәче. Казан ун-тын (1985), СССР ФА Казан ф-лы Тел, әдәбият, тарих ин-ты каршында аспирантура (1989) тәмамлый. 1985–86 елларда Балык Бистәсе р-ны Казаклар Чаллысы авылында татар теле һәм әдәбияты укыта. 1989–92 дә Тел, әдәбият, тарих ин-ты кече фәнни хезмәткәре. 1992–94 тә «Мирас» ж-лы редакциясендә фәлсәфә һәм тарихи мирас бүлеге мөдире; 1994–2001 дә Татарстан китап нәшриятында: мөхәррир, фәнни-популяр әдәбият редакциясе мөдире; 2001–03 тә «Матбугат йорты» нәшриятында: мөхәррир, баш мөхәррир. 2003 тән ТР ФА Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү ин-тында: татар телендәге басмалар мөхәррирләре төркеме җитәкчесе, өлкән фәнни хезмәткәр. Төрле районнар, пр-тиеләр тарихын чагылдырган китапларның автор-төзүчесе һәм фәнни мөхәррире, аерым авыл тарихларына һәм шәхесләргә багышланган басмалар авторы, урта мәктәпләр өчен тарих дәреслекләре тәрҗемәчесе. Хезмәтләре татар халкының урта гасырлар тарихы, биобиблиографиягә, әдәби тәнкыйть һәм сәнгать белеме мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Яңа Тинчәле таңы. К., 2006; Әлки ядкәре. К., 2011 (автордаш); Үз нәселегезне онытмагыз = Не забывайте рода своего. К., 2018 (автордаш); Основные этапы монгольского нашествия на Волжскую Булгарию // Волжская Булгария и монгольское нашествие. К., 1988 (автордаш); О монгольском походе на Волжскую Булгарию 1232 г. // Волжская Булгария и монгольское нашествие. К., 1988; Среднее Поволжье и Нижнее Прикамье в XIII в. // Материалы по истории татарского народа. К., 1996; На защите конституционных прав и свобод. К., 2016 (автордаш).

ХӘЛИУ́ЛЛИН Йолдыз Нури улы (25.9.1939, Әгер җ р-ны Иске Кызылъяр а.), дипломат, шәркыятьче галим, икътисад фән. канд. (1980). Казан механика-технол. техникумын (1955), СССР Тышкы эшләр министрлыгының Мәскәү халыкара мөнәсәбәтләр ин-тын (Мәскәү, 1964), СССР Тышкы эшләр министрлыгының Дипломатия академиясен (1978) тәмамлый. 1964 елдан Урта һәм Үзәк Азия илләрендә (Пакъстан, Индонезия һ.б.) дипломатия эшендә. 1981–84 тә Румыниядә СССР илчелегенең 1 нче секретаре. 1984–2000 дә СССР Тышкы эшләр министрлыгының Көньяк Азия илләре идарәсендә киңәшче, Казакъстанда Россия илчелегенең өлкән киңәшчесе. 2000 нән РФАнең П.П.Ширшов исем. Океанология ин-ты директоры ярдәмчесе, соңрак киңәшчесе. Хезмәтләре Индонезия, Пакъстан, Непал, Казакъстанның дипломатиясе, тышкы сәясәте мәсь әләләренә карый; татар поэзиясе буенча хезмәтләр авторы.



М.Х. Хәлиуллин.



Ю.М. Хәлиуллин.

Х е з м.: Восток глазами дипломата. К., 2001; Лауреат Нобелевской премии Абдус Салам. М., 2006; Мир вокруг нас (научные записки дипломата). М., 2011.

Әд.: А х т а м з я н А. Дипломат, учёный и писатель (к 70-летию Ю.Н.Халиуллина) // Татарские новости. 2006. № 10.

ХӘЛИУ́ЛЛИН Мәхмүт Габид улы (20.11.1937, Ташкент), физик, физика-матем. фән. д-ры (1979), проф. (1980). Ташкент пед. ин-тын тәмамлый (1961), шунда ук эшли (1969 дан), физика каф. мөдире (1980 нән). 1961 елдан Ташкент фармакол. ин-тында, 1965–69 да Мәскәү ун-тында. 1986 дан Ташкент элемтә электр техникасы ин-тының физика каф. мөдире. Хезмәтләре сыекчалар һәм эретмәләрнең оптик һәм акустик үзлекләренә карый. Х. 26 кГц тан алып 5 гГц ка кадәр диапазондагы һәм киң температура аралыгындагы сыекчалар һәм эретмәләрнең оптик һәм акустик үзлекләрен өйрәнә.

Х е з м.: Элементар физика масалалари. Таш., 1993.

ХӘЛИУ́ЛЛИН Мисбах Хәлиулла улы (12.3.1916, Самара губ., Бөгелмә өязе Сугышлы а. — 18.4.1983, Казан), Сов. Союзы Герое (18.8.1945), подполковник. Минзәлә а.х. техникумын (1934), Энгельс очучылар хәрби авиация мәктәбен (1940), Хәрби-һава көчләренең Югары штурманнар мәктәбен (1941), Югары офицерлар очу-тактик курсларын (1951) тәмамлый. Туган авылы колхозында зоотехник булып эшли. 1936 елдан Кызыл Армиядә. 1943 нең маеннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 199 нчы штурм авиациясе дивизиясе 783 нче штурм авиациясе полкының эскадрилья командиры (4 нче һава армиясенең 4 нче штурм авиациясе корпусы). 1945 нең апреленә 2 нче Белоруссия фронты гаскәрләре составында дошман ныгытмаларын һәм гаскәрләрен бомбага тоту өчен 88 су -

гышчан очыш ясый; 16 һава сугышында дошманның 3 самолётын бәреп төшерә. 1958 дән запаста, Казанда яши. Ленин ордены, өч Кызыл Йолдыз, Александр Невский, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Бөгелмә һәм Лениногорск шәһәрләрендә Геройлар аллеясында Х.га бюстлар куела. Сугышлы авылында, Бөгелмә, Лениногорск, Чаллы шәһәрләрендә урамнарга Х. исеме бирелә.

Әд.: Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

М.З.Хәбибуллин.

ХӘЛИУ́ЛЛИН Назыйр Миңнегали улы (15.10.1936, Ютазы р-ны Кәрәкәшле а. — 20.10.2004, шунда ук), а.х. пр-тиесе җитәкчесе. БАССРның Бәләбәй а.х.н механикалаштыру һәм электрлаштыру техникумын тәмамлый (1974). Баулы р-нының (1991 дән Ютазы р-ны) Киров исем. к-зында эшли: механизатор, баш инженер (1974–77), рәис (1977–94). 1994–95 елларда Кәрәкәшле авылының җирле үзидарә рәисе. Х. җитәкчелек иткән чорда җитештерү-техник һәм социаль-мәдәни инфраструктура булдырыла; Кәрәкәшле, Ак Чишмә, Салкын Чишмә авылларына газ кертелә, югары икътисади күрсәткечләргә ирешелә. Бөртекле культураларның уңышы 1 *га* дан 13,4 *ц* дан 22,6 *ц* га кадәр, уртача еллык савым һәр сыердан 2489 *кг* нан 2943 *кг* га кадәр арта. 1981 дә а.х. продукциясен җитештерүдә югары казанышларга ирешкәне өчен колхозга РСФСР МС һәм ВЦСПСның күчмә Кызыл Байрагы бирелә. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

И.Н.Афанасьев.

ХӘЛИУ́ЛЛИН Нурислам Хазылган улы (5.12.1954, Төмән өлкәсе), спортчы (самбо), СССРның атказ. спорт остасы (1984). 1973 елдан Владивосток шәһәрендә яши. Спорт б-н 1973 тә «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятендә (Владивосток) шөгыльләнә башлый, тренеры — А.А.Полукаров. СССР (1978–79, 1982–83; 1977 — бронза, 1980 — көмеш, 1984–85 — бронза) чемпионатларында, СССР халыклары спартакиадаларында (1979, 1983), «Дуслык-84» халыкара ярышларында, Европа (1984), дөнья (1983; 1979 — көмеш) чемпионатларында җиңүче, СССР (1976, 1983–84), дөнья (1980) Кубоклары иясе.

ХӘЛИУ́ЛЛИН Фәр һад Гаделҗан улы (1.7.1962, Чүпрәле р-ны Кәкерле а.), фармацевт, фарм. фән. д-ры (1999), проф. (2000). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1985), Башкорт мед. ун-тында эшли, фарм. химия каф. мөдире (1992 дән). Төп фәнни юнәлеше — яңа дару препаратлары синтезлау өчен югары нәтиҗәле биол. актив матдәләр эзләү, тиираннарның азотлы гетероциклларын китереп чыгарылган препаратлар б-н реакциясен тикшерү. Уйлап табуга 13 патенты һәм авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Синтез биологически активных тиетансодержащих производных триазола и ксантина // Мед. вестн. Башкортостана. 2007. № 3/4 (автордаш); Синтез и гемореологические свойства новых производных 1,2,4-триазола // Химико-фармацевт. журн. 2008. № 9 (автордаш).

ХӘЛИУ́ЛЛИН Хәбибрахман Фәйзрахман улы (15.8.1942, Киров өлкәсенең Малмыж ш.), астрофизик, физика-матем. фән. д-ры (1998), проф. (2004). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1969), Мәскәү ун-тының П.К.Штернберг исем. астрономия ин-тында эшли. Хезмәтләре Вольф-Райе төрендәге йолдызларны тикшерүгә, куш йолдызлар системасында апсид линияләр әйләнешендәге хәрәкәтнең нечкә тәэсирен өйрәнүгә карый. Төньяк күк йөзенең WBVB-үлчәмендәге якты йолдызлар каталогын төзүгә мөмкинлек биргән югары төгәллекле астрофотометрия методикасын эшли.

Х е з м.: Photometric elements and apsidal motion of the eclipsing binary ES Lac // Astronomy Reports. 2007. V. 51, №3 (автордаш); Synchronization and circularization in early-type binaries on main sequence // Monthly Notices of the Royal Astronomical Society. 2010. V. 401 (автордаш).

ХӘЛИУ́ЛЛИН Юрий Михайлович (10.8.1943, хәзер БРның Шаран р-ны Анисимова Поляна а.), контр-адмирал (1990), техник фән. д-ры (1996), проф. (1993), РФнең атказ. фән эшлеклесе (2002). В.И.Ленин исем. Югары хәрби-диңгез инженерлар уч-щесен (Ленинград өлкәсенең Пушкин ш., 1968), адмирал Н.Г.Кузнецов исем. Ленинград хәрби-диңгез академиясен (1975) тәмамлый. 1950 елда гаиләсе б-н Верхнеднепровск шәһәренә (Украина ССРның Днепропетровск өлкәсе) күчеп килә. Хәрби хезмәткә алынганчы район г-тасы редакциясендә, «Днепрометаллургстрой» (Вольногорск ш.) трестында эшли. 1962 дән Совет Армиясендә, Балтыйк флотында хезмәт итә. 1968–87 дә (бүленеп) Камчатка хәрби флотилиясендә: 1968–71 дә 5 нче хәрби частьта, «Лунь» сакчы корабленең электромеханика хәрби часть тенда төркем командиры, 1975–80 дә электромеханика частеның су асты көймәсенә каршы корабльләр бригадасы командиры урынбасары, 1982–87 дә техник бүлек башлыгы. 1971–75 һәм 1980–82 дә В.И.Ленин исем. Югары хәрби-диңгез инженерлар уч-щесендә пар казанлы һәм газ турбиналы энергия җайланмалары ф-ты башлыгы урынбасары, 1987–91 дә Кара диңгез флотында: техник идарә башлыгы, 1989 дан эксплуатация һәм ремонт буенча командующий урынбасары. 1992 дән В.И.Ленин исем. Ленинград Югары хәрби-диңгез инженерлар уч-щесендә (1998 дән — Хәрби-диңгез инженерлар ин-ты), башлык (2000 гә кадәр), проф. (2000 нән). Бер үк вакытта, 2000–03 тә, Балтыйк төзү компаниясе техник директоры; 2003–05 тә Суднолар төзү технологиясе үзәк фәнни-тикшеренү ин-тында директор урынбасары; 2005–09 да «Кризо» з-ды (Ленинград өлкәсе) ген. директоры; 2009 дан Суднолар төзү һәм суднолар ремонтлау технологиясе үзәгенең суднолар төзү сәнәгате кадрларының белемен күтәрү ин-ты директоры. Хезмәтләре суднолар ремонтлау өлкәсе һәм корабльнең физик кырлары төзелеше анализы теориясенә, суднолар ремонтлауны оештыруны камилләштерү мәсьәләләренә карый. Уйлап табуга 21 патенты бар. Кара диңгез флотында суднолар ремонтлау з-дын (1991), кайнар цинк йөгертү цехын (2003) оештыручыларның берсе. 1990–93 тә Кырым ЮС депутаты. 3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт иткән өчен», «Хәрби хезмәт - ләре өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

ХӘЛИУ́ЛЛИНА Роза Зәһит кызы (14.6.1931, Актаныш р-ны Әҗәкүл а. — 15.1.2014, Казан, туган авылында җирләнә), шагыйрә.1948 елдан Казанда яши. Шигырьләре респ-ка матбугатында 1960 елларда басыла башлый. «Агыйдел — Аккош иле» шигырьләр һәм поэмалар җыентыгы (1979) авторы. Аның лирик герое тормыш сынауларына дучар булса да, оптимистик рухын югалтмый. «Идел суы илле батман» (1984) җыентыгында Бөек Ватан сугышы елларында хезмәт куйган хатын-кызларның чыдамлыгына һәм батырлыгына дан җырлана. Балалар өчен язылган шигырьләре тупланган («Бөрлегәнгә медаль», 1973; «Чүкеч — нәни булышчы», 1977) китаплары тапкырлык һәм хезмәт яратуны тәрбияләүгә юнәлдерелгән.

Әд.: С и б г а т у л л и н а Т. Шәфкатьлелек // Казан утлары. 2001. № 6; Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

ХӘЛИУ́ЛЛОВ Исмәгыйль Минтаһир улы (28.8.1929, Куйбышев өлкәсенең Ставрополь р-ны Татарские Выселки а. — 15.3.2009, Казан), рәссам. ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1979). 1947 елдан Казанда. Казан сынлы сәнгать уч-щесен тәмамлаганнан соң (1952), РСФСР Сәнгать фондының Татарстан бүлегендә эшли. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1960). Х. тарихи-революцион һәм көнкүреш жанрындагы татар тематик картиналарын үстерүгә зур өлеш кертә. Аның иҗатында халык тормышы чынбарлыгын чагылдыр-



И.М. Х ә л и у л л о в. «Минем кадерлеләрем». 1964. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее.

ган, революциягә, гражданнар сугышына, татар авылларында күмәк хуҗалык төзелеше - нә багышланган сюжетлар мөһим урын то - та — «Ленинны беренче тапкыр кулга алу» (1952), «Крәстияннәр авыру Тукай янында» (1954), «Печән өсте» (1957), «Беренче бала» (1960), «Отряд китте» (1962), «Минем кадерлеләрем» (1964), «Җир хуҗалары» (1969), «Тарас Шевченко Казанда» (1970), «Хөсәен Ямашев дуслары арасында» (1974), «Комсомол туе», «Кызыл милəш (В.Шукшин истəлегенə)» (икесе дə — 1979), «Революция исеменнән», «Олау» (икесе дə — 1982), «1920 ел» (1989). Портретлар («Карт», 1956; «Әнием портреты», 1970), Идел буе, кара туфраклы булмаган төбәк, Балтыйк буе романтик пейзажлары («Нократ елгасы», 1953; «Татарстан пейзажы», 1959; «Балтыйк», 1962; «Салкын көн», 1978; «Имән - лек», 1979), натюрмортлар («Пəрəмəчлəр белəн на - тюрморт», 1968; «Гөмбəлəр», 1969) авторы. Х. нәкышенә киндер өслеккә рельефлык бирүче тыгыз сурәтләү техникасы, бай төсләр фактурасы, образлы-композиция чишелеше хас.



И.М. Х ə л и у л л о в. «Җир хуҗалары». 1969. ТР Дəүлəт сынлы сəнгать музее.

Респ-ка (1952 дән), Мәскәүдә татар әдәбияты һәм сәнгате декадаларында ТАССР сынлы сәнгате (1957, 1980), «Совет Татарстаны» (Ленинград, 1972), «Зур Идел» (1964, 1969, 1980), «Совет Россиясе» (Мәскәү, 1960), Германия Демократик Респ-касында совет сәнгате (1978–79) күргәзмәләрендә катнаша. Картиналары ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, Казанда А.М.Горький музеенда, Әлмәт шәһәре картиналар галереясында һ.б.да саклана. Медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: С а г а д е е в А. Эпоха свершений // Вечерняя Казань. 1979. 26 сент.; Н о в и ц к и й А. Когда есть, что сказать // Советская Татария. 1983. 28 авг.; Ч е р в о н н а я С.М. Художники Советской Татарии. К., 1984.

ХӘЛФИН Ибраһим Исхак улы (1778, Казан — 14. 1. 1829, шунда ук), педагог, тел белгече, тәрҗемәче, коллежский асессор (1824). 1800–29 елларда *Казандагы Беренче ир балалар гимназиясендә* татар теле укыта; бер үк вакытта, 1812 дән, Казан ун-тында: татар теле укытучысы, 1823 тән шәрекъ телләре адъюнкты, ш.у. гарәп һәм фарсы телләре укыта. Татарлардан ун-тта беренче укытучы. Руслар өчен татар теле буенча уку ярдәмлекләре авторы («Татар теленең этимология һәм лексика әлифбасы» — «Букварь этимологии и лексики татарского языка», 1804; «Император Казан гимназиясендә гарәпчә уку кагыйдәләре б-н укытыла торган татар теле әлифбасы һәм грамматикасы» — «Азбука и грамматика татарского языка с правилами арабского чтения, преподаваемые в Императорской Казанской гимназии», 1809). Х.М.Френ б-н бергә гарәпчә исламгача «Әмәт турында хикәят»не («Повесть об Амате»), Тимер-Котлыгъ хан ярлыгын 1397 басмага әзерли (1816–18 дә Венада «Fundgruben des Orients» ж-лында басыла). «Әхвәле Чыңгыз хан вә Аксак Тимер» урта гасырлар риваятьләр җыентыгын уку басмасы буларак татар һәм рус телләрендә сүзлек кушымтасы б-н чыгара. *Әбелгазый Баһадур ханның* «Монголлар һәм татарлар турында тарих» китабын төрки телдә басмага әзерли (эшкәртү, шәрехләүләр һәм исем күрсәткечләре) (1825). Аның татар теле буенча университет курсы лекцияләренең бастырылмаган конспектлары Казан ун-тының фәнни китапханәсендә саклана. 1819 да Университет советына татарлар өчен рус теле һәм дөньяви фәннәр укытыла торган уч-ще ачарга тәкъдим итә (бу беренче шундый проект була). Бер үк вакытта, 1800–29 да, *Азия басмаханәсе* цензоры. Х. җитәкчелегендә гигиена буенча татар телендә брошюралар бастырыла. Хакимият кушуы буенча закон актларын татар теленә тәрҗемә итә, аларның кайберләре Азия басмаханәсендә басыла. 1803–05 тә император Александр I йөкләмәсе буенча митрополит Платонның (Левшинның) Катехизисын татар теленә тәрҗемә итә, ул Азия басмаханәсендә бастырыла һәм татар телендә христиан лексикасын куллануның беренче тәжрибәсе була.

Әд.: А х м е т г а л е е в а Я.С. Грамматика татарского языка Ибрагима Хальфина // Советская тюркология. 1979. № 6; М и х а й л о в а С.М. Ибрагим Исхакович Хальфин. 1778–1829. К., 2002.

ХӘЛФИН Исхак Сәгыйть улы (? — 1800, Казан), тәрҗемәче, педагог, губерна секретаре (1785). С.Х.*Хәлфиннең* улы. Дәүләт учреждениеләрендә һәм Казанда Татар ратушасында тәрҗемәче булып эшли, 1785–1800 елларда Казан гимназиясендә татар теле укыта (асылда гимназиядә 1773 тән эшли, әтисенә булыша). 1792 дә император Екатерина II кушуы буенча губерна реформасының «Губерналар турында нигезләмәләр» («Учреждения о губерниях») һәм «Җәмәгать тәртибен саклау идарәсе уставы» («Устав Управы благочиния») дигән хокук актларын татар теленә тәрҗемә итә, тәр җәмәләр басылып чыга.

ХӘЛФИН Мөхәммәтнәҗип Латыйф улы (12.6.1886, Уфа губ., Минзәлә өязе Теләнче Тамак а. — 1938), сәясәт эшлеклесе, әдәбият тәнкыйтьчесе, тәр җәмәче, географ. Казан татар укытучылар мәктәбен (1908), Казан ун-тын (1914) тәмамлый. Студентлар хәрәкәтендә актив катнаша, «Аң» ж-лы б-н хезмәттәшлек итә. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң Мөселманнар ком-тын оештыруда, 1 нче һәм 2 нче Бөтенроссия мөселманнары корылтайлары (1917) эшендә катнаша. 1917 дә Казан губернасы Милли Шурасы башкарма ком-ты әгъзасы. Милләт Мәҗлесе депутаты (1917–18), Идел-Урал штатын гамәлгә кертү һәйәте әгъзасы. 1921 дән Әзәрбайҗан ун-тында (Баку) фәнни һәм пед. эштә. Г.Исхакый, Й.Акчура һәм 20 йөз башы татар әдипләре иҗатына, икътисади географиягә караган хезмәтләр авторы. К.Ф.*Фукснын* хезмәтләрен татар теленә тәр җәмә итә. Репрессияләнә; үлгәннән соң аклана.

ХӘЛФИН Рөстәм Нурмөхәммәт улы (14.10.1949, Ташкент — 31.12.2008, Казакъстан Респ-касы, Унгуртас пос.), архитектор, нәкышьче, концептуаль сәнгать рәссамы. 1950 елдан Алма-Ата шәһәрендә. Мәскәү архит-ра ин-тын тәмамлый (1972). Алма-Атада проектлау ин-тларында эшли (1972–83), бер үк вакытта картиналар иҗат итү б-н шөгыльләнә. 1983 тән үзен тулысынча сәнгатькә багышлап, абстракционизм һәм рус авангарды традицияләренә мөрәҗәгать итә. 1971 дә Ленинград рәссамы В.В.Стерлигов (К.Малевичта укыган) б-н таныша һәм аның шәкерте була. 1995 тән Х. постмодернизм юнәлешендә эшли, рәссам-концептуалист буларак, үзенең эшчәнлеген «Евразия утопиясе», «Балчык проект», «Төньяк вәхиләре» видео-арт кебек зур сәнгать проектлары кыса-







Р.Н. Х ə л ф и н. 1. «Предметсыз фəза чагылышы». Диптих. 1990 еллар; 2. Р. Хәлфин рәсемнәреннән инсталляция. 1990–2000; 3. «Пулоталы уң күл». «Ноленче биеклек. Балчык проект» циклыннан. 2000. Барысы да – «Тәңре-Умай» галереясында. Алма-Ата.

ларында гамәлгә ашыра. Алма-Атаның «Азия-арт» галереясы кураторы (1996–98). «Ноленче биеклек» рәссамнар төркеме оештыра (1998). Шәхси «Look» заманча сәнгать галереясын оештыручы һәм аның директоры (1998–2001). 2001 дә «World Views» халыкара заманча сәнгать үзәгенә (Нью-Йорк) чакырыла.

Х. — авангард сәнгатенең күренекле вәкиле, Казакъстанда иң беренче постмодернистларның берсе, заманча сәнгатьнең объект («әзер предмет» стилендә), инсталляция, перформанс кебек формаларын, Казакъстан видео-артын башлап җибәрүче. Күп кенә кураторлык проектлары авторы һәм катнашучысы. Рус авангарды идеяләрен номадик дискурс (гөмбәз-тирмәнең универсаль образы) б-н берләштерү максатын куя, соңрак сәнгать теленең тактиль табигатьлелеге концепциясен игълан итә, «пулота» (русча «пустота — полнота»дан) неологизмы авторы.

Х. нәкышытән, карандаш б-н рәсем ясаудан фотосурәт, объект, инсталляция һәм видеога күчә. Тышкы дөньяны төсле һәм аклы-каралы абстракцияләр б-н модельләштерүче «Гитара һәм ирис белән натюрморт» (1989), «Кыйпылчыклар» (1989), «Үтә күренмәлелек» (1991), «Pars pro toto» (1992), «Көзгесез автопортретлар», «Жанр кысаларыннан тыш» (1990 еллар), «Берчеметем» (1995), «Бродский хөрмәтенә» (1996), «Исәнмесез, Матисс әфәнде» (1996), «Пулота» (2001) картиналары авторы. 1990 елларда юеш төсле яки ак массада бармаклар хәрәкәте б-н (бармаклар б-н рәсем ясау, «Тоеп белү» варианлары, барысы да — 1997) әсәрләр иҗат итә. Пластик материал — балчык б-н эшләргә омтыла башлый: «Камил ияр» (1997), «Ноленче биеклек. Балчык проект» (1999–2000). Перформанс һәм инсталляция акцияләре авторы һәм катнашучысы: «Кыйпылчыклар» (1990 еллар), «Нәфрәтнең көзге ишарәләре», «Почтальон җыры» (икесе дә — 1996), «Рәссам тиресе» (1997), «Соңгы нокта» (1997, Алма-Ата, Кастеев исем. Дәүләт сәнгать музее), «Җайдак хөрмәтенә» (1997, Казакъстан, Тянь-Шань обсерваториясе), «Зур пыяла. Чикләрне тою», «Очучы аклык» (икесе дә — 1998), «Чыңгызхан байрагы» (1999, Самара өлкәсе, Беренче Ширяев заманча сәнгать биенналесе), «Алтын алиһә» (2007). «Теләкләр ландшафты», «Кияү һәм кәләш» (автордаш Ю.Тихонова), «Мәхәббәт бәйгеләре» һ.б. («Төньяк вәхшиләре-2» сериясеннән, 1999–2000) видеофильмнары төшерә.

«Дүртлек» (Алма-Ата, 1981, 1983), «Рәсми булмаган сәнгать» (Алма-Ата, 1986), «Стерлигов төркеме» (Ленинград, 1990, 1991), «Арт-миф-92», «Евразия зонасы» (Мәскәү,1999), «Петербург биеналлесе» (1994) һ.б. күргәзмәләрдә, «Тәңре-Умай» (Алма-Ата, 2002) сәнгать фестивалендә, Урта Азия халыкара видео-арт күргәзмәләрендә: Канадада (Виндзор ш., 2001), 1 нче Валенсия биеналесендә (Испания, 2001), 51 нче Венеция биенналесендә (2005), АКШта (Нью-Йорк, 2007, 2008; Филадельфия, 2007–08) катнаша. Шәхси күргәзмәләре 1985 (Ленинград), 1994 (Мәскәү), 2003 (Вильнюс, Литва), 1996, 2005, 2007 (Алма-Ата), 2007 дә (Лондон, Англия; Мәскәү) уздырыла.

Картиналары Третьяков галереясында, «Тәңре-Умай» галереясының заманча сәнгать үзәгендә (Алма-Ата), Көнчыгыш халыклары Дәүләт сәнгать музеенда, Көнчыгыш Казакъстан өлкә сынлы сәнгать музеенда (Семипалатинск ш.), Архангельск өлкә сынлы сәнгать музеенда, Нью-Джерси шәһәрендәге Зиммерли музеенда (АКШ) саклана.

Әд.: Рустам Хальфин: Каталог произведений. Алматы, 1995; Рустам Хальфин. «Нулевой уровень — глиняный проект»: Буклет. Алматы, 1998; Нуриева А. Охота на мамонта // Новое поколение. 2002. 24 мая; Левская А. Переоткрытие тела // Эксперт. Казахстан. 2007. 26 марта.

Г.Ф.Вәлиева-Сөләймановa.

ХӘЛФИН Сәгыйть Хәсән улы (1732, Казан — 1785, шунда ук), педагог, тәрҗемәче. Казандагы Татар бистәсенең йомышлы татары улы, 1750 елларның 2 нче яртысыннан Казан адмиралтействосында тылмач. 1769–85 тә Казан гимназиясендә татар теле укыта. Казан бистәләренең йомышлы татарларыннан *Яңа кануннар эшләү комиссиясе* (1767–69) депутаты була, сайлаучылар исеменнән аның тарафыннан төзелгән наказ өлешчә бастырыла. Руслар өчен беренче «Татар әлифбасы» («Азбука татарского языка с обстоятельным описанием букв и складов, сочинённая Казанских гимназий учителем и Адмиралтейской конторы переводчиком Сагитом Хальфиным, и татарских в Казани слобод муллами в оных гимназиях рассмотренная и одобренная») авторы, әлифба 1778 дә Мәскәүдә басыла һәм 50 елдан артык киң кулланыла. Татар грамматикасы дәреслеген һәм фундаменталь рус-татар сүзлеген төзи (өч кулъязмасы калган, Казан ун-ты-ның Фәнни китапханәсендә, С.-Петербург ун-ты китапханәсендә саклана), аларны тел белгечләре һәм әдәбиятчылар куллана.

Х е з м.: Из «мнения» депутата от служащих татар Старой и Новой слобод Казанской провинции в «Комиссии для составления нового уложения» Сагита Хальфина // Сб. Рус. ист. об-ва. СПб., 1875. Т. 14.

Әд.: Владимиров В.В. Историческая записка о 1-й Казанской гимназии. К., 1867. Ч. 1; Артемьев А.И. Казанская гимназия в XVIII столетии // Журн. Мин-ва нар. просвещения. 1874. Ч. 2–3.

ХӘЛФИН Халит Галиәсгар улы (10.3.1925, Кыргызстан АССР, Акмулла ш.–31.8.2007, Казакъстан Респ-касы, Караганда ш.), тау эшләрен оештыручы, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1972). Бөек Ватан сугышында, Мәскәүдә 1945 елның 24 июнендә уздырылган Җиңү парадында катнаша. 1950 дә Совет армиясе сафларыннан демобилизацияләнә. Казакъстан тау-металлургия ин-тын тәмамлаганнан соң (Алма-Ата, 1956), Караганда шәһәре шахталарында эшли: тау эшләре остасы, участок җитәкчесе, баш инженер. 1968–73 тә — «Михайловская» шахтасы, 1973–79 да Окт. рев-циясенең 50 еллыгы исем. шахта директоры. Караганда күмер бассейнын үзләштерүгә зур өлеш кертә. СССР Дәүләт бүләге югары нәтиҗәле күмер алу технологияләрен эшләгәне һәм гамәлгә кертkәне, Караганда күмер бассейнында җитештерүне комплекслы механикалаштыру чаралары куллану нигезендә оештырганы өчен бирелә. Ленин, Хезмәт Кызыл Байрагы, Ватан сугышы орденнары; медальләр б-н бүләкләнә; «Шахтёр даны» билгесенең тулы кавалеры.

И.Р.Вәлиуллин.

ХӘЛФИННАР, тәр җемәчеләр һәм педагоглар династиясе. Нигез салучы — С.Х.*Хәлфин* (1732–85); аның уллары — Исхак Сәгыйть улы *Хәлфин* (?-1800), Исмәгыйль Сәгыйть улы (?–?) — дәүләт учреждениеләрендә тәрҗемәче, Казан гимназиясе укытучысы; оныгы — педагог, тел белгече, тәр җемәче Ибраһим Исхак улы *Хәлфин* (1778–1829); оныгының улы — Шаһингәрәй Ибраһим улы (1807–?), 1828 елда Казан гимназиясен тәмамлый һәм Казан ун-тына укырга керә, бер үк вакытта, 1825 тән, Казан гимназиясендә татар теле укыта. Әтисенең вафатыннан соң матди хәле авыр булу сәбәпле укуын ташлый, 1829–31 дә университет басмаханәсендә хәреф җыючы, соңрак офицер булып хезмәт итә.

Әд.: Валиди Ж. Хәлфиннәр семьясы // Шура. 1913. № 3–5; Ханбиков Я.И. Русские педагоги Татарии и их роль в развитии просвещения и педагогической мысли татарского народа (Из истории русско-татарских педагогических связей). К., 1968.

ХӘМӘДИ́ЕВ Ривнур Хаҗи улы (6.1.1946, Әлки р-ны Югары Әлморза а. — 26.3.2003, Казан), вет. вирусологы, вет. фән. д-ры (1991), проф. (2000), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1997). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1970), Респ-ка вет. лаб-ясендә, Казан вет. ин-тының вирусология бүлегендә (1970 елдан) эшли. 1981–2003 тә Бөтенроссия вет. фәнни-тикшеренү ин-тында әйдәп баручы, баш фәнни хезмәткәр. Тикшеренүләренең төп юнәлешләрен мөгезле эре терлекләр һәм дуңгызлар хламидиозларын өйрәнү (эпизоотология, диагностика, авыруны кисәтү үзенчәлекләре һәм дәвалау чаралары) тәшкил итә. Х.нең турыдан-туры катнашында хламидиоз диагностикумнары (РСК, РИФ, РНГА) эшләнә, мөгезле эре һәм вак терлекләр, дуңгызлар хламидиозларына каршы моно- һәм ассоциацияләштерелгән вакциналар гамәлгә кертелә (ТР Дәүләт бүләге, 1995). Уйлап табуга патенты һәм 6 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Хламидиозы сельскохозяйственных животных. М., 1984 (автордаш); Хламидиозы крупного рогатого скота и меры борьбы с ним. Чебоксары, 2001 (автордаш).

Әд.: Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.): Биогр. словарь учёных. К., 2006.

К.Х.Папуниди.

ХӘМӘДИ́ШИН Дәүфит Закир улы (1.1.1959, Мөслим р-ны Баек а.), Эчке эшләр генерал-лейтенанты (2008), ТРның атказ. юристы (2005). СССР Эчке эшләр министрлыгы академиясе каршындагы Мәскәү юридик читтән торып уку ф-лының Казан бүлеген тәмамлый (1987). 1980–92 елларда Чаллы шәһәренең Автозавод р-ны эчке эшләр бүлегендә: инспектор, җинаять эшләрен тикшерү өлкән инспекторы, җинаять эшләрен тикшерү бүлеге башлыгы (1984–89), җинаять эшләре буенча милиция башлыгы (1989–92). 1992–95 тә Чаллы шәһәрендә Эчке эшләр идарәсенең җина-

ять эшләре буенча милиция башлыгы. 1995–98 дә — Түбән Кама, 1998–2002 дә Чал лы шәһәренең Эчке эшләр идарәсе башлыгы. 2002 дән РФ Юстиция министрлыгының ТР буенча Җәзаларны үтәү идарәсе башлыгы. 2005–17 дә РФ Җәзаларны үтәү федераль хезмәтенең ТР буенча идарәсе башлыгы. Медальләр, ш.и. 2 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» ордены медале б-н бүләкләнә. РФ һәм ТР Эчке эшләр министрлыгының мактаулы хезмәткәре. Чаллы шәһәренең мактаулы граждане.

ХӘМЗӘ́ әл-Бирәзәви (як. 1775–1826, Казан губ., Казан өязе Югары Бирәзә а.), галим-ма тематик. Белемне Бохара, Кабул шәһәрләрендәге дини уку йортларында ала. Замандашлары арасында Х. мөнәҗим (астроном) буларак билгеле.

Әд.: М ә р ж а н и Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әх вали Казан вә Болгар. К., 1989.

ХӘ́МЗИН Касыйм Зыятдин улы (5.12.1895, Казан губ., Тәтеш кантоны Олы Тормы а. — 5.2.1976, Казан), тел галиме, педагог. Казанда «Касыймия» мәдрәсәсен (1912), Шәрекъ пед. ин-тын (1930) тәмамлый. 1912 елдан Бохара, Ташкент, Казанда мәктәп укытучысы булып эшли. Беренче бөтендөнья сугышында катнаша. 1924–26 да татар-башкорт хәрби командирлар мәктәбендә татар теле һәм хәрби хәзерлек дәресләре укыта. 1927 дән Казан ун-тында, 1936 дан мәктәп укытучысы, бер үк вакытта, 1939 дан, СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында һәм Татарстан дәүләт нәшриятында (Татгосиздат). Татар лингвистика терминологиясен эшләүчеләрнең берсе. Хез мәтләре татар теле лексикологиясе, терминологиясе һәм орфографиясенә карый. Мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен татар теле дәреслекләре авторы. «Татар теленең орфографик сүзлеге»н (1941), «Татар теленең диалектологик сүзлеге»н (1947), «Татарча-русча сүз лек»не (1950) һәм «Русча-татарча сүзлек»не (М., 1966) төзүчеләрнең берсе. Репрессияләнә (1948); аклана (1956).

Х е з м.: Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге. К., 1965 (автордаш).

Әд.: Ә х м ә т ж а н о в М. Телче Касыйм Хәмзин // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2009. № 1; Ш а к и р з я н о в М. Учёный, педагог, просветитель (к 100-летию К.Хамзина) // Идель. 1996. № 7–8. *М.Ә.Сәгыйтов.*

ХӘ́МЗИН Рафат Әсван улы (29.1.1952, Улья нов өлкәсенең Иске Кулаткы р-ны Урта Те решка а.), эпизоотолог, вет. фән. д-ры (2007), Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1982), шунда ук эпизоотология кафедрасында эш ли. 1993–98 елларда Респ-ка терлек авырула рына каршы көрәш станциясендә, 1998 дән ТР МС Баш вет. идарәсенең эпидемияләргә каршы көрәш бүлеге башлыгы. Хезмәтләре респ-ка терлекчелек пр-тиеләрендә эпизоото логик халәтне тикшерүгә карый. Уйлап табу га патенты һәм 2 авторлык таныклыгы бар. Мөгезле эре терлекләр һәм дуңгызларда ту беркулёзга диагноз кую, авыруны кисәтү һәм дәвалау буенча чаралар комплексын эшләүдә катнашкан өчен ТР Дәүләт бүләгенә лаек була (1996).


Х е з м.: Провокация скрытого носительства микробактерий туберкулёза у крупного рогатого ско -



Д.З. Хәмәдишин.



Ш.Г. Хәмзин.



Р. Хәмид.

та // Ветеринария. 2001. № 2 (автордаш); Совершенствование диагностики, профилактики и мер ликвидации туберкулёза крупного рогатого скота в зоне длительного неблагополучия: Дис. ... К., 2006.

Әд.: Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.): Биогр. словарь учёных. К., 2006.

ХӘ́МЗИН Шамил Габдуллажан улы (29.12.1915, Архангельск ш. — 14.9.1991, Мәскәү), разведчик. Ленинград электротехника ин-тын тәмамлаганнан соң (1941), Мәскәүдә хәрби з-дта эшли. 1943 елдан дәүләт куркынычсызлыгы органнарында. 1940 елларның 2 нче яртысыннан Азия, Якын Көнчыгыш, Көнбатыш Европа илләрендә һәм АКШта разведка эшендә. Яңа һөҗүм итү коралы үр нәкләре, атом-төш коралы булмаган илләрдә атом технологиясе үсеше, Азия-Тын океан Советын (АЗПАК, Сеул,1966) төзү планна ры турында мәгълүматлар туплауга мөнәсәбәтле «Боулинг» операциясен эшләүдә кат наша. Кызыл Байрак, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары б-н бүләкләнә.

Әд.: М у с т а ф и н Р. Татарский Зорге // Татарстан. 2009. № 12. *Г.Н.Булатова.*

ХӘМИ́Д Ризван Мирхәбибулла улы (24.10.1941, БАССРның Ярмәкәй р-ны Усман-Ташлы а. — 17.9.2017, Казан), драматург, прозаик, ТССРның атказ. сәнгать эш леклесе (1991). Казан пед. ин-тын (1971), Дәүләт театр сәнгате ин-ты (ГИТИС) кар шындагы Югары театр курсларын (Мәскәү, 1979), Әдәбият ин-ты каршындагы Югары әдәби курсларны (Мәскәү, 1983) тәмамлый. 1961–63 елларда Октябрьский һәм Уфа шәһәрләрендәге заводларда слесарь булып эш ли. 1971–78 дә Казанда яши, «Чаян» ж-лын да әдәби хезмәткәр, бүлек мөдире. 1984–85 тә ТАССР Язучылар берлегенең Чаллы бүлек чәсе рәисе, 1985–87 дә Татарстан Язучылар берлегенең идарә рәисе урынбасары. Х. пье саларының тематикасы — татар авылы яз мышы, кешенең туган нигезеннән читләшүе («Майның унбишләрендә», 1984 тә куела; «Җиде ба жа», 1988 дә куела). Х. драмала рында геройларның үзара мөнәсәбәтләре һәм шәхси кичерешләре аша илдәге иҗтима гый-сәяси проблемалар яктыртыла: «Синең урыны ң кайттым» (1978 дә куела), «Китәм инде» (1983 тә куела), «Ике сәгать — бер го мер» (1985 тә куела) (барысы да — Татар акад. театрында). 1970–80 елларда популяр булган җитештерү темасына багышланган «Айсберг» («Әманәткә хыянәт», 1984 тә куе ла) пьесасында үз һөнәрләренә мөнәсәбәтләре аркылы геройларның әхлакый йөзе — ха рактер ныклыгы, принципиальлек, таләпчәнлек, рухи тотнаклылык кебек сый фатлары ачыла. «Идегәй» (Р.Мингалим б-н берлектә, «Казан утлары» ж-лында басыла, 1995), «Хан кызы» (1998 дә куела) драмаларында татар халкының тарихи үткәне, атаклы тарихи шәхес ләр образлары гәүдәләндерелә. Х. драмаларында хатын-кыз об разлары аеруча зур роль уйный. «Пыяла кыз» (1979 да куела), «Язмышлар хәл ителгәндә» (1980 дә куела), «Каен җиле» (1984 тә куела), «Диде кардәш...» (1985 тә куела), «Олы юлның тузаны» (1986 да куела) пьесаларында бөек Ана образы сурәтләнә. Г.Исхакый әсәр ләренә («Кәләпүшче кыз», «Ике йөз елдан соң инкыйраз») нигезләнеп язылган «Курчак туе» (М.Гыйләҗев б-н берлектә, 2009 да куела) пьесасында татар хатын-кызы язмышы 20 йөз башы драматик вакыйгалары шартларында яктыртыла. Х. иҗатында татар драматургиясенә хас традицион һәм традицион булмаган сәнгатьчә сурәтләү чаралары (гипербола, гротеск, җанландыру, абсурд күренешләр, фарс, фантастика элементлары), модернизм (мифологема образлары, символик-метафорик мәгънә, шартлылык һ.б.) һәм постмодернизм (уен, ирония, пародия, фрагментарлык, гиперреализм һ.б.) күренешләре файдаланыла. «Ике сәгать — бер гомер» драмасында сугыш кешелекнең табигый үсешенә ят күре неш итеп күрсәтелә; «Көзнең соңгы яфраклары» (1996 да куела), «Ирем китте войнага» (1998) пьесаларында тормышның фаҗигале яклары, «Иске йорт кешеләре» сатирик комедиясендә (1979 да куела) һәм «Тигезәкләр» трагифарсында (2000 дә куела) җәмгыятьтәге әдәп-әхлак нормаларының юкка чыга баруы ачык сурәтләнә; «Чабаталы чәүчәләк» комедиясендә (2001) туган тел мәсьәләсе күтәрелә; «Җанкай улы Җанкыяр» трагифарсында (1998 дә куела), «Ак тамырлар иле» трагедиясендә (1989–90) татар халкының милләт бу ларак юкка чыгуына китерергә мөмкин вазгыять — милли гореф-гадәтләрнең, буыннар ара сындагы рухи бәйләнешнең югалуы, әхлакый нигезләрнең җуелуы тасвирлана. Х. — балалар өчен язылган «Айдарның авыр көне» (1980), «Тәбе» (1982) һ.б. пьесалар, ш.у. чәчмә әсәрләр һәм публицистик мәкаләләр, «Тукай» телефильмының (Г.Ахунов, Ә.Зарипов б-н бер лектә, Казан телестудиясе, 1991–93) сценарий авторы. Әдипнең сәхнә әсәрләре рус, баш корт, чуаш, кабардин, кыргыз, украин, грузин һ.б. телләргә тәрҗемә ителә. Татарстан комсомолының М.Җәлил исем. бүләге (1984), М.Сәлимҗанов исем. Респ-ка бүләге лауреаты (2017). Медаль б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Китәм инде: пьесалар. К., 1991.

Әд.: Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2; К а ю м о в а Г.И. Концепция личности в драматургии Ризвана Хамида и её художественное воплощение: Автореф. дис. ... К., 2007.

Г.И.Каюмова.

ХӘМИДИ́ Латыйф Габделхәй улы (17.7.1906, Казан губ., Зөя өязе Бүәле, хәзер Рус Ябалагы а., — 29.11.1983, Алма-Ата), композитор, педагог, дирижёр, Казакъстан ССРның халык артисты (1966). Казакъ проф. музыкасына нигез салучыларның берсе. 1926 елда — Ташкент төрки милли азчылык мәгарифе ин-тын, 1938 дә Мәскәү консерваториясе каршындагы Татар опера студиясен (Г.Литинский классы) тәмамлый. 1934–35 тә Казакъ радиосы хорын оештыручы һәм аның җитәкчесе, 1938–42 дә — Курмангазы исем. Казакъ дәүләт халык музыка уен кораллары оркестрының, бер үк вакытта, 1940–42 дә, Казакъ хор капелласының баш дирижёры һәм сәнгать җитәкчесе, 1944–74 тә Алма-Ата консерваториясенең халык музыка уен кораллары каф. мөдире. Х.ның беренче әсәрләре — М.Җәлил шигырьләренә язылган балалар җырлары һәм хорлары, ш.у. Мәскәү татар эшче театры спектакльләренең муз. бизәлеше. Төп әсәрләре: «Абай» (1944; 1956 да 2 нче редакция) һәм «Түләгән Тохтаров» (1947; 1961 дә 2 нче редакция) — икесе дә М.Ауэзов либреттосына Ә.Җубанов б-н берлектә; симф. оркестр, рус һәм казакъ халык музыка уен кораллары оркестрлары, инструменталь ансамбльләр, фортепиано һәм домбра өчен әсәрләр; хорлар; җырлар һәм романслар (С.Муканов шигыренә «Казакъ вальсы» һәм Н.Алимкулов шигыренә «Былбыл» җыры аеруча популяр); кинофильмнар һәм спектакльләргә музыка һ.б. Традицион казакъ, үзбәк, төрекмән вокаль-инструменталь музыка әсәрләре; татар, башкорт һ.б. халыкларның фольклор көйләре эшкәртмәләрен (100 дән артык) иҗат итә һәм яздыра (200 дән артык); Казакъстан Дәүләт гимны музыкасы авторларыннан берсе (1945, Е.Брусиловский һәм М.Түләбаев б-н берлектә). «Домбрада уйнау мәктәбе» (Алма-Ата, 1950; Б.Гыйззәт б-н берлектә); «Казакъ халык оркестры музыка уен кораллырында уйнау белеме» (Алма-Ата, 1952; Л.Шаргородский б-н берлектә); «Дирижёрлык нигезләре» (Алма-Ата, 1966; Х.Тастанов б-н берлектә) һ.б. уку-укыту ярдәмлекләре нәшер итә. Казакъстан ССРның К.Байсәитова исем. Дәүләт бүләге лауреаты (1978). Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.



Л.Г.Хәмиди.

Әд.: Юсфин А. Латыф Хамиди. М., 1964; Гизатов Б. Латыф Хамиди. Алма-Ата, 1966; Ерзакович Б. Латыф Хамиди. Алма-Ата, 1978.

Ф.Ш.Салитова.

ХӘМИДИ́ Шәйхелислам (1869, Сембер губ. — 4.6.1911, Казан), дин эшлеклесе, илаһият белгече. «Мәр җания» (Казан) мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң, төрле уку йортларында, ш.и. «Госмания» (Уфа ш.) мәдрәсәсендә укыта, бертуган Кәримовлар типографиясендә (Казан) корректор булып эшли (1904 кә кадәр). Соңыннан Уфа губернасының Минзәлә өязе Яхшыбай авылында имам һәм мөдәррис була. Төрки халыклар арасында киң билгеле булган, Япониядә (1949), Төркиядә (1984) һәм Катарда (1985) күчереп бастырылган «Әл-Иткан фи-тәрҗимәтил-Коръән» («Коръәнне тәрҗемә итүдә камиллек», Оренбург, 1907, 1911) Коръән тәфсиренең авторы.

Әд.: Фәхретдинов Р. Асар. К., 2010. Т. 3–4.

ХӘМИДУ́ЛЛИН Айдар Фаяз улы (10.4.1955, Казан), балалар йөрәк-кан тамырлары авырулары хирургы, ТРның атказ. табибе (2012), ТРның Фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт бүләге лауреаты (2015). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1978), Казан шәһәре 2 нче балалар клиник хастаханәсендә эшли.1984–86 елларда Респ-ка балалар клиник хастаханәсе урологы, 1986–94 тә хирург-рентгенолог, 1994 тән ангиография бүлеге мөдире. Респ-када беренче булып балаларда тумыштан килгән йөрәк һәм кан тамырлары зәгыйфьлеген эндоваскуляр операцияләр б-н дәвалауны гамәлгә кертә. Хезмәтләре балаларда йөрәк-кан тамырлары авырулары, урология, рентгенология өлкәләренә карый. ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш балалар рентгенологы. Медаль б-н бүләкләнә.

ХӘМИДУ́ЛЛИН Әсхәдулла Гыйбадулла улы (14.2.1923, Төньяк Казакъстан өлкәсе Петропавловск ш. — 2001, ноябрь, Казакъстан Респ-касы, Алма-Ата), журналист, тәр җәмәче, язучы. 1948 елда Югары партия мәктәбен тәмамлый (Алма-Ата). 1953 кә кадәр Петропавловскида: 1945 тән «Ленинское знамя» өлкә г-тасында әдәби хезмәткәр, бүлек мөдире, мөхәррир урынбасары, 1952 дән Төньяк Казакъстан өлкә радиоком-ты рәисе. 1953–61 дә һәм 1974 тән Алма-Атада яши: «Казахстанская правда» г-тасы хәбәрчесе, 1959 дан «Сельская жизнь» үзәк г-тасының үз хәбәрчесе, 1975–84 тә «Казакъстан» китап нәшриятында редакция мөдире, баш мөхәррир урынбасары, баш мөхәррир, 1985–89 да «Казакъстан мәдәнияте һәм тарихы истәлекләре» альманахын төзүче-мөхәррир. 1961–75 тә Караганда шәһәрендә: «Индустриальная Караганда» г-тасы редакциясендә бүлек мөдире, җаваплы сәркәтип, 1968 дән Караганда телевидениесе студиясенең баш мөхәррире. Мәкаләләре Казакъстанның социаль-икътисади үсешенә, төбәкне өйрәнүгә, татар-казакъ әдәби бәйләнешенә, Г.Тукай, Г.Ибраһимов, И.Салахов, М.Җәлил һ.б.га багышлана. Якут революционеры һәм дәүләт эшлеклесе М.К.Аммосов турындагы «Легендар Максим» («Легендарный Максим», Алма-Ата, 1988) документаль повесте авторы. «Автограф б-н китап» (49 чыг.) авторлык программасы, Х. сценарийлары буенча телеспектакльләр («Бер тапкыр һәм бөтен гомергә», «Карт испан», «Куркыныч кичү» һ.б.) киң таныла. Казакъстан радиосын-да татар телендәге радиотапшырулар авторы. Ш.Усмановның «Легион юлы» («Путь легиона», 1970) повестен, А.Расихның «Ямашев» романын (1975) рус теленә тәр җәмә итә. 1952–53 тә Петропавловск шәһәр советы депутаты. Медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Татары в Казахстане. Алма-Ата, 1996.

Әд.: Галиев В.З. Штрихи творческой биографии А.Г.Хамидуллина // Татары в Казахстане. Алма-Ата, 1996; Татары в Казахстане: Энцикл. словарь. Алматы, 2011.

ХӘМИДУ́ЛЛИН Булат Лирон улы (13.8.1968, Казан), тарихчы, публицист, ТР Язучылар берлеге әгъзасы (2001), тарих фән. канд. (2004), ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (2011), ТРның фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт бүләге лауреаты (2016). Казан ун-тын тәмамлый (1992). 1992–94 тә «Казан» милли мәдәният үзәге хезмәткәре. 1994–98 елларда ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында, Тарих ин-тында. 1998–2002 дә Татарстан китап нәшриятының фәнни-популяр әдәбият редакциясе мөдире. 2002–2014 тә ТР ФАнең «Фән» нәшрияты баш мөхәррире, «Научный Татарстан» һәм «Фәнни Татарстан» ж-лларының баш мөхәррире урынбасары. 2016 дан ТР ФАнең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институтында татар диаспорасын өйрәнү үзәге мөдире. «История татар» (2002; 15 китап, 2018), «История татар в лицах» (2010; 12 китап, 2018) иллюстрацияле китаплар сериясенең идея авторы, I Бөтендөнья татар галимнәре форумы материаллары җыентыгын төзүче (2010) һ.б. Хезмәтләре төрки халыклар (хәзәрләр, болгарлар, татарлар) тарихына карый; Г.Ахуновның «Тимерханның күргән-кичергәннәре» трилогиясен («Увиденное и прожитое Тимерханом», 2001), Л.Х.Хәмидуллинның «Дәрдемәнд» (2003), В.Имамовның «Казан дастаны» («Казанская крепость», 2005) китапларын һ.б. әсәрләрне рус теленә тәр җәмә итә. ТРның Дәүләт бүләге күптомлы «Иң борынгы заманнардан алып татарлар тарихы» («История татар с древнейших времён», К., 2002–15. Т. 1–7) хезмәтен төзүдә катнашканы өчен бирелә. «Татар халкының тарихын һәм мәдәниятен пропагандалау буенча нәтиҗәле эшчәнлеге» өчен Кол Гали исем. бүләк (2000), «Иң яхшы китап басмасы өчен» «Бәллүр каләм» респ-ка конкурсы лауреаты (2000). Медаль б-н бүләкләнә.

Хезм.: Из глубины столетий. К., 2000; Чингиз-хан — 850. К., 2002; Казанның нигезе һәм Казан ханлыгы тарихы. К., 2005; Pax Chazarica: main written sources and scientific literature. К., 2013.

Әд.: Писатели Татарстана — лауреаты литературных премий. К., 2011; Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2; Avrasya Türkologları sözlügü. Ankara, 2012. 1 cilt, 2 kitap.

ХӘМИДУ́ЛЛИН Гали Заһид улы (3.8.1903, Уфа губ. Бәләбәй өязе, хәзер Башкортстан Респ-касының Миякә р-ны Яңа Ишле а. — 14.8.1983, Уфа ш.), икътисадчы, а.х. фән. д-ры (1961), проф. (1965). Мәскәүнең К.А.Тимирязев исем. а.х. академиясен тәмамлаганнан соң (1932), Башкорт а.х.н социаль реконструкцияләү ин-тында бүлек мөдире булып эшли. 1934 елдан ВКП(б)ның Башкортстан өлкә ком-тында, 1938–39 да Башкорт а.х. ин-тында. 1939–42 һәм 1945–52 дә Башкорт кырчылык тәҗрибә станциясе директоры, 1942–45 тә БАССРның игенчелек халык комиссарының беренче урынбасары. 1955 тән СССР ФАнең Башкортстан ф-лында икътисади тикшеренүләр бүлеге мөдире. Хез-

мәтләре Башкортстанда таулы р-ннарның үзләштерелүе һәм төбәктә а.х. үсешенә, игенчелек һәм терлекчелектә җитештерүнең нәтиҗәлелеген күтәрү мәсьәләләренә карый. Х. Башкортстан терр-ясендә беренче тапкыр а.х.н районлаштыру эшен башкара, районнарның табигый-икътисади үзенчәлеген тасвирлый.

БАССР ЮС депутаты. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, 2 «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Сельское хозяйство Башкирии за 25 лет. Уфа, 1944; Себестоимость сельскохозяйственной продукции и пути её снижения в колхозах и совхозах. Уфа, 1961.

ХӘМИДУ́ЛЛИН Лирон Хәйдәр улы (10.11.1932, Ульянов өлкәсенең Яңа Малыклы р-ны Иске Төгәлбуга а.), язучы, тәр җәмәче, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1982). СССР Язучылар берлеге әгъзасы (1977). Бөтенсоюз читтән торып уку политехник ин-тының Орск ф-лын тәмамлый. Орск, Уфа, Казан тимер юл оешмаларында эшли (1956–67). СССР Язучылар берлеге Әдәби фондының Татарстан бүлеге директоры (1967–83), Татарстан китап нәшрияты мөхәррире (1985–94). ТР ФАнең Татар энциклопедиясе ин-тында тәрҗемәче, мөхәррир (1998–2005). Х.ның беренче очерк һәм хикәяләре вакытлы матбугатта 1960 елларда күренә башлый. «Юлда» (1968) хикәяләр җыентыгы, «Дала иртәсе» (1971) повесте, хикәя, повесть, очеркларны берләштергән «Офыктагы рәшәләр» (1990), «Ак төннәр хәтере» (2002), «Күңелдә калганнар» (2007), «Кичке шәфәкъь» (2009), «Барыбыз да көрәштек» (2010) җыентыклары, «Дәрдемәнд» альбомы (2003) авторы. Ә.Әлимҗановның «Отрар сыгнагы» («Отрар хатирәсе», 1974) повестен, Ә.Мохтарның «Чинор» («Чинар», 1976) романын, С.Моратбәковның «Әрем исе» (1986) повесть һәм хикәяләрен, В.В.Быковның «Обелиск» («Һәйкәл», 1984) повестен һ.б. әсәрләрне татар теленә тәрҗемә итә. Татар халкының тарихын барлауга, аның энциклопедиясен булдыруга зур өлеш кертә. ТР Мәдәният министрлыгы һәм Язучылар берлегенең Г.Исхакый исем. (2010), ТР Язучылар берлегенең Ж.Вәлиди исем. (2017) бүләкләре лауреаты. Медаль б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Дәрдмәнд. К., 2010; Буранлы төндә. К., 2012; Җиңү җи ңел бирелмәде К., 2015 (автордаш); Амирхан Еники. К., 2013; Поэт, издатель, меценат: Док. повесть: К 95-летию со дня смерти Закира Рамиева. К., 2016; Зарницы на горизонте. К., 2017.

Әд.: М и ң н у л л и н Ф. Лирон Хәмидуллин // Балта явызлар кулында. К., 1994; Г о с м а н о в М. Тыйнак табигатьле каләмдәшебез // Гасырдан — гасырга. К., 2004; Ф ә й з у л л и н Р. Аксакал әдипләребезнең берсе // Казан утлары. 2007. № 11; Г а л и м у л л и н Ф. Игелекле эшләр // Казан утлары. 2012. № 10; М а н с у р о в З. Рухият югарылыгына чакыру // Казан утлары. 2017. № 11.

ХӘМИДУ́ЛЛИН Рагыйб Ибраһим улы (28.5.1928, Пермь ш.), терапевт-паразитолог, мед. фән. д-ры (1984), проф. (1987). Пермь мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1951), Пермь өлкәсенең Чусовой шәһәре һәм Чусовой р-ны Югары Калина авылы участок хастаханәләрендә табиб булып эшли. 1957 елдан Казан ГИДУВында, гаилә медицинасы кафедрасында, 1973 тән каф. мөдире. ТРның баш паразитологы (1973 тән). 2006 дан ТР ФА поликлиникасында. Хезмәтләре описторхозны, беренчел бавыр рагын, паразитар авыруларны, аллергияне өйрәнүгә карый. Х. тарафыннан ТРда описторхоз буенча эндемик терр-я билгеләнә. «Описторхоз һәм беренчел бавыр рагы» («Описторхоз и первичный рак печени») хезмәте өчен ТР ФАнең Э.Б.Терегулов исем. бүләге бирелә (1998). Медаль б-н бүләкләнә. Казан мед. академиясенең шәрәфле профессоры (2005).

Х е з м.: Описторхоз и псевдамфистомоз в Республике Татарстан // Казан. мед. журн. 1995. № 2 (автордаш); Растения и здоровье: Применение лекарственных растений в терапевтической практике. К., 1998 (автордаш); Гельминтозы: выявление и лечение. К., 2007 (автордаш).

ХӘМИДУ́ЛЛИН Рәшит Лотфулла улы (28.11.1936, Мәскәү өлкәсенең Красногорск ш. – 27.11.2013, Мәскәү), дипломат. Мәскәү дәүләт халыкара мөнәсәбәтләр ин-тын тәмамлый (1960). 1960–64 елларда СССРның Вьетнам Демократик Респ-касындагы Илчелеге атташесы, секретарь. 1964–66 да СССР Тышкы эшләр министрлыгының Көньяк-Көнчыгыш Азия бүлегендә секретарь, 1971–80 дә 1 нче секретарь, сектор мөдире, бүлек мөдире урынбасары. 1966–71 дә СССРның Камбоджа Королълегендәге Илчелеге секретаре, 1 нче секретаре. 1980–82 дә СССРның Лаос Халык Демократик Респ-касындагы Илчелеге киңәшчесе — илче-вәкил. 1983–86 да СССР Тышкы эшләр министрлыгының Көньяк-Көнчыгыш Азия бүлеге мөдире урынбасары, 1986–87 дә Кораллларны чикләү һәм коралсызлану мәсьәләләре идарәсе баш киңәшчесе, 1987–88 дә Азия соц. илләре идарәсе башлыгы урынбасары, бүлек башлыгы. 1988–89 да СССРның Кампучия Халык Респ-касында, 1989–90 да Камбоджа дәүләтендәге илчесе. 1990–91 дә Вьетнам Соц. Респ-касында СССР, 1992–96 да РФ илчесе. 1996–98 дә Азиянең 3 нче департамент директоры, РФ Тышкы эшләр министрлыгы коллегиясе әгъзасы. 1998–2001 дә РФнең Австралия Союзында һәм Фиджи Респ-касы, Науру Респ-касы һәм Вануату Респ-касы Суверен Демократик Респ-каларындагы илчесе. Халыклар дуслыгы, «Почёт билгесе», Дуслык орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Е.Б.Долгов.

ХӘМИДУ́ЛЛИН Ренат Фәрит улы (4.5.1962, Алтай краеның Бийск ш.), нефть химиясе белгече, техник фән. д-ры (2003), проф. (2005). Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң (1986), шунда ук эшли, нефть һәм газ эшкәртүнең химик технологиясе каф. мөдире (2002–10). Хезмәтләре нефть-химия пр-ти еләренең технологиясе һәм җиһазларына карый. Х. механик катышмалары күп булган авыр, артык үзле һәм күкертле нефтьләрне һәм табигый битумнарны эшкәртүгә әзерләүнең теоретик нигезләрен һәм технология-ләре; технол. аппаратларны: ротор-пульсацияле акустик аппаратларны, ш.у. тондыргычларны, резервуарларны, реагентларны дозалау өчен фаза бүлгечләрен һәм блоклар-ны эшләүдә катнаша. Нефтьне җыю, транс-



Л.Х. Хәмидуллин.



С.С. Хәмидуллин.

портлау һәм әзерләү системасы эчендә сулы нефть эмульсияләрен таркату өчен югары нәтиҗәле композицион деэмульсация кушылмаларын тәкъдим итә. Нефть дисперсияле системаларны дисперсияле анализлау һәм деэмульгаторларның актив-өслек үзлекләренә бәяләмә ясауның методикаларын эшли (эшләрнең нәтиҗәләре «Казаноргсинтез», «Татнефтепром» һ.б. АҖләрдә гамәлгә кертелә). Уйлап табуга 32 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Теплота растворения асфальтено-смолопарафиновых отложений в прямогонных нефтяных фракциях // Технология нефти и газа. 2007. Т. 47, № 2 (автордаш); Моделирование процессов подготовки и переработки нефтегазового сырья в среде ChemCAD. К., 2009 (автордаш).

Әд.: Выпускники — гордость Казанского технологического университета: Краткий биогр.справ. К., 2009.

ХӘМИДУ́ЛЛИН Салих Сөнгать улы (12.8.1932, Кама Тамагы р-ны Кече Мәрәтхуҗа а. — 9.10.2004, Балтач р-ны Кили а.), станоклар ремонтлау буенча слесарь, Соц. Хезмәт Герое (1960). Өч еллык мастерлар мәктәбен тәмамлый (1968). Хезмәт эшчәнлеген 1944 елда туган авылында башлый. 1949–88 дә Казан моторлар төзү ҖБдә эшли: тимерчелек-пресслау җиһазларын ремонтлау буенча слесарь, бригадир (1953 тән). Х. бригадасы көнлек йөкләмәне графиктан бер сәгать алда үти, бу ай саен планнан тыш 1 станок ремонтларга мөмкинлек бирә. Герой исеме җитештерүдәге уңышлары һәм соц. ярыш оештыруда күрсәткән инициативасы өчен бирелә. 1970–74 тә РСФСР ЮС депутаты. КПССның 24 съезды делегаты (1971). Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Заводым — туган йортым. К., 1974.

Әд.: Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы. К., 2003; Гүзәл Кама Тамагы = Камское Устье — жемчужина природы. К., 2006.

ХӘМИДУ́ЛЛИН Сәгыйть Һади улы (18.9.1929, БАССРның Ярмәкәй р-ны Яңа Шах а. — 11.6.2001, Чита өлкәсенең Краснокаменск ш.), геолог, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1980), Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тын тәмамлый (1950). Таҗикстан, Кыргызстан һәм Үзбәкстан ССР, Чита өлкәсенең җитештерү оешмаларында эшли. Дәүләт бүләге уран чыганакларын ачуда катнашуы өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: М е л у а А.И. Геологи и горные инженеры. Нефтяники. М.–СПб., 2003. Т. 2.



Ф.Г. Хәмидуллин.



А.Р. Хәмитов.

ХӘМИДУ́ЛЛИН Фәрит Филзә улы (22.6.1959, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2008). Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлый (1980). 1980–88 елларда Казан ун-тында укыта. 1988–2002 дә Казан коммерция оешмаларында эшли. 2002 дән «ТИСБИ» идарә ун-тында финанс менеджменты каф. мөдире. Хезмәтләре эшмәкәрлек эшчәнлеге мәсь әләләренә карый.

Х е з м.: Малый бизнес в трансформируемой экономике: тенденции и перспективы развития. К., 2006; Институциональные факторы становления и развития малого предпринимательства. М., 2007; Место и роль малого бизнеса в экономике региона. К., 2008.

ХӘМИДУ́ЛЛИН Филзә Гариф улы (3.1.1936, Казан), икътисадчы, җәмәгать эшлеклесе, икътисад фән. д-ры (1982), ТР ФА академигы (2010; 1991 дән мөхбир әгъза). ТАССРның атказ. икътисадчысы (1986). Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлаганнан соң (1958), шунда ук эшли (1990–2000 елларда бүленеп): тармак икътисадлары каф. мөдире (1975–80), каф. профессоры (1983), ректор (1980–90), проф. (2006 дан). 1990–95 елларда ТАССР МС рәисе урынбасары, премьер-министр урынбасары. 1995–2003 тә ТР Президентының социаль-икътисади мәсьәләләр буенча киңәшчесе, бер үк вакытта ТР ФАнең Социаль-икътисади һәм хокук фәннәре ин-ты директоры. Хезмәтләре ТРның икътисады һәм сәнәгатьтә хезмәт интенсивлыгы, ТРның социаль-икътисади үсеше, дөньядагы финанс кризисының Татарстан икътисадына йогынтысы мәсьәләләренә карый. 2003–05 тә РФ Федераль Җыенының Федерация Советы әгъзасы, Татарстан хакимиятенең башкарма органнары вәкиле, бюджет ком-ты рәисе урынбасары. 2007–2015 тә ТР ФА президенты киңәшчесе. 1990 еллардан ТР икътисадының базар мөнәсәбәтләренә күчү проблемалары б-н шөгыльләнә. «Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнары белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында эшләр бүлешү һәм үзара вәкаләтләр алмашу турында» Шартнамә проектын (1994) эшләүдә катнаша. 1991–95 тә Казакъстан, Үзбәкстан, Кыргызстан, Таҗикстан, Төркмәнстан, Белоруссия, Молдова, Әзәрбайҗан б-н тышкы икътисади багланышлар булдыру һәм үстерү максатыннан Татарстан хөкүмәте делегацияләрен җитәкли. «ТРның социаль-икътисади, хокукый һәм сәяси моделе: генезисы һәм перспективалары» фәнни юнәлеше җитәкчесе. Бөтенсоюз икътисадчылар җәмгыяте әгъзасы (1984–90), ТР Иҗтимагый палатасы әгъзасы (2006–09). Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Планирование научной организации труда в кондитерской, сахарной, пивобезалкогольной промышленности. К., 1969; Проблемы интенсивности труда в отрасли. К., 1974; Интенсивность труда в промышленности. К., 1978; Проблемы управления социально-экономическим развитием региона. К., 2004 (автордаш); Tatarstan in the new century. К., 2001 (автордаш).

Әд.: Кто есть кто в Республике Татарстан. К., 2005; Совет Федерации Федерального собрания Российской Федерации, 1994–2004: Энцикл. справ. М., 2005. *Ф.С.Зыятдинов.*

ХӘМИДУ́ЛЛИН Һидият Хәлил улы (10.7.1923, Спас кантоны Иске Үргәгар а. — 8.9.1998, Казан), хокук белгече, юридик фән.канд. (1970). Бөтенсоюз читтән торып уку юридик ин-тының Казан ф-лын тәмамлый (1958). 1945–46 елларда хезмәт ияләре депутатлары Әлки район советы башкарма ком-тының бүлек мөдире, башкарма ком-т рәисе урынбасары, 1948–49 да — Баулы, 1954–57 дә Минзәлә район советлары башкарма ком-тлары рәисе урынбасары. 1949–50 дә КПСС ның Баулы район ком-ты секретаре, 1958–61 дә Азнакай район ком-ты 1 нче секретаре. 1950–54 тә хезмәт ияләре депутатларының Беренче май, 1957–58 дә Азнакай район советлары башкарма ком-тлары рәисе. 1961–68 дә ТАССР прокуроры. Бу елларда респ-када, аеруча районнарда прокуратура органнарын квалификацияле кадрлар б-н ныгыту буенча зур эш башкарыла; прокуратура эшчәнлегендә законнарны үтәүгә, хокук бозуларны бетерүгә принципиаль әһәмият бирелә. 1982–94 тә Казан ун-тында: 1988 гә кадәр җинаять процессы һәм криминалистика каф. мөдире. 1994 тән ТР Прокуратурасының сәяси репрессия корбаннарын аклау бүлеге прокуроры. Хезмәтләре прокурор күзәтчелеге мәсьәләләренә карый. РСФСР (1959–63) һәм ТАССР (1963–85) ЮСлары депутаты. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

ХӘМИДУ́ЛЛИНА Абруй Хөсәен кызы (24.3.1914, Әстерхан губ. Кызыл Яр а. — 13.6.1996, Казан), педиатр, мед. фән. д-ры (1960), проф. (1963), ТАССРның атказ. табибе (1964). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1937), шунда ук, балалар авырулары кафедрасында эшли, факультет педиатриясе (1953–55), госпиталь педиатриясе (1962–78) кафедралары мөдире. 1978 елдан Казан шәһәр сәламәтлек саклау идарәсенең хуҗалык исәбендәге поликлиникасында проф.-консультант. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче, 2 нче, 3 нче Белоруссия фронтларында, соңрак Польша һәм Көнчыгыш Пруссия дә батальон табибе, аерым часть сан. хезмәте башлыгы, армия хирургия күчмә кыр госпитале өлкән ординаторы. 5 нче армиянең 4382 нче госпитале составында Япониягә каршы сугышта катнаша. 1945 тә, яраланганнан соң, мед. хезмәте капитаны дәрәҗәсендә демобилизацияләнә. Хезмәтләре сабыйлык яшендәге балаларның нерв эшчәнлеген, аллергик авыруларны өйрәнүгә карый. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Нервная деятельность грудного ребёнка в норме и при острых токсикозах. М., 1966; Вы растите детей. К., 1987; Особенности деонтологии и этики в педиатрии. К., 1992.

Әд.: Красильников С.Н., Амиров Н.Х. Поклонимся и мёртвым и живым. К., 2000.

ХӘМИДУ́ЛЛИНА Камәрия Зиннур кызы (5.11.1949, Саба р-ны Шекше а.), педагог, җәмәгать эшлеклесе. ТРның атказ. укытучысы (1992), ТРның халык укытучысы (2014). «Ак калфак» татар хатын-кызлары респ-ка иҗтимагый оешмасы җитәкчесе (2003–2011). Арча пед. уч-щесен (1969) һәм Казан пед. ин-тын (1973) тәмамлый. Казан мәктәпләрендә укыта. 1993 елдан 2 нче татар гимназиясе директоры. Х. җитәкчелегендә гимназиядә балаларга ана телен укытуның заманча алымнары, шушы профиль буенча инновацияле программалар актив эшләнә. Ул директор булган елларда гимназия КФУның база учреждениесенә әверелә. Хезмәтләре математика укыту методикасы мәсьәләләренә карый. «Мәгариф» ж-лы мөхәрририяте әгъзасы. Казан шәһәренең мактаулы граждане (2010). Медальләр б-н бүләкләнә.

ХӘМИТЖА́НОВ Нигъмәт җан Хәмит улы (1.6.1943, БАССРның Балтач р-ны Усман а.), нефтьче, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2006), техник фән. канд. (2002). Уфа нефть ин-тын тәмамлый (1965), 1966–88 елларда «Главтюменнефтегаз» ҖБдә эшли. 1989 дан Татарстан нефть фәнни-тикшеренү һәм проектлау ин-тында (Бөгелмә ш.), бораулау эшләре бүлеге мөдире, лаб. мөдире (1995 тән). Хезмәтләре төзелешнең сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген күтәрү, скважиналарны киңәя торган торбалар куллану юлы б-н файдалануга һәм ремонтлауга карый. Х. скважиналарны билгеле бер урынга беркетү өчен яңа җиһазлар булдыруда катнаша, бораулауда туган кыенлыкларны тикшерү һәм бетерү алымнарын фәнни нигезли. Дәүләт бүләге нефть һәм газ скважиналарын киңәя торган махсус торбалар кулланып беркетү өчен яңа технологияләр һәм техник чаралар эшләүгә һәм гамәлгә кертүе өчен бирелә. Уйлап табуга 100 патенты бар. Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

ХӘМИ́ТОВ Айрат Ринат улы (2.3.1971, Казан), балет артисты, хореография режиссёры, ТРның халык артисты (2004). Химиклар мәдәният сараенда үзешчән «Яшьлек» халык бию ансамблендә шөгыльләнә (Казан, җитәкчесе Н.Г.Кретов). 1991 елда — Казан мәдәният һәм сәнгать академиясен, 2001 дә Россия театр сәнгате академиясен тәмамлый. 1986–2006 да ТРның Дәүләт җыр һәм бию ансамблендә балет солисты, 2005 тән аның сәнгать җитәкчесе. Биюче буларак югары артистлык осталыгы, эмоциональлеге, сәхнәдәге мөлаемлеге б-н аерылып тора. Х.ның соло репертуарын 20 дән артык хореографик композиция тәшкил итә, аның бер өлеше Л.Р.Хәмитова б-н берлектә куела. «Егетләр» (сәхнәгә куючы Ә.Кәлимуллин), «Казан кунаклары» һәм «Башмаклар» (сәхнәгә куючы Г.Таһиров),



А.Р. Х ә м и т о в куйган «Җиде энҗе бөртеге» татар этномюзиклыннан күренеш.

«Җизнәкәй» һәм «Кияү» (сәхнәгә куючы Ф.Гаскәров) биюләрендә, ш.у. үзе иҗат иткән «Татар соло биюе», «Башкорт аучысы», «Малайзия картинасы» һ.б. хореографик номерларда соло башкара. Сәнгать җитәкчесе буларак ансамбль репертуарын һәрдаим яңартырга омтыла. Х.ның актив катнашы нәтиҗәсендә «Казан турында риваять» («Сказ о Казани», 2005), «Истанбул хыяллары» («Грёзы Стамбула», 2006), «Җиде энҗе бөртеге» («Семь жемчужин», 2007), «Кызыл ромашка» («Красная ромашка», 2010) программалары дөнья күрә. Россия «Лидер-2002» бию конкурсы лауреаты (Мәскәү). 30 дан артык илдә, ш.и. Бөекбритания, Италия, Франция, Мисыр, Кытай, Малайзиядә чыгышлар ясый.

В.Н.Горшков.

ХӘМИ́ТОВ Гомәр Павел улы (18.3.1939, Красноярск краеның Удерей р-ны Мотыгино а. — 7.5.2011, Иркутск ш.), информатика һәм кибернетика өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1984), проф. (1985), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (1999). Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң (1963), Иркутск политехник ин-тында эшли. 1978 елдан Байкал икътисад һәм хокук ун-тында: информатика һәм кибернетика каф. мөдире (2000 гә кадәр), декан (1990–2001), каф. профессоры (2001 дән). Хезмәтләре стохастик системалар һәм процессларны имитацияләү, ихтималлыклар теориясендә җитештерүче функцияләр алымын эшләү мәсьәләләренә карый. Уйлап табуга 19 авторлык таныклыгы бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Имитация случайных процессов. Иркутск, 1983; Производящие функции в теории вероятностей. Новосиб., 1999; Вероятности и статистики. Иркутск, 2006 (автордаш).

ХӘМИ́ТОВ Малик (Габделмалик) Әхмәдулла улы (22.8.1930, Норлат р-ны Күгәй а. – 17.7.1983, Казан), язучы. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1952), «Совет әдәбияты» ж-лында, ТАССР Мәдәният министрлыгының радиомәгълүмат бүлегендә, Татарстан китап нәшриятында эшли. 1956–78 елларда «Казан утлары» ж-лы редакциясендә бүлек мөдире. Авыл хуҗалыгы һәм сәнәгать җитештерүе алдынгыларына, галимнәргә, сугыш ветераннарына багышланган «Гүзәл җимешләр» (1959), «Ышану» (1961), «Күтәрелештә» (1965), «Егетлек» (1975) очерклар җыентыклары авторы.

Әд.: Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

ХӘМИ́ТОВ Равил Әнвәр улы (12.8.1962, Әлмәт р-ны Бишмунча а.), тау инженеры, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2002). Лениногорск нефть техникумын (1981), Куйбышев политехник ин-тын (1991) тәмамлый. 1981–2006 елларда «Татнефть» АҖдә: «Лениногорскбурнефть» идарәсендә электромонтёр, электрбатырма җайланмаларын прокатлау һәм ремонтлау буенча хезмәт күрсәтү үзәк базасында мастер, оператор, технолог, башлык урынбасары, нефть һәм газ чыгару буенча цех башлыгы, үзәк-технол. хезмәте башлыгы; 2001 дән «Иркеннефть» НГДУда баш инженер. 2006 дан «Татнефть-Трубопроводсервис» идарәче компаниясе» ҖЧҖ башлыгы.

ХӘМИ́ТОВ Рәкыйп Хатыйп улы (9.7.1952, Чаллы р-ны Мусабай-Завод а.), спортчы (татар-башкорт спорт көрәше), спортның милли төрләре буенча РСФСРның спорт остасы (1985), ТРның атказ. спорт остасы (1992). 1970 еллар башында ирекле көрәш, 1980 нән татар-башкорт көрәше б-н шөгыльләнә башлый. Татарстан (1986, 1997), РСФСР (1983–84, 1986) чемпионатларында, «Кичке сабантуй» ярышларында (1990, Казан), ТРның халыкара фестивальләрендә (1990–91) җиңүче, 1990 елларда ТРның респ-ка сабан туйларында 100 *кг* һәм аннан да югары үлчәү категорияләрендә абсолют батыр. «Татавтотранс» төзелеш-монтаж идарәсендә (Чаллы ш.) директор. Медаль б-н бүләкләнә.

ХӘМИ́ТОВ Рөстәм Радик улы (8.6.1960, Казан), психиатр, мед. фән. д-ры (2004). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1983), Респ-ка психиатрия хастаханәсендә (Казан) эшли, 1988–94 елларда бүлек мөдире, 1994–96 да баш табиб урынбасары. 1996 дан РФ Сәламәтлек саклау министрлыгының интенсив күзәтүле, махсус типтагы Казан психиатрия хастаханәсе баш табибе, бер үк вакытта Казан мед. академиясенең психиатрия һәм мәхкәмә-психиатрия экспертизасы каф. профессоры, 2008 дән Казан мед. ун-тының психиатрия каф. профессоры. Хезмәтләре авыруларга психиатрия ярдәме күрсәтү ысулларын эшләүгә карый.

Х е з м.: Подходы к разработке антропоцентрической модели организации психиатрической помощи. К., 2000; Факторы риска общественно опасного поведения женщин, страдающих шизофренией // Рос. психиатр. журн. 2015. № 5 (автордаш).

ХӘМИ́ТОВ Рөстәм Фидәгый улы (6.10. 1964, Казан), терапевт-пульмонолог, мед. фән. д-ры (2003), проф. (2006). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1987), шунда ук эшли, 1990 елдан — 3 нче клиник фармакол. һәм эчке авырулар, 1992 дән — 4 нче эчке авырулар, 2000 нән факультет терапиясе кафедраларында, 2007 дән 2 нче эчке авырулар каф. мөдире. Х. тарафыннан кискен үпкә ялкынсынуының барышы үзенчәлекләре һәм ахыргы нәтиҗәләрен фаразлауның клиник-матем. ысуллары эшләнә, авыру барышын фаразлау һәм авыруларны дәвалау буенча рекомендацияләр бирелә, бронхиаль астма барышындагы микроблы (хламидияләр һәм микоплазмалар аркылы) йогышлану процессларын өйрәнелә, дәвалауны оптимальләштерү юллары тәкъдим ителә. Уйлап табуга 4 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Клинико-математическое прогнозирование особенностей течения и исходов острых вирусных и бактериальных заболеваний дыхательных путей. К., 1992 (автордаш); Антибактериальная терапия хронического обструктивного бронхита // Рус. мед. журн. 2002. Т. 10, № 23; Клинические аспекты «атипичных» пневмоний // Практическая пневмония. 2004. № 2; Ишемическая болезнь сердца в разрезе респираторных проблем // Вестн. современной клинической медицины. 2015. Т. 8, прил. 1.

ХӘМИ́ТОВ Фидәгый Сабир улы (26.7.1936, Пермь өлкәсе, Октябрь р-ны Щучье Озеро станциясе — 4.9.2002, Казан), стоматолог, мед. фән. д-ры (1979), проф. (1983), Чуаш Респ-касының атказ. фән эшлеклесе. Казан мед. ин -тын тәмамлаганнан соң (1960), Түбән Тагил шәһәрендә эшли. 1965–82 елларда Казан мед. ин-тының казналык-бит хирургиясе кафедрасында. 1982 дән Казан ГИДУВының хирургик стомат. каф. мөдире. 1987 дән Чуаш ун-тында: госпиталь хирургиясе каф. профессоры, стомат. каф. мөдире (1988–2002). Хезмәтләре казналык-биттәге ялкынсыну процессларын һәм җәрәхәтләрне дәвалауны камилләштерүгә карый.

Х е з м.: Функциональное состояние симпато-адреналовой системы и почек у больных с хроническим остеомиелитом челюстей // Казан. мед. журн. 1974. № 2; Содержание катехоламинов в моче больных озоитогенным остеомиелитом челюсти // Стоматология. 1978. № 2; Белковый спектр сыворотки крови у больных с хроническими воспалительными процессами челюстей // Казан. мед. журн. 1981. № 1 (автордаш). Хронические остеомиелиты челюстей и их лечение. Л., 1985.

Әд.: Чувашская медицинская энциклопедия. Чебоксары, 1998. Т. 2.

ХӘМИ́ТОВ Хәниф Сабир улы (10.5.1928, БАССРның Тәтешле р-ны Ялгызнарат а. — 29.1.2003, Казан), физиолог, мед. фән. д-ры (1966), проф. (1967), ТАССРның, РФнең атказ. фән эшлеклесе (1974, 1980). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1950), шунда ук, нормаль физиол. кафедрасында эшли, 1982 елдан каф. мөдире, 1961–63 тә проректор, 1963–89 да ректор. 1992 дән проф.-консультант. Х. җитәкчелек иткән елларда ин-тта яңа уку корпуслары, студентлар өчен тулай тораклар төзелә; Октябрьнең 50 еллыгы уңаеннан ин-т РСФСР ЮС Президиумы, РСФСР МС һәм ВЦСПСның истәлек Байрагы б-н бүләкләнә (1967); ин-т базасында медицинаның актуаль мәсьәләләренә багышланган бөтенроссия съездлары һәм конфе-

ренцияләре үткәрелә. Хезмәтләре ашказаны-эчәк тракты моторикасын көйләү һәм медиаторларның трофик функциясен, кан тамырлары тонусын, синаптик структуралар эшчәнлеген өйрәнүгә карый. Нерв системасы физиологиясе өлкәсендәге фәнни тикшеренүләре өчен ТРның Дәүләт бүләгенә лаек була (1995). Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Ацетилхолин и серотонин в норме и патологии желудочно-кишечного тракта. К., 1977 (автордаш); Влияние позвоночного нерва на некоторые показатели мозгового кровотока // Физиол. журн. СССР. 1979. № 2 (автордаш); Барьерная функция лёгких и обеспечение гомеостаза. К., 1987 (автордаш).

Әд.: Профессор Хамитов Ханиф Сабирович // Казан мед. журн. 2003. № 3; Казанский государственный медицинский университет (1804–2004 гг.): Заведующие кафедрами и профессора: Биогр. словарь. К., 2004.

ХӘМИ́ТОВ Эдуард Шәйхулла улы (22.9.1937, БАССРның Борай р-ны Яңа Кызган а.), педагог, пед. фән. д-ры (2000), проф. (1991), БАССРның атказ. фән эшлеклесе (1977), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (1998), БР ФАнең шәрәфле академигы (1998). Бөре пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1958), шунда ук эшли. 1964 елдан Куйбышев пед. ин-тында, 1966 дан Уфа нефть ин-тында, 1969 дан Башкорт пед. ин-тында (хәзер Башкорт пед. ун-ты), физика-матем. ф-ты деканы (1969–72), проректор (1972–83), ректор (1983–2005). 2005–07 дә РФ Дәүләт Думасы депутаты. Хезмәтләре физика белеме бирү, һөнәри ориентация, педагоглар әзерләү мәсьәләләренә карый. Халыклар дуслыгы, «Башкортстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» орденнары б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Практические занятия по физике в педагогическом вузе. Уфа, 1974 (автордаш); Педагогическая профориентация в школе и вузе. Уфа, 1988; Контингент гуманитарного вуза: теория, подходы, практика формирования. Челябинск, 1999.

ХӘМИ́ТОВА Ләйсән Рәшит кызы (30.12.1971, Казан), балет артисты, педагог, ТРның халык артисты (2004). Уфа хореография уч-щесен (1991), Казан мәдәният һәм сәнгать академиясен (2002) тәмамлый. 1991 елдан ТРның Дәүләт җыр һәм бию ансамблендә балет солисты, бер үк вакытта, 2006 дан, ансамбль каршындагы «Юлдаш» балалар хореография (2009 дан вокаль-хореография) студиясенең сәнгать җитәкчесе. Соло хореография партияләре: таулы бадахшан, чегән, һинд биюләре, Аргентина көтүчеләре биюе «Гаучо»; «Әпипә», «Татар лирик биюе», танго, испан чегәннәре биюе «Фламенко» һ.б. Артист буларак Х. халыкчан бию хәрәкәтләренең югары техникасы, артистлык осталыгы, сәхнәдәге хәрәкәтчәнлеге, юмор хисе б-н аерылып тора; ирләр милли хореография партияләрен уңышлы башкара. ТРның Дәүләт җыр һәм бию ансамбле балетмейстеры буларак татарча «Кара-каршы бию» шаян биюен, «Мәскәү татарлары биюе»н, «Татарстан яшьлеге», «Фламенко» һ.б. биюләрне, ш.у. «Юлдаш» студиясендә 20 дән артык хореографик композиция куя. Россия «Лидер-2002» бию конкурсы лауреаты (Мәскәү). Ире А.Р.Хәмитов б-н бергә Бөекбритания, Италия, Франция, Мисыр, Кытай, Малайзия һ.б. илләрдә чыгышлар ясый.

В.Н.Горшков.



Л.Р. Хәмитова.



Л.М. Хәмитова.



Л.Р. Хәмитова «Таулы Бадахшан» соло номерында.



Л.М. Хәмитова Биби ролендә («Беренче театр», Г. Камал).

ХӘМИ́ТОВА Люция Миннәхмәт кызы (12.7.1967, Казан), актриса, ТРның халык артисты (2007). Казан театр уч-щесен тәмамлаганнан соң (1987), Татар акад. театры труппасына кабул ителә. Иң элек Х., Гәүһәр («Алмазбулат», Ю.Сафиуллин) һәм Зөһрә («Таһир һәм Зөһрә», Ф.Бурнаш) рольләрен башкарып, лирик героиня буларак таныла. Х. башкаруында яңгыравыклы тавышлы һәм аристократ кыяфәтле йөнтәс эт Чарли («Авыл эте Акбай», Т.Миңнуллин) тышкы рәсеменең үзенчәлекле булуы б-н аерылып тора. Порция («Шейлок», У.Шекспир; Казан Зур драма театры сәхнәсендә куела) һәм Джульетта («Ромео һәм Джульетта», У.Шекспир; Татар акад. театры сәхнәсендә куела) образларында актрисаның драматик сәләте гәүдәләнә. Х. героиняларының характеры вакыйгалар үсешенә бәйле рәвештә, хәрәкәттә, зур эчке темперамент б-н ачыла, образның тышкы рәсеменнән үк сәнгатьчәлеге б-н аерылып тора. Актриса тугры Көнәкә («Идегәй», Ю.Сафиуллин), Зөбәржәт («Ай тотылган төндә», М.Кәрим), куплышы Шүрәлия («Җан кисәкәем», Т.Миңнуллин), акыллы, зирәк һәм горур Карачәч («Җирән чичән һәм Карачәч сылу», Н.Исәнбәт) рольләрен образга кереп, ышандырырлык итеп башкара. Вера («Илгизәр+Вера», Т.Миңнуллин), Хәбибә («Казан егетләре», «Тагын Казан егетләре», М.Гыйләҗев), Гөл җамал (шул исем. әсәр буенча, Н.Исәнбәт), Чибәр («Кара чикмән», Г.Хугаев), Маша («Өч сеңел», А.П.Чехов), Елена Николаевна («Өзелгән өмет», М.Горький), Фелисьяна («Бияче», Лопе де Вега) образлары пластик рәсемнең үзенчәлеге, рухи байлыгы б-н аерылып тора. Х.ның чәрелдек Зойка («Мәхәббәт хатирәсе», Ф.Бүләков), беркатлы һәм хәйләккәррәк Биби («Беренче театр», Г.Камал), Фазилә («Зәңгәр шәл», К.Тинчурин) кебек характерлы рольләре фантазиягә байлыгы, эчкерсезлеге, сәнгатьчә чаралардан кыю файдаланып, истә калырлык итеп башкарылуы б-н үзенчәлекле. Актриса ш.у. Хатын («Җәйнең бер көнендә», Й.Фоссе), Королева



Л.Р. Хәмитова һәм А.Р. Хәмитов Бондюг татарлары биюендә.



Л.М. Хәмитова Чибәр ролендә («Кара чикмән», Г.Хугаев).

Елизавета («Ричард III», У.Шекспир), Эльвира («Дон Жуан», Ж.-Б.Мольер), Эстрелья («Тәкъдир», П.Кальдерон) һ.б. рольләрне зур уңыш б-н башкара. ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге лауреаты (2019).

Әд.: И л я л о в а И. Г.Камал театры артистлары = Артисты театра им. Г.Камала. К., 2005.

И.И.Илялова.

ХӘМИ́ТОВА Наилә Хәниф кызы (7.3.1958, Казан), балалар стоматологы, мед. фән. д-ры (2001). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1980), Табибләр белемен күтәрү ин-тында эшли (Мәскәү). 1982 елдан Казан мед. ин-тының балалар стоматологиясе кафедрасында. Хезмәтләре пародонт авыруларын һәм теш-казналык аномалияләрен дәвалау ысулларын эшләүгә карый. Х. бу авыруларның балалар һәм яшүсмерләр арасында таралышын өйрәнә.

Х е з м.: Состояние капиллярного кровотока в пародонте у детей с зубочелюстными аномалиями // Ортодент-инфо. 1999. № 3; Заболевания пародонта и их особенности в детском возрасте. К., 2002; Рациональная методика ортодонтического лечения сельских школьников // Казан. мед. журн. 2013. № 4 (автордаш).

ХӘМИ́ТОВА Рәйсә Якуб кызы (16.9.1949, Казан), гигиенист, мед. фән. д-ры (1996), проф. (1999). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1972), «Радиоприбор» з-дында эшли. 1975 елдан Казан химия фәнни-тикшеренү ин-тында. 1986 дан Казан мед. ин-тында: гомуми гигиена кафедрасында, 1996 дан мед. экологиясе һәм сан.-эпид. күзәтчелеге курсы мөдире. 2013 тән КФУның Фундаменталь мед. һәм биол. ин-тында баш фәнни хезмәткәр. Хезмәтләре фосфорорганик кушылмалар токсикологиясенә, химик матдәләрнең кешегә зарарлы тәэсире механизмнарына, химия сәнәгатендә хезмәт гигиенасы мәсь әләләренә карый.

Х е з м.: Медико-экологические аспекты химизации сельского хозяйства.К., 2006 (автордаш); Региональные факторы риска смертности взрослого населения от ведущих неинфекционных заболеваний // Проблемы социальной гигиены, здравоохранения и истории медицины. 2017, № 4 (автордаш).

ХӘМИ́ТОВА Флюра Харис кызы (2.5.1936, Казан), драма актрисасы, педагог, ТАССР-ның атказ. артисты (1976). Казан пед. уч-ще сен тәмамлый (1956), урта мәктәптә өлкән пионервожатый булып эшли. 1961 елда, Мәскәүдә М.С.Щепкин исем. Югары театр уч-щесен тәмамлаганнан соң, Татар акад. театрына кабул ителә. Җырлау осталыгына һәм драматик сәләткә ия булганга күрә, Х. истә калырлык



Ф.Х.Хәмитова Сәрвәр ролендә («Сүнгән йолдызлар», К.Тинчурин; Исмәгыйль ролендә — Н.Әюпов).



Ф.Х.Хәмитова.

Мәйсәрә, Сәрвәр («Зәңгәр шәл», «Сүнгән йолдызлар», К.Тинчурин), Хәмдия («Ак калфак», М.Фәйзи) образларын иҗат итә. Актрисаның Дибәҗә («Көзге ачы җилләрдә», А.Гыйләҗев), Сәрия, Разия («Кайда соң син?», «Ике килен-килендәш», Х.Вахит), Хупҗамал («Без аерылышмабыз», Ш.Шаһгали), Сәрбиҗамал («Яшь йөрәкләр», Ф.Бурнаш) рольләре көчле лиризм һәм тирән психологизм б-н сугарылган. 1985 тә Казан мәдәният ин-тында пед. эшчәнлеккә күчә, бер үк вакытта радиода әдәби-драматик тапшырулар алып бара. Тыңлаучылар арасында «Тел күрке — сүз» тапшыруы аеруча зур популярлык казана.

Әд.: И л я л о в а И. Г.Камал театры артистлары = Артисты театра им. Г.Камала. К., 2005.

Д.Ә.Гыймранова.

«ХӘМИЯ́Т» («Саклау»), атналык иҗтимагый-сәяси газета. «Борһане тәрәкъкый» нәшрияты органы. 1907 елның апреленнән 1908 гә кадәр Әстерхан шәһәрендә татар телендә нәшер ителә. Нашире һәм мөхәррире — М.*Исмәгыйлев-Ширванский*. Газетада татар халкының иҗтимагый-сәяси, социаль-мәдәни мәнфәгатьләрен яклаган язмалар басыла, Әстерхан төбәге тормышы яктыртыла. Ш.у.к. «*Мизан*».

Әд.: Р ә м и е в И. Вакытлы татар матбугаты (Альбом). 1905–1925. К., 1926.

әл-ХӘНӘФИ́ Бор һәнеддин Ибраһим ибне Хызыр әл-Болгари (14 йөз), Болгар галиме. Мөселман дин белгече Хөсамеддин Мөхәммәд Акситанинның өйрәтмәләренә багышланган «Ысул әл-Хөсами» китабы авторы.

ХӘНӘФИЛӘ́Р, исламдагы дүрт дини-хокукый мәктәпнең берсендә — имам Әбү Хәнифә ән-Ногман бине Сабит (якынча 699–767) нигезләгән сөнни мәзһәбендә булучылар. Хокукый карар чыгаруда хәнәфи ысулының төп чыганаклары: *Коръ әң Сөннә*, иҗмагъ (элгергеләр яки башка абруйлы дин белгечләре төркеме тарафыннан килешенгән фикер), кыяс (Коръәндә булган аналогия буенча фикер йөртү), истихсан (кайбер очракларда кыяс дәлилләреннән баш тарту). Х. ш.у. ислам кадәрге *гореф-гадәтләрне* таныйлар һәм башка халыкларның да гадәтләрен ихтирам итәләр. Кайбер Көньяк-Көнбатыш илләренең (Төркия, Сүрия, Гыйракның үзәк районнары, Әфганстан), Көньяк Азия (Пакъстан, Төньяк Һиндстан), Урта Азия (Үзбәкстан, Таҗикстан, Төрекмәнстан, Кыргызстан), Казакъстан һәм Россия мөселманнары арасында Х. күпчелекне тәшкил итә. Татарстан мөселманнары хәнәфи мәзһәбендә.

Әд.: Абу-Джафар ат-Тахави. Акыда. К., 2000; Абу-Ханифа. Трактаты. М., 2001; Б а т ы р Р. Абу-Ханифа: Жизнь и наследие. Н.Новгород, 2007; М а р д ж а н и Ш. Зрелая мудрость в разъяснении догматов ан-Насафи (ал-Хикма ал-балига). К., 2008; Ш а г а в и е в Д.А. Татарская богословско-философская мысль (XIX — нач. XX вв.). К., 2008; Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

ХӘРА́М (гарәп. حرام), мөселманнарга тыелган ризык, шөгыль, гамәл. Х.ның кампа-каршысы *хәләл* (рөхсәт ителгән). Х.ның берничә төре бар: 1) мөселман хокукы (фикъһ) буенча гөнаһ санала (Коръәндә язылганнарны үтәмәү, рибачылык (процентка яшәү), кыерсыту һәм золымлык, чит мөлкәтне алу һ.б.); 2) якын туганнар белән никахлашу (сөт туган да якын туган исәпләнә); 3) спиртлы, аңны томалаучы башка әчемлекләр һәм нәрсәләр, ш.у. дуңгыз, ишәк яки мул, тырнаклы һәм казык тешле ерткыч кош, хайван (ш.и. мәче һәм эт) итләре, кан, үләксә, бөҗәкләр, кимерүчеләр, җир-су хайваннарын, сөйрәлүчеләр һәм кортлар, ш.у. бисмилласыз яки мәҗүсиләр, утка табынучылар, индуслар, буддачылар һ.б. тарафыннан чалынган хайван итләре; кайбер мөселманнар христиан һәм яһүди ризыкларын (дуңгыз итеннән башка), әгәр ул Алла исеме телгә алынып һәм диннең башка шартлары үтәлеп әзерләнелгән очракта кулланырга мөмкин дип саныйлар; 4) комарлы уеннар (*хәнәфиләр* аларны мөмкин, ләкин хупланмый дип саныйлар), күрәзәлек итү һәм сихерчелек; 5) *хаҗ* кылганда изге Мәккә һәм Мәдинә терр-ясендә, ш.у Иерусалимның изге урыннарында тыела торган гамәлләр: көндәлек кием һәм корал б-н йөрү, чәч алдыру һәм кырыну, интим мөнәсәбәтләр, сугыш алып бару, үч алу һәм хаҗ үтәүне бозарга мөмкин барлык гамәлләр.

Әд.: К а р д а в и Ю. Дозволенное и запретное в исламе. М., 2004; аль-Мунаджжид М.С. Запретное, по отношению к которому люди проявляют небрежность, но которого следует остерегаться. К., 2008; Ч е т и н О. Напоминание о дозволенном и запретном в исламе. М., 2010.

ХӘРӘ́Җ (гарәп. خراج — салым, ясак), мөселман илләрендә урта гасырларда һәм Яңа заманда дәүләт тарафыннан җир биләмәсеннән алынган салым. Баштарак буйсындырылган мөселман булмаган халыктан җыела, аннары мөселманнар арасында да таратыла. Х. күләме уңышның уннан өч өлешен тәшкил итә. Идел буе Болгар дәүләтендә башта буйсындырылган фин-угор кабиләләре, аннары болгарлар үзләре дә Х. түләгән. Алтын Урдада һәм татар ханлыкларында Х.не төрлеләндерү күзәтелә: Х.- хәражәт (җан башыннан алынган салым), берч-Х. (җир биләмәсеннән яки җан башыннан алынган салым), төтен-Х. (моржа башыннан, ягъни һәр йорттан алынган салым), иген-Х. (иген уңышыннан салым). Гадәттә, Х. салымының бер төре генә кулланылган һәм аның күләме уннан бер өлештән артмаган.

Әд.: Ф ё д о р о в - Д а в ы д о в Г.А. Общественный строй Золотой Орды. М., 1973.

И.Л.Измайлов.

ХӘРБИ́ КАБУЛХАНӘЛӘ́Р, Россиядә армиядә хезмәт итәргә тиешле кешеләрне хәрби хезмәткә чакыру мәсь әләләре б-н шөгыльләнгән җирле дәүләт органнары. Казан губернасында Гомуми хәрби бурыч турында 1874 ел 1 февраль указы нигезендә төзеләләр. Югары Идел хәрби-округ идарәсенә һәм Россия Эчке эшләр министрлыгының Хәрби бурыч турында эшләр буенча идарәсенә (1900 дән; элегрәк — Эчке эшләр министрлыгының Земство бүлегенә) буйсыналар. Ка-

зан хәрби губерна кабулханәсе губернатордан (рәис), губерна дворяннары җитәкчесеннән, вице-губернатордан, губерна земство идарәсе сайлаган рәис һәм әгъзалардан, округ мәхкәмәсе прокурорыннан һәм 1912 дән җирле хәрби гарнизон вәкиленнән тора. Хәрби хезмәткә чакыру һәм хәрби хезмәткә яраклы халыкны кабул итү барышын күзәтә, хезмәткә яңа алынучыларның участоклар буенча саның билгели, яңадан тикшерү уздыра, өяз һәм шәһәр Х.к. шикаятьләрен һәм хисаплар карый, Эчке эшләр министрлыгы өчен хисаплар төзи. Өяз Х.к.е (барысы 12) өяз дворяннары җитәкчесеннән (рәис), өяз хәрби башлыгыннан, өяз исправнигыннан, земство идарәсенә сайлап куелган әгъзалардан тора. Составына шәһәрне алган өяз участок Х.к.нә шәһәр идарәсеннән әгъза да керә. Казанда, Спаста һәм Чистайда шәһәр Х.к.е түбәндәге составта эшли: шәһәр башлыгы (рәис), хәрби командование билгеләгән офицер, полиция башлыгы билгеләгән чиновник, шәһәр үзидарәсеннән сайлап куелган ике әгъза. Өяз һәм шәһәр Х.к.е гамәлләренә: хәрби хезмәткә чакырылучылар исемлеген төзү һәм тикшерү, хезмәткә чакырылучыларның саны турында мәгълүмат бирү, хезмәткә чакыру һәм хезмәткә билгеләп кую тәртибен күрсәтү, кабат мед. тикшерүе уздыру, армиягә яңа чакырылучыларны кабул итү, хисаплар төзү керә. РСФСР НКВДсының 1918 ел 20 гыйнвар карары б-н бетереләләр.

Әд.: Зайончковский П.А. Военные реформы 1860–1870 гг. в России. М., 1952.

С.А.Фролов.

«ХӘРБИ́ КОММУНИ́ЗМ», Гражданнһар сугышы шартларында Совет дәүләтенең эчке сәясәте; икътисади кризистан команда-адм. һәм хәрби алымнар б-н чыгарга омтылу. Коммунизмны турыдан-туры кертү мөмкинлегене турындагы теоретик күзаллауларга таяна. Төп билгеләре: җәмгыять б-н идарә итүдә хәрби-приказ системасы; капиталистик элементларның каршылыгын сындыруда штурм алымы һәм аларны илнең халык хуҗалыгыннан тулысынча диярлек кысыклап чыгару; барлык эре һәм урта сәнәгатьне, вак пр-тиеләрнең күп өлешен национализацияләү (к. *Национализацияләү*); хосусый хуҗалыклы җирбиләүчелекне (ш.и. алпавыт, удел, кулак, хутор, отруб) һәм хосусый сәүдәне бетерү; Кызыл Армияне, эшчеләрне һәм шәһәр халкын азык-төлек б-н, сәнәгатьне чимал б-н төп тәэмин итү чарасы буларак, азык-төлек һәм чимал развёрсткасы кертү (к. *Продразвёрстка*); шәһәр б-н авыл арасында туры-туры продуктлар алмашу; акча әйләнешен натуралата алмашуга күчерү; сәүдәне тыю һәм аны төп азык-төлекне һәм сәнәгать продуктларын сыйнфый билге буенча (карточка системасы, паеклар һ.б.) һәм җитештерелгән продукциянең күләмен һәм сыйфатын катгый исәпләмичә генә дәүләт бүленеше б-н алмаштыру; хуҗалык мөнәсәбәтләрен һәм хезмәт хакын натуралаштыру; хезмәткә тарту, хезмәткә түләүдә тигезләштерү формалары буларак, гомуми хезмәт йөкләмәсе һәм хезмәткә мобилизацияләүләр; халык хуҗалыгы б-н җитәкчелекне макс. үзәкләштерү (главкизм).

«Х.к.» елларында Казан губернасында, Россиянең башка төбәкләрендәге кебек үк, азык-төлек диктатурасы урнаштырыла, ул РСФСР Азык-төлек халык комис-ты органнарына «артык икмәкләрен» яшергән һәм «күләгәдәге» базарда саткан («капчыкчылар») крәстияннәр б-н көрәш буенча чиктән тыш вәкаләтләр бирә. Аграр рев-цияне тирәнәйтү һәм азык-төлек органнарына ярдәм итү өчен авылда *ярлылар комитетлары* оештырыла. Әлеге чаралар икмәк һәм чимал килүне көчәйтәләр, тик шәһәр халкын һәм Казанда һәм губернаның башка торак пунктларында таратып урнаштырылган Кызыл Армия частьларын азык-төлек б-н тәэмин итү мәсьәләсен хәл итә алмыйлар. 1918 елның август–сентябрендә сәнәгать товарлары җитмәү сәбәпле, авыл җирләрендә мәҗбүри товар алмашы ш.у. көткән нәтиҗәне бирми. 1919ның гыйнварында продразвёрстка кертелә. Икмәк һәм азык-төлекнең, чималның мөһим төрләрен сату тыела. Продразвёрстканы башкарып чыгу өчен, Казан губернасы авылларына азык-төлек отрядлары җибәрелә, алар башлыча күрше губерналарның эшчеләр сыйныфы вәкилләреннән тора. 1919–20 дә крәстияннәрдән 20 млн. поттан артык икмәк (фаразланганча, «Х.к.» елларында авыл халкыннан җыеп алынган икмәк, бәрәңгене дә кертеп, 40 млн. потка якын тәшкил итә) тартып алына. Моннан тыш, мәҗбүри рәвештә ит, йомырка, май, бал, печән һәм терлек чималы (тире, йон, кыл һ.б.) җыйнала. Җыйналганның күпчелек өлеше губернадан читкә чыгарыла. Җирне социальләштерү барышында хосусый хуҗалыклы җирбиләүчелек бетерелә, а.х. биләмәләренең күп өлеше авыл җәмгатьләренә тапшырыла (к. *Җәмгать җирбиләүчелеге*), хуҗалык итүнең яңа формалары — күмәк хуҗалыклар: *колхоз, авыл хуҗалыгы коммунасы, совхоз, җирне уртак эшкәртү ширкәте* кертелә. Сәнәгать өлкәсендә «Х.к.» сәясәте урта һәм вак пр-тиеләрне национализацияләүдә (1918 нең җәенә кадәр национализацияләнгән эре ф-калар һәм з-длардан тыш) чагыла. 1920 нең ахырында — 1921 нең башында Казан губерна XXC карары б-н аерым затлар һәм җәмгыятьләр кулында булган, механик двигательле җитештерүдә 5 тән артык яисә двигательсез җитештерүдә 10 нан артык эшче исәпләнгән барлык сәнәгать пр-тиеләре национализацияләнә. Сәнәгать б-н идарә итүдә катгый үзәкләштерү гамәлгә кертелә. Дәүләт заказларын үтәүгә мәҗбүри рәвештә кустар-һөнәрчелек һәм кооператив пр-тиеләр тартыла. Сәнәгать һәм азык-төлек товарлары бүленешен дәүләт үз кулына ала, бу очракта бүленеш өлкәсендә буржуазиянең икътисади позицияләрен өзү максаты да күздә тотыла. Халыкны совет һәм кооператив бүлү пунктларыннан барлык продуктлар б-н тәэмин итү РСФСР Азык-төлек комис-тына һәм аның сәнәгать һәм азык-төлек товарларын әзерләү һәм бүлүне гамәлгә ашыручы җирле органнарына йөкләнә. Кулланучылар кооперациясе ярдәмче азык-төлек органы сыйфатында җәлеп ителә. Кооперациядә әгъза булып тору барлык халык өчен мәҗбүри итеп куела. Шушы максаттан шәхси күмәртәләп сату складларына реквизиция һәм конфискация үткәрелә, сәүдә фирмалары национализацияләнә, аерым сәүдә нокталары муниципальләштерелә. Төп азык-төлек һәм сәнәгать товарлары сәүдәсен дәүләт тулысынча монополияләштерә, продуктларны халык арасында карточка системасы буенча паёклар рәвешендә сыйнфый билгегә карап бүлә: эшчеләр халыкның башка категорияләренә караганда күбрәк алалар, эшкә яраклы башка гражданнар фәкать алар тарафыннан хезмәт йөкләмәсе үтәлгән шартта гына азык-төлек белән тәэмин ителәләр. «Кем эшләми, шул ашамый» принцибы гамәлгә ашырыла. Тарифлар сәясәтендә тигезләштерү өстенлек итә. Квалификацияле һәм квалификациясе булмаган хезмәткә түләүдә аерма юк дәрәҗәсендә була. Бу азык-төлек һәм сәнәгать товарларының кискен җитмәүчелеге, шул сәбәпле хезмәт ияләренә аларның тормыш итүе өчен кирәк булган акча минимумын түләргә мәҗбүр булу б-н аңлатыла. Хезмәт хакын түләү торган саен натураль төс ала бара: эшче һәм хезмәткәрләргә азык-төлек паёгы бирелә, дәүләт түләүсез фатирлар, коммуналь хезмәтләр, транспорт һ.б. б-н тәэмин итә. Хуҗалык мөнәсәбәтләренең өзлексез натуральләшү процессы күзәтелә. Акчалар тулысынча диярлек бәясезләнә. Хәлиткеч рәвештә капиталистик элементларның тамырын кору тактикасы үткәрелә. 1918–19 да шәһәр һәм авыл буржуазиясенә Кызыл Армия ихтыяҗлары өчен бердәм гадәттән тыш революцион салым (контрибуция) билгеләнә. Губернаның хезмәткә яраклы барлык халкы мәҗбүри хезмәткә тартыла, Казанда һәм башка шәһәрләрдә яшәүчеләр арасында совхозларда һәм халык хуҗалыгының башка объектларында эшләү өчен хезмәткә ирексезләп мобилизацияләүләр уздырыла. Тайпылучыларны адм. һәм җинаять җаваплылыгына тарталар, Казан, Зөя һ.б. шәһәрләрдәге хезмәт б-н төзәтү лагерьларына җибәрәләр, тоткыннар хезмәте халык хуҗалыгы объектларында файдаланыла. Әлеге чаралар элеккеге җитештерү мөнәсәбәтләрен «коммунистик» дип аталганнары б-н алыштыруга юнәлтелгән була. 1920 ел ахыры — 1921 ел башында халыкка азык-төлек продуктларын түләүсез бирү; куллану предметларын бушлай бирү; эшчеләргә һәм хезмәткәрләргә бирелә торган ягулыкның теләсә нинди төренә түләүне бетерү; эшче һәм хезмәткәрләргә бирелгән торак өчен түләүне гамәлдән чыгару, эшчеләр һәм хезмәткәрләрдән, хезмәт һәм сугыш инвалидларыннан һәм алар каравында булган затлардан су үткәргечтән, канализациядән, газдан, электрдан файдаланган өчен түләү алуны бетерү һ.б. турында декретлар кабул ителә. А.х. өлкәсендә продразвёрстка сәясәте һәм крәстиян хуҗалыгын торгызу эшендә дәүләтнең ирексезләү башлангычы көчәя бара. Крәстиян биләмәләренең кискен кимүе, авылда яшәүчеләрнең хуҗалык итүнең куллану нормасына күчүе сәбәпле, һәрбер крәстиян хуҗалыгы өчен культураларның мәҗбү-

ри исемлеге б-н мәҗбүри чәчү планын билгеләгән дәүләт көйләве кертелә. Планнар үтәлешен тәэмин итү максатында чәчү ком-тлары (посевкомнар) һәм чәчү материалын тарату пунктлары оештырыла. А.х. җитештерүен үзәкләштерүне көчәйткән әлеге чаралар аграр өлкәдәге проблемаларны хәл итә алмыйлар һәм 1920 еллар башындагы ачлыкның бер сәбәбе булып торалар (к. *Ачлык*). «Хәрби-коммунистик» тенденцияләр дәүләти һәм мәдәни тормышның башка өлкәләрендә дә күзәтелә. «Х.к.» сәясәте халыкның киң катлауларында, аеруча крәстияннәр арасында, ризасызлык китереп чыгара. Казан губернасында 30 га якын крәстияннәр чыгышы була (Арча күтәрелеше, 1918; *«Сәнәкчеләр» фетнәсе,* 1920). Гражданнар сугышы тәмамланып, тыныч хуҗалык төзелешенә күчү б-н, яңа шартларда әлеге сәясәтнең яраксызлыгы ачыклана: ул сәнәгать б-н а.х., шәһәр б-н авыл арасында икътисади багланышларны тәэмин итми. 1921 нең мартында ил хөкүмәте «Х.к.»ның нигезсезлеген танырга һәм *яңа икътисади сәясәткә* күчәргә мәҗбүр була.

Әд.: Шишкин А., Лебедева А. Комитеты деревенской бедноты Татарии. К., 1961; Литвин А.Л. Крестьянство Среднего Поволжья в годы гражданской войны. К., 1972; Назипова К.А. Национализация промышленности в Татарии 1917–1921 гг. М., 1976; Рабочий класс Татарии (1861–1980). К., 1981; Шайдуллин Р.В. Крестьянские хозяйства Татарстана: проблемы и пути их развития в 1920–1928 гг. К., 2000.

Р.В.Шәйдуллин.

ХӘРБИ́ ШУРА́, к. *Бөтенроссия мөселманнары хәрби шурасы.*

ХӘСӨ́Н посёлогы, Кукмара р-нында, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогыннан 21 *км* көньяктарак, Баш-Арбаш елгасы башында урнашкан. 2010 елда 12 кеше (татарлар) яшәгән. 1910 елларда нигез салына. Оешкан көненнән Казан губернасының Мамадыш өязе Петропавел волостенда. 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Кукмара, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1920 дә — 50, 1926 да — 145, 1949 да — 100, 1958 дә — 97, 1970 тә — 77, 1979 да — 51, 1989 да — 23, 2002 дә — 20 кеше.

ХӘСӨ́Н (Хәсән хан) (14 йөз), болгар әмире. Болгар идарәчесе, Алтын Урда әмире *Булат Тимер* рус җирләренә уңышсыз рәвештә яу чапканнан һәм Түбән Идел буйларына качканнан соң (1367), Х. Болгарда хакимиятне үз кулына ала. 1370 елда ул әмир Мамайның вассалы була, вәкиле *Мөхәммәд Солтанны* кабул итә; аның б-н бергә хакимлек итә. 1376 да Мәскәү бөек кенәзе Дмитрий Иванович (Донской) *Болгарга яу б-н баруы* нәтиҗәсендә Х. һәм Мөхәммәд Солтан Мәскәүдән бәйлелекне танырга мәҗбүр булалар. 1380 тирәсендә Мамай Болгар өстеннән хакимиятне үз кулына кайтара һәм, ихтимал, Х.не үтерә. Кайбер фаразларга караганда (В.Л.Егоров), 1370 елларда Мөхәммәд Солтан Х.гә җир бүлеп бирә һәм ул анда Казан шәһәренә нигез сала.

Әд.: Фахрутдинов Р.Г. Очерки по истории Волжской Булгарии. М., 1984; Егоров В.Л. Историческая география Золотой Орды в XIII–XIV вв. М., 1985.

И.Л. Измайлов.

ХӘСӨ́Н САРЬЯ́Н (Хәсәнов Сарьян Салихҗан улы) (24.3.1930, хәзер БРның Илеш р-ны Иске Аю а. — 21.9.1978, Казан), язучы. Уфа пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1955), «Кызыл таң», «Совет Башкортстаны» г-талары һәм «Сәнәк» ж-лы редакциясендә әдәби хезмәткәр булып эшли. 1957–60 елларда Башкорт ун-тында татар теле һәм татар теле тарихы укыта. 1960 тан Казанда яши, «Азат хатын» ж-лы редакциясендә җаваплы сәркәтип, СССР Әдәби фондының Татарстан бүлеге директоры, «Идел» альманахы мөхәррире. Иҗтимагый тормышның аеруча кискен мәсьәләләренә мөрәҗәгать итә. «Дөнья бу!» (1956) һәм «Финал» (1963) беренче сатирик хикәяләрендә торгынлык заманы күренешләре тасвирлана. «Ноктасы өтер» (1967) сатирик повестенда заманның кискен социаль һәм психол. коллизияләре чагыла. «Бер ананың биш улы» (1979) повестенда сугыштан соңгы авыл үрнәгендә язучы совет чынбарлыгының тискәре якларын күрсәтә. Татар милли характеры, халыкларның әхлак-әдәп идеаллары «Әткәм һөнәре» (1966), «Егет язмышы» (башка исеме «Җәза», 1980) повестьларында чагылыш таба. «Күңел моңнары» (1969), «Туган як хикәяләре» (1972) җыентыклары халык тарихына, теленә, мәдәниятенә мәхәббәт б-н сугарылган. Тел белеме һәм әдәби осталык турындагы «Уеңны уйдырып сал» (1977) мәкаләләр җыентыгы авторы. Ч.Айтматовның «Гүзәлем Әсәл» (1965) повестен кыргызчадан татар теленә тәрҗемә итә.



Хәсән Сарьян.

Әд.: Макарова В.Ф. Хәсән Сарьян прозасының поэтикасы. Яр Чаллы, 2003.

В.Ф.Макарова.

ХӘСӨ́Н УГЫЛЫ́ (14 йөзнең 2 нче яртысы), төрки-татар шагыйре. Фаразланганча, Идел буенда, Әзәрбай җан, Төркия һәм Мисырда яши. Газәл жанрындагы ике шигыре б-н мәгълүм, аларның берсе — *«Китабе Гөлестан бит-төрки»* кулъязма җыентыгында, икенчесе — төрек шагыйре Гомәр бине Мәҗид тарафыннан төзелгән «Мәҗмугат ән-нәзаир» («Шигъри үрнәкләр мәҗмугасы») антологиясендә безнең көннәргәчә сакланган.

ХӘСӨ́Н бине́ ЮНЫ́С әл-БОЛГАРИ́ (13 йөз), болгар табибе, фармаколог. Та җәдин бине Юныс әл-Болгаринең абыйсы. Әнесенең «әт-Тиръяк әл-кәбир» исемле хезмәтен күчереп яза. Гомеренең соңгы елларын Мосул шәһәрендә (хәзерге Гыйрак) уздыра.

ХӘСӘНИ́ Әхмәтгәрәй Сибгатулла улы (15.12.1883, Казан губ., Царёвококшайск өязе Түбән Көек а. — 1933, Свердловск ш.), нашир, тәр җемәче, язучы. 1888 елда Х. гаиләсе Казанга күченә. Рус, төрки телләрен камил өйрәнә, гарәп һәм француз телләрен белә. 1907 дә Г.Рәхмәтуллин б-н *«Гасыр»* нәшриятын оештыра. 1910 да басмаханә эшен өйрәнү өчен Швейцария, Польша, Германия, Франциягә бара. Татар телендәге *«Аң»* ж-лының нашире һәм мөхәррире (1912–18). Татар драматургиясендә «Г.Ильяси» тәхәллүсе б-н билгеле. 1907 дә Х.нең бер актлы «Денщик Гали», «Хат болгатты» комедияләре, 1914 тә халык әкиятләре мотивлары буенча балалар өчен «Батыр тегүче һәм үги ана» хикәяләр җыентыгы басылып чыга. А.Чеховның «Спор» («Бәхәс»), А.Франсның «История бин Башира» («Бине Бәшир тарихы»), А.Амфитеатровның «Ученик-друг» («Укучы дус»), А.Апинянскийның «Простор» («Сахара») хикәяләрен татар теленә тәрҗемә итә. 1926 да татар язучылары, галимнәре, журналистлары, әдәбиятчылары, ш.и. Х. тарафыннан *«Яңа китап»* кооператив нәшрияты оештырыла, анда Х. нәшрият эше белгече буларак чакырыла. 1931 дә «милли буржуазия б-н элемтәдә торуда, яшерен әдәбият таратуда» гаепләнеп репрессияләнә. 3 елга конц лагерьга хөкем ителә, җәза срогын Беломор-Балтыйк каналы төзелешендә үти. Азат ителгәннән соң, күп тә үтми тифтан үлә. Үлгәннән соң аклана (1959).

Әд.: Йөзмөхәммәтова Л. XX йөз башы татар мәдәни тормышында Әхмәтгәрәй Хәсәни // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2009. № 2.

«ХӘСӘНИЯ́», Уфа шәһәрендә, 3 нче җамигъ мәчет каршындагы мәдрәсә. 1903 елда мәхәллә белән бер вакытта ачыла, яңа ысуллы мәдрәсә була һәм 1919 га кадәр эшли. Шул чорда мөдәррис булып мәчетнең имам-хатибы М.М.*Хәсәнов* тора. «Х.»дә дин дәресләрен укыту системасы *«Рәсүлия»* мәдрәсәсе тәэҗрибәсендә нигезләнә, бу мәдрәсәдә М.Хәсәнов белем ала һәм укыта. Шәкертләре арасында — Н. *Исәнбәт.* Махсус төзелгән таш бинада (хәзерге 5 нче хастахәнә) урнаша.

ХӘСӨ́НОВ Айрат Мансур улы (1959), физик, физика-матем. фән. канд. (1984), 1984–94 тә Казан, Марбург (Германия) ун-тларында, 1994 елдан Төньяк Каролина ун-тында (АКШ, Ашвилл ш.). Хезмәтләре катый җисем физикасына карый.

ХӘСӨ́НОВ Албир Алмаз улы (27.9.1948, Казан), акушер-гинеколог, мед. фән д-ры (1997), проф. (2008), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2017). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1972), Казандагы 4 нче бала тудыру йортында эшли. 1977 елдан Казан мед. ун-тының 1 нче акушерлык һәм гинекол. кафедрасында, каф. мөдире (2002 дән). Хезмәтләре яралгының ана карынында һәм туган вакытта, ш.у. яңа туган баланың нерв системасы зарарлану очракларын киселүгә карый.

Х е з м.: Акушерская проблема родового травматизма новорожденных. К., 1992; Онкогинекология. М.,2000; Диагностика, профилактика и органосохраняющие методы родоразрешения беременных с врастанием плаценты // Казан. мед. журн. 2016. № 4.

ХӘСӨ́НОВ Альберт Бари улы (1.12.1937, Дөбъяз р-ны Кече Кавал а.), язучы, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1995). Татар һәм рус телләрендә яза. Казан пед. ин-тын тә-

мамлый (1961). 1956–61 елларда Дөбъяз р-нында укыта. 1961 дән Лениногорск шәһәрендә яши. 1961–68 дә «Ильич васыятьләре» г-тасы редакциясендә, теле- һәм радиостудиядә эшли. 1969 дан «Лениногорск - нефть» бораулау эшләре идарәсе конторасында монтажчы. 1976 дан «Радиоприбор» ҖБнең Лениногорск ф-лында слесарь. 1991–2002 дә «Ватаным Татарстан» г-тасының, «Татарстан» ж-лының Лениногорск р-ны буенча үз хәбәрчесе. Х.ның әсәрләре нефтьчеләр тормышы һәм хезмәтенә, табигатьне саклау мәсьәләләренә багышлана. «Озын аяк» (1966), «Таң йолдызы» (1967), «Юллар үргә илтә» (1975), «Сөенеч» (1984; русчага тәр җәмәсе «Радость», 1986), «Кемгә сөйлим серләремне» (1990), «Тугрылык төене» («Узел верности», 1997), «Бал корты очышы» («Полёт пчелы», М., 2007), «Җәнбәт җәвере» (2007) хикәяләр һәм очерклар җыентыклары авторы. Х. иҗатына сюжетның кызыклыгы, конфликтларның кискенлеге, вакыйгаларның хәрәкәтчәнлеге хас.

Әд.: Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

ХӘСӘ́НОВ Альберт Хөсәен улы (21.11.1938), физик, физика-матем. фән. д-ры (1985). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1961), шунда ук эшли (1992 елга кадәр), магнит радиоспектроскопиясе һәм квант электроникасы фәнни-тикшеренү лаб-ясенең әйдәп баручы фәнни хезмәткәре (1987 дән). Хезмәтләре ион парамагнит кристалларындагы тигезләнешсез спин системаларын тәжрибәви тикшерүгә карый. Х. Мандельштам-Бриллюэн якты лык чәчелеше буенча ЭПРны туендыру фонында парамагнетикның резонанс фононнары системасындагы процессларны тикшерә. Парамагнит ионнарының диполь-диполь резервуарының тигезләнешсез халәтләре тарафыннан индукцияләнгән ЭПР сызыкчалар канатында фонон ташкынының югары интенсив күренеше барлыгын ачыклый. Резонанс магнит кыры б-н корреляцияләнгән парамагнит ионнарының спин кузгалышларында комбинацион яктылык чәчелешен (КЯЧ) эксперименталь яктан тикшереп нәтиҗәсенең интенсивлык күрсәткечен исәпкә алганда спонтан спин КЯЧннән 100 мең тапкыр зуррак булуын билгели.

Х е з м.: Обнаружение лавины фононов с помощью Мандельштам-Бриллюэновского рассеяния света в условиях импульсного насыщения ЭПР // Письма в журн. эксперим. и теорет. физики. 1971. Т. 13 (автордаш); Сверхрассеяние света на спиновой системе парамагнитных ионов // Письма в журн. эксперим. и теорет. физики. 1983. Т. 38, № 10 (автордаш); Спин-комбинационное сверхрассеяние света в условиях нагрева резонансных фононов // Изв. АН СССР. Сер. физ. 1986. Т. 50 (автордаш). *Р.Г.Усманов.*

ХӘСӘ́НОВ Әнәс Хәсән улы (23.6.1935, Куйбышев р-ны Көек а.), журналист, язучы, тәрҗемәче, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1980). Казан пед. ин-тын (1959), Югары партия мәктәбен (1974, Ленинград) тәмамлый. 1959–72 елларда Казан телевидение студиясе мөхәррире, баш мөхәррире. 1974 тән КПССның Татарстан өлкә ком-ты мәдәният бүлеге инструкторы, 1984 тән Татарстан китап нәшриятының баш мөхәррире урынбасары, 1988 дән «Коммунист Татарии» ж-лы җаваплы сәркәтибе, 1991 дән ТР Президентының матбугат үзәге җитәкчесе, 1999 дан ТР Президентының матбугат архивы мөдире, шул ук вакытта, 1990–97 дә, «Хәтер китабы»ның баш мөхәррире урынбасары. Язмалары Татарстанның иҗтимагый-сәяси, социаль-икътисади үсешенә, рухи-әхлакый тәрбия проблемаларына багышлана. «Яшьли табылган бәхет» (1974) документаль повесте авторы. Х. сценарийлары буенча «Тайгада шәһәрләр туа», «Мин кешеләрне яратам» документаль фильмнары; «Көтелмәгән очрашу», «Тылсымлы яулык», «Алмагачым син» һ.б. телеспектакльләр төшерелә. М.Ш.Шәймиевнең «Татарстан тотрыклы үсештә» мәкаләләр һәм чыгышлар җыентыгын төзүче (1–11 кит., 2001–10). Түбән Кама драма театрында Х.ның «Әти диясем килә» (1997) пьесасы буенча спектакль куела. Нәфис фильмнарны, Г.Данилов, В.Черных һ.б. пьесаларын, Ж.Верн, В.Воскобойников, В.Обручев һ.б.ның романнарын татар теленә тәрҗемә итә. ТР Журналистлар берлегенең Х.Ямашев исем. (1995), ТР Язучылар берлегенең А.Алиш исем. (2003) бүләкләре лауреаты. Дуслык ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Җырым — ал җилкән: Шигырьләр. К., 2003; Кояшлы яңгыр: Шигырьләр, пьесалар. К., 2004; Минем сандугачларым: Поэма, шигырьләр, хикәяләр. К., 2005; Үзәгең алтын синең = Сердце у тебя золотое. К., 2006; Әнис алмалар = Анисовые яблоки: Повестьлар. К., 2008; Узыгыз күңелем түренә. К., 2010; Бәхет кайда оя кора. К., 2015; Первый президент Татарстана Минтимер Шаймиев (Штрихи к политическому портрету). К., 1995 (автордаш).

Әд.: Күпкырлы иҗатчы // Казан утлары. 2005. № 6; Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

ХӘСӘ́НОВ Әнис Сәлах улы (29.4.1954, БАССРның Шаран р-ны Хафиз а.), математик, физика-матем. фән. д-ры (2007). Мәскәү ун-тын тәмамлаганнан соң (1976), шунда ук эшли. 1982–88 дә Химия сәнәгате министрлыгы Бөтенсоюз фәнни-тикшеренү ин-тының Мәскәү ф-лында. 1988–97 дә Мәскәү өлкә пед. ин-тының теоретик физика кафедрасында, 1997 дән Г.В.Плеханов исем. Россия икътисад академиясенең (Мәскәү) югары матем. каф. профессоры. Хезмәтләре хәрәкәт теориясенә һәм аэрозоль кисәкчәләрнең тыш кы кырларда тәэсирләшүенә карый. Х. төрле температуралы газлар эчендәге эре аэрозоль кисәкчәләрнең хәрәкәтен һәм үзара тәэсирләшүен тасвирлау өчен төгәл алым эшли. Термофоретик һәм фотофоретик хәрәкәткә, бертөрле һәм күптөрле эре аэрозоль кисәкчәләргә кагылышлы мәсьәләләрнең (ш.и. сыекчаларда һәм газлардагы үзара тәэсир итешкән кисәкчәләрнең гравитацион утыруы мәсьәләсенең) төгәл чишелешен таба.

Х е з м.: Теория движения сублимирующих и взаимодействующих твёрдых сферических неоднородных аэрозольных частиц во внешних полях. М., 2006 (автордаш); Теория движения неоднородных по теплопроводности сублимирующих твёрдых сферических аэрозольных частиц в поле оптического излучения // Докл. РАН. 2005. Т. 403, № 1 (автордаш).

ХӘСӘ́НОВ Варис Габдулла улы (12.5.1941, Казан), нәкышче, И.Е.Репин исем. Ленинград нәкышь, скульптура, архит-ра ин-тын тәмамлый (1971). 1971–75 елларда РСФСР Сәнгать фондының Татарстан бүлегендә. 1976 дан Мәскәүдә, РСФСР Сәнгать фондының Мәскәү шәһәр бүлеге Нәкышь сәнгате комб-тында эшли (1991 гә кадәр). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1977). Х. — Мәскәүдәге күренекле татар рәссамнарының берсе, көнкүреш жанры портрет, пейзаж тематик картиналары остасы. Иҗатының башлангыч чоры Казан б-н бәйле, «Чәчәкле май ае»



В.Г.Хәсәнов. «Икмәк». 1974.

(1972), «Камазчылар» (1974), татар нәкышь сәнгатенең алтын фондына кергән «Икмәк» (1971–74, вариантлар) картиналарын шунда иҗат итә. Х.ның сәнгать теле акад. реализм стилендә язылган картиналардан («Якташ игенчеләр», 1976; «Чик сакчылары», 1980; «Сабан туе», 1982; «Беренче трактор», 1980 еллар) француз импрессионистлары һәм заманча мөселман сәнгате тәэсирен чагылдырган картиналарга кадәр, аеруча иҗатында зур урын алып торган портрет жанрында, эволюцион үсеш кичерә. Аның тарафыннан замандашлары образлары галереясы иҗат ителә: «Хатын-кыз портреты» (1985, 2002), «Әни портреты» (1985, 2006), «Сәнгать белгече Наилә Вәлиева» (1986), «Генерал Р.Вәлиев.



В.Г.Хәсәнов. «Карт портреты». 1990 еллар.

Мәскәү янындагы җиңүнең 50 еллыгына» (1991), «Генерал Р.Вәлиев» (1995–99, вариантлар), «Кыз портреты» (1995), «Рәссам О.М.Савостюк» (1998), Т.Миңнуллин, Н.Фәттах портретлары вариацияләре, «Шагыйрь Әхмәт Саттаров» (1990 еллар ахыры — 2000 еллар). Пейзажларда Х. табигатьнең лирик образын тасвирлый: «Авыл пейзажы» (1973), «Печищи» (1978) этюдлары, «Бакчасарай этюдлары» (1981) сериясе, «Ай-Петри» (1980 еллар), «Севастополь» (1983) темаларына вариацияләр, «Каспий этюдлары» (1988) сериясе һ.б. Ялангач натура («Ялангач хатын-кыз», 1997, 2006), натюрмортлар авторы.

1976 дан Мәскәү рәссамнары күргәзмәләрендә, «Совет Татарстаны» (Ленинград, 1972–73), төбәкара — «Зур Идел» (1974), Мәскәү рәссамнары (1982, 1992), «Нәкышта-төс» (Мәскәү, 2006), «Җир һәм кешеләр» (Мәскәү, 1976; Смоленск, 1993), бөтенсоюз — «Ил яшьлеге» (Мәскәү, 1986), Мәскәүдәге татар рәссамнарының күмәк күргәзмәсендә (Мәскәү 1995), Мәскәү һәм Казан рәссамнары (Мәскәү, 2002) күргәзмәләрендә катнаша. Картиналары Париж, Прага, Братислава, Мәскәү, Казан һ.б. шәһәрләрдәге шәхси тупланмаларда саклана.

Әд.: Мицлебаев К. Онытылмый яклар // Сөембикә. 1991. № 2.

ХӘСӘ́НОВ Гәрәфи (Гәрәфетдин) Хәким улы (13.6.1921, Казан — 15.4.1992, шунда ук), язучы. 1934 елда Татарстан язучыларының Беренче корылтаенда катнаша (аның балалар әдәбияты хакындагы чыгышын «Известия» г-тасында М.Горький уңай яктан телгә алып китә). 1940–42 дә Октябрь р-нының Бикүле авылы мәктәбендә укыта. 1943 тә репрессияләнә, Красноярск краенда сөргендә була. 1965 тән Казанда яши. Беренче хикәяләре 1930 елларда «Яшь ленинчы» г-тасында басыла. Иҗаты туган як табигате темасына багышлана. «Унике матур» (1968), «Җирем-суым» (1972), «Чү!Сайрар кошым оя тибә» (1976), «Җир ул уртак йортыбыз» (1981), «Елның дүрт фасылы» (1991), «Табигать могҗизалары» (2004; русчага тәрҗемәсе «Причуды природы», 2004). Дж.Родари һәм Н.И.Сладков әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итә.

Әд.: Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

ХӘСӘ́НОВ Закир Шакир улы (25.12.1911, Вологда ш. — 15.8.1983, Удмурт АССРның Балезино р-ны Балезино штп), а.х. җитештерүен оештыручы, Соц. Хезмәт Герое (1976). Түбән Новгород пед. техникумын тәмамлый (1931). Хезмәт эшчәнлеген 1932 елда «Кызыл текстильче» ф-касы каршында фабрика-завод өйрәнчекләре мәктәбендә укытучы булып башлый (Кукмара штп); 1932 дән Удмурт АССРның Балезино р-нында: тулы булмаган урта мәктәптә укытучы, уку-укыту мөдире, директор (Кестым а.), 1945 тән район советы башкарма ком-тының а.х. бүлеге мөдире, 1950 дән ятим балалар йорты директоры (Кестым а.), 1954–83 тә Мичурин исем. к-з рәисе. Х. җитәкчелегендә колхоз зур, күптармаклы югары табышлы хуҗалыкка әверелә, үрнәк-тәҗрибә статусын ала (1961). Җитештерү һәм торак биналар, мәктәпләр, кибетләр, мәдәни-көнкүреш билгеләнештәге объектлар төзелә, асфальт юллар салына. Колхозчыларның тормыш шартлары сизелерлек яхшыра. Колхоз «Почёт билгесе» орденына лаек була, СССР ВДНХсының Мактау тактасына кертелә (1971). Х.ның алдынгы тәҗрибә мәктәбе булдырыла, тәҗрибә уртаклашырга респ-каның башка районнарыннан киләләр. Герой исеме Бөтенсоюз соц. ярышларда ирешкән уңышлары, 1976 да бөртекле ашлык һәм башка а.х. продуктларын җитештерү һәм дәүләткә сатуны арттыру буенча соц. йөкләмәләрне һәм планнарны үтәгәндә хезмәт батырлыклары өчен бирелә. Бөек Ватан сугышында катнаша. Ике Ленин ордены, ике Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы орденнары, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының бронза медале б-н бүләкләнә. Балезино штп да, Кожило авылында урамнар Х. исеме б-н атала; районның тарих-төбәк музеенда Геройлар стендында портреты, колхозның идарә бинасында мемориаль такта куела.


Әд.: Герои Социалистического Труда — наши земляки. Ижевск, 1983; Удмуртская Республика: Энцикл. Ижевск, 2000.

ХӘСӘ́НОВ Илгизәр Галимҗан улы (25.5.1957, Казан), актёр, ТРның халык артисты (2008). Казан театр уч-щесен тәмамлаганнан соң (1978), Минзәлә татар драма театрына чакырып алына. 1980 елда Татар респ-ка күчмә театрына кабул ителә. Кискен характерлы, күбесенчә комик рольләр башкаручы актёр буларак, әлеге театр сәхнәсендә Х. тормышчан, танып беленә торган һәм шул ук вакытта киң гомумиләштерүгә ия образлар иҗат итә. Ул һәр роль өчен аңа гына хас сәнгатьчә сурәтләү чаралары, үзенчәлекле пластика, грим, костюм, сөйләм манерасы таба белә. Х. башкаруында исерек Фәйрүз («Исән-лектә-саулыкта», Р.Хәмид), елгыр Еланов («Баҗа — мал түгел, кәҗә — туган түгел», Т.Миңнуллин), мәгънәсез һәм тынгысыз Хәмит («Хикмәтле доклад», К.Тинчурин), «хаклык» эзләп йөрүче бәйләнчек Антонио («Фигароның өйләнүе», П.Бомарше), фарс-гротеск алымнарын кулланып гәүдәләндерелгән Оронт («Галиҗәнап де Пурсоньяк», Ж.Б.Мольер) образлары тышкы рәсемнәрен төгәллеге һәм эчке дөньяларының ышандырырлык булуы б-н аерылып тора. Актёр, ш.у. Эбин («Богауланган мәхәббәт», Ю.О'Нил), Клещ («Кояш төшмәгән җирдә», М.Горький), Кадержан Ябагаев («Айгөл иле», М.Кәрим), Закир («Кара йөзләр», М.Гафури), Әмир Якупович («Әллә язмыш, әллә ялгыш...», Н.Нестерова), Артист («Гамлет. Күренешләр», У.Шекспир), Саттар («Гайфи бабай, өйлән давай!», Г.Зәйнашева), Сәлимгәрәй, Сәйфетдинов («Американ», «Сакла, шартламасын!..», К.Тинчурин), Шакир («Төн яна учакта», Х.Ибраһим), Мисыр сәүдәгәре («Йосыф-Зөләйха», Н.Хисамов), Зигмунд Керн, карт Керн («Без барыбыз да кешеләр», Эрих Мария Ремарк), Хәйбуш («Эх, алмагачлары!», Ш.Фәрхетдинов), Әдһәм («Ефәк баулы былбыл кош», А.Гыйләҗев), Хаммат, Колый тархан («Хуҗа Насретдин», Н.Исәнбәт), Закир («Туй күлмәгем — соңгы бүләгем», Д.Салихов), Хаммат («Әйдә барыйк, кызлар карыйк», Р.Вәлиев), Флүн («Сакаллы сабыйлар», Р.Суфиев-Солнцев), Эльфир («Яз галәмәте», Р.Сәгъди) һ.б. рольләрне уңышлы башкарып, тамашачының ихтирамын яулый. Һәвәскәр балалар театр студиясе б-н җитәкчелек итә.

Әд.: Илялова И. Театр имени Тинчурина. К., 2002. *И.И.Илялова.*



З.Ш. Хәсәнов.



И.Г. Хәсәнов.



И.Г.Хәсәнов Мөгаллим ролендә («Хажи әфәнде өйләнә», Ш.Камал).

ХӘСӘ́НОВ Кәлимулла Гомәр улы (1878, Казан губ., Мамадыш өязе Чулпыч а. — 3.3.1948, Казан), сәясәт эшлеклесе. Казан татар укытучылар мәктәбен тәмамлый (1900). 1900–07 елларда Уфа губернасы Бөре өязенең Борай авылы башлангыч мәктәбендә укыта. Укытучылар һәм халык мәгарифе эшлеклеләре берлегенең Бөтенроссия съезды (Мәскәү, 1905 нең декабре) делегаты. Бөре өязе крәстиннәреннән 2 нче Дәүләт Думасы депутаты (1905); мөселман хезмәт таифәсен оештыручыларның берсе һәм аның сәркәтибе. Думаның ачларга ярдәм күрсәтү буенча азык-төлек комиссиясен оештыруда катнаша. Аграр мәсьәлә, МС декларациясе һ.б. буенча чыгышлар ясый. Башкортлар җиренә милек хокукын саклауны таләп итә. Мөселман трудовикларының «Стражникларның Уфа губернасы Бөре өязендәге золымнары» рәсми соравын имзалый. Мөселман авыллары мәктәпләрендә туган телдә укытуны яклый, укытучыларның хакимиятләр өчен кулай, махсус белемнәре булмаган затлардан билгеләнмәвен таләп итә. 1907 нең апрель–маенда мөселман трудовиклары тарафыннан нәшер ителгән татарча «Дума» г-тасы мөхәррире (С.-Петербург). 1907 нең сентябрендә Борай авылындагы вакыйгалар вакытында агитация

алып баруда гаепләнеп, укытучы вазифасыннан читләштерелә. 1908 дән Азов-Дон банкының Казан бүлекчәсендә акчалар күчерү бүлеге мөдире. Революцион эчтәлекле мәкаләләре өчен хөкем ителеп (1911 нең марты), Казан губерна төрмәсендә тотыла. 1912 нең маендa иреккә чыгарылганнан соң, Мамадыш өязе буенча үз кандидатурасын 4 нче Дәүләт Думасына сайлауга тәкъдим итә (хакимиятләр тарафыннан кире кагыла). 1912–14 тә иминият агенты булып эшли. 1914 нең сентябрендә сугышка каршы чыгышлары өчен полиция күзәтчелегендә яшәүгә Оренбургка сөрелә. Февр. рев-циясеннән соң Россия мөселманнарының Вакытлы үзәк бюросы әгъзасы булып сайлана (Петроград); Казан губернасы җәмәгать иминлеге комиссары урынбасары вазифаларын башкара, җирләрне тартып алу һәм җирбиләүчеләргә карата җәзалар турындагы эшләр б-н шөгыльләнә. 1917 нең ноябрендә Милләт Мәҗлесе депутаты, 1918 нең гыйнварында Милли Идарә әгъзасы булып сайлана. 1919 ның язында 2 нче армиянең азык-төлек бүлегендә хезмәт итә, Кызыл Армия өчен азык-төлек җыюны оештыруда катнаша. Совет хакимияте елларында берничә тапкыр эзәрлекләнүгә дучар ителә. 1921 нең 13 сентябрендә «яшерен рәвештә ачларга ярдәм күрсәтү җыелышын җыюда» гаепләнеп кулга алына, аннары азат ителә. 1933 тә кабат кулга алына, «милләтче баш күтәрүчеләр оешмасында катнашучы, партия һәм хөкүмәт сәясәтенең аборуена зыян китерү» эше буенча гаепләнә. Иреккә чыгарылганнан соң, Казанның СК-4 з-дында эшли. 1941 нең сентябрендә кабат кулга алына һәм 1942 нең маендa СССР Эчке эшләр халык комис-тының Махсус киңәшмәсе тарафыннан 5 елга адм. сөрелүгә хөкем ителә. Хөкем срогын БАССРның Юмаху җа авылында уздыра. 1946 ның ноябрендә Казанга кайта. 1956 да аклана.

Әд.: Жертва царя и генсека (депутат 2-й Гос. думы России Калимулла Хасанов) // Султанбеков Б.Ф. Не навреди. К., 1999; Анохина З.Н. Уральские депутаты в Государственной думе (1907–1917 гг.). Челябинск, 2009.

Р.А.Айнетдинов.

ХӘСӘ́НОВ Мансур Хәсән улы (25.6.1930, Чаллы кантоны Бигеш а. — 13.3.2010, Казан), дәүләт эшлеклесе, әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1971), ТР ФА академигы (1992), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1995). Алабуга китапханә техникумын (1948), Казан ун-тын (1955) тәмамлый, шунда ук эшли, 1972 елдан татар әдәбияты каф. мөдире. 1961 дән КПССның Татарстан өлкә ком-тында: фәнни һәм уку-укыту учреждениеләре бүлеге мөдире. 1971–92 дә ТАССР МС, ТР МК рәисе урынбасары, 1 нче урынбасары. 1992–2006 да ТР Фәннәр академиясе президенты; бер үк вакытта, 1994–2010 да, ТР ФАнең Татар энциклопедиясе ин-ты директоры. Татарстанның гомуми белем бирү, һөнәри-техник һәм югары мәктәбе, китапханәләр, музейлар, кино прокаты челтәре үсешенә зур өлеш кертә. Х.ның турыдан-туры катнашы б-н респ-када мед., пед. һәм муз. уч-ләре (Чаллы, Түбән Кама һ.б.), Казан мәдәният ин-ты (Казан мәдәният һәм сәнгать ун-ты), Мәскәү энергетика ин-тының Казан ф-лы (Казан энергетика ун-ты), Волгоград физик культура һәм спорт ин-тының Казан ф-лы (Кама физик культура, спорт һәм туризм академиясе, Чаллы ш.), Г.Тукай музейлары (Арча р-ны Яңа Кырлай а., 1971; Казан, 1986 һ.б.) ачыла, А.М.Бутлеровка (1978), М.М.Вахитовка (1985) һ.б.га һәйкәлләр куела. *Татарстан Республикасы Фәннәр академиясен* оештыручыларның (1991) берсе һәм аның беренче президенты була. Татарстанда акад. ин-тлар һәм үзәкләр (*Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты, Тарих институты, Тел, әдәбият һәм сәнгать институты* һ.б.) системасын булдыруда зур роль уйный. Х.ның актив катнашында *Татарстан Совет Социалистик Республикасының дәүләт суверенитеты турында Декларациясе* (1990), Татарстанның дәүләт статусы буенча референдум уздыру турында карар (1992), ТР Конституциясе (1992), Казанның 1000 еллыгын бәйрәм итү турында карарлар кабул ителә. Хезмәтләре татар әдәбияты тарихына, әдәбият белеменең методология мәсьәләләренә, татар иҗтимагый фикере тарихына (Г.Ибраһимов, Ш.Мәрҗани, Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Камал, К.Тинчурин, Г.Исхакый, С.Максуди һ.б.) карый. «Татар энциклопедиясе»нең (аның вакытында 6 том - нан 2002–10 да рус телендә — 5, 2008–10 да татар телендә 2 том дөнья күрә), урта мәктәпләр өчен татар әдәбияты дәреслекләренең (1973; 5 басма, 1990) фәнни концепциясе авторы һәм баш мөхәррире; Г.Ибраһимов (1–8 т., 1974–87), Ф.Әмирхан (1–4 т., 1984–86), Г.Тукай (1–5 т., 1985–86) әсәрләре җыелмаларын, «Татар әдәбияты тарихы»н (1–6 т., 1984–89) басмага әзерләү буенча редколлегияләр рәисе. «Татар энциклопедиясе сүзлеге»н рус (1999) һәм татар (2002) телләрендә булдыруга керткән өлеше өчен ТРның Дәүләт бүләгенә лаек була (2005). 1963–90 да ТАССР ЮС депутаты, ТАССР ЮС ның Халык мәгарифе һәм мәдәният буенча даими комиссиясе рәисе (1963–71). ТАССРның әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге буенча ком-т (1971–90), ТРның фән һәм техника өлкәсендә Дәүләт бүләге буенча ТР Президенты каршындагы комиссия (1993–2005) рәисе. Ике Хезмәт Кызыл Байрагы, Халыклар дуслыгы, «Почёт билгесе», 4 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен», «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.



М.Х.Хәсәнов.

Х е з м.: Галим һәм Ибра һимов: Тормышы һәм иҗат юлы. К., 1964; Интернационализмның җанлы традицияләре: Әдәби тәнкыйть мәсь әләләре һәм публицистика. К., 1980; Галимджан Ибрагимов (1887 — 1938): Краткий очерк истории и творчества. К., 1960; Галимджан Ибрагимов. К., 1977; Писатель, учёный, революционер. Страницы жизни и творчества Галимджана Ибрагимова. М., 1987.

Әд.: А х у н о в Г. Без Тукайлы дөнья кешесе // Идел. 2000. № 6; Ә х м ә д у л л и н А. Олы галим, күренекле җәмәгать эшлеклесе // Казан утлары. 2000. № 6; Фидакарьлек // Казан утлары. 2005. № 6; Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2; Академия наук Татарстана. К., 1992; Татарское возрождение: Эпоха и личности. К., 2000; Временем призванный: воспоминания о Мансуре Хасанове. К., 2015.

Г.С.Сабирҗанов.

ХӘСӘ́НОВ Марсель Ха жи улы (26.6.1939, Чаллы ш.), тренер (самбо), Украина ССРның атказ. тренеры (1986), Халыкара категорияле судья (1991). Киев физик культура ин-тын тәмамлый. Спорт б-н 1950 еллар ахырында шөгыльләнә башлый, «Авангард», «Буревестник», «Динамо» (Киев ш.) ирекле спорт җәмгыятләрендә чыгыш ясый. 1970 тән «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятендә һәм Украина Эчке эшләр министрлыгының Милли академиясендә тренерлык һәм укыту эшендә, 1990 еллардан Европа, дөнья чемпионатлары судьялыгында катнаша. Х.ның шәкертләре — Европа, СССР яшьләр беренчелекләре, дөнья чемпионатларында җиңүчеләр һәм медаль алучылар — В.Бобошко, В.Быченок, И.Гребенщиков, В.Служенко. Е.Соловьёв, С.Сушко. Халыкара самбо федерациясенең көмеш ордены б-н бүләкләнә.

ХӘСӘ́НОВ Мәхмүт Максуд улы (21.12.1927, Арча кантоны Югары Кибәхуҗа а. — 14.9.1990, Казан), язучы, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1977). Бөтенсоюз театр сәнгате ин-тын (ГИТИС, Мәскәү, 1949), А.М.Горький исем. әдәбият ин-ты каршындагы Югары әдәби курсларны (Мәскәү, 1957) тәмамлый. Яшь тамашачылар театрында, Татар акад. театрында актёр (1949–51), ТАССР МСның Радиофикация ком-тында (1952–55) хәбәрче булып эшли. 1959 елдан шәһәр тибындагы Азнакай посёлогында: Мәдәният йортында үзешчән сәнгать коллективына җитәкчелек итә, «Маяк» г-тасы редакциясендә сәнәгать бүлеге мөдире вазифаларын башкара (1967–80). Х. әсәрләренең геройлары — көчле рухлы, батыр һәм бурычларына тугрылыклы кешеләр. Нефтьчеләр тормышы һәм хезмәте турында «Беренче хикәяләр» (1952), «Сөмбел» (1954) хикәяләр җыентыклары; «Яңа горизонт» (1953), «Урман шаулый» (1955), «Кыюлар юлы» (1956), «Ике повесть» (1968) повестьлары; «Беренче ау» (1990) повестьлар җыентыгы; «Бораулау мастеры» (1953) очерклар җыентыгы авторы. Эшчеләр, нефтьчеләр һәм авыл халкы б-н Х. романнарының тематикасы күптөрле: авыл кешеләренә багышланган «Саф җилләр» (1964); нефть төбәгендә автострада төзүчеләр тормышын яктырткан «Юллар, юллар» (1966), «Кама таңнары» (1973; русчага тәрҗемәдә «Камские зори», 1980); нефтьчеләргә багышланган «Шөгеровлар» (1984); тарихи-революцион тема күтәрелгән «Саумы, кояш» (М., 1973; русчага тәрҗемәдә «Здравствуй, солнце!», М., 1980) романнары. Х. иҗатында күмәкләштерү һәм кулакларга каршы көрәш турындагы «Язгы аҗаган» романы (1987; русчага тәрҗемәдә «Весенняя заря - ца», 2004; ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт

бүләге, 1988) аерым урын били. «Нурихан» комедиясе (1955 тә куела), «Рамай» драмасы (1957 дә куела) Әлмәт татар драма театры сәхнәсендә күрсәтелә. Балалар өчен «Дино - заврлар өнендә» (1978), «Ут-малай» (1989) һ.б. китаплар авторы.

Әд.: Галимуллин Ф. Юл кешесе // Казан утлары. 1982. № 3; Гамбәр Н. Ул тормышны ярата иде // Казан утлары. 1997. № 12; Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

ХӘСӘ́НОВ Мөхәммәд Фәттах (псевд. Мәмәт Хәсән) (24.7.1904, Ташкент — 1937), журналист, тәр әдәбиәче. 1930 елда ВКП(б) ҮК карашындагы Югары газета курсларын (Мәскәү) тәмамлый. 1918 дән (бүленеп) Ташкентта яши. Россия телеграф агентлыгының Төркестан бүлегендә тәрҗемәче, 1922 дән «Кизил байрок» г-тасында, 1924 тән «Кизил Узбекистон» г-тасында. 1927 дә Үзбәкстан ВКП(б) ҮКның матбугат бүлеге мөдире урынбасары (Сәмәрканд ш.), 1928–30 да «Камбагал дехкон» г-тасы мөхәррире, 1933 тән «Кизил Узбекистон» г-тасы, 1936 да «Правда Востока» г-тасы мөхәррире. 1930–33 тә Мәскәүдә: «Правда» г-тасында эшли, ВКП(б) ҮКның матбугат бүлегендә партия милли матбугаты эше өчен җаваплы була. Язмалары Үзбәкстанда социализм төзүгә, мамыкчылык үсеше, беренче коммунарларга, Үзбәкстандагы милли матбугатка багышлана. В.И.Ленинның әсәрләрен үзбәк теленә тәр әмә итә. 1928 дән Үзбәкстан КП(б) ҮКның пропаганда һәм агитация бүлеге каршындагы үзбәк телендә иҗтимагый-сәяси терминология эшләү комиссиясе составына керә. Репрессия - ләнә, үлгәннән соң аклана.

Әд.: Пидаев Т. Жизнь, отданная народу // Печать Узбекстана. 1968. № 5; Ядгаров Х. Наш редактор // Правда Востока. 1968. 11 июня.

ХӘСӘ́НОВ Мөхәммәтсабир Мөхәммәт җан улы (Сабир Хәсәни) (1866 — 1924), җәмәгать эшлеклесе. Чыгышы б-н Самара губернасы Богырыслан өязе крәстияннәреннән. Уфа губернасы Бәләбәй өязенең Карач авылы мәдрәсәсендә, имам Д. әл-Казанлы мәдрәсәсендә (Оренбург губ. Троицк ш.) укый; соңгысының вафатыннан соң имам З.Рәсүлидә белем ала. «Рәсүлия» мәдрәсәсендә укыта (Троицк, 1903 елга кадәр). Уфаның 3 нче җамигъ мәчете имам-хатибы һәм мәчет каршындагы мәдрәсә мөдәррисе (1903 тән). Уфа губернасыннан 2 нче Дәүләт Думасы депутаты (1907), мөселманнар фракциясе бюросына керә. Сәяси карашлары буенча кадетлар партиясенә һәм «*Иттифакъ әл-мөслимин*»гә якын тора. Думаның «Дин тоту һәм милләт б-н бәйле сәяси һәм гражданлык хокукларын чикләүләрне гамәлдән чыгару турында - гы төп нигезләмәләр» проектын имзалаган депутатларының берсе (1907 нең мае). «Дин вә мәгыйшәт» ж-лында мөселман депутатлар эшчәнлеге турында мәкаләләр бастыра. Дума таратылганнан соң, кабат имам вазифаларын башкара. 1908 дә Оренбург Мөселман Диния нәзарәтенең «*Мәгълумате мәхкәмәи шәргыяи Ырынбургия*» ж-лының мөхәррире була (Уфа); мөселман корылтайлары идеяләрен тараткан өчен, мөхәррир вазифасыннан читләштерелә. Уфа мөселманнары хәйрия җәмгыяте әгъзасы.

Әд.: Анохина З.Н. Уральские депутаты в Государственной думе (1907–1917 гг.). Челябинск, 2009. *Р.А.Айнетдинов.*

ХӘСӘ́НОВ Нариман Мирсәет улы (24.4.1926, Чаллы ш.), педагог, пед. фән. д-ры (1986), проф.(1990), РФнең атказ. фән эшлеклесе (1996). Мәскәү ун-тын тәмамлый (1953). 1943–48 елларда Чаллы р-нының Никоновка авылында башлангыч мәктәптә, 1953–55 тә Мамадыш урта мәктәбендә укыта. 1958 дән РСФСР Мәгариф министрлыгында инспектор. 1960 тан РСФСР Мәгариф министрлыгы Милли мәктәпләр фәнни-тикшеренү ин-тының Татарстан ф-лында, 1974–2005 тә Мәскәүдә, баш фәнни-тикшеренү ин-тында (1991дән Мәгарифнең милли мәсьәләләр ин-ты), 1974–92 дән директор урынбасары, 1996- 2000 дә лаб. мөдире. Хезмәтләре милли мәктәпләрдә рус телен укыту мәсь әләләренә карый. Татар мәктәпләренең 2–4 сыйныфлары өчен рус теле дәреслекләре, методик ярдәмлекләр һәм аларга дидактик материаллар җыентыклары авторы, алар 1965–1999 да берничә тапкыр яңадан басыла. СССР ПФАнең К.Д.Ушинский исем. медале б-н һәм башка медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Вопросы обучения русскому языку в начальной татарской школе. К., 1974.

ХӘСӘ́НОВ Нурислам Габдулла улы (1.3.1941, Теләче р-ны Шәтке а.), язучы, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1992). Бөтенсоюз җиңел һәм текстиль сәнәгате ин-тын тәмамлый (Мәскәү, 1976). Казан моторлар төзү ҖБдә эшли (1960–81, бүленеп). 1981 елдан ТАССР МСның Телевидение һәм радиотапшырулар ком-тында мөхәррир, инженер, 1986 дан ТР Язучылар берлеге каршындагы матур әдәбиятны пропагандалау бюросында әдәби хезмәткәр. 1992–2001 дә «Теләче хәбәрләре» г-тасының баш мөхәррире. Әсәрләрен 1950 еллар ахырыннан бастыра башлый. «Энҗеләр балкышы» беренче хикәяләр җыентыгы (1982) яшьләр темасына багышлана. «Бәхилләрме йөрәк?» (1986; 3 басма, 2011), «Ак балык» (1988), «Тәкъдир» (1990), «Инрәү» (1998) повестьларына чынбарлык турында уйланулар хас. Россия армиясендәге башбаштаклыкларны фаш иткән «Җан авазы» повесте (2000; русчага тәрҗемәдә «Крик души», 2007) публицистик яңгырашка ия. «Хакыйкать хакы» (2005; русчага тәр әмәдә «Цена правды», 2004), «Кыя өстендә калган да...» (2010), «Золым» (2011) повестьларында көндәлек тормыш мәсь әләләре күтәрелә. Сатирик һәм юмористик әсәрләр авторы.

Әд.: Баширов Г. Яшьләргә өмет // Казан утлары. 1985. № 7; Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

ХӘСӘ́НОВ Радик Шәүкәт улы (30.7.1955, Чүпрәле р-ны Иске Шәйморза а.), хакимият-ху җалык хезмәткәре, ТРның атказ. машина төзүчесе (2000), РФнең мактаулы машина төзүчесе (2005). Казан авиация ин-тын тәмамлаганнан соң (1978), Яшел Үзән судно - лар төзү з-дында эшли: участок мастеры, башлык урынбасары, цех башлыгы. 1991 елдан Яшел Үзән пассажир автотранспорт пр-тие - се директоры. 1998 дән (бүленеп) «Серго исем. завод» ҖБ» АҖ ген. директоры. 2009–10 да Яшел Үзән р-ны башлыгы, Яшел Үзән шәһәре мәры. Х. җитәкчелегендә пр-тие реконструкцияләнә һәм яңартыла, заманча оборона продукциясе һәм суыту техникасы, ш.и. донор канын һәм аның компонентларын саклау өчен соңгысының яңа төрләрен җитештерү үзләштерелә (ТР Дәүләт бүләге, 2006). 2009 да ТР халык депутаты. Дуслык ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Яшел Үзән шәһәренең мактаулы гражданы (2005 тән). 2011 дән Россия машина төзүчеләр берлегенең Татарстан төбәк бүлеге рәисе.



Р.М. Хәсәнов.

ХӘСӘ́НОВ Рим Мәхмүт улы (9.3.1947, БАССРның Благовар р-ны Языков а.), композитор, БАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1979), БРның халык артисты (2017). 1973 елда Уфа сәнгать ин-тын (З.Исмәгыйлевтә композиция классы) тәмамлый. 1973–78 дә М.Гафури исем. Башкорт акад. драма театрының музыка бүлеге мөдире. Х. иҗатында төп урынны башкорт милли җыр иҗатын һәм заманча популяр музыка тенденцияләрен берләштергән җырлар алып тора. Аның җырлары (нигездә, башкорт һәм татар шагыйрьләре, ш.у. үз шигырьләренә иҗат ителгән 400 дән артык җыр) танылган башкаручыларның (Ә.Авзалова, Алсу, И.Газиев, Р.Гәрәев, Н.Кадыйрова, И.Шакиров һ.б.) репертуарын тәшкил итә: «Мәктәп еллары» (Ш.Галиев шигыре); «Уфа юкәләре», «Кыш - кы романс» (Н.Нәҗми шигырьләре) һ.б. Әсәрләре: «Курай турында легенда» (1979), «Салават» (1987) балетлары; «Прометей» (1980), «Сибай» (1982) симф. поэмалары; хор, камера-инструменталь әсәрләр, романслар, кино- һәм телефильмнарга, драматик спектакльләргә (70 тән артык) музыка һ.б. БАССРның Г.Сәләм исем. Комсомол бүләге лауреаты (1976). Татар акад. театрында З.Хәкимнең «Телсез Күке» әсәре буенча куелган спектакльгә язган музыкасы өчен ТРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләгенә лаек була (2009). Уфа шәһәренең мактаулы гражданы (2017).

ХӘСӘ́НОВ Ринат Радик улы (13.12.1957, Казан), геолог, геол.-минерал. фән. д-ры (2006), проф. (2008). Казан ун-тын тәмамлый (1984), шунда ук эшли, файдалы казылмалар һәм разведкалау эше каф. мөдире (2007 дән). Хезмәтләре литология, петрография, геохимия һәм металлогениягә карый. Х. Татар гөмбәзенең кристаллик нигезе токымнарында руда минералларының бүленү үзенчәлекләрен һәм типоморфизмын билгели, Идел-Урал антеклизасының үзәк өлешендә палеозой чоры күмерләре барлыкка килүнең палеогеогр. закончалыкларын һәм аның төрле формадагы руда чагылмалары б-н бәйләнешен ачыклый, күмерле формацияләрдә рудогенез моделен эшли.

Х е з м.: Основы геологии. К., 2000 (автордаш); Петрографические типы визейских углей Камского бассейна: Атлас. К., 2001 (автордаш).

ХӘСӘ́НОВ Рөстәм Шамил улы (8.3.1956, Ульянов өлкәсенең Мәләкәс ш. (хәзер Димитровград ш.), хирург-онколог, мед. фән. д-ры (2001), проф., РФА мөхбир әгъзасы (2016), ТРның, РФнең атказ. табибе (1996, 2002). ТР Дәүләт бүләге (2003), РФ Хөкүмәтенең фән һәм техника өлкәсендәге бүләге (2009) лауреаты. Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1979), Казан шәһәре 15 нче клиник хастаханәсендә эшли. 1985–2015 елларда ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының Респ-ка онкология клиник диспансеры баш табибе. Бер үк вакытта, 1999 дан, Казан мед. академиясенең онкология һәм хирургия кафедрасында, 2003 тән каф. мөдире, 2008 дән РМФА Россия онкология фәнни үзәгенең Идел буе ф-лы директоры. 2016 дан РФ Сәламәтлек саклау министрлыгының Казан мед. академиясе ректоры. Хезмәтләре яман шешләргә диагноз кую һәм авыруны дәвалау мәсь әләләренә карый. Идел буе федераль округы һәм ТРның баш онкологы (1985 тән). РФ Онкологлар ассоциациясенең идарә әгъзасы (1986 дан). Медаль белән бүләкләнә.

Х е з м.: Выявление злокачественных новообразований визуальных локализаций в амбулаторно-поликлинических учреждениях. К., 2001; Комбинированное лечение злокачественных опухолей мягких тканей туловища и конечностей. К., 2004 (автордаш); Мастопатия. К., 2006 (автордаш).

ХӘСӘ́НОВ Фәрит Мансур улы (23.12.1945, Казан), тренер (фехтование), РСФСРның атказ. тренеры (1977), халыкара категорияле судья (1993). Казан пед. ин-тының физик тәрбия ф-тын тәмамлый (1973). 1967 елдан «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятенең Татарстан советында, 1970 тән Олимпия резервындагы махсуслаштырылган 3 нче балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә тренерлык эшендә, 1976–84 тә СССР яшьләр җыелма командасында тренер. Х.та тәрбияләнүчеләр арасында — яшүсмерләр, яшьләр чемпионатларында һәм СССР, Россия, дөнья, СССР халыклары спартакиадаларында, бөтенсоюз укучылар спартакиадаларында медаль алучылар һәм чемпионнар: А.Әбделмәнов, И.Абрамов, Ю.Андреев, Ә.Баянов, А.Җаббаров, С.Маслов, Ф.Михеев, В.Осокин, А.Падеров, Р.Садыков, Д.Тимофеев, И.Шәмшетдинов. «ТАССРның иң яхшы тренеры» (1975), «ТРның иң яхшы физкультура хезмәткәре» (1976).

ХӘСӘ́НОВ Хатыйп Хөсәен улы (1916, Вятка губ., Уржум өязе Бәрәңге а., хәзер Мари Респка-сының Бәрәңге штп — 12.9.1943, Украина ССРның Сумы өлкәсе Рыльск р-ны Нехаевка а.), Сов. Союзы Герое (17.10.1943, үлгәннән соң), өлкән сержант. 1935–37 елларда һәм 1942 нең мартыннан Кызыл Армиядә. 1942 нең августыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 248 нче аерым укчы бригаданың пулемёт расчёты командиры (60 нчы армия). Воронеж һәм Үзәк фронтлар составында Воронеж-Касторная һәм Харьков һөҗүм операцияләрендә (икесе дә — 1943), Сулъяк яр Украинаны азат итүдә катнаша. 1943 нең 29 августында Прихотьково авылы (Курск өлкәсе) өчен барган сугышларда батырлык күрсәтә: рота б-н җитәкчелекне үз өстенә алып, сугышчыларны һөҗүмгә күтәрә, 1943 нең 12 сентябрендә Нехаевка авылы янында авыр яраланган Х. әсирлеккә эләгә һәм җәзаланып үтерелә. Ленин ордены, медаль б-н бүләкләнә. Йошкар-Ола шәһәрендә тимер юл вокзалында һәм Герой исеме б-н аталган урамда мемориаль такта куела. Шәһәр тибындагы Бәрәңге посёлогында бер урамга Х. исеме бирелә.



Хатыйп Х. Хәсәнов.

Әд.: Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000. *М.З.Хәбибуллин.*

ХӘСӘ́НОВ Хөсәен Хәсән улы (9.3 1907, Казан губ., Казан өязе Казанбаш а. — 5.4.1995, Казан), тарихчы, тарих фән. д-ры (1967), ТАССР, РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1977, 1977). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1941). 1930 елларда «Кызыл Татарстан» г-тасы редакциясендә эшли. 1941–43 тә Казанда ВКП(б)ның Совет район ком-тында пропагандист, 1944–47 дә ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-тында мәдәният секторы мөдире. 1950–90 да СССР ФА Казан ф-лының Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында. Хезмәтләре 1905-07 еллар рев-циясе тарихына, татар милләте формалашуы мәсь әләләренә карый. «Татар буржуаз милләте формалашу» («Формирование татарской буржуазной нации», 1977) монографиясендә ил тарих фәнендә беренче мәртәбә татарларда капиталистик мөнәсәбәтләр үсешенең төп этаплары, татар милләте формалашуның үзенчәлекләре һәм этаплары үзара бәйләнештә карала, милләтнең төп билгеләре (терр-я, тел, икътисад, милли мәдәният һәм психология) оешу процессы күрсәтелә. «Революционер-интернационалист: Большевик Хөсәен Ямашевның тормышы һәм эшчәнлеге» («Революционер-интернационалист: Жизнь и деятельность большевика Хусаина Ямашева», 1971) монографиясе өчен ТАССР Журналистлар берлегенең Х.Ямашев исем. Респ-ка бүләгенә лаек була.

Х е з м.: Революция 1905–1907 гг. в Татарии. М., 1965; Большевистская газета «Урал». К.,1967; Казань в годы первого штурма царизма. К., 1985; Садык Сагеев. К., 1987.

ХӘСӘ́НОВ Чулпан Гомәр улы (1.1.1939, Буа р-ны Зур Кырлаңгы а. — 7.12.1997, Казан), вет. эпизоотологы, вет. фән. д-ры (1986), проф. (1991), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1994). Казан вет. ин-тын (хәзер Казан вет. медицинасы академиясе) тәмамлаганнан соң (1966), шунда ук эшли: эпизоотология, аэрозольләр лаб-яләре, микроорганизмнар штаммнары музее мөдире. Хезмәтләре гомуми эпизоотологиягә, аэрозоль иммунизациясенә, дезинфекцияләүгә, йогышлы авыруларга (тилчә, Ауэски авыруы, туберкулёз, бруцеллёз, түләмә һ.б.) каршы көрәш ысулларына карый. Уйлап табуга 4 патенты, 12 авторлык таныклыгы бар. 1986–88 елларда Чернобыль АЭС һәлакәте нәтиҗәләренә карашы көрәш чараларында катнаша. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Групповая профилактика инфекционных болезней животных. М., 1983 (автордаш).

Әд.: Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.): Биогр. словарь учёных. К., 2006.

ХӘСӘ́НОВ Шәүкәт Гариф улы (14.5.1920, Буа кантоны Яңа Тинчәле а. — 5.4.1986, шунда ук), а.х. пр-тиесе җитәкчесе. 1944–58 елларда хезмәт ияләре депутатларының Будённый район советы башкарма ком-тында эшли: социаль тәэминат бүлеге хезмәткәре, район башкарма ком-ты рәисе урынбасары. 1959–60 та Буа р-нының «Искра» к-зы партоешмасы секретаре, 1960–76 да рәисе. Х. җитәкчелегендә колхоз респ-када алдынгы хуҗалыкка әверелә. 1973 тә бөртекле культураларның уңышы 1 *га* дан 30,4 *ц*, бәрәңгенеке — 209 *ц*, чөгендернеке 347 *ц* тәшкил итә. Уртача еллык савым һәр сыердан 3000 *кг* нан арта. Совет-фин һәм Бөек Ватан сугышларында катнаша. Ленин ордены, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

ХӘСӘ́НОВА Асия Фәрит кызы (23.8.1912, Бологое а., хәзер Тверь өлкәсендәге ш. — 2.11.2009, Харьков ш., Казанда җирләнә), журналист, ТАССРның һәм РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1966,1973). Казан химия-технол. ин-тын (1937), КПСС ҮК каршындагы Үзәк газета курсларын (1945) тәмамлый. 1937–57 елларда Татарстан китап нәшриятында бүлек башлыгы, фәнни-техник әдәбият редакциясе мөдире булып эшли. «Азат хатын» хатын-кызлар ж-лы мөхәррире (1957–77). Иҗтимагый-сәяси, социаль-мәдәни проблемаларга, татар әдәбияты үсеше, журналист осталыгы мәсь әләләренә багышланган аналитик язмалар, рецензияләр, мәкаләләр, очерклар авторы. Язмалары респ-ка, бөтенсоюз һәм чит ил газета-журналларында басыла. 7–10 сыйныфлар өчен химия дәреслекләрен татар теленә тәрҗемә итә. ТАССР Журналистлар берлеге идарәсе рәисе урынбасары (1958–62), респ-ка хатын-кызлар ком-ты әгъзасы (1958–77). 2004 тән Харьков шәһәрендә яши. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Өегез ямьле булсын. К., 1976; Синең юлдашың. К., 1983.

Әд.: Бәдретдинова Ф. Асия Фәридовна // Сөембикә. 2002. № 8.

ХӘСӘ́НОВА Асия Шамил кызы (11.4.1954, БАССРның Эстәрлетамак ш.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1999), проф. (2000), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2004). Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлаганнан соң (1976), шунда ук эшли. 1978 елдан Казан химия-технол. ин-тында, 1983 тән Кама политехник ин-тында. 1986–98 дә Казан архит-ра-төзелеш академиясендә. 1998 дән Казан техник ун-тында: икътисад теориясе һәм хокукы каф. мөдире (2000 нән), проректор (2003 тән); бер үк вакытта, 2009 дан, ун-т каршындагы Бизнес һәм инновацион технологияләр ин-ты директоры. Хезмәтләре базар икътисады һәм трансформацияле икътисад шартларында көндәшлек мөнәсәбәтләре системасын үстерү мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Конкурентные отношения и их трансформация в рыночной экономике. К., 1998; Экономическая теория: Учеб. пособие. К., 2004 (автордаш); Основы экономической теории человеческого капитала: методологические и институционные аспекты. К., 2007 (автордаш).

ХӘСӘ́НОВА Галия Булат кызы (4.8.1958, Казакъстан ССРның Кустанай ш.), педагог, пед. фән. д-ры (2005), проф. (2010). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1982), Гамәли оптика ин-тында (Казан) эшли. 1995 елдан Казан технол. ун-тының гуманитар белем бирү кафедрасында, 1998 дән социаль эшләр, пед. һәм психол. кафедрасында. Хезмәтләре социаль хезмәткәрләр әзерләү мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Антропологизация профессиональной подготовки специалистов социальной работы. К., 2004; Профессионализм специалиста социальной работы: компетентностный подход. К., 2008.

ХӘСӘ́НОВА Гөлнара Фатыйх кызы (22.8.1962, Казан), педагог, пед. фән. д-ры (1999), проф. (1999). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1983), ПФАнең Профтехпедагогика ин-тында (хәзер РМАнең Һөнәри белем бирү пед. һәм психол. ин-ты), 1995 елдан Казан технол. ун-тының югары һөнәри белем бирү педагогикасы һәм методикасы кафедрасында. Хезмәтләре мәгариф системасында милли үзаңны формалаштыру мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Без догм и стереотипов: Новый подход к общественно-гуманитарному образованию. К., 1993; О подходах к сексуальному просвещению детей в Европе // Дошкольное воспитание. 2015. Вып. 6.

ХӘСӘ́НОВА Динә Рөстәм кызы (13.4.1955, Казан), невропатолог, мед. фән. д-ры (1999), проф. (2000), ТРның атказ. табибе (2010), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2016). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1978), Респ-ка клиник хастаханәсендә табиб-невропатолог булып эшли. 1981 елдан Казан мед. ин-тының неврология кафедрасында, 2000 нән мед. генетикасы курсы булган неврология каф. профессоры, бер үк вакытта Төбәкара клиник диагностика үзәгенең (Казан) неврология бүлеге мөдире, ген. директоры урынбасары, Респ-ка баш кан тамырлары үзәге җитәкчесе. Хезмәтләре вегетатив нерв системасы авыруларын (балалар һәм яшүсмерләр дисфункцияләрен) дәвалауга карый.

Х е з м.: Эхоэнцефалографические показатели у здоровых детей в возрастном аспекте // Журн. невропатология и психиатрия. 1983. Вып. 8 (автордаш); Генетические и функциональные факторы в развитии когнитивных нарушений при артериальной гипертензии (проспективное исследование) // Неврология. Нейропсихиатрия. Психосоматика. 2016. Т. 8, № 4 (автордаш).

ХӘСӘ́НОВА Миләүшә Ильяс кызы (11.11.1960, Казан), табиб-терапевт, мед. фән. канд (1999), ТРның Фән һәм техника өлкәсендәге Дәүләт бүләге лауреаты (2016). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1984), Казан шәһәре 1 нче хастаханәсендә эшли, 1985–88 елларда Мәслим Үзәк район хастаханәсе табиб-терапевты, 1988–92 дә Казан ГИДУВында, 1992–93 тә Респ-ка клиник хастаханәсендә табиб-аллерголог. 1993–2000 дә Казан мед. ин-тының клиник иммунология һәм аллергология кафедрасы ассистенты, 2003 тән Казан мед. академиясенең урология һәм нефрология кафедрасында. Фәнни тикшеренүләре нефрология, трансплантология, иммунология өлкәсенә карый. Уку әсбаплары авторы. Дәүләт бүләге «Бәвел юллары системасында тайпылышлар булган авыруларны дәвалауда яңа технологияләр эшләү һәм кулланута кертү» хезмәте өчен бирелә.

Х е з м.: Иммунологические методы исследования в лабораторной диагностике гломерулонефритов. Учебное пособие. К., 2004; Организация динамического наблюдения реципиентов почки в регионе. Общественное здоровье и здравоохранение. 2008. № 1 (автордаш); Диабетическая нефропатия. Учебное пособие. К., 2010; Assesment of intensity of pain syndrome in patients with secondary hyperparathyroidism on program hemodialysis. Abstracts. ISN's World Congress of Nephrology. 2015 (автордаш).

ХӘСӘ́НОВА Нурзидә Харис кызы (20.5.1924, Семипалатинск ш. — 17.11.2015, Казан), офтальмолог, мед. фән. д-ры (1971), проф. (1971), ТРның атказ. табибе (1985). Кыргыз мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1948), шунда үк, күз авырулары кафедрасында эшли. 1952 елдан 1 нче Мәскәү, Кыргыз (1955 тән) мед. ин-тларының күз авырулары кафедраларында. 1966 дан Казан мед. ин-тының күз авырулары кафедрасында, 1975–90 да каф. мөдире, 1990 нан каф. профессоры. Хезмәтләре глаукоманың барышы, авыруга иртә сроклларда диагноз кую, аның төрле формаларын дәвалау һәм кисәтүгә карый. Аккомодация һәм фузия тайпылышларын дәвалау приборы авторы. Уйлап табуга 3 патенты бар. Респ-ка офтальмологлар җәмгыяте рәисе (1980–2003).

Х е з м.: Флюоресцентная ангиография сетчатки при высокой близорукости // Вестн. офтальмологии. 1975. № 1; Определение толерантного давления для ранней диагностики и выбора тактики лечения больных глаукомой // Казан. мед. журн. 1987. № 6.

Әд.: Казанский государственный медицинский университет (1804–2004)гг.: Заведующие кафедрами и профессора: Биогр. словарь. К., 2004.

ХӘСӘ́НОВА Флюра Ибраһим кызы (18.3.1947, Үзбәкстан ССРның Чирчик ш.), пианист, педагог, ТРның халык артисты (2000), проф. (2001). Казан консерваториясен (Э.Монасзон классы) тәмамлый (1971). 1973 елдан Казан консерваториясендә укыта. Илебездә һәм чит илләрдә солист (60 тан артык программа), ансамблист һәм концертмейстер буларак концерт эшчәнлеге алып бара; Н.Рахлин, Ф.Мансуров, В.Дударова, Р.Салаватов һ.б. җитәкчелегендәге симф. оркестрлар б-н чыгыш ясый. Зур репертуарга (И.С.Бах, В.А.Моцарт, Ф.Шуберт, П.Чайковский, А.Скрябин, С.Рахманинов, С.Прокофьев һ.б.) ия. Татарстан композиторлары музыкасын актив пропагандалый: әсәрләрне беренче булып башкара, телевизион концерт-әңгәмәләр циклы алып бара, радио һәм телевидение фондлары өчен язмалар әзерли, Н.Җиһанов, Ф.Яруллин, А.Ключарёв һ.б.ның балет номерларын фортепиано концертлары өчен эшкәртә; фортепиано өчен язылган әсәрләрнең (Р.Яхин, Р.Еникиев, А.Луппов, А.Миргородский, Л.Любовский һ.б.) басмаларын төзүче һәм мөхәррире; респ-ка композиторлары һәм музыкант-баш-



Ф.И. Хәсәнова.

каручыларына (Р.Белялов, Э.Монасзон, И.Дубинина, Н.Фомина һ.б.) багышланган мәкаләләр, «Рөстәм Яхин замандашлары истәлекләрендә» («Рустем Яхин в воспоминаниях современников». К., 1996) җыентыгы авторы. Укучылары арасында халыкара һәм бөтенроссия конкурслары лауреатлары һәм дипломантлары бар.

В.М.Спиридонова.

ХӘСӘ́НОВА Эльвира Рамил кызы (28.3.1981, Мәскәү), спортчы (синхрон йөзү), Россиянең атказ. спорт остасы (2002). Россия физик культура ун-тын (2005), Эшкуарлык һәм хокук ин-тын (Мәскәү, 2009) тәмамлый. Спорт б-н 1988 елда «Олимпия» спорт комлексында (Мәскәү, тренерлары — Э.И.Шәриб җанова, О.Ю.Кузнецова, Т.Н.Покровская) шөгыльләнә башлый. 1999–2012 дә Россия җыелма командасында.

1999 дан Җыелма командаларны спортча әзерләү үзәгендә спортчы-инструктор (Мәскәү). 2005–12 дә шәһәр «Динамо» физкультура-спорт җәмгыятендә чыгыш ясый. Европа (2002, 2004, 2006, 2010), дөнья (2001,2003, 2005, 2007, 2011) чемпионатларында, Олимпия уеннарында төркемле күнегүләрдә (2004, 2008, 2012) җиңүче. Дөнья кубогы (2002) иясе, Европа 2001 (көмеш, дуэтта), 2003 (төркемле күнегүләрдә) медальләр алучы. Дуслык, Почёт, 4 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

ХӘСӘНША́ авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 26 *км* төньяк-көнбатыштарак, Ушма елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 91 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1923 тә нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Мамадыш кантоны Мамадыш волостена керә. 1930 ның 10 августыннан Мамадыш р-нында. Халык саны: 1926 да — 286, 1938 дә — 337, 1949 да — 300, 1958 дә — 233, 1970 тә — 279, 1979 да — 267, 1989 да — 146, 2002 дә — 99 кеше.

ХӘСӘНШӘ́ЕХ авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 35 *км* төньяктарак, Шушма елгасы буенда. 2010 елда 620 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1678 елдан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Янчиково, Яншиково, Хасанчик буларак та билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, лашманчы хезмәтен үти; игенчелек, терлекчелек, умартачылык, чыпта сугу, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 3 мәчет, 2 мәдрәсә, су тегермәне, тимерче алачыгы, чүлмәк ясау йорты, 8 вак-төяклэр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2697 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан гу-



М.Р. Хәсәншин.



Г.Х. Хәсәншина.



М.Б. Хәстиев.



Ф.Ш. Хәсьянова.

бернасының Казан өязе Балтач волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән Арча р-нында. Халык саны: 1678 дә — 31, 1716 да — 81, 1745 тә — 140, 1763 тә — 244 ир-ат; 1795 тә — 650, 1859 да — 1289, 1897 дә — 1556, 1908 дә — 1765, 1914 тә — 1722, 1920 дә — 1616, 1926 да — 1534, 1938 дә — 1265, 1958 дә — 775, 1970 тә — 858, 1979 да — 749, 1989 да — 605, 2002 дә — 604 кеше.

Әд.: З ы я т д и н о в Б. Рәхмәт си ңа, Хәсәншәех! К., 2006.

ХӘСӘ́НШИН Гафур Шәйхулла улы (6.5.1959, Теләче р-ны Иске Җөри а.), галим агроном, а.х. пр-тиесе җитәкчесе, а.х. фән. канд. (2005), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2006), ТРның атказ. а.х. хезмәткәре (2003). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1981), «Әсәнбаш» к-зында агроном-орлыкчылык белгече, баш агроном (1985 елдан) булып эшли. 1987 дән Кукмара р-нының «Нырты» с-зында директор, 1992 дән директор урынбасары. 1994 тән Саба р-нында: совхоз директоры, «Саба» күмәк пр-тие рәисе (1999 дан), район а.х. һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (2000 нән). Дәүләт бүләге ТРда игенчелекнең биол. факторлары нигезендә ресурс саклау технологияләрен эшләүдә һәм бөртекле ашлык җитештерүгә кертүдә катнашканы өчен бирелә.

Х е з м.: Опыт практического внедерения ресурсосберегающих технологий // Слагаемые эффективного агробизнеса: обобщение опыта и рекомендации. К., 2005.

ХӘСӘ́НШИН Мансур Рәхип улы (12.12.1923, Ростов-Дон ш. — 13.4.1975, Көньяк Сахалинск ш.), Сов. Союзы Герое (3.6.1944), гв. өлкән лейтенанты. Смоленск артиллерия уч-щесен (1942), офицерлар югары артиллерия мәктәбен (Мәскәү, 1945) тәмамлый. 1941 елның мартыннан Кызыл Армиядә. 1942 нең ноябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 9 нчы гв. механикалаштырылган бригадасының миномёт ротасы командиры (47 нче армиянең 3 нче гв. механикалаштырылган корпусы). Көнбатыш, Көньяк-Көнбатыш, Сталинград, Воронеж, 1 нче Украина, 3 нче Белоруссия һәм 1 нче Балтыйк буе фронтлары гаскәрләре составында Сталинград (1942–43), Курск (1943) сугышларында, Сулъяк яр Украинаны азат итүдә (1943), Балтыйк буе һөҗүм операциясендә (1944) катнаша. 1943 нең сентябрь ахыры — октябрь башында Селище авылы янында (Черкасск өлкәсе Канев р-ны) плацдарм - ны яулаганда батырлык күрсәтә: 30 сентябрьдә Х. җитәкчелегендәге рота беренчеләрдән булып кул астындагы чараларны файдаланып Днепр елгасын кичеп чыга һәм сугышка керә. 2 октябрьдә контрһөҗүмнәрне кире кайтарганда рота өч тапкыр кул сугышына күтәрелә, 3 көн дәвам иткән сугышта немец - ларның 23 һөҗүмен кире кайтара. Сугыштан соң запаска чыгарыла, Чукотка милли округында, Ростов-Донда, 1960 тан механи - калаштырылган «Дальэнергострой» (Южно-Сахалинск) колоннасында эшли. Мәскәүдә Җиңү Парадында катнаша (1945 нең 24 июне). Ленин ордены, Кызыл Байрак, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.
М.З.Хәбибуллин.

ХӘСӘ́НШИНА Газыйфа Хәсән кызы (25.1.1915, Чистай р-ны Наратъелга а. — 20.10.1986, Азнакай), акушер-гинеколог, ТАССРның атказ. табибе (1966), Соц. Хезмәт Герое (1969). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1936), Азнакай р-ны Сәпәй участок хастаханәсендә хатын-кызлар һәм балалар консультациясе мөдире. 1945–47 елларда Көньяк Сахалин терр-ясендә яши. 1947 дән Азнакай р-нында: Сәпәй авылы участок хастаханәсе табибе, район хастаханәсенең бала тудыру бүлеге мөдире (1954–70), Үзәк район хастаханәсе акушер-гинекологы (1970–72). Ленин ордены, медаль, ТАССР ЮС Мактау грамотасы б-н бүләкләнә. Х. исеме Азнакай шәһәренең бер урамына бирелә. Ул яшәгән йортка мемориаль такта куела (1997).

Әд.: Герой Социалистического Труда Газифа Хасановна Хасаншина // Казан. мед. журн. 1969. № 3.

ХӘСИТӘ, Идел буе -Урал алды татарларында хатын-кызларның бәйләвеч тибындагы күкрәк бизәмәсе. Астына катыргы куелган, хордасы озынлыгы 30–35 *см* булган һәм киң-



Хәситә – хатын-кызның күкрәк бизәмәсе. Тукыма, зәркән аеллар, асылташлар, ярымасылташлар. 19 йөз. ТР Милли музее.

леге 5–10 *см* лы сегмент рәвешендәге тукыма кисәгеннән гыйбарәт. Тукыма буйның очларына җилкәне иңләгән һәм култык астында яки иңбашта эләктерелгән тар каптырма тегелгән. Кайбер чакларда ике буйны да бөжра итеп тегеп, баш яки сул иңбаш аша уң кул астына кигәннәр. Х.нең тышкы ягына төрле аеллар, көмеш тәңкәләр, кыйммәтле ташлар, сәдәфләр һәм бөти буларак кулланылган предметлар тагылган. Керәшеннәрдә тәңкәләр б-н генә бизәлгән бәйләвечләр гамәлдә булган (локаль атамалары дәвәт яки муйтомар). Мөселман татарлар Х.гә еш кына «бөти» — кечкенә Коръ ән яки дога текстлары өчен тукыма яисә металл савыт-текәннәр. Үзара күгән б-н беркетелгән бер үк төрле формадагы аел-тәңкәләрдән торган чылбыр рәвешендәге Х.ләр заказ буенча зәркәнче осталар тарафыннан эшләнгән. Казан татарларында хатын-кызлар арасында 20 йөз башына кадәр киң таралган.

Әд.: Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967; С у с л о в а С.В. Женские украшения Казанских татар середины XIX — начала XX вв.: Ист.-этногр. исслед. М., 1980; ш у л у к. Одежда // Татары. М., 2001.

ХӘСТИ́ЕВ Мирбат Бәдри улы (7.7.1927, Арча кантоны Казанбаш а. — 14.7.2000, шунда ук), а.х. пр-тиесе җитәкчесе. Соц. Хезмәт Герое (1984). ТАССР А.х. министрлыгының колхоз рәисләрен әзерләү буенча Татарстан урта а.х. мәктәбен (1953), Казан а.х. ин-тын (1969) тәмамлый. 1941–86 елларда Арча р-нының «Известия» к-зында эшли, рәисе (1953 тән). 1986 да 1953 ел күрсәткечләре б-н чагыштырганда бөртекле культураларның уңышы 6,2 тапкыр, бәрәңге — 37, тамыразыклар — 5,5, яшел масса өчен кукуруз — 6,2 тапкыр арта; уртача еллык савым һәр сыердан 1,9 тапкыр, һәр сарыктан йон алу — 2,3, мөгезле эре терлекнең артымы — 3,3, тулай продукциянең бәясе — 7, товар продукциясенең бәясе — 13,9 тапкыр арта. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: Герои Социалистического Труда и Полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.
И.Н.Афанасьев.

ХӘСЬЯ́НОВА Фәридә Шаһимәрдан кызы (11.12.1952, Казан), график, нәкышьче, ТР атказ. сәнгать эшлеклесе (1999), ТР халык рәссамы (2008). Казан сынлы сәнгать уч-щесен тәмамлый (1973). 1973 елдан Татарстан сәнгать фондында, 1984 тән Татарстан китап нәшриятында, баш рәссам (1987–91). 2994–2005 тә «Идел» ж-лында баш рәссам. Рәссамнар берлеге әгъзасы (1994). Китап иллюстрацияләре остасы. Балалар китабын иллюстрацияләүгә зур өлеш кертә: 60 тан артык китап бизи, шуларның 40 ка якыны балалар өчен. Образларның ачыклыгы, форма һәм колоритның декоративлыгы б-н аерылып торган станлы графика (пастель, акварель, гуашь, тушь), көнкүреш жанрындагы картиналар (майлы буяу), натюрморт, портретлар авторы. Х. татар халык гамәли сәнгате традицияләрен стильләштереп тәкъдим итә — «Ак бүре» татар халык әкиятенә (1993), инглиз (2002) һәм татар (сувенир басма, 2007) телләрендә «Татар халык әкиятләре», Ф.Әмир-



Ф.Ш.Хәсьянова. «Туй». «Гомернең дүрт фасылы» сериясеннән. 2000.

ханның «Хәят» повестена (1985), Себер татарларының «Агыйделкәй» халык җыры җыентыгына (1988, Мәскәүдә бөтенсоюз «Китап сәнгате» күргәзмәсендә диплом ала) иллюстрацияләр. Х. ясаган иллюстрацияләр б-н Татарстан китап нәшриятында басылган китаплар: А.Алишның «Кем иң көчле?» (1985), Ф.Кәримнең «Гармунчы Аю белән җырчы Маймыл» (1988), Н.Исәнбәтнең «Мыраужан мажаралары», Р.Батулланың «Бишек әкиятләре», М.Фәйзуллинның «Салават күпере» (барысы да — 1989), Р.Корбанның «Капкорсак» (1992), Р.Харис «Лап-лап» (1992), «Әбәк» (2001), «Матур өй» (2003), Р.Миңнуллинның «Күчтәнәч» (1995), Ш.Галиевнең «Көләч көзге» (1998; инглиз теленә тәрҗемәсе — 2002), Ж.Сөләймановның «Шәмәхә Дзән» (2002) һ.б. Х. уку әсбапларын да бизи һәм иллюстрацияли: «Әлифба» (1994), 2 нче, 3 нче (1993) һәм 4 нче (1994) сыйныфлар өчен «Татар теле», «Рәсемле русча-татарча-инглизчә сүзлек» (1996), балалар бакчаларында тәрбияләнүчеләр өчен «Алтын ачкыч» (2000) хрестоматиясе. Станлы графика өлкәсендә дә нәтиҗәле эшли, Ә.Фәйзинең «Г.Тукай» (1979), Г.Тукайның «Кисекбаш» (1986), «Ак бүре» триптихы (1999, ТР Мәдәният министрлыгының Б.Урманче исем. бүләге), «Гомернең дүрт фасылы» (2000) сериясе, «Татар җырлары» (2007) циклы һ.б. Алар образлар эзтәлеклелеле, формаларның җентекле эшләнеше ягыннан аерылып тора. «Казан ишегалды» (1976), «Тукайга багышлау. «Туган тел» җыры» (2012) картиналары, натюрмортлар сериясе (1995–2013) авторы.



Ф.Ш.Хәсьянова. Р.Харисның «Матур өй» поэмасына иллюстрация. Кәгазь. Акварель. 2003.

1973 тән респ-ка, «Зур Идел» (1979 дан), 16 автономияле респ-ка рәссамнары (Мәскәү, 1988), «Совет Россиясе» (Мәскәү, 1976, 1985) күргәзмәләрендә, «Китап сәнгате» күргәзмә-конкурсында, халыкара — «Төрки дөнья: мәдәният һәм сәнгать» (Әнкара, 2000), ТЮРКСОЙ (Истанбул, 2010) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре 1992, 1995 (А.Тимергалина һәм Н.Кумысникова б-н бергә), 2001, 2002, 2007, 2008, 2010, 2011, 2012–13, 2017, 2018 дә Казанда, 2006 да Висагинас шәһәрендә (Литва) уздырыла.

Картиналары Көнчыгыш халыклары сәнгате музеенда (Мәскәү), ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, «Казан» милли мәдәният үзәге музеенда, Тукай-Кырлай авылында Г.Тукай музеенда, шәхси тупланмаларда саклана.



Ф.Ш.Хәсьянова. «Болгар кувшины белән натюрморт». «Татар сөлгесе» сериясеннән. 2013.

Әд.: Тимбикова К. Шагыйрь йөргән юлардан // Азат хатын. 1985. № 4; Улемнова О. Нәфислек // Сөембикә. 2003. № 3; Саттарова Л. Фарида Хасьянова // Идель. 1992. № 3/4; Ильина М. «Считаю время по минутам» // Идель. 2002. № 11; Валеева-Сулейманова Г.Ф. Фарида Хасьянова. Подлинный мир сказки // Казань. 2008. № 11.

ХӘТӘНИ́, к. *Билла, Боксу һәм Хәтәни.*

«ХӘТЕ́Р КИТАБЫ́», редакция. 1990 елның гыйнварында Казанда ТР Министрлар Кабинеты каршында КПССның Татарстан респ-ка ком-ты карары буенча оештырыла. 2010 нан ТР Мәдәният министрлыгы карамагында. Редакция коллегиясе рәисләре — Р.Р.Идиятуллин (1990–99), И.К.Хәйруллин (2000–01), З.Р.Вәлиева (2001 дән), баш мөхәррирләре — А.А.*Иванов* (1990–2015), Р.М.*Вәлиев* (2015 тән). Төп максаты — Татарстанда туып, Бөек Ватан сугышы кырларында, аннан соңгы унъеллыкларда «кайнар нокталарда» һәлак булганнар һәм хәбәрсез югалганнар; ш.у. Совет хакимияте елларында сәяси һәм адм. репрессияләр корбаннары хакында татар һәм рус телләрендә «*Хәтер–Память*» күптомлы басмасын чыгару. Һәлак булган, хәбәрсез югалган, әсирлектә һәм госпитальләрдә үлгән 350 меңнән артык солдат һәм офицер турында мәгълүмат тупланган. Киңрлек эшчәнлегеннән тыш зур тикшеренү эше алып барыла. 1990 нан редакция, «Кар десанты», ТРның «Ватан» берләшмәсе» иҗтимагый яшьләр оешмасы һәм Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы б-н берлектә, һәлак булган якташлар турында мәгълүматлар җыю, хәбәрсез югалган дип исәпләнгән солдат гаиләләренә аларның һәлак булу датасы һәм урыны күрсәтелгән белешмәләр тапшыру өчен респ-ка рай-оннары буйлап Хәтер маршы оештыра. Серләре ачылган документлар нигезендә редакция хезмәткәрләре тарафыннан чыгышлары б-н Татарстаннан булган элеккеге хәрби әсирләр турында мәгълүматлар табыла. Сәяси репрессияләр корбаннары исемлегенә 50,5 меңгә якын, күмәкләштерү елларында адм. тәртиптә сәяси репрессияләргә дучар ителгәннәр исемлегенә — 15 мең гаилә кертелгән (гаилә әгъзаларының саны якынча 90 мең кеше) (к. *Кулакларны йорт-җирләреннән куу*). «Сәяси репрессияләр корбаннарының Хәтер Китабы»ның («Книга Памяти жертв политических репрессий») 27 томы (2000–14) басылып чыга. «Х.К.» тарафыннан «Әфганстандагы сугыш корбаннары Хәтер Китабы» («Книга Памяти жертв войны в Афганистане», 1999); «Оныклар каһарман бабалары турында» («Внуки о дедах-героях», 2000); «Татарстан Бөек Ватан сугышы елларында (1941–1945 еллар)» («Татарстан в годы Великой Отечественной войны (1941–1945 гг.)», 2000; 2 басма 2009) «Социалистик Хезмәт Геройлары һәм Хезмәт Даны орденының тулы кавалерлары — безнең якташларыбыз» («Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки», 2003); «Дан орденының тулы кавалерлары» («Кавалеры ордена Славы трёх степеней», 2005); «Казанлылар — Җиңүгә. Вахитов районы» («Казанцы — Победе. Вахитовский район», 2005); «Татарстан — Сталинградка» («Татарстан — Сталинграду», 2009); «Чернобыль атом электр станциясендәге һәлакәт нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучыларның Хәтер Китабы» («Книга Памяти участников ликвидации катастрофы на Чернобыльской АЭС», 2011), «Россия Федерациясе Геройлары» («Герои Российской Федерации», 2012), «Биографик сүзлек: 1979–1989 елларда Әфганстандагы сугышчан хәрәкәтләр ветераннары Хәтер Китабы» («Биографический словарь: Книга Памяти ветеранов боевых действий в Афганистане (1979–1989)», 2018) китаплары әзерләнә һәм басылып чыга. 2005 тән редакция һәр район буенча сугыштан исән кайтканнар хакындагы мәгълүматларны эченә алган «Алар илгә Җиңү алып кайтты» («Они вернулись с Победой») сериясен бастыруга керешә (2005–19 елларда барлыгы 46 том дөнья күрә, эш дәвам итә). 2015 тән тыл хезмәтчәннәренә багышланган «Татарстан Республикасы тыл геройлары» («Герои тыла Республики Татарстан») күптомлыгы әзерләнеп бастырыла башлый.

Р.Р.Сәләхиев.

«ХӘТЕ́Р–ПА́МЯТЬ», Татарстанда туган һәм яшәгән, Икенче бөтендөнья сугышы елларында һәлак булган һәм хәбәрсез югалган кешеләрнең исемлекләрен туплаган тарихи-мемориаль басма. «*Хәтер Китабы*» редакциясе тарафыннан чыгарыла. Бөтенсоюз Хәтер

Китабы чыгару турында КПСС ҮК карары 1989 елның 17 гыйнварында 1941–45 тә Бөек Ватан сугышында һәлак булган совет граждannары истәлеген мәңгеләштерү максатында кабул ителә. 1993 нең 18 маенда ТР Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы «Хәтер Китабы»н әзерләү турында» карары басылып чыга, анда: «Хәтер Китабын әзерләү һәм бастырып чыгаруны Татарстан Республикасының социаль, милли-мәдәни үсеше дәүләт программасының составөлеше дип санарга», — диелә. Китап материаллары респ-каның район хәрби комиссариатлары, ТРның тарихи-сәяси документлар үзәк дәүләт архивы, РФ Оборона министрлыгының Үзәк архивы, аның Хәрби-мед. документлары филиалы һ.б. картотекалары мәгълүматларына нигезләнә. Китап районлап чыгарыла; һәр томда һәлак булучылар исемлеге татар һәм рус телләрендә китерелә. Һәлак булучының фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы һәм урыны, хәрби комис-т исеме, хәрби дәрәҗәсе, хәрби часте, үлгән вакыты һәм урыны (җирләнгән урыны), яралардан үлүчеләрнең ш.у. госпиталь яисә медсанбат номеры күрсәтелә. 1993–2010 да 350 меңнән артык якташлар исемнәрен эченә алган 28 том (гомуми тираж 110 мең данәдән артык) дөнья күрә. Баш мөхәррире — А.А.*Иванов*. Басма ТР Дәүләт бүләгенә лаек була (2000).

Әд.: Иванов А.А. Памяти павших посвящается // Науч. Татарстан. 1995. № 2; Иванов А.А. Поиск длиною в двадцать лет // Увековечение исторической памяти народов Татарстана: Материалы респ. науч.-практ. конф. (18 февр. 2011 г.). К., 2011. *Р.Р.Сәләхиев.*

ХӘТНӨ́, Көнбатыш Кама алдындагы елга, Шушма елгасының (Вятка елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 16,3 *км*. Бассейнының мәйданы 107,7 *км*². Елга башы Арча р-ны Акчишмә авылыннан көнбатыштарак, тамагы Балтач р-ны Таузар авылының көнчыгыш чигендә. Елга башының абс. биеклеге 170 *м*, тамагыныкы — 90 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 40%. Х.нең 1,2 *км* дан 4,4 *км* га кадәр озынлыктагы 5 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 31 *км/км*². Туенуы катнаш, дүрттән өч өлеше кар сулары исәбенә туры килә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1,1–3 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 131 *мм*, ташу агымы катламы 100 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ункөнлегендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,115 *м*³/*с*. Суы язын чагыштырмача каты (12–20 *мг-экв/л*). Гомуми минераль-ләшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*.

ХӘТНӨ́ авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 27 *км* төньяктарак, Хәтнә елгасы буенда. 2010 елда 11 кеше (руслар, татарлар) яши. 19 йөз башында алпавыт П.А.Перцев нигез сала. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Петропавловский, Урус-Баклауш, Аркадия буларак та билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстиянәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, киндер туку б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Петропавел чиркәве (1830 да төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1870 тә ачыла), хастаханә, араклы һәм кирпеч з-длары, 3 вак-төякләр кибете була; сишәмбе базары эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 535,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Яңа Кишет волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Арча, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Юл, 1956 ның 18 июленнән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән Арча р-нында. Халык саны: 1859 да — 348, 1897 дә — 541, 1908 дә — 485, 1920 дә — 545, 1926 да — 728, 1938 дә — 504, 1949 да — 261, 1958 дә — 377, 1970 тә — 283, 1979 да — 96, 1989 да — 37, 2002 дә — 11 кеше.

ХӘЙ́ЛИН Сәгыйд (Сәет) (18 йөз), Каргалы бистәсенә нигез салучы. Казан губернасының Мәмәт Пустоше авылы (хәзер Саба р-нының Байлар Сабасы а.) крәстияне. 1740 елларда Казан губернасы татарларыннан беренчеләрдән булып хакимиятнең Оренбург краена «килергә, төпләнергә, яшәргә, сәүдә итәргә һәм төрле кәсепләр белән шөгыльләнергә» чакыруына кушыла. П.И.Рычков хәбәр итүенчә, Х. хакимияткә күченүчеләрне Казан губернасының «сәүдә эшендәге хәлле татарлары» арасыннан «эзләп табарга» вәгъдә итә. Алар өчен Оренбургтан 18 чакрым ераклыкта Каргалы елгасы буенда җир бүлеп бирелә, 1744 тә шунда башта Сәет бистәсе дип аталган (Х. исеме буенча) торулык нигезләнә; соңыннан ул Россия б-н Урта Азия арасындагы транзит сәүдә үзәгенә әверелә. Х. үтенече буенча күченүчеләр рекрутлык бурычыннан азат ителәләр, аларга мәчет төзү хокукы бирелә. Х. старшина булып билгеләнә һәм бистә б-н идарә итә. Ш.у.к. *Каргалы бистәсе*.

Әд.: Рычков П.И. Топография Оренбургской губернии. Оренбург, 1887; Искандаров Р., Искандаров А. Сеитов посад: Очерки по истории Оренбургской (Татарской) Каргалы. К., 2005. *И.Р.Вәлиуллин.*

ХӘЙ́РОВ Альберт Ибраһим улы (10.4.1941, Казан), физик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2009), физика-матем. фән. канд. (1986). Казан ун-тын тәмамлый (1969), шунда ук, органик химия кафедрасында (1987 гә кадәр һәм 2002–07 дә) эшли. 1987 елдан Бөтенроссия вет. фәнни-тикшеренү ин-тында ЯМР секторы мөдире. 1990 нан «Сувар» уртак фәнни-җитештерү пр-тиесенең гомуми проектлау башлыгы. 1992 дән Казан җи һәл сәнәгать техникумының хисаплау техникасы лаб-ясе мөдире; 1998–2001 дә «Түбәнкамаһефтехим»АҖдә. Хезмәтләре органик кушылмаларның структурасын тикшерүгә карый. ТР Дәүләт бүләге молекуляр системаларны структуралы-динамик тикшерү барышында югары дәрәҗәдә аерылышлы төш-магнит резонансын өйрәнү буенча хезмәтләр циклы өчен бирелә.

ХВОСТО́В Михаил Михайлович (14.10.1872, Керчь ш. — 25.2.1920, Томск ш.), антик чорны өйрәнүче тарихчы, тарих фән. д-ры (1914). Керчь Александр гимназиясен (1891), Мәскәү ун-тын (1895) тәмамлый. Укытучылары арасында — проф. П.Г.Виноградов, В.И.Герье, В.О.Ключевский, П.Н.Милюков. Мәскәү ун-тында профессор дәрәҗәсенә әзерләү өчен калдырыла, бер үк вакытта Константин җир төзү ин-тында, соңрак С.А.Арсеньева һәм А.Ф.Гросманның хатын-кызлар гимназиясендә укыта. 1901 елдан Казан ун-тының гомуми тарих кафедрасында; проф. (1907 дән). Гомуми тарих, тарихи танып белү методологиясе буенча лекцияләр укый. Казанда Югары хатын-кызлар курсларын оештыручыларның берсе (1906), директор урынбасары (1908 гә кадәр), попечительләр советы секретаре, директор (1917). Кадетлар партиясенең Казан губерна бүлекчәсе әгъзасы, аның лидерларының берсе (1905 тән). Казан ун-ты каршындагы Археол., тарих һәм этнография җәмгыяте рәисе (1914 тән), Болгар шәһәрлегендә археол. казуларга зур игътибар бирә. 1918 нең сентябре башында Казан ун-тының Гыйльми советы тарафыннан Самара шәһәренә, халык мәгарифе мәсьәләләре буенча КОМУЧ оештырган махсус киңәшмәгә (9 сентябрьдә булып уза) җибәрелә. Кызыл Армиянең Көнчыгыш фронтта киң колачлы контрһөҗүме Х.ка Казанга кайтырга мөмкинлек бирми. Хезмәтләре Грециянең эллинизм чоры тарихына һәм Көнбатыш Европаның яңа заман тарихына карый. 1901–14 тә яңа чыганаклар эзләү максатында 11 мәртәбә чит илләрдә була, чыганакларның күбесен фәнни әйләнешкә кертә. Эллинистик һәм рим Мисыры тарихының социаль-икътисади мәсьәләләренә багышланган хезмәтләре — «Грек-рим Мисырының Шәрекъ б-н сәүдәсе тарихы» («История восточной торговли греко-римского Египта», 1907), «Грек-рим Мисырында сәнәгатьне һәм сәүдәне оештыру буенча очерклар» («Очерки организации промышленности и торговли в греко-римском Египте», 1914) һ.б. авторны борынгы заман тарихының иң яхшы белгечләреннән берсе итеп таныта. Х. һөнәрләр һәм сәүдә үсешен аерым илләрнең социаль-икътисади үсешенең гомуми юнәлеше б-н бәйләнештә, хезмәт ияләренең көнкүрешен һәм хәлен өйрәнә. Борынгы тарихның барлык бүлекләрен колачлаган 5 лекцияләр курсы авторы. Аларда Х. тарих фәненең теоретик мәсьәләләрен карый, төрле фикерләр кузгаткан проблемаларны аерып чыгара. Чыганакларның һәм фактик материалның байлыгы б-н Х.ның хезмәтләре бүген дә әһәмиятләрен югалтмый. Тифтан вафат була.

Хезм.: История Рима. К., 1907; История Греции. М., 1908; История Древнего Востока. К., 1909; История Римской империи. К., 1909; История Римской республики. К., 1911; Лекции по методологии и философии истории. К., 1913; Развитие форм промышленности в древнем мире. К., 1915; История рабочего движения в Западной Европе в новое время. К., 1917.

Әд.: Шофман А.С. Михаил Михайлович Хвостов. К., 1979. *Л. М.Айнетдинова.*

«ХЕЗМӨ́Т», Оренбург губернасы Троицк шәһәрендәге китап бастыру ширкәте. 1902 елда Ә.Әхмәров һәм Ф.Черкасов тарафыннан оештырыла. Казан, Оренбург басмаха-

нәләренә заказлар тарата, соңрак Троицкида Х.Сосновский басмаханәсен сатып ала. Ширкәт гомуми тиражы 6 мең данәдән артык булган 6 татар һәм казакъ китабын бастыра, алар арасында Акмулла шигырьләренең беренче 2 басмасы (1904, 1907), Г.Яушевның хатын-кызлар мәдрәсәсе программасы, Ф.Нурмавиның «Кем гаепле?» драмасы, Ә.Галимовның «Надан мулла»сы, М.Сералинның казакъ телендәге шигырьләре һ.б.; «Акмулла» һәм «Иҗтиһад» ж-лларын нәшер итә. «Х.»нең җәмәгатьчелек файдалануында булган түләүсез китапханәсе була, рус, татар китапларын, ш.и. Төркия, Мисыр, Һиндстанда басылган чит ил әдәбиятын сату б-н шөгыльләнә. Эшчәнлеген 1918 дә туктата.

Әд.: Каримуллин А.Г. Татарская книга начала XX века. К., 1974.

Г.Г.Габделганиева.

ХЕЗМӘТ БИ́РЖАСЫ, эш бирүче һәм яллаучы эшләүче арасында арадашчылык итүче оешма (учреждение). Россиядә 1915 елда барлыкка килә. Шәһәрләрдә алар б-н бергә эшкә яллау буенча хосусый түләүле конторалар эшли, эшсезләрнең тармак профсоюзлары һәм советлары оештырыла. 1918 нең гыйнварында яңа «Хезмәт биржалары турында нигезләмә» кабул ителә. Хезмәт базарын көйләү дәүләт карамагына күчә. Эшкә яллау буенча хосусый конторалар һәм бюролар ябыла. 1923 тә РСФСР ХКСның 1918 ел 31 май декреты нигезендә Казан Х.б. оештырыла; ул 1931 гә кадәр эшли. Х.б. ярдәме түләүсез була. Дәүләт биржалар аша хезмәт базарына актив йогынты ясый; Х.б. эшкә урнашуда, эш урынын алыштыруда, һөнәр сайлауда гражданнарга ярдәм күрсәтергә тиеш була, аларга ш.у. халык хуҗалыгының барлык тармакларында эшчеләрне исәпкә алу һәм бүлү, эшсезләрне исәпкә алу һәм аларга пособиеләр бирүдә катнашу функциясе йөкләнә. 1931 дә СССРда эшсезлекнең бетерелүе турында игълан ителә һәм Х.б.ларының эшчәнлеге туктатыла. Икътисади реформа нәтиҗәсендә 1990 еллар башында респ-када яңадан *эшсезлек* барлыкка килә һәм тиешле хезмәтләр оештырыла. РФдә Х.б. функцияләрен мәшгульлек хезмәте (үзәкләре) үти. Алар пр-тиеләрдәге эшләреннән бушатылган кадрларны яңа эшкә әзерләү һәм аларга өстәмә белемнәр, проф. юнәлеш бирү һәм эшкә урнашуга ярдәм итүгә җаваплы оешма буларак гамәлгә кертелә. Респ-када дәүләт мәшгульлек хезмәте Хезмәт һәм мәшгульлек министрлыгы структурасында. 1991 дә «Халыкны эш б-н тәэмин итү турында» ТР Законы кабул ителә, ул эш биручеләргә бу өлкәдә дәүләт сәясәтен үткәрүдә булышлык итү бурычын йөкли. Эш биручеләр шушы оешмада проф. авыру яки инвалидлык алган эшчеләрне эш урыны б-н тәэмин итү, хезмәткәрләрнең һөнәри әзерлеге, квалификацияләрен күтәрү һәм яңадан әзерләү өчен дәүләт органнары тарафыннан тотылган чыгымнарны хезмәт һәм мәшгульлек органнарына кайтарырга тиешләр. Мәшгульлек хезмәте (үзәкләр) һәр адм. районда һәм респ-ка карамагындагы шәһәрләрдә булдырыла. Дәүләт хезмәте б-н берәттән ТРда дәүләтнеке булмаган оешмалар да башкарма хакимият лицензиясе буенча түләүле нигездә эшкә урнаштыру эшчәнлеге башкаралар.

Әд.: Социальные проблемы города в условиях перехода к рыночным отношениям. К., 1994; Краснова О.М. Структура занятости и её особенности в Татарстане // Актуальные проблемы экономики и права. 2008. № 4.

К.И.Азизов.

ХЕЗМӘ́Т ГЕРОЕ́, СССРда 1920–38 елларда мактаулы исем. Җитештерү б-н бәйле хезмәттә аерылып торган эшчеләрне мораль яктан кызыксындыру максатында гамәлгә кертелә. Баштарак пр-тие, учреждение һәм оешма коллективлары, 1921 дән — эшчеләр җыелышлары тәкъдиме буенча Профсоюзларның губерна советы тарафыннан бирелә. Татарстанда 1920 дә профсоюз оешмалары һәм пр-тие коллективлары 200 дән артык эшче һәм хезмәткәрне Х.Г. буларак зурлыйлар. 1921 нең мартында Казанда Х.Г.ларын беренче тапкыр гомумшәһәр күләмендә хөрмәтләү уздырыла. 1920–26 да ТАССРда Х.Г. исеме 550 дән артык эшчегә, инженер-техник, хуҗалык, профсоюз һәм партия хезмәткәрләренә бирелә. 1927 дә Х.Г. исеме бирү тәртибе үзгәрә: СССР ҮБКның 27 июль карары буенча исем бирү хокукы СССР һәм союздаш респ-калар ҮБК Президиумына тапшырыла. Исем ВЦСПС һәм аның респ-ка органнары тәкъдиме б-н җитештерү, фәнни, иҗтимагый яки дәүләти эшчәнлек өлкәсендәге аерым казанышлары булган эшче һәм хезмәткәрләргә (эш стажы 35 елдан ким булмаска тиеш) бирелә. 1927–38 дә ТАССРда бу исемгә 25 кеше лаек була. 1938 дә Х.Г. исемен бирү аерымлыкның югары дәрәҗәсе — *Социалистик Хезмәт Герое* исеме кертелүгә бәйле рәвештә туктатыла.

Әд.: Герои Труда Татарии. К., 1974.

ХЕЗМӘ́Т ГИГИЕ́НАСЫ, җитештерү мохитен һәм аның организмга тәэсирен өйрәнү, гигиена нормативлары эшләү, хезмәт шартларын яхшыртуны тәэмин итү, проф. авыруларны кисәтүгә юнәлдерелгән чаралар оештыру б-н шөгыльләнүче гигиена тармагы. Медицинаның мөстәкыйль тармагы буларак, Россиядә Х.г. 19 йөз башында барлыкка килә. 1930 елда Казан мед. ин-тында Х.г. кафедрасы ачылу (мөдире С.М.Шварц) бу тармакка караган мәсьәләләрнең актив рәвештә өйрәнелә башлавына юл ача.

Казан галимнәренең беренче тикшеренүләре җирле сәнәгать тармакларында (тире, мех эшкәртү, сабын кайнату, дары ясау һ.б.) эшләүчеләрнең хезмәт шартларын өйрәнүгә багышлана.

1940–70 елларда сәнәгать токсикологиясе өлкәсендә нефть чыгару тармагындагы хезмәт шартлары, ш.и. углерод оксидының һәм аз концентрацияле терекөмеш парларының агулау үзлекләре тикшерелә (А.Г.Тимофеев, М.М.Гыймадиев, В.Г.Козявин һ.б.). Фәнни тикшеренүләрнең нәтиҗәсе буларак, терекөмеш парларының, этиленхлоргидринның, ди-бета-хлорэтилформальнең, синтетик юу чараларының хезмәт зонасы һавасында таралуының нормада каралган чиге билгеләнә.

1950–70 елларда кинофотоматериаллар җитештерүдә эшләүчеләргә химик факторлар йогынтысын тикшерү барышында караңгыда эшләүчеләрнең физиол. активлыгында аерым үзгәрешләр (баш мие кабыгының тонусы төшү, күрү һәм хәрәкәт анализаторларының функциональ халәте кимү, вестибуляр анализаторның активлыгы, тир бүленеп чыгу арту, хезмәт эшчәнлеге кимү, гомуми йончу һ.б.) булуны дәлилләүче нәтиҗәләр алына. Үткәрелгән тикшеренүләр кинофотоматериаллар һәм магнитлы тасма җитештерүдә эшләүчеләр өчен 6 сәгатьлек эш көне зарурлыгын дәлилләргә һәм хокукый яктан беркетергә, ш.у. тәрәзәсез һәм фонарьсыз типтагы биналарда эшләүче затларның астеник халәтен фаразлау һәм кисәтү өчен чаралар комплексы булдырырга мөмкинлек бирә (В.П.Камчатнов, Н.Х.Әмиров).

1970 еллардан фәнни тикшеренүләр түбәндәге юнәлешләрдә алып барыла: респ-ка икътисадының төп тармакларында Х.г. һәм проф. авырулар; җитештерү өлкәсендә канцероген һәм мутаген матдәләр куркынычы мәсьәләләре; хатын-кызлар хезмәте гигиенасы һәм физиологиясе; хезмәт шартларының сан.-гигиена һәм психофизиол. үзенчәлекләренең эш урынындагы кеше сәламәтлегенә йогынтысы. 1980 елларда «КамАЗ» АҖнең махсус призводстволары машина йөртүчеләре һәм эшчеләре арасында авыру очракларын кимету, проф. патологияләрне кисәтү системасы эшләнә һәм гамәлгә кертелә. Сәнәгать пр-тиеләре җитәкчеләре һәм инженер-техник хезмәткәрләренең хезмәт эшчәнлеге шартларын һәм сәламәтлеге торышын клиника-гигиена ягыннан комплекслы тикшерү барышында аерым нерв-эмоциональ йөкләнеш очраклары — йөрәк-кан тамырлары системасы авыруларының югары күрсәткечләре билгеләнә.

Әйләнә-тирә мохитнең яңа факторлары — тулай көчәнешләре табигый фон б-н чагыштырганда йөзләрчә тапкыр артык булган антропоген килеп чыгышлы электромагнит кырлары; видеосплейлардан файдаланучыларның сәламәтлеге торышы махсус тикшеренүләр предметын тәшкил итә. 1980 еллардан башлап химик матдәләр һәм физик факторлар тәэсире, проиводство шартларында нерв-эмоциональ халәт актив рәвештә өйрәнелә. Көнкүреш химиясе эшләнмәләре җитештерүдә эшләүчеләрнең сәламәтлеген тикшерү барышында сәламәтлек какшауның берничә төрле авыруны берләштергән полинозологик формалары барлыкка килү күзәтелә. Авыр машиналар төзелеше, нефть химиясе тармагында техноген һәм табигый физик һәм химик факторлар йогынтысы астында эшләүчеләр арасында онкологик авырулар куркынычының стандартлаштырылган чагыштырма күрсәткече дәрәҗәләре исәпләп чыгарыла.

Н.Х.Әмиров.

ХЕЗМӘ́Т ДАНЫ́ О́РДЕНЫНЫҢ ТУЛЫ́ КАВАЛЕРЛАРЫ́, өч дәрәҗәдәге Хезмәт Даны орденнарына лаек булган, халык хуҗалыгының җитештерү һәм җитештерүгә карамаган өлкәләре хезмәткәрләре. Орден 1974 елның 18 гыйнварында гамәлгә кертелә; 3 нче, 2 нче, 1 нче (югары) дәрәҗәдәге орденнар б-н бүләкләүләр бер-бер артлы бара, 1991 гә кадәр. Хезмәт Даны ордены б-н сәнәгать, транспорт, төзелеш эшчеләре һәм шул өлкә-

ләрдәге җитештерү осталары (мастерлары), колхозчылар һәм эшчеләр намуслы, югары җитештерүчән, озак вакыт бер пр-тиедә, оешмада, колхозда яки совхозда хезмәт куйган өчен бүләкләнә. Өч дәрәҗәдәге Хезмәт Даны ордены б-н бүләкләнүчеләргә аерым ташламалар һәм өстенлекләр карала.

Орден (1 нче, 2 нче, 3 нче дәрәҗә) көмештән эшләнә, аның биеклек һәм киңлек үлчәмнәре — 43 *мм*. 1 нче дәрәҗә орден бераз кабарынкы, алтын йөгертелгән күппочмак рәвешендә, өске өлешендә чәчелеп киткән 5 алтынсыман нурлар бәйләме, аскы өлештә — «СССР» дип язылган кызыл эмаль тасма белән чорналган 3 рәт бодай башакларыннан венок б-н каймаланган. Язу, бодай башаклары һәм тасманың читләре алтынланган. Орденның үзәк өлешендә кызыл эмаль б-н каплан ган чәчелеп киткән нурлар фонында домна миче һәм төзелеп килүче гидроэлектростанция, ш.у. алтын йөгертелгән урак һәм чүкеченең рельефлы оксидлаштырылган сурәтләре урнаштырылган. Орденның өске өлешенә 5 почмаклы читләре алтынланган кызыл эмаль йолдызчык куелган. 2 нче дәрәҗә орден 1 нче дәрәҗә орденнан өске өлешендә чәчелеп киткән 5 нурлар бәйләменең көмешсыман төсе б-н, үзәк өлешенең ачык зәңгәр эмальдән булуы б-н аерыла. 3 нче дәрәҗә орденның түбәнге 2 рәт бодай башаклары, тасма читләре, «СССР» һәм «Хезмәт Даны» язулары алтынланган; орденның калган өслеге һәм беркетелгән урак һәм чүкеч оксидлаштырылган. Барлык өч дәрәҗә Хезмәт Даны ордены муар тасма б-н кысаланган 5 почмаклы колодкага җыела; күкрәкнең сул ягына тагып йөртелә. 1974–91 дә Татарстанда 8 кеше Хезмәт Даны орденының тулы кавалерлары була: Аверьянов Василий Игнатьевич (1975, 1976, 1983), Афзалетдинов Нәфис Әбделгата улы (1978, 1986, 1991), Газизова Хәлимә Хисаметдин кызы (1976, 1981, 1986), Гыйльфанов Мәсгуть Хәйретдин улы (1975, 1981, 1986), Дорофеева Валентина Александровна (1975, 1981, 1986), Проценко Виктор Кузьмич (1976, 1981, 1986), Фәтхуллин Данил Зыяф улы (1976, 1981, 1988), Шәкүров Әнәс Харис улы (1974, 1978, 1983).

Әд.: Колесников Г.А., Рожков А.М. Ордена и медали СССР. М., 1978; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003.

М.З.Хәбибуллин.

ХЕЗМӘТ РЕСУ́РСЛАРЫ, икътисадта хезмәткә яраклы яшьтәге мәшгуль (эшләмәүче 1 нче һәм 2 нче төркем хезмәт һәм сугыш инвалидларыннан, яшь буенча ташламалы пенсия алучылардан тыш), ш.у. хезмәт яшендә булмаган халык (яшүсмерләр һәм хезмәткә яраклы яшьтән өлкәнрәкләр). РФнең гамәлдәге законнары нигезендә ир-ат өчен хезмәт яше — 16–59, хатын-кызлар өчен 16–54 яшь каралган. Х.р.ның саны җәмгыятьтәге ихтимал булган эшләүчеләр санын билгели, һәм эшче урыннарга макс. сорау мөмкинлеген билгели. Татарстанда 2008 елда Х.р. 2446,4 мең кеше тәшкил итә (респ-ка халкының 65% ы). Х.р.ның гомуми санының 74,1%ы хезмәт б-н мәшгуль халык, 9,3%ы — укучылар, 16,6%ы — хезмәткә яраклы яшьтәге эшләмәүчеләр.

2015 тә Х.р. 2385,2 мең кеше тәшкил итә (барлык халыкның 61,7% ы), ш.и. хезмәт б-н мәшгуль — 1806,6 мең кеше (Х.р.ының 75,7% ы), укучылар — 178,6 мең кеше (7,5%), эшләмәүче хезмәткә яраклы яшьтәгеләр — 400,1 мең кеше (16,8%). 2014 тә хезмәт б-н мәшгуль халыкның 17,5% ы — эшкәртү, 17,1% ы — күмәртәләп һәм ваклап сату сәүдәсе, 9,9% ы — төзелеш, 9,5% ы — а.х., 8,9% ы — мәгариф, 8,3%ы — күчемсез милек, аренда б-н бәйле эшләр һәм хезмәт күрсәтү өлкәсенә туры килә. Ш.у.к. *Икътисади актив халык.*

ХЕЗМӘ́Т ХАКЫ́, милли керемнең хезмәткәр тарафыннан эш вакытының билгеле бер чорында сарыф ителгән хезмәтнең күләме һәм сыйфаты буенча билгеләнгән өлешенең акчалата чагылышы; хезмәт өчен матди түләү формасы; хезмәт эшчәнлекләрен гамәлгә ашыру вакытында хезмәткәрләр күрсәткән хезмәтләр өчен түләү бәясе. Х.х. — җитештерелгән һәм сатылган продукция бәясенең эш челәргә һәм хезмәткәрләргә бирелә торган өлеше, җитештерү чыгымнары элементы. Ай саен күчерелә һәм продукциянең үзкыйммәтенә кертелә. Х.х.ның төп билгеләнеше — хезмәткәрнең җитештерү процессында сарыф ителгән физик һәм акыл энергиясе чыгымнарын каплау. Х.х.ның зурлыгы хезмәткәрнең шәхси ихтыяҗларын гына түгел, аның гаилә әгъзаларының ихтыяҗларын да канәгатьләндерергә тиеш. Җәмәгать милке шартларында, милли керемнең бер өлеше буларак, Х.х.ның күләме җитештерүне үстерү фонды, резерв (иминият) фонды, оборона, дәүләт аппаратын тоту, өлкән яшьтәге һәм эшкә сәләтсез гражданнар, социаль өлкәне үстерү, куллануның җәмәгать фондлары өчен чыгымнарны исәпләгәннән соң, калдык ысул б-н билгеләнә. Базар икътисадында ул — эшмәкәр кеременең яллы хезмәткәрләр хезмәтенә түләү өчен сарыф ителә торган, һәр конкрет очракта турыдан-туры квалификация алмашу принцибы, яллы хезмәткәрнең вакыты һәм аның хезмәте нәтиҗәләре буенча билгеләнүче өлеше. Х.х. — «эш көче» товары бәясенең акчалата чагылышы. Х.х.ның зурлыгы җитештерү дәрәҗәсенә, хезмәтнең интенсивлыгына һәм катлаулылыгына, бәяләргә, барыннан да элек куллану товарлары һәм хезмәт күрсәтүләр бәяләнешенә бәйле. Х.х.н исәпләүнең төп принциплары: эшче көчне гадәти һәм киң күләмдә яңарту өчен иҗтимагый зарури чыгымнар; Х.х. күләмнәренең хезмәтнең ахыргы нәтиҗәләренә бәйлелеген билгеләү; бертигез катлаулылыктагы эшләр башкарган бертөрле һөнәр ияләре хезмәте өчен түләүдә бердәйлек; дәүләт тарафыннан булган кайбер чикләүләр (Х.х.ның минималь күләме, төбәк коэффициентлары) һәм тариф килешүләре шартларында хезмәт өчен түләү системасын төзүдә пр-тиеләрнең мөстәкыйльлеге; продукция һәм эшләрнең сыйфатын, хезмәткәрнең квалификациясен күтәрүне матди һәм мораль стимуллаштыру.

Х.х.ның төп формалары — вакытка һәм эшләүнең күләменә карап түләү. Вакытка карап түләү формасы — хезмәткәрнең билгеле бер вакыт эчендә (көн, атна һ.б.) башкарган хезмәте өчен ала торган Х.х. Эшләү күләменә карап түләгәндә хезмәткәр вакыт берәмлегә эчендә җитештергән эшләнмәләр күләме өчен Х.х. ала, эшләнмәләрнең һәрберсе өчен билгеләнгән аерым бер бәяләр буенча түләнә. Х.х.ның бүленеше, күләме, нисбәте һәр тарихи чорның социаль-икътисади, техник-икътисади һәм сәяси факторларына, җитештерү көчләренең үсеш дәрәҗәсенә, хезмәт җитештерүчәнлегенең ирешелгән дәрәҗәсенә бәйле рәвештә үзгәрә.

Х.х.ның зурлыгы РФнең конкрет субъектлары үзенчәлекләреннән һәм мөмкинлекләреннән чыгып формалаша. ТРда ул башлыча респ-када билгеләнгән мин. Х.х. зурлыгыннан һәм аеруча табышлы ягулык, энергетика һәм нефть химиясе тармакларының чагыштырма өлешенә бәйле. Хезмәт җитештерүчәнлегенең үсеш темплары уртача Х.х. үсеше темпларыннан өстен булырга тиеш. Хезмәт җитештерүенең үсүеннән һәм җитештерү күләмнәренең артуыннан башка Х.х.ның ирекле үсеше инфляциянең көчәюенә китерә. 2017 елда ТРның пр-тиеләрендә һәм оешмаларында уртача Х.х. 31,5 сум тәшкил итә.

Әд.: Слезинтер Г.Э. Труд в условиях рыночной экономики. М., 1996; Экономика труда и социально-трудовые отношения. М., 1996; Еловиков Л.А. Экономика труда. Омск, 2000; Азизов К.И. Рынок и заработная плата, условия ее повышения // Изв. Академии труда и занятости. 2000. № 3/4.

К.И.Азизов.

ХЕ́ННИГ Юрген Клаус (5.3.1951, ГФР, Штутгарт ш.), физика химиясе белгече, мед. физикасы д-ры (1989), проф. (1993), РФ ФАнең чит ил әгъзасы (2004). Фрайбург ун-тын (ФРГ) тәмамлый (1978), шунда ук эшли, 1983–92 елларда — радиология кафедрасында, 1998 дән ун-т хастаханәсенең мед. физикасы секциясе рәисе, 2001 дән Магнит резонансын куллану һәм үстерү үзәге җитәкчесе, 2004 тән шул ук хастаханәнең мед. физикасы һәм радиология кафедрасында фән буенча директор, 2009 дан ун-тның мед. ф-ты деканы урынбасары. Хезмәтләре магнит резонансы күренешен тикшерү методикалары, йөрәк-кан тамырлары системасы магнит-резонанс томографиясе (МРТ), мине, тәнне функциональ сканерлауга карый. Х. томография дә иң еш кулланылучы тизлекле спин кайтавазы алымын; комплекслы радиоешлыклы кәтүкләрдән (фәзаи локализация чыганагы буларак) файдалануга корылган һәм мине 25.10–3 секунд эчендә сканерлауга мөмкинлек бирүче магнит-резонанс энцефалография алымын эшли. 1997 дән Халыкара медицинада магнит резонансы халыкара җәмгыятенең вице-президенты, 1998–99 да — президенты. 2003 тән Ми магнит резонансы томографиясе милли үзәгенең акад. ком-ты (Пекин) рәисе. 2006 дан Сингапур томография үзәгенең фәнни-консультатив советы рәисе. 2007 дән Европа биомедицина томография сесе ин-тының (Вена) гыйльми директоры. Х. Казан фәнни учреждениеләре белгечләре б-н актив хезмәттәшлек итә, аларга магнит резонансын куллану буенча методик һәм консультатив булышлык күрсәтә. Ул тәкъдим иткән методикалар Казан 2 нче респ-ка кли-

ник хастаханәсенең МРТ бүлегендә файдаланыла. Германиядә Х. Россия галимнәренә ярдәм итү максатыннан Академик Е.К.Завойский фондын оештыра. Европа радиология җәмгыяте шәрәфле әгъзасы (2007). Магнит резонансы өлкәсендә Европа бүләгенә (1992), М.Планк җәмгыятенең (ГФР) мед. өлкәсендәге М.Планк исем. бүләгенә (ГФР, 2003) лаек була. Медальләр б-н бүләкләнә.

Р.Г.Усманов.

«ХЁРЛЕ́ ЯЛА́В» («Хёрлё ялав – Кызыл байрак»), к. *«Ленин ялаве»*.

ХИКАЙӘ́Т, (гарәп. حكايت — хикәяләү), Якын һәм Урта Көнчыгыш, Көньяк-Көнчыгыш Азия, Идел-Урал буе төрки халыклары әдәбиятындагы жанр. Х. тамырлары б-н фольклордагы эпик жанрларга барып тоташа. Проза, сирәк шигырь яисә катнаш формада языла. Эчтәлеге һәм жанр табигате ягыннан хәзерге хикәя, новелла, мәсәлгә якын тора.

Кагыйдә буларак, вакыйга бер яки берничә кеше, ша һитлар тарафыннан хикәяләнә. Х.нең үзәгендә — геройның теге яки бу вакыйгалар б-н бәйле реаль булмаган, фантастик эш-гамәлләре. Х.ләрдә хайваннар, кошлар да катнашырга мөмкин, кеше ышанмаслык, әкияти хәлләр дә тасвирланырга мөмкин. Татар әдәбиятында Х. популяр жанрларның берсе, Г.Исхакый, Ф.Әмирхан, Г.Ибра һимов, Ш.Камал, М.Әмир, Ф.Хөсни, И.Гази, Ә.Еники һ.б. иҗатларында очрый. 20 йөз башыннан «хикәя», «озын хикәя» дип атау гамәлгә керә.

Әд.: Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990.

ХИКӘ́Я (гарәп. حكايه — сөйләп бирү), татар әдәбиятының эпик төренә караган кечкенә күләмле жанр. Х.дә, гадәттә, кеше тормышыннан эпизод яисә вакыйгалар сурәтләнә. Әсәрдә геройлар күп түгел, аларның характерлары тулысынча ачылмый, ә аерым сыйфатлары аша гына күрсәтелә, Х.нең кечкенә күләмле булуы шуның б-н аңлатыла. *Хикәятькә* барып тоташа.

Татар әдәбиятында Х. 19 йөзнең 2 нче яртысында формалаша. Әлеге жанр әсәрләре мәгърифәтчелек характерында, гадәти булмаган хәл турында хикәяләүче исеменнән бәян итүдән, дидактик гомумиләштерү-нәсыйхәттән гыйбарәт була. Г.Исхакыйның «Тәгаллемдә — сәгадәт», Ф.Кәриминең «Салих баба байның өйләнүе», «Җи һангир мәхдүмнең авыл мәдрәсәсендә укуы» әсәрләрендә акыл һәм мәгърифәтнең көченә мәдхия җырлана; тулаем дөнья һәм анда яшәүче кеше әхлакый күзлектән чыгып карала.

Алгарышның гомуми мәгърифәт формуласы 20 йөз башы Х.сендә дә чагылыш таба. Язучылар мәгърифәтне җәмгыять үсешенең нигезе дип саныйлар, гыйлемле һәм әдәпле геройларны наданнарга һәм әдәпсезләргә каршы куялар (Я.Вәли, «Мәңгелек мәчет»), белемле һәм гармоник үсешкә ия шәхес тәрбияләү киряклеген ассызыклыйлар (Ә.Бикимеров, «Үткән мәхәббәт»), идеаль геройны үрнәк алырлык кеше итеп сурәтлиләр (Я.Моради, «Яхшы тәрбия»). Прозаикларның тәнкыйтьтә яшәп килгән тәртипләргә каршы юнәлдерелә; алар игътибарны гади халыкның ярлы тормышына юнәлтәләр (М.Гафури, «Фәкыйрьлек берлә үткән тереклек»), надан муллаларның акылсыз гамәлләрен кире кагалар (З.Һади, «Бәхетсез кыз»), яшь кешенең кешелек дәрәҗәсен түбәнсетә торган кадими мәдрәсәләрне тәнкыйтьлиләр (З.Һади, «Мәгъсүм»; Г.Ибра һимов, «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы»). 20 йөз башында Х.не жанрларга аеруның алшартлары барлыкка килә: социаль-көнкүреш, социаль-сәяси, тарихи, сатирик, психол. һәм романтик Х.ләр языла. Көнбатыш мәдәниятенә игътибар арту жанрның эчтәлек һәм формасы өлкәсендә эзләнүләргә китерә. Кешенең социаль статусы, шәхси сыйфатлары б-н кызыксыну башлана. Аларны чагылдыру өчен авторлар, урта гасырлар әдәбиятына барып тоташкан Х.-назыйрә, пародия (З.Һади, «Яңа әсхабе кәһәф») кебек яңа формалар тудыралар. Бер яктан, публицистиклык һәм сатирик пафосның көчәюе күзәтелә (Ф.Әмирхан, «Бәйрәмнәр»; Ш.Камал, «Сәмруг кош», «Депутат»). Чын тормыш факторларына нигезләнгән Х. укучыга очерк дип тәкъдим ителә. Коткы тарату (К.Бәкер, «Кара тап»; Г.Гобәйдуллин, «Олуг ләгънәт»), «кечкенә кеше» (Г.Исхакый, «Калуш», «Башкорт бәхете»; Г.Ибра һимов, «Карт ялчы»), «артык кешеләр» (Г.Ибра һимов, «Уты сүнгән җәһәннәм», «Мәрхүмнең дәфтәреннән»; М.Гафури, «Хәмитнең хәяте»), сугыш (Ф.Әмирхан, «Зәгыйфь карчыкның корбаны»; Н.Думави, «Ватан кайгысы, яки Агач аяк»; К.Тинчурин, «Хәким җан агай») һ.б. яңа темалар 20 йөз башында аерым кеше һәм җәмгыять, матди һәм рухи башлангычлар, чынбарлык һәм интеллигенциянең идеаллары арасында көчәя барган каршылыкларны аңларга омтылу нәтиҗәсе булып тора. Икенче яктан, кеше психологиясе б-н кызыксыну арта. Психол. Х.дә (Ш.Камал, «Буранда», «Сукбай», «Уяну», «Козгыннар оясында») геройларның эчке дөньясы, рухи кичерешләре чагылыш таба.

20 йөз башы — романтик Х.ләр чәчәк аткан чор (Ф.Әмирхан, «Гарәфә кич төшемдә»; Ш.Мөхәммәдов, «Хан кызы»; К.Тинчурин, «Искәндәр»). Әлеге әсәрләрдә шәхес иреге мәсьәләсе үзенчәлекле итеп ачып бирелә (Г.Ибраһимов, «Сөю-сәгадәт», «Диңгездә», «Табигать балалары»). Авторларның игътибарын геройларның яшәеше генә түгел, ә аларның аңы һәм күзаллаулары да җәлеп итә (Ф.Әмирхан, «Габделбасыйр гыйшкы», «Сәмигулла абзый»). Бу дәвердә милләт темасы төп урынны алып тора. Хикәя жанрында язылган әсәрләрнең күпчелеге татар халкының киләчәгә турындагы драматик уйланулар б-н сугарылган. Милли үзаң тәрбияләү максаты б-н авторлар халык риваятьләренә һәм татар фольклорына (М.Хәнәфи, «Айсылу»; Ф.Әмирхан, «Ай өстендә Зөһрә кыз»; З.Нуркин, «Бәхет»; Г.Рәхим, «Хан мәчетендә»), төш символик образларына (Ш.Саттаров, «Бетсә бетәр») мөрәҗәгать итә. Тарихи Х.ләр — тарихи вакыйгаларны яисә Идегәй, Чыңгызхан, Чура батыр, Нуретдин һ.б. мәшһүр шәхесләрнең биографияләрен хикәяләү активлаша (Ф.Туйкин, «Сугышчы Сатыш әфәнде»; Ш.Саттаров, «Татар халкы»; Ә.Таңгатаров, «Чыңгыз»). Үткәндәге драматик вакыйгаларның котылгысызлыгы, тарихның тәкъдирдә алдан билгеле булуы тарихи Х.ләрнең лейтмотивына әверелә. 20 йөз башы татар әдәбиятында күпсанлы фәлсәфи Х.ләр иҗат ителә. Аларның асылын дөнья һәм яшәү мәгънәсен югалткан кеше һәлакәте концепциясе тәшкил итә (М.Гафури, «Болгар кызы Айсылу»; Ф.Әмирхан «Бер хәрабәдә»; М.Хәнәфи, «Тегеннән», «Бер гөл бакчасында»; Г.Газиз, «Бер хыял», «Юлдаш эзләгәндә»; Г.Насрый «Мазарстанда»). Татар Х.сендә дөньядагы вакыйгаларны һәм кешенең рухи кичерешләрен махсус ысулы — контраст чагыштырулар юлы б-н сурәтләү формалаша. Х. эчендә үзенчәлекле кечкенә күләмле әсәр төре — *нәсер* барлыкка килә.

Ш.Камал, Ш.Мөхәммәдов, Ф.Әмирхан композицион сыйфатлары б-н *новеллага* туры килә торган Х.ләр иҗат итәләр, һәм бу тенденция 1930 елларда да дәвам итә (К.Тинчурин, «Мәрҗәннәр» новеллалар циклы).

1920–30 елларда 1917 елгы рев-циягә (Г.Гали, «Беренче мәхәббәт»; Ш.Усманов, «Ил кызы», «Краском мәхәббәте», «Митинг»), Гражданнар сугышына (А.Шамов, «Днепр буенда»), яңа тормыш төзүгә (И.Гази, «Кич алтыда», «Байраговның көндәлек дәфтәреннән»), күмәкләштерүгә (М.Галәү, «Төеннәр»), искелек һәм яңалыкның фаҗигаи конфликтына (Г.Толымбай, «Кара такта алдында»), иске дөньяны тәнкыйтьләүгә (Г.Гобәйдуллин, «Скрипач Хөсәен», «Фа җигале төннәрдә») багышланган героик-революцион Х.ләр өстенлек итә. 1921 елгы ачлыкны сурәтләүче әсәрләрдә натурализм элементлары барлыкка килә (Г.Ибраһимов, «Адәмнәр» һ.б.). К.Нәҗминең «Кырлар буенча», «Үзебезнекеләр», Г.Кутуйның «Солтанның бер көне» Х.ләрендә күтәренке рухта яңа кешенең яңа тормышы чагыла. 1920–30 елларда М.Максуд лирик прозаны, нәсерне үстерә («Минем кануннарым», «Оҗмах сезгә, дөнья безгә», «Магнолия чәчәкләре»). 1917 елгы революциягә тискәре мөнәсәбәт эмигрант авторлар Х.ләрендә күрсәтелә (Г.Исхакыйның «Локман Хәким» антиутопиясе).

Бөек Ватан сугышы елларында ватанны дошманнардан саклау төп темага әверелә (Ш.Камал, «Марат»; А.Расих, «Якташларым»; Г.Әпсәләмов, «Хәйбулла солдат»). Фронттагы көндәлек тормышны тасвирлаучы (Г.Бәширов, «Сержант Хәйруллин»; М.Әмир, «Тагын да зуррак бәйрәмнәргә кадәр!»; Г.Әпсәләмов, «Ватан улы»; А.Расих, «Дошман тылында»), фашизмның чын йөзен ачып бирүче (Ф.Хөсни, «Рубенс»; Г.Кутуй «Рәссам»; А.Әхмәт, «Шул көннәрдә»; Ф.Хөсни, «Авылда яз») Х.ләр «хәрби проза» хасил итә. Хәрби-патриотик темага багышланган Х.ләр очеркка якыная.

Шуның б-н бергә капма-каршы процесс башлана — Х. жанрының эстетик кысалары киңәя. Ә.Еники, И.Газинның башлангыч иҗатында фәлсәфи-психол. юнәлеш, сугышка кешенең рухи кичерешләре, гомумкешелек кыйммәтләре күзлегеннән карарга омтылу өстенлек итә (Ә.Еники, «Бала», «Бер генә сәгатькә», «Ялгыз каз»; И.Гази, «Ана», «Малай белән эт»). Ә.Еники хикәяләрендә су-

гыш вакыты рәхимсезлеге б-н кешелеклелек («Бала»), эгоизм б-н альтруизм («Ана һәм кыз») һ.б. арасында сайлау проблемасы урын ала. Болардан тыш авторлар лириэмга, идеал эзләүгә, көчле характерлар һәм үзенчәлекле язмышларны кабат торгызуга әйләнеп кайталар (А.Расих, «Ютазы егете»; И.Гази, «Алар өчәү иде»).

Сугыштан соңгы әдәбиятта очерк стилендәге хәрби-патриотик Х.ләр (М.Садри, «Генерал»; С.Баттал «Карчыга»), көндәлек дәфтәрләр, хатирәләр формасына (Ә.Еники, «Шиһап абзыйның таныш кызы») мөрәҗәгать итү беренче планда кала килә. Психологизм (А.Шамов, «Агач башмаклы кыз»; Ф.Хөсни, «Ул һәм без», «Малай белән солдат»), мажаралы (Ә.Айдар, «Солдат хикәясе»), фәлсәфи-психол. һәм лирик (Ә.Еники, «Йөрәк сере») башлангыч көчәя. Татар әдәбиятында эш-хезмәт (Г.Әпсәләмов, «Инженерлар», «Теләк булса»; Г.Ахунов «Закир абзый бригадасы»), этика (А.Шамов, «Миңнур карт»; Р.Төхфәтуллин, «Җәйге челләдә», «Елга аръягындагы йорт») мәсъәләләренә багышланган социаль-көнкүреш Х.ләре активлаша.

1960–80 елларда психологизмның тирәнәюе әхлак проблемаларына мөрәҗәгать итү б-н бергә үрелеп бара (Ә.Еники, «Төнге тамчылар», «Матурлык»; Э.Касыймов, «Таш чыгаручы»; Ф.Яруллин, «Бөек сер»). Романтик Х.ләрдә мәхәббәт (И.Гази, «Тургай картаямы икән?»; Ф.Яруллин, «Мәхәббәт сынавы»), ялгызлык (Ә.Еники, «Шаяру», «Тыныч-лану»), халыкның гореф-гадәтләре, йолалары, көнкүрешенең милли үзенчәлекләре кыйммәтен раслау (Ф.Яруллин, «Сагыш», «Тыкрык кырыендагы өй») темалары әйдәп бара. Нефть чыгару, техник прогресс темаларына (Э.Касыймов, «Сөеneч»; Ф.Яруллин, «Кар күзе») багышланган Х.ләр иҗат ителә.

Илнең иҗтимагый-мәдәни тормышындагы «җепшеклек» элегрәк тыелган темаларга, иң элек шәхес культы б-н бәйле темаларга мөрәҗәгать итү б-н бергә бара. А.Гыйләҗевнең «Өч тәгәрмәчле арба» Х.сендә заман фаҗигасе сынган язмышлы кешеләр (репрессияләнгән иреннән баш тарткан хатын, һәм шуның өчен аны гафу итә алмаган улы хәсрәте) фа җигасе булрак аңлатыла. Тәүге тапкыр мәҗбүри эмиграция мәсь әләсе күтәрелә (М.Юныс, «Безнең өй өянке астында иде»). Язучылар тоталь рәвештә коммунистик идеология таратуның нәтиҗәсе булган туган телгә кимсетеп карау, рухи байлыкларны һәм милли традицияләрне югалту кебек тискәре күренешләргә (Ә.Еники, «Әйтелмәгән васыять», «Туган туфрак»; Ф.Хөсни, «Кояш баешы»; Ф.Латыйфи «Рустик») игътибар итә башлыйлар. Яшәешнең рухи нигезләрен эзләү авторларның карашын кабат алар тарафыннан милли рухны саклауның төп факторы дип күзалланган татар авылына юнәлдерә (Ф.Яруллин, «Иске өй истәлеге»; И.Гази, «Кояш артыннан киткән тургай»). Тормышның көнкүреш һәм социаль шартларын тәнкыйтьләп (Ф.Хөсни, «Кем гаепле?»), авторлар бер үк вакытта җәмгыятьтәге әхлакый үзгәрешләрне ачып бирәләр (Ф.Шәфигуллин, «Ана һәм кыз», «Ялгыз өрәңге»).

Фантастик Х.ләр (А.Тимергалин, «Рибб Локсның үлеме», «Сәер планетада», «Космостан кунаклар» һ.б.), Х.-этюдлар (Г.Гыйльманов, «Чалгы җыры»; И.Иксанова, «Телефон»), Х.-новеллалар (Ф.Җамалетдинова, «Тукталыш») барлыкка килә.

20–21 йөзләр чиге әдәбиятында парадигмалар алмашыну беренче чиратта Х. жанрында чагыла. Милли кыйммәтләрне торгызу, әдәбиятта милли характерны яңадан тудыру жанрның характерлы үзенчәлеге булып тора (Ф.Латыйфи, «Көмеш белүзек», «Әманәт»; Ф.Сафин, «Гөлләрем-сиреньнәрем»). Милли тарихка аерым игътибар юнәлтелә. Әдәбият сәхнәсенә тарихи Х.ләр — укучы б-н бүтенге милли проблемалар турында үзенчәлекле диалог чыга (М.Хуҗин, «Куларада кәлтә уйный»; Р.Зәйдулла, «Хан һәм шагыйрь»; И.Иксанова, «Балан чәчәге»). Әхлакый проблемалар куелышында прозаиклар иң элек милли, дини кыйммәтләргә юнәлеш тоталар (Т.Галиуллин, «Кияү»; М.Хуҗин, «Елау»; Н.Гыйматдинова, «Төш узгач»), аларны гомумкешелек категорияләре югарылыгына күтәрәләр (Р.Рахман, «Бер микъдар былбыл»).

Элекке идеологик, социаль һәм мәдәни ориентирларны инкарь итү, совет (М.Хуҗин, «Мәгарә»; Ф.Садриев, «Ялгышны төзәтү»; Р.Габделхакова «Сират күпере») һәм совет чорыннан соңгы (Ф.Садриев, «Балта сабы чәчәк аткач»; Р.Зәйдулла, «Яңгыр астындагы ябалак») чынбарлыкны мифлардан арындыру сәнгати экспериментның башы була. Х. авторлары яңа шартлы-метафорик алымнар үзләштерәләр (Р.Зәйдулла, «Йорт»). Символик характердагы Х.ләр барлыкка килә (Р.Зәйдулла, «Дару», «Бала»; Ф.Җамалетдинова, «Алма», «Таш чыгаручы»). Ассоциатив проза, бер текстта берничә эчтәлекле катлам, дискурслар кушу жанрның эстетик мөмкинлекләренең киңәюе, синестезия күренеше турында сөйли (М.Кәбиров, «Дүртенче үлчәм», «Канатлы кеше»; Р.Габделхакова, «Даладан килүче», «Китүчеләр»).

Әд.: Хәйруллин Х.Ф. Язучы һәм тормыш: Әдәбият теориясе, әдәби хәрәкәт мәсьәләләре. К., 1979; Татар әдәбияты тарихы. К., 1985–2001. Т. 2–6; Заһидуллина Д. Яңа дулкында. К., 2006; Миннегулов Х.Ю. Татарская литература и Восточная классика (Вопросы взаимосвязей и поэтики). К., 1993. *Д.Ф.Зәһидуллина.*

ХИКМӘТ (гарәп. حكمت — зирәклек, зирәк сүз), Якын һәм Урта Көнчыгыш, Көньяк-Көнчыгыш Азия, Идел-Урал буе төрки халыклары әдәбиятында чагыштырмача кечерәк күләмле, башлыча, шигъри, фәлсәфи-дидактик жанр. Аның асылын аңлаешлы, үтемле, афористик формада акыллы, гыйбрәтле сүз әйтү, мәгънәле хәлне гәүдәләндерү тәшкил итә. Бер яисә берничә шигырьдән торган әхлакый характердагы Х.ләр *касыйдәгә* кертелгән. Борынгы гарәпләрдә Х. иҗтимагый әхлак нормаларын хикәяләүче төп чара була, төрки телле халыкларның дини шигъриятендә әйдәп баручы жанр. Ә.*Ясәвинең* мәшһүр «Диване хикмәт» («Хикмәтләр тупланмасы») шигырьләр җыентыгы Х. жанрында язылган. Татарларда Х. жанрында С.Сараи, Мәүлә Колый, Акмулла, Дәрдемәнд һ.б. иҗат итәләр.

Әд.: Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990.

ХИМАЯЧЕЛЕ́К, балигъ булмаганнар, хезмәткә яраксыз (тулысынча яки өлешчә), ш.у. йорт-җирсез гражданнарның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау формасы; Х. эшчәнлеге алып бара торган хәйрия оешмалары; фәкыйрьләргә, авыруларга, ятимнәргә, картларга, ш.у. белем бирү һәм мәдәният учреждениеләренә гамәли ярдәм күрсәтү. Россиядә табылдык балалар өчен беренче тәрбия йортлары Мәскәүдә (1763) һәм Санкт-Петербургта (1770) ачыла. «Губернаслар турында нигезләмә» Указы буенча 1775 елда аерым затларга һәм оешмаларга хәйрия җәмгыятьләре оештыру рөхсәт ителә. *Җәмәгать кабулханәләре* барлыкка килә. 19 йөздә хәйрия оешмалары эчке эшләр, халык мәгарифе, хәрби министрлыклар, ш.у. дини ведомстволар һ.б. каршында төзелә. 1869 дан Эчке эшләр министрлыгы җәмәгать һәм аерым хәйрия оешмаларының уставын раслый, алар эшчәнлегенә күзәтчелек итә. 1896 да Россиядә 1404 хәйрия оешмасы, борадәрлеге, Х. исәпләнә (барысы да 1917 дә бетерелә).

1828 нең 26 октябрендә императрица Мария учреждениеләре ведомствосы (Император Галижәнапләре шәхси канцелариясенең 4 нче бүлекчәсе) — императрица Мария Фёдоровна яклавында булган хәйрия, хатын-кызлар һәм кайбер махсус уку йортлары б-н идарә итүче югары дәүләт органы оештырыла (39 учреждение керә). Учреждениеләр 15 төркемгә, ш.и. опекуннар советлары, җәмәгать кабулханәләренең попечительләр советлары, Балалар ятимханәләренең төп Х. ком-ты, Пенза, Киев һәм Сембер шәһәрләрендәге бүлекчәләре б-н бергә, Мәскәү фәкыйрьләр Х.е, Хезмәткә өйрәтү йортлары, ш.у. хастаханәләр, гарипләр йортлары, коммерция уч-щеләре, кызлар өчен өйдән килеп укый торган хатын-кызлар уч-щеләренә (1862 дә Мария гимназияләре дип үзгәртелә) бүленә. 1883 нең 10 мартында Ведомство составына сукырлар өчен Мария химаячеләге (1881 нең 13 февралендә рус-төрек сугышында катнашкан мохтаҗ сугышчы гаиләләрен пособиеләр б-н тәэмин итү Х.е буларак оештырыла; 1889 ның 15 декабрендә императрица Мария Александровнаның сукырлар өчен Х.е итеп үзгәртелә) кертелә. Сукырларны мөстәкыйль тормышка әзерләү максатында Х. ятимханәләр, уч-щеләр һәм остаханәләр ача, сукырлар өчен махсус китаплар бастырып чыгара. Сукырлыкны кисәтү бүлеге (1892) дәваханәләр ача, илнең ерак төбәкләренә табибләрнең күчмә отрядларын җибәрә: 1893 тә 7 отряд, 1897 дә — 33; бу еллар дәвамында 38867 күз операциясе ясала. Х. капиталдан килгән табышлар, кертемнәр, хәйрия ярдәме, сукырлар остаханәләре эшләнмәләрен сатудан кергән акчалар, «сукырларга ярдәм атналыгы» дәвамында тупланган чиркәү-хәер җыемнары хисабына яшәп килә. 1898 нең 3 маенда императрица Мария учреждениеләре ведомствосы каршында чукрак-телсезләр өчен Х. оештырыла, ул Хезмәткә өйрәтү йортлары, мәктәпләр, ятимханәләр, остаханәләр ача. Тәрбияләнүчеләр эш һәм торак б-н тәэмин ителәләр. Картларга һәм гарип чукрак-телсезләргә ярдәм күрсәте-

лә. Чукрак-телсезләргә белем бирү өчен укытучылар әзерләү курслары оештырыла. 1913 тә Ведомство составына аналарны һәм яшь балаларны саклау Гомумроссия Х.ге кертелә. 1917 нең 4 мартында Ведомство учреждениеләре Халык мәгарифе министрлыгына тапшырыла. 1917 нең 16 июлендә опекуннар советы ябыла, 1917 нең 12 декабрендә императрица Мария ведомствосының балалар ятимханәләре б-н идарә итү буенча барлык учреждениеләре бетерелә. 1918 нең 23 февралендә Ведомствога кергән уку йортлары Мәгариф халык комис-ты карамагына тапшырыла.

Казан губернасы балалар ятимханәләре Х.ге Балалар ятимханәләре турында 1839 ел 27 декабрь нигезләмәсе б-н 1843 тә оештырыла. Императрица Мария учреждениеләре ведомствосы Балалар ятимханәләренең баш Х.енә буйсына. Казанда *Николай исемендәге балалар ятимханәсе* (1844), *Мөселман балалар ятимханәсе* (1844) һәм *Александра исемендәге кыз балалар ятимханәсе* (1845) ачыла. Императрица Александра Федоровна яклавында халыкның социаль яклауга мохтаҗ катлауларына булышлык итүче учреждениеләр: Хезмәткә өйрәтү йортлары, кунып чыгу йортлары, яслеләр, ашханәләр, дәвалау-азык-төлек станцияләре, Ольга исем. балалар ятимханәләре, сукбайлар өчен артельләр барлыкка килә. 1911 дә 253 хезмәт ярдәме күрсәтү оешмасының 34 е Мәскәүдә һәм С.-Петербургта, 79 ы губерна һәм өлкә шәһәрләрендә була, еш кына игеннәр уңмау һәм җәмәгать эшләрен оештыру зарурлыгына бәйле рәвештә, 52 се Вятка, Казан, Самара,

Саратов һәм Сембер губерналарында туплана. 20 йөз башында хезмәт ярдәме күрсәтү Х. җәмгыяте Тәтеш, Лаеш шәһәрләрендә, Казан губернасының Цивильск һәм Спас өязләрендә кыз балалар һәм малайлар өчен 7 тегү һәм һөнәр остаханәсе оештыра. Укытуда һөнәрләрне (туку, кисү һәм тегү, столярлык, итекчелек һ.б.) гамәли үзләштерү төп урын ны алып тора; эшләнмәләр заказ буенча башкарыла, хезмәт хакы түләнә. Остаханәләр Финанс министрлыгы карамагында була. Ольга исем. хезмәткә өйрәтү балалар ятимханәләрендәге балалар 11–12 яшьтән укырга-язарга өйрәтү мәктәпләрендә укыйлар: гомуми предметларны өйрәнәләр, рәсем ясау һәм сызым серләренә төшенәләр, һөнәрләр үз ләштерәләр. Казан губернасында Ольга исем. ятимханәләр Казан, Цивильск, Козьмодемьянск, Зөя, Ядрин (1900), Мамадыш (1911) шәһәрләрендә, Лаеш өязенең Алексеев авы лында (1909) ачыла.

Хезмәткә өйрәтү йортлары Х.е 1895 нең 1 сентябрендә оештырыла. 1898 дә Россиядә 175 Хезмәткә өйрәтү йорты исәпләнә: хаста ханәдән һәм төрмәдән чыккан фәкыйрьләр өчен билгеләнгән әлеге йортларда алар тук талар урын һәм хәлдән килгән эш б-н тәэмин ителә. Тулай тораклар, остаханәләр һ.б. була.

1892 дә Казанда христиан динендәге бар лык катлау ятим ир һәм кыз балалар өчен хезмәткә өйрәтү мәктәпләре ачыла. Х.не архиепископ Владимир, О.С.Александрова-Гейнс, проф.А.П.Ге, сәүдәгәр Н.В.Унженин гамәлгә куя. Х. составына Сәүдәгәрләр бан кы вәкилләре Л.Н.Урванцов һәм Я.Ф.Шамов, профессорлар Д.А.Корсаков һәм Н.Ф.Высоцкий керә. Химаячеләр ятимнәргә дини-әхлакый тәрбия бирү мәсь әләсен кайгырталар, мәктәпне тәмам иткәннән соң эш табарга булышалар. Ир балалар укуларын Александр исем. һөнәр уч-щесендә мәктәп хисабына дәвам итә алганнар.

Белем бирү өлкәсендә Х. советлары химаяче җитәкчелегендә Ун-т уставы буенча ревизияләр уздыралар (к. *Казан уку-укыту округы*). Х. аерым уку йортларында (гимназия, уч-щеләрдә) була. Фәкыйрьләргә ярдәм буенча Х.нең Казан ком-ты (к. *Кешелеклелек императорлык Казан ярлыларга ярдәм итү ком-ты*) карамагында башлангыч уч-ще, хуҗалык-кул эшләре мәктәбе һәм хатын-кызлар һәм балалар өчен вакытлыча тору урыны, кухня, арзанлы ашханә, чәйханә исәпләнә.

Россиядә фәкыйрьлеккә төшкән дин әһелләре өчен Х. 1813 тә гамәлгә куела: ул дин әһелләре гаиләләреннән булган толлар һәм ятимнәргә, ш.у. авыру чиркәү әһелләренә матди ярдәм күрсәтү максатында һәрбер епархиядә оештырыла.

Халык аеклыгын кайгырту Х.е 1894 нең 20 декабрендә, эчемлек сатуга дәүләт монополиясе кертелү б-н бер үк вакытта, эчкечелекнең зарары турындагы белемнәрне тарату максатында барлыкка килә. Акчалар казнадан, Х. басмаларын сатудан, җәмәгать укуларын үткәрүдән һәм театр тамашаларыннан керә. Х. кереме көчле эчемлекләрне сату кагыйдәләрен бозган өчен штрафлар; аерым кешеләрдән хәйрия кертемнәре б-н тулылана. Губерна ком-тына губернатор, архиерей, губерна дворяннары башлыгы, округ мәхкәмәсе рәисе һәм прокуроры, Казан дәүләт милке палатасы управляющие һ.б. түрәләр, табиблар керә. Өяз ком-тлары шул ук схеманы кабатлый. Мактаулы эгъзалыкка аерым хезмәтләр күрсәткән затлар сайлана, алар финанс министры тарафыннан раслана. Ярышучы эгъзалар ком-т утырышларында фикер белдерү хокукы б-н катнашалар. *Казан аеклар җәмгыятенә* хәйрия ярдәме күрсәтүчеләрнең берсе П.А.Столыпин була.

Х. ролен ш.у. опека һәм опекуннар советлары да үти. 1720 дә кече яшьтәге ятимнәр мөлкәтенә опекуннар билгеләү кагыйдәләре эшләнә. Опекуннар шәһәр кешеләре арасын нан билгелән куела, аларга ятимнәр биләмәсен император рөхсәтеннән башка сату тыела. 1750 дән акылдан язып юридик хокуксыз дип табылганнарның биләмәләре аларның варислары каравына тапшырыла. 1780 елларның 2 нче яртысында дворян катлавыннан булган толларга һәм ятимнәргә карата дворяннар опекасы бурычлары эшләнә. 1825 тән генерал-губернаторларга һәм хәрби губернаторларга рәхимсезлек яки әрәм-шәрәм итү сыйфатлары б-н танылган алпавытларның биләмәләренә опека булдыру хокукы бирелә.

1885 тә Казан сукырлар җәмгыяте ачыла. 1898 дә аның каршында уч-ще эшли башлый, анда 5 тән 20 гә кадәр ир һәм кыз балалар белем ала; аларны кәрзиннәр, паласлар үрергә һ.б., музыкага сәләте булганнарны — рояль көйләргә өйрәтәләр; кызлар бәйләү һәм чигү б-н шөгыльләнә; гомуми предметлар: рус теле, арифметика, тарих, геогр., ш.у. гимнастика, музыка, җыр, рәсем, әвәләү укытыла.

Чукрак-телсез балаларны тәрбияләү һәм укыту җәмгыятьләре Казанда 1883 тә Казан сәүдәгәре И.Я.Павловский инициативасы б-н ачыла; баштарак хосусый уку йорты буларак яшәп килә. Җәмгыятьнең уставы 1887 нең 17 апрелендә раслана. Шәхси кертемнәр һәм шәһәр җәмәгать идарәсе һәм земствосы акчасына тотыла. «Дәрәҗәгә һәм дини аерымлыкларга карамастан», чукрак-телсез ир һәм кыз балалар кабул ителә. Җәмгыять каршындагы уч-ще чукрак-телсез балаларны мөстәкыйль тормышка әзерли, аның беренче чыгарылышы 1891 дә була.

Х. 1990 елларда торгызыла башлый. Попечительләр советлары дәүләт учреждениеләрендә, музейларда, китапханәләрдә, уку йортларында оештырыла. 2000 нең 11 июнендә, балигъ булмаган гражданнарның шәхси һәм мөлкәти хокукларын һәм белем алу мәнфәгатьләрен яклау формасы буларак, Казан администрациясенең Мәгариф идарәсе каршындагы Мәгариф фонды попечительләр советы турында Нигезләмә раслана. 2008 нең 11 апрелендә РФ Дәүләт Думасы тарафыннан Опека һәм Х. турында закон кабул ителә; ул ятим нәр һәм эшкә яраксыз гражданнарны саклауны көчәйтә. Ш.у. к. *Иганәчелек, Ятимханәләр*.

Әд.: Россия: её настоящее и прошедшее. СПб., 1900; Высшие и центральные государственные учреждения России. 1901–1917 гг. СПб., 1998. Т. 1; Брокгауз Ф.А., Ефрон И.А. Энциклопедический словарь. СПб., 1898. Т. 24 А.

И.А.Новицкая.

ХИ́МИК КИНЕ́ТИКА, химик реакцияләр нең тизлекләре һәм механизмнары турындагы тәгълимат; физик химия бүлеге. Х.к.да химик реакцияләр тип буенча гадиләр һәм катлаулылар (ш.и. чылбырлылар), активация характеры буенча термик, фотохимик, радиацион-химик, электрохимик, каталитик реакцияләр буларак классификацияләнәләр. Формаль кинетика химик реакцияләр барышында реакциягә керүче матдәләрнең концентрациясе үзгәрешен тасвирлый. Хәрәкәт итүче массалар законы нигезендә реакциянең элементар стадиясе тизлеге $K[A]^n[B]^m$ га тигез. Биредә [A], [B] — реагентлар концентрацияләре, K — тизлек константасы, n һәм m — A һәм B атомнар микъдары. Тизлек константасын Аррениусның $K=K_0e^{(-E/RT)}$ тигезләмәсе (биредә E — активация энергиясе, R — газ константасы, T — абсолют температура, K_0 — экспоненция алды тапкырлаучы).

Химик реакцияләр тизлекләрен беренче булып систематок рәвештә тикшергән (1870 еллар) галим — рус химигы Н.А.Меншуткин; ул кушылмаларның реакциягә сәләте б-н аларның төзелеше арасында бәйләнешне, ш.у. эреткеч табигатенең химик әверелеш барышына йогынтысын тикшерә. Голландияле химик Я.Х.Ван-Гофф гади (моно-, би- һәм тримолекуляр) реакцияләр барышының кинетик закончалыкларын формалаштыра (1884). Актив молекулалар ролен һәм элементар реакцияләр тизлегенең температурага бәйле булуын швед химигы С.А.Аррениус билгели (1889).

Россия галимнәре катлаулы реакцияләр кинетикасында арадаш продуктларның һәм арадаш әверелешләрнең хәлиткеч ролен ачыклыйлар; газ фазасындагы реакцияләрнең һәм фотохимик реакцияләрнең кинетикасын, электрохимик кинетиканы тикшерәләр (А.Н.Бах, Н.А.Шилов, А.Н.Фрумкин һ.б.). Н.Н.*Семёнов* (1930 еллар) эшләгән чылбыр реакцияләре гомуми теориясе (инглиз физикохимигы С.Н.Хиншелвуд б-н бергә; Нобель бүләге, 1956) катлаулы химик процессларны өйрәнү өлкәсендә искиткеч зур казаныш була. Тармаклы чылбырлы реакцияләр теориясе химик процесслар б-н идарә итү, ягъни аларны тизләтү, әкренәйтү, теләсә нинди стадиясендә өзү мөмкинлеге бирә. Семёнов җылылыклы шартлау һәм газ кушылмалары яну теориясен эшли, алга таба шәкертләре б-н берлектә ялкын таралу, детонация, шартлаткыч матдәләр һәм дары яну турындагы тәгълиматны үстерә.

Татарстанда кинетик тикшеренүләр Казан химия мәктәбе өчен традицион булган чиксез кушылмалар химиясе, элементорганик химия, электр химиясе, полимерлар химиясе һәм энергия б-н туендырылган кушылмалар кебек өлкәләрдә алып барыла. Чиксез кушылмалар химиясен тикшергәндә терпеннар, кареннар, пиненнар табигый кушылмаларының реакциягә керү мөмкинлеге (Б.А.Арбузов хезмәткәрләре б-н бергә), цикл кушылу реакцияләре механизмнары (А.И.Коновалов, В.Д.Киселёв, И.С.Антипин, Б.Н.Соломонов, Я.Д.Самуилов һ.б.) өйрәнелә. Элементорганик химия өлкәсендә мышьякорганик (Г.Х.Камай, Б.Д.Чернокальский, В.А.Гаврилов һ.б.) һәм фосфororганик (А.Н.Пудовик, Р.Ә.Черкасов, В.И.Галкин һ.б.) кушылмалар реакцияләренең кинетикасы тикшерелә. Гетерофазлы сополимерлашуның кинетикасы һәм топологиясе (В.А.Мягченков), нитролаштыру кинетикасы (Г.С.Марченко, А.В.Косточко, Г.П.Шарнин, А.Д.Николаева), күкерт кушылмаларының металл комплекслы һәм гетероген катализаторлар б-н сыек фазалы оксидлашу кинетикасы (Ә.М.Мазһаров), термодеструкция кинетикасы (Г.М.Храпковский), электродлы процесслар кинетикасы (Ю.М.Каргин, В.П.Барабанов, Р.С.Сәйфуллин һ.б), суда эрүчән полимерлар синтезы кинетик закончалыклары (В.Ф.Куренков) өйрәнелә. Кинетиканы тикшерү нәтиҗәләре химик процессларны идарә итүнең рациональ принципларын эшләү, файдалы химик реакцияләрне стимуллаштыру, кирәкмәгәннәрен туткарлау (бастыру), химик технологиядә гамәлдә булган процессларны һәм аппаратларны камилләштерү, яңаларын булдыру өлкәләрендә кулланылыш таба. Диеннарны, ацетофенонны, альфа-метилстиролны гидрирлау, этилбензолны оксидлаштыру кинетикасы буенча фәнни эшләр (Б.Р.Серебряков, А.Ш.Зыятдинов, Х.Э.Харлампиди һ.б.), полимеризация тизлегенә ингибиторлар йогынтысы һәм изопрен, бутадиен, стирол җитештерүдә стабильләштерүче системалар булдыру буенча хезмәтләр (П.А.Кирпичников, А.Г.Лиакумович һ.б.; СССР Дәүләт бүләге, 1989) «Түбәнкаманефтехим» пр-тиесендә гамәлгә кертелә. Нефтьне, газны, нефть продуктларын һәм ташландык суларны күкертле газлардан чистарту технологияләре 2005 тә РФ Хөкүмәте бүләгенә лаек була (Ә.М.Мазһаров, А.Ф.Вилданов һ.б.). Бу технологияләр буенча Россиядә һәм БДБ илләрендә 50ләп сәнәгый корылма, Иранда 20 шундый корылма төзелә (2004 тән). Химик кинетика өлкәсендә тикшеренүләр Казан ун-ты, РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында, Казан технол. ун-тында, Бөтенроссия углеводород чималы фәнни-тикшеренү ин-тында, РФА КГҮнең Казан физика-техника ин-тында, Химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында һәм Татарстанның башка фәнни оешмаларында алып барыла.

Әд.: Э м а н у э л ь Н.М., К н о р р е Д.Г. Курс химической кинетики. М., 1969; Б а р а б а н о в В.П. Казанский химико-технологический институт — продолжатель традиций Казанской химической школы // Казанский химико-технологический институт: вчера, сегодня, завтра. К., 1990. Ч.1.

ХИ́МИК РЕА́КЦИЯЛӘРДӘ МАГНИ́Т-СПИН КҮРЕНЕШЛӘРЕ́, химик реакцияләрдә спиннар һәм электрон б-н төшләрнең магнит моментлары күренешләре. Мо ңа химик реакцияләрнең элементар актлары өчен актуаль булган сайланыш кагыйдәләре шарт булып тора. Иң тирән тикшерелгән Магнит-спин күренешләре МСК радикаль реакцияләргә карый. МСК фәндә яңа юнәлеш — спин химиясе өчен нигез була. СССР галимнәре бу фән өлкәсенең формалашуы һәм үсешенә зур өлеш кертә. Магнит-кыр күренешен (МКК) беренче булып Ренад З. Сәгъдиев хезмәткәрләре б-н СССР ФА Себер бүлегенең Химик кинетика һәм янучанлык ин-тында (Новосибирск ш., 1972), магнит-изотоп күренешен (МИК) — Ренад З. Сәгъдиев һәм Ю.Н.Молин хезмәткәрләре б-н СССР ФА Себер бүлегенең Химик кинетика һәм янучанлык ин-тында (Новосибирск, 1976), А.Л.Бучаченко һәм хезмәткәрләре СССР ФАнең Химик физика ин-тында (Мәскәү, 1976) күзәтәләр. МКК һәм МИКне беренче эксперименталь күзәтүнең аңлатмасын К.М.Салихов бирә; ул ш.у. көчсез магнит кырлары өлкәсендә радикаль парлар рекомбинациясе ихтималлыгының кырга бәйле булуы экстремаль характерын теоретик яктан алдан әйтә, көчсез магнит кырларындагы төш спиннарының химик полярлашуы законча лыкларын билгели, төшләрнең полярлашуга үзара йогынты ясаулары күренешен теоретик җәһәттән әйтеп бирә. К.М.Салихов, Ренад З.Сәгъдиев, Ю.Н.Молин төш спиннарын стимуллаштырылган полярлаштыру механизмын тәкъдим итәләр һәм аның нигезендә кыска гомерле радикаль парларның ЭПР спектрларын теркәү алымын үстереп җибәрәләр (Новосибирск, 1980). Төшләрнең химик полярлашу (ТХП) күренешен (фосфор-31 төшләрендә) беренчеләр булып А.В.Ильясов һәм Я.А.Левин СССР ФАнең Органик һәм физик химия ин-тында (Казан, 1972) күзәтәләр. МСК буенча эш РФА КГҮнең Физика һәм техника ин-тында дәвам ителә: фотосинтез реакцияләре үзәгендә бүленгән зарядлар өчен ЭХП (электроннарны химик полярлаштыру) күренешләре теориясе үстерелә, радикаль парларда һәм триплетлы ярсынган молекулалардагы электрон спиннарның тигез булмаган полярлашуын тикшерү өчен хәл ителгән вакытлы ЭПР-спектроскопия җайланмасы булдырыла, тоткарланган флуоресценциянең сәбәпчесе булган триплетларның үзара аннигиляциясе нәтиҗәсендә триплет халәтләрендәге электрон спиннар полярлашуының яңа механизмы тәкъдим ителеп, тәҗрибә юлы б-н исбат ителә.

МСК химик реакцияләрнең механизмын җентекләп тикшерү өлкәсендә, ш.и. фотосинтезның беренчел стадиясендә зарядларның бүленүен өйрәнү өчен кулланыла, ш.у. радикаль парлар, биорадикаллар, ярсынган триплет молекулалар кебек кыска гомерле арадаш халәтләрнең ЭПР спектрларын яңа теркәү алымнарын булдыруда нигез була.

Әд.: Б у ч а ч е н к о А.Л., С а г д е е в Р.З., С а л и х о в К.М. Магнитные и спиновые эффекты в химических реакциях. Новосиб., 1978; С а л и х о в К.М. 10 лекций по спиновой химии. К., 2000; Spin Polarization and Magnetic Effects in Radical Reactions. Amst., 1984; S a l i k h o v K.M. Magnetic isotope effect in radical reactions. W.–N.Y., 1996.

К.М.Салихов.

ХИ́МИК ТӨЗЕЛЕ́Ш ТЕО́РИЯСЕ, органик кушылмалардагы молекулада атомнар һәм бәйләнешләр урнашуының эзлеклелеген (тәртибен), аларның тәэсир итешүен, ш.у. матдәләрнең физик һәм химик үзлекләре аларның төзелешенә бәйле булуын тасвирлаучы нигезләмәләр системасы. Беренче тапкыр Х.т.т.н А.М.*Бутлеров* Шпейер шәһәрендә (Германия) Немец табигыять галимнәре корылтаенең химия секциясендә «Матдәләрнең химик төзелеше турында» («О химическом строении веществ», 1861) дигән докладында бәян итә (1861). Аңарчы атом, молекула кебек төшенчәләр (1 нче Халыкара химиклар конгрессы, Карлсруэ, 1860), валентлык һәм органик кушылмаларны график формулалар рәвешендә күрсәтү (немец химик-органигы Ф.А.Кекуле, шотландияле химик А.С.Купер) билгеләнә. Х.т.т.нең төп нигезләмәләре: 1) органик молекулаларда атомнар валентлыкларына карап билгеле тәртиптә бер-берсенә кушыла, бу исә молекулаларның химик төзелешен билгели; 2) органик кушылмаларның химик һәм физик үзлекләре алар составына керүче атомнарның табигатенә һәм санына, ш.у. молекулаларның химик төзелешенә бәйле; 3) һәр эмпирик формула өчен теоретик яктан мөмкин булган билгеле сандагы структуралар (изомерлар) чыгару мөмкин; 4) һәр органик кушылманың химик төзелеш формуласы бар, ул исә бу кушылманың үзлекләрен күзалларга мөмкинлек бирә; 5) молекулаларда үзара бәйләнешле яки бәйләнешсез атомнар бер-берсенә тәэсир итә. Бу теоретик нигезләмәне Бутлеров шәкерте В.В.*Марковников* һәм аннан соң башка галимнәр дә (к. *Марковников кагыйдәсе*) үстерә. Молекуладагы атомнарның фәзада ничек урнашуын билгеләү мөмкин дигән фаразын алга сөргән Бутлеров хаклы булып чыга. Алга таба химик бәйләнешләрнең фәзаи ориентациясе турындагы тәгълимат (*сте-*

реохимия) ул вакытта ук мәгълүм булган, ләкин химиклар аңламаган геом. һәм аеруча оптик изомерия очракларын, ш.у. таутомерия күренешләрен аңлатуга юл ача. Бутлеров берничә органик кушылманы синтезлап теориясенең дөреслеген исбатлый. Х.т.т. органик кушылмалар синтезы һәм алдан мәгълүм булган матдәләр төзелешен билгеләү өлкәсендә фаразлау үзенчәлегенә ия була, бу исә химия фәне, ш.и. синтетик органик химия һәм химия сәнәгате үсешенә көчле этәргеч бирә. Алга таба үсеш барышында Х.т.т. органик химияне бензолның циклик төзелеше, аның молекуласында икеле бәйләнешләрнең күчүе, иярешле бәйләнешле кушылмаларның махсус үзлекләре турындагы яңа мәгълүматлар б-н баета. Стереохимия алгарышы циклларның төрле тотрыклылыкка ия булуын, аларның зурлыкларына бәйләп аңлатучы киренкелек теориясен тудыра һәм аннан соң *конформацион анализ* барлыкка килүенә сәбәпче була. Х.т.т.нең төп нигезләмәләре органик кушылмаларны химик, физик һәм хисаплау алымнары кулланып тикшерү нәтиҗәсендә раслана. Органик кушылмалар молекулаларындагы атомнарның үзара йогынтысы хакындагы фикерләр Х.т.т.дә төп әһәмияткә ия. Әмма ләкин теория бу йогынтының килеп чыгышын, аның эчке механизмын, «валентлык» һәм «химик бәйләнеш» төшенчәләрен аңлата алмый. Органик химиядә электрон нарга бәйле күзаллаулар (ионнарны, ион һәм ковалент бәйләнеше табигатен электрон яссылыгыннан чыгып аңлатулар) атомнарның үзара йогынтысын молекулада электрон тыгызлыкның статик һәм динамик күчеше сәбәбе б-н аңлатуга юл ача, реакцияләр юнәлешен реагентларның химик төзелешенә карап фаразлау мөмкинлеге бирә. 1920 еллар ахырыннан башлап химик бәйләнеш турында квант химиясе принципларыннан чыгып фикер йөртелә. Х.т.т. органик кушылмалар номенклатурасы һәм систематикасы нигезендә ята, структуралы формулаларны куллану исә яңа матдәләрне синтезлау юлларын табарга һәм катлаулы (ш.и. табигый) кушылмаларның төзелешен белергә ярдәм итә.

Әд.: Быков Г.В. История классической теории химического строения. М., 1960; БСЭ. 3 изд. М., 1978. Т. 28. *В.Г.Абзалова.*

ХИ́МИЯ, химик кушылмалар, аларның үзлекләре, әверелешләр (химик реакцияләр) һәм бу әверелешләрне идарә итү ысуллары турындагы фән. Химик реакцияләр дип бары тик химик кушылмалар катнашында, ш.у. матдә оешуының башка төрле кимәлдәге (мәс., электр тогы тәэсирендә су таркалу) объектлар катнашында үткән процесслар ата ла. Реакция вакытында бер химик кушылманың молекулалары башка кушылмаларның молекулалары б-н үзләрен тәшкил итүче өлешләрен алмашалар (алмашу реакцияләре) яки атом төшләре саны азрак булган молекулаларга таркалалар (таркалу реакцияләре) яисә башка кушылмаларның молекулалары белән бәйләнешкә кергәндә катлаулырак матдәләр барлыкка китерәләр (кушылу реакцияләре). Химик реакция вакытында анда катнашкан кушылмаларның электрон структурасы үзгәрә, атом төшләре исә үзгәрми. Х.нең үсешен 2 этапка бүлү мөмкин. Беренчесе (19 йөзнең 1 нче яртысы) түбәндәге периодлардан тора: эмпирик фактлар туплау һәм беренчел төшенчәләр формалаштыру чоры, «алхимия» чәчәк аткан чор, флогистон теориясе хакимлек иткән чор, тикшеренүнең микъдари алымнарын үстерү чоры һәм Х.нең фән буларак формалашу чоры. Икенче этапта (19 йөзнең 2 нче яртысы — 20 йөзнең 1 нче декадасы) химиянең төп законнары ачыла һәм аның иң мөһим теоретик концепцияләре булдырыла; химик кушылмаларның составын һәм төзелешен анализлауның физик-химик алымнары, структураларының һәм бәйләнешләренең спецификасын хисаплауның квант-химик алымнары (алар химик тикшеренүләрнең традицион алымнарына караганда өстенлек казана) эшләнә һәм гамәлгә кертелә; матдәләрнең саф химик үзлекләрен өйрәнүдән аларның физик-химик (электр, магнит, спектраль һ.б.) үзлекләрен тикшерүгә күчеш ясала. Х.нең төп бүлекләре — нәорганик химия, органик химия, аналитик химия, физик химия. Х.нең Татарстандагы үсеше Казан ун-тында тәүге химия лаб-ясе ачылу (1806) б-н бәйле. Анда платина рудасын тикшерү (К.К.Клаус), хуш исле нитрокушылмаларны торгызу (Н.Н.Зинин) буенча төпле нәтиҗәләр алына; органик кушылмаларның *химик төзелеше теориясе* (А.М.Бутлеров) һәм химик кушылмаларда атомнарның үзара тәэсир итешүе тәгълиматы (В.В.Марковников), ш.у. төзелеш теориясен куллану өлкәсе киңәйтелә (А.М.Зайцев). Бу тикшеренүләр Казанда *органик химия*, *нәорганик химия*, *аналитик химия* алгарышына этәргеч бирә. 1840–1900 елларда дөньякүләм шөһрәт казанган *Казан химия фәнни мәктәбе* формалаша. 1900 елларда *физик химия*, *электрохимия* буенча, 1940 елларда *координацион химия*, *нефть химиясе* өлкәләрендә интенсив тикшеренүләр башланып китә. Казан галимнәре *фосфорорганик кушылмалар, югарымолекуляр кушылмалар, мышьякорганик кушылмалар, элементорганик кушылмалар, күкерторганик кушылмалар* Х.нә, *фосфорорганик дару кушылмалары, композицион электрохимик капламнар*, пиротехник составлар, *дары, шартлаучан матдәләрне* булдыруга зур өлеш кертәләр; *химиядә физик тикшеренү ысуллары, стереохимия, конформацион анализ, квант химиясе* киң кулланыла. *Электроаналитик химия*, электроорганик химия, фуллереннар химиясе, супрамолекуляр химия үсеш ала. Химия технологиясе өлкәсендә уңышларга ирешелә. Химик тикшеренүләр алып барган төп фәнни үзәкләр — *Казан университеты*, Казан ун-тының *Бутлеров А.М. исемендәге химия институты, Органик һәм физик химия институты (ИОФХ), Казан технология университеты, Химия продуктлары институты, Казан химия институты*, Идел углеводород чималы ин-ты, *Полимерлар һәм махсус каучуклар институты, Казан фотоматериаллар институты*, вузларның, тармак фәнни-тикшеренү ин-тларының лаб-яләре, «Түбәнкаманефтехим» акционер җәмгыятенең һ.б. пр-тиеләрнең фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә эшләре идарәләре.

Әд.: Штрубе В. Пути развития химии: В 2 т. М., 1984; Соловьёв Ю.И., Курашов В.И. Химия на перекрёстке наук: Исторический процесс развития взаимодействия естественнонаучных знаний. М., 1989; Сироткин О.С. Начала единой химии. К., 2003.

О.В. Михайлов.

ХИ́МИЯ ЗАВОДЫ́, Куйбышев исем., к. «*Тасма*».

ХИ́МИЯ ЗАВОДЫ́, Л.Я.Карпов исем., ТР һәм РФ химия сәнәгате пр-тиеләренең берсе, нәорганик химия продукциясен эшләп чыгару буенча махсуслаша. Менделеев шәһәрендә урнашкан. Эшләүчеләр саны 1308 кеше (2017).

1868 елда Капитон Яковлевич һәм Пётр Капитонович Ушковлар тарафыннан Бондюг химия з-ды буларак нигезләнә. 1918 дә национализацияләнә. 1921 дән — Л.Я.Карпов исеме бирелә. 1967 дә Л.Я.Карпов исем. Менделеев химия з-ды итеп үзгәртелә. 1988 дән «Л.Я.Карпов исем. химия заводы» ҖБ. 1994 тән АҖ.

Пр-тиедә Россиядә беренче буларак нәорганик химия продуктларын — күкерт (20 йөз башында илдә җитештерелгән әлеге продукциянең яртысын эшләп чыгара) һәм тоз к-таларын, хлор, синтетик натрий сульфатын, сода, хлорлы кальций, суперфосфат, пироколлоид һәм төтенсез дары (Д.И.Менделеев технологиясе буенча) җитештерү оештырыла. Эшне үрнәк тәртиптә кору һәм алдынгы технологияләр куллану нәтиҗәсендә 19–20 йөзләр чигендә күәтле җитештерү комплексына, Россиядә иң алдынгы нәорганик химия пр-тиесенә әверелә. Завод продукциясе күп тапкырлар күргәзмәләргә куела һәм С.-Петербургта, Мәскәүдә, Түбән Новгородта, Чикагода, Филадельфиядә, Венада, Парижда (ш. и. 1878 елгы Бөтендөнья күргәзмәсендә) бүләкләргә лаек була. 1916–17 дә тимер һәм бакыр купорасы, сыек хлор, хромлы ачуташ, бакыр һәм техник хлороформ җитештерү җайга салына; глинозём (алюминий оксиды) сульфаты производствосы яңартып җиһазландырыла. 1921–25 тә Радий ин-ты (Ленинград) өчен Россиядә беренче тапкыр илдәге чималдан радий тозлары эшләп чыгарыла башлый. Заводның аякка басуына илнең атаклы галимнәре Д.И.*Менделеев*, Д.Н.Прянишников, В.Г.Хлопин, П.П.Федотьев, К.Г.Дементьев, Б.И.*Збарский* һ.б. зур өлеш кертәләр.

Бөек Ватан сугышы елларында завод оборона ихтыяҗлары өчен эшли, 20 дән артык яңа төр оборона продукциясе чыгара. 1959–90 да барий окисе гидраты, углекислый һәм барий сульфаты, хлорлы кальций, эретмәләрне чит катнашмалардан арындыру өчен флюслар, техник һәм индикатор силикагеле, фото ачыклагычлар һ.б. реактивлар производстволарны файдалануга тапшырыла; әйләнешле су тәэминаты һәм фильтрлау станцияләре, биол. чистарту корылмалары, агып җыелган суларны эшкәртү бүлекләре эшкә кертелә; хлорлы барий цехы яңа технологиягә күчерелә, бу атмосферага зарарлы матдәләр чыгуны күпкә киметергә мөмкин -





Л.Я. К а р п о в исемендәге химия заводы. 1. Завод идарәсе бинасы. 2. Барий тозлары җитештерү. 3. Полимерлар эшкәртү цехы.

лек бирә. 1990 еллардан җитештерүдә дивер - сификация гамәлгә ашырыла. Җылылык саклаучы төзелеш материалы күбекле полистирол, парафинлы җи нел углеводородларны судан арындыру катализаторы, утырма тау токымнарыннан вак ташлар, ОПЦ -200 кор - розия ингибиторын җитештерү оештырыла. 2005 тән заводның продукция сыйфаты менеджменты халыкара ISO 9000 стандарты таләпләренә җавап бирә.

Пр-тие структурасын 11 төп производство, 8 ярдәмче цех һ.б. подразделениеләр тәшкил итә. Химия з-ды 40 тан артык исемдә нәорганик химия продукциясе (1 елга — *m*) — нат - рий сульфаты һәм тиосульфаты (тиңдәшле рәвештә 5000 нән һәм 4000 нән артык), хлорлы кальций (5000 тирәсе), магний сульфаты (3000 нән артык), техник силикагель (3000 тирәсе), катализатор (1000 тирәсе), аккуму - ляторлар өчен барий сульфаты (500 дән ар - тык), магний һәм барий фармакопея сульфатлары (тиңдәшле рәвештә 400 тирәсе һәм 300 дән артык) һ.б. эшләп чыгара. Чимал б-н илнең 30 дан артык пр-тиесе, ш. и. «Түбәнка - манефтехим» АҖ, «Татнефть–АЗС Центр» ҖЧҖ (Әлмәт ш.) тәэмин итә. Продукцияне кулланучылар: РФнең һәм чит илләрнең (Белоруссия, Казакъстан, Үзбәкстан, Польша) нефть чыгару, газ эшкәртү, төзелеш, азык-төлек, текстиль, күн җитештерү, пыяла, кино-фотография сәнәгатьләре пр-тиеләре. За - вод — шәһәр төзүче пр-тие, Менделеев шәһәрендә торак, мәгариф, сәламәтлек саклау системаларына караган, социаль-мәдәният, спорт юнәлешендәге объектлар һ.б. төзелешендә төп заказчы.

Пр-тие Хезмәт Кызыл Байрагы ордены (1968), «Европаның алтын призы» (Париж, 1996), халыкара күргәзмәләр дипломнары б-н бүләкләнә. Күп кенә хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә лаек була: СССР Дәүләт бүләге лауреаты — 1, ТАССР, ТРның атказ. хи - мигы — 29, РСФСР, РФнең мактаулы химигы — 19, ТРның атказ. төзүчесе — 1, ТРның атказ. икътисадчысы — 1 кеше; 80 кеше — Ленин ордены, 5 кеше — Октябрь Револю - циясе, 90 кеше — Хезмәт Кызыл Байрагы, 1 кеше — Халыклар дуслыгы, 28 кеше — «По - чёт билгесе», 20 кеше — 3 нче дәрәҗә «Хезмәт Даны», 2 кеше — 2 нче дәрәҗә «Хезмәт Даны» орденнары, 3260 тан артык кеше медальләр б-н бүләкләнә.

Пр-тие җитәкчеләре арасында — П.К.Ушков (1868–98), И.П.Ушков (1898–1915), Л.Я.Карпов (1915–18), Е.И.Микитон (1928–32), И.И.Мардер (1934–37), В.Ф.Вольнов (1937–40, 1944–57), Н.И.Тимкин (1958–62), И.Г.Лексин (1962–75), Д.П.Иванов (1975–83), Х.В.Мостафин (1985–91), Л.Х.Фәйрушин (1991–95), В.М.Бусыгин (1995–99), Л.Г.Гайсин (1999–2003), Д.Р.Шәмсин (2003 тән).

Әд.: К а ш и н С.Г., В о л к о в Р.В., Т а ш - к о в с к и й А.Б. Есть на Каме завод: Очерк о революционных и трудовых делах бондюжских рабочих. К., 1965; Г л у х о в М.О. О Бондюге и бондюжцах. К., 1994; С а б и р о в А. Менделеевский самоцвет. К., 1998.

М.Ж.Гаитов, Г.Я.Мәүлетова, С.Г.Белов.

ХИ́МИЯ ПРОДУ́КТЛАРЫ ИНСТИТУ - ТЫ́, Россия сәнәгать һәм энергетика агентлыгының дәүләт фәнни-тикшеренү ин-ты (ХПФТИ), 1941 елда Казан В.И.Ленин исем. з-ды янында 40 нчы Махсус техник бюро (МТБ-40) буларак формаштырыла. Ул 1938 дә төзелгән, 1941 дә исә Казанга эвакуацияләнеп, НИИ-6 (Мәскәү) янында оештырылган СССР НКВДсының 4 нче махсус бүлегендәге Махсус техник бюро базасында төзелә. 1947 дән — СССР А. х. машиналары төзү министрлыгының 3 нче Баш идарәсе карамагындагы мөстәкыйль оешма, 1965 тән НИИ-40, 1966 да Казан химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-ты дип исемләнә, 1992 дән хәзерге исем б-н атала, 2001 дән — федераль дәүләт унитар пр-тиесе (ФДУП ХПФТИ), 2002 дән — федераль фәнни-җи - тештерү үзәге. 1992 гә кадәр ин-тның Шост - ка шәһәрендә (Украина) һәм Ташкентта ф-ллары була.

ХПФТИ Россиядә химия, целлюлоза һәм аның нитратлары, пироксилинлы һәм сфе - рик дары рецептурасы һәм технологияләре, артиллерия өчен югары энергияле тиз янучан, термик чыдам дары, янып бетүче гильзалар, махсус бөкеләү типлары өлкәсендә; ш.у. танк, танкка каршы, кыр һәм диңгез артиллериясе өчен снарядлар, проектлау, якын арадагы сугыш системалары, миномётлар, 5,45 тән 240 *мм* га кадәр калибрлы авиация, зенит һәм ату кораллары проектлау өлкәсендә эшләүче оешмаларның әйдәп баручыларыннан санала.

1941–45 тә МТБ-40 җитештерү процессы б-н турыдан-туры бәйле фәнни-техник үзәк ролен үти. Яңа төрле дары җитештерү өчен рецептуралар һәм технологияләр эшләнә, ок - купацияләнгән территорияләрдә калган дары заводларында элек җитештерелгән зарядларга алмашка миномёт һәм ракета системалары өчен атылгыч зарядлар (ш.и. «Катюша» залп уты ракета системасында кулланылган М-8, М-13 снарядлары) конструкцияләнә. Ленд-лиз буенча кайтарылган инглиз һәм Америка дарыларын СССРда җитештерелгән артиллерия һәм җиңел корал системаларында куллану мәсь әләләре хәл ителә; артиллерия һәм җи нел коралларның ватан һәм чит ил системалары өчен атылгыч зарядларны проектлау һәм хисаплауның ышанычлы инже - нерлык алымнары булдырыла. Сугыш шартларында сериялe заводларда дары һәм заряд ясау һәм сынау барышында килеп чыккан техник һәм технол. мәсьәләләр хәл ителә. Бөек Ватан сугышы елларында Совет Армиясен һәм Хәрби-диңгез флотын сугыш кирәк-яраклары б-н тәэмин итүдә ирешкән казанышлары өчен В.И.Ленин исем. з-д (аның эчендә МТБ-40 та) 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ор - дены б-н бүләкләнә. 1955–75 тә пироксилин һәм пироксилинлы дары җитештерүнең өзлексез технологияләре эшләнә һәм тармак заводларында гамәлгә кертелә, вак төерле пироксилинлы дары җитештерү буенча документация производствога тапшырыла. Сферик дары җитештерүче ярымзавод рәвешендәге корылма эксплуатациягә, танк пушкасы өчен корпусы янучан гильзадагы атылгы зарядлар — сериялe җитештерүгә тапшырыла. Аучылар өчен пироксилинлы дары («Фазан», «Беркут») җитештерүнең рецептура - сы һәм технологиясе, «щётка» конструкцияле дары һәм заряд, аларны якыннан торып сугышу системаларына көйләп җыю технологиясе, снаряд элементлары өчен сәнәгый технол. һәм конструктлау алымнары эшләнеп гамәлгә кертелә.

1975–90 елларда атылгыч зарядларны сынау, баллистик хисаплаулар һәм хәзерге заман проектлау алымнары булдырыла. Авиация артиллериясе системалары өчен дөнья - да беренче тапкыр буларак атылгыч зарядлар эшләнә. Целлюлоза, эре төерле һәм көпшәле дары, киң номенклатуралы сферик дары җитештерүнең өзлексез технологияләре эшләнә һәм гамәлгә кертелә. Кыр, танк һәм диңгез ар - тиллериясе системалары өчен атылгыч зарядлар гамәлгә кертелеп гаскәргә корал итеп алына, янучан каты картузлы яңа зарядлар булдырыла. Зарядларга конструктив табыш-

лар һәм оригинальлек хас, нәтиҗәлелек буенча алар иң яңа чит ил үрнәкләреннән дә калышмый, я алардан өстен чыга. Күп кенә дары төрләре һәм зарядлар НАТО һәм АКШ илләренең җиңел корал һәм артиллерия системаларына яраклаштырыла. Конверсия юнәлешләре: гражданнар һәм хезмәткәрләр кораллы, төзелеш-монтаж патроннары һәм махсус билгеләнешле патроннар өчен дары һәм зарядлар эшләү, целлюлозадан порошоксыман материаллар, ш.и. микрокристаллик целлюлоза, сферик целлюлозалы сорбентлар, мембраналар, фильтрлар һәм аларны җитештерү технологияләре; целлюлоза һәм аның нитратлары нигезендә халык кулланышы товарлары (лаклар, буяулар, җилем композицияләре, кыстырма һәм төргәкләү эшләнмәләре) эшләү; фейерверк өчен эшләнмәләр җитештерү буенча эшләр җәелдерелә.

Ин-т РФАнең фәнни оешмалары, тармак ин-тлары, Россия ун-тлары, чит ил партнёрлары б-н иҗади һәм сәнәгый бәйләнештә тора. ХПТФИдә фәнни-техник совет, докторлык һәм кандидатлык диссертацияләре яклау советы, аспирантура, техник укыту бүлеге эшли. Уйлап табуга 2 меңнән артык авторлык таныклыгы һәм патент алына. СССР һәм РФ Дәүләт бүләгенә 19 кеше (Гиндич В.И. — ике тапкыр), СССР МК бүләгенә — 14, РФ Хөкүмәте бүләгенә — 11, Ленин исем. комсомол бүләгенә — 4 кеше лаек була. Ин-т хезмәткәрләренә ВДНХның 6 алтын, 35 көмеш, 102 бронза медале; Бөтендөнья уйлап табулар, фәнни тикшеренүләр һәм сәнәгый инновацияләр «Брюссель — Эврика-94» салонының 2 бронза медале һәм дипломнары (конверсия юнәлешендәге эшләре өчен); Мәскәү халыкара корал күргәзмәсенең дипломнары (1997,1998); бөтенсоюз, федераль һ.б. күргәзмә һәм конкурсларның медальләре һәм дипломнары бирелә. 2 кеше РФнең атказ. фән һәм техника эшлеклесе почётлы исеменә, 5 кеше ТРның шундый ук исеменә, 3 кеше РФнең атказ. уйлап табучысы һәм рационализаторы исеменә, 7 кеше ТРның шундый ук исеменә, 3 кеше РФнең атказ. машиналар төзүче исеменә, 8 кеше ТРның шундый ук исеменә, 3 кеше ТРның атказ. химигы исеменә лаек була; 200 дән артык хезмәткәр төрле хөкүмәт бүләкләре б-н бүләкләнә. Ин-тта төрле елларда РФ һәм ТРның 5 академигы һәм мөхбир-әгъзасы, 22 фәннәр докторы һәм 150 чамасы фән-нәр кандидаты эшли. Фәнни тармак үсешенә М.С.Горохов, Г.Н.Марченко, Ф.Ф.Газизов, Г.Г.Валеев, М.Ф.Йосыпов, В.Ф.Сопин, Б.А.Соков, Б.И.Щипачёв зур өлеш кертәләр. Оешма җитәкчеләре: В.Б.Осипов (1938–41 дә НИИ-6 янында МТБ оешкан вакытта СССР НКВДсының 4 нче махсус бүлек башлыгы урынбасары), М.И.Левичек (1941–43, 1946–47), А.В.Грязнов (1948–49, 1967–75), М.М.Тропп (1949–51), П.М.Потапов (1951–55), К.В.Емельянов (1955–67), Г.Н.Марченко (1975–92), Ф.Ф.Газизов (1993–94, 1997–2001), М.Ф.Йосыпов (1994–97), В.Ф.Сопин (2001–2007), Ю.М.Михайлов (2007–2008), Р.Ф.Гатина (2008 дән).

Әд.: Бельдер М.А. Сборник аннотаций по работам, выполненным институтом за период 1939–67 гг. К., 1967.

В.Г.Абзалова.

ХИ́МИЯ СӘНӘГАТЕ́, технологияләре нигезендә чималны эшкәртүнең һәм төрле матдәләр алуның химик алымнары яткан җитештерү пр-тиеләре комплексы; Татарстан сәнәгатенең иң борынгы һәм аеруча мөһим тармакларыннан берсе. Респ-каның Х.с.ндә синтетик материалларны һәм алардан эшләнмәләрне органик химик юл б-н җитештерү әйдәп баручы юнәлеш булып тора. Нәорганик (төп) химик юл б-н к-талар, селтеләр, тозлар җитештерү, ш.у. нефть продуктлары, лаклар һәм буяулар җитештерү, химия-фарм., фотохимия, резина-техник, көнкүреш химиясе, минераль ашламалар, шартлаткыч матдәләр эшләп чыгару тармаклары шактый алга киткән. Татарстан Респ-касы химия комплексы пр-тиеләре киң ассортиментлы продукция — ягулык-майлау материаллары, минераль ашламалар, бензол, фенол, стирол, этилен, ясалма каучук, төп химия матдәләре, химик җепселләр һәм җепләр, синтетик сумалалар һәм пластик массалар (ш.и. полиэтилен, полипропилен), пластмасса эшләнмәләр (тәрәзәләр һәм аларның полимер тартмалары, ишекләр һәм аларның полимер тартмалары, башка полимер эшләнмәләр), пыяла-җепселле материаллар, лак-буяу продукциясе, фото материаллары, төп органик синтез продуктлары, техник углерод, шиннар һәм резина эшләнмәләр, органик өслек-актив матдәләр, сабын һәм юу чаралары, парфюмерия һәм косметика чаралары, фарм. продукциясе җитештерә.

Төбәктә химия нигезендә махсус җитештерү дары эшләп чыгарудан башлангыч ала. 16 йөзнең 2 нче яртысында, Казан ханлыгы Рус дәүләте тарафыннан яуланганнан соң, ул эш — Казандагы «яшел утар»да, 17 йөздә — Казан өязенең Кадышево авылындагы заводта (1707 елда ябыла), 1788 дән Екатерина II указы б-н төзелгән, илдәге иң эре пр-тиеләрнең берсенә әверелгән *Казан дары заводын-да* җайга салына. Дары пр-тиеләрен селитра б-н тәэмин итү өчен 17 йөз ахырында Казан өязенең Успенское авылында аны җитештерәчәк эре казна з-ды нигезләнә (1763 тә анда 360 тан артык кеше эшли).

18 йөзнең 2 нче яртысында сабын җитештерү һәм балавыз шәмнәр эшләп чыгару киң тарала; 19 йөз башында Казан губернасының хосусый сабын кайнату пр-тиеләрендә илдәге барлык сабынның 45% ы җитештерелә.

Капиталистик мөнәсәбәтләр үсеше нәтиҗәсендә катлаулырак химик продукциягә ихтыяҗ арта. К.Я. һәм П.К.Ушковлар һәм аларның варислары тарафыннан Вятка губернасы Алабуга өязенең Кокшан (1850) һәм Бондюг авылларында төзелгән химия з-длары илдә нәорганик химик матдәләр җитештерүче туллы технол. цикллы иң эре комплекс хасил итәләр. Ул Европада башлап хром кушылмалары җитештерүче үзәкләрнең берсе була, Россиянең эчке базарында хромпикка, күкерт һәм тоз к-таларына, тимер һәм бакыр купоросына, күкертле ачы чернозёмга, ачы ташка, натрий сульфатына, хлорга, содага һ.б.га ихтыяҗны асылда тулысынча тәэмин итә. Аның продукциясенең зур өлеше чит илләргә җибәрелә. 1868 дә Казан губернасындагы утарында И.Лихачев Кама-сода з-дын (дөньяда икенче) нигезли, анда сода җитештерүнең аммиаклы ысулы кулланыла (1872 дә отышсыз булуы сәбәпле ябыла).

1855 тә Казанда илдәге иң эре сабын кайнату пр-тиесе — бертуган Крестовниковларның *шәм-стеарин, сабын кайнату, глицерин* җитештерү химия заводы ачылу Х.с. үсешендә зур роль уйный. Күп кенә вак сабын кайнату пр-тиеләре һәм уртача зурлыктагы категориягә кергән М.И.Үтәмешев з-ды эшли. 19 йөз ахырында төбәктә беренче нефть эшкәртү сәнәгате пр-тиеләре сафка баса. Яктырту газы җитештерүче Башмаков з-ды (1874–95) һәм Бельгиянең «Газ һәм электр» АҖ (1897), аспирин, карбол һәм салицил к-талары кебек феноллы-салициллы матдәләр һәм препаратлар эшләп чыгаручы пр-тиеләр (барысы да — 1916; Казанда), Е.Гордееваның Зөя өязе Печищи авылындагы илдә беренче тапкыр нефть кудыру калдыкларыннан керосин (1915 тән ш.у. бензол һәм толуол) җитештерүче заводы (1882) нефтьне кудыру һәм каталитик пиролизлау б-н шөгыльләнәләр. 20 йөз башына Казан губернасының фән һәм техниканың алдынгы казанышларын, җитештерүне оештыруның заманча алымнарын файдаланган химия пр-тиеләре, продукциянең күләме һәм ассортименты буенча Россиядә алдынгы урын билиләр. 18 йөздә — 20 йөз башында, эре пр-тиеләр б-н беррәттән, җирле халык арасында таралган поташ, агач күмере, сумала, дегет, скипидар, олифа һ.б.ны бирүче вак оешмалар һәм урман химиясе кәсепләре зур роль уйный.

1918–21 дә җирле химия һәм сабын кайнату заводлары национализацияләнә. Граждан-нар сугышы һәм җимереклек елларында тармак зур зыян кичерә; Кокшан, Казан химия з-дларын һәм күп кенә башка пр-тиеләр таркалу хәленә киләләр һәм яшәүдән туктыйлар, продукция җитештерү берничә тапкыр кими, вак заводлар ябыла, аларның җиһазлары эре пр-тиеләргә тапшырыла.

Тизләтелгән индустрияләштерү чорында ТАССРда капитал салулар һәм төзелеш күләмнәре буенча Х.с. машина төзелешеннән соң икенче урынны били. 1930–40 елларда Казанда бөтенсоюз әһәмиятенә ия пр-тиеләр, ш.и. ясалма каучук эшләп чыгару буенча дөньяда беренчеләрдән булган СК-4 з-ды (хәзер *Казан ясалма күн заводы*), 8 нче кинотасмалар ф-касы (*«Тасма»*), желатин з-ды (*«Полимерфото»*), резина-тезник эшләнмәләр з-ды (*«Квадрат»*) төзелә, химия-фарм. ф-касы (*«Татхимфармпрепаратлар»*) оештырыла. Эшләп килгән Бондюг, В.И.Ленин исем. дары, М.Вахитов исем. сабын кайнату з-дларын тамырдан үзгәртеп корыла. Респ-ка сәнәгатенең гомуми күләмендә Х.с.нең өлеше шактый арта һәм 1944 кә 12,65 тәшкил итә.

1958 дә ил җитәкчелеге ТАССРны *нефть химиясе сәнәгатенең* интенсив үсешенең, ясалма һәм синтетик җепселләр, пластик массалар һ.б. синтетик материаллар җитештерүнең төп төбәкләреннән берсе буларак тәгаенли. 1950–60 елларда сыек углеводородлар (*Миңлебай газ эшкәртү заводы*), полимер кушылмалар һәм пластмассалар (*«Казаноргсинтез»*),

автомобиль шиннары (*«Түбәнкамашин»*) җитештерү буенча эре тоннажлы комплекслар төзелеше җәелдерелә. 1980 еллар башында тулы куәтләренә ирешү нәтиҗәсендә алар илдә тармакның иң эре пр-тиеләренә әверелделәр. Шулай ук Х.с.нең яңа юнәлешләре — көнкүреш химиясе (*«Хитон»*), азотлы ашламалар (*«Менделеевазот»*), техник корым (*«Түбәнка - матехуглерод»*) эшләп чыгару үзләштерелә. Барлык эшләп торган пр-тиеләрдә җитештерүне реконструкцияләү, продукциянең күләмен һәм ассортиментын арттыру фәнни-техник алгарыш казанышлары нигезендә башкарыла. Нәтиҗәдә, 1960–85 тә төп сәнәгый фондларның гомуми күләмендә Х.с.нең өлеше 7,8 % тан 20 % ка кадәр, аның продукциясенең гомуми күләме 18,3 тапкыр арта.

1990 елларның 2 нче яртысыннан Х.с. үсешендәге төп юнәлеш нефть эшкәртүнең тирәнәюеннән гыйбарәт була. Түбән Кама шәһәрендә «ТАИФ-НК» пр-тиесе төзелә, аның составына берничә завод керә (к. *«ТАИФ»*); анда мотор ягулыгының (дизель ягулыгы, авиация керосины, автомобильләр өчен бензин) һәм майларның барлык төрләрен, нефть химиясе сәнәгате өчен чималның кыйммәтле төрләрен эшләп чыгару җайга салына.



«ТАНЕКО» АҖнең ЭЛОУ-АВТ-7 җайланмасы.

Түбән Камада ш.у. «ТАНЕКО» АҖ нефть эшкәртү һәм нефть химиясе з-длары комплексының 2 нче чиратын төзү дәвам итә, якындагы елларда аның Россия базарында иң эре нефть продуктлары җитештерүче булуы күздә тотыла. 2000 елларда «Казаноргсинтез», «Түбәнкаманефтехим», «Түбәнка - машин» пр-тиеләре модернизацияләнә, аларда продукциянең яңа төрләре үзләштерелә; полимер төрү материалларын чыгаручы «Данафлекс» АҖ пр-тиесе сафка баса (Казан, 2001). Динамикалы үсеш кичерүче компаниләр исәбенә *«Нәфис Косметикс»*, «Кварт», «НефтеХимСәвилен», Түбән Кама техник углерод з-ды, П.Я.Карпов исем. *Химия заводы,* Казан ясалма каучук з-ды, «Менделеевазот», «Татхимпрепаратлар» керә. ТР Х.с.нең инновацион үсеш юлына күчешен гамәлгә ашыру өчен «Идея» инновацион-җитештерү технопаркы, «Түбән Кама сәнәгый округы» ассоциациясе, Кама «Мастер» индустриаль паркы, «Алабуга» аерым икътисади зонасы, «Химград» технополисы, «Кама Аланы» индустриаль паркы һ.б. объектлар булдырыла.

2015 тә ТР Х.с.ндә 900 ләп эре, урта һәм вак оешмалар эшли, аларда 55 меңнән артык кеше хезмәт куя. Респ-ка сәнәгате тармаклары арасында Х.с. продукция реализацияләү, экспортлау һәм алынган табыш буенча 2 нче урын били. ТРда Х.с. җитештергән продукциянең 35% тан артык өлеше чит илләргә чыгарыла. ТР Х.с. Россия базарында полистирол (64%), полиэтилен (47%), ясалма каучук (40%), полипропилен (31%), шин (30 %), юу чаралары (14%) җитештерү буенча өстенлек итә. Аңа РФ Х.с. продукциясе күләменең 10% тан артыграк өлеше туры килә. Ш.у.к. *Нәорганик химия, Органик химия*.

Әд.: Лукьянов П.М. Краткая история химической промышленности СССР. М., 1959; Петрова А.А., Лифшиц И.М., Цитрина Л.Н. Большая химия Татарии. К., 1976.

С.Г.Белов, М.В.Сәлимгәрәев.

ХИ́МИЯДӘ ФИ́ЗИК ТИКШЕРЕНҮ ЫСУЛЛАРЫ́ (ХФТЫ), матдәләр структурасын, кушылмаларның химик үзлекләрен һәм реакция мөмкинлеген, химик реакцияләрнең юлларын һәм механизмнарын билгеләү ысуллары тупламасы. ХФТЫ төшеп баручы нурланышның, кисәкчәләр агымының яисә нинди дә булса кырның матдә б-н тәэсир итешүенә нигезләнә. Казанда ХФТЫн химиядә Б.А.*Арбузов* һәм аның шәкертләре файдалана башлый. Гамәлдә ТМР, инфракызыл (ИК), комбинацион чәчелешле (КЧ) спектроскопия, дифракцион, электр һәм электрооптик алымнар кулланыла. ТМР спектрометрларының иң әүвәлгеләреннән берсе Казан ун-тында Й.Ю.*Сәмитов* тарафыннан ясала. Бик күп органик һәм элементорганик кушылмалар өчен спектраль мәгълүматлар алына (А.В.Ильясов, А.В.Агапов, Р.М.Әминова, В.В.Клочков, Ф.Х.Каратаева, Т.А.Зябликова, Ш.К.Латыйпов). Теләсә нинди агрегат халәтендәге молекулалар симметриясе һәм структурасы тирбәнешле спектроскопия алымы б-н билгеләнә: шул ук алым химик реакцияләрнең химик тигезләнешен һәм кинетикасын тикшергәндә, технол. процессларның барышын контроль астында тотканда кулланыла (Р.Р.Шәһидуллин, А.Б.Ремизов, В.И.Коваленко, С.А.Кацюба). Газлардагы гади молекулаларның, аларның диполь моментларының һәм термодинамик параметрларының геометриясен билгеләү газ электронография алымы б-н башкарыла (В.А.Наумов б-н шәкертләре). Рентгеноструктур анализ ярдәмендә кристал ләдагы атом координатларын билгеләнә. Рентгеноструктур анализ юнәлешен И.А.Литвинов, О.Н.Катаева, А.Т.Гобәйдуллин һ.б. үстерә. А.Н.*Верещагин* органик һәм элементорганик кушылмаларның конформацион анализын ясау өчен Керр эффектын (даими электр кырындагы куш нур сынышы) һәм Рәлей чәчелешен (молекуляр анизотропия алымы) куллана, С.Г.Вульфсон белән бергә ике нурлы магнит сынышын ача, СССРда беренче булып Керр константаларын билгеләү җ һәзын ясый (1964). Магнит кырындагы куш нур сынышы алымнан (Коттон-Мутон эффекты) файдаланып теләсә нинди полярлашу мохитләрендәге молекуляр һәм ион системаларны тикшерүләр йөртелә, комплекслар хасил булу күренеше, сольватация, комплексларның фәзаи структурасы өйрәнелә (С.Г.Вульфсон, В.Ф.Николаев). Газ һәм эремәдәге электр диполь моментларын билгеләү өчен файдаланылган П.Дебай алымы химиядә молекулалар полярлашуын бәяләү, симметрияне, молекулаларның фәзаи һәм электрон структурасын торгызу максатыннан кулланыла. Диполь моментлар химик бәйләнеш, атомнар һәм атом төркемнәре арасындагы тәэсирләшүү, индуктив эффект һәм иярмә эффекты тәгъликатын үстерүдә, реакция мөмкинлеге теориясен эшләүдә аерым роль уйный. Структур органик химиянең күп параметрлы катлаулы мәсьәләрен хәл итү өчен, А.Н.Верещагин төрле физик алымнар — электр, электрооптик һәм оптик (диполь моментлар, Керр, Коттон-Мутон эффектлары), тирбәнешле спектроскопия, ТМР, ультрашәмәхә һәм фотоэлектрон спектрометрия, газ электронографиясе, масс-спектроскопия ярдәмендә конформацион анализның методологиясен, теоретик һәм тәжрибәви ысулларын эшли. РФА КГҮнең Органик һәм физик химия ин-тында һәм Казан ун-тында (Р.П.Аршинова, Э.И.Ишмаева, Я.А.Верещагина) төрле класс органик һәм элементорганик кушылмаларның реакция мөмкинлеген һәм структурасын өйрәнү юнәлешендә төпле фәнни нәтиҗәләргә ирешелә. Ш.у.к. *Казан химия фәнни мәктәбе.*

Әд.: Конформационный анализ элементоорганических соединений. М., 1983; Вилков Л.В., Пентин Ю.А. Физические методы исследования в химии. М., 1987.

Я.А.Верещагина, Е.Н.Климовицкий.

ХИРУРГИ́Я (грек. cheirurgía, chéir — кул һәм érgon — эш), авыруларны өйрәнүдә төп дәвалау ысулы операция (ш.и. ярмыйча ясала торган) булган клиник медицина һәм ветеринария өлкәсе; операция ясау алымнарын, ысулларын һәм башкару техникасын эшли. Гомуми Х., оператив Х., үлекле Х., абдоминаль (корсак куышлыгы әгъзалары) Х., торакаль (күкрәк читлеге әгъзалары) Х., пластик Х., реконструктив Х., тернәкләндерү Х.се, казналык-бит Х.се, йөрәк-кан тамырлары Х.се, нейрохирургия, онкохирургия кебек мөстәкыйль бүлекләргә аерып йөртелә. Балалар Х.се өлкәсендә балалар авырулары (ш.и. үсеш аномалияләре) һәм имгәнүләре очрак - ларына диагноз кую, авыруларны дәвалау ысуллары эшләнә. Колопроктология (туры эчәк авырулары), эндоскопик Х., комбустиология мөстәкыйль клиник дисциплиналар буларак карала.

Россиядә элекке заманнарда Х. ярдәме күрсәтүчеләр булып имчеләр һәм «сөяк утыртучылар» санала. 1707 елда Пётр I кушуы буенча Мәскәү ген. госпитальдә анатомия б-н бергә Х. белеме бирелә торган госпиталь мәктәбе ачыла. 1733 тә шундый ук мәктәпләр С.-Петербург һәм Кронштадтта да барлыкка килә. 19 йөзнең 1 нче яртысында Россиядә үз хезмәтләре б-н Россия Х. мәктәбен алдынгы урыннарга чыгарган аталыклы хирурглар — И.В.Буяльский, Е.О.Мухин, И.Ф.Мойер, Н.Ф.Арендт, И.Ф.Буш һ.б. эшли. Россия Х.се үсешендә хәрби-кыр Х.сенә нигез салган Н.И.Пирогов аерым роль уйный.

19 йөздә, наркоз, антисептиклар һәм асептиклар билгеле булу һәм киң кулланыла башлау б-н бәйле рәвештә, Х. үсеш ала. 20 йөздә

мед. өлкәсендә урология, травматология, *офтальмология*, *анестезиология*, *онкология* һ.б. кебек аерым дисциплиналар барлыкка килә. Х. өлкәсендәге иң нәтиҗәле эшләнмәләр Бөек Ватан сугышы елларында тәкъдим ителә: яралыларның 72 % ы кабат сафка бастырыла. 20 йөзнең 2 нче яртысында Россиядә кардиохирургия аерым уңышларга ирешә (А.Н.Бакулев, Е.Н.Мешалкин, А.А.Вишневский, Б.В.Петровский, Н.М.Амосов, В.И.Бураковский һ.б.). Бу чорда трансплантология, микрохирургия, эндоскопик Х., рентген-эндоваскуляр Х. барлыкка килә һәм актив рәвештә үсеш ала. 20 йөз ахырында диагноз кую һәм дәвалауның нәтиҗәле ысуллары гамәлгә кертелә (ультратавыш, магнит-резонанс һәм компьютер томографиясе, цифрлы ангиография, эндовидеоскопия һ.б.).

Казанда Х.нең фәнни юнәлешләре 19 йөз башында формалаша башлый (нигез салучылары — И.О.Браун һәм Ф.Х.*Эрдман*). Аның алга таба үсеше И.Х.Ренард, Л.Л.*Фогель*, Э.О.*Вердерамо* һ.б. исемнәр б-н бәйле. 1834 тән Казан ун-тының гомуми Х. кафедрасын Ф.О.*Елачич* җитәкли (бүсерләрне кисә, катлаулы яраларны дәвалый, литотрипсия (сидек юлларындагы һәм үт куыгындагы ташларны ваклату) ясый. Ул Л.А.*Китер* б-н берлектә эфирлы наркоз куллана һәм дөньяда беренче булып аналыктагы яман шешне алуга ирешә. Казан ун-ты клиникасы Идел-Урал буе һәм Себер төбәкләре өчен табиблар әзерләү үзәгенә әверелә. 1897 дә П.А.Дубовицкий пластик Х.гә (ринопластика) нигез сала. Шул ук елда Н.Ф.Высоцкий Россиядә ясалган иң беренче яман шеш операцияләрнең берсен башкара; әлеге галим хирургик инфекцияләрне кисәтүгә зур өлеш кертә, Казан ун-ты каршында Бактериология ин-ты оештыра (1901). А.Н.*Бекетов* хлороформ наркозын тирәнтен клиник өйрәнү буенча тикшеренүләр уздыра (1860–70). Л.Л.*Лёвшин* Россиядә беренчеләрдән буларак корсак куышлыгы шешләренә операция ясый (1880 еллар); Казанда беренче булып аналыктан тыш йөклелек, корсак җәрәхәтләре һ.б. очракларны оператив Х. юлы б-н дәвалый; «Хирургия нигезләре» («Основы хирургии», 1–2 бүлекләр, 1880–85), «Руководство по частной и общей хирургии» («Аерым һәм гомуми хирургия буенча кулланма», 1896) дәреслекләрен яза. Атаклы галим, хирург, Казан Х. фәнни мәктәбе һәм нейрохирургиясенә нигез салучы В.И.*Разумовский* шушы чорның иң билгеле вәкилләреннән саналы. И.А.*Праксин* урология өлкәсендәге пластик операцияләрне, зобны оператив юл б-н дәвалауны гамәлгә кертә. В.Л.*Боголюбов* бавыр, ашказаны асты бизе һәм корсак куышлыгы арты Х.се, ш.у. фасцияләр трансплантациясе өлкәсендә уңышларга ирешә. Казан Х.се үсешендә аерым урында авыртуны басуның бөтен дөньяга танылган новокаин анестезиясе — фасциаль тукымалар буенча тарапучы «тыгыз күчмә инфильтрат» ысулына нигез салучы А.В.*Вишневскийның* үз урыны бар. Ул эшләп тәкъдим иткән новокаин блокадасы, майлы-бәлзәмле бәйләвеч ысуллары нәтиҗәлелек һәм киң куллану мөмкинлеге б-н уңыш казана. И.В.*Домрачев* ашказаны җәрәхәтен һәм уникеилле эчәкне хирургик юл б-н дәвалауны иң беренчеләрдән башлап җибәрә. С.М.*Алексеев*, И.Ф.*Харитонов* һәм аларның шәкертләре (Э.Н.*Ситдыйков*, В.А.*Кузнецов* һ.б.) урология, абдоминаль Х. үсешенә сизелерлек өлеш кертәләр.

1950 елларда үпкә Х.се барлыкка килә (Н.В.Соколов, М.М.Шалагин, Ю.А.*Ратнер*, А.О.Лихтенштейн, И.З.*Сигал* һ.б.). И.Г.*Салихов* беренче булып корсак ярысы ялкынсынганда абдоминаль рецепторларның рефлектор реакцияләре характерын һәм динамикасын, В.А.Кузнецов перитонит очрагында йөрәк-кан тамырлары системасы үзгәрешләрен билгели. А.А.*Агафонов*, Ә.Х.*Дәүләтшин*, С.В.*Доброквашин* төрле әгъзалардагы микроциркуляцияне, корсакның арткы ягындагы гематомаларга диагноз кую һәм авыруны дәвалау ысулларын өйрәнә. 1950 елларда торакаль Х. үсеш ала (Н.В.Соколов, М.М.Шалагин, Ю.А.Ратнер, А.О.Лихтенштейн, М.З.Сигал һ.б.).

Россиядә беренче кичектергесез Х. кафедрасы Казан ГИДУВында О.С.*Кочнев* тарафыннан оештырыла (1922). Кафедра хезмәткәрләре (И.А.Ким, Р.Ш.Шәймәрданов, И.С.Малков һ.б.) б-н берлектә ул унике илле эчәк җәрәхәтләре, үт юллары һәм ашказаны асты бизе патологияләре очрагында үзенчәлекле операция алымнары тәкъдим итә.

ГИДУВның 1935–72 дә Ю.А.Ратнер җитәкчелек иткән Х. һәм онкология кафедрасы яман шеш авыруларына диагноз кую һәм аларны хирургик юл б-н дәвалау мәсь әләләрен хәл итү өстендә уңышлы эшли. Алга таба бу юнәлеш М.З.Сигал һәм аның шәкертләре (Р.М.*Таҗиев*, Ф.Ш.*Әхмәтҗанов*, Е.И.*Сигал* һ.б.) хезмәтләрендә дәвам иттерелә. Алар тарафыннан тупланган фәнни потенциал нигезендә 2007 елда Респ-ка онкология үзәге (хәзер Респ-ка онкология клиник диспансеры) базасында РМФА Н.Н.Блохин исем. Россия онкология фәнни үзәгенең Идел буе ф-лы оештырыла (директоры Р.Ш.*Хәсәнов*).

1960–70 елларда балалар Х.се сизелерлек алга китә. Аңа кадәр Казанда балаларга операцияләр атаклы хирурглар Н.А.Геркен, А.В.Вишневский, Н.В.Соколов, И.В.Домрачев, С.М.Алексеев һ.б. җитәкчелек иткән клиникаларда гомуми профиль хирурглары тарафыннан ясала. Беренче балалар хирургы И.Ф.*Харитонов* балалар һәм өлкәннәрне үңәч, корсак куышлыгы әгъзалары, проктологик һәм хирургик авыру очракларында оператив юл б-н дәвалый. 1930 елларда балалар Х.се өчен клиник нигез әзерләнә, Вишневский исем. клиникада аерым бүлек (1935), 6 нчы шәһәр клиник хастаханәсендә 85 ятак-урынлы балалар Х.се бүлеге (1963), 15 нче шәһәр клиник хастаханәсендә ике балалар Х.се бүлеге (1971), ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының Респ-ка балалар клиник хастаханәсендә 347 ятак-урынлы махсус балалар Х.се бүлекләре ачыла (1977, 1994). Казан мед. ин-тында 1932 дә — педиатрия, 1935 тә Х. (мөдире — И.В.Домрачев) ф-тлары оештырылу балалар өчен уңышлы рәвештә табиб кадрлар әзерләү мөмкинлеге бирә. 1957 дә балалар Х.се курслары гамәлгә кертелә, 1968 дә балалар Х.се кафедрасы ачыла (мөдире — М.Р.*Рокицкий*). 1977 дә Респ-ка балалар клиник хастаханәсе Идел буеның 5 респ-касы өчен Респ-каара балалар Х.се үзәге базасына әверелә.

1960 елларда Казан мед. ин-тының 2 нче госпиталь Х.се каф. базасында (6 нчы шәһәр клиник хастаханәсе) Н.П.*Медведев* җитәкчелегендә йөрәк-кан тамырлары Х.се җәелдерелә. Казан галимнәре тарафыннан тумыштан булган һәм барлыкка килгән йөрәк зәгыйфьлеген гипотермия һәм ясалма кан әйләнеше шартларында коррекцияләү, төп кан тамырларына операция ясау ысуллары эшләнеп гамәлгә кертелә (А.П.Титов, В.Е.Мамаев). Йөрәк-кан тамырлары Х.сенең алга таба үсешен Н.П.Медведев шәкертләре — В.Н.*Медведев* (1940–99), Р.К.*Джорджикия*, Л.М.*Миролюбов* һ.б. тәэмин итә. Хәзерге вакытта йөрәк-кан тамырлары үзәкләре Төбәкара клиник диагностика үзәгендә, Респ-ка клиник хастаханәсендә, Респ-ка балалар клиник хастаханәсендә, ашыгыч мед. ярдәме хастаханәсендә (Чаллы), «Татнефть» АҖ мед.-сан. частенда (Әлмәт) эшли.

1980 еллардан эндоскопик Х. кызу темплар б-н үсә (А.Н.Чугунов, В.Ю.*Муравьёв*, И.В.*Фёдоров*, И.С.Малков һ.б.). Эндоскопик ысуллар күп төрле авыру очракларында диагноз кую һәм дәвалауны, аз җәрәхәт ясап, югары дәрәҗәдә башкару мөмкинлеге бирә.

Респ-ка клиник хастаханәсендә, Респ-ка балалар клиник хастаханәсендә, Төбәкара клиник диагностика үзәгендә, Казан шәһәре 1 нче, 2 нче ашыгыч мед. ярдәме хастаханәләрендә, Казан шәһәре 5 нче, 7 нче, 12 нче, 16 нчы, 18 нче клиник хастаханәләрендә, Чаллы, Түбән Кама, Яшел Үзән, Әлмәт, Бөгелмә һ.б. шәһәрләрнең ашыгыч мед. ярдәме хастаханәләрендә эре Х. бүлекләре бар.

Әд.: Ахунзянов А.А. Прошлое и настоящее детской хирургии в Республике Татарстан // Казан. мед. журн. 2003. № 1; Этюды Казанской хирургии. К., 2005; История Казанского государственного медицинского университета. К., 2006; Галеев Р.Х. Органозамещающие и реконструктивные операции на органах мочеполовой системы. К., 2008.

С.В.Доброквашин, Р.К.Джорджикия, Г.А.Измайлов, С.Г.Измайлов.

ХИСА́М КЯТИ́Б (14 йөз), төрки-татар шагыйре. Дини-дидактик характердагы лиро-эпик «*Җөмҗөмә солтан*» әсәре авторы. Совет тюркологы Е.Э.Бертельс, ш. у. төрек галимнәре Ф.Күпрелезадә һәм С.Эрген фикеренчә, дастан Алтын Урда шәһәрләреңең берсендә язылган. Ф.Күпрелезадә, аерым алганда, поэманың 1375–76 еллар б-н билгеләнгән һәм *Сәхибгәрәй* хан кушуы буенча 1548–49 да иске госманлы теленә тәр җәмә ителгән үзенда сакланган күчермәсенә сылтама ясый.

Әд.: Средневековая татарская литература VIII–XVIII вв. К., 1999; Исламов Р. Ещё раз о «Джумджума султан» Х.Катиба // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2004. № 1; Koprulu M.F. Early Mystics in Turkish Literature. L.–N.Y., 2006.

ХИСАМЕТДИ́НОВ Алик Исмәгүзам улы (25.12.1952, БАССРның Аскын р-ны Аскын а.), тау инженеры, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2009). Уфа нефть ин-тын тәмамлаганнан соң (1974), «Татнефть» АҖдә эшли

(бүленеп): оператор, инженер-технолог, нефть чыгару цехы, инженерлык-технол. хезмәте үзәге, «Әлмәтнефть» НГДУда технол. бүлеге башлыгы, АҖнең катламнарның нефть бирүчәнлеген арттыру алымнарын проектлаштыру бүлеге башлыгы (1988 елдан). 1994–98 дә «Татех» АҖ ген. директоры урынбасары. Дәүләт бүләге нефть чыгару скважиналарының нәтиҗәлеген арттыру, яңарту һәм саклауны тәэмин итә торган техник һәм технол. чишелешләр комплексын эшләүдә һәм сәнәгатькә кертүдә катнашканы өчен бирелә.

Х е з м.: Восстановление температурного поля пласта, охлаждённого в результате нагнетания холодной воды // Нефтепромысловое дело. 2003. № 8.

ХИСАМЕТДИ́НОВ Альфред Ибраһим улы (18.12.1941, Казан), математик, физика-матем. фән. д-ры (1984), проф. (1987). Новосибирск ун-тын тәмамлый (1965), РФАнең Себер бүлегендә (Новосибирск ш.) эшли: Хисаплау үзәгендә, Матем. ин-тында (1987 дән); бер үк вакытта, 1974 тән, Новосибирск ун-тында, 2000 елдан Геофизика ин-тында (хәзер Нефтегаз геологиясе һәм геофизикасы ин-ты). Хезмәтләре Монте-Карло сан алымнары, геофизика, астрофизика мәсьәләләрен хәл итү өчен кисәкчәләр күчеше процессларын матем. модельләштерү, сирәкләнгән газлар агымнары мәсьәләсен микъдари ысул б-н хәл итүгә карый. Монте-Карло алымнарын линия операторлары итерациясе өчен кулланa (ш.и. 2 нче төр интеграль тигезләмәләрне һәм күчереш тигезләмәсен чишү өчен); Больцманның нәлинияле кинетик тигезләмәсе (сирәкләнгән газларны өйрәнү өчен) өчен стат. модельләштерү алымнары теориясен үстерә. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: «Единичный класс» оценок для вычисления по методу Монте-Карло функционалов от решения интегрального уравнения 2-го рода // Вычисл. математика и мат. Физика. 1970. Т. 10, № 5; Алгоритмы Монте-Карло в ядерной геофизике. Новосиб., 1985 (автордаш); Математическое моделирование нестационарного переноса частиц в задачах импульсного нейтронного гамма-каротажа. Новосиб., 2008 (автордаш).

ХИСАМЕТДИ́НОВ Әмир Александрович (16.2.1952, Красноярск краеның Хатанга р-ны Каяк пос.), тарихчы, тарих фән. д-ры (2005). Ерак Көнчыгыш ун-тын тәмамлый (1985). 1985–90 елларда СССР ФА Геогр. җәмгыятенең Приморье крае ф-лы гыйльми секретаре, 1991–93 тә Амур краен өйрәнү җәмгыяте рәисе, 1996–98 дә М.Горький исем. Приморье крае китапханәсенең туган якны өйрәнү бүлеге библиографы, бер үк вакытта, 1994–2010 да, Владивосток икътисад һәм сервис ун-тының чит телләр каф. укытучысы. 1998–2010 да Ерак Көнчыгыш техник ун-тының Көнчыгыш ин-тында Япония һәм туган якны өйрәнү, соңрак көнчыгыш телләре кафедралары мөдире. 2010 нан Ерак Көнчыгыш федераль ун-тының гаммәви коммуникацияләр каф. профессоры. Хезмәтләре Ерак Көнчыгыш тарихын, Россиянең Азия-Тын океан төбәге сәясәтен; Кытай, Корея, Япония, Төньяк һәм Көньяк Америкадагы рус эмиграциясен өйрәнүгә карый.

Х е з м.: В Новом Свете или История русской диаспоры на тихоокеанском побережье Северной Америки и Гавайских островах. Владивосток, 2003; Русское слово в стране иероглифов: К истории эмигрантской печати, журналистики, библиотековедения и архивов. Владивосток, 2006; Русская Япония. М., 2010.

ХИСАМЕТДИ́НОВ Әнвәр Гаяз улы (26.10.1928, Казан — 7.2.2009, шунда ук), сан. табибе, эпидемиолог, мед. фән.д-ры (1975), проф. (1976). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1953), Октябрь р-ны сан.-эпид. станциясе баш табибе булып эшли. 1957 елдан Казан эпидемиология һәм микробиол. фәнни-тикшеренү ин-тында, 1964 тән — эпидемиология төркеме, 1966 дан эпидемиология бүлеге җитәкчесе, директор урынбасары вазифасын башкаручы. 1970–93 тә ГИДУВның эпидемиология каф. мөдире. Хезмәтләре дифтерия, бума ютәл эпидемиологиясенә һәм респ-када бу авыруларны кисәтүгә карый. Респ-ка эпидемиологлар, микробиологлар һәм паразитологлар фәнни җәмгыяте рәисе (1975–84). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: О защитных свойствах сывороток крови детей с различным содержанием коклюшных агглютининов // Казан. мед. журн. 1973. № 6 (автордаш); Эпидемиология и профилактика современной дизентерии // Казан. мед. журн. 1985. № 4 (автордаш); Опыт использования лифузоля при катетеризации сосудов // Казан. мед. журн. 1986. № 5 (автордаш).

ХИСАМЕТДИ́НОВ Габделсамат Гыйлаҗ улы (26.8.1925, Белоруссия ССРның Гомель ш. – 16.12.2011, Казан), инженер-механик, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1971), ТАССРның, РСФСРның атказ. машина төзүчесе (1980, 1989). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1951). Хезмәт эшчәнлеген 1942 елда Казандагы 230 нчы з-дта слесарь булып башлый. 1951–91 дә Казан авиация ҖБдә: конструктор, бюро башлыгы, махсус КБ бүлеге башлыгы, заводның партия ком-ты секретаре (1963–67), берләшмәнең баш инженеры. Дәүләт бүләге универсаль җайланмалар һәм стапельләр конструкцияләрен җыюда принципаль яңа технологияләрне кулланып самолётлар төзү алымнарын эшләүдә һәм гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә. Ленин ордены, Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары б-н бүләкләнә.

Д.С.Фәхретдинов.

ХИСАМЕТДИ́НОВ Госман Камали улы (6.11.1917, Оренбург губ., Верхнеуральск өязе Җәмбит (Джамбита) а. — 5.12.1985, Оренбург өлкәсенең Илек р-ны Озерки а.), а.х. җитештерүен оештыручы, Соц. Хезмәт Геroe (1966). 1933–84 елларда Илек р-нында: 1938 гә кадәр авыл кулланучылар кооперациясе оешмаларында, 1943–84 тә (бүленеп) Киров исем. к-з рәисе, 1945 тән «Заготживсырьё» конторасында, 1948–50 дә РСФСР Хәзерләүләр министрлыгы район вәкиле урынбасары. Х. җитәкләгән чорда колхозда бөртекле культураларның уңышы (1 *га* да 1960 та 16 *ц* дан 1974 тә 21 *ц* га кадәр), а.х. тер-лекләренең продуктлылыгы арта; а.х. продукциясен җитештерү буенча дәүләт йөкләмәләре арттырып үтәлә. 1966–70 тә дәүләткә якынча 37 мең *т* бөртекле ашлык сатыла. Җитештерү-техник база булдырыла, 20 дән



Г.К. Хисаметдинов.

артык җитештерү, социаль-мәдәни объектлар төзелә. Герой исеме бөртекле һәм терлек азыгы культураларын җитештерү һәм хәзерләүне арттыруда ирешкән уңышлары һәм техникадан югары җитештерүчән файдаланганы өчен бирелә. Бөек Ватан сугышында катнаша. КПССның 25 нче съезды делегаты. 1953–69 да Оренбург өлкә советы депутаты. Ленин ордены, Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә. Озерки авылындагы бер урамга Х. исеме бирелә.

Әд.: Россовский В.П. Герои Труда: Биогр. справ. Калуга, 1999; Хакимов М.С., Сафаров М.А. Татары: Воины, труженики, патриоты: Биогр. справ. М., 2006.

М.Ж.Гаитов.

ХИСАМЕТДИ́НОВ Марат Рәкыйп улы (26.9.1969, Калуга өлкәсенең Калуга ш.), техник фән. канд. (2009), фән һәм техника өлкәсендә ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2017). Казан дәүләт ун-тын тәмамлаганнан соң (1993), Казан химия-технол. ин-тының (хәзер Казан технол. милли-тикшеренү ун-ты) Бөгелмә ф-лында эшли, 2002 елдан ТатНИПИнефтьтә (Бөгелмә ш.), катламнарның нефть бирүчәнлеген арттыру бүлегендә лаб. мөдире. Дәүләт бүләге ТРның нефть чыганакларында нефть чыгару темпларын һәм нефть алу күләмен арттыру өчен технологияләр комплексы эшләүдә һәм сәнәгатькә кертүдә катнашканы өчен бирелә. Нефть чыгару алымнарын камилләштерү өлкәсенә караган 30 патент авторы.

ХИСАМЕТДИ́НОВ Мәхмүт Гаяз улы (28.6.1913, Казан — 8.1.1998, С.-Петербург), геолог, геол.-минерал. фән. д-ры (1972). Ленинград ун-тын тәмамлый (1937), Бөтенроссия геол. ин-тында (С.-Петербург) эшли, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1972 дән). Хезмәтләре полиметалл чыганаклар геологиясенә карый. Х. полиметалл рудаларның матди составы үзгәрешләре закончалыкларын, Алтай һәм Казакъстанда аларның барлыкка килү һәм таралу үзенчәлекләрен билгели. 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Металлогения и полиметаллические месторождения Рудного Алтая. Л., 1978.

ХИСАМЕТДИ́НОВ Рушад Билял улы (27.10.1912, Верный ш., хәзер Казакъстан Респ-касының Алма-ата ш. — 28.8.1992, Кыргыз Респ-касының Ош ш.), фашистларга каршы яшерен эш алып барган *«Җәлилчеләр төркеме»* оешмасында катнашучы. Зоовет. техникумын тәмамлаганнан соң (Әүлия-Ата ш., 1931), өлкән вет. табибе булып эшли. 1932–40 елларда чик буе гаскәрләрендә вет. табибе булып хезмәт итә. Шуннан соң Казакъстан ССРның Алма-Ата өлкәсе Или р-нында баш вет. табибе булып эшли. Бөек Ватан сугы-

шында катнаша. 1942 дә чолганышта кала, аннары әсирлеккә эләгә. Польша терр-ясен дә Демблин кальгасында, Едлино лагеренда тотыла. *«Идел-Урал» легионына* керә, совет хәрби әсирләренең яшерен эшчәнлегендә актив катнаша. Муз. капелла (агитация-пропаганда эшен яшерү өчен) җитәкчесе була. М.Җәлилнең «Моабит дәфтәре»ндә иң якын һәм ышанычлы көрәштәшләр арасында күрсәтелә. 1943 нең августында оешма тар-мар ителә, Х. кулга алына, Варшава, Берлин төрмәләрендә була, аннары Франциягә җибәрелә. 1944 тә кача һәм француз Каршылык хәрәкәтендә катнашучылар сафларында сугыша; батальон командиры урынбасары. 1945 тә Ватанга кайта. 1949 да репрессияләнә; 1956 да амнистияләнә, 1967 дә аклана. Соңыннан Көньяк Кыргызстан геол. экспедициясенең атлар базасы башлыгы булып эшли. М.Җәлил-Г.Кормаш яшерен оешмасының батырлыгын пропагандалауда мөһим роль уйный. Медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: М о с т а ф и н Р.Ә. Өзелгән җыр эзеннән. К., 1982; З а б и р о в И.Х. Джалиль и джалильцы. К., 1983.

А.И.Бадюгина, Ш.С.Мостафин.

ХИСАМЕТДИ́НОВ Шамил Шәмшәтдин улы (20.9.1950, Тула өлкәсе Узловая ш.), спортчы, тренер (грек-рим көрәше), СССРның атказ. спорт остасы (1972), СССРның атказ. тренеры (1978), РФнең атказ. физик культура хезмәткәре (2006). Омск физик культура ин-тын тәмамлый (1977). «Узловая» ирекле спорт мәктәбендә тәрбияләнә. 1968–71 елларда «Труд» ирекле спорт җәмгыяте (Тула ш.), 1972–74 тә «Спартак» (Мәскәү өлкәсе) өчен чыгыш ясый, тренерлары — А.М.Белоусов (1971 гә кадәр), Н.Н.Пархоменко. СССР (1967, яшүсмерләр арасында; 1971–74), Европа (1973–74), дөнья (1973, 1975), Олимпия уеннары (1972, 1 нче ярым уртача авырлыкта) чемпионы. Х. СССР (1977–80, 1980–90), Швеция (1990–93), Россия (1993–2001) җыелма командаларында баш тренер. 1996 дан Подольский р-нының Новогромово посёлогында яши. «Почёт билгесе», Почёт орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Узловая шәһәренең мактаулы гражданы.

ХИСАМЕТДИ́НОВА Зөһрә Әнфәс кызы (24.9.1958, Азнакай р-ны Сәпәй а.), педиатр, мед. фән. д-ры (2002). ТРның сәламәтлек саклау отличнигы (2003), ТРның атказ. табибе (2007). Казан мед. ин-тын (1981), Казан финанс-икътисад ин-тын (1995), Казан ун-тын (2004) тәмамлый. Мед. ин-тын тәмамлаганнан соң, 1 нче балалар хастаханәсендә эшли (Казан). 1983 елдан Казан мед. уч-щесендә укытучы, 1984 тән Казан шәһәре 2 нче мед. уч-щесендә акушерлык бүлеге мөдире, 1987 дән филиал мөдире, 1990 нан директоры, 1996–98 дә Казан мед. көллияте директоры урынбасары, 1998 дән директоры. Бер үк вакытта, 2009 дан, иҗтимагый сәламәтлек һәм сәламәтлек саклау б-н идарә итү каф. доценты. Хезмәтләре мед. көллиятендә белем бирү методикасын эшләүгә карый. Өзлексез урта мед. белеме бирүнең методологиясе һәм сыйфаты б-н идарә итү технологиясенә караган эшләр циклы өчен РФ Хөкүмәтенең мәгариф өлкәсендәге бүләгенә лаек була (2010).

ХИСАМЕТДИ́НОВА Равилә Рәхим җан кызы (21.1.1956, Оренбург өлкәсенең Саракташ р-ны Яңа Колчым а.), тарихчы, тарих фән. д-ры (2004), проф. (2006), РФ югары һөнәри белем бирүнең мактаулы хезмәткәре (2007). Оренбург пед. ин-тын (1996 елдан — ун-т) тәмамлый (1979). 1982 елдан шунда ук эшли: СССР тарихы каф. укытучысы (1990 га кадәр), тарих ф-ты деканы урынбасары (1990–2001), тарих һәм җәмгыять белемен укыту методикасы (2004–12), гомуми тарих һәм тарих, җәмгыять белемен укыту кафедралары мөдире (2012 дән). Уралның а.х. тарихы буенча, Бөек Ватан сугышы турындагы хезмәтләр авторы.

Х е з м.: Сельское хозяйство Урала в годы Великой Отечественной войны. Малоизвестные страницы. Оренбург, 2002; Аграрная политика Советского государства на Урале после окончания Великой Отечественной войны. Оренбург, 2003; Великая Отечественная война и органы НКВД Южного Урала. Оренбург, 2007 (автордаш).

ХИСАМИ́ЕВ Ибраһим Габделхак улы (5.3.1945, Пермь өлкәсенең Чусовой р-ны Калино станциясе), компрессорлар төзү өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1995), ТР ФА мөхбир әгъзасы (2001), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1995). 1968 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлый. 1962–63 елларда Әлмәт шиннар ремонтлау з-дында эшли. 1969 дан компрессорлар төзү махсус КБда (Казан), әйдәп баручы конструктор (1972–75). 1987–89 да Татарстан нефть машиналары төзү фәнни-тикшеренү ин-ты директоры. 1989–2013 тә «НИИтурбокомпрессор» АҖ директоры. Бер үк вакытта, 1996–2013 тә, «Казанкомпрессормаш» АҖ ген. директоры, ген. директор киңәшчесе (2013 тән). 2000 нән Казан технол. ун-тының суыту техникасы һәм технологиясе каф. мөдире, проф. (1999). Хезмәтләре сәнәгать компрессор машиналарын һәм газ кудыру агрегатларын хисаплау, проектлау, ясау һәм эксплуатацияләү теориясенә карый. Газ кудыру агрегатлары кугычларының югары нәтиҗәле агышлы алмаш өлешләрен эшләгәнә һәм гамәлгә керткәне өчен ТР Дәүләт бүләгенә лаек була (2005). Уйлап табуга 25 автор лык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын медале б-н бүләкләнә. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2000).

Х е з м.: Бесконтактные уплотнения винтовых и центробежных компрессоров. К., 1998 (автордаш); Двухроторные винтовые и прямозубые компрессоры: теория, расчёт и проектирование. К., 2000 (автордаш).

ХИСА́МОВ Ифрат (Евфрат) Нигъмәт улы (14.11.1930, Тымытык р-ны Сарлы а. — 8.6.2000, Казан, Балтач штп да җирләнә), композитор, педагог. 1962–64 елларда Казан консерваториясендә (музыка һәм композиция теориясе классы) укый. 1953–57 дә Балтач район мәдәният йортының сәнгать җитәкчесе. Мәдәният йорты хоры Мәскәүдә Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасында катнаша (1957), лауреат исеменә лаек була. 1964–76 да респ-ка Халык иҗаты йортында халык музыка уен кораллары оркестры дирижёры, 1982–89 да Казан музыка уч-щесендә укыта. 1989–90 да ТАССР Мәдәният министрлыгының Респ-ка фәнни-методик үзәге каршындагы «Курай» пр-тиесенең милли музыка уен кораллары әзерләү остасы. Традицион татар музыка уен кораллары (курай, кубыз, сорнай, гөслә һ.б.) әзерләү һәм камилләштерү белгече буларак танылу ала. Әсәрләре: Флейта һәм фортепиано өчен соната (1961), Симф. оркестр өчен сюита (1962), Флейта һәм симф. оркестр өчен концерт (1964), «Укытучыма», «Утыр әле яннарыма», «Умартачы сөйгәнем», «Бәрәңге» һ.б. популяр җырлар. «Курайда уйнарга өйрән» (1983) уку-укыту ярдәмлеге авторы. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

Ә с ә р.: Якын дустың барын онытма: Җырлар. К., 1974; Бәхет турында: Җырлар һәм романслар. К., 2006.

Ф.Ш.Салитова, Ә.М.Хисамова.

ХИСА́МОВ Нурмөхәммәт Шаһвәли улы (24.3.1937, Чүпрәле р-ны Мунчәли а.), әдәбият галиме, шагыйрь, драматург, филол. фән. д-ры (1996), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1997). Казан ун-тын тәмамлый (1960). 1969 елдан ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-тында, 1997 дән кулъязмалар һәм текстология бүлеге мөдире, 2001–06 да директор. К.Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасын өйрәнә. Г.Тукай, Дәрдемәнд, Һ.Такташ, Ш.Мөддәрис, Г.Афзал, Х.Камал, Р.Харис һ.б. әдипләрнең иҗатларына багышланган мәкаләләр, «Йосыф-Зөләйха» пьесасы авторы (2012, Татар драма һәм комедия театры сәхнәсендә куела). Халыклар дуслыгы ордены б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Бөек язмышлы әсәр. К., 1984; Хәтер сагында. К., 2004; Поэма «Кысса-и Йусуф» Кул Али. М., 1979; Сюжет Йусуфа и Зулейхи в тюрко-татарской поэзии XIII–XV вв. К., 2001.

Әд.: Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

ХИСА́МОВ Рәис Салих улы (1.8.1950, Азнакай р-ны Балтач а.), геолог-нефтьче, ТРның атказ. геологы (1993), геол.-минерал. фән. д-ры (1996), проф. (2005), РФнең атказ. нефть һәм газ сәнәгате хезмәткәре (2001). Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тының Татарстан кичке ф-тын тәмамлый (1978). 1969–97 елларда «Иркеннефть» НГДУында, баш геолог (1988 дән). 1997 дән баш геолог — «Татнефть» АҖнең ген. директор урынбасары. Хезмәтләре геологиягә, нефть чыганакларын эшкәртү технологияләренә, нефть чыгару проблемаларына карый. Х. җитәкчелегендә нефть эзләү эшләре, промысел геологиясе, катламнарны контрольдә тоту һәм эшкәртүне көйләүнең алдынгы алымнарын куллану, Россия, Сүрия, Ливиядә авыр чыгарыла торган нефть запасларын эшкәртүнең нәтиҗәлелеген күтәрү өлкәсендә эшләр алып барыла. Уйлап табуга 100 дән артык патенты бар. ТР дәүләт бүләге, РФ Хөкүмәте (2007) бүләкләре иясе. Дуслык ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Высокоэффективные технологии освоения нефтяных месторождений. М., 2005; Геолого-экономические перспективы развития ресурс-

ной базы Волго-Уральской нефтегазоносной провинции. М., 2007 (автордаш); Гидрогеологические условия нефтяных месторождений Татарстана. К., 2009 (автордаш); Контроль за разработкой нефтяных и газовых месторождений. К., 2009 (автордаш).

ХИСА́МОВ Роберт Габдрахман улы (10.2.1940, Казан), журналист, кинорежиссёр, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2000). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1967), «Заветы Ильича» г-тасында (Лениногорск ш.) әдәби хезмәткәр, бүлек мөдире. 1969–2005 елларда ТАССР МС каршындагы Телевидение һәм радиотапшырулар ком-тында (1992 дән «Татарстан» ДТРК) хәбәрче, мөхәррир, баш мөхәррир, кинорежиссёр, баш кинорежиссёр. Татарстанның нефть сәнәгате казанышлары, КамАЗ төзелеше турындагы репортажлар әзерләүдә һәм төшерүдә, автор һәм режиссёр буларак телевизион документаль фильмнар булдыруда катнаша, аларның 25е респ-ка, бөтенроссия, халыкара конкурсларда бүләкләргә һәм дипломнарга лаек була. Х. илдә беренчеләрдән булып оешкан яшүсмерләр җинаятьчелеге проблемасын күтәрә: «Бушлык» («Пустота») фильм-трилогиясе (1987, СССР Эчке эшләр министрлыгы бүләге), «Яшьләрнең куркыныч уеннары» («Страшные игры молодых», 1988), «Җан авазы. ПТУга арткы ишектән» («Крик. ПТУ не с парадного подъезда», 1989). Әфганстан сугышында катнашучыларның тыныч тормышка кайтуы темасы «Без кайттык» («Мы вернулись»), «Алар мәңгегә ятып калды» («Мы, пережившие друзей») телефильмнарында ачыла. «Коръән — мәхәббәтем» («Любовь моя — Коран») (В.Порохова турында), «Үз халкына — үз кеше» («Свой среди своих») (М.Шәймиев турында), «Күкләр музыкасы» («Музыка небесных сфер») (С.Гобәйдуллина турында), «Владимир Муравьевның тарту көче» («Харизма Владимира Муравьева») һ.б. фильм-портретлар авторы. ТР Журналистлар берлегенең «Бәллүр каләм — Хрустальное перо» бүләге лауреаты (2000).

ХИСА́МОВ Франгиз Гыйльфанетдин улы (26.6.1944, Казан), мәгълүмат куркынычсызлыгы өлкәсе галиме, техн. фән. д-ры (1997), проф. (2001), полковник. РФ нең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2008). 1974 елда Элемтә хәрби академиясен тәмамлаганнан соң (Ленинград), Краснодар югары хәрби уч-ще сендә эшли (1976–79 да, бүленеп, Элемтә хәрби академиясендә), махсус элемтәне автоматлаштыру бүлеге (1980–81), махсус элемтә техникасы һәм автоматлаштыру фәнни-тикшеренү лаб-ясе (1983–83) башлыгы, матем. һәм физика каф. мөдире (1998–2010). 2017 дән Кубань мәгълүмат куркынычсызлыгы ин-тында (Краснодар ш.). Хезмәтләре гражданнар һәм хәрбиләр өчен каралган телекоммуникация системаларында мәгълүматны саклауның криптографик ысуллары на карый. Уйлап табуга 32 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Электрорадиоизмерения. Краснодар, 1988 (автордаш); Физические методы защиты от угроз терроризма. Краснодар, 2015; Криптографические и технические методы защиты от угроз международного терроризма. Краснодар, 2017.

ХИСА́МОВА Әнисә Мәгъсүм кызы (3.2.1932, Арча р-ны Хәсәншәех а. — 15.9.2013, Казан, Балтач штп да җирләнә), библиограф, ТАССРның һәм РСФСРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1982, 1987). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1955), Балтач р-ны мәктәпләрендә рус теле һәм әдәбияты укыта. 1958 дән ТАССР китап палатасында: китапханәче, директор (1972–88). 1995–2008 дә ТР ФА Татар энциклопедиясе ин-тында эшли. Х. җитәкчелегендә «Татарстан матбугат елъязмасы» (1960–80), «Татарстан китаплары» (1–2 т., 1979–86), «Татарстан китаплары: Рус китаплары» (1995) һ.б. библиографик басмалар әзерләнә.

Әд.: З ы я т д и н о в Б. Рәхмәт си ңа, Хәсәншәех! К., 2006; Балтач энциклопедиясе. К., 2006. 1 кит.

ХИСА́МОВА Венера Нәфыйк кызы (25.8.1957, Яшел Үзән ш.), тел галиме, филол. фән. д-ры (2005), ТРның атказ. укытучысы (2003), проф. (2006). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1981), Казан оптика-механика з-дында тәрҗемәче булып эшли, 1989 елдан Казан төзелеш көллиятендә инглиз теле укыта. 1996 дан Татар гуманитар ин-тын да, 1998 дән инглиз теле ф-ты деканы һәм шул исемдәге каф. мөдире, 2005 тән Татар гуманитар-пед. ун-тында көнчыгыш телләр ф-ты деканы, ш.у. инглиз теле теориясе һәм практикасы каф. мөдире; 2011 дән Казан ун-тының Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү ин-тында роман-герман телләре һәм халыкара коммуникацияләр каф. мөдире. Хезмәтләре инглиз һәм татар телләренең чагыштырма типологиясенә карый. Урта мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен инглиз теленнән уку-укыту ярдәмлекләре төзи.

Х е з м.: Татар аудиториясендә инглиз теле дәресләре. К., 2000; Древняя и современная Казань. К., 2003 (автордаш); Лингводидактика поликультурного образования. М., 2012 (автордаш).

ХИСА́МОВА Фәһимә Миргали кызы (1.12.1936, Ютазы р-ны Кәрәкәшле а. — 17.09.2018, Казан), тел галиме, филол. фән. д-ры (1995), проф. (1998), Татарстанның атказ. мәктәп укытучысы (1994), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2007). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1960), Чүпрәле һәм Азнакай р-ннары мәктәпләрендә эшли. 1970 елдан Казан ун-тында: 1999–2007 дә татар теле каф. мөдире. Хезмәтләре татар әдәби теле тарихына, морфологиясенә карый. Х. — югары уку йортлары өчен татар теле морфологиясенә караган дәреслекләр авторы. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Функционирование и развитие старотатарской деловой письменности XVI–XVII вв. К., 1990; Татарский язык в восточной дипломатии России (XVI — нач. XIX вв.). К., 1999; Татар теле морфологиясе. К., 2006.

Әд.: А х у н о в А.М. Фагима Хисамова: Казань может стать центром тюркологии // Татарстан. 2006. № 12.

ХИСМӘ́ТОВ Әсхәт Әсәдулла улы (Әсхәт Хисмәт) (1.1.1952, Әлки р-ны Түбән Әлки а.), актёр, ТРның халык артисты (2003). Казан театр уч-щесен тәмамлаганнан соң (1978), Татар акад. театрына кабул ителә. Матур җырлау сәләтенә ия күпкырлы актёр буларак, Х. яшь герой рольләрен ышандырырлык итеп башкара: темпераментлы, ярсу Булат, өзелеп яратучы Ильяс («Зәңгәр шәл», «Казан сөлгесе», К.Тинчурин), Хәйретдин («Яшь йөрәкләр», Ф.Бурнаш), фидакарь һәм намуслы Марат («Туй алдыннан», Х.Вахит) һ.б. Х. гәүдәләндергән Акбай (Т.Миңнуллинның Акбай турында пьесалар циклы буенча), Ташчәйнәр («Ахырзаман», Ч.Айтматов романы буенча),



Ә.Ә. Хисмәтов.



Ә.Ә. Х и с м ә т о в Хәсән ролендә («Ләйсән ире — Хәсән», Ю. Сафиуллин).

Бәчке («Гөргөри кияүләре», Т.Миңнуллин), Платон («Баскетболист», М.Гыйләҗев), Вакыйф («Мәхәббәт турында сөйләшик», И.Зәйниев), Тынгысын («Идегәй», Ю.Сафиуллин), Буранлы Идегәй («Мәңгелек буран», Ч.Айтматов романы буенча) образлары эчкерсез һәм тормышчан ышандырырлык булулары, сәнгатьчә сурәтләү чараларының төгәллеге б-н аерылып тора. Актёр, ш.у. Шәйдулла («Талак, талак», Х.Вахит), Гөлүс («Улыбыз өйләнә, без аерылышабыз», И.Юзеев), Иван, Денис Иванович



Ә.Ә. Х и с м ә т о в Хәйретдин ролендә («Яшь йөрәкләр», Ф.Бурнаш).

(«Бирнәсез кыз», «Җимерелгән бәхет», А.Островский), Габдрахман («Күрәзәче», З.Хәким), Максуд («Әни килде», Ш.Хөсәенов), Шәйхи («Килә ява, килә ява...», «Ява карлар, ява карлар...», З.Хәким), Галәмов Илбарис Сәйдәшевич («Суган чәчәге», И.Зәйниев), Мокай («Мин ышанам сиңа», Л.Айтуганов), Акоп («Ханума», А.Цагарели), Һади Чалыш («Арбалы хатыннар», З.Зәйнуллин), Айдар («Ут күршеләр», С.Юзеев), 1нче Аксакал («Хан кызы Турандык», К.Гоцци), Сэр Роберт Брэкенбери («Ричард III», У.Шекспир), Вәзирләр («Ху җа Насретдин», Н.Исәнбәт) рольләрен дә уңышлы башкарып, тамашачының ихтирамын яулый. Медаль б-н бүләкләнә.

Әд.: И л я л о в а И. Г.Камал театры артистлары = Артисты театра им. Г.Камала. К., 2005.

И.И.Илялова.

ХИСМӘТУЛЛА́ (Хисмәтуллин) Рахмай (Рәхмәтулла) Хисмәтулла улы (25.9.1934, Актаныш р-ны Әнәк а. — 28.1.2004, Чаллы ш., туган авылында җирләнә), язучы, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1984). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1958), «Маяк» (Азнакай ш.), «Алга» (Питрәч а.) г-талары редакцияләрендә әдәби хезмәткәр, ТАССР МС каршындагы Радиотапшырулар һәм телевидение ком-тында мөхәррир. 1963–66 елларда Казанда яши, Казан ун-тында ЭВМ программисты булып эшли. 1966–88 дә Түбән Кама шәһәрендә яши, «Социалистик Татарстан» г-тасының үзхәбәрчесе, урта мәктәптә укытучы, «Түбәнкаманефтехим» ҖБдә инженер-төзүче булып эшли. 1989–97 дә ТР Язучылар берлегенең Чаллы бүлегендә җаваплы сәркәтип. Хезмәт кешеләре турында очерклар җыентыклары авторы: «Салават күпере» (1964), «Күкрәү авазлары» (1967), «Үземне таптым» (1980), «Сусау» (1984), «Кыйбла җиле» (1992). Х. геройларын документаль төгәллек һәм романтик пафос б-н сурәтли. «Яшенле тау» (1988), «Ак догалар» (1992), «Тәүбә» (1995) шигырь җыентыклары авторы.

Әд.: Ә г ъ з а м о в Ф. Вөҗдан баскычларын санаганда // Казан утлары. 1981. № 7.

ХИСМӘТУ́ЛЛИН Нәҗип Ихсан улы (1.12.1934, БАССРның Аургазы р-ны Семёнкино а.), инженер-механик, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1985). Уфа нефть ин-тының Эстәрлетамак ф-лын тәмамлый (1967). Хезмәт эшчәнлеген 1956 елда «Туймазыбурнефть» трестында бораулаучы ярдәмчесе булып башлый; 1961 дән Эстәрлетамак ясалма каучук з-дында (БАССР): машинист, цех механигы. 1970–2001 дә «Түбәнкаманефтехим» АҖдә: цех башлыгы урынбасары, баш механик урынбасары, бутилкаучук җитештерү з-дында баш механик, АҖдә баш механик (1997 дән). Уйлап табуга 10 авторлык таныклыгы, 2 патенты бар. Дәүләт бүләге ясалма каучук алу өчен автоматлаштырылган линияләр булдыруда һәм аларны сәнәгатькә кертүдә катнашканы өчен бирелә. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале, ТАССР ЮСның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Механики Нижнекамскнефтехима. К., 1996 (автордаш).

ХИСМӘТУ́ЛЛИН Ришат Сәхап улы (4.3.1953, Әлки р-ны Базарлы Матак а.), зооинженер, вет. фән. канд.(2006), ТРның, РФнең атказ. а.х. хезмәткәре (2000, 2010). Казан вет. ин-тын (хәзер Казан вет. медицинасы академиясе) тәмамлаганнан соң (1978), Саба р-нының Ленин исем. Тәҗрибә-җитештерү хуҗалыгында баш зоотехник булып эшли. 1983–86 елларда «Татгосплемобъединение» башлыгы урынбасары, бүленеп, башлыгы (1991–92). 1986–90 да КПССның Татарстан өлкә ком-тында. 1990 нан «Татхлебопродукт» ҖБ ген. директоры урынбасары, 1992 дән авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары, 1995 тән — «Сөт продукциясе» АҖ, 1997 дән — «Агрофирма «Ак Барс-Питрәч» АҖ ген. директоры, 2003 тән «Казан» кошчылык фабрикасы» АҖ ген. директоры киңәшчесе, 2011 дән «Ак Барс» холдинг компаниясе» АҖ ген. директоры киңәшчесе. Медальләр б-н бүләкләнә.

ХИСМӘТУ́ЛЛИН Хәй (Габделхәй) Хисмәтулла улы (8.11.1895, Казан өязенең Кыснa а. — 1.12.1977, Казан), әдәбият галиме, текстолог. 1933 елда Татар пед. ин-тын тәмамлый. 1938–41 дә Татар укытучылар белемен күтәрү ин-тында эшли, аннан соң ТАССР Үзәк музеенда бүлек мөдире. 1944–65 тә СССР ФАнең Казан ф-лы Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында. Хезмәтләре татар әдәбияты тарихына, З.Һади, Г.Камал, Ф.Кәрими, С.Рәмиев, М.Гафури иҗатларына карый. Г.Тукай (1–2 т., 1943–48), К.Насыйри (1953), Ф.Әмирхан (1–2 т., 1957–58), Г.Толымбайский (1959), Ф.Сәйфи-Казанлы (1960) хезмәтләренең җыентыкларын басмага әзерләүдә катнаша.

Х е з м.: ХХ йөз башында татар әдәбияты. К., 1954 (автордаш); Фатих Әмирхан. К., 1961; Галиәсгар Камал. К., 1969.

Әд.: Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

ХИСМӘТУ́ЛЛИНА Зөләйха Гатаулла кызы (22.11.1922, Казан — 24.2.1994, шунда ук), җырчы (лирик-драматик сопрано), педагог, РСФСРның һәм ТРның халык артисты (1966, 1992), проф. (1983). 1950 елда Казан консерваториясен (К.Цветов классы) тәмамлый. 1945–74 тә Татар опера һәм балет театрының әйдәп баручы солисты. 1961 дән Казан консерваториясендә укыта (1974–83 тә ялгыз җырлау каф. мөдире). Опера сәхнәсендә 40 тан артык партия башкара: Аида (шул исем. әсәр буенча, Дж.Верди), Чио-Чио-сан (шул исем. әсәр буенча, Дж.Пуччини), Тоска (шул исем. әсәр буенча, Дж.Пуччини), Татьяна, Лиза («Евгений Онегин», «Пики дамасы», П.Чайковский), Леонора («Трубадур», Дж.Верди), Земфира («Алеко», С.Рахманинов), Каракаш, Аембикә («Алтынчәч», «Түләк һәм Сусылу», Н.Җиһанов), Әлфия («Самат», Х.Вәлиуллин), Галия («Тапшырылмаган хатлар»,



З.Г.Хисмәтуллина.



З.Г.Хисмәтуллина Русалка ролендә (шул исем. әсәр буенча. А.Даргомыжский).

Ж.Фәйзи) һ.б. Җырчының күпкырлы концерт репертуары тематик программаларны да («Муса Җәлил һәм музыка», «Тукай һәм музыка», «ХХ гасыр композиторлары» һ.б.) үз эченә ала. Җырчының тавышы — матур аһәңе, яңгыравыклы булуы, башкаруы дикциясенең төгәллеге, тәэсирлелеге, образлылыгы, югары техник үзенчәлеге һәм сәнгатьчәлеге, башкарыла торган әсәрнең эчтәлеген тирәнтен ачып бирә белү осталыгы б-н аерылып тора. Укучылары — Ә.Заһидуллина, З.Сәхәбиева, Г.Казанцева, Р.Маликов. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

Әд.: Народные артисты. К., 1980.

Ф.Ш.Салитова.



З.Г.Хисмәтуллина Леонора ролендә («Трубадур», Дж.Верди).

ХИСМӘТУ́ЛЛИНА Наилә Әнвәр кызы (2.10.1959, Казан), иммунолог, вирусолог, биол. фән. д-ры (2001), проф. (2008), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2010). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1982), Хайваннарның токсикологик, радиацион һәм биол. куркынычсызлыгы буенча федераль үзәктә (Казан) эшли, иммунология лаб-ясе мөдире (2008 елдан). Хезмәтләре хайваннардагы йогышлы авыруларга диагноз кую, авыруларны кисәтү һәм дәвалау мәсьәләләренә карый. Х. котыру авыруына диагноз кую өчен иммун-химик чаралар эшли, төрле токымга караган а.х. терлекләренең иммун статусын бәяләү, кыр-



М.Д. Хитев.

гый фауна вәкилләренә һәм а.х. терлекләренә котыру авыруына, РФ төбәкләрендә һәм БДБ илләрендә Ауэски авыруына һәм дуңгызларда классик чумага каршы ясалган вакцина профилактикасының нәтиҗәлелеген ачыклау өчен мониторинг тикшеренүләре үткәрә. Уйлап табуга 2 патенты бар.

Х е з м.: Разработка экспресс-методов иммунологического мониторинга при бешенстве // Вопр. вирусологии. 2001. № 5 (автордаш); Бешенство. Этиология. Эпизоотология. Диагностика: Учеб.-метод. пособие в илл. М., 2010 (автордаш); Совершенствование мер борьбы с бешенством в Смоленской области // Ветеринария. 2011. № 4 (автордаш).

ХИ́ТЕВ Михаил Дмитриевич (12.9.1919, Казан губ., Зөя өязе Бишбатман а.- ?, Украина ССРның Одесса өлкәсе Любашёвка штп), Дан орденының тулы кавалеры (19.1.1944, 18.5.1944, 27.6.1945), гв. өлкән сержанты. Туган авылында колхозда эшли. 1939 елдан Кызыл Армиядә.1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында: туп төзәүче, 32 нче гв. артиллерия полкының (5 нче гв. армиясенең 13 нче гв. укчы дивизиясе) туп командиры. 1 нче һәм 2 нче Украина фронты гаскәрләре составында Кировоград, Умань-Ботошани (икесе дә 1944 тә), Сандомир-Силезия, Югары Силезия һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 5–6 гыйнварында Ново-Николаевка торак пункты (Украина ССРның Запорожье өлкәсе) тирәсендә дошманның танк һөҗүмнәрен кире кайтарганда (туп расчёты составында туры төзәп атып, 2 танкны һәм 3 бронетранспортёрны сафтан чыгара), 1944 нең 9 февраль — 12 мартында Шпаково, Кениш, Квитка авыллары һәм Шевченко утары (Украина ССРның Кировоград өлкәсе) янындагы сугышларда (артиллеристлар һәм туп төзәүче Х., ачык позициядә калып, 1 танк, 2 бронетранспортёр һәм 4 автомашинаны юк итәләр, 2 блиндажны җимерәләр), 1945 нең 27 гыйнвар — 19 февраледә Етцдорф, Гросс-Пейскерау, Шлауп (Бреслау ш. янында, хәзер Вроцлав ш., Польша) торак пунктлары тирәсендәге сугышларда (Х. җитәкчелегендә, ачык позициядән утка тотып, дошманның танкка каршы атучы тубы, 10 лап пулемёт ноктасы сафтан чыгарыла, күп кенә солдаты юк ителә, бу терәк пунктларны басып алырга мөмкинлек туды ра) батырлык күрсәтә. Демобилизацияләнгәч (1946), туган җиренә кайта. 1948 дән Любашёвкада яши, балта остасы булып эшли. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

М.З.Хәбибуллин.

«ХИТО́Н», химия сәнәгате пр-тиесе. 1942 елда Молотов р-ны сәнәгать комб-ты буларак нигезләнә, 1956 дан Казан химия з-ды, 1961 дән Казан лак-буяу з-ды, 1967 дән Казан көнкүреш химиясе з-ды, 1984 тән «Казаньбытхим» ҖБ, 1990 нан «Х.» ҖБ, 1993 тән АҖ. Башта пр-тие тегүчелек, итек тегү, слесарьлык остаханәләре һ.б.ны үз эченә ала. 1946 да буяу, сабын кайнату, күн эшләү цехлары һ.б. оештырыла. Алга таба майлы буяулар, олифа, лак, идән мастикасы, машина мае, аяк киеме кремы, тәрәзә замазкасы, мездра һәм резина җилеме, язу каралары, пыялалар, көзгеләр, фарфор чистарту өчен чаралар, май нигезендә шампуньнар, универсаль «Мальва» юу пастасы һәм полиэтилен банкалар эшләп



«Хитон» АҖ. Завод идарәсе бинасы.

чыгаруны үзләштереп, 1955 тән пр-тие тулысынча көнкүреш химиясе продукциясе җитештерүгә күчә. 1960 еллар ахырында — 1970 еллар башында яңа җитештерү мәйданчыгы төзелә һәм заводны тамырдан реконструкцияләү, җитештерү процессларын механикалаштыру һәм автоматлаштыру уздырыла. 1976 да аэрозоль сыешлыкка салынган товарлар (илдә беренче тапкыр) һәм лак-буяу материаллары производстволары файдалануга тапшырыла. 1980 елларда һава сафландыргычлар, тән дезодоранты, шампуньнар, юу чаралары, ПФ эмале һ.б. эшләнә һәм җитештерелә башлый. 2005 тә гофрокартон производствосы сафка баса, Германия, Италия, Швейцариядән кайтарылган югары технологияле автоматлаштырылган җи һазлар нигезендә аэрозоль һәм лак-буяу производстволарын модернизацияләү җәелдерелә. Нәтиҗәдә, ассортимент киңәйтелә, калайдан баллоннар эшләп чыгару күләме арта, төрле максатлардагы заманча лак-буяу материалларын эшләү җайга салына. Пр-тиенең сыйфат менеджменты системасының халыкара ИСО 9001–2008 стандартына туры килүе сертификат б-н раслана. «Х.» составына аэрозоль продукциясе (еллык җитештерү куәте 50 млн. баллон), лак-буяу (15 мең *т*), синтетик юу чаралары (4,5 мең *т*), гофропродукция (30 млн. кв. м дан артык) производстволары, пластмассалар цехы һ.б. бүлекләр керә, гомуми эшләүчеләр саны 300 дән артык кеше (2014). Пр-тие ассортименты 100 дән артык исемдәге эшләнмәдән («КРА», «Антис», «Стиль-Классик», «Toilex», «Derbi», «Секунда», «Мальва», «Рулевой» маркалары) гыйбарәт, ш.и. сулы һәм коры бөркүле һава сафландыргычлар; бөҗәкләргә каршы инсектицидлар һәм репеллентлар; чәч лаклары; торбалар, пыялалар, савыт-саба юу, чистарту өчен чистартучы һәм дезинфекцияләүче, автомобильне карап тоту өчен универсаль чаралар; шампуньнар, юу пастасы; өс лекләрне антистатик эшкәртү өчен чаралар; лаклар, буяулар, эмаль, грунтовка; гофросыешлык; җылылык изоляциясе өчен базальт матлар; калайдан сувенир эшләнмәләр. Чимал б-н ТР («Татспиртпром», «Казаноргсинтез», «Барс Синтез», «Түбәнкаманефтехим-Сервис», «Татхимреактив», «Химпласт», «Промполиграф»), Мәскәү һәм Мәскәү яны, Түбән Новгород, Дзержинск һ.б. шәһәрләр компанияләре тәэмин итә. «Х.» РФдә көнкүреш химиясе җитештерүче әйдәп баручы пр-тиеләрнең берсе булып тора. Аның вәкиллекләре Мәскәүдә һәм Мәскәү өлкәсендә, С.-Петербургта, Краснодар краенда, Хабаровск, Самара, Пермь шәһәрләрендә эшли. Продукция Венгриягә, Польшага, ГДР га җибәрелде, Украинага, Белоруссиягә, Казакъстанга, Үзбәкстанга, Молдавиягә, Кыргызстанга чыгарыла. «Х.» төрле елларда «Россиянең иң яхшы



«Хитон» АҖ. 1. Аэрозоль производствосы; 2. Предприятие продукциясе.

100 товары», «Илнең иң яхшы товары», «Россиянең иң яхшы 10 товары», «Татарстан Республикасының иң яхшы товарлары» конкурслары, «БытХимЭкспо», «ИнтерБытХим» халыкара күргәзмәләре лауреаты.

Пр-тиенең күп кенә хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә лаек була, ш.и. 1әр кеше — Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе», 2 нче һәм 3 нче дәрәҗә «Хезмәт Даны» орденнары, 15 кеше медальләр б-н бүләкләнә. Пр-тие җитәкчеләре арасында — Ф.Ф.Балахнин (1942–?), Р.А.Каргин (1968–2003), С.П.Щетников (2003–05), А.А.Хәнәфиев (2005–07), В.М.Егоров (2007–12), С.А.Дёшин (2012 дән).

С.Г.Белов.

ХИТРИДИОМИЦЕТЛА́Р, архимицетлар (Chytridiomycetes), иң түбән төзелешле микроскопик вак гөмбәләр классы. 100 гә якын төре билгеле, бөтен Җир шарында таралганнар. Татарстан терр-ясендә Olpidium, Synchytrium, Cladochytrium, Plysoderma һ.б. ыруглар очрый. Х.ның вегетатив гәүдәсе — мицелий, начар үсеш алган яки шома плазмадан тора. Күзәнәк стеналарында целлюлоза юк, скелет матдәсе сыйфатында хитин катнаша. Җенессез үрчи, бу вакытта бер камчылы зооспоралы зооспорангийлар барлыкка килә. Хитридияле гөмбәләрнең күпчелеге — суүсемнәр, югары төзелешле үсемлекләр паразиты, дымлылык артык булганда а. х. культураларында авырулар (бәрәңге рагы, кәбестә, салат караягы һ.б.) китереп чыгаралар.

ХИТРО́В Венедикт Юрьевич (31.5.1945, Казан — 27.12.2011, шунда ук), стоматолог, мед. фән. д-ры (2002), проф. (2002), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2006). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1967), 9 нчы поликлиникада эшли (Казан). 1970 елдан «Теплокон троль» з-ды амбулаториясендә.1971 дән Казан ГИДУВының (хәзер Казан мед. академиясе) стомат. кафедрасында, 1991–2010 да терапевтик стомат. һәм балалар стоматологиясе каф. мөдире, бер үк вакытта, 2008 гә кадәр, стомат. ф-ты деканы. Х. теш-казналык системасы формалашуда кальцийның ролен өйрәнә, балаларда стоматологик авыруларны (ш.и. шикәр диабеты очракларында) кисәтү ысулларын, үсмерлек чоры пародонтозына функциональ диагностика уздыру методларын тәкъдим итә. Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Глоссалгия: Клиника, диагностика, лечение. К., 1998 (автордаш); Кальций и его значение в формировании зубочелюстной системы: Современные аспекты. К., 2003 (автордаш); Эндоскопические штифты: аргументированный выбор. К., 2007 (автордаш).

ХИЩНЕЦЛА́Р (Reduviidae), кандалалар семьялыгы. Гәүдәсенең озынлыгы 4–30 *мм*, еш кына 10–20 *мм*. Кыска, калын, нык кына бөгелгән хортумчыгы бар, ул гәүдәгә орынып тормый. 3 меңгә якын төре билгеле, тропикларда киң таралган. Европада 14 ыругка караучы 30 лап төре бар. Татарстан терр-ясендә 4 төре билгеле; гадәттә, божралы хищнец (Rhynocoris annulatus) еш очрый. Агачларда, үләндә, туфрак өслегендә, кайбер төрләре — вак имезүчеләрнең оялларында һәм өннәрендә, корылмаларда, ташлар астында яшиләр. Ерткычлар, төрле бөҗәкләр б-н туеналар. Кайбер төрләренең тешләве кешедә авырту барлыкка китерә.

С.М.Шәфигуллина.

ХЛАМИДИОЗГА́ КАРШЫ́ ИНАКТИВЛАШКА́Н ЭМУЛЬСИО́Н ВАКЦИ́НА, препарат бозау, сыер һәм нәсел үгезләренең иммунитетын арттыру өчен кулланыла. 1993 елда Бөтенроссия вет. фәнни-тикшеренү ин-тының вирусология лаб-ясендә Р.Х.Хәмәдиев, Г.Равилев, Ф.М.Хөсәенов, А.Ю.Бекалешева тарафыннан китереп чыгарыла. Вакцина стерильләштерелгән, зыянсыз, авыруга каршы торучанлыкны арттыра. Каплатырга 25–30 көн кала сыерлар һәм таналарның мускул тукымасына — 2 *мл*, 1 айлык бозауларга 1 *мл* дозасында кадаганда, очраклы рәвештә йоккан хламидиоз инфекцияләргә дәвамлы һәм тотрыклы иммунитет тудыра. Вакцина кулланганда бозау салу, үле бозау китерү һәм үлем очраклары сизелерлек ким. Идел буе төбәгендә кулланыла.

Р.Х.Хәмәдиев.

ХЛЕ́БНИКОВ Велимир (Виктор) Владимирович (28.10.1885, Әстерхан губ., Кече Дербент олысы Зимняя Ставка а. — 28.6.1922, Түбән Новгород губ., Крестцы өязе Санталово а.), шагыйрь, футуризм теоретигы. Казандагы Өченче ир балалар гимназиясен тәмамлый (1903), уку елларында нәкышьче П.П.Беньковтан дәресләр ала. 1903–08 елларда Казан ун-тында укый, нәевклид геометриясе б-н кызыксына башлый («Язмыш такталары» — «Доски судьбы» фәлсәфи-матем. хезмәте, М., 1922). Иҗатының Казандагы башлангыч чорында халыкларның борын-гы община дәвере тормышы, борынгы һәм урта гасырлар тарихы, мәҗүсилек мифологиясе, славян халыклары фольклоры, ш.у. «акыллы табигать» идеясе б-н кызыксына («Көймәдә» — «Как во лодочке, во лодочке...» шигыре, 1903–04; «Кар кызы» — «Снежимочка» Раштуа әкияте, 1908). Студент елларында, гомумславян телен булдыру турында хыялланып, сүзләр б-н тәжрибәләр ясый башлый («Бобэоби пелись...», «Кузнечик», «О, рассмейтесь, смехачи»). 1905–07 еллардагы Рев-ция һәм М.Горькийның романтик әсәрләре тәэсирендә прозасы аллегорияләр б-н сугарыла («Караңгылык иде» — «Была тьма», «Караңгылык җыры» — «Песнь мраков»). Гомере буе Х.ның рухи дөньясы Казан б-н бәйле була, алдагы иҗатында Казан мотивлары (Идел, Казан Кремле, Болгар ш.) һәм Шәрекъ темасы урын ала: «Разин», «Хаҗитархан» — «Хаджи-Тархан» (икесе дә — 1913), «Ладомир» (1920), «Егет юкка кычкырды» — «Напрасно юноша кричал» (1921) поэмалары, «Зәңгәр богаулар» — «Синие оковы», «Көлке китабы» — «Буфная книга», «Ачлык» — «Голод», «Уйнагыз, кычкырыгыз, күтәреп барыгыз...» — «Трубите, кричите, несите» шигырьләре (барысы да — 1921) һ.б. Казанда Х. галим һәм шагыйрь булып формалаша.

Х е з м.: Неизданные произведения Велимира Хлебникова. М., 1940; Творения. М., 1987.

Әд.: А р и с т о в В.В. Хлебников в Казани. К., 2001; С т а р к и н а С. Велимир Хлебников: Корень времени: Биография. СПб., 2005.

И.И.Андреева.


ХЛЕ́БНИКОВА Тамара Александровна (22.5.1928, БАССРның Калтасы р-ны Яңа Берёзовка а. — 22.7.2001, Казан), археолог, тарих фән. канд. (1964). Казан ун-тын тәмамлый (1952). 1957–86 елларда СССР ФА Казан ф-лының Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында эшли. Болгар, Суар, Жүкәтау шәһәрлекләрендә, Казан Кремлендә, Татарстан һәм Мари АССРның, Ульянов өлкәсенең борынгы һәм урта гасырлар авыллыкларында тикшеренүләр уздыра. Хезмәтләре Болгар тарихына һәм болгарларның һөнәрчелек җитештерүенә карый. «Татарстан Республикасының археологик картасы»н («Археологическая карта Республики Татарстан», т. 1–6, 1981–90) төзүдә катнашуы өчен ТР Дәүләт бүләгенә лаек була (1994).

Х е з м.: Археологические памятники у села Рождествено. К., 1962 (автордаш); Керамика памятников Волжской Булгарии. М., 1984.

Әд.: С т а р о с т и н П.Н., Х у з и н Ф.Ш., Ш а р и ф у л л и н Р.Ф. Видный археолог-булгаровед (к 65-летию Т.А.Хлебниковой) // Археология Волжской булгарии: проблемы, поиски, решения. К.,1993; Археологи Волго-Уральского региона. Уфа, 2002.

Ф.Ш.Хуҗин.

ХЛЕ́БНИКОВА-МИТУ́РИЧ Вера Владимировна (20.3.1891, Әстерхан губ., Кече Дербет олысы Зимняя Ставка а. — 1941, Мәскәү) нәкышьче, график, шагыйрә. Шагыйрь Велимир Хлебниковның сеңлесе, рәссам П.Митуричның хатыны. Казанда Мария кыз





В.В. Хлебникова-Митурич.
1. Автопортрет. 1900. Әстерхандагы В.Хлебников музей-йорты.
2. «Су анасы». «Урман сагышы» поэмасына иллюстрация. Кәгазь. Акварель. 1920 еллар.

балалар гимназиясендә укый (1899–1905). Рәсем дәресләрен башлап П.П.Беньковтан һәм Л.М.Чернов-Плесскодан ала. Укуын Казан сынлы сәнгать уч-щесендә дәвам иттерә (1905–08). «Карчык башы», «Натрущик башы», «Велимир мордва бүрегеннән» (бары сы да — 1910 елга кадәр, иҗатының Казан чоры). Со ңыннан Италиядә, Франциядә яши һәм эшли, К.ван Донгеннан дәресләр ала. 1916 да Россиягә кайта. Х.-М.ның иҗаты — илебез сәнгате тарихында якты сәхифә. В.Хлебниковның фәлсәфи карашлары б-н күп очракта тәңгәл килгән, нәкышь һәм графикадан тыш шигырьләрдә, эпистоляр мираста үсеш алган гаҗәп әдәби талантка ия. Картиналары Рус музеенда, А.С.Пушкин исем. сынлы сәнгать музеенда, П.М.Догадин исем. Әстерхан картиналар галереясында, Әстерхан шәһәрендә В.Хлебников музей-йортында саклана.

Әсәр.: «Что нужно душе...»: Стихи. Проза. Письма. М., 2000.

Әд.: Хлебникова Вера Владимировна. 1891–1941: Живопись, графика из музеев СССР и собрания М.П.Митурича: Каталог выставки. М., 1977; Ключевская Е.П. Казанская художественная школа. 1895–1917. СПб., 2009.

ХЛЕБОДА́РОВКА авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 18 *км* төньяктарак, Салман елгасы буенда. 2010 елда 119 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Урта мәктәп, клуб. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстиянәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында земство мәктәбе, 2 җил тегермәне, тимерче алачыгы, ярма яргыч, 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1456 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Базарлы Матак волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Спас, 1935 нең 25 гыйнварыннан — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1859 һәм 1908 дә — 709 ар, 1920 дә — 713, 1926 да — 529, 1938 дә — 363, 1949 да — 216, 1958 дә — 172, 1970 тә — 142, 1979 да — 97, 1989 да — 73, 2002 дә — 139 кеше.

ХЛО́ПИН Виталий Григорьевич (26.1.1890, Пермь ш. — 10.7. 1950, Ленинград), радиохимик, СССР ФА академигы (1939; 1933 тән мөхбир әгъза), РСФСРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1940), Соц. Хезмәт Герое (1949). Гёттинген һәм Петербург ун-тларын тәмамлый (1911, 1912). 1915 елдан РФА Радиология лаб-ясендә, 1922 дән Радий ин-тында (Ленинград) эшли, 1939–50 дә директор. Бер үк вакытта, 1924 тән, Ленинград ун-тында, СССРда беренче буларак, радиоэлементлары химиясе һәм радиохимия буенча махсус курс укый, проф. (1934). Хезмәтләре радиоактив элементларның химиясе һәм геохимиясенә карый. Х. — илдә радиохимиягә һәм радий сәнәгатенә нигез салучылардан берсе. 1918–21 дә И.Я.Башилов б-н берлектә Бондюг авылында (хәзер ТРның Менделеевск ш.) Россиядәге беренче радий з-дын төзүгә җитәкчелек итә. Заводта җирле чималдан



В.Г.Хлопин.

радий препаратлары җитештерелә. Х. җитәкчелегендә ураннан плутонийны сәнәгый кисуллар б-н алу технологияләре, газ, күләм, үлчәү б-н бәйле һәм калориметрик анализ алымнары эшләнә. Бөек Ватан сугышы елларында Казанда радиоторий кулланып яктылык составлары җитештерү ысулын эшли. Оборона сәнәгате өчен яктылык составларын җитештергәндә кулланылган радиоторийны бүлеп чыгару максатыннан радийның дәүләт запасларын тикшерү эшләре алып барганы өчен Сталин бүләге (1943), СССР Дәүләт бүләге (1946,1949) бирелә.

Хезм.: Избр. труды: В 2 т. М.–Л., 1957.

Әд.: Виталий Григорьевич Хлопин: Материалы к биобиблиогр. учёных СССР. Сер. хим. наук. М.–Л., 1947. Вып. 4; Волков В.А., Вонский Е.В. Кузнецова Г.И. Выдающиеся химики мира: Биогр. справ. М., 1991.

ХЛЫСТО́ВО (Ылыстау) авылы, Алабуга р-нында, Алабуга шәһәреннән 8 *км* төньяк-көнбатыштарак, Казан-Уфа автомобиль юлы буенда. 2010 елда 383 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 65%, руслар — 29%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты. Мәдәният-спорт комплексы. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстиянәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында тегермән эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2341 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Лекарево волостенда, 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Алабуга р-нында. Халык саны: 1859 да — 712, 1887 дә — 878, 1905 тә — 964, 1920 дә — 932, 1926 да — 948, 1938 дә — 705, 1949 да — 311, 1958 дә — 292, 1970 тә — 175, 1979 да — 88, 1989 да — 80, 2002 дә — 279 кеше.

ХОДАЙКО́Л (? — 13.3.1523, Мәскәү), Казан угланы (ханзадәсе). *Ибра һим хан* улы. Мәскәү гаскәрләре Казанны яулап алганнан соң (1487), Карголома авылына (Белоозеро шәһәре бистәсе) сөрелә. Соңрак сөргеннән кайтарыла. 1505 елда Петр Ибрагимович исеме б-н чукына. Мәскәүнең бөек кенәзе Василий III сеңлесе Евдокиягә өйләнә. 1510 да, рус гаскәрләре Псков шәһәренә яу б-н барганда, полкны җитәкли. Бөек кенәз сараенда югары урын бири; берара тәхет варисы булып санала; бөек кенәз яулары вакытында (1513–14, 1521) Мәскәүдә идарәче булып кала. Архангел соборында җирләнә (Мәскәү).

Әд.: Вельяминов-Зернов В.В. Исследования о касимовских царях и царевичах. СПб., 1863. Ч. 1; Худяков М.Г. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923.

И.Л.Измайлов.

ХОДАЙКО́Л БӘК (? — 1552 елның мартыннан соң), Казан ханлыгы карачыбәге. *Сөембикә* тәхеттән төшерелгәннән соң (1551), тәхеткә *Шаһгалине* чакырган хөкүмәт әгъзасы. Зөядә Иван IV хөкүмәте вәкилләре б-н сөйләшүләр алып барган Казан аксөякләре илчелеге составына керә (1551–52). 1552 елның мартында Ислам, Кибәк һәм Нарыйк улы Галикәй бәкләр Иван IV наместнигы С.И.Микулинскийның Казанга килергә тиешлеге турындагы килешүне бозганнан соң, русларда әсирлектә кала. Шуннан соңгы язмышы билгесез.

Әд.: Худяков М.Г. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923; Алишев С.Х. Казань и Москва: межгосударственные отношения в XV – XVI вв. К., 1995.

ХОДАЯ́РОВ (Кудояров) Галә (Галәветдин) Гайнетдин улы (7.9.1891, Уфа губ., Уфа өязенең Яңа Абдул а. — 1966), дәүләт эшлеклесе. «Галия» мәдрәсәсендә укый. 1908–18 елларда Уфа шәһәрендә укыта. 1917 дә Мөселман шәкертләр ком-тын оештыручыларның берсе һәм аның рәисе (Уфа). 1920 дә «Шәрекъ ярлылары» г-тасы мөхәррире. 1924–27 дә «Таткожтрест» директоры, ТАССР ХХС рәисе урынбасары. 1928 дән А.х. кооперациясе берлеге рәисе, Шәрекъ пед. ин-ты ректоры, ТАССР Мәгариф халык комиссары, бер үк вакытта, 1920 елларда, тәр җемәчелек эшчәнлеге б-н шөгыльләнә, ВКП(б) тарихы буенча хезмәтләр авторы. 1932 дә репрессияләнә; 1956 да аклана.

Хезм.: Научный коммунизм. К., 1921.

Ф.Г.Кәлимуллина.

ХОДЖА́ЕВ (Хуҗиев) Равил Шәриф улы (11.9.1937, Петропавловск ш.), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1982), проф. (1983). Караганда политехник ин-тын тәмамлый (1964). 1965–66 елларда шунда ук эшли. 1966–69 да Үзәк ташкүмер фәнни-тикшеренү ин-тында (Мәскәү). 1970 тән Караганда ташкүмер ин-тында сектор мөдире, 1976–2002 дә Караганда политехник ин-тында каф. мөдире. Төп хезмәтләре тау эшләре пр-тиеләрендә планлаштыру һәм идарә итүне камилләштерү өчен табигый факторларга прогноз ясау һәм аларны исәпкә алу мәсь әләләренә карый.

Хезм.: Экономическая оценка разработки нарушенных угольных пластов. М., 1978; Экономическая эффективность эксплуатации сложных угольных месторождений. М., 1983.

Әд.: Казахская ССР: Краткая энцикл. А.-А., 1989. Т. 3.

ХОДОРО́ВСКИЙ Иосиф Исаевич (1885, Херсон губ. Николаев ш. — 7.5.1938, Мәскәү), революционер, партия, хуҗалык эшлеклесе. 1903 елдан РСДРП(б), 1905 тән РСДРП(б) ның Николаев ком-ты әгъзасы. 1905–07 дәге рев-циядә, 1917 нең октябрендә Мәскәүдәге кораллы күтәрелештә катнашучы. 1918 дә Хезмәт халык комис-ты әгъзасы. Гражданнар сугышында катнаша: 1918 дән Көньяк фронтта, сәяси бүлек башлыгы, РВС әгъзасы. 1919–20 дә Казан губерна башкарма ком-ты һәм РКП(б)ның губерна ком-ты рәисе, Татревком рәисе урынбасары. Эшче һәм кызылармияче депутатлары-ның Казан шәһәр советы башкарма ком-тын ул оештырылган вакыттан 1920 нең көзенә кадәр җитәкли. 1921 дән Тула губерна башкарма ком-ты рәисе, аннары РКП(б) ҮК ның Себер бюросы секретаре. 1922–28 дә РСФСР

халык мәгарифе халык комиссары урынбасары, бер үк вакытта, 1924 тән Һөнәри-техник белем бирү баш идарәсе мөдире. 1928 дән Италиядә, Төркиядә сәүдә вәкиле. 1932 дән СССР ҮБК каршындагы Югары техник мәктәп эшләре ком-ты рәисе урынбасары, 1934 тән Кремльнең Дәвалау-санитария идарәсе башлыгы. Репрессияләнә; үлгәннән соң аклана.

Әд.: Чернышёв Г. Ходоровский Йосиф Исаевич // Борцы за счастье народное. К., 1983. Кн. 2.

Л.М.Айнетдинова.

ХОДЯ́Ш тимер юл разъезды посёлогы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 14 *км* көньяктарак, Ульянов–Зөя тимер юлы буенда. 2010 елда 26 кеше (руслар) яши. 1940 елларда нигез салына. Оешкан көненнән — Норлат, 1963 нең 1 февраленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1958 дә — 57, 1970 тә — 85, 1979 да — 55, 1989 да — 37, 2002 дә — 31 кеше.

«ХОЗӘЙФӘ ИБНЕ́ ӘЛ-ЯМӘНИ́», Казандагы мәчет. Мөхәммәд пәйгамбәрнең көрәш - тәше, хәрби җитәкче һәм күп кенә хәдисләр - не төзүче (?–656) хөрмәтенә атала. 1996–97 елларда арх. В.Е.Белицкий, инженер А.Г.Хәйретдинов проекты буенча төзелә. Казанның көньяк-көнчыгыш өлешендә, 10 нчы микрор-нда урнашкан. Өстә гөмбәзле, аста намаз уку заллары, төньякта дүрт яруслы манарасы булган ике катлы бина. Мәчетнең якты ртылган эргә катында зур булмаган зал, уку һәм эш бүлмәләре бар. Ирләр өчен төнъ - якта н һәм хатын-кызлар өчен көнчыгыштан аерым керү юллары гардероблы булган вестибюльләргә илтә. Хатын-кызлар өчен зал 1 нче катның көньяк өлешендә урнашкан, ул 2 нче катка көньяк-көнчыгыш почмактагы баскыч б-н тоташтырылган. Ирләр өчен билгеләнгән 2 нче катка вестибюльдән манара тирәли эшләнгән өч маршлы баскыч күтәрелә. Ирләр залындагы квадрат 4 колонна сигез кырлы якты лык барабаны һәм очлаеп тәмамланган гөмбәзне тота. Көньяк фасадтагы ярымтүгәрәк михраб ике яклап дивар чы - гынтылары б-н чикләнгән һәм бер кыеклы түбә б-н капланган. Мәчетнең гөмбәзе күчәргә карата кыек түбәләр б-н «төньяк-көньяк» өлешләргә бүленә. Өскә таба квадрат кырлары кечерәя барган дүрт яруслы манара кечкенә чатыр б-н төгәлләнә. Кирпеч диварлар штукатурланган һәм яшел-зәңгәр төскә буялган. Фасадлар фигуралап ясалган кәрнизләр һәм парлы тар тәрәзәләр ясалган тирән булмаган куышлыклар б-н бизәлгән.



Казандагы Хозәйфә ибне әл-Ямәни мәчете.

Әд.: Мечети Татарстана / Сост. Х.Г.Надырова, Р.Р.Салихов, Р.Р.Хайрутдинов. К., 2000.

Х.Г.Надыйрова.

ХО́ЗИН Вадим Григорьевич (18.9.1939, Әлмәт ш.), химик-технолог, техник фән. д-ры (1982), проф. (1984), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1992), РФнең атказ. фән эшлеклесе (1998). 1962 елда Казан төзүче инженерлар ин-тын тәмамлый, 1963 тән күзәнәкле бетон з-дында (Чаллы ш.) эшли. 1964 тән Казан архит-ра-төзелеш ун-тында, төзү материаллары, эшләнмәләр һәм конструкцияләр технол. каф. мөдире (1984 тән). Хезмәтләре материаллар белеменә, полимерлар һәм минераль беркеткечләр нигезендә ясалган композицион материалларның физик-химик модификациясенә карый. Х. эпоксид полимерларның антипластификация эффектын ачыклый, бу процессның төп законча - лыкларын һәм механизмын таба. Олигомер бәйләгечләрнең виброакустик модификация - се ысулын, челтәрле полимерлар модификациясенең структур нәселдәнлек (сыек олигомердан каты полимерга таба) принцибын, активлаштырылган коры катнашмалардан цемент күбек бетоннарны җитештерү ысулын; коррозиягә каршы торучан полимер композицияләрне, композицион бәйләгечләрнең яңа төре — органик-нәорганик гибрид полимерларны, битумполимер материалларны һәм битум эмульсияләрен, үтә ныклы комлы бетоннарны һәм базальт фибробетоннарын эшли. «Цементлы бетоннар өчен яңа АРОС суперпластификаторын җитештерү» һәм «Суга ихтыя җы аз карбонат цементлары» инновация проектлары авторы һәм җитәкчесе. Уйлап табуга 60 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. «Төзелеш эшендә полимерлар» («Полимеры в строительстве») фәнни хезмәтләр җыенты - гы мөхәррире (1999, 2004, 2009). Медальләр б-н бүләкләнә. РФнең мактаулы югары һөнәри белем бирү хезмәткәре (2000).

Х е з м.: Усиление эпоксидных полимеров. К., 2004; Строительные материалы на основе поливинилхлорида и полифункциональных техногенных отходов. К., 2008 (автордаш); Химическое наполнение карбамидных пенопластов. К., 2009 (автордаш).

ХОККЕ́Й (Алкалы хоккей), кәшәкә һәм алка (шайба) б-н командалы спорт уены. Уеннның максаты — көндәшнең капкасына алка кертү. 1948 елда «Спартак» ирекле спорт җәмгыятенең Татарстан өлкә советы тарафыннан (рәисе Р.К.Бажина) Казанда беренче «Спартак» алкалы хоккей командасы оештырыла (уенчы тренер И.Х.Милушев), ул беренче булып «Спартак» ирекле спорт җәмгыяте Россия советы беренчелегенә зональ турнирда катнаша. 1955 нең 25 ноябрендә С.П.Горбунов исем. Казан ҖБнең физик культура коллективының туплы хоккей командасы җирлегендә булдырылган Казанның «Ленин районы» Х. командасы остала - ры «Б» классы буенча СССР чемпионатының беренче матчын уздыра (уенчы тренер А.В.Муравьёв). Казанның беренче чемпионаты «Спартак», «Динамо», «Химик», «Машстрой», «Льнокомбинат» ирекле спорт җәм - гыятьләре командалары катнашында 1956 да үткәрелә. 1965 тән даими рәвештә Казан чемпионатлары, 1966 дан «Алтын алка» клубы призына төрле яшьтәге төркемнәрдән яшьләр командалары арасында турнирлар уздырыла. Татарстанның хоккей командалары — СССР һәм РФ чемпионатларында катнашучылар: Казанда — «Ленин районы» (соңрак «Искра», «Рубин») (1955–59, 1960–61, 1964,1967), «Льнокомбинат» (1956–60), «Химик» (1957), «Урицкий исем. СК» («Итиль», «*Ак Барс*») (1958 дән), «Металлист» (Воровский исем. СК») (1959–69), «Киров районы» (1960–61), «Урицкий-2 исем. СК» (Итиль-2»,



Алкалы хоккей буенча балалар командалары арасында «Алтын алка» клубы призына Казан шәһәре беренчелеге. 2011.

«Ак Барс-2») (1963, 1965, 1993 тән), «Автомобилист» («Спартак») (1978–80), «Таң» (1991–94); Әлмәт шәһәрендә — «Спутник» («Нефтяник») (1965 тән), «Нефтяник-2» (1999 дан); Лениногорск шәһәрендә — «Нефтяник» (1966–82, 1995 тән); Түбән Кама шәһәрендә — «Нефтехимик-2» (1995 тән); Чаллы шәһәрендә — «КАМАЗ» (1973–82), «Чаллы» (2004 тән). 2010 нан Татарстан командалары Идел буе һәвәскәр хоккей лигасы Кубогына ярышларда катнаша; Казанда балалар-яшүсмерләр командалары арасында ТР буенча ЭЭМ кубогына турнир уздырыла (2011 дән халыкара). Хатын-кызлар хоккее Татарстанда 2005 тән үсештә. Иң яхшы ха - тын-кызлар командалары: «Тимерхан» (Байлар Сабасы шт п, «Лесхоз» пос.) — «Ак төннәр» турнирында бронза медаль (2008); «Форвард» (Казан) — А.Невский истәлегенә 3 нче кубок җиңүчесе (2011). «Ак Барс» ветераннар җыелма командасы (1997 дә оештырыла, тренеры В.Б.Короткин) — Россия 2002, дөнья 2004, 2006–09, 2012 чемпионы, Швейцариядә 2002–04 халыкара турнирларда (клуб командалары арасында) чемпион, Европа (2005), дөнья (2003) чемпионатларында, Россия (2004) беренчелегендә (җыелма командалар арасында) көмеш медаль ала, Россия (2003) беренчелегендә, Уфада «Президент турниры»нда (2001) бронза медаль ала. 2012 гә ТРның проф. дәрәҗәдәге командалары, Континенталь хоккей лигасында уйнаучылар — «Ак Барс» (Казан), «Нефтехимик» (Түбән Кама), Россия чемпионатының югары лигасында уйнаучылар — «Нефтяник» (Әлмәт), 1 нче лигада — «Нефтяник-2» (Әл -

мәт), «Чаллы» хоккей клубы (Чаллы), яшьләр хоккей лигасында — «Барс» (Казан), «Реактор» (Түбән Кама), «Б» төркемендәге «Ирбис» (Казан); 40 боз спорт сарае һәм 2 ясалма бозлы ачык стадион, якынча 600 хоккей мәйданчыгы, Х. бүлекләре булган 48 Балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе (ш.и. 3 махсуслаштырылган) (600 кеше шөгыльләнә) эшли. Х. б-н шөгыльләнүчеләрнең гомуми саны 30 меңнән артык кеше (шуларның 400 дән артыгы хатын-кызлар). Югары лигада (8 команда), 1 нче лигада (12 команда), ТР кубогына (24 команда) респ-ка чемпионатлары һәм беренчелекләре, балалар-яшүсмерләр командалары арасында беренчелектә финал ярышлар (100 дән артык команда), «Алтын алка» клубы призына ярышлар (62 команда) уздырыла. Иң яхшы уенчылар — С.М.Абрамов, Д.М.Архипов, Д.А.Балмин, Э.Гарипов, А.М.Гарифуллин, И.А.Гыйззәтуллин, Д.Зарипов, С.В.Золотов, Е.Казачкин, С.А.Котов, Э.Д.Кудерметов, В.В.Курбатов, Г.С.Маслов, А.Морозов, Д.А.Обухов, А.Н.Орлов, А.И.Пономарёв, М.Е.Сарматин, С.Н.Столбун, В.Ф.Ткачёв, И.Ш.Хөснуллин, А.Г.Чупин, Р.Ш.Шәвәлиев, В.Л.Шалахин, Р.Х.Якупов. Иң яхшы тренерлар — Р.Н.Әбделхәев, В.Я.Андреев, В.Г.Гусев, А.С.Дюмин, В.А.Елфимов, А.В.Загайнов, В.Н.Зайцев, Ю.Н.Комаров, В.Б.Короткин, С.А.Котов, М.В.Литвинов, И.Х.Милушев, А.В.Муравьёв, В.Д.Петров, А.П.Романов, Н.Г.Хәйруллин, А.Н.Чернецов. ТРның әйдәп баручы судьялары — В.И.Бокарев, Р.М.Габдрахманов, А.А.Григорьев, В.Ю.Миронычев, Д.Г.Нестеров, В.Ю.Носов, И.Х.Сафиуллов, В.И.Суслов, Ю.В.Тимонин, А.П.Юркин. РТның Хоккей федерациясе президентлары — Ш.Ф.Тәхәветдинов (2004–2016), Н.Ө.Маганов (2016 дан), Казанның Хоккей федерациясе рәисе — А.А.Рябов (2010 нан). Ш.у.к. *Туплы хоккей, Чирәмдәге хоккей.*

«ХОКУ́К ВӘ ХӘЯ́Т», хокук мәсьәләләренә багышланган татар телендәге беренче журнал. 1913 елның гыйнварыннан 1914 нең гыйнварына кадәр Казанда нәшер ителә, барысы 10 саны чыга. Нашире һәм мөхәррире — Ш.Х.Иманаев, сәркәтибе — Ш.Әхмәдиев. Татарларда хокукый культура үсеше һәм хокук мәсьәләләрен яктыртуны максат итеп куя. Язмаларның күбесе тәр җәмәдә, кайберләре рус телендә бирелә. Рәсми карар һәм боерыклар, хокук фәннәренең актуаль мәсьәләләре турында, мәхкәмә хроникасы, мәдәни-агарту тематикасы буенча мәкаләләр басыла. Журналның юнәлеше тар була, ул популярлашып китми һәм әбүнәчеләре булмау сәбәпле, чыгудан туктый.

Әд.: Усманова Д.М., Гильмутдинов Н.В. Из опыта издания специализированного юридического журнала в Казани: «Хокук ва хаят» // Науч. Татарстан. 2009. № 1.

ХО́ЛЕВО Николай Александрович (17.6.1897, Минск губ. Борисов өязенең Лисино а. — 9.9.1959, Казан), химик-технолог, техник фән. д-ры (1949), проф. (1949), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1955). Ф.Э.Дзержинский исем. Эшче-Крәстиян Кызыл Армиясе хәрби-техник академиясен тәмамлаганнан соң (1928), «Красное знамя» з-дының соңыннан Хәрби-химик фәнни-тикшеренү ин-ты (НИИ-6) дип үзгәртелгән Дары һәм шартлаучан матдәләр үзәк фәнни-тикшеренү лаб-ясендә, лаб. мөдире, бүлек мөдире булып эшли. 1939 елдан Казан химия-технол. ин-тында, каты химик матдәләр технологиясе кафедрасын оештыра һәм җитәкли. Хезмәтләре шартлаучан матдәләрнең (ШМ) технологиясенә һәм синтезына карый. Х. к-та катнашмаларының нитратлаштыру активлыгына теоретик нигезләмә бирә, кызу к-та әйләнешен гамәлгә кертү һәм к-та катнашмаларының нитратлаштыру факторын көчәйтү исәбенә ШМнең технологияләрен камилләштерә (СССР Министрлар Советы бүләге, 1935). Тиз үтүчән физик-химик процессларның химик-динамик теориясен булдыра (каты югары энергияле органик матдәләр шартлавына этәргеч бирү). ШМ сизгерлеге аларның химик табигате, физик халәте (ш.и. реологик үзлекләре) һәм динамик йөкләм кушылу функциясе икәнлеген дәлилли. Шартлаучы снарядларда дефект яки ярык-чатнак хасил булу сәбәпләрен ачыклый, аларны бетерү буенча нәтиҗәле чаралар булдыра. Нефть чыгаруны интенсивлаштыру өчен шартлау энергиясен һәм ШМне кулланы буенча тикшеренү эшләре б-н җитәкче лек итә. «Кислоталарның нитратлаштыру факторы» атамасын әйләнешкә кертә, ШМнең сугуга сизгерлеген өйрәнү өчен приборлар (№ 1, № 2) эшли. 100 дән артык фәнни хезмәт һәм уйлап табу авторы. Ленин ордены, «Почёт билгесе» ордены, медальләр, ТАССР ЮС Президиумы Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Чувствительность взрывчатых веществ к удару на копре. М., 1974.

Әд.: Николай Александрович Холево: Воспоминания. К., 1997; Специалисты по взрывчатым материалам, пиротехнике и боеприпасам: Биогр. энцикл. М., 2006.

ХОЛЕ́РА (грек. cholе́ra, cholе́ — үт сыекчасы һәм rheae — агып чыгу) (ваба), көчле диарея, косу, су-тоз алмашы бозылу һәм организмның сусызлануы б-н баручы карантинлы кискен йогышлы авыру. Х. пандемия киткәреп чыгарырлык дәрәҗәдә таралырга мөмкин, шул сәбәпле ул аеруча куркыныч инфекция буларак Халыкара мед.-сан. кагыйдәләренә кертелгән авырулар төркеменә керә. Авыруны китереп чыгаручы — холера вибрионы (Vibrio cholerae), Грам буенча тискәре, хәрәкәтчән микроб 3 типка карый: Vibrio cholerae asiaticae (классик), Vibrio cholerae eltor (Х.ны китереп чыгаручы Эль-тор) һәм серовар 0139 (Бенгал, Х.ны Көньяк-Көнчыгыш Азиядә китереп чыгаручы). Алар морфологик һәм тинкториаль үзлекләре б-н охшаш, түбән темп-ратураларга (туңган сулыклар да, диңгез суларында) чыдам, ләкин кайнатканда 1 *мин* эчендә һәлак булалар, киптерүгә, яктылык тәэсиренә, дезинфекцияләүче һәм бактерияләргә каршы кулланылучы чараларга бирешүчән. Х. вибрионы термолабиль Н-антиген (җепсыман) һәм термостабиль О-антиген (соматик) бүлеп чыгара, агулы субстанцияләргә: күзәнәк мембранасы б-н бәйле, эндотоксин үзлекләре булган һәм иммуноген тәэсир итүче термостабиль липопротеинлы комплексқа; Х. билгеләрен билгеләүче термолабиль экзотоксинга (энтеротоксин, яки холероген) ия. Инфекция чыганагы — авыру кеше яки вибрион йөртүче. Йоктыру механизмы — фекаль-ораль (алиментар) юл, сирәгрәк — контактлар аша. Күчерү факторлары: су, азык-төлек; чебеннәр. Х.га бирешүчәнлек гомуми һәм югары (өлкән яшьтәгеләр һәм балалар арасында авыру ешрак очрый) дәрәҗәдә була.

Х. бик борынгы заманнардан билгеле. 1817 елга кадәр Көньяк-Көнчыгыш Азия илләрендә ул эндемик авыру була. Х.ның бердәнбер тарихи эндемия учагы — Ганг һәм Брахмапутра елгалары дельтасы (Һиндстан). 1817–1926 да Х. халык күпләп кырылган эндемия учаклары чикләренән чыгып тарала һәм 6 пандемиягә сәбәп була. 19 йөздә Россия терр-ясендә ш.у. көчле эпидемияләр була.

Казан губернасында 19 йөз ахырыннан башлап Х. таралуны кисәтү буенча чаралар күрелә, эпидемиягә әзерлек эшләре алып барыла. Күргәзмә агитация кулланыла, рус һәм татар телләрендә брошюралар чыгарыла (татар вариантын мөгаллим Мөхетдинов төзи); һәр өяз өчен аерым инструкцияләр эшләнә; дезинфекцияләү чаралары запасы булдырыла; мед. персоналы билгеләнә һәм авыруларны аерып дәвалау өчен урыннар бүлеп бирелә. Вакытлыча эвакуацияләү өчен мед. пунктлары (Казанның Бишбалта бистәсендә) оештыру үзен аклый: 1893 тә Казан губернасында Х. йоктырган 130 торак пункт исәпләнә. Бу эпидемия 1092 кешенең гомерен өзә. 1895 тә Казан ун-тында сан. юнәлешендәге табиблар әзерли башлау тәкъдиме кертелә.

20 йөз башы ш.у. киренке сан.-эпид. халәт б-н үзенчәлекле. 1908 елның апрелендә Самара шәһәрендә Идел буе (15 губерна) табибләренең земство мед. учреждениеләре тарафыннан Х. авыруын һәм аның таралуын туктатуга юнәлдерелгән чаралар әзерләүгә багышланган съезды була. СССРда Х. таралу очраклары 1970 елларда теркәлә, РФдә авыруның спорадик очраклары хәзерге вакытта да күзәтелә.

Татарстанда Х. 1971 дә, Казанга Идел буйлап килгән «Сухона», «Клара Цеткин» теплоходлары пассажирлары һәм экипаж әгъзалары арасында, 1975 тә Мамадыш шәһәрендә (1 авыру) билгеле була, 1963 тә Сүрия һәм Төркия туристлары арасында аерым очраклар ачыклана. Чаллы (Кама елгасы, 1975), Чистай (Кама, 1977), Казан (Идел, 1989, 97) шәһәрләре һәм Югары Ослан (Идел, 1991) р-ны өске сулыкларында Эль-тор Х. вибрионының аверулент штаммнары табыла. 2001 дә Казанда, Әлки һәм Биектау р-ннарында 52 пациентта Х. булуы беленә, 18 кешенең бактерия йөртүче булуы ачыклана. Респ-ка сан. хезмәте (баш табиб А.Л.Якобсон) тарафыннан оештырылган профилактика чаралары Х.ның Казанда һәм ТРда таралуына чик куя. Эпидемиологик күрсәткечләр буенча Татарстан 3 нче типка (А астибы) караган, ягъни инфекция кергән очракта да таралыш алмый торган терр-я санала.

2017 елга ТР терр-ясендә Х. инфекциясе теркәлмәгән.

Әд.: Б у н и н К.В. Инфекционные болезни. М., 1977; Клинико-эпидемиологическая характеристика вспышки холеры в Казани // Казан. мед. журн. 2003. № 2; З ы я т д и н о в К.Ш., П а в л у х и н Я.Г. Очерки истории медицины Татарстана (до 1917). К., 2005.

Д.Р.Нуретдинова, Н.С.Нуруллова.

ХОЛМОГО́Р ТОКЫМЛЫ́ МӨГЕЗЛЕ́ ЭРЕ́ ТЕРЛЕ́К, илебездәге иң элгәреге сөт токымнарыннан берсе. Җирле терлекләрнең продуктлылыгын күтәрү һәм экстерьер күрсәткечләрен яхшырту юлы б-н хәзерге Архангельск өлкәсе терр-ясендә 18–19 йөзләрдә китереп чыгарыла. Холмогор токымлы терлекләр типик сөт экстерьерына ия, гәүдә төзелеше нык, бәдәне тупас һәм куәтле. Мускул үсеше уртача, гәүдәсе озынча, аркасы һәм биле туры, аяклары озын, оча башы сөяге күтәренке, уртача озынлыкта, күкрәге түгәрәк, тирән түгел, җилененең үлчәмнәре уртача, тиресе сузынкы, төсе башлыча кара-чуар. Сыерларның тереләй авырлыгы — 500–600 *кг* (кайвакыт 700 *кг* га кадәр). Җилкә калкымына кадәр биеклеге 130–134 *см*,



Холмогор токымлы мөгезле эре терлек.

күкрәк тирәнлеге — 66–74 *см*, гәүдә озынлыгы — 152–170 *см*, калак сөяге артында күкрәк әйләнәсе — 176–196 *см*, сыйрак әйләнәсе — 17–20 *см*. Үгезләрнең тереләй авырлыгы 1000 *кг* га җитә. Бер сыердан елга уртача 3000–5000 *кг* сөт савып алына (интенсив технологияләр кулланганда 6000 гә кадәр), сөтнең майлылыгы 3,6–4% (макс. 5,3). РФдә Холмогор токымлы сыерлардан 2010 елда уртача 4731 *кг*, Татарстанда — 4664 *кг* сөт савып алына; 2011 елда әлеге күрсәткечләр тиңдәшле рәвештә 4834 *кг* һәм 4701 *кг*. Холмогор токымлы сыерларны продукт өчен куллану срогы — уртача 4–4,5 лактация (макс. 6–7) тәшкил итә. Сыерлардан уртача ит чыгышы 50%, үгезләрдән — 54–58%. Татарстан терр-ясендә Холмогор токымлы сыерлар беренче тапкыр 1908 дә пәйда була. 1927 дә 4 нәсел үрчетү хуҗалыгы, 2 нәсел үрчетү совхозы оештырыла. Җирле терлекләрне Холмогор токымлы терлекләр б-н кушу 1934 елдан бирле алып барыла; нәсел башы үгезләр Архангельск өлкәсеннән кайтартыла. 2017 елга Татарстанда Холмогор токымлы 100102 баш терлек исәпләнә, бу барлык мөгезле эре терлекнең 40% ын тәшкил итә. Токымны яхшырту төрле илләрдән кертелгән 8 линиягә (чиф, элевейшн, айвенго, астронавт, рокмэн, бутмейкер, хоуп, ситейшн) караган нәсел башларының варисларын йотылулы кушу юлы б-н алып барыла.

Әд.: Программа совершенствования пород молочного скота в Татарстане. К., 1995; Разведение Холмогорского скота в Татарстане // Нива Татарстана. 2001. № 4; Продуктивное долголетие коров холмогорской породы и их помесей с голштинами // Нива Татарстана. 2001. № 5; Скотоводство. М., 2007; Современное состояние селекционно-племенной работы в хозяйствах Республики Татарстан и пути её улучшения (итоги бонитировки за 2010 год). К., 2011.

Әд.Х.Фазылҗанов, Г.С.Шәрәфетдинов.

ХОЛМОГО́РОВ Иван Николаевич (20.7.1818, Сембер губ. — 4.11.1891, Мәскәү), филолог, гарәп теле белгече. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1841), гимназиядә фарсы теле, Агабабов уч-щесендә тарих һәм география укыта (Әстерхан ш.). 1846 елдан Пенза гимназиясендә эшли. 1848 дән Казан ун-тында: студентлар инспекторы ярдәмчесе, гарәп теле һәм әдәбияты укыта. 1852–55 тә Ришелье лицеенда (Одесса ш.), борынгы Херсон, Таврия, Пантикапей, Ольвия, Боспор һәм Рим акчаларын өйрәнү һәм аларны системага салу б-н шөгыльләнә. 1857 дән гимназия инспекторы, со ңыннан халык уч-щеләре директоры (Әстерхан ш.). 1861 дән Казан ун-тында, экстраординар проф. (1863 тән). 1867–68 дә Иранда фәнни командировкада. 1869 дан Җәмәгать китапханәсендә эшли (С.-Петербург). 1872–76 да Сембер гимназиясендә. 1888 дән Лазарев шәрекъ телләре ин-тында фарсы теле һәм әдәбияты экстраординар профессоры (Мәскәү). Фарсы һәм гарәп язучыларыннан Сәгъди Мөслахеддин, Мирхонд, әл-Фәхри һ.б.ның әсәрләрен рус теленә тәр җемә итә.

Х е з м.: Об основных постановлениях ислама // Уч. зап. Казан. ун-та. 1848. Т. 15, кн.1; Очерки арабской речи и арабской письменности // Уч. зап. Казан. ун-та. 1862. Т. 29, вып. 1; Гюлистан: Творение Шейха Саади Ширазского. М., 1882.

Әд.: В а л е е в Р.М. Казанское востоковедение: истоки и развитие (XIX в. — 20-е гг. XX в.). К., 1998; Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2002. Т. 1.

ХОМЕ́НКО Вадим Васильевич (25.4.1958, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (1994), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (2004). Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлый (1979), 1985–91 елларда шунда ук укыта. 1992–98 дә Мәскәү дәүләт ун-тының Ульянов ф-лында, проф. (1998). 1998–2004 тә ТР ФА Социаль-икътисад һәм хокук фәннәре ин-ты һәм Перспективалы икътисади тикшеренүләр үзәгенең икътисад бүлеге мөдире, бер үк вакытта Татар-Америка региональ ин-тының дөнья икътисады каф. мөдире; 2005–08 дә Татар гуманитар пед. ун-тының фәнни-тикшеренүләр ин-ты директоры. 2008–10 да ТР фән һәм мәгариф министры урынбасары. 2010 елдан Казан техник ун-тының «Автомобильләр һәм автомобиль хуҗалыгы» укыту үзәге профессоры. 2012 дән Казан ун-тының Халыкара бәйләнешләр, тарих һәм Көнчыгышны өйрәнү ин-ты профессоры.

Төп фәнни хезмәтләре сәнгать пр-тиеләренең, төбәк икътисады үсешен планлаштыру һәм фаразлау, ш.у. төбәк халыкара транспорт-логистика системаларын проектлау мәсьәләләренә карый. Х. ТРның 2006–10 елларга социаль-икътисади үсеш программасын эшләүдә актив катнаша. Рус интермодаль логистика ассоциациясенең фән һәм мәгариф ком-ты җитәкчесе буларак, Идел буе транспорт комплексының чит илләр б-н үзара эшчәнлеген координацияли.



П.Ф.Хомутов.

Х е з м.: Стимулирование технического развития предприятий. К., 1992; Проблемы управления социально-экономическим развитием региона. К., 2004 (автордаш); Система межрегионального кооперационного взаимодействия регионов России: теория и практика. К., 2009 (автордаш); Интеллектуальная собственность. Учеб. пособие. К., 2014 (автордаш); Инновации в управлении транспортными логистическими средствами. К., 2015 (автордаш).

ХОМУТО́В Павел Фёдорович (1.8.1856, Кострома губ., Кинешма өязе Соколово а. — 1919, Херсон губ., Александрия өязе Знаменка тимер юл станциясе), дәүләт эшлеклесе, хакыйкый статский советник (1902). Чыгышы б-н дворяннардан. Павел хәрби уч-щесен тәмамлый (С.-Петербург, 1875). 1875 елдан хәрби һәм дәүләт хезмәтендә. 1877–78 дәге рус-төрек сугышында катнаша. 1883–1900 дә Кострома губернасының Кинешма өязендә: крәстиян эшләре буенча өяз кабулханәсенең зарури әгъзасы (1884 кә кадәр), 1885 тән өяз дворяннары башлыгы һәм бер үк вакытта, 1892 дән, өяз земство идарәсе башлыгы. 1900–01 дә Енисейск вице-губернаторы. Казан губернасы терр-ясендә эшчеләр забастовкалары һәм крәстияннәр хәрәкәте б-н көрәшә. 1903 ел 17 октябрь Манифесты басылып чыкканнан соң полицияне коралсызландыруга һәм революционерларның Казан шәһәр думасы бинасын кулга төшерүенә юл куя. 21 октябрьдә карагруһчылар ярдәмендә кораллы юл б-н Казанда революцион чыгышларны бастыра, әмма шәһәрдә погромнарны һәм талауларны булдырмый кала алмый. 1905 нең октябрендә отставкага җибәрелә. Кострома губерна (1907–17) һәм Кинешма өяз (1907–17) земство җыеннары гласные.

Әд.: Д о л г о в Е.Б. Казанские губернаторы — главы и хозяева «врученной на смотрение губернии» // Проблемы истории государственного управления: Государственный аппарат и реформы в России. СПб., 2003.

Е.Б.Долгов.

ХОМЯКО́В Михаил Аристархович (6.6.1841, Пермь ш. — 19.7.1894, Казан), терапевт, медицина д-ры (1870). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1862), Демидовларның Түбән Тагил заводларында табиб булып эшли. 1866 елдан Губерна земство хастаханәсендә (Казан) земство табибе, 1868 дән Казан ун-тының факультет терапиясе клиникасы ординаторы, диагностика һәм семиотика курсы приват-до-

центы (1872 дән), 1878 дән махсус патология һәм терапия кафедрасында, ординар проф. (1885 тән), госпиталь терапиясе клиникасы профессоры (1886 дан), бер үк вакытта, 1883 тән, Родионованың затлы нәсел кыз балалар ин-ты табибе. Хезмәтләре эчке авыруларга диагноз куюга карый.

Х е з м.: Критическо-экспериментальный разбор теорий, предложенных для объяснения сущности icterus gravis. К., 1870; История равития учения о паразитизме. Киев, 1883; Курс частной патологии и терапии внутренних болезней. К., 1884.

Әд.: К о т о в щ и к о в Н. Воспоминания о М.А.Хомякове. К.,1897.

ХОР МУ́ЗЫКАСЫ, күмәк башкару өчен иҗат ителгән музыка. Дини һәм муз. традицияләр йогынтысы аркасында татар халык иҗатында хор б-н җырлау формалары берекми (керәшен татарлар этник төркеменнән кала). Х.м.ның төп формалары: халык җырлары эшкәртмәләре (аранжировка, транскрипция, гармонизация), хор җыры, хор миниатюрасы, кантата, оратория, цикл, сюита, поэма, концерт; муз. сәхнә әсәрләреннән хорлар (операләр, муз. драма спектакльләре), зур вокаль-симф. һәм вокаль-инструменталь әсәрләр. Татарстанның композиторлык сәнгате формалашкан чорда хор б-н җырлау тәүге тапкыр С.Габәши һәм С.Сәйдәшевнең муз. әсәрләрендә файдаланыла һәм 1920 елларда С.Габәши, Г.Әлмөхәммәдов һәм В.Виноградовның беренче «Сания» (1925) һәм «Эшче» (1930) милли операларында тәкъдим ителә. Респ-када Х.м.н үстерүнең төп инициаторы — хор коллективларын (ш.и. Шәрекъ музыка техникумының татар хорын) оештыручы һәм җитәкчесе, хор әсәрләренең һәм татар халык көйләренең күптавышлы эшкәртмәләре авторы С.Габәши. 1930 дан халык көйләренең хор эшкәртмәләре жанры алга таба ТАССР Дәүләт җыр һәм бию ансамбленең концерт эшчәнлегендә (М.Мозафаров, А.Ключарёв, Ж.Фәйзи һ.б.) үсеш ала; шул чор өчен актуаль тематикага хор җырлары һәм кантаталар иҗат ителә; хор җыры үзешчән иҗатның төп төрләреннән берсе булып тора. 1940–50 елларда хорлар Н.Җи һ а нов операларында («Алтынчәч», «Җәлил» һ.б.) мөһим урын били. Казан консерваториясе ачылу б-н (1945), хор дирижёрлары әзерләү системасы оеша. Ул үз чиратында проф. хор коллективлары барлыкка килүгә, Х.м.ның төрле жанрларында әсәрләр иҗат ителүгә этәргеч бирә. 20 йөзнең 2 нче яртысыннан татар Х.м.нда төрледән-төрле фольклор чыганакларга, Көнбатыш Европа һәм рус Х.м. культурасына, төрле халыклар, ш.и. мөселман Шәреге музыкасы стилистикасына һәм образлылыгына мөрәҗәгать итү күзәтелә. Татар музыкасында беренче «Кеше» (1970) ораториясенең авторы — М.Яруллин. Татар халкының архаик муз. традицияләренә үзләренең хор әсәрләрендә Ш.Шәрифуллин («Мөнәҗәтләр» (1975) һәм «Авыл көйләре» (1977) хор концертлары, «Туган якта» (1984) кантатасы), М.Шәмсетдинова («Кадер киче» (2000) оратория-балеты, «Адәм балалары» (1993) кантатасы, «Җир уллары» (2012) ораториясе) һ.б. мөрәҗәгать итә.

Б.Мөлеков — «Казан» (1979), «Тукай» (1985) ораторияләрен, «Татарстан» (1967), «Гасырлар һәм минутлар» («Века и минуты», 1987) кантаталарын; Р.Ахиярова — «Тарих битләре» (1998) триптихын, «Илаһи жыр» (2001), «Гармониягә гимн» («Гимн гармонии», 2007) кантаталарын; А.Луппов «Казан» (1977), «Сходка» (1985) кантаталарын һ.б. шундый зур хор әсәрләре иҗат итәләр. Казанда С.В.*Смоленский* исем. һәм С.А.*Казачковка* багышланган фестивальләр, Казан хор ассамблеясы һ.б. булып уза. ТРның әйдәп баручы хор коллективлары: ТРның Дәүләт камера хоры, ТР Дәүләт жыр һәм бию ансамбленең хор төркеме, Казан консерваториясе студентлары хоры, Казан федераль (Идел буе) ун-тының хор капелласы. Респ-каның Х.м. үсешенә С.Казачков (Казан хор дирижёрлыгы мәктәбенә нигез салучы), Ж.Котдусов, Н.Җүрәева, И.Рәхимуллин, В.Лукьянов, А.Булдакова, М.Тәминдарова һ.б. зур өлеш кертә. *Ф.Ш.Салитова.*

ХОРВА́Т Алексей Николаевич (22.12.1836, Херсон губ. Александрия ш. — 1926, шунда ук), патофизиолог, медицина д-ры (1876). Киев ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1865), шунда ук эшли. 1869–82 елларда Европа илләре ун-тларында фәнни командировкаларда була. 1882–96 да Казан ун-тының гомуми патология каф. ординар профессоры. 1896 дан Александрия шәһәрендә. Хезмәтләре гипотермия һәм кышкы йокыга талуга (физиол. процесслар халәтенә) карый. Организмның терморегуляциясе өлкәсендә тикшеренү башлаучыларның иң беренчеләреннән. Казанның шәрәфле җәмәгать судьясы (1889–92). Кырым сугышы истәлегенә Андрей Первозванный ордены тасмасындагы бронза медаль б-н бүләкләнә (1856).

Х е з м.: Об отношении общей патологии к физиологии. К., 1883; К учению о корневой силе. О движении воды по растению // Тр. Об-ва естествоиспытателей при Казан. ун-те.1896. Т. 26, вып. 4; О гипертрофии сердца (Из лекции по общей патологии). К.,1896.

Әд.: Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1814–1904). К., 1904.Ч. 2.

ХОРНОВА́Р-ШИГАЛИ́ (Хурымвар) авылы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 18 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Чуваш Респ-касы б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 161 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, дуңгыз асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөздә нигез салына. Халкы башта дәүләт крәстияннәре катлавына керә, 1835–60 елларда Удел ведомствосы карамагында була; игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Х.-Ш. да Сергий Радонежский чиркәве (1901 дә төзелә; архит-ра истәлеге), 2 мәктәп, 2 сәүдә-сәнәгать йорты эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 506,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Үби волостенда, 1920 дән ТАССР-ның Буа кантонында. 1930 ның 10 августында — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1859 да — 167, 1897 дә — 342, 1913 тә — 471, 1920 дә — 481, 1926 да — 468, 1938 дә — 521, 1949 да — 531, 1958 дә — 465, 1970 тә — 470, 1979 да — 399, 1989 да — 252, 2002 дә — 206 кеше.

ХОСУСЫЙЛАШТЫРУ́ (лат. privates — хосусый), дәүләт милкен (пр-тиеләрне, транспорт чараларын, торак биналарны һ.б.) хосусый яки коллектив милеккә тапшырудан (бушлай яисә сату юлы б-н) гыйбарәт реформа. Алга киткән илләрдә Х. — катнаш икътисад булдыру чарасы, чөнки хосусый-дәүләти пр-тиеләр көндәшлеккә сәләтлерәк. РФдә 1990 елларда, күчеш икътисады чорында, Х. зур масштабларда, тиз темплар





Хор музыкасы. 1. ТРның Дәүләт камера хоры (җитәкчесе М. Тәминдарова); 2. Казан консерваториясе студентлары хоры (җитәкчесе В.Г. Лукьянов).

б-н башкарыла һәм асылда гомуми дәүләт милкен яңадан бүлү рәвешендә гамәлгә ашырыла.

РФнең «Хосусыйлаштыру турында» 1991 ел 4 июль Законында реформаны уздыруның 4 схемасы күздә тотыла: пр-тиене конкурс буенча сату (сатып алучылардан пр-тиенең профиле, билгеле бер санда эш урыннары һ.б. шартлар саклану таләп ителә); пр-тиене аукционда сату (сатып алучылардан ниндидер шартларның үтәлүе таләп ителми); пр-тие капиталының өлешләрен (акцияләрен) сату; пр-тиенең милке аның арендачылары тарафыннан сатып алыну. Х.ның объекты — дәүләти яки муниципаль милек, субъекты закон буенча аерылып чыгарылучы милекнең сатып алучысы булырга мөмкин физик яки юридик зат була.

ТРда Х.ның беркадәр гомумроссия программасыннан үзгә программасы гамәлгә ашырыла: Х. башлыча зур ташламалы, тавыш бирүле акцияләрнең зур пакетларына хуҗа булган хезмәт коллективлары аша башкарыла. Иң беренче хосусыйлаштырылган (акционерлаштырылган) пр-тиеләрнең берсе — милекнең коллектив формасына нигезләнгән (хезмәт коллективының милке өлешләргә (акцияләргә) бүленгән нигездә рәсмиләштерелгән) «КамАЗ» ҖБ (1990). 1990 елларның 1 яртысыннан ТРда торакны Х. тулысынча диярлек гамәлгә ашырыла — фатирлар бушлай, сатып алу яки өлешчә сатып алу юлы б-н гражданнарның хосусый милкенә тапшырыла. Х.ның башлангыч этабы киң күләмдә Х. чекларын (ваучерлар) — дәүләтнең кыйммәтле кәгазьләрен куллану б-н уздырыла, хуҗасы аларны хосусыйлаштырылучы пр-тиенең билгеле бер сандагы акцияләренә алыштыра ала. Чек мөстәкыйль рәвештә акцияләр сатып алу, инвестиция фондына тапшыру (яки фондның кыйммәтле кәгазьләренә ия булу) (бу очракларда фондка Х. чегы хуҗасына инвестицияләүдән килгән керемнәрнең бер өлешен түләү йөкләнә), ш.у.сату, бүләк итү яки мирас итеп тапшыру өчен кулланылырга мөмкин була. Х. процессында, номиналь бәясе 10 мең сумлык Х. чекларыннан тыш, ТРның һәр гражданы өчен номиналь бәясе 30 мең сумлык (1993 нең 1 гыйнварына булган бәяләрдә) исемле хосусыйлаштыру вкладлары кертелә. 1990 елларда — 2000 еллар башында уздырылган Х. чынлыкта ил халкының зур өлешен алдагы елларда булдырылган гомумхалык милкеннән читләштерүгә китерә.

А.Ш.Хәсәнова, Ф.С.Зыятдинов.

ХОХЛО́ВА Людмила Петровна (10.12.1938), Калинин ш., хәзер Тверь ш.), үсемлекләр физиологы, биол. фән. д-ры (1986), проф., (1990), ТРның атказ. фән. эшлеклесе (1995), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2008). Казан ун-тын тәмамлый (1961), шунда ук эшли, 1991–2008 елларда үсемлекләр физиологиясе (2001 дән — үсемлекләр физиологиясе һәм биотехнологиясе кафедрасы) каф. мөдире. Бер үк вакытта үсемлекләрнең үсүен һәм тотрыклыгын көйләү лаб-ясендә фәнни җитәкче (1988 дән). Хезмәтләре экологик һәм физик-химик физиологиягә, үсемлекләрнең түбән темп-рага чыдамлылыгының структур-метаболик нигезлеген өйрәнүгә карый. Х. җитәкчелегендә үсемлек күзәнәкләреннән беренче тапкыр цитоплазманың эрүчән аксымнары һәм аларның препаратив формалары алына; үсемлекләрнең суыкка чыдамлылыгы артуын чикләүче күренеш — яңа митохондрия популяциясе биогенезының күзәнәкләрдә хасил булучы энергия дефицитына китерүче тайпылышы ачыклана. Үсемлекләрнең түбән темп-рага ярсучанлык шартларында, цитоск ҽетның күзәнәкләрдәге сизү структуралары доминанты буларак эшләү концепциясе күрсәтелә. Көзге бодайның суыкка чыдамлыгын бәяләү өчен югары сизгерлекле цитоскелет критерияләре (маркерлар) билгеләнә һәм бу культураның төрле сортларына апробация үткәрелә. ТР ФАнең А.В.Энгельгард исем. бүләге лауреаты (2005). РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Морфофизиологические изменения корней разных генотипов озимой пшеницы в связи с деструкцией цитоскелета // Физиология растений. 2006. Т. 53, № 3 (автордаш); Реорганизация цитоскелета при действии на растения низких температур // Уч. зап. Казан. ун-та. Сер. Естеств. науки. 2006. Т. 148, кн. 3 (автордаш); Цитоскелет и водный обмен растений // Уч. зап. Казан. ун-та. Сер. Естеств. науки. 2008. Т. 150, кн. 2 (автордаш).

ХОХЛО́ВО авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 20 *км* төнья-к-көнчыгыштарак, Кырлай елгасы буенда. 2010 елда 30 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. 16 йөзнең 2 нче яртысыннан татар авылы буларак билгеле, 1620 елларда дворян А.Д.Хохлов утарына кертелә. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кырлай, Введенский исемнәре б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, өс-баш киемнәре тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Введение (Богородица) чиркәве (1704 тә төзелә, 1780–90 елларда яңартыла; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1884 тә ачыла), тимерче алачыгы, җил һәм су тегермәне, аракы з-ды, киез итек басу йорты, 7 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1151,8 дис. тәшкил ителә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Чыпчык волостенда, 1920 дән ТАССР-ның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1935 нең 10 февраленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1646 да — 102 кеше; 1782 дә — 153 ир-ат; 1859 да — 865, 1897 дә — 770, 1908 дә — 816, 1920 дә — 853, 1926 да — 996, 1938 дә — 952, 1949 да — 790, 1958 дә — 450, 1970 тә — 328, 1989 да — 113, 2002 дә — 43 кеше.

Әд.: Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

ХОХО́РИН Артём Валерьевич (30.7.1970, Казан), эчке хезмәт генерал-майоры (2011). Казан ун-тын (1993), РФ Эчке эшләр министрлыгының юридик ин-тын (Мәскәү, 1999) тәмамлый. 1993–97 елларда ТР Эчке эшләр министрлыгында оперуполномоченный, өлкән оперуполномоченный, 1997–98 дә ТР Эчке эшләр министрлыгында бүлек башлыгы урынбасары, 1998–2002 дә бүлек башлыгы. 2002–08 дә ТР эчке эшләр министры урынбасары — ТР Эчке эшләр министрлыгы штабы башлыгы. 2008–11 дә Мари Респ-ка-сы буенча эчке эшләр министры. 2011–12 дә РФ Эчке эшләр министрлыгы департаменты башлыгы. 2012 дән ТР буенча эчке эшләр министры. Медальләр б-н бүләкләнә.

ХӨҖӘНДИ́ Камал (Шәех Камаледдин бине Мәсгуд) (1321, Хөҗәнд, хәзер Таҗикстан Респ-касы — 1391 һәм 1400 еллар арасында, Тәбриз ш., хәзер Иранда), фарсы-та җирлек суфи шагыйре. Фарсы һәм төрки телләрдә яза. Сәмәрканд һәм Ташкент мәдрәсәләрендә укый, Мәккәгә хаҗ кыла, гомеренең күп өлешен Тәбриздә яши. 1385 елда Туктамыш ханның хатыны чакыруы буенча Алтын Урдага килә һәм дәүләтнең башкаласы Сарай әл-Җәдидтә 10 ел яши. «Диван» (14 мең бәйт исәпләнә; 8 меңгә якын бәйт сакланган), күпсанлы газәлләр авторы. Кайбер галимнәр фикеренчә, төрки халыклар арасында киң таралган һәм *Харәзминең* «Мәхәббәтнамә» (1353) поэмасына *нәзирә* буларак язылган «Ләтафәтнамә» («Гүзәллек турында китап») поэмасы да Х.гә нисбәт ителә. Шагыйрьнең күп кенә әсәрләрендәге протест мотивлары аның дөньяга карашының бунтарь характерын чагылдыралар. Х. поэзиясендә аеруча татар халык җырлары традицияләре сизелә.

Ә с ә р.: Избранная лирика. Душ., 1949; Стихотворения. Душ., 1958.

Әд.: Т а м и м д а р и А. История персидской литературы. СПб., 2007.

А.М.Ахунов.

«ХӨР МИЛЛӘ́Т», иҗтимагый-сәяси газета. Троицк шәһәренең Мөселман бюросы органы. 1917 елның 17 мартыннан 13 сентябренә кадәр Оренбург губернасы Троицк шәһәрендә атнага 2 тапкыр татар телендә нәшер ителә, барысы 35 саны чыга. Мөхәррире — Ә.Т.Рахманколов. Төп игътибарын Оренбург төбәгендәге вакыйгаларга, милли һәм мөселман оешмалары эшчәнлегенә юнәлтә. Бөтенроссия мөселманнарының беренче корылтае (Мәскәү, 1917 нең 1–11 мае) эше тәфсилләп яктыртыла. «Х.м.» милли өлкәләргә сәяси мохтарият һәм тулы мөстәкыйльлек бирүне яклый, милли-мәдәни мохтарият лозунгын хуплый. Газета б-н шагыйрь Ш.Бабич хезмәттәшлек итә. Троицк мөселман бюросы эше тукталу һәм аның дәвамчысы — Милли Шураның газета басуны дәвам итәргә акчасы булмау сәбәпле ябыла.

ХӨРРИ́ЯТ авылы, Ютазы р-нында, шәһәр тибындагы Урыссу посёлогыннан 19 *км* төньяк-көнбатыштарак, Бәйрәкә елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 19 кеше (татарлар) яши. 1924 тә нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Бөгелмә кантоны Бәйрәкә волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 20 октябреннән — Азнакай (Баулы), 1935 нең 10 февраленнән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Баулы, 1991 нең 6 апреленнән Ютазы р-нында. Халык саны: 1938 дә — 152, 1949 да — 190, 1958 дә —



Л.Һ. Хөсәения.

144, 1970 тә — 122, 1979 да — 93, 1989 да — 44, 2002 дә — 27 кеше.

«ХӨРРИЯ́Т», к. «*Кызыл Шималь*».

«ХӨРРИЯ́Т» («Свобода»), татар яшьләренең яшерен иҗтимагый-сәяси оешмасы. «*Ширкәтлек*» яшерен җәмгыятенең дәвамчысы. 1904 елда Казанда милли-революцион юнәлештә оештырыла. Башлап йөрүчеләре: Г.*Исхакый*, Ф.*Туктаров* һ.б. Үз сафларына «Ширкәтлек» һәм «*Тәрәкъкый*» оешмаларының әгъзаларын җәлеп итә. Патша хөкүмәте сәясәтенә һәм сугышка каршы агитация алып бара, рус-япон сугышы башлану б-н хәрби хезмәткә барудан читләшергә өнди. «Х.» җитәкчеләре 1 нче Бөтенроссия мөселманнары корылтае (Түбән Новгород, 1905 нең август-ты; к. *Бөтенроссия мөселманнары корылтайлары*) эшендә катнаша. Гектографик «*Хөррият*» г-тасын чыгара. 1905 ел ахырында таркала, аның җирлегендә татар эсерларының «*Таңчылар*» оешмасы барлыкка килә.

Р.Г.Әмирханов.

«ХӨРРИЯ́Т», татар эсерларының легаль булмаган газетасы. Шул исемдәге оешма органы. 1905 елның август–сентябрендә Казанда татар телендә нәшер ителә, барысы 2 саны чыга. Гектографта күбәйтелгән кулъязма басма сыйфатында була. Авторлары арасында — Г.Исхакый, Г.Баимбәтов. Газета «Хөррият» оешмасының программа карарларын бастыра. Редакция сәясәттән ерак булган татарларны революцион идеяләрне кабул итүгә әзерләүне төп максат итеп куя. Газета язмаларында демократик лозунглар, татарларны үз хокуклары өчен актив катнашырга чакыру, самодержавиянең реакцион асылына бәя бирү, аның милли кысрыклау һәм халыкларны бүлү сәясәте яктыртыла. Урыннарындагы, ш.и. Саратов, Одесса хәбәрләрен бастыра.

Әд.: Низамов И. Хөррият (Татар матбугатының онытылган бер сәхифәсе) // Мирас. 1994. № 10.

ХӨРШИДӘ. к. *Гәүһәршад*.

ХӨСӘЁН (Хөсәенов) Мәхмүт Хафиз улы (15.4.1923, Казакъстан АССРның Җаңакала р-ны Урда а. — 15.3.1993, Казан), шагыйрь, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1983). Югары артиллерия мәктәбен (Ленинград, 1945), Казан ун-тын (1952) тәмамлый. 1952–75 елларда Татарстан китап нәшриятында эшли: мөхәррир, матур әдәбият редакциясе мөдире, өлкән мөхәррир. «Туган ил өчен» беренче шигырь җыентыгы 1945 тә нәшер ителә. «Идел таңнары» (1954), «Җырлар, шигырьләр һәм поэмалар» (1956), «Чор һәм җыр» (1963), «Җир мәрҗәннәре» (1967), «Ләйсән» (1973), «Әнием миләше» (1979), «Мәхәббәт һәм моң» (1983), «Якты моң» (1997) шигырь җыентыклары; «Чирәм җирләр сулышы» (1960), «Ангара утлары» (1963), «Аю-Даг итәгендә» (1968) очерк һәм новелла җыентыклары авторы. Х. мәдхия, сонет, поэма жанрларында иҗат итә. Патриотик тематика, туган илгә, хезмәт халкына дан җырлау мәхәббәт лирикасы, сатира һәм юмор б-н үрелеп бара. Балалар өчен язылган «Нәни дусларыма» (1949), «Чебиләр» (1951), «Назар һәм казлар» (1955) шигырь җыентыкларында мавыктыргыч һәм серле табигать дөньясы сурәтләнә. Х. шигырьләренә «Студент Ульянов» кантатасы (комп. А.Вәлиуллин), Туган ил турында симф. поэма (1954, комп. М.Латыйпов), Балалар өчен язылган «Ел фасыллары» («Времена года», 1967, комп. Б.Мөлеков) кантатасы, күп кенә популяр җырлар иҗат ителә. Х.ның шигырьләре йөгерек һәм аһәңле тел б-н язылган. Күп шигырьләре рус, украин, кыргыз, үзбәк, казакъ, чуаш һ.б. телләргә тәрҗемә ителә. Татар теленә молдаван шагыйрьләренең әсәрләрен тәрҗемә итә («Молдаван шагыйрьләре», 1972). Бөек Ватан сугышында катнаша. Кызыл Байрак, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

«ХӨСӘЕНИЯ́», Оренбург шәһәрендә, 6 нчы җәмигъ мәчет каршындагы мәдрәсә. 1889 елда А. һәм М. *Хөсәеновлар* акчасына булдырыла, тиздән иң зур яңа алымлы уку йортына әверелә (500 дән артык шәкерт), анда югары дәрәҗәдә дини һәм дөньяви фәннәр укыты-ла: математика, география, политэкономия, татар, рус, немец, француз телләре, татар,



«Хөсәения» мәдрәсәсе. 20 йөз башы фотосы.

рус, гарәп әдәбияты, Россия һәм татар халкы тарихы, пед., дидактика, гигиена һәм гимнастика, чиста язу, сызым, рәсем һ.б. Тулы уку курсы 14 ел тәшкил итә (башлангыч мәктәп б-н бергә). Мәдрәсәне тәмамлаучылар урта татар дөньяви уку йортларында укытачаклар дип планлаштырыла.

Ә.Хөсәенов (1906 да вафат) мәдрәсәгә 25 мең сумлык еллык керемле вакф васыять итеп калдыра. 1905/06 уку елларында «Х.» яңа төзелгән өч катлы бинада урнаша (хәзер Оренбург аграр ун-тының уку корпусы, архит-ра истәлеге). «Х.» мәдрәсәсе биргән бергән стипендиягә укуларын дәвам итү өчен 11 иң яхшы укучы Әл-Әзһар ислам ун-тына (Каһирә), 2 укучы Истанбулга, 3 укучы Бәйрутка дөньяви ун-тларга җибәрелә. «Х.»дә якынча 35 укытучы эшли, шулар исәбендә күренекле галимнәр һәм педагоглар: Р.*Фәхретдин* (1908–10 да ректор), Ж.*Вәлиди*, Ф.*Кәрими*, Г.*Исхакый*, Г.*Еникиев*, Н.*Надиев* һ.б. Мәдрәсәне тәмамлаучыларның кайберләре үзләре дә шунда укыта: З.*Кадыйри*, С.*Бикбулатов*. Шәкертләре арасында — Ж.*Абызгилдин*, Ш.*Әхмәдиев*, М.Гали, Г.*Гобәйдуллин*, М.*Җәлил*, Х.*Ибраһимов*, И.*Кудашев-Ашказарский*, Г.Г.*Максудов*, С.*Рәмиев*, Ш.*Усманов*, М.*Фәйзи*, башкорт язучылары Г.Амантай, С.Алиш, М.Буранголов, А.Таһиров һ.б. 1919 да мәдрәсә дөньяви пед. уку йорты — Татар халык мәгарифе ин-ты итеп үзгәртелә. 1991 дән «Х.» исеме астында Оренбург өлкәсе мөселманнары Диния нәзарәте мәдрәсәсе эшли.

Әд.: Коблов Я.Д. Конфессиональные школы Казанских татар. К., 1916; Валидов Д. Очерк истории образованности и литературы татар (до революции 1917 г.). М.–П., 1923; Фархатов М.Н. Народное образование в Башкирии в пореформенный период (60–90-е годы XIX в.). М., 1994.

ХӨСӘЕНИЯ́ (Хөсәенова) Ләбибә Һади кызы (7.12.1879, Чистай өязе Яңа Әмзә а. — көз 1920, Казан), педагог. М.*Һадиевның* сеңлесе. Өйдә белем ала, Казанда абыйсында һәм М.Барудиның кыз балалар мәктәбендә укый. Кыз балаларны укыту хокукын 1911 елда Оренбург Мөселман Диния нәзарәтенән ала. 1895 тән Сембер губернасының Карсун өязе Гурьевка авылындагы К.А.Акчурин ф-касы каршындагы татар кыз балалар мәктәбендә укыта, 1896 дан Казанда М. Баруди мәктәбендә. 1904 тә үзенең рәсми булмаган *Хөсәения Ләбибә мәктәбен* нигезли, 1910 да ул Казанның зур татар кыз балалар уку йортына әверелә. Җәдитчелекне, мәктәпләрдә дөнья-ви фәннәр, ш.и. рус телен укытуны актив яклый.

ХӨСӘЕНИЯ́ ЛӘБИБӘ МӘКТӘБЕ́ Казанда, кыз балалар өчен яңа ысуллы уку йорты. 1904 елда Л.Хөсәениянең үз йортында ачыла; 1908 дә утарда мәктәп өчен яңа бина төзелә. Башта рәсми эшләми, 1911 дә *Зәңгәр мәчет* каршында кыз балалар мәктәбе булырак теркәлә. Уку йорты М. Барудиның вафатыннан соң ябылган кыз балалар мәктәбенең дәвамчысы була. Тиздән Казанда зур татар кыз балалар мәктәбенә әверелә. Укыту җәдитчелек ысулы б-н сыйныф-дәрес системасы нигезендә алып барыла. 1910 га 8 сыйныф исәпләнә, беренче 4 се гомуми белем бирүче; өлкән сыйныфларда кызларны пед. эшчәнлеккә әзерлиләр. Мәктәптә дини һәм дөньяви фәннәр, ш.и. математика, Россия һәм татар халкы тарихы, география, табигыять белеме укытыла. Рус теле һәм пед. фәннәр укытуга зур игътибар бирелә. 1913 кә укучылар саны 170 кә, укытучылар саны 6–7 гә җитә. Л.Хөсәения б-н бергә мәктәп җитәкчелегендә педагог һәм библиограф С.Ш.*Таһирова* зур урын уйный. Мәктәпне тәмамлаган дистәләгән кыз ел саен кыз балалар мәктәпләренә мөгаллимә булып урнаша. 1917 дә, Вакытлы хөкүмәт вакытында, мәктәп

татар хатын-кыз укытучылар семинариясенә әверелә, 1918 дә Казан укытучылар семинариясенә кушыла (к. *Казан татар укытучылар семинариясе*).

Әд.: Биктимирова Т.А. Ступени образования до Сорбонны. К., 2003; Махмутова А.Х. Пора и нам зажечь зарю свободы! Джадидизм и женское движение. К., 2006.

ХӨСӘЕ́НОВ Азат Гаян улы (10.5.1959, Актаныш р-ны Әтәс а.), композитор, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1998). Казан консерваториясен (Ш.Низаметдиновта тромбон классы) тәмамлый (1983). Театрларда куелган 40 тан артык спектакльнең музыка авторы. Татар акад. театрында: «Бичура», «Казан егетләре» (М.Гыйләҗев, 1989, 1990), «Җанкисәккәем», «Акбайның яңа ма җаралары» (Т.Миңнуллин, 1991, 1995), «Әле кичә генә яз иде» (Аманулла, 1998) һ.б.; Әлмәт татар драма театрында: «Туй күлмәге» (М.Гыйләҗев, 2006) һ.б.; Казан татар яшь тамашачылар театрында: «Кышкы әкият» (Ш.Фәрхетдинов, 2008), «Ничек миллионер булырга?» (М.Гыйләҗев, 2009) һ.б. Шулай ук «Әкият» курчак театрында сәхнәләштерелгән «Казлар-аккошлар» («Гуси-лебеди», 1999), «Али-Баба һәм 40 юлбасар» («Али-Баба и 40 разбойников», 2000), «Муха-Цокотуха» (2004), «Колобок» (2006), «Кызыл башлыклы кыз» («Красная Шапочка», 2007), «Шалкан» («Репка», 2008) һ.б. әкиятләргә дә музыка яза. Инструменталь әсәрләре: татар гармоны өчен скерцо; флейта, фортепиано, эстрада һәм тынлы музыка уен кораллары оркестрлары өчен брасс-квинтет, пьесалар һ.б. Композиторның җырлары танылган җырчылар тарафыннан башкарыла, аудио- һәм видеодискларда чыгарыла; респ-ка, ш.и. К.Тинчурин исем. (1994), Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 50 еллыгына багышланган (1995), «Җырым си ңа, әнкәй» (2000), «Татар жыры–2005», «XXI гасыр музыкасы һәм ритмнары» («Мелодии и ритмы XXI века», 2002), Казанның 1000 еллыгына багышланган (2005) һ.б. фестиваль һәм конкурсларда бүләкләнә. РФ Театр эшлеклеләре берлеге әгъзасы (2015).

Ф.Ш.Салитова.

ХӨСӘЕ́НОВ Азат Тимер (Тимершәех) улы (10.4.1958, Актаныш р-ны Түбән Богады а.), җырчы, ТРның атказ. мәдәният эшлеклесе (1997), ТРның халык артисты (2008). Чаллы пед. ин-тын тәмамлый (1998). 1970–2005 елларда Актаныш р-нында, Чаллы, Казан шәһәрләрендә мәдәни-агарту һәм адм. эшләр б-н шөгыльләнә. 2005 тән «Татпотребсоюз» җитештерү-сәүдә оешмасында эшли. Бер үк вакытта концерт эшчәнлеге алып бара, татар композиторлары җырларыннан, татар халык көйләреннән торган репертуар б-н чыгыш ясый. Үз җырларының авторы һәм башкаручысы, «Кайтам сиңа, әнкәй» җыры (И.Хөснетдинов шигыре) аеруча зур популярлык казана. «Татар эстрадасы-89», «Татар җыры-93» конкурслары лауреаты.

ХӨСӘЕ́НОВ Әхмәтсәви Хөсәен улы (24.7.1924, Минзәлә кантоны Актаныш-баш а. — 26.10.1992, шунда ук), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, ТАССРның атказ. зоотехнигы (1979). Минзәлә а.х. техникумын тәмамлый (1962). 1938–85 елларда Актаныш р-нында эшли: район әлемтә бүлеге башлыгы (1947 дән), «Изаиль» к-зы (1955 тән), «Чишмә» к-зы рәисе (1963 тән). Х. җитәкчелек иткән вакытта «Чишмә» к-зында җитештерү-техник һәм социаль-мәдәни инфраструктура булдырыла; бөртекле культураларның уңышы 1 *га* дан 8 *ц* дан 25 *ц* га кадәр арта. 1967–71 дә ТАССР ЮС депутаты. Бөек Ватан сугышында катнаша. Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

ХӨСӘЕ́НОВ Васил Мөхәммәт улы (3.4.1953, Чиләбе өлкәсенең Копейск ш.), инженер-геолог, геол.-минерал. фән. канд. (1999), техник фән. д-ры (2012), РФнең атказ. геологы (1998). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1975), «Татнефть» АҖдә эшли: геолог, өлкән геолог, «Җәлилнефть» НГДУда технол. бүлеге башлыгы; «Татнефтебитум» тәҗрибә НГДУда баш геолог (1986 дан), «Азнакайнефть» НГДУда баш геолог (1989 дан), ТатНИПИнефть директоры урынбасары (2010 нан). Катламнарның геол. төзелешен детальләштерү өлкәсендә тикшеренүләр алып бара, токымнарның фильтрацион сыешлылыгы үзгәрешләрен исәпкә алып, углеводородларның калдык запаслары структурасын өйрәнә. Х. эшкәртүнең соңгы стадиясендә терриген коллекторлар нефтьнең калдык запасларын суыртып алу технологиясен булдыруны тәкъдим итә. Уйлап табуга 59 патенты бар. ТР Дәүләт бүләге Татарстанның авыр чыгарыла торган нефть запаслары чыганаклары б-н ятмаларның нефть бирүчәнлеген арттыру технологияләре комплексын эшләүдә һәм сәнәгатькә кертүдә катнашканы өчен бирелә (1999). Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Стратегические аспекты выработки остаточных запасов нефти // Георесурсы. 2001. № 4; Интенсификация выработки запасов нефти заводнённых коллекторов в условиях дифференцированного налогообложения // Проблемы экономики и управления нефтегазовым комплексом. 2011. № 4 (автордаш); Как извлекать запасы нефти на поздних стадиях разработки? // ЭКО. 2012. № 1 (автордаш).

ХӨСӘЕ́НОВ Владимир Николаевич (1.10.1929, Чиләбе ш. — 20.02.2017, Казан), очучы-инженер, Идел буе гражданнар авиациясе идарәсенең Татарстан берләштерелгән авиаотряды командиры (1974 — 84), 1 нче класслы очучы, СССРның атказ. очучысы (1983). Троицк авиация-техник уч-щесен (Чиләбе өлкәсе, 1950), Богырыслан очучылар уч-щесен (Чкалов өлкәсе, 1954), Ленинград гражданнар һава флоты югары авиация уч-щесен (1963) тәмамлый. Хезмәт эшчәнлеген 1950 елда Якутск аэропортында башлый. 1954 тән авиаотряд очучысы (Ташкент), 1958 дән очучылар отрядының корабль командиры (Красноярск, Свердловск шәһәрләре), 1963 — 71 дә авиаэскадрилья командиры, берләштерелгән авиаотрядның очучылар отряды командиры урынбасары, командиры (Свердловск ш.), Литва гражданнар авиациясе идарәсенең очучы-штурманнар бүлеге башлыгы (Вильнюс). 1984–85 тә Казан берләштерелгән авиаотряды очучы-инструкторы. 14 мең сәгатьтән артык очыш тәҗрибәсе туплый (По-2, Ли-2, Ил-14, Як-40, Ил-18, Ан-12,Ту-124, Ту-134 самолётларында). 1985 тән Казанның 5 нче йөк автотранспорты ҖБдә, 1988 дән Казан приборлар төзү КБ бүлеге башлыгы урынбасары. 1990–2009 да һава юллары агентлыгы башлыгы, «Татарстан Республикасының һава юллары агентлыгы» АҖ ген. директоры. 1968–71 дә Вьетнам Респ-касында командировкада була (очучы-инструктор, совет белгечләре төркеме командиры, ТР Президентының шеф-очучысы). Х. җитәкчелегендә «Казан-2», «Бигеш» аэропортлары һ.б. төзелә. Диспетчерлык пунктларын һәм аэродромнарны элемтәнең, навигациянең һәм һавадагы хәрәкәт б-н автоматлаштырылган идарәнең заманча радиотехник чаралары б-н тәэмин итүгә өлеш кертә. Халыклар дуслыгы, «Почёт билгесе», Вьетнам Респ-касының 2 нче дәрәҗә «Сугышчан батырлык» орден-нары, медальләр, ш.и. 2 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» ордены медале б-н бүләкләнә.



В.Н. Хөсәенов.



Г.К.Хөсәенов.

ХӨСӘЕ́НОВ Гали Кәрим (2.11.1919, Казан губ., Зөя өязе Күгәй а. — 26.7.2001, Казан), драма актёры, режиссёр, ТАССР һәм РСФСРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1966, 1982). Татар акад. театры каршындагы студияне (1938) һәм Мәскәүдәге Дәүләт театр сәнгате ин-ты (ГИТИС) каршындагы Татар студиясен (1949) тәмамлый. 1949–52 елларда Казан яшь тамашачылар театрының (ТЮЗ) татар төркеме һәм Татар акад. театры (1950 дән) актёры. 1952–69, 1972–75 тә Татарстан респ-ка радио һәм телевидениесендә мөхәррир, режиссёр, баш режиссёр; татар әдәбиятын пропагандалауда сизелерлек роль уйнаган күп кенә радиоспектакльләр һәм телевизион спектакльләр куя («Муса», Ш.Маннур һ.б.). 1969 дан Х. Әлмәт татар драма театры б-н җитәкчелек итә. Аның режиссёрлыгында куелган 30 га якын спектакль театрның иҗади үсешенә зур йогынты ясый: «Козы көрпеш һәм Баян сылу» (Г.Мөсрәпов, 1969), «Бишбүләк» (Т.Гыйззәт, 1970), «Анам кыры» (Ч.Айтматов повесте буенча, 1971, 1977; ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләге, 1979), «Әни килде» (Ш.Хөсәенов, 1971), «Тылсымлы кыз» («Трактирщица», К.Гольдони, 1975), «Кар астында кайнар чишмә» (А.Гыйләҗев, 1976), «Шәмсекамәр» (М.Әблиев, 1976), «Ай булмаса, йолдыз бар» (Т.Миңнуллин, 1978), «Tahир-Зөһрә» (Ф.Бурнаш, 1979), «Антигона» (Ж.Ануй, 1980), «Ни булган бу ирләргә?» (Ю.Сафиул-



Г.С.Хөсәенов.



З.С.Хөсәенов.

лин, 1981), «Җанның җиденче тамыры» (А.Гыйләҗев, 1981), «Зөлфия» (К.Әмиров, 1982) һ.б. 1983 тән Ташкент үзбәк драма театрында эшли. Теге яки бу спектакльне сәхнәгә куйганда, Х.ның яңа сәнгатьчә чаралар табарга омтылуы, иҗат коллективын үз тирәсенә туплый белү осталыгы татар театр сәнгатен тагын да баета. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

И.И.Илялова.

ХӨСӘЕ́НОВ Галимҗан Салих улы (27.6.1937, ТАССРның Октябрь р-ны Яңа Иглай а. — 5.2.2010, Мәскәү), спортчы, тренер (футбол), СССРның атказ. спорт остасы (1967). «Труд» ирекле спорт җәмгыятендә тәрбияләнә (Куйбышев ш.). 1960 елдан Мәскәүдә яши. Футбол клублары командаларында уйный: «Динамо» (яшьләр составы, 1953–56), «Крылья Советов» (Куйбышев, 1957–60), «Спартак» (Мәскәү, 1961–73). СССР чемпионатларында медальләр ала: 1961 (бронза), 1962, 1963 (көмеш), 1968 (көмеш), 1969, 1970 (бронза); СССР (1963, 1965, 1971), Европа (1964, көмеш) кубоклары иясе. СССР җыелма командасы составында 1960–69 да уйный: 33 матч уздыра, 4 гол кертә. СССРда сезонның иң яхшы 33 футболчы исемлегенә керә (№ 1 — 1963; № 2 — 1961, 1964, 1965; № 3 — 1960, 1962, 1968, 1969), Г.Федотов клубы әгъзасы (145 гол). 1974 тә — «Спартак» (Нальчик), 1975 тә — СССР җыелма командасында (яшүсмерләр), 1976 да — «Спартак» (Мәскәү), 1980–82 дә — «Пахтакор» (Ташкент), 1983–86 да — «Спартак» мәктәбендә (Быково, Мәскәү өлкәсе), 1987–88 дә — «Спартак» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә, 1989–91 дә «Мясокомбинат» СКда (Мәскәү) тренерлык эшендә.

ХӨСӘЕ́НОВ Денис Яхъя улы (21.1.1946, Таганрог ш.), математик, физика-матем. фән. д-ры (1992), проф. (1994). Киев ун-тын тәмамлый (1969), шунда ук эшли, катлаулы системаларны модельләштерү каф. профессоры (1993 тән). Хезмәтләре дифференциаль тигезләмәләргә, хәрәкәт тотрыклылыгына, оптимизация алымнарына карый. Х. киче гүчән һәм нейтраль типтагы тайчанучан аргументлы системаларның тотрыклылыгын, гомуми динамик системаларның тотрыклылыгын тикшерә; Ляпуновның оптималь функцияләр алымы нигезендә динамик системаларның күрсәткечләренә бәяләмә бирә. Медаль б-н бүләкләнә. Бокс буенча спорт мастеры (1967).

Х е з м.: Оценки абсолютной устойчивости системы регулирования с отклоняющимся аргументом нейтрального типа. Киев, 1989; «Магнитная потенциальная яма» — эффект стабилизации сверхпроводящих динамических систем. Киев, 1991 (автордаш); Оптимизация оценок характериистик решений в динамике систем. Нукус, 1992 (автордаш).

ХӨСӘЕ́НОВ Җәүдәт Абдулла улы (7.2.1948, Чүпрәле р-ны Кече Чынлы а), педагог, пед. фән. д-ры (2008), проф. (2013). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1973). 1967 елдан туган авылы урта мәктәбендә эшли, 1981 дән директор; 1986 дан Казанның урта мәктәпләрендә укыта, 1992 дән Киров р-ны халык мәгарифе бүлеге мөдире урынбасары, 1994 тән 4 нче татар гимназиясе директоры. 2002 дән Татар гуманитар-пед. ун-тының икътисади геогр. кафедрасында, 2011 дән Казан (Идел буе) федераль ун-тының Экология һәм география ин-тында. Хезмәтләре география укыту методикасы, экологик тәрбия мәсьәләләренә карый.

Х е з м.: Занимательная география. К., 1982; Экологическая культура учащихся национальной школы. К., 2005; Краеведение: Уч. пособие. К., 2011.

ХӨСӘЕ́НОВ Җәүдәт Салих улы (17.6.1953, Буа р-ны Зур Кырлаңгы а. — 5.12.2017, Буа ш.; Буа р-ны Күл Черкене авылында җирләнә), галим агроном, а.х. пр-тиесе җитәкчесе, а.х. фән. канд. (2003), ТР Дәүләт бүләгеләуреаты (2003), ТРның, РФнең атказ. а.х. хезмәткәре (1994, 2003). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1975). Буа р-нында эшли: «Ватан» к-зында агроном-орлыкчылык белгече, баш агроном (1978 елдан), «Коммуна» к-зы партоешмасы секретаре (1980 нән), «Марс» к-зы (1987 дән), шул исемдәге күмәк хуҗалык (1992 дән) һәм а.х. җитештерү кооперативы (2003) рәисе; 2004 тән «Коммуна» ҖЧҖ директоры. Х. җитәкчелек иткән вакытта «Коммуна» а.х. пр-тиесендә җитештерү-техник һәм социаль-мәдәни инфраструктура булдырыла; Килдураз, Өчмунча, Бәбки, Күзби, Иске Лашчы, Кабалан авылларына газ кертелә. 2008 дә 1992 ел күрсәткечләре б-н чагыштырганда бөртекле ашлык җитештерү 2,8 тапкыр, шикәр чөгендере 2,3, сөт 3,5, ит 1,7 тапкыр арта, бөртекләрнең уңышы 1 *га* дан 14 *ц* дан 72,4 *ц* га, шикәр чөгендере 187 *ц* дан 415 *ц* га кадәр, уртача еллык савым һәр сыердан 2417 *кг* нан 9773 *кг* га кадәр арта. 2008 дә җитештерүнең табышлылык дәрәҗәсе 15,4% тәшкил итә. Дәүләт бүләге Буа р-нының а.х. җитештерүенә ТРның агроминераль чималын кулланып ресурс саклау технологияләрен кертүдә катнашканы өчен бирелә. «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены, медаль б-н бүләкләнә.

ХӨСӘЕ́НОВ Зәкәри Сәфит улы (7.3.1914, Ульянов өлкәсенең Иске Кулаткы р-ны Мөси а. — 12.10.1944, Хайду-Соват торак пункты, Венгрия), Сов. Союзы Герое (24.3.1945, үлгәннән соң), гв. старшинасы. Туган авылында колхозда эшли. 1937 елның сентябреннән Кызыл Армиядә. 1942 нең августын нан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 134 нче танк полкында танк командиры (4 нче гв. кавалерия корпусының 30 нчы кавалерия дивизиясе). 2 нче Украина фронты гаскәрләре составында Дебрецен һөҗүм операциясендә катнаша (1944). 1944 нең 12 октябрендә Дебрецен шәһәренә якынайганда Хайду-Соват янындагы сугышта батырлык күрсәтә: Х. танкы экипажы, техник төзексәлектән арынып, дошманның 18 авыр танктан торган колоннасына тап була, сугыша башлый, дошманның 6 танкын һәм җиңел машинасын сафтан чыгара; Х. әлеге сугышта һәлак була. Ленин ордены, Кызыл Байрак, ике Кызыл Йолдыз, 3 нче дәрәҗә Дан орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

М.З.Хәбибуллин.

ХӨСӘЕ́НОВ Мансур Гариф улы (18.12.1954, Чистай ш.), физик, физика-матем. фән. д-ры (1998), ТРның атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2008). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1977), СССР ФА Казан ф-лының Физика-техника ин-тында эшли. 1987 елдан Казан «Восток» техник ун-тының ф-лында (Чистай ш.), проф., табигыять фәннәре каф. мөдире (1998 дән). Хезмәтләре ясалма катламлы структураларда үтә үткәрүчәнлек һәм магнетизм мәсьәләсенә карый. Х. критик темп-раның артуына һәм тәжрибәви вазгыятькә тәңгәл килгән нормаль металл (N) б-н үтә үткәргеч катламнарының калынаюына юл ачучы эффектив электронара тартылышның логарифмик көчәюе күренешен ача. N/S-структуралар өчен Бардин-Купер-Шиффферларның якынлашу чикләүләреннән бәйсез булган якынлык эффекты теориясен беренче булып төзи. Суперрәшәткә периоды азаю б-н күлон этәрүенең роле көчәя дигән нәтиҗәгә килә. Үткәрүчәнлек электроннары парамагнит резонансы ешлыгында үтә үткәрүчән пластинаның селектив үтәкүренүчәнлеге күренешен алдан әйтеп бирә; соңыннан ул тәжрибә нәтиҗәсендә табыла.

Х е з м.: Пространственная дисперсия спиновой восприимчивости электронов проводимости в сверхпроводниках // Журн. эксперим. и теорет. физики. 1979. Т. 76, вып. 2 (автордаш); Эффект близости при произвольной прозрачности N/S границы // Письма в журн. эксперим. и теорет. физики. 1991. Т. 53, вып. 11; Конкуренция сверхпроводимости и магнетизма в гетероструктурах ферромагнетик/сверхпроводник // Успехи физ. наук. 2002. Т. 172, № 2 (автордаш).

ХӨСӘЕ́НОВ Мәгъсүм Шәйгазәм улы (15.8.1911, Уфа губ., Минзәлә өязе Балтамак а. — 15.1.1986, Казан), Соц. Хезмәт Герое (1966). ВКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты каршында Респ-ка партия мәктәбен (1948), Минзәлә а.х. техникумын (1964) тәмамлый. Хезмәт эшчәнлеген 1930 елда Сарман р-нының «Үрнәк яшьләр» к-зында хисапчы булып башлый. Пед. курсларны тәмамлаганнан соң (1931), Сарман, Чаллы р-ннары мәктәпләрендә укытучы булып эшли. 1938–46 да ВЛКСМның Чаллы район ком-тында бүлек мөдире, ВКП(б)ның Чаллы район ком-ты секретаре, 1948 дән Мөслим район башкарма ком-ты рәисе, 1950 дән КПССның Минзәлә район ком-ты 1 нче секретаре, 1957 дән Мөслим район ком-ты 1 нче секретаре, 1962 дән Минзәлә терр. җитештерү колхоз-совхоз идарәсе партия ком-ты секретаре, 1965–72 дә КПССның Минзәлә район ком-ты 1 нче сек-


Мәгъсүм Ш.Хөсәенов.

ретаре. Герой исеме терлекчелекне үстерүдә, ит, сөт, йомырка, йон җитештерү һәм әзерләүне арттыруда ирешелгән уңышлары өчен бирелә. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1971–75 тә ТАССР ЮС депутаты. КПССның 22 нче һәм 23 нче съездлары делегаты (1961, 1966). Ленин ордены, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының ике алтын медале, ТАССР ЮСның Мактау грамоталары (1945, 1960, 1961, 1971) б-н бүләкләнә. Минзәлә шәһәренең Герой - лар аллеясында Х.ка бюст куела, аның исеме б-н бер урам атала, төбәкне өйрәнү музеенда аңа экспозиция багышланган.

Әд.: Минзәләнең алтын йолдызлары — Золотые звёзды Мензелинска. Мензелинск, 1999; Б е л я л о в У. Хусаинов Магсум Шайгазалиевич // Герои Социалистического Труда Татарии (1938–1978 гг.): Док. очерки. К., 1980. Кн. 1; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003; Х а к и м о в М.С. С а ф а р о в М.А. Татары: Воины, труженики, патриоты: Биогр. справ. М., 2006.

М.Ж.Гаитов.

ХӨСӘЕ́НОВ Мөнир Ширияздан улы (15.8.1945. Алексеев р-ны Кыр Шонталысы а. — 21.5.2013, Казан), зоотехник, биол. фән. д-ры (1996), проф. (1997), ТРның атказ. а.х. хезмәткәре (1995). Казан вет. ин-тын (хәзер Казан вет. медицинасы академиясе) тәмамлый (1977). 1969–84 елларда ТАССР А.х. министрлыгында эшли, 1981 дән министр урынбасары. 1984 тән халык депутат - ларының Арча район советы башкарма ком-ты рәисе. 1986 дан Питрәч р-нында: КПСС райкомы 1 нче секретаре, халык депутатларының район советы башкарма ком-ты рәисе (1990 нан). 1991 дән «Казан ит комбинаты» АҖ ген. директоры. Пенза өлкәсенең авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры (1999). РФ Дәүләт Думасы депутаты ярдәмчесе (2000 нән), РФ Федерация Советы әгъзасы (2003 тән). Казан һөнәри-пед. көллияте директоры урынбасары (2006 дан), Социаль һәм гуманитар белемнәр ин-ты проректоры (Казан, 2009). Хезмәтләре экология мәсьәләләренә карый. 1985–95 тә ТАССР, ТССР, ТР ЮС депутаты. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Резервы высокопродуктивного стада. К., 1987 (автордаш); Микробиологические среды. К., 1999 (автордаш).

ХӨСӘЕНОВ Мөхәммәт җан (1756, Оренбург губ., Уфа провинциясе Солтанай а. — 17.7.1824, Уфа, хәзерге БРның Кырмыскалы р-ны Атҗитәр авылында җирләнә), дин эшлеклесе. Каргалы бистәсе, Оренбург, Бохара һәм Кабул шәһәрләре мәдрәсәләрендә укый. 1777 елда туган ягына кайта. 1785 тән Оренбург чик буе миссиясендә ахун, 1788 дән Уфа Дини Мөхәммәди Канун Җыены мөфтие була. Аны төбәк филиаллары булган Үзәк мөселман коллегиясенә әйләндерү, дөньяви фәннәр укытыла торган дини уку йортлары челтәре булдыру проектлары авторы. Каргалыдагы мәдрәсәләрне үзәкләштерелгән системага берләштерә. Россиянең эчке һәм тышкы сәясәтен (хәзерге Башкортстан терр-ясендә, Урта Азия дәүләтләрендә һәм Кавказда) үткәрүдә активлык күрсәтә. Медаль б-н бүләкләнә.

Әд.: А з а м а т о в Д.Д. Оренбургское магометанское духовное собрание в конце XVIII — XIX вв. Уфа, 1996; Х а б у т д и н о в А.Ю. Российские муфтии: От екатерининских орлов до ядерной эпохи (1788–1950). Н.Новгород, 2006; Ислам на Урале: Энцикл. словарь. М.–Н.Новгород, 2009.

ХӨСӘЕ́НОВ М. БАСМАХАНӘСЕ́, Оренбургта, шәһәрдәге 2 нче татар басмаханәсе. 1906 елның 5 декабрендә «*Дин вә мәгыйшәт*» ж-лын нәшер итү өчен ачыла, аның нашире һәм шул ук вакытта басмаханә хуҗасы сәүдәгәр һәм мулла М.Хөсәенов була. 1907 дән татар китаплары басыла башлый. 1917 нең октябренә кадәр гомуми тиражы 175750 данә булган 104 китап чыга, аларның 40 тан артыгы дини җыентыклар, М.Хөсәенов акчасына басылалар, заказчылары Казан губернасы, Оренбург, Уфадан була. Дөньяви әсәрләр арасында — И.Казаковның «Гимназия»се (10 сәгатьтә рус телен өйрәнү буенча дәрес - ләр сериясе, аны хатыны Н.Казакова үз акчасына бастыра), 10 нан артык дәреслек, казакъ авторларының шигырьләр җыентыгы, татар әдәбияты вәкилләре әсәрләре (Т.Гыйззәт, Г.Зариф, Г.Шәрифов, Х.Абушаев-Атлаши), Г.Гомәринең «Башкорт халкы тарихы», фәнни-популяр әсәрләр, татар халык җырлары җыентыклары, хәйрия җәмгыятьләре хисаплары һ.б. Кайбер басмалар цензура әзерлекләве астында була. Алга таба иселе рәсми рәвештә «Дин вә мәгыйшәт» дип үзгәртелә, 1917 нең ахырында Оренбургның өч басмаханәсе арасында шул исем б-н санала. Басмаханәнең татар-гарәп шрифтлары, башка татар басмаханәләренең шрифтлары кебек үк, хәрби-поход басмаханәсен булдыру өчен Кызыл Армия частьлары тарафыннан конфискацияләнә.

Әд.: К а р и м у л л и н А.Г. Татарская книга начала XX века. К., 1974; ш у л у к. Татарское государственное издательство и татарская книга России (1917–1932). К., 1999.

Г.Г.Габделганиева.

ХӨСӘЕ́НОВ Нәҗип Хөсәен улы (23.2.1885, Казан губ., Мамадыш өязе Сәртек а. — 1937), сәясәт эшлеклесе. 1905–07 еллардагы рев-циядә катнаша (Казан). Казан вет.-фельдшерлык уч-щесендә укый (1904). 1910 нан Урта Азиядә. Бохара коммунистлар партиясен оештыручыларның берсе һәм аның җитәкчесе (1919–20), Бохара шәһәренең ХКС әгъзасы (1920). 1920–30 да Сырдәрья өлкә ком-тында бүлек мөдире урынбасары, Үзбәкстан ВКП(б) УК инструкторы, «Кызыл Үзбәкстан» («Кизил Узбекистан») г-тасы редакциясенең партия тормышы бүлеге мөдире, Үзбәкстан дәүләт нәшриятының социаль-икътисади әдәбият секторы мөхәррире. 1931 дән ВКП(б) инспекторы, контроль комиссиясе, ТАССРның Сарман р-ны Эшче-Крәстиян инспекциясе рәисе. Репрессияләнә; үлгәннән соң аклана.

Әд.: Революцией призванные. Таш.,1987; Возвращённые имена: Док.очерки. К., 1990.

Ф.Г.Миңнеханов.

ХӨСӘЕ́НОВ Рәкыйп Равил улы (17.7.1898, Сембер губ., Буа өязе Яңа Ишле а. — 19.3.1963, Казан), үсемлекчелек белгече, а.х. фән. д-ры (1949), проф. (1950). Самара а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1928), Казан яшелчә-җиләк-җимеш техникумында укыта. 1929 елдан Казан а.х. ин-тында, үсемлекчелек каф. мөдире (1931–63), бер үк вакытта директор урынбасары (1949–53). Соя, ногыт борчагы, вика селекциясен уздыра. Хезмәтләре бөртекле-кузаклы культуралар (чина, соя, ясмык, борчак, нути) һәм кукуруз биологиясе, агротехникасы һәм селекциясе мәсьәләренә карый. Медаль, ТАССР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Зернобобовые культуры Татарии. К., 1940.

ХӨСӘЕ́НОВ Рәхим җан Сабит улы (5.1.1953, Балтач р-ны Түбән Кенә а.), инженер-механик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1995), ТРның атказ. а.х. хезмәткәре (1993). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1978), Яшел Үзән р-нында эшли: Ильич исем. к-зда инженер, Күгәй авыл советы башкарма ком-ты рәисе (1981–85), «Сельхозхимия»нең Норлат бер - ләшмәсендә инженер. 1986–97 елларда Арча р-нында: агросәнәгать берләшмәсендә инженер, КПСС район ком-тының а.х. бүлеге мөдире-инструкторы, 8 нче Март исем. к-з рәисе (1988 дән), а.х. һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (1993 тән). 1997 дән Саба р-ны хакимияте башлыгы, 1999 дан «Татсельхозтехника» АҖ ген. директоры урынбасары. 2004 тән «ВАМИН-Татарстан» АҖ ген. директоры урынбасары. 2012 дән «Простор» агросәнәгать комплексы ҖЧҖ ген. директоры урынбасары. Дәүләт бүләге җитештерүдә фән һәм техника казанышларын киң куллану нигезендә бөртекле культуралардан югары уңыш алуда катнашканы өчен бирелә.

ХӨСӘЕ́НОВ Фидаил Миңнегали улы (2.7.1963, Казан), микробиолог, вет. фән. д-ры (2007). 1987 елдан Хайваннарның токсикологик, радиацион һәм биол. куркынычсызлыгы буенча федераль үзәктә (элекке Бөтенроссия вет. фәнни-тикшеренү ин-ты): хайваннарны хламидиозлардан һәм башка йогышлы авырулардан саклау чаралары эшләү һәм җитештерү секторы өлкән фәнни хезмәткәре (2007 дән). Хезмәтләре хламидияләрнең иммунобиол. үзлекләренә өйрәнүгә, мөгезле эре терлек, дуңгыз һәм ат хламидиозларына лаборатор диагностика, махсус профилактика ысулларын эшләү һәм камилләштерүгә карый (ТР Дәүләт бүләге лауреаты, 1995). Дуңгыз хламидиозларын; мөгезле эре терлек, сарык хламидиозларын кисәтү өчен вакциналар эшли (2002, 2005). Уйлап табуга 3 патенты, 1 авторлык таныклыгы бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Хламидиоз крупного рогатого скота // Ветеринария. 1990. № 2 (автордаш); Вакцина против хламидиоза крупного рогатого скота // Ветеринария. 1996. № 6 (автордаш); Течение хламидиоза и его профилактика на свинокомплексе // Ветеринария. 2002. № 2 (автордаш).



Х.Х. Хөсәенов.

ХӨСӘЕ́НОВ Хөрмәт Хәмзә улы (10.3.1920, хәзер БРның Көергәзе р-ны Ялчыкай а. — март, 2002, Үзбәкстан Респ-касының Сәмәрканд ш.), Дан орденының тулы кавалеры (22.9.1944, 8.3.1945, 15.5.1946), старшина. Уфа шәһәренең моторлар з-дында слесарь булып эшли. 1940 елдан Кызыл Армиядә. 1942 нең октябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында: 435 нче танкка каршы артиллерия полкында (69 нчы армиянең 8 нче аерым танкка каршы артиллерия бригадасы) туп командиры. Белоруссия һәм 1 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Люблин-Брест (1944), Варшава-Познань һәм Берлин (икесе дә 1945 тә) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 20 августында Пулавы (Польша) шәһәре янында Висла елгасының сул ярында урнашкан плацдармны киңәйтү операциясендә (танкка каршы атучы тупны сафтан чыгара һәм пулемёт утын бастыра, 1945 нең 14 гыйнварында Лавецко-Нове торак пунктны (Пулавыдан 10,5 *км* көньяк-көнчыгыштарак) янында дошманның күзәтү пунктын һәм 10 лап солдатын юк итә) батырлык күрсәтә. Познань (Польша) шәһәре янындагы сугышта, ачык позициядән атып, дошманның миномёт утын бастыра һәм күп кенә солдатын юк итә; 1945 нең 17 апрелендә Лебус шәһәренең (Германия) көнбатыш читендә барган сугышларда, туптан атып, дошманның танкка каршы атучы тубын, 2 пулемётны сафтан чыгара һәм 10 лап солдатын юк итә. Демобилизацияләнгәч (1946), туган илгә кайта. 1948–53 елларда Гарм шәһәрендәге (Таҗикстан ССР) мәктәптә хәрби әзерлек укытучысы, 1953–80 дә 3 нче Сәмәрканд авторемонт з-дында слесарь булып эшли. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр.словарь. М., 2000.

ХӨСӘЕ́НОВ Шәмсетдин Хөсәен улы (1878, Вятка губ., Малмыж өязе Шеңшеңәр а. — 1927 елдан соң), җәмәгать эшлеклесе. Чыгышы б-н крәстияннәрдән. Семипалатинск шәһәрендә мәдрәсә тәмамлаганнан соң, дини белем алуын Константинополь шәһәрендә дәвам итә. 1904 тә Вятка губернасында мулла була. Вятка губернасыннан 1 нче Дәүләт Думасы депутаты (1906). Думада мөселман нар фракциясенә керә, актив эшләми. Шунан соңгы язмышы билгесез.

Әд.: Члены первой Государственной думы. М., 1906; Мусульманские депутаты Государственной думы России. 1906–1911 гг.: Сб. док. и материалов. Уфа, 1998.

ХӨСӘЕ́НОВ Шәриф Нургали улы (26.11.1929, Буа р-ны Өчмунча а. — 7.7.1999, Казан), драматург, терапевт, ТАССРның атказ. табибе (1979), ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1989). Казан мед. ин-тын (1953), А.М.Горький исем. Әдәбият ин-ты каршындагы югары әдәби курсларны тәмамлый (Мәскәү, 1962). Казанның 12 нче һәм 2 нче хастаханәләрендә (1953–60, 1962–64), 17 нче поликлиникасында (1964–99) эшли. Иҗатының башлангыч чорында «Бирнәле кыз» (1954), «Чулпан» (1955), «Егерме ел үткәч» (1962), «Туган көнең котлы булсын» (1965) пьесаларын иҗат итә. Әхлак һәм әдәп мәсь әләләренә багышланган «Профессор кыяве» (Татар акад. театрында куела, 1953) комедиясе аеруча таныла. «Зөбәйдә — адәм баласы» (1961) трагикомедиясе жанр үзенчәлеге һәм теманың актуальлеге б-н аерылып тора. Игътибар үзәгендә — өлкән буынның балалар тәрбиясе өчен җаваплылыгы. Пьесада комик һәм трагик вакыйгалар органик рәвештә үрелеп бара. «Әниемнең ак күлмәге» (беренче исеме — «Әни килде», 1968 дә куела) драмасында әхлак, рәхимсезлек, нәфеслелек темасы аеруча кискен күтәрелә. Пьеса берничә тапкыр Татар акад. театрында (1960 һәм 1990 еллар театр сезоннарында), Казан Зур драма театрында (1970 елларда) куела, 17 телгә тәрҗемә ителә, СССРның 48 театрында бара. Сюжет нигезендә гади һәм тирән фаҗигале тормыш вакыйгасы ята. Бер гаилә үрнәгендә драматург төрле социаль катлау кешеләрен күрсәтеп бирә, капма-каршы тормыш позицияләрен бәрелештерә. Спектакль төрлечә кабул ителә: кемдер хуплый, кемдер кара ягуда гаепли. «Безнең подъезд төбендә» (телевидение өчен языла, 1990), «Көфер почмагы» (1993 тә куела) пьесалары гаилә-көнкүреш темаларына багышлана. Х. «Мәхәббәт сагышы» (1965) повесте һәм юмористик хикәяләр авторы. Аның «Егерме ел үткәч» пьесасы «Бер актлы совет пьесалары антологиясе»нә («Антология советской одноактной пьесы», М., 1967) кертелә. «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

Әсәр.: Пьесалар. К., 1979.

Әд.: Шәриф Хөсәенов. К., 2006; Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

А.Г.Әхмәдуллин.

ХӨСӘЕ́НОВ Ш. ВАРИСЛАРЫ́ НӘШРИЯТЫ́ ҺӘМ КИТА́П САТУ́ ФИ́РМАСЫ, Казан өязе Түбән Курса авылы крәстияне Шәмсетдин Хөсәенов тарафыннан оештырыла. Ул 19 йөз уртасыннан китап сату һәм 1866 елдан нәшрият эшчәнлеге б-н шөгыльләнә. 1866 да казакъ телендәге беренче басма китап — «Кыйссаи Тамимдар»ны чыгара: Казанда кабатлап басыла (1882, 4 басма, 1913), 1880 дә казакъ телендәге цензура тарафыннан алынган беренче китап — «Васыятьнамә»не бастыра. Фирма рәсми рәвештә 1875 тә оеша. Ш.Хөсәенов Казан басмаханәләренә, беренче чиратта, ун-т басмаханәсенә мөрәҗәгать итә. 1890 га аның заказы буенча 6 мең сумлык 500 мең данә китап һәм брошюралар басыла. Алар ел саен Россиянең Европа өлешендә, Азиядә һәм хәтта Африкада 10 меңгә кадәрге суммада тарала, сатудан кергән чиста табыш 2 мең сумга җитә. Казан фәнни-сәнәгать күргәзмәсендә (1890) татар нашире эшчәнлеге диплом б-н билгеләп үтелә.

1900 еллар башына Ш.Хөсәеновның зур китап кибете була. 1897 дә ул, формаль рәвештә фирма башлыгы булып калган хәлдә, эштән туктый. Вафатыннан соң, 1904 тә, аның эшен кызы Б.Ш.Кәтиева дәвам итә. 1905 тән фирма «Хөсәенов варислары» исеме б-н эшли. Элеккечә китап чыгару эшчәнлеге б-н шөгыльләнеп, Хөсәеновлар, ун-т басмаханәсеннән тыш, Б.Л.Домбровский, И.Н.Харитонов, И.В.Ермолаева, Н.М.Чижова, «Өмид» басмаханәләренә, һ.б.га да заказлар бирә. Урта гасырлар көнчыгыш, татар, казакъ әдәбияты һәм фольклоры, дини әдәбият әсәрләре зур күләмдә чыгарыла, аң-белем бирү характерындагы, ш.и. уку-укыту, белешмә, популяр китаплар; календарьлар, юл күрсәткечләре сирәк басыла. Китап сату эшчәнлеге Казанда гына түгел, Уфа, Оренбург һ.б. шәһәрләрдә дә алып барыла, китап ярминкәләрендә һәм китап сатучыларның киң сату челтәре аша сатыла. Басмаларның ассортименты нәшрият-китап сату каталогларында рекламалана («*Әсами көтеп*», 1892, 7 басма, 1916).

1917–19 да хосусый-кооператив нәшрият буларак эшли, 30 татар китабы: әлифбалар, туган тел буенча уку ярдәмлекләре һәм Г.Әхмәровның арифметика дәреслекләре, З.Шакировның рәсемле география дәреслеге, Г.Шнасиның пед. буенча кулланмасы, Ф.Сәйфи-Казанлының «Мәктәптә татар теле дәресләре», Г.Рәшиди әсәрләре һ.б. басыла. 1918–20 дә Уфада Хөсәеновлар 17 татар китабы чыгаралар, «Хезмәткәр» китап сату фирмасына нигез салалар, Казанда басылган китапларны сату б-н шөгыльләнәләр.

Әд.: Каримуллин А.Г. Книги и люди. К., 1985; шул ук. Становление и развитие татарской советской книги, 1917–1932. К., 1989; Габдельганеева Г.Г. Книжная торговля в Казанской губернии, вторая половина XVIII в. — 1917 г. К., 2006.

ХӨСӘЕ́НОВ Эдуард Ришат улы (24.1.1960, Мәскәү өлкәсенең Балашиха ш.), спортчы (бокс), СССРның халыкара класслы спорт остасы (1983). Үзәк физик культура ин-тын тәмамлый (Мәскәү). СССР (1982 — бронза, 1983 — көмеш), СССР халыклары спартакиадаларында (1983) медальләр ала. СССР җыелма командасы әгъзасы (1979–83). 1999–2000 елларда Россиянең Бокс федерациясе вице-президенты, 2000–07 дә президенты, бер үк вакытта, 2006–07 дә Европа һәвәскәр боксчылар ассоциациясе президенты, Россиянең Олимпия ком-ты башкарма ком-ты әгъзасы.

ХӨСӘЕ́НОВА Ләбибә Һади кызы, к. *Хөсәения* Ләбибә Һади кызы.

ХӨСӘЕ́НОВА Наирә Йосыф кызы (14.10.1944, Казан), психолог, педагог, пед. фән. д-ры (1998), проф. (2001). Казан ун-тын тәмамлый (1967), шунда ук эшли: 1977 елга кадәр кешеләр һәм хайваннар физиологиясе кафедрасында, 2003 тән гомуми психол. кафедрасында. Бер үк вакытта, 1997–2005 тә, Татар-Америка региональ ин-тының пед. һәм психол. каф. мөдире.

Хезмәтләре хезмәт коллективы һәм идарә психологиясе мәсь әләләренә карый.

Хезм.: Педагогика трудового коллектива: Дидактика. К., 1997; Формирование позитивной Я-концепции руководителя в процессе педагогической подготовки. К., 1997.

ХӨСӘЕ́НОВА Нәгыймә Җамали кызы (21.10.1911, Казан — 17.11.1971, Алма-Ата), гидробиолог, биол. фән. д-ры (1959), проф. (1960). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1932), Казакъстан ун-тында (Алма-Ата): умырткасызлар зоологиясе каф. мөдире (1945–54), проректор (1949–54), 1961 елдан үзе оештырган гидробиол. һәм ихтиология каф. мөдире. Хезмәтләре Казакъстан сулык - ларындагы хайваннар дөньясына, Арал диңгезе умырткасызларының биол. үзенчәлекләренә карый. Х. җитәкчелегендә Талас һәм Или елгалары бассейннарына, күлләренә комплексны тикшеренүләр үткәрелә, аларның биопродуктлылыгы билгеләнә, азык запасларын арттыру юллары тәкъдим ителә. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары; Казакъстан ССР ЮС Президиумының Мактау грамоталары б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Планктон затона (Аракчинского), его состав и сезонные изменения. К., 1936; Биологические особенности некоторых массовых донных кормовых беспозвоночных Аральского моря. А.-А., 1958; Генезис донной фауны Аральского моря // Сборник работ по ихтиологии и гидробиологии. А.-А., 1959. Вып. 2.

Әд.: Казахская ССР: Краткая энцикл. А.-А., 1989. Т. 3.

ХӨСӘЕ́НОВА Нәркис Габбас кызы (23.12.1938, Казан), химик-органик, химия фән. д-ры (1988), проф. (1992), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1999). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1961), шунда ук эшли: 1974 елдан элементорганик кушылмалар фәнни-тикшеренү лаб-ясендә, 1987 дән А.М.Бутлеров исем. химия ин-тының әйдәп баручы фәнни хезмәткәре. Хезмәтләре элементорганик кушылмалар химиясенә карый. Х. ал - ленлы, ацетиленлы һәм виниллы фосфорорганик кушылмалар һәм ике координацияле фосфорның циклик продукты — диазафосфол реакцияләре нигезендә яңа күп функцияле фосфор продуктларын максатчан синтезлау алымнарын эшли. Чикләнмәгән фосфорорганик чыгарылмалар реакциясенең гомуми закончалыкларын ачыклый. Тәҗрибә нәтиҗәсендә алынган элементорганик кушылмаларның стуктураларын, стерео- һәм региохимиясен, спектраль, кинетик һәм квант химик алымнар һәм хисаплаулар комплексын файдаланып кушылу һәм цикллы кушылу процессларының механизмнарын билгели. Ике координацияле циклик фосфор чыгарылмаларының реакция мөмкинлеген тикшерә. Фосфоразот һәм фосфоркүкерт эчтәлекле кушылмаларның яңа типларын синтезлау алымнарын эшли, яңа тип бу кушылмалар арасында югары пестицид, дәвалау активлыгына һәм бактерицид үзлекләренә ия матдәләрне ача. Үйлап табуга 9 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Фосфорилированные аллены. Методы получения, свойства // Успехи химии. 1987. Т. 56, вып 6 (автордаш); Реакции 1,2-этандитиола 2-меркаптоэтанола с ненасыщенными производными кислот четырёхкоординированного фосфора // Изв. РАН. Сер. хим. 2004. № 10 (автордаш); Interaction of Vinylphosphonates with 1,2-Diaminoethane and Ethanolamine // Phosphorus, Sulfur, Silicon and the Related. Elements. 2009. V. 184, № 4 (автордаш).

ХӨСӘЕ́НОВЛАР, Оренбург, Казан сәүдәгәрләре, җәмәгать эшлеклеләре, иганәчеләр. Х. династиясен нигезләүче булып, Казан губернасы Мамадыш өязенең Кибәхуҗа авылыннан чыккан Иманкол санала. Х.ның бабалары Оренбург губернасы Сәет бистәсен (к. *Каргалы бистәсе,* 18 йөз) нигезләүчеләрдән булалар. **Мөхәммәтгали Хөсәен улы** (1804–58, хәзер Оренбург өлкәсе Илек а.), Оренбург сәүдәгәре, сәүдә б-н шөгыльләнә. Аның уллары: Әхмәт, Габделгани һәм Мәхмүт. **Әхмәт Мөхәммәтгали улы** (1837, Оренбург губ. Сәет бистәсе — 10.12.1906, Казан), 1 нче гильдия Оренбург һәм Казан сәүдәгәре. 1861 елда бертуганнары б-н сәнәгать һәм а.х. товарлары сәүдәсе алып барган «Әхмәт Хөсәенов һәм борадәрләре» фирмасын нигезли. Оренбургта әчәк юу производствосы (1885), әчәк эшкәртү з-ды (1899), ярма ф-касы оештыра; ш.у. аның Сәмәрканд өлкәсенең Хөҗәнд шәһәрендә мамык чистарту з-ды, Сырдәрья өлкәсенең Ташкент шәһәрендә әчәк эшкәртү з-ды була. 1896 дан Казанда, Кабан күле буендагы үз йортында яши. Аның кибетләрендә (Казан, Оренбург һәм Оренбург губ., Түбән Новгород, Мәскәү һ.б.) а.х. һәм сәнәгать товарлары б-н сәүдә итәләр. Оренбург (1879–97), Казан (1898–1901) шәһәр думалары гласные. Оренбургта ярлыларга ярдәм ком-ты (1888 дән), Оренбургның мохтаҗ кешеләренә ярдәм итү җәмгыяте әгъзасы (1892 дән), Казан губерна ятимханәләре попечительлегенең шәрәфле әгъзасы (1896–1906), «Казан шәһәре мөселманнары хәйрия җәмгыяте» (1898 дән) попечителе. Бөтенроссия мөселманнарының беренче корылтаенда (1905) катнаша. Аның акчаларына Оренбургта мөселман татарлар өчен түләүсез ашханә ачыла (1892), гомуми чыгымнар 3 мең сум тәшкил итеп, *«Хөсәения»* мәдрәсәсе, Оренбургта һәм Оренбург губернасында 20 ләп мәчет төзелә (1896–1906). Түбән Новгород ярминкәсендә Мөселман хәйрия җәмгыятен оештыручыларның берсе (1906). Вафатыннан соң 500 мең сумнан артык акчасын хәйрия эшенә (мохтаҗларга сәдака тарату, укытучыларга хезмәт хакы, яшьләрне укытуга стипендияләр түләү, «Хөсәения» мәдрәсәсен тоту һ.б.) васыять итә. Хәйрия капиталы б-н идарә итү өчен Ә.Хөсәенов исем. попечительләр шурасы (1906–17) оештырыла. **Габделгани Мөхәммәтгали улы** (1839, Оренбург губ., Орск өязенең Юлык а. — 3.11.1902, Оренбург), 1 нче гильдия Казалы шәһәре сәүдәгәре. 1869–92 дә Казалы шәһәрендә һәм күрше шәһәрләрдә «Әхмәт Хөсәенов һәм борадәрләре» фирмасы вәкиллекләрен, Перовск, Сырдәрья, Семипалатинск, Маргелан, Ташкент, Сәмәрканд, Җамбул, Чимкент һәм Ыргыз шәһәрләрендә Казалы конторасы бүлекчәләрен нигезли. 1896 дан соң Сырдәрья өлкәсенең Казалы һәм Перовск шәһәрләрендә — мануфактура һәм бакалея товарлары, Тургай өлкәсенең Ыргыз шәһәрендә күн товарлар б-н сәүдә итә. 1897–1902 дә аның тарафыннан Оренбург өлкәсе авылларында 100 ләп яңа ысуллы уку йортлары, 20 дән артык хатын-кызлар мәктәпләре ачыла. Фатыйма Әдһәмованың хатын-кызлар мәктәбен финанслый. **Мәхмүт Мөхәммәтгали улы** (1845, Оренбург губ. Сәет бистәсе — 10.8.1910, Оренбург), 1 нче гильдия Оренбург сәүдәгәре. 1876 дан «Әхмәт Хөсәенов һәм борадәрләре» фирмасының Түбән Новгород, Казан, Әстерхан, Мәскәү шәһәрләрендәге бүлекчәләре б-н җитәкчелек итә. 1896 да капитал бүлгәннән соң, Оренбургта гомуми бәясе 800 сумлык 3 йортның, Казан, Оренбург, Сембер, Казалы, Ыргыз, Перовск, Бохара, Истанбул, Берлин шәһәрләрендә урнашкан һәм күмәртәле ефәк, мануфактура товарлары, мамык, йон, терлек мае, күн сәүдәсе б-н шөгыльләнгән 11 сәүдә-сәнәгать конторасының хуҗасы була. Каргалыда аның терлек чалу, йон юу пр-тиеләре эшли. Тәфкилев утарын били (Оренбург губ.). Оренбург биржасының 1 нче разрядлы әгъзасы (1906 дан), Оренбург биржа ком-ты старшинасы (1906–07), «Актүбә он тарту һәм бодай ширкәте»ндә 40 мең сумлык пае була. Оренбургның мохтаҗ кешеләренә ярдәм итү җәмгыяте (1892 дән), «Оренбург шәһәренең һөнәрчелек, мәхәлләләренең ир-атлар һәм уч-щеләренең мохтаҗ шәкерт егетләренә һәм кызларына ярдәм итү җәмгыяте» (1892–1910), «Оренбург төрмәләр буенча губерна попечительлеге җәмгыяте» әгъзасы, Оренбург җәмгать банкының хисап ком-ты әгъзасы булып сайлана. 1909 да Дәүләт Думасындагы мөселман фракциясенә финанс ярдәме күрсәтергә тиешле комиссия рәисе итеп сайлап куела. 1873 тән бертуган Х. Түбән Новгород ярминкәсендә катнашалар, Мишәр тыкрыгында кунакханә номерлары һәм фатирлар, склад бүлмәләре, таш кибетләр, ашханәләр, трактирлар, чәйханәләр урнашкан Хөсәеновлар мөсафирханәсен тоталар. 1899 да Оренбургта таш бина төзиләр, аның эчендә ресторан һәм кибетләр урын ала («Америка кунакханәсе»). Оренбургта, Казанда, Казалыда, Илек Защитасында һ.б.да йортлар, Оренбург губернасының Оренбург, Орск, Чиләбе һәм Троицк өязләрендә җирләр билиләр. Россия, Урта Азия һәм Европаның төп икътисади үзәкләрен колачлаган киң сәүдә челтәре оештыралар. 1873 кә Х.ның гомуми капиталы 80 мең сум, 1896 да 3 млн. сум тәшкил итә. 1896 да бертуган Х. үз капиталларын бүлеп алалар.

Мөхәммәтвәли Габделгани улы (1871–1933, Оренбургның 1 нче мәчете имамы, «Вәлия» мәдрәсәсе мөдире, «Дин вә мәгыйшәт» ж-лы нашире, басмаханә, 100 мең сумлык капитал әйләнеше булган сәүдә йорты били. Оренбургта һәм күрше губерналарда сәүдә итә. Уфада Оренбург мөселман Дин ия нәзарәте каршында узган дин әһелләре киңәшмәсендә катнаша (1905 нең 10–15 апреле). **Хөсәен Мәхмүт улы** (1883–1918 дән иртәрәк түгел), 1 нче гильдия Оренбург сәүдәгәре. 1906 дан «Кәримов, Хөсәенов һәм К°» ширкәте б-н җитәкчелек итә. 1909 да Дәүләт Думасындагы мөселман фракциясенә финанс ярдәме күрсәтү комиссиясе әгъзасы. «Оренбург мөселман шәкертләренә ярдәм итү җәмгыяте»н оештыруда башлап йөрүчеләрнең берсе (1912), аның гомерлек әгъзасы, идарә составына сайлана. Оренбург мө-

селманнар хәйрия җәмгыяте, Актүбә мөселманнар җәмгыятенең һәм Казандагы Шәрекъ клубының шәрәфле әгъзасы. **Шәрәфетдин Мәхмүт улы** (1885–1926, Урта Азия), 2 нче гильдия Оренбург сәүдәгәре. Истанбулда укый. Аның «М.Г.Хөсәенов варислары Оренбургта» фирмасының Казанда, Түбән Новгород ярминкәсендә, Илек Защитасында, Ыргызда, Казалыда, Перовскида, Кокандта бүлекчәләре була. Оренбург шәһәр думасы гласные (1913–17), Оренбург биржа ком-ты арбитраж комиссиясе, Оренбург губерна хәрби сәнәгать ком-ты әгъзасы (1915–17); «Оренбург мөселман шәкертләренә ярдәм итү җәмгыяте»нең гомерлек әгъзасы, Оренбург мөселманнар хәйрия җәмгыяте әгъзасы. Совет чорында Мәскәүдә Төркия илчелегендә эшли. **Габделхәмит Габделгани улы** (? — 1976, Ташкент), сәүдәгәр һәм иганәче. Оренбург мөселманнар хәйрия җәмгыяте рәисе. Оренбург шәһәр думасы гласные (1913 — 17), биржа ком-ты старшинасы (1917 дән) һәм аның Оренбург хәрби-сәнәгать ком-тындагы вәкиле (1915 — 17), «Бөтенроссия туберкулёзга каршы көрәш җәмгыяте» һәм «Ашыгыч ярдәм күрсәтү җәмгыяте» казначее. С.-Петербург, Сембер губернасының Сембер өязе, Актүбә һ.б. хәйрия җәмгыятьләре әгъзасы; «Оренбург мөселман музыка-драма җәмгыяте»н оештыручыларның берсе.

Әд.: Ф ә х р е т д и н Р. Әхмәт бай. Оренбург, 1911; Гани бай: Тәр җәмәи хәле, хатлары, аның хакында хатирәләр. Оренбург, 1913; Х ә м и д у л л и н Л. Иганәче Хөсәенов байларның варислары // Гасырлар авазы-Эхо веков. 2009. № 1; Р а х и м к у л о в а М.Ф. Медресе «Хусаиния» в Оренбурге. Оренбург, 1997.

Р.Р.Шәйдуллина.

ХӨСНЕТДИ́НОВ Айрат Асаф улы (9.7.1960, Октябрь р-ны Киекле а.), радиоинженер, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2005). Пушкин югары радиоэлектроника уч-щесен тәмамлый (Ленинград өлкәсе, 1981). 1981–87 елларда Совет Армиясендә. 1987–88 дә Зәй автоагрегат з-дының исәпләү һәм оештыру техника-сын ремонтлау лаб-ясендә инженер-электроник. 1988–92 дә төзелүче Татарстан атом электростанциясе дирекциясендә әйдәп баручы инженер-электроник. 1995–96 да «Энергобанк» ф-лында (Түбән Кама р-ныңың Кама Аланы штп) инженер-программист. 1996–2004 тә «Татнефть» АҖнең Мәгълүмат технологияләре идарәсендә әйдәп баручы инженер-программист, бүлек башлыгы. Дәүләт бүләге оператив контроль һәм нефть чыгару процесслары б-н идарә итүнең корпоратив мәгълүмат системаларын эшләүдә һәм сәнәгатькә кертүдә катнашканы өчен бирелә.

ХӨСНЕТДИ́НОВ Әхнәф Галим җан улы (28.4.1925, БАССРның Тамьян-Катай кантоны, хәзер БРның Учалы р-ны Учалы а. — 12.7.2005, шунда ук), Дан орденының тулы кавалеры (3.9.1944, 18.3.1945; 1959 ның 24 декабрендә 1 нче дәрәҗә орден б-н кабат бүләкләнә, 8.3.1945), гв. рядовое. Пед. ин-тын тәмамлый (Уфа ш.,1956). Мәктәптә укытучы булып эшли. 1943 елның маеннан Кызыл Армиядә һәм Бөек Ватан сугышы фронтларында, 29 нчы гв. мотоукчылар бригадасының (4 нче гв. танк армиясенең 10 нчы гв. танк корпусы) 3 нче мотоукчылар батальонында артиллерия расчёты туп коручысы. 1 нче Украина фронты гаскәрләре составында Проскуров-Черновцы, Львов-Сандомир (икесе дә 1944 тә) һәм Сандомир-Силезия (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 16 августын-да Олесница (Сташув (Польша) шәһәреннән 12–13 *км* көньяк-көнбатыштарак) торак пункты янында дошман һөҗүмен кире кайтарганда батырлык күрсәтә: расчёт составында дошманның кыр артиллериясе батареясын, 5 автомашинасын, 10 лап солдатын юк итә; бу сугышларда, туры төзәп атып, дошманның күпсанлы хәрби техникасын сафтан чыгара, күпләгән солдатын юк итә; 1945 нең 13 гыйнварында Хмельник (Польша) шәһәреннән 7 *км* төньяктарак, дошманның каршы һөҗүмен кире кайтарып, 2 танкны сафтан чыгара; 1945 нең 25–26 гыйнварында Штейнау (Германия; хәзер Сьцинава, Польша) шәһәре тирәсендә Одер елгасын кичкәндәге бәрелештә дошманның 2 тубын сафтан чыгара, үзенең тубын сул ярга чыгарып, десантка плацдармны саклап калырга ярдәм итә. Демобилизацияләнгәч (1945), туган ягына кайта, урта мәктәптә директор булып эшли. Кызыл мәйданда Җиңү Парадында катнаша (1995). 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.



Ә.Г.Хөснетдинов.

Әд.: Кавалеры ордена Славы трёх степеней: Краткий биогр. словарь. М., 2000.

ХӨСНЕТДИ́НОВ Валерий Алтынбай улы (13.1.1941, Таҗикстан ССР, Сталинабад ш.), химик-технолог, химия фән. д-ры (2001), проф. (2003), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2006). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1963), Л.Я.Карпов исем. химия з-дында эшли. 1964 елдан Казан технол. ун-тында, 1998–99 да нәорганик матдәләр технол. каф. мөдире. Хезмәтләре нәтрадицион чимал технологиясенә, гетероген реакцияләр кинетикасына карый. Х. каты матдәләр термоткалуы реакцияләренең физик моделен эшләп кинетик тигезләмәсен тасвирлый, «утырма — ана эремә» системасы картаю механизмының критериен билгели. Элек нәмәгълүм 5 кушылманы синтезлый, өчесенең кристалл-химик структурасын ачыклый. Магний гидрокс тозларының тотрыклылыгы тезмәсен билгели һәм аңлата. Д.И. Менделеев таблицасындагы 2 нче группа s-элементлары оксидларының гидратация механизмын эшләп хасил булучы гидроксидлар реакциясенең һәм дисперслыгының тизлегенә электролитлар тәэсирен прогнозлауга юл ача (фәнни эш нәтиҗәләре Л.Я.Карпов исем. химия з-дында гамәлгә кертелә). Уйлап табуга 16 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Оборудование производств неорганических веществ. Л., 1987 (автордаш); Минеральное сырьё. Соли минеральные: Справ. М., 1999 (автордаш); Производство кальцинированной соды. К., 2008 (автордаш).

Әд.: Выпускники — гордость Казанского технологического университета: Краткий биогр. справ. К., 2009.

ХӨСНЕТДИ́НОВ Исмәгыйль Шакир улы (18.9.1966, Казан), химик-технолог, техник фән. д-ры (2005), ТР ФАнең мөхбир әгъзасы (2008). Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң (1989), шунда ук эшли, нефть һәм нефть химиясе ф-ты деканы (1999–2005), органик һәм нефтехимик синтез нигезләре технол. каф. профессоры (2005 тән), бер үк вакытта, 2004–07 елларда, «Химия һәм нефтехимия» фәнни-технол. үзәге директоры, 2006–07 дә Нефть һәм химия ин-ты директоры; 2007 дән РФА КГУнең Органик һәм физик химия ин-тының нефтьне һәм битумны эшкәртү лаб-ясе мөдире. ТР ФА Президиумы секретариаты җитәкчесе (2007 дән). Хезмәтләре нефть химиясе технологияләрен эшләүгә карый. Х. югары сыйфатлы битум үзләләрен булдыру һәм табигый битумнарны торба-үткәргеч буенча транспортлауга әзерләү өчен сольвент технологиясен тәкъдим итә. Уйлап табуга 5 патенты бар.

Х е з м.: Сопоставление различных методов фракционирования тяжёлого органического сырья // Журн. прикладной химии. 1998. № 6 (автордаш); Разработка и совершенствование сольвентных технологий переработки тяжёлого органического сырья. К., 2009 (автордаш); Сопоставительный анализ битумов // Химия и хим. технология. 2009. Т. 52, вып. 12 (автордаш).

ХӨСНЕТДИ́НОВ Наил Рөстәм улы (7.9.1962, Оренбург өлкәсенең Богырыслан ш.), физик, физика-матем. фән. д-ры (2004). Казан ун-тын тәмамлый (1985). 1988 елдан Татар гуманитар-пед. ун-тында, 2009 дан Казан ун-тында, проф. (2004 тән), физика ф-ты деканы (2005–06), матем., информатика һәм информатика укыту методикасы каф. мөдире (2006 дан). Хезмәтләре чагыштырмалылык теориясенә һәм гравитациягә карый. Х. топологик дефектлар һәм фәзадагы «туннельдә» классик һәм квант эффектларны тикшерә, квант чыганаклы «туннельләр» («сукыр тычкан өннәре»нең) булу мөмкинлеген дәлилли, фуллереннарга нисбәтән Казимир һәм Казимир-Полдер эффектын тикшерә.

Х е з м.: Интеграл столкновений с точностью до членов линейных по кривизне // Журн. эксперим. и теорет. физики. 1991. Т. 100; Эффекты самодействия частиц в гравитационном поле // Успехи физ. наук. 2005. Т. 175, № 6; Ground state energy in wormhole spacetime // Phys. Rev. D. 2002. V. 65 (автордаш).

ХӨСНЕТДИ́НОВ Равил Исмәгыйль улы (12.2.1947, БАССРның Фёдоровка р-ны Кораллачык а.), химик-органик, химия фән. д-ры (1989), проф. (2004), БРның атказ. фән эшлеклесе (2001). 1970 елда Башкорт ун-тын тәмамлый, 1972 дән РФА Уфа Гыйльми үзәгенең Органик химия ин-тында эшли, 1986 дан әйдәп баручы фәнни хезмәткәр. 1992 дән директор урынбасары һәм РФАнең Нефтехимия һәм катализ ин-тында углеводородлар химиясе лаб-ясе мөдире. Хезмәтләре органик синтезга, металл комплексы ката-

лизга карый. Х. югары киеренкелекле каркаслы һәм полициклик углеводородларны синтезлау алымнарын һәм аларны, металл комплексны катализаторлар файдаланып, селектив функциональләштерү ысулларын эшли. Линияле һәм циклик мономерлар катнашындагы цикл кушылуы реакцияләре өчен никель, кобальт, тимер, палладий һәм родий кушылмалары нигезендә югары нәтиҗәле һәм универсаль катализаторлар тәкъдим итә (күләм ягыннан чикләнелгән ракета системалары өчен югары энергияле ягулык сыйфатында, махсус полимерлар, дарулар, гербицидлар синтезлаганда кулланыла). Норборнадиен җитештерүнең куркынычсыз технологиясен, пинан гидроперекисен барлыкка китерү өчен беренчел чимал итеп кулланылган циспинанны синтезлау алымын (циспинан бутадиен б-н стиролның түбән температура үзара полимерлашуының башлангычы сыйфатында кулланыла) эшли һәм гамәлгә кертә (эш нәтиҗәләре Эстәрлетамак шәһәренең «Каучук» АҖдә гамәлгә кертелә). Уйлап табуга 89 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Башкортстан комсомолы бүләгенә (1978), РФ Дәүләт бүләгенә (2003) лаек була. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Хлорирование адамантана и его производных четырёххлористым углеродом в присутствии марганец-, ванадий- и молибденсодержащих катализаторов // Нефтехимия. 2004. № 2 (автордаш); Окисление моно- и диатомных спиртов CCl_4 под действием соединений молибдена // Журн. орган. химии. 2006. Т. 42, № 11 (автордаш); Одностадийный синтез 3-дихлорметилпиридина из пиридина в присутствии железосодержащих катализаторов // Журн. орган. химии. 2007. Т. 43, № 12 (автордаш).

ХӨСНЕТДИ́НОВ Рәис Әгъзам улы (27.6.1950, Камчатка өлкәсенең Елизово р-ны Елизово а.), хакимият эшлеклесе, икътисадчы, икътисад фән. канд. (1998). Казан авиация ин-тын (1977), РФ Президенты каршындагы Дәүләт идарәсе академиясен (Мәскәү, 2003) тәмамлый. 1972–77 елларда Казан электротехника з-дында инженер. 1977–80 дә ВЛКСМның Татарстан өлкә ком-тында сектор мөдире. 1980–87 дә Казан мед. аппаратлары з-ды производство башлыгы, баш технолог урынбасары, профсоюз ком-ты рәисе, директор ярдәмчесе. 1987–89 да ТАССР МС инструкторы. 1989–91 дә ТССР МС Дәүләт план ком-ты бүлекчәсе башлыгы. 1991–93 тә ТРның Дәүләт милке б-н идарә итү дәүләт ком-тында идарә башлыгы, рәиснең баш киңәшчесе. 1993–95 тә ТРның Стат. буенча дәүләт ком-ты рәисенең 1 нче урынбасары, 1995–2000 дә рәисе. 2000–01 дә Казан хакимиятендә ком-т рәисе урынбасары. 2001–04 тә РФ Мөлкәти мөнәсәбәтләр министрлыгы департаменты җитәкчесе урынбасары. 2004–08 дә «Россия һәм К°» АҖ (Мәскәү) директоры урынбасары. 2008–09 да «Согласие» хәйрия фонды вице-президенты. 2009–12 дә В.И.Шимков исем. «Радиоэлектроника» федераль фәнни-җитештерү үзәге директоры ярдәмчесе, 2012 дән «Экран» фәнни-тикшеренү ин-ты (Самара ш.) ген. директоры ярдәмчесе. Хезмәтләре милек, Татарстанның социаль-икътисади үсеш мәсьәләләренә карый.

Е.Б.Долгов.

ХӨСНЕТДИ́НОВА Мария Николаевна (10.5.1920, Минзәлә кантоны Сарсаз-Багаж а. — 6.4.2003, Зәй р-ны Аксар а.), комплексны бригада бригадиры, Соц. Хезмәт Герое (1966). 1937–55 елларда Зәй һәм Чаллы р-ннары мәктәпләрендә укытучы булып эшли, 1955–60 та Чаллы р-нының Аксар авыл советы рәисе. 1960–76 да (бүленеп), 21 нче партия съезды исем. к-зда Аксар комплексны бригада бригадиры. 1961–62 дә Зәй р-нының Иске Тәкмәк авыл советы рәисе. 1964 тә Х. җитәкләгән бригада районда иң югары уңыш ала — бөртекле ашлыктан 1 *га* дан 31 *ц*, шикәр чөгендереннән — 178 *ц*, кукурузның яшел массасы — 156 *ц*; икмәк әзерләү планын алдан үти. Х. башлангычы б-н механикалаштырылган ындыр табагы төзелә, авыр процессларны механикалаштыру б-н терлекчелек биналары үзгәртеп корыла. 1966 да савым бер сыердан (320 баш) 2500 *кг* тәшкил итә (1960 та 1500 *кг* нан артмый). Герой исеме а.х. продукциясе җитештерүне һәм әзерләүне арттыруда ирешелгән уңышлары һәм техникадан югары җитештерүчән файдаланганы өчен бирелә. 1959–63 тә ТАССР ЮС депутаты. КПССның 23 нче съезды делегаты (1966). Ленин ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының бронза медале б-н бүләкләнә.



М.Н. Хөснетдинова.

Әд.: Герои Социалистического Труда Татарии: Док. очерки. К., 1984. Кн. 2; Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003; Заинская энциклопедия. К., 1994.

М.Ж.Гаитов.

ХӨСНЕТДИ́НОВА Нила Вәли кызы (9.3.1933, Казан), математик, физика-матем. фән. д-ры (1982), проф. (1985). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1956), Казан авиация ин-тында эшли. 1966–68 дә РФАнең Себер бүлегендә: Теоретик һәм гамәли механика ин-тында, 1973 елдан Гидродинамика ин-тында, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1992–2008). Хезмәтләре гидродинамика мәсьәләләрендә гадиләштә баручы параболик дифференциаль тигезләмәләр һәм системалар өчен чик буе мәсьәләләре теориясенә карый. Х. ике үлчәмле нәстационар фильтрация тигезләмәләре өчен чик буе мәсьәләренең корректлыгын тикшерә, күп компонентлы газ өчен чик буе катламы матем. моделен нигезли (бергә). Яссы параллель һәм күчәр симметрияле сыпырым очракларында кысылган төрле составлы сыекча өчен кулланылган чик буе темп-ра катламының дифференциаль тигезләмәләре системасын тикшереп аңа нисбәтән чик буе мәсьәләренең барлыгы һәм берлеге теоремаларын исбатлый. Акробатика буенча спорт остасы.

Х е з м.: О стабилизации решений нелинейного уравнения фильтрации двухфазной жидкости // Прикладная механика и техн. физика. 1999. Т. 40, № 3; Качественные свойства отрывных течений в пограничном слое Прандтля // Сибирский мат. журн. 2001. Т. 42, № 6; Теоретический анализ модели теплового пограничного слоя с сопротивлением // Сибирский мат. журн. 2005. Т. 46, № 2.

ХӨСНЕТДИ́НОВА Роза Госман кызы (2.5.1940, Уфа ш.), киносценарист, кинодраматург, язучы. Мәскәүдә А.М.Горький исем. Әдәбият ин-тын (1964), СССР Дәүләт кинематография ком-ты каршындагы югары сәхнә курсларын (1970) тәмамлый. 20 дән артык мультипликацион (анимацион) фильм сценарие авторы. Аларның иң танылганнары — «Корабльдәге балерина» («Балерина на корабле», 1969, реж. Л.Атаманов; Лондондагы кино фестивалендә «Көмеш пеликан» призы, 1975), «Күбәләк» («Бабочка», 1972, реж. А.Хржановский, комп. А.Шнитке; халыкара балалар фильмнары фестивальләрендә призлар: Иран ун-тының пед. ф-ты дипломы, Тәһран ш.; жюриның махсус бүләге, Испания, Хихон ш., 1973). «Калейдоскоп» кино альманахында Х. сценарийлары буенча «Бегемот», «Велосипедчы», «Җыр укытучысы» («Учитель пения», барысы да — 1968 дә), «Шкаф» (1971) сюжетлары төшерелә. М.Горький исем. (Мәскәү), «Әзәрбай җанфильм», «Үзбәкфильм», «Кыргызфильм» кино студияләрендә төшерелгән «Триптих» (1979, реж. А.Хамраев; Сан-Ремо шәһәре халыкара кинофестивале, гран-при, Италия, 1980), «Зифа оныгы Ришад» («Ришад — внук Зифы», 1981, реж. М.Осепьян, комп. С.Гобәйдуллина), «Анар агачы турында хатирә» («Воспоминание о гранатовом дереве», 1984, режиссёрлар Ш.Мәхмүдбәков, Г.Турабов), «Дилетант» (1987, режиссёрлар А.Камчибеков, Д.Соданбек) нәфис фильмнарының сценарийлары авторы.

Әсәр.: Как прекрасно светит сегодня луна: Сб. рассказов. М., 1990; Балерина на корабле: Сб. сказок. М., 2001.

Е.П.Алексеева.

ХӨСНЕТДИ́НОВА (Нигъмәт җанова) Фәһимә Шакир кызы (18.5.1955, Кукмара р-ны Мәмәшир а.), СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1980). «Полимерфото» (1974 тән), «Эләдия» (1996 дан) пр-тиеләрендә кассеталар җыючы булып эшли. 2005–10 елларда «Мебельград» сәүдә үзәгендә. Дәүләт бүләге җитештерүне оештыруны камилләштерү һәм эштә алдынгы алымнар кертү нигезендә хезмәттәге казанышлары өчен бирелә. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

ХӨСНИ́ (Хөснетдинов) Сәләх Мөхетдин улы (5.10.1912, Казан губ., Зөя өязе Олы Кариле а. — 11.5.1974, Казан), актёр, режиссёр, драматург, ТАССРның атказ. артисты (1950), ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1960). Казанда И.Гаспринский исем. тәжрибә-үрнәк мәктәп тәмамлаганнан соң (1928), Ленинградта эшче яшьләр театрларының югары режиссёрлык курсларына укырга керә; бер үк вакытта, 1928–31 елларда, М.В.Сокольский исем. Ленинград эшче яшләр театрында режиссёр-лаборант булып эшли. 1931–33 тә Казан эшче яшләр театры актёры. 1937 дән Минзәлә колхоз-совхоз театры директоры. 1938 дән Казан курчак театрында: актёр, режиссёр, 1940–65 тә баш режиссёр. Спектакльләр куя, театр өчен пьесалар яза,

иҗади составның укуын оештыра. Казан курчак театрының проф. үсеше, иҗади йөзе барлыкка килүе, репертуары формалашу, ш.и. курчак спектакльләренең сәнгатьчә чаралары төптән яңару, аларның милли төс алуы, эстетикасы үзгәрү Х. эшчәнлеге б-н бәйле. Аеруча зур спектакльләре — «Шүрәле» (Ш.Зәйни), «Канатлы ат» («Конёк-Горбунок», П.П.Ершов), «Ху җа Насретдин», «Әбүгалисина» (Н.Исәнбәт), үзе иҗат иткән «Камыр-батыр», «Гөлчәчәк» (барысы да рәссам П.П.Троицкий б-н берлектә), «Галәветдиннең тылсымлы лампасы» («Волшебная лампа Аладдина», Н.Гернет), «Золушка» (Т.Г.Габбе), «Башмаклар» («Черевички», Н.В.Гоголь нең «Раштуага каршы төн» — «Ночь перед Рождеством» повесте буенча; барысы да рәссам Э.Б.Гельмс б-н берлектә). Курчак театры өчен «Дутан-батыр», «Алпамша», «Хәйләкәр Таҗи», «Алтын чәкән», «Курай-Шамбай» пьесалары авторы. Аларның кайберләре режиссёр шәрехләмәләре б-н махсус җыентыкларда басыла.

Х е з м.: Курчак театры. К., 1951; Балалар өчен пьесалар: Курчак театры. К., 1955; Курчак театры: пьесалар, режиссёр киңәшләре. К., 1964.

Әд.: И г л а м о в Р. От Петрушки к «Аладдину» // Казань. 2002. № 3/4; ш у л у к. Искусство играющих кукол. К., 2004.

Ю.А.Благов.

ХӨСНИ́ (Хөснетдинов) Фатих Хөснетдин улы (3.2.1908, Казан губ., Лаеш өязе Олы Мәтәскә а. — 19.5.1996, Казан), язучы, ТРның халык язучысы (1993). Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлый (1933). Яшь автор ның беренче шигырьләре, поэмалары, очерклары «Безнең юл», «Авыл яшьләре», «Яңалиф», «Атака» ж-лларында дөнья күрә. 1935 елдан «Кызыл Татарстан» г-тасы, «Совет әдәбияты», «Чаян» ж-ллары редакцияләрендә эшли, 1955–57 дә ТАССР Язучылар берлеге идарәсендә җаваплы сәркәтип. Хикәяләре («Хикәяләр», 1934; «Минем күгәрченнәрем», 1938; «Минем беренче елмаюым», 1941 җыентыклары), повестьлары («Гармунчы», «Зәңгәр җыр»; икесе дә — 1940), комедияләре («Урманда», 1938 дә куела) татар авылының хәзерге һәм үткәндәге тормышына багышлана. «Йөзек кашы» повесте (1942) әдипкә киң танылу китерә. Әсәрдә мәхәббәт, тугрылык, намуслылык, кешенең үз язмышы өчен җаваплылыгы мәсьәләләре күтәрелә. Х.нең әлеге повестьта чагылыш тапкан үзенчәлекле стиле алга таба иҗатында камилләшә бара. 2011 дә повесть буенча язылган инсценировка Татар акад. театрында куела. Сугыштан соңгы елларда әдип «Авыл өстендә йолдызлар» (1955; русчага тәр җемәдә «Любовь под звёздами» 1956), «Гыйльмениса һәм аның күршеләре» (1971) повестьларын, «Җәяүле кеше сукмагы» (1957; русчага тәр җемәдә «Тропа пешехода», 1960), «Утызынчы ел» (1963; русчага тәр җемәдә «Год тридцатый», 1965) романнарын һ.б. яза. Аларда рев-ция һәм күмәкләштерү, социаль үзгәрешләр шартларында кеше язмышлары темасы чагылыш таба. Х. драматургия жанрында уңышлы иҗат итә. «Еллар һәм юллар» (1956) пьесасында үз кыйбларын югалткан, көндәлек көнкүреш ыгы-зыгысына кереп баткан геройларның рухи ярлылыгын күрсәтә. «Бертуган Тәһировлар» пьесасында (1965) туганнар арасындагы мөнәсәбәтләр, кешенең үз намусы каршында җаваплылыгы кебек әхлакый-этик мәсьәләләр куела. Нечкә психологизм — Х. иҗатының үзенчәлеге. Ул тудырган образлар индивидуаль һәм тормышчан сыйфатлы. Х. геройның эчке дөньясын ача, аның язмышын халык тормышы контекстында күрсәтә. Персонажларның психол. портреты аларның кабатланмас үзенчәлекле теле хисабына байый. Иҗтимагый-мәдәни, әдәби мәсьәләләргә багышланган мәкаләләр («Уйланулар», 1961); «Ни әйтергә? Ничек әйтергә?», 1974); «Карурманга керәм», 1985) җыентыклары авторы. ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләгенә лауреаты (1972). Октябрь Революциясе, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары һәм медальләр б-н бүләкләнә. 1998 дә туган авылында Х.нең музее ачыла.



Ф.Хөсни.

Ә с ә р.: Сайланма әсәрләр: 3 томда. К., 1966–68; Сайланма әсәрләр. К., 2002.

Әд.: С в е р и г и н Р. Фатих Хөсни: тормыш юлы һәм иҗаты. К., 1968; ш у л у к. Фатих Хөсни феномены // Казан утлары. 2008. № 2; Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2; Н и г м а т у л л и н Э. Творческая позиция писателя в свете литературных контактов (на примере творчества Фатыха Хусни) // Романтизм и реализм в литературных взаимодействиях. К., 1982.

Ф.Г.Галимуллин.

ХӨСНИЯ́Р (Хөснетдинов) Зиннур Зыятдин улы (18.7.1961, Биектау р-ны Бикнарат а.), язучы, драматург, шагыйрь, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (2001). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1983), «Ялкын» ж-лы редакциясендә эшли. 1987 елдан ТАССР Телевидение һәм радиотапшырулар ком-тында әдәби-драматик тапшырулар мөхәррире. 1990 нан «*Салават күпере*», «Тәһир-Зөһрә» (1997 дән), «Яучы» (1999 дан), «Җүләр чак» (1999 дан), «Әбугалисина» (1999 дан), «Сәхнә» (2001 дән) газета-журналларын җитәкли, бер үк вакытта, 2001 дән «Ак Барс» нәшрият йорты» ҖЧҖ директоры. Х.ның беренче хикәяләр җыентыгы — «Таң ата да кич була» (1989) яшьләр тормышына багышлана. «Тәгәри китте язмышлар» җыентыгына (1991) Сталин репрессияләре, армиядәге «дедовщина» корбаннары, хәзергә татар авылы мәсьәләләре турындагы хикәяләр керә. «Терсәк сугышы» (2001), «Эттән туган» (2003) романнарында әхлак-әдәп мәсьәләләре күтәрелә. Х. иҗатында авыл темасы «Хуш, авылым!» (2011) романында дәвам итә. «Ут чәчәге» (Казан татар яшь тамаша-чылар театры, 2018), «Баһадур» (Минзәлә татар драма театры, 2018), «Ай җаный, вай җаный» (Буа драма театры, 2018) пьесалары; балалар өчен «Шүрәле шаяруы» (1996), «Аллага шөкер: Балалар өчен дин сабаклары» (2003), «Мин инглизчә сөйләшәм» (2010) һ.б. җыентыклар авторы. М.Җәлил исем. Респ-ка бүләге (2009), ТР Язучылар берлегенең Ф.Хөсни исем. (2001), Г.Исхакый исем. (2008) бүләкләре лауреаты.

Ә с ә р.: Два билета на трагедию. К., 2007; Кичү. К., 2012.

Әд.: Х ә с ә н о в М. Читтә калмаска! // Казан утлары. 1987. № 5; Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

ХӨСНУ́ЛЛИН Марат Шакиржан улы (9.8.1966, Казан), хакимият-хуҗалык эшлеклесе, икътисад фән. канд. (2006), ТРның, РФнең атказ. төзүчесе (2005, 2013). Казан финанс-икътисад ин-тын тәмамлый (1990). 1987–95 елларда «Темп» кооперативы (Казан) баш бухгалтеры, рәисе. 1995–97 дә «Ин терпластсервис» ҖЧҖ, 1997–2000 дә «Ак Барс» сәүдә-сәнәгать фирмасы ген. директоры. 2000–01 дә «Татэнерго» энергия җитештерү берләшмәсе ген. директоры урынбасары. 2001–02 дә ТР төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы, 2002–10 да ТР төзелеш, архит-ра һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министры. Респ-када тузган тораклы бетерү программасын гамәлгә ашыруга өлеш кертә, шуңа нигезләнеп, торак йортлар, мәктәпләр, мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләре, хастаханәләр, поликлиникалар, мәдәният йортлары күпләп төзелә. 2010 нан Мәскәү шәһәре мэрының шәһәр төзелеше сәясәте һәм төзелеш мәсьәләләре буенча урынбасары. Хезмәтләре төзелеш комплексы үсеше, Татарстанда инвестиция эшчәнлеге идарәсе стратегиясе мәсь әләләренә карый. 1999–2001 дә ТР халык депутаты. «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Е.Б.Долгов.

ХӨСНУ́ЛЛИН Хәниф Хәким улы (8.2.1935, Түбән Кама р-ны Шәңгәлче а. — 6.10.1994, Чаллы ш., туган авылында җирләнә), шагыйрь. Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1963), Тукай р-ны Биклән авылы урта мәктәбендә эшли. 1965 елдан җирле радиотапшырулар мөхәррире, «Минзәлә-Мензеля» г-тасы (Минзәлә ш.) хезмәткәре. 1976 дан «Якты юл» г-тасында (Чаллы) бүлек мөдире. «Исәнмесез» (1967), «Алтын тояк» (1981), «Дөньяның матур җире» (1985), «Чикерткә ник сикерә?» (1990), «Ялгыз капка» (2010) шигырь җыентыклары авторы. Төп темасы — КАМАЗ төзелеше.

ХӨТБӘ́ (гарәп. خطبه), нотык, вәгазь, имам-хатипның чыгышы; җомга (к. *Җомга*), ш.у. *Корбан бәйрәме* һәм *Ураза бәйрәме* намазларының, ш.у. аерым сәбәпләр б-н укыла торган (корылык, ай тотылу һ.б.) намазларның бер өлеше. Х., Коръәндә әйтелмәсә дә, Мөхәммәт пәйгамбәр вакытында барлыкка килгән. Х.дә җыелган җәмәгать сәламләнә, Аллаһка мактау әйтелә, Мөхәммәдне ярлыкау сорала, Коръән укыла, дингә ышанучыларга атап һәм аларны тугры юлдан яздырмаска өндәп дога кылына. Х.нең тексты догалар, Коръән уку һәм вәгазь белән аралаштырыла. Җомгада Х. намаздан алда, калган көннәрдә намаздан соң укыла.

Әд.: Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

ХРАМЧЕНКО́В Максим Георгиевич (23.2.1959, Казан), механика өлкәсе белгече,

физика-матем. фән. д-ры (2004), проф. (2011). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1982), Нефть химиясе фәнни-тикшеренү ин-тында (1984 елга кадәр), 1986–87 дә Казан елга техникумында, 1987–90 да Руда булмаган файдалы казылмалар геологиясе үзәк фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1990 нан Казан ун-тында: Матем. һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында (1990–2011), гомуми геол. һәм гидрогеол. каф. мөдире (2004 тән), бер үк вакытта Фәнни-тикшеренү үзәге директоры (2012 дән). Хезмәтләре табигый күзәнәкле мохитларның физик-химик механикасына карый. Х. эремәләрне күзәнәкле мохитларда фильтрацияләгәндә булган химик реакцияләр макрокинетикасының матем. моделен, балчыклы токымнарның фильтрацияләү үзлекләре теориясен, балчыклы токымнар һәм туфрак бүртү теориясен эшли. Нефть катламнарында табигый нанокисәкчәләр барлыкка килү һәм миграциясе механизмын нигезли (автордаш). Төрле тыгызлыктагы сыекчаларның күпфазалы фильтрация моделен тәкъдим итә (автордаш).

Х е з м.: Элементы физико-химической механики природных пористых сред. К., 2003; Точные решения некоторых задач подземного массопереноса. К., 2005; Физико-структурные характеристики почвогрунтов и их влияние на влаго- и теплообмен с атмосферой. К., 2007 (автордаш).

ХРАПКО́ВСКИЙ Григорий Менделевич (14.9.1946, Чкалов өлкәсенең Чкалов р-ны Донгузская станциясе), физик химия белгече, химия фән. д-ры (1991), проф. (2001). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1969), Казан химия-фото сәнәгате фәнни-тикшеренү һәм проектлау ин-тында эшли, 1972 елдан — Химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында (лаб-я башлыгы, бүлек башлыгы урынбасары). 1995 тән Казан технол. ун-тында, Яңа мәгълүмати технологияләр үзәге директоры урынбасары, компьютерлы химия бүлеге башлыгы урынбасары (2008–10). Хезмәтләре химик реакцияләрнең кинетикасына һәм механизмнарына, нитр кушылмалары молекулаларының төзелешенә карый. Х. молекулалар төзелешенең төрле класстагы нитр кушылмалары термик таркалышы рекцияләренең кинетик параметрларына йогынтысын өйрәнә. 10 яңа мономолекуляр таркалыш механизмын тәкъдим итә. Целлюлоза нитратын җитештерү процессындагы үзлекләрне көйләү алымнарын эшли, аның термик таркалышы механизмын тикшерә. Уйлап табуга 10 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. СССР Министрлар Советы бүләге бирелә (1987). «Молекуляр-структур төрлелек һәм С белән О нитрат кушылмаларын җитештерүнең һәм мономолекуляр таркалышының реакцияләре механизмы» хезмәте өчен ТР Дәүләт бүләгенә лаек була (2006).

Х е з м.: Влияние строения молекул на кинетические параметры мономолекулярного распада С-и О-нитросоединений. К., 1997 (автордаш); Структурно-кинетические особенности получения и термодеструкции нитратов целлюлозы. М., 2005 (автордаш); Молекулярная структура нитрата целлюлозы: от получения до термодеструкции. К., 2009 (автордаш).

Әд.: Казанский университет (1804–2004): Био-библиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

ХРИЗАНТЕ́МА, к. *Алтын чәчәк*.

ХРИСА́НФ (Ретивцев Владимир Николаевич) (1832, Тверь губ., Бежецк өязе Эська а. — 6.11.1883, Мәскәү), дин эшлеклесе, дин белеме д-ры (1878). Мәскәү руханилар академиясен тәмамалаганнан соң (1856), Кострома руханилар семинариясендә укытучы булып эшли. 1857 елдан монахлыкта. 1858 дән Казан руханилар академиясендә, экстраординар проф. (1865). 1865 тән Петербург руханилар академиясендә инспектор, бер үк вакытта «Христианское чтение» ж-лының редакция ком-ты әгъзасы. 1866 дан архимандрит. 1869 дан Петербург руханилар академиясе ректоры, бер үк вакытта, 1872–74 тә, Изге Синод каршындагы Уку-укыту ком-ты рәисе. 1874 тән Әстерхан һәм Енотаевск, Түбән Новгород һәм Арзамас епископы. 1879 да ялга җибәрелә һәм җитәкчелек хокукы б-н Мәскәүдәге Донской монастырена озатыла. 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Изге Анна, 3 нче дәрәҗә Изге Владимир орденнары белән бүләкләнә. Хезмәтләре дини тәгълимәт һәм чиркәү тарихына карый.

Х е з м.: Взгляд на мнение новейших рационалистов о существе религии (из лекции по основному богословию) // Православный собеседник. 1860. Ч. 2; Задача нравственного богословия, как науки // Христианское чтение. 1868. Ч. 1.

ХРИСТИАНЛАШТЫРУ́ СӘЯСӘТЕ́, Урта Идел һәм Урал янында яшәүче төп халыкларны дини унификацияләү сәясәте, 16 йөздә — 20 йөз башында Рус хөкүмәте һәм православие чиркәве тарафыннан этномәдәни ассимиляцияләү максатында гамәлгә ашырыла. Идел буе төбәгендә яшәгән татарлар, чуашлар, удмуртлар, мордвалар һ.б. төп халыклар арасында беренче булып православиене бөек Мәскәү кенәзләренә хезмәткә күчкән кенәзләр (бәкләр), морзалар, һәм ш.у. шул рәвешчә үз вотчиналарын һәм социаль өстенлекләрен саклап калырга омтылган *йомышлы татарлар* кабул итә. Рус дәүләтенең өстенлек итүче сыйныфы составына кереп, аларның бер өлеше бик тиз руслаша, әмма нәсел-ыру фамилиясен саклап кала (Карамзиннар, Урусовлар, Юсуповлар һ.б.). 1545–52 елларда *Казанга Рус дәүләте яулары* чорында, православие чиркәве бөек кенәз администрациясе катнашында Казан ханлыгындагы титуллы булмаган халыкларны (чуашларны, мариларны һ.б.ны) үз кул астына алу һәм чукындыру буенча чаралар уздыра башлагач, Идел буе төбәге халыкларын Х.с. максатчан төс ала. Рус дәүләте Казан (1552), Әстерхан (1556) ханлыкларын һәм Идел буе һәм Урал янындагы башка җирләрне яулап алу б-н, җирле халыклар — мәҗүсилек тарафдарлары арасында православие чиркәвенең миссионерлык эшчәнлеге киңрәк колач ала (к. *Православие миссионерлары*). 16 йөзнең 2 нче яртысында Х.с. процессын активлаштыру һәм Рус православие чиркәвенең дини-икътисади позицияләрен көчәйтү максатында патша администрациясе җирле халыкларның яулап алынган җирләрендә монастырьлар һәм чиркәүләр төзергә рөхсәт итә, культ корылмаларына бик зур җир, урман, балык һәм башка биләмәле терр-яләр бүлеп бирә, *Казан епархиясен* (1555) оештыра, төбәкне *колонияләштерүне* тизләтү өчен, рус халкына билгеле бер мөмкинлекләр билгели. Христианлаштыру процессын оештыру буенча башлангыч күрсәтмә булып, *«Иван IV нең Казан архиепископы Гурийга җибәргән күрсәтмәсе»* («Наказная память») исәпләнә, ул төп халыкларны чукындыру өчен нигез булып торган кагыйдәләрне үз эченә ала. Казан Кремленең Спас-Преображение монастыре һәм Зөя Успение монастыре миссионерлык эшчәнлеге үзәкләре була; аларның башлыклары *Варсонофий* һәм *Герман* рус булмаган халыкларга йогынты ясауның адм. һәм социаль-икътисади чараларын (ш.и. православие кабул итүчеләргә төрле ташламалар ясауны) кулланалар. 16 йөз ахырына чуашлар, марилар, удмуртларның күпчелек өлеше, татарларның зур булмаган өлеше (иске керәшеннәр) чукындырылуга дучар ителә. Җирле халык, яңа диндә социаль-икътисади һәм этномәдәни мәҗбүр итүнең үзенчәлекле формасын күреп, ирексезләп чукындыруга каршы теләсә нинди исуллар б-н, кузгалышларга кадәр барып җитеп (к. *Казан ханлыгы яуланганнан соңгы фетнә-чуалышлар*), масса-күләм миграция аша каршылык күрсәтә. Нәтиҗәдә, мәҗүси халыкларны чукындыру формаль төстә була, алар тарафыннан христианлыкка кадәрге йолалар саклану дәвам итә. Идел һәм Урал буе мөселманнарының күпчелеге чукынудан баш тарта; хакимиятләрнең тыюына карамастан, мәчетләр һәм мәдрәсәләрне торгызалар, яңаларын (ш.и. Казанда) төзиләр. 1593 тә патша Фёдор Ивановичның «Яңа чукындырылган татарлар, аларга аерым сөрү җирләре бүлеп бирү һәм мәчетләрне юкка чыгару турында» Грамотасы басылып чыга, әмма *«Болгавыр заман»* чорында актив Х.с. туктатыла. *Кануннар мәҗмугасы (1649)* һәм 17 йөзнең 2 нче яртысы патша грамоталарын — биләмәләрне бары тик рус кешеләренә һәм чукындырылган башка милләт кешеләренә сату хокукы бирү турында (1653), чукындырылмаган җирбиләүчеләрнең иясез калган биләмәләренең аларның чукындырылган туганнарына күчүе турында (1654), православиегә күчкән өчен татарларны һәм башка халык вәкилләрен аларның чукындырылмаган туганнарыннан тартып алынган җирләр б-н бүләкләү, җир биләүче мөселманнарның биләмә хокукын бетерү турында (1683), яңа керәшеннәрне холоплыктан азат итү турында (1684) — кабул итү Х.с. уздыруда кискен борылыш чоры була; әлеге тенденцияләр рус крәстияннәрен йомышлы мөселман морзалары милкеннән чыгару турында Пётр I указларында (1713, 1715), чукынган татарларны җан башына салымнан һәм рекрутлыкка алудан һ.б.дан азат итү хакында Сенат указында (1720) алга таба көчәйтелә һ.б. Бу актлар ирексезләп чукындыруга дәүләт сәясәте төсмере бирәләр һәм законнарның нигезен Рус православие чиркәвенең миссионерлык эшчәнлегенә яраклаштыралар.

1731 дә, Х.с. процессы тагын да максатчанрак колач алсын өчен, Зөя шәһәрендә Яңа чукындырылганнар комиссиясе (1734 тән — *Яңа чукындырылганнар конторасы*) төзелә.

1738–55 тә, Казан һәм Зөя архиепископы *Лука* (Конашевич) эшчәнлеге чорында, Х.с.нең иректәлеү формасы аеруча киң колач ала. 1744 кә Казан губернасының Казан өязендә 536 мәчетнең 418е җимертелә, бик күп мөселман зиратлары, марилар, удмуртлар, чуашлар һ.б.ның табыну урыннары (изге агачлыклар, мәҗүсиләр гыйбадәтханәләре (капище-лар) һ.б.) мәсхәрәләнә. Нәтиҗәдә, 18 йөз уртасына чуашлар, марилар, мордвалар һәм удмуртларның зур күпчелеге христианлыкка күчә. Бер үк вакытта чиркәүләрдә, Казан славян-латин мәктәбендә (1723 тә ачыла) һ.б. учреждениеләрдә яңа чукындырылганнар арасында эшләү өчен актив рәвештә миссионер кадрлар әзерләү алып барыла. Иректәсеп-ләп Х.с. 18 йөздә татарларның хөкүмәткә каршы чыгышларына бер сәбәп булып тора (к.: *Башкорт-татар кузгалышлары*, *Батырша хәрәкәте*, *Крәстияннәр кузгалышы (1773–75)*). Бу кузгалышлар Россия хөкүмәтенең дини сәясәтендә билгеле бер үзгәрешләргә китерә: мөселманнар мәчетләр төзү хокукы ала (1756 елгы Указ), барлык диннәр тарафдарларының дин иреген тану игълан ителә (1773 елгы Синод указы), Уфа Дини Мөхәммәди канунары Җыены оештырыла (1788 елгы Указ, к. *Россия һәм БДБның Европа илләре мөселманнары Үзәк Диния нәзарәте*) һ.б.

19 йөз башыннан Х.с.нең төп бурычы яңа чукындырылганнарны православие кысаларында тоту була, чөнки татарлар, марилар, чуашлар һ.б.ның христианлыктан массакүләм чыгулары күзәтелә. Х.с.нең иректәсеп-ләү алымнары теләгән нәтиҗәне бирмәгәнлектән, миссионерлар акрынлап христиан динен һәм аның йолаларын рус булмаган халыкларның дини ышануларына һәм йолаларына, аларның җитештерү һәм көнкүреш шартларына җайлаштыра башлыйлар. Яңа чукындырылганнар арасында миссионерлык эшен тирәнәйтү максатында җирле халык вәкилләренән православие уку йортларында дин әһелләре әзерләү башланып китә (*Казан үзәк керәшен-татар мәктәбе*, *Изге Гурий борадәрлеге* мәктәпләре һ.б.). Аларда башлангыч белем бирү туган телдә алып барыла; татар телендә һәм рус булмаган башка халыклар телләрендә зур тиражлар б-н православие дини әдәбияты басыла (аеруча 1812 дә Казанда Библия җәмгыяте оештырылганнан соң). 19 йөзнең 2 нче яртысында Х.с. этномәдәни *руслаштыру сәясәте* сыйфатларын ала башлый (к. *Ильминский системасы*). Әмма рәсми хакимият органнары тарафыннан 19 йөздә — 20 йөз башында кулланылган чараларга да карамастан, чукындырылган татарларның православиедән массачыл китүен туктату мөмкин булмый; алай гына да түгел, исламның Идел һәм Урал буенда яшәүче башка халыкларга йогынтысы арта (к.: *Чукындырылган татарларның мөселманлыкка кайту хәрәкәте*). Әлеге процесс 1905 ел 17 октябрь патша Манифесты дөньяга чыккач аеруча көчәя, анда башка демократик иректәр б-н бергә, дин тоту иреге игълан ителә. 1910 ның гыйнварында православие чиркәвенең миссионерлык позицияләрен ныгыту һәм Х.с. процессын көчәйтү максаты б-н Россия хөкүмәте тарафыннан «*Идел буе төбәгендә мөселман татарлар йогынтысына каршы чаралар билгеләүче махсус киңәшмә*» чакырыла. Ләкин Беренче бөтендөнья сугышы һәм 1917 елгы революцион процесслар аның карарларын гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирми. 1917 нең октябрендә хакимияткә большевиклар килү б-н дингә ышану гражданнарның шәхси эше дип белдерелә, чиркәү — дәүләттән, мәктәп чиркәүдән аерыла. Христиан миссионерлары, шактый тырышуга да карамастан, *мәҗүсилекне* ахыргача җиңүгә ирешә алмыйлар, аның калдыклары марилар, чуашлар, удмуртлар, мордвалар арасында 20 йөзнең башына кадәр сакланып кала. Х.с. кайбер мәҗүси халыклар тарихында уңай роль дә уйный, ул аларның рус мәдәнияте б-н танышуларына булышлык итә. Татарларга килгәндә, иректәсеп-ләп Х.с. аларның социаль-икътисади, сәяси һәм этномәдәни үсешендә сизелерлек тоткарлыкларга китерә.

Әд.: Малов Е.А. О Новокрещенской конторе. К., 1878; Можаровский А.Ф. Изложение хода миссионерского дела по просвещению Казанских инородцев с 1552 по 1867 годы. М., 1880; Харлампович К.В. Казанские новокрещенские школы (к истории христианизации инородцев Казанской епархии в XVIII в.). К., 1905; Григорьев А.Н. Христианизация нерусских народностей как один из методов национально-колониальной политики царизма в Татарии (с половины XVI в. до февраля 1917 г.) // Материалы по изучению Татарии. К., 1948. Вып. 1; Ислаев Ф.Г. Ислам и православие в Поволжье XVIII столетия: От конфронтации к терпимости. К., 2001; Ногманов А.И. Татары Среднего Поволжья и Приуралья в российском законодательстве второй половины XVI -XVIII вв. К., 2002; Исхаков Р.Р. Миссионерство и мусульмане Волго-Камья (последняя треть XVIII — начало XX в.). К., 2011.

ХРИСТИАНЛЫ́К, дөньякүләм өч диннең (ислам һәм буддачылык б-н бергә) берсе. Христиан җәмгыятен берләштерә торган гомуми күренеш булып Иисус Христоска ышану тора. Христиан дине өйрәтмәләренең чыганаклары — Изге язма (Библия) һәм Изге риваять. Х. 1 йөздә яһүдиләр яшәгән тирәлектә барлыкка килә, тиз арада Урта диңгез буенда яшәүче халыклар арасында таралыш ала. Аерым догмаларны төрлечә аңлату нәтиҗәсендә 11 йөздә Х. православиегә һәм католиклыкка аерыла. 16 йөздә католиклыкта протестантлык, 17 йөздә православиедә иске дин тарафдарлары барлыкка килә. 17 йөздән протестантлыкта яңа юнәлешләр — баптистлык, адвентистлык, пятидесятниклык һ.б. пәйда була. Татарстанда Х.ның православие юнәлеше өстенлек итә, ш.у. католиклык, лютеранлык һ.б. протестантлык агымнары вәкилләре дә яши.

Әд.: Карташев А.В. Очерки по истории Русской Церкви: В 2 т. М., 1991; Христианство: В 3 т. М., 1993–95.

ХРИСТОФО́РОВА Наталья Николаевна (26.1.1954, Чистай ш. — 3.4.2009, Казан), физик, геолог, геол.-минерал. фән. д-ры (2002). Казан ун-тын тәмамлый (1978), шунда ук эшли. Хезмәтләре Җир физикасына, гидрогеологиягә, нефтьлелекне ачыклауга карый. Рус платформасының көнчыгышында литосфера җылылык режимының төп закончалыкларын билгели. Халыкара «Георесурсы» ж-лын нигезләүче (1999) һәм баш мөхәррире.

Х е з м.: О влиянии спиральной структуры Галактики на эволюцию планеты // Георесурсы. 2000. № 1; К вопросу о протяжённости разуплотнённых зон в кристаллическом фундаменте // Георесурсы. 2004. № 1 (автордаш).

«ХРУСТА́ЛЬНОЕ ПЕРО́ – БӘЛЛҮ́Р КАЛӘ́М», к. *Татарстан Республикасының Журналистлар берлеге бүләкләре*.

ХРУЩЁВА Ирина Константиновна (28.6.1952, Казан), химик-технолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2008), техник фән. канд. (1986). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1975), шунда ук эшли. 1975 елдан Идел углеводород чималы фәнни-тикшеренү ин-тында. Хезмәтләре углеводород чималын күкертле кушылмалардан чистартуга карый. Х. күкертле кушылмаларның реакцияләре кинетикасын тикшерүдә, нефтьне, җи ңел углеводород чималын һәм күкерт-селте агынтысын күкертле кушылмалардан чистарту процессларынның технологиясен эшләү һәм гамәлгә кертүдә катнаша. Уйлап табуга 20 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. ТР Дәүләт бүләге җиңел углеводород чималын күкертле кушылмалардан бер стадияле чистарту процессын эшләүдә һәм гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

ХРУЩЛА́Р, пластинкамыеклылар семьялыгыннан үсемлекләр б-н туенучы, төгәл систематик статусы булмаган коңгызлар төркеме. 5 меңгә якын төрне үз эченә алучы күп кенә ассемьялыкларны берләштерә: хрущлар (Melolonthinae), шелковка (Sericinae), хрущики (Rutilinae), тамыр кимергечләр (Rizotroginae) һ.б. БДБ илләрендә якынча 240 төре билгеле. Татарстан терр-ясендә көнчыгыш май коңгызы (Melolonsa hippocastani) һәм бакча хрущигы (Phyllopertha horticola) киң таралган. Ара-тирә болын хрущигы (Anomalia dubia), җирән шелковка (Serica brunneas) — Раифа урманында (Яшел Үзән р-ны), мәрмәр хрущ яки июль хрущы (Pobyphylla fullj) «Түбән Кама» милли паркында (Алабуга һәм Тукай р-ннары) очрый. Гәүдәсенең озынлыгы 4–60 *мм*, көрән, кара яки сары төстә, кайвакыт металлсыман ялтыравыклы, төкчәләр яки тәнкәчекләр б-н капланган. Очу чорында (майдан августка кадәр) ана затлар җиргә күмелөләр, күкәй (20–80) салалар, аннары үләләр. Личинкалары үсемлек тамырлары, чери торган агач, черемә б-н туена. Коңгызлар агач һәм куак яфракларын, үләнчел үсемлекләрне ашый; а. х. культураларына аеруча *май коңгызлары* зыян китерә. Мәрмәр хрущы ТРның Кызыл китабына кертелгән.

ХРЩОНО́ВИЧ Лев Казимирович (1838–1907, Казан), гражданлык төзелеш инженеры, архитектор. Поляк дворяннарыннан. Минск архитекторы К.М.Хрщоновичның улы. 1853–59 елларда С.-Петербургтагы Төзүчеләр уч-щесендә укый. 1859 да Казанга Губерна төзү һәм юл комиссиясе архитекторы ярдәмчесе итеп җибәрелә. 1874 тән Казан губернасы архитекторы, 1881 дән (башка мәгълүматлар буенча 1883 тән) Казан гу-





Л.К.Хрщоновичның. 1. Алафузовлар театры бинасы. Хәзерге күренеше; 2. Казан сукырлар училищесе бинасы. 19 йөз ахыры – 20 йөз башы фоторәсеме.

бернасы инженеры. Архит-рада төрле эклектик юнәлешләр вәкиле. Х. проектлары буенча Казанда Санкт-Катерина Кирхасы (1865), Александра исем. кыз балалар ятимханәсе (1890; хәзер Галимнәр йорты бинасы), Казан сукырлар уч-щесе һәм аның Изге Пантелеймон йорт чиркәве (1899; совет чорында бинада 2 нче йогышлы авырулар хастаханәсе урнаша, 2009 да сүтелә), Алафузов театры (1900), Болак аша таш көянтә күпер (1907), Католиклар костёлы (1908; Х.ның улы инженер Л.Л.Хрщонович төзеп бетерә), «Щетинкин номерлары» бинасы реконструкцияләнә һәм почмак гөмбәзле дүртенче кат өстәп төзелә (1902; совет чорында — «Казан» кунакханәсе, 2010 да сүтелә).

Әд.: Муртазина Л.М. Казанские архитекторы конца XVIII — начала XX века: Биогр. справ. К., 1999.

ХУБУЛА́ВА Зураб Ильясович (31.3.1935, Грузия ССР, Аджария АССРның Кобулети р-ны Чаква а. — 14.11.2015, Казан), инженер-технолог, «Заря» кондитер ф-касы ген. директоры (1966–2002, 2004–05), РСФСРның атказ. азык-төлек индустриясе хезмәткәре (1987), ТРның атказ. азык-төлек сәнәгате хезмәткәре (1995). Воронеж технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1963), Воронежның 6 нчы икмәк з-дында эшли, директор. 2007 елда «Заря» АҖ директорлар советы рәисе. Х. җитәкчелегендә «Заря» АҖ пр-тиеләрендә, ш.и. карамель һәм конфет производстволарында реконструкция уздырыла; камыр ризыклары җитештерү цехы, җитештерү-көнкүреш корпусы һ.б. файдаланууга тапшырыла; төп технол. процесслар механикалаштырыла һәм автоматлаштырыла, нәтиҗәдә, эшләп чыгарылучы продукциянең ассортименты киңәя, күләме арта, сыйфаты яхшыра; 2 торак йорт һәм балалар бакчасы төзелә. Уйлап табуга 12 авторлык таныклыгы бар. «Почёт билгесе», Дуслык орденнары, РСФСР, ТР ЮСларының Мактау грамоталары б-н бүләкләнә. Публицистик эчтәлекле «Каян һәм кая барабыз? Совет директоры язмалары» («Откуда и куда идем? Записки советского директора», 2006), «Калфак астындагы оҗмах: Хәр фикерле кеше язмалары» («Рай под колпаком: Записки вольнодумца», 2007), «Ышанасым килә» («Хочу верить», 2010) китаплары авторы.

ХУДЯКО́В Василий Григорьевич (24.12.1825, Сембер губ., Корсун өязе Акшуат (Шуваты) а. — 14.7.1871, С.-Петербург), нәкышьче, рәсем төшерүче. Дворян Поливановлар крепостное улы. Х.та рәсем ясау сәләтен күреп алгач, сенатор, хакыйкый яшерен советник И.П.Поливанов аны Мәскәүгә укырга җибәрә. С.Т.Строгановның техник рәсем мәктәбендә (1842–43), Мәскәү сәнгать һәм скульптура уч-щесендә (1843–47) Ф.С.Завьяловта (1845–47) укый. 1847 елда САнә тәкъдим иткән эшләре, ш.и. «Печән чабучы» (1847, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда саклана) картинасы өчен Зур көмеш медаль б-н бүләкләнә һәм рәссам дәрәҗәсе ала. Бу исә Х.ка крепостнойлыктан чыгарга мөмкинлек бирә. САндә сәнгать тарихы классында А.Т.Марковта ирекле тыңлаучы буларак укуын дәвам итә (1848–50). СА ректоры А.И.Мельников портреты өчен 1851 дә академик дәрәҗәсенә, 1860 та «Шар белән уйнау» картинасы өчен проф. дәрәҗәсенә лаек була. 1862 дән С.-Петербургта яши, нигездә, Пётр I гә кадәрге Руська багышланган тарихи жанрдагы картиналар иҗат итә. Х.ның «Әсир ителгән Сөембикә ханбикәнең Казаннан китүе» картинасы Идел буйлап сәяхәттән соң языла (1869). Казан ханбикәсе Сөембикәнең язмышы аның игътибарын җәлеп итә, картинаны иҗат итү өчен Казанга килә һәм вакытлыча остаханә ала. Картинадагы күпкатлы композициядә аерым төркемле күренешләрне, сюжетлы планнарны Казан Кремле силуэты б-н панорамалы пейзажны оста тоташтыра. Картинага әзерлек материаллары-ннан шул ук исемдәге эскиз (1869, ТР Милли музее) һәм «Казан татар хатын-кызы» портреты этюды (1869, Рус музее) саклана. Х. иҗат мирасының шактый өлешен таныл-ган Казан коллекционеры А.Ф.*Лихачёв* сатып ала. Рәссам б-н ул дустанә мөнәсәбәттә була, «Әсир ителгән Сөембикә ханбикәнең...» картинасын иҗат иткәндә аның остаханәсенә барып рәсем дәресләре ала. Нәтиҗәдә, Х.ның картиналар һәм графика коллекциясе Лихачёвның рус сәнгате тупланмасында зур урын били — 18 картина һәм 57 рәсем (хәзер ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее тупланмасында).

СА (1849–70, бүленеп), Мәскәү сәнгать һәм скульптура уч-щесе (1860, 1862) күргәзмәләрендә катнаша. Шәхси күргәзмәләре 1976 да Ульяновта, 2001 дә Ульянов һәм Казанда уздырыла. Картиналары Дәүләт Третьяков галереясында, Рус музеенда (С.-Петербург), Россия СА фәнни-тикшеренү музеенда, Киев рус сәнгате музеенда, Ульянов өлкә сәнгать музеенда, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда, ш.у. Мәскәү, С.-Петербург, Баку, Саратов, Киров һ.б. шәһәрләрнең музейларында һәм шәхси тупланмаларда саклана.

Әд.: Корнилов П.Е. Василий Григорьевич Худяков (1826–1871): К 100-летию со дня рождения художника. К., 1926; Корнилов П.Е. Василий Григорьевич Худяков // Рус. искусство: Очерки о жизни и творчестве художников середины XIX века. М., 1958; Василий Григорьевич Худяков: Каталог выставки. Ульяновск, 2001; Бакюра Л.П. Произведения Василия Худякова в Ульяновском художественном музее // Третьяковская галерея. 2005. № 3.

И.Ф.Лобашёва.

ХУДЯКО́В Михаил Григорьевич (3.9.1894, Вятка губ. Малмыж ш. — 19.12.1936, Ленинград), тарихчы, археолог, этнограф, тарих фән. д-ры (1936). Казандагы Икенче ир балалар гимназиясен (1912), Казан ун-тын (1918) тәмамлый. 1919–21 елларда Төньяк-Көнчыгыш археол. һәм этнография ин-ты укытучысы. 1919–25 тә губерна музеенең тарих-археол. бүлеге мөдире. Бер үк вакытта ТАССР Халык мәгарифе халык комис-тында, Шәрекъ академиясенең уку-укыту бүлеге мөдире. Казанда, Малмыжда музейлар оештыруда актив катнаша. Татар халкын гыйльми өйрәнү җәмгыятен оештыручыларның берсе һәм аның сәркәтибе. 1925 тән Ленинградта, Салтыков-Щедрин исем. китапханә, СССР ФАнең Матди мәдәният тарихы академиясе фәнни хезмәткәре (1929 дан). Хезмәтләре





В.Г.Худяков. 1. «Казан татар хатын-кызы». 1869. Дәүләт Рус музее; 2. «Әсир ителгән Сөембикә ханбикәнең Казаннан китүе». 1869. Ульянов өлкә сәнгать музее.



М.Г. Худяков.

Ананьино культурасына, Казан ханлыгы, Урта Идел буендагы мөселман мәдәнияте тарихына карый. Аның «Казан ханлыгы тарихыннан очерклар» («Очерки по истории Казанского ханства», К., 1923) аеруча киң таныла. Әлеге хезмәтендә Х., рус тарихчыларыннан беренчеләрдән буларак, Казан ханлыгының объектив тарихын яза, аның югары дәрәҗәдәге икътисади, хәрби, мәдәни һәм рухи үсешен ачып бирә. Репрессияләнә, үлгәннән соң аклана.

Х е з м.: Развалины Великого города // Казан. музейный вестн. 1921. № 1–2; Мусульманская культура в Среднем Поволжье. К., 1922; Деревянное зодчество Казанских татар // Казан. музейный вестн. 1924. № 1; Татарское искусство // Вестн. знания. 1926. № 26; История Камско-Вятского края. Избранные труды. Ижевск, 2008.

Әд.: Госманов М.Галимнең гыйбрәтле язмышы // Татарстан. 1994. № 9–10; Знаменитые люди о Казанском крае. К., 1990; Байрамова Ф.А.Михаил Худяков и история татарского народа. К., 2003.

Ф.Г.Миңнеханов.

ХУҖА́ ӘХМӘ́Д әл-БОЛГАРИ́ (11 йөз), болгар галиме, мөселман илаһият галиме. Аның «Әл-Җамигъ» («Җыючы»), «Фәваид әл-Җәва һир» («Файдалы асыллар»), «Тарика Быргырия» («Болгар юлы») мөселман хокукына багышлана. Мөселман дөньясының күп кенә илаһият галимнәре Х.Ә.әл-Б.нең фикерләрен үрнәк итеп китерәләр. Урта Азия солтаны Мәхмүд Газнәвинең (970–1030) остазы була.

Әд.: Д а в л е т ш и н Г.М. Очерки по истории духовной культуры предков татарского народа (истоки, становление и развитие). К., 2004.

ХУҖА́ НАСРЕТДИ́Н, Шәрекъ, Урта Азия, Кавказ һәм Көнчыгыш Европа халыклары, ш.и. Казан татарлары фольклоры персонажы; халыкның зирәк фикер иясе һәм тапкыр сүзле кеше, гаделлекне яклаучы, көлү ярдәмендә иҗтимагый явызлыкка каршы көрәшүче. Татар *мәзәкләре* һәм *ләтыйфәләре* герое. Аларның эчтәлеген иҗтимагый-көнкүреш коллизияләр тәшкил итә, ә вакыйгалар ханнар заманыннан алып безнең көннәргәчә чорны били. Бөек Ватан сугышы чоры Х.Н. мәзәкләре циклы билгеле. Аларда немец-фашист илбасарлары көлкегә калдырыла. Х.Н. совет хәрби җитәкчелегенең дә булдыксызлыгын ачы һәм ачулы итеп фаш итә, аларның сугыштагы уңышсызлыкларыннан көлә. Циклның әһәмияте аның сәнгати дәрәҗәсе б-н түгел, ә теманың актуальлеге б-н бәйле. Х.Н. мәзәкләре тупланган беренче җыентык — «Ләтаиф Ху җа Насретдин әфәнде» төрек теленнән тәр җемәдә нәшер ителә (1845). 1939 елда Н.Исәнбәт «Ху җа Насретдин» исемле пьеса-сын яза. Беренче тапкыр ул 1940 та Татар акад. театрында куела һәм бүгенге көнгә кадәр театр репертуарына кертелә.

Әд.: Б ә ш и р о в Г. Туксан тугыз мәзәк. К., 1960; Весёлая россыпь: Татарский народный юмор. М., 1978. *Ф.И.Урманчеев.*

«ХУҖА́ НАСРЕТДИ́Н», Н.Исәнбәтнең 5 күренеш, 6 картинадан торган пьесасы. 1939 елда языла, беренче тапкыр 1940 та Татар акад. театрында куела (режиссёрлар Е.Амантов, К.Тумашева, Х.Уразиков; рәссам П.Т.Сперанский; комп. Җ. Фәйзи). Баш роль-ләрне Х.Әбҗәлилов, К.Шамил башкара. 1941 дә спектакльгә кайбер текст үзгәрешләре кертелә. 1952 дә реж. Х.Уразиков спектаклнең шул ук башкаручылар б-н элекке-ге куелышын яңадан кайтара. 1957 дә Мәскәүдә узган Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасына «Х.Н.» кабат куела (режиссёрлар Х.Уразиков, К.Тумашева); Насретдин ролен Х.Әбҗәлилов һәм Г.Шамуков башкара. 1966 да спектакль рәссам Л.Насыйров тарафыннан бизәлә, Насретдин ролендә — Ф.Халитов. 1990 да популяр комедиянең яңача укылышын реж. М.Сәлимҗанов тәкъдим итә (рәссам А.Кноблок, Насретдин ролендә — Р.Шәрәфиев). «Х.Н.» — урта гасырлардагы популяр төрки халыклар легендаларының төрле хәлләрдән чыгу юлларын белгән, тормыш зирәклеген гәүдәләндергән, кыерсытылган һәм хаксызга рәнҗетелгәннәрне яклаучы, нык рухлы һәм яхшылыкның тантана итүенә ышанучы үткен сүзле һәм зирәк Насретдин турындагы сюжетларына нигезләнеп язылган пьеса. 2015 тә реж. Ф.Бикчәнтәев, Н.Исәнбәтнең «Х.Н.» пьесасын һәм Сирия драматургы Саадулла Ваннусның бер пәрдәле «Фил галиҗәнапләре» пьесасы күренешләрен берләштереп, спектаклнең өр-яңа куелышын тәкъдим итә (рәссам С.Г.Скоморохов, комп. Э.Низамов, Насретдин ролендә — Ф.Җиһаншин, Гөлбану — М.Шәйхетдинова). «Х.Н.» — ТР Мәдәният министрлыгының «Ел вакыйгасы» номинациясендә «Тантана» бүләге лауреаты (2015).

Әд.: И л я л о в а И.И. Театр имени Г.Камала. К., 1986; А р с л а н о в М.Г. Татарское режиссёрское искусство (1906–1941). К., 1992; Татарский государственный академический театр имени Галиасгара Камала. Сто лет = Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры. Йөз ел. К., 2009. Т. 1. *И.И.Илялова.*

ХУ ҖА́ ХӘСӘ́Н авылы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 26 *км* көнбатыш-тарак, Инеш елгасы буенда. 2010 елда 635 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1619 дан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәктәп, 2 тегермән, тимерчелек, 4 ярма яргыч, вак-төяк-ләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1544,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Цивильск өязе Иске Тәберде волостенда, 1920 дән Чуаш автономияле өлкәсендә, 1921 дән ТАССРның — Буа, 1922 дән Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Ульянково, 1927 нең 1 августыннан — Кайбыч, 1944 нең 19 февраленнән — Подберезье, 1956 ның 17 маеннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1747 дә — 121, 1782 дә — 123 ир-ат; 1859 да — 571, 1897 дә — 823, 1908 дә — 1334, 1920 дә —









Н.Исәнбәт әсәре буенча Татар акад. театрында куелган «Хуҗа Насретдин» спектакленнән күренеш. 1. 1940 ел. Гөлбану ролендә — Ф.Камалова, Насретдин — Х.Әбҗәлилов; 2. 1952 ел. Зөбәрҗәт ролендә — Ш.Әсфәндиярова, Алчын — К.Гыйльманов; 3. 1966 ел. Насретдин ролендә — Ф.Халитов, Гөлбану – М.Миңлебаева; 4. 2015 ел. Насретдин ролендә — Ф.Җиһаншин.

1354, 1926 да — 1350, 1938 дә — 1314, 1949 да — 1090, 1958 дә — 1036, 1970 тә — 1002, 1979 да — 939, 1989 да — 742, 2002 дә — 668 кеше.

ХУҖӘЕВ Ташху җә Гомәр улы (1.9.1922, Ташкент — 2.5.1975, шунда ук), режиссёр, педагог, Үзбәкстан ССРның халык артисты (1959). 1941 елда Ташкент балет мәктәбен тәмамлый һәм М.Ә.Мөкими исем. Үзбәк муз. драма театрына балет артисты итеп җибәрелә. 1951 дә Ташкент театр-сәнгать ин-тының режиссёрлык ф-тын тәмамлый. Режиссёрлык эшчәнлеген 1950 дә Хәмзә исем. Үзбәк акад. драма театрында башлап җибәрә (1958–60 та һәм 1966 дан театрның баш режиссёры). «Гаилә» («Семья», И.Ф.Попов, 1952), «Ефәк сөзәнә» (А.Каххар, 1952), «Йөрәк серләре» (Б.Рахманов, 1953), «Изге кан» («Священная кровь», Айбәк романы буенча үз инсценировкасы, 1954), «Шәхси эш» («Персональное дело», А.П.Штейн, 1956), «Юл күрсәтүче йолдыз» (К.Яшен, 1958), «Хөррият» (Уйгун, 1958), «Урланган тормыш» («Украденная жизнь», Моримото Каору, 1965), «Монсерра» (Э.Роблес, 1967) спектакльләрен куя. 1966 да Татар акад. театрында Ч.Айтматовның «Гүзәлем Әсәл» повестен сәхнәләштерә. Ул Казанның театр тормышында зур вакыйгага әверелә һәм 1967 дә ТАССРның Г.Тукай исем. Дәүләт бүләгенә лаек була. Баш рольләрне Р.Тажетдинов, Н.Гәрәева, Ш.Биктимеров һәм Ш.Әсфәндиярова башкара. Х. режиссурасы фикер төгәллеге, актёрларның күмәк башкаруын оештыру осталыгы, характерларның тирәнтен эшләнеше һәм мизансценаларның сәнгатьчә бирелеше б-н аерылып тора. Режиссёрлык эшчәнлеге б-н бергә Ташкент театр-сәнгать ин-тында пед. эшчәнлек алып бара; К.С.Станиславскийның «Актёрның үз өстендә эшләве» («Работа актёра над собой») китабын, рус һәм чит ил драматургларының пьесаларын үзбәк теленә тәр җемә итә.

Әд.: Государственный ордена Ленина академический узбекский театр драмы им. Хамзы. Таш., 1957. *И.И.Илялова.*

ХУҖАЛЫ́К-ЙОРТ КИРӘ́К-ЯРАКЛАРЫ́, йортта кулланыла торган әйберләр һәм кирәк-яраклар. Ризык әзерләү, саклау һәм куллану өчен файдаланыла торган савыт-сабаны; төрле предметлар һәм кием-салым саклау өчен савытларны, җи һазларны; шәхси гигиена һәм торак гигиенасы әйберләрен үз эченә ала. Төбәктә Х.-й. к.-я.ның беренче үрнәкләре таш гасырда барлыкка килә, бронза гасырда үсеш ала. Борынгы заманда һәм урта гасырларда төбәк халкы агач, балчык һәм металл Х.-й.к.-я.ннан файдалана. Төбәктә казан б.э.ның 4–5 йөзләреннән кулланыла, шу ңа салып ризык пешергәннәр һәм кыздырганнар. Мичтә ризыкны кайнар эшкәртү башлангач, Х.-й.к.-я.ның исәбе шактый арта. Киң авызлы, төбәнәк, ирнәүле, түгәрәк, төпкә таба тарайган балчык чүлмәкләр таралыш ала. Чүлмәкләр 200–300 *г* нан 30–40 *л* га кадәр сыйдырышлы төрле зурлыкта була. 18–19 йөзләрдә йортларда коелган чуен чүлмәкләр (чуеннар) кулланыла башлый; алар да аш һәм ботка пешерәләр, тирән табаларда кыздыралар һәм камыр ризыклары әзерлиләр; алар янына ухват, кисәү агачы һәм табагач өстәлә. Сөт продуктларын һәм әчемлекләрне (бал яки буза) саклау, күчереп йөртү өчен 2–3 *л* сыйдырышлы тар муенлы чүлмәкләр һәм кувшиннар, 30 *л* га кадәр сыйдырышлы зур чүлмәкләр кулланылган. Хуҗалыкта ш.у. төрле пычаклар, он иләү өчен иләкләр, сөт һәм су чиләкләре (19 йөз ахырына кадәр агачтан эшләнгәннәр, соңрак металл чиләкләр өстенлек иткән) файдалануда булган.

20 йөз уртасына кадәр татарларда кухняда агач Х.-й.к.-я. (тәлинкәләр, кружкалар, кашыклар, җамаяклар һ.б.) киң кулланылган. Ипи пешергәндә дә агач савыт-саба файдаланылган: яркалардан тыгызлап җыелган һәм кыршау б-н беркетелгән, яки тоташ агачтан чокып ясалган күәс чиләгендә камыр изгәннәр, аны сай ялгашка салып басканнар һәм махсус металл формаларга салганнар. Су, квас, әйрән, буза һ.б. әчемлекләрне чумырып алу өчен озынча формада чокып ясалган, сабының очы аска таба бөгеп эшләнгән кыска саплы чүмеч кулланганнар. Катык оету һәм күчереп йөртү өчен кечкенә кисмәк файдаланылган. Тыгыз ябыла торган зур булмаган кисмәкләрдә бал, еш кына эретелгән май саклаганнар. Шикәр, тоз ваклаганда, тәмләткечләр, кипкән шомырт һәм корт төйгәндә саплы киледән файдаланганнар; казаннан яки чуеннан ризыкны агач чүмеч б-н алганнар. Безнең көннәргәчә һәртөрле мичкәләр һәм кисмәкләр, продуктлар хәзерләү һәм саклау өчен кәрзиннәр һәм тартмалар, камыр басу өчен куна һәм уклаулар, продуктларны туглау һәм бәрәңге төю өчен тукмаклар кулланылышта кала.

19 йөз ахырында — 20 йөз башында татарларның көнкүрешенә фабрикаларда һәм заводларда җитештерелгән металл (ш.и. эмальле), фаянс һәм пыяла савыт-саба үтеп керә. Аеруча чәй савыт-сабасы таралыш ала. Чәйне түгәрәк төпле һәм тәлинкәле кечкенә тәбәнәк касәләрдән (татар касәләре — чынаяклардан) эчәргә яраталар. Табынга чәй кашыклары, ягъни бал кашыклары, шикәр һәм бал өчен махсус савыт-саба, ш.у. фарфор май савытлары куела. Самовар һәм чәй пешерә торган чәйнек чәй эчүнең зарури атрибуты була. Чәй савыт-сабасы табынга бакыр яки тимер подносларда китерелә. 19 йөз ахырына — 20 йөз башына кадәр Х.-й.к.-я.н, бигрәк тә аларның агачтан (бизәкле Хохлома кашыклары популярлык казана) һәм каен тузыннан эшләнгәннәрен бизәкләү традициясе яшәп килә.

20 йөзнең 2 нче яртысында татарларның аш бүлмәсе зур үзгәрешләр кичерә. Газ һәм электр плитәләрен файдалану аш бүлмәсе кирәк-яракларының яңаруына китерә: казаннар, чуеннар, агачтан һәм балчыктан эшләнгән Х.-й.к.-я.ның зур өлеше кулланылыштан чыга. Гаиләләрдә, иң элек шәһәр җирендә, Х.-й.к.-я.ның металл һәм эмальле савыт-сабадан, электр чәйнекләреннән, самоварларыннан һ.б. дан гыйбарәт зур җыелмасы барлыкка килә.

Шәхси гигиена һәм йортның эчен җи һазлау б-н бәйле предметлар зур әһәмияткә ия була. Кер өслеген тигезләү өчен татарлар озак вакытлар уклау һәм сырлы такта яки кырлы бәләк кулланганнар. Бөгәрләнгән әйберләрне ышкылап шомартылган таякка чолгап, тигез өслек буйлап кырлы бәләк тәгәрәткәннәр, бәләкнең сырлары тукымадагы җыерчыкларны тигезләгән (әлеге тигезләү конструкциясен руслар «рубель» дип атаганнар). 18 йөз уртасында беренче җылыткычлы үтүкләр (яссы түбән өслекле һәм тоткалы чуен кисәге) барлыкка килә башлый. Аларны мичтә кыздырганнар; башлыча тупас тукымаларны тигезләгәннәр. 18 йөз ахыры — 19 йөз башында эченә утлы күмер салынган үтүкләр барлыкка килә. 20 йөзнең 2 нче яртысында аларны электр үтүкләре алыштыра. Татарларның шәхси гигиенасына хас деталь юыну һәм тәһарәт алу өчен кулланылган бакыр яки җиз савытлардан — зур таслардан һәм комганнардан гыйбарәт була; сөлге б-н бергә алар татар йортының ачык этник һәм дини символын тәшкил итәләр.

18 йөздә — 20 йөз уртасында сәкедәге сандык яки бер-берсе өстенә куелган кечкенә сандыклар татар өендә зарури җи һаз була. Татарларга әйберләр һәм кием-салым саклау өчен махсус, башлыча Пермь губернасы һөнәрчеләре тарафыннан бизәкле яки ялтыравык калай б-н тышланган, еш кына музыкалы эчке йозак куелган сандыклар эшләнә.

19 йөз ахырында — 20 йөз башында татар йорты интерьерында (бигрәк тә сәүдәгәрләр, руханилар һәм таза тормышлы крәстияннәр йортларында) суга торган дивар сәгатьләре мөһим предмет була. Этнограф Н.П. Штейнфельд «Дивар сәгатенә карата татарлар аеруча һәвәслек кичерәләр. Бай йортта һәр бүлмә зарури рәвештә сәгать белән бизәлгән» дип билгеләп уза. Сырланган агач кысалага куелган көзгеләр дә югары бәяләнгән. алар йортның түр ягында, тәрәзәләр арасындагы диварларда берничә данә урнаштырылган.

Әд.: Фукс К.Ф. Казанские татары в статистическом и этнографическом отношениях. К., 1844; Штейнфельд Н.П. Малмыжские татары, их быт и современное положение // Календарь и памятная книжка Вятской губернии на 1894 г. Вятка, 1893; Воробьёв Н.И. Казанские татары. К., 1953; Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967; Татарская кухня. К., 1985; Мухамедова Р.Г. Пища и домашняя утварь // Татары. М., 2001. *Р.Р.Батыршин.*

ХУҖАЛЫКТА́Н ЧИТКӘ́ КИТЕ́П ЭШЛӘ́Ү, крәстияннәрнең акча эшләү өчен вакытлыча авыллардан шәһәрләргә һәм башка төбәкләргә авыл хуҗалыгы эшләренә китүе. Күренеш буларак, 17 йөз тирәләрендә, *капитализм* үсеше башлангач, барлыкка килә. Крәстияннәрне товар-акча мөнәсәбәтләренә тартуга (алар вакытлыча яллы эшчеләргә әвереләләр) булышлык итә. 19 йөзнең 1 нче яртысында Россиядә 1 млн.нан артык хуҗалыктан читкә китеп эшләүче крәстиян исәпләнә.

Казанда һәм Казан өязендә 17 йөздә, нигездә, «йөрүчеләр» дип аталган кешеләрнең төп массасы мәшгуль булган хуҗалыктан читтәге кәсепләр яшәп килә. Казанның 1646 елгы

исәп алу кенәгәсендә «йөрүчеләр» («зур кабакта ялланып» яшәүчеләр) билгеләп үтелә. Х.ч.к.э. Казан губернасындагы алпавыт крәстияннәре арасында киң таралган була. Идел буенда һәм Уралда транспортта интенсив күчерүләр б-н бәйле ат б-н ташу (к. «*Барабыз*») һәм судно эшләре Х.ч.к.э.нең үзенчәлекле төрләре булып санала. Идел буенда крәстияннәрдән яллы эшчеләрнең бөтен бер төркемнәре: урман кисүчеләр, сал агызучылар, бурлаклар, ш.у. балык кәсәбәчелегендә һ.б. ярдәмче эшләрдә эшләүчеләр барлыкка килә. Сезон эчендә эшләп алынган акча еш кына крәстиян гаиләсен ел буена туендыра. 19 йөз уртасында бурлак Иделдә көмеш б-н 10 сумнан 40 сумга кадәр акча эшләгән. 1834 тә Казан губернаторы С.С.Стрекалов үзенең император Николай I гә хисабында Казан губернасыннан ел саен 20 меңгә якын судно эшчеләре һәм бурлаклар чыгуы, 3 меңләп кешенең шәхси фабрика һәм заводларда эшләве турында билгеләп үтә. Губернаның урманлы өязләрендә крәстияннәр табышының төп өлешен кәсәбәчелектән һәм Х.ч.к.э.дән кергән акча тәшкил итә. Казан губернасыннан җәйге кыр эшләренә товар җитештерүче игенчелек зоналарына (Россиянең Европа өлеше көньяк-көнчыгыш районнарына) да китәләр. Шәһәрләрдә татарлар урам себерүче, йөк ташучы, мунчачы, кара эшче булып ялланалар. 19 йөз уртасында а.х. эшләренә яллану Сембер губернасының Буа, Карсун һәм Алатырь өязләрендә яшәүче татарлар арасында киң таралган була. Х.ч.к.э. таралуга 1861 елгы Крәстиян реформасы булышлык итә, аны гамәлгә ашыру барышында Казан губернасында хуҗалыктан читкә китеп эшләүчеләр саны 1863 тә 152 меңнән 1897 дә 1,5 млн. кешегә җитә. 19 йөз ахырында Самара губернасы Бөгелмә өязе Керкәле авылының барлык җитлеккән яшьтәге халкы, шул губернаның Богыруслан өязе Балыклы авылыннан — 70% ка якын ир-атлар читкә китеп эшли. Игенчелек б-н бәйле Х.ч.к.э. юнәлеше еш кына катлаулы форма ала: Вятка губернасы крәстияннәре Самара һәм Уфа губернасына, ә соңгы ике губерна крәстияннәре читкә китеп эшләүчеләр хезмәтенә түләү Урта Идел буендагыга караганда югарырак булган Оренбург губернасына китеп эшлиләр. Җирле сәнәгать булган төбәкләрдә крәстияннәр якындагы завод һәм фабрикаларда эшкә яллана-лар. Х.ч.к.э. б-н, гадәттә, сентябрьдән март ахырына кадәр шөгыльләнәләр. Ераккарак, мәс., Каспий диңгезенә балык кәсәбәчелегенә, Себергә агач әзерләү эшенә, Уралга алтын прискаларына китеп эшләү дә таралган була. Х.ч.к.э.нең мондый формасы да яшәп килә — крәстиян, пролетариат катлавына күчеп (юридик яктан үз катлавында кала, җирен арендага бирә, барлык салымнарны түли), игенчелек эшеннән озак вакытка (бер елдан артыкка) аерылып тора. Татарлар Казан губернасының Казан, Мамадыш һәм Царёвококшайск өязләреннән, Рязань губернасының Касыйм өязеннән (мәс., Татар волостеннан ир-атларның 55,5% ы китә, өяз буенча уртача 40,7%; нигездә, хезмәт күрсәтү өлкәсендә: хезмәтче, лакей, буфетчы, официант һ.б. булып урнашалар) Мәскәү, С.-Петербург, Киев, Ташкент кебек зур шәһәрләргә, Урал, Донбасс шахталарына һәм заводларына, Бакуның нефть промыселларына һ.б. урыннарга актив рәвештә эшләргә китәләр; Тамбов губернасы татарлары Кырымда сарык асраучыларда эшлиләр. Читкә китеп эшләүчеләрнең бер өлеше шәһәрләрдә торып кала, аларның кайберләре сәүдәгәрләр яки мещаннар катлавына күчә.

Әд.: Шаховский Н.В. Сельскохозяйственные отхожие промыслы. М., 1896; Смыков Ю.И. Крестьяне Среднего Поволжья в период капитализма (социально-экономическое исследование). М., 1984; Халиков Н.А. Хозяйство татар Поволжья и Урала (середина XIX — начало XX в.). К., 1995; Хафизов Г.Г. Культуртрегерская деятельность татарской интеллигенции в XIX — первой четверти XX вв. К., 2003.

Л.М.Айнетдинова.

ХУҖАМӘТ авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 24 *км* көньяк-көнбатыштарак, Казан — Уфа автомобиль юлы буенда. 2010 елда 786 кеше (татарлар) яши. Ремонт-техника, асфальт-бетон з-длары. Урта мәктәп, мәдәният йорты, Минзәлә һөнәр уч-щесе ф-лы, китапханә. 1734 тән мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы асабалар, дәүләт крәстияннәре һәм типтәрләр катлауларына бүленә. 1773 — 75 еллардагы Крәстияннәр кузгалышында Е.И.Пугачёв ягында сугышалар. Халкы игенчелек, терлекчелек, чабата үрү, олаучылык б-н шөгыльләнә; тирә-якта-гы алпавытларга эшкә яллана. 20 йөз башында Х.тә мәчет (1836 дан билгеле), мәктәп, мәдрәсә, 3 су тегермәне, 2 ярма яргыч, тимерче алачыгы, әвен, 20 кибет була; пән җәшәмбе базары эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1536,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Күсәкәй волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августын-нан Минзәлә р-нында. Халык саны: 1795 тә — 149, 1859 да — 396, 1870 тә — 447, 1897 дә — 753, 1913 тә — 1081, 1920 дә — 840, 1926 да — 545, 1938 дә — 568, 1949 да — 504, 1970 тә — 725, 1979 да — 942, 1989 да — 880, 2002 дә — 864 кеше.

ХУ ҖӘСӘЁТОВ Мөхәммәт җан Хәлил угылы (19 йөзнең 2 нче яртысы, Казан губ. Царёвококшайск өязе — 20 йөз башы), басма (төсле һәм аклы-каралы ташбасмалар), кулъязма шәмаилләр авторы. Х.ның эшләре югары осталыкта башкарылуы һәм сурәтләнгән символларның текст эчтәлегенә тәңгәл килүе б-н аерылып тора. Үзе имзалаган 8 шәмаиле билгеле. Төсле ташбасмалар арасында дүрт хәлифәнең исеме язылган «Исме хөснә» (1898), «Әсхабе кәһаф» (1898), «Кәгъбә» (1901), «Исме әгъзам» (1902), Казан ун-ты басмаханәсендә басылган «Фәзаилеш-шөһүр», «Аллаһ — иң яхшы саклаучы» (20 йөз башы), аклы-каралы «Кыйбла» ташбасмасы (1901) бар. Х. шәмаилләрендә суфилык һәм шигыйлык элементлары чагылыш тапкан. Алар төрле төсләр кушылмасы бергә файдаланылган катлаулы күп планлы композиция б-н аерылып тора. Гадәттә, композиция үзәген үсемлек һәм геом. бизәкләрне файдаланып, сөлес, куфи һәм нәсех ысулы б-н табличалар рәвешендә дини һәм гарәп, фарсы, иске татар телләрендәге аңлатма текстлар язылган символик (мәс., чалма — Нәкышбәндия суфичылык борадәрлеге), метафорик (күзге — инануның йөрәге) яки архит-ра (Кәгъбә, пәйгамбәр мәчете) сурәт тәшкил итә. Х.ның кулъязмада сакланып калган бердәнбер «Икенче сәфинәи Нух» (1902) шәмаиле — кәгазьдә төсле тушь һәм карандаш б-н башкарылган. Аның композициясе үзәгендә татарларда популяр булган Эфес үсемлә-ренең («мәгарә ияләренең)» исемнәре кал-







М.Х.Хуҗасәетов. 1. «Икенче сәфинәи Нух» шәмаиле. Ташбасма. Казан ун-ты басмаханәсе. 1902; 2. «Мөселман ай исемнәре» шәмаиле. Ташбасма. Казан. Вараксин басмаханәсе. 1904; 3. «Аят-әл-Көрси» шәмаиле. Ташбасма. Казан. Казан ун-ты басмаханәсе. 1910.

лиграфик язу б-н сурәтләнгән кораб (символик «Иман көймәсе») тора.

Х.ның шәмаилләре ТР Милли музеенда, Казан ун-тының Н.И.Лобачевский исем. Фәнни китапханәсенең кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә саклана.

Әд.: Шамаилы из коллекции Национального музея Республики Татарстан (конец XIX — начало XX вв.): Собрания профессоров И.М.Покровского и Н.Ф.Катанова: Альбом. К., 2003; Шамсутов Р.И. Слово и образ в татарском шамаиле: от прошлого до настоящего. К., 2003.

Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.

ХУҖӢ авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 32 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Инеш елгасы (Минзәлә бассейны) буенда. 2010 елда 87 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, ит терлеге асрау. Клуб. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1920 елларга кадәрге рәсми рус чыганакларында Козеева (Козяева, Кузеева) буларак телгә алына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 887 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Бишенде-Останково волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1935 нең 10 февраленнән — Ворошилов, 1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл, 1959 ның 12 октябреннән — Сарман, 1984 нең 4 июненнән Тукай р-нында. Халык саны: 1816 да — 87 ир-ат; 1870 тә — 422, 1906 да — 718, 1920 дә — 739, 1926 да — 439, 1938 дә — 485, 1949 да — 302, 1958 дә — 286, 1970 тә — 250, 1979 да — 202, 1989 да — 117, 2002 дә — 75 кеше.

ХУҖӢ (Хуҗиев) Гали Хуҗи улы (17.10.1912, Апас р-ны Карамасар а. — 13.10.1966, Казан), шагыйрь. Казан пед. ин-тын тәмамлый (1941). «Кызыл армеец» (1932–41), «Яшь сталинчы» (1932–41, 1949–52) г-таларында, «Ватан намусы өчен» (1942) фронт г-тасында, ТАССР Язучылар берлеге идарәсендә (1954–62) эшли. «Шатлык» исемле беренче шигырьләр җыентыгында Х. иҗатында тыныч тормышка сөенү, сугыш геройларына, сугышта һәм тылда совет кешеләренең батырлыкларына дан җырлау кебек төп темалар билгеләнә. «Комсомолка» (1937), «Хәсән күле» (1939), «Зоя Космодемьянская» (1942), «Россия» (1944), «Яшәү мәгънәсе» (1963) поэмаларына, герой-шагыйрь М.Җәлилнең тормышы һәм батырлыгы турында «Кырыс хикәят» (1964) трилогиясенә героик пафос хас. «Сабан туе гайлары» (1941), «Янар йөрәкләр» (1967), «Шигырьләр һәм поэмалар» (1980), «Таныш күзләр, таныш карашлар» (1991) шигырь һәм поэмалар җыентыклары авторы. Бөек Ватан сугышында катнаша. Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: Гайнанов Р. Герой, стиль, осталык. К., 1975; Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

ХУ ҖИ ӘХМӘ́ТОВ Әнвәр Нури әхмәт улы (30.7.1952, Куйбышев р-ны Йолдыз а.), педагог, пед. фән. д-ры (1997), проф.(1996), ТАССР, РСФСРның атказ. мәктәп укытучысы (1984, 1986), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1999). 1974 елда Казан ун-тын, 1996 да Россия социаль-гуманитар ин-тын тәмамлый. 1976 дан Куйбышев р-нының Яңа Бәрән (хәзер Чәчәкле а.) урта мәктәбендә укытучы, 1978 дән директор. 1988дән ТР Мәгариф министрлыгының милли мәктәпләр бүлеге мөдире, 1993 тән Татар гуманитар-пед. ун-тында, 2011 дән Казан (Идел буе) федераль ун-тының Пед. һәм психол. ин-тында. Хезмәтләре мәктәп укучыларын тәрбияләү мәсь әләләренә карый. Татар телендә мәктәп педагогикасы, дидактика, пед. югары уку йортлары һәм урта һөнәри уку йортлары өчен тәрбия теориясе буенча уку ярдәмлекләре, 8–9 сыйныфлар өчен татар әдәбияты дәреслекләре авторы. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Татарстан комсомолының М.Җәлил исем. (1985), К.Насыйри исем. (2001) бүләкләр лауреаты.

Х е з м.: Начало всех начал (Трудовое воспитание в школе). К., 1990; Социализация и индивидуализация личности школьника. К., 1998; Педагогика: Учеб. К., 2004.

ХУҖӢЕВ Марсель Вәли улы (23.11.1938, Казан), химик-технолог, техник фән. д-ры (1999), проф. (2000). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1961), Украина ССР ФАндә эшли. 1964 елдан Казан технол. ун-тында. Хезмәтләре энергия керемле материалларны җитештерүнең теоретик нигезләренә багышлана. Х. энергия керемле материалларны җитештергәндә булган гидромеханик процессларны тикшерә. Кәгазь җитештерү һәм пластик массаларны эшкәртү процессларының теоретик нигезләрен эшләүдә, үтә тулы целлюлозалы материаллар ның технологиясен камилләштерүдә һәм үзлекләрен модификацияләүдә катнаша. Конструкцион янып бетүчән материалларның полимер нигезе үзлекләрен тикшерә. Энергия керемле материалларның сыйфатын контрольдә тотуның хәзерге заман алымнарын эшли. Фәнни эшләренең нәтиҗәләре оборона сәнәгате пр-тиеләрендә гамәлгә кертелә. Уйлап табуга 45 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: Выпускники — гордость Казанского технологического университета: Краткий биогр. справ. К., 2009.

ХУ ҖӢЕВ Рәшит Гали улы (1.1.1946, Буа р-ны Килдураз а. — 24.6.1997, Казан), географ-икътисадчы, геогр. фән. д-ры (1991), проф. (1993). Казан ун-тын тәмамлый (1968), шунда ук эшли. Хезмәтләре географиядә математик ысуллар куллануга, ТРның халык хуҗалыгы тармакларының үсешен урнаштыруга һәм фаразлауга карый. Х. терр. һәм тармак мәнфәгатьләрен исәпкә алып карарлар кабул итүнең социаль-икътисади өлкәдәге мәсь әләләрне хәл итүдә гомуми юлын тәэмин итәрлек теориясен эшли. «Географиядә математик ысуллар» («Математические методы в географии», 1976) уку ярдәмлеге авторларының берсе. Математик модельләр буенча Халыкара геор. берләшмә комиссиясе әгъзасы (1976 дан).

Х е з м.: Процессы взаимодействия в экономико-географических системах. К., 1980 (автордаш.); Структура геосистем и представление о функциональном прогнозе // Изв. Всесоюз. геогр. об-ва. 1985. Т. 117, вып. 1 (автордаш); Всё о Татарстане: Экон.-геогр. справ. К., 1992 (автордаш).

ХУ́ ҖИН Мәгъсүм Хәмит улы (15.5.1930, Саба р-ны Тенеки а. — 25.8.2008, Казан, туган авылында җирләнә), язучы, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1986). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1954), «Яшь сталинчы», «Колхоз байрагы» (Байлар Сабасы штп), «Коммунизмга» (Арча штп), «Хезмәт» (Балтач а.) г-таларында эшли. 1969 елдан Казанда яши, «Чаян», «Казан утлары», «Татарстан» ж-лларында эшли. «Ерганак юл яра» (1961), «Урманлы үр» (1980), «Бәхет җире» (1987), «Ерактагы кыялар» (1990), «Айның уты сүнгән» (2004) хикәяләр җыентыклары; «Урак өсте болытлары» (1988) повесте һ.б. авторы. Х. әсәрләренең тематикасы — авыл һәм аның кешеләре. «Татар хикәясе антологиясе»н әзерләп бастыра (2001).

Әд.: Хатипов Ф. Якты җирлектәге һәлакәт // Мөлкәтебезне барлаганда. К., 2003; Әдипләребез: Биобиблиогр. белешмәлек. К., 2009. Т. 2.

ХУ́ ҖИН Рафаэль Шәйху әҗә улы (тәхәллүсе Рафаэль Сибат) (28.10.1946, Киров өлкәсенең Вятка Аланы р-ны Түбән Шөн а. — 15.8.2003, шунда ук), язучы, публицист. Казан ун-тын тәмамлый (1968). 1970–88 елларда Кукмара р-ны урта мәктәпләрендә укытучы, директор, аннан соң Татар опера һәм балет театрында администратор, шәһәр тибындагы Кукмара посёлогында халык театры режиссёры, Киров шәһәрендә классик көрәш буенча тренер булып эшли. 1988 дән туган авылында яши, мәдәният йортында сәнгать җитәкчесе булып эшли. 1990 нан «Дуслык» г-тасында (Киров өлкәсе) хәбәрче, әдәбият һәм сәнгать бүлеге мөдире. Әсәрләрен 1960 еллардан бастыра башлый. «Ялгызак» романы, «Кайту» роман-тетралогиясе (2005) авторы. «Көлдән күтәрелгән гөлләр» (2002), «Без дә җирдән күтәрелдек» (Чаллы, 2003), «Көзге Сабантуй = Осенний Сабантуй» (2005) документаль повестьлары Кукмара р-нының атаклы кешеләренә багышлана. ТР Язучылар берлегенең Г.Исхакый исем. бүләге лауреаты (2003).

Әд.: Мостафин Ш. Безнең заман геройлары. К., 2005.

ХУ́ ҖИН Фаиз Хуҗи әхмәт улы (1.4.1933, Мөслим р-ны Түбән Табын а. — 1978), спортчы (җиңел атлетика — озын дистанциягә йөгерү), СССРның мактаулы спорт остасы (1964). 10 *км* га йөгерүдә РСФСР (1960), СССР (1960) чемпионы, «Милләтләр кроссы» халыкара ярышларында җиңүче (1963, Женева). 1989 дан Х. истәлегенә кросс уздырыла (Түбән Табын — Мөслим).

ХУ́ ҖИН Фаяз Шәрип улы (1.8.1951, Зәй р-ны Карман а.), археолог, тарихчы, тарих фән. д-ры (2002), ТР ФА мөхбир әгъзасы (2004), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2002). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1972). 1974–96 елларда ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында (1989–90 да археол. бүлеге мөдире), 1997 дән Тарих ин-тында (2007 дән баш фәнни хезмәткәр), Археол. ин-тында. Бер үк ва-



Ф.Ш.Хуҗин.



П.П.Хузангай.

кытта Татар гуманитар ин-ты (2012 дән Казан ун-ты) профессоры (2008–11 дә Татарстан тарихы каф. мөдире). Х. җитәкчелегендә Биләр, Суар, Жүкәтау, Чаллы шәһәрлекләрендә, Казан Кремлендә киң колачлы казу эшләре башкарыла. Казанның иң борынгы шәһәр нигытмаларын, Казан ханнары каберләрен, Колшәриф мәчетенең археол. калдыкларын һәм 11–16 йөзләрдәге башка архит-ра корылмаларын тикшерүгә, археол. чыганаклар нигезендә урта гасырлар шәһәрләренең (ш.и. Казанның, Алабуганың) яшен ачыклау методологиясен һәм методикасын эшләүгә зур өлеш кертә. Хезмәтләре элгәреге болгарлар, Идел буе Болгар дәүләте, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы археологиясенә һәм тарихына, Идел буе халыклары тарихи-мәдәни мирасын саклауның актуаль мәсьәләләренә карый; урта мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен уку ярдәмлекләре, фәнни-популяр китаплар авторы. Болгар шәһәрендәге Болгар цивилизациясе музее, Татарстанның Казан Кремлендәге Археол. музее һәм Биләр шәһәрлеге музее фәнни концепцияләрен эшләүчеләрнең берсе. «Поволжская археология» ж-лының баш мөхәррире, «Гасырлар авазы = Эхо веков», «Филология и культура» ж-ллары редколлегияләре әгъзасы. «Татарстан Республикасының археологик картасы»н («Археологическая карта Республики Татарстан», т. 1–6. 1981–90) төзүдә катнашканы өчен, ТР Дәүләт бүләгенә лаек була. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Великий город на Черемшане. К., 1995; Булгарский город в X — начале XIII вв. К., 2001; Древняя Казань. К., 2005 (автордаш); Ранние булгары и Волжская Булгария: VIII — начало XIII вв. К., 2006; Исследования по булгаро-татарской археологии. К., 2011.

Әд.: Г а р и ф Н. Халкын олылаган олы галим // Казан утлары. 2001. № 8; Археологи Волго-Уральского региона. Уфа, 2002; Хузин Фаяз Шарипович: Биобиблиогр. указ. К., 2011.

ХУЗАНГА́Й авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 18 *км* көньяктарак, Инча елгасы (Кече Чирмешән бассейны) буенда. 2010 елда 249 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, клуб, китапханә. Чиркәү. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1968 гә кадәр — Иске Сихтермә, 2004 нең 22 декабреннән Сихтермә-Хузангай исемнәре б-н билгеле. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Урта Иштубай, Сихтәрмә, Сихтермә буларак мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Никола чиркәве (1865 — 68 дә төзелә; архит-ра истәлеге), Халык мәгарифе министрлыгы мәктәбе, земство хастаханәсе, 1 казна шәраб, 2 вак-төякләр һәм 2 бакалея-мануфактура кибете була; чәршәмбе базары эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1878 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Әлки волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1944 нең 19 февраленнән — Юхмачы, 1956 ның 7 декабреннән — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 129 ир-ат; 1859 да — 581, 1897 дә — 908, 1908 дә — 1013, 1920 дә — 1037, 1926 да — 755, 1938 дә — 672, 1958 дә — 316, 1970 тә — 410, 1979 да — 338, 1989 да — 257, 2002 дә — 250 кеше. Х.да шагыйрь П.П.*Хузангай* туган.

ХУЗАНГА́Й Педер (Пётр) Петрович (22.1.1907, Казан губ., Спас өязе Сихтермә а. — 4.3.1970, Чабаксар ш.), шагыйрь, Чуаш АССРның халык шагыйре (1950). 1923–27 елларда Чуаш пед. техникумында, 1927–30 да Шәрекъ пед. ин-тында укый. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1920–30 еллар лирикасының тематикасы — туган халкының яңарышы, аның теле һәм мәдәнияте үсеше: «Яшеннән соң» («Уяртсан», Чабаксар, 1928), «Шигырьләр һәм поэмалар» («Сава семпе поэмасем», М., 1931) шигырь җыентыклары, «Магнит тау» («Магнитту», М., 1933), «Колач» («Сулмак», Чабаксар, 1934) поэмалары, «Тилли җырлары» («Тилли юрисем», Чабаксар, 1975) шигырьләр циклы. Сугыш темасы «Таня» (Чабаксар, 1943) поэмасында, «Ант» («Тупа», Чабаксар, 1942) китабында, «Аптраман нәселе» («Аптраман тавраш», Чабаксар, 1946) шигъри романында чагылыш таба. Х. поэзиясендә Татарстанга карата мәхәббәт темасы да урын ала: «Татар шагыйрьләренә» («Тутар савасисене», 1927), «Якташлар» («Хамар ялсем») шигырьләр циклы, «Сихтермә» («Сиктерме»), 1930–40 еллар шигырьләре циклы. Соңгы еллардагы әсәрләренә тормышка фәлсәфи караш хас: «Без Россиядә яшибез» («Эпир Российара пуранатпар», 1950 еллар), «Күтәрелгән дулкыннар» («Хушка хумсем», Чабаксар, 1963). М.Җәлил, Х.Туфан, Ә.Ерикәй әсәрләрен чуаш теленә тәрҗемә итә. З.Бәширы, Х.Туфан һ.б. татар язучылары иҗатларына багышланган мәкаләләр авторы. Чуаш АССРның К.Иванов исем. Дәүләт бүләге (1967), Чуаш АССР комсомолының С.Сеспель исем. бүләге лауреаты (1969). Хезмәт Кызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Репрессияләр чоры корбаны; аклана.

Әсәр.: Избранное: В 2 т. Чебоксары, 1958; Дуслар белән. К., 1960.

Әд.: Х а р и с Р. Чувашча сөйләшә торган күңел // Татарстан. 2007. № 1; Ф е т и с о в М.И. Народный поэт Чувашии П.П.Хузангай. Чебоксары, 1957; Чувашская энциклопедия. Чебоксары, 2011. Т. 4.

ХУЗАНГА́Й П.П. МУЗЕ́Е, Әлки р-нының Хузангай авылында. 1970 елда шагыйрь укыган мәктәптә оештырыла. 2002 нең 5 февралендә ТРның Милли музее ф-лы буларак ачыла, 2007 дән муниципаль музей. Бер катлы таш бинада урнашкан. Экспозиция мәйданы — 110 *м*², фондларында 400 саклау берәмлеге исәпләнә. Экспозиция «Шагыйрьнең кече ватаны — Хузангай авылы тарихы», «Мәктәп еллары», «Шагыйрьнең Казан чоры тормышы», «Мәскәүдәге эш», «П.П.Хузангай фронтта», «Шагыйрьнең иҗтимагый эшчәнлеге» бүлекләреннән тора. Кыйммәтле экспонатлар арасында — шагыйрьнең шәхси китапханәсеннән аның имзасы куелган китаплар, мемориаль әйберләр (П.П.Хузангайның фронт шинеле, фуражкасы, офицер каешы). Музей ел саен шагыйрьнең туган көнен (22 гыйнвар), музей ачылу көнен (5 февраль) билгеләп үтә. Директоры — О.В.Мурзин (2002 дән).



Әлки районының Хузангай авылында П.П. Хузангай музее.

ХУЛА́Ш ШӘҺӘРЛЕГЕ́ (Кошки-Яңа Тимбай шәһәрлеге), археол. истәлек; урта гасырлардагы (10 йөз — 13 йөз башы) болгарлар шәһәре калдыклары. Тәтеш р-ны Кошки-Яңа Тимбай авылыннан көнбатыштарак 3 *км* ераклыкта, Кылна елгасының (Зоя елгасы кушылдыгы) текә уңъяк ярында урнашкан. Х.ш.ндә археол. тикшеренүләр 20 йөзнең 1 нче яртысыннан алып барыла (Н.Ф.Калинин, 1949; А.П.Смирнов, В.Ф.Каховский, 1962–65 һ.б.).

Х.ш.нең нигытылган мәйданы 11 *га* дан арта, урлар яныннан шәһәр яны торулыгы (30 *га*) башланган. Шәһәр урлардан һәм чокырлардан, манаралы имән диварлардан гыйбарәт ныклы саклану корылмалары системасы б-н әйләндереп алынган. 19 бура тораклар, 17 балчык корылмалар, идән астыннан җылытулы кирпеч бина (фаразланганча, җәмәгать мунчасы), 130 лап хуҗалык һәм 7 җитештерү биналары, ш.и. тимерче алачыгы калдыклары, балчык металлургия һәм һөнәрчелек мичләре ачыклана. Шәһәрлек терр-ясендә югары сыйфатлы төрле керәч савыт-саба, төсле металлардан (ш.и. көмештән һәм алтыннан), пыяладан һәм ярымасылташлардан эшләнгән бизәнү әйберләре, кораллар (сугыш балталары, ук һәм сөңге очлыклары һ.б.), ат дирбиясе детальләре, һөнәрчелек һәм сәүдә кирәк-яраклары (үлчәү детальләре, кечкенә герләр), шифер орчык башлары, тегермән ташлары һ.б. табыла.

Әд.: К а л и н и н Н.Ф., Х а л и к о в А.Х. Итоги археологических работ за 1845–1952 гг. К., 1954; Городище Хулаш и памятники средневековья Чувашского Поволжья. Чебоксары, 1972; Х у з и н Ф.Ш. Булгарский город в X — начале XIII вв. К., 2001.

Ф.Ш.Хуҗин.

ХУ́ННУЛАР (сөннәр), б.э.к. I меңьеллык башында Үзәк Азиядә оешкан күчмә халык. Б.э.к. 209 елда Х.ның идарәчесе Модэ була; бердәм дәүләт барлыкка килә. Х. Кытай б-н сугышлар алып баралар; б.э.к. 51 дә Х.ның бәйсезлеге Кытайга карата вассаллык мөнәсәбәтләре б-н чикләнә. Соңрак Х. бәйсезлекләрен кире кайтаралар, әмма 48 дә хунну ыруларының бер өлеше кабат Кытай тарафыннан буйсындырыла һәм көньяк Х.га башлангыч бирә. Төньяк Х. 87–93 тәге сугыш барышында тар-мар ителә. Төньяк Х.ның бер өлеше Көнбатышка күчеп китә, 4 йөздә массакүләм күчүләре *Халыкларның бөек күчешенә* этәргеч биргән *һуннар* кабиләләре бер леге оешуда катнаша. Х. мәдәнияте скиф-сарматларныкына охшаш була.

Әд.: Гумилёв Л.Н. Хунну. М., 1960.

ХУРА́МШИН (Курамшин) Җамалетдин Хурамша улы (1873, башка мәгълүматлар буенча, 1877, Уфа губ., Бәләбәй өязе Каран а. — 19.12.1937, Томск ш.), дин һәм җәмәгать эшлеклесе. Бәләбәй өязе Килим авылы мәдрәсәсен тәмамлый. Каран авылы мулласы. Уфа губернасыннан кадетлар партиясе исемлеге буенча 1 нче Дәүләт думасы депутаты (1906), мөселманнар фракциясе әгъзасы. «Иттифак әл-мөслимин» партиясе әгъзасы. Депутатлыкка кадәр һәм аннан соң Бәләбәй шәһәре ахуны. Беренче бөтендөнья сугышында катнаша, 1916 елда сан. отряды каршында полк мулласы. 1918–19 да Милли Шура әгъзасы, Милләт Мәҗлесе депутаты. 1924 тән Томски да Кызыл мәчет мулласы. 1930 еллар башыннан Ташкентта Бабаев исем. артельдә эшли. 1937 нең 28 сентябрендә кулга алына һәм этаплап Томскига җибәрелә. Мөселманнар ның «Гаскәри оешма»сы эше буенча хөкем ителә, атып үтерелә; үлгәннән соң аклана.

Әд.: Мусульманские депутаты Государственной думы России. 1906–1917. Уфа, 1998; Османова Д.М. Мусульманская фракция и проблемы «свободы совести» в Государственной думе России (1906–1917). К., 1999. *Ф.Г.Миңнеханов.*

ХУРУМША́ (Күремсә, Коренца) (13 йөз), монгол ханзадәсе. Жүчинең оныгы. Бату ханның Көньяк Руська һәм Көнбатыш Европага яуларында катнаша. 1250 елларда Галич-Волынь кенәзлегенә уңышсыз һөҗүм нәр оештыра. 1240–60 елларда Днепр буенда олыс били.

ХУ́ТОРОВА Ольга Германовна (10.9.1963, Казан), физик, физика-матем. д-ры (2006). Казан ун-тын тәмамлый (1985), шунда ук эшли, проф. (2010 нан). Хезмәтләре атм. физикасына, атмосферада радиодулкыннар җәелүенә карый. Х. тропосферада дулкынлану процессларын, аларның атм. күшылмаларында, радиодулкыннарның рефракция индексында, биоаэрозольләрдә күренүен тикшерә. Спутник навигациясе системаларының алгычлар челтәрен һәм мезокүләм атм. моделен нигез итеп алып, атм. мониторингы комплексын эшли.

Х е з м.: Исследование мезомасштабных вариаций в тропосфере по наблюдениям концентрации примесей // Изв. РАН. Физика атмосферы и океана. 2001. Т. 37, № 6 (автордаш); Волновые возмущения локальных и синоптических масштабов по синхронным измерениям атмосферных примесей // Докл. РАН. 2005. Т. 400, № 1 (автордаш).

ХЫЗЫ́Р ХАН (? — 1361), Алтын Урда ханы (1360 елдан). *Нәүруз хан* вафатыннан соң Сарай әл-Җәдидтә хакимиятне үз кулына ала. Акча суктыра. Рус кенәзләрен 1360 елда Жүкәтау шәһәрен җимереп-талап киткән *үшкуйникларны* (Новгород кораллы дружиналары әгъзаларын) Урдага тотып бирергә мәҗбүр итә. Фетнә нәтиҗәсендә хакимияттән төшерелә, хан тәхетенә *Тимер Хуҗа хан* утыра.

Әд.: Греков Б.Д., Якубовский А.Ю. Золотая Орда и её падение. М.–Л., 1950; Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960. *И.Л.Измайлов.*

«ХЫПА́Р» («Хәбәр»), иҗтимагый-сәяси газета. Чуаш телендәге беренче газета; чуаш журналистикасына нигез сала. 1906 елның 8 гыйнварыннан 1907 нең 27 маена кадәр Казанда нәшер ителә, барысы 65 саны чыга. Мөхәррирләре — Н.В.*Никольский*, С.К.Кирилов, С.И.Игнатьев, П.А.Алексеев, В.И.Иванов. Сәяси һәм социаль-икътисади темаларны яктырткан язмалар басыла. Газета әүтәлеге б-н революцион-демократик юнәлештә була, самодержавиене гаепләп чыга, халыкларның азатлыгы һәм тигезлеге талап ителүне яклый, җир мәсьәләсе турында фикер алышына, дингә каршы пропаганда алып барыла. 1917 нең 1 маенда Идел буеның вак халыклары берлегенең чуаш секциясе «Х.» г-тасын чыгаруны торгыза, 1917 нең августыннан нашире — Чуаш милли җәмгыяте. Мөхәррирләре — А.П.Милли (Прокопьев), Н.П.Петров, А.В.Васильев, М.Ф.Филиппов




«Хыпар» газетасының беренче саны. 1906.

(Спиридонов), И.В.Васильев. 1918 нең 28 февраленнән «Канаш» исеме б-н чыга. (Үзәк чуаш хәрби советы органы, мөхәррире — Д.Е.Ефимов). 1921 нең җәеннән Чабаксар шәһәрендә, 1991 дән кабат «Хыпар» исеме б-н басыла.

ХЫЯЛЕТДИ́НОВ Шакир Шәйхелислам улы (15.5.1890, Оренбург губ. Звериноголовка а. — 15.6.1974, Уфа ш.), дин эшлеклесе. 1909 елда «Рәсүлия» мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң (Оренбург губ. Троицк ш.), «Буби» мәдрәсәсендә укый (Вятка губ., Сарапул өязенең Иж-Бубый а.). 1910 нан Урта Азиядә яши: Кустанай, Күкчәтау шәһәрләрендәге, Жамбиты авылындагы (хәзер Казакъстан Респ-касы) мөселман уку йортларында укыта, 1918 дән Акмулла өлкәсендәге Атбасар авылы мәчете имам-хатибы. 1930 дан Ташкент (Үзбәк ССР) һәм Петропавловск (Казакъстан ССР) пр-тиеләрендә хисапчы. 1943–47 тә Урта Азия һәм Казакъстан мөселманнары Диния нәзарәтенең ревизия комиссиясе рәисе, аннан соң Жаркент һәм Чимкент шәһәрләре мәчетләрендә имам (Казакъстан ССР). 1951 дән СССРның Европа өлеше һәм Себер мөселманнары Диния нәзарәте рәисе һәм мөфти; дини традицияләрне сакларга омтыла. Медаль б-н бүләкләнә.

Әд.: Королёв А.А. Власть и мусульмане России. 1945–2000 гг. (По материалам Среднего Поволжья). Пенза, 2007; Ислам на Урале: Энцикл. словарь. М.–Н.Новгород, 2009.



Хулаш шәһәрлеге. 1. Китмәннәр, кәйлә, аркылы балта, тишкеч; 2. Ураклар; 3. Яктырткычлар һәм шалтыравыклар; 4. Касәләр; 5. Стакансыман савыт һәм кувшиннар.

Һ

ҺАВА́ ДЫМЛЫЛЫГЫ́, һавада су пары микъдары, һава торышын һәм климатны сыйфатлаучы билгеләрнең берсе. Су пары басымы (*ГПа*), абс. (*г/м*³) һәм чагыштырма (%) дымлылык, дымлылык кытлыгы (*ГПа*), чык ноктасы темп-расы (°С) һ.б. билгеләр б-н билгеләнә. ТР терр-ясендә су пары басымы уртача 2 *ГПа* дан (гыйнварда) 15 *ГПа* га кадәр (июльдә) үзгәрә, уртача еллык күрсәткече 7 *ГПа* га якын. Һаваның чагыштырмача дымлылыгы кышын уртача 80–85%, җәен 60–70%. Коры көннәр (Һ.д. 30% тан ким) — 23–29, дымлы (Һ.д. 80% тан ким булмаган) — 95–120 көн. ТР терр-ясендә Һ.д.ның кышкы билгеләре түбән һава темп-расы, ш.у. күбрәк бертөрле түшәлмә (кар капламы) өслек халәте б-н бәйле булганлыктан, акрын үзгәрә. Респ-ка терр-ясендә Һ.д. таралышындагы төрлелекне аеруча җәен күзәтергә мөмкин. Зур сулыкларның (сусаклагычлар) яр буе зоналарында, аеруча су баса торган (сазлыклы) урыннарда, грунт сулары якын ятучы табигый иңкүлекләрдә, урман массивларында, ясалма сугарылучы участокларда Һ.д.ның югары күрсәткечләре билгеләнә. Елның җылы вакытында (май–октябрь) Һ.д. күп булганда, Куйбышев сусаклагычының яр буе зонасы 10–13 *км* га җитәргә мөмкин. Яр буе тирәсендә (100 *м* киңлектәге аңа чиктәш 100 *м* киңлектәге коры җир полосасы) су пары басымы уртача 1–2 *ГПа* га артыграк. Урмансыз, төрле якта җил исүче калкулыклы урыннарда аеруча коры. Зур шәһәрләр эчендә Һ.д.н билгеләгәндә шактый гына фәзаи аерымлыклар туарга мөмкин; мәс., апрельдә тыныч, аяз һава булганда, Казанда 1 Май һәм Ирек мәйданында Һ.д. Казансу елгасы тугаена чыгучы кварталларга караганда чагыштырмача 25–30% ка азрак.

М.А.Верещагин.

ҺАВА́ МА́ССАЛАРЫ, зур күләмле, тропосфераның физик үзлекләре буенча чагыштырмача бертөрле өлешләре, материк һәм океаннар өстендә формалаша һәм атм. циркуляциясе агымы тәэсирендә күчә. Формалашу районына нисбәттә арктик, уртача, тропик һәм экваториаль Һ.м.н билгелиләр, алар үз чиратында диңгез һәм континенталь типларга бүленә. Темп-ралар чагыштырмасыннан чыгып, җылы һәм салкын Һ.м.н аералар. Чик буе зоналары — атм. фронтлары б-н бүленәләр, аларда метеорологик зурлыкларның бик еш үзгәрүе күзәтелә. Һ.м. һава торышы һәм климат режимын билгеләүдә мөһим роль уйный, ә аларның циклон эшчәнлеге процессында алмашынуы һава торышының үзгәреп торуына китерә. ТР терр-ясенә арктик, уртача һәм тропик Һ.м.ның үзара хәрәкәте йогынты ясый, шуның өстенә уртача киңлекләрнең континенталь (50 % ка якын) һәм диңгез (20 %) Һ.м. өстенлек итә. Көзен һәм кышын күбрәк Атлантик океан диңгезләре, язын һәм җәен континенталь Һ.м. үтеп керә. Диңгез Һ.м. климатның кырыслыгын киметә, көзен һәм кышын темп-раны күтәрә, язын һәм җәен төшерә. Салкын арктик (20%) һәм җылы тропик (10%) Һ.м. еш кына корылык алып килә.

Әд.: К о л о б о в Н.В. Климат Среднего Поволжья. К., 1968.

Э.П.Наумов.

ҺАВА́ ТЕМПЕРАТУ́РАСЫ, туфрак өслегеннән 2 *м* биеклектә, ш.у. тагын да биектәрәк катламда һаваның җир тирәсе катламы темп-расы. Татарстан терр-ясендә Һ.т. июльдә иң югары., гыйнварда иң түбәндә тирбәлә. Уртача Һ.т. июльдә — якынча +19 °С, гыйнварда — якынча −14 °С. Терр-ядә һаваның уртача айлык темп-ра үзгәрешләре зур түгел (1,5–2 °С). Һаваның уртача еллык темп-расы 2,3 °С тан (Бөгелмә ш.) 3,1 °С ка кадәр (Казан) үзгәрә. Соңгы 100 ел эчендә Татарстан терр-ясендә һаваның уртача еллык темп-расы 0,6 °С ка күтәрелә. (к. *Климат үзгәрешләре*). Абс. миним. темп-ра — −47–52 °С, абс. макс. темп-ра — 37–40 °С. Гыйнварда 2–5 °С лы җепшек көннәр булуы, июльдә темп-раның 1–5°С ка төшүе мөмкин (төнәк-көнчыгышта 0 дән −2°С ка кадәр). Көнлек һава торышы үзгәрешләре аеруча җәй көне сизелә: көнлек үзгәрешләрнең иң югары амплитудасы — июньдә (8,8–11,5 °С), иң түбәне — гыйнварда (−1,4–2,4 °С). Уртача көнлек Һ.т.ның тотрыклы рәвештә 0 °С тан күчүе апрельнең беренче ункөнлегендә һәм октябрь ахырында күзәтелә. Җылы чорның терр. дәвамлылыгы (0°С тан тотрыклы югары темп-ра) — 198–209, салкын чор (0°С тан тотрыклы түбән темп-ра) — 156–167 көн; суыксыз чор — 106 дан 150 көнгә кадәр. Арктик һава үтеп кергәндә һәм җир кабыгы бик көчле радиацион суынганда шактый гына салкынайта, нәтиҗәдә, Һ.т.ның тискәре аномаль учаклары формалаша. Каты салкыннар (−35 °С һәм түбәнрәк) уртача 1–2, кайбакыт 5–10 көн (гыйнвар 1940, 1941) дәвам итә. Елның суык вакытында, кышын һәм язын кар эрегәндә кар капламы темп-раны киметеп Һ.т.на йогынты ясый.

Әд.: Климат Татарской АССР. К., 1983; Климат и загрязнение атмосферы в Татарстане. К., 1995.

Ю.П.Переведенцев, М.А.Верещагин.

ҺАВА́ ТРА́НСПОРТЫ, транспортның пассажирларны, почтаны, йөкләрне һава юлы б-н күчерүче төре. Һ.т.ның төп өстенлеге — күчерү-ташуның югары тизлеге хисабына шактый күләмдә вакытны янга калдыру. Россиядә беренче даими авиалинияләр: Мәскәү–Кёнигсберг (1922 елның 1 маеннан) һәм Мәскәү–Түбән Новгород (1923 нең 15 июленнән). Авиалинияләргә «Дерулюфт» һәм «Добролёт» җәмгыятьләре хезмәт күрсәтә. ТРда Һ.т.ның формалашуы 1924 нең 26 июнендә Казан аэропорты ачылу б-н бәйле. Шул ук елда беренче Мәскәү–Казан һава авиалиниясе дә гамәлгә керә. 1928 дә ул Свердловскига, аннан соң Новосибирскига кадәр озайтыла. 1929 да «Добролёт» җәмгыяте тарафыннан Мәскәү–Иркутск һава-почта линиясе гамәлгә кертелү б-н бәйле рәвештә Казан аэропорты төнге очышлар өчен әзерләнә. Казан аэропорты аркылы почта, үзәк газеталарның матрицалары, Уралдагы һәм Себердәге яңа төзелешләр өчен йөкләр китерелә. 1931 дә Казанда аэровокзал бинасы файдалануга тапшырыла. 1933 тә респ-ка эчендә Казан–Чистай–Алабуга– Минзәлә–Сарман–Бөгелмә–Чистай–Казан бөжралы һава почта линиясе эшли башлый. 1935 тә Казан авиаотряды тарафыннан авиахимия эшләре үзләштерелә. 1938 дә — Чистай шәһәренә, соңрак Чүпрәле авылына пассажирлар йөртү башлана. Рейсларны У-2 самолетлары башкара. 1940 ка Казан респ-каның 12 районы б-н даими авиация элемтәсендә була. Бөек Ватан сугышы елларында гражданнар авиациясенең эшчәнлеге фронт ихтыяҗларына юнәлдерелә. 1950 елларның 2 нче яртысыннан пешкәкле Як-12, Ан-2, Ил-14, Ли-2 машиналарын файдалану нәтиҗәсендә Татарстанда Һ.т. үсеше тизләнә. Казан аэропортында тәүлеккә 40 тан артык рейс башкарыла. 1954 тә сәгатькә 200 пассажир үткәрү сәләтле яңа аэровокзал бинасы сафка баса. Казан Һ.т.ның эре үзәгенә әверелә. 1957 дә — Сочига, соңрак Минеральные Воды, Симферополь, Ленинград, Новосибирск һ.б. шәһәрләргә даими рейслар ачыла. Чистай шәһәрендә (1957), Актаныш авылында (1958), Бөгелмә шәһәрендә (1960) аэровокзаллар төзелә. 1960 елардан Татарстанда күп урынлы реактив һәм турбовинтлы Ту-124 һәм Ан-24 самолётлары файдаланыла башлый. 1971 дә — Бигеш аэропорты, 1979 да Казанда яңа аэропорт ачыла. Бөгелмә,Чистай, Куйбышев (хәзер — Болгар) шәһәрләренең, Сарман авылының реконструкцияләнгән аэропортларында очышларның даимилеге күпкә арта, пассажирларга хезмәт күрсәтү яхшыра. 1981 дә җирле һава линияләрендә Л-410 самолетларын файдалана башлыйлар. Татарстан Һ.т. Ту-134, Ту-154, Як-40, Як-42, Ан-24, Ан-26, Ил-103 самолетлары, Ми-2, Ми-8 вертолетлары б-н тулылана. 1987 дә — Казан–Берлин халыкара линиясе эшли башлый. 1992 дән Берләшкән Гарәп Әмирлекләренә, Һиндстанга, Төркиягә, Грециягә, Сүриягә, Германиягә, Болгариягә, Чехиягә, Венгриягә, 2002 дән КХРга чартер рейслары гамәлгә керә; Казан–Истанбул даими һава линиясе ачыла. 2000 елларда киң колачлы реконструкция уздырылганнан соң, халыкара «Казан» аэропорты Әрмәнстанга, Әзәрбайҗанга,

Болгариягә, Грециягә, Мисырга, Һиндстанга, Испаниягә, Казакъстанга, Берләшкән Гарәп Әмирлекләренә, Тажикстанга, Тайландка, Төркиягә, Үзбәкстанга, Финляндиягә, Россиянең 20 дән артык шәһәренә даими, сезонлы, чартер рейсларына хезмәт күрсәтә. Ш.у. «Бигеш» (халыкара), «Бөгелмә» аэропортлары, ведомство, спорт һәм кече авиация аэродромнары эшли. ТР авиакомпанияләренең һава суднолары паркында 100 гә якын берәмлек исәпләнә. Пассажирларны күчерү-ташу (мең кеше): 1940 та — 1,5 тирәсе, 1960 та — 450, 1968 дә — 1000, 1973 тә — 1500, 1980 дә — 1700, 1987 дә — 1800, 1996 да — 400, 2001 дә — 600. Күчерү-ташуларның күләме (мең *т/км*): 1960 та — 16, 1994 тә — 91, 1995 тә — 98,1, 1996 — 109,7, 2001 дә — 52,4. 2016 да респ-ка аэропортлары тарафыннан 2345,6 мең кеше пассажирлар, 3103,9 *т* йөкләр озатыла һәм кабул ителә. Пассажирлар һәм йөкләр күчерү-ташу б-н «Авиасервис», «Казан авиапредприятиесе», «КАПО-Авиа», «Тулпар Эйр», «ЮВТ-Аэро» авиакомпанияләре шөгыльләнә. Моннан тыш, вертолётлар һәм кече авиация нефть сәнәгатендә, урман хуҗалыгында һәм а.х.нда, төзелештә, коткару операцияләре вакытында, янгын сүндергәндә, медицинада, хокук тәртибен саклауда файдаланыла. ТР терр-ясендә очышларны оештыру һәм аларның иминлеге тәэмин ителү, авиапр-тиеләрнең һәм авиакомпанияләрнең лицензияләнүе һәм сертификатлануы өстеннән дәүләт күзәтчелеге Россия Транспорт министрлыгы Ространснадзорының Татарстан дәүләт авиация күзәтчелеге идарәсе тарафыннан гамәлгә ашырыла. Ш.у.к. *Авиация.*

Әд.: Ибрагимов Р.А. Крылья Татарстана. К., 1985; Ибрагимов Р.А., Вениаминов Р.Г., Урунов Б.Г. Время летать. История авиации Татарстана с 1910 по 2002 гг. К., 2003.

Р.Г.Вениаминов, Г.Я.Мәүлетова.

ҺАДИ́ Закир Һадиулла улы (16.3.1863, Оренбург губ., Бәләбәй өязе Ярмәкәй а. — 1933, Рязань өлкәсенең Касыйм р-ны Бимсала а.), язучы, педагог. Башлангыч белемне туган авылында этисеннән ала, 1875–85 елларда Самара губернасының Бөгелмә өязе Тымытык авылы мәдрәсәсендә, Рязань губернасының Касыйм шәһәрендә укытучылар курсларында укый, аларны тәмамлаганнан соң, Одесса, Харьков шәһәрләрендә, Башкортстанда, Рязань губернасының Касыйм шәһәре тирәсендәге авылларда (1923 тән Бимсала авылында) татар мәктәпләрендә укыта.

Һ. — мәгърифәтчел характердагы повесть һәм хикәяләр авторы, аларда татар авылы тормышы чагыла. Аның әсәрләренең төп проблематикасы — хатын-кызларның тигез хокуклылыгы һәм укытудагы иске тәртипләрне тәнкыйтьләү. «Бәхетле кыз» (Оренбург, 1904) хикәясе героинясы Гайшә ирексезләп тагылган никахтан катгый баш тартып, хатын-кызга кеше һәм дус дип карый белгән укымышлы Габбас муллага кия үгә чыга. Гайшә мөгәллимә булып китә, иҗтимагый мәнфәгатьләр б-н кызыксынып яши. Үгет-нәсыйхәткә корылган «Официант» исемле хикәясендә (Оренбург, 1904) яңа мәчетләр ачылу турында бәян ителә, аларга халык арасында абруй казанган укымышлы муллалар килә. «Хәер дога» (Оренбург, 1905), «Мәгъсүм» (Оренбург, 1906) хикәяләрендә Һ. кадими мәдрәсәләрне тәнкыйтьли, аларны борынгы карашлы мәгарәләргә тиңли, ә укырга дип килеп, шунда гомерләрен бушка уздырган шәкертләрне «яңа мәгарә кешеләре» дип атый («Яңа Әсхабе кәһәф», 1908). Һ.ның иң күләмле әсәрләреннән берсе — «Җи Һанша хәзрәт» повесте (1908). Авыл халкы арасында агарту эше алып барган Хәсән мулла комсыз кадимче ишан Җиһаншага каршы куела. Хәсән мулланың агарту эшчәнлеге нәтиҗәсендә авыл халкы чәчүлекләрнең уңышын күтәрүгә, сәүдә өлкәсендә уңышларга ирешә, яшәү шартларын яхшырта.

Һ.ның кайбер әсәрләре — Одесса шәһәрендә яһүдләрне талау-җәберләүләр тәэсирендә язылган повесте (1905), рус-япон сугышы турындагы поэмасы, берничә хикәясе кулъязмалары югалган. Һ. сәнгатьчә хикәяли, мәкаль-әйтемнәргә бай, тере, аңлаешлы тел б-н яза. Аның әсәрләре укучыга көчле эмоциональ тәэсир итә. Һ. иҗаты 19 йөз татар мәгърифәтчелек әдәбиятын йомгаклый һәм 1905–07 елгы Рев-ция чоры демократик әдәбиятына юл ача.

Әсәр.: Сайланма әсәрләр. К., 1957.

Әд.: Татар әдәбияты тарихы. К., 1985. Т. 2; Гайнуллин М.Х. Татарская литература XIX в. К., 1975.

ҺАДИ́ЕВ Мөхәммәтмөнир Мөхәммәт Һади улы (10.12.1876, Казан губ., Чистай өязе Яңа Әмзә а. — 10.8.1913, Казан), тарихчы, педагог, дин эшлеклесе. 1902–04 елларда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе мөгаллиме (Казан). 1905 тән мулла, Чиләбе шәһәре җамигъ мәчетенең имам-хатибы, мәдрәсә мөдәррисе, 1907 дән аның җитәкчесе. Җәдитчелек тарафдары, Чиләбедәге татар уку йортларын үзгәртеп коруда актив катнаша: аларда укытуның тавыш алымын, яңа дөньяви фәннәрне укытуны гамәлгә кертә һ.б. Чиләбе мөселман хәйрия җәмгыятен булдыруда башлап йөрүчеләрнең һәм аны оештыручыларның берсе (1906). 1912 дән Чиләбе укытучылар гимназиясендә укыта. Оренбург гыйльми архив комиссиясе әгъзасы (1911 дән). Казанның «Йолдыз» г-тасы һәм «Шура» ж-лы б-н хезмәттәшлек итә. Әл-Әфганинең «Татимма әл-бәйан фи тарих әл-әфган» («Әфганстан тарихы») хезмәтен татар теленә тәрҗемә итә. Хезмәтләре дин һәм башкорт халкы тарихы мәсьәләләренә карый.

Хезм.: Зәкәт хакында // Йолдыз.1907. 3 июнь; Башкортлар // Шура. 1909. № 10–21; 1910. № 10–13, 16; Башкорт тарихы. К., 1912.

Әд.: Атласов Һ. Мәрхүм Мөнир әфәнде (иске төшерү) // Йолдыз. 1913. 25 авг.; Шакуров Ф.Н. Развитие исторических знаний у татар до февраля 1917 года. К., 2002; Денисов Д.Н. Мусульманская община Челябинска (60-е годы XIX — нач. XX в.) // Вестн. Челябин. гос. ун-та. 2008. Вып. 27.

Ж.С.Миңнуллин, Ф.Г.Миңнеханов.

ҺАДИ́ЕВ Муллагали Бари улы (20.8.1945, Әтнә р-ны Түбән Шашы а.), компрессорлар төзү өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2002), проф.(2005). Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлаганнан соң (1968), 1985 елга кадәр компрессорлар төзү махсус КБда эшли: әйдәп баручы конструктор — төркем җитәкчесе (1974 тән), үзәктән кугыч компрессорларны тикшерү һәм сынау лаб-ясе мөдире (1978 дән). 1985 тән Казан технол. ун-тының компрессорлы машиналар һәм җайланмалар кафедрасында, проф. (2002 дән). Хезмәтләре сыеклык һәм газ механикасына, вакуум һәм компрессор техникасына, гидродинамик майлау теориясенә карый. Һ. югары йөкләм һәм чагыштырмалы шуу тизлеге шартларында эшләүче турбомашиналарның терәү-тыгызлау узелларын теоретик һәм тәжрибәви яктан тикшереп матем. модельләштерә һәм параметрик анализын ясый (эш нәтиҗәләре «Турбокомпрессор» фәнни-тикшеренү ин-ты, «Казанкомпрессормаш», «Оргсинтез» АҖдә гамәлгә кертелә). Уйлап табуга 14 авторлык таныклыгы бар. Медаль б-н бүләкләнә.



Г.М. Һадимөхәммәтов.

Хезм.: Гидродинамические, тепловые и деформационные характеристики смазочных слоёв упорных подшипников турбомашин. К., 2001; Газораспределительные станции. К., 2005; Компрессорные и газораспределительные станции. К., 2005 (автордаш).

ҺАДИ́ЕВ Таһир Галимҗан улы (15.11.1951, Балтач р-ны Чепья а.), галим агроном, а.х. фән. канд. (2001), ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2000), ТРның атказ. а.х. хезмәткәре (1996). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1978), Зәй р-нында эшли: баш агроном, «Коммунизмга юл» к-зы рәисе (1981 елдан), КПССның шәһәр ком-ты секретаре (1986 дан), «Искра» к-зы рәисе (1988 дән). 1992–2004 тә ТРның а.х. һәм азык-төлек министры урынбасары. 2004–06 да Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-ты директоры. 2006–07 дә «АгроКонсул» Идел буе инновация технологияләрен файдалануга кертү үзәге ген. директоры, ТР буенча «Россельхозцентр» федераль дәүләт идарәсе ф-лы җитәкчесе (2007 дән). Дәүләт бүләге ТРда уҗым арышының югары продуктлы сортларын булдыруда һәм җитештерүгә кертүдә катнашканы өчен бирелә. 2014 тән ТР Дәүләт Советы депутаты.

ҺАДИМӨХӘММӘ́ТОВ Гомәр Мостафа улы (5.1.1906, Уфа губ., Минзәлә өязе Яңа Бикчәнтәй а. – 21.2.1959, Ростов-Дон ш.), Сов. Союзы Герое (22.7.1944), капитан. Пед. ин-тын (Кемерево өлкәсе, Анжеро-Судженск ш.), командирлар составы белемен күтәрү курсларын тәмамлый (1941). 1915 елдан Анжеро-Судженск шәһәрендә, күмер шахтасында эшли, мәктәп директоры. 1928–30 да Кызыл Армиядә. 1941 нең ноябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 732 укчы полкта рота командиры (43 армиянең 235 укчы ди-



В.Н.Һидиятуллин.

визиясе). Көнбатыш, Калинин, 1 нче Балтыйк буе һәм 3 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләре составында Мәскәү янындагы сугышта (1941–42), Смоленск (1943), Белоруссия, Балтыйк буе (икесе дә — 1944) һәм Көнбатыш-Пруссия (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1944 нең 23 июнендә Жеребичи торак пункты янында (Витебск өлкәсе) Һ. җитәкчелегендәге рота дошман оборонасын өзгәндә батырлык күрсәтә: подразделение 2 траншея линиясен кулга төшерә һәм Новосёлки, Завязье авыллары янында дошман тылына килеп чыга. Һ. яралана, әмма ротасын кабат һөҗүмгә алып китә; Завязье авыллы дошманнан азат ителә, аның тере көчләренә һәм хәрби техникасына зур зыян килә. 1946 дан запаста. Ростов-Дон шәһәрендә яши, зоопарк директоры, «Ростовский транспортник» артеле рәисе урынбасары булып эшли. Ленин ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: Батырлар китабы – Книга Героев. К., 2000.

М.З.Хәбибуллин.

ҺАДИУ́ЛЛИН Әмир Гыйльмулла улы (1.9.1949, Алабуга р-ны Татар Дөм-Дөме а. — 11.10.2005, шуда ук), инженер-механик, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (2000). Казан а.х. ин-тын тәмамлый (1978). Алабуга р-нында эшли (1966–2005): «Сельхозтехника»ның Морт бүлегендә тракторчы, «Красный луч» к-зында шофёр, өлкән инженер (1978 елдан), «Батыр кул» к-зында баш инженер (1980 нән), Тукай исем. (1984 тән), «Яшь көч» (1989–90) к-зларында партия ком-ты секретаре, «Яшь көч» а.х. җитештерү кооперативы рәисе (1996–98 һәм 2000–05). 1998–2000 дә финанслар идарәсе башлыгы, район хакимияте башлыгының 1 нче урынбасары. Дәүләт бүләге фәнни нигезләнгән орлыкчылык системасы нигезендә уҗым арышының юга-ры продуктлы сортларын булдыруда һәм җитештерүгә тиз кертүдә катнашканы өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

И.Н.Афанасьев.

ҺАДИУ́ЛЛИН Зәйнулла Шәйхулла улы (15.5.1926, Мамадыш кантоны Акман а.), а.х. пр-тиесе җитәкчесе, ТАССРның атказ. а.х. хезмәткәре (1963). 1940 елдан Мамадыш р-нының «Таң» к-зында (1961 гә кадәр — «Чулпан» к-зы) эшли, 1953–95 тә рәис. Һ. җитәкләгән елларда колхозда җитештерү-техник һәм социаль-мәдәни инфраструктура булдырыла, Дүсмәт, Акман, Көрәш-Ерыкса, Яковка, Иске Комазан, Малмыж авылларында газ, су, телефон кертелә. Бөртекле культураларның уңышы 1 *га* дан 7,56 *ц* дан (1953) 43 *ц* га (1995) кадәр арта, уртача еллык савым һәр сыердан 661 *кг* нан 3214 *кг* га кадәр, бөртекле ашлык җитештерү 9,1, сөт — 5,9, ит — 19,1 тапкыр арта. 1971–75 тә ТАССР ЮС депутаты. Бөек Ватан сугышында катнаша. Октябрь Революциясе, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

ҺАДИУ́ЛЛИНА Гөлнара Нәсим кызы (14.4.1967, Казан), икътисадчы, икътисад фән. д-ры (2005), проф. (2008). ТРның атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2007). Казан ун-тын тәмамлый (1991). 1994 елдан Казан техник ун-тының теория һәм хокук кафедрасында (2005 тән каф. профессоры). Бер үк вакытта, 2006 дан, Россия Эчке эшләр министрлыгының Казан юридик ин-тында икътисад теориясе, хокук статистикасы, матем. һәм информатика каф. профессоры. Полиция полковнигы. Хезмәтләре икътисад һәм икътисади фикер тарихына карый.

Х е з м.: Экономические воззрения представителей татарской зарубежной диаспоры. М., 2003; Экономические идеи в наследии Мусы Акъегетзаде (1864–1923). К., 2003; Экономическая теория: Учеб. пособие. К., 2004 (автордаш); Учёт и аудит в условиях экономических изменений. К., 2009 (автордаш).

ҺАУА́ (Библиядәге Ева), күп кенә халыкларның изге китапларында һәм мифологиясендә — беренче хатын-кыз һәм кешелекнең нәсел анасы. Адәмнең кабыргасыннан барлыкка китерелгән һәм аның хатыны: *Корьән*-*дә* исеме аталмыйча телгә алына. Христиан мифологиясендә елан кыяфәтендә килгән *Иблис* Һ. б-н Адәмне җәннәттәге тыелган җимеш б-н сыйлый, гөнаһ кылдырта. Һ. б-н Адәм бу эшләре өчен җәннәттән бер-берсеннән аерым рәвештә җиргә сөрелә. *Хәдисләрдә* әйтелгәнчә, Адәм һәм Һ. Мәккә янындагы Гарәфә тавында очрашалар, Аллаһ боерыгы буенча Адәм шунда *Кәгъбә* төзи һәм алар кешелек тарихында беренче булып *хаҗ* кылалар. Мөселман риваятьләре буенча, Һ.ның гөнаһлары өчен хатыннар бала тудырган вакытта физик газапларга дучар ителә; тәкъва хатыннар оҗмахка керә. Хәзерге татар телендә «Һ.» сүзе ялгызлык исеме сыйфатында да файдаланыла.

Әд.: Ислам: Энцикл. словарь. М., 1991.

ҺИДИЯТУ́ЛЛИН Вагыйзь Назыйр улы (3.3.1959, Пермь өлкәсенең Губаха ш.), спортчы (футбол), СССРның атказ. спорт остасы (1988). Спорт интернат-мәктәбендә тәрбияләнә (Ростов-Дон ш.). 1976–80, 1986–88 елларда «Спартак» командасында уйный, 1981–82 дә — ЦСКА, 1994 тә — «Динамо» (барысы да Мәскәү), 1984–85 тә — «Карпаты» Армия СК (Львов ш.), 1988–90 да — «Тулуза», 1990–93 тә — «Монтобан», 1993–94 тә — «Ля-Беж» (барысы да Франция) команда-ларында уйный. СССР (1978–90) һәм Олимпия (1980) җыелма командалары составында 61 матч уздыра (8 гол кертә). СССР (1977 — 1нче лига; 1979; 1980 — көмеш; 1986 — бронза; 1987), Россия (1994 — көмеш), Европа (1988 — көмеш; 1976 һәм 1977 — СССР яшүсмерләр җыелма командасы составында), дөнья (1977 — СССР юниорлар җыелма командасы составында) чемпионатларында, Олимпия уеннарында (1980 — бронза) җиңүче (призлар иясе). СССР футбол федерациясе Кубогы (1987), Россия Кубогы (1994–95) иясе. 1995 тән футболчылар һәм тренерлар профсоюзы президенты, 2002 дән Россия футбол берлеге әгъзасы, 2010 нан Гомумроссия футболчылар профсоюзы үзәк советын җитәкли.

ҺИДИЯТУ́ЛЛИН Рим Зиннәтулла улы (25.2.1940, БАССРның Кушнаренко р-ны Тартыш а.), шагыйрь, БАССРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1996). Башкорт ун-тын тәмамлый (1967). 1965–87, 1992–2002 елларда «Кызыл таң» (Уфа ш.) г-тасында, 1987–92 дә «Сәнәк» ж-лында әдәби хезмәткәр, баш мөхәррир урынбасары. Һ. поэзиясендә туган як пейзажлары һәм якташлар образлары сурәтләнә. «Хәерле иртә» (Уфа, 1983), «Хәерле көн» (Уфа, 1997) җыентыкларына кергән шигырьләре күргән һәм яшәгән вакыйгаларны эмоциональ аңлау, дөньяга фәлсәфи караш б-н сугарылган.

Әд.: Гомәрова Г. Рим Идиятуллин иҗаты: шагыйрь турында сәхифә. Уфа, 2000.

ҺИДИЯТУ́ЛЛИН Ринат Гайсә улы (26.4.1941, Үзбәкстан ССРның Денау ш.), энергетик, техник фән. д-ры (1988), проф. (1991), ТРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (2001). 1964 елда Ташкент тимер юл транспорты инженерлары ин-тын, 1976 да Мәскәү энергетика ин-тын тәмамлый. 1966–76 да Ташкент тимер юл транспорты инженерлары ин-тында электр җи һәзлары секторы мөдире; 1976–90 да Ташкент сугару һәм механикалаштыру ин-тының тракторлар һәм автомобильләр кафедрасында. 1990–92 дә Та җикстан а.х. ин-тында тракторлар һәм автомобильләр каф. мөдире. 1992 дән Казанда: Татар кадрлар белемен күтәрү һәм агробизнес ин-ты проректоры; 1995 тән Казан энергетика ун-тында, энергетика системалары электромеханикасы һәм көч бирү җи һәзлары каф. мөдире, сәнәгать пр-тиеләрен электр б-н тәэмин итү ф-ты деканы (1997–2000). Хезмәтләре энергетика машиналарындагы электр җи һәзларының ышанычлылыгын хисаплау теориясенә һәм ысулларына карый. Һ. а.х. машиналарына егәрлек бирә торган көйләүле электр тапшыргыч аппаратлар эшли; энергия саклагыч технологияләр эшләү өчен электр б-н тәэмин ителү системасын тикшерә; электромеханика системаларының оптималь конструктив элементларын уйлап таба. Уйлап табуга 6 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Надёжность тяговых электрических машин. Таганрог, 1987; Электромеханика. Ч. 1. Электрические цепи. К., 1997 (автордаш); Электрические машины. К., 1999 (автордаш); Проблемы энергоснабжения предприятий в промышленности: Теория и практика. К., 2002 (автордаш).

ҺИҖРӘТ (гарәп. هجرت), Мөхәммәд пәйгамбәр һәм аның сәхабәләренең Мәккәдән Мәдинәгә (исламга кадәрге атамасы Ясриб) күченүләре. Моның төп сәбәбе — Мөхәммәднең бераллалык, үлгәннәрнең Ахирәттә кабат тереләчәге, Кыямәт көнне гөнаһлыларны җәза көтәчәге турындагы фикерләре урын алган тәүге вәгазьләренең Мәккә мөшрикләренең

һәм җирле сәүдә олигархларының кискен каршылыгына очравы. 622 елның 16 июленә каршы төндә Мөхәммәд, ул шәһәрдән китеп, Мәдинәгә барып урнаша. Гомәр хәлифә (634–644) тарафыннан Һ. елы мөселман ел исәбенең башлануы дип игълан ителә. Аның башлангыч датасы итеп 622 нең 1 нче мөхәррәме (622, 16 июль) санала. Мөселман һиҗри ай календарендагы даталарны Европа кояш календарена күчерү өчен махсус таблицалар файдаланыла. Исламның формалашуында һәм таралыш алуында Һ. хәлиткеч роль уйный: туганлык элемтәләрен өзү нәтиҗәсендә яшь мөселман җәмгыяте тар ыруглык кысаларыннан чыга һәм яңа шартларда булачак ислам дәүләтенең үзәгенә әверелә. Мәдинә яһүдиләре б-н дин проблематикасы буенча бәхәсләр ш.у. ислам дини доктринасын эшләп бетерергә һәм камилләштерергә ярдәм итә.

Әд.: Синхронистические таблицы для перевода исторических дат по хиджре на европейское летоисчисление. Л., 1940; Уотт У.М. Мухаммад в Медине. М.–СПб., 2007.

ҺИЛАЛЕТДИ́НОВ Әлфәрит Низам улы (16.1.1929, хәзер Казакъстан Респ-касы Кызыл Урда өлкәсенең Яңа Курган р-ны Бишарык ст. – 2010, Казакъстан Респ-касы Алма-Ата ш.), микробиолог, биол. фән. д-ры (1967), Казакъстан ССР ФА академигы (1983), Казакъстан ССРның атказ. фән эшлеклесе (1971). Мәскәү ун-тын тәмамлый (1951). Казакъстан ССР ФА учреждениеләрендә эшли: 1954 елдан Туфрак белеме ин-тында (1957 дән лаб. мөдире), 1966 дан микробиол. һәм вирусология ин-ты директоры, 1983–88 дә Биол. фәннәре бүлеге акад.-секретаре, проф. (1968). Хезмәтләре микроорганизмнар экологиясенә, биотехнологиягә карый. Сәнәгать пр-тиеләре агынты суларын микробиол. чистартуның фәнни нигезләрен һәм рудадан металларны селтесезләндерүнең бактериаль ысулларын эшли. Уйлап табуга 25 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Биологическая мобилизация минеральных соединений. А.-А., 1966; Микробиологические превращения азотсодержащих соединений в почве. А.-А., 1976; Микробиологические превращения металлов. А.-А., 1984.

ҺИЛА́ЛОВ Исмәгыйль Гобәйдулла улы (15.1.1898, Троицк ш. — 24.7.1992, Казан), музыкант-башкаручы, мандолинада уйнаучы, концерт һәм театр администраторы. Иждади эшчәнлеген Троицкида беренче милли кыллы музыка уен кораллары ансамбльләрендә һәм театр оркестрларында катнашучы — мандолинада һәи скрипкада уйнаучы буларак башлап җибәрә. Актив концерт эшчәнлеге алып бара. Һ.ның башкаруы зур остalтыгы һәм мандолина өчен язылган татар халык һәм композиторлар музыкасын үзенчәлекле интерпретацияләве б-н аерылып тора. 1934–38 елларда Мәскәү консерваториясе каршындагы Татар опера студиясенең уку-укыту бүлеге мөдире. Казанда һәм СССРның башка шәһәрләрендә концерт-иҗат оешмалары, татар театрлары администраторы сыйфатында талантлы оештыручы буларак таныла.

Ф.Ш.Салитова.

ҺИЛА́ЛОВ Рәмзи Ибраһим улы (13.12.1923, БАССРның Баймак р-ны Темәс а. — 11.8.2009, Казан), язучы. Рус телендә яза. Казан пед. ин-тын (1947) һәм СССР Тышкы эшләр министрлыгының Югары дипломат-лар мәктәбен (1949) тәмамлый. 1950 елдан «Учительская газета», «Советский спорт», «Советская торговля», «Советский патриот» г-таларының үз хәбәрчесе. «Лачын төркемдә качмый» («Сокол не прячется в стае», 1977), «Наган кабында кала» («Наган остаётся в кобуре», 1979), «Егет иярдә туа» («Джигит рождается в седле», 1982), «Батыр легендага күчә» («Батыр уходит в легенду», 1984), «Детектив бәреп керә» («Детектив вторгается», 1991) документаль повестьлары авторы. Бөек Ватан сугышында катнаша. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, 3 нче дәрәҗә Дан орденнары б-н бүләкләнә.



И.Г.Һилалов.

Әд.: Морозова Т. Мужество инакомыслия // Татарстан. 1991. № 4.

ҺӨДҺӨ́Д (Upupa epops), кош; шул ук исемдәге семьялыктан бердәнбер төр. Евразия, Африкада таралган. Татарстан терр-ясендә барлык р-ннарда очрый. Оя коручы күчмә кош. Апрельдә очып килә. Гәүдәсенең озынлыгы 30 *см* га кадәр, авырлыгы 68–75 *г*. Җете җирән төстә, корсагы алсу. Канат һәм койрыгы киң ак буйлы кара. Башында очлары кара булган җирән каурыйлы зур бүрекчәсе бар. Томшыгы озын, нәзек, җиңелчә бөгелгән. Тәпиләре кыска, нык, җирдә хәрәкәт итүгә җайлашкан. Кисәк-кисәк канат кагынып, акрын гына оча. Сирәкләнгән урманнарда, урман буйларында, алан, кисенде һәм янган урманнарда (янтыкларда), агачлар үскән ерымнарда оялый. Оясын агач куышында, өннәрдә, корылмаларда кора. Оялары (аеруча берничә кат кулланылганнары) бик пычрак, тизәк күп җыелганлыктан, исле; оя кору чорында ана затларның һәм кечкенә кош балаларының койрыкча бизендә тәмсез исле майсыман сыекча барлыкка килә, курыккан вакытларында алар аны тышка сиптерә. 3–12 аксыл йомырка сала. Вак умырткасызлар (бөҗәкләр, аларның личинкалары, ш.у. курчаклары, үрмәкүч, кыргаяк, күбаяклылар һ.б.) б-н туклана. ТРның Кызыл китабына кертелгән.



Һөдһөд.

ҺӨНӘРИ́ БЕЛЕ́М БИРҮ́, квалификацияле эшчеләр һәм һөнәрчеләр, түбән буын идарәсе һәм житештерүгә өйрәтү белгечләрен (мастерлар, техниклар, десятниклар) әзерләү. Россиядә беренче һөнәри уку йортлары 1860 елларда барлыкка килә, нигездә, алар шәһәр һәм земство үзидарә органнары башлангычында ачылалар һәм шулар карамагында булалар. Һәр уку йорты җирле хакимият органнары тарафыннан расланган үз уставы буенча эшли; уку срогы һәм уку программалары Халык мәгарифе министрлыгы күзәтүендә булмый. Төбәк терр-ясендә шәһәр үзидарә органнары тарафыннан Казан Александр (1875) һәм Алабуга (1887) һөнәр уч-щеләре ачыла.

1895 тә Халык мәгарифе министрлыгында Сәнәгать уч-щеләре департаменты булдырыла, һөнәри уку йортларының типлаштырылган уставлары раслана (аларны күзәтү губерна халык уч-щеләре дирекцияләренә тапшырыла), Һ.б.б.не үстерүгә дәүләттән акча бүлеп бирелә башлый. Шулай итеп, күп дәрәҗәле Һ.б.б. системасы формалаштырыла. Заманча урта махсус белем бирүгә туры килгән югары звено урта техник уч-щеләрдән тора. Аларда, нигездә, техниклар, ш. у. һөнәри уку йортлары өчен укытучы кадрлар әзерләнә; уч-щене иң яхшы тәмамлаучыларга югары техник уку йортларына керү хокукы бирелә. Түбән техник уч-щеләр һәм статусы буенча аларга тигез булган һөнәр уч-щеләре ш.у. югары квалификацияле белгечләр әзерлиләр, алардагы һөнәри әзерлек гомуми белем бирү б-н туры килә, аларны тәмамлаучылар җитештерүдә яисә һөнәри уку йортларында техниклар, десятниклар, мастерлар була.

Һөнәри укучылар мәктәпләрендә һәм түбән һөнәр мәктәпләрендә һөнәрчеләр һәм эшчеләр әзерләнә, һөнәри әзерлек гомуми белем б-н, әмма башлангыч мәктәп базасында тулыландырыла. Һ.б.б.нең түбән буынын һөнәри укыту остаханәләре тәшкил итә.

Төбәк терр-ясендә *Казан сәнәгать училищесе* (1897) эшли, аның составында урта химия-технол., түбән механик, химия-технол., төзелеш уч-щеләре була. Моннан тыш Чистай шәһәрендә һөнәр уч-щесе (1896 да ачылган түбән һөнәр мәктәбеннән 1907 дә оештырыла), Алабугада һөнәри укучылар мәктәбе (1899 да уставтан тыш һөнәр уч-щесеннән үзгәртелә), Буада (1892), Бөгелмәдә (1896), Зөядә (1906), Лаешта (1910), Мамадышта (1912) түбән һөнәр мәктәпләре, авылларда якынча 20 һөнәр укыту остаханәләре, ш и. *Питрәч сәнгать-һөнәр укыту остаханәсе, Балык Бистәсе сәнгать-һөнәр остаханәсе, Чабаксар сәнгать-һөнәр остаханәсе* ачыла. Александр һөнәр уч-щесе 1917 гә кадәр Казан шәһәр идарәсенә буйсына һәм үз уставы буенча эшли. Барлык һөнәри уку йортларында якынча 2 мең укучы санала, 100 дән артык укытучы эшли.

Окт. рев-циясеннән һәм земство һәм шәһәр үзидарә органнары бетерелгәннән соң, барлык

һөнәри уку йортлары дәүләт карамагына күчә. Гражданнар сугышы елларында аларның күбесе ябыла, калганнары расланмаган мәгариф стандартлары б-н эшли. 1919 да СССР Мәгариф халык комис-ты системасында Һөнәри белем бирү баш идарәсе (Главпрофобр) булдырыла, 1920 нең августында гомуми урта белем һәм һөнәри квалификация бирүче һөнәри-техник мәктәпләр, 4–5 еллык уку йортлары турында Нигезләмә раслана. Мондый уку йортлары киң таралыш алмый, ТАССРда Казан, Чистай, Алабуга һөнәр уч-щеләре һөнәри-техник мәктәпләр итеп үзгәртелә.

1922 дән сәнәгать пр-тиеләрендә булдырылган фабрика-завод өйрәнчеклеге (ФЗӨ) мәктәпләре системасы үсеш ала; укыту-методика мәсьәләләре буенча алар һөнәри белем бирү баш идарәсе карамагында була. Уку вакыты 2 ел тәшкил итә, укыту җитештерүдә эшләү б-н бергә алып барыла. 1929–30 да Һ.б.б.нең үзәкләштерелгән җитәкчелеге бетерелә, һөнәри-техник мәктәпләр ябыла, ФЗӨ пр-тиеләр карамагына тапшырыла, уку вакыты 1 елга кадәр, ә күп белгечлекләр буенча ярты елга кадәр кыскартыла. 1933 тә ТАССРда 22 ФЗӨ мәктәбе санала, аларда 3 мең укучы укый. Интенсив индустрияләштерү шартларында һөнәри белем бирүнең үзәкләштерелгән системасы булмау, укыту срогының кыскалыгы һәм гадилеге югары квалификацияле эшчеләрнең кискен җитешмәвенә китерә. СССР ЮС Президиумының 1940 ел 2 октябрь Указы б-н Дәүләт хезмәт резервлары баш идарәсе булдырыла (1946 дан — министрлык), аңа барлык һөнәри уку йортлары һәм уку йортларын тәмамлаучыларны оешмаларга бүлү тапшырыла; ФЗӨ б-н беррәттән 2 еллык һөнәр уч-щеләре булдырыла. ТАССРда 1941 ел ахырына 9,4 мең укучы б-н 11 һөнәр уч-щесе эшли, ФЗӨдә 5 мең кеше укый. Бөек Ватан сугышы елларында 58 мең квалификацияле эшче әзерләнә, 1946–55 тә һөнәр уч-щеләрен 29,5 мең, ФЗӨ мәктәпләрен 22 мең кеше тәмамлый. 1958–59 да Һ.б.б.дә реформа уздырыла, Дәүләт хезмәт резервлары министрлыгы Һөнәри белем бирү дәүләт ком-ты итеп, һөнәр уч-щеләре һәм ФЗӨләр 2 еллык шәһәр һәм авыл һөнәри-техник уч-щеләре (ПТУ) итеп үзгәртелә. Аларга 8 еллык мәктәпне тәмамлаучылар кабул ителә; тулы урта мәктәп базасында берьеллык техник уч-щеләр булдырыла. 1960 еллардан авыл ПТУ челтәре үсеш ала, аларда авыл механизаторлары әзерләнә (ТАССРның күп районнарында ачыла). 1970 тә ТАССРда 69 ПТУ эшли, 29 мең кеше тәмамлый. КПСС ҮК һәм СССР МС-ның 1969 ел 2 апрель карары б-н ПТУлар акрынлап 3 еллык урта һөнәри-техник уч-щеләргә үзгәртелә, аны тәмамлаучылар диплом б-н бергә урта белем турында аттестат ала. 1984 кә ТАССРда уч-щеләрнең яртысыннан артыгы урта һөнәри-техник уч-щегә (СПТУ) әверелә. КПСС ҮКның 1984 ел апрель Пленумы карары б-н СССР мәгариф системасында реформа кысаларында барлык ПТУлар СПТУ итеп үзгәртелә, укучылар җыю планы кискен киңәйтелә.1984 тә ТАССРның 124 уч-щесендә 69 мең кеше укыса (22% ы 8 класс тәмамлаучылар), 1988 гә СПТУлар саны 150 гә җитә, Һ.б.б. учреждениеләренә тулы булмаган урта мәктәпне тәмамлаучыларның 37% ы җибәрелә (бу күрсәткечне 47% ка җиткерү планлаштырыла). СПТУлар челтәренең көчәйтелгән үсеше һәм тизләтелгән гомуми урта белем бирүнең тискәре яклары да була. Гомуми урта белемнең һәм ПТУларда һөнәри әзерлек дәрәҗәсе түбән кала, аларны тәмамлаучыларның яртысыннан азрагы гына белгечлек буенча эшли. Казан һәм Чаллы ПТУларына авыр тәрбияләнүче укучыларны туплау яшүсмерләрнең криминаль төркемнәре үсешенә китерә. КПСС ҮКның 1988 ел февраль Пленумы карары б-н гомуми һәм Һ.б.б. җитәкчелеге берләштерелә (ТАССРда һөнәри белем бирү дәүләт ком-ты кыскартыла, һөнәри уку йортлары Мәгариф министрлыгы карамагына күчә, укучылар җыю планы бетерелә, уч-щеләр мөстәкыйль рәвештә белгечлекләр исемлеген һәм укыту планын булдыру мөмкинлеген алалар).

Базар икътисадына күчү Һ.б.б. системасында кризиска китерә. 1990 елларда РФдә башлангыч Һ.б.б. уку йортларының яртысыннан артыгы ябыла, укучылар саны 5 тапкыр кими. ТРда дәүләт ярдәме аркасында уч-щеләрнең күп өлеше саклана, әмма укучылар саны 2 тапкырдан артык кими, матди база начарлана. 2017 дә Татарстанда 91 һөнәри уку йорты, ш.и. 40 лицей, 2 көллият, 52 уч-ще, 40 а.х., 3 елга һәм 2 тимер-юл уку йорты эшли. 29 уку йорты Казанда, 7 се Чаллыда, 7 се Түбән Камада, 24 е ТРның башка шәһәрләрендә, 31 е район үзәкләрендә һәм авыллларда урнашкан. Башлангыч Һ.б.б. учреждениеләрендә 68817 кеше укый.

Әд.: Низшее профессиональное образование в Казанской губернии. К., 1909; Очерки истории профессионально-технического образования в СССР. М., 1981.

ҺӨНӘРИ́-ТЕ́ХНИК УЧИ́ЛИЩЕЛӘР, к. *Һөнәри белем бирү*.

ҺӨРЛЕГӘ ВӘ ҺӘМРА́, гомумтөркитатар дастаны. Татарларда, казакъларда, төрекмәнәрдә, уйгырларда һ.б. төрки халыкларда таралыш алган. Дастанда падишаһ улы Һәраның хан кызы Һөрлегәгә мәхәббәте хикәяләнә. Күпсанлы газаплар һәм югалтулар аша үтеп, бертуганнарының хыянәтен кичереп, үлгәннән соң терелеп, Һәмра сөйгәне б-н кавыша. Мавыктыргыч хикәяләү, баш герой-ның мәрхәмәтле, батыр һәм намуслы булуы, дастанның гуманистик юнәлеше аның популярлыгын тагын да арттыра. Дастанның үзбәк, казакъ һәм уйгыр версияләре 19 йөздән башлап ташбасма ысулы б-н берничә тапкыр нәшер ителә. Казакъ һәм уйгыр версияләре акад. В.В.Радловның «Төрки кабиләләрнең халык әдәбияты үрнәкләре» («Образцы народной литературы тюркских племён», ч. 1–10, 1885) хезмәтенә кертелә, төрекмән версиясе 1941 елда нәшер ителә. Дастанның 1978 дә Менделеев р-нында табылган татар телендәге (17 йөз) күчермәсе сакланган. Аның сюжеты татар әкиятләре формасында да яши. 1941 дә әкиятче М.Хәмидуллиннан «Нурга зарлы кош» әкияте язып алына.

Әд.: XVIII гасыр татар әдәбияты: Поэзия. К., 2006; К о р-о г л ы Х. «Хурлукга и Хемра» и «Сият и Хемра» // Народы Азии и Африки. 1973. № 1; А х м е т з я н о в М. Татарская версия дастана «Хурлуга и Хемра» // Новые пласты литературного наследия. К., 1990.

М.И.Әхмәтҗанов.

ҺУННА́Р (Unnos, Huni, Hunni), 2–5 йөзләрдә Көнчыгыш һәм Үзәк Европада этносәяси берләшмә (һуннар державасы) төзегән ыруг кланы (идарә итүче ыруг). Килеп чыгышлары б-н Һ. Монголиядәге һәм Көнчыгыш Төркестандагы державалары таркалганнан соң Көнбатыш Себергә, Арал буе һәм Көньяк Урал янына күченгән төрки-монгол *хунну* кабиләсенең көнбатыш өлешенә барып тоташа. Көнбатышка күчү юлында социаль-мәдәни үсешнең югарырак баскычында торган Һ. төрле төрки (огур), угор һәм Иран (сармат-алан һәм сак-массагет) кабиләләренә зур йогынты ясыйлар. 160–80 елларда Идел аръягына килгән Һ. антик әдәбиятта «һуни» буларак билгеле кабилә берләшмәсе төзиләр. Тел ягыннан һәм этномәдәни нисбәттә ул Үзәк Азия хуннуларыннан аерылып тора (дәвамчанлык социаль оешуда һәм этнонимга мөнәсәбәттә саклана).

3 йөз уртасыннан Һ. актив сугыш хәрәкәтләре башлап җибәрәләр, 375 тә аланнарны, король Ерманарихның – остгот һәм Атанарихның вестгот берләшмәләрен тар-мар итәләр, Рим империясе чикләренә килеп чыгалар. Аланнарны һәм готларны җиңү *Халыкларның бөек күчешенең* яңа этабына башлангыч бирә. Көнчыгыш һәм Үзәк Европаның дала зонасы терр-ясендә (Идел буеннан Дунай буена кадәр) Һ. идарәчеләр җитәкчелегендәге этносәяси берләшмә төзиләр, ул Төньяк Кара диңгез буенда күченеп йөри. Һ. державасы төрле кабиләләрнең идарә итүче һун кланы җитәкчелегендәге хәрби союзы берләшмәсеннән гыйбарәт була. Ихтимал, Һ. үзләре, Үзәк Азиядән һәм Көньяк Себердән кысрыклап чыгарылган кабиләләрнең бер өлеше кебек үк, төрки телле булып калалар, әмма асылда держава халкы күптелле була. Социаль яктан Һ. дәүләт оешу баскычында торалар. Аларның державасы башында идарә итүче кландагы юлбашчы тора, аның хакимияте нәселдән нәселгә күчми һәм нәселдәге өлкән кешегә тапшырыла. Ш.у., антик чыганаклар мәгълүматларына караганда, монголоид кыяфәтле ыруг аксөякләре аерылып торган. Һ. ның ыруг аксөякләре үзләрен өстен саныйлар, бу, аерым алганда, баш сөягенең ясалма деформацияләнүе һәм җирләү йолаларында б-н ассызыклана. Һ. державасы халкы дини ышанулары буенча нигездә мәҗүсилеккә табына, әмма алар арасында христианнар да була.

Һ. ның төп шөгыле – күчмә терлекчелек, аучылык. Күчмә ставкалардан тыш, һун аксөякләре яшәгән нығытмалы кечерәк шәһәрчекләре булуы да билгеле. Һ. державасы тормышында ясак җыю максатында оештырылган һөҗүмнәр һәм сугыш хәрәкәтләре зур роль уйный. Держава көчәйгән чорда һун идарәчеләре Алгы Көнчыгышка (398) һәм Рим империясенә (4 йөз ахыры) яулар оештыралар. Якынча 412 дән Кара диңгез буен-

да Һ. державасы б-н Доната, аның вафатыннан соң Ругила (432 дән) җитәкчелек итә, ул Көнбатыш Рим империясе б-н союзга кереп, вестготларны җиңә, моның өчен аңа Паннония бирелә. Иң югары куәтенә Һ. державасы Аттила (434 – 53) идарә иткәндә ирешә. Ул Көнчыгыш һәм Көнбатыш Рим империяләренә герман кабиләләренә (вестготлар, вандаллар, баварлар, бургундларга) каршы беренчә уңышлы поход ясый. Аттиланың вафатыннан соң, аның уллары арасында Һ. державасының таркалуына китергән үзара ызгышлар башлана. Аттиланың өлкән улы Эллак һәлак була, ә Денгизих һәм Ирник исемле уллары Һ. ның бер өлеше башында Кара диңгез буена кайталар, анда акацир кабиләләре төп роль уйный башлый. 5 йөз ахырында Идел-Урал төбәгеннән бәреп кергән огур-болгар кабиләләре (сарагурлар, уроглар, онногурлар һ.б.) Һ.ның Евразиядәге хакимлеген тәмам юкка чыгаралар. Рим империясен җимерүдә һәм төрки телле кабиләләргә Европага юл ачкан Халыкларның бөек күчеше чорында кабиләләрнең актив күченүендә Һ. державасы аерым урын тота.

Көнчыгыш Европа терр-ясендә Һ. чорына караган археол. истәлекләр сакланып калган. Элгәреге сармат-аланнарныкыннан шактый аерылып торган курганлы каберлекләр табыла, аларга курганнар астында яндырулар, учак урыннары хас: мәетләрне ат яисә аның тиресе б-н бергә җирләгәннәр. Һ. ның матди культурасына хас элементлар – ритуаль бронза казаннар, өч канатлы ук очлыклары, ныклы иярләр. Киемнәрне, корал һәм көнкүреш предметларын алтын б-н бизәгәннәр, кыйммәтле ташлар һәм асылташлар б-н инкрустацияләгәннәр.

Әд.: Иностранцев К.И. Хунны и гунны. Л., 1926; Толль Н.П. Скифы и гунны. Из истории кочевого мира. Прага, 1928; Бернштам А.Н. Очерк истории гуннов. Л., 1951; Гумилёв П.Н. Хунну. Срединная Азия в древние времена. М., 1960; шул ук. Хунны в Азии и Европе // Вопросы истории. 1989. № 6/7; Дерфер Г. О языке гуннов // Зарубежная тюркология. М., 1986; Засецкая И.П. Культура кочевников южно-русских степей в гуннскую эпоху (конец IV – V вв.). СПб., 1994; Буданова В.П., Горский А.А., Ермолова И.Е. Великое переселение народов: Этнополитические и социальные аспекты. М., 1999; Movavesi R.G. Attilas Tod in Geschichte und Sage. Bdpst., 1926; Thompson E.A. A history of Attila. Oxf., 1948; Altheim F. Attila und die Hunnen. Baden-Baden, 1951.

И.Л.Измайлов.

Ц

ЦАГАРЕ́ЛЛИ Юрий Алексеевич (6.4.1946, Мәскәү өлкәсенең Химки ш.), психолог, пед. фән. д-ры (1990), проф. (1992). 1971 елда Казан консерваториясен тәмамлый, 1974 тән шунда ук эшли, 1982 дән пед. һәм психол. каф. мөдире. 2000 нән Икътисад, идарә итү һәм хокук ин-тында (Казан), бер үк вакытта, 1990 нан, системалы психол. диагностика өчен җайланмалар эшләү һәм җитештерү б-н шөгыльләнүче Халыкара «Акцептор» берләшмәсенең ген. директоры. Хезмәтләре муз. иҗат психологиясе, психол. диагностика мәсь әләләренә карый.

Х е з м.: Психология музыкально-исполнительской деятельности. Л., 1989; Теория и практика системной диагностики человека. К., 2002.

ЦӘ́ЛИКОВ (чын фамилиясе Цалык-каты) Әхмәтбәк Тимербулат улы (1882, Төньяк Осетия Ногкау а. — 2.9.1928, Варшава), сәясәт эшлеклесе. Мәскәү ун-тының юридик ф-тын тәмамлый (1904). 1905–07 елларда-гы рев-циядә катнаша (Владикавказ ш.). РСДРП әгъзасы, меньшевик, меньшевикларның «Наше дело» (1906), «Возрождение» (1908–09) вакытлы басмалары б-н хезмәттәшлек итә. «Сүз» г-тасын чыгара (Мәскәү, 1915–16). Мөселманнарның милли яңарыш идеяләрен пропагандалый. Беренче бөтендөнья сугышы (1914–18) алдыннан Тереката мөселманнар хәрәкәтен җитәкли. 4 нче Дәүләт Думасының мөселманнар фракциясе каршындагы бюро әгъзасы. 1917–18 дә Петроград Эшче һәм солдат депутатлары советы әгъзасы, Бөтенроссия мөселманнарының беренче корылтае эшендә катнаша (1917 нең мае, Мәскәү), аның Президиумы әгъзасы; Россиянең милли-дәүләт төзелеше турында доклад б-н чыгыш ясап, «Россия үзәкләштерелмәгән, демократик парламент республикасы булырга тиеш. Россия мөселманнарының мәдәни-милли мохтарияты ил конституциясе б-н иҗтимагый-хокукый институт буларак гарантияләнергә тиеш» дип белдерә. *Бөтенроссия мөселманнарының Милли Шурасы* (Милли Шура) рәисе булып сайлана; «Известия Временного Центрального бюро российских мусульман» («Россия мөселманнарының вакытлы мәркәз бюросы хәбәрләре») г-тасы мөхәррирe (1917 нең июне –декабре). Бөтенроссия мөселманнарының икенче корылтаенда (1917 нең 21 июле – 2 августы, Казан) Учредительләр җыенында мөселман фракциясен булдыру турында доклад б-н чыга, мөселманнарны сайлау алды компания-сендә бердәмлек күрсәтергә чакыра. Демократик утырышта (1917 нең сент.) катнаша, хакимиятне Советларга тапшыруга каршы чыгыш ясый, Парламент алды җыены (аның составына керә) оештыру ягында була. Октябрь рев-циясен кабул итми, И.В.Сталин-



Ә.Т. Цаликов.



П.А. Цаплин.

ның РСФСРның Милләтләр эшләре буенча халык комис-ты каршындагы Мөселман комис-тын җитәкләү тәкъдимен кире кага. Учредительләр җыены әгъзасы, 1918 нең 5 гыйнварында үз чыгышында мөселман социалистлар фракциясе исеменнән Учредительләр Җыенын тулы хакимият буларак танырга өнди, Россияне Федератив респ-ка итеп, ш.у. аның составында оешкан «Идел буе», «Көнъяк Урал», «Төркестан» кебек штатларны танырга; Россиядәге барлык халыкларның Милли хәрби частьлар оештыруга хокукы б-н исәпләшергә чакыра. 1918 дә Тифлис шәһәрендә Кавказ тау халыклары Мәҗлесен җитәкли. 1919 да генерал А.И.Деникин армиясе б-н көрәшү өчен төзелгән Дагстан Оборонасы Советы әгъзасы. Грузиядә Совет хакимияте җиңгәннән соң (1921 нең февр.), Прагага эмиграциягә китә, анда 1924–25 тә «Кавказский горец» ж-лы чыгара, ж-л үз тирәсенә Төньяк Кавказның эмигрант яшьләрен туплый. Кавказ тау халыклары берлеге оештырыла, «Россияне өйрәнү институты каршындагы Кавказны өйрәнү җәмгыяте» Уставы (авторы Ц.) эшләнә. Эмиграциядә Ц. «Тау республикасы — физик-географик, статистик-лингвистик, икътисади очерклар» («Горская республика — физико-географические, статистико-лингвистические, экономические очерки») монографиясен (басылып чыкмаган), «Туган туганга каршы» («Брат на брата», Прага, 1926), «Канлы тау-лар» («Окровавленные горы», басылып чыкмаган) романнарын яза.

Х е з м.: Кавказ и Поволжье: Очерки инородческой политики и культурно-хозяйственного быта. М., 1913; Мусульмане России и федерация: Речи, произнесённые на Всероссийском мусульманском съезде в Москве 1–11 мая 1917 г. П., 1917; Мусульманская фракция в Учредительном собрании. К., 1917.

Әд.: Политические деятели России, 1917: Биогр. словарь. М., 1993. *Л.М.Айнетдинова.*

ЦӘ́ПЛИН Павел Алексеевич (23.12.1906, Самара губ., Бөгелмә өязе Мордва Афонькасе а. — Арчена ш., Испания), Сов. Союзы Герое (27.6.1937, үлгәннән соң), капитан. Тула хәрби-пехота мәктәбен (1926), Ленинград бронетанк курсларын (1932) тәмамлый. 1923 елдан Кызыл Армиядә. 1936–37 дә Испаниядә гражданнар сугышында катнаша (танк ротасы командиры). Теруэль шәһәре өчен барган сугышта батырлык күрсәтә: хәрәкәтсез калган танктан торып 8 сәгать дәвамында дошман б-н сугыша; Харам елгасы янындагы сугышта, танкы сафтан чыгарылгач, шәхси коралыннан атыша; һәлак була. Ленин ордены, Кызыл Йолдыз ордены, медаль б-н бүләкләнә.

Әд.: Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000. *М.З.Хәбибуллин.*

ЦАРЕ́ВСКИЙ Сергей Леонидович (26.9.1939, Казан), физик, физика-матем. фән. д-ры (1994), проф. (1999). Казан ун-тын тәмамлый (1963), шунда ук эшли, 1996 елдан теоретик физика каф. профессоры. Хезмәтләре үтә үткәргечләрнең магнит үзлекләренә карый. Ц. төп синглет халәтендәге җирдә сирәк очраучы ионнарның нәтиҗәле төш моменты үткәргечләрдә (ш.и. үтә үткәргечләрдә) уннарча тапкыр артуын күрсәтә. Үтә үткәргеч — магнетик (ферромагнетик, антиферромагнетик, парамагнетик) системаларында спин-дулкынлы резонанс теориясен төзи, анизотроп үтә үткәргечләрдә магнит резонансы сызыкчаларының формасын тәкъдим итә.

Х е з м.: Форма линий магнитного резонанса на электронно-ядерных уровнях в металлах и интерметаллических соединениях // Физика твёрдого тела. 1971. Т. 13, вып. 4; Возбуждение и детектирование магнитостатических волн на границе сверхпроводника второго рода // Журн. эксперим. и теорет. Физики. 1987. Т. 92, вып. 5; Форма линий магнитного резонанса в сверхпроводниках второго рода с учётом скин-эффекта // Физика твёрдого тела. 1996. Т. 38, вып. 11 (автордаш).

ЦАРЕГОРО́ДЦЕВ Александр Дмитриевич (26.8.1946, Киров өлкәсенең Санчурск р-ны Кисты а.), инфекционист, сәламәтлек саклау өлкәсе эшлеклесе, мед. фән.д-ры (1985), проф. (1986). РФнең атказ. табибе (1995). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1970), шунда ук балалар авырулары кафедрасында эшли, 1981 елдан каф. мөдире, бер үк вакытта, 1985–86 да, педиатрия ф-ты деканы. 1986 дан ТАССР сәламәтлек саклау министры. 1989 дан СССР сәламәтлек саклау министры урынбасары, 1995 тән РФ сәламәтлек саклау министры, 1996 дан Мәскәү педиатрия фәнни-тикшеренү ин-тында (хәзер Россия Сәламәтлек саклау министрлыгының Мәскәү педиатрия һәм балалар хирургиясе фәнни-тикшеренү ин-ты), 1997 дән директор. Хезмәтләре балалар вируслы инфекцияләренә, кискен респиратор инфекцияләргә диагноз кую, авыруларны дәвалау һәм кисәтүгә карый.

Х е з м.: Циркулирующие иммунные комплексы при аденовирусной инфекции у детей // Казан.

мед. журн. 1984. № 3; Инфекционные болезни: Справ. М., 1998 (автордаш); Актуальные проблемы и перспективы развития диагностических технологий в педиатрии // Рос. вестн. перинатологии и педиатрии. 2006. № 1 (автордаш).


Әд.: Александр Дмитриевич Царегородцев (к 60-летию со дня рождения) // Рос. вестн. перинатологии и педиатрии. 2006. № 5.

ЦАРЁВ Михаил Иванович (18.11.1903, Тверь ш. — 10.11.1987, Мәскәү), актёр, педагог, театр эшлеклесе, СССРның халык артисты (1949), Соц. Хезмәт Герое (1973). 1919–21 елларда Петроград шәһәрендә Ю.М.Юрьевта рус драма мәктәбендә укый, бер үк вакытта, 1920–23 тә, шул ук шәһәрдә Зур драма театры актёры. 1924–26 да Мәскәүдә — Корш театрында, 1926–27 дә — Махач-кала шәһәре театрында, в 1927–28 дә Казан Зур драма театрында эшли. Казан сәхнәсендә Гирькин («Яшьлек фабрикасы», А.Н.Толстой), Башкиров («Доцент Янбулатов», А.М.Файко), поручик Полевой («Разлом», Б.А.Лавренёв), Васька Пепл («Тормыш төбендә», М.Горький), Иван («Ачкыччы Ванька», Н.И.Собольщиков-Самарин), Курчаев («Һәр акыл иясен дә гадилек җиңәр», А.Н.Островский), Петенька («Головлёв әфәнделәр», М.Е.Салтыков-Щедрин романы буенча), Алёша («Абыйлы-энеле Карамазовлар», Ф.М.Достоевский романы буенча), граф Федерико («Печән өстендә эт», Лопе де Вега) һ.б. Жанрның күптөрлелеге, яшь совет драматурглары пьесаларында вакыйганың динамик кискенлеге актёрдан теге яки бу рольне башкарганда зур осталык, сәнгатьчә чаралардан кыю файдалануны таләп итә, аның иҗат диапазонын киңәйтү мөмкинлеге бирә. Аннан соңгы елларда Ц. Кырым рус театрында, Ленинград акад. драма театрында, В.Э.Мейерхольд исем. театрда, 1937 дән Мәскәүдә Кече театрда (1950–67, 1970–85 тә директор, 1985 тән сәнгать җитәкчесе) эшли. Бер үк вакытта В.Э.Мейерхольд исем. театр каршындагы мәктәптә, М.С.Щепкин исем. театр уч-щесендә укыта (1962 дән проф.). 1964–86 да Бөтенсоюз театр җәмгыяте идарәсе рәисе. Кинога төшә. СССР Дәүләт бүләгә лауреаты (1969).

Әд.: Коржевич Л. Путь актёра: М.И.Царёв. М., 1981; Театральная энциклопедия. М., 1967. Т. 5; Русский драматический театр: Энцикл. М., 2001.

ЦАРЁВО авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 22 *км* төньяк-көнбатыштарак, Нокса елгасы буенда. 2010 елда 8 кеше (руслар) яши. 1565–67 дән Новоцарёво исеме б-н мәгълүм; 19 йөз рәсми чыганакларында — 1920 елларда өч аерым авыл (1 нче Ново-Царёво, 2 нче Ново-Царёво, 3 нче Ново-Царёво), 1930 елардан 1 нче Царёво, 2 нче Царёво, 3 нче Царёво буларак билгеле, 1960 еллар уртасына 1 нче Царёво (2000 еллар уртасыннан — Царёво) гына кала. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, йон тегү, тегү, киез итек-киез басу, балта эше б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында земство мәктәбе (1880 ләрдә ачыла), ярма яргыч, 1 җил һәм 2 су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 777,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кощаково волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Воскресенский, 1927 нең 1 августыннан Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Столбище, 1959 ның 26 мартыннан — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән Питрәч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 134 ир-ат; 1859 да — 259, 1897 дә — 301, 1908 дә — 325, 1920 дә — 331, 1926 да — 400, 1949 да — 162, 1958 дә — 81, 1970 тә — 36, 1979 да — 26, 1989 да — 8, 2002 дә — 2 кеше.

ЦАРЁВОКОКША́ЙСК (Чар) ӨЯЗЕ́, 1708–1920 елларда Казан губернасында. Үзәге — Царёвококшайск шәһәре (1584 тә Кече Кокшага елгасының уң ярында кальга буларак нигезләнә; хәзер Йошкар-Ола ш.). Илләт, Царёвококшайск янәшәсеннән аккан Олы һәм Кече Кокшага елгалары буйларындагы җирләрдән оеша. 1708 дә Казан губернасының состав өлешенә әверелә. 1781–96 да Казан наместниклыгында, аннары кабат Казан губернасында. Төньякта — Вятка губернасының Яранск һәм Уржум өязләре, көнбатышта — Казан губернасының Козьмодемьянск, көнчыгышта — Казан, көньякта Чабаксар өязләре б-н чикләшә. Мәйданы 7118,4 кв. чакрым. Халкы — 125715 кеше, ш.и. 56,6% марилар, 22,3% татарлар, 21% руслар (1901). Адм. нисбәттә өяз Арбан, Олы Шигак, Вараксин, Күлле Киме, Кшклау, Морки, Петриков, Ронга, Себеусад, Сотнур, Шиньши волостьларына бүленә (20 йөз башы). Халкы игенчелек б-н шөгыльләнә, әмма җирләрнең 13% ы гына сөрелә. Өяз терр-ясенең зур өлешен урманнар били, шуңа күрә урман кәсепләре киң тарала. Өяздә Куженер һәм Воскресенск пыяла з-длары, 137 мәктәп, ш.и. 19 татар мәктәбе эшли. 1920 дә Ц. (Ч.) өязе Мари автономияле өлкәсе составына керә.



Әд.: Дерюжев И.О. Очерк 290-летнего состояния г. Царёвококшайска и его уезда (1584–1874). К., 1876; Айплатов Г.Н. Город Царёвококшайск и его уезд в XVII–XVIII вв. // Страницы истории Марийского края. Йошкар-Ола, 1970.

Д.Г.Мостафина.



М.И. Царёв.



Е.С. Царьков.

ЦАРЬКО́В Евгений Степанович (26.7.1953, Казан), драма актёры, ТРның халык артисты (2013). Казан театр уч-щесен тәмамлый (1973), шул ук елда Бөгелмә рус драма театры актёры булып эшли. 1976 елдан Казан яшь тамашачылар театры (ТЮЗ) актёры (бүленеп, 1976–77 дә «Радиоприбор» з-дында слесарь-җыючы). Аеруча мөһим рольләре: Малахов («Малаховны туктатыгыз», В.Аграновский), Хомяк («Бумбараш», Е.Митько, Ю.Михайлов), Бушттец («Рядовойлар», А.Дударев), Ланцелот («Дракон», Е.Шварц), Алеха («Вальпургия



Е.С.Царьков (уңнан икенче) Замухрышкин ролендә («Уенчылар», Н.Гоголь).

төне», В.Ерофеев), Валера («Сөйгәннәрегездән аерылмагыз», А.Володин), Филострат («Җәйге төндә кергән төш», У.Шекспир), Ипполит, Счастливцев («Капкан саен калҗа булмый», «Урман», А.Островский), Анучкин, Замухрышкин («Өйләнү», «Уенчылар», Н.Гоголь), Филя-Кубырь («Җимерү», Б.Васильев; РФ Дәүләт бүләге, 1992), Актёр («Розенкранц һәм Гильденстерн үлеме», Т.Стоппард; Россия «Алтын битлек» («Золотая маска») милли театр фестивале бүләге, 2003), Шериф Томас («Яңгыр сатучы», Р.Нэш), Дымба («Генерал белән туй» А.Чехов). Ц. ш.у. балалар өчен әкияти образлар иҗат итә: Иван, Бүре («Иван Дурак», «Куян йөрәк», М.Бартенев), Шарик («Ике өрәңге», Е.Шварц) һ.б. ТР Театр эшлеклеләре берлеге әгъзасы (1980). Медаль б-н бүләкләнә.

ЦВЕТА́ЕВ Пётр Александрович (10.10.1898, Түбән Новгород губ., Лукоян өязе Наруксово а. — 6.10.1970, Казан), актёр, педагог, ТАССРның халык артисты (1957). Ленинградта Н.Н.Ходотов исем. драма студиясен



П.А. Цветаев.



М.И. Цветаева.

тәмамлый (1926). 1927–36 елларда Түбән Новгород, Сталинград, Днепропетровск, Одесса, Свердловск театрлары актёры. 1936 дан Казан Зур драма театрында. Аның сәхнәсендә психол. рәсемнең төгәллеге, социаль характеристиканың сәнгатьчәлеге, тышкы детальләрнең җентекле сайланышы һәм тарихи дөреслек б-н гәүдәләнеше ягыннан аерылып торган 140 тан артык зур роль башкара. Аның башкаруында Александр («Соңгылар», М.Горький), бөек кенәз Кирилл («Порт-Артур», А.Н.Степанов, И.Ф.Попов), Король («Гадәттән тыш илче», А. һәм П.Турлар), Мижуев («Үле җаннар», Н.В.Гоголь әсәре буенча), Руже («Ерткыч хатын» Э.Фабр), поручик Порох («Җинаять һәм җәза», Ф.М.Достоевский романы буенча), Шонхаузер («Берлинда эссе җәй», Д.Кьюсак) рольләре зур социаль масштабтагы типик күренешләр сыйфатларына ия була. Казарин («Маскарад», М.Ю.Лермонтов), митрополит Филипп («Иоанн Грозныйның үлеме», А.Н.Толстой) образлары актёрның драматургия материалына тирәнтен үтеп кереп, язучы фикерен нечкә тоеп җиткерергә омтылуы б-н аерылып тора. Рәссам буларак, Казан Зур драма театры актёрларының график портретлары галереясын иҗат итә, Казан консерваториясендә һәм Казан Зур драма театры студиясендә грим сәнгате укыта.



П.А.Цветаев Мижуев ролендә («Үле җаннар», Н.В.Гоголь әсәре буенча).

Әд.: Народные артисты. К., 1980; Ингвар И., Илялова И. Русский театр в Казани. К., 1991.

Ю.А.Благов.

ЦВЕТА́ЕВА Марина Ивановна (26.9.1892, Мәскәү — 31.8.1941, Алабуга ш.), шагыйрә. «Чакрымнар» («Вёрсты», 1921), «Тау поэмасы» («Поэма Горы»), «Ахыр поэмасы» («Поэма Конца», икесе дә — 1926), «Россиядән соң» («После России», 1928) шигырь җыентыклары, «Федра» (1928) трагедиясе, «Минем Пушкин» («Мой Пушкин», 1937) эссесы, хатирәләр һ.б. авторы. Ц. иҗаты өчен романтик максимализм, ялгызлык, мәхәббәтнең фаҗигаи өметсезлеге мотивлары хас. 1922 елдан шагыйрә эмиграциядә була, 1939 да ватанга кайта. ТАССРга эвакуацияләнә. 1941 нең 8 августында Алабугага килә. Эвакуацияләнгән язучылар яшәгән Чистай шәһәрендә урнашырга омтыла. 31 августта үз-үзенә кул сала. 1990 да Алабугада әдәби музей ачыла, хәзер *Цветаева М.И. мемориаль комплексы* составына керә.

Әсәр.: Собр. соч.: В 7 *т.* М., 1994–95.

Әд.: Эфрон Г.С. Дневники. М., 2004. Т. 1; Кудрова И.В. Путь комет. СПб., 2007.

ЦВЕТА́ЕВА МАРИ́НА МЕМОРИА́ЛЬ КО́МПЛЕКСЫ, Алабуга шәһәрендә. Комплекс составына М.И.Цветаева һәйкәле урнаштырылган (2002, скульпторлары А.В.Головачёв, В.А.Демченко) мемориаль мәйдан, М.И.Цветаеваның әдәби музее, М.И.Цветаеваның хәтер йорты, «Көмеш дәвер» китапханәсе керә. **М.И.Цветаеваның әдәби музее** 1990 елда шагыйрә И.В.Лимонова башлангычы б-н оештырыла. 2003 нең 29 декабрендә Алабуга тарих-архит-ра һәм сәнгать музей-саклаулыгының структур өлеше буларак ачыла. Музейның фәнни концепциясе авторы — Е.В.Поздина, сәнгать проекты авторы — Р.М.Сәлахов. Ике катлы йортта (19 йөзнең 2 нче яртысы) урнашкан. Экспозиция мәйданы — 94,8 *м*², фондларында



Алабуга шәһәрендә М.И. Цветаева һәйкәле. 2002. Скульпторлары — А.В.Головачёв, В.А.Демченко.

269 саклау берәмлеге исәпләнә. Экспозиция 4 залда оештырылган. М.Цветаеваның балачак елларына багышланган 1 нче бүлектә аның беренче «Кичке альбом» («Вечерний альбом», М., 1910) шигырьләр җыентыгының репринт басмасы, Цветаевлар гаиләсе әгъзаларының фоторәсемнәре куелган. 2 нче зал экспозициясе Цветаеваның 20 йөз башындагы иҗаты, шагыйрәнең эмиграциядәге (Чехия, Франция) һәм туган ягына кире кайтканнан соңгы тормышы б-н таныштыра. Экспонатлар арасында замандашларының (А.Блок, А.Ахматова, Н.Гумилёв, Б.Пастернак һ.б.) басмалары, М.Цветаеваның эмиграциядә нәшер ителгән әсәрләре: «Патша-кыз» («Царь-девица», Берлин, 1922) әкият-поэмасы, «Аерылышу» (Берлин, 1922) шигырьләр җыентыгы; Ц.ның әсәрләре басылган «Перезвоны», «Воля России», «Вёрсты» ж-ллары (1922–27); улы Георгий тууы турында метрика кенәгәсеннән өземтә күчермәсе, М.Цветаеваның иренең эшен яңадан карау турында НКВДның тикшерү бүлегенә һәм эчке эшләр халык комиссары Л.П.Берия



Алабуга шәһәрендә М.И. Цветаева әдәби музее. Экспозиция фрагменты.

исеменә язган хаты, улының көндәлек язулары, Алабугадагы фатир хуҗабикәсенең хатирәләре һ.б.; ш.у. аның шәхси әйберләре: чәчәкле бизәк төшкән тәлинкә, чәй кашыклары, камея, язу кәгазьләре бар. «Эвакуация — Алабуга» экспозициясе бүлегендә 1940 еллар провинциаль совет шәһәрчегенә хас йортның интерьеры торгызылган. Хәтер залы экспозициясендә Цветаеваның СССРда нәшер ителгән беренче шигырь җыентыклары; дөньяның төрле телләренә тәрҗемә ителгән әсәрләре; Цветаева турында китап авторларының автографлары куелган китаплар урын алган. Музейда М.Цветаеваны искә алу (31 август), Халыкара Цветаева укулары (2002 дән), «Цветаева учаклары» («Цветаевские костры») поэзия кичәләре уза. Музей директорлары: Л.Г.Мокшина (2003–05), Е.В.Поздина (2005–09), С.Г.Әндәрҗанова (2009–10), Р.Р.Брускова (2010–12), Е.А.Кашапова (2013 тән).

М.И.Цветаеваның Хәтер йорты 2005 нең 4 июнендә ачыла. 1941 нең августында шагыйрә гомеренең соңгы 10 көнен уздырган бер катлы агач йортта урнашкан. Экспозиция мәйданы — 50,2 *м*², фондларында 188 саклау берәмлеге исәпләнә. Зал, Цветаева улы б-н





Алабуга шәһәрендә М.И.Цветаеваның Хәтер йорты. 1. Гомуми күренеше; 2. Экспозиция фрагменты.

яшәгән бүлмәләр, аш-су бүлмәсе интерьерлары П.С.Волков (йорт хуҗаларының онығы) тасвирламасына нигезләнеп торгызылган. Йортның верандасында урнаштырылган витриналарда — М.Цветаеваның Алабугадагы тормышын яктырткан документлар: эвакуацияләнүчеләр исемлеге, йорт кенәгәсеннән өземтә, улының көндәлегеннән өзек, үлеме алдыннан язып калдырган сүзләре һ.б.ның күчермәләре. Иң мөһим экспонатлар арасында — М.Цветаеваның куен дәфтәре. Йортка мемориаль такта куелган (1980).

«**Көмеш дәвер» китапханәсе** 2005 нең 4 июнендә ачыла. Гомуми мәйданы 256,5 *м*^{2} булган ике катлы йортта урнашкан. Фондларында 6 меңнән артык китап саклана, аларның күбесе М.Цветаева замандашларының (Б.Пастернак, О.Мандельштам, Н.Гумилёв, А.Ахматова һ.б.) әсәрләре.

ЦЕ́ЙТЛИН Борис Ильич (12.9.1945, Ленинград ш.), режиссёр, ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1992). Ленинград театр, музыка һәм кинематография ин-тын тәмамлый (1973), Красноярск, Куйбышев, Орёл, Омск, Вологда, Брянск шәһәрләрендәге театрларда эшли, «Гадәти могҗиза» («Обыкновенное чудо», Е.Л.Шварц), «Артуро Уи карьерасы» («Карьера Артуро Уи», Б.Брехт), «Могҗиза тудыручы» («Сотворившая чудо», У.Гибсон), «Уникенче төн» («Двенадцатая ночь», У.Шекспир), «Өченче ракета» («Третья ракета», В.В.Быков повесте буенча) спектакльләрен куя. 1987–95 елларда Казан яшь тамашачылар театрының баш режиссёры, аның сәхнәсендә «Аждаһа» («Дракон», Е.Л.Шварц, 1988), «Иртәнге күктә йолдызлар» («Звёзды на утреннем небе», А.М.Галин; Ю.А.Благов б-н берлектә, 1988), «Иисус анасы» («Мать Иисуса», А.М.Володин, 1989), «Җимерү» («Погром», Б.Л.Васильевның «Кич тә була, иртә дә» — «И был вечер, и было утро» повесте буенча, 1991; РФ Дәүләт бүләге, 1992), «Сычуаньнан килгән мәрхәмәтле кеше» («Добрый человек из Сычуани», Б.Брехт, 1992), «Тынгысыз җан» («Неугомонный дух», Н.Коуард, 1992) спектакльләрен куя, «Давыл» («Буря», У.Шекспир, 1994; «Алтын битлек» — «Золотая маска» милли бүләге, 1996) пьесасының үз версиясен сәхнәләштерә. Ц. спектакльләренә күзгә бәрелеп торган театральлек, режиссёрның сәнгатьчә чаралардан оста файдалануы, үзенчәлекле куелыш хас.

ЦЕ́ЙТЛИН Рафаэль Семёнович (3.11.1935, Харьков ш.), тарихчы, тарих фән. д-ры (1988), проф. (1991), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1995). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1960), Тимертау шәһәрендә урта мәктәптә һәм Караганда металлургия ин-ты ф-лында укыта (Казакъстан), 1961 елдан Казан мәктәпләрендә эшли, 1964 тән 93 нче мәктәп директоры. 1974 тән Казан технол. ун-тында: 1989 дан сәяси тарих һәм социология каф. (1995 тән — дәүләт идарәсе, тарих һәм социология, 2004 тән — дәүләт идарәсе, муниципаль идарә һәм социология каф.) мөдире, бер үк вакытта, 1995 тән, Югары идарә мәктәбе директоры, 2009 дан ректор киңәшчесе. Ц. башлангычында 1995 тә төбәктә технол. ун-ты каршында беренче тапкыр дәүләт идарәсе һәм муниципаль идарә буенча белгечләр әзерли башлыйлар. Хезмәтләре Россия Кораллы Көчләрендә 1917 елда барган сәяси көрәш тарихына карый. Казан технол. ун-тының атказ. профессоры. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: В борьбе за солдатские массы (Большевики и их политические противники в тыловых военных округах Восточной России в мирный период развития революции 1917 г.). К., 1987; История государственного и муниципального самоуправления в России: Учеб. пособие. К.–М., 2003 (автордаш).

Әд.: Лидеры научных школ КХТИ-КГТУ. К., 2007.

ЦЕЛЕСТИ́Н (лат. caelestis — сыек зәңгәрсу), сульфатлар классындагы минерал, $Sr[SO_4]$. Составында 56,4% ка кадәр CrO, CaO, BaO кушылмалар бар. Пластина яки призма тибындагы кристаллар барлыкка китерә; бөртекле, алтыкырлы һәм кабыксыман агрегатлар рәвешендә. Зәңгәр, ак, соры, алсу һ.б. төсләрдә була. Пыяласыман ялтыравыклы. Катылыгы 3–3,5, тыгызлыгы 4 *г/см*^{3}.



Шомартылган целестин кристаллары.

Утырма токымнарда: гипс, таш һәм калий тозларында, известьташларда һ.б.; гидротермаль тамырларда, җир өстенә чыккан тау токымнары куышлыкларында очрый. Чыганаклар хасил итә. Ц. — стронций алуда төп руда. Татарстан терр-ясендә Ц. чагылмалары Иделнең уңъяк ярындагы югары Пермь доломитларында табыла.

ЦЕЛИ́ННЫЙ РАЙОНЫ́, Курган өлкәсенең көньягында урнашкан. 1924 елда Усть-Уйский (Уйтамак) р-ны буларак оештырыла, 1934 тән Чиләбе өлкәсенә керә, 1943 тән — Курган өлкәсендә, 1953 тән — Яңа Күчердек районы, 1962 дән хәзерге исемен йөртә. Мәйданы — 3445,6 *км*^{2}. Үзәге — Целинный авылы (Курган шәһәреннән 219 *км* көнья-кө́нбатыштарак). Халкы — 15130 кеше (2017). Татарлар саны: 2002 дә — 1346, 2010 да — 1043 кеше. Алар, тупланып, Өчкүл (238 кеше), Мәһди (Зур Дубровный) (262), Белозёрка (129), Кече Дубровный (29) авылларында яшиләр. Идел буе татарларының Ц.р. терр-ясенә күплап күченүләре 19 йөзнең 80 елларына туры килә. Бу чорда Дубровный (хәзер Мәһди), Өчкүл (1920 еллар ахырында бу авылдан күченүчеләр Белозёрка авылын нигезлиләр) авылларына нигез салына. 1920 елларга кадәр аларда мәчетләр була. Мәһди һәм Белозёрка башлангыч мәктәпләре каршында татар милли йолаларын һәм гореф-гадәтләрен өйрәнүче түгәрәкләр эшли; «Дини мәдәниятләр һәм дөньяви этика нигезләре» уку курслары кысаларында ислам мәдәнияте нигезләре укытыла. Мәһди һәм Өчкүл авыллары мәдәният йортларында татар музыка һәм бию түгәрәкләре эшли. «Умырзая» кызлар вокаль төркеме (Мәһди а.) — «Җидегән чишмә янында» Төбәкара татар мәдәнияте фестивале дипломанты. *Сабан туе*, Чәчәк бәйрәме үткәрелә. Мәһди авылында мәчет, Өчкүл һәм Белозёрка авылларында мөселман җәмгыятьләре эшли.

Әд.: История земли Целинной. Куртамыш, 2004.

ЦЕМЕ́НТ ЧИМАЛЫ́, цемент җитештерүдә кулланыла торган известьташ, акбур, балчык һ.б. токымнар. Татарстан терр-ясендә югары Пермь яшендәге известьташ чыганаклары 80 млн. *т* дан артык гомуми запас б-н Менделеев (Салтыково чыганагы), Лениногорск (Шөгер) һәм Алабуга (Камай) р-нна-рында ачыкланган; Салтыково чыганагындагы известьташларның 15–17 млн. *т* сын файдаланып була, калган өлеше терр-ясен тимер юллар һәм нефтьүткәргечләр били. Пермь яшендәге Татар Бизнәсе (Чүпрәле р-ны) акбурга охшаш известьташ чыганагы киләчәктә цемент җитештерү өчен чимал булып тора. Токымнар М-400 маркалы портландцемент алырга мөмкинлек бирүче балчыксыл-карбонатлы кушылмадан тора.

Әд.: Геология твёрдых полезных ископаемых Республики Татарстан. К., 1999.

ЦЕНТО́ВСКИЙ Владимир Михайлович (26.11.1935, Казан), физик-химик, химия фән. д-ры (1979), проф. (1981). 1959 елда Казан химия-технол. ин-тын (хәзер Казан технол. ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли (1962 дән), аналитик химия каф. мөдире (1975–86). Хезмәтләре электролит эремәләренең физик һәм аналитик химиясенә карый. Ц. азот, фосфор, мышьяк, сөрмә һәм висмут органик кушылмаларының оний тозларын тикшерә; бу элементларның химик табигате сусыз мохитләрдә диссоциация һәм ассоциация процессларына ничек итеп тәэсир итүен ача. Мондый процессларның тигезләнеш константаларын электрон хисаплау машиналарындагы матем. алымнарны кулланып хисаплау методикасын эшли. Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Изучение ионной ассоциации ониевых солей в растворах. 13. Электропроводность тетрафторборатов этилтиоарсония в ацетоне // Журн. общей химии. 1981. Т. 51, № 5 (автордаш); Электронные спектры гидрокси- и аминопиридина в ДМСО и ДМФ // Изв. вузов. Химия и хим. технология. 1989. Т. 32, № 8 (автордаш).

Әд.: Выпускники — гордость Казанского технологического университета: Краткий биогр.справ. К., 2009.

ЦЕНТРИЗДА́Т, к. *СССР халыклары үзәк нәшрияты.*

ЦЕОЛИТЛА́Р (грек. zéo — кайнау һәм *...лито*), минераллар төркеме, селтеле һәм селтеле-җир металларының сулы алюмосиликатлары. 50 дән артык төре һәм төрчәләре билгеле. Гадәттә, ак төстә, кайвакыт үтә күренмәле, сирәк кенә кызгылт, коңгырт, яшькелт төстә була. Катылыгы 3,5–5,5. Барлыкка килүләре буенча вулканоген, вулканоген-утырма (аеруча сәнәгый әһәмияткә ия) һәм утырма (Татарстандагы барлык чыганаклар) булалар. Үчпрәле р-нында акбур системасы то-



В.В. Цивилин.

кымнарында ЦНИИгеолнеруд хезмәткәрләре тарафыннан 5 чыганак (1989–91), ш.и. *Татар Шатыршаны цеолитлар чыганагы* ачыла, аларның гомуми ресурслары 3 млрд. $м^3$ тан артык тәшкил итә. Ц. сәнәгый һәм табигый газларны, эчәргә яраклы һәм агымсуларны чистартуда, цемент, пластмасса җитештерүдә, а.х.нда һ.б.да кулланыла. ТРда җирле Ц.ны туфракны химик мелиорацияләү өчен, терлекчелектә терлек азыгына өстәмә буларак файдаланалар.

Әд.: Агроминеральные ресурсы Татарстана и перспективы их использования. К., 2002.

«ЦЕРКО́ВНО-ОБЩЕ́СТВЕННАЯ ЖИЗНЬ» («Дини-иҗтимагый тормыш»), атналык дини журнал, Казан руханилар академиясе органы (12 нче санга кадәр). 1905 елның 16 декабреннән 1907 нең 6 ноябренә кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә, барысы 46 саны чыга. Мөхәрририяткә «Православный собеседник» ж-лы мөхәррире Л.И.Писарев, А.В.*Смирнов*, Казан руханилар академиясе мөгаллимнәре М.А.*Машанов*, К.Г.Григорьев керә. Авторлары арасында — Ф.В.Благовидов (диннәргә тигез караш, чиркәү реформалары һәм руханилар академиясен реформалаштыру мәсьәләләренә караган язмалар), А.М.Кулясов, В.И.Несмелов, К.Г.Григорьев була. Журнал үзенә максат итеп заманча дини тормыш һәм иҗтимагый аңның халәтен, чиркәү реформалары барышын чагылдыруны куя. Редакция либераль юнәлешкә таяна, анда октябристлар партиясе (1906, 2 нче сан), Петербург либераль руханилары оешмасының «Чиркәүне яңарту берлеге» (1906, 6 нчы сан) программалары басыла. А.В.Смирнов, октябристлар партиясе әгъзасы булудан тыш, чиркәү илдә барган сәяси вакыйгаларда актив катнашырга тиеш дип исәпләгән Казан «Чиркәү пастырьлары һәм старосталары берлеге» җитәкчелеге состав на да керә. Басма битләрендә дини мәгариф реформалары проекты турында фикер алышу бара. Россиядәге иҗтимагый-сәяси вазгыять урта-либераль, күбесенчә октябристлар күзлегеннән торып бәяләнә. Казан губернасындагы чиркәү тормышы яктыртыла, патриархлык җитәкчелеге кертү проблемасы карала, Синод һәм хакимиятләр эшчәнлеге тәнкыйтьләнә. Редакция православиене дәүләт дине хәлендә саклауны яклап чыгыш ясаган чиркәү хакимиятенә оппозициядә тора. Казан руханилар академиясенең консерватив өлеше таләбе буенча 1906 ның мартыннан журнал Казан руханилар академиясе басмасы статусын югалта. Редакция төбәкнең әҗнәби халкын укыту процессына *Ильминский системасын* кертүне яклый. «Әҗнәби татар-мөселман матбугатыннан» рубрикасында «Казан мөхбире», «Йолдыз», «Өлфәт», «Урал», «Тәр җәман», «Вакыт», «Бәянелхак» һ.б. татар г-талары язмаларына күзәтү басыла. 46 нчы санда либераль характердагы мәкаләләрне бастырган өчен Казан губернаторы тарафыннан штрафка тартыла һәм ябыла.

Әд.: Журавский А.В. К истории «Православного собеседника» // Православный собеседник. 2000. № 1.

Р.А.Айнетдинов.

ЦЕТРА́РИЯ (Cetraria), пармелиячәләр семьялыгыннан лишайниклар ыругы. Якынча 45 төре билгеле, Төньяк һәм Көньяк ярымшарларда таралганнар. Татарстанда бер төре — Исландия Ц.се (C. islandica) бар, Идел-Кама саклаулыгының Раифа һәм Саралан участоклары терр-ясендә очрый. Комлы ачык урыннарда, коры нарат һәм каен-нарат урманнарында очрый. 5–10 *см* биеклектәге яфраксыман куаклы күпьеллык лишайник, туфракка яки агач кайрысына береген үсә, яшькелт-коңгырт төстәге тармаклы катламалы. Калаксыман яфраклары яссы батынкы, кыска кара керфекчекле, аскы ягына төрле формадагы аксыл таплар сибелгән. Тәлинкәсыман, көрән, яссы яки җиңелчә батынкы дисклы үрчү өлеше нык кына киңәеп киткән калаклары төбендә барлыкка килә. Катламасы дымлы һава булганда йомшак тиречел, корыда — каты, көрән-соры. Нигездә, вегетатив юл (таллом кисәкләре) б-н үрчи. Ц. — әйләнә-тирә мохитнең чисталыгын күрсәтүче үсемлек. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

ЦИБУ́ЛЬКИН Анатолий Павлович (23.9.1940, Минск), иммунолог, мед. фән. д-ры (1983), проф. (1984). ТАССРның, РФнең атказ. фән эшлекчесе (1990, 2006). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1964), шунда ук патофизиол. кафедрасында эшли. 1973 елдан Казан ГИДУВында, Үзәк фәнни-тикшеренү лаб-ясе мөдире, 1984 тән фәнни эш буенча проректор, 1988 дән клиник һәм лаборатор диагностика каф. мөдире. Хезмәтләре иммунодепрессия механизмнарын тикшерүгә: пиримидин төркеменнән китереп чыгарылган иммунотроп актив яңа дару матдәләрен эшләү һәм сынауга карый. Уйлап табуга 2 авторлык таныклыгы бар.

Хезм.: Спектральный анализ поздних желудочковых потенциалов по результатам СУ-ЭКГ у больных с инфарктом миокарда. К., 2002; Иммунная система человека — от защиты к патологии // Казан. мед. журн. 2006. № 1.

Әд.: Казанский государственный медицинский университет (1804 — 2004 гг.): Заведующие кафедрами и профессора: Биогр. словарь. К., 2004.

ЦИБУ́ЛЬКИНА Вера Николаевна (9.8.1943, Мари АССРның Красногорск пос.), аллерголог-иммунолог, мед. фән. д-ры (1987), ТРның атказ. табибе (1994). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1967), туган посёлогындагы участок хастаханәсендә терапевт булып эшли. 1970 елдан Казан ГИДУВында функциональ диагностика кафедрасында, 1972 дән аллергология кафедрасында, 1986 дан клиник иммунология (аллергология б-н) каф. мөдире, 1988 дән эндокринология, клиник иммунология (аллергология б-н) кафедрасында, 1998 дән шул ук каф. мөдире. Хезмәтләре бронхиаль астма, поллинозлар, кычыткан бизгәге һ.б. аллергик авырулар функциональ диагностикасы һәм аларны дәвалауга, диметофосфон, теофиллинны дәвалау практикасында куллануга карый. «Прик-тест энәсе» өчен уйлап табуга авторлык таныклыгы бар (1987).

Хезм.: Лечение хронической крапивницы димефосфоном и антагонистами гистамина // Казан. мед. журн. 1996. № 3; Экология и аллергопатология детей. К., 2003 (автордаш).

Әд.: Казанский государственный медицинский университет (1804 — 2004 гг.): Заведующие кафедрами и профессора: Биогр. словарь. К., 2004.

ЦИВИ́ЛИН Владислав Валентинович (26.1.1947, Чистай ш.), инженер-механик, «Восток» Чистай сәгать заводы» АҖ ген. директоры (1992–2009), ТРның, РФнең атказ. машина төзүчесе (1992, 1995). Казан авиация ин-тын тәмамлый (1971). 1963–2009 елларда «Восток» Чистай сәгать заводы» АҖдә: слесарь, инженер-конструктор, өлкән технолог, цех башлыгы, баш механик, баш инженер (1981 дән), завод директоры (1987 дән). Ц. җитәкчелегендә сәгать детальләренең барлык төрләрен эшләп чыгару үзләштерелә һәм механик сәгатьләрне җитештерүнең тулы технол. циклы булдырыла. Су, газ, электр энергиясен исәпкә алучы көнкүреш приборлары һ.б. эшләнә һәм аларны сериялән җитештерү гамәлгә кертелә. 1990–95 тә ТССР, ТР ЮС депутаты, 1995–99 да халык депутаты. Халыклар дуслыгы, Почёт, 3 нче дәрәҗә Изге тәкъва Даниил Московский орденнары, медальләр, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

ЦИВИ́ЛЬСК (Чуел) ӨЯЗЕ́, 1708–1920 елларда Казан губернасында. Үзәге — Цивильск шәһәре (1584 тә Олы Цивил (Чуел) елгасының уң ярында кальга буларак нигезләнә. Ц.(Ч.)ө. Сура һәм Идел елгалары арасында - гы, Цивильск янәшәсендәге җирләрдән оеша. 1708 дә Казан губернасының составөлешенә әверелә. 1781–96 да Казан наместниклыгында, аннары кабат Казан губернасында. Төньякта — Казан губернасының Чабаксар, көнбатышта — Ядрин, көнчыгышта — Зөя һәм Тәтеш өязләре, көньякта Сембер губернасының Буа өязе б-н чикләшә. Ц.(Ч.)ө. терр-ясеннән Олы һәм Кече Цивил, Аниш,



Олы Гөбенә һ.б. елгалар ага. Мәйданы 3044,9 кв. чакрым. Халкы 175631 кеше, ш.и. 78,9% чуашлар, 11,4 % татарлар, 9,5 % руслар (1901). 1796 дан соң өяз адм. нисбәттә 12 волостька: Кешәл, Яңа Кавал, Яңа Мәми, Иске Арабас, Иске Тәбәрде, Хормалы, Цивил, Чуратчык, Шибылгы, Шихазан, Яниково-Шоркистры, Янтык волостьларына бүленә. 1918 дән Тобурдан волосте оештырыла. Халкы игенчелек, бер өлеше кәсепләр (балта эше, мич чыгару, тегүчелек һ.б.) б-н шөгыльләнә, әмма соңгылары акрын үсә. Өяздә 555 вак сәнәгать пр-тиеләре була (1901). 19 йөздә Урмар авылындагы Вена җи һазлары ф-касы таныла. Өяздә 94 мәктәп эшли. 1920 дә Ц.(Ч.)ө. Чуваш автономияле өлкәсе составына керә.

Чыг.: Материалы для географии и статистики России, собранные офицерами Генерального штаба: Казанская губерния. СПб., 1861.

Әд.: С п а с с к и й Н.А. Очерки по родиноведению: Казанская губерния, К., 1912; Чувашская энциклопедия. Чебоксары, 2011. Т. 4.

Д.Г.Мостафина.

ЦИВИ`ЛЬСКИЙ Константин Фёдорович (2.9.1913, Казан губ., Лаеш өязе Олы Ялан а. – 1973 тән соң), хокук белгече. Казан юридик мәктәбен тәмамлый (1939). 1930–32 елларда 51 нче Ташкент мамык з-ды эшчесе. 1933–34 тә «Новая жизнь» к-зы (Питрәч р-ны) хисапчысы. 1936–38 дә ВЛКСМның Казан шәһәр ком-тында бүлек мөдире. 1939–41 дә Казан шәһәре Сталин районы халык мәхкәмәсе халык судьясы. 1941–50 дә ТАССР Адвокатлар коллегиясе президиумы рәисе. 1950–73 тә Казан шәһәре Совет р-ны юридик консультациясе адвокаты. Медаль б-н бүләкләнә. *Е.Б.Долгов.*

ЦИВУ́НИН Валерий Семёнович (14.1.1931, Коми АССРның Часово а.), химик-органик, химия фән. д-ры (1969), проф. (1971), ТССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1991), Казан технол. ун-тының атказ. профессоры (2005). 1953 елда Казан химия-технол. ин-тын (КХТИ) тәмамлаганнан соң (1953), С.М.Киров исем. ясалма каучук з-дында эшли. 1956 дан Казан технол. ун-тында, КХТИның Түбән Кама ф-лында гомуми теория фән. каф. мөдире (1970–75), аналитик химия каф. мөдире (1985–95), 1995 тән каф. профессоры. Хезмәтләре фосфорорганик кушылмалар химиясенә, төп органик синтезга, аналитик химиягә карый. Ц. фосфор хлоридлары, ш.и. диалкил һәм диарилхлорфосфиннар реакциясе мөмкинлегенең законча лыкларын билгели. Вируска каршы актив лыкка ия бер төркем фосфорорганик кушылмаларны синтезлый. Пласттан чыгарылган нефть күләмен арттыручы композицияләр; Казан «Органик синтез» ҖБ өчен продуктлар һәм ярымпродуктларны анализлау методикасын эшли. Уйлап табуга 50 дән артык авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Идел буе югары уку йортлары төбәк советының химия-технол. фәннәре буенча экспертлар комиссиясе рәисе (1970–80). Медальләр б-н бүләкләнә. РФнең Мактаулы югары белем бирү хезмәткәре (1996).

Х е з м.: Взаимодействие пятихлористого фосфора с алкилаллиловыми эфирами // Журн. общей химии. 1966. Т. 36, вып. 9 (автордаш); Синтез и свойства производных 1,4-диоксана и его аналогов // Изв. вузов. Химия и хим. технология. 1986. Т. 29, вып. 10; Изучение поглощения акролеина суспензией гидроксида кальция // Журн. прикладной химии. 1999. Т. 72, вып. 4 (автордаш).

Әд.: Выпускники – гордость Казанского технологического университета: Краткий биогр. справ. К., 2009.

ЦИКА́ДАСЫМАННАР (Cicadinea), тигезканатлылар отрядыннан бөҗәкләр ассемьялыгы. Озынлыгы 3–65 *мм*. Арткы аяклары, гадәттә, сикерүгә җайлашкан, җыелган халәттә канатлары түбәсыман. Авыз аппараты суыручы типта. Асотряд күп кенә семьялыкларга бүленә, күпсанлы сайрар цикадалар (Cicadidae), күбекле цикадалар (Aphrophoridae), дельфацидалар (Delphacidae), цикадкалар (Cicadellidae) семьялыклары киң таралганнар. 17 мең тирәсе, Европада – 215 ыругка караучы 660 ка якын төре билгеле. Татарстан терр-ясендә якынча 200 төре бар. Аеруча үләнчел бергәлекләрдә таралганнар. Күкәйләрен күкәй салгычы б-н кискәләгән сабакларга сала, шулай яшь ботакларны зарарлый. Үсеше – тулы булмаган әверелешле. Күпчелек төрләренең личинкалары ачык рәвештә үсемлекләрдә, кайвакыт туфракта (циксидалар, цикадкалар, церкопидалар) яки үзләре махсус бүлеп чыгаручы күбекләрдә (күбекле цикадалар) яши. Олы затлар һәм личинкалары түгел, ә еш кына күкәйләре кышлый. Күпчелек төрләре елына ике буын бирә. Яфрак һәм үсемлек сабагы суы б-н туеналар. Кайбер Ц. а.х. һәм урман культурала рын зарарлый. Үсемлекләрдә вируслы авырулар таратырга мөмкиннәр.

С.М.Шәфигуллина.

ЦИКЛАМЕ́Н, к у я н к о л а г ы (Cyclamen), нәүрүзгөлчәләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 20 гә якын төре билгеле. Килеп чыгышы урыны – Урта диңгез буе. Сабаксыз, бүлбесыман тамырча хасил итә. Яфраклары тамыр янында, озын саплы, түгәрәк бөресыман формада, еш кына соры яки көмешсыман бизәкле яшел, куе яшел төстә. Чәчәкләре берле, озын чәчәк сапларында, иенке; ак, алсу, кызыл, аксыл шәмәхә, шәмәхә, еш кына ике төслеләр; чачаклы тажы яфракчыклы гади, катмарлы. Октябрьдән мартка кадәр чәчәк ата. Чәчәк атканнан соң, яфраклары үлә, үсемлек «йокы» халәтенә күчә. Май ахырыннан үсә башлый (бу вакытта аны киң савытка күчереп утырталар). ТРда кайбер кушылгак формаларын матур чәчәк атучы бүлмә гөле буларак үстерәләр: фарсы Ц.ы (C. persicum) – эре чәчәкле, орлыктан үрчи (аларны алу өчен ясалма серкәләндерү мөһим), үсентеләрне берничә тапкыр, башта тартмаларга, аннары чүлмәкләргә күчереп утырталар; Европа яки Альп Ц.ы (C. europaeum) – хуш исле вак чәчәкле, ян бүлбеләрне бүлеп үрчетәләр. Ц. салкынча, бернидән күләгәле урынны ярата. Коры һавалы эссе бүлмәләрдә тиз үлә. Суны мулдан сипкәнне ярата. Чәчәк атып бетергәннән соң, яфраклары һәм бөреләре шиңгәнче су сибү туктатыла. Дөрес тәрбияләгәндә, Ц.ны 20 ел дәвамында үстерергә мөмкин.

ЦИКЛО́Н, (грек. kyklón – бөтерелүче, әйләнүче), атм. басымы чагыштырмача түбән булган өлкә, һава торышы карталарында йомык изобарлар б-н күрсәтелә һәм үзәгендә латин алфавитының «Н» хәрефе б-н билгеләнә; зур масштаблы, тропикларга хас булмаган, җир өслегендә үлчәмнәре горизонталь буенча 1000 нән 3000 *км* га кадәр, вертикаль буенча 2 дән 10 *км* га кадәр җитүче җилләр системасына ия, Төньяк ярымшарда астан күтәрелүче һаваның гомуми хәрәкәте сәгать теле йөрешенә каршы булган халәттә кырыйлардан үзәккә таба спираль буенча басым иң түбән булган үзәккә таба хәрәкәт итүче барик-циркуляцион өермә. Ц.ның көнчыгыш өлешендә көньяктан – җылы, көнбатышта төньяктан салкын һава массалары күчеше өстенлек итә. Көньяк өлешендә көнчыгыштан җылы, ә көнбатыштан салкын атм. фронтлары б-н чикләнгән җылы сектор барлыкка килә. Салкын атм. фронты артында Ц.ның «тылы» урнаша. Атмосферада Ц. *антициклон* б-н беррәттән барлыкка килә, үзгәрә һәм хәрәкәт итә. Ц.ның уртача хәрәкәт тизлеге 30–50 *км/сәг*., иң зур тизлеге – 100 *км/сәг*. кә кадәр. Еш кына Ц.нар сериялап – берсе артыннан берсе күчәләр. Аларда, аеруча үзәге һәм фронтлары янында шактый күләмдәге явым-төшемнәр б-н болытлы һава өстенлек итә. Җилнең тизлеге, гадәттә, 10–15 *м/с*, 20 *м/с* һәм артыграк та булырга (шторм), 30 *м/с* ка (давыл) җитәргә мөмкин; Ц. үзәгендә җил көчсез. Ц.га тиз һәм кисәк үзгәрүчән һава торышы хас. Татарстан терр-ясендә Ц. үзәгендә диңгез өсте тигезлегеннән китерелгән атм. басымы 950–970 *гПа* гә кадәр (кышын) төшәргә мөмкин. Ц. тибындагы һава торышы елына уртача 171 көн (47%) күзәтелә, июльдә ешрак – 17 көн (55%), апрельдә сирәгрәк – 13 көн (43%). Көзге-кышкы чорда – атлантик көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш өстенлек итә, язын – көньяк-көнбатыш, җәен – җирле һәм көнбатыш Ц.нар тәэсире өстенлек итә. Ц. кышын җылы, җәен салкын һава китерә.

Әд.: В о р о б ь ё в В.И. Синоптическая метеорология. Л., 1991; Климатические условия и ресурсы Республики Татарстан. К., 2008.

Ю.П.Переведенцев, Э.П.Наумов.

ЦИКЛОПЛА́Р (Cyclopoida), суда яшәүче кысласыманнар классындагы отряд (башка система буенча асотряд). 250 дән артык төре билгеле. Татарстан терр-ясе өчен аеруча гадәти төрләр: Mesocyclops leuckarti, M. oitonoides, Cyclops vicinus, C. kolensis, Eucyclops serrulatus, Acanthocyclops vernalis һ.б. Вак кыслачыклар (1 мм га кадәр) өч өлештән: баш, күкрәк һәм корсактан торучы буынтыклы гәүдәле; баш һәм күкрәк өлеше икесе бергә цефалоторакс барлыкка китерәләр дә инде. Чагыштырмача тар корсагы очында каурыйлы берничә төкчәсе булган ике койрык тармагы б-н тәмамлана. Ц. аякларының 4 парын (5 нчесе үсеш алмаган) да бер үк вакытта селтәп йөзәләр, аннары алгы антенналары ярдәмендә бер урында торалар. Ана затларның гәүдәләреннең ян-ягында ике күкәй капчыгы бар. Күкәйләрдән личинкалар (науплия), күп кенә үсеш стадияләреннән узганнан соң, ул олы кыслачыкка әверелә. Ц. төче сулыкларның яр буендагы сайлыкларыннан алып шактый тирән урыннарына кадәр очрый. Сулыклар-

ның кибүен һәм катуын, күп кенә төрләре суда бөтенләй кислород булмавын кичерергә сәләтле. Күпчелеге — ерткычлар, вак умыртказыларга, балык уылдыкларына һәм личинкаларына һөҗүм итәләр. Үсемлекләр б-н туенучылары бар, сүүсемнәрнең яшел җепселләре б-н тукланалар. Күбесе — балык һәм умыртказыларның паразитлары. Ц. балыклар өчен азык булып торалар.

Әд.: Жизнь животных. Т. 3. Беспозвоночные. М., 1969; Краткий определитель водных беспозвоночных Среднего Поволжья. К., 1977; Райков Б.Е., Римский-Корсаков М.Н. Зоологические экскурсии. М., 1994.

В.А.Яковлев.

ЦИКО́РИЙ, фәрештә чәчәге (Cichorium), оешма чәчәкләләр семьялыгыннан бер-, икегодичлы күпьеллык үсемлекләр ыругы. Якынча 10 төре билгеле, Евразиядә һәм Төньяк Африкада таралганнар. Татарстан терр-ясендә бер төре — гади Ц. (C. Intybus), барлык районнарда очрый. Болын, алан, буш урыннарда, юл буйларында, торак пунктлар терр-яларенда үсә. 30–120 *см* биеклектәге күпьеллык үсемлек. Тамыры калын, үзәк, сөтчел сыекчалы. Сабагы туры, кабыргалы, кытыршы. Тамыр яны яфраклары каурыйсыман-бүленмә, яфрак таралгысына җыйналган, сабактагылары — чиратлашкан, очтагылар — бөтен читле. Чәчәкләре зәңгәр, эре, утырма кәрҗиннәргә җыелган. Җимеше — бүрекчәле озынча орлыкча. Бер үсемлек 3 меңнән 25 меңгә кадәр орлык бирә (шыту сәләтен 7 елга кадәр саклый). Июль–августта чәчәк ата. Август–сентябрьдә җимеш бирә. Орлыктан үрчи. Тамырларында инулин, гликозид, органик к-талар бар. Халык медицинасында төнәтмәсе гастрит, үт куыгы авыруларында вакытында, аппетитны күтәрү өчен кулланыла. Декоратив, баллы үсемлек.



Гади цикорий.

ЦИНАНХУ́М (Cynanchum), мамыкбашчалар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Якынча 5 төре билгеле (башка мәгълүматлар буенча 150 төр), уртача, субтропик һәм тропик поясларда таралган. Татарстан терр-ясендә бер төре — очлы Ц. (C. acutum) бар, Идел алдында Карлы елгасы буенда очрый. Тозлырак туфракларны өстен күрә. 30–60 *см* биеклектәге үсемлек. Тамыры кыска. Сабагы нәзек, үрмәле. Яфраклары йомыркасыман, озын саплы, күгел җем төстә. Чәчәкләре ике җенесле, ак яки алсу, күентылы яисә оч чатыр чәчәк төркемнәрендә. Җимеше бер, сирәк кенә ике табакчадан тора. Орлыклары озын бүрекчәле. Июнь–июльдә чәчәк ата. Җимешләре август–сентябрьдә өлгерә. Орлыктан һәм вегетатив юл б-н (тамыр үрентеләреннән) үрчи. Халык медицинасында үләне суы эч йомшарткыч чара буларак кулланыла. Декоратив, агулы үсемлек. Баллы.

ЦИ́ННА (Cinna), кыяклылар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 3 төре билгеле, Төньяк ярымшарның уртача поясында һәм Көньяк Америка тауларында таралганнар. Татарстан терр-ясендә бер төре — киң яфраклы Ц. (C. latifolia), Кама алдында очрый. Күләгәле ылыслы һәм катнаш урманнарда үсә. 60–130 *см* биеклектәге үсемлек. Тамырчасы шуышма. Сабагы туры, шома. Яфраклары киң кыяк, озын. Чәчәк төркеме — кытыршы иенке ботакчыклы җәенке себеркәч. Җимеше — бөртекчә. Июльдә чәчәк ата. Җимешләре августта өлгерә. Орлыктан һәм вегетатив юл б-н (тамырчалардан) үрчи. Терлек азыгы. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

«ЦИРКУЛЯ́Р ПО КАЗА́НСКОМУ УЧЕ́БНОМУ О́КРУГУ» («Казан уку-укыту округы буенча циркуляр»), журнал. 1834–1917 елларда Казанда рус телендә нәшер ителә. 1834, 1837–64 тә «Начальственные распоряжения по Казанскому учебному округу», 1835–36 да «Начальственные распоряжения, издаваемые Императорским Казанским университетом» исеме б-н басыла. Уку-укыту округы попечителе рөхсәте б-н дөнья күрә. Округ гимназияләре һәм уч-щеләре, ш.у. директорлар һәм инспекторлар өчен басмага язылу мәҗбүри була. Журналның рәсми өлешендә патша боерыклары, Халык мәгарифе министрлыгы, Казан уку-укыту округы идарәсе карарлары басыла, ш.и. кадрларны алмаштыру, бүләкләү, пенсия һәм пособие билгеләү, укытучы исеменә таныкнамәләр бирү мәсьәләләре карала. Рәсми булмаган өлештә уку-укыту округы попечителе каршындагы совет, гимназия һәм уч-щеләр пед. советлары беркетмәләре, округның уку йортлары буенча хисапларыннан күчермәләр, пед. әхтәлектәге мәкаләләр, дәрес планнары һ.б. басыла. Мөһим язмалар арасында — В.Владимировның «Казандагы беренче гимназиядә шәрекъ телләрен укытуның барышы» («О ходе преподавания восточных языков в 1-й Казанской гимназии», 1866). Журналда округ җитәкчелеге эшчәнлеге, уку йортлары тарихы буенча, татарларның белем дәрәҗәсе, ш.и. Казан татар укытучылары мәктәбе эшчәнлеге, рус-татар уку йортлары эшен оештыру, «әҗнәби» мәгарифе буенча төбәк киңәшмәләре карарлары турында киң материал бирелә.

Р.А.Айнетдинов.

ЦИУНЧУ́К Рөстәм Аркадьевич (13.5.1957, Казан), тарихчы, тарих фән. д-ры (2004), проф. (2007). Казан ун-тын тәмамлый (1979). 1982 елдан Казан финанс-икътисад ин-тының тарих, политология һәм хокук кафедрасында, 2004 тән Казан ун-тының сәяси тарих кафедрасында. 1988–92 дә Татарстан Яшь тарихчылар ассоциациясе рәисе. Хезмәтләре Россия империясендә сәяси партияләр, иҗтимагый-сәяси фикер, парламентаризм барлыкка килү тарихына, этноконфессиональ мәсьәләләргә һәм милли сәясәткә карый. Россия интеллектуаль тарих җәмгыятенең әгъзасы.

Хезм.: От имени пролетариата: историография истории большевистской думской тактики в 1905–1907 гг., К., 1989; Думская модель парламентаризма в Российской империи в этноконфессиональном и региональном измерениях. К., 2004.

Әд.: Историк российского парламентаризма (к 50-летию профессора Р.А.Циунчука) // Уч. Зап. Казан. ун-та. 2008. Т. 150, кн.1.

ЦМИН, к. *Улмәсгөл.*

ЦНИИГЕОЛНЕРУ́Д, к. *Руда булмаган файдалы казылмалар геологиясе үзәк институты.*

ЦОМАКИ́ОН Фёдор Михайлович (1.2.1848 — 19.6.1887, Казан), физик, физика д-ры (1884). 1869 елда Новороссия ун-тын (Одесса ш.) тәмамлый, 1877 дән шунда ук эшли. 1881 дән Казан ун-тында укыта (1884 тән проф.). Хезмәтләре газларның электр үткәрүчәнлегенә һәм магнитларны күзәтүгә карый.

Хезм.: Электропроводность газов. Од., 1879; Магнитные наблюдения, произведённые в городе Казани в течение 1883 года. К., 1884.

ЦЫПЛАКО́В Дмитрий Эдуарович (27.11.1961, Казань), патологоанатом, мед. фән. д-ры (1997), проф. (2008). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1985), шунда ук патологик анатомия кафедрасында эшли, 2004 елдан каф. мөдире, ун-тның патологик анатомия музее директоры. Хезмәтләре психофармакологиягә, йоткылык миндальсыман бизенең микроциркулятор юлын, регионар лимфа төеннәрендәге яман шешне (иммуногистохимик һәм ультраструктур тикшерү) өйрәнүгә карый. Казан шәһәре Сәламәтлек саклау идарәсенең баш штаттан тыш патологоанатомы (2002 дән).

Хезм.: Изучение новообразованной ткани внутри пористой структуры никелид-титанового имплантата методом глубокого травления по М.З.Миргазизову // Рос. вест. дентальной имплантологии. 2006. № 1/2 (автордаш); Морфологические особенности кровеносного микроциркуляторного русла глоточной миндалины при различных стадиях восстановительного процесса // Рос. оториноларингология. 2008. № 3 (автордаш).

ЦЮПА́К Владислав Иосифович (7.5.1910, Ленинград — 5.5.2001, Яшел Үзән ш.), инженер-суднолар төзүче, СССР Дәүләт бүләге (1949), Ленин бүләге (1965) лауреаты. Ленинград төгәл механика ин-тын тәмамлаганнан соң (1932), «Радиоприбор» з-дының проектлау бюросында конструктор булып эшли (Ленинград). 1934–37 елларда 192 нче з-дта өлкән конструктор, баш конструктор (Мәскәү). 1937 дән Мариинск лагере механизаторы (Кемерово өлкәсенең Юрга ст.); 1939–45 тә НКВДның Тәжрибә КБда механика төркеме башлыгы (Казан). 1945–50 дә Яшел Үзән суднолар төзү з-дында эшли, баш конструктор (1948 дән).1950–89 да Яшел Үзән проектлау-конструкторлык бюросында: башлык урынбасары — баш конструктор (1979га кадәр), әйдәп баручы инженер (1979 дан). Дәүләт бүләге корабльләр төзелешендә агымлы алымны эшләүдә һәм гамәлгә кертүдә катнашканы өчен (122б проекты), Ленин бүләгә махсус машина төзелеше өлкәсендәге эшләре өчен (204 проект) бирелә. Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Ч

ЧАБА́К (Rutilus), карплар семьялыгыннан балыклар ыругы. 7 төре билгеле, Евразиянең, Төньяк Американың төче һәм тозлырак суларында тереклек итәләр. Татарстан терр-ясендә бер төре — гади Ч. (R. rutilus) бар. Елга, күл, сусаклагычларда яши. Өер булып йөри. Гәүдәсе биек, ян-яктан нык кысылган, озынлыгы 25–30 *см*, авырлыгы 200–250 *г*. Тәңкәсе эре. Сырты зур таплы яшькелт төстә. Ян-яклары һәм корсагы көмешсыман. Койрык һәм сырт йөзгечләре соры, калганнары кызгылт-сары. Күзләренең төсле катлавы кызгылт-сары, башка карплардан күзенең өске өлешендәге кызыл табы б-н аерыла. Яшәвенең 3–4 елында җенси җитлегә. Суның темп-расы 10–12,5 °С булганда, күпләп уылдык чәчә башлый. Уылдык чәчү урыннары — 1 *м* га кадәр тирәнлектәге үсемлек субстратлы яр буйлары. Үрчемлелеге 1 дән 100 мең уылдык бөртегенә кадәр. Бөҗәк личинкалары, кысласыманнар, вак моллюскълар, сууисемнәр б-н туклана. Җирле кәсәбәчелек һәм балыкчылык спорты объекты.

ЧАБАКСА́ авылы, Казанның Совет р-ны составында, Биектау тимер юл станциясеннән 13 *км* көньяктарак, Киндерле елгасы буенда. «Агропромэнерго» пр-тиесе. Тулы булмаган урта мәктәп, китапханә. 1557 елда нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Покровский исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы удел (1797 гә кадәр — сарай) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, олаучылык б-н шөгыльләнә. 19 йөзнең 2 нче яртысында Ч. тимерчелек кәсепчелеге үзәге булып китә. Югары сәнгать осталыгы б-н аерылып торган Ч. осталары эшләнмәләре (чүкеп ясалган рәшәткәләр, балконнар, баскыч култыксалары һ.б.) Казан һәм Россиянең башка губерналарында дан казана. 20 йөз башында Ч. да Покров чиркәве (1861–63тә төзелә), земство мәктәбе (1872 дә ачыла), һөнәр сыйныфы, (1893), 40 тимерчелек, 4 җил тегермәне, 1 сыраханә, 1 казна шәраб, 2 мануфактура һәм 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2416,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кощаково волостенда, 1920 дән ТАССР-ның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Воскресенский, 1927 нең 1 августыннан Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Столбище, 1959 ның 26 мартыннан — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Биектау р-нында, 2007 нең 28 декабреннән Казанның Совет р-ны карамагында. Халык саны: 1646 да — 149, 1782 дә — 287 ир-ат; 1859 да — 1008, 1897 дә — 1257, 1908 дә — 1230, 1920 дә — 1558, 1926 да — 1577, 1949 да — 1097, 1958 дә — 1080, 1970 тә — 863, 1989 да — 337, 2002 дә — 345 кеше (руслар).

Әд.: Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

ЧАБАКСА́ ТИМЕРЧЕЛЕ́К КӘСЕПЧЕЛЕГЕ́, архит-ра бизәлеше, йорт җиһазы, экипаж (пролётка, тарантас, фаэтон) өчен металлдан орнаментлы эшләнмәләр ясау буенча халык нәфис кәсепчелеге. Эшләнмәләр кою һәм чүкү ысулы б-н башкарыла. Ч.т.к. Казан губернасы Чабакса авылында оеша, алга таба якын-тирәдәге Самосырово, Әки, Вознесенское, Константиновка, Олы Дербышки, Биектау, Киндерле, Пановка авылларына да тарала. 1812 елгы Ватан сугышына кадәр барлыкка килә, нигезләнүе шушы төбәк кешесе Ф.Никитин тарафыннан беренче тимерчелек ачылу б-н бәйле. Башта авыл осталары экипаж көпчәкләрен металлдан кыршаулау б-н шөгыльләнә, соңрак, эшләнмә төренә карап, хезмәт бүленеше барлыкка килә — экипажчылар, караватчылар, рәшәткәчеләр; нәфис чүкү б-н шөгыльләнүче вак һөнәрчеләр төркемнәре аерылып чыга.

Ч.т.к.нең чәчәк ату чоры 19 йөзнең икенче яртысы – 20 йөз башына туры килә. 1842 елгы янгыннан соң, Казанда бина фасадларын, бакча-парк коймаларын, капкаларны һ.б. металл детальләр (балкон рәшәткәләре, ишек өсте, шпильләр) б-н бизәү тарала. 19 йөз ахырында Чабаксада тимерчелек-слесарьлык эше киң колач ала: 75 тимерчелек исәпләнә, шуларның 11 ндә рәшәткәләр һәм караватлар җитештерелә. Ч.т.к.ндә Агафоновлар, Масловлар, Микешиннар, Новожиловлар, Симоновлар, Сосковлар, Фёдоровлар һ.б. тимерче нәселләренең гаилә төркемнәре барлыкка килә. В.П., А.В., В.С.Гребенщиковлар, Т.Н., И.Н.Филипповлар, С.Е.Михайлов, Ф.Е.Фёдоров койма һәм капкаларны чүкү һәм калыплап кою ысулларын кулланып ясау б-н шөгыльләнә. 1890 да Казанда уздырылган фәнни-сәнәгать күргәзмәсендә архит-ра эшләнмәләре чүкеп ясауның яхшы осталары итеп бертуган Гребенщиковлар таныла (Зур көмеш медаль б-н бүләкләнәләр).

Архит-ра эшләнмәләрен чүкеп ясау шәхси һәм дәүләт заказлары буенча башкарыла. Тимерчеләр үз эскизлары, архитекторлар сызымнары буенча һәм Казан сәнгать мәктәбе б-н элемтәдә эшлиләр. Соңрак авылда *Чабакса һөнәр-сәнгать остаханәсе* оештырыла һәм ул һөнәри осталыкны, сәнгати формаларны камилләштерүгә (бизәкләр стильләштерелә, геом. орнамент мотивлары өлеше артырыла) зур өлеш кертә. Халык традицияләре үсешендә дәвамлылык төп үзенчәлеге авыл өйләренең тәрәзә капкачларына, тәрәзә йөзлекләренә һәм ишекләренә хас агачка уеп бизәк төшерү (ромашкалар, үсемлек сабаклары, колмак үрентеләре, әтәч, балык, кояш сурәте һ.б.), үсемлек орнаменты, тоташ келәмсыман рәсемнәрдән торган һ.б. бер-берсенә беркетелгән, калыплап коелган детальләрдән гыйбарәт аерым стиль тууга китерә. Ч.т.к.нең архит-рада чүкеп башкарылган үрнәкләре — Казан ун-тының төп бинасындагы рәшәткәләр, капка, ян-як баскыч култыксалары, сәүдәгәр Оконишников йортының (хәзерге ТР Язучылар берлеге бинасы; бертуган Гребенщиковлар эше) тышкы коймасы, капкасы, баскыч өслеге, веранда һәм балкон рәшәткәсе, Ушкова йортының (хәзер ТР Милли китапханәсе бинасы) балкон рәшәткәләре, элекке Казан хәрби округы башкомандующие йортының (хәзер ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее бинасы), Кекин йортының, «Казан» кунакханәсенең, Дәүләт банкы бинасының (Ф.Е.Фёдоров эше, 2 нче каттагы култыксалар А.П.Волков җитәкчелегендә Чабакса һөнәр-сәнгать мәктәбе укучылары тарафыннан башкарылган) капкалары, коймалары, баскыч гөмбәзләре һәм ә́ркалары, ш.у. Сембер шәһәрендәге (хәзерге Ульянов ш.) Александр бакчасындагы рәшәткәләр һ.б.

Беренче бөтендөнья сугышы вакытында нәфис чүкеп ясалган бизәкле архит-ра детальләренә сорау кими. Ч.т.к. төрле экипаж-лар эшләүгә күчә, 20 йөз башында аларны җитештерү күләме елга 5 меңгә җитә (нигездә тимер һәм корыч детальләрдән эшләнгән тарантаслар). 1913 тә Казанда уздырылган сәнәгать күргәзмәсендә Чабаксада ясалган фаэтоннар һәм тарантаслар күрсәтелә. Гражданнар сугышы алдыннан Чабаксада 120 тимерчелек була, анда 400 гә якын кеше, ш.и. ялланып эшләүчеләр, башлыча тарантаслар, а.х. кирәк-яраклары эшләү б-н шөгыльләнә. Ул чорда аеруча танылган тимерчеләр В.С.Гребенщиков, П.З.Сосков, П.И.Симонов, П.И.Задовский, П.Д.Афонин, С.Д.Гогулин, А.С.Новожилов була. Тимерчелек эше б-н хатын-кызлар да, аерым алганда, Г.Максимова (сиртмәле пролётказлар ясый), Д.Симагина, Ю.Суханова, А.Тутуркина (чүкеччеләр) шөгыльләнә. 1923 тә Мәскәүдә 1 нче Бөтенсоюз а.х. күргәзмәсендә Чабакса осталары ясаган экипажлар дипломнар б-н бүләкләнүгә дә карамастан, Ч.т.к. акрынлап сүнә. 1925 тә Ч.т.к. остаханәләре нигезендә «Прогресс» вак һөнәрчелек артеле оештырыла. 1920 еллар ахырында осталар тулысынча олаулар ясауга күчә һәм 1956 да артель олаулар ясау з-ды итеп үзгәртелә (чаналар һәм арбалар җитештерелә), 1968 дән — агач эшкәртү комб-ты. 20 йөзнең уртасында һәм икенче яртысында Казан архитекторлары Ә.Һ.Бикчәнтәев, М.К.Игъламов, И.Г.Гайнетдинов, рәссам И.Башмаков һ.б. тарафыннан Ч.т.к.н һәм архит-ра чүкеп ясау традицияләрен торгызырга омтылыш ясала.



Чабакса тимерчелек кәсепчелеге. 1, 2. ТР Милли китапханәсе (элеккеге Ушкова йорты) балконы рәшәткәләре. Металл. Чүкү. 20 йөз башы; 3, 4. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее бинасы (элеккеге Казан хәрби округы башкомандующие йорты) янындагы декоратив рәшәткә. Металл. Чүкү. 20 йөз башы; 5. Ваза аслыгы. Металл. Чүкү. 20 йөз башы; 6. Рәшәткәнең декоратив детале. Металл. Чүкү. 20 йөз башы (5, 6. – ТР Милли музеенда); 7, 8, 9, 10. ТР Язучылар берлеге бинасы (элеккеге М.Оконишников йорты) янындагы декоратив рәшәткә. Металл. Чүкү. 20 йөз башы.

Әд.: Тәхау К. Гасырлар кичкән сәнгать. К., 2008; Кустарные промыслы в Казанской губернии. К., 1897; Мелкая промышленность Казанской губернии. К., 1911; Перцев В. Очерк статистики и экономики Казанской губернии. К., 1919; Воробьёв Н.И., Бусыгин Е.П. Художественные промыслы Татарии в прошлом и настоящем. К., 1957; Глухов М. Не молот железо куёт. К., 1969; Халитов Н. Металлическое кружево Казани. К., 1988.

Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.

ЧАБАКСА́ ҺӨНӘР-СӘНГА́ТЬ ТИМЕРЧЕЛЕ́К-СЛЕ́САРЬЛЫК УКУ́ ОСТАХАНӘСЕ́. Рус *тимерчелек кәсепчелегенең* тарихи яктан формалашкан үзәгендә — Казан губернасы Чабакса авылында Россия Сәүдә һәм сәнәгать министрлыгының сәнгать-сәнәгать учреждениеләре турындагы Нигезләмәсе, губерна земствосы Уставы һәм 1910 ел 16 гыйнвар җыены карары нигезендә 1910 да ачыла. Сәүдә һәм сәнәгать министрлыгының уку-укыту бүлеге карамагында була; гомуми җитәкчелек, уку-укыту һәм хезмәт эшчәнлегенә күзәтчелек итү Казан земствосына, аның попечительләр ком-тына (рәисе һәм һөнәри белем бирү бүлеге мөдире Н.С.Теренин; әгъзалары — А.А.Мельников, А.Н.Боратынский, җирле вак һөнәрче Е.П.Фёдоров) йөкләнә. Остаханә җирле һөнәрчеләрнең сәнгати белемнәрен күтәрергә, нәфис чүкеп ясау техникасын яңарту һәм камилләштерүдә ярдәм итәргә тиеш була. М.И.Завалишин проекты буенча махсус төзелгән бинада урнаша. Остаханә б-н Казан сәнәгать уч-щесен тәмамлаган А.И.Павлов идарә итә, ул бер үк вакытта һөнәри технол. һәм арифметика укыта. Укытучылар — В.П.Зефиров (технол. рәсем, инҗади рәсем, акварель, натурадан рәсем ясау, стильләштерү, орнамент тарихы), Н.Д.Болтунов, П.О.Безсонов (гамәли сәнгать буенча рәссамнар), А.П.Волков (нәфис чүкү). Укырга 12–20 яшьлекләр кабул ителә. Өч еллык уку курсы сәнгать буенча гомуми белем бирүне һәм тимерчелек-слесарьлык технологиясен үзләштерүне үз эченә ала. Уку тәмамланганнан соң, оста ярдәмчесе дәрәҗәсе, ә 3 елдан, мөстәкыйль эш турында хисап тапшырылган очракта, оста дәрәҗәсе бирелә. Кайберәүләр алга таба укуларын Екатеринбургтагы сәнгать-сәнәгать, Мәскәүдәге Строганов уч-ще ләрендә дәвам иттерә.

Остаханәдә кече формадагы архит-ра детальләре — бизәкле рәшәткәләр, кронштейннар һәм зиннәтле чатырлар, флаг тоткычлар, чәчәк өстәлләре, аерым алганда, Казандагы Дәүләт банкының төп баскычы өчен култык-салар һәм фонарьлар эшләнә, император Александр II гә һәйкәл коела. Остаханә 1912–13 тә Петербургта 2 нче Бөтенроссия вак һөнәрчелек сәнәгать күргәзмәсендә катнаша, анда «рус стилендәге» шәмдәлләр, кара савытлары, 2 рәсемнәр альбомы, остаханә эшчәнлеге турында фоторәсемнәр күрсәтелә. Мактау бәяләмәсе б-н бүләкләнә. Беренче бөтендөнья сугышы башлану һәм гамәли әйберләр эшләүгә күчү сәбәпле, остаханәнең уку-укыту юнәлешле эшчәнлеге туктатыла. 1917 дән соң бетерелә.

Әд.: Отчёт о деятельности кузнечно-слесарной художественно-ремесленной мастерской в с. Чебакса за 1912–13 уч.г. К., 1913; Отчёт о деятельности кузнечно-слесарной художественно-ремесленной мастерской в с. Чебакса за 1914–15 уч.г. К., 1915; Ключевская Е.П. Искусство народное и профессиональное: К проблеме взаимодействия в художественной культуре Поволжья XIX–XX вв. // Из истории татарского народного искусства: Сб. статей. К., 1995.

Е.П.Ключевская.

ЧАБАКСА́Р елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Олы Чирмешән елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 20,9 *км*. Бассейнының мәйданы 150,9 *км*². Идел аръягы түбәнлегеннән ага. Елга башы Яңа Чишмә р-ны Рус Чабаксары авылыннан 8 *км* көньяк-көнчыгыштарак, урман буенда, тамагы Чистай р-ны Рус Ялтаны авылыннан 4 *км* көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 150 *м*, тамагыныкы — 122 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы — 20%. Ч.ның 0,8 дән 2,3 *км* га кадәр озынлыктагы 4 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,18 *км/км*². Туенуы катнаш, күбрәк кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км*². Гидрологик режимы язгы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Елганың югары агымы яңгыр булмаган елларда кибә. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Ч. ноябрь уртасында туңа. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минераль әшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. Елгада суының күләме 1,02 млн. *м*³ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

ЧАБАКСА́Р ӨЯЗЕ́, 1708–1920 елларда Казан губернасындагы адм.-терр. берәмлек. Үзәге — Чабаксар шәһәре (1555 тә Идел елгасының уң ярында кальга буларак нигезләнә). *Зоя өязенең* Чабаксар кальгасы тирә-ягындагы җирләрнең бер өлешеннән оеша. 1708 дә — Казан губернасы, 1781–96 да — Казан наместниклыгы, аннары кабат Казан губернасы составына керә. Төньякта — Казан губернасының Царёвококшайск (Чар), көн-батышта — Козьмодемьянск, көнчыгышта — Казан һәм Зоя, көньякта Ядрин һәм Цивильск (Чуел) өязләре б-н чикләшә. Өязне Идел елгасы бүлә; аның терр-ясе буйлап ш.у. Олы һәм Кече Кокшага, Илләт, Олы Цивиль (Олы Чуел), Олы Аниш елгалары ага. Мәйдаными 3,7 мең кв.чакрым. Халкы 137,7 мең кеше, ш.и. чуашлар — 66,7 %, руслар — 18,3 %, марилар — 12,1%, татарлар — 2,8 % (1901). Адм. яктан Акулево, Алым-Касы, Богородский, Воскресенский, Никольский, Покровский, Помары, Помьял, Посад-Сотниковский, Тогаш, Чабаксар волостьларына бүленә. Халкы игенчелек, кәсепчелек — киже-җитен туку, сумала куу, мичкә ясау, балта эше б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ч.ө. ндә механик, күн, салат кайнату, аракы, кирпеч, сагыз кайнату һәм скипидар, такта яру з-длары эшли. Өязда 128 мәктәп була. 1920 дә Ч.ө. терр-ясе Чуаш автономияле өлкәсе составына керә.



Чыг.: Материалы для географии и статистики России, собранные офицерами Генерального штаба. Казанская губерния. СПб.,1861.

Әд.: Спасский Н.А. Очерки по родиноведению: Казанская губерния. К., 1912; Краткая чувашская энциклопедия. Чебоксары, 2001.

Д.Г.Мостафина.

ЧАБАТА́, юкәдән үреп ясалган аяк киеме. Ихтимал, Идел буе татарларына курыс аяк киеме күрше халыклардан — мордвалардан, чуашлардан, руслардан үтеп кергән. Ч. башлыча эштә файдаланылган аяк киеме булган. 19 йөздә аны һәркайда үрәләр, халыкның күпчелек өлеше өчен бу шөгыль өй кәсебенә әверелә. Казан һәм Уфа губерналарында тупыйк башлы, табаны кыек юллы, кырыйлары сай, кыска баулы булуы б-н аерылып торган «татар Ч.сы» үрү кустар кәсебе барлыкка килә. Алар, матурлыклары буенча рус Ч. ларыннан калышсалар да, чыдамрак булганнар һәм арзанрак торганнар; алыпсатарлар аша андый Ч.лар Иделнең түбәнге агымында урнашкан губерналарда, приискларда һ.б. җирләрдә күпләп сатылган. Ч.ны киндер яки тула оеклар яисә аяк чолгаулары б-н кигәннәр, кыска баулары балтырны ук ураугa җитмичә, ашык сөяге тирәсендә бәйләнгән. Язын-көзен агач аслыклы «күтәртмәле Ч.» кигәннәр. Ашык сөяге тирәсендә киндер өслеге бәйләнгән үзенчәлекле «бышымлы Ч.» Урал яны татарлары арасында, башлыча хатын-кызларның кышкы аяк киеме буларак таралыш алган. «Юкә башмак» киң кулланылган, аны еш кына артсыз туфли рәвешендә, арткы ягын ачык калдырып, күн яки агач табан куеп үргәннәр. Ч.лар аеруча керәшен татарлар арасында популяр булган, нагайбәк-ләр төркемендә хатын-кызлар һәм балалар өчен юкәгә ачык төстәге йон җепләр кушып үреп, төсле күпшы Ч.лар ясаганнар. Кешеләр аңында Ч.лар ярлылыкка һәм хәерчелеккә тиңләштерелүгә карамастан, алар күп кенә авыл районнарында 20 йөз уртасына кадәр кулланылган.

Әд.: Суслова С.В., Мухамедова Р.Г. Народный костюм татар Поволжья и Урала. К., 2000; Халиков Н.А. Традиционное хозяйство // Татары. М., 2001.

Ф.Ф.Гулова.

«ЧАБАТАЛЫ́ МОРЗАЛА́Р», бөлгән татар морзаларының кинаяле атамасы. 18 йөз башында Россия хөкүмәте кануннар б-н татар аксөякләренең икътисади хокукларын чикли: Петр I нең 1713 ел 3 ноябрь һәм 1715 ел 12 июль указлары б-н чукынмаган татарлар-



Ш.М. Чабдаров.



Владимир Г.Чагин.

ның утарларын, биләмәләрен һәм крепостной крәстияннәрен тартып алырга күрсәтмә бирелә. Морзаларның бер өлеше православие кабул итә һәм рус феодаль сыйныфы составына керә, башкалары үзләренең җирләрен һәм крәстияннәрен югалталар. 1718 дә морзалар ш.у. корабльләр төзү өчен урман кисәргә, эшкәртергә һәм чыгарырга беркетеләләр (к. *Лашманнар*). Соңрак алар салым түләүче катлауга күчерелә ләр. Шул рәвешле морзалар социаль статусларыннан һәм өстенлекләреннән мәхрүм ителәләр. Бу күренеш татар халкында татар аксөякләренең бөлгән яки ярлыланган вәкилләренә карата «Ч.м.» кушаматы таралуда чагылыш таба.

ЧАБДА́РОВ Шамил Мидхәт улы (26.1.1937, Казан), радиоэлектроника өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1982), ТР ФА академигы (1992), ТАССРның атказ. фән һәм техника эшлеклесе (1987), Казан техник ун-тының атказ. профессоры (2007). 1960 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли: проф. (1983), радиоаппаратура житештерү (1976–85), радио аша идарә (1985–87) кафедралары мөдире, радиотехника ф-ты деканы (1973–87), каф. профессоры (1987дән). Бер үк вакытта, 1987–2000, дә Казан «Радиоэлектроника» фәнни-җитештерү үзәгендә: директор урынбасары (1987–88), директор, күренмә объектларның кайсы дәүләтнеке булуын белү бердәм системасы ген. конструкторы (1988–97), ТР ФА вице-президенты (2002–07), ТР ФА президенты киңәшчесе (2007 дән). Хезмәтләре эксплуатация һәм җитештерү күрсәткечләренең Гауссныкы булмаган реаль флуктуацияләре очрагында радиотехник җайланма һәм системаларны оптималь ләштерүнең бер үк төрле алымнарына карый. Статик радиотехникада *полигаусс процесслары* һәм алымнары фәнни юнәлешенә нигез салучы. Ч. тарафыннан ирекле бирелгән комачау комплекслары һәм ярсыткыч тәэсир шартларында радиосигналлар кабул итүнең оптималь һәм адаптив алгоритмларын анализлау һәм синтезлау алымнары эшләнә. Ч. В.А.Котельников тарафыннан куелган бердәнбер чикләнүле сигналлар һәм комачаулыкларның ирекле флуктуацияләре шартларында потенциаль комачауга потенциаль чыдамлылык мәсь әләсен беренче булып чишә. Уйлап табуга 47 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. «Машиналарны һәм приборларны виброакустик сынау өчен радиоэлектрон система лар һәм комплекслар (теория, алымнар һәм чаралар)» хезмәтендә катнашуы өчен ТР Дәүләт бүләге бирелә (1996). «Почёт билгесе» ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш һәм бронза медальләре, ТРның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә. СССРның мактаулы радисты (1978).

Х е з м.: Идеальный приёмник и потенциальная помехоустойчивость при произвольных флуктуациях негауссовских сигналов и помех // Наукоёмкие технологии. 2004. Т. 5, № 4; Смеси случайных явлений в статистической радиотехнике // Вестн. Казан. техн. ун-та.2008. № 4.

Әд.: Казанская научная школа полигауссовых явлений посткорреляционной статистической радиотехники // Физика волновых процессов и радиотехнические системы. 2004. Т. 7, № 1.

ЧАБЫ́Р ҮЛӘНЕ́ (Thymus), иренчәчәклеләр семьялыгыннан ярымкуакчыклар яки куакчыклар ыругы. 150 гә якын төре билгеле, Евразиянең уртача поясында, Төньяк Америкада таралганнар. Татарстан терр-ясендә 6 төре бар. Шуышма Ч.ү. (T. serpyllum) барлык районнарда очрый, башкорт Ч.ү. (T. bashkiriensis), Маршалл Ч.ү. (T. marschallianus), Талиев Ч.ү. (T. Talijevii) һ.б. — Кама аръягында. Далаланган болыннарда һәм сөзәк лекләрдә үсәләр. 2–25 *см* биеклектәге ярымкуакчыклар. Сабагы агачланучан. Яфраклары эллипссыман, вак, күбесе сабакчалы. Чәчәкләре алсу шәмәхә, башча чәчәк төркемендә. Җимеше 4 чикләвекчектән тора. Май ахырыннан сентябрьгә кадәр чәчәк ата. Орлыктан һәм вегетатив юл (шуышма ботаклардан) б-н үрчи. Эфир майлы үсемлекләр. Халык медицинасында үләне төнәтмәсе салкын тигәндә, ашказаны җәрәхәте, ревматизм, бавыр һәм йөрәк авырулары вакытында кулланыла. Эфир маеның төп компонентын авыртуны басу һәм дезинфекцияләү үзлегенә ия тимол тәшкил итә. Ч.ү.нең сыек экстракты «Пертуссин» препараты составына керә. Яфраклары аш-су әзерләүдә, консерв һәм ликёр-аракы сәнәгатендә тәмләткеч буларак файдаланыла. Баллы үсемлекләр.

ЧАГАТА́Й Сәгадәт Гаяз кызы (15.7.1905, Казан губ., Чистай өязе Яуширмә а. — 24.6.1989, Әнкара), филолог, филол. фән. д-ры (1933). Г.*Исхакыйның* кызы. 1916 елдан Смольный затлы нәсел кыз балалар ин-тында укый. 1917 елгы Окт. рев-циясеннән соң туган авылына кайта. 1922 дә Финляндиягә, аннары Германиягә китә. Берлин ун-тын тәмамлаганнан соң (1932), «*Яңа милли юл*» ж-лы редакциясендә эшли. 1940 тан Төркиядә. 1943–77 дә Әнкара ун-тында укыта, проф. (1953 тән). Ч. борынгы төрки әдәби ядкәрләрне текстологик яктан басмага әзерли. Хезмәтләре төрки телләр морфологиясенә карый.

Х е з м.: Altun Yaruk'tan Iki Parça. Ankara, 1945; Türk Lehçeleri Örnekleri: 2 kitapta. Ankara, 1950–72; Kazakça Metinler. Ankara, 1961; Prof. Dr. Saadet Çağatay'ın Yayinlanmiş Tüm Makaleleri. Ist., 2008. 2 ciet.

Әд.: Ş e n o l H. Prof. Dr. Saadet Ishaki Çağatay' in Yaşam Öyküsü. Ist., 2007.

ЧА́ГИН Виктор Георгиевич (23.4.1912, Саратов өлкәсенең Вольск өязе Тепляково а. — 26.11.1971, Казан), вет. терапевты, вет. фән. д-ры (1950), проф. (1951). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1934), шунда ук эшли, 1942 елдан терапия каф. мөдире. Хезмәтләре а.х. терлекләренең канын тикшерүгә, сулыш әгъзалары, йөрәк, ашказаны-эчәк тракты авырулары патологиясен һәм аларны дәвалау юлларын өйрәнүгә карый. «Авыл хуҗалыгы терлекләренең йогышлы булмаган авырулары патологиясе һәм терапиясе» («Патология и терапия внутренних незаразных болезней сельскохозяйственных животных», М., 1960) дәреслеге автордашы.

Х е з м.: К вопросу о лечении и профилактике диспепсии телят // Ветеринария. 1968. № 4 (автордаш); Фонокардиография и её использование в ветеринарной практике // Ветеринария. 1968. № 7 (автордаш).

Әд.: Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.): Биогр. словарь учёных. К., 2006.

ЧА́ГИН Владимир Геннадьевич, (5.1.1970, Пермь өлкәсенең Нытва ш.), спортчы (автомобиль спорты), ТР, РФнең атказ. спорт остасы (1999, 2003), ТРның атказ. машина төзүчесе (2009). Йөк автомобильләре арасында ралли-марафоннарда җиңүче: «Дакар» 2000: Дакар – Каһирә (Мисыр), 2002: Аррас (Франция) — Мадрид (Испания) — Дакар, 2003: Марсель (Франция) — Шарм-әл-Шәех (Мисыр), 2004: Клермон-Ферран (Франция) — Дакар, 2006–07: Лиссабон (Португалия) — Дакар, 2010: Буэнос-Айрес (Аргентина) — Антофагаста (Чили) — Буэнес-Айрес, 2011: Буэнес-Айрес — Арика (Чили) — Буэнес-Айрес, «Дезерт Челендж» (1999, 2001, 20002, 20003, 20005, 2006, 2008), Россия чемпионатлары этапларында «Дебри-2000», «Баха Жемчужина», «Калмыкия», (2000), «Бөек дала» (2005), «Хәзәр далалары» (2004, 2006, 2010), «Маршрут 1000», «Тын Дон» (2008), «Көнчыгыш-Каппадокия раллие» (2003, 2004), «Мастер-Ралли» (1995, 1996, 2000, 2002), «Оптик Тунис» (2000, 2001), «Баха Италия-2000», Россия чемпионатларында 2000, 2004, 2008 җиңүче. «Дакар» 2009: Буэнес-Айрес — Вальпараисо (Чили) — Буэнес-Айрес (көмеш), «Дезерт-Челендж» (2000) (бронза) медальләр ала. Дөнья Кубогы 1996, 2000, Россия Кубогы 2000 иясе. Ч. 1988–94 тә механик, 1995–2011 дә пилот, 2012 дән «КАМАЗ-мастер» спорт командасы җитәкчесе. Бер үк вакытта, 2009 дан, «КамАЗ — Автоспорт» коммерцияле булмаган партнерлык директоры. РФнең Дәүләт бүләге (2001), Милли бүләк (2000) лауреаты. «Почёт билгесе», 3 нче, 4 нче дәрәҗә «Ватан алындагы казанышлары өчен», Батырлык, Мактау, Дуслык, «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» орденнары, медальләр, ТРның, РФнең «Физик культура һәм спортны үстерүдәге казанышлары өчен» мактау билгеләре б-н бүләкләнә. Чаллы шәһәренең мактаулы гражданы (2002).

ЧАГЫШТЫРМА́ ЛИНГВИ́СТИКА, к. *Контрастив лингвистика*.

ЧАЖ елгасы, Көнчыгыш Кама алдында, Иж елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 50 *км*, ТР чикләрендә — 35 *км*. Бассейнының мәйданы 592 *км*^{2}. Можга калкулыгыннан ага. Елга башы Удмурт Респ-касы терр-ясенең урман массивында, тамагы Әгерҗе р-ны Мордыбай авылыннан 3,5 *км* көньяк-көнчыгыштарак.

Елга башының абс. биеклеге 230 *м*, тамагы-ныкы — 66 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 20%. Ч.ның 0,3 тән 34 *км* га кадәр озынлыктагы 25 кушылдыгы бар, иң зурлары — Сарсак (21 *км*), Юри (34 *км*) — сул кушылдыклар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,59 *км/км*^{2}. Туенуы катнаш, күбрәк кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,3–0,5 *л/с·км*^{2}. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су



Чаж елгасы.

агымының уртача күпьеллык катламы 99 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 81 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрель башында башлана. Ч. ноябрьнең беренче ункөнлегендә туң. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,36 *м*^{3}*/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минераль-ләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*.

ЧАЙНСК РАЙОНЫ, Томск өлкәсенең үзәгендә, Обь елгасының сул ярында урнашкан. 1924 елда оештырыла. Мәйданы — 7,24 мең *км*^{2}. Үзәге — Подгорный авылы. Халкы — 11663 кеше (2018). 2010 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 100 ләп (1970 тә — 258, 1979 да — 216, 1989 да — 187, 2002 дә —108) кеше. Татарлар (нигездә, керәшеннәр) Ч.р. терр-ясенә 20 йөз башыннан Столыпинның аграр реформасын үткәрү б-н бәйле рәвештә килеп урнаша. 1920–30 елларда алар Рождественка, Галеевка, Карамзинка авылларына нигез сала. 1920–40 елларда Рождественка һәм Карамзинка авылларында татар мәктәп-ләре була. Татарлар, тупланып, Подгорный, Коломино, Чаинск авыл җирлекләрендә яшиләр. Подгорный төбәкне өйрәнү музее каршында «Кызлар» клубы эшли (2010 нан).

ЧАЙКИН Владимир Григорьевич (15.8.1949, Казан), геолог, геол.-минерал. фән. д-ры (2005), ТРның атказ. геологы (1997). Казан ун-тын тәмамлый (1971). 1973 елдан ЦНИИгеолнерудта, файдалы казылмалар геологиясе бүлеге мөдире (2000 нән). Хезмәтләре файдалы казылмалар геологиясенә һәм геотехнологиягә карый. Ч. Рус платформасында руда булмаган файдалы казылмалар (флюорит, апатит, тозлар) ятмалары урнашуның геол. үзенчәлекләрен билгели (автордашлыкта), таштоз чыгаруның геотехнол. ысулларын эшли. Медальләр, «Җир асты байлыкларын эзләү отличнигы» Мактау билгесе б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Месторождения природной соды // Геологическое строение и минерагения СССР. Л., 1989 (автордаш); Минерагения осадочного чехла востока Русской платформы. К., 2004 (автордаш).

ЧАЙКО́ВСКИЙ шәһәре, Пермь краеның көньяк-көнбатыш өлешендә, Пермь шәһәреннән 325 *км* көньяк-көнбатыштарак урнашкан. 1955 елда гидротөзүчеләр посёлогы буларак нигез салына, 1962 дән — шәһәр. Халкы — 83486 кеше (2017), ш.и. 7,5 меңләп татар. Алар монда Ч.ш. нигезләнгән көннән яшиләр, Воткинск ГЭСын төзиләр. Татарларның монда күченүе ефәк тукыма комб-ты (1950 еллар ахыры), ясалма каучук һәм төгәл машина төзелеше з-длары (1970 еллар) төзелү, «Пермтрансгаз» пр-тиесе оештырылу (1984) б-н бәйле. 1959 да — 1960 еллар ахырында «Гидростроитель» клубы каршында татар җыр һәм бию ансамбле, халык театры студиясе эшли. Шәһәрнең 2 мәктәбендә һәм 1 лицейда татар теле факультатив дәрес буларак укытыла (1991 дән); 2 нче балалар музыка мәктәбендә татар бүлеге бар (2005 тән). 1998 дә «Якташлар» татар г-тасының берничә саны чыга, «Тамчылар» балалар үзәге (2000–04), «Дуслык» милли-мәдәни үзәге (1995 тә — «Нур» татар-башкорт җәмгыяте буларак оештырыла, 1996–2002 дә Татар-башкорт иҗтимагый үзәге), «Чулман» татар-башкорт җәмгыяте (1989), «Туган тел» татар поэзиясен һәм прозасын яратучылар түгәрәге (1989), «Сәйләп» татар ансамбле (1988–2003 тә «Дуслык» исеме астында), «Идел» җыр һәм бию ансамбле (1996), «Йолдызлар» балалар вокаль ансамбле, Мөселманнар дини җәмгыяте (1980 нән), якшәмбе мәктәбе б-н мәчет эшли.

Әд.: З а к и р о в Д.Г. Известные татары Прикамья. Пермь, 2005; Ч е р н ы х А.В. Народы Пермского края: История и этнография. Пермь, 2007.

ЧАКМАГЫ́Ш РАЙОНЫ́, *Башкортстан Республикасының* төньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан. 1930 елның 20 августында оештырыла. Мәйданы — 1692 *км*^{2}. Үзәге — Чакмагыш авылы (Уфадан 111 *км* төньяк-көнбатыштарак). Халкы — 28546 кеше (2017). Татарлар саны: 1970 тә — 28212, 1979 да — 22361, 1989 да — 24695, 2002 дә — 19510, 2010 да — 19300 кеше. Район составында 78 торак пункт, ш.и. 51 татар, 17 башкорт-татар авылы исәпләнә. Иң зур татар авыллары (2009): Чакмагыш (11018 кеше), Иске Калмаш (1837), Имәнлекүл (877) һәм Калмаш-баш (843). Иң борынгылары: Митрәй-Әюп (1635 тән билгеле), Уйбулат (1635), Бикмәт (1655), Рәҗәп (1703), Көсәкәй (1710), Иске Биккенә (1719), Тузлыкуш (1730), Сыерыш-баш (1730), Иске Үзмәш (1745), Яңа Йомран (1748 һәм 1762 еллар арасында) авыллары. 2004/05 уку елында Ч.р.ның 46 мәктәбендә укыту татар телендә бара, 10 мәктәптә татар теле фән буларак өйрәнелә. Татар телендә «Игенче» г-тасы нәшер ителә. Ч.р. нда хәрби эшлекле Ә.М.*Бәхтизин*, Сов. Союзы Герой-лары В.Г.*Галимов* һәм Г.Х.*Латыйпов*, тарих-чы Р.Ә.*Нәбиев* туган.

ЧАКСЫ́ авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 44 *км* төньяк-көнбатыштарак, Шыя елгасы (Вятканың уң кушылдыгы) бассейнында урнашкан. 2010 елда 136 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб. 1619 дан Чакшы исеме б-н мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Часкы буларак та билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең беренче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында земство мәктәбе (1867 дә ачыла), тегермән, 2 тимерче алачыгы, 2 май язу йорты, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмгатенең имана җире 1881,8 дис. тәшкил итә. 1920 еллларга кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Кабык Күпер волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Кукмара, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 42 ир-ат; 1859 да — 660, 1897 дә — 1370, 1908 дә — 1141, 1920 дә — 1229, 1926 да — 1390, 1949 да — 236, 1958 дә — 446, 1970 тә — 391, 1979 да — 308, 1989 да — 206, 2002 дә — 184 кеше.

ЧАЛГЫЧУ́Т, б а л ы к ч ы ү л ә н е (Sisymbrium), әвернә чәчәклеләр семьялыгын-нан бер-, ике- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Якынча 90 төре билгеле, Төньяк ярымшарның уртача поясында очрыйлар. ТР терр-ясендә 6 төре бар: дару Ч.ы (S. officinale), биек Ч. (S. altissimum), Лёзель Ч. (S. loeselii), Идел буе Ч.ы (S. wolgense) респ-каның барлык җирендә, үзгәрүчән Ч. (S. polymorphum) — Кама аръягында таралганнар, туры Ч. (S.strictissimum) — сирәк төр. Кырларда, юл буйларында, торак йортлар тирәсендә үсәләр. 20–200 *см* биеклектәге үсемлек. Сабагы тармаклы, шома яки төкчәле. Яфраклары киселмә яки каурыйсыман теленмә. Чәчәкләре сары яки ак, чукка җыелган. Җимеше — кузакчык. Май–сентябрьдә чәчәк аталар. Орлыктан һәм тамыр үрентеләреннән үрчиләр. Орлыкларында майлар, гликозидлар, таркалганда хасил булучы тәме яндырып ала торган зәһәр исле горчица майлары, яфракларында С витамины, гликозидлар барлыкка килә. Халык медицинасында җир өсте өлешләреннән ясалган төнәтмәсе бәвел кудыру һәм какырык куптару чарасы буларак кулланыла. Лёзель Ч., биек Ч. — терлек азыгы үсемлеге. Туры Ч. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

ЧАЛДА́ЕВ Виктор Алексеевич (Вәлиулла Али улы) (15.5.1915, Зилово станциясе, хәзер Чита өлкәсенең Чернышевский р-ны Аксёново-Зиловское штп — 15.4.1944), Сов. Союзы Герое (24.5.1944, үлгәннән соң), гв. кече лейтенанты. Тимер юлда эшли. 1937 елдан Кызыл Армиядә: Хасан күлендә (1938) һәм Халхин-Гол елгасы буенда (1939) япон милитаристлары б-н сугышларда катнаша. Кече лейтенантлар курсларын тәмамлый (1940). 1942 нең августыннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, 106 нчы танк бригадасында Т-70 танкы командиры (3 нче танк армиясенең 12 нче танк корпусы), 53 нче танк бригадасында взвод командиры (3 нче танк ар-

миясенең 6 нчы танк корпусы). Көнбатыш, Воронеж, Брянск, 1 нче Украина фронтлары составында Вытебеть елгасы янында Козельск (Калуга өлкәсе, 1942) шәһәреннән көньяктарак барган сугышларда, Курск сугышында (1943), Острогожск-Россошь, Харьков һәм Житомир-Бердичев (барысы — 1943 тә), Проскуров-Черновцы һөҗүм операцияләрендә (1944) катнаша. 1944 нең 12–15 апрелендә Тернополь (Украина ССР) шәһәре янындагы сугышларда батырлык күрсәтә: 12 танкны сафтан чыгара, дошманның 5 транспортёрын яндыра. 1944 нең 15 апрелендә Ч. танкы утка тотыла һәм дошман тарафыннан уратып алына. Ч. сугышуын дәвам итә, танк эчендә янып үлә. Ленин ордены, медаль б-н бүләкләнә. Туган ягында бер урамга Ч. исеме бирелә, Тернопольда Геройга бюст куела.



В.А. Чалдаев.

Әд.: Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

М.З.Хәбибуллин.

ЧАЛКАВЫ́Й-БОЛГАРИ́ Ардашир, к. *Ардашир.*

ЧАЛЛЫ́, Шуралинка елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Кама елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 30,8 *км*. Бассейнының мәйданы 364,3 *км*². Тукай р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Ташкичү авылында, тамагы Чаллы шәһәрендә. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 62 *м*. Елганың түбән агымы Түбән Кама су саклагычының терәк сулары астында калган. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 5%. Ч.ның 0,2 дән 21,4 *км* га кадәр озынлыктагы 13 кушылдыгы бар; иң зурлары — Мәләкәс елгасы (сул кушылдык). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,35 *км/км*². Туенуы катнаш, күбрәк кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1–3 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 105 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 90 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрель башында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,19 *м*³/*с*. Суы бик каты: язын 9–12 *мг-экв/л*, кышын һәм язын 12–20 *мг-экв/л*. Гомуми минераль әшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. Ч. бассейнында суының гомуми күләме 4,2 млн. *м*³ булган 10 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

ЧАЛЛЫ́ елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Олы Чирмешән елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 28,2 *км*, ТР чикләрендә — 12 *км*. Бассейнының мәйданы 121,7 *км*². Идел аръягы түбәнлегеннән, Нурлат р-нында ага. Елга башы Самара өлкәсе терр-ясендә, тамагы Нурлат р-ны Иске Чаллы авылыннан 2 *км* көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 190 *м*, тамагыныкы — 77 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 5%. Ч.ның 0,7 дән 2,4 *км* га кадәр озынлыктагы 4 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,23 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 100 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,09 *м*³/*с*. Суы каты: язын 9–12 *мг-экв/л*, кышын һәм җәен 20–40 *мг-экв/л*. Гомуми минераль әшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

ЧАЛЛЫ́ елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Чишмә елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 21,6 *км*. Бассейнының мәйданы 197 *км*². Идел аръягы түбәнлегеннән ага. Елга башы Яңа Чишмә р-ны Чаллы Башы авылыннан 3 *км* көньяктарак, тамагы Горшково авылыннан 3 *км* төньяктарак; түбәнлекләрдә Яңа Чишмә һәм Түбән Кама р-ннары чикләре буйлап ага. Елга башының абс. биеклеге 120 *м*, тамагыныкы — 54 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 5%. Ч.ның 3,3 тән 6,8 гә кадәр озынлыктагы 6 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,23 *км/км*². Туенуы катнаш, күбрәк кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1–3 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 111 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 97 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,096 *м*³/*с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минераль әшүе язын 300–400 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. Ч. бассейнында суының гомуми күләме 0,61 млн. *км*² булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

ЧАЛЛЫ́ елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Актай елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 12,7 *км*. Бассейнының мәйданы 104,3 *км*². Идел аръягы түбәнлегеннән, Әлки р-нында ага. Елга башы Иске Чаллы авылыннан 6 *км* төньяк-көнчыгыштарак, тамагы Каргалы авылыннан 3 *км* көньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 150 *м*, тамагыныкы 83 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 15%. Ч.ның 0,5 тән 8,6 *км* га кадәр озынлыктагы 5 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,19 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы, җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 111 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 104 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,024 *м*³/*с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минераль әшүе язын 100–200 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. Ч. бассейнында суының гомуми күләме 3,8 млн. *м*³ булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

ЧАЛЛЫ́, респ-ка карамагындагы шәһәр, Тукай р-ны үзәге. ТРның төньяк-көнчыгыш өлешендә, Кама елгасының сул ярында урнашкан. Әгерҗе — Круглое Поле — Бөгелмә юнәлешендәге тимер юл станциясе. Әре автомобиль юллары төйнәлеше (Казан, Ижевск, Уфа, Оренбург һ.б. якларга). Казаннан 225 *км* ераклыкта урнашкан. Кама елгасы порты. Мәйданы — 146 *км*². 2017 елда 529797 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 45,7%, руслар — 45,1%, чуашлар — 2,1%, украиннар — 1,4%, башкортлар — 1,4%) яши.

Хәзерге Ч. терр-ясенә халык неолит дәвендә һәм бронза гасырда урнаша башлый. Шәһәрдәге археол. казу эшләре вакытында агач йортлы авыллар һәм *Имәнкискә культурасы*, 13–14 йөзләр болгар авыллары калдыклары табыла. 17 йөзнең 2 нче чиректә бу терр-яләрне руслар басып ала башлый. 1626 да Фёдор Попов җитәкчелегендәге бер төркем Алабуга крәстияннәре Мәләкәс һәм Чаллы елгалары кушылган урында Чалнинский Починок (1640 еллар ахырыннан — Мыс-Челны, соңрак Мысовые Челны исемен йөртә) авылына нигез сала. 1640 еллар башында соңрак Ч. составына кергән башка авыллар да була: Набережная Слобода (Бережные Челны); Орловка, Сидоровка, Боровецкий авыллары. Аларны күчмә халыклар һөҗүменнән саклау өчен, 1650 дә 100 казактан торган гарнизоны б-н Чаллы кальгасы төзелә (1652 дә таркатыла, Зәй елгасы буена күчерелә һәм Зәй кальгасы буларак яңадан салына). 17 йөз уртасында Мысовые Челны һәм Набережная Слобода авылларында чиркәүләр (Илия һәм Никола) була, ярминкәләр үткәрелә. 17 йөзнең 2 нче яртысында — 18 йөзнең 1 нче яртысында *башкорт-татар кузгалышлары* барышында бу авыллар берничә тапкыр талана. 1773–75 еллардагы *Крәстияннәр кузгалышында* Мысовые Челны, Бережные Челны, Орловка һәм Сидоровка авыллары крәстияннәре Е.И.Пугачёв гаскәрләренә мобилизацияләнә, баш күтәрүчеләрне фураж, печән, азык-төлек б-н тәэмин итә. 19 йөзнең 1 нче яртысында Камадагы пароходлар йөреше һәм йөк ташуның артуы, авылларның геогр. яктан уңайлы урнашуы Бережные Челны авылы янында елга пристанен (Чаллы пристане) булдыруга һәм үстерүгә зур ярдәм итә. Ул, ашлыкны саклау, эшкәртү һәм озатуда махсуслашып, 1842 дә Түбән Камада иң зур пристаньнардан берсенә әверелә. 1860 елгы навигациягә 1359 мең пот арыш оны, 90 мең пот арыш, 54 мең пот борчак, 210 мең пот солы һ.б. әзерләнә. Поташ, агач материаллары, чыпта, мунчала һ.б. товарлар, ш.и. *Минзәлә ярмин кәсенең* барлык йөкләре диярлек шушы пристаньнан озатыла. Шунда берничә причал




Чаллы шәһәре. 1. Камага караган проспектлар; 2. Тынычлык проспекты.

(кайбер мәгълүматларга караганда, алар 8 була), зур пароходчылык конторалары («Волга-Кама», «Кавказ һәм Меркурий», «Самолёт») эшли; күп кенә Алабуга, Казан, Самара, Мәскәү сәүдәгәрләренең милке һәм вәкилләре була. Бережные Челны һәм Мысовые Челны авыллары халкының күбесе сәүдәгәрләргә склад һәм торак биналарны арендага бирү исәбенә яшиләр һәм елга пристаньнарында да эшлиләр. Сәүдә эшләренең күләме һәм Чаллы пристаненың мөһимлеге Түбән Кама буе икътисадына зур йогынты ясый: 1860 еллардан өяз үзәген Минзәләдән Бережные Челны авылына күчерү мәсьәләсе берничә тапкыр күтәрелә. 20 йөз башында икмәк б-н сәүдә итү бик киң җәелә. 1910 да Чаллы пристаненнан 10,9 млн. пот икмәк җибәрелә һәм аның күбесе (дүрттән өч өлеше) Рыбинск, Ярославль, Түбән Новгород, Городец, Казан, Әстерхан, Муром, Пермь шәһәрләренә озатыла. Куллану базарында «И.Г.Стахеев һәм аның уллары», «Борадәр Хәлфиннәр», «В.С.Стахеев варислары», «И.А.Бушмакин һәм аның уллары», «Кама–Вятка сәүдә-сәнәгать ширкәте» эре сәүдә йортлары; М.С.*Сәетбатталов*, Г.Зәйнетдинов, Н.И.Былинкин һ.б. сәүдәгәрләр өстенлек итә. Икмәктән тыш, чәй, шикәр, йомыркa, мануфактура, бакалея, галантерея, тимер эшләнмәләр, агач материаллары б-н сату итәләр. 1912–17 дә 2 млн. пот сыешлы саклау урыны булган элеватор төзелә (Новороссийск һәм Самарадан кала, Россиядә өченче урынны били). Элеватор салыну сәнәгать пр-тиеләре: В.Ф.Котковның Мысовые Челны авылындагы якорь-механика з-ды (механика остаханәсе җирлегендә, 1897 дән эшли), Ф.В.Стахеевның Бережные Челныдагы такта яру з-ды (1912) барлыкка килүгә этәргеч бирә. Ваклап сату үсеш ала. 1916 да Бережные Челны авылында берничә дистә сәүдә пр-тиесе һәм йорты (бакалея, мануфактура, галантерея, зур һәм кечкенә тимер эшләнмәләр кибетләре, икмәк пешерү йортлары, трактирлар, сыраханәләр) була; Мысовые Челныда — 10, Орловкада — 8, Сидоровкада 2 бакалея кибете эшли. Бережные Челны авылы шәһәр төсен ала (еш кына икетатлы таш һәм агач йортлы туры һәм киң урамнар, сыйфатлы хуҗалык биналары); хастаханә (1879 да ачыла, 1881 гә кадәр кечкенә земство хастаханәсе), даруханә (1884), казначылык, почта-телеграф конторасы, земство китапханәсе (1904), 3 китап кибете, телефон (1913), кинематограф (1914) эшли; җомга базары, 9 майда һәм 6 декабрьдә Никола ярминкәләре үткәрелә. 1913 тә Бережные Челныда — 714, Орловкада — 2396, Мысовые Челныда — 2237, Сидоровкада — 1111, Мироновкада 145 кеше исәпләнә. Төбәкнең икътисади үсеше мәдәният үсешенә этәргеч бирә. 1841 дә Мысовые Челныда — ир балалар өчен мәктәп (1874 тә Халык мәгарифе министрлыгының 2 сыйныфлы уч-щесе итеп үзгәртелә, 1912 дә земство карамагына бирелә), 1869 да кыз балалар өчен уч-ще ачыла. 1878 дә Орловка авылында — земство мәктәбенә, 1879 да Боровецкий авылында земство уч-щесенә нигез салына. Бережные Челны һәм Сидоровка авылларында балалар чиркәү-приход мәктәбендә укыйлар. Мысовые Челныда Изге Илия (1823 тә төзелә), Бережные Челныда Изге Николай Чудотворец (1838), Орловкада (1859), Боровецкийда (1872–82) Изге Косьма һәм Дамиан православие чиркәүләре эшли. 1910 да Бережные Челны атамасына алмашка Набережные Челны (Чаллы) исеме кулланыла башлый. 1920 гә кадәр Ч., тирә-як авыллар б-н бергә, Уфа губернасының Минзәлә өязе Мысовые Челны волостена керә, 1920–21 дә ТАССРның Минзәлә кантонында. 1922 дә Ч. шәһәр статусын ала һәм Чаллы кантоны үзәге була; 1926 ның 18 октябрендә авыллар исемлегенә күчерелә; 1930 ның 10 августында шәһәр итеп үзгәртелә һәм Ч. р-ны (1976 дан — Тукай) үзәгенә әверелә. 1930 да Ч.га Мысовые Челны (1920 елларда Красные Челны исеме б-н билгеле) кушыла. Бөек Ватан сугышы чорында шәһәр илнең көнбатыш төбәкләреннән эвакуацияләнгән халыкны кабул итә. Монда 4 балалар йорты, эвакогоспиталь, фронт өчен марля, бәз, мамык җитештерүче Вышний Волочёк шәһәре туку ф-касы урнаша. Чаллылылар «Татарстан колхозчысы» («Колхозник Татарии») танк колоннасы, «Совет Татарстаны» («Советская Татария») самолёт эскадрильясе төзелешләренә акча, җылы киемнәр җыялар. Ч.ның 3 мең кешесе сугышчан орденнар һәм медальләр б-н бүләкләнә, 9 кеше Советлар Союзы Герое исеменә лаек була. 1950 еллар башында шәһәрдә киже-мамык ф-касы, суднолар ремонтлау остаханәләре, такта яру з-ды, 2 тегермән, инкубатор-кошчылык станциясе; 3 урта, 2 җидееллык, 1 башлангыч мәктәп; авыл хуҗалыгын механикалаштыру уч-щесе эшли; Мәдәният йорты. Пионерлар йорты, 2 китапханә, кинотеатр. Ч.ның алдагы үсеше Татарстанның көньяк-көнчыгышындагы нефть ятмаларын эшкәртү б-н бәйле. Нефть чыгаручы районнарны тәэмин итү өчен Ч.да су алу һәм су үткәрү җайланмасы төзелә, тимер юл тармагы һәм автомобиль юллары салына, 1962 дән Түбән Кама ГЭСы төзелә башлый. Ч. кызу темплар б-н 1970 тә — *КамАЗ* Бөтенсоюз удар комсомол төзелеше б-н бәйле рәвештә үсә башлый. Төзелешкә СССРның төрле төбәкләреннән халык агыла (1970–76 да ел саен 20–30 мең кеше килә), шәһәр инфраструктурасы үсә. 1970 елларда — 1980 еллар башында шәһәрдә сәнәгать, социаль һәм мәдәни объектлар, күпләгән торак микрорайоннары төзелә. Ч. зур булмаган текстиль һәм азык-төлек сәнәгате булган гади район үзәгеннән халык саны буенча Татарстанда икенче урынны биләгән заманча, эре индустриаль үзәккә әверелә. 1984 тә шәһәр составына Орловка, Сидоровка, Мироновка торак пунктлары керә. 1988 нең маенда халык саны 500 мең кешедән артып китә. Хәзерге вакытта Ч.да 170 ләп машина җитештерү һәм металл эшкәртү пр-тиесе урнашкан, аларда 76 мең кеше эшли. «КамАЗ» АҖ — Россиядә иң эре машиналар җитештерү комплексы, ул Россиядә эшләнгән үзбушаткыч машиналар, тагылмалар, автобуслар, махсус автотехника, дизель двигательләре, инструментлар, инженерия һәм технология җи һәзлары һ.б.ның 70% ын чыгара. «Татэлектромаш» ФҖБ; электромонтаж җи һәзлары, ремонт-механика, вагоннар ремонтлау з-длары һ.б. Ч.дагы машина төзелешенең өстенлекле юнәлешен үс -

терү чикләрендә 100 ләп фирманы берләш - терүче«Мастер» техника паркы төзелә. Электроника сәнәгатенең зур үзәге булып «Форт-Диалог» фирмасы тора, ул персональ компьютерлар җыю, Россия һәм дөнья базарына программалашкан товарлар чыгару б-н шөгыльләнә. Төзелеш өлкәсендә 120 дән артык пр-тие эшли, алар арасында «*Камгэсэнергострой*» АҖ; эре панельле йортлар төзү, металл конструкцияләр, тимер-бетон эш - ләнмәләр, «Стройдеталь» кәрәзле бетон, электромонтаж җи һәзлары һ.б.заводлар; төзелеш материаллары комб-ты. Россиядә алюминий профиль һәм конструкцияләр җи - тештерүчеләр арасында «Расстал» АҖ бе - ренчелекне били. Энергетика сәнәгатен үс - терүдә *Түбән Кама ГЭСы* һәм *Чаллы җылылык электр үзәге* зур эш башкара. «Полимер» ФҖБ файдаланылган полимерларны яңадан эшкәртү б-н шөгыльләнә. Россия базарында шактый зур урынны Чаллы картон-кәгазь комб-ты (гофротартмалар, бәд - рәф кәгазе һ.б.) алып тора. Азык-төлек сәнә - гате пр-тиеләре арасында әйдәп баручы то - вар җитештерүчеләр: ит, сөт, «Чаллы икмәге», икмәк продуктлары комб-тлары; «Чел - ны-бройлер», «Холод», «Горпищекомбинат», «Булгарпиво» АҖ, кондитер пр-тиеләре һ.б. Түбән Кама буе хуҗалык тормышында «Челныводоканал» АҖ мөһим роль уйный, ул Чаллыдан тыш Түбән Кама, Әлмәт шәһәрләрен, респ-каның көньяк-көнчыгышындагы торак пунктларны һәм сәнәгать объектларын эчәргә яраклы һәм техник су б-н тәэмин итә. Шәһәрдә башлыча сәүдә һәм җәмәгать тукланыу өлкәсендә эшләүче 5,5 мең кече пр-тие теркәлгән. Зур сәүдә үзәкләре (һәр - берсенең мәйданы — 5 мең $м^2$дан артык): «Палитра», «Омега», «Эссен», «Мегастрой», «Алтын Ай», «Мэтро Кэш энд Керри»; күп функцияле «Торговый квартал» сәүдә-күңел ачу комплексы; гомуми мәйданы 41,6 мең $м^2$ булган вакланып сату базары эшли. 47 мең урынлы 438 җәмәгать тукланыу пр-тиесе эшли. 20 ресторан, 93 кафе, 143 бар һәм кабымлыкханә исәпләнә. Шәһәр терр-ясендә нефть чыгарыла (Орловка һ.б. чыганаклар). Ч. — фән һәм мәдәният үзәге. 4 институт (сәнгать һәм дизайн, сәүдә-технология, социаль-пед. технологияләр һәм ре - сурслар, Кама ин-ты), 7 югары уку йорты (ш.и. Казан ун-ты) ф-лы; 9 урта махсус уку йорты, ш.и. автомеханика техникумы; техни - ка, икътисад-төзелеш, пед., мед., 2 политех - ника, төзелеш һәм сәүдә-технология, сән - гать көллиятләре, 50 гомуми белем бирү мәк - тәбе эшли. Шәһәрнең социаль инфраструктурасы зур үсеш алган. 93 мәктәпкәчә тәрбия учреждениесе, театр сәнгате, 3 хореография, 6 балалар музыка, 2 рәсем, 4 сәнгать мәктә - бе эшчәнлеген алып бара. Балалар һәм яшь - ләр иҗат сарае эшли, андагы секция һәм түгәрәкләргә 12 меңләп кеше йөри; 4 яшьләр һәм 25 яшүсмерләр клубы бар. Шәһәрдә 12 мәчет һәм 6 православие храмы бар.



Чаллы шәһәре. «Тәүбә» мәчете. 1992.

Ч. халкына 40 дәвалау-профилактика учреждениесе, ш.и. 9 хастаханә, 5 диспансер, 9 дәваханә, 3 бала тудыру йорты, 4 шәһәр стомат. дәваханәсе, 5 шифаханә-профилакторий мед. ярдәме күрсәтә. Физкультура һәм спорт б-н шөгыльләнү өчен Боз сарае, 3 ста - дион, 3 йөзү бассейны, җиңел атлетика манежы һ.б. спорт корылмалары, ат спорты мәк - тәбе, ипподром; 18 балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе эшли. Спортның 68 төре б-н шөгыльләнәләр, иң популярлары — йөзү, футбол, баскетбол. Татар драма, рус драма һәм курчак театрлары, цирк, дельфинарий; 5 мәдәният сарае («Энергетик», «КАМАЗ», «Строитель» һ.б.); картиналар галереясы, Халыклар дуслыгы йорты эшли. Шәһәр төбәкне өйрәнү (КАМАЗ төзелеше һәм шәһәр тарихы музее), Россия автомобиль гаскәрләре тарихы һәм сугышчан дан, Түбән Кама ГЭСы, экология һәм табигатьне саклау, В.Высоцкий истәлегенә багышланган һ.б. музейлар мәдәни-агарту эшчәнлеге алып ба - ра. Иҗат төркемнәре: «Чаллы» берләшмә - се, И.Лерман җитәкчелегендәге камера ор - кестры, А.Колигер джаз-оркестры, «Болгар» ансамбле, «Салават» җыр театры киң таны - ла. Мәдәният һәм сәнгать өлкәсендәге чара - лар Орган музыкасы концерт залында, С.Са - дыйкова исем. театр-концертлар залында, «Мәйдан», «Батыр» мәдәни-күңел ачу ком - плексы мәйданчыкларында уза. «Шәһри Чаллы», «Көмеш кыңгырау», «Вечерние Челны», «Челнинские известия», «Час», «Челнинская неделя» һ.б. г-талар чыга. 1991–2000 дә «*Аргамак*», 2001 дән «Мәй - дан» ж-ллары нәшер ителә. Яшь язучылар - ның «Орфей» һәм «Ләйсән» иҗат берләшмә - ләре эшли. 3 телевидение («Чаллы-ТВ» һ.б.) һәм берничә радио станциясе хезмәт күрсә - тә. 1982–88 дә шәһәр Брежнев исемен йөртә. 1976 да Ч. 2 районга (Комсомол һәм Автоза - вод р-ны) бүленә. 1988 дә районнар урыны - на 7 адм.-терр. берәмлек оештырыла. 2006 - ның 1 гыйнварында кабат районнарга бүле - неш кертелә (Комсомол, Автозавод, Үзәк р-ннар). 2006 да Ч. составына Боровецкий авылы кушыла. Халык саны: 1920 дә — 3214, 1926 да — 3870, 1938 дә — 9295 кеше, 1959 да — 16,2 мең, 1970 тә — 37,9 мең, 1979 да — 301,4 мең, 1989 да — 500,7 мең, 1997 дә — 525,5 мең, 2002 дә — 513,4 мең кеше.

Әд.: Ермаков В. Обращение к истокам: Очерки истории г.Набережные Челны. Елабуга, 1997; шул ук. Вехи челнинской истории. Наб. Челны, 1998; шул ук. Крестьянство Восточного Закамья (с древнейших времён до 1917 года). Наб. Челны, 2000; Дубровский А. Из истории г.Набережные Челны и восточных районов Нижнего Прикамья: В 3 ч. Наб.Челны, 2002–03; шул ук. Чем славны Набережные Челны? Наб. Челны, 2006; шул ук. Наш регион: Нижнее Прикамье. К., 2007; Ишкина-Яковлева Л., Шишкина Н., Яковлева И. Набережные Челны: Архитектурный облик. К., 2005; Энциклопедия города Набережные Челны. К., 2007.

А.Г.Дубровский.

ЧАЛЛЫ́ авылы, Кама Тамагы р-нында, шә - һәр тибындагы Кама Тамагы посёлогыннан 29 *км* көнбатыштарак, Коры Үләмә елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 185 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Баш - лангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез са - лына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Чол - лы исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөз - нең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстиян - нәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет (1887 дә төзелә), мәдрәсә, 4 җил тегермәне, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 694 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тә - теш өязе Олы Кариле волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа канто - нында. 1930 ның 10 августыннан — Кама Та - магы, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кама Тамагы р-нын - да. Халык саны: 1782 дә — 116 ир-ат; 1859 да — 558, 1884 тә — 880, 1897 дә — 910, 1908 дә — 1071, 1920 дә — 1012, 1926 да — 585, 1938 дә — 622, 1949 да — 568, 1958 дә — 515, 1970 тә — 487, 1979 да — 387, 1989 да — 218, 2002 дә — 201 кеше.





Чаллы шәһәре. 1. М.Җәлил исемендәге шәһәр үзәк китапханәсе. 2. Шәһәр хакимияте бинасы.

ЧАЛЛЫ́ авылы, Кукмара р-нында, Кукмара шәһәреннән 12 *км* төньяктарак, Туйма елгасы (Вятка бассейны) буенда. 2010 елда 134 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — сарык асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, Ч. да мәчет була. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 840 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Кошки волостенда, 1920 дән ТАССРның — Арча, 1928 дән Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара районында. Халык саны: 1859 да — 255, 1884 тә — 302, 1905 тә — 472, 1920 дә — 496, 1926 да — 485, 1938 дә — 533, 1949 да — 437, 1958 дә — 368, 1970 тә — 323, 1979 да — 336, 1989 да — 235, 2002 дә — 235 кеше.

ЧАЛЛЫ́ БАШЫ́ авылы, Яңа Чишмә р-нында, Яңа Чишмә авылыннан 15 *км* төньяк-көнбатыштарак, Чаллы елгасының (Чишмәнең сул кушылдыгы) югары агымы буенда. 2010 елда 529 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 18 йөзнең уртасына кадәр нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ч.Б.нда 2 мәчет, 3 җил тегермәне, тимерче алачыгы, 10 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 4348 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Каргалы волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чистай, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Армия, 1958 нең 23 маеннан — Яңа Чишмә, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1983 нең 26 апреленнән Яңа Чишмә р-нында. Халык саны: 1782 дә — 180 ир-ат; 1859 да — 1515, 1897 дә — 2379, 1908 дә — 2450, 1920 дә — 2462, 1926 да — 2211, 1938 дә — 1499, 1949 да — 840, 1958 дә — 856, 1970 тә — 1007, 1979 да — 768, 1989 да — 549, 2002 дә — 591 кеше.

ЧАЛЛЫ́ ҖЫЛЫЛЫ́К-ЭЛЕ́КТР ҮЗӘГЕ́, катнаш электр энергиясе һәм җылылык (пар һәм кайнар су рәвешендә) эшләп чыгаручы җылылык пар электр станциясе; «Татэнерго» АҖ ф-лы. Эшләүчеләр саны 1 мең чамасы кеше (2017). 1970 елда КамАЗ җылылык электр үзәге буларак төзелә башлый. 1994 тән хәзерге исемдә. 1971 дә 2 су җылыту казаны шәһәр җылылык челтәренә кайнар су җибәрә. 1973 тә пар казаны һәм 2 турбина файдалануга кертелә. 1979 да 9 турбинаны һәм 10 пар казанын үз эченә алган беренче чираты тапшырыла, 1993 тә 11 нче турбина 14 нче пар казаны гамәлгә кертелү б-н, пр-тиенең киңәюе төгәлләнә. Станциянең үзенчәлеге зур күләмдә кайнар су алу ачык системасыннан гыйбарәт. Төп ягулык сыйфатында табигый газ файдаланыла. Билгеләнгән электр егәрлеге — 1180 *МВт·с*, җылылык егәрлеге — 4092 *Гкал·с*, еллык җитештерү күләме — 4,5 *МВт·с* дән артык (2016). Станция хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә, ш.и. 9 кеше — РСФСР, ТАССР, ТР ның атказ. энергетигы исеменә лаек була, 1 кеше — Ленин ордены, 2 кеше — 3 нче дәрәҗә Дан ордены, 3 кеше «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

Директорлары: Л.М.Островский (1970–77), И.Н.Һадиев (1977–88), С.Д.Җангиров (1988–91), С.М.Тюклин (1991–2008), А.И.Мәҗитов (2008–12), А.М.Хаҗиев (2012 дән).

ЧАЛЛЫ́ ИКЪТИСА́Д-ТӨЗЕЛЕ́Ш КӨЛЛИЯТЕ́. РФ Энергетика министрлыгы карамагында, урта һөнәри уку йорты. 1971 елда Түбән Кама энергетика техникумының Кама кичке ф-лы буларак ачыла (к. *Түбән Кама политехник көллияте*), 1988 дән Кама кичке энергетика-төзелеш техникумы, 1989 дан Чаллы техникумы, 1996 дан Ч. и.-т. к. Укыту торак һәм җәмәгать биналары төзелеше, смета документлары һәм төзелештә бәяләр, биналар һәм корылмаларны техник файдалану, эчке сантехника җиһазларын монтажлау һәм файдалану һәм вентиляция, бухгалтерлык хисабы һәм контроль, финанслар, иминиятләштерү эше, социаль эш белгечлекләре буенча алып барыла.

2009 да көллияткә 47 нче һөнәри уч-ще, «Төзүче» уку-курслар комб-ты кушыла һәм Соц. Хезмәт Герое, ТАССР һәм РСФСРның атказ. төзүчесе Е.Н.Батенчук исеме бирелә. 2015 тә көллият һәм Чаллы төзелеш көллияте б-н берләштерелеп, уку йорты Е.Н.Батенчук исем. Кама төзелеш көллияте дип атала. Анда укыту биналар, корылмалар төзелеше һәм аларны файдалану, автомобиль юллары һәм аэродромнар төзелеше һәм аларны файдалану, гамәли информатика (тармаклар буенча) икътисад һәм бухгалтерлык хисабы (тармаклар буенча) белгечлекләре кысаларында алып барыла. 2017 дә көндезге бүлектә — 1181, читтән торып уку бүлегендә — 89, ш.и. хуҗалык исәбендә 210 студент укый; укытучылар коллективында 87 кеше, ш.и. 5 фән кандидаты эшли.

ЧАЛЛЫ́ КАБЕРЛЕГЕ́, б.э.к. 2 нче меңьеллык уртасына караган археол. истәлек; төп террасадагы борыннарның берсендә, хәзер Чаллы шәһәренең көнбатыш өлешендә (тимер юл вокзалы тирәсендә) урнашкан *Буралы курган культурасы* зираты. 1958 елда Е.П.Казаков тарафыннан 5 корбан китерү чокыры һәм 8 кабер өйрәнелә. Мәрхүмнәр баш ягы б-н төньякка юнәлтелеп җирләнгән. Терсәктән бөгелеп, чуклары б-н баш сөягенең бит өлеше алдына куелган куллар янында тараксыман һәм уеп ясалган бизәкле яссы төпле чүлмәкләр табыла. Ч.к. — буралы курган культурасының төньяк (Кама) вариантына хас истәлек.

Әд.: Казаков Е.П. Набережно-Челнинский могильник // Отчёты Нижне камской археологической экспедиции. М., 1972. Вып. 1.

Е.П.Казаков.

ЧАЛЛЫ́ КАНТОНЫ́, 1921–30 елларда ТАССР дагы адм.-терр. берәмлек. Респ-ка-ның төньяк-көнчыгышында урнаша. Татарстан ҮБК Президиумының 1921 ел 20 июль карары нигезендә *Минзәлә кантонының* 18 волосте җирлегендә оештырыла. Үзәге — Чаллы шәһәре. Ч.к. ның чикләре һәм адм. бүленеше берничә тапкыр үзгәрә. 1928 дә аның составына *Алабуга кантоны* кертелә. 1923 тә Ч.к. ның мәйданы — 7115 кв. *км*, 1926 да — 7132 кв.км, 1929 да 10572 кв.км тәшкил итә. 1921 дә кантон 18 волостьтан, 1 шәһәр пунктыннан һәм 335 авыл торак пунктыннан тора. ТАССР дагы 1924 елгы адм.-терр. реформа нәтиҗәсендә Ч.к. нда волостьлар саны 11 гә калдырыла (Абдул, Акташ, Афанас, Әхмәт, Зәй, Кармалы, Кузай, Нөркәй, Сарман, Чаллы, Шәңгәлче волостьлары), 1 шәһәр һәм 512 авыл торак пунктлары була; 1929 да 17 волость (Алабуга кантонының 6 волос-





Чаллы каберлегендә табылган керәч савытлар.

тен — Алабуга, Исәнбай, Камай, Костенеево, Салагыш, Чиркәс волостьларын кушканнан соң), 1 шәһәр һәм 1 эшчеләр посёлоклары һәм 764 авыл торак пункты исәпләнә. 1922 дә Ч.к. нда 233408 кеше (татарлар — 56 %, руслар — 41 %) , 1926 да 213591 кеше (татарлар — 54,1 %, руслар — 43 %) яши. Шәһәр халкы — 3874 кеше, авыл халкы — 209717 кеше. Халыкның уртача урнашу тыгызлыгы — 1 кв. *км* га 30 кеше. 1929 да — 343860 кеше (1926 елгы халык исәбе буенча). Ч.к.нда металл һәм агач эшкәртү, азык-төлек, полиграфия сәнәгатьләре пр-тиеләре эшли; кустар-һөнәрчелек җитештерүе б-н 3,8 меңгә якын кеше шөгыльләнә (1926). 1924 тә — 192 мәктәп (ш.и. 190 — 1 нче баскыч мәктәбе), 16 китапханә, 7 уку өе; 1927 дә 219 мәктәп (ш.и. 211 — 1 нче баскыч, 2 — 2 нче баскыч, 2 — җидееллык, 2 — крәстиян яшьләре мәктәпләре) була. 1922 дә чәчүлек мәйдан 97670 *га*; 1925 тә 199342 *га*, ш.и. арыш чәчүлекләре — 94169 *га*, бодай — 4465 *га*, солы — 40148 *га*, карабодай — 18658 *га*, борай — 4744 *га*, бәрәңге — 4346 *га*, ясмык 4047 *га* тәшкил итә. 1922 дә — 47412 крәстиян хуҗалыгы, 1925 тә 46035 крәстиян хуҗалыгы, 70 а.х. кооперативы була; 312303 баш терлек, ш.и. 38772 ат, 71508 баш мөгезле эре терлек (ш.и. 36828 сыер), 169876 баш мөгезле вак терлек (151804 сарык, 18072 кәҗә); 32146 дуңгыз исәпләнә. БҮБК Президиумының 1930 ел 10 август карары нигезендә районнарга бүленешкә күчүгә бәйле рәвештә Ч.к. Акташ, Бондюг, Алабуга, Красный Бор, Сарман, Чаллы һәм Ширәмәт р-ннары на бүленә.

Чыг.: Статистический справочник по промышленности ТССР. К., 1924; Статистический справочник по сельскому хозяйству. К., 1925; Всесоюзная перепись населения 1926 года. М., 1928. Т. 3; 1929. Т. 9; Статистический ежегодник по Татарской Социалистической Советской Республике: В 5 вып. К., 1928–29; Административно-территориальное деление Союза ССР и список важнейших населённых пунктов. М., 1929; Всесоюзная школьная перепись 15 декабря 1927 года. М., 1930. Т. 1.


С.А.Фәйзуллин.

ЧАЛЛЫ́ КАРТИ́НАЛАР ГАЛЕРЕ́ЯСЫ, ТР Дәүләт Сынлы сәнгать музее ф-лы. 1979 елда оештырыла, 1980 дә ачыла. Экспозиция мәйданы — 500 $м^2$. Коллекцияләрендә рәссамнар Б.И.Урманче, Л.Г.Фәттахов, Н.Д.Кузнецов, А.Л.Прокопьев, И.К.Зарипов, В.И.Морозов, Ә.С.Фәтхетдинов, А.И.Вашуров, В.И.Сынков, Ю.Г.Свинин, А.И.Дербилов, Л.А.Зимина, В.Я.Акимов, В.В.Антюнин, А.Л.Петров, Х.М.Шәрипов, һ.б.ның нәкышь, графика, скульптура әсәрләреннән 683 саклау берәмлеге исәпләнә. Мәскәү, С.-Петербург, Эрбет, Казан, Киров һ.б. шәһәрләр, Россия төбәкләре (Башкортстан, Чуаш Респ-касы, Мари Респ-касы, Удмурт Респ-касы) һәм чит илләр (Әрмәнстан Респ-касы, Төркия) музей тупланмаларыннан күргәзмәләр узды рыла. Ел саен җирле рәссамнарның «Ел нәтиҗәләре», «Сәләт» (дек.–гыйн.), изге Рамазан аена, Г.Тукайның туган көненә (апр.), Халыкара музейлар көненә (май), Республика көненә багышланган сынлы сәнгать күргәзмәләре уздырыла. Музей директорлары — Г.М.*Хәкимова* (1983–2003), Ф.М.Гайнетдинова (2003 тән).

Ч.к.г. басмалары: «20 лет Картинной галерее»: Буклет. Наб. Челны, 2004; «25 лет Картинной галерее»: Буклет. Наб. Челны, 2005.

«ЧАЛЛЫ́ КАРТО́Н-КӘГА́ЗЬ КОМБИНАТЫ́» ХАЛЫ́К ПРЕДПРИ́ЯТИЕСЕ, С.П.Титов исемендә, целлюлоза-кәгазь тармагы пр-тиесе. Эшләүчеләр саны — 1780 кеше (2017). 1981 елда картон-кәгазь комб-ты буларак нигезләнә. Дәүләт ярдәменнән башка, банк кредиты хисабына төзелә. 1987 дән дәүләт пр-тиесе — Брежнев картон-кәгазь комб-ты, 1993 тән «Чаллы картон-кәгазь комбинаты» коллектив пр-тиесе, 1998 дән хәзерге исемдә. Пр-тие төп һәм ярдәмче производстволарын тора. Төп производствода — картон, гофротартма, кәгазь ф-калары; ярдәмче производствога хәзерләү-склад, электроремонт, ремонт-механика, ремонт-төзелеш цехлары, автотранспорт һәм склад хуҗалыклары, чистарту корылмалары, җылылык-газ-су тәэминаты хезмәте, техник контроль бүлеге һәм үзәк җитештерү лаб-ясе керә. Комб-т Австрия (Voith), Германия (KBA Planeta, BHS, Tunkers), Франция (Sodem, Martin), Швеция (GL&V, Metso), Швейцария (Bobst, Roda), Япония (Sumitomo) фирмаларында, ш.у. илдә җитештерелгән («Иж-буммаш» ҖБ, «Петрозаводскбуммаш» ҖБ) җи һазлар б-н коралландырылган. Пр-тиедә аның икътисади тотрыклылыгын һәм продукциянең көндәшлеккә сәләтен үстерүгә юнәлтелгән яңа техника һәм технологияләр гамәлгә кертелә. Табыштан җитештерүгә күчерелгән инвестицияләр елга 300–400 млн. сум тәшкил итә, шуның 60% ы пр-тиене яңартып, техник яктан җиһазлауга җибәрелә. Төп продукция: киң тип һәм зурлык диапазонында төрле конструктив катлаулыктагы флексографик басмалы гофротартма, гофрокартон (ш.и. микрогофрокартоннан тулы төсле басмалы кап-





1. Чаллы картиналар галереясы;
2. Галерея залларында.

лар), хром-эрзац картоннан төрле формадагы, тулы төсле югары сыйфатлы офсет басмалы һәм лаклы каплар, этикеткалар, бәдрәф кәгазе, кәгазь сөлгеләр. Продукция ISO 9000 сыйфат системасы буенча сертификацияләнгән. Россиянең барлык төбәкләренә диярлек, якын чит илләргә җибәрелә.

Комб-т Россиядә җитештерелгән картон тартмаларның 7,6 % ын, бәдрәф кәгазенең 11 % ын эшләп чыгара. 2016 да 9368,4 млн. сумлык продукция җитештерелә. Чимал сыйфатында комб-т башлыча макулатура файдалана, шул рәвешчә елга 20 мең *га* урманны саклап калуга ирешелә. Целлюлоза Соломбал целлюлоза-кәгазь комб-тыннан (Архангельск ш.), Братск һәм Усть-Илим урман сәнәгате комплексларыннан һ.б.дан китерелә. Сәнәгатьтә файдаланылган һәм җир өстендә җыела торган суларны чистарту корылмалары, кабат файдаланулы һәм шартлы-чиста сулар б-н әйләнешле тәэмин итү системасы, автоюгыч файдалануга кертелә. Технол. линияләр тузан-газ тотучы җайланмалар б-н җиһазландырыла. Пр-тие тарафыннан 125,6 мең $м^2$ мәйданда торак фонды, балалар бакчалары, шифаханә-профилакторий, балалар мәдәният сарае, физкультура-сәламәтләндерү үзәге, социаль-мәдәни максатлардагы башка объектлар төзелә. 1995 тән продукциясенең югары сыйфаты һәм дизайны өчен комб-т халыкара күргәзмәләрдә 15 медаль һәм 60 дипломга, Россия төбәк күргәзмәләрендә 10 медальгә һәм 50 дипломга лаек була. Бөтенроссия конкурсларында пр-тие «Аеруча югары финанс нәтиҗәлелеге өчен» (1999, 2000), «Социаль эшне оештыруда казанышлары өчен» (2002) дипломнары, шул ук номинациядә РФ Хөкүмәте грамотасы (2001), респ-ка конкурсында «Эколидер» дипломы (2014) һ.б. б-н бүләкләнә. Пр-тие хезмәткәрләренә дәүләт бүләкләре, ш.и. 6 кешегә — халык хуҗалыгының төрле тармаклары атказ. хезмәткәрләре исемнәре, 1 кешегә — Почёт ордены, 2 кешегә — 2 нче дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» ордены медальләре, 21 кешегә ТР Мактау грамотасы бирелә.

Пр-тие җитәкчеләре — С.П.Титов (1981–2011), В.И.Бестолоков (2011–15), А.Г.Фомичёв (2015 тән).

Әд.: Дронова Т., Дронов П. Набережночелнинский картонно-бумажный комбинат: Право быть хозяином. К., 2001.

М.Ж.Гаитов.

ЧАЛЛЫ́ КУРЧА́К ТЕА́ТРЫ, балалар өчен театр (рәсми булмаган исеме «Балалар һәм кошлар йорты»). 1987 елда рус труппасы составында оеша, 1994 тә ш.у. татар труппасы барлыкка килә. Курчаклар конструкторы — А.Бәширов. Спектакльләрне сәхнәгә кую б-н режиссёрлар И.Н.Зиннуров, Е.Ю.Гиммельфарб, М.А.Хусид шөгыльләнә, бизәү эшенә рәссамнар С.В.Тараканов, Б.В.Насихов, комп. А.С.Миргородский һ.б. җәлеп ителә. Театр шәһәрнең үзендә һәм аннан читтәге шәһәрләрдә киң җәмәгатьчелекнең ихтирамын казанган 100 дән артык пьесаны сәхнәләштерә. Ул Россия, Белоруссия, Украинаның күп кенә шәһәрләрендә гастрольләрдә була; С.-Петербург (1999), Омск

(2001), Бурса (Төркия, 2001), Белгород (2002), Актүбә (Казакъстан, 2004, 2010, 2013), Мәскәү (2005), Волгоград (2007), Винницада (Украина, 2009, 2011) курчак театрлары фестивальләрендә катнаша. Театр сәхнәсендә «Казлар-аккошлар» («Гуси-лебеди», рус халык әкияте буенча), «Йомры калач» («Колобок», рус халык әкиятләре буенча), «Алинә белән Каз бәбкәсе турында»





Чаллы курчак театры спектакльләреннән күренешләр: 1. «Авыл эте Акбай», Т. Миңнулин; 2. «Баһадирлар илендә», Ә. Фәйзи.

(«Про Алёнку и Гусёнка», Н.Гернет), «Нык торучан аккургаш солдат» («Оловянный солдатик», Г.Х.Андерсен), «Тылсымлы курай» («Волшебная дудочка», Л.Миневская), «Авыл эте Акбай» (Т.Миңнуллин), «Елан Патша» (Р.Корбан, З.Думави), «Сак-Сок» (И.Зәйниев), «Уймак кыз» («Дюймовочка», Г.Х.Андерсен), «Өч күңелле дуңгыз баласы» («Три поросёнка», С.В.Михалков) һ.б. спектакльләр зур уңыш б-н бара. Театр җир-легендә бер исем б-н «Эш аты» дип аталган 3 масштаблы проект эшли: курчак театрларының Халыкара театр фестивале (2008 дән), Төбәкара театраль уку-укыту форумы (2015 тән), Яшь режиссёрларның иҗат лаб-ясе (2016 дан). Курчак театры инвалид балалар, катлаулы хәлдәге гаиләләрдән чыккан һәм күп балалы гаиләләрнең балалары арасында актив рәвештә хәйрия эшчәнлеге алып бара («Әкият — кунакта» — «Сказка в гостях», «Дөнья киң ябылган күзләр белән» — «Мир широко закрытыми глазами», ел саен уздырыла торган яңа елга багышланган хәйрия тамашалары).

2017 дә театр труппасында — актёрлар Е.В.Мингажева, Т.М.Салихова, Е.А.Митрофанов, Р.А.Митрофанова, Э.Н.Гурлев, М.Г.Туктарова, Л.Р.Морзаханова, Е.А.Голобокова һ.б.

1987–99 да сәнгать җитәкчесе һәм баш режиссёр — А.М.*Янкелевич*, 1999 дан баш режиссёр — ТРның атказ. артисты И.Ю.Клюев, баш рәссам — ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе А.Ю.Митрофанов. Директоры — ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре З.Ф.Митрофанова (1999 дан).

Әд.: Набережночелнинский государственный театр кукол: Буклет. Наб. Челны, 2002.

Д.Ә.Гыймранова.

ЧАЛЛЫ́ МЕДИЦИ́НА КӨЛЛИЯТЕ́, ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагында, урта һөнәри уку йорты. 1978 елда мед. уч-щесе буларак ачыла, 1995 тән хәзерге исемдә. Укыту дәвалау эше, шәфкать туташы эше, фармация, стомат. белгечлекләре буенча алып барыла. 2017 дә 1095 студент укый, шуларның 695е бюджетта, 324е бюджеттан тыш финанслауда, 60ы читтән торып уку бүлегендә.

ЧАЛЛЫ́ ПЕДАГО́ГИКА КӨЛЛИЯТЕ́, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагында, урта һөнәри уку йорты. 1977 елның 20 маенда пед. уч-ще буларак ачыла, 1995 тән хәзерге исемдә. Укыту башлангыч сыйныфларда укыту, мәктәпкәчә белем бирү, чит тел, татар-теле һәм әдәбияты, музыка белгечлекләре буенча алып барыла. 2018 дә 716 студент укый. Пед. коллективта 55 укытучы эшли.

ЧАЛЛЫ́ ПЕДАГО́ГИКА УНИВЕРСИТЕТЫ́, РФ Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагында, югары уку йорты. 1980 елда Алабуга пед. ин-ты ф-лы буларак ачыла, 1990 нан мөстәкыйль уку йорты. Башлангыч белем бирү педагогикасы һәм методикасы, мәктәпкәчә пед. һәм психол., чит телләр, татар филологиясе, матем. һәм информатика ф-тлары эшли. Укыту рус теле һәм әдәбияты, татар теле һәм әдәбияты, чит тел, матем., информатика, география, рәсем, пед. һәм психол., мәктәпкәчә пед. һәм психол. башлангыч белем бирү педагогикасы һәм методикасы, социаль пед. белгечлекләре буенча алып барыла. 2018 дә 1502 студент көндезге бүлектә, 2526 читтән торып уку бүлегендә укый. Пед. коллективта 122 кеше, ш.и. 7 фән докторы, 86 фән кандидаты эшли. 2018 дән ректоры А.А.Галиәбәрова.

ЧАЛЛЫ́ РАЙОНЫ́, к. *Тукай районы.*

ЧАЛЛЫ́ СӘНГА́ТЬ КӨЛЛИЯТЕ́, ТР Мәдәният министрлыгы карамагында, урта һөнәри уку йорты. 1979 елда сәнгать уч-щесе буларак ачыла. Укыту инструментларда башкару (фортепиано, кыллы уен кораллары, халык уен кораллары), музыка теориясе, хореография сәнгате, дизайн белгечлекләре буенча алып барыла (262 студент). 1993 тән хәзерге исемдә. Якынча 800 белгеч әзерләнә. 2017 гә пед. коллективта 88 кеше, ш.и. 1 фән докторы һәм 2 фән кандидаты. 3 ТРның атказ. артисты, 2 ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе, 4 ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре, 1 РФнең атказ. мәдәният хезмәткәре эшли.

ЧАЛЛЫ́ ТАТА́Р ДРА́МА ТЕА́ТРЫ, 1990 елда Чаллы шәһәрендә халык депутатлары Чаллы шәһәр советы башкарма ком-ты карары нигезендә ТАССР Мәдәният министрлыгы б-н килешеп оештырыла. Башта «Чаллы татар яшь тамашачылар театр-студиясе» дип аталган муниципаль театр була, 1999 елда дәүләт театры статусына ия була һәм хәзерге исемне ала. Беренче «Күбәләк булып җаның кайтыр» (Р.Батулла пьесасы буенча) спектакле 1990 ның 21 декабрендә куела. Труппа Минзәлә, Әлмәт татар драма театрлары һәм Чаллы татар халык театры актёрларыннан формалаша. Беренче составны И.Фәхретдинов, А.Колмакова, М.Зәйнетдинова, Г. һәм С. Гайнетдиновлар, Р.Сәгъдуллин, Р.Хәмидуллин, Б.*Салəхов*, К.Шәрифуллин, Р.Каюмов тәшкил итә. Труппа б-н реж. Ф.М.*Ибра һимов* җитәкчелек итә. Театр, күбрәк яшь тамашачыны күздә тотып, «Су буенда учак яна» (Ф.Галиев), «Ут төртүче» («Поджигатель», В.И.Шашин), «Гашыйклар тавы» (И.Юзеев), «Һинд кызы» (Г.Каюмов), «Язлар моңы» (Ә.Гаффар) һ.б. пьесаларны сәхнәләштерә. Актёрларның уйнау осталыгын гәүдәләндергән, зур темаларны сәнгатьчә чаралар ярдәмендә яктырткан «Американ» (К.Тинчурин) һәм «Йосыф-Зөләйха» (Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәре буенча) пьесалары буенча куелган спектакльләр җитлегүгә имтихан тоту булып тора. Театр репертуарын Г.Камал, Г.Исхакый, А.Гыйләҗев, Ф.Яруллин, Т.Миңнуллин, М.Гыйләҗев, З.Хәким, Ф.Бүләков, Р.Корбан, Н.Гаетбай, З.Исмәгыйлев, Р.Сәгъди, Р.Солнцев, Ю.О'Нил, Ж.Б.Мольер, Кобо Абэ, К.Гольдони, Ж.Сиблейрас пьесалары тәшкил итә. «Саташу» (Т.Миңнуллин), «Тирәкләр шаулый җилдә» («Ветер шумит в тополях»,





Чаллы татар драма театры спектакльләреннән күренешләр:
1. «Йосыф-Зөләйха», Кол Гали поэмасы буенча; 2. «Кол», Г.Фигейредо әсәре буенча.

Ж.Сиблейрас), «Өч аршын җир» (А.Гыйләҗев), «Гашыйклар тавы» (И.Юзеев), «Кызлар, ишек ачыгыз!» (Н.Гаетбай), «Ике ху җаның хезмәтчесе» («Слуга двух господ», К.Гольдони), «Ярым ятларга кала», «Күбәләк булып җаның кайтыр», «Яшь аралаш көлү» (Р.Батулла), «Язмыш сынавы», «Сагыныр сың, мин булмам...» (З.Кадыйрова), «Яратылмый калган ярлар» (Б.Саләхов) һ.б. спектакльләр зур уңыш б-н бара. Театр шәһәрнең иҗтимагый-мәдәни тормышында һәм ТРда уздырылучы театр фестивальләрендә актив катнаша.

2017 дә театр труппасында — РФнең атказ. артисты, ТРның халык артисты И.Фәхретдинов, ТРның халык артистлары Г.Гайнетдинова, Б.Саләхов, ТРның атказ. артистлары Р.Сәгъдуллин, Р.Каюмов, Э.Шиһапова, Р.Таһирова, Г.Фәйзерахманова, И.Әскәров, Р.Гыйләҗев, Чулпан Казанлы, Н.Сәлахова, М.Имамова, А.Хәбетдинова һ.б. Театрның баш режиссёры — ТРның атказ. сәнгать эшлеклесе Ф.М.Ибраһимов (1990–99 һәм 2002 дән), директоры — ТРның һәм РФнең атказ. мәдәният хезмәткәре Р.Ф.Фәйзерахманов (2007 дән).

Әд.: Чаллы татар дәүләт драма театры: Буклет. Яр Чаллы, 2000.

Д.Ә.Гыймранова.

ЧАЛЛЫ́ ШӘҺӘРЕ́ ТАРИХЫ́ МУЗЕЙ́, 1972 елның 2 апрелендә оештырыла, ТАССР Дәүләт музее ф-лы буларак 1973 нең 6 маенда ачыла; 2003 тән мөстәкыйль музей; 2006 дан ТР Мәдәният министрлыгы карамагында, 2010 нан муниципаль музей. Экспозиция мәйданы — 240 *м*², коллекцияләрендә 40 меңнән артык саклау берәмлеге исәпләнә. Музей структурасында — архив, китапханә, күргәзмәләр залы. Экспозиция системалы рәвештә борынгы заманнардан алып төбәк тарихын һәм 19 йөз ахырыннан шәһәр үсеше тарихын чагылдыра. Экспозициягә археол., этнография, халык гамәли-бизәлеш сәнгате предметлары, фото- һәм документаль материаллар куелган. Экспонатлар арасында — рус һәм татар халыкларының көнкүрешен яктырткан 20 йөз башы шәһәр фоторәсемнәре, сәүдәгәрләрнең көнкүреш кирәк-яраклары, интерьер комплекслары интерьерлары. 1917 дән соңгы шәһәр тарихына багышланган бүлектә экспозициягә Окт. рев-циясе, Граждданнар сугышы, 1930 еллардагы күмәкләштерү чорларындагы фотоматериаллар куелган. Экспозициянең бер өлеше Бөек Ватан сугышы елларындагы шәһәр тормышын ачып бирә: сугышта катнашучыларның һәм тыл хезмәтчәннәренең шәхси әйберләре, сугыш кирәк-яраклары, сугышчыларның «Үлем үзәнендә» (Новгород өлкәсендә 2 нче Удар армия алып барган сугыш урыны) табылган «үлем медальоннары» һ.б. «Чаллы — автомобиль төзүчеләр шәһәре» бүлегендә КАМАЗ, Түбән Кама ГЭСы, Яңа шәһәр төзелеше тарихы тәфсилләп яктыртыла, сәламәтлек саклау, мәгариф, спорт һ.б. үсеше турында материаллар урнаштырылган. Экспозициягә бай раклар, сәнәгать продукциясе үрнәкләре, фоторәсемнәр, документлар һ.б. куелган. Аеруча кыйммәтле экспонатлар арасында: Тула самоварлары коллекцияләре (15 берәмлек), бизәкләп тукылган халык осталары эшләнмәләре, Чаллы шәһәренә һәм КАМАЗга багышланган значоклар һәм истәлекле медальләр (1500 берәмлек), Я.Ф.Дремлюкның фронт хатлары (164 берәмлек), 20 йөз башы металл савыт-саба коллекциясе (4 берәмлек), радиоалгычлар һәм радиоаппаратура (80 нән артык берәмлек), Түбән Кама буе терр-ясендәге археол. казу эшләре табылдыклары (248 берәмлек), «Актүбә уенчыгы — Актюбинская игрушка» (22 берәмлек) сувенир продукциясе. Музей ел саен үзенең оешу (10 апр.) һәм ачылу (6 май) көннәрен, Җиңү көнен (9 май), Халыкара музейлар көнен (18 май), Республика көнен (30 авг.), Белем көнен (1 сент.), КАМАЗ төзелеше башланган көнне (13 дек.) билгеләп уза.

Әд.: Исторические и краеведческие музеи СССР: Каталог. М., 1988.





Чаллы шәһәре тарихы музее. 1. Гомуми күренеш; 2. «КАМАЗ төзелеше тарихы» экспозициясеннән күренеш.

ЧАЛЛЫ́ ШӘҺӘРЛЕГЕ́ (Тәбәрде шәһәрлеге), археол. истәлек, урта гасырлардагы (12 йөз — 16 йөзнең 1 нче яртысы) болгар-татар шәһәре калдыклары. Балык Бистәсе р-ны Тәбәрде Чаллысы авылы янында урнашкан. Фаразланганча, болгарларның 12 йөз рус елъязмаларында буенча мәгълүм «челмата» кабиләсе тарафыннан нигезләнгән. Ч.ш.ндә археол. тикшеренүләр 19 йөзнең 2 нче яртысыннан алып барыла (К.И.Невоструев, С.М.Шпилевский, М.Б.Зәетов, Н.А.Толмачев, И.А.Износков); беренче казу эшләре 1955 елда Н.Ф.Калинин тарафыннан оештырыла (ул Ч.ш. 14 йөздә — 16 йөз уртасындагы Чаллы бәклеге үзәге булган, дип исәпли). Археол. тикшеренүләр 1983 тә — Н.А.Корина, С.В.Кузьминых, 1989 да — Т.И.Останина, 1990 елларда Ф.Ш.Хуҗин тарафыннан дәвам иттерелә.

Ч.ш.нең мәйданы 1 *га* дан арта: дүртпочмаклык рәвешендә, ике якстан төньяк-көнчыгыш тарафта керү-чыгу урыны булган, 4–5 рәт туфрак урларыннан һәм чокырлардан гыйбарәт катлаулы ныгытмалар системасы б-н сакланган. Шәһәрлекнең тирә-ягында гаять зур шәһәр яны авыллыклары — посадлар (гомуми мәйданнары 60 *га* чамасы), мөселман каберлекләре урнашкан. Ч.ш. терр-ясендә монгол яуларына кадәрге чорга нисбәтле, җир өстенә салынган һәм яртылаш җиргә казылып корылган тораклар, сөяк эшкәртү остаханәсе, хуҗалык чокырлары (азык-төлек саклау өчен) һәм Казан ханлыгы дәверенә караган тимерчелек алачыклары калдыклары табыла.

Әд.: Древние Чаллы — Борынгы Чаллы. К., 2000; Хузин Ф.Ш. Булгарский город в X — начале XIII вв. К., 2001; Нигамаев А.З. Болгарские города Предкамья: Алабуга, Кирмень, Чаллы. К., 2005.

Ф.Ш.Хуҗин.

ЧАЛЛЫ́ ЭЛЕВА́ТОРЫ, бөртекле ашлык хәзерләү, саклау һәм эшкәртү б-н шөгыльләнүче пр-тие. Эшләүчеләр саны — 320 ләпкеше (2017). 1912–17 елларда Россия Дәүләт банкының бөртекле ашлык саклау урыннары бүлеге тарафыннан Чаллы елга элеваторы буларак төзелә. 1934 тән — «Заготзерно»ның Чаллы бүлекчәсе, 1957 дән — Чаллы (1982–87 дә — Брежнев) ашлык продуктлары элеваторы; 1995 тән хәзерге исемдәге АҖ. Башта элеваторның бөртекле ашлык саклау урыннары сыйдырышлылыгы 32 мең *т*, кабул итү мөмкинлеге 128 *т/сәг.* тәшкил итә. Кама елгасыннан китерелгән бөртекле ашлыкны бушату һәм кабул итү өчен дебаркадер һәм 40 башка исәпләнгән ат абзары төзелә, Англиядә эшләнгән 4 «Авери» автомат үлчәүләре урнаштырыла. Бөртекле ашлык 7 катлы тимер-бетон башнядагы «Говес» ашлык киптергечендә (АКШ) пар ярдәмендә киптерелә һәм таштырылган галереялар буйлап тимер б-н тышланган 486 силослы агач силослар корпусына килә. Ашлык чистарту һәм күтәрү механизмнары электр двигательләре, 110 һәм 300 ат көчле ике локомобиль б-н хәрәкәткә китерелә. Зурлыгы буенча илдә өченче урынны биләгән Ч.э. продразвёрстка, күмәкләштерү чорларында, Бөек Ватан сугышы вакытында икмәк хәзерләүләрне гамәлгә ашыру барышында мөһим роль уйный. 1950–70 елларда ашлык складлары, киптерү-чистарту башнялары, лабораторияләр, катнаш азык, борчак ярмасы һәм он җитештерү куәтләре төзелеше колач җәя; яңа күчмә һәм стационар ашлык киптергечләр урнаштырыла, югары вольтлы электр линияләре сузыла. 1980 елларда кабул итү җайланмалары булган керә торган тимер юллар, ачык типтагы ашлык киптергечләр төзелә, техник якстан искергән катнаш азык з-ды һәм тегермән туктатыла. 1990 елларда кабул итү җайланмалары автомобиль бушаткычлары б-н җиһазландырыла, онны савытсыз кабул итү һәм җибәрү, төрле ярмалар ясау һәм төргәкләү куәтләре, бодайны ике сортлы итеп тарту тегермәне, макароннар җитештерү ярымавтоматы эшли башлый.

Ч.э.нда 2 ашлык кабул итү участогы, бер үк вакытта төрле бөртекле һәм бөртекле-кузаклы культуралар продукциясен эшкәртүгә сәләтле 220 *т/сәг.* күтәрле 5 газлаштырылган һәм механикалаштырылган ашлык чистарту-киптерү җайланмасы, 26 мең *т* һәм 81,3 мең *т* сыйдырышлы силослар корпусы һәм 28 склад (ашлык саклау урыннарының гомуми сыйдырышлылыгы 110 мең *т*), тәүлеккә 120 *т* га кадәр борчактан һәм 70 *т* га кадәр арпадан ярма җитештерүче ярма з-ды, он һәм макарон эшләнмәләре чыгаручы куәтләр бар. 2007 дә йорт кошлары өчен тулы рационлы гранулалы катнаш азык (тәүлеккә 720 *т*) һәм премикслар — азыкка витаминлы-минераль өстәмәләр (тәүлеккә 72 *т*) җитештерүче завод, 2010 да рапс эшкәртү цехы (тәүлеккә 45 *т*) эшли башлый. 2014 тә икенче катнаш азык з-ды (тәүлеккә 960 *т*) ачыла. Пр-тие эшчәнлеген автопарк, ярдәмче цехлар һәм остаханәләр тәэмин итә.

Сыйфатлы продукция җитештерүе өчен пр-тие Халыкара махсуслаштырылган а.х. күргәзмәсендә (Казан, 1999) ТР А.х. министрлыгының Почёт дипломы б-н бүләкләнә. Хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә, ш.и. 1 кеше — ТРның атказ. а.х. хезмәткәре, 1 кеше — атказ. азык-төлек һәм эшкәртү сәнәгате хезмәткәре исемнәренә, 3 кеше — 3 нче дәрәҗә «Хезмәт даны», 1 кеше — «Почёт билгесе» орденнарына, 1 кеше «Намуслы хезмәт өчен» медаленә лаек була.

Пр-тие җитәкчеләре арасында: М.В.Дивавин (1920–26), Сорокин (1934–35), Казаев (1935–37), Скрябин (1937–38), Герасимов (1938–39), А.Тужилин (1939–42), Н.И.Федотов (1942–45), Романов (1945–47), А.А.Антонов (1947–50), А.М.Забродин (1950–52), А.Ә.Әхмәт җанов (1952–53), Г.И.Стыскин (1953–59), Н.К.Курдеков (1959–69), Г.Н.Закиров (1969–90), И.И.Шәйхетдинов (1990–97), В.Г.Ха жиев (1997–2004), Ф.Т.Газетдинов (2004–07), И.И.Шәйхетдинов (2007 дән).

Әд.: Хвала рукам, что хлебом пахнут: Из прошлого и настоящего «Татархлебопродукта». К., 2001.

С.Г.Белов.

ЧАЛЛЫБА́Ш авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 34 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Шомбыт елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 124 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1619 дан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Җәнбатыр чишмәсе буендагы авыл буларак билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, вак-төяклөр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 278 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Шомбыт волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Мамадыш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1782 дә — 31 ир-ат; 1859 да — 147, 1897 дә — 179, 1908 дә — 211, 1920 дә — 234, 1926 да — 243, 1938 дә — 300, 1949 да — 331, 1958 дә — 279, 1970 тә — 318, 1989 да — 123, 2002 дә — 141 кеше.

ЧАЛЛЫБА́Ш РАЙОНЫ́, Самара өлкәсенең төньягында урнашкан. 1928 елда оештырыла. Мәйданы — 1162,3 *км*². Үзәге — Чаллыбаш авылы (Самарадан 148 *км* ераклыкта). Халкы — 15085 кеше (2017). Татарлар саны — 2097 кеше (2010). Алар Зәет, Шламка һәм Благодаровка авылларында, Кече Норлат, Яңа Норлат, Совет Иглае, Совет Норлаты посёлокларында яшиләр. Кече Норлат, Совет Норлаты, Совет Иглае посёлокларына 1927 дә нигез салына. Беренче булып ТАССРның Октябрь р-ныннан Югары Норлат, Түбән Норлат, Яңа Иглай авыллары халкы күченә, алар а.х. б-н шөгыльләнә. 1954 тә «Яңа тормыш» к-зы оештырыла. Хәзерге көндә районда 6 мәчет эшли. 1907 дә төзелгән Благодаровка авылы мәчетенә 2007 дә капиталь ремонт ясала. Совет Иглае посёлогында татар теле факультатив дәрес буларак укытыла. Чаллыбаш авылы мәдәният йорты каршында татар бию ансамбле (җитәкчесе А.Г.Кәбиров) эшли. ТАССРның халык артисты З.Х.*Туишеваның* тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге Ч.р. б-н бәйле.

ЧАЛМА́, озын тукыма кисәге рәвешендәге, баш тирәли уратып бәйләнә торган ирләр баш киеме. Ислам динен тотучы халыклар арасында киң таралган. Тукымасының төсе, сыйфаты, зурлыгы, урау рәвеше буенча аерыла, иясенең милли һәм социаль ягын күрсәтеп тора (мәс., пәйгамбәр варислары булып саналган затлар яки Мәккәдә булып кайткан кешеләр яшел Ч.дан, башка мөселманнар ак Ч.дан йөргәннәр). Ч.ны, гадәттә, бүрек, фәс өстеннән, сирәгрәк баш киеменнән башка да киеп йөриләр. Руханилар һәм *хаҗ* кылып кайткан затлар Ч. ны *түбәтәй* өстеннән кияләр.

Әд.: Суслова С.В. Одежда // Татары. М., 2001.

ЧАЛМА́ ЧӘЧӘ́К (Paeonia), күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы, сирәгрәк чалма чәчәксыманнар семьялыгыннан куаклыклар яисә ярымкуаклыклар. 50 гә якын агачсыман һәм үләнчел үсемлекләр төре билгеле; якынча 15 төре кыргый хәлдә Россиядә үсә. 1,5 мең елдан артык Кытайда үстерелә. Үләнчел Ч.ч.нең ТРда үстерелә торган хәзерге бакча сортлары нигездә 2 төрдән килеп чыккан: Гади яисә дару Ч.ч. (P. officinalis), һәм Сөтсеман чәчәкле Ч.ч. (P. Lactiflora). Биекләге 60 *см* дан 120 *см* га кадәр. Яфраклары чиратлашкан, катлаулы, ике- яисә өчәрле. Чәчәкләре эре (диаметры 6–20 *см*), ярымкатмарлы һәм катмарлы, ак, алсу, куе кызыл (сирәгрәк сары) төстә. Чәчәк атуы май ахыры — июнь башында башлана һәм, сортына карап, июль уртасына кадәр дәвам итә. Җимеше 1–5 җимешән яфрагыннан һәм тыгыз тиречел тышчадан тора. Орлыгы 6–18 *мм* озынлыкта, 3–15 *мм* калынлыкта. Шулай ук гади кызыл чәчәкле авышкак Ч.ч. яисә «Марья тамыры» (P. Anomala) Ч.ч. үстерелә. Ч.ч., башлыча, куакларын аеру юлы б-н үрчетелә, 15 августтан 15 сентябрьгә кадәр утыртыла. «Марья тамыры» халык медицинасында кан китүләр, ашказаны җәрәхәте вакытында кулланыла. Ч.ч.нең авырулары — соры черек, фитофтороз, тутык авыруы, ончыл чык, сабаклары шиңү.

Әд.: Савков С.Г. Оранжерейные и комнатные растения и уход за ними. М., 1971; Зелёные оазисы дома и на работе. Минск, 1985; 1000 ответов и идей для вашего сада. М., 2007.

ЧАЛМАНАРА́Т авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 20 *км* көнбатыштарак, Шәбез елгасы буенда. 2010 елда 305 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөздә нигез салына.1860 елларга кадәр халкы асабалар һәм типтәрләр катлавына бүленә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ч.та мәчет, мәктәп, су һәм җил тегермәне, ашлык саклау-сату кибете, шәрабханә һәм сыраханә була; базар эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1698 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Семиостров (Өшәр) волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 150, 1834 тә — 471, 1859 да — 686, 1884 тә — 781, 1906 да — 669, 1913 тә — 545, 1920 дә — 592, 1926 да — 535, 1938 дә — 374, 1949 да — 229, 1958 дә — 367, 1970 тә — 400, 1979 да — 350, 1989 да — 309, 2002 дә — 324 кеше.

ЧАЛПЫ́ елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Ык елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 13,8 *км*. Бассейнының мәйданы 188,2 *км*². Елга башы Азнакай р-ны Ирекле авылыннан 2 *км* көнчыгыштарак, тамагы Башкортстан Респ-касы терр-ясендә. Елга башының абс. биеклеге 210 *м*, тамагыныкы — 78 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 15%. Ч.ның 1,9 дан 5,8 *км* га кадәр озынлыктагы 3 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,14 *км /км*². Туенуы катнаш, дүрттән өч өлеше кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Җәен озак вакыт яңгырлар булмаганда елга ләмләнә һәм еш кына тамагына кадәр барып җитми. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 90 *мм*, ташу вакытында су катламы агымы 68 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,195 *м*³*/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 400–500 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк. Ч. бассейнында суының гомуми күләме 3,8 млн. *м*³ булган 8 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла. Ч.ның икенче исеме — Наратлы елгасы.

ЧАЛПЫ́ авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 35 *км* төньяктарак, Чалпы елгасы буенда. 2010 елда 818 кеше (татарлар)



Я.Ж.Чанышев.

яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1704 тән мәгълүм. Рев-ция -гә кадәрге чыганакларда Каратлы Елга исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы асабалар, типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 5 мәчет, 2 мәдрәсә, су тегермәне, ярма яргыч була; базар эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 6338 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Тымытык волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 20 октябреннән — Азнакай, 1935 нең 10 февраленнән — Тымытык, 1958 нең 16 июленнән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1795 тә — 350, 1859 да — 706, 1889 да — 2825, 1897 дә — 2885, 1910 да — 3518, 1920 дә — 3678, 1926 да — 2322, 1938 дә — 1382, 1949 да — 1378, 1958 дә — 1457, 1970 тә — 1488, 1979 да — 1236, 1989 да — 1038, 2002 дә — 935 кеше.

Әд.: Ш ә р и п о в С. Чалпы // Мирас. 1994. № 9–10.

ЧАЛЫ́М, баш күтәрүчеләр кальгасы; *Казан җирләрендә азатлык сугышлары (1552–56)* чорында рус гаскәрләренә каршылык күрсәтү үзәкләренең берсе. Фаразланганча, Тау ягында (Кама елгасының уң яры) урнашкан була. Никон елъязмасында һ.б. рус елъязмаларында воевода П.В.Морозовның 1556 елда «яр буе кешеләре»нә каршы явы вакытында Ч.ның җимертелүе хакында искә алына: «...алар белән сугышып күпләрне кырды һәм шәһәрчекне яндырды...», — диелә.

Әд.: Д и м и т р и е в В.Д. Антимосковское движение в Казанской земле в 1552–1557 годах и отношение к нему её Горной стороны // Народная школа. 1999. № 6.

ЧАН РАЙОНЫ́, *Новосибирск өлкәсенең* көнбатыш өлешендә урнашкан. 1925 елда оештырыла. Мәйданы — 5515 *км*². Үзәге — шәһәр тибындагы Чан посёлогы. Халкы — 23713 кеше (2017). 2010 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 2916 (1979 да — 3363, 1989 да — 3332, 2002 дә — 3256) кеше. Тупланып, Ая-лу, Кошкүл, Чөплегөл (Тебисс), Бәләхтә, Чортану (Кече Тебисс), Тармакүл авылларында яшиләр. Татар халкы Бараба татарларыннан (Бараба урман далаларының төп халкы) һәм 19 йөз ахырында — 20 йөзнең 1 нче яртысында илнең Европа өлешеннән Себергә күченгән татар варисларыннан гыйбарәт. 1930 елларга кадәр Ч.р. терр-ясендә 2 мәчет эшли. Районның 4 мәктәбендә татар теле фән буларак укытыла. Тармакүл гомуми белем бирү мәктәбе җирлегендә «Дуслык» иҗат берләшмәсе, татар мәдәни үзәге эшли. 2003 тән Сабан туе бәйрәм ителә. Тармакүл авылында ТРның атказ. артисты Закир Шаһбан туган.

Әд.: К о р у с е н к о С.Н., К у л е ш о в а Н.В. Генеалогия и этническая история барабинских и курдакско-саргатских татар. Новосиб., 1999.

ЧАНБАРИ́СОВ Шәйхулла Хәбибулла улы (9.5.1916, Уфа губ., Бәләбәй өязе Иске Бүздәк а. — 4.10.1996, Уфа ш.), тарихчы, тарих фән. д-ры (1975), проф. (1976), БАССРның атказ. фән эшлеклесе (1976). Башкорт пед. ин-тын (Уфа, 1937), ВКП(б) УК каршында-гы Иҗтимагый фәннәр академиясен (Мәскәү, 1951) тәмамлый. 1940–41 елларда Златоуст хәрби пехота уч-щесендә укыта. Бөек Ватан сугышында катнаша: 1941 дә 133 нче укчы бригаданың аерым укчы батальоны комиссары; 1942–43 тә 384 нче укчы дивизиянең 276 нчы укчы полкында, 170 нче укчы дивизиянең 391 нче укчы полкында полк командирының сәяси эшләр буенча урынбасары (Төньяк-Көнбатыш, Үзәк һ.б. фронтлар). 1943–44 тә Кызыл Армиянең сәяси составын камилләштерү Югары курслары тыңлаучысы. 1946 дан (бүленеп) Башкорт пед. ин-тында: марксизм-ленинизм каф. мөдире 1951 дән), ин-т директоры (1954–57). 1952–53 тә партиянең Башкортстан крайкомында мәктәпләр бүлеге мөдире. 1957–81 дә Башкорт ун-ты ректоры. Хезмәтләре педагогикага, югары белем бирү тарихына карый. Октябрь Революциясе, ике Кызыл Байрак, 1 нче һәм 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Формирование советской университетской системы. М., 1988.

Әд.: Башкирская энциклопедия. Уфа, 2011. Т. 1.

ЧАНГА́Р елгасы, Идел алдында, Сөлчә елгасының (Зөя елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 14,4 *км*. Бассейнының мәйданы 70,6 *км*². Идел буе калкулыгыннан, Югары Ослан р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Харино авылыннан 2 *км* төньяк-көнбатыштарак, тамагы Олан авылыннан 3 *км* төньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 175 *м*, тамагыныкы — 70 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 15%. Ч.ның 0,2 дән 4,2 *км* га кадәр озынлыктагы 9 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,43 *км/км*². Туенуы катнаш, күбрәк кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,25–0,5 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпеллык катламы 104 *мм*, ташу вакытында су катламы 100 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь уртасында туң. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,01 *м*³/*с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минераль-ләшүе 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. Ч. бассейнында суының гомуми күләме 0,2 млн. *м*³ булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

ЧА́НЫШЕВ Әнвәр Хәйдәр улы (2.10.1924, БАССРның Бәләбәй кантоны Күзәй а. – 27.4.2017, Мәскәү), физик культура һәм спортны оештыручы, полковник (1967), РФ нең атказ. физик культура хезмәткәре (2005). 1943 елда пехота уч-щесен (Уфа ш.), 1952 дә Хәрби физик культура һәм спорт ин-тын тәмамлый. 1952–62 дә Карпат алды хәрби округының физик әзерлек башлыгы, 1962–67 дә Армиянең үзәк СК башлыгы урынбасары, 1967–70 тә башлыгы, 1971–79 да СССР Оборона министрлыгының спорт ком-ты рәисе урынбасары, 1980 дә СССР Милли олимпия ком-тының спорт команда-лары идарәсе башлыгы урынбасары, 1980–2000 дә Мәскәү шәһәр физкультура-спорт берләшмәсенең Балалар-яшүсмерләр спорт клубында бүлек башлыгы, 2000 нән Мәскәү Мәгариф департаменты каршындагы Хәрби-патриотик һәм гражданлык тәрбиясе үзәгендә бүлек башлыгы, директор урынбасары. СССР Фехтование федерациясе рәисе (1969–83), Мәскәү татарларының төбәк милли-мәдәни автономиясе советы әгъзасы (2004 тән). Бөек Ватан сугышында катнаша. Кызыл Байрак, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз, 3 нче дәрәҗә «РФ Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәт өчен» орденнары, медальләр, ш.и. Болгария, Германия, Польша медальләре б-н бүләкләнә.

ЧА́НЫШЕВ Якуб Җиһангир улы (27.02.1892, Уфа губ., Эстәрлетамак өязе Тукай а. — 6.11.1987, Мәскәү), генерал-лейтенант (1944). Казанда хәрби уч-ще (1917), Мәскәүдә М.В.Фрунзе исем. Эшче-Крәстиян Кызыл Армиясе хәрби академиясен (1934) һәм СССР Кораллы Көчләре Генштабының Хәрби академиясе каршындагы К.Е.Ворошилов исем. Югары акад. курсларны (1943) тәмамлый. Беренче бөтендөнья сугышында катнаша, туп төзәүче, 3 нче артиллерия бригадасы батареясы разведчик-күзәтүчесе. Георгий тәресе б-н бүләкләнә. Окт. рев-циясеннән соң Казан хәрби округы комиссары. КОМУЧ халык армиясе һәм Чех-словак корпусы частьлары б-н сугышларда катнаша. 1918 елдан 1 нче аерым Идел буе татар укчы бригадасы хәрби комиссары, Төркестан фронтында сугыша, Бохара һәм Фирганә шәһәрләрен алуда катнаша. 1925–32 дә 1 нче Казан укчы дивизиясенең командиры һәм комиссары. 1934 нең декабреннән Урта Азия Хәрби округының 68 нче Төркестан тау укчы дивизиясе б-н җитәкчелек итә. 1937 нең 17 маенда кулга алына, 1939 ның декабрендә аклана һәм эше туктатыла. 1940–41 дә М.В.Фрунзе исем. Хәрби академиядә укыта. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында: Көньяк-Көнбатыш фронтның 6 нчы һәм 9 нчы армияләренең 103 нче һәм 333 нче укчы дивизияләре командиры, Төньяк-Көнбатыш фронтның 68 нче һәм 38 нче армияләре командующие урынбасары. 1 нче һәм 2 нче Белоруссия фронтларының 70 нче армиясенең 96 нчы укчы корпусы командиры. Ч. җитәкчелегендәге частьлар Мәскәү

(1941–42), Харьков (1942), Сталинград (1942–43) янында, Люблин-Брест (1944), Көнчыгыш Померания һәм Берлин (икесе дә 1945 тә) һөҗүм операцияләрендә катнаша. Ч. Сов Союзы Герое исеменә тәкъдим ителә. 1946 дан СССР Кораллы Көчләре Генштабының К.Е.Ворошилов исем. Хәрби академиясендә укыта. 1957 нең гыйнварыннан — отставкада. Мәскәүдә яши. Ике Ленин ордены, Октябрь Революциясе, дүрт Кызыл Байрак, 2 нче дәрәҗә Суворов, 1 нче дәрәҗә Кутузов, 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Әс ә р.: Вспоминая былые походы (Боевой путь Первой татарской стрелковой бригады). К., 1973.

Әд.: Великая Отечественная. Комкоры: Военный биогр. словарь. М., 2006. Т. 1.

М.З.Хәбибуллин.

ЧА́НЫШЕВА Гөлнара Габделхак кызы (22.7.1963, Таҗикстан ССРның Ленинабад ш.), педагог, пед. фән. д-ры (2006), проф. (2010). Ленинабад пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1984), Ленинабад мәктәпләрендә укыта. 1993 елдан Түбән Кама мәктәпләрендә эшли, 1996 дан шәһәр хакимиятендә. 2001 дән Казан юридик ин-тының криминология һәм җинаять-җәза үтәтү хокукы кафедрасында, 2006 дан каф. мөдире. Хезмәтләре хокук белгечләре әзерләү мәсьәләләренә карый. Сөйләм культурасы, криминология буенча уку ярдәмлекләре авторы. «Юридик сөйләм культурасы» («Культура юридической речи», 2005) укыту ярдәмлеге барлык ведомство югары уку йортларында куллану өчен Эчке эшләр министрлыгы тарафыннан хуплана.

Хез м.: Развитие коммуникативных способностей будущих юристов в условиях национально-русского двуязычия. К., 2004; Становление профессиональной речи у студентов-юристов. М., 2005.

ЧА́НЫШЕВА Фаина Хөсәен кызы (20.12.1922, Казан — 15.8.1998, шунда ук), хирургия шәфкать туташы. Бөек Ватан сугышында катнаша. Халыкара Кызыл Хач ком-ты тарафыннан Флоренс Найтингейл исем. алтын медаль б-н бүләкләнә (1965). ТАССР Сәламәтлек саклау халык комис-тының шәфкать туташлары мәктәбен тәмамлаганнан соң (1939), 2 нче йогышлы авырулар хастаханәсендә (Казан) эшли. 1941 елдан Кызыл Армия сафларында: 1942–43 тә 5191 нче хәрәкәттәге кыр госпиталендә шәфкать туташы, аннары 221 нче укчы дивизия-нең 659 нчы артиллерия полкы 3 нче дивизионында мед. хезмәте кече лейтенанты дәрәҗәсендәге фельдшер. Ул йөзләрчә солдатны үлемнән коткарып кала. Сталинград сугышында, Кёнигсбергны азат итү өчен барган сугышларда, Ерак Көнчыгыштагы хәрби хәрәкәтләрдә катнаша. 1946–87 дә Казан суворовчылар хәрби уч-щесендә өлкән шәфкать туташы. 1 нче, 2 нче дәрәҗә Бөек Ватан сугышы орденнары, ике Кызыл Йолдыз ордены, «Батырлык өчен», «Сугышчан батырлык өчен» һәм 12 башка медальләр б-н бүләкләнә.

ЧА́НЫШЕВЛАР, татар бәкләре нәселе. Алтын ханнан һәм Гөрләвеч ханшадан башлангыч ала. 16 йөздән нәсел вәкилләре рус хезмәтенә керә. Документлар б-н расланган шәҗәрә 16 йөз ахырында хезмәттә булган, Касыйм өязендә яшәгән һәм крепостной крәстияннәре б-н Темгеново авылын биләгән Темген бәктән башлана. Аның улы Чемай дворян һәм бояр балалары исәбендә саналып, полкта хезмәт итә. Патша Михаил Фёдорович тарафыннан аңа Шацк өязендәге Цыпляково һәм Баскаково авылларында, Касыйм өязендәге Темгеново, Поповское, Коркодышево авылларында утарлар бирелә, акчалата түләү билгеләнә. 1681, 1684 елларда Чемайның утарлары аның уллары Нарукайга, Бикмайга, Уразмәмәткә, Акбулатка һәм оныгы Сәфәр Мәмәтовка күчереп языла. Нарукай ш.у. дәүләт хезмәтендә тора. Петр I нең мөселманлыктагы йомышлы кешеләрне чукындыру турындагы 1713 елгы указыннан соң Ч.ның крепостной крәстияннәре, җирләре һ.б. биләмәләре казна милкенә күчерелә (1728 дә җир биләмәләре кайтарып бирелә). 18–19 йөзләрдә Ч. Шацк (соңрак Тамбов) өязенең Тенишево, Касыйм өязенең Фроловская һәм Темгеново авылларында яшиләр. 1754, 1759 да бәк Ч. Тенишево авылыннан Уфа губернасы Бәләбәй өязенең Күзәй авылына күченеп утыралар; 1851 дә анда әлеге нәселнең 106 вәкиле яши. Ибраһим Биктимер улы (?-1812 дә соң) Оренбург краенда сәүдә б-н шөгыльләнә. 1773–75 тәге Крәстияннәр кузгалышы вакытында «чит диндәгеләр» командасын җитәкли, Оренбургны Е.И.Пугачёвның баш күтәрүчеләр гаскәреннән саклауда актив катнаша, Сакмар шәһәрчеге янында хөкүмәт гаскәрләре ягында сугыша. Хөкүмәт алдындагы хезмәтләре өчен прапорщик дәрәҗәсенә лаек була, алтын медаль б-н бүләкләнә, «җан башыннан алынган салымнан мәңгелеккә азат ителә»; аңа ш.у. «барлык Россия буенча сәүдә итәргә» юл куела. Баш күтәрү бастырылганнан соң хакимиятләр тарафыннан Оренбургка күченергә рөхсәт бирелә. «Азия халыклары» б-н сәүдә мөнәсәбәтләрен үстерә. Оренбургның түбәнге земство мәхкәмәсе утырышчысы була (1780 еллар). Аның бертуганы Мостафа Ч. пугачёвчылар б-н көрәштәге хезмәтләре өчен җан башыннан алынган салымнан азат ителә, алтын медаль һәм кылыч б-н бүләкләнә. Соңрак Ибраһим б-н Мостафаның уллары һәм оныклары Туркай авылында (хәзер Башкортстан Респ-касының Бишбүләк р-ны) яшиләр. Ч. нәселенә дворянлык Сенатның 1796 елгы указы б-н кайтарыла; аның вәкилләре Оренбург губернасы дворяннары шәҗәрәсе китабының 4 нче өлешенә кертелә. Ч. нәселеннән генерал Я.Ж.*Чанышев* чыккан.

Әд.: Шишкинцев И. К истории Пугачёвского бунта (неизданные материалы) // Тр. Оренбург. уч. арх. комиссии. 1902. Вып. 9; Габдуллин И.Р. От служилых татар к татарскому дворянству. М., 2006; Ахметшин Ш.К. Бархатная книга татар: Российские дворянские роды тюрко-татарского происхождения. СПб., 2010. Т. 2.

ЧАҢГЫ́ СПОРТЫ́, спортның иң киң таралган кышкы төрләреннән берсе. Аңа чаңгы ярышлары, чаңгыда трамплиннан сикерү, ике төр ярыш (узышу һәм сикерү), слалом, тизлек б-н төшү (махсус трасса буенча таудан төшү), биатлон (винтовкадан мишеньнәргә ата барып узышу) керә. ТАССР беренчелегенә чаңгы ярышлары 1921 елдан, Татарстанның иң көчле чаңгычылары узышы — 1953 тән, «Казан чаңгы марафоны» — 1968 дән, «Раштуа чаңгы ярышы» 2003 тән уздырыла. Ч.с. «Бөркет», «Көч һәм сәламәтлек», «Сокол», «Яхт-клуб» һ.б. Казан спорт җәмгыятьләрендә җәелдерелә. 1920–30 да йолдыз-чаңгычылар, агитацияләү узышлары һәм билгеле даталарга багышланган, шәһәрләр һәм ТАССРның башка торак пунктлары буйлап 130 дан 1000 *км* га кадәр озынлыктагы эстафеталар популяр була. 20 йөзнең 1нче яртысында көчле спортчылар — А.Е.Казаков, Н.А.Майков, Н.М.Курбатов, А.Т.Баженов, Б. һәм А.Горн, В.Дмитриев, С.Н.*Гладков*, В.А.Берланд, Н.Сапугульцев, В.Данилов, Т.Шулешкина, В.А.*Бекасов*. 1958 дә ТАССРның Чаңгы спорты федерациясе оештырыла (рәисе Н.П.Назаров), президенты И.Ш.Фәрдиев (2011 дән). ТАССР (ТР) чаңгычы-узышчылар җыелма командасы респ-ка һәм Идел буе өлкәләре (РСФСР зонасы) спартакиадаларында чемпион (1958), көмеш (1961, 1980, 1985, 1987, 1989, 1995) һәм бронза (1976–78, 1986, 1988, 1994) медальләр, РСФСР халыклары спартакиадаларында бронза (1974), РСФСР чемпионатында көмеш (1979), РФ автономияле респ-калары җыелма командалары арасындагы чемпионатта көмеш (2003) медальләр иясе. ТРда 41 чаңгы базасы эшли, Зәй р-ны-ның Федотово, Мөслим р-нының Мөслим авылларында яктыртылган чаңгы трассалары бар (2006). ТРның иң көчле чаңгычы-узышчылары, Олимпия уеннарында, Дөнья кубокларында, Дөнья, СССР, РФ, «Спартак», «Буревестник», «Трудовые резервы», «Зенит», «Локомотив», «Труд», «Уңыш» ирекле спорт җәмгыятьләре, «Динамо» физкультура-спорт җәмгыяте үзәк советлары чемпионатларында катнашучылар һәм медаль алучылар — О.В.Агеева, Р.З.*Бакиев*, Е.Д.Белов, А.В.Бурылов, С.Васюков, П.С.Волков, А.Ф.Вялимаа, С.М.Габделхәев, М.М.Галиев, И.Р.Гайнуллина, Ә.Г.*Гайфуллина*, А.И.Галиуллина, Н.П.Герасимов, Г.Я.Григорьев, Е.В.Григорьева, Т.В.Дәүләтшина, О.В.*Данилова*, Е.Н.Данилова, Н.М.Ермолаев, А.В.Завьялов, З.И.Закирова, Ф.Закирова, Г.Х.Идрисов, А.Р.Ихсанова, А.Я.Калашников, Р.Г.Камалов, Е.Кирпичников, В.Н.Киселёва, Ю.В.Козлов (чаңгыда ике төр ярыш), И.Кондрашов, Е.Ю.Косинцев, В.Н.Крымцова, В.И.Кузьмин (чаңгыда трамплиннан сикерү), И.В.Максимов, В.И.Маркелов, В.В.Матвеева, М.Р. һәм А.Р.Нәҗметдиновлар, М.Ф.Пашунина, Л.Е.Петрова, А.Н.Писанов, А.Д.Пискунов, А.Г.Романов, Д.Х.Сабирҗанова, А.Х.Сабирова, И.А.Сәләхов, Ф.Х.Сафиуллин, Ф.П.*Симашёв*, Н.И.Степанова, Е.М.Тихомирова, И.С.*Утробин*, Ф.Ф.Фәйзрахманова, Н.Н.Фирстова, Р.Г.Ханнанов. Тренерлары — А.Д.Аверьянов, В.Г.Апрелев, А.Г.Бусарин, А.Ф.Вялимаа, В.А.Гордеев, В.Я.Григорьев (чаңгыда ике төр ярыш), С.Е.Егоров, Н.М.Ермолаев, А.И.Желнов,

Ю.Ф.Золотов, В.П.Калашников, Г.А.Клементьев, Ю.В.Козлов, В.И.Кокуркин, С.В.Колесов, З.К.Корбангалиева, С.П.Ляпахин, Р.И.Мәхмүтов, Д.Х.Мифтахов, С.А.Нафиков, М.М.Нигъмәтҗанов, В.А.Перетурин, Г.В.Ремизов, Г.Н.Рожков, А.Н.Рябов, Р.С.Сафин, Ф.И.Сафиуллина, Ю.В.Сидоров, А.Г.Сиражиев (ветераннар арасында), Н.Д.Талманов, В.Е.Трушков, А.И.Шибаев, В.Д.Шутов, Н.Е.Яковлев.

Чаңгычы-узышчылар, Параолимпия һәм Сурдлимпия уеннарында катнашучылар һәм медаль алучылар — М.А.Зәйнуллина (бронза, 2014), Р.Р.Миңнеголов (алтын, 2014), В.С.Мухин (алтын, 1979), Ф.И.Низамов (көмеш, 1987), И.В.Полякова (көмеш, 2006). Чаңгыда трамплиннан сикерү, ике төр ярыш, слалом ТАССРда 1927 дән җәелдерелә (башлап җибәрүчеләре — В.А.Бекасов, И.Б.Брен). 1934 тә Казанда тау чаңгысы мәктәбе ачыла, көчле спортчылар, 1930–60 елларда Бөтенроссия һәм Бөтенсоюз ярышларында катнашучылар һәм медаль алучылар — М.Мараканов, В.И.Маркелов, В.Кайсаров, В.Кладов, А.Х.Гыйльметдинов, Н.В.Покровская, З.К.Корбангалиева (слалом, тизлек б-н төшү), А.Сәләхетдинов (чаңгыда трамплиннан сикерү). 1975 тә чаңгыда трамплиннан сикерү буенча һәм Лениногорск шәһәрендә «Спартак» ирекле спорт җәмгыяте каршында чаңгыда ике төр ярыш буенча (1987 дән Олимпия резервындагы балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе) Балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе ачыла. 1994 тә ТР Чаңгыда трамплиннан сикерү һәм чаңгыда ике төр ярыш буенча федерация оештырыла (президент — Э.К.Вәлиев).

ТР (ТАССР) спортчылары, Профсоюзлар ирекле спорт җәмгыятенең бөтенсоюз совет ы, РФ (СССР, РСФСР) чемпионатлары һәм беренчелекләрендә, СССР, РСФСР халыклары, Дуслык армияләре СКлары спартакиадаларында, Россия, дөнья, Европа кубоклары этапларында, Бөтендөнья студентлар уеннарында, «Россиянең өметле олимпия уенчылары» беренчелекләрендә, Олимпия уеннарында катнашучылар һәм медаль алучылар — И.Г.Әхмәтшин, М.И.Гыйрфанов, А.В.Ларьков, А.А.Нечаевская, И.А.Панин, Д.В.Передин (тренерлары — А.Н.Зорин, Е.Ю.Кузьмина, В.А.Лобашов, Н.Г.Наговицин, Н.П.Овечкин, М.А.Перетягин, Л.Д.Савосин, А.Н.Федорук, Алексей Н. Чальцев, А.А.Щеклеин, Р.В.Щеклеина) (чаңгыда ике төр ярыш); А.А.Леонтьев, С.Н.Наговицин, Н.А.Петрушин, А.Б.Пушкарёв, Александр Н. Чальцев (тренерлары — А.М.Бор һәнов, С.А.Лысов) (чаңгыда трамплиннан сикерү). 2018 нең 1 гыйнварына ТРда 49 чаңгы базасы, 4 трамплин, Югары Ослан р-нында «Казан» тау чаңгысы комплексы, Кукмара р-нында һәм Әлмәт р-нының Поташ Аланы посёлогында тау чаңгысы базалары эшли. ТРның Зәй шәһәрендә 2013 тә «Ялта-Зәй» чаңгычы-узышчыларны спортка әзерләү үзәге (1984 тә төзелә) реконструкцияләнә, һәм 2015 тә «Федотово» чаңгы-биатлон үзәге файдалануга тапшырыла.

Әд.: Лыжные гонки. К., 2002.

ЧАПА́Н, татарларда ир-атларның традицион өс киеме, иркен сырган халат. Ч.ны, төрле тукымадан (бәрхет, парча, сатин һ.б.) мамык яки йон б-н сырып, ситсы эчлек куеп теккәннәр. Ука-Сура елгалары арасындагы терр-ядә яшәгән татарлар, Себер һәм Урта Азия халыклары арасында киң таралган була. Нигездә, аны руханилар һәм өлкәнрәк яшьтәге бай кешеләр мәчеткә барганда кигәннәр.

Әд.: Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967; Суслова С.В. Одежда // Татары. М., 2001.

ЧАПКЫ́Н БӘК Отыч улы (? — 1552), бәк, Казан ханлыгы дәүләт эшлеклесе. Башта Мәскәүгә юнәлеш тота. 1551 елда Казан аксөякләренең кайбер вәкилләре б-н бергә рус гаскәренең Казанга явында катнаша (к. *Казанга Рус дәүләтенең яулары (1545–51)*). 1552 нең мартында казанлылар тарафыннан рус наместнигы С.И.Микулинскийның шәһәргә керүе турындагы килешүгә бозылганнан соң, Мәскәүгә каршылар ягына күчә. Казан тәхетенә Әстерхан ханзадәсе Ядегәр Мөхәммәдне чакырган Вакытлы хөкүмәтне җитәкли; Казанны Иван IV гаскәрләреннән саклауны оештырган җитәкчеләрнең берсе (к. *Казанның яулап алынуы*).

Әд.: Худяков М.Г. Очерки по истории Казанского ханства. К., 1923; Алишев С.Х. Казань и Москва: межгосударственные отношения в XV–XVI вв. К., 1995.

И.Р.Вәлиуллин.

ЧАПКЫННА́Р (Cieindela), бызылдавыклар семьялыгыннан коңгызлар ыругы (Ч.ның Cicindelinae ассемьялыгын да билгелиләр). Гәүдәсенең озынлыгы 8–18 *мм*. Башка бызылдавыклардан зур күзле, киңәеп киткән башы (алгы сыртыннан тар түгел) б-н аерыла. Төсе өлешчә металлсыман, канат өсте еш кына сары яки ак әвернә рәвешендәге ачык бизәкле. Якынча 200 төре билгеле, нигездә, Төньяк ярымшарның арид районнарында таралганнар. Россиядә 100 төре бар; Идел буенда 100 ләп төре ачыкланган. Ерткычлар. Үлән капламлы ачык кояшлы урыннарда, якты нарат урманнарында, комлы участокларда һ.б. җирләрдә яшиләр. Көндез активлар. Олы коңгызлар тиз очалар һәм йөгерәләр (очар алдыннан бик тиз чабып килеп очып китәләр, исеме шуннан). Личинкалары өнәрдә яши, вак умырткасызлар, ш.и. куркыныч корткычлар б-н туеналар. Татарстан терр-ясендә тәгаен 4 төре ачыкланган, шуның 3 се ТРның Кызыл китабына кертелгән: урман чапкыны (C. silvatica), герман чапкыны (C. Germanica) һәм кыр чапкыны (C. Campestris).

Р.М.Зелеев.

ЧАПША́Р авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 7 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Норма елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 313 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — тирлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. Мәчет. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Нурма-Шапшар буларак та телгә алына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, балта эше, чүлмәк ясау, урман кисү, чабата үрү б-н шөгыльләнә. 1773–75 еллардагы Крәстияннәр кузгалышында Е.И.Пугачёв ягында сугышалар. 20 йөз башында мәчет, мәдрәсә, су тегермәне, 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1262,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Балтач волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1782 дә — 128 ир-ат; 1859 да — 543, 1897 дә — 651, 1908 дә — 674, 1920 дә — 640, 1926 да — 591, 1938 дә — 528, 1949 — 346, 1958 дә — 390, 1970 тә — 319, 1979 да — 198, 1989 да — 273, 2002 дә — 308 кеше.

Әд.: Балтач энциклопедиясе. К., 2010. 2 китап.

ЧАРДАКЛЫ́ КҮЛЕ́, Көнбатыш Кама алдында. Идел елгасының югары террасасында, Лаеш р-ны Травкино авылыннан 1,2 *км* көньяк-көнбатыштарак урнашкан. Су өслегенең мәйданы 4 *га*. Суының күләме якынча



Чардаклы күле.

50 мең $м^3$. Озынлыгы 245 *м*, иң зур киңлеге 220 *м*. Уртача тирәнлеге 1,2 *м*, иң зур тирәнлеге 2,5 *м*. Күл карст күренешләре нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Түгәрәк формада. Ярлары сөзәк, тәбәнәк, тал агачлары үсә. Яр буе зонасы үләннәр б-н каплана бара, урыны б-н сазлы. Ял итү урыны.

ЧАРДАКЛЫ́ РАЙОНЫ́, *Ульянов өлкәсенең* төньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан. 1928 елда оештырыла. Үзәге — шәһәр тибындагы Чардаклы посёлогы (Ульянов шәһәреннән 35 *км* көнчыгыштарак). Мәйданы — 2441 $км^2$. Халкы — 42110 кеше (2017). Татарлар саны: 2002 дә —9450, 2013 тә — 9654, 2010 да — 8603 кеше. Алар, тупланып, район үзәгендә, Абдулла, Янганай, Малаевка, Поповка, Иске Үрәнбаш, Татар Колмаеры, Уразгильдино авылларында яшиләр. Татарларның борынгы бабалары Ч.р. терр-ясенә Идел буе Болгар дәүләте чорыннан килеп урнаша. 17 йөзнең 2 нче яртысында бу җирләргә Темников, Сембер һәм Саранск өязләреннән йомышлы татарлар күчеп утыра. Бу чорда Абдулла, Әсән, Янганай, Поповка, Иске Үрәнбаш, Чардаклы авылларына нигез салына. 1917 гә кадәр Ч.р. терр-ясендә мәчетләр (Татар Колмаерында — 5, Поповка, Әсән, Абдуллада — 2 шәр, Иске Үрәнбашта — 1) була, алар каршында мәктәп һәм мәдрәсәләр эшли. 1924 тән Татар Колмаерында татар мәктәбе эшли. Ч.р.нда район татар милли-мәдәни автономиясе эшләп килә (1998 дән; рәисе З.С.Хәкимов). 2002 дән Чардаклыда *Сабан*

туе уздырыла. Абдулла, Янганай, Татар Колмаеры, Уразгильдино авыллары мәктәпләрендә татар теле фән буларак өйрәнелә. Чардаклыда (1 нче мәктәп) һәм Мирный посёлогында «Татар халкының мәдәнияте һәм гореф-гадәтләре» түгәрәкләре эшли. Чардаклының 2 нче урта мәктәбе каршындагы «Туган тел» түгәрәгендә, Татар Колмаерындагы «Сандугачкай» фольклор түгәрәгендә татар мәдәнияте өйрәнелә. Татар фольклоры, татар язучылары һәм шагыйрьләре иҗаты «Әдәби төбәкчелек белеме» һәм «Тарихи төбәкчелек белеме» фәннәре кысаларында гомуми белем бирү мәктәпләренең 6–9 сыйныфларында өйрәнелә. Чардаклыда (2) һәм Абдулла, Янганай, Поповка, Иске Үрәнбаш, Татар Колмаеры, Уразгильдино авылларында мәчетләр эшли. Актёр Г.Р.*Шамуковның* (Татар Колмаеры мәктәбендә мемориаль такта куелган), Дан орденының тулы кавалеры Д.К.*Кыямов* (Поповка авылында бюсты куелган), дин һәм җәмәгать эшлеклесе З.Х.*Кадыйри*, галим-филолог З.Н.Аюханов, физика-матем. фән. д-ры Г.Х.Кадыйров, биол. фән. д-ры А.К.Сәгыйтов, шагыйрьләр С.К.*Урайский*, Д.*Фәтхи*, Х.С.*Сөнгатзадә* һәм Х.Шаммасова, Ульянов өлкәсенең мактаулы гражданнары Р.Ф.Әхмәдуллов һәм Д.И.Шәриповның (Татар Колмаеры мәктәбе аның исемен йөртә) тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге Ч.р. б-н бәйле. Татар Колмаеры авылы зиратында 1349–57 еллардан калган болгар кабер ташлары сакланган.

ЧАРЛЫ́ авылы, Кукмара р-нында, Кукмара шәһәреннән 29 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Консар елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 273 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1795 еллар тирәсендә нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Новопоселённая Тулба исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлек асрау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Никола чиркәве (1901–02 дә төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1877 дә ачыла), ярма яргыч, тимерче алачыгы, 4 вак-төяклөр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 887,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Лыябаш-Келәүш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августын нан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Кукмара, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1859 да — 442, 1897 дә — 806, 1908 дә — 853, 1920 дә — 667, 1926 да — 703, 1949 да — 583, 1958 дә — 448, 1970 тә — 280, 1979 да — 267, 1989 да — 295, 2002 дә — 339 кеше.

ЧАРО́НОВ Владилен Яковлевич (29.3.1938, Волгоград өлкәсенең Рудня р-ны Рудня станциясе), электроэнергетик, техник фән. д-ры (2000), проф.(2001), РСФСРның атказ. энергетигы (1989). 1970 елда Куйбышев политехник ун-тын тәмамлый. 1956–2000 елларда «Татнефть» АҖдә эшли (Әлмәт ш.). 2000 дән Әлмәт нефть ин-тында электр энергетикасы каф. мөдире. Хезмәтләре нефть һәм газ табуда кулланылган электротехник җиһазларны камилләштерүгә карый. Нефть табу объектларында энергия саклау системаларын эшли. Уйлап табуга 40 авторлык таныклыгы һәм патенты бар. СССР Нефть сәнәгате министрлыгы бүләгә лауреаты (1991). Медальләр, ТРның Мактау грамотасы белән бүләкләнә. РФнең мактаулы нефтьчесе (2001).

Хезм.: Электрические комплексы с синхронным двигателем и тиристорным возбуждением. СПб., 1995 (автордаш); Автоматизация работы основного оборудования и проблемы энергосбережения на объектах нефтедобычи. Альметьевск, 1998; Средства автоматизации технологических установок нефтегазодобывающих предприятий. Чебоксары, 2002.

ЧАРША́У, пәрдә; традицион татар йортына хас предмет. Гадәттә, йортның эчен аш ягына һәм кунак ягына (ак һәм кара якка) бүлү өчен хезмәт иткән. Килен бирнәсенең мәжбүри өлеше булып исәпләнгән. Иң киң таралган Ч. чуар тукымадан (кызыл-зәңгәр шакмаклы җирлеккә тар гына ак сызыклар төшкән) тегелгән, ш.у. чүпләмле бизәкләр төшерелгән Ч.лар да очрый. Ч.лар төсләренең, композицияләренең күптөрлелеге, бизәк мотивлары



Крәстиян йортында чаршау.

һәм үлчәмнәре б-н аерылган. 20 йөзнең 2 нче яртысында көнкүрештә киң кулланылыштан чыгалар. Ш.у.к. *Чыбылдык*.

Әд.: Сафина Ф.Ш. Ткачество татар Поволжья и Урала (конец XIX — начало XX вв.): Ист.-этногр. атлас татар. народа. К., 1996; Шулу к. Ткачество // Татары. М., 2001.

ЧАТ авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 30 *км* көнбатыштарак, Шәбез елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 154 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 17 йөздә нигез салына. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ч.та мәчет (1829 дан билгеле), 2 җил тегермәне, ашлык саклау-сату һәм 3 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3677,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Семиостров (Өшәр) волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 234, 1834 тә — 448, 1859 да — 743, 1870 тә — 784, 1884 тә — 785, 1897 дә — 822, 1906 да — 1050, 1913 тә — 972, 1920 дә — 868, 1926 да — 718, 1938 дә — 575, 1949 да — 373, 1958 дә — 336, 1970 тә — 406, 1979 да — 313, 1989 да — 162, 2002 дә — 157 кеше.

ЧАТ КҮЛЕ́, Көнбатыш Кама алдында. Лаеш р-ны Столбище авылыннан 1 *км* көньяк-көнбатыштарак урнашкан. Су өслегенең мәйданы 1,8 *га*. Суының күләме 12,6 мең $м^3$. Озынлыгы 750 *м*, иң зур киңлеге 60 *м*. Уртача тирәнлеге 0,7 *м*, иң зур тирәнлеге 2,5 *м*. Озынча формада. Ярлары сөзәк, тал агачлары үсә. Яр буе зонасында йөзмә «үлән-утрау» бар.



Чат күле.

Сулык үсемлекләр б-н каплана һәм ерым, сызалардан агып төшкән комлы-балчыклы китерелмәләр нәтиҗәсендә сазлана бара. Ч.к. «*Күл акчарлаклары колониясе*» табигать истәлеге составына керә.

«ЧАТКЫ́», әдәби-сәяси, юмористик рәсемле журнал. 1923 елның апреленнән 1924 нең 2 нче яртысына кадәр Царицын шәһәрендә (хәзерге Волгоград) татар телендә нәшер ителә. Нашире — РКП(б) губерна ком-тының Татар-кыргыз бюросы, мөхәррире — И.Ильясов. Журнал большевизм һәм буржуаз, милли, дини хорафатлардан азат булган яңа җәмгыять төзү идеяләрен пропагандалый, эшче һәм крәстияннәрне искелек калдыкларына каршы көрәшергә чакыра. Наданлыкка каршы көрәшкә зур игътибар бирә. Мәкаләләр янына сатирик рәсемнәр һәм карикатуралар урнаштырыла. Аерым фельетон һәм хикәяләрнең атамалары рус теленә тәр җәмәдә дә бирелә. *З.З.Гыйләҗев.*



«Чаткы» журналы.

ЧАТЫ́Р ТА́У, комплекслы табигать саклаулыгы. Азнакай р-ны терр-ясендә. Сәпәй, Ура - зай һәм Ишкәй торак пунктлары янындагы Вәрәжде һәм Эстәрле елгалары үзәннәренең сулъяк яр сөзәкләкләрендәге, ш.у. Чәкән авылы янындагы Ык елгасының уңъяк ярында - гы 5 участоктан тора. 1999 елда оештырыла. Мәйданы 4149,5 *га*. Чатыр тау һәм Чәкән ай - магын үз эченә ала. Ч.т. (1972 елдан ТРның табигать истәлеге; мәйданы 130 *га*) — ТР-ның иң биек ноктaларыннан берсе (321,7 *м*). Калкулык сөзәкләкләрендә имән, кабар агачы, чикләвек куагы, өрәңге һәм миләш катыш куаклыклардан торучы яфраклы кече урманнар сакланган. Текә сөзәкләкләрне куаклар үскән кыяк-кылганлы һәм төрле үлән - ле-солычалы далалар били. Биредә ТРда иң зурлардан саналган сөркә-байбак колониясе урнашкан, сукыр әрләи, Эверсман әрләне,



Чатыр Тау.

соры әрләи, дала чуары (соңгы 3 төр ТРның Кызыл китабына кертелгән) ареалының төньяк чиге уза. Чәкән аймагы (мәйданы 2073 *га*) төрле яшьтәге имән һәм наратлыклардан, карама, өрәңге һәм тәбәнәк миндаль, дала чиясе, буяу куагы, шомырт, чикләвек куагы, кошкунмас агач, гөлҗимеш, тубылгы куакларыннан торучы агачлыклардан тора. Саклаулык терр-ясендә үсемлекләрнең саклаулы төрләреннән садә оносма, әре чәчәкле тәңкәяфрак, шома сабаклы (голоножковый) сыргаташ, известь мәкәсе, йомыркасыман мәче борчагы, Лессинг кылганы, матур һәм каурый кылганнар, Исет ялмачасы, болын канәфере, дарулы шома көпшә, чөйсыман яфраклы аю табаны, җәрәфи үлән, гади дөгәнәк, биек ярмабаш печән үсә. Бөҗәкләр — спорадикус һәм йонеллюс төклетурасы, балтачы бал корты, ураксы кырмыска, адмирал һәм зәңгәр тасма күбәләкләр; кошлардан үләт бөркете, дала торымтае, лачын, сары корташар төрләре ТРның Кызыл китабына кертелгән. Саклаулык табигатьне саклау, фәнни-танып белү әһәмиятенә ия.

Ф.Г.Борһанов.

ЧАТЫ́Р ЧӘЧӘКЛЕЛӘ́Р, зонтчәчәклеләр (Umbelliferae), ике өлешле үсемлекләр семьялыгы. Күбесе бер-, ике- һәм күпьеллык үләннәр, сирәк кенә куаклар яки зур булмаган агачлар. 300 ыруткa караучы 3 меңнән артык төре билгеле. Башлыча, Төньяк ярымшарның уртача поясында таралган - нар. ТР терр-ясендә 37 ыруттан 44 төре билгеле. Бер-, ике- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр. *Кыр кишере*, *мәкә*, *кишер үләне*, *шома - лак*, *кишер*, *сельдерей* киң таралганнар.

Сабагы туры, еш кына буын аралары куыш. Яфраклары гади, чиратлашкан, нык теленмә. Төпчек яфраклары юк. Чәчәкләре вак, ике җенесле, катлаулы чатыр чәчәк төркемендә. Җимеше — иенке җимешлек, өлгергәндә ике өлешкә бүленә. Ч.ч.нең җимешлек тышчаларында, кайвакыт үрчү органнарында эфир майлы кечкенә каналлар бар. Ч.ч. семьялыгында, нигездә, азык, тәмләткеч һәм эфир майлы культуралы үсемлекләр (кишер, *пастернак*, сельдерей, *петрушка*, *кориандр*, *әнис*) шактый, кайбер төрләре дәвалау үзлегенә ия (*балтырган*, мәкә, *курай үләне*, *шома көпшә*, *кисәр үлән* һ.б.), азык культуралары бар (*ким үләне*, әнис, мәкә, *сәрдә*, балтырган һ.б.). Мәкә, әнис — баллы үсемлекләр. *Кискеч үлән*, *елан көпшәсе*, пастернак — чүп үләннәр; балтырган, им үләне, *чәнчү үләне* — декоратив; *түндербаш*, *су балтырганы* — көчле агулы үсемлекләр. 5 төре ТРның Кызыл китабына кертелгән.

«ЧАТЫРТА́У», карабодай сорты. Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында 2002 елда Ф.З.Кадыйрова, Л.Р.Кадыйрова, И.Ю.Никифорова, Н.А.Бойцова тарафыннан чыгарыла. Уртача иртә өлгерешле сорт, вегетация чоры 66–67 көн. Бер вакытта өлгерүе һәм корылыкка чыдамлыгы белән аерыла. Үсемлек уртача биеклектә, тармакланган үрентеле, юан һәм нык сабаклы. Орлыгы әре, түгәрәк формада, соры-коңгырт төстә; 1000 данәнең авырлыгы 33–35 *г*. 2005 тә Урта Идел төбәгендә чәчәргә рөксәт ителгән Дәүләт сортлар реестрына кертелгән.

Әд.: Каталог научно-технической продукции. К., 2005.

«ЧАЯ́Н», сатира һәм юмор журналы. 1923 елның апреленнән Казанда татар телендә, 1956 дан рус телендә дә нәшер ителә. 1941–50 дә чыкмый, 1951 нең декабрендә яңадан басыла башлый. Оештыручысы һәм беренче мөхәррире — Ф.*Бурнаш*, соңрак мөхәррирләре — Г.Толымбайский, Г.Нигъмәти, С.Борһан, Г.Кушаев, И.Еникиев, З.Галиев, Г.Ризванов, Ш.Рәмзи, А.Дәүләтъяров, И.Үзбәков, Х.Габдрахманов, Г.Рябков, С.Ибра һимов, С.Бәхтияров, Ә.Исхак, А.Яхин, Р.Зәкиев, Р.Хәлиуллов (2011 дән). Беренче



«Чаян» журналы. 1923.

авторлары арасында — М.Җәлил, Г.Кутуй, К.Нәҗми, Һ.Такташ. Беренче саннары аклы-каралы була, аларда күпчелек өлешне текстлар алып тора. Татарстан рәссам-карикатурачыларыннан журнал б-н беренчеләрдән булып Г.Арсланов хезмәттәшлек итә. Алга таба журналның сәнгати бизәлешен Н.Христенко, Г.Поляков, Д.Красильников,



«Чаян» журналы. 2010.

Г.Йосыпов, И.Әмир рәсемнәре билгели. Юмореска һәм карикатураларның персонажлары — байлар, муллалар, кулаклар һәм кулак иярченнәре. Журнал нәпманнарның комсызлыгыннан, руханиларның консерватизмыннан, буржуаз интеллигенциянең декадентлыгыннан көлә. 1950 елларда сатириклар халыкара мөнәсәбәтләр, сәяси һәм а.х. тематкасына мөрәҗәгать итә. Рәсемнәр плакат характерын ала. Даими авторлары арасында — Г.Афзал, С.Баттал, Ә.Еники, З.Мансур, Г.Минский, Г.Мөхәммәтшин. Журналның рус телендәге басмасын оештыруга С.Офенгенден зур өлеш кертә; редакция Г.Вәлиев, В.Луценко, В.Монасыйпов, А.Мелузников, Г.Паушкин, В.Седых, Р.Смирнов кебек авторларны, Х.Якупов, Л.Фәттахов кебек танылган рәссамнарны җәлеп итә. 1960–70 елларда журналның тематикасы киңәя: «Ч.» журналистлары әрәмтамаклыктан, исраф итүчәнлектән, бюрократизмнан көләләр. Журнал б-н күренекле шагыйрьләр, прозаиклар, журналистлар, фельетончылар З.Хөсәенов, И.Хантимеров, Л.Елькович, Ю.Денисов, Л.Бочкова кебек рәссамнар хезмәттәшлек итә, Г.Огородников, Л.Насыйров, С.Насыйрова соңрак «крокодилчылар» булып китә. Юмореска һәм сатирик язмалар авторлары арасында — Ф.Шәфигуллин, Зөлфәт, Б.Бронштейн. 1970–80 елларда сәнгать бүленген Т.Фәизов, И.Ханов җитәкли. «Ч.»ның рәссамнар мәктәбен Б.Старчиков, П.Новичков, Э.Гельмс, В.Игнатьев, И.Бобровицкий, В.Космылин, Э.Дышаев, И.Әхмәдиев оештыра; басманың үсешенә Р.Абзалов, А.Алёшин, А.Шульпинов, С.Привина, В.Феоктистов, С.Фәттахова, И.Әҗимев, С.Андрианов, Е.Хитрова, А.Мамаев, бертуган Зөфәр һәм Заһир Хәкимовлар, И.Нәфиев, Ф.Вахитов,

Ф.Галиев, Р.Гатауллин, М.Насыйбуллин, А.Үтәгәнов өлеш кертә. 1970 елларда «Ч.» рәссамнары сатирик графика күргәзмәләрен оештыралар, ш.и. Мәскәүдә дә. 1990–2000 елларда журналда карикатуралар, сатирик миниатюралар, актуаль фельетоннар өстен лек ала. 1998 дә «Ч.» формат б-н дизайнын үзгәртә. ТР Мәдәният министрлыгы һәм «Татмедиа» агентлыгы б-н берлектә «Ч.» редакциясе Г.Тукайга һәм толерантлык темасына багышланган ике халыкара конкурс уздыра. Журнал бөтен Россиядә, якын һәм ерак чит илләрдә, ш.и. Болгария, Германия, Израиль,Төркиядә һ.б. тарала; СССР Рәссамнар берлеге (1971), СССР САнең (1977) Почёт дипломнары б-н бүләкләнә. Журналның даими авторлары С.Я.Насыйрова (кызыксындыру бүләге, 1977), В.Бибишев (Гран-при, 2005) Габрово шәһәрендә (Болгария) узган Халыкара карикатуралар күргәзмәсе лауре атлары була.

Әд.: Е л ь к о в и ч Л.Я. На линии огня. К., 1977.

Р.А.Айнетдинов.

ЧАЯНЧЫ́ ЧЕБЕННӘ́Р (Mecoptera), бөҗәкләр отряды. Пермь чорыннан ук билгеле. Гәүдәсенең озынлыгы 30 *мм* га кадәр. Башының алгы алгы өлеше томшыксыман сузылган, очында кимерүче типтагы авыз аппараты урнашкан. Канатлары челтәрсыман, кара таплы, кайбер төрләрендә канатлары юк ка чыккан. Корсагының арткы өлеше чаяннардагы кебек күтәрелеп һәм ата затларда бүлбесыман юанаеп тора (исеме шуннан). Үсеше — тулы әверелешле. Личинкалары гусеницага охшаш, рудиментар 8 пар корсак , әмма хәрәкәтләнүче аяклары бар. Дөнья фаунасында 300 дән артык төре билгеле. Россиядә чын Ч.ч. (Panorpidae), бозлачлар (Boreidae) һәм биттаклар (Bittacidae) семьялыгыннан 10 га якын төре бар. Татарстан терр-ясендә 2 төре — беренче ике семьялык вәкилләре очрый. Аеруча гади Ч.ч. (Panorpa communis) таралган. Үләксәләр һәм чәчәк нектары б-н туена. Парлашу вакытында ата бөҗәк ана затны авыз бүлендекләре б-н сыйлый. Личинкалары туфракта җитлегә; ерткычлар. Кышкы бозлач (Boreus westwoodi) күбрәк мүктә яши. Үсемлек кисәкчекләре, төре һәм үлгән буынтыгаяклылар б-н туена. Канатлары юк, арткы аяклары сикерә торган. Бөҗәкләр кышкы һәм җепшек чорда да актив тереклек эшчәнлеге алып баралар.

Н.В.Шулаев.

ЧӘБЕРЧЕКЛӘ́Р, (Anthus), чәберчек кошлар семьялыгыннан кошлар ыругы. 35 төре билгеле, Евразиядә һәм Төньяк-көнбатыш Африкада таралганнар. ТР терр-ясендә 4 төре бар. Сабан тургае (A. pratensis) — күпсанлы гадәти төр, очып күченү вакытында кырларда, болыннарда очрый, оялау чорында ара-тирә Идел алдында түмгәкле дымлы болыннарда күренә. Урман тургае (A. trivialis) төрле типтагы урманнарда, күбесенчә урман буйларында, аланнарда, киселделәрдә яши. Кызыл түшле тургай (A. cervina) язын һәм көзен очып күченү вакытында очрый.

Гәүдәсенең озынлыгы 14–18 *см*, авырлыгы 17–25 *г*. Томшыгы очлы. Аяклары нәзек, җирдә йөгереп йөрүгә җайлашкан. Аркасында каурый капламы кара буй-буй таплы коңгырт-соры, корсак ягы кара тимгелле аксыл төстә. Койрыгы түгәрәкләнгән яки аз гына уемтылы. Арткы бармагы озын тырнаклы. Ояларын яшереп җирдә коралар. Апрельдә тимгелле 4–5 зәйтүнсыман-көрән йомыркалар салалар, беренче оя балалары 9–14 тәүлектән соң чыга. Июнь–июльдә икенче оя балалары чыга. Бөҗәкләр, моллюсклар, суалчаннар, кайвакыт бөҗәкләр б-н тукланалар. Кышлау урынына сентябрьдә очып китәләр.

ЧӘБИ́Я-ЧУРЧИ́ авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 21 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Мишә елгасы буенда. 2010 елда 79 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, умартачылык. Башлангыч мәктәп, клуб. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Чәбия, Чилючи, Чирич исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында земство һәм чиркәү-приход (1890 да ачыла) мәктәпләре, су тегермәне, вак-төяклэр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 943,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Әбде волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 42 ир-ат; 1859 да — 201, 1897 дә — 426, 1908 дә — 431, 1920 дә — 400, 1926 да — 401, 1938 дә — 346, 1949 да — 304, 1958 дә — 246, 1970 тә — 180, 1979 да — 192, 1989 да — 81, 2002 дә — 92 кеше.

ЧӘБКИ́-САБА́ (Чәүкә) авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 11 *км* көньяктарак, Казкаш елгасы буенда. 2010 елда 52 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Чәүкә, Чәбия исемнәре б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет (1888 дә төзелә; архит-ра истәлеге), мәктәп, 4 вак-төяклэр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 828,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Сатыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 48 ир-ат; 1859 да — 179, 1897 дә — 325, 1908 дә — 372, 1920 дә — 356, 1926 да — 345, 1938 дә — 302, 1949 да — 186, 1970 тә — 126, 1979 да — 97, 1989 да — 65, 2002 дә — 52 кеше.

ЧӘКӘ́Н авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 45 *км* көнчыгыштарак, Ык елгасы буенда. 2010 елда 365 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 48 %, татарлар — 41 %) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. Урта мәктәп, клуб, китапханә. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганаклларында Чекан-Перевоз, Воскресенский, Линовка исемнәре б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, тәгәрмәч һәм чүлмәк ясау, таш вату б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша; Воскресение чиркәве, земство мәктәбе, хастаханәсе һәм почта станциясе була; якшәмбе базары, 26 ноябрь — 3 декабрьдә ярминкә эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 7025 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Чәкән волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тымытык, 1931 нең 20 октябреннән — Азнакай, 1935 нең 10 февраленнән — Ютазы, 1963 нең 1 февраленнән — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1859 да — 1126, 1889 да — 1652, 1897 дә — 1998, 1910 да — 2037, 1920 дә — 2537, 1926 да — 2247, 1938 дә — 1451, 1949 да — 833, 1958 дә — 570, 1970 тә — 478, 1979 да — 385, 1989 да — 312, 2002 дә — 403 кеше.

ЧӘКЧӘ́К, татар халкының, төче камырдан озынча яки түгәрәк формада вак кына итеп кисеп, кайнап торган майда пешерелгән төш ләрдән, кайнатылган бал б-н беркетеп, билгеле бер рәвешкә китереп өелгән милли бәйрәм



Чәкчәк.

ризыгы. Ч. мәҗбүри туй сые булып тора: аны ире йортына килен (яшь килен чәкчәге), ш.у. киленнең анасы (кодагый чәкчәге) алып килә. Туй Ч.ге зур итеп ясала һәм төрле төстәге түгәрәк вак конфетлар, как б-н бизәлә. Бохара кәләвәсе һәм казакъ халкының шек-шек дигән ризыгы да Ч.кә охшаш, алар өчен камыр кайчак токмач рәвешендә киселә. Ч. — татар халкының кунакчыллыгын күрсәтә торган сый.

Әд.: Пища // Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967; Татарская кухня. К., 1985; М у х а м е д о в а Р.Г. Пища и домашняя утварь // Татары. М., 2001.

ЧӘЛӘБИ́ Мөхәммәд (чын исеме Язычы оглы Мөхәммәд Бижан) (? — 1451), госманлы төрек шагыйре. Төрек язучысы *Әхмәд Бижанның* абыйсы. Гомеренең бер өлеше Төркиянең Галиболу шәһәрендә үтә. Якын һәм Урта Көнчыгыш илләре буйлап сәяхәт кыла, бәйрәмия суфичылык борадәрлеге эшен дәвам итүче. Мөхәммәд пәйгамбәрнең тормышы һәм дини эшчәнлеге турында дини-дидактик «Мөхәммәдия» поэмасы авторы. 18 йөздән поэма татар халкы арасында

кулъязма нөсхәләрдә, басылган китаплар рәвешендә киң таралыш ала, мәктәп-мәдрәсәләрдә уку-укыту әсбабы буларак файдаланыла.

Әд.: Миңнегулов Х. Татар-төрек әдәби багланышлары // Татарстан. 1993. № 9; Әхмәтҗанов М.И. Урта гасыр төрек әдәбиятының татар халкында сакланган истәлекләре // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2004. № 1.

ЧӘЛӘБЙ Сөләйман (1351 — 1421), госманлы төрек шагыйре. Халватийа суфичылык борадәрлеге эшен дәвам иттерүче. Идел буе төбәкләрендә киң таралыш алган дини-дидактик «Мәүлид ән-нәби» («Пәйгамбәр туган көн», 1409) поэмасы авторы. 18 йөздән поэма мәктәп-мәдрәсәләрдә уку-укыту әсбабы буларак файдаланыла, *мәүлид кичәсен* бәйрәм иткәндә кычкырып укыла. Поэма буенча 2006 елда комп. М.Шәмсетдинова хор, солистлар, нәфис сүз осталары һәм инструменталь ансамбль өчен «Мөхәммәд пәйгамбәрнең тууы» суфичылык ораториясен яза.

Әд.: Трименгэм Дж. С. Суфийские ордены в исламе. М., 1989.

ЧӘМӘК авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 32 *км* төньяк-көнбатыштарак, Сая елгасы буенда. 2010 елда 28 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. 1646 дан рус чыганакларында — Пустошь Островок Кебековский на ключе на Каменном, рев-циягә кадәрге чыганакларда Починок по Кубеку горе, Починок Шемякин, деревня по Айбашинской дороге и Кубяк горе, Атняш Ключ, Каменный Ключ, Ташкичу (1940 ка кадәрге рәсми исеме) буларак билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, татар милли аяк киеме тегү, олаучылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, 2 вак-тояклар кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 775,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Салкын Чишмә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 69 ир-ат; 1859 да — 335, 1897 дә — 422, 1906 да — 454, 1920 дә — 587, 1926 да — 564, 1938 дә — 501, 1949 да — 411, 1958 дә — 300, 1970 тә — 247, 1989 да — 74, 2002 дә — 38 кеше.

ЧӘНЧҮ УТЫ́, күкбаш (Eryngium), чатыр чәчәклеләр семьялыгыннан ике яки берьеллык үләнчел үсемлекләр семьялыгы. Якынча 250 төре билгеле, ике ярымшарның да тропик, субтропик һәм уртача поясларында таралганнар. Татарстан террр-ясендә бер төре бар — җәенке яфраклы Ч.у. (Eryngium), Идел алдында һәм Кама аръягында очрый. Далаланган болыннарда, аланнарда, юл буйларында үсә. 20–60 *см* биеклектәге зәңгәрсу төстәге күпьеллык үсемлек. Үзәк тамырлы. Сабагы шома, өске өлеше тармаклы. Яфраклары куе яшел, калын, аскылары — сабакчыл бармаксыман-теленмә. Чәчәкләре вак, күксел яки зәңгәр төстә, башча чәчәк төркеменә җыйналган. Җимеше — иенке җимешлек. Июль–августта чәчәк ата. Җимешләре август–сентябрьдә өлгерә. Нигездә, орлыклардан үрчи. Җир өсте өлешләрендә сапонин, танин, флавоноидлар, эфир мае бар. Халык медицинасында үләне төнәтмәсе какырык куптару, тынычландыру, бәвел кудыру чарасы буларак кулланыла. Декоратив үсемлек.

ЧӘТБА́Ш авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 29 *км* көнбатыштарак, Бола елгасы буенда. 2010 елда 45 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Клуб. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Уразлы-Чәтбаш исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәдрәсә, вак-тояклар кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 850,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Урта Балтай волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 54 ир-ат; 1859 да — 330, 1897 дә — 495, 1908 дә — 690, 1920 дә — 737, 1926 да — 550, 1938 дә — 492, 1949 да — 348, 1958 дә — 290, 1970 тә — 252, 1979 да — 159, 1989 да — 101, 2002 дә — 71 кеше.

ЧӘТИ́ посёлогы, Кукмара р-нында, Кукмара шәһәреннән 37 *км* төньяк-көнбатыштарак, Киров өлкәсе б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 26 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1678 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Вершина Китяк исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1880 елларда авыл җәмәгатенең имана җире 186 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Сизнер волостенда, 1920 дән ТАССРның — Арча, 1928 дән Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1887 дә — 82, 1920 дә — 140, 1926 да — 141, 1938 дә — 108, 1949 да — 90, 1958 дә — 79, 1970 тә — 84, 1979 да — 64, 1989 да — 37, 2002 дә — 31 кеше.

ЧӘҮКӘ (Corvus monedula), карга кошлар семьялыгындагы кош. Европада, Төньяк-көнбатыш Африкада, Азиядә (көньякка таба Һиндистан, Малайга кадәр һәм көнчыгышка таба Урта Себергә кадәр) таралган. Көнчыгыш Европа тигезлегендә ареалының төньяк чиге Архангельск шәһәре киңлекләренә кадәр җитә. Татарстан терр-ясендә Ч. иң күп таралган кошларның берсе, урман буйларында яши, еш кына торак пунктларда, тугайлы агачлыкларда оялый. Гәүдәсенең озынлыгы 22–23 (кайвакыт 30 га кадәр) *см*, авырлыгы 150–200 *г*. Каурый капламы йомшак, аркасы металлсыман ялтыравыклы кара, корсагы — соргылт-кара, муенында ярыммуенчак рәвешендәге аксыл буй бар. Агач куышларында, кыя ярыкларында, йорт түбәләре астында парлашып һәм колония булып оя кора. Елга бер тапкыр (апрель–майда) кара тимгелле 3–6 зәңгәрсу-яшел йомырка сала. 16 көн утыра. Оя корганнан соң, төркем булып яшиләр һәм күчмә тормыш алып баралар. Үсемлекләр һәм бөҗәкләр б-н туклана. Балаларын ашаткан чорда зарарлы бөҗәкләрне аеруча күпләп юк итә.

ЧӘЧӘКЛЕ́ авылы, Спас р-нында, Болгар шәһәреннән 70 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Ульянов өлкәсе б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 445 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1710 елларда Бәрән авылыннан (хәзер Иске Рәҗәп а.) күченүчеләр нигез сала; 1992 гә кадәр — Яңа Бәрән авылы. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Чичиклы исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, он тарту, арба, тәгәрмәч, көрәк ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 мәчет (1884 һәм1902 дә төзелә), 2 мәдрәсә, 6 җил тегермәне, 3 вак-тояклар кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1786 дис. тәшкил итә. 1912 дә рус-татар уч-щесе ачыла. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Кузнечиха волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1935 нең 10 февраленнән — Кузнечиха, 1960 ның 28 октябреннән — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1991 нең 4 октябреннән Спас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 113 ир-ат; 1859 да — 692, 1897 дә — 1343, 1908 дә — 2162, 1920 дә — 1835, 1926 да — 1244, 1938 дә — 1182, 1949 да — 954, 1958 дә — 825, 1970 тә — 895, 1979 да — 760, 1989 да — 584, 2002 дә — 486 кеше.

ЧӘЧӘКЧЕЛЕ́К, үсемлекчелек тармагы, ул чәчәк бәйләме ясау, оранжерея һәм ачык грунтта яшеллек булдыру өчен, ш.у. торак йортлар һәм җитештерү биналарын бизәү өчен декоратив максатларда үсемлекләр һәм матур чәчәк атучы үсемлекләр үстерү һәм аларның селекциясе б-н шөгыльләнә.Үсемлекләрнең составы һәм билгеләнеше буенча ачык һәм ябык грунт Ч.ге төрләренә аерыла. Ачык грунтта җирле шартларга яраклашкан күпьеллык һәм берьеллык чәчәк культуралары үстерелә. Ябык грунтта җылы яратучылар, бүлмә гөлләре үстерелә, сирень һәм лаләләрнең кышкы чорда үсешен тизләтү уздырыла. 18 йөз башында Россиядә чәчәкләкләр б-н архит-ра бакчалары һәм парклар булдырыла башлый. Эре һәвәскәр Ч. Россиядә нигездә алпавыт һәм шәһәр утарларында туплана. Сәнәгый Ч., чәчәк һәм аларның орлыкларын сату б-н Россиядә башлыча чит ил фирмалары шөгыльләнә. Совет хакимияте елларында Ч. шактый уңышка ирешә, моңа шәһәрләрне, сәнәгать үзәкләрен, эшчеләр посёлокларын, авыл торак пунктларын реконструкцияләү һәм төзекләндерү ярдәм итә. Заводлар каршында «яшел цехлар» булдырыла,



Чәчәкчелек. «Майский» теплица комбинаты. Яшел Үзән районы.

аларда завод терр-ясен яшелләндерү өчен чәчәкләр һәм декоратив үсемлекләр үстерелә. Казанда 1934 елда бакча, парк, скверларны һәм яңа яшел объектларны карап тоту буенча бүлек оештырыла — хәзер Казан шәһәр муниципаль унитар пр-тиесе «Горводзеленхоз» тресты; ул шәһәрнең 99 парк, бакча һәм скверларын (гомуми мәйданы 261 *га*) карап тора. Чаллы шәһәрендә 250 чәчәклек санала: мәйданы 70 мең $м^2$, якынча 100 төр чәчәк үстерелә. Респ-каның барлык шәһәр һәм торак пунктларында терр-яне төзекләндерү һәм яшелләндерү б-н шөгыльләнүче махсус учреждение бар. ТРда сәнәгый Ч. «Майский», «Резонанс» теплица комб-тларында, «Казан» с-зында алып барыла, алар шәһәр һәм район үзәкләрен яшелләндерү өчен чәчәк үсемлекләренең утырту материаллары, ш.у. халыкка сату өчен чәчәк бәйләмнәре б-н төп тәэмин итүчеләр. 2002 дә «Резонанс» комб-ты 1,2 *га* мәйданда яңа Европа технологияләре буенча розалар үстерә башлый, 2010 да 800 мең роза сатыла. ТРның барлык терр-ясендә чәчәкләр үстерү б-н һәвәскәр чәчәкчеләр шөгыльләнә.

Әд.: Киселёв Г.Е. Цветоводство. М., 1964; Выращивайте цветы. К., 1978; Юскевич Н.Н., Лунц Л.Б. Озеленение городов России. М., 1986.

Р.Ә.Әсретдинова.

ЧӘЧБА́Й, тутык үләне (Calamagrostis), кыяклылар семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 150 дән артык төре билгеле, ике ярымшарның да салкын һәм уртача поясларында очрыйлар. ТР терр-ясендә 5 төре бар: урман Ч. (C. Arundinacea), гади Ч. (C.epigeios), соргылт Ч. (C. canescens) бөтен районнарда да таралганнар. Сирәкләнгән урманнарда, елга тугайларында, сазлык кырыйларында үсәләр. Билгесез Ч. (C. neglecta), Лангсдорф Ч. (C. langsdorffa) сазлыкларда очрый. 35–150 *см* биеклектәге үсемлек. Шуышма тамырчалы. Сабагы туры, нык, кытыршы. Яфрагы кыяк, каты. Башаклары бер генә чәчәкле. Себеркәч чәчәк төркемендә. Җимеше — бөртекчә. Июнь–июльдә чәчәк аталар. Орлыктан һәм куакчыкларны бүлеп үрчетәләр. Барлык төрләре дә — тупас терлек азыгы үсемлекләре. Киптерелгән букетлар (гөлләмәләр) ясауда кулланыла. Билгесез Ч. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

ЧӘЧБАШЛА́Р (Trichocephalidae), нематодалар классыннан суалчаннар семьялыгы. Кеше һәм күп кенә вак имезүчеләрнең паразитлары. 62 төре билгеле. Бөтен җирдә таралганнар, Татарстанда кайбер урыннарда гына очрыйлар. Кешедә Trichocephalus trichiuris паразитлык итә. Ана затның озынлыгы 35–50, ата затның — 30–40 *мм*. Гәүдәсенең алгы очы җепсыман диярлек, бу паразитка организмга керүне җиңеләйтә. Юан эчәкнең тышчасына кереп, Ч. кан б-н туеналар. Фекалияләр б-н чыккан мичкәсыман күкәйләрдән тышкы тирәлектә личинкалар җитлегә. Азык яки су б-н йотканнан соң, күкәйләр хуҗа эчәклегендә ачылалар, личинкалары чыга һәм бер кая күчмичә бер ай эчендә җенси җитлегәләр. Кеше организмында Ч. берничә ел яшәргә мөмкин. Трихоцефалёз авыруын китереп чыгаралар.

О.Д.Любарская.

ЧӘЧЕЛМӘЛӘ́Р, чәчелмә чыганаклар, составында чәчелмә барлыкка китерүче теге яки бу кыйммәтле минераллар, аларның кисәкләре яки агрегатлары, бөртекләре булган көпшәк яки цементлашкан кисәкле материалларның тупланышы. Ч. файдалы казылмалар һәм тау токымнарының физик һәм химик ашалуы нәтиҗәсендә барлыкка киләләр. Чыгышлары буенча — диңгез, елга, бозлык чоры, техноген, барлыкка килү вакыты буенча — хәзерге һәм борынгы заман, яту шартлары буенча — ачык һәм күмелгән, яту тирәнлеге буенча — җир өслегенә якын (20 *м* га кадәр) һәм тирәндә ятучылар, ятмаларның формасы буенча — катламлы, оялы һ.б., файдалы казылмаларның тибы буенча — затлы металлар, асылташлар һ.б.га аерыла.

РФнең Европа өлешендә 300 гә якын чәчелмә чыганаклар һәм Au, Ti, Zr һ.б.ның чагылмалары ачыкланган. Татарстан терр-ясендә, аның төньяк-көнчыгыш һәм көнбатыш районнарында *алтын, алмаз, гранатларның*, титан һәм цирконийның елга, ачык, җир өслегенә якын ятучы, катламлы һәм оялы чагылмалары билгеләнгән. Ком-вак чуерташ материалларны чыгарганда барлыкка килүче иләнгән комнарда тупланганлыктан, алар ком-вак чуерташ катнашмалары б-н бәйле. Аерым алганда, Кама-Агыйдел зонасында Au тупланышы 3,5 *г/т* га җитә, минераллар: титанлы — 20 *кг/т*, тимер оксидлы — 30–35 *кг/т*, цирконийлылар — 10 *кг/т* дан артык.

Әд.: Ведерников Н.Н. Ресурсы твёрдых полезных ископаемых Республики Татарстан // Георесурсы. 1999. № 1; Горнодобывающая промышленность России: Ежегодный справ. М., 2006.

ЧӘЧЕ́Р авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 44 *км* көнбатыштарак, Ык елгасы тамагы буена урнашкан. 2010 елда 109 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 17 йөздә нигез салына. Рев-ция-гә кадәрге рус чыганакларында Шайгурино исеме б-н билгеле. 18–19 йөзләрдә халкы типтәрләр катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1773–75 еллардагы *Крәстияннәр кузгалышында* Е.И.Пугачёв ягында сугышалар. 20 йөз башында мәчет, мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 946,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Пучы волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 107, 1816 да — 246, 1858 дә — 360, 1870 тә — 425, 1884 тә — 479, 1897 дә — 550, 1906 да — 641, 1913 тә — 639, 1920 дә — 698, 1926 да — 621, 1938 дә — 649, 1949 да — 588, 1958 дә — 501, 1970 тә — 455, 1979 да — 247, 1989 да — 140, 2002 дә — 92 кеше.

ЧӘЧКӘ авылы, Әгерҗе р-нында, Әгерҗе шәһәреннән 89 *км* көньяктарак, Әзи елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 2 кеше (татарлар) яши. 1920 елларда нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонының Салагыш волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Красный Бор, 1960 ның 28 октябреннән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгер җе р-нында. Халык саны: 1922 дә — 92, 1926 да — 129, 1938 дә — 157, 1949 да — 138, 1958 дә — 112, 1970 тә — 65, 1989 да — 11, 2002 дә — 14 кеше.

ЧӘЧКЕ́Ч, а.х. культуралары орлыкларын параллель рәтләрдә (тасмалап), бертөсле аралыкта (рәт аралап) чәчү һәм күмдерү, ш.у. туфракка минераль ашламалар кертү машинасы. Чәчү ысулы буенча Ч.ләр рәтләп (орлыкларны тоташ тар рәтләп, киң рәтләп һәм тасмалап чәчү ысулы); пунктирлап (орлыкларны рәтләрдә бертөрле аралыкта чәчү өчен); оялап (орлыкларны төркемләп-оялап чәчү өчен); пунктирлы-оялап (орлыкларны бер-берсеннән бертөрле аралыкта оя-

лап һәм орлыкларны ояларда билгеле бер санда урнаштыру өчен) чәчә торган; чәчү алдыннан туфракны әзерли, чәчә һәм чәчүдән соң туфракны тыгызлый торган чәч-кеч-культиваторларга бүленәләр. Ч.ләр универсаль (төрле культура орлыкларын чәчү өчен) һәм башлыча бер культура яисә аз санда берничә культура орлыгын чәчү өчен каралган махсус Ч.ләргә аерылалар. Туфракка орлык б-н бергә минераль ашламалар кертә торган аппаратлар белән җиһазландырылганнары катнаш Ч.ләр дип атала. Тракторлы (асылмалы, ярымасылмалы һәм тагылмалы), атлы һәм кул Ч.ләренә бүленә. Ч.нең төп җи һазлары: рамнар, терәк көпчәкләр, орлыклар өчен бункерлар (банкалар), туфракта буразна ясаучы төрәннәр (анкерлы, дисклы, табансыман, җәенке); чәчә торган аппаратлар (кәтүкле, дисклы, барабанлы, тасмалыга бүленә), алар ярдәмендә орлыклар һәм ашламалар тиешле микъдарда орлык салгыч һәм ашлама салгыч аша буразнага төшерелә; эшче кораллар (буразнаны туфрак белән күмәләр, тигезлиләр һәм басуның өстен тыгызлыйлыр). Аерым Ч.ләрнең бункерларында орлыкларның һәм аларның катнашмаларының чәчү аппаратларына яхшырак төшүенә ярдәм итә торган болгаткычлар була. Алар Ч.нең тәгәрмәченнән яисә трактор, гидро- яки электр моторы ярдәмендә хәрәкәткә китерелә. ТРда Ч.ләрнең гомуми саны 2000 дә — 12,9 мең, 2006 да 7,7 мең данә тәшкил итә. Хәзерге вакытта Татарстанда чит илләр һәм Россия фирмалары, ш и. Мөслим р-нының «Агромастер» фирмасы җитештергән чәчү комплекслары кулланыла.

ЧӘЧСУАЛЧАННА́Р (Nematomorpha, яки Gordiacea), беренчел куышлы суалчаннар классы. Бөҗәкләр һәм кысласыманнар паразитлары. 300 гә якын төре билгеле. Татарстан терр-ясендә гади Ч. (Gordius aquaticus) таралган. Гәүдәсе чәчсыман, озынлыгы 40–150 *см*, диаметры 1–3 *мм*. Көнкүрештә аны «ат чәче» дип йөртәләр. Алгы очы түгәрәкләнгән, арты (бигрәк тә ата затларда) калаксыман 2 өлешкә аерылган. Эчәклеге ныклы кына кыскарган. Тышкы тирәлектә тукланмыйлар. Ху җәсы гәүдәсендә осмотик рәвештә туеналар. Бүлеп чыгару органнары юк. Нерв системасы һәм сизү органнарының үсеше зур түгел. Ч. — аерым җенеслеләр. Олы затлар суда яши. Ак бау рәвешендә ябышкан миллионлап күкәй сала. Алардан чыккан личинкалар ху җәсы гәүдәсенә керәләр. Ч.ның үсеше бер, еш кына ике арадаш ху җәкатнашында бара. Беренчесе, гадәттә, төрле вак су бөҗәкләре (көнлекчеләр, озынборынларның личинкалары һ.б.), икенчесе — эре ерткыч бөҗәкләр, аларда паразитлар тиз үсә, әмма җенси җитлекмиләр. Паразит, ху җәсы гәүдәсенең өзелгән тышчасыннан суга эләккәннән соң, җенси җитлегә.

Әд.: Гинецинская Т.А., Добровольский А.А. Частная паразитология. М., 1978. *О.Д.Любарская.*

ЧӘЧҮ ӘЙЛӘНЕШЕ́, а.х. культуралары һәм пар җиренең еллар һәм басулар буенча фән-ни нигезләнеп аралашуы; игенчелек системасының нигезе. А.х.культуралары һәм пар җиренең билгеләнгән әзлеклектә Ч.ә.нең һәр басуы аша узган чоры ротация дип атала.

1930 елларга кадәр Татарстан терр-ясендә нигездә өч басулы Ч.ә. була (пар — арыш — язгы бөртекле культуралар), күп басулы Ч.ә. чәчү мәйданының бары тик 4% ын гына тәшкил итә (1927). Авыл хуҗалыгын күмәкләштерү башлану б-н акрынлап күп басулы Ч.ә. кертелә башлый, кырларга күпьеллык үләннәр (терлек азыгы культуралары), сөрүле һәм техник культуралар чәчелә.

Алдагы елда басуларны биләгән а.х. культуралары һәм парлар элгәрләр дип атала. Туфрак үзлекләренә һәм уңышка тәэсир итү дәрәҗәсе буенча аларны берничә төркемгә берләштерәләр: чиста (кара, иртә), биләүле пар, кулисалы пар (аларның уңай тәэсире 2–3 ел дәвам итә). Көзге культуралар (арыш, бодай, тритикале) сызма, язгы бөртеклеләр, бөртекле-кузаклылар, ярма культуралар, күпьеллык үләннәр өчен яхшы элгәрләр булып тора; сызма культуралар (шикәр чөгендере, бәрәңге, кукуруз) барлык язгы бөртекле культуралар өчен кыйммәтле элгәрләр (аларның уңай тәэсире 2 ел бара); язгы бөртеклеләр һәм ярма культуралары бодай, арпа, солы, тары, карабодай) шул ук төркемдәге башка культуралар өчен канәгатьләнерлек элгәрләр; бөртекле-кузаклы культуралар (борчак, вика) барлык язгы һәм көзге культуралар өчен яхшы элгәрләр (аларның уңай тәэсире 2 ел дәвам итә); күпьеллык үләннәр (люцерна, клевер, донник, эспарцет), беренче чиратта, кыйммәтле азык һәм техник культуралар өчен элгәрләр буларак кулланылалар: бодай, бәрәңге, җитен, тары, кукурузга (аларның уңай тәэсире 3–5 ел дәвам итә).

3 тип Ч.ә. классификацияләнә: басу Ч.ә., терлек азыгы Ч.ә., махсус Ч.ә. Басу Ч.ә.ндә чәчүлек мәйданның күп өлешен бөртеклеләр, техник культуралар, бәрәңге били, терлек азыгы Ч.ә.ндә чәчүлек мәйданының яртысыннан артыгы терлек азыгы культураларына бирелә; махсус Ч.ә.ндә аерым шартлар һәм технологияләр таләп итүче культуралар үстерелә (яшелчә, бәрәңге, шикәр чөгендере).

А.х. культуралары һәм пар җирләре нисбәтте буенча Ч.ә.н бөртекле-пар, бөртекле-пар-сөрүле, бөртекле-үләнле, бөртекле-сөрүле, үләнле-басулы, үләнле-сөрүле, сидераль, бөртекле-үләнле-сөрүле һәм сөрүле төрләргә бүләләр.

Респ-када Ч.ә.нең теоретик мәсь әләләре Казан аграр ун-ты, Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-ты һәм башка фәнни учреждениеләр галимнәре тарафыннан тикшерелә. А.х. оешмаларында Ч.ә.н, гадәттә, оештыру-хуҗалык планын төзү б-н бер вакытта проектлаштыралар. Бу эш Респ-ка «Җир» АҖ кадастр үзәге тарафыннан а.х. оешмалары белгечләре катнашында уздырыла. Климат һәм туфрак-гидрология шартлары, туфрак картасы, агрохимия картограммалары өйрәнелә, ху җалык эчендәге җир төзелеше планнары һәм файдалану җирләренең трансформацияләре, чәчүлек мәйданнарының структурасы төзелә. Расланганнан соң, проект терр-ягә күчерелә һәм Ч.ә. басуларының чикләрен билгелиләр. Ч.ә. 2–3 ел дәвамында үзләштерелә. Һәр культура проектта каралган, чикләре сакланган басуларда чәчелгәндә Ч.ә. үзләштерелгән дип санала.

Әд.: Зиганшин А.А., Павлов М.И. Системы земледелия и севооборота в Татарской АССР // Системы земледелия и севообороты основных зон Российской Федерации. М., 1968; Шайдуллин Р.В. Крестьянские хозяйства Татарстана: проблемы и пути развития в 1920–1928 гг. К., 2000; Севооборот — основной биологический фактор ресурсосберегающих технологий и повышения эффективности земледелия в современных условиях // Слагаемые эффективного агробизнеса: Обобщение опыта и рекомендации. Ч. 1. Земледелие и растениеводство. К., 2005.

И.Н.Афанасьев.

ЧӘШКЕ́, сусарсыманнар семьялыгыннан имезүче Mustela ыругы. Ике төре бар: Европа Ч.се һәм Америка Ч.се. Беренче төр Европада һәм Россия терр-ясендә — аның Европа өлешендәге, Себер һәм Ерак Көнчыгыштагы тигезлекле районнарында таралган. Гәүдә озынлыгы — 45 *см* га, койрыгы 20 *см* га кадәр (Америка Ч.се беркадәр эрерәк) җитә. Гәүдәсе тар, сузынкы, сыгылмалы. Аяклары кыска, бармак аралары элпәле. Йон капламы куе, шома, көрән төснең төрле төсмерләрендә. Табигый шартларда Ч.ләр туңмый торган бормалы һәм чоңгыллы урман елгалары ярларындагы, күл һәм сазлык тирәләрендәге өннәрдә яшиләр; кайвакыт башка җәнлекләрнең өннәренә урнашалар. Вак имезүчеләр, кошлар һәм кош йомыркалары, бакалар, балыклар б-н тукланалар. Парлашулары март–апрель айларында. Буазлык чоры 56 көн. Берьюлы 1–9 (кайвакыт 16 га кадәр) бала китерәләр. Татарстанда Европа Ч.се 1920 елларга кадәр киң таралган була, затлы мех кәсепчелеге объектын тәшкил итә. Хәзерге вакытта сирәк очрый, ТРның Кызыл китабына кертелгән. 1948 дә респ-кага читлектә асрау максатыннан кертелә. Нәсел үрчетү эше, йон капламы төсенең нәсел буенча тапшырылу генетик закончалыкларына нигезләнеп, төсле Ч.ләр китереп чыгару юнәлешендә алып барыла. Нәселле җәнлекләр 3–4 ел файдаланыла. ТРда Ч. үрчетү б-н берничә җәнлек совхозында шөгыльләнәләр. 2007 елга ана затлар 55975 баш, ш.и. «Бөреле» нәсел үрчетү з-дында — 14,2 мең, «Бөрсет» агрофирмасында — 16 мең, «Кощаково», «Матюшино» акц. җәмгыятьләрендә тиңдәшле рәвештә 13 һәм 12,8 мең баш исәпләнә. Аларның (гомуми күләмнән % ларда) кара көрән (стандарт) төстәгеләре — 92, сапфир (зәңгәр якут) — 0,96, пастель — 1,8, топаз — 1,7, ак төстәгеләре 0,75 % тәшкил итә. ТРда Ч. тиресе җитештерү күләме: 2000 елда — 140223 данә, 2006 — 294750, ш.и. «Бөреле» нәсел үрчетү з-дында: 2000 — 82754, 2006 — 84100; «Бөрсет» агрофирмасында: 2000 — 33734, 2006 — 80000; «Матюшино» АҖндә: 2000 — 7825, 2006 — 68350; «Кощаково» АҖндә: 2000 — 15910, 2006 — 62300.

Әд.: Абрамов М.Д. Разведение норок. М., 1961; Ильина Е.Д., Кузнецов Г.А. Осно-

вы генетики и селекции пушных зверей. М., 1983; Берестов В.А. Звероводство. СПб., 2002.

Ә.Х.Фазылҗанов, Г.Б.Вәлиев.

ЧВА́НОВ Василий Александрович (25.12.1902, Казан губ., Чистай өязе Чияле Алан а. — 1967 дән соң), хакимият-ху җәлык эшлеклесе. СССР Финанс халык комис-ты каршындагы Югары финанс курсларын тәмамлый (Мәскәү, 1941). 1927–28 елларда Егоркино авылы кулланучылар җәмгыяте (Чистай кантоны) кибете мөдире, 1928–30 да идарә рәисе. 1930–31 дә Октябрь р-ны кулланучылар җәмгыяте идарәсе рәисе. 1931–35 тә Эшче, крәстиян һәм кызылармияче депутатларының Октябрь р-н советы башкарма ком-тының бүлек мөдире һәм рәис урынбасары. 1935–37 дә Хезмәт ияләре депутатлары-ның Чаллы р-н советы башкарма ком-ты рәисе урынбасары, 1937–39 да рәисе, 1942–44 тә Куйбышев р-н советы башкарма ком-ты рәисе. 1939–42 дә ТАССР финанс халык комиссарының 1 нче урынбасары. 1944–47 дә ВКП(б) ның Подберезье райкомы 1 нче секретаре. 1947–55 тә ТАССР сәүдә министры. 1950 елларның 2 нче яртысында КПССның Казан шәһәре ком-тында. 1947–51 дә ТАССР ЮС депутаты. Ике «Почёт билгесе» ордены б-н бүләкләнә.

Е.Б.Долгов.

ЧЕБЕ́Н ГӨМБӘСЕ́ (Amanita), аманитачалар семьялыгыннан җәймәле гөмбәләр ыругы. Якынча 100 төре билгеле, Евразиядә, Төньяк Америка, Австралия, Африкада таралганнар. ТР терр-ясендә 5 төре бар. Кызыл Ч.г. (A. muscaria) ешрак каен һәм нарат урманнарында, июньнән октябрьгә кадәр ялгыз гына яки зур төркем булып үсә. Эшләпәсенең диаметры 20 *см* га кадәр, яссы-кабарынкы, ачык кызыл яки кызгылт-сары; эшләпә өсте күпсанлы ак яки саргылт сөялләр б-н капланган. Йомшагы ак, йомшак, исе юк. Бу гөмбәнең төнәтмәсен чебеннәрне юк итү өчен кулланырга мөмкин (исеме шуннан). Халык медицинасында ревматизм һәм радикулитны дәвалауда файдаланалар. Сасы Ч.г. (A.virosa) ылыслы һәм катнаш дымлы урманнарда июльдән сентябрьгә кадәр үсә. Эшләпәсенең диаметры 12 *см* га кадәр, яшь гөмбәләрнеке — конуссыман, соңрак җәенке, сөтчел-ак, җи ңелчә ябышкак, коры булганда ялтырап тора. Чуар Ч.г. (A. pantherina) яфраклы һәм ылыслы урманнарда июльдән октябрьгә кадәр үсә. Сирәк, ялгыз һәм зур булмаган төркем булып очрый. Эшләпәсенең диаметры 12 *см* га кадәр, җәенке, үзәге киң калкулыклы, кырыйлары сырлы-сырлы. Соргылт көрән, зәйтүнсыман соры, коңгырт төсләрдә. Эшләпәсенең кабыгы ябышкак, үзәктәш әйләнәләрдә күпсанлы ак сөялләр сибелгән. Сулы экстракты инсектицид чара буларак кулланыла. Томсык Ч.г. (A. mappa) ылыслы һәм катнаш урманнарда, күбесенчә наратлыкларда, комлы җи ңел туфракларда августтан сентябрьгә кадәр үсә. Эшләпәсенең диаметры 10 *см* га кадәр, җәенке-каба-рынкы, үзәгендә батынкы, лимонсыман сары яки яшькелт сары, әре ак яки соргылт тәңкәчекләр белән капланган. Барлык төрләренең дә споралы порошогы ак төстә. Гөмбә сабы ак яки сары, төбенә таба бүлбесыман калынаеп киткән, өске өлеше бөҗралы. Йомшагы ак, тәмсез исле. Барлык төрләре дә агулы. Ш.у.к. *Томсык гөмбә*. Илл. к. *Гөмбәләр*.

ЧЕБЕНЧЕ́ КОШЛА́Р (Muscicapa), чебен чыпчыклары семьялыгыннан кошлар ыругы. Якынча 330 төре билгеле, Евразия, Африка, Австралиядә таралганнар. ТРда 4 төре бар: ак муенлы чебенче (M. albicollis), соры чебенче (M. striata), кече чебенче (M. Parva), чуар чебенче (M. hupoleuca). Күчмә кошлар. Респ-каның барлык терр-ясендә очрыйлар. Урман, парк, бакча, елга тугайларында яшиләр, кеше тораклары янында оялыйлар. Кечкенә кошлар. Барлык төрләре дә бөҗәкләрне очып барганда аулау өчен җайлашкан, каты каурый төкләр б-н әйләндереп алынган киң яссы томшыклы. Каурый капламы йомшак, бала кошларныкы — тимгелле, зур кошларныкы — томсыграк, бер генә төстә яки аклы-каралы. Койрыгы озын түгел, туры, еш кына очы кисентеле. Аяклары кыска, көчсез. Агач ботагында канатлары б-н кагынып вертикаль диярлек торышта утыралар, шушы сыйфатлары буенча Ч.к.ны урманда тануы җи ңел. Ояларын агач кәүсәсендә барлыкка килгән куышларда, йорт кәрнизләре астында коралар. Көрән тимгелле 5–6 яшькелт йомырка сала. Күбесенчә бөҗәкләр (ш.и. чебеннәр б-н, исеме шуннан) һәм үрмәкүчләр б-н тукланалар. Кышлау урынына август–октябрьдә очып китәләр.

ЧЕБОКСА́РОВ Михаил Николаевич (15.5.1878, Сембер ш. — 24.2 1932, Казан), терапевт, медицина д-ры (1910). Проф. А.Н.Казимбәк шәкерте. Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1903), Германия клиникаларында практика уза, 1911 елда — Венада, 1914 тә Парижда (Сорбонна) фәнни командировкада була. 1906 дан факультет клиникасының штаттан тыш ординар терапевты, 1909 — 11 дә Казан ун-тының проф. стипендиаты, 1911 дән штатлы ассистент, 1912 дән приват-доцент, 1917 дә экстраординар проф., пропедевтика клиникасының табиблек диагностикасы каф. мөдире. 1919, 1921, 1927–29 да Казан ун-тының мед. ф-ты деканы. 1922–23 тә Казан ун-ты ректоры. 1920 дә факультет терапиясе клиникасы директоры. 1930–32 дә Казан мед. ин-тының факультет терапиясе каф. мөдире. Хезмәтләре эчке секреция бизләре һәм иммунитет арасында бәйләнеш хасил булуда бөер өсте бизләренең ролен өйрәнүгә карый. 1919, 1924–25 тә Казан табиблә ре җәмгыяте рәисе.

Хезм.: О секреторных нервах надпочечников: Эксперим. исслед. К., 1910; О пилоро-дуодените х // Казан. мед. журн. 1928. № 12; К вопросу о функциональной диагностике надпочечников // Казан. мед. журн. 1929. № 1 (автордаш).

Әд.: Анисимов В.Е. Профессор М.Н.Чебоксаров. К., 1970; Дмитриева А., Шарангина Н., Маликова К. Казанский университет в биографиях ректоров // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2008. № 1/ 2.

ЧЕБОТАРЁВ Константин Константинович (8.2.1892, Уфа губ., Бәләбәй өязе Юрминск хуторы — 21.5.1974, Мәскәү), нәкышьче, график, педагог, сәнгать тарихчысы. Казан сынлы сәнгать уч-щесен (1917), Казан сәнгать-техник ин-тын (1922) тәмамлый. 1918–20 елларда Ак армия составында Гражданнар сугышында катнаша. 1920–21 дә Омск сәнгать-сәнәгать мәктәбендә укыта. 1921–26 да Казан сәнгать-техник ин-тында, бер үк вакытта, 1923–26 да, Казан театр техникумында укыта һәм КЭМСТ театрында рәссам булып эшли. «Кызыл блуза» Казан театр оешмасы эшчәнлегендә катнаша. Казан яшь рәссамнарының авангард эзләнүләрен чагылдырган «Подсолнечник» төркем сәнгать берләшмәсен оештыручы һәм аның әгъзасы була (1918). 1921–23 тә «Всадник» графика төркемен җитәкли. ТатЛЕФ (1923–26) хәрәкәтен оештыручыларның берсе һәм лидеры. 1924 тә «Красная Татария» г-тасы б-н хезмәттәшлек итә, сәяси темаларга карикатуралар ясый. 1926 ның җәендә Мәскәүгә күченеп китә. 1927–32 дә ВЦСПС, «Молодая гвардия» нәшриятлары, «Прожектор», «Красное студенчество» ж-ллары, «Межрабпомфильм» кино оешмасы б-н хезмәттәшлек итә. Мәскәүдә Яшь тамашачылар театрында (1927–29), Татар сәнгать эшче театрында (1930) рәссам була, берничә спектакльгә декорация ясый. 1930 еллар башына кадәр «Синяя блуза» берләшмәсе б-н хезмәттәшлек итә. Бөек Ватан сугышы чорында «Окна ТАСС» өчен плакатлар ясый. «Октябрь» берләшмәсе (1929–32), Рәссамнар берлеге (1970) әгъзасы.



Н.Г. Чеботарёв.

Кыска гына вакыт эчендә О.Бердслей рухындагы символик-аллегорик характерлы һәм модерн стильле композицияләрдән



К.К.Чеботарёв. «Композиция». 1922. Картондагы киндер. Майлы буяу.

нәкышькә кадәр эволюцион юл үткән кубофутуристик һәм абстракт юнәлешле 1910 еллар ахыры — 1920 еллар башы Казан авангарды лидерларының берсе. Казанда массакүләм агитация сәнгатен үстерүчеләрнең актив тарафдары була, совет бәйрәмнәрендә урамнарны һәм мәйданнарны бизәүдә катнаша. 1921 дә линолеумда үеплау ысулын, литографияне, офортны үзләштерә, төрле басма техникалар б-н тәжрибәләр ясый («кыздырган энә белән» фанерага гравировка ясау), экспрессионизм йогынтысын кичерә. «Всадник» графика альманахларын чыгаруда катнаша, «Революция» (1921, линогравюра), «Эскизы» (1922, литография) альбомнарын бастыра. 1924–25 тә «Ленинизм», «Сыраханәләр» линогравюра сериялəрен, аерым битлəрдə, ш.и. гарəп хəрефле татар язмаларын да файдаланып, төрле тематик хезмәтләр башкара. 1930 еллар - да монотипия техникасында эшли: Казан күренешләре һәм архит-ра истәлекләре тасвирланган «Казан — яраткан шәһәрем», 1940–50 еллар) сериясе. 1910–1920 елларда Казан сынлы сәнгать тарихы буенча «Следы» гомуми исеме б-н берничә хезмәт яза (кулъязмалары С.-Петербургта Рус музеенда, Мәскәүдә Россия дәүләт әдәбият һәм сәнгать архивында саклана). Күргәзмәләрдә — 1914 тән, халыкара күргәзмәләрдә 1930 дан катнаша.

Әсәрләре Третьяков галереясында, А.С.Пушкин исем. Сынлы сәнгать музеенда (Мәскәү), Рус музеенда, ТРның Дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР Милли музеенда, Чуаш сәнгать музеенда, Козьмодемьянск мәдәни-тарихи музей комплексында, Мари Респ-касы Милли музеенда, Удмуртия Респ-касы Сынлы сәнгать музеенда, Вологда өлкә картиналар галереясында, Россия һәм чит илләрдәге шәхси тупланмаларда саклана.

Әд.: Ф о м и н А. На пути к искусству будущего (Революция в картинах К. Чеботарёва). К., 1922; Д у л ь с к и й П.М. Казанские современные графики // Гравюра и книга. 1925. № 1/2; К.К.Чеботарёв: Каталог выставки. К., 1971; К.К.Чеботарёв (1892–1974): Каталог выставки. М., 1978; АРХУМАС: Казанский авангард 20-х: Каталог выставки. М., 2005; Р о м а н о в и ч А.С. Художник Чеботарёв К.К.: Казанский период творчества (1914–1926). М.-К., 2007.

О.Л.Улемнова.

ЧЕБОТАРЁВ Николай Григорьевич (3.6.1894, Каменец-Подольский ш. — 2.7.1947, Мәскәү, Казанда җирләнә), математик, физика-матем. фән. д-ры (1927), СССР ФА мөхбир әгъзасы (1929), РСФСР, ТАССРның атказ. фән эшлеклесе (1940, 1944). Казан алгебра мәктәбенә нигез салучы. Киев ун-тын тәмамлаганнан соң (1916), шунда ук эшли, бер үк вакытта шәһәрнең уку йортларында укыта. 1921 елдан Одесса шәһәрендә, Халык мәгарифе ин-тында фәнни-тикшеренү каф. сек - ретаре (бүленеп: 1924 нең гыйнвар–сентябрендә Мәскәү гражданлык инженерлары ин-тында матем. профессоры), 1925 елда Германиядә фәнни командировкада. 1927 дән Казан ун-тында; Ч. катнашында алгебра кафедрасы (1934–47 дә каф. мөдире); Матем. һәм механика фәнни-тикшеренү ин-ты (1935–47 дә директор); СССР ФАнең Физика-техника ин-ты (1945–46 да директор) оештырыла. Хезмәтләре югары алгебрага, төркемнәр теориясенә, саннар теориясенә, геометриягә карый. Ч. класс кырларының Галуа абсолют төркеме структурасын билгели, класслар санының гади бүлүчеләренә куелган чикләүләрне ачыклый. Ли төркемнәре теориясендә Картан гипотезасын дәлилләүне тәкъдим итә, алдан бирелгән Ли төркеменең үлчәме барлыгын күрсәтүче аналитик билгесен таба. Ч. — Ли төркемнәре теориясе буенча язылган рус телендәге тәүге китап авторы («Ли төркемнәре теориясе» — «Теория групп Ли», М.–Л., 1940). Алгебраик тигезләмәне бәйсез параметрларының саны иң ким булган тигезләмәгә үзгәртү мәсьәләсенә («резольвент мәсьәләсе буларак» билгеле) багышланган төпле тикшеренүләр өлкәсендәге казанышлары өчен 1948 дә 1 нче дәрәҗә Сталин бүләгенә лаек була (үлгәннән соң). Ч.ның берничә хезмәте матем. тарихына багышлана. Казан физика-матем. җәмгыяте рәисе (1943–1947). Ленин ордены, ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медаль б-н бүләкләнә. Ч. исеме Матем. һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тына бирелә (1947).

Х е з м.: Собр. соч.: В 3 т. М.–Л., 1949–50.

Әд.: Ш а ф а р е в и ч И.Р., М о р о з о в В.В. Николай Григорьевич Чеботарёв. 1894–1947. К., 2002.

ЧЕБОТАРЁВСКИЙ Рәфкать Заһидулла улы (3.9.1947, Чиләбе өлкәсенең Троицк ш. — 19.4.1994, Мәскәүдә җирләнә), контр-адмирал (1989). С.О.Макаров исем. Тын океан югары хәрби-диңгез уч-щесен (Владивосток ш., 1969), Сов. Союзы маршалы А.А.Гречко исем. Хәрби диңгез академиясен (Ленинград, 1984), Генштабның Хәрби академиясен (Мәскәү, 1992) тәмамлый. 1969–82 елларда су асты көймәсе командиры, 1984–90 да командир урынбасары. Төньяк флотта су асты көймәләре дивизиясе (Мурманск ш.) командиры. 1990–93 тә РФ халык депутаты, РФ ЮСның Оборона һәм куркынычсызлык мәсьәләләре буенча ком-ты рәисе. 1993 нең октябрендә Ак йортны саклауда катнаша, ЮСны таратуга каршы чыгыш ясый. Югославия Соц. Федератив Респ-касында командировкада вакытында вафат була. Ленин ордены, Кызыл Йолдыз ордены б-н бүләкләнә.

ЧЕ́БЫШЕВ-ДМИ́ТРИЕВ Александр Павлович (18.4.1835, Мәскәү-9.1.1877, С.-Петербург), хокук белгече, криминалист, җинаять хокукы д-ры (1866), публицист, нашир, статский советник (1868). Мещаннар катлавыннан. Мәскәү ун-тын тәмамлый (1856). 1856–58 елларда Мәскәү генерал-губернаторы канцеляриясендә хезмәт итә. Бер үк вакытта, 1857–58 дә, «Молва» г-тасы редакциясе (Мәскәү) әгъзасы. 1858–60 та Ярославль шәһәренең Демидовлар юридик лицее профессоры. 1860–64 тә Казан ун-тында: 1861–62 дә адъюнкт, 1862 дән җинаять һәм полиция законнары каф. экстраординар профессоры. 1861–64 тә «Учёные записки Императорского Казанского университета» ж-лы мөхәррире. 1864–66 да Петербург ун-тының җинаять хокукы, суд төзелеше һәм суд эшләрен башкару каф. доценты, 1866–68 дә экстраординар профессоры, 1868 дән ординар профессоры. 1864 тән Хокук белеме уч-щесендә, Хәрби-юридик академиядә, Диңгез министрлыгында (С.-Петербург) укыту эшендә. 1865–68 дә «Журнал Министерства юстиции» ж-лы мөхәррире. «Судебный вестник» г-тасына нигез салучы (1866) һәм аның мөхәррире (1868–71). 1872 дән «Биржевые ведомости» г-тасында әдәби бүлек мөдире. Россиядә 1864 елгы Мәхкәмә реформасын уздыруда катнаша. Славянофиллар карашын яклый, уртача либераль позициядә тора. Юриспруденциядә догматик юнәлеш вәкиле. «Җәза хокукы турында» («О праве наказания», Ярославль,





К.К.Ч е б о т а р ё в. 1. «Кызыл армия». 1917. «Хәзинә» милли сәнгать галереясы; 2. «Малайлар». Эскиз. 1918; 3. «КЭМСТ театры». 1932. Барысы да — ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда

1859), «Кул сузу турында» («О покушении», СПб., 1866) хезмәтләрендә, Гегель философиясе постулатына туры китереп, җинаять һәм җәза турындагы тәгълиматка аңлатма бирә. «Җинаять хокукы теориясеннән очерк» («Очерк теории уголовного права», СПб., 1860), «Җинаять хокукы фәненең хәзерге халәте һәм бурычлары турында» («О современном состоянии и задачах науки уголовного права», СПб., 1860) хезмәтләрендә җинаять хокукының гомуми мәсьәләләрен тикшерә. «Пётр I гә кадәрге чор җинаять хокукы» («О преступном действии по русскому допетровскому праву», 1862) монографиясендә Россия җинаять хокукы ин-тлары тарихын чагылдыра. Күп кенә хезмәтләре Көнбатыш Европа һәм Россиядәге җинаять-процессуаль хокук мәсьәләләренә багышлана. Юридик әдәбиятка караган мәкалә һәм фельетон җыентыклары авторы.

Х е з м.: Опыты по уголовному праву: В 2 ч. СПб., 1866–67; Экс. На полпути: Очерки и заметки. СПб., 1874.

Әд.: К и с т я к о в с к и й А.Ф. Воспоминания об учёной деятельности покойного профессора А.П.Чебышева-Дмитриева. Киев, 1877; А г а ф о н о в Н.Я. Заволжская вивлиофика. К., 1887. Ч. 1; Биографический словарь профессоров и преподавателей Императорского Казанского университета (1804–1904). К., 1904. Ч. 2.

Е.Б.Долгов.

ЧЕВЕЛА́ Владимир Всеволодович (28.9.1956, Казан), химик-нәорганик, химия фән. д-ры (1998), проф. (2003). Казан ун-тын тәмамлый, шунда ук эшли. Хезмәтләре комплексы кушылмалар структурасын тикшерүгә, окси-кислоталы металл комплекслары химиясенә карый. Ч. полифункциональ оксикислоталы өч разрядлы тимер, алюминий, галлий комплексларының һәм лантаноид комплексларының структурасын, тотрыклылыгын һәм составын тикшерә. Су эремәләрендәге конформацион каты булмаган координацион лантаноид кушылмаларының структурасын билгеләү өчен ысуллар (куш нурлы парамагнит сынышы б-н молекуляр механика алымнарын бердәм куллануга нигезләнгән) таба. Уйлап табуга 6 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Структура монотартрата диспрозия в водном растворе по данным метода магнитного двулучепреломления и молекулярной механики // Изв. РАН. Сер. хим. 1992. № 10 (автордаш); Основные конформации лигандного скелета тетраядерного тартратного комплекса диспрозия (III) // Журн. неорган. химии. 1999. Т. 44, № 3 (автордаш); Структура полиядерных d- и dl-тартратов лантаноидов в водном растворе. Оренбург, 2006 (автордаш).

ЧЕГОДА́ЕВА Клавдия Константиновна (5.5.1926, Ульянов губ. Кандалы а. — 13.11.1997, Спас р-ны «КИМ» пос. совхозы), сыер савучы, Соц. Хезмәт Герое (1966). 1942–77 елларда Куйбышев р-нының «КИМ» с-зында эшли. Алдынгы технологияләрне кулланып, елга уртача һәр сыердан 4005 *кг* сөт сава. Ч. «ТАССРның иң яхшы сыер савучысы» исеменә лаек була (1965). Герой исеме терлекчелекне үстерүдә, җитештерүне, ит, сөт һәм башка продукция әзерләүне арттыруда ирешелгән уңышлары өчен бирелә. 1967–71 дә ТАССР ЮС депутаты. Ленин ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының медале, РСФСР ЮС Президиумының Мактау грамотасы б-н бүләкләнә. «КИМ» посёлогында бер урам Ч. исемен йөртә. Болгар тарих-архит-ра музей-саклаулыгында, «КИМ» мәктәбе музеенда Ч.га багышланган экспозицияләр куелган.

Әд.: Герои Социалистического Труда и полные кавалеры ордена Трудовой Славы — наши земляки. К., 2003; Спасские сказания. К., 2003.

М.Ж.Гаитов.

ЧЕКА́ЛИН Анатолий Николаевич (3.1.1937, Казан), механика өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (1987). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1959), шунда ук эшли, 1967 елдан Хисаплау үзәге мөдире; 1980 нән Матем. һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында, җирасты гидромеханикасы лаб-ясе мөдире (1987–92). Хезмәтләре күп фазалы һәм күп компонентлы фильтрациягә, фильтрация мәсьәләрен чишүнең санлы алымнарына, катламнан нефть чыгаруны арттыру һәм сулы катламнарда пычрануның күчеше алымнарын матем. модельләштерүгә карый. Ч. ин-теграль чик шартлары параболик һәм эллиптик типтагы тигезләмәләр өчен мәсьәләр тәкъдим итә, аларның чишелешен һәм бердәнберлеген дәлилли. Сулы катламнарда тозлыклар күчешенең фильтрацион-диффузияле матем. моделен эшли; катлаулы төзелешле катламнарда фильтрация процессын хисаплау тәжрибәләре ярдәмендә тикшерә. Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Численные решения задач фильтрации в водонефтяных пластах. К., 1982; Исследование двух- и трехкомпонентной фильтрации в нефтяных пластах. К., 1990 (автордаш); Миграция разноплотностных жидкостей в водоносных пластах сложной структуры. К., 2005 (автордаш).

ЧЕ́КИН Борис Сергеевич (5.3.1922, Чистай кантоны Волчья Слобода а. — 20.1.2009, С.-Петербург), Сов. Союзы Герое (19.4.1945), полковник. Чистай а.х.н механикалаштыру техникумының 3 курсын (1940), Ульянов очучылар хәрби авиация мәктәбен (1943), Хәрби-һава академиясен (шәһәр тибындагы Монино посёлогы, Мәскәү өлкәсе, 1952) тәмамлый. 1941 елдан Кызыл Армиядә. 1944 нең июленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, очучы, өлкән очучы, 556 нчы штурм авиациясе полкының (1 нче һава армиясенең 277 нче штурм авиациясе дивизиясе) эскадрилья командиры урынбасары. Ленинград һәм 3 нче Белоруссия фронтлары эскадрильясе составында Ленинград блокадасын бетерүдә (1944), Балтыйк буен азат итүдә (1944), Көнбатыш Пруссия һөҗүм операциясендә (1945) һәм Кёнигсберг шәһәрен штурмлауда катнаша (1945). Сугыш дәвамында Ил-2 самолёты б-н 180 сугышчан очыш ясый. Сугыштан соң Ленинград хәрби округының авиация полкы командиры урынбасары. 1956–60 та Балтыйк буе һава һөҗүменнән саклану округында. 1960–65 тә 11 нче һава һөҗүменнән саклану корпусының (Белоруссия ССР), 1965–75 тә 6 нчы һава һөҗүменнән саклану аерым армиясенең (Ленинград янында) разведка башлыгы. 1976 ның августыннан запаста, Ленинградта яши. Ленин ордены, ике Кызыл Байрак, Александр Невский, ике 1 нче дәрәҗә һәм бер 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, ике Кызыл Йолдыз,



К.К. Чегодаева.



Б.С. Чекин.

3 нче дәрәҗә «СССР Кораллы Көчләрендә Ватанга хезмәте өчен» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Чистай шәһәрендәге Ч. укыган 1 нче мәктәп бинасына мемориаль такта эленә.

Әд.: Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

М.З.Хәбибуллин.

ЧЕ́КОВ Иван Григорьевич (27.1.1929, Чалы кантоны Нагорное а. — 2.1.2011, Әлмәт ш.), инженер-механик, Әлмәт спираль җәйле торбалар җитештерү кыр базасы директоры (1973–89), ТАССРның атказ. төзүчесе (1979). Бораулаучы кадрлар мәктәбен (1954), Мәскәү нефть химиясе һәм газ сәнәгате ин-тын (1968) тәмамлый. 1944–49 елларда «Богатырь» к-зында тимерче булып эшли (Әлмәт р-ны). 1954–60 та Баш автотранспорт конторасының 3 нче автотранспорт конторасында автомеханик, инженер, директор. 1960 тан Акташ кирпеч з-ды директоры. 1963 тән «Татнефтестройматериалы» трестында (Әлмәт ш.): өлкән инженер, баш механик, идарәче урынбасары; шул ук трестның партком секретаре. Ч. җитәкчелегендә пр-тие төзелә һәм анда реконструкция үздырыла; тышкы полиэтилен катлам б-н төрү производствосы оештырыла, торбаларны эчке катлам б-н каплау технологиясе үзләштерелә (технологиянең илдә тиңнәре булмый). СССРда беренче тапкыр торбалар югары ешлыкта эретеп ябыштыру алымы б-н җитештерелә. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Г.Я.Мәүлетова.

ЧЕЛӘ́Н КОШЛА́Р (Ardeidae), ләкләксымаллар отрядыннан кошлар семьялыгы. 66 төре билгеле, поляр өлкәләрдән кала бөтен Җир шарында таралганнар. Татарстан терр-ясендә 4 төре бар. Соры челән (A. cinerea) респ-каның барлык районнарында очрый (к. *Сумка соры челән колониясе, Курса соры челән колониясе*), колонияләр булып биек агач башларында оялый. Зур күлбога (Botaurus stellaris), кече күлбога



Соры челән.

(Ixobrychus minutus) һәм зур ак челән (Egretta alba) күпләп курак, җикәнбаш, тал үскән сулык буйларында яшиләр. Оя коручы күчмә төрләр. Гәүдәсенең озынлыгы 40–100 *см*, ян-яктан кысылган; авырлыгы 2 *кг* га кадәр. Муены озын, нечкә. Томшыгы очлы, озын, очында туры, читләре вак тешчекле (корбанын тоту өчен). Каурый капламы йомшак, күксел, соры, көрән яки буй-буй чуар ак төстә. Акрын очалар. Ояларын агачларда, куакларда, кураклларда коралар. Бер генә төстәге 3–7 йомырка салалар. Ана һәм ата кош икесе дә утыра. Ч.к. вак балыклар, бака, моллюсклар, бөҗәкләр, ш.у. кимерүчеләр, кош балалары б-н тукланалар. Зур күл-бога, кече күлбога һәм зур ак челән ТРның Кызыл китабына кертелгән.

ЧЕЛТӘР БӘЙЛӘҮ, күл яки машина б-н җепләрне үзара катнаштырып үреп, бизәкләр ясап текстиль эшләнмәсе җитештерү; гамәли-бизәлеш сәнгатенең бер төре. Челтәр башлыча өй эчендәге тукыма эшләнмәләрне һәм кием-салымны бизәү өчен кулланыла. Җияк (махсус агач таякчыклар) б-н күлдан башкарыла, 19 йөзнең уртасыннан машина б-н җитештерелә башлый.

Россиядә 17 йөздән башлап челтәр үрү таралыш ала (Вологда, Елец челтәре һ.б.). 18–19 йөзләрдә ак һәм төсле (ефәк һәм металл җепләр өстәп) җепләр б-н Ч. б. югары үсешкә ирешә. Аның өчен «җирлек» — киез һәм киндер б-н тышланган, иләк кыршавына урнаштырылган түгәрәк мендәрләр файдаланыла. Булачак эшләнмәнең катыргы кисәкләренә төшерелгән рәсеме булавка б-н «җирлек» өстенә беркетелеп куела. Челтәр бизәге җепне җияклəр (озынлыгы якынча 12 *см*) ярдәмендә булавкалар арасында йөртеп үрелә. 19 йөзнең 2 нче яртысында Ч.б., өй һөнәре булудан туктап, Россиянең күпләгән губерналары (Вологда, Орёл, Тула, Вятка, Түбән Новгород, Мәскәү һ.б.), ш.и. Казан губернасының да ун меңнәрчә челтәр бәйләүчеләре шөгыльләнә торган кәсепчелеккә кадәр үсә. Челтәр б-н тастымалларны, сөлге башларын, өстәл япмаларын, күлмәк җиңе һәм итәкләрен, баш япмаларын (тастар), яулыкларны (чубар яулык) бизиләр; хатын-кызлар өчен челтәр якалар һ.б. эшләнмәләр ясыйлар. Ч.б. б-н керәшен татарлар, мишәрләр һәм Касыйм татарлары шөгыльләнә.

Ч.б. Урта Иделдә бирегә русларны күчереп утырту процессында таралыш ала, 19 йөздә Казан губернасының Лаеш һәм Мамадыш өязләрендәге Нырты, Балык Бистәсе, Каймар, Анатыш, Полянка, Троицк-Урай, Горица һ.б. торак пунктларда халык нәфис кәсепчелеге рәвешендә үсә. Борынгы челтәрләрдә зооморф һәм геом. мотивлар өстенлек итә, аларга бизәкне калын җеп белән эшләү хас була, һәм бу җирле осталарның эшен башка губерналарда җитештерелгән эшләнмәләрдән аерып тора. Катлаулы бизәк б-н үрелгән аерым челтәр буйлар һәм итәк-җиң читләре өчен эшләнгән челтәрләр тагын бер үзенчәлекне тәшкил итә.

1883 елда Балык Бистәсендә — эре Ч.б. кәсепчелеге үзәгендә 250 оста эшли, өйдә җитештерү б-н бергә алар җирле алпавыт Е.Донаурова артеленә дә берләшәләр. Ул эшчеләрне материаллар (җепләр Мәскәүдән алдырыла, «бель» дип аталган калын җепне Анатыш авылы крәстияннәре җитештерә), эшләнмәләр (җәйге зонтиклар, хатын-кыз киемендәге киң якалар, гадәти якалар, перчаткалар һ.б.) өчен модерн стиленә хас бизәкле рәсемнәр б-н тәэмин итә. 1892 дән 1910 га кадәр Балык Бистәсендә Донаурова җитәкчелегендә челтәр бәйләргә өйрәтү уч-щесе эшли. *Балык Бистәсе һөнәр-сәнгать остаханәсендә* хатын-кызлар өчен челтәр бәйләргә өйрәтә торган сыйныфлар була. Икенче үзәк — Ныртыда (хәзерге Саба р-нда) 19 йөз ахырында авылдагы 200 йорт-ның барысында да диярлек хатын-кызлар Ч.б. б-н шөгыльләнә. Аларның эшләнмәләренә ихтыяҗ зур була һәм алар алыпсатарлар аша сатыла. 1899 да Мамадыш земство идарәсе тарафыннан Ныртыда «Челтәр бәй-



Челтәр бәйләү. 1. Китап япмасы. Фрагмент. Киже-мамык тукыма, әрләнгән ука һәм ефәк җепләр. Шома чигү, үрелгән челтәр. 19 йөзнең 1 нче яртысы. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 2. Йола сөлгесе. Тукыма, киже-мамык җепләр. Кулдан туку, бәйләп эшләнгән челтәр. Кайбыч районы Мәлки авылы. 20 йөз башы; 3. Урын япмасы чите. Тукыма, киже-мамык җепләр. Бәйләп эшләнгән челтәр. Авторы Т.Брагина. 1950 еллар. Әлмәт районы Көләй авылы; 4. Туй сөлгесе. Тукыма, киже-мамык җепләр. Шома чигү, бәйләп эшләнгән челтәр. Авторы Р.Шәйхетдинова. 1984. Самара өлкәсе Ярмәк авылы; 5. Өчпочмаклы яулык чите. Ефәк, җияклəр белән үреп эшләнгән челтәр. Казан губернасы Мамадыш өязенең (хәзер Теләче районы) Әбде авылы. 19 йөз ахыры; 6. Балык Бистәсе үреп эшләнгән челтәр үрнәкләре. 1920–30 еллар.ТР Милли музее; 7. Челтәр җыелма (жилет, башлык, сумка). Киже-мамык җепләр. Җияк белән үреп эшләнгән челтәр. Рәссам А.П.Обрезкова. 2000; 8. «Зәңгәр үрдәк» панносы. Киже-мамык җепләр. Җияк белән үреп эшләнгән челтәр. Рәссам А.П.Обрезкова. 2002.

ләү мәктәбе» ачыла (1911 дә ябыла). Осталарның эшләнмәләре нәфислеге һәм җыйнаклыгы б-н аерылып тора. Әгәр дә Балык Бистәсе челтәрләре катлаулы булмаган парлы һәм тигез үрү техникасында (бизәк җепләрне санап эшләнә), җияклəр тигез арага күчерелеп, бизәк тигез рәтләр ясап эшләнсә, Ныртыныкылар катлаулырак һәм югары сәнгать техникасында, ягъни бизәкнең аерым өлешләре ыргак б-н беркетеп башкарыла. Бизәкләр тасма ярдәмендә бер сызыкта ясала һәм катлаулы композицияле эре формалары б-н аерылып тора. Орнамент еш кына үсемлек мотивларыннан (яфраклар, чәчәкләр, «тормыш агачы» һ.б.) тора, шул ук вакытта Балык Бистәсе челтәрләрендә геом. формалар өстенлек итә (квадрат, ромб, розетка, дулкын мотивы һ.б.).

Казан губернасы осталарының эшләнмәләре Мәскәүгә, Петербургка һәм чит илләргә җибәрелә. 20 йөз башында алар, Казанда Халыкара кече сәнәгать һәм һөнәри белем күргәзмәсендә, Чикаго шәһәрендә (АКШ) Халыкара күргәзмәдә куелып, бүләкләргә лаек була, ш.у. Брюссель һәм Париж күргәзмәләрендә күрсәтелә.

20 йөзнең беренче унъеллыкларында респ-када Ч.б. акрынлап кими, шулай да челтәр эшләнмәләр 1923 тә Мәскәүдә Бөтенсоюз а.х. күргәзмәсендә зур уңыш казана, Бөтенсоюз ХХСның вак һөнәр сәнәгате даими күргәзмәсе экспозициясенә кертелә. 1927 дә Балык Бистәсендә, озакка булмаса да (1940 елларга кадәр), Ч.б. артеле кабат торгызыла. 1928 дә ул «Разнопромысловик» күппрофильле артеленә керә. Анда 100 дән артык челтәр бәйләүче эшли. 1930 да «Ныртылы кызыл заводы» каршында Ч.б. буенча зур булмаган, якынча 20 останы берләштергән остаханә оештырыла. Җитештерелгән продукция Мәскәү Центросоюзына җибәрелә һәм 1930 еллар уртасына кадәр читкә чыгарыла. Ләкин, җитештерү эчке базар ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә күчү сәбәпле, челтәр эшләнмәләргә сорау кинәт кими, һәм сугыштан соңгы елларда Ч.б. эшчәнлеге сүлпәнәя. Челтәр эшләнмәләрдә чорның яңа социаль билгеләре, аерым алганда, СССР гербы, биш почмаклы йолдыз, В.И.Ленинның портрет сурәте һ.б. чагылыш таба башлый. Бу Ч.б.нең гасырлар буе тупланган сәнгати формасын юкка чыгара. 1980 елларда традицион җияклəр б-н Ч.б. Полянка, Питрәч, Дон-Урай һәм Балык Бистәсе халык осталары (О.Балыкова, А.Воробьёва, А.Седова, Л.Артемьева һ.б.) иҗатында күзәтелә. Аларның эшләнмәләре — челтәр белән бизәлгән сөлгеләр, тастымаллар, якалар һ.б. — Казанда 1 нче Респ-ка гамәли-бизәлеш сәнгате күргәзмәсендә күрсәтелә (1983).

Халык гамәли-бизәлеш сәнгатенең бер төре буларак, хәзерге вакытта респ-када Ч.б. югалып бара, әмма үзешчән иҗатның бер төре булган макраме популярлаша. Борынгы Ч.б. 1990 елларда рәссам һәм педагог А.П.Обрезкова һәм аның укучылары иҗатында яңарыш ала. Ч.б. остасының эшчәнлеге нәтиҗәсендә борынгы челтәр эшләнмәләрнең уникаль коллекциясе туплана, җияклəр б-н Ныр-ты традициясендә Ч.б. үзләштерелә. А.Обрезкова бизәкләргә яңа, аерым алганда, татар халык орнаментына хас мотивлар кертә, заманча эшләнмәләр барлыкка китерә (жилетлар, сарафаннар, блузоннар, галстуклар, көндәлек кирәк-яраклары), аларны Франциядә (Дижон, 2002; Париж, 2003), Германиядә (Мюнхен, 2002) һ.б.да уздырылган Халыкара күргәзмәләрдә күрсәтә. Борынгы Ч.б. сәнгатенә өйрәтү Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать ин-тының гамәли-бизәлеш сәнгате кафедрасында «челтәр бәйләү» дисциплинасы буенча уку программасы кысаларында алып барыла.

Борынгы челтәр үрнәкләре С.-Петербургтагы Рус музеенда һәм Россия халыклары этнографиясе музеенда, Мәскәүдәге Бөтенроссия гамәли-бизәлеш сәнгате музеенда, ТР Милли музеенда, ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда саклана.

Әд.: Обрезкова А.П. Һөнәрчеләрнең кулы алтын // Сөембикә. 2003. № 10; Давыдова С.А. Кружевной промысел // Труды комиссии по исследованию кустарной промышленности в России. СПб., 1886. Вып. 7; Косолапов В.Н. Кустарные промыслы Казанской губернии. К., 1905; Справочник по художественным промыслам системы Всекопромсовета. М.–Л., 1939; Воробьёв Н.И., Бусыгин Е.П. Художественные промыслы Татарии в прошлом и настоящем. К., 1957; Валеева-Сулейманова Г.Ф. Декоративное искусство Татарстана (1920-е — начало 1990-х годов). К., 1995; Махмутова А. Не прервётся волшебная нить // Казань. 1998. № 11; Обрезкова А.П. Ныртинское плетёное куржево. К., 2002; шул ук. История развития кружевоплетения в Казанской губернии (XIX — XXI вв.). К., 2006.

Г.Ф. Вәлиева-Сөләйманова.

ЧЕЛТӘРКАНАТЛЫЛА́Р (Neuroptera), бөҗәкләр отряды. Дөнья фаунасында — якынча 5 төре, Россиядә — 50 дән артык, Татарстан терр-ясендә *алтынкүзләр* һәм *арыслан бөҗәкләр* семьялыгыннан 5 төре теркәлгән. Канат җәеме 2–7 *см*, бик күп җепселле һәм күзәнәкле, кайвакыт ачык төстә, еш кына үтәкүренмәле. Авыз аппараты кимерүче типта. Аяклары йөри торган, бары тик мантиспаларның (Mantispa ыругы) алгы пар очлыклары суфи чикерткәләрнеке кебек элəктерә торган. Корсагында церкалар һәм күкәй салгычы юк. Үсеше — тулы әверелешле. Личинкалары камподеясыманнар, чәнчеп суыручы авыз аппаратына әверелгән сузынкы казналыклы. Урта һәм арткы эчәклек арасында бүлем бар, бөҗәк олыгайгач кына ул юкка чыга, шунлыктан эшкәртелеп бетмәгән азык кисәкчекләре курчактан чыккач кадәр эчәклектә туплана. Олы затлары да, личинкалары да ерткычлар. Азыкның эшкәртелүе организмнан читтә (үрмәкүчләрдәге кебек) бара, личинкалары селәгәй бизләре бүлендекләре б-н корбанын үтерә, аннары аның эчендәге сыек азыкны суыра. Кайбер личинкалары төче су бадягы болыт-сыманнарында (Sisyra ыругы) паразитлык итеп суда җитлегә яки дымлы мүкләрдә (Osmylus ыругы) яшиләр, башкалары (мантиспа) үрмәкүчләрнең күкәй кузыларында паразитлык итәләр. Комлы туфракта яшәүче арыслан бөҗәкләр бөҗәкләрне аулау өчен махсус конуссыман чокырлар ясыйлар. Күпкенә челтәрканатлылар бакча һәм урман корткычларын юк итәләр, мәс., алтынкүз личинкалары күбесенчә гөбләләр һәм кортчалар б-н туеналар. Матур алтынкүз (Chrysopa perla) һәм чуар аскалаф (Libelloides macaronius) ТРның Кызыл китабына кертелгән.

Әд.: Жизнь пресных вод СССР. М.–Л., 1940; Словарь-справочник энтомолога. М.–Л., 1955; Общая и сельскохозяйственная энтомология. М., 1983; Жизнь животных. Т. 3. Членистоногие: трилобиты, хелицеровые, трахейнодышащие. Онихофоры. М., 1984.

Н.В.Шулаев.

ЧЕ́ЛЫШЕВ Василий Львович (1.1.1828, Казан губ., Чистай өязе Шереметьевка а. — 2.8.1900, Чистай ш.), Чистайның 1 нче гильдия сәүдәгәре (1865), коммерция советнигы (1883), иганәче. Икмәк б-н сәүдә итә, Казан губернасы терр-ясендә он тарту, ярма һәм капчык туку пр-тиеләре били. Чистайның помор юнәлешендәге иске дин тарафдарлары җитәкчеләрененең берсе. 1872–75 елларда Чистай шәһәре башлыгы. Чистайда суүткәргеч төзүгә һәм тотуга (1881), хатын-кызлар прогимназиясе (1883), иске дин тарафдарлары гыйбадәтханәсе (1890), хастаханә



В.Л. Челышев портреты. 1884.
Рәссам И.Н. Крамской.
Пермь сәнгать галереясы.

(1893–95), сәүдә йорты (1896) биналары һ.б. төзелешләреңә, Чистай өязендә уч-щеләр һәм хастаханәләр биналарын төзүгә күп акчалар сарыф итә. Казан губернасы халкына 1891–92 дәге ачлык чорында азык-төлек б-н ярдәм күрсәтә. Чистай шәһәренең мактаулы гражданы.

Е.Б.Долгов.

ЧЕ́ЛЫШЕВ Михаил Юрьевич (16.11.1971, Казан — 22.8.2013, Лаеш р-ны Иске Пристань а.), хокук белгече, юридик фән. д-ры (2009), проф. (2010). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1993), гражданлык хокукы һәм процессы кафедрасында, 2005 елдан гражданлык һәм эшмәкәрлек хокукы каф. мөдире. Хезмәтләре гражданлык хокукының тармакара бәйләнешләре, коммерциячел һәм башка эшмәкәрлек хокукын көйләү мәсьәләләреңә карый. Кулланучылар хокукын, эшмәкәрлек хокукын яклау буенча уку-укыту ярдәмлекләре авторы.

Х е з м.: Концепция оптимизации межотраслевых связей гражданского права. К., 2006; Основы учения о межотраслевых связях гражданского права. К., 2008.

Әд.: Казанский университет (1804–2004): Биобиблиогр. словарь. К., 2004. Т. 3.

Е.Б.Долгов.

ЧЕ́ЛЫШЕВ Юрий Александрович (8.7.1949, Казан), гистолог, мед. фән. д-ры (1984), проф. (1988). ТРның атказ. фән эшлеклесе, РФнең Сәламәтлек саклау отличнигы (2014). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1972), шунда ук гистология кафедрасында эшли, 1992 елдан каф. мөдире. Хезмәтләре мускул механорецепторлары гистологиясе һәм физиологиясен, сизгер нейроннарның трофик функциясен өйрәнүгә карый. Ч.ның CD «Нейрогистология» дәреслеге 5 нче Россия CD-ROM «Континент-2000» мультимедиа фестивален лауреат дипломына лаек була.

Х е з м.: Фактор поддержания регенерации периферических нервов // Успехи физиол. наук. 1995. Т. 26. № 3; Чувствительные нейроны шванновские клетки при фармакологической стимуляции регенерации нерва // Морфология. 2000. Т. 118. № 6 (автордаш); Гистология, эмбриология, цитология. М., 2007 (автордаш).

ЧЕМБОРИ́СОВ Наил Әнвәр улы (29.10.1962, БАССРның Туймазы ш.), металл кисү инструментларын конструкцияләү өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2004). 1989 елда Кама политехник ин-тын (хәзер Кама инженерлык-икътисад академиясе, Чаллы ш.) тәмамлый, шунда ук эшли, машина төзү технологиясе, металл кисү станоклары һәм инструментлары каф. профессоры (2004 тән). Хезмәтләре машина детальләренең катлаулы өслекләрен кисү ысулы б-н формалаштыру теориясенә, кисүче инструментлар проектлауның автоматлашты рылган проектлау системаларын булдыруга карый. Хисаплау алымнары һәм гамәли программа пакетлары «КамАЗ», «АЛНАЗ» АҖләрдә, «ЕлАЗ» ҖБдә һ.б.да гамәлгә кертелә.

Х е з м.: Повышение эффективности инструмента для обработки сложных поверхностей на базе математического моделирования. К.–Наб.Челны, 1998 (автордаш); Формирование информационно-поисковой системы инструментального обеспечения автоматизированного производства и проектирование САПР РИ. М., 2000 (автордаш); Резание материалов. Режущий инструмент: В 3 т. Наб. Челны, 2006 (автордаш).

ЧЕМБУЛА́Т авылы, Әтнә р-нында, Олы Әтнә авылыннан 29 *км* төньяктарак, Шашы елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 117 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 18 йөздә Югары Шашы (Вершины Шеши) авылыннан күченүчеләр нигез сала. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ч.та 2 мәчет, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 790 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Царёвококшайск (1919 дан — Краснококшайск) өязе Кышлау волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тукай, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Юл, 1956 ның 18 июленнән — Тукай, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1990 ның 25 октябреннән Әтнә р-нында. Халык саны: 1859 да — 545, 1897 дә — 768, 1908 дә — 708, 1920 дә — 377, 1926 да — 721, 1938 дә — 685, 1949 да — 406, 1958 дә — 362, 1970 тә — 227, 1979 да — 164, 1989 да — 140, 2002 дә — 121 кеше.

ЧЕ́МЕЗОВ ЙОРТЫ́, Казандагы архит-ра истәлеге. Фараза ланганча, башкала архитекторы И.Е.Старов проекты буенча 1798 елда алпавыт В.И.Чемезов төзетә, төзелеш б-н арх. М.Е.Емельянов җитәкчелек итә. Йорт тирәли зур парк булдырыла. Бина турыпочмаклык формасында, төп ишек һәм парк — каршы якта. Ч.й.ның эчке планировкасы сакланмаган. Фасадлар ш.у. үзгәреш кичергән. Кабан күле тарафындагы көньяк-көнчыгыш фасад башта өч өлештән торган структуралы һәм симметрияле композициягә ия була. Аның үзәк өлеше 2 кат биеклегендәге



В.И.Чемезов йорты. Архитекторы М.Е.Емельянов. 1788.

пилястралары булган ярымротонда һәм терраса б-н аерылып тора. Парлы дүрт колоннага утыртылган балконлы ярымротонда ярымтүгәрәк гөмбәз б-н капланган. Пилястралар ионик капительләр б-н тәмамланган, дивар өслеге горизонталь руст б-н эшкәртелгән. Симметрияле ишегалды фасады үзәктә һәм ян-якта ризалитлары булган биш өлештән тора. Аның бизәлешендә калаклар төп роль уйный, калаклар арасында, сай уентыларда тәрәзәләр урнашкан. 1876 да бинаның көнчыгыш ягында төгәл симметрияне бозган янкорма төзелә, эчке планировка үзгәртелә, яңа түр баскыч эшләнә. Йортны үзгәртеп кору барышында капительләр, тәрәзә куышлыклары, көньяк-көнчыгыш фасадның 2 нче катындагы рустика юкка чыга. Ишегалды фасады традицион симметриягә китерелә. 4 ризалит аны 7 өлешкә бүлә. Дивар ларда рустланган бизәкләр, ян-яктагы ризалитлардагы пилястралар һәм өслекнең киң калаклар б-н бүлгәләнүе сакланып калган.

1817 дә утар йорт һәм бакча б-н Н.В.Чемезов карамагына күчә. 1871 дә бина прогимназия (1876 дан — Казандагы Өченче ир балалар гимназиясе) өчен арендага бирелә, 1875 тә дәүләт милкенә күчә. Совет хакимияте вакытында анда урта белем бирү мәктәпләре урнаша, паркның төп өлеше төзелешкә бирелә. 1976 да 4 нче урта белем бирү мәктәбе өчен йортка янкорма итеп типлашкан мәктәп биласы төзелә. 2007 дән йорт 6 нчы кадет мәктәп-интернаты комплексының бер өлешенә әверелә.

1798 дә бу йортта Казанга император Павел I б-н килгән бөек кенәзләр Александр (булачак император Александр I) һәм Константин туктала. 19 йөз башында йортка һәм бакчага еш кына С.Т.Аксаков килгәли. 1876–86 да Казандагы Өченче ир балалар гимназиясендә Ионас Юшка (И.А.Юшкевич, литва тел һәм фольклор галиме) латин теле укыта. Гимназияне тәмамалаучылар арасында шагыйрь В.В.Хлебников, рәссам һәм шагыйрь Д.Д.Бурлюк та бар.

С.Г.Персова, Е.В.Липаков.

ЧЕМОДУ́РОВО авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 25 *км* көньяк-көнбатыштарак, Түбән Ямаш елгасы (Дала Зәе бассейны) буенда. 2010 елда 523 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 58 %, татарлар — 29 %) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау; нефть чыгару. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 19 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Анновка исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, арба һәм тәгәрмәч ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында май язу з-ды эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 737 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Микулин волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Бөгелмә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1859 да — 420, 1889 да — 518, 1897 дә — 544, 1910 да — 491, 1920 дә — 578, 1926 да — 524, 1938 дә — 476, 1949 да — 253, 1958 дә — 192, 1970 тә — 259, 1979 да — 297, 1989 да — 403, 2002 дә — 538 кеше.

ЧЕНӘКӘ́ЕВ Хәнәфи Мәүлетдин улы (20.4.1947, Ленинград), гобойчы, композитор, педагог, РФнең атказ. артисты, РФнең атказ. сәнгать эшлеклесе (1992, 2008). 1971 елда Ленинград консерваториясен (К.Никончукта гобой һәм О.Евлаховта композиция класслары) тәмамлый. Симф. коллективлар солисты (С.-Петербург филармониясенең симф. оркестры, С.-Петербург филармониясенең тынлы музыка уен кораллары квинтеты һ.б.) һәм музыка уку йортлары укытучысы. 2005–09 да Казан консерваториясендә укыта. Солист һәм ансамблист буларак чыгышлар ясый, Россиядә һәм чит илләрдә мастер-класслар уздыра. Ч. репертуарын классик һәм заманча музыка тәшкил итә. Шәкертләре арасында оркестрлар солистлары, халыкара конкурслар лауреатлары бар. «Дөньяның иң яхшы гобойчылары Санкт-Петербургта», «Санкт-Петербург-Арт-Үзәк», «Санкт-Петербургның камера оркестрлары» һ.б. халыкара проектларны оештыручы һәм аларның сәнгать җитәкчесе. ТРның әйдәп баручы муз. коллективлары б-н хезмәттәшлек итә.

Төп әсәрләре: Ике гобой һәм камера оркестры өчен концертино, Кыллы квартет, го-

бой һәм фортепиано өчен пьесалар, романслар һ.б. Халыкара «Прага язы» конкурсы лауреаты (1977).

Ф.Ш.Салитова.

ЧЕНӘКӘЙ (Ченәкәев) Төхфәтулла Гыйззәтулла улы (1893, Рәдүт а., хәзер Оренбург өлкәсенең Саракташ р-ны Никитино а. — 18.4.1959, Әндижан ш., Үзбәкстан ССР), шагыйрь. 1914 елда «Галия» мәдрәсәсен (Уфа ш.) тәмамлый, шунда ук укыта, 1915–17 дә «Кармак» ж-лы редакциясендә (Оренбург ш.). 11 яшендә яза башлый. «Өмет очкыннары», «Теләкләр төркеме» (икесе дә — 1918), «Кан дулкыннары, яки Сугыш» (Оренбург, 1919), «Бакчаларда» (Уфа, 1928), «Карагайлы каен урманында» (1928) һ.б. шигырь һәм җыр җыентыклары авторы. Фольклорчы буларак та таныла, Ш.Бабичның әдәби һәм муз. мирасын саклап калырга булышлык итә.

Әд.: Рахимкулова М. Медресе «Хусаиния» в Оренбурге. Оренбург, 1997.

Р.Н.Даутов.

ЧЕНДАРЁВ Владимир Владимирович (2.9.1960, Нурлат ш.), геолог-нефтьче, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1996). Казан ун-тын тәмамлый (1986), Нефть сәнәгатендә технол. процессларны химияләштерү фәнни-тикшеренү ин-тында (Казан) эшли (2000 елга кадәр). Дәүләт бүләге «Татарстан Республикасының нефть чыгару районнарында техногенез, мониторинг, халык сәламәтлеге һәм экологик хәлне яхшырту чараларын сәнәгый кулланылышка кертү» хезмәтендә катнашканы өчен бирелә.

ЧЕПКА́С-ИЛМӘ́Т (Чатказ, Чатказ Башы) авылы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 26 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Чуваш Респ-касы б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 296 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1667 дән Чаткас исеме б-н мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Югары Чепкас буларак та билгеле. 1720 еллардан халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, лашман хезмәтен үти. 1835–60 елларда Удел ведомствосы карамагында була, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәдрәсә, 2 сәүдә-сәнәгать йорты эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1562 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Янтуган волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1966 ның 30 декабрен нән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1859 да — 447, 1897 дә — 739, 1913 тә — 848, 1920 дә — 908, 1926 да — 803, 1938 дә — 736, 1949 да — 600, 1958 дә — 556, 1970 тә — 577, 1979 да — 458, 1989 да — 335, 2002 дә — 327 кеше.

ЧЕПУРЕ́НКО Анатолий Алексеевич (1915, Казан — 22.1.1945, Прейсишес-Мирк, Көнчыгыш Пруссия), Сов. Союзы Герое (21.3.1940), гв. капитаны. 1936 елдан Кызыл Армиядә. Кече командирлар полк мәктәбен (1937), Казан танк уч-щесен (1938) тәмамлый. Совет-фин сугышында катнаша (1939–40), 7 нче армиянең 86 мотоукчы дивизиясе 109 аерым разведка батальонының танк взводы командиры. 1940 ның марты башында Төньяк-Көнбатыш фронт гаскәрләре составында батырлык күрсәтә: Ч. җитәкчелегендәге танк взводы дошман тылы буенча рейд ясый һәм аның тере көчләренә һәм сугыш техникасына шактый зыян китерә. Керп торак пункты өчен барган сугышта танкистлар дошманның барлык ут чараларын юк итәләр һәм беренче булып авылга керәләр. Мухулакти авылы янында Ч. шәхсән дошманның ныгытылган позициясенә 7 танк һөҗүмендә катнаша. Сугыш кырыннан сафтан чыгарылган танкның экипажын алып чыга. 1941 нең июленнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 3 нче танк батальоны (5 нче гв. танк армиясенең 32 танк бригадасы) командиры. 1 нче Балтыйк буе, 3 нче һәм 2 нче Белоруссия фронтлары составында Белоруссия (1944) һәм Көнчыгыш Пруссия (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. Ч. беренчеләрдән булып Көнчыгыш Пруссия чиген үтеп чыга. 1945 нең 22 нче гыйнварында Кёнигсберг шәһәре өчен барган сугышта һәлак була. Ленин ордены, 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены б-н бүләкләнә.



А.А. Чепуренко.

Әд.: Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

М.З.Хәбибуллин.

ЧЕПЬЯ́ авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 22 *км* төньяк-тарак, Арбор елгасы буенда. 2010 елда 1597 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 49 %, удмуртлар — 44 %) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык; а.х. химиясе һәм а.х. техникасы пр-тиеләре, май з-ды, мех ф-касы. Урта мәктәп, мәдәният йорты, участок хастаханәсе, 2 китапханә. *«Халыклар дуслыгы» музее.* Мәчет, чиркәү. 1710–11 елларда мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Чипья, Яңа Чепья, Чепья Гурьевская, Гурьевское исемнәре б-н дә билгеле; 1930 ларга кадәр Ч.ның көнчыгыш өлешендә Тлогурт дип аталган аерым бер авыл була. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ч.да (Тлогурт а.)



Чепья авылы. «Халыклар дуслыгы» музее.

волость идарәсе урнаша; Троица чиркәве (1830–48 дә төзелә; архит-ра истәлеге), земство (1870 тә ачыла) һәм миссионерлык (Тлогурт а., 1891 дә ачыла) мәктәпләре, земство хастаханәсе (1890–1900 дә фельдшерлык кабул итү пункты статусын ала), ветеринария һәм почта станцияләре, зур базар (1750 еллардан) эшли. 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 715,02 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Чепья волостенда, 1921 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1938 нең 4 августыннан — Чепья р-ны үзәге, 1958 нең 16 июленнән — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1746 да — 111, 1763 тә — 96 ир-ат; 1795 тә — 193, 1859 да — 224, 1884 тә — 208, 1897 дә — 221, 1905 тә — 316, 1920 дә — 370, 1926 да — 540, 1938 дә — 1188, 1949 да — 941, 1958 дә — 831, 1970 тә — 1465, 1979 да — 1335, 1989 да — 1399, 2002 дә — 1548 кеше.

ЧЕПЬЯ́ РАЙОНЫ́, ТАССРда. 1938 елның 4 августында оештырыла. Үзәге — Чепья авылы. 1920 гә кадәр район терр-ясе Казан губернасының — Казан, Вятка губернасының Малмыж өязләрендә, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында һәм Вятка губернасының Малмыж өязендә, 1921 дән ТАССРның Арча кантонында, 1930 дан — Түнтәр, 1932 дән Балтач р-нында. 1940 та районның мәйданы — 521 *км*^{2}, халык саны — 24,8 мең кеше, 23 авыл советы, 51 торак пункт исәпләнә. 1956 да районның мәйданы 524,6 *км*^{2} була, 15 авыл советын һәм 49 торак пунктны берләштерә. 1958 нең 16 июлендә Ч.р. таркатыла, терр-ясе Балтач р-ны составына кертелә.

ЧЕРВО́ННАЯ Светлана Михайловна (7.6.1936, Мәскәү), сәнгать белгече, сәнгать фән. д-ры (1990), проф. (2004), ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1982). Мәскәү ун-тының тарих ф-тын тәмамлый (1958). 1962–2008 елларда Россия САнең Сынлы сәнгать теориясе һәм тарихы фәнни-тикшеренү ин-тында эшли. 1994–95 тә Ватиканда Югары дини мәктәптә «Европада Ислам» белгечлеге буенча курс уза. 2004 тән Польшада яши, Н.Коперник исем. ун-т профессоры (Торунь ш.). Рәссамнар берлеге әгъзасы (1961). СССР, РФ халыклары сәнгате, төрки һәм ислам мәдәнияте турында монографияләр авторы. Ч.ның аерым хезмәтләре Татарстан рәссамнарына һәм сынлы сәнгатенә багышланган: «Совет Татарстаны рәссамнары: Биографик белешмәлек» («Художники Советской Татарии: Биографический справочник», 1975), «Совет Татарстаны сәнгате. Нәкышь. Скульптура. Графика» («Искусство Советской Татарии. Живопись. Скульптура. Графика», М., 1978), «Харис Якупов» (Л., 1983), «ТАССР рәссамнар берлегенең сынлы сәнгать осталары» («Художники Советской Татарии (Мастера изобразительного искусства Союза художников ТАССР)», 1984), «Совет Татарстаны рәссамнары. Иң борынгы заманнардан



В.А. Чердынцев.

1917 елга кадәр сынлы сәнгать һәм архитектура тарихы» («Художники Советской Татарии. История изобразительного искусства и архитектуры с древнейших времён до 1917 года», М., 1987). Сәнгать белгечләренең һәм тәнкыйтьчеләренең Халыкара ассоциациясе (1991), Германия этнологлар җәмгыяте (1995), Польша «Шәрекъ сәнгатен өйрәнү» җәмгыяте (2007) һ.б. әгъзасы. Тбилиси ун-тының (1996), Карачай-Чиркәс пед. ин-тының (2001) мактаулы докторы. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Живопись автономных республик РСФСР (1917–1977). М., 1978; Вазимодействие художественных культур народов СССР. М., 1982; Искусство татарского Крыма. М., 1995; Тюркский мир в центре Северного Кавказа: Парадоксы этнической мобилизации. М., 1999; Современное исламское искусство народов Росси. М., 2008.

Әд.: Кто есть кто в науке об искусстве (Республика Татарстан): Справ. К., 1998; Художники Татарстана: Справ. К., 2011.

ЧЕРВИ́НСКИЙ Алексей Андреевич (20.5.1829, Харьков губ. — 22.6.1878, Петербург губ., Царское Село), хокук белгече, сенатор (1875), яшерен советник (1875). Дворяннар нәселеннән. Мәскәү ун-тын тәмамлый (1851). 1851–52 елларда Мәскәү гражданнар губернаторы канцеляриясендә, 1852–56 да Чернигов, Полтава һәм Харьков генерал-губернаторы канцеляриясендә. 1857–65 тә Рязань губерна идарәсе киңәшчесе. 1866 дан Юстиция министрлыгында. 1867–68 дә Сумы өлкә мәхкәмәсе прокуроры. 1868–70 тә Харьков мәхкәмә палатасы прокуроры урынбасары, прокурор вазифасын башкаручы, 1870–75 тә Казан мәхкәмә палатасы прокуроры. Казан губернасы терр-ясендә Мәхкәмә реформасы уздыруга өлеш кертә. 1875 тән Сенатның җинаять эшләре буенча кассация департаментында.

Әд.: М у р з а н о в Н.А. Словарь русских сенаторов. 1711–1917 гг.: Материалы для биографий. СПб., 2011. *Е.Б.Долгов.*

ЧЕРВЯКО́В Дмитрий Кириллович (12.10.1912, хәзер Орёл өлкәсенең Малоархангельск р-ны Васильевка а. — 14.10.1992, Казан), вет. фармакологы, вет. фән. д-ры (1956), проф. (1957), ТАССРның атказ. фән һәм техника хезмәткәре (1973). Мәскәү вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1936), шунда ук эшли. 1940 елдан Бурят-Монголия зоовет. ин-тында, фармакол. каф. мөдире(1944 тән). 1958–88 дә Казан вет. ин-тының фармакол. каф. мөдире. Хезмәтләре фосфорорганик кушылмалар, фенотиазин препаратлары, новокаин, синтетик мочевина, күкерторганик кушылмаларны, гербицидлар токсикологиясен өйрәнүгә карый. Бурятия үләннәренең фармакол. ресурсларын тикшерә, төрле фармакол. динамикалы күп кенә үлән препаратларының, синтетик кушылмаларның фармакологиясен өйрәнә.

Х е з м.: Вклад Казанских учёных в фармакологию // Ветеринария. 1973. № 5; Лечебные свойства сульфона // Ветеринария. 1975. № 1 (автордаш); Применение лекарственных растений в ветеринарии // Ветеринария. 1981. № 7 (автордаш).

Әд.: Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.): Биогр. словарь учёных. К., 2006.

ЧЕ́РДЫНЦЕВ Виктор Алексеевич (12.11.1882, Пермь губ., Оса өязе Фёдоровка а. — 29.4.1954, Казан), геолог-палеонтолог, проф. (1932), ТАССРның атказ. фән. эшлеклесе (1945). Казан ярусы фаунасын өйрәнүдә биостратиграфик юнәлешне нигезләүче. Казан ун-тын тәмамлый (1909), шунда ук укыта (бүленеп, 1919–20 елларда Пермь ун-тында), геол., тарихи геол. һәм палеонтология кафедралары мөдире (1935 тән). Бер үк вакытта, 1920–23 тә, Төньяк-Көнчыгыш археол. һәм Казан вет. ин-тларында, 1946–47 дә СССР ФАнең Казан ф-лы Геол. ин-тында гомумгеол. секторы мөдире. Хезмәтләре геол., палеонтология, файдалы казылмаларга карый. Ч. Бөгелмә һәм Уфа кантоннарының геол. картасын эшли, Эстәрлетамак–Бөгелмә тимер юл линиясен һәм Куйбышев ГЭС төзелешен проектлау районнарында инженер-геол. тикшеренүләр үткәрә. Илдә беренчеләрдән булып, Идел-Кама бассейны үзәк өлешенең микрофаунасын өйрәнә башлый. ТАССР терр-ясенә геол. тасвирлама бирә. Ленин ордены, «Почёт билгесе» ордены, медальләр, ТАССР ЮС Президиумының ике Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Геологическое описание Татарской Республики // Геология и полезные ископаемые ТАССР. К., 1940 (автордаш).

Әд.: С и л а н т ь е в В.В., Р я з а н ц е в а И.Н., Р я з а н ц е в С.И. Виктор Алексеевич Чердынцев, 1882–1954. К., 2003.

ЧЕРЕ́ВИН Валерий Филиппович (17.9.1939, Мари АССРның Йошкар-Ола ш.), инженер-технолог, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1997), ТРның атказ. рационализаторы (1993). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлаганнан соң (1961), «Казаноргсинтез» АҖдә: аппаратчы, өлкән техник, цех мастеры, смена мастеры, бүлек башлыгы, цех башлыгы урынбасары, башлыгы, җитештерү башлыгы урынбасары, техник бүлек башлыгы, баш инженер урынбасары (1988 дән), техник директор урынбасары (1999–2004). Үйлап табуга 30 дан артык авторлык таныклыгы һәм 50 патенты бар. Дәүләт бүләге дезинфекцияләүче, дәвалау-профилактик һәм технол. химик препаратлар үйлап табуда, эшләүдә җитештерүгә кертүдә катнашканы өчен бирелә. «Почёт билгесе» ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.

Әд.: А ю п о в М.Ю., Ю с у п о в И.В. Общество изобретателей и рационализаторов 50 лет. К., 2009.

ЧЕ́РЕЗОВА Елена Николаевна (7.4.1959), Киров өлкәсенең Яранск ш.), химик-органик, химия фән. д-ры (2003). Казан ун-тын тәмамлый (1981), Казан технол. ун-тында эшли. Хезмәтләре полимерлар химиясенә карый. Ч. 2,6-ди-трет-бутилфенол нигезендә ясалган полимерларның элементорганик стабилизаторлар үзлекләрен синтезлый һәм тикшерә. Полиолефиннар һәм каучукларның файдалану үзлекләрен тотрыклыландыру өчен фенол класслы нәтиҗәле антиоксидантлар эшли. Үйлап табуга 12 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Синтезы на основе синтонов с фрагментами пространственно-затруднённого фенола // Башк. хим. журн. 1996. № 1–2 (автодаш); Реакционная способность органических соединений: Учеб. пособие. К., 2003 (автордаш).

ЧЕРЕ́К КҮЛ, Көнбатыш Кама алдында. Яшел Үзән шәһәреннән 2 *км* төньяк-көнбатыштарак урман массивында урнашкан. Су өслегенең мәйданы 1,18 *га*. Суының күләме 76 мең $м^3$. Озынлыгы 250 *м*, иң зур киңлеге



Черек күл. Яшел Үзән шәһәре янында.

70 *м*. Уртача тирәнлеге 4 *м*, иң зур тирәнлеге 6 *м*. Күл карст-суффозия күренешләре нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Суы бик йомшак, гидрокарбонат-хлорид-кальцийлы типта. Күл нык кына сазлана бара.

ЧЕРЕ́К КҮЛ, Көнбатыш Кама алдында. Идел-Кама саклаулыгының Раифа урман участогында, Яшел Үзән р-ны Раифа посёлогыннан (даими яшәүчеләр юк) көнчыгыштарак урнашкан. Мәйданы 0,81 *га*. Суының күләме 28,5 мең $м^3$. Озынлыгы 212 *м*, иң зур киңлеге 50 *м*. Иң зур тирәнлеге 5,6 *м*. Күл карст-суффозия күренешләре нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Озынча түгәрәк формада. Атм. явым-төшемнәре һәм җир асты сулары б-н туена. Күл нык кына ләмләнгән, аның шактый өлеше сазланган һәм йөзмә «үлән-утрау» б-н капланган.

ЧЕРЕ́К КҮЛ, Казанда, Черек күл (хәзерге Дзержинский) урамы буенча көньяк-көнчыгыштан төньяк-көнбатышка таба сузылган карст иңкүлегендә урнашкан булган, озынлыгы 500 *м* (хәзерге Лобачевский һәм Чернышевский урамнары арасында), су өслегенең мәйданы 9 *га* га, иң зур тирәнлеге 25–30 *м* га җиткән. Ч.к.дә балыклар йөзгән, суы эчү өчен кулланылган. Чишмә сулары б-н туенган: су ермаклар буйлап Мунча күленә, Түбән Шакшы күлгә, аннары Казансуга агып төшкән. 19 йөз башында Ч.к. ярлары буенда төзелеш эшләре башлана, чишмәләр һәм ермаклар әкренләп күмелә. 1829 елда Ч.к.дә шәһәр бакчасы булдырыла. 1875 тә сәүдәгәр Ожегов Ч.к. бакчасында ресторан ача, аның тирәли аллеяларда фонтаннар, газ фонарь-

лары куела, чәчәкләкләр һәм клумбалар ясала; паркта А.П.Вяткин фотосалоны, кышын шугалак эшли. 1890 да Ч.к.нең төнъяк-көнбатыш ярында бертуган Никитиннар циркының агач бинасы төзелә (1961 дә яна). Ч.к. буендагы төзелеш аның чүпләнүенә китерә, агым бетә, суы тынчый. 1890



Черек күл бакчасы. 20 йөз башы фоторәсеме.

елларда шәһәр хакимияте карары б-н Ч.к. күмелә. Совет чорында аның урынында шул ук исемдәге пионерлар һәм мәктәп балалары паркы оештырыла. Ч.к. паркы шәһәр халкының ял итү урыннарының берсе. 2016–18 дә анда күләмле реконструкция эшләре алып барыла.

1918–2004 тә элеккеге Ч.к. урамында Н.И.Лопатин йортында НКВД (соңрак КГБ, ФСБ) идарәсе, со ңыннан ТАССР, ТР Эчке эшләр министрлыгы урнаша. Ф.Э.Дзержинский үлеменнән соң (1926) урамга аның исеме бирелә. Сталин репрессияләре вакытында «Ч.к.» атамасы җәза бирүче органнар урнашкан урын буларак күзаллана башлый («Черек күлгә алып киттеләр»).

О.В.Ерёгин, Г.С.Сабирҗанов.

ЧЕРЕМХО́ВО шәһәре, *Иркутск өлкәсендә*, Иркутск шәһәреннән 131 *км* төнъяк-көнбатыштарак урнашкан. 1772 елда Мәскәү юлындагы почта станциясе каршындагы Черемховский авылы буларак нигез салына. 1917 дән — Ч. шәһәре. Мәйданы — 114,4 *км*^{2}. Халкы — 51230 (2017). Татарлар саны: 1959 да — 5331, 1970 тә — 4317, 1979 да — 3144, 1989 да — 2375, 2002 дә — 1704, 2010 да — 1518 кеше. Черемховский авылына татарлар 19–20 йөзләрдә Ч. ташкүмер бассейны чыганакларын файдалану б-н бәйле рәвештә урнаша башлыйлар. 1906–11 дәге Столыпин аграр реформасы чорында Урта Идел һәм Урал буеннан килүчеләрнең күбесе Черемховский тирәсендә (Ныгда, Голуметь, Касьяновка, Морат авыллары) төпләнеп калалар. 1917 дә Ч. да мәчет (1937 дә ябыла), мәктәп эшли, Шадринск тарлавының (соңрак — Шадринка пос.; рәсми исеме — Дзержинский исем. пос.; хәзерге вакытта Ч. составында) Комарово мәктәбендә татар сыйныфы оештырыла. 1920–37 дә Ч.да татар мәктәбе эшли, наданлыкны бетерү кампаниясе чорында Татар кызыл почмагы була, аның өчен Казаннан һ.б. җирләрдән татар басмалары алдырыла. 1932 дән Ч.да татар җәмгыяте, Идел-Урал төбәгеннән сөрелеп, репрессияләнгән таза тормышлы крәстиннәр, мөселман руханилары вәкилләре исәбенә арта. Алар Шадринка посёлогында урнашып кала. 1938 гә кадәр татар мәктәбе була, анда ш.у. башкортлар, хакаслар, бурятлар укый; наданлыкны бетерү пункты эшли. 8 нче шахта клубы каршында Татар клубы һәм татар театры түгәрәге эшли (1938 дә ябылалар), «Шүрәле», «Зәңгәр шәл», «Башмагым» спектакльләре куела, концертлар һәм бәйрәмнәр үткәрелә. 1937 дә Шадринкада сөргендәгеләр рус, татар (Х.Д.Динисламов җитәкчелегендә) һәм хакас к-зларын оештыралар, соңрак алар үзәге Сафроновка авылында булган «Яңа тормыш» к-зына берләшәләр. 1956 дан татар дини йолалары Шадринка посёлогындагы зур булмаган гыйбадәтханәдә (иганә акчасына сатып алына) башкарыла. 2008 дә шәһәрнең үзәк өлешендә яңа мәчет ачыла. 1990 нан «Туган тел» татар-башкорт үзәге (1998 гә кадәр шул ук исем. татар-башкорт клубы), аның каршында 3 бүлек: татар, башкорт, «Ләйсән» балалар һәм яшьләр (2004 тән) бүлекләре эшли. Үзәк актив рәвештә мәдәни-агарту эше б-н шөгыльләнә: «Каз өмәсе», «Бавырсак нәрсә ул», «Казан сөлгесе», «Әниемә», «Нәүрүз», *Ураза бәйрәме, Корбан бәйрәме, Мәүлид кичәсе* кебек бәйрәмнәр үткәрә; 1996, 2000, 2004 тә өлкә *Сабан туен*, 2007 дә Иркутск өлкәсе татар үзәкләре өчен «Хәзерге шартларда татар халкының мәдәни мирасын саклау һәм киң җәмәгатьчелеккә таныту» семинарын оештыручыларның берсе була, халыкның гореф-гадәтләрен саклау, балалар һәм яшьләрдә милли үзаң тәрбияләү өчен ел саен 9 майда төрле буын вәкилләренең очрашуын уздыра. 1993–96 да Ч.ның 3 нче урта мәктәбендә татар теле факультатив дәрестә өйрәнелә. 1995–96, 2004–05 тә рус һәм татар телләрендә радиотапшырулар алып барыла, телевидениедә системалы рәвештә шәһәр татарлары тормышы турында тематик тапшырулар әзерләнә: 1995 тә «Туган тел» клубы турында тапшыру, 1996 да «Сабан туе бәйрәме», 1998 дә «Тарихи сәхифәләр», 2005 тә «Сафран юлы», 2008 дә «Бию тылсымы», 2008 дә шәһәр уртасында мәчет ачыла. 2008 дән «ТСТ» каналында атнага ике тапкыр рус һәм татар телләрендә «Сәлам» тапшыруы чыга. Ч. тарихында шахтёрлар М.Абдуллин, Х.Г.Әхмәтов, М.Вәлиуллин, Н.Мөхәммәтдинов, Ф.Шәмсетдинов (Ленин ордены б-н бүләкләнәләр), С.Кашапов, З.Низамов («Шахтёр Даны» медаленең 3 дәрәҗәсе б-н дә бүләкләнәләр) якты эз калдыралар.

ЧЕРЕМЧЕ́Л, күке төкереге (Melandrium), канәферчәләр семьялыгыннан күпьеллык, сирәк кенә бер- яки икееллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Якынча 100 төре билгеле, бөтен Җир шарында таралганнар. ТР терр-ясендә бер төре — ак Ч. (M.album), респ-каның һәр җирендә таралган. Болынларда, сөрүлекләрдә, чүп үләне буларак күпьеллык үләннәр чәчүлекләрендә, яшелчә, җиләк-җимеш бакчаларында үсә. 25–100 *см* биеклектәге үсемлек. Сабагы бер-ле, туры, төкчәле. Яфраклары йомыркасыман яки озынча, тамыр янындагылары — сабакчыл, сабактагылары — утырма. Чәчәкләре ачык кызыл, күпчәчәкле ярымчатырда. Җимеше — бер оялы күп орлыклы тартмачык. Май–августта чәчәк ата, Орлыктан үрчи. Үләне төнәтмәсе ашказаны-эчәк чәнчүләре вакытында авыртуны басу чарасы буларак кулланыла. Декоратив, баллы үсемлек.

«ЧЕРЕМША́НКА», карабодай сорты. 1998 елда Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тында Ф.З.Кадыйрова, В.М.Галактионова, И.Ю.Никифорова тарафыннан чыгарыла. Уртача өлгерешле сорт, вегетация чоры 80–84 көн. Корылыкка чыдамлылыгы б-н аерылып тора. Куагы таралгы формадагы, юан сөрлекми торган сабаклы үсемлек. Орлыгы эре (1000 данәнең авырлыгы 33–36 *г*), канатлы, куе-коңгырт төстә. Бөртеге югары нату-ралы (470 *г/л*). 2001 дән бу сорт РФнең Идел-Вятка, Төньяк Кавказ, Урта Идел, Түбән Идел, Ерак Көнчыгыш төбәкләрендә чәчәргә рөхсәт ителгән.

Әд.: Каталог научно-технической продукции. К., 2005.

ЧЕРЕМЫ́ШИ авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 13 *км* төньяктарак, Үшнә елгасы буенда. 2010 елда 56 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. 1596–97 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәр-ге чыганакларда Богородский исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре (хуҗалары берничә тапкыр алмашына, 18 йөздә алар арасында кенәз



Черемыш авылы.
Казан Богородица чиркәве. 1741.

Кропоткиннар һәм Болховскийлар була) катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, сәүдә б-н шөгыльләнә. 1850 елларда Ч.та поташ з-ды була, 20 йөз башында волость идарәсе урнаша; Казан Богородица чиркәве (1741 дә төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1872 дә ачыла), ашлык саклау-сату кибете, су тегермәне, ярма яргыч, 3 тимерче алачы-гы, столярлык остаханәсе, 5 кибет, ирекле янгын дружинасы эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1146 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Черемыш волосте үзәге, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1924 тән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 227 ир-ат; 1859 да — 590, 1897 дә — 764, 1908 дә — 821, 1920 дә — 956,

1926 да — 1038, 1949 да — 487, 1958 дә — 367, 1970 тә — 287, 1979 да — 250, 1989 да — 31, 2002 дә — 51 кеше.

ЧЕРЕНГА́ (Черәнге) авылы, Алабуга р-нында, Алабуга шәһәреннән 41 *км* көньяк-көнбатыштарак, Казан — Уфа автомобиль юлы буенда. 2010 елда 8 кеше (руслар) яши. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә; 1760 елларда граф П.И.Шуваловның Кама тимер ясау з-дларына теркәлә. 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 1148,8 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Казиле волостенда, 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга, 1944 нең 19 февраленнән — Костенеево, 1944 нең 8 июненнән — Морт, 1954 нең 19 ноябреннән Алабуга р-нында. Халык саны: 1859 да — 373, 1887 дә — 417, 1905 тә — 454, 1920 дә — 468, 1926 да — 503, 1938 дә — 192, 1949 да — 166, 1958 дә — 127, 1970 тә — 73, 1979 да — 41, 1989 да — 28, 2002 дә — 17 кеше.

ЧЕРЕПА́НОВ Владимир Николаевич (2.2.1930, Әзәрбайҗан ССРның Баку ш. — 30.11. 2002, Казан), слесарь-инструментчы, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1980). 1945 елдан Казан пр-тиеләрендә. 1960–2000 дә «Казан медицина инструментлары заводы» АҖдә. Дәүләт бүләге эчке җитештерү резервларын уйлап табу нигезендә эшнең нәти-жәлелеге һәм сыйфаты, хезмәттәге югары казанышлары өчен бирелә. Ленин ордены, «Почёт билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

ЧЕРЕПА́НОВ Михаил Валерьевич (12.12.1960, Төмән өлкәсенең Ишем ш.), журналист, ТРның Дәүләт бүләге лауреаты (2000), ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1994). Казан ун-тын тәмамлый (1983). 1983–91 елларда «Коммунист Татарии» (бүленеп: 1986 да «Вечерняя Казань» г-тасы хәбәрчесе) г-тасында хезмәткәр. 1991–2007 дә ТР МК каршындагы «Хәтер китабы» редакциясендә мөхәррир урынбасары, эшче төркем җитәкчесе. 2007 дән ТР Милли музеенда Бөек Ватан сугышы музей-мемориалы мөдире. «Сәяси репрессия корбаннары хәтер китабы», «Алар илгә җиңү алып кайтты» басмаларын әзерләүгә зур өлеш кертә. «Әфганстан сугышы корбаннары хәтер китабы»н төзүче, «*Кар десантларының*» 1980–2000 еллар елъязмасы авторы. Дәүләт бүләге Икенче бөтендонья сугышында һәлак булган Татарстанлылар турындагы «*Хәтер–Память*» китабы басма сериясен нәшер итүдә катнашканы өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Зачем живым Долина смерти? 25 лет поисковых экспедиций Татарстанцев. К., 2006.

ЧЕРЕПНИ́Н Лев Владимирович (30.3.1905, Рязань ш. — 12.6.1977, Мәскәү), тарихчы, чыганаклар белгече, историограф, тарих фән. д-ры (1947), СССР ФА академигы (1972), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1970). Мәскәү ун-тын тәмамлый (1925). 1946 елдан СССР ФАнең Тарих ин-тында, 1951 дән СССРның феодализм чоры тарихы секторы мөдире, бер үк вакытта, 1969 дан, СССР терр-ясендә капитализмга кадәрге формацияләр тарихы бүлеге мөдире. Мәскәү тарих-архив ин-тында (1942–49), Мәскәү ун-тында (1944–60) укыта, проф. (1947). Ч. Россия дәүләтчелеге барлыкка килүнең теоретик, чыганакларны өйрәнү һәм тәгаен-тарихи мәсьәләләрен тикшерә, феодализм чоры рус тарихын чорларга бүлүне, 10–13 йөзләрдәге борынгы рус җәмгыятенең социаль-икътисади, сәяси тарихын, Россиядә сословиеле-вәкиллекле монархия һәм абсолютизм үсешен, 14–17 йөзләрдәге сыйнфый һәм сәяси көрәшне, рус тарихи процессы типологиясен өйрәнүгә өлеш кертә. Хезмәтләре чыганакларны өйрәнү фәненә һәм историографиягә, ярдәмче тарихи фәннәргә карый. «Россиядә феодализм үсешенең төп этаплары» («Основные этапы развития феодализма в России», М., 1955), «XIV–XV йөзләрдә үзәкләштерелгән Рус дәүләте оешу» («Образование Русского централизованного государства в XIV — XV вв.», М., 1960) монографияләрендә һ.б. хезмәтләрендә Идел буе һәм Урал алды халыклары тарихы, ш.и. Россиянең Алтын Урда, татар ханлыклары б-н мөнәсәбәтләре мәсьәләләре; Идел буе төбәгенең руслар тарафыннан колонияләштерелүе процессы карала. Татар халкы килеп чыгышының болгар теориясен яклый. СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1981, вафатыннан соң). Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.



Л.В. Черепнин.

Х е з м.: Русские феодальные архивы XIV — XV вв.: В 2 ч. М.–Л., 1948–51; Русская палеография. М., 1956; Русская историография до XIX в. М., 1957; Земские соборы Русского государства в XVI — XVII вв. М., 1978.

Әд.: Лев Владимирович Черепнин (1905 — 1977) // Материалы к биобиблиографии учёных СССР. М., 1983. *Е.Б.Долгов.*

ЧЕРЁМУХА елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Чөкәнеш елгасының (Чишмә елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 9,5 *км*. Бассейнының мәйданы 67,9 *км*². Идел аръягы калкулыгыннан, Яңа Чишмә р-ныннан ага. Елга башы Черёмуха Бистәсе авылыннан 3 *км* көньяктарак, тамагы әлеге авылдан 6 *км* төньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 135 *м*, тамагыныкы — 81 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 7%. Ч.ның 2,5 һәм 8,7 *км* озынлыктагы 2 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,35 *км/км*². Туенуы катнаш, күбрәк кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,1–0,25 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен ныклы сае-гуы б-н характерлана. Җәен озак вакыт яңгырлар булмаганда елга урыны-урыны б-н кибә. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 91 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,026 *м*³*/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 300–400 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

ЧЕРЁМУХА БИСТӘСЕ́ авылы, Яңа Чишмә р-нында, Яңа Чишмә авылыннан 13 *км* көньяк-көнбатыштарак, Черёмуха елгасы буенда. 2010 елда 701 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1730–40 елларда нигез салына. Башта анда *игенче солдатлар* яши, соңрак алар дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә; игенчелек, терлекчелек, тимерчелек, май язу һәм он тарту, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ч.Б.ндә агач Крестовоздвижение чиркәве (1867 дә төзелә; 1907–17 дә яңа таш бинасы салына), земство (1869 дан эшләүче приход мәктәбе урынында 1875 тә ачыла) һәм чиркәү-приход (1894 тә ачыла) мәктәпләре, 1 су һәм 6 җил тегермәне, ярма яргыч, 2 май язу йорты, 3 тимерче алачыгы, сыраханә, 1 казна шәраб һәм 11 вак-тәякләр кибете була; шимбә базары эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 7153 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Яңа Чишмә волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Яңа Чишмә, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1983 нең 26 апреленнән — Яңа Чишмә р-нында. Халык саны: 1859 да — 2095, 1897дә — 2213, 1908 дә — 4920, 1920 дә — 4759, 1926 да — 4383, 1938 дә — 2513, 1949 да — 1642, 1958 дә — 1927, 1970 тә — 1868, 1979 да — 1448, 1989 да — 979, 2002 дә — 843 кеше.

ЧЕРЁМУХИН Владимир Иванович (21.6.1935, Казан — 11.1.1999, шунда ук), радиобиолог, биол. фән. канд. (1969), СССР Дәүләт бүәге лауреаты (1979). Казан вет. ин-тын тәмамлаганнан соң (1959), Пермь өлкәсенең Усольск р-ны «Усольский» с-зында баш вет. табибе, Татарстан респ-ка совхозлар идарәсендә өлкән вет. табибе булып эшли. 1961–97 елларда Казан вет. ин-тының гражданнар оборонасы һәм радиобиол. кафедрасында. Хезмәтләре ионлаштыручы нурланышларның хайваннар һәм кошлар организмына тәэсирен көчәйтү механизмнарын өйрәнүгә, хайваннарда кискен нур авыруына иртә срокларда диагноз кую һәм дәвалауысулларын эшләүгә карый. Дәүләт бүләге махсус тема буенча эшләүдә катнашканы өчен бирелә.

Әд.: Казанская государственная академия ветеринарной медицины (1873–2006 гг.): Биогр. словарь учёных. К., 2006.

ЧЕРЁМУШКИ, ерым, геол. табигать истәлеге. Идел елгасы үзәненең уңъяк яры сөзәклегендә, Югары Ослан р-ны Печище авылыннан көнбатыштарак. 1986 елда билгеләнә. Мәйданы 3 *га*. Ерым битләрендә (якынча 50 *м* озынлыкта) Пермь системасы Биармий бүлегенең Уржум ярусы эталон киселеше ачыла, 2 (астан өскә таба) — сулицк һәм ишиев свиталарыннан тора. Сулицк свитасы Ка-

зан ярусының аксыл-соры доломитларның юылган өслегендә ята. 2 дән 5,85 *м* га кадәр калынлыктагы катламлы 7 пачкадан (балчыклы-комсу, мергельле, балчыклы, доломитлы, комсу-балчыклы һ.б.) тора. Ишиев свитасы 6 дан 7,5 *м* га кадәр калынлыктагы 6 пачкадан («яшел балчыклар», «черёмушка», «тасмасыман мергельләр», «воробьёвка»,«табаксыман комташ», «текә ерым») гыйбарәт. Уржум ярусы утырмалары палеонтологик остракода, филопода, ике кабырчыклы моллюскларкалдыклары, ганоид балыклар тәңкәчекләре, амфибияләр һәм рептилияләр сөякләренә, харофит, строматолитларга бай. Уржум



«Черёмушки» ерымы.

ярусы киселеше Урта Идел буе терр-ясенең терәге булып тора. Биредә фәнни экскурсияләр, Казан югары уку йортларының табигыять ф-тлары студентлары өчен уку практикалары уздырыла. Казан ун-ты доценты А.К.Гусев тарафыннан җентекләп өйрәнелә.

Әд.: Геология Приказанского района: Путеводитель по полигонам учеб. геолог. практик. К., 2007.

ЧЕ́РЗОР Прокопий Петрович (17.11.1899, Казан губ., Цивильск өязе Шигали а. — 25.4.1976, Казан), хакимият-хуҗалык эшлеклесе. СССР «Колхозцентр»ының югары колхоз мәктәбен тәмамлый (Мәскәү, 1931). Хезмәт эшчәнлеген 1915 елда Тамбов дары з-дында төрле эшләр башкаручы буларак башлый. 1924–27 дә Шигали авыл советы рәисе (Биектау р-ны). 1927–30 да «Татпчёлоцентр» идарәсе рәисе, «Молколхозцентр»ның Татарстан бүлеге идарәчесе (1930 дан). 1938–40 та ТАССР игенчелек халык, 1940–47 — ТАССР ит һәм сөт сәнәгате халык комиссары (1946 дан министр). 1947–50 дә «Заготзерно» респ-ка конторасы идарәчесе. 1951–57 дә Казан шәһәр сөт з-ды директоры. 1947–51 дә ТАССР ЮС депутаты. Медальләр б-н бүләкләнә.

И.Н.Афанасьев.

ЧЕРКА́СОВ Артём Рафаэлович (30.3.1971, Казан), химик-органик, химия фән. д-ры (2000). Казан ун-тын тәмамлый (1993), шунда ук эшли, 1999 елдан Ванкувер тикшеренү үзәгендә (Канада). Хезмәтләре органик кушылмаларны һәм биол. актив матдәләрне модельләштерүгә һәм теоретик алымнар яр дәмендә тикшерүгә, геномны анализлауга карый. Ч. өч үлчәүле корреляцион анализны ягъни органик һәм элементорганик кушылмаларның реакция мөмкинлеген теоретик яктан бәяләү алымын тәкъдим итә. Аны куллану антибиотиклар, паразитларга каршы препаратлар һәм шешкә каршы матдәләр өлкәсендә бер төркем яңа дару прототиплары эшләргә мөмкинлек тудыра. Тикшеренүләр нигезендә Канадада һәм АКШта ике фарм. ширкәте оештырыла. Уйлап табуга 41 патенты бар.

Х е з м.: Корреляционный анализ в химии свободных радикалов // Успехи химии. 2001. Т. 70, вып. 1 (автордаш); Bioinformatics Tools for Researching Protein Interaction Networks // Genome Research Advances. N.Y., 2007 (автордаш); Identification of novel antibacterial peptides by chemoinformatics and machine learning // J. of Medicinal Chemistry. 2009. V. 52 (автордаш).

ЧЕРКА́СОВ Леонид Иванович (26.3.1836, Оренбург губ. — 1907 елдан соң), хәрби һәм дәүләт эшлеклесе, генерал-майор (1880). Чыгышы б-н Казан губернасы дворяннарыннан. Хәрби-юридик академия тәмамлый (С.-Петербург, 1869). 1855 тән хәрби хезмәттә. 1861–64 тә Владимир губернасы Судогодский өязенең җәмәгать арадашчысы. 1864–67 дә Витебск губернасы Полоцк җәмәгать съезды рәисе. 1869–71 дә Вильно хәрби округы мәхкәмәсе хәрби судьясы, 1871–72 дә Казан хәрби округы мәхкәмәсе хәрби прокуроры ярдәмчесе, 1872–74 тә хәрби судьясы, 1874–80 дә (бүленеп) Варшава хәрби округы хәрби судьясы. 1878–79 да Тырново аерым кыр хәрби мәхкәмәсе рәисе һәм бер үк вакытта Болгариядәге рус оккупация гаскәрләре каршындагы кыр хәрби мәхкәмәсе хәрби судьясы. 1880–82 дә Вологда, 1882–84 тә Казан губернаторы. 1883–84 тә Казан губернасында ачлык б-н көрәшне җитәкли. Ул эшләгән елларда Казанда «Волжский вестник» г-тасы (1883 тән) нәшер ителә башлый. 1884–87 дә Полоцк губернаторы. 1887 дән Петербург губернасы Яңа Ладога өязенең шәрәфле җәмәгать судьясы.

Әд.: Долгов Е.Б. Казанские губернаторы — главы и хозяева «врученной на смотрение губернии» // Проблемы истории государственного управления: Государственный аппарат и реформы в России. СПб., 2003.

Е.Б.Долгов.

ЧЕРКА́СОВ Николай Григорьевич (3.10.1938, Красноярск краеның Большемуртинск р-ны Российка а. — 22.5.1991, Түбән Кама), инженер-химик-технолог, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1989). Томск политехник ин-тын тәмамлый (1960). 1963–69 елларда Пермь, Красноярск шәһәрләренең химия пр-тиеләрендә. 1969–91 дә «Түбәнкамаснефтехим» ҖБдә: инженер-технолог, цех башлыгы урынбасары, башлыгы, техник бүлек башлыгы. Дәүләт бүләге ясалма каучук мономерларын җитештерүне интенсификацияләүнең яңа алымнарын эшләүдә һәм гамәлгә кертүдә катнашканы өчен бирелә. Медаль б-н бүләкләнә.

ЧЕРКА́СОВ Рафаэль Әсхәт улы (20.11.1939, Казан), химик-органик, химия фән. д-ры (1976), проф. (1981), ТРның, РФнең атказ. фән эшлеклесе (1995, 2002), Казан ун-ты атказ. профессоры (2010). Казан ун-тын тәмамлый (1962), шунда ук эшли: элементорганик кушылмалар фәнни-тикшеренү лаб-ясе мөдире (1974–88), югары молекуляр һәм элементорганик кушылмалар каф. мөдире (1988–2009), каф. профессоры (2009 елдан). Хезмәтләре элементорганик кушылмаларга (ЭОК) карый. Ч. фосфорның органик чыгарылмаларын алу ысулларын эшли, ЭОКның реакцияләр механизмын тикшерә һәм структура, реакция мөмкинлеге һәм ЭОК үзлекләре арасындагы үзара бәйләнешне бәяләү (микъдари кимәлдә) алымнарын тәкъдим итә. Затлы, сирәк очраучы һәм чәчелгән элементларга, органик һәм минераль к-талар һәм табигый-технол. чыгышлы башка объектларга караган яңа югары нәтиҗәле, селектив фосфорорганик сыекчалы һәм мембраналы экстрагентларның үзлекләрен синтезлап тикшерә. Уйлап табуга 70тән артык патенты бар.

Х е з м.: 1.3.2-дигетерофосфацикланы, содержащие шестикоординированный атом фосфора // Успехи химии. 1987. Т.56, вып. 2 (автордаш); Реакция Кабачника-Филдса: синтетический потенциал и проблема механизма // Успехи химии. 1998. Т. 67, вып. 10 (автордаш); N-Acylamidophosphinates: structure, properties and complexation towards main group metal cations // Current Organic Chemistry. 2006. V. 10, N 1 (автордаш).

ЧЕРКА́СССКИЙ Эмиль Давыдович (16.7.1873, Киев — 19.7.1955, Казан), композитор, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе (1944). 1893 елда Киев музыка уч-щесен (фортепиано һәм дирижёрлык класслары) тәмамлый, 1907 дә Мәскәүдә М.Ипполитов-Иванов һәм В.Сук җитәкчелегендә композитор һәм дирижёр буларак стажировка уза. 1890–98 дә — оперетта труппасы (Житомир ш.), 1898–1904 тә Минск, Казан, Саратовта опера труппалары хормейстеры һәм дирижёры. Иҗтимагый һәм сәяси эшчәнлек алып бара, ш.и. 1906 да Краснодарда Халык ун-ты каршында эшчеләр өчен музыка курслары оештыра, «Дон» эшчеләр г-тасын чыгаруда катнаша; 1918 дә шунда ук Оркестрантлар берлеген оештыра; Эшчеләр депутатлары советы составына сайлана. 1920 дән Ч. Сталинабад, Омск, Днепропетровск, Киров һ.б. шәһәрләрдә драма театрларының муз. җитәкчесе һәм дирижёры булып эшли. 1940–48 дә — *Казан Зур драма театры* дирижёры. Ч. иҗатының төп жанры — театраль музыка. Казанда яшәгән чорында композитор башка муз. жанрларга да мөрәҗәгать итә һәм шактый зур әсәрләр тудыра: «Рашуа алдындагы төн» («Ночь перед Рождеством», Н.Гогольнең шул исем. әсәре буенча, 1938) муз. комедиясе, «Татар темаларына ике эскиз» («Два эскиза на татарские темы», 1945), «Кавказ сюитасы» («Кавказская сюита», 1946); «Иван Грозный» һәм «Отелло» увертюралары (1946), симф. оркестр өчен «Иске стильдәге сюита» («Сюита в старинном стиле», 1948); «Юбилей увертюрасы» («Юбилейная увертюра»; ТАССРның 30 еллыгына, 1950), Б.Зернит шигыренә «Героик кантата» («Героическая кантата», 1952), М.Лермонтов шигырьләренә романслар циклы һ.б.

Әд.: Композиторы Советского Татарстана. К., 1957.

ЧЕРКЕ́Н елгасы, Идел алдында, Зөя елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 12 *км*. Бассейнының мәйданы 41,9 *км*^{2}. Идел калкулыгыннан, Буа р-нында ага. Елга башы Зур

Фролово авылыннан 6 *км* көнчыгыштарак, тамагы Күл Черкене авылыннан 3 *км* көньяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 170 *м*, тамагыныкы — 64 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 10%. Ч.нең 1 дән 3,6 *км* га кадәр озынлыктагы 6 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,6 *км*/*км*^{2}. Туенуы катнаш, кар сулары исәбенә шактый күбрәк. Җир асты сулары б-н туену модуле 1–3 *л*/*с*·*км*^{2}. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен ныкса егуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 114 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 100 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,02 *м*^{3}/*с*. Язын суы уртача каты (3–6 *мг-экв*/*л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв*/*л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг*/*л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг*/*л*. Елгада суының гомуми күләме 1,06 млн. *м*^{3} булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла. Зур Фролово авылы тирәсендә, Ч.нең уңъяк ярында православие диненә дәгеләрнең 2 изге урыны бар.

ЧЕРКИЛӘ́Р (Simuliidae), икеканатлылар отрядыннан бөҗәкләр семьялыгы. Вак (2–5 *мм*), соры, кара, кара-зәңгәр төстәге бөҗәкләр. Башы күкрәгенең аскы өслегенә бөгелгән. Ана затларда авыз аппараты чәнчеп-суыручы типтагы хортумчык, ата затларда шактый гына кыскарган. Якынча 1 мең төре билгеле, Россиядә 300 дән артык төре теркәлгән. Тиз агымлы елга үзәннәрендә һәм тайга зоналарында Ч. аеруча күп. ТРда канәчкеч Ч.нең 11 төренә тасвирлама бирелгән, алар арасында Schobaueria pusilla һәм Eusimulium aureum өстенлек алып тора. Ч.нең үсеше — тулы әверелешле. Кан суырып туйган ана затлар күкәйләрен су б-н юешләнүче ташларга, су үсемлекләренең яфраклары һәм сабакларына сала яки очып барганда суга ата. Ч. бер сезонда 1–3 буын бирәләр. Күкәй һәм личинка фазасында кышлыйлар. ТРда гомуми черки составында Ч. 30 дан (августта) 55% ка кадәр (май ахыры – июнь башы) тәшкил итәләр. Ч.нең кешеләргә һөҗүме май ахырыннан сентябрь уртасына кадәр дәвам итә, пик вакыты май ахыры — июнь башына һәм июль–августның беренче яртысына туры килә. Тәүлек дәвамында да ш.у. 2 иң актив вакыты: иртәнге (4–6) һәм кичке (18–21) сәгатьләрдә күзәтелә. Дымлылык чагыштырмача югары, җилсез һәм һава темп-расы 10–15 °С булганда көн дәвамында һөҗүм итәргә мөмкиннәр. Ч. каты авырттырып тешлиләр. Күпләп һөҗүм иткәндә кешеләрдә җирле (тәннең тешләгән урыннарында), ш.у. гомуми хәлсезләнү һәм бизгәк реакцияләре тудыра, яшь йорт хайваннары арасында үлү очраклары да бар. Ч. җепсыман бөжралы суалчаннар — онхоцеркалар (хайван һәм кешеләрдә онхоцеркоз авыруын китереп чыгаралар) личинкаларының арадаш хуҗаларры, ш.у. үзенчәлекле канәчкеч паразитларның (споровикларның иң гади классы), йорт кошлары авырулары (гемоспоридиозлар) һәм түләмә, түләрәмә һ.б.ны тудыручыларны механик йоктыручылар булып торалар.

В.А.Бойко.

ЧЕРМОШЕ́НЦЕВ Сергей Фёдорович (23.1.1956, Казан), мәгълүмати технологияләр өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (2005), проф. (2006). 1979 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли, электрон-хисаплау аппаратурасын конструкцияләү һәм җитештерү каф. профессоры (2005–10), Гыйльми-пед. кадрларны әзерләү һәм аттестацияләү идарәсе башлыгы (2005–07), электрон-хисаплау чараларын проектлауның мәгълүмати технологияләре каф. мөдире (2010 нан). Хезмәтләре электрон чараларның электромагнит тәэсирләргә технологияләренә карый.

Х е з м.: Компонентные модели межсоединений при автоматизированном проектировании электронно-вычислительных средств // Вестн. Казан. технол. ун-та. 1996. № 4; Электромагнитная совместимость печатных плат цифровых электронных средств // Информационные технологии. 2001. № 4; Методы и средства анализа и прогнозирования электромагнитных излучений от электронных средств // Информационные технологии. 2003. № 11 (автордаш).

ЧЕРНЕ́ЦКИЙ Василий Александрович (6.8.1913, Херсон губ. Григорьевка а. — 29.3.1980, Казан), актёр, ТАССРның халык артисты (1968). Сәхнә эшчәнлеген 1931 елда Симферополь шәһәре театрында башлый, шул ук вакытта әлеге театр студиясендә укый.



В.А.Чернецкий Кирсанов ролендә («Яңа кешеләр», Н.Г.Чернышевскийның «Нәрсә эшләргә?» романы буенча).

1934–49 да Чиләбе, Горький, Липецк, Сочи, Краснодар, Грозный, Симферополь шәһәрләрендәге драма театрлары актёры, аларның сәхнәләрендә Бенволио, Меркуцио, Кассио («Ромео һәм Джульетта», «Отелло», У.Шекспир), Калаф («Принцесса Турандот», К.Гоцци), Незнамов, Пётр («Гаепсездән гаепләләр», «Урман», А.Н.Островский), Яровой («Любовь Яровая», К.А.Тренёв) кебек зур рольләр башкара. 1949 дан Казан яшь тамашачылар театры трупасында. Матур тышкы кыяфәтле, сирәк очрый торган аһәңле тавышка ия актёр булараk, Ч. Казан сәхнәсендә тәүге рольләреннән үк (Инсаров — «Бер көн элек», И.С.Тургенев романы буенча, Саша иптәш — «Качу», Д.А.Щеглов) әйдәп баручы актёрларның берсенә әверелә. Ч., нигездә, романтик рухтагы рольләр башкара. Аның геройлары тирән акыллы, төпле, саф хисле, эмоциональ булулары б-н аерылып тора: Кирсанов («Яңа кешеләр», Н.Г.Чернышевскийның «Нәрсә эшләргә?» әсәре буенча), Карл Моор, Ферди-нанд («Юлбасарлар», «Мәкер һәм мәхәббәт», Ф.Шиллер), король Марк («Тристан һәм Изольда», А.Я.Бруштейн), Анжольрас («Хоккусызлар», В.Гюго романы буенча). Актёр



В.А.Чернецкий.

Борис Богатырёв, Фёдор («Тормыш сәхифәләре», «Шатлык эзләгәндә», В.С.Розов), Олег («Мог җизалы эретмә», В.М.Киршон), Костя Белоус («Шәһәрдә таң ата», А.Н.Арбузов) рольләрендә замандашларының характер үзенчәлекләрен яктырта, персонажларның рухи дөньяларын ачуда тирән психологизмга омтылып, сәнгатьчә детальләрдән оста файдалана. «Революция исеме белән» спектаклендә (М.Ф.Шатров пьесасы буенча) Ч. иҗат иткән Ленин образы югары актёрлык осталыгы б-н аерылып тора. Кречинский («Кречинский-ның туе», А.В.Сухово-Кобылин), Паратов, Крутицкий («Бирнәсез кыз», «Һәр акыл иясен дә гадилек җиңәр», А.Н.Островский), Иван Коломийцев («Соңгылар», М.Горький) образларын ышандырырлык итеп төрле яклап ача. Актёр иҗатында тирән психологизм б-н сугарылган образларны ачуда тормышчан хаклык эчке пафос һәм романтизм б-н үрелеп бара. Медальләр б-н бүләкләнә.

Әд.: Народные артисты. К., 1980; Благов Ю. Казанский театр юного зрителя. К., 1986.

Ю.А.Благов.

ЧЕРНЕЦОВЛА́Р, нәкышьчеләр, рәсем ясаучылар, литографлар. Бертуган Григорий Григорьевич (12.11.1802, Кострома губ. Лух ш. — 8.6. 1865, С.-Петербург) һәм Никанор Григорьевич (21.7.1805, Кострома губ. Лух ш. — 11.1. 1879, С.-Петербург) — икона язучы уллары. Язучы һәм рәссам П.П.Свиньин булышлыгы б-н С.Петербургка күчәләр. Петербург САн, М.Н.Воробьёв остаханәсен тәмамлыйлар (1827). Нәкышь сәнгате академиклары (1831 һәм 1832). Рус пейзажында романтик юнәлеш вәкилләре, перспективада сурәтләнгән архит-ра һәм күренеш пейзажы авторлары. 1837 елдан бертуган Ч. бергә эшли. 1838 нең 22 маеннан 18 ноябренә кадәр Ч., аларның кече энесе Поликарп һәм шәкертләре А.Иванов Рыбинск шәһәреннән Идел буенча елга тамагына кадәр махсус җиһазландырылган көймә-остаханәдә сәяхәт итәләр; Ч. күп рәсемнәр, майлы буяу б-н этюдлар,



Г.Г.Чернецов. «Казан губернасында Идел буендагы Сөйки таулары күренеше». 1840. Рус музее.

планнар һәм караламалар ясыйлар һәм соңыннан алар нигезендә Идел ярларындагы күренешләрне һәм архит-ра истәлекләрен чагылдырган картиналар язалар. Ч. Казан күренешләрен, Казан Кремлен, Болгардагы Зур һәм Кече манараларны, Кара һәм Ак пулатларны, Көнчыгыш төрбәне рәсемгә төшерәләр. 1938–51 дә алар шул нигездә Иделнең ике як яры да сурәтләнгән, чорнап куела торган уникаль панорама иҗат итәләр (озынлыгы 746, биеклеге 2,5 *м*, башта Эрмитажда, хәзер С.-Петербургта Россия милли китапханәсендә саклана). 1840 елларда алар башлыча чит илдә эшлиләр. Ч.ның «Казан губернасында Идел күренеше» һәм «Казан губернасында Иделдә Сөйки таулары күренеше» (икесе дә — 1840) картиналары Рус музеенда, «Идел буйлап сәяхәт» («Путешествие по Волге», 1970) көндәлек-китабы Эрмитажда, Ч.ның әсәрләре ш.у. Третьяков галереясында, А.С.Пушкин исем. Дәүләт сынлы сәнгать музеенда (Мәскәү), ТР Дәүләт сынлы сәнгать музеенда һ.б. тупланмаларда саклана.

Әд.: Чернецовы Г. и Н. Путешествие по Волге. М., 1970; Никольская Е. Братья Чернецовы. М., 2002; Государственный музей изобразительных искусств Республики Татарстан: Русское искусство XVII – начала XX века. Живопись: Каталог. К., 2005.

Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.

ЧӘ́РНИКОВО авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 24 *км* көнбатыштарак, Нокса елгасы буенда. 2010 елда 7 кеше (руслар) яши. 1565–67 ләрдән Починок Енгилдеевской буларак мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Починок Новоцарёвской исеме б-н дә билгеле. Авыл башта Казан Спас-Преображение монастырена карый, 17 йөздә үзәк биләмә авыл була. Хәзерге исеме алпавыт Ф.С.Черников-Онучин исеме б-н бәйле. Халкының төп шөгыле — игенчелек, терлекчелек; кайбер гаиләләр умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ч.да су тегермәне, вак-тәякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 106,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кощаково волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Воскресенский, 1927 нең 1 августыннан — Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Столбище, 1959 ның 26 мартыннан — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән Питрәч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 41 ир-ат; 1859 да — 81, 1897 дә — 99, 1908 дә — 108, 1920 дә — 121, 1926 да — 176, 1949 да — 132, 1958 дә — 156, 1970 тә — 62, 1979 да — 31, 1989 да — 19, 2002 дә — 11 кеше.

ЧЕРНО́В Владислав Моисеевич (24.11.1961, Төмән ш.), генетик, биол. фән. д-ры (1998), проф. (2007). Казан ун-тын тәмамлый (1983). 1987 елдан РФА КГҮнең Биохимия һәм биофизика ин-тында: патогенезның молекуляр нигезләре лаб-ясе мөдире (1993 тән). Хезмәтләре микробиологиягә, молекуляр һәм күзәнәк биологиясенә карый. Ч. үсемлекләрдә микоплазмаларның молекуляр-генетик тоткарлану механизмын һәм аларның тирәлекнең төрле шартларына яраклашуын билгели; микоплазмаларны ачыклау өчен молекуляр-генетик зондлар конструкцияли. Уйлап табуга 5 авторлык таныклыгы һәм 1 патенты бар. СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Взаимодействие микоплазм с иммунной системой животных и человека // Цитология. 2001. Т. 43, №3 (автордаш); Микоплазмы: молекулярная и клеточная биология, взаимодействие с иммунной системой млекопитающих, патогенность, диагностика. СПб., 2002 (автордаш); Адаптация микоплазм к стрессорам: у некультивируемых форм Mycoplasma gallisepticum S6 определяются нуклеотидные последовательности, не регистрируемые у вегетативных форм // Молекулярная биология. 2009. Т. 43, № 4 (автордаш).

ЧЕРНО́В Игорь Анатольевич (13.11.1937, Казан), үсемлекләр физиологы, биол. фән. д-ры (1995), проф. (1997), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2003). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1961), Казакъстан ССРның Кустанай өлкәсе Некрасов исем. с-зында агроном булып эшли. 1963–2003 елларда Казан ун-тында, Ботаника бакчасы директоры (1985 тән), бер үк вакытта үсемлекләр физиологиясе каф. мөдире (1995 тән). Хезмәтләре терлек азыгы культуралары физиологиясе, биохимиясе һәм агроэкологиясенә карый. Ч. тарафыннан үткәрелгән интродуцент үсемлекләрнең физиол.-биохимик яраклашуын тикшерү нәтиҗәләре аларны уңайсыз табигать-климат шартларында эшкәртүне камилләштерергә мөмкинлек бирә. Җитештерелүче продуктларны эшкәртү һәм куллануның нәтиҗәле технологияләрен тәкъдим итә. Уйлап табуга 6 патенты бар.

Х е з м.: Физиология хлоропластов: Учеб. пособие. К., 1981; Амарант — фабрика белка. К., 1991 (автордаш); Амарант: физиолого-биохимические основы интродукции. К., 1992; Специфика взаимодействия углеродного и азотного метаболизма у амаранта. К., 2006 (автордаш).

ЧЕРНО́ВА Ольга Александровна (28.10.1960, Казан), генетик, биол. фән. д-ры (1998), проф. (2009). Казан ун-тын тәмамлый (1983). 1987 елдан РФА КГҮнең Биохимия һәм биофизика ин-тында, әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (1998). Хезмәтләре күзәнәк биологиясенә, микробиологиягә, молекуляр биологиягә карый. Ч. кешедә микоплазмаларның молекуляр-генетик тоткарлану механизмнарын һәм аларның тирәлекнең тискәре шартларына яраклашуын билгели; микоплазмаларны ачыклау өчен диагностик молекуляр-генетик зондлар конструкцияли. Уйлап табуга 7 авторлык таныклыгы һәм 1 патенты бар. Халыкара микоплазмологлар җәмгыяте әгъзасы (1990 нан). СССР ВДНХсының көмеш медале б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Взаимодействие микоплазм с иммунной системой животных и человека // Цитология. 2001. Т. 43, №3 (автордаш); Микоплазмы: молекулярная и клеточная биология, взаимодействие с иммунной системой млекопитающих, патогенность, диагностика. СПб., 2002 (автордаш).

ЧЕРНОКА́ЛЬСКИЙ Борис Дмитриевич (17.2.1932, Кырым өлкәсенең Джанкой ш. — 28.12.1978, Казан), химик-органик, химия фән. д-ры (1970), проф. (1971). Казан химия-технол. ин-тын тәмамлый (1954), 1961 елдан шунда ук эшли, 1971 дән органик һәм нефтехимик синтез нигезләре технол. каф. мөдире. 1957–60 та Бөтенсоюз фәнни-тикшеренү кинофотоин-тының Казан ф-лында. Хезмәтләре мышьякорганик кушылмаларга карый. Ч. кислородлы мышьяк кушылмаларының реакция мөмкинлеген тикшерә, чыгарылмаларын синтезлау алымнарын тәкъдим итә һәм физик-химик үзлекләрен өйрәнә. Мышьякның гетероциклик чыгарылмалары үзлекләрен синтезлап тикшерә, аларны алу технологиясен эшләү б-н шөгыльләнә (югары биол. активлыгы аркасында бу чыгарылмалар утырткыч кушылмалар буларак диңгез судноларының суасты өлешен биокоррозиядән, майлаучы-суытучы сыекчаларны, технол. майлагычларны һәм үзагачны биотаркалудан, әйләнешле су тәэминаты системаларын биомасса үсүдән саклау өчен кулланыла). Ч. антигельминт активлыкка ия, буй үсүне







Чернецовлар. 1. «Зур манара»; 2. «Ак пулатлар»; 3. «Хан мунчалары». Барысы да – 1838.

стимуллаштыра торган мышьяк кушылмаларын; бозауларда бронхопневмония чирен дәвалау чараларын, ш.у. шешкә һәм вируска каршы препаратлар эшли. Уйлап табуга 20 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Методы синтеза и реакции эфиров кислот мышьяка // Реакции и методы исследования органических соединений. М., 1964. Кн. 13 (автордаш); Влияние заместителей на реакционную способность мышьякорганических соединений // Строение и реакционная способность органических соединений. М., 1978 (автордаш); Структура и реакционная способность пятихлористого фосфора // Успехи химии. 1978. Т. 47, № 8 (автордаш).

Әд.: Выпускники — гордость Казанского технологического университета: Краткий биогр. справ. К., 2009. *В.Г. Абзалова.*

ЧЕРНОПЕ́НЬЕ авылы, Казанның Совет р-нында, Нокса елгасы буенда. 1565–67 еллардан рус чыганакларында Починок новый под Чёрным пнём исеме б-н билгеле. Халкы башта Казан Спас-Преображение монастырена карый, 1764 тә — экономик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә; игенчелек, терлекчелек, яшелчә үстерү, умартачылык, экипаж ясау, он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ч.да чиркәү-приход мәктәбе (1894 тә ачыла), җил тегермәне, 3 ярма яргыч, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 872,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кощаково волостенда, 1920 дән ТАССР-ның Арча кантонында. 1927 нең 1 августын нан — Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Столбище, 1959 ның 26 мартыннан — Питрәч р-нында, 2007 нең 28 декабреннән Казанның Совет р-ны карамагында. Халык саны: 1782 дә — 88 ир-ат; 1859 да — 312, 1897 дә — 398, 1908 дә — 390, 1920 дә — 446, 1926 да — 631, 1949 да — 239, 1958 дә — 180, 1970 тә — 65, 1979 да — 41, 1989 да — 9, 2002 дә — 4 кеше (руслар).

«ЧЕРНОСО́ТЕНЕЦ» («Карагруһчы»), атналык иҗтимагый-сәяси газета. 1906 елның ноябреннән 1907 нең мартына кадәр Казанда рус телендә нәшер ителә. Башта (1 нче һәм 2 нче саннар) нашире Казан ун-ты профессоры В.Ф.*Залесский* була, мөхәррире — китап сатучы П.К.Кувшинов; 3 нче саннан Залесский ике вазифаны да башкара. Шәһәр халкы өчен атап чыгарыла (шул ук вакытта алар тарафыннан авыл кешеләре өчен «*Сошники*» г-тасы басыла). Консерватив-карагруһчы юнәлеш тота, иҗтимагый-сәяси, аграр, милли һ.б. мәсьәләләр буенча Казанның уң монархист оешмалары карашларын пропагандалый. Язмаларның күп өлеше Залесский каләме б-н языла: «Нәрсә ул «Карагруһ»?» («Что такое «Черная сотня»?»), «Парламентаризм һәм аны Көнбатышта бәяләү» («Парламентаризм и его оценка на Западе»), «Японнар күзлегеннән чыгып караганда хокук нәрсә ул?» («Что такое право с японской точки зрения?») һ.б. Авторлары арасында Казан карагруһчылары С.А.Соколовский («Яһүдләр мәсьәләсенә карата» — «К еврейскому вопросу»), Р.В.Ризположенский һәм Ф.С.Гребенщиков аерылып тора. Газетада 2 нче Дәүләт Думасына сайлауларда карагруһчы оешмалар вәкилләре өчен тавыш бирергә чакырып язган мөхәррир мәкаләләре, агитация-пропаганда материаллары һәм чыгышлары, монархик эчтәлектәге шигырьләр (ш.и. Л.А.Кологривованыкы), җирле уң монархист оешмалар җыелышлары, хисаплары, Казан кадетлары һәм октябристларының сәяси белдерүләренә мөрәҗәгатьләр һәм шәрехләмәләр, «Рус кешеләреннән Дәүләт Думасына сайлаучылар исемлеге» («Список выборщиков в Государственную Думу от русских людей») һәм «Киевта рус кешеләренең 3 нче Бөтенроссия съезды турындагы хисап» («Отчёт о 3-м Всероссийском съезде русских людей в Киеве») басыла. Газета шәһәрнең түбән катлавы өчен атап чыгарыла, әмма, акча җитмәү сәбәпле, 2 нче Дәүләт Думасына сайлаулардан соң чыгудан туктый.

И.Е.Алексеев.

ЧЕРНОЯ́РОВ ПАССАЖЫ́, Казандагы архит-ра истәлеге. 1900–01 елларда арх. Г.Б.*Руш* проекты буенча сәүдәгәр Д.И.Чернояров варислары А.Д. һәм Д.Д.Черноя ровлар Воскресенский урамында (хәзер Кремль ур., 21) төзетә. Беренче катында кибетләр булган өч катлы табыш йортының структурасына ике катлы кирпеч флигель (хәзергә кадәр сакланмаган) дә керә. Ч.п. бинасы каршы ягы Черек күл ягына чыга торган ишегалдының бөтен киңлеге буенча сузыла. Ишегалдының бу өлешендә бакча була. 1901 дә арх. Г.Б.Руш проекты буенча бер катлы кирпеч



Казанда Чернояров пассажы. Архитекторы Г.Б.Руш. 1900–01.

флигель урынына участокның уңъяк чиге буйлап озынга сузылган табыш китерә торган квартиралары булган ике катлы кирпеч бина төзелә. Өч катлы Ч.п. бинасының үзәге булып яктырту фонаре б-н капланган һәм урамнан вестибюль б-н тоташтырылган баскыч читлеге тора. Аның ике ягында Воскресенский урамы ягыннан аерым керү ишекләре булган кибетләр тезелеп китә. Икенче һәм өченче катларда квартиралар урнашкан. Бинаны элек булмаган ике корылма реконструкцияләү кергеп ишегалдты фасадын тигезсез итә. Урам ягы фасады үзәктә һәм ике ян-якта чарлак тәрәзәләре булган, өзекле фронтон б-н төгәлләнгән ризалитлар б-н ныгытылган. Ризалитлар бинаның үзәк түбәсе өстендә күтәрелгән үзәк һәм ян-яктагы күләмнәргә туры килә һәм валюта рәвешендәге зур терәкләрдәге декоратив очлымнар б-н төгәлләнә. Катлаулы ордерлы ярымтүгәрәк колонналар рәвешендәге ризалитлар тәрәзәләре бизәкле йөзлекле фасад үзәгенә симметрияле урнаштырылган. Кибет ишекләре нурсыман фронтонлы калын агач кысаларда урнаштырыла. Ч.п.ның Воскресенский урамы ягындагы төп фасады штукатурка б-н капланган һәм төрле төсләргә буялган. 1912 дә арх. С.В.*Бечко-Друзин* проекты буенча урам ягындагы фасад үзгәртелә, аның беренчел бизәлеше югала: ризалитларның өченче каттагы ярымколоналары, пилястра бизәлеше, түбәнге катлардагы ярымколонналар юнып алына, өске кәрниз алмаштырыла; кибет ишекләренең агач кысалары алына һ.б. Үзәк ризалитның беренче каты ялтыравык кирпеч б-н тышлана, икенчесе зур балкон б-н тулыландырыла, өченчесе сылап ясалган күпертмә бизәкләр б-н бизәлә. Башта икенче һәм өченче катларда шәһәрнең иң яхшы кунакханәләренең берсе «Үзәк номерлар», С.С.Фельзернең фотоателесы, конторалар, кибетләр, ш.и. Ф.Х.Грахенең фотография аппаратлары һәм кирәк-яраклары кибете урнаша. Ч.п.ның атамасы аның якты лык гөмбәзе, кибетләре һәм Александр пассажы янына урнашу аналогиясеннән булырга мөмкин дип фаразлана.

Совет хакимияте елларында Ч.п. национализацияләнә. Беренче катта дәүләт кибетләре, кунакханә номерлары урынына коммуналь фатиралар урнаша. Ч.п.ның әүвәлге интерьерыннан (күпертмә бизәкләрне өлешчә югалтып) бары тик баскыч мәйданчыгының эчке бизәлеше сакланып кала. Бинаның фасадына зыян килә. Урам як фасадының беренче каттагы бизәлеше югала. Кибет тәрәзәләре һәм ишекләре киңәйтелеп, витрина кыяфәтенә китерелә. Ризалитлары ян күләмнәренә һәм бинаның ишегалды ягына — дүртенче кат, төп бинага галерея б-н тоташтырылган ишегалды флигеленә өченче кат өстәп салына. Кибет складларына кереп-чыгып йөрү өчен ишегалды ягындагы фасадның беренче катына түгәрәк а́ркалы 7 ишек эшләнә. Бинаның реконструкцияләнгән өлешләрендә балконнар, яңа тәрәзәләр, ишекләр барлыкка килә. 1980 еллар ахырында арх. С.Ә.Мамлиева-Козлова тарафыннан яңадан төзекләндерү эшләре башкарылып, бинаның төп фасадында ризалитларда балконнар һәм өлешчә күпертмә бизәкләр торгызыла. 2000 еллардан Ч.п. бинасы, беренче каттагы беркадәр мәйданны исәпләмәгәндә, файдаланылмый һәм кулланылышка яраксыз хәлгә килә. 2016 елдан бинада төзекләндерү эшләре бара.

Әд.: Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982. *Д.А.Надыйрова.*

ЧЕРНУ́ШКА РАЙОНЫ́, *Пермь краеның* көньягында урнашкан. 1924 елда оештырыла. Мәйданы — 1676 *км*². Үзәге — Чернушка шәһәре (Пермьнән 231 *км* көньяк-көнбатыштарак). Халкы — 50652 кеше (2017). Татарлар саны: 1959 да — 2650, 1970 тә — 3413, 1989 да — 3616, 2002 дә — 4104, 2010 да — 4093 кеше. Башлыча, район үзәгендә һәм Сулмаш авылында (18 йөздән мәгълүм) яши-

ләр. Ч.р.нда һәм Чернушка шәһәрендә татар иҗтимагый үзәкләре, Чернушка шәһәрендә Балалар иҗаты үзәге җирлегендә «Мирас» клубы, «Яшьлек» сәнгать-фольклор ансамбле эшли. 2008 дән Сулмаш авылында мәчет, җирле гомуми белем бирү мәктәбендә татар теле укытыла. Район үзәгендә һәм Сулмаш авылында ел саен Сабан туе үткәрелә. Ч.р.нда тел белгече Х.Г.*Госман* туган.

ЧЕРНЫШЕ́ВСКИЙ Николай Гаврилович (12.7.1828, Саратов ш. — 17.10.1889, шунда ук), революционер-демократ, фикер иясе, философ, язучы. 1856–62 елларда «Современник» ж-лы җитәкчеләренең берсе. «Нәрсә эшләргә?» («Что делать?», 1863), «Пролог» (1869) романнары авторы. Саратов семинариясендә укыган елларда (1842–45) проф. Г.С.Саблуков җитәкчелегендә татар телен өйрәнә, Саратов губернасының татар чыгышлы топонимнарын тикшерә, татар-рус кулъязма сүзлеген (1200 сүз) төзи. Ч. патша хөкүмәтенең колонизаторлык сәясәтенә каршы чыга, Россиядәге милли хәрәкәт һәм милли проблемалар б-н кызыксына. В.А.Сбоевның татар халкын киная б-н тасвирлаган «Казан губернасы крәстияннәренең тормышы турында» («О быте крестьян Казанской губернии», 1856) брошюрасын тәнкыйтьләп чыга. Н.Бергның «Төрле халыкларның җырлары» («Песни разных народов», 1854) мәкаләсен, А.Ф.Гильфердингның «Славян теленең санскрит теле белән үзара охшашлыгы-якынлыгы турында» («О сродстве языка славянского с санскритским», 1854) китабын өйрәнеп, Ч. милли тематиканы тикшергәндә тенденциозлык һәм кимсетеп карау чагыла дип билгели. «Философиядә антропологик принцип» («Антропологический принцип в философии», 1860) хезмәтендә Ч., рус галимнәреннән беренчеләрдән буларак татарлар килеп чыгышының монгол версиясен шик астына куеп: «...хәзерге Кырым, Казан, Оренбург татарлары арасында Батый сугышчыларыннан чыккан бер генә кеше бар микән... хәзерге татарлар — руслар кебек Батый тарафыннан буйсындырылган, аңа кадәр шушы җирләрдә яшәгән кабиләләр нәселе... «татарлар» термины б-н яулап алучыларны гына түгел, ә буйсындырылган халыкны да атый башлыйлар, ул «болгарлар» терминын кысрыклап чыгара», — дип яза. Шәрекъ төсмерләре «Нәрсә эшләргә?» романында да бар — баш геройның Рахметов фамилиясе төрки «рәхмәт» сүзеннән ясалган. Бер фараз буенча, Рахметов образында нәселе татар ханзадәсе Ослам Бахметка барып тоташкан Саратов алпавыты П.А.Бахметевның кайбер чалымнары чагыла. Ч. 1850–64 тә берничә тапкыр Казанга килә. Аның карашлары татар мәгърифәтчеләре Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Г.Ильясиның дөньяга карашларына йогынты ясый, аларга Ч.ның милләт, милли тарих һәм мәдәният, халыклар тигезлеге мәсьәләләренә демократик карашлары якын була. Ч. татар эстетик фикере үсешенә дә тәэсир итә. Аның хезмәтләрен Г.Тукай укый, Х.Ямашев, Г.Коләхмәтов өйрәнәләр.

Әсәр.: Полное собр. соч.: В 15 т. М., 1939–53; Письма без адреса. М., 1979.

Әд.: Демченко А.А. Н.Г.Чернышевский: Научная биография: В 4 ч. Саратов, 1978–94; Абдуллин Я.Г., Фасеев К.Ф. Н.Г.Чернышевский и татарская общественная мысль. К., 1978; Н.Г.Чернышевский в воспоминаниях современников. М., 1982. *В.Н.Крылов.*

ЧЕРНЫШЁВ Валериан Андреевич (25.2.1893, Казан губ. Козьмодемьянск ш. — 3.12.1937, Куйбышев ш.), сәясәт эшлеклесе. Казан ун-тын тәмамлый (1915). Эсерлар партиясенә иярә. 1915–17 елларда Казанда антлы ышанычлы утырышчы ярдәмчесе. 1917 нең маеннан Вакытлы хөкүмәтнең Казан губернасы комиссары һәм бер үк вакытта губернаның җәмәгать иминлегe ком-ты рәисе. Окт. рев-циясеннән соң вазифасыннан читләштерелә. Репрессияләнә: 1937 нең 9 февралендә, «контрреволюцион пропаганда»да һәм «контрреволюцион оештыру эшчәнлеге»ндә гаепләнеп, Куйбышев шәһәрендә кулга алына һәм иң югары җәза чарасына хөкем ителә. Үлгәннән соң аклана.

Әд.: Белая книга: О жертвах политических репрессий. Самарская область. Самара, 1997. Т. 1.

ЧЕРНЫШЁВ Евгений Иванович (7.3.1894, Сембер ш. — 1979), тарихчы, тарих фән. канд. (1954). Казан ун-тын тәмамлый (1917). 1919–21 елларда Халык мәгарифе югары ин-тында (Казан), 1921–22 дә Казан пед. ин-тында , 1922–31 дә Шәрекъ пед. ин-тында укыта. Бер үк вакытта, 1921 дән, ТАССР Үзәк архивы мөдире, 1924–26 да әлеге архивның фәнни-техник бүлеге һәм халык хуҗалыгы секциясе мөдире. 1931–32 дә репрессиягә дучар ителә. 1932–37 дә «Динамо» суднолар верфендә икътисадчы. 1937–43 тә Казанда, Беренче Май р-нында урта мәктәпләр укытучысы. 1943–45 тә Казан ун-тының СССР тарихы кафедрасында. 1946–66 да СССР ФА Казан ф-лының Тел, әдәбият һәм тарих ин-тында. Хезмәтләре Казан төбәгенең 16 йөз — 20 йөз башы социаль-икътисади һәм сәяси тарихына, татар вакытлы матбугаты, Идел буе һәм Кырым халыклары тарихына, архив белеменә карый. «1878 елда Казан татарлары чуалышлары» («Волнения Казанских татар в 1878 г.», 1927), «1917 елда Казан төбәгендә крәстияннәр хәрәкәтләре тарихыннан» («Из истории крестьянских движений в Казанском крае в 1917 г.», 1928), «XVIII йөздә Россиядә эшчеләр хәрәкәте тарихыннан (Казан постаучылары көрәше)» («Из истории рабочего движения в России в XVIII в. (Борьба Казанских суконщиков»), 1930) һ.б. хезмәтләр авторы. «XVI йөздә рус-нугай мөнәсәбәтләре материалларына күзәтү» («Обзор материалов русско-ногайских отношений в XVI веке», 1925), «XVI йөздә Казан тормышы рәвеше» («Облик Казанской жизни в XVI в.», 1927), « XVI йөзнең икенче яртысы һәм XVII йөз татар авылы» («Татарская деревня второй половины XVI и XVII вв.», 1963), «Казан ханлыгы авыллары (писцовый кенәгәләр буенча)» («Селения Казанского ханства (по писцовым книгам)», 1971) хезмәтләрендә Татарстанның урта гасырлардагы тарихының аерым өлешләре яктыртыла. Ч. — «Татарстан АССР тарихы: Иң борынгы заманнардан безнең көннәргә кадәр» («История Татарской АССР: С древнейших времён до наших дней», 1968) дәреслеге авторларының берсе. Г.Ибраһимов хакында хатирәләр яза. Казан ун-ты каршындагы Археол., тарих һәм этнография җәмгыяте әгъзасы (1920–31), китапханәчесе (1924 тән), сәркәтибе (1927 дән) һәм Җәмгыять «Хәбәрләр»енең техник мөхәррире (1928–30). Татар халкын гыйльми өйрәнү җәмгыяте әгъзасы (1923–29), сәркәтибе (1925–26), Җәмгыять «Хәбәрче»сенең техник мөхәррире (1925–30).



Н.Г. Чернышевский.

Х е з м.: Без прошлого нет настоящего: об архивном деле в ТАССР // Вестн. просвещения. 1921. № 1; Восточная печать в эпоху реакции // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1925. Т. 33, вып. 3; Проф. Н.Н.Фирсов как историк Поволжья. К., 1930; Крестьянская реформа в Казанской губернии // Материалы по истории Татарии. К., 1948. Вып. 1.

Ю.А.Лексина, В.И.Шишкин.

ЧЕРНЫШЁВ Феодосий Николаевич (24.9.1856, Киев — 15.1.1914, С.-Петербург), геолог һәм палеонтолог, Петербург ФА академигы (1899). Тау эшләре ин-тын тәмамлый (С.-Петербург, 1880). 1882 елдан Геол. ком-тында, директор (1903 тән). 1900 дән ФАнең Геол. музее директоры (С.-Петербург). Пермь системасын 4 катламга бүлүне тәкъдим итә, Россиянең, шул. Казан губернасының геол. картасын төзи.

Х е з м.: Материалы к изучению девонских отложений России // Тр. Геолог. комитета. 1884. Т. 1, № 3; Верхнекаменноугольные брахиоподы Урала и Тимана // Тр. Геол. комитета. 1902. Т. 16, № 2.

ЧЕРНЫШЁВА Алефтина Юрьевна (17.6.1950, Казан), тел галиме, филол. фән. д-ры (1998), проф. (2000). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1972), Казан пед. уч-щесендә укыта. 1979 елдан — Казан ун-тында, бер үк вакытта Казан руханилар семинариясендә белем бирә. Хезмәтләре рус әдәби теленең семантик-лингвистик мәсьәләләренә, мәдәниятара коммуникацияләргә карый. Югары уку йортлары студентлары өчен рус теле буенча уку-укыту ярдәмлекләре авторы.

Х е з м.: Частицы в сложном предложении. К., 1997; Сложное предложение в разных речевых сферах. К., 1999; Синтаксис современного русского языка. К., 2008.

ЧЕРНЫШЁВКА (Крутояр) авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 8 *км* төньяктарак, Казансу елгасы буенда. 2010 елда 846 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 65% , татарлар — 30%) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек, яшелчә үстерү. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1920 елларда Чернышевский исем. Коммуна буларак нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Арча кантоны Калинин волостенда. 1930 ның 10 августын-

нан — Казан авыл р-нында, 1935 нең 10 февраленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1926 да — 23, 1938 дә — 160, 1949 да — 207, 1958 дә — 191, 1970 тә — 263, 1989 да — 697, 2002 дә — 837 кеше.

ЧЕРНЯ́ВСКИЙ Сергей Меерович (13.11.1939, Орёл өлкәсенең Локоть пос.), матем. модельләштерү өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (2004). 1963 елда Казан авиация ин-тын (хәзер Казан техник ун-ты) тәмамлый, шунда ук эшли (бүленеп), «Сокол» спорт авиациясе тәжрибә КБда (1969 га кадәр), аэрогидродинамика (1969–74), махсус матем. (1980 нән) кафедраларында эшли, проф. (2005 тән). 1974–80 дә Саратов политехника ин-ты ф-лында (Балаково ш.). Хезмәтләре динамик системаларны оптималь идарә итү алымнарына, тигезләмәләр системаларын чишүнең адаптив оптик системаларына һәм проекцион алымнарына карый. Ч. линияле системалар б-н оптималь идарә итү мәсьәләләре өчен моментлар алымын, проекция алымын һәм оптиканың фаза мәсьәләсен чишүдә моментлар алымын эшли. РФнең мактаулы югары мәктәп хезмәткәре (2005).

Х е з м.: Обобщённая 1-проблема моментов и её приложения // Тр. Казан. авиац. ин-та. 1971. Вып. 135; Оптимальное управление объектом при наихудшем распределении случайных параметров // Изв. вузов. Авиац. техника. 1978. № 2 (автордаш); К задаче о восстановлении волнового поля по объёмному изображению // Оптика атмосферы и океана. 1996. Т. 9, № 1.

ЧЕРНЯ́К Эрнст Васильевич (20.11.1934, Кырым, Бакчасарай ш. – 2016), философ, политолог, филос. фән. д-ры (1993), проф. (1996). Киев ун-тын тәмамлый (1957). 1965–68 елларда Караганда металлургия комб-ты каршындагы югары техник уку йортында укыта (Тимертау ш., Казакъстан ССР). 1968 дән Казан төзүче инженерлар ин-тында, 1996 дан Казан технол. ун-тында, 1998 дән Россия сәүдә-икътисад ун-тының Казан ин-тында. Хезмәтләре сәяси социол., политология тарихы мәсьәләләренә карый. РФнең югары һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре (2002). Медаль б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Критика буржуазных фальсификаций социалистического самоуправления народа. К., 1990; Политология. К., 2001 (автордаш); Земское самоуправление в России (на примере Казанской губернии). 1864 — март 1918. К., 2005.

ЧЕРТУ́Ш авылы, Яңа Чишмә р-нында, Яңа Чишмә авылыннан 19 *км* төньяк-көнбатыштарак, Чаллы елгасы (Чишмәнең сул кушылдыгы) буенда. 2010 елда 295 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, сәүдә б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ч.та 3 мәчет, мәктәп, тегермән, тимерче алачыгы, 8 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3447 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Каргалы волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чистай, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Армия, 1958 нең 23 маеннан — Яңа Чишмә, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1983 нең 26 апреленнән Яңа Чишмә р-нында. Халык саны: 1782 дә — 122 ир-ат; 1859 да — 897, 1897 дә — 1682, 1908 дә — 2165, 1920 дә — 1899, 1926 да — 1384, 1938 дә — 886, 1949 да — 532, 1958 дә — 451, 1970 тә — 506, 1979 да — 380, 1989 да — 256, 2002 дә — 327 кеше.

ЧЕСМА́ РАЙОНЫ́, *Чиләбе өлкәсенең* көньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан. 1935 елның 18 гыйнварында оештырыла. Мәйдане — 2670 *км*^{2}. Үзәге — Чесма авылы (Чиләбедән 219 *км* көньяк-көнбатыштарак). Халкы — 18800 кеше (2017). Татарлар саны: 2002 дә — 794, 2010 да — 731 кеше. Ч.р. терр-ясенә татарлар 1843 тә Новолинейный оборона р-нын үзләштерү б-н бәйле рәвештә урнаша башлыйлар. Бу чорда Березиновка станицасына нигез салына, беренче күченүчеләр арасында керәшен татарлар — *нагайбәкләр* дә була. 1903 тә Рәдүт посёлогына нигез салына, һәм 1904 тә монда казак катлавыннан 28 татар гаиләсе күченә. 1914 тә мәчет төзелә (1930 елларда ябыла). 1930 елларда «Кызыл Йолдыз» к-зы оештырыла (хәзер ҖЧҖ). 1926 га кадәр посёлокта татар башлангыч (1980 еллардан — урта) мәктәбе ачыла, аның каршында фольклор төркеме һәм «Чишмә» төбәк тарихы музее эшли.

Әд.: Чесминский район: Энцикл. Челябинск, 2009.

ЧЕТА́ЕВ Николай Гурьевич (32.11.1902, Казан губ., Лаеш өязе Карадулат а. — 17.10.1959, Мәскәү), механика өлкәсе галиме, физика-матем. фән. д-ры (1939), СССР ФА мөхбир әгъзасы (1943), Артиллерия фәннәре академиясе хакыйкый әгъзасы (1947), ТАССР-ның атказ. фән эшлеклесе (1940). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1924), шунда ук эшли, проф. (1930–40); 1929 елда Гёттинген ун-тында (Германия) фәнни командировкада. 1932 дә Казанда авиация ин-тын (Казан ун-ты аэродинамика бүлеге җирлегендә) оештыруны башлап йөрүче, директор урынбасары (1932–33), аэродинамика каф. мөдире (1932–36). 1940 тан Мәскәүдә: СССР ФАнең Механика ин-ты гомуми механика бүлеге мөдире, директор (1945–53); бер үк вакытта проф. (1940 тан), Мәскәү ун-тының теоретик механика каф. мөдире (1957 дән). Хезмәтләре хәрәкәт тотрыклылыгы мәсьәләләренә, аэродинамикага, аналитик механикага, дифференциаль тигезләмәләр теориясенә карый. Ч. чикле параметрлы механик системаларның тигезләнеше һәм хәрәкәте тотрыклылыгы теориясен (Ляпунов теориясе) механиканың гамәли мәсьәләрен чишү өчен кулланы мөмкинлеген исбат итә; тотрыклылык постулатын билгели, Лагранжның тигезләнеш тотрыклылыгы турындагы теоремасының кире теоремасын эшли. Гаусс принцибын нәголоном бәйләнеш очрагына кертә. Ж.А.Пуанкареның механикада Ли төркемнәре теориясенә караган матем. алымнарны куллану хакындагы нигезләмәләрен гомумиләштерә һәм үстерә. Төркемле үзгәрмәләрдә системалар динамикасы бүлеген булдыра, Кошиның матем. яктылык теориясе б-н голоном консерватив механик системаларның тотрыклы хәрәкәтләре арасында аналогия булуын ачыклый. Бу эшләре циклы өчен 1960 та Ленин бүләгенә лаек була (үлгәннән соң). «Прикладная математика и механика» ж-лы мөхәррире (1945–59). Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә. 1962 дән халыкара Четаев конференцияләре үткәрелә. Казанда бер урам аның исеме б-н атала. Казан техника ун-тының төп бинасында Четаев хөрмәтенә такта куела.



Н.Г. Четаев.

Х е з м.: Теоретическая механика. М., 1987; Устойчивость движения. М., 1990.

Әд.: К у з ь м и н П.А. Воспоминания о Н.Г. Четаеве // Очерки истории НИИ математики и механики им. Н.Г. Чеботарёва. К., 1989; Ш а к и р о в а Л.Р. Казанская математическая школа, 1804–1954. К., 2002.

ЧЕТВЕРГО́В Кузьма Сидорович (1847 — ?), Казанның 1 нче гильдия сәүдәгәре, иганәче. Сәүдә эше б-н мөстәкыйль рәвештә 1893 елдан шөгыльләнә. 1894 тә Ч. һәм аның берутуганы Семён Сидорович «Казанда бертуган К. һәм С. Четверговлар» сәүдә йортын оештыралар (устав капиталы 300 мең сум, ел-лык тулай сәүдә әйләнеше 1 млн. 500 мең сум): нефть һәм утын сату б-н шөгыльләнәләр, үзләренең пароходчылыгы була. Казан шәһәр думасы гласные булып сайлана. Дәүләт банкының Казан бүлекчәсе хисап ком-ты әгъзасы (1894 тән). Иске дин тарафдарлары хәрәкәтендә катнаша: Казанда аның акчасына иске дин тарафдарлары чиркәве төзелә (1906–09).

Әд.: С а л и х о в Р.Р., Х а й р у т д и н о в Р.Р., Х а й р у т д и н о в а Л.Ф. Очерки истории Национального банка Республики Татарстан. К., 2000.

ЧЕ́ТВЕРТЬ (чирек, дүрттән бер), Урта Идел буеның аерым терр-ясен билгеләгән төшенчә (16 йөзнең 2 нче яртысы). Рус актлар материалларында Казан ханлыгы Рус дәүләте тарафыннан яуланганнан (1552) соң, беренче дистә еллыкларда кулланыла. Ч.ләрнең күпме булганлыгы һәм атамалары, Нугай һәм Арча чирекләренннән тыш, мәгълүм түгел. «Ч.» төшенчәсе киң таралмый, фаразланча, «даруга» төшенчәсе тарафыннан кысрыклап чыгарыла.

Әд.: Е р м о л а е в И.П. Среднее Поволжье во второй половине XVI–XVII вв. (Управление Казанским краем). К., 1982.

Д.Г.Мостафина.

ЧЕХ-СЛОВА́К КО́РПУСЫ ФЕТНӘСЕ́, 1918 елның мае–августында чех-словак гаскәрләренең Идел буенда, Себердә һәм Ерак Көнчыгышта кораллы күтәрелеше. Ч.-с.к.ф. Совет хакимияте органнарын бетерү, советларга каршы хөкүмәтләр оештыру һәм киң колачлы сугыш хәрәкәтләре башлану өчен уңай шартлар тудыра. Чех-словак частьләре Беренче бөтендөнья сугышы чорында Россиядә Германиягә һәм Австро-Венгриягә кар-

шы сугышта катнашу теләге белдергән Австро-Венгрия армиясе хәрби әсирләреннән һәм чех милләтеннән булган Россия подданныйларыннан оештырыла. 1917 нең июнендә ике укчы дивизия Чех-словак корпусына берләштерелә, ул Украинада урнаша (40 меңләп кеше, алга таба легиончыларның саны арта). Окт. рев-циясеннән соң, совет хөкүмәте б-н килешенү буенча, коралларның күпчелек өлешен Кызыл Армиягә тапшыру шарты б-н корпус Владивосток аша Көнбатыш Европага эвакуацияләнергә тиеш була. Әмма Кызыл Армия командованиесенең һәм Совет хакимиятенең урыннардагы органнарының эзлексез гамәлләре, ш.у. Антанта илләренең тыкшынуы фетнә кабынуга китерә; корпус командованиесе солдатларны Владивостокка корал көче кулланып үтеп чыгарга өнди. Май ахырына чех-словак гаскәрләре төялгән эшелоннар тимер юл магистрале буйлап Ртищево станциясеннән (Пенза тирәсе) Владивостокка кадәр (7 мең *км* чамасы арада) сузыла. Фетнәләр 25 майда — Мариинск, 26 майда Чиләбе шәһәрләрендә башлана. Алар барышында Идел буе (8–10 мең кеше), Чиләбе (9–12 мең кеше), Себер (10–12 мең кеше) һәм Владивосток (14 меңләп кеше) төркемнәре оеша. Чех-словак частьләре сугыш хәрәкәтләре башлыйлар, Идел буенда, Себердә һәм Ерак Көнчыгышта Новониколаевск (26 май), Пенза (29 май), Сызрань (30 май), Томск (31 май), Омск (7 июнь), Самара (8 июнь), Красноярск (18 июнь) шәһәрләрен басып алалар; урыннарда Совет хакимиятен бәреп төшерәләр һәм советларга каршы хөкүмәтләр оештыралар. 8 июньдә Самарада *Учредительләр җыены әгъзалары комитеты* (КОМУЧ) төзелә, ул шәһәрдә һәм губернада Совет хакимияте бәреп төшерелүен игълан итә һәм һәм шәһәр думасын, земство идарәләрен торгызу турында күрсәтмә бирә; КОМУЧның Халык армиясе оештырыла. Большевикларга каршы хөкүмәтләр ш.у. Екатеринбург (кадетларның һәм эсерларның «Урал хөкүмәте»), Омск («Себер вакытлы хөкүмәте») шәһәрләрендә төзелә. Советлар Россиясенең гражданнар һәм хәрби җитәкчелеге гадәттән тыш чаралар күрә: 13 июльдә *Көнчыгыш фронт* (4 армия составында) һәм РВС оештырыла. Июль ахырында чех-словак частьләре һәм акгвардиячеләр б-н көрәштә төп көч булырга тиешле *Бишенче армия* формалаштырыла башлый. 22 июльдә Семберне басып алганнан соң, Чех-словак корпусының Идел буе төркеме 1–3 августта Казан юнәлешендә һөҗүм җәелдерә. Шәһәр өчен каты сугышлар 3 көн дәвам итә. Зур югалтулар кичереп, Кызыл Армия частьләре 7 августа шәһәрне калдыралар. Шуннан соң Казанда ак террор башлана: партия, совет хезмәткәрләре (М.М.Вахитов, С.Н.Гассар, А.П.Комлев, М.И.Межлаук, Я.С.Шейнкман һ.б.) кулга алына һәм атып үтерелә, Совет хакимияте тарафдарларының эзәрлекләүләргә дучар ителә. РСФСР алтын запасының төп өлеше ак чехлар кулына эләгә. Әмма легиончыларның алга таба хәрәкәте Көнчыгыш фронтның 2 нче һәм 5 нче армияләре частьләре тарафыннан туктатыла. Сентябрьдә Кызыл Армия частьләре контрһөҗүмгә күчә; 10 сентябрьдә — Казанны (к. *Казанны азат итү операциясе*), 12 сентябрьдә Семберне азат итәләр. 1918 ел ахырына Казан губернасы терр-ясе тулысынча азат ителә. Урта Идел буенда зур җи һәлүгә дучар булып, бәйсез Чехословакия игълан ителү хакындагы хәбәр килеп ирешкәч, Ч.-с.к.ф. ндә катнашучылар үзләрен ватаннарына кайтарып җибәрүне таләп итәләр, легиончыларның бер өлеше Кызыл Армия ягына чыга. 1918 нең ахырында — 1920 нең ноябрендә корпусның төп көчләре Владивостокка эвакуацияләнә, шуннан Европага җибәрелә. Ватаннарына барлыгы 72544 кеше кайта. Ш.у.к. *Граждан нар сугышы*.

Ф.Г.Миңнеханов.

ЧЕ́ХОВ Анатолий Иванович (2.5.1923, Чаллы кантоны Бондюг а., хәзер Менделеев ш. — 6.6.1967, Горький ш., хәзер Түбән Новгород ш., Казанда җирләнә), снайпер, гв. өлкән сержанты. Бондюг химия з-дында эшли. 1939–42 елларда һәм 1944 тән Казан кино тасмасы ф-касында. 1942 нең маеннан Бөек Ватан сугышы фронтларында, Сталинград фронтының 62 нче армиясе составындагы 1 нче батальонның 3 нче рота (13 гв. укчы дивизиянең 39 гв. полкы) снайперы. Ч.ны Сталинград фронтының легендар снайперы дип атаганнар: 1942 нең октябреннән 1943 нең гыйнварына кадәр дошманның 256 солдатын юк итә, шәхси исәбендә — 265 дошман солдаты; инструктор буларак 20 дән артык снайпер әзерли; Сов. Союзы Герое исеменә тәкъдим ителә. Курск сугышында (1943), Украинаны азат итүдә (1943) катнаша, яралана. Демобилизацияләнгәннән соң (1943), Казандагы электромеханика з-дында эшли. Кызыл Байрак, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр б-н бүләкләнә. Волгоградның бер урамына Ч. исеме бирелә, Геройга Волгоград телестудиясендә төшерелгән «Снайпер Чехов исән!» («Снайпер Чехов жив!», 1964), Казан киностудиясендә төшерелгән «Коткарылган дөнья онытмас» («И помнит мир спасённый», 1965) документаль фильмнары һәм «Исеме билгесез батыр эзләреннән» («По следам безымянного героя») исемле махсус тапшыру багышлана.

Әд.: Гроссман В. Глазами Чехова // Годы войны. М., 1945; Дятлова А.М. Тасмовцы второй мировой...: Документы. Воспоминания. Мемуары. К., 2001.

С.Г.Белов, М.З.Хәбибуллин.

ЧЕЧУ́ЛИНА Ольга Васильевна (19.1.1960, Казан), акушер-гинеколог, мед. фән. д-ры (2007). ТРның атказ. табибе (2012). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1987), 4 нче балалар тудыру йортында (Казан) табиб акушер-гинеколог булып эшли, 1992–93 елларда баш табиб урынбасары. 1993 тән Казан ГИДУВының 2 нче акушерлык һәм гинекология кафедрасында, 2008 дән каф. мөдире. Хезмәтләре яшүсмер кызларның йөкләлек чорын һәм бала тудыру барышын өйрәнүгә: йөклелек ахырында һәм бала тудырганда ана һәм баланың кардиоритмын нейровегетатив көйләү, беренче баласын табучының йөкләлек һәм бала табуы барышына прогноз эшләү, яшь аналардан туган яшүсмер кызларның репродуктив сәламәтлеген ачыклау мәсьәләләренә карый.

ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының акушерлык һәм гинекология буенча штаттан тыш баш белгече, ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының аттестация комиссиясе әгъзасы, ТР акушерлар һәм гинекологлар ассоциациясе әгъзасы, Россия гинеколог-ювенологлары ассоциациясе әгъзасы, Евразия мед. фән. академиясе әгъзасы.

Х е з м.: Медико-социальные факторы осложнений беременности, родов и состояния здоровья плода у юных женщин. К., 2006 (автордаш); Репродуктивное здоровье девочек-подростков, сопряжённое с дисплазией соединительной ткани // Современное искусство медицины. 2011. № 1.

ЧЁРНЫЙ ЯР РАЙОНЫ́, *Әстерхан өлкәсенең* төньягында урнашкан. 1928 елда оештырыла. Мәйданы — 4,2 мең *км*^{2}. Үзәге — Чёрный Яр авылы. Халкы — 19349 кеше (2017). Татарлар саны: 2002 дә — 500, 2010 да — 346 кеше. Алар, тупланып, Ташлыяр авылында (480 кеше) яшиләр. Казан татарлары Ч.Я.р. терр-ясенә 18 йөз ахырында төпләнәләр. 1870 тә алар авыл халкының өчтән берен тәшкил итә (2754 кеше). Татар халкының төп шөгыле — игенчелек, терлекчелек, вак-төякләр б-н сәүдә итү (7 кибетнең 1 се (мануфактура кибете) 2 нче гильдия сәүдәгәр Б.Сәмитовныкы була). Мәчет (1790 да төзелә), «Идел» татар үзешчән ансамбле (1980 нән), шагыйрә Г.Б.*Сәмитова* музее эшли. 1985–94 тә авыл мәктәбендә татар теле фән буларак укытыла. Сәүдәгәр Баһаветдин Сәмитов йорты — тарих һәм мәдәният истәлеге. Сов. Союзы Герое Ф.Р.*Әбләзов*, Соц. Хезмәт Герое К.Н.Бәшировның тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге Ч.Я.р. б-н бәйле.

ЧЁРТОВО авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 22 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Норма елгасы (Мишәнең уң кушылдыгы) буенда. 2010 елда 46 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1565–67 дән рус чыганакларында Пустошь Тереулова буларак мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Тереулова исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 1850 елларда поташ з-ды, 20 йөз башында ашлык саклау-сату һәм вак-төякләр кибете, су тегермәне, тимерче алачыгы эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 430,25 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Аркатау волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 23 ир-ат; 1859 да — 282, 1897 дә — 335, 1908 дә — 360, 1920 дә — 360, 1926 да — 401, 1949 да — 165, 1958 дә — 148, 1970 тә — 92, 1979 да — 87, 1989 да — 60, 2002 дә — 54 кеше.

ЧИБӘРКҮ́Л шәһәре, *Чиләбе өлкәсендә*, Чиләбе шәһәреннән 78 *км* көнбатыштарак, Чибәркүл р-ны үзәге. 1736 елда нигез салына. Халкы — 39914 кеше (2017). Татарлар саны: 1979 да — 1372, 1989 да — 1403, 2002 дә — 1463, 2010 да — 1234 кеше. Татарлар Ч.дә шәһәр нигезләнгән көннән яшиләр. Ч.дә һәм

Чибәркүл р-нында татар-башкорт мәдәни үзәкләре (2010 нан), Горький исем. Шәһәр ял үзәге каршында «Яшьлеккә кире кайту» үзешчән татар-башкорт ансамбле (1990 нан) эшчәнлеген алып бара. 2004 тән «Уральская кузница» телерадиокомпаниясе «Татарстан-Яңа гасыр» телеканалы тапшыруларын трансляцияли. Мәчет эшли.

ЧИБӘРКҮЛ РАЙОНЫ, *Чиләбе өлкәсенең* үзәгендә урнашкан. 1935 елның 18 гыйнварында оештырыла. Үзәге — Чибәркүл шәһәре. Халкы — 29753 кеше (2017). Татарлар саны: 1979 да — 1286, 1989 да — 1246, 2002 дә — 932, 2010 да — 827 кеше. Ч.р. терр-ясенә татарлар *Казан ханлыгы* җимерелгәннән соң урнаша башлый. Татарларның күпләп күченүләре 1730–40 еллардагы Чибәркүл калькасы төзелеше һәм Столыпинның аграр реформасы чорларына туры килә. Ч.р.нда Идел-Урал татарлары б-н берәттән *нагайбәкләр* дә яши (Варламово, 2 нче Ключевка һәм Болотово авыллары). 2010 да Ч.р.нда һәм Чибәркүл шәһәрендә татар-башкорт мәдәни үзәкләре оештырыла. Бишкил посёлогында «Бүләк» татар-башкорт ансамбле һәм «Дуслык» татар ансамбле, Варламово авылында «Чишмә» һәм «Бәрмәнчек» ансамбльләре эшли. 2009 да Ч.р. делегациясе 1 нче Керәшен яшьләре форумында (Казан) катнаша. Варламово авылында нагайбәкләрнең милли-мәдәни музее эшли.

ЧИ́БРИКОВА Любовь Ивановна (6.3.1925, Арча кантоны Яңа Шигали а. — 18.6.2001, Казан), математик, физика-матем. фән. д-ры (1964), проф. (1965), ТАССР, РФнең атказ. фән эшлеклесе (1982, 1997). Казан ун-тында хатын-кызлардан беренче матем. профессоры. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1947), шунда ук эшли (бүленеп, 1950–51 дә Новочеркасск политехник ин-тында), дифференциаль тигезләмәләр каф. мөдире (1959–91), 1991 дән каф. профессоры. Хезмәтләре аналитик функцияләр һәм аларга бәйле сингуляр интеграль тигезләмәләр теориясенең кырый мәсьәләләренә, дифференциаль тигезләмәләрнең аналитик теориясенә карый. Ч. автоморф функцияләр классындагы Риман кырый мәсьәләсен төрле гидромеханика гамәли мәсь әләләренә, сыгылмалылык теориясенә, катнаш типлы тигезләмәләр теориясенә карата кулланылуы тикшерә. Риман мәсь әләсен чишү проблемасы б-н (теләсә нинди индекс очрагында да) Абель интегралларын әверелешенең классик Якоби мәсь әләсе һәм алдан билгеләнгән дивизорга кабатлы рациональ алгебраик функция төзү мәсь әләсе арасында бәйләнеш булуын ачыклый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Основные граничные задачи для аналитических функций. К., 1977; Граничные задачи теории аналитических функций на римановых поверхностях // Итоги науки и техники. Мат. анализ. 1980. Т. 18; Избранные главы аналитической теории обыкновенных дифференциальных уравнений. К., 1996.

Әд.: Ж е г а л о в В.И. Любовь Ивановна Чибрикова // Механико-математический факультет Казанского университета: Очерки истории. К., 2003.

ЧИГА́ЙКА авылы, Кукмара р-нында, Кукмара шәһәреннән 18 *км* көньяктарак, Кенә елгасының (Вятка бассейны) югары агымы буенда. 2010 елда 35 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, марилар — 63%) яши. 18 йөз ахырында Вятка губернасының Малмыж өязенән килүчеләр нигез сала. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Чирмеш Көеге, Көек-Чирмеш исемнәре б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстианнәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 356,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Петропавел волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1782 дә — 24 ир-ат; 1859 да — 78, 1897 дә — 191, 1908 дә — 224, 1920 дә — 244, 1926 да — 289, 1938 дә — 274, 1949 да — 246, 1958 дә — 141, 1970 тә — 124, 1979 да — 117, 1989 да — 62, 2002 дә — 49 кеше.

ЧИГА́РИН Пётр Иванович (20.6.1935, Питрәч р-ны Аркатово а. — 4.6. 2003, шунда ук), слесарь-җыючы, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1983). 1951–90 елларда «Терминал» ҖБдә, слесарь-җыючылар бригадасы бригадиры (1979 дан). 1990–93 тә «Паритет» кече пр-тиесендә эшли (Казан). 1993–2002 дә «Турбокомпрессор ФТИ» АҖдә механика-җыю эшләре слесаре. Дәүләт бүләге идарәнең автоматлаштырылган системасын булдыруда катнашканы өчен бирелә. 3 нче дәрәҗә Дан ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

ЧИГҮ, гамәли-бизәлеш сәнгате төре; киемнәргә, көнкүреш һәм йола әйберләренә төрле җепләр б-н кулдан яки машина ярдәмендә бизәк төшерү. Өй шартларында һәм нәфис кәсепчелек (баш һәм аяк киемнәрен бизәү) рәвешендә үсүче татар традицион сәнгатенең киң таралган төрләренең берсе. Алтын һәм көмеш җепләр б-н нәгыш техникасында сюжетлы һәм орнамент мотивлы Ч.нең иң элгәрге үрнәкләре 14 йөзгә — 15 йөзнең 1 нче яртысына карый. ТР Милли музеендагы укалап һәм нәгыш техникасында чигелгән япманың уникаль үрнәге Казан ханлыгы чорына нисбәтле дип исәпләнә. Борынгы Ч.ләрнең күпчелек өлеше 19 йөзнең 2 нче яртысына — 20 йөз башына туры килә, аерым музей үрнәкләре 18 йөз ахырына карый.

Башка төркы халыкларда кебек үк, татарларда тамбур — әлмәләп Ч. (төбәк вариантларында — татар чигүе) техникасы популяр була. Ул әре чәнчемнәр б-н чигелгән кыска тамбурга һәм вак чәнчемнәр б-н чигелгән — күпертмә элмә — биек тамбурга бүленә, кайвакыт эрләнгән ефәк кулланып рельефлы өслек барлыкка китерә торган үреп Ч. төре очрый. Ш.у. йон җебе һәм металл җеп, 19 йөздән —



Чигү. 1. Туй сөлгесе. Фрагмент. Киҗе-мамык тукыма. Укалы тасма, алтын чуклар. Тамбур. 19 йөз. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 2. Япма чите. Фрагмент. Ефәк, алтын чуклар. Тамбур, келәм җөе. 19 йөз уртасы. ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее; 3. «Алтынчәч» мендәре. Бәрхет. Тамбур. Рәссам С.Д.Кузьминых. 1960 еллар; 4. Чигүле янчык. Бәрхет, энҗе, ука. Рәссам Р.Ф.Фәйзрахманова. 1980 еллар.

гарус файдаланыла. 19 йөзнең 2 нче яртысына кадәр әнә, соңрак ш.у. ыргак б-н дә чигәләр, махсус җайланма — киерге кулланыла.

1870 еллар уртасыннан, аеруча татарлар арасында, Европа тамбур машинасы киң тарала. Кулдан элмәләп Ч. б-н бергә, сирәк булса да, шома чигү (төбәк варианты — йомшак чигү) техникасы кулланыла. 18 йөзнең 2 нче яртысыннан алтын яки көмеш кәнител (нечкә металл уралган ефәк яки киже-мамык җеп) б-н укалап Ч. популярлаша. Рельефлы бизәк барлыкка китерү өчен, җеп астына тукыма яки кәгазь куела. Ч. өстәмә рәвештә үрелгән металл спиральләр-трунцаллар, ялтыравыклар, сәйләп, энҗе б-н бизәлә, чачаклар, чуклар, челтәрләр тегелә. 19 йөз ахырында күпертеп, элмәкләп Ч. таралыш ала. Керәшен татарларда камба (хачлап, чалыштырып чигү) төре яши, ул 20 йөзнең 2 нче яртысында төп масса татарларда «рус чигүе» буларак тарала.

Ч. өчен нигез булып өй шартларында җитештерелгән һәм сатып алынган (ситса, сатин, ефәк, парча, бәрхет, вельвет) тукымалар, юка йомшак күн хезмәт иткән. Зәңгәр, яшел, алтын-сары, шәмәхә, кызыл һәм ак төсләр популяр була. Гадәттә, тукымага алдан төшерелгән рәсем буенча, тәжрибәле осталар үрнәксез чигәләр. Нигездә, элекке үрнәкләр күчерелә һәм яңа бизәкләр, төсләр б-н тулыландырыла. Ч. өчен дала, болын, бакчага бәйле мотивларның — лалә, кыңгырау чәчәк, зәңгәр чәчәк, мәк, канәфер, күкчәчәк, гөл җимеш чәчәге, ромашкалар, кашкарый, алтын чәчәк, дәлия, чалма чәчәк, розалар, «төрек» кыяры, анар — рәткә тезелгән, гөлләмә һәм челтәр композицияләрендәге розетка һәм шахмат корылышындагы чәчәк-үсемлек бизәлеше характерлы. Кошларның, күбәләкләрнең, бал кортларының, әтәчләрнең, күгәрченнәрнең стильләштерелгән мотивлары, Борынгы Болгар һәм Алтын Урда бизәкләренә хас тукранбашлар, пальма, розеткалар, үрмәле гөл, интеграль спиральләр һ.б. файдаланыла. Ч. төсләр байлыгы белән аерылып тора (бер әйбердә 10–12 төсмер бергә кулланылырга мөмкин). Ч. б-н көндәлек һәм йола сөлгесе — *Казан сөлгесе* (вариантлары — битъяулык, байлар сөлгесе) чите, чаршау, ашъяулык, каша га, түрләмә, намазлык, япмалар, бирнә букча лары, *ләүхә*, *күкрәкчә*, алъяпкыч, җиңсә, хатын-кыз күлмәге итәкләре, туй чолгаулары, баш киемнәре — *калфак*, түбәтәй, такыя, яулыклар; тукыма һәм күн аяк киемнәре, янчыклар һ.б. бизәлгән.

Хәзеге һәвәскәр осталар, нигездә, шома Ч. һәм Болгар хачы техникасы б-н чигәләр. Проф. рәссамнар (С.Д.Кузьминых, С.Ю.Гарбузова, Л.Ф.Фәсхетдинова, А.Липина һ.б.) һәм халык осталары (М.Бикбулатова, Н.Сәйхетдинова, Р.Фәйзуллина һ.б.) элмәләп һәм укалап Ч. традицияләрен үстерә.

Ч. үрнәкләре Казан, Яшел Үзән, Чистай һәм ТРның башка шәһәрләре, Уфа, Касыйм, Сарапул, Рязань, Әстерхан, Пермь, Тубыл, Төмән, Омск музейларында, Россия халыклары этнографиясе музеенда (С.-Петербург), Бөтенроссия гамәли-бизәлеш сәнгате музеенда (Мәскәү), Хельсинкидагы Милли музейда (Финляндия) һ.б. саклана.

Әд.: Валеев Ф.Х. Орнамент Казанских татар. К., 1969; шул ук. Народное декоративное искусство Татарстана. К., 1984; Гулова Ф.Ф. Татарская народная вышивка. К.,1981; Валеева-Сулейманова Г.Ф., Шагеева Р.Г. Декоративно-прикладное искусство Казанских татар. М., 1990; Валеева-Сулейманова Г.Ф. Декоративное искусство Татарстана. К., 1995.

Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.

ЧИЖО́В Никифор Осипович (1779 елның мае, Мәскәү губ. Серпухов ш. — 9.5.1841, Казан), Казанның 2 нче гильдия сәүдәгәре, эшмәкәр, җәмәгать эшлеклесе, иганәче. Казанда Гостиный дворда тасма товар б-н сәүдә итә. 1832 елда М.С.Верин б-н бергә киже-кинде р ф-касы ача. Кече Проломная урамында йорт били. 1804–06 да Казан шәһәр думасы гласные, 1830–32 дә шәһәр башлыгы. 1824–26 да Казан вөждан мәхкәмәсе утырышчысы. 1832 дән Төрмәләр попечительләре ком-ты әгъзасы. Холера б-н көрәшкә (1830), Казанда шәһәр гарипләр йорты төзелешенә (50 мең сум), Благовещение соборының чаң манарасы астында урнашкан кафедраль соборны торгызуга (17 мең сум) акчалар сарыф итә. Иганәчелек эшчәнлеге өчен ике алтын медаль б-н бүләкләнә.

ЧИК БУ́Е КИРТӘЛӘ́РЕ (засечные черты), 16–17 йөзләрдә Россиядә саклану корылмалары системасы. Урманнардагы аркылы-торкылы аударылган агачлардан, урлардан, казылган озын чокырлардан, утыртма коймалардан торган. Саклану системасында ш.у. башка табигый тоткарлыклар — елгалар, күлләр, сазлыклар, чокырлар файдаланылган. Ч.б.к.терр-ясендә шәһәр-кирмәннәр һәм кальгалар төзегәннәр. 16 йөзнең 3 нче чиregеннән башлап халыктан салым — засека акчалары җыелган. 16 йөзнең 2 нче яртысында Ч.б.к.ндә 35 меңгә кадәр кеше хезмәт иткән. 16 йөздә — 18 йөзнең 1 нче яртысында Зур (1566), Белгород (1635–53), Сембер (1648–54), Пенза (1675–80), Изюм (1679–81), Кама аръягы (к. *Кама аръягы искә чик сызыгы*, *Кама аръягы чик сызыгы*) һ.б. Ч.б.к. корыла.

Әд.: Яковлев А.И. Засечная черта Московского государства в XVII веке. М., 1916.

ЧИКА́ЕВ Вячеслав Фёдорович (13.1.1955, Мари АССРның Волжск р-ны Петьял а.), травматолог-ортопед, мед. фән. д-ры (2000), проф. (2007). ТРның атказ. табибе (2012). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1983), 15 нче Казан шәһәр хастаханәсенең хирургия бүлегендә эшли. 1987 елдан Казан мед. ин-ты-ның травматология, ортопедия һәм хәрби-кыр хирургиясе кафедрасында, 2006 дан Казан мед. ун-ты каф. профессоры. Хезмәтләре кичектергесез абдоминаль хирургиядә үлекле-септик катлаулану очракларын фаразлау һәм дәвалауга карый. Уйлап табуга 2 патенты бар.

Хезм.: Состояние антибактериального иммунитета при перитоните // Казан. мед. журн. 2001. № 2 (автордаш); Тактика лечения пострадавших с повреждениями селезёнки // Практическая медицина. 2004. № 4 (9) (автордаш); Принципы диагностики и лечения пострадавших при сочетанной травме с повреждением паренхиматозных органов // Практическая медицина. 2010. № 8 (47) (автордаш).

ЧИКАНА́С авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 16 *км* төньяктарак, Бирәзә елгасы буенда. 2010 елда 304 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1678 дән мәгълүм. 1920 гә кадәрге исеме — Алич Тархан. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстиннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, киндер сугу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет (1889 да төзелә;



Чиканас авылы мәчете. 1889.

архит-ра истәлеге), җил тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 939,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Яңа Кишет волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 48 ир-ат; 1859 да — 350, 1897 дә — 599, 1908 дә — 620, 1920 дә — 651, 1926 да — 681, 1938 дә — 679, 1958 дә — 484, 1970 тә — 445, 1979 да — 366, 1989 да — 302, 2002 дә — 308 кеше.

«ЧИКЕРТКӘ», татар телендә чыккан беренче сатирик, юмористик журнал. 1906 елның 23 апреленнән 22 октябренә кадәр Оренбург шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, барысы 5 саны чыга. Нашире һәм мөхәррире — П.А.Александров, соңгы саннықы —



«Чикерткә» журналы.

Е.И.Бурцев. «Саранча» рус сатирик ж-лы тышлыгы б-н чыга, анда татарлар өчен 5–6 бит сан бүленеп бирелә (3 нче санда андый кушымта булмый). Ф.Кәрими басмаханәсендә басыла. «Ч.» халыклар тигезлеге идеясен яклый, С.Ю.Витте, П.Н.Дурнов һ.б. эшчәнлегенә үз мөнәсәбәтен белдерә, җирле хакимият органнарының, аерым түрәләрнең, кадими дин эшлеклеләренең, аерым мөгалимнәрнең эшчәнлегендәге наданлыкларны һәм җитешсезлекләрне, милли басмаларның кимчелекләрен тәнкыйтьли. Комик образларны тудырганда төрле жанрлар — фельетон, шигырь, телеграмма, мәзәк, сәхнә, диалог файдаланыла. Карикатуралар авторы — Л.Мостафин (псевд. Нагайка).

ЧИКЕРТКӘ ЧЫПЧЫКЛА́Р (Locustella), әрәмә чыпчыклары семьялыгыннан кошлар ыругы. 7 төре билгеле, Евразиядә, Төньяк-көнбатыш Африкада таралганнар. Татарстан терр-ясендә 3 төре бар. Елга чикерткә чыпчыгы (L. fluviatilis) барлык районнарда очрый, сайрар чикерткә чыпчык (L. Luscinioides) һәм гади чикерткә чыпчык (L. naevia) — сирәк төрләр. Сулык ярлары буенда, дымлы болыннарда, бакча һәм паркларда яшиләр. Күчмә кошлар. Гәүдәсе озынча, 14–17 *см*. Канатлары кыска һәм киң. Койрыгы киртләч. Томшыгы туры һәм нәзек. Каурый капламы тонык, бер генә төстә, өсте коңгырт, аскы ягы аксыл, еш кына кара чуар. Житез, хәрәкәтчән кошлар. Ч.ч.ның сайравы чикерткәләр черелдәвен хәтерләтә (исеме шуннан). Ачык чокырчыксыман ояларын жирдә яки биек булмаган куакларда коралар. Ак яки алсу 5–7 йомырка салалар. Вак бөжәкләр (башлыча, гөбләләр, ш.у. яфрак борчаклыклары, цикадкалар, филчекләр һ.б.) һәм үрмәкүчләр б-н тукланалар. Кышлау урынына август ахырында — сентябрь башында очып китәләр.

ЧИКЕРТКӘЛӘ́Р, к. *Турыканатлылар*.

ЧИКЛӘВЕ́К КУАГЫ́, чиклəвек агачы (Corylus), каенчалар семьялыгыннан куаклар, сирәк кенә агачлар ыругы. Якынча 20 төре билгеле, Евразиядә, Төньяк Америкада таралган. ТР терр-ясендә бер төре — гади Ч.к. (C. avellana) бар; барлык районнарда үсә. Киң яфраклы урманнарда куаклыклар хасил итә. 3–5 *м* биеклектәге куак. Кабыгы кызгылт соры. Ботаклары төкчәле, ачык төстәге ясмакчыклар б-н капланган. Яфраклары куе яшел, чиратлашкан, сабакчалы, озынча түгәрәк, очлы башлы һәм кырыйлары тигезле-тигезсез тешчекле. Яшь яфраклары ефәксыман төкчәле. Чәчәкләре аерым женесле, ата чәчәкләр куе, озын алкалы, ана чәчәкләр бөре эчендә, чәчәк ату чорында алардан фәкатъ алсу төстәге жимешлек авызчыгы гына чыга. Иртә язда, яфрак ярганчы чәчәк аталар. Жимеше — бер орлыклы, шарсыман формадагы чикләвек, кыңгыраусыман тышча б-н әйләндереп алынган. Жимешләре август ахыры–сентябрьдә өлгерә, тышчасыз гына жиргә коелалар. Орлыктан һәм вегетатив юл б-н — тамыр үрентеләреннән һәм тамырлы ботаклардан үрчи. 4–6 елдан соң жимеш бирә башлый. Чикләвекләре тәмле һәм туклыклы, ашамлык буларак чи килеш һәм кызды-рып кулланыла. Ч.к.ның яфрак, чәчәк һәм кайрысында дуплау матдәләре, алкалоид, флавоноид, эфир мае, органик к-талар, каротин бар. Халык медицинасында салкын тигәндә, кан тамырлары киңәйгәндә, иң нечкә кан тамырларыннан кан киткәндә һәм сәламәтлекне ныгыту чарасы буларак кулланыла. Чикләвекләре күп кенә урман хайваннары (тиен, кабан дуңгызы, тукран, тычканнар) өчен азык булып тора. Агачы вак эшләнмәләр, агач мичкәләр өчен кыршау ясауда файдаланыла. Тамыр системасының куәтле булуы һәм ераккa жәелүе сәбәпле, Ч.к. сөзәкләкләрне, сызаларны ныгыта. Бакча һәм парклларда декоратив үсемлек, ш.у. урман полосаларында кыр ышыклау урман полосалары буларак үстерелә. Баллы үсемлек. 60–80 ел яши.

ЧИКЛӘВЕКСЫМАННА́Р, 4 семьялыкны берләштерүче элпәканатлылар отрядыннан сабаксыман корсаклы бөжәкләр өссемьялыгы. Якынча 1900 төре билгеле. Киң таралганнар. Төньяк ярымшарның имән һәм роза чалар ареалы чикләрендә аеруча күп. Озынлыгы 1–5 *мм*, кайвакыт 25 *мм* га кадәр. Күпчелек төрләре үсемлекләр, сирәк кенә хайваннар (икеканатлылар, жайдаклар) паразиты. Исеме икенчел-үсемлек б-н туенучы формаларыннан алынган, күкәй салгычы б-н яфракны кисеп күкәй салганда орылар (чикләвекчекләр) хасил итә, алар эчендә личинкалар житлегә. Яшь затлар тишек тишеп орылардан чыгалар. Татарстан терр-ясендә гади имән чикләвексыманы (Diplolepis quercus-follu), тамыр чикләвексыманы (Biorrhiza pallida) һ.б. гадәти төр. Ч. күпләп үрчегәндә яфраклар вакытыннан алда коелырга мөмкин. Көрәш чаралары: яшел утыртмаларда орыларны жыю һәм аларны юкка чыгару, үсемлекләрне агулагыч матдәләр б-н бөркү.

ЧИ́КОВ Владимир Иванович (26.8.1938, Казан), үсемлекләр физиологы, биол. фән. д-ры (1988), проф. (1991), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1999). Казан а.х. ин-тын тәмамлаганнан соң (1961), Куйбышев р-нының Куйбышев исем. с-зында агроном булып эшли. 1965–68 елларда Казан а.х. ин-тында. 1971–72 дә Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тының үсемлекләр физиологиясе лаб-ясе мөдире. 1972 дән РФА КГҮнең Биохимия һәм биофизика ин-тында, фотосинтез лаб-ясе мөдире (1978 дән), әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (2008 дән). Хезмәтләре фотосинтезны көйләү механизмнарына һәм үсемлекләрнең продуктылылыгына карый. Ч. фотосулауның яфраклардагы шикәр экспортына бәйлеле-ген билгели. Үсемлекләрнең нитратлы тукланыу яфраклардан ассимилятлар экспортын тоткарлауның NO сигнал системасы аша флоэма тамырларының тыгылуы һәм яфракның күзәнәктән тыш фазасында сахароза гидролизының көчәюе б-н бәйле үзлегенә ия булуын ачыклый. Кулланылучы минераль ашламаларны киметү б-н бер үк вакытта микроорганизмнарның үзара бәйләнешен көчәйтү исәбенә үсемлекләрнең продуктылылыгын күтәрү мөмкинлеген күрсәтә. Үйлап табуга 3 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Фотосинтез и транспорт ассимилятов. М., 1987; Участие апопласта в регуляции транспорта ассимилятов, фотосинтеза и продуктивности растения // Физиология растений. 2004. Т. 53, № 3 (автордаш); Эволюция представлений о связи фотосинтеза с продуктивностью растений // Физиология растений. 2008. Т. 55, № 1.

ЧИЛА́П Анатолий Яковлевич (5.2.1934, Днепропетровск ш.), математик һәм механик, физика-матем. фән. д-ры (1974), проф. (1979). Казан ун-тын тәмамлый (1956), шунда ук — Матем. һәм механика фәнни-тикшеренү ин-тында, гомуми матем. һәм радиоэлектроника кафедраларында эшли (1964–78). 1978–87 елларда Казан төзүче инженерлар ин-тында: теоретик механика каф. мөдире (1983 кә кадәр). 1987 дән Казан энергетика ин-тында (бүленеп), югары матем. каф. мөдире (1988–99), каф. профессоры (2005 тән). 1999–2003 тә Казан ун-тының Яшел Үзән ф-лында физика каф. профессоры, 2003–05 тә Казан а.х. академиясендә физика һәм матем. каф. профессоры. Хезмәтләре жирасты гидромеханикасына һәм уеннар матем. теориясенә карый. Ч. эллиптик функцияләр теориясенә иярешле мәсьәләләрне хәл итү алымын тәкъдим итә; уеннар матем. теориясенең мәсьәләләре классын нефть чыганакларын эшкәртүгә кушып, уеннар матем. теориясенең мәсьәләләре классын тикшерә; статик аныкланмаган мәсьәләләрне хәл итү алымын материаллар сыгылмалылыгы үзлекләренә нән файдаланмыйча тасвирлый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Об одной задаче сопряжения для секториальной области // Журн. вычисл. математики и мат. физики. 1962. Т. 2, № 6; Решение некоторых задач сопряжения сведением к обобщённой задаче Римана // Прикладная математика и механика. 1963. № 3 (автордаш); Определение поля давлений в полосообразном кусочно-неоднородном пласте // Изв. АН СССР. Механика и машиностроение. 1964. № 3.

ЧИЛӘБЕ́ шәһәре, Чиләбе өлкәсе үзәге. 1736 елда морза К.М.*Тәфкилев* тарафыннан кальга буларак нигез салына. Халкы — 1198858 кеше (2017). Татарлар саны: 1979 да — 56754, 1989 да — 60682, 2002 дә — 57520, 2010 да — 54400 кеше. Алар Чиләбе кальгасын төзүдә катнашалар, хәрби хезмәтләрен үтиләр, чик буе халыклары б-н сәүдә итәләр. 18 йөзнең 2 нче яртысында башлыча Казан, Уфа, Вятка, Түбән Новгород губерналарыннан килүчеләрдән торган татар жәмгыяте оеша башлый. 1873 тә сәүдәгәр М.М.Сәлимов мәктәп ача, һәм ул шәһәрдә яшәүче татар һәм башкортлар өчен рухи тормыш үзәге булып китә. 19 йөз ахырында татарларның (сәүдәгәрләр, мещаннар, элеккеге дәүләт крәстиянәре) күбесе Азиатская урамына (хәзер Елькин урамы) килеп урнаша. 1897 дә Ч.дә 719 (1857 дә — 130) татар яши. Башлыча мануфактура товарлары, жиләк-жимеш һәм мех б-н сәүдә итүче татар сәүдәгәрләре рус сәүдәгәрләре б-н уңышлы гына көндәшлек итә. Ч.дә сәүдә йортлары булган күп кенә татар эшмәкәрләре (М.Ф.Вәлиев, *Яушевлар* һ.б.) *Троицкида*, Ташкентта яшиләр. 1890–99 да Ч.нең күренекле эшмәкәре З.Г.Галиев акча-сына шәһәрдә вакытлыча салынган агач мәчет урынына таш Жамигъ мәчет («Ак мә-

чет», 1904 тә икенче мулласы булып тарихчы М.М.*Һадиев* сайлана) төзелә, 1907 дән аның каршында яңа ысуллы мәдрәсә эшли. 1917 дә шәһәрдә 2 мәчет була (1923 һәм 1930 да ябыла). 20 йөз башында Транссебер тимер юл магистрале төзелү б-н бәйле рәвештә Ч.дә татарлар саны шактый арта башлый (1913 тә — 4021 кеше). 1906–12 дә шәһәрдә Чиләбе мөселман хәйрия җәмгыяте (1913 тә Романовлар нәселе идарә итүнең 300 еллык юбилеена багышлап оештырылган Чиләбе мөселман хәйрия җәмгыяте буларак яңадан торгызыла) эшли. Ул мохтаҗ мөселманнарга, ш.и. укучыларга матди ярдәм күрсәтә; мөселман зиратын карап тору һәм саклау, фәкыйрь диндәшләрне күмү буенча чыгымнарны түләүне үз өстенә ала; 1906 да мәчет каршында түләүсез мөселман китапханә-уку залын (1920 еллардан — Ш.*Бабич* исем. татар-башкорт китапханәсе), 1914 тә мобилизацияләнгән ярлы һәм солдат гаиләләрендәге яшүсмерләр өчен агач эшенә өйрәтү һөнәрчелек мәктәбен ача. 1913 тә Ч.дә «Музыка һәм драма» театр җәмгыяте (к. *Чиләбе өлкәсе*) оештырыла. 1917 дән соң татар җәмгыятенең күп кенә хәлле вәкилләре Урта Азиягә яки чит илләргә китәләр. Шәһәрдә Чиләбе Эшче, крәстиян һәм солдат депутатлары советының мөселман секциясе эшли. 1918–30 елларда китаплар, брошюралар, «Урал тавышы» (1918), «*Кызыл яу*», «*Төзү ударнигы*» (1931–38; 1935 тән — «*Коммунист*») г-талары, «Красный стрелок» г-тасына татарча кушымта нәшер ителә. 1930–50 елларда Ч.дәге татарлар саны Урта Идел буеннан һәм Ч. өлкәсендәге төзелеш эшләрендә ялланып һәм мәҗбүри җибәрелгән эшләүчеләр, кулаклар буларак куылганнар исәбенә арта. Совет чорында Ч.татар җәмгыяте тормышында Ш.Бабич исем. татар-башкорт китапханәсе мөһим роль уйный. 1920 елларда аның каршында түгәрәкләр (драма, яшь эшче хәбәрчеләр, китап сөючеләр) эшли, спектакльләр куела, китап күргәзмәләре үткәрелә. 1960 еллар башында Көньяк Урал татар-башкорт язучылары һәм шагыйрьләренең М.Җәлил исем. әдәби берләшмәсе ачыла; 1987 дә татар-башкорт мәдәни үзәге оештырыла; 1990 еллар башында Ч.дә ислам негезләрен һәм гарәп телен өйрәнү буенча беренче курслар оештырыла. Китапханә каршында *Акмулла* исем. әдәби берләшмә, «Уралым» дуслар клубы, шәһәрнең Металлургия р-нында татар-башкорт милли-мәдәни үзәге, Курчатов р-нында «Ватан» татар иҗтимагый оешмасы, «Юлдаш» шәһәр хәйрия фонды, «Берлек» татар яшьләре оешмасы, Ч. трактор з-ды мәдәният йорты каршындагы Милли музыка уен кораллары һәм этнография музеенда «Татар һәм башкорт мәдәнияте. Көнкүреш. Гореф-гадәтләр. Традиция» тематик күргәзмәсе эшли; 4 мәчет бар.



Чиләбе шәһәре. Исмәгыйль мәчете. 1996.

«Хәзинә» (2010 нан, 2012 дән «Атна вакыйгалары» өстәмә бите б-н чыга) һәм Ч. өлкәсе мөселманнары Төбәк Диния нәзарәтенең рус, башкорт, татар һәм казакъ телләрендә «Һилал» (2006 дан) г-талары нәшер ителә. 1992–2004 тә «Дуслык» г-тасы чыга. Ч. пед. ун-тында татар теле һәм әдәбияты укытучылары әзерләнә. Армия генералы М.Ә.*Гәрәев*, Сов. Союзы Геройлары И.Г.*Газизуллин* һәм Л.И.*Кадыйргалиев*, хоккей буенча ике тапкыр дөнья чемпионы Д.З.*Зарипов*, велосипедта ярышучы Г.Р.*Сәетхуҗин*, ядрә ыргытучы Г.Р.Хәнәфиева кебек шәхесләрнең тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге Ч. шәһәре б-н бәйле. Татар сәүдәгәрләре вәкилләре б-н бәйле тарихи-мәдәни истәлекләр сакланган: бертуган Яушевлар һәм М.Ф.Вәлиевнең Сәүдә йортлары биналары, Ш.Әхмәтов кибете (хәзер анда өлкә картиналар галереясы, «Яшьләр модасы» ЯАҖ универмагы һәм филармония урнашкан).

Р.Н.Гыйззәтуллин, М.Ш.Әхәтов.

ЧИЛӘБЕ́ ӨЛКӘСЕ́, РФ дә. 1934 елның 17 гыйнварында оештырыла. Үзәге — Чиләбе шәһәре. Мәйданы — 88,5 мең *км*². Халкы — 3493036 кеше (2018). Татарлар саны: 1959 да — 190227, 1970 тә — 216809, 1979 да — 219743, 1989 да — 224605, 2002 дә — 205087 (нагайбәкләрдән тыш — 9038), 2010 да — 180913 кеше. Алар, тупланып, Чиләбе (57520 кеше), Магнитогорск (24532), Златоуст (12813), Копейск (8414), Троицк (6566), Югары Өфәле (2610) шәһәрләрендә һәм Сатка (Чаткы) (Сатка шәһәрен дә кертеп — 11859), Коншак (11365), Аша (Аша шәһәрен дә кертеп — 6263), Варна (2890), Нязепетровск (2748), Уй (2455 кеше) р-ннарында яшиләр. 88 торак пунктта татарлар күпчелекне тәшкил итә. Алар Ч.ө. терр-ясенә күпләп *Казан ханлыгы* яулангач күченә. Миграциянең икенче этабы 18 йөзнең 2 нче чирегендә Көньяк Уралны үзләштерү б-н бәйле. Бу чорда татарлар Чиләбе (1736), Чибәркүл (1736) һ.б. чик буе киртәләрен һәм кальгаларын төзүдә һәм саклауда катнашалар, Казакъстан һәм Урта Азия (к. *Троицк*) халыклары б-н сәүдә алмашуда төп рольне уйныйлар. 1740–60 елларда күченгән татарларның күпчелеген Казан губернасының Казан, Сембер һәм Зөя өязләреннән килүчеләр тәшкил итә. 1798 нең 10 апрель фәрманы нигезендә Троицк һәм Чиләбе өязләре йомышлы мишәрләре *Башкорт-мишәр гаскәренә* керә һәм 1 нче Мишәр кантонына берләшә. 1799 да составына Ч.ө. терр-ясе дә кергән Оренбург губернасында яшәүче татарларның бер өлеше Оренбург казак гаскәренә беркетелә. Татарларның Көньяк Уралга (башлыча, Оренбург губернасының Верхнеуральск, Троицк һәм Чиләбе өязләре) күченүләренең икенче дулкыны 19 йөздә — 20 йөз башында төбәктә сәнәгатьнең көчле үсеше б-н аңлатыла. Күп кенә татар һөнәрчеләре (тире иләүчеләр, күнчеләр, тегүчеләр, агач осталары) читкә — казакъ авылларына барып эшлиләр. Троицк Россия татарларының зур мәдәни һәм икътисади тормыш үзәкләреннән (1897 дә — 7803 кеше) берсе була. 1917 гә кадәр 7 мәчет (һәр мәчет каршында мәдрәсә була), 6 мөселман хәйрия һәм мәдәни-агарту җәмгыяте эшли. Зур татар җәмгыятьләре Верхнеуральскида (1897 дә — 1077 татар, 1917 дә 3 мәчет була) һәм Чиләбедә (719 татар, 2 мәчет) барлыкка килә. Көньяк Урал татарларының рухи-мәдәни тормышын оештыруга, мәчетләр төзелешенә, мәдрәсәләр, милли дөньяви уку йортлары, хәйрия һәм мәдәни-агарту җәмгыятьләрен ачуга, милли басма нәшрият чыгаруга зур акчалар биргән татар сәүдәгәрләре — *Яушевлар*, *Рәмиевләр*, Әбдрәшитовлар, Бакировлар, Вәлиевләр, Габбасовлар, Дәминовлар, Идрисовлар, Нигъмәтуллиннар, Учаровлар, Уразаевлар, Хәсәновлар зур роль уйный. 1917 елгы Окт. рев-циясеннән соң Троицкида Милләтләр эше буенча халык комис-тының Татар бүлеге һәм мөселман комиссариаты оештырыла, «Ирек» (1920), «*Кызыл Урал*» (1920–22), «*Коммунист*» (1931–38) г-талары нәшер ителә. 1922–60 елларда Татар пед. техникумы эшли. Совет чорында татарларның Ч.ө. терр-ясенә күченүе Магнитогорск шәһәренә нигез салыну (1929) һәм Магнитогорск металлургия комб-ты төзелеше б-н бәйле. Монда татар-башкорт мәктәбе эшли (1929–32), «*Магнит эшчесе*» г-та-





Чиләбе шәһәре. 1.М.Ф.Вәлиевнең Сәүдә йорты бинасы. 20 йөз башы фоторәсеме; 2. Бертуган Яушевларның сәүдә пассажы. 1911–13. 20 йөз башы фоторәсеме.

сы нәшер ителә (1931–35). 1935 тә Чиләбедә «Музыка һәм драма» театр җәмгыяте (1913 тән эшли) җирлегендә Чиләбе өлкә күчмә колхоз-совхоз татар театры (Бөек Ватан сугышы башлану б-н таркатыла) оештырыла. 1941 дә Троицк үзешчән татар театры (1970 еллар — 1980 еллар башы) эшли башлый. 1957 дә «Маяк» җитештерү берләшмәсендә һәлакәт булу сәбәпле, Ч.ө.нең төньяк өлеше радиоактив зарарлана. Иң зур зыян күргән татар торак пунктлары: Мөслим һәм Татар Караболагы. Хәзерге вакытта Ч.ө. татар конгрессы, «Татар һәм башкорт мәдәни үзәге» өлкә иҗтимагый оешмасы, Татар мәдәни үзәге һәм Магнитогорскида «Төп йорт»



Чиләбе өлкәсе. Троицк шәһәрендә бертуган Яушевларның сәүдә пассажы. 1911. 20 йөз башы фоторәсеме.

татар мәдәни-социаль үзәге, Сатка шәһәрендә Татар-башкорт мәдәни үзәге, Югары Өфәле шәһәрендә «Мирас» татар-башкорт мәдәни үзәге эшли. Татар теле өлкәнең 10 нан артык гомуми белем бирү учреждениесендә укытыла. Татар теле һәм әдәбияты буенча олимпиадаларда Кызыл Армия, Коншак, Нязепетровск һәм Уй р-ннарының укучылары катнаша.Татар һәм башкорт һәвәскәр композиторларының Чиләбе өлкә иҗат берләшмәсе, Троицк Үзәк китапханәсе системасының 1 нче ф-лы — татар-башкорт китапханәсе эшчәнлеген алып бара, аның каршында «Сөембикә» хатын-кызлар клубы, «Яшьлек», «Ләйсән», «Шатлык» (Магнитогорск), «Уралым» (Миасс ш., 1952 дән) ансамбльләре эшли. Өлкә телевидениесендә «Хәзинә» (2010 нан), «Һилал» телетапшырулары чыга. Златоуст шәһәрендә «Ак Барс» акц. коммерция банкының ф-лы бар. 100 дән артык мөселман мәхәллә эше эшли. Өлкә Сабан туе үткәрелә. Татар халкының күп кенә күренекле эшлеклеләренең тормышы Ч.ө. б-н бәйле. Алар арасында: Сов. Союзы Геройлары И.Г.*Газизуллин*, Г.И.*Байморзин*, Л.И.*Кадыйргалиев*, Х.Ә.*Нигъбәков*; Россия Герое Т.Ф.*Ибраһимов*; шагыйрьләр М.К.*Акмулла*, Ш.М.*Бабич*, Ә.М.*Галимов*, Г.*Тукай*, Б.Ш.*Рәфыйков*; дин эшлеклеләре Габдулла *Буби* һәм М.*Буби*, З.*Рәсүлев* һәм Г.З.*Рәсүлев*, М.М.*Һадиев*; язучылар С.С.*Әдһәмова*, Р.В.*Вәлиев*, М.Н.*Гафури*, А.К.*Расих*; педагоглар Ф.З.*Аитова*, Л.К.*Газизов*; тел галиме Ф.Г.*Исхаков*, тарихчылар Г.Г.*Баттал*, Г.С.*Гобәйдуллин*; журналистлар М.К.*Бөдәйли*, Г.Т.*Гыйсмәти*, Г.И.*Идриси*, Х.Ф.*Искәндәров*; рәссам Ч.Г.*Әхмәров*; развед-чик И.Г.*Әхмәров*; нефтьче-геолог А.А.*Бакиров*; мәдәният эшлеклеләре *Иляловлар*; драматург С.Г.*Кальметов*; актёр һәм режиссёр М.И.*Мутин*; бокс буенча Европа чемпионы Э.М.Абзалимов һ.б.

Әд.: Илялова И. Татарский театр на Урале // Идель. 1991. № 4; Плешкевич Е.А. Троицк был «Уральской Меккой» // Междуречье. 2000. № 6; Абубакирова М., Шамсутдинов И., Хасанжанова Р. Историю оставить народу своему. Троицк, 2002; Этнотерриториальные группы татар Поволжья и Урала и вопросы их формирования: Ист.-этногр. атлас татар. народа. К., 2002; Денисов Д.Н. Очерки по истории мусульманских общин Челябинского края (XVIII — начало XX в.). М., 2011; Усманова А. Библиотека башкирской и татарской литературы // Челябинск: Энцикл. Челябинск, 2001; Гайнуллин М.Ш. Татары // Челябинская область: Энцикл. Челябинск, 2006. Т. 6; Ислам на Урале: Энцикл. словарь. М., 2009.

Р.Н.Гыйззәтуллин, М.Ш.Әхәтов.

ЧИЛӘБЕ́ ТАТА́Р ТЕА́ТРЫ. Иң элек Чиләбе шәһәрендә татар музыкасын һәм әдәбиятын пропагандалау б-н шөгыльләнүче «Музыка һәм драма» ширкәте (1913, җитәкчесе Г.Борнаев) каршында татар телендә спектакльләр куючы һәвәскәрләр төркеме оеша. Өзеклек б-н 1930 елларга кадәр эшли. 1935 тә аның нигезендә Чиләбе күчмә колхоз-совхоз театры оеша. 1937–38 дә театр Троицк шәһәрендә эшли, 1939 да кабат Чиләбегә күчерелә һәм Чиләбе өлкә күчмә драма театры на үзгәртелә. Репертуарын милли классика һәм совет драматургиясе әсәрләре тәшкил итә: «Банкрот», «Уйнаш» (Г.Камал), «Хаҗи әфәнде өйләнә» (Ш.Камал), «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин), «Галиябану» (М.Фәйзи), «Наёмщик» (Т.Гыйззәт), «Яшь йөрәкләр» (Ф.Бурнаш), «Урманда» (Ф.Хөсни), «Любовь Яровая» (К.А.Тренёв) һ.б. спектакльләр Чиләбе трактор з-ды цехларында, клубларда күелa. Күпчелек актёрлар армиягә мобилизацияләнү сәбәпле, 1941 дә театр таркатыла. 1950 еллар башында Татар театр уч-щесен тәмамлаган Г.Сәлимов тарафыннан Чиләбе трактор заводы каршында Татар халык театры оеша.

ЧИЛЧӘ́ елгасы, Идел алдында, Зөя елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 29,2 *км*. Бассейнының мәйданы 237,8 *км*^{2}. Идел буе калкулыгыннан, Буа р-нында ага. Елга башы Сарсаз авылыннан 3,5 *км* көнбатыштарак, тамагы Чуаш Сарыкамышы авылыннан көньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 70 *м*. Ч.нең су җыелу мәйданында урман үсемлекләре үсми диярлек. 1,6 дан 33 *км* га кадәрге озынлыктагы 5 кушылдыгы бар, иң зурысы — Олы Тилчә (уң кушылдык). Елга челтәренең тығызлыгы 0,4 *км/км*^{2}. Туеныу катнаш, күбрәк кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,1 *л/с·км*^{2}. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Җәен озак вакыт яңгырлар булмаганда, елганың кайбер урынары кибә. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 50 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 52 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,015 *м*^{3}*/с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*. Ч. бассейнында суының гомуми күләме 3,2 млн. *м*^{3} булган 3 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

ЧИЛЧӘ елгасы, Көнчыгыш Кама алдында, Иж елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 13,7 *км*. Бассейнының мәйданы 37,8 *км*^{2}. Әгерҗе р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Шаршады һәм Иске Чыкалда авыллары арасындагы урман массивында, тамагы — Татар Чилчәсе авылыннан 4 *км* төньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 140 *м*, тамагыныкы — 62 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 85%. Ч.нең 0,3 һәм 1,2 *км* озынлыктагы 2 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тығызлыгы 0,4 *км/км*^{2}. Туеныу катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1–3 *л/с·км*^{2}. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Җәен озак вакыт яңгырлар булмаганда елганың түбән агымы кибә. Язгы ташу, гадәттә, апрель башында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*.

ЧИМТА́Й БӘК (? — 1364/65 еллар тирәсе), Күк Урда идарәчесе (1344–45 тән). Эрзен хан улы. Тәхеткә атасы вафатыннан соң һәм бертуганы *Мөбарәк-хаҗи* хан куылгач утыра. Хакимиятне нығыту сәясәте алып бара. Ак Урда ханнары хакимияте көчсезләнүеннән файдаланып, үз олысының мөстәкыйльлеген нығыта. Сарай әл-Җәдидтәге үзәк хакимияткә актив булыша. Аның ярдәмендә Хызыр, Тимер Хуҗа, Урда Мәлик, Мөрид, Газиз Шәех Алтын Урда тәхетенә утыралар.

Әд.: Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960.

И.Л.Измайлов.

ЧИ́НКИН Габделәхәт Сиражетдин улы (22.4.1937, хәзер Чуаш Респ-касының Батыр р-ны Кыр Бикшиге а. – 3.6.2016, Казан), физиолог, биол. фән. д-ры (1989), проф. (1990), РФнең атказ. физик культура хезмәткәре (2002). Казан пед. ин-тын тәмамлый (1959), Казан вет. ин-тында эшли (1961 дән). 1965 елдан Казан пед. ин-тында физик тәрбиянең мед.-биол. нигезләре каф. мөдире (1976–85, 1987–91). 1991 дән Кама физик культура, спорт һәм туризм академиясендә (Чаллы ш; 2010 нан — Идел буе физик культура, спорт һәм туризм академиясе, Казан); мед.-биол. дисциплиналары каф. мөдире (1991–97 һәм 2011 дән), проректор (1997 дән), ректор (1999–2005). Хезмәтләре йөрәк эшчәнлеген көйләүче нервларга һәм гумораль факторлар механизмнарына төрле хәрәкәтләнү режимнарының тәэсирен өйрәнүгә карый. Спортчыларда брадикардия барлыкка килүгә сәбәп булучы физиол. механизмнарны ачыклый. Медаль, ТАССР ЮСның Мактау грамотасы б-н бүләкләнә.

Хезм.: Двигательная активность и сердце. К., 1995; Вестибулярные реакции юных спортсменов, занимающихся прыжками на лыжах с трампли-

на // Физиология человека. 2008. Т. 34, № 2 (автордаш); Основы подготовки бегунов на длинные дистанции: Метод. пособие. М., 2008 (автордаш).

ЧИ́НКИН Миңнулла Низаметдин улы (4.6.1931, хәзер Чуаш Респ-касының Батыр р-ны Кыр Бикшеге а.), тренер (җи ңел атлетика), ТАССРның атказ. физик культура хезмәткәре (1988), РСФСР, ТРның атказ. тренеры (1989, 2004). 1958–67 елларда урта мәктәптә физкультура укытучысы (Бөгелмә р-нының Карабаш а.), 1967–72 дә физик культура техникумында укытучы һәм директор урынбасары (Әлмәт ш.), 1973 тән Чаллы шәһәрендә — «КамАЗ» СКның олимпия резервындагы 3 нче махсуслаштырылган балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә (1973–94), ТРның физкультура-спорт буенча дәүләт ком-ты үзәк СКда (1994–95), «Чаллы» балалар-сәламәтләндерү комплексында (1995–2003), «Яр Чаллы» комплексты балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә (2003 тән) тренер-укытучылык эшендә. Бер үк вакытта, 1983–89 да, җи ңел атлетика буенча СССР җыелма командасы тренеры. Шәкертләре арасында (30 дан артык СССР, Россия спорт осталары әзерләнгән) — РСФСР, СССР, Европа, дөнья чемпионатларында, Олимпия уеннарында, РСФСР, СССР халыклары спартакиадаларында җиңүчеләр һәм медаль алучылар, Россия, Европа Кубоклары ияләре: Г.И.*Сәмитова*, Ф.И.Зарипов, Р.И.*Кашапов*, Е.С.Маськина-Бикулова, В.И.Стариков, Ю.И.Стариков, Ф.Р.*Солтанова-Жданова*, Н.Х.Хөснуллин. Медальләр б-н бүләкләнә. Чаллы шәһәренең мактаулы гражданы (2007).

ЧИ́НКИНА Нурия Шәйхетдин кызы (5.8.1949, Үзбәкстан ССРның Харәзем өлкәсе Хива ш.), педагог, пед. фән. д-ры (2000), проф. (2002). Ульянов пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1971), Ульянов өлкәсе һәм Чаллы шәһәре мәктәпләрендә география укытучысы, директор урынбасары һәм директор булып эшли. 1993 елдан Чаллы пед. ин-ты нының пед. һәм психол. кафедрасында, 2001 дән каф. мөдире, бер үк вакытта, 2003 тән, проректор. Хезмәтләре педагог шәхесенең иҗади үзлектән камилләшүенә багышлана.

Х е з м.: Педагогические основы стимулирования мотивации творческого саморазвития учителя в условиях инновационной деятельности. К., 1999.

ЧИНЧУ́РИНО авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 16 *км* төньяк-көнбатыштарак, Үләмә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 309 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1618–19 дан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Дмитриевский, Тинчурино исемнәре б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы удел (1797 гә кадәр — сарай) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, балта эше б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Дмитрий Солунский чиркәве, Белая Криница иерархиясенең иске дин тарафдарлары гыйбадәтханәсе, земство мәктәбе (1866 да ачыла), 10 җил тегермәне, 3 тимерче алачыгы, 2 май язу йорты, 2 ярма яргыч, салат оны ясау йорты, 2 сыраханә, казна шәраб һәм 7 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3556 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Кызыл Алан волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Тәтеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 490 ир-ат; 1859 да — 1780, 1897 дә — 2639, 1908 дә — 2711, 1920 дә — 2739, 1926 да — 1895, 1938 дә — 1628, 1949 да — 1143, 1958 дә — 1021, 1970 тә — 815, 1979 да — 646, 1989 да — 480, 2002 дә — 344 кеше.

ЧИРӘМДӘГЕ́ ХОККЕ́Й, капкалы (3,66×2,14 *м*) махсус кырда (55×91,4 *м*) туп һәм кәшәкә б-н командалы (11 кеше) спорт уены. Уенның максаты — көндәшенең капкасына кәшәкә б-н туп кертү. Ч.х.ның төре — индорхоккей (ябык биналарда уздырыла, мәйданы 20×40 *м*, командада 6 кеше). Казанда 1975



Чирәмдәге хоккей. «Динамо-Казан» командасы.

елда «Спартак» ирекле спорт җәмгыяте каршында Ч.х.ның хатын-кызлар секциясе барлыкка килә. 1981 дә Казан химия-технол. ин-ты каршында «Буревестник» ирләр командасы оештырыла (тренеры В.А.Стариков), 1987 дә «Луч» исеменә үзгәртелә (Профсоюзларның бөтенсоюз ирекле физкультура-спорт җәмгыяте каршында), 1992 дән — «УНИКС», 1993 тән — «Идел», 2000 нән — «Динамо-Казан» («Динамо» физкультура-спорт җәмгыяте каршында). Балалар-яшүсмерләр өчен Ч.х.ны Профсоюзларның ирекле спорт җәмгыяте балалар-яшүсмерләр спорт клубы, «Яшүсмер» шәһәр берләшмәсенең Алиш исем. Балалар иҗат үзәге спорт секциясе (1981–96), 1996 дан Казанның Авиатөзелеш р-ны балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе җәелдерә. 2000 нән Ч.х. Олимпия резервындагы «Динамо» респ-ка махсуслаштырылган балалар-яшүсмерләр мәктәбендә (Яшел Үзән шәһәрендәге ф-лы) һәм Казанның «Авиатор» балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә, 2005 тән Казан Олимпия резервы уч-щесендә үстерелә.

ТРның иң яхшы ирләр командалары: «Динамо-Казан» (2001 дән суперлигада) — РФ чемпионатларында 2003–08, 2010, 2010/11 — 2015/16, 2016, 2017, (2002 һәм 2009 — көмеш; 2000–01 — бронза), БДБ илләре чемпионатында (2014/15) җиңүче, Россия (2001, 2005), Викинглар (2000), Европа кубоклары ияләре (2003), «Трофи» Европа чемпионнары (2007); «РСДЮШОР-Динамо» (югары лига) кубоклары иясе; хатын-кызлар командалары: «Динамо-Гипроний авиапром» (2006 дан «Сөембикә», 2007 дән «Сөембикә-Нефтехимик», 2008–11 дә «Динамо-Идел»; 2007 дән суперлигада); «Динамо» УОР-РСДЮСШОР (2012 дән суперлигада). 2007 дә Ч.х. үзәге файдаланылуга тапшырыла — РФнең халыкара таләпләргә туры килгән иң яхшы махсуслаштырылган объектларының берсе. 2018 гә Ч.х. (индорхоккей) б-н шөгыльләнүчеләр Татарстанда 1200 кеше (шуларның якынча 500 е — хатын-кызлар). Ч.х. федерациясе президенты — Б.П.Павлов (2007 дән).

ЧИ́РИКОВ Евгений Николаевич (24.7.1864, Казан — 18.1.1932, Прага), язучы. 1883–87 Казан ун-тында укый, студентлар сходкасында катнашканы өчен (В.И.Ульянов б-н берлектә), Түбән Новгородка сөргенгә җибәрелә. 1886 елда «Волжский вестник» г-тасында Ч.ның «Җирән» («Рыжий») исемле беренче хикәясе басыла. Казаннан алган тәэсирләре «Идел буе халыклары әкиятләре» («Волжские сказки», 1916) җыентыгында һәм «Тархановның тормышы» («Жизнь Тарханова», 1911–25) автобиографик тетралогиясендә чагылыш таба. 1917 дән соң Чехословакиягә эмиграциягә китә.

Х е з м.: Собр. соч.: В 17 т. М., 1910–16.

Әд.: Русские писатели 20 века: Биогр. словарь. М., 2000.

ЧИРКӘ́С авылы, Алабуга р-нында, Алабуга шәһәреннән 35 *км* төньяк-көнбатыштарак, Күклек елгасы буенда. 2010 елда 27 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Клуб. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ч.тә волость идарәсе урнаша; 2 тегермән эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1151,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Чиркәс волостенда, 1920 дән ТАССРның — Мамадыш, 1921 дән — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга, 1944 нең 19 февраленнән — Костенеево, 1944 нең 8 июненнән — Морт, 1954 нең 19 ноябреннән Алабуга р-нында. Халык саны: 1859 да — 246, 1887 дә — 572, 1905 тә — 810, 1920 дә — 728, 1926 да — 848, 1938 дә — 652, 1949 да — 326, 1958 дә — 217, 1970 тә — 130, 1979 да — 70, 1989 да — 47, 2002 дә — 35 кеше.

ЧИРКӘСКҮ́Л КУЛЬТУ́РАСЫ (археол.), бронза гасырның соңгы чорында (якынча, б.э.к. 2 нче меңъеллыкның 3 нче чиреге) Урал-Чулман буе төбәгендә яшәгән халыкка караган культура. Атамасы Чиләбе өлкәсе Касли р-ны Чиркәскүл туктаулыгына нисбәтле. Ч.к. истәлекләре беренче тапкыр (1956) К.В.Сальников тарафыннан тасвирлана һәм мөстәкыйль археол. культура сыйфатында күрсәтелә. Татарстан терр-ясендә Ч.к. торулыклары һәм каберлекләре Е.П.Казаков тарафыннан өйрәнелә, аларның иң зурысы — Такталачык каберлеге. Ч.к. халкы, башлыча, терлекчелек б-н шөгыльләнгән, бронза койган. Ч.к. кабиләләренең үзәннәр өстендәге сөзәк мәйданнарда урнашкан туктаулыкларында геом. бизәкләр төшерелгән яссы төп ле, әвәләп эшләнгән балчык савыт-саба (изгә вакланган кабырчыклар кушылган),



М.А. Чирков.

бронза эшләнмәләр, хайван сөякләре һ.б. та - была. Үзенчәлекле җирләү йоласы эзләре сакланган һәм әйберләр җыелмасы (бронза бизәнү әйберләре, сөңгеләр, чакматаш һәм сөяк ук очлыклары, мәрхүмнәрнең башлары янында балчык савытлар һ.б.) куелган каберләр өстенә курганнар өелгән. Мәетләр аяклары бөгелгән хәлдә ян-якларына яки



Чиркәскүл культурасы керәч савытлары. Бронза дәвере.

җилкәләренә яткырылган, башлары көнчы - гышка каратылган. Татарстан терр-ясендә Ч.к. истәлекләре Актаныш р-ны Такталачык, Меңнәр авыллары тирәсендә табылган.

Е.П.Казаков.

ЧИРКӘҮ-ПРИХОД МӘКТӘПЛӘРЕ, Пра - вославие чиркәве карамагындагы гомуми бе - лем бирү уку йортлары. Башта Халык уч-ще - ләре уставы нигезендә (1804) булдырыла - лар; 1860 еллар уртасына Россиядә 21420 Ч.-п.м. исәпләнә, аларда 412 мең укучы укый. Аларга бюджеттан акча бүлеп бирелми; алар - ның күп өлеше кәгазьдә генә кала, кайбер приходларда руханилар үз теләкләре б-н ба - лаларны укырга-язарга өйрәтә. 1884 нең 13 июнендә император Александр III тара - фыннан расланган «Чиркәү-приход мәктәп - ләре турында кагыйдәләр»гә нигезләнеп, Ч.-п.м. ачуга һәм аларны тотуга шактый ак - ча бүлеп бирелә. Белем бирүнең яңа система - сы б-н җитәкчелек итү өчен Синодның Чир - кәү-укыту ведомствосы, урыннарда Епархи - аль уч-ще советлары оештырыла. Россиядә 1885 тә — 5517, 1905 тә — 42696, 1915 тә — 40530, Казан губернасында 1885 тә — 272, 1890 да — 392, 1900 дә — 662, 1903 тә — 817, 1917 дә — 700 Ч.-п.м. исәпләнә. Ч.-п.м. систе - масын булдыруда башлап йөрүчеләр — Си - нодның обер-прокуроры К.П. Победоносцев һәм педагог С.А. Рачинский, аларның макса - ты барлык башлангыч белем бирү система - сын акрынлап чиркәү контроленә күчерүдән гыйбарәт була. Земство һәм шәһәр органна - ры үзләренең мәктәпләрен, тотуга акча бүлеп бирүне дәвам итеп, аларны чиркәү-укыту ве - домствосына күчерерләр дип планлаштыры - ла. Земство һәм Ч.-п.м. системалары бер-бер - сеннән бәйсез рәвештә эшләүләрен дәвам итәләр. Приход мәктәпләре земство мәктәп - ләре булмаган авылларда ачыла. «Кагыйдә - ләр....» нигезендә 3 типтагы Ч.-п.м. — икеел - лык грамоталылык мәктәпләре, өч еллык бер класслы мәктәпләр (күпчелек), бишьеллык ике класслы мәктәпләр күздә тотыла.1896 дан пед. уку йортлары челтәре булдырыла баш - лый (к. *Икенче класслы мәктәпләр*). «Кагый - дәләр....»дә земство мәктәпләреннән аермалы буларак, Ч.-п.м. — чын православие мәктәп - ләре, аларда гади халык өчен «дөрес» белем бирелә, дип игълан ителә. Асылда укыту шул ук башлангыч мәктәпләрдәге программалар, методика һәм дәреслекләр буенча алып бары - ла. Күпчелек Ч.-п.м.ндә чиркәү җыры дәрес - ләре, кайберләрендә иске славян теле укыты - ла. Рус булмаган халык яшәгән авылларда, кагыйдә буларак, укыту *Ильминский система - сы* буенча ана телендә алып барыла.

Мәктәпләр б-н приходларның настоятель - ләре җитәкчелек итә, алар Алла канунын укыта, җирле руханилар һәм псаломчылар укытучы булалар, ләкин күп очракта Ч.-п.м.н - дә штатта торган укытучылар укыта. Гому - мән, приход мәктәпләре укытучыларга хезмәт хакы түләү буенча (югары квалификация - леләре земство мәктәпләренә күчә), уку яр - дәмлекләренә һәм бинаны тотуга чыгымнар буенча җирле үзидарә уку йортларыннан ка - лыша. Шу ңа карамастан, алар грамоталы - лыкны таратуда уңай роль уйный, 20 йөз ба - шына аларда кәрәстиян балаларының өчтән бере чамасы укый. 1905 тән соң, Ч.-п.м.н зем - стволарга күчерү нәтиҗәсендә, аларның чел - тәре кыскартыла башлый, 1917 елгы Фев. рев-циясеннән соң бу процесс тизләтелә. Чир - кәүләрнең дәүләттән аерылуы турындагы 1918 ел 20 гыйнвар Декреты нигезендә Ч.-п.м. совет башлангыч мәктәпләре итеп үзгәрте - лә; шактый өлеше финанслау булмау сәбәп - ле ябыла.

Әд.: Исторический очерк развития церковных школ за истекшее двадцатипятилетие (1884–1909 гг.). СПб., 1909; Захарьевский П.И. Церковные школы Казанской епархии за 25 лет их существования (1884–1909) // Изв. по Казанской епархии (1884–1909). 1909. № 10.

ЧИ́РКИН Анатолий Павлович (5.8.1860, Әс - терхан ш. — 1917 дән соң), хокук белгече, ха - кыйкый статский советник (1907). Сәүдә - гәрләр катлавыннан. Казан ун-тын тәмам - лый (1883). 1883–88 елларда Казан округ мәхкәмәсе канцеляриясендә: 1885 тән 2 нче җинаять эшләре бүлеге секретаре. 1888–91 дә Казан губернасы Цивильск һәм Тәтеш өязләрендә участок мәхкәмә тикшерүчесе. 1891–1900 дә Сембер, 1900–04 тә Казан округ мәхкәмәләре прокуроры урынбасары. 1904–06 да Сарапул, 1906–07 дә Сембер, 1907–16 да Казан округ мәхкәмәләре прокуроры. 1916–17 дә Мәскәү мәхкәмә палатасы әгъзасы.

Е.Б.Долгов.

ЧИРКО́В Михаил Алексеевич (1898, Казан губ., Тәтеш өязе Кирельский пос. — 3.2.1945, Тимендорф торак пункты, Германия), Сов. Союзы Герое (17.10.1943), рядовой. Беренче бөтендөнья һәм Гражданнар сугышларында катнаша. 1937 елдан Казанда яши һәм эшли. 1942 дән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 167 нче җиңел артиллерия полкы телефончы - сы (47 нче армиянең 23 нче укчы дивизиясе). Воронеж, 1 нче Украина, 2 нче һәм 1 нче Бе - лоруссия фронтлары гаскәрләре составын - да Белгород-Харьков (1943), Люблин-Поз - нань (1945) һөҗүм операцияләрендә катна - ша. 1943 нең сентябрендә сугышларның бер - сендә батырлык күрсәтә: дошман уты астын - да Днепр елгасы аша ут астында кабель сы - зыгын уздыра һәм җитәкчелек б-н уң ярдагы разведка төркеме арасында элемтә урнашты - ра; совет тупчыларының утын дөресләргә булыша, плацдармда дошманның контрһө - җүмен кире кагуда катнаша. Дошман уты ас - тында элемтә урнаштырганда Германия терр-ясендә һәлак була. Ленин ордены, Кы - зыл Байрак ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Шәһәр тибындагы Кама Тамагы посёлогында бер урамга Ч. исеме бирелә.

Әд.: Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

М.З.Хәбибуллин.

ЧИРКОВЛА́Р БАСМАХАНӘСЕ́. *Коковин Н.П. басмаханәсеннән* башлангыч ала, 1853 ел - да ул аның тол хатыны А.А.Коковинага кала. А.А.Коковина бинаны Казан сәүдәгәре С.И.Чирковка арендага бирә. Гарәп шрифт - ларының запасы шактый булып, басмаханә татар китапларын ел саен күпләп чыгара. Басмаханә җи һазлары һәм материаллар *Ще - вица Л. басмаханәсе* вакытыннан ук яңар - тылмый, басмаларның сыйфаты начар була. 1884 тә, А.А.Коковина вафат булгач, басмаха - нә — арендатор милкенә, алга таба аның улы И.С.Чирковка күчә. 1880 еллар ахырыннан Чиркова М.А. басмаханәсе, 1894 тән Чирко - ва М.А. варислары басмаханәсе дип атала башлый. 19 йөзнең 2 ярты сында басылган татар китаплары саны буенча Ч.б. Казан ун - ты басмаханәсеннән генә калыша. 1884–1900 дә 560 исемдәге гомуми тиражы 6 млн.нан артык татар басмасы нәшер ителә, алар арасында — Коръән, Һәфтияк, дини әдә - бият, фольклор әсәрләре («Һарун Рәшит», «Кыз Җибәк», «Малик Хәсән»), иске һәм яңа укыту алымлы мәктәпләр өчен әлифба - лар, арифметика дәреслекләре, татар әдәбия - ты әсәрләре, мед. һәм терлекчелек буенча по - пуляр хезмәтләр, кыргыз телендәге китап - лар. Басмаханәнең актив заказчылары — Ш.Хөсәенов, М.Г.Кәримов, И.Ишморатов, И.Идрисов, Г.Галиев (Баруди). Рус нашир - ләре: Казан руханилар академиясе, миссионер - ларның заказлары да үтәлә, татар, чуаш, ма -

ри һ.б. телләрдә христиан язмалар басыла. 1901–1906 да гомуми тиражы 2481990 данә булган 171 исемдәге басма чыгарыла, алар арасында дидактик әдәбият, урта гасырлар Шәрекъ язмалары өстенлек ала. 1901–1909 да рус телендә 77 исемдә рәсми-ведомство, уку, популяр басмалар дөнья күрә (20 йөздә Казанда чыккан рус телендәге китапларның 1,5 % ы). 1913 тә хуҗасы алышына, басмаханә Идел-Кама басмасы дип атала башлый. 1915–17 дә 25 исемдә рус китаплары чыга. 1919 ел башында басмаханә А.И.Ширмановныкы була, шул ук елның мартында Губерна хәрби ком-ты карамагына тапшырыла, 1921 дә национализацияләнә.

Әд.: Каримуллин А.Г. Татарская книга пореформенной России. К., 1983; Габдельганеева Г.Г. Полиграфия и печать в Казанской губернии. 1800–1917 гг. К., 2005.

Г.Г.Габделганиева.

ЧИРКӘ́ВО авылы, Бөгелмә р-нында, Бөгелмә шәһәреннән 22 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Кырымсарай елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 154 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 18 йөз ахырында Ч.да генерал-майор Н.А.Чирковның аракы з-ды, 20 йөз башында Дионисий чиркәве (1841–45 тә төзелә; архит-ра истәлеге), чиркәү-приход мәктәбе (1885 тә ачыла), сабын з-ды эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1585 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Сумароково волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Бөгелмә р-нында. Халык саны: 1859 да — 641, 1889 да — 1135, 1897 дә — 1053, 1910 да — 983, 1920 дә — 1135, 1926 да — 1063, 1938 дә — 680, 1949 да — 529, 1958 дә — 562, 1970 тә — 268, 1979 да — 190, 1989 да — 193, 2002 дә — 162 кеше.

ЧИРКО́ВСКИЙ Василий Васильевич (1.1.1875, Самара губ. Натальино а. — 2.3.1956, Ленинград), офтальмолог, медицина д-ры (1904), СССР МФА хакыйкый әгъзасы (1945), РСФСРның атказ. фән эшлеклесе (1936). Казан ун-тының мед. ф-тын тәмамлаганнан соң (1899), шунда ук күз авыруларының клиникасында проф. Е.В.Адамюк карамагында калдырыла. 1904 елда Казан бактериология ин-тында эшли. 1907–08 дә Франция, Австрия, Германия клиникаларында фәнни командировкаларда. 1908 дән Казан ун-тының күз авырулары клиникасында, проф. (1917). 1920–22 дә Пермь ун-тында күз авырулары кафедрасын оештыручы һәм мөдире. Трахома ин-тына нигез салучы һәм директоры (1922–29), бер үк вакытта Казан ун-ты ректоры (1923–26) һәм Казан ГИДУВының күз авырулары каф. мөдире. 1929–52 дә 1 нче Ленинград мед. ин-тында офтальмология каф. мөдире, бер үк вакытта Гиршман исем. Ленинград күз авырулары фәнни-тикшеренү ин-ты директоры һәм фәнни җитәкчесе. Хезмәтләре трахома эпидемиологиясенә һәм авыруның социаль-гигиена аспектларына, күрү әгъзаларының патологик анатомиясе һәм физиологиясенә, глаукома мәсьәләләренә карый. «Трахома» монографиясе өчен 1948 дә СССР Дәүләт бүләгенә лаек була, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Ленинград офтальмология җәмгыяте рәисе (1935–50).

Хезм.: О новых путях в диагностике трахомы // Советский врачебный журн. 1936. № 6; Боевые повреждения глаза и доокулистическая хирургическая помощь при них. М., 1941.

Әд.: Видные учёные отечественной медицины и здравоохранения — питомцы Казанского медицинского института. К., 1989.

ЧИРМЕШӘ́Н елгасы, Идел алдында, Бола елгасының (Зөя елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 32,8 *км*, ТР чикләрендә — 28,1 *км*. Бассейнының мәйданы 221 *км*². Идел буе калкулыгыннан ага. Елга башы һәм югары агымы Чуаш Респ-касы терр-ясендә, берникадәр өлеше Кайбыч р-нында, тамагы — Апас р-ны Дәүләки авылыннан 2 *км* көньяктарак. Елга башының абс. биеклеге 180 *м*, тамагыныкы — 61 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 20%. Ч.нең 0,9 дан 10,1 *км* га кадәр озынлыктагы 14 кушылдыгы бар, аеруча зурлары — Томба елгасы (уң кушылдык). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,45 *км/км*². Туенуы катнаш, күбрәк кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,1–0,25 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы, җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 123 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 100 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,18 *м*³/*с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. Ч. бассейнында суының гомуми күләме 1,4 млн. *м*³ булган 2 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

ЧИРМЕШӘ́Н авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 32 *км* көнба-тыштарак, Чирмешән елгасы буенда. 2010 елда 470 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау; тире илүү цехы. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1646 дан Югары Башка Чирмешән исеме б-н мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Башка Чирмешән, Икенче Чирмешән буларак та билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәдрәсә, Халык мәгарифе министрлыгы мәктәбе, җил һәм 3 су тегермәне, 3 тимерче алачыгы, 2 ярма яргыч, 2 мануфактура һәм 2 вак-төяклә кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1723,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Зур Тояба волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кайбыч, 1944 нең 19 февраленнән — Подберезье, 1956 ның 17 маеннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 151 ир-ат; 1859 да — 809, 1897 дә — 1349, 1908 дә — 2116, 1920 дә — 1646, 1926 да — 1547, 1938 дә — 1557, 1949 да — 1154, 1958 дә — 1018, 1970 тә — 1078, 1979 да — 1025, 1989 да — 672, 2002 дә — 557 кеше.

ЧИРМЕШӘ́Н авылы, Чирмешән р-ны үзәге. ТРның көньягында, Шонталы тимер юл станциясеннән (Ульянов — Уфа юнәлеше) 26 *км* төньяктарак, Казаннан 251 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Самара өлкәсе б-н чиктәш урнашкан. Район терр-ясеннән Олы Чирмешән елгасы ага. 2010 елда 5927 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 51%, руслар — 29%) яши. «Чирмешәнагрохимсервис», икмәк комб-ты, икмәк кабул итү пр-тиесе АҖ ләре, төзелеш (ш.и. кирпеч з-ды), энергия б-н тәэмин итү, коммуналь хезмәтләр, элемтә, сәүдә пр-тиеләре. 106 нчы һөнәр уч-щесе, лицей, 2 урта, балалар сәнгать һәм балалар-яшүсмерләр спорт мәктәпләре, 4 мәктәпкәчә тәрбия учреждениесе. Район мәдәният йорты, китапханә, Мемориаль үзәк, яшьләр ял үзәге, төбәк тарихы музее, район үзәк хастаханәсе, стадион, «Юбилейный» боз спорт сарае, «Чирмешән» физкультура-сәламәтләндерү комплексы. Мәчет, 2 чиркәү. 1734–35 елларда *Кама аръягы чик сызыгындагы* кальга буларак нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда авыл Чирмешән Крепосте исеме б-н телгә алына. Башта халкын Чишмә һәм Алексеев ландмилиция полклары солдатлары (462 кеше) тәшкил итә. 1753 тән соң Чирмешән Крепостена шунда имана җирләре һ.б.ташламалар алган отставкадагы (игенче) солдатлар урнаша. 1768 дә — 1035, 1780 дә 1347 кеше яши. 1767–68 дә авылда *Акаде-*



Чирмешән районы Чирмешән авылы. Гомуми күренеше.




Чирмешән авылы. 1. Мәдәният йорты; 2. Хакимият бинасы.

мия экспедицияләрендә катнашучылар И.И.*Лепёхин*, П.С.*Паллас*, Н.П.Рычков була. 1773–75 тәге Крәстияннәр кузгалышы чорында генераллар Миллер һәм Фрейман җитәкчелегендәге хөкүмәт гаскәрләре урнаша, алар Е.И.Пугачёв отрядларын берничә тапкыр җи ңелүгә дучар итә. 1831 дә җирле халык хәрбиләрдән дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә. П.Д.Киселёвның 1837–41 дәге реформасыннан соң, 1843–47 дә Чирмешән Крепосте халкының күбесе (1800 гә якын кеше), элеккеге игенче солдатлар, әүвәлге ташламалар сакланган Урал елгасы буена күченәләр. 1847 дән буш җирләргә дәүләт крәстияннәре килеп утыра. Халкының төп шөгыле игенчелек, терлекчелек, умартачылык, тире иләү, курыс төшерү-мунчала ясау, столярлык эше, кирпеч сугу, бияләй һәм перчатка тегү, олаучылык, сәүдә була. Авылның социаль-икътисади үсешенә 600 ләп йортны юкка чыгарган 1890 елгы янгын тискәре йогынты ясый. 20 йөз башында Ч.дә волость идарәсе, стан приставы фатиры урнаша; земство почта станциясе, почта-телеграф бүлекчәсе, сугыш атлары участогы, Михаил-Архангел чиркәве (1891 дә төзелә; архит-ра истәлеге), 2 земство (1868 һәм 1908 дә ачыла) һәм һөнәр мәктәбе (1910), чиркәү (2) һәм земство мәктәпләре каршында китапханәләр, 2 су тегермәне, земство хастаханәсе (табиб, 3 фельдшер, акушерка), аптека, ветеринар була; икмәк һәм җомга базары, 2 ярминкә эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 9262 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Югары Карамалы волосте үзәге, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Беренче Май (1938 дән — район үзәге), 1963 нең 1 февраленнән — Лениногорск р-нында, 1965 нең 12 гыйнварыннан — Чирмешән р-ны үзәге. Халык саны: 1859 да — 1582, 1889 да — 3729, 1910 да — 4151, 1920 дә — 3921, 1926 да — 3103, 1949 да — 3055, 1958 дә — 2775, 1970 тә — 3188, 1979 да — 3455, 1989 да — 4373, 2002 дә — 5635 кеше. Авыл янында Кама аръягы чик сызыгы корылмаларының (1732–36) калдыклары саклана.

Әд.: Фролов Н.С. Село Черемшанская крепость (XVII–XIX век): Очерки истории. К., 2002.

ЧИРМЕШӘН МЕМОРИА́ЛЬ ҮЗӘГЕ́, җәмәгатьчелек тәртибендә төбәкне өйрәнүче Н.С.Фролов башлангычы б-н 1980 елның 8 маенда ачыла, 1991 дән Берләштерелгән Дәүләт музее (2001 дән — ТР Милли музее) ф-лы, 2006 дан муниципаль музей. Чиркәү бинасының бер өлешен алып тора (1878; архит-ра истәлеге). Экспозиция мәйданы — 300 *м*², төп фондны 5 меңнән артык берәмлек тәшкил итә. Үзәк Бөек Ватан сугышы елларында һәлак булганнарның һәм хәбәрсез югалганнарның исемнәрен табу һәм кайтару буенча эш алып бара. 13 мең шәхес турында мәгълүмат тупланган. Экспозиция өч залда урнашкан. Төбәк тарихының рев-циягә кадәрге чорына багышланган бүлектә шагыйрь Г.*Утыз Имәни* һәм язучы Г.*Исхакый* тормышы һәм эшчәнлеге турында сөйләүче документлар куелган. Совет хакимияте урнашу чорын төбәктә яшәүчеләрнең — Беренче бөтендөнья һәм Гражданнар сугышларында катнашучыларның документлары һәм фоторәсемнәре чагылдыра. Экспозициянең бер бүлеге авылда яшәүчеләрнең Бөек Ватан сугышында катнашу темасына багышлана. Шактый урынны Совет хакимияте елларындагы сәяси репрессияләр турындагы материаллар алып тора. Кече сержант Ә.*Җиһаншинның* документлары бик кызыклы. 1960 ның гыйнварында Ә.Җиһаншин һәм аның 3 хезмәттәше ачык океанда эчәргә яраклы сусыз һәм азык-төлексез 49 тәүлек уздырып батырлык күрсәтәләр. Этнография бүлегендә 19 йөз ахыры — 20 йөз башы көнкүреш әйберләре, милли киемнәр, татар халкының гамәли-бизәлеш сәнгате әйберләре күрсәтелгән. Аеруча кыйммәтле экспонатлар арасында: сәяси репрессияләнгәннәрнең тикшерү эшләре күчермәләре, а.х.н күмәкләштерү турында документлар, фронттан хатлар, 1930–50 еллардагы салым кәгазьләре (квитанцияләре). Директор — Н.С.Фролов (1991 дән).




Чирмешән мемориаль үзәге. 1. Гомуми күренеше; 2. Экспозициянең үзәк залы.

Әд.: Фролов Н.С. Трагедия народа. К., 1999; шул ук. Село Черемшанская крепость (XVIII–XIX вв.): Очерки истории. К., 2002; шул ук. Все они хотели жить. К., 2003.

ЧИРМЕШӘ́Н РАЙОНЫ́, ТРның көньягында, Самара өлкәсе б-н чиктәш урнашкан. Мәйданы — 1364,3 *км*². 18 авыл җирлеген, 48 торак пунктны берләштерә. Үзәге — Чирмешән авылы. 2017 елда 19370 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 54%, чуашлар — 21,6%, руслар — 18,5%, мордвалар — 5%) яши. Халкының уртача урнашу тыгызлыгы — 1 *км*² *га* 14,8 кеше. 1930 ның 10 августында үзәге Түбән Кәминкә авылында булган Беренче Май р-ны оештырыла. 1920 гә кадәр Казан губернасының — Чистай, Самара губернасының Бөгелмә өязендә була, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә һәм Чистай кантоннарында. Оешкан көненнән районга 30 авыл советы, 60 торак пункт керә, аларда 42229 кеше (татарлар — 24143, руслар — 9491, башка милләтләр — 8595) яши. 1938 дә район үзәге Түбән Кәминкәдән Чирмешән авылына күчерелә. 1940 та районның мәйданы — 1487 *км*², халык саны — 47 мең кеше, 28 авыл советы, 71 торак пункт була. 1960 та район 1459,8 *км*² җир били, 12 авыл советы, 71 торак пункт керә. 1963 нең 1 февралендә ТАССРда адм. берәмлекләрне эреләндерү сәбәпле, Беренче Май р-ны таркатыла, терр-ясе Лениногорск һәм Октябрь р-ннарына бирелә. Хәзерге исеме кире кайтарылгач (1965 нең 12 гыйн.), районның мәйданы — 1362 *км*², халык саны — 39,4 мең кеше, 13 авыл советы, 64 торак пункт исәпләнә.

Ч.р.ның рельефы — дулкынсыман тигезлек (биеклеге 90 — 215 *м*). Елгалар: Олы Чирмешән һәм аның кушылдыклары Олы Сөлчә, Чишмә. Җирләре күбесенчә селтесезләнгән, карбонатлы һәм типик кара, карасу соры урман туфраклы. Терр-ясенең 25% ы — урманлык. Нефть, известьташ, доломит ятмалары бар. Саклаулы табигать объектлары: Олы Чирмешән, Олы Сөлчә һәм Чишмә, Асфальтит чыгышы геол. табигать истәлеге. Район терр-ясендә бронза гасырдан алып Болгар чорына кадәрге 30 лап археол. истәлек табыла. Терлекчелек тармагы алга киткән. А.х. җирләре — 94,2 мең *га*, ш.и. сөрүлекләр — 75,3 мең *га* (2013). Сабан бодае һәм көзге бодай, арыш, арпа, солы, борчак, карабодай игелә; шикәр чөгендере, бәрәңге үстерелә. 2014 тә районда 8 а.х. пр-тиесе исәпләнә. Сәнәгать пр-тиеләре Чирмешән авылында тупланган. Ч.р. терр-ясеннән Чирмешән–Лениногорск, Чирмешән–Яңа Чишмә–Чистай автомобиль юллары уза. 25 гомуми белем бирү мәктәбе, балалар сәнгать мәктәбе, һөнәр уч-щесе, кадет интернат-мәктәбе, балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбе, 25 мәктәпкә-



чә тәрбия учреждениесе, 39 клуб, 29 китапханә, 1 хастаханә. Төбәк тарихы музее. Татар һәм рус телләрендә «Безнең Чирмешән» — «Наш Черемшан» район г-талары нәшер ителә.

ЧИРМЕШӘН УРМАНЧЫЛЫГЫ, Чирмешән р-ны терр-ясендә урманнарны файдалану, саклау, ышыклау һәм яңадан утырту өлкәсендә идарә эшләре алып бара. 1991 ел - да Чирмешән урман ху җалыгы буларак оештырыла; 2007 дән хәзерге исемендә. Гомуми мәйданы — 36373 *га*. 3 урманчылык: Светлогорский (13058 *га*), Казанка (10303), Шешминка (13012 *га*) участогыннан тора. Урман б-н капланган мәйдан — 34474 *га*, ш.и. ылыслы токымнар — 4689 *га*, каты яфраклылар — 3780 *га*, йомшак яфраклылар — 25910 *га*, куаклыклар 95 *га* тәшкил итә. Урман барлыкка китерүче төп токымнар: усак (30,6%), юкә (30,2%), каен (9,2%), нарат (9,6%), биек кәүсәле имән (5,6%), тәбәнәк кәүсәле имән (3,4%) һ.б. Төрле үләнле һәм өрәңгеле юкәлекләр, каенлыклар һәм зелпеле усаклыклар, чияле имәнлекләр, чикләвек куаклы наратлыклар таралган. Яшь урманнар — 30%, урта яшьтәгеләр — 46%, өлгереп килүчеләре — 4%, өлгергәннәре һәм картайганнары 20% урман мәйданын алып тора. Гомуми агач запасы — 5409 мең $м^3$, ш.и. өлгергәннәре һәм картайганнарының — 258 мең $м^3$. 1991–2010 да 3000 *га* дан артык мәйданда урман культуралары, 340 *га* ерым-сыза һәм юл буе утыртмалары булдырыла. 2 урман питомнигында нарат, чыршы, имән чәчкеннәре һәм үсентеләре, ш.у. торак пунктларны яшелләндерү өчен декоратив культуралар үстерелә. Предприятие җитәкчесе — Р.М.Мотыйгуллин, ТРның атказ. урманчысы.

ЧИРМЕШЛӘР, к. *Марилар*.

ЧИРҮ авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 31 *км* көнбатыштарак, Шәбез елгасы буенда. 2010 елда 79 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп. 18 йөз башында нигез салына. Рев-ция - гә кадәрге рус чыганакларында Чуриева, Чирякова исемнәре б-н дә билгеле. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет (1811 дән мәгълүм), җил тегермәне, ашлык саклау-сату кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2311,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Семиостров волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 136, 1834 тә — 305, 1859 да — 397, 1870 тә — 435, 1884 тә — 429, 1897 дә — 510, 1906 да — 624, 1913 тә — 580, 1920 дә — 507, 1926 да — 399, 1938 дә — 278, 1949 да — 280, 1958 дә — 259, 1970 тә — 159, 1979 да — 161, 1989 да — 122, 2002 дә — 80 кеше.

ЧИРҮ авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 17 *км* көнбатыштарак, Бола елгасы буенда. 2010 елда 34 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Клуб. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ч.дә мәчет, мәдрәсә, су тегермәне, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 519 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Урта Балтай волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 48 ир-ат; 1859 да — 240, 1897 дә — 390, 1908 дә — 519, 1920 дә — 519, 1926 да — 391, 1938 дә — 294, 1949 да — 251, 1958 дә — 215, 1970 тә — 179, 1979 да — 140, 1989 да — 67, 2002 дә — 59 кеше.

ЧИРҮЛЕ́ ШОНТАЛЫ́ авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 32 *км* көньяк-көнбатыштарак, Шонталы елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 57 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Клуб. Мәчет. 17 йөзнең 2 нче яртысында татарлар нигез сала. 18 йөздә авылның бер өлеше рус алпавыты карамагына күчә. 1860 елларга кадәр халкы алпавыт һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ч.Ш.да мәчет (1832 дән), мәктәп, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1379 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Кызылъяр волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан Чистай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 381 ир-ат; 1859 да — 878, 1897 дә — 1165, 1908 дә — 1460, 1920 дә — 1447, 1926 да — 1239, 1938 дә — 1067, 1949 да — 686, 1958 дә — 613, 1970 тә — 516, 1979 да — 324, 1989 да — 132, 2002 дә — 88 кеше. Химик А.М.*Бутлеровның* бала чагы Ч.Ш.да уза.

ЧИРҮЧИ́ авылы, Яшел Үзән р-нында, Яшел Үзән шәһәреннән 35 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Питиал елгасы буенда. 2010 елда 200 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Мәчет. 1602–03 тән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Черевчи, Чурячи исемнәре б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, кап сугу, балта эше, тегү һәм олаучылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, җил тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 785,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кукмара волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1938 нең 4 августыннан — Юдино, 1958 нең 16 июленнән Яшел Үзән р-нында. Халык саны: 1782 дә — 103 ир-ат; 1859 да — 482, 1897 дә — 549, 1908 дә — 618, 1920 дә — 528, 1926 да — 626, 1938 дә — 607, 1949 да — 244, 1958 дә — 262, 1970 тә — 394, 1979 да — 299, 1989 да — 215, 2002 дә — 236 кеше.

ЧИСТА́ КҮЛ, Көнбатыш Кама аръягында, Идел елгасының сулъяк яр югары терраса - сында, Спас р-ны Өчкүл авылында урнашкан. Су өслегенең мәйданы 13,21 *га*. Суының күләме якынча 200 мең $м^3$. Озынлыгы 640 *м*, иң



Чиста күл. Спас районы.

зур киңлеге 380 *м*. Уртача тирәнлеге 1,5, иң зур тирәнлеге 4 *м*. Күлнең килеп чыгышы ясалма (казылма күл). Түгәрәк формада. Җир асты сулары б-н тотрыклы туена. Суы гидрокарбонат-хлорид-кальцийлы типта, җиңелчә минераль ләшкән (76 *мг/л*), бик йомшак (1,1 *мг/л*), саргылт төстә. Үтә күренмәлелеге 40 *см*. Хуҗалык-көнкүреш һәм ял итү максатларында файдаланыла. ТРның табигать истәлеге (1978).

ЧИСТА́ КҮЛ, Көнбатыш Кама алдында, Идел елгасының сулъяк яр югары терраса - сында, Лаеш р-ны Чистое озеро авылыннан көнчыгыштарак. Су өслегенең мәйданы



Чиста күл. Лаеш районы.



Чистай шәһәре. Гомуми күренеше.

7,77 *га*. Суының күләме якынча 300 мең $м^3$. Озынлыгы 820 *м*, иң зур киңлеге 220 *м*. Уртача тирәнлеге якынча 4 *м*, иң зур тирәнлеге 14,2 *м*. Күл карст күренешләре нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Катлаулы, сузынкы формада. Көньяк яры текәрәк һәм күтәренке. Күбесенчә җир асты сулары б-н тотрыклы тотрыклы туена. Суы сульфат-гидрокарбонат-кальцийлы типта, җиңелчә минераль ләшкән, йомшак, җи ңелчә үзгәрүчән зәңгәрсу төстә. Үтә күренмәлелеге якынча 90 *см*. Яр буе үсемлекләреннән чатырлы сусак һәм очлы күрән өстенлек алып тора. Күлнең төнь як яр буенда ху җалык бакчалары урнашкан, көньягына нарат урманы тоташа. ТРның табигать истәлеге (1978).

Л.В.Мошкова.

ЧИСТА́ ПАР, к. *Пар.*

ЧИСТА́Й, респ-ка карамагындагы шәһәр, *Чистай районы* үзәге. ТРның үзәгендә, Нурлат тимер юлы (Ульянов–Уфа юнәлеше) станциясеннән 125 *км* төньяктарак, Казаннан 144 *км* ераклыкта урнашкан. Кама елгасының сул ярындагы пристань. Автомобиль юллары (Казан–Саескан Тавы–Әлмәт, Чистай–Түбән Кама һ.б.) төйнәлеше. Мәйданы — 16,8 $км^2$. 2017 елда 60564 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 62,7%, татарлар — 33,2%, чуашлар — 2,3%) яши. Хәзерге Ч. терр-ясенә халык элек-электән килеп уты ра. Шәһәр тирәсендә күп кенә археол. истәлекләр, ш.и. Көнбатыш Кама арьягындагы болгарларның зур сәяси, икътисади һәм сәүдә үзәге булган *Җүкәтау* шәһәре (к. *Җүкәтау бәклеге*, *Җүкәтау комплексы*, *Җүкәтау хәзинәсе*) хәрабәләре табыла. 17–18 йөзләрдә анда Чистое Озеро (Архангельский дигән атамасы да бар) исемле рус авылына нигез салына. Беренче булып качкын крәстияннәр күчеп килә, 1720 елларда алар дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә, 1750 елларда Авзян-Петр тимер кою з-дына (1760 та сәнәгатьче Е.Н.Демидов милкенә күчә) беркетелә. 1763 тә 437 ир-ат исәпләнә. 1781 дә Чистое Поле авылы Казан наместниклыгының (1796 дан — Казан губернасы) өяз шәһәре статусын ала һәм хәзергечә атала башлый, җирле халык шәһәр халкы катлавына кертелә. 18 йөз ахырыннан Ч. даими план буенча (үзәк урамнар, туры почмак булып кисешеп, кварталлар ясый) төзелә, 1793 тә анда шәһәр магистраты оештырыла. Геогр. яктан уңайлы урнашуы һәм Кама елгасы ярында гавань тотуы нәтиҗәсендә, 19 йөзнең 1 нче ярты сында Ч. тиз үсә һәм 1860 елларда зур сәүдә-йөк күчерү пунктына әверелә; Әстерхан, Вятка, Түбән Новгород, Пермь, Рыбинск, Саратов шәһәрләренә җибәрү өчен Кама арьягының көнбатышындагы өязләрдән ик мәк һәм а.х. чималы китертелә. Ревизия нәтиҗәләре буенча, 1815 тә шәһәрдә — 4404, 1834 тә — 5528, 1858 дә 14550 кеше яши. Реформадан соңгы чорда Ч.ның ландшафты нык үзгәрә: берничә шәһәр төзелеш зонасы барлыкка килә, һәм анда төрле социаль катлау вәкилләре, ш.и. Татар бистәсе урнаша. 1870 елларда юлларга таш җәюгә керешәләр, шәһәрнең үзәк урамнары яктыртыла, 1880 елларда беренче сүткәргеч эшли башлый. 20 йөз башында Ч. Казан губернасындагы иң зур өяз шәһәре була, анда 20104 кеше яши. 6 чиркәү (ш.и. *Никола соборы*), Успение-Богородица хатын-кызлар монастыре (1864 тә нигез салына), 2 мәчет (1859 һәм1882 дә төзелә), «Камалия» (ирләр; М.*Камалов* нигезли) һәм «Әмирхания» (хатын-кызлар) мәдрәсәләре, 4 иске дин тарафдарлары гыйбадәтханәсе, өяз казначейлыгы, дәүләт һәм җәмәгать банклары, почта-телеграф бүлекчәсе, кыз (1870) һәм ир (1907) балалар гимназияләре, руханилар (1829) һәм һөнәр (1896) уч-щесе, 5 приход мәктәбе, земство хастаханәсе, шәһәр китапханәсе (1875), ирләр һәм хатын-кызлар өчен ятимнәр, карт-корылар (1869) һәм куныпчыгу йортлары, янгын сүндерү часте, төрле ширкәт пристаньнары эшли; шимбә базары, 8 декабрьдә ярминкә үткәрелә. Шәһәр төзелешенең шактый зур өлешен сәүдә-сәнәгать йортлары — тегермәннәр, заводлар, зур һәм кечкенә кибетләр, складлар, амбарлар, сарайлар һ.б. алып тора. 1900 дә Ч. пристане аша 600 меңнән артык сумлык төрле йөк ташучы 1000 ләп судно уза. 1911 дә шәһәрдә су үткәрелә, 1913 тә үзәк урамнарга ут кертелә. Бу чорда Ч.да 28,3 мең кеше яши, 558 таш һәм 5223 агач корылма исәпләнә. 1918–19 да шәһәрне икешәр тапкыр Кызыл һәм Ак армия частьлары ала. 1920 дә ТАССР төзелгәч, Ч. — *Чистай кантоны*, 1930 дан Чистай р-ны үзәге. Бөек Ватан сугышы чорында Ч. халкы көнбатыш өлкәләрдән эвакуацияләнгәннәр исәбенә шактый арта. Анда гаиләләре б-н 200 ләп СССР Язучылар берлеге әгъзасы (алар арасында А.А.*Ахматова*, М.В.Исаковский, Л.М.*Леонов*, Б.Л.*Пастернак*, К.Г.Паустовский, А.Т.Твардовский,



Чистай шәһәрендәге беренче җамигъ мәчет. 1859.

К.А.Тренёв, А.А.Фадеев, К.А.Федин, К.И.Чуковский һ.б.) һәм идарәсе, яралылар өчен 3 госпиталь, 4 балалар йорты, Киев трикотаж һәм Гомель галантерея ф-калары, Калачинск һәм Сталинград суднолар ремонтлау з-длары, Икенче Мәскәү сәгать з-ды урнаша. Шәһәр пр-тиеләре сугыш кирәк-яракларын эшләүгә керешә. 1952 нең 8 маеннан 1953 нең 30 апреленә кадәр Ч. *Чистай өлкәсе* үзәге була. 1950–80 елларда шәһәрнең үсеше *Чистай «Восток» сәгать заводы*, елга суднолары (паромнар, елга ледоколлары, янгын-һәлакәт һәм коткару буксирлары, гидротөягечләр һ.б.) төзүче суднолар ремонтлау һәм «Автоспецоборудование» з-длары эшчәнлеге б-н бәйле. Хәзерге вакытта Ч.да «Восток» инновация-җитештерү техника паркы», «Бетар» җитештерү-коммерция фирмасы» АҖләре, «Вектор» радиокомпаниясе» ЯАҖ, «Вектор-Навигатор» ҖЧҖ, «Азимут» АҖ ф-лы; суднолар ремонтлау, «Автоспецоборудова-





Чистай шәһәре. 1.Үзәк мәйдан. 2. К.Маркс урамы.

ние», агрегат з-длары; мебель ф-касы, азык-төлек (ликёр-аракы һәм икмәк з-длары, кондитер ф-касы, сөт комб-ты, элеватор) һәм җиңел (тегү, трикотаж, аяк киеме ф-калары) сәнәгать пр-тиеләре эшли. А.Н.Туполев исем. Казан фәнни-тикшеренү техник ун-тының (КАИ) «Восток» ф-лы, Икътисад, идарә итү һәм хокук ин-ты, Кама икътисади-инженерлар академиясе ф-ллары; мед. уч-щесе, а.х. техникумы, пед. һәм политехника көллиятләре. 19 гомуми белем бирү, музыка һәм сәнгать мәктәпләре. Чистай дәүләт тарих-архитектура һәм әдәби музей-саклаулыгы (ТР МКның 2014 ел 11 июнь карары нигезендә оеш - тырыла). Музей-саклаулык составына *Шәһәр тарихы музее*, *Пастернак Борис мемориаль музее*, «Укытучылар йорты» әдәби-мемори - аль музее, Яуширмә авылындагы *Исхакый Гаяз тарихи-мемориаль һәм этнография комплексы*, сувенирлар салоны керә), Үзәк мәдәният һәм ял паркы («Скарятин бакчасы», 5 мәчет, 3 православие храмы. Татар һәм рус телләрендә «Чистай хәбәрләре» — «Чистопольские известия» г-талары нәшер ителә. Ч.да химик А.М.*Бутлеров*, тарихчы һәм сәнгать белгече Н.П.*Лихачёв*, комп. С.Ә.*Гобәйдул - лина* туган. Халык саны: 1926 да — 17,6 мең, 1939 да — 32 мең, 1959 да — 51,9 мең, 1970 тә — 60 мең, 1979 да — 64,3 мең, 1989 да — 65,5, 2002 дә — 63 мең, 2010 да — 60,7 мең кеше.

Әд.: Чистополь и чистопольцы: Из прошлого и настоящего. К., 2004; Чистаем — Родной Чисто - поль: Ист.-публицист. очерки. К., 2009.

А.И.Ногманов.

«ЧИСТАЙ», Чистай р-нындагы кошчылык ф-касы. 1974 елда «Каргалы» с-зын бүлү нәтиҗәсендә Каргалы авылында оештырыла; 2002 дән АҖ. А.х. җитештерүендә эшләүчеләр саны 160 кеше (2009); а.х. файдалану җирләренең мәйданы 5105 *га*; кошларның баш саны 336,7 мең баш. 68,3 млн. данә йомырка, 270,6 *т* ит, 7,9 мең *т* бөртекле ашлык җитештерелә. Бөртекле культураларның уңышы — бер *га* дан 22,6 *ц*. Югары җи - тештерү күрсәткечләре өчен ф-ка КПСС ҮК, СССР МС, ВЦСПС һәм ВЛКСМ ҮКның (1978), КПССның Татарстан өлкә ком-ты, ТАССР ЮС, Татарстан өлкә профсоюзлар советы һәм ВЛКСМ өлкә ком-тының Мактау грамоталары (1980) б-н бүләкләнә. Ф-каның җитәкчеләре: Ф.Г.*Фасахов* (1974–2006), В.В.Алиуллов (2006 дан). 2015 тә «Ч.»ның эшчәнлеге туктатыла.

И.Н.Афанасьев.

ЧИСТАЙ АВЫЛ ХУ ҖАЛЫГЫ ТЕХНИКУМЫ Г.И.Усманов исем., ТР Авыл ху җа - лыгы һәм азык-төлек министрлыгы карама - гында. 1920 елда 1917 дән эшләгән земство а.х. мәктәбе җирлегендә булдырыла. 1970 кә ка - дәр а.х. техникумы, 1970 тә В.И.Чапаев исем. к-з б-н берләштерелә һәм совхоз-техникум итеп үзгәртелә (уку-җитештерү пр-тиесе, 2 мең *га* сөрүле җирләр, якынча 2 мең баш мөгезле эре терлек), 2001 дән кабат а.х. техни - кумы. Эшләү вакытында 19 меңнән артык белгеч әзерләнә, техникумны тәмамлаучылар арасында күренекле дәүләт эшлеклесе Г.И.*Усманов* бар. 2018 гә укыту агрономия, а.х.н механикалаштыру, а.х.н электрлаштыру һәм автоматлаштыру, җир төзүчелек, икътисад һәм бухгалтерлык хисабы белгечлекләре буенча алып барыла; якынча 822 студент, ш.и. түләүле нигездә 24 студент укый. Пед. коллективта 51 укытучы эшли.

Әд.: Карташова Л.Б. Кузница сельских кадров // Чистополь и чистопольцы: Из прошлого и настоящего. К., 2004.

ЧИСТАЙ «ВОСТОК» СӘГАТЬ ЗАВОДЫ, төгәл приборлар төзү пр-тиесе. 1941 ел ахырында Мәскәүдән эвакуацияләнгән 2 нче сәгать з-ды (1930 да нигезләнә) җирлегендә 835 нче з-д буларак оештырыла; 1967 дән Ч.«В.».с.з., 1993 тән АҖ (2010 да ябыла).

Бөек Ватан сугышы елларында завод миналар өчен сәгатьле механизмнар чыгара. 1943 тә илдә беренче тапкыр ирләр механик кул сәгатьләре җи - тештерү җайга са - лына (беренче марка — «Кировские»), киләчәктә алар төп продукциягә әверелә. 1940–60 елларда төрле типтагы — бәрелүдән сакланган, тузан һәм дым кермәслек, секунд телләре һәм дискларының, линза календарь урнаштырылган («Победа», «Кама», «Мир», «Волна», «Сатурн», «Космос» маркалы сәгатьләр), ил - дә беренче югары төгәллекле «Восток», ш.у. дивар, урам, якты ручы циферблатлы судно сәгатьләрен, «ЗиМ», «Победа», «Волга» автомобильләре өчен сәгатьләр эшләп чыгару үз - ләштерелә. 1950 дә завод корпуслары ком - плексы төзелеше башлана, алар заманча җи - һазлар б-н коралландырыла. 1965 тә СССР Оборона министрлыгы заказы буенча завод - та махсус «Командирские», 1967 дә «Амфи - бия» сәгатьләрен сериялә җитештерү җай - га салына. 1970 елларда пр-тие санлы идарә - ле җиһазлар б-н техник яктан яңартып коралландырыла: еллык җитештерү күләме макс. күрсәткечкә ирешеп, 4,5 млн. сәгать тәшкил итә (1980). 1990 да 2,5 млн. сәгать эшләп чы - гарыла. 1950–80 елларда заводта 300 дән ар - тык төрле максатлардагы төгәл приборлар (тахометрлар, тахографлар, манометрлар, сә - гатьле приводлы станоклар, гидродинамик



«Командирские» ирләр механик сәгате.



Чистай «Восток» сәгать заводы. Административ-җитештерү корпусы.

тикшеренүләр өчен сәгатьле приводлар, радиорелелы станцияләр өчен фазалаштырылган антенна рәшәткәләре модульләре һ.б.) конструкцияләнә һәм җитештерүгә кертелә.

1990 елларның 2 нче яртысыннан Ч.«В.»с.з.нда җыю ку әгләрен тамырдан структур үзгәртеп кору, реконструкция, гальваник производствода экологик технологияләр куллану гамәлгә ашырыла. Элек төрдәш пр-тиеләрдән китерелгән барлык комплектлаучы детальләрне (кору пружиналары, сәгать ташлары, пыялалар) эшләп чыгаруны үзләштерү нәтиҗәсендә сәгатьләр җитештерүдә тулы технол. цикл булдырыла. Продукция ассортименты шактый киңәя: механик сәгатьләр б-н беррәттән кварцлы сәгатьләр эшләнә; хатын-кызлар сәгатьләре, заманча дизайнерлык һәм индивидуаль башкаруда, кыйммәтле металлардан ясалган корпуслы сәгатьләр; кварцлы һәм механик, ш.и. җиде тәүлеклек корулы будильниклар (дөньяда тиңнәре юк); өстәл һәм идән сәгатьләре, энергия һәм ресурслар саклаучы приборлар җи - тештерү үзләштерелә. 2005 тә завод җирле - гендә «Восток» инновация-җитештерү техно - паркы оештырыла, аның составында сәнәгый продукция, инструментлар һәм җиһазлар җитештерүче, фәнни-конструкторлык эш - ләнмәләрен гамәлгә кертүче, төрле хезмәтләр (транспорт, төзелеш һ.б.) күрсәтүче 50 гә якын кече һәм урта пр-тиеләр эшли. Эшләү - челәрнең гомуми саны 2,8 меңнән артык кеше (2014).

Технопаркның куәтләре санлы програм - ма идарәле универсаль фрезер станоклары, өслекләргә магнетрон һәм вакуумлы сип - терү җайланмалары, термопласт автоматлар, эрозиягә каршы универсаль эшкәртү систе - масы һәм штамплар, кою формалары, ин - струмент эшләү өчен югары төгәллекле ста - ноклар, автомат проектлау һәм идарә систе - малары б-н җиһазландырылган; аларның ха - лыкара JQNET һәм ISO9001–2008 (2009) сыйфат стандартларына туры килүе сертификатлар б-н расланган.

Технопаркка керүче пр-тиеләр автомат ко - рулы, секунд уклары, календарьлар (мизгел - ле нәтиҗәле, атна көннәрен күрсәтүче, ай календаре), «көн-төн» индикаторы, 24 сәгать - лек санагыч урнаштырылган, бәрелүдән һәм магнит тәэсиреннән сакланган, тузан һәм дым, су кермәслек корпуслы, якты ручы ци - ферблатлы һәм уклы, хром, титан нитриды, кыйммәтле металлар йөгертелгән, 33 сәгать - тән 42 сәгатькәчә йөрүле механизмлы ирләр һәм хатын-кызлар кул сәгатьләре коллек - цияләре; дивар, өстәл, камин, идән, судно сә - гатьләре, будильниклар (20 ләп төрдә елга 300 мең данәдән артык) эшләп чыгаралар; Россиядә көнкүреш һәм сәнәгать максатла - рында су, газ, электр энергиясе чыгымнарын исәпләүче санагычлар җитештерүдә әйдәп баручылар, «АвтоВАЗ» АҖне приборлы па - нельләр һ.б. комплектлаучы детальләр б-н төп тәэмин итүчеләр булып торалар; авто - буслар һәм йөк автомобильләре өчен тахо - метрлар, манометрлар, вакыт санагычлар, өс - тәмә ычкындыргыч көйләгечләр һ.б. сәнә-

гать җиһазлары, оборона максатындагы продукция җитештерәләр.

Продукцияне экспортлау 1957 дә башлана. Төрле елларда пр-тие һәм аның продукция - се Лейпциг халыкара ярминкәсенең Зур ал - тын медаленә (1965), «Россия сәгатьләре» исеменә, «Алтын глобус» (Копенгаген), «Ха - лыкара сыйфат бриллиант йолдызы» (Мехико), «Коммерция абруе өчен халыкара приз» (Париж) халыкара бүләкләренә лаек була, «Россия икътисады лидеры», «Россиянең иң яхшы 100 товары», «Россия Милли Олимпы» һ.б. бөтенроссия конкурсларында җиңүгә ирешә.

Ч.«В.»с.з. эшләгән чорда 145 мең $м^2$ дан артык мәйданда торак, мәдәният сарае, мәктәп, хастаханә комплексы, поликлиника, санаторий-профилакторий һ.б. социаль һәм мәдәни-көнкүреш объектлары төзелә, ярдәмче хуҗалык оештырыла. 1987 дән Казан техник ун-тының Чистай «Восток» ф-лы эшләп килә. Заводның аерым хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә, ш.и. 2 кеше СССР Дәүләт бүләге лауреаты исеменә лаек була, 1 кеше — Ленин ордены, 14 кеше — Хезмәт Кызыл Байрагы, 18 кеше — «Почёт билгесе», 1 кеше 2 нче дәрәҗә Хезмәт Даны орденнары б-н бүләкләнә. Завод җитәкчеләре: Н.С.Лукьянов (1941–54), В.Ф.Славгородский (1954–57), А.П.Михайлов (1957–72), Н.В.Окунцов (1972–86), В.В.*Цивилин* (1987–2009); технопарк җитәкчесе — А.В.Цивилин (2009 дан).

Әд.: Цивилин В.В. Время жить. К., 2001; Проверено временем: Чистопольский часовой завод «Восток». 1942–2002. К., 2002.

С.Г.Белов, М.В.Сәлимгәрәев.

ЧИСТАЙ ВЫСЕЛКАСЫ авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 4 *км* көньяктарак, Казан–Оренбург автомобиль юлы буенда. 2010 елда 2661 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 68%, татарлар — 28%) яши. «Вамин Чистай» агрофирмасы. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. «Чистай» совхоз-техникумы, урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1860 елларда Чистай шәһәреннән күчүчеләр нигез сала. Халкы игенчелек, терлекчелек, мичкә ясау б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ч.В.нда Троица чиркәве (1886 да төзелә; архит-ра истәлеге; хәзер дә эшли), земство мәктәбе



Чистай Выселкасы авылындагы Троица чиркәве. 1886.

(1888 дә ачыла), җил тегермәне, ярма яргыч, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 4500 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Иванаево волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан Чистай р-нында. Халык саны: 1897 дә — 1420, 1908 дә — 1915, 1920 дә — 2026, 1926 да — 1794, 1949 да — 917, 1958 дә — 1196, 1970 тә — 1326, 1979 да — 1412, 1989 да — 2641, 2002 дә — 2863 кеше.

ЧИСТАЙ ДӘҮЛӘТ БАНКЫ БИНАСЫ, архит-ра истәлеге. 19 йөзнең 1 нче чиреген - дә классицизм стилендәге торак йорт буларак төзелә. 20 йөз башында банк ихтыяҗлары өчен классицизм юнәлешендәге эклетика стилендә үзгәртеп корыла. Планда ассимметрик канатлы һәм түгәрәк почмаклы Г рәвешендәге ике катлы бина шәһәр үзәгендә, урам чатында урнашкан. Беренче каттагы почмак



Чистайда дәүләт банкы бүлеге бинасы. 19 йөзнең беренче чиреге. 20 йөз реконструкциясе. Хәзерге күренеше.

өлешендә тоскан ордерлы дугасыман алты колонналы портик чүкеп ясалган рәшәткәле балконның калын нигезен тотып тора. Сул канатта металл терәкләргә куелган яшмалы төп керү ишеге бар. Биек икенче кат дентикуллы чыгынты кәрниз б-н төгәлләнә. Тәрәзәләр классик сандриклы йөзлекләр б-н каймаланган. Бина тиешле максатта файдаланыла.

Әд.: Свод памятников истории и культуры Республики Татарстан. Т. 1. Административные районы. К., 1999.

Т.С.Чудинова.

ЧИСТАЙ «КАМАЛИЯ» МӘДРӘСӘСЕ, 1847 елда *Чистай беренче җәмигъ мәчете* каршында М.*Камалов* (бер үк вакытта имам-хатип, дин белгече, бай сәүдәгәр һәм «Нәкышбәндийә» суфичылык борадәрлеге шәехе була) тарафыннан ачыла. Аның аброуе һәм хәйрия акчасы ярдәмендә зур уку йортына әверелә. М.Камалов җәдитчелекне кабул итми, һәм, хакимиятнең басымына карамастан, мәдрәсәдә аның вафатына кадәр (1893) рус теле укытылмый. Шуның б-н бергә укыту фәкать кадимчә генә дә булмый, М.Камалов Бохара системасын кабатламый. Дин фәннәре һәм телләр юга - ры дәрәҗәдә укытыла. Укучылар саны 200–300 кеше исәпләнә. М.Камаловның ва - фатыннан соң, мәдрәсәне имам-хатиплар М.Х.Әмирханов (язучы Ф.Әмирхан атасының бертуганы) (1893–1921) һәм М.Камаловның улы Мөхәммәтибра һим (1903–21) җитәкли. 19 йөз ахырында укыту системасы



Чистай шәһәрендә «Камалия» мәдрәсәсе. Хәзерге күренеше.

яңа ысулга күчә, рус теле укыту кертелә. Мәдрәсәне тәмамлаучылар арасында — Р.*Фәхретдин*, Г.*Исхакый*, Ф.Кәрими, Ф.Туктаров, Г.Гафуров-Чыгътай, Г.С.*Бадамшин* бар. 1874 тән М.Камалов акчасына төзелгән үз бинасында урнаша (архит-ра истәлеге). 1918 дә ябыла.

Әд.: Салихов Р.Р., Хайрутдинов Р.Р. Памятники истории и культуры татарского народа (конец XVIII — начало XX веков). К., 1995; Амирханов Р. Закир ишан Камалов и татарское просвещение // Гасырлар авазы — Эхо веков. 2001. № 1/2.

ЧИСТАЙ КАНТОНЫ, 1920–30 елларда ТАССРдагы адм.-терр. берәмлек. Үзәк комиссиянең 1920 ел 8 сентябрь карары нигезендә ТАССРның Чистай өязендәге 23 волосте җирлегендә оештырыла. Үзәге — Чистай шәһәре. Ч.к.ның чикләре һәм адм. бүленеше бернича тапкыр үзгәрә. 1920 дә кантон 23 волостьтан 323 авыл торак пунктыннан тора. 1921 дә аның мәйданы 9088 $км^2$, 1926 да 9793 $км^2$ тәшкил итә. ТАССРда 1924 елгы адм.-терр. реформа нәтиҗәсендә Ч.к.ндагы волостьлар саны 17 гә кала. 1926 да аңа ш.у. 17 волость (Аксубай, Алексеев, Биләр, Галактионово, Егоркино, Зирекле, Каргалы,



Кәкре Атау, Күтәмә, Котыш, Мөслим, Яңа Адәм, Яңа Чишмә, Иске Әлмәт, Иске Чаллы, Иске Чишмә, Чулпан волостьлары) һәм 629 авыл торак пункты керә. 1920 дә Ч.к.нда 375336 кеше исәпләнә (1917 елгы халык исәбе буенча, руслар — 47 %, татарлар — 32 %, чуашлар — 17 %); шәһәр халкы саны — 21 133 кеше, авыл халкы саны 354203 кеше тәшкил итә. 1926 да 324674 кеше исәпләнә (ш.и. руслар — 52,6 %, татарлар — 27,9 %, чуашлар — 15,5 %); шәһәр халкы саны — 17589, авыл халкы — 307085 кеше. Халыкның уртача ур - нашу тыгызлыгы — 1 *км*^{2} га 33,1 кеше. Ч.к.нда металл һәм агач эшкәртү, химия, күн-мех, азык-төлек һәм полиграфия сәнәгатьләре пр-тиеләре эшли, кустар-һөнәрчелек сәнәгатендә 6 меңнән артык кеше хезмәт куя (1926). 1920 гә 267 мәктәп (ш.и. 260 — 1 нче баскыч һәм 7 — 2 нче баскыч мәктәпләр), 1924 тә 225 мәктәп (ш.и. 216 — 1 нче баскыч, 4 — 2 нче баскыч һәм 5 җидееллык мәктәпләр), 27 китапханә, 1927 дә 285 мәктәп (ш.и. 272 — 1 нче баскыч, 3 — 2 нче баскыч, 7 җидеел - лык һәм 1 тугызъеллык мәктәпләр) була. 1920 дә чәчүлек мәйданнар 281148 *га*, 1925 тә 294695 *га* тәшкил итә, ш.и. арыш — 145491 *га*, бодай — 31915 *га*, солы — 33153 *га*, карабо - дай — 9843 *га*, борай — 25344 *га*, бәрәңге — 3978 *га*, ясмык 3183 *га* мәйданда чәчелә. 1920 дә 72723 крәстиян хуҗалыгы, 1925 тә 65402 крәстиян хуҗалыгы һәм 80 а.х. кооперативы; 417552 баш терлек, шулардан 55362 ат, 93381 баш мөгезле эре терлек (ш.и. 47155 сыер), 221545 баш мөгезле вак терлек (ш.и. 195226 сарык, 26319 кәҗә), 47264 баш дуңгыз исәпләнә.

БҮБК Президиумының 1930 ел 10 август карары нигезендә районлап бүленешкә күчүгә бәйле рәвештә Ч.к. Аксубай, Алексеев, Биләр, Яңа Чишмә, Октябрь, Беренче Май һәм Чистай районнарына бүленә.

Чыг.: Предварительные итоги переписи населения 28 августа 1920 г. Население 25 губерний Европейской и Азиатской России. М., 1921. Т. 1, вып. 2; Статистический сборник за 1913–1917 гг. М., 1921. Т. 7, вып. 1; Народное образование по основному обследованию 1920 года (1920–21 учеб. год): Поуездные итоги предварительного подсчета. М., 1922. Т. 12, вып. 1; Статистический справочник по промышленности ТССР. К., 1924; Статистический справочник по сельскому хозяйству. К., 1925; Все - союзная перепись населения 1926 года. М., 1928. Т. 3; 1929; Статистический ежегодник по Татарской Социалистической Советской Республике: В 5 вып. К., 1928–29; Всесоюзная школьная перепись 15 декабря 1927 года. М., 1930. Т. 1.

С.А.Фәйзуллин.

ЧИСТА́Й ЛИКЁР-АРАКЫ́ ЗАВОДЫ́, азык-төлек сәнәгате пр-тиесе, «Татспирт - пром» АҖ ф-лы (2002 елдан). Эшләүчеләр саны 270 кеше чамасы (2017). 1934 тә 1901 дә нигезләнгән шәраб склады җирлегендә оеш - тырыла. 1960 еллар башына кадәр завод кул хезмәте нигезендә эшли; төп продукциясе — аракы һәм ликёр-аракы эчемлекләре, алар (1948 гә кадәр) 8,12 һәм 30 *л* сыешлы мичкәләргә тутырылып, томалап чыгарылалар. 1940 та җитештерелгән продукция күләме 170 мең *дкл* тәшкил итә.

Бөек Ватан сугышы елларында завод башлыча фронт ихтыяҗлары өчен эшли, эшләүчеләр саны 54 кешедән артмый (шулардан 34 хатын-кыз), 1945 тә продукция җитештерү күләме 117 мең *дкл* тәшкил итә.

1963 тән башлап заводта этаплап берничә реконструкция һәм модернизация уздырыла. 1960–70 елларда җитештерү мәйданнары күпкә киңәйтелә, савытларны юу һәм эчемлекләрне бүлеп салу өчен илдә эшләнгән, сәгатькә 6 мең шешәгә исәпләнгән җитештерү ку ағле 2 автомат линия һәм су әзерләү җайланмасы урнаштырыла; ликер участогы ачыла, аракы һәм ликёр җитештерү бер технол. чылбырга берләштерелә. Ассортимент киңәя һәм аракы, ликёр-аракы эшләнмәләрен чыгару күләме үсә (50 исемнән артык продукция). 1980 гә аракы җитештерү елга 1 млн. *дкл* га («Русская», «Столичная», «Золотое кольцо», «Экстра» һ.б. сортлар), ликёр-аракы эшләнмәләрен җитештерү 80 мең *дкл* га җитә, ягъни 1960 ел күрсәткечләреннән 5,2 һәм 9 тапкыр арта. 1998 дә аракы чистарту өчен порошоксыман активлаштырылган һәм көмеш б-н баетылган кокос чикләвеге күме - рен кулланучы («көмешле» фильтрлау), сәгатькә 1,6 мең *дкл* ку ағле югары җитештерү - чән җайланма гамәлгә кертелә.

1998–2002 дә ТРда беренчеләрдән булып сәгатькә 19 мең шешәгә исәпләнгән җитештерү ку ағенә ия 3 автоматлаштырылган бүлеп салу линиясе (ш.и. берсе — продукцияне су - венир савытларда чыгару өчен), суны молекуляр дәрәҗәдә чистартучы су әзерләү ком - плексы урнаштырыла. Продукциянең сыйфат буенча ГОСТ Р ИСО 9000 гә (2002) һәм Ха - лыкара IFS азык-төлек стандартына (вер - сия 5; 2009) туры килүе сертификатлар б-н раслана.

Завод «Татспиртпром» АҖ пр-тиеләрен - нән китерелүче «Люкс», «Альфа» спиртлары, 50 төрдән артык үсемлек чималы (мәтрүшкә, сары мәтрүшкә, алтын тамыр, тәпичә, ромашка, миләш, гөлҗимеш һ.б.) нигезендә якынча 40 исемдә алкогольле продукция чыгара. 2016 да завод 2 млн. *дкл* чамасы продукция (аракы, тонәтмәләр, бальзам һ.б.) җитештерә.

Продукция РФнең төрле төбәкләренә һәм БДБ илләренә җибәрелә. Пр-тие даими рә - вештә Бөтенроссия азык-төлек биотехноло - гиясе фәнни-тикшерү ин-ты (Мәскәү) бер - лектә эшләнгән фирма рецептуралары буен - ча аракының һәм аракы-ликёр эшләнмәләре - нең яңа төрләрен чыгаруны үзләштерә. Югары сыйфатлы алкогольле продукция эш - ләүдәге һәм җитештерүдәге казанышлары өчен завод Россия-Америка алкоголь конгрессы - ның Мактау дипломы б-н бүләкләнә (1996). 1998 дән башлап халыкара, бөтенроссия күр - гәзмәләрендә һәм дегустация конкурсларын - да пр-тие продукциясе якынча 90 бүләк б-н билгеләп үтелә, берничә тапкыр «Россиянең иң яхшы йөз товары» конкурсында лауреат бу - ла («Элитная Гимаевская», «Тундра», «Ваш выбор» аракылары, «Чистай» бальзамы, «Царь кедр», «Багира» тонәтмәләре һ.б.).

Аерым хезмәткәрләре дәүләт бүләкләре - нә лаек була: 3 кешегә — ТАССР, ТРның ат - каз. азык-төлек сәнәгате хезмәткәре, 1 кешегә ТР ның атказ. икътисадчысы исемнәре би - релә; 1 кеше — Халыклар дуслыгы, 1 кеше — 3 нче дәрәҗә Хезмәт Даны орденнары, 11 ке - ше медальләр б-н бүләкләнә. Пр-тие җитәк - челәре арасында — А.В.Дерюгин (1934–44), М.Н.Калашников (1945–47, 1949–52), А.Н.Николаев (1952–63), И.Ф.*Гыймаев* (1963–2002), Н.И.Гыймаев (2004–06), И.И.Миңлебаев (2008–10), Р.Ш.Фәттахов (2010–11), А.А.Миңнуллин (2011–15), С.А.Николаев (2015 тән). Ш.у.к. *Спирт* һәм *ликёр-аракы җитештерү сәнәгате*.


Әд.: Абрамов Л. От хлебного вина до «Элитной Гимаевской» 100 лет. К., 1998; Дронова Т.И., Дронов П.Р. Огонь, мерцающий в сосуде: 100 лет Чистопольскому ликёроводочному заводу. Наб. Челны, 2001; Карташова Л.Б. Чистопольская марка // Чистополь и чистопольцы: Из прошлого и настоящего. К., 2004.

М.Ж.Гаитов, И.Н.Цигвинцева.

ЧИСТА́Й МЕДИЦИ́НА УЧИ́ЛИЩЕСЕ, ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының урта һөнәри уку йорты. 1932 елда мед. политехникумы буларак оештырыла, 1936 дан фельдшер-акушерлык мәктәбе, 1952 дән хәзерге исемдә. 2012 дә «шәфкать туташы эше» һәм «дәвалау эше» белгечлекләре буенча 200, ш.и. 41 кеше түләүле нигездә укый. 1992 дән урта мед. хезмәткәрләренә өстәмә һөнәри белем бирү бүлеге эшли; ел саен якынча 500 кеше яңадан әзерләү уза. Эшләү вакытында якынча 15 меңләп шәфкать туташы һәм фельдшер әзерли. Уч-щене тәмамлаучылар арасында Казан мед. ун-ты про - фессоры Ә.Х.*Дәүләтшин*, Сов. Союзы Герое Н.Я.*Якупов* бар. 2018 дә «шәфкать туташы эше» һәм «дәвалау эше» белгечлекләре буенча 282 кеше укый. Пед. коллективта — 17 штаттагы укытучы (ш.и. 1 ТРның атказ. табибе, 2 РФнең сәламәтлек саклау отличнигы, 1 ТРның атказ. физик культура хезмәткәре, 1 ТРның атказ. укытучысы) һәм 50 дән артык читтән килеп эшләүче (ш.и. 3 мед. фән. канд.).

Әд.: Карташова Л.Б. Выбираю медицину // Чистополь и чистопольцы: Из прошлого и настоящего. К., 2004.

ЧИСТА́Й МӨСЕЛМА́Н ҚЫЗ БАЛАЛА́Р УЧИ́ЛИЩЕСЕ БИНАСЫ́, архит-ра истәлеге. 1911 елда Татар бистәсендә *Чистай шәһәренең беренче мәчете* уч-щесе өчен татар сәүдәгәрләре төзетә. Хезмәткәрләр өчен флигельләр һәм ху җалык каралтылары б-н ком - плекс составында була. Ике катлы, турыпочмаклы кызыл кирпеч бина квартал почмагына урнаштырыла. Уч-щегә бинаның уң өлешендәге а́рка үтеп йөрешле ишегалды аша керелә. Эклектика стилендәге төп урам як



Чистай шәһәрендә мөселман кыз балалар училищесе бинасы. 1911. Хәзерге күренеше.


фасады аркатур путалы һәм аттик тумбалы ике ян-як ризалитлар, пилястралардагы архивольтлар рәвешендәге тәрәзә йөзлекләре, ярымколонналар, филёнкалы кессоннар һәм башка элементлар б-н бизәлгән.

Әд.: Свод памятников истории и культуры Республики Татарстан. Т. 1. Административные районы. К., 1999.

ЧИСТА́Й ӨЛКӘСЕ́, 1952–53 елларда ТАССРдагы адм.-терр. берәмлек. Үзәге — Чистай шәһәре. Ч.ө.нә Аксубай, Алексеев, Әлки, Биләр, Бондюг, Алабуга, Зәй, Кызыл Армия, Кызыл Йолдыз, Кузнечиха, Куйбышев, Мамадыш, Морты, Яңа Чишмә, Октябрь, Беренче Май, Тельман, Чаллы, Чистай, Ширәмәт, Юхмачы, Ямаш р-ннары керә (1953 ел башына кадәр Бондюг, Алабуга, Кызыл Йолдыз, Мамадыш һәм Морты р-ннары *Казан өлкәсе* составында була). 1953 нең 30 апрелендә бетерелә.

ЧИСТА́Й ӨЯ́З КАЛАСЫ́ МУЗЕЙ́, к. *Шәһәр тарихы музее.*

ЧИСТА́Й ӨЯЗЕ́, 1797–1920 елларда Казан губернасындагы адм.-терр. берәмлек. Үзәге — Чистай шәһәре; 18 йөз башында Кама елгасының сул ярында нигезләнә; чыганакларда Чистое Поле (Архангель бистәсе) буларак мәгълүм; 1781 дә авылга өяз шәһәре статусы һәм хәзерге исем бирелә. Ч.ө. 1781 дә Казан наместниклыгы составында оештырыла, 1796 дан — Казан губернасының бер өлеше; аның көньяк-көнчыгыш өлешен били. Төньякта Казан губернасының Мамадыш, көнбатышта Спас һәм Лаеш өязләре, көнчыгышта Уфа губернасының Минзәлә өязе, көньякта Самара губернасының Бөгелмә һәм Богырыслан өязләре б-н чикләшә. Өяз терр-ясе буйлап Уратма, Чишмә, Шонталы, Олы һәм Кече Чирмешән елгалары һ.б. ага. Мәйданы 8,2 мең кв. чакрым. Халкы 328,9 мең кеше, шулардан 48 % руслар, 32,9 % татарлар, 15,7% чуашлар, 3,4 % мордвалар (1901). Адм. җәһәттә өяз Аксубай, Биләр, Богородский, Олы Талкыш, Егоркино, Зирекле, Изгар, Каргалы, Кызылъяр, Күтәмә, Котыш, Мөслим, Яңа Адәм, Яңа Чишмә, Седелькино, Иске Әлмәт, Иске Ивайнай, Иске Максимкино, Иске Мукшы, Иске Чаллы, Иске Чишмә волостьларына бүленә. Авыл халкы, башлыча, игенчелек б-н шөгыльләнә. Өязда киже-мамык эрләү һәм мануфактура ф-калары, нефть кудыру, аракы, чуен кою, ярма яру, сабын кайнату, урман кисү з-длары эшли. Читкә икмәк, май, постау, бал, балавыз, күн, поташ һ.б. чыгарыла. Өязда 212 мәктәп, ш.и. 77 мәдрәсә була. Ч.ө. терр-ясендә археологлар тарафыннан болгарларның Биләр һәм Жүкәтау шәһәрләре калдыклары табыла. 1920 дә өяз бетерелә, волостьларның күпчелек өлеше *Чистай кантоны* составына керә.



Чыг.: Материалы для географии и статистики России, собранные офицерами Генерального штаба: Казанская губерния. СПб., 1861.

Әд.: Спасский Н.А. Очерки по родиноведению: Казанская губерния. К., 1912.

Д.Г.Мостафина.

ЧИСТА́Й ПЕДАГО́ГИКА КӨЛЛИЯТЕ́, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының урта һөнәри уку йорты. 1915 елда Гольдинген шәһәреннән (хәзер Латвиянең Кулдига ш.) эвакуацияләнгән Прибалтика укытучылар семинариясе җирлегендә Чистай укытучылар семинариясе булдырыла. 1919 дан Халык мәгарифе ин-ты, 1922 дән пед. техникум, 1937 дән пед. уч-ще. 2010 нан хәзерге исемдә. Эшләвенең беренче ун елында, нигездә, башлангыч мәктәпләр, ш.и. татар һәм чуаш уку йортлары өчен укытучылар әзерләнә. 1937 дә мәктәпкәчә тәрбия бүлеге барлыкка килә. 1932–41 дә сәнәгать пр-тиеләре өчен кадрлар әзерләү буенча политехник бүлек, ә 1945 тән балалар бакчалары тәрбиячеләре бүлеге эшли. Уч-ще мәктәпкәчә белем бирү буенча респ-ка методик эшләр үзәге булып тора. 1997 дән — социаль пед., 2006 дан — чит телләр, 2009 дан гамәли информатика буенча белгечләр әзерләү башлана. Эшләү вакытында Ч.п.к. якынча 17 мең белгеч әзерләп чыгара. Көллиятне тәмамлаучылар арасында — Сов. Союзы Геройлары А.П.Кулясов, К.Х.Ситдыйков, Г.Н.Шәмсетдинов. 2015 тә, Чистай пед. көллияте һәм Чистай политехник көллият берләштерелеп, Чистай күппрофильле көллият итеп үзгәртелә. 2018 гә 647 студент укый, пед. коллективта 51 укытучы эшли. Чукашёвларның элеккеге утарында урнашкан (19 йөзнең 2 нче яртысы архит-ра истәлеге).

Әд.: Карташова Л.Б. Будем учиться, чтобы потом учить других // Чистополь и чистопольцы: Из прошлого и настоящего. К., 2004.

ЧИСТА́Й РАЙОНЫ́, ТРның үзәк өлешендә урнашкан. Мәйданы — 1799 *км*². 23 авыл җирлеген, 60 торак пунктны берләштерә. Үзәге — Чистай шәһәре. 2017 елда 78082 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 61%, руслар — 33,4%, чуашлар — 4,5%) яши. Халкының уртача урнашу тыгызлыгы — 1 *км*² *га* 10,6 кеше. 1930 ның 10 августында оештырыла. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязендә, 1920 дән ТАССРның Чистай һәм Спас кантоннарында, 1927 дән Чистай, Спас кантоннарында һәм Балык Бистәсе р-нында. Оешкан көненнән районга 1 шәһәр һәм 56 авыл советы, 112 торак пункт керә, аларда 91172 кеше (ш.и. руслар — 45747, татарлар — 41597, башка милләтләр — 3828 кеше) яши. Районның чикләре һәм адм. бүленеше берничә тапкыр үзгәрә. 1935 тә Ч.р.ның бер өлеше яңа төзелгән *Кызыл Армия районына* керә. 1940 та районның мәйданы — 1312 *км*², халык саны — 69 мең кеше; 1 шәһәр советы, 23 авыл советы, 78 торак пункт була. 1958 нең 23 маендa Ч.р.на таркатылган Кызыл Армия р-ның бер өлеше кертелә. 1960 та район 1808,5 *км*² җир били, аңа 19 авыл советы, 105 торак пункт керә. ТАССРда адм. берәмлекләрне эреләндерү сәбәпле, Ч.р.на Алексеев р-ны, Биләр, Яңа Чишмә һәм Ширәмәт р-ннарының бер өлеше кушыла. Районның мәйданы — 5778 *км*², халык саны — 121,2 мең кеше, 52 авыл советы, торак пунктлар саны 260 ка җитә. Алексеев р-ны торгызылгач (1964 нең 4 марты) һәм Түбән Кама р-ны төзелгәч (1965 нең 12 гыйн.), Ч.р. терр-ясе 3340 *км*² га кала, халык саны — 70,6 мең кеше, 32 авыл советы, 157 торак пункт исәпләнә. Районның хәзерге чикләре 1983 нең 26 апреленнән соң, Ч.р.ннан *Яңа Чишмә районы* бүленеп чыккач, билгеләнә. 1986 да районның мәйданы — 1770 *км*², халык саны — 21,6 мең кеше, 21 авыл советы, 63 торак пункт була.

Ч.р.ның рельефы аз гына калкулы, дулкынсыман тигезлек (биеклеге 100–150 *м*). Елгалар: Кама елгасы (Куйбышев сусаклагычы) һәм аның кушылдыклары Олы Бахта, Талкыш, Кече Чирмешән. Җирләре күбесенчә селтесезләнгән, көлсуланган типик кара, карасу-соры урман туфраклы. Терр-ясенең 6% ы — урманлык. Бентонитлы балчык, комташ-чуерташ катнашмасы, пыяла җитештерү өчен ком, бут ташы, мергель ятмалары бар. Саклаулы табигать истәлекләре: *Кече Чирмешән, Талкыш* елгалары, «Чиста болыннар» комплекслы табигать тыюлыгы. Район терр-ясе таш гасырдан алып урта гасырларның Алтын Урдага кадәрге чорына караган



археол. истәлекләргә (иң мәшһүрләре — *Жүкәтау* шәһәрлеге, 14 йөз кабер ташлары сакланган Исләй, Наратъелга, Иске Роман, Татар Талкышы һ.б. авылларның зиратлары) бай. Сәнәгать пр-тиеләре район үзәгендә урнашкан. Мөгезле эре терлек, дуңгыз, сарык асрау, җәнлек, кош-корт үрчетү тармаклары алга киткән. А.х. җирләре — 124,6 мең *га*, ш.и. сөрүлекләр — 108,7 мең *га* (2010). Сабан һәм көзге бодай, арыш, арпа, солы, борчак игелә. 2010 да районда 15 а.х. пр-тие се эшли. Ч.р. терр-ясеннән Казан–Оренбург, Чистай–Түбән Кама, Чистай–Нурлат, Чистай–Әлмәт автомобиль юллары уза. Кама ярында Чистай пристане урнашкан. 34 гому ми белем бирү мәктәбе (2011/12 уку елында 8104 укучы), 4 гимназия, һөнәр лицее, а.х. техникумы, 25 мәктәпкәчә тәрбия учреждениесе, 40 клуб, 40 китапханә, 3 китапханә (2011). Г.Исхакый тарихи-мемориаль һәм этнография комплексы (Яушырмә а.). Рус һәм татар телләрендә «Чистопольские известия» — «Чистай хәбәрләре» район г-тала ры нәшер ителә.

ЧИСТА́Й РУС ДРА́МА ТЕА́ТРЫ. Чистай шәһәрендә беренче җәмәгать спектакльләре 19 йөз ахырында күрсәтелә. 1908 елда шәһәр бакчасында җәйге театр төзелә. Анда һәвәскәр һәм гастрольләр б-н йөрүче труппалар тарафыннан спектакльләр куела. 1918 дә элекке земство идарәсе бинасында шәһәр театры ачыла. Күрсәтелгән елларда чыгыш ясаган труппалар шәһәрнең мәдәни тормышын да сизелерлек эз калдыра: 1926–27 дә — Д.И.Осипов-Дальский җитәкчелегендәге труппа, составында актёрлар Е.К.Амман-Дальская, Н.И.Анненский, А.И.Баева, М.И.Коварская, И.М.Кузнецов, Н.Г.Лоскутов, З.В.Мазуренко, А.В.Рудаков, Э.Р.Славский, П.М.Тамаров була, баш реж. К.Н.Яхонтов (репертуарын «Ревизор» (Н.В.Гоголь), «Кабарып пешкән бәлеш» («Воздушный пирог», Б.С.Ромашов), «Вера Мирцева» (Л.Н.Урванцов), «Көзге скрипкалар» («Осенние скрипки», И.Д.Сургучёв), «Кигәвен» («Овод», Э.Войнич романы буенча) спектакльләре тәшкил итә); 1927–28 дә — С.И.Ткачёв җитәкчелегендәге труппа, составында актёрлар А.Н.Врубель, Б.И.Градов, И.И.Кузнецов, К.А.Миганович, Н.С.Самойлова, А.М.Славина, А.М.Шуманская була (репертуарын «Гаепсездән гаеплеләр» («Без вины виноватые», А.Н.Островский), «Ялган акча» («Фальшивая монета», М.Горький), «Буран» («Пурга», Д.А.Щеглов) спектакльләре тәшкил итә); 1929–30 да — Михальский җитәкчелегендәге труппа (репертуарын «Авангард» (В.П.Катаев), «Ярсу» («Ярость», Е.Г.Яновский), «Көннәр югала» («Плавятся дни», Н.Ф.Львов) спектакльләре тәшкил итә). 1931 дә Михайловский һәм Сычёв җитәкчелегендә һәвәскәрләр коллективыннан һәм кайбер проф. актёрлардан даими труппа (23 кеше) оеша: «Чәчәкләр юлы» («Дорога цветов», В.П.Катаев), «Любовь Яровая» (К.А.Тренёв), «Чит кеше баласы» («Чужой ребёнок», В.В.Шкваркин), «Агай-эне — ак мыек» («Свои люди, сочтёмся», А.Н.Островский) спектакльләре куела. 1935 тә ТАССР Халык мәгариф комис-ты боерыгы б-н театр 2 нче колхоз-совхоз күчмә театрына үзгәртелә; сәнгать җитәкчесе итеп элегрәк Казан Зур драма театрында реж. булып эшләгән Б.Я.Раздольев билгеләнә; директоры С.И.Кальбин була, бер елдан аны Э.К.Савицкий алыштыра (репертуарын «Алты гашыйк», («Шестеро любимых», А.Н.Арбузов), «Платон Кречет» (А.Е.Корнейчук), «Гаепсездән гаеплеләр» («Без вины виноватые», А.Н.Островский), «Профессор Мамлок» (Ф.Вольф) спектакльләре тәшкил итә). 1941–42 дә театр труппасына Ленинград (Ленинград өлкә театры) һәм Мәскәүдән (Мәскәү өлкә театры, Мәскәү художество театры) эвакуацияләнгән актёрлар А.О.Степанова, Ц.А.Воскресенская (Блох), Л.Л.Кайранская, Н.Л.Нелидинская, О.О.Дашевская, Н.М.Сусленникова, И.И.Санин, Т.Г.Василенко, Я.Н.Чаров, В.А.Григорьев, А.Д.Авдеев, М.М.Минеев, Н.Д.Минич, М.М.Гурвич, М.Л.Мирович, Н.А.Ольшевская кабул ителә; «Текә яр» («Обрыв», И.А.Гончаров романы буенча), «Анна Кристи» (Ю.О'Нил), «Минем улым» («Мой сын», Ш.Гергей, О.Р.Литовский), «Белугинның өйләнүе» («Женитьба Белугина», А.Н.Островский, Н.Я.Соловьёв); 1942–43 елгы сезонда «Ябырылу» («Нашествие», Л.М.Леонов — драматургның Чистайда язган әлеге пьесасын беренче тапкыр тәкъдим итүе), «Егор Булычов һәм башкалар» («Егор Булычов и другие», М.Горький), «Гаепсездән гаеплеләр» («Без вины виноватые», А.Н.Островский), «Солдат хатыннары» («Солдатские жёнки», Н.А.Вирта), «Зәңгәр кулъяулык» («Синий платочек», В.П.Катаев) спектакльләре куела. Сугыштан соңгы елларда театр шәһәр стационар театры буларак эшләвен дәвам итә. 1946–48 дә труппа составында ТАССРның атказ. артисты А.П.Григорьев, Казан Зур драма театры студиясен тәмамлаган М.Г.Карнеев, Е.Д.Матросов, актёрлар Е.Н.Авхледиани, Е.Г.Волковицкая, Н.П.Володина, Е.Г.Воробьёва, А.М.Дикий, С.Б.Кибардин, А.В.Лучинский, А.А.Люлюкин, Ц.М.Могилевская, М.П.Прудникова, А.Я.Строителев, баш реж. И.Г.Ингвар була. Сезон дәвамында коллектив 18 премьера чыгара, Алабуга, Чаллы, Мамадыш, Минзәләгә гастрольләргә йөри (бу елларның аеруча зур спектакльләре: «Прага кәстәнәләре астында», «Рус мәсь әләсе» («Под каштанами Праги», «Русский вопрос», К.М.Симонов), «Бер шәһәрдә» («В одном городе», А.В.Софронов), «Соңгылар», «Карт», «Зыковлар» («Последние», «Старик», «Зыковы», М.Горький), «Ярлылык гаеп түгел», «Күктән төшкән бәхет» («Бедность не порок», «Не было ни гроша, да вдруг алтын», А.Н.Островский). 1948 дә театр дәүләт дотациясеннән төшерелә һәм үз-үзен тәэмин итүгә күчерелә. 1948–59 да коллективның сәнгать җитәкчелеген режиссёрлар Г.В.Рохгендлер, П.А.Дубовцев, ТАССРның атказ. артисты В.И.Истомин тәшкил итә. 1958 нең көзендә театр ябыла, труппаның бер өлеше Ц.М.Могилевская исемендәге һәвәскәрләр театрын оештыра («халык театры» статусы ала).

Ю.А.Благов.

ЧИСТА́Й СУДНОЛА́Р ТӨЗҮ́ ҺӘМ РЕМОНТЛА́У ЗАВОДЫ́, машиналар төзү һәм металл эшкәртү сәнәгате пр-тиесе. Эшләүчеләр саны 200 кеше (2017). Тарихы Чистай затоны каршында хосусый остаханәләр оештырылган вакыттан (19 йөзнең 2 нче яртысы) башлангыч ала. 1936 елдан — Чистай судноларремонтлау з-ды (1945–95 тә — ТАССР ның 25 еллыгы исемендә, 1995 тән — АҖ, 2004 тән — ҖЧҖ, 2011 дән — хәзерге исемдәге ҖЧҖ. Баштарак ярымкустар тимерчелек-слесарьлык остаханәләрендә үзйөрешле булмаган флот ремонтлана. 1918 дә алар национализацияләнә, 1920–30 елларда шактый киңәйтеләләр, алдынгы технол. һәм энергетик җиһазлар б-н коралландырылалар. Бөек Ватан сугышы елларында Кызыл Армия (Сталинград ш.) һәм Гомель суднолар ремонтлау з-дларының эвакуацияләнгән күәтләре җир легендә Чистай суднолар ремонтлау з-дында судноларның эчке янулы двигательләрен җитештерү оештырыла. 1957 дән Кама һәм Идел елга пароходчылыкларының 100 гә якын пасс., йөк судноларына, дебаркадерларына һәм җир снарядларына хуҗалык-техник хезмәт күрсәтелә. Шул ук елда 1650 *m* га кадәр йөк күтәрешле слип файдалануга тапшырылу нәтиҗәсендә судноларны капиталь ремонтлау һәм модернизацияләү җайга салына. 1958 дә суднолар төзү буенча эшләр башлана, 1960–90 елларда заводта 60 *m* йөк күтәрешле үзйөрешле елга паромнарын, 600 ат көчле буксир бозваткычлар, янгын сүндерү-авария-коткару буксирлары, рейд чистарту судноларын, рудалы булмаган материалларны гидротөягеч судноларны төзү, ш.у. йөкләрне элә ктерүче порт грейферларын, нефть чыгару өчен үзәктән куулы насослар эшләп чыгару үзләштерелә. 1990 еллар башына эшләүчеләр саны 700 кешегә җитә. Җитештерү мәйданчыкларында планлы рәвештә пр-тиене заманча җиһазлар б-н коралландыру бара, эшләр Россия Елга регистры күзәтчелегендә башкарыла. «Волго-Дон» һәм «Волго-нефть» тибындагы габаритлы судноларга хезмәт күрсәтүче Г-300 слипы модернизацияләнә. Яңа төзелешләр хисабына завод үсә.

Пр-тие составына механик цех, кою, энергия-ремонт, суднолар җыю, агач эшкәртү, транспорт участоклары, слип, ярдәмче бүлекләр керә. Барлык төр ремонт, төрле типтагы судноларны һәм аларның элементларын яңартып җиһазлау, модернизацияләү, җитешсезлекләрен билгеләү, судноларны кышкы тукталышта тоту эшләрен башкара. Сәйранлык катерлары, пасс. судно-катамараннары, грейферлар, судноларның эчке янулы двигательләре өчен алмаш-запас частьләр, газ компрессорлары детальләре, суыту насослары һәм күпбуынлы үзәктән куулы насослар эшләп чыгара.

Аерым хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә, ш.и. 1 әр кеше — СССР Дәүләт бүләгенә, Ленин орденына, Октябрь Революциясе орденына, 2 шәр кеше Хезмәт Кызыл Байра-

гы, «Почёт билгесе» орденнарына лаек була. Пр-тие җитәкчеләре арасында — Н.С.Леонтьев (1926–34), А.С.Завьялов (1934–39), В.А.Мокроусов (1939–46), И.И.Лезнов (1946–72), М.А.Воронов (1972–88), М.С.Коробов (1988–99), А.П.Плеханов (1999–2003), А.И.Фиалкин (2003–06), А.А.Лаврентьев (2006–07), Е.В.Колбасов (2007–11), Р.У.Мөхетдинов (2011 дән).

Әд.: К а р т а ш о в а Л.Б. Пароходных дел мастера // Чистополь и чистопольцы: Из прошлого и настоящего. К., 2004.

С.Г.Белов, Г.Я.Мәүлетова.

ЧИСТАЙ ТАТАР ДРАМА ТЕАТРЫ. ТАССР Халык мәгариф комис-ты коллегиясенең 1934 ел 15 октябрь карары б-н Чистай шәһәрендә Г.Гайсин җитәкчелегендәге һәвәскәрләр коллективы нигезендә (1922 дән) Беренче районара күчмә татар театры оеша. 1935 тә театр директоры — С.Г.Өметбаев, администраторы — Ю.С.Фарсин, сәнгать җитәкчесе — А.К.Нагаев. Труппа 16 кешедән тора: Г.Казанский, И.Максудов, Г.Йосыпова, Р.Садыйкова, Х.Сәлимова һ.б. Репертуарын «Томан арты» (Ш.Камал), «Яшь йөрәкләр» (Ф.Бурнаш), «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин) һ.б. спектакльләр, концерт программалары тәшкил итә. 1936 да театр Минзәлә шәһәренә күчерелә (к. *Минзәлә татар драма театры*).

ЧИСТАЙ ТРИКОТАЖ ФАБРИКАСЫ, к. *Трикотаж сәнәгате*.

ЧИСТАЙ ШӘҺӘР ИДАРӘСЕ БИНАСЫ, архит-ра истәлеге. 1876–77 елларда Петербург хәрби инженеры Н.Смирнов проекты буенча романтик юнәлештәге эклектика стилендә төзелә. Тәрәзәле эргәгә утыртылган ике катлы бина шәһәр үзәгендә урамнар чатында урнашкан. Итальян палаццосы үрнәгендә псевдоренессанс формаларындагы монументаль корылма. Төп фасад яссы ризалит б-н бүленгән, үзәктә борылма бизәкле баганаларга беркетелгән чуен яппа һәм калын нигезле балкон б-н аерып күрсәтелгән төп ишек бар. Тәрәзә уентылары классик өч өлешле фасадны чагылдыра: эргәдә — квадрат, беренче катта — турыпочмаклы, икенче катта — аркалы. Диварлар катлаулы профиль б-н рустлау һәм бизәкле калын кәрниз б-н төгәлләнгән. 1917 гә кадәр бинада шәһәр һәм мещаннар идарәсе, җәмәгать банкы, китапханә һәм мәхәллә уч-ще се була.



Чистай шәһәр идарәсе бинасы. Хәрби инженер Н.Смирнов. 1876–77. Хәзерге күренеше.

Әд.: Свод памятников истории и культуры Республики Татарстан. Т. 1. Административные районы. К., 1999.

Т.С.Чудинова.

ЧИСТАЙ ШӘҺӘР КАБУЛХАНӘЛӘРЕ БИНАСЫ, архит-ра истәлеге. 1847 елда сәүдәгәр М.Л.Мешкичев йорты буларак арх. Карпов проекты буенча төзелә. Шәһәр һәм өяз кабулханәләрен урнаштыру өчен 1857 дә бина шәһәр тарафыннан сатып алына. 1887 дә арх. А.Е.Остовский проекты буенча төзекләндерелә. Биек эргәле һәм өченче антресоль



Чистай шәһәр кабулханәләре бинасы. 1847. Архитекторы Карпов. 1887 елгы реконструкция. Архитекторы А.Е.Остовский. Хәзерге күренеше.

катлы П рәвешендәге ике катлы бина классицизм юнәлешендәге эклектика стилендә төзелә. Кирпеч диварлар штукатурланган һәм буялган. Фасад һәр катта 9 тәрәзә уенты булган төгәл метрик композициягә ия. Икенче каттагы тәрәзә йөзлекләре кессон, сандрик һәм пилястраларны берләштерә. Катлаулы профильле киң тәҗе беренче һәм икенче катларны аерып тора. Бинада почта, полиция, өяз казначылыгы, ә участокның периметры буенча бина артында янгын сүндерү олавы һәм кулга алынганнарны тоту өчен корылмалар була. Хәзерге вакытта бинада полиция бүлеге урнашкан.

Әд.: Свод памятников истории и культуры Республики Татарстан. Т. 1. Административные районы. К., 1999.

Т.С.Чудинова.

ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕНЕҢ БЕРЕНЧЕ МӘЧЕТЕ, милли-романтик юнәлештәге эклектика стилендәге дини архит-ра истәлеге. Элекке Татар бистәсендә урнашкан. 1859 елда Малмыж сәүдәгәре Х.М.Якупов акчасына 1844 елгы «үрнәк проект» буенча төзелә. Бинаның нигезен тышкы яктан такта б-н тышланган бүрәнә бура тәшкил итә. Биек эргәгә утыртылган, гөмбәзле гыйбадәт заллы бер катлы агач мәчет ишегалдының эчке өлешендә урнашкан. Мәчетнең гомуми композициясе үзәкләштерелгән күчәрле: вестибюль, кече һәм төп гыйбадәт заллары анфилада б-н тоташтырылган. Вестибюль һәм кече зал уртак күләмгә берләштерелеп, ике кыеклы түбә б-н ябылган. Вестибюльдән башланган тар баскыч ишек өстендә урнаштырылган манарага алып менә. Өч яруслы, сигез кырлы, биек чатыр б-н төгәлләнгән манараның фонаре һәм балконы бар.Төп зал өстендә сигез кырлы барабанда кильсыман гөмбәз күтәрелә. Зал интерьерында барабандагы гөмбәзне 4 колонна тотып тора. Мәчет заллары аркалы тәрәзәләр яктырта. Фасадлар бизәлешендә кыек сызыклы элементлары һәм филёнкалары булган путалы тәҗеләр файдаланылган. Ике катлы вестибюль төп бинаның төньягына шактый соңрак өстәп салына. Әүвәлге манара 1930 елларда сүтелә, 1970 елларда кабат торгызыла. 1980 еллар ахырында вестибюльгә көнчыгыш тарафтан керү янкормасы төзелә. Бина тиешле максатта файдаланыла.

Әд.: Мечети Татарстана // Сост. Х.Г.Надырова, Р.Р.Салихов, Р.А.Хайрутдинов. К., 2000.

Х.Г.Надыйрова.

ЧИСТАЙ ЭЛЕВАТОРЫ, ашлык әзерләү, саклау һәм эшкәртү б-н шөгыльләнүче, респ-када шул өлкәдә иң эре пр-тиеләрнең берсе (ТРда барлык ашлыкның 10% ка кадәр өлешен әзерли). Ашлык базарында дәүләт көйләүчесе вазифаларын башкара. 1935 елда Татарстан «Заготзерно» өлкә конторасы Чистай бүлекчәсенең 17 нче икмәк хуҗалыгы буларак нигезләнә. 1957 дә Чистайның 2 нче тегермән з-ды б-н Чистай он-ярма комб-тына берләштерелә, 1968 дә Чистай икмәк кабул итү пункты итеп үзгәртелә, 1974 тән хәзерге исемдә, 1994 тән АҖ, 2016 дан «Ч.э.» ҖЧҖ. Эшләүчеләр саны якынча 200 кеше (2017). Пр-тие 1936 да эшли башлый. 1940 еллар ахырында электрлаштырыла, 1950 елларда киңәйтелә һәм тулысынча механикалаштырыла; елга 17 мең *т* га кадәр арыш оны һәм ярмалар эшләп чыгара. 1971 дә — катнаш азык з-ды, 1965–74 тә термодатчиклар б-н җиһазландырылган 78 силос банкасыннан (һәрберсенең биеклеге 68 *м*, диаметры 6 *м*) торган монолит типтагы силос корпусы төзелә.

Силос корпусының сыйдырышлыгы — 50 мең *т*, ашлык складларыныкы 105 мең *т* тәшкил итә. Ачык вакытлыча саклау урыннары (Ч.э. барлыгы 250 мең *т* га кадәр ашлык



Чистай элеваторы. Гомуми күренеше.

кабул итәргә сәләтле), көнгә 4 мең *т* га исәпләнгән 6 киптерү-чистарту башнясы, 3 ашлык һәм орлык цехы, ашлык лаб-ясе, елга 60 мең *т* җитештерү куәтле катнаш азык з-ды, причал һәм су транспортына тояу һәм аннан бушату җайланмасы, автомобильләр паркы һ.б. бүлекчәләр (Чистайдан төньяк-көнбатышка таба 9 *км* ераклыктагы Крутая Гора посёлогында урнашканнар), елга 10 мең *т* җитештерү куәтле тегермән з-ды (шәһәрдә) бар.

Ч.э., ел саен 120 мең *т* га якын иген кабул итеп, аны киптерә, чистарта, йогышсызландыра, ашлыкка, фуражга, орлыкка, саклауга һәм озатуга аера; 3,9 мең *т* югары, 1 нче һәм 2 нче сортлы икмәк пешерү оны, 20 гә якын төрдә 59,6 мең *т* күп компонентлы катнаш азык җитештерә. Ашлык, башка төрле чимал

китерүчеләр һәм продукцияне кулланучылар арасында — Алексеев, Аксубай, Яңа Чишмә һәм Чистай р-ннарының а.х. пр-тиеләре, Печищи икмәк продуктлары комб-ты, Казан май экстракциясе з-ды, «Биоэнергия» ҖЧҖ (Саратов ш.), респ-ка икмәк з-длары, кибетләр.

Пр-тие хисабына торак йортлар, 320 укучыга мәктәп төзелә, Крутая Гора посёлогы газлаштырыла. Ч.э.ның аерым хезмәткәрләре дәүләт бүләкләренә, ш.и. 1 кеше ТРның атказ. а.х. хезмәткәре исеменә лаек була, 2 кеше Хезмәт Кызыл Байрагы ордены б-н бүләкләнә. Пр-тие җитәкчеләре: Б.М.Тимербаев (1935–41), Равинский (1941–46), Шенталинский (1946–48), Н.В.Обрядин (1948–61), В.М.Данилов (1961–62), К.И.Окунев (1962–68), В.В.Прохоров (1968–73, 1983–86), А.А.Захаренко (1973–80), Н.И.Ульянов (1980–83), И.М.Качан (1986–90), Ф.Ш.Сиражетдинов (1990–99), И.Ф.Минсафин (1999–2011), Р.М.Мәхмүтов (2011–13), Р.Р.Мотыйгуллин (2013 тән).

Әд.: Хвала рукам, что хлебом пахнут. К., 2001; К а р т а ш о в а Л.Б. Заполним закрома хлебом — до неба! // Чистополь и чистопольцы: Из прошлого и настоящего. К., 2004.

С.Г.Белов.

ЧИСТАЙДАГЫ́ БЕРЕНЧЕ́ ИР БАЛАЛА́Р ГИМНА́ЗИЯСЕ БИНАСЫ́, архит-ра истәлеге. Планын коридор системасы тәшкил иткән уку бинасы. 1908–09 елларда Казан уку-укыту округы архитекторы С.В.Бечко-Друзин проекты буенча шәһәр һәм земство, сәүдәгәрләр А.Н. һәм С.Н.Чукашевлар, Е.П.Шашин тарафыннан берничә бина үзгәртеп төзетелә. Планда Г рәвешле, биек эргәгә утыртылган өч катлы кызыл кирпеч бина Чистай шәһәре уртасында квартал почмагына урнашкан. Төп фасад тәрәзә аралары-ның төрле ритмда булуы, антаблементларының биеклеге б-н аерылып торган ике өлештән гыйбарәт. Фасадның сул ягы 2 нче каттагы шома пилястралы ян-яктагы ике ризалит, ә уң ягы рустланган композит пилястра һәм киртләч кәрниз ритмнары б-н аерылып тора. Төп берләштерү пьедесталы ролен уң як өлеше ионик ордерлы ярымколонналы керү портигы булган беренче кат үти. Аның фронтонына кисеп кертелгән һәм ике баганага урнаштырылган чуен каркаслы яппа соңынан эшләнә. Бина эче аркалы биек һәм нурлар рәвешендә төгәлләнгән тәрәзәләр ярдәмендә яктыртыла. Фасадларны бизәүдә руст-лар, филёнкалар, аттик фронтоннар һәм тумбалар файдаланылган. Фасадлар неоренессанс һәм модерн мотивлары б-н эклетика стилендә башкарылган. Хәзер бинада 1 нче мәктәп урнашкан. Биредә Сов. Союзы Геройлары В.И.Маринин, А.С.Калашников, Б.С.Чекин укыган.

Әд.: Свод памятников истории и культуры Республики Татарстан. Т. 1. Административные районы. К., 1999. *Х.Г.Надыйрова.*

ЧИСТАЙДАГЫ́ БЕРЕНЧЕ́ КЫЗ БАЛАЛА́Р ГИМНА́ЗИЯСЕ БИНАСЫ́, архит-ра истәлеге. 19 йөзнең 1 нче чирегендә сәүдәгәр Котовлар өчен торак йорт буларак классицизм стилендә төзелә. Йорт һәм утарны М.Г.Котовадан сатып алган сәүдәгәр В.Л.Челышев 1876–83 елларда төзекләндерә һәм 1883 тә ачылган кызлар прогимназиясе (1905 тән гимназиягә әйләндерелә) өчен бирә. Ике урам чатына урнашкан ишегалды ягыннан антресоль кат өстәлгән ике катлы кирпеч бинаның диварлары штукатурланган, түбәсе дүрт кыеклы. Урам як фасадлары өчпочмаклы фронтон б-н төгәлләнгән һәм стильләштерелгән дорик ордерлы дүрт пилястра б-н аерылган үзәк ризалитлар б-н бизәлгән. Чүкеп ясалган рәшәткәле балконнар



Чистайдагы Беренче ир балалар гимназиясе бинасы. С.В.Бечко-Друзин реконструкциясе. 1908–09. Хәзерге күренеше.

фасадларга күркәмлек бирә. Фасадны бизәүдә ш.у. диварларны рустовкалау, ташлар һәм сандриклары булган тәрәзә йозлекләре, медальонлы филёнкалар, почмак калаклары, триглифлар һ.б. файдаланылган. Бина тулаем ампир элементлары б-н классицизм юнәлешле эклектика стилендә эшләнгән.

Әд.: Свод памятников истории и культуры Республики Татарстан. Т. 1. Административные районы. К., 1999.

ЧИСТАЙДАГЫ́ ИКЕНЧЕ́ КЫЗ БАЛАЛА́Р ГИМНА́ЗИЯСЕ БИНАСЫ́, архит-ра истәлеге. 1912–14 елларда арх. П.И.Абрамычев проекты буенча инженерлар Н.М.Андреев һәм В.А.Степанов катнашында неоренессанс формалары өстенлек иткән модерн стилендә төзелә. Ике катлы кызыл кирпеч бина кварталның почмагын били һәм дүрт төп күләмнән тора. Урам якларга икенче каттагы аслы-өсле ике рәт тәрәзәле заллар һәм беренче каттагы симметрия күчәре буйлап ишекләр урнашкан төп күләмнәр карый. Аларга ян-яктан ике катлы, уку сыйныфлары урнашкан тәбәнәгрәк флигельләр терәлә. Турыпочмаклы тәрәзәләр өчәрләп төркемләнгән, тәрәзә астының диварлары кессоннар б-н бизәлгән; бина



Чистайдагы Икенче кыз балалар гимназиясе бинасы. Архитекторы П.И.Абрамычев, инженерлар Н.М.Андреев һәм В.А.Степанов. 1912–14. Хәзерге күренеше.

почмакларында һәм тәрәзә төркемнәре арасында модульләрнең зур пилястралары, ә тәрәзә араларында тулы дорик ордерлы кече пилястралар урнаштырылган. Барлык фасадларны да антаблемент берләштерә. 1914–17 дә бинада пропорщиклар мәктәбе (юнкерлар уч-щесе) урнаша.

Әд.: Свод памятников истории и культуры Республики Татарстан. Т. 1. Административные районы. К., 1999. *Т.С.Чудинова.*

ЧИСТАКӲЛ, к. *Чистое Озеро.*

ЧИСТО́ВИЧ Фёдор Яковлевич (1.2.1870, Петербург — 24.11.1942, Новосибирск), патологоанатом, медицина д-ры (1896), РСФСРның атказ. мед. эшлеклесе (1935). Хәрби-мед. академиясен тәмамлаганнан соң (1893), патологик анатомия кафедрасында проф. К.Н.Виноградов карамагында калдырыла. 1896, 1902 елларда Берлин ун-тында, Фрейбургта, Парижда фәнни командировкаларда була. 1894–1908 дә академиядә укыта, бер үк вакытта, 1902 дә, Петропавел хастаханәсе (хәзер Эрисман исем.) һәм хатын-кызлар мед. ин-ты (хәзер 1 нче Санкт-Петербург мед. ин-ты) клиникасы прозекторы. 1908–20 дә Казан ун-тының патологик анатомия каф. профессоры. 1921 дә Ленинград табибләр белемен күтәрү ин-тының патологик анатомия каф. профессоры һәм мөдире. Бер үк вакытта 1 нче Ленинград мед. ин-тында мәхкәмә медицинасы кафедрасына җитәкчелек итә (бүленеп, 1921–32, 1935–37 дә) һәм ин-тның ректоры була. Хезмәтләре үпкә ялкынсыну патогенезына карый. Чит аксымның специфик антитәнчекләр б-н преципитацияләнүе феноменын ача (1904). Ленинград мәхкәмә-мед. экспертлары фәнни җәмгыятенең рәисе һәм оештыручысы (1925).

Х е з м.: Курс патологической анатомии: Общая часть: В 2 вып. К., 1919–20; Практический курс патологической гистологии. М.-П., 1924.

Әд.: Х м е л ь н и ц к и й О.К. Фёдор Яковлевич Чистович (к 25-летию со дня смерти) // Архив патологии. 1968. Т. 30, № 6.

ЧИ́СТОЕ О́ЗЕРО авылы, Лаеш р-нында, Казан тимер юл станциясеннән 28 *км* көньяк-тарак урнашкан. 2010 елда 22 кеше (руслар) яши. 1930 елларда нигез салына. Оешкан көненнән Казан авыл р-нында, 1938 нең 4 августыннан — Столбище, 1959 ның 26 мартыннан — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1949 да — 185, 1958 дә — 191, 1970 тә — 125, 1979 да — 162, 1989 да — 49, 2002 дә — 20 кеше.

ЧИ́СТЫЕ КЛЮЧИ́ посёлогы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 30 *км* төньяк-көнбатыштарак, Гөбенә елгасы буенда. 2010 елда даими яшәүчеләр юк. 19 йөздә нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 104 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Ульянково волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Ульянково, 1927 нең 1 августыннан — Кайбыч, 1944 нең 19 февраленнән — Подберезье,

1956 ның 17 маеннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1859 да — 79, 1897 дә — 154, 1908 дә — 164, 1920 дә — 192, 1926 да — 196, 1958 дә — 112, 1970 тә — 72, 1979 да — 55, 1989 да — 16, 2002 дә — 7 кеше (руслар).

ЧИСТЯКО́В Арнольд Иванович (16.1.1930, Иваново өлкәсенең Кинешма ш. — 16.7. 2007, Ульянов ш.), механика өлкәсе галиме, техник фән. д-ры (1977), проф. (1978), РСФСРның атказ. уйлап табучысы (1979). 1953 елда Казан авиация ин-тын тәмамлый, шунда ук эшли (1986 га кадәр), очу аппаратларының ориентация һәм тотрыклылandыру системалары каф. мөдире (1971 дән). 1986–96 да Ульянов политехник ин-ты профессоры. Хезмәтләре очу аппаратлары б-н автоматик идарә итүгә һәм аларның динамикасына карый. Ч. эшләгән пилотсыз очу аппаратлары, ш.у. океанологик аппаратураны буксирлаган яки мөстәкыйль йөрткән транспорт б-н идарә итү ысуллары сериялəп җитештерүдə һәм илнең кораллы көчләрендə гамəлгə кертелə. Уйлап табуга 50 дән артык авторлык таныклыгы һәм патенты бар. Почёт ордены, медальләр, ш.и. СССР ВДНХсының алтын, көмеш һәм бронза медальләре б-н бүләкләнə.

Х е з м.: Автоматическое управление буксируемыми и автономными гидродинамическими подводными аппаратами. М., 1976.

ЧИТА́ЛИН Николай Александрович (12.2.1957, Чуаш АССРның Шумерля ш.), педагог, пед. фән. д-ры (2007), проф. (2008). Казан пед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1979), Алабуга пед. ин-тында эшли. 1982 елдан Казанда ПФАнең Профтехпед. ин-тында (хəзер РМАнең Һөнəри белем бирү пед. һəм психол. ин-ты), 1998 дəн физика-матем. əзерлек лаб-ясе мөдире, 2006–10 да директор урынбасары, 2010–13 тə табигыять-фəнни һəм гомуми һөнəри əзерлек лаб-ясе мөдире, 2013 тəн баш фəнни хезмəткəр. Урта һөнəри белем бирү системасын фəнни-методик тəэмин итү мəсьəлəлəрен эшлəүдə катнашканы өчен РФ Хөкүмəтенең мəгариф өлкəсендəге бүлəгенə лаек була (2005).

Х е з м.: Многоуровневая фундаментализация содержания профессионального образования. К., 2005.

ЧИТЕ́К, татарларда йомшак табанлы традицион күн аяк киеме — күннән тегелгән итек яки кыска итек. Ч.не ирләр дə, хатын-кызлар да кия, өйдəн чыкканда Ч.ләргə кəвешлəр, кыш көне кыска киез итекләр кидерелə. Ир-ат Ч.ләрен, гадəттə, бербөтен итеп, кунычларын тезгə кадəр җиткереп, кара йомшак күннән (*юфть*), сирəк кенə бер төстəге *сəхтияннəн* яисə хромнан тегəлəр. Ныклык өчен итекнең артына шагрень күн кисəге тегеп куела. Хатын-кыз Ч.ләре кыскарак, кайтармасыз кунычлы итеп, төсле сəхтияннəн оригиналь орнамент б-н каюлы күн техникасында башкарыла. 19 йөз ахырында — 20 йөз башында хатын-кыз Ч.ләрен төрле фасондагы итек яки ботинкалар рəвешендə биек үкчəле итеп тегə башлыйлар. Ч. җитештерү татар халкының икътисади тормышында мөһим роль уйный. 20 йөз башына Ч. һөнəрчелеге Казан, Вятка, Тверь, Оренбург губерналарында, ш.у. Себердə һəм Урта Азиядə яшəп килə. 1930–40 елларда, фабрика-заводларда аяк киеме җитештерү үсешенə бəйле рəвештə, Ч.ләр киң кулланылыштан чыга. Хəзерге вакытта Татарстанда аларны зур булмаган аяк киеме җитештерү пр-тиеләре индивидуаль заказлар буенча тегəлəр.

Əд.: Одежды и украшения // Татары Среднего Поволжья и Приуралья. М., 1967; Г у л о в а Ф.Ф. Татарская национальная обувь (искусство кожаной мозаики). К., 1983; С у с л о в а С.В. Одежда // Татары. М., 2001.

Р.Р.Батыршин.

ЧИЧӘ́Н, татар фольклоры персонажы, сүз остасы, җырчы-импровизатор, халык шагыйре. Кырым татарларында, тувалыларда таралган; монголларда Ч. — ыру башлыгы. Татар фольклорында монгол фольклоры тəэсирендə барлыкка килə. Татар дастаннарында *Җирəн чичəн* дип телгə алынганы башка төрки халыкларда да билгеле.

Əд.: Ə х м ə т ь я н о в Р. Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге. К., 2001.

Ф.И.Урманчеев.

ЧИШМӘ, к. *Җир асты су чыганаклары.*

ЧИШМӘ елгасы, Кама елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 234,1 *км*, ТР чикләрендə — 206,6 *км*. Бассейнының мəйданы 6200 *км*^{2}. Елга башы һəм югары агымы Самара өлкəсендə, ТРда Лениногорск, Чирмешəн, Əлмəт, Яңа Чишмə, Түбəн Кама һəм Чистай р-ннары терр-ясеннəн ага. Ч. Куйбышев сусаклагычы төзелгəнче Түбəн Кама р-ны Иске Чишмə авылыннан 14 *км* төньяк-көнбатыштарак Камага коя торган була, хəзерге вакытта елга юлы Яланта, Кармалы авылларыннан түбəнрəк ята һəм сусаклагычның терəк сулары астында калып, Чишмə культыгы барлыкка китерə. Елга башының абс. биеклеге 260 *м*, тамагыныкы — 53 *м*. Су җыелу мəйданының уртача биеклеге 176 *м*. Елганың уртача авышлыгы 0,8 м/км. Ч.нең су җыелу мəйданы асимметрияле террасалашкан елга үзəннəре, ерым һəм сызалар челтəре б-н ергаланган калкулыклы тигезлектəн гыйбəрəт. Су җыелу мəйданының урманлылыгы 24%.





1. Хатын-кыз читекләре. Каюлы күн. 19 йөз ахыры – 20 йөз башы;
2. Ир-атлар читеге. 19 йөз.



Чишмə елгасы түбəнге агымында. Яңа Чишмə районы.

Югары агымында үзəне V-сыман, киңлеге 0,9–1,2 *км*, калган озынлыгында трапеция рəвешендə, киңлеге 3–4 *км*. Үзəненең уңъяк сөзəклеге биек (20–55 *м*), урыны б-н бик текə (56–60°); сул ягы сөзəк (5–10°), салмак кына җир өслеге б-н тоташа. Елганың шактый озынлыгында тугай ике яклы, урыны-урыны б-н чиратлаша; киңлеге югары агымында 100–300 *м* дан тамак өлешендə 2 *км* га кадəр. Тугай өслеге элеккеге елга юлындагы күлләр һəм уйсулыклар б-н ергаланган, кайбер урыннары сазлыкланган. Елга юлы борма-лы, тармакланмаган, плёс һəм сайлыклар-ның тигезсез чиратлашуы күзəтелə. Плёсларда елганың тирəнлеге 2–3 *м*, сайлыкларда 0,5–0,9 *м* тəшкил итə. Плёсларда агым тиз-леге 0,1–0,2 *м/с*, сайлыкларда 0,4–0,8 *м/с*. Ярлары текə (20–45о), вак куаклыклар үсə, су өсте сызыгыннан биеклеге 3–4 *м*. Ч.нең 0,4 тəн 110 *км* га кадəр озынлыктагы 66 кушылдыгы бар, иң зурлары: Урдала (11,4 *км*), Урдала (12,7 *км*), Урман Чишмəсе (51,1 *км*), Каратай (11,4 *км*), Куак (30,7 *км*), Вəткə (17,3 *км*), Чумач (12,5 *км*), Баграж (10 *км*), Шөгерчə (13,8 *км*), Кичү (110 *км*) — уң; Олы Кəминкə (17,4 *км*), Чөкəнеш (29,7 *км*), Чаллы (21,6 *км*), Талкыш (49 *км*) — сул кушылдыклар. Елга челтəренең тыгызлыгы 0,38 *км/км*^{2}. 20 йөз урталарыннан су җыелу мəйданында көчəеп киткəн эрозия күренешлəре Ч.нең озынлыгы кыскаруга һəм аның кушылдыкларының саны кимүгə (74 тəн 66 га кадəр) китерə. Елга режимын күзəтүлəр 28 гидрологик постта алып барылган, 1934 елдан Яңа Чишмə р-ны Петропавел Бистəсе авылы янында алып барыла.

Елга уртача сулылыкта, күп кенə кушылдыкларының суы буалар б-н көйлəнгəн. Туенуы катнаш, өчтəн ике өлеше кар сулары исəбенə. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 110–145 *мм*, ташу вакытында су катламы 60–80 *мм*. Язгы ташу, гадəттə, март ахырында башлана һəм апрель

ахырына кадәр дәвам итә. Суының иң зур чыгымы: Лениногорск р-ны Иске Куак авылы янында 435 *м³/с* (1979), Петропавел Бистәсе авылы янында 625 *м³/с* (1974), 460 *м³/с* (1979). Җәйге челлә вакытында су биеклеге тотрыклы. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 8,8 *м³/с*. Җир асты сулары б-н туену модуле бассейнының югары һәм урта өлешендә 5–10 *л/с·км²* дан түбән агымында 1 *л/с·км²* га кадәр. Җәен озак вакыт яңгырлар булмаган да елга тулысынча грунт сулары б-н туенуга күчә. Ч. бассейнында 0,5–1 дән 2–3 л/с ка кадәр дебитлы чишмәләр күп. Елга, гадәттә, ноябрь уртасында туңа. Бозлы чор 120–150 көн дәвам итә. Кыш ахырына бозның калынлыгы 60–70 *см* га (макс. 110 *см*) җитә. Грунт сулары чыккан урыннарда күлләвекләр барлыкка килә. Суы гидрокарбонат-хлорид-кальцийлы типта; язын суы елганың югары агымыннан Кичү елгасы тамагына кадәр каты (6–9 *мг-экв/л*) һәм түбән агымында чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*); кышын бөтен озынлыгында бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–400 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. Суы иң аз булган вакытта уртача болганчыклыгы 180–230 *г/м*. Ч. бассейнында суының гомуми күләме 160 млн. *м³*.

Су ресурслары сугару, сәнәгать һәм а.х. пр-тиеләрен су б-н тәэмин итү өчен файдаланыла. Ч. — ТР табигать истәлеге (1978). Аның бассейнында табигать истәлекләре *Чыршы һәм карагай урман культуралары, 1910–13 еллар*, *Асфальтит чыгышы*, Чыршылы сөркә (байбак) колониясе, *Үргәнеч ботаника тыюлыгы*, *Коржинский сөзәкләкләре* табигать тыюлыгы урнашкан.

О.Н.Урбанова.

ЧИШМӘ авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 17 *км* көньяктарак, БР б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 145 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты. Мәчет. 20 йөз башында нигез салына. Оешкан көненнән Уфа губернасының Минзәлә өязе Актаныш волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1913 тә — 238, 1920 дә — 413, 1938 дә — 408, 1949 да — 338, 1958 дә — 361, 1970 тә — 388, 1979 да — 259, 1989 да — 185, 2002 дә — 173 кеше.

ЧИШМӘ авылы, Әгер җ р-нында, Әгер җ шәһәреннән 31 *км* көньяктарак, Иж елгасыннан 2 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 38 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. 1678 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Иске Чишмә исеме б-н дә билгеле. Авыл башта морза Яушевлар милке була, 1733 тә К.М.*Тәфкилевкә* сатыла. 1740–60 елларда җирле халык берничә тапкыр Тирсә волостеның башка авыл крәстияннәре б-н бергә алпавыт Тәфкилевләргә каршы баш күтәрә (к. *Тирсә крәстияннәре кузгалышлары*); игенчелек, терлекчелек, курыс төшерү, агач ташу б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ч.дә мәчет, мәктәп эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 200 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Зур Кибә волостенда, 1921 дән ТАССРның — Әгерҗе, 1924 тән Алабуга кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1859 да — 120, 1887 дә — 190, 1905 тә — 239, 1920 дә — 389 (Дерново авылын да кертеп), 1926 да — 334, 1938 дә — 330, 1958 дә — 127, 1970 тә — 87, 1989 да — 29, 2002 дә — 31 кеше.

Әд.: Мәрданов Р.Ф., Һадиев И.Г. Әгерҗе төбәге тарихы. К., 2003.

ЧИШМӘ авылы, Әгер җ р-нында, Әгер җ шәһәреннән 48 *км* көньяктарак, Иж елгасыннан 3 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 68 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, иткә терлек асрау. 1640 елларга кадәр нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Тоба исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, каен тузыннан тартма һәм тырыслар ясау б-н шөгыльләнә. 19 йөздә сәүдәгәр К.Лихачёвның күн з-ды эшли. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 412 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Мөшәк волостенда, 1921 дән ТАССРның — Әгер җ, 1924 тән Алабуга кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Әгерҗе, 1963 нең 1 февраленнән — Алабуга, 1964 нең 4 мартыннан Әгерҗе р-нында. Халык саны: 1744 тә — 14 ир-ат; 1859 да — 81, 1887 дә — 171, 1905 тә — 247, 1920 дә — 283, 1926 да — 193, 1938 дә — 270, 1958 дә — 157, 1970 тә — 106, 1989 да — 69, 2002 дә — 70 кеше.

Әд.: Мәрданов Р.Ф., Һадиев И.Г. Әгерҗе төбәге тарихы. К., 2003.

ЧИШМӘ посёлогы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 3 *км* көнбатыштарак, Самара өлкәсе б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 275 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. Башлангыч мәктәп, китапханә. Мәчет. 1921 дә нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Чистай кантоны Егоркино волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Октябрь (1997 нең 10 декабреннән — Нурлат) р-нында. Халык саны: 1926 да — 243, 1949 да — 316, 1958 дә — 309, 1970 тә — 424, 1979 да — 334, 1989 да — 238, 2002 дә — 320 кеше.


ЧИШМӘ КИРМӘНЕ, к. *Шешминка*.

ЧИШМӘ РАЙОНЫ, *Башкортстан Республикасының* үзәгендә урнашкан. 1930 елның 20 августында оештырыла. Мәйданы — 1824 *км²*. Үзәге — шәһәр тибындагы Чишмә посёлогы (Уфадан 57 *км* көнбатыштарак). Халкы — 52607 кеше (2017). Татарлар саны: 1970 тә — 31091, 1979 да — 28299, 1989 да — 27618, 2002 дә — 27889, 2010 да — 28599 кеше. Район составында 105 торак пункт, ш.и. 45 татар, 14 рус-татар, 3 башкорт-татар, 2 рус-башкорт-татар һәм 1 рус-украин-татар торак пункты исәпләнә. Иң зур татар торак пунктлары (2009): Чишмә штп (22096 кеше), Чишмә (1771) һәм Сәфәр (1033) авыллары. 2015/16 уку елында Ч.р.ның 9 мәктәбендә укыту татар телендә алып барыла, 18 мәктәптә татар теле фән буларак өйрәнелә. «Куштирәк» татар фольклор ансамбле эшли. Рус һәм татар телләрендә «Родник» — «Чишмә» г-талары нәшер ителә. Ч.р.нда шагыйрь М.С.*Кәрим*, язучы С.Ф.*Кудаш*, артист, җырчы Ф.Я.*Кудашева*, тарихчылар Раил Г.*Кузиев* һәм Рөстәм Г.*Кузиев*, Сов. Союзы Герое А.Г.*Гыйззәтуллин* туган; агроном-селекция белгече С.А.*Кунакбаевның* тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге шушы район б-н бәйле.

ЧИШМӘБА́Ш авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 31 *км* көньяктарак, Сөн елгасы буенда. 2010 елда 151 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Клуб. Мәчет. 1920 елларда нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Минзәлә кантоны Байсар волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1926 да — 17, 1938 дә — 361, 1949 да — 247, 1958 дә — 224, 1970 тә — 313, 1979 да — 262, 1989 да — 168, 2002 дә — 171 кеше.

ЧИШМӘБА́Ш авылы, Кукмара р-нында, Кукмара шәһәреннән 22 *км* төньяк-көнбатыштарак, Борбаш елгасы буенда. 2010 елда 732 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына, 1940 елларга кадәр Коллар исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә, 19 йөзнең 1 нче яртысында Коллар авылы янындагы бакыр руднигында руда чыгаралар. 1859 елгы мәгълүматларга караганда, мәчет, кытай тукымасы җитештерү ф-касы, 20 йөз башында 3 мәчет һәм 3 мәдрәсә эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2151,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Сәрдекбаш волостенда, 1920 дән ТАССРның — Арча, 1928 дән Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Кукмара, 1963 нең 1 февраленнән — Саба, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1905 тә — 922, 1920 дә — 1124, 1926 да — 1148, 1949 да — 655, 1958 дә — 633, 1970 тә — 755, 1979 да — 747, 1989 да — 679, 2002 дә — 733 кеше.

ЧИЯ́ (Cerasus), розачалар семьялыгыннан агачсыман яфрак коючы үсемлекләр ыругы. Куак яисә калын кабыклы озынча-эллиптик яисә озын ланцетсыман чиратлашкан яфраклы, кечкенә чәчәк оешмасы — чатырларга җыелган ак һәм алсу чәчәкле зур булмаган агач. Җимеше — эчендә бер орлыгы булган түгәрәк яисә озынча төшле 2,5–5 *г* лы сусыл каты төшле җимеш. Тамыр системасы өстә урнашкан, актив тамырларының төп өлеше 35–40 *см* тирәнлектә була. Ч.нең 150 төре билгеле, ләкин Татарстан терр-ясендә дала Ч.се (C. fruticosa) һәм гади Ч. (C. Vulgaris)



Чия. 1. «Заря Татарии»; 2. «Краса Татарии»; 3. «Обильная»; 4. «Память Сахарова»; 5. «Севастьяновская»; 6. «Тверитиновская»; 7. «Труженица Татарии»; 8. «Шакиров».

таралган, аз санда ком Ч.се (C. pumila) һәм төкчәле Ч. (C. Tomentosa) очрый. Ч. — Татарстан терр-ясендә алмагачтан кала иң киң таралган культура (җимеш агачлары мәйданының 18%ын били). Корылыкка чыдамлылыгы югары, салкынга чыдамлылыгы һәм уңыш бирүчәнлеге уртача (бер куактан 10–30 *кг*). Иртә чәчәк ата (10–15 майда), шуңа чәчәкләре еш кына кыраулардан зыян күрә. Җимешләренең тәме диетик һәм дәвалау сыйфатлары, иртә өлгерүе (июль), тиз җимеш бирә башлавы (3–4 елда) б-н югары бәяләнә. Җимешләрендә 15% шикәр, 0,8–2,4% кислоталар, 0,15–0,88% дуплау матдәләре, пектин, С, А, В һәм РР витаминнары бар. Яңа өлгергән һәм эшкәртелгән килеш (кайнатма, джем, шәраб, сок, компот, кондитер әйберләр) кулланыла. Ч.нең ТР терр-ясендә үстерелә торган күп сортларының чыгышы — катлаулы гибрид сорт, ләкин дала Ч.се сортлары («Түбән Кама», «Поздняя розовая», «Маяк», «Уральская рубиновая», «Шакиров», «Обильная») өстенлек итә. Гади Ч.гә «Владимирская» сорты керә, аңа чыгышы б-н катлаулы булган «Тверитиновская», «Память Сахарова», «Севастьяновская», «Заря Татарии», «Краса Татарии» сортлары якын тора; аларның кайберләрендә төче чия билгеләре бар. Гади Ч. төрендәге сортлар көчле үсешле (биеклеге 2,5–4 *м*), эрерәк яфраклы һәм җимешләре тәмлерәк, ләкин салкынга чыдамлылыгы түбәнрәк һәм уңдырышлы туфракка таләпчәнрәк. Дала Ч.се төрендәге сортлар тәбәнәк (биеклеге 1,5–2 *м*), яфраклары вак, тар һәм калын кабыклы, җимешләре ваграк һәм әчерәк, нигездә, эшкәртү өчен кулланыла. Алар салкынга һәм корылыкка чыдамрак, туфракка талымсызрак, ләкин куаклыклары күп була. Өлгерү вакытына һәм җимешләрен куллануга карап, Ч. сортлары иртә (июльнең 1 нче яртысында өлгерәләр), уртача (июльнең 2 нче яртысынды), соң (июль ахыры — августның 1 нче яртысында) өлгерешләләргә бүленә. Ч. үстерү өчен иң яхшы участоклар — Иделнең уң як яр буендагы югары сөзәкләкләр һәм аз селтеле туфраклы субүләрләр; түбән урыннарда аңа салкын тия һәм ул уңыш бирми. ТРда Ч.не куак формасында үстерәләр, 3,5 х 3,5 *м* квадрат ысулы б-н яисә рәт аралары 4 *м* киңлектә булган рәтләргә 2 *м* аша утырталар. Агач төпләре тамырларын зарарламас өчен 15 *см* тирәнлектә генә эшкәртелә. Ч.не томан барлыкка китерә торган корылмалар б-н җиһландырылган теплицаларда чыбыкча ялгау, куаклыклар, тамыр үрентеләре, яшел чыбыкчалар ярдәмендә үрчетәләр. Үзтамырлы үсемлекләр яшәүгә сәләтлерәк һәм 20–25 елга кадәр җимеш бирәләр, салкын тигәннән соң, культура куаклыклары хисабына тиз тереләләр; ялганган нары — 14–16 елга кадәр яши. Төп корткычлары — чия көясе, лайлалы кисмәннәр, чия озынборыннары. Төп авырулары — коккомикоз. Ч.нең районлаштырылган сортименты ТРда Татарстан а.х. фәнни-тикшеренү ин-тының Тәмте бүлегендә чыгарылган, салкынга һәм коккомикозга чыдамлылыгы, югары уңышы һәм җимешләренең сыйфаты б-н аерылып торган яңа селекция сортларыннан тора.

Әд.: Культура вишни в Средней полосе СССР: Материалы совещания 28–30 июня 1983 г., Орел. М., 1985; Колесникова А.Ф., Колесников А.И., Муханин В.Г. Вишня. М., 1986; Севастьянова Л.А. Селекция и сортоизучение вишни в Среднем Поволжье // 75 лет Татарскому науч.-иссл. ин-ту сел. х-ва. К., 1996.

Л.А.Севастьянова.


ЧИЯБАШЫ́ (Никифорово) авылы, Мамадыш р-нында. Мамадыш шәһәреннән 40 *км* төньяк-көнбатыштарак, Шыя елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 324 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты. Чиркәү. 1646 дан рус чыганакларында Азбердеевская Пустошь исеме б-н мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Никола чиркәве, земство мәктәбе (1866–81дә Изге Гурий бородәрлеге мәктәбе эшли), тегермән, тимерче алачыгы, 3 вак-төякләр кибете була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1404,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Кабык Күпер волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Мамадыш р-нында, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән Мамадыш р-нында. Халык саны:1782 дә — 82 ир-ат; 1859 да — 448, 1897 дә — 970, 1908 дә — 898, 1920 дә — 1007, 1926 да — 990, 1949 да — 754, 1958 дә — 1031, 1970 тә — 813, 1979 да — 703, 1989да — 542, 2002 дә — 372 кеше.

ЧИЯЛЕ́ АЛА́Н авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 17 *км* төньяктарак, Олы Чирмешән елгасы буенда. 2010 елда 421 кеше (чуашлар, руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, клуб, китапханә. 1710 нан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Рождественский исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ч.А.да Рождество чиркәве (1823 тә төзелә), земство мәктәбе, су тегермәне, 2 тимерче алачыгы, 3 ярма яргыч, 4 вак-төякләр кибете була; чәршәмбе базары эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 4907 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Егоркино волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында.1930 ның 10 августыннан — Октябрь (1997 нең 10 декабреннән — Нурлат) р-нында. Халык саны: 1782 дә — 247 ир-ат; 1859 да — 1247, 1897 дә — 2021 (Абляскино Пүчинкәсен дә кертеп), 1908 дә — 1690, 1920 дә — 2030, 1926 да — 1844, 1938 дә — 1088, 1958 дә — 412, 1970 тә — 780, 1979 да — 555, 1989 да — 304, 2002 дә — 417 кеше.

ЧИЯЛЕ́К авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 58 *км* көньяктарак, Мөшегә елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 42 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1920 елларда нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Минзәлә кантоны Пучы волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1949 да — 286, 1958 дә — 210, 1970 тә — 271, 1979 да — 191, 1989 да һәм 2002 дә — 69 кеше.

ЧИЯЛЕ́К авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 35 *км* көньяктарак, Сөн елгасы буенда. 2010 елда 42 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. 1927 дә нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Минзәлә кантоны Байсар волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1949 да — 180, 1958 дә — 149, 1970 тә — 184, 1979 да — 133, 1989 да — 77, 2002 дә — 58 кеше. Авыл янындагы археол. культура авыл исемен йөртә (к. *Чиялек куль - турасы)*.

ЧИЯЛЕ́К КУЛЬТУ́РАСЫ (археол.), Урал-Чулман буе төбәгендә (якынча 13–15 йөзләр). Атамасы Актаныш р-ны Чиялек авылы янындагы урта гасырлар торулыгына нисбәтле. Ч.к. истәлекләре беренче тапкыр (1969) Е.П.Казаков тарафыннан тасвирлана һәм мөстәкыйль археол. культура сыйфатында күрсәтелә. 20 дән артык авыллык, 30 дан артык каберлек мәгълүм. Ч.к. халкы башлыча ярымкүчмә терлекчелек б-н шөгыльләнгән (атлар һәм мөгезле эре терлек). Чиялек торулыклары (авыллыклар) терр-ясендә йортлар, тирмәләр, чумнар, шалашлар һ.б. төрле тораклар, хуҗалык базлары һәм чокырлары, ташлар түшәлгән культ корылмалары калдыклары, бау-тарак тешләре рәвешендәге бизәкләр (*Постпетрогром*



Чиялек культурасының Әҗмәт каберлеге. Чиялек культурасы савытлары.

культурасына тартым) төшерелгән, әвәләп эшләнгән савыт-саба, болгар керәч савытлары (һөнәрче түгәрәгендә эшләнгән) һәм металл эшләнмәләр калдыклары табыла. Такталачык, Әҗмәт һәм Дербёшка каберлекләрендә 500 ләп кабер тикшерелә, аларда кайбер мәҗүси культлар элементлары б-н бергә мөселман җирләү йоласы башкарылган. Күп кенә каберләрдә алкалар, муенсалар, йөзекләр, Алтын Урда ханнары Үзбәк һәм Җанибәк заманнарына нисбәтле акчалар, мәет битлекләре, балалар каберләрендә җирле угорларга хас бау-тарак тешләре рәвешендәге бизәкләр төшерелгән, әвәләп ясалган яссы төп-ле савытлар табыла. Фаразланганча, Ч.к. мөселманлашкан Урал угорлары тарафыннан калдырылган. 13 йөз уртасында Көнбатыш Европадан килгән сәяхәтчеләр П.Карпини, В.Рубрук Ч.к. терр-ясен — *Баскарт*, аның халкын венгрларга кардәш паскатирлар дип атыйлар. Соңрак Ч.к. халкы Урта Идел һәм Урал алды төбәгенең төрки телле халыклары арасында йотылган. Татарстан терр-ясендә Ч.к. истәлекләре Актаныш р-ны Әҗмәт (*Әҗмәт каберлеге*), Такталачык авыллары, элеккеге Дербёшка штп, Мөслим р-ны Мәлләта-мак авылы тирәләрендә табыла.

Әд.: К а з а к о в Е.П. Чияликская культура: территория, время, истоки // Угры: Материалы 6 Сибир. симп. «Культурное наследие народов Зап. Сибири». Тобольск, 2003; ш у л у к. Угры Восточного Закамья в составе Улуса Джучи // История татар с древнейших времён. К., 2009. Т. 3.

Е.П.Казаков.

ЧИЯЛЕТА́У авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 45 *км* көньяк-көнбатыштарак, Самара өлкәсе б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 2 кеше (татарлар) яши. 1920 елларда нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Бөгелмә кантоны Шөгер волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Шөгер, 1959 ның 16 октябреннән Лениногорск р-нында. Халык саны: 1926 да — 62, 1938 дә — 165, 1949 да — 176, 1958 дә — 129, 1970 тә — 121, 1979 да — 77, 1989 да — 31, 2002 дә — 9 кеше.

ЧИЯТҮБӘ (Чияле) посёлогы, Мөслим р-нында, Мөслим авылыннан 19 *км* көньяк-көнбатыштарак, Баланлы елгасы башында урнашкан. 2010 елда 21 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — бакчачылык. 1930 елларда нигез салына. Оешкан көненнән — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән — Сарман, 1965 нең 12 гыйнварыннан Мөслим р-нында. Халык саны: 1938 дә — 77, 1949 да — 101, 1958 дә — 76, 1970 тә — 65, 1979 да — 39, 1989 да — 20, 2002 дә — 31 кеше.

ЧМУ́ТОВА Галина Алексеевна (6.1.1940, Казан), химик-органик, химия фән. д-ры (1981), проф. (1983), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1996), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2004), Казан ун-тының атказ. профессоры (2010). Казан ун-тын тәмамлый (1962), шунда ук эшли, 1987–92 дә химия ф-ты деканы. Хезмәтләре элементорганик кушылмалар химиясенә карый. Ч. селенорганик кушылмалар структурасының электрон һәм фәзаи эффектларын (күкертле һәм кислородлы аналоглары б-н чагыштырып) анализлау системасын эшли. Органик кушылмалар структурасы б-н специфик һәм нәспецифик сольватация эффектлары, Н-комплексларның һәм күчешле корылмалы комплексларның термодинамик күрсәткечләре арасындагы бәйләнешне ачыклап күрсәтә. Квант химиясе алымнары ярдәмендә газ фазасындагы һәм эремәләрдәге кислородлы һәм азотлы гетероциклик кушылмаларда таутомерия күренешен тикшерә, химик һәм электр химик процессларда катнашучы селен һәм тиоргаником кушылмаларның активлыгын билгеләү максатында хисапланган структура күрсәткечләреннән файдалану мөмкинлеген ачыклый. Медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Электронная и пространственная структура некоторых ароматических производных элементов VI группы // Строение и реакционная способность органических соединений. М., 1978; Квантово-химическое исследование структуры и реакционной способности пиразолонов-5, их тио- и селеноаналогов. IX. 1-метипиразол-2-ин-5-он, его тио- и селеноаналоги в реакциях Н-комплексообразования в газовой фазе и в растворах // Журн. общей химии. 2007. Т. 77, вып. 9 (автордаш); Molecular Structure of 1-Phenyl-3-methyl-4-benzoylthiopyrazolones in the Crystalline Phase and their Tautomeric Transformation in Solutions and in The Gas Phase // J. Mol. Struct. 2001. V. 570, № 1–3 (автордаш).

Әд.: Казанский университет: Время, события, люди. К., 1994.

ЧОКАЛЫ́Й (тәхәллүсе, чын исеме һәм фамилиясе Гайнуллин Гарифулла Гайнулла улы) (1878, Сембер губ., Буа өязе Иске Чокалы а. — 1935, Омск өлкәсенең Тюкалинск р-ны Охотниково а.), язучы. Сембер шәһәрендә мәдрәсәдә укый, туган авылында укыта. 1919–21 елларда Буа кантонының халык мәгарифе бүлегендә инструктор, аннан соң тегүчелек кәсебе б-н шөгыльләнә. Вакытлы матбугатта басыла. «Надан ата» (1911), «Тәрәкъкый мәхәббәте» (1911), «Кызыклы шигырьләр» (1912), «Гаффар агай тормышы» (1912), «Яхъя суфи» (1914) шигырьләр җыентыклары авторы.Ч. иҗатына мәгърифәтчел характер хас. Репрессияләр чоры корбаны; үлгәннән соң аклана.

Әд.: Б у л а т о в Ә. Мәгърифәтче язучы Г.Чокалый // Казан утлары. 1979. № 5.

Ф.И.Ибраһимова.

ЧОКРЫ́Й Гали (тәхәллүсе, чын исеме һәм фамилиясе Көеков Мөхәммәдгали Габдесса-лих угылы) (8.1.1826, Уфа губ., Бөре өязе Иске Чокыр а. — 10.12.1889, шунда ук), шагыйрь. Бөре, Минзәлә, Эстәрлебаш мәдрәсәләрендә укый. 1852 елдан туган авылында мулла. Дүрт тапкыр Мәккәгә хаҗ кылырга бара. Мәдхияләр, элегияләр, дини-дидактик әсәрләргә шәрехләр, юлъязмалар, тарихи хезмәтләр авторы; үзе исән чакта аларның бер өлеше генә нәшер ителә. Ч.ның беренче әсәре — «Тәҗвид» (1860). «Хаҗнамә»дә (1872) заводлар һәм фабрикалар саны, тимер юл үсеше турында сөйләнә; автор үзгәрешләргә карата патриотик рухлы һәм игътибарлы күзәтүче буларак күз алдына килеп баса. «Зам-ме нәзыйр» (1888), «Тәрхибе рамазан» (СПб., 1903) һ.б. әсәрләргә дини-мистик идеяләр хас. Китапларның төп мотивы — дини үгет-нәсыйхәт, исламга һәм аның эшлеклеләренә мәдхия. Шагыйрь Болгар шәһәре тарихын һәм мәдәниятен данлый («ислам йорты изге»; «анда китаплар, язулар»), Казанны, аның осталарының, галимнәренең, язучыларының казанышларын мактап җырлый. «Мәдхе Казан» да (1889) Казанны Идел буе Болгар дәүләте традицияләрен дәвам итүче дип атый. Ч.ның замандашларына багышланган мәдхияләрендә аларның ватандашлары алдындагы казанышларына аеруча игътибар бирелә. Нигъмәтулла ишанга багышланган мәдхиядә җәмгыять өчен файдалы башка эшләр б-н берраттан ул чишмәдән авылга кадәр салган су үткәргеч тә телгә алына.



Гали Чокрый. «Дөррә Гали китабы»ның титул бите. 1903. С.-Петербург.

Ч. Ш.Мәржанинең мәгърифәтчелек өлкәсендәге эшчәнлегенә соклана, аны бөек фикер иясе һәм дин галиме итеп күрә. Аеруча кыйммәтле «Мәнзүм әт-Гали» дәфтәрендә табигатьне шигъри тасвирлаулар, шагыйрь биографиясенә бәйле язулар китерелгән. «Фөсүле әрбага» шигырендә Ч. туган як матурлыгын мактап җырлый. Шагыйрь телнең лексик байлыгына, шигыр юлы төзелешенә, форма купшылыгына аеруча игътибар бирә. Ч. әсәрләренең кулъязмалары Казан, С.-Петербург, Уфа китапханә һәм музейларында саклана. 2001 дә Ч.ның туган ягында аның исемендә музей ачыла.

Әд.: Г о м ә р о в И.Г. Мәгърифәт җырчысы: Г.Чокрыйның тормыш һәм иҗат сәхифәләре. К., 2006; Г а й н у л л и н М.Х. Татарская литература XIX в. К., 1975.

ЧОКРЫ́Й ХАН (? — 1416), Алтын Урда ханы (1413 елдан). Урта Азия идарәчесе *Аксак Тимер* сараенда яши. 1405 тә әмир Идегәй тарафыннан хан тәхетенә чакырыла, аның Себергә явында катнаша. Болгарда һәм Сарай әл-Җәдидтә акча суктыра. *Туктамыш хан* улы *Җаббарбирде хан* тарафыннан тәхеттән төшерелә.

Әд.: С а ф а р г а л и е в М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; История татар с древнейших времён. К., 2009, Т. 3.

И.Л.Измайлов.

ЧОКЫ́Р КҮЛЕ́, Көнчыгыш Кама аръягында. Ык елгасының ике сулъяк кушылдыгы субүләрендә, Азнакай р-ны Чәкән авылыннан

6 *км* көньяк-көнбатыштарак урнашкан. Су өслегенең мәйданы 1,12 *га*. Суының күләме якынча 11 мең *м*³. Озынлыгы 190 *м*, иң зур киңлеге 75 *м*. Уртача тирәнлеге якынча 1 *м*, иң зур тирәнлеге 2,5 *м*. Күл карст күренешләре нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Озынча формада. Атм. явым-төшемнәре һәм грунт сулары б-н туена. Суы гидрокарбонат-хлорид-кальцийлы типта, җиңелчә минераль-ләшкән, йомшак, төс үзгәрүчәнлеге уртача. Үтә күренмәлелеге 55 *см*. Сугару һәм терлекләргә су эчерү өчен файдаланыла. Ял итү урыны.

ЧОЛЫ́ авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 24 *км* төньяк-көнбатыштарак, Тәтеш — Апас автомобиль юлы буенда. 2010 елда 25 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ч.да укырга-язарга өйрәтү мәктәбе (1886 да ачыла), 3 җил тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 808,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Олы Шәмәк волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Тәтеш р-нында. Халык саны: 1859 да — 252, 1897 дә — 557, 1908 дә — 577, 1920 дә — 583, 1926 да — 406, 1938 дә — 394, 1949 да — 283, 1958 дә — 232, 1970 тә — 146, 1979 да — 97, 1989 да — 60, 2002 дә — 29 кеше.

ЧОЛЫКЧЫЛЫ́К, урман умартачылыгы. Элек агач куышларыннан кыргый бал кортларының балын җыю, аларны шул куышларда үрчетү. Агачлардагы табигый чолыклар (куышлар) файдаланылган яки агачларда (наратта, карамада һ.б.да) ясалма куыш чокылып, шунда бал кортлары күче урнаштырылган. Агачның өске өлешен кисеп, аның киңлеккә үсүе тәэмин ителгән; агач куышын киңәйтеп, бал кортларына кәрәз ясауны җиңеләйтү өчен, аның эченә ике пар аркылы-тор-кылы куелган таякчыклар урнаштырганнар, керү урынын тишекле капкач б-н томалаганнар. Чолыкның эчке озынлыгы 1–1,7 *м* га, диаметры 0, 35 *м* га җиткән. Аны аюлардан саклау өчен агач кәүсәсе тирәли очлы корыч чөйләр тыгып чыкканнар һ.б. Ибне Фазлан хәбәрендә болгарларда «урманнарда агач куышларында бик күп бал кортлары яши, алар (болгарлар) эшне белеп башкарып, бик күп бал җыялар» диелә. Идел буе Болгар дәүләтендә Ч. ху җалыкның мөһим тармакларыннан берсе була, бал һәм балавыз башка илләргә дә чыгарыла. Ч. ш.у. Казан ханлыгын-да да алга китә. Чолыклы биләмәләргә карата милек хокукы беркетелә. Казан ханлыгы яулап алынганнан соң, рус хөкүмәте биләмәләрнең бер өлешен элеккеге ху җалары милкендә калдыра. Казан өязендә шәһәрләр, кальгалар һ.б. төзегәндә чолыклы агачлар-ны кисү тыела. Чолыклы мул биләмәләр ш.у. Казан архиерее йорты милкендә дә була, ул милеккә кергән урманнарда татарлар Ч. б-н шөгыльләнәләр һәм шуның өчен бал б-н натураль оброк, акчалата түлиләр (1623–24 елларда — 2330 чолыклы агачтан). Урманнарны кисү һәм игенчелекнең таралышы, ш.у. бал алуга күп көч сарыф ителү Ч. ның мөһимлеге кимүгә китерә, аны кискәле һәм умарталы умартачылык алыштыра (к. *Умартачылык*).

Әд.: Покровский И.М. Бортничество (пчеловодство) как один из видов натурального хозяйства и промысла близ Казани в XVI–XVII // Изв. Об-ва археологии, истории и этнографии при Казан. ун-те. 1901. Т. 17, вып. 1; Халиков Н.А. Хозяйство татар Поволжья. К.. 1995.

И.Р.Вәлиуллин.

ЧОМГА́ КОШЛА́Р (Podicipedidae), чомгасыманнар отрядыннан кошлар семьялыгы. Якынча 20 төре билгеле. Арктика һәм Антарктидадан кала бөтен Җир шарында диярлек таралганнар. Татарстан терр-ясендә Ч.к. семьялыгы 4 төрне берләштерүче чомгалар ыругы б-н бирелгән. Зур чомга (Podiceps cristatus) һәм кара муенлы чомга (P. nigricollis) зур сусаклагычларның сай урыннарында һәм балыкчылык хуҗалыкларының су үсемлекләренә бай буаларында, соры яңаклы чомга (P. griseigena) Агыйдел, Вятка, Кама, Миша елгалары тугайларында, кызыл муенлы чомга (P. auritus), нигездә, Идел алдында очрый. Оя коручы күчмә кошлар. Итеннән балык исе килә. Гәүдәсенең озынлыгы 30–50 *см*, авырлыгы 200–1500 *г*, аз гына җәенке, өсте кара төстә, аскы ягы — көмешсыман-ак. Каурый капламы тыгыз, су үткәрмәү үзлегенә ия. Канатлары тар һәм кыска, койрыгы җитлекмәгән. Аяклары көчле, гәүдәсенең арткы очындарак, бу аңа яхшы йөзәргә һәм чумарга мөмкинлек бирә, әмма җирдә авырлык б-н генә йөриләр. Аягындагы 3 бармагы алга, 4 нчесе артка караган. Һәрбер бармагы йөзү элпәсе б-н әйләндереп капланган. Томшыгы очлы, безсыман. Туй чорында күпчелек төрләрендә яка һәм бүрекчәләр сыйфатында бизәүче каурыйлары була. Аерым парлар булып оялыйлар. Оялары сай сулыкларда яки йөзмә. Бизәксез 3–6 аксыл-яшькелт йомырка салалар. Су умырткасызлары, балык, су үсемлекләре б-н тукланалар. Кышлау урынына август ахыры — сентябрь башында очып китәләр. Кызыл муенлы чомга, соры яңаклы чомга ТР-ның Кызыл китабына кертелгән.

ЧОРМАВЫ́К, кускута (Cuskuta), чормавыкчалар семьялыгыннан берьеллык паразит үсемлекләр ыругы; үтә явыз чүп үләне. Якынча 700 төре билгеле, күбесенчә Төньяк Америкада таралганнар. ТР терр-ясендә бик үк өйрәнелмәгән. Ч. — хлорофиллсыз, яфрак һәм тамырсыз җеп яки баусыман сабаклы үсемлек. Чәчәкләре бәйләмгә яки шарсыман башча чәчәк төркеменә җыйналган. «Ху җа» үсемлекне сабаклары б-н урап алалар, имгечләре (гаусторияләр) ярдәмендә аның тукымаларына үтеп керәләр һәм үсемлекнең согы б-н тукланалар. «Ху җа» үсемлекләрдә матдәләр алмашы бозыла, аларның үсеше тоткарлана, уңышы һәм салкынга чыдамлыгы кими, үсемлек корырга да мөмкин. ТР терр-ясендә 3 төре бар: Европа Ч.ы (C. europaea) аеруча киң таралган. Бәрәңге, җиләк куакларын, кычыткан һ.б.ны зарарлый. Бөтен җирдә: елга тугайларында, дым-лы урманнарда һәм болыннарда очрый. Халык медицинасында эч йомшартқыч чара буларак кулланыла. Җитен Ч.ы (C. epilinum) җитендә паразитлык итә; югала баручы төр, Минзәлә р-нында билгеләнә. Колмаксыман Ч. (C. Luperlitormis) елга тугайларында, ерымнарда үсә, талда, шомыртта, сирәк кенә агач һәм үләнчел үсемлекләрдә паразитлык итә. Ч. орлыктан, ш.у. сабак өлешләреннән үрчи. Печән өчен чабылган Ч.лы үлән акрын кибә, күгәрә. Көрәш чаралары: карантин булдыру, агротехника кагыйдәләрен үтәү, Ч. чыганакларын чабу һәм яндыру, басуларны нитрофен, динитроорток-резол б-н эшкәртү.

ЧОШЫ́ елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Кама елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 30,5 *км*, бассейнының мәйданы 358 *км*². Балык Бистәсе р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Күки авылыннан 5 *км* көнбатыштарак урман массивында, тамагы — Тегермән Пүчинкәсе авылыннан 4 *км* көньяктарак. Елганың түбән агымы Куйбышев сусаклагычы суы астында



Чошы елгасы.

калган. Елга башының абс. биеклеге 160 *м*, тамагыныкы — 53 *м*. Су җыелу мәйданы Кама елгасының төп яры һәм аның террасаларының эре киртләчләре буйлап сусаклагыч ягына таба түбәнәюче көньякка авыш тигезлектән гыйбарәт. Катнаш һәм киң яфраклы урманнар б-н капланган, урманлылыгы 25%. Ч.ның үзәне шактый гына озынлыкта асимметрияле, көнбатыш экспозицияле сулъяк сөзәкләкләр, күбесенчә, текәрәк. Түбән агымында үзәннең киңлеге 2–3 *км*. Елга юлы бормалы, тармакланмаган. Ч.ның 16 кушылдыгы бар, аеруча зурлары: Сола (16,4 *км*), Макарка (12,1 *км*) — уң; Баравыш (13,2 *км*) — сул кушылдыклар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,43 *км/км*². Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 3–5 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәенеклы саегуы б-н характерлана. Бассейнда елык су агымының уртача күпьеллык катламы 120–150 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 92 *мм*. Көчле агымлы язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ункөнлегендә башлана һәм айга якын дәвам итә. Җәйге челлә вакытында суның биеклеге тотрыклы; озак вакыт яңгырлар булмаганда, Ч.ның һәм аның кушылдыкларының аерым урыннары кибә. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,5 *м*³/*с*. Кышкы челлә ноябрьнең беренче ункөнлегендә, яр буйларында беренче боз капламнары барлыкка килү б-н башлана. Елга ноябрь урта-

сында туңа, бозлы чор якынча 150 көн дәвам итә. Суы сульфат-гидрокарбонат-кальцийлы типта, язын чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минераль әшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 700–1000 *мг/л*. Ч.да суының гомуми күләме 1,2 млн. $м^3$ булган 2 буа бар. Су ресурслары а.х. ихтыяҗлары өчен кулланыла. Елга ярларында кошлар, ш.и. ТРның Кызыл китабына кертелгән кече акчарлак, сары борынлы (нәфис) аккош яши. ТРның табигать истәлеге (1978).

О.Н.Урбанова.

ЧӨГӘ БАЛЫ́К, к. *Мәрсин балыклар*.

ЧӨГӘНӘ́ авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 4 *км* төньяк-көнчыгыштарак урнашкан. 2010 елда 160 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1745 тән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Чуганы исеме б-н телгә алына. Халкы асабалар һәм типтәрләр катлауларына бүленә; игенчелек, терлекчелек, товар ташу б-н шөгыльләнә, җирле пристаньда эшли. 20 йөз башында мәчет (1832 дән билгеле), мәктәп, икмәк пристане була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 955 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Актаныш волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 145, 1858 дә — 527, 1870 тә — 542, 1906 да — 546, 1920 дә — 599, 1926 да — 427, 1938 дә — 425, 1949 да — 318, 1958 дә — 324, 1970 тә — 279, 1979 да — 236, 1989 да — 186, 2002 дә — 186 кеше.

ЧӨГЕНДЕ́Р (Beta), алабутачалар семьялыгыннан бер-, ике- һәм күпьеллык үсемлекләр ыругы. 13 төре бар (11 кыргый һәм 2 культурада). Кыргый Ч. азык буларак борынгы заманнан файдаланыла. Беренче тапкыр яфраклы Ч. турында Вавилон патшасы Мародах-Баладан (б.э.к. 722–711 еллар) бакчаларындагы үсемлекләр исемлегендә искә алына. Б. э. к. 2–1 меңьеллыкларда ул культурага дару һәм яшелчә үсемлеге буларак кертелә. Б.э. башына Урта диңгез һәм Азия алдында гади азык Ч.енең культуралы формасы барлыкка килә; 10–11 йөзләрдә алар Киев Русенда, 13–14 йөзләрдә — Көнбатыш Европа илләрендә билгеле була; 16–17 йөзләрдә аның азык һәм терлек азыгы формалары барлыкка килә; 18 йөздә терлек азыгы Ч.енең гибрид формасыннан шикәр Ч.е аерымлана. **Яфраклы Ч.** — икееллык яисә берьеллык үсемлек, чук тамырлы (кайвакыт үзәк тамырлы), юан, тамыры көчле тармакланган. Яфраклары көчле үскән, сабаклары киң. ТРда яшелчә культурасы буларак йорт яны участокларында үстерелә. Гади тамыразык Ч.е сусыл, итчел, тамыразыгы ян-якка ботакланмый, күпчелек сортларныкы туфрак өстенә чыга. Тамыр системасы көчле, 2,5 *м* га кадәр. Чәчәк сабагы үләнчел, туры, бик нык тармакланган, ике- яисә күпьеллык төрләре икенче елда барлыкка килә. Яфраклары эре, шома яисә дулкынлы, өчпочмаклы, телсыман яисә йөрәксыман формада, тамыр янындагылары — озын киң булмаган сабакларда, сабак янындагылары — вак, утырып диярлек торалар. Чәчәкләре ике женесле, яшел яисә аксыл, озын яфраксыз чәчәк оешмасына җыелган, берничә данә булып бергә утыралар. Читтән серкәләнә — вак бөҗәкләр һәм җил б-н. Җимешләре бөресыман формада, өлгерү вакытында берничә җимешле йомгак барлыкка китереп, бер-берсенә бетерегәләр (2–6 җимеш б-н), алар чәчү материалы була. Үсемлек дым һәм яктылык ярата, салкынга һәм корылыкка чыдам. **Азык Ч.енең** кабыгы һәм җимеш йомшагы куе кызыл, кара- яисә җете кызыл төстә, тамыразыклары төрле формада (яссы, озынча-конуссыман һәм орчыксыман). Азык буларак техник өлгергән (составында шикәр, аксым, микроэлементлар, C,B,P,PP витаминнары булган) тамыразыклар һәм яшь үсемлекләр кулланыла. Кан әйләнеше системасының кайбер авырулары вакытында диетик һәм дәвалау чаралары буларак файдаланыла. Чәчү әйләнешендә кәбестә, томат, кыярдан соң чәчелә. ТРда 1035 *га* мәйданда шәһәр яны яшелчәлек хуҗалыкларында «Бордо 237», «Несравненная А-463», «Мулатка», «Ике орлыклы ТСХА», «Хавская» сортлары. 2016 да ТРда азык чөгендеренең тулай җыемы 498,6 мең *ц* тәшкил итә. **Терлек азыгы Ч.енең** тамыразыгы эре (10–12 *кг* га кадәр), төсләре һәм формалары буенча төрле, шома, күбесенчә тармакланмаган, җирдән җи өлеп чыгарыла. Яфрак таралгысы ярым туры, уртача һәм эре яфраклар б-н, сусыл азык сыйфатында файдаланылалар. Ч.нең гадәти терлек азыгы сортлары тамыразыкларында аз күләмдә коры матдә һәм шикәр бар. Хайваннарга һәм кошларга азык буларак кулланыла. 100 *кг* тамыразыкка 12,2 азык берәмлеге һәм 0,9 *кг* үзләштерелә торган протеин, 100 *кг* яфракка 10,2 азык берәмлеге һәм 1,8 үзләштерелә торган протеин туры килә. Чәчү әйләнешендә берьеллык үләннәрдән һәм кукуруздан соң чәчелә. 2016 да терлек азыгы тамыразыкларының чәчүлек мәйданнары респ-када 2,4 мең *га* тәшкил итә, уңышы — 1 *га* дан 298 *ц*; «Эккендорфская жёлтая», «Баррес», «Сибирская оранжевая», «Полусахарная белая», «Лань» сортлары үстерелә. **Шикәр Ч.енең** тамыразыгы конуссыман, капчыксыман яисә цилиндр формасында, ак төстә (җирдән авыр чыгарыла, авырлыгы уртача 300–600 *г*) һәм яфрак таралгысы ачык яшел төстә. Яфракларында барлыкка килә торган органик матдәләр паренхима тукымасында шикәр буларак туплана (23%ка кадәр). Шикәр Ч.е — *шикәр сәнәгате* өчен чимал. «Льговская односемянная 52», «Маша», «Ювена», «Кива», «Кристелла», «Лауренция» сортлары үстерелә. Шикәр Ч.ендә башка формаларга караганда икееллык үсеш циклыннан читкә чыгу күзәтелә: «шау чәчәк ату» (беренче елда чәчәк ату) һәм «киреләнү» (икенче елда чәчәк атмау), бу сортларның үзенчәлекләре һәм тамыразыкларны үстерү һәм саклау шартлары б-н бәйле. 2016 да ТРда аның чәчүлекләре 63,2 мең *га* били, уңышы 1 *га* дан 369 *ц* тәшкил итә.



Азык чөгендере.



Шикәр чөгендере.

Ш.у. к. *Чөгендер үстерүчелек*.

Әд.: Культурная флора СССР. Т. 19. Корнеплодные растения. Л., 1971.

ЧӨГЕНДЕ́Р ҮСТЕРҮЧЕЛЕ́К, шикәр алу өчен шикәр чөгендере үстерү һәм аны эшкәртү б-н шөгыльләнә торган үсемлекчелек тармагы. ТРда шикәр чөгендере, нигездә, черемә күп булган (8–10%) кара туфраклы җирләрдә үстерелә. Россиядә Ч.ү. 19 йөз башында Тула губернасының Алябьево авылында беренче шикәр з-ды ачылганнан соң (1802) үсеш ала башлый. Татарстанда сәнәгый максатларда шикәр чөгендерен үстерү 1944 елдан 3 мең *га* мәйданда Октябрь һәм Тельман р-ннарында башлана. Чөгендернең уртача уңышы 1944–51 дә 1 *га* дан 21 *ц* тәшкил итә, 1953 тә 1 *га* дан 103 *ц* га җитә, 1970 тә — 171, 1990 да — 190, 2008 дә — 300 *ц*. 1956 да шикәр чөгендеренең уртача уңышы Октябрь р-ны колхозларында 1 *га* дан 150 *ц*, 1960–61 дә — 176–178 *ц*. 1956–1957 дә Ч.ү. б-н Аксубай, Буа һәм Чирмешән р-ннары хуҗалыкларында шөгыльләнә башлыйлар. Нурлат шикәр з-дын эшләтеп җибәрү алдыннан (1958) шикәр чөгендере чәчүлекләреңең гомуми мәйданы 20,6 мең *га* тәшкил итә, 1970 тә — 43,7, 1990 да — 49,1, 2016 да — 63,2 мең *га*. Эшкәртү сәнәгатенең, ш.и. шикәр җитештерүнең, чимал нигезе булып, 3 зона — Буа, Зәй, Нурлат тора. Шикәр чөгендерен иң күп җитештерүче а.х. пр-тиеләре Апас, Буа, Зәй, Кайбыч һәм Сарман р-ннарында, алар өлешенә 2007 дә ТРдагы гомуми мәйданның 8,8% тан 19,4% ка кадәре туры килә. 2016 да шикәр чөгендеренең уңышы Буа р-нында 1 *га* дан 386 *ц* тәшкил итә, Зәйдә — 418, Кайбычта — 320, Сарманда — 304; респ-ка буенча уртача уңыш — 369 *ц*.

2005 тән башлап ТРда шикәр чөгендерен үстерүдә кул хезмәтен файдаланмый торган

яңа технологияләр кертелә (нем., франц. һ.б.). Респ-када шикәр чөгендере чәчелгән мәйданның 90% кадәрен Россия һәм чит илләрнең әйдәп баручы фирмаларының бер орлыклы сортлары һәм гибридлары били, аларны үстерү механикалаштырылган ысулларны киңрәк куллану мөмкинлеген бирә.Татарстан Россиядә шикәр чөгендерен тулай җитештерү буенча 4 нче урынны били. Ч.ү. үсешендә һәм аны үстерү технологияләре буенча Казан аграр ун-ты галимнәренең (Р.Р.Хөсәенов, А.К.Вершинин), Бөтенсоюз шикәр чөгендере фәнни-тикшеренү ин-ты (Е.А.Тонкаль, Н.В.Куцуруба һ.б.) һәм Украина чөгендер үстерү белгечләренең тикшеренүләре зур ярдәм күрсәтә. Җирле шартларда бу культураның агротехникасын эшләүгә Г.Д.Аверьянов, Ю.Г.Бутаков, И.Т.Храмов мөһим фәнни өлеш кертәләр.

Чыг.: Республика Татарстан. 1920–2000: Стат. сб. К., 2001; Сельское хозяйство Республики Татарстан: Стат. сб. К., 2008.

Әд.: Пути повышения эффективности свекловодства в Татарии. К., 1970; Юнусов Р.А. Северное свеклосеменоводство К., 1998; Состояние и перспективы развития свеклосахарного производства // Нива Татарстана. 2003. № 5/6.

Р.Ә.Әсретдинова.

ЧӨКӘНӘ́Ш (Сәкинәс, Сикәнәс) елгасы, Көнбатыш Кама алдында, Чишмә елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 29,7 *км*, бассейны-ның мәйданы 299,8 *км*². Идел аръягы түбәнлегеннән, Яңа Чишмә р-нында ага. Елга башы Ивановка авылыннан 1 *км* төньяк-көнчыгыштарак, тамагы Яңа Чишмә авылыннан 3 *км* көнчыгыштарак һәм Петропавел Бистәсе авылыннан көнбатыштарак, Елга башының абс. биеклеге 140 *км*, тамагыныкы — 60 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 10%. Ч.нең 7 кушылдыгы бар, иң зурлары: Черёмуха (9,5 *км*), Устье (10,6 *км*) — уң кушылдыклар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,25 *км/км*². Туенуы катнаш, күбрәк кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 3–5 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 85 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахыры — апрель башында башлана. Елга ноябрь ахырында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,05 *м*³*/с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минераль-ләшүе язын 300–400 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. Елгада суының гомуми күләме 1,2 млн. *м*³ булган 3 буа бар. Ч. бассейнында *Коржинский сөзәкләкләре* ландшафтлы тыюлыгы (1991) урнашкан.

ЧӨМӘ́-ЕЛГА́ авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 23 *км* көнчыгыштарак, Кесмәс елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 69 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — сарык асрау. Башлангыч мәктәп. 17 йөздә нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында По Ключу Муй-Илга исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, өс-баш киемнәре тегү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 мәчет, тегермән, 4 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1128,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Яңа Чүриле волостенда, 1920 дән ТАССРның — Мамадыш, 1921–22 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Арча, 1944 нең 19 февраленнән — Чүриле, 1956 ның 14 маеннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 110 ир-ат; 1859 да — 563, 1897 дә — 814, 1908 дә — 806, 1920 дә — 860, 1926 да — 821, 1938 дә — 649, 1958 дә — 364, 1970 тә — 252, 1979 да — 279, 1989 да — 117, 2002 дә — 97 кеше.

ЧУА́Р АБДУ́Л, к. *Чубар Абдул.*

ЧУА́Р КОҢГЫЗЛА́Р, талпаннар ыругы, к. *Алтынкүзләр*.

ЧУА́Ш АКСУ́Ы́ авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 19 *км* төньяк-көнбатыштарак, Лашчы елгасы буенда. 2010 елда 217 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 19 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы удел крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, балта эше б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 95,2 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Ырынгы волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Буа р-нында. Халык саны: 1859 да — 253, 1910 да — 295, 1920 дә — 333, 1926 да — 295, 1938 дә — 294, 1949 да — 258, 1958 дә — 300, 1970 тә — 344, 1979 да — 351, 1989 да — 136, 2002 дә — 228 кеше.

ЧУА́Ш АФО́НЬКӘСЕ (Ишлинка) авылы, Чирмешән р-нында, Чирмешән авылыннан 17 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Чишмә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 66 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1730 елларда нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында су тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1061 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сама-ра губернасының Бөгелмә өязе Мордва Афонькәсе волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Беренче Май, 1963 нең 1 февраленнән — Лениногорск, 1965 нең 12 гыйнварынан Чирмешән р-нында. Халык саны: 1859 да — 293, 1889 да — 373, 1910 да — 382, 1920 дә — 405, 1926 да — 175, 1949 да — 207, 1958 дә — 208, 1970 тә — 201, 1979 да — 163, 1989 да — 126, 2002 дә — 89 кеше.

ЧУА́Ш БИЗНӘСЕ́ (Бизнә Башы) авылы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 9 *км* көнъяк-көнбатыштарак, Бизнә елгасы (Сураның уң кушылдыгы) буенда. 2010 елда 520 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау; урман хуҗалыгы. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. 1654 тән — Мемкеева, 17 йөзнең 2 нче яртысыннан Мамкейка Тарабаева исемнәре б-н дә билгеле. 1720 еллардан халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, 1835–1860 елларда Удел ведомствосы карамагында; игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәктәп, 3 сәүдә-сәнәгать йорты эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 859,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Городище волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1859 да — 487, 1897 дә — 853, 1913 тә — 1024, 1920 дә — 990, 1926 да — 1200, 1938 дә — 1034, 1949 да — 896, 1958 дә — 991, 1970 тә — 868, 1979 да — 989, 1989 да — 516, 2002 дә — 496 кеше.

ЧУА́Ш БИМОРЗАСЫ́ авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 18 *км* көнъяктарак, Олы Тилчә елгасы буенда. 2010 елда 141 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Пимурзино исеме б-н дә билгеле. 1720 елларданхалкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, 1835–60 елларда Удел ведомствосы карамагында; игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү, земство мәктәбе эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 426,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Борындык волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Буа, 1935 нең 10 февраленнән — Будённый, 1957 нең 29 ноябреннән — Чынлы, 1959 ның 12 октябреннән Буа р-нында. Халык саны: 1859 да — 276, 1897 дә — 835, 1913 тә — 247, 1920 дә — 277, 1926 да — 250, 1938 дә — 305, 1958 дә — 391, 1970 тә — 345, 1979 да — 193, 1989 да — 171, 2002 дә — 157 кеше.

ЧУА́Ш БОРНАЕ́ авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 35 *км* көнъяк-көнбатыштарак, Борнай елгасы буенда. 2010 елда 398 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1710 елларда нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Югары Борнай исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Казан Богородица чиркәве, чиркәү-приход мәктәбе (1903 тә ачыла), 6 җил тегермәне, 1 казна шәраб һәм 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1893,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Кузнечиха волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1935 нең 10 февраленнән — Кузнечиха, 1960 ның 28 октябреннән — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварынан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 137 ир-ат; 1859 да — 687, 1897 дә — 1274, 1908 дә — 1480, 1926 да — 1329, 1938 дә — 955, 1949 да — 880, 1958 дә — 956, 1970 тә — 927, 1979 да — 669, 1989 да — 608, 2002 дә — 508 кеше.

ЧУ́АШ ЕНОРУ́СКИНОСЫ авылы, Аксубай р-нында, шәһәр тибындагы Аксубай посёлогыннан 14 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Кече Сөлчә елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 412 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, клуб, китапханә. 18 йөз уртасында нигез салына. Рев-циягә рус чыганакларында Новопоселённая Янорусова исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында су тегермәне, 2 ярма яргыч, 2 тимерче алачыгы, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1964 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Аксубай волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Аксубай, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1965 нең 12 гыйнварыннан Аксубай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 114 ир-ат; 1859 да — 811, 1897 дә — 919, 1908 дә — 947, 1920 дә — 1061, 1926 да — 1113, 1938 дә — 1115, 1949 да — 648, 1958 дә — 738, 1970 тә — 757, 1979 да — 668, 1989 да — 524, 2002 дә — 482 кеше.

ЧУ́АШ ИЛЕ́ авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 26 *км* төньяк-көнбатыштарак, Питиал елгасы буенда. 2010 елда 131 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. 1602–03 тән Чуаш исеме б-н билгеле. 1940 елларга кадәрге рәсми чыганакларда 2 авыл — Чуаш Лашманкасы һәм Чуаш-Ясак буларак телгә алына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, башмак һәм өс киемнәре тегү, балта эше, он тарту, бакырдан әйберләр ясау, олаучылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 мәчет, 2 мәктәп, 3 җил тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1718,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Кавал волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 109 ир-ат; 1859 да — 797, 1897 дә — 962, 1908 дә — 1172, 1920 дә — 736, 1926 да — 1157, 1938 дә — 854, 1949 да — 658, 1958 дә — 502, 1970 тә — 401, 1989 да — 207, 2002 дә — 168 кеше.

Әд.: Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

ЧУ́АШ ИШЛЕСЕ́ авылы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 9 *км* төньяк-көнбатыштарак, Бизнә елгасының (Сураның уң кушылдыгы) югары агымы буенда. 2010 елда 239 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, дуңгыз асрау. 1654 тән мәгълүм. 1720 еллардан халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, 1835–60 елларда Удел ведомствосы карамагында, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 10 сәүдә-сәнәгать йорты эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1231,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Шомырша волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән Чүпрәле районында. Халык саны: 1859 да — 447, 1884 тә — 555, 1897 дә — 645, 1920 дә — 856, 1926 да — 988, 1938 дә — 1030, 1949 да — 892, 1958 дә — 813, 1970 тә — 982, 1979 да — 706, 1989 да — 355, 2002 дә — 282 кеше.

ЧУ́АШ КИЧУ́Е авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 25 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кече Чирмешән елгасы буенда. 2010 елда 741 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау; «Кызыл Шәрекъ» ААҖнең терлекчелек комплексы. Урта мәктәп, мәдәният йорты, амбулатория. 1660–70 елларда нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Темеево исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 мәчет, мәдрәсә, 5 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1912 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Әлки волостенда, 1920 дән ТАССРның Спас кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Әлки, 1944 нең 19 февраленнән — Юхмачы, 1956 ның 7 декабреннән — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 92 ир-ат; 1859 да — 682, 1897 дә — 1072, 1908 дә — 1204, 1920 дә — 1514, 1926 да — 844, 1938 дә — 576, 1949 да — 1143, 1958 дә — 1737, 1970 тә — 1722, 1979 да — 1365, 1989 да — 975, 2002 дә — 868 кеше.

ЧУ́АШ КИШТӘГЕ́ авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 27 *км* көньяк-көнбатыштарак урнашкан. 2010 елда 398 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Киштәк исеме б-н дә билгеле. 1720 еллардан халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, 1835–60 елларда Удел ведомствосы карамагында; игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү-приход мәктәбе, 12 сәүдә-сәнәгать йорты эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 784,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Борындык волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Буа, 1935 нең 10 февраленнән — Будённый, 1957 нең 29 ноябреннән — Чынлы, 1959 ның 12 октябреннән Буа р-нында. Халык саны: 1859 да — 255, 1897 дә — 595, 1913 тә — 822, 1920 дә — 821, 1926 да — 911, 1938 дә — 953, 1949 да — 882, 1958 дә — 910, 1970 тә — 990, 1979 да — 924, 1989 да — 512, 2002 дә — 471 кеше.

ЧУ́АШ МАЙНАСЫ́ авылы, Алексеев р-нында, шәһәр тибындагы Алексеев посёлогыннан 47 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Кече Чирмешән елгасы буенда. 2010 елда 516 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөз башында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Югары Кече Чирмешән, Салкын Чишмә исемнәре б-н дә билгеле. 1860 еллар-га кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү-приход мәктәбе (1896 да ачыла), җил тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1210 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Биләр волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Биләр, 1963 нең 1 февраленнән — Чистай, 1964 нең 4 мартыннан Алексеев р-нында. 1782 дә — 69 ир-ат; 1859 да — 364, 1897 дә — 655, 1908 дә — 786, 1920 дә — 821, 1926 да — 599, 1938 дә — 625, 1949 һәм 1958 дә — 612 шәр, 1970 тә — 757, 1979 да — 681, 1989 да — 538, 2002 дә — 535 кеше.

ЧУ́АШ МӘНҖЕСЕ́ авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 6 *км* төньяк-көнбатыштарак урнашкан. 2010 елда 412 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, дуңгыз асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Менча, Верхняя Менча, Степная Менча исемнәре б-н телгә алына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Изге Гурий борадәрлеге мәктәбе (1898 дә ачыла), 2 ярма яргыч, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1825 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Егоркино волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Октябрь (1997 нең 10 декабреннән — Нурлат) р-нында. Халык саны:1782 дә — 42 ир-ат; 1859 да — 306, 1897 дә — 568, 1908 дә — 578, 1920 дә — 731, 1926 да — 725, 1938 дә — 446, 1949 да — 477, 1958 дә — 413, 1970 тә — 617, 1979 да — 575, 1989 да — 434, 2002 дә — 421 кеше.

ЧУ́АШ РЕСПУ́БЛИКАСЫ, Көнчыгыш Европа тигезлегенең үзәгендә, Идел елгасының уң ярында, Сура һәм Зөя елгалары арасында урнашкан. 1920 елның 24 июненнән — Чуаш автономияле өлкәсе, 1925 нең 21 апреленнән — Чуаш АССР, 1991 нең 24 маеннан — Чуаш ССР, 1992 нең 13 февраленнән хәзерге исемен йөртә. Мәйданы — 18,3 мең *км*^{2}. Башкаласы — Чабаксар шәһәре. Халкы — 1231117 кеше (2018). Татарлар саны: 1926 да — 22317, 1939 да — 29007, 1959 да — 31357, 1970 тә — 36217, 1979 да — 37573, 1989 да — 35689, 2002 дә — 36379, 2010 да — 34214 кеше. Ч.Р. терр-ясе *Идел буе Болгар дәүләте*, *Казан ханлыгы* составына керә. 16 йөзнең 2 нче яртысында Сура буена (Ч.Р.ның көнбатышында һәм көньяк-көнбатышында) чик буе ныгытмаларын саклау өчен йомышлы татар-мишәрләр күчерелә; 17 йөздә Гөбенә һәм Бола елгалары бассейннары (Ч.Р.ның көньяк-көнчыгышында) үзләштерелә.18 йөздә төбәкнең төньяк-көнчыгышында Казан татарлары авыллары (хәзер

Козловка р-нының Әлмән, Кармыш а.) барлыкка килә. 1708–1920 елларда Ч.Р. терр-ясенең шактый зур өлеше *Казан губернасына* керә. Татарлар, башлыча, игенчелек, терлекчелек, сәүдә һ.б. кәсепләр б-н көн күрә; алар 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында лашман хезмәтенә җәлеп ителә. 1920–30 елларда татарлар тупланып яшәгән урыннарда 28 мәчет (Кыр Бикшиге, Татар Согыты, Шыгырдан, Кармыш авылларында — 3 әр, Озын Куак, Сориле (Ишмурзино-Суринск), Кызыл Чишмә, Урмай авылларында — 2 шәр), 22 мәдрәсә һәм мәктәп була. Совет чорында татар мәктәпләре һәм сыйныфлары оештырыла. 1929–39 да Чуаш АССРда 22 татар авылын берләштергән Шыгырдан татар милли р-ны була. 1932 дән районда татар телендә «Коммунизм байрагы» г-тасы (1939 дан — Чкалов, 1957 дән Батыр р-ннары матбугат органы) нәшер ителә, 1953 тән «Авангард» исеме б-н чыга. Татарлар, тупланып, Чабаксар (4777 кеше), Канаш (3956), Яңа Чабаксар (1600) шәһәрләрендә; Батыр (10512), Комсомол (7370), Шомырша (1601), Козловка (605), Ибреси (656), Ялчик (332) р-ннарында яшиләр. Ч.Р.нда 16 татар, 12 катнаш (башлыча, чуаш-татар) торак пункт бар; иң зурлары — Батыр р-нының Шыгырдан (5418 кеше) һәм Татар Согыты (1290), Комсомол р-ның Урмай (2889) һәм Тукай (1745) авыллары (2010). Ч.Р. татарларының Милли-мәдәни автономиясе (2007 дән, җитәкчесе Ф.А.Гыйбатдинов), 4 җирле милли-мәдәни автономиясе (Канаш һәм Яңа Чабаксарда, Батыр һәм Комсомол р-ннарында), Бөтен-татар иҗтимагый үзәге (2000 нән) эшли. Респ-када фәннәрне татар телендә укытучы 7 урта, 5 тулы булмаган урта, 2 башлангыч мәктәп бар, икесендә татар теле фән буларак өйрәнелә (2009). Ел саен татар теле һәм әдәбияты буенча респ-ка олимпиадасы, «Шыгырдан укулары» укытучылар фәнни-гамәли конференциясе, Татар китабы көннәре үткәрелә. Күп кенә мәктәп һәм китапханәләрдә татар традицион мәдәниятенә багышланган экспозицияләре булган музейлар, татар гамәли-бизәлеш сәнгатен өйрәнү түгәрәкләре, милли ризыклар һ.б. оештырыла. «Мишәр» халык фольклор-эстрада коллективы һәм «Урмай егетләре» ансамбле (Комсомол р-ның Урмай а.), халык театры (Батыр р-ның Кыр Бикшиге а.), халык төбәкара эстрада студиясе (Комсомол а.), Чабаксарда П.Хузангай исем. мәдәният йорты каршындагы эстрада студиясе; «Чишмә» фольклор-эстрада ансамбле (Батыр р-ның Кызыл Чишмә а.), Козловка р-ның Кармыш авылы фольклор төркеме, мөселман җыры, мөнәҗәтләр һәм бәетләр ансамбле (Батыр р-ның Татар Согыты а.), «Ләйсән» балалар фольклор төркеме (Козловка р-ның Кармыш а.) эшли. «Урмай моңы» татар эстрада җыры (Урмай а.; 1988 дән), мөселман җыры (2008 дән), «Рамазан» татар җыры (Шыгырдан а.), «Яңгырасын татар моңнары» балалар иҗат фестивальләре үткәрелә; татарлар тупланып яшәүче районнарда һәм аерым авылларда респ-ка күләмендә *Сабан туе* бәйрәм ителә, Татар мәдәнияте көннәре, татар язучылары һ.б. мәдәният эшлеклеләре б-н очрашулар, Казан һәм ТРның башка шәһәрләреннән артистлар, иҗат төркемнәре гастрольләре оештырыла. Комсомол авылында респ-ка атналык «Вакыт» г-тасы нәшер ителә. Ч.Р.ның көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш районнарында «Татарстан-Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе тапшыруларын карыйлар. Ч.Р. мөселманнарының Диния нәзарәте (1994 тән, мөфти А.Крганов), 40 мәчет, 47 мөселман оешмасы, 50 дән артык приход эшли, «Гөлестан» мәдрәсәсендә һәм якшәмбе мәктәбендә ислам нигезләре өйрәнелә. «Гөлестан» («Вакыт» г-тасына кушымта), «Имам», «Ихлас», «Мәдрәсә» г-талары нәшер ителә. Ел саен 8–15 яшьлек мөселман балалары өчен җәйге лагерьлар оештырыла. *Корбан бәйрәме*, *Ураза бәйрәме*, *Мәүлид кичәсе* бәйрәм



Чабаксар шәһәрендәге «Болгар» мәчете.

ителә. Күп кенә татар торак пунктларында приход җәмәгать советлары эшли, алар ислам һәм этномәдәни традицияләрне җанландыру б-н шөгыльләнә, күп балалы һәм тулы булмаган гаиләләргә ярдәм күрсәтә. Ч.Р. б-н ТР арасында күптәнге тарихи һәм мәдәни багланышлар урнашкан. Мишәрләр һәм түбәнге чуашлар (анатри), Казан татарлары һәм урта-түбәнге чуашлар арасындагы тыгыз элемтәләр булу нәтиҗәсендә, телдә, матди һәм рухи культурада охшаш элементлар барлыкка килә.Чуаш интеллигенциясе кадрларын әзерләүдә Казан ун-ты күренекле роль уйный. Анда педагог һәм мәгърифәтче И.Я.*Яковлев*, Ч.Р.ның беренче Президенты Н.В.Фёдоров, тарихчылар И.В.Денисов һәм Н.В.*Никольский*, чуаш әлифбасын төзүчеләрдән берсе В.А.Белилин, механика өлкәсендәге галимнәр С.Ф.*Сайкин* һәм А.Г.Терентьев, физик С.А.*Абруков*, филолог Ю.М.Артемьев, хокук белгече В.А.Малюткин һ.б. белем ала. Казанда чуаш телендә «*Хыпар*» (1906–07), «*Канаш*» (1918–21), «*Ленин ялаве*» (1921–22 һәм 1936–63), «*Сене ял*» (1925–26), «*Сувар*» (1993 тән) г-талары; «*Ана*» (1918–20), «*Сер еслекен*» (1919–20), «*Шурампус*» (1919–21; ш.у. 1990 еллардан) ж-ллары нәшер ителә. ТР терр-ясендә чуаш-лар: Сов. Союзы Геройлары К.К.*Афанасьев*, Г.П.*Евсеев*, С.В.*Коновалов*, Г.Ф.*Ларионов*, В.И.*Маринин*, Н.К.*Синдряков*, С.А.*Уганин*, П.С.*Юхвитов*, Е.Г.*Яковлев*; Соц. Хезмәт Геройлары П.В.*Дементьев* (ике тапкыр), Л.В.*Дергунов*, А.Е.*Ефремов*, А.Ф.*Мокшин*, А.И.*Николаева*, Ю.И.Петрова, геодезист А.А.Изотов, дәүләт эшлеклесе С.М.Ислюков, сәнгать белгече А.А.Трофимов, Олимпия чемпионы Н.А.*Колесников*, чуаш драма театрына нигез салучы И.С.*Максимов-Кошкинский*, язучы П.Т.Петров, Дан орденының тулы кавалерлары А.И.*Башкиров*, П.Е.*Михеев*, Г.Д.*Садовников*, шагыйрьләр П.П.*Хузангай*, Н.И.Полоруссов-Шелеби, А.Е.*Алга*, П.В.*Афанасьев*, рәссам Е.И.Ефремов, икътисадчы Н.Т.Саврукова һ.б. туган. 2009 да Ч.Р. б-н ТР арасында сәүдә-икътисади, фәнни-техник һәм социаль-мәдәни хезмәттәшлек турында килешүгә кул куела. Сов. Союзы Геройлары Г.Г.*Гобәйдуллин*, Б.С.*Рәхимов*, М.А.*Салихов*, Дан орденының тулы кавалерлары Я.Г.*Бикчәнтәев*, Б.С.*Төхфәтуллов*, язучылар Ф.З.*Бурнаш*, Д.М.*Гыйсметдинов*, Р.Р.*Зәйдулла*, гамәли бизәлеш сәнгате остасы М.З.*Бикбулатова*, җырчы М.З.*Булатова*, СССР ФА академигы Х.М.*Миначёв*, механика өлкәсе галиме С.М.*Минуллин*, ТР ФА академигы Ж.Ш.*Сөләйманов*, физиолог Р.А.*Абзалов*, фәлсәфәче Ә.З.*Фәизов*, журналист М.М.*Сәфәров* кебек шәхесләрнең тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге Ч.Р. б-н бәйле.

Әд.: Иванов В.П. Этнокультурная карта Чувашии. Чебоксары, 1997; Бойко И.И., Матвеев Г.Б. Татары (Чувашская Республика) // Бюлл. сети этнологического мониторинга и раннего предупреждения конфликтов. 2009. № 152; Чувашская энциклопедия. Чебоксары, 2011. Т. 4.

Г.Б.Матвеев.

ЧУА́Ш САРЫКАМЫШЫ́ авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 30 *км* көньяктарак, Зөя елгасы буенда. 2010 елда 127 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 1910 елларга кадәр Борындык авылы (к. *Иске Борындык*) составында. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Борындык волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Буа, 1935 нең 10 февраленнән — Будённый, 1957 нең 29 ноябреннән — Чынлы, 1959 ның 12 октябреннән Буа р-нында. Халык саны: 1913 тә — 548, 1920 дә — 572, 1926 да — 650, 1938 дә — 569, 1949 да — 544, 1958 дә — 490, 1970 тә — 356, 1979 да — 276, 1989 да — 181, 2002 дә — 146 кеше.

ЧУА́Ш СӘРӘНЕ́ авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 44 *км* көнбатыштарак, Каты Елга елгасы буенда. 2010 елда 385 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөз башында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Кителга, Кителга Чувашская исемнәре б-н дә билгеле. 1920 елларга кадәрге рәсми чыганакларда еш кына Зур Сосновый Баграж (хәзерге Рус Сәрәне) авылы б-н бергә исәпләнә. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, төлке һәм куян аулау, бал-

та эше, йон тетү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү (1886–89 да төзелә), чиркәү-приход мәктәбе (1891 дә ачыла), икмәк саклау-сату һәм бакалея кибетләре эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1726,8 дис. (Зур Сосновый Баграж авылын да кертеп) тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Ерсубай волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1944 нең 19 февраленнән — Ямаш, 1956 ның 7 декабреннән — Акташ, 1959 ның 26 мартыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1782 дә — 77 ир-ат; 1795 тә — 162, 1859 да — 232, 1870 тә — 257, 1884 тә — 286, 1900 дә — 478, 1906 да — 478, 1913 тә — 528, 1920 дә — 544, 1926 да — 362, 1938 дә — 384, 1949 да — 382, 1958 дә — 359, 1970 тә — 436, 1979 да — 412, 1989 да — 413, 2002 дә — 445 кеше.

ЧУ́АШ ТАЙБАСЫ́ авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 27 *км* көньяк-көнбатыштарак, Кылна елгасы буенда. 2010 елда 100 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Таяба-Таушева исеме б-н билгеле. 1720 еллардан халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, 1835–1860 елларда Удел ведомствосы карамагында; игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 сәүдә-сәнәгать йорты эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 428,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Сембер өязе Олы Тархан волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәтеш, 1938 нең 4 августыннан — Олы Тархан, 1959 ның 12 октябреннән Тәтеш р-нында. Халык саны: 1721 дә — 143 ир-ат; 1859 да — 185, 1897 дә — 230, 1913 тә — 397, 1920 дә — 425, 1926 да — 325, 1938 дә — 389, 1949 да — 314, 1958 дә — 321, 1970 тә — 281, 1979 да — 147, 1989 да — 171, 2002 дә — 116 кеше.

ЧУ́АШ ТЕЛЕ́, *чуашлар* теле. *Төрки телләр*нең болгар төркеменә карый. Ч.т.ндә сөйләшүчеләр Чуаш, Татарстан, Башкортстан респ-каларында, Ульянов, Самара, Саратов, Оренбург өлкәләрендә һәм РФ, БДБнең башка төбәкләрендә тыгыз урнашып яшиләр; чуаш халкының гомуми саны — 1435872 кеше (2010), ш.и. ТРда — 116,2 мең кеше (нигездә, Аксубай, Чүпрәле, Нурлат, Буа, Чирмешән, Әлки, Тәтеш һ.б. р-ннарда). 2 диалектны: түбәнге («у»лаштыручы) һәм югары («о»лаштыручы) диалектларны үз эченә ала, аларда шактый сөйләшләр аерып карала. Ч.т.нең хәзерге алфавиты рус алфавиты нигезендә төзелә. Бүгенге формасы 1949 елдан бирле яшәп килә. 37 хәрефне үз эченә ала, ш.и. 4 хәреф диакритик тамгалы (ӑ, ӗ, ҫ, ӳ). Ч.т. агглютинатив типтагы телләргә карый. Ч.т.ндә сүз басымы озын һәм көч б-н ясала. Морфологик үзенчәлеген гомумтөркиләр -лар күплек сан кушымчасы урынына -сем кушымчасы билгели. Сүз ясалышының төп ысуллары — сүзләр кушылу һәм кушымчалау. Ч.т. тарихының төрле чорларында төрле язу төрләре — рун язуы (4–7 йөзләр), гарәп графикасына нигезләнгән язу (8–16 йөзләр), латин язуы (18 йөз), кириллица (18–19 йөзләр) кулланыла. Беренче басма грамматика һәм тәрҗемә китаплар 18 йөздә барлыкка килә. Ч.т.н фәнни яктан өйрәнүгә Н.И.Ашмарин нигез сала (19 йөз ахыры — 20 йөз башы); бу телне өйрәнү һәм үстерүгә ш.у. И.А.Андреев, В.Г.Егоров, Й.Бенцинг һ.б. саллы өлеш кертә. Чуаш әдәби теле 20 йөз башына түбән диалект җирлегендә формалаша. Ч.т. рус теле б-н беррәттән Чуаш Респ-касының дәүләт теле санала. Бу телдә башлангыч мәктәпләрдә укыту алып барыла, дәреслекләр, матур һәм публицистик әдәбият басыла, газета һәм журналлар, ш.и. Казанда «Сувар» г-тасы һәм «Шурампус» («Таң») ж-лы, Буа р-нында «Ялав» («Байрак») г-тасы нәшер ителә, теле- һәм радиотапшырулар гамәлгә ашырыла. Ч.т.ндә радиотапшырулар эфирга Татарстан радиосы аша чыга («Якын кардәшлек — иң зур байлык» — «Доброе братство — лучшее богатство»). 1990 елларда Казан пед. ун-тында һәм Чистай пед. уч-щесендә — чуаш бүлекләре, ТРның чуашлар тыгыз урнашкан районнарында Ч.т. укытыла торган мәктәпләр ачыла. Чуаш гуманитар фәннәр ин-ты һәм Чуаш ун-ты (Чабаксар ш.) Ч.т.н фәнни өйрәнү үзәкләре булып тора.

Әд.: А ш м а р и н Н.И. Материалы для исследования чувашского языка. К., 1989; Современный чувашский литературный язык. Чебоксары, 1990. Т. 1; Ф е д о т о в М.Р. Чувашский язык: Истоки. Отношение к алтайским и финно-угорским языкам. Историческая грамматика. Чебоксары, 1996; Чувашская энциклопедия. Чебоксары, 2011. Т. 4.

ЧУ́АШ ТИМЕРЛЕГЕ́ авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 50 *км* төньяк-көнбатыштарак, Тимерлек елгасы буенда. 2010 елда 492 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, дуңгыз асрау; икмәк з-ды. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1681 дән Исенеева исеме б-н билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында тимерче алачыгы, 3 вак-төяклөр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 873 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Әлмәт волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Октябрь, 1935 нең 10 февраленнән — Тельман, 1958 нең 16 июленнән — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән Нурлат р-нында. Халык саны: 1859 да — 289, 1897 дә — 401, 1908 дә — 462, 1920 дә — 511, 1926 да — 458, 1938 дә — 487, 1949 да — 331, 1958 дә — 495, 1970 тә — 636, 1979 да — 493, 1989 да — 486, 2002 дә — 489 кеше.

ЧУ́АШ ЧАБАКСАРЫ́ авылы, Яңа Чишмә р-нында, Яңа Чишмә авылыннан 21 *км* көнбатыштарак, Чабаксар елгасы буенда. 2010 елда 330 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөз башында нигез салына. Рев-циягә кадәрге рус чыганакларында Новопоселённая Чебоксарка, Чебоксарка исемнәре б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү-приход мәктәбе (1895 тән), 2 җил тегермәне, 3 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1553 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Изгар волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чистай, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Армия, 1958 нең 23 маеннан — Чистай, 1983 нең 26 апреленнән Яңа Чишмә р-нында. Халык саны: 1782 дә — 44 ир-ат; 1859 да — 398, 1897 дә — 561, 1908 дә — 665, 1920 дә — 726, 1926 да — 742, 1938 дә — 594, 1949 да — 442, 1958 дә — 600, 1970 тә — 567, 1979 да — 471, 1989 да — 430, 2002 дә — 414 кеше.

ЧУ́АШ ЧАГЫЛДЫМЫ́ авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 43 *км* көньяк-көнбатыштарак, Зөя елгасыннан 1 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 71 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1698 дән мәгълүм, 1920 елларга кадәр Чагылдым (Татар Чагылдымы авылын да кертеп) буларак билгеле. 1720 елардан халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, 1835–60 ларда Удел ведомствосы карамагында; игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мөселман гыйбадәтханәсе, чиркәү-приход мәктәбе, сәүдә-сәнәгать йорты эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 453,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Борындык волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Буа, 1938 нең 4 августыннан — Олы Тархан, 1959 ның 12 октябреннән Тәтеш р-нында. Халык саны: 1859 да — 154, 1897 дә — 327, 1913 тә — 366, 1920 дә — 437, 1938 дә — 332, 1949 да — 442, 1958 дә — 404, 1970 тә — 241, 1979 да — 176, 1989 да — 102, 2002 дә — 90 кеше.

ЧУ́АШ ЧУРАПАНЫ́ авылы, Тәтеш р-нында, Тәтеш шәһәреннән 32 *км* көньяк-көнбатыштарак, Зөя елгасыннан 3 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 188 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 17–18 йөзләр арасында нигез салына. 1720 еллардан халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, 1835–60 елларда Удел ведомствосы карамагында; игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Халык мәгарифе министрлыгы мәктәбе, 11 сәүдә-сәнәгать йорты эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 891,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Борындык волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәтеш, 1938 нең 4 августыннан — Олы Тархан, 1959 ның 12 октябреннән Тәтеш р-нында. Халык саны: 1859 да — 442 (Татар Чурапаны авылын да кертеп), 1897 дә — 637, 1913 тә — 830, 1920 дә — 834, 1926 да — 957 (Татар Чурапаны авылын да кертеп), 1938 дә — 834, 1949 да — 983, 1958 дә — 598, 1970 тә — 471, 1979 да — 329, 1989 да — 249, 2002 дә — 226 кеше.

ЧУА́Ш ЧҮПРӘЛЕСЕ́ авылы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 4 *км* көнь - як-көнбатыштарак, Кече Чынлы елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 1068 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Чиркәү. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1835 кә кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, 1835–60 елларда Удел ведомствосы карамагында; игенчелек, терлек - челек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ч.Ч.ндә Халык мәгарифе министрлыгы мәктәбе, 17 сәүдә-сәнәгать йорты эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1494,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Уби волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1859 да — 495, 1897 дә — 893, 1913 тә — 1243, 1920 дә — 1266, 1926 да — 1371, 1938 дә — 1691, 1949 да — 1464, 1958 дә — 1351, 1970 тә — 1761, 1979 да — 1774, 1989 да — 1173, 2002 дә — 1143 кеше.

ЧУА́Ш ШӘЙМОРЗАСЫ́ авылы, Чүпрәле р-нында, Иске Чүпрәле авылыннан 32 *км* көнчыгыштарак, Чынлы елгасы буенда. 2010 елда 259 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. 17 йөз уртасында нигез салына. 1920 гә кадәр *Иске Шәйморза* авылы составында. 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Буа, 1935 нең 10 февраленнән — Будённый, 1957 нең 29 ноябреннән — Чынлы, 1959 ның 12 октябреннән — Чүпрәле, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1966 ның 30 декабреннән Чүпрәле р-нында. Халык саны: 1926 да — 543, 1938 дә — 723, 1949 да — 637, 1958 дә — 673, 1970 тә — 578, 1979 да — 384, 1989 да — 258, 2002 дә — 277 кеше.

ЧУА́Ш ШӘПКӘСЕ́ авылы, Әлки р-нында, Базарлы Матак авылыннан 14 *км* көньяк-көнбатыштарак, Шәпкә елгасы буенда. 2010 елда 119 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, чуашлар — 59%, руслар — 33%) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөз башында нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү-приход мәктәбе (1884 тә ачыла), 2 вак-тәякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1464,3 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Спас өязе Кузнечиха волостенда, 1920 дән ТАССР - ның Спас кантонында. 1930 ның 10 август - тыннан — Әлки, 1963 нең 1 февраленнән — Куйбышев, 1965 нең 12 гыйнварыннан Әлки р-нында. Халык саны: 1782 дә — 122 ир-ат; 1859 да — 553, 1897 дә — 927, 1908 дә — 1133, 1920 дә — 1084, 1926 да — 679, 1938 дә — 484, 1949 да — 403, 1958 дә — 269, 1970 тә — 253, 1979 да — 178, 1989 да — 166, 2002 дә — 132 кеше.

ЧУА́Ш ЯЛТАНЫ́ авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 36 *км* көньяктарак, Кече Чирмешән елгасы буенда. 2010 елда 371 ке - ше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 92%) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 18 йөз башында нигез салына. Рев-цияга кадәрге чыганакларда Нарат Елга, Ялтан исемнәре б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында земство мәктәбе, 2 тегермән, тимерче алачыгы, ярма яргыч, йон тетү йорты, 3 вак-тәякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1514 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Яңа Әдәмсу волостенда. 1930 ның 10 августыннан — Чистай, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Армия, 1958 нең 23 маеннан Чистай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 94 ир-ат; 1859 да — 464, 1897 дә — 716, 1908 дә — 747, 1920 дә — 974, 1926 да — 662, 1938 дә — 738, 1949 да — 539, 1958 дә — 583, 1970 тә — 755, 1979 да — 624, 1989 да — 456, 2002 дә — 445 кеше.

ЧУА́Ш ЯНТУГАНЫ́ посёлогы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 35 *км* көнбатыштарак, Карлы елгасы бассейнында урнашкан. 2010 елда 11 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1920 елларга кадәр *Ян - туган* авылы составында, Сембер губернасының Буа өязе Янтуган волостена керә. 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Буа, 1935 нең 10 февраленнән — Будённый, 1957 нең 29 ноябреннән — Чынлы, 1959 ның 12 октябреннән Буа р-нында. Халык саны: 1926 да — 166, 1938 дә — 231, 1949 да — 159, 1958 дә — 99, 1970 тә — 105, 1979 да — 63, 1989 да — 30, 2002 дә — 28 кеше.

ЧУАШЛА́Р (үзатамалары чаваш), төрки тел - ле халык, *Чуаш Республикасының* төп халкы. РФдә Ч.ның гомуми саны — 1435872 кеше (2010), шулардан 814750 кеше Чуаш Респ-касында гомер кичерә. Самара (84105), Ульянов (94970) өлкәләрендә, Мәскәүдә (14300), Башкортстан Респ-касында (107450) тупланып яшиләр. ТРда чуаш халкы — 116,2 мең кеше, башлыча Аксубай, Буа, Чүпрәле, Нурлат, Тәтеш, Чирмешән р-ннарында, Казан, Чаллы, Түбән Кама шәһәрләрендә го - мер кичерәләр. Туган телләре — *чуаш теле*. Башлыча православие динен тоталар (18 йөздән). 3 субэтноска бүленәләр: Тау ягы Ч.ы (вирьял, тури) — Чуаш Респ-касының төнья - гында һәм төньяк-көнбатышында, Болын ягы Ч.ы (анат енчи) — респ-каның үзәк һәм төньяк-көнчыгыш өлешендә, түбән як Ч.ы (анатри) респ-каның көньягында һәм аннан тыш өлкәләрдә яшиләр. Үрге Ч.ның бабалары — 7–8 йөзләрдә Төньяк Кавказ һәм Азов алды далаларыннан килеп, җирле фин-угор һәм







Чуашлар. 1. Чуаш хатын-кызы; 2. Чуаш хатын-кызы җәйге киемнән. Икесе дә — И.-Г.Георгиның «Россия дәүләтендә яшәүче барлык халыкларны, шулай ук аларның гореф-гадәтләрен, йолаларын, торакларын, диннәрен һәм башка үзенчәлекләрен тасвирлау» китабыннан (1 кис.; С.-Петербург, 1776) буялган гравюра; 3. Чуаш кызлары йорт каршында. К.Рехбергның «Россия халыклары, яки Россия империясендәге төрле милләт вәкилләренең гореф-гадәтләрен, йолаларын, өс киемнәрен тасвирлау» китабыннан (1 т., Париж, 1812) буялган гравюра; 4. Тау ягы чуашлары милли киемнән (сулда – бәйрәм киемендәге кәләш). Г.Ф.Локке фоторәсеме. 1869; 5. «Сеспель» чуаш фольклор ансамбле. Лениногорск ш. 1997.

төрки кабиләләрне ассимиляцияләгән төрки-болгар кабиләләре. Фаразларның берсе буенча, «Ч.» этнонимының тамырлары болгарларга кардәш кабиләләрнең берсе — суарлар атамасына барып тоташа (суваз, суас). *Идел буе Болгар дәүләтендә, Алтын Урдада* һәм *Казан ханлыгында* Ч.ның бергә туплану процессы бара. Рус чыганакларында «чаваш» үзатамасы беренче тапкыр 1508 елда очрый. Казан ханлыгының Рус дәүләте тарафыннан яулануы барышында Ч. Россия составына керәләр (1551). Чуаш халкы ясаклылар, 18 йөздән дәүләт һәм удел крәстияннәре катлауларында теркәлә. 18 йөз уртасына Ч.ның төп өлеше христианлык кабул итә. 1708–1920 дә Ч.ның күпчелеге Казан губернасында (башлыча Чабаксар, Цивильск һәм Ядрин өязләрендә) яши. 19 йөз ахырында Казан губернасында Ч.ның саны 500 мең кешедән арта. 1906–07 дә Казанда чуаш телендә «Хыпар» г-тасы нәшер ителә (берен-че мөхәррире — Н.В.Никольский). Окт. рев-циясеннән соң Ч.га автономия бирелә (1920 дән автономияле өлкә, 1925 тән АССР, 1990 нан ССР, 1992 дән Чуаш Респ-касы). 1920 елларда РКП(б)ның Татарстан өлкә ком-ты агитация-пропаганда бүлеге составында чуаш секциясе эшли, ул Ч.ның мәдәни-агарту мәсь әләләре б-н шөгыльләнә. 1921–22 дә, 1936–63 тә чуаш телендә «Ленин ялаве» («Ленин байрагы») г-тасы нәшер ителә.

Ч.ның төп традицион шөгыле — игенчелек: күбесенчә бөртекле культуралар — арыш, солы, арпа, борай, сиргәк борчак, карабодай, бодай чәчәләр. Азык хәзерләү биләмәләре аз булу сәбәпле, терлекчелек үсеше алга китми. Ч. ху җалыгында бакчачылык, умартачылык, колмак үстерү һәм йорт кәсепләре (чигү, чүлмәкчелек, үрү-бәйләү, тукучылык һ.б.) зур роль уйный. Зур чуаш авылларында кустар-кәсепчелек җитештерүе (мичкә, көпчәк ясау, агач эше), бау-аркан ишү, чыпта сугу һ.б. үсеш кичерә. 19 йөзнең 2 нче яртысыннан Ч. арасында читкә китеп эшләү (урман кисеп агач әзерләү һәм башка төбәкләрдә а.х. эшләре) тарала башлый.

Торулыкларның төп төрләре — авыллар һәм салалар — кагыйдә буларак, елга һәм күл буйларында урнашалар. 19 йөзнең 2 нче яртысыннан Ч.да торулыкларны урамнар тәртибендә планлаштыру таралыш ала. Ишеге көнчыгыш тарафта булган һәм тәрәзәләре көньякка караган традицион агач өй ишегалды уртасында корыла, кара ягулы балчык мич б-н җылытыла. 19 йөзнең 2 нче яртысыннан өч өлешле планлаштырулы (өй, өйалды, келәт) уртача-рус тибындагы тораклар төзелә башлый. 20 йөз башланганда кара мич-не мор җалы һәм сәндерәле рус миче алыштыра, шул ук вакытта өстенә асылган яки кертеп сыланган казанлы традицион учак саклана. Ике, дүрт кыеклы түбә салам, чыра яки такта б-н ябыла. Йорт полихром һәм кисеп ясалган бизәкләр, ябыштырылган элементлар б-н бизәлә. Чуаш өенең интерьеры өстәлдән һәм алгы почмактагы киң сәкеләрдән, бүлем дивары урынына чаршаулар элүдән гыйбарәт була.

Ч.ның традицион киемнәре милли үзенчәлекләре б-н аерылып тора. Хатын-кызлар киеменең нигезен туника рәвешендәге күлмәк (кепе) тәшкил итә, тау ягы Ч.ы һәм Болын ягы Ч.ы — өйдә тукылган юка ак тукымадан тегелгән кепеләр, түбән як Ч.ы 19 йөз уртасына — 20 йөз башына кадәр аска таба киңәеп киткән ак, соңрак чуар тукымадан бөрмәләп тегелгән күлмәкләр киеп йөргәннәр. Аларны чигелгән, аппликацияләп бизәлгән алъяпкыч һәм күкрәкчә б-н кигәннәр (түбән як Ч.ыннан тыш). Ирләр киеме — ак киндер күлмәк һәм ыштан (йем). Тышкы кием — киндер кафтан (шубёр), көзен — постаудан тегелгән кәзәкн (сахман), кышын — сарык тиресненнән билле итеп тегелгән тун (керек). Ирләр — җәйге баш киемнәре — кара яки ак киез эшләпәләр (ялкас), кышын — киң кырпулы һәм өсте гөмбәз сыман озынча бүрекләр (челек); хатын-кызлар җитен һәм киндер яулыклар, читләренә тасмалар тегелгән япмалар ябынганнар. Хатын-кызларның бәйрәмчә баш киемнәре — шлем сыман башлык (пухья), киселгән конус рәвешендәге башлык (хушпу). Хатын-кызлар киемен көмеш һәм бакыр акчалардан, сәйләп, комач, тасмадан гыйбарәт бизәнү әйберләре (күкрәкчәләр, бәйләвечләр, йөзекләр һ.б.) тулыландырган. Ч.ның традицион аяк киемнәре — ыштырлы яки оеклы курыс чабаталар (чапата), күн итекләр.

Ч.ның аш-суында үсемлек продуктларыннан әзерләнгән ризыклар өстенлек итә. Ит чагыштырмача сирәк, сезонлы (терлек чалганда) һәм бәйрәм ризыгы була. Туклану нигезен арыш икмәге (хура сакар) тәшкил итә. Ч. төрле ашлар (чумарлы, ярмалы), борщ, щи һ.б.; боткалар (карабодай, борай, бодай, ясмык), талкан, бәрәңге, солы һәм борчак онынан кесәл (нимер), бөккән (кәбестә, җиләкләр б-н), көлчә, дучмак пешерәләр. Төп эчемлекләр — ачыган сөт (турах), әйрән (уйран), ачы бал (сим пыл), сыра (сара), киндер орлыклары төнәтмәсе. Бәйрәм табынына кабарынкы бодай икмәге (хапарту), итле эчлекле бәлеш (хуплу), шарчыклар (йава) һ.б.ны пешерәләр.

1920 елларга кадәр Ч.ның традицион социаль җәмгыяте — авыл җәмәгате. Чуаш гаиләсе башлыча ике буынлы моногамик гаилә була. Никахлар, кагыйдә буларак, ике як киленшенгәнчә, димләү-яучылау юлы б-н коры-ла. Гаилә башлыгы ир булып, хатын хуҗалык эшчәнлегенең кайбер керемнәреннән мөстәкыйль файдалана ала. Улның иртә өйләнүе һәм кызның чагыштырмача со ңарып кия үгә чыгуы хуплана. Безнең көннәргәчә минорат традициясе саклана: варис буларак, төпчек ул ата-анасы янында кала.

18 йөз уртасына кадәр Ч. борынгы Иран кабиләләрендәге зороастризм, хәзәрләрдәге иудаизм, Идел буе Болгар дәүләте һәм Алтын Урда чорларындагы ислам элементлары катнашкан халык (мәҗүсилек) динен тоталар. Чуаш мәҗүсилегенең үзенчәлеге мәрхәмәт-ле, ш.у. явыз рухларны шәфкатьләндерү мак-сатында урманнарда, мәҗүсиләрнең махсус гыйбадәтханәләрендә — кирәмәтләрдә корбан чалудан гыйбарәт.

Элек Ч.ның йолалары һәм бәйрәмнәре аларның мәҗүси карашлары б-н тыгыз бәйләнгән була һәм катгый рәвештә ху җалык-игенчелек календаре б-н яраша: кояшны олылау бәйрәме (Май чабу), кояшка, Тура аллага һәм бабаларга корбан чалулы күпкөнлек язгы бәйрәм (Манкун), язгы җир сөрү бәйрәме (Акатуй) һ.б. Ашлыкларны җыеп алгач, яңа уңыш хөрмәтенә аллаларга һәм рухларга ялварулар һәм рәхмәт белдерүләр йоласы башкарыла. Ел дәвамында, бигрәк тә язгы-кышкы айларда, яшьләр арасында күңел ачулар, тамаша кылулар (аулак өйләр, әйләп-бәйләннәр һ.б.) оештырыла. 19 йөз ахырында — 20 йөз башында Ч.ның көнкүрешендә христиан йолалары һәм бәйрәмнәре өстенлек итә башлый.

Безнең көннәрдә Татарстанда Ч. сан ягыннан өченче этник төркемне хасил итәләр, респ-каның мәдәни, иҗтимагый һәм икътисади тормышында сизелерлек роль уйныйлар. 1990 еллардан Казанда «*Сувар*» г-тасы һәм «*Шурампус*» («Таң») ж-лы, ТРның кайбер районнарында чуаш телендә газеталар нәшер ителә. 1997 дә Казанда Ч.ның милли-мәдәни автономиясе оештырыла, аның төп максаты — ТРдагы чуаш халкының мәдәни традицияләрен саклау. ТР Мәдәният министрлыгы булышлыгында даими рәвештә *Уяв* бәйрәме һәм «Чаваш шапчаке» («Чуаш сандугачы») фестивале уздырыла.

Әд.: Димитриев В.Д. История Чувашии периода феодализма. Чебоксары, 1986; Шупук. Мирное присоединение Чувашии к Российскому государству. Чебоксары, 2001; Иванов В.П., Фокин П.П. Семья чувашей. Чебоксары, 1991; Иванов В.П., Николаев В.В., Димитриев В.Д. Чуваши: этническая история и традиционная культура. М., 2000; Чуваши Татарстана. Чебоксары, 2006; Чувашская энциклопедия. Чебоксары, 2011. Т. 4.

Р.Р.Батыршин.

ЧУБА́Р авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 10 *км* төньяктарак, Казансу елгасы буенда. 2010 елда 143 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — дуңгыз асрау. 1602–03 еллардан Кече Бимәр исеме б-н билгеле. Халкы 1861 елгы реформага кадәр алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында земство мәктәбе (1903 тә ачыла), 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 323 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Собакино волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1935 нең 10 февраленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 44 ир-ат; 1859 да — 356, 1897 дә — 301, 1908 дә — 388, 1920 дә — 380, 1926 да — 442, 1938 дә — 453, 1949 да — 369, 1958 дә — 279, 1970 тә — 188, 1989 да — 100, 2002 дә — 101 кеше.

ЧУБА́Р АБДУ́Л авылы, Азнакай р-нында, Азнакай шәһәреннән 40 *км* төньяк-көнбатыштарак, Мәллә елгасы буенда. 2010 елда 393 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау.

Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 18–19 йөзләрдә халкы типтәрләр кат-лавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп, су тегермәне, ашлык саклау-сату һәм 3 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2210,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Александр-Кармалы волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Сарман, 1935 нең 10 февраленнән — Тымытык, 1958 нең 16 июненнән — Азнакай, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1965 нең 12 гыйнварыннан Азнакай р-нында. Халык саны: 1859 да — 512, 1897 дә — 962, 1906 да — 1059, 1920 дә — 1202, 1926 да — 791, 1938 дә — 816, 1949 да — 665, 1958 дә — 745, 1970 тә — 745, 1979 да — 507, 1989 да — 448, 2002 дә — 444 кеше.

ЧУВЕ́РОВ Александр Дмитриевич (6.12.1930, Башкортстан АССРның Яңавыл р-ны Петровка а. — 11.6.1981, Мәскәү; Казанда җирләнә), химик-технолог, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1974). Казан муз. уч-ще-сен (1951), Казан химия-технол. ин-тын (1957) тәмамлый. Хезмәт эшчәнлеген 1952 елда Татар опера һәм балет театрында артист булып башлый. 1957–59 да Дзержинск шәһәренең химия пр-тиеләрендә (хәзер Түбән Новгород өлкәсе). 1959 дан Казан химия продуктлары фәнни-тикшеренү ин-тында: инженер, өлкән инженер, лаб. һәм бүлек башлыгы. 1978–81 дә СССР Машина төзелеше министрлыгының 3 нче Баш идарәсендә башлык урынбасары. Дәүләт бүләге махсус эш-ләнмәләрне булдыруда катнашканы өчен бирелә. Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Г.Я.Мәүлетова.

ЧУГУНО́В Александр Николаевич (31.10.1949, Казан), хирург, мед. фән. д-ры (1999), ТРның атказ. фән эшлеклесе (2010). Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1973), факультет хирургиясе кафедрасында эшли (бүленеп: 1975 елда РКБның 2 нче хирургия бүлеге табибе). 1982–87 дә 2 нче хирургия авырулары кафедрасында, 1987–95 тә Казан мед. ин-тының травматология, ортопедия һәм хәрби-кыр хирургиясе каф. доценты. 1995 тән Казан мед. академиясенең эндоскопик һәм гомуми хирургия каф. мөдире. Хезмәтләре үт куыгындагы таш б-н бәйле авыруларга диагноз кую, авыруны дәвалау һәм киселүгә карый. Ч. әлеге авыруны хирургик юл б-н дәвалаганда Идел буе төбәгендә беренче-ләрдән булып лапароскопик операция ысулын куллана башлый. Беренче операциясен 1991 дә ясый. Уйлап табу авторы (голографик микроскоп). ТРның Дәүләт бүләге лауреаты (2004).

Х е з м.: Профилактика, диагностика и лечение повреждений внепечёночных желчных путей при лапароскопической холецистэктомии: методические рекомендации для врачей. К., 1994 (автордаш); Заболевания, симулирующие острую хирургическую патологию. К., 2003 (автордаш).

ЧУГУНО́В Андрей Кириллович (10.10. 1827, Томск губ. — 15.12.1898, Казан), химик-технолог, проф. (1862), Казан ун-тының атказ. профессоры (1882). Казан ун-тын тәмамлый (1853), шунда ук эшли (1886 елга кадәр), 1861–62 дә чит илдә командировкада була (тау һәм металлургия эшләрен өйрәнә, Лондонда Бөтендөнья күргәзмәсендә була). Ч. пыяла өрү сәнәгатен һәм аның Россиядәге торышын өйрәнә. Казанда химия з-дларын тоткан бертуган Крестовниковлар б-н хезмәттәшлек итә, фәнни тикшеренүләр буенча техник комиссия эшендә катнаша. «Записки Императорского Казанского экономического общества» ж-лы мөхәррире (1857–1860), «Казанский биржевой листок» г-тасының нашире һәм мөхәррире (1868–78).

Х е з м.: Исторический обзор мер правительства к развитию земледелия в России. К., 1858; Кто виноват? Положение кожевенного производства в России. СПб., 1863; Серная кислота и сода: Необходимость в развитии химических заводов и в особенности необходимость и выгодность содового производства в России. К., 1865.

ЧУГУНО́В Виктор Дмитриевич (31.1. 1922, Пенза губ., Рузаевка өязе Лыковщина а., 1922 — 28.11. 2007, Казан), механика өлкәсе галиме, математик, техник фән. д-ры (1969), проф. (1972). Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1950), шунда ук эшли. 1953–79 елларда СССР ФА Казан ф-лының Физика-техника ин-тында, гамәли матем. бүлеге мөдире (1963 тән); 1972–92 дә Казан финанс-икътисад ин-тының югары матем. каф. мөдире. Хезмәтләре аэрогидродинамиканың кире мәсь әләләренә, җирасты гидромеханикасына, нефть чыганакларын проектлауны һәм эшләүне линияле һәм нәлинияле программалау алымнары б-н оптимизацияләүгә карый. Ромашкино чыганагының конкрет мәйданнары өчен хисаплау эшләрен башкара. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз, «Почёт билгесе» орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Х е з м.: Решение смешанных краевых задач теории фильтрации // Гидродинамика и оптимизация разработки нефтяных месторождений. К., 1977 (автордаш); Определение проницаемости на забоях скважин методом математического программирования // Исследования по подземной гидромеханике. К., 1983. Вып. 5 (автордаш); Идентификация значений гидропроводности, приведённых радиусов и коэффициентов взаимовлияния скважин нефтяной залежи по замерам дебитов, забойных и пластовых давлений // Исследования по подземной гидромеханике. К., 1986. Вып. 8 (автордаш).

ЧУГУНО́В Владимир Аркадьевич (30.3.1947, Казан), математик һәм механик, физика-мат. фән. д-ры (1993), проф. (1994), ТРның атказ. фән эшлеклесе (1998), РФнең атказ. югары мәктәп хезмәткәре (2010). Казан ун-тын тәмамлый (1970), шунда ук эшли, гамәли матем. каф. профессоры (1994 елдан), хисаплау математикасы һәм кибернетика ф-ты деканы (1994–99), бер үк вакытта, 2001–11 дә, Мәгълүмат технологияләре үзәге директоры, 2011 дән Матем. һәм механика ин-ты директоры. 1976–79 да Оран ун-тында (Алжир) укыта. Хезмәтләре гамәли механикада матем. модельләштерүгә карый. Ч. фаза күчешле катлаулы мохитләрдә (контактлы эрү, туңдыру, бозлыклар агу, күзәнәкле мохитләрдә эремәләр агу) җылылыкның массакүләм күчешенең матем. моделен төзи; гляциомеханика тигезләмәләренең төркем үзлекләрен һәм инвариант чишелешләрен тикшерә. Уйлап табуга 3 авторлык таныклыгы бар.

Х е з м.: Тепломассоперенос при контактном плавлении. К., 1984 (автордаш); Теплофизика горных пород нефтяных месторождений. М., 2003 (автордаш); V Mathematical Modeling of Mass Transport in Complex Media. Sendai, 2008 (автордаш).

ЧУГУНО́В Николай Иванович (31.8.1920, Брянск губ. Песочный Завод пос. — 12.7.1992, Казан), хирург, ТАССР һәм РСФСРның атказ. табибе (1960,1966). Бөек Ватан сугышында катнаша. Казан мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1942), хәрәкәттәге армиягә дивизион табибе буларак чакырыла: Курск дугасы һөҗүмендә (1943), Белгород, Харьков, Полтава, Верхнеднепровск, Кривой Рог, Тирасполь һ.б. шәһәрләрне алуда, Днепр, Көньяк Буг, Днестр һәм Дунай елгаларын кичүдә катнаша. 1946 елдан Казан стомат. ин-тының хирургия авырулары каф. ординаторы, бер үк вакытта 3 нче шәһәр хастаханәсе баш табибе. 1963–86 да Респ-ка хастаханәсе баш табибе. Авыруларны дәвалауның хирургик ысулларын камилләштерүгә, респ-када дәвалау хезмәтенең нигып урнашуына зур өлеш кертә. 1 нче дәрәҗә Ватан сугышы ордены, Кызыл Йолдыз, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары б-н бүләкләнә. Күпләгән шәһәрләр-не һәм дошманның хәрби саклану пунктларын алуда катнашканы өчен, СССР Югары башкомандующие И.В.Сталиннан 9 Рәхмәт хаты ала.

ЧУДНО́ВСКИЙ Владимир Сергеевич (11.1.1930, Самара ш. — 4.2.2015, Ставрополь ш.), психиатр, мед. фән д-ры (1967), проф. (1968). Куйбышев мед. ин-тын тәмамлаганнан соң (1953), психиатрия кафедрасында эшли. 1957 елдан — Казан, 1978 дән — Куйбышев, 1983 тән Ставрополь мед. ин-тларының психиатрия кафедраларында. Хезмәтләре электроэнцефалографиягә карый. Уйлап табуга 4 авторлык таныклыгы, 10 патенты бар.

Х е з м.: Электроэнцефалографические исследования в клинике психических заболеваний. М., 1960; Основные принципы и методы изучения центральной нервной системы при психических заболеваниях. К., 1979 (автордаш); Общая и социальная психология. Ставрополь, 2001.

ЧУ́ЕН КОЮ́, МАШИНА́ ТӨЗҮ́, ТИМЕРЧЕЛЕ́К-КАЗА́Н ЯСА́У ҺӘМ МЕХА́НИКА ЗАВОДЫ́, к. «*Урак һәм чүкеч*».

ЧУЕРТА́Ш, агымсу яки диңгез дулкыннары тәгәрәтеп шомарткан, диаметры 1–10 *см* булган түгәрәк кисәкле тау токымнары. Ч.ның 5 тән 70 *мм* га кадәрге үлчәмдәге бөртекләре төзелеш материаллары сәнәгатендә *вак чуерташка* кертелә. Ч.ның формасы күптөрле, башлыча, матди составына, тау токымнарының структур һәм текстур үзенчәлекләренә һ.б. сәбәпләргә бәйле. Кремнийлы Ч. ком һәм вак чуерташ б-н бергә ком-вак чуерташ чыганаклары (к. *Чуерташлык*), фосфоритлы Ч. һәм *конгломераглар* — фосфорит чыганаклары (к. *Сөендек фосфоритлар чыганагы*) хасил итә.



В.И. Чуйков.

ЧУЕРТАШЛЫ́К (галечник), көпшәк утырма тау токымы, вак чуерташ, ком, кайвакыт балчыксыл материал катнашмасыннан торучы тау токымнарының шомарган кисәкләре тупланмасы. Эре (50–100 *мм*), уртача (25–50 *мм*) һәм вак Ч.ка (10–25 *мм*) бүленә. Татарстан терр-ясендә Идел, Кама, Агыйдел елгалары һәм аларның кушылдыклары үзән-нәренең дүртенчел чор утырмаларында таралган, биредә утраулар, комборын, сайлык, террасалар төзелешендә катнаша һәм ком-вак чуерташ чыганаклары барлыкка китерә. Фаразланган 2 млрд. $м^3$ чамасы ресурслар б-н 700 тирәсе чыганак ачыклана. 20 гә якын чыганак эшкәртелә. Кама елгасы үзәнендә таралган чыганаклар һәм ятмалар аеруча әһәмияткә ия (к. *Танай ком-чуерташ чыганагы*). Елына 4 млн. $м^3$ дан артыграк чыгарыла. Чыганаклар ТРның 10 нан артык пр-тиесе тарафыннан эшкәртелә, зур күләмдә чыгару аеруча «Татфлот» (якынча 2 млн. $м^3$) һәм Чаллы портларына (0,8 млн. $м^3$ дан артык) туры килә. 1990 еллар башында РФнең 15 өлкәсенә һәм 6 респ-касына, 1990 еллар ахырыннан 64 өлкәгә ком-вак чуерташ материалы җибәрелә. Юл төзелешендә һәм бетонга салу өчен кулланыла (к. *Ком-вак чуерташ кушылмасы*).

Әд.: Сементовский Ю.В., Бирюлёв Г.Н. Минеральное сырьё. Сырьё песчано-гравийное: Справ. М., 1998; Геология твёрдых полезных ископаемых Республики Татарстан. К., 1999.

Г.Н.Бирюлёв.

ЧУЙКО́В Василий Иванович (12.2.1900, Тула губ., Венёв өязе Серебряные Пруды а. — 18.2.1982, Мәскәү), Сов. Союзы Маршалы (1955), ике тапкыр Сов Союзы Герое (1944, 1945). М.В.Фрунзе исем. Хәрби академияне (1925), шул ук академиянең Көнчыгыш ф-тын (1927) тәмамлый. 1918 елдан — Кызыл Армиядә. Гражданнар сугышы чорында В.М.Азинның 28 нче дивизиясе составында Мурзиха, Алабуга, Бөгелмә һ.б. торак пунктларны азат итүдә катнаша; Көньяк һәм Көнбатыш фронтларда сугыша. 1921–40 та укчы подразделениеләр һәм частьлар, бригада, корпус б-н җитәкчелек итә; Казан пехота уч-ще-сендә эшли. Көнбатыш Белоруссияне азат итүдә һәм сов.-фин сугышында (1939–40) армия б-н җитәкчелек итә. 1940–42 дә — Кытайда хәрби атташе. 1942 нең маеннан Бөек Ватан сугышы фронтларында: Сталинград, Дон, Көньяк-Көнбатыш, 3 нче Украина һәм 1 нче Белоруссия фронтларында 1 нче резерв (64 нче), 62 нче (1943 нең апреленнән — 8 нче гв.) армияләр командующие. Сугыштан соң Германиядәге Совет гаскәрләре төркемендә баш командующий урынбасары, 1 нче урынбасары (1945–49) һәм баш командующие (1949–53). 1953 тән Киев Хәрби округы гаскәрләре командующие, 1960–64 тә — Коры җир гаскәрләре баш командующие, оборона министры урынбасары, бер үк вакытта СССР Гражданнар оборонасы башлыгы. 1972 дән СССР Оборона министрлыгының Ген. инспекторлар төркеме ген. инспекторы. 1946–82 дә СССР ЮС депутаты. 8 Ленин ордены, Октябрь Революциясе, 4 Кызыл Байрак, өч 1 нче дәрәҗә Суворов, Кызыл Йолдыз орденнары, медальләр, мәртәбәле корал — кылыч һәм ш.у. чит ил дәүләтләре орденнары һәм медальләре б-н бүләкләнә.

Хезм.: Конец третьего рейха. М., 1973; Миссия в Китае. М., 1983; От Сталинграда до Берлина. М., 1985; Сражение века. М., 1985.

Әд.: Великая Отечественная война 1941–1945: Энцикл. М., 1985; Маршалы Советского Союза: Личные дела рассказывают. М., 1996; Великая Отечественная. Командармы: Военный биогр. словарь. М., 2005.

ЧУК, керәшен татарлар, чуашлар һәм удмуртларның календарь бәйрәме. Май ахыры — июньдә уздырылган, яңгыр чакыру йоласы б-н бәйле була. Бәйрәм вакытында авыл кешеләре кырга чыкканнар, бергәләп табын корганнар (нигездә ботка ашаганнар), яхшы уңыш сорап бергәләп гыйбадәт кылганнар. Ч. барлык бәйрәмдә катнашучыларны су б-н коендырып тәмамланган. 20 йөз башына кадәр киң таралышта була.

Әд.: Уразманова Р.К. Праздники // Татары. М., 2001.

ЧУКАШЁВ ЙОРТЫ́, Казанда, архит-ра истәлеге. 1908 елда арх. К.С.Олешкевич проекты буенча инженер К.М.Петров тарафыннан сәүдәгәр С.А.Чукашёв өчен модерн элементлары б-н эклектика стилендә төзелә. Ике катлы кирпеч бинаның аттик б-н төгәлләнгән ризалитлар б-н бизәлгән уң як өлешендә кат-ка менү өчен аерым ишек бар. Уң яктагы ишек беренче катта урнашкан даруханәгә, сул яктагысы икенче катка парад баскычы булган вестибюльгә илтә. Монда урам якка карый торган а́ркалы биек тәрәзәле зал һәм залдан ишегалдына, бакчага карый торган тәрәзәле коридор б-н аерылган торак бүлмәләр урнашкан. Залга урам як фасадта дүрт кырлы гөмбәзле, чыгып торган ризалит б-н аерып алынган зур кабинет тоташа. Урам ягындагы фасадның икенче катындагы ризалит үзәге буенча эркер куелган. Кабинеттан бинаның көнчыгышындагы бакчага караган, а́ркалы портик тотып торган террасага чыгарга була. Бүлмәләр Витебск (Б.Я.Лисовскийның чынаяк кирпеч-майолика з-ды) һәм Мейсен (Саксония мич ф-касы) чынаяк кирпечләре б-н тышланган мичләр ярдәмендә җылытыла. Штукатурланган һәм сылап бизәлгән фасадларда һәм интерьерларда барокко стиле элементлары өстенлек итә. Окт. рев-циясенә кадәр һәм совет чорында беренче катны аптека алып тора. Озак вакытлар икенче катта ТР Архитекторлар берлеге урнаша, хәзер бинаны ТР Туризм буенча Дәүләт ком-ты били.



Чукашёв йорты. Архитекторы К.С.Олешкевич. 1908. Хәзерге күренеше.

Әд.: Казань в памятниках истории и культуры. К., 1982.

Х.Г.Надыйрова.

ЧУ́КИН Габделвәли Йосыф улы (1824 — 1895), Казанның 2 нче гильдия сәүдәгәре. 1845 елда чимал, балавыз һәм бал сату фирмасы ача. Уфа губернасы Минзәлә өязенең Шыгай, Янурыс, Косякау авылларындагы мәчетләрне, Казан губернасы Казан өязенең Югары Курса авылын төзекләндерүгә акча-лар бирә. Арендадан алынган керемнәрне мәчет каршында мәктәп ачуга, ятим мөселман балаларын укытуга һәм тәрбияләүгә сарыф итү шарты б-н Екатерининская (хәзерге Тукай) урамындагы йортын Мәрҗани мәчете милкенә тапшыра.

Р.Р.Хәйретдинов.

ЧУКМАРЛЫ́ авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 15 *км* көнбатыштарак, Игәнә елгасының сул кушылдыгы буенда. 2010 елда 348 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 18 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, олаучылык б-н шөгыльләнә, сәүдәгәр Стахеевлар утарында көнлекле эшкә яллана. 20 йөз башында 2 мәчет, 2 мәдрәсә, тимерче алачыгы, икмәк саклау-сату һәм 3 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2389,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әлмәтмулла волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Сарман р-нында. Халык саны: 1816 да — 29, 1834 тә — 131, 1859 да — 147 ир-ат; 1870 тә — 316, 1897 дә — 859, 1906 да — 517, 1920 дә — 1132, 1926 да — 911, 1938 дә — 905, 1949 да — 640, 1958 дә — 556, 1970 тә — 586, 1979 да — 544, 1989 да — 449, 2002 дә — 400 кеше. Ч.да язучы А.М.*Гыйләҗев* туган.

ЧУКЫНДЫРЫЛГА́Н ТАТАРЛАРНЫ́Ң МӨСЕЛМАНЛЫККА́ КАЙТУ́ ХӘРӘКӘТЕ́ (1865–66). Чукындырылган татарларның 1802–03, 1827, 1850, 1856 еллардагы мөселманлыкка кайту хәрәкәтенең чираттагы этабы. Казан губернасының 120 дән артык авылын, Сембер һәм Түбән Новгород губерналарының кайбер авылларын колачлый. 1865 нең ахырында Казан өязенең чукындырылган татарлары арасында патша тарафыннан аларга ислам динен тотарга рөхсәт ителгән закон чыгарылуы турындагы имеш-мимешләр тарала; 1865 нең декабрендә үтенечнамәләр тапшыру өчен Казанга чукындырылган татарлар вәкилләре килә. Казан губернасы Тәтеш өязендә аларның ышанычлылары — Ә.Әлмәмәтов, А.Сәлимов, Ш.Шәмсетдинов, Я.Юнысов, Лаеш өязендә Ш.Рәхимов була.

Г.Абдюшев Казан губернасының Казан, Зөя, Царёвококшайск, Цивильск һәм Чабаксар өязләре чукындырылган татарлары исемеңнән эш йөртә. П.Фёдоров (Мәхмүт Миргазов) Лаеш, Зөя, Тәтеш, Цивильск өязләренең 600 чукындырылган татарларыннан ышанычлы итеп сайлана. Цивильск өязендә үтенечнамәләр б-н мөрәҗәгать итүне башлап йөрүче В.Григорьев була, ул чукындырылган татарларны яңа туган балаларны чукындырмаска, мәрхүмнәрне христиан йолалары буенча җирләмәскә, никахлашу йоласын чиркәүдә башкармаска һ.б.га үгетли. Мөселман руханилары вәкилләре — Зөя өязеннән мулла Мөхәммәт Җанов һәм Цивильск өязеннән И.Халитов актив эшчәнлек җәелдерә, соңгысы чукындырылган татарларны мөселманлыкка күчәргә өнди, чукындырылган татарлар өйләрендә гыйбадәтләр кыла. Хәрәкәтне оештыручыларның берсе — Г.*Алкин*. Ул Зөя, Тәтеш һәм Цивильск өязләрендәге чукындырылган татарлар арасында пропаганда алып бара. Ташкичү, Әлки (Тәтеш өязе), Норлат, Бузай, Тау Иле (Зөя өязе), Елыш (Мамадыш өязе) авылларының чукындырылган татарлары һ.б. приход руханилары һәм волость башлыкларына үз вәкилләрен җибәрәләр, ачыктан-ачык үзләренең ислам диненә күчүләре турында белдерәләр, мөселман гореф-гадәтләре буенча яшиләр. Хәрәкәтне туктатырга омтылып, хакимиятләр чукындырылган татарларны үгетлиләр, аларның авылларында вице-губернатор Е.А.Розов һәм танылган православие миссионеры Н.И.*Ильминский* булып китә. Алар татар крәстияннәрен мөселманлыкка күчмәүгә инандырырга тырышалар. Каршылыкны бастыру өчен, Олы Солабаш, Шыпшыек (Казан өязе), Олы Кибәхуҗа (Лаеш өязе) авылларына гаскәрләр җибәрелә. Кулга алулар, төрмәгә ябулар һәм Себергә сөрү чаралары гамәлгә ашырыла (Олы Кибәхуҗа авылында 33 кеше кулга алына, шуларның 7 се Себергә сөрелүгә хөкем ителә). 1867 дә хәрәкәтне оештыручылар һәм активистлар, ш.и. Г.Алкин, Г.Абдюшев, Г.*Сәмигуллин* (барлыгы 31 кеше) Себергә сөрелә. Хакимиятләрнең җиназәт һәм адм. эзәрлекләвенә карамастан, 1860 елларда 12 меңләп кеше мөселманлыкка кайта.

Әд.: Загидуллин И.К. К вопросу отпадения крёщеных татар Казанской губернии в мусульманство 1866 года // Национальный вопрос в Татарии дооктябрьского периода. К., 1990.

И.К.Загидуллин.

ЧУКЫРЛА́Р (Loxia), тау чыпчыклары семьялыгыннан кошлар ыругы. 3 төре билгеле, башлыча Төньяк ярымшарның ылыслы урманнарында таралганнар. Гәүдәсенең озынлыгы 10–20 *см*, авырлыгы 45–60 *г*. Тән төзелеше тыгыз. Каурый капламы ата кошларда кызгылт яки куе алсу төстә, ана һәм бала кошларда — яшькелт-соры. Зур томшыгы очында өске һәм аскы өлешләре икесе ике якка чалшаеп кисешә, бу Ч.га ылысны агачларның күркәләреннән орлыкларны чыгарырга мөмкинлек бирә. Канатлары озын, койрыгы чагыштырмача кыска, уемтылы, аяклары көчле, кыска. ТР терр-ясендә 3 төре яши. Нарат чукыры (L. pytyopsittacus) — очып керүче сирәк төр. Ылыслы урманнарда (нигездә, көзен һәм кышын) яши, аларның саны орлык уңышына бәйле. Томшыгының тагын да зуррак булуы б-н аерыла. Чыршы чукыры (L. curvirostra) Кама алдындагы ылыслы һәм катнаш урманнарда яши. Ак канатлы чукыр (L. leucoptera) респ-ка терр-ясендә ел саен очрамый, күрәсең, бу оялау урыннарындагы ылыслы агач токымнарының орлык уңышына бәйле. Башка Ч.дан канатындагы ике ак буй б-н аерыла. Барлык Ч. да даими күчеп йөриләр. Ояларын агачта коралар. Уңыш мул елларда Ч. коңгырт таплы 3–5 яшькелт-зәңгәр (кайвакыт ак) йомыркалардан ике оя бала чыгаралар. Ылыслы токымнарның орлыклары, җиләкләр һәм бөҗәкләр б-н тукланалар. Ылыслы агачларның орлык уңышы түбән булганда ерак араларга очып китәләр.

ЧУЛКО́В Алексей Петрович (30.4.1908, Казан губ., Спасс өязе Юхмачы а. — 7.11.1942, Калуга ш.), Сов. Союзы Герое (31.12.1942, үлгәннән соң), майор. Эшчеләр ф-тын (1932, Мәскәү), Луганск хәрби-авиация мәктәбен тәмамлый (1934). 1926–30 елларда Владимир өлкәсенең Карабаново авылында туку ф-касында эшли, 1930 дан Мәскәүдә. 1933 тән Кызыл Армиядә. Совет-фин сугышында катнаша. 1941 нең июненнән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 751 нче авиация полкының (17 нче ерак араларга хәрәкәт итүче авиация дивизиясе) сәясәт буенча эскадрилья командиры урынбасары. Ил-4 бомбардировщигы б-н дошман тылына — Берлингә, Будапештка, Данцигка, Кёнигсбергка һ.б. шәһәрләргә, 1942 нең ноябренә хәрби-сәнәгать объектларына 114 (111 — төнге) очыш ясый. 1942 нең 7 ноябрендә, Орша шәһәре янындан сугышчан бурычын үтәп кайтканда, дошманның зенит уты б-н сафтан чыгарыла һәм Калуга шәһәре янында һәлакәткә очрый. Ике Ленин ордены, ике Кызыл Байрак ордены б-н бүләкләнә. Юхмачи авылында Геройга һәйкәл куела, Карабаново шәһәренең бер урамына, Юхмачы авылында урта мәктәпкә Ч. исеме бирелә.

Әд.: Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000; Владимирская энциклопедия. Владимир, 2002.

Р.Р.Сәләхиев.

ЧУЛЛЫКЛА́Р, бекаслар (Gallinago), чуллык кошлар семьялыгыннан сазлык кошлары ыругы. 13 төрне үз эченә ала. Австралиядән кала бөтен Җир шарында киң таралганнар. Гәүдәсенең озынлыгы 25–30 *см*. Канатлары озын һәм очлы, койрыгы түгәрәкләнгән. Озын, нәзек томшыгының очында күп



Гади чуллык.



А.П. Чулков.

санлы сизү ноктaлары урнашкан, шулар ярдәмендә йомшак грунтта Ч. азык таба. Каурый катламы тыгыз, сыланып торучан. Аркасы кара тимгелле җирән-коңгырт төстә, түше һәм корсагы — аксыл. ТР терр-ясендә 2 төре бар: гади чуллык (G. gallinogo) һәм урман үрдәге (G. media). Гади чуллык түмгәкле, үләнчел сазлыкларда очрый. Ч.ның үзенчәлекле билгеләре — киң маңгай, күзләренең маңгайга якынрак урнашкан булуы һәм озын томшык (7 *см* тирәсе). Туй очышы вакытында кошлар биеккә һавага күтәрелә, ә аннары кисәк кенә аска таба оча, бу вакытта койрыгының тибрәлүче каурыйлары бәрән бәәлдәвенә охшаш тавыш чыгара. Урман үрдәге су баса торган болыннарда яки куаклар б-н капланган чагыштырмача коры сазлыкларда яши. Гади чуллыктан берникадәр зуррак һәм ак кырый төстәге койрык каурыйлары бар (кагыйдә буларак, гади чуллыкта 14, урман үрдәгендә 16 койрык каурые). Ике төре дә — юка түшәлмәле, тирән булмаган чокырчыкларны хәтерләткән ояларын түмгәкләрдә, кәзлекләрдә, коры чыбык-чабык арасында коралар. Коңгырт ноктaлы 3–5 зәйтүнсыман-соры йомырка сала. Бала чыгарганнан соң, яшерен яшәү рәвеше алып баручы тыныч кошлар; эңгер-меңгердә активлар, көндез куе үлән эченә яшеренәләр; Ч. бөҗәк личинкалары, суалчаннар, вак моллюсклар б-н тукланалар, кайвакыт үсемлек сабакларын ашыйлар. Август–сентябрьдә очып китәләр. Сунарчылык спорты объекты. 1950 еллардан, Идел һәм Кама елгаларының тугай болыннары су астында калу һәм сазлыкларның кибүе сәбәпле, Ч.ның саны шактый кими.

Әд.: Птицы Волжско-Камского края. Неворобиные. М., 1977.

ЧУЛМА́Н елгасы, к. *Кама*.

ЧУЛМА́Н БУ́Е КУЛЬТУ́РАСЫ (археол.), Урта һәм Түбән Кама буендагы мезолит дәвере (б.э.к. 7–4 нче меңьеллыклар) культурасы. Беренче тапкыр Урта һәм Югары Кама буе археол. истәлекләре материаллары буенча О.Н.*Бадер* тарафыннан аерып күрсәтелә. Татарстан терр-ясендә Ык һәм Агыйдел елгалары аралыгындагы Ч.б.к. туктаулыклары (Татар Әҗбие IV туктаулыгы һ.б.) М.Г.Косменко тарафыннан тикшерелә. Ч.б.к. халкы җыючылык, сунарчылык һәм балыкчылык б-н шөгыльләнгән, чакматаштан (башлыча микропластиналардан) эш кораллары ясау техникасын белгән. Зур күләмдә таштан эшләнгән хезмәт кораллары (кискечләр, очлыклар, кыргычлар, ышкылар һ.б.) табыла. Торулыклар елга тугайлары өстендәге террасаларда урнашкан. Башлыча җир өстенә бер-

кадәр казып (30–40 *см*) корылган тораклар планда дүртпочмаклы рәвештә булган. Татарстанда Ч.б.к. истәлекләре Минзәлә р-ны - ның Дәвек һәм Апас р-нының Кабык Күпер авыллары тирәсендә табылган.

Әд.: Косменко М.Г. Итоги раскопок Татарско-Азибейской IV стоянки // Древности Икско-Бельского междуречья. К., 1978.

Р.С.Габәшев.

ЧУЛМА́Н ТАМАГЫ́ КУЛЬТУ́РАСЫ (археол.), югары *палеолитның* соңгы чоры һәм элгәреге *мезолит* дәвере (якынча б.э.к. 14–9 меңьеллыклар), Идел һәм Чулман елгалары кушылган төбәктә. Беренче тапкыр 1977 елда Урта Идел буенда табылган мезолит чоры материаллары буенча М.Г.Косменко тарафыннан тасвирлана. 1960–70 елларда Ч.т.к. истәлекләре М.Г.Косменко, П.Н.Старостин, Р.С.Габәшев, 1980–2000 елларда М.Ш.Галимова һ.б. тарафыннан тикшерелә. Фаразланганча, Югары һәм Урта Идел, Урта Чулман буе төбәгендә палеолит һәм мезолит чорлары чикләрендә яшәгән, чакматашны яргалау һәм таштан кораллар ясауның гомуми традицияләренә ия борынгы община дәвере кабиләләре тарафыннан калдырылган. Татарстан терр-ясендә Иделнең уңъяк (биек) ярында (Кама Тамагы II, Сөйки Кичүе) һәм сулъяк ярында (Атабай VIII, Беганчик, Косякау, Любава, Семёнов, Тәтеш III һ.б.) туктау - лык-остаханәләр булуы мәгълүм. Ч.т.к. халкының таш кораллары — трапеция рәвешендәге эшкәртелмәгән зур пластиналар, авыр кискечләр һәм кителгән (очтагы) кыргычлар, тупасланган кырыйлы, ланцетсыман кечкенә очлыклар һәм очлары кителгән пластиналар, зур кискеч кораллар һәм кыргычлар (әзер формалар һәм эшләнмәләр) һ.б.

Ч.т.к. таш коралларының үзенчәлекле сый - фаты — төрле пропорцияле һәм зурлыктагы, ян-яклары шомартылган трапеция рәвешендәге эшләнмәләр. Кося кау һәм Любава туктауларында табылган юка, тар чакматаш пластиналар һәм микропластиналар эш ко - раллары җитештерүнең пластиналы технологиясе югары дәрәҗәгә ирешүен чагылдыра.

Әд.: Косменко М.Г. Мезолит Среднего Поволжья // Краткие сообщения Ин-та археологии. Вып. 149. Памятники эпохи мезолита. 1977; Кольцов Л.В. Мезолит Среднего Поволжья // Мезолит СССР. М., 1989; Галимова М.Ш. Памятники позднего палеолита и мезолита в устье реки Камы. М.-К., 2001.

М.Ш.Галимова.

ЧУЛПА́Н авылы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 7 *км* көньяк-көнбатыштарак, Казансу елгасыннан 2 *км* ераклыкта урнашкан. 2010 елда 191 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 64%, руслар — 35%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, тимерчелек, тегү , штука - тур-маляр, балта эшләре б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ч.да Никола чиркәве (1858 дә төзелә), земство мәктәбе (1874 тә ачыла), су тегермәне, тимерче алачыгы, бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җи - ре 688 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Арча волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1782 дә — 28 ир-ат; 1859 да — 130, 1897 дә — 452, 1908 дә — 574, 1920 дә — 582, 1926 да — 642, 1938 дә — 549, 1949 да — 442, 1958 дә — 265, 1970 тә — 149, 1979 да — 276, 1989 да — 213, 2002 дә — 162 кеше.

ЧУЛПА́Н авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 16 *км* көньяктарак, Брустан елгасы башында урнашкан. 2010 елда 39 ке - ше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — сарык асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1914 тә Яңа Саклау авылыннан күченүчеләр нигез сала. Оешкан көненнән Уфа губернасының Минзәлә өязе Минзәлә волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1944 нең 19 февраленнән — Матвеевка, 1954 нең 19 ноябреннән Минзәлә р-нында. Халык саны: 1926 да — 89, 1938 дә — 179, 1949 да — 181, 1958 дә — 199, 1970 тә — 177, 1979 да — 108, 1989 да — 49, 2002 дә — 58 кеше.

ЧУЛПА́Н авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 29 *км* төньяк-көнбатыштарак, Олы Чирмешән елгасының элеккеге юлына урнашкан. 2010 елда 1061 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 77%) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек, умартачылык. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 18 йөзнең 1 нче чиректә нигез салына. Рев-цияга кадәрге чыганакларда Барское Чулпаново исеме б-н дә билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша; чиркәү, зем - ство мәктәбе (1882 дә ачыла), хастаханә (1913–14 тә төзелә; архит-ра истәлеге), 2 су тегермәне, 2 тимерче алачыгы, ярма яргыч, йон тетү йорты, 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1454 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губер - насының Чистай өязе Иске Максимкино волостена керә. Халык саны: 1782 дә — 104 ир-ат; 1859 да — 537, 1897 дә — 798, 1908 дә — 930,1920 дә — 1239, 1926 да — 1041, 1938 дә — 1171, 1949 да — 1213, 1958 дә — 793, 1970 тә — 1678, 1979 да — 1269, 1989 да — 988, 2002 дә — 1141 кеше.

ЧУЛПА́Н авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 29 *км* көньяктарак, Баганалы елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 126 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек, са - рык асрау. Клуб, китапханә. 1928 дә нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Чис - тай кантоны Мөслим волостенда. 1930 ның 10 августыннан Чистай р-нында. Халык саны: 1938 дә — 340, 1949 да — 272, 1958 дә — 324, 1970 тә — 420, 1979 да — 177, 1989 да — 158, 2002 дә — 149 кеше.

ЧУЛПА́Н авылы, Югары Ослан р-нында, Югары Ослан авылыннан 52 *км* көньяк-көн - батыштарак, Зөя елгасыннан 1,5 *км* ераклык - та урнашкан. 2010 елда 87 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәк - тәп. 1565–67 еллардан Кече Итякова буларак мәгълүм. Рев-цияга кадәрге чыганакларда Кече Өтәк, Чулпаниха-Ключ исемнәре б-н дә билгеле. Халкы башта Зөя Успение Богородица монастырена карый, 1764 тә — эконо - мик, соңрак дәүләт крәстияннәре катлавына күчерелә; игенчелек, терлекчелек, он тар - ту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында земство мәктәбе (1903 тә ачыла), май язу з-ды, 6 җил тегермәне, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1987 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Келәнче волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Норлат-Ачасыр, 1927 нең 1 августыннан — Норлат, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Югары Ослан р-нында. Халык саны: 1782 дә — 192 ир-ат; 1859 да — 525, 1897 дә — 735, 1908 дә — 935, 1920 дә — 992, 1926 да — 958, 1938 дә — 1030, 1949 да — 503, 1958 дә — 429, 1970 тә — 207, 1989 да — 184, 2002 дә — 128 кеше.

«ЧУЛПА́Н», иҗтимагый-сәяси газета. Себер үзәк Милли Шурасы органы. 1918 елның февраль–мартында Томск шәһәрендә татар телендә нәшер ителә. Мөхәррире — Ә.Тангаташов. Газета ташбасма ысул б-н басыла. «Се - бер мохтарияте яшәсен! Себер мөселманнарының милли һәм мәдәни мохтарияте яшәсен!» лозунгы б-н дөнья күрә. Шул вакытта Себердә милли тормышны бар яктан яктырту һәм мөселманнар мәнфәгатен яклау мак - саты б-н чыккан бердәнбер татар газетасы була. Аерым алганда, ул эшчеләрне үзләрен яклый торган оешма булдырырга чакыра. Россиядәге вакыйгалар артыннан барып, Себер мөселманнарының иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни тормышы мәсьәләләренә игътибар бирә.

«ЧУЛПА́Н», иҗтимагый-сәяси газета. РСФСРның Милләтләр эше буенча халык комис-ты каршындагы Үзәк мөселман комис-ты органы; «сул социалистик юнәлештәге газета» дигән исем асты була. 1918 елның 18 гыйнварыннан 1919 ның 21 мартына кадәр Петроградта (12 сан) һәм Мәскәүдә (33 сан) татар телендә нәшер ителә, барысы 45 саны чыга. Башта рәсми мөхәррире — Г.Абушаев, фактик мөхәррире — Г.*Ибра һимов*. 13 сан - нан (30 март), совет хөкүмәте Мәскәүгә күч - кәч, газета б-н мөхәрририят идарә итә. Г.Ибра һимов чакыруы буенча аның составына Төньяк фронт Мөселман солдатлар ком-тының «*Сугыш сафы*» г-тасы (Псков ш.) хез - мәткәрләре, ш.и. актив авторлары — М.Дулат Али, Й.Ибраһимов, Һ.Килдебәков, М.Конов, Г.Максудов керә. Газетада галимнәр, рев-ция һәм җәмәгать эшлеклеләре Ш.Әхмәдиев, М.Вахитов, Ш.Манатов, Б.Мансуров, И.Рәх - мәтуллин, М.Сөбхи, Х.Урманов, Ш.Ходайбирдин һ.б.ның хезмәтләре; күренекле әдип - ләр Ш.Бабич, Н.Исәнбәт, С.Кудаш, М.Мак - суд һ.б.ның мәкаләләре чыга. Татар теленә тәр җемә ителеп, совет хөкүмәтенең мөһим карарлары, ш.и. Татар-Башкорт Сов. Соц. Респ-касы турындагы Нигезләмә, Үзәк мөсел - ман комис-ты коллегиясе утырышлары бер - кетмәләре һәм аларның карарлары басыла.

«Ч.» соц. идеяләрне актив пропагандалый, рев-циянең бөек казанышларын сакларга, контррев-ция һәм дин тәэсиренә каршы көрәшергә чакыра. Брест солыхы турындагы мәсьәләдә газета аны кабул итмәүдән алып солыхны имзалау зарурлыгын аңлатуга кадәр үзгәреш кичерә. Мөһим темалар арасында татарларның милли үзбилгеләнү, милли дәүләтчелек формалары, ш.и. терр. мохтарият мәсь әләләре күтәрелә. «Ч.» Учредительләр җыенын таратуга, милли оешмалар — Бөтенроссия Мөселман хәрби советын (Хәрби Шура), Бөтенроссия Мөселман советын (Милли Шура), Эчке Россия һәм Себер мөселманнары Милли идарәсен (Милли идарә)



«Чулпан» газетасы.

юкка чыгаруга, большевистик булмаган матбугатны ябуга уңай карый. Сугыш хәрәкәтләре барышын даими яктырта, Кызыл Армия солдатлары рухын күтәрергә (ш.и. Казанны алу чорында), мөселманнарны Кызыл Армия сафына басарга чакыра. Совет милли матбугаты эчтәлегенә зур йогынты ясый. 1919 нның мартында, Үзәк мөселман комис-ты матбугат бүлеге Мәскәүдән Казанга күчкәч, «Ч.» хәзерге «Ватаным Татарстан» г-тасына нигез салган «*Эш*» г-тасы б-н берләштерелә.

Әд.: Нуруллина Р.М. Становление партийно-советской печати на татарском языке (1917–1925). К., 1978.

ЧУЛПАНЫЙ Мирхәйдәр (Газизмирхәйдәр) Зөлкарнәй улы (1850 — 20 йөз башы), шагыйрь. 1890 елларда «Мотыйгия» (Уральск ш.) мәдрәсәсендә укый, Г.Тукай ны укыткан мөгаллимнәрнең берсе. Со ңын нан Самара губернасының Бозаулык шәһәре мәчетендә имам-хатиб. Патша хөкүмәтенең көчләп чукындыру сәясәтенә каршы халык арасында аңлату эшләре алып барганы өчен төрмәдә утырып чыга. «Сәед бистәсе» (Оренбург, 1890) тарихи-публицистик китап, шигъри әсәрләр, тарихи-мәдәни темага публицистик мәкаләләр авторы.

Әд.: Нуруллин И. Габдулла Тукай. К., 1979.

ЧУЛПЫ́ (бака), татарларда чәчкә тагыла торган традицион бизәмә. Элегрәк татарларның, керәшеннәрдән кала, барлык этнотерр. төркемнәре арасында киң таралган була. Көмеш тәңкәләрдән һәм җиз асылмалардан тезелгән чыңлый торган асылма тасмага тагылла һәм шуның ярдәмендә чәчкә күшып үрелә. Җиз тәңкәләр җепкыр, штамповка, кою техникасында башкарылып, гравирлау, каралту, чүкеп бизәкләү ярдәмендә асылташлар, бөртекләү, чәчәк-үлән яисә гарәп язуы б-н бизәлә. Җепкыр яки гравирлау ысулы кулланып ясалган калак формасындагы җиз тәңкәле тезмә аеруча популяр була. 6–9 җиз тәңкәле тезмәдән торган, атлама ярдәмендә берничә рәт бергә тоташтырылган зур Ч.лар да була, алар ике толымга берьюлы беркетелә. 20 йөзнең 1 нче яртысында киң кулланылыштан чыга.

Әд.: Суслова С.В. Одежда // Татары. М., 2001.

ЧУЛПЫ́Ч авылы, Саба р-нында, шәһәр тибындагы Байлар Сабасы посёлогыннан 13 *км* көнбатыштарак, Кече Мишә елгасы (Мишәнең уң кушылдыгы) буенда. 2010 елда 71 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. Башлангыч мәктәп. 18 йөзнең 1 нче чирегендә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Челпыш исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, тимерче алачыгы, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 846,9 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Сатыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 нның 10 августыннан Саба р-нында. Халык саны: 1782 дә — 42 ир-ат; 1859 да — 205, 1897 дә — 325, 1908 дә — 402, 1920 дә — 381, 1926 да — 390, 1938 дә — 400, 1949 да — 370, 1970 тә — 161, 1979 да — 145, 1989 да — 107, 2002 дә — 80 кеше.

ЧУЛЫ́ГИНО авылы, Кукмара р-нында, Кукмара шәһәреннән 46 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Лубян елгасы буенда. 2010 елда 3 кеше (татарлар) яши. 1960 та торак пункт буларак теркәлә. Оешкан көненнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән — Мамадыш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Кукмара р-нында. Халык саны: 1979 да — 4, 1989 да — 6, 2002 дә — 6 кеше.

ЧУЛЫМА́Н, урта гасырларда Чулман елгасының югары агымындагы шәһәр һәм тарихи өлкә. Идел буе Болгар дәүләте йогынтысында була. Болгарлар һәм төньяк халыклары сәүдәсендә алыш-биреш урыны. Тикшеренүчеләр Ч. өлкәсен коми халкының борынгы бабалары (Ромодан культурасы, 9–15 йөзләр) яшәгән терр-я б-н бәйлиләр.

Әд.: Талицкий М.В. Верхнее Прикамье в X-XIV вв. // Материалы и исслед. по археологии СССР. 1951. № 22. *И.Л.Измайлов.*

ЧУМА́Ч елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Чишмә елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы12,5 *км*. Бассейнының мәйданы 40,5 *км*^{2}. Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгыннан, Чирмешән р-нында ага. Елга башы Чумач авылыннан 4 *км* төньяк-көнчыгыштарак урман массивында, тамагы Түбән Карамалы авылыннан 2 *км* көньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 190 *м*, тамагыныкы — 79 *м*. Су җыелу мәйданының урманлыгы 85%. Ч.ның 1,7 *км* озынлыктагы 1 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,35 *км/км*^{2}. Туенуы катнаш, яртысыннан артыграгы кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км*^{2}. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы, җәен нык сае гуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 129 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 67 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,082 *м*^{3}*/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (20–40 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

ЧУМА́Ч авылы, Чирмешән р-нында, Чирмешән авылыннан 25 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Чумач елгасы буенда. 2010 елда 133 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1920 елларда нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Бөгелмә кантоны Чирмешән волостенда. 1930 нның 10 августыннан — Беренче Май, 1963 нең 1 февраленнән — Лениногорск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Чирмешән р-нында. Халык саны: 1926 да — 188, 1949 да — 353, 1958 дә — 362, 1970 тә — 373, 1979 да — 274, 1989 да — 196, 2002 дә — 153 кеше.

ЧУМГАЛА́К ҮРДӘКЛӘ́Р (Mergus), үрдәк кошлар семьялыгыннан суда йөзүче кошлар ыругы. 7 төре билгеле: 5 төре Төньяк ярымшарда, 1 — Көньяк Американың тропик өлешендә, 1 — Яңа Зеландиядә очрый. ТР терр-ясендә 3 төре бар: зур чумгалак үрдәк (M. merganser), озын томшыклы чумгалак үрдәк (M. serrator) һәм ак чумгалак үрдәк (M. albellus). Елга һәм күлләрдә яши. Гәүдәсе нык кына сузынкы, 75 *см* га кадәр озынлыкта, авырлыгы 0,6–1,4 *кг*. Томшыгы озын, тар, кырыйлары тешчекле, очында ырганкысман аска бөгелгән. Башында юка каурыйлы бүрекчә. Бармаклары озын, алгылары элпә б-н тоташкан, арткы бармагы киң яссылы. Яхшы йөзәләр һәм чумалар. Озын томшыклы чумгалак үрдәк зур чумгалак үрдәктән кечерәк гәүдәсе һәм бүксәсенең коңгыртырак төстә булуы б-н аерыла. Озын томшыклы чумгалак үрдәк һәм ак чумгалак үрдәк язын һәм көзен очып күченү вакытында аерым пар булып яки зур булмаган төркемнәрдә очрый, зур чумгалак үрдәкнең кайберләре сулыкларның (Урта Кабан, Илләт, Казансу һ.б.) катмый торган участокларында кышлый. Ояларын җирдә, ташлар арасында һәм агач куышларында кора. 8–10 йомырка сала. Башлыча вак балык, ара-тирә вак су умырткасызлары, үсемлекләр б-н туклана. Аучылык спорты объекты. Ак күзле чумгалак ТРның Кызыл китабына кертелгән.

ЧУМГАЛАКЛА́Р (Netta), үрдәк кошлар семьялыгыннан суда йөзүче кошлар ыругы төркеме. 35 тән артык төре билгеле, Евразиядә, Төньяк һәм Көньяк Америка, Африка, Австралия, Яңа Зеландиядә таралганнар. ТР терр-ясендә 9 төре бар. Кызыл башлы чумгалак (Aythya ferina) һәм ала чумгалак (Bucephala clangula) аеруча еш очрый һәм оялый; бүрекле карагай (Aythya fuligula) һәм ак күзле чумгалак (A. nyroca) сирәк оялаучы кошларга керә; диңгез карагае (A. marila),



Н.Г.Чунтонов.

диңгез үрдәге (Clangula hyemalis), гади турпан (Melanitta fusca) язын һәм көзен очып күченү вакытында очрый; синьга (M. nigra) һәм кикрикле гага (Somateria spectabillis) — сирәк очып керүче төрләр. Ч. елга үрдәкләреннән арткы бармагында яхшы үсеш алган калак булу б-н аерыла. Ата кошлар ачык, контраст төстә, бизәүче каурыйлары бар; аналары кечерәк гәүдәле, гадирәк төстә. Аяклары кыска, арткы яктарак урнашкан, коры җирдә вертикаль рәвештә диярлек алпан-тилпән атлап тиз йөриләр. Канатлары тар һәм чагыштырмача кыска. Бүрекле карагай башка төрләрдән җилкәсендәге озын толымчыгы б-н аерыла. Гади турпан һәм кикрикле гаганың канатлары ялтырап торган ак «көзгечекле». Ч. яхшы йөзә, чума, озак вакыт су астында тора ала. Йөзгән вакытта койрыгын су астына төшерә. Моногамнар. Куракта, сулыкларның сай урыннарында яки яр буенда оялый. Ояны ана кош кора. 7–12 йомырка сала. Ч. елга 2 тапкыр йон коя: тулысы б-н җәен (туй чорыннан соң) һәм өлешчә көзен (туй чорыннан соң). Күбесенчә су үсемлекләре, мол люсклар, кысласыманнар, су бөҗәкләре ли чинкалары, вак балыклар б-н туклана. Күп төрләре һәвәскәр аучылык объекты.

ЧУНТО́НОВ Николай Григорьевич (22.5.1925, Казан — 17.6.1977, Мәскәү), Сов. Союзы Герое (10.1.1944), гв. өлкән сержанты. Хәрби пехота уч-щесен (1943), Хабаровск артиллерия уч-щесен (1945), Мәскәү төзүче инженерлар ин-тын (1959) тәмамлый. Чимкент шәһәрендә (Казакъстан ССР) заводта слесарь булып эшли. 1943 елның октябреннән Бөек Ватан сугышы фронтларында, 71 нче механикалаштырылган бригаданың артиллерия дивизионында (3 нче гв. танк армиясенең 9 нчы механикалаштырылган корпусы) туп төзәүче. 1 нче Украина фронты гаскәрләре составында Сульяк яр Украинаны азат итүдә (1943), Житомир-Бердичев (1943), Львов-Сандомир (1944) һәм Түбән Силезия (1945) һөҗүм операцияләрендә катнаша. 1943 нең 6–8 ноябрендә Фастов шәһәре (Украина ССР) янындагы сугышларда батырлык күрсәтә: Хотов авылы янында (Киев өлкәсенең Киев-Святошино р-ны) дошманның 5 тубын, машинасын сафтан чыгара, Волица авылы янында (Фастов р-ны) контрһөҗүмне кире кайтарганда пехота ротасын юк итә. 1960–77 дә Мәскәү өлкәсендә баш архитектор булып эшли. Ленин ордены, Кызыл Йолдыз ордены, медальләр б-н бүләкләнә. Казанның бер урамына Ч. исеме бирелә.

Әд.: Батырлар китабы — Книга Героев. К., 2000.

М.З.Хәбибуллин.

ЧУПА́Й елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Кичү елгасының (Чишмә елгасы бассейны) сул күшылдыгы. Озынлыгы 13,7 *км*. Бассейнының мәйданы 64,9 *км*². Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгыннан, Әлмәт р-нында ага. Елга башы Чупай авылыннан 3 *км* көньяктарак, тамагы Кичүчат авылында. Елга башының абс. биеклеге 270 *м*, тамагыныкы — 161 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 25%. Ч.ның 0,8 һәм 4,8 *км* озынлыктагы 2 күшылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,31 *км/км*². Туенуы катнаш, якынча яртысы кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 3–5 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы, җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 146 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 75 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,16 *м*³/*с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*. Ч. бассейнында суының гомуми күләме 0,8 млн. *м*³ булган буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

ЧУПА́Й елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Кичү елгасының (Чишмә елгасы бассейны) уң күшылдыгы. Озынлыгы 11,4 *км*. Бассейнының мәйданы 66 *км*². Бөгелмә-Бәләбәй калкулыгыннан ага. Елга башы Зәй р-ны Иске Ялан авылыннан 4 *км* төньяк-көнчыгыш тарак һәм Гулькин авылыннан 6 *км* көнчыгыштарак, тамагы Әлмәт р-ны Йосып авылыннан (даими яшәүчеләр юк) 1 *км* читтәрәк. Елга башының абс. биеклеге 200 *м*, тамагыныкы — 85 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 50%. Ч.ның 1,8 һәм 4,6 *км* озынлыктагы 2 күшылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,29 *км/км*². Туенуы катнаш, яртысыннан артыгы кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1–3 *л/с·км*². Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 124 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 68 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,128 *м*³/*с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 300–400 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

ЧУПА́Й авылы, Әлмәт р-нында, Әлмәт шәһәреннән 25 *км* көньяк-көнбатыштарак, Чупай елгасы буенда. 2010 елда 729 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1735 тән Чупайкина исеме б-н билгеле. 1860 елларга кадәр халкы типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, таш вату б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет (1877 дә төзелә), мәдрәсә, су тегермәне, бакалея кибете була; сишәмбе базары эшли (1891 дән). Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2576 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Мордва Ивановкасы волостенда, 1920 дән ТАССРның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан Әлмәт р-нында. Халык саны: 1747 дә — 49, 1762 дә — 67, 1811 дә — 164 ир-ат; 1850 дә — 588, 1859 да — 695, 1889 да — 1040, 1897 дә — 1010, 1910 да — 1118, 1920 дә — 1241, 1926 да — 922, 1938 дә — 998, 1949 да — 952, 1958 дә — 1098, 1970 тә — 1268, 1979 да — 762, 1989 да — 606, 2002 дә — 634 кеше.

ЧУПА́Й авылы, Мамадыш р-нында, Мамадыш шәһәреннән 38 *км* төньяктарак, Юкәче елгасының уң күшылдыгы буенда. 2010 елда 11 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 50%, татарлар — 50%) яши. 17 йөз ахырында 18 йөз уртасында чукындырылган һәм православие диненә күчкән татарлар нигез сала. 1795 еллар тирәсендә Мамадыш өязенең — Красная Горка, Отарка, Казан өязенең Чокырча авылларыннан күченгән рус крәстияннәре (иске дин тарафдарлары) килеп урнаша. 1930 еллар уртасына кадәр рәсми чыганакларда Отар-Елга буларак телгә алына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү-приход мәктәбе (1885 тә ачыла), тегермән, ярма яргыч, вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 671,6 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Мамадыш өязе Лыябаш-Келәүш волостенда, 1920 дән ТАССРның Мамадыш кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Тәкәнеш, 1932 нең 1 гыйнварыннан — Кукмара, 1935 нең 10 февраленнән — Тәкәнеш, 1963 нең 1 февраленнән Мамадыш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 23 ир-ат; 1859 да — 242, 1897 дә — 458, 1908 дә — 452, 1920 дә — 431, 1926 да — 528, 1949 да — 379, 1958 дә — 274, 1970 тә — 273, 1979 да — 124, 1989 да — 30, 2002 дә — 18 кеше.

ЧУПА́Й авылы, Минзәлә р-нында, Минзәлә шәһәреннән 34 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Мөшере елгасы буенда. 2010 елда 105 кеше (марилар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Башлангыч мәктәп, клуб. 1747 дән мәгълүм. 1860 елларга кадәр халкы типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, чабата үрү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында авыл җәмәгатенең имана җире 513 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Пучы волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Минзәлә, 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1944 нең 19 февраленнән — Матвеевка, 1954 нең 19 ноябреннән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Мөслим, 1963 нең 1 февраленнән Минзәлә р-нында. Халык саны: 1747 дә — 27 ир-ат; 1795 тә — 242, 1859 да — 219, 1870 тә — 240, 1906 да — 280, 1913 тә — 356, 1920 дә — 333, 1926 да — 364, 1938 дә — 318, 1949 да — 277, 1958 дә — 259, 1970 тә — 270, 1979 да — 225, 1989 да — 148, 2002 дә — 113 кеше.

ЧУПРИ́НА Николай Семёнович (25.4.1947, Владимир өлкәсенең Гороховец а. — 29.5.2007, Казан), геолог-икътисадчы, ТР Дәүләт бүләге лауреаты (1995), геогр. фән. канд. (1979). Казан ун-тын тәмамлый (1970), ЦНИИгеолнерудта эшли, гыйльми секретарь (1999 дан), әйдәп баручы фәнни хезмәткәр (2003 тән). Ч. икътисади һәм социаль прогресс, җитештерүче көчләрнең үсеше һәм урнашуының респ-ка максатчан программаларын; төбәкләрдә табигатьне саклауның комплексны схемаларын, геол.-икътисади бәяләүнең методик нигезләрен, металл булмаган һәм фәнни-техник продукция маркетингын эшләүдә катнаша. Дәүләт бүләге ТР-да төзелеш материалларының минераль-җитештерү комплексын үстерү мәсьәләләрен геол.-икътисади яктан тикшерү һәм үсеш перспективаларын нигезләү өчен бирелә.

ЧУРА́ (чури, чурин, йөри), титул. Беренче тапкыр 6 йөздә Төркн каганлыкта барлыкка килә. Идел буе Болгар дәүләтендә, Алтын Урдада һәм татар ханлыкларында йомышлы хәрби аксөякләр титулы буларак кулланыла. 17–18 йөзләрдә Ч. — вассал, бәйле кеше атамасы. Совет чоры тарихи әдәбиятында кайбер очракларда «кол» төшенчәсенең синонимы буларак күрсәтелә. «Ч.» сүзе исемнәрдә, топонимнарда чагылыш таба (мәс., Казан ханлыгының дәүләт эшлеклесе *Нарыйк улы Чура бәк*, «*Чура Батыр*» дастаны каһарманы; Кукмара р-нының Түбән Чура а. һ.б.).

Әд.: У с м а н о в М.А. Татарские исторические источники XVII–XVIII вв. К., 1972.

ЧУРА́ БАТЫ́Р авылы, Нурлат р-нында, Нурлат шәһәреннән 69 *км* төньяк-көнбатыштарак, Гәрәй елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 95 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1680 елларда нигез салына. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ч.Б.да 3 вак-төяклар кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1000 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Иске Әлмәт волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августын-нан — Биләр, 1963 нең 1 февраленнән — Октябрь, 1997 нең 10 декабреннән Нурлат р-нында. Халык саны: 1782 дә — 51 ир-ат; 1859 да — 384, 1897 дә — 703, 1908 дә — 778, 1920 дә — 889, 1926 да — 622, 1938 дә — 506, 1949 да — 448, 1958 дә — 360, 1970 тә — 333, 1979 да — 256, 1989 да — 131, 2002 дә — 100 кеше.

«ЧУРА́ БАТЫ́Р», 16 йөз уртасында барлыкка килгән гомумтөркн героик дастан. Шигъри версияләренең берничәсе Казан һәм Кырым татарларында, нугайларда, башкортларда, казакъларда мәгълүм. Баш геройның тарихи прототибы ханлыктагы Кырым йогынтысына каршы чыккан Казан ханлыгының дәүләт эшлеклесе *Нарыйк улы Чура бәк* дип фаразлана. Дастанда Чура батырның Казан ханлыгының азатлыгы һәм бәйсезлеге өчен барган сугышларда батырларча көрәше бәян ителә. Эчтәлекләре ягыннан дастанның милли версияләре бер-берсеннән аерыла. Татар һәм нугай версияләрендә үсеп баручы Мәскәү экспансиясе б-н көрәш игътибар үзәгендә. Кайбер вариантларда («Чура батыр хикәяте») башка геройларның күпсанлы мажараларының тасвирлана, хикәяләүнең ахырында гына Чура батыр барлыкка килә. Шушы ук вариантта бик борынгы, дастан иҗат ителгән чор өчен анхронизм булган мотив — атаның, танылмыйча, үз угылы б-н көрәшү мотивы бар. Казакъ версиясендә баласызлык һәм, озак еллар көткәннән соң, угыл туу мотивы урын алган. Ул, батыр булып үсеп җитеп, калмык гаскәренә каршы көрәшне җитәкләргә тиеш булган. Дастан беренче тапкыр И.Н.Березин тарафыннан нәшер ителә («Төрек хрестоматиясе» («Турецкая хрестоматия», 1862, т. 2.)). Әсәрне Л.Х.Ибраһимова өйрәнә.

Әд.: Кыйссаи Чура батыр. К., 1884; Чура батыр хикәяте // Татар халык иҗаты: Дастаннар. К., 1984; У р м а н ч е Ф. Чура батыр // Мирас. 1996. № 8–12. *Ф.И.Урманчеев.*

ЧУРА́ БӘК, к. *Нарыйк улы Чура бәк.*

ЧУРА́К авылы, Буа р-нында, Буа шәһәреннән 7 *км* төньяк-көнбатыштарак урнашкан. 2010 елда 534 кеше (чуашлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Кабек-Касы (Кибекасси) буларак та билгеле. 1720 еллардан халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, 1835–60 елларда Удел ведомствосы карамагында, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү-приход мәктәбе, сәүдә-сәнәгать йорты эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 468,1 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязе Ырынгы волостенда, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан Буа р-нында. Халык саны: 1859 да — 174, 1913 тә — 417, 1920 дә — 434, 1926 да — 503, 1938 дә — 543, 1949 да — 461, 1958 дә — 498, 1970 тә — 607, 1979 да — 701, 1989 да — 496, 2002 дә — 526 кеше.

ЧУРАКА́Й авылы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 40 *км* көньяк-көнбатыштарак, Калмыя елгасы буенда. 2010 елда 452 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1711 дән — Калмый, 18 йөз чыганакларында Калмаи, Калмыя, Калмыятамак исемнәре б-н дә очрый. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында 2 мәчет, мәдрәсә, су тегермәне, икмәк саклау-сату кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3448 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Әмәкәй волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Актаныш, 1935 нең 10 февраленнән — Калинин, 1959 ның 12 октябреннән — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнварыннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 98, 1834 тә — 185, 1859 да — 386, 1870 тә — 423, 1884 тә — 701, 1897 дә — 713, 1906 да — 911, 1920 дә — 940, 1926 да — 1032, 1938 дә — 852, 1949 да — 602, 1958 дә — 574, 1970 һәм1979 да — 995 әр (Зиланово авылын да кертеп), 1989 да — 564, 2002 дә — 502 кеше.

ЧУРА́Ш авылы, Сарман р-нында, Сарман авылыннан 39 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Минзәлә елгасы буенда. 2010 елда 260 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1722 гә кадәр нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Саклау-Чураш исеме б-н дә билгеле. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар һәм дәүләт крәстияннәре катлауларына бүленә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, мәктәп, су тегермәне, 2 икмәк саклау-сату һәм 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 984,7 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Нөркәй волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Чаллы, 1935 нең 10 февраленнән — Ворошилов, 1957 нең 29 ноябреннән — Яңа Юл, 1959 ның 12 октябреннән Сарман р-нында. Халык саны: 1795 тә — 53, 1834 тә — 68, 1870 тә — 386, 1897 дә — 619, 1906 да — 658, 1922 дә — 831, 1926 да — 780, 1938 дә — 858, 1949 да — 591, 1958 дә — 506, 1970 тә — 583, 1979 да — 426, 1989 да — 297, 2002 дә — 293 кеше.

ЧУРЗИ́Н Виктор Васильевич (16.12.1939, Казакъстан ССРның Уральск өлкәсе Жәнҗыйбәк ст.), юл төзелеше–төзелеш машиналары техник-механигы, СССР Дәүләт бүләге лауреаты (1991), ТАССРның атказ. торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәткәре (1985). Волжск индустриаль техникумын тәмамлый (1960, Волгоград өлкәсе). 1966–99 елларда Казан шәһәр башкарма ком-тының төзекләндерү һәм яшелләндерү буенча җитештерү ремонт-төзелеш берләшмәсендә. Дәүләт бүләге хезмәттә һәм фәнни-техник иҗатта зур казанышлары өчен бирелә. Медальләр б-н бүләкләнә.

ЧУРКАЛЕ́Й елгасы, Көнбатыш Кама аръягында, Олы Чирмешән елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 12,9 *км*. Бассейнының мәйданы 43,5 *км*^{2}. Идел аръягы түбәнлегеннән ага. Елга башы һәм иң югары агымы Самара өлкәсе терр-ясендә, елга 10 *км* тирәсе озынлыгында ТРның табигый чиге булып тора, тамагы Чирмешән р-ны Казанка авылыннан 3 *км* көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 155 *м*, тамагыныкы — 96 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 5%. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,3 *км/км*^{2}. Туенуы катнаш, күбрәк кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,5–1 *л/с·км*^{2}. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Җәен озак вакыт яңгырлар булмаганда елга еш кына кибә. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 90 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга но-

ябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,016 *м*^{3}*/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (20–40 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 500–700 *мг/л*.

ЧУРТА́Н КОЙРЫГЫ́, к. *Сансевьера*.

ЧУРТА́Н КҮЛЕ́, Көнбатыш Кама аръягында. Үтәк һәм Бизнә елгалары бассейнының субүләрендә, Спас р-ны Отрада авылыннан 4 *км* көньяк-көнчыгыштарак урнашкан. Су өслегенең мәйданы 21,31 *га*. Суының күләме якынча 900 мең *м*^{3}. Озынлыгы 1000 *м*, иң зур киңлеге 260 *м*. Уртача тирәнлеге 4,5 *м*, иң зур тирәнлеге 15 *м*. Күл карст күренешләре



Чуртан күле.

нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Ярлары сөзәк. Озынча формада. Явым-төшемнәр һәм җир асты сулары б-н туена. Суы гидрокарбонат-сульфат-кальцийлы типта, җи ңелчә минеральләшкән (117 *мг/л*), йомшак (1,6 *мг-экв/л*), азрак болганчык, саргылт төстә. Үтә күренмәлелеге якынча 100 *см*. Ял итү урыны. ТРның табигать истәлеге (1978).

ЧУРТАННА́Р (Esox), чуртан балыклар семьялыгыннан төче су балыклары. 5 төре билгеле, Евразиядә һәм Төньяк Америкада таралганнар. Татарстан терр-ясендә бер төре — гади чуртан (E. lucius) бар. Су үсемлекләренә бай акрын агымлы сулыкларда яши. Гәүдәсе озынча, 1,5 *м* га кадәр озынлыкта; авырлыгы 18 *кг* га кадәр. Ана балыклар аталарыннан зуррак. Башы зур, сузынкы һәм җәйпәк борынлы. Аскы казналыктагы тешләре хәнҗәрсыман. Койрыгы уемтылы. Төсе яшеренү өчен җайлашкан: сырты кара, ян-яклары аксыл, зәйтүнсыман-көрән зур таплы һәм чиратлашып килгән аркылы буйлы. Саңак капкачы турыпочмаклы. Сырт һәм кой-рык асты йөзгечләре артка карый һәм койрык йөзгече янында урнашканнар, бу Ч.га кызу ыргылыш ясарга мөмкинлек бирә. Тәңкәсе вак, гәүдәсен һәм башын каплый. Яшәвенең 2–3 елында җенси җитлегә. Иртә язда уылдык чәчә. Үрчемлелеге — 3–4 мең уылдык бөртеге. Уылдыгын яр буе үсемлекләренә сала, алар шунда ябышып кала; 2–3 тәүлектән соң уылдык төпкә төшә һәм шунда җитлегә. Кыйммәте ягыннан әһәмияте булмаган балыклар (чабак, алабуга, шыртлака, густера, тюлька), ш.у. җир-су хайваннары, рептилияләр, зур бөҗәкләр б-н туклана. Кәсәбәчелек һәм аучылык спорты объекты. 12–15 ел яши. Илл. к. *Балыклар* мәкаләсендә.

ЧУСОВО́Й шәһәре, *Пермь краеның* көнчыгышында, Пермь шәһәреннән 224 *км* төньяк-көнчыгыштарак урнашкан. 16 йөздән — Камасино авылы, 1880–1923 елларда — Чусовой Заводы, 1923–33 тә — шәһәр тибындагы Чусовая посёлогы, 1933 тән Ч. шәһәре булараК билгеле. Халкы — 45291 кеше (2017). 2010 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 3850 кеше. Татарларның (башлыча, Казан һәм Вятка губерналарыннан) Ч.га күпләп күченүләре 1880 дә Ч. металлургия з-ды төзелеше башлану б-н бәйле. Алар, нигездә, урман кисү, киптерү һәм сугару каналлары төзү, цех нигезләре астында чокырлар казу, завод өчен агач күмере әзерләү кебек эшләр башкара. 20 йөз башында татарлар сәүдә өлкәсендә мөһим роль уйный: савыт-саба, лампа, галантерея, ипи, мануфактура, бакалея, колониаль товарлар һ.б. б-н сату итә. Алар күбесенчә мәчет (1930 ларда ябыла) янындагы «татар» һәм «харбин» баракларында яшиләр. 1930 елларда Ч.да дүртьеллык, соңрак җидееллык 2 нче татар мәктәбе эшли. 1931–39 да татар телендә «*Ударник*» г-тасы нәшер ителә. 1970 елларда металлургия мәдәният йортында татар үзешчән хоры эшли. 1993 тә мөселман җәмгыяте оештырыла, 2011 дә мәчет ачыла. *Сабан туе*, *Корбан бәйрәме*, *Ураза бәйрәме* уздырыла.

Әд.: Ю ж а к о в О.Ю. Из истории Чусовского края. Чусовой, 1999.

ЧУТА́Й авылы, Балтач р-нында, шәһәр тибындагы Балтач посёлогыннан 29 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Киров өлкәсе б-н чиктәш урнашкан. 2010 елда 475 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Тулы булмаган урта мәктәп, клуб, китапханә. Мәчет. 1678 дән мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Түбән Чутай исеме б-н билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, кирпеч сугу, пыяла ясау, балта эше, такта яру, киез итек-киез җитештерү, олаучылык, сәүдә б-н шөгыльләнә. Казан артының төрле авылларында гыйбадәтханә һәм сәүдә биналары төзүче ташчылар зур абруй казана. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша, 2 мәчет (1854 тә — агач, 1901 дә таш мәчет төзелә), 2 мәдрәсә, 2 су тегермәне, берничә сәүдә ноктасы эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1643 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Вятка губернасының Малмыж өязе Түбән Четаево волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Түнтәр, 1932 нең 2 мартыннан — Балтач, 1938 нең 4 августыннан — Чепья, 1958 нең 16 июленнән — Балтач, 1963 нең 1 февраленнән — Арча, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балтач р-нында. Халык саны: 1742 дә — 185, 1762 дә — 250 ир-ат; 1795 тә — 509, 1859 да — 942, 1884 тә — 1154, 1926 да — 1733, 1938 дә — 1382, 1949 да — 831, 1958 дә — 708, 1970 тә — 665, 1979 да — 559, 1989 да — 496, 2002 дә — 510 кеше.

Әд.: Балтач энциклопедиясе. К., 2010. 2 кит.

ЧУТА́Й елгасы, к. *Кугубор*.

ЧУЧА́ авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 25 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Казан — Теләче автомобиль юлы буенда. 2010 елда 18 кеше (руслар) яши. 1654 тән Яңа Чеча исеме б-н мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Богородский буларак та билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында чиркәү-приход мәктәбе (1889 да ачыла), 2 икмәк саклау-сату һәм 3 вак-төякләр кибете, җил тегермәне эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1262,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Пановка волостенда, 1920 дән ТАССРның — Лаеш, 1927 дән Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 31 ир-ат; 1859 да — 253, 1897 дә — 502, 1908 дә — 547, 1920 дә — 519, 1926 да — 579, 1949 да — 229, 1958 дә — 248, 1970 тә — 125, 1979 да — 75, 1989 да — 51, 2002 дә — 18 кеше.

ЧУШКА́Н елгасы, Көнчыгыш Кама алдында, Әзи елгасының (Иж елгасы бассейны) уң кушылдыгы. Озынлыгы 10 *км*. Бассейнының мәйданы 31,4 *км*^{2}. Сарапул калкулыгыннан, Әгерҗе р-нында ага. Елга башы Саклау авылыннан 4,5 *км* көнчыгыштарак урман массивында, тамагы — Яморза авылыннан төньяк-көнбатыштарак. Елга башының абс. биеклеге 175 *м*, тамагыныкы — 77 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 55%. Ч.ның 1,2 *км* озынлыктагы кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,36 *км/км*^{2}. Туенуы катнаш, күбрәк кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 1–3 *л/с·км*^{2}. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 58 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 47 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрель башында башлана. Елга ноябрь башында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,012 *м*^{3}*/с*. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*.

ЧҮГҮЧӨ́К, Кытайның Шөн җан-Уйгыр автономияле р-ндагы шәһәр. Урта Азиядәге чиктә рус-кытай сәүдәсен җайга салу турындагы Гол җа шартнамәсе (1851) буенча рус сәүдәгәрләренә Ч.тә сәүдә итү мөмкинлегебирелә. Анда рус факториясе һәм консуллыгы ачыла. Ч. Россия һәм Кытай арасындагы сәүдәдә зур роль уйнарга керешә. 19 йөзнең 2 нче яртысыннан шәһәрдә Идел буеннан һәм Уралдан күченеп килгән татарлардан *мәхәллә* оеша башлый. Озак еллар дәвамында Ч.нең имамы, ш.у. шәһәрнең һәм округның казые К.*Халиди* була. 1930 еллар уртасына кадәр Ч.тә татар сәүдәгәрләренең (башлыча Семипалатинскидан күченеп килүчеләрнең) берничә сәүдә компаниясе эшләп килә, алар Россия, соңрак СССР б-н экспорт-импорт сәүдәсе алып баралар. 1917 дән соң, бигрәк тә Казакъстанда күмәкләштерү һәм ачлык чорында (1930 еллар), Советлар Союзыннан күчеп килүчеләр хисабына Ч.тәге татарлар-

ның саны шактый арта. 1950 елларда аларның күпчелеге СССР га килеп урнаша.

М.Г.Госманов.


ЧҮКЕ́П БИЗӘ́К ТӨШЕРҮ́, зәркән сәнгатендә махсус чүкегеч (пуансон) б-н алтын, көмеш, җиз әйберләрне бизәү техникасы, ягъни өслеккә рельефлы бизәкләр ясау. Татар зәркәнчеләрендә Ч.б.т. «төймә» дип йөртелә, 3 төрле була: пуансонлы (төрткеле, фигуралы), яссы рельефлы һәм биек рельефлы. Пуансоннар — очына төртке, сызыкча, өч-почмак, йолдыз һ.б. фигуралар төшерелгән чыныктырылган металлда (корыч, эретмә) ясалган таякчыклар. Аларны оста үзе ясый һәм чыныктыра; тәҗрибәле зәркәнчеләрдә аларның саны берничә дистәгә җитә. Ч.б.т.гә канфарлау техникасы да керә, ягъни эшләнмә өстенә очлы без (канфар) б-н вак орлыксыман рельеф ясала. Яссы рельефлы Ч.б.т.дә очы түгәрәк (күләмле шар рәвешендә), озынча түгәрәк һ.б. төрле пуансоннар кулланыла; булачак рәсемнең фоны эчкә төелә, ә бизәк үзе рельефлы (каеш каптырмалары, беләзекләр) була. Биек рельефлы Ч.б.т.дә еш кына калып һәм басма файдаланыла; рәсемнең биек өлешләре металл табакның сул ягыннан сугыла. Ч.б.т. мотивлары үз эченә үсемлек, геом. һәм зооморфлы орнаментның төрле төрләрен ала.





Татарстанда Ч.б.т. сәнгать төре буларак борынгы Болгар чорыннан ук үсеш ала. Археологлар тарафыннан аның төрле төрләре, ш.и. кисеп эшләнгән бизәкләр дә табыла (Болгар, Биләр шәһәрлекләре). Ч.б.т. ысулы сурәтләре уртадагы түгәрәк медальонының алтын йөгертелгән җирлегенә нечкә төртке-ле пуансон б-н эшләнгән көмеш савыт-саба, көзгеләр, каеш каптырмалары, ш.у. җиздән коелган камчы сапларын, пычак сапларын, пломбалар, йозаклар бизәүдә кулланыла, моның белән берраттан алар өстәмә рәвештә уеплап эшкәртелә. Алтын Урда чорында бил буу б-н бәйле эшләнмәләр (аеллар, каеш очлары һ.б.), касәләр, чүмечләр, беләзекләр, алкалар, төймәләр, бөти савытлары чүкеп бизәлә. Ч.б.т. еш кына күпертмә җепкыр, уеплау, каралту, алтын йөгертү б-н берләшә. Казан ханлыгы чорыннан Ч.б.т. техникасы б-н эшкәртелгән җиз кувшин — Сөембикә кувшины дип аталган (к. *Насыйр оста*) уникаль савыт, әре төймәләр һәм бил каешы каптырмасы үрнәкләре килеп ирешкән.

18–19 йөзләрдә рельефлы Ч.б.т. юлы б-н күптөрле алтын, көмеш, электрум (алтын һәм көмеш катнашмасы), алтын йөгертелгән эшләнмәләрдә — бил каптырмаларында, муенсаларда, яка чылбырларында Коръән савытларында, чулпыларда, тезмәләрдә, пластиналардан эшләнгән беләзекләрдә, аелларда һ.б. формаларның, бизәкләрнең югары сурәтләү тәэсирлелегенә ирешелә. Аларда чүкелгән бизәк, еш кына төп бизәлеш элементы булудан бигрәк, каралтылган, уепланган бизәкләрнең каймалары итеп тә файдаланыла (бау, сызыклар, дулкынсыман сабаклар, бөртекләр һ.б. рәвешендәге буйлар). Әйберләрдәге бизәктән калган урыннар, гадәттә, күперенке рельеф һәм ритм төгәллеге ягынан аерылып торучы канфарлау юлы б-н эшкәртелә. Күп көч сорый торган Ч.б.т. 19 йөз уртасыннан калыплау һәм басмага алыштырыла, канфарлау өзек ритмлы түбән рельефлыга әверелә һәм еш кына җиңелчә уепланган челтәр б-н алыштырыла.







Чүкеп бизәк төшерү. 1. Чүмеч. Алтын. Кою, уеплау. 13 йөз. Эрмитаж; 2. Комган һәм ләгән. Бакыр. 18 йөз ахыры. ТР Милли музее; 3. Шәраб кувшины. Җиз. Уеплау, кою. 16 йөзнең 1 нче яртысы. ТР Милли музее; 4. Беләзек фрагменты. Көмеш. Уеплау. 19 йөз; 5. Беләзек. Көмеш, алтын йөгертү, сердолик, фирүзә. Уеплау, инкрустация. 19 йөз.

20 йөз башында Ч.б.т. гамәлдән чыга һәм 20 йөз уртасында проф. рәссамнарның станлы скульптура һәм монументаль-бизәлеш сәнгате: дивар тәлинкәләре, панно, идән вазалары, композиция элементлары, тышлау бизәлеше (мәс., колонналарны), җәмәгать биналары һәм торак интерьерлары өчен фәзаи конструкцияләр (декоратив рәшәткәләр, киртәләр), кайвакыт бина экстерьерлары буларак яңарыш ала. 1960 елардан җизгә Ч.б.т. б-н Казан рәссамнары К.Бәширов, М.Зерзизов, А.Сысоев, З. Хөсәенов, 1970–80 елларда Г.Арчуашвили (Түбән Кама ш.), Я.Зиннәтуллин (Лениногорск ш.), М.Мостафин (Әлмәт ш.), М.Шәйдуллин (Чаллы ш.) һ.б. шөгыльләнә. Монументаль Ч.б.т. эшләренең иң әүвәлгеләре арасында — Е.В.Киселёваның Казанда Химиклар мәдәният сарае фойесындагы «Батырлар» (мәйданы якынча 6 *м*², 1969), Татар ашлары йортындагы (М.Мостафин җитәкчелегендәге рәссамнар бригадасы, 1972), Төзүчеләр мәдәният сарае вестибюлендәге «Сабантуй» (Ю.Ефремов, И.Киселёв, 1974) дивар панноларын, Чаллыдагы «Кама» ресторанының диварларындагы бизәкләр (М.Шәйдуллин, 1974). Казан сувенирлар ф-касы рәссамнары һәм халык нәфис кәсепчелегенең өйдә эшләүчеләре ижатында сувенир Ч.б.т. киң таралыш ала.

Әд.: Валеев Ф.В. Орнамент Казанских татар. К., 1969; шул ук. Народное декоративное искусство Татарстана. К., 1984; Валеева-Сулейманова Г.Ф. Монументально-декоративное искусство Советской Татарии. К., 1984; шул ук. Декоративное искусство Татарстана (1920-е — начало 1990-х годов). К., 1995; Крамаровский М.Г. Золото Чингисидов: культурное наследие Золотой Орды. СПб., 2001.

Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова.

«ЧҮКЕ́Ч», иҗтимагый-сәяси, әдәби, сатирик рәсемле журнал. 1906 елның 22 июненнән 1910 ның мартына кадәр Оренбург шәһәрендә татар телендә нәшер ителә, барысы 78 саны чыга. Атналык журнал буларак күзаллана, әмма басмалар даими чыкмый. Төрле вакытта наширләре һәм мөхәррирләре — Т.*Соловьев*, М.*Алмаев*, З.*Бәшири*. Карикатуралар рәссамнар Орлов, Романов, графиклар Л.Мостафин (псевд. «Л.М.»), А.Иделбаев (псевд. «А.И.») тарафыннан ясала, кайвакыт башка басмалардан, ш.и. «Мелла Насреддин» әзәрбай җән сатирик журналының күчереп бастырыла. Актив авторлары арасында — Г.Борнашев, Н.Думави, Г.Мустакаев, Г.Рәхмәти, З.Өммәти һ.б. Журналның баштагы 2 саны ике өлештән тора: берсе «газета» дип атала, анда җитди материаллар урын ала, икенчесе — «сатира һәм юмор бүлеге»; калган саннар журнал форматында

чыга. «Ч.» демократик идеяләрне пропагандалый, әсерлар һәм кадетлар адресына тәнкыйть б-н чыга, социализм б-н ислам арасындагы уртак якларны билгели, татар халкы хокукларында тигезлек өчен чыгыш ясый, татарлар тыгыз урнашкан төбәкләрдәге вакыйгаларны, җәмгыятьтәге тискәре күренешләрне яктырта. Журналда шигырьләр, җырлар, хикәяләр дөнья күрә. Нәкъ менә анда беренче булып татар драматургы М.Фәйзи үзенең әсәрләрен бастыра. Басмада З.Бәширинең унлап шигыре һәм фельетоннары чыга; аларның кайберләрен Г.Тукай тәнкыйтьли, «*Яшен*» ж-лында бәхәс бара. «Ч.» материалларында архаизмнар, неологизмнар, диалектизмнар, варваризмнар актив кулланыла. Кушымта сыйфатында берничә китап, ш.и. Мөселманнарның «Түбән Новгородтагы корылтае турында тәфсилле хисап һәм аның суллар тарафыннан тәнкыйтләнүе» («Подробный отчёт о третьем съезде мусульман в Нижнем и критика его со стороны левых»), «Мәктәпләрнең Диния нәзарәтенә тапшырылуы» («Передача школ Духовному Собранию», авторы — Т.Соловьев) һ.б. басыла.

Әд.: Гыймадиев Y. Сатира коралы белән. К., 1977.

ЧҮКРИ́-АЛА́Н авылы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 20 *км* көньяк-көн-чыгыштарак, Имәнле елгасы буенда. 2010 елда 52 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, сарык асрау. 18 йөзнең 1 нче яртысында нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстиянәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, җил тегермәне, 3 вак-тояклар кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 436 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Зөя өязе Ивановка волостенда, 1920 дән ТАССРның Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Ульянково, 1927 нең 1 августыннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 38 ир-ат; 1859 да — 242, 1897 дә — 453, 1908 дә — 457, 1920 дә — 445, 1926 да — 316, 1938 дә — 368, 1949 да — 245, 1958 дә — 201, 1970 тә — 219, 1979 да — 198, 1989 да — 79, 2002 дә — 71 кеше.

ЧҮЛ УТЧЫГЫ́ (Arabidopsis), әвернә чәчәклеләр семьялыгыннан бер- һәм икееллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Татарстан терр-ясендә бер төре — Таль Ч.у. (A. thaliana) бар; ара-тирә барлык районнарда очрый. Коры тау битләрендә, таш-ландык җирләрдә, чүплекләрдә үсә. Биекле-ге 8–30 *см* булган соргылт төстәге берьеллык үсемлек. Сабагы нәзек, туры, тармаклы. Яфраклары озынча ланцетсыман, кырыйлары сирәк тешчекле: тамыр яны яфраклары божрага җыйналган, сабактагылары — утырма, кечерәк, күп түгел. Чәчәкләре ак, вак, сабак очындагы көпшәк чук чәчәк төркеменә җыйналган. Җимеше — кузакчык. Апрель–июньдә чәчәк ата. Җимешләре июнь–июльдә өлгерә. Орлыктан үрчи. Яшь үсемлекләре азык-төлек хәзерләүдә кулланыла.

ЧҮЛ УТЫ́ (Arabis), әвернә чәчәклеләр семьялыгыннан бер-, ике- һәм күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 100 дән артык төре билгеле, Төньяк ярымшарның уртача поясында һәм тропик Африка тауларында таралган. Татарстан терр-ясендә 3 төре бар. Иенке Ч.у. (A. pendula) һәм уксыман яфраклы Ч.у. (A. sagittata) — ара-тирә барлык районнарда, Жерард Ч.у. (A. gerardii) Кама һәм Идел алдында очрыйлар. Дымлы һәм күләгәле урыннарда, урман буйларында, куаклыкларда, ерымнарда үсәләр. 15–150 *см* биеклектәге ике- һәм күпьеллык үсемлекләр. Сабагы гади яки тармаклы, йолдызсыман төкчәләр б-н капланган. Тамыр яны яфраклары озынча түгәрәк, сабакчалы; сабактагылары — утырма, йөрәксыман, сабакны урап алганнар. Чәчәкләре вак, ак. Җимешләре — озынча кузакчык. Май–июльдә чәчәк ата-лар. Җимешләре июль–августта өлгерә. Орлыктан һәм вегетатив юл б-н үрчиләр. Иенке Ч.у.ның җир өсте өлешендә флавоноид, гликозид, аскорбин к-тасы бар. Халык медицинасында төнәтмәсе баш авыртулары вакытында кулланыла. Терлек азыгы үсемлеге. Жерард Ч.у. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

ЧҮЛМӘ́К САЗЫ́ КҮЛЕ́, Көнбатыш Кама аръягында. Ата һәм Бизнә елгалары субүләрендә, Әлки р-ны Чуаш Шәпкәсе авылыннан 1 *км* көньяктарак. Су өслегенең мәйданы 0,12 *га*. Суының күләме 8,5 мең $м^3$. Озынлыгы 70 *м*, иң зур киңлеге 25 *м*. Уртача тирән-леге якынча 1 *м*, иң зур тирәнлеге 1,5 *м*. Күлнең килеп чыгышы ясалма (казылма). Суы бик йомшак, саргылт төстә, гидрокарбонат-хлорид-кальцийлы. Үтә күренмәлелеге 76 *см*. Хуҗалык-көнкүреш максатларында кулланыла.

ЧҮП ҮЛӘННӘ́Р, а.х. җирләрен чүпләүче һәм а.х. культураларына зарар китерүче үсемлекләр. 1500 төре билгеле. ТРда 400 дән артык төре бар, һәр җирдә 50 ләп төре очрый (иң зыян китерүчеләре — кыр билчәне, *кыр эт әчәгесе*, *алабута*, гади *солычык*, сары *билчән*, шушшма *сарут*, басу *кырлыгы*). Бакчаларны, урман полосаларын, яшел утырмаларны, чәчәкләрне, елга, сулыкларны чүплиләр; а.х. үсемлекләрен күләгәлиләр, чорныйлар һәм аларның сөрлегүенә китерәләр, туфракны киптерәләр һәм ярлыландыралар, аның кәслөнүенә һәм сазлануына китерәләр. Печәнлекләрдәге һәм көтүлекләрдәге терлек азыгы үләннәрен кысрыклап чыгарып, Ч.үү. терлек азыгы җирләренең уңдырышлылыгын һәм терлек азыгының туклану кыйммәтен киметәләр. А.х. продукциясендә чүп үләннәр һәм аларның орлыклары булу аның азык һәм тәм сыйфатларын начарлата, орлыклык материалны сортларга аеруны һәм чистартуны авырлаштыра, аны саклауны катлауландыра. Ч.үдә еш кына а.х. культураларының күп кортлыкчылары һәм авыруларының беренчел тарылу чыганагы барлыкка килә (эт әчәгесе уҗым ябалакчыклары һәм болын күбәләгенең таралуына, шайтан таягы — борчак бөртекчәсе, ак алабута — чөгендер филчекләренең, паслённар — бәрәңге рагы һәм паслён-чалар семьялыгының башка авырулары, сарут һәм кычыткан — тутык авыруы таралуга булышлык итә). Ч.үнең үскән урынына һәм махсуслаштырылуына карап бүленеше: кыр чүпләре һәм сөрүле җир чүпләре (сегеталь); печәнлекләр һәм көтүлекләр (табигый җирләр), урман, сулыклар, елгалар, каналлар һәм аларның яр буйлары чүпләре; чүп-лекләр, каракура (рудераль); махсус мәйданчыклар чүпләре (чәчүлекләрдә авыр табылалар һәм орлыклык материалдан авыр аерылалар). Карантин чүпләргә әрем яфраклы аморозия, алсу ачыкый, калын җимешле софора керә. Ч.үү. бик югары җимеш бирүчәнлекләре, тышкы шартларга җайлашырга сәләтле булулары, төрле вакытта үреп чыгулары һәм орлыкларының тишелеп чыгуы озак дәвам итүе, таралу ысулларының күп төрле булуы б-н аерылалар. Туклану һәм үрчү ысулы һәм яшәү вакыты озынлыклары буенча Ч.үнең аерым төркемнәргә бер-ләштерәләр: паразит булмаган (төп төркем) — тамырлары, яфраклары бар, туфрактан туеналар; паразитлар — тамыр һәм яфраклары юк, фотосинтезга һәм мөстәкыйль тамырдан тукланува сәләтле түгел (аларны тамырлыга — шомбия үләне һәм сабаклыга — чормавык бүләләр); ярымпаразитлар — яшел яфраклылар һәм фотосинтезга сәләтлеләр, ләкин хуҗасы хисабына да вегетация чорын узарга мөмкиннәр (кыска күз уты, зур шөлдерут, саз тубалагы). Фәнни нигезләнгән көрәш чаралары системасын уңышлы куллану өчен, җирләрнең чүпләнү дәрәҗәсен һәм типларын билгелиләр. Чүпләнү тибы (тамыр үргенле, тамырлы, яшь һәм катлаулы) — иң зарарлы Ч.үнең үсүенә карап, чүпләнү дәрәҗәсе Ч.үнең чәчүлекләрдәге санына карап билгеләнә. Бу характеристикаларны исәпкә алып, һәр басу өчен Ч.үү. б-н көрәш буенча профилактик һәм юкка чыгару чаралары системасы эшләнә, ул агротехник чараларны үз эченә ала: чәчү әйләнеше, туфракны эшкәртүysуллары, гербицидлар куллану, карантин Ч.үгә каршы карантин чаралар (к. *Карантин*). Яңа химик чараларны сынау һәм Ч.үү. б-н көрәшү өчен агротехник чараларны эшләү б-н «Россия авыл хуҗалыгы үзәге» федераль дәүләт учреждениесенең ТР буенча ф-лында һәм Казан аграр ун-тында шөгыльләнәләр. Ш.у.к. *Күпьеллык чүп үләннәр, Яшь чүп үләннәр*.

Әд.: Новицкий С.М. Сорные растения и меры борьбы с ними. Минск, 1966; Бадина Г.В., Королёв А.В., Королёва Р.О. Основы агрономии. Л., 1988.

Р.Ә. Әсретдинова.

ЧҮПРӘ́, чүпрә гөмбәләре (Saccharomycetales), беркүзәнәкле микроскопик гөмбәләр. Якынча 500 төре билгеле. Ч. күзәнәкләренең озынлыгы 8–10 *мкм*, киңлеге 2–7 *мкм*. Нигездә, бөреләнү юлы б-н үрчиләр, бу вакытта түгәрәк, йомырка сыман яки озынча түгәрәк күзәнәкләр барлыкка килә, алар төссез, сары һәм кызыл колонияләр хасил итә. Температура 22–30 °С, водород күрсәт-

кече — pH 5,5–6 һәм туену мохитендә шикәрнең күләме якынча 1% булганда Ч. аеруча нык үрчи. 50–55 °С темп-рада үләләр. Ч.дә углеводлар, В төркеме витаминнары, аук-синнар, төрле ферментлар бар. Күпчелек Ч.гә хас физиол. үзенчәлек — шикәрнең спиртлы әчүен барлыкка китерү үзлеге, бу вакытта шикәрнең этил спиртына һәм углекислый газга таркалуы күзәтелә. Кыргый һәм культуралы Ч.гә бүленә.Табигатьтә Ч. үсемлекләр, чәчәк нектары, җимеш, җиләкләр һ.б.ның өслегендә очрый. Мед., икмәк пешерү һәм терлек азыгы Ч.сен җитештерү буенча махсус заводлар бар. Мед. һәм икмәк пешерү Ч.сен җитештерүдә сыра Ч.се (Saccharomyces cerevisiae) кулланыла. Икмәк пешерү Ч.сен ТР терр-ясендә Буа шикәр з-ды чыгара. Сыек сыра Ч.се кеше организмының инфекцияләргә каршы торучанлыгын арттыра. Аларны анемия, шикәр диабеты, чуан чыкканда, яман шеш һ.б. авырулар вакытында билгелиләр. Ч. һәм чүпрәсыман гөмбәләр арасында кеше һәм хайван авыруларын, ш.и. бластомикоз һәм кандидамикоз китереп чыгаручы патоген формалар да очрыйлар. Терлек азыгы Ч.сен җитештерүдә Ч.нең Torula utilis, Monilia murmanica һ.б. төрләрен кулланалар. Агач калдыкларында, спирт җитештерүдә, саламда үстерәләр, аксымлы-витаминлы өстәмә буларак файдаланалар.

Әд.: Жизнь растений. М., 1976. Т. 2.

ЧҮПРӘЛЕ́ РАЙОНЫ́, ТРның көньяк-көнбатыш өлешендә, Чуаш Республикасы һәм Ульянов өлкәсе б-н чиктәш урнашкан. Мәйданы — 1029,5 *км*². 19 авыл җирлеген, 52 торак пунктны берләштерә. Үзәге — Иске Чүпрәле авылы. Халкы — 22813 кеше (2017, 2002 елгы халык исәбе буенча, татарлар — 57,6%, чуашлар — 40,9%). Халкының уртача урнашу тыгызлыгы — 1 *км*² га 25 кеше. Район 1930 елның 10 августында оештырыла. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа өязендә, 1920 — 30 елларда ТАССРның Буа кантонында. Оешкан көненнән районга 40 авыл советы, 59 торак пункт керә, аларда 64275 кеше (татарлар — 41523, чуашлар — 22500, руслар — 252) яши. Районның чикләре һәм адм. бүленеше берничә тапкыр үзгәрә. 1935 тә Ч.р.ның берничә авыл советы яңа төзелгән Будённый р-нына бирелә. 1940 та районның мәйданы — 824 *км*², халкы — 57,4 мең кеше, 35 авыл советы, 52 торак пункт була. 1959 ның 12 октябрендә Ч.р. составына таркатылган *Чылы районының* бер өлеше кушыла. 1960 та район 1103 *км*² җир били, аңа 21 авыл советы, 61 торак пункт керә. ТАССРда адм. берәмлекләрне берләштерү сәбәпле, Ч.р. бетерелә (1963 нең 1 февр.), терр-ясе Буа р-нына бирелә. Район элеккеге хәленә кайткач (1966 ның 30 дек.), мәйданы — 1047 *км*², халкы — 49,1 мең кеше, 19 авыл советы, 55 торак пункт исәпләнә.

Ч.р.ның рельефы — калкулы тигезлек (биеклеге 170 — 220 *м*). Район терр-ясеннән Чылы һәм аның кушылдыклары Кече Чылы, Бизнә, Олы Яклы елгалары ага. Җирләре, башлыча, селтесезләнгән, типик һәм көлсу кара туфраклы. Терр-ясенең 3% ы — урманлык. Фосфорит, янучан катламташ, торф,



балчык, балчыксыман туфрак ятмалары бар. Саклаулы табигать объекты: *Кирәмәт* ландшафтлы табигать истәлеге (Яңа Чәке урман даласы). Район терр-ясендә бронза гасырдан алып Казан ханлыгына кадәрге чорга караган 20 ләп археол. истәлекләр табыла. Район икътисадының нигезен терлекчелек тәшкил итә. А.х. җирләре — 92,2 мең *га*, сөрүлекләр — 73,1 мең *га* (2002). Сабан бодае, көзге бодай, арыш, арпа, солы, тары, карабодай, борчак игелә; шикәр чөгендере, бәрәңге үстерелә. 2004 тә районда 26 а.х. пр-тиесе: 13 күмәк пр-тие, 12 крәстиян хуҗалыклары ассоциациясе, 1 ҖЧҖ эшли. Сәнәгать пр-тиеләре: май-сыр з-ды, икмәк-азык-төлек комб-ты, басмаханә, катнаш азык (Иске Чүпрәле а.) һәм яшелчә киптерү з-длары (Уби а.), элеватор (Борындык а.). Ч.р. терр-ясеннән Цивильск–Ульянов автомобиль юлы уза. Районда 35 гомуми белем бирү мәктәбе (2004/05 уку елында 4319 укучы), ш.и. 2 башлангыч, 10 тулы булмаган урта, 22 урта мәктәп; һөнәри уч-ще, 22 мәктәпкәчә тәрбия учреждениесе, 43 клуб, 32 китапханә, 2 хастаханә (2000) эшли. Татар һәм чуаш телләрендә «Туган як» — «Тăванен» район г-талары нәшер ителә.

Әд.: Субаев Р.С. Чүпрәле узган еллар, үткән юллар. Чүпрәле, 2000; Гафаров И.А. Туган як мирасы — Наследие родного края. 3 нче кит. К., 2017; Закиров И.З. Край Дрожжановский. Историко-публицистический очерк. Чебоксары, 2015.

ЧҮРӘКӘЙЛӘ́Р, кечкенә елга үрдәкләренең гомуми исеме. Якынча 20 төре билгеле, поляр өлкәләрдән кала киң таралганнар. Татарстан терр-ясендә 2 төре бар: сыбызгы чүрәкәй (алмабаш) (Anas crecca) һәм чытырдавык чүрәкәй (A. querquedula). Барлык районнарда да очрый. Сулык ярлары буенда яшиләр. Күчмә кошлар. Сыбызгы чүрәкәй — елга үрдәкләре арасында иң кечкенәсе: гәүдәсенең озынлыгы 35 *см* тирәсе, авырлыгы 200–300 *г*. Башы көрән төстә, ян-ягыннан яшел буй сузылган. Бүксәсе кара таплы охрасыман. Ян-яклары сузылып киткән кара бизәкле. Канатлары ялтырап торган яшел «көзгечекле». Исеме ата кошның туй чорында чыгару чы тавышына бәйле. Чытырдавык чүрәкәй берникадәр зуррак. Язын ата үрдәкнең тавышы чытырдап бакылдауны хәтерләтә (исеме шуннан). Башы көрән төстә, күзеннән җилкәсенә таба ак буй сузылган. Каурый капламы аксыл коңгырт, чуар. Томшыгы кара. Аяклары гәүдәсенең арткы ягындарак, йөзү элпәләре яхшы үсеш алган. Канатлары тар һәм очлы. Манёвр ясап тиз оча; судан һәм коры җирдән югарыга вертикаль диярлек күтәрелергә мөмкин. Моногамнар. Оясын (тирән булмаган чокырчык) су янында кора. Ак яки аз гына саргылт 7–12 йомырка сала. Яңа гына чыккан балалары куе мамык б-н капланган, беренче көннәреннән үк яхшы йөзәләр һәм чумалар, коры җирдә җитез йөгерәләр. Су үсемлекләренең орлыклары, бөжәкләр һәм моллюскләр б-н тукланалар. Кышлау урынына сентябрь–октябрьдә очып китә. Аучылык спорты объекты.

ЧҮРИ́-БУРА́Ш авылы, Апас р-нында, шәһәр тибындагы Апас посёлогыннан 6 *км* көнчыгыштарак, Үләмә елгасы буенда. 2010 елда 393 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 13–14 йөзләрдә хәзерге Ч.-Б. урынында авыл була, 17 йөз уртасында морза Бибарс Ишәев милке булып исәпләнә. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет, су һәм 4 җил тегермәне, 4 ярма яргыч, 7 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1457,5 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Тәтеш өязе Ильинка-Шонгат волостенда, 1920 дән ТАССРның — Тәтеш, 1927 дән Буа кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Апас, 1963 нең 1 февраленнән — Тәтеш, 1964 нең 4 мартыннан Апас р-нында. Халык саны: 1782 дә — 101 ир-ат; 1859 да — 570, 1897 дә — 1219, 1908 дә — 1358, 1920 дә — 1295, 1926 да — 1087, 1938 дә — 1156, 1949 да — 1047, 1958 дә — 835, 1970 тә — 1047, 1979 да — 690, 1989 да — 447, 2002 дә — 438 кеше.

ЧҮРИ́-БУРА́Ш УРМА́Н-ДАЛАСЫ́, к. *Гран-Тау*.

ЧҮРИЛЕ́ тимер юл разъезды посёлогы, Арча р-нында, Арча шәһәреннән 12 *км* көньяк-көнбатыштарак, Казан–Әгерже тимер юлы буенда. 2010 елда 11 кеше (руслар, татарлар) яши. 1920 елларда нигез салына. Оешкан көненнән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Арча р-нында. Халык саны: 1958 дә — 45, 1970 тә — 34, 1979 да — 39, 1989 да — 33, 2002 дә — 21 кеше.

ЧҮРИЛЕ́ РАЙОНЫ́, ТАССРда. 1944 елның 19 февралендә оештырыла. Үзәге — Яңа Чүриле авылы. 1920 гә кадәр терр-ясе Казан губернасының Казан, Лаеш һәм Мамадыш өязләрендә, 1920 дән ТАССРның Арча һәм Мамадыш кантоннарында, 1930 елларда Арча һәм Саба р-ннарында. 1948 дә Ч.р.нда 16 авыл советы, 58 торак пункт була. 1956 да районның мәйданы — 625,8 *км*², 1 посёлок, 14 авыл советы һәм 56 торак пунктны берләштерә. 1956 ның 17 маенда Ч.р. таркатыла, терр-ясе Арча һәм Саба р-ннарына бирелә.

ЧҮТЕ́ елгасы, к. *Каратай*.

ЧҮТЕ́ авылы, Лениногорск р-нында, Лениногорск шәһәреннән 26 *км* көнбатыштарак, Каратай елгасының югары агымы буенда. 2010 елда 86 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Башлангыч мәктәп, клуб. 1760–80 елларда нигез салына.

Рев-циягә кадәрге чыганакларда Яңа Вершина исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы типтәрләр һәм дәүләт крәстияннәре катлавына бүленә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет була. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1003 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Самара губернасының Бөгелмә өязе Кузайкино волостенда, 1920 дән ТАССР-ның Бөгелмә кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Шөгер, 1959 ның 16 октябреннән Лениногорск р-нында. Халык саны: 1859 да — 344, 1889 да — 505, 1910 да — 606, 1920 дә — 594, 1926 да — 521, 1938 дә — 436, 1949 да — 392, 1958 һәм 1970 тә — 313 әр, 1979 да — 230, 1989 да — 163, 2002 дә — 134 кеше.

ЧҮТИ́ авылы, Кайбыч р-нында, Олы Кайбыч авылыннан 36 *км* көнбатыштарак, Гөбенә елгасы буенда. 2010 елда 673 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1646 дан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә; кайберләре ат урлап кәсеп итә (иң атаклысы Шәкүр Рәхимов — Шәкүр Карак). 20 йөз башында Ч.дә 2 мәчет, мәдрәсә, 2 җил тегермәне, 4 ярма яргыч, тимерче алачыгы, 10 вак-төяклөр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 2866 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Цивильск өязе Кешәл волостенда, 1920 дән Чуваш автономияле өлкәсендә, 1921 дән ТАССРның — Буа, 1921–22 еллардан Зөя кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Ульянково, 1927 нең 1 августыннан — Кайбыч, 1944 нең 19 февраленнән — Подберезье, 1956 ның 17 маеннан — Кайбыч, 1963 нең 1 февраленнән — Буа, 1964 нең 4 мартыннан — Апас, 1991 нең 19 апреленнән Кайбыч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 96 ир-ат; 1859 да — 873, 1897 дә — 1867, 1908 дә — 2599, 1920 дә — 2782, 1926 да — 2097, 1938 дә — 1561, 1949 да — 1362, 1958 дә — 1206, 1970 тә — 1047, 1979 да — 1069, 1989 да — 823, 2002 дә — 709 кеше. Мәдрәсә бинасы — 19 йөз ахыры-20 йөз башы архит-ра истәлеге.

ЧЫБЫ́К ҮЛӘ́Н (Kochia), алабутачалар семьялыгыннан берьеллык үләнчел үсемлекләр яки ярымкуакчыклар ыругы. Якынча 90 төре билгеле, башлыча, Австралиядә, ш.у. Евразия, Африка, Төньяк Америкада таралганнар. Татарстан терр-ясендә 2 төре бар: яткын Ч.үл. (K. prostrata) — Көнбатыш һәм Көнчыгыш Кама аръягында, себеркелек үлән (K. scoparia) Кама алдында очрыйлар. Акбурлы һәм ташлы тау битләрендә, тимер юл буйларында, чүпле урыннарда үселәр. Яткын Ч.үл. — 20–50 *см* биеклектәге ярымкуакчык, тамыр системасы көчле, ботаклары күтәрелеп тора, себеркелек үлән — 30–70 *см* биеклектәге нык тармаклы берьеллык үсемлек. Ч.үл.нең яфраклары вак, ланцетсыман яки кыяк, аксыл яшел төстә. Чәчәкләре 1–3 әр булып яфрак куенты-



Яткын чыбык үлән.

на җыйналган. Июль–сентябрьдә чәчәк аталар. Августтан башлап җимеш бирә башлыйлар. Орлыктан үрчиләр. Себеркелек үлән — декоратив үсемлек. Яткын Ч.үл. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

ЧЫБЫКЛЫ́ елгасы, Көнчыгыш Кама аръягында, Шумыш елгасының (Дала Зәе елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 11,1 *км*. Бассейнының мәйданы 46,6 *км*^{2}. Зәй р-ны терр-ясеннән ага. Елга башы Суыкчишмә авылыннан 2 *км* көнбатыштарак урман массивында, тамагы — Чыбыклы авылыннан көньяк-көнчыгыштарак. Елга башының абс. биеклеге 175 *м*, тамагыныкы — 82 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 15%. Ч.ның 1,8 дән 5,7 *км* га кадәр озынлыктагы 2 кушылдыгы бар. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,41 *км/км*^{2}. Туенуы катнаш, күбрәк кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,25–0,5 *л/с·км*^{2}. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәенык саегуы б-н характерлана. Бассейнда елык су агымының уртача күпьеллык катламы 92 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 82 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, март ахырында башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,016 *м*^{3}*/с*. Суы бик каты: язын 9–12 *мг-экв/л*, кышын һәм җәен 12–20 *мг-экв/л*. Гомуми минеральләшүе язын 300–400 *мг/л*, кышын һәм җәен 1000 *мг/л* дан күбрәк.

ЧЫБЫКЛЫ́ авылы, Зәй р-нында, Зәй тимер юл станциясеннән 12 *км* көньяктарак, Чыбыклы елгасы буенда. 2010 елда 619 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1735 кә кадәр нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, чыпта һәм капчык сугу, тәгәрмәч һәм чана ясау б-н шөгыльләнә. 1773–75 еллардагы Крәстияннәр кузгалышында Е.И.Пугачёв ягында сугышалар. 20 йөз башында Ч.да мәчет, мәктәп, 2 тегермән, 2 ярма яргыч, икмәк саклау-сату, 1 мануфактура һәм 3 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1733 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Зәй волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә, 1921 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Акташ, 1935 нең 10 февраленнән — Зәй, 1963 нең 1 февраленнән — Әлмәт, 1972 нең 1 ноябреннән Зәй р-нында. Халык саны: 1859 да — 469, 1897 дә — 1051, 1906 да — 1221, 1913 тә — 1401, 1920 дә — 1261, 1926 да — 1126, 1938 дә — 1087, 1949 да — 820, 1958 дә — 843, 1970 тә — 878, 1979 да — 739, 1989 да — 610, 2002 дә — 607 кеше.

Әд.: Заинская энциклопедия. К., 1994.

ЧЫБЫЛДЫ́К, каплама, аның б-н, нигездә, йокы урынын бүлеп куйганнар. Ул традицион татар йортына хас предмет булып тора. Ч. тегү өчен шактый күләмдә тукыма (кайчак 20 *м* га якын) кирәк була, чөнки ул өсте ябулы дүрт почмаклы каплавыч рәвешендә тегелә. Ч. өчен тукыма җитен, кайчак исә киндер җепләрдән тукылган. Бизәкләр рельефлы турыпочмаклыклардан торган. Ч.ны туйга да әзерләгәннәр һәм никахлашучылар ятагы өстенә корганнар. 19 йөзнең 2 нче яртысында Казан арты, Көнчыгыш һәм Көнбатыш Кама аръягы һәм Урал буе татарлары көнкүрешендә Ч. һәркайда таралган була, әмма 20 йөз башыннан аны башта фабрикада җитештерелгән ситсыдан тегелгән чаршаулар алыштыра, бераздан ул бөтенләй кулланылыштан чыга.

Әд.: к. *Чаршау* мәкаләсе.

ЧЫГАНАКЛАРНЫ́ ӨЙРӘНҮ́ ГЫЙЛЕМ́Е, тарих фәненең тарихи, башлыча язма чыганакларны өйрәнү һәм файдалану теориясен, методологиясен, тарихын эшләү б-н шөгыльләнүче тармагы; Ч.ө.г. ярдәмче тарих фәннәре б-н тыгыз бәйләнгән (к.*Тарих*). Казан төбәгендә «фәнгә кадәрге», гамәли Ч.ө.г. элементлары Алтын Урда, Казан ханлыгы чорларында формалаша һәм текстка, язма традицияләргә мөнәсәбәттә, гыйбадәт кылуларда, дини бәхәсләрдә, публицистикада, тәрҗемә сәнгатендә, актлар, ярлыклар, шартнамәләр төзүдә һ.б.да урын ала. Татар ханлыклары Рус дәүләте тарафыннан яулланганнан соң, Ч.ө.г. 17 йөздә – 19 йөз башында тарихи хезмәтләрдә һәм әдәби әсәрләрдә чагылыш таба. (Кадыйр Галибәкнең «Елъязмалар җыентыгы», Х.Мөслиминең «Тәварихы Болгарийә»се һ.б.). Кама-Идел төбәге терр-ясендәге сугышлар, Казанда күп тапкырлар кабатланган янгыннар, миссионерлар погромнары һ.б. нәтиҗәсендә борынгы һәм урта гасырлар татар тарихи әсәрләре сакланмаган диярлек. Бу Идел буе һәм Урал алды халыклары тарихын өйрәнүне кыенлаштыра.

Чыганакларның аерым бер категориясе — халык-төбәкчелек тарихы әдәбияты ядкәрләре (ш.и. гаилә риваятьләре, *шәҗәрәләр*). Тарихи әдәбиятның бу төре татарларда 18–19 йөзләрдә әсәрләрнең яңа юнәлеше — «җирле тарихлар», ягъни авыллар, салалар, шәһәрләр тарихы барлыкка килүнең һәм үсешенең нигезен хасил итә. Чыганаклар башлыча шәхси сыйфатларга ия (ш.и. актлар, кулъязмалардагы колофон (әсәрнең иҗат ителүе яки күчерелүе турында мәгълүматлар китерелгән) язмалар, хуҗа тарафыннан өстәлгән язулар). Татар язма

чыганакларының тагын бер төре — *тарихи җырлар* (ш.и. болгар кызлары, Сөембикә, лашманнар турында). Казан төбәгендә Ч.ө.г. фән буларак 19 йөздә формалаша. Аның үсешенә 1804 елда Казан ун-ты ачылу һәм аның каршында *Көнчыгыш телләр бүлеге* оештырылу булышлык итә. 19 йөзнең 1 нче яртысыннан Казанда шәрекъ чыганакларын барлау һәм өйрәнү б-н Х.М.*Френ*, К.Ф.*Фукс*, Ф.И.*Эрдман*, И.Н.*Березин*, И.И.*Хәлфин*, М.К.*Казимбәк*, О.М.*Ковалевский*, В.П.*Васильев*, Г.*Чокрый*, Г.*Утыз-Имәни*, Г.С.*Саблуков*, И.Ф.Готвальд, Н.Ф.*Катанов* һ.б. шөгыльләнәләр. Аларның эшчәнлеге нәтиҗәсендә «Кыйссаи Йосыф» әсәре, Ибне Фазлан, И.Бикмөхәммәдов язмалары һ.б. нәшер ителә. Казан ун-ты каршында Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте оештырылганнан соң (1878), Ч.ө.г. алга таба үсеш кичерә. Идел буе халыклары тарихына караган чыганакларны төрле елларда барлау һәм өйрәнү б-н Н.П.Загоскин, Н.А.Фирсов, И.А.Бодуэн де Куртенә, В.В.Радлов, Ш.Мәржани, Г.Н.Әхмәров, М.С. Аитов, В.Г.Тизенгаузен, К.Насыйри, Г.М.Рәхим һ.б. шөгыльләнә. Шәрекъ чыганакларын өйрәнү нәтиҗәсендә Казанда И.И.Хәлфин «Әхвале Чыңгыз хан вә Аксак Тимер» (1819; 2 нче басма — 1822), Әбелгазый Баһадур ханның «Шәҗәрәи-төрек» (1825), А.К.Казимбәк Сәед Мөхәммәд Ризаның «Ассәб Сәйяр» («Җиде планета», 1832) әсәрләрен, И.Н.Березинның «Шәрекъ тарихчылары китапханәсе» сериясендә 16–17 йөзләр хан ярлыклары текстларын («Шәйбанинамә», Кадыйр Галибәкнең «Елъязмалар җыентыгы», «Тәварихы Рәшиди», 1849–54), Х.Мөсліминең «Тәварихы Болгарийә»сен, Н.И.Ильминский Заһаретдин Бабурның «Бабурнамә»сен һ.б.ны бастырып чыгаралар. Дөнья күргән чыганаклар беренче тапкыр В.В.Вельяминов-Зернов тарафыннан аның «Касыйм патшалары һәм ханзадәләре турында тикшеренү» («Исследование о касимовских царях и царевичах», ч. 1–2, СПб., 1863–87) хезмәтендә фәнни әйләнешкә кертелә һәм тәнкыйди анализлана. Рус елъязмалары һәм төрки-татар чыганаклары (аларны үзара чагыштырып) Г.Н.Әхмәров, Һ.М.Атласи хезмәтләрендә файдаланыла. Кырым ханлыгы тарихы буенча 1850 еллардагы документлар текстологик эшкәртүдә Х.Фәезханов тарафыннан «Кырым ханлыгы тарихы буенча Тышкы эшләр министрлыгының Мәскәү баш архивыннан алынган материаллар» («Материалы для истории Крымского ханства, извлеченные из Московского главного архива МИД», (1864; В.В.Вельяминов-Зернов мөхәррирлегендә) җыентыгын да бастырыла, 1860 елларда ул Касыйм шәһәрендәге эпиграфик истәлекләрне тикшерә. Казан төбәгенең язма истәлекләрен өйрәнү б-н Ш.Мәр җәни шөгыльләнә.

Ч.ө.г. мәсь әләләре теоретик-методологик яссылыкта Казан ун-ты укытучыларының лекция курсларында карала. 1846/47 уку елында Россиядә беренчеләрдән буларак проф. Н.А.Иванов рус тарихыннан күзәтү-лекция укый, анда Ч.ө.г. курсы буенча чыганаклар анализлана. Рус историографиясе һәм Ч.ө.г. курсын системалы уку нигезләрен проф. Д.А.Корсаков башлап җибәрә. 1880/81 уку елыннан башлап 30 ел дәвамында диярлек аның тарафыннан «Рус тарихы фәненә кереш» махсус дисциплинасы укыла. Бу курсны укуда проф. П.Г.Архангельский аның дәвамчысы була. Тарих-филол. ф-ты ябылганнан соң (1921), Казан ун-тында Ч.ө.г.н укыту тукталып тора (1944 тан кабат укытыла); Ч.ө.г. курсын В.И.Пономарёв укыта башлый. Ч.ө.г. н укыту б-н Г.Н.Вульфсон, Ш.М.Мөхәммәдьяров һәм Ч.ө.г. буенча укыту-методик ярдәмлекләр, Татарстан тарихы буенча документлар җыентыклары авторлашы Н.М.Силаева шөгыльләнә. Казан ун-ты галимнәре тарафыннан төбәк тарихы буенча чыганаклар нәшер ителә — «Казан төбәге тарихы буенча документлар. XVI йөзнең 2 нче яртысы – XVII йөз уртасы» («Документы по истории Казанского края. Вторая половина XVI – середина XVII вв.», 1990; төзүчеләр И.П.Ермолаев, Д.Г. Мостафина), «Татарстан тарихы буенча хрестоматия (XIX йөзнең II яртысы – XX йөз башы» («Хрестоматия по истории Татарии (II пол. XIX – нач. XX вв.», 1979; төзүче Г.Н.Вульфсон) һ.б. дөнья күрә. Татар чыганакларын ачыклау-барлауга, классификацияләүгә һәм өйрәнүгә М.Г.Госманов зур өлеш кертә («XVII — XVIII йөзләр татар тарихи чыганаклары» — «Татарские исторические источники XVII — XVIII вв», 1972; «Җүчи Олысының XIV — XVI йөзләр ярлыкаш актлары» — «Жалованные акты Джучиева Улуса XIV — XVI вв.», 1979). Аның тарафыннан табылган Алтын Урда тарихына нисбәтле документлар урта гасырларны өйрәнүдә Ч.ө.г.ндәге бушлыкларны тулыландыра. Феодализм дәверенең татар нарратив истәлекләре дә (Кадыйр Галибәкнең «Елъязмалар җыентыгы», билгесез авторның «Дәфтәре Чыңгызнамә»се, Х.Мөсліминең һәм Т.Ялчыголның Идел буе Болгар дәүләте тарихы буенча әсәрләре, шәҗәрәләр һ.б.) аның тикшеренүләре объекты була. Галимнең хезмәтләрендә татар Ч.ө.г.нең торышы җентекләп тикшерелә, үзенчәлекләре ачыклана. 1963 тә М.Г.Госманов җитәкчелегендә *археографик экспедицияләр* уздыру өчен Казан ун-тында даими төркем төзелә. 1989 да ун-тта историография һәм Ч.ө.г. каф. оештырыла (А.Л.Литвин, Н.М.Силаева, А.А.Сальникова, Б.Ф.Солтанбәков, В.В.Астафьев, С.Ю.Малышева һ.б.).

2001 дә Казан ун-ты галимнәре тарафынан «Казан өязенең 1647–1656 еллар писцовый кенәгәсе» («Писцовая книга Казанского уезда 1647–1656 годов»); җаваплы мөхәррирләр Н.М.Рогожин, М.Г.Госманов; төзүчеләр И.П.Ермолаев, Д.Г.Мостафина) нәшер ителә.

20 йөз уртасыннан *Казан университетының фәнни китапханәсе* кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә шәркый-төрки һәм рус телендәге чыганакларны тикшерү эшләре алып барыла (А.С.Фәтхиев, В.И.Шишкин, Ж.С.Миңнуллин, Д.Г.Мостафина һ.б.).

1920–30 елларда Ч.ө.г. ш.у. Академүзәкнең *Татар халкын гыйльми өйрәнү җәмгыятендә* үсеш кичерә. Н.Н.*Фирсов*, М.Г.*Худяков*, Г.Г.*Ибраһимов*, Г.С.*Гобәйдуллин* һ.б.ның хезмәтләрендә татар халкы, Окт. рев-циясе, эшчеләр тарихына һ.б.га нисбәтле чыганаклар анализлана. Татарстан тарихының төрле чорларына багышланган җыентыклар нәшер ителә: «Казан Октябре. 1917 ел революциясе хроникасы» («Казанский Октябрь. Хроника революции 1917 г.», ч. 1, 1926; төзүче Е.Грачев), «Казан өчен көрәш: 1918 ел да чехлар-учредительләр интервенциясе турында материаллар җыентыгы» («Борьба за Казань: Сборник материалов о чехо-учредиловской интервенции в 1918 г.», 1924), «Татарстанда пролетар диктатураның беренче елы» («Первый год пролетарской диктатуры в Татарии», 1933; М.Вольфович, С.Гафуров мөхәррирлегендә), «Татарстан тарихы материалларда һәм документларда» («История Татарии в материалах и документах», М., 1937; Н.Л.Рубинштейн мөхәррирлегендә), «XIX йөзнең 50–70 елларында аграр мәсьәлә һәм крәстияннәр хәрәкәте: Татарстанның XIX йөзнең икенче яртысы тарихы буенча материаллар» («Аграрный вопрос и крестьянское движение 50–70-х гг. XIX в.: Материалы по истории Татарии второй половины XIX в.», ч. 1, М.–Л., 1936; В.П.Волгин мөхәррирлегендә), «Алтын Урдага нисбәтле материаллар җыентыгы» («Сборник материалов, относящихся к Золотой Орде», М.–Л., 1941; җаваплы мөхәррир П.П.Иванов). Кулъязма ядкәрләрне, ш.и. хан ярлыкларын барлауга һәм өйрәнүгә С.Г.Вахиди зур өлеш кертә (к. *Сәхибгәрәй хан ярлыгы*).

1922–24 тә Г.С.Гобәйдуллин һәм Г.Рәхим сакланып калган чыганаклар нигезендә татар әдәбияты тарихы буенча өч томлы «Татар әдәбияты тарихы» хезмәтен әзерлиләр. Ә.*Вәлиди*, Ибне Фазлан сәяхәте турындагы язмаларны табып, аларны 1920 елларда бастырып чыгара. Борынгы төрки халыклар тарихына нисбәтле чыганакларны барлау һәм тикшерү б-н ш.у. С.Н.*Максуди*, Г.*Баттал*, Г.*Айда*, Ә.Тимер, 1920–40 елларда татарларның революцион хәрәкәте тарихына кагылышлы документларны туплау һәм нәшер итү б-н *Испарт* («*Пути революции*» ж-лын чыгара) шөгыльләнә. Бөек Ватан сугышы елларында Ч.ө.г. мәсь әләләрен тикшерү эше вакытлыча туктала. Кайбер татар чыганакларын (Алтын Урда тарихы буенча, аерым алганда, «*Идегәй*» дастаның; к. «Татарстан партия оешмасында масса-политик һәм идеология эшенең торышы һәм аны яхшырту чаралары турында») өйрәнү тыела.

Сугыштан соңгы чорда, ике томлык Татарстан тарихын әзерләү б-н бәйле рәвештә, Ч.ө.г. буенча эш көчәя. 1940 елларда — 1950 еллар башында төбәктә крәстияннәр хәрәкәтенә, Бөек Ватан сугышына нисбәтле чыганаклар нәшер ителә: «1861 елгы Бизнә күтәрелеше» («Бездненское восстание

1861 г.», 1948; төзүчеләр А.И.Сочалов, Г.Н.Вульфсон, җаваплы мөхәррирләр А.И.Ямпольская, Д.С.Гутман), «Бөек Октябрь Социалистик революциясе алдыннан Казан губернасында крәстияннәр хәрәкәте» («Крестьянское движение в Казанской губернии накануне Великой Октябрьской Социалистической революции», 1950; Е.И.Устюжанин мөхәррирлегендә), «Татарстан АССР Бөек Ватан сугышы елларында» («Татарская АССР в годы Великой Отечественной войны», 1948). 1950 еллардан Ч.ө.г. СССР ФА Казан ф-лының Тел, әдәбият һәм тарих ин-ты эше б-н бәйле. Төбәктә социалистик төзелешкә, ТАССР тарихына кагылышлы чыганакларга зур игътибар бирелә, документлар һәм материаллар җыентыклары бастырып чыгарыла: «1905–07 елларда Татарстанда революцион хәрәкәт» («Революционное движение в Татарии в 1905–07 гг.», 1957; Х.Х.Хәсәнов мөхәррирлегендә), «Татарстанда Совет хакимиятенең нығуы (1917 елның октябре — 1918 елның июле)» («Упрочение Советской власти в Татарии (октябрь 1917 – июль 1918)», 1964; Н.А.Адрианов мөхәррирлегендә), «Татарстан АССР төзелү» («Образование Татарской АССР», 1963; И.М.Климов мөхәррирлегендә), «ТАССРның төзелүе һәм дәүләти-хокукый хәле. (1917–1926)» («Образование и государственно-правовое положение ТАССР (1917–1926)», ч. 1., 1960; Р.Н.Фәтхуллин мөхәррирлегендә), «Татарстан Бөек Ватан сугышы чорында (1941–1945)» («Татария в период Великой Отечественной войны (1941–1945)», 1963; И.М.Климов, А.М.Җәлалов мөхәррирлегендә), «Татарстан пролетар революция җиңүе өчен көрәштә (1917 елның феврале–октябре)» («Татария в борьбе пролетарской революции (февраль–октябрь 1917)», 1957; М.К.Мөхәрәмов, В.П.Тимофеев, С.Н.Фомичев мөхәррирлегендә), «1927–1937 елларда ТАССРның авыл хуҗалыгын күмәкләштерү» («Коллективизация сельского хозяйства ТАССР в 1927–1937 гг.», 1968; А.М.Җәлалов, Е.И.Устюжанин мөхәррирлегендә), «Татарстанда мәдәни төзелеш. 1917–1941» («Культурное строительство в Татарии. 1917–1941», 1971; төзүчеләр М.Б.Кочурова, Р.Ш.Хәкимова), «Татарстанда мәдәни төзелеш» («Культурное строительство в Татарии (1941–1970)», 1976; М.К.Мөхәрәмов, М.З.Тутаев, мөхәррирлегендә) һ.б.; ш.у. «Октябрь алдыннан Казан губернасы крәстияннәренең революцион көрәше» («Революционная борьба крестьян Казанской губернии накануне Октября», 1958; И.М.Ионенко мөхәррирлегендә) «1926–1941 елларда ТАССРны индустияләштерү» («Индустриализация ТАССР 1926–1941 гг.», 1968). 1980 дә «Татарстан чыганакларны өйрәнү гыйлеме буенча тикшеренүләр» («Исследования по источниковедению Татарии») китабы басылып чыга, анда төбәкнең рев-циягә кадәрге тарихы һәм ТАССР тарихы мәсь әләләре тикшерелә (Р.Г.Әмирханов, В.М.Плужников, Җ.И.Гыйльманов, И.Г.Гыйззәтуллин, Ю.И.Смыков, Р.Г.Фәхретдинов, Ә.Г.Мөхәммәдиев һ.б.).

1940–60 елларда Ә.Н.*Курат* Алтын Урда һәм Кырым ханлыгы ханнарының берничә ярлыгын һәм юлламасын фәнни әйләнешкә җибәрә. Ч.ө.г.нә, крәстияннәр сугышлары заманы татар чыганакларын өйрәнүгә С.Х.Алишев үз өлешен кертә («Татар телендәге XVIII йөз тарихи чыганаклары» — «Исторические источники XVIII в. на татарском языке», Уфа, 1973; «1773–1775 еллардагы Крәстияннәр сугышы баш күтәрүчеләренең татар телендәге документлары» — «Документы повстанцев Крестьянской войны 1773–1775 на татарском языке» («Советские архивы» ж-лында басыла, 1973, № 5), «Крестьяннар сугышында татарлар» («С.Разин восстаниесенә 300 ел») («Казан утлары» ж-лында басыла, 1970, № 7) һ.б.). Аның тарафыннан Г.Г.Ибраһимов әсәрләренең язучының тарихи хезмәтләрен үз эченә алган алган 7 нче томы төзелә һәм текстологик яктан әзерләнә. М.И.Әхмәтҗанов татар нәселләренең һәм гаиләләренең шәҗәрәләрен, Нугай Урдасы тарихы буенча чыганаклар таба һәм аларны тикшерә («Нугай Урдасы: Татар халкының тарихи мирасы», 2002). Вакытлы матбугат тарихына нисбәтле чыганакларны өйрәнүдә Р.Г.Әмирхановның өлеше зур. 1988 дә Казан галимнәре 1773–75 тәге Крәстияннәр күзгалышы тарихы буенча беренчел чыганаклар комплексын фәнни әйләнешкә кертәләр. — «Идел буенда һәм Урал янында Пугачев хәрәкәте җитәкчеләренең өндәмәләре һәм хат алышуы» («Воззвания и переписка вожаков Пугачевского движения в Поволжье и Приуралье», төзүчеләр М.Г.Госманов, С.Х.Алишев, И.А.Гыйләҗев, Ф.М.Хисамова) җыентыгы басылып чыга. Тарихи Ч.ө.г. б-н бергә әдәби Ч.ө.г. үсеш кичерә (Г.М.Халит, Х.Х.Хисмәтуллин, М.В.Гайнетдинов, М.Х.Гайнуллин, Ш.Ш.Абилов, М.Х.Хәсәнов, Н.Г.Юзиев, Я.Г.Абдуллин һ.б.). 1996 да ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм тарих ин-ты җирлегендә ТР ФАнең Тарих ин-ты оештырыла, аның галимнәре Ч.ө.г. өлкәсендәге, текстологик тикшеренүләрне дәвам итәләр.

1990 еллар башында С.Л.Князев тарафыннан 17–20 йөзләрдә Татарстан терр-ясендә нефть һәм газ табу, чыгару тарихы буенча чыганаклар нәшер ителә — өч томлык «Татарстан Республикасының нефте һәм газы: Документлар, цифрлар һәм материаллар» («Нефть и газ Республики Татарстан: Сборник документов, цифр и материалов», т. 1–3, М., 1993) дөнья күрә.

Төбәк тарихы буенча чыганакларны эзләп табу һәм нәшер итү б-н ш.у. ТР МК каршындагы *Баш архив идарәсе* шөгыльләнә, ул 1920–30 елларда «*Записки Центрального архива Татарской Соц. Сов. Республики*», 1995 тән «*Гасырлар авазы — Эхо веков*» ж-лларын чыгара. 1990 еллар ахырыннан Казанда татар Ч.ө.г. мәсь әләләре буенча халыкара конференцияләр уздырыла. Ш.у.к. *Археография.*

Әд.: Госманов М.Г. Каурый каләм эзеннән. К., 1994; Миннуллин З.С. Источниковедческая характеристика татарских частных актов XVII — 1-й половины XIX вв.: Дисс... К., 1988; 50 лет поисков и открытий. К., 1989; Шайхиев Р.А. Татарская народно-краеведческая литература XIX–XX вв. К., 1990; Ахметзянов М.И. Татарские шеджере. К., 1991; Валеев Р.М. Казанское востоковедение: истоки и развитие (XIX в. — 20 гг. XX в.). К., 1998; Жить историей: 60 лет историческому факультету Казанского университета. К., 1999; Источниковедение истории Улуса Джучи (Золотая Орда). От Калки до Астрахани. 1223–1556. К., 2002; Gusmanov M.G. Zur Geschichte der tatarischen Handschriften // Muslim Cultur in Russia and Central Asia from the 18 th to Early 20 th Centuries. Islamkundliche untersuchungen. B., 1996.

М.Г.Госманов, Ж.С.Миңнуллин.

ЧЫГТА́Й ТЕЛЕ́, карлук төркеменә караган *төрки телләрнең* берсе. 15–16 йөзләрдә Аксак Тимер һәм аның варислары заманында Мавәраэннәһердә (Урта Азия) барлыкка килгән әдәби-язма тел. Чыңгызханның 3 нче улы хөрмәтенә шулай аталган. Диалект булмаган, күпләп кергән гарәп-фарсы алынмалары һәм *гарәп язуы* (графикасы) б-н катлауландырылган тел. Ч.т.нең кайбер фонетик, грамматик үзенчәлекләре 15–18 йөзләр иске татар әдәби теленә дә хас. Ч.т.нең төп морфологик системасында «иске үзбәк теле элементлары»н да табарга мөмкин. Шуңа бәйле рәвештә Үзбәкстан телчеләре 1930–60 елларда Ч.т.н «иске үзбәк теле» дип тә атыйлар.

Әд.: История татарского литературного языка (XIII — первая четверть XX в.). К., 2003; Языкознание: Большой энцикл. словарь. М., 1998.

ЧЫЕЛДЫ́К КОШЛА́Р (Certhia), чыелдык чыпчыклар семьялыгыннан кошлар ыругы. 5 төре билгеле, Евразиядә, Төньяк-көнбатыш Африка һәм Төньяк Америкада таралганнар. ТР терр-ясендә бер төре — гади чыелдык кош (*C. familiaris*) бар. Ылыслы сирәк кенә яфраклы урманнарда яши. Утрак һәм күчмә кош. Гәүдәсенең озынлыгы 12–15 *см*, авырлыгы 7–10 *г*. Аркасы кара көрән чуар һәм ак таплы коңгырт-соры төстә, аскы ягы ак. Канатлары һәм койрыгы коңгырт, аркылы аксыл буйлы. Күзе астыннан башы әйләнәсе буйлап ак буй уза. Томшыгы чагыштырмача озын, нәзек, аска таба бөгелгән, бөҗәкләрне һәм аларның личинкаларын кайры һәм агач кәүсәләрендәге ярыклардан чыгарырга яраклашкан. Агач буйлап кыска сикерешләр б-н астан өскә таба хәрәкәт итә, бу вакытта ул кәүсә тирәли божрасыман әйләнешләр ясый. Оясын агач куышларында, ярыкларда, купкан агач кайрысы артына кора. Мартта парлашулары башлана, шул вакыттан урманда ата кошның сайравы даими ишетелә. Кызгылт-көрән тимгелле 5–7 ак йомырка сала. Нигездә, бөҗәкләр, үрмәкүчләр, кышын ш.у. үсемлек орлыклары б-н туклана.

ЧЫКАЛДА́ елгасы, Көнчыгыш Кама алдында, Кырыкмас елгасының (Иж елгасы бассейны) сул кушылдыгы. Озынлыгы 17,8 *км*, ТР чикләрендә — 10,8 *км*. Бассейнының мәйданы 115 *км*^{2}. Сарапул калкулыгыннан ага. Елга башы Әгерҗе р-ны Иске Чыкалда авылыннан 2,5 *км* көньяк-көнчыгыштарак, тамагы Удмурт Респ-касы

терр-ясендә, урман массивында. Елга башының абс. биеклеге 170 *м*, тамагыныкы — 68 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 45%. Ч.ның 9 кушылдыгы бар, иң зурысы Кырынды елгасы (18,7 *км*), калган кушылдыклар 0,4 тән 1,5 *км* га кадәр озынлыкта. Елга челтәренең тыгызлыгы 0,38 *км/км*^{2}. Туенуы катнаш, күбесенчә кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,25–0,5 *л/с·км*^{2}. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы һәм җәен нык саегуы б-н характерлана. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ункөнлегендә башлана. Елга ноябрь башында туңа. Язын суы каты (6–9 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен бик каты (9–12 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*.

ЧЫКЛЫ́ ҮЛӘ́Н (Drosera), чыклы үләннәр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. Якынча 100 төре билгеле, ике ярымшарның да тропик һәм уртача поясларында таралганнар. Татарстан терр-ясендә 3 төре бар. Түгәрәк яфраклы Ч.ү. (D. rotundifolia) ара-тирә Кама алдында очрый, мүкле сазлыкларда һәм «йөзмә-утраулар»да үсә. Инглиз Ч.ү.е (D. anglica) һәм кире йомыркасыман Ч.ү. (D. Obovata) Көнбатыш Кама алдында билгеләнә. 10–25 *см* биеклектәге үсемлек. Тамыр системасы зәгыйфь. Яфраклары тамыр яны бөҗрасында, ланцетсыман яки түгәрәк, озын сапларда, өске ягы ябышкак сыекча бүлеп чыгаручы башчалы бизле төкчәләр б-н капланган. Чәчәкләре вак, ике җенеслеләр, дөрес формада, биш бүлемле, ак, көпшәк чук чәчәк төркемендә. Җимеше — тартмачык. Июль–августта чәчәк ата. Җимешләре август–сентябрьдә өлгерә. Орлыктан һәм вегетатив (җенессез үрчү бөресе ярдәмендә) юл б-н үрчи. Түгәрәк яфраклы Ч.ү. халык медицинасында какырык күптару, тирләтү, бәвел кудыру чарасы буларак кулланыла; сулыш органнары авырулары вакытында файдаланылучы җыелма составына керә. Инглиз Ч.ү.е һәм түгәрәк яфраклы Ч.ү. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

ЧЫЛМАТА́, Идел буе Болгар дәүләтендә урта гасырлар (12 йөз) шәһәре. Фаразланганча, Чулман алдының түбәнге өлешендә яки Чулман аръягының көнбатышында урнашкан; феодаль өлкә үзәге. Рус елъязмаларында рус гаскәрләренең Биләр шәһәренә явы (1183) нисбәтле искә алына. Ч.ның каекларга утырган гаскәре, башка болгар шәһәрләреннән килгән отрядлар б-н бергә, Исад утравындагы (фаразланганча, Чулман елгасы тамагында) сугыш хәрәкәтләрендә катнаша һәм җи ңелүгә дучар була.

Әд.: Полное собрание русских летописей. М., 1962. Т. 1. *И.Л.Измайлов.*

ЧЫН КӨЯЛӘ́Р (Tineidae), түбән төзелешле төрле мыеклы күбәләкләр семьялыгы. Якынча 2000, Россиядә 200 гә якын төре билгеле; киң таралганнар. Вак күбәләкләр, кыска, нечкә ирен кармавычлы рудиментар хортумчыклы. Гусеницалары хайван (йон, мөгез, сөяк калдыкларында һ.б.) һәм азык продуктларында, ш.у. агач гөмбәләрендә яшиләр. Эволюция барышында типик урман бөҗәге (мәс., гөмбә һәм бөртек көяләре) амбар һәм йортларда тереклек итүче үзенчәлекле корткычка әверелә. Татарстан терр-ясендә аеруча йон көясе (T. tapetzella L.) — озынлыгы 14–22 *мм*, апрельдән майга һәм августтан сентябрьгә кадәр оча, йон әйберләргә зыян китерә; кием көясе (T. Bisseliella Humm.) — озынлыгы 9–12 *мм*, көз көне оча, мех, йон әйберләрне, каурый, тирегә зыян китерә; тун көясе (T. PellionellaL.) — озынлыгы 10–16 *мм*, апрельдән майга кадәр оча, мех, йон, фетргa зыян китерә; бөртек көясе (Nemapogon granellus L.) — озынлыгы 9–15 *мм*, яздан көзгә кадәр яши, бөртек, киптерелгән җиләк-җимеш һәм яшелчәләргә кайбер кондитер әйберләренә зыян китерәләр.

С.Г.Гордиенко.

ЧЫН ЧЕБЕННӘ́Р (Muscidae), түгәрәк җәйле кыскамыеклылар асотрядыннан бөҗәкләр семьялыгы. Якынча 4 мең, Россиядә — 1 мең тирәсе, Татарстан терр-ясендә берничә йөз төре билгеле. Гәүдәсенең озынлыгы 2–15 *мм*, соргылт-көрән яки кара төстә. Олы затлар чәчәк нектары б-н, аксым һәм шикәр булган төрле калдык-постыкларда туеналар, кайберләре канэчкечләр (*көзге усал чебен*). Яшәү рәвешләре буенча личинкалары төрле: үсемлек б-н туенучылар үсемлек тукымаларында яшиләр; сапрофаглар — чери башлаган органик хайван һәм үсемлек калдыкларында (чери башлаган үсемлекләр, тирес, кеше фекалияләре һ.б.ш.); ерткычлар үзләре б-н бергә шул мохиттә яшәүче башка бөҗәкләрнең личинкаларына һөҗүм итәләр. Кайберләре — вакытлыча яки даими паразитлар, чәчәк чебеннәре (Anthomyinae) ассемьялыгының аерым вәкилләре — үсемлек корткычлары. Кәбестә чебене кәбестә тамырларын һ.б. әвернә чәчәкләләрне зарарлый; суган чебененнән суган зыян күрә; чөгендер чебене чөгендер яфракларын тишкәли. Күп кенә төрләре — синантроплар (кеше янында яшиләр). Аларга *бүлмә чебене*, кече бүлмә чебене, өй чебене һ.б. чебеннәр керә, бу бөҗәкләр кешедә йогышлы, аеруча эчәк авыруларын (дизентерия, корсак тифы) тудыручыларны йокты ручылар булырга мөмкин.

ЧЫНЛЫ́ елгасы, Идел алдында. Зөя елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 54,1 *км*, ТР чикләрендә — якынча 30 *км*. Бассейны -



Чынлы елгасы. Буа районы.

ның мәйданы 845 *км*^{2}. Идел буе калкулыгыннан ага. Елга башы Чүпрәле р-ны Городище авылыннан 3 *км* төньяк-көнчыгышта - рак, тамагы Буа р-ны Әлши авылыннан 1 *км* көньяктарак. Елга үз юлында берничә тапкыр ТР һәм Ульянов өлкәсе чикләрен кисеп чыга. Елга башының абс. биеклеге 200 *м*, тамагыныкы — 75 *м*. Су җыелу мәйданының урманлылыгы 5%. Ч.ның 0,7 дән 54 *км* га кадәр озынлыктагы 17 кушылдыгы бар, иң зурысы — Кече Чынлы (сул кушылдык). Елга челтәренең тыгызлыгы 0,22 *км/км*^{2}. Туенуы катнаш, күбрәк кар сулары исәбенә. Җир асты сулары б-н туену модуле 0,1 *л/с·км*^{2}. Гидрологик режимы ташу вакытында су муллыгы, җәен нык саегуы б-н характерлана. Җәен озак вакыт яңгырлар булмаганда, Ч.ның кайбер кушылдыклары кибә. Бассейнда еллык су агымының уртача күпьеллык катламы 85 *мм*, ташу вакытында су агымы катламы 80 *мм*. Язгы ташу, гадәттә, апрельнең беренче ункөнлегендә башлана. Елга ноябрь уртасында туңа. Елга тамагында суының иң аз вакытындагы уртача күпьеллык чыгымы 0,2 *м*^{3}*/с*. Язын суы чагыштырмача каты (3–6 *мг-экв/л*), кышын һәм җәен каты (6–9 *мг-экв/л*). Гомуми минеральләшүе язын 200–300 *мг/л*, кышын һәм җәен 400–500 *мг/л*. Ч. бассейнында суының гомуми күләме 3 млн. *м*^{3} булган 7 буа бар. Су ресурслары сугару өчен файдаланыла.

«ЧЫНЛЫ́», Чүпрәле р-нындагы а.х. пр-тиесе. 1930 елда Кече Чынлы авылында «Гигант» к-зы буларак оештырыла, 1962 дән хәзерге исемдә; 1994 тә күмәк пр-тие итеп үзгәртелә, 2004 тән — ҖЧҖ. 2012 елга эшләүчеләр саны — 160 кеше; а.х. файдалану җирләренең мәйданы 6405 *га* (ш.и. 5423 *га* сөрүле җирләр). Җитештерүнең төп тармаклары булып бөртекле ашлык хуҗалыгы, чөгендер үстерү, терлекчелек санала; 7500 *т* бөртекле ашлык, 40000 *т* шикәр чөгендере, 4866 *т* сөт, 559 *т* сугымга терлек (тере үлчәмдә) җитештерелә. Бөртекле культураларның уңышы 1 *га* дан 55 *ц*, шикәр чөгендере 400 *ц* тәшкил итә; һәр сыердан уртача еллык савым 8984 *кг* алына. 100 *га* а.х. файдалану җирләренә күчереп исәпләгәндә 760 *ц* сөт, 87,3 *ц* сугымга терлек (тере үлчәмдә) җитештерелә. Җитештерүнең табышлылык дәрәҗәсе 20,3% тәшкил итә. Хуҗалыкның алдынгы хезмәткәрләре дәүләт бүләкләре һәм мактаулы исемнәргә лаек була, ш.и. ТАССР, ТРның атказ. механизаторы исеме — 4 кешегә, ТАССРның атказ. агрономы — 3, ТРның атказ. терлекчесе — 4, ТРның атказ. а.х. хезмәткәре — 6, ТРның атказ. вет. табибы — 1, ТРның атказ. энергетигы — 1, ТРның атказ. икътисадчысы — 1, ТРның атказ. төзүчесе — 1 кешегә бирелә; Октябрь Революциясе ордены б-н 1 кеше, Хезмәт Кызыл Байрагы — 6 , «Почёт билгесе» — 3, 2 нче дәрәҗә Хезмәт Даны — 1, 3 нче дәрәҗә Хезмәт Даны — 1, 2 дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» ордены б-н — 1, медальләр б-н 3 кеше бүләкләнә.

Пр-тиенең җитәкчеләре: Х.З.Сибгатуллин (1950–60), И.А.Садыйков (1985–89), Б.А.Гафуров (1989 дан).

ЧЫНЛЫ́ РАЙОНЫ́, ТАССРда. 1935 елның 10 февралендә Будённый р-ны буларак оештырыла. Үзәге — Иске Шәйморза авылы. 1920 гә кадәр Сембер губернасының Буа һәм Сембер өязләрендә, 1920 дән ТАССРның Буа кантонында, 1930 дан Буа һәм Чүпрәле р-ннарында. 1940 та районның мәйданы — 731 *км*², халык саны — 38,8 мең кеше, 26 авыл советы, 43 торак пункт исәпләнә. 1956 да район 721,3 *км*² җир били, 21 авыл советын, 49 торак пунктны берләштерә. 1957 нең 29 ноябрендә Чынлы р-ны итеп үзгәртелә. 1959 ның 12 октябрендә Ч.р. таркатыла, терр-ясе Буа һәм Чүпрәле р-ннарына бирелә.

ЧЫНЛЫ́ РАЙОНЫ́, Ульянов өлкәсенең төньяк-көнчыгыш өлешендә урнашкан. 1927 елда оештырыла. Мәйданы — 1293 *км*². Үзәге — Олы Нагаткино авылы (Ульянов шәһәреннән 35 *км* ераклыкта). Халкы — 25432 кеше (2017). Татарлар саны — 4047 кеше (2010). Алар, башлыча, Кәшә (Зирекле Күл), Яңа Тимерчән авылларында яшиләр. Татарлар 1649 да Кәшә авылына нигез сала. 1917 елгы рев-циягә кадәр 4 мәчет һәм 2 мәктәп була. Хәзерге вакытта 2 мәчет (1993 һәм 2011 елларда төзелә) эшли. Мәктәп диварына — профессор, РСФСРның атказ. зоотехнигы А.Г.*Курчаковка*, язучы һәм публицист Г.Г.Насыйров (авыл тарихы музеена аның исеме бирелә) яшәгән йортка мемориаль такта куелган. Яңа Тимерчән авылы 19 йөздә төзелә. 1917 елгы рев-циягә кадәр 4 мәчет һәм 4 мәдрәсә була. Хәзерге вакытта мәчет эшли. 2015 тә Олы Нагаткино авылында татар халык иҗатының 9 нчы төбәкара «Язгы моңнар» балалар фестиваль-конкурсы уздырыла. 2016 да мәчет ачыла. Районда барлыгы 5 мәчет эшли. 2015 тә Зирекле Күл авылында Татар теле һәм мәдәнияте көне үткәрелә, үзешчән театр эшли. Район мәктәпләрендә татар теле һәм әдәбияты фән буларак өйрәнелә. Сабан туе бәйрәм ителә. Кәшә авылында: Соц. Хезмәт Герое С.Х.Фәизов, генерал-лейтенант Х.А.Арсланов, РСФСРның атказ. зоотехнигы А.Г.Курчаков, техник фән д-ры З.Х.*Ногманов*, журналист һәм шагыйрь Г.Г.Насыйров, шагыйрь, драматург, ТАССРның атказ. сәнгать эшлеклесе Р.М.*Харисов* (Ренат Харис), язучы, ТРның атказ.мәдәният хезмәткәре Р.Г.*Ибраһимов*, 1971 елгы дөнья чемпионы, СССР ның атказ. спорт (биатлон) остасы Н.Г.Мөхитов; Яңа Тимерчән авылында: ТССР һәм РФнең атказ. табибе Т.Ф.*Сафин*, РФнең атказ. а.х. хезмәткәре И.А.Хәмзин; Олы Нагаткино авылында РФнең атказ. табибе А.Ф.Кашапов; Яңа Ирекәй авылында этнограф Р.Г.*Мөхәммәдова*; Дала Анненковосында актёр Ф.К.Сафин туган. РФнең атказ. а.х. хезмәткәре Х.В.Рамазановның тормышы һәм хезмәт эшчәнлеге Ч.р. б-н бәйле.

ЧЫНЛЫДАГЫ́ КАН КОЕ́Ш, 1906 елның 6 апрелендә Сембер губернасы Буа өязе Кече Чынлы авылы татар крәстияннәренең патша хакимиятләре тарафыннан рәхимсез бастырылган күтәрелеше. Хәл ителмәгән җир бәхәсе аркасында килеп чыга. 18 йөздә Кече Чынлы крәстияннәренең җирләре законсыз рәвештә алпавыт милкенә күчерелә, 1902 дә Рус Чынлысы авылы крәстияннәренә сатыла. Татар крәстияннәренең законлы юл б-н җирләрен кайтарып алу омтылышлары нәтиҗәсез тәмамлана. 1905 елгы рев-ция йогынтысында Кече Чынлы крәстияннәре җир өчен көрәшне активлаштыралар. 1905 нең августында алар үз ихтыярлары б-н бәхәсле җирне сөрәләр һәм чәчәләр. Шул вакытта алар һәм күтәрелешне оештырган затларны кулга алырга омтылып, уңышсызлыкка очраган патша чиновниклары арасында бәрелешләр була. Крәстияннәрне буйсындыру өчен, Кече Чынлыга гаскәр җибәрелә. 1906 ның апреле башында крәстияннәр янә дәгъвалы җирне сөрә башлыйлар. «Законсызлык»ны туктатуны таләп иткән хакимият вәкилләренә алар: «Без гә атсалар да, без бу җирдән беркая да китмәячәкбез», — дип белдерәләр. Чуалышларда 4 меңнән артык крәстиян (ш.и. күрше авылларда һәм салаларда яшәүчеләр) катнаша. 6 апрельдә каршылык барышында казаклар кырда җыелган крәстияннәргә каршы ут ачалар; качып котылырга теләгәннәрне куып җитеп, кылычлар б-н чабалар, «башка авылларга качучылар артыннан шунда бара лар». 200 дән артык кеше үтерелә һәм яралана. Яңа күтәрелешләргә юл куймау өчен хакимиятләр Кече Чынлыны озак еллар дәвамында хәрби контрольдә тотарга мәҗбүр булалар.

Әд.: Хасанов Х.Х. Революция 1905–1907 гг. в Татарии. М., 1965.

ЧЫНЫ́К посёлогы, Актаныш р-нында, Актаныш авылыннан 29 *км* көнбатыштарак, Шәбез елгасы буенда. 2010 елда 34 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. 1707 дән мәгълүм. 18–19 йөзләрдә халкы асабалар һәм типтәрләр катлавына бүленә, игенчелек, терлекчелек, киез итек-киез басу б-н шөгыльләнә. 1773–75 еллардагы Крәстияннәр кузгалышында Е.И.Пугачёв ягында сугышалар. 20 йөз башында Ч.та мәчет (1814 тән билгеле), икмәк саклау-сату кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1174 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Семиостров волостенда, 1920 дән ТАССРның Минзәлә кантонында. 1930 ның 10 августын нан — Актаныш, 1963 нең 1 февраленнән — Минзәлә, 1965 нең 12 гыйнвареннан Актаныш р-нында. Халык саны: 1795 тә — 145, 1859 да — 229, 1870 тә — 208, 1884 тә — 209, 1897 дә — 269, 1906 да — 316, 1913 тә — 278, 1920 дә — 307, 1926 да — 175, 1949 да — 206, 1958 дә — 115, 1970 тә — 156, 1979 да — 74, 1989 да — 45, 2002 дә — 43 кеше.

«ЧЫҢГЫ́З БАЛАСЫ́», атналык иҗтимагый-сәяси хәрби газета. Оренбург мөселман хәрби коллегиясе органы. 1917 елдан 1918 нең гыйнварына кадәр Оренбург шәһәрендә татар телендә нәшер ителә. Мөхәррире — С.Гайфи. Газета милли хәрәкәткә, ш.и. 2 нче Мөселман хәрби съезды эшенә зур игътибар бирә. Делегатларның *Идел-Урал штатын* оештыру идеясен гамәлгә ашырырга омтылуларын хуплый, хәрбиләрне милли бердәмлек рухында тәрбияләүгә, аларның үзаңын үстерергә чакыра.

ЧЫҢГЫ́З ХАН (чын исеме Темуҗин, Тимучин) (1155 яки 1162 ел тирәсе, Онон елгасының Делюн-Болдок үзәне — 25.8.1227), *Монгол империясенә* нигез салучы һәм аның бөек ханы (1206 дан), җиһангир. Аксөяк монгол феодалы Есугей баһадур гаиләсендә туа.



Чыңгыз хан портреты.
Урта гасырлар кытай рәсеме.

Күренекле хәрби һәм дипломатик сәләтләргә ия була. Хакимият өчен көрәш алып бара, 1204 тә Таян ханны — аңардан бәйсез булган соңгы найманнар кабиләсе идарәчесен җиңә, зур терр-ләләр яулый һәм асылда монгол кабиләләре берләшмәләренең башлыгына әверелә. 1206 да аксөякләр корылтаенда бердәм дәүләткә берләштерелгән барлык монгол кабиләләренең бөек ханы дип игълан ителә. Хан булып сайланганда Ч.х. карарлар мәҗмугасын — Ясаны бәян итә. Ил билгеле бер күләмдә яугирләр биргән хәрби-адм. берәмлекләргә — «унлыклар»га, «йөзлекләр»гә, «меңлекләр»гә һәм «төмәннәр»гә бүленә. Ч.х.ның хәрби куәтенең нигезен яхшы өйрәтелгән һәм дисциплиналы армия тәшкил итә. 1207–11 дә аның тарафыннан Себер һәм Көнчыгыш Төркестан халыклары (буряттлар, якутлар, ойратлар, кыргызлар, уйгырлар) буйсындырыла. Ч.х. тангутларның Си-Ся дәүләтенә (1227 дә тар-мар ителә), Кытайга (1217 гә Хуанхэ елгасыннан төнъякътагы барлык җирләрне яулый) каршы яулар б-н бара. 1219–21 дә Урта Азияне буйындыра. 1223 тә аның отрядлары *Калка елгасы буендагы сугышта* рус-кыпчак гаскәрен тар-мар итәләр, шуннан соң Самара Дугасы төбәгендә Идел болгарлары тарафыннан зур җи ңелүгә тарыйлар (к. *Идел буе Болгар дәүләтенә монгол яулары*). Тангутлар дәүләте башкаласын камау вакытында вафат була. Ч.х. оештырган Монгол империясе Евразия тарихы барышын үзгәртә. Чыңгызыйлар Ч.х. империясе таркалганнан соң барлыкка килгән барлык дәүләтләрдә идарәче нәсел булалар.

Әд.: Кычанов Е.И. Жизнь Темучжина, думавшего покорить мир. М., 1973; Груссе Р. Чингисхан: Покоритель Вселенной. М., 2003.

И.Л.Измайлов.

«ЧЫҢГЫЗХА́Н», Башкортстандагы татар рәссамнарының иҗат берләшмәсе. 1990 елда Уфада Н.С.*Лотфуллин* (беренче рәисе) инициативасы б-н оештырыла. 1992 дән берләшмәне В.М.Ханнанов җитәкли. Төркем оешкан көннән башлап аның әгъзалары булып Р.*Әхмәтвәлиев*, В.*Ханнанов*, Р.*Харисов*, Н.*Байбурин*, И.Әхмәтвәлиев, И.Бикбулатов тора (соңгы икесе аның составыннан чыга), соңрак Р.Морташин, М.Мөхәммәтов кушыла. «Ч.» символы — Н.Лотфуллиның «Чыңгызхан» картинасында (1992) гәүдәләндерелгән «Бөек даланы» яулап алган «Ак җайдак» образы. Рәссамнар милли мәдәнияте нең рухи киңлекләрен үз эченә алган һәм дөнья актуаль сәнгате үсеше агымында булган хәзерге татар нәкыше идеясен игълан итәләр; модерн сәнгатьнең стиль юнәлешләрен үзләштерәләр (нәкышь авангарды, супрематизм, поп-арт, объект, перформанс һ.б.) һәм үзләренең әсәрләрендә коллектив концепциясе генә түгел, шәхси концепцияләрен дә гамәлгә ашыралар. Кайберләре чит илләргә дә эшкә чакырыла (Н.Лотфуллин АКШка, Р.Әхмәтвәлиев Франциягә, Р.Харисов Канадага).

Берләшмәдә катнашучылар хәзерге татар һәм башкорт сәнгатен үстерүгә һәм пропагандалауга зур өлеш кертәләр. Беренче күргәзмә 1990 да Ленинградта була. «Ч.» әгъзалары 1 нче Бөтентатар төбәкара «*Татарт*» күргәзмә оештыручылардан санала (С.-Петербург — Казан, 1991). «Ч.»ның Төркем күргәзмәләре Уфада, Мәскәүдә, Казанда һ.б. шәһәрләрдә уздырыла. 1996–2002 елларда Мәскәүдә үткәрелгән халыкара «Арт-Манеж» күргәзмә-ярминкәләрендә даими катнаша. Берләшмә әгъзаларының төркем б-н һәм шәхси күргәзмәләре Төркиядә, Франциядә, АКШта, Испаниядә, Голландиядә, Австриядә, Канадада һ.б. илләрдә үткәрелә. «Ч.» рәссамнары «Нәүрүз-бәйрәм», «Гравицаппа-I» (икесе дә — 1997, Уфа), «Гравицаппа-II», «Нәүрүз-Мөбарәк» (икесе дә — 1998, Уфа), «Госел храмы» (1999, Мәскәү), «Чыңгызхан ханәкәләре» (2000, Уфа), «Алтын пайцза» (2001), «Пыльтрыш» (2001, 2003, Башкортстан Респ-касының Благовар районы Карга лы а.), «Балкышлы арба» (2004, Мәскәү), «Үтәкүренмәле шәүләләр» (2010, Уфа) коллектив перформансларны гамәлгә ашыра; төбәкара һәм халыкара сәнгать проектларының инициаторлары була («Айлар балкышы», 2001–07; «Яратылыш», 2011 һ.б. Төркия, Әнкара; Мәскәү һәм РФнең башка шәһәрләре).

«Ч.» — Уфа «Мирас» галереясын (1994); Башкортстан Респ-касының Н.Лотфуллин исем. Заманча сәнгать музеен (2002; инициаторы һәм беренче директоры В.Ханнанов) оештыручыларның берсе.

Әд.: Группа «Чингиз-хан». Живопись: Каталог. СПб., 2000; Творческое объединение художников «Чингисхан»: 1990-е годы // Эстетика ислама в современном искусстве Южного Урала. М., 1997; Чингисхан в холстах и наяву // Рампа. 2000. № 9; ВХ: Высокохудожественный журнал: Спец. вып., посвящённый 15-летнему юбилею творческого объединения «Чингисхан». 2005. № 1; ЧингисХан — Chenghishhan. M., 2008.

Г.Ф. Вәлиева-Сөләйманова.

ЧЫҢГЫЗЫЙЛА́Р, *Чыңгыз хан* варислары, аның уллары һәм оныклары тарафыннан нигезләнгән идарәче династияләр. Башта Чыңгыз хан династиясе аңардан олыслар алган улларының 4 тармагына бүленә: *Җучиләр*, Чагатайлар, Үгәдәйләр һәм Тулуйлар. Алгы Азия һәм Якын Көнчыгышның бер өлеше Һулагу хан тарафыннан яуланганнан соң шул терр-ядә яңа Һулагулар олысы һәм династиясе барлыкка килә. *Монгол империясенең* (1260 елларда таркалганчы) барлык олыслары терр-ясе Чыңгыз ханның барлык варисларының уртак биләмәсе санала. Беренче монгол бөек ханнарын (каганнарын) барлык идарәче династия сайлый. Олыслар барлыкка килү һәм аларның мөстәкыйльлеге ныгу процессында идарәчеләрнең гомуммонгол ханы хакимиятеннән һәм башка олыслардан бәйсезлеккә омтылышы көчәя. 1260 елларда олыслар тәмам аерымлана, алар Ч.ның аерым бер тармагының мирас буенча тапшырылучы милкенә әверелә ләр. 13–14 йөзләр чигендә Ч.ның 4 монгол дәүләте оеша: Җүчи Олысы (Көнчыгыш Европада, Урал алдының көньягында, Көнбатыш Себердә һәм Арал буенда — *Алтын Урда*), Чагатай Олысы (Көнчыгыш Төркестанда, Мавәраэннәһердә һәм Җидесуда — Моголстан), Һулагу Олысы (Якын, Урта һәм Алгы Көнчыгышта Илханнар дәүләте) һәм Тулуй Олысы (Монголиядә, Кореядә һәм Кытайда — Олуг Олыс яки Юань империясе). Чыңгыз хан *Ясасы* буенча, фәкать аның варислары гына югары хакимиятктә хокуклы булган. Үз хакимиятләрен мирас буенча тапшыру, варисларын хан итү өчен идарәчеләр һәм олуг карачыбәкләр Ч. б-н туганлашырга омтылганнар (Тимериләр, Идегәй варислары). Ч.ның Монгол империясен нигезләүчедән килеп чыгышы һәм аларның сакраль бәйләнеше рәсми тарих бәяннарында («Алтын Тобчи» һ.б.) ассызыкланган. Ч. идарәчеләр, монголлар булараk, озак вакыт дәвамында документларның һәм дипломатик язышуларның рәсми теле сыйфатында (кайчакта идарәче нәселнең үзатамасында — Моголстан, Бөек Моголлар дәүләте) монгол телен саклап килгәннәр. Тора-бара рәсми тел буларак монгол теле үзенең әһәмиятен югалта (14 йөз башында Юань империясендә, 1360 еллардан Җүчи Олысында, 14 йөз ахырында Моголстанда һәм Тимериләр дәүләтләрендә). 15 йөзгә кергәндә Ч.ның бердәмлеге җуела һәм аларның җирле династияләренә (Җүчиләр, Чагатайлар, Һулагулар, Хубилай варислары) һәм Ч.ның ян һәм тугандаш тармакларына (Тимериләр, Гәрәйләр, Шәйбанилар һ.б.) карауга зуррак әһәмият бирелә. Ч.ның тугандаш тармагы — Тимериләр Бөек Моголлар империясен төзиләр, ул дәүләт инглизләр яулап алганчы һәм Тимериләр бәреп төшерелгәнче (1857) Төньяк Һиндстанны били. Ч. Бохара әмирлегендә (1756 га кадәр) һәм Хива ханлыгында (1804 кә кадәр) идарә итәләр. Алтын Урда таркалганнан соң барлыкка килгән ханлыкларда хакимияткә Җүчи варисларының аерым нәселләре килә: Казанда — Олуг Мөхәммәд варислары, Кырымда — Гәрәйләр, Себер һәм Үзбәк ханлыкларында — Шәйбанилар һ.б. Аларның вәкилләре Әстерхан, Казан, Касыйм, Кырым, Себер ханлыкларында тәхет билиләр. Ч.дан чыгучылар (Касыйм хан, Данияр, Мөхәммәдәмин хан, Шаһгали хан һ.б.) Мәскәү дәүләте һәм аның югары хәрби-йомышлы катлавы барлыкка килүдә мөһим роль уйныйлар.

Чыг.: Рашид ад-Дин. Сборник летописей. М.–Л., 1952–66. Т. 1–2; Кононов А.Н. Родословная туркмен. Сочинение Абу-л-Гази, хана хивинского. М.–Л.,1958; Лубсан Данзан. Алтан Тобчи («Золотое сказание»). М., 1973.

Әд.: Сафаргалиев М.Г. Распад Золотой Орды. Саранск, 1960; Фёдоров-Давыдов Г.А. Общественный строй Золотой Орды. М., 1973; Трепавлов В.В. Государственный строй Монгольской империи XIII в.: Проблема исторической преемственности. М., 1993; Беляков А.В. Чингисиды в России XV–XVII веков. Рязань, 2011.

И.Л.Измайлов.

ЧЫПТА́-КАП СУГУ́ ҺӘМ БА́У-АРКА́Н ИШУ́ СӘНӘГАТЕ́, Казан губернасында киң таралган сәнәгать төре. 19 йөздә — 20 йөз башында Казан губернасында В.Л.Свечниковның чыпта-кап сугу кәсепханәсе (Казан; 1866 елда нигезләнә; 50 эшче; елга 8700 сумлык товарлар җитештерелә), А.Я.Логутов чыпта-кап сугу ф-касы (Чистай ш.; 1867 дә нигезләнә; 167 эшче; елга 19 мең сумлык продукция җитештерелә), М.В.Колчуринның чыпта һәм дегет ясау кәсепханәсе (Чистай өязенең Елаур а.; 1870 тә нигезләнә; 200 эшче), В.Н.Володинның аркан һәм бау ишү пр-тиесе (Мамадыш өязенең Кукмара а.; 1880 дә нигезләнә), Н.А.Назаровның чыпта-кап сугу һәм мунчала кәсепханәсе (Чистай ш., 1886 да нигезләнә; 145 эшче; елга 21 мең сумлык продукция чыгарыла). Чыпталар, мунчала, баулар, арканнар җитештерелә.

Әд.: Фабрично-заводские предприятия Российской империи. СПб., 1909.

ЧЫПЦА́ ТАТАРЛАРЫ́, к. *Нократ татарлары*.

ЧЫПЧЫ́К авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 18 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Казансу елгасы буенда. 2010 елда 1677 кеше (2002 елгы халык исәбе буенча, руслар — 56%, татарлар — 41%) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау, яшелчәчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Чиркәү. Мәчет. 1557 дә нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Архангельский исеме б-н дә билгеле. 1860 елларга кадәр халкы удел (1797 гә кадәр — сарай) крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, сарык тиресе эшкәртү, тимерчелек, йон-тукыма ману б-н шөгыльләнә; юлаучылар йорты тота. 1774 нең 1 июнендә Ч. янында Е.И.Пугачёв отрядлары полковник Михельсон гаскәрләре б-н бәрелешә. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша, земство хастаханәсе (1881 дә ачыла), этап йорты, земство мәктәбе (1857 дә шәхси мәктәп буларак ачыла,

1868 дән — земство мәктәбе, 1885 тән ике мәктәп — кыз һәм ир балалар өчен), 3 тимерче алачыгы, 2 су тегермәне, 4 сыраханә, 1 казна шәраб һәм 12 бакалея кибете, 20 юлаучылар йорты була; чәршәмбедә һәм Изге Троица көнендә базарлар эшли. Троица чиркәве (1856, беренчесе 1565 тә төзелә). Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 3404,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Чыпчык волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан Казан авыл р-нында, 1935 нең 10 февраленнән — Биектау, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1646 да — 522, 1782 дә — 373 ир-ат; 1859 да — 1755, 1897 дә — 1498, 1908 дә — 1586, 1920 дә — 1726, 1926 да — 1745 (Заря посёлогы, Юныс һәм Бирсаково утарларын да кертеп), 1938 дә — 1399, 1949 да — 1356, 1958 дә — 853, 1970 тә — 940, 1989 да — 1628, 2002 дә — 1630 кеше.

Әд.: Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

ЧЫПЧЫ́К ҖИЛЕМЕ́ (Steris), канәферчәләр семьялыгыннан күпьеллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 5 төре билгеле, Төньяк ярымшарның салкын һәм уртача поясларында таралганнар. Татарстан терр-ясендә бер төре — гади Ч.ж. (S. viscaria) бар. Барлык районнарда очрый. Коры болыннарда, тау битләрендә, аланнарда, нарат урманнары буенда үсә. 40–80 *см* биеклектәге үсемлек. Сабаклары туры, буынлы, чиясыман көрән төстә, ябышкак (исеме шуннан). Яфраклары каршыдаш, тар, ланцетсыман. Чәчәкләре алсу төстә, чук сыман себеркәч чәчәк төркеменә җыйналган. Җимеше — вак тартмачык. Май–июньдә чәчәк ата. Җимешләре июль–августта өлгерә. Орлыктан үрчи. Үсемлектә флавоноид, сапонин, углеводлар бар. Халык медицинасында үлән төнәтмәсе үт кудыру, кан туктату, какырык куптару, тире авырулары вакытында тәнгә сөртү чарасы буларак кулланыла. Декоратив, баллы үсемлек.

ЧЫПЧЫ́К ОРЛЫГЫ́, несле үләне (Neslia), әвернә чәчәкләләр семьялыгыннан бер- яки икееллык үләнчел үсемлекләр ыругы. 2 төре билгеле, Евразиядә һәм Төньяк Африкада таралганнар. ТР терр-ясендә бер төре — себеркәчле Ч.о. (N. paniculata) бар, барлык районнарда да очрый. Кырларда, далаланган сөзәкләкләрдә, тимер юл, юл буйларында үсә. 15–50 *см* биеклектәге үсемлек. Сабагы туры, өске өлеше тармаклы, куе кырпулы. Сабак яфраклары чиратлашкан, утырма, озынча ланцетсыман, төбендә уксыман. Чәчәкләре вак, алтынсыман сары, чук чәчәк төркемнәрендә. Җимеше — бер орлыклы ачылмаучан шарсыман кузакчык. Май–июньдә чәчәк ата. Җимешләре июль–августта өлгерә. Орлыктан үрчи. Тамырында флавоноид, майлар бар. Халык медицинасында үләненең сулы төнәтмәсе талак авырулары вакытында кулланыла; яңа өзелгән яфракларын җәрәхәтләргә, шешләргә куялар. Чүп үләне.

ЧЫПЧЫКЛА́Р (Passer), тукыр кошлар семьялыгыннан кошлар ыругы. Дөнья фаунасында 18 төре билгеле, Европада, Азия һәм Африкада таралганнар, кайбер төрләре Америка, Австралия һәм Яңа Зеландиягә кертелгән. ТР терр-ясендә 2 төре бар: йорт чыпчыгы (P. domesticus) һәм басу чыпчыгы (P. montanus). Ике төре дә киң таралган, ел әйләнәсе очрыйлар. Җәен йорт һәм басу Ч.ы аерым йөриләр, көзен һәм кышын уртак өер хасил итәләр. Гәүдәсенең озынлыгы 17 *см* га, авырлыгы 35 *г* га җитә. Ата йорт чыпчыгының баш түбәсе соры, муены һәм күкрәгендә зур кара тап бар, яңаклары соры. Ана кошлар соры төстә генә, каурый капламы кара тапларсыз гына. Басу чыпчыгы (ата һәм ана кош) йорт чыпчыгыннан көрән баш түбәсе һәм ак яңакларындагы өтерсыман кара тимгел б-н җи ңел аерыла. Йорт чыпчыгы торак пунктларда, басу чыпчыгы бакчаларда, парк һәм урман буйларында яши. Ч. ояларын торак йортларда, агач куышларында кора. Елга 2 тапкыр үрчем бирә, кара тимгелле 3–6 тонык ак яки соргылт йомырка сала. Балаларына башта бөҗәкләр



Чыпчыклар.

(гусеницалар, яфраккимергеч, филчекләр) ашата. Бөртек ашаучы кошлар. А.х. өчен куркыныч бөҗәкләрне юк итеп һәм шактый күләмдә үүп үләннәрнең орлыкларын ашап файда китерәләр. Кайвакыт бөртекле культураларга һәм җиләкләкләргә зыян китерергә мөмкин.


ЧЫРПЫ́ авылы, Лаеш р-нында, Лаеш шәһәреннән 14 *км* көнчыгыштарак, Казан-Оренбург автомобиль юлы буенда. 2010 елда 309 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — мөгезле эре терлек асрау; сөт з-ды. Урта мәктәп, клуб, китапханә. Крәстиян В.М.Мареф йорты (20 йөз башы архит-расы истәлеге). 1565–67 еллардан мәгълүм. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Богородский исеме б-н билгеле. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, сәүдә, Кама болыннарында аштамыр әзерләү б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында волость идарәсе урнаша; Смоленск Богородица чиркәве (1747 дә төзелә; архит-ра истәлеге), земство мәктәбе (1872 дә ачыла), 3 тегермән, ярма яргыч, тимерче алачыгы, 12 юлаучылар йорты, 5 вак-төяклэр кибете, халыкта аек яшәү рәвеше тәрбияләүче уку өе эшли. Бу чорда авыл



Чырпы авылында крәстиян В.М.Мореф йорты. 1912–13.

җәмәгатенең имана җире 2271,74 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Чырпы волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Лаеш, 1963 нең 1 февраленнән — Питрәч, 1965 нең 12 гыйнварыннан Лаеш р-нында. Халык саны: 1782 дә — 262 ир-ат; 1859 да — 660, 1897 дә — 1026, 1908 дә — 1217, 1920 дә — 1485, 1926 да — 1353, 1938 дә — 710, 1949 да — 460, 1958 дә — 832, 1970 тә — 581, 1979 да — 419, 1989 да — 362, 2002 дә — 376 кеше.

ЧЫРШЫ́ (Picea), наратчалар семьялыгыннан мәңге яшел агачлар ыругы. 50 гә якын төре билгеле, кабыгының төзелеше, ботаклану тибы, ябалдашының формасы һ.б. буенча һәрберсенең берничә формасы бар, күбесенчә Төньяк ярымшарның уртача поясында таралганнар. ТР терр-ясе 2 төрнең: гади Ч. яки Европа Ч.сы (P. abies, яки P. excelsa) һәм Себер Ч.сының (P. obovata) интрогрессив гибридлашу зонасында урнашкан. Ике төре дә, күп кенә гибрид төрләр (агачларның 90–95% ка кадәре) хасил итеп, үзара иркен серкәләнә. Кама алдында, Кама аръягының төньяк-көнчыгыш, ш.у. Идел алдының төньяк өлешләрендә үсә. Ч.дан гына торган, башка ылыслы (нарат, ак чыршы), вак яфраклы (каен, юкә, усак) һәм каты яфраклы (имән)



Чыршы. 1. Гомуми күренеше; 2. Ана күркәчекләр; 3. Ата күркәчекләр; 4. Өлгергән күркә.

агач токымнары үскән катнаш урманнарда таралган. Чыршылыклар 63,7 мең *га*, яисә урман б-н капланган гомуми мәйданның 7,3% ын алып торалар. Агачның биеклеге 30 *м* га, диаметры 1м га кадәр. Тамыр системасы җир өслегенә якын. Ябалдашы куе, конуссыман. Ылысы каты, чәнечкеле, дүрт кырлы; агачта 5–7 ел тора. Ана чәчәкләре (күркәчекләр) кызыл-яшел төстә, берле, ябалдашының өске өлешендәге ботаклары очларында формалаша; ата чәчәкләр — саргылт вак башакчыклар (серкәлек) кәүсәнең урта өлешендә. Себер Ч.сы гади Ч.дан иенке берьеллык ботаклары, тәңкәчекләре бөтен читле кечкенә күркәләре б-н аерыла. Орлыклары көрән төстә, 3–4 *мм* озынлыкта, канатчалы, чәчәк аткан елында сентябрь–ноябрьдә өлгерәләр. Күркәләре цилиндр-, йомыркасыман озынча формада, ачыклыкта үскән Ч.да 10–15, агачлар арасындагыда 25–30 елдан соң күренәләр. Орлыктан, бик сирәк кенә үрентеләрдән үрчи. Ч. күләгәгә, суыкка чыдам, әмма яшь вакытта язын соңгы кыраулардан зыян күрә. 250–300 ел яши. Үзагачы целлюлоза-кәгазь сәнәгатендә, төзелештә, агач һәм йорт җиһазлары эшендә, музыка инструментлары ясауда кулланыла. Кабыгы — дуплау матдәләре чыганагы. Сумала, дегет, скипидар, канифоль алырга мөмкин. Чәнечкеле Ч. (P. pungens), аеруча ылыслары балавызлы зәңгәрсу яки көмешсыман куныклы булган формасы шәһәрләрне яшелләндерүдә файдаланыла.

А.Н.Кузнецов.

ЧЫРШЫ́ авылы, Алабуга р-нында, Алабуга шәһәреннән 40 *км* көнбатыштарак, Казан — Уфа автомобиль юлы буенда. 2010 елда 29 кеше яши. 18 йөздә нигез салына. 1860 елларга кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 19 йөз ахырында авыл җәмәгатенең имана җире 1148,3 дис. тәшкил итә. 1921 гә кадәр Вятка губернасының Алабуга өязе Казиле волостенда, 1921 дән ТАССРның — Алабуга, 1928 дән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Алабуга, 1944 нең 19 февраленнән — Костенеево, 1944 нең 8 июненнән — Морт, 1954 нең 19 ноябреннән Алабуга р-нында. Халык саны: 1859 да — 415, 1887 дә — 424, 1905 тә — 415, 1920 дә — 489, 1926 да — 449, 1938 дә — 290, 1949 да — 242, 1958 дә — 136, 1970 тә — 109, 1979 да — 75, 1989 да — 32, 2002 дә — 48 кеше.

ЧЫРШЫ́ авылы, Биектау р-нында, Биектау тимер юл станциясеннән 20 *км* төньяктарак, Касыйм елгасы буенда. 2010 елда 322 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. Казан ханлыгы чорында нигез салына. Рев-циягә кадәрге чыганакларда Торнаяз исеме б-н дә билгеле. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, умартачылык, өс һәм күн аяк киемнәре тегү, олаучылык б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында мәчет (1871 дә төзелә), мәдрәсә, тимерче алачыгы, 3 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1539,4 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Казан өязе Салкын Чишмә волостенда, 1920 дән ТАССРның Арча кантонында. 1930 ның 10 августыннан — Дөбъяз, 1963 нең 1 февраленнән — Зеленодольск, 1965 нең 12 гыйнварыннан Биектау р-нында. Халык саны: 1782 дә — 187 ир-ат; 1859 да — 672, 1897 дә — 850, 1908 дә — 949, 1920 дә — 919, 1926 да — 1045, 1938 дә — 912, 1949 да — 589, 1958 дә — 498, 1970 тә — 473, 1989 да — 346, 2002 дә — 352 кеше. Авыл зиратында 16 йөзнең 1 нче яртысы кабер ташлары сакланган.

Әд.: Очерки истории Высокогорского района Республики Татарстан. К., 1999.

ЧЫРШЫ́ ҺӘМ КАРАГА́Й УРМА́Н КУЛЬТУ́РАЛАРЫ, 1910–13 еллар, ландшафтлы табигать истәлеге. Баграж елгасы үзәнендә, Әлмәт р-ны Баграж авылыннан төньяк-көнбатыштарак, Кәләй урманчылыгының 1 нче Чишмә участок урманчылыгы терр-ясендә. Мәйданы 6,9 *га*. 1987 елда билгеләнә. Үзләренең табигый ареалларыннан читтә үстерелгән уникаль ылыслы культуралар, авыр балчыксыл селтесезләнгән кара туфракларда югары продуктлы ценозлар формалаштыра. Башта 3 участоктан тора. Хәзерге вакытта, 117 нче кварталда үз эченә Себер карагае, Европа чыршысы, Себер чыршысы, Себер ак чыршысы, эрбет нараты (Себер эрбете), гади нарат секцияләрен алган участок (гомуми мәйданы 0,44 *га*) сакланган. 1а-1бонитет класслы һәм утыртма запаслары 886 һәм 481 *м*^{3}*/га* тәшкил иткән карагай һәм нарат иң яхшы күрсәткечләр б-н сыйфатлана, (к. табл.).

Яшь урманнарда ак чыршы өстенлек итә. Урман эчендәге куаклыклар миләш, шомырт, зелпе, сөялле кабар агачыннан тора. Туфрак өслегендә нemopaль төрләр: исле сырмавык, имәнлек яушаны, плющсыман будра, Европа тайтоягы, елга кысыр тигәнәге үсә. Тамыр болытсыманнары б-н зарарланганлыктан агачларның күпләп коруы нәтиҗәсендә калган 2 участок (102 һәм 109 кварталларда) киселә, 1994 тә карагай агачлары утыртыла. Объект фәнни әһәмияткә ия.

Ә.Һ.Газизуллин.

ЧЫРШЫЛЫ́ авылы, Тукай р-нында, Чаллы шәһәреннән 29 *км* көньяк-көнчыгыштарак, Буклы елгасы буенда. 2010 елда 59 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык. Клуб. 1747 дән мәгълүм. 1860 еллар-га кадәр халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ч.да мәчет, мәктәп, икмәк саклау-сату һәм 2 бакалея кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 685,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Уфа губернасының Минзәлә өязе Бишенде-Останково волостенда, 1920 дән ТАССРның — Минзәлә, 1924 тән Чаллы кантонында. 1930 ның 10 августыннан Чаллы (1976 ның 20 апреленнән — Тукай) р-нында. Халык саны: 1870 тә — 254, 1906 да — 402, 1920 дә — 453, 1926 да — 392, 1938 дә — 363, 1958 дә — 364, 1970 тә — 285, 1979 да — 151, 1989 да — 56, 2002 дә — 42 кеше.

ЧЫРШЫЛЫ́ ЕЛГА́ авылы, Балык Бистәсе р-нында, шәһәр тибындагы Балык Бистәсе посёлогыннан 42 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Шомбыт елгасының уң кушылдыгы буенда. 2010 елда 143 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — урманчылык. Башлангыч мәктәп, клуб. 1916 да нигез салына. Оешкан көненнән Казан губернасының Лаеш өязе Шомбыт волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1935 нең 10 февраленнән — Кызыл Йолдыз, 1959 ның 26 мартыннан — Балык Бистәсе, 1963 нең 1 февраленнән — Мамадыш, 1965 нең 12 гыйнварыннан Балык Бистәсе р-нында. Халык саны: 1938 дә — 35, 1970 тә — 203, 1989 да — 138, 2002 дә — 142 кеше.

ЧЫРШЫЛЫ́ СӨРКӘ́ (БАЙБА́К) КОЛО́НИЯСЕ, к. «*Дала*».

ЧЫРШЫЛЫ́К ҮЛӘНЕ́ (Hypopitys), чукмарбашсыманнар семьялыгыннан күпьеллык хлорофилсыз үләнчел үсемлекләр ыругы. Бердәнбер төре — гади Ч.ү. (H. monotropa). Төньяк ярымшарның уртача поясында таралган. Татарстан терр-ясендә барлык районнарның ылыслы, катнаш, икенчел вак яфраклы урманнарында очрый. Ч.ү. үсү өчен төп шарт — туфракта органик матдәләргә бай үсемлек коелдыкларының калын түшәлмәсе булу. Үсемлек гөмбәләр б-н микориза ясый. Тамырчасы оясыман, нык тармаклы. Сабагы сусыл, туры, биеклеге 10–25 *см*, аксыл яки саргылт. Яфраклары чиратлашкан, тәңкәсыман. Чәчәкләре саргылт, кыңгыраусыман, иенке чук чәчәк төркемендә. Җимеше — вак орлыклы тартмачык. Июнь ахыры — июльдә чәчәк ата. Җимешләре августта өлгерә. Орлыктан үрчи. Тукануы буенча Ч.ү. эшләпәле гөмбәләр б-н охшаш һәм сапрофитларга керә. Баллы үсемлек. ТРның Кызыл китабына кертелгән.

Чыршы һәм карагай урман культуралары.
Утыртмаларның таксацион күрсәткечләре (60 яшьлек агачлар)

Таксацион күрсәткечләр	Секцияләр карагай	ак чыршы	чыршы	эрбет	нарат
Утыртмалар составы	10Лц	10П	9Е1С	10К	10С+Е
Уртача биеклек, *м*	27,7	17,6	19,2	13,0	23,8
Уртача диаметр, *см*	21,2	17,0	19,0	17,0	20,0
Киселешләр мәйданы суммасы, *м*^{2}*/га*	63,3	37,0	38,1	49,5	37,8
Чагыштырмача тыгызлык	1,3	1,2	1,1	1,6	1,0
Запас, *м*^{3}*/га*	886,0	318,0	424,0	333,0	481,0
Бонитет классы	1а	2	2	4	1

ЧЫТЫ́ авылы, Питрәч р-нында, Питрәч авылыннан 18 *км* көнчыгыштарак, Мишә елгасы буенда. 2010 елда 483 кеше (татарлар) яши. Халкының төп шөгыле — кырчылык, мөгезле эре терлек асрау. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. Мәчет. 1649 дан мәгълүм. 18 йөздә — 19 йөзнең 1 нче яртысында халкы дәүләт крәстияннәре катлавына керә, лашман хезмәтен үти; игенчелек, терлекчелек, тегү б-н шөгыльләнә, күбесе скрипка һәм гармунда уйный. 20 йөз башында Ч.да 2 мәчет, 2 мәдрәсә, 7 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 1602 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Лаеш өязе Казиле волостенда, 1920 дән ТАССРның Лаеш кантонында. 1927 нең 14 февраленнән — Балык Бистәсе, 1930 ның 10 августыннан Питрәч р-нында. Халык саны: 1782 дә — 122 ир-ат; 1859 да — 783, 1897 дә — 1213, 1908 дә — 1573, 1920 дә — 1371, 1926 да — 1119, 1949 да — 878, 1958 дә — 979, 1970 тә — 937, 1979 да — 693,1989 да — 555, 2002 дә — 495 кеше.

ЧЫТЫРЧЫ́ авылы, Чистай р-нында, Чистай шәһәреннән 21 *км* төньяк-көнчыгыштарак, Куйбышев сусаклагычы ярында урнашкан. 2010 елда 312 кеше (руслар) яши. Халкының төп шөгыле — терлекчелек. Урта мәктәп, мәдәният йорты, китапханә. 1670 елларда нигез салына. 1861 елгы реформага кадәр халкы алпавыт крәстияннәре катлавына керә, игенчелек, терлекчелек, он тарту б-н шөгыльләнә. 20 йөз башында Ч.да Казан Богородица чиркәве, 3 җил тегермәне, 2 вак-төякләр кибете эшли. Бу чорда авыл җәмәгатенең имана җире 652,8 дис. тәшкил итә. 1920 гә кадәр Казан губернасының Чистай өязе Олы Талкыш волостенда, 1920 дән ТАССРның Чистай кантонында. 1930 ның 10 августын нан Чистай р-нында. Халык саны: 1782 дә — 171 ир-ат; 1859 да — 298, 1897 дә — 536, 1908 дә — 548, 1920 дә — 647, 1926 да — 618, 1938 дә — 643, 1949 да — 387, 1958 дә — 338, 1970 тә — 188, 1979 да — 312, 1989 да — 349, 2002 дә — 330 кеше.

ТАТАР ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕНДӘ КУЛЛАНЫЛГАН ТӨП КЫСКАРТУЛАР

а. — авыл
абс. — абсолют
авг. — август
адм. — администрация, административ
адм.-терр. — административ-территориаль
акад. — академик, академия
акц. — акционерлык
апр. — апрель
арх. — архитектор
археол. — археология, археологик
архит-ра — архитектура
атказ. — атказанган
атм. — атмосфера
а.м. — атом массасы
а.х. — авыл хуҗалыгы
әзәрб. — әзәрбайҗан
башк. — башкорт
балетм. — балетмейстер
биол. — биология, биологик
вет. — ветеринария
б.к. — баш килеш
г-та — газета
б.э. — безнең эра
б.э.к. — безнең эрага кадәр
гарәп. — гарәпчә (гарәп теленнән)
гв. — гвардия, гвардияче
ген. — генераль
геогр. — география, географик
геол. — геология, геологик
геом. — геометрия, геометрик
гинекол. — гинекология, гинекологик
геоморфол. — геоморфология
гистол. — гистология
гыйн. — гыйнвар
грек. — грекча (грек теленнән)
губ. — губерна
дек. — декабрь
дис. — дисәтинә
д-р — доктор
ж-л — журнал
з-д — завод
зоол. — зоология
и.к. — иялек килеше
инстр-т — инструмент
илл. — иллюстрация
ин-т — институт
инг. — инглизчә (инглиз теленнән)
исем. — исемендәге
ит. — итальянча (итальян теленнән)
к. — кара(гыз)
канд. — кандидат
к-та — кислота (исем янында)
К° — компания
кап. — капиталь (төзелеш)
каф. — кафедра
кв. — квадрат
к-з — колхоз
ком. — командир
ком-т — комитет
комис-т — комиссариат
комп. — композитор
комб-т — комбинат
конф. — конференция
коэф. — коэффициент
крист. — кристаллик
к/т — кинотеатр
күпл. — күплек (саны)
лаб., лаб-я — лаборатория
лат. — латинча (латин теленнән)
либр. — либретто
лингв. — лингвистика
макс. — максималь
матем. — математика, математик
мәс. — мәсәлән
мед. — медицина
метеорол. — метеорология
минерал. — минералогия
миним. — минималь
мифол. — мифология
млн. — миллион
млрд. — миллиард
монгол. — монголча (монгол теленнән)
морфол. — морфология, морфологик
муз. — музыкаль
нем. — немецчә (немец теленнән)
неол. — неологизм
норм. — нормаль
нояб. — ноябрь
окт. — октябрь
Окт. рев-циясе — Октябрь революциясе (1917)
пасс. — пассажир
пед. — педагогика, педагогия, педагогик
пос. — посёлок
пр-тие — предприятие
проф. — профессор, профессиональ
псевд. — псевдоним
психол. — психология, психологик
райком — район комитеты
райсовет — район советы
ревком — революцион комитет
рев. — революцион
рев-ция — революция
реж. — режиссёр
рентгенол. — рентгенология
респ-ка — республика
р-н — район
сан.-эпид. — санитария-эпидемиология
сент. — сентябрь
с.-д. — социал-демократлар
симф. — симфоник, симфония
скульп. — скульптор
сов. — совет(лар)
с-з — совхоз
соц. — социалистик
социол. — социология, социологик
ст. — станция
стат. — статистика, статистик
стомат. — стоматология
т. — том
темп-ра — температура
терр. — территориаль
терр-я — территория
технол. — технология, технологик
ун-т — университет
ур. — урам
уч-ще — училище
фарм. — фармацевтика, фармацевтик
фармакол. — фармакология
фарсы. — фарсыча (фарсы теленнән)
фән. — фәннәр
февр. — февраль
физиол. — физиология, физиологик
филол. — филология
филос. — философия
ф-ка — фабрика
ф-л — филиал
ф-ла — формула
ф-т — факультет
фр. — французча (француз теленнән)
һ.б. — һәм башкалар
һ.б.ш. — һәм башка шундый
ш. — шәһәр
штп — шәһәр тибындагы посёлок
ш.и. — шул исәптән
ш.у. — шулай ук
ш.у.к. — шулай ук кара
экз. — экземпляр

ШӘҺӘР ИСЕМНӘРЕНДӘГЕ КЫСКАРТУЛАР
(библиографиядә)

Татар/рус телләрендә

А.-А. — Алма-Ата
Аш. — Ашхабад
Г. — Горький
Дүш./Душ. — Дүшәнбе/Душанбе
Ер. — Ереван
К. — Казан/Казань
Киш. — Кишинёв
Л. — Ленинград
М. — Мәскәү/Москва
М.—Л. — Мәскәү—Ленинград/Москва—Ленинград
Н. Новгород — Нижний Новгород
Наб. Челны — Набережные Челны
Новосиб. — Новосибирск
Од. — Одесса
П. — Петроград (Петербург)
Ростов н/Д. — Ростов-на-Дону
СПб. — Санкт-Петербург
Тал. — Таллин
Таш. — Ташкент
Тб. — Тбилиси
Фр. — Фрунзе
Хар. — Харьков

Чит ил телләрендә

Amst. — Amsterdam
Antw. — Antwerpen
B. — Berlin
Balt. — Baltimore
Bdpst. — Budapest
Brat. — Bratislava
Brux. — Bruxelles
Buc. — Bucuresti
Camb. — Cambridge
Chi. — Chicago
Cph. — Copenhagen, Copenhague
Fr./M. — Frankfurt am Main
Gen. — Geneve
Hamb. — Hamburg
Hdlb. — Heidelberg
Hels. — Helsingfors, Helsinki
Ist. — Istanbul
L. — London
Los Ang. — Los Angeles
Lpz. — Leipzig
Mass. — Massachusetts
Melb. — Melbourne
Mex. — Mexico
Mil. — Milano
Münch. — München
N.Y. — New York
Oxf. — Oxford
P. — Paris
Phil. — Philadelphia
Rio de J. — Rio de Janeiro
S.F. — San Francisco
Stockh. — Stockholm
Stuttg. — Stuttgart
W. — Wien
Warsz. — Warszawa
Wash. — Washington
Z. — Zürich

Башка шәһәрләрнең исемнәре кыскартылмыйча бирелә.

БИБЛИОГРАФИЯДӘГЕ КЫСКАРТУЛАР

әд. — әдәбият
әсәр. — әсәрләр
библиогр. — библиография
бюл. — бюллетень
вестн. — вестник
дис. — диссертация
докл. — доклад(лар)
журн. — журнал (лар)
зап. — записки
кис. — кисәк
кит. — китап
конгр. — конгресс
конф. — конференция
реф. — реферат
рец. — рецензия
т. — том
тәрҗ. — тәрҗемәче
төз. — төзүче
у. һәм е.к. — урыны һәм елы күрсәтелмәгән
хезм. — хезмәт(ләр)
чыг. — чыганак
энцикл. — энциклопедия

АББРЕВИАТУРАЛАР

АААҖ — ачык акционерлык җәмгыяте
АҖ — акционерлык җәмгыяте
АКШ — Америка Кушма Штатлары
АТС — автоматлаштырылган телефон станциясе
БАССР — Башкортстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы
БДБ — Бәйсез Дәүләтләр Берлеге
БР — Башкортстан Республикасы
БҮБК — Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты
ВАСХНИЛ — Ленин исемендәге Бөтенсоюз авыл хуҗалыгы фәннәре академиясе (Всесоюзная академия сельскохозяйственных наук имени Ленина)
ВДНХ — Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсе (Выставка достижений народного хозяйства)
ВКП(б) — Бөтенсоюз коммунистлар (большевиклар) партиясе (Всесоюзная коммунистическая партия (большевиков))
ВЛКСМ — Бөтенсоюз ленинчыл коммунистик яшьләр союзы (Всесоюзный ленинский коммунистический союз молодёжи)
ВНИВИ — Бөтенсоюз ветеринария фәнни-тикшеренү институты (Всесоюзный научно-исследовательский ветеринарный институт)
ВНИИгеолнеруд — Бөтенсоюз руда булмаган файдалы казылмалар геологиясе фәнни-тикшеренү институты (Всесоюзный научно-исследовательский институт геологии полезных ископаемых)
ВРК — Вакытлы революцион комитет (Временный революционный комитет)
ВЧК — Бөтенроссия гадәттән тыш комиссиясе (Всероссийская чрезвычайная комиссия)
ВЦСПС — Профсоюзларның бөтенсоюз үзәк советы (Всесоюзный центральный совет профессиональных союзов)
ГИДУВ — Табибларнең белемен күтәрү дәүләт институты (Государственный институт для усовершенствования врачей)
ГЭС — гидроэлектростанция
ДОСААФ — Армия, авиация һәм флотка булышлык итү ирекле җәмгыяте (Добровольное общество содействия армии, авиации и флоту)
ДУП — дәүләт унитар предприятиесе
ҖБ — җитештерү берләшмәсе
ҖЧҖ — җаваплылыгы чикләнгән җәмгыять
КамАЗ (КАМАЗ) — Кама автомобиль заводы
КБ — конструкторлык бюросы
КГБ — Дәүләт иминлеге комитеты (Комитет государственной безопасности)
КГҮ — Казан гыйльми үзәге
КОМУЧ — Учредительләр җыены әгъзалары комитеты (Комитет членов учредительного собрания)
КОМЗ — Казан оптик механика заводы
КП — Коммунистлар партиясе
КПО ВС — Казан хисаплау системалары җитештерү берләшмәсе (Казанское производственное объединение вычислительных систем)
КПСС — Советлар Союзы коммунистлар партиясе (Коммунистическая партия Советского Союза)
КЭМСТ — Хәзерге заман театрының конструктив тәҗрибә остаханәсе (Конструктивно-экспериментальная мастерская современного театра)
МК — Министрлар Кабинеты
МС — Министрлар Советы
МТС — машина-трактор станциясе
НГДУ — нефть һәм газ чыгару идарәсе (нефтегазодобывающее управление)
НКВД — Эчке эшләр халык комиссариаты (Народный комиссариат внутренних дел)
нэп — яңа икътисади сәясәт (новая экономическая политика)
ОГПУ — Дәүләтнең берләштерелгән сәяси идарәсе (Объединенное государственное политическое управление)
ОСОАВИАХИМ — Авиация һәм химия төзелешенә булышлык итү җәмгыяте (Общество содействия авиационному и химическому строительству)
ПТУ — профессиональ-техник училище
ПФА — Педагогия фәннәре академиясе
РАХФА — Россия авыл хуҗалыгы фәннәре академиясе
РВС — Революцион хәрби совет (Революционный военный совет)
РМА — Россия Мәгариф академиясе
РМФА — Россия Медицина фәннәре академиясе
РОСТО — Россия оборона-спорт техник оешмасы (Российская оборонно-спортивная техническая организация)
РСДРП — Россия социал-демократик эшчеләр партиясе (Российская социал-демократическая рабочая партия)
РСФСР — Россия Совет Федератив Социалистик Республикасы
РФ — Россия Федерациясе
РФА — Россия Фәннәр академиясе
СА — Сәнгать академиясе
СК — спорт клубы
СССР — Совет Социалистик Республикалар Союзы
ТАССР — Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы
ТМР — төш магнит резонансы
ТР — Татарстан Республикасы
ТССР — Татарстан Совет Социалистик Республикасы
ТЭЦ — җылылык-электр үзәге (теплоэлектроцентраль)
ФА — Фәннәр академиясе
ФҖБ — фәнни-җитештерү берләшмәсе
ХКС — Халык комиссарлары советы
ХХС — Халык хуҗалыгы советы
ЦНИИгеолнеруд — Руда булмаган файдалы казылмалар геологиясе үзәк фәнни-тикшеренү институты (Центральный научно-исследовательский институт геологии нерудных полезных ископаемых)
ЧК — Гадәттән тыш комиссия (Чрезвычайная комиссия)
ҮК — Үзәк Комитет
ҮБК — Үзәк Башкарма Комитеты
ЭПР — электрон парамагнит резонансы
ЮС — Югары Совет
ЯАҖ — ябык акционерлык җәмгыяте

ЗУРЛЫК БЕРӘМЛЕКЛӘРЕ КЫСКАРТУЛАРЫ

А — ампер
а.б. — астрономик берәмлек
а.к. — ат көче
В — вольт
Вб — вебер
В·А — вольт-ампер
Вт — ватт
Гн — генри
Гц — герц
Гпа — гектопаскаль
Гс — гаусс
г — грамм
га — гектар
град — почмакча градус
Дж — джоуль
дБ — децибел
дал — декалитр
дптр — диоптрия
К — кельвин
кВт·сәг. — киловатт-сәгать
кал — калория
кар — карат
кг — килограмм
Кл — кулон
км — километр
л — литр
лк — люкс
лм — люмен
м.а.б. — массаның атом берәмлеге
м — метр
мг — миллиграмм
мин. — минут
мкм — миктрометр
мм — миллиметр
Н — ньютон
окт — октава
Па — паскаль
рад — радиан
с — секунд
°*С* — градус (Цельсий шкаласы буенча)
сәг. — сәгать
см — сантиметр
т — тонна
Ф — фарад
ц — центнер
Э — эрстед
эВ — электронвольт
‰ — промилле

КАРТАЛАР ИСЕМЛЕГЕ
(җәя эчендә бит саны күрсәтелә)

Тарихи карталар.
Тәтеш кантоны (11), Тәтеш өязе (12), Төрки каганлык (701), Фра-Мауро картасы фрагменты (353), Хәзәр каганлыгы (419), Царёвококшайск өязе (509), Цивильск өязе (512), Чабаксар өязе (517), Чаллы кантоны (523), Чистай кантоны (566), Чистай өязе (568).

Географик карталар.
Татарстан Республикасының туфрак картасы (162–163).

Административ карталар.
Тәтеш районы (12), Теләче районы (30), Тукай районы (143), Түбән Кама районы (175), Чирмешән районы (563), Чистай районы (568), Чүпрәле районы (595).

КАРТАЛАРДА КАБУЛ ИТЕЛГӘН КЫСКАРТУЛАР

а. — авыл
исем. — исемендәге
пос. — посёлок
р-н — район
с-з — совхоз
ш. — шәһәр
штп — шәһәр тибындагы посёлок

ШАРТЛЫ БИЛГЕЛӘР

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РАЙОННАРЫНЫҢ АДМИНИСТРАТИВ КАРТАЛАРЫНДА

Торак пунктлар

Татарстан Республикасы башкаласы - Казан шәһәре
Район үзәкләре

Төре буенча

ЛЕНИНОГОРСК — Шәһәрләр
УРЫССУ — Шәһәр тибындагы посёлоклар
Тимәш — Авыл тибындагы торак пунктлар

Яшәүчеләр саны буенча

10 000 һәм аннан артыграк
1000 нән 10 000 гә кадәр
500 дән 1000 гә кадәр
500 дән кимрәк

Чик билгеләре

Республика һәм өлкәләр арасында
Районнар арасында

Юл билгеләре

Тимер юллар
Төп автомобиль юллары һәм аларның номерлары
Башка төр автомобиль юллары:
а) түшәүле юллар
б) түшәүсез юллар

Елгалар
Сусаклагычлар

ТАССР КАНТОННАРЫ КАРТАЛАРЫНДА

Чик билгеләре

Татарстан АССР 1921 елда
Татарстан Республикасы 2011 елда
Татарстан АССР кантоннары 1921 елда

Юл билгеләре

Тимер юллар
Төп юллар (трактлар)
Башка юллар

ӨЯЗЛӘР КАРТАЛАРЫНДА

Чик билгеләре

Россия империясенең 1890 нчы еллардагы губерналары
Өязләр

Юл билгеләре

Тимер юллар
Төп юллар (трактлар)
Башка юллар

Татар энциклопедиясенең фәнни мөхәрририяте

Археология. Ф.Ш.Хуҗин (рәис), А.Ә.Бор һанов, Рафаэль М.Вәлиев, Е.П.Казаков, А.Г.Ситдыйков.

Архитектура. Х.Г.Надыйрова (рәис), Г.Н.Айдарова, С.П.Саначин, Н.Х.Халитов.

Астрономия. Н.А.Сәхибуллин (рәис), Е.Е.Беляева, И.Ф.Бикмаев, Р.В.Заһретдинов, Н.Г.Ризванов.

Биология. А.А.Җәләлов (рәис), В.А.Бойко, В.И.Гаранин, Р.Я.Гыйльметдинов, Р.Х.Фәйзрахманова.

География. Ю.П.Переведенцев (рәис), А.Х.Газизуллин, Ю.А.Горшков, Э.П.Наумов, В.А.Рубцов.

Геология. Д.К.Нургалиев (рәис), У.Г.Дистанов, Р.Х.Мөслимов, В.М.Смелков, Р.Р.Хәсәнов.

Дәүләт һәм хокук. В.П.Малков (рәис), Н.В.Бахарев, Е.Б.Долгов, Б.Л.Железнов, Г.И.Курдюков, И.Г.Тарханов, Р.Ш.Хафизов.

20 йөзгә кадәрге Татарстан һәм татар халкы тарихы. И.Л.Измайлов (рәис), И.К.Заһидуллин, Ф.Г.Ислаев, А.Х.Мәхмүтова, Д.Г.Мостафина.

20—21 йөз башы Татарстан һәм татар халкы тарихы. И.Р.Таһиров (рәис), Р.К.Вәлиев, Ә.Г.Галләмова, Я.Я.Гришин, И.А.Гыйләҗев, Р.Р.Салихов, Р.В.Шәйдуллин.

20 йөзгә кадәрге татар әдәбияты. Х.Й.Миңнегулов (рәис), М.И.Әхмәт җанов, Р.К.Ганиева, Н.Ш.Хисамов.

20—21 йөзләр татар әдәбияты. Д.Ф.Заһидуллина (рәис), А.Г.Әхмәдуллин, Ф.Г.Галимуллин, Т.Н.Галиуллин, Р.М.Харисов.

Икътисад. Ф.Г.Газизуллин (рәис), В.П.Захаров, В.А.Мальгин, Ф.Н.Мөхәммәтгалиев.

Массакүләм мәгълүмат чаралары. В.З.Гарифуллин (рәис), Е.С.Дорощук, Р.А.Ратникова.

Математика. М.М.Арсланов (рәис), А.М.Елизаров, Э.В.Скворцов.

Медицина. Сәламәтлек саклау. М.К.Михайлов (рәис), Н.Х.Әмиров, А.С.Созинов, В.Х.Фазылов.

Музейлар. Г.Р.Нәҗипова (рәис), С.Ю.Измайлова, Е.И.Карташова, Р.М.Нургалиева, О.Е.Щелковская.

Музыка. Р.К.Абдуллин (рәис), В.Р.Дулат-Алиев, Р.Ф.Кәлимуллин, А.Л.Маклыгин, Ш.Х.Монасыйпов, З.Н.Сәйдәшева, В.М.Спиридонова.

Педагогика, халык мәгарифе. Җ.Г.Нигъмәтов (рәис), Ә.Н.Хуҗи әхмәтов, Ф.Г.Ялалов, И.Э.Ярмәкиев.

Сәнәгать, төзелеш, транспорт, элемтә. Ш.М.Вәлитов (рәис), С.А.Нәҗипова, Р.З.Рәхимов, К.Ф.Фәсхетдинов.

Сынлы сәнгать. Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова (рәис), Е.П.Ключевская, Д.Д.Хисамова.

Театр сәнгате. А.Г.Әхмәдуллин (рәис), М.Г.Арсланов, И.И.Илялова, Д.Ә.Гыймранова.

Терлекчелек. Ветеринария. Р.Г.Госманов (рәис), А.М.Алимов, Р.Ә.Әсретдинова, А.В.Иванов, К.Х.Папуниди, Ә.Х.Фазылҗанов, М.Ш.Шәкүров.

Техника һәм технология. Ш.М.Чабдаров (рәис), Р.И.Әдһәмов, О.Ш.Даутов, И.М.Закиров, С.О.Мирумянц.

Торак пунктлар тарихы. М.И.Әхмәт җанов (рәис), Д.Г.Мостафина, А.И.Ногманов, Р.Р.Салихов, Р.Р.Хәйретдинов.

Үсемлекчелек. Ф.З.Кадыйрова (рәис), Е.И.Захарова, М.Л.Пономарёва, И.П.Таланов.

Фәлсәфә һәм дин. Р.М.Мөхәммәтшин (рәис), В.П.Козлов, Н.М.Мөхәррәмов, Р.Ә.Нәбиев, Р.М.Нугаев, Ф.М.Солтанов.

Физик культура һәм спорт. Х.Х.Шәйхетдинов (рәис), А.Ш.Баһаветдинов, Н.Д.Бобырев, И.Г.Илдарханов, З.Н.Пантелеева.

Физика. К.М.Салихов (рәис), В.А.Голенищев-Кутузов, Ә.В.Ильясов, И.В.Овчинников, В.В.Самарцев.

Фольклор. Ф.И.Урманчеев (рәис), Л.Ш.Җамалетдинов, Х.Ш.Мәхмүтов.

Хәрби эшлеклеләр, Советлар Союзы Геройлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, Россия Геройлары, Дан орденының тулы кавалерлары. И.Ш.Мостюков (рәис), Н.Х.Булатов, А.Ш.Кәбирова, С.Н.Погодин, В.Ф.Телишев, М.В.Черепанов.

Химия һәм химия технологиясе. В.П.Барабанов (рәис), Г.К.Будников, А.О.Визель, В.И.Галкин.

Этнография. Д.М.Исхаков (рәис), Р.Н.Мусина, Г.Р.Столярова, С.В.Суслова, Р.К.Уразманова.

Энциклопедия басмаларын татар телендә әзерләү буенча фәнни мөхәрририят. М.З.Зәкиев (рәис), М.И.Әхмәтҗанов, Р.М.Мөхәммәтшин, Д.Б.Рамазанова, Р.Ф.Рахмани, Р.Ә.Шакирҗанов, А.Г.Яруллина.

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты

Директор — тарих фән. д-ры, ТР ФАнең мөхбир әгъзасы, профессор И.А.ГЫЙЛӘҖЕВ
Директор урынбасары — пед. фән. д-ры, профессор Ф.Г.ЯЛАЛОВ
Гыйльми секретарь — тарих фән. канд., доцент М.З.ХӘБИБУЛЛИН

Үзәкләр

ЭНЦИКЛОПЕДИСТИКА ҮЗӘГЕ. Мөдире — тарих фән. д-ры, профессор Р.В.Шәйдуллин.

Татарстан һәм татар энциклопедистикасы бүлеге. Җитәкчесе — өлкән фәнни хезмәткәр, тарих фән. канд. И.Р.Вәлиуллин; әйдәп баручы фәнни хезмәткәрләр: тарих фән. канд. Ф.Г.Кәлимуллина, тарих фән. канд., доцент Г.С.Сабирҗанов; өлкән фәнни хезмәткәрләр: тарих фән. канд-тлары Р.Р.Батыршин, Ф.Г.Миңнеханов, Б.И.Сибгатов.

Энциклопедия басмаларын татар телендә әзерләү бүлеге. Җитәкчесе — әйдәп баручы фәнни хезмәткәр, филол. фән. канд. А.Г.Яруллина; баш фәнни хезмәткәр, филол. фән. д-ры Р.Ф.Исламов; өлкән фәнни хезмәткәрләр: филол. фән. канд. Г.И.Каюмова, Ф.Р.Бәдретдинова, В.А.Габдрахманова, И.Х.Хәлиуллин; фәнни хезмәткәрләр: тарих фән. канд. Р.М.Кадыйров, Л.К.Галиева, Ф.С.Гыйниятуллина, Р.Г.Зәкиева, Ф.Г.Камалетдинова, И.Г.Нигъмәтҗанов, Г.Х.Нургалиева.

Фәнни мәгълүмат хезмәте бүлеге. Әйдәп баручы фәнни хезмәткәрләр: техник фән. канд. Р.Р.Сәләхиев, Г.Р.Дәүләтьянова; өлкән фәнни хезмәткәрләр: Г.Х.Галимуллина, Ф.Э.Ибраһимова, Л.Т.Мөхәммәтшина, Л.Т.Нигъмәтҗанова, Р.Н.Нурмөхәммәтов; фәнни хезмәткәрләр: А.Б.Насыйбуллина, Л.М.Сәхапова, Л.Р.Хисамиева, Р.Ф.Шәрәпова; рәссам-конструктор Р.Н.Шакиров.

ТӨБӘКНЕ ӨЙРӘНҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ-МӘДӘНИ ТИКШЕРЕНҮЛӘР ҮЗӘГЕ. Мөдире — тарих фән. канд., доцент Л.М.Айнетдинова; әйдәп баручы фәнни хезмәткәрләр: а.х. фән. канд. Р.Ә.Әсретдинова, тарих фән. канд-тлары: Р.А.Айнетдинов, Е.Б.Долгов, Г.Э.Рафикова; өлкән фәнни хезмәткәрләр: а.х. фән. канд. Ф.Г.Борһанов, тарих фән. канд-тлары: Ч.Х.Саматова, А.Б.Солтанбәков, С.А.Фәйзуллин, филол. фән. канд. Р.Р.Мусабәкова, С.Г.Белов, А.Н.Хәсәнова; фәнни хезмәткәрләр: тарих фән. канд. Н.А.Кореева, Л.Р.Әскәрова, Ф.Ә.Әхмәтшина, Г.М.Габделхакова, О.В.Ерёгин, Р.Э.Рәхмәтуллин.

ТАТАР ДИАСПОРАСЫН ӨЙРӘНҮ ҮЗӘГЕ. Мөдире — тарих фән. канд. Б.Л.Хәмидуллин; әйдәп баручы фәнни хезмәткәр, тарих фән. канд. Р.Р.Ибраһимов; өлкән фәнни хезмәткәр, филол. фән. канд. З.З.Гыйләҗев; фәнни хезмәткәр Л.Р.Хәлилова.

* * *

Хуҗалык эшләре хезмәте. Е.С.Чиляков, Р.В.Эминов, О.А.Бастраков, Г.Р.Вәлиуллина, Р.Ә.Хөснетдинов, Р.Н.Хөснетдинова.

ТЭ 6 нчы томының авторлар исемлеге

В.Г.Абзалова, Г.Д.Аверьянов, А.А.Агафонов, К.И.Азизов, Р.К.Аймәтов, Р.А.Айнетдинов, Л.М.Айнетдинова, И.Е.Алексеев, Е.П.Алексеева, Т.А.Алмазова, И.И.Андреева, Р.Н.Апкин, В.П.Архиреев, М.М.Арсланов, И.Н.Афанасьев, Н.И.Афанасьева, А.М.Ахунов, Р.И.Әдһәмов, Э.Г.Әлмәнова, Л.К.Әминов, Н.Х.Әмиров, Р.Г.Әмирханов, Р.К.Әмиров, Л.Р.Әскәрова, Резилә Ә.Әсретдинова, Руфинә Ә.Әсретдинова, К.А.Әхәтов, М.Ш.Әхәтов, А.Г.Әхмәдуллин, И.М.Әхмәт, М.И.Әхмәтҗанов, Ф.Ә.Әхмәтшина, А.И.Бадюгина, М.Х.Бакиров, В.Г.Бакирова, Г.А.Балакин, Р.Р.Батыршин, Н.М.Баянова, М.Ш.Бәдретдинова, Ф.Р.Бәдретдинова, Л.К.Бәйрәмова, С.Г.Белов, Р.В.Билалов, Г.Н.Бирюлёв, Ю.А.Благов, Н.Д.Бобырев, О.В.Богоявленская, В.Ф.Богоявленский, В.А.Бойко, Ф.Г.Борһанов, Г.К.Будников, Ю.Г.Будникова, Г.Н.Булатова, А.А.Бус, Л.Е.Бушканец, Р.С.Вафина, Г.Б.Вәлиев, Е.К.Вәлиев, Л.С.Вәлиев, Рамил М.Вәлиев, Рафаэль М.Вәлиев, Р.Ш.Вәлиев, Ф.В.Вәлиева, Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова, И.Р.Вәлиуллин, Э.С.Вәлишин, Р.Г.Вениаминов, М.А.Верещагин, Я.А.Верещагина, Р.Г.Власова, Р.С.Габәшев, А.Габәши, Г.Г.Габделганиева, Х.Ә.Габделкаюмов, Б.Г.Габделхәев, Г.М.Габделхакова, В.А.Габдрахманова, Э.В.Габдрәхимова, Ә.Һ.Газизуллин, Р.Г.Газизуллина, М.В.Гайнетдинов, Л.М.Гайнетдинова, М.Ж.Гаитов, Р.Р.Гайнов, К.С.Гайфуллин, И.Ф.Галанин, Б.М.Галиев, Р.Х.Галиев, Л.К.Галиева, Р.М.Галиева, Э.М.Галимҗанова, М.Ш.Галимова, Ф.Г.Галимуллин, Г.Х.Галимуллина, А.К.Галиуллин, К.Р.Галиуллин, Т.Н.Галиуллин, Г.Р.Галиуллина, Ф.Ә.Ганиев, В.И.Гаранин, А.В.Гарзавина, Ф.Г.Гарипова, Р.С.Гәрәев, Н.Г.Гәрәева, А.Л.Гиммельфарб, Н.В.Гобәев, А.М.Гобәйдуллин, Э.В.Гоголь, Т.В.Голубцова, С.Г.Гордиенко, О.Л.Горшевникова, В.Н.Горшков, М.Г.Госманов, Р.Г.Госманов, Д.М.Госманова, Я.Я.Гришин, Ф.Ф.Гулова, И.Г.Гыйззәтуллин, Н.Г.Гыйззәтуллин, Р.Н.Гыйззәтуллин, Т.Ш.Гыйлаҗев, З.З.Гыйләҗев, И.А.Гыйләҗев, Д.Ә.Гыймранова, Ф.С.Гыйниятуллина, Р.Н.Даутов, Р.В.Даутова, Ә.Х.Дәүләтшин, Г.Р.Дәүләтьянова, А.П.Дедков, Р.К.Джорджикия, Г.С.Дмитриев, С.В.Доброквашин, Е.Б.Долгов, А.Г.Дубровский, А.В.Дуглав, А.В.Егоров, Н.Б.Егорова, А.М.Елизаров, О.В.Ерёгин, Л.М.Жаржевский, А.К.Жеребцов, Ф.Ф.Җамалиева, А.А.Җәләлов, А.А.Җиһаншин, Р.Ә.Закиров, И.Н.Зарипов, И.К.Заһидуллин, Д.Ф.Заһидуллина, Г.Г.Зәйнуллин, М.З.Зәкиев, Р.Г.Зәкиева, Н.В.Звёздочкина, Р.М.Зелеев, А.Л.Зефиров, К.З.Зиннәтуллина, Ф.С.Зыятдинов, М.Х.Ибраһимов, Р.Р.Ибраһимов, А.И.Ибраһимова, Ф.Ә.Ибраһимова, Ф.И.Ибраһимова, Г.Ж.Идрисов, Г.А.Измайлов, И.Л.Измайлов, С.Г.Измайлов, И.И.Илялова, Р.Ф.Исламов, Ә.В.Ильясов, Г.Г.Исмәгыйлев, Р.Г.Исхакова, С.М.Исхакова, Р.Х.Йосыпов, А.Ф.Йосыпова, Н.М.Йосыпова, Р.Т.Йөзмөхәммәтов, С.И.Кадошников, И.Г.Кадошникова, О.Х.Кадыйров, Р.М.Кадыйров, Е.П.Казаков, Ф.Г.Камалетдинова, Л.Р.Камалиева, И.М.Камалов, Б.А.Канеев, Н.П.Капитонова, И.О.Кармазина, Д.Г.Касыймова, Р.Ә.Кашапов, Г.И.Каюмова, Ф.Г.Кәлимуллина, А.В.Климин, Е.Н.Климовицкий, Е.П.Ключевская, Р.Ә.Колшәрипова, А.Е.Кондаков, Т.А.Кондратьева, Н.Ф.Краева, В.Н.Крылов, А.М.Кузнецов, А.Н.Кузнецов, С.В.Кузьминых, А.Л.Ларионов, Ю.А.Лексина, Е.В.Липаков, И.Ф.Лобашёва, Е.И.Ломако, Л.В.Луконина, Ю.А.Лукьянова, О.Д.Любарская, Е.Л.Любарский, В.Ф.Макарова, А.Л.Маклыгин, М.М.Маликов, Б.З.Малкин, Э.Х.Мамкеев, Р.С.Мансуров, Н.В.Марянин, Г.Б.Матвеев, Р.К.Мәҗитова, Г.Я.Мәүлетова, Э.Ф.Мельничнова, Б.Р.Милицын, Н.М.Минһаҗева, Г.Г.Миңнекәев, Ф.Г.Миңнеханов, Җ.С.Миңнуллин, О.В.Михайлов, Р.И.Михайлова, С.М.Михайлова, В.П.Модестов, В.И.Мозжерин, Л.М.Мортазина, Р.Ә.Мостафин, Ш.С.Мостафин, Д.Г.Мостафина, Л.В.Мошкова, Җ.Г.Мөхәммәтшин, Л.Т.Мөхәммәтшина, Р.Х.Мөхиярова, Л.В.Муравьёва, Р.Р.Мусабәкова, Х.Г.Мусин, И.Н.Надыйров, Х.Г.Надыйрова, А.Б.Насыйбуллина, Т.М.Насыйров, В.А.Наумов, Э.П.Наумов, Р.Г.Нашарова, Ә.Н.Нәҗипова-Зиннәтуллина, Л.Ф.Недашковский, М.В.Недорезов, Л.Т.Нигъмәтҗанова, И.А.Новицкая, А.И.Ногманов, Г.Г.Ногманова, Д.Р.Нуретдинова, Ф.Ш.Нуриева, Р.Н.Нурмөхәммәтов, Н.С.Нуруллова, Л.С.Панягина, К.Х.Папуниди, Ю.П.Переведенцев, С.Г.Персова, В.И.Полякова, С.Н.Пономарёв, Л.В.Просвиркина, М.А.Пудовик, А.П.Пухачёв, О.В.Пьянова, Д.Б.Рамазанова, Р.Ф.Рахмани, З.З.Рәмиев, Г.Э.Рәфыйкова, Р.Э.Рәхмәтуллин, Э.Х.Рәхмәтуллин, Г.С.Сабиржанов, Р.М.Сабиров, Н.Г.Савельева, Ф.Ш.Салитова, К.М.Салихов, Р.Р.Салихов, Ф.Д.Самуилов, Е.А.Сапаев, М.Г.Сафин, Р.Сафин, М.Ә.Сәгыйтов, З.Н.Сәйдәшева, М.А.Сәйдәшева, Р.Р.Сәләхиев, М.В.Сәлимгәрәев, Х.Х.Сәлимов, Л.М.Сәхапова, Л.М.Свердлова, Р.Х.Сверигин, Л.А.Севастьянова, Т.В.Селезнёва, Г.И.Середа, Б.И.Сибгатов, Н.И.Силкин, Р.И.Ситдыйков, М.Э.Ситдыйкова, В.М.Смирнов, А.П.Соколов, Н.К.Соловаров, В.Я.Соловьёв, А.Б.Солтанбәков, Б.Ф.Солтанбәков, Р.Р.Солтанова, Л.Р.Сөрмәтова, В.М.Спиридонова, П.Н.Старостин, Е.А.Стахов, Р.И.Такташ, И.Р.Таһиров, М.С.Таһиров, В.Ф.Телишев, Д.М.Туган-Барановский, Г.П.Тулузакова, А.А.Турцева, А.М.Туфитуллов, В.С.Угрюмова, О.Л.Улемнова, О.Н.Урбанова, Ф.И.Урманчеев, Р.Г.Усманов, О.Л.Усманова, Б.В.Успенский, Ә.Х.Фазылҗанов, В.Х.Фазылов, Г.Р.Фәйзрахманова, С.А.Фәйзуллин, К.Ф.Фәсхетдинов, Г.М.Фәттахов, Я.В.Фәттахов, Д.С.Фәхретдинов, Р.Г.Фәхретдинов, Л.И.Федотова, Н.А.Фёдорова, С.А.Фролов, В.Х.Хаков, Н.А.Халиков, И.И.Халитов, Р.Ф.Халитов, М.М.Хәбетдинова, М.З.Хәбибуллин, Р.Г.Хәйретдинов, Р.Р.Хәйретдинов, Р.Н.Хәйруллин, С.Г.Хәкимова, Л.Р.Хәлилова, И.Х.Хәлиуллин, Р.И.Хәлиуллина, Р.Х.Хәмәдиев, Б.Л.Хәмидуллин, Л.Х.Хәмидуллин, Р.Я.Хәмитова, А.Н.Хәсәнова, А.Ш.Хәсәнова, Ф.Ф.Хәсәнова, Л.Р.Хисамиева, Э.М.Хисамова, Ф.М.Хисамова, Р.И.Хөсәенов, К.М.Хөснетдинов, Р.А.Худякова, Ф.Ш.Хуҗин, Ф.Ф.Һадиуллина, И.Н.Цигвинцева, Р.А.Циунчук, Е.В.Цыганова, Р.А.Черкасов, В.И.Чиков, Р.Э.Чиспияков, Т.С.Чудинова, В.А.Шагалов, О.Л.Шайтанов, В.З.Шакиров, Р.Н.Шакиров, Ә.А.Шамова, Р.Г.Шаһиева, Р.В.Шәйдуллин, Р.Р.Шәйдуллина, Б.Ф.Шәкүров, Р.М.Шәмсутов, А.А.Шәмсутова, Р.Ф.Шәрәпова, Г.С.Шәрәфетдинов, Д.Р.Шәрәфетдинов, Ә.М.Шәрипов, Р.Ф.Шәфигуллина, С.М.Шәфигуллина, А.А.Шинкарёв, Р.Р.Шиһабетдинов, В.И.Шишкин, М.И.Шпекин, Н.В.Шулаев, В.В.Шурыгин, В.А.Яковлев, Н.М.Якупова, Ф.Г.Ялалов, А.Г.Яруллина.

Тышлыкның макеты, «Биология», «Үсемлекчелек», «Ветеринария» бүлекләрендәге төсле иллюстрацияләр һәм таблицалар рәссам В.Е.Булатов тарафыннан эшләнде.
Махсус фотолар З.Г.Бәширов, Е.Г.Бычков, О.В.Ерёгин, И.М.Йосыпов, Р.Н.Шакиров тарафыннан әзерләнде.
Томда шулай ук Г.П.Бутаков, А.И.Галиев, М.Г.Гафуров, Ә.Г.Гаянов, Ф.С.Гобәев, В.А.Голенищев-Кутузов, Ш.Ф.Дәүләтшин, Д.Р.Йосыпов, В.Г.Марфин, М.М.Медведев, В.Ю.Соломахин, О.Г.Столова, А.Л.Яскович, И.В.Яценко архивларыннан һәм М.Җәлил исем. Татар опера һәм балет театры (Р.Һ.Такташ), Г.Камал исем. Татар академия театры (Л.Г.Шакирҗанова), В.И.Качалов исем. Казан Зур драма театры (Ю.С.Копылов) музейлары, Казан (Идел буе) федераль университеты Геология музее (В.В.Силантьев), В.П.Энгельгардт исем. Астрономия обсерваториясе фотоархивы (Н.Г.Ризванов) фондларыннан алынган фоторәсемнәр һәм слайдлар файдаланылды.
Иске Казан фотографияләре А.И.Дубин, Г.В.Фролов коллекцияләреннән алынды.

Томның материалларын туплауда ТР Дәүләт архивы (директоры А.Р.Ибрагимов), Казан (Идел буе) федераль университетының Н.И.Лобачевский исем. фәнни китапханәсе (директоры Е.Н.Струков), ТР Милли китапханәсе (директоры С.Р.Җиһаншина), ТР Милли музее (директоры Г.Р.Нәҗипова), ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее (директоры Р.М.Нургалиева) хезмәткәрләре катнашты.

ТР ФАнең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты бу томны әзерләүдә зур ярдәм күрсәткәннәре өчен ТР ФА аппаратына, ТР буенча Дәүләт статистикасы федераль хезмәт территориаль оешмасына (җитәкчесе Н.В.Гатауллина), ТРның Архив эшләре буенча дәүләт комитетына (Г.З.Габдрахманова), ТРның Мәгълүматлаштыру һәм элемтә (Р.А.Шәйхетдинов), Икътисад (Ф.С.Габделганиев), Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек (М.Г.Әхмәтов), Мәгариф һәм фән (Р.Т.Борһанов), Мәдәният (И.Х.Әюпова), Сәламәтлек саклау (М.Н.Садыйков) министрлыкларына, Казан (Идел буе) федераль университеты (ректоры И.Р.Гафуров), Казан дәүләт консерваториясе (ректоры Р.К.Абдуллин), Казан дәүләт медицина академиясе (ректоры Р.Ш.Хәсәнов), Казан дәүләт медицина университеты (ректоры А.С.Созинов), Казан дәүләт техник университеты (ректоры А.Х.Гыйльметдинов), Казан дәүләт технология университеты (ректоры С.В.Юшко), Казан дәүләт аграр университеты (ректоры А.Р.Вәлиев); ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать институты (директоры К.М.Миңнуллин), Тарих институты (директоры Р.С.Хәкимов), ТР ФАнең Археология институты (директоры А.Г.Ситдыйков), Руда булмаган файдалы казылмалар геологиясе үзәк фәнни-тикшеренү институты (директоры Е.М.Аксёнов), Татарстан авыл хуҗалыгы фәнни-тикшеренү институты (директоры М.Ш.Таһиров) галимнәренә һәм белгечләренә зур рәхмәтен белдерә.

Татар энциклопедиясенең 6 нчы томын әзерләүдә төрле вакытта катнашучылар: фәннәр докторлары: Р.М.Вәлиев, Г.Ф.Вәлиева-Сөләйманова, Ф.Г.Гарипова, Ф.С.Зыятдинов, Н.Н.Максютова, Х.Г.Надыйрова, Ф.Ш.Салитова, Ф.И.Урманчеев, Р.Г.Усманов, Ә.Х.Фазылҗанов; фәннәр кандидатлары: В.Г.Бакирова, Ю.А.Благов, Н.Д.Бобырев, Г.Н.Булатова, М.Я.Гаитов, Р.Г.Исхакова, И.Г.Кадошникова, Э.Х.Рәхмәтуллин, Э.Г.Сәйфетдинова; фәнни хезмәткәрләр: В.Г.Абзалова, И.Н.Афанасьев, Р.С.Вафина, Х.Ә.Габделкаюмов, Р.И.Гурьянова, Д.Ә.Гыймранова, Т.П.Жучкова, Л.Р.Камалиева, Ф.Г.Макарова, Г.Я.Мәүлетова, А.Х.Мәхмүтова, Н.Ф.Мироновская, Р.И.Раскулова.

Текстларны компьютерда җыю һәм макетка салуда «Jahat Lab., KAI» лабораториясенең (җитәкчесе Р.Р.Имамов) Jahat™ программалар пакеты кулланылды.

Татар энциклопедиясе: 6 томда / Баш мөхәррир М.Х.Сәлахов, җаваплы мөхәррир Г.С.Сабиржанов. — Казан: ТР ФАнең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты, 2019. — **6 т. 1 кис.**: Тә–Ч. — 612 бит, ил., карталар.

ISBN 978-5-902375-31-9

Татар энциклопедиясе — татар халкы һәм Татарстанның борынгы чордан алып безнең көннәргә кадәрге тарихын һәм яшәешен яктырткан беренче фәнни универсаль басма. Китапта 2820 мәкалә (1225 биографик), 990 иллюстрация (600 төсле) урын алды.

Tatar ensiklopediəse: 6 tomda / Baş məxərrir M.X.Səlaxov, cavaplı məxərrir Ğ.S.Sabircanov. — Qazan: TR FAneŋ Tatar ensiklopediəse həm təbəkne öyrənü institutı, 2019. — **6 t. 1 kis.**: Tə–Ç. — 612 b., il., kartalar.

Tatar ensiklopediəse — tatar xalqı həm Tatarstannıŋ borıngı zamannardan alıp bezneŋ könnərgə qadərge tarixın həm yəşəyeşen yaqtırtqan tatar telendəge berençe universal' basma. Tomda 2820 məqalə (1225 şəxeslərgə qarıy), 990 illustratsiə 600 təsle).

Татар энциклопедиясе

6 нчы том
1 нче кисәк

Басарга кул куелды 29.12.2018. Махсус кәгазьдә. Форматы 84×108/16.
«Петербург» гарнитурасы. Офсет ысулы белән басылды.
Шартлы басма табагы 64,26. Нәшер-хисап табагы 113.75.
Заказ № ___.

ТР ФАнең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты.
420015, Казан шәһәре, Пушкин урамы, 56.
e-mail: info-ite@mail.ru

Әзер оригинал-макеттан «Фолиант» ҖЧҖ басмаханәсендә бастырылды.
420111, Казан шәһәре, Профсоюз урамы, 17 В.
Тел. (843) 292-27-25
Web: print-kzn.ru